авари́йн||ый, -ая, -ое авария[ләр] ...ы; **~ая маши́на** авария машинасы; **~ый сигна́л** авария сигналы

ава́рия *м* авария, каза, һәлакәт; бәрелешү (*транспорт турында*)

ава́рка *ж* авар хатыны (кызы)

ава́рский, -ая, -ое авар[лар] ...ы; **~ язы́к** авар теле

ава́рцы *мн.* аварлар, авар халкы

а́вгиев: ~ы коню́шни Авгий конюшнясе (*утә пычрак бина турында*)

а́вгуст *м* август, август ае

а́вгустовск||ий, -ая, -ое август ...ы; **~ие дни** август көннәре

а́виа- *кушма сүзләрнең «авиация», «авиацион» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **авиаба́за** авиабаза, **авиашко́ла** авиамәктәп

авиабиле́т *м* авиабилет

авиаконстру́ктор *м* авиаконструктор

авиали́ния *ж* авиалиния

авиамодели́зм *м* авиамодельчелек, авиамодельчелек, авиамодельчелек

авиамодели́ст *м* авиамодельче, авиамоделизм белән шөгыльләнүче

авиамоде́ль *ж* авиамодель

авиамоде́льный, -ая, -ое авиамодель ...ы, авиамодельчелек ...ы; **~ кружо́к** авиамодельчелек түгәрәге

авиано́сец *м* авианосец

авиаперево́зки *мн.* авиайөкташу

авиапо́чта *ж* авиапочта

ави́атор *м* очучы, авиатор

авиацио́нный, -ая, -ое авиация ...ы, авиацион; **~ полк** авиация полкы

ави́ация *ж* авиация; **вое́нная ~** хәрби авиация; **гражда́нская ~** гражданнар авиациясе

авитаминоз *м мед.* авитаминоз

ава́сь *частица разг.* бәлки, бәлкем, ихтимал ♦ **на ~** булса булыр, булмаса юк, дип

ава́ська *ж разг.* авоська

авра́л *м* аврал (**1.** *мор. корабльдә гадәттә тревога буенча барлык команданың катнашы белән уткәрелә торган ашыгыч эш* **2.** *перен. ботен коллективның катнашы белән башкарыла торган ашыгыч эш*)

австрали́ец *м* австралияле, Австралия кешесе

австрали́йка *ж* австралияле хатын (кыз)

австрали́йский, -ая, -ое австралияле[ләр] ...ы; Австралия ...ы; **~ матери́к** Австралия материгы

австрали́йцы *мн.* австралиялеләр, Австралия халкы

австри́ец *м* австрияле, Австрия кешесе

австри́йка *ж* австрияле хатын (кызы)

австри́йский, -ая, -ое австрияле [ләр] ...ы; Австрия ...ы; **~ наро́д** Австрия халкы

австри́йцы *мн.* австриялеләр, Австрия халкы

авта́ркия, автарки́я *ж эк.* автаркия (*империалистик дәүләтләрнең илнең милли хуҗалыгын аерырга омтылган икътисадый сәясәте*)

авто- I *кушма сүзләрнең «автоматик», «автомат рәвештә» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **автосва́рка** автоябыштыру

авто- II *кушма сүзләрнең «автомобиль» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **автотури́ст** автотурист

автоба́за *ж* автобаза, автомобильләр базасы

автобиографи́ческ||ий, -ая, -ое автобиографик; **~ая литерату́ра** автобиографик әдәбият

автобиографи́чный, -ая, -ое автобиографик, автобиография характерындагы, автобиографиягә нигезләнгән; **~ рома́н** автобиография характерындагы роман

автобиогра́фия *ж* автобиография, тәржемәи хәл

автоблокиро́вка *ж ж.-д.* автоблокировка (*поездларның йөрешен тәртипкә сала торган автоматик приборлар системасы*)

авто́бус *м* автобус

авто́бусн||ый, -ая, -ое автобус[лар] ...ы; **~ое сообще́ние** автобус юлы

автоге́нн||ый, -ая, -ое *тех.* автоген белән ..., автоген белән эретеп ...; **~ая сва́рка** автоген белән эретеп ябыштыру

автого́нки *мн.* автоузышлар

автого́нщик *м* автоузышчы, автоузышта катнашучы

авто́граф *м* автограф

автографи́ческ||ий, -ая, -ое автографик, автор үзе язган; **~ая ру́копись** автор үзе язган кулъязма

автогужев||о́й, -а́я, -о́е автойөк ...ы; **~ о́й тра́нспорт** автойөк транспорты

автодоро́жный, -ая, -ое автоюл[лар] ...ы; **~ те́хникум** автоюллар техникумы

автодрези́на *ж ж.-д.* автодрезина

автодро́м *м* автодром (*автомобильләрне сынау, автоярышлар үткәру өчен махсус җиһазландырылган урын*)

автозавод *м* автозавод, автомобиль заводы

автоинспе́кция *ж* автоинспекция (*автомобиль хәрәкәтенең дөреслеген тикшеру, шундый тикшерү эшен башкара торган дәүләт органы*)

автока́р *м* автокар (*рельссыз юллардан йөк йөртү өчен хезмәт итә торган эчке янулы двигательле яки аккумуляторлы арба*)

автокла́в *м физ., хим.* автоклав

автоколо́нна *ж* автоколонна

автокра́н *м* автокран

автокра́т *м* автократ (*чикләнмәгән югары хакимиятне үз кулында гына тотучы патша, монарх*)

автократи́ческий, -ая, -ое автократик, автократ ...ы

автокра́тия *ж* автократия (*чикләнмәгән югары хакимият бер кеше кулында гына булу*)

авто́л *м тех.* автол

автолюби́тель *м* автоһәвәскәр

автомагистра́ль *ж* автомагистраль

автома́т *м в разн. знач.* автомат; **стреля́ть из автома́та** автоматтан ату; **телефо́н-~** автомат телефон

автоматиза́ция *ж см.* **автоматизи́ровать, автоматизи́роваться**; **~ производства** производствены автоматлаштыру

автоматизи́ровать *сов., несов. что* автоматлаштыру; **~ произво́дственный проце́сс** производство процессын автоматлаштыру; **~ движе́ние** хәрәкәтне автоматлаштыру

автоматизи́роваться 1. *сов., несов.* автоматлашу **2.** *несов. страд. от* **автоматизи́ровать**

автомати́зм *м* автоматизм, автоматлык

автома́тика *ж* автоматика

автомати́ческ||ий, -ая, -ое **1.** автомат ..., үзеннән-үзе эшли торган; **~ое ружьё** автомат мылтык **2.** (*непроизвольный*) автоматик, ирексездән эшләнгән; **~ое движе́ние** автоматик хәрәкәт

автомати́чность *ж* автоматиклык, ирексездән эшләнгәнлек

автомати́чный, -ая, -ое *см.* **автомати́ческий** 2

автома́тчик *м* автоматчик (**1.** *автомат аппаратта эшләруче эшче* **2.** *автомат коралдан атучы*)

автомаши́на *ж* автомашина

автомобили́зм *м* автомобилизм, автомобиль спорты

автомобили́ст *м* автомобильче, автомобиль спорты һәвәскәре

автомоби́ль *м* автомобиль

автомоби́льн||ый, -ая, -ое автомобиль[ләр] ...ы; **~ая ши́на** автомобиль шины; **~ый заво́д** автомобиль заводы

автоно́мия *ж* автономия, мохтарият, үзидарә

автоно́мн||ый, -ая, -ое автономияле, үзидарәле; **~ая респу́блика** автономияле республика

автопило́т *м* автопилот

автопогру́зчик *м* автотөягеч

автопои́лка *ж* автоэчергеч

автопортре́т *м* автопортрет

а́втор *м* автор; **Пу́шкин — ~ «Евге́ния Оне́гина»** Пушкин «Евгений Онегинның» авторы; **~ прое́кта** проектның авторы

автореферáт *м* автореферат

авториз||ова́ть *сов., несов. что* авторлаштыру; **~о́ванный перево́д** авторлаштырылган тәрҗемә

авторита́рный, -ая, -ое авторитар (**1.** *хакимиятька сукырларча буйсынуга нигезләнгән* **2.** *үзенең хакимиятен, авторитетын ныгытуга омтылган*)

авторите́т *м* **1.** абруй, авторитет; иҗтимагый әһәмият; **по́льзоваться ~ом** абруйлы булу **2.** авторитет, авторитет иясе, танылган кеше; **кру́пный ~ в хи́мии** химиядә зур авторитет

авторите́тн||ый, -ая, -ое **1.** авторитетлы, абруйлы, танылган; **~ый учёный** абруйлы галим **2.** ышанычлы; **~ое мне́ние** ышанычлы фикер

а́торск||ий, -ая, -ое **1.** авторлык ...ы, автор[лар] ...ы; **~ое пра́во** авторлык хокукы; **~ий коллекти́в** авторлар коллективы **2.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн. разг. см.* **гонора́р**

а́торство *с* авторлык

автору́чка *ж* авторучка

автосбо́рочный, -ая, -ое автомобильләр җыю ...ы; **~ цех** автомобильләр җыю цехы

автоспо́рт *м* автоспорт

автосто́п *м* автотуктаткыч (*ябык сигналга якынлашканда поездны туктата торган җайланма*)

автостра́да *ж* автострада

автосце́пка *ж ж.-д.* автототаштыргыч

автотипи́ческий, -ая, -ое *полигр.* автотипик, автотипик юл белән басылган (*фоторәсем турында*)

автоти́пия *ж полигр.* автотипия (**1.** *фоторәсемнәрне фотография ярдәмендә төшерү ысулларының берсе* **2.** *автотипик ысул белән басылган рәсемнең үзе*)

автотра́нспорт *м* автотранспорт, автомобиль транспорты

автотра́нспортный, -ая, -ое автотранспорт ...ы; **~ цех** автотранспорт цехы

автотури́зм *м* автотуризм

автотури́ст *м* автотурист

автохто́ны *мн.* автохтоннар, җирле халык, илнең төп халкы

ага́ I *межд.* әһә; **~, попа́лся!** әһә, эләктеңме!

ага́ II *частица прост.* әйе; **ви́дишь? — Ага, ви́жу** күрәсеңме? — Әйе, күрәм

ага́ва *ж бот.* агава

ага́т *м мин.* ахак

ага́тов||ый, -ая, -ое *мин.* ахак ...ы, ахак ...; **~ое ожере́лье** ахак муенса ♦ **~ые глаза́** кара ялтырак күзләр

агглютинати́вн||ый, -ая, -ое *лингв.* ялганмалы, агглютинатив; **~ые языки́** агглютинатив телләр

агглютина́ция *ж лингв.* агглютинация

аге́нт *м* **1.** агент, вәкил; **~ по снабже́нию** тәэминат агенты **2.** (*шпион*) агент, шымчы

аге́нтство *с* агентлык; **телегра́фное ~** телеграф агентлыгы

аге́нту́ра *ж* **1.** агентура (*разведка ясау яки шпионлык иту хезмәте*) **2.** *собир.* агентлар

аге́нту́рн||ый, -ая, -ое агентура ...ы, шпионлык ...ы; **~ые све́дения** агентура мәгълүматлары

агита́тор *м* агитатор

агита́торский, -ая, -ое агитаторлык ...ы, агитатор[лар] ...ы

агитацио́нн||ый, -ая, -ое агитация ...ы, агитацион; **~ая рабо́та** агитация эше

агита́ция *ж* агитация, өндәү

агитбрига́да *ж* агитбригада, агиторлар бригадасы

агити́ровать *несов.* **1.** *за кого-что и без доп.* агитация ясау, агитация алып бару **2.** *кого-что* (*берәр нәрсәгә*) өндәү, димләү, чакыру

аги́тка *м разг.* агитка (*агитация максатларын гына күздә тотып язылган әдәби әсәр яки сәнгать әсәре*)

агитколлекти́в *м* агитколлектив, агиторлар коллективы

агитма́ссов||ый, -ая, -ое агитмасса ...ы; **~ая рабо́та** агитмасса эшләре

агитпу́нкт *м* агитпункт

агломера́т *м геол., тех.* агломерат

агломерацио́нн||ый, -ая, -ое *тех.* агломерацион, агломерация ...ы; **~ая маши́на** агломерация машинасы

агломера́ция *ж тех.* агломерация (*йомшак вак рудаларны, тузансыман материалларны югары температура тәэсирендә кушып зур кисәкләргә әверелдерү*)

агно́стик *м филос.* агностик, агностицизм тарафдары

агностици́зм *м филос.* агностицизм (*объектив дөньяны таный белүне инкарь итә торган философик тәгълимат*)

агонизи́ровать *несов.* агониядә булу, үлем газабында булу

агони́ровать *несов. см.* **агонизи́ровать**

аго́ния *ж* агония, үлем газабы

аграр́н||ый, -ая, -ое аграр, җир ...ы; **~ая рефо́рма** аграр реформа

агрега́т *м* агрегат, җайланма; **убо́рочный ~** урып җыю агрегаты

агресси́вность *ж* агрессивлык

агресси́вн||ый, -ая, -ое агрессив, басып алу ...ы; **~ая поли́тика** агрессив политика

агре́ссия *ж* агрессия, басып алу, яулап алу

агре́ссор *м* агрессор, басып алучы, яулап алучы

агробиологи́ческ||ий, -ая, -ое агробиологик, агробиология ...ы; **~ая нау́ка** агробиология фәне

агробиоло́гия *ж* агробиология

агрокульту́ра *ж* агрокультура (*игенчелекнең культурасын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар җыелмасы*)

агрокульту́рн||ый, -ая, -ое агрокультура ...ы, игенчелекне яхшырту ...ы; **~ые мероприя́тия** агрокультура чаралары

агролесомелиора́ция *ж* агроурман-мелиорация

агромáксимум *м* агромаксимум (*авыл хуҗалыгы эшләре өчен кирәкле агрономик чараларның, белемнәрнең һ.б.ш. максимумы*)

агроми́нимум *м* агроминимум (*авыл хуҗалыгы эшләре өчен кирәкле агрономик чараларның, белемнәрнең һ.б.ш. минимумы*)

агроно́м *м* агроном, агрономия белгече

агрономи́ческ||ий, -ая, -ое агрономик, агрономия ...ы; **~ие мероприя́тия** агрономик чаралар

агроно́мия *ж* агрономия

агроте́хник *м* агротехник, агротехника белгече

агроте́хника *ж* агротехника

агротехни́ческ||ий, -ая, -ое агротехник, агротехника ...ы; **~ие приёмы** агротехника алымнары

агрохими́ческ||ий, -ая, -ое агрохимик, агрохимия ...ы; **~ие мероприя́тия** агрохимия чаралары

агрохи́мия *ж* агрохимия

ад *м* **1.** *рел.* тәмугь, җәһәннәм **2.** *перен.* авырлык, тәмугь, михнәт

ада́жио *муз.* **1.** *нареч.* адажио, акрын, салмак (*музыкаль әсәрнең башкарылу темпына карата*) **2.** *с нескл.* адажио (*акрын темптагы музыкаль әсәр яки аның бер кисәге*)

адапта́ция *ж* **1.** адаптация (*тою органнарының, организмнарның әйләнә-тирәдәге шартларга җайлашуы*) **2.** адаптация, адаптацияләү, жиңелләштерү (*чит телләрне өйрәнә башлаучылар өчен текстны жиңелләштерү*)

ада́птер *м* адаптер (*пластинкаларга язылган музыканы, җырларны һ.б.ш. электрик дулкыннарга әйләндерә торган прибор*)

адапти́ровать *сов., несов. что* жиңелләштерү, җайлаштыру (*чит телдә язылган текстны укуны шул телне өйрәнүчеләр өчен*)

адвока́т *м* адвокат, яклаучы

адвока́тск||ий, -ая, -ое адвокат ...ы, адвокатлык ...ы; **~ая де́ятельность** адвокат эшчәнлеге

адвокату́ра *ж* 1. адвокатлык 2. *собир.* адвокатлар

адеква́тность *ж* адекватлык, тәңгәллек, тиңдәшлек, бердәйлек, туры (тапкыр) килгәнлек

адеква́тн||ый, -ая, -ое адекват, тәңгәл, тиндәш, бердәй, тапкыр килгән; **~ые поня́тия** тәңгәл төшенчәләр

аденои́ды *мн.* (*ед.* **аденои́д** *м*) *мед.* аденоид (*йоткылык бизенең шешеп зураюы*)

аджа́рец *м* аҗар, аҗар кешесе

аджа́рка *ж* аҗар хатыны (кызы)

аджа́рский, -ая, -ое аҗар[лар] ...ы; Аҗарстан ...ы; **~ язы́к** аҗар теле

аджа́рцы *мн.* аҗарлар, аҗар халкы

администрати́вн||ый, -ая, -ое 1. администрация ...ы; **~ый отде́л исполко́ма** исполкомның администрация бүлеге 2. административ; **~ые ме́ры** административ чаралар; **в ~ом поря́дке** административ тәртиптә

администра́тор *м* администратор

администра́торск||ий, -ая, -ое администратор ...ы, администраторлык ...ы; **~ие спосо́бности** администраторлык сәләтләре

администра́ция *ж* 1. администрация, идарә органы 2. *собир.* администраторлар, җитәкчеләр

администри́ровать *несов.* 1. идарә итү, администраторлык итү 2. *перен.* түрәлек итү, түрәләрчә эш итү (*бюрократларча формаль, коры боерулар белән генә идарә итү*)

адмира́л *м* адмирал

адмиралте́йство *с уст.* адмиралтейство (*хәрби суднолар ясау һәм аларны җиһазлау урыны*)

адмира́льск||ий, -ая, -ое адмирал ...ы, адмираллык ...ы; **~ое зва́ние** адмирал званиесе

а́дрес *м* 1. адрес; **то́чный ~** төгәл адрес; **дать ~** адрес бирү 2. адрес, котлау язуы (*юбилей уңае белән хезмәт яки фән эшлеклесенә бирелә торган котлау язуы*); **поднести́ ~** адрес бирү ◆ **по ~у** *кого-чего, чьему* ...га карата; **по его́ ~у бы́ло сде́лано не́сколько замеча́ний** аңа карата берничә кисәтү ясалды; **не по ~у** кешесенә карата түгел; тиешле урынына түгел; **ва́ше замеча́ние сде́лано не по ~у** сезнең кисәтүегез тиешле кешесенә карата түгел

адреса́т *м* адресат (*адресы язып җибәрелгән хатны яки посылканы алырга тиешле кеше яки учреждение*)

а́дресный, -ая, -ое адрес[лар] ...ы; **~ стол** адреслар бүлеге

адресова́ть *сов., несов. что кому* 1. адреслау, адрес буенча җибәрү; **~ письмо́** *кому-л. берәр кешегә* адресы буенча хат җибәрү 2. *перен.* җибәрү, юнәлтү; **вопро́с адресо́ван вам** сорау сезгә юнәлтелгән

адресова́ться 1. *сов., несов. куда, к кому-чему* мөрәҗәгать итү 2. *несов. страд. от* **адресова́ть**

а́дск||ий, -ая, -ое 1. тәмугъ ...ы, җәһәннәм ...ы 2. (*злобный, коварный*) усал, явыз; **~ий за́мысел** явыз ният 3. *перен.* (*невыносимый*) коточкыч авыр, түзә алмаслык; **~ий хо́лод** түзә алмаслык салкын ◆ **~ое терпе́ние** чиктән тыш түземлек

адсорби́ровать *сов., несов. что и без доп., физ., хим.* адсорбцияләү

адсо́рбция *ж физ., хим.* адсорбция (*сыеклык яки каты җисемнең өске катлавы тарафыннан эремәдән яки газдан матдәнең үзләштерелүе*)

адъю́нкт *м воен.* адъюнкт (*югары хәрби уку йортларында аспирант*)

адъюнкту́ра *ж воен.* адъюнктура

адъюта́нт *м* адъютант

адъюта́нтск||ий, -ая, -ое адъютант ...ы, адъютантлык ...ы; **~ие обя́занности** адъютантлык вазыйфалары

адыге́ец *м* адыгей, адыгей кешесе

адыге́йка *ж* адыгей хатыны (кызы)

адыге́йский, -ая, -ое адыгей[лар] ...ы; **~ язы́к** адыгей теле

адыге́йцы *мн.* адыгейлар, адыгей халкы

ажиота́ж *м* ажиотаж, ыгы-зыгы, шау-шу

ажу́р *нареч. бухг.* көннеке көнгә; шул ук көнне; икенче көнгә калдырмый ◆ **в ~е** шәп, бик шәп (*эшләр турында*)

ажу́рн||ый, -ая, -ое 1. челтәрләп эшләнгән, үтә күренмәле; **~ые чулки́** үтә күренмәле оек 2. *перен.* (*искусно сделанный*) оста эшләнгән, пөхтә эшләнгән; **~ая рабо́та** пөхтә эшләнгән эш

аз *м* 1. аз (*рус телендә «а» хәрефенең борынгы исеме*) 2. *мн.* **азы́** *перен.* башлангыч мәгълүматлар, элементар мәгълүматлар; **нача́ть изуче́ние с ~ов** өйрәнүне башлангыч мәгълүматлардан башларга ◆ **ни аза́ не зна́ть (не смы́слить)** әлифне таяк дип тә белмәү

аза́лия *ж* азалия чәчәге (*декоратив усемлек*)

аза́рт *м* азарт, кызып китү, көчле мавыгу, һәвәсләнү; **рабо́тать с ~ом** һәвәсләнеп эшләү

аза́ртн||ый, -ая, -ое һәвәсләнүчән, кызып китүчән, мавыгучан; **~ый челове́к** кызып китүчән кеше ◆ **~ая игра́** комарлы уен, отышлы уен (*мәс. карта уены*)

а́збука *ж* 1. (*алфавит*) әлифба 2. (*букварь*) әлифба 3. *перен.* башлангыч, әлифба; **~ нау́ки** фәннең әлифбасы

а́збучн||ый, -ая, -ое 1. әлифба ...ы; **~ый материа́л** әлифба материалы 2. алфавит буенча төзелгән; **~ый указа́тель** алфавит буенча төзелгән күрсәткеч ◆ **~ая и́стина** һәркемгә билгеле хакыйкать

азербайджа́нец *м* азербайҗан, азербайҗан кешесе

азербайджа́нка *ж* азербайҗан хатыны (кызы)

азербайджа́нский, -ая, -ое азербайҗан[нар] ...ы; Азербайҗан ...ы; **~ язы́к** азербайҗан теле

азербайджа́нцы *мн.* азербайҗаннар, Азербайҗан халкы

азиа́т *м* Азиядә яшәүче кеше, Азия кешесе

азиа́тск||ий, -ая, -ое Азия ...ы; **~ие стра́ны** Азия илләре

а́зимут *м астр., геод.* азимут.

азо́т *м хим.* азот

азо́тист||ый, -ая, -ое *хим.* азотлы; **~ые удобре́ния** азотлы ашламалар

азо́тн||ый, -ая, -ое *хим.* азот ...ы; **~ая кислота́** азот кислотасы

а́ист *м* ләкләк

ай *межд.* 1. әй, абау; **ай, бо́льно!** әй, авырта! 2. әй-әй; **ай, как нехорошо́!** әй-әй, алай яхшы түгел! ◆ **ай да молоде́ц!** егет тә соң!, менә булдырдын!

айва *ж* айва (*агачы һәм җимеше*)

айво́в||ый, -ая, -ое 1. айва ...ы; **~ый сад** айва бакчасы 2. айва ...ы, айвадан хәзерләнгән; **~ое варе́нье** айва вареньесе

айда́ *межд. разг.* әйдә (*чакыру, өндәү, кыстау*); **~ в лес!** әйдә, урманга киттек!

айма́к *м* аймак

айма́чный, -ая, -ое аймак ...ы; **~ сове́т** аймак советы

айра́н *м* әйран

а́йсберг *м* айсберг (*диңгездә йөзеп йөри торган боз тавы*)

академи́зм *м* 1. академизм (*фән һәм сәнгать өлкәсендә яшәп килгән традицияләрне саклау*) 2. *перен.* академизм, академиклык (*теориянең практикага бәйләнмәве*)

акаде́мик *м* академик

академи́ческ||ий, -ая, -ое 1. академик, академия ...ы; **~ий уста́в** академия уставы; **~ое изда́ние** академик басма 2. (*соблюдающий традиции*) академик, академизмга нигезләнгән; **~ая жи́вопись** академизмга нигезләнгән рәсем ясау сәнгате 3. (*учебный*) академик ...; **~ий час** академик сәгать 4. *перен.* академик, саф теоретик, практик әһәмияте булмаган ◆ **~ий теа́тр** академия театры

академи́чность *ж* академиклылык (*конкрет түгеллек, практикадан аерылганлык*)

академи́чный, -ая, -ое *см.* **академи́ческий** 3, 4

акаде́мия *ж* академия; **~ нау́к** фәннәр академиясе; **сельскохозя́йственная ~** авыл хуҗалыгы академиясе

ака́нт *м* акант (*декоратив усемлек*)

а́кать *несов.* алаштыру (*басымсыз «о» авазын «а» авазына тартым итеп әйтү*)

ака́ция *ж* акация, сәрви агачы

аквала́нг *м* акваланг

акваланги́ст *м* акваланчы

аквамари́н *м* аквамарин (*асылташ*)

аквамари́нов||ый, -ая, -ое аквамарин ...ы, аквамарин ...; **~ые се́рьги** аквамари́н алкалар

аквана́вт *м* акванавт (*су астында кузәтү алып барып диңгезне тикшерүче*)

аквана́втика *ж* акванавтика (*диңгездә озак вакытлар буена су астында булу мөмкинлекләрен өйрәнә торган фән*)

акварели́ст *м* акварельче

акваре́ль *ж* акварель (1. *суга изелә торган буяу* 2. *шундый буяу белән ясалган рәсем*)

акваре́льн||ый, -ая, -ое акварель ...; акварель белән ясалган; **~ая кра́ска**

акварель буяу; **~ый портре́т** акварель белән ясалган портрет

аква́риум *м* аквариум

аква́риумн||ый, -ая, -ое аквариум ...ы; **~ые ры́бы** аквариум балыклары

аквато́рия *ж* акватория (*сулыкның мәйданы*)

акведу́к *м спец.* акведук (*су торбаларын һ.б.ш. елгалар, чокырлар аша уткәру өчен ясалган күпер*)

акклиматиза́ция *ж* климатлаштыру, яңа климатка җайлаштыру

акклиматизи́ровать *сов., несов. кого-что* климатлаштыру, яңа климатка җайлаштыру, күнектерү

акклиматизи́роваться 1. *сов., несов.* климатлашу, яңа климатка җайлашу, күнегү 2. *несов. страд. от* **акклиматизи́ровать**

аккомода́ция *ж* аккомодация, ияләшү, җайлашу; **~ гла́за** күзнең ияләшүе

аккомпанеме́нт *м* аккомпанемент, кушылып уйнау; **петь под ~ гита́ры** гитарага кушылып җырлау

аккомпаниа́тор *м* аккомпаниатор, кушылып уйнаучы

аккомпани́ровать *несов. кому-чему, на чём* кушылып уйнау; **~ певцу́ на роя́ле** җырлаучыга кушылып рояльдә уйнау

акко́рд *м муз.* аккорд; **брать ~ы** аккордлар алу ♦ **заключи́тельный ~** соңгы күренеш, соңгы нәтиҗә

аккордео́н *м* аккордеон

аккордеони́ст *м* аккордеончы, аккордеонда уйнаучы

акко́рдн||ый, -ая, -ое аккорд ..., берьюлы туләнә торган, тулаем түләнә торган; **~ая рабо́та** тулаем түләнә торган эш

аккредити́в *м фин.* аккредитив

аккредитова́ть *сов., несов.* 1. *кого, дип.* дипломатик вәкил итеп билгеләү 2. *что, фин.* вәкаләт бирү (*берәр кешене акча алу яки сәүдә эшләре башкару өчен вәкил итеп җибәрү*)

аккумули́ровать *сов., несов. что* аккумуляцияләү, энергияне җыю (туплау); **~ электроэне́ргию** электроэнергияне аккумуляцияләү

аккумуля́тор *м физ., тех.* аккумулятор

аккумуля́ция *ж см.* **аккумули́ровать**

аккура́тность *ж* 1. (*исполнительность*) пөхтәлек, төгәллек, җыйнаклык 2. (*тщательность*) пөхтә эшләнгәнлек, җентекле эшләнгәнлек

аккура́тн||ый, -ая, -ое 1. (*исполнительный*) пөхтә, төгәл, җыйнак; **~ый учени́к** пөхтә укучы 2. (*тщательный*) пөхтә [эшләнгән], җентекле [эшләнгән]; **~ое исполне́ние рабо́ты** эшне җиренә җиткереп башкару

акмеи́зм *м лит.* акмеизм

акмеи́ст *м лит.* акмеизм тарафдары

акони́т *м бот.* аконит

акр *м* акр (*Англиядә һәм Төньяк Америкада 4047 кв. метрга тигез җир үлчәү берәмлеге*)

акри́д||ы *мн.*: **пита́ться ~ами [и ди́ким мёдом]** ачлы-туклы яшәү

акроба́т *м* акробат

акроба́тика *ж* акробатика

акроба́тическ||ий, -ая, -ое 1. акробатика ...ы, акробатик; **~ие упражне́ния** акробатик күнегүләр 2. (*ловкий*) акробатларча ..., акробатсыман, бик оста, бик җитез

акро́поль *м* акрополь (*борынгы грек шәһәрләрендә үзәк ныгытма, кремль*)

акроти́х *м лит.* акростих

акселера́т *м* акселерат

акселера́ция *ж* акселерация (*балаларның һәм яшүсмерләрнең тиз формалашуы һәм усеү*)

аксельба́нт *м* аксельбант (*революциягә кадәрге Россиядә һәм кайбер буржуаз армияләрдә: офицерларның, адъютантларның, жандармнарның иңбашлары аша уткәрелгән шнурлар*)

аксессуа́р *м* аксессуар (1. *сынлы сәнгатьтә төп предметка өстәмә деталь* 2. *сәхнә җиһазы* 3. *перен. төп күренешкә өстәмә генә булган икенче дәрәҗәдәге күренеш*)

аксио́ма *ж* аксиома (*дөреслеген исбат итмичә дә дөрес булган хакыйкать*)

акт *м* 1. чыгыш, хәрәкәт, кыланыш; **террористи́ческий ~** террористик чыгыш 2. (*документ*) акт; **обвини́тельный ~** гаепләү акты; **соста́вить ~** акт төзү 3. *театр.* пәрдә, бүлек; **коме́дия в трёх ~ах** өч пәрдәле комедия

актёр *м* актёр

актёрск||ий, -ая, -ое актёр[лар] ...ы, актёрларча ...; **~ая те́хника** актёр техникасы; **~ие же́сты** *перен.* актёрларча кыланышлар

актёрство *с* 1. (*профессия актёра*) актёрлык 2. *перен. разг.* (*притворство*) кыланыш, күз буяу, шамакайлык

акти́в I *м* актив; **парти́йный ~** партия активы

актив II *м бухг.* актив (*предприятиенең барлык булган һәм аңа түләнергә тиешле мөлкәтенең кыйммәте*)

активиза́ция *ж см.* **активизи́ровать, активизи́роваться**

активизи́ровать *сов., несов. кого-что* активлаштыру, активлыгын көчәйтү, активлыгын арттыру; **~ ма́ссы** массаларны активлаштыру; **~ рабо́ту** эшне көчәйтү

активизи́роваться 1. *сов., несов.* активлашу, активлык көчәю, активлыгы арту, активлаштырылу, активлыгы көчәйтелү 2. *несов. страд. от* **активизи́ровать**

активи́ст *м* активист, актив кеше

активи́стка *ж* активистка, актив хатын (кыз)

акти́вность *ж* активлык, актив эшчәнлек

акти́вн||ый I, -ая, -ое 1. актив, эшлекле; **~ый член кружка́** түгәрәкнең актив члены 2. (*развивающийся*) актив, көчле; **~ый проце́сс в лёгких** үпкәдә актив процесс ♦ **~ое избира́тельное пра́во** актив сайлау хокукы

акти́вный II, -ая, -ое *бухг.* актив; **~ бала́нс** актив баланс

акти́ровать *сов., несов. что* акт төзү (*берәр нәрсәнең барлыгын яки юклыгын раслау өчен*)

а́ктов||ый, -ая, -ое акт[лар] ...ы; **~ая бума́га** актлар кәгазе; **~ый зал** актлар залы

актри́са *ж* актриса

актуа́льность *ж* актуальлек, әһәмиятлелек

актуа́льн||ый, -ая, -ое актуаль, көнүзәк, бик әһәмиятле; **~ая те́ма** актуаль тема

аку́ла *ж* акула

аку́стик *м* акустик (1. *акустика белгече* 2. *разг. авазтоткыч аппаратларга хезмәт күрсәтүче*)

аку́стика *ж* акустика (1. *физиканың тавышны өйрәнә торган өлеге* 2. *биналарда музыканың яки тавышның ишетелү шартлары*)

акусти́ческ||ий, -ая, -ое акустик, ишетелү ...ы, ишетелеш ...ы; **~ие усло́вия** акустик шартлар

акуше́р *м* акушер (*йөкле хатыннарга медицина ярдәме күрсәтә торган табип*)

акуше́рка *ж* акушерка

акуше́рский, -ая, -ое акушер[лар] ...ы, акушерлык ...ы

акуше́рство *с* акушерлык

акце́нт *м* 1. *лингв.* басым; басым билгесе 2. акцент, бозыбрак әйтү; **говори́ть с ~ом** акцент белән сөйләү ♦ **сде́лать ~** *на чём* берәр нәрсәгә басым ясау

акцентри́ровать *сов., несов. что и без доп.* 1. (*ставить ударение*) басым билгесе кую 2. *перен.* басым ясап әйтү, акцент ясау

акци́з *м* акциз (1. *кайбер киң кулланыш товарларының сату бәясен күтәрү юлы белән хезмәт ияләренә салына торган кыек салым* 2. *революциягә кадәрге Россиядә: шундый салымларны җыю учреждениесе*)

акци́зный, -ая, -ое *уст.* акциз ..., акциз ...ы; **~ сбор** акциз җыю

акционе́р *м* акционер

акционе́рн||ый, -ая, -ое акционерлар ...ы; акцияләр ...ы; акцияләргә нигезләнгән; **~ое о́бщество** акционерлар җәмгыяте; **~ый капита́л** акцияләргә нигезләнгән капитал

а́кци||я I *ж фин.* акция ♦ **его́ ~и си́льно поднялись** аның дәрәҗәсе бик күтәрелде; **~и** *чьи* **повыша́ются** дәрәҗәсе күтәрелә; **~и** *чьи* **па́дают** дәрәҗәсе төшә

а́кция II *ж* акция, чыгыш, хәрәкәт: **дипломати́ческая ~** дипломатик акция

акы́н *м* акын

алба́нец *м* албан, албан кешесе

алба́нка *ж* албан хатыны (кызы)

алба́нский, -ая, -ое албан[нар] ...ы; Албания ...ы; **~ язы́к** албан теле

алба́нцы *мн.* албаннар, Албания халкы

а́лгебра *ж* алгебра

алгебраи́ческ||ий, -ая, -ое алгебра ...ы, алгебраик; **~ое уравне́ние** алгебраик тигезләмә

алгори́тм *м мат.* алгоритм; **~ извлече́ния ко́рня из числа́** саннан тамыр алу алгоритмы

алеба́стр *м* алебастр

алеба́стровый, -ая, -ое **1.** алебастр ...ы; **~ зав|о́д** алебастр заводы **2.** алеба́стр ..., алебастрдан ясалган; **~ бюст** алебастрдан ясалган бюст

але́||ть *несов.* **1.** (*становиться алым*) аллану, алсулану, ал төскә керү **2.** (*виднеться — о чём-л. алом*) алланып (алсуланып) күренү, алсуланып тору; **вдали́ ~ют ма́ки** ераткы мәкләр алланып күренә

а́либи *с нескл.* алиби (*берәр җинаять ясауда гаепләнүченең гаепсезлегенә дәлил буларак җинаять ясалган урында булмавы*); **доказа́ть своё ~** үзеңнең алибиеңне исбат итү

ализари́н *м* ализарин (*тукымаларны ману һәм буяу өчен кулланыла торган буяу матдәсе*)

ализари́нов||ый, -ая, -ое ализарин ...ы; ализарин ..., ализариннан ясалган; **~ые кра́ски** ализарин буяулар

алиме́нтщик *м разг.* алиментчы, алимент түләүче

алиме́нты *только мн.* алимент; **плати́ть ~** алимент түләү

алкоголи́зм *м* эчкечелек, эчкечелеккә сабышу

алкого́лик *м* эчкече, исерекбаш

алкоголи́ческ||ий, -ая, -ое эчкече ...ы; **~ие наклóнности** эчкече гадәтләре

алкого́ль *м* **1.** (*винный спирт*) алкоголь **2.** *разг.* (*спиртные напитки*) алкоголь, аракы, исерткеч эчемлек

алкого́льн||ый, -ая, -ое **1.** алкогольле, исерткеч; **~ые напи́тки** исерткеч эчемлекләр **2.** алкоголь белән, алкогольдән ...; **~ое отравле́ние** алкоголь белән агулану

алла́х *м* алла, тәңре, ходай ♦ **~ зна́ет** алла белсен

аллегори́ческий, -ая, -ое аллегория ...ы, аллегорик; **~ жанр** аллегория жанры

аллегори́чный, -ая, -ое аллегорик, аллегорияле, кинаяле, читләтеп әйтелгән; **~ стиль** аллегорик стиль

аллего́рия *ж лит., иск.* аллегория ♦ **говори́ть ~ми** киная белән сөйләү

алле́гро *муз.* **1.** *нареч.* аллегро, тиз, мәп (*музыкаль әсәрләрнең башкарылу темпына карата*) **2.** *с нескл.* аллегро (*тиз темптагы музыкаль әсәр яки аның бер кисәге*)

аллерге́н *м* аллерген (*аллергия китереп чыгара торган матдә*)

аллерги́ческ||ий, -ая, -ое аллергия ...ы, аллергик; **~ое заболева́ние** аллергик авыру

аллерги́я *м* аллергия (*нинди дә булса ярсыткычның тәэсиренә организмның нормаль булмаган реакциясе*)

аллерго́лог *м* аллерголог, аллерголия белгече

аллерголо́гия *ж мед.* аллергология

алле́я *ж* аллея

аллига́тор *м* аллигатор (*крокодилның бер төре*)

аллитера́ция *ж лит.* аллитерация

алло́ *межд.* алло

аллопа́т *м* аллопат (*аллопатия методларын кулланучы табиб*)

аллопа́тия *ж* аллопатия (*гомеопатиягә капма-каршы буларак дәвалауның гадәттәге системасы*)

аллю́вий *м геол.* аллювий

аллю́р *м* аллюр (*атның йөрү яки чабуысулы, мәс. юырту, атлатып бару, чабып бару*)

алма́з *м* алмаз

алма́зный, -ая, -ое **1.** алмаз ...ы; **~ блеск** алмаз ялтыравы **2.** алмазлы, алмаз ...ы, алмаздан ясалган; **~ пе́рстень** алмазлы йөзек

алоги́зм *м* алогизм, логикасызлык (*логик фикер йөртүдәге каршылык*)

алоги́ческий, алоги́чный, -ая, -ое *книжн.* алогик, логикасыз, логикага сыймый торган

ало́э *с нескл. бот.* алой, йөзьяшәр

алта́рь *м* алтарь (*чиркәүнең төп залының туре, арткы өлеше*)

алты́н *м уст.* барнау (*борынгы заманда Россиядә 3 тиенлек бакыр акча*)

алфави́т *м* әлифба, алфавит; **ру́сский ~** рус алфавиты; **написа́ть фами́лии по ~у** фамилияләрне әлифба буенча язу

алфави́тный, -ая, -ое әлифба ...ы, алфавит ...ы, алфавитлы, алфавит тәртибендә тезелгән; **~ поря́док** алфавит тәртибе; **~ указа́тель** алфавитлы күрсәткеч

алхи́мик *м* алхимик, алхимия белән шөгыльләнүче

алхи́мия *ж* алхимия (*урта гасырларда гади металлардан кыйммәтле металлар ясарга маташкан мистик тәгълимат*)

а́лчность *ж* комсызлык, туемсызлык, ачкүзлелек

а́лчный, -ая, -ое комсыз, туемсыз, ачкүзле, хирыс; **~ челове́к** комсыз кеше; **~ до де́нег** акчага хирыс [кеше]

а́лый, -ая, -ое ал; **~ флаг** ал флаг

альбатро́с *м зоол.* альбатрос

альбино́с *м* альбинос (*пигмент җитешмәү сәбәпле төсе агарган организм*)

альбо́м *м* альбом

альбуми́н *м биохим.* альбумин

алько́в *м* стена куышы (*кровать кую өчен*)

альмана́х *м* альманах

альпи́йск||ий, -ая, -ое (*высокогорный*) биек тау ...ы; **~ие луга́** биек тау көтүлекләре

альпини́зм *м* альпинизм, тау туризмы

альпини́ст *м* альпинист, тау туристы

альпини́стка *ж* альпинист хатын (кыз)

альт *м* альт (**1.** *хатын-кызларның яки балаларның калын тавышы, шундый тавышлы җырчы* **2.** *скрипкадан бераз зуррак кыллы музыка коралы*)

альтернати́ва *ж* альтернатива (*мөмкин булган ике карарның берсен генә сайлау кирәклеге*)

альтернати́вн||ый, -ая, -ое альтернатив (*икенең берсе мөмкин яки тиешле булган*); **~ое реше́ние** альтернатив карар

альти́ст *м* альтчы, альтта уйнаучы

альтруи́зм *м* альтруизм (*үзенең шәхси мәнфәгатьләре белән хисаплашмыйча, башкаларга файда китерергә теләү, тырышу*)

альтруи́ст *м* альтруист (*кешеләргә яхшылык итәргә теләүче*)

альтруисти́ческий, -ая, -ое, **альтруисти́чный,** -ая, -ое альтруистик; **~ посту́пок** альтруистик эш

а́льф||а *ж* альфа (*грек алфавитындагы хәреф*) ♦ **~а и оме́га** *чего* башы һәм ахыры; барсы да тулысы белән; **от ~ы до оме́ги** башыннан ахырына кадәр

а́льфа-лучи́ *мн. физ.* альфа нурлар

алья́нс *м* альянс, союз; **полити́ческий ~** сәяси альянс

алюми́ниев||ый, -ая, -ое **1.** алюминий ...ы; **~ая руда́** алюминий рудасы **2.** алюминий ..., алюминийдан ясалган; **~ая ло́жка** алюминий кашык

алюми́ний *м* алюминий

аляпова́т||ый, -ая, -ое тупас, тупас эшләнгән, аннан-моннан гына эшләнгән; **~ая карти́на** тупас эшләнгән картина

амальга́ма *ж хим.* амальгама (*нинди дә булса бер металлның терекөмеш белән кушылмасы*)

амальгами́ровать *сов., несов. что* **1.** *хим.* амальгама ясау (*берәр металлны терекөмеш белән кушып*) **2.** амальгама белән каплау, амальгамалау; **~ зе́ркало** көзгене амальгамалау

амба́р *м* амбар, кәләт

амби́ци||я *ж* (*самолюбие*) амбиция, һавалылык, тәкәбберлек, эрелек; (*спесь, чванство*) борын чөю, борын күтәрү, масаю, шапырыну; **уда́риться в ~ю** амбициягә бирелү

а́мбра *ж* гамбәр

амбрazу́ра *ж* амбразура (**1.** *хәрби ныгытмаларның стеналарында ату өчен ясалган махсус тишек, уем* **2.** *тәрәзә уемы, ишек уемы*)

амбулато́рия *ж* амбулатория

амбулато́рный, -ая, -ое амбулатория ...ы, амбулаториядә ...; **~ приём** амбулаториядә кабул итү; **~ больно́й** амбулаториядә дәвалана торган авыру

амво́н *м церк.* мөнбәр (*чиркәүдә*)

амёба *ж зоол.* амёба

америка́нец *м* америкалы, Америка кешесе

америка́нка *ж* америкалы хатын (кыз)

америка́нский, -ая, -ое америкалы ...ы; Америка ...ы; **~ матери́к** Америка материгы

америка́нцы *мн.* америкалылар, Америка халкы

амети́ст *м* аметист (*асылташ*)

амети́стовый, -ая, -ое аметист ...ы; аметист ...; аметисттан ясалган; **~ пе́рстень** аметист балдак

ами́нь *частица* амин (*дога, вәгазь азагында әйтелә торган суз*)

аммиа́к *м хим.* аммиак

аммиа́чн||ый, -ая, -ое *хим.* аммиак ...; аммиаклы; **~ая вода́** аммиаклы су

аммо́нал *м* аммонал (*шартлый торган матдә*)

аммо́ний *м хим.* аммоний

амнисти́ровать *сов., несов. кого-что* амнистия белән азат итү, амнистиягә кертү, җәзадан коткару

амни́стия *ж* амнистия

аморáльность *ж* аморальлек, моральсезлек, әхлаксызлык, бозыклык; **~ повéдения** тәртипнең бозыклыгы

аморáльный, -ая, -ое амораль, моральсез, әхлаксыз, бозык; **~ постýпок** амораль эш

амортизáтор *м тех.* амортизатор

амортизáционн||ый, -ая, -ое амортизация ...ы; амортизацион; **~ый срок** амортизация срогы; **~ый капитáл** амортизация капиталы; **~ые срéдства** амортизация чаралары (*рессорлар, буферлар һ.б.ш.*)

амортизáция *ж* амортизация (**1.** *тузу сәбәпле биналарның, машиналарның, һ.б.ш. бәясе кими бару* **2.** *автомобильләрнең юлда барганда, самолётларның җиргә төшкәндә бәрелүләрен йомшарту*)

амортизи́ровать *сов., несов. что* амортизацияләү, амортизация ясау

амóрфность *ж* **1.** *мин., хим.* аморфлык, кристаллик төзелеше юклык **2.** *перен.* формасызлык, таркаулык

амóрфн||ый -ая, -ое **1.** *мин., хим.* аморф, кристаллик төзелеше булмаган; **~ое вещество́** аморф матдә **2.** *перен.* формасыз, таркау

ампéр *м физ.* ампер

амперме́тр *м физ.* амперметр

ампи́р *м иск.* ампир (*19 йөз башында Франциядә антик урнәкләр нигезендә барлыкка килгән сәнгать стиле*)

амплиту́да *ж физ.* амплитуда; колач; **~ колеба́ний** тирбәнешләрнең амплитудасы; **~ су́точного измене́ния температу́ры** температураның тәүлек дәвамында үзгәреп тору амплитудасы

амплуá *с нескл. прям., перен.* амплуа; **у негó ~ кóмика** аңарда комик артист амплуасы

а́мпула *ж* ампула (*дару саклау өчен кулланыла торган тар муенлы герметик кечкенә пыяла савыт*)

ампутáционный, -ая, -ое ампутация ...ы

ампута́ция *ж* ампутация, ампутацияләү, кисеп алу; **~ ноги́** аякны кисеп алу

ампути́ровать *сов., несов. что* ампутация ясау, кисеп алу (*операция юлы белән*)

амулéт *м* бәти

амуни́ция *ж* амуниция (*солдатның коралдан һәм кием-салымнан башка кирәк-яраклары*)

амýрничать *несов. прост.* гыйшык (мәхәббәт) эшләре белән чуалу

амýрн||ый, -ая, -ое *шутл.* мәхәббәт ...ы; сөешү ...ы; **~ое письмó** мәхәббәт хаты

амфи́бия *ж* **1.** *зоол., бот.* амфибия **2.** *воен.* амфибия (*суда да, җирдә дә йөри ала торган машина*)

амфибрáхий *м лит.* амфибрахий

амфибрахи́ческий, -ая, -ое *лит.* амфибрахий ...ы; амфибрахик, амфибрахийләрдән төзелгән; **~ размéр** амфибрахик үлчәү; **~ стих** амфибрахийләрдән төзелгән шигырь

амфитеáтр *м* амфитеатр (**1.** *борынгы грекларда һәм римлыларда: цирк сыман тамаша урыны* **2.** *хәзерге театрларда һәм цирклар да: партер артындагы яки ложалар өстендәге югарыгы ярым түгәрәк урын*)

анабио́з *м биол.* анабиоз

анагрáмма *ж лит.* анаграмма

анако́нда *ж зоол.* анаконда, буар елан

анакреонти́ческ||ий, -ая, -ое *лит.* анакреонтик; **~ая поэ́зия** анакреонтик поэзия

анáлиз *м* анализ, тикшерү, анализлау; **~ произведéния** әсәрне тикшерү; **~ крóви** канның анализы

анализáтор *м* анализатор, анализлаучы (**1.** *тех. матдәләрне, күренешләрне анализлый торган приборларның исеме* **2.** *кеше һәм хайван организмнарында — тышкы һәм эчке ярсыткычларны кабул итеп анализлаучы нервлар җыелмасы*)

анализи́ровать *сов., несов. что* анализ ясау, тикшерү, өйрәнү

анали́тик *м* аналитик, анализчы (*һәрьяклап тикшерүче*)

аналити́ческ||ий, -ая, -ое анализ ...ы; аналитик; **~ий мéтод** анализ методы; **~ий ум** аналитик акыл ♦ **~ая геоме́трия** аналитик геометрия; **~ая хи́мия** аналитик химия; **~ие языки́** аналитик телләр

анáлог *м* аналог (*берәр нәрсә белән охшаш, бердәй булган предмет, күренеш*)

аналоги́ческ||ий, -ая, -ое аналогик, аналогиягә нигезләнгән; **~ое мы́шле́ние** аналогик фикер йөртү

аналоги́чность *ж* охшашлык, тиндәшлек, бердәйлек

аналоги́чный, -ая, -ое охшаш, тиндәш, бердәй, тәнгәл; **~ слу́чай** охшаш вакыйга

анало́гия *ж* охшашлык, бердәйлек, тәнгәллек

ананáс *м* ананас (*үсемлек һәм җимеше*)

ананáсн||ый, -ая, -ое, **ананáсов||ый,** -ая, -ое ананас ...ы; **~ые ли́стья** ананас яфраклары; **~ое варéнье** ананас вареньесе

анáпест, *уст.* **анапéст** *м лит.* анапест

анапести́ческий, -ая, -ое *лит.* анапестик; **~ стих** анапестик шигырь

анархи́зм *м полит.* анархизм

анархи́ст *м полит.* анархияче, анархист

анархи́стск||ий, -ая, -ое *полит.* **1.** анархияче[ләр] ...ы; анархист[лар] ...ы; **~ая организа́ция** анархиячеләр оешмасы **2.** анархистик, анархистларча ..., анархистларга хас; **~ие взгля́ды** анархистик карашлар

анархи́ческ||ий, -ая, -ое *прям., перен.* анархизм ...ы; анархия ...ы; анархик; **~ие иде́и** анархизм идеяләре; **~ие явле́ния** анархия күренешләре

анархи́чный, -ая, -ое анархик, тәртипсез, стихияле

анáрхия *ж* **1.** *полит.* анархия, власть-сызлык **2.** *перен. разг.* тәртипсезлек; стихиялелек

анáрхо-синдикали́зм *м полит.* анархо-синдикализм

анáтом *м* анатом, анатомия белгече

анатоми́ровать *сов., несов. кого-что* яру, мәет яру

анатоми́ческий, -ая, -ое анатомик, анатомия ...ы; **~ áтлас** анатомия атласы ♦ **~ теáтр** анатомия театры (*үлекләрне ярып тикшерә торган бина*)

анатоми́чка *ж разг.* анатомия театры

анато́мия *ж* анатомия; **~ челове́ка** кеше анатомиясе; **~ расте́ний** үсемлекләр анатомиясе

анáфема *ж* **1.** *церк.* диннән сөрү, анафема **2.** *бран.* мәлгунь, ләгънәт

анáфора *ж лит.* анафора

анахрони́зм *м* **1.** анахронизм (*бер эпоха вакыйгаларын башка эпохага күчереп хронологияне бозу*) **2.** искелек калдыгы, анахронизм

анахрони́чный, -ая, -ое анахронизм ...ы; анахронистик, искелек калдыгы булып торган

анаэро́бн||ый, -ая, -ое *биол.* анаэроб ...; **~ые бакте́рии** анаэроб бактерияләр

анаэро́бы *мн.* (*ед.* **анаэро́б** *м*) *биол.* анаэроблар (*ирекле кислород булмаганда да яши һәм үрчи ала торган организмнар*)

ангажеме́нт *м уст.* ангажемент (*артистларны договор буенча билгеле бер срокка эшкә чакыру*); **получи́ть ~** ангажемент алу

ангажи́ровать *сов. несов.* **1.** *кого-что* (*предложить ангажемент*) ангажемент тәкъдим ите **2.** *кого* (*приглашать на танец*) танцевать итәргә чакыру, биергә чакыру

ангáр *м* ангар

áнгел *м прям., перен.* фәрештә; **~ красоты́** матурлык фәрештәсе; **мой ~** фәрештәм

áнгельск||ий, -ая, -ое **1.** фәрештә ...ы; **2.** *перен. разг.* фәрештәләрчә ..., ягымлы, мәләем, нәфис; **~ий хара́ктер** ягымлы холык; **~ий гóлос** нәфис тавыш; **~ая улы́бка** мәләем елмаю

ангидри́д *м хим.* ангидрид

анги́на *ж* ангина, тамак бакасы

англи́йск||ий, -ая, -ое инглиз[ләр] ...ы; Англия ...ы; **~ий язы́к** инглиз теле ♦ **~ая соль** инглиз тозы (*эчне йомшарта торган дару*)

англича́не *мн.* инглизләр, инглиз халкы

англича́нин *м* инглиз

англича́нка *ж* инглиз хатыны (кызы)

анда́нте *муз.* **1.** *нареч.* анданте, әкрен, салмак (*музыкаль әсәрнең башкарылу темпына карата*) **2.** *с нескл.* анданте (*салмак темптагы музыкаль әсәр яки аның бер өлеше*)

аневри́зма *ж мед.* аневризм; **~ ао́рты** аорта аневризмы

анекдóт *м прям., перен.* анекдот, мәзәк; **рассказáть ~** анекдот сөйләү

анекдоти́ческий, -ая, -ое **1.** анекдот ...ы; мәзәк ...ы; **~ расска́з** анекдот хикәясе **2.** анекдотка хас, анекдотка охшаган, кеше ышанмаслык

анекдоти́чный, -ая, -ое *см.* **анекдоти́ческий** 2

АНЕ-АНТ

анеми́ческий, -ая, -ое аз канлы; **~ое состоя́ние** аз канлы булу

анеми́чный, -ая, -ое **1.** *см.* **анеми́ческий**; **2.** *перен.* зәгыйфь, сүлпән, төсе киткән

анеми́я *ж мед.* анемия, кан азлык, аз канлылык

анемо́метр *м* анемометр (*һава хәрәкәтенең тизлеген үлчәү приборы*)

анеро́ид *м* анероид (*барометрның бер төре*)

анестезио́лог *м* анестезиолог, анестезия белгече

анестези́р||овать *сов., несов. что, мед.* анестезияләү, авырту сизүне бетерү, авыртусызландыру; **~ующие сре́дства** авырту сизүне бетерә торган дарулар

анестези́я *ж мед.* (*обезболивание*) анестезия, анестезияләү, авырту сизүне бетерү; **ме́стная ~** аерым урынны анестезияләү (*организмның*)

анили́н *м хим.* анилин

анили́нов||ый, -ая, -ое **1.** анилин ...ы; **~ый заво́д** анилин заводы **2.** *хим.* анилинлы; **~ая соль** анилинлы тоз

анимали́ст *м* анималист (*хайваннар рәсемен яки сынын ясаучы рәссам яки скульптор*)

аними́зм *м* анимизм (*борынгылар фикеренчә, табигатьтәге барлык предметларны җанлы дип санау*)

анимисти́ческ||ий, -ая, -ое анимистик; **~ие ве́рования** анимистик ышанулар

ани́с *м* әнис (**1.** *үсемлек һәм орлыгы* **2.** *алма төре*)

ани́совка *ж* **1.** әнис алма **2.** әнис аракысы (*әнистә тәнәтелән аракы*)

ани́сов||ый, -ая, -ое **1.** әнис ...ы; **~ое се́мя** әнис орлыгы **2.** әнис ...ы; әнистә тәнәтелгән; **~ое ма́сло** әнис мае; **~ая во́дка** әнис аракысы

а́нкер *м* анкер (**1.** *сәгать теленең көйләгече* **2.** *корылмаларда тимер ныгыткыч*)

а́нкерн||ый, -ая, -ое анкерлы; **часы́ с ~ым хо́дом** анкерлы сәгать

анке́т||а *ж* анкета; **запо́лнить ~у** анкета тутыру

анке́тн||ый, -ая, -ое анкет ...ы; **~ые све́дения** анкет мәгълүматлары

анна́л||ы *только мн.* (*летопись*) елъязмалар **♦ в ~ах исто́рии** тарих битләрендә

аннекси́ровать *сов., несов. что* аннексияләү, көчләп тартып алу

анне́ксия *ж* аннексия, көчләп тартып алу

аннота́ция *ж* аннотация (*китапның мәкаләнең һ.б.ш. эчтәлеге турында кыскача аңлатма*)

анноти́ровать *сов., несов. что* аннотацияләү, аннотация язу

аннули́ровать *сов., несов. что* көчен бетерү, гамәлдән чыгару, көченнән чыгару; **~ догово́р** договорны гамәлдән чыгару

аннуля́ция *ж книж.* көчен бетерү, гамәлдән чыгару, көченнән чыгару, юкка чыгару (*законны, карарны, договорны һ.б.ш.*)

ано́д *м физ.* анод

анодирование *с см.* **анодировать**

анодировать *сов., несов. что* анодизацияләү, анодлау

ано́дн||ый, -ая, -ое *физ.* анод ...ы; **~ая батаре́я** анод батареясе

анома́лия *ж* аномалия (*нормадан читкә чыгу*); **магни́тная ~** магнит аномалиясе

анома́льн||ый, -ая, -ое аномаль, нормадан авышкан, аномалияле; **~ое состоя́ние** аномаль хәл

анони́м *м* аноним (**1.** *әсәрендә, хатында үзенең исемен яшергән автор* **2.** *авторның исеме курсәтелмәгән әсәр*)

анони́мка *ж разг.* имзасыз хат, аноним хат

анони́мн||ый, -ая, -ое аноним ..., имзасыз; **~ое письмо́** аноним хат

ано́нс *м* анонс (*концерт, лекция һ.б.ш. турында алдан бирелгән кыскача игълан, белдерү*)

анонси́ровать *сов., несов. что, о чём* алдан белдерү, алдан игълан итү (*берәр нәрсә турында*)

анорма́льн||ый, -ая, -ое нормаль булмаган; **~ые явле́ния** нормаль булмаган күренешләр

ано́фелес *м* анофелес (*малярия озынборыны*)

ансамбль *м в разн. знач.* ансамбль; **~ пе́сни и пля́ски** җыр һәм бию ансамбле; **архитекту́рный ~** архитектура ансамбле; **стру́нный ~** кыллы ансамбль

антагони́зм *м* антагонизм (*килешә алмаслык, каршылык*); **кла́ссовый ~** сыйнфый антагонизм

антагони́ст *м* антагонист (*килешә алмаслык дошман*)

антагонисти́ческ||ий, -ая, -ое антагонистик, килешә алмаслык; **~ие противоре́чия** антагонистик каршылыклар

Анта́рктика *ж* Антарктика

антаркти́ческ||ий, -ая, -ое антарктик, Антарктида ...ы; **~ий материк** Антарктида материгы; **~ая экспеди́ция** антарктик экспедиция

анте́нна *ж* антенна; **телевизио́нная ~** телевизор антеннасы

анти- *приставка, татар теленә «каршы» дигән сүз белән тәрҗемә ителә, мәс.* **антирелигио́зный** дингә каршы; **антивое́нный** сугышка каршы

антиалкого́льн||ый, -ая, -ое **1.** алкогольгә каршы; **~ое сре́дство** алкогольгә каршы чара **2.** алкоголизмга каршы; **~ая пропага́нда** алкоголизмга каршы пропаганда

антибио́тики *мн.* (*ед.* **антибио́тик** *м*) антибиотиклар (*микроорганизмнар эшләп чыгара торган бактерияләрне һәм микробларны үтерүгә сәләтле булган химик матдә*)

антивое́нный, -ая, -ое сугышка каршы

антидемократи́ческий, -ая, -ое демократиягә каршы, антидемократик

антиимпериалисти́ческий, -ая, -ое антиимпериалистик, империализмга каршы; **междунаро́дный ~ ла́герь** халыкара антиимпериалистик лагерь

антииститори́ческий, -ая, -ое тарихка каршы

антиква́р *м* антиквар (*борынгы әйберләр белән сәүдә итүче; борынгы әйберләр һәвәскәре*)

антиквариа́т *м* борынгы әйберләр белән сату итү

антиква́рн||ый, -ая, -ое **1.** антиквар ...; борынгы һәм кыйммәтле; **~ая вещь** борынгы һәм кыйммәтле әйбер **2.** антиквар[лар] ...ы; борынгы әйберләр ...ы; **~ый магази́н** борынгы әйберләр кибете

антикоммуни́зм *м* антикоммунизм (*коммунистик теориягә һәм практикага каршы идеология һәм сәясәт*)

антикоммунисти́ческий -ая, -ое антикоммунистик, коммунизмга каршы

антило́па *ж зоол.* антилопа

антимаркси́стский, -ая, -ое антимарксистик, марксизмга каршы

антиматериалисти́ческий, -ая, -ое антиматериалистик, материализмга каршы

антимилитари́зм *м* антимилитаризм (*милитаризмга һәм империалистик сугышларга каршы масса-күләм халыкара хәрәкәт*)

антимилитари́ст *м* антимилитарист

антимилитаристи́ческий, -ая, -ое, **антимилитари́стский,** -ая, -ое антимилитаристик (милитаризмга) каршы

антимо́н||ия *ж*: **разводи́ть ~и** *прост.* юк-барны сөйләү, сафсата сату, суган сату, ләчтит сату

антинаро́дный, -ая, -ое халыкка каршы; халык ихтыяҗларына каршы

антинау́чн||ый, -ая, -ое фәнгә каршы, фәнни булмаган; **~ые реакцио́нные тео́рии** фәнгә каршы реакцион теорияләр

антинациона́льн||ый, -ая, -ое милләткә каршы, милләт ихтыяҗларына каршы; **~ая поли́тика** милләт ихтыяҗларына каршы сәясәт

антиобще́ственный, -ая, -ое җәмгыятькә каршы; **~ поступо́к** җәмгыятькә каршы эш

антипартийный, -ая, -ое партиягә каршы, партия ихтыяҗларына каршы

антипати́чн||ый, -ая, -ое нәфрәт тудыра торган, сөйкемсез, биздерә торган; **~ая ли́чность** нәфрәт тудыра торган шәхес

антипа́тия *ж* антипатия, нәфрәт тойгысы, яратмау тойгысы

антипо́д *м* **1.** *только мн.* **~ы** антипод (*җир шарының бер-беренә капма-каршы ике очында яшәүчеләр*) **2.** антипод (*карашлары, узенчәлекләре яки зәвыкләре ягыннан башкаларга капма-каршы кеше*)

антирелигио́зн||ый, -ая, -ое дингә каршы; **~ая пропага́нда** дингә каршы пропаганда

антисанита́рн||ый, -ая, -ое санитариягә каршы, санитария кагыйдәләренә каршы; **~ые усло́вия** санитария кагыйдәләренә каршы шартлар

антисеми́т *м* антисемит (*еврейларне дошман күруче*)

антисемити́зм *м* антисемитизм (*еврейларне дошман куру, еврейларгә дошманлык*)

антисеми́тск||ий, -ая, -ое антисемитларча ..., еврейләргә каршы

антисе́птика *ж мед.* антисептика (**1.** *җәрәхәтләрне йогышсызландыру* **2.** *собир. яраларны йогышсызландыру дарулары*)

антисепти́ческ||ий, -ая, -ое *мед.* антисептик, йогышсызландыру ...ы; **~ие сре́дства** антисептик чаралар

антисоветизм *м ист.* антисоветизм (*Советлар Союзына, совет төзелешенә, тормыш-конкурешенә дошман булган идеология һәм саясәт*)

антисове́тский, -ая, -ое совет хакимиятенә каршы, советларга каршы

антите́за *ж* антитеза, капма-каршылык, каршы кую

антите́зис *м филос., лог.* антитезис

антител́а *мн.* (*ед.* **антите́ло** *с*) *биохим.* антитәнчекләр

антитокси́ны *мн.* (*ед.* **антитокси́н** *м*) *биохим.* антитоксиннар

антитокси́ческ||ий, -ая, -ое антитоксик, зарарсызландыра торган, агуга каршы; **~ая сы́воротка** антитоксик сыворотка

антифаши́ст *м* антифашист

антифаши́стск||ий, -ая, -ое антифашистик, фашизмга каршы; **~ое движе́ние** фашизмга каршы хәрәкәт

анти́христ *м* **1.** *рел.* дәҗҗәл **2.** *прост.* динсез, кыфер, мөртәт

антихудо́жественный, -ая, -ое сәнгатькә каршы

антицикло́н *м метеор.* антициклон

античасти́цы *мн.* (*ед.* **античасти́ца** *ж*) *физ.* антикисәкчекләр

анти́чн||ый, -ая, -ое антик; **~ое иску́сство** антик сәнгать

антоло́гия *ж* антология (*төрле авторларның сайланма әсәрләре җыентыгы*)

анто́ним *м лингв.* антоним

анто́новка *ж* антоновка (*алма төре*)

антра́кт *м* антракт, тәнәфес

антраци́т *м* антрацит

антраци́тн||ый, -ая, -ое, **антраци́тов||ый,** -ая, -ое антрацит ...ы; **~ые месторожде́ния** антрацит чыганаклары

антраша́ *с нескл.* антраша (*балетта биегәндә сикереп аякларны берничә кат бер-беренә бәрү*)

антреко́т *м* антрекот (*сыер итеннән тапап хәзерләнгән котлет*)

антрепренёр *м* антрепренёр

антресо́ль *мн.* антресоль

антропо́лог *м* антрополог, антропология белгече

антропологи́ческ||ий, -ая, -ое антропология ...ы, антропологик; **~ие иссле́дования** антропологик тикшеренүләр; **~ий музе́й** антропология музее

антрополо́гия *ж* антропология (*кешенең биологик табигатен өйрәнә торган фән*)

антропометри́ческ||ий, -ая, -ое антропометрия ...ы, антропометрик; **~ие да́нные** антропометрик мәгълүматлар

антропоме́трия *м* антропометрия (*фәннең кеше гәүдәсен һәм аның кисәкләрен үлчәү белән шөгыльләнә торган тармагы*)

антропоморфи́зм *м* антропоморфизм (**1.** *борынгы кешеләрнең фикер йөртүе буенча, кешенең үзлекләрен җансыз предметларга күчеру* **2.** *кайбер карашлар буенча алла кеше сурәтендә була дип уйлау*)

анфа́с *нареч.* анфас (*туп-туры карганда кеше битенең куренеше*)

анча́р *м бот.* анчар

анчо́ус *м* анчоус (*вак балык төре*)

аншла́г *м* аншлаг (*театр, концертка һ.б.ш. билетлар сатылып бетү турында белдерү, игълан*)

аню́тин: ~ы гла́зки *бот.* ала миләүшә, елан күзе

а́орист *м лингв.* аорист

а́орта *ж анат.* аорта

апарта́менты, апартаме́нты *мн.* апартамент (*зиннәтле зур бүлмә яки бина*)

апартеи́д *м ист.* апартеид (*Көньяк Африка республикаларында аз санлы ак тәнлеләр интересы өчен кара һәм төсле тәнле төп халыкны раса ягыннан аерым тоту һәм дискриминацияләү сәясәте*)

апати́т *м мин.* апатит

апати́тов||ый, -ая, -ое *мин.* апатит ...ы; **~ые месторожде́ния** апатит ятмалары

апати́ческ||ий, -ая, -ое **1.** дәртсезлек ...ы, төшенкелек ...ы; **~ое состоя́ние** төшенкелек хәле **2.** төшенке, рухсыз, дәртсез, апатияле; **~ий взгляд** апатияле караш

апати́чный, -ая, -ое **1.** *см.* **апати́ческий; 2.** рухсыз, дәртсез; **~ челове́к** дәртсез кеше

баснослО́вн||ый, -ая, -ое кеше ышанмаслык, акылга сыймаслык; чиктән тыш ...; чиктән тыш зур; **~ая дешеви́зна** чиктән тыш арзанчылык

ба́сн||я *ж* **1.** мәсәл **2.** *обычно мн.* **~и** (*небылицы*) уйдырмалар, әкиятләр; **расска́зывать ~и** әкиятләр сөйләү

басО́в||ый, -ая, -ое бас ...ы; **~ая па́ртия** бас партиясе ♦ **~ый ключ** *муз.* бас ачкыч (*түбән регистр ачкычы*)

басО́к *м* **1.** *разг.* уртача калын тавыш **2.** (*струна*) бас кылы

бассе́йн *м в разн. знач.* бассейн; **~ Во́лги** Идел бассейны; **зи́мний ~** кышкы бассейн; **каменноуго́льный ~** ташкүмер бассейны

ба́ста *межд.* җитәр, җитте, булды, бетте, вәссәлам

бастио́н *м воен.* бастион (*бишпочмак формасында төзелгән хәрби ныгытма*)

бастио́нн||ый, -ая, -ое *воен.* бастион ...ы; **~ые укрепле́ния** бастион ныгытмалары

бастова́ть *несов.* эш ташлау, забастовка ясау

басурма́н *м уст.* басурман (*башка диндәге кеше — гадәттә ислам динендәге кеше*)

бата́лист *м жив.* баталист (*сугыш куренешләре турында рәсем ясаучы художник*)

бата́лия *ж* **1.** *уст.* сугыш, баталия **2.** *разг.* ызгыш, талаш; кычкырыш

бата́льн||ый, -ая, -ое баталия ...ы, сугыш ...ы; **~ая жи́вопись** баталия рәсемнәре

батальО́н *м* батальон; **та́нковый ~** танк батальоны

батальО́нный, -ая, -ое батальон ...ы; **~ командИ́р** батальон командиры

батаре́я *ж в разн. знач.* батарея; **миномётная ~** миномёт батареясе; **~ радиоприёмника** радиоалгыч батареясе; **~ парово́го отопле́ния** пар белән җылыту батареясе ♦ **~ буты́лок** *шутл.* шешәләр батареясе

ба́тенька *м прост.* (*при обращении*) туганкай

батиска́ф *м* батискаф (*су астында күзәтүләр алып бару өчен үзйөрешле махсус җиһазландырылган камера*)

бати́ст *м* батист (*тукыма*)

бати́стов||ый, -ая, -ое батист ...ы, батист ..., батисттан тегелгән; **~ое пла́тье** батисттан тегелгән күлмәк

батО́г *м уст.* **1.** таяк, таяну таягы **2.** *мн.* **~и́** (*палки для наказания*) җәза таягы

батО́н *м* батон, күмәч; **све́жий ~** яңа пешкән күмәч

батра́к *м* батрак; ялчы

батра́цкий, -ая, -ое батрак[лар] ...ы; ялчы[лар] ...ы; **~ труд** батраклар хезмәте

батра́чество *с* **1.** (*занятие батрака*) батраклык **2.** *собир.* батраклар; ялчылар

батра́чить *несов.* батраклык итү, батрак булып эшләү; ялчы булып эшләү

батра́чка *ж* батрак хатын (кыз)

баттерфля́й *м спорт.* баттерфляй (*йөзүнең бер стиле*)

ба́тюшк||а *м* 1. *уст.* эти 2. (*священник*) батюшка 3. *разг.* (*при обращении*) туганкай, агай ♦ **~и [мой]!** я рабби!, я алла!

ба́тя *м прост. см.* **оте́ц** 1, 4

ба́ул *м* баул, юл сандыгы

бах *межд.* шап, доңк, гөрс

ба́хать *несов. см.* **ба́хнуть**

бахва́л *м прост.* мактанчык, шапырынучы

бахва́литься *несов. прост.* мактану, шапырыну

бахва́льство *с прост.* мактанчыклык, шапырынучанлык

бахи́лы *мн.* 1. озын кунычлы йомшак итек 2. тукыма йомшак итек (*аяк киеме өстеннен киелә*)

ба́хну||ть *сов. однокр. разг.* 1. гөрселдәп кую, шарт итү, гөрс итү; **~ло ору́дие** туп гөрселдәп куйды 2. *кого-что* (*с шумом бросить, ударить*) шап итеп бәрү (сугу, төшерү); бәреп вату

бахрома́ *ж* чук, чачак

бахро́мчатый, -ая, -ое 1. (*с бахромой*) чуклы, чачаклы 2. (*похожий на бахрому*) чачакка охшаган

бахча́ *ж* бакча (*кавын, карбыз бакчасы*)

бахчево́д *м* бакчачы, бакчачылык белгече

бахчево́дство *с* бакчачылык

бац *межд.* чалт, шалт, шап, чалт бернә (*сукты, чәпәде*)

баци́лла *ж* бацилла; **туберкулёзная ~** туберкулёз бацилласы

ба́шенн||ый, -ая, -ое башня ...ы, башнялы; **~ые часы́** башня сәгате; **~ый кран** башнялы кран

башка́ *ж прост.* баш

башки́р *м* башкорт, башкорт кешесе

башки́рка *ж* башкорт хатыны (кызы)

башки́рский, -ая, -ое башкорт[лар] ...ы, Башкортстан ...ы; **~ язы́к** башкорт теле

башки́ры *мн.* башкортлар, башкорт халкы

башкови́тый, -ая, -ое *прост.* башлы, акыллы

башлы́к *м* башлык

башма́к *м* 1. башмак 2. *тех.* башмак (*вагоннарны туктату өчен тәгәрмәч астына куела торган җайланма*) ♦ **быть (находи́ться) под ~о́м** *у кого* олтырак булу

башма́чник *м* башмакчы, башмак тегүче

ба́шня *ж* 1. башня, манара, каланча 2. башня; **~ та́нка** танк башнясы

баштан *м диал. см.* **бахча́**

ба́ю-ба́й *межд.* бәлли-бәү, бәү-бәү

ба́ю-ба́юшки-баю́, ба́юшки-баю́ *см.* **ба́ю-ба́й**

баю́канье *с см.* **баю́кать**

баю́кать *несов. кого* бәү-бәү иттерү; көйли-көйли тирбәтү

баян *м* баян

баяни́ст *м* баянчы, баянда уйнаучы

бде́ние *с см.* **бдеть**

бдеть *несов. книжн.* 1. (*не спать*) уяу булу, йокламау, вакытны йокламыйча үткәрү 2. (*следить за чем-л.*) ник күзәтү, күзәтеп тору

бди́тельность *ж* уяулык, сизгерлек, саклык; **прояви́ть ~** сизгерлек күрсәтү

бди́тельный, -ая, -ое уяу, сизгер, сак

бег *м* 1. *см.* **бе́гать** 1, **бежа́ть** 1; **уста́ть от ~а** йөгереп ару; **~ на ме́сте** бер урында йөгерү (*физкультура кунегуе*) 2. *спорт.* йөгереш, узыш; **чемпио́н по ~у** йөгереш чемпионы; **~ на сто ме́тров** йөз метрга йөгереш 3. *перен.* кызу хәрәкәт, тиз узу; **~ вре́мени** вакытның тиз узуы 4. *мн.* **~а́** бәйге, юртаклар чабышы; **пойти́ на ~а́** бәйгегә бару ♦ **в ~а́х** эш артыннан йөрү

бе́га||ть *несов.* 1. (*вообще*) йөгерү; (*в разных направлениях*) йөгереп йөрү; **де́ти ~ют на у́лице** балалар урамда йөгереп йөриләр 2. (*избегать кого-чего-л.*) качу; качып йөрү; **от де́ла не ~й** эштән качма 3. *за кем, разг.* артыннан йөрү 4. *перен.* (*о глазах*) ялтйолт итү, ялт-йолт итеп тору, уйнаклап тору; **глаза́ у него́ так и ~ют** күзләре ялт-йолт итеп тора

бегемо́т *м* (*самец*) су үгезе; (*самка*) су сыеры

бегле́ц *м* качкын

бе́глость *ж* йөгереклек, тизлек, җәһәтлек (*укуда, музыка коралында уйнауда*)

бе́гл||ый, -ая, -ое 1. качкан, качып киткән; **~ые крестья́не** качып киткән крестьяннар 2. *в знач. сущ.* **~ый** *м* качкын, качкан кеше 3. йөгерек, тиз; **~ое чте́ние** йөгерек уку; **~ая игра́** тиз уйнау (*музыка коралында*) 4. өстән-өстән генә (*эшләнгән*), игътибарсыз гына (*эшләнгән*); **~ый обзо́р** өстән-өстән генә күзәтү ♦ **~ые гла́сные** *лингв.* төшеп кала торган сузыклар; **~ый ого́нь** *воен.* тиз-тиз атыш

бегов||о́й, -а́я, -о́е 1. чабыш ...ы; **~а́я ло́шадь** чабыш аты 2. узыш ...ы, узышу ...ы, ярышу ...ы; **~а́я доро́жка** узышу сукмагы

бего́м *нареч.* йөгереп, тиз генә, бик тиз

бего́ния *ж бот.* карабодай гөле, бегония

беготн||я́ *ж* 1. арлы-бирле йөгереп йөрү; **де́ти по́дняли ~ю** балалар арлы-бирле йөгерә башладылар 2. *перен.* (*хлопоты, спешка*) ыгы-зыгы

бе́гство *с* 1. (*самовольный уход*) качу, качып китү; **~ из пле́на** пленнан качу 2. (*беспорядочное отступление*) тәртипсез чигенү (*сугышта*); **обрати́ться в ~** тәртипсез чигенә башлау

бегу́н *м* йөгерешче, йөгерүче

бегу́нья *ж* йөгерешче хатын (кыз)

бед||а́ *ж* 1. бәла, бәла-каза, хәвефхәтәр 2. *в знач. сказ.* (*очень плохо, трудно*) аптыраш, тынычсызлык; **про́сто ~а́!** аптыраш! ♦ **~а́ как ...** бик ..., бөтенләй ...; **~а́ как надое́ло** бөтенләй туйдырып бетерде; **на ~у́** бәхетсезлеккә каршы, бәлагә каршы; **не ~а́** зарар юк, куркырлык урын юк; **что за ~а́!** борчылыр урын юк!, булса соң!, булса ни кайгы!

бедла́м *м разг.* (*неразбериха, беспорядок*) искиткеч тәртипсезлек, чуалчыклык, ыгы-зыгы, шау-шу

беднéть *несов.* ярлылану, фәкыйрьләну

бе́дность *ж* 1. ярлылык, фәкыйрьлек; мохтаҗлык 2. *перен.* сайлык; ярлылык; **~ мы́сли** фикернең сайлыгы

беднота́ *ж собир.* ярлы-ябагай, ярлылар, ярлы халык

бе́дн||ый, -ая, -ое 1. (*небогатый*) ярлы, фәкыйрь; **~ый челове́к** фәкыйрь кеше 2. *перен.* ярлы; **~ая приро́да** ярлы табигать; **~ая фанта́зия** ярлы фантазия 3. (*несчастный*) мескен, бичара, бәхетсез

бедня́га *м, ж разг.* мескен, бичара, бәхетсез кеше

бедня́жка *м, ж разг.* мескенкәй, бичаракай

бедня́к *м* ярлы крестьян, авыл ярлысы

бедня́цк||ий, -ая, -ое ярлы крестьян[нар] ...ы; **~ое хозя́йство** ярлы крестьян хуҗалыгы

бедо́вый, -ая, -ое *разг.* 1. (*смелый*) кыю, базымчан, үткен 2. (*разбитной*) елгыр, җитез

бе́дренн||ый, -ая, -ое бот ...ы; **~ая кость** бот сөяге

бедро́ *с* бот

бе́дственн||ый, -ая, -ое бәлалы, бәла-казалы, хәвефле, авыр; **~ое положе́ние** авыр хәл

бе́дствие *с* бәла-каза, һәлакәт, афәт, зур бәхетсезлек

бе́дствовать *несов.* мохтаҗлыкта яшәү, фәкыйрьлектә яшәү, авыр көн күрү

бедуи́н *м* бәдәви (*күчмә гарәп*)

беж *прил. неизм.* аксыл көрән

беж||а́ть 1. *несов.* (*вообще*) йөгерү; (*туда*) йөгереп бару; (*сюда*) йөгереп килү; (*напр. о лошади*) чабу, чабып бару 2. *несов. разг.* ташу; **самова́р ~и́т** самавыр ташый; **молоко́ ~и́т** сөт ташый 3. *сов., несов.* (*спасаться, спастись бегством*) качу, качып китү; **~а́ть из пле́на** пленнан качу 4. *несов.* агу; **река́ ~и́т** елга ага; **вода́ ~и́т из кра́на** кранннан су ага; **слёзы бегу́т** күз яшьләре ага; **го́ды бегу́т** еллар уза; **облака́ бегу́т** болытлар агыла; **часы́ бегу́т** сәгать алга китә

бе́жевый, -ая, -ое аксыл көрән

бе́женец *м* качак

бе́женка *ж* качак хатын (кыз)

без (безо) *предлог с род.п.* 1. (*при указании на недостаток, отсутствие кого-чего-л.*) ...сыз; ...дан башка; **оста́вить ~ отве́та** җавапсыз калдыру; **э́то сде́лано ~ посторо́нней по́мощи** бу чит кешеләрнең ярдәменнән башка эшләнде 2. (*в отсутствие*) югында (*эшләнде*), юк чакта; **~ вас приходи́ли посети́тели** сез югында кешеләр килде 3. (*за вычетом*) ...дан ким; **метр ~ трёх сантиме́тров** метрдан өч сантиметр ким ♦ **без вести** хәбәрсез; **~ ма́лого** диярлек; **~ ма́лого три го́да** өч ел диярлек; **~ огля́дки** артына карамыйча, алдынартын карамый; **~ пяти́ шесть** 1) (*на вопрос «который час?»*) алты туларга биш минут; 2) (*на вопрос «в котором*

часу?») алты туларга биш минут калгач; ~ **у́стали** армый-талмый; ~ **у́молку** туктаусыз, туктамыйча, өзлексез

без- (безъ-, бес-) *приставка* **1.** (*при образовании прил.*) ...сыз; **безно́гий** аяксыз; **безрабо́тный** эшсез; **безве́тренный** җилсез; **бессерде́чный** шәфкатьсез **2.** (*при образовании сущ.*) ...сызлык; **безво́дье** сусызлык; **безве́трие** җилсезлек; **бездоро́жье** юлсызлык; **бессерде́чие** шәфкатьсезлек; **безвку́сица** зәвыксызлык

безаварийн||ый, -ая, -ое авариясез, бәла-казасыз; ~**ое движе́ние** авариясез хәрәкәт

безала́берность *ж* тәртипсезлек; җыйнаксызлык, рәтсезлек

безала́берн||ый, -ая, -ое тәртипсез; буталчыклы, җыйнаксыз, рәтсез; ~**ый челове́к** җыйнаксыз кеше; ~**ая жизнь** тәртипсез тормыш

безала́берщина *ж разг.* буталчыклык, чуалчыклык, ерып чыккысыз тәртипсезлек

безалкого́льн||ый, -ая, -ое алкогольсез, исерткечсез; ~**ые напи́тки** алкогольсез эчемлекләр

безапелляцио́нный, -ая, -ое катгый, категорик, каршы килә алмаслык; ~**тон** каршы килә алмаслык тон

беза́томн||ый, -ая, -ое атомсыз, атом коралы булмаган; ~**ая зо́на** атомсыз зона

безбе́дн||ый, -ая, -ое иркен, җитешлекле, мохтаҗлыксыз; ~**ое существова́ние** иркен тормыш

безбиле́тный, -ая, -ое билетсыз; ~**пассажи́р** билетсыз пассажир

безбо́жие *с* алласызлык, алланы танымау, дәһрилек

безбо́жник *м* алласыз, динсез, дәһри

безбо́жница *ж* алласыз хатын (кыз)

безбо́жный, -ая, -ое оятсыз, инсафсыз; вөждансыз, намуссыз; ~ **враль** оятсыз ялганчы

безболе́зненн||ый, -ая, -ое **1.** авыртусыз, авырттырусыз; ~**ая опера́ция** авырттырусыз операция **2.** *перен.* (*без неприятностей, затруднений*) зарарсыз, зыянсыз

безборо́дый, -ая, -ое сакалсыз

безбоя́зненный, -ая, -ое кыю, куркусыз

безбра́чие *с* буйдаклык; (*мужчины*) өйләнмәү; (*женщины*) кияүгә чыкмау

безбре́жность *ж* очсыз-кырыйсызлык, иксез-чиксезлек

безбре́жный, -ая, -ое очсыз-кырыйсыз, иксез-чиксез; бик зур, бик киң

безве́стност||ь *ж* билгесезлек; **жить в ~и** билгесезлектә яшәү

безве́стный, -ая, -ое билгесез, билгеле булмаган; ~ **геро́й** билгесез герой

безве́тренный, -ая, -ое җилсез, тын, ышыкы; ~ **день** җилсез көн

безве́трие *с* җилсезлек, тынлык, ышыклык

безви́нный, -ая, -ое гаепсез, гөнаһсыз

безвку́сица *ж* зәвыксызлык, татымсызлык; матурлыкны аера белмәү (аңламау), матурлыктан тәм таба белмәү

безвку́сн||ый, -ая, -ое **1.** (*о еде*) тәмсез **2.** зәвыксыз; ямьсез, ятышсыз; ~**ая обстано́вка** ямьсез җиһаз

безвла́стие *с* хакимиятсезлек, хакимият булмау

безво́дн||ый, -ая, -ое **1.** сусыз, суга ярлы, суы аз; ~**ая пусты́ня** сусыз чүл **2.** *хим.* сусыз, су катнашмаган

безво́дье *с* сусызлык, су азлык

безвозвра́тн||ый, -ая, -ое **1.** *книжн.* (*утраченный навсегда*) мәңгегә югалган, кире кайтмый торган **2.** кире алынмый (кайтарылмый) торган; ~**ая ссу́да** кире кайтарылмый торган ссуда

безвозду́шн||ый, -ая, -ое һавасыз; ~**ое простра́нство** һавасыз бушлык

безвозме́здн||ый, -ая, -ое түләүсез, бушлай, акча түләмичә; ~**ое по́льзование** түләүсез файдалану

безво́лие *с* ихтыярсызлык, йомшак характерлылык, җебегәнлек

безволо́сый, -ая, -ое чәчсез, чәч үсмәгән

безво́льный, -ая, -ое ихтыярсыз, йомшак характерлы, җебегән; ~ **челове́к** ихтыярсыз кеше; ~ **хара́ктер** җебегән характер

безвре́дн||ый, -ая, -ое зарарсыз, зыянсыз; ~**ое сре́дство** зарарсыз чара

безвре́менн||ый, -ая, -ое вакытсыз, вакытыннан элек, иртә; ~**ая кончи́на** вакытыннан элек үлү

безвре́менье *с уст.* (*тяжёлое время*) авыр вакыт, бәла-казалар вакыты; торгынлык (*җәмгыятьтә*)

безвы́ездно *нареч.* читкә чыкмыйча, беркая да китмичә (китмәстән); **он ~ живёт в Каза́ни** ул беркая да китмичә Казанда яши

безвы́ходность *ж* котылгысызлык, чарасызлык, аптыраш; ~ **положе́ния** хәлнең котылгысызлыгы

безвы́ходн||ый, -ая, -ое **1.** беркая да чыкмыйча (бармыйча) ...; ~**ое сиде́ние до́ма** беркая да чыкмыйча өйдә утыру **2.** *перен.* (*безысходный*) котылгысыз, чарасыз, аптыраш; ~**ое положе́ние** котылгысыз хәл

безгла́зый, -ая, -ое күзсез, күз[ләр]е сукырайган

безгла́сый, -ая, -ое *уст.* (*не выражающий своего мнения*) кыюсыз, юаш, тавышы да чыкмый торган

безголо́в||ый, -ая, -ое **1.** башсыз; ~**ая ту́ша** башсыз түшкә **2.** *перен. разг.* (*глупый*) башсыз, аңгыра, миңгерәү **3.** *перен. разг.* (*крайне рассеянный*) башсыз, тиз онытучан

безголо́сый, -ая, -ое тавышсыз, начар тавышлы; ~ **певе́ц** тавышсыз җырчы

безгра́мотность *ж* **1.** (*неграмотность*) грамотасызлык, наданлык, укый-яза белмәү **2.** *перен.* (*невежественность*) наданлык

безгра́мотный, -ая, -ое **1.** (*неграмотный — о человеке*) укый-яза белмәүче, надан, грамотасыз **2.** (*с ошибками*) хаталы, күп хаталы (*мәс. диктант хакында*) **3.** *перен.* (*невежественный*) надан; мәгълүматсыз; ~ **худо́жник** надан рәссам

безграни́чн||ый, -ая, -ое **1.** чиксез, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз, чиге булмаган; ~**ые просто́ры** очсыз-кырыйсыз киңлекләр **2.** *перен.* чиксез, чиктән тыш зур; ~**ая скорбь** чиктән тыш зур кайгы; ~**ая ра́дость** чиктән тыш зур шатлык

безгре́шный, -ая, -ое гөнаһсыз, гаепсез

безда́рность *ж* **1.** (*отсутствие таланта*) талантсызлык, сәләтсезлек, булдыксызлык, уңмаганлык **2.** (*о человеке*) талантсыз (сәләтсез, булдыксыз) кеше

безда́рн||ый, -ая, -ое **1.** (*лишённый таланта*) талантсыз, булдыксыз, сәләтсез, уңмаган **2.** (*выполненный неталантливо*) талантсыз (эшләнгән), начар (эшләнгән)

бе́здарь *ж разг.* талантсыз кеше, булдыксыз кеше

безде́йствие *с* бер нәрсә дә эшләмәү; чара күрмәү, гамьсезлек

безде́йств||овать *несов.* **1.** (*о людях*) бер нәрсә дә эшләмәү **2.** (*о машинах, предприятиях и т.п.*) эшләмәү, туктап тору; **маши́на ~ует** машина эшләми

безде́лица *ж* вак-төяк, юк-бар нәрсә, әһәмиятсез нәрсә

безделу́шк||а *ж* бизәнү әйбере; **же́нские ~и** хатын-кызларның бизәнү әйберләре

безде́лье *с* эшсезлек, тик йөрү; **вы́нужденное ~** мәҗбүри эшсезлек

безде́льник *м* эшлексез; ялкау

безде́льница *ж* эшлексез хатын (кыз)

безде́льничать *несов.* бер нәрсә дә эшләмәү; ялкаулыкка бирелу (сабышу)

безде́льн||ый, -ая, -ое эшсез; ~**ая жизнь** эшсез тормыш

безде́нежный, -ая, -ое **1.** (*нуждающийся в деньгах*) акчасыз, акчага мохтаж, ярлы; ~ **челове́к** акчага мохтаж кеше **2.** *спец.* акчасыз, акча түләмичә башкарыла торган; ~ **расчёт** акча түләмичә башкарылган расчёт

безде́нежье *с* акчасызлык, акча юклык, акчага мохтажлык

безде́тность *ж* баласызлык, баласы юклык

безде́тный, -ая, -ое баласыз, баласы юк, балалары булмаган

бездефици́тн||ый, -ая, -ое *эк.* дефицитсыз, зыян китермичә эшли торган; ~**ое предприя́тие** дефицитсыз предприятие

безде́ятельность *ж* эшлексезлек, эштә сүлпәнлек

безде́ятельный, -ая, -ое эшлексез, эштә сүлпән

бе́здна *ж* **1.** упкын, тирән чокыр, чоңгыл, тоба; **морска́я ~** диңгез чоңгылы **2.** *перен. разг.* чиксез күп, иксез-чиксез, исәпсез-хисапсыз; ~ **дел** чиксез күп эш

бездо́ждье *с* яңгырсызлык, корылык

бездоказа́тельность *ж* исбатланмаганлык, исбат ителмәгәнлек; ~ **обвине́ния** гаепләүнең исбат ителмәгәнлеге

бездоказа́тельн||ый, -ая, -ое исбатланмаган, исбат ителмәгән; **~ое обвине́ние** исбат ителмәгән гаеп

бездо́мн||ый, -ая, -ое (*о человеке*) йортсыз-җирсез; гаиләсез; (*о животном*) хуҗасыз; оясыз; **~ая соба́ка** хуҗасыз эт

бездо́нн||ый, -ая, -ое төпсез, бик тирән; **~ая про́пасть** бик тирән чокыр ◆ **~ая бо́чка** 1) төпсез мичкә (*файдасызга күп акча тоту турында*); 2) аракы мичкәсе (*күп эчә торган кеше хакында*)

бездоро́жный, -ая, -ое юлсыз, начар юллы

бездоро́жье *с* **1.** (*отсутствие дорог*) юлсызлык, юллар юклык **2.** (*распутица*) юл өзеклек (*ни арба, ни чана вакыт*)

бездохо́дный, -ая, -ое табышсыз, файдасыз, килер бирми торган

бездýмн||ый, -ая, -ое гамьсез, ваемсыз; **~ое житьё** гамьсез яшәү

бездýмье *с* гамьсезлек, ваемсызлык

бездýшие *с* каты күнеллелек, миһербансызлык, **проявúть ~** каты күнеллелек күрсәтү

бездýшн||ый, -ая, -ое **1.** (*бессердечный*) каты күнелле, миһербансыз **2.** рухсыз, дәртсез; күңел салмыйча ...; **~ая игрá актёров** актёрларның рухсыз уйнавы

бездымный, -ая, -ое төтенсез, төтен чыгармый торган; **~ пóрох** төтенсез дары

бездыха́нный, -ая, -ое (*мёртвый*) җансыз, үле

безé *с нескл.* безе (*куперткән йомырка агыннан пешерелгән пирожный*)

безжа́лостность *ж* аяусызлык, рәхимсезлек, шәфкатсезлек

безжа́лостный, -ая, -ое аяусыз, рәхимсез, шәфкатсез

безжúзненн||ый, -ая, -ое **1.** җансыз, үле, үлгән; **~ое те́ло** җансыз гәүдә **2.** *перен.* (*невыразительный*) сүнгән, рухсыз, дәртсез; **~ый взгляд** сүнгән караш

беззабóтность *ж* **1.** (*беспечность*) гамьсезлек, ваемсызлык, кайгысызлык, хәсрәтсезлек **2.** (*отсутствие забот*) мәшәкатьсезлек, мәшәкать булмау

беззабóтн||ый, -ая, -ое **1.** (*о человеке*) гамьсез, ваемсыз, кайгысыз; **~ый челове́к** гамьсез кеше **2.** (*напр. об условиях жизни*) мәшәкатьсез, борчусыз; **~ое житьё** мәшәкатьсез яшәү

беззаве́тн||ый, -ая, -ое үзен аямыйча (*эшләнгән*), җан-тән белән (*эшләнгән*), чын күңелдән (*эшләнгән*), фидакарьләрчә ...; **~ая хра́брость** фидакарьләрчә батырлык; **~ая пре́данность** җан-тән белән бирелгәнлек

беззако́ни||е *с* **1.** (*нарушение закона*) законсызлык, законга каршы китү, закон бозу; **борьба́ с ~ем** законсызлык белән көрәш **2.** (*беззаконный поступок*) законга каршы эш итү, законга каршы эш: **соверша́ть ~я** законга каршы эшләр эшләү

беззако́нный, -ая, -ое законсыз, законга каршы, законга сыймаган; **~ постýпок** законга каршы эш

беззасте́нчивый, -ая, -ое оятсыз, сөмсез; **~ лгун** оятсыз ялганчы

беззащúтность *ж* ярдәмчесезлек, яклаучысызлык; гаҗизлек

беззащúтный, -ая, -ое ярдәмчесез, яклаучысыз; гаҗиз

беззвёздн||ый, -ая, -ое йолдызсыз, йолдызлар булмаган; **~ое не́бо** йолдызсыз күк; **~ая ночь** йолдызсыз төн

беззвýчный, -ая, -ое тавышсыз, тын, ишетелер-ишетелмәс; **~ плач** тавышсыз елау

безземе́лье *с* җирсезлек, җир азлык

безземе́льн||ый, -ая, -ое җирсез, җиргә мохтаж; **~ые крестья́не** җирсез крестьяннар

беззло́бный, -ая, -ое ачусыз; (*о человеке*) йомшак күңелле, юаш; **~ смех** ачусыз көлү

беззýб||ый, -ая, -ое **1.** тешсез, аз тешле **2.** *перен.* көчсез, тешсез, йомшак; **~ая крúтика** көчсез тәнкыйть

безле́сн||ый, -ая, -ое урмансыз, урманга ярлы; **~ая степь** урмансыз дала

безле́сье *с* урмансыз җирләр, урманга ярлы җирләр, урманга ярлылык

безлúк||ий, -ая, -ое үзенчәлексез; төссез; **~ий челове́к** үзенчәлексез кеше; **~ое произведе́ние** төссез әсәр

безлúственный, -ая, -ое агачлары яфраксыз калган, агачлары яфракларын койган; **~ лес** агачлары яфракларын койган урман

безлúстн||ый, -ая, -ое, **безлúст||ый,** -ая, -ое яфраксыз, яфракларын койган; **~ое де́рево** яфракларын койган агач

безли́чн||ый, -ая, -ое үзенчәлексез, характерсыз; **~ый челове́к** характерсыз кеше ◆ **~ый глагóл** *грам.* затланышсыз фигыль; **~ое предложе́ние** *грам.* иясез җөмлә

безлошáдн||ый, -ая, -ое атсыз; **~ое хозя́йство** атсыз хуҗалык

безлýнн||ый, -ая, -ое айсыз; **~ая ночь** айсыз төн

безлю́дн||ый, -ая, -ое **1.** (*малонаселённый*) кешесез; кеше аз яши торган; **~ый райóн** кеше аз яши торган район **2.** (*пустынный*) кешесез, аулак, тын, кеше йөрми торган; **~ая у́лица** кеше йөрми торган урам

безлю́дье *с* кешеләр булмау, кирәкле кешеләр булмау

безмéн *м* бизмән, үлчәү

безмéрн||ый, -ая, -ое чиксез, чамасыз, чиктән тыш зур, чамадан тыш зур; **~ая уста́лость** чиксез арыганлык; **~ая ра́дость** чиктән тыш зур шатлык

безмóзглый, -ая, -ое *разг.* мисез, аңгыра, мингерәү; **~ дура́к** мисез ахмак

безмóлвие *с* тынлык, тынычлык

безмóлвн||ый, -ая, -ое **1.** сүзсез, тавышсыз, сүзсез-нисез, дәшми-нитми; **~ое согла́сие** тавышсыз-тынсыз ризалык **2.** тын, тыныч; **~ая степь** тын дала

безмóлвствовать *несов.* эндәшмәү, берсүз дә әйтмәү, ләм-мим әйтмәү

безмýжняя, -ее *прост.* ирсез; ирсез калган, тол

безмятéжност||ь *ж* тынычлык, тыныч хәл; борчу булмау; **пребывáть в пóлной ~и** тыныч хәлдә яшәү

безмятéжный, -ая, -ое тыныч, борчусыз, гаугасыз; **~ сон** тыныч йокы

безнадёжность *ж* өметсезлек, ышанычсызлык; **~ безнадёжность состоя́ния больно́го очеви́дна** авыру хәленең өметсезлеге ап-ачык

безнадёжный, -ая, -ое өметсез, ышанычсыз; **~ больно́й** өметсез авыру; **~ взгляд** өметсез караш

безнадзóрность *ж* караучысызлык, күзәтүсезлек

безнадзóрный, -ая, -ое караучысыз, күзәтүчесез; **~ ребёнок** күзәтүчесез бала

безнака́занн||ый, -ая, -ое җәзасыз, җәзасыз калдырылган, җәза бирелми калдырылган; **преступле́ние не оста́лось ~ым** жинаять җәза бирелми калдырылмады

безнали́чный, -ая, -ое акчасыз, акча түләнми торган; **~ расчёт** акча түләнми торган расчёт

безнача́лие *с* башлыкның булмавы, башлык булмау

безно́гий, -ая, -ое **1.** аяксыз, аягы өзелгән, аяксыз калган; **~ челове́к** аягы өзелгән кеше **2.** *разг.* аягы сынган; **~ стул** аягы сынган урындык

безно́сый, -ая, -ое **1.** борынсыз, борынсыз калган **2.** *разг.* борыны сынган; **~ ча́йник** борыны сынган чәйнек

безнра́вственность *ж* әхлаксызлык, әдәпсезлек, оятсызлык

безнра́вственный, -ая, -ое әхлаксыз, әдәпсез, оятсыз; **~ посту́пок** әдәпсез кыланыш; **~ челове́к** әхлаксыз кеше

безо *см.* **без**

безоби́дность *ж* хәтер калдырмау, хәтәр калдырмый торган булуы, зарарсызлык; **~ шу́тки** шаяруның хәтер калдырмый торган булуы

безоби́дн||ый, -ая, -ое **1.** хәтер калдырмый торган, үпкәлятми торган; **~ая шу́тка** үпкәлятми торган шаяру **2.** зарарсыз, юаш; **~ое существо́** зарарсыз бер зат

безо́блачность *ж* **1.** болытсызлык, аязлык; **~ не́ба** күкнең болытсызлыгы **2.** *перен.* тынычлык, яктылык, мәшәкатьсезлек; **~ сча́стья** бәхетнең яктылыгы

безо́блачн||ый, -ая, -ое **1.** болытсыз, аяз; **~ое не́бо** болытсыз күк; **~ый день** аяз көн **2.** *перен.* тыныч, якты; мәшәкатьсез; **~ое сча́стье** якты бәхет

безобра́зи||е *с* **1.** (*уродство*) шөкәтсезлек, шыксызлык, ямьсезлек **2.** (*безобразный поступок*) тәртипсезлек, начар эш; **не допуска́ть ~й** тәртипсезлекләр эшләмәскә; **что за ~е!** нинди тәртипсезлек бу!

безобра́з||ить *несов. кого-что* ямьсезләү, шыксызлау, бозып күрсәтү; **э́та оде́жда ~ит его́** бу кием аны ямьсезли

безобра́зник *м разг.* әшәке, тәртипсез [кеше]

безобра́зница *ж разг.* әшәке хатын (кыз)

безобра́зничать *несов. разг.* әшәкеләнү, әшәке кылану, тәртипсезләнү, тыйнаксызлану

безобра́зн||ый, -ая, -ое **1.** (*уродливый, некрасивый*) шыксыз, ямьсез, шөкәтсез, килбәтсез **2.** (*возмутительный*) әшәке, начар; **~ое поведе́ние** әшәке тәртип

безоговоро́чн||ый, -ая, -ое берсүзсез, чикләүсез, каршылыксыз; **~ое согла́сие** берсүзсезризалык; **~ая капитуля́ция** берсүзсез капитуляция ясау

безопа́сно *в знач. сказ.* куркыныч түгел; **здесь ~** монда куркыныч түгел

безопа́сность *ж* куркынычсызлык, хәвеф-хәтәрсезлек, иминлек; **~ у́личного движе́ния** урам хәрәкәтенең куркынычсызлыгы

безопа́сн||ый, -ая, -ое **1.** куркынычсыз, хәвеф-хәтәрсез, имин; **~ое ме́сто** куркынычсыз урын **2.** (*безвредный*) зарарсыз, зарар-зыян китерми торган; **~ое сре́дство** зарарсыз дару

безору́жн||ый, -ая, -ое **1.** коралсыз, коралланмаган **2.** *перен.* гаҗиз, көчсез; **в э́том спо́ре я оказа́лся соверше́нно ~ым** бу бәхәстә мин бөтенләй гаҗиз булып калдым

безостано́вочн||ый, -ая, -ое туктаусыз, өзлексез; **~ое движе́ние** туктаусыз хәрәкәт

безо́ст||ый, -ая, -ое *спец.* кылчыксыз, кылчыксыз башаклы; **~ая пшени́ца** кылчыксыз бодай

безотве́тность *ж* карусызлык, җавапсызлык, сүзсез буйсыну[чанлык], юашлык

безотве́тн||ый, -ая, -ое **1.** җавапсыз; җавапсыз калдырылган; **~ая любо́вь** җавапсыз мәхәббәт **2.** карусыз, җавапсыз, сүз кайтара белми торган; **~ый челове́к** карусыз кеше

безответственность *ж* җавапсызлык

безответственн||ый, -ая, -ое җаваплылыксыз, җаваплылыгы булмаган; **~ое лицо́** җаваплылыксыз кеше; **~ое реше́ние** җаваплылыксыз карар

безотка́зный, -ая, -ое **1.** тоткарсыз, тоткарсыз эшли торган; **~ механи́зм** тоткарсыз эшли торган механизм **2.** баш тартмый торган, карусыз, күндәм; **~ челове́к** карусыз кеше

безотлага́тельн||ый, -ая, -ое кичектергесез, ашыгыч; **~ое де́ло** кичектергесез эш

безотлу́чн||ый, -ая, -ое беркая китми ...; **~ое сиде́ние до́ма** беркая китми өйдә утыру; **~ый сто́рож** беркая китми саклаучы

безотноси́тельный, -ая, -ое нисбәтсез, һәр очракта да дөрес, һәр очракта да үзгәрми торган

безотра́дность *ж* күңелсезлек, юанычсызлык, сөенечсезлек; **~ существова́ния** яшәүнең куанычсызлыгы

безотра́дн||ый, -ая, -ое күңелсез, юанычсыз, сөенечсез; **~ая жизнь** күңелсез тормыш

безотцо́вщина *ж* атасызлык, атасыз үсү

безотчётность *ж* **1.** (*бессознательность*) ихтыярсыз эшләнү, ирексездән эшләнү, абайламыйча эшләнгәнлек **2.** (*отсутствие контроля*) контрольсезлек; исәпләшмәү, санашмау

безотчётный, -ая, -ое **1.** (*бессознательный*) ихтыярсыз (*эшләнгән*), абайламыйча (*эшләнгән*), ирексездән (*эшләнгән*), сәбәпсез (*эшләнгән*); **~ страх** сәбәпсез курку **2.** (*безконтрольный*) контрольсез

безоши́бочность *ж* хатасызлык, ялгышсызлык, дөреслек; **~ сужде́ний** фикерләрнең дөреслеге

безоши́бочный, -ая, -ое хатасыз, ялгышсыз, дөрес; **~ расчёт** дөрес расчёт

безрабо́тица *ж* эшсезлек, эш юклык, эш булмау

безрабо́тный, -ая, -ое эшсез, эшсез калган

безра́достный, -ая, -ое шатлыксыз, куанычсыз; эчпошыргыч

безразде́льн||ый, -ая, -ое бүленмәс; **~ое госпо́дство** бүленмәс хакимлек

безразли́чие *с* кызыксынмау, салкын караш

безразли́чно *нареч.* **1.** салкын, искитмичә; **относи́ться ~** *к кому-чему-либо* салкын карау **2.** *в знач. сказ.* (*всё равно*) барыбер, аермасы юк; **мне э́то ~** бу минем өчен барыбер

безразли́чный, -ая, -ое **1.** (*равнодушный*) кызыксынусыз, салкын; **~ взгляд** салкын караш **2.** (*несущественный*) әһәмиятсез, әһәмияте юк

безрассу́дность *ж см.* **безрассу́дство**

безрассу́дн||ый, -ая, -ое уйламыйча (*эшләнгән*); акылсыз, дуамал; **~ая хра́брость** дуамал батырлык; **~ый посту́пок** акылсыз кыланыш

безрассу́дство *с* акылсызлык, ахмаклык, дуамаллык

безрезульта́тность *ж* нәтиҗәсезлек, уңышсызлык; **~ по́исков** эзләнүләрнең нәтиҗәсезлеге

безрезульта́тный, -ая, -ое нәтиҗәсез, уңышсыз; **~ о́пыт** нәтиҗәсез тәҗрибә

безре́льсовый, -ая, -ое (*о транспорте*) рельссыз, рельссыз йөри торган; (*о дорогах*) рельс салынмаган

безро́гий, -ая, -ое мөгезсез, мүкләк

безро́дный, -ая, -ое **1.** (*не имеющий родственников*) туган-тумачасыз, кардәш-ырусыз **2.** *перен.* (*порвавший связь с народом*) туган иле булмаган, иленнән аерылган **3.** (*неродовитый*) затлы нәселдән булмаган

безро́потность *ж* буйсынучанлык, карышмаучанлык; юашлык, карусызлык

безро́потный, -ая, -ое буйсынучан, карышмаучан; юаш, карусыз

безрука́вка *ж* җиңсез күлмәк

безру́кий, -ая, -ое **1.** кулсыз **2.** *перен. разг.* сәләтсез, булдыксыз, кулыннан эш килми торган

безры́бье *с* балыксызлык, балык юклык ◆ **на ~ и рак ры́ба** *посл.* ≈ ит юкта үпкә тансык

безубы́точн||ый, -ая, -ое зыянсыз, зыян ясамый (китерми) торган; **~ая торго́вля** зыян китерми торган сәүдә; **~ое хозя́йство** зыян китерми торган хуҗалык

безуда́рный, -ая, -ое *лингв.* басымсыз; **~ слог** басымсыз иҗек

безу́держный, -ая, -ое тыелгысыз; **~ смех** тыелгысыз көлү

безукори́зненность *ж* кимчелексезлек, тел тидермәслек, сүз әйтмәслек, әйбәтлек; **~ рабо́ты** эшнең әйбәтлеге

безукори́зненн||ый, -ая, -ое кимчелексез, тел тидермәслек, әйбәт, яхшы; **~ое поведе́ние** әйбәт холык

безу́мец *м* **1.** *уст.* (*сумасшедший*) тиле, акылсыз, акылдан язган **2.** (*безрассудный*) башсыз, ахмак, дуамал

безу́ми||е *с* **1.** *уст.* (*сумасшествие*) акылдан язу; **люби́ть до ~я** акылдан язганчы сөю **2.** (*безрассудство*) чиктән тыш дуамаллык, акылсыз эш

безу́мн||ый, -ая, -ое **1.** *уст.* (*сумасшедший*) акылсыз, тиле, акылдан язган **2.** чиктән тыш дуамал; **~ая отва́га** чиктән тыш дуамал батырлык **3.** *разг.* (*очень сильный*) чиктән тыш [зур], искиткеч көчле; **~ая уста́лость** чиктән тыш арыганлык

безу́молчный, -ая, -ое өзлексез, тоташ, туктаусыз, тынмас

безу́мство *с см.* **безу́мие**

безу́мствовать *несов.* ярсу, дулау, ду килү, дуамаллану, шашу

безупре́чн||ый, -ая, -ое саф, керсез, тел тидермәслек, бик яхшы, мактауга лаек; **~ая рабо́та** тел тидермәслек эш; **~ое поведе́ние** бик яхшы тәртип

безусло́вно *нареч.* **1.** һичшиксез; **он ~ че́стный челове́к** ул һичшиксез намуслы кеше **2.** *в знач. вводн. сл.* һичшиксез, әлбәттә; **~, он ничего́ не знал об э́том** әлбәттә, ул бу турыда бернәрсә дә белмәгән

безусло́вн||ый, -ая, -ое һичсүзсез, берсүзсез; шартсыз, шартлар белән чикләнмәгән, шарт куелмаган; **~ое повинове́ние** берсүзсез буйсыну

безуспе́шность *ж* уңышсызлык, файдасызлык, нәтиҗәсезлек; **~ попы́тки** сынап карауның уңышсызлыгы

безуспе́шн||ый, -ая, -ое уңышсыз, файдасыз, нәтиҗәсез; **~ая попы́тка** уңышсыз сынап карау

безуста́нный, -ая, -ое *уст.* туктаусыз, бертуктаусыз, өзлексез; **~ труд** өзлексез хезмәт

безу́сый, -ая, -ое мыексыз, мыек чыкмаган; **~ мальчи́шка** *перен.* бик яшь малай

безуте́шн||ый, -ая, -ое юанычсыз, юатып булмый торган, кайгыга чумган; **~ое го́ре** юанычсыз кайгы

безу́хий, -ая, -ое колаксыз

безуча́стный, -ая, -ое ваемсыз, салкын йөрәкле, кызыксынмаучан, исе китмәүчән; **~ взгляд** ваемсыз караш

безъя́дерн||ый, -ая, -ое: **~ая зо́на** атомсыз зона (*атом коралы эшләү, саклау һәм куллану тыелган зона*)

безыде́йность *ж* идеясезлек, фикерсезлек

безыде́йный, -ая, -ое идеясез, фикерсез

безымя́нный, -ая, -ое исемсез, исеме билгесез ♦ ~ **па́лец** атсыз бармак

безынициати́вность *ж* инициативасызлык, инициативасы булмау

безынициати́вный, -ая, -ое инициативасыз, инициативасы булмаган

безыску́сственность *ж* садәлек, гадилек; табигыйлек; ~ **мане́р** кыланышларнын садәлеге

безыску́сственный, -ая, -ое садә, гади, табигый; ~ **расска́з** садә хикәя

безысхо́дность *ж* котылгысыз булу, чарасызлык, төзәлмәслек

безысхо́дн||ый, -ая, -ое котылгысыз, чарасыз, төзәлмәс; ~**ое го́ре** төзәлмәс кайгы

бей *м* бәй

бек *м* бәк

бека́с *м* чуллык (*кош*)

беке́ша *ж* бекеш

бекО́н *м* бекон (*ыслап какланган яки аз гына тозланган дуңгыз ите*)

белен||а́ *ж* тилебәрән (*агулы усемлек*) ♦ **что ты, ~ы́ объе́лся?** күктән төштенме әллә?

беле́ние *с см.* **бели́ть** 1, 2

белёный, -ая, -ое агартылган, акка буялган; ~ **потоло́к** агартылган түшәм; ~ **холст** агартылган киндер

белёс||ый, -ая, -ое аксыл; ~**ые ресни́цы** аксыл керфекләр

беле́ть *несов.* **1.** (*виднеться — о чём-л. белом*) агарып күренү, агарып күренеп тору **2.** (*становиться белым*) агару, ак төскә керү

беле́ться *несов. см.* **беле́ть** 1

бе́ли *только мн. мед.* ак килү авыруы (*хатын-кызларда*)

белиберда́ *ж разг.* юк-бар сүз, сафсата, сүз боткасы

белизна́ *ж* аклык

бели́ла *только мн.* **1.** ак буяу; **свинцо́вые** ~ кургашын ак буяу **2.** кершән; **покры́ть лицо́** ~**ми** биткә кершән ягу

бели́льный, -ая, -ое агарту ...ы; ~ **раство́р** агарту измәсе; ~ **чан** агарту чаны

бели́ть *несов. что* **1.** агарту, акка буяу; акшарлау; ~ **потоло́к** түшәмне агарту **2.** (*отбеливать*) агарту (*эрләнгән җепне, тукыманы*) **3.** кершән ягу; ~ **лицо́** биткә кершән ягу

бели́ться *несов.* **1.** кершән ягыну **2.** *страд. от* **бели́ть**

бе́лич||ий, -ья, -ье **1.** тиен ...ы; ~**ья шку́рка** тиен тиресе **2.** тиен ..., тиен мехыннан тегелгән; ~**ья шу́ба** тиен тун

бе́лка *ж* тиен

белко́в||ый, -ая, -ое *биол., хим.* **1.** аксым ...ы; ~**ые вещества́** аксым матдәләре **2.** аксымлы; ~**ые корма́** аксымлы азыклар

белладО́нна *ж* **1.** *бот.* эт җиләге **2.** (*лекарство*) белладонна

беллетри́стика *ж* беллетристика, матур әдәбият

беллетристи́ческ||ий, -ая, -ое беллетристик; матур әдәбият ...ы; ~**ая литерату́ра** беллетристик әдәбият

белобиле́тник *м разг.* ак билетлы (*гаскәри хезмәткә яраксыз табылган никрут*)

белобО́к||ий, -ая, -ое ак янтыклы; **сорО́ка-~а** ак янтыклы саескан

белобры́с||ый, -ая, -ое **1.** аксыл чәчле, җитен чәчле; ~**ый ма́льчик** аксыл чәчле малай **2.** ак, аксыл, җитен төсендәге; ~**ые ресни́цы** аксыл керфекләр

белови́к *м* аклама, акка күчереп язылган кулъязма

белово́й, -а́я, -о́е акка язылган, чистага язылган, аклама; ~ **экземпля́р ру́кописи** акка язылган кулъязма

белогвардеец *м* акгвардияче

белогвардейский, -ая, -ое акгвардиячеләр ...ы; ~ **отря́д** акгвардиячеләр отряды

белО́к *м* **1.** (*яйца́*) йомырка агы **2.** (*гла́за*) күз агы **3.** *биол., хим.* аксым

белокро́вие *с мед.* акканлылык (*авыру*)

белоку́р||ый, -ая, -ое **1.** сары чәчле; ~**ая де́вочка** сары чәчле кыз **2.** (*о волосах*) сары, аксыл

белоли́цый, -ая, -ое ак йөзле, ак чырайлы

белору́с *м* белорус, белорус кешесе

белору́ска *ж* белорус хатыны (кызы)

белору́сский, -ая, -ое белорус[лар] ...ы; Белоруссия ...ы; ~ **язы́к** белорус теле

белору́сы *мн.* белоруслар, белорус халкы

белору́чка *м, ж* аксөяк, эш сөймәүче

белорыби́ца *ж* акбалык

белоснЕ́жный, -ая, -ое ап-ак, кардай ак

белоте́лый, -ая, -ое ак тәнле

белошве́йка *ж* тегүче (*кулмәкләр тегүче хатын-кыз*)

белошве́йн||ый, -ая, -ое күлмәк тегү ...ы; ~**ая мастерска́я** күлмәк тегү мастерское

белоэмигра́нт *м* ак эмигрант

белу́га *ж* кырпы балыгы, белуга

белу́ж||ий, -ья, -ье кырпы [балыгы] ...ы; ~**ья и́кра** кырпы уылдыгы

бе́л||ый, -ая, -ое **1.** ак; ~**ая бума́га** ак кәгазь **2.** ак; аклар ...ы; ~**ая а́рмия** аклар армиясе; ~**ый офице́р** ак офицер; ~**ая гва́рдия** ак гвардия **3.** *в знач. сущ.* ~**ые** *мн.* аклар **4.** (*белокожий*) ак тәнле; ~**ая ра́са** ак тәнле раса ♦ ~**ая кость** *ирон.* аксөяк (*дворяннарга карата әйтелә*); **Бе́лая олимпиа́да** Ак олимпиада; ~**ое мя́со** кош (бозау) ите; ~**ые стихи́** *лит.* ак шигырьләр; ~**ый биле́т** ак билет (*авыру сәбәпле хәрби хезмәттән азат итү өчен бирелгән документ*); ~**ый свет** дөнья; ~**ый у́голь** ак күмер (*су көче турында*); ~**ый хлеб** ак икмәк; ~**ы́м-~о́** ап-ак; ~**ыми ни́тками ши́то** җеп очы күренеп тора; хәйләсе бик өстә ята; **игра́ть** ~**ыми** (*в шахматах, шашках*) аклар белән уйнау; **средь (среди́)** ~**а дня** көпә-көндез

бельведе́р *м архит.* бельведер

бельги́йцы *мн.* бельгиялеләр, Бельгия халкы

бельё *с* кер; **ни́жнее** ~ күлмәк-штан; **посте́льное** ~ мендәр тышы һәм җәймә; **столО́вое** ~ ашъяулык, тастымал

бельев||ОЙ, -а́я, -о́е кер ...ы; ~**а́я корзи́нка** кер кәрзине

бельмЕ́с *м*: **ни** ~**а не зна́ет (не понима́ет** *и т.п.*) әлифне таяк дип тә белми, бернәрсә дә белми (аңламый *һ.б.ш.*)

бельмО́ *с* күзгә төшкән ак ♦ **как** ~ **на глазу́** күзгә кергән чүп шикелле, җан көеге

бельэта́ж *м* бельэтаж (**1.** *өйнең икенче каты* **2.** *театрда партердан өске кат*)

беля́к *м зоол.* ак куян

бемО́ль *м муз.* бемоль

бенефи́с *м театр.* бенефис

бензи́н *м* бензин

бензоба́к *м* бензобак

бензово́з *м* бензовоз

бензозапра́вочн||ый, -ая, -ое машинага бензин салу ...ы; ~**ая колО́нка** машинага бензин салу колонкасы

бензозапра́вщик *м* бензин җибәреп торучы

бензоколО́нка *ж* бензоколонка

бензО́л *м хим.* бензол

бенуа́р *м театр.* бенуар

бергамО́т *м* бергамот (*грушаның бер сорты*)

берда́нка *ж уст.* берданка (*мылтыкның бер төре*)

бердЫш *м* айбалта (*ярым ай рәвешендә ясалган озын саплы сугыш коралы*)

бе́рег *м* **1.** яр; **крутО́й** ~ текә яр **2.** яр буе, су кырые; **жить на** ~**у́** яр буенда яшәү

берегов||О́й, -а́я, -о́е яр ...ы; яр буе ...ы; ~**а́я ли́ния** яр буе сызыгы

бередИ́ть *несов. что* авырттыру (*авыртканн урында тиеп*); ~ **сердечные ра́ны** *перен.* авыр кичерешләрне искә төшерү

бережли́вость *ж* сакчыллык

бережли́вый, -ая, -ое сакчыл, сак тотучан, хәстәрле; ~ **хозя́ин** сакчыл хужа

бе́режность *ж* (*осторожность*) саклык, сакчыллык; (*заботливость*) кайгыртучанлык, игътибарлылык

бе́режный, -ая, -ое (*осторожный*) сак, сакчыл; (*заботливый*) кайгыртучан, игътибарлы

берёза *ж* каен

березня́к *м* каен урманы; каенлык

берёзовик *м* (*гриб*) каен гөмбәсе

берёзов||ый, -ая, -ое **1.** каен ...ы; ~**ая ро́ща** каен урманы; ~**ый сок** каен суы; ~**ый лист** каен яфрагы **2.** каен ..., каеннан ясалган; ~**ая доска́** каен такта ♦ ~**ая ка́ша** каен чыбыгы (*борынгыда чыбык белән суктыру — җәзалау өчен*)

бере́йтор *м* берейтор (**1.** *атларны атланып йөрү өчен өйрәтүче* **2.** *атка атланып йөрергә өйрәтүче*)

бере́менеть *несов.* йөккә узу (калу), балага узу, корсакка калу

бере́менная *прил. и в знач. сущ. ж* көмәнле, йөкле, авырлы

бере́менность *ж* йөклелек, балага узганлык

берёста *ж* туз, каен тузы

берёстов||ый, -ая, -ое каен тузы ...ы; каен тузыннан ясалган; ~**ые изде́лия** каен тузыннан ясалган әйберләр

берестян||о́й, -а́я, -о́е *см.* **берёстовый** ♦ **~ы́е гра́моты** каен тузына язылган язмалар

бере́т *м* берет

бере́чь *несов.* **1.** *кого-что* саклау; **~ здоро́вье** сәламәтлекне саклау **2.** *что* (*хранить*) саклау, сак тоту, әрәм итмәү; **~ вре́мя** вакытны әрәм итмәү **3.** *что* (*не разглашать*) яшереп тоту, сер итеп тоту, сер итеп саклау, саклау; **~ та́йну** серне саклау

бере́чься *несов.* **1.** саклану, сак булу **2.** *страд. от* **бере́чь**

бе́ркут *м* бөркет

берло́га *ж* аю өне

берцо́в||ый, -ая, -ое: **~ая кость** балтыр сөяге

бес *м* җен, шайтан ♦ **рассыпа́ться ме́лким ~ом** *перед кем* оста итеп ялагайлану, тәлинкә тоту

бесе́да *ж* **1.** (*разговор*) әңгәмә, гәп, сөйләшеп утыру **2.** (*собеседование*) әңгәмә, фикер уртаклашу (*тыңлаучылар белән*)

бесе́дка *ж* беседка, чатыр

бесе́довать *несов. с кем* әңгәмә кору, сөйләшеп утыру, гәпләшү

бесёнок *м разг.* **1.** *уменьш. от* **бес**; җен (шайтан) баласы **2.** (*о шалуне, шалунье*) шаян, шук, тиктормас (*бала турында*)

беси́ть *несов. кого-что* җенләндерү, ачуын кабарту, шаштыру

беси́ться *несов.* **1.** (*заболевать бешенством — о животных*) котыру **2.** *разг.* (*быть в раздражении*) котырыну, шашыну, җенләну **3.** *разг.* (*резвиться, шалить*) бик каты шаяру, пыр тузу

бескла́ссов||ый, -ая, -ое сыйныфсыз, сыйныфларга буленмәгән; **~ое о́бщество** сыйныфсыз җәмгыять

бескозы́рка *ж* бескозырка (*козырексыз фуражка*)

бесконе́чност||ь *ж* чиксезлек, очсыз-кырыйсызлык, иксез-чиксезлек; **~ь простра́нства и вре́мени** пространство һәм вакытның чиксезлеге ♦ **до ~и** бик озак; **ждать до ~и** бик озак көтү

бесконе́чн||ый, -ая, -ое **1.** (*безграничный*) чиксез, очсыз-кырыйсыз, иксез-чиксез; **~ое мирово́е простра́нство** очсыз-кырыйсыз дөнья бушлыгы; **~ая дробь** *мат.* чиксез вакланма **2.** (*очень длинный*) бик озын; (*очень долгий*) бик озак, бетмәс-төкәнмәс; **~ая доро́га** бик озын юл; **~ые разгово́ры** бетмәс-төкәнмәс сөйләшүләр

бесконтро́льность *ж* контрольсезлек, контроль юклык

бесконтро́льн||ый, -ая, -ое контрольсез, тикшерми; **~ое расхо́дование де́нег** акчаның контрольсез тотылуы

бесконфли́ктный, -ая, -ое конфликтсыз, низагсыз

бескóрмица *ж* кытлык, азык кытлыгы, азык җитмәү (*терлеккә*)

бескоры́стие *с* тәмгысызлык; ияусызлык, хирыссызлык

бескоры́стн||ый, -ая, -ое тәмгысыз, ияусыз, хирыссыз; **~ая по́мощь** ияусыз ярдәм

бескóстный, -ая, -ое сөяксез, скелетсыз

бескра́йний, -яя, -ее чиксез, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз; **~ прост**о́р очсыз-кырыйсыз иркенлек

бескро́вн||ый, -ая, -ое **1.** кансыз, аз канлы; (*бледный*) агарынган, ап-ак **2.** кан коюсыз; **~ая побе́да** кан коюсыз җиңү

бескры́л||ый, -ая, -ое **1.** канатсыз **2.** *перен.* иҗади көчсез, буш; **~ая фанта́зия** буш хыял

бескульту́рье *с* мәдәниятсезлек

беснова́ться *несов.* җенләну, котырыну, шашыну

беспа́лый, -ая, -ое бармаксыз, бармаклары өзелгән

беспа́мятный, -ая, -ое (*забывчивый*) онытучан, хәтерсез

беспа́мятство *с* **1.** (*обморок*) һушсызлык, аң югалту **2.** (*исступление*) ярсу, шашыну, үз-үзен белештермәү

беспардо́нн||ый, -ая, -ое *разг.* (*беззастенчивый*) оятсыз, әдәпсез, тыйнаксыз, пырдымсыз; **~ое поведе́ние** үзен әдәпсез тоту

беспарти́йный, -ая, -ое партиясез, партиядә тормаучы

беспа́спортный, -ая, -ое паспортсыз

беспате́нтный, -ая, -ое патентсыз

бесперебо́йность *ж* туктаусызлык, өзлексезлек; **~ снабже́ния** тәэмин итүнең өзлексезлеге

бесперебо́йн||ый, -ая, -ое туктаусыз, өзлексез; **~ое снабже́ние** өзлексез тәэмин итү

беспереса́дочн||ый, -ая, -ое пересадкасыз; **~ое сообще́ние** пересадкасыз юл

бесперспекти́вность *ж* перспективасызлык, киләчәге өметсез булу

бесперспекти́вный, -ая, -ое перспективасыз, киләчәге өметсез

беспеча́льный, -ая, -ое (*не омрачённый печалью*) кайгысыз, борчылусыз, хәсрәтсез

беспе́чность *ж* гамьсезлек, ваемсызлык, кайгысызлык

беспе́чн||ый, -ая, -ое гамьсез, ваемсыз, кайгысыз; **~ая жизнь** гамьсез тормыш; **~ый челове́к** гамьсез кеше; **~ый вид** ваемсыз кыяфәт; **~ый смех** гамьсез көлү

беспило́тный, -ая, -ое: **~ косми́ческий кора́бль** пилотсыз космик корабль

беспи́сьменный, -ая, -ое язусыз, язуы булмаган, алфавиты булмаган (*халыклар, телләр турында*)

беспла́новость *ж* плансызлык, план юклык; **~ хозя́йства** хуҗалыкның плансызлыгы

беспла́нов||ый, -ая, -ое плансыз; **~ая рабо́та** плансыз эш

беспла́тн||ый, -ая, -ое түләүсез, тиген, буш; **~ое медици́нское обслу́живание** түләүсез медицина ярдәме күрсәтү; **~ое обуче́ние** түләүсез укыту

беспло́дие *с* **1.** балага узмау (*хатын-нарга карата*); кысырлык (*ана хайван-нарга карата*) **2.** (*неплодородие почвы*) уңдырышсызлык, үсемлек үсмәү

беспло́дность *ж* (*бесполезность, безрезультатность*) файдасызлык, нәтиҗәсезлек

беспло́дн||ый, -ая, -ое **1.** бала тудыруга сәләтсез; үрчемсез **2.** (*неплодородный — о почве*) уңдырышсыз, уңыш бирми торган **3.** *перен.* (*бесполезный, напрасный*) файдасыз, файдасызга ...; нәтиҗәсез, әрәм; **~ые уси́лия** файдасыз тырышулар

бесповоро́тн||ый, -ая, -ое катгый, кискен, тайпылышсыз; **~ое реше́ние** катгый карар

бесподо́бный, -ая, -ое чагыштыргысыз, тиңдәшсез, охшашы булмаган; **~ го́лос** тиңдәше булмаган тавыш

беспозвоно́чн||ый, -ая, -ое **1.** умырткасыз, умыртка сөяксез; **~ые живо́тные** умырткасыз хайваннар **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. зоол.* умырткасызлар

беспоко́||ить *несов. кого-что* **1.** (*нарушать покой*) борчу, тынычсызлау, бимазалау; **шум ~ит больно́го** тавыш авыруны борчый **2.** (*внушать тревогу*) борчу, куркуга төшерү, курку тудыру; **меня́ ~ит его́ отсу́тствие** анын юклыгы мине борчый **3.** (*причинять неудобство*) комачаулау, унайсызлау, борчу; **пе́ние не ~ит?** җырлау комачауламыймы?

беспоко́||иться *несов.* **1.** (*волноваться, тревожиться*) борчылу, тынычсызлану **2.** (*утруждать себя*) борчылу, мәшәкатьләнү; **не ~йтесь, я сам сде́лаю** мәшәкатьләнмәгез, мин үзем эшләрмен

беспоко́йн||ый, -ая, -ое **1.** тынычсыз; **~ый челове́к** тынычсыз кеше **2.** мәшәкатьле; **~ое де́ло** мәшәкатьле эш **3.** борчулы; **~ый сон** борчулы йокы

беспоко́йство *с* **1.** тынычсызлык, тынычлыкны бозу; **причиня́ть ~** тынычлыкны бозу **2.** борчылу, тынычсызлык; **меня́ охвати́ло ~** мин борчыла башладым

бесполе́зность *ж* файдасызлык, нәтиҗәсезлек

бесполе́зный, -ая, -ое файдасыз, нәтиҗәсез, әрәм

беспо́л||ый, -ая, -ое җенессез (*ике женеснең берсенә дә карамаган*); **~ое размноже́ние** *биол.* җенессез үрчү

беспо́мощность *ж* ярдәмгә мохтаҗлык, ярдәмчесезлек, көчсезлек; **~ ребёнка** баланың ярдәмгә мохтаҗлыгы

беспо́мощный, -ая, -ое **1.** (*слабый, бессильный*) ярдәмгә мохтаж, ярдәмчесез, көчсез **2.** *перен.* (*бездарный*) пешмәгән, начар (*мәс. шигырь*)

беспоро́чн||ый, -ая, -ое кусрез, намуслы, кимчелексез; **~ая слу́жба** намуслы хезмәт

беспоря́д||ок *м* **1.** тәртипсезлек, тәртип юклык, тәртип бозу **2.** *мн.* **~ки** *уст.* чуалышлар, тәртипсезлекләр

беспоря́дочность *ж* **1.** (*отсутствие порядка*) тәртипсезлек, таркаулык, буталчыклык **2.** (*человека*) тәртипсезлек

беспоря́дочн||ый, -ая, -ое тәртипсез, буталчык, таркау; **~ая гру́да бума́г** кәгазьләрнең тәртипсез өеме; **~ая стрельба́** тәртипсез атыш

беспоса́дочный, -ая, -ое: ~ **перелёт** бер тукталышсыз очып барып җитү

беспо́чвенность *ж* нигезсезлек, дәлилсезлек; ~ **подозре́ний** шикләнүләрнең нигезсезлеге

беспо́чвенн||ый, -ая, -ое нигезсез, нигезләнмәгән, төпсез, тәрәксез; ~**ое обвине́ние** нигезсез гаепләү

беспо́шлинный, -ая, -ое пошлинасыз, пошлина түләмичә ...; ~ **ввоз това́ров** товарларны пошлинасыз кертү

беспоща́дность *ж* мәрхәмәтсезлек, рәхимсезлек, шәфкатьсезлек, катылык, аяусызлык

беспоща́дный, -ая, -ое аяусыз, мәрхәмәтсез, рәхимсез, шәфкатьсез, каты

беспра́вие *с* **1.** (*отсутствие прав у кого-л.*) хокуксызлык **2.** (*беззаконие*) законсызлык

беспра́вный, -ая, -ое хокуксыз, хокуктан мәхрүм ителгән

беспреде́льн||ый, -ая, -ое **1.** чиксез, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз; ~**ые сте́пи** чиксез далалар **2.** чиксез, чиге булмаган, бик көчле; ~**ая любо́вь** чиксез мәхәббәт

беспредме́тность *ж* максатсызлык, нигезсезлек, эчтәлексез; ~ **спо́ра** бәхәснең нигезсезлеге

беспредме́тный, -ая, -ое (*билгеле бер*) максатсыз, нигезсез, эчтәлексез; ~ **спор** максатсыз бәхәс

беспрекосло́вн||ый, -ая, -ое һичсүзсез, каршылыксыз, карусыз; ~**ое подчине́ние** каршылыксыз буйсыну

беспрепя́тственный, -ая, -ое тоткарсыз, тоткарлыксыз, киртәсез

беспрерыв́ный, -ая, -ое өзлексез, тоташ, туктаусыз; ~ **дождь** туктаусыз яңгыр

беспреста́нн||ый, -ая, -ое өзлексез, туктаусыз, бертуктаусыз; ~**ые напа́дки** бертуктаусыз бәйләнүләр

беспрецеде́нтность *ж* моңарчы күрелмәгән булу, тиңдәше булмау

беспрецеде́нтный, -ая, -ое моңарчы булмаган, моңарчы күрелмәгән, охшашы булмаган, тиңдәшсез; ~ **слу́чай** моңарчы булмаган вакыйга

беспри́быльн||ый, -ая, -ое табыш бирми торган, файда китерми торган; ~**ая торго́вля** файда китерми торган сәүдә

беспри́вязн||ый, -ая, -ое: ~**ое содержа́ние скота́** терлекне бәйләмичә тоту

бесприда́нница *ж* бирнәсез кыз

беспризо́рник *м* тәрбиячесез бала, караучысыз бала, урам баласы

беспризо́рница *ж* тәрбиячесез кыз

беспризо́рность *ж* **1.** (*заброшенность*) иясезлек **2.** (*отсутствие присмотра, надзора*) тәрбиячесезлек, караучысызлык

беспризо́рн||ый, -ая, -ое **1.** иясез; ~**ое хозя́йство** иясез хуҗалык **2.** (*бездомный*) тәрбиячесез, караучысыз, тәрбиячесез (караучысыз) булган **3.** *в знач. сущ.* ~**ый** *м* урам баласы, тәрбиячесез бала; ~**ая** *ж* тәрбиячесез кыз

беспреме́рный, -ая, -ое охшашы (тиңдәше) булмаган, искиткеч, тиңдәшсез; ~ **геро́изм** искиткеч геройлык

беспринци́пность *ж* принципсызлык, аумакайлык; ныклы фикерләрнең (карашларның) юклыгы; ~ **поведе́ния** тәртипнең принципсызлыгы

беспринци́пн||ый, -ая, -ое принципсыз, аумакай, принцибы булмаган; ~**ый карье́рист** принципсыз карьерачы; ~**ое реше́ние** принципсыз карар

беспристра́стие *с*, **беспристра́стность** *ж* гаделлек, риясызлык, турылык

беспристра́стн||ый, -ая, -ое гадел, риясыз, дөрес, хак; ~**ый судья́** гадел судья; ~**ое реше́ние** дөрес карар

беспричи́нный, -ая, -ое сәбәпсез; сылтаусыз; ~ **смех** сәбәпсез көлү

бесприю́тный, -ая, -ое йортсызҗирсез, торыр җире булмаган, сыеныр урыны булмаган

беспробу́дный, -ая, -ое **1.** (*о сне*) уянмас, каты **2.** *разг.* (*о пьянстве, пьянице*) айнымас, туктаусыз, чиктән тыш

беспро́волочный, -ая, -ое чыбыксыз, тимерчыбыксыз; ~ **телегра́ф** чыбыксыз телеграф

беспро́игрышн||ый, -ая, -ое оттырышсыз, отмый калмый торган; ~**ая лотере́я** оттырышсыз лотерея

беспросве́тн||ый, -ая, -ое **1.** дөм [караңгы]; кап-караңгы, яктырмас; ~**ая тьма** дөм караңгылык **2.** *перен.* шатлыксыз, күңелсез, өметсез, караңгы; ~**ая тоска́** өметсез сагыну

беспросы́пный, -ая, -ое *см.* **беспробу́дный**

беспроце́нтный, -ая, -ое процентсыз; ~ **заём** процентсыз заём

беспу́тничать *несов. разг.* азу-тузу, азгынлану, бозыклыкка бирелү

беспу́тный, -ая, -ое азгын, бозык, юлдан язган

беспу́тство *с* азгынлык, бозыклык, бозык тормыш

бессвя́зный, -ая, -ое бәйләнешсез, өзек-өзек; ~ **расска́з** бәйләнешсез хикәя

бессерде́чие *с*, **бессерде́чность** *ж* рәхимсезлек, шәфкатьсезлек, каты күңеллек, кансызлык, миһербансызлык

бессерде́чный, -ая, -ое рәхимсез, шәфкатьсез, каты күңелле, миһербансыз; ~ **челове́к** рәхимсез кеше

бесси́лие *с* көчсезлек, хәлсезлек; **ста́рческое** ~ картлык көчсезлеге

бесси́льный, -ая, -ое көчсез, хәлсез, хәлдән тайган, егәрсез; ~ **гнев** көчсез ачулану

бессисте́мность *ж* системасызлык, тәртипсезлек; ~ **зна́ний** белемнәрнең системасызлыгы

бессисте́мн||ый, -ая, -ое системасыз, тәртипсез; ~**ое изложе́ние фа́ктов** фактларны системасыз аңлатып бирү

бесслове́сность *ж* хурлык, яманат, дансызлык, кадерсезлек

бесслове́сный, -ая, -ое хурлыклы, данлыксыз, кадерсез; ~ **коне́ц** хурлыклы тәмамлану

бесслове́сн||ый, -ая, -ое эзсез, хәбәрсез, эзсез-хәбәрсез, бөтенләйгә; ~**ое исчезнове́ние** эзсез-хәбәрсез югалу

бесслове́сн||ый, -ая, -ое **1.** телсез; ~**ое живо́тное** телсез хәйван **2.** (*молчаливый, безропотный*) телсез, сүзсез, сөйләшми торган, эндәшмәс

бессме́нный, -ая, -ое даими, алмашсыз

бессме́ртие *с* **1.** *высок.* үлемсезлек, мәңгелек дан; **стяжа́ть себе́** ~ үзеңә мәңгелек дан казану **2.** *рел.* мәңге булу, мәңге яшәү

бессме́ртник *м бот.* үлмәс гөл

бессме́ртн||ый, -ая, -ое **1.** *высок.* мәңгелек, мәңге онытылмыс; ~**ая сла́ва** мәңгелек дан **2.** *рел.* үлмәс, үлми торган

бессмы́сленность *ж* мәгънәсезлек, ахмаклык, ахмак сүз

бессмы́сленный, -ая, -ое **1.** (*лишённый смысла*) мәгънәсез, аңлаешсыз, буталчык; ~ **набо́р слов** мәгънәсез сүзләр җыелмасы **2.** (*нелепый*) акылсыз, ахмак; ~ **посту́пок** ахмак кыланыш

бессмы́слица *ж* мәгънәсез сүзләр, буш сүзләр; мәгънәсезлек, ахмаклык, ахмак сүз, ахмак фикер

бесснéжн||ый, -ая, -ое карсыз, кар яумаган; ~**ая зима́** карсыз кыш

бессо́вестный, -ая, -ое вөҗдансыз, намуссыз, оятсыз; ~ **посту́пок** оятсыз кыланыш

бессодержа́тельн||ый, -ая, -ое сай эчтәлекле, кызыксыз, буш; ~**ая кни́га** сай эчтәлекле китап

бессозна́тельн||ый, -ая, -ое **1.** аңсыз, аңын югалткан; **быть в** ~**ом состоя́нии** аңсыз хәлдә булу **2.** (*невольный*) аңсыз эшләнгән, аңсызлык белән эшләнгән, белештермичә эшләнгән; ~**ый жест** белештермичә эшләнгән ишарә

бессо́нниц||а *ж* йокысызлык; **страда́ть** ~**ей** йокысызлык белән җәфалану

бессо́нн||ый, -ая, -ое йокысыз, йокысыз үткәрелә торган; ~**ая ночь** йокысыз төн

бесспо́рно *нареч.* **1.** һичшиксез, бәхәссез; **он** ~ **че́стный челове́к** һичшиксез намуслы кеше ул **2.** *в знач. вводн. сл.* әлбәттә; ~**, ты во́лен поступа́ть, как хо́чешь** син, әлбәттә, ничек теләсәң, шулай эшләргә хаклы

бесспо́рн||ый, -ая, -ое бәхәссез, шөбһәсез, ачыктан-ачык; ~**ая и́стина** бәхәссез хәкыйкать

бессре́бреник *м уст.* тәмгысыз, хирыссыз, сатылмас кеше

бессре́бреница *ж уст.* тәмгысыз хатын (кыз), хирыссыз хатын (кыз)

бессро́чный, -ая, -ое сроксыз, срогы чикләнмәгән; ~ **па́спорт** срогы чикләнмәгән паспорт

бесстра́стие *с* тынычлык, рухи тынычлык, салкын канлылык, салкын күңеллелек; ваемсызлык

бесстра́стный, -ая, -ое тыныч, салкын күңелле, салкын канлы; ваемсыз; ~ **челове́к** салкын канлы кеше; ~ **взгляд** тыныч караш

бесстра́шие *с* куркусызлык, кыюлык, батырлык

бесстра́шный, -ая, -ое куркусыз, кыю, батыр, йөрәкле; ~ **путеше́ственник** кыю илгизәр

БЕС-БИЕ

бесты́дник *м* оятсыз, әдәпсез, инсафсыз, җир бит

бесты́дница *ж* оятсыз хатын(кыз), инсафсыз хатын(кыз)

бесты́дный, -ая, -ое оятсыз, әдәпсез, инсафсыз; ~ **посту́пок** әдәпсез кыланыш

бесты́дство *с* оятсызлык, әдәпсезлек, инсафсызлык

бесты́жий, -ая, -ее *прост. см.* **бесты́дный**

бессчётн||ый, -ая, -ое: ~**ое число́** *разг.* хисапсыз, исәпсез-хисапсыз, күп тапкыр

беста́ктность *ж* **1.** (*отсутствие такта*) тактсызлык, тотнаксызлык, әдәпсезлек, сөмсезлек **2.** (*бестактный поступок*) урынсызлык, килешсезлек, килешсез кыланыш

беста́ктный, -ая, -ое (*о человеке*) тактсыз, тотнаксыз, әдәпсез, сөмсез; (*о словах, поступке*) урынсыз, килешсез

бесталáнность *ж* талантсызлык, булдыксызлык, сәләтсезлек

бесталáнный I, -ая, -ое талантсыз, булдыксыз, сәләтсез; ~ **поэ́т** талантсыз шагыйрь

бесталáнный II, -ая, -ое *фольк.* (*несчастный, неудачливый*) бәхетсез, бичара, мескен

бе́стия *ж прост.* әрсез кеше, ертлач, алдакчы

бестолко́вость *ж* **1.** (*несообразительность*) аңгыралык, миңгерәүлек **2.** (*бессвязность, беспорядочность*) бәйләнешсезлек, буталчыклык, мәгънәсезлек

бестолко́вщина *ж разг.* тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык

бестолко́в||ый, -ая, -ое **1.** (*о человеке*) аңгыра, миңгерәү **2.** бәйләнешсез, мәгънәсез, рәтсез, юньсез; ~**ое письмо́** мәгънәсез хат

бе́столочь *ж разг.* **1.** *см.* **бестолко́вщина; 2.** (*о бестолковом человеке*) аңгыра кеше, миңгерәү кеше

беспре́петный, -ая, -ое *высок.* куркусыз, кыю, батыр, йөрәкле

бестсе́ллер *м* бестселлер (*күп укыла торган китап*)

бесфо́рменный, -ая, -ое формасыз, чуалчык, буталчык

бесхара́ктерность *ж* характерсызлык, йомшак характерлылык; аумакайлык; тотрыксыз холыклылык

бесхара́ктерный, -ая, -ое характерсыз, йомшак характерлы; аумакай; ~ **челове́к** йомшак характерлы кеше

бесхво́стый, -ая, -ое коерыксыз

бесхи́тростный, -ая, -ое **1.** (*о человеке*) хәйләсез, эчкерсез, беркатлы **2.** (*незамысловатый*) гади, садә, бормалы-сырмалы булмаган; ~ **расска́з** гади хикәя

бесхо́зн||ый, -ая, -ое, хуҗасыз, иясез; ~**ое иму́щество** хуҗасыз милек

бесхозя́йственность *ж* хуҗалыксыз булмау, хуҗалыкны алып бара белмәү, хуҗасызлык

бесхозя́йственн||ый, -ая, -ое **1.** йорт көтә белми торган, хуҗалыксыз булмаган, хуҗаларча эш итми торган; ~**ый челове́к** хуҗалыксыз булмаган кеше **2.** хуҗаларча булмаган; ~**ое отноше́ние к иму́ществу** милеккә хуҗаларча булмаган мөнәсәбәт

бесхребе́тность *ж разг.* принципсызлык, аумакайлык

бесхребе́тный, -ая, -ое *разг.* (*непринципиальный*) аумакай, принципсыз

бесцве́тный, -ая, -ое **1.** төссез, үтә күренмәле; ~ **газ** төссез газ **2.** *перен.* кызыксыз, төссез, начар; ~ **расска́з** кызыксыз хикәя

бесце́льность *ж* максатсызлык; файдасызлык; бушлык; ~ **существова́ния** яшәүнең максатсызлыгы

бесце́льн||ый, -ая, -ое максатсыз; файдасыз, буш; ~**ый спор** файдасыз бәхәс; ~**ое путеше́ствие** максатсыз сәяхәт

бесце́нн||ый, -ая, -ое **1.** бик кыйммәтле, бәя биреп бетергесез; ~**ые сокро́вища** бик кыйммәтле хәзинәләр **2.** *перен.* кыйммәтле; сөекле, кадерле; ~**ый друг** кыйммәтле дус

бесце́нок *м*: **за** ~ бик арзанга, юк бәягә, юк хакка, шалкан бәясенә; **купи́ть за** ~ бик арзанга сатып алу; **прода́ть за** ~ бик арзанга сату

бесцеремо́нность *ж* әдәпсезлек, тупаслык, дорфалык, тартынусызлык

бесцеремо́нн||ый, -ая, -ое әдәпсез, тупас, дорфа, тартынусыз; ~**ое обраще́ние** тупас мөгамәлә

бесчелове́чность *ж* кешелексезлек, рәхимсезлек, шәфкатьсезлек, аяусызлык, кансызлык

бесчелове́чн||ый, -ая, -ое кешелексез, рәхимсез, шәфкатьсез, аяусыз, кансыз; ~**ое обраще́ние с живо́тными** хайваннар белән рәхимсез мөгамәлә итү

бесче́стить *несов. кого-что* хур итү, яман атын сату, оятлы итү

бесче́стность *ж* намуссызлык, вөҗдансызлык, инсафсызлык

бесче́стный, -ая, -ое намуссыз, вөҗдансыз, инсафсыз; ~ **посту́пок** намуссыз кыланыш

бесче́стье *с уст.* хурлау, мәсхәрәләү; намусына (вөҗданына) тукыну; **нанести́** ~ *кому-л. кемнеңдер* намусына тукыну

бесчи́нство *с* тәртип бозу, җәнҗал, гауга, башбаштаклык

бесчи́нствовать *несов.* тәртип бозу, җәнҗал кубару, гауга чыгару

бесчи́сленн||ый, -ая, -ое исәпсез, исәпсез-хисапсыз, санап бетергесез, бихисап, бик күп; ~**ое коли́чество** бик күп сан

бесчу́вственность *ж* каты күңеллелек, таш күңеллелек, аямаучанлык

бесчу́вственный, -ая, -ое **1.** (*лишённый способности чувствовать*) сиземи әләтен югалткан, тою сәләтен югалткан **2.** (*лишённый чувства сострадания*) каты күңелле, таш күңелле

бесчу́вствие *с* **1.** (*потеря сознания*) аңны югалту, аңсызлык хәле **2.** (*равнодушие*) ваемсызлык, салкын күңеллелек, таш күңеллелек

бесшаба́шность *ж разг.* **1.** (*беспечность*) гамьсезлек, ваемсызлык **2.** (*безрассудство*) башсызлык, чаялык

бесшаба́шный, -ая, -ое *разг.* **1.** (*беспечный*) гамьсез, ваемсыз **2.** (*безрассудный*) башсыз, чая

бесшу́мный, -ая, -ое тавышсыз; тавышсыз-тынсыз, шау-шусыз, тыпты-ныч; ~ **мото́р** тавышсыз мотор

бе́та-лучи́ *мн. физ.* бета-нурлар

бе́та-части́цы *мн. физ.* бета-кисәкчекләр

бето́н *м* бетон

бетони́рование *с см.* **бетони́ровать**

бетони́ровать *несов. что* бетонлау, бетон тутыру, бетон кою

бетономеша́лка *ж* бетонболгаткыч

бето́нн||ый, -ая, -ое **1.** бетон ...ы; ~**ая ма́сса** бетон массасы **2.** бетон ..., бетоннан ясалган; ~**ый пол** бетон идән

бето́нщик *м* бетончы, бетон коючы

бефстро́ганов *м нескл. кул.* бефстроганов

бечева́ *ж* аркан, юан бау

бечёвка *ж* бау

бе́шенство *с* **1.** (*болезнь*) котыру, котыру авыруы **2.** (*неистовство, ярость*) шашу, котырыну; ярсу

бе́шен||ый, -ая, -ое **1.** котырган (*хайваннар турында*) **2.** *перен.* чиктән тыш көчле, чиктән тыш зур; ~**ое сопротивле́ние** чиктән тыш көчле каршылык; ~**ая ско́рость** чиктән тыш зур тизлек **3.** *перен.* ярсулы, котырынкы; ~**ый хара́ктер** ярсулы холык ◆ ~**ые де́ньги** котырган акчалар (җилдән килгән акча); ~**ые це́ны** чиксез зур бәя

бешмéт *м* бишмәт

биатло́н *м спорт.* биатлон (*винтовкадан ата-ата чаңгыда узышу*)

биатлони́ст *м* биатлончы

библио́граф *м* библиограф

библиографи́ческий, -ая, -ое библиографик, библиография ...ы; ~ **указа́тель** библиографик күрсәткеч; ~ **кабине́т** библиография кабинеты

библиогра́фия *ж* библиография (**1.** *китапларның эчтәлеге турында гыйльми язма һәм аларның исемекләрен, күрсәткечләрен төзү* **2.** *берәр мәсьәләгә карата китаплар һәм мәкаләләр исемлеге*)

библиоте́ка *ж* китапханә; **передви́жная** ~ күчмә китапханә; ~ **учёного** галим китапханәсе

библиоте́карь *м* китапханәче

библиоте́чный, -ая, -ое китапханә ...ы; ~ **катало́г** китапханә каталогы

библиофи́л *м* библиофил, китаплар сөюче (һәвәскәре)

би́блия *ж* (*с прописной*) Тәүрат (*яһудларнең һәм христианнарның дини китабы*)

бива́к *м* бивак (*гаскәрнең куну яки ял итү өчен ачык һавада туктаган урыны*)

бива́ч||ый, -ая, -ое бивак булып ...ы, биваква ...; ~**ая жизнь** биваква яшәү

би́вни *мн.* казык тешләр, бәрмә-тешләр (*мамонт, фил, мөгезборын кебек хайваннарда*)

бигуди́ *мн. нескл.* бигуди

бидо́н *м* бидон

бие́ние *с см.* **би́ться** 3; ~ **се́рдца** йөрәкнең тибүе; ~ **пу́льса** пульснын тибүе

би́знес *м* бизнес; кәсәбә, табышлы эш; **де́лать ~** *на чём-л.* бизнес ясау

бизнесме́н *м* бизнесмен, кәсәбәче

бизо́н *м* бизон (*Төньяк Америкада яши торган кырыгый үгез*)

бикфо́рдов: ~ шнур бикфорд шнуры

биле́т *м в разн. знач.* билет; **~ на самолёт** самолёт билеты; **~ в теа́тр** театр билеты; **парти́йный ~** партия билеты; **пригласи́тельный ~** чакыру билеты; **креди́тный ~** кәгазь акча

билетёр *м* билетчы, билет тикшерүче (*мәс. театрда*)

билетёрша *ж разг. см.* **билетёр**

биле́т||ный, -ая, -ое билет ...ы; **~ая ка́сса** билет кассасы

биллио́н *м мат.* биллион

би́ло *с спец.* бәргеч, суккыч (**1.** *сигналлар бирү өчен файдаланыла торган металл такта* **2.** *берәр җайланманың бәрә торган детале*)

билья́рд *м* бильярд; **игра́ть в ~** бильярд уйнау

бильа́рдный, -ая, -ое бидьярд ...ы; **~ шар** бильярд шары

бино́кль *м* бинокль; **полево́й ~** кыр бинокле; **театра́льный ~** театр бинокле

бино́м *м мат.* бином, икебуын

бинт *м* бинт, бәйләвеч

бинтова́ть *несов. кого-что* бинтлау, бинт белән бәйләү, бинт урау

био- *рус телендәге кушма сүзләрнең «биологиягә караган», «биология» дигән беренче кисәге, мәс.* **биофи́зика** биофизика; **биохи́мия** биохимия

био́граф *м* биограф

биографи́ческий, -ая, -ое биография ...ы, биографик; **~ о́черк** биографик очерк

биогра́фия *ж* биография, тәрҗемәи хәл (*кемнең дә булса тормыш юлы*)

био́лог *м* биолог

биологи́ческ||ий, -ая, -ое биологик, биология ...ы; **~ая нау́ка** биология фәне

биоло́гия *ж* биология

био́ника *ж* бионика (*кибернетиканың инженерлык мәсьәләләрен чишүдә биологик процессларны файдалануны өйрәнә торган булеге*)

биосфе́ра *ж* биосфера (*җир шарының тереклек таралган өлеше*)

биото́ки *мн.* биотоклар

биохи́мия *м* биохимия (*тере материягә хас булган химик процессларны өйрәнә торган фән*)

бипла́н *м* биплан (*аслы-өсле ике канатлы самолёт*)

би́ржа *ж* биржа; **това́рная ~** товар биржасы; **~ труда́** хезмәт биржасы (*хезмәткә яллау эшләре алып баручы учреждение*)

биржеви́к *м* биржачы (*биржа малкуары, эшкуары*)

би́рка *ж* **1.** тамга (*берәр эшне санап бару өчен киртләп тамга салынган таяк яки такта кисәге*) **2.** *спец.* бирка (*атларның ялына, товар тутырылган капларга тагыла торган номерлы яки язулы такта кисәге*)

бирюза́ *ж* фирәзә

бирюзо́вый, -ая, -ое **1.** фирәзә ...ы, фирәзә ...; фирәзәдән ясалган; **~ пе́рстень** фирәзә йөзек **2.** (*о цвете*) фирәзә төсле; ачык зәңгәр

бирю́к *м разг.* караңгы чырайлы кеше, ялгызлыкны яратучы кеше; **смотре́ть ~о́м** караңгы чырай күрсәтү

бирю́льки *мн.*: **игра́ть в ~** юкны бушка аудару, юк-бар белән шөгыльләнү

бис *межд.* бис (*«кабатла!», «тагын бер кат!» дип кычкырып җырлаучының, уйнаучының җырны һ.б.ш. кабатлавын сорау ымлыгы*); **вызыва́ть на ~** биска чакыру

би́сер *м* сәйләп; **вышива́ть ~ом** сәйләп белән чигү ♦ **мета́ть ~ пе́ред сви́ньями** ≈ юләргә акыл сату

би́серина *ж* сәйләп бөртеге

би́серный, -ая, -ое бик вак; **~ по́черк** бик вак хәрефләр белән язылган язу

биси́рова||ть *сов., несов. что и без доп.* кабатлау, биска чыгып уйнау; **певе́ц ~л свою́ а́рию** җырчы биска чыгып үзенең ариясен кабатлады

бискви́т *м* бисквит (*татлы печеньенең бер төре*)

биссектри́са *ж мат.* биссектриса

бита́ *ж* (*при игре в бабки*) сага; (*при игре в городки*) бура таягы; (*в разных играх*) аткы, атабай

би́тва *ж* сугыш, зур сугыш; **~ за Москву́** Мәскәү өчен сугыш

битко́м *нареч.*: **~ наби́тый (набит, набита́, набито́)** шыгырым тулы, дыңгычлап тутырылган (*мәс. халык тулган вагон*)

биту́мный, би́тумный, -ая, -ое битум ...ы; битум ...

биту́мы, би́тумы *мн.* битум

би́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **бить** 1, 3, 4; **2.** ватылган; **~ая посу́да** ватылган савыт-саба ♦ **~ая пти́ца** суелган кош; **~ый час** бер сәгать буе, бик озак

бить *несов.* **1.** (*ударять*; *избивать*) бәрү; кыйнау, тукмау, сугу, ору, кагу; **~ кулако́м** йодрык белән сугу **2.** *кого-что* (*скот, птицу*) сую, чалу, бугазлау **3.** *кого-что* кыйнау, тукмау; **~ врага́** дошманны кыйнау **4.** *кого-что* үтерү, атып төшерү; **~ пти́цу на лету́** кошны очып барганда атып төшерү **5.** (*стрелять*) ату, [атып] тидерү; **винто́вка бьёт хорошо́** винтовка яхшы ата **6.** *что* вату, ваклау; **~ посу́ду** савыт-сабаны вату; **~ ще́бень** ташны ваклау **7.** *во что* бәрү, кагу, сугу; шакылдату; чабу; **~ в бараба́н** барабан кагу; **~ в ко́локол** чан кагу **8.** (*стремительно вытекать*) бәреп чыгу, чаптырып агу, ургу, ургылып тору, ургып чыгу; **бьёт фонта́н** фонтан ургылып тора; **из ра́ны бьёт кровь** ярадан кан чаптырып ага **9.** *что и без доп.* (*давать сигнал ударами*) кагу, чаң кагу; (*о часах*) сугу; **~ отбо́й** 1) *воен.* берәр эшне туктатырга сигнал бирү; 2) *перен.* фикердән кире кайту ♦ **~ в глаза́** күзгә бәрелеп тору, күзгә ташлану; **~ ка́рту** кәртне ябу; **~ в одну́ то́чку** бер ноктага бәрү; **~ в цель** максатка ирешү; **~ ма́сло** май язу, май атлау; **~ ми́мо це́ли** максаттан читкә китү, максатка ирешмәү; **~ наверняка́** ышанып эш итү; **~ по карма́ну** бик кыйбатка төшү; **~ челом** баш ору; **~ по *чьим* интере́сам** *кемнең дә булса* интересларына зарар китерү; **~ шерсть** йон тету, йон язу; **его́ бьёт лихора́дка** аны бизгәк тота (калтырата); **жизнь бьёт ключо́м** тормыш кайнап тора

битьё *с см.* **бить** 1, 6; **~ посу́ды** савыт-сабаны вату

би́ться *несов.* **1.** *обо что* (*колотиться, ударяться*) бәрелү, сугылу **2.** тыпырчыну, калтырану; **~ в исте́рике** истерикага бирелеп тыпырчыну **3.** тибү, кагу, сугу; **се́рдце бьётся** йөрәк тибә **4.** *с кем-чем* (*драться, сражаться*) сугышу, кыйнашу; **~ с неприя́телем** дошман белән сугышу **5.** *перен. над чем, с кем-чем и без доп.* тырышу, көч кую, азаплану; **~ над реше́нием зада́чи** мәсьәләне чишәргә тырышу **6.** (*о посуде, стекле*) ватылу, уалу ♦ **~ об закла́д** берәр нәрсәдән бәхәсләшү; **~ как ры́ба об лёд** ≈ пәрәвезгә эләккән чебен кебек тыпырчыну

битю́г *м* зур йөк аты

бифште́кс *м* бифштекс

би́цепс *м анат.* бицепс (*мускул*)

бич *м* **1.** (*плеть*) озын камчы, чыбыркы **2.** *перен.* (*несчастье, бедствие*) бәлаказа, афәт; бәхетсезлек

бичева́ть *несов. что* фаш итү, тәнкыйть итү; **~ поро́ки** бозыклыкларны тәнкыйть итү

бишь *частица прост.* дисең, дисен әле; **как ~ его́ зову́т?** ничек дисен әле аның исемен?

бла́г||о I *с* **1.** бәхет, игелек; **труди́ться на ~о Ро́дины** Туган ил бәхете өчен хезмәт итү **2.** *обычно мн.* **~а** байлыклар, рәхәтлекләр; **земны́е ~а** тормыш рәхәтлекләре; **материа́льные ~а** материаль байлыклар ♦ **всех благ!** сау бул! (*аерылышканда әйтелә*)

бла́го II *союз разг.* икән, ярый инде; **бери́, ~ даю́т** бирәләр икән, ал

благове́рная *ж разг. шутл.* хәләл җефет, җәмәгать (*ир хатыны турында*)

благове́рный *м разг. шутл.* хәләл җефет, ир (*хатын ире турында*)

благови́дн||ый, -ая, -ое: **~ предло́г** җайлы сәбәп; уңайлы сылтау

благоволе́ние *с* мәрхәмәт, илтифат; **по́льзоваться *чьим-л.* ~м** *берәр кешенең* мәрхәмәтеннән файдалану

благоволи́ть *несов. к кому* яхшы мөнәсәбәттә тору, илтифат итү, теләктәшлек күрсәтү

благово́ние *с книжн.* хуш ис

благово́нный, -ая, -ое *книжн.* хуш исле

благовоспи́танность *ж* тәрбиялелек, әдәплелек

благовоспи́танный, -ая, -ое тәрбияле, әдәпле

благогове́йный, -ая, -ое *книжн.* ихтирамлы, олылыклы; тирән хөрмәт белән сугарылган

благогове́ние *с книжн.* тирән хөрмәт, зур ихтирам, олылау

БЛА-БЛЕ

благогове́ть *несов. перед кем-чем* (*берәр кешегә*) тирән хөрмәт күрсәтү, түбәнчелек күрсәтү, ихтирам итү

благодари́ть *несов. кого что* рәхмәт белдерү (әйтү)

благода́рность *ж* рәхмәт; илтифат, хөрмәт

благода́рн||ый, -ая, -ое **1.** (*признательный*) рәхмәтле, яхшылыкның кадерен белүче; **~ый взгляд** рәхмәтле караш; **я вам о́чень благода́рен** минем сезгә рәхмәтем зур **2.** *перен.* нәтиҗәле, уңышлы; **~ая те́ма** уңышлы тема

благода́рственн||ый, -ая, -ое *высок.* рәхмәт ...ы; **~ое письмо́** рәхмәт хаты

благодаря́ *предлог с дат.п.* ... аркасында, ... сәбәпле, ...га күрә, ...лыктан; **~ ва́шим забо́там** сезнең кайгыртуларыгыз аркасында; **~ иссле́дованиям** тикшеренүләр сәбәпле ♦ **~ тому́, что ...** *союз* ...га күрә

благода́тный, -ая, -ое рәхәт, иркен; бай, мул; куанычлы; **~ край** бай өлкә; **~ дождь** куанычлы яңгыр

благода́ть *ж* рәхәтлек, иркенлек, бәрәкәт, байлык; **кака́я тут ~!** нинди иркенлек монда!

благоде́нствие *с уст.* тынычлык, иминлек, иркен (имин) тормыш

благоде́нствовать *несов. уст.* рәхәт (иркен, бәхетле, имин) яшәү

благоде́тель *м уст.* игелек күрсәтүче, шәфкать итүче

благоде́тельница *ж уст.* шәфкать итүче хатын (кыз)

благодея́ние *с высок.* яхшылык, игелек, шәфәгать

благодýшествовать *несов.* кайгысыз (тыныч, борчылмыйча) яшәү

благодýшие *с* киң күңеллелек, тыныч булу

благодýшн||ый, -ая, -ое тыныч, гамьсез; киң күңелле; **~ое настрое́ние** тыныч күңел

благожела́тель *м уст.* яхшылык теләүче, хәерхаһлык теләүче

благожела́тельность *ж* яхшылык теләү, хәерхаһлык, киң күңеллелек

благожела́тельн||ый, -ая, -ое хәерхаһлы, киң күңелле; **~ый челове́к** киң күңелле кеше; **~ое отноше́ние** хәерхаһлы мөнәсәбәт

благозвýчие *с*, **благозвýчность** *ж* аһәнлелек, матур яңгырашлылык

благозвýчный, -ая, -ое аһәңле, матур яңгырашлы; **~ стих** аһәңле шигырь

благ||о́й I, -а́я, -о́е *уст.* яхшы; **~о́е намéрение** яхшы теләк

благ||о́й II, -а́я, -о́е: **~и́м ма́том крича́ть (ора́ть, вопи́ть)** *прост.* ачы тавыш белән кычкыру (акыру, бакыру)

благолéпие *с уст.* мәһабәтлек, күркәмлек, матурлык

благонадёжный, -ая, -ое (*заслуживающий доверия*) ышанычлы, турылыклы

благонамéренный, -ая, -ое *уст.* яхшы теләкле, теләктәшле

благонра́вный, -ая, -ое *уст.* (*благовоспитанный*) әдәпле, тәрбияле, күркәм холыклы, әхлаклы; **~ ребёнок** әдәпле бала

благообра́зный, -ая, -ое күркәм кыяфәтле, матур кыяфәтле; **~ стари́к** күркәм кыяфәтле карт

благополу́чие *с* **1.** (*спокойная жизнь*) иминлек, тынычлык **2.** (*обеспеченность, довольство*) муллык; иркен тормыш, мул тормыш

благополу́чный, -ая, -ое **1.** (*удачный, успешный*) уңышлы, нәтиҗәле; **~ исхо́д де́ла** эшнең уңышлы төмамлануы **2.** (*спокойный, без неприятностей*) тыныч, кайгы-хәсрәтсез

благоприобрете́нный, -ая, -ое (*об имуществе*) үзе тырышып тапкан (*ата-бабадан калмаган мал-мөлкәт хакында*); (*напр. о болезни*) нәселдән күчмәгән, нәселдән килмәгән; үзеннән-үзе барлыкка килгән

благопристо́йность *ж* әдәплелек, әхлаклылык, инсафлылык, тыйнаклык

благопристо́йн||ый, -ая, -ое әдәпле, әхлаклы, инсафлы, тыйнак; **~ое поведе́ние** инсафлы тәртип

благоприя́тн||ый, -ая, -ое уңайлы, яхшы, жайлы; **~ые усло́вия** уңайлы шартлар

благоприя́тств||овать *несов.* уңай булу, булышлык (ярдәм) итү; **пого́да ~ует пое́здке** һава шартлары сәфәр өчен уңай

благоразу́мие *с* акыллылык, төплелек, акылга ятышлылык

благоразу́мный, -ая, -ое акыллы, төпле, уйлап эшләнгән

благоро́дие *с*: **ва́ше ~** галиҗәнаб әфәнде (*революциягә кадәрге Россиядә: чиновникларга, офицерга мөрәҗәгать сүзе*)

благоро́дн||ый, -ая, -ое **1.** намуслы, вөжданлы; **~ый челове́к** намуслы кеше **2.** күркәм, гүзәл; **~ое де́ло** күркәм эш; **~ая цель** күркәм максат **3.** нәзәкатьле, нәзыйт; **~ая красота́** нәзыйт матурлык **4.** *уст.* (*дворянского происхождения*) затлы, затлы нәселдән булган; **институ́т ~ых деви́ц** затлы нәселдән булган кызлар институты ♦ **~ые мета́ллы** затлы металлар (*алтын, көмеш, агалтын*)

благоро́дство *с* **1.** (*высокие нравственные качества*) намуслылык, вөжданлылык **2.** *уст.* (*принадлежность к дворянству*) дворяннар нәселеннән чыкканлык

благосклóнность *ж* яхшылык теләү, илтифатлылык, хәерхаһлылык

благосклóнный, -ая, -ое илтифатлы, хәерхаһлы

благослове́ние *с* **1.** *см.* **благослови́ть** 1; **2.** *уст.* (*одобрение; напутствие*) яхшы теләк

благослове́нн||ый, -ая, -ое *высок.* бәхетле, имин; **~ая страна́** бәхетле ил

благослови́ть *сов. кого-что* **1.** *рел.* фатиха бирү, ризалык бирү **2.** *высок.* хуплау, яхшы дип табу; **~ на по́двиг** батырлыкны хуплау **3.** (*воздать благодарность*) шөкер итү, рәхмәт белдерү

благослов|я́ть *несов. см.* **благослови́ть**

благосостоя́ние *с* иркен тормыш, мул тормыш; муллык, байлык

благотвори́тель *м уст.* хәер-сәдака бирүче, матди ярдәм күрсәтүче

благотвори́тельность *ж уст.* ярлыларга матди ярдәм

благотвори́тельн||ый, -ая, -ое: **~ое о́бщество** җәмгыяте хәйрия; **~ый спекта́кль** билгеле бер төркем кешеләр (*авырулар, ятимнәр һ.б.ш.*) файдасына куела торган спектакль

благотво́рн||ый, -ая, -ое шифалы, яхшы, файдалы; **~ый кли́мат** файдалы климат; **~ое влия́ние** файдалы тәэсир

благоустра́ивать *несов. см.* **благоустро́ить**

благоустро́енный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **благоустро́ить; 2.** төзек; уңайлыклары булган; **~ дом** уңайлыклары булган йорт

благоустро́ить *сов. что* төзекләндерү; **~ у́лицу** урамны төзекләндерү

благоустро́йство *с* төзекләндерү; **~ го́рода** шәһәрне төзекләндерү

благоухáние *с* хуш ис

благоухáнный, -ая, -ое хуш исле

благоухáть *несов.* хуш ис аңкыту, хуш ис чыгару (тарату)

благочести́вый, -ая, -ое *уст.* диндар, динчел, тәкъва; **~ челове́к** тәкъва кеше

благоче́стие *с уст.* диндарлык, тәкъвалык

блажéнн||ый, -ая, -ое **1.** (*очень счастливый*) бәхетле, шат[лыклы], шат күңелле; **2.** (*глуповатый*) аңгырарак, акылга сайрак, юләррәк

блажéнств||о *с* югары рәхәтлек, хозурлык; **быть на верху́ ~а** иң югары хозурлыкта булу

блажéнствовать *несов.* рәхәтләнү, хозурлану, рәхәттә яшәү

блажи́ть *несов. прост.* үзсүзлеләнү, киреләнү, кәжәләнү

блажно́й, -а́я, -о́е *прост.* тинтәк, дивана, кире беткән

блажь *ж прост.* тинтәклек, юләрлек, диваналык, кирелек

бланк *м* бланк

блат *м* блат; **по ~у** танышлык белән

бледне́ть *несов.* **1.** төс китү, агарыну, чырай китү; **~ от стра́ха** куркудан агарыну **2.** *перен.* (*терять свою силу, выразительность*) тоныклану, көчен югалту, әһәмиятсез булып калу, әһәмиятен югалту

бледноли́цый, -ая, -ее ак чырайлы; агарынган йөзле

бле́дность *ж* **1.** аклык, төссезлек, агарынганлык, нурсызлык; **~ лица́** чырайның аклыгы **2.** тоныклык; **~ кра́сок** буяуларның тоныклыгы **3.** *перен.* тасвирсызлык, тасвирсыз булу; **~ изложе́ния** хикәяләүнең тасвирсызлыгы

бле́дн||ый, -ая, -ое **1.** төссез, төсе киткән, агарынган, чырайсыз, нурсыз; **~ое лицо́** агарынган йөз **2.** тоныклы; сыек; **~ое не́бо** тонык күк **3.** *перен.* көчсез, төссез; **~ый расска́з** төссез хикәя ♦ **~ая не́мочь** *уст.* аз канлылык (*хатын-кызларда җенси өлгергәнлек вакытында була торган аз канлылыкның бер төре*)

блёкл||ый, -ая, -ое шиңгән, шиңә төшкән, сулган; төсен югалткан; **~ые цветы́** шиңгән чәчәкләр

блёкну||ть *несов.* **1.** шиңү, сулу, төсен югалту; **цветы́ ~т** чәчәкләр шиңәләр **2.** тоныклану; **звёзды ~т** йолдызлар тоныкланалар

блеск *м* **1.** ялтырау, җем-җем итү, жемелдәү; **~ со́лнца** кояшның ялтыравы **2.** *перен.* зиннәтлелек; **~ наря́да** киемнең зиннәтлелеге **3.** *перен.* якты чагылыш; **~ ума́** акылның якты чагылышы ♦ **во всём ~е** бөтен ягы килгән; **с ~ом** бик шәп

блесна́ *ж* блесна, ялтыравык, селкенмә алдавыч

блесну́||ть *сов.* **1.** *однокр.* ялтырап китү **2.** *перен.* барлыкка килү, башка килү, чагылып китү; **у меня́ ~ла мысль** минем башымда бер уй чагылып китте; **~ла наде́жда** өмет туды ♦ **он ~л свои́ми позна́ниями** ул үзенең белеме белән безне таңга калдырды

блест||е́ть *несов. чем и без доп.* **1.** ялтырау, ялтырап (җемелдәп) тору; жемелдәү, җем-җем итү, ялкылдау, ялкылдап тору; **~е́ли огни́ го́рода** шәһәр утлары ялтырый иде; **глаза́ ~я́т ра́достью** күзләр шатлык белән ялтырыйлар **2.** *перен.* аерылып тору (*берәр сыйфат белән*); **он не бле́щет умо́м** ул акылы белән аерылып тормый

блёстк||и *мн.* **1.** ялтыравык; ялтыравык төнкә; **пла́тье с ~ами** ялтыравыклы күлмәк **2.** *перен.* очкын, чаткы; **~и тала́нта** талант чаткылары

блестя́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **блесте́ть; 2.** ялтырый торган, җем-җем итә торган; **~ие звёзды** ялтырый торган йолдызлар **3.** *перен.* менә дигән, бик шәп, бик яхшы; **~ий ора́тор** бик яхшы оратор; **он получи́л ~ее образова́ние** бик шәп белем алу; **~ие успе́хи** менә дигән уңышлар

блеф *м* уйдырма, ялган; коры куык

бле́ять *с см.* **бле́ять**

бле́ять *несов.* бәэлдәү, «бәә» дип кычкыру

ближа́йш||ий, -ая, -ее **1.** иң якын, иң якындагы; **~ая зада́ча** иң якындагы бурычлар **2.** турыдан-туры, туп-туры; **при ~ем рассмотре́нии** турыдан-туры тикшергәндә

бли́жн||ий, -яя, -ее **1.** якын, якындагы ...; **~ие города́ и сёла** якын шәһәрләр һәм авыллар; **е́хать ~ей доро́гой** якын юл белән бару **2.** *уст.* (*о родне*) якын; **~ий ро́дственник** якын туган **3.** *в знач. сущ.* **~ий** *м уст.* кардәш

близ *предлог с род.п.* якынында, тирәсендә; **~ до́ма** өй якынында

бли́зи||ться *несов.* якынлашу, якынаю, якынлашып килү; **~тся о́сень** көз якынлашып килә

бли́зк||ий, -ая, -ое **1.** якын, якындагы ...; **~ое расстоя́ние** якын ара; **~ий лес** якындагы урман **2.** (*по времени*) якын, якында булачак; **~ое бу́дущее** якын киләчәк **3.** (*о родстве*) якын; **~ий ро́дственник** якын кардәш **4.** *в знач. сущ.* **~ие** туганнар, якыннар, кардәшләр **5.** якын, ахирәт ...; **~ий друг** якын дус; **~ие отноше́ния** якын мөнәсәбәтләр **6.** *кому-чему* якын, таныш; **~ое мне де́ло** миңа таныш эш **7.** *по чему, к чему* (*сходный*) якын, охшаш; **перево́д, ~ий к ориги́налу** оригиналга якын тәрҗемә

бли́зко *нареч.* **1.** якыннан; **~ познако́миться** якыннан танышу **2.** *в знач. сказ.* якын; **до го́рода ~** шәһәргә якын

близлежа́щий, -ая, -ее якындагы ..., якында урнашкан, күрше[дәге] ...; **~ го́род** якында урнашкан шәһәр

близнецы́ *мн.* **1.** игезәкләр, игез балалар **2.** (*с прописной*) *астр.* Игезәкләр

близору́к||ий, -ая, -ое **1.** ерактан начар күрүче, күрә караучы **2.** *перен.* сукыр, алдан күрмәүче; **~ая поли́тика** сукыр сәясәт

близору́кость *ж* **1.** күрә карау, ерактан начар күрү **2.** *перен.* сукырлык

бли́зость *ж* **1.** якынлык; **~ го́рода** шәһәрнең якынлыгы **2.** якын мөнәсәбәт[ләр]; **ме́жду ни́ми установи́лась ~** алар арасында якын мөнәсәбәтләр урнашты

блик *м* якты тап, якты шәүлә; **со́лнечные ~и на траве́** үләнгә төшкән якты кояш шәүләсе

блиндаж *м* блиндаж

блиста́тельный, -ая, -ое бик шәп, гүзәл; **~ успе́х** бик шәп уңыш

блиста́ть *несов. книжн. см.* **блесте́ть**

блиц *м* блиц (*фотография эшендә кинәт яктырту өчен лампа*)

блицтурни́р *м* блицтурнир (*мәс. шахматта*)

блок I *м тех.* блок, чыгыр

блок II *м* **1.** *полит.* блок **2.** *тех.* блок (*берәр нәрсә[ләр]нең төркеме*); **дверно́й ~** ишек блогы

блока́д||а *ж* **1.** *воен.* блокада; камалыш, камап тоту; **в кольце́ ~ы** блокада божрасында **2.** *перен.* блокада; **экономи́ческая ~а** икътисадый блокада **3.** *физиол.* блокада, блокадалау (*берәр эгъзаның функциясен туктатып тору*); **новока́иновая ~а** новокаин белән блокада ясау

блока́дный, -ая, -ое блокада ...ы

блоки́рование *с см.* **блоки́ровать**

блоки́ровать *сов., несов. что* **1.** *воен.* блокада ясау, блокадалау, камап алу; **~ порт** портны блокадалау **2.** *ж.-д.* юлны ябу

блоки́роваться *сов., несов. полит.* блокка керү

блокиро́вка *ж* **1.** *см.* **блоки́ровать, блоки́роваться; 2.** *ж.-д.* блокировка (*тимер юлның ачыкмы яки ябыкмы икәнлеген күрсәтә торган сигналлар системасы*)

блокиро́вочн||ый, -ая, -ое *ж.-д.* блокировка ...ы; **~ая систе́ма** блокировка системасы

блокно́т *м* блокнот, куен дәфтәре, кесә дәфтәре

блонди́н *м* блондин

блонди́нка *ж* блондинка

блоха́ *ж* борча

бло́чн||ый, -ая, -ое чыгыр ...ы; чыгырлы; **~ая верёвка** чыгыр бавы

блуд *м* уйнаш, зина, женси азгынлык

блуди́ть I *несов. прост.* (*распутничать*) уйнашлык итү, азып йөрү, зина кылу

блуди́||ть II *несов. прост.* (*блуждать*) адашып йөрү; **мы до́лго ~ли по́ лесу** урманда озак адашып йөредек

блудли́вый, -ая, -ое *прост.* азгын, азгынлыкка бирелгән, уйнашчы ..., зиначыл

блудни́ца *ж* уйнашчы хатын

блу́дный: ~ сын *уст.* юлдан язган ул

блужда́ние *с см.* **блужда́ть**

блужда́ть *несов.* **1.** (*искать дорогу*) адашып йөру **2.** (*странствовать*) ил гизү, ил гизеп йөрү, дөнья гизү; **~ по све́ту** дөнья гизеп йөрү **3.** *перен.* (*о взгляде, мыслях*) йөгерү; йөрү

блужда́ющ||ий, -ая, -ее: **~ие огни́** убыр уты; **~ий взгляд** йөгерек караш; **~ий нерв** *анат.* сәйяр нерв; **~ая по́чка** *мед.* гизүче бөер

блу́за *ж* блуза

блу́зка *ж* блузка; **шёлковая ~** ефәк блузка

блю́до *с* **1.** (*посуда*) зур тәлинкә **2.** (*кушанье*) ашамлык; **вку́сное ~** тәмле ашамлык

блюдоли́з *м уст.* тәлинкә ялаучы; әрәмтамак

блю́дце *с* чәй тәлинкәсе

блю́минг *м* блюминг (*прокат станогы*)

блюсти́ *несов. что, книжн.* саклау, күзәтү; **~ поря́док** тәртип саклау

блюсти́тель *м книжн.* саклаучы, күзәтүче, күзәтеп торучы; **~ поря́дка** тәртип саклаучы; **~ зако́на** законнын үтәлүен күзәтүче

бля́х||а *ж* **1.** бляха (*мәс. каравылчыда*) **2.** жиз тәңкә; **реме́нь с ~ой** жиз тәңкәле каеш

боб *м* **1.** *мн.* **~ы́** бакча борчагы **2.** ногыт, ногыт борчагы ♦ **на ~а́х (оста́ться, сиде́ть** *и т.п.*) коры калу, алдану; ≈ төпсез чанага утыру

бобёр *м* кондыз мехы

бобы́на *ж тех.* бобина, зур кәтүк

бобо́в||ый, -ая, -ое **1.** ногыт ...ы, ногыт борчагы ...ы; **~ый стручо́к** ногыт кузагы **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. бот.* кузаклылар, күбәләк чәчәклеләр

бобр *м* кондыз

бобрёнок *м* кондыз баласы

бо́брик *м* бобрик, йонлач постау, мәллә ♦ **под ~** үрә калдырып (*чәчне алдыру турында*)

бобро́вый, -ая, -ое **1.** кондыз[лар] ...ы **2.** кондыз мехыннан ясалган (тегелгән)

бобсле́й *с спорт.* бобслей (*рульле чанада таудан төшү*)

бобы́ль *м* (*бессемейный человек*) ялгызак, ялгызак кеше

бог *м* алла, ходай, тәңре ♦ **~ зна́ет** алла белсен; **как ~ на́ душу поло́жит** ничек житте алай; ничек туры килсә шулай; **на ~а наде́йся, а сам не плоша́й** *погов.* атны аллага тапшыр, дилбегәне үзең тот; **не ~и горшки́ обжига́ют** искитәрлек эш түгел, һәркемнең кулыннан килә; **не дай ~** *или*

изба́ви ~ алла сакласын; **ра́ди ~а** алла хакына, алла хакы өчен; **сла́ва ~у!** аллага шөкер!

богаде́льн||я *ж* 1. гарипләр йорты (*революциягә кадәрге Россиядә*) 2. *перен. ирон.* булдыксызлар оясы (*хезмәткәрләре булдыксыз булган оешма турында*); **развели́ ~ю** булдыксызлар оясына әйләндергәнсез

богара́ *ж* бәһәра (*Урта Азиядә сугарылмый торган чәчүлекләр*)

бога́рн||ый, -ая, -ое сугарылмый торган; **~ое земледе́лие** сугарылмый торган җиргә иген чәчү

богате́й *м прост.* бай, байгура

богате́ть *несов.* баю

бога́тство *с* байлык, муллык

бога́т||ый, -ая, -ое 1. бай; **~ый колхо́з** бай колхоз 2. бай, зиннәтле; **~ая обстано́вка** бай җиһаз 3. мул; **~ый урожа́й** мул уңыш 4. *перен.* яхшы; **~ый го́лос** яхшы тавыш ♦ **чем ~ы, тем и ра́ды** хәзинәдә барынча

богаты́рск||ий, -ая, -ое 1. баһадир[лар] ...ы, баһадирлар турындагы; **~ий э́пос** баһадирлар турындагы эпос 2. (*могучий*) баһадир ...ы, бик көчле; **~ое телосложе́ние** баһадир гәүдәсе

богаты́р||ь *м прям., перен.* батыр, баһадир, пәһлеван; **спорти́вные ~и** спорт баһадирлары

бога́ч *м* бай

бога́ма *ж* 1. *собир.* богема (*актёрлар, рәссамлар, әдипләр арасында тормыштан ләззәтләнү өчен оешкан җәмгыятьчелек*) 2. богемачылык (*шул җәмгыятьчелек вәкилләренең үз ара тормыш-конкурешләре*)

бога́мный, -ая, -ое богема ...ы, богемачылык ...ы

бога́ня *ж* хатын алла, алиһә

богобоя́зненный, -ая, -ое *уст.* алладан куркучы, динаятьле, тәкъва

богоиска́тельство *с ист.* алла эзләүчелек (*Россиядә 19 йөз ахырында һәм 20 йөз башында диндә социаль каршылыкларның хәл ителүен эзләгән дини-философик агым*)

богомо́лец *м уст.* гыйбадәт кылучы

богомо́лка *ж уст.* гыйбадәт кылучы хатын(кыз)

богомо́лье *с уст.* гыйбадәткә йөрү; гыйбадәт кылу

богомо́льный, -ая, -ое *уст.* гыйбадәтчел, диндар, тәкъва

богоро́дица *ж рел.* Гайса анасы (*христианнарда*); Мәрьям ана (*мөселманнарда*)

богосло́вие *с* дин өйрәтмәләре, дини тәгълимат

богослуже́ние *с* гыйбадәт, гыйбадәт кылу

богостро́ительство *с ист.* богостроительство (*1905нче ел революциясеннән соң рус социалистик интеллигенциясе арасында марксизмны дин белән берләштерүгә омтылган әдәби-философик агым*)

боготвори́ть *несов. кого-что* алла [-сы] кебек күрү, табыну

богоху́льник *м* алланы сүгүче, көфер сүзләр сөйләүче

богоху́льн||ый, -ая, -ое алланы сүгү ...ы, көфер; **~ые ре́чи** көфер сүзләр

богоху́льство *с* алланы сүгү, көферлек

богоху́льствовать *несов.* алланы сүгү, көфер сүзләр сөйләү

бода́ть *несов. кого-что* сөзү

бода́||ться *несов.* сөзешү; **коро́ва ~ется** сыер сөзешә

бодли́в||ый, -ая, -ое сөзгәк; **~ая коро́ва** сөзгәк сыер; **~ой коро́ве бог рог не даёт** *посл.* сөзгәк сыерга алла мөгез бирмәгән

бодну́ть *сов. однокр. кого-что* сөзеп җибәрү

водри́||ть *несов. кого-что* дәртләндерү, дәрт кертү, күңелне күтәрү, рухландыру; **моро́зный во́здух ~т** салкын һава күңелне күтәрә

бодри́ться *несов.* күңелне күтәрергә тырышу, бирешмәскә тырышу

бо́дрость *ж* дәрт, күңел күтәренкелеге, рухи күтәренкелек

бо́дрствование *с см.* **бо́дрствовать**

бо́дрствовать *несов.* йокламау, йокламый үткәрү; уяу булу; **~ ночь напроле́т** төнне йокламый үткәрү

бо́др||ый, -ая, -ое 1. таза, нык; **~ый стари́к** таза карт 2. дәртле, күтәренке; егетләрчә ...; **~ый вид** дәртле кыяфәт; **~ое настрое́ние** күтәренке кәеф

боеви́к *м* боевик (*зур уңышлы кинофильм*)

боеви́тость *ж* сугышчанлык, кыюлык, күтәренке рухлылык, дәртлелек; активлык

боеви́т||ый, -ая, -ое сугышчан, кыю, күтәренке рухлы, дәртле; актив; **~ая организа́ция** актив оешма

боев||о́й, -а́я, -о́е 1. сугыш ...ы; хәрби; **~о́й конь** сугыш аты; **~а́я подгото́вка** хәрби хәзерлек 2. сугышчан; **привести́ в ~у́ю гото́вность** (*гаскәрләрне-кораллары*) сугышчан әзерлеккә китерү 3. булдыклы, үткен; **~о́й па́рень** булдыклы егет 4. күтәренке, дәртле; **~о́е настрое́ние** күтәренке кәеф 5. (*очень важный*) сугышчан, бик мөһим, беренче чираттагы; **~а́я зада́ча** сугышчан бурыч ♦ **~о́е креще́ние** 1) сугышта беренче мәртәбә катнашу; 2) беренче сынау; беренче мәртәбә чирканыч алу

боеголо́вка *ж* боеголовка (*ракетаның, снарядның шартлаткыч механизм куелган алгы өлеше, башы*)

боёк *м* 1. (*в оружии*) боёк, чакма 2. (*у парового молота*) боёк, бәргеч

боепита́ние *с* сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итү

боеприпа́сы *только мн.* сугыш кирәк-яраклары (*снарядлар, патроннар һ.б.ш.*)

боеспосо́бность *ж* сугышка сәләт, сугышка сәләтлелек

боеспосо́бн||ый, -ая, ое сугышка сәләтле; **~ые ча́сти** сугышка сәләтле частьләр

бое́ц *м* 1. (*воин; солдат*) сугышчы; солдат, гаскәри 2. *спец.* (*рабочий-мясник*) сугымчы, чалучы ♦ **бойцы́ ты́ла** тыл солдатлары

бо́же *межд.* 1. я алла, я рабби; **~ мой, что я сде́лал!** я алла, ни эшләдем мин! 2. ии, ай-яй; **~, как здесь краси́во!** ии, нинди матур монда!

боже́ственн||ый, -ая, -ое 1. *рел.* илаһи, дини; **~ые кни́ги** дини китаплар 2. *разг.* гажәеп матур, искиткеч шәп, гүзәл; **~ый го́лос** гажәеп матур тавыш

божество́ *с* алла, ходай, тәңре

бо́ж||ий, -ья, -ье *рел.* алла ...ы, ходай ...ы, тәңре ...ы; **~ий суд** алла хөкеме ♦ **ка́ждый ~ий день** һәр көнне, көн саен, алланың бирмеш көне; **как ~ий день [я́сно]** көн кебек ачык, ап-ачык; **~ья коро́вка** *зоол.* камка, чуар таракан

божи́ться *несов.* ант итү, каргану

бой *м* 1. *см.* **бить** 2, 5, 6, 7, 9; **~ скота́** терлек чалу; **~ часо́в** сәгать сугу; **бараба́нный ~** барабан кагу; **~ петухо́в** әтәчләр талашуы; **у винто́вки хоро́ший ~** винтовка яхшы ата 2. сугыш, сугышу; **на по́ле бо́я** сугыш кырында; **приня́ть ~** сугышка каршы сугыш башлау; **вести́ ~** сугыш алып бару; **оборони́тельный ~** оборона сугышы 3. (*пыяла, савыт-саба, таш*) ватыклары; **в я́щике с посу́дой оказа́лось мно́го бо́я** савыт-саба ящигында пыяла ватыклара күп иде ♦ **объяви́ть ~** *чему* сугыш игълан итү

бо́йк||ий, -ая, -ое 1. җитез, өлгер, булдыклы; **~ий па́рень** җитез егет 2. үткен, тапкыр; **~ий ум** үткен акыл 3. халык күп була торган, халык күп йөри торган, халык кайнап тора торган; **~ое ме́сто** халык күп була торган урын ♦ **~ая торго́вля** кызу сәүдә; **~ое перо́** *у кого* үткен каләм

бойко́т *м* бойкот; **объяви́ть ~** бойкот белдерү

бойкоти́ровать *несов. кого-что* бойкот игълан итү (белдерү)

бо́йлер *м* бойлер (*су кайнату җайланмасы*)

бо́йлерная *ж* бойлер бинасы

бойни́ца *ж* бойница (*мылтыктан, пулемёттан ату өчен крепость стенасына ясалган тишек*)

бо́йня *ж* 1. бойня (*терлек сую бинасы*) 2. *перен.* кан коеш, үтереш, суеш, канлы сугыш; **крова́вая ~** канлы суеш

бок *м* 1. як, ян; **боли́т ле́вый ~** сул ягы авырта; **перева́ливаться с ~у на́ бок** бер яктан икенче якка аву 2. як, кырый; **конве́рт разо́рван с одного́ ~а** конверт бер ягыннан ертылган ♦ **~ о́ бок** бер-беренә терәлеп, яңь-янәшә; **взять за ~а́** *кого* якасыннан тоту (эшләргә мәҗбүр итү); **по́д боком** бик якын, яп-якын, монда гына

бока́л *м* бокал

боков||о́й, -а́я, -о́е 1. ян; кырый, кырыйдагы; **~о́е окно́** ян тәрәзә; **~а́я ко́мната** кырый бүлмә 2. яннан искән, яннан исә торган; **~о́й ве́тер** яннан искән җил ♦ **отпра́виться на ~у́ю** йокларга яту

бо́ком *нареч.* 1. (*плечом вперёд*) ян белән; **войти́ ~** ян белән керү 2. (*не прямо*) читләтеп (*турыдан түгел*); **ты не иди́ пря́мо по доро́ге, а обойди́ ~**

син турыдан юл белән барма, читләтеп үт ♦ ~ **ыгышло** барып чыкмады, килеп чыкмады

бокс *м спорт.* бокс

боксёр I *м* боксчы (*спортчы*)

боксёр II *м* боксёр (*эт токымы*)

боксировать *несов.* бокста көрәшү

боксит *м* боксит (*алюмин рудасы*)

болван *м* 1. *прост.* бүкән, түмәр 2. калып (*эшләпә һәм шуның кебек әйберләрне калыплау өчен*) 3. *перен.* күзле бүкән, ахмак, надан

болванка *ж* 1. *тех.* болванка (*төрле әйберләр ясау өчен китә торган корыч коелмасы*) 2. *см.* **болван** 2

болгарин *м* болгар, болгар кешесе, болгарияле

болгарка *ж* болгар хатыны (кызы)

болгарский, -ая, -ое болгар[лар] ...ы; Болгария ...ы; ~ **язык** болгар теле

болгары *мн.* болгарлар, болгар халкы, болгарияләре

более *см.* **больше** ♦ ~ **или менее** беркадәр, азмы-күпме; ~ **или менее известно** беркадәр билгеле; **не** ~ **и не менее как ...** нәкъ, нәкъ менә шушы; ~ **чем** бигрәк тә, бөтенләй, ... артык; **ваше поведение** ~ **чем возмутительно** сезнең үзегезне тотуыгыз бигрәк тә ачу китергеч; ~ **того** алай гына да түгел, аннан да бигрәк; **всё** ~ **и** ~ барган саен, торган саен

болезненность *ж* 1. чирләшкәлек, чирләүчән (авыручан) булу 2. авыру булу; авыртулы булу

болезненный, -ая, -ое 1. чирләшкә, чирләүчән, авыручан; ~ **ый ребёнок** чирләшкә бала 2. авыру ...ы, чирләү ...ы; сырхаулау ...ы; ~ **ый румянец** авыру кызыллыгы; ~ **ое состояние** сырхаулау хәле 3. *перен.* (*ненормальный*) нормаль булмаган; ~ **ое самолюбие** нормаль булмаган мин-минлек 4. (*вызывающий боль*) әрнүле, авыртулы, авыртырулы; ~ **ый укус** әрнүле чагу

болезнетворный, -ая, -ое авыру тудыручы, авыру тудыра торган, авыруга сәбәп булган; ~ **ые бактерии** авыру тудыра торган бактерияләр

болезнь *ж* авыру, чир, хаста, сырхау; **заразные** ~ **и** йогышлы авырулар; **тяжёлая** ~ **ь** авыр чир

болельщик *м* борчылучы, уңыш теләүче, җиңүгә рухландыручы

болеть I *несов.* 1. *чем* авыру, чирләү, сырхаулау; ~ **тифом** тиф белән авыру 2. *перен. за кого-что, о ком-чём* борчылу, кайгыру; ~ **за успех дела** эшнең уңышы турында борчылу 3. *перен. за кого-что* борчылу, уңыш теләү; ~ **за свою команду** үз командаңның уңышын теләү; ~ **за любимого артиста** яраткан артистның уңышын теләү

болеть II *несов.* авыру, сызлау; **у меня** ~ **ят зубы** минем тешләрәм сызлый; ~ **ит ухо** колак авырта ♦ **душа (сердце)** ~ **ит** күңел борчыла

болеутоляющий, -ая, -ее *мед.* авыртуны (сызлауны) баса торган; ~ **ие средства** авыртуны баса торган чаралар

болид *м астр.* болид (*зур метеор*)

болонка *ж* болонка (*булмә эте*)

болотист||ый, -ая, -ое 1. сазлы, сазлыклы, сазламык; ~ **ая местность** сазламык урын (җир) 2. баткак; ~ **ая почва** баткак туфрак

болото *с* 1. саз, сазлык; баткак, баткаклык 2. *перен.* сазлык, торгынлык; **обывательское** ~ обывательлек сазлыгы

болт *м* 1. болт (*бер башы винтлы, икенче башы эшләпәле металл беркеткеч*) 2. (*железный прут*) аркылы тимер (*тәрәзә капкачын биклә өчен*)

болтанка *ж разг.* болтанка (*самолётның һавада чайкалуы-яңтаюы*)

болтать I *несов.* 1. *что* болгату, тугылау; ~ **лекарство** даруны болгату; ~ **чай ложкой** чәйне кашык белән болгату 2. *чем* (*аякларны, кулларны як-якка*) селкетү; ~ **ногами** аякларны селкетү 3. *безл.* (*о движении самолёта*) чайкалдыру, чайкалту

болтать||ть II *несов.* 1. *что и без доп.* юкбарны сөйләү, сафсата сату, ләчтит сату; такылдау; ~ **ть вздор** юк-барны сөйләү; ~ **ть без умолку** бер туктаусыз такылдау 2. (*чит телдә*) сөйләшү, сөйләшә белү; ~ **ть по-французски** французча сөйләшү 3. лыгырдау, ялгыш әйтеп ташлау; **не** ~ **й никому об этом** бу турыда беркемгә дә лыгырдама

болтаться *несов.* 1. (*як-якка*) селкенеп тору, чайкалып тору (*элеңгән әйбер турында*); **конец пояса** ~ **ется** билбауның очы селкенеп тора; **на верёвке** ~ **лось бельё** бауга элеңгән кер селкенеп тора иде 2. *разг.* (*бродить без дела*) буталып йөрү, эшсез йөрү; **что ты тут** ~ **ешься?** нәрсә син монда буталып йөрисең?

болтливый, -ая, -ое 1. күп сөйләүчән, такылдык 2. (*не умеющий хранить тайну*) сер сакламаучан, сер тотмый торган, тишек авыз

болтовня *ж разг.* 1. (*пустословие*) буш сүз, сүз боткасы, сафсата 2. (*сплетня*) гайбәт, уйдырма

болтун I *м разг.* күп сөйләүче, такылдык, тел бистәсе

болтун II *м* (*яйцо без зародыша*) чәберчек йомырка

болтунья *ж разг.* такылдык хатын (кыз) тел бистәсе

болтушка *м, ж разг. ласк. от* **болтун** I, **болтунья**

боль *ж* авырту, сызлау; әрнү; **головная** ~ баш авырту; **душевная** ~ җан әрнүе

больница *ж* хастаханә

больничный, -ая, -ое больница ...ы; ~ **режим** больница режимы ♦ ~ **лист** больничный лист

больно I *нареч.* 1. авырттырып, бик каты; ~ **ударить** бик каты сугу 2. *в знач. сказ. безл. кому* авырта, сызлый, авыр; **мне** ~ **вздохнуть** миңа сулыш алу авыр

больно II *нареч. прост.* бик, артык, үтә; ~ **хитёр** бик хәйләкәр

больн||ой, -ая, -ое 1. авыру, чирле, сырхау, хаста; ~ **ое сердце** авыру йөрәк 2. *в знач. сущ.* ~ **ой** *м,* ~ **ая** *ж* авыру кеше, чирле, авыручы; **приём** ~ **ых** авыруларны кабул итү; ♦ ~ **ое место** авырткан җир, нечкә җир; ~ **ой вопрос** авыр мәсьәлә, чишелеше кыен мәсьәлә; **[валить] с** ~ **ой головы на здоровую** ≈ ак эт бәласе кара эткә

большак *м обл.* олы юл

больше 1. *сравн. ст. от* **большой** *и* **великий** зуррак, олырак; **этот велик, а тот ещё** ~ монасы зур, ә тегесе тагын да зуррак 2. *сравн. ст. от* **много** күбрәк; артыграк; ~ **ния физкультуре!** физкультурага артыграк дикъкать! 3. моннан соң, моннан ары, моннан болай, артык; ~ **туда не ходи** моннан ары анда барасы булма; ~ **не буду** моннан ары эшләмәм; ~ **нет вопросов?** артык сораулар юкмы? ♦ ~ **чем** *см.* **более чем**; ~ **того** *см.* **более того**

большевизировать *сов. несов. кого-что* большевиклаштыру, большевизм рухында тәрбияләү

большевизм *м ист.* большевизм

большевик *м* большевик

большевичка *ж* большевик хатын (кыз)

большеголовый, -ая, -ое зур башлы

больш||ий, -ая, -ее *сравн. ст. от* **большой** *и* **великий** 2, 3 ♦ ~ **ей (ею) частью** *или* **по** ~ **ей части** күбесенчә, күпчелектә, башлыча; **самое** ~ **ее я пробуду в пути двое суток** юлда мин күп дигәндә ике тәүлек булырмын

большинств||о *с* күпчелек; **подавляющее** ~ **о** ин зур күпчелек ♦ **в** ~ **е случаев** еш кына, күпчелек очракларда

больш||ой, -ая, -ое 1. зур; ~ **ой город** зур шәһәр; ~ **ая семья** зур гаилә 2. зур, мөһим, әһәмиятле; ~ **ой вопрос** зур мәсьәлә; ~ **ой успех** зур уңыш 3. үсеп җиткән, олы; ~ **ой сын** олы ул 4. күп, күп санлы; ~ **ая родня** күп санлы туганнар ♦ ~ **ая буква** баш хәреф, зур хәреф; ~ **ая вода** зур су; ~ **ая дорога** олы юл; **Большая Медведица** *астр.* Җидегән Йолдыз, Зур Җидегән; ~ **ой палец** баш бармак

болячка *ж* сызлавык, чуан, шеш; кутыр

бомба *ж* бомба

бомбардир *м* бомбардир (*футболда, хоккейда һөҗүм итүче*)

бомбардировать *несов. кого-что* 1. бомбага тоту; тупка тоту, утка тоту; ~ **город** шәһәрне утка тоту 2. *перен.* аптыратып бетерү, йөдәтеп бетерү, яудыру; ~ **друзей письмами** дусларга хатлар яудыру

бомбардировка *ж см.* **бомбардировать**

бомбардировочный, -ая, -ое бомбардировка ...ы; бомбага тота торган; ~ **ая авиация** бомбардировка авиациясе

бомбардировщик *м* бомбардировщик, бомбага тотучы

бомбёжка *ж см.* **бомбить**

бомбить *несов. кого-что* бомбага тоту, бомбалар ташлау; ~ **переправу на реке** елгадагы кичүне бомбага тоту

бомбовоз *м см.* **бомбардировщик**

бомбов||ый, -ая, -ое бомба[лар] ...ы, ~ **ые погреба** бомба базлары

БОМ-БОЯ

бомбодержа́тель *м* бомба элэктергеч (*самолётка бомба тагу җайланмасы*)

бомбомёт *м* бомбомёт (*якын арага бомба ыргыта торган орудие*)

бомбомета́ние *с* бомба ташлау

бомбоубе́жище *с* бомбоубежище

бонда́рн||ый, -ая, -ое мичкә ясау ...ы; **~ое произво́дство** мичкә ясау производствосы

бо́ндарь, бонда́рь *м* мичкәче, мичкә ясаучы

бо́нна *ж уст.* бонна, тәрбияче, мәрәббия (*бай гаиләдә балалар тәрбияләүче, чит илдән килгән хатын*)

бо́ны *мн.* (*ед.* **бо́на** *ж*) *фин.* бон (**1.** *билгеле бер сроккка учреждениедән акча алып тору срокуы бирә торган кредит документы* **2.** *вакытлыча чыгарылган төрле-төрле кәгазь акчаның исеме*)

бор I *м* наратлык, нарат урманы ◆ **с ~у да с со́сенки** аннан-моннан, карап-нитеп тормыйча; **отку́да сыр-~ загоре́лся** ни сәбәпле бу эш килеп чыкты, нәрсәдән ыгы-зыгы килеп чыкты (шаушу башланды)

бор II *хим.* бор

бор III *м* (*сверло*) бор, борау

бордо́ *прил. неизм.* куе кызыл, чия кызыл; **пла́тье цве́та ~** куе кызыл төсле күлмәк

бордо́вый, -ая, -ое *см.* **бордо́**

бордю́р *м* кайма, әдеп

боре́ц *м* **1.** көрәшче, көрәшүче; **~ за свобо́ду** азатлык өчен көрәшүче **2.** *спорт.* көрәшче; **~ тяжёлого ве́са** зур авырлыклы көрәшче

боржо́м *м* боржом

боржо́ми *м, с нескл. см.* **боржо́м**

борза́я *ж* бурзай, ау эте

борзопи́сец *м ирон.* елгыр язучы, елгыр каләмче

бо́рзый, -ая, -ое җитез, елгыр, елдам, йөгерек; (*гадәттә ат турында*); **~ конь** елдам ат

бормаши́на *м* бормашина (*теш бораулау машинасы*)

бормота́ть *несов. что и без доп.* мыгырдау, мыгырдану, мыгыр-мыгыр килү

бо́рн||ый, -ая, -ое: **~ая кислота́** *хим.* бор кислотасы

бо́ров I *м* печтерелгән дуңгыз

бо́ров II *м* (*часть дымохода*) юллык (*мич эчендә төтен юллыгы*)

боровúк *м* ак гөмбә, нарат гөмбәсе

боровúнка *ж* боровинка (*алма сорты*)

боров||о́й, -а́я, -о́е нарат урманы ...ы, нарат урманлы; **~о́е ме́сто** нарат урманлы урын

бород||а́ *ж* сакал; **~а́ лопа́той** көрәк сакал; **отпусти́ть бо́роду** сакал үстерү ◆ **с ~о́й** күптән билгеле, яңа түгел

борода́вка *ж* сөял

борода́вчатый, -ая, -ое сөялле, сөялләр белән капланган

борода́тый, -ая, -ое сакаллы, сакал үстергән

борода́ч *м разг.* сакалбай, зур саккалы кеше

боро́дка *ж* **1.** *уменьш. от* **борода́**; **2.** (*выступ на конце ключа*) ачкыч теле, ачкыч балтасы

борозда́ *ж* буразна

борозд||и́ть *несов. что* **1.** (*пахать*) буразна яру, буразналау, буразна салу **2.** (*пересекать*) буразландырып бетерү, каплау, каплап алыну (*мәс. җыерчыклар белән*); **кана́вы ~я́т по́ле** канаулар кырны буразналандырып бетергәннәр **3.** (*оставлять следы, подобные борозде*) ярып бару (йөрү, үтү)

боро́здка *ж* **1.** *уменьш. от* **борода́**; сай буразна **2.** (*углубление*) җыерчык, ярык

борона́ *ж* тырма, ат (трактор) тырмасы

борони́ть *несов. что* тырмалау; **~ по́ле** кырны тырмалау

боронова́ние *с см.* **борони́ть**

боронова́ть *несов. см.* **борони́ть**

боро́||ться *несов.* **1.** *с кем-чем* көрәшү, алышу; **~ться с лу́чшим борцо́м** иң яхшы көрәшче белән көрәшү **2.** *против кого-чего, с кем-чем и без доп.* көрәшү, көрәш алып бару; **~ться с конкуре́нтами** конкурентлар белән көрәш алып бару **3.** *с чем, против чего* көрәшү, көрәшеп бетерергә тырышу; **~ться с пья́нством** эчкечелек белән көрәшү **4.** *за что* көрәшү; (*берәр нәрсәне булдырыра*) тырышу; **~ться за свобо́ду** азатлык өчен көрәшү **5.** *с чем* (*вступать в столкновение, в борьбу*) көрәшү, көрәшкә керү, бәрелешү; **в нём за́висть ~лась с великоду́шием** аңарда көнләшү белән киң күңеллелек көрәшә иде

борт *м в разн. знач.* борт; **на ~у́** бортта (*корабльдә яки самолётта*); **~ о́ борт** бортка борты тиеп, терәлеп (*суднолар турында*); **взять на ~** *мор.* бортка алу; **челове́к за ~о́м** кеше суга төште ◆ **вы́кинуть (вы́бросить) за́ борт** *кого-что* чыгарып ташлау (*кирәксез кешене яки әйберне*); **оста́ться (оказа́ться) за́ бортом** төшеп калу, кертелмәү

бортжурна́л *м* бортжурнал

бортинжене́р *м* бортинженер

бортмеха́ник *м* бортмеханик

бо́ртник *м уст.* чолыкчы (*чолыкчылык белән шөгыльләнүче*)

бо́ртничать *несов. уст.* чолыкчылык белән шөгыльләнү

бо́ртничество *с уст.* чолыкчылык, чолык умартачылыгы, урман умартачылыгы

бортов||о́й: ~а́я ка́чка *мор.* як-якка чайкалу (*корабльдә*); **~о́й журна́л** борт журналы

бортпроводни́к *м* бортпроводник (*самолётта пассажирларга хезмәт күрсәтүче*)

бортпроводни́ца *ж* бортпроводница

бортради́ст *м* бортрадист, авиация радисты

борть *ж уст.* (*улей в дупле*) чолык (*кыргый умарта кортлары оялаган агач куышы*); (*улей в выдолбленном чурбане*) багана умарта

борцо́вки *мн.* борцовка (*көрәшче аяк киеме*)

борцо́вый, -ая, -ое көрәш ...ы, көрәшү ...ы; **~ зал** көрәшү залы

борщ *м* борщ

борьба́ *ж в разн. знач.* көрәш; **класси́ческая ~** классик көрәш; **кла́ссовая ~** сыйнфый көрәш; **~ за жизнь** яшәү өчен көрәш; **~ за повыше́ние ка́чества проду́кции** продукциянең сыйфатын күтәрү өчен көрәш; **душе́вная ~** рухи көрәш

босико́м *нареч.* яланаяк, яланаяктан; **ходи́ть ~** яланаяк йөрү

босо́й, -а́я, -о́е, **босоно́гий,** -ая, -ое яланаяк, яланаяклы; **на бо́су но́гу** яланаякка

босоно́жки *мн.* босоножки (*җәйге аяк киеме*)

босс *м* **1.** босс, хуҗа (*капиталистик илләрдә хуҗа, җитәкче*) **2.** босс, җитәкче (*АКШта партия яки профсоюз оешмалары җитәкчесе*)

босто́н *м в разн. знач.* бостон; **костю́м из ~а** бостоннан тегелгән костюм; **игра́ть в ~** бостон уйнау (*карт уенында*); **танцева́ть ~** бостон танцевать итү

босто́новый, -ая, -ое бостон, бостоннан тегелгән; **~ костю́м** бостон костюм

бося́к *м* сукбай, йолкыш, зимагур

бося́цкий, -ая, -ое сукбай ...ы, зимагур ...ы

бося́чество *с* сукбайлык, зимагурлык

бота́ник *м* ботаник, ботаника белгече

бота́ника *ж* ботаника

бота́нический, -ая, -ое ботаника ...ы; **~ сад** ботаника бакчасы

ботва́ *ж* сабакъяфрак, сабак

ботви́нья *ж* ботвинья (*чөгендер сабагын пешереп квастан хәзерләнгән балыклы салкын аш*)

бо́тики *мн. см.* **бо́ты**

боти́нки *мн.* ботинки

ботфо́рты *мн.* ботфорт (*озын кунычлы итек*)

бо́ты *мн.* боты (*озын кунычлы резин аяк киеме*)

бо́цман *м* боцман

бочо́нок *м* кечкенә мичкә

бочо́нок *м* кечкенә мичкә

бочо́нок *м* кечкенә мичкә

боя́||ться *несов.* **1.** *кого-чего и с неопр.* курку, шүрләү, өркү; **де́ти ~тся темноты́** балалар караңгыдан куркалар; **~ться просту́ды** салкын тиюдән курку **2.** *чего* (*портиться*) бозылу; **фане́рные изде́лия ~тся сы́рости** фанер әйберләр юештә бозылалар

бра *с нескл.* бра, стена шәмдәле (*шәм яки электр лампасы кую өчен стенага беркетелгән җайланма*)

брава́да *ж* ясалма батырлык, әтәчлек; ясалма кыланыш

брави́ровать *несов. чем* әтәчләнү, кирәксезгә батырлык күрсәткән булу

брави́ссимо *см.* **бра́во II**

бра́во I *нареч.* егетләрчә; **~ закрути́ть усы́** мыекны егетләрчә бөтереп кую

бра́во II *межд.* браво, яшә, шәп, афәрин (*оста башкаручы артистны мактау, алкышлау сүзе*)

брави́рный, -ая, -ое күтәренке, дәртле, дәртләндергеч, җанлы; **~ марш** күтәренке марш

бра́вый, -ая, -ое җитез, булдыклы, елгыр, егетсымак; **~ солда́т** җитез солдат

бра́га *ж* бал, әче бал

брадобре́й *м уст.* чәчтараш, чәч алучы, парикмахер

бра́жник *м уст.* (*гуляка*) эчкече, исерекбаш

бра́жничать *несов. уст.* (*пьянствовать*) эчеп йөрү, эчү

бразды́ *мн. нескл.*: **~ правле́ния** *высок.* власть, идарә, идарә итү; **приня́ть ~ правле́ния** хакимиятне кабул итеп алу

брак I *м* өйләнү (*ирләргә карата*), кияүгә чыгу, тормышка чыгу (*хатын-кызларга карата*); **вступи́ть в ~** өйләнешү; **раста́ргнуть ~** аерылышу

брак II *м* брак, бозык

бракёр *м спец.* бракёр (*бракераж белән шөгыльләнүче*)

бракераж *м спец.* бракераж (*товарларның яраклылыгын һәм заказ шартларына җавап бируен билгеләү*)

бракова́нн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **бракова́ть; 2.** бракка чыгарылган, яраксызга чыгарылган; **~ые изде́лия** бракка чыгарылган әйберләр

бракова́ть *несов. что* **1.** бракка чыгару, яраксызга чыгару, яраксыз дип табу; **~ това́р** товарны бракка чыгару **2.** яраксыз дип табу, кире кагу; **~ стихи́** шигырьләрне яраксыз дип табу

брако́вка *ж см.* **бракова́ть**

брако́вщик *м* браковщик (*товарларның яраклылыгын билгеләүче*)

брако́вщица *ж* браковщик хатын (кыз)

браконье́р *м* браконьер (*тыелган урыннарда, тыелган вакытларда яки тыелганысул кулланып аучылык яки балык тоту белән шөгыльләнүче*)

браконье́рство *с* браконьерлык

бракоразво́дный, -ая, -ое аерылышу ...ы; **~ проце́сс** аерылышу процессы (*ир белән хатын арасында*)

бракосочета́ние *с* никах, никахланышу

брами́н *м* брамин (*Һиндстанда иң югары руханилык кастасының әгъзасы*)

брандмайо́р *м уст.* брандмайор (*электә шәһәрләрдә янгынга каршы көрәшүче командаларның начальнигы*)

брандме́йстер *м уст.* брандмейстер (*электә янгын сүндерү командасының начальнигы*)

брандспо́йт *м* брандспойт (**1.** *янгын насосы* **2.** *бырлы*)

брани́ть *несов.* **1.** *с кем-чем* тиргәшү, сүгешү, әрепләшү **2.** сүгенү ♦ **~ на чём свет стои́т** дөнья бетереп тиргәү

бра́нн||ый I, -ая, -ое тиргәү ...ы, сүгену ...ы; **~ые слова́** сүгенү сүзләре

бра́нн||ый II, -ая, -ое *уст.* сугыш ...ы; **~ое по́ле** сугыш мәйданы

брань I *ж* (*ругань*) тиргәш, сүгеш, сүгенү [сүзләре]

брань II *ж уст.* (*битва*) сугыш; **на по́ле ~и** сугыш мәйданында

брасле́т *м* беләзек

брасле́тка *ж разг. см.* **брасле́т**

брасс *с* брасс (*йөзүнең махсус бер стиле*)

брат *м* **1.** бертуган (*ир туган турында*); **ста́рший ~** абый, абзый; **мла́дший ~** эне; **двою́родный ~** туганнан туган, тудыка; **моло́чный ~** сөт кардәше, имчәктәш туган; **сво́дный ~** үги туган **2.** (*при обращении*) туганкай; **ты, ~, мне зу́бы не заговáривай** син, туганкай, миңа юкә чәй какма **3.** (*единомышленник*) дус, фикердәш, кардәш; **мы ~ья по убежде́ниям** без фикердәшләрбез ♦ **наш ~** безнен кеше[ләр]; **ваш ~** сезнең кеше[ләр]; **на ва́шего ~а не угоди́шь** сезнең кешеләргә ярый алмассың; **на ~а** кеше башына; **пришло́сь по рублю́ на ~а** кеше башына берәр сум туры килде

брата́ние *с см.* **брата́ться**

брата́ться *несов. с кем* **1.** (*вступать в дружеские отношения*) дуслашу, туганлашу **2.** (*прекращать военные действия*) туганлашу, дуслашу (*сугышта ике як солдатларының татулашулары*)

братва́ *ж собир. прост.* туганкайлар, туганнар, дуслар; егетләр (*күбрәк мөрәҗәгать иткәндә*)

бра́тина *ж* (*старинный ковш*) чүмеч, тустаган (*борынгы Россиядә: туйларда эчемлек салып бирү өчен*)

брати́шка *м разг. уменьш. от* **брат** 1, 2; эне, энекәш

бра́тия *ж собир.* **1.** ... халкы (*бер профессия кешеләре*); **актёрская ~** артистлар халкы **2.** *уст.* (*монашеская община*) бер монастырь монахлары

брато́к *м прост.* энекәш, туганкай

братоуби́йственн||ый, -ая, -ое: **~ая война́** үзара үтерешү сугышы

братоуби́йство *с* **1.** (*убийство брата*) бертуганын үтерү **2.** (*убийство собратьев*) үзенең якын кешесен үтерү

братоуби́йца *м, ж* үз туганын (бертуганын) үтерүче

бра́тск||ий, -ая, -ое **1.** (*родственный*) туганлык ...ы; кардәшлек ...ы; **~ие чу́вства** туганлык хисләре **2.** туганнарча ...; **~ие отноше́ния** туганнарча мөнәсәбәтләр ♦ **~ие респу́блики** тугандаш республикалар; **~ая моги́ла** туганнар каберлеге

бра́тство *с* **1.** туганлык, бердәмлек; **~ наро́дов** халыклар бердәмлеге **2.** *уст.* (*религиозная община*) дини җәмгыять

брать *несов.* **1.** *кого-что* алу; **~ в доро́гу чемода́н** юлга чемодан алу; **~ с собо́й сы́на** узең белән бергә улыңны алу; **~ на прока́т** прокатка алу **~ в долг (взаймы́)** бурычка алу; **~** *кого-л.* **на слу́жбу** (*берәр кешене*) хезмәткә алу **2.** (*клевать — о рыбе*) чиртү, кабу **3.** *чем* (*добиваться*) алдыру, уңышка ирешү, җиңү; **он берёт умо́м** ул акыл белән алдыра **4.** (*держаться какого-л. направления пути*) тоту; **~ вле́во** сулга тоту ♦ **~ быка́ за рога́** үгезне мөгезеннән алу (*кискен рәвештә эш итү*); **~ верх** өстен чыгу, җинеп чыгу; **~ в оборо́т** кирәген бирү, арт сабагын укыту; **~ курс (направле́ние)** юл тоту, юнәлеш алу; **~ за го́рло** якасыннан алу (мәҗбүр итү); **~ на вооруже́ние** корал итеп алу; **~ нача́ло** башлану, башланып китү; **река́ Ка́ма берёт нача́ло в Ура́льских гора́х** Кама елгасы Урал тауларыннан башланып китә; **~ по́д руку** култыклап алу; **~ своё** үзенекен итү; **жизнь берёт своё** тормыш үзенекен итә; **тоска́ берёт** эч поша; **~ приме́р** үрнәк алу

бра́ться *несов.* **1.** *за что* тотыну; **~ за верёвку** бауга тотыну **2.** *за что* (*приниматься*) башлау, керешү, тотыну; алыну; **~ за рабо́ту** эшләргә тотыну; **~ за кни́гу** укырга тотыну; **~ за перо́** язарга тотыну **3.** *за что и с неопр.* өскә алу, булу; **~ помо́чь** *кому-л.* (*берәр кешегә*) ярдәм итәргә булу **4.** (*появляться, возникать*) килү, табылу; **отку́да беру́тся у него́ де́ньги?** кайдан акча килә аңа? ♦ **~ за ум** акылга утыру

бра́унинг *м* браунинг (*автомат пистолет*)

бра́чн||ый, -ая, -ое никах ...ы, өйләнешү ...ы; **~ое свиде́тельство** никах таныклыгы

бревё́нчат||ый, -ая, -ое бүрәнәдән гыйбарәт; бүрәнә ...; **~ая стена́** бүрәнә стена

бревно́ *с* бүрәнә

бред *м* саташу (*йокы аралаш яки өндә авыру хәлендә*)

бре́день *м* җылым, сөрәкә

бре́ди||ть *несов.* **1.** саташу; **больно́й ~ т** авыру саташа **2.** *перен. кем-чем* хыяллану; **~ть му́зыкой** музыка белән хыяллану

бре́дни *только мн.* хыяллар, уйдырмалар; **пусты́е ~** буш хыяллар

бредов||о́й, -а́я, -о́е саташу ...ы. хыялый; **~о́е состоя́ние** саташу хәле; ♦ **~а́я иде́я** хыялый идея

бредо́вый, -ая, -ое *разг. см.* **бредово́й**

бре́зга||ть *несов. разг.* җирәнү, чиркану; тайчану, тартыну; **он не ~ет ниче́м** ул бер нәрсәдән дә җирәнми; **тако́му негоди́ю ~ешь и ру́ку пода́ть** андый кабахәт кешегә кул бирерге дә тайчанасың

БРЕ-БРО

брезгли́вость *ж* **1.** (*привередливость*) җирәнүчәнлек, чирканучанлык; **его́ ~ всем изве́стна** аның җирәнүчәнлеге бар кешегә дә билгеле **2.** (*чувство отвращения*) тайчануучанлык, тартынучанлык

брезгли́в||ый, -ая, -ое **1.** (*привередливый*) җирәнүчән, чирканучан; **~ый челове́к** җирәнүчән кеше **2.** (*полный отвращения*) җирәнү ...ы, тайчану ...ы, тартыну ...ы; **~ое чу́вство** җирәнү тойгысы

бре́зговать *несов. разг. см.* **бре́згать**

брезе́нт *м* брезент

брезе́нтов||ый, -ая, -ое **1.** брезент ...ы, брезент эшләп чыгару ...ы; **~ое произво́дство** брезент производствосы **2.** брезент ..., брезенттан тегелгән; **~ый плащ** брезент плащ

бре́зжить, бре́зжиться *несов.* **1.** (*рассветать*) таң ату, таң белену, яктыра башлау, яктырып килү **2.** (*едва виднеться*) яктырып күренү, җемелдәү, җем-җем итү

брело́к *м* брелок (*сәгать чылбырына яки беләзеккә тагыла торган вак-төяклар*)

бре́м||я *с* **1.** *уст.* авыр йөк **2.** *перен.* авырлык; **~я забо́т** мәшәкатьләр авырлыгы ♦ **разреши́ться от ~ени** бала табу, йөктән котылу

бре́нн||ый, -ая, -ое *уст.* чери торган, бетә торган, фани; **~ый мир** фани дөнья; **~ое те́ло** фани гәүдә

бренча́||ть *несов.* **1.** *чем и без доп.* шылтырау, шалтырау, челтерәү, чыңгырау, чалтыр-чолтыр килү; **~ть ключа́ми** ачкычлар шалтырату **2.** *на чём, разг.* дыңгырдату, белер-белмәс уйнау (*музыка коралында*), дыңгырдату

брести́ *несов.* көчкә-көчкә бару, әкрен бару, сөйрәлеп бару

брете́лька *ж* бретель (*күлмәкне, юбканы тотып тору өчен җилкә аркылы үткәрелгән тасма*)

бретёр *м уст.* бретёр, җәнҗалчы дуэльче (*дуэльгә чакыру өчен кечкенә генә булса да сылтау табарга әзер торучы*)

бреха́ть *несов. прост.* **1.** (*о собаке*) өрү, ләңгелдәү **2.** (*врать*) ләңгелдәү; ялганлау, ялган сөйләү

брехня́ *ж прост.* ялган сүз, буш сүз, сафсата, уйдырма

бреху́н *м прост.* лыгырдык, ялганчы

бреху́нья *ж прост.* лыгырдык хатын (кыз), ялганчы хатын (кыз)

брешь *ж* **1.** тишек, җимерек урын (*крепость стенасында*) **2.** *перен.* (*недостача*) җитмәгәнлек, ким чыгу ♦ **проби́ть ~** *в чём* юл яру

бре́ющий: ~ полёт кырдырып очу (*самолётта бик түбәннән очу*)

бриг *м уст.* бриг (*18-19 йөзләрдә ике мачталы җилкәнле судно*)

брига́да *ж в разн. знач.* бригада; **та́нковая ~** танк бригадасы; **поездна́я ~** поезд бригадасы; **тра́кторная ~** трактор бригадасы

бригади́р *м* бригадир

брига́дный, -ая, -ое бригада ...ы

бриганти́на *ж* бригантина (*җилкәнле җиңел судно*)

бри́джи *только мн.* бриджи (*балаклары кунычка тыгып кия торган чалбар*)

бриз *м мор.* бриз (*көндез диңгездән ярга таба, төнлә яр буеннан диңгезгә таба исә торган җил*)

бриза́нтный, -ая, -ое *воен.* (*разрывной*) бризант, һавада шартлый торган; **~ снаря́д** бризант снаряд

брике́т *м* брикет (*күмер, пычкы чүбе, металл йомычкасы кебекләрдән ясалган кирпеч, аерым кисәк*)

брикети́ровать *сов., несов. что* брикетлау, брикет сугу, брикет ясау; **~ торф** торфтан брикет сугу

брике́тный, -ая, -ое брикет ..., брикет ...ы

бриллиа́нт *м см.* **брильянт**

бриллиа́нтовый, -ая, -ое *см.* **брильянтовый**

брильянт *м* бриллиант

брильянтов||ый, -ая, -ое **1.** бриллиант ...ы; **~ый блеск** бриллиант ялтыравы **2.** бриллиантлы, бриллиант белән бизәлгән; **~ые се́рьги** бриллиантлы алкалар

бри́тва *ж* бритва, кырыну пәкесе; **безопа́сная ~** куркынычсыз бритва

бри́твенный, -ая, -ое кырыну ...ы; **~ прибо́р** кырыну приборы

бри́тый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **брить**; **2.** кырынган, кырдырган

брить *несов. кого-что* кыру, алу, китерү (*чәчне, сакалны, мыекны*)

бритьё *с см.* **брить, бри́ться**

бри́ться *несов.* кырыну, кырынып йөрү

бри́чка *ж уст.* бричка, җинел арба

бровь *ж* каш ♦ **не в ~, а [прямо] в глаз** нәкъ өстенә басу (*урынлы әйтелгән сүз турында*)

брод *м* кичү

броди́льный, -ая, -ое **1.** әчү ...ы; **~ проце́сс** әчү процессы **2.** (*служащий для брожения*) әчетү ...ы; **~ чан** әчетү чаны

броди́ть I *несов.* йөрү, йөреп тору; **~ по ле́су** урманда йөрү ♦ **мы́сли бро́дят** фикерләр чуала

броди́ть II *несов.* әчү, әчешү

броди́га *м, ж* сукбай, йолкыш, зимагур

броди́жить, броди́жничать *несов.* сукбайлыкта (зимагурлыкта) йөрү

броди́жничество *с* сукбайлык, зимагурлык

броди́ч||ий, -ая, -ее **1.** (*кочующий*) күчмә, күчеп йөри торган; **~ие племена́** күчмә кабиләләр **2.** сәйяр, гизүче, күчмә; **~ая жизнь** күчмә тормыш

броже́ние *с* **1.** *биол.* әчү, әчешү **2.** *перен.* (*волнение*) чуалыш, буталыш, кузгалыш, ризасызлык

бро́йлер *м* **1.** (*цыплёнок*) бройлер (*60 көнлек чебеш*) **2.** (*помещение для выращивания цыплят*) бройлер бинасы, бройлер абзары

бром *м хим.* бром

бро́мист||ый, -ая, -ое *хим.* бромлы; **~ка́лий** бромлы калий

бро́не- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар телендә «броняланган», «броня белән тышланган, капланган» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.* **бронеба́шня** бронялы башня; **бронедрези́на** бронялы дрезина

бронебо́йн||ый, -ая, -ое бронятишкеч, броня[ны] тишә торган; **~ое ору́жие** бронятишкеч корал

броневи́к *м* броневик (*бронялы автомобиль*)

бронев||о́й, -а́я, -о́е **1.** бронялы, броня белән капланган; **~о́й автомоби́ль** бронялы автомобиль **2.** (*служащий для брони*) броня ..., броня ...ы; **~ы́е пли́ты** броня плиталар

бронемаши́на *ж* бронемашина

броненó́сец *м* броненосец (*бронялы эре сугыш корабле*)

броненó́сный, -ая, -ое бронялы, броня белән капланган; **~ кре́йсер** бронялы крейсер

бронепо́езд *м* бронепоезд

бронетранспортёр *м* бронетранспортёр

бро́нза *ж* бронза (**1.** *бакыр һәм аккургаш эретмәсе* **2.** *сәр.* *бронзадан ясалган художество әйберләре*)

бронзирова́ть, бронзи́ровать *сов., несов. что, спец.* бронзалау, бронза йөгертү

бро́нзов||ый, -ая, -ое бронза ..., бронзадан ясалган; **~ая статуэ́тка** бронза статуэтка

бронирó́ванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **бронирова́ть**; **2.** (*покрытый бронёй*) бронялы; броня капланган

брони́ровать *несов. что* бронировать итү, броньга калдыру, броньлау (*бронь буенча гына биру өчен аерып кую, мәс. поезддагы урынны, гостиницадагы номерны һ.б.ш.*); **~ ме́сто в вагóне** вагонда урын бронировать итү

бронирова́ть *сов., несов. что* броня белән каплау (*снарядлардан саклану өчен*)

бро́нхи *мн.* (*ед.* **бронх** *м*) *анат.* бронхлар

бронхиа́льн||ый, -ая, -ое бронхиаль, бронх[лар] ...ы; **~ые же́лезы** *анат.* бронх бизләре; **~ая а́стма** бронхиаль астма

бронхи́т *м* бронхит

бро́нь *ж* бронь (*берәр нәрсәне, мәс. поезддагы урынны, гостиницадан номерны һ.б.ш. беркетү, беркетү турында документ*); **~ на железнодоро́жный биле́т** тимер юл билеты броне

броня́ *ж* **1.** көбә (*электә сугышчыларга кидерү өчен металлдан ясалган кием*) **2.** броня (*автомобильләрне һ.б.ш. тышлау өчен корычтан ясалган плита*)

броса́||ть *несов.* **1.** *кого-что* ташлау, ыргыту, ату, атып бәрү; **~ть грана́ту** граната ыргыту **2.** *кого-что* (*покидать, оставлять*) ташлау, ташлап китү, калдыру, калдырып китү; **~ть семью́** семьяны ташлау; **~ть пози́ции** позицияне ташлап китү **3.** *что и с неопр.* (*прекращать что-л. делать*) ташлау; **~ть кури́ть** тәмәке тартуны ташлау; **~йте рабо́ту!** эшне ташлагыз! **4.** *кого-что* (*направлять в большом количестве*) кертү, чыгарү; җибәрү; **~ть войска́ в бой** сугышка гаскәрләр кертү; **~ть това́ры на ры́нок** базарга товарлар

чыгару; **~ть дополни́тельные сре́дства на строи́тельство** төзелешкә өстәмә акча җибәрү 5. *что (направлять, пускать)* чәчү; сибү; **со́лнце ~ет лучи́** кояш нурларын сибә ♦ **~ть де́ньги на ве́тер** акчаны әрәм итү, акчаны җилгә очыру; **~ть на произво́л судьбы́** язмыш иркенә ташлау; **~ть тень** *на кого-что* йөзгә кара ягу; **~ть взгляд** *на кого-что* күз ташлау; **~ть жре́бий** шобага салу, шобага тоту; **меня́ ~ет то в жар, то в хо́лод** тәнем эсселе-суыклы булып китә; **~ть ка́мешки в** *чей* **огоро́д** *кемнең* булса бакчасына таш ыргыту (*кешегә төрттереп әйтү, тешләп әйтү мәгънәсендә*)

броса́||ться *несов.* 1. *чем* ыргытышу, атышу, бәрешү; **~ться снежка́ми** кар атышу (ыргытышу) 2. *на кого-что* ташлану, ыргылу; **соба́ки ~ются на прохо́жих** этләр үтеп боручыларга ташланалар 3. (*устремляться на помощь*) ташлану; **~ться на по́мощь** ярдәмгә ташлану 4. (*прыгать с высоты*) сикерү, ташлану; **~ться в во́ду** суга ташлану 5. *страд. от* **броса́ть** ♦ **~ться в глаза́** күзгә чалыну, күзгә ташлану; **~ться в дра́ку** сугыша башлау; **~ться деньга́ми** акчаны җилгә очыру, акчаны әрәм итү; **~ться со всех ног** җан-фәрманга йөгерә башлау; **~ться слова́ми** авызы ни әйткәнне колагы ишетмәү

бро́сить *сов. см.* **броса́ть**

бро́ситься *сов.* 1. (*сверху вниз*) ташлану 2. башлау; тотыну; **~ бежа́ть** йөгерә башлау; **~ в дра́ку** сугышырга тотыну

бро́ский, -ая, -ое күзгә ташланып тора торган, бик ачык; **~ цвет** бик ачык төс

бро́совый, -ая, -ое яраксыз, бик начар, начар сыйфатлы; **~ това́р** яраксыз товар

броско́ *м* 1. *см.* **броса́ть** 1, **броса́ться** 2, 3, 4; 2. ыргылыш, кискен ыргылыш; **~ вперёд** алга ыргылыш

бро́шка, брошь *ж* брошка

брошю́ра *ж* брошюра

брошюрова́льный, -ая, -ое брошюралау ...ы; **~ стано́к** брошюралау станогы

брошюрова́ние *с см.* **брошюрова́ть**

брошюрова́ть *несов. что* брошюралау, брошюровкалау

брошюро́вщик *м* брошюралаучы, брошюровщик

брошюро́вщица *ж* брошюралаучы хатын(кыз)

брудершафт *м*: **пить [на] ~** *с кем* дуслашу хөрмәтәнә чәкешеп эчү

брус *м* борыс (*дурт кырлы итеп ясалган агач эшләнмә*) ♦ **паралле́льные ~ья** *спорт.* параллель борыслар (*махсус гимнастика җайланмасы*)

бруско́в||ый, -ая, -ое дүрт кырлы, кисәкле; **~ое мы́ло** кисәкле сабын

брусни́ка *ж* нарат җиләге, көртләмек

брусни́чник *м* нарат җиләклеге, көртләмеклек

брусни́чн||ый, -ая, -ое 1. нарат җиләге ...ы, көртләмек ...ы; **~ый куст** нарат җиләге куагы 2. нарат җиләге ..., нарат җиләгеннән хәзерләнгән; **~ое варе́нье** нарат җиләге вареньесе

брус||о́к *м* 1. (*камень для шлифовки*) кайрак, янавык, беләү (*чалгы һ.б.ш. кайрау өчен*); **точи́ть нож на ~ке́** пычакны беләү белән кайрау 2. кисәк (*дурт кырлы*); **~о́к мы́ла** бер кисәк сабын

брусо́чн||ый, -ая, -ое 1. *спец.* борыс ...ы; **~ое произво́дство** борыс производствосы 2. (*имеющий форму бруска*) кисәкле; **~ое мы́ло** кисәкле сабын

бру́ствер *м воен.* бруствер (*окоп алдындагы туфрак өеме*)

брусча́тка *ж* брусчатка (1. *собир. шакмаклап вакланган таш* 2. *таш түшәлгән урам*)

бру́тто *прил. неизм.* брутто

бруцеллёз *м мед.* бруцеллёз (*терлекләрдә, дуңгызларда йогышлы авыру*)

брыже́йка *ж анат.* җыерча (*корсакта эчәкләрне тотып тора торган катлау*)

бры́з||гать *несов.* 1. *чем* (*разбрасывать капли*) сиптерү, су сиптерү; **фонта́н ~жет** фонтан сиптерә 2. *на кого-что, что* (*кропить, обрызгивать*) бөркү, чәчрәтү; **не ~гай на меня́ водо́й** миңа су чәчрәтмә; **~гать бельё** кергә су бөркү 3. (*разлетаться*) чәчрәү; **и́скры ~жут** очкыннар чәчри

бры́згаться *несов.* 1. *чем* [су] чәчрәтү; сибү, бөркү; **не смей ~!** су чәчрәтмә! 2. (*обрызгивать друг друга*) [су] чәчрәтешү, сибешү, бөркешү

бры́зги *только мн.* 1. (*капли жидкости*) чәчрәвек, чәчрәгән тамчы [бөртекләре] 2. (*частица твёрдого тела*) вак кисәк, бөртек (*мәс. таш бөртекләре*)

бры́знуть *сов.* 1. *однокр.* чәчрәтү; чәчрәп чыгу; **~ть ма́слом на пла́тье** күлмәккә май чәчрәтү 2. (*внезапно политься*) сибәли башлау, ява башлау; **~л дождь** яңгыр ява башлады

брыка́ть *несов. кого-что* тибү (*ат турында*)

брыка́||ться *несов.* 1. тибешү, тибү; **не подходи́, э́та лоша́дь ~ется** якын барма, бу ат тибешә 2. (*брыкать друг друга*) тибешү

брыкли́вый, -ая, -ое *прост.* тибешкәк, тибешүчән; **~ конь** тибешкәк ат

брыкну́ть *сов. однокр. кого-что* тибеп җибәрү

бры́нза *ж* брынза

брысь *межд.* перс (*мәчене куып җибәрү ымлыгы*)

брюзга́ *м, ж* мыгырдык, сукранучан кеше

брюзгли́вость *ж* мыгырдануучанлык, сукранучанлык

брюзгли́вый, -ая, -ое мыгырдык ..., мыгырдануучан, сукранучан; **~ стари́к** мыгырдануучан карт

брюзжа́ние *с см.* **брюзжа́ть**

брюзжа́ть *несов.* мыгырдау, мыгырдану, сукрану

брю́ква *ж* гәрәнкә, бүкән шалкан

брю́квенный, -ая, -ое гәрәнкә ...ы; гәрәнкәдән хәзерләнгән

брю́ки *только мн.* чалбар

брюне́т *м* брюнет

брюне́тка *ж* брюнет хатын (кыз)

брюха́тый, -ая, -ое *прост.* зур корсаклы

брю́хо *с прост.* корсак

брю́чн||ый, -ая, -ое чалбар ...ы; чалбар тегү ...ы; **~ая пу́говица** чалбар төймәсе; **~ый цех** чалбар тегү цехы; **~ый костю́м** чалбарлы костюм (*хатын-кызлар киеме*)

брюши́на *ж анат.* корсак ярысы

брюшко́ *с* 1. (*толстый живот*) юан корсак 2. (*у маленьких животных, птиц*) түш 3. (*задний отдел тела членистоногих*) корсак

брюшн||о́й, -а́я, -о́е корсак ...ы; **~а́я по́лость** корсак куышлыгы ♦ **~о́й тиф** корсак тифы

бряк *межд. в знач. сказ.* шап иттереп сукты, шап итеп егылды; **кто́-то ~ в окно́** кемдер тәрәзәгә шап иттереп сукты; **он ~ на́ пол** ул шап итеп идәнгә егылды

бря́кать *несов. разг. см.* **бря́кнуть**

бря́каться *несов. разг. см.* **бря́кнуться**

бря́кнуть *сов. однокр. разг.* 1. *чем* шалт итү; шалтыратып җибәрү, шалтыратып кую, чалтыратып җибәрү, чалтыратып кую; **~ посу́дой** савыт-сабаны чалтыратып кую 2. *кого-что* (*бросить, уронить*) шап иттереп төшерү (ташлау); шап иттереп төшереп җибәрү (атып бәрү); **~ вяза́нку дров на́ пол** бер кочак утынны шап иттереп идәнгә ташлау 3. *что и без доп.* (*необдуманно сказать*) [сүз] ычкындыру, әйтеп салу, әйтеп җибәрү

бря́кнуться *сов. однокр. разг.* шап итеп (егылу) барып төшү; **~ на́ пол** шап итеп идәнгә егылу

бря́цать *несов. чем, на чём и без доп. уст.* шалтырау, чыңгырдау; шалтырату, чыңгырдату; **~ шпо́рами** шпорлар чыңгырдату ♦ **~ ору́жием** корал белән янау, сугыш белән куркыту

бу́бен *м* шөлдерле барабан (*музыка коралы*)

бубенцы́ *мн.* шөлдер, кечкенә кыңгырау

бубе́нчик *м* 1. кечкенә шөлдер 2. *бот.* кыңгырау чәчәк

бу́блик *м* бублик, келиндер

бубни́ть *несов. что и без доп., разг.* мыгырдау, сукрану

бубно́вый, -ая, -ое *карт.* буби ...ы; **~ вале́т** буби валеты

бу́бны *мн. карт.* (*ромб рәсемнәре төшерелгән уен кәрте*)

бубо́н *м мед.* бубон (*лимфатик бизләрнең ялкынсынуы*)

буга́й *м* үгез

бугро́ *м* калкулык, калку җир

бугорко́ *м* 1. *уменьш. от* **бугро́**; 2. *мед.* төер (*туберкулез белән авырганда упкәдә була торган төер*)

бугро́рчатый, -ая, -ое төерле

бугри́стый, -ая, -ое калкулыклы, калкулар белән капланган

буддизм *м* буддизм, Будда дине

буддист *м* буддачы (*Будда динен тотучы*)

буддистка *ж* буддачы хатын (кыз)

будёновец *м ист.* буденовчы

БУД-БУМ

будёновка *ж* (*шлем*) буденовка

бу́дет 1. *Зл. буд. вр. от* **быть** булыр 2. *разг.* (*довольно, достаточно*) җитәр инде, ташлагыз (туктагыз инде); **~ вам разгова́ривать, спать меша́ете** җитәр инде, сөйләшмәгез, йокларга бирмисез

буди́льник *м* будильник, уяткыч сәгать

буди́ть *несов.* 1. *кого-что* уяту, йокыдан уяту 2. *перен. что* кузгату, тудыру, уяту; **~ не́нависть к врагу́** дошманга нәфрәт тудыру

бу́дка *ж* будка (*сакчы, каравылчы өйчеге*)

бу́дни *только мн.* 1. (*рабочие дни*) эш көннәре 2. *перен.* (*о повседневной жизни*) көндәлек тормыш

бу́дний, -яя, -ее *см.* **бу́дничный**

бу́дничн||ый, -ая, -ое 1. эш ...ы; **~ый день** эш көне 2. *перен.* (*повседневный*) көндәлек, көндә була торган; **~ая рабо́та** көндәлек эш 3. *перен.* (*безрадостный*) гадәти, көндәлек; күңелсез; **~ая жизнь** гадәти тормыш

будора́жить *несов. кого-что* тынгысызлау, тынычсызлау; борчу, дулкынландыру, ыгы-зыгы китерү

бу́дто 1. *союз сравн.* (*словно, как*) кебек, шикелле, ...дәй, гүя, гүяки, әйтерсең; **смо́трит, ~ живо́й** тере кебек карап тора 2. *союз сравн.* (*как бы, как если бы*) бугай; **посмотри́ ~ идёт кто́-то** кара әле, кемдәр килә бугай 3. *частица вопр.* (*разве*) шулаймыни?, ...мыни?; **уж ~ ты так силён?** әйтерсең лә син шундый көчле?; **я винова́т ~?** мин гаеплемени? 4. *союз изъясн.* (*что*) имеш, ...дип; **уверя́ет, ~ сам ви́дел** үзем күрдем дип сөйләгән була

будуа́р *м уст.* будуар (*бай хатыныңкиену-ясану һәм кунакларны кабул итубүлмәсе*)

бу́дущ||ий, -ая, -ее 1. (*предстоящий*) киләчәк, булачак, киләчәктәге, киләчәктә булачак; **~ее поколе́ние** киләчәк буын 2. (*следующий*) киләсе; **~ий год** киләсе ел; **на ~ий год** киләсе елга, яренгә 3. *в знач. сущ.* **~ее** *с* киләчәк; **счастли́вое ~ее** бәхетле киләчәк

бу́дущность *ж* киләчәк; **~ се́льского хозя́йства** авыл хуҗалыгының киләчәге; **его́ ожида́ет блестя́щая ~** аны бик яхшы киләчәк көтә

будь *повел. накл. от* **быть** ♦ **~ то** кирәк ... булсын; **он всё чита́л, ~ то стихи́, про́за и́ли пье́са** кирәк шигырь булсын, кирәк проза яки пьеса булсын, ул барсын да укый иде

буёк *м* буёк

бу́ер *м* буер, боз көймәсе (*боз өстендәшуу өчен җилкәнле көймә*)

буера́к *м* ерганак, су ерган чокыр

буери́ст *м* буерчы (*буерлар ярышында катнашучы*)

бу́ерный, -ая, -ое буер ...ы; **~ спорт** буер спорты

бужени́на *ж* пешкән дуңгыз ите

буза́ I *ж прост.* (*скандал, беспорядок*) гауга, җәнҗәл, ызгыш; тәртипсезлек

буза́ II *ж* буза (*марыдан, карабодайдан, арпадан ясалган исерткеч эчемлек*)

бузина́ *ж* аю баланы, карга миләше

бузи́ть *несов. прост.* щау-шу күтәрү, гауга чыгару, дау куптару

бузотёр *м прост.* гауга куптаручы, җәнҗәл чыгаручы, гаугачы

бузотёрство *с прост.* гауга; җәнҗәл (гауга) күтәрү

буй *м* буй, сигнал калкавычы (*сай җирне яки балыкчы ятьмәләре салынганурынны курсәтү өчен*)

бу́йвол *м* буйвол (*күшәүче эре хайван*)

буйволи́ца *ж* ана буйвол

бу́йный, -ая, -ое 1. (*порывистый, сильный*) көчле, каты; **~ ве́тер** каты җил 2. (*о растительности*) куе үләнле 3. ялкынлы, кайнар; котырынкы; **~ хара́ктер** кайнар характер

бу́йствовать *несов. разг.* котырыну, дау кубару; холыксызлану

бук *м* бүк агачы

бу́ка *м, ж разг.* (*угрюмый человек*) кеше сөймәс, караңгы чырайлы (*ялгызлыкны яратучан кеше*)

бука́шка *ж* корт, бөҗәк

бу́кв||а *ж* 1. хәреф 2. *перен.* хәреф, формаль як; **соблюда́ть ~у зако́на** законны формаль яктан гына үтәү ♦ **~а в ~у** сүзгә-сүз; **перевести́** *что* **~а в ~у** *берәр нәрсәне* сүзгә-сүз тәрҗемә итү

буквали́зм *м* хәрефкә ябышып яту

буква́льно *нареч.* 1. (*дословно*) сүзгә-сүз; һич үзгәртмичә; **~ переводи́ть** сүзгә-сүз тәрҗемә итү 2. (*действительно*) бөтенләй, чынлап та, һич тә; **у меня́ нет ~ ни одного́ свобо́дного дня** минем чынлап та бер генә буш көнем дә юк

буква́льн||ый, -ая, -ое 1. (*дословный*) сүзгә-сүз, хәрефкә-хәреф; **~ый перево́д** сүзгә-сүз тәрҗемә 2. (*прямой, не переносный*) туры, төгәл; **~ое значе́ние** туры мәгънә

буква́рный, -ая, -ое (*производимый по букварю*) әлифба ...ы, әлифба буенча өйрәтү ...ы; **~ спо́соб обуче́ния гра́моте** укырга-язарга әлифба буенча өйрәтү ысулы

буква́рь *м* әлифба, әлифба китабы

бу́квенн||ый, -ая, -ое хәрефле, хәреф[ләр] белән ...; **~ое уравне́ние** *мат.* хәрефле тигезләмә

буквое́д *м ирон.* хәрефкә ябышып ятучы (эш итүче)

буквое́дство *с ирон.* хәрефкә ябышып яту (эш итү)

буке́т *м* 1. букет, чәчәкләр бәйләме 2. [үзенә бер] тәм, [үзенә бер] ис; **~ ча́я** чәйнең тәме

букини́ст *м* букинист

букинисти́ческий, -ая, -ое букинистика ...ы, букинистик; **~ магази́н** букинистика кибете

букле́т *м* буклет

бу́кли *мн. уст.* дулкынсыман чәч бөтеркәләре

бу́ков||ый, -ая, -ое 1. бүк ...ы; **~ое де́рево** бүк агачы 2. бүк, бүк агачыннан ясалган; **~ая ме́бель** бүк агачыннан ясалган мебель

буко́лика *ж лит.* буколика (*көтүчеләр һәм авыл тормышын табигатьчолганышында идеаллаштырып бирәторган әдәбият*)

буколи́ческ||ий, -ая, -ое *лит.* буколика ...ы, буколик; **~ая поэ́зия** буколик поэзия

бу́кса *ж ж.-д.* букса (*вагон күчәреурнаштырылган металл тартма*)

букси́р *м* буксир; **ба́ржа идёт на ~е** баржаны буксир алып бара ♦ **взять на ~** *кого-что* буксирга алу (*берәр кешегә берәр нәрсәне үтәүдәярдәм күрсәтү*)

букси́рный, -ая, -ое буксир ...ы; **~ парохо́д** буксир пароходы

букси́рование *с см.* **букси́ровать**

букси́р||овать *несов. что* (*канаткатагып*) тартып бару; буксирлау; **парохо́д ~ует ба́ржу** пароход баржаны тартып бара

буксиро́вка *ж см.* **букси́ровать**

буксиро́вщик *м* буксировщик (*тартып алып баручы пароход, автомобильh.б.ш.*)

буксова́ние *с см.* **буксова́ть**

буксова́ть *несов.* буксовать иту (*бараалмыйча көпчәге бер урында әйләнептору*)

булава́ *ж* 1. чукмар (*борынгы корал*) 2. булава (*электә хакимият символы*); **ге́тманская ~** гетманлык булавасы

була́вка *ж* булавка

була́вочн||ый, -ая, -ое булавка ...ы; **~ая голо́вка** булавка башы ♦ **с ~ую голо́вку** энә очы кадәрле

була́ный, -ая, -ое кола (*ат төсе турында*)

була́т *м* булат (1. *ист. бизәкле корыч* 2. *уст. корыч кылыч, хәнҗәр*)

бу́лка *ж* булка, күмәч

бу́лочная *ж* икмәк кибете

бу́лочник *м уст.* 1. булка пешерүче 2. булка сатучы; икмәк кибете хуҗасы

бу́лочн||ый, -ая, -ое булка ...ы, күмәч ...ы; булкалар пешерү ...ы; **~ое произво́дство** булкалар пешерү производствосы

бултых *межд. в знач. сказ.*: **~ в во́ду** суга барып төште (чумды)

бултыхну́ться *сов. однокр.* (*упасть, кинуться в воду*) суга барып төшү, суга ташлану (сикерү)

булы́жник *м* йомры таш

булы́жн||ый, -ая, -ое йомры таш түшәлгән; **~ая мостова́я** йомры таш түшәлгән урам

бульва́р *м* бульвар

бульва́рный, -ая, -ое 1. бульвар ...ы 2. бульвар ..., сай эчтәлекле (*мещаннарның, обывательләрнең кызыксынуларынкүздә тотып кына язылган*); **~ рома́н** бульвар роман

бульдо́г *м* бульдог (*эт токымы*)

бульдо́зер *м* бульдозер

бульдозери́ст *м* бульдозерчы

бу́лькать *несов.* былт-былт итү, былт-былт итеп агу; челтерәү

бульо́н *м* шулпа, ит шулпасы

бум *м разг.* бум, ясалма шау-шу күтәрү, ыгы-зыгы күтәрү; **газе́тный ~** газетада шау-шу күтәрү

бума́г||а I *ж* 1. кәгазь 2. (*документ*) кәгазь, язу, документ; **ры́ться в ~ах** документлар актару ♦ **оста́ться на ~е** кәгазьдә генә калу (*гамәлгә ашмаган карар турында әйтелә*)

бума́га II *ж уст.* (*хло́пок*) киҗе-мамык (*мамык үзе һәм аннан тукылган тукымалар*)

бумагомара́нье *с разг.* кәгазь пычрату (*кирәкмәгән нәрсә яки начар язу*)

бума́жка *ж* 1. *уменьш. от* **бума́га** I 1; кәгазь кисәге 2. *уменьш. от.* **бума́га** I 2; язу документ 3. *уст.* (*денежный знак*) кәгазь акча

бума́жник I *м* бумажник (*кечкенә букча*)

бума́жник II *м* кәгазьче (*кәгазь промышленностендә эшләүче*)

бума́ж||ный I, -ая, -ое 1. кәгазь ...ы; **~ое произво́дство** кәгазь производствосы 2. кәгазьдән ясалган, кәгазь ...; **~ые салфе́тки** кәгазь салфеткалар

бума́жн||ый II, -ая, -ое 1. (*выделанный из хлопка*) киҗе-мамыктан эшләнгән, киҗе-мамык ...; **~ая мате́рия** киҗе-мамык тукыма 2. (*сделанный из бумажной ткани*) киҗе-мамык ..., киҗе-мамыктан тегелгән; **~ая блу́за** киҗе-мамыктан тегелгән блуза

бумазе́йн||ый, -ая, -ое 1. бумази ...ы, бумази эшләп чыгара торган; **~ое произво́дство** бумази производствосы 2. бумази ..., бумазидән тегелгән; **~ое пла́тье** бумази күлмәк

бумазе́я *ж* бумази

бумера́нг *м* бумеранг (*ыргытканнан соң кире әйләнеп кайта торган һөҗүм коралы*)

бундесве́р *м* бундесвер (*Германия Федератив Республикасы армиясенең атамасы*)

бундеста́г *м* бундестаг (*Германия Федератив Республикасында иң югары хакимият органы*)

бу́нкер *м* бункер (1. *коела, сибелә торган әйберләр салу урыны, мәс. комбайнда орлык җыйгыч һ.б.ш.* 2. *җир астындагы махсус җиһазландырылган бина*)

бункерова́ть *сов., несов. что, спец.* бункерга салу (тутыру); **~ у́голь** күмерне бункерга салу

бунт I *м* (*мятеж*) бунт, фетнә, баш күтәрү; гыйсьян

бунт II *м спец.* 1. (*связка, кипа*) бунт, төргәк, бәйләм; **пенька́ в ~а́х** сүс бәйләме 2. өем; **~ы́ хло́пка** мамык өеме

бунта́рск||ий, -ая, -ое бунтарь ...ы, бунтарьлык ...ы, гыйсьянчылык ...ы; **~ие ре́чи** бунтарьлык чыгышлары

бунта́рство *с* бунтарьлык, гыйсьянчылык

бунта́рь *м* бунтарь, гыйсьянчы

бунтова́ть *несов.* 1. (*участвовать в бунте*) бунт чыгару, бунт күтәрү, бунтта катнашу 2. *кого-что* бунтка чакыру; бунтка котырту; **~ наро́д** халыкны бунтка чакыру 3. (*протестовать*) каршы чыгу, котырыну, ду килү

бунтово́й, -а́я, -о́е (*о товаре*) бәйләмле, бунтлы, пачкалы

бунтовщи́к *м* фетнәче, бунт чыгаручы, бунт күтәрүче, бунтчы, гыйсьянчы

бунтовщи́ческий, -ая, -ое фетнәче ...ы, бунтчы ...ы

бунчу́к *м* бунчук (*гетманның, казак атаманының хакимлек билгесе буларак ат коерыгы тагылган таяк*)

бур *м* бур, жир боравы (*җир бораулау инструменты*)

бура́ *ж* бура

бура́в *м* борау

бура́вить *несов. что* бораулау, бораулап тишү

бура́вчик *м* кечкенә борау

бура́к *м* кызыл чөгендер

бура́н *м* буран, кар бураны

бура́нный, -ая, -ое буранлы; **~ день** буранлы көн

бургоми́стр *м* бургомистр (*Көнбатыш Европада шәһәр идарәсе башлыгы*)

бурда́ *ж* бурда, боламык (*тәмсез сыек аш*)

бурдю́к *м* саба, турсык (*сыек әйберләр салыр өчен хайван тиресеннән тегелгән капчык*)

буреве́стник *м* давыл хәбәрчесе, давыл кошы (*дингез кошы*)

бурело́м *м* ауган агачлар, давыл еккан агачлар

буре́ние *с см.* **бури́ть**

буре́ть *несов.* көрәнләнү, көрән төскә керү

буржуа́ *м нескл.* буржуа

буржуази́я *ж* буржуазия

буржуа́зно-демократи́ческий, -ая, -ое буржуаз-демократик

буржуа́зн||ый, -ая, -ое 1. буржуаз, буржуазия ...ы; **~ая пре́сса** буржуаз матбугат; **~ая па́ртия** буржуаз партия 2. буржуаз; **~ая революция** буржуаз революция

буржу́й *м презр.* буржуй

буржу́йка *ж* 1. *презр.* буржуй хатын (кыз) 2. *разг.* (*печка-времянка*) тимер мич

бури́льн||ый, -ая, -ое бораулау ...ы; **~ая маши́на** бораулау машинасы

бури́льщик *м* бораулаучы (*эшче*)

буриме́ *с нескл. лит.* буриме (*алдан бирелгән рифмаларга язылган шигырьләр; әдәби уен*)

бури́ть *несов. что* бораулау, җир бораулау

бу́рка *ж* бурка (*җилкәгә салып йөри торган җиңсез тула чикмән*)

бу́ркать *несов. что и без доп., разг.* мыгырдау

бу́ркнуть *сов. однокр. что и без доп., разг.* мыгырдап кую

бурла́к *м* бурлак

бурла́цк||ий, -ая, -ое бурлак[лар] ...ы; **~ие пе́сни** бурлак жырлары

бурла́чество *с* 1. (*бурлацкий промысел*) бурлаклык 2. (*бурлаки*) бурлаклар

бурла́чи||ть *несов.* бурлак булып йөрү, бурлаклыкта йөрү; **в мо́лодости он ~л на Во́лге** яшьлегендә ул Иделдә бурлак булып йөргән

бурли́вый, -ая, -ое ургылып ага торган; шаулы, кайнап тора торган; **~ пото́к** ургылып ага торган ташкын

бурли́ть *несов.* 1. ургылу, ургылып агу 2. *перен.* ярсыну, ярсып дулкынлану

бурми́стр *м* бурмистр (*алпавыт тарафыннан крепостной крестьяннар өстеннән күзәтчелек итү өчен куелган староста*)

бурну́с *м* бурнус (*19 йөздә хатын-кызларның җилкәгә салына торган киеме*)

бу́рн||ый, -ая, -ое 1. (*с бурей*) давыллы; **~ая ночь** давыллы төн 2. (*бушующий*) дулкынлы; **~ое мо́ре** дулкынлы диңгез 3. *перен.* кайнар, ярсулы; бик көчле; **~ые аплодисме́нты** бик көчле кул чабулар 4. (*резкий, стремительный*) тиз, бик тиз бара торган; **~ый проце́сс в лёгких** үпкәләрдә бик тиз бара торган процесс

буровщи́к *м* бораулаучы (*эшче*)

буров||о́й, -а́я, -о́е бораулау ...ы; **~а́я сква́жина** бораулау скважинасы

бу́рса *ж уст.* бурса (*иске заманда дини мәктәп, дини семинария*)

бурса́к *м уст.* бурсада укучы

бурт *м с.-х.* өем, бурт; **~ы́ карто́феля** бәрәңге өемнәре

бурунду́к *м* борындык

бурч||а́ть *несов.* 1. *что и без доп.* мыгырдау; мыгырдану; **что ты там ~и́шь?** син анда нәрсә мыгырдыйсың? 2. чурлау, быкырдау (*эч турында*); **~и́т в живо́те** *безл.* эче чурлый

бу́р||ый, -ая, -ое 1. көрән, коңгырт; **~ый у́голь** көрән ташкүмер 2. (*о масти*) коба; **~ая коро́ва** коба сыер

бурья́н *м* чуп үләннәр; каракура

бу́ря *ж* 1. давыл, җил-давыл; буран; җилле яңгыр 2. *перен.* давыл, көчле дулкынлану ♦ **~ в стака́не воды́** юкка дулау, бер дә юкка шау-шу куптару

буря́т *м* бурят, бурят кешесе

буря́тка *ж* бурят хатыны (кызы)

буря́тский, -ая, -ое бурят[лар] ...ы; **~ язы́к** бурят теле

буря́ты *мн.* бурятлар, бурят халкы

бу́сина, бу́синка *ж* энҗе бөртеге, сөйләп бөртеге, мәрҗән бөртеге

буссо́ль *ж спец.* буссоль (*геодезиядә, артиллериядә почмак үлчәгеч корал*)

бу́сы *только мн.* муенса

бут *м тех.* бут, акташ (*юлга түшәү ташы*)

бутафо́р *м* бутафор, бутафория хәзерләүче

бутафо́рия *ж театр.* бутафория (*уйнала торган пьеса өчен кирәкле җиһазлар, киемнәр*)

бутербро́д *м* бутерброд

бути́ть *несов. что, тех.* бут (таш) салу, бут (таш) җәю

бу́товый, -ая, -ое бут ташы җәелгән

бутто́н *м* чәчәк бөресе, чәчәк төймәсе

бу́тсы *мн.* бутсы (*футбол уйнаганда киелә торган махсус ботинка*)

бутэ́з *м* таза бала

буты́лка *ж* шешә

буты́лочн||ый, -ая, -ое 1. шешә ...ы; **~ое стекло́** шешә пыяласы 2. шешәле; **~ое пи́во** шешәле сыра ♦ **~ый цвет** кара яшел төс

бутыль *ж* зур шешә

бу́фер *м ж.-д.* буфер

бу́фер||ный, -ая, -ое **1.** буфер ...ы; **~ое приспособле́ние** буфер җайланмасы (*бәрелүдән саклый торган җайланма*) **2.** *перен.* буфер ...; **~ое госуда́рство** буфер дәүләт (*бер-берена дошман дәүләт арасында аларны бәрелешүдән саклый торган дәүләт*)

буфе́т *м* буфет

буфе́тчик *м* буфетчы

буфе́тчица *ж* буфетчы хатын (кыз)

буффона́да *ж* буффонада (*тамаша*)

бу́фы *только мн.* буф (*хатын-кызлар күлмәгендә була торган купшы бөрмәләр*)

бух *межд. в знач. сказ.* «*бу́хнул*», «*бу́хнулся*» гөмберт, гөрс, шап, шап итеп барып төште, шап итеп сукты; **он ~ в во́ду!** ул гөмберт суга!; **он ~ кулако́м в дверь!** ул йодрык белән шап ишеккә!

бухáнка *ж* бер кирпеч [ипи]

бу́ха||ть *несов.* **1.** шап иттереп бәрү (сугу); **~ть топоро́м** балта белән шап иттереп сугу **2.** гөрселдәү, гөрс итү; **за ле́сом ~ли ору́дия** урман аръягында туплар гөрселди иде

бухга́лтер *м* бухгалтер

бухгалте́рия *ж* бухгалтерия

бухга́лтерск||ий, -ая, -ое **1.** бухгалтер ...ы; бухгалтерлык ...ы; **~ая до́лжность** бухгалтер вазифасы **2.** бухгалтерия ...ы; **~ий счёт** бухгалтерия счёты

бу́хнуть I *сов. однокр. см.* **бу́хать**

бу́хнуть II *несов.* (*разбухать*) бүртү, күбү, күбенү

бу́хта I *ж* бухта, кечкенә култык (*диңгездә*)

бу́хта II *ж* (*круг каната*) бухта, уралган канат түгәрәге

бу́хты-бара́хты: с ~ *прост.* тик-томалга, уйлап-нитеп тормастан

бу́ч||а *ж прост.* шау-шу, ызгыш, талаш, гауга; **подня́ть ~у** шау-шу күтәрү

бу́чить *несов. что тех.* **1.** (*кипятить в щёлочи*) [селтегә салып] кайнату (*чистарту өчен*); **~ бельё** кер кайнату **2.** (*разрыхлять в растворе*) (*илəу алдыннан тирене эремәгә салып*) йомшарту; **~ ко́жу** тирене эремәдә йомшарту

буш||ева́ть *несов.* **1.** котыру, котырыну, давыллау, дулау (*җил, су, ут турында*); **река́ ~у́ет** елга котырына **2.** *перен. разг.* (*буйстворать*) дулау, ярсу, котырыну

бу́шель *м спец.* бушель (*бөртекле әйберләрне үлчәү берәмлеге Англиядә — 36,3 л., АКШта — 35,2 л.*)

бушла́т *м* бушлат (*матрослар кия торган махсус куртка*)

буя́н *м* сугыш чукмары, гаугачы, җәнҗалчы

буя́нить *несов. разг.* җәнҗал чыгару, ду куптару; гауга чыгару

бы *частица* **1.** (*в знач. предположительной возможности*) ...ган булыр иде; **он ~ пришёл, е́сли бы был здоро́в** әгәр дә сәламәт булса, ул килгән булыр иде **2.** (*в знач. предложения или просьбы*) ...п алыр иде, ...алсаң иде, ... алырга (аласы) иде; **я ~ погуля́л ещё немно́го** мин тагын бераз йөреп алыр идем; **ты ~ отдохну́л немно́жко** син бераз ял итеп алыр идең; **поспа́ть ~ немно́го** бераз йоклап аласы иде

быва́ло *вводн. сл.* бервакытлар (кайчандыр) ...ган чаклар бар иде; электә ...а торган иде; **в моло́дости, ~, мы с ним охо́тились на за́йцев** яшьлектә аның белән куян аулаган чаклар бар иде; **ся́дет, ~, и начнёт расска́зывать** утыра иде дә сөйли башлый торган иде ♦ **как ни в чём не ~** 1) (*без последствий*) бер нәрсә дә булмаган шикелле; 2) (*с невинным видом*) бер гаебе дә юк шикелле

быва́лый, -ая, -ое дөнья күргән, күпне күргән, тәжрибәле, шомарган

быва́||ть *несов.* **1.** (*быть время от времени*) булу; **по вечера́м он ~ет в клу́бе** кичләрен ул клубта була **2.** (*происходить*) булгалау; **~ют стра́нные слу́чаи** гаҗәп хәлләр булгалый

бы́вший, -ая, -ее **1.** *прич. от* **быть; 2.** элекке, электә ... булган; **~ дире́ктор** элекке директор

бы́дло *с собир. бран.* гыйбад, гыйбди (*электә гади халыкка карата: аңгыра, томана, булдыксыз мәгънәсендә кулланылган*)

бык *м* үгез ♦ **взять (брать) ~á за рогá** мәсьәләне кабыргасы белән кую

быки́ *мн.* күпер баганалары

были́на *ж* былина

были́нный, -ая, -ое, былина ...ы; **~ сюже́т** былина сюжеты

бы́ло *частица* иде дә; **пошёл ~, да останови́лся** киткән иде дә, туктап калды

было́й, -а́я, -о́е **1.** үткән, булган, элекке, узган; **~ы́е дни** үткән көннәр **2.** *в знач. сущ.* **~о́е** *с* үткәннәр; **вспо́мнить ~о́е** үткәннәрне искә төшерү

быль *ж* **1.** (*прошлое*) баштан үткән вакыйга, булган хәл; **э́то ~, а не ска́зка** бу булган вакыйга, әкият түгел **2.** сөйләк (*булган вакыйга турында хикәя*)

бы́льё *с уст.*: **~м поросло́** онытылган, күптән булып оныл тылган

быстрина́ *ж* ургыл, каты агым (*елганың бик каты ага торган урыны*)

быстрораствори́мый, -ая, -ое тиз эрүчән, тиз эри торган

быстрота́ *ж* тизлек, җитезлек, кызулык

быстроте́ч||ный, -ая, -ое тиз үтә торган; **~ое вре́мя** тиз үтә торган вакыт

быстрохо́дный, -ая, -ое тиз йөрешле, тиз йөри торган; **~ ка́тер** тиз йөри торган катер

бы́стр||ый, -ая, -ое **1.** тиз, кызу, шәп; **~ое тече́ние** кызу агым **2.** *перен.* булдыклы; бик җитез, елгыр; **~ый в рабо́те** эштә бик булдыклы **3.** (*происходящий в короткий промежуток времени*) бик тиз; **~ый рост промы́шленности** промышленностнең бик тиз үсүе

быт *м* көнкүреш, көндәлек тормыш

бытие́ *с* **1.** (*жизнь*) яшәеш **2.** *филос.* чынбарлык, яшәеш

бы́тность *ж*: **в ~** булган вакытта, булган чагында; **в ~ мою́ студе́нтом** мин студент булган вакытта

бытова́ть *несов.* (*иметь место, бывать*) булып тору, бар булу, булу, яшәү, яшәп тору

бытов||о́й -а́я, -о́е көнкүреш ...ы; тормыш ...ы; **~ы́е усло́вия** көнкүреш шартлары; **~о́е обслу́живание** көнкүреш хезмәте күрсәтү

бытописа́ние *с уст.* көнкүрешне сүрәтләү

бытописа́тель *м* **1.** *уст.* (*историк*) тарихчы **2.** (*писатель*) көнкүрешне сүрәтләүче

быть *несов.* **1.** (*существовать, иметься*) бар [булу], булу; (*уткән заман формасында*) ... иде; **у меня́ есть дочь** минем кызым бар; **кни́ги бы́ли в шкафу́** китаплар шкафта иделәр **2.** (*находиться, присутствовать*) булу; **ве́чером я бу́ду до́ма** кичен мин өйдә булырмын **3.** (*происходить, случаться*) булу; **вчера́ был дождь** кичә яңгыр булды; **собра́ние бу́дет за́втра** җыелыш иртәгә булачак **4.** (*приходить, приезжать*) килү, булу; **бу́ду к вечеру́** кичкә килермен **5.** *употр. как часть составного сказ.* 1) *ия белән исем хәбәр арасында бәйләүче чара буларак кулланыла*: булу, ... иде; **оте́ц был врачо́м** атасы врач иде; 2) *төшем юнәлешенең, катлаулы формасын ясый*: ... иде; **сад был поса́жен шко́льниками** бакча мәктәп укучылары тарафыннан утыртылган иде; 3) *тәмамланмаган төрнең киләчәк заман формасын ясаудан катнаша*: ...ыр, ... ачак; **бу́дешь чита́ть?** укырсыңмы? ♦ **была́ не была́!** булса булыр, булмаса юк!; беткән баш беткән!; **будь что бу́дет** нәрсә булса да булыр

бытьё *с* көнкүреш, тормыш

быча́ч||ий, -ья, -ье, **бы́ч||ий,** -ья, -ье үгез ...ы; **~ья ко́жа** үгез тиресе; **~ья ше́я** үгез муены

бычо́к I *м* яшь үгез бозау

бычо́к II *м* ташбаш, бычок (*балык төре*)

бюва́р *м* бювар (*киптергеч кәгазьләр салынган дәфтәр яки папка*)

бюдже́т *м* бюджет

бюдже́тный, -ая, -ое бюджет ...ы; **~ год** бюджет елы

бюллете́н||ь *м в разн. знач.* бюллетень; **пода́ча ~ей** бюллетеньнәр бирү; **Бюллете́нь Акаде́мии нау́к** Фәннәр академиясенең бюллетене; **он на ~е** ул бюллетеньдә

бю́ргер *м* бюргер (*Германиядә шәһәр кешесе*)

бюро́ I *с нескл.* бюро; **~ райко́ма** райком бюросы; **спра́вочное ~** белешмәләр бюросы

бюро́ II *с нескл.* бюро (*язу өстәлләренең бер төре*)

бюрокра́т *м* бюрократ

бюрократи́зм *м* бюрократлык

бюрократи́ческ||ий, -ая, -ое бюрократларча ..., бюрократик; **~ое отноше́ние к де́лу** эшкә бюрократларча мәнәсәбәттә булу

бюрокра́тия *ж* **1.** бюрократия (*хакимият чиновниклар администрациясе кулында булган идарә системасы*) **2.** *собир.* бюрократлар

бюст *м* 1. бюст (*кеше гәүдәсенең, билдән югары өлешенең сыны, скульптурасы*) 2. бюст, күкрәк (*хатын-кызда*)

бюстга́льтер *м* бюстгальтер, күкрәкчә

бя́зев||ый, -ая, -ое бәз ..., бәздән тегелгән; **~ая руба́шка** бәз күлмәк

бязь *ж* бәз, бүз (*тукыма*)

бя́ка *ж дет.* аай, начар нәрсә, пычрак нәрсә

В

в (во) *предлог* 1. *с вин.п.* (*на вопрос «куда»*) ...га, эченә; **внести́ ве́щи в ко́мнату** әйберләрне бүлмә эченә кертү; **пойти́ в теа́тр** театрга бару; **положи́ть бума́ги в я́щик** кәгазьләрне тартмага салу; **уе́хать в Сиби́рь** Себергә китү 2. *с вин.п.* (*при обознач. предмета, в к-рый что-л. заключается, облекается*) ...га; **завернýть в бума́гу** кәгазьгә төрү 3. *с вин.п.* (*при обознач. занятия, состояния*) ...га; **погрузи́ться в размышле́ния** уйга бату; **уйти́ в рабо́ту** эшкә чуму 4. *с вин.п.* (*при обознач. предмета, через к-рый совершается действие*) ...дан; **смотре́ть в бино́кль** бинокльдән карау; **смотре́ть в ще́ль** ярыктан карау 5. *с вин.п.* (*на вопрос «когда», «во сколько»*) ...да; **в де́сять часо́в** сәгать унда; **в понеде́льник** душәмбедә 6. *с вин.п.* (*при обознач. свойства, качества, количественного признака*) ...лы; **тетра́дь в лине́йку** сызыклы дәфтәр; **ко́мната в де́сять квадра́тных ме́тров** ун квадрат метрлы бүлмә 7. ...лыкка; **кандида́т в депута́ты** депутатлыкка кандидат; **кандида́т в мастера́** мастерлыкка кандидат 8. (*при обознач. способа, характера действия*) ...га, ...булып; **развернýться в цепь** цепькә җәелү; **сжа́ться в ко́мок** йомарлану, йомарлам булып йомарлану 9. *с вин.п.* (*при обознач. игры*): **игра́ть в футбо́л** футбол уйнау; **игра́ть в ша́хматы** шахмат уйнау 10. *с вин.п.* (*при указ. на сходство*) ...га; **ребёнок весь в отца́** баласы атасына бик нык охшаган 11. *с предл.п.* (*на вопрос «где»*) ...да, эчендә; **в я́щике стола́** өстәл тартмасы эчендә; **жить в го́роде** шәһәрдә яшәү; **рабо́тать в мастерско́й** мастерскойда эшләү; **стоя́ть в стороне́** читтә тору 12. *с предл.п.* (*на вопрос «когда»*) ...да; **в де́тстве** балачакта; **в октябре́** октябрьдә; **в пя́тницу** җомгада 13. *с предл.п.* ...лы; **дра́ма в трёх де́йствиях** өч пәрдәле драма; **не́бо в ту́чах** болытлы күк йөзе; **челове́к в очка́х** күзлекле кеше 14. *с предл.п.* (*при обознач. предмета, к-рый находится на ком-чём-л.*) ...дан; белән; **в зи́мнем пальто́** кышкы пальтодан; **чита́ть в очка́х** күзлек белән уку 15. *с предл.п.* белән ...ган; **рису́нок в кра́сках** буяу белән ясалган рәсем; **рома́н в стиха́х** шигырь белән язылган роман 16. *с предл.п.* (*при указ. на кратность чисел, величин*): **в два ра́за бо́льше** ике мәртәбә зур; **в три ра́за ме́ньше** өч мәртәбә ким ♦ **в ка́честве** ... булып, ... итеп, сыйфатында; **в конце́ концо́в** ахыр чиктә; **во исполне́ние постановле́ния** карарны үтәү йөзеннән; **оста́ться в дурака́х** алдану, төпсез чанага утыру; **в слу́чае, е́сли** ... әгәр ...са, әгәр ...а калса; **в слу́чае, е́сли он придёт** әгәр ул килә калса

в- (во-, въ-) *приставка, бу приставка белән ясалган фигыльләр нигездә тезмә фигыльләр белән тәрҗемә ителә, приставканың мәгънәсе түбәндәге чаралар ярдәмендә бирелә* 1. *«керү» яки «кертү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **вбежа́ть** йөгереп керү; **влете́ть** очып керү; **вбить** кагып кертү; **вкати́ть** тәгәрәтеп кертү 2. *«кую» дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **вписа́ть** язып кую; **вложи́ть** салып кую 3. *кайбер приставкалы фигыльләрнең төп фигылен тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **войти́** керү; **впада́ть** кою; **вдеть** саплау 4. *«-ся» кисәкчәле фигыльләр белән килгәндә төрлечә тәрҗемә ителә*: 1) *тиешле мәгънәле хәл фигыль белән, мәс.* **всмотре́ться** текәлеп карау; **ввяза́ть** кушып бәйләү 2) *аерым сүзләр белән, мәс.* **вду́маться** тирәнтен уйлану; **вслу́шаться** дикъкать белән тыңлау

ва-ба́нк *нареч.* «сугам», «уендагы бөтен акчага барам» ♦ **идти́ (пойти́)** ~ тәвәккәлләү, бик тәвәккәл эш итү; бөтен нәрсәне куркыныч астына куеп эш итү

вавило́нск||ий, -ая, -ое: **~ое столпотворе́ние** мәхшәр, кыямәт көне

ва́га *ж* 1. (*большие весы*) вага, зур үлчәү 2. (*толстая жердь*) күсәк

ваго́н *м* 1. вагон; **пассажи́рский ~** пассажир вагоны; **това́рный ~** йөк вагоны 2. (*количество груза*) вагон, бер вагон; **~ зерна́** бер вагон ашлык

вагоне́т||а *ж* вагонетка; **ша́хтная ~а** шахта вагонеткасы; **насы́пать у́голь в ~у** вагонеткага күмер төяү

вагоне́тчик *м* вагонетка йөртүче

вагóнн||ый, -ая, -ое вагон[нар] ...ы; **~ая ось** вагон күчәре; **~ый парк** вагоннар паркы

вагоновожа́тая *ж* трамвай йөртүче хатын (кыз)

вагоновожа́тый *м* трамвай йөртүче, трамвайчы

вагонреми́нтн||ый, -ая, -ое вагон ремонтлау ...ы, вагоннар ремонтлый торган; **~ые мастерски́е** вагон ремонтлау мастерское

вагонострое́ние *ж* вагоннар төзү; вагоннар төзү тармагы

вагонострои́тельный, -ая, -ое вагон[нар] ...ы, вагоннар ясау ...ы, вагон[нар] ясый торган; **~ заво́д** вагоннар ясый торган завод

вагóнчик *м* 1. *уменьш. от* **вагóн**; 2. кыр вагоны (*механизаторлар яшәү өчен күчеп йөри торган вагон-бина*)

вагра́нка *ж тех.* вагранка, металл эретү миче

вагра́нщик *м* (*рабочий*) вагранкачы

ва́жничанье *с см.* **ва́жничать**

ва́жничать *несов. разг.* эреләнү, эре кылану, көдерәю, кукыраю, тәкәбберләнү, тәкәббер кылану; **~ пе́ред това́рищами** иптәшләрең алдында эре кылану

ва́жно *нареч.* 1. (*с важным видом*) тәкәбберләнеп, эре, эреләнеп, көдерәеп, кукыраеп, тәкәббер рәвештә, тәкәббер; **~ держа́ть себя́** үзеңне эре тоту 2. *в знач.сказ.* мөһим; кирәк; **э́то о́чень ~** бу бик мөһим; **~ бы́ло э́то знать** моны белүе мөһим иде

ва́жность *ж* 1. (*значительность*) мөһимлек, әһәмиятлелек, мөһим булу, әһәмиятле булу 2. (*надменность*) тәкәбберлек, эрелек, тәкәббер кыяфәт, эре кыяфәт ♦ **э́ка (не велика́)** ~ искитәрлек нәрсә юк, исең киткән икән

ва́жн||ый, -ая, -ое 1. мөһим, әһәмиятле; **~ое откры́тие** әһәмиятле ачыш; **~ое реше́ние** мөһим карар; **~ые вопро́сы госуда́рственной жи́зни** дәүләт тормышының мөһим мәсьәләләре 2. зур, зур дәрәҗәле кеше; **~ая персо́на** зур дәрәҗәле кеше 3. (*гордый*) эре, тәкәббер; **~ый вид** эре кыяфәт

ва́за *ж* ваза; **~ для фру́ктов** жимеш вазасы

вазели́н *м* вазелин; **бо́рный ~** борлы вазелин

вазели́нов||ый, -ая, -ое 1. вазелин ...ы; **~ое произво́дство** вазелин производствосы 2. вазелинлы, вазелин кушылган; **~ое мы́ло** вазелинлы сабын

вазóн *м* гөл үлмәге

вака́нсия *ж* вакансия, буш урын (*учреждение штатындагы, уку йортындагы һ.б.ш. буш урын*); **откры́лась ~** вакансия ачылды

вака́нт||ый, -ая, -ое вакант, буш; **~ое ме́сто** вакант урын

ва́кса *ж* вакса (*аяк киеме креме*)

ва́ксить *несов. что, разг.* ваксалау, кремлау; **~ сапоги́** итекләрне ваксалау

ва́куум *м физ., тех.* вакуум, бушлык

ва́куумный, -ая, -ое *физ., тех.* вакуум ...ы; **~ аппара́т** вакуум аппараты

вакхана́лия *ж* 1. вакханалия (*борынгы Греция белән Римда шәрап алласы Вакх хормәтенә уткәрелә торган бәйрәм*) 2. эчкечелек тамашасы, гадәттән тыш кәеф-сафа

вакха́нка *ж* 1. вакханка (*шәрап алласы Вакхның каһинасе*) 2. *уст.* фахишә хатын, оятсыз хатын

вакци́на *ж мед.* вакцина; **противотифо́зная ~** тифка каршы вакцина

вакцина́ция *ж мед.* вакцинация, вакцинация ясау, прививка ясау

вакцини́ровать *сов., несов. кого-что, мед.* вакцинация ясау, вакцинацияләү

вал I *м* 1. (*насыпь*) вал, туфрак өеме; **~ пе́ред кре́постью** крепость алдындагы вал 2. (*волна*) зур дулкын ♦ **огнево́й ~** ут валы (*артиллериянең күчә барган утка тоту сызыгы*)

вал II *м тех.* вал, үзәк; **коле́нчатый ~** терсәкле вал

вале́жник *м* коры-сары, чыбык-чабык (*агачлыкта*); **собира́ть ~** агачлыкта коры-сары җыю

вал||ёк *м* 1. (*для белья*) бәләк, кер тукмагы, чәпәмә 2. (*в упряжи*) вәлүк, постромка агачы 3. (*металлический*

брусок) валёк; **ката́ть на ~ька́х** валёклар өстеннән тәгәрәтү

ва́ленки *мн.* киез итек; пима; **наде́ть ~** киез итек кию

вале́нтность *ж хим.* валентлык

вале́нтный, -ая, -ое *хим.* валентлы

валериа́на *ж см.* **валерья́на**

валериа́новый, -ая, -ое *см.* **валерья́новый**

валерья́на *ж бот.* песи үләне, валерьян

валерья́нка *ж разг.* валерьянка, валерьян даруы

валерья́нов||ый, -ая, -ое 1. песи үләне ...ы, валерьян ...ы; **~ый ко́рень** песи үләне тамыры 2. валерьян ...ы; **~ые ка́пли** валерьян тамчылары

вале́т *м карт.* валет, егет; **бубно́вый ~** шакмак валет

ва́лик *м* 1. *уменьш.от* **вал** II; 2. валик (*тахта яки диванның ике башындагы мендәрләр*)

вали́ть I *несов.* 1. *кого-что* аудару, түнтәрү, егу; егыту; **~ дере́вья** агачларны егу; **ве́тер ва́лит с ног** җил аяктан ега 2. *что, разг.* (*ничек җитсә шулай*) ташлау, төяү; **~ ве́щи в сунду́к** әйберләрне сандыкка төяү 3. *что на кого, разг.* сылтау, япсару, аудару; **~ вину́ на това́рища** гаепне иптәшенә аудару ♦ **~ с больно́й голово́й на здоро́вую** ≈ ак этнеке кара эткә

вали́ть II *несов.* 1. агылу, агылып килү, агылып бару; **толпа́ вали́т** халык төркеме агыла 2. (*о снеге и т.п.*) ишелеп яву; (*о дыме, паре*) бөркелеп чыгу; ургылып чыгу

вали́||ться *несов.* 1. аву, төшү, егылу; **~лись дере́вья** агачлар аудылар; **се́но ~лось из теле́ги** арбадан печән төшә иде 2. (*кривиться*) кырынаю, кыйшаю 3. (*обрушиваться*) ишелү, җимерелү ♦ **ва́лится из рук** 1) (*не удаётся, не выходит*) кулым эшкә бармый, кулым эшкә ятмый; 2) (*нет сил что-л.делать*) кулдан эш төшә; **~ться с ног от уста́лости** арудан аяктан егылу

валки́ *мн.* (*ед.* **вало́к** *м*) *тех.* валоклар, валки; **~ прока́тного ста́на** прокат станының валоклары

ва́лкий, -ая, -ое (*неустойчивый*) тотрыксыз; кырынаючан, янтаючан

валов||о́й, -а́я, -о́е тулай, тулаем, барлык, гомуми; **~а́я проду́кция** тулай продукция; **~о́й дохо́д** барлык керем

вал||о́к *м* тезем

вало́м *нареч.*: **~ вали́ть** агылу, агылып килү, агылып бару

валто́рна *ж* валторна (*музыка коралы*)

валторни́ст *м* валторначы, валторнада уйнаучы

валу́й *м* валуй (*гөмбә*)

валу́н *м* валун, зур йомры таш

ва́льдшнеп *м* тәлләтәвеч, урман кулигы

вальс *м* вальс (*бию һәм бию көе*)

вальси́ровать *несов.* вальс бию

вальцева́ть *несов. что, тех.* вальцовкалау; **~ желе́зный лист** калай вальцовкалау

вальцо́вка *ж* 1. *см.* **вальцева́ть;** 2. (*машина*) вальцовка машинасы, вальцовка

вальцо́вочный, -ая, -ое *тех.* вальцовкалау ...ы, вальцовка ...ы; **~ цех** вальцовка цехы

вальцы́ *только мн. тех.* вальцы (*станок*)

валья́жность *ж* мәһабәтлелек, күренеклелек

валья́жный, -ая, -ое мәһабәт, күренекле; **~ вид** мәһабәт кыяфәт

валю́т||а *ж* 1. (*денежная единица*) валюта; **твёрдая ~а** ныклы валюта: **золота́я ~а** алтын валюта 2. *собир.* валюта, чит ил акчасы; **купи́ть на ~у** чит ил акчасына сатып алу

валю́тный, -ая, -ое валюта ...ы; **~ кри́зис** валюта кризисы

валю́тчик *м разг.* валютачы

валя́льщик *м* киез итек басучы

ва́лян||ый, -ая, -ое киез ..., басылган, йоннан басылган; **~ые сапоги́** киез итекләр

валя́ть *сов.* 1. *кого-что* аунату, ауната-тып йөртү; **~ в снегу́** карда ауната 2. *что* басу, басып ясау; **~ ва́ленки** киез итек басу ♦ **валя́й[те]!** әйдә!; эшли бир!; әйдә, тәпилә!; **~ дурака́** 1) (*дурачиться*) ахмак булып кылану, ахмакка салыну; 2) (*бездельничать*) ялкаулану, тик яту, бер нәрсә дә эшләмәү

валя́||ться *несов.* 1. аунау, аунап яту; **~ться на земле́** җирдә аунау 2. (*лежать бездельничая*) тик яту, аунау, аунап яту 3. *страд. от* **валя́ть** ♦ **на доро́ге (на у́лице, на полу́) не ~ется** *что* (*даром не достаётся*) жирдә ятмый, юлда ятмый

вампи́р *м* вампир (1. *фольк. убыр* 2. *зоол. зур ярканат*)

вана́дий *м хим.* ванадий

ванда́л *м* вандал, вәхши

вандали́зм *м* вандаллык, вәхшилек

ванили́н *м* ванилин

вани́ль *ж* ваниль (*үсемлек һәм аның җимеше*)

вани́ль||ый, -ая, -ое 1. ваниль ...ы, ваниль ...; **~ый за́пах** ваниль исе 2. ванильле; **~ые сухари́** ванильле сохарый

ва́нн||а *ж в разн. знач.* ванна; **нали́ть во́ду в ~у** ваннага су тутыру; **приня́ть ~у** ванна керү; **принима́ть со́лнечные ~ы** кояшта кызыну

ва́нная *ж* ванна бүлмәсе

вар *м* вәр, кайнатылган сумала

ва́рвар *м* 1. варвар (*борынгы римлыларда, грекларда: чит ил кешесе*) 2. варвар, вәхши; залим; **фаши́стские ~ы** фашист вәхшиләре

варвари́зм *м* варваризм (*әдәби тел нормаларын боза торган чит тел сүзе яки тәгъбире*)

ва́рварск||ий, -ая, -ое 1. вәхши, варвар[лар] ...ы; варвар ...; **~ие племена́** варварлар кабиләләре 2. варварларча ...; вәхшиләрчә ...; **~ое отноше́ние к па́мятникам иску́сства** сәнгать ядкарьләренә варварларча мөнәсәбәт 3. (*грубый*) тупас, искиткеч дорфа

ва́рварство *с* 1. (*бескультурье*) варварлык, вәхшилек 2. (*жестокость, грубость*) кансызлык, залимлек; кешелексезлек

ва́рево *с прост.* өйрә, шулпа, сыек аш

ва́режки *мн.* бияләй; **наде́ть ~** бияләй кию; **сня́ть ~** бияләй салу

варене́ц *м* катык

≈варе́ние *кушма сүзләрнең икенче кисәге, беренче сүз белдергән предметны хәзерләү мәгънәсен аңлата, «кою», «кайнату», «пешерү» кебек сүзләр белән тәрҗемә ителә, мәс.* **сталевaréние** корыч кою; **мыловаре́ние** сабын кайнату; **пивоваре́ние** сыра кайнату

варе́ники *мн.* эремчек пилмәне; жиләк пилмәне

варён||ый, -ая, -ое пешкән, пешерелгән; **~ое мя́со** пешкән ит

варе́нье *с* варенье, кайнатма; **сморо́динное ~** карлыган вареньесе

вариа́нт *м* вариант, төр

вариацио́нн||ый, -ая, -ое вариацион, вариацияле, үзгәрешле; **~ая фо́рма в му́зыке** музыкада вариацияле форма

вариа́ция вариация, төр (1. *асылы бер булып, аерым детальләрендә, кисәкләрендә үзгәлек, төрлелек* 2. *бер музыкаль теманың төрләре*)

вари́ть *несов. что* 1. пешерү; кайнатып пешерү; **~ ка́шу** бутка пешерү 2. (*путём кипячения*) кайнату, кайнатып хәзерләү; (*путём плавления*) эретү; **~ мы́ло** сабын кайнату; **~ сталь** корыч эретү 3. *тех.* (*сваривать*) ябыштыру, эретеп ябыштыру (*металл кисәкләрен*)

вари́ться *несов.* 1. пешү 2. *страд. от* **вари́ть** ♦ **~ в со́бственном соку́** ≈ үз казанында кайнау

ва́рка *ж см.* **вари́ть; ~ ста́ли** корыч эретү

варьете́ *с нескл.* варьете (*җиңел жанрдагы эстрада театры*)

варьи́ровать *несов. что* төрлеләндерү, үзгәртү; яңа вариантларын ясау; **~ расска́з** хикәяне үзгәртү

варьи́роваться *несов.* 1. (*разнообразиться*) төрлеләнү, үзгәрү 2. *страд. от* **варьи́ровать**

варя́ги *мн.* варяглар

василёк *м* күкбаш, күкчәчәк

васили́ск *фольк.* аждаһа, юха елан

василько́вый, -ая, -ое 1. күкбаш ...ы, күкчәчәк ...ы; **~ сте́бель** күкбаш сабагы 2. (*о цвете*) зәңгәр күк, күкчәчәк төсендәге

вассáл *м прям., перен.* вассал

вассáль||ый, -ая, -ое 1. вассал ...ы; вассалык ...ы; **~ые отноше́ния** вассалык мөнәсәбәтләре 2. *перен.* вассал ..., бәйле; **~ые госуда́рства** вассал дәүләтләр

ва́та *ж* мамык

вата́га *ж* 1. *разг.* өер, көтү, төркем; **~ мальчи́шек** малайлар төркеме 2. *спец.* (*рыболовецкая артель*) ватага, балыкчылар төркеме (әртиле)

ватерли́ния *ж мор.* ватерлиния (*судно бортында аның суга батуының нормаль линиясенә туры килгән сызык*)

ватерпа́с *м* ватерпас, тигезләвеч

ватерполи́ст *м* ватерполочы, ватерполист

ватерполи́стка *ж* ватерполист хатын (кыз)

ватерпо́ло *с нескл. спорт.* ватерполо, су тубы (*суда туп уены*)

ватин *м* ватин

ва́тман *м* ватман (*сызым яки рәсем ясау кәгазе*)

ва́тманск||ий, -ая, -ое: **~ая бума́га** ватман кәгазе

ва́тник *м разг.* сырма, җылы куфайка

ва́тн||ый, -ая, -ое **1.** мамык ...ы; мамык ...; **~ая фа́брика** мамык фабрикасы **2.** мамык ..., мамыктан ясалган; **~ое одея́ло** мамык юрган

ватру́шка *ж* дучмак, эремчек шәнгәсе

ватт *м физ.* ватт

ваттме́тр *м физ.* ваттметр

ватт-ча́с *м физ.* ватт-сәгать

ва́фельница *ж* вафельница (*вафля ясау әсбабы*)

ва́фельн||ый, -ая, -ое **1.** вафля ...ы; вафля ...; вафля житештерү ...ы; **~ый цех** вафля житештерү цехы **2.** сырлы, кәрәзсыман сырлы, кәрәзсыман; **~ое полоте́нце** кәрәзсыман сырлы тастымал

ва́фля *ж* вафля

ва́хмистр *м* вахмистр (*Россиядә революциягә кадәрге армиядә кавелериядәге унтер-офицер*)

ва́хт||а *ж* **1.** вахта, корабльдә сакта тору; **стоя́ть на ~е** вахтада тору **2.** *перен.* вахта; **~а ми́ра** тынычлык вахтасы; **трудова́я ~а** хезмәт вахтасы

ва́хтенн||ый, -ая, -ое **1.** вахта ...ы, корабльдә сакта тору ...ы; **~ая слу́жба** корабльдә сакта тору хезмәте; **~ый журна́л** вахта журналы **2.** вахтада торучы, сакта торучы; **~ый матро́с** вахтада торучы матрос

вахтёр *м* вахтёр, сакчы (*берәр учреждениедә*)

ваш *м мест.* **1.** сезнең, сезнеке **2.** *в знач.сущ.* **~е** *с* сезнеке; **~его не ну́жно** сезнеке кирәкми **3.** *в знач. сущ.* **~и** *мн.* сезнең туганнар, туганнарыгыз; **приве́т ~им** туганнарыгызга сәлам ♦ **~ брат** сезнең ише халык

ва́ша *ж см.* **ваш** ♦ **~ взяла́** сезнеке өскә чыкты

ва́ше *с см.* **ваш**

ва́ши *мн. см.* **ваш** ♦ **и ~м и на́шим** сезгә дә, безгә дә (*ике йөзле кеше турында*)

вая́тель *м высок.* һәйкәлче, сынчы, скульптор

ваять *несов. что* ясау, һәйкәл ясау (*кырып, кисеп, әвәлап, коеп*)

вбега́ть *несов. см.* **вбежа́ть**

вбежа́ть *сов.* **1.** йөгереп керү, йөгереп (чабып) килеп керү; **~ в ко́мнату** бүлмәгә йөгереп килеп керү **2.** (*взбежать*) йөгереп менү (менеп китү); **~ на ле́стницу** баскычка йөгереп менү

вбива́ть *несов. см.* **вбить**

вбира́ть *несов. см.* **вобра́ть**

вбить *сов. что* кагу, кагып (бәреп) кертү; **~ гвоздь** кадакны кагып кертү ♦ **~ в го́лову** *кому что* башына туку, әйтә-әйтә аңлату; **~ себе́ в го́лову** *что* башына алу

вблизи́ **1.** *нареч.* якында, якыннан; **~ разгова́ривали** якында гына сөйләшләр иде **2.** *предлог с род. п.* янында; **~ ле́са** урман янында

вбок *нареч. разг.* (*в сторону*) янга, бер кырыйга, бер читкә, бер якка

вброд *нареч.* кичеп, су ерып; атлап; **перейти́ реку́ ~** елганы кичеп чыгу

вбу́хать *сов. что, прост.* күп салу, күп итеп салу; күп итеп агызу

вва́ливаться *несов.* **1.** *см.* **ввали́ться; 2.** *страд. от* **вва́ливать**

ввали́||ться *сов.* **1.** *во что* (*упасть*) егылып (авып, барып) төшү **2.** (*стать впалым*) эчкә бату (батып керү); эчкә керү; **у больно́го ~лись глаза́** авыруның күзләре эчкә баткан **3.** *прост.* (*войти*) килеп керү; **~ться в кварти́ру** квартирга килеп керү

введе́ние *с* **1.** *см.* **ввести́**; **2.** (*отдел науки*) кереш; **~ в языкозна́ние** тел белеменә кереш **3.** (*вводная часть произведения*) кереш, кереш сүз, сүз башы

ввести́ *сов. кого-что* **1.** (*внутрь*) кертү, китерү; **~ дрова́ во двор** утынны ишегалдына кертү; **~ това́ры из-за грани́цы** чит илдән товарлар кертү **2.** (*наверх*) күтәрү, мендерү, алып менү (*автомашина*); **~ на́ гору** тауга күтәрү

ввек *нареч. разг.* беркайчан да, һичкайчан да; **~ не забу́ду** беркайчан да онытмам

ввергать *несов. см.* **ввергнуть**

ввергаться *несов.* **1.** *см.* **ввергнуться; 2.** *страд. от* **ввергать**

ввергнуть *сов. кого-что* дучар итү, төшерү; **~ в отча́яние** өметсезлеккә төшерү

ввери́ть *сов. кого-что кому* ышанып тапшыру, карамагына тапшыру (бирү); **~ свою́ судьбу́** *кому-л.* үзеңнең язмышыңны ышанып тапшыру

ввери́ться *сов. кому-чему* үзен ышанып тапшыру, (*берәр кеше*) карамагына үзен тапшыру

ввернуть *сов. что* **1.** борып кертү; **~ ла́мпочку** лампочканы борып кертү **2.** *перен. разг.* кыстыру, кушу; **~ сло́во** сүз кыстыру

ввернуться *сов.* керү (*борудан*); **винт хорошо́ ~лся** винт яхшы керде

вверх *нареч.* **1.** өскә; өскә таба, югарыга; **подня́ться ~ по ле́стнице** баскыч буйлап өскә күтәрелү; **поста́вить бо́чку ~ дном** мичкәнең астын өскә таба әйләндерү **2.** (*к истоку*) өскә таба, югарыга таба; **~ по реке́** елга буйлап югарыга таба ♦ **~ дном (нога́ми)** асты өскә, астын өскә; **всё ~ дном пошло́** бар нәрсәнең асты өскә килде

вверху́ *нареч.* өстә, югарыда

вверя́ть *несов. см.* **ввери́ть**

вверя́ться *несов.* **1.** *см.* **ввери́ться; 2.** *страд. от* **вверя́ть**

ввести́ *сов.* **1.** *в разн. знач. кого-что* кертү; китереп кертү; җибәрү; **~ войска́ в го́род** шәһәргә гаскәр кертү; **~ но́вую мо́ду** яңа мода кертү; **~ лека́рство в ве́ну** венага дару җибәрү **2.** *что* тапшыру; бирү; **~ кана́л в эксплуата́цию** каналны эксплуатациягә тапшыру ♦ **~ во владе́ние (в насле́дство)** милекне (мирасны) рәсми рәвештә тапшыру; **~ в дом** гаилә белән таныштыру; **~ в заблужде́ние** ялгыштыру, ялгыш юлга кертү; **~ в курс** курска кертү, төшендерү, аңлату; **~ в курс де́ла** эш белән таныштыру; **~ в обма́н** алдау; **~ в расхо́д** чыгымландыру; **~ в собла́зн** күңел аздыру

ввести́сь *сов.* (*войти в употребление*) керү, кереп китү

ввиду́ *предлог с род.п.* аркасында, сәбәпле, ...га күрә, ...ганлыктан, ...лыктан; **~ нея́сной пого́ды** көн аяз булмаганлыктан

ввинти́ть *сов. что* борып кертү; **~ винт** винтны борып кертү

ввинчивать *несов. см.* **ввинти́ть**

ввить *сов. что* кушып үрү (ишү); **~ ле́нту в косу́** тасманы толымга кушып үрү

ввод *м* **1.** *см.* **ввести́; ~ в эксплуата́цию но́вых предприя́тий** яңа предприятиеләрне эксплуатациягә тапшыру **2.** кертү җайланмасы; кертү урыны; **электри́ческий ~** электр кертү җайланмасы

вводи́ть *несов. см.* **ввести́**

вводи́ться **1.** *несов. см.* **ввести́сь**; **2.** *страд. от* **вводи́ть**

ввод||ный, -ая, -ое **1.** кертү ...ы; **~ое отве́рстие** кертү тишеге **2.** кереш ..., кереш тәшкил иткән; **~ая ле́кция** кереш лекция; **~ая статья́** кереш мәкалә ♦ **~ое предложе́ние** *грам.* кереш җөмлә; **~ое сло́во** *грам.* кереш сүз

ввоз *м* **1.** *см.* **ввезти́**; **~ това́ров из-за грани́цы** чит илләрдән товарлар кертү **2.** (*импорт*) импорт, кертелгән товар (нәрсә)

ввози́ть *несов. см.* **ввезти́**

ввози́м||ый, -ая, -ое **1.** читтән китерелгән, читтән кертелгән; **~ый това́р** читтән китерелгән товар **2.** читтән кертү ...ы; **~ая по́шлина** читтән кертү пошлинасы

ввола́ *нареч.* теләгәнчә, иркенләп туйганчы, теләгән чаклы; **отдохну́ть ~** иркенләп ял итү

ввосьмеро *нареч.* сигез мәртәбә (тапкыр); сигез кат (өлеш), сигезләтә

ввосьмеро́м *нареч.* сигезәүләп, сигезәү, сигезәү бергә

в-восьмы́х *вводн. сл.* сигезенчедән

ввязать *сов.* **1.** *что* кушып бәйләү, кушу, бәйләү; бәйләп кушу; **~ пя́тку в чуло́к** үкчәне оекка бәйләп кушу **2.** *перен. кого-что, разг.* (*впутать*) бутау, катнаштыру; **~ кого-л. в неприя́тное де́ло** *кемне дә булса* яман эшкә бутау

ввяза́ться *сов. во что. разг.* катнашу, катнашып китү, тыгылу, кысылу, кысылып китү; **~ в разгово́р** сүзгә кысылып китү

ввя́зывать *несов. см.* **ввяза́ть**

ввя́зываться *несов.* **1.** *см.* **ввя́зываться**; **2.** *страд. от* **ввя́зывать**

вгиб *м* бөгелгән урын, бөгелеш, бөгелмә

вгиба́ть *несов. см.* **вогну́ть**

вгиба́ться *несов.* 1. *см.* **вогну́ться**; 2. *страд. от* **вгиба́ть**

вглубь *нареч.* эченә, эченә таба, тирәнгә, эченә үк

вгляде́ться *сов.* тикәлеп карау, дикъкать белән карау

вгля́дываться *несов. см.* **вгляде́ться**

вгоня́ть *несов. см.* **вогна́ть**

вгорячу́х *нареч. разг.* кызып китеп, ярсып китеп, кызып, ярсып; ~ **отказа́ться** кызып китеп баш тарту

вгрыза́ться *несов. см.* **вгры́зться**

вгры́зться *сов. разг.* (*вцепиться зубами*) тешләрнe батыру, тешләр белән эләктерү

вдава́ться *несов. см.* **вда́ться**

вдави́ть *сов. что* 1. *во что* батырып кертү; ~ **про́бку в буты́лку** бөкене шешәгә батыру 2. (*вмять*) яньчү, яньчеп бетерү; ямьшәйтү

вда́вливать *несов. см.* **вдави́ть**

вда́лбливать *несов.* **вдолби́ть**

вдалеке́, **вдали́** *нареч.* ераста

вдаль *нареч.* ераккa; **смотре́ть** ~ ераккa карау

вда́||ться *сов.* 1. [тирәнгә] бату, тирәнгә керү, [тирәнгә] батып китү, тирәнгә кереп китү; **каблу́к глубоко́** ~**лся в песо́к** үкчә комга тирәнгә керде 2. эчкә керү, эчкә кереп тору; **гора́** ~**ла́сь в мо́ре** тау диңгез эченә кереп тора ♦ ~**ться в подро́бности** тәфсилләп сөйләргә керешү

вдвига́ть *несов. см.* **вдви́нуть**

вдвига́ться *несов.* 1. *см.* **вдви́нуться**; 2. *страд. от* **вдвига́ть**

вдви́нуть *сов. что* этеп кертү, этәреп кертү, шудырып кертү

вдви́нуться *сов.* керү, кереп китү (*хәрәкәт иттерудән*)

вдво́е *нареч.* 1. (*в два раза*) ике тапкыр (мәртәбә); ике өлеш 2. (*пополам*) урталай, уртага, икегә

вдвоём *нареч.* икәү, икәүләп, икәүләшеп, икәү бергә

вдвойне́ *нареч.* икеләтә, ике кат артык, ике мәртәбә артык

вдева́ть *несов. см.* **вдеть**

вдева́ть *несов. см.* **вдеть**

вде́вятеро *нареч.* тугыз тапкыр (мәртәбә); тугыз кат (өлеш), тугызлата

вдевятеро́м *нареч.* тугызау, тугызау бергә, тугызаулап

в-девя́тых *вводн. сл.* тугызынчыдан

вде́лать *сов. что во что* (*вставить внутрь, закрепив*) кертеп ныгыту (урнаштыру, кую)

вде́лывать *несов. см.* **вде́лать**

вдёргивать *несов. см.* **вдёрнуть**

вдёрнуть *сов. что во что* (*вдеть*) [эчкә] тартып кертү

вде́сятеро *нареч.* ун мәртәбә (тапкыр); ун кат (өлеш), унлата

вдесятеро́м *нареч.* унау, унаулап, унау бергә

в-деся́тых *вводн. сл.* унынчыдан

вдеть *сов. что во что* кертү, тыгу; (*нитку*) кидерү, саплау; ~ **но́гу в стре́мя** аякны өзәңгегә тыгу

вдоба́вок *нареч. разг.* өстәвенә, шуның (аның) өстенә, җитмәсә тагын

вдова́ *ж* тол хатын

вдове́||ть *несов.* тол булып яшәү; **она́ ~ет тре́тий год** ул өченче ел тол яши

вдове́ц *м* тол ир

вдо́в||ий, -ья, -ье тол хатын ...ы; ~**ья жизнь** тол хатын тормышы

вдо́воль *нареч.* 1. (*до полного удовлетворения*) туйганчы, җитәрлек, теләгәнчә; күпме кирәк булса, шулкадәр 2. *в знач. сказ.* (*много*) күп, җитәрләк, җитеш, бик мул; **у нас всего́** ~ бездә барысы да җитәрлек

вдовство́ *с* толлык, тол яшәү

вдо́вствовать *несов.* толлыкта яшәү, тол яшәү

вдо́вый, -ая, -ое тол ..., тол яшәүче, тол калган

вдого́нку *нареч.* артыннан; артыннан куып; **кри́кнуть** ~ артыннан кычкырып калу

вдолби́ть *сов. что* 1. (*вбить*) кагып кертү 2. *кому, прост.* тукып аңлату (кертү), туку

вдоль 1. *нареч.* буйга; **разре́зать мате́рию** ~ тукыманы буйга кису 2. *предлог с род.п.* буйлап, буенча; ~ **доро́ги** юл буенча ♦ ~ **и поперёк** 1) (*во всех направлениях*) аркылыга-буйга; 2) (*до мельчайших подробностей*) аркылысын-буен, бик җентекле

вдох *м* сулыш (тын) алу, эчкә сулау

вдохнове́ние *с* илһам, ижади дәрт, ижади күтәренкелек

вдохнове́нн||ый, -ая, -ое *высок.* 1. дәртле, күтәренке рухлы; илһамлы; ~**ое сло́во** дәртле сүз; ~**ый по́эт** илһамлы шагыйрь 2. илһам чагылган; илһамлы; ~**ое лицо́** илһамлы йөз

вдохнови́тель *м* илһамчы, рухландыручы, илһам бирүче, дәртләндерүче, илһамландыручы

вдохнови́тельница *ж* илһам бирүче хатын (кыз), рухландыручы хатын (кыз)

вдохнови́ть *сов. кого-что* 1. (*вызвать вдохновение*) рухландыру, илһамландыру 2. *на что* (*побудить*) дәртләндерү, рухландыру; ~ **на по́двиг** батырлыкка рухландыру

вдохнови́ться *сов.* рухлану, күңел күтәрелү, илһам килү, илһамлану, дәртләнү

вдохновля́ть *несов. см.* **вдохнови́ть**

вдохновля́ться *несов.* 1. *см.* **вдохнови́ться**; 2. *страд. от* **вдохновля́ть**

вдохну́ть *сов. что* 1. сулау, эчкә сулау (алу); ~ **осе́нний во́здух** көзге һаваны эчкә сулау 2. *перен. в кого-что* кузгату, уяту; җанландыру; ~ **чу́вство го́рдости** горурлык хисе кузгату

вдре́безги *нареч.* 1. челпәрәмә; **разби́ть** ~ челпәрәмә китеру 2. *разг.* бөтенләй, тәмам, тулысынча; ~ **проигра́ться** бөтенләй отылу

вдруг *нареч.* 1. (*внезапно*) кинәт, кинәттән, капылдан, көтмәгәндә, искәрмәстән; ~ **раздался вы́стрел** кинәт ату тавышы ишетелде 2. *разг.* (*одновременно*) берьюлы, бер үк вакытта 3. *в знач. частицы* (*а если*) әгәр ...са; ~ **он заболе́ет?** әгәр ул авырый калса?

вдрызг *нареч. прост.* 1. челпәрәмә; **разби́ть** ~ челпәрәмә ватy 2. бөтенләй, тәмам; лаякыл, аңын югалтканчы; ~ **пья́ный** лаякыл исерек

вдува́ть *несов. см.* **вдуть**

вду́маться *сов. во что* төптән уйлау, тирәнтен уйлау, уйлап төшенү (аңлау)

вду́мчи||ый, - ая, -ое 1. төптән уйлаучы, тирәнтен уйлаучан; ~**ый челове́к** төптән уйлаучан кеше 2. уйчан; ~**ое лицо́** уйчан йөз

вду́мываться *несов. см.* **вду́маться**

вдуть *сов. что* өреп тутыру, өреп кертү; ~ **во́здух в мяч** тупка һаваөреп тутыру

вдыха́ть *несов. см.* **вдохну́ть**

вегетариа́нец *м* вегетарианчы, вегетариан

вегетариа́нка *ж см.* вегетарианчы хатын (кыз)

вегетариа́нский, -ая, -ое (*о пище*) кысыр, итсез; ~ **суп** итсез аш

вегетариа́нство *с* вегетарианлык (*ит ашамау, яшелчә һәм сөт азыклары белән генә тукланy*)

вегетати́вн||ый, -ая, -ое *биол.* вегетатив; ~**ые о́рганы** вегетатив органнар (*усемлекләрдә усу һәм тукланy органнары*); ~**ое размноже́ние** вегетатив үрчү ♦ ~**ая не́рвная систе́ма** *физиол.* вегетатив нерв системасы

вегетацио́нный, -ая, -ое: ~ **пери́од** вегетация чоры

вегета́ция *ж бот.* вегетация (*усемлекләрнең усу, җитлегү, үрчү процессы*)

ведá *м рус телендәге кушма исемнәрнең икенче кисәге, «белгеч» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **литературове́д** әдәбият белгече; **языкове́д** тел белгече; **музыкове́д** музыка белгече *h.б.ш.*

ве́дать *несов.* 1. *что уст.* (*знать*) хәбәрдар булу, белү; мәгълүмат булу; **не** ~, **что бу́дет** нәрсә буласын белмәү 2. *чем* (*управлять*) идарә итү, башкару; карау, күзәтеп тору; ~ **хозя́йственной ча́стью** хуҗалык белән идарә итү

введе́ни||е *с* карамагында булу, карамагында тору; идарә ителү; **принима́ть в своё** ~**е** үз карамагына алу; **вопро́сы, относя́щиеся к** ~**ю Верховного Совета Республики** Республика Верховный Советы карамагындагы мәсьәләләр

ведéние *с рус. телендәге кушма исемнәрнең икенче кисәге, «фән», «белем» яки «фән тармагы», «белем тармагы» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **языкове́дение** тел белеме; **почкове́дение** туфрак белеме; **обществове́дение** җәмгыять белеме

веде́ние *с см.* **вести́** 1, 2; ~ **заседа́ния** утырыш алып бару; ~ **хозя́йства** хуҗалык белән җитәкчелек итү; ~ **протоко́ла** протокол язу

ведёрн||ый, -ая, -ое 1. чиләк ...ы; ~**ая ру́чка** чиләк бавы 2. бер чиләкле, бер чиләк сыешлы; ~**ый самова́р** бер чиләк сыешлы самовар

ве́дом||о: с ~**а** *кого-л. кемнеңдер* рөхсәте белән, ризалыгы белән; **без** ~**а** *кого-л. кемнең дә булса* рөхсәтеннән башка, ризалыгыннан тыш

ве́домост||ь *ж* 1. исемлек, ведомость; **расчётная** ~**ь** акча түләү исемлеге 2. *мн.* ~ **и** ведомостьлар, хәбәрләр; **Ве́домости институ́та** Институт ведомостьлары

ве́домственн||ый, -ая, -ое **1.** ведомство ...ы; ведомствога караган; **~ые архи́вы** ведомство архивлары **2.** ведомствочылык ...ы, идарәчелек ...ы, тар ведомство мәнфәгатен күзәтүгә нигезләнгән; **~ый подхо́д к вопро́су** мәсьәләгә ведомствочылык карашы

ве́домство *с* ведомство; идарәчелек (*дәүләт идарәсе тармагы*)

ведо́м||ый, -ая, -ое **1.** алып барыла торган; ияртелеп баручы; алып барылучы; ияртелүче; **~ый самолёт** ияртелеп баручы самолёт **2.** *тех.* йөртелүче; **~ое колесо́** йөртелүче тәгәрмәч

ведро́ *с* **1.** чиләк **2.** *уст.* (*мера жидкости около 12 л*) бер чиләк

вёдро *с уст.* (*ясная погода*) аяз көн, аяз, кояшлы көн

веду́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **вести́; 2.** (*головной*) алып бара торган, ияртеп баручы, алып баручы; **~ий самолёт** алып баручы самолёт **3.** *тех.* йөртүче, хәрәкәтләндерүче; **~ее колесо́** йөртүче тәгәрмәч **4.** әйдәүче, төп, җитәкләүче; **~ая о́трасль промы́шленности** промышленностьның төп тармагы; **игра́ть ~ую роль** төп рольне уйнау

ведь *частица, союз* бит, ич, ләбаса; **~ не ребёнок, мог бы поня́ть** бала түгел ич, аңлый ала иде; **~ како́й челове́к!** нинди кеше бит!; **~ ему́ говори́ли, а он не слу́шался** аңа бит әйтеп килделәр, ә ул тыңламады

ве́дьма *ж прям., перен.* убырлы карчык, җен карчыгы

ве́ер *м* җилпәзә, җилләткеч

ве́ером *нареч.* (*полукругом*) ярым түгәрәк булып; ярым түгәрәк ясап

ве́жды *мн. уст. поэт.* (*веки*) күз кабаклары; (*глаза́*) күз

ве́жливост||ь *ж* әдәплелек, әдәп, кече күңеллелек, ихтирамлылык, ихтирам; **визи́т ~и** ихтирам йөзеннән килү

ве́жлив||ый, -ая, -ое әдәпле, кече күңелле, ихтирамлы; **~ый челове́к** әдәпле кеше; **~ое обраще́ние** ихтирамлы мөгамәлә

везде́ *нареч.* һәркайда, һәржирдә, һәр урында

вездесу́щ||ий, -ая, -ее *ирон.* һәркайда була торган, һәркая өлгерүче, барысына да җитешүче; **~ие мальчи́шки** һәркайда була торган малайлар

вездехо́д *м* вездеход (*теләсә нинди юлдан йөри ала торган автомобиль*)

везе́ние *с разг.* җай килү, җай килеп тору, уңышлы килеп чыгу; бүресе улау

вез||ти́ *несов.* **1.** *кого-что* алып бару, алып кайту, утыртып алып бару, төяп алып бару; тартып алып бару; **~ти́ дете́й в ла́герь** балаларны лагерьга алып бару; **~ти́ песо́к на та́чке** комны тачкада алып бару **2.** *безл. кому в чём, разг.* (*об удаче*) җай килү, җай килеп тору; уңышлы килеп чыгу, бүресе улау; эше уңу; **ему́ ~ёт в жи́зни** аңа тормышта гел җай килеп тора ♦ **~ёт как уто́пленнику** бәхетсезгә җил каршы; ≈ сукыр тавык юлга чыкса, буран булыр

везу́чий, -ая, -ее эше уңучан, бүресе улаучан, җай килеп торучан; **~ челове́к** эше уңучан кеше

век *м* **1.** (*столетие*) гасыр, йөз, йөз ел; **двадца́тый ~** егерменче йөз; **в про́шлом ~е** үткән гасырда **2.** (*период*) гасыр, чор, дәвер; **ка́менный ~** таш гасыры; **сре́дние ~а́** урта гасырлар **3.** (*жизнь*) гомер; **на своём ~у́** үз гомерендә **4.** *разг.* (*длительное время*) озак вакыт, бик күптән; **они́ ~ не ви́дались** алар озак вакыт бер-берсен күрмәгәннәр **5.** *в знач. нареч.* (*всегда*) һәрвакыт, гомер буена; һаман; **я го́тов ~ слу́шать вас** мин сезне гомер буена тыңларга әзермен ♦ **во ~и ~о́в** *уст.* мәңге, гомер буена; **на ~и ве́чные** гомер-гомергә, мәңгегә; **в ко́и ~и** бик сирәк, озак вакыттан соң; **испоко́н (споко́н) ~о́в** элек-электән, күптәннән

ве́ко *с* күз кабагы; **ве́рхнее ~** өске күз кабагы

вековá́ть: век ~ гомер итү, яшәү

вековéчн||ый, -ая, -ое мәңгелек ..., гомер-гомердән килгән; бетмәс-төкәнмәс; **~ые спо́ры** мәңгелек бәхәсләр

веков||о́й, -а́я, -о́е **1.** карт, гасырлар буена үскән (яшәгән); **~о́й дуб** карт имән **2.** элек-электән килгән, күптәнге, борынгы; **~ые тради́ции** элек-электән килгән традицияләр

ве́ксель *м* вексель (*билгеле бер вакытка билгеле бер сумма акча түләү турында язма йөкләмә*)

ве́ктор *м мат.* вектор

веле́нев||ый -ая, -ое: **~ая бума́га** велен кәгазь (*шома тыгыз кәгазь*)

веле́ние *с уст. высок.* боеру, боерык, әмер, кушу, фәрман

велеречи́в||ый, -ая, -ое *уст.* күпшы, тәкәллефле (*сөйләү турында*); **~ая речь** күпшы сөйләм

веле́ть *сов. несов. кому и с неопр.* кушу, боеру, әмер итү; **~ прийти́ за́втра** иртәгә килергә кушу

велика́н *м* алып, алпамша, дәү кеше

вели́к||ий, -ая, -ое **1.** бөек; **Вели́кая Оте́чественная война́** Бөек Ватан сугышы; **~ие лю́ди** бөек кешеләр **2.** бик зур; **~ая ра́дость** бик зур шатлык **3.** (*просторный*) зур, артык иркен; **сапо́ги ~и́** итекләр зур ♦ **~а́ беда́ (ва́жность)!** исең киткән икән!; **~ие держа́вы** бөек державалар; **~ое мно́жество** хисапсыз күп

великова́т *в знач. сказ.* зуррак, бераз, зур, бераз иркенрәк; **пальто́ ~о** пальто зуррак

великово́зрастный, -ая, -ое *уст.* яше үткән, яше узган; олы яшьтәге; **~ гимнази́ст** яше үткән гимназист

великодержа́вный, -ая, -ое бөек державачылык ...ы; **~ шовини́зм** бөек державачылык шовинизмы

великоду́шие *с* киң күңеллелек, хуш күңеллелек; эчкерсезлек

великоду́шничать *несов.* киң күңеллелек күрсәтү, хуш күңеллелек күрсәтү, киң күңеллелек күрсәтеп маташу

великоду́шный, -ая, -ое киң күңелле, хуш күңелле; эчкерсез; **~ хара́ктер** эчкерсез холык

великоле́пие *с* зиннәтлелек, күркәмлек, гүзәллек

великоле́пный, -ая, -ое **1.** зиннәтле, гүзәл, бик күркәм; **~ вид** бик күркәм кыяфәт **2.** бик яхшы, менә дигән; **~ за́втрак** менә дигән иртәнге аш

великору́сы *мн. книжн.* великорусслар, руслар

великосве́тский, -ая, -ое *уст.* югары катлау ...ы; югары катлаулар ...ы; аксөякләр ...ы; **~ сало́н** аксөякләр салоны

велича́в||ый, -ая, -ое мәһабәт, мәһабәт кыяфәтле; **~ая по́ступь** мәһабәт адымнар

велича́ть *несов. кого* **1.** *кем* исемен атау, исемләү; исеме белән әйтү; **~ по ба́тюшке** атасының исеме белән әйтү **2.** (*чествовать*) мактап җырлау; котлап җырлау; **~ жениха́ с неве́стой** кияү белән кәләшне котлап җырлау

вели́чественн||ый, -ая, -ое мәһабәт, бөек; **вели́чественная панора́ма Кавка́зских гор** Кавказ тауларының мәһабәт панорамасы; **~ый вид** мәһабәт күренеш

вели́чество *с* галижанәп (*патшаларны һәм аларның хатыннарын атау сүзе*)

вели́чие *с* бөеклек, олылык; **~ Пу́шкина** Пушкинның бөеклеге; **~ труда́** хезмәтнең олылыгы

величин||а́ *ж* **1.** зурлык, күләм; **изме́рить ~у́** *чего-л. нәрсәнең дә булса* зурлыгын үлчәү **2.** *мат.* зурлык; **постоя́нная ~а́** даими зурлык; **перемéнная ~а́** үзгәрешле зурлык **3.** *перем.* күренекле кеше, атаклы кеше, зур зат; **он — ~а́ в литерату́рном ми́ре** әдәбият дөньясында ул күренекле кеше

велого́нки *мн.* велосипед ярышлары

велого́нщик *м* велосипедта ярышучы

велодро́м *м* велодром (*велосипедта ярышу мәйданы*)

велосипе́д *м* велосипед

велосипеди́ст *м* велосипедчы, велосипедта йөрүче

велосипеди́стка *ж* велосипедчы хатын (кыз)

вельбо́т *м* вельбот (*ишкәкле һәм паруслы зур озын көймә*)

вельве́т *м* вельвет

вельве́тов||ый, -ая, -ое **1.** вельвет ...ы; **~ое произво́дство** вельвет производствосы **2.** вельвет ..., вельветтан тегелгән; **~ый костю́м** вельвет костюм

вельмо́жа *м* **1.** *ист.* вельможа, зур түрә **2.** *ирон.* үзен әллә кемгә куючы кеше

вельмо́жный, -ая, -ое **1.** вельможа булган, зур түрә булган; вельможа ...; **~ боя́рин** вельможа боярин **2.** вельможаларга хас, зур түрәләргә хас; **~ тон** зур түрәләргә хас тон

велю́р *м* велюр

велю́ров||ый, -ая, -ое **1.** велюр ...ы; **~ый цех** велюр цехы **2.** велюр ..., велюрдан эшләнгән; **~ая шля́па** велюр эшләпә

ве́на *ж* вена, кан тамыры, кара кан тамыры; **расшире́ние вен** кара кан тамырының киңәюе

венге́рка I *ж* венгр хатыны (кызы)

венге́рка II *ж* **1.** венгерка (*бию*) **2.** *уст.* венгерка (*гусарлар курткасы*)

венге́рский, -ая, -ое венгр[лар] ...ы; Венгрия ...ы; ~ **язы́к** венгр теле

венгр *м* венгр, венгр кешесе, мажар

ве́нгры *мн.* венгрлар, венгр халкы, мажарлар, мажар халкы

венери́ческ||ий, -ая, -ое венерик ..., ~**ие боле́зни** венерик авырулар; ~**ий больно́й** венерик авыру

венеро́лог *м* венеролог, венерология белгече

венеролО́гия *ж* венерология (*венерик авырулар һәм аларны дәвалау турындагы фән*)

вене́ц *м* **1.** *уст. поэт.* венок; **терно́вый** ~ чәнечкеле венок **2.** (*корона*) таҗ; **ца́рский** ~ патша таҗы **3.** (*ореол*) алка, божра; ~ **вокру́г луны́** ай тирәсендәге алка **4.** (*один ряд брёвен в срубе*) ниргә ♦ **пойти́ (идти́) под** ~ никахланышу, өйләнешү

вене́чн||ый, -ая, -ое **1.** таж ...ы; ~**ые украше́ния** таҗ бизәкләре **2.** ниргә ...ы; (*бурада*); ~**ая ско́ба** ниргә атламасы; **3.** *анат.* коронар; ~**ые сосу́ды** коронар тамырлар

ве́нзель *м* (*исем белән фамилия баш хәрефләренең бер-беренә чорналып матур язылышы*)

ве́ник *м* миннек, мунча себеркесе

вено́зн||ый, -ая, -ое вена ...ы, кара кан тамыры ...ы; ~**ая кровь** вена каны

вено́к *м* венок

вентили́ровать *несов. что* **1.** җилләтү, вентиляция ясау **2.** *перен. прост.* (*обсуждать*) тикшереп карау, ачыклап карау; ~ **вопро́с** мәсьәләне тикшереп карау

ве́нтиль *м* вентиль (**1.** *сыеклык, пар, газ агымын туктатып тору яки көйләү өчен җайланма* **2.** *тынлы музыка кораллларында тавышның югарылыгын көйләү өчен клапан*)

вентиля́тор *м* вентилятор, җилләткеч

вентиляцио́нн||ый, -ая, -ое вентиляция ...ы; ~**ая труба́** вентиляция торбасы

вентиля́ция *ж* **1.** (*проветривание*) вентиляцияләү, җилләтү **2.** (*устройство*) вентиляция

венценО́сец *м уст. высок.* патша, таҗдар, таҗ иясе

венча́||ть 1. *несов., сов. кого* кидерү (*венок, таҗ*); ~**ть лавро́вым венко́м** дәфнә веногы кидерү **2.** *несов. что* (*находиться наверху*) очлану, очында булу; барып бетү (*югарыда*); **ба́шню** ~**ла руби́новая звезда́** манаранын очында кызыл якут йолдыз иде **3.** *несов. перен. что* (*успешно завершать*) төгәлләү, тәмамлау; уңышлы рәвештә, уңышлы килеп чыгу **4.** *несов. кого* (*совершать обряд*) никах уку, никахландыру

венча́ться *несов.* никах укыту, никахланышу

ве́нчик *м бот.* таҗ

вепрь *м* кабан, кабан дуңгызы

ве́ра *ж* **1.** ышану, инану, ышаныч; ~ **в побе́ду** җиңүгә ышану; ~ **в лю́дей** кешеләргә ышаныч **2.** дин; иман; **христиа́нская** ~ христиан дине

вера́нда *ж* веранда, балкон

ве́рба *ж* кызыл тал, песиле тал

вербА́льн||ый, -ая, -ое *книжн.* (*устный*) телдән, сүз белән, вербаль ♦ ~**ая но́та** вербаль нота (*имза куелмаган нота*)

вербе́на *ж бот.* вербена

верблю́д *м* дәя; **одного́рбый** ~ бер өркәчле дәя; **двуго́рбый** ~ ике өркәчле дәя

верблю́дица *ж* ана дәя

верблюжА́тина *ж* дәя ите

верблю́ж||ий, -ая, -ое **1.** дәя ...ы; ~**ья шерсть** дәя йоны; ~**ий горб** дәя өркәче **2.** дәя йоныннан ясалган, дәя йоныннан эшләнгән; ~**ье одея́ло** дәя йоныннан эшләнгән юрган

верблюжО́нок *м* бута, дәя баласы

вербова́ть *несов. кого-что* вербовкалау, вербовать итү, эшкә яллау; ~ **люде́й на стро́йку** кешеләрне төзелешкә вербовкалау

вербова́ться *несов.* **1.** вербовкалану, вербовать ителү, эшкә яллану **2.** *страд. от* **вербова́ть**

вербо́вщик *м* вербовщик, вербовкалаучы, эшкә яллаучы

верёвк||а *ж* бау, аркан ♦ ~**и вить** *из кого* кырыкка бөгү *кемне*

верёвочн||ый, -ая, -ое **1.** бау ...ы, аркан ...ы; ~**ое произво́дство** бау производствосы **2.** бау ..., аркан ..., баудан ясалган, арканнан ясалган; ~**ая ле́стница** бау баскыч

верени́ца *ж* төркем, көтү; тезмә, саф; (*напр. машин*) олау; ~ **журавле́й** торналар сафы

ве́реск *м бот.* арчан

ве́ресков||ый, -ая, -ое **1.** *бот.* арчан ...ы; ~**ый куст** арчан куагы **2.** арчан ..., арчаннан ясалган; ~**ая па́лка** арчан таяк

веретено́ *с* орчык

верещА́ние *с* черелдәү, чыелдау; черелдәү тавышы, чыелдау тавышы; ~ **кузне́чиков** чикерткәләр черелдәве

верещ||а́ть *несов.* черелдәү, чыелдау; **сверчо́к** ~**и́т** өй чикерткәсе черелди

верзи́ла *м, ж разг.* әзмәвер, сузан

вери́ги *мн.* чылбыр, тән чылбыры (*дини фанатикларда үз-үзләрен җәзалау йөзеннән тәнгә таккан чылбыр*)

вери́тельн||ый, -ая, -ое: ~**ая гра́мота** ышаныч грамотасы (*дипломатия вәкиленә аны башка илгә җибәргәндә бирелә торган хөкүмәт документы*)

ве́р||ить *несов.* **1.** *кому-чему, в кого, во что* ышану, ышанып тору; ~**ить в успе́х** уңышка ышану; ~**ить в торжество́ справедли́вости** гаделлеккә җиңеп чыгуына ышану; ~**ить в наро́д** халыкка ышану; **я** ~**ю в него́** мин аңа ышанам **2.** *кому* ышану, ышанып карау, ышанып эш итү; ~**ить дру́гу** дуска ышанып карау **3.** дингә ышану, инану; дин тоту ♦ ~**ить на́ слово** коры сүзгә ышану; **не** ~**ить свои́м глаза́м (уша́м)** үз күзеңә (колагыңа) үзең ышанмау

ве́риться *несов. безл.* ышанасы килү, ышанып булу, ышану; **не ве́рится, что э́то так** моның алай буласына ышанасы килми

ве́рмахт *м* вермахт (*фашистлар Германиясенең Бөек Ватан сугышында тармар ителгән кораллы көчләре*)

вермише́ль *ж* токмач, вермишель; **суп с** ~**ю** вермишельле аш

ве́рмут *м* вермут (*шәраб*)

верне́е 1. *сравн. ст. от* **ве́рный** *и* **ве́рно; э́то реше́ние зада́чи** = мәсьәләнең бу чишелеше дөресрәк **2.** *в знач. вводн. сл.* дөресрәге, дөресе, дөресен әйткәндә

ве́рно *нареч.* **1.** турылыклы, гадел, туры; ~ **служи́ть** турылыклы хезмәт итү **2.** дөрес, чын; ~ **скопи́ровать** дөрес күчерү **3.** *в знач. вводн. сл.* ихтимал, бәлки, мөгаен; **он,** ~**, сего́дня не придёт** ул, мөгаен, бүген килмәс

вернопО́дданн||ый, -ая, -ое *уст.* патшага турылыклы [булган], патшага турылыклы хезмәт итүче; ~**ые дворя́не** патшага турылыклы дворяннар

ве́рность *ж* **1.** тугрылык, турылыклылык, турылык, бирелгәнлек; ~ **Ро́дине** Ватанга турылыклылык; ~ **университе́тским тради́циям** университет традицияләренә турылыклык **2.** дөреслек; ~ **реше́ния** карарның дөреслеге; ~ **перево́да** тәрҗемәнең дөреслеге

верну́ть *сов. кого-что* **1.** кире кайтару, кайтарып бирү, кайтару, кире бирү; кайтарып алу; ~ **долг** бурычны кайтару; ~ **здоро́вье** сәламәтлекне кайтару **2.** кире кайтару, борып кайтару, кирегә бору; ~ **люде́й** кешеләрне борып кайтару

верну́ться *сов.* **1.** кайту, борылып кайту, кире [әйләнеп] кайту; ~ **из о́тпуска** ялдан кайту **2.** *к чему* яңадан кире кайту, яңадан кузгату; ~ **к да́нному вопро́су** бу мәсьәләгә яңадан кире кайту

ве́рн||ый, -ая, -ое **1.** тугрылыклы, турылыклы, тугры, туры; ~**ый помо́щник** турылыклы ярдәмче; ~**ые друзья́** тугры дуслар **2.** дөрес, дөреслекле; ~**ая мысль** дөрес фикер; ~**ый перево́д** дөрес тәрҗемә **3.** ышанычлы, нык, ныклы; үткен, төгәл; төз; ~**ая рука́** ышанычлы кул; ~**ый глаз** үткен күз **4.** (*неизбежный*) котылгысыз, шиксез; ~**ая ги́бель** котылгысыз һәлакәт

ве́рования *мн.* ышанулар, иман, дини караш; ~ **дре́вних** борынгыларның дини карашлары

ве́ровать *несов.* **1.** *в кого-что* ышану, ышанып карау **2.** (*иметь веру в бога*) аллага инану, аллага ышану, дин тоту

вероиспове́дание *с* дин, диндә булу; **католи́ческое** ~ католик дине; **правосла́вное** ~ православие дине

веролО́мн||ый, -ая, -ое хыянәтчел [рәвештә], мәкерле, хаин ..., монафыйк ...; ~**ое нападе́ние** хыянәтчел рәвештә һөҗүм итү; ~**ый враг** мәкерле дошман

веролО́мство *с* хыянәтчеллек, хыянәт, мәкерлелек, хаинлык, монафыйклык

верони́ка *ж бот.* яушан, яуша

вероотсту́пник *м уст.* мөртәт, динен ташлаган кеше

вероотсту́пница *ж уст.* мөртәт хатын (кыз)

вероотсту́пничество *с уст.* мөртәтлек, дин ташлау, диннән язу

веротерпи́мость *ж* диннәргә тигез караш; дин иреген тану

вероуче́ние *с* дин тәгълиматы, дин гыйльме, дин кагыйдәләре

вероя́тно *вводн. сл.* мөгаен, ихтимал, бәлкем; **он, ~, не придёт** ул, ихтимал, килмәс

вероя́тност||ь *ж* ихтималлык, мөмкинлек ♦ **теория ~и** *мат.* ихтималлык теориясе; **по всей ~и** ≈ мөгаен

вероя́тн||ый, -ая, -ое ихтимал ителгән, мөмкин булган, мөмкин саналган, булуы мөмкин

ве́рсия *ж* версия, юрама, риваять; **но́вая ~** яңа юрама; **после́дняя ~** сонгы версия

верст||а́ *ж* **1.** чакрым (*1,06 кмга тигез*) **2.** *уст.* (*дорожный столб*) чакрым баганасы; юл баганасы ♦ **за ~у́** әллә каян, ерактан; бер чакрымнан; **коло́менская ~а́** *или* **с коло́менскую ~у́** чакрым баганасы, телеграмм баганасы (*бик озын кеше турында*)

верста́к *м* верстак

верста́льщик *м полигр.* верстальщик, вёрсткалаучы

верста́ть *несов. что, полигр.* версткалау, биткә салу; **~ кни́гу** китапны биткә салу

вёрстк||а *ж* **1.** *см.* **верста́ть; ~а кни́ги** китапны биткә салу **2.** вёрстка (*биткә салынган набор; шуның басмасы*); **чита́ть ~у** вёрстка уку

верстов||о́й, -а́я, -о́е чакрым ...ы; **~ы́е столбы́** чакрым баганалары

ве́ртел *м* шеш (*ит кисәкләрен кыздыру өчен*)

верте́п *м* вертеп (*бозык кешеләр җыела торган урын*)

верт||е́ть *несов.* **1.** *кого-что* әйләндерү, бору; **~е́ть колесо́** тәгәрмәчне әйләндерү; **~е́ть рукоя́тку** тотканы бору **2.** *что* төрү, бөтерү; **~е́ть цига́рку** тәмәке төрү **3.** *перен. кем-чем, разг.* биетү, биетеп тору (тоту); **она́ ~е́ла им, как хоте́ла** аларны ул ничек теләсә шулай биетеп тора иде ♦ **~е́ть хво́стом** койрык болгау, хәйләләү; **как ни ~и́** ничек кенә борсаң да

верт||е́ться *несов.* **1.** әйләнү, әйләнеп тору; борылу; **колесо́ ве́ртится** тәгәрмәч әйләнеп тора **2.** бөтерелү, боргалану, әйләнү; **~е́ться пе́ред зе́ркалом** көзге алдында боргалану **3.** *перен.* чуалу, буталу; **~е́ться о́коло ста́рших** өлкәннәр янында чуалу **4.** *перен.* боргалану, койрык болгау; **не ~и́сь, говори́ пра́вду** боргаланма, дөресен сөйлә ♦ **~е́ться волчко́м** бөтерелү; бөтерелеп эшләү; **~е́ться вьюно́м** еландай бөтерелү; **ве́ртится на языке́** тел очында гына тора; **~е́ться под нога́ми** аяк астында чуалу; **как ни ~и́сь** ничек кенә боргаласаң да; нәрсә генә эшләсәң дә

вертика́ль *ж* вертикаль, вертикаль сызык, асма сызык

вертика́льн||ый, -ая, -ое вертикаль ...ы; асма; **~ая ли́ния** асма сызык

вертихво́стка *ж разг.* җилбәзәк хатын (кыз); җиңел холыклы хатын

вёрткий, -ая, -ое *разг.* елгыр, җитез, өлгер

вертлю́г *м* **1.** *анат.* чукмар сөяк **2.** *тех.* вертлюг (*механизмларда күчәрнең оя эчендә әйләнә торган очы*)

вертлю́жн||ый, -ая, -ое **1.** *анат.* чукмар сөяге ...ы **2.** *тех.* вертлюг ...ы; вертлюгы ...ы; **~ое соедине́ние** вертлюглы тоташу

вертля́в||ый, -ая, -ое кыбырсык, тиктормас; тынгысыз; **~ая де́вочка** кыбырсык кызчык

вертолёт *м* вертолёт

вертолётн||ый, -ая, -ое вертолёт ...ы; вертолёт ...; **~ое сообще́ние** вертолёт очу (*ике арада*)

вертолётчик *м* вертолётчы

вертопра́х *м разг.* җилкуар, җилбәзәк ир

верту́н *м* **1.** *разг.* тиктормас, кыбырсык кеше **2.** (*голубь*) турман, әйләнчек күгәрчен

верту́шка *ж* **1.** бөтерчек (*инструментларда*) **2.** *разг.* җилбәзәк хатын (кыз), җилкуар хатын

ве́рующ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **ве́ровать; 2.** *в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~ая** *ж рел.* дингә ышанучы, дин тотучы, диндар, динле кеше

верфь *ж* верфь (*суднолар төзү һәм ремонтлау урыны*)

верх *м* **1.** өс, түбә, баш, үр; **~и́ сне́жных гор** карлы тауларның түбәләре; **~и́ дере́вьев** агачларның башлары; **на са́мом ~у́** иң өстә **2.** (*верхний этаж*) өске кат, югары кат **3.** (*лицевая сторона*) тыш; **шу́ба с су́конным ~ом** постау тышлы тун **4.** (*экипажа, машины*) япма **5.** *разг.* (*верхнее течение реки*) югары өлеше, үрге өлеше (*елганың*) **6.** *мн.* **~и́** югары даирә, идарә итүчеләр; югары катлау; **пра́вящие ~и́** идарә итүчеләр даирәсе **7.** *мн.* **~и́** *муз.* югары ноталар, нечкә тавышлар **8.** *мн.* **~и́** *перен.* өс; **скользи́ть по ~а́м** өстән шуу ♦ **быть на ~у́ блаже́нства** искиткеч рәхәтлек кичерү

ве́рхн||ий, -яя, -ее **1.** өске, югарыгы, өстәге, югарыдагы, үрге, үрдәге; **~ий эта́ж** өске кат; **~яя по́лка** югары шүрлек **2.** (*об одежде*) өске, тышкы **3.** (*близкий к истоку реки*) үрге, югарыгы; **~ее тече́ние ре́ки** елганың югарыгы агымы **4.** *муз.* югары; **~ий регистр** югары регистр ♦ **~яя пала́та** *полит.* югары палата

верхо́вн||ый, -ая, -ое югары; баш, верховный; **~ая власть** югары хакимият; **Верхо́вный Сове́т Республики** Республиканың Югары Советы; **Верхо́вный Главнокома́ндующий** Баш главнокомандующий

верхово́дить *несов. кем-чем, разг.* башлык булу, идарә итү; башлап йөрү; **~ ребя́тами** малайларга башлык булу

верхов||о́й I, -а́я, -о́е **1.** менеп йөри торган, атланып йөри торган, сыбай йөри торган, менге; **~ая ло́шадь** менге ат; **~ая езда́** сыбай йөрү **2.** *в знач. сущ.* **~о́й** *м* җайдак, сыбайлы, атка атланган кеше

верхов||о́й II, -а́я, -о́е **1.** югарыгы, өске, үрге; сыбайлы; **~о́й ве́тер** югарыгы җил; **~о́й бура́н** сыбайлы буран **2.** (*расположенный выше по течению*) үрге, югарыдагы; **~ы́е сёла** үрге авыллар **3.** *разг.* верховой, өстә эшләүче (*мәс. вышкада*)

верхо́вье *с* (*верхняя часть реки*) үрге агым, баш (*елганың*); **~ Во́лги** Иделнең үрге агымы

верхогля́д *м разг.* өстән караучы, җиңел караучы (*мәсьәлә*)

верхогля́дство *с* өстән карау, өстән караучылык, җиңел карау

верхола́з *м* өстә эшләүче, верхолаз

ве́рхом *нареч.* **1.** (*по нагорной части местности*) өстән, үрдән, югарыдан өске яктан, югары яктан; **идти́ ~** үрдән бару **2.** (*выше краёв*) түбәләмә итеп, мөлдерәмә итеп, артык тутырып; **насыпа́ть кру́пу в ча́шку ~** чынаякка ярманы түбәләмә итеп салу

верхо́м *нареч.* ат менеп, атка атланып, атланып, сыбай; **е́хать ~** сыбай бару

верху́шечный, -ая, -ое өске өлешендәге, югары өлешендәге; **~ процесс в лёгких** үпкәнең югары өлешендәге процесс

верху́шка *ж* **1.** түбә, баш, оч; югарыгы өлеш; **~ де́рева** агач башы; **~ горы́** тау түбәсе **2.** *перен. разг.* югары катлау, өстен катлау; **пра́вящая ~** хакимлек итүче өстен катлау

ве́рша *ж* мурда, сөкә (*балык тоту җайланмасы*)

верши́н||а *ж* **1.** түбә, баш, оч; **го́рные ~ы** тау түбәләре; **~ы тополе́й** актирәк башлары **2.** *перен.* иң югары дәрәҗә, иң югары баскыч; **на ~е сла́вы** даны чәчәк аткан вакытта

верши́тель *м высок.* хәл итүче, идарә итүче; **~ су́деб** язмышларны хәл итүче

верши́ть *несов.* **1.** *что* хәл кылу, хәл итү, чишү; **~ правосу́дие** хөкем итү **2.** *чем* идарә итү; **~ чьими-л. су́дьбами** *кемнең дә булса* язмышлары белән идарә итү **3.** *что, диал.* очлау; **~ стог** кибәнне очлау

вершки́ *мн.* өске өлеш, яфрак; **мне ~, а тебе́ корешки́** *фольк.* миңа яфраклары, сиңа тамырлары

вершко́в||ый, -ая, -ое бер карыш, бер карыш озынлыктагы; **~ые гво́зди** бер карыш кадаклар

вершо́к *м* карыш (*электә 4,4 см чамасындагы озынлык үлчәве*)

вес I *м* **1.** авырлык; **определи́ть ~** авырлыгын билгеләү; **~ом в оди́н пуд** бер пот авырлыгындагы **2.** *перен.* авторитет, дәрәҗә, йогынты; **челове́к с больши́м ~ом** авторитетлы кеше ♦ **~ бру́тто** брутто авырлыгы (*савыты, төргәге белән бергә товар, азык авырлыгы*); **~ не́тто** нетто авырлыгы (*савытыннан, төргәгеннән башка товар, азык авырлыгы*); **~ взят** *спорт.* авырлыкны күтәрә алды; **на ~ зо́лота** алтын бәрабәренә (*бик кыйммәт*)

вес II *м*: **держа́ть на ~у́** асылынган хәлдә [килеш] тоту

весели́ть *несов.* күңеллеләнү, күңел күтәрелү (күтәрелә бару)

весели́ть *несов. кого-что* күңелләндерү, күңелен күтәрү, күңелен ачу, кәефләндерү; юандыру; **~ ребёнка** баланы юандыру; **~ пу́блику** халыкның күңелен ачу

весели́ться *несов.* күңел ачу, кәефсафа чигү; күңелләнү

ве́село *нареч.* **1.** күңелле, күңелле итеп, шат, шатланып; **~ смея́ться** күңелле көлү; **~ игра́ть** күңелле итеп, уйнау **2.** *в знач. сказ. безл.* күңелле; **ему́ ~** ана күңелле

весёлость *ж* күңеллелек, күңел күтәренкелеге, шат күңеллелек

весёл||ый, -ая, -ое **1.** күңелле; шат күңелле; хозур; **~ая шу́тка** күңелле мәзәк; **~ый спекта́кль** күңелле спектакль; **~ое настрое́ние** күңелле кәеф **2.** көләч, шат; **~ое лицо́** көләч йөз ♦ **~ую жизнь устро́ить** *кому* ≈ әпипәгә бастыру, эссе табада биетү

весе́лье *с* **1.** (*радостное настроение*) күңеллелек, шат күңеллелек, кәефлелек, хозурлык **2.** (*развлечение*) кәефсафа, күңел ачу; уен-көлке

ве́сельн||ый, -ая, -ое **1.** ишкәк ...ы; **~ая ру́чка** ишкәк тоткасы **2.** ишкәкле; **~ая ло́дка** ишкәкле көймә

вёсельный, -ая, -ое *разг. см.* **ве́сельный**

весельча́к *м разг.* күңелчәк, мәзәкчән кеше, уен-көлкечел кеше

весе́нн||ий, -яя, -ее яз ...ы; язгы; **~ий во́здух** язгы һава; **~ий день** язгы көн; **~ее со́лнце** язгы кояш; **~ий сев** язгы чәчү

ве́с||ить *несов.* тарту; **груз ~ит де́сять килогра́ммов** йөк ун килограмм тарта

ве́ск||ий, -ая, -ое **1.** авыр, саллы, тос; **~ие мета́ллы** авыр металлар **2.** нигезле, төпле, саллы; **~ий до́вод** нигезле дәлил

ве́скость *ж* **1.** авыр булу, саллы булу, тос булу; **~ зо́лота** алтынның авыр булуы **2.** нигезле булу, төпле булу; **~ до́водов** дәлилләрнең нигезле булуы

весло́ *с* ишкәк

весна́ *ж* яз; **ра́нняя ~** иртә килгән яз

весновспа́шка *ж с.-х.* язгы сөрү (*туңга сөрелмәган җирне*)

весно́й, весною́ *нареч.* язын, яз көне, яз көнендә; **ра́нней ~** иртә язын

весну́шки *мн.* сипкел; **весе́нние ~** язгы сипкел

весну́шчат||ый, -ая, -ое сипкелле, сипкел чыккан; **~ое лицо́** сипкелле йөз

весов||о́й, -а́я, -о́е **1.** үлчәү ...ы; **~а́я ги́ря** үлчәү гире; **~а́я катего́рия** *спорт.* авырлык категориясе **2.** үлчәүле, үлчәнмәле, үлчәп сатыла торган; **~о́й това́р** үлчәүле товар

весовщи́к *м* үлчәүче, үлчәп торучы

весовщи́ца *ж* үлчәүче хатын (кыз)

весо́мый, -ая, -ое **1.** (*обладающий весом*) авырлыклы **2.** *перен.* саллы, әһәмиятле; салмак; **~ вклад** саллы өлеш

вести́ *несов.* **1.** *кого-что* алып бару (килү); **~ ма́льчика за́ руку** малайны кулыннан тотып алып бару; **~ маши́ну** машинаны алып бару **2.** *что* алып бару, үткәрү; **~ семина́р** семинар алып бару; **~ заня́тия** дәресләр үткәрү; **~ хозя́йство** хуҗалыкны алып бару **3.** *чем по чему* йөртү; сыздыру; **~ ука́зкой по ка́рте** карта буйлап указканы йөртү; **~ смычко́м по стру́нам** сызгыч белән кылларны сыздыру **4.** *что* салу, үткәрү, төзү, сузу; **~ телефо́нную ли́нию** телефон линиясе үткәрү; **~ желе́зную доро́гу** тимер юл салу **5.** *перен.* китереп чыгару; китерү; **нео́пытность ведёт к ава́риям** тәҗрибәсезлек аварияләргә китерә ♦ **~ дру́жбу** дус булу; **~ нача́ло** *от кого-чего* башлану, башланып китү; **~ ого́нь** *воен.* ату; **~ перепи́ску** хат язышу; **~ себя́ как ...** үзеңне ... кебек тоту

вестибуля́рный, -ая, -ое; **~ аппа́рат** *анат.* вестибуляр аппарат

вестибю́ль *м* вестибюль

вести́сь *несов.* **1.** алып барылу; башкарылу, үткәрелү; **веду́тся перегово́ры** сөйләшүләр алып барыла **2.** *безл.* гадәткә керү; гадәт булып килү, килү; **так ведётся и́сстари** электән шулай килә **3.** *страд. от* **вести́** 1, 2, 4

ве́стник *м* **1.** хәбәрче, хәбәр китерүче **2.** вестник, белдермә; **Ве́стник Росси́йской Акаде́мии нау́к** Россия Фәннәр академиясе вестнигы

вестов||о́й, -а́я, -о́е **1.** хәбәрче, хәбәр бирүче; сигнал бирүче; **~о́е су́дно** хәбәрче судно **2.** *в знач. сущ.* **~о́й** *м* (*солдат для посылок*) вестовой, йомышчы солдат

вест||ь I *ж* хәбәр, белдерү; **ра́достная ~ь** шатлыклы хәбәр; **бе́з ~и пропа́сть** хәбәрсез югалу

весть II: **бог ~** алла белсен, алла беләмени

весы́ *только мн.* үлчәү; **класть на ~** үлчәүгә салу

весь I *м мест.* (вся *ж*, всё *с*, все *мн.*) **1.** (*целый, целиком*) бөтен, барлык, һәммә, барча; бүе; **всё лето́** бөтен җәй; **во всём ми́ре** бөтен дөньяда; **~ наро́д** бөтен халык; **все лю́ди** барлык кешеләр; **~ день** көн буе; **всю ночь** төн буе; **всю зи́му** кыш буе **2.** бөтенләй, тулысынча; тәмам; **са́хар ~ вы́шел** шикәр бөтенләй бетте; **бума́га вся ко́нчилась** кәгазь тулысынча бетте **3.** *в знач. сущ.* **всё** *с*, **все** *мн.* барысы, бөтенесе; **всё для побе́ды** барысы да җиңү өчен; **добре́е всех** барысыннан да игелеклерәк; **все за одного́, оди́н за всех** барысы да бер кеше өчен, бер кеше барысы да өчен ♦ **~ в отца́** нәкъ атасы; **всего́ хоро́шего** сау бул[ыгыз]; **во всю́ ива́новскую крича́ть** бик каты кычкыру; **всем взял[а́]** бар ягы да килгән; **всё равно́ (одно́)** барыбер; **всё вре́мя** һәрвакыт, даими рәвештә; **на все четы́ре сто́роны** дүрт ягың кыйбла; **не все до́ма** *у кого* ≈ туксан тугызлы, кырыкка бер тулмаган; **при всём том** шуңа да карамастан, шуның өстенә тагын

вес||ь II *ж уст.* авыл; **города́ и ~и** калалар һәм авыллар

весьма́ *нареч.* бик, бик тә, гаять, үтә; **~ рад** бик тә шат

ветви́стость *ж* ботаклылык

ветви́стый, -ая, -ое ботаклы, ботаклары күп булган; **~ дуб** ботаклы имән

ветви́ться *несов.* (*пускать отростки*) ботаклану, ботак җибәрү; (*разветвляться*) тармаклану, тармакларга аерылу

ветвь *ж* **1.** ботак; **~ ду́ба** имән ботагы **2.** *ж.-д.* тармак

ве́т||ер *м* җил; **си́льный ~ер** көчле җил; **сла́бый ~ер** акрын җил; **стоя́ть на ~ру́** җилдә тору ♦ **~ер в голове́** башында җил; **~ер занёс** *или* **~ром занесло́** җил ташлады; **броса́ть слова́ на ~ер** уйламый сөйләү; бушка сөйләү; **броса́ть де́ньги на ~ер** акчаны суга салу

ветера́н *м* **1.** ветеран, карт сугышчы; **~ граждане́кой войны́** гражданнар сугышы ветераны **2.** *чего* ветеран; карт эшче, карт эшлекле; **~ тру́да** хезмәт ветераны

ветерина́р *м* ветеринар, мал табибы, байтар; ветеринария белгече

ветерина́рия *ж* ветеринария (*хайваннарның авыруын һәм аларны дәвалауны өйрәнә торган фән*)

ветерина́рный, -ая, -ое ветеринария ...ы; **~ те́хникум** ветеринария техникумы

ветер||о́к *м* акрын җил, йомшак җил ♦ **с ~ко́м** (*прокатиться*) җилләндереп, бик шәп (*бару һ.б.ш.*)

ве́тк||а *ж* **1.** ботак, кечкенә ботак, ботакчык; **~и ви́шни** чия ботаклары **2.** *ж.-д.* ветка; тармак

ветла́ *ж* өянке, ак тал

ве́то *с нескл.* вето, тыю, рәхсәт итмәү; **наложи́ть ~** вето салу; **пра́во ~** тыю хокукы

ве́тошь *ж собир.* чүпрәк-чапрак, иске-москы

ве́треник *м разг.* җиңел акыллы кеше, җилкуар, җилбәзәк

ве́треница *ж разг.* җилбәзәк хатын (кыз)

ве́треность *ж* җилкуарлык, җилбәзәклек, җиңел акыллылык

ве́трен||ый, -ая, -ое **1.** җилле; **~ая пого́да** җилле һава **2.** *перен.* җилкуар ..., җилбәзәк ..., җиңел, җиңел акыллы; **~ая де́вушка** җилбәзәк кыз

ветри́ло *с уст.* җилкән

ветров||о́й, -а́я, -о́е **1.** җил ...ы; **~о́й шквал** җил өермәсе **2.** җилгә каршы тору ...ы; җилдән саклый торган; **~о́е стекло́** җилдән саклый торган пыяла

ветродви́гатель *м* җил двигателе

ветрозащи́тн||ый, -ая, -ое җилдән саклаучы ..., җилдән саклый торган; **~ая полоса́ ле́са** җилдән саклый торган урман полосасы

ветроме́р *м* җилүлчәгеч (*җил көчен үлчәү әсбабы*)

ветросилов||о́й, -а́я, -о́е җил көче белән эшләүче, җил көче белән эшли торган; **~а́я установка** җил көче белән эшләүче җайланма

ветря́к *м разг.* **1.** (*ветродвигатель*) җил двигателе **2.** (*ветряная мельница*) җил тегермәне

ветря́нка *ж разг.* су чәчәге, җил чәчәге (*балалар авыруы*)

ветрян||о́й, -ая, -о́е җил ...ы; **~ая ме́льница** җил тегермәне

ве́трян||ый, -ая, -ое: **~ая о́спа** су чәчәге (*балалар авыруы*)

ве́тхий, -ая, -ое **1.** иске, искереп беткән, тузган, тузып беткән; **~ дом** тузып беткән өй **2.** (*о человеке*) бик карт, бетәшкән, картаеп беткән; бетәшеп беткән ♦ **Ветхи́й заве́т** Иске тәурат

ветхозаве́тн||ый, -ая, -ое борынгы, иске; иске карашлы; **~ые нра́вы** иске гореф-гадәтләр

ве́тхость *ж* искереп беткән булу, искергәнлек, тузып беткән булу; тузган булу; **~ строе́ния** корылманың тузып беткән булуы

ветчина́ *ж* ветчина (*тозланган һәм ысланган дуңгыз ите*)

ветша́ть *несов.* **1.** (*приходить в негодность*) искерү, тозу, искерә бару, туза бару **2.** (*становиться дряхлым, слабеть*) бетәшү, картаю; искерү; тузу

ве́х||а *ж* **1.** маяк (*юлда адашмас өчен*); казык (*чик билгәләү өчен*); **поста́вить ~и на грани́це уча́стка** җир бүлемтегенең чигенә казык кагу **2.** *обычно мн.* **~и** *перен.* маяк, этап; **~и исто́рии** тарих этаплары

ве́че *с* вече (*борынгы Русьның кайбер шәһәрләрендә, мәс. Новгорода, Псковта хакимиятнең иң югары органы булган жыелыш, халык җыелышы*)

вечев||о́й, -а́я, о́е вече ...ы; **~а́я пло́щадь** вече мәйданы; **~о́й ко́локол** вече чаңы

ве́чер *м* **1.** кич; **тёплый ~** җылы кич; **прийти́ под ~** кичкә таба килү **2.** кичә; **литерату́рный ~** әдәби кичә; **музыка́льный ~** музыка кичәсе

вечере́ть *несов. безл.* кичләү, кич якынлашып килү, кич житеп килү, кич булып килү

вечери́нка *ж* кичә; уен-көлке кичәсе; **студе́нческая ~** студентлар кичәсе

вечерко́м *нареч. разг.* кичен, кич белән

вечёрн||ий, -яя, -ее **1.** кичке; **~яя заря́** кичке шәфакъ; **~яя газе́та** кичке газет; **~ее вре́мя** кичке вакыт **2.** (*об одежде*) кичке, кичә ...ы ♦ **~ее образова́ние** кичке белем алу; кичен укып алган белем

вечером *нареч.* кичен, кич белән; **возвраща́ться ~** кичен кайту

ве́чно *нареч.* **1.** мәңге, һәрвакыт; **мате́рия существу́ет ~** материя мәңге яши **2.** *разг.* һәрвакыт, гел, һаман; **он ~ опа́здывает** ул гел соңга кала

вечнозелён||ый, -ая, -ое мәңге яшел; **~ые расте́ния** мәңге яшел үсемлекләр

ве́чность *ж* мәңгелек ♦ **ка́нуть в ~** исе дә калмау, онытылу, эзсез югалу; **отойти́ в ~** үлү; **це́лую ~** бик озак вакыт, бик озак

ве́чн||ый, -ая, -ое **1.** мәңгелек ..., **~ая мате́рия** мәңгелек материя; **~ая мерзлота́** мәңгелек туң жир; **~ая сла́ва** мәңгелек дан **2.** *разг.* (*всегдашний*) гомерлек ..., мәңгелек ..., һәрвакыттагы; **~ые ссо́ры** мәңгелек бәхәсләр ♦ **~ая исто́рия** ≈ һаман бер балык башы; **~ая па́мять** *кому* хатирәсе мәңге яшәсен

ве́шалк||а *ж* **1.** кием элгеч; **пове́сить пальто́ на ~у** пальтоны кием элгечкә элү **2.** *разг.* (*помещение*) чишенмәлек, гардероб **3.** (*на одежде*) элгеч, элмәк (*киемдә*)

ве́шать I *несов.* **1.** *что* элү, асу; тагу, элеп кую; **~ занаве́ски** пәрдәләрне элү **2.** *кого-что* (*казнить*) асу, асып үтерү ♦ **~ го́лову** башны аска салу, башны түбән ию; **~ нос** борынны салындыру; **~ соба́к** *на кого* бәла тагу, бәла япсару

ве́шать II *несов. кого-что* (*взвешивать*) үлчәү

ве́шаться *несов.* **1.** (*лишать себя жизни*) асылыну, асылынып үлү **2.** *страд. от* **ве́шать** I ♦ **~ на ше́ю** *кому* муенга асылыну

ве́шка *ж* юл казыгы, таякчык

ве́шн||ий, -яя, -ее *уст.* язгы; **~ие луча́** язгы нурлар; **~ее полово́дье** язгы ташу

вещ||а́ть *несов. что и без доп.* **1.** (*предсказывать*) алдан әйтү, алдан хәбәр итү, алдан хәбәр бирү **2.** (*передавать по радио*) тапшыру, хәбәр тапшыру (*радиодан*)

вещев||о́й, -а́я, -о́е **1.** әйберләтә ..., әйберләр белән ...; **~о́е дово́льствие** әйберләр белән тәэмин итү **2.** әйбер [-ләр] ...ы; **~о́й склад** әйберләр склады

вещественность *ж* матдилек, материальлек

вещественн||ый, -ая, -ое **1.** *филос.* матди, материаль; **~ый мир** матди дөнья **2.** әйбер[ләр] ...ы; әйберләтә ...; әйберләрдән гыйбарәт; **~ые доказа́тельства** әйберләрдән гыйбарәт дәлилләр

вещество́ *с* матдә; **органи́ческое ~** органик матдә; **хими́ческое ~** химик матдә

вещи́зм *м* әйбергә табыну, әйбер-челек

ве́щий, -ая, -ое (*проницательный*) алдан хәбәр бирүче, күрәзә ...; зирәк

вещи́ца *ж* **1.** *уменьш. от* **вещь** 1; **2.** (*небольшое произведение*) әйбер, иҗат әйберсе, әсәр

ве́щн||ый, -ая, -ое: **~ое пра́во** *юр.* әйбергә иялек хокукы

вещу́н *м уст.* (*прорицатель*) күрәзә, күрәзәче; алдан хәбәр бирүче

вещу́нья *ж уст.* (*прорицательница*) күрәзә (күрәзәче) хатын, алдан хәбәр бирүче хатын

вещ||ь *ж* **1.** әйбер, нәрсә; **дома́шние ~и** өй әйберләре; **доро́жные ~и** юл әйберләре **2.** *мн.* **~и** (*напр. о платье, одежде*) кием-салым, киемнәр **3.** (*произведение*) әйбер, әсәр; **писа́ть кру́пные ~и** эре әйберләр язу **4.** әйбер, нәрсә, бер нәрсә; хәл, күренеш; **произошла́ непоня́тная ~ь** аңлашылмаган бер нәрсә килеп чыкты

ве́ялка *ж* җилгәргеч

ве́яльщик *м* җилгәрүче, җилгәргечтә эшләүче

ве́яльщица *ж* җилгәрүче хатын (кыз)

ве́яни||е *с* **1.** *см.* **ве́ять** 1, 2; **лёгкие ~я ве́тра** җилнең йомшак кына исүе; **~ зерна́** ашлык җилгәрү **2.** *перен.* йогынты, шаукым; тәэсир; караш; **но́вые ~я в иску́сстве** сәнгатьтәге яңа карашлар

ве́ян||ый, -ая, -ое җилгәргән, җилгәрелгән; **~ое зерно́** җилгәргән ашлык

ве́ять *несов.* **1.** исү, өрү; **ве́тер ве́ет** җил исә **2.** *что* җилгәрү; **~ зерно́** ашлык җилгәрү **3.** җилфердәү, жилбер-жилбер килү; **ве́ют знамёна** байраклар җилферди **4.** *безл. чем* исе килү; бәреп тору, сизелү, аңку; **ве́ет прохла́дой** салкынча һава бәреп тора

вжива́ться *несов. см.* **вжи́ться**

вжи́ться *сов. разг.* (*свыкнуться*) ияләшү, күнегеп китү; кереп китү

вз- (**взо-, взъ-, вс-**) *приставка; бу приставка белән ясалган фигыльләр татар теленә тезмә фигыльләр белән тәрҗемә ителә, приставканың мәгънәсе тубәндәге чаралар ярдәмендә бирелә* **1.** *«менү» дигән фигыль ярдәмендә, мәс.* **взлете́ть** очып менү; **взбежа́ть** йөгереп менү **2.** *«җибәрү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **взвыть** улап жибәрү; **вскри́кнуть** кычкырып жибәрү **3.** *«китү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **взбу́хнуть** бүртеп китү **4.** *«чыгу» яки «чыгару» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **вскипе́ть** кайнап чыгу; **вскипяти́ть** кайнатып чыгару

взад *нареч.*: **~ и вперёд** әрле-бирле; артка-алга; **ни ~ ни вперёд** артка да алга да юк

взаи́мность *ж* кара-каршы мәхәббәт, кара-каршы дуслык, кара-каршы хис; **отвеча́ть ~ю** мәхәббәткә каршы мәхәббәт белән жавап бирү

взаи́мн||ый, -ая, -ое (*обоюдный*) үзара; кара-каршы, бердәмләшеп ..., үзара уртак; (*проявляющийся по отношению друг к другу*) ике якның ...; ике яклы, бер-беренә ...; **~ая по́мощь** үзара ярдәм; **~ая любо́вь** кара-каршы мәхәббәт; **~ое дове́рие** бер-береңә ышану; **~ое согла́сие** ике якның да ризалыгы; **~ая оборо́на от агре́ссии** агрессиядән бердәмләшеп саклану ♦ **~ый зало́г** *грам.* уртаклык юнәлеше

взаимо- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, «үзара», «үзара уртак» дигән сүзләр белән тәрҗемә ителә, мәс.* **взаимовлия́ние** үзара йогынты, **взаимоотноше́ние** үзара мөнәсәбәт

взаимовлия́ние *с* үзара йогынты, үзара тәэсир

взаимоде́йствие *с* **1.** үзара йогынты ясау, үзара тәэсир итешү; үзара бәйләнеш; **~ спро́са и предложе́ния** сорауның һәм тәкъдимнең үзара бәйләнеше **2.** үзара ярдәм, үзара ярдәм итешү, үзара булышу; бердәм хәрәкәт; **~ пехо́ты и артилле́рии** пехота белән артиллериянең үзара ярдәм итешүе

взаимоде́йствие *несов.* үзара йогынты ясау, тәэсир итешү; үзара бәйләнештә булу; үзара ярдәм итешү; үзара булышу; бердәм хәрәкәт итү; **~ с партиза́нским отря́дом** партизаннар отряды белән бердәм хәрәкәт итү

взаимозави́симость *ж* үзара бәйлелек, бер-берена бәйлелек; **~ ме́жду промы́шленностью и се́льским хозя́йством** промышленность белән авыл хуҗалыгы арасында үзара бәйлелек

взаимоисключа́ющ||ий, -ая, -ее капма-каршы; бер-берсен инкарь итә торган; **~ие мне́ния** капма-каршы фикерләр

взаимообусло́вленность *ж* үзара бәйләнгәнлек, үзара шартлы бәйләнеш белән бәйләнгән булу

взаимоотноше́ни||е *с* үзара мөнәсәбәт; үзара бәйләнеш; бер-берена мөнәсәбәт; **норма́льные ~я** нормаль үзара мөнәсәбәтләр

взаимопо́мощ||ь *ж* үзара ярдәм, үзара булышу; бер-берена ярдәм итү, үзара ярдәмләшү; **ка́сса ~и** үзара ярдәмләшү кассасы; **до́говор о ~и** үзара ярдәмләшү шартнамәсе

взаимопонима́ни||е *с* үзара килешкәнлек, үзара аңлашканлык; үзара килешү, үзара аңлашу; **доби́ться ~я** үзара аңлашуга ирешү

взаимосвя́з||ь *ж* бәйләнеш, үзара бәйләнеш, үзара элемтә; **культу́рные ~и** мәдәният бәйләнешләре

взаймы́ *нареч.* әҗәткә, бурычка, көтәргә, үтечкә; **взять ~** бурычка алу

взаме́н 1. *нареч.* алмашка; **предложи́ть ~ свой план** алмашка үз планыңны тәкъдим итү 2. *предлог с род. п.* (*вместо*) алмашка, урынына; **~ э́той посу́ды** бу савыт урынына

взапе́рти *нареч.* бикләнеп, бикләнелгән хәлдә, бикләнүдә; **сиде́ть ~** бикләнеп утыру

взапра́вду *нареч. разг.* (*в самом деле*) чыннан да, чынлап та, чын-чыннан

взапу́ски *нареч. разг.* куышып, узышып; **бежа́ть ~** куышып йөгерү

взасо́с *нареч. разг.*: **целова́ться ~** суырып үбешү

взахлёб *нареч. прост.* йотлыга-йотлыга, йотлыгып; **расска́зывать ~** йотлыгып сөйләү

взя́шей, взя́шеи, взаше́и *нареч. прост.* җилкәсенә биреп, артына тибеп; **~ прогна́ть** җилкәсенә тондырып куып чыгару

взбад|ривать *несов. см.* **взбодри́ть**

взбад|риваться *несов.* 1. *см.* **взбодри́ться**; 2. *страд. от* **взбад|ривать**

взбаламу́тить *сов. разг.* 1. *что* (*жидкость*) болганчыкландыру, болганчыкка әйләндерү 2. *перен. кого-что* башын әйләндерү, болгату

взба́лмошный, -ая, -ое баламут, килделе-киттеле, дуамал

взба́лтывать *несов. см.* **взболта́ть**

взба́лтываться *несов.* 1. *см.* **взболта́ться**; 2. *страд. от* **взба́лтывать**

взбега́ть *несов. см.* **взбежа́ть**

взбежа́ть *сов.* йөгереп менү, йөгерешеп менү

взбелени́ть *сов. кого-что, прост.* бик каты ярсыту, шаштыру, шашындыру

взбелени́ться *сов. прост.* бик каты ярсу, шашу, шашыну, котырыну

взбеси́ть *сов. кого-что* бик каты ярсыту, шаштыру, шашындыру

взбеси́ться *сов.* 1. (*заболеть бешенством — о животных*) котыру 2. (*прийти в ярость*) тилерү, ярсу, котырыну, шашыну

взбива́ть *несов. см.* **взбить**

взбива́ться *несов.* 1. *см.* **взби́ться**; 2. *страд. от* **взбива́ть**

взбира́ться *несов. см.* **взобра́ться**

взбить *сов. что* 1. кабарту, күпертү, кабартып җибәрү, күпертеп җибәрү; **~ поду́шки** мендәрләрне кабарту 2. күпертү, туглап күбекләндерү, туглап күпертү; **~ сли́вки** каймакны күпертү

взби́||ться *сов.* 1. кабару, күперү; **~вшиеся во́лосы** кабарган чәчләр 2. (*вспениться*) күбекләнү, күперү (*туглаудан*)

взблеск *м* ялтырау, ялтырап китү

взбле́скивать *несов. см.* **взблесну́ть**

взблесну́||ть *сов. однокр.* ялтырап китү; **вдалеке́ ~ла мо́лния** еракта яшен ялтырап китте

взбодри́ть *сов. кого-что* дәртләндереп җибәрү, күңелен күтәреп җибәрү, рухландырып җибәрү

взбодри́ться *сов.* дәртләнеп китү, күңел күтәрелеп китү, рухланып китү

взболта́ть *сов. что* болгату, болгатып җибәрү

взболта́ться *сов.* (*о жидкости*) болгану

взбороздить *сов. что* буразналап бетерү (сызу, чыгу)

взборони́ть *сов. что* тырмалап бетерү (чыгу), тырмалау

взборонова́ть *сов. см.* **взборони́ть**

взбреда́ть *несов. см.* **взбрести́**

взбрести́ *сов. разг.* [барып] менү; **~ на́ гору** тауга менү ♦ **~ в го́лову (на ум)** башка килү, уйга килү

взбры́кивать *несов. см.* **взбрыкну́ть**

взбрыкну́ть *сов. однокр.* (*о животных*) тибеп җибәрү, тибү

взбудора́живать *несов. см.* **взбудора́жить**

взбудора́живаться *несов.* 1. *см.* **взбудора́житься**; 2. *страд. от* **взбудора́живать**

взбудора́жить *сов. кого-что разг.* ыгы-зыгы куптару, ыгы-зыгы китерү, аякка бастыру, борчу салу, ярсыту, ярсытып җибәрү; кузгату

взбудора́житься *сов. разг.* ыгы-зыгы кубу, ыгы-зыгы килү, аякка басу, ярсу, ярсып китү; кузгалу

взбунтова́ть *сов. кого-что* бунт күтәрү, бунтка өндәү, бунтка тарту, баш күтәрү

взбунтова́ться *сов.* бунт күтәрү, баш күтәрү; бунтка күтәрелү

взбуха́ть *несов. см.* **взбу́хнуть**

взбу́х||нуть *сов.* 1. бүртү, бүртенү, бүртеп китү, күбү, күбенү; **~шие зёрна** бүрткән бөртекләр 2. [ярларыннан] ташу, ташып чыгу; **~шая река́** ярларыннан ташып чыккан елга

взбу́чк||а *ж прост.* 1. (*побои*) кыйнау, бәргәләп алу, тукмау 2. (*выговор*) каты шелтә; шелтәләү, орышу, сүгү, әрләү; **дать ~у** каты шелтәләү

взва́ливать *несов. см.* **взвали́ть**

взвали́ть *сов. что* 1. китереп салу, салу, күтәртү; төяү; **~ мешо́к на́ спину** капчыкны аркага салу 2. *перен. разг.* (*поручить*) йөкләү, [эш] тагу; **~ рабо́ту на но́вого сотру́дника** яңа хезмәткәргә эш йөкләү 3. *перен. разг.* (*приписать кому-л. что-л. предосудительное*) аудару, сылтау, япсару; өстенә алу

взве́сить *сов.* 1. *кого-что* үлчәү, авырлыгын үлчәү; **~ мешо́к** капчыкның авырлыгын үлчәү 2. *перен. что* үлчәүгә салу, үлчәп карау, бизмәнгә салу, исәпкә алу; **~ все до́воды** барлык дәлилләрне үлчәүгә салу

взве́ситься *сов.* үлчәну, үзенен авырлыгын үлчәү

взвести́ *сов.* 1. *кого-что* (*ведя, помочь подняться*) күтәрү, өскә мендерү 2. *что на кого-что* аудару, ябу, сылтау, япсару, тагу, ягу; **~ клевету́** яла ягу ♦ **~ куро́к** курокны кору

взве́шивать *несов. см.* **взве́сить**

взве́шиваться *несов.* 1. *см.* **взве́ситься**; 2. *страд. от* **взве́шивать**

взвива́ть *несов. см.* **взвить**

взвива́ться *несов.* 1. *см.* **взви́ться**; 2. *страд. от* **взвива́ть**

взвизг *м разг.* чинау, чинау тавышы, чыелдау; чәрелдәү тавышы; сызгыру; **~ пу́ли** пуля сызгыруы

взви́згивать *несов.* чинау, чыелдау; чәрелдәү

взви́згнуть *сов. однокр.* чинау (чыелдап) җибәрү, чинап (чыелдап) кую; чәрелдәп җибәрү

взвинти́ть *сов. кого-что, разг.* каты ярсыту, нык дулкынландыру, кузгату; **~ не́рвы** нервларны кузгату ♦ **~ це́ны** бәяләрне нык күтәрү

взвинти́ться *сов.* ярсып китү, нык дулкынлану; кузгалу (*мәс. нервлар турында*)

взви́нчивать *несов. см.* **взвинти́ть**

взви́нчиваться *несов.* 1. *см.* **взви́нтиться**; 2. *страд. от* **взви́нчивать**

взви||ть *сов. что* күтәрү, өереп күтәрү; **ве́тер ~л пыль** җил тузанны өереп күтәрде

взви́ться *сов.* өскә күтәрелү, күтәрелеп китү

взви́хри||ть *сов. что* өермә итеп күтәрү, өереп күтәрү; **ве́тер ~л пыль** җил тузанны өермә итеп күтәрде

взвихри́ть *сов. что, разг.* (*волосы*) тузгыту, туздыру

взви́хриться *сов.* өермә булып күтәрелү, өерелеп күтәрелү

взвихри́ться *сов. разг.* (*о волосах*) тузгу, тузылу

взвод I *м* взвод; **пехо́тный ~** пехота взводы

взвод II *м спец.* (*часть затвора или замка*) взвод; **поста́вить куро́к на ~** курокны взводка кую ♦ **быть на ~е** кызмача булу

взводи́ть *несов. см.* **взвести́**

взводн||о́й, -а́я, -о́е *спец.* взвод ...ы; **~а́я пружи́на** взвод пружинасы

взво́дный, -ая, -ое 1. взвод ...ы; **~ командир** взвод камандиры 2. *в знач. сущ.* **~** *м* взводный, взвод командиры

взволно́ванность *ж* дулкынланганлык, тынычсызлык

взволно́ванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **взволнова́ть; 2.** (*встревоженный*) дулкынланган; борчулы, борчылган; **~ вид** дулкынланган кыяфәт **3.** (*выражающий волнение*) дулкынланган; **~ го́лос** дулкынланган тавыш

взволнова́ть *сов. прям., перен. кого-что* дулкынландыру; **~ изве́стием** хәбәр әйтеп дулкынландыру

взволнова́||ться *сов. прям., перен.* дулкынлану; **мо́ре ~лось** диңгез дулкынланды

взвыть *сов.* **1.** (*о животных*) чинап жибәрү, улап җибәрү **2.** *разг.* (*громко заплакать*) акырып елап жибәрү, үкереп елый башлау

взгляд *м* **1.** күз карашы, карау, күз; **при́стальный ~** төбәп карау; **ра́достный ~** шатлыклы күз карашы; **обмена́ться ~ами** күз ташлашып алу **2.** (*воззрение*) караш; фикер; **полити́ческие ~ы** политик карашлар; **пра́вильный ~** *на что-л.* дөрес караш ♦ **на ~** тыштан караганда; **на мой ~** минем карашымча (фикеремчә); **с пе́рвого ~а** *или* **на пе́рвый ~** беренче карашта (караштан) ук

взгля́дывать *несов. на кого-что* карап тору, күз төшергәләү (салгалау)

взгляну́ть *сов. на кого-что* **1.** (*посмотреть*) карап алу, күз салу (төшерү, ташлау) **2.** *перен.* (*обратить внимание*) карау, игътибар итү

взго́рье *с* калкулык, үр; **подня́ться на ~** үргә менү

взгреть *сов. кого-что, прост.* (*выругать*) шелтәләү, кыздыру, пешерү, нык әрләү; (*побить*) кыйнау, тукмау, пешерү, кирәген бирү

взгромажда́ть *несов. см.* **взгромозди́ть**

взгромажда́ться *несов.* **1.** *см.* **взгромозди́ться; 2.** *страд. от* **взгромажда́ть**

взгромозди́ть *сов. кого-что, разг.* мендерү, мендереп кую, күтәреп урнаштыру (*авырлык белән*); **~ ве́щи на маши́ну** әйберләрне машинага мендереп кую

взгромозди́ться *сов. на что разг.* менеп утыру, менеп урнашу

взгрустну́ть *сов.* эч пошып китү, күнелсезләнеп китү, ямансулау

взгрустну́ться *сов. безл.* эч пошып китү, күнелсезләнеп китү, кайгы төшү, ямансулау

вздва́ивать *несов. см.* **вздво́ить**

вздво́ить *сов. что:* **~ ряды́** сафларны икегә әйләндерү

вздво́ить *сов. что, с.-х.* (*вспахать вторично*) икенче кат сөрү, яңадан сөрү

вздво́иться *сов.* икегә тезелү, икегә әйләнү (*һәр саф*)

вздева́ть *несов. см.* **вздеть**

вздёргивать *несов. кого-что* тартып күтәргәләү, тартып мендергәләү

вздёрнутый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **вздёрнуть; 2.** төелмә; өскә караган; **~ нос** төелмә борын

вздёрнуть *сов. разг.* **1.** *что* тартып күтәрү (мендерү); өскә күтәрү **2.** *кого-что* (*повесить*) асу, асып үтерү ♦ **~ нос** борын күтәрү (*тәкәбберләну*); **~ плеча́ми** иңбашларны жысру (*аңлашылмауны, ризасызлыкны белдереп*)

вздёрнуться *сов. разг.* өскә күтәрелү; өскә тартылу

вздор *м разг.* юк-бар сүз, сафсата, мәгънәсез сүз; **моло́ть ~** юк-бар сүз сөйләү

вздо́рить *несов. разг.* (*ссориться*) талашу, ызгышу, ачуланышу, тиргәшү

вздо́рность *ж* мәгънәсезлек; ялган булу; нигезсезлек

вздо́рный, -ая, -ое **1.** мәгънәсез, буш, ялган, юк-бар ...; **~ слух** юк-бар хәбәр **2.** ызгышучан, талашучан; **~ челове́к** ызгышучан кеше

вздорожа́ть *сов.* кыйбатлану, кыйммәтләнү, хакы (бәясе) күтәрелү

вздох *м* көрсенү, тирән сулау

вздохну́ть *сов.* **1.** *однокр.* көрсенеп кую, тирән сулыш алу **2.** *разг.* (*передохнуть*) тын алу, ял итү, хәл алу; **дать лошаде́й ~** атларга хәл алырга мөмкинлек бирү ♦ **~ свобо́дно** тыныч-ланып калу, тынып калу (*берәр куркынычтан соң*)

вздра́гивать *несов.* калтырау, дерелдәү, тертләү, калтырап (дерелдәп, тертләп) тору

вздремну́ть *сов. разг.* черем итү (итеп алу)

вздро́гнуть *сов.* калтырап кую, сискәнеп китү; тертләп кую

вздува́ть *несов. см.* **вздуть**

вздува́ться *несов.* **1.** *см.* **вздува́ться; 2.** *страд. от* **вздува́ть**

вздума́||ть *сов. разг. с неопр.* кинәт уйлау, уйлап җибәрү, кинәт ...макчы булу, кинәт ...га булу ♦ **не ~й[те]** *с неопр.* уйлама да, башыңа да китермә, уена да китермә; ...сы булма[гыз]; **не ~й бежа́ть!** йөгерергә уйлама да!

вздума́||ться *сов. безл. разг.* уй башка килү, теләк уяну; кинәт бер уй килү; **~лось пойти́ в кино́** кинога бару уе башка килде

вздо́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **вздуть** I; **2.** (*распухший*) күбенгән **3.** *перен.* артык кабарган; артык күтәрелгән; **~ые це́ны** артык күтәрелгән бәяләр

вздо́||ть I *сов. что* **1.** [өреп] очыру, [өреп] очырып җибәрү; [өреп] күтәрү; **ве́тер ~л ли́стья к не́бу** җил яфракларны күккә очырды **2.** *безл.* (*сильно увеличить в объёме*) күптерү, кабарту; **~ло живо́т** эч күбенде **3.** *перен. разг.* артык күтәрү; күпертү; **~ть це́ны** бәяләрне артык күтәрү **4.** *прост.* (*зажечь*) кабызу, кабындыру, кабызып (кабындырып) җибәрү; **~ть ого́нь** ут кабызып җибәрү

вздуть II *сов. кого, прост.* (*побить*) тукмау, пешерү, кирәген бирү, кыйнап ташлау

вздо́||ться *сов. разг.* **1.** (*надуться*) кабару, кабарып китү, өрелеп кабару; **парусо́ ~ лись** җилкәннәр кабарды **2.** (*подняться выше обычного*) күтәрелү, күтәрелеп китү; **река́ ~лась** елга күтәрелде **3.** (*вспухнуть*) күбү, кабару, кабарып чыгу, күбеп чыгу, шешеп чыгу; **щека́ ~лась** яңак шешеп чыкты **4.** *перен.* артык күтәрелү, ныкүтәрелү; **це́ны ~лись** бәяләр нык күтәрелде

вздыбить *сов. кого* арт аягына бастыру, үрә торгызу (*атны*)

вздыбиться *сов.* арт аягына басу, үрә тору (*ат турында*)

вздыма́ть *несов. что* күтәрү, кубару, туздыру; **~ пыль** тузан күтәрү

вздыма́||ться *несов.* күтәрелү, кубу, тузылу; **пыль ~лась от ве́тра** җилдән тузан купты

вздыха́тель *м шутл.* мәгъшук, гыйшык тотучы, яратып йөрүче

вздыха́ть *несов.* **1.** көрсенү, авыр сулау, уфылдау; **тяжело́ ~** авыр көрсенү **2.** *по ком-чём, о ком-чём* (*тосковать*) сагыну, юксыну, ямансулау **3.** *по ком, разг.* (*быть влюблённым*) яратып йөрү, ярату, гыйшык тоту, мәхәббәт утында яну

взима́ть *несов. что* (*взыскивать*) түләтү, алу, җыю (*мәс. налогны*)

взира́ть *несов. на кого-что* карау, карап тору

взла́мывать *несов. см.* **взлома́ть**

взлеле́ять *сов. кого-что* кадерләп үстерү, назлап үстерү

взлёт *м* **1.** *см.* **взлете́ть; во вре́мя ~а** очып күтәрелгәндә **2.** *перен.* күтәрелеш; **~ нау́чного тво́рчества** фәнни иҗат күтәрелеше

взлета́ть *несов. см.* **взлете́ть**

взлете́ть *сов.* **1.** (*подняться в воздух*) очып күтәрелү (менү); һавага күтәрелү **2.** *разг.* атылып менү, йөгереп менеп китү; **~ на ле́стницу** баскычка атылып менү ♦ **~ на во́здух** (*взорваться, разрушиться*) көле күккә очу, шартлау

взлётн||ый, -ая, -ое очып менү ...ы, очып күтәрелү ...ы; очып күтәрелү өчен; **~ая доро́жка** очып күтәрелү юлы

взлом *м см.* **взлома́ть; ~ замка́** йозакны ватып ачу

взлома́ть *сов. что* **1.** ватып ачу, ватау; актарып ташлау; **~ замо́к** йозакны ватып ачу; **~ пол** идәнне актарып ташлау **2.** *перен.* җимерү, җимереп (ватып) ташлау; **~ оборо́ну проти́вника** дошман оборонасын җимерү

взло́мщик *м* ватып ачып талаучы (талап чыгучы)

взлохма́тить *сов. что* тузгыту, тырпайту, тузгытып (тырпайтып) бетерү; **~ во́лосы** чәчне тузгытып бетерү

взлохмати́||ться *сов.* тузгу, тырпаю, тузгып (тырпаеп) бетү; **во́лосы ~лись** чәче тузгып беткән

взлу́щить *сов. что* лущить итү, лушилкалау

взмах *м см.* **взмахну́ть, взма́хивать**

взма́хивать *несов. чем* селтәү, айкау, болгау, селтәнү; җилпү, кагу (*канатларны*)

взмахну́ть *сов. однокр. чем* селтәнү, селтәп җибәрү, айкап җибәрү, селтәп кую; җилпеп җибәрү; **~ кры́льями** канатларын җилпеп җибәрү

взмести́ *сов. что* (*вскинуть вверх*) күтәрү, өскә ташлау

взмёт *м* **1.** *см.* **взмета́ть** I 1, **взмету́ть**; ~ **пла́мени** ялкынның өскә күтәрелүе **2.** *с.-х.* күтәрү, сөрү (*береңче кат*); ~ **зя́би** тунга сөрү; ~ **па́ра** пар күтәрү

взмета́ть *сов. что* **1.** (*подбросить*) өскә ташлау, актарып ташлау, күтәрү; туздыру **2.** *с.-х.* (*распахать*) сөрү, күтәрү; ~ **пар** пар күтәрү

взмета́ть II *несов. см.* **взмести́, взмету́ть**

взмету́||ть *сов. однокр.* **1.** *кого-что* актарып ташлау, өскә ташлау, күтәрү; **взрыв ми́ны** ~**л зе́млю** мина шартлавы җирне актарып ташлады **2.** *чем* (*взмахнуть*) чәеп җибәрү, селтәп җибәрү, жилпеп җибәрү

взмету́||ться *сов.* **1.** кинәт күтәрелү, атылып менү, атылу; **раке́та** ~**лась к не́бу** ракета һавага атылды **2.** (*стремительно вскочить*) сикереп тору, атылып тору; **во́лки** ~**лись** бүреләр сикереп тордылар

взмётывать *несов. см.* **взмета́ть** I

взмётываться *несов.* **1.** *см.* **взмету́ться**; **2.** *страд. от* **взмётывать**

взмоли́ться *сов.* ялынып сорау, инәлеп сорау, ялына башлау, ялвара башлау; ~ **о прощéнии** гафу итүне ялынып сорау

взмо́рье *с* диңгез буе (яры); **жить на** ~ диңгез буенда яшәү

взмути́ть *сов. что* болганчыклау, болганчыкландыру (*суны һ.б.ш.*)

взмути́ться *сов.* болганчыклану

взмыва́ть *несов. см.* **взмыть**

взмы́ленный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **взмы́лить**; **2.** (*о лошади*) ак күбеккә баткан (төшкән)

взмы́ливать *несов. см.* **взмы́лить**

взмы́лить *сов. кого* ак күбеккә батыру (төшерү); ~ **ло́шадь** атны ак күбеккә батыру

взмыть *сов.* (*быстро взлететь*) очып менү (менеп китү), очып күтәрелү (күтәрелеп китү); атылып менү

взнос *м* **1.** түләү, акча түләү; **сро́чный** ~ ашыгыч рәвештә түләү **2.** взнос; түләм; **чле́нские** ~**ы** членлык взнослары

взнузда́ть *сов. кого* авызлыклау, авызлык кидерү; ~ **коня́** атны авызлыклау

взну́здывать *несов. см.* **взнузда́ть**

взобра́ться *сов.* менү, менеп җитү (*авырлык белән, тырышып-тырмашып*)

взойти́ *сов.* **1.** атлап менү, менү, менеп җитү; күтәрелү; ~ **на крыльцо́** болдырга атлап менү **2.** (*о небесных светилах*) чыгу, калкү; **со́лнце взошло́** кояш чыкты **3.** *разг.* (*о тесте*) кабару, кабарып чыгу; күтәрелү **4.** шытып чыгу, шыту; үсеп чыгу; **пшени́ца взошла́** бодай шытып чыкты

взор *м* **1.** күз карашы, караш, күз төбәү, күз төкәү; карау; **устреми́ть** ~ күз карашын төбәү **2.** *обычно мн.* ~**ы** *перен.* (*внимание, интерес*) игътибар, дикъкать, кызыксыну; ~**ы многи́х бы́ли прико́ваны к э́тим собы́тиям** күпләрнең дикъкате бу вакыйгаларга юнәлгән иде

взорва́||ть *сов.* **1.** *что* шартлату, шартлатып күтәртү (җимерү); ~**ть мост** күперне шартлатып күтәртү **2.** *перен. кого, разг.* чыгырдан чыгару, шартлар хәлгә җиткерү, шартлый язу, бик нык ачуландыру; **его́ слова́** ~**ли меня́** аның сүзләре мине чыгырдан чыгардылар

взорва́||ться *сов.* **1.** шартлау, шартлап ярылу; **грана́та** ~**лась** граната шартлады **2.** *перен. разг.* (*возмутиться*) чыгырдан чыгу, шартлар хәлгә җитү, шартлый язу, бик нык ачулану

взрасти́ть *сов. кого-что, высок.* (*вырастить*) тәрбияләп үстерү, карап үстерү

взра́щивать *несов. см.* **взрасти́ть**

взрове́||ть *сов.* **1.** (*внезапно издать рёв*) үкереп (акырып) җибәрү; **медве́дь** ~**л** аю акырып җибәрде **2.** (*о моторе*) үкерү, үкерә башлау

взрез *м* **1.** *см.* **взре́зать**; **2.** (*место*) киселгән урын, кисек, кискән урын

взре́зать *сов. что* ярып җибәрү, кисү, кисеп җибәрү (ачу); ~ **брю́хо ры́бы** балыкның эчен ярып җибәрү

взреза́ть *несов. см.* **взре́зать**

взросле́ть *несов.* бәлигъ булу, буйга җитү, зурга әйләнү, зураю; үсеп җитү

взро́сл||ый -ая, -ое **1.** бәлигъ булган, буйга җиткән, үсеп җиткән, җиткән, зур, өлкән; ~**ый ю́ноша** җиткән егет **2.** *в знач. сущ.* ~**ые** *мн.* зурлар, өлкәннәр, олылар; **фильм для** ~**ых** зурлар өчен булган фильм

взрыв *м* **1.** шартлау, шартлап ярылу; шартлау тавышы; ~ **бо́мбы** бомба шартлавы **2.** (*разрушение*) шартлату, шартлатып җимерү, шартлатып күтәртү; ~ **вра́жеского корабля́** дошман кораблен шартлату; ~ **моста́** күперне шартлатып күтәртү ♦ ~ **аплодисме́нтов** көчле (бик каты) кул чабулар; ~ **зло́бы** бик каты ачулану; ~ **не́нависти** чиктән тыш нәфрәт күрсәтү; ~ **сме́ха** кинәт кычкырып көлү

взрыва́тель *м* шартлаткыч (*гранатада, минада, снарядта һ.б.ш.*)

взрыва́ть I *несов. см.* **взорва́ть**

взрыва́ть II *несов. см.* **взрыть**

взрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **взорва́ться**; **2.** *страд. от* **взрыва́ть** I

взрывни́к *м разг.* шартлатучы, шартлату белгече

взрывн||о́й, -а́я, -о́е **1.** шартлау ...ы, шартлату ...ы; шартлаулы; шартлый торган; ~**ы́е рабо́ты** шартлату эшләре; ~**а́я волна́** шартлау дулкыны; ~**о́й снаря́д** шартлаулы снаряд **2.** *лингв.* шартлаулы; ~**о́й звук** шартлаулы аваз

взрывоопа́сн||ый, -ая, -ое шартлау куркынычы булган, шартлавы мөмкин булган; вакыйгалар кискен үзгәрү куркынычы булган; ~**ая ситуа́ция** выкыйгалар кискен үзгәрү куркынычы булган ситуация

взрывча́тка *ж разг.* шартлаткыч, шартлаткыч матдә

взры́вчат||ый, -ая, -ое шартлый торган, шартлаучан; ~**ые вещества́** шартлаучан матдәләр

взрыть *сов. что* казу, казып бетерү (чыгу), казып йомшарту; ~ **зе́млю** җирне казып йомшарту

взрыхли́ть *сов. что* казып бетерү, казып чыгу, казып йомшарту, көпшәкләндерү (*казып*); ~ **гря́дку** түтәлне казып көпшәкләндерү

взрыхля́ть *несов. см.* **взрыхли́ть**

взъерепе́ниться *сов. прост.* ачуланып киреләнү, ачуланып тискәреләнү, кәҗәләнү

взъеро́шенн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** *прич. от* **взъеро́шить**; **2.** тузгыган, тузылган; тырпайган; ~**ые во́лосы** тырпайган чәч **3.** тырпайган (тузгыган) чәчле; тузгыган йонлы; ~**ый медве́дь** тузгыган йонлы аю

взъеро́шивать *несов. см.* **взъеро́шить**

взъеро́шить *сов. что, разг.* тузгыту, тырпайту, кабарту; ~ **во́лосы** чәчне тырпайту

взъеро́ши||ться *сов. разг.* тузгу, тырпаю, кабару; **усы́** ~**лись** мыеклары тырпайган

взъе́сться *сов. на кого-что, разг.* каныгу, ябышу, колак итен ашарга тотыну

взыва́ть *несов.* **1.** (*громко кричать, звать*) кычкырырга (чакырырга) тотыну (*кешеләрне*) **2.** *к кому-чему, о чём* (*призывать*) өндәү, чакыру; ~ **к справедли́вости** гаделлеккә өндәү

взыгра́||ть *сов.* **1.** дулый башлау, котырына башлау; **мо́ре** ~**ло** диңгез котырына башлады **2.** (*разыграться*) күңел уйный башлау, күңел күтәрелү, кәефләнү ♦ ~**ла душа́** *или* ~**ло се́рдце** күңел күтәрелеп китте

взыска́ние *с* **1.** *см.* **взыска́ть** I; **2.** *офиц.* (*взысканные деньги*) түләтелгән акча **3.** (*наказание*) җәза, шелтә; **дисциплина́рное** ~ дисциплинар җәза

взыска́тельный, -ая, -ое таләпчән, таләп итүчән; ~ **челове́к** таләпчән кеше

взыска́ть *сов.* **1.** *что с кого* түләтү, түләттерү; ~ **долг** бурычны түләтү; ~ **штраф** штраф түләтү **2.** *с кого за что* (*привлечь к ответственности*) жавапка тарту, шелтәләү ♦ **не взыщи́[те]** гаеп итмә[гез], гаеп итмә[гез] инде

взы́скивать *несов. см.* **взыска́ть**

взя́т||ка *ж* **1.** ришвәт **2.** взятка (*кәрт уенында*) ♦ ~**и гла́дки** *с кого* аңардан сорап та торасы юк, барыбер ала алмассың

взя́ток *м пчел.* табыш (*бал кортларының билгеле бер вакытта җыйган балы*)

взя́точник *м* ришвәтче, ришвәт алучы

взя́точница *ж* ришвәтче хатын (кыз)

взя́точничество *с* ришвәтчелек, ришвәт алу

взять *сов.* **1.** *кого-что* алу; ~ **де́ньги** акча алу; ~ **па́лку** таяк алу **2.** *кого-что* (*нанять*) яллау, алу; ~ **такси́** такси алу **3.** *что* (*купить*) алу, сатып алу; ~ **биле́т** билет алу **4.** *кого-что* (*арестовать*) кулга алу; ~ **престу́пника** жинаятьчене кулга алу **5.** *чем* алдыру; ~ **сме́лостью** кыюлык белән алдыру **6.** (*с союзами «да», «и», «да и»*) тоту; **возьми́ да скажи́** тот та әйт; ~ **да пое́хать** тотарга да

китәргә; **возьми́те да купи́те** тотыгыз да алыгыз (*сатып*) ♦ ~ **быка́ за рога́** үгезне мөгезеннән алу (*кыю эш итү*); ~ **верх** өстен чыгу, өскә чыгу, җиңү; ~ **в толк** аңлау; ~ **себя́ в ру́ки** үзеңне кулга алу; ~ **за го́рло** бугазыннан алу; ~ **за́ душу (се́рдце)** күңелне нечкәртү; ~ **приме́р** *с кого* мисал алу *кемнән*; ~ **под своё крыло́** үз канаты астына алу; **с чего́ ты взял?** каян алдың? кем әйтте сиңа бу сүзне

взя́ться *сов.* **1.** *за кого-что* (*хвататься*) тотыну **2.** *за что* башлау, керешү, тотыну; ~ **за рабо́ту** эшкә тотыну **3.** *за что и с неопр.* алыну, булу; ~ **помо́чь** ярдәм итәргә алыну **4.** (*появиться*) килеп чыгу; **отку́да ты взя́лся?** каян килеп чыктың ♦ ~ **за у́м** акылга утыру, акыл керү; **отку́да ни возьми́сь** уйламаганда, көтмәгәндә

виадýк *м* виадук (*чокыр аркылы, тимер юл өстеннән үтү өчен күпер*)

вибра́тор *м тех.* вибратор (*тирбәнешләр хасил итүче әсбап*)

вибра́ция *ж* вибрация, тирбәнеш; калтырау; ~ **мото́ра** моторның вибрациясе

вибрио́н *м* вибрион (*бактерия*)

вибри́ровать *несов.* тибрәнү, калтырау, вибрация ясау

вива́рий *м* виварий (*тәжрибә хайваннарын асрау өчен бина*)

вивисе́кция *ж* вивисекция, тереләй яру (*организмның бераз әгъзасының функциясен өйрәнү өчен аңа операция ясау*)

вигва́м *м* вигвам (*индеецларның чыбык-чабыклардан яки тиредән ясалган куышы*)

вигóневый, -ая, -ое вигонь ...ы; вигонь ..., вигоньнан ясалган

вигóнь *ж* вигонь (*тукыма*)

вид I *м* **1.** күренеш; ~ **ле́са издалека́** урманның еракта күренеше; ~**ы Пами́ра** Памир күренешләре **2.** кыяфәт; чырай; килбәт, килеш-килбәт; **больно́й** ~ авыру кыяфәт; **здоро́вый** ~ таза кыяфәт; **смешно́й** ~ көлкеле кыяфәт **3.** килеш; **в испра́вленном** ~**е** төзәтелгән килеш; **в пья́ном** ~**е** исерек килеш **4.** күз алды; **скры́ться из́ ~у** күз алдыннан югалу **5.** *мн.* ~**ы** ният, теләк, исәп, план; ~**ы на бу́дущее** киләчәккә исәп ♦ ~ **на жи́тельство** *уст.* паспорт, тору кәгазе; **для** ~**а** күз буяу өчен; **на** ~**, по** ~**у, с** ~**у** тыштап караганда; **под** ~**ом** *кого* ... дигән булып, ... дигән сылтау белән, ...га салынып; **вида́вший** ~**ы** күпне күргән, ачысын-төчесен татыган; **име́ть** ~**ы** *на кого-что* исәп тоту, ният тоту; **де́лать** ~ ...мәмешкә салыну; ...мәмешкә салышу; **ни под каки́м** ~**ом** һичничек, һичбер хәлдә; **поста́вить на** ~ *что кому* жиңелчә шелтә бирү; **упусти́ть из** ~**у** күздән очыру, оныту

вид II *м в разн. знач.* төр; ~**ы расте́ний** үсемлекләр төрләре; **катего́рия** ~**а глаго́лов** фигыльләрнең төр категориясе

вида́ть I *несов. кого-что* күрү; **мно́го про́жито, мно́го ви́дано** күп яшәлгән, күп күрелгән

вида́ть II *несов. разг.* **1.** *в знач. сказ. безл.* күреп булу, күренү; **пароха́да не** ~ пароход күренми **2.** *в знач. вводн. сл.* күрәсең, мәгаен, ахры

вида́ться *несов. см.* **ви́деться** I

ви́дение *с* күрү, күреп булу; күрү сәләте; ~ **на расстоя́нии** еракта күреп булу

виде́ние *с* (*призрак*) өрәк, шәүлә

видеоза́пись *ж* видеоязма

видеомагнитофо́н *м* видеомагнитофон

видеотелефо́н *м* видеотелефон

ви́д||еть *несов.* **1.** кого-*что* күрү; **хорошо́** ~**еть** яхшы күрү; ~**еть собстве́нными гла́зами** үз күзең белән күрү; **мно́го** ~**еть в жи́зни** тормышта күпне күрү **2.** *что* күрү, аңлау; сизү; ~**еть свою́ оши́бку** үзеңнең хатаңны күрү ♦ ~**ить (**~**ите) ли** *в знач. вводн. сл.* күрәсеңме, күрәсезме; беләсеңме, беләсезме; ~**еть на два арши́на под землёй** ≈ җир астында елан кыймылдаганны да сизү; ~**еть насквозь** *кого кемне дә булса* үтәдән үтә күрү; ~**еть не могу́** күрәсем дә килми; **как** ~**ите** *в знач. вводн. сл.* күргәнегезчә, күренгәнчә; **не** ~**еть све́та** якты дөнья күрмәү; **то́лько и** ~**ели** *кого* койрыгын гына күреп калдылар

ви́де||ться *несов.* **1.** *с кем-чем и без доп.* очрашу, күрешү; ~**ться с това́рищами** иптәшләр белән очрашу **2.** (*представляться воображению*) күренү; сизелү; керү; төшкә керү; **мне** ~**лось во сне́** минем төшемә керде

ви́димо *нареч. в знач. вводн. сл.* күрәсең, ахры, мәгаен, булса кирәк; **он,** ~**, не зна́ет э́того** ул, күрәсең, моны белми

ви́димо-неви́димо *нареч. разг.* иксез-чиксез, чиксез күп, хисапсыз күп, исәпсез-хисапсыз; **наро́ду бы́ло** ~ халык чиксез күп иде

ви́димост||ь *ж* **1.** күрү мөмкинлеге, күренүчәнлек; **хоро́шая** ~**ь** яхшы күренүчәнлек; **в я́сную пого́ду** ~**ь лу́чше** аяз көнне күрү мөмкиелеге яхшырак **2.** *разг.* тышкы кыяфәт, тышкы күренеш; **оста́лась одна́** ~**ь** бары тышкы кыяфәте генә калган; **для** ~**и** күз буяу өчен ♦ **по [всей]** ~**и** *в знач. вводн. сл.* мәгаен, күрәсең

ви́дим||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **ви́деть; 2.** күренә торган; күренүчән; ~**ые лучи́** күренә торган нурлар **3.** күзгә бәрелеп торган, күзгә ташланып торган, күренеп торган; ~**ая ра́зница в во́зрасте** яшьтәге күзгә бәрелеп торган аерма **4.** тышкы яктан, тышкы; э́тот успе́х то́лько ~**ый** бу бары тышкы яктан гына уңыш

видне́||ться *несов.* күренү, күренеп тору; **вдали́** ~**лся лес** еракта урман күренеп тора иде

ви́дно 1. *в знач. сказ. безл.* күренә, күренеп тора; **следа́ не** ~ эзе күренми **2.** *в знач. вводн. сл.* күрәсең, булса кирәк, ахрысы, мәгаен; ~ **, придётся уе́хать** китәргә туры килер, күрәсең

ви́дный, -ая, -ое **1.** күренә торган; **дом ви́ден издалека́** өй еракта күренә **2.** күренекле, зур; ~ **де́ятель нау́ки** фәннең күренекле эшлеклесе **3.** мәһабәт, мәһабәт гәүдәле; ~ **мужчи́на** мәһабәт гәүдәле ир кеше

***ви́дный** *рус телендәге кушма сүзләрәнең икенче кисәге «сыман» дигән сүз белән тәрҗемә ителә, мәс.* **шарови́дный** шарсыман; **конусови́дный** конуссыман

видов||о́й I, -а́я, -о́е **1.** *спец.* төр ...ы; ~**ые при́знаки** төр билгеләре **2.** *лингв.* төр ...ы, төр ягыннан; ~**ые па́ры глаго́лов** фигыльләрнең төр ягыннан парлары

видово́й II, -а́я, -о́е: ~ **фильм** табигать күренешләре турындагы фильм

видоизмене́ние *с* **1.** үзгәреш, үзгәрү; ~ **расте́ний** үсемлекләрнең үзгәрешләре **2.** (*разновидность*) төр, үзгәртелгән төр, вариант; **плуг — усоверше́нствованное** ~ **сохи́** сабан — суканың камилләштерелгән бер төре

видоизмени́ть *сов. что* үзгәртү, үзгәреш кертү, төрләндерү

видоизмени́||ться *сов.* үзгәрү, үзгәреш керү; төрләнү; ~**вшиеся фо́рмы расте́ний** үсемлекләрнең үзгәргән формалары

видоизменя́ть *несов. см.* **видоизмени́ть**

видоизменя́ться *несов.* **1.** *см.* **видоизмени́ться; 2.** *страд. от* **видоизменя́ть**

видоиска́тель *м опт.* күренеш эзләгеч, объект эзләгеч

видообразова́ни||е *с биол.* төрләр барлыкка килү, төрләр хасил булу; **тео́рия** ~**я** төрләр хасил булу теориясе

ви́дывать *несов.* күргәләү, күргән булу

ви́за *ж* **1.** виза (*гаризада, документта һ.б.ш.*) **2.** виза, рөхсәт (*берәр дәүләткә килу яки чыгу өчен хөкүмәт тарафыннан паспортка мөһер сугып бирелгән рөхсәт*); **транзи́тная** ~ транзит виза

визави́ **1.** *нареч.* икәүдән-икәү, каракаршы, йөзгә-йөз; **сиде́ть** ~ каракаршы утыру **2.** *м, ж нескл.* каршыдаш, каршыда утыручы кеше; **мой** ~ минем каршыда утыручы кеше

визг *м* чинау, чыелдау, чәрелдәү, чинау (чыелдау, чәрелдәү) тавышы; сызгыру, ачы тывыш; ~ **соба́ки** эт чинавы; ~ **пу́ли** пуля сызгыруы

визгли́вый, -ая, -ое чыелдык, чәрелдек, чинаучан; ~ **го́лос** чәрелдек тавыш; ~ **поросёнок** чыелдык дуңгыз баласы

визж||а́ть *несов.* чинау, чәрелдәү, чыр-чулашу, чыелдау; **соба́ка** ~**ит** эт чиный

визи́га *ж* сырт сөнәре, визига (*мәрсин балыгында*)

визи́р *м* **1.** *см.* **видоиска́тель; 2.** *воен.* визир (*прицел детале*)

визи́рование I *с см.* **визи́ровать I**

визи́рование II *с см.* **визи́ровать II**

визи́ровать I *сов., несов. что* виза салу, виза салдыру (*паспортка, гаризага, документка*)

визи́ровать II *сов. несов. что* визирлау (*теодолит һ.б.ш. ярдәменә карау сызыгын билгеле бер ноктага төбәү*)

визи́рь *м* вәзир

визи́т *м* **1.** визит; **нанести́** ~ визит ясау **2.** визит, табиб баруы (килүе) (*авыру янына өйгә*)

ВИЗ-ВИС

визи́тн||ый, -ая, -ое: **~ая ка́рточка** визит карточкасы (*берәр кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме язылган һәм адресы күрсәтелгән карточка, танышканда бирелә*)

визуа́льн||ый, -ая, -ое визуаль, турыдан-туры күреп (*оптик прибор ярдәмендә яки күз белән*); **~ые наблюде́ния** визуаль күзәтүләр

ви́ка *ж бот.* кәрешкә, вика

вико́нт *м* виконт (*Франциядә, Англиядә һ.б.ш. кайбер илләрдә графлык белән баронлык арасындагы титул һәм шул титулны йөрткән дворян*)

виконте́сса *ж* виконт хатыны (кызы)

викто́рина *ж* викторина; **литерату́рная ~** әдәби викторина; **музыка́льная ~** музыкаль викторина

ви́лк||а *ж* **1.** чәнечке **2.** *тех.* вилка; **ште́псельная ~я** штепсель вилкасы **3.** *воен.* вилка (*снарядларның цельгә барып җитмәүләре һәм аннан узып китүләре арасындагы урын*); **взять в ~у** вилкага алу **4.** *шахм.* вилка, сәнәк

ви́лла *ж* вилла (*шәһәрдән читтәге бай, зиннәтле дача яки аерым йорт*)

вило́к *м разг.* кәбестә күчәне, бер баш кәбестә

вилообра́зный, -ая, -ое сәнәксыман; **~ язычо́к змеи́** еланның сәнәксыман теле

ви́л||ы *только мн.* сәнәк ◆ **~ами на воде́ (по воде́) пи́сано** суга сәнәк белән язылган, бозга язган

вильну́ть *сов.* **1.** *однокр. чем* болгап кую, селтәп кую; **~ хвосто́м** койрыкны болгап кую **2.** (*в сторону*) тайпылу, [читкә] ташлану **3.** (*повернуть — о дороге, реке*) кинәт борылу, тайпылу

виля́||ть *несов.* **1.** *чем* болгау, селтәү; **соба́ка ~ет хвосто́м** эт койрыгын болгый **2.** *разг.* (*поворачивать*) бормаланып-бормаланып китү, бормаланып-бормаланып бару (*юл турында*); бормаланып-бормаланып агу, бормалана-бормалана агу (*елга турында*) **3.** *перен.* (*лукавить*) койрык болгау, хәйләләү, туры жаваптан баш тарту ◆ **~ть хвосто́м** койрык болгау

вин||а́ *ж* **1.** гаеп; **~а престу́пника** жинаятьченең гаебе **2.** (*причина*) сәбәп; **~ой э́тому явля́ется уста́лость** моның сәбәбе — арыганлык

винегре́т *м* **1.** винегрет **2.** *разг.* боламык, винегрет (*җыен юк-бар*)

вини́тельный, -ая, -ое: **~ паде́ж** *грам.* төшем килеше

вини́ть *несов. кого-что* гаеплӛу, гаеп ташлау, гаепле санау; **~ други́х** башкаларны гаепле санау

ви́нн||ый, -ая, -ое шәраб ...ы; **~ый за́пах** шәраб исе; **~ая буты́лка** шәраб шешәсе; **~ая я́года** инжир; **~ый ка́мень** шәраб ташы

вино́ *с* шәраб, кызыл аракы

винова́тый, -ая, -ое **1.** (*виновный*) гаепле **2.** (*являющийся причиной*) сәбәһ булып торган ◆ **винова́т** гафу итегез

вино́вник *м* **1.** гаепле кеше, гаепле; **~ преступле́ния** жинаятьнең гаепле кешесе **2.** сәбәпче; **~ торжества́** тантананың сәбәпчесе

вино́вница *ж* **1.** гаепле хатын (кыз) **2.** (*являющаяся причиной чего-л.*) сәбәпче хатын (кыз)

вино́вность *ж* (*наличие вины*) гаеплелек, гаепле булу

вино́вн||ый, -ая, -ое **1.** гаепле; **~ые ли́ца** гаепле кешеләр **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м,* **~ая** *ж* гаепле, гаепле кеше; **~ый созна́лся** гаепле гаебен таныды

виногра́д *м* виноград, йөзем (*куагы һәм җимеше*)

виногра́дарск||ий, -ая, -ое виноградчылык ...ы; виноградчы ...ы; **~ая брига́да** виноградчылык бригадасы

виногра́дарство *с* **1.** (*разведение винограда*) виноградчылык, йөзем үстерүчелек, виноград (йөзем) үстерү **2.** (*наука*) виноград (йөзем) үстерү фәне

виногра́дарь *м* виноградчы, виноград (йөзем) үстерүче

виногра́дина *ж разг.* бер виноград, бер йөзем (*җимеш*)

виногра́дник *м* виноград (йөзем) бакчасы

виногра́дн||ый, -ая, -ое **1.** виноград ...ы, йөзем ...ы; **~ая лоза́** виноград чыбыгы **2.** виноград ...ы, виноградтан ясалган; **~ый спирт** виноград спирты

виноде́л *м* шәрабчы, шәраб ясаучы

виноде́лие *с* шәраб хәзерләү (эшләү, ясау)

винодельческий, -ая, -ое шәраб хәзерләү ...ы, шәраб эшләү ...ы; шәраб ясау ...ы; **~ совхо́з** шәраб хәзерләү совхозы

винокýр *м* аракы куучы (ясаучы)

винокуре́ние *с* аракы куу (ясау)

виноку́ренный, -ая, -ое аракы куу ...ы, аракы ясау ...ы; **~ заво́д** аракы куу заводы

виноторго́вец *м* шәрабчы, шәраб сатучы

виноторго́вля *ж* шәраб сату

виноче́рпий *м уст.* көрәгәче, шәраб коючы

винт I *м* **1.** шөреп, винт; **голо́вка ~а́** шөрепнең башы **2.** винт (*самолёт һәм судноларда*) **3.** *в знач. нареч.* **~о́м** бөтерелеп; бормаланып; **дым поднима́ется ~о́м** төтен бөтерелеп күтәрелә

винт II *м* винт (*кәрт уены*)

ви́нтик *м уменьш.* от винт I 1; шөрепчек

винти́ть *несов. что, разг.* борып кертү, бора-бора кертү; борып чыгару, бора-бора чыгару

винтова́льный -ая, -ое *см.* **винторе́зный**

винто́вка *ж* винтовка (*сырлы көпшәле мылтык*)

винтов||о́й, -а́я, -о́е **1.** винт ...ы, шөреп ...ы; **~а́я наре́зка** винт сыры **2.** винтлы; **~о́й парохо́д** винтлы пароход

винто́вочный, -ая, -ое винтовка ...ы, винтовкадан ...; **~ патро́н** винтовка патроны; **~ вы́стрел** винтовкадан ату

винтомото́рн||ый, -ая, -ое винтлы, винт моторлы (*очкыч аппаратлар турында*); **~ые и реакти́вные самолёты** винтлы һәм реактив самолётлар

винтообра́зн||ый, -ая, -ое винтсыман, сырлы; **~ая ле́стница** винтсыман баскыч

винторе́зный, -ая, -ое винт сыры ясый торган, винт сыры кыру ...ы; сыр ясый торган; **~ стано́к** винт сыры кыру станогы

винче́стер *м* винчестер (*ау мылтыгы*)

винье́тка *ж* виньетка (*китапның, булекнең ахырында яисә башында орнаменттан, рәсемнән гыйбарәт бизәк*)

вио́ла *ж муз.* виола (*зур скрипкага охшаган кыллы инструмент*)

виолончели́ст *м* виолончельче, виолончельдә уйнаучы

виолончели́стка *ж* виолончельче хатын (кыз)

виолонче́ль *ж* виолончель

ви́ра *межд.* вира, үргә

вира́ж I *м* **1.** вираж (*самолётның, автомобильнең һ.б.ш. кәкре сызык буенча хәрәкәте, борылуы*) **2.** вираж, борылма (*спорт юлының эчкә таба янтаеп борылган урыны*)

вира́ж II *м фото* вираж (*билгеле бер төс биру өчен басылган фоторәсемне юдыра торган химик эремә*)

виртуо́з *м* виртуоз, зур оста

виртуо́зность *ж* виртуозлык, зур осталык

виртуо́зн||ый, -ая, -ое виртуоз ..., виртуозларча ..., бик оста ...; **~ое испо́лнение** виртуозларча башкару; **~ая лётная те́хника** виртуоз очу техникасы

ви́рус *м* вирус; **~ гри́ппа** грипп вирусы

ви́русн||ый, -ая, -ое **1.** вирус ...ы; **~ые боле́зни** вирус авырулары **2.** вируслы; **~ая эму́льсия** вируслы эмульсия

вирусо́лог *м* вирусолог, вирусология белгече

ви́рши *только мн.* **1.** вирша (*электә: силлабик шигырь*) **2.** *ирон.* вирша, шигырь тезмәсе (*бик начар шигырь турында әйтелә*)

ви́селица *ж* дар, дар агачы (*кеше аса торган*)

воздава́ть *несов. см.* **возда́ть**

возда́ть *сов. книжн.* **1.** *что кому-чему* күрсәтү, бирү; **~ по заслу́гам** эшенә күрә бәясен бирү **2.** *чем* кайтару, әжерен бирү, жавап бирү, түләү, ... итү; **~ добро́м за зло** яманлыкка каршы яхшылык белән жавап бирү

воздвига́ть *несов. что* төзү, торгызу, кору, салу; **~ мост** күпер салу; **~ па́мятник** һәйкәл салу

воздви́гнуть *сов. см.* **воздвига́ть**

возде́йствие *с* йогынты, тәэсир; **оказа́ть мора́льное ~** мораль йогынты ясау

возде́йствовать *сов., несов. на кого-что* йогынты ясау, тәэсир итү; **~ на ученика́** укучыга тәэсир итү

возде́лать *сов. см.* **возде́лывать**

возде́лывание *с см.* **возде́лывать; ~ поле́й** басуларны эшкәртү; **~ овоще́й** яшелчәләр үстерү

возде́лывать *несов. что* **1.** эшкәртү; **~ зе́млю** җирне эшкәртү **2.** игү, үстерү; **~ гречи́ху** карабодай үстерү; **~ овощны́е культу́ры** яшелчә культураларын үстерү

воздержа́вшийся 1. *прич. от* **воздержа́ться; 2.** *в знач. сущ. м* битараф, битараф булган, тавыш бирмичә калучы

воздержа́ние *с* тыелу, үзен тыю; баш тарту; **~ в еде́** ашауда тыелу

воздержанность *ж* үз-үзен тыю, тыелу; тыйнаклык

воздержанный, -ая, -ое тыйнак, сабыр, тотнаклы; **~ челове́к** тотнаклы кеше

воздержа́ться *сов. от чего* **1.** тыелу, тыелып калу, үз-үзен тыю, үз-үзен тотып калу; баш тарту; **~ от куре́ния** тәмәке тартудан тыелып калу **2.** (*уклониться*) битараф калу,битараф булу, тавыш бирми калу; **~ от голосова́ния** тавыш биргәндә тавыш бирми калу

воздержа́ться *несов. см.* **воздержа́ться**

возде́ть *сов.*: **~ ру́ки** кулларны күккә күтәрү

во́здух *м* һава; **све́жий ~** саф һава; **вы́йти на ~** һавага чыгу; **на откры́том ~е** ачык һавада; **подня́ть на ~** һавага күтәрү; **~!** һава! (*дошман килүен белдерә*) ♦ **в ~е но́сится (чу́вствуется)** сизелеп тора, сизелә

воздухо- *рус телендәге кушма сүзләрнең береңче кисәге, «һава», «һавага караган», «һавага бәйләнешле» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **воздухово́д** һава үткәргеч; **воздухообме́н** һава алмашы; **воздухонагрева́тель** һаваҗылыткыч

воздуходу́вка *ж тех.* һава өрдергеч

воздухопла́вание *с* һавада йөзү, һавада очу

воздухопла́ватель *м* һавада йөзүче, һавада очучы

воздухопла́вательный, -ая, -ое һавада йөзү ...ы; һавада йөзә торган, һавада очу ...ы

возду́шн||ый, -ая, -ое **1.** һава ...ы; **~ые тече́ния** һава агымы; **~ое сообще́ние** һава юлы; **~ый бой** һава сугышы; **~ый нале́т** һава һөҗүме **2.** һава белән ...ы; һава ...ы; һава ярдәмендә; **~ое охлажде́ние** һава белән суыту; **~ый то́рмоз** һава тормозы **3.** *перен.* өрфия, бик нәфис, **~ое пла́тье** өрфия күлмәк ♦ **~ые за́мки** буш хыял; **~ый оке́ан** һава диңгезе; **~ая я́ма** *ав.* һава чокыры

воздыха́ние *с уст.* зар, зарлану, сукрану

возже́чь *сов. что, уст.* **1.** (*зажечь*) кабызу, кабызып җибәрү, яндыру, яндырып җибәрү **2.** *перен.* (*возбудить*) кабызу, уяту

возжига́ть *несов. см.* **возже́чь**

воззва́ние *с* өндәмә, воззвание

воззва́ть *сов. к кому-чему, высок.* мөрәҗәгать итү

воззре́ние *с книжн.* караш, фикер

вози́ть *несов.* **1.** *кого-что* ташу, китерү; **~ дрова́ из ле́са** урманнан утын ташу **2.** *что, разг.* (*таскать, волочить*) өстерәү, өстерәп йөртү; **~ по́ полу** идән буйлап өстерәү **3.** *чем, разг.* йөртү; **~ рукаво́м по столу́** җиңне өстәл өстеннән йөртү ♦ **~ во́ду** *на ком кемне дә булса* ат урынына эшләтү

вози́ться *несов.* **1.** ыгы-зыгы килү, мәш килү, кайнашу; **де́ти во́зятся во дворе́** балалар ишек алдында мәш киләләр **2.** *с кем-чем, разг.* шөгыльләнү, азаплану, маташу; **~ с неуспева́ющими ученика́ми** өлгерәчүче укучы белән шөгыльләнү

во́зк||а *ж см.* **вози́ть** I; **~а дров** утын ташу; **~а сно́п о́в** көлтә ташу; **дров оста́лось на две ~и** ике мәртәбә китерерлек утын калды

возлага́ть *несов. см.* **возложи́ть** ♦ **~ наде́жды** *на кого-что* өмет баглау; **~ отве́тственность** *на кого-что* җаваплылыкны йөкләү

во́зле 1. *нареч.* янда гына, якында; **он живёт ~** ул якында яши 2. *предлог с род.п.* яныңда; **~ до́ма** өй янында

возлежа́ть *несов. на чём шутл.* (*лежать*) яту, ятып тору

возликова́ть *сов.* бик нык куану, бик нык шатлану

возли́яние *с шутл.* (*выпивка*) эчү, салу (*араканы*)

возложе́ние *см.* **возложи́ть**

возложи́ть *сов. что* 1. (*тантаналы рәвештә*) өстенә салу, өстенә кую; **~ венки́ на моги́лу** венокларны кабер өстенә кую 2. (*поручить*) йөкләү, тапшыру, кушу; **~ о́бщее руково́дство** гомуми житәкчелекне йөкләү; **~ отве́тственность** *на кого* жаваплылык йөкләү; **~ вину́** *на кого* гаепле санау

возлюби́ть *сов. кого-что, уст.* ярату, сөю

возлю́бленн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **возлюби́ть**; 2. сөекле, иң яраткан, ин сөйгән 3. *в знач. сущ.* **~ый** *м* сөйгән яр, яраткан кеше; **~ая** *ж* сөяркә, сөйгән яр

возме́здие *с высок.* җәза, җавап җәзасы

возмести́ть *сов. что* каплау, кайтару, түләтү, түләү; **~ расхо́ды** расходларны каплау; **~ убы́тки** күрелгән зыянны түләтү

возмечта́ть *сов.*: **~ о себе́** *уст.* үз-үзен зурга кую (куя башлау); тәкәбберләнеп китү

возмеща́ть *несов. см.* **возмести́ть**

возмо́жно *нареч.* 1. (*со сравн. ст. прил.*) мөмкин кадәр; **сде́лать ~ лу́чше** мөмкин кадәр яхшырак эшләү 2. *в знач. сказ. безл.* мөмкин; **э́то де́ло ~** бу эш мөмкин 3. *в знач. вводн. сл.* ихтимал бәлки, бәлкем; **мне ~, придётся уе́хать** мина, ихтимал, китәргә туры килер

возмо́жност||ь *ж в разг. знач.* мөмкинлек; ихтималлык; **больши́е ~и** зур мөмкинлекләр; **материа́льные ~и** материал мөмкинлекләр; **дать ~ь** мөмкинлек бирү; **е́сли предста́вится ~ь** мөмкинлек чыкса ♦ **по ~и** *или* **по ме́ре (си́ле) ~и** мөмкин кадәр, мөмкин булганча, хәл кадәренчә, кадәри хәл

возмо́жный, -ая, -ое мөмкин, мөмкин булган, ихтимал булган, булуы ихтимал, булуы мөмкин; **вполне́ ~ слу́чай** булуы мөмкин очрак

возмужа́лый, -ая, -ое 1. (*физически развитый*) буйга житкән, бәлигъ булган; 2. өлкәнәеп житкән, өлгереп житкән; **~ вид** өлкәнәеп житкән кыяфәт

возмужа́||ть *сов.* 1. (*достигнуть зрелости*) буйга житү, бәлигъ булу; **ю́ноша ~л** егет буйга житкән 2. (*физически окрепнуть*) өлкәнәеп житү, өлкәнгә әйләнү

возмути́тель *м*: **~ споко́йствия** тынычлыкны бозучы

возмути́тельный, -ая, -ое ачу китергеч, ачу китерә торган, ачу китерерлек; **~ слу́чай** ачу китерә торган очрак

возмути́ть *сов. кого-что* 1. ачуын китерү, ачуын кабарту, ачуландыру; **~ гру́бостью** тупаслык белән ачуын китерү 2. *уст.* (*побудить к мятежу*) котырту, коткы салу; чуалту

возмути́ться *сов.* 1. ачу килү, ачу кабару, ачулану; **~ несправедли́востью** гаделсезлектән ачу килү 2. *уст.* (*поднять мятеж*) чуалышу, баш күтәрү; фетнә күтәрү

возмуща́ть *несов. см.* **возмути́ть**

возмуща́ться *несов.* 1. *см.* **возмути́ться**; 2. *страд. от* **возмуща́ть**

возмуще́ни||е *с* 1. (*недовольство*) ачу, ачу килү; **чу́вство ~я** ачу хисе 2. *уст.* (*мятеж*) чуалыш, фетнә; баш күтәрү 3. *астр.* тайпылыш, тайпылу

возмущённый, -ая, -ое 1. *прич. от* **возмути́ть**; 2. ачуы килгән, ачуы кабарган; **~ челове́к** ачуы кабарган кеше 3. ачулы; ачуланган; **~ вид** ачулы кыяфәт

вознагради́ть *сов. кого-что* бүләкләү, бүләк бирү; тиешлесен бирү; **~ за труд** хезмәте өчен бүләк бирү

вознагражда́ть *несов. см.* **вознагради́ть**

вознаграждённое *с* 1. *см.* **вознагради́ть**; 2. бүләк; түләү; **де́нежное ~** акчалата түләү

вознаме́риваться *несов. см.* **вознаме́риться**

вознаме́риться *сов. с неопр. уст.* ният кылу (итү), ниятләү; карар итү; **~ уе́хать** китәргә ният итү

вознегодова́ть *сов. на кого-что, книжн.* ачуы килү, ачуы кабару; нык ачулану

возненави́деть *сов. кого-что* күрәлмәү, нәфрәт уяну, нәфрәт туу

вознести́ *сов. кого-что* 1. *высок.* (*поднять вверх*) өскә күтәрү, югарыга күтәрү 2. *перен.* күкләргә күтәрү; бик мактау

вознести́сь *сов.* 1. *высок.* (*подняться вверх*) күтәрелү, югарыга күтәрелү 2. *перен.* үзен зурга кую, масаеп китү, тәкәбберләнү

возника́ть *несов. см.* **возни́кнуть**

возникнове́ние *с* барлыкка килү, хасил булу, килеп чыгу, туу; **~ жи́зни на Земле́** Җирдә тереклекнең барлыкка килүе; **~ пожа́ра** янгынның килеп чыгуы; **~ ча́стной со́бственности** хосусый милекнең барлыкка килүе

возни́кнуть *сов.* барлыкка килү, хасил булу, килеп чыгу; туу

возни́ца *м* кучер, ат йөртүче, ямщик

возноси́ть *несов. см.* **вознести́**

возноси́ться *несов.* 1. *см.* **вознести́сь**; 2. *страд. от* **возноси́ть**

возн||я́ *ж* 1. ыгы-зыгы, шау-шу, тавышлы ыгы-зыгы; **~я́ детей́** балаларның ыгы-зыгысы 2. (*хлопоты*) мәшәкать, мәшәкатьле эш; **в саду́ ~и́ мно́го** бакчада мәшәкать күп

возоблада́ть *сов. книжн.* (*одержать вверх*) өстенлек итү (алу), өстен чыгу

возобнови́ть *сов. что* яңадан башлау, яңадан башлап җибәрү; **~ рабо́ту** эшне яңадан башлау; **~ пре́рванный разгово́р** бүленгән сөйләшүне яңадан башлау

возобнови́||ться *сов.* яңадан башлану (башланып китү); кабатлану; **заня́тия ~лись** дәресләр яңадан башланды

возобновля́ть *несов. см.* **возобнови́ть**

возобновля́ться *несов.* 1. *см.* **возобнови́ться**; 2. *страд. от* **возобновля́ть**

возо́к *м* көймәле чана; артлы чана

возомни́ть: ~ о себе́ *разг.* үзен әллә кемгә санау, үзен зурга кую, масаеп китү

возра́доваться *сов. уст.* шатлану, куану, сөену

возража́ть *несов. см.* **возрази́ть**

возраже́ни||е *с* 1. **возрази́ть**; 2. каршы сүз, каршы килү; **слу́шать ~я** каршы сүзләрне тыңлау

возрази́ть *сов.* каршы [сүз] әйтү, каршы килү (төшү); **~ докла́дчику** докладчикка каршы әйтү

во́зраст *м* яшь; **вы́йти из шко́льного ~а** мәктәп яшеннән узу; **сре́дний ~** урта яшь ♦ **войти́ в ~** бәлигъ булу

возраста́ть *несов. см.* **возрасти́**

возрасти́ *сов.* үсү, арту, көчәю; **си́лы возросли́** көчләр артты

возрастн||о́й, -а́я, -о́е яшь ...ы; яшь ягыннан; **~ы́е осо́бенности** яшь үзенчәлекләре; **~о́й соста́в населе́ния** халыкның яшь ягыннан төркемнәре

возроди́ть *сов. кого-что* яңадан торгызу, яңадан барлыкка китерү, яңадан аякка бастыру

возроди́||ться *сов.* яңадан торгызылу; яңадан барлыкка килү; яңадан аякка басу; **~вшееся иску́сство** яңадан торгызылган сәнгать

возрождА́ть *несов. см.* **возроди́ть**

возрожда́ться *несов.* 1. *см.* **возроди́ться**; 2. *страд от* **возрожда́ть**

возрожде́ние *с* 1. яңадан торгызу; яңадан туу; яңадан аякка басу; яңадан торгызылу; яңадан аякка бастыру; **~ промы́шленности** промышленностьне яңадан торгызу 2. (*с прописной*) Яңарыш, Ренессанс (*Европада урта гасырлардан соң фән, мәдәният, сәнгать үсеп киткән чор*)

возропта́ть *сов. уст.* сукрану, ризасызлык белдерү

во́зчик *м* олаучы, йөкче, йөк ташучы, йөк йөртүче

возыме́ть *сов.*: **~ де́йствие** тәэсир итү, йогынты ясау; **~ жела́ние** теләк уяну

во́ин *м высок.* сугышчы, гаскәри; **до́блестный ~** батыр сугышчы

во́инск||ий, -ая, -ое хәрби; гаскәри; **~ий уста́в** хәрби устав; **~ая часть** хәрби часть; **~ий долг** хәрби бурыч

вои́нственность *ж* 1. сугышчанлык, сугышчан булу; **~ племе́ни** кабиләнең сугышчан булуы 2. сугышучан булу; әтәчлек; **~ ви́да** сугышучан кыяфәтле булу

вои́нственн||ый, -ая, -ое 1. сугышчан, сугышырга әзер торган; **~ые племена́** сугышчан кабиләләр 2. сугыш ...ы; **~ые пла́ны** сугыш планнары 3. *перен.* сугышучан, әтәч ..., сугышырга ратучан; **~ый вид** сугышучан кыяфәт

вои́нство *с высок.* гаскәр, чирү

вои́нствующий, -ая, -ое сугышчан; **~ материали́зм** сугышчан материализм

вои́стину *нареч. высок.* чыннан да, чынлап та, дөрестән дә

вой *м* 1. улау; улау тавышы; улаган тавыш; **~ во́лка** бүре улавы 2. *разг.*

(*громкий плач*) кычкырып елау, улау **3.** *перен.* ыжгыру; **~ ве́тра** җилнең ыжгыруы **4.** *перен.* (*злобная брань*) акырыну, улау

во́йлок *м* киез, тула

во́йлочн||ый, -ая, -ое **1.** киез басу ...ы, киез ...ы; **~ое произво́дство** киез басу производствосы **2.** киез ...; тула ...; **~ая шля́па** киез эшләпә

война́ *ж* сугыш; **Вели́кая Оте́чественная ~á** Бөек Ватан сугышы; **втора́я мирова́я ~á** икенче бөтендөнья сугышы; **граждáнская ~á** гражданнар сугышы

во́йск||о *с* гаскәр, яу; **регуля́рные ~á** регуляр гаскәрләр; **погрáничные ~á** чик гаскәрләре

войстков||о́й, -áя, -óе гаскәри, гаскәр ...ы; гаскәри, хәрби; **~ы́е ча́сти** хәрби частьләр

войти́ *сов. во что* **1.** керү; **~ в дом** өйгә керү; **~ в комúссию** комиссиягә керү **2.** (*уместиться*) сыю, сыеп бетү; **в шкаф вошло́ мно́го книг** шкафка бик күп китап сыйды **3.** *с чем* (*обратиться*) керү, мөрәҗәгать итү; **~ в дирéкцию с заявлéнием** дирекциягә гариза белән керү **4.** (*вникнуть*) асылын аңлау, төшенү; **~ в суть дéла** эшнең асылына төшенү ♦ **~ в быт** көнкүрешкә керү; **~ во вкýс** тәмен табу, тәмен аңлап алу; **~ в довéрие** ышаныч казану; **~ в жизнь** гадәткә әйләнү; тормышка керү; **~ в истóрию** тарихка керү; **~ в колéю** элекке эзенә төшү, элекке эзенә кайту; **~ в курс** төшенү, төшенеп җитү, аңлау; **~ в положéние** *чьё* хәленә керү; **~ в привы́чку** гадәткә әйләнү; **~ в си́лу** көченә керү; **~ в строй** сафка басу

вока́була *ж лингв.* (*единица словаря*) вокабула; баш сүз

вокали́зм *м лингв.* вокализм, сузыклар системасы

вокали́ст *м* вокалчы

вокали́стка *ж* вокалчы хатын (кыз)

вока́льн||ый, -ая, -ое жыр ...ы; вокаль ...; **~ое иску́сство** җыр сәнгате; **~ая му́зыка** вокаль музыка

вокза́л *м* вокзал; **железнодоро́жный ~** тимер юл вокзалы; **речно́й ~** елга вокзалы

вокза́льный, -ая, -ое вокзал ...ы; **~ буфе́т** вокзал буфеты

вокру́г 1. *нареч.* тирәли, әйләнә-тирәдә, тирә-юньдә; **~ ни души́** тирә-юньдә бер кеше дә юк **2.** *предлог с род.п.* тирәсендә, әйләнәсендә; тирәли; **~ до́ма** өй тирәли; **~ стола́** өстәл тирәсендә **3.** *предлог с род.п.* тирәсендә, хакында; турында; **спóры ~** *какого-л.* **вопро́са** *нинди дә булса* мәсьәлә хакында бәхәсләр ♦ **~ да о́коло** асылын аңламыйча, өстән-өстән генә, өстән йөзү; **~ па́льца обверти́** *кого* төп башына утырту, кәкре каенга терәтү

вол *м* эш үгезе, печкән (печелгән) үгез ♦ **рабóтать (трудúться) как ~** ат кебек эшләү

волáн *м* **1.** волан, бәби итәк, бала итәк **2.** *спорт.* волан

волга́рь *м* Идел кешесе, Иделдә [туып] үскән кеше

волды́рь *м* кабарчык

волев||о́й, -áя, -óе **1.** ихтыяр ...ы; **~ о́й и́мпульс** ихтыяр импульсы **2.** ихтыярлы, көчле ихтыярлы; нык ихтыярлы; **~ о́й челове́к** ихтыярлы кеше: **~ óе лицó** ихтыярлы йөз

волеизъявле́ние *с книжн.* ихтыяр (теләк) белдерү; **~ наро́да** халыкның үз ихтыярын белдерүе

волейбóл *м* волейбол

волейболи́ст *м* волейболчы

волейболи́стка *ж* волейболчы кыз

волейбóльный, -ая, -ое волейбол ...ы; **~ мяч** волейбол тубы

вóлей-невóлей *нареч.* теләсә дә теләмәсә дә, ирекле-ирексез, ирексездән; **он ~ согласи́лся** теләсә дә теләмәсә дә риза булды

волк *м* бүре ♦ **~ в ове́чьей шку́ре** сарык тиресе бөркәнгән бүре; **~ óв боя́ться — в лес не ходи́ть** *посл.* бүредән курыккан урманга бармас; **~ом смотре́ть** бүре кебек карау; **морско́й ~** диңгез бүресе; **хоть ~ом вой** ятып үлсән дә

волкода́в *м* бүре эте, бүре басучы эт

волна́ *ж в разн. знач.* дулкын; **морска́я ~** диңгез дулкыны; **возду́шная ~** һава дулкыны; **звукова́я ~** *физ.* тавыш дулкыны; **~ патриоти́ческого движе́ния** патриотик хәрәкәт дулкыны

волне́ни||е *с* **1.** дулкынлану; **~е мóря** диңгезнең дулкынлануы **2.** *перен.* дулкынлану, борчылу, тынычсызлану; **~е доклáдчика** докладчының дулкынлануы **3.** *обычно. мн.* **~я** *перен.* (*массовый протест*) чуалыш

волни́ст||ый, -ая, -ое **1.** дулкынлы, дулкынсыман, дулкынланып торган (тора торган); **~ая ли́ния** дулкынлы сызык; **~ые вóлосы** дулкынланып торган чәчләр **2.** таулы-чокырлы, чокырлы-чакырлы; **~ая мéстность** таулы-чокырлы урын; **~ая равни́на** чокырлы-чакырлы тигезлек

волн||ова́ть *несов.* **1.** *что* дулкынландыру; **вéтер ~у́ет мóре** җил диңгезне дулкынландыра **2.** *кого-что* дулкынландыру. борчу, тынычсызлау; **~ова́ть ду́шу** күңелне тынычсызлау **3.** *кого-что, уст.* (*подстрекать*) котырту; чуалдыру

волн||ова́ться *несов.* **1.** дулкынлану; **мóре ~у́ется** диңгез дулкынлана **2.** дулкынлану, борчылу, тынычсызлану; **толпá ~у́ется** халык төркеме дулкынлана **3.** *уст.* (*выражать протест*) кузгалышка күтәрелү, кузгалу, чуалыша башлау

волнов||о́й, -áя, -óе *физ.* дулкын ...ы; **~áя теóрия свéта** яктылыкның дулкын теориясе; **~óе движе́ние** дулкынсыман хәрәкәт

волнолóм *м* дулкынтоткыч

волнообра́зн||ый, -ая, -ое **1.** дулкынсыман; дулкын-дулкын; **~ые облака́** дулкынсыман болытлар **2.** *см.* **волни́стый** 2

волнорéз *м см.* **волнолóм**

волну́шка *ж* йөнтәс гөмбә

волó||ий, -ья, -ье үгез ...ы; эш үгезе ...ы; **~ье ста́до** үгез көтүе; **~ья шку́ра** үгез тиресе ♦ **~ья ше́я** кыска муен, үгез муены

вóлок *м* волок, сөйрәмә җир (*электә бер елгадан икенчесенә иң якын арадан көймәләрне сойрәп күчерә торган җир*)

волоки́та I *ж* волокита, чуалчыклык; **борьбá с ~ой** волокита белән көрәшү

волоки́та II *м уст.* өстәлчек, сөйрәлчек

волоки́ст||ый, -ая, -ое сүсчел, җепселле; **~ые расте́ния** җепселле үсемлекләр

волокнó *с* **1.** сүс; **льняно́е ~** җитен сүсе **2.** *обычно мн.* **волóкна** җепселләр; **не́рвные волóкна** нерв җепселләре

вóлоком *нареч.* сөйрәп, өстерәп; **тащи́ть ~** өстерәп бару

волоку́ша *ж* сөйрәткеч, сөйрәтке; чүмәлә тарттыргыч

волонтёр *м уст.* ирекле, волонтер

волоóкий, -ая, -ое зур күзле, акай күзле

вóлос *м* **1.** чәч; бер чәч; чәч бөртеге; **седóй ~** чал чәч **2.** *собир.* кыл (*мәс. ат койрыгында*), йон, ябага (*хайваннарда*), тәк (*кеше тәненда*) ♦ **~ы рвать (драть) на себе́** чәчләрен йолку; **~ы ста́ли ды́бом** чәчләре үрә торды; **ни на́ волос** азрак та, аз гына да, бөтенләй; бөртек тә

волоса́т||ый, -ая, -ое **1.** йонлач, йонлы, тәкле; **~ая грудь** йонлач күкрәк **2.** куе чәчле; **~ый мужчи́на** куе чәчле ир кеше

волоси́нка *ж* чәч бөртеге, бер чәч

волосн||о́й, -áя, -óе бик нечкә, нәзек, чәч кебек ...; **~ы́е сосу́ды** бик нечкә кан тамырлары

волос||о́к 1. *уменьш. от* **вóлос** 1; **2.** кыл, сәгать кылы; **~о́к ла́мпочки** лампочка кылы **3.** *бот.* төк; ук; **~ки́ крапи́вы** кычыткан уклары ♦ **на ~ке́ висе́ть** кыл өстендә булу

волостн||о́й, -áя, -óе *ист.* волость ...ы; **~óе правле́ние** волость идарәсе

вóлость *ж ист.* волость

волосяно́й, -áя, -óе **1.** йон ...ы; тәк ...ы, чәч ...ы; **~ покро́в** йон капламы **2.** кыл ..., кылдан ясалган; **~ матра́ц** кыл матрац

волочи́ть *несов.* **1.** *кого-что* өстерәү, сөйрәү, өстерәп бару (килү), сөйрәп бару (килү); **~ мешóк с зерно́м** ашлык төялгән капчыкны өстерәп бару **2.** *что, спец.* кысып нечкәртү, кысып нәзегәйтү; **~ про́волоку** тимерчыбыкны кысып нәзегәйтү ♦ **е́ле ~ но́ги** аякны көчкә сөйрәү

волочи́||ться *несов. разг.* өстерәлү, сөйрәлү, өстерәлеп (сөйрәлеп) бару; **поводóк ~лся по земле́** тезген җир өстеннән өстерәлеп бара иде

волó||чь *несов. разг. см.* **волочи́ть** 1; **де́ти ~кли́ теле́жку** балалар кул арбасын өстерәп бара иделәр

волóчься *несов. разг. см.* **волочи́ться**

волхв *м* (*колдун*) волхв, сихерче

волча́нка *ж мед.* волчанка (*тире туберкулёзы*)

волча́тник *м разг.* бүре аучысы (аулаучы)

волче́ц *м* (*название сорных растений*) билчән; шайтан таягы

во́лч||ий, -ья, -ье **1.** бүре; **~ий след** бүре эзе; **~ья шку́ра** бүре тиресе **2.** бүре ..., бүре тиресеннән тегелгән (ясалган); **~ья шу́ба** тиресеннән тегелгән тун **3.** *перен.* бүре ...ы, ерткыч ...ы, бүреләрчә ..., ерткычларча ...; **~ьи зако́ны** бүре законнары ♦ **~ий аппети́т** бүре аппетиты, бик нык ашыйсы килү; **~ий биле́т (па́спорт)** кәҗә билеты (пасспорты); **~ья я́года** бүре җиләге, карга миләше; **~ья я́ма** *охот.* бүре базы, бүре чокыры

волчи́ха *разг.*, **волчи́ца** *ж* ана бүре

волчо́к *м* (*игрушка*) бөтерчек, бөтергеч

волчо́нок *м* бүре баласы

волше́бник *м* тылсымчы, тылсым иясе, сихерче, күрәзәче

волше́бница *ж* тылсымчы (сихерче, күрәзәче) хатын

волше́бн||ый, -ая, -ое **1.** тылсым ...ы; тылсымлы; **~ая па́лочка** тылсым таягы; **~ые ска́зки** тылсымлы әкиятләр; **~ая вода́** тылсымлы су **2.** *перен.* сокландырғыч, искиткеч, матур, тылсымлы; **~ый го́лос** сокландырғыч тавыш

волшебство́ *с* тылсым, күрәзәлек, сихер

волы́нить *несов. разг.* сүлпән эшләү, юри сузу (*эшне*), акрын кыймылдау

волы́нк||а *ж* **1.** *муз.* сорнай **2.** *разг.* (*медлительность в работе*) сүлпәнлек, акрынлык, сузу (*эшне*); **тяну́ть ~у** акрын кыймылдау **3.** (*затяжное дело*) мәшәкатьле эш, матавыклы эш

волы́нщик *м* сорнайчы

вольго́тн||ый, -ая, -ое *разг.* иркен, рәхәт; **~ая жизнь** иркен тормыш

воль|е́р *м,* **~а** *ж* вольер (*мәс. зоопаркта*)

во́льная *ж ист.* азатлык язуы, азатлык кәгазе (*крепостнойлыктан азат итү турында*)

во́льница *ж собир.* качаклар

во́льничать *несов. разг.* башбаштаклану, башбаштаклык итү, ни теләсә шуны эшләү

во́льно *нареч.* иркен, рәхәт; **жить ~** иркен яшәү ♦ **~!** (*команда*) иркен торыгыз!; **~ йли нево́льно** теләсәң дә теләмәсәң дә

вольно́ *в знач. сказ. кому с неопр., разг.* кем кушкан соң [сиңа]; **уста́л? Вольно́ было тебе́ так бы́стро бежа́ть** ардыңмы? Кем кушкан соң сиңа шулай тиз йөгерергә

вольноду́мец *м уст.* хәр фикерле кеше

вольнодýмн||ый, -ая, -ое *уст.* хәр фикерле, хәр фикер белән сугарылган; **~ые стихи́** хәр фикерле шигырьләр

вольнодýмство *с уст.* хәр фикерлелек

вольнолюби́вый, -ая, -ое азатлык сөюче, ирек сөюче; **~ наро́д** азатлык сөюче халык

вольнонаёмный, -ая, -ое **1.** үзе теләп ялланган, үз ирке белән ялланган, вольнонаёмный (*хәрби хезмәттә*) **2.** *ист.* ялланып эшләүче ..., ялланган; яллы, ялланып эшләргә нигезләнгән; **~ труд** яллы хезмәт

вольноопределя́ющийся *м* ирекле хезмәт итүче

вольноотпу́щенник *м ист.* иреккә җибәрелгән кеше (*кол яки крепостной*)

вольноотпу́щенный, -ая, -ое *ист.* иреккә җибәрелгән, азат ителгән (*кол, крепостной*)

вольнослу́шатель *м уст.* ирекле тыңлаучы

вольнослу́шательница *ж уст.* ирекле тыңлаучы хатын-кыз

во́льность *ж* **1.** *уст.* (*свобода*) ирекле, азатлык **2.** (*развязанность*) тыйнаксызлык, тәкәллефсезлек, тәртипсезлек **3.** ирекле лек; **поэти́ческая ~** шигъри ирекле лек

во́льн||ый, -ая, -ое **1.** ирекле, азат; бәйсез; **~ый труд** ирекле хәзмәт; **~ый челове́к** ирекле кеше **2.** иркен; **~ая жизнь** иркен тормыш **3.** *уст.* (*свободолюбивый*) хәр ..., азатлык ...ы; **~ая мысль** хәр фикер; **~ые иде́и** азатлык идеяләре **4.** (*нескромный*) тәкәллефсез, тыйнаксыз; **~ые шу́тки** тәкәллефсез мәзәкләр **5.** (*не ограниченный нормами*) ирекле, ирекле рәвештә, чикләнүсез; **~ая прода́жа хле́ба** икмәкне ирекле сату; **по ~ым це́нам** ирекле хак белән **6.** *уст.* (*частный*) ирекле, хосусый; **~ая типогра́фия** ирекле типография **7.** ихтыярлы, үз ихтыяры белән эшләнгән; **~ые и нево́льные грехи́** ихтыярлы һәм ихтыярсыз гөнаһлар ♦ **~ая пти́ца** һавадагы кош, ирекле кош; **~ый го́род** *ист.* ирекле шәһәр (шәһәр-дәүләт); **~ый каза́к** ирекле казак; **~ый перево́д** ирекле тәрҗемә; **~ый стих** ирекле шигырь; **на ~ом во́здухе** саф һавада

вольт *м эл.* вольт

во́льта *ж* вольта (*тукыма*)

вольтижи́ровать *несов.* вольтижирлау (*атка атланып барганда төрле күнегүләр ясау*)

вольтижиро́вка *ж см.* **вольтижи́ровать**

вольтме́тр *м эл.* вольтметр

вольфра́м *м хим.* вольфрам

вольфра́мов||ый, -ая, -ое **1.** вольфрам ...; **~ая спира́ль** вольфрам спираль; **~ый резе́ц** вольфрам кискеч **2.** *хим.* вольфрамлы; вольфрам ...ы; **~ые со́ли** вольфрамлы тозлар

волюнтари́зм *м* **1.** *филос.* волюнтаризм **2.** *психол.* волюнтарчылык (*ихтыяр көченә генә тыянып эш итү*)

волюнтари́ст *м* волюнтарчы

волюнтаристи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** *филос.* волюнтаризм ...ы, волюнтаристик; **~ая тео́рия** волюнтаризм теориясе **2.** волюнтарчылык ...ы; волюнтарчыларча ...; **~ий подхо́д к де́лу** эшкә волюнтарчыларча карау

во́л||я *ж* **1.** ихтыяр, ихтыяр көче; **воспита́ть ~ю** ихтыяр көче тәрбияләү; **си́ла ~и** ихтыяр көче **2.** *к чему* омтылыш, омтылу; **~я к побе́де** җиңүгә омтылыш **3.** (*желание*) теләк, ирек, таләп; **~я избира́телей** сайлаучыларның теләге **4.** (*право*) хокук, ирек; **э́то в твое́й ~е** бу синең иректә **5.** (*свобода*) ирек; **вы́рваться на ~** иркәкә чыгу ♦ **~ею су́деб** язмыш кушуы белән (буенча); **~и рука́м не дава́й** кулыңны озайтма, кулыңны тый; **~я ва́ша (твоя́)** ихтыярыгыз (ихтыярың), мәйлегез (мәйлең); **на ~е** *прост.* тышта, саф һавада; **на ~ю** саф һавага, тышка

вон I *нареч. разг.* **1.** тышка, читкә; моннан; **вы́нести ве́щи ~** әйберләрне тышка чыгару; **вы́гнать ~** моннан куып чыгару **2.** *в знач. межд.* чыгып кит, югал, ычкын, кит моннан; **~ отсю́да!** моннан чыгып кит!

вон II *частица разг.* әнә, менә; **~ там** әнә тегендә; **~ ты тако́й!** менә син нинди икән! ♦ **~ [оно́] что!** менә нәрсә икән!

вонза́ть *несов. см.* **вонзи́ть**

вонза́ться *несов.* **1.** *см.* **вонзи́ться; 2.** *страд. от* **вонза́ть**

вонзи́ть *сов. что* чәнчү, кадау; батыру; чәнчеп (кадап) кую; **~ лопа́ту в зе́млю** көрәкне җиргә батыру; **~ кинжа́л** хәнҗәрне кадау

вонзи́ться *сов.* кадалу, чәнчелү; **игóлка ~лась в па́лец** энә бармакка кадалды

вонь *ж разг.* сасы ис

вонюч||ий, -ая, -ое *разг.* сасы, сасы исле

вонючка *ж* **1.** *зоол.* сасык, сасы бурсык **2.** *бот.* сасы үлән

воня́ть *несов. разг.* сасы ис чыгару, сасыту; һава бозу

вообража́ть *несов. см.* **вообрази́ть** ♦ **~ о себе́** *прост.* үзен зурга кую, үзен әллә кемгә санау

воображе́ние *с* **1.** күз алдына китерү, хыял; **твóрческое ~** иҗади хыял **2.** (*домысел*) фараз; **э́то то́лько твоё ~** бу синең генә фаразың

вообрази́||ть *сов.* **1.** *кого-что* (*мысленно представить*) күз алдына китерү, күзаллау, хыялга китерү **2.** *кого-что кем-чем и с союзом «что»* (*предположить*) фараз итү, гоман кылу, ... дип уйлау **3.** *повел.* **~[те]** фараз итү, фараз кылу; **~те, что о́на не прие́дет** ул килми дип фараз итегез

вообще́ *нареч.* **1.** гомумән, гомумән алганда; **~ э́то ве́рно** гомумән алганда бу дөрес **2.** (*совсем*) бөтенләй, гомумән; **я ~ сего́дня никуда́ не пойду́** мин бүген бөтенләй бер кая да бармыйм **3.** (*всегда*) гел, һәрвакыт, гомумән; **он ~ тако́й** ул һәрвакыт шундый **4.** гомумән; **я говорю́ о лю́дях ~, а не о тебе́** мин кешеләр турында гомумән сөйлим, синен турында түгел ♦ **~ говоря́** *в знач. вводн. сл.* гомумән, гомумән алганда

воодушеви́ть *сов. кого-что* рухландыру, рухын күтәрү; канатландыру, илһам бирү; дәрт бирү; **~ на по́двиг** батырлыкка рухландыру

воодушеви́ться *сов.* рухлану, рух күтәрелү; канатланып китү; илһамлану; дәртләнү, дәрт килү

воодушевле́ние *с* **1.** *см.* **воодушеви́ть; 2.** күтәренке рух, илһам; дәрт; **с ~м говори́ть** илһам белән сөйләү

воодушевля́ть *несов. см.* **воодушеви́ть**

воодушевля́ться *несов.* 1. *см.* **воодушеви́ться**; 2. *страд. от* **воодушевля́ть**

вооружа́ть *несов. см.* **вооружи́ть**

вооружа́ться *несов.* 1. *см.* **вооружи́ться**; 2. *страд. от* **вооружа́ть**

вооруже́ни||е *с* 1. *см.* **вооружи́ть, вооружи́ться**; 2. корал, кораллар; **сокраще́ние ~й** кораллары киметү; **но́вые ви́ды ~й** кораллардың яңа төрләре; **стратеги́ческие ~я** стратегик кораллар; **брать на ~е** *прям., перен.* корал итеп алу

вооружённость *ж* коралланганлык, коралланган булу, корал белән тәэмин ителгәнлек; **техни́ческая ~ се́льского хо́зяйства** авыл хуҗалыгының техник яктан коралланган булуы

вооружённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **вооружи́ть**; 2. (*имеющий оружие*) кораллы, коралланган, коралы булган; **~ый отря́д** кораллы отряд; **~ый солда́т** кораллы солдат 3. (*производимый с оружием в руках*) кораллы, корал белән ...; **~ое восста́ние** кораллы восстание; **~ое нападе́ние** корал белән һөҗүм итү; ♦ **~ые си́лы** кораллы көчләр; **~ый нейтралите́т** кораллы нейтралитет

вооружи́ть *сов.* 1. *кого-что* (*снабдить оружием*) коралландыру, корал белән тәэмин итү 2. *перен. кого-что чем* коралландыру, җиһазландыру, тәэмин итү; **~ промы́шленность но́вой те́хникой** промышленностне яңа техника белән тәэмин итү 3. *перен. кого-что* коралландыру; 4. *перен. кого-что против кого-чего, разг.* (*внушить неприязнь*) котырту, дошманлаштыру; **~ сы́на про́тив отца́** улын атасына каршы котырту

вооружи́ться *сов.* 1. кораллану, корал белән тәэмин ителү; **~ до зубо́в** баштан аяк кораллану 2. кораллану, корал итеп алу; **~ но́вой те́хникой** яңа техника белән кораллану 3. *перен.* (*приобрести знания*) кораллану; **~ передово́й тео́рией** алдынгы теория белән кораллану 4. *перен. против кого-чего* (*восстать, ополчиться*) каршы чыгу, каршы булу ♦ **~ терпе́нием** чыдарга тырышу, чыдау

воо́чию *нареч. книжн.* 1. (*своими глазами*) үз күзе белән, үзе күреп, үзе сынап; **~ уви́деть** үз күзе белән күрү 2. (*наглядно*) ачык, ачык рәвештә; **~ показа́ть** ачык күрсәтү

во-пе́рвых *вводн. сл.* беренчедән, беренчеләй

вопи́ть *несов.* 1. *разг.* (*громко кричать*) бакыру, акыру, кычкыру 2. *диал.* (*громко плакать*) акырып елау, кычкырып елау

вопию́щ||ий, -ая, -ее күзгә бәрелеп торган, шаккатарлык, искитәрлек; **~ий факт** күзгә бәрелеп торган факт; **~ее противоре́чие** күзгә бәрелеп торган каршылык; **~ая несправедли́вость** шаккатарлык гаделсезлек

воплоти́ть *сов. кого-что* (*конкретно выразить*) гәүдәләндерү, чагылдыру ♦ **~ в себя́** үзендә гәүдәләндерү; **~ в жизнь** тормышка ашыру

воплоти́ться *сов.* (*получить конкретное выражение*) гәүдәләнү, чагылу; гамәлгә ашу

воплоща́ть *несов. см.* **воплоти́ть**

воплоща́ться *несов.* 1. *см.* **воплоти́ться**; 2. *страд. от* **воплоща́ть**

воплоще́ние *с* 1. *см.* **воплоти́ть, воплоти́ться**; 2. гәүдәләнеш; **найти́ своё ~** үзенең гәүдәләнешен табу

воплощённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **воплоти́ть**; 2. камил, нәкъ үзе; **~ая хра́брость** батырлыкның нәкъ үзе; **~ая че́стность** камил намуслылык

вопль *м* кычкырган тавыш, ачы тавыш

вопреки́ *предлог с дат.п.* ...га карамастан, ...га каршы; **~ ожида́ниям** көтүгә каршы; **~ жела́нию** теләккә каршы

вопро́с *м* 1. сорау, сәяль; **отве́тить на ~** сорауга җавап бирү 2. (*проблема*) мәсьәлә; **~ я́сен** мәсьәлә ачык; **национа́льный ~** милли мәсьәлә; **жили́щный ~** торак мәсьәләсе; **обсуди́ть ~** мәсьәләне тикшерү; **оста́вить ~ откры́тым** мәсьәләне ачык калдыру ♦ **~ жи́зни и сме́рти** яшәү белән үлем мәсьәләсе, чиктән тыш мөһим мәсьәлә; **что за ~?** сорау булырга да мөмкин түгел; әлбәттә, һичшиксез; **под [большим] ~ом** зур сорау астында

вопроси́тельный, -ая, -ое 1. сораулы, сораган кебек, гаҗәпсенгән кебек; **~ взгляд** сораулы караш 2. *грам.* сорау ...ы; **~ знак** сорау билгесе

вопро́сник *м* сораулык

вор *м* карак, угры, бур

во́рвань *ж уст.* ворвань (*тюлень, дельфин, кит h.б.ш. мае*)

ворва́ться *сов.* атылып килеп керү, кинәт килеп керү, бәреп керү; **~ в око́пы проти́вника** дошман окопларына бәреп керү

вори́шка *м уменьш. от* **вор**; кесә карагы, вак карак

воркова́ние *с см.* **воркова́ть**

воркова́ть *несов.* 1. (*о голубях*) гөрләү, гөрләшү 2. *перен.* (*о влюблённых*) чәкәрдәшү, гөрләшү, гөрләшеп сөйләшү; серләшү

воркотня́ *ж разг.* сукрану, мыгырдану

воробе́й *м* чыпчык ♦ **ста́рый (стре́ляный)** ~ карт чыпчык

воробьи́н||ый, -ая, -ое чыпчык[лар] ...ы; **~ое гнездо́** чыпчык оясы ♦ **~ая ночь** 1) (*с непрерывной грозой*) яшенле төн; аҗаганлы төн; 2) (*короткая летняя ночь*) җәйге кыска төн

воробьи́ха *ж разг.* ана чыпчык

воро́ванн||ый, -ая, -ое урланган, урлап алынган; **~ые ве́щи** урланган әйберләр

вороват||ый, -ая, -ое 1. алдакчы, хәйләкәр; бик астыртын; **~ые глаза́** хәйләкәр күзләр 2. сак, куркулы; **~ая похо́дка** сак адымнар

ворова́ть *несов.* 1. *кого-что* урлау 2. (*заниматься воровством*) урлашу, караклык итү

воро́вка *ж* карак хатын (кыз)

воровски́ *нареч. разг.* каракларча; астыртын (яшертен) рәвештә; **~ сбежа́ть** яшертен рәвештә качу

воровск||о́й, -ая, -о́е карак[лар] ...ы; **~а́я ша́йка** караклар шайкасы; **~о́й язы́к** караклар теле

воровство́ *с* караклык, угрылык; урлашу

во́рог *с уст.* дошман

ворожба́ *м уст.* багучылык итү, күрәзәлек итү, багу; сихерләү

ворожея́ *ж* багучы, күрәзәче, фалчы, фал ачучы (*хатын*)

ворожи́ть *несов.* (*гадать*) фал ачу, багу, күрәзәлек итү; (*колдовать*) сихерләү

во́рон *м* козгын; **~ ~у глаз не выклюёт** *посл.* карга күзен карга чукымас

воро́на *ж* 1. карга, кара карга, ала карга 2. *перен.* (*разиня*) ачык авыз ♦ **воро́н счита́ть** авыз белән кош тоту, авыз ачып тору; **~ в павли́ньих пе́рьях** ≈ салам торхан

воронён||ый, -ая, -ое карайтылган, каралтылган; оксидлашкан (*корычның өсте турында*); **~ая сталь** каралтылган корыч

воронёц *м бот.* карга җиләге, бүре бөресе

воро́н||ий, -ья, -ье карга ...ы, ала карга ...ы, кара карга ...ы; **~ье крыло́** карга канаты

ворони́ть *несов. что* карайту, каралту, оксидлаштыру (*корычның өстен*); **~ сталь** корычны каралту

воро́нка *ж* 1. (*для переливания*) бүрәнкә 2. (*от снаряда*) снаряд (*бомба h.б.ш.*) чокыры, чокыр

вороно́й, -а́я, -о́е (*о масти лошади*) кара

вороньё *с собир.* козгыннар

во́рот I *м* (*одежды*) изү, яка

во́рот II *м тех.* чыгыр; кое чыгыры

воро́та *только мн.* капка; **хокке́йные ~** хоккей капкасы; **откры́ть ~** капканы ачу

вороти́ла *м разг.* (*делец*) эшкуар

вороти́ть I *сов. кого-что, разг.* (*вернуть*) борып кайтару, кире кайтару

вороти́ть II *несов. прост.*: **~ нос** *от чего* борып (йөз) чөерү

вороти́ться *сов. разг.* кайту, кире кайту; **~ домо́й** өйгә кайту

воротни́к *м* яка; **отложно́й ~** кайтарма яка; **мехово́й ~** мех яка

воротничо́к *м уменьш. от* **воротни́к; кружевно́й ~** челтәр яка

во́рох *м* 1. өем, күбә; **~ соло́мы** салам өеме; **~ се́на** печән күбәсе; **~ бума́г** кәгазь өеме 2. *с.-х.* көшел; **~ зерна́** ашлык көшеле; **льняно́й ~** җитен орлыгы көшеле

воро́ча||ть *несов.* 1. *что* әйләндерү; **~ ка́мни** ташлар әйләндерү 2. *перен. чем, разг.* (*распоряжаться*) баш булу; эш йөртү, эш итү

воро́ча||ться *несов. разг.* (*переворачиваться*) әйләнү, әйләнгәләү, боргалану; **он ~лся под одея́лом** юрган астында ул әйләнгәли иде

ворош||и́ть *несов. что* 1. (*переворачивать*) әйләндерү; кабарту; болгату;

~ть се́но печән әйләндерү **2.** (*шевелить*) кыймылдату, селкетү; тузгыту; **ве́тер ~т во́лосы** җил чәчне тузгыта ◆ **~ть про́шлое** үткәннәрне искә төшерү

ворс *м* йон, ворс (*тукымада*)

ворси́нка *ж* **1.** (*волосок ворса*) төк, төк бөртеге **2.** *анат.* төкчә (*эчәктә*) **3.** *бот.* үсенте, төкчә

ворси́ст||ый, -ая, -ое ворслы, йөнтәс, йонлы; **~ое оде́яло** йонлы юрган

ворсова́льн||ый, -ая, -ое *текст.* ворслау ...ы; **~ая маши́на** ворслау машинасы

ворсова́ть *несов. что, текст.* ворслау, ворс ясау, йонландыру; **~ сукно́** постауны ворслау

ворч||а́ть *несов.* **1.** ырылдау, ырлау; **соба́ка ~и́т** эт ырылдый **2.** *разг.* (*брюзжать*) мыгырдау, мыгырдану; сукрану; **стару́шка ~и́т** карчык мыгырдана

ворчли́вый, -ая, -ое мыгырданучан, мыгырдаучан, сукрануучан

ворчу́н *м разг.* мыгырдавык, мыгырдык кеше, мыгырдаучы

ворчу́нья *ж разг.* мыгырдык хатын (кыз)

восвояси *нареч. разг.* үз өенә, үз өенә таба; **опра́виться ~** үз өенә китү

восемна́дцатый, -ая, -ое *числ.* унсигезенче

восемна́дцать *числ.* унсигез

во́семь *числ.* сигез

во́семьсо́т *числ.* сигез йөз

во́семью *нареч.* сигез тапкыр, сигез җирдә; **~ три — два́дцать четы́ре** сигез җирдә өчен егерме дүрт

воск *м* балавыз; **пчели́ный ~** умарта балавызы

воскли́кнуть *сов.* кычкыру, кычкырып җибәрү, әйтеп җибәрү; **~ от удивле́ния** гаҗәпләнүдән кычкырып җибәрү

восклица́ни||е *с* кычкыру, кычкыру тавышы, аваз, тавыш; **послы́шались ~я́** кычкыру тавышлары ишетелде

восклица́тельный, -ая, -ое *грам.* өндәү ...ы; **~ знак** өндәү билгесе

восклица́ть *несов. см.* **воскли́кнуть**

воско́вка *ж* восковка, балавызлы кәгазь (*кучермәләр алу өчен*)

восков||о́й, -а́я, -о́е **1.** балавыз ...ы; балавыз ...; **~а́я свеча́** балавыз шәм **2.** *перен.* балавыздай сары, балавыз төсендәге, аксыл сары; **~о́е лицо́** балавыздай сары йөз ◆ **~а́я спе́лость** балавызсыман өлгереш

воскреса́ть *несов. см.* **воскре́снуть**

воскресе́ние *с* **1.** *см.* **воскре́снуть; 2.** *перен.* (*возрождение, обновление*) яңадан туу

воскресе́нье *с* якшәмбе

воскреси́ть *сов.* **1.** *кого, рел.* терелту, үлгәннән соң терелту, җан кертү **2.** *перен. кого-что* (*оживить*) яңадан терелту, яңадан көч бирү, җан кертү **3.** *перен. кого-что* (*восстановить*) күз алдына китерү, китереп бастыру, яңадан искә (хәтергә) төшерү; **~ в па́мяти дни мо́лодости** яшьлек көннәрен яңадан искә төшерү

воскре́сник *м* өмә, якшәмбе өмәсе

воскре́с||нуть *сов.* **1.** *рел.* терелү, үлгәннән соң терелү, җан керү **2.** *перен.* (*стать вновь бодрым*) яңадан туу, көч керү, җан керү **3.** *перен.* күз алдына килү (килеп басу), яңадан искә [хәтергә] төшү; **в па́мяти ~ло про́шлое** үткәннәр яңадан искә төште

воскре́сн||ый, -ая, -ое якшәмбе ..., якшәмбе ...ы; **~ый день** якшәмбе көн; **~ый о́тдых** якшәмбе ялы ◆ **~ая шко́ла** якшәмбе мәктәбе (*Россиядә революцияга кадәр җирле өчен якшәмбе көнне эшли торган мәктәп*)

воскреша́ть *несов. см.* **воскреси́ть**

воспале́ние *с* ялкынсыну; җилсенү; **~ сре́днего у́ха** урта колак ялкынсыну; **~ лёгких** үпкә ялкынсынуы

воспалённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **воспали́ть; 2.** ялкынсынган, җилсенгән; ялкынсынып кызарган, кызарган; **~ые глаза́** җилсенгән күзләр

воспали́тельный, -ая, -ое ялкынсыну ...ы; **~ проце́сс** ялкынсыну процессы

воспали́ть *сов. что* ялкынсындыру, җилсендерү, ялкынсындырып кызарту

воспали́||ться *сов.* ялкынсыну; җилсенү; **глаза́ ~лись** күзләре җилсенгән

воспаля́ть *несов. см.* **воспали́ть**

воспаля́ться *несов. см.* **воспали́ться**

воспари́ть *сов. уст.* очып менү, очып күтәрелү; **~ под облака́** болытлар астына очып күтәрелү ◆ **~ мы́слью** башка фикер килү

воспева́ть *несов. см.* **воспе́ть**

воспе́ть *сов. кого-что, высок.* дан җырлау, данлыклау, мактап җырлау, җырлау (*шигырьләрдә, җырларда*)

воспита́ние *с* **1.** *см.* **воспита́ть; ~ дете́й** балаларны тәрбияләү; **нра́вственное ~ трудя́щихся** хезмәт ияләрен әхлакый яктан тәрбияләү **2.** (*культурные навыки*) тәрбия; **хоро́шее ~** яхшы тәрбия

воспи́танник *м* **1.** (*питомец*) тәрбияләнүче **2.** (*приёмыш*) асрау, асрау бала **3.** укучы, тәмамлаган кеше (укучы); шәкерт; **~ Каза́нского университе́та** Казан университеты тәмамлаган кеше; **~ сувóровского учи́лища** Суворов училищесы укучысы

воспи́танница *ж см.* **воспи́танник**

воспи́танность *ж* (*умение себя вести*) тәрбиялелек, әдәплелек, тәрбияле булу

воспи́танный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **воспита́ть; 2.** тәрбияле, әдәпле; **~ ребёнок** әдәпле бала

воспита́тель *м* тәрбияче, тәрбияләүче, тәрбияләп үстерүче; карап үстерүче

воспита́тельница *ж* тәрбияче хатын (кыз)

воспита́тельн||ый, -ая, -ое тәрбия ...ы, тәрбияләү ...ы, тәрбияви ...ы; **~ая рабо́та** тәрбия эше; **~ое значе́ние** тәрбияви әһәмият; **~ая систе́ма** тәрбияләү системасы

воспита́ть *сов. в разн. знач. кого-что* тәрбияләү, тәрбияләп үстерү, карап үстерү; **~ дете́й** балаларны тәрбияләп үстерү; **~ любо́вь к Ро́дине** Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү

воспита́ться *сов.* тәрбияләнү

воспи́тывать *несов. см.* **воспита́ть**

воспи́тываться *несов.* **1.** *см.* **воспита́ться; 2.** *страд. от* **воспи́тывать**

воспламени́ть *сов.* **1.** *что* (*зажечь*) кабызып җибәрү, кабызу, дөрләтеп җибәрү, дөрләтү **2.** *перен. кого-что* уяту; ялкынландыру, ярсыту, рухландыру, рухландырып (ярсытып) җибәрү

воспламени́ться *сов.* **1.** (*загореться*) кабыну, кабынып (янып) китү, дөрләп яна башлау **2.** *перен.* яна башлау, рухланып китү, ялкынлану

воспламеня́емость *ж* кабынучанлык, кабынып китүчәнлек; **~ горю́чего** ягулыкның кабынучанлыгы

воспламеня́ть *несов. см.* **воспламени́ть**

воспламеня́ться *несов.* **1.** *см.* **воспламени́ться; 2.** *страд. от* **воспламеня́ть**

воспо́лнить *сов. что* тулыландыру, тутыру; **~ пробе́л в зна́ниях** белемдәге житешмәгән якларны тулыландыру

воспо́лниться *сов.* тулылану, тулу

восполня́ть *несов. см.* **воспо́лнить**

восполня́ться *несов.* **1.** *см.* **воспо́лниться; 2.** *страд. от* **восполня́ть**

воспо́льзоваться *сов. чем* файдалану, файдаланып алу, файдаланып калу; **~ слу́чаем** очрактан файдаланып калу

воспомина́ни||е *с* **1.** искә төшерү, хәтергә төшерү; **~ де́тства** балачакны искә төшерү **2.** *мн.* **~я** истәлек[ләр], хәтирә[ләр], истә калганнар; **ве́чер ~й** истәлекләр кичәсе

воспрепя́тствовать *сов. кому-чему* тоткарлау, киртә кую, комачаулау, каршы төшү; **~ продвиже́нию против́ника** дошманның алга таба хәрәкәтен тоткарлау; **~ *чьим-л.* наме́рениям** *кемнең дә булса* теләкләренә каршы төшү

воспреща́||ться *несов.* тыелу, рөхсәт ителмәү; **здесь кури́ть ~ется** биредә тәмәке тарту тыела

воспри́имчивость *ж* **1.** (*способность легко усваивать, понимать*) тиз аңлаучанлык, тиз төшенүчәнлек, зирәклек **2.** тиз бирешүчәнлек, бирешүчәнлек; **~ к инфекцио́нным заболева́ниям** йогышлы авыруларга бирешүчәнлек

воспри́имчивый, -ая, -ое **1.** тиз аңлаучан, тиз төшенүчән, зирәк; **~ ум** зирәк акыл **2.** бирешүчән, тиз бирешүчән; **~ к боле́зням ребёнок** авыруларга тиз бирешүчән бала

воспринима́ть *несов. см.* **воспри́нять**

воспринима́ться *несов.* **1.** кабул ителү, үзләштерелү **2.** *страд. от* **воспринима́ть**

воспри́нять *сов. что* **1.** алу, кабул итү **2.** (*понять*) үзләштерү, төшенү, отып алу

воспри́яти||е *с филос., психол.* [аңга] кабул итү, үзләштерү; [аңга] алу; **зако́ны ~я** үзләштерү законнары; **~е ребёнка** баланың анга алуы

воспроизведе́ние *с* **1.** *см.* **воспроизвести́; 2.** (*копия*) күчермә

воспроизвести́ *сов. что* **1.** (*создать вновь*) яңадан җитештерү, кабат җитештерү; яңадан үстерү **2.** ясау, күчереп ясау; **~ карти́ну** картинаны күчереп ясау

воспроизводи́ть *несов. см.* **воспроизвести́**

воспроизво́дство *с* яңадан җитештерү, кабат җитештерү; яңадан үстерү; **простóе ~** *эк.* гади кабат җитештерү; **расши́ренное ~** *эк.* киңәйтелгән кабат җитештерү; **~ приро́дных ресу́рсов** табигать ресурслары яңадан җитештерү

воспроти́виться *сов. кому-чему* каршы төшү, каршы килү, каршылык күрсәтү; **~ реше́нию** карарга каршы төшү

воспря́нуть *сов.*: **~ ду́хом** күңеле күтәрелеп китү; рухланып китү, дәртләнеп китү; **~ ото сна́** йокыдан уяну

воспыла́ть *сов. чем, книжн.* яну, яна башлау; **~ не́навистью** нәфрәт белән яну

восседа́ть *несов. шутл.* тантаналы рәвештә утыру

воссе́сть *сов. уст.* менеп утыру, тантаналы рәвештә менеп утыру; **~ на престо́л** тантаналы рәвештә тәхеткә менеп утыру

восслáвить *сов. кого-что, высок.* данлыклау, дан җырлау; мәдхия уку; **~ побе́ду** җиңүне данлыклау

восславля́ть *несов. см.* **восслáвить**

воссоедине́ние *с см.* **воссоедини́ть, воссоедини́ться; ~ Украи́ны с Росси́ей** *ист.* Украинаның Россия белән яңадан кушылуы

воссоедини́ть *сов. кого-что* яңадан кушу, яңадан берләштерү

воссоедини́ться *сов.* яңадан кушылу, яңадан берләшү

воссоединя́ть *несов. см.* **воссоедини́ть**

воссоединя́ться *несов.* **1.** *см.* **воссоедини́ться; 2.** *страд. от* **воссоединя́ть**

воссоздава́ть *несов. см.* **воссозда́ть**

воссозда́ть *сов. что* **1.** (*создать вновь*) торгызу, яңадан барлыкка китерү **2.** (*восстановить в памяти*) хәтергә китерү, хәтергә (искә) төшерү **3.** (*творчески воспроизвести*) иҗат итү, яңадан торгызу

восстава́ть *несов. см.* **восста́ть**

восстана́вливать *несов. см.* **восстанови́ть**

восстана́вливаться *несов.* **1.** *см.* **восстанови́ться; 2.** *страд. от* **восстана́вливать**

восста́ние *с* восстание, баш күтәрү; **вооружённое ~** кораллы восстание

восстанови́тель *м* **1.** (*рабочий*) яңадан торгызучы, аякка бастыручы, яңадан төзүче **2.** (*для волос*) төс кайтаргыч **3.** *хим.* яңадан кайтаргыч матдә

восстанови́тельный, -ая, -ое торгызу ...ы, яңадан торгызу, аякка бастыру ...ы; **~ пери́од** [хуҗалыкны] торгызу чоры

восстанови́ть *сов.* **1.** *что* торгызу, яңадан торгызу, аякка бастыру, төзәтү; **~ разру́шенное хозя́йство** жимерелгән хуҗалыкны яңадан торгызу **2.** *кого* кайтару, кире кайтару, кире бирү, кире кую; **~ в права́х** хокукларын кире кайтару; **~ в до́лжности** эшләгән урнына кире кую **3.** *кого-что* (*враждебно настроить*) каршы кую; дошманлаштыру, дошманлык тойгысы уяту **4.** *перен. кого-что* (*воспроизвести*) күз алдына китерү, [хәтергә] төшерү, [искә] төшерү; **~ в па́мяти** хәтергә төшерү

восстанови́||ться *сов.* **1.** [яңадан] башлау, аякка басу; төзәлү, элекке хәленә кайту; **~лось движе́ние поезло́в** поездлар яңадан йөри башладылар; **здоро́вье его́ ~лось** аның сәламәтлеге төзәлде **2.** *в чём* кире кайтарып алу, кире кайтару; кире куелу; **~ться в права́х** хокукларны кире кайтарып алу **3.** *перен.* (*вновь возникнуть в памяти*) күз алдына килү, [хәтергә] төшү, [искә] төшү

восстановле́ни||е *с см.* **восстанови́ть** 1, 2, 4, **восстанови́ться**

восста́||ть *сов.* **1.** баш күтәрү, восстание күтәрү; **~вшие рабы́** баш күтәргән коллар **2.** (*не согласиться с кем-чем-л.*) каршы чыгу, баш күтәрү, каршы төшү; каршы күтәрелү

восто́к *м* **1.** (*страна света*) көнчыгыш, шәрык **2.** (*с прописной*) Көнчыгыш; **Бли́жний Восто́к** Якын Көнчыгыш; **Сре́дний Восто́к** Урта Көнчыгыш

востоково́д *м* көнчыгышны өйрәнүче, шәрыкне өйрәнүче, көнчыгышны өйрәнү белгече

востоково́дение *с* көнчыгышны өйрәнү, шәрыкне өйрәнү фәне

востоково́дческ||ий, -ая, -ое көнчыгышны өйрәнү ...ы; **~ие нау́ки** көнчыгышны өйрәнү фәннәре

восто́рг *м* соклану, таңга калу; зур кауныч; **прийти́ в ~** таңга калу; **приводи́ть в ~** таңга калдыру

восторга́ть *несов. кого-что* таңга калдыру, сокландыру, ис китәрү

восторга́ться *несов. кем-чем* соклау, таңга калу, ис китү

восто́рженность *ж* сокланучанлык, таңга калучанлык, ис китүчәнлек

восто́рженн||ый, -ая, -ое **1.** сокланучан, таңга калучан, исе китүчән; **~ый челове́к** сокланучан кеше **2.** сокланган, таңга калган, сокланып, таңга калып, ис китеп; **~ый взгляд** сокланып карау; **~ая похвала́** ис китеп мактау

восторжествова́ть *сов. над кем-чем, высок.* җиңү, җиңеп чыгу, өстен чыгу

восто́чн||ый, -ая, -ое көнчыгыш, көнчыгыш ...ы, көнчыгыштан; көнчыгыштагы; **~ые стра́ны** көнчыгыштагы илләр; **~ый ве́тер** көнчыгыштан җил

востре́бовани||е *с*: **до ~я** сорап алу өчен; **вкла́ды до ~я** сорап алганга кадәр салынган акча

востре́бовать *сов. что* сорап алу, таләп итү; **~ бага́ж** багажны сорап алу

востро́ *нареч.*: **держа́ть у́хо ~** *разг.* уяу булу, бик сак булу, сизгер тору

востру́шка *ж разг.* бөтерчә кыз, бик тере кыз

восхвале́ние *с* **1.** *см.* **восхваля́ть; 2.** (похвала) мәдхия, бик нык мактау

восхваля́ть *несов. кого-что* бик нык мактау, күкләргә күтәрү, мәдхия уку

восхити́тельный, -ая, -ое сокландыргыч, таң калдыргыч; ис китәрлек; **~ го́лос** сокландыргыч тавыш

восхити́ть *сов. кого-что* таң калдыру, сокландыру, хәйран калдыру

восхити́ться *сов. кем-чем* таң калу, соклану, ис китү, хәйран калу

восхища́ть *несов. см.* **восхити́ть**

восхища́ться *несов. см.* **восхити́ться**

восхище́ние *с* таңга калу, соклану, ис китү; **смотре́ть с ~м** ис китеп карап тору

восхо́д *м* чыгу (*кояш турында*); калку (*ай турында*); **на ~е со́лнца** кояш чыкканда; **~ луны́** айның калкуы

восходи́ть *несов.* **1.** *см.* **взойти́** 1, 2; **2.** *к чему* барып тоташу, барып бәйләнү, ...дан килү; **мно́гие обы́чаи восхо́дят к дре́вности** бик күп гореф-гадәтләр борынгы заманнардан килә

восходя́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **восходи́ть; 2.** күтәрелә барган, күтәрелә бара торган; **~ая ли́ния** күтәрелә бара торган сызык ♦ **~ее светúло** *или* **~ая звездá** яңа йолдыз (*зур данга ия булып барган кеше турында*); **~ее ударе́ние** *лингв.* күтәрелмә басым

восхожде́ние *с см.* **взойти́** 1; **~ на Эвере́ст** Эверестка менү

восше́ствие *с уст.*: **~ на престо́л** тәхеткә менеп утыру

восьмери́к *м уст.* сигезле, сигез үлчәүле, сигез кисәткән гыйбарәт; **ги́ря-~** сигез кадаклы гер

восьмёрка *ж разг.* **1.** (*цифра*) сигезлек, сигез саны **2.** (*группа из восьми*) сигез; **~ самолётов** сигез самолёт **3.** *разг.* сигезенче; сигезле (*трамвай, троллейбус һ.б.ш.*) **4.** (*восьмивесельная лодка*) сигез ишкәкле көймә **5.** *карт.* сигезле

во́сьмеро *числ. собир.* сигезәү, сигез

восьми- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, «сигез», «сигездән гыйбарәт», «сигезле» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **восьмигра́нный** сигез кырлы; **восьмичасово́й** сигез сәгатьлек

восьмигра́нник *м* сигезкырлык

восьмигра́нный, -ая, -ое сигез кырлы

восьмидесятиле́тний, -ая, -ое **1.** (*о сроке*) сиксән еллык **2.** (*о возрасте*) сиксән яшьлек

восьмидеся́т||ый, -ая, -ое сиксәненче; **в ~ые го́ды** сиксәненче елларда; **~ый но́мер** сиксәненче номер

восьмидне́вный, -ая, -ое сигез көнлек ...; **~ срок** сигез көнлек срок

восьмикла́сник *м* сигезенчедә укучы

восьмикла́сница *ж* сигезенчедә укучы кыз

восьмиле́тн||ий, -яя, -ее **1.** сигезьеллык ...; **~яя шко́ла** сигезьеллык мәктәп **2.** сигез яшьлек ...; **~яя де́вочка** сигез яшьлек кызчык

восьмисо́тый, -ая, -ое *числ.* сигезенче

восьмиуго́льник *м* сигезпочмаклык, сигезпочмак

восьмичасово́й, -а́я, -о́е сигез сәгатьлек; **~ рабо́чий день** сигез сәгатьлек эш көне; **~ по́езд** *разг.* сигез сәгатьтә килә (китә) торган поезд

восьмо́й, -а́я, -о́е *числ.* сигезенче

восьму́шка *ж уст.* **1.** (1/8 *фунта*) бер әчмуха, әчмуха; **~ табаку́** бер әчмуха тәмәке; **~ ча́ю** бер әчмуха чәй; **2.** сигездән бер өлеш; **~ бума́жного листа́** кәгазь табагының сигездән бер өлеше

вот *частица* **1.** *указ.* әнә, менә; **~ по́езд идёт** әнә поезд килә; **~ наш дом** менә безнең өй **2.** *указ., усил.* менә; **во́т что я тебе́ скажу́** әмин сиңа менә нәрсә әйтим; **во́т в чём вопро́с** мәсьәлә менә нәрсәдә; **~ послу́шайте, что говоря́т** менә тыңлагыз әле, нәрсә сөйлиләр ♦ **во́т ещё!** тагын нәрсә!; **~ и ...** ... менә инде; **во́т как!** шулаймыни!; менә ничек!; **во́т [оно] что!** менә нәрсә икән!; **во́т так!** менә шулай!; **во́т тебе!** мә сиңа!; **~ тебе́ и** ... менә сиңа ...; **~ тебе́ и пра́здник!** менә сиңа бәйрәм!; **во́т тебе [и] на́ (раз)!** менә сиңа кирәк булса!; менә сиңа мә!

вот-во́т *разг.* **1.** *частица* (*вот именно, именно так*) менә шулай шул, шул-шул, менә шулай **2.** *нареч.* менә-менә, менә хәзер, менә хәзер генә; менә генә, әле генә; **он ~ придёт** ул менә-менә килә

вотиро́вать *сов., несов. что, книжн.* тавышка куеп карар кабул итү, карар чыгару; **~ креди́ты** кредитлар буенча карар чыгару

вотка́ть *сов. что* түпләмләп сугу, түпләмләп туку

воткну́ть *сов. что во что* кадау, чәнчү, кадап кую, чәнчеп, кую; **~ була́вку в пла́тье** булавканы күлмәккә кадап кую

воткну́ться *сов.* кадалу, чәнчелү

во́тум *м* вотум (*парламентларда: тавыш биреп кабул ителгән карар*) ♦ **~ дове́рия** ышаныч белдерү карары; **~ недове́рия** ышанмауны белдерү карары

во́тчина *ж ист.* вотчина, биләмә (*ата-бабадан килгән биләмә*)

вотяки́ *мн. уст.* арлар (*удмуртларның элекке исеме*)

воцари́||ться *сов.* **1.** урнашу, чолгап алу; **~лась тишина́** тынлык урнашты **2.** *уст.* (*начать царствовать*) патшалык итә башлау

воцаря́ться *несов. см.* **воцари́ться**

вошь *ж* бет ♦ **расти́тельная ~** үлән бете

вощ|а́нка *ж* балавызланган кәгазь (тукыма)

вощён||ый, -ая, -ое балавызлы, балавызланган, балавыз сеңдерелгән; **~ые ни́тки** балавызланган җепләр

вощи́на *ж* **1.** (*соты*) кәрәз **2.** (*воск*) балавыз

вощи́ть *несов. что* балавызлау, балавыз сеңдерү; **~ ни́тки** җепләрне балавызлау

вояка *м разг. ирон.* (*задира*) сугыш чукмары

впада́ть *несов.* **1.** *см.* **впа́сть; 2.** (*о реке, ручье*) кою, кушылу

впаде́ние *с* **1.** *см.* **впа́сть** 2; **2.** (*устье реки́*) елга тамагы, кушылган урын

впа́дина *ж* **1.** чокыр, батынкы урын; **глазна́я ~** *анат.* күз чокыры **2.** (*небольшая долина*) иңкүлек

впа́йка *ж* **1.** *см.* **впаять; 2.** (*то, что впаяно*) эретеп ябыштырылган нәрсә

впа́л||ый, -ая, -ое эчкә баткан, эчкә кергән; эчкә кысылган, батынкы; **~ые щёки** эчкә баткан яңаклар

впасть *сов.* **1.** эчкә бату, эчкә керү; **щёки у него́ впа́ли** яңаклары эчкә баткан **2.** *перен. во что* бирелү, килү, төшү; **~ в отча́яние** өметсезлеккә бирелү ♦ **~ в де́тство** балага әйләнү; **~ в противоре́чие** үз-үзеңә каршы килү

впая́ть *сов. что* эретеп ябыштыру, эретеп ябыштырып кую

впервы́е *нареч. разг.* (*обычно с отриц.*) *см.* **впервые́; э́то не ~** бу аңа беренче түгел

впервы́е *нареч.* беренче тапкыр, беренче мәртәбә

впереба́й *нареч. разг.* бер-берсен бүлдереп, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә

вперева́лку *нареч. разг.* алпан-тилпән, ава-түнә; **ходи́ть ~** алпан-тилпән йөрү

вперегонки́, вперего́нки *нареч. разг.* куышып, узышып, узыша-узыша, куыша-куыша; **бежа́ть ~** узыша-узыша йөгерү

вперёд *нареч.* **1.** алга, алга табан; **идти́ ~** алга бару; **шагну́ть ~** алга атлау **2.** *разг.* алда, киләчәктә, моннан ары; **~ бу́дьте осторо́жнее** киләчәктә саграк булыгыз **3.** *разг.* элек, башта; **~ посмотри́те** башта карагыз **4.** алдан; **получи́ть зарпла́ту ~** эш хакын алдан алу **5.** *в знач. межд.* алга; **взвод, ~!** взвод, алга! ♦ **взад и ~** әрле-бирле; **шаг ~** бер адым алга; **часы́ ушли́ ~** сәгать алга киткән

впереди́ 1. *нареч.* алда, алдан; каршыда; **~ был лес** алда урман иде; **идти́ ~ всех** барысыннан да алда бару **2.** *нареч.* алда, киләчәктә; **у нас всё ~** безнең әле барсы да алда **3.** *предлог с род.п.* алдында, алдыннан; **идти́ ~ взво́да** взвод алдыннан бару

впереме́жку *нареч.* алмашлап, аралаш, алмаш-тилмәш; аралашып; **берёзы росли́ ~ с е́лями** каеннар чыршылар белән аралашып үскәннәр

впереме́жку *нареч.* аралаш, буталып, аралашып; **кни́ги лежа́ли ~ с тетра́дями** китаплар дәфтәрләр белән буталып яталар иде

вперехва́т *нареч. прост.* **1.** әйләндереп алып, чолгап алып; **взя́ть ~** әйләндереп алып бәйләү **2.** (*наперерез*) юлын кисеп, юлына аркылы төшеп

впери́ть *сов.*: **~ взор (взгляд, глаза́)** күз текәү, төбәп карау

вперя́ть *несов. см.* **впери́ть**

впечатле́ни||е *с* **1.** тәэсир, истәлек, күнелдәге әз; **~я де́тства** балачакның тәэсирләре **2.** тәэсир, йогынты; **находи́ться под ~ем** *чего-л. берәр нәрсәнең* тәэсирендә булу; **производи́ть благоприя́тное ~е** яхшы тәэсир калдыру **3.** тәэсир, фикер; **дели́ться ~ями** тәэсирләр белән уртаклашу

впечатли́тельность *ж* тәэсирләнүчәнлек, тәэсирләнүчән булу; йомшак күнеллелек

впечатли́тельный, -ая, -ое тәэсирләнүчән, тәэсиргә тиз бирелүче, йомшак күнелле; **~ челове́к** тәэсирләнүчән кеше

впечатля́ть *несов. разг.* тәэсир итү, тәэсир калдыру

впечатля́ющ||ий, -ая, -ое тәэсирле, нык тәэсир итә торган; **~ее зре́лище** нык тәэсир итә торган тамаша

впива́ть *несов. что*: **~ зву́ки му́зыки** музыка тавышларын йотылып тыңлау; **~ за́пах ле́са** урман исен иснәү

впива́ться *несов. см.* **впи́ться**

впи́санный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **вписа́ть; 2.** *мат.* камаулы, камалган; **~ треуго́льник** камалган өчпочмак

вписа́ть *сов.* **1.** *кого-что* өстәп язу, өстәп язып кую, арага кертеп язу; **~ пропу́щенные слова́** төшеп калган сүзләрне арага кертеп язу **2.** *что, мат.* эченә сызу, эченә сызып кую, камап сызу; **~ треуго́льник в окру́жность** әйләнә эченә өчпочмак сызу

вписа́ться *сов. во что* (*гармонично сочетаться*) матур туры килү, туры килеп тору

впи́сывание *с см.* **вписа́ть**

впи́сывать *несов. см.* **вписа́ть**

впи́сываться *несов.* **1.** *см.* **вписа́ться; 2.** *страд. от* **впи́сывать**

впита́ть *сов. что* **1.** сеңдерү, сеңдереп бетерү, суыру, суырып алу; **~ вла́га** дымны сеңдереп бетерү **2.** *перен.* үзләштерү, үзенә сеңдерү; үзенә алу; **~ культу́ру пре́дков** ата-бабаларның мәдәниятен үзенә сеңдерү

впита́||ться *сов.* сеңү, суырылу, сеңеп бетү; **вла́га ~лась в по́чву** дым туфракка сеңеп бетте

впи́тывать *несов. см.* **впита́ть**

впи́тываться *несов.* **1.** *см.* **впита́ться; 2.** *страд. от* **впи́тывать**

впи́||ться *сов.* **1.** кадалу, кадалып керү; **клещ ~лся** талпан кадалган; **пия́вка ~ла́сь** сөлек кадалган **2.** батыру, батырып кертү; **~ться зуба́ми** тешләрне батырып кертү **3.** кадалу, керү; **була́вка ~ла́сь в па́лец** булавка бармакка кадалды **4.** *в кого-что чем и без доп.* текәлү, кадалу, күзләрне текәү; **~ться глаза́ми** күзләре белән кадалу (текәләп карау); **~ться в глаза́** *кому-л.* күзләргә текәлү; **~ться в кни́гу** китапка кадалу

впи́хивать *несов. см.* **впихну́ть**

впихну́ть *сов. кого-что, разг.* тыгу, тыгып кую, кертү, кертеп кую; (*втолкнуться*) этәреп кертү

вплавь *нареч.* йөзеп; **переправи́ться че́рез ре́ку ~** елга аша йөзеп чыгу

вплести́ *сов. что* кушып үрү, кушып үреп кую, кертеп үрү; **~ ле́нту в косу́** тасманы толымга кушып үрү

вплета́ть *несов. см.* **вплести́**

вплотну́ю *нареч.* **1.** (*тесно*) бик тыгыз итеп, бик тыгыз булып **2.** (*предельно близко*) бик якын, янәшә үк, терәлеп; **сиде́ть ~** терәлеп утыру **3.** *перен. разг.* ныклап, бик якыннан торып; **взя́ться за де́ло ~** эшкә ныклап тотыну

вплоть *нареч.*: **~ до** ...га кадәр, ...га чаклы; **~ до ве́чера** кичкә кадәр

вплыва́ть *несов. см.* **вплыть**

вплыть *сов.* **1.** йөзеп барып керү, йөзеп килеп керү, йөзеп керү **2.** *перен.* (*плавно войти*) салмак кына килеп керү

вповалку *нареч. разг.* тезелешеп, янәшә ятып; **спать ~** янәшә ятып йоклау

вполгла́за *нареч. разг.* күз кырые (чите) белән генә; **наблюда́ть ~** күз кырые белән генә күзәтү

вполго́лоса *нареч.* акрын гына тавыш белән; **петь ~** акрын гына тавыш белән җырлау

вползá́ть *несов. см.* **вползти́**

вползти́ *сов.* **1.** (*внутрь*) шуышып керү **2.** (*взобраться куда-л., на что-л.*) шуышып менү, үрмәләп менү

вполнака́ла *нареч.* сүрән генә, бик тоныk

вполне́ *нареч.* тулысынча, бик, бөтенләй, тәмам; **он ~ дово́лен** тулысынча канәгать

вполоборо́та *нареч.* яртылаш борылып, яртылаш борылган килеш

вполови́ну *нареч. уст. прост.* яртылаш, яртылай

впопа́д *нареч. разг.* урынлы, дөрес, туры китереп; **отвеча́ть ~** урынлы җавап бирү

впопыха́х *нареч.* ашык-пошык, ашыгып, ашыккан хәлдә, кабаланып

впо́ру *нареч.* **1.** таман гына, чак кына; **сапоги́ мне ~** итекләр миңа таман гына **2.** *в знач. сказ. с неопр., разг.* (*только и остаётся*) мөмкин, бик мөмкин; бик вакыт; **мне ~ уе́хать домо́й** миңа өйгә китәргә бик вакыт

впорхну́ть *сов.* **1.** (*влететь*) очып кереп китү, очып килеп керү, очып керү **2.** *перен.* очынып килеп керү

впосле́дствии *нареч.* соңыннан, шуннан соң, аннан соң, ахырда

впотьма́х *нареч.* караңгыда; утсыз (*төнлә*)

впра́ву *нареч. разг.* чынлап та, чынлап та, дөрестән дә

впра́ве *нареч. в знач. сказ. с неопр.* хаклы, хакы бар; **он ~ спроси́ть об э́том** аның моны сорарга хакы бар

впра́вить *сов. что* урнына утыртү, урнына утыртып кую (*тайган, каймыккан әгъзаны*); **~ па́лец** (*тайган*) бармакны урнына утырту ♦ **~ мозги́** *кому, прост.* акылга утырту

вправля́ть *несов. см.* **впра́вить**

впра́во *нареч.* (*в правую сторону*) унга, уң якка; (*в правой стороне*) унда, уң якта; **поверну́ть ~** уң якка бору; **~ от до́ма** өйдән унда

впредь *нареч.* алда, киләчәктә, моннан ары, моннан соң, моннан болай ♦ **~ до** *чего* ...га кадәр, ...га чаклы; **~ до разреше́ния** рөхсәт иткәнгә кадәр

вприку́ску *нареч.*: **пить ~** (*чай, кофе и т.п.*) шикәрне тешләп эчү (*чәй, кофе һ.б.ш. белән*)

вприпры́жку *нареч.* сикерә-сикерә, сикерешә-сикерешә, сикергәләп

вприся́дку *нареч.* чүгәли-чүгәли, чүгә-чүгә, чүгәләп; **плеса́ть ~** чүгәли-чүгәли бию

вприти́рку *нареч. разг.* (*вплотную*) янәшә үк, бер-берсенә тиеп

вприти́к *нареч. см.* **вприти́рку**

впро́голодь *нареч.* ачлы-туклы, туяр-туймас

впрок *нареч.* **1.** (*про запас*) алдагы көнгә, саклыкка, киләчәккә, запаска, запас итеп **2.** (*на пользу*) файдага, яхшыга; **э́то не пошло́ ему́ ~** бу аңа файдага булмады

впроса́к: попа́сть ~ ике такта арасында калу, уңайсыз хәлгә килеп кабу, уңайсыз хәлгә эләгү

впросо́нках *нареч. разг.* йокы аралыш, уянып-уянмас

впро́чем *союз* **1.** *против.* әмма, ләкин, шуңа карамастан **2.** *в знач. вводн. сл.* хәер; **~, не зна́ю, реша́й сам** хәер, мин белмим, үзең хәл ит

впры́гивать *несов. см.* **впры́гнуть**

впры́гнуть *сов.* (*во что-л.*) сикерү, сикереп керү; (*на что-л.*) сикереп менү; **~ в ло́дку** көймәгә сикереп керү; **~ на сту́л** урындыкка сикереп менү

впры́скивать *несов. см.* **впры́снуть**

впры́снуть *сов. что* җибәрү, (*тире астына*) кертү (*дару*); **~ больно́му мо́рфий** авыруга морфий җибәрү

впряга́ть *несов. см.* **впрячь**

впряга́ться *несов.* **1.** *см.* **впря́чься; 2.** *страд. от* **впряга́ть**

впрямь *частица разг.* чыннан да, дөрестән дә, чынлап та

впрячь *сов. кого-что* җигү, кушып җигү; **~ лошаде́й в са́ни** атларны чанага җилү ♦ **~** *кого* **в рабо́ту** эшкә җигү

впря́чься *сов.* җигелү, үзен җигү ♦ **~ в рабо́ту** эшкә җигелү

впуск *м см.* **впусти́ть; ~ пассажи́ров на перро́н** пассажирларны перронга үткәрү

впуска́ть *несов. см.* **впусти́ть**

впускно́й, -а́я, -о́е *тех.* кертү ...ы; **~ кла́пан** кертү клапаны

впусти́ть *сов.* **1.** *кого-что* кертү, җибәрү; кертеп җибәрү, үткәрү; **~ пар в тру́бы** буны торбаларга җибәрү; **~ зри́телей в зал** тамашачыларны залга кертеп җибәрү; **2.** *что* салу, тамызу; **~ ка́пли в нос** тамчыларны борынга салу

впусту́ю *нареч.* бушка, юкка, әрәмгә, җилгә; **говори́ть ~** бушка сөйләү

впу́тать *сов.* **1.** *что* (*вплести*) кушып үрү , чуалтып бәйләү, кушып бәйләү **2.** *перен. кого-что, разг.* бутау, катыштыру (*берәр эшкә*)

впу́таться *сов.* **1.** (*запутаться*) чуалу, чуалып бетү **2.** *перен. разг.* чуалу, буталу, катышу (*берәр эштә*)

впу́тывать *несов. см.* **впу́тать**

впу́тываться *несов.* **1.** *см.* **впу́таться; 2.** *страд. от* **впу́тывать**

впя́теро *нареч.* биш мәртәбә (тапкыр), бишләтә; **~ бо́льше** биш тапкыр зур

впятеро́м *нареч.* бишәүләп, бишәүләшеп, бишәү

в-пя́тых *вводн. сл.* бишенчедән, бишенчеләй

враг *м* дошман; **кла́ссовый ~** сыйнфый дошман; **разби́ть ~а́** дошманны тар-мар итү ♦ **~ у́ тако́го не пожела́ю** дошманыма да аны теләмим

вражд||а́ *ж* дошманлык, дошманлык хисе, кинә, хаслык; **пита́ть** *к кому-л.* **~ у́** *кемгә дә карата булса* дошманлык хисе булу

вражде́бность *ж* дошманлык, хаслык

вражде́бн||ый, -ая, -ое **1.** дошманлык ...ы, дошманнарча ..., дошман ...; **~ое отноше́ние** дошманлык мөнәсәбәте **2.** дошман ...; дошман ...ы; **~ые сто́роны** дошман яклар

вражду́ва́ть *несов.* дошманлашу, бер-бере белән дошман булу, дошманлык итү; **~ друг с дру́гом** бер-бере белән дошман булу

вра́жеский, -ая, -ое дошман ...ы; **~ самолёт** дошман самолёты

вра́ж||ий, -ья, -ье *фольк. см.* **вра́жеский ♦ ~ья си́ла** ≈ шайтан, җен

враз *нареч. разг.* **1.** (*одновременно*) берьюлы, бердән, дәррәү, бергә; **все ~ закрича́ли** барысы бердән кычкырып җибәрделәр **2.** (*сразу*) шунда ук

вразби́вку *нареч. разг.* бүлеп-бүлеп, аралаштырып, тәртипсез рәвештә; **спра́шивать ~** тәртипсез рәвештә сорашу

вразбро́д *нареч. разг.* **1.** (*порознь*) чәчелеп, сибелеп, таралышып **2.** (*недружно*) таркау, аерым-аерым. һәрберсе үз алдына; **де́йствовать ~** аерым-аерым хәрәкәт итү

вразбро́с *нареч. разг.* чәчелеп, таралып; **кни́ги лежа́ли ~** китаплар чәчелеп ята иде

вразва́лку *нареч.* (*переваливаясь*) айкала-чайкала, алпан-тилпән; **идти́ ~** айкала-чайкала бару

вразнобо́й *нареч.* аерым-аерым, таркау рәвештә, ничек җитте шулай; **де́йствовать ~** таркау рәвештә хәрәкәт итү

вразре́з: идти́ ~ *с чем* каршы килү (бару); каршы әйтү

вразря́дку *нареч. полигр.* хәрефләрне сирәкләтеп (сирәк итеп); **набра́ть сло́во ~** сүзне хәрефләрен сирәкләтеп җыю

вразуми́тельный, -ая, -ое аңлаешлы, ачык аңлаешлы, кеше аңларлык, кеше төшенерлек; **~ отве́т** аңлаешлы җавап

вразуми́ть *сов. кого-что* акылга утыртү, акылга өйрәтү, үгетләп акылга утырту; **~ шалуна́** шаян малайны акылга өйрәтү

вразумля́ть *несов. см.* **вразуми́ть**

вра́ки *только мн. разг.* ялган, ялган сүз, юк сүз, уйдырма

враль *м разг.* ялганчы, алдакчы

враньё *с* **1.** *см.* **врать; 2.** *см.* **вра́ки**

враска́чку *нареч. разг.* алпан-тилпән, ава-түнә, айкала-чайкала; **идти́ ~** алпан-тилпән бару

враспло́х *нареч.* көтмәгәндә, искәрмәстән; капылт, кинәт; **заста́ть ~** көтмәгәндә килеп чыгу

врассыпну́ю *нареч.* төрлесе төрле якка, таралышып; **побежа́ть ~** төрлесе төрле якка йөгереп китү

врастá́ть *несов. см.* **врасти́**

врасти́ *сов.* кереп үсү; батып керү; **но́готь врос в те́ло** тырнак тәнгә кереп үскән

врастя́жку *нареч.* **1.** сузылып; **лежа́ть ~** сузылып яту **2.** сузып, сузып-сузып; **говори́ть ~** сузып сөйләү

врата́ *только мн. книжн.* ишек, капу; **~ ра́я** оҗмах ишеге; **у врат ра́я** оҗмах ишеге алдында

врата́рь *м спорт.* капкачы

врать *несов.* **1.** ялганлау, ялган сөйләү, алдау **2.** дөрес ...мау, хата җибәрү; **часы́ врут** сәгать дөрес йөрми; **~ в пе́нии** дөрес җырламау

врач *м* табиб; врач

врачебн||ый, -ая, -ое врач[лар] ...ы; табиб ...ы; **~ая по́мощь** табиб ярдәме; **~ая коми́ссия** табиблар комиссиясе

врачева́ть *несов. кого-что, уст.* дәвалау; **~ неду́ги** авыруларны дәвалау

враща́тельн||ый, -ая, -ое **1.** әйләндерә торган, әйләндерүче, әйләндерү ...ы; **~ая си́ла** әйләндерүче көч **2.** әйләнмә ..., әйләнмәле, әйләнү ...ы; **~ое движе́ние** әйләнмә хәрәкәт

враща́ть *несов. что, чем* әйләндерү, бөтерү, бору ♦ **~ глаза́ми (белка́ми)** күзләрне әйләндерү; күз аклары белән карау

враща́||ться *несов.* **1.** әйләнү, бөтерелү; **Луна́ ~ется вокру́г Земли́** Ай Жир тирәсендә әйләнә **2.** *перен.* булу, болгану, аралашу; **~ться среди́ актёров** актёрлар арасында булу **3.** *страд. от* **враща́ть**

враще́ние *с см.* **враща́ть, враща́ться** 1; **~ Земли́ вокру́г свое́й оси́** Җирнең үз күчәре тирәсендә әйләнүе

вред *м* зарар, зыян; **причини́ть ~** зыян китерү

вреди́тель *м* корткыч

вреди́тельск||ий, -ая, -ое корткыч ...ы. корткычлар ...ы, корткычлык ...ы; **~ая гру́ппа** корткычлар төркеме

вреди́тельство *с* корткычлык

вреди́ть *несов. кому-чему* зарар китерү, зыян китерү, зарарлау

вре́дность *ж* **1.** зарарлылык, зыянлылык, зарар; **~ куре́ния** тәмәке тартуның зарарлылыгы **2.** зарарлылык, зарарлы шартлар; **дополни́тельный о́тпуск за ~** зарарлы шартлар өчен өстәмә ял

вре́дн||ый, -ая, -ое зарарлы, зыянлы; **~ая привы́чка** зарарлы гадәтләр; **~ые приме́си** зарарлы кушылмалар

вредоно́сн||ый, -ая, -ое *книжн.* үтә зарарлы [булган]; зыян (зарар) китерә торган; **~ые де́йствия** үтә зарарлы кыланышлар

вре́зать *сов. что во что* уеп кую, уеп урнаштыру; **~ замо́к в дверь** ишеккә уеп йозак кую

врезáть *несов. см.* **вре́зать**

вре́за||ться *сов.* **1.** барып керү, ярып керү, барып төртелү; **ло́дка ~лась в песо́к** көймә комга барып төртелде **2.** кереп тору, кереп китү; **песча́ная коса́ ~лась в мо́ре** ком сырты диңгезгә кереп киткән **3.** *перен.* бәреп керү, бәреп килеп керү; **ко́нница ~лась в неприя́тельские ряды́** атлы гаскәр дошман сафларына бәреп килеп керде **4.** *перен.* калу, сенү; урнашу; **~ться в па́мять** хәтердә калу

врезáться *несов.* **1.** *см.* **вре́заться**; **2.** *страд. от* **врезáть**

врезно́й, -а́я, -о́е уеп куелган, уеп урнаштырылган; уеп куела торган; **~ замо́к** уеп куелган йозак

вре́зывать *несов. см.* **вре́зать**

вре́зываться *несов.* **1.** *см.* **вре́заться**; **2.** *страд. от* **вре́зывать**

временáми *нареч.* вакыт-вакыт, аратирә, кайчакта, кайвакытта; **~ шёл дождь** вакыт-вакыт яңгыр ява иде

временн||о́й, -а́я, -о́е вакыт ...ы; **~а́я после́довательность** вакыт эзлеклелеге

вре́менн||ый, -ая, -ое вакытлы; вакытлыча ...; **~ая постро́йка** вакытлы корылма; **~ые неуда́чи** вакытлы уңышсызлыклар

временщи́к *м* вакытлы хаким, вакытлы хакимият иясе

вре́м||я *с* **1.** вакыт; **со́лнечное ~я** кояш вакыты; **~я идёт** вакыт уза; **~я тя́нется** вакыт сузыла; **~я жа́твы** урак вакыты (өсте); **в осе́ннее ~я** көз вакыты; **~ена го́да** ел фасыллары; **~я по Гри́нвичу** Гринвич вакыты белән; **~я начина́ть** башларга вакыт **2.** (*период*) вакыт, чор, заман; **вое́нное ~я** сугыш вакыты; **в ду́хе ~ени** заман рухында **3.** (*момент*) вакыт, чак; мизгел **4.** *грам.* заман ♦ **во ~я о́но** *уст.* әллә кайчан, хан заманында; **во все ~ена́** һәрвакыт, гел; **в пе́рвое ~я** башта, беренче вакытта; **в своё ~я** заманында, үз вакытында; **до поры́ до ~ени** билгеле бер вакытка кадәр; көне килгәнче, сәгате сукканчы; **до сего́ ~ени** бу вакытка кадәр, хәзергә кадәр; **на ~я** вакытлыча; **со ~енем** вакытлар узу белән, киләчәктә, бара-бара, тора-бара; **всё ~я** гел, һәрвакыт; **са́мое ~я** нәкъ вакыты; **тем ~енем** шул ук вакытта; **~я от ~ени** вакыт-вакыт, кайвакытта, кайчакта; **по ~ена́м** кайчакта, кайбер вакытта; **в то ~я как ...** ...ганда, ...ган чакта; **~я не ждёт** вакыт бик аз, вакыт кысан

времяисчисле́ние *с* вакыт исәбе, ел исәбе

время́нка *ж разг.* **1.** (*переносная лестница*) күчерелмә баскыч **2.** (*железная печка*) тимер мич **3.** (*временная постройка*) вакытлы корылма; вакытлы торак

времяпрепровожде́ние, времяпровожде́ние *с* вакыт уздыру (үткәрү); көн үткәрү

вро́вень *нареч. с чем* бертигез, тигез; тип-тигез; **вода́ в бо́чке ~ с края́ми** су мичкәнең кырыйлары белән тигез

вро́де **1.** *предлог с род.п.* кебек, шикелле, ...дай кебек; **костю́м ~ моего́** минеке шикелле костюм **2.** *частица прост.* бугай, булса, кирәк; **он ~ заболе́л** ул авырып китте бугай

врождённ||ый, -ая, -ое тумыштан булган, тумыштан килгән; **~ые рефле́ксы** *физиол.* тумыштан килгән рефлекслар; **~ый тала́нт** тумыштан килгән талант

врозь *нареч.* аерым, аерым-аерым, аерым рәвештә; **жить ~** *с кем-л.* аерым яшәү

вруб *м горн.* уем, ярык, тишек (*тау токымнарында махсус ясала*)

вруба́ть *несов. см.* **вруби́ть**

вруба́ться *несов.* **1.** *см.* **вруби́ться**; **2.** *страд. от* **вруба́ть**

вруби́ть *сов. что* киселе утырту, уеп утырту, уеп кую

вруби́ться *сов.* **1.** кисә-кисә керү, киселеп керү (*эченә*); **~ в тайгу́** кисә-кисә тайга эченә керү **2.** кылыч белән кисә-кисә (чаба-чаба) бәреп керү; **~ в неприя́тельские ряды́** дошман сафларына кылыч белән чаба-чаба бәреп керү **3.** *горн.* ую, (тишек, ярык) ясау (*тау токымында*)

вру́бов||ый, -ая, -ое *горн.* уя (тишә) торган (*тау токымын*); **~ая маши́на** тау токымын тишү машинасы

врун *м разг.* ялганчы, алдакчы

вру́нья *ж разг.* ялганчы хатын (кыз), алдакчы хатын (кыз)

вруча́ть *несов. см.* **вручи́ть**

вручи́ть *сов. что* **1.** тапшыру, бирү, кулына тоттыру; **~ пода́рок** бүләк тапшыру; **~ о́рден** орден тапшыру **2.** *книжн.* ышанып тапшыру; **~ свою́ судьбу́** үз язмышыңны ышанып тапшыру

вручну́ю *нареч.* кулдан, кул белән, кул ярдәмендә; **обрабо́тать дета́ль ~** детальне кулдан эшкәртү

врыва́ть *несов. см.* **врыть**

врыва́ться I *несов.* **1.** *см.* **вры́ться**; **2.** *страд. от* **врыва́ть**

врыва́ться II *несов. см.* **ворва́ться**

врыть *сов. что* казып утырту, чокып утырту; **~ столб** багананы казып утырту

вры́||ться *сов. во что* казып кереп урнашу; **пехо́та ~лась в зе́млю** пехота җиргә окоп казып кереп урнашты

вря́д ли *частица* ...мы икән, ай-һай, икеле, шикле; **~ он придёт** аның килүе шикле

всади́ть *сов. что* **1.** кадау, чәнчү; чабып утырту; **~ топо́р в бревно́** балтаны бүрәнәгә чабып утырту **2.** *разг.* атып тидерү, тидерү (*пуляны һ.б.ш.*)

вса́дник *м* җайдак, атлы, сыбайлы, атка атланган кеше

вса́живать *несов. см.* **всади́ть**

вса́сывать *несов.* **всоса́ть**

вса́сываться *несов.* **1.** *см.* **всоса́ться**; **2.** *страд. от* **вса́сывать**

все *мн. см.* **весь** I

все́ *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «бөтен», «барлык», «тулы» дигән сүзләр белән тәрҗемә ителә, мәс.* **всеми́рный** бөтендөнья; **всесою́зный** бөтенсоюз; **всенаро́дный** бөтенхалык

всё I *нареч. разг.* **1.** (*постоянно*) һәрвакыт, һәркайчан, гел, һаман; **он ~ пи́шет** ул һаман яза **2.** (*до сих пор*) һаман, әле дә булса; **он ~ бо́лен** ул әле дә булса авырый **3.** (*только*) тик, бары тик, фәкать ... гына; **э́то ~ он винова́т** бу фәкать ул гына гаепле **4.** *в знач. частицы усил.* торган саен, барган саен, тагын да ...рак; **~ смеле́е и смеле́е** тагын да кыюрак һәм кыюрак **5.** *в знач. союза против.* (*однако*) әмма, ләкин, шуна карамастан; **как ни стара́йся, ~ зря** ничек кенә тырышмасын, әмма бушка ♦ **(и) ~ же (ж)** шулай да, әмма

всё II *с см.* **весь** I

всевéдущий, -ая, -ее *ирон.* барысын да белүче, бар нәрсәдән дә хәбәрдар

всевозмо́жн||ый, -ая, -ое һәртөрле, төрле-төрле; **~ые това́ры** төрле-төрле товарлар

всевы́шний *м книжн.* аллаһы тәгалә

всегда́ *нареч.* һәрвакыт, һәркайчан, һәрчак, гел ♦ **~ гото́в!** һәрвакыт хәзер!

всегда́шний, -яя, -ее һәрвакыттагы, һәркайчандагы, һәрчактагы; гадәттәге, даими; **~ гость** даими кунак

всего́ *нареч.* **1.** бөтенесе, барлыгы, барысы; **~ израсхо́довано сто рубле́й** барлыгы йөз сум тотылган **2.** *в знач. частицы огранич.* нибары, бары тик, гына; **откли́кнулось ~ пя́теро** нибары бишесе җавап бирде ♦ **~ хоро́шего!** хушыгыз!, сау булыгыз!, хуш, сау бул!; **то́лько и ~** шул гына, бары шул; **~ -на́всего** бары тик, нибары, фәкать

в-седьмы́х *вводн. сл,* җиденчедән, җиденчеләй

всезна́йка *м, ж разг.* минбеләмче, мәддагый

вселе́ние *с см.* **всели́ть** 1, **всели́ться** 1; **~ в но́вый дом** яңа өйгә керү

вселе́нная *ж* **1.** (*мироздание*) бөтен галәм, дөнья **2.** (*вся земля*) җир йөзе, дөнья

всели́ть *сов.* **1.** *кого-что* кертү, урнаштыру, кертеп урнаштыру; **~ в но́вый дом** яңа өйгә кертеп урнаштыру **2.** *перен. что* тудыру, кертү, күңеленә салу; **~ уве́ренность** ышаныч тудыру

всели́||ться *сов.* **1.** урнашу, керү, кереп урнашу; **~ться в но́вый дом** яңа өйгә кереп урнашу **2.** *перен.* керү, төшү, туу; **в его́ се́рдце ~лась наде́жда** аның күңеленә өмет керде

вселя́ть *несов. см.* **всели́ть**

вселя́ться *несов.* **1.** *см.* **всели́ться**; **2.** *страд. от* **вселя́ть**

всеме́рн||ый, -ая, -ое бөтен, чаралар белән, барлык мөмкинлекләр белән, һәрьяклап; **~ая подде́ржка** һәрьяклап ярдәм итү

все́меро *нареч.* җиде мәртәбә (тапкыр), җиде кат, җиделәтә

всемеро́м *нареч.* җидәү, җидәүләшеп. җидәүләп

всеми́рно-истори́ческ||ий, -ая, -ое *высок.* дөньякүләм-тарихи

всеми́рн||ый, -ая, -ое дөньякүләм, бөтендөнья ...ы, бөтендөньядагы; **~ая исто́рия** бөтендөнья тарихы

всемогу́щество *с* чиктән тыш куәтлелек, чиксез куәт; зур кодрәт

всемогу́щий, -ая, -ее чиктән тыш куәтле, чиксез куәтле; зур кодрәтле

всенаро́дн||ый, -ая, -ое бөтен халык[ның] ...ы, гомум халык ...ы; **~ое обсужде́ние** фикер алышуда бөтен халыкның катнашуы; **~ое голосова́ние** бөтен халыкның тавыш бирүе; **~ый пра́здник** бөтен халык бәйрәме; **~ое досто́яние** гомум халык байлыгы

всео́буч *м* гомуми мәгъбүри уку, всеобуч

всео́бщ||ий, -ая, -ее гомум, гомуми, бөтен; **~ее избира́тельное пра́во** гомуми сайлау хокукы

всео́бщность *ж* гомумилек

всеобъе́млющ||ий, -ая, -ее бөтенесен эченә ала торган; бөтенесен иңли торган

всеору́жи||е: во ~и ныклы коралланып, ныклы коралланган хәлдә; **во ~и зна́ний** белемнәр белән ныклы коралланып

всепобежда́ющ||ий, -ая, -ее бөтен нәрсәне җиңүче, бөтен нәрсәне җиңә торган; **~ая си́ла иде́й** идеяләрнең бөтен нәрсәне җиңә торган көче

всепроще́ние *с* бөтен нәрсәне гафу итү

всеросси́йский, -ая, -ое бөтенроссия ...ы, бөтенроссия күләмендәге; **Всеросси́йское театра́льное о́бщество** Бөтенроссия театр җәмгыяте

всерьёз *нареч.* **1.** чынга; **не принима́й его́ слова́ ~** аның сүзләрен чынга алма **2.** чынлап, чын-чынлап, җитди рәвештә; **~ взя́ться за де́ло** эшкә чынлап керешү

всеси́льный, -ая, -ое чиктән тыш көчле, куәтле, чиктән тыш куәтле, бик куәтле

всесою́зн||ый, -ая, -ое *ист.* бөтенсоюз .... бөтенсоюз ...ы, бөтенсоюз күләмендәге; **во ~ом масшта́бе** бөтенсоюз күләмендә

всесторо́нний, -яя, -ее бөтен яктан, бөтен яклап, һәр яктан, һәрьяклап; җентекләп; **~ разбо́р де́ла** эшне бөтен яклап тикшерү

всё-таки 1. *союз против.* (*тем не менее, однако*) шулай булса да, шуңа карамастан, шулай булуга карамастан, әмма **2.** *частица* шулай да; **~ где я ви́дел его́?** шулай да мин аны кайда күрдем соң?

всеуслы́шание *с*: **во ~** бөтен кешегә ишеттерерлек итеп, кычкырып; бөтен кешегә җиткерү өчен

всеце́ло *нареч.* бөтенләй, бөтенләйгә, тулысынча; **он ~ пре́дан нау́ке** ул бөтенләй фәнгә бирелгән

всея́дн||ый, -ая, -ое бөтен нәрсәне ашаучан, бөтен нәрсәне ашаучы; **~ое живо́тное** бөтен нәрсәне ашаучан хайван

вска́кивать *несов. см.* **вскочи́ть**

вска́пывать *несов. см.* **вскопа́ть**

вскара́бкаться *сов. разг.* үрмәләп менү, үрмәләп менеп житү, тырмашып менү; **~ на де́рево** агачка үрмәләп менү

вскара́бкиваться *несов. см.* **вскара́бкаться**

вска́рмливать *несов. см.* **вскорми́ть**

вскачь *нареч.* чаптырып, чабып, җилдереп чабып; **мча́ться ~** чаптырып бару

вски́дывать *несов. см.* **вски́нуть**

вски́нуть *сов. что* **1.** ташлау; күтәреп салу (ташлау); **~ мешо́к на плечо́** иңбашка капчыкны күтәреп салу **2.** тиз генә күтәрү, кинәт күтәрү; **~ го́лову** башны тиз генә күтәрү ♦ **~ глаза́** күзне текәү (төбәү)

вскипа́ть *несов.* **1.** кайнап чыга башлау **2.** *перен* чәпчү, кызу, дулау

вскипе́||ть *сов.* **1.** кайнау, кайнап чыгу; **молоко́ ~ло** сөт кайнап чыкты **2.** *перен.* ярсу, чәпчү, кызу, ярсып (кызып) китү; чәпчеп китү; **~ть от негодова́ния** ачудан ярсып китү

вскипяти́ть *сов. что* кайнату, кайнатып алу; кайнатып чыгару; **~ молоко́** сөтне кайнатып чыгару

всклоко́чивать *несов. см.* **всклоко́чить**

всклоко́чить *сов. что* тузгыту; тырпайту (*чәкләрне, каурыйларны*)

всклоко́читься *сов.* тузгу; тырпаю

всколыхну́||ть *сов.* **1.** *что* тибрәндерү, селкетү, дулкынландыру, чайкалдыру, тибрәтеп (селкетеп, дулкынландырып) җибәрү; **ве́тер ~л рожь** җил арышны дулкынландырып җибәрде **2.** *перен. кого-что* кузгату, кузгатып җибәрү, дулкынландыру, аякка бастыру; **э́то собы́тие ~ло всю дере́вню** бу вакыйга бөтен авылны кузгатты

всколыхну́||ться *сов.* **1.** дулкынлану, тибрәнү, селкенү, чайкалып (дулкынланып) китү, җилфердәп (селкенеп) кую; **вода́ ~лась** су дулкынланып китте; **занаве́ска ~лась** тәрәзә пәрдәсе җилфердәп куйды **2.** *перен.* кузгалу, кузгалып китү, аякка басу; **всё село́ ~лось** бөтен авыл аякка басты

вско́льзь *нареч.* болай гына, өстән генә; сүз җаенда гына; **упомяну́ть** *о чём-л.* **~** *берәр нәрсәне* сүз җаенда гына искә алу

вскопа́ть *сов. что* казу, казып бетерү (чыгу); **~ гря́дку** түтәлне казып чыгу

вско́ре *нареч.* тиздән, тиз арада, якын арада, озакламыйча; озак вакыт үтмәстән; **он ~ придёт** ул тиздән киләчәк

вскорми́ть *сов. кого* **1.** (*животное, птицу и т.п.*) ашатып үстерү **2.** (*воспитать, вырастить*) карап (тәрбияләп) үстерү

вскочи́||ть *сов.* **1.** сикереп менү, ыргып менү; **~ть на коня́** атка сикереп менү; **~ть в ваго́н** вагонга сикереп менү **2.** (*быстро встать*) сикереп тору, ыргып тору **3.** *перен. разг.* чыгу, килеп чыгу; **прыщ ~л** бетчә чыкты

вскри́кивать *несов.* кычкырып-кычкырып җибәрү (кую)

вскри́кнуть *сов. однокр.* кычкырып җибәрү (кую)

вскрича́ть *сов.* кычкырып әйтеп җибәрү (кую)

вскружи́ть *сов.*: **~ го́лову** *кому* башын әйләндерү

вскружи́||ться *сов.*: **~лась голова́** башы әйләнде

вскрыва́ть *несов. см.* **вскрыть**

вскрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **вскры́ться**; **2.** *страд. от* **вскрыва́ть**

вскры́тие *с см.* **вскрыть, вскры́ться** 2; **~ те́ла** *мед.* гәүдәне ярып карау; **~ рек весно́й** яз көне елгаларның бозын арчылуы; **~ недоста́тков** кимчелекләрне ачу

вскрыть *сов. что* **1.** ачу, ачып кую; **~ конве́рт** конвертны ачу **2.** *перен.* ачып салу, ачу, табу; **~ недоста́тки в рабо́те** эштәге кимчелекләрне ачу **3.** *мед.* яру; ярып җибәрү; ярып карау; **~ нары́в** шешне яру

вскры́||ться *сов.* **1.** тишелү, сытылу, тишелеп ачылу; **нары́в ~лся** шеш тишелде **2.** ачылу, бозын арчылу, бозын арыну; **река́ ~лась** елга бозын

арчылды **3.** *перен.* ачылу, беленү; ачыклану; **~ лись причи́ны отстава́ния** артта калуның сәбәпләре ачылды

всласть *нареч.* туйганчы, рәхәтләнеп; **~ пораба́тать** туйганчы эшләү; **~ поспа́ть** туйганчы йоклау

вслед *нареч.* **1.** *за кем-чем* артыннан, артыннан ук; **~ за това́рищем** иптәшнең артыннан ук **2.** *в знач. предлога с дат.п.* артыннан; **смотре́ть ~ по́ездy** поезд артыннан карап калу ♦ **~ за тем** шуннан соң, соңыннан

вследствие *предлог с род.п.* аркасында, сәбәпле, нәтиҗәсендә, булганлыктан, булу сәбәпле, булганга күрә; **~ боле́зни** авыру аркасында

вслепу́ю *нареч. разг.* **1.** күрмичә, карамыйча; **печа́тать на маши́нке ~** машинкада карамыйча басу **2.** *перен.* тикшереп тормыйча, сукырларча, белмичә; **де́йствовать ~** сукырларча эш итү

вслух *нареч.* кычкырып, ишеттереп, ишеттерерлек итеп; **чита́ть ~** кычкырып уку

вслу́шаться *сов. во что* игътибар белән тыңлый башлау, бирелеп тыңлый башлау, күнел биреп тыңлау, колак салу; **~ в разгово́р** сүзләренә колак салу

вслу́шиваться *несов. см.* **вслу́шаться**

всма́триваться *несов. см.* **всмотре́ться**

всмотре́ться *сов. в кого-что* дикъкать белән карау, текәлеп карау

всмя́тку *нареч.* пешәр-пешмәс итеп, пешәр-пешмәс; **яйцо́ ~** пешәр-пешмәс итеп хәзерләнгән йомырка

все́вывать *несов. см.* **всу́нуть**

все́вываться *несов.* **1.** *см.* **всу́нуться**; **2.** *страд. от* **все́вывать**

всоса́ть *сов. что* суыру, суырып алу, эчкә суыру; сеңдерү; **~ вла́гу** суны эченә суыру ♦ **~ с молоко́м ма́тери** ана сөте белән керү, яшьтән үк өйрәнү

всоса́||ться *сов.* **1.** сеңү; сеңеп бетү; **вода́ ~лась в песо́к** су комга сеңгән **2.** кадалу, ябышу, кадалып имә башлау; ябышып имә башлау; **пия́вка ~лась в но́гу** сөлек аякка кадалып имә башлаган

вспа́ивать *несов. см.* **вспои́ть**

вспа́рывать *несов. см.* **вспоро́ть**

вспаха́ть *сов. что* сөрү, сукалау; сөреп бетерү (чыгу), сукалап чыгу; **~ по́ле** басуны сөрү

вспа́хивать *несов. см.* **вспа́хать**

вспа́шка *ж см.* **вспаха́ть**; **зя́блевая ~** туңга сөрү

вспе́нивать *несов. см.* **вспе́нить**

вспе́ниваться *несов.* **1.** *см.* **вспе́ниться**; **2.** *страд. от* **вспе́нивать**

вспе́нить *сов. что* **1.** (*образовать пену*) күбекләндерү, күбекләү, күбеккә әйләндерү **2.** (*довести лошадь до испарины*) ак күбеккә батыру

вспе́ни||ться *сов.* күбекләнү; күбек белән каплану; **пи́во ~лось** сыра күбекләнде

всплакну́ть *сов. о ком-чём и без доп., разг.* елап алу, сыктап алу

всплёск *м* **1.** *см.* **всплесну́ть**; **2.** (*звук*) чапылдау тавышы; чайпалу тавышы; чайкалу тавышы; **~ вёсел** ишкәкләрнең чапылдау тавышы

всплёскивать *несов. см.* **всплесну́ть**

всплесну́||ть *сов. однокр.* чайпалу, чайпалып кую; чайкалып кую; чәчрәп китү; чапылдап кую (сикерү); **в реке́ ~ла ры́ба** елгада балык чапылдап сикерде ♦ **~ть рука́ми** кулларны җәю (*гаҗәпләнүдән һ.б.ш.*)

всплошну́ю *нареч. прост.* тоташтан, тоташ булып; **лёд шёл ~** боз тоташ булып ага иде

всплыва́ть *несов. см.* **всплыть**

всплы||ть *сов.* **1.** [су өстенә] калку, калкып чыгу, [су өстенә] чыгу; **подво́дная ло́дка ~ла** суасты көймәсе калкып чыкты **2.** *перен* ачылу, беленү, килеп чыгу; **~ли недоста́тки** кимчелекләр килеп чыкты

вспои́ть *сов. кого* **1.** сөт эчерү, сөт эчереп үстерү; **~ телёнка** бозауны сөт эчереп үстерү **2.** (*вырастить, воспитать*) карап (тәрбияләп) үстерү

всполоши́ть *сов. кого-что, разг.* ыгы-зыгы куптару, аякка бастыру, ыгы-зыгы китерү

всполоши́ться *сов.* ыгы-зыгы килә башлау, ыгы-зыгы куптару, аякка басу; кинәт тынычсызланып китү

вспомина́ть *несов. см.* **вспо́мнить**

вспомина́ться *несов.* **1.** *см.* **вспо́мниться**; **2.** *страд. от* **вспомина́ть**

вспо́мнить *сов. кого-что* искә алу, искә (хәтергә) төшерү; **~ мо́лодость** яшьлекне искә төшерү

вспо́мни||ться *сов. кому* искә (хәтергә) төшү; **мне ~лся оди́н слу́чай** минем хәтергә бер вакыйга искә төште

вспомога́тельный, -ая, -ое ярдәмче ..., өстәмә ...; **~ отря́д** ярдәмче отряд ♦ **~ глаго́л** *грам.* ярдәмче фигыль

вспоро́ть *сов. что* сүтү, сүтеп ачу, сүтеп җибәрү; (*напр. живот*) яру, ярып ачу; **~ мешо́к** капчыкны сүтү

вспорхну́ть *сов.* очып китү, очып күтәрелү (күтәрелеп китү)

вспоте́ть *сов.* тирләү, тиргә бату, шабыр тиргә төшү

вспры́гивать *несов. см.* **вспры́гнуть**

вспры́гнуть *сов.* сикерү, ыргу, сикереп (ыргып) менү; **~ на теле́гу** арбага сикереп менү

вспры́скивание *с см.* **вспры́снуть**

вспры́скивать *несов. см.* **вспры́снуть**

вспры́снуть *сов. что* **1.** су бөркү, су сиптерү; **~ бельё** җәймәгә су бөркү **2.** *перен. прост.* (*отметить выпивкой*) юу, билгеләп үтү

вспу́гивать *несов. см.* **вспугну́ть**

вспугну́ть *сов. кого-что* куркыту, өркетү, куркытып кузгату, куркытып җибәрү, өркетеп җибәрү, куркытып очырып җибәрү

вспуха́ть *несов. см.* **вспу́хнуть**

вспу́хнуть *сов.* шешү, шешеп чыгу; кабару, кабарып чыгу; **па́лец вспух** бармак шешеп чыкты

вспу́чивать *несов. см.* **вспу́чить**

вспу́чи||ть *сов. безл. что, разг.* күбү, күбеп чыгу; кабару; **живо́т ~ло** эч күбеп чыкты

вспу́читься *сов. разг.* күбү, күбеп чыгу, күбенү, кабару

вспыли́ть *сов.* [кинәт] кабынып китү, кызып китү, ярсып китү; **~ из-за пустяка́** юктан кабынып китү

вспы́льчивость *ж* кызулык, кызу канлылык, тиз ярсып китү, тиз кызып китү

вспы́льчивый, -ая, -ое кызу, кызу канлы, тиз кызып китүчән, тиз ярсып китүчән; **~ челове́к** кызу канлы кеше; **~ хара́ктер** кызу холык

вспы́хну||ть *сов.* **1.** (*загореться*) кабынып китү, кабыну, янып китү, дөрләп китү, яна башлау **2.** кызарып китү, кызару; **лицо́ его ~ло** анын бите кызарып китте **3.** кабыну, башланып китү; **~ла ссо́ра** ызгыш башланып китте **4.** кабыннып китү; ярсып (кызып, чәпчеп) китү; **~ть от гне́ва** ачудан кызып китү

вспы́шка *ж* **1.** кабыну, кабынып китү; дөрләп китү; **~ по́роха** дарының кабынып китүе; **~ пла́мени** ялкынның дөрләп китүе **2.** *перен.* ярсу, ярсып (кызып, чәпчеп) китү

вспя́ть *нареч. книжн.* кирегә, артка; **поверну́ть ~** кирегә бору

встава́||ть *несов. см.* **вста́ть ♦ не ~я** баш калкытмый (*мәс. эшләү*)

вста́вить *сов. что* **1.** кую, куйдыру; кертеп кую; **~ стекло́** пыяла кую; **~ зуб** теш куйдыру **2.** кыстыру, кыстырып жибәрү; **~ сло́во в разгово́р** сөйләшкәндә сүз кыстыру

вста́вк||а *ж* **1.** *см.* **вста́вить**; **~а стёкол** пыяла кую **2.** ялгау; **пла́тье со ~ой** ялгау куелган күлмәк **3.** (*вписанный текст*) өстәмә, өстәмә текст

вставля́ть *несов. см.* **вста́вить ♦ ~ па́лки в колёса** таяк тыгу, комачаулау (*нәрсәгә дә булса*)

вставн||о́й, -а́я, -о́е алынмалы, алынма..., алып куела торган; (*о зубах*) куелган; **~ы́е ра́мы** алынмалы рамнар

вста́рь *нареч.* борынгыда, электе, элекке (борынгы) заманда

вста́||ть *сов.* **1.** тору, басу, торып басу; **~ть со сту́ла** урындыктан тору; **~ть на стул** урындыкка басу; **ра́но ~ть** иртә тору; **~ть на́ ноги** *прям., перен.* аякка басу; **2.** аякка басу, сәламәтләнү, йөри башлау; **~ть по́сле боле́зни** авырудан соң аякка басу **3.** күтәрелү; **~ть на защи́ту Ро́дины** Ватанны сакларга күтәрелү **4.** (*о светилах*) чыгу, күтәрелү; **со́лнце ~ло** кояш чыкты **5.** *перен. перед кем-чем* (*возникнуть, появиться*) килеп чыгу, алга килеп басу **6.** (*приступить к какой-л. работе, деятельности*) басу, башлау; **~ть к станку́** станок янына басу **7.** (*покрыться льдом — о реке*) туңу **8.** туктау, йөрми башлау, эшләми башлау; **часы ~ли** сәгать туктады ♦ **~ть гру́дью** күкрәк киереп каршы тору; **~ть в строй** сафка басу; **~ть на кварти́ру** квартирга керү; **~ть на путь** *чего, какой* юлына басу; **~ть на сто́рону** *кого, чью* яклау, ягына басу; **~ть на учёт** учётка басу; **~ть поперёк доро́ги** юлына аркылы төшү

встопо́рщи||ть *сов. что* тырпайту, кабарту, тырпайтып (кабартып) жибәрү;

кабáн ~л щетúну кабан йоннарын тырпайтты

встопóрщиться *сов.* тырпаю, кабару, тырпаеп (кабарып) китү

встрáивать *несов. см.* **встрóить**

встревóженный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **встревóжить**; **2.** шомлы, борчулы, пошаманга төшкән, тынычсыз; **~ гóлос** борчулы тавыш

встревóжить *сов. кого-что* шомландыру, шом салу; пошаманга төшерү, борчу салу (борчылдыру); тынычсызлау

встревóжиться *сов.* шомлану, күңелгә шом килү, пошаманга төшү, борчылу, тынычсызлану

встрёпанн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **встрепáть**; **2.** тузгыган, тырпайган, кабарган; **~ые вóлосы** тузгыган чәч

встрепáть *сов. что*, *разг.* тузгыту, тырпайту, кабарту

встрепенýться *сов.* **1.** (*о птицах*) талпыну, талпынып кую **2.** (*забиться сильнее — о сердце*) дөп-дөп тибә башлау

встрёпк||а *ж прост.*: **задáть ~у** *кому-л.* арт сабагын укыту

встрéтить *сов.* **1.** *кого-что* очрату, туры китерү; тару; **~ друзéй** дусларны очрату **2.** *кого-что* каршы алу, каршылау; **~ хорошó** яхшы каршы алу; **~ гостéй** кунакларны каршылау **3.** *перен. что* күрү, табу, алу; **~ отпóр** отпор алу; **~ сочýвствие** теләктәшлек табу

встрéти||ться *сов.* **1.** *с кем-чем* очрашу, очрау, юлыгу, тап булу, тару; **~ться на дорóге** юлда очрашу; **~ться с трýдностями** авырлыкларга очрау **2.** (*увидеться*) күрешү, очрашу; **влюблённые ~лись** яратышучылар күрештеләр **3.** (*обнаружиться*) очрау, булу; **в кни́ге ~лись интере́сные места́** китапта кызыклы урыннар очрады

встрéч||а *ж* **1.** очрашу; **неожи́данная ~а** көтелмәгән очрашу; **поздоро́ваться при ~е** очрашканда исәнләшү **2.** каршылау, каршы алу; **~а делега́тов** делегатларны каршылау **3.** *спорт.* очрашу **4.** (*торжество*) каршы алу, бәйрәм итү; **~а Но́вого го́да** Яңа елны каршы алу

встреча́ть *несов. см.* **встрéтить**

встрéчаться *несов. см.* **встрéтиться**

встрéчн||ый, -ая, -ое **1.** каршы, каршы килә торган; **~ый по́езд** каршы килә торган поезд **2.** каршы, каршылау ...ы, каршы җавап ...ы; **~ый иск** *юр.* каршы дәгъва; **~ый план** каршы җавап планы **3.** кара-каршы, кара-каршы алып барыла торган; **~ый бой** кара-каршы алып барыла торган сугыш **4.** *в знач. сущ.* **~ый** *м* очраучы, очрашкан кеше; **спра́шивать доро́гу у ка́ждого ~ого** юлны һәр очраган кешедән сорашу ♦ **~ый и попере́чный** теләсә кем, һәр очраган кеше; **пе́рвый ~ый** беренче очраган кеше, ят кеше

встро́ить *сов. что* эченә салу, эчендә төзү, эченә төзү, (салу); **~ шкаф в сте́ну** стенаның эченә кертеп шкаф төзү

встря́ска *ж* **1.** *разг.* (*душевное потрясение*) дулкынлану, кайгы-хәсрәт, пошаман **2.** *перен. прост.* (*нагоняй*) каты шелтә; кирәген бирү; бәргәләп алу

встря́хивать *несов. см.* **встряхну́ть**

встря́хиваться *несов.* **1.** *см.* **встряхну́ться**; **2.** *страд. от* **встря́хивать**

встряхну́||ть *сов. кого-что* **1.** селкү, кагу, селкеп (кагып) алу; **~ть останови́вшиеся часы́** туктаган сәгатьне селкү; **~ть пальто́** пальтоны кагу **2.** *безл.* селкету; **телéгу си́льно ~ло** арбаны бик нык селкетте

встряхну́||ться *сов.* **1.** кагыну, селкенеп (кагынып) кую; **соба́ка ~лась** эт кагынды **2.** *перен. разг.* (*ободриться*) күңеллеләнү, дәртләнү; селкенеп алу **3.** *перен.* (*развлечься*) күңел ачу

вступа́ть *несов. см.* **вступи́ть**

вступа́ться *несов. см.* **вступи́ться**

вступи́тельный, -ая, -ое **1.** кереш ...; кереш ...ы; **~ое сло́во** кереш сүз **2.** керү ...ы; **~ый взнос** керү взносы; **~ый экза́мен** керү имтиханы

вступи́ть *сов.* **1.** *во что* керү, барып керү, килеп керү; **~ в го́род** шәһәргә керү **2.** *во что* керү; **~ в о́бщество** җәмгыятькә керү **3.** башлау, керешү, тотыну; **~ в перегово́ры** сөйләшүләр башлау; **~ в перепи́ску** языша башлау; **~ в разгово́р** сөйләшә башлау ♦ **~ в брак** никахка керү, өйләнү яки кияүгә чыгу; **~ в си́лу** көченә керү; **~ в строй** сафка басу; **~ на путь** *чего, какой* юлына басу; **~ в зре́лый во́зраст** үсеп житү, бәлигъ булу

вступи́ться *сов. за кого-что* яклау, яклашу, аралау

вступле́ние *с* **1.** *см.* **вступи́ть**; **~ в о́бщество** җәмгыятькә керү **2.** кереш; **~ к поэ́ме** поэмага кереш

всу́нуть *сов. что во что* тыгу, салу, тыгып (салып) кую; **~ ру́ки в карма́ны** кулларны кесәгә тыгу

всухомя́тку *нареч. разг.* корылай, коры килеш, коры...; **есть ~** коры ашау

всу́чивать *несов. см.* **всучи́ть**

всучи́ть *сов.* **1.** *что* кату, кыстырып кату, кушып кату; **~ щети́ну в дра́тву** кылны җеп очына кыстырып кату **2.** *перен. кого-что, прост.* (*заставить взять*) көчләп тоттыру, кулына тоттыру, көчләп тагу

всхли́пнуть *сов. однокр.* сулкылдап кую, үксеп кую

всхли́пывание *с см.* **всхли́пывать**

всхли́пывать *несов.* сулкылдау, үксү, сулкылдап елау, үксеп елау

всходи́ть *несов. см.* **взойти́**

всхо́ды *только мн.* шытып чыккан иген, шытым; (*озимых*) уҗым

всхо́жесть *ж с.-х.* шытучанлык, шыту сәләте; **~ семя́н** орлыкның шыту сәләте

всхо́ж||ий, -ая, -ее *с.-х.* шытучан, шытуга сәләтле; **~ие семена́** шытуга сәләтле орлыклар

всхрапну́ть *сов.* **1.** *однокр.* (*о животном*) пошкырып кую, пошкырып җибәрү **2.** *разг. шутл.* (*поспать*) черем итеп алу, йоклап алу

всхра́пывать *несов.* **1.** (*о человеке*) гырылдау, гырылдап (гырлап) йоклау **2.** (*о лошадях*) пошкыру, пошкырып тору

всы́пать *сов.* **1.** *что, чего* салу, тутыру; **~ зерно́ в мешо́к** ашлыкны капчыкка тутыру **2.** *перен. кому, разг.* (*побить, отругать*) тамызу; кирәген бирү, кыйнау

всыпа́ть *несов. см.* **всы́пать**

всю́ду *нареч.* һәркайда, һәрҗирдә, кая карама шунда

вся *ж см.* **весь** I

вся́к||ий, -ая, -ое *мест.* **1.** (*каждый*) һәр, һәрбер; **~ий челове́к** һәр кеше **2.** (*разный*) һәртөрле, төрле, төрле-төрле, теләсә нинди; **~ие кни́ги** һәртөрле китаплар **3.** бернинди, һичнинди, һичбер; **отсу́тствие ~их жела́ний** бернинди теләкнең булмавы; **без ~их сомне́ний** бернинди шиксез **4.** *в знач. сущ.* **~ий** *м* һәркем, һәр кеше **5.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* төрле хәл, төрле нәрсә; **расска́зывают ~ое** төрле нәрсә сөйлиләр; **~ое быва́ет** төрле хәлләр була ♦ **~ая вся́чина** төрле нәрсә[ләр]; әллә нәрсә[ләр]; теләсә нәрсә[ләр]; **во ~ом слу́чае** һәрхәлдә; **на ~ий слу́чай** кирәк була калса дип, кирәк була калса

вся́ко *нареч. прост.* төрлечә; **~ быва́ет** төрлечә була

вся́ческ||ий, -ая, -ое *разг.* һәртөрле, төрле-төрле; **ока́зывать ~ую по́мощь** һәртөрле ярдәм күрсәтү

вся́чина *ж разг.*: **вся́кая ~** *см.* **вся́кий**

вта́йне *нареч.* яшерен, яшертен, яшертен рәвештә, астыртын рәвештә, сиздермичә

вта́лкивать *несов. см.* **втолкну́ть**

вта́птывать *несов. см.* **втопта́ть**

вта́скивать *несов. см.* **втащи́ть**

вта́скиваться *несов.* **1.** *см.* **втащи́ться**; **2.** *страд. от* **вта́скивать**

втача́ть *сов. что*, *портн.* тегеп кую, каеп тегү, каеп тегеп кую; **~ воротни́к** яканы каеп тегү

вта́чивать *несов. см.* **втача́ть**

втащи́ть *сов. кого-что* **1.** *во что* өстерәп (сөйрәп) кертү; **~ мешо́к в сара́й** капчыкны сарайга өстерәп кертү **2.** (*на что*) өстерәп (сөйрәп) мендерү

втащи́ться *сов. разг.* көч-хәл белән килеп (барып) керү, көчкә генә менеп җитү

втека́ть *несов.* (*вливаться*) агып керү; агып төшү; (*впадать, напр. о реке*) кою, кушылу

втемя́ши||ться *сов. разг.* кереп утыру, керү, сеңү (башка); **~лось ему́ в го́лову** башына кереп утырган

втере́ть *сов. что* ышку, ышкып сендерү (кертү), сылап сендерү; **~ мазь** мазьне ышкып сендерү ♦ **~ очки́** *кому* күз буяу, алдау

втере́ться *сов.* **1.** (*впитаться*) сеңү, кереп сеңү (*ышкудан*) **2.** *разг.* ышкынып килеп керү, кысылып килеп керү (китү); **~ в то́лпу** халык төркеменә кысылып килеп керү **3.** *перен.* тырышып-тырмашып керү, килеп керү; **~ в компа́нию** компаниягә тырышып-тырмашып керү ♦ **~ в дове́рие** тырышып-тырмашып ышанычка казану

втечь *сов. см.* **втека́ть**

ВТИ-ВЧЕ

втира́ни||е *с* 1. *см.* **втере́ть**; 2. (*лекарственное вещество*) тәнне ышку даруы, тәнгә сылау даруы

втира́ть *несов. см.* **втере́ть**

втира́ться *несов.* 1. *см.* **втере́ться**; 2. *страд. от* **втира́ть**

вти́скивать *несов. см.* **вти́снуть**

вти́снуть *сов. кого-что во что* тыгу, тыгып кертү; басып (кысып, тыгызлап) кертү

вти́снуться *сов. разг.* 1. (*поместиться*) сыю, сыеп бетү 2. (*с трудом проникнуть*) килеп тыгылу; тыгылып керү; кысылышып керү, кысыла-кысыла керү

втихомо́лку *нареч. разг.* дәшминитми, дәшми-тынмый, эндәшминитми

втиху́ю *нареч. прост. см.* **втихомо́лку**

втолкну́ть *сов. кого-что во что* этеп (төртеп) кертү, этеп-төртеп (этә-этә) кертү

втолкова́ть *сов. что кому* аңлатып (төшендереп) бирү; башына кертү; ~ **пра́вило** кагыйдәне аңлатып бирү

втолко́вывать *несов. см.* **втолкова́ть**

втопта́ть *сов. кого-что во что* таптап кертү (батыру, сеңдерү) ♦ ~ **в грязь** пычракка буяу, яла ягу

вторга́ться *несов. см.* **вто́ргнуться**

вто́рг||нуться *сов. во что* 1. бәреп керү, басып керү; **враг ~ся с за́пада** дошман көнбатыштан бәреп керде 2. *перен.* (*вмешаться*) тыкшыну, тыгылу

вторже́ние *с см.* **вто́ргнуться**; ~ **неприя́теля** дошманның басып керүе

вто́ри||ть *несов.* 1. *муз.* кабатлау; кабатлап җырлау; кабатлап уйнау 2. *кому-чему* кабатлау; **эхо ~т гро́му** кайтаваз күкрәү тавышын кабатлый 3. *перен. кому* җәплән тору, сүзен кабатлау

втори́чн||ый, -ая, -ое 1. икенче, икенче мәртәбә ..., икенче тапкыр ..., икенче кат ...; ~**ое напомина́ние** икенче мәртәбә искәртү 2. (*производный*) икенчел; ~**ое явле́ние** икенчел күренеш; **мате́рия — первича́, а созна́ние — ~о** *филос.* материя — беренчел, ә аң — икенчел 3. (*побочный*) икенчел; өстәмә; ~**ые половы́е при́знаки** икенчел женси билгеләр

вто́рник *м* сишәмбе

второ- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге «икенче», «икенчел» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **второкла́ссный** икенче класслы

второго́дник *м* бер сыйныфта ике ел утыручы

второго́дница *ж* бер сыйныфта ике ел утыручы кыз

втор||о́й, -а́я, -о́е 1. *числ.* икенче; ~**о́й год** икенче ел; ~**а́я весна́** икенче яз 2. (*второстепенный*) икенче, икенче дәрәҗәдәге; **на ~ы́х роля́х** икенче дәрәҗәдәге рольләрдә; **на ~о́м пла́не** икенче планда 3. икенче; ~**а́я ро́дина** икенче туган ил; ~**а́я мать** икенче ана 4. *в знач. сущ.* ~**о́е** *с* икенче блюдо, икенче ♦ ~**а́я мо́лодость** икенче яшьлек; ~**а́я сигна́льная систе́ма** *физиол.* икенче сигнал системасы (*сигналлар системасы буларак авазлардан торган сөйләм*); **до ~ы́х петухо́в** икенче этәчләргә кадәр; **из ~ы́х рук** икенче кулдан

второкла́ссник *м* икенче класста укучы

второкла́ссница *ж* икенче класста укучы кыз

второку́рсник *м* икенче курста укучы

второку́рсница *ж* икенче курста укучы кыз

второочередн||о́й, -а́я, -о́е икенче чираттагы, икенче чират ...ы; ~**о́е де́ло** икенче чираттагы эш

второпя́х *нареч.* ашыгып, кабаланып, ашыгып китеп, кабаланып китеп, ашык-пошык; ~ **забыть** *кого-что-л., о ком-чём-л.* ашыгып китеп онытып жибәрү

второразря́дн||ый, -ая, -ое икенче дәрәҗәдәге, икенче разрядлы; ~ **рестора́н** икенче разрядлы ресторан

второсо́ртн||ый, -ая, -ое 1. икенче сорт ..., икенче сортлы; ~**ая мука́** икенче сорт он 2. *разг.* (*посредственный*) икенче дәрәҗәдәге, урта кул

второстепе́нн||ый, -ая, -ое 1. икенче дәрәҗәдәге; ~**ый вопро́с** икенче дәрәҗәдәге мәсьәлә 2. (*посредственный*) икенче дәрәҗәдәге, урта кул, уртача ♦ ~**ые чле́ны предложе́ния** *грам.* җөмләнең иярчен кисәкләре

втрави́ть *сов. кого-что* 1. *охот.* ауга өйрәтү, сунарга өйрәтү; ~ **соба́ку** этне ауга өйрәтү 2. *перен. во что, прост.* (*вовлечь*) кызыктырып җәлеп итү

втрави́ться *сов.* 1. *охот.* ауга өйрәнү, сунарга өйрәнү (*этлар, ау бөркете һ.б.ш. турында*) 2. *перен. во что, прост.* (*вовлечься*) кызыгып китеп катышу, мавыгып китеп катнашу

втра́вливать *несов. см.* **втрави́ть**

в-тре́тьих *сл.* өченчедән, өченчеләй

втри́дорога *нареч. разг.* өчләтә артык, өчләтә кыйбат, бик кыйбат

втро́е *нареч.* өч кат, өч өлеш, өч тапкыр, өч мәртәбә; **он ~ ста́рше** өч мәртәбә өлкәнрәк

втроём *нареч.* өчәү, өчәүләп, өчәүләшеп, өчәү бергә

втройне́ *нареч.* өч мәртәбә артык, өч мәртәбә күбрәк, өч тапкыр артык; **заплати́ть ~** өч мәртәбә артык түләү

втуз *м* втуз (*югары техник уку йорты*)

вту́лка *м* 1. *тех.* втулка, чөй; **колёсная ~** тәгәрмәч чое 2. (*пробка, затычка*) бәке; тыккыч

втыка́ть *несов. см.* **воткну́ть**

втыка́ться *несов.* 1. *см.* **воткну́ться**; 2. *страд. от* **втыка́ть**

втя́гивать *несов. см.* **втяну́ть**

втя́гиваться *несов.* 1. *см.* **втяну́ться**; 2. *страд. от* **втя́гивать**

втяжно́й, -а́я, -о́е суыру ...ы, суыртқыч; ~ **рука́в насо́са** насосның суыру җиңсәсе

втя́нут||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **втяну́ть**; 2. эчкә баткан, эчкә кергән, эчкә суырылган; ~**ые щёки** эчкә суырылган яңаклар

втяну́ть *сов. кого-что* 1. тартып чыгару, тартып мендерү, өстерәп чыгару, өстерәп мендерү; тартып кертү; ~ **ло́дку на бе́рег** көймәне ярга тартып чыгару 2. (*вобрать в себя*) эчкә суыру, эчкә суырып алу, эчкә суырып бетерү; эчкә тарту 3. *разг. перен.* тарту, җәлеп итү; ~ **в игру́** уенга тарту

втяну́||ться *сов.* 1. эчкә суырылу, эчкә бату, эчкә керү, эчкә батып керү; **у больно́го ~лись щёки** авыруның яңаклары эчкә баткан 2. (*постепенно войти, углубиться*) килеп керү 3. *перен.* катнашу, кушылу, катнашып (кушылып) китү, тартылу, тартылып китү; ~**ться в разгово́р** сүзгә тартылу 4. *перен.* гадәтләнү, ияләшү, күнегү, гадәтләнеп (күнегеп, ияләшеп, кереп) китү; ~**ться в рабо́ту** эшкә кереп китү

вуали́ровать *несов. что* яшерү, каплау, томалау

вуа́ль *ж* вуаль, бит челтәре

вуз *м* вуз (*югары уку йорты*)

ву́зовец *м разг.* вузда укучы

ву́зовск||ий, -ая, -ое вуз ...ы; ~**ие програ́ммы** вуз программалары

вулка́н *м* янартау; вулкан; **поту́хший ~** сүнгән вулкан; **де́йствующий ~** янартау

вулканиза́ция *ж тех.* вулканизация, вулканизация ясау

вулканизи́ровать, вулканизова́ть *сов., несов. что, тех.* вулканизация ясау, вулканлаштыру, вулканизация юлы белән эшкәртү

вульгариза́тор *м* вульгарлаштыручы

вульгариза́ция *ж см.* вульгаризировать

вульгаризи́ровать *сов., несов. что* вульгарлаштыру, бозып күрсәтү

вульгари́зм *м лингв.* тупас сүз (гыйбарә), вульгаризм (*әдәби телдә*)

вульга́рность *ж* вульгарлык, тупаслык, әдәпсезлек

вульга́рный, -ая, -ое 1. (*пошлый*) әдәпсез, тупас, вульгар 2. (*упрощённый*) вульгар, артык гади; бозык; ~ **материали́зм** вульгар материализм

вурдала́к *м фольк.* убыр, өрәк

вход *м* 1. *см.* **войти́**; 2. (*место*) керү урны, керә торган урын; ~ **в парк** паркка керү урны

входи́ть *несов. см.* **войти́**

входн||о́й, -а́я, -о́е керү ...ы; керә торган; ~**а́я дверь** керә торган ишек; ~**о́й биле́т** керү билеты

входя́щ||ий, -ая, -ее 1. *прич. от* **входи́ть**; 2. (*полученный упрощённым*) керә торган (*учреждениегә*); ~**ая бума́га** керә торган кәгазь

вхо́жий, -ая, -ее *разг.* кереп чыгып йөрүче, кереп чыгып йөри торган; үз кеше

вхолосту́ю *нареч.* тиккә, бушка, файдасызга, юкка; **стано́к рабо́тает ~** станок бушка эшли

вцепи́||ться *сов. в кого-что, разг.* эләктереп алу, ябышу; тотыну; **соба́ка ~лась в но́гу** эт аяктан эләктереп алды

вцепля́ться *несов. см.* **вцепи́ться**

вчера́ *нареч.* кичә

вчера́шний, -яя, -ее кичәге, үткән көндәге

вчерне́ *нареч.* каралама хәлендә; **прое́кт ~ гото́в** проект каралама хәлендә әзер

вчéтверо *нареч.* дүрт тапкыр (мәртәбә), дүрт кабат, дүртләтә

вчетверóм *нареч.* дүртәү, дүртәү бергә, дүртәүләп, дүртәүләшеп

в-четвёртых *вводн. сл.* дүртенчедән, дүртенчеләй

вчистýю *нареч. разг.* бетенләйгә, бөтенләй

вчитáться *сов. разг.* 1. укып аңлау (төшенү); ~ **в текст** текстны укып аңлау 2. укырга күнегү, укырга күнегеп китү; ~ **в Тукáя** Тукайны укырга күнегеп китү

вчúтываться *несов. см.* **вчитáться**

вшéстеро *нареч.* алты тапкыр (мәртәбә); алты кабат, алтылата

вшестерóм *нареч.* алтау, алтаулашып, алтау бергә, алтаулап

в-шестых *вводн. сл.* алтынчыдан

вшивáть *несов. см.* **вшить**

вшúветь *несов.* бетләү, бетләнү

вшивнóй, -áя, -óе эчкә тегелгән, эчкә тегеп куелган; ~ **кармáн** эчкә тегелгән кесә

вшúвость *м* бетлелек

вшúвый, -ая, -ое бетле, бетләгән, бетләп беткән

вширь *нареч.* як-якка, иңгә, кинлеккә, аркылыга; **раздáться** ~ як-якка җәелү

вшить *сов. что* [эчкә] тегеп кую, [эчкә] куеп тегү; ~ **рукáв** җиңне тегеп кую

въедáться *несов. см.* **въéсться**

въéдливость *ж* 1. (*едкость*) ныклык сенүчәнлек 2. (*придирчивость*) вакчыллык, бәйләнчеклек, сәркәшлек

въéдлив||ый, -ая, -ое *разг.* 1. ныклык сеңә торган; борын яргыч, үтеп керә торган; ~ **ая крáска** ныклык сеңә торган буяу; ~ **ый зáпах** үтеп керә торган ис 2. (*придирчивый*) вакчыл, төпченүчән, сәркәш, бәйләнчек

въезд *м* 1. *см.* **въéхать**; 2. (*место*) керү урыны, керә торган урын; ~ **в гóрод** шәһәргә керү урыны

въездн||óй, -áя, -óе керү ...ы, керә торган (*машинада, атта*); ~ **áя вúза** керү визасы (*берәр илгә*)

въезжáть *несов. см.* **въéхать**

въé||сться *сов.* кереп сеңү, сеңү; үтеп керү; **каменноугóльная пыль** ~**лась в кóжу** ташкүмер тузаны тирегә сеңгән

въéхать *сов.* 1. керү, барып (килеп) керү; ~ **в гóрод** шәһәргә барып керү 2. менү, күтәрелү; ~ **нá гору** тауга менү 3. килеп керү (урнашу); ~ **в нóвую квартúру** яңа квартирга килеп урнашу

вы (вас, вам, вас, вáми, о вас) *мест.* сез ◆ **быть на «вы»** *с кем кем белән дә булса* сез дип сөйләшү

вы- *приставка, татар теленә түбәндәге чаралар ярдәмендә тәрҗемә ителә:* 1) *«чыгу» яки «чыгару» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **выбéжать** йөгереп чыгу; **вы́гнать** куып чыгару; 2) *«алу» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **вы́винтить** борып алу; **вы́брать** сайлап алу; 3) *«бетү» яки «бетерү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **вы́белить** агартып бетерү; **вы́мокнуть** чыланып бетү; 4) *«тую» дигән фигыль ярдәмендә, мәс.* **вы́спаться** йоклап тую; 5) *төп фигыльне тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **вы́бить рисýнок** бизәк төшерү

выбáлтывать *несов.* **вы́болтать**

выбегáть *несов. см.* **вы́бежать**

вы́бежать *сов.* йөгереп чыгу; ~ **úз дому** өйдән йөгереп чыгу

вы́белить *сов. что* агартып бетерү (чыгу), агарту, аклау, аклап чыгу

вы́бели||ться *сов.* (*стать белым*) агару, агарып җитү; **холст** ~**лся** киндер агарды

выбивáть *несов. см.* **вы́бить**

выбивáться *несов.* 1. *см.* **вы́биться**; 2. *страд. от* **выбивáть**

выбирáть *несов. см.* **вы́брать**

выбирáться *несов.* 1. *см.* **вы́браться** 1, 2; 2. *страд. от* **выбирáть**

вы́бить *сов.* 1. *кого-что* бәреп чыгару; бәреп төшерү; ~ **прóбку** бөкене бәреп чыгару; ~ **из седлá** иярдән бәреп төшерү 2. *кого-что* куып чыгару, бәреп чыгару; ~ **противника из окóпа** окоптан дошманны бәреп чыгару 3. *что* [тузанын] кагу, кагып чыгару, кагып чыгарып бетерү; ~ **пыль из коврá** келәмнән тузан кагып чыгару; ~ **ковёр** хәтфә келәмнең тузанын кагу 4. *что* (*вытоптать*) таптап бетерү; (*уничтожить градом*) сугу 5. *что* (*вычеканить*) сугу, сугып ясау; чүкеп ясау; (*выдавить*) чокып ясау, чокып язу; (*вытиснить*) салу; ~ **монéту** тимер акча сугу; ~ **бýквы на мрáморе** мәрмәрга чокып хәрефләр язу ◆ ~ **дорóгу** юлны салуландыру; ~ **дурь из головы́** баштан җилне чыгарып ташлау; ~ **из колéй** чыгырдан чыгару

вы́би||ться *сов.* 1. *разг. из чего* чыгу, ерып чыгу; килеп чыгу (*көч-хәл белән*); ~**ться из окружéния** чолганыштан чыгу 2. *из чего, разг.* котылу, чыгу; ~**ться из долгóв** бурычтан чыгу 3. (*пробиться*) чыгу; үсеп чыгу; **бурья́н** ~**лся** кура үсеп чыккан 4. чыгып тору, чыгып күренеп тору; **вóлосы** ~**лись из-под шáпки** бүрек астыннан чәче чыгып тора ◆ ~**ться в лю́ди** кеше булу; ~**ться из гра́фика (расписа́ния)** графиктан (расписаниедән) чыгу; ~**ться из колéй** чыгырдан чыгу; ~**ться из сил** хәлдән таю

вы́боина *ж* (*яма, ухаб*) казылма, юл чокыры, сикәлтә; (*углубление на поверхности*) уем, уемты

вы́болтать *сов. что, разг.* сөйләп ташлау, ачып салу, сөйләп бирү (*серне һ.б.ш.*)

вы́бор *м* 1. *см.* **вы́брать** 1, 2; ~ **профéссии** профессия сайлау 2. сайлаганы, сайлап алганы; сайлап алган кеше; **одóбрить** *чей-л.* ~ *кемнең дә булса* сайлап алганын хуплау 3. төрле, төрле-төрле, сайлап алырлык, сайларлык; **большóй** ~ **товáров** товарлар бик күп, товарлар күп төрле 4. *мн.* ~**ы** сайлаулар; ~**ы наро́дных депута́тов** халык депутатларын сайлаулар ◆ **без** ~**а** сайлап-нитеп тормыйча; **на** ~ теләгәнен; **по своемý** ~**у** үзе теләгәнне, үзе теләгәнчә

вы́борк||а *ж* 1. *см.* **вы́брать** 3, 4; ~**а гру́нта** грунт сайлап алу 2. *мн.* ~**и** күчереп алынган өземтә, өзек; ~**и из произведе́ний А. С. Пу́шкина** А. С. Пушкин әсәрләреннән күчереп алынган өземтәләр

вы́борность *ж* сайлап куелу; ~ **су́дей** судьяларның сайланып куелуы

вы́борн||ый, -ая, -ое 1. сайланып куелган, сайлап куела торган, сайланган; ~**ое лицó** сайлап куелган кеше 2. сайлау ...ы, сайлаулар ...ы; сайлауларга караган; ~**ое собра́ние** сайлау җыелышы

вы́борочн||ый, -ая, -ое сайлаулы, сайланмалы; сайлап ...; өлешчә ...; ~**ая жáтва** сайлап уру

вы́борщик *м* 1. (*тот, кто производит выборку*) сайлап алучы, сайлаучы 2. сайлаучы, выборщик (*күп баскычлы сайлауларда*)

вы́браковать *сов. кого-что, спец.* бракка чыгару, брак дип санау

выбракóвывать *несов. см.* **вы́браковать**

вы́бранить *сов. кого-что, разг.* тиргәп ташлау, сүгеп ташлау

выбрáсывать *несов. см.* **вы́бросить**

выбрáсываться *несов.* 1. *см.* **вы́броситься**; 2. *страд. от* **выбрáсывать**

вы́брать *сов.* 1. *кого-что* сайлау, сайлап алу; ~ **профéссию** профессия сайлау 2. *кого-что* сайлау, сайлап кую; ~ **председáтеля** рәис сайлау 3. алу, алып бетерү; ~ **всё из я́щика** тартмадан барысын да алып бетерү 4. *что* күтәрү, тартып алу, тартып чыгару; ~ **я́корь** якорьне күтәрү; ~ **сеть** ятьмәне тартып чыгару 5. *что* үпләү, үпләү алу, тазарту; ~ **сор из семя́н** орлыктан үпне үпләп алу 6. *кто, разг.* табу, табып алу; ~ **свобóдную мину́ту** буш минут табу

вы́бра||ться *сов.* 1. чыгу, көчкә чыгу, ерып чыгу, ерынып чыгу; **мы е́ле** ~**лись из лесу** без урманнан көчкә чыктык; ~**ться из дому** өйдән ерынып чыгу 2. чыгу, котылу; ~**ться из нужды́** мохтаҗлыктан чыгу 3. *разг.* бара алу, килә алу; ~**ться в теáтр** театрга бара алу 4. *разг.* (*отыскаться — о времени*) табылу

вы́бре||сти *сов. разг.* барып (килеп) чыгу; **они́** ~**ли на дорóгу** юлга килеп чыктылар

выбрáивать *несов. см.* **вы́брить**

вы́брить *сов. что* кыру, кырып ташлау; кырдыру, кырдырып ташлату; алу, алдыру (*пәке белән*); ~ **гóлову** башны кырдыру; ~ **лицó** битне кыру

вы́бриться *сов.* кырыну, кырынып ташлау

вы́брос *м см.* **вы́бросить**; ~ **вре́дных веще́ств в атмосфе́ру** атмосферага зарарлы матдәләрнең чыгарылуы

вы́бросить *сов.* 1. *кого-что* ташлау, чыгарып ташлау, ыргыту, чыгарып ыргыту, ату, чыгарып ату; ~ **мýсор** үпне чыгарып ташлау 2. (*резким движением*) [алга] ташлау, сузу; ~ **рукú** кулларны ташлау 3. *перен. что, разг.* чыгару; ~ **товáр на ры́нок** базарга товар чыгару ◆ ~ **зá борт** чыгарып ташлау; ~ **из**

ВЫБ-ВЫВ

голову́ баштан чыгарып ташлау; **~ на у́лицу** 1) (*выселить*) урамга чыгарып ташлау; 2) (*лишить работы*) эштән куу; **~ на ве́тер** жилгә очыру

вы́броситься *сов.* ташлану, сикерү, ыргу; **~ с парашю́том** парашют белән сикерү

выбыва́ть *несов. см.* **вы́быть**

вы́быть *сов.* чыгу, китү; **~ из го́рода** шәһәрдән китү; **~ из стро́я** *прям., перен.* сафтан чыгу

выва́ливать I *несов. см.* **вы́валить**

выва́ливать II *несов. см.* **вы́валять**

выва́ливаться I *несов.* **1.** *см.* **вы́валиться**; **2.** *страд. от* **выва́ливать** I

выва́ливаться II *несов.* **1.** *см.* **вы́валяться**; **2.** *страд. от* **выва́ливать** II

вы́валить *сов.* **1.** *кого-что, разг.* аудару, аударып ташлау, егып төшерү, түгү, бушату; **~ песо́к из мешка́** капчыктан комны түгү **2.** *прост.* (*выйти толпой, группой*) агылып килеп чыгу, агылу

вы́вали||ться *сов.* **1.** төшү, төшеп китү, килеп төшү, барып төшү, егылып төшү; **кни́га ~лась из рук** кулдан китап төшеп китте **2.** *см.* **вы́валить** 2

вы́валять *сов. кого-что, разг.* аунату, аунатып пычрату, аунатып буяу; **~ в грязи́** баткакта аунату

вы́валяться *сов. разг.* аунау, аунап пычрану, аунап буялу; **~ в снегу́** карда аунау

выва́ривать *несов. см.* **вы́варить**

выва́риваться *несов.* **1.** *см.* **вы́вариться**; **2.** *страд. от* **выва́ривать**

вы́варить *сов. что* **1.** пешереп җиткерү; **~ мя́со** итне пешереп җиткерү **2.** кайнатып табу (алу, чыгару); **~ жир из косте́й** сөякләрдән май кайнатып чыгару

вы́вариться *сов.* пешеп изелү, пешеп изрәү, изелеп пешү

вы́варка *ж см.* выварить 2; **~ са́хара** шикәр кайнатып табу

вы́ведать *сов. что и без доп., разг.* сорашып белү, сорашып ачыклау, төпченеп белү; **~ чьи-л. наме́рения** *кемнең дә булса* ниятләрен сорашып белү

выведе́ние *с см.* **вы́вести**; **~ но́вых сорто́в пшени́цы** бодайның яңа сортларын китереп чыгару; **~ пя́тен** тапны бетерү; **~ фо́рмулы** формула чыгару

выве́дывать *несов. см.* **вы́ведать**

вы́везти *сов. кого-что* **1.** чыгару, төяп чыгару, алып чыгу; чыгарып ташлау (түгү); **~ дете́й за́ город** балаларны шәһәр читенә чыгару; **~ семена́ в по́ле** орлыкны басуга төяп чыгару; **~ му́сор на сва́лку** чүпне чүплеккә чыгарып ташлау **2.** (*привезти с собой*) алып кайту (килү) **3.** *разг.* (*выручить*) коткару, котылдыру; **его вы́вез слу́чай** аны бер очрак коткарды ♦ **~ на себе́** үз җилкәсендә алып чыгу

вы́верить *сов. что* тикшерү, тикшереп дөресләү; **~ спи́ски избира́телей** сайлаучылар исемлеген тикшерү

вы́верка *ж см.* **вы́верить**

вы́верну||ть *сов. что* **1.** борып алу, борып чыгару; **~ть винт** винтны борып чыгару **2.** *разг. см.* **вы́вихнуть**; **3.** (*выдернуть*) йолкып алу, йолкып (куптарып) чыгару; **сосну́ ~ло бу́рей** *безл.* наратны давыл куптарып чыгарган **4.** әйләндерү; **~ть рука́в наизна́нку** җиңне тискәре ягына әйләндерү

вы́верну||ться *сов.* **1.** *разг.* борылып чыгу; **винт ~лся** винт борылып чыкты **2.** *разг. см.* **вы́вихнуться**; **нога́ ~лась** аяк таеп чыкты **3.** әйләнү, әйләнеп чыгу; **рука́в ~лся наизна́нку** җиңе тискәре ягына әйләнгән **4.** (*выскользнуть из чьих-л. рук*) шуып чыгу, ычкыну, ычкынып китү **5.** *перен.* (*выйти из затруднительного положения*) котылу, ычкыну, ычкынып котылу

вы́верт *м разг.* **1.** боргаланыш, боргалану-сыргалану; **плеса́ть с ~ами** боргаланып-сыргаланып бию **2.** *перен.* (*причуда*) әкәмәт, әкәмәт кыланыш, сәер кыланыш, сәерлек

вывёртывать *несов. см.* **вы́вернуть**

вывёртываться *несов.* **1.** *см.* **вы́вернуться**; **2.** *страд. от* **вывёртывать**

выверя́ть *несов. см.* **вы́верить**

вы́весить I *сов. что* элү, элеп кую, чыгарып элү; **~ фла́ги** флагларны элеп кую; **~ бельё** керне чыгарып элү; **~ объявле́ние** белдерүне элеп кую; **~ прика́з** приказны элү

вы́весить II *сов. что* (*определить вес*) үлчәү, үлчәп карау (тикшерү)

вы́веска I *ж* **1.** **вы́веска 2.** *перен.* (*показная сторона*) пәрдә

вы́веска II *ж см.* **вы́весить** II

вы́вести *сов.* **1.** *кого-что* чыгару, алып чыгу; **~ дете́й в сад** балаларны бакчага чыгару; **~ ло́шадь из коню́шни** атны абзардан алып чыгу **2.** *кого-что* чыгару; **~ из игры́** уеннан чыгару; **~ из соста́ва прези́диума** президиум составыннан чыгару **3.** *что* чыгару; **~ фо́рмулу** формула чыгару **4.** чыгару; **~ цыпля́т** чебиләр чыгару **5.** *кого-что* китереп чыгару, барлыкка китерү; **~ но́вую поро́ду коро́в** сыерларның яңа токымын барлыкка китерү **6.** *что* (*построить*) төзү, ясау, салу, чыгару; **~ фунда́мент** фундамент төзү **7.** *кого-что* (*уничтожить*) бетерү, юкка чыгарү; **~ пятно́** тапны бетерү **8.** *что* (*старательно написать*) чыгару, язып кую **9.** *кого-что* (*изобразить*) тасвирлау, сурәтләү; **~ в рома́не но́вого челове́ка** романда яңа кешене тасвирлау ♦ **~ отме́тку** билге чыгару; **~ нару́жу** тышка чыгару; **~ в лю́ди** кеше итү; **~ из равнове́сия** чыгырыннан чыгару; **~ из себя́** чыгырыннан чыгару; **~ из стро́я** сафтан чыгару; **~ на доро́гу** дөрес юлга бастыру (чыгару); **~ на чи́стую во́ду** фаш итү, ачып салу

вы́ве||стись *сов.* **1.** бетү, юкка чыгу; **пятно́ ~лось** тап бетте; **ста́рые обы́чаи ~лись** иске гореф-гадәтләр юкка чыкты **2.** (*появиться — о птенцах*) чыгу

вывё́тривать *несов. см.* **вы́ветрить**

вывё́триваться *несов.* **1.** *см.* **вы́ветриться**; **2.** *страд. от* **вывё́тривать**

вы́ветр||ить *сов. что* **1.** җилләтеп бетерү, җилләтеп юкка чыгару; **~ить за́пах нафтали́на** нафталин исен җилләтеп бетерү **2.** *геол.* җимерү, ашау; **~енные ска́лы** җил ашаган кыялар

вы́ветри||ться *сов.* **1.** җилдән бетү, җилдән юкка чыгу; **угар ~лся** ис җилдән юкка чыкты **2.** *геол.* җилдән җимерелү, җилдән ашалу **3.** *перен.* (*забыться*) баштан чыгу, истән чыгу; онытылу

вывё́шивание *с см.* **вы́весить** I

вывё́шивать I *несов. см.* **вы́весить** I

вывё́шивать II *несов. см.* **вы́весить** II

вы́винтить *сов. что* борып алу, борып чыгару; **~ винт** винтны борып чыгару

вы́винти||ться *сов.* борылып чыгу; **ла́мпочка ~лась** лампочка борылып чыккан

вывёрнчивать *несов. см.* **вы́винтить**

вывёрнчиваться *несов.* **1.** *см.* **вы́винтиться**; **2.** *страд. от* **вывёрнчивать**

вы́вих *м* **1.** каймыгу, таю, каймыгып чыгу, таеп чыгу; **~ руки́** кулның каймыгуы **2.** (*место*) тайган сөяк; тайган урын, каймыккан урын **3.** *перен. разг.* тайпылыш; **теорети́ческие ~и** теоретик тайпылышлар

вы́вихнуть *сов. что* каймыктыру, тайдыру, каймыктырып (тайдырып) чыгару; **~ ру́ку** кулны каймыктыру

вы́вихну||ться *сов.* каймыгу, таю, каймыгып (таеп) чыгу; **нога́ ~лась** аягы тайган

вы́вод *м* **1.** *см.* **вы́вести**; **~ войск** гаскәрләрне чыгару **2.** нәтиҗә, йомгак, сөземтә; **прийти́ к пра́вильному ~у** дөрес нәтиҗәгә килү **3.** *тех.* чыгынты

выводи́ть *несов. см.* **вы́вести**

выводи́ться *несов.* **1.** *см.* **вы́вестись**; **2.** *страд. от* **выводи́ть**

выводн||о́й, -а́я, -о́е чыгару ...ы, чыгара торган; **~а́я тру́бка** чыгару торбачыгы

вы́водок *м* бер оя ... балалары; бер оя ... бәбкәләре; **ути́ный ~** бер оя үрдәк бәбкәләре; **во́лчий ~** бер оя бүре балалары

вы́воз *м* **1.** *см.* **вы́везти** 1, 2; **~ дете́й в лес** балаларны урманга алып чыгу; **~ удобре́ний** ашламалар чыгару **2.** (*экспорт*) читкә чыгару; экспорт; **~ това́ров** товарларны читкә чыгару

вывози́ть *сов.* что, *разг.* пычрату; **~ пла́тье в грязи́** күлмәкне баткакта пычрату

вывози́ть *несов. кого-что* **1.** *см.* **вы́везти**; **2.** чыгару, читкә чыгару; **~ сырьё** чималны читкә чыгару

вы́вози||ться *сов. разг.* пычрану; **ребёнок ~лся в грязи́** бала баткакта пычранган

вы́возка *ж см.* **вы́везти** 1, 2

вывозн||о́й, -а́я, -о́е **1.** чыгару ...ы; **~а́я систе́ма** чыгару системасы **2.** читкә чыгару ...ы; читкә чыгарганда алына торган; **~а́я по́шлина** читкә чыгару пошлинасы

вывола́кивать *несов. см.* **вы́волочь**

вы́волочк||а *ж прост.* кирәген бирү; чәченнән тарту; тиргәү; әрләү; **зада́ть ~у** кирәген бирү

вы́волочь *сов. кого-что, разг.* сөйрәп (өстерәп) чыгару; ~ **мешки́ из амба́ра** келәттән капчыкларны сөйрәп чыгару

выворáчивать *несов. см.* **вы́воротить**

выворáчиваться *несов.* 1. *см.* **вы́воротиться**; 2. *страд. от* **выворáчивать**

вы́воротить *сов. что, прост.* 1. куптарып (каерып, борып) алу, куптарып (каерып) чыгару; ~ **столб** багананы куптарып чыгару 2. әйләндерү, тискәре ягын әйләндерү; ~ **карма́н** кесәне әйләндерү 3. (*перешить, вывернув наизнанку*) әйләндереп тегү

вы́вязать *сов. что, разг.* бәйләү, бәйләп алу (*бишинә белән*)

вы́гадать *сов. что* [акчаны] янга калдыру; файда итү; оту; ~ **вре́мя** вакыт оту; ~ **пятьсо́т рубле́й** биш йөз сумны янга калдыру

выга́дывать *несов. см.* **вы́гадать**

вы́гиб *м* бөгелгән урын, бөгелеш, бөгелмә

выгиба́ть *несов. см.* **вы́гнуть**

выгиба́ться *несов.* 1. *см.* **вы́гнуться**; 2. *страд. от* **выгиба́ть**

вы́гладить *сов. что* 1. (*выровнять*) тигезләү, шомарту 2. (*утюгом*) өтеләү, үтүкләү, өтелəп (үтүкләп) алу

выгла́живать *несов. см.* **вы́гладить**

вы́глядеть *несов.* күренү, ... булып күренү; ~ **молоды́м** яшь күренү

выгля́дывать *несов. см.* **вы́глянуть**

вы́гляну||ть *сов.* 1. сузылып карау, башны чыгарып карау, башны тыгып карау; ~**ть из окна́** тәрәзәдән башны чыгарып карау 2. күренү, килеп чыгу; карау; ~**ло со́лнце** кояш күренде

вы́гнать *сов.* 1. *кого-что* куып чыгару, куып җибәрү, куу, сөреп чыгару; сөрү; ~ **из дому** өйдән куып чыгару; ~ **с рабо́ты** эштән куып, сөреп чыгару; ~ **ста́до в по́ле** көтүне кырга куу 2. *что, спец.* куу, куып хәзерләү; кайнату; ~ **спирт** спирт куу; ~ **дёготь** дегет куу

выгнива́ть *несов. см.* **вы́гнить**

вы́гни||ть *сов.* черү, эчтән черү; **зуб** ~**л** теш эчтән черегән

вы́гнуть *сов. что* бөгү, бөгеп кую, бөкрәйтү; ~ **па́лку** таякны бөгү

вы́гнуться *сов.* бөгелү; бөгелеп китү; бөкрәю

выгова́ривать *несов.* 1. *см.* **вы́говорить**: 2. *кому, разг.* шелтәләү, әрләү, сүз әйтү

выгова́риваться *несов.* 1. *см.* **вы́говориться**; 2. *страд. от* **выгова́ривать** 1

вы́говор *м* 1. (*произношение*) сөйләү, әйтелеш; **во́лжский** ~ Идел кешеләречә сөйләү 2. шелтә, шелтәләү; **объяви́ть** ~ шелтә белдерү; **получи́ть** ~ шелтә алу

вы́говорить *сов. что* 1. (*произнести*) әйтү, әйтеп кую 2. *разг.* алдан сорап алу (кую), алдан үтенеп алу, алдан алу; ~ **себе́ пра́во отсро́чки** срокны кичектерү хокукын алдан сорап алу

вы́говориться *сов. разг.* (*высказать всё*) сөйләп бетерү, әйтәсен әйтеп бетерү, барысын да әйтү (сөйләү)

вы́года *ж* 1. (*прибыль*) табыш, файда 2. (*польза*) файда

вы́годно *нареч.* 1. файда белән, табыш белән; **прода́ть** ~ файда белән сату 2. *в знач. сказ.* файдалы, табышлы; **кому́ э́то** ~? кемгә бу файдалы?

вы́годн||ый, -ая, -ое 1. табышлы, файдалы; файда китерә торган; ~**ая сде́лка** файда китерә торган килешү; ~**ое ме́сто** табышлы урын; **экономи́чески** ~**ый** экономик яктан файдалы 2. файдалы; җайлы, уңай, уңайлы; **производи́ть** ~**ое впечатле́ние** уңай тәэсир калдыру

вы́гон *м* 1. *см.* **вы́гнать** 1; 2. (*напр. пастбище*) көтүлек, утлавык

вы́гонка *ж см.* **вы́гнать** 2; ~ **спи́рта** спирт куу

выгоня́ть *несов. см.* **вы́гнать**

выгора́живать *несов. см.* **вы́городить**

выгора́ть I *несов.* **вы́гореть** I

выгора́ть II *несов.* **вы́гореть** II

вы́горевш||ий, -ая, -ее 1. *прич. от* **вы́гореть** 1; 2. кояшта унган, кояшта янган, уңып беткән; кояш ашаган; ~**ая руба́шка** кояшта унган күлмәк

вы́горе||ть I *сов.* 1. (*сгореть*) янып бетү, яну; көю, көеп бетү; **кусты́** ~**ли** (*сгорели*) куаклар янып бетте; **степь** ~**ла** (*от зноя*) дала көйгән (*эсседән*); **керосúн весь** ~**л** керосин янып бетте 2. (*выцвести*) кояшта уңу, кояшта яну, уңып бетү, кояш ашау

вы́горе||ть II *сов. разг.* пешү, пешеп чыгу, барып чыгу, уңу; **де́ло** ~**ло** эш пеште

вы́городить *сов.* 1. *что* (*отделить изгородью*) киртәләп алу, киртәләү, коймалап алу; коймалау 2. *перен. кого-что, разг.* яклау, аралау; яклап алып калу, аралап калу; ~ **себя́** үзеңне аралап калу

вы́гравировать *сов. что* гравюрлау, гравюра ясау; чокып язу (ясау)

вы́гребать *несов. см.* **вы́грести**

вы́гребн||о́й, -а́я, -о́е: ~**а́я я́ма** шакшы сулар чокыры

вы́грести *сов.* 1. *что* көрәп чыгару, көрәп (сосып) алу; ~ **золу́** көлне сосып алу 2. (*вёслами*) ишеп килеп чыгу, ишеп чыгу; ишеп җиту

выгружа́ть *несов. см.* **вы́грузить**

выгружа́ться *несов.* 1. *см.* **вы́грузиться**; 2. *страд. от* **выгружа́ть**

вы́грузить *сов. кого-что* бушату, бушатып бетерү, йөген бушату, [йөген] чыгару; ~ **багаж** багажны чыгару

вы́грузи||ться *сов.* 1. (үз йөгеңне) бушату, бушатып бетерү; **су́дно** ~**лось у при́стани** судно пристань янында үз йөген бушатты 2. (*высадиться — о многих*) төшү, төшеп калу, чыгу

вы́грузка *м см.* **вы́грузить**, **вы́грузиться**

выгрыза́ть *несов. см.* **вы́грызть**

вы́грызть *сов. что* кимереп тишү (чыгару)

вы́гул *м* ялан абзар, тышкы абзар

выдава́ть *несов. см.* **вы́дать**

выдава́ться *несов.* 1. *см.* **вы́даться**; 2. аерылып тору, аерылу; ~ **свои́м умо́м** акылы белән аерылып тору

вы́давить *сов. что* 1. сыгу, сыгып чыгару; кысу, сытып (кысып, изеп) чыгару; ~ **сок из я́год** җиләктән сок кысып чыгару 2. бәреп чыгару, этеп вату, бәреп вату; ~ **стекло́ из ра́мы** рамнан пыяланы бәреп чыгару 3. (*вытиснить*) басып чыгару (төшерү, ясау)

♦ ~ **из се́бя улы́бку** көчләнеп елмаю

вы́дави||ться *сов.* 1. чыгу (*кысудан, сыгудан*); **па́ста** ~**лась из тю́бика** паста тюбиктан чыккан 2. (*басудан, кысудан*) килеп чыгу (төшү), ватылу; **сиде́нье сту́ла** ~**лось** урындыкның утыра торган тактасы килеп төшкән 3. (*вытиснúться*) чыгу, төшү (*эз, рәсем һ.б.ш. турында*)

выдáвливать *несов. см.* **вы́давить**

выдáвливаться *несов.* 1. *см.* **вы́давиться**; 2. *страд. от* **выдáвливать**

выдáивать *несов. см.* **вы́доить**

выдáлбливать *несов. см.* **вы́долбить**

вы́данье *с*: **на** ~ *уст.* житкән, кияүгә бирерлек (*кыз турында*)

вы́дать *сов.* 1. *что* бирү; өләшү, тарату; ~ **ава́нс** аванс бирү; ~ **де́ньги** акча өләшү 2. *кого-что* (*возвратить*) кире бирү, кире кайтару; ~ **пле́нного** әсирне кире кайтару 3. *кого-что* белгертү, белдерү; ачу; ~ **секре́т** серне ачу; ~ **своё волне́ние** дулкынлануны белгертү 4. *кого-что* (*предать*) тоттыру, сату; фаш итү 5. за *кого-что* (*представить не тем*) ... дип күрсәтү, ... итеп күрсәтү; ~ **за своё произведе́ние** үз әсәре итеп күрсәтү 6. *что* (*добыть, изготовить*) бирү; чыгару, эшләп бирү; ~ **нефть сверх но́рмы** нефтьне нормадан тыш бирү; **цех вы́дал проду́кцию ра́ньше сро́ка** цех продукцияне вакытыннан алда эшләп бирде ♦ **не вы́дай[те]** батырма[гыз], утыртма[гыз]; ~ **себя́ с голово́й** үзен тоттыру, үз гаебен үзе ачып салу; ~ **за́муж** кияүгә бирү

вы́да||ться *сов.* 1. чыгып (калкып) тору; **скала́** ~**лась вперёд** кыя алга чыгып тора 2. (*отличиться*) аерылып чыгу, аерылып тору 3. *разг.* (*случиться*) булу; ~**лся хоро́ший день** яхшы көн иде ♦ ~**лся слу́чай** жай чыкты

вы́дача *ж* 1. *см.* **вы́дать** 1-4, 6; ~ **па́спорта** паспортны бирү; ~ **проду́кции сверх пла́на** планнан тыш продукция бирү 2. бирелгән акча; бирелгән товар; **кру́пная** ~ күп итеп бирелгән акча

выдаю́щ||ийся, -аяся, -еяся 1. *прич. от* **выдава́ться** 1, 2; 2. күренекле, атаклы; ~**еяся произведе́ние** күренекле әсәр

выдвига́ть *несов. см.* **вы́двинуть**

выдвига́||ться *несов.* 1. *см.* **вы́двинуться**; 2. тартып (шудырып) чыгарыла торган булу; **доска́ стола́** ~**ется** өстәлнең тактасы шудырып чыгарыла 3. *страд. от* **выдвига́ть**

выдвиже́нец *м* җитәкче итеп куелган эшче, выдвиженец

выдвиже́ние *с см.* **вы́двинуть**, **вы́двинуться**; ~ **молоды́х рабо́чих** яшь эшчеләрне күтәрү; ~ **кандида́тов в депута́ты** делутатлыкка кандидатлар күрсәтү

выдвижн||о́й, -а́я, -о́е шудырма ..., тартып чыгарыла торган, шудырып чыгарыла торган; ~**о́й я́щик** тартып чыгарыла торган тартма

ВЫД-ВЫЕ

вы́двинуть *сов.* **1.** *что* тартып чыгару, тартып күчерү; этәреп күчерү; **~ я́щик стола́** өстәл тартмасын тартып чыгару **2.** *что* ташлау, кую; **~ пра́вую но́гу вперёд** уң аякны алга кую **3.** *перен. что* кую, китерү, ташлау; **~ те́зис** тезис кую; **~ обвине́ние** гаеп ташлау **4.** *перен. кого* күтәрү, үрләтү, кую; күрсәтү, тәкъдим итү; **~ кандида́том в депута́ты** депутатлыкка кандидат итеп күрсәтү

вы́двину||ться *сов.* **1.** алга чыгу, (күчү, китү); **~ться** из толпы халык төркеменнән алга чыгу **2.** *перен.* күтәрелү, үсү, күтәрелеп китү, үсеп китү; **молодо́й музыка́нт бы́стро ~лся** яшь музыкант тиз күтәрелеп китте

вы́дворить *сов. кого-что* куып (сөреп) чыгару, куу, сөрү

выдворя́ть *несов. см.* **вы́дворить**

вы́дел *м* **1.** *юр.*: **~ до́ли из о́бщего иму́щества** уртак мөлкәтнең өлешен бүлеп бирү **2.** (*часть имущества*) бүлеп бирелгән мөлкәт; бүлендек

вы́дела||ть *сов. что* **1.** эшләү, ясау; **иску́сно ~нная вещи́ца** оста ясалган әйбер **2.** эшкәртү; (*шкуру*) илəү

выделе́ние *с* **1.** *см.* **вы́делить, вы́делиться**; **~ иму́щества** мөлкәтне бүлеп бирү; **~ по́та** тирнең бүленеп чыгуы **2.** *мн.* **~я** бүлендек

выдели́тельн||ый, -ая, -ое *физиол.* бүлеп чыгара торган, бүлеп чыгару ...ы; **~ые о́рганы** бүлеп чыгару әгъзалары

вы́делить *сов.* **1.** *кого-что* бүлеп (аерып) алу, бүлеп (аерып) чыгару, бүлеп (аерып) бирү; бүлү, аеру; **~ стригуно́в из та́буна** көтүдән кырыкмышларны аерып алу; **~ о́пытных рабо́тников** тәҗрибәле хезмәткәрләрне бүлеп бирү **2.** *что* күрсәтү, билгеләү, күрсәтеп бирү, аеру, аерып күрсәтү; **~ цита́ту курси́вом** өземтәне курсив белән аерып күрсәтү **3.** *что* (*отдать во владение часть*) бүлеп бирү, бүлү; **~ иму́щество** мал бүлеп бирү **4.** *кого-что* (*имущественно отделить*) башка чыгару, аерып чыгару; **жени́ть и ~ сы́на** улны өйләндереп башка чыгару **5.** *что, спец.* чыгару, аерып алу, аерып чыгару; бүлеп чыгару; **~ водоро́д из воды́** судан водород бүлеп чыгару; **~ пот** тир бүлеп чыгару

вы́дели||ться *сов.* **1.** аерылу, аерылып (бүленеп) чыгу; **~ться в самостоя́тельный отде́л** мөстәкыйль бер бүлек бүлеп аерылып чыгу **2.** (*отличиться*) аерылып тору **3.** башка чыгу, аерылып чыгу; **брат по́сле жени́тьбы ~лся** абый өйләнгәннән соң башка чыкты **4.** бүленеп чыгу, аерылу, чыгу; **пот ~лся** тир бүленеп чыкты

вы́делка *ж* **1.** *см.* **вы́делать, выде́лывать** 2; **~ кирпича́** кирпеч сугу **2.** ясалу, эшләнү, эшкәртелү, эшләнеш, ясалыш, эшкәртелеш; **хоро́шая ~** эшкәртелеше яхшы

выде́лыва||ть *несов. что* **1.** *см.* **вы́делать**; **2.** эшләп чыгару, эшләү, ясау; **~ть пу́говицы** төймәләр ясау **3.** *перен. разг.* (*вытворять*) кыландыру, эшләү; кылану; **что то́лько он не ~л!** ул ничек кенә кыланмады!

выделя́ть *несов. см.* **вы́делить**

выделя́ться *несов. см.* **1.** *см.* **вы́делиться**; **2.** *страд. от* **выделя́ть**

вы́дергать *сов. что, разг.* тартып чыгару, йолкып (суырып) чыгару

выдёргивать *несов. см.* **вы́дергать, вы́дернуть**

выдёргиваться *несов.* **1.** *см.* **вы́дернуться**; **2.** *страд. от* **выдёргивать**

вы́держанность *ж* **1.** эзлеклелек; **~ сти́ля** стильнең эзлеклелеге **2.** тотнаклык, сабырлык; **он не отлича́лся ~ю** аңа тотнаклык җитми иде

вы́держанн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **вы́держать**; **2.** тотнаклы, сабыр; **~ый челове́к** тотнаклы кеше **3.** тиешенчә тотылган, тиешенчә тотып хәзерләнгән; **~ое вино́** тиешенчә тотылган шәраб

вы́держа||ть *сов.* **1.** *кого-что* чыдау, түзү, бирешмәү; күтәрү; **лёд не ~л** боз чыдамады **2.** *что* (*вытерпеть*) чыдый алу, түзә алу, күтәрә алу **3.** *что* унышлы бирү, уңышлы тапшыру; бирә алу; **~ть приёмные экза́мены** керү имтиханнарын уңышлы бирү **4.** *что* (*соблюсти*) тоту, үтәү; саклау; **~ть срок рабо́ты** эш срогын үтәү **5.** *что* (*продержать*) тоту, тотып тору **6.** *что* тиешенчә тоту, тиешенчә тотып хәзерләү; **~ть сыр** сырны тиешенчә тотып хәзерләү; **~ть вино́** шәрабны тиешенчә тоту ♦ **~ть не́сколько изда́ний** берничә басмасы чыгу; **~ть роль** рольне башкарып чыгу; **~ть хара́ктер** бирешмәү, нык тору; **~ть испыта́ние** (*о машинах и т.п.*) сынауны үтү

выде́ржива||ть *несов. см.* **вы́держать** ♦ **не ~ет кри́тики** тәнкыйтьне күтәрә алмый

вы́держк||а I *ж* **1.** тотнаклык, сабырлык; түземлек, чыдамлылык; **прояви́ть большу́ю ~у** зур тотнаклык күрсәтү **2.** *фото* **вы́держка**; **снять с большо́й ~ой** зур выдержка белән төшерү

вы́держка II *ж* (*выписка, цитата*) өземтә, өзек (*берәр тексттан*)

вы́дернуть *сов. что* тартып алу, суырып алу (чыгару), йолкып алу (чыгару), тартып чыгару; **~ гво́здь** кадакны суырып чыгару; **~ сорня́к** чүп үләнне йолкып алу

выдира́ть *несов. см.* **вы́драть I**

вы́доить *сов.* **1.** *кого* (*корову*) саву, савып бетерү **2.** *что* (*молоко*) савып алу

вы́долбить *сов. что* **1.** чокып ясау; **~ чёлн** каек чокып ясау **2.** уеп (чокып) ясау; **~ паз** ырмау уеп ясау

вы́дох *м* үпкәдән [һава] чыгару, тын чыгару, сулыш чыгару

вы́дохнуть *сов. что* [үпкәдән] тын (сулыш) чыгару

вы́дох||нуться *сов.* **1.** исе бетү; тәме бетү, тәмен югалту, айну, көче бетү; табак **~ся** тәмәкенең көче беткән **2.** *перен. разг.* хәлдән таю, көче китү, дәрман китү, бетү, бетерешү; **стари́к ~ся** карт хәлдән тайган

вы́дра *ж* **1.** *зоол.* кама (елгада); **морска́я ~** камчат **2.** (*мех*) кама мехы (тиресе); камчат мехы (тиресе) **3.** *прост. бран.* ләтчә (*хатын-кыз турында*)

вы́драть *сов. разг.* **1.** *что* ертып (йолкып, кубарып) алу; тартып чыгару; **~ пу́говицу** төймәне йолкып алу **2.** *кого* (*высечь, выпороть*) кыйнау, тукмау, суктыру

вы́дрессировать *сов. кого-что* өйрәтү, дрессировкалау, өйрәтеп җиткерү

вы́дубить *сов. что* дуплау, кайрылау; **~ шку́ру** тирене дуплау

вы́дубиться *сов.* дуплану, кайрылану

выдува́ть *несов. см.* **вы́дуть**

вы́дувка *ж см.* **вы́дуть** 3; **~ посу́ды** савытны өреп ясау

вы́думать *сов. что* **1.** уйлап чыгару, уйлап табу; башына килү; **~ но́вую игру́** яңа уен уйлап чыгару **2.** (*сфантазировать*) уйлап чыгару, ялган кору

вы́думк||а *ж* **1.** (*вымысел*) уйдырма, ялган **2.** уйлап чыгару, уйлап табу; **он хитёр на ~и** ул уйлап чыгарырга оста

вы́думщик *м разг.* **1.** (*затейник*) уйлап чыгаручы, уйлап табучы; мәзәкчән кеше **2.** (*фантазёр*) уйдырмачы, ялганчы, алдакчы

выду́мыва||ть *несов. см.* **вы́думать** ♦ **не ~й[те]** уйлап та карама[гыз]

вы́ду||ть *сов. что* **1.** өреп чыгару; **~ть из тру́бки пе́пел** трубкадан көлне өреп чыгару **2.** *разг.* өреп суыту, өрә-өрә суыту; жил өреп суыту; **пе́чку ~ло** *безл.* мичне җил өреп суыткан **3.** (*изготовить дутьём*) өреп ясау **4.** *прост.* (*выпить много, всё*) төбен ялтырату, чөмереп бетерү, эчеп бетерү ♦ **~ть печь** *тех.* мичне туктату

вы́дыха́ть *несов. см.* **вы́дохнуть**

вы́дыха́ться *несов.* **1.** *см.* **вы́дохнуться**; **2.** *страд. от* **вы́дыха́ть**

выеда́ть *несов. см.* **вы́есть**

вы́езд *м* **1.** *см.* **вы́ехать** 1, 2; **~ в командиро́вку** командировкага китү **2.** (*место*) чыгу юлы, чыга торган урын; **на ~е из го́рода** шәһәрдән чыгу юлында **3.** *уст.* (*лошади с экипажем*) җигүле ат, җигүле атлар; ат-арба

вы́ездить *сов. кого* (*в упряжи*) җиге йөрергә өйрәтү; (*под седлом*) менеп йөрергә өйрәтү

выездн||о́й, -а́я, -о́е **1.** чыгу ...ы; **~ые воро́та** чыгу капкасы **2.** юл ...ы, юл йөри торган; **~ые ло́шади** юл йөри торган атлар **3.** күчмә; **~о́е заседа́ние суда́** судның күчмә утырышы

выезжа́ть I *несов. см.* **вы́ехать**

выезжа́ть II *несов. см.* **вы́ездить**

вы́ем *м см.* **вы́емка** 2

вы́емка *ж* **1.** *см.* **вы́нуть**; **~ гру́нта** грунтны алу **2.** (*углубление*) уем, уенты, уеп алынган урын; чокыр

вы́есть *сов. что, разг.* **1.** эчен ашау, уртасын ашау, эчен ашап бетерү; **~ начи́нку пирога́** бәккәннен эчен ашау **2.** ашау, яндыру, кису; ачыттыру (*мәс. кислота турында*)

вы́ехать *сов.* **1.** китү, чыгу, чыгып китү (*атта, машинада һ.б.ш.*); **~ из го́рода** шәһәрдән китү **2.** килеп чыгу, килеп җитү; **~ на пло́щадь** мәйданга

килеп чыгу **3.** *перен. на ком-чём, разг.* (*извлечь выгоду*) ... исәбенә яшәү, ... исәбенә тору; ...дан файда алу

вы́жать I *см. что* **1.** сыгу; кысып (сыгып) чыгару; **~ из лимо́на сок** лимоннан сок кысып чыгару; **~ бельё** керне сыгу **2.** *перен.* (*с трудом извлечь, получить*) сыгып алу, сыгу, файда алу, алу, тулы файдалану; **~ после́дние си́лы** *из кого-л.* соңгы көчләрен сыгу **3.** *спорт.* күтәрү; **~ шта́нгу** штанганы күтәрү

вы́жать II *сов. что* урып бетерү (алу, чыгу); **~ гекта́р ржи** бер гектар арышны урып бетерү

вы́ждать *сов. что и без доп.* көтеп (сагалап) алу; **~ подходя́щий моме́нт** кулай вакытны көтеп алу

вы́ж||ечь *сов. что* **1.** яндыру, көйдерү, яндырып (көйдереп) бетерү; **со́лнце ~гло посе́вы** кояш чәчүлекләрне көйдерде **2.** (*прожечь*) яндыру, кисү, яндырып тишү; ашап тишү, ашап тишеп бетерү **3.** яндырып ясау; яндырып [бизәк] төшерү, яндырып [тамга] салу; **~ечь тавро́** яндырып тамга салу **4.** (*очистить обжиганием*) яндырып чистарту, яндыру

выжива́ть I *несов. см.* **вы́жить** I

выжива́ть II *несов. см.* **вы́жить** II

вы́жига *м, ж прост.* алдакчы, саран, кырыгалдар

выжига́ние *с см.* **вы́жечь**; **~ по де́реву** агачны яндырып бизәк төшерү

выжига́ть *несов. см.* **вы́жечь**

выжида́тельн||ый, -ая, -ое көтеп тору ...ы, сагалап тору ...ы; **~ая та́ктика** көтеп тору тактикасы

выжида́ть *несов.* көтеп тору, сагалап тору

вы́жим *м спорт.* күтәрү

выжима́ть *несов. см.* **вы́жать** I

вы́жимка *ж см.* **вы́жать** I 1, 2

вы́жимки *только мн.* түп, сыгынты; **льняны́е ~** җитен түбе

выжина́ть *несов. см.* **вы́жать** II

вы́жи||ть I *сов.* исән калу, сау калу; **ра́неный ~л** яралы исән калды ♦ **~ть из ума́** акылдан язу (картаймыш көндә)

вы́жить II *сов. кого-что, разг.* чыгару, чыгарып җибәрү, кысыклап чыгару; **~ со слу́жбы** эшеннән кысыклап чыгару

вы́звать *сов.* **1.** *кого-что* чакырып алу, чакыру, чакырып чыгару; **~ из до́ма** өйдән чакырып чыгару; **~ к себе́** үзенә чакырып алу **2.** *кого-что* чакыру; **~ на соревнова́ние** ярышка чакыру **3.** *кто* китереп чыгару, барлыкка китерү, хасил итү, кузгату, уяту; **~ гнев** ачу кузгату; **~ ра́дость** шатландыру; **~ пожа́р** янгын китереп чыгару ♦ **~ на откровéнность** ачылырга мәҗбүр итү

вы́зваться *сов.* теләк белдерү, булу, ...рга алыну; **~ помо́чь** булышырга теләк белдерү

вы́звезди||ть *сов. безл.*: **~ло** йолдызлар белән капланды

вы́зволить *сов. кого-что* коткару, йолып алу, йолу, азат итү; **~ из беды́** бәладән коткару

вызволя́ть *несов. см.* **вы́зволить**

выздора́вливать *несов. см.* **вы́здороветь**

вы́здороветь *сов.* сәламәтләнү, савыгу, терелү, сәламәтләнеп җитү, савыгып (терелеп) җитү

выздоровле́ние *с см.* **вы́здороветь**

вы́зов *м* **1.** *см.* **вы́звать** 1, 2; **~ врача́ на дом** табибны өйгә чакырып китерү; **~ на соревнова́ние** ярышка чакыру; **прибыть по ~у** чакыру буенча килү **2.** (*документ*) чакыру кәгазе; **получи́ть ~** чакыру кәгазен алу **3.** *кому-чему* каршы булу, каршы килү, каршы чыгу; **в его́ слова́х прозвуча́л ~** аның сүзләрендә каршы килү чагылып китте

вы́золотить *сов. что* алтынга ману, алтын йөгертү

вызрева́ть *несов. см.* **вы́зреть**

вы́зреть *сов.* өлгерү, пешү, өлгереп (пешеп) җитү

вызу́бривать *несов. см.* **вы́зубрить**

вы́зубрить *сов. что, разг.* ятлау, яттан бикләү (*мәгънәсен төшенмичә*)

вызыва́ть *несов. см.* **вы́звать**

вызыва́ться *несов.* **1.** *см.* **вы́звать**ся; **2.** *страд. от* **вызыва́ть**

вызыва́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **вызыва́ть**; **2.** ачу китергеч, ачу китерерлек, дорфа; **~ее поведе́ние** ачу китергеч кыланыш

вы́играть *сов.* **1.** *что и без доп.* оту; өстен чыгу, жиңү, жиңеп чыгу; **~ па́ртию** партияне оту; **~ бой** сугышта жиңү; **~ проце́сс** процессны оту **2.** *кого-что без доп.* отып алу, оту; **~ сто рубле́й** йөз сум отып алу **3.** *что* оту, файда алу; **~ время́** вакытны оту **4.** *перен. в чём* уңай бәяләнү, уңай бәя алу, оту; **~ во мне́нии о́бщества** җәмәгатьчелек фикеремдә уңай бәя алу

вы́игрыш *м* **1.** оту, отыш; **кру́пный ~** зур отыш; **быть в ~е** 1) (*выиграть*) оту; 2) *перен.* (*оказаться в более выгодном положении*) отыш алу (булу) **2.** (*выгода*) отыш, файда

вы́игрышн||ый, -ая, -ое **1.** отышлы; **~ый заём** отышлы заём **2.** отышлы, файдалы, уңайлы; **~ое положе́ние** уңайлы хәл

вы́искать *сов. кого-что, разг.* әзләп табу

вы́иска||ться *сов. разг.* табылу; **то́же мне у́мник ~лся!** акыллы баш табылган икән!

вы́йскивать *несов. см.* **вы́искать**

вы́йскиваться *несов.* **1.** *см.* **вы́иска**ться; **2.** *страд. от* **вы́йскивать**

вы́йти *сов.* **1.** чыгу, чыгып китү; **~ из ко́мнаты** бүлмәдән чыгу; **~ из стро́я** 1) сафтан чыгу; 2) *перен.* эшли алмый башлау (*мәс. авыру сәбәпле*) **2.** барып чыгу, килеп чыгу; чыгу; **~ на доро́гу** юлга килеп чыгу; **~ в мо́ре** диңгезгә чыгу **3.** (*израсходоваться*) сарыф ителеп бетү, чыгу, бетү **4.** *за кого* чыгу; **~ за́муж** кияүгә чыгу **5.** (*получиться*) чыгу; **из куска́ мате́рии вы́шло два пла́тья** бер оч тукымадан ике күлмәк чыкты; **де́ло не вы́шло** эш барып чыкмады **6.** булып чыгу; **~ победи́телем** җиңүче булып чыгу ♦ **~ в лю́ди** кеше булу, кеше арасына кереп китү; **~ в отста́вку** отставкага чыгу; **~ из берего́в** ярларыннан чыгу, ташу; **~ из голово́й** баштан чыгу, оныту; **~ из дове́рия** ышанычтан чыгу; **~ из печа́ти** матбугатта басылу; **~ из повинове́ния** буйсынмый башлау; **~ из положе́ния** авыр хәлдән чыгу; **~ из себя́** чыгырдан чыгу, чәпчеп китү; **~ из терпе́ния** чыгырдан чыгу; **~ на пе́нсию** пенсиягә чыгу; **~ нару́жу** билгеле булу, ачылу; тышка чыгу; **~ сухи́м из воды́** судан коры чыгу; **лицо́м не вы́шел** матур түгел; **умо́м не вы́шел** акыллы түгел; **ро́стом не вы́шел** озын түгел

вы́казать *сов. что, разг.* күрсәтү; **~ хра́брость** кыюлык күрсәтү

выка́зывать *несов. см.* **вы́казать**

выка́лывать *несов. см.* **вы́колоть**

выка́пывать *несов. см.* **вы́копать**

вы́карабкаться *сов.* **1.** үрмәләп чыгу (килеп чыгу); **~ из я́мы** чокырдан үрмәләп чыгу **2.** *перен.* котылу, ерып чыгу; **~ из беды́** бәладән котылу

выкара́бкиваться *несов. см.* **вы́карабкаться**

выка́рмливать *несов. см.* **вы́кормить**

вы́катать *сов.* **1.** *что* тәгәрәтү, тәгәрәтеп алу, тәгәрәтеп тигезләү; **~ бельё** кер тәгәрәтү **2.** *кого-что* аунату, аунатып алу, аунатып бетерү; **~ в снегу́** карда аунатып алу

вы́кати||ть *сов.* **1.** *что* тәгәрәтеп чыгару; **~ть бо́чку из сара́я** сарайдан мичкәне тәгәрәтеп чыгару **2.** *разг.* (*быстро выехать*) килеп чыгу (*чабып, йөгереп һ.б.ш.*); **из-за угла́ ~л велосипе́д** почмактан велосипед килеп чыкты

вы́кати||ться *сов.* **1.** тәгәрәп төшү тәгәрәп китү; **арбу́з ~лся из корзи́ны** карбыз кәрзиннән тәгәрәп төште **2.** *разг.* (*выехать*) килеп чыгу

выка́тывать I *несов. см.* **вы́катать**

выка́тывать II *несов. см.* **вы́катить**

выка́тываться *несов.* **1.** *см.* **вы́ка**титься; **2.** *страд. от* **выка́тывать** II

вы́качать *сов. что* **1.** суырып алу, суырып чыгару; суыртып алу, суыртып чыгару; **~ во́здух** һаваны суыртып алу **2.** *перен. прост.* суырып алып бетерү, акрынлап алып бетерү; **~ все де́ньги** барлык акчаны суырып алып бетерү

выка́чивание *с см.* **вы́качать**

выка́чивать *несов. см.* **вы́качать**

выка́шивать *несов. см.* **вы́косить**

выка́шливать *несов. см.* **вы́кашлять**

вы́кашлять *сов. что, разг.* йөткереп чыгару, йөткереп чыгарып бетерү, ютәлләп чыгару, ютәлләп чыгарып бетерү

выки́дывать *несов. см.* **вы́кинуть**

вы́кидыш *м* **1.** (*у женщины*) бала төшерү; (*у кобылы*) колын салу; (*у коровы*) бозау салу; (*у овцы, козы*) бәрәнен төшерү, бәрән салу **2.** (*плод*) сикыт, үле туган бала; үле бозау (колын, бәрән)

вы́кинуть *сов.* **1.** *см.* **вы́бросить**; **~ ве́щи** әйберләрне чыгарып ату; **~ флаг** флаг күтәрү; **~ ко́лос** башак чыгару **2.** *кого что и без доп., прост.* (*преждевременно родить*) ташлау, салу, төшерү **3.** *что, разг.* эшләү, кыландыру, эшләп

ташлау; ~ **фо́кус** фокус эшләү ♦ ~ **из головы́** баштан чыгарып ташлау; ~ **на у́лицу** 1) (*выселить*) урамга чыгарып ташлау; 2) (*лишить работы*) эштән куу

выкипа́ть *несов. см.* **вы́кипеть**

вы́кипеть *сов.* кайнап бетү, кайнап парга әйләнү

вы́кипятить *сов. что* кайнатып чыгару; яхшылап кайнату, яхшылап кайнатып алу

вы́кладк||а *ж* **1.** *см.* **вы́ложить** 2; **2.** *мн.* ~**и** (*расчёты, вычисления*) исәпхисап, хисаплау нәтиҗәсе **3.** *воен.* кирәк-ярак; **с по́лной** ~**ой** бөтен кирәк-ярак белән

выкла́дывать *несов. см.* **вы́ложить**

вы́клевать *сов. что* чукып чыгару, чукып алу, чуку

вы́клеваться *сов. см.* **выклёвываться**

выклёвывать *несов. см.* **вы́клевать**

выклёвываться *несов.* **1.** (*о птицах*) чыгу, тишеп чыгу **2.** *страд. от* **выклёвывать**

выкрика́ть *несов.* **1.** *кого-что и без доп.* (*громко вызывать*) бәрлау, атап әйтү **2.** *что и без доп., разг.* (*громко выкрикивать*) кычкырып әйтү; атап әйтү

выкли́кивать *несов. см.* **выкрика́ть**

вы́кликнуть *сов.* **1.** *кого-что* (*кликнув, позвать*) чакырып чыгару, чакырып алу **2.** *что и без доп., разг.* (*громко объявить*) кычкырып әйтү, кычкыру

вы́клюнуть *сов. однокр. см.* **вы́клевать**

выключа́тель *м* выключатель, өзгеч

выключа́ть *несов. см.* **вы́ключить**

выключа́ться *несов.* **1.** *см.* **вы́ключиться**; **2.** *страд. от* **выключа́ть**

вы́ключить *сов.* **1.** *что* өзү, туктату, сүндерү; ~ **ток** токны өзү; ~ **ла́мпочку** лампочканы сүндерү; ~ **ра́дио** радионы туктату; ~ **мото́р** моторны сүндерү **2.** *кого-что* чыгару, чыгарып ташлау; ~ **из спи́ска** исемлектән чыгарып ташлау

вы́ключи||ться *сов.* **1.** өзелү, туктау, сүнү; **свет** ~**лся** ут сүнде **2.** (*устраниться, исчезнуть*) юкка чыгу; югалу, бетү

выкля́нчивать *несов. см.* **вы́клянчить**

вы́клянчить *сов. что, разг.* теләнеп алу, сораып алу

вы́ковать *сов. что* **1.** чүкеп ясау (эшләү); ~ **подко́ву** дага чүкеп ясау **2.** *перен. книжн.* булдыру, җитештерү, тәрбияләп үстерү; ~ **но́вые ка́дры** яңа кадрлар тәрбияләп үстерү

выко́вывать *несов. см.* **вы́ковать**

выковы́ривать *несов. см.* **вы́ковырять**

вы́ковырнуть *сов. однокр. см.* **вы́ковырять**

вы́ковырять *сов. что* казып (чокып) чыгару, казып (чокып) алу

выкола́чивать *несов. см.* **вы́колотить**

вы́колоситься *сов.* башаклану, башак җибәрү, баш кысу

вы́колотить *сов. что* **1.** кагып (сугып, суккалап, бәреп) чыгару; ~ **клин** чәйне кагып чыгару **2.** кагу, кагып чистарту; ~ **ковёр** хәтфә келәмне кагу **3.** *спец.* суккалап (кагып) йомшарту; ~ **ко́жу** күнне кагып йомшарту

вы́кол||оть *сов. что* **1.** төртеп (чәнчеп) тишү, тишеп чыгару; ~**оть глаз** күзен төртеп тишү **2.** (*нанести узор*) чәнчеп ясау, чәнчеп төшерү (бизәк) **3.** ярып алу, ярып төшерү, ярып чыгару; ~**оть глы́бу** [illegible]а зур боз кисәген ярып төшерү ♦ **[те[illegible]ó], хоть глаз** ~**и** күзгә төртсәң күренмәс

вы́копа||ть *сов.* **1.** *что* казу, казып ясау; ~**ть коло́дец** кое казу **2.** *кого-что* казу, казып чыгару, казып алу; ~**ть карто́фель** бәрәңге казып алу **3.** *перен. кого-что, разг.* табып алу, казып чыгару; **отку́да ты** ~**л э́ту кни́гу**? бу китапны син каян казып чыгардың?

вы́кормить *сов. кого-что* ашатып үстерү, асрап үстерү; ~ **телёнка** бозауны ашатып үстерү

вы́кормыш *м прост.* **1.** үксез бозау (колын, бәрән *h.б.ш.*) **2.** *перен. презр.* кабәхәт, әшәке кеше; адәм актыгы

вы́корчевать *сов. что* **1.** төпләү, төпләп бетерү, [төп] чыгару, йолкып чыгару; ~ **пень** төп чыгару **2.** *перен.* тамырын корыту, тамырыннан бетерү, төбе-тамыры белән юк итү; ~ **бюрократи́зм** бюрократизмны тамырыннан бетерү

выкорчёвка *ж см.* **вы́корчевать** 1; ~ **куста́рника** куакларны төпләү

выкорчёвывать *несов. см.* **вы́корчевать**

вы́косить *сов. что* чабып бетерү (чыгу); ~ **поля́ну** аланны чабып бетерү

выкра́дывать *несов. см.* **вы́красть**

выкра́ивать *несов. см.* **вы́кроить**

вы́красить *сов. что* буяп бетерү (чыгу), буяу; ~ **сте́ну** стенаны буяп чыгу

вы́краси||ться *сов.* **1.** буялу; **пла́тье хорошо́** ~**лось** күлмәк яхшы буялган **2.** (*запачкаться краской*) буялу, буялып бетү **3.** *разг.* (*выкрасить себе волосы*) чәчне буяу

вы́красть *сов. кого-что* урлау, урлап алу, урлап бетерү (алып китү)

выкра́шивать *несов. см.* **вы́крошить**

выкра́шиваться *несов.* **1.** *см.* **вы́крошиться**; **2.** *страд. от* **выкра́шивать**

вы́крик *м* кычкыру, кычкырган тавыш, кычкырык

выкри́кивать *несов. см.* **вы́крикнуть**

вы́крикнуть *сов. что и без доп.* **1.** (*громко крикнуть*) кычкыру, кычкырып әйтү **2.** (*вызвать криком*) кычкырып чакыру

вы́кристаллизова||ться *сов.* **1.** *хим.* кристаллашу, кристаллар барлыкка китерү, кристаллга әверелү, кристаллашып җитү **2.** *перен.* оешу, оешып җитү, хасил булу, формалашу; ~**лись но́вые фо́рмы бы́та** көнкүрешнең яңа формалары оешып җитте

выкристаллизо́вываться *несов. см.* **вы́кристаллизоваться**

вы́кроить *сов. что* **1.** кисү, кием кисү; ~ **пла́тье** күлмәк кисү **2.** *перен.* бүлү, бүлеп алу; [тырышып] табу; ~ **сре́дства** акча бүлү; ~ **вре́мя** вакыт табу

вы́кройка *ж* (*образец*) өлге, кием өлгесе

вы́крошить *сов. что* ваклап бетерү, китеп бетерү

вы́кроши||ться *сов.* вакланып бетү, кителеп бетү; **зуб** ~**лся** теш кителеп бетте

выкрута́с||ы *только мн. разг.* **1.** (*затейливые телодвижения*) боргалану-сыргалану, боргалану, бормалы-сырмалы хәрәкәт **2.** *перен.* бормалы-сырмалы сүзләр, артык бизәү (*сөйләмне h.б.ш.*); **говори́ть с** ~**ами** артык бизәп сөйләү

вы́крутить *сов. что* **1.** борып алу, борып чыгару; ~ **ла́мпочку** лампочканы борып алу **2.** *разг.* сыгу, сыгып бетерү; ~ **бельё** керне сыгып бетерү

вы́крутиться *сов.* **1.** (*вывинтиться*) борылып чыгу **2.** *перен.* (*выпутаться*) ерып чыгу; коры чыгу

выкру́чивать *несов. см.* **вы́крутить**

выкру́чиваться *несов.* **1.** *см.* **вы́крутиться**; **2.** *страд. от* **выкру́чивать**

вы́куп *м* **1.** *см.* **вы́купить**; **2.** (*плата, деньги*) йолым, йолым түләү, йолым акчасы; ~ **за неве́сту** *уст.* калым, мәһәр

вы́купать *сов. кого-что* коендыру, юындыру; коендырып алу, юындырып алу; ~ **ребёнка** баланы коендыру

выкупа́ть *несов. см.* **вы́купить**

вы́купаться *сов.* коену, су керү, су коену

выкупа́ться *несов.* **1.** *см.* **вы́купиться**; **2.** *перен.* (*возмещаться*) йолыну, капланы **3.** *страд. от* **выкупа́ть**

вы́купить *сов.* **1.** *что* түләп алу; ~ **зало́женную вещь** закладка салынган әйберне түләп алу **2.** *кого-что* (*освободить за плату*) йолып алу, йолу

вы́купиться *сов.* акча түләп азатлык алу

выкупн||о́й, -а́я, -о́е йолым ...ы; түләп алу ...ы; ~**ы́е де́ньги** йолым акчасы

выку́ривать *несов. см.* **вы́курить**

вы́курить *сов.* **1.** *что* тартып бетерү; ~ **две сигаре́ты** ике сигаретны тартып бетерү; ~ **весь таба́к** барлык тәмәкене тартып бетерү **2.** *кого-что* төтәслӛү, төтәслӛп чыгару (куып чыгару); ~ **лису́ из но́ры** төлкене өненнән төтәслӛп куып чыгару

выла́вливать *несов. см.* **вы́ловить**

вы́лазка *ж* **1.** *воен.* һөҗүм, һөҗүм итү **2.** *перен.* (*враждебный выпад*) каршы чыгу, дошманлык чыгышы **3.** йөрергә чыгу; **лы́жная** ~ чаңгыда йөрергә чыгу

вы́лака||ть *сов. что* **1.** лакап бетерү; **ко́шка** ~**ла молоко́** мәче сөтне лакап бетергән **2.** *перен. прост.* (*о человеке*) лакап бетерү; чөмереп бетерү, эчеп бетерү

выла́мывать *несов. см.* **вы́ломать**

вы́лежать *сов.* яту, ятып тору, ятып алу; **больно́му на́до** ~ авыруга ятып торырга кирәк

вы́лежаться *сов.* **1.** *разг.* озак яту, ятып тору; туйганчы яту, ятып ял итү; **больно́му ну́жно** ~ авыруга озак ятарга кирәк **2.** ятып өлгереп җитү, ятып пешеп җитү, ятып өлгерү, ятып пешү; **недозре́лые помидо́ры должны́** ~ пешмәгән помидорлар ятып өлгереп җитәргә тиешләр

вылёживать *несов. см.* **вы́лежать**

вылёживаться *несов. см.* **вы́лежаться**

вылеза́ть *несов. см.* **вы́лезти**

вы́лез||ти, вы́лезть *сов.* **1.** үрмәләп (тырмашып) чыгу, шуышып чыгу, чыгу; **~ти из я́мы** чокырдан үрмәләп чыгу; **~ти че́рез окно́** тәрәзә аша чыгу **2.** *разг.* чыгу; **~ти из маши́ны** машинадан чыгу **3.** *перен. разг.* чыгу; **~ти из нужды́** мохтаҗлыктан чыгу **4.** *разг.* чыгу; **во́лосы ~ли из-под ша́пки** бүрек астыннан чәчләре чыккан **5.** (*выпасть — о волосах, шерсти*) коелу, төшү

геометри́ческ||ий, -ая, -ое геометрик; геометрия ...ы; **~ая зада́ча** геометрия мәсьәләсе; **~ие фигу́ры** геометрик фигуралар

геоме́трия *ж* геометрия

георги́н *м* георгин, дәлия

геофи́зик *м* геофизик, геофизика белгече

геофи́зика *ж* геофизика

геофизи́ческ||ий, -ая, -ое геофизик, геофизика ...ы; **~ие ме́тоды** геофизик методлар; **~ая обсерва́тория** геофизика обсерваториясе

геохи́мик *м* геохимик, геохимия белгече

геохими́ческ||ий, -ая, -ое геохимик; геохимия ...ы; **~ие иссле́дования** геохимик тикшеренүләр

геохи́мия *ж* геохимия

гепа́рд *м зоол.* гепард

гепати́т *м мед.* гепатит

гера́льдика *ж* геральдика (*гербларны, аларның тарихын өйрәнү*)

гера́нь *ж* яран, яран гөл

герб *м* герб; **Госуда́рственный ~ Росси́и** Россиянең дәүләт гербы

герба́рий *м* гербарий

гербици́ды *мн.* (*ед.* **гербици́д** *м*) *с.-х.* гербицидлар (*чүп үләннәрне бетерә торган агу препаратлары*)

ге́рбов||ый, -ая, -ое герб ...ы, герблы; **~ая печа́ть** герблы печать; **~ая ма́рка** герблы марка ♦ **~ый сбор** герб җыемы (*гражданлык хокуклары буенча документны рәсмиләштергәндә алына торган махсус җыем*)

гериатри́я *ж* гериатрия (*медицинаның олы яшьтәге кешеләрнең авыру үзенчәлекләрен өйрәнү һәм аларны дәвалау белән шөгыльләнә торган булеге*)

геркуле́с *м* геркулес (**1.** *бик кочле кеше* **2.** *солы ярмасының бер төре*)

германи́зм *м* германизм (*герман телләреннән алынган сүз яки тагъбир*)

герма́ний *м хим.* германий

германи́ст *м* германистика белгече

германи́стика *ж* германистика (*герман телләре һәм әдәбиятлары турындагы фән*)

герма́нск||ий, -ая, -ое **1.** Германия ...ы; **~ое госуда́рство** Германия дәүләте **2.** герман ...ы; **~ие языки́** герман телләре

герма́нцы *мн. ист.* германнар, германияләр

гермафроди́т *м* гермафродит, кыстәкә, хонса

герметиза́ция *ж тех.* герметиклаштыру, ныгытып ябу (*савытны*)

гермети́ческ||ий, -ая, -ое герметик (*һава яки сыеклык кермәслек*); **~ая заку́порка** герметик итеп ябу; **~ий шлем** герметик шлем

гермети́чность *ж* герметиклык

гермети́чный, -ая, -ое *см.* **гермети́ческий**

гермошле́м *м* герметик шлем (*лётчиклар, космонавтлар өчен*)

геро́изм *м* геройлык, батырлык, каһарманлык; **трудово́й ~** хезмәттә күрсәтелгән батырлык; **проявля́ть ~** геройлык күрсәтү

геро́ика *ж* героика (*героик эчтәлек, героик кичерешләр*); **~ труда́** хезмәт героикасы

геро́ин *м* героин (*наркотик*)

геро́иня *ж* **1.** герой хатын (кыз) **2.** героиня (*спектакльдә төп хатын-кыз роле*)

геро́йческ||ий, -ая, -ое героик, геройларча...; герой ...ы; **~ий по́двиг** героик батырлык, **~ие защи́тники Ленингра́да** Ленинградның героик саклаучылары

геро́й *м* **1.** герой, батыр, каһарман **2.** герой; **~ рома́на** романның герое **3.** герой (*уз эпохасының характерлы үзенчәлекләрен, сыйфатларын чагылдырган шәхес*); **~ на́шего вре́мени** безнең заман герое **4.** герой (*урнәк алырлык шәхес*); **~ дня** көн герое ♦ **Геро́й Сове́тского Сою́за** Советлар Союзы Герое; **Геро́й Социалисти́ческого Труда́** Социалистик Хезмәт Герое

геро́йский, -ая, -ое геройларча ...; каһарманнарча ...; батырларча ...; **~ посту́пок** геройларча эш итү

геро́йство *с* геройлык, батырлык, каһарманлык; **проявля́ть ~** геройлык күрсәтү

геро́льд *м ист.* герольд, хәбәр бирүче, сөрән салучы, нидаче

геронтоло́гия *ж* геронтология

герпетоло́гия *ж* герпетология (*җирсу хайваннарын һәм сөйрәлүчеләрне өйрәнә торган фән*)

герц *м физ.* герц

ге́рцог *м* герцог

герцоги́ня *ж* герцогиня (*герцог хатын-кыз яки герцог хатыны*)

ге́рцогство *с* герцоглык (**1.** *башында герцог тора торган өлкә, дәүләт* **2.** *герцоглык дәрәҗәсе*)

геста́по *с нескл.* гестапо

геста́повец *м* гестапочы

ге́тман *м ист.* гетман (*Украинада электә: казаклар гаскәре башлыгы*)

ге́тры *мн.* гетр (*балтыр кунычы*)

ге́тто *с нескл.* гетто; **негрита́нское ~** негрлар геттосы

гиаци́нт *м* сөмбел, сөмбел гөле

гиббо́н *м* гиббон (*маймылларның бер төре*)

ги́бель *ж* **1.** һәлакәт, үлем, үлеш; **~ корабля́** корабльнең һәлакәте; **траги́ческая ~** фаҗигале үлем; **обре́чь на ~** *кого-что-л. кемне я нәрсәне булса да* фаҗигале үлемгә дучар итү **2.** *в знач. сказ. разг.* (*множество*) бик күп, тулып ята; чиксез, бетмәс-төкәнмәс, исәбе-хисабы юк; **там ~ комаро́в** анда озын-борыннарның исәбе-хисабы юк

ги́бельн||ый, -ая, -ое һәлакәтле, һәлакәткә илтә торган; фаҗигале; **~ый шаг** һәлакәтле адым; **~ые после́дствия** фаҗигале нәтиҗәләр

ги́бк||ий, -ая, -ое **1.** сыгылмалы, сыгылучан; бөгелүчән; пеше; **~ий прут** пеше чыбык **2.** *перен.* сизгер, зирәк; **~ий ум** сизгер акыл; **~ая поли́тика** зирәк сәясәт

ги́бкость *ж* **1.** сыгылмалылык, бөгелүчәнлек; пешелек; **~ те́ла** гәүдәнең сыгылмалылыгы **2.** *перен.* зирәклек, сизгерлек; **прояви́ть ~** зирәклек күрсәтү

ги́бл||ый, -ая, -ое *прост.* баш бетәрлек, һәлакәтле; **~ое ме́сто** баш бетәрлек урын ♦ **~ое де́ло** өметсез эш

ги́бнуть *несов.* һәлак булу, кырылу, үлү, бетү; (*о кораблях, самолётах и т. п.*) һәлакәткә очрау; **зимо́й мно́го птиц ги́бнет** кышын бик күп кошлар кырыла; **~ от боле́зни** авырудан үлү

гибри́д *м* гибрид

гибридиза́ция *ж* гибридлаштыру; **вегетати́вная ~** вегетатив гибридлаштыру

гибри́дн||ый, -ая, -ое гибрид; **~ые семена́** гибрид орлыклар

гига́нт *м* **1.** гигант, зур гәүдәле кеше, Алып батыр **2.** *перен.* үтә зур, бик зур, гаять зур; **заво́д-~** гигант завод **3.** *перен.* даһи; **~ы мы́сли** даһи фикер ияләре

гигантома́ния *ж* гигантомания, зурдан кубу (*берар нәрсәне практик аклanмаган зур күләмнәрдә оештырырга омтылу*)

гига́нтск||ий, -ая, -ое гигант ...; гаять зур, бик зур, чиксез зур; **~ий стано́к** гаять зур станок; **~ие успе́хи** бик зур уңышлар ◆ **~ие шаги́** гигант адымнар (*багана башындагы тәгәрмәчкә эленгән бауларга утырып тирәли әйләну җайланмасы*)

гигие́н||а *ж* гигиена; **~а труда́** хезмәт гигиенасы; **ли́чная ~а** шәхси гигиена; **соблюда́ть пра́вила ~ы** гигиена кагыйдәләрен үтәү

гигиени́ческ||ий, -ая, -ое гигиеник, гигиена ...ы; **~ие пра́вила** гигиена кагыйдәләре

гигиени́чн||ый, -ая, -ое гигиеналы, гигиеник, гигиена кагыйдәләренә җавап бирә торган; **~ая оде́жда** гигиеник кием

гигроскопи́ческ||ий, -ая, -ое гигроскопик, дым сендерүчән (*мәс. агач, кәгазь һ.б.ш.*); **~ая ва́та** гигроскопик мамык

гигроскопи́чность *ж* гигроскопиклык, дым сендерүчәнлек

гигроскопи́чный, -ая, -ое *см.* **гигроскопи́ческий**

гид *м* гид, экскурсия йөртүче

ги́дра *ж* **1.** *миф.* гидра, аждаһа (*башы кискәч яңадан үсеп чыга торган күп башлы елан*) **2.** *зоол.* гидра (*точе суларда яши торган күп капшавычлы умырткасыз вак хайван*)

гидра́влика *ж* гидравлика

гидравли́ческ||ий, -ая, -ое **1.** гидравлик, гидравлика ...ы; **~ое давле́ние** гидравлик басым **2.** гидравлик, су көче белән эшли торган; **~ий дви́гатель** гидравлик двигатель; **~ий пресс** гидравлик эскәнҗә

гидро- *рус телендәге кушма сузләрнең «су», «су белән бәйләнешле» дигән мәгънәне белдерүче беренче кисәге, мәс.* **гидроавиа́ция** гидроавиация, су авиациясе; **гидроагрега́т** гидроагрегат

гидроаку́стика *ж* гидроакустика

гидроакусти́ческ||ий, -ая, -ое гидроакустик; **~ие иссле́дования** гидроакустик тикшеренүләр

гидробио́лог *м* гидробиолог, гидробиология белгече

гидробиоло́гия *ж* гидробиология

гидробио́ника *ж* гидробионика (*техникада файдалану өчен су организмнарының үзенчәлеген өйрәнә торган бионика бүлеге*)

гидробу́р *м* гидробур

гидро́граф *м* гидрограф (**1.** *гидрография белгече* **2.** *су агымы тизлеген үлчи торган прибор*)

гидрографи́ческ||ий, -ая, -ое гидрография...ы; гидрографик; **~ая ка́рта** гидрография картасы; **~ое су́дно** гидрографик судно

гидрогра́фия *ж* гидрография (*географиянең җир өстендәге суларны өйрәнә торган бүлеге*)

гидродина́мика *ж* гидродинамика

гидродинами́ческ||ий, -ая, -ое гидродинамик, гидродинамика ...ы; **~ие иссле́дования** гидродинамик тикшеренүләр

гидроизоляцио́нн||ый, -ая, -ое гидроизоляцион, гидроизоляция ...ы (*тозелеш конструкцияләрен су, дым тәэсиреннән саклауга караган*); **~ые материа́лы** гидроизоляцион материаллар

гидрокомпре́ссор *м* гидрокомпрессор, гидравлик компрессор

гидрокостю́м *м* гидрокостюм

гидро́лиз *м* гидролиз

гидро́лог *м* гидролог, гидрология белгече

гидрологи́ческ||ий, -ая, -ое гидрологик, гидрология ...ы; **~ое иссле́дование** гидрологик тикшерү

гидроло́гия *ж* гидрология (*сулыклар һәм табигатьтә суның хәрәкәте турындагы фән*)

гидрометеоро́лог *м* гидрометеоролог, гидрометеослужба хезмәткәре

гидропо́ника *ж* гидропоника (*ашламалы эремәләр кушылган ясалма субстратта, мәс. суда үсемлекләр үстерү*)

гидропо́нный, -ая, -ое гидропон ...ы, **~ спо́соб выра́щивания овоще́й** яшелчәләрне гидропон ысулы белән үстерү

гидропу́льт *м* гидропульт, су сиптергеч

гидросамолёт *м* гидросамолёт

гидроси́стема *ж* гидросистема

гидроста́нция *ж* гидростанция

гидросфе́ра *ж* гидросфера (*Җир шарының сулыклардан гыйбарәт сурәте*)

гидротерапи́я *ж мед.* гидротерапия (*су белән дәвалау*)

гидроте́хника *ж* гидротехника

гидротехни́ческ||ий, -ая, -ое гидротехник, гидротехника ...ы; **~ие сооруже́ния** гидротехник корылмалар

гидротурби́на *ж* су турбинасы

гидроу́зел *м* гидроузел

гидрофо́н *м* гидрофон (*судагы тавышларны тоту аппараты*)

гидрохи́мия *ж* гидрохимия

гидроэнерге́тика *ж* гидроэнергетика

гидроэнергети́ческ||ий, -ая, -ое гидроэнергетик, гидроэнергетика ...ы, **~ий ко́мплекс** гидроэнергетик комплекс; **~ие ресу́рсы** гидроэнергетика ресурслары

гие́на *ж зоол.* сыртлан

ги́каньe *с см.* **ги́кать**

ги́кать *сов. разг.* «һайт!» дип кычкыру

ги́кнуть *сов. однокр. разг.* «һайт!» дип кычкырып җибәрү

ги́льдия *ж ист.* гильдия (**1.** *урта гасырларда сәүдәгәрләр яки һөнәрчеләр берләшмәсе* **2.** *революциягә кадәрге Россиядә сәүдәгәрләр дәрәҗәсе*)

ги́льза *ж* гильза (**1.** *патронның, снарядның дары тутырылган өлеше* **2.** *папирос ясау өчен эшләнгән кәгазь көпшә*)

гильоти́на *ж* гильотина

гильотини́ровать *сов., несов. кого* гильотинада башын кисү

гимн *м* **1.** гимн; **Госуда́рственный ~** Дәүләт гимны **2.** (*хвалебная песня*) мактау җыры, мәдхия

гимнази́ст *м* гимназист, гимназиядә укучы

гимнази́стка *ж* гимназиядә укучы кыз

гимна́зия *ж* гимназия

гимна́ст *м* гимнаст

гимнастёрка *ж* гимнастёрка

гимна́стика *ж* гимнастика; **у́тренняя ~** иртәнге гимнастика; **произво́дственная ~** производство гимнастикасы; **спорти́вная ~** спорт гимнастикасы

гимнасти́ческ||ий, -ая, -ое гимнастика ...ы; **~ий зал** гимнастика залы; **~ие снаря́ды** гимнастика җиһазлары

гимна́стка *ж* гимнастка

гинеко́лог *м* гинеколог, гинекология табибы

гинекологи́ческ||ий, -ая, -ое гинекологик, гинекология ...ы; **~ая опера́ция** гинекологик операция; **~ая кли́ника** гинекология клиникасы

гинеколо́гия *ж* гинекология

гипе́рбола I *ж лит.* гипербола (*чиктән тыш арттырып, көчәйтеп сурәтләү*)

гипе́рбола II *ж мат.* гипербола

гиперболи́ческий 1, -ая, -ое *лит.* гипербола ...ы, гиперболик; гиперболалы; **~ стиль** гипербола стиле

гиперболи́ческ||ий II, -ая, -ое *мат.* гипербола ...ы, гиперболик; **~ое сече́ние** гиперболик кисем

гипертони́ческ||ий, -ая, -ое гипертония ...ы; **~ая боле́знь** гипертония авыруы

гипертони́я *ж* гипертония

гипертрофи́рованн||ый, -ая, -ое гипертрофияләнгән; **~ые мы́шцы** гипертрофияләнгән мускуллар

гипертрофи́роваться *сов., несов.* гипертрофияләнү, артык зураю, чамасыз үсү (*берәр орган турында*)

гипертрофи́я *ж* гипертрофия; **~ се́рдца** йөрәк гипертрофиясе

гипно́з *м* гипноз; **сеа́нс ~а** гипноз сеансы; **лечи́ть ~ом** гипноз ярдәмендә дәвалау

гипнотерапи́я *ж* гипнотерапия

гипнотизёр *м* гипнотизёр, гипнозчы, гипноз ясаучы; күз буучы

гипнотизи́ровать *несов. прям., перен. кого-что* гипнозлау; күз буу

гипноти́зм *м* гипнотизм (**1.** *гипноз турындагы тәгълимат* **2.** *гипноз осталыгы*)

ГИП-ГЛА

гипноти́ческ||ий, -ая, -ое гипноз ...ы; гипнотизм ...ы; **~ий сеа́нс** гипноз сеансы; **~ие явле́ния** гипнотизм күренешләре

гипо́теза *ж* гипотеза, гөман, фараз, юрама

гипотену́за *ж мат.* гипотенуза

гипотети́ческ||ий, -ая, -ое гипотезага (фаразга) нигезләнгән, фараз ителгән; **~ое сужде́ние** фаразга нигезләнгән фикер йөртү

гипотети́чн||ый, -ая, -ое *см.* **гипотети́ческий; э́та тео́рия ~а** бу теория фаразга нигезләнгән

гипо́физ, гипофи́з *м анат.* гипофиз

гиппопота́м *м* гиппопотам; (*самец*) су үгезе; (*самка*) су сыеры

гипс *м в разн. знач.* гипс; **скульпту́ра из ~а** гипстан ясалган сын; **наложи́ть ~ на́ руку** *мед.* кулны гипска салу

гипсова́ние *с см.* **гипсова́ть**

гипсова́ть *несов. что* **1.** *мед.* гипслау, гипска салу **2.** *с.-х.* гипс белән ашлау

ги́псов||ый, -ая, -ое **1.** гипс ...ы; **~ый раство́р** гипс измәсе **2.** гипс ..., гипстан ясалган; **~ый сле́пок** гипстан ясалган күчермә; **~ая повя́зка** гипс бәйләвеч

гипю́р *м* гипюр (*күпертеп бәйләнгән челтәрнең бер төре*)

гиреви́к *м спорт.* гер күтәрүче

гирев||о́й, -а́я, -о́е герләр белән эшләнә торган; герләр ...ы; **~ы́е упражне́ния** герләр белән эшләнә торган күнегүләр ♦ **~о́й компле́кт** герләр комплекты; **~ы́е весы́** герле үлчәү

ги́рло *с спец.* тармак, елга тармагы; **~ До́на** Дон тармагы

гирля́нда *ж* гирлянда, үрем, бәйләм; **~ из цвето́в** чәчәкләр үреме

гироско́п *м* гироскоп (*әсбап*)

гироскопи́ческ||ий, -ая, -ое гироскопик, гироскоп ...ы; **~ий ко́мпас** гироскопик компас; **~ие прибо́ры** гироскопик приборлар

ги́р||я *ж* гер; **двухкилогра́ммовая ~я** ике килограммлы гер; **поднима́ть ~и** герләр күтәрү

гисто́лог *м* гистолог, гистология белгече

гистологи́ческ||ий, -ая, -ое гистология ...ы, гистологик; **~ое иссле́дование** гистологик тикшеренүләр

гистоло́гия *ж* гистология

гита́р||а *ж* гитара; **игра́ть на ~е** гитара уйнау

гитари́ст *м* гитарачы, гитара уйнаучы

гитари́стка *ж* гитаристка, гитара уйнаучы хатын (кыз)

ги́чка *ж мор., спорт.* гичка (*тиз йөрешле ишкәкле көймә*)

глав||а́ I *ж* **1.** *уст. книжн. см.* **голова́; 2.** башлык, җитәкче; **~а́ правительства** хөкүмәт башлыгы; **~а́ делега́ции** делегация җитәкчесе; **~а́ семьи́** гаилә башлыгы **3.** гөмбәз; **~а́ це́ркви** чиркәү гөмбәзе ♦ **во ~е́** *кого-чего* җитәкчелегендә; **ста́вить во ~у́ угла́** иң төп мәсьәлә итеп тану

глава́ II *ж* (*раздел книги*) бүлек

главарь *м* атаман, башлык, башлап йөрүче; **~ ша́йки** шайка башлыгы

главе́нство *с* хакимлек, өстенлек

главе́нствовать *несов. над кем-чем* башында тору (*берәр эшнең*); өстенлек итү, житәкчелек итү, идарә итү

главк *м* главк (*министрлыкларның, үзәк оешмаларның баш идарәләре*)

главнокома́ндующий *м* башкомандующий; **Верхо́вный ~** Верховный башкомандующий

гла́вн||ый, -ая, -ое **1.** төп, иң мөһим, иң әһәмиятле; **~ая у́лица** төп урам; **~ая зада́ча** иң төп бурыч **2.** баш, өлкән; **~ый врач** баш врач; **~ый инжене́р** баш инженер **3.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* иң мөһиме, иң әһәмиятлесе ♦ **~ая кварти́ра** *уст.* баш квартира (*башкомандующийның уз штабы белән урнашкан урыны*); **~ое де́ло** *в знач. вводн. сл. см.* **гла́вный** 3; **~ое предложе́ние** *грам.* баш җөмлә; **~ым о́бразом** башлыча

глаго́л *м* **1.** *грам.* фигыль; **времена́ ~а** фигыль заманнары; **вспомога́тельный ~** ярдәмче фигыль **2.** *уст. поэт.* (*слово, речь*) сөйләм

глаго́льн||ый, -ая, -ое *грам.* фигыль ...ы; **~ые ви́ды** фигыль төрләре; **~ые су́ффиксы** фигыль кушымчалары

гладиа́тор *м* гладиатор

гладио́лус *м* гладиолус (*бакча гөле*)

гла́дить *несов.* **1.** *что и без доп.* (*бельё и т. п.*) үтүкләү **2.** *кого-что* (*приглаживать; ласкать*) сыпыру, сыйпау; **~ во́лосы** чәчне сыпыру ♦ **~ по голо́вке** *кого* юл кую, узындыру; **~ про́тив ше́рсти** йон каршысына сыпыру

гла́дк||ий, -ая, -ое **1.** (*ровный*) шома, тигез; **~ая пове́рхность** шома өслек **2.** (*прямой, приглаженный — о волосах*) шома **3.** (*одноцветный*) бизәксез, бертөсле; **~ая мате́рия** бизәксез материя **4.** *прост.* (*упитанный*) симез, көр **5.** *перен.* шома, оста башкарылган; **~ая речь** шома сөйләм

гла́дко *нареч.* **1.** (*ровно*) шома, чиста; **~ вы́бритый** чиста кырынган **2.** *перен.* йөгерек, оста; шома; **~ говори́ть** шома сөйләү; **собра́ние прошло́ ~** җыелыш шома үтте

гладкостно́льный, -ая, -ое шома көпшәле (*ау мылтыгы, миномёт, элекке туп көпшәләре турында*)

гладь I *ж* киң тигезлек (*тигез су өсте, боз өсте*) ♦ **тишь да ~** бик тыныч тормыш

гладь II *ж* (*вышивка*) тоташ чигү, тоташтан чигү

глаз *м* **1.** күз; **голубы́е ~а́** зәңгәр күзләр; **зажму́рить ~а́** күзләрне кысу; **вы́таращить ~а́** күзләрне акайту; **сомкну́ть ~а́** күзләрне йому; **в ~а́х двои́тся** күзгә икәү булып күренү; **в ~а́х ряби́т** күзләр әлҗе-мөлҗе килә; **игра́ть ~а́ми** күзләрне уйнату; **определи́ть расстоя́ние невооружённым ~ом** ераклыкны гади күз белән билгеләү **2.** караш, карау; **оки́нуть ~а́ми** караш ташлау **3.** *перен.* күзәтү, карау, багу; **хозя́йский ~** хуҗаларча карау; **за ни́ми ну́жен ~ да ~** аларны гел күзәтеп торырга кирәк; **у семи́ ня́нек дитя́ без ~у** *посл.* ≈ син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала? ♦ **име́ть пе́ред ~а́ми** *что* күз алдында тоту; **не попада́йся на ~а́** күземә күренмә, күземә күренәсе булма; **броса́ться (кида́ться) в ~а́** күзгә бәрелеп тору, күзгә ташлану; **во все ~а́ гляде́ть** дүрт күзләп карау, зарыгып көтү; **в ~а́ говори́ть** күзенә карап эйтү, күзенә бәреп эйтү; **в ~а́ не ви́дел** *кого, прост.* күргәнем дә юк; **в ~а́х** *кого, чьих* каршында, күз алдында; **в ~а́х темне́ет** күз аллары караңгылана; **~а́ бы не гляде́ли** күрәсе дә килми, каберең якын булмасын; **~а́ горя́т** *на что* күзләре кыза; **~а́ на лоб ле́зут** исең-акылың китәрлек, күзләреңнән агыза тора; **глаз не каза́ть (не пока́зывать)** күзгә-башка күренмәү; **~а́ разбега́ются** кайсына кararга да белмәү; **~а́ разгоре́лись** күзе кызды, күзе янды; **~а́ смыка́ются (слипа́ются)** күз йомыла, йокы килә; **~ом не моргну́ть** күзен дә йоммау, уйлап та тормау; **де́лать больши́е ~а́** шаккатып карап тору; **для отво́да глаз** күз буяу өчен; **есть (пожира́ть) ~а́ми** йотардай (ашардай) булып карау; **за ~а́ [говори́ть]** үзе юкта; күз артында; **куда́ ~а́ гляде́т** (*идти*) теләсә кай якка, дурт ягы кыйбла; **на ~ якынча, чама белән; на ~а́х** күз алдында, күз каршында; **намётанный ~** очлы күз, тәҗрибәле кеше; **наско́лько хвата́ет глаз** күз күрә алган кадәр; **не знать, куда́ ~а́ деть** күзне кая яшерергә белмәү, кая керергә тишек тапмау; **ни в одно́м ~у́** аек, күзенә дә чыкмаган; **просты́м (невооружённым) ~ом** гади күз белән; **ра́ди *чьих* прекра́сных глаз** кемнендер матур күзләре өчен, һич кирәкмәгәнгә; **с глаз доло́й** күз алдыннан кит; күземнән югал, күземә күренмә; **с глаз доло́й, из се́рдца вон** *погов.* ≈ хәзер ике ятып бер төшемә керми; **с ~у на ~** кара-каршы, күзгә-күз, икәүдән-икәү генә; **с *какими* ~а́ми появи́ться (показа́ться)** *куда* ни күз белән күренмәк кирәк, кеше күзенә күренергә оят; **смотре́ть (гляде́ть) в ~а** *кому* күзенә генә карап тору, ялагайлану, куштанлану; **смотре́ть (гляде́ть) пря́мо (сме́ло) в ~а́** *чему* [курыкмыйча] күзенә туп-туры карау; **смотре́ть (гляде́ть) в о́ба ~а** уяу булу, аң булып тору; **упа́сть в ~а́х** *кого* күздән төшү, абруй югалу; **хоть ~ вы́коли** дөм-караңгы, күзгә төртсәң дә күренми; **чита́ть по ~а́м** күзенә карап белү, күзенә карап чамалау

глаза́стый, -ая, -ое **1.** (*с большими глазами*) зур күзле, шар күзле **2.** (*зоркий*) очлы күзле, үткен күзле, яхшы күрүчән

глазе́т *м* (*род парчи*) укалы парча, асыл

глазе́ть *несов. на кого-что и без доп., прост.* карап тору, кызыксынып карап тору, авыз ачып карап тору; **~ по сторона́м** як-якка карау

глазирова́ние *с см.* **глазирова́ть**

глазиро́ванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **глазирова́ть; 2.** (*покрытый глазурью*) глазурьлы, глазурьланган, ширбәткә катырылган; **~ый сыро́к** глазурьланган

сырок 3. (*покрытый глянцем*) ялтыравык, ялтыратылган; ~ **ая бума́га** ялтыратылган кәгазь

глазирова́ть *сов., несов. что* 1. глазурьлау, глазурь белән каплау; ~ **фру́кты** жимешләрне глазурь белән каплау 2. (*придать глянец*) ялтырату (*мәс. калайны*)

глазни́к *м разг.* күз табибы

глазни́ца *ж анат.* күз чокыры

глаз||о́к *м* 1. (*мн.* **гла́зки**) *уменьш.-ласк. от* **глаз** 1; 2. (*мн.* ~ **ки́**) *бот.* күз, күзәнәк, күзчә; бөре 3. (*мн.* ~ **ки́**) (*отверстие для надзора*) күз, тишек 4. (*пигментное пятно в окраске птиц, насекомых и т. п.*) сипкел, бөртек ♦ **ано́тины гла́зки** *бот.* ала миләүшә; **на** ~ **о́к** чама белән, үлчәп тормыйча

глазоме́р *м* күз үлчәме (*ераклыкны күз белән чамалау*)

глазоме́рн||ый, -ая, -ое күз үлчәме белән...; ~ **ая съёмка** күз үлчәме белән генә төшерү (*рәсемгә*)

глазу́нья *ж* йомырка тәбәсе

глазурова́ние *с см.* **глазирова́ть**

глазиро́ванный, -ая, -ое 1. *прич. от* **глазирова́ть**; 2. (*покрытый глазурью*) глазурьлы, ялтыравык йөгертелгән; ~ **кирпи́ч** глазурьлы кирпеч

глазирова́ть *сов., несов. что* ялтыравык йөгертү; ~ **посу́ду** савытларга ялтыравык йөгертү

глазу́рь *ж* 1. (*сплав*) глазурь, ялтыравык 2. (*сироп*) шикәр ширбәте; **торт с** ~ **ю** шикәр ширбәте белән капланган торт

гла́нды *мн.* (*ед.* **гла́нда** *ж*) гланда, аңкау бизе (*аңкаудагы миндальсыман биз*)

глас *м уст.*: ~ **вопию́щего в пусты́не** жавапсыз калдырылган чакыру

гласи́ть *несов. что и без доп.* белдерү, хәбәр бирү, хәбәр итү; **зако́н гласи́т так** закон болай куша, закон кушканча болай

гла́сност||ь *ж* хәбәрдарлык, ачыклык, (*халыкка, җәмәгатьчелеккә*) билгеле булу; **преда́ть** ~ **и** халыкка игълан итү

гла́сн||ый I, -ая, -ое *лингв.* 1. сузык; ~ **ые зву́ки** сузык авазлар 2. *в знач. сущ.* ~ **ый** *м*, ~ **ая** *ж* сузыклар; **безудо́рные** ~ **ые** басымсыз сузыклар

гла́сный II, -ая, -ое ачык, халыктан яшерен булмаган, һәркем катнашырга ирекле булган; ~ **суд** ачык суд

глауко́ма *ж мед.* глаукома

глаша́тай *м* 1. *уст.* сөрән салучы, өндәүче, нидачы (*борынгы заманда халыкка рәсми хәбәрләрне белдереп йөрүче*) 2. *перен. высок.* белдерүче, яклаучы; ~ **и́стины** хакыйкатьне яклаучы

гле́тчер *м* глетчер, бозлык (*таулардан шуып төшә торган бозлык*)

гли́на *ж* балчык; кызыл балчык; **огнеупо́рная** ~ утка чыдам балчык

гли́нист||ый, -ая, -ое балчыклы; кызыл балчыклы; ~ **ая по́чва** кызыл балчыклы туфрак

глиноби́тн||ый, -ая, -ое балчык ... (*салам яки чыбык катнаш балчыктан салынган*); ~ **ая стена́** балчык дивар

глинозём *м* глинозём (*алюминий окисе*)

глинтве́йн *м* глинтвейн (*кызыл аракыдан һәм төмләткечләрдән кушып әзерләнгән шикәрле кайнар эчемлек*)

гли́няный, -ая, -ое балчык ...; кызыл балчыктан ясалган; ~ **горшо́к** балчык чүлмәк

гли́ссер *м* глиссер (*яссы төпле, тиз йөрешле көймә*)

глист *м* суалчан

глистого́нн||ый, -ая, -ое суалчан куа торган, суалчан бетерә торган (*дару*); ~ **ые сре́дства** суалчан куа торган дарулар

глицери́н *м* глицерин, гөлсирин

глицери́нов||ый, -ая, -ое глицерин ...ы; глицеринлы; ~ **ое мы́ло** глицеринлы сабын

глици́ния *ж* глициния (*урмәле усемлек*)

глоба́льн||ый, -ая, -ое: ~ **ая раке́та** глобаль ракета (*ерак араларга җибәрелә торган ракета*); **в** ~ **ом масшта́бе** гаять зур масштабларда

глода́ть *несов.* 1. *что* кимерү; ~ **кость** сөяк кимерү 2. *перен. кого* җәфалау, азаплау; **его́ гло́жет со́весть** аны вөжданы җәфалый

глота́ть *несов.* 1. *кого-что* йоту; ~ **лека́рство** дару йоту 2. *перен. что, разг.* күп уку, комсызланып уку; ~ **кни́ги** китапларны күп уку ♦ ~ **слёзы** күз яшен йоту (*еламаска тырышу*); ~ **слова́** сүзләрне йотып сөйләү

гло́тк||а *ж* 1. йоткылык 2. *прост.* тамак, бугаз; **схвати́ть за** ~ **у** бугазына ябышу

глотну́ть *сов. однокр. что чего и без доп.* йотып җибәрү, йоту (*бер тапкыр*)

глот||о́к *м* 1. йоту; **вы́пить в два** ~ **ка́** ике йотуда эчеп бетерү 2. йотым, бер йотым; ~ **о́к воды́** бер йотым су

гло́хн||уть *несов.* 1. (*становиться глухим*) чукраклану, саңгыраулану 2. акрыная бару, тына бару; **шум постепе́нно** ~ **ет** тавыш акрынлап тына бара 3. томалану, чүп басу, ташландык хәлгә килү; **сад без ухо́да** ~ **ет** караучысыз бакчаны чүп баса

глубин||а́ *ж* 1. тирәнлек; **на** ~ **е́ 200 ме́тров** 200 метр тирәнлектә; **морски́е глуби́ны** диңгез тирәнлекләре 2. *чего* түр, урта, эч; **в** ~ **е́ са́да** бакча түрендә; **в** ~ **е́ ле́са** урман уртасында 3. *перен.* тирәнлек, әһәмиятлелек; ~ **а́ иде́и** идеянең тирәнлеге; ~ **а́ зна́ний** белемнәрнең тирәнлеге ♦ **в** ~ **е́ веко́в** бик борынгыда, бик борынгы чорда; **в** ~ **е́ души́** йөрәктә, йөрәк (күңел) түрендә, күңелдә; **до** ~ **ы́ души́** бик нык, чиктән тыш; **из** ~ **ы́ веко́в** борын-борыннан, бик борынгыдан; **от** ~ **ы́ души́** чын йөрәктән, чын күңелдән

глуби́нка *ж разг.* глубинка, эчкәре пункт (*тимер юлдан, су юлларыннан ерак урнашкан ашлык сату пункты*)

глуби́нн||ый, -ая, -ое тирәнлек ...ы; тирәндәге, тирәннән; эчкәре; ~ **ая бо́мба** тирәнлек бомбасы; ~ **ый лов** тирәннән тоту (*балыкны*) ♦ ~ **ый райо́н** эчкәре район

глубиномер *м* тирәнлек үлчәгеч

глубо́к||ий, -ая, -ое 1. тирән; ~ **ий коло́дец** тирән кое; ~ **ая таре́лка** тирән тәлинкә; ~ **ая вспа́шка** тирән сөрү; ~ **ие ко́рни** тирән тамырлар 2. эчкәре, эчкәреге, ерак; ~ **ий тыл** ерак тыл 3. *перен.* ерак; ~ **ая старина́** ерак тарих 4. тирән, тирәнтен, җитди; ~ **ое изуче́ние вопро́са** мәсьәләне җитди тикшерү 5. тирән, көчле; ~ **ая заду́мчивость** тирән уйлану; ~ **ие пережива́ния** көчле кичерешләр ♦ ~ **ий взгляд** тирән караш; ~ **ий го́лос** калын тавыш; ~ **ая ночь** тән уртасы, җиде төн уртасы; ~ **ая о́сень** кара көз (*көзнең соңгы көннәре*); ~ **ий покло́н** башны нык түбән ию; ~ **ая ста́рость** үтә картлык; **пита́ть** ~ **ое уваже́ние** бик нык ихтирам итү

глубоко́, глубо́ко *нареч.* 1. тирән, тирәнтен, тирән итеп, тирәнгә, тирәндә, тирәнлектә; ~ **вы́рыть я́му** тирән итеп чокыр казу 2. бик нык, тирән, тирәнтен; ~ **пережива́ть** бик нык кайгыру; ~ **заду́маться** тирән уйга чуму 3. *в знач. сказ.* тирән; **здесь о́чень** ~ монда бик тирән

глубоково́д||ный, -ая, -ое 1. тирән сулы, җитәрлек тирәнлектәге; ~ **ые ре́ки** тирән сулы елгалар 2. тирән судагы, тирән суларда яши торган, тирән су ...ы; ~ **ые ры́бы** тирән су балыклары 3. тирән су асты ...ы; ~ **ые иссле́дования** тирән су асты тикшеренүләре

глубокомы́сленн||ый, -ая, -ое 1. төпле, тирән фикерле, тирән мәгънәле, тирән уйлы; ~ **ое замеча́ние** тирән мәгънәле искәртү 2. җитди, төпле; ~ **ый взгляд** җитди караш

глубокомы́слие *с* тирән фикерлелек, тирән мәгънәлелек, тирәнтен аңлау, төпле фикердә булу

глубокорыхли́тель *м с.-х.* тирән йомшарткыч (*туфракны*)

глубокоуважа́емый, -ая, -ое хөрмәтле, мөхтәрәм

глубь *ж см.* **глубина́** 1, 2

глуми́ться *несов. над кем-чем* мыскыл итү, мәсхәрәләү

глупе́ть *несов.* аңгыралану, ахмаклану, тинтәкләнү, юләрләнү

глупе́ц *м* аңгыра, юләр, ахмак, тинтәк, сантый

глуп||и́ть *несов. разг.* ахмаклыклар эшләү, тилерү; **не** ~ **и́** тилермә

глу́пост||ь *ж* 1. ахмаклык, тинтәклек, юләрлек, аңгыралык, сантыйлык; **он изве́стен свое́й** ~ **ью** ул үзенең ахмаклыгы белән танылган 2. ахмаклыклар, ахмак сүзләр, ахмак эшләр; **де́лать** ~ **и** ахмаклыклар эшләү; **сказа́ть** ~ **ь** ахмак сүз сөйләү

глу́п||ый, -ая, -ое 1. аңгыра, акыл кермәгән, ахмак, юләр, тинтәк; ~ **ый челове́к** тинтәк кеше 2. ахмак, мәгънәсез, акылсыз, ахмакларча ...; **зада́ть** ~ **ый вопро́с** ахмак сорау бирү; **попа́сть в** ~ **ое положе́ние** ахмакларча хәлдә калу; ~ **ая зате́я** акылсыз эш

глуха́рь *м* 1. суер, урман тавыгы 2. *разг. шутл.* (*глухой человек*) чукрак, саңгырау

глух||о́й, -а́я, -о́е 1. чукрак, саңгырау, колакка каты; **~ о́й стари́к** саңгырау карт 2. *перен.* игътибарсыз; ишетми [торган], колак салмый [торган], игътибарсыз калдыра [торган]; **он глух к мои́м мольба́м** ул минем ялваруларыма колак салмый 3. тонык, талгын; **~ о́й го́лос** тонык тавыш 4. аулак, тын, тыныч; **~ а́я у́лица** тын урам 5. *перен.* ишетелер-ишетелмәс, эчтән генә; **~ о́й ро́пот** эчтән генә сукрану 6. кыргый; **~ о́й сад** үләнбаскан бакча; **~ о́й лес** кара урман ♦ **~ а́я стена́** тоташ дивар; **руба́шка с ~и́м во́ротом** ябык якалы күлмәк; **~ о́й согла́сный** *лингв.* саңгырау тартык; **~ а́я крапи́ва** сукыр кычыткан; **~ а́я ночь** караңгы төн

глухома́нь *ж разг. см.* **глушь**

глухонем||о́й, -а́я, -о́е *и в знач. сущ.* **~ о́й** *м*, **~ а́я** *ж* чукрак-телсез; **~ о́й ребёнок** чукрак-телсез бала; **шко́ла для ~ы́х** чукрак-телсезләр мәктәбе

глухонемота́ *ж* чукраклык, телсезлек

глухота́ *ж* чукраклык, саңгыраулык

глуши́тел||ь *м* 1. *спец.* тавышйоткыч, тавышкиметкеч 2. *перен.* ирек бирмәүче, (*берәр нәрсәне*) томалаучы, буучы; **~ и кри́тики** тәнкыйтьне буучылар

глуши́ть *несов.* 1. *кого-что* миңгерәйтү; **~ ры́бу** балыкны миңгерәйтү (*шартлатып*) 2. *что* басу, томалау; **~ звук** тавышны томалау 3. *что* томалау, каплау, басу, басып китү; **сорня́ки глу́шат сад** чүп үләннәр бакчаны баса[лар] 4. *что* сүндерү, томалау; **~ самова́р** самавырны сүндерү; **~ мото́р** моторны сүндерү 5. *перен. что* томалау, басу, буу, ирек бирмәү; **~ инициати́ву** инициативаны буу 6. *что, прост.* (*пить спиртное*) күп эчү; **~ во́дку** аракыны күп эчү

глушь *ж* караңгы почмак, аулак (тын) почмак, аулак урын (*мәдәният үзәкләреннән ерак урын*)

гль́ба *ж* кантар, зур кисәк; **ка́менная ~** зур таш кисәге; **~ льда** зур боз кисәге

глюко́за *ж* глюкоза

гляд||е́ть *несов.* 1. карау, карап тору; **при́стально ~ е́ть** текәлеп карап тору 2. *за кем-чем* күзәтү, күз-колак булу; **~ е́ть за ребёнком** балага күз-колак булу 3. (*иметь вид*) булып күренү, охшау; **~ е́ть геро́ем** герой булып күренү ♦ **~ е́ть в о́ба** сак булу, абай булу, алны-артны карап эш итү; **~ е́ть пра́вде в глаза́** дәреслектән курыкмау; **на́ ночь гля́дя** төнгә каршы; **того́ и ~ и́** күр дә тор, көт тә тор, менә карап тор

гляд||е́ться *несов. во что*: **~ е́ться в зе́ркало** көзгегә карау; **ме́сяц ~ и́тся в ре́чку** айның шәүләсе елга өстенә төшкән

глядь *частица разг.* карасам; **~, он идёт** карасам, ул килә

гля́нец *м* ялтыравык; **~ потускне́л** ялтыравыгы тоныкланган; **навести́ ~** 1) ялтырату; 2) *перен.* эшне ялтыратып кую

гля́нуть *сов. однокр.* карау, карап алу, карап кую, күз төшереп алу, күз салып алу

глянцева́ть *несов. что, спец.* ялтыратү; шомарту

глянцеви́тый, -ая, -ое *см.* **гля́нцевый**

гля́нцев||ый, -ая, -ое ялтыравыклы; **~ ая пове́рхность** ялтыравыклы өслек; **~ ая бума́га** ялтыравыклы кәгазь

гляцио́лог *м* гляциолог (*бозлыкларны өйрәнүче белгеч*)

гляциоло́гия *ж* гляциология (*бозлыкларны өйрәнә торган фән*)

гм *межд. разг.* һе, һем, алай икән (*шикләну, ышанмау*)

гнать *несов.* 1. *кого-что* куу, куып алып бару (килү); **~ ста́до** көтү куу 2. *кого-что* куып чыгару, сөреп чыгару; **~ и́з дому** өйдән куып чыгару 3. *кого-что* куу, куалау, тиз алып бару, чаптыру; **~ маши́ну** машинаны тиз алып бару 4. (*быстро ехать*) җилдерү, элдертү; **го́нит на велосипе́де** велосипедта элдертә 5. *что, прост.* (*быстро, много производить*) күпләп җитештерү (*ашыгыч рәвештә*); **~ проду́кцию** әйберләрне күпләп җитештерү 6. *что* куу, чыгару, табу; **~ спирт** спирт куу ♦ **~ в хвост и в гри́ву** бик каты куу; **~ в ше́ю** артына тибеп чыгару; **~ лес** *спец.* сал агызу

гна́ться *несов. за кем-чем* 1. куу, куып бару; **~ за отступа́ющим проти́вником** чигенүче дошман артыннан куып бару; **~ по пята́м** үкчәсенә басып бару 2. *разг.* куу, чабу, артыннан куу; **~ за при́быльюю** табыш артыннан куу 3. *страд. от* **гнать** 1, 6

гнев *м* ачу; **вспы́шка ~ а** ачу чыгу; **в поры́ве ~ а** ачудан уйлап-ниткән тормыйча ♦ **смени́ть ~ на ми́лость** ачуны шәфкать белән алмаштыру, ачу саклamый башлау

гне́ваться *несов. на кого-что и без доп., уст.* ачулану, ачу кабару

гневи́ть *несов. кого-что, уст.* ачуландыру, ачуын кабарту (китерү)

гне́вный, -ая, -ое ачулы; **~ взгля́д** ачулы караш

гнедо́й, -а́я, -о́е (*о масти лошади*) туры

гнезди́||ться *несов.* 1. (*о птицах*) оялау, оя ясау; (*о насекомых*) оялау 2. *перен.* тулу, тулып яту; **в голове́ ~ лись назо́йливые мы́сли** башым эчпошыргыч уйлар белән тулы иде 3. *перен.* урнашу; **по скло́ну горы́ ~ лись хи́жины** алачыклар тау итәгенә урнашканнар

гнездо́ *с* 1. оя; **свить себе́ ~** 1) (*о птицах*) үзенә оя ясау; 2) *перен.* үзенә тормыш кору 2. *перен.* (*домашний очаг*) куыш, оя 3. *перен.* (*притон*) оя; **воровско́е ~** караклар оясы 4. оя, төркем; **~ груздей́** гөреңдәләр оясы 5. *спец.* уем, уемтык, чокыр; **~ для патро́на** патрон уемтыгы 6. оя, чокыр; **пулемётные гнёзда** пулемёт чокырлары (*пулемётлар урнашкан урыннар*) ♦ **~ слов** (*в словаре*) тамырдаш сүзләр

гнездова́ни||е *с* оялау һәм балалар чыгару; **пери́од ~ я** оялау һәм балалар чыгару вакыты

гнездова́ться *несов.* оялау һәм балалар чыгару

гнездов||о́й, -а́я, -о́е оялап ..., оялап [башкарылган]; **~ о́й посе́в ле́са** оялап утыртылган урман ♦ **~ о́е расположе́ние слов в словаре́** сүзлектә сүзләрне оялап урнаштыру

гнездо́вье *с* оялау урыны (*кошларга оялау очен уңай урын*)

гнейс *м* гнейс (*шпат, кварц һәм слюдадан торган тау токымы*)

гнести́ *несов. кого-что* борчу, җәфалау, интектерү; **тоска́ гнетёт** сагыш җәфалый

гнёт *м* 1. (*пресс, груз*) эскәнҗә, бастыргыч, бастырык (*таш, тимер һ.б.ш.*) 2. изү, кысу, кысым; **колониа́льный ~** колониаль изү; **~ ра́бства** коллык изүе

гнету́щ||ий, -ая, -ее авыр, эчпошыргыч, күңелсез; **~ ее впечатле́ние** авыр тәэсир; **~ ее чу́вство** эчпошыгыч хис

гни́да *ж* серкә, бет серкәсе

гние́ние *с* черү, бозылу

гнил||о́й, -а́я, -о́е 1. черек, чергән; бозылган; **~ о́е я́блоко** чергән алма 2. юеш, яңгырлы; **~ а́я пого́да** юеш һава; **~ о́й кли́мат** юеш климат 3. *перен.* начар, черек; **~ а́я тео́рия** черек теория

гни́лостн||ый, -ая, -ое 1. черек; черү ...ы; **~ ый за́пах** черек ис 2. черетә торган, череткеч; **~ ые бакте́рии** череткеч бактерияләр

гнилу́шка *ж разг.* черек, черек агач кисәге; черек әйбер

гниль *ж* 1. черек, черегән нәрсә 2. (*плесень*) күгәрек

гнильё *с собир. разг.* черек-чарык, черегән әйберләр

гнильц||а́ *ж*: **с ~ о́й** *разг.* чери башлаган, бозыла башлаган, черек; **я́блоки с ~ о́й** чери башлаган алмалар; **челове́к с ~ о́й** *перен.* бозыла башлаган кеше (*начар кеше турында*)

гни||ть *несов.* черү, череп таркалу; **се́но ~ ёт** печән чери

гное́ние *с см.* **гнои́ть, гнои́ться**

гноеотделе́ние *с* эрен бүлеп чыгару, эрен бүленеп чыгу

гноеотдели́тельный, -ая, -ое эрен бүлеп чыгару ...ы; **~ проце́сс** эрен бүлеп чыгару процессы

гноеро́дн||ый, -ая, -ое эрен барлыкка китерә торган; **~ ые бакте́рии** эрен барлыкка китерә торган бактерияләр

гнои́ть *несов.* 1. *что* черетү; сасыту, исләндерү; **дождь гнои́т се́но** яңгыр печәнне черетә; **~ мя́со** итне сасыту 2. *перен. кого-что, книжн.* авыр шартларда тоту, черетү; **~ в тюрьме́** төрмәдә черетү

гнои́т||ься *несов.* эренләү, үлекләү; **ра́на ~ ся** җәрәхәт үлекли

гной *м* эрен, үлек

гнойни́к *м* эрен җыелган урын, үлекләгән урын; **вскрыть ~** үлекләгән урынны яру

гно́йн||ый, -ая, -ое үлекләү ...ы, эренләү ...ы; эренле, үлекле; **~ ая ра́на** үлекле яра; **~ ый проце́сс** үлекләү процессы

гном *м* гном (*Көнбатыш Европа мифологиясендә: җир астындагы хәзинәне саклап тора торган кәрлә кеше*)

гносеологи́ческ||ий, -ая, -ое *филос.* гносеологик ..., гносеология ...ы; **~ ие вы́воды** гносеологик нәтиҗәләр

гносеоло́гия *ж филос.* гносеология (*танып-белү теориясе*)

гнус *м собир.* черки, чебен-черки

гнуса́вить *несов.* тыңкышланып сөйләү, борын аша сөйләү

гнуса́вость *ж* тыңкышлык

гнуса́вый, -ая, -ое тыңкыш; **~ ребёнок** тыңкыш бала; **~ го́лос** тыңкыш тавыш

гну́сност||ь *ж* әшәкелек, кабәхәтлек; **~ь поведе́ния** үз-үзен тотышының кабәхәтлеге; **соверша́ть ~и** әшәкелекләр эшләү

гну́сн||ый, -ая, -ое кабахәт, түбән, әшәке; **~ый челове́к** әшәке кеше; **~ая клевета́** чирканыч гайбәт

гну́т||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **гнуть** 1, 2; 2. бөгелгән, бөгеп ясалган; **~ая ме́бель** бөгеп ясалган мебель

гнуть *несов.* 1. *что* бөгү; **~ про́волоку** тимерчыбыкны бөгү; **~ подко́вы** дагалар бөгү 2. *кого-что* ию, сыгу, бөгү; **бу́ря гнёт дере́вья** давыл агачларны ия 3. *что, к чему и без доп., прост.* бору, каеру; **к чему́ он гнёт?** кая таба бормакчы була ул? 4. *перен. что, к чему* яклау, каеру; **~ своё** *или* **свою́ ли́нию** үз фикереңне яклау ♦ **~ в три поги́бели** бишкә бөгү, тәмам буйсындыру; **~ горб (спи́ну)** бөкрең чыкканчы эшләү; **~ спи́ну (ше́ю)** *перед. кем* бил бөгү, буйсыну

гну́т||ься *несов.* бөгелү, иелү, сыгылу; **про́волока гнётся** тимерчыбык бөгелә; **дере́вья ~ся от ве́тра** агачлар җилдән сыгылалар

гнуша́ться *несов. кого-чего, кем-чем и с неопр.* чиркану, җирәнү; хурлык дип санау, гарьлек дип санау, кимчелек дип санау

гобеле́н *м* гобелен (1. *бизәкләп эшләнгән стена келәме* 2. *декоратив тукыма*)

гобои́ст *м* гобойчы (*гобойда уйнаучы*)

гобо́й *м* гобой (*музыка коралы*)

говя́ *несов. рел.* ураза тоту

го́вор *м* 1. сөйләшү, сөйләшкән тавыш; **ти́хий ~** әкрен сөйләшү 2. (*манера произносить*) сөйләш, сөйләшү; сөйләү үзенчәлеге 3. *лингв.* сөйләш; **ме́стный ~** җирле сөйләш; **среднеру́сские ~ы** урта рус сөйләшләре

говори́льня *ж разг. ирон.* бака базары (*мәгънәсез сүзләр лыгырдап уздырылган җыелыш*)

говор||и́ть *несов.* 1. сөйләшү; **ребёнок ещё не на́чал ~и́ть** бала сөйләшми әле; **~ и́ть по-ру́сски** русча сөйләшү 2. *что, о ком-чём и с союзом «что»* сөйләү, әйтү, дию; **~ и́ть пра́вду** дөресен сөйләү; **~и́ть ме́дленно** әкрен генә сөйләү 3. *о ком-чём* сөйләү, сөйләп тору, әйтеп тору; күрсәтеп тору, белдереп тору; **об э́том ~и́т весь го́род** бу хакта бөтен шәһәр сөйли 4. *с кем* (*беседовать*) сөйләшү, гәпләшү 5. *перен.* (*сказываться в ком-чём-л.*) күренү, чагылу; күренеп тору; **в нём ~и́т го́рдость** аңарда горурлык күренеп тора ♦ **~и́т само́ за себя́** үзеннән үзе күренеп тора; **~и́ть на ра́зных языка́х** ≈ һәркемнең үз туксаны туксан; **~я́т вам** *или* **~ю́ тебе́** әйтәм бит мин сезгә, әйтәләр бит сезгә; **ина́че ~я́** башкача әйткәндә, икенче төрле әйткәндә; **и не ~и́** әйтмә дә инде, сөйләмә дә инде; әйтмә дә, сөйләмә дә; әйтеп торасы да юк; **по пра́вде ~я́** дөресен генә әйткәндә; **со́бственно ~я́** ачык кына итеп әйткәндә, турысын гына әйткәндә; **что вы ~и́те!** нәрсә сез сөйлисез!; **что и ~и́ть** сөйләп тә торасы юк, әйтәсе дә юк; **что ни ~и́** ни әйтсәң дә, ни генә дисәң дә

говори́||ться *несов.* 1. әйтелү, сөйләнү, диелү; **в письме́ ~тся так** хатта болай диелгән 2. *страд. от* **говори́ть** 2 ♦ **как ~тся** *в знач. вводн. сл.* әйткәндәй

говорли́вый, -ая, -ое 1. сүзчән, сөйләмчәк, күп сөйләүчән 2. *перен.* чылтыравык; **~ руче́й** чылтыравык инеш

говору́н *м разг.* тел бистәсе, лыгырдык, телчән

говору́нья *ж разг. см.* **говору́н**

говя́дина *ж* сыер ите

говя́ж||ий, -ья, -ье 1. сыер итеннән пешерелгән; **~ьи котле́ты** сыер итеннән пешерелгән котлет 2. сыер ...ы; **~ье са́ло** сыер мае; **~ья печёнка** сыер бавыры

го́гол||ь *м* гоголь, ала чумгалак ♦ **~ем ходи́ть** фырт йөрү, көязләнеп йөрү, купшыланып йөрү

го́голь-мо́голь *м* гоголь-моголь, әлбә (*йомырка сарысын шикәр белән туглап әзерләнгән татлы ашамлык*)

го́гот *м* 1. каңгылдау, кыйгаклау (*каз тавышы*) 2. *перен. прост.* шаркылдап көлү

гоготта́ть *несов.* 1. (*о гусях*) каңгылдау, каңгылдап кычкыру, кыйгаклау, кыйгак-кыйгак кычкыру 2. *прост.* (*хохотать*) шаркылдап көлү

год *м* (*мн.* **~а́, ~ы**) 1. ел; **четы́ре вре́мени ~а** елның дүрт фасылы; **в про́шлом ~ý** узган елда, былтыр; **в э́том ~ý** быел; **учёбный ~** уку елы; **фина́нсовый ~** финанс елы; **кру́глый ~** ел буе, ел буена; **из ~а в ~** ел саен, елдан-ел; **~ о́т году** елдан-елга 2. (*мн.* **~ы, ~а́**) чак, ел; **молоды́е ~ы** яшь чаклар; **в ~ы ю́ности** яшьлек елларында; **в ~ы войны́** сугыш елларында 3. (*мн.* **~ы**) (*промежуток времени в течение десятилетия*) еллар; **шестидеся́тые ~ы** алтмышынчы еллар 4. (*мн.* **~ы, ~а́**) яшь; **ребёнку три ~а** балага өч яшь ♦ **бе́з году неде́ля** *шутл.* ≈ аягы кереп җитмәгән әле; ≈ аягы керсә, таягы кермәгән; ≈ башы керсә, аягы кермәгән (*яңа гына, күптән түгел генә мәгънәсендә*); **в ~а́х** олы яшьтә

года́ми *нареч.* еллар буена

годи́н||а *ж высок.* еллар; **~а испыта́ний** сынау еллары; **в тяжёлую ~у** авыр елларда

год||и́ться *несов.* ярау, яраклы булу; **сапоги́ не ~я́тся** итек ярамый ♦ **э́то никуда́ не ~и́тся** бу бернигә дә ярамый; **так поступа́ть не ~ится** *безл.* болай эшләргә ярамый

годи́чн||ый, -ая, -ое бер еллык; **~ый срок** бер еллык срок; **~ое собра́ние** (*ежегодное*) еллык җыелыш; **~ые ко́льца** *бот.* еллык балдаклар (*агач кисемендә*)

го́дный, -ая, -ое яраклы, ярарлык, эшкә ярарлык; **~ для посе́ва** чәчүлеккә ярарлык; **~ к вое́нной слу́жбе** хәрби хезмәткә яраклы

годова́лый, -ая, -ое бер яшьлек; **~ ребёнок** бер яшьлек бала

годово́й, -а́я, -о́е еллык, бер еллык; **~ отчёт** еллык отчёт

годовщи́н||а *ж* еллык; еллык бәйрәм; **в ~у сва́дьбы** туй еллыгында

гол *м спорт.* гол; **заби́ть ~** туп (алка) кертү

гола́вль *м зоол.* кушбаш, аҗау

голена́стый, -ая, -ое озын ботлы (аяклы, сыйраклы)

голени́ще *с* куныч, балтыр

голе́ц *м зоол.* 1. (*пресноводная рыба*) сагалак 2. (*рыба северных морей*) ялангач балык

голи́к *м разг.* себерке, ындыр себеркесе (*яфраксыз себерке*)

голки́пер *м* капкачы, голкипер

голла́ндец *м* голланд, голландияле, Голландия кешесе

голла́ндка I *ж* (*печь*) галанка

голла́ндка II *ж* голландияле хатын (кыз)

голла́ндский, -ая, -ое голланд ...ы ♦ **~ сыр** голланд сыры

голла́ндцы *мн.* голландлар, голландиялеләр

голов||а́ 1. *ж* баш 2. *ж* (*единица счёта скота*) баш; **сто голо́в ове́ц** йөз баш сарык 3. *ж перен.* акыл; **челове́к с ~о́й** кыяллы кеше 4. *м* баш, башлык; **городско́й ~а́** шәһәр башлыгы 5. *ж* баш; **~а́ колоннады** колоннаның башы 6. *ж* баш; **~а́ са́хару** бер баш шикәр ♦ **быть ~о́й вы́ше** *кого* әллә никадәр югары тору (*акыл ягыннан*); **в ~а́х** баш очында; **~а́ идёт кру́гом** *у кого* баш катты, баш катып бетте, баш әйләнеп бетте; **~а́ садо́вая** ачыгавыз, томана, аңгыра бәрән; **~а́ ва́рит** башы эшли; **го́лову потеря́ть** башны югалту; аптырашта калу, нишләргә белмәү; **~ы́ не жале́ть** башны да кызганмау, зур корбаннарга әзер булу; **из ~ы́ вон** баштан чыккан, истән чыккан, онытылган; **как снег на́ голову** көтмәгәндә килеп чыгу; **с ~о́й уйти́ (погрузи́ться)** *во что берәр эшкә* баш белән чуму; **с ~ы́ до ног** *или* **с ног до ~ы́** баштанаяк; **сам себе́ ~а́** үзенә үзе хужа; **че́рез го́лову** *кого, чью кемнән дә булса* узып мөрәҗәгать итү

голова́стик *м* чукмарбаш, бака баласы

голове́шка *ж* кисәү, кисәү башы (*яңып бетмәгән утын агачлары*)

головизн||а *ж* балык башы, баш ите; (*кызыл балык башы һәм сырты*); **суп с ~ой** балык башыннан пешерелгән шулпа

голо́вк||а *ж* 1. *уменьш. от* **голова́** 1, 6; 2. эшләпә; **~а винта́** винт эшләпәсе 3. баш; **~а лу́ка** бер баш суган 4. (*группа вожаков, главарей*) җитәкчеләр, башлыклар 5. *мн.* **~и** (*передняя часть сапог*) итек башы; чана башы (*чана табанының бөгелгән урыны*)

ГОЛ-ГОН

головн||о́й, -а́я, -о́е **1.** баш ...ы; **~ о́й мозг** *анат.* баш мие; **~ о́й убо́р** баш киеме **2.** баш ...; алдан, башлап (башта) баручы; **~ о́й отря́д** алдан баручы отряд; **~ о́е предприя́тие** баш предприятие **3.** баштагы ..., алдагы ...; **~ ы́е вагоны** алдагы вагоннар

головня́ *ж* **1.** *см.* **голове́шка**; **2.** *с.-х.* (*болезнь злаков*) кисәү, корымбаш, гөмбә (*ашлык авыруы*)

головокруже́ние *с* баш әйләнү; **чу́вствовать ~** баш әйләнә башлау; **~ от успе́хов** *перен.* уңышлардан баш әйләнү

головокружи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** баш әйләндергеч, баш әйләнерлек; **~ая высота́** баш әйләнерлек биеклек **2.** *перен.* искитәрлек, зур; **~ый успе́х** зур уңыш

головоло́мк||а *ж* башваткыч; **зада́ть ~у** *перен.* уйланырга мәҗбүр итү

головоло́мный, -ая, -ое башваткыч, катлаулы, кыен, читен; **~ вопро́с** башваткыч мәсьәлә

головомо́йк||а *ж разг.* каты шелтә, кыздыру, пешерү; **зада́ть хоро́шую ~у** бик нык кыздыру

головоре́з *м разг.* башкисәр, юлбасар; җәнҗалчы

головотя́п *м разг.* юньсез, эш рәтен белмәүче

головотя́пство *с разг. неодобр.* юньсезлек, эш рәтен белмәү, мәгънәсезлек

голо́вушка *ж ласк. от* **голова́** 1, 3; башкай **♦ пропа́ла моя́ ~** бетте баш, харап булдым; **бу́йная ~** батыр кеше

го́лод *м* **1.** ашыйсы килү, ачыгу, тамак ачу; **почу́вствовать ~** ашыйсы килә башлау **2.** (*длительное недоедание*) ачлык, кытлык **3.** *перен.* (*нехватка чего-л. нужного*) кытлык; **кни́жный ~** китап кытлыгы

голода́ть *несов.* **1.** (*испытывать голод*) ачыгу; ачлы-туклы тору (яшәү) **2.** (*воздерживаться от принятия пищи*) ашамый тору, ашаудан баш тарту

го́лодно *нареч. в знач. сказ. безл.* ач, ачлы-туклы

голо́дн||ый, -ая, -ое **1.** ач; **~ая соба́ка** ач эт **2.** ач; ачтан ...; **~ая смерть** ач үлем, ачтан үлү **3.** ачлы-туклы; җитәр-җитмәс; **~ый паёк** җитәр-җитмәс паёк **4.** ачлык ...; кытлык ...; **~ый год** ачлык ел

голодо́вк||а *ж* ачлык, ашаудан баш тарту (*протест белдереп*); **объяви́ть ~у** ачлык игълан итү

голодра́нец *м прост.* ялангач, сукбай, ач кернә

гололёд *м*, **гололе́дица** *ж* бозгалак, бозлавык

голоно́гий, -ая, -ое яланаяклы; шәрә аяклы; **~ мальчи́шка** яланаяклы малай

голопу́зый, -ая, -ое *прост.* ялангач корсаклы (*балалар турында*)

го́лос *м* **1.** тавыш; **ни́зкий ~** калын тавыш; **высо́кий ~** нечкә тавыш; **повы́сить ~** тавышны күтәрү **2.** тавыш, җырчы; **рома́нс для двух ~о́в** ике җырчыга исәпләп язылган романс; **певе́ц сего́дня в ~е** җырчының бүген тавышы яхшы; **потеря́ть (сорва́ть) ~** тавышсыз калу **3.** *перен.* аваз; **~ со́вести** вөждан аваз **4.** *перен.* фикер, сүз; **~ чита́телей** укучылар фикере **♦ во весь ~** бөтен тавышына, барлык көченә; **в оди́н ~** бертавыштан; **пла́кать в ~** акырып елау

голоси́стый, -ая, -ое (*обладающий звучным голосом*) көчле тавышлы, яңгыравык тавышлы

голоси́ть *несов.* **1.** такмаклап елау; **~ по поко́йнику** мәет өстендә такмаклап елау **2.** *что и без доп., прост.* акырып җырлау; **~ пе́сню** акырып җыр җырлау

голосло́вн||ый, -ая, -ое нигезсез, дәлилсез, коры; **~ое обвине́ние** нигезсез гаепләү

голосова́ние *с* сайлау, тавыш бирү; **откры́тое ~** ачык сайлау; **та́йное ~** яшерен сайлау; **ста́вить вопро́с на ~** мәсьәләне тавышка кую

голосова́ть *несов.* **1.** *за кого-что* сайлау, тавыш бирү **2.** *что* тавышка кую; **~ резолю́цию** резолюцияне тавышка кую **3.** *разг.* кул күтәрү; **~ на доро́ге** юлда кул күтәрү (*машина туктату өчен*)

голосов||о́й, -а́я, -о́е тавыш ...ы; **~ ы́е свя́зки** тавыш ярылары; **~ о́й аппара́т** тавыш аппараты (*бугазда*); **~ а́я щель** тавыш ярыларындагы ярык

голубево́дство *с* күгәрчен асрау (үрчетү)

голубе́ть *несов.* **1.** (*виднеться — о чём-л. голубом*) күгелҗемләнеп, (зәңгәрләнеп) күренү **2.** (*становиться голубым*) күгелҗемләнү, зәңгәрләнү

голубизна́ *ж* күклек, зәңгәрлек; **~ глаз** күзләрнең зәңгәрлеге

голуби́ка *ж* күк җиләк

голуби́н||ый, -ая, -ое күгәрчен ...ы; **~ ы́е я́йца** күгәрчен йомыркалары; **~ая по́чта** күгәрчен почтасы

голу́бить *несов. кого-что, разг.* иркәләү, сөю

голу́бка *ж* **1.** (*самка голубя*) ана күгәрчен **2.** *ласк.* (*при обращении*) күгәрченкәй (*хатын-кызларга иркәләп эндәшү сүзе*)

голубогла́зый, -ая, -ое зәңгәр (күк) күзле

голуб||о́й, -а́я, -о́е **1.** зәңгәр, күк; **~ ы́е глаза́** зәңгәр күз **2.** *перен.* (*идиллический*) күңел ...ы; **~ а́я мечта́** күңел хыялы **♦ ~ а́я кровь** *уст.* аксөяк; **~ о́й песе́ц** күк төлке

голубцы́ *мн.* голубцы (*кәбестә яфрагына төреп пешерелгән итле дөге һ. б. ш.*)

голу́бчик *м разг.* күгәрченем, күгәрченкәй; энекәш, егеткәй, туганкай

го́лубь *м* күгәрчен

голубя́тник *м* күгәрчен асраучы

голубя́тня *ж* күгәрчен оясы, күгәрчен кетәге

го́л||ый, -ая, -ое **1.** ялангач, ялан, шәрә; **~ ые но́ги** яланаяк **2.** (*лишённый растительности*) ялангач; **~ая степь** ялангач дала **3.** (*без волос, шерсти и т.п.*) шәрә, такыр **4.** буш, коры; **~ ые сте́ны** буш стеналар; **спать на ~ом полу́** коры идәндә йоклау **5.** *перен.* коры; шәрә, апачык; **~ ые ци́фры** коры саннар; **~ая и́стина** ап-ачык хакыйкать **♦ брать ~ыми рука́ми** җинел генә кулга төшерү, ансат кына (көч сарыф итмичә генә) алу; **~ая зима́** карсыз кыш; **гол как соко́л** үзе дә ике күзе

голытьба́ *ж собир. уст.* ярлылар, йолкышлар, сукбайлар

голы́ш *м* **1.** *разг.* ялангач, шәрә; **ку́кла-~** шәрә курчак **2.** (*гладкий камень*) шома түгәрәк таш, чүерташ

голыша́м *нареч. разг.* ялангач (шәрә) килеш, ялангач; **бе́гать ~** шәрә килеш йөгерсен йөрү

голь *ж см.* **голытьба́**

гольё *с спец.* **1.** (*части мясной туши*) эче-башы (*баш-аяк, үпкә-бавыр, эчәкләр*) **2.** (*шкура*) шәрә тире (*кун илләү өчен эзерләп куелган тире*)

гомеопа́т *м* гомеопат

гомеопати́ческ||ий, -ая, -ое гомеопатик; **~ая апте́ка** гомеопатик аптека; **~ие сре́дства** гомеопатик чаралар

гомеопа́тия *ж* гомеопатия (*сәламәт кешеләрдә авыру китереп чыгара торган даруларны чирле кешеләргә аз күләмдә биреп, шул авырудан савыктыру алымы*)

гомери́ческий: ~ смех (хо́хот) тыела алмыйча шаркылдап көлү

гомоге́нный, -ая, -ое *книжн.* гомоген (*составы яки чыгышы буенча бер төрле*)

го́мон *м разг.* шау-шу, чыр-чу, тавыш

гомони́ть *несов. прост.* кычкырып сөйләшү, кычкыру

гомосексуали́зм *м* гомосексуализм (*бер җенестәге кешеләрнең бер-берсенә табигый булмаган омтылышы*)

гон *м* **1.** *см.* **гнать** 1, **гна́ться** 1; **2.** *охот.* эзәрлекләү (*ауда*) **3.** (*состояние зверей в брачный период*) куышу, куышу вакыты

гонг *м* гонг (*музыка коралы, шулай ук сигнал бирү өчен дә кулланыла*); **уда́рить в ~** гонгка сугу; **прозвуча́л ~** гонг яңгырады

гондо́ла *ж* гондола (**1.** *Венециядә кәүтәлы махсус көймә* **2.** *һава шарында кеше утыра торган зур кәрзин; дирижабльдә кеше утыра торган яки механизм куела торган асылмалы урын*)

гондолье́р *м* гондольер (*гондолада ишеп баручы*)

гоне́ни||е *с книжн.* эзәрләү, эзәрлекләү; кысу, җәберләү; **подве́ргнуть ~ям** туктаусыз эзәрлекләү

гоне́ц *м* атчабар, хәбәр йөртүче

гони́тель *м* эзәрлекләүче, кысучы, изүче, җәберләүче

го́нк||а *ж* **1.** *см.* **гнать, гна́ться, гоня́ть, гоня́ться; 2.** (*спешка*) ашыгу, кабалану; **начала́сь ~а пе́ред отъе́здом** китәр алдыннан кабалана башладылар **3.** *мн.* **~и** узышу (*йөгерүдә, чабышта*); **автомоби́льные ~и** автомобильләрдә узышу **♦ ~а вооруже́ний** ашкынып кораллану

го́нк||ий, -ая, -ое *охот.* йөгерек, житез, тиз чаба торган; **~ая борза́я** тиз чаба торган бурзай

го́нор *м* һавалылык, масаючанлык, артык горурлык, эрелек, тәкәбберлек

гонора́р *м* гонорар (*язучыларга, рәссамнарга һ.б.ш. иҗат кешеләренә шартнамә буенча түләнә торган хезмәт хакы*)

гонорé́я *ж мед.* гонорея (*венерик авыру*)

гóночн||ый, -ая, -ое ярыш ...ы, узышу ...ы, узышу өчен ясалган; **~ый автомоби́ль** узышу автомобиле; **~ая ло́дка** узышу көймәсе

гонт *м собир.* гонт (*тубә ябу өчен бер кыры юкартылган, икенче кыры ырмауланган эшләнган такта*)

гонтов||о́й, -а́я, -о́е гонт ...ы; гонт белән ябылган; **~а́я кры́ша** гонт белән ябылган түбә

гончáр *м* чүлмәкче

гончáрн||ый, -ая, -ое **1.** чүлмәк ясау ...ы; **~ое произво́дство** чүлмәк ясау производствосы **2.** балчыктан ясалган; **~ые изде́лия** балчыктан ясалган әйберләр

гóнчая *ж* эзәрлекләүче эт

гóнщик *м спорт.* узышчы

гоньбá *ж разг. см.* **гон** 2

гонять *несов.* **1.** *кого-что* куу, куып китерү; **~ скот на водопóй** көтүне су эчерергә куып китерү **2.** *кого-что, разг.* (*посылать*) йөртү, йөртеп тору; йөгертеп тору (*мәс. йомыш белән*) **3.** *что, прост.* тибеп йөрү; тибеп үткәрү; **~ мяч** туп тибеп йөрү ♦ **~ ло́дыря** җил куып йөрү, тырай тибеп үткәрү

гоня́ться *несов. за кем-чем* куып йөрү, арттан йөрү; **~ за зве́рем** җәнлек артыннан йөрү

гоп *межд.* һоп, һуп; **не говори́ ~, пока́ не перепры́гнешь** *посл.* ≈ алдан кычкырган күкенең башы ярылган

гопáк *м* гопак (*украин халык бию һәм шуның көе*)

гопкомпáния *ж разг.* гопкомпания (*күңел ачып йөрүчеләр төркеме*)

гор||á *ж* **1.** тау; **Ура́льские го́ры** Урал таулары; **ледяна́я ~á** боз тавы; **ката́ться с гор** тау шуу **2.** *мн.* **го́ры** таулар; **жить в ~áх** таулар арасында яшәү **3.** *перен.* бик күп, өем-өем, тау-тау; **го́ры книг** өем-өем китап ♦ **~á с плеч [свали́лась]** җилкәдән тау төшкән кебек булу (*җиңеләеп калу*); **~о́й [стои́ть]** бөтен көч белән яклау; **идти́ в го́ру** югары күтәрелү, уңышларга ирешү; **идти́ по́д гору** түбән төшү, кире китү (*уңышсызлыкларга очрау*); **надéяться** *на кого* **как на ка́менную го́ру** бик нык ышану; **не за ~а́ми** тиздән, күп калмады инде; **пир ~о́й** мул сый; **сули́ть золоты́е го́ры** күпне вәгъдә итү, алтын таулар вәгъдә итү

гора́зд *в знач. сказ. с неопр., на что, в чём, прост.* оста, булдыра; булдыра алу; **на вы́думки ~** төрле нәрсәләр уйлап чыгарырга оста ♦ **кто во что ~** кем нәрсә булдыра ала

гора́здо *нареч.* күп, шактый, байтак; **здесь ~ просто́рнее** монда шактый иркен; **э́то ~ лу́чше** монысы шактый әйбәт

горб *м* бөкре, өркәч; **верблю́жий ~** дөя өркәче ♦ **свои́м ~о́м** (*добывать, зарабатывать*) үз җилкәсе белән, үз кул көче белән (*табу*); **на чужо́м ~ý** (*ехать и т. п.*) кеше җилкәсен (*кимерү*); кеше җилкәсендә (*яшәү*); **на своём ~ý испыта́ть** үз җилкәсендә татып карау

горба́тый, -ая, -ое **1.** (*имеющий горб*) бөкре, бөкрәйгән **2.** кәкрәеп килгән, кәкре; **~ нос** кәкре борын

горби́нк||а *ж*: **нос с ~ой** кәкре борын

го́рбить *несов. что* бөкрәйтү; **~ спи́ну** арканы бөкрәйтү

го́рбиться *несов.* бөкрәю; **~ при ходьбе́** бөкрәеп йөрү

горбоно́сый, -ая, -ое (*о человеке*) кәкре борынлы; (*о животном*) кәкре танаулы

горбу́н *м* бөкре кеше

горбу́нья *ж* бөкре хатын (кыз)

горбу́ша I *ж* горбуша (*балык*)

горбу́ша II *ж с.-х.* (*вид косы*) кәкре чалгы

горбу́шка *ж* кибән башы, кыерчык, икмәк кыерчыгы

горбы́ль *м* горбыль, кыртыш (*бурәнә не ярганда ике кырыйда кала торган такта*)

горделúв||ый, -ая, -ое горур, тәкәббер, һавалы, масаючан; **~ая похóдка** горур йөреш

горде́ц *м* тәкәббер, горур, мактанчык

го́рдиев: ~ у́зел чишә алмаслык итеп бәйләнгән төен, чишә алмаслык мәсьәлә, буталчык мәсьәлә

горди́ться *несов. кем-чем* горурлану, мактану; **~ успе́хами** уңышлар белән горурлану; **~ свои́ми детьми́** үзеңнең балаларың белән горурлану

го́рдост||ь *ж в разн. знач.* горурлык, мактаныч; **национáльная ~ь** милли горурлык; **~ь побе́дой** җиңү горурлыгы; **э́тот студе́нт — ~ь институ́та** бу студент — институтның горурлыгы; **обвини́ть** *кого-л.* **в ~и** *кемне булса да* горурлыкта гаепләү

гóрд||ый, -ая, -ое **1.** горур; **~ый челове́к** горур кеше; **~ый взгля́д** горур караш **2.** бөек, илаһи; **~ые мечты́** илаһи хыяллар **3.** *чем* шат; **горд успе́хом** уңышлардан шатмын

гордыня *ж уст.* [үтә] тәкәбберлек, артык масаючанлык, һавалылык

гордя́чка *ж разг.* һавалы, тәкәббер, масаючан (*хатын-кыз*)

го́р||е *с* **1.** (*печаль*) кайгы, хәсрәт, көенеч, сагыш **2.** (*несчастье*) бәхетсезлек, бәла-каза ♦ **а ему́ и ~я ма́ло** ≈ ике ятып бер төшенә дә керми, аның исе дә китми; **к моему́ ~ю** *или* **на моё ~е** бәхетсезлегемә каршы; **с ~ем попола́м** көч-хәл белән, көчкә, илләлла

горева́ть *несов. о ком-чём и без доп.* кайгыру, хәсрәтләнү, көенү, сагышлану, хәсрәт чигү; **не горю́й!** кайгырма!

горе́лка *ж* горелка (*мәс. газ плитасында*); челтәр (*лампада*)

горе́лки *только мн.* (*вид русск. нар. игры*) так-җәп уены, так-каравыл уены

горе́л||ый, -ая, -ое **1.** янган, көйгән; **~ый лес** янган урман **2.** черегән; **~ая ко́жа** черегән күн **3.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* көек; **па́хнет ~ым** көек исе килә

горельéф *м* горельеф (*яссылыкка калку итеп ясалган сын*)

горемы́ка *м, ж разг.* бичара, бәхетсез, мескен; хәсрәт капчыгы

горемы́чн||ый, -ая, -ое *разг.* кайгы-хәсрәтле, көенечле, бәхетсез, кара, караңгы; **~ая до́ля** кара язмыш

го́рестн||ый, -ая, -ое кайгылы, сагышлы, хәсрәтле, күңелсез; **~ое собы́тие** күңелсез вакыйга

го́рест||ь *ж* **1.** (*скорбь*) кайгы, сагыш, хәсрәт **2.** *обычно мн.* **~и** (*несчастья*) бәхетсезлекләр, күңелсез вакыйгалар

гор||е́ть *несов.* **1.** яну; **де́рево ~и́т** агач яна **2.** (*быть в жару*) яну, кызышу, эсселәнү **3.** балку, яну, балкып тору, балкып яну; **~и́т заря́** таң балкый; **все ла́мпочки ~я́т** барлык лампочкалар балкып яналар **4.** *перен.* ялтырау, ялтырап (яныпмы) тору, ут кебек яну; **глаза́ его́ ~я́т от ра́дости** шатлыктан күзләре ялтырый **5.** кызу, яну, бурсу, черү; **мо́крое се́но в стога́х ~и́т** юеш печән кибәндә яна **6.** *перен. разг.* (*быстро изнашиваться, рваться*) тиз черү, тетелү, тузу **7.** *перен. чем* бик нык теләү, яну; **~е́ть любо́вью** мәхәббәт утында яну **8.** *перен.* бик нык ярату; яну; **~е́ть энтузиа́змом** энтузиазм белән яну **9.** *перен.* кыпкызыл булу; **~е́ть от стыда́** оялудан кып-кызыл булу ♦ **де́ло ~и́т** эш яхшы бара; **душа́ ~и́т** йөрәк яна, эч яна; **земля́ ~и́т под нога́ми** ≈ кая барырга урын тапмый; **не ~и́т** ут капмагандыр әле

го́рец *м* таулы, тау кешесе, тауларда яшәүче

го́речь *ж* **1.** ачы тәм; **~ во рту́** авызда ачы тәм **2.** *разг.* ачы нәрсә; **я проглоти́л каку́ю-то ~** ниндидер ачы нәрсә йоттым **3.** *перен.* әрнү, пошыну, ачы тойгы, көенү; ачыну; **~ воспомина́ний** истәлекләрнең ачы тойгысы

горизóнт *м* **1.** горизонт, офык (*күкнең җир яки су белән тоташкан кебек күренә торган сызыгы*) **2.** күк йөзе; **на ~е ни о́блачка** күк йөзендә бер генә болыт та юк **3.** киң пространство, киң мәйдан, киң сахра; **с горы́ откры́лся широ́кий ~** таудан киң офык ачылды ♦ **исче́знуть** *с чьего* **~а** юкка чыгу, күренми башлау; **появи́ться на ~е** килеп чыгу, күренү

горизонта́л||ь *ж* **1.** ятма сызык (*юнәлеш*), горизонталь сызык; **по ~и** горизонталь буенча **2.** *геод.* горизонталь (*географик картада яки планда бер үк биеклектә булган ноктaларны тоташтыра торган сызык*)

горизонта́льн||ый, -ая, -ое горизонталь ..., ятма ...; **~ая ли́ния** горизонталь сызык

гори́лла *ж* горилла

гори́ст||ый, -ая, -ое таулы; **~ая ме́стность** таулы урын

горихво́стка *ж зоол.* уткойрык (*кош*)

горицве́т *м бот.* утчәчәк

го́рка *ж* **1.** *уменьш. от* **гора́** 1, 3; **2.** горка (*совыт-саба шкафы*)

го́ркнуть *несов.* әчү, әче тәм керү

горко́м *м* горком, шәһәр комитеты

горла́нить *несов. что и без доп., прост.* акырып сөйләшү, акырып җырлау, акыру, бакыру

горла́стый, -ая, -ое *прост.* каты (ачы) тавышлы, акыручан; кушбугаз; **~ пету́х** каты тавышлы әтәч

го́рлинка, го́рлица *ж* урман күгәрчене

го́рл||о *с* **1.** бугаз, тамак; **дыха́тельное ~о** сулыш юлы, бугаз; **в ~е пересо́хло** тамак кипте; **~о боли́т** тамак авырта; **кровь идёт ~ом** бугаздан кан килә **2.** (*сосуда*) авыз, муен **3.** *перен.* (*устье*) тамак (*елга тамагы*) ♦ **взять ~ом** кычкырып жиңәргә тырышу; **взять за ~о** бугазына ябышу; **во всё ~о** дөнья яңгыратып (*кычкыру*); **драть ~о** акыру; **по ~о** муеннан, бугаздан, бик күп; **приста́ть с ножо́м к ~у** сорап (үтенеп) теңкәгә тию, сагыз булу; **промочи́ть ~о** аз гына эчеп алу, тамак чылату; **слова́ застря́ли у него́ в ~е** әйтер сүзен әйтә алмады; **стать поперёк ~а** тамакка таш булып утыру

горлови́на *ж* авыз (*киң һәм тирән тишек*); **~ парово́го котла́** пар казанының авызы

горлов||о́й, -а́я, -о́е бугаз ...ы, бугаздан ...; **~о́е кровотече́ние** бугаздан кан килү; **~ы́е боле́зни** бугаз авырулары

го́рлышко *с* **1.** *уменьш. от* **го́рло** 1; **2.** (*сосуда*) авыз, муен

гормо́н *м физиол.* гормон (*эчке секреция бизләре эшләп чыгара торган матдә*)

гормона́льн||ый, -ая, -ое *физиол.* гормональ; **~ые препара́ты** гормональ препаратлар

горн I *м* **1.** (*печь*) тимерче учагы **2.** горн (*домна миченең асты*)

горн II *м* (*духовой инструмент*) быргы

горни́л||о *с высок.* ут, ялкын; **в ~е войны́** сугыш утында

горни́ст *м* быргычы, сигналчы

го́рница *ж* **1.** *уст.* (*комната*) бүлмә **2.** (*чистая половина избы*) ак өй, кунак бүлмәсе

го́рничная *ж* хезмәтче; асрау

го́рно- *рус телендәге кушма сүзләрнең «тау», «тауга бәйләнешле» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **горнометаллурги́ческий** тау металлургиясе ...ы; **горно-обогати́тельный** тау-баету ...ы

горново́й *м* горновой (*домнада эшләүче белгеч*)

горнозаво́дский, -ая, -ое тау промышленносте ...ы, тау заводы ...ы; **~ райо́н** тау промышленносте районы

горнозаво́дчик *м* горнозаводчик (*тау промышленносте предприятиеләре хуҗасы*)

горнолы́жник *м* тау чаңгычысы

горнолы́жница *ж* тау чаңгычысы (хатын-кыз)

горнолы́жн||ый, -ая, -ое тауда чаңгы шуу ...ы; **~ая ста́нция** тауда чаңгы шуу станциясе; **~ый спорт** тауда чаңгы шуу спорты

горнопромы́шленный, -ая, -ое тау промышленносте ...ы, тау промышленносте булган, тау промышленностьлы; **~ райо́н** тау промышленностьлы район

горнораба́чий *м* тау эшчесе

горноу́дн||ый, -ая, -ое тау токымнары ...ы; **~ая промы́шленность** тау токымнары промышленносте

горноспаса́тель *м* тау эшләре коткаручысы

горноста́ев||ый, -ая, -ое ас...ы, ас мехыннан тегелгән; **~ый мех** ас мехы; **~ая ма́нтия** ас мехыннан тегелгән мантия

горноста́й *м* **1.** (*зверь*) ас **2.** (*мех*) ас мехы

го́рн||ый, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* тау...ы; **~ые поро́ды** тау токымнары; **~ый кли́мат** тау климаты; **~ое о́зеро** тау күле; **~ые лы́жи** тау чаңгысы **2.** таулы; **~ая страна́** таулы ил ♦ **~ый лён** тау җитене (*асбест төре*)

горня́к *м* горняк (*тау промышленносте эшчесе яки инженеры*)

го́род *м* **1.** шәһәр; кала; **областно́й ~** өлкә шәһәре; **жить за́ городом** шәһәрдән читтә яшәү **2.** (*в играх*) мәйданчык (*чүрәкәй, городки кебек уеннарда һәр ике якта шакмаклар урнаштыру очен сызып билгеләнгән урын*) ♦ **~-геро́й** герой шәһәр

городи́ть *несов. что, разг.*: **~ чепуху́ (чушь)** сафсата сату, юк-барны сөйләү; **огоро́д ~** файдасыз эш башкару, юкка маташу; **не́чего бы́ло [и] огоро́д ~** мондый эшне башларга да кирәк түгел иде

городи́ще *с археол.* борынгы шәһәр калдыклары, шәһәрлек

городки́ *только мн.* бура уены, городки; **игра́ть в ~** городки уйнау

городни́чий *м ист.* шәһәр башлыгы

городово́й *м ист.* (*революциягә кадәрге Россиядә: полициядә түбән чин*)

городо́шник *м* городки (бура) уенында катнашучы

горожа́нин *м* шәһәр кешесе, шәһәрдә торучы

горожа́нка *ж* шәһәрдә яшәүче хатын (кыз)

гороско́п *м* гороскоп (*урта гасырларда астрологлар тарафыннан яңа туган баланың язмышын билгеләү максаты белән төзелгән таблица*)

горо́х *м* борчак ♦ **как об стену ~** стенага борчак сипкән кебек; ≈ колагына да элми; **при царе́ Горо́хе** *шутл.* хан заманында, бик күптән

горо́ховый, -ая, -ое **1.** борчак ...ы; **~ стручо́к** борчак кузагы; **~ суп** борчак шулпасы **2.** (*о цвете*) борчак төсле, соргылт сары

горо́шек *м* **1.** *уменьш. от* **горо́х; 2.** бөрчек-бөрчек, бөрчек (*материягә төшерелгән бизәк*); **пла́тье в ~** бөрчекләр төшерелгән күлмәк ♦ **души́стый ~** *бот.* иске борчак (*бакча гөле*); **зелёный ~** яшел борчак (*аштәмләткеч*)

горо́шина *ж* борчак бөртеге, бер бөртек борчак

горо́шинка *ж уменьш. от* **горо́шина**

горсть *ж* **1.** уч; **зачерпну́ть ~ю воды́** учка су алу **2.** бер уч; **~ песку́** бер уч ком **3.** бер төркем; **~ храбрецо́в** бер төркем батырлар

горта́нн||ый, -ая, -ое **1.** *лингв.* бугаз ...ы, гырылдык ...; **~ые согла́сные** бугаз тартыклары **2.** тамак төбе белән ...; **слы́шался ~ый го́вор** тамак төбе белән сөйләшү ишетелә иде

горта́нь *ж анат.* бугаз

горте́нзия *ж бот.* гортензия, япон гөле

го́рцы *мн.* тау кешеләре; тау халыклары

горчи́ть *несов.* әче тәм килү; күксегән тәм килү; **ма́сло горчи́т** майдан күксегән тәм килә

горчи́ца *ж* горчица (*усемлек һәм шул усемлектән әзерләнә торган аш тәмләткеч*)

горчи́чник *м* горчичник (*горчица компрессы*); **поста́вить ~и** горчичниклар кую

горчи́чница *ж* горчица савыты

горчи́чн||ый, -ая,-ое горчица ...ы; **~ое ма́сло** горчица мае

горше́чник *м* чүлмәкче, чүлмәк ясаучы

горшо́к *м* чүлмәк; **цвето́чный ~** чәчәк чүлмәге

го́рьк||ий, -ая, -ое **1.** ачы; **~ое лека́рство** ачы дару **2.** *перен.* ачы, авыр, кайгылы, аяныч; **~ая до́ля** авыр язмыш; **~ая и́стина** ачы хакыйкать ♦ **~ие слёзы** канлы яшь; **~ий пья́ница** исерек баш; **пить ~ую** туктаусыз эчү

го́рько *нареч.* **1.** ачы, авыр; **~ в э́том созна́ться** бу турыда әйтүе дә авыр **2.** каты; **~ пла́кать** каты елау, ачы күз яше белән слау **3.** *в знач.сказ. безл.* ачы; ачы тәм; **во рту́ ~** авызда ачы тәм **4.** *в знач. сказ. безл. кому* авыр, читен; **мне ~, что ты не понима́ешь э́того** миңа бик авыр, син шул хәлне анламыйсың ♦ **~!** (*возглас на свадьбе*) ачы!

го́рько-солёный, -ая, -ое (*о воде*) ачы тозлы

горю́ч||ий I, ая, -ее **1.** яна торган; кабынучан; **~ий материа́л** яна торган материал; **~ая смесь** яна торган катнашма **2.** *в знач. сущ.* **~ее** *с* ягулык, сыек ягулык

горю́ч||ий II, -ая, -ее: **~ие слёзы** канлы (ачы) күз яше

горя́нка *ж* тау хатыны (кызы), тауларда яшәүче хатын (кыз)

горя́чечный, -ая, -ое *уст.*: **~ бред** кызышып саташу

горя́ч||ий, -ая, -ее **1.** кайнар, эссе; **~ий чай** кайнар чәй; **~ее ю́жное со́лнце** көньякның эссе кояшы **2.** кызган, кызу; **~ий утю́г** кызган үтүк **3.** *перен.* кызу; **~ее вре́мя** кызу эш вакыты; **~ие дни** кызу эш көннәре **4.** *перен.* ялкынлы; **~ие ре́чи** ялкынлы чыгышлар; **~ая любо́вь** ялкынлы мәхәббәт ♦ **~ая голова́ (кровь)** *или* **~ий челове́к** кызу канлы кеше; **~ая обрабо́тка** *тех.* кыздырып эшкәртү (*металлны*); **по ~им следа́м** кичекмәстән, эзе суынганчы, онытылганчы, шунда ук; **[попа́сть] под ~ую ру́ку** кызган чагына туры килү

горячи́тельн||ый, -ая, -ое *разг.*: **~ые напи́тки** исерткеч (кыздыргыч) эчемлекләр

горячи́ть *несов. кого-что* кыздыру, ярсыту; (*коня*) чарысландыру

горячи́ться *несов.* кызу, ярсу, дулау; **напра́сно ~** юкка кызу

горя́чка *ж* кабалану, ашыгу, ыгы-зыгы [килү]; **~ пе́ред отъе́здом** китәр

алдыннан ыгы-зыгы килү; **экзамена-ци́о́нная** ~ имтихан вакытындагы ыгы-зыгы

горя́чность *ж* кызулык, кызу канлылык, дуамаллык; **проявля́ть излиш-нюю** ~ артык дуамаллык күрсәтү

гос- *рус телендәге кушма сүзләрнең «дәүләт», «дәүләткә бәйләнешле» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **госаппара́т** дәүләт аппараты; **госучрежде́ние** дәүләт оешмасы; **госконтро́ль** дәүләт контроле; **госторго́вля** дәүләт сәүдәсе

госба́нк *м* дәүләт банкысы

госбюдже́т *м* дәүләт бюджеты

госдепарта́мент *м* дәүләт департаменты (*мәс. АКШта*)

госкреди́т *м* дәүләт кредиты

госпитализи́ровать *сов. несов. кого-что* хастаханәгә салу, госпитальгә салу

го́спиталь *м* госпиталь

господи́н *ж* **1.** (*при обращении*) әфәнде **2.** (*хозяин*) хуҗа **3.** (*представитель привилегированного класса*) бай ♦ ~ **своей́ судьбы́** үз язмышына үзе хуҗа; **сам себе́** ~ үзенә үзе хуҗа

госпо́дство *с* хакимлек, өстенлек; ~ **в во́здухе** һавада өстенлек итү (*сугыш вакытында авиация өстенлеге*); **полити́ческое** ~ сәяси хакимлек

госпо́дств||овать *несов.* **1.** хөкем сөрү, хакимлек итү, өстенлек итү, өстен булып тору; ~**овать на мо́ре** диңгездә өстенлек итү **2.** (*преобладать*) өстенлек итү, күбрәк булу, кин таралу; **здесь** ~**уют ю́го-за́падные ве́тры** монда көньяк-көнбатыш яктан искән җилләр өстенлек итә **3.** *над чем* (*возвышаться*) югарырак тору, биектәрәк тору, тирәюньһән өстәрәк тору

госпо́дствующ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **госпо́дствовать**; **2.** өстенлек итүче, хөкем сөрүче, өстен, хаким; ~**ие кла́ссы** өстен сыйныфлар **3.** өстенлек алган, кин таралган; ~**ее мне́ние** өстенлек алган фикер

госпо́дь *м* алла, тәнре, хода ♦ **упаси́ (не дай) го́споди!** ходай күрсәтмәсен, була күрмәсен!

госпожа́ *ж* **1.** (*при обращении*) ханым **2.** (*представительница привилегированного класса*) бикә, байбикә **3.** (*хозяйка*) хуҗа хатын

гост *м* гост (*ботенсоюз дәүләт стандарты*)

гостеприи́мный, -ая, -ое кунакчыл; кече күңелле; ~ **хозя́ин** кунакчыл хуҗа

гостеприи́мство *с* кунакчыллык; **прояви́ть** ~ кунакчыллык күрсәтү

гости́ная *ж* **1.** (*комната*) кунак бүлмәсе **2.** (*комплект мебели*) кунак бүлмәсе җиһазы

гости́нец *м прост.* күчтәнәч; бүләк

гости́ница *ж* кунакханә, гостиница

гости́ничн||ый, -ая, -ое гостиница ...ы; **дом** ~**ого ти́па** кунакханә тибындагы йорт

гости́ный: ~ **двор** *уст.* сәүдә йорты

гости́ть *несов.* кунак булу

гост||ь *м* кунак; **идти́ в** ~**и** кунакка бару; **быть в** ~**я́х** кунакта булу; **он у нас ре́дкий** ~**ь** ул безнең сирәк кунагыбыз

го́стья *ж* кунак хатын (кыз)

государ́ственно-монополисти́ческий, -ая, -ое дәүләт монополиясе ...ы

государ́ственность *ж* дәүләтчелек, дәүләт булып оешу

государ́ственн||ый, -ая, -ое **1.** дәүләт ...ы; ~**ый аппара́т** дәүләт аппараты; ~**ый бюдже́т Татарста́на** Татарстанның дәүләт бюджеты; ~**ые грани́цы** дәүләт чикләре; **де́ло** ~**ой ва́жности** дәүләт күләмендә әһәмиятле эш; ~**ая изме́на** дәүләткә хыянәт; ~**ое пра́во** дәүләт хокукы ♦ ~**ые экза́мены** дәүләт имтиханнары

государ́ство *с* дәүләт; **демократи́ческое** ~ демократик дәүләт

государ́ыня *ж* **1.** (*правительница*) хатын патша, әби патша **2.** *уст.*(*при обращении*) ханым; **ми́лостивая** ~ шәфкатьле ханым

государ́ь *м* **1.** (*правитель*) патша **2.** *уст.*(*при обращении*) әфәнде; **ми́лостивый** ~ мөхтәрәм әфәнде

го́тика *ж* готика (*архитектура стиле*)

готи́ческий, -ая, -ое готика ...ы; готик, готик стильдәге ...; ~ **храм** готик храм ♦ ~ **шрифт** готик хәреф

гото́вальня *ж* готовальня (*махсус футлярлы сызым әсбаплары*)

гото́вить *несов.* **1.** *кого-что* әзерләү; ~ **ученика́ к экза́мену** укучыны имтиханга әзерләү; ~ **ру́копись к набо́ру** кулъязманы басарга әзерләү **2.** *что* хәзерләү; ~ **уро́ки** дәрес хәзерләү **3.** *что и без. доп.* әзерләү, пешерү; ~ **обе́д** ашарга пешерү; **она хорошо́ гото́вит** ул әйбәт пешерә **4.** *что* хәзерләү, хәзерлек күрү; ~ **уда́р по врагу́** дошманга һөҗүм итәргә әзерлек күрү

гото́в||иться *несов.* **1.** *к чему и с неопр.* әзерләнү; ~**иться к ле́кции** лекциягә әзерләнү **2.** *к чему и с неопр.* әзерләнү, җыену; ~**иться к отъе́зду** китәргә җыену **3.** булырга тору, якынлашып килү; ~**ятся ва́жные собы́тия** мөһим вакыйгалар булырга тора **4.** *страд. от* **гото́вить**

гото́вность *ж* **1.** әзерлек; **боева́я** ~ сугышчан әзерлек **2.** (*согласие*) ризалык, әзер булу; **вы́разить** ~ **е́хать** барырга ризалыгын белдерү

гото́в||ый, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* әзер; ~**ые изде́лия** әзер әйберләр; **я гото́в к экза́менам** мин имтиханнарга әзер; **он гото́в помо́чь** ул ярдәмләшергә әзер **2.** ...га тора, ...лык хәлгә килгән; **по́чки** ~**ы распусти́ться** бөреләр ачылырга тора ♦ **всегда́ гото́в!** һәрвакыт әзер!; **[жить] на всём** ~**ом** әзергә әзер булып яшәү, аныкка таныклы булып тору

гофриро́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **гофрирова́ть**; **2.** сырлы, сырланган; ~**ая бума́га** сырлы кәгазь

гофрирова́ть *сов., несов. что* гофрлау, бөрү, сырлау

гофриро́вка *ж* **1.** *см.* **гофрирова́ть**; **2.** параллель бөрмәләр (сырлар)

граб *м* күгагач

грабёж *м прям., перен.* талау, кычкыртып талау; ~ **среди́ бе́ла дня** көпәкөндез кычкыртып талау

граби́тель *м* талаучы, юлбасар

граби́тельск||ий, -ая, -ое талау ...ы; ~**ие во́йны** талау сугышлары

гра́бить *несов. кого-что* талау

гра́блен||ый, -ая, -ое талап алынган; ~**ые ве́щи** талап алынган әйберләр

гра́бли *только мн.* тырма, кул тырмасы; **ко́нные** ~ атлы тырма

гравёр *м* гравёр (*металлга яки агачка чокып рәсем ясаучы*)

гравёрн||ый, -ая, -ое гравёр ...ы; гравёрлык ...ы; граверлау ...ы; ~**ое иску́сство** гравёрлык сәнгате; ~**ая мастерска́я** граверлау остаханәсе

гра́вий *м* чуерташ, вак таш

гравирова́льн||ый, -ая, -ое граверлау ...ы; ~**ые инструме́нты** граверлау инструментлары

гравирова́ть *несов. что* граверлау (*металлга, сөяккә һ.б.ш. чокып рәсем төшерү*)

гравиро́вщик *м см.* **гравёр**

гравита́ция *ж физ.* гравитация

грави́ра *ж* гравюра (*чокып ясалган клишедән төшерелгән рәсем*)

град I *м* боз; ~ **побил посе́вы** игеннәрне боз сукты ♦ ~ **насме́шек** чиксез күп мыскыллаулар; ~ **обвине́ний** исәпсез-хисапсыз гаепләүләр; ~ **пи́сем** бик күп хатлар; **посы́пался** ~ **пуль** пулялар яңгыр кебек ява башлады; **пот с меня́ льётся** ~**ом** манма (шабыр) тиргә баттым

град II *м уст. см.* **го́род** I

гради́ция *ж* градация (*бер нәрсәдән икенчесенә күчкәндәге эзлеклелек*)

гра́дина *ж разг.* боз бөртеге (*куктан ява торган*)

гра́динка *ж уменьш. от* **гра́дина**

гради́рня *ж* **1.** градирня (*тоз алу өчен тозлы суны парга әйләндерә торган корылма*) **2.** суыткыч (*промышленностьта кайнар суны суыта торган җайланма*)

гради́ровать *сов., несов. что* градирлау (*тозлы суны парга әйләндерү*)

градоби́тие *с* боз сугу (*мәс. игенне*)

градов||о́й, -а́я, -о́е боз...ы, бозлы; ~**а́я ту́ча** боз болыты; ~**о́й дождь** бозлы яңгыр

градонача́льник *м* шәһәр башлыгы (*19 йөздә Россиядә шәһәр башлыгы, губернатор хокукындагы начальник*)

градострое́ние *с см.* **градострои́тельство**

градострои́тель *м* шәһәр төзүче

градострои́тельство *с* шәһәр төзү

градуи́ровать *сов., несов. что, спец.* бүлемләү, градусларга бүлү, градус билгеләре сызу; ~ **термо́метр** термометрны градусларга бүлү

гра́дус *м* градус (**1.** *тугәрәкнең 360 тан бер өлеше* **2.** *температураны, берәр нәрсәнең катылыгын, куәтлелеген үлчәү берәмлеге*) ♦ **под** ~**ом** исерек, сәрхуш, кызмача

граду́сник *м* градусник

граждани́н *м* гражданин

граждани́нка *ж* гражданка

граждани́нск||ий, -ая, -ое **1.** гражданлык ...ы; граждан ...ы; ~**ое пра́во** гражданлык хокукы; ~**ий иск** гражданлык судына бирү **2.** гражданлык ...; **в** ~**ом**

пла́тье гражданлык киемендә ◆ **~ая война́** гражданнар сугышы; **~ая пани́хида** гражданлык жәназасы; **~ая смерть** *уст.* барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителү; **~ий брак** загста язылышып өйләнү

граждáнст||во *с* гражданлык; **Зако́н о ~е** гражданлык турында закон; **получи́ть права́ ~а** гражданлык хокукларын алу

грамза́пись *ж* грамзапись (*махсус пластинкага язылган музыка әсәрләре һәм төрле чыгышлар*)

грамм *м* грамм

грамма́тика *ж* грамматика; **сравни́тельная ~** чагыштырмалы грамматика; **шко́льная ~** мәктәп грамматикасы

грамматúческ||ий, -ая, -ое грамматика...ы; грамматик; **~ие пра́вила** грамматика кагыйдәләре; **~ий строй языка́** телнең грамматик төзелеше; **~ие оши́бки** грамматик ялгышлар

граммофо́н *м* граммофон

граммофо́нн||ый, -ая, -ое граммофон ...ы; **~а́я пласти́нка** граммофон пластинкасы

гра́мот||а *ж* **1.** укый-яза белү; грамота; **вы́учиться ~е** грамотага өйрәнү **2.** грамота; [мактау] кәгазе; **почётная ~а** мактау грамотасы; **вери́тельные ~ы** *дип.* ышаныч язулары ◆ **фи́лькина ~а** мәгънәсез документ, буш кәгазь

грамоте́й *м шутл.* грамоталы, укый-яза белүче

гра́мотный, -ая, -ое **1.** грамоталы, укый-яза белүче, укый-яза белә торган; **~ челове́к** укый-яза белә торган кеше; **~ учени́к** грамоталы укучы **2.** (*не содержащий ошибок*) хатасыз язылган, грамоталы язылган (*мәс. хат*) **3.** (*знающий*) белемле, мәгълүматлы; **он ~ инжене́р** ул белемле инженер **4.** (*умело выполненный*) җиренә җиткереп эшләнгән, дөрес эшләнгән; **~ чертёж** җиренә җиткереп эшләнгән сызым

грампласти́нка *ж* грампластинка

гран *м* гран (*аптека үлчәве берәмлеге — 0,062 граммга тигез*) ◆ **ни ~а** *чего* бөртеге дә юк, тузан кадәрле дә юк

грана́т I *м бот.* анар (*агачы һәм җимеше*)

грана́т II *м мин.* гранат (*асылташ*)

грана́та *ж* граната

грана́тов||ый I, -ая, -ое **1.** *бот.* анар ...ы; **~ое де́рево** анар агачы **2.** (*о цвете*) гранат төсле, куе кызыл

грана́товый II, -ая, -ое гранат ...ы; **~ брасле́т** гранат беләзек

гранатомётчик *м* гранатомётчик, граната ыргытучы

грандио́зн||ый, -ая, -ое гаять зур, бик зур, искиткеч зур; **~ое строи́тельство** гаять зур төзелеш

гранённый, -ая, -ое **1.** кырлы; **~ стака́н** кырлы стакан **2.** кырланган, кырлап ясалган; **~ хруста́ль** кырлап ясалган хрусталь

грани́льн||ый, -ая, -ое кырлый торган; **~ая мастерска́я** кырлый торган остаханә

грани́льщик *м* кырлаучы, кырлаучы оста

грани́т *м* гранит

грани́тн||ый, -ая, -ое гранит ...ы; гранит...; **~ая глы́ба** зур гранит таш

гранито́ль *м* гранитоль (*ясалма кун*)

грани́тчик *м* гранитчы, гранит эшкәртүче

грани́ть *несов. что* кырлау (*ташны, пыяланы*)

грани́ц||а *ж* чик ◆ **вы́йти из грани́ц** чиктән чыгу, чиктән ашу; **за ~у** чит илләргә; **за ~ей** чит илләрдә; **из-за ~ы** чит илләрдән

грани́ч||ить *несов. с чем* **1.** (*иметь общую границу*) чиктәш булу, янәшә булу, чикләшү **2.** *перен.* якын тору, бер булу; **тру́сость в бою́ ~ит с преда́тельством** сугышта куркаклык хыянәт итү белән бер

гра́нка *ж полигр.* гранка (*типографиядә битләргә салынмыйча гына җыелган набор һәм шул наборның кәгазьдәге күчермәсе*)

гранули́ровать *сов., несов. что* ваклау, грануляцияләү, бөртекләндерү

грануля́ция *ж* грануляция (**1.** *яра урынына ит үсү* **2.** *кояш өстенең бөрчек-бөрчек булып куренүе* **3.** *бөртекләндерү, бөртекләргә әверелдерү, вакълау*)

гра́н||ь *ж* **1.** кыр; **~и ку́ба** кубның кырлары **2.** *перен.* аерма; **стира́ние ~ей ме́жду физи́ческим и у́мственным трудо́м** физик һәм акыл хезмәте арасындагы аерманың бетә баруы ◆ **на ~и** соңгы чик; **на ~и безу́мия** акылдан язу хәлендә; **на ~и войны́** сугыш куркынычы килеп туу

грасси́ровать *несов. книжн.* «р» авазын сакау итеп әйтү

граф *м* граф

графá *ж* графа, багана (*кенәгәдә, таблицада ике сызык арасы*)

гра́фик I *м* график (**1.** *төрле процессларның үсешен күрсәтә торган диаграмма* **2.** *утәлү вакыты һәм нормасы күрсәтелгән план*)

гра́фик II *м* график (*рәссам*)

гра́фика *ж* графика (**1.** *сызыклар һәм штрихлар белән генә рәсем ясау сәнгате* **2.** *хәрефләрнең язылу рәвеше*)

графúн *м* графин

графúня *ж* графиня

графúт *м* **1.** *мин.* графит, графит ташы, кара таш **2.** (*стержень внутри карандаша*) графит, карандаш үзәге

графúтн||ый, -ая, -ое графит ...ы; графиттан ясалган, графит ...; **~ые изде́лия** графиттан ясалган әйберләр

графúтов||ый, -ая, -ое *см.* **графúтный**; **~ые месторожде́ния** графит чыганаклары

графúть *несов. что* графалау, графалар сызу

графúческ||ий I, -ая, -ое графика ...ы; **~ое иску́сство** графика сәнгате

графúческий II, -ая, -ое график ...ы; график ...; график юл белән, график ярдәмендә ...; **~ ме́тод** график метод

графлён||ый, -ая, -ое графалы, сызыклы, юллы; **~ая бума́га** сызыклы кәгазь

графо́лог *м* графолог, графология белгече

графоло́гия *ж* графология (*кешенең язу рәвешенә карап характерын белергә маташу*)

графома́н *м* графоман, графомания белән авыручы

графома́ния *ж* графомания (*әдәби әсәрләр язу белән мавыгу авыруы*)

гра́фство *с* графлык (**1.** *графлык дәрәҗәсе* **2.** *административ-территориаль берәмлек, мәс. Англиядә, АКШта* **3.** *феодализм чорында граф билгән җирләр*)

грацио́зн||ый, -ая, -ое зифа буйлы, матур сынлы, нәзакәтле, грацияле; матур [йөрешле]; **~ые движе́ния** грацияле хәрәкәтләр; **~ая де́вушка** зифа буйлы кыз

гра́ция *ж* **1.** грация, матурлык; нәзакәтлелек (*хәрәкәт һәм буй-сынга карата әйтелә*) **2.** грация (*корсетның бер төре*)

грач *м* каракарга

грачúн||ый, -ая, -ое каракарга ...ы; **~ое гнездо́** каракарга оясы

гребёнка *ж* тарак

гре́б||ень *м* **1.** тарак; **ча́стый ~ень** еш тешле тарак **2.** *тех.* тарак; тәрәш тарагы **3.** (*у птиц*) кикрик **4.** (*верхний край чего-л.*) сырт **5.** *перен.* алдынгы саф; **на ~не наро́дного движе́ния** халык хәрәкәтенең алдынгы сафында

гребе́ц *м* ишкәкче, ишкәк ишүче

гребешо́к *м уменьш. от* **гре́бень** 1, 3, 4

гре́бля *ж см.* **грести́** I

гребн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*көймәдә*) ишү ...ы; **~о́й спорт** ишү спорты **2.** ишкәкле; **~о́е су́дно** ишкәкле судно **3.** ишә торган; **~о́е колесо́** ишә торган көпчәк

гребо́к *м* ишем (*ишкәк белән бер тапкыр ишеп кую*)

грёза *ж* хыял, татлы хыял; **де́вичьи грёзы** кызларның татлы хыяллары

гре́зить *несов.* **1.** татлы хыялга чуму, хыяллану **2.** (*видеть во сне*) төшләну

гре́зиться *несов.* **1.** хыялга килү, күз алдына килү **2.** (*сниться*) төшкә керү

гре́йдер *м* грейдер (*юл тигезләгеч машина*)

грек *м* грек, грек кешесе

гре́ки *мн.* греклар, грек халкы

гре́лка *ж* грелка, җылыткыч

грем||е́ть *несов.* **1.** күкрәү, күк күкрәү (*күкрәү турында*); яңгырау (*музыка турында*); гөрелдәү, гөрселдәү; шартлау (*ату тавышы турында*); шалтырату, чалтыр-чолтыр китерү (*тимер-томыр әйберләр турында*); дөбердәү, дыңгырдау (*мәс. арба турында*); шаулау, ишетелеп тору (*тавыш турында*); шалтырау (*кыңгырау турында*); **гром ~и́т** күк күкри; **~е́ть посу́дой** савыт-саба шалтырату **2.** *перен.* (*славиться*) таралу, шаулау

грему́ч||ий, -ая, -ее: **~ий газ** *хим.* шартлагыч газ; **~ая змея́** *зоол.* шалтырак елан (*тропикларда яши торган агулы елан*); **~ая ртуть** шартлый торган терекөмеш

гре́на *ж собир.* грена (*ефәк күбәләге күкәйләре*)

гренадёр *м ист.* гренадер (*революциягә кадәрге Россиядә махсус полкта хезмәт итүче озын буйлы солдат яки офицер*)

гре́нк||и *мн.* кыздырылган икмәк кисәкләре; кәтермәч; **суп с ~а́ми** кыздырылган икмәк кисәкләре салынган шулпа

грести́ *несов.* **1.** *чем и без доп.* (*работать вёслами*) [ишкәк] ишү; **~ к бе́регу** ярга таба ишү **2.** *что* [тырма белән] җыю; тырмалау; көрәү, көрәп алу; **~ се́но** печән җыю ♦ **~ де́ньги лопа́той** акчаны көрәп алу

гре́ть *несов. кого-что и без. доп.* җылыту, кыздыру; **со́лнце гре́ет** кояш кыздыра; **шу́ба хорошо́ гре́ет** тун яхшы җылыта; **~ воду** су җылыту ♦ **~ ру́ки** бәю (*алдашып*)

гре́ться *несов.* җылыну, кызыну; **~ на со́лнце** кояшта кызыну; **вода́ гре́ется** су җылына

грех *м* **1.** *рел.* гөнаһ, язык **2.** *перен.* гөнаһ, гаеп, гаеплә эш; **~и́ мо́лодости** яшьлек гөнаһлары **3.** *в знач. сказ. разг.* ярамый, яхшы түгел; **над ста́ростью смея́ться ~** картлыктан көләргә ярамый ♦ **~ попу́тал** шайтан котыртты; **~ сказа́ть** әйтергә дә оят; **как на ~** бәхетсезлеккә каршы, гөнаһ шомлыгына каршы; **не ~** ярый, мөмкин; **от ~а́ пода́льше** бәладән баш-аяк; **с ~о́м попола́м** ничек итте алай, әштер-әштер генә, көчкә-көчкә генә, ничек җитте шулай

грехо́вн||ый, -ая, -ое *уст.* гөнаһлы; **~ые мы́сли** гөнаһлы уйлар

греховóдник *м разг. уст.* гөнаһлы кеше, бозык кеше; гөнаһ капчыгы

греховóдница *ж* гөнаһлы хатын (кыз), бозык хатын (кыз)

гре́цкий, -ая, -ое: **~ оре́х** Әстерхан чикләвеге, кузы

гречáнка *ж* грек хатыны (кызы)

гречи́ха *ж* карабодай

гречи́шный, -ая, -ое карабодай ...ы; **~ мёд** карабодай балы

гре́чнев||ый, -ая, -ое карабодай ...ы; **~ая ка́ша** карабодай боткасы

греши́ть *несов.* **1.** *рел.* гөнаһлану гөнаһ кылу (ясау, эшләү) **2.** *против чего* каршы бару, бозу; **~ про́тив и́стины** хакыйкатькә каршы бару

гре́шник *м* гөнаһлы кеше

гре́шница *ж* гөнаһлы хатын (кыз)

грешнó *в знач. сказ. с неопр., разг.* гөнаһ, оят, яхшы түгел

гре́шн||ый, -ая, -ое гөнаһлы, языклы, гаепле; **~ый челове́к** гөнаһлы кеше; **~ые по́мыслы** гөнаһлы уйлар ♦ **~ым де́лом** *в знач. вводн. сл.* үкенечкә каршы, гөнаһ шомлыгына каршы

гриб *м* гөмбә, мәшкә; **кра́сный ~** усак гөмбәсе; **бе́лый ~** ак гөмбә ♦ **расти́ как ~ы́ [по́сле дождя]** бик тиз һәм күп үсү, бик тиз үрчү

грибкóв||ый, -ая, -ое гөмбә ...ы; **~ая культу́ра** гөмбә культурасы; **~ое заболева́ние** гөмбә авыруы

грибни́к *м разг.* гөмбәче, гөмбә җыю һәвәскәре

грибни́ца *ж* **1.** *бот.* гөмбәлек (*гөмбә җепселләре*) **2.** (*теплица для грибов*) гөмбәлек, гөмбә үстерү урыны

грибн||о́й, -ая, -о́е **1.** гөмбәле; **~о́е ме́сто** гөмбәле урын **2.** гөмбә ...ы; **~о́й пиро́г** гөмбә бөккәне ♦ **~о́й дождь** кояшлы яңгыр

грибова́рный, -ая, -ое гөмбә кайнату ...ы; **~ пункт** гөмбә кайнату пунктты

грибова́рня *ж* гөмбә кайнату урыны (*гөмбә тоздау һәм маринадлау урыны*)

грибо́к *м* **1.** *уменьш. от* **гриб;** гөмбәчек **2.** гөмбәчек (*әчеткеч, череткеч, авыру тудыргыч микроблар*) **3.** (*для штопки*) калып (*оек ямаганда кулланыла торган гөмбә сыман калып*)

гри́ва *ж* ял; **льви́ная ~** арыслан ялы; **ко́нская ~** ат ялы

гри́венник *м разг.* ун тиен, ун тиенлек акча

гри́вна *ж ист.* (*денежная единица*) гривна (*борынгы Русьта акча берәмлеге*)

грилья́ж *м* грильяж (*шоколадлы конфетларның бер төре*)

грим *м* грим; **игра́ть в ~е** грим салып уйнау; **наложи́ть ~** грим салу

грима́са *ж* чырай бозу, чырай сыту, гримаса

грима́сничать *несов.* чырай сыту, чырай бозу, кылану, гримаса ясау

гримёр *м* гримлаучы, грим салучы

гримирова́ть *несов. кого-что* грим салу, гримлау

гримирова́ться *несов.* **1.** грим салу (*үзеңә*) **2.** *страд. от* **гримирова́ть**

грипп *м* грипп

гриппова́ть *несов. разг.* грипп белән авыру

гриппо́зн||ый, -ая, -ое грипп ...ы; грипплы, грипп белән...; **~ое заболева́ние** грипп авыруы; **~ый больно́й** грипплы авыру

гриф I *м зоол.* гриф (*ерткыч кош*)

гриф II *м муз.* гриф (*кыллы музыка коралларының кыл тартып куелган озын тар өлеше*)

гриф III *м* гриф (*китаплардагы һәм документлардагы махсус язу*); **кни́га с ~ом институ́та** институт грифы белән басылып чыккан китап

гри́фель *м* грифель (*аспид тактага язу өчен кулланыла торган таш карандаш*)

гроб *м* табут ♦ **в ~** *разг.* **гляде́ть** үлем алдында тору; **вогна́ть в ~** *кого* кабергә (гүргә) кертү; **стоя́ть одно́й ногой в ~у́** кабер якасында тору; бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә булу; **по ~ [жи́зни]** үлгәнче; гүргә кергәнче; **хоть в ~ ложи́сь** хет шартла

гробни́ца *ж* төрбә, бина сыман эшләнгән зиннәтле кабер

гробов||о́й, -ая, -о́е табут...ы ♦ **~о́е молча́ние** *или* **~а́я тишина́** кабер тынлыгы; **~о́й го́лос** ямьсез калын тавыш; **до ~о́й доски́** мәңгегә, үлгәнче, кабергә кергәнче

гробовщи́к *м* табут ясаучы, табутчы

грог *м* грог (*аракыга яки ромга шикәрле кайнар су катыштырып әзерләнгән эчемлек*)

гроза́ *ж* **1.** күк күкрәп яшен яшьнәү; яшенле яңгыр **2.** *перен.* (*то, что внушает страх*) дәһшәт, куркыныч

гроздь *ж* төлгәш, чук; **~ виногра́да** йөзем төлгәше

гроз||и́ть *несов.* **1.** *кому и без доп.* (*угрожать*) янау; куркыту, өркетү **2.** *кому-чему* (*делать угрожающий жест*) янау; **~и́ть па́льцем** бармак янау **3.** *чем* ...га тору, алдында тору, куркыныч тудыру, куркыныч алдында тору; **ему́ ~и́т смерть** ул үлем куркынычы алдында тора

грози́ться *несов. разг. см.* **грози́ть** 1, 2

гро́зн||ый, -ая, -ое **1.** (*суровый*) рәхимсез, кансыз, усал; **~ый взгляд** усал караш **2.** дәһшәтле, куркыныч; **~ая си́ла** дәһшәтле көч; **~ый час** куркыныч сәгать

грозов||о́й, -а́я, -о́е яшенле, яшенлеяңгырлы; **~ы́е облака́** яшенле болытлар; **~о́е ле́то** яшенле-яңгырлы җәй

гром *м* **1.** күкрәү, күк күкрәү; **раска́ты ~а** күк күкрәү тавышлары **2.** *перен.* дөбердәү, гөрселдәү, каты шартлау; **~ пу́шек** туплар гөрселдәве; **~ аплодисме́нтов** көчле кул чабулар ♦ **пока́ ~ не гря́нет** килеп терәлмичә

грома́д||а *ж* бик (гаять) зур әйбер (*корылма, таулар һ.б.ш.*); **~ы гор** бик зур таулар; **~ы корабле́й** гаять зур корабльләр

грома́дина *ж разг.* бик зур нәрсә

грома́дный, -ая, -ое бик (гаять) зур, бик дәү; **~ го́род** гаять зур шәһәр; **~ успе́х** бик зур уңыш

громи́л||а *м разг.* **1.** (*вор*) талаучы, карак (*йозак, ишек ватып кереп талаучы*) **2.** погромчы; **фаши́стские ~ы** фашист погромчылары

громи́ть *несов. кого-что* **1.** талау, җимерү **2.** *перен. разг.* (*обличать*) тетеп ташлау, тәмам фаш итү, тетмәсен тетү **3.** тар-мар итү; **~ вра́жеские войска́** дошман яуларын тар-мар итү

гро́мк||ий, -ая, -ое **1.** каты, кычкырып ..., яңгыравыклы; көчле; **~ий го́лос** каты тавыш; **~ий разгово́р** кычкырып сөйләшү **2.** *перен.* данлыклы, атаклы; шау-шулы, дөнья шаулаткан; **~ое и́мя** данлыклы исем; **~ий проце́сс** дөнья шаулаткан процесс **3.** *перен.* (*напыщенный*) кабарынкы, күперенке, буш; **~ие фра́зы** буш сүзләр

громкоговори́тель *м* репродуктор

громкоголо́сый, -ая, -ое каты тавышлы

громов||о́й, -а́я, -о́е **1.** күк күкрәү ...ы; **~ы́е раска́ты** күк күкрәү тавышлары **2.** *перен.* бик каты, көчле; **~о́й го́лос** көчле тавыш

громкогла́сн||ый, -ая, -ое каты тавыш белән ...; бөтен кеше ишетерлек ...; **~ое заявле́ние** бөтен кеше ишетерлек белдерү

громозди́ть *несов. что* **1.** өю, өстеөстенә өю; **~ я́щики** әрҗәләрне өю **2.** *перен.* тутыру, өсте-өстенә тутыру; **~ цита́ты** цитаталар белән тутыру

громозди́||ться *несов.* өелеп тору, берсе өстенә берсе өелеп тору; күпләп калкып тору; **вдали́ ~лись ска́лы** еракта кыялар күпләп калкып тора иде

громо́здк||ий, -ая, -ое зур һәм авыр; **~ие ве́щи** зур һәм авыр әйберләр

ГРО-ГРЫ

громоотво́д *м* яшен уздыргыч, яшен кайтаргыч.

громоподо́бный, -ая, -ое күк күкрәгәндәй, күк күкрәгән кебек, бик көчле; **~ го́лос** бик көчле тавыш

громыха́ние *с см.* **громыха́ть**

громыха́ть *несов. разг.* (*напр. о телеге*) дөбердәү, дыңгырдау, дөбер-дөбер килү, шалтыр-шолтыр килү; (*о громе*) күк күкрәү, дөбердәү

громыхну́ть *сов. однокр.* дыңгырдап кую, гөрселдәп кую; дөбердәп кую

гроссме́йстер *м* гроссмейстер

гроссме́йстерск||ий, -ая, -ое гроссмейстер...ы; гроссмейстерлык ...ы; **~ое зва́ние** гроссмейстер исеме; **~ий балл** гроссмейстерлык баллы

грот *м* тау куышы, мәгарә

гроте́ск *м* гротеск (*әкәмәт- фантастик һәм көлке стильдә язылган сәнгать әсәре*)

гроте́скный, -ая, -ое гротеск...ы; **~ сти́ль** гротеск стиле

гроте́сков||ый, -ая, -ое гротесклы, көлкеле; **~ая роль** көлке роль

гро́хать *несов. см.* **гро́хнуть**

гро́хнуть *сов.* **1.** *разг. кого-что* шап иттереп ташлау, гөрс иттереп ыргыту, шап иттереп төшерү; дөп иттереп кую; **~ вязáнку дров нá пол** утын бәйләмен дөп иттереп идәнгә кую **2.** *разг.* (*издать грохот*) шарт итү, гөрс итү; гөрселдәү **3.** *прост.* (*громко рассмеяться*) пырхылдап җибәрү, кинәт кычкырып көлеп җибәрү; **~ со́ смеху** кинәт кычкырып көлеп җибәрү

гро́хнуться *сов. разг.* шап итеп егылу, шап итеп егылып төшү; гөрселдәп барып төшү

гро́хот I *м* гөрселдәү, гөрелдәү, дөбердәү; **~ пу́шек** туплар гөрселдәве

гро́хот II *м тех.* эре иләк (*орлык, ком, вак таш, руда иләүдә кулланыла*)

грохота́нье *с см.* **грохота́ть**

грохота́ть *несов.* күк күкрәү; дөбердәү; **гром грохо́чет** күк күкри

грош *м* **1.** *уст.* ярты тиен (*акча*) **2.** *обычно мн.* **~и́** бик арзан бәя; бик арзан акча; **прода́ть за ~и́** бик арзан бәягә сату **3.** грош (*Австриядә һәм Польшада бер тиен акча*) ♦ **~á ме́дного (ло́маного) не сто́ит** сукыр бер тиен дә тормый; **~ цена́** поты бер тиен; **ни в ~ не ста́вить** *кого-что* санга санамау, бернигә дә санамау, бар дип тә белмәү

грошо́в||ый, -ая, -ое **1.** бик арзан, бик арзанлы; **~ая цена́** бик арзан бәя **2.** *перен.* вак-төяк; **~ые расчёты** вак-төяк исәп-хисаплар

грубе́||ть *несов.* **1.** (*о голосе*) тупаслану, дорфалану **2.** кытыршылану; **ко́жа ~ет** тире кытыршылана

груби́ть *несов. кому* начар (әшәке, тупас) сүзләр әйтү

грубия́н *м разг.* гөрбиян, тупас (дорфа) кеше, каты бәрелүчән

грубия́нка *ж разг.* дорфа (тупас) хатын (кыз)

грубия́нить *несов. разг.* тупаслык эшләү, әдәпсезлек күрсәтү

гру́бост||ь *ж* **1.** тупаслык, дорфалык; **~ь обраще́ния** мөгамәләдәге тупаслык **2.** тупас сүзләр, тупас мөгамәлә; тупаслык; **говори́ть ~и** тупас сүзләр әйтү; **допусти́ть ~ь в игре́** *спорт.* уенда тупаслыклар җибәрү

грубошёрстный, -ая, -ое (*об овце*) тупас йонлы (*сарык хакында*); (*о ткани*) тупас йоннан эшләнгән (*тукыма хакында*)

гру́б||ый, -ая, -ое **1.** (*плохо отделанный*) тупас; **~ая о́бувь** тупас аяк киеме **2.** (*жесткий*) каты, тупас, кытыршы; **~ая ко́жа** тупас күн **3.** *перен.* (*недостаточно искусный*) тупас; **~ая рабо́та** тупас эш **4.** (*о голосе*) тупас, калын **5.** (*нетактичный*) тупас, дорфа, тәрбиясез; **~ый челове́к** дорфа кеше; **~ый отве́т** тупас җавап **6.** (*недопустимый*) тупас; **~ая оши́бка** тупас хата ♦ **~ая пи́ща** тупас ашамлык; **~ые корма́** *с.-х.* тупас азык (*салам, печән һ.б.ш.*)

гру́да *ж* [зур] өем, күч; **~ камне́й** таш өеме; **~ книг** күп китаплар өеме, өем-өем китаплар

груда́стый, -ая, -ое *прост.* кин күкрәкле; калку күкрәкле

груди́на *ж* **1.** *анат.* түш (күкрәк) сөяге **2.** *см.* **груди́нка**

груди́нка *ж* түш ите

груди́: за ~ [взять, схвати́ть, трясти́] *кого, прост.* якасыннан эләктереп алу, якасына ябышу (*сугыша башлау*)

грудни́ца *ж разг.* имчәк шешү

грудн||о́й, -áя, -óе **1.** *анат.* күкрәк ...ы; **~áя кле́тка** күкрәк читлеге **2.** имчәк ...ы; **~о́й ребёнок** имчәк баласы ♦ **~о́й го́лос** күкрәктән чыккан тавыш

грудобрю́шн||ый, -ая, -ое: **~ая прегра́да** *анат.* күкрәк-корсак пәрдәсе, түш ярысы, диафрагма

груд||ь *ж* **1.** күкрәк, түш; **широ́кая ~ь** киң күкрәк **2.** имчәк, түш (*хатын-кызларда*); **корми́ть ~ью** имезү; **отня́ть от ~и́** имчәктән аеру **3.** (*у платья, рубашки*) күкрәкчә; **вы́шитая ~ь** чигелгән күкрәкчә ♦ **стоя́ть (встать) ~ью** күкрәк киерсп каршы тору, яклау

гружёный, -ая, -ое йөкле, йөк төялгән; **~ вагóн** йөк төялгән вагон

груз *м* **1.** авырлык, авыр нәрсә **2.** йөк; **вагóн с ~ом** йөк төялгән вагон

груздь *м* гөрәждә

грузи́ло *с рыб.* батыргыч

грузи́н *м* грузин, грузин кешесе

грузи́нка *ж* грузин хатыны (кызы)

грузи́нский, -ая, -ое грузин[нар] ...ы; **~ язы́к** грузин теле

грузи́ны *мн.* грузиннар, грузин халкы

грузи́ть *несов. кого-что* төяү; **~ ба́ржу дрова́ми** баржага утын төяү; **~ скот в вагóны** вагоннарга терлек төяү

грузи́ться *несов.* төяну, төялү; **~ на парохо́д** пароходка төялү

грузне́ть *несов. разг.* авыраю; **к ста́рости он на́чал ~** картая башлагач авырая төште

гру́зный, -ая, -ое (*о человеке*) авыр сөякле, авыр гәүдәле

грузови́к *м* йөк автомобиле

грузовладе́лец *м* йөк хуҗасы

грузово́й, -áя, -óе йөк ...ы; **~ тра́нспорт** йөк транспорты

грузооборо́т *м* йөк әйләнеше

грузоотправи́тель *м* йөк җибәрүче, йөк җибәреп торучы

грузоподъёмность *ж* йөк күтәрүчәнлек, авырлык күтәрә алу дәрәҗәсе (*мәс. күтәру кранының*)

грузоподъёмный, -ая, -ое йөк күтәрү ...ы; **~ кран** йөк күтәрү краны

грузополуча́тель *м* йөк алучы (*кеше яки учреждение*)

грузопото́к *м* йөкләр хәрәкәте (*йөкләрнең юлда булуы*)

гру́зчик *м* йөкче

грунт *м* **1.** туфрак, җир; **песча́ный ~** комлы туфрак **2.** (*твёрдое дно*) су төбе **3.** *жив.* җирлек, грунт (*агачка яки киндергә беренче кат буяган ак буяу*) **4.** *жив.* штрихланган фон (*рәсемдә*)

грунтова́ть *несов. что жив.* грунтлау, җирлек салу (*рәсем ясаласы яки буяласы әйберне беренче кат буяп чыгу*)

грунто́вка *ж* **1.** *см.* **грунтова́ть; 2.** *жив.* грунтовка, грунт җирлек (*рәссамчылыкта*)

грунтов||о́й, -áя, -óе **1.** грунт ...ы; җир асты ...ы; җир астыннан чыга торган; **~ы́е во́ды** җир асты сулары **2.** *жив.* грунт ...ы; **~ы́е кра́ски** җирлек буяулары ♦ **~áя доро́га** арба юлы (*таш түшәлмәгән юл*)

гру́ппа *ж* төркем, группа; **~ уча́щихся** укучылар төркеме

группирова́ть *несов. кого-что* төркемләү, группаларга аеру

группирова́ться *несов.* **1.** группаларга оешу (җыелу, туплану) **2.** *страд. от* **группирова́ть**

группиро́вка *ж* **1.** *см.* **группиро́вать, группирова́ться; ~ фа́ктов** фактларны төркемләү **2.** группа, оешма, берләшмә

группов||о́й, -áя, -óе төркем ...ы, төркем [группа] белән ...ган; төркем белән ...а торган; группа ...ы; **~о́й сни́мок** төркем белән төшкән рәсем; **~ы́е заня́тия** группа белән үткәрелә торган дәресләр

групповщи́н||а *ж неодобр.* группачылык, төркемчелек; **борьба́ с ~ой** группачылыкка каршы көрәш

грусти́ть *несов.* ямансылау, сагыну, юксыну, күңелсезләну

гру́стно *нареч.* **1.** күңелсез, моңсу, ямансу; **~ смотре́ть** моңсу гына карау **2.** *в знач. сказ. безл.* күңелсез, моңсу, ямансу; **мне ста́ло ~** миңа ямансу булып китте

гру́ст||ный, -ая, -ое күңелсез, кайгылы, ямансу, моңсу; **~ый взгляд** моңсу караш; **~ый ито́г** күңелсез нәтиҗә; **~ые мы́сли** күңелсез уйлар

груст||ь *ж* кайгы, сагыш, хәсрәт; **предава́ться ~и** кайгыга сабышу

гру́ша *ж* груша, армут (*агачы һәм җимеше*)

грушеви́дный, -ая, -ое грушасыман, груша рәвешендәге

гру́шев||ый, -ая, -ое груша ...ы, армут ...ы; **~ое де́рево** груша агачы; **~ое варе́нье** груша кайнатмасы

гры́жа *ж мед.* бүсер

гры́зло *с спец.* авызлык (*йөгәндә*)

грызня́ *ж разг.* **1.** (*драка между животными*) тешләшү, талашу **2.** *перен.* (*склока*) ачуланышу; сүгеш, ызгыш, талаш

грызть *несов.* **1.** *что* кимерү; ватып ашау; ~ **кость** сөяк кимерү; ~ **оре́хи** чикләвек ватып ашау; ~ **се́мечки** көнбагыш яру **2.** *перен. кого, разг.* чәйнәү, талау, колак итен ашау (*тиргәп тору мәгънәсендә*)

грыз||ться *несов.* **1.** тешләшү, талашу; **соба́ки** ~ **у́тся** этләр талаша **2.** *перен. прост.* (*ссориться*) тиргәшү, талашу, әрләшү

грызу́н *м зоол.* кимерүче (*тиен, күсе, тычкан, йомран һ.б.ш.*)

гряда́ *ж* **1.** (*ряд холмов*) таулар тезмәсе; ташлар тезмәсе (*су астындагы*) **2.** (*в огороде*) түтәл **3.** өем, төркем; ~ **облако́в** болытлар өеме

гря́дка *ж см.* **гряда́** 2

гряду́щ||ий, -ая, -ее киләчәк, якынлашып килә торган; ~**ие поколе́ния** киләчәк буыннар

грязев||о́й, -а́я, -о́е ләм ...ы; ~**ые исто́чники** ләм чыганаклары

грязелече́бница *ж* ләм белән дәвалау учреждениесе (бинасы)

грязелече́ние *с* ләм белән дәвалау (дәвалану)

гря́зи *только мн.* **1.** (*лечебное средство*) ләм (*дәвалау өчен яраклы күл яки диңгез ләме*) **2.** (*место*) ләм белән дәвалау урыны; **пое́хать на** ~ ләм белән дәваланырга бару

грязне́ть *несов.* пычрану, керләнү, каралу

грязни́ть *несов.* **1.** *кого-что* пычрату, буяу, керләндерү, тап төшерү, каралту; ~ **помеще́ние** бүлмәне пычрату **2.** чүпләү; ~ **в ко́мнатах** бүлмәләрне чүпләү

грязни́ться *несов.* пычрану, буялу, керләнү, каралу

гря́зно *нареч.* **1.** пычрак, шапшак, әшәке; ~ **писа́ть** пычрак язу **2.** *в знач. сказ. безл.* пычрак; **на у́лице** ~ урамда пычрак

грязну́ля *м, ж разг.* пычрак, шапшак, шакшы

гря́зн||ый -ая, -ое **1.** пычрак, быкырдык, әшәке; ~**ый двор** пычрак ишегалды; ~**ый пол** шапшак идән **2.** пычрак, буялган, пычранган, керләнгән, каралган; ~**ые ру́ки** пычрак куллар **3.** (*о цвете*) соргылт-тоныксу **4.** *перен.* әшәке, бозык, нәҗес; ~**ая ли́чность** бозык кеше; ~**ый анекдо́т** әшәке мәзәк ◆ ~**ое ведро́** чүп чиләге

гряз||ь *ж* **1.** пычрак, баткак, быкырдык; **на у́лице** ~**ь** урамда пычрак **2.** (*на теле, белье*) кер **3.** (*нечистота*) пычрак, чүп-чар **4.** *перен.* (*безнравственность, бесчестность*) пычраклык, әшәкелек ◆ **обли́ть** ~**ью** *или* **смеша́ть с** ~**ью, втопта́ть в** ~**ь** *кого* пычрату, яла ягу, хур итү, адәм мәсхәрәсе итү

гря́н||уть *сов.* **1.** гөрселдәү, гөреләдән китү; күкрәп алу; яңгырау, яңгырап китү; ~**ул гром** күк күкрәде **2.** *что и без доп.* уйный башлау; **музыка́нты** ~**ули марш** музыкантлар марш уйный башладылар **3.** *перен. высок.* башлану, башланып китү; ~**ула война́** сугыш башланып китте

гуа́но *с нескл.* гуано (*кыргый кошларның тизәге-ашлама итеп файдаланыла*)

гуа́шь *ж* гуашь (**1.** *утә күренми торган акварель буяу* **2.** *шундый буяу белән ясалган рәсем*)

губ||а́ I *ж* **1.** ирен; **за́йчья** ~**а́** *мед.* китек ирен **2.** *мн.* **гу́бы** *спец.* борын (*келәшчәдә, кыскычта*) ◆ **губа́ не ду́ра** *у кого, прост.* борыны ис сизә; **куса́ть гу́бы** ирен тешләү (*ачу белдерү, ризасызлык күрсәтү*)

губа́ II *ж геогр.* култык; **О́бская** ~ Обь култыгы

губа́стый, -ая, -ое *разг.* калын иренле

губерна́тор *м* губернатор

губерна́торск||ий, -ая, -ое губернатор ...ы; ~**ая до́лжность** губернатор вазифасы ◆ **положе́ние ху́же** ~**ого** *шутл.* эшләр шәптән түгел, эшләр хәрти, бик мәшкел, хәл бик начар

губерна́торство *с* губернаторлык; губернаторлык вазифасы

губе́рния *ж ист.* губерна ◆ **пошла́ писа́ть** ~ *шутл.* ыгы-зыгы башланды, ду купты

губи́тель *м* һәлак итүче, харап итүче

губи́тельница *ж см.* **губи́тель**

губи́тельный, -ая, -ое һәлакәтле, һәлакәткә китерә торган, һәлак (харап) иткеч, җимергеч; зарарлы, зарар китерә торган; ~ **для здоро́вья** сәламәтлеккә зарарлы

губи́ть *несов. кого-что* һәлак (харап) итү; ~ **посе́вы** чәчүлекләрне һәлак итү; ~ **здоро́вье** сәламәтлекне харап итү

гу́бк||а I *ж уменьш.-ласк. от* **губа́** I 1; ~ **ба́нтиком** уймак ирен

гу́бка II *ж* губка, болыт (**1.** *суда бер урынга береген яши торган тереклек иясе* **2.** *шуның гәүдәсеннән яки шуңа охшатып ясалган мунчала*)

губошлёп *м прост.* **1.** (*с отвислыми губами*) салпы ирен, бәлеш авыз **2.** (*растяпа*) мәми авыз, булдыксыз, уҗым бозавы

гу́бчатый, -ая, -ое вак-вак (күз-күз) тишекле, көпшәк

гувернáнтка *ж* гувернантка

гувернёр *м* гувернёр

гугено́ты *мн.* гугенотлар (*16-18 йөзләрдә француз протестантлары*)

гугу́: ни ~ *в знач. сказ. разг.* 1) (*молчит*) дәшми, тынын да чыгармый, бер сүз дә әйтми; 2) (*просьба молчать*) дәшмә, тыныңны да чыгарма, авызыңны да ачасы булма, ләм-мим сүз әйтмә, май кап

гуде́ние *с см.* **гуде́ть**

гуд||е́ть *несов.* **1.** гүләү, гөрелдәү, ыжгыру, гүелдәү (*чебен, коңгыз һ. б. ш. турында*); уылдау, улау, жуылдау, шаулау, шаулап тору; жу-у-у итеп тору; кычкыру, кычкырту (*машиналар, гудоклар турында*); **ве́тер** ~**и́т в трубе́** торбада җил улый; **в уша́х** ~**и́т** колак шаулый; **гудо́к** ~**и́т** гудок кычкырта **2.** сызлау; **но́ги** ~**я́т** аяклар сызлый

гудо́к *м* гудок; кычкырту; ~ **парохо́да** пароход гудогы

гудро́н *м* гудрон (*ташкүмер сумаласыннан яки нефть калдыкларыннан кайнатып чыгарыла торган кара масса*)

гудрони́ровать *сов., несов. что* гудронлау, гудрон каплату, гудрон белән каплау; ~ **шоссе́** шоссены гудрон белән каплау

гуж *м* (*петля у хомута*) камыт бавы

гужево́й, -а́я, -о́е **1.** камыт бавы ...ы; ~ **реме́нь** камыт бавы **2.** жигүле; ~ **тра́нспорт** жигүле транспорт

гужо́м *нареч.* ат белән; **перево́зка** ~ ат белән ташу

гул *м* шау, гөрелдәү (гүелдәү) тавышы, гөрелте; ~ **мо́ря** диңгез шавы

гу́лк||ий, -ая, -ое яңгыравыклы, яңгыраулы; ачык ишетелгән; ~**ие шаги́** ачык ишетелгән аяк тавышлары

гульба́ *ж прост.* типтерү, типтереп күңел ачу

гу́льден *м* гульден (*Нидерландиядә акча берәмлеге*)

гу́лькин: с ~ **нос** *прост.* бик аз, чебен чукындырырлык кына

гуля́ка *м, ж разг.* типтерүче, типтерергә яратучы

гуля́нка *ж прост.* күңел ачу мәҗлесе

гуля́нье *с* **1.** *см.* **гуля́ть** I; **2.** (*массовое празднество*) күмәк күңел ачу

гуля́||ть *несов.* **1.** (*совершать прогулку*) йөрү, саф һавада йөрү **2.** *разг.* (*иметь выходной*) эштән бушап тору, ял итү **3.** *прост.* күңел ачу; типтерү, әйттерү; ~**ть на сва́дьбе** туйда әйттерү **4.** *с кем, прост.* йөрү, йөрешү (*кыз белән егет турында*) ◆ **ве́тер** ~**ет** җил уйный

гуля́ш *м кул.* гуляш

гумани́зм *м* **1.** *ист.* гуманизм (*Яңарыш чорында кешеләрне һәм аларның фикерен феодализм һәм католицизм богауларыннан азат итүгә юнәлдерелгән хәрәкәт*) **2.** гуманизм, кешелеклелек; **по́длипный** ~ чын кешелеклелек

гумани́ст *м* **1.** *ист.* гуманист, гуманизм тарафдары **2.** гуманист, кеше сөюче, кешелекле кеше

гуманисти́ческ||ий, -ая, -ое гуманистик, гуманизм ...ы; в ~**их це́лях** гуманистик максатларны күздә тотып

гуманита́рн||ый, -ая, -ое гуманитар, ижтимагый; ~**ые нау́ки** гуманитар фәннәр (*философия, тарих, филология һ.б.ш.*)

гума́нный, -ая, -ое гуманлы, кешелекле, шәфкатьле

гумно́ *с* ындыр, ындыр табагы

гундо́сый, -ая, -ое *прост. см.* **гнуса́вый**

гу́нны *мн.* һуннар (*безнең эра башында Европага үтеп кергән борынгы төрки кабиләләр*)

гу́рия *ж миф.* хур кызы

гурма́н *м* гурман, тәмле (татлы) тамак (*тәмле-татлы ашамлыклар яратучы*)

гурма́нство *с* гурманлык, тәмле (татлы) тамак булу

гурт *м* көтү; ~ **ове́ц** сарык көтүе

гуртовщи́к *м* көтү йөртүче, көтү куучы, көтүче

гурто́м *нареч. разг.* көтүе белән; җыйнаулашып, барысы бергә

гурьба́ *ж разг.* төркем, көтү (*кешеләр турында*)

гурьбо́й *нареч. разг.* өелеп, җыелышып, барысы бергә, бергәләшеп; **идти́** ~ җыелышып бару

гусак *м* ата каз

гуса́р *м* гусар (*революциягә кадәрге Россиядә: җиңел кавалериядә хезмәт итүче гаскәри*)

гу́сеница *ж* **1.** (*личинка бабочки*) корт, күбәләк корты **2.** *тех.* гусеница, тәгәрмәч чылбыры (*трактордә, танкта һ.б.ш.*)

гу́сеничный, -ая, -ое чылбырлы; ~ **тра́ктор** чылбырлы трактор

гусёнок *м* каз бәбкәсе

гуси́н||ый, -ая, -ое каз ...ы; ~**ое перо́** каз каурые ♦ ~**ая ко́жа** каз тиресе (тәне), төерчекләр (*тәндә*)

гу́сли *только мн.* гөслә (*ике кул белән уйный торган кыллы музыка коралы*)

гусля́р *м* гөсләче, гөслә дә уйнаучы; гөслә дә уйнап җырлаучы

густе́||ть *несов.* **1.** куеру; **ка́ша** ~**ет** ботка куера **2.** куелану, куелана бару; **лес** ~**ет** урман куелана бара

гу́сто *нареч.* **1.** куе, куе булып; **трава́ растёт** ~ үлән куе булып үсә **2.** каты, каты итеп; ~ **замеси́ть те́сто** камырны каты итеп басу ♦ **то** ~**, то пу́сто** *погов.* бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй

густо́й, -а́я, -о́е **1.** куе (*мәс. чәч турында*) **2.** (*не жидкий*) куе, каты, тыгыз **3.** калын; ~ **бас** калын тавыш

густопсо́вый, -ая, -ое (*о борзых собаках*) муены куе йонлы

гусы́ня *ж* ана каз

гус||ь *м* каз ♦ **как с** ~**я вода́** *кому* колагына да элми

гусько́м *нареч.* бер-бер артлы тезелешеп, аллы-артлы

гуся́тина *ж* каз ите

гуся́тник *м* **1.** (*помещение*) казлар кетәге (абзары) **2.** (*ястреб*) каз карчыгасы

гуся́тница *ж* **1.** казлар караучы **2.** (*посуда*) озынча тирән металл савыт (*казны, үрдәкне тоташ пешерү өчен*)

гуталин *м* гуталин (*итек мае*)

гуттапе́рча *ж* гуттаперча (*каучукка охшаган матдә*)

гуттапе́рчевый, -ая, -ое гуттаперча ...ы; гуттаперчадан ясалган

гу́ща||а *ж* **1.** куелык; куесы; **кофе́йная** ~**а** кофе куесы **2.** куелык, чытырманлык; ~**а ле́са** урман куелыгы **3.** урта, ара, эч; **в** ~**е толпы́** халык төркеме эчендә; **в** ~**е собы́тий** буталчык вакыйгалар эчендә

гряу́р *м презр.* кяфер

Д

да I *частица* **1.** *утв.* әйе, шулай; **отвеча́й пря́мо: да и́ли нет?** дөресен әйт: шулаймы, түгелме? **2.** *вопр.* шулаймыни, алаймыни, шулаймы, әйеме; **всё обошло́сь благополу́чно, да?** барысы да уңышлы тәмамланды, шулаймы? **3.** (*вот ещё, кстати*) әй; **да, я ведь до́лжен идти́** әй, миңа барырга кирәк бит **4.** әйе, дөрестән дә; **да, хоро́шее вре́мя тепе́рь** әйе, хәзер заманалар яхшырды **5.** *разг.* бит, ич, инде; **куда́ идти́? — Да пря́мо!** кая барырга? — Турыга бит инде! **6.** (*при отклике на вопрос*) нәрсә, ә; **Ива́н Ива́нович! — Да? Что хоти́те?** Иван Иванович! — Ә? Ни кирәк? **7.** *высок.* ...сын; **Да здра́вствует дру́жба наро́дов!** Яшәсен халыклар дуслыгы! ♦ **вот это да!** менә монысы шәп, менә сиңа мә; әйбер дисәң дә әйбер!; **ну да** 1) әлбәттә; **ты е́дешь? — Ну да!** син барасыңмы? — Әлбәттә!; 2) шулаймыни?, китсәнә?; **он без тебя́ скуча́ет. — Ну, да?** ул сине сагына. — Китсәнә?

да II *союз* **1.** *соед.* да, һәм; **он да я** ул да мин **2.** *присоед.* өстәвенә, тагын, шуның өстенә, җитмәсә тагын; **я купи́л кни́гу, да ещё каку́ю интере́сную** мин китап сатып алдым, җитмәсә тагын нинди кызыклысын **3.** *против.* ләкин, әмма, да; **мал золотни́к, да до́рог** *погов.* кечкенә булса да төш кенә

да́бы *союз уст.* өчен; **подогна́ть ло́дку бли́же к бе́регу,** ~ **дать возмо́жность вы́садиться** төшәргә мөмкинлек бирү өчен көймәне мөмкин кадәр ярга якынрак китерү

дав||а́ть *несов. см.* **дать** 1-4, 6-11 ♦ ~**а́й[те]** *повел. разг.* әйдә, әйдәгез, ягез, ягез(я) әле; ~**а́й пообе́даем** әйдәгез, төшке ашны ашап алыйк; ~**а́й** башлады, тотынды; **она́** ~**а́й пла́кать** еларга тотынмасынмы; ~**а́й уходи́** әйдә кит моннан; **вот (во) даёт!** әнә нишләтә!

дава́ться *несов.* **1.** *см.* **да́ться**; **2.** *страд. от* **дава́ть**

да́веча *нареч. прост.* бая, баягынак, күптән түгел генә

да́вешний, -ая, -ее *прост.* баягы, әлеге; ~ **слу́чай** баягы вакыйга

дави́льный, -ая, -ое изә (сыга, сыта) торган; ~ **пресс** сыга торган пресс

дави́ть *несов.* **1.** *на кого-что* басу; басым ясау; **снег да́вит на кры́шу** кар түбәне баса **2.** *что* кысу; **сапо́г да́вит но́гу** итек аякны кыса **3.** *перен. кого-что* кысу, ирек бирмәү; ~ **инициати́ву** инициативаны кысу **4.** *что* сыгу; ~ **лимо́н** лимонны сыгу **5.** *кого-что* буу, буып үтерү; **лиса́ да́вит кур** төлке тавыкларны буып үтерә **6.** *кого-что* (*калечить, убивать*) тапта[т]у, имгәтү, таптап үтерү **7.** *перен. кого-что* кысу, изү; **тоска́ да́вит** кайгы изә **8.** *безл. что* (*о чувстве боли*) кысу, кысылу; **мне да́вит грудь** минем күкрәгем кыса

дави́ться *несов.* **1.** *чем* төелү, тыгылу, кадалу; тамакка утыру; ~ **ко́стью** тамакка сөяк кадалу **2.** *перен. чем* буылу (*йөткерүдән, көлүдән*) **3.** *прост.* кысылу; ~ **в авто́бусе** автобуста кысылу

да́вка *ж разг.* этешү, кысышу, этештөртеш; ~ **у вхо́да** ишек янында этештөртеш

давле́ние *с* **1.** *см.* **дави́ть** 1, 2, 3; **2.** басым; ~ **воды́** су басымы; **кровяно́е** ~ кан басымы; **прове́рить** ~ **у больно́го** авыруның кан басымын үлчәү **3.** басым ясау, кысым ясау, кысу; **ока́зывать** ~ *на кого-л. кемгә булса да* басым ясау

да́влен||ый, -ая, -ое *разг.* изелгән, сытылган, яньчелгән; ~**ые помидо́ры** изелгән помидорлар

да́вний, -ая, -ее **1.** күптәнге, әллә кайчангы; ~ **слу́чай** күптәнге вакыйга **2.** күптәнге, иске; ~ **друг** иске дус

давни́шний, -яя, -ее *разг. см.* **да́вний**

давно́ *нареч.* күптән, әллә кайчан; күптәннән бирле; **он** ~ **возврати́лся** ул әллә кайчан кайтты инде; **он** ~ **здесь живёт** ул күптәннән биредә яши ♦ ~ **бы так** күптән шулай кирәк иде

давнопроше́дш||ий, -ая, -ое күптән үтеп киткән, күптән булган; әллә кайчангы, бик борынгы заманнардагы ♦ ~**ее вре́мя** *грам.* күптән үткән заман

да́вность *ж* **1.** күптән булу, ... элек булу; ~ **собы́тия** вакыйганың күптән булуы **2.** күптәнлек, озаклык; ~ **дру́жбы** дуслыкның озаклыгы **3.** *юр.* срок; **исково́я** ~ дәгъваның срогы ♦ **за** ~**ю лет** еллар узып срок чыкканлыктан

давны́м-давно́ *нареч. разг.* әллә кайчан инде, бик күптәннән, хан заманында

дагеста́нец *м* дагстанлы

дагеста́нка *ж* дагстанлы хатын (кыз)

дагеста́нск||ий, -ая, -ое дагстан ...ы; Дагстан ...ы; ~**ие обы́чаи** дагстан гореф-гадәтләре; ~**ие языки́** Дагстан телләре

дагеста́нцы *мн.* дагстанлылар, Дагстан халкы

да́же *частица усил.* **1.** хәтта ...да; ~ **он придёт** хәтта ул да киләчәк **2.** *в знач. союза* хәтта; **днём бы́ло о́чень тепло́,** ~ **жа́рко** көн бик җылы, хәтта эссе булды

дактилоскопи́я *ж* дактилоскопия (*бармак бите сырларына карап шәхесне билгеләү, эзләп табу ысулы*)

да́ктиль *м лит.* дактиль (*басымы беренче иҗеккә төшә торган өч иҗекле шигырь буыны*)

дала́й-ла́ма *м* далай-лама (*Тибетның иң югары идарә итүчесе һәм дин башлыгы*)

да́лее *нареч. см.* **да́льше** 2-3; ~ **приступи́м к изуче́нию вопро́са** аннан соң мәсьәләне тикшерергә керешербез ♦ **и так** ~ **(и т.д.)** һәм башка шундыйлар (*һ.б.ш.*); **не** ~ **как ... (чем ...)** 1) әле ... генә; **не** ~ **как вчера́** әле кичә генә; 2) ...да калмыйча, кичекмичә; **не** ~ **как за́втра** иртәгәдән дә калмыйча

далёк||ий, -ая, -ое **1.** ерак; ~**ий путь** ерак юл **2.** (*отделённый большим промежутком времени*) ерак; ~**ое про́шлое** ерак тарих, күптән үткән заман; ~**ое бу́дущее** ерак киләчәк **3.** ерактагы ...; ~**ий го́род** ерактагы шәһәр **4.** *перен.* ят, чит; **мы с ним лю́ди** ~**ие** без аның белән

ят кешеләр **5.** *перен. разг.* (*только с отриц.*) акыллы, башлы; **он челове́к не о́чень-то ~ий** ул бик үк акыллы кеше түгел ◆ **я далёк от мы́сли** *что-л. сделать* *берәр нәрсә эшләргә* уйлаган да юк, *нәрсә дә булса эшләргә* уйлап караган да юк

далеко́, далёко *нареч.* **1.** *прям., перен.* ерак; **мне ~ е́хать** миңа ерак барасы; **оста́вить** *кого-л.* **~ позади́** *берәрсен* бик ерак артта калдыру **2.** *в знач. сказ.* озак, ерак; **до пра́здника ещё ~** бәйрәмгә кадәр әле ерак ◆ **далеко́ до ...** әле ерак, бөтенләй җитми; **тебе́ далеко́ до него́** сиңа аның кебек булырга ерак әле; **далеко́ за ...** күптән үткән (узган), үтеп (узып) киткән; **уже́ далеко́ за по́лночь** күптән инде төн урталары үтеп киткән; **ему́ далеко́ за пятьдеся́т** ул күптән илледән узган; **далеко́ зайти́** чиктән ашу, тирәнгә китү; **далеко́ не ...** бер дә, һич тә; ул кадәр; **далеко́ не так** һич тә алай түгел; **де́вушка далеко́ не краса́вица** кыз һич тә матур түгел; **он далеко́ не трус** ул бер дә куркак түгел; **далеко́ не уе́дешь (не уйдёшь)** ерак бара (китә) алмассың; **далеко́ пойти́** ерак китү

дал||ь *ж* **1.** *разг.* ерак җир; **не пойду́ в таку́ю ~ь** мин андый ерак җиргә бармыйм **2.** (*далёкое пространство*) офык, ераклык; **тума́нные ~и** томанлы офыклар

дальне́йш||ий, -ая, -ее алдагы, киләчәктәге, моннан соңгы; **в ~ем** 1) (*в будущем*) киләчәктә, алда, алдагы көндә; 2) (*ниже, далее*) түбәндә, моннан соң

да́льн||ий, -яя, -ее **1.** ерак, ерактагы; еракка ... торган; **капита́н ~его пла́вания** еракка йөзә торган капитан; **~ие райо́ны** ерак районнар; **авиа́ция ~его де́йствия** еракка оча торган авиация **2.** ерак, чыбык очы ...; **~ий ро́дственник** ерак туган

дальнобо́йный, -ая, -ое *воен.* ерактан ата торган, еракка ата торган

дальнови́дность *ж* алдан күрүчәнлек

дальнови́дный, -ая, -ое алдан күрүчән

дальнозо́ркий, -ая, -ое ерактан яхшы күрүче, якыннан начар күрүче; **~ поли́тик** *перен.* зирәк сәясәтче

дальнозо́ркость *ж* ерактан яхшы күрү, якыннан начар күрү

дальноме́р *м* ераклык үлчәгеч (*прибор*)

да́льность *ж* ераклык; **~ полёта** очуның ераклыгы

дальтони́зм *м* дальтонизм (*кайбер төсләрне аермау*)

дальто́ник *м разг.* дальтоник

да́льше 1. *сравн. ст. от* **далёкий** 1, 2, **далеко́; 2.** *нареч.* (*затем*) аннары, аннан (моннан) ары, аннан (шуннан, моннан) соң; **~ что бы́ло?** шуннан соң нәрсә булды? **3.** *нареч.* (*продолжая начатое*) соңрак, түбәндәрәк; алга табан; **об э́том напи́сано ~** бу турыда түбәндәрәк язылган; **расска́зывай ~** сөйләвеңне алга табан дәвам ит ◆ **~ — бо́льше** алга табарак эш тагын да кискенләшер; **не ~ как (чем)** кайчан гына әле; **не ~ чем вчера́** әле кичә генә

да́ма *ж* **1.** бикә, ханым (*буржуаздворян җәмгыятьтә*) **2.** (*в танце*) дама **3.** *карт.* дама ◆ **~ се́рдца** *шутл.* сөйгән яр, җанкай, жанаш

дама́сск||ий, -ая, -ое: **~ая сталь** Димәшкъ корычы

да́мба *ж* дамба (*су басудан саклау, су булу яки су баса торган урыннарга юл салу өчен өелгән ныгытма*)

да́мка *ж* дамка (*шашка уенында*)

дамо́клов: ~ меч дамокл кылычы, даими куркыныч; **быть под ~ым мечо́м** даими куркыныч астында булу

да́мск||ий, -ая, -ое хатын-кызлар ...; **~ое пальто́** хатын-кызлар пальтосы; **~ий портно́й** хатын-кызлар киеме тегүче

да́нник *м ист.* салым түләүче, ясак түләүче

да́нность *ж* чынбарлык, барлык

да́нные *только мн.* **1.** мәгълүматлар; **анке́тные ~** анкета мәгълүматлары **2.** мөмкинлекләр; нигезләр; **у него́ есть все ~ стать хоро́шим врачо́м** аның яхшы табиб булу өчен сәләте җитәрлек

да́нн||ый, -ая, -ое шушы, бу, хәзерге, әлеге; **в ~ую мину́ту** шушы минутта; **~ый слу́чай** бу вакыйга ◆ **~ая величина́** *мат.* билгеле зурлык

да́нсинг *м* дансинг (*чит илләрдә танцылар залы*)

дантиcт *м* дантист, теш табибы

дань *ж* **1.** *ист.* ясак, салым **2.** *перен. книжн.* тиешле бәя, тиешле хөрмәт (ихтирам); ихтирам билгесе **3.** (*уступка*) саклау, ияру; **~ мо́де** модага ияру ◆ **отда́ть ~** *кому-чему* тиешле бәяне бирү

дар *м* **1.** *высок.* (*подарок*) бүләк **2.** сәләт, сәләтлелек; **литерату́рный ~** әдәби сәләт ◆ **лиши́ться ~а ре́чи** телсез калу, сүзеңне әйтә алмыйча тору

дарвини́зм *м* дарвинизм, Дарвин тәгълиматы

дарвини́ст *м* дарвинчы, дарвинизм тарафдары

дарён||ый, -ая, -ое *разг.* бүләк ителгән, бүләк итеп бирелгән; **~ому коню́ в зу́бы не смо́трят** *посл.* бүләк атның тешенә карамыйлар

дари́тель *м уст.* бүләк итүче, бүләк итеп бирүче

дари́ть *несов. кому-чему, кого-что* бүләк бирү, бүләк итү, бүләк итеп бирү ◆ **~ улы́бкой** *кого кемгә дә булса* елмаеп карау; **~ внима́нием** *кого кемгә дә булса* игътибар күрсәтү

дармовщи́нк||а *прост.*: **на ~у** бушлай, түләүсез

дармое́д *м разг.* әрәмтамак, бушка ашап ятучы, кеше җилкәсен кимерүче, сорыкорт

дарова́ние *с* сәләт; **музыка́льное ~** музыкага сәләт

дарова́ть *сов., несов. что, высок.*: **~ свобо́ду** азат итү; **~ жи́знь** үлем җәзасыннан коткару, гафу итү

даровы́тый, -ая, -ое сәләтле

даровой, -а́я, -о́е *разг.* бушлай алынган, бушлай бирелгән, түләүсез; **~ прое́зд** бушлай утырып бару (*мәс. автобуста*)

даровщи́нк||а *ж разг.*: **на ~у** бушлай, түләүсез

да́ром *нареч.* **1.** (*бесплатно*) буш, бушлай, бушка, түләүсез, акчасыз гына **2.** (*очень дёшево*) бик арзанга, бушка **3.** кирәкмәскә, файдасызга, әрәмгә, юкка, бушка; **~ потеря́ть вре́мя** вакытны бушка әрәм итү ◆ **~ что...** ...га карамастан, ... булса да; **~ что ста́рый** карт булуына карамастан; **э́то тебе́ ~ не пройдёт** син моның җәзасын күрерсең әле

да́рственн||ый, -ая, -ое бүләклек ...ы; бүләк ...ы, бүләк итү ...ы, бүләк итү ...ы; **~ая на́дпись** бүләк итү язуы ◆ **~ая за́пись** *юр.* бүләк язуы (*милекне бүләк итеп биру акты теркәлгән документ*)

да́т||а *ж* дата (*ел, ай, көн*); **истори́ческие ~ы** тарихи даталар

да́тельный: ~ паде́ж *грам.* юнәлеш килеше

дати́ровать *сов., несов. что* датасын (дата) кую; датасын күрсәтү; **~ сего́дняшним число́м** бүгенге көн датасын кую

дати́р||оваться *несов.* ...га карау, ... белән билгеләнү (*вакыт яғыннан*); **~уется оди́ннадцатым ве́ком** унберенче гасырга карый

да́тский, -ая, -ое датчан[нар] ...ы; Дания ...ы; **~ язы́к** датчан теле

датча́не *мн.* датчаннар, даниялеләр, Дания халкы

датча́нин *м* датчан, данияле, Дания кешесе

датча́нка *ж* данияле хатын (кыз)

да́тчик *м тех.* датчик (*механизмның, тере организмның эшчәнлеген тикшерә торган прибор*)

дать *сов.* **1.** *кого-что* бирү, биреп тору; **~ письмо́** хат бирү; **~ де́нег на доро́гу** юлга акча бирү; **~ лека́рство** дару бирү; **~ о́рден** орден бирү; **~ а́дрес** адрес бирү; **~ взаймы́** бурычка бирү; **дай почита́ть свою́ кни́гу** китабыңны укырга биреп тор әле **2.** *кого-что* (*представить*) бирү; **~ крестья́нам зе́млю** крестьяннарга җир бирү; **~ кварти́ру** квартир бирү **3.** *что* (*поручить*) бирү, кушу; **~ тру́дную рабо́ту** авыр эш бирү **4.** *что* (*ударить*) берне бирү, сугу, кундыру, тондыру, чалтырату; **~ пощёчину** яңагына сугу; **~ в у́хо** колагына тондыру **5.** *что* (*определить возраст*) бирү; **ему́ нельзя́ ~ бо́льше сорока́ лет** аңа кырык яшьтән дә артык биреп булмый **6.** *что* (*устроить, организовать*) оештыру, жыю; **~ обе́д в че́сть юбиля́ра** юбиляр хөрмәтенә мәҗлес оештыру **7.** *что* (*показать*) бирү, күрсәтү; **~ конце́рт** концерт бирү **8.** *что* (*принести как результат*) бирү, китерү; **~ большо́й дохо́д** зур табыш китерү **9.** *что* (*произвести, сделать*) бирү; **~ залп** залп бирү; **~ сигна́л** сигнал бирү **10.** *что и с неопр.* (*позволить*) ...га [мөмкинлек] бирү, рөхсәт итү; **не ~ спать** йокларга [мөмкинлек] бирмәү; **да́йте мне вы́сказаться** мина сөйләргә рөхсәт итегез **11.** (*обозначает попытку сделать что-л.*) (*эшләп*) карау; әйдә әле; **дай, ду́маю, отдохну́**

бераз ял итеп алыйм әле, дим; **дай я сам пойдý** әйдә, үзем барыйм әле ♦ **~ вóлю** (*напр. чувствам, слезам*) ирек кую, ирек бирү; **~ вóлю рукáм** кулны узындыру, кул белән уйнау; **~ дорóгу** *кому* юл бирү, юл сабу; олы юлга чыгару; **~ жúзнь** *кому* бала табу, бәби тудыру; **~ зáнавес** пәрдәне ачу; **~ знать** хәбәр итү, белдерү; **~ клáтву** ант итү; **~ máху** ялгышу, ялгышлык жибәрү; **~ начáло** башланып китү; **~ понять** сиздерү, аңлату; **~ свет** яктырту, ут кабызу; **~ себé труд** тырышып карау; тиеш дип табу; **~ слóво** 1) (*на собрании*) сүз бирү; 2) (*пообещать*) вәгъдә итү, сүз бирү; **~ течь** агу, тишелү; **~ трéщину** 1) ярылу; 2) *перен.* кимчелек килеп чыгу; **~ тянý (стрекачá)** качып китү, шылу, кыяклау, табан ялтырату; **~ урóк** *кому* арт сабагын укыту, кирәген бирү; **~ шпóры** ашыктыру; тизләтү, **как пить ~** бер дә шикләнмә, булмыйча калмас; **не ~ спýску** каты тоту; **ни ~ ни взять** нәкъ үзе, бик охшаган, ике тамчы судай охшаш: **он тебé даст** ул синең кирәгеңне бирер әле; **я тебé дам** күрмәгәненең күрсәтермен

дáться *сов. разг.* **1.** (*поддаться*) бирелү; тоттыру; мөмкинлек бирү **2.** *кому* (*легко усвоиться*) җиңел бирелү, җиңел үзләштерелү **3.** *кому, неодобр.* кирәге булу; табылу; **далáсь тебé э́та кни́га!** бу китапның нигә сиңа кирәге бар?

дáча I *ж* **1.** *см.* **дать; ~ а показáний** *юр.* мәгълүматлар бирү **2.** (*порция*) бирем, бер тапкыр бирерлек; **две ~и овсá** ике тапкыр бирерлек солы

дáча II *ж* (*загородный дом*) дача

дáча III *ж спец.* (*участок земли под лесом*) дача (*шәһәр читендәге җир участогы*)

дачевладéлец *м* дача хуҗасы

дáчник *м* дачада торучы

дáчница *ж см.* **дáчник**

дая́ние *с уст.* иганә

два *м, с числ.* **1.** ике **2.** (*оценка*) икеле, ике ♦ **в ~ счёта** бик тиз, күз ачып йомганчы; **в двух слова́х** кыска гына итеп, ике сүз белән; **в двух шага́х** бик якын, яп-якын, ике адымда гына

двадцатиле́тие 1. (*срок*) егерме ел **2.** (*годовщина*) егерме еллык

двадцатиле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) егерме еллык; **~ стаж** егерме еллык стаж **2.** (*о возрасте*) егерме яшьлек

двадца́тый, -ая, -ое *числ.* егерменче

два́дцать *числ.* егерме

два́жды *нареч.* **1.** ике тапкыр, ике мәртәбә, ике кат; **~ сказа́ть** ике тапкыр әйтү **2.** (*при умножении*) ике тапкыр, ике жирдә; **~ пять — де́сять** ике жирдә биш — ун ♦ **как ~ два [четы́ре]** бик гади, ике икең дүрт шикелле

две *ж см.* **два**

двенадцатипе́рстн||ый, -ая, -ое: **~ая кишка́** *анат.* уникe илле эчәк

двена́дцатый, -ая, -ое *числ.* уникенче

двена́дцать *ж числ.* уникe

две́рка *ж см.* **две́рца**

дверн||о́й, -а́я, -о́е ишек ...ы; **~а́я ру́чка** ишек тоткасы

две́рца *ж* капкач; ишек

двер||ь *ж* ишек; **дубо́вая ~ь** имән ишек; **стоя́ть в ~я́х** ишек янында басып тору ♦ **показа́ть (указа́ть) на ~ь** *кому* куып чыгару

две́сти *числ.* ике йөз

дви́гатель *м* **1.** двигатель; **раке́тный ~** ракета двигателе; **~ вну́треннего сгора́ния** эче янулы двигатель **2.** *перен.* этәргеч, этәрүче, алга җибәрүче, үстерүче (*көч*); **труд — ~ нау́ки и культу́ры** хезмәт — фәнне һәм мәдәниятне алга этәрүче көч

дви́гательн||ый, -ая, -ое хәрәкәт ...ы, хәрәкәткә китерүче, хәрәкәтләндерүче; **~ые не́рвы** *анат.* хәрәкәт нервлары

дви||гать *несов.* **1.** *кого-что* этү, шудыру, күчерү, йөртү; **~гать ме́бель** мебельне күчерү **2.** *чем* кыймылдату, селкетү; **~гать рука́ми** кулларны селкетү **3.** *кого-что* алып бару, юнәлдерү; **~гать войска́ к побере́жью** гаскәрне елга буена алып бару **4.** *перен. что* алга җибәрү, алга этәрү, үстерү; **~гать нау́ку вперёд** фәнне алга этәрү **5.** *что* хәрәкәтләндерү, хәрәкәткә китерү, йөртү; **пружи́на ~жет часово́й механи́зм** пружина сәгать механизмын хәрәкәткә китерә **6.** *перен. кем* илһамландыру, рухландыру; **им ~жет чу́вство патриоти́зма** аны патриотизм хисе рухландыра **7.** *прост.* (*отправляться*) кузгалу, бара башлау; **~гай вперёд** алга таба кузгал

дви́га||ться *несов.* **1.** бару, хәрәкәт итү, йөрү; **стре́лка дви́жется по цифербла́ту** сәгать теле цифрблат буйлап хәрәкәт итә **2.** кузгалу, кузгалып китү, чыгып китү; **~ться в путь** юлга чыгып китү **3.** кыймылдау, селкенү, кузгалу; **не ~йся!** [урыныннан] кузгалма! **4.** *перен.* үсү, күтәрелү, алга үрләү; **~ться по слу́жбе** хезмәт буенча күтәрелү **5.** *страд. от* **дви́гать** 1, 3-5

движе́ни||е *с* **1.** хәрәкәт; **привести́ в ~е** хәрәкәткә китерү; **~я ног и рук** кул-аяк хәрәкәтләре; **равноме́рное ~е** тигез хәрәкәт; **вращáтельное ~е** *физ.* әйләнмә хәрәкәт; **лежáть без ~я** хәрәкәтсез яту **2.** йөреш, хәрәкәт; **~е авто́бусов** автобуслар хәрәкәте; **расписа́ние ~я поездо́в** поездлар йөреше расписаниесе **3.** йөрү, хәрәкәт, хәрәкәт итү; **пра́вила у́личного ~я** урам хәрәкәте кагыйдәләре **4.** хәрәкәт; **революцио́нное ~е** революцион хәрәкәт; **~е сторо́нников ми́ра** тынычлык яклаучылар хәрәкәте; **национа́льно-освободи́тельное ~е** милли азатлык хәрәкәте **5.** барыш, агыш; **~е собы́тий** вакыйгаларның барышы

дви́жимость *ж юр.* күчмә милек

дви́жим||ый, -ая, -ое рухланган, дәртләнгән; **~ый чу́вством любви́ к Ро́дине** Ватанга мәхәббәт хисе белән рухланган ♦ **~ое иму́щество** *см.* **дви́жимость**

движо́к *м* движок (**1.** *төрле механизмнарда күчәр буйлап хәрәкәтләнә торган деталь* **2.** *разг. кечкенә двигатель, күчмә двигатель* **3.** *кар көрәү өчен киң агач көрәк*)

дви́жущ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **дви́гать; 2.** этәргеч, алга этәрүче, хәрәкәткә китерүче, әйдәүче; **~ие си́лы** хәрәкәткә китерүче көчләр

дви́нуть *сов.* **1.** *однокр. см.* **дви́гать** 1-4, 7; **2.** *кого и без доп., прост.* (*стукнуть*) сугып җибәрү, тондыру, бәреп жибәрү

дви́нуться *сов. см.* **дви́гаться**

дво́||е *числ. собир.* **1.** ике; икәү; **~е дете́й** ике бала; **пока́ пришли́ то́лько ~е** әлегә икесе генә килде; **их ~е** алар икәү **2.** ике пар; **~е сапо́г** ике пар итек ♦ **за ~и́х** ике кеше өчен; **на свои́х [на] ~и́х** *шутл.* җәяүләп, тәпи-тәпи

двоебо́рец *м* ике төр спортчы

двоебо́рье *с спорт.* ике төр ярыш; **олимпи́йское ~** Олимпия ике төр ярышы

двоевла́стие *с* ике властьлылык

двоеду́шие *с* икейөзлелек, монафыйклык

двоежене́ц *м* ике хатынлы кеше

двоежёнство *с* ике хатын белән тору, ике хатынлы булу

двоето́чие *с* ике нокта

дво́ечник *м* икелегә укучы

дво́ечница *ж* икелегә укучы кыз

двои́т||ься *несов.* **1.** (*раздваиваться*) икегә бүленү, икегә аерылу **2.** ике булып күренү; **у меня́ ~ся в глаза́х** минем күземә ике булып күренә

дво́йка *ж* **1.** (*цифра*) ике, икеле цифр **2.** (*отметка*) икеле, икеле билгесе **3.** *карт.* икелек **4.** *спорт.* ике ишкәкле көймә

дво́йник *м* **1.** *кого, чей* охшаш кеше (*тышкы кыяфәтләре белән бер-берсенә бик нык охшаган ике кешенең берсе*) **2.** *см.* **двойча́тка**

двойн||о́й, -а́я, -о́е **1.** икеләтә; **~о́й за́работок** икеләтә эш хакы **2.** ике катлы; **~ы́е ра́мы** ике катлы рам; **~о́е дно** ике катлы төп **3.** ике инле; **~а́я мате́рия** ике инле материя ♦ **~а́я игра́** икейөзлелек; монафыйклык, мәкерлелек; **~а́я бухгалте́рия** исәпләү операциясе икеләтә чагылган бухгалтерия

дво́йня *ж* игез балалар, игезәкләр

двойня́шка *м, ж разг.* игезәк, игез бала

дво́йственность *ж* **1.** (*противоречивость*) ике төрлелек, икелелек **2.** (*двуличность*) аумакайлык, икеле-микеле булу

дво́йственный, -ая, -ое **1.** (*противоречивый*) ике төрле, икеле **2.** (*двуличный*) аумакай, икеле-микеле

двойча́тка *ж* куш (*чикләвек, башак һ.б.ш.*)

двор I *м* ишегалды; **въе́хать во ~** ишегалдына килеп керү (*мәс. атта*) **2.** йорт, хуҗалык; **дере́вня в сто ~о́в** йөз йорттан торган авыл; ♦ **на ~е́** тышта, урамда; **на ~е́ хо́лодно** тышта салкын; **прийти́сь ко ~ý** ошау, туры килү

двор II *м* сарай; сарай даирәсе (*патшага якын, аның янына, тирәсенә тупланган кешеләр*); **быть при ~е́** сарай даирәсендә булу

дворе́ц *м* сарай; **Дворе́ц культу́ры** Мәдәният сарае; **Дворе́ц съе́здов** Съездлар сарае

дворе́цкий *м* дворецкий, баш лакей (*байлар өендәге баш хезмәтче*)

дво́рник *м* дворник (**1.** *урам себеруче* **2.** *автомашиналарда: пыяла чистарткыч*)

дво́рня *ж собир. уст.* йорт хезмәтчеләре (*алпавыт йортында эшләүчеләр*)

дворня́га, дворня́жка *ж* гади эт, йорт эте, нәселсез эт

дворо́в||ый, -ая, -ое **1.** йорт ...ы; **~ая соба́ка** йорт эте **2.** хезмәтче, асрау (*алпавыт йортында*); **~ые лю́ди** алпавыт хезмәтчеләре

дворцо́вый, -ая, -ое сарай ...ы; **~ парк** сарай паркы ♦ **~ перево́рот** сарай әйләнешләре

дворя́не *мн.* дворяннар, морзалар

дворяни́н *м* дворян, морза

дворя́нка *ж* дворян хатын (*кыз*)

дворя́нство 1. (*сословие*) дворянлык **2.** *собир.* дворяннар

двою́родн||ый, -ая, -ое ике туган; **~ый брат** (*старший*) ике туган абый; (*младший*) ике туган эне; **~ая сестра́** (*старшая*) ике туган апа; (*младшая*) ике туган сеңел

двоя́к||ий, -ая, -ое ике төрле; ике яклы, ике яклап; **~ое значе́ние** ике төрле мәгънә; **~ая вы́года** ике яклап файда

двоя́ко *нареч.* ике төрле, ике төрле юл белән; **его́ слова́ мо́жно понима́ть ~** аның сүзләрен ике мәгънәдә аңларга мөмкин; **реши́ть зада́чу ~** ике төрле юл белән мәсьәләне чишү

двояково́гнут||ый, -ая, -ое ике ягы [да] батынкы; **~ое стекло́** ике ягы да батынкы пыяла

двояковы́пуклый, -ая, -ое ике ягы [да] кабарынкы

двоякоды́шащие *мн. зоол.* ике төрле сулаучылар (*саңак һәм үпкә белән сулаучы балыклар*)

двуˣ (двух-) *рус телендәге кушма сүзләрнең «ике» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **двуме́рный** ике үлчәүле; **двухколёсный** ике тәгәрмәчле

двубо́ртн||ый, -ая, -ое ике капламлы, ике якка да төймәләнә торган; **~ое пальто́** ике якка да төймәләнә торган пальто

двугла́вый, -ая, -ое ике башлы; **~ орёл** ике башлы бөркет (*гербта*)

двуго́рбый, -ая, -ое ике өркәчле

двугри́венный *м разг.* егерме тиен, егерме тиенлек акча

двудо́льн||ый, -ая, -ое **1.** (*о стихотворном размере*) ике өлештән торган **2.** *бот.* ике орлык өлешле; **~ые расте́ния** ике орлык өлешле үсемлекләр

двудо́мные *мн. бот.* ике өйле; **~ расте́ния** ике өйле үсемлекләр (*үсемлекләрнең берсендә аналык чәчәкләре, икенчесендә аталык чәчәкләре булган үсемлекләр*)

двуеди́н||ый, -ая, -ое *книжн.* икелекле, куш; **~ое явле́ние** куш күренеш

двужи́льный, -ая, -ое *прост.* чыдам, нык, таза, көчле

двузна́чн||ый, -ая, -ое ике урынлы; **~ое число́** ике урынлы сан

двуко́лка *ж* ике тәгәрмәчле арба

двукра́т||ый, -ая, -ое ике кат, ике тапкыр, икеләтә; **~ый чемпио́н** ике тапкыр чемпион; **~ое напомина́ние** ике мәртәбә кисәтү; **в ~ом разме́ре** икеләтә күләмдә

двукры́лые *мн. зоол.* куш канатлылар (*чебен, черки һ.б.ш.*)

двули́кий, -ая, -ое *книж. см.* **двули́чный**; **~ Я́нус** икейөзле кеше

двули́чие *с*, **двули́чность** *ж* икейөзлелек, монафыйклык

двули́чный, -ая, -ое икейөзле, монафыйк

двуно́гий, -ая, -ое ике аяклы

двуо́кись *ж хим.* двуокись

двупла́нн||ый, -ая, -ое ике планда урнашкан, ике планда күрсәтелә торган; **~ое изображе́ние** ике планда күрсәтелә торган сурәт

двупо́лый, -ая, -ое **1.** *биол.* ике женесле, кызтәкә, хонса **2.** *бот.* ике женесле (*аталык һәм аналык чәчәкләре дә булган үсемлек*)

двупо́лье *с с.-х.* ике басулы чәчү әйләнеше (*электә чәчү әйләнеше системасы*)

двупо́льный, -ая, -ое *с.-х.* ике басулы; **~ севообора́т** ике басулы чәчү әйләнеше

двуру́чн||ый, -ая, -ое ике тоткалы; **~ая пила́** аркылы пычкы

двуру́шник *м* икейөзле кеше, монафыйк

двуру́шничать *несов.* икейөзлеләнү, монафыйк булу

двуру́шнический, -ая, -ое икейөзле, монафыйкларча ...; **~ посту́пок** икейөзле кыланыш

двуру́шничество *с* икейөзлелек, монафыйклык

двусве́тный, -ая, -ое ике як тәрәзәле, аслы-өсле тәрәзәле; **~ зал** ике як тәрәзәле зал

двуска́тн||ый, -ая, -ое ике кыеклы; **~ая кры́ша** ике кыеклы түбә

двусло́жн||ый, -ая, -ое ике иҗекле; **~ое сло́во** ике иҗеклс сүз

двусмы́сленность *ж* **1.** ике мәгънәлелек, ике төрле аңлашыла торган булу; **~ поведе́ния** тәртипнең ике төрле аңлашыла торган булуы **2.** ике мәгънәле сүз, киная, кинаялелек; **сказа́ть ~** ике мәгънәле сүз әйтү

двусмы́сленный, -ая, -ое **1.** ике мәгънәле, ике төрле аңларлык ...; **~ отве́т** ике төрле аңларлык җавап **2.** кинаяле (*әдәпсез мәгънәне эченә ала торган*); **~ая шу́тка** кинаяле шаярту

двусмы́слица *ж* ике төрле аңларлык сүз, төрле мәгънәле тәгъбир

двуспа́льн||ый, -ая, -ое ике кешелек ..., ике кеше йокларлык ...; **~ая крова́ть** ике кешелек карават

двуство́лка *ж* ике көпшәле мылтык

двуство́льн||ый, -ая, -ое ике көпшәле, куш көпшәле; **~ое ружьё** ике көпшәле мылтык

двуство́рчатый, -ая, -ое ике якка ачылмалы (*тәрәзә, ишек, шкаф*)

двусти́шие *с* (*стихотворение*) ике юллы шигырь; (*строфа*) шигырьнең ике юллык өлеше

двусторо́нн||ий, -яя, -ее **1.** ике яклы (*мәс. ике ягы да бер төрле сукно*); **~ее движе́ние** ике яклы хәрәкәт **2.** ике яклы, һәр ике як өчен мәҗбүри; **~ее соглаше́ние** ике яклы килешү; **~ие конта́кты** ике яклы бәйләнешләр

двух- *см.* **дву-**

двухгоди́чный, -ая, -ое ике еллык ...; **~ курс** ике еллык курс

двухгодова́лый, -ая, -ое ике яшьлек, ике яшь тулган; **~ ребёнок** ике яшьлек бала

двухдне́вный, -ая, -ое ике көнлек ...; **~ перехо́д** ике көнлек юл

двухдоро́жечный, -ая, -ое ике юллы, ике сызыклы; **~ магнитофо́н** ике юллы магнитофон

двухквартирный, -ая, -ое ике квартирлы; **~ дом** ике квартирлы йорт

двухкилометро́вый, -ая, -ое ике километрлы, ике километрлык ...; **~ путь** ике километрлы юл

двухколёсный, -ая, -ое ике тәгәрмәчле

двухме́стн||ый, -ая, -ое ике урынлы, ике кешелек ...; **~ая каю́та** ике урынлы каюта

двухнеде́льный, -ая, -ое **1.** ике атналык ...; **~ о́тпуск** ике атналык ял; **~ ребёнок** ике атналык бала **2.** ике атнага бер чыга торган; **~ журна́л** ике атнага бер чыга торган журнал

двухпала́тный, -ая, -ое ике палаталы; **~ парла́мент** ике палаталы парламент

двухпарти́йн||ый, -ая, -ое ике партияле, ике партиялелек ...ы; **~ая систе́ма** ике партиялелек системасы

двухпрогра́ммный, -ая, -ое ике программалы; **~ое вещание** ике программалы тапшыру

двухра́зов||ый, -ая, -ое ике тапкыр эшләнә торган; **~ое пита́ние** ике тапкыр туклану

двухсотле́тие *с* **1.** (*срок*) ике йөз ел **2.** (*годовщина*) ике йөзьеллык

двусотле́тн||ий, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) ике йөз сл[га] барган (сузылган) **2.** (*о годовщине*) ике йөзьеллык ...

двухсо́тый *числ.* ике йөзенче

двухта́ктн||ый, -ая, -ое ике тактлы; **~ый мото́р** ике тактлы мотор; **~ая па́уза** ике такт озынлыгындагы пауза

двухты́сячный, -ая, -ое **1.** *числ.* ике меңенче **2.** *разг.* (*о цене*) ике мең сумлык..., ике меңлек ... **3.** ике меннән торган, ике мең кеше катнашкан, ике мең кешелек ...; **~ отря́д** ике мең кешелек отряд

двухцве́тн||ый, -ая, -ое ике төсле, ике буяулы, ике төрле төстәге; **~ая ткань** ике төстәге тукыма

двухчасово́й, -а́я, -о́е **1.** ике сәгатьлек ...; **~ докла́д** ике сәгатьлек доклад **2.** ике сәгатьтә китә (килә) торган; **~ по́езд** ике сәгатьтә китә торган поезд

двухэта́жный, -ая, -ое ике катлы; **~ дом** ике катлы йорт

двучле́н *м мат.* ике буын; бином

ДВУ-ДЕЗ

двуязы́чие *с* **1.** (*равноправное существование двух языков*) ике теллелек ..., ике телдә сөйләшү **2.** (*знание двух языков*) ике тел белү, ике телдән файдалану

двуязы́чн||ый, -ая, -ое **1.** ике тел белә торган, ике телдә сөйләшә торган; **~ое населе́ние** ике телдә сөйләшә торган халык **2.** ике телле, ике телдә төзелгән; **~ый слова́рь** ике телле сүзлек

дебарка́дер, дебаркаде́р *м* дебаркадер

дебати́ровать *несов.* что, о чём и без доп., *книжн.* бәхәс алып бару, фикер алышу; **~ вопро́с** мәсьәлә буенча фикер алышу

деба́ты *только мн. книжн.* фикер алышулар, бәхәсләр

дебе́л||ый, -ая, -ое *разг.* юан, симез; **~ая же́нщина** симез хатын

де́бет *м бухг.* дебет (*керем-чыгым кенәгәсендә керем һәм алачаклар языла торган як*)

деби́т *м спец.* дебит (*билгеле бер вакыт эчендә чыганактан килә торган газ, су, нефть һ.б.ш. ларның микъдары*)

дебито́р *м бухг.* дебитор (*бурычлы кеше яки учреждение*)

дебо́ш *м разг.* җәнҗал, тавыш, гауга, орыш-талаш; **устро́ить (подня́ть) ~** гауга күтәрү

дебоши́р *м разг.* тавыш куптаручы, гауга чыгаручы, җәнҗалчы

дебоши́рить *несов. разг.* тавыш-гауга күтәрү, җәнҗал чыгару

дебоши́рство *с разг.* җәнҗал чыгару, тавыш-гауга күтәрү; җәнҗал, тавыш-гауга

де́бри *мн.* **1.** ешлык, куелык, чытырманлык (*урманның утә алмаслык куе җире*) **2.** *перен. чего, какие* чытырманлык, кыенлыклар; **~ матема́тики** математика чытырманлыклары

дебю́т *м* дебют (**1.** *артистның беренче тапкыр чыгышы яки язучының беренче әсәрен чыгаруы* **2.** *шахматта яки шашка уенында*: *йөри башлау, уен башлау*)

дебюта́нт *м* дебютант (*беренче тапкыр чыгыш ясаучы, мәс. сәхнәдә, кинода, спортта*)

дебюта́нтка дебютант хатын (кыз)

дебюти́ровать *сов., несов.* беренче тапкыр чыгыш ясау (*мәс. сәхнәдә*)

де́ва *ж* **1.** *уст. см.* **де́вушка** 1; **2.** (*с прописной*) *астр.* Кыз (*йолдызлык*)

девальва́ция *ж* девальвация (*яңа акча керту юлы белән яки куллануда булган акчаның рәсми курсын төшерү юлы белән үткәрелә торган акча реформасы*)

дева́ть *несов. см.* **деть**

дева́ться *несов. см.* **де́ться**

де́верь *м* (*старший брат мужа*) каенага, биага; (*младший брат мужа*) каене

девиа́ция *ж* девиация (**1.** *компас үгының зур күләмдәге тимер масса тәэсирендә авышуы* **2.** *снаряд, пуля, корабль кебекләрнең төрле сәбәпләр аркасында юнәлеш үзгәртүе*)

деви́з *м* девиз (**1.** *үзеңне тотуда, эштә төп идеяне күрсәтә торган әйтем,* **2.** *конкурсларда авторның үз иҫеме урынына куйган сүзе*)

деви́ца, де́вица *ж уст. см.* **де́вушка** 1

деви́ческий, -ая, -ое *см.* **деви́чий**

деви́чество *с* кызлык, кыз вакыт, кызлык чоры

деви́ч||ий, -ья, -ье, **де́вич||ий**, -ья, -ье кыз ...ы, кызлар ...ы; **~ья краса́** кызлар матурлыгы ◆ **~ья па́мять** *шутл.* кызлар хәтере (*начар хәтер турында*)

деви́чник *м* кыз озату кичәсе (*русларда иртәгә никах буласы кичне кияүгә чыгачак кызның өендә ипташ кызлары белән җыелып утырулары*)

де́вичья *ж уст.* кызлар бүлмәсе (*байлар йортларында асрау кызлар яши торган бүлмә*)

де́вочка *ж* кыз бала

де́вственник *м* гыйффәтле егет

де́вственница *ж* гыйффәтле кыз

де́вственность *ж* **1.** гыйффәтлелек, сафлык **2.** *перен.* табигыйлек, кеше кулы-аягы тимәгәнлек

де́вственн||ый, -ая, -ое **1.** гыйффәтле, саф **2.** *перен.* табигый хәлендәге..., кеше кулы-аягы тимәгән; **~ый лес** кеше аягы басмаган урман; **~ая по́чва** чирәм җир

де́вушка *ж* **1.** кыз, [буйга] җиткән кыз **2.** *уст* (*служанка*) асрау, асрау кыз

девча́ч||ий, -ья, -ье *разг.* кызлар ...ы; **~ья мане́ра** кызлар кыланышы; **~ий шарф** кызлар шарфы

девчо́нка *ж* кызый, кызкай

девчо́ночий, -ья, -ье *см.* **девча́чий**

девяно́сто *числ.* туксан

девяностоле́тие *с* **1.** (*срок*) туксан ел **2.** (*годовщина*) туксан еллык

двяностоле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) туксан еллык ... **2.** (*о возрасте*) туксан яшьлек ...

девяно́стый, -ая, -ое *числ.* туксанынчы

де́вятеро *числ. собир.* тугыз, тугызау; **~ сыново́й** тугыз ул

девятикла́ссник *м* тугызынчы класста укучы

девятикла́ссница *ж* тугызынчы класста укучы кыз

девятитысячный, -ая, -ое *числ.* тугыз меңенче

девятичасово́й, -а́я, -о́е **1.** (*продолжающийся девять часов*) тугыз сәгатьлек ... **2.** тугыз сәгатьтә китә (килә) торган; **~ по́езд** тугыз сәгатьтә китә торган поезд

девя́тка *ж* **1.** (*цифра*) тугызлык, тугызлы цифр **2.** *карт.* тугызлы кәрт **3.** *разг.* тугызынчы, тугызынчы номер (*мәс. трамвай*)

девятна́дцатый, -ая, -ое *числ.* унтугызынчы

девятна́дцать *числ.* унтугыз

девя́тый, -ая, -ое *числ.* тугызынчы

де́вять *числ.* тугыз

девятьсо́т *числ.* тугыз йөз

де́вятью *нареч.* тугыз тапкыр, тугыз җирдә; **~ де́вять — во́семьдесят оди́н** тугыз җирдә тугызын сиксән бер

дегаза́тор *м* дегазатор (**1.** *дегазация ясау аппараты* **2.** *дегазация ясаучы*)

дегазацио́нный, -ая, -ое дегазация ...ы; **~ прибо́р** дегазация приборы

дегаза́ция *ж* дегазация (*агулы газ яки сыекчалар белән агуланган урыннарны, әйберләрне зарарсызландыру*)

дегенера́т *м* дегенерат, беткән кеше (*физик яки психик яктан гарип кеше*)

дегенерати́вный, -ая, -ое дегенератив, зәгыйфь, бетүгә йөз тоткан

дегенера́ция *ж книжн.* дегенерация (*организмда биологик һәм психик билгеләрнең зәгыйфьләнә баруы, бетүгә йөз тоту*)

дёготь *м* дегет

деграда́ция *ж* деградация (*начарлана бару*)

дегради́ровать *сов., несов.* деградация хәленә төшү, начарлану, бетүгә йөз тоту

дегтя́рн||ый, -ая, -ое **1.** дегет ...ы; **~ый за́пах** дегет исе **2.** дегеттән ясалган, дегет кушылган; **~ое мы́ло** дегет кушылган сабын

дегуста́тор *м* дегустатор (*азыкның һәм эчемлекләрнең тәмен татып карап, аларның сыйфатын билгеләүче*)

дегуста́ция *ж* дегустация (*тәмен татып карау юлы белән азыкның һәм эчемлекләрнең сыйфатын билгеләү*)

дегусти́ровать *сов., несов. что* дегустация ясау, тәмен татып карап сыйфатын билгеләү

дед *м* **1.** (*отец отца или матери*) бабай, дәү әти **2.** (*старик*) бабай, карт ◆ **~ы и пра́деды** ата-бабалар, бабайлар

дедеро́н *м* дедерон (*синтетик тукыма*)

дед-моро́з *м* кыш бабай

деду́кция *ж лог.* дедукция (*гомумидән хосусыйга бару юнәлешендә фикер йөртү*)

де́душка *м* **1.** *см.* **дед** 1; **2.** (*при обращении*) бабай, бабакай

дееприча́стие *с грам.* хәл фигыль

дееприча́стный, -ая, -ое *грам.* хәл ...ы, хәл фигыль ...ы; **~ оборо́т** хәл әйләнмәсе

дееспосо́бность *ж* **1.** эшкә яраклылык, эшкә сәләтлелек **2.** *юр.* юридик хокуклылык, хокукка сәләтлелек

дееспосо́бный, -ая, -ое **1.** эшкә яраклы, эшкә сәләтле; **~ органи́зм** эшкә яраклы организм **2.** *юр.* юридик хокуклы, хокукка сәләтле; **~ граждани́н** юридик хокуклы гражданин

дежа́ *ж* дежа (*камыр басу өчен зур чан*)

дежу́рить *несов.* **1.** (*быть дежурным*) дежур тору, кизү тору **2.** *перен.* саклап тору; көтеп тору; **~ всю ночь у больно́го** төн буе авыруны саклап чыгу

дежу́рн||ый, -ая, -ое **1.** дежур, дежур торучы, кизү ... **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* дежур, дежурный ◆ **~ое блю́до** әзер аш (*ресторанларда алдан хәзерләп куелган аш*); **~ый магази́н** дежур кибет

дежу́рство *с* дежурлык, дежур тору, кизүлек [итү]

дезавуи́ровать *сов., несов. кого-что, книжн.* риза түгеллекне белдерү (*үз вәкиленең яки тарафдарының фикере яки эшчәнлеге белән риза түгеллеге турында белдерү*); **~ своего́ представи́теля** үз вәкиленең эшчәнлегеннән риза түгеллекне белдерү

дезерти́р *м* дезертир, качкын

дезерти́ровать *сов., несов.* дезертирлау, качу

дезерти́рство *с* дезертирлык

дезинсе́кция *ж* дезинсекция (*зарарлы бөҗәкләрне агулап кырып бетерү*)

дезинфекцио́нн||ый, -ая, -ое дезинфекция ...ы; йогышсызландыру ...ы; **~ая ка́мера** дезинфекция камерасы

дезинфе́кция *ж* дезинфекция, йогышсызландыру

дезинфици́ровать *сов., несов. что* дезинфекция ясау, йогышсызландыру; **~ оде́жду** киемнәрне дезинфекцияләү

дезинформа́ция *ж* ялган информация, ялган мәгълүмат бирү, дезинформацияләү; **~ обще́ственного мне́ния** җәмәгатьчелек фикерен дезинформацияләү

дезинформи́ровать *сов., несов. кого-что* ялган информация бирү, ялган мәгълүмат бирү

дезорганиза́тор *м* дезорганизатор, таркатучы, таркаулык (тәртипсезлек) кертүче

дезорганиза́торск||ий, -ая, -ое дезорганизаторлык ...ы; **~ая де́ятельность** дезорганизаторлык эшләре

дезорганиза́ция *ж* дезорганизация, тәртипсезлек, таркаулык

дезорганизова́ть *сов., несов. кого-что* дезорганизацияләү, тәртипсезлек кертү, таркату

дезориента́ция *ж* дезориентация, ялгыш юлга кертү (юнәлдерү, салу), ялгыш фикер тудыру

дезориенти́ровать *сов., несов. кого-что* дезориентацияләү, саташтыру, ялгыш юлдан җибәрү, бутау

дейзм *м филос.* деизм (*галәмне башлап барлыкка китерүче — алла, ләкин ул табигать һәм җәмгыять тормышына йогынты ясамый дип раслый торган дини философик тәгълимат*)

де́йственность *ж* тәэсир итүчәнлек, тәэсир итү көче, нәтиҗәлелек, тәэсирлелек

де́йственн||ый, -ая, -ое тәэсирле, нәтиҗәле, тәэсир итәрлек ..., көчле; **~ое сре́дство** көчле чара

де́йстви||е *с* **1.** (*деятельность; работа*) эш, хәрәкәт **2.** *юр.* көч; **догово́р сохраня́ет своё ~е** договор үзенең көчен саклый **3.** тәэсир, йогынты; **под ~ем со́лнечных луче́й** кояш нурлары тәэсире астында **4.** *обычно мн.* **~я** эш итү, эш, үзен тоту; **незако́нные ~я** законсыз эш итүләр **5.** (*события*) вакыйга **6.** *театр.* пәрдә, бүлек, акт **7.** гамәл; **четы́ре ~я матема́тики** математиканың дүрт гамәле ◆ **вое́нные ~я** сугыш хәрәкәтләре

действи́тельно *нареч.* **1.** чыннан, чынлап, чыннан да; **он ~ заболе́л** ул чыннан да авырып китте **2.** *в знач. вводн. сл.* чынлап та, чыннан да; **~, на э́тот раз он прав** чыннан да, ул бу юлы хаклы

действи́тельност||ь *ж* чынбарлык; **совреме́нная ~ь** хәзерге чынбарлык ◆ **в ~и** чынлыкта, дөреслектә, чынында

действи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** чын, дөрес, булган, хакыйкый, реаль; **~ый факт** булган факт **2.** яраклы, көчендә, гамәлдә; **удостовере́ние ~о на оди́н ме́сяц** таныклык бер айга чаклы яраклы ◆ **~ая вое́нная слу́жба** действительный хәрби хәзмәт; **~ое число́** *мат.* чын сан; **~ый зало́г** *грам.* төп юнәлеш; **~ый член Акаде́мии нау́к** Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы

де́йств||овать *несов.* **1.** эш итү; **~овать реши́тельно** кыю эш итү **2.** эшләү; **аппара́т хорошо́ ~ует** аппарат яхшы эшли **3.** хәрәкәт итү, эшләү; **~овать одно́й руко́й** бер кул белән эшләү **4.** *на кого-что* тәэсир итү, йогынты ясау; **уговоры на него́ не ~уют** үгетләүләр аңа тәэсир итми **5.** (*применяться, иметь силу*) көчендә булу, гамәлдә булу

де́йствующ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **де́йствовать; 2.** (*о законах, постановлениях*) гамәлдәге... ◆ **~ая а́рмия** хәрәкәттәге (сугыштагы) армия; **~ие ли́ца** катнашучылар (*мәс. пьесада*)

де́ка *ж* дека (*кыллы музыка коралының тавышны көчәйтү хезмәтен үти торган аскы һәм өске тактасы*)

декабри́ст *м ист.* декабрист

декабри́стка *ж ист.* декабрист хатыны

дека́брь *м* декабрь, декабрь ае

дека́брьск||ий, -ая, -ое декабрь ...; **~ие моро́зы** декабрь салкыннары

дека́да *ж* **1.** ун көн, ун көнлек **2.** декада (*ун көн эчендә сәнгать һәм әдәбият уңышларын курсәту*)

декаде́нт *м иск., лит.* декадент

декаде́нтск||ий, -ая, -ое *иск., лит.* декадент ...ы, декадентлык ...ы; **~ие стихи́** декадентлык шигырьләре

декаде́нтство *с иск., лит.* декадентлык (*19нчы йөз ахырында 20нче йөз башында әдәбияттә һәм сәнгатьтә төшенкелек һәм чиктән тыш индивидуализм белән характерлана торган буржуаз, антиреалистик юнәлешләрнең гомуми исеме*)

дека́дный, -ая, -ое ункөнлек ...; **в ~ срок** ункөнлек срокта

декали́тр *м* декалитр, ун литр

дека́н *м* декан

декана́т *м* деканат

декатирова́ть *сов., несов. что, спец.* декатировка ясау

декатиро́вка *ж см.* **декати́ровать**

деквалифика́ция *ж* деквалификация, квалификациясез калу, квалификацияне югалту

деквалифици́роваться *сов.* квалификациясез калу, квалификацияне югалту

деклама́тор *м* декламатор, нәфис сүз остасы

деклама́ция *ж* декламация, нәфис уку сәнгате; сәнгатьле уку

деклами́ровать *несов. что* декламацияләү, декламация сөйләү; сәнгатьле уку (*мәс. шигырьне*)

декларати́вн||ый, -ая, -ое *книжн.* декларатив, рәсми; **~ое заявле́ние** декларатив белдерү

деклара́ция *ж* декларация, рәсми белдерү (**1.** *хөкүмәт тарафыннан берәр мәсьәләгә карата ясалган рәсми белдерү* **2.** *берәр төрле кирәкле мәгълүматларны белдерә торган кайбер рәсми документларның исеме*)

деклари́ровать *сов., несов. что, книжн.* декларация ясау, игълан итү

деклассси́рованный, -ая, -ое сыйнфый йөзен югалткан

деклассси́роваться *сов., несов.* сыйнфый йөзен югалту, үзенең сыйныфы белән бәйләнешен югалту

декольте́ *с нескл.* декольте (*хатын-кыз күлмәгендә муен һәм күкрәк тирәсен ачык калдырып уелган зур изү*)

декорати́вно-прикладн||о́й, -а́я, -о́е декоратив-гамәли ...ы; **~о́е иску́сство** декоратив-гамәли сәнгать

декорати́вн||ый, -ая, -ое **1.** декоратив, бизәү ...ы; **~ое расте́ние** декоратив үсемлек **2.** матур; **~ый вид** матур күренеш

декора́тор *м* декоратор (**1.** *декорацияләр ясучы рәссам* **2.** *йортларны декорацияләр белән бизәүче*)

декора́ция *ж* декорация (*әсәрдәге шартларга туры китереп сәхнәне җиһазлау, бизәү*)

декори́ровать *сов., несов. что* бизәү

деко́рум *м книжн.* декорум, тышкы нәзакәт

декре́т *м* декрет (*югары хакимиятнең закон көчендәге карары*) ◆ **пойти́ в ~** декретка чыгу (*бала тапкан вакытта*)

декрети́ровать *сов., несов. что, книжн.* декретлаштыру, декрет чыгару

декре́тн||ый, -ая, -ое декрет ...; **в ~ом поря́дке** декрет тәртибендә ◆ **~ый о́тпуск** декрет ялы

де́ланный, -ая, -ое ясалма, табигый булмаган; **~ смех** ясалма көлү

де́лать *несов.* **1.** *что* эшләү; **ничего́ не ~** берни дә эшләмәү **2.** *что* ясау; **~ ме́бель** мебель ясау **3.** *что* бару, үтү, йөрү **~ во́семь киломе́тров в час** сәгатенә сигез километр бару **4.** *что* тектерү; **~ пальто́ в ателье́** ательеда пальто тектерү **5.** *кого-что кем* итү; **~ счастли́вым** бәхетле итү ◆ **~ акце́нт** *на чём* басым ясап әйтү, астына сызу; **~ больши́е (круглы́е) глаза́** күзләрне шардай итү; **~ вид** күрмәмешкә салыну, белмәмешкә салыну; **~ вы́бор** сайлап алу, теләгәненә алу; **~ гла́зки** *кому* күзләрне уйнату; **~ из му́хи слона́** төймәдән дөя ясау; **~ крюк** әйләнеч юлдан бару; **~ *какую* ми́ну** йөзгә ... чырай бирү; **~ не́чего** *в знач. вводн. сл.* бернәрсә дә эшләп булмый; **~ оши́бки** хаталар ясау, ялгышлыклар жибәрү, ялгышу; **~ под себя́** астына жибәрү, йоклаганда урынны юешләү; **~ пода́рок** *кому* бүләк бирү; **~ попы́тку** тырышып карау; тәвәккәлләп карау; **~ посме́шищем** *кого* адәм мәсхәрәсе итү, кеше көлкесенә калдыру, хур итү; **~ предложе́ние** *кому* тәкъдим ясау; **~ честь** *кому* 1) (*оказывать уважение*) ихтирам итү; 2) (*являться заслугой*) ихтирамга лаек булу; **де́ло ~** файдалы эш эшләү, юк-бар белән маташмау; **от не́чего ~** эш юктан, тик торганчы

де́ла||ться *несов.* **1.** ...а бару; **~ется жа́рко** эсселәнә бара **2.** *разг.* барлыкка килү, [килеп] чыгу, хасил булу; **в стене́**

ДЕЛ-ДЕМ

~ются тре́щины стенада ярыклар барлыкка килә **3.** *страд. от* **де́лать** 1, 2, 4 ◆ **что у вас ~ется?** сездә ниләр бар?

делега́т *м* делегат

делега́тка *ж* делегат хатын (кыз)

делега́ция *ж* делегация, делегатлар; **торго́вая ~** сәүдә делегациясе

делегі́ровать *сов., несов. кого-что* делегат итеп җибәрү, вәкил итеп җибәрү; **~ на съезд** съездга делегат итеп җибәрү

делёж *м*, **делёжка** *ж разг.* бүлү, бүлеш, бүлешү

деле́ни||е *с* **1.** *см.* **дели́ть; ~е на ча́сти** өлешләргә бүлү **2.** *мат.* бүлү гамәле **3.** *биол.* бүленеш, үрчү; **~е кле́тки** күзәнәкнең бүленүе **4.** бүлем; **~я термо́метра** термометр бүлемнәре

деле́ц *м* малкуар, эшкуар

делика́тес *м* деликатес (*иң яхшы сыйфатлы тәмле ашамлыклар*)

делика́тничать *несов. разг.* артык нечкәләнеп тору, артык әдәпләлек (нәзакәтлек) күрсәтү

делика́тность *ж* әдәпләлек, нәзакәтлелек

делика́тный, -ая, -ое **1.** әдәпле, нәзакәтле, түбәнчелекле; инсафлы; **~ челове́к** әдәпле кеше **2.** (*щекотливый*) четерекле; **~ вопро́с** четерекле мәсьәлә

дели́мое *с мат.* бүленүче

дели́мость *ж мат.* бүленүчәнлек

дели́тель *м мат.* бүлүче

дели́ть *несов.* **1.** *кого-что* бүлү, аеру; **~ учеников на гру́ппы** укучыларны төркемнәргә бүлү **2.** *кого-что* (*между собой*) бүлү, бүлешү; **~ дохо́д** табыш бүлешү; **~ иму́щество** милек бүлешү **3.** *перен. что с кем* бүлешү, уртаклашу; **~ го́ре и ра́дость** кайгы һәм шатлыкны уртаклашу **4.** *что с кем* өлеш чыгару; **~ за́работок** хезмәт хакыннан өлеш чыгару **5.** *что, мат.* бүлү ◆ **~ не́чего** бүләсе нәрсә юк; **~ шку́ру неуби́того медве́дя** үтермәгән аюның тиресен тунау (бүлешү)

дели́ться *несов.* **1.** (*разделяться*) бүленү, аерылу **2.** (*производить раздел имущества*) бүленеп (аерылып) чыгу, башка чыгу **3.** *чем с кем* бүлешү; **~ ку́ском хле́ба** икмәк сыныгын бүлешү **4.** *перен. чем с кем* уртаклашу; **~ о́пытом** тәжрибә уртаклашу **5.** *мат.* бүленү, бүленә алу; **де́сять де́лится на́ пять** ун бишкә бүленә **6.** *страд. от* **дели́ть** 1

ершо́в||ый, -ая, -ое шыртлака ...ы, шыртлака балык ...ы; **~ая уха́** шыртлака шулпасы

есау́л *м* есаул (*революциягә кадәр казачий гаскәрләрдә офицер чины*)

е́сли *союз* **1.** ...са; әгәр ...са, әгәр дә ...са; **~ придёт, пусть зайдёт ко мне** килсә, миңа керсен; **~ расте́ние не поли́вать, оно́ засо́хнет** үсемлекне сугармасаң, ул корыр **2.** (*при противопоставлении, сопоставлении главного предлож. с придат.*) ...ган вакытта; ...са[лар]; **е́сли на восто́ке на́шей страны́ у́тро, то на за́паде — ве́чер** илебезнең көнчыгышында иртә булган вакытта, көнбатышта кич була **3.** (*с частицей «бы»*) ...ган булса; **~ бы я знал, то не пришёл бы** белгән булсам, килмәгән булыр идем ◆ **~ бы да кабы́** ≈ «дыр»ны чәчкәнгә илле ел ди, һаман да тишелмәгән ди

есте́ственно *нареч.* **1.** табигый, табигый рәвештә, табигый буларак; **вести́ себя́ ~** үзен табигый тоту **2.** *в знач. вводн. сл.* табигый ки, билгеле, әлбәттә; **он, ~, согласи́лся** ул, билгеле, риза булды

есте́ствен||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* табигый, табигать ...ы; **~ые бога́тства Тата́рстана** Татарстанның табигый байлыклары; **~ые нау́ки** табигать фәннәре; **~ая смерть** табигый үлем; **~ый цвет лица́** битнең табигый төсе; **~ый путь разви́тия** үсешнең табигый юлы

естество́ *с* **1.** *книжн.* (*суть, сущность*) асыл, табигый үзлек,төп үзлек; **э́то я́вствует из самого́ ~а́ вопро́са** бу — мәсьәләнең табигый үзлегеннән үк күренеп тора **2.** *уст.* (*природа*) табигать

естествове́д *м уст.* табигать белгече; табигать укытучысы

естествове́дение *уст.*, **естествозна́ние** *с* табигать белеме, табигать фәннәре

естествоиспыта́тель *м* табигать фәннәре белгече

есть I *несов.* **1.** *кого-что и без доп.* ашау, туклану **2.** *что* (*разъедать*) ую, кисү, ашау; **кислота́ ест тка́ни** кислота тукымаларны ашый **3.** *что* (*причинять жгучую боль*) әчеттерү; **дым ест глаза́** төтен күзләрне әчеттерә ◆ **~ глаза́ми** *кого* күзләре белән ашау; **~ пое́дом** колак итен ашау

есть II **1.** *3 л.ед. наст. вр. от* **быть**; **2.** *в знач. сказ.* (*имеется*) бар; **~ ли у тебя́ вре́мя?** синең вакытың бармы?

есть III *межд. воен.* есть, була ул

ефре́йтор *м* ефрейтор

е́хать *несов.* **1.** бару; **~ на парохо́де** пароходка утырып бару; **~ верхо́м на ло́шади** атка атланып бару **2.** (*уезжать*) китү; **экспеди́ция е́дет на Пами́р** экспедиция Памирга китә ◆ **да́льше ~ не́куда** актык чиккә барып җиттек, килеп терәлдек, башка барыр урын юк

ехи́дна *ж* **1.** *зоол.* ехидна (*керпе сыман хайван*) **2.** *зоол.* ехидна (*агулы елан*) **3.** *разг.* (*о человеке*) елан, кара елан, кара эчле кеше

ехи́дничать *несов. разг.* мыскыллау, мыскыллап көлү, чәнчүле сүзләр әйтү

ехи́дный, -ая, -ое мәкерле, хәйләле, хәйләкәр; ачы, чәнчүле, зәһәр; **~ челове́к** мәкерле кеше; **~ смех** ачы көлү

ехи́дство *с* ачы теллелек; мәкерлелек, хәйләкәрлек, зәһәрлек

ещё *нареч.* **1.** (*вдобавок и при сравн. ст.*) тагы, тагын, янә; **возьми́ ~ э́ту кни́гу** тагы бу китапны ал **2.** (*до сего времени*) әле; **он ~ не око́нчил шко́лу** ул әле мәктәпне бетермәгән **3.** (*уже*) инде, ук; **он уе́хал ~ неде́лю тому́ наза́д** ул инде моннан бер атна элек китте **4.** *в знач. частицы усил.* тагын да; **он ~ сильне́е** ул тагын да көчлерәк ◆ **всё ~** әле хәзер дә, һаман, хәзергә кадәр; **да ~ [и]** шуның өстенә, өстәвенә, җитмәсә тагы; **он не о́чень спосо́бен, да ~ лени́в** ул булдыксыз, җитмәсә тагы ялкау; **~ ничего́** хәзергә ярый әле, ярыйсы әле

Ж

ж I *см.* **же** I

ж II *см.* **же** II

жа́ба I *ж* гөберле бака, җир бакасы, йорт бакасы

жа́ба II *ж*: **грудна́я ~** *уст.* күкрәк бакасы (*авыру*)

жа́берн||ый, -ая, -ое **1.** саңак ...ы; **~ые ду́жки** саңак дугалары; **~ые отве́рстия** саңак тишекләре **2.** саңаклы: **~ые живо́тные** саңаклы хайваннар

жа́б||ий, -ья, -ье гөберле бака ...ы; **~ьи ла́пки** гөберле бака аяклары

жа́бник *м бот.* куян йоны (*улән*)

жабо́ *с нескл.* жабо (*челтәр яки җиңел тукымадан ясалган бизәкле яка*)

жа́бры *мн.* саңак

жаве́лев||ый, -ая, -ое: **~ая вода́** жавель суы (*хлорлы зәһәр эремә*)

жа́воронок *м* тургай, сабан тургае

жа́дина *м прост.* комсыз, ачкүз, карун, саран

жа́дничать *несов. разг.* комсызлану, ачкүзләнү, саранлану

жа́дность *ж* **1.** комсызлык, ачкүзлелек; **есть с ~ю** комсызлык белән ашау **2.** (*скупость, корыстолюбие*) саранлык, хирыслык

жа́дн||ый, -ая, -ое **1.** комсыз, ачкүз; **~ый к деньга́м** акчага комсыз **2.** атлыгып торучы, ашкынып торучы; **~ый на рабо́ту** эшләргә атлыгып торучы; **~ое любопы́тство** ник кызыксыну **3.** (*скупой, корыстолюбивый*) саран, карун, хирыс ◆ **~ый взор** йотылып карау

жадю́га *м, ж см.* **жа́дина**

жа́жд||а *ж* **1.** сусау, эчәсе килү, тамак кибү; **си́льная ~а** бик нык сусау; **утоли́ть ~у** сусауны басу **2.** *перен. чего и с неопр.* көчле теләк, ашкыну, атлыгу, омтылу; **~а сча́стья** бәхеткә омтылу

жа́жд||ать *несов.* **1.** *уст.* (*хотеть пить*) сусау, эчәсе килү, тамак кибү **2.** *перен. чего и с неопр., книжн.* көчле рәвештә теләү, нык теләү, ашкынып тору; **наро́ды ~ут ми́ра** халыклар тынычлык телиләр

жака́н *м* жакан (*ау мылтыгыннан ату өчен ясалган пуля*)

жаке́т *м* жакет (*кыска итеп тегелгән өске кием*)

жаке́тка *ж разг. см.* **жаке́т**

жале́||ть *несов.* **1.** *кого-что* кызгану, аяу, жәлләү **2.** *о ком-чём, чего и с союзом «что»* (*сожалеть*) кайгыру, үкенү; **он ~ет о допу́щенной оши́бке** ул үзенең ясаган хатасы өчен үкенә **3.** *кого-что, чего* кызгану; **~ть де́ньги** *или* **~ть де́нег** акча кызгану

жа́лить *несов. кого-что* чагу; **пчёлы жа́лят** умарта кортлары чага

жа́лк||ий, -ая, -ое **1.** кызганыч, аяныч; **~ий вид** кызганыч кыяфәт; кызганыч чырай; **~ая улы́бка** кызганыч елмаю **2.** кызганычлы, мескен, боек, бичара; **~ий челове́к** мескен кеше **3.** начар, бик начар, таушалган, тузган; **ру́копись име́ла ~ий вид** кулъязма бик начар хәлдә иде **4.** бик аз, бик кечкенә; **~ая су́мма** бик аз сумма ♦ **~ая смерть** кызганычлы үлем; **~ий трус** мескен куркак; **~ие слова́** кызгандыргыч сүзләр

жа́лко *нареч.* **1.** кызганыч[лы]; **~ улыбну́ться** кызганычлы елмаю **2.** *в знач. сказ. безл. кого-что, кого-чего и с неопр.* жәл, жәлли; кызганыч, кызгана; **ему́ ~ поте́рянного вре́мени** *или* **~ поте́рянное вре́мя** аңа әрәмгә киткән вакыт кызганыч

жа́ло *с* **1.** (*насекомых*) ук, чаккыч; (*растений*) чәнечке; (*змей*) тел **2.** (*инструментов*) йөз, тел, кискеч ♦ **~ сати́ры** сатира угы

жа́лоб||а *ж* зар, зарлану; **~ы на одино́чество** ялгызлыктан зарлану **2.** жалоба, шикаять; **пода́ть ~у** жалоба бирү

жа́лобн||ый, -ая, -ое кызганыч, аяныч, жан әрнеткеч; **~ый писк** кызганыч чыелдау ♦ **~ая кни́га** жалобалар кенәгәсе

жа́лобщик *м* жалоба бирүче, шикаять итүче, шикаятче

жа́лобщица *ж см.* **жа́лобщик**

жа́лованн||ый, -ая, -ое: **~ая гра́мота** *ист.* жалованный грамота (*льготалар белән файдалану өчен югары хакимият тарафыннан бирелгән грамота*)

жа́лованье *с уст.* хезмәт хакы; эш хакы

жа́л||овать *несов.* **1.** *кого-что чем, кому что, уст.* (*награждать*) бүләкләү, бүләк итү, бүләк итеп бирү **2.** *кого-что, разг.* тәкъдир итү, ярату; **его́ не о́чень ~уют** аны бик үк яратып бетермиләр **3.** *уст.* (*приходить, посещать*) килү; **он давно́ к нам не ~ует** аның күптәннән безгә килгәне юк

жа́ловаться *несов.* **1.** *на кого-что или с союзом «что»* зарлану; **~ на нездоро́вье** саулык юкка зарлану **2.** *на кого-что* (*подавать жалобу*) жалоба бирү, шикаять итү **3.** *на кого-что и без доп.* (*ябедничать*) әләкләү, чагу

жалоно́сн||ый, -ая, -ое *зоол.* уклы, чаккычлы, чага торган; **~ые насеко́мые** чага торган бөҗәкләр

жа́лостлив||ый, -ая, -ое *разг.* кызганулы, аяучан, кызганучан, жәлләүчән; **~ челове́к** кызганучан кеше; **~ взгляд** кызганулы караш

жа́лостн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** (*сострадательный, соболезнующий*) кызганулы, кызганучан, аяучан; **~ое выраже́ние лица́** кызганулы чырай **2.** кайгылы, сагышлы, кызганыч, аяныч, җан әрнеткеч; **~ый го́лос** аяныч тавыш

жа́лост||ь *ж* **1.** кызгану, жәлләү, аяу; **сде́лать** *что-л.* **из ~и** кызганудан *нәрсә булса да* эшләү **2.** кайгы, үкенеч, кызганыч; **кака́я ~ть!** нинди кызганыч!

жаль 1. *в знач. сказ. безл. кого-что и с неопр.* кызганыч, жәл; **~ бра́та** абый кызганыч; **~ смотре́ть на него́** аңарга каравы да кызганыч **2.** *в знач. сказ. безл. кого-что, кого-чего* (*о чувстве горечи, грусти*) кызганыч, жәл; **~, что вы уезжа́ете** китәсез икән, кызганыч; **~, что он не придёт** кызганычка каршы, ул килми **3.** *вводн. сл.* кызганычка каршы, үкенечкә каршы; **зайти́ бы, ~, вре́мени нет!** кызганычка каршы, кереп чыгарга вакытым юк!

жалюзи́ *с нескл.* жалюзи (*пластинкалардан ясалган тәрәзә пәрдәсе*)

жандарм *м* жандарм

жандарме́рия *м* жандармерия

жанр *м* жанр (**1.** *әдәбиятның, сәнгатьнең төрләре*) **2.** *көнкурешне сурәтли торган рәсем әсәре* **3.** *стиль, манера*

жа́нров||ый, -ая, -ое жанр ...ы; **~ая разнови́дность** жанр төрлелеге; **~ая живопись** жанр рәссамчылыгы

жар *м* **1.** кызу[лык], эссе[лек]; **о́бда́ло ~ом** эсселек килеп бәрелде **2.** кызу урын, эссе урын; **не сади́сь на са́мом ~ý** кызу урында утырма; **кастрю́ля стои́т на ~ý** кәстрүл кызуда тора **3.** *разг.* утлы күмер; **вы́грести ~ из печи́** мичтәге утлы күмерне тартып чыгару **4.** (*повышенная температура тела*) жар, кызу **5.** дәрт, ашкыну; **рабо́тать с ~ом** дәртләнеп эшләү ♦ **его́ броса́ет в ~ и в хо́лод** аны бер кыздыра, бер калтырата; **как ~ гори́т** ялт итеп тора, ут кебек янып тора

жара́ *ж* эссе, кызу, кызулык, эсселек; **си́льная ~** бик эссе [көн]; **насту́пила ~** эссе көннәр башланды

жарго́н *м* жаргон (*әдәби телдән аермалы буларак, аерым бер социаль төркем кешеләре арасында гына кулланыла торган үзенчәлекле тел, сөйләм*); **профессиона́льный ~** профессиональ жаргон

жаргони́зм *м* жаргон сүз, жаргонизм

жарго́нн||ый, -ая, -ое жаргон ...ы; **~ое сло́во** жаргон сүз

жа́рен||ый, -ая, -ое кыздырган, кыздырылган, куырган, куырылган; **~ая карто́шка** кыздырган бәрәңге; **~ая ры́ба** кыздырылган балык

жа́рить *несов.* **1.** *кого-что* кыздыру, кыздырып пешерү; **~ котле́ты** кәтлит кыздыру **2.** *кого-что и без доп.* (*жечь — о солнце*) кыздыру **3.** *что* (*калить на сковороде*) куыру, кыздыру; **~ горо́х** борчак куыру **3.** *прост.* оста башкару, сиптерү; **~ на гармо́шке** гармунда сиптерү

жа́рит||ься *несов.* **1.** куырылу, кыздырылу, кызу; **ры́ба ~ся** балык кыза **2.** *разг.* кызыну **3.** *страд. от* **жа́рить** I

жа́рк||ий, -ая, -ое **1.** кызу, эссе; (*о печи*) кайнар; **~ая ба́ня** эссе мунча; **~ое ле́то** эссе җәй; **~ий кли́мат** эссе климат **2.** *перен.* кызу, каты; кайнар; **~ий спо́р** кызу бәхәс; **~ий бой** каты сугыш; **~ий поцелу́й** кайнар үбү ♦ **~ие стра́ны** эссе илләр

жа́рко *нареч.* **1.** эссе итеп, кызу итеп; **~ затопи́ть ба́ню** мунчаны кызу итеп ягу **2.** *перен.* кызып, кызу рәвештә; **~ спо́рить** кызып бәхәсләшү **3.** *в знач. сказ. безл.* эссе, кызу; **сего́дня о́чень ~** бүген бик эссе; **мне ~** миңа эссе

жарко́е *с* куырдак, кыздырма, кыздырган ашамлык

жарови́ня *ж* тимер учак, мангал

жаровыно́слив||ый, -ая, -ое *бот.* кызуга чыдам, эссегә чыдам; **~ые расте́ния** кызуга чыдам үсемлекләр

жаропонижа́ющ||ий, -ая, -ее температураны төшерә торган; **~ие сре́дства** температураны төшерә торган дарулар

жаропро́чный, -ая, -ое *тех.* утка чыдам; **~ кирпи́ч** утка чыдам кирпеч

жаросто́йкий, -ая, -ое *тех.* утка чыдам; **~ мета́лл** утка чыдам металл; **~ бето́н** утка чыдам бетон

жаротру́бный, -ая, -ое: **~ котёл** *тех.* кайнар көпшәле казан (*эчендәге торбалар буенча кайнар газ узудан җылына торган казан*)

жар-пти́ца *ж фольк.* бәхет кошы (*әкиятләрдә сөйләнелә торган алтын каурыйлы кош*)

жасми́н *м* ясмин

жа́тва *ж* **1.** (*уборка хлебо́в*) уру **2.** (*время уборки хлебо́в*) урак өсте **3.** (*сжатые хлеба́*) (*җыеп алынган*) уңыш

жа́тка *ж* ургыч, уру машинасы

жать I *несов.* **1.** *что и без доп.* кысу; **сапо́г жмёт но́гу** итек аякны кыса; **~ру́ку** кулны кысу **2.** *что* сыгу, сыгып чыгару; **~ сок из винограда́** йөземнең согын сыгу **3.** *кого-что, прост.* кысрыклау, ашыктыру; **сро́ки жмут** вакыт ашыктыра

жать II *несов. что* уру; **~ рожь** арыш уру

жа́||ться *несов.* **1.** бөрешү; кысылу; **~ся от хо́лода** суыктан бөрешү **2.** сырышу, елышу, сыену; **ребёнок ~лся к ма́тери** бала анасына сырыша иде **3.** *перен. разг.* (*стесняться*) тартыну, оялып тору **4.** *перен. разг.* (*скупиться*) саранлану, карунлану, кысылу, бирәсе килмәү

жбан *м* жбан (*савыт*); **~ ква́су** бер жбан куас

жва́чк||а *ж* күшәү; **жева́ть ~у** күшәм күшәү

жва́чн||ый, -ая, -ое күшәүче, күши торган; **~ые живо́тные** күшәүче хайваннар

жгут *м* жгут, бау; **соло́менный ~** көлтә бавы; **кровоостана́вливающий ~** кан агуын туктатучы жгут

жгу́тик *м* **1.** *уменьш. от* **жгут**; **2.** *зоол.* төкчә, камчы (*түбән төзелешле организмнарның хәрәкәтләну органнары*)

жгу́ч||ий, -ая, -ее **1.** кайнар, эссе, кызу; **~ие лучи́ со́лнца** кояшның кызу нурлары **2.** (*о холоде*) чатнама, чеметчереп ала торган; (*о боли*) үзәккә үтә торган, бик каты, йөрәккә тиярлек **3.** *перен.* тирән, зур, бик ныk; **~ий стыд** зур оят; **~ее раска́яние** бик ныk үкенү ♦ **~ие слёзы** кайнар күз яшьләре; **~ий брюне́т** чем кара чәчле кеше; **~ие вопро́сы совреме́нности** хәзерге заманның иң мөһим мәсьәләләре

жда́||ть *несов.* **1.** *кого-что, кого-чего* көтү, көтеп тору; **~ть по́езда** поезд көтү; **~ть, когда́ переста́нет дождь**

ЖЕ-ЖЕМ

яңгыр туктаганын көтеп тору **2.** *чего (надеяться)* өмет итү; **~ть награ́ды** бүләк өмет итү **3.** *(считать, предполагать)* уйлау, ...дип уйлау, ышанып тору; **~ли, что он бу́дет хоро́шим рабо́тником** ул яхшы хезмәткәр булыр дип уйлаганнар иде ♦ **~ть не дожда́ться** сабырсызланып көтү, түземсезләнеп көтү; **~ть у мо́ря пого́ды** ≈ аяз күктән яңгыр көтү; **жду не дожду́сь** зарыгып (өзелеп) көтәм; **заста́вить себя́ ~ть** озак көттерү

же I *союз* **1.** *против.* ә, исә; **я уезжа́ю, това́рищ же остаётся** мин китәм, ә иптәшем кала **2.** *присоед.* ә; **когда́ мы прие́хали, прие́хали же мы ле́том** ... без килгән чакта, ә без җәен килгән идек...

же II *частица* **1.** *усил.* соң, инде, бит, ләбаса; ук, үк; **когда́ же вы бу́дете гото́вы?** кайчан соң сез әзер булырсыз?; **пойдём же!** барыйк инде!; **есть же у нас хоро́шие кни́ги!** бездә яхшы китаплар бар бит!; **мы пое́дем сего́дня же** без бүген үк китәбез **2.** *(после нареч. и мест. означает полное тождество)* ук, үк; **тот же** шул ук; **тако́й же** шундый ук; **тогда́ же** шул вакытта ук

жёван||ый, -ая, -ое **1.** чәйнәлгән; **~ый хлеб** чәйнәлгән икмәк **2.** *перен. разг.* изелгән; бөгәрләнеп (таушалып) беткән; **~ое пла́тье** бөгәрләнеп беткән күлмәк

жева́тельн||ый, -ая, -ое **1.** чәйнәү ...ы; **~ые мы́шцы** чәйнәү мускуллары **2.** чәйни торган; **~ая рези́нка** чәйни торган резинка; **~ый таба́к** насвай

жева́ть *несов. что* чәйнәү; **~ пи́щу** азык чәйнәү ♦ **~ губа́ми** иреннәрне кыймылдату

жезл *м жезл* **(1.** *тирәлек һәм дәрәҗә билгесе булган махсус таяк* **2.** *тимер юлда поездларның йөрешен тәртипкә салу өчен хезмәт итә торган автомат приборның металл таягы* **3.** *регулировщик таягы)*

жела́ние *с* теләк, дәрт; **заве́тное ~** иң зур теләк; **име́ть ~** теләк булу; **горе́ть ~ем** теләк белән яну **2.** *(просьба)* үтенеч, теләк; **испо́лни моё после́днее ~** минем соңгы теләгемне үтә

жела́нн||ый, -ая, -ое **1.** көтелгән, көтеп алынган, теләп алынган; **~ая весть** көтеп алынган хәбәр **2.** сөекле, газиз, кадерле; **~ый друг** кадерле дус

жела́тельный, -ая, -ое кирәкле, көтелгән, теләгән; **де́ло при́няло ~ для нас оборо́т** эш без теләгән юнәлешне алды

желати́н *м желатин (кулинариядә, фотографиядә h.б.ш. кулланыла)*

желати́нов||ый, -ая, -ое желатин ...; желатиннан ясалган; **~ые пласти́нки** *тех.* желатин пластинкалар; **~ый сту́день** желатиннан ясалган койка

жела́||ть *несов. кого-что, чего, с неопр. и с союзом «чтобы»* теләү, ...ысы килү; **я ~ю его́ ви́деть** минем аны күрәсем килә ♦ **оставля́ет ~ть лу́чшего** бик әйбәт түгел, кимчелекле

жела́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **жела́ть; 2.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* теләк белдерүчеләр, теләүчеләр; **~их мно́го** теләк белдерүчеләр күп

желва́к *м* төер, оры; каты шеш; **на ску́лах заходи́ли желваки́** аның яңакларында төерләр йөри башлады

желе́ *с нескл.* **1.** желе *(желатин белән җимеш суын кушып әзерләгән кесәл сыман ашамлык)* **2.** *(студень)* койка, дерелдәвек

железа́ *ж* биз; **слюнна́я ~** төкрек бизе

желе́зистый I, -ая, -ое *хим.* тимерле, составына тимер кергән; **~ исто́чник** тимерле чишмә

желе́зист||ый II, -ая, -ое биз ...ы; **~ая кле́тка** биз күзәнәге

желе́зка I *ж разг.* тимер кисәге

желе́зк||а II: **на всю ~у** бөтен көчкә, ахырына кадәр

желе́зка *с (резец в рубанке)* ышкы тимере, рубанок тимере

железнодоро́жник *м* тимерюлчы, тимер юлда эшләүче

железнодоро́жный, -ая, -ое тимер юл ...ы; **~ тра́нспорт** тимер юл транспорты

желе́зный, -ая, -ое **1.** тимер ...ы; **~ая руда́** тимер рудасы; **~ая стру́жка** тимер йомычкасы **2.** тимердән ясалган, тимер ...; **~ая крова́ть** тимер карават **3.** *перен.* корычтай: **~ое здоро́вье** корычтай сәламәтлек **4.** *перен.* нык; **~ая дисципли́на** нык дисциплина; **~ая во́ля** нык ихтыяр; **~ая ло́гика** нык логика ♦ **~ая доро́га** тимер юл; **~ый век** *археол.* тимер гасыры

железня́к *м* тимер рудасы

желе́зо *с* **1.** *хим.* тимер **2.** *собир.* тимер-томыр [әйберләр]; **торгова́ть ~м** тимер-томыр әйберләр белән сату итү **3.** *разг. (лекарство)* тимерле дару

железобето́н *м* тимер-бетон *(төзү материалы)*

железобето́нн||ый, -ая, -ое тимер-бетон ..., тимер-бетоннан ясалган; **~ое сооруже́ние** тимер-бетон корылма

железоплави́льный, -ая, -ое тимер эретә (коя) торган

железопрока́тный, -ая, -ое тимер прокатлау ...ы, тимер прокатлый торган стан

железору́дн||ый, -ая, -ое **1.** тимер рудалы; **~ый райо́н** тимер рудалы район **2.** тимер рудасы ...ы; **~ая промы́шленность** тимер рудасы промышленносте

железя́ка *ж разг. см.* **желе́зка** I

желе́йный, -ая, -ое желе...ы; желедән әзерләнгән; **~ мармела́д** желедән әзерләнгән мармелад

жёлоб *м* улак, колаша, ялгаш

желоб́чат||ый, -ая, -ое колашасыман; улаксыман; **~ая черепи́ца** улаксыман сырлы чирәп

жело́нка *ж тех.* желонка *(скважинадан сыеклык, ком һ.б.ш. күтәрту җайланмасы)*

желте́ть *несов.* **1.** *(становиться жёлтым)* саргаю, сары төскә керү **2.** *(виднеться — о чём-л. жёлтом)* саргаеп тору, сары булып күренү

желте́ться *несов. см.* **желте́ть** 2

желтизн||а́ *ж* сарылык, сары төс; **его́ лоб отлива́л ~о́й** аның маңгае сары төскә кергән

желти́нка *ж разг.* сары тап, сары тимгел, саргылт төс

желти́ть *несов. что* саргайту, сары төскә кертү, сарыга буяу

желто́к *м* йомырка сарысы

желтоко́жий, -ая, -ее сары тәнле

желтокры́лый, -ая, -ое сары канатлы

желтоли́цый, -ая, -ое сары чырайлы (йөзле), сары тутлы

желторо́тый, -ая, -ое **1.** сары томшыклы, сары авызлы *(кош баласы турында)* **2.** *перен. разг.* борын асты кипмәгән, тәжрибәсез *(тормыш тәжрибәсе булмаган кеше турында)*

желтоцве́т *м* сары чәчәк *(сары чәчәкле уләннәрнең гомуми исеме)*

желту́ха *ж* сары [авыруы], сары төшү

желту́шный, -ая, -ое сары авыруы ...ы, сары авырулы

жёлт||ый, -ая, -ое *прям., перен.* сары; **~ая кра́ска** сары буяу; **~ая лихора́дка** сары бизгәк *(тропикларда була торган йогышлы авыру)*; **~ая ра́са** *уст.* сары раса, сары тәнле кешеләр; **~ая пре́сса** сары матбугат; **~ые профсою́зы** сары профсоюзлар *(эшчеләр сыйныфы интересларына хыянәт итә торган профсоюзлар)*

желтя́к *м прост.* саргайган кыяр

желудёвый, -ая, -ое имән чикләвеге ннән ясалган, имән чикләвеге ...ы; **~ кофе** имән чикләвегеннән ясалган кофе

желу́д||ок *м* ашказаны; **катар́ ~ка** ашказаны катары; **здоро́вый ~ок** сау ашказаны ♦ **расстро́йство ~ка** эч китү

желу́дочек *м анат.* карынчык

желу́дочно-кише́чный, -ая, -ое ашказаны-эчәк ...ы; **~ые заболева́ния** ашказаны-эчәк авырулары

желу́дочн||ый, -ая, -ое **1.** ашказаны ...ы; **~ый сок** ашказаны сүле **2.** ашказанын дәвалый торган; **~ые ка́пли** ашказанын дәвалый торган тамчылар

жёлудь *м* имән чикләвеге

жёлчность *ж (раздражительность)* усал булу, зәһәрлек

жёлчный, -ая, -ое **1.** үт ...ы; **~ пузы́рь** үт куыгы, үт капчыгы **2.** *перен. (раздражительный, злой)* усал, тиз ачуланучан, зәһәр

жёлчь *ж* **1.** үт, үт суы **2.** *перен. (раздражение)* зәһәр, усаллык

жема́ниться *несов. разг.* назлану, кылану, сырлану

жема́нница *ж разг.* кыланчык [назлы] хатын

жема́нничать *несов. разг.* назлану, кылану, сырлану

жема́нность *ж* назлылык, кыланчыклык

жема́нный, -ая, -ое назлы, кыланчык, кыстатучан

жема́нство *с* назлылык, назлану, кыланчыклык, кылану

же́мчуг *м* энже

жемчу́жина *ж* **1.** энҗе бөртеге **2.** *перен.* хәзинә; **стихи́ Тука́я — ~ татарской поэ́зии** Тукай шигырьләре — татар поэзиясенең хәзинәсе ул

жемчу́жница *ж* энҗе моллюскысы *(кабыгы эчендә энҗе барлыкка килә торган моллюск)*

жемчу́жн||ый, -ая, -ое 1. энҗе ...ы; **~ое ожере́лье** энҗе муенса 2. *перен.* энҗе кебек ак, энҗесыман, энҗедәй ак; **~ые зу́бы** энҗедәй ак тешләр

жена́ *ж* хатын, ир хатыны

жена́тый, -ая, -ое өйләнгән, хатынлы

жени́||ть *сов., несов. кого* өйләндерү, хатын алып бирү ♦ **без меня́ меня́ ~ли** мине үзем юкта өйләндергәннәр (*кешегә үзенең ризалыгыннан башка берәр эш йөкләү турында*)

жени́тьба *ж* өйләнү, хатын алу

жени́ться *сов., несов.* өйләнү, хатын алу; өйләнешү, никахлашу

жени́х *м* кияү буласы кеше, кыз яраткан егет ♦ **смотре́ть ~о́м** шат күренү, шат күңелле булу

женолюби́вый, -ая, -ое хатын-кызларны бик яратучан

женоненави́стник *м* хатын-кызларны яратмаучы (*дошман күрче, хатын-кызлардан качучы*)

женоненави́стнический, -ая, -ое хатын-кызларны яратмый (дошман күрә) торган, хатын-кызлардан кача торган

женоненави́стничество *с* хатын-кызларны яратмау (дошман күрү)

женоподо́бный, -ая, -ое хатын-кызга охшаган, хатын-кыз төсле

женоуби́йца *м* хатынын үтерүче, үз хатынын үтергән кеше

же́нск||ий, -ая, -ое хатын-кыз[лар] ...ы; **~ое любопы́тство** хатын-кызлар кызыксынуы; **~ая кома́нда** хатын-кызлар командасы ♦ **~ая ло́гика** *шутл.* хатыннар логикасы (*эзлекле булмаган логика*); **~ие боле́зни** *мед.* хатын-кыз авырулары; **~ий род** *грам.* женский род; мәэннәс (*уст.*)

же́нственность *ж* нәфислелек, гүзәллек, мөлаемлылык, йомшаклык

же́нственный, -ая, -ое мөлаем, хатын-кызларга хас, нәфис, хатын-кыз табигатьле

же́нщина *ж* 1. хатын, хатын-кыз 2. (*взрослая, не девушка*) хатын кеше, хатын

женьше́нь *м* женьшень (*Ерак Көнчыгышта үсә торган дару үсемлеге*)

жерди́на *ж разг. см.* **жердь**

жердь *ж* колга, киртә

жерёбая *ж* буаз (*бия, ишәк, дәве турында*)

жеребёнок *м* (*до года*) колын, колкай; (*от одного года до двух лет*) кырыкмыш тай; (*до трёх лет*) тай

жеребе́ц *м* айгыр; **племенно́й ~** нәселле айгыр

жереби́ться *несов.* колынлау (*бия, ишәк, дәве турында*)

жеребо́к *м* (*вакытсыз туган*) колынның тиресе

жерёбость *ж* буазлык (*бия, ишәк, дәве турында*)

жеребьёвк||а *ж* шобага салу, жирәбә салу, таяк тотышу; **провести́ ~у** шобага салу

жеребя́чий, -ья, -ье колын ...ы, тай ...ы

же́рех *м* опты, ак опты

жерли́ца, же́рлица *ж* жерлица (*балык тоту коралы*)

жерло́ *с в разн. знач.* авыз, тишек; **~ пу́шки** туп авызы; **~ вулка́на** вулкан авызы; **~ пе́чи** мич авызы

жёрнов *м* тегермән ташы

же́ртв||а *ж* корбан; **~ы наводне́ния** су басу корбаннары; **принести́ в ~у** *прям., перен. кого-что* корбан итү 2. авырлык, кыенлык, үзен корбан итү; **пойти на любы́е ~ы** теләсә нинди авырлыклар алдында да тукталып калмау 3. *уст.* (*пожертвование*) иганә, бүләк

же́ртвенник *м* корбан чалу урыны, келәү урыны (*борынгы мәҗүсиләрдә*)

же́ртвенн||ый, -ая, -ое 1. *уст.* корбан ...ы; **~ая кровь** корбан каны 2. (*самоотверженный*) җаны-тәне белән ..., үзен аямастан

же́ртвовать *несов.* 1. *кого-что и без доп.* бүләк итеп бирү, иганә итү 2. *кем-чем* корбан итү, фида итү, үзен аямау; санашмау; **~ собо́й** үзен корбан итү; **~ здоро́вьем** сәламәтлек белән санашмау

жертвоприноше́ние *с* корбан чалу [йоласы] (*борынгыда*); **соверша́ть ~** корбан итү

жест *м* 1. ым, ишарә, кул хәрәкәте; **вырази́тельный ~** тирән мәгънәле ишарә; **привы́чный ~** гадәти ишарә 2. *перен.* кыланыш; **благоро́дный ~** галиҗәнапларча кыланыш; **сде́лать краси́вый ~** яхшы эш эшләү

жестикули́рование *с см.* **жестикули́ровать**

жестикули́ровать *несов.* кул хәрәкәтләре ясау, кулларны селтәү

жестикуля́ция *ж* кулларны селтәү

жёстк||ий, -ая, -ое 1. каты; **~ое мя́со** каты ит; **~ие во́лосы** каты чәч 2. *перен.* кырыс, каты; **~ий хара́ктер** кырыс характер 3. *перен.* кискен, катгый; **~ие сро́ки** катгый сроклар; **~ие усло́вия** кискен шартлар ♦ **~ая вода́** каты су; **~ий ваго́н** каты вагон

жесткокры́лые *мн. зоол.* катыканатлылар

жесто́к||ий, -ая, -ое 1. каты күңелле, аяусыз, рәхимсез, кансыз, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез; **~ий челове́к** мәрхәмәтсез кеше 2. бик көчле, бик нык, бик каты; **~ая борьба́** бик каты көрәш; **~ое сопротивле́ние** каты каршылык ♦ **~ая необходи́мость** котылгысыз кирәклек, үтә зарурлык; **~ие моро́зы** чатлама салкыннар

жестокосе́рдие *с высок.* каты күңеллек, кансызлык, мәрхәмәтсезлек

жестокосе́рдный, -ая, -ое *высок.* каты күңелле, мәрхәмәтсез, кансыз, аяусыз, шәфкатьсез

жесто́кость *ж* катылык, рәхимсезлек, кансызлык, шәфкатьсезлек, мәрхәмәтсезлек; **~ нра́вов** гореф-гадәтләрнең рәхимсезлеге 2. (*жестокий поступок*) каты мөгамәлә, каты чара

жесть *ж* калай

жестя́ник *м см.* **жестя́нщик**

жестя́нка *ж* 1. (*жестяная коробка*) калай савыт, калай банка 2. *разг.* (*кусок жести*) калай кисәге

жестя́нщик *м* чиләк төпләүче, калайчы, суык тимерче

жето́н (1. *ярышта катнашучыга приз итеп, берәр вакыйгада катнашучыга истәлек итеп бирелә торган металл значок* 2. *берәр әйбер, мәс. кассадан акча, алу өчен бирелә торган цифрлы калай кисәге*)

жечь *несов.* 1. *кого-что* яндыру; **~ бума́гу** кәгазь яндыру 2. *что* ягу; **~ дрова́** утын ягу 3. *кого-что и без доп.* яндыру, кыздыру, көйдерү; (*о солнце*) көйдерү, кыздыру, пешерү; (*о морозе*) чеметтерү, чеметтереп алу; (*о крапиве*) чагу; (*о йоде*) яндыру, ачыттыру

же́чься *несов.* 1. чагу; **крапи́ва жжётся** кычыткан чага 2. пешерү; **утю́г жжётся** үтүк пешерә 3. *страд. от* **жечь** 1, 2

жже́ние *с* (*ощущение жара*) пешерү, кыздыру

жжёнка *ж* жжёнка (*көйдерелгән шикәр катнаштырып ромнан яки коньяктан хәзерләнгән эчемлек*)

жжёный, -ая, -ое кыздырылган, көйдерелгән, яндырылган; **~ са́хар** кыздырылган шикәр

живе́ц *м рыб.* җимбалык; маймыч, вак балык; **лови́ть на живца́** маймычка балык эләктерү

живи́нка *ж разг.* иҗади башлангыч; **~ в де́ле** эштә иҗади башлангыч

живи́тельный, -ая, -ое көч бирә торган, хәл кертә торган, дәртләндереп җибәрә торган; **~ во́здух** хәл кертә торган һава

жива́ *ж* сагыз, чәер

жи́вность *ж собир. разг.* вак терлек; йорт кошлары; вак хайваннар

жи́во *нареч.* 1. җанлы [итеп], тасвирлы [итеп]; ачык [итеп]; **~ расска́зывать** тасвирлы сөйләү 2. (*оживлённо*) рухлы, күтәренке рух белән, җанлы 3. *разг.* бик тиз, тиз генә, җәһәт кенә; **он ~ сбе́гал за до́ктором** ул тиз генә докторны алып килде

живогло́т *м прост.* кап-йот, ертлач, карун

живодёр *м прост.* тереләй тунаучы, кычкыртып талаучы

жив||о́й, -а́я, -о́е 1. тере, исән, исән-сау; **~а́я ры́ба** тере балык; **оста́ться в ~ы́х** исән калу 2. (*подлинный*) җанлы, чын, табигый; **~о́й приме́р геро́изма** геройлыкның җанлы мисалы; **изобрази́ть ~ы́х люде́й** чын кешеләрне сурәтләү; 3. (*яркий, выразительный*) җанлы; **~а́я бесе́да** җанлы әңгәмә 4. тере, елгыр, хәрәкәтчән; **~о́й ребёнок** тере бала; **~ы́е глаза́** хәрәкәтчән күзләр 5. (*отвечающий потребностям жизни*) тормышчан, тормыш өчен кирәкле 6. (*сильно переживаемый*) тирән тәэсирле, кискен кичерешле; **~о́е воспомина́ние** тирән тәэсирле истәлек; **~а́я оби́да** тирән тәэсирле үпкә ♦ **~а́я вода́** *фольк.* тереклек суы (*әкиятләрдә*); **~а́я и́згородь** үсемлек киртә, үсемлек койма **~а́я о́чередь** җанлы чират; **~а́я при-**

ЖИВ-ЖИМ

ро́да тере табигать (*хайваннар һәм усемлекләр*); **~ая ра́на** төзәлмәгән яра; **~ая си́ла** җанлы көчләр (*кешеләр, эш хайваннары*); **~ о́й вес** тереләй авырлык, тереләтә авырлык; **~ о́й инвента́рь** эш терлеге; **~ые цветы́** табигый чәчәкләр, чын чәчәкләр; **жив-здоро́в** исән-имин, исән-сау; **~ о́го ме́ста нет (не оста́лось)** зарарланмаган урыны калмаган; **заде́ть (забра́ть, затро́нуть) за ~ о́е** авырткан урынына кагылу, чуанына тию (кагылу); **на ~ую ни́тку** ашыгып, аннанмоннан гына (*эшләү*); әштер-өштер генә (*эшләп ташлау*); **ни жив ни мёртв** коты алынган, коты очкан, коты чыкканга (*куркудан*); **ни ~ о́й души́** бер генә җан иясе дә юк

живопи́сец *м* рәссам

живопи́сн||ый, -ая, -ое **1.** рәсем ясау ...ы; **~ая мастерска́я** рәсем ясау мастерское **2.** матур, рәсемдәге шикелле; **~ый вид** матур күренеш **3.** ачык, сәнгатьле, образлы; **~ое сравне́ние** сәнгатьле чагыштыру

жи́вопис||ь *ж* **1.** рәсем сәнгате; сынлы сәнгать; **уро́ки ~и** рәсем сәнгате дәресләре **2.** *собир.* рәсемнәр, картиналар; **вы́ставка ~и** картиналар күргәзмәсе

живороди́ящий, -ая, -ее тере бала тудыручы (*хайваннар һәм кайбер балыклар турында*)

живоры́бн||ый, -ая, -ое тере балыклы, тере балык ...ы; **~ый бассе́йн** тере балыклы буа; **~ое су́дно** тере балык судносы

жи́вость *ж* **1.** җитезлек, өлгерлек, хәрәкәтчәнлек; **~ движе́ний** хәрәкәтләр җитезлеге **2.** сизгерлек, үткенлек; **~ ума́** акылның үткенлеге

живо́т I *м* корсак, эч, карын

живо́т II *м уст.* җан, тормыш, тереклек; **не жале́ть ~а́** җанны да кызганмау; **не на ~, а на́ смерть** үз-үзеңне аямыйча

животво́рн||ый, -ая, -ое *высок.* җанландыра торган, рухландыра торган, җанландыргыч, дәртләндерә торган, яшәү көче бирә торган; **~ое де́йствие сна** йокының җанландыргыч тәэсире; **~ая си́ла любви́** мәхәббәтнең дәртләндерә торган көче

животи́на *ж прост.* йорт хайваны

животново́д *м* терлекче, малчы, терлекчелек белгече

животново́дство *с* терлекчелек, терлек асрау, терлек асраучылык

животново́дческ||ий, -ая, -ое терлекчелек ...ы; **~ая фе́рма** терлекчелек фермасы

живо́тное *с* **1.** тереклек иясе; хайван **2.** *разг.* хайван (*юньсез, тупас кеше турында*)

живо́тн||ый, -ая, -ое **1.** хайван[нар] ...ы; **~ый мир** хайваннар дөньясы **2.** хайваннарча ...; хайвани; **~ый страх** хайваннарча курку; **~ая страсть** хайвани дәрт ♦ **~ый э́пос** хайваннар турындагы эпос; **~ый орна́мент** хайваннар сурәте төшерелгән орнамент

животрепе́щущий, -ая, -ое көн үзәгендәге, көн кадагындагы, бүгенге көн өчен иң әһәмиятле, иң мөһим; актуаль; **~ вопро́с** иң мөһим мәсьәлә

живу́честь *ж* яшәргә сәләтлелек, чыдам булу, яшәүчәнлек

живу́чий, -ая, -ее **1.** (*жизнеспособный*) яшәүчән, яшәргә сәләтле **2.** *перен.* озак саклана торган, гомерлек; **~ обы́чай** озак саклана торган гадәт

жи́вчик *м* **1.** *см.* **живе́ц**; **2.** *разг.* (*о человеке*) тере (җитез, өлгер, елгыр) кеше **3.** *физиол.* аталык орлыгы

живьём *нареч. разг.* тереләй, тере килеш, тереләтә

жи́дк||ий, -ая, -ое **1.** сыек; **~ие тела́** *физ.* сыек җисемнәр; **~ий суп** сыек аш **2.** сирәк; **~ий лес** сирәк урман; **~ие во́лосы** сирәк чәч; **~ие аплодисме́нты** сирәк кул чабулар **3.** *перен. разг.* сыек, зәгыйфь, көчсез; **~ие му́скулы** көчсез мускуллар

жи́дкостн||ый, -ая, -ое *тех.* сыеклык ...ы; **~ые сво́йства** сыеклык үзлекләре

жи́дкост||ь *ж* **1.** сыеклык, сыекча; **ме́ры ~ей** сыекчалар үлчәве **2.** сыеклык; **~ь кле́я** җилемнең сыеклыгы **3.** сирәклек; **~ь воло́с** чәчнең сирәклеге

жи́ж||а *ж* сыекча; **навозная ~а** тирес сыекчасы **2.** *разг.* аш шулпасы, сыек шулпа; **нали́ть одно́й ~и** шулпаның сыгын гына салу

жизнеде́ятельность *ж* **1.** *биол.* тереклек эшчәнлеге; **~ органи́зма** организмның тереклек эшчәнлеге **2.** (*деятельность*) эшчәнлек, шөгыль

жизнеде́ятельный, -ая, -ое **1.** *биол.* яшәүгә сәләтле; **~ о́рган** яшәүгә сәләтле әгъза **2.** (*деятельный*) булдыклы, эшлекле (*кеше турында*)

жизнелю́б *м* тормыш сөюче, тормышка гашыйк

жизнелюби́вый, -ая, -ое тормыш сөючән, тормышка гашыйк

жизнелю́бие *с* тормыш сөючәнлек, тормышка гашыйк булу

жи́зненность *ж* **1.** яшәүгә сәләтлелек; тереклек сәләте; **~ органи́зма** организмның яшәүгә сәләтлелеге **2.** тормышчанлык; **~ иде́и** идеянең тормышчанлык

жи́зненный, -ая, -ое **1.** тормыш ...ы, тереклек ...ы; **~ путь** тормыш юлы; **~ о́пыт** тормыш тәҗрибәсе **2.** (*близкий к жизни, к действительности*) тормышчан **3.** *перен.* (*важный, необходимый*) тормыш өчен кирәкле, әһәмиятле, мөһим, кирәкле; **~ вопро́с** мөһим мәсьәлә

жизнеобеспе́чение *с* тереклек тәэмин итү

жизнеописа́ние *с* тәрҗемәи хәл

жизнера́достность *ж* шат күңеллелек; көр күңеллелек

жизнера́достный, -ая, -ое шат күңелле, көр күңелле; **~ челове́к** көр күңелле кеше; **~ хара́ктер** шат күңелле характер

жизнеспосо́бность *ж* яшәүгә сәләтлелек, тереклек сәләте; **~ органи́зма** организмның яшәүгә сәләтлелеге

жизнеспосо́бный, -ая, -ое **1.** яшәүгә сәләтле; **~ органи́зм** яшәүгә сәләтле организм **2.** эшкә сәләтле, сәләтле; **~ коллекти́в** эшкә сәләтле коллектив

жизнесто́йкий, -ая, -ое чыдам, түземле; **~ органи́зм** чыдам организм

жизнесто́йкость *ж* чыдамлык, түземлелек

жизнеустро́йство *с* нормаль тормыш шартлары булдыру

жизнеутвержда́ющ||ий, -ая, -ое тормышчан; тормышчанлык (*оптимизм*) белән сугарылган; **~ая тата́рская литерату́ра** оптимизм белән сугарылган татар әдәбияты

жизн||ь *ж* **1.** тереклек; **возникнове́ние ~и на Земле́** Җирдә тереклекнең барлыкка килүе; **~ь расти́тельного ми́ра** үсемлекләр дөньясының тереклеге **2.** гомер; **в тече́ние всей его́ ~и** бөтен гомере буена; **на всю ~ь** гомергә, гомер буена **3.** тормыш; **обще́ственная ~ь** иҗтимагый тормыш; **семе́йная ~ь** гаилә тормышы; **духо́вная ~ь** рухи тормыш; **кипу́чая ~ь** кайнап торган тормыш; **вну́тренняя ~ь страны́** илнең эчке тормышы; **~ь бьёт ключо́м** тормыш кайнап тора **4.** чынбарлык, тормыш; **войти́ в ~ь** тормышка ашу; **провести́ предложе́ние в ~ь** тәкъдимне тормышка ашыру **5.** җанлылык, хәрәкәт; **у́лицы полны́ ~и** урамда зур җанлылык хөкем сөрә ♦ **~и не рад** яшисе килми, тормыштан туйдым; **[находи́ться] ме́жду ~ью и сме́ртью** яшәү белән үлем арасында тору; **ни в ~ь** беркайчан да, һичбер вакытта да, гомердә дә; **не на ~ь, а на́ смерть боро́ться (би́ться)** үз-үзеңне аямыйча көрәшү; **отда́ть (положи́ть) ~ь** *за кого-что* гомереңне бирү, үзеңне корбан итү

жи́л||а *ж* **1.** (*кровеносный сосуд*) тамыр, кан тамыры, кан юлы; (*сухожилие*) сеңер **2.** *горн.* катлам; **золотоно́сная ~а** алтынлы катлам ♦ **тяну́ть (вытя́гивать) ~ы** *из кого* җелеген суыру, үзәгенә үтү, интектерү

жиле́т *м* жилет (*җиңсез өс киеме*)

жиле́ц *м* кешедә торучы, фатирчы ♦ **не ~ [на бе́лом све́те]** гүр якасында тора, озак яшәмәс

жили́ще *с* торак, тора торган урын

жили́щный, -ая, -ое торак ...ы; тораклар ...ы; **~ые усло́вия** торак шартлары

жи́лка *ж* **1.** *уменьш. от* **жи́ла** I; **2.** *бот., зоол.* җепсел (*бөҗәкләр канатында һәм усемлек яфракларындагы җепселләр*) **3.** тамыр; **бе́лый мра́мор с кра́сными ~ми** кызыл тамырлы ак мәрмәр **4.** *разг.* сәләт; **артисти́ческая ~** артистлык сәләте

жил||о́й, -ая, -о́е **1.** торак ...; **~о́й дом** торак йорт **2.** кешеләр тора торган; торырга яраклы; **~а́я ко́мната** торырга яраклы бүлмә

жилпло́щадь *ж* торак мәйдан

жиль||ё *с* **1.** кеше яши торган җир; **вдали́ от челове́ческого ~я** кешеләр яши торган җирдән ераклы **2.** *разг.* (*жилище*) торак **3.** *разг.* тору; **го́дный для ~я** тору өчен яраклы

жим *м спорт.* салмак күтәрү (*штанганы*)

жи́молость *ж* зелпе

жир *м* май; **гуси́ный ~** каз мае; **расти́тельные ~ы́** үсемлек майлары; **ры́бий ~** балык мае ♦ **с ~у беси́ться** *прост.* маена чыдаша алмау ; **от ~у ло́паться** *прост.* чиртсәң каны чыгарлык

жира́ф *м*, **жира́фа** *ж* жираф

жире́ть *несов.* симерү, көрәю, май басу

жи́рность *ж* **1.** майлылык; **~ молока́** сөтнең майлылыгы **2.** (*упитанность*) симезлек

жи́рн||ый, -ая, -ое **1.** симез, майлы; **~ый суп** майлы аш; **~ое мя́со** симез ит **2.** симез; **~ый кот** симез мәче **3.** (*о почве*) ашлы; (*о глине*) үзле, сутлы **4.** майлы, майланган, майланып беткән, майга катканг; **~ое пятно́** майлы тап; **~ые ру́ки** майлы куллар **5.** (*толстый — о линии, шрифте*) калын ♦ **~ый кусо́к** симез калҗа (*кызыктырырлык нәрсә хакында*)

жирова́ть I *несов. что, тех.* (*пропитывать жиром*) майлыландыру, май белән туендыру

жир||ова́ть II *несов.* **1.** *охот.* май жыю, симерү; **кабаны́ ~у́ют в боло́тах** кабан дуңгызлары сазлыкта йәреп симерәләр **2.** *сад.* жимеш бирмичә үсү (*жимеш агачлары турында*)

жирови́к *м* май шеше, майлы шеш

жирО́вка *жс разг.* жировка (*квартира, ут һ.б.ш. өчен түләргә бирелгән документ*)

жиров||о́й, -а́я, -о́е **1.** май ...ы, майлы; **~ы́е вещества́** майлы матдәләр **2.** май ...ы, майдан әйберләр ясау ...ы; **~а́я промы́шленность** май промышленносте

жиропо́т *м спец.* майлы тир (*сарыкларның май һәм тире бизләре бүлеп чыгара торган матдә*)

жироприка́з *м фин.* жириприказ (*акча хуҗасының кредитор белән исәп-хисапны өзү турында кредит оешмаларына биргән боерыгы*)

жироско́п *м уст.* жироскоп (*то же, что* **гироско́п**)

жирото́пный, -ая, -ое *спец.* май кайнату ...ы; май кайната торган; май эретү ...ы; май эретә торган; **~ цех** май кайнату цехы

жите́йск||ий, -ая, -ое тормыш ...ы көндәлек, көн дә була торган; **~ие дела́ и забо́ты** көндәлек эшләр һәм мәшәкатьләр

жи́тел||ь *м* торучы, яшәүче; торучы халык; **~и го́рода** шәһәрдә торучы халык

жи́тельница *ж см.* **жи́тель**

жи́тельств||о *с* тору, яшәү; **ме́сто ~а** тору урыны

жи́тница *ж* **1.** *уст.* амбар, келәт **2.** *перен.* игенгә бай җир (өлкә)

житня́к *м бот.* арышбаш (*кыяклы азык үлән*)

жи́тный, -ая, -ое (*о хлебе*) арыш ...ы; (*о крупе*) арпа ...ы

жи́то *с диал.* иген, ашлык

жи||ть *несов.* **1.** *в разн. знач.* яшәү, тору, гомер итү; **до́лго ~ть** озак яшәү; **~ли́-бы́ли** торганнар ди; **~ть душа́ в ду́шу** тату яшәү, дус тору; **~ть на широ́кую но́гу** мул тормышта яшәү; **~ть-пожива́ть** хафасыз яшәү, ваемсыз тормыш; **~ть с семьёй** гаилә белән бергә яшәү; **~ть свои́м трудо́м** үз хезмәтең исәбенә яшәү; **с волка́ми ~ть — по во́лчьи выть** ≈ кем чанасына утырсаң шуның җырын җырларсың **2.** *перен.* булу, яшәү; **в наро́де живёт уве́ренность в побе́де** халыкта җиңүгә ышаныч яши

жить||ё *с разг.* **1.** тормыш, көнкүреш; **приво́льное ~ё** иркен тормыш; **~ёнам бу́дет в дере́вне!** авылда тормышыбыз яхшы булыр! **2.** тору, яшәү; **дом, приго́дный для ~я** торыр өчен яраклы өй ♦ **~я нет** *кому от кого* көн юк (*кысалар, җәберләнүләр*)

житьё-бытьё *с см.* **житьё** I

жи́ться *несов. безл. кому, разг.* яшәү, тору; **ему́ живе́тся хорошо́** ул яхшы тора

жмот *м прост.* саран, карун

жму́рить *несов.:* **~ глаза́** күзләрне кысу

жму́риться *несов. то же, что* **жму́рить глаза́** (*см.* **жму́рить**)

жму́рки *только мн.* сукыр тәкә уены, күз бәйләш уены

жмых *м* **жмы́хи, жмыхи́** *мн.* түп (*майлы орлыкларның маен сыгып чыгарганнан соң калган сыгынты*)

жне́йка *ж* ургыч, уру машинасы

жнец *м* ураксы

жнивьё *с* **1.** (*невспаханное поле*) урылган кыр **2.** (*солома*) камыл

жни́ца *ж* ураксы хатын (кыз)

жоке́й *м* жокей (*ат чабышында катнашучы*)

жом *м* (*пресс*) эскәнҗә **2.** (*свекловичные выжимки*) чөгендер түбе

жонглёр *м* жонглёр (*цирк артисты*)

жонглёрство *с* **1.** жонглёрлык **2.** *перен.* хәйләләү, әвеш-түеш китерү, кылану

жонгли́рование *с см.* **жонгли́ровать**

жонгли́ровать *несов. чем* **1.** жонглёрлык итү (*мәс цирката*) **2.** *перен.* әвеш-түеш китерү, хәйләләү, кыландыру; **~ цита́тами** өземтәләрне әвеш-түеш китерү

жор *м рыб.* балыкның нык чиртүе

жох *м прост.* хәйләкәр, мут, алдакчы; саран

жрать *несов. что и без доп. прост.* бүсү, тыгыну, ашау

жре́бий *м* **1.** шобага, жирәбә; **тяну́ть ~** шобага салу **2.** *перен. уст.* язмыш, тәкъдир; **тако́в уж мой ~** минем язмышым шундый инде ♦ **~ бро́шен** ни булса булыр, тәвәккәллек итү

жрец *м* **1.** *рел.* кәһин, жрец (*мәҗүсилардә дин башлыгы*) **2.** *перен.* әһел, ата; **~ы́ нау́ки и иску́сства** фән һәм сәнгать әһелләре

жрица *ж рел.* кәһинә, жрец хатын

жу́желица *ж* бызылдавык, бызлавык, сасы коңгыз

жужжа́ть *несов.* **1.** (*напр. о комарах*) жуылдау, бызылдау, безелдәү **2.** (*напр. о пулях*) выжлау, выжлап очу, сызгыру

жук *м* коңгыз; **ма́йский ~** май коңгызы; **наво́зный ~** тирес коңгызы

жу́лик *м* карак, жулик

жуликова́тый, -ая, -ое *разг.* **1.** жуликрак, хәйләкәр; **~ челове́к** хәйләкәр кеше **2.** шикле, караксыман, жуликсыман; **~ вид** шикле кыяфәт

жульё *с собир. разг.* караклар, жуликлар

жу́льничать *несов. разг.* алдашу, алдау, хәрәмләшү, мутлашу

жу́льничество *с разг.* алдашу, мутлык

жупа́н *м* жупан, кыска чикмән (*полякларда һәм украинналарда*)

жу́пел *м* букай, карачкы

журавли́н||ый, -ая, -ое **1.** торна ...ы; **~ые пе́рья** торна каурыйлары **2.** *перен.* торнача, торна кебек; **~ая похо́дка** торна кебек йөрү

жура́вль *м* **1.** торна; **се́рый ~** соры торна **2.** (*у колодца*) кое сиртмәсе

журИ́ть *несов. кого-что, разг.* шелтәләү, әрләү, орышу, тиргәү

журна́л *м* журнал; **литерату́рный ~** әдәби журнал; **~ мод** модалар журналы; **путево́й ~** юл журналы

журнали́ст *м* журналист

журнали́стика *ж* журналистика

журнали́стка *ж* журналист хатын (кыз)

журна́льн||ый, -ая, -ое журнал ...ы; **~ая статья́** журнал мәкаләсе; **~ый вариа́нт по́вести** повестьның журнал варианты ♦ **~ый сто́лик** тәбәнәк өстәл

журч||а́ть *несов.* **1.** шылтырау, челтерәү, чылтырап агу; **~и́т руче́й** инеш чылтырап ага **2.** *перен.* әкрен генә ишетелеп тору; **~и́т речь** сөйләшкән тавыш әкрен генә ишетелеп тора

жу́ткий, -ая, -ое **1.** (*страшный*) куркыныч, коточкыч, йөрәк яргыч, куркынычлы, хәвефле, дәһшәтле **2.** *перен. прост.* коточкыч, бик каты; **~ хо́лод** бик каты салкын

жу́тко *нареч.* **1.** бик, коточкыч; **он вы́глядел ~** ул коточкыч кыяфәттә иде **2.** *в знач. сказ. безл. кому:* **мне ~ в темноте́** миңа караңгыда куркыныч

жуть *ж разг.* курку, кот очу (чыгу); **меня́ ~ берёт** минем котым оча

жу́хлый, -ая, -ое (*о листьях, траве и т.п.*) саргайган, саргаеп кипкән; (*о красках*) тоныкланган

жу́хнуть *несов.* (*о листьях, траве и т.п.*) саргаю, саргаеп кибү; (*о красках*) тоныклану

жучо́к *м* **1.** *уменьш. от* **жук; 2.** жучок (*электросчётчик бөкесенә электр үткәрү өчен чорнап куйган бакыр чыбык*)

жэк *м* жэк (*торакларны эксплуатацияләү конторасы*)

жюри́ *с нескл. собир.* жюри

З

за *предлог* **1.** *с вин.п.* (*около, вокруг*) янына, янында; **сесть за стол** өстәл янына утыру **2.** *с вин.п.* (*при указании на начало действия*) ... лый башлау, ... га тотыну; **приня́ться за рабо́ту** эшли башлау **3.** *с вин.п.* (*при указании пред-*

мета, лица, позади или по другую сторону к-рого что-то помещено, спрятано) ...га; **заткну́ть** *что-л.* **за по́яс** *нәрсәне дә булса* билбауга кыстыру **4.** *с вин.п.* (*при указании цены, платы*) ...га; **купи́ть за ты́сячу рубле́й** мең сумга сатып алу **5.** *с вин.п.* (*позднее; больше; сверх*) ...дан; **ему́ за со́рок** анарга кырыктан артык, ул кырыктан узган; **вре́мя за́ полночь** төн уртасыннан узган вакыт; **моро́з за три́дцать гра́дусов** салкын утыз градустан артып китте **6.** *с вин.п.* (*при указании на расстояние*) ...да; **за де́сять киломе́тров отсю́да** моннан ун километрда; **за́ три киломе́тра от до́ма** өйдән өч километр ераклыкта **7.** *с вин.п.* (*раньше на какое-л. время*) ...нан ...элек; **за пять дней до сро́ка** срогыннан биш көн элек **8.** *с вин.п.* (*в течение какого-л. времени*) ... га, ... да, өчен; **за́работок за́ год** бер ел өчен хезмәт хакы; **мно́гое сде́лано за неде́лю** бер атна эчендә күп нәрсә эшләнде; **за после́днее вре́мя** соңгы вакытларда **9.** *с вин.п.* (*при указании на лицо или предмет, к к-ому прикасаются*) ...дан, ...га; **взять за́ руку** кулыннан тоту; **держаться за пери́ла** култыксага тотыну **10.** *с вин.п.* (*ради, в пользу чего-л.*) өчен; **борьба́ за мир** тынычлык өчен көрәш; **сража́ться за ро́дину** ватан өчен сугышта катнашу; **голосова́ть за предложе́ние** тәкъдим өчен тавыш бирү **11.** *с вин.п.* (*вместо, в качестве кого-л.*) өчен, урынына; **я за тебя́ всё сде́лаю** мин синең өчен барысын да эшләрмен; **рабо́тать за секретаря́** секретарь урынына эшләү **12.** *с вин.п.* (*при указании лица или предмета, выступающего в качестве кого-чего-л.*) ... итеп алу, ... дип белү; **приня́ть за образе́ц** үрнәк итеп алу; **приня́ть** *кого-л.* **за своего́ знако́мого** *кемне дә булса* танышың дип белү **13.** *с вин.п.* (*при указании лица, к к-ому возникает какое-л. чувство*) өчен; **беспоко́иться за дете́й** балалар өчен борчылу; **я рад за вас** мин сезнең өчен шатмын **14.** *с вин. и тв.п.* (*по причине, вследствие*) өчен; ...лыктан; **цени́ть за хра́брость** кыюлыгы өчен хөрмәт итү; **за отсу́тствием вре́мени** вакыт булмаганлыктан **15.** *с вин. и тв.п.* (*через, по ту сторону, позади, около*) артына, аръягына, артында, аръягында, читенә, кырыена; янында; ...га; **ступи́ть за поро́г** бусага артына чыгу; **стать за де́рево** агач артына басу; **стоя́ть за две́рью** ишек артында басып тору; **уе́хать за́ город** шәһәр читенә китү; **сиде́ть за столо́м** өстәл янында утыру **16.** *с тв.п.* (*позади, вслед, следом*) артыннан,эзеннән; **иди́те за мной** минем артымнан барыгыз; **оди́н за други́м** берсе артыннан берсе **17.** *с тв.п.* (*во время чего-л.*) ...да; вакытында, чакта, арада; **за едо́й** ашаганда; **за рабо́той** эшләгән чакта; **поговори́ть за обе́дом** төшке аш вакытында сөйләшеп алу **18.** *с тв.п.* (*при указании лица или предмета, на к-ые направлено действие*) ...ны; **наблюда́ть за детьми́** балаларны күзәтү; **следи́ть за чистото́й** чисталыкны саклау **19.** *с тв.п.* (*с целью, для чего-л.*) ...га; **иди́ за водо́й** суга бару; **в пого́не за уда́чей** уңыш артыннан куып; **посла́ть за до́ктором** докторны чакырырга җибәрү **20.** *с тв.п.* (*при указании лица, от к-ого зависит наступление какого-л. действия, за к-ым числится что-л.*) ...га; ... ным; **кни́га чи́слится за мной** китап минем исемемә язылган; **де́ло за деньга́ми** эш акчадан тора; **за тобо́й долг** синең бирәчәгең бар; **о́чередь за тобо́й** хәзер синең чиратың **21.** *с тв.п.* ...ган; ...лы; **отве́т за по́дписью председа́теля** рәис кул куйган җавап; **прика́з за но́мером 45** 45нче номерлы приказ **22.** *с тв.п.* (*при указании на смену действия, состояния, лица, предмета, явления*) ...дан; соң; **за дождя́ми наступи́ла жара́** яңгырлардан соң эссе көннәр башланды; **чита́ть кни́гу за кни́гой** китап артыннан китап уку; **год за го́дом** ел артыннан ел ♦ **кто за?** кем риза?; **в э́том де́ле есть свои́ за и свои́ про́тив** бу эшнең уңай һәм кире яклары бар; **вы́йти за́муж за** *кого кемгә дә булса* кияүгә чыгу; **за исключе́нием** ...дан башка; **за исключе́нием дете́й** балалардан башка, балаларны санамаганда; **за счёт** *кого кемнең* дә булса исәбенә (хисабына); **за счёт** *чего* берәр нәрсә исәбенә, нәрсә булса да хисабына; **ни за что́ !** беркайчан да!, ничкайчан!

заакти́ровать *сов. что* акт төзү, актлаштыру

заале́ть *сов.* **1.** (*виднеться — о чём-либо алом*) алланып күренү, алсуланып күренү **2.** (*начать алеть*) алсулана башлау

заарка́нить *сов. кого-что* аркан белән эләктереп алу, арканлау

заарта́читься *сов.* **1.** (*о лошади*) чыгым(чы)лый башлау **2.** *разг.* (*заупрямиться*) кәҗәләнә башлау, үҗәтләнә башлау, киреләнә башлау,карыша башлау

заасфальти́ровать *сов. что* асфальтлап чыгу, асфальтлап бетерү

заатмосфе́рн||ый -ая, -ое атмосфера тышындагы ..., атмосферадан тыш; **~ные наблюде́ния** атмосферадан өстә күзәтүләр

заба́в||а *ж* уен, мәзәк, уен-көлке, күңел ачу; **де́тские ~ы** балалар уен-көлкесе; **пуста́я ~а** буш мәзәк

забавля́ть *несов. кого-что* юату, күңелен ачу; **~ дете́й игру́шками** уенчыклар белән балаларның күңелен ачу

заба́вник *м* уенчак, көлдерүчән, мәзәкчән, шаян

заба́вница *ж* уенчак хатын (кыз)

заба́вный , -ая, -ое кызык, кызыклы, көлкеле; **~ расска́з** көлкеле хикәя; **~ ребёнок** кызык бала

забаллоти́ровать *сов. кого-что* сайламый калдыру, кандидатурасын үткәрмәү ; **~ кандида́та** кандидатны сайламый калдыру

заба́лтывать *несов. разг. см.* **заболта́ть** I

заба́лтываться *несов. разг. см.* **заболта́ться** I

забарахли́||ть *сов. прост.* бозылу, эшләмәү; **мото́р ~л** мотор бозылды

забаррикади́ровать *сов. что* баррикада[лар] кору

забаррикади́роваться *сов.* баррикада[лар] корып яшеренү, барикада [-лар] кору

забастова́ть *сов.* эш ташлау, забастовка ясау

забасто́вк||а *ж* эш ташлау, забастовка; **всеоби́щая ~а** гомуми эш ташлау; **объяви́ть ~у** забастовка игълан итү

забасто́вочн||ый, -ая, -ое забастовка ...ы; **~ ая борьба́** забастовка көрәше

забасто́вщик *м* забастовкачы, эш ташлаучы, забастовкада катнашучы

забве́ни||е *с* **1.** *книжн.* оныту, истән чыгару; **предать ~ю** *что-л. нәрсәне дә булса* бөтенләйгә оныту **2.** (*пренебрежение чем-л.*) оныту, искә дә кертмәү; **~ свои́х обя́занностей** үзеңнең бурычларыңны оныту

забе́г *м спорт.* йөгерү, йөгереш, узыш; **~ на сто ме́тров** йөз метрга йөгерү

забега́ловка *ж прост.* забегаловка (*ашыгыч кына ашап-эчеп чыгу урыны*)

забе́га||ть *сов.* **1.** йөгерә башлау, арлы-бирле йөгерү; **челно́к ~л** шуре арлы-бирле йөгерә башлады **2.** уйный башлау; **глаза́ у него́ ~ли** аның күзләре уйный башлады

забега́ть *несов. см.* **забежа́ть**

забе́гаться *сов. разг.* йөгерә-йөгерә хәлдән таю, йөгерә-йөгерә арып бетү

забежа́||ть *сов.* **1.** йөгереп керү; **~ть во двор** ишегалдына йөгереп керү **2.** *разг.* (*ашыгыч кына*) кереп чыгу; **~ть к знако́мым** танышларга кереп чыгу ♦ **~ть вперёд** 1) алга узып китү; 2) алга йөгерү (чабу) (*башлаган бер эшне ташлап, икенчесенә тотыну*)

забеле́ть *сов.* **1.** (*показаться — о чём-л. белом*) агарып күренү **2.** (*начать белеть*) агара башлау, яктыра башлау

забе́ливать *несов. см.* **забели́ть**

забели́ть *сов. что, разг.* **1.** агарту, акка буяу, акшарлау; **~ стёкла о́кон** тәрәзә пыялаларын акка буяу **2.** катык (каймак) салу, кату; **~ борщ** боршка катык кату

забере́менеть *сов.* балага узу, авырга узу, корсакка калу, йөккә узу, йөккә калу

забеспоко́иться *сов.* борчыла башлау, тынычсызлана башлау

забетони́ровать *сов. что* бетонлау, бетон салып катыру

забива́ть *несов. см.* **заби́ть** I ♦ **~ козла́** *прост.* домино уйнау (сугу)

забива́ться *несов.* **1.** *см.* **заби́ться** I; **2.** *страд. от* **забива́ть**

забинтова́ть *сов. кого-что* бинт белән урап бәйләү, (*яраны*) бәйләп кую

забинтова́ться *сов.* үзеңне бинт белән бәйләү

забира́ть *несов. см.* **забра́ть**

забира́ться *несов. см.* **забра́ться**

заби́тый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заби́ть** I; **2.** боек, кыерсытылган, кимсетелгән, нәүмиз; **~ челове́к** кыерсытылган кеше

заби́ть I *сов.* **1.** *что* кагып кертү; **~ гвоздь** кадакны кагып кертү **2.** *что* (*напр. при игре в футбол*) кертү, бәреп

(тибеп) кертү; (*при игре в бильярд*) бәреп кертү, сугып кертү; **~гол** туп кертү; **~ шар в ýгол** шарны почмакка бәреп кертү **3.** *что* (*наполнить*) тутыру, тыгызлап тутыру, дыңгычлап тутыру (*мәс. чемоданны*) **4.** *что* томалау, каплау; **~ окнó доскáми** тәрәзәне такталар белән томалау **5.** *кого-что* сую; **~ двáдцать голóв скотá** егерме баш терлек сую ♦ **~ гóлову** *кому чем, разг.* башны катыру, аптырату; **~ себé в гóлову** *что, прост.* һаман бер нәрсә турында баш вату

забú||ть II *сов.* **1.** кага башлау; **~ть в колоколá** кыңгыраулар кага башлау **2.** ата башлау, ургылып чыга башлау; **нефть ~ла фонтáном** нефть фонтан булып ата башлады

забú||ться I *сов.* **1.** посу, качу; **~ться в ýгол** почмакка посу **2.** тыгылу, томалану; **трубá ~лась сáжей** торбага корым тыгылган

забú||ться II *сов.* (*начать биться*) бәрелә-сугыла башлау, бәргәләнә башлау; (*о сердце*) тибә башлау; **~ться в истéрике** истерикадан бәргәләнә башлау

забúяка *м, ж разг.* бәйләнчек, сугыш чукмары, җәнҗалчы

заблаговрéменно *нареч.* алдан ук; **известúть ~** алдан ук хәбәр итү

заблагорассýдит||ься *сов. безл.*: **он дéлает всё, что емý ~ся** башына ни килсә, шуны эшли; ни теләсә, шуны эшли

заблестé||ть *сов.* ялтырый башлау, җемелди башлау, балкый башлау, ялтырап күренә башлау; **~ли сóлнечные лучú** кояш нурлары җемелди башлады; **на глазáх ~ли слёзы** күзләрендә яшь бөртекләре ялтырый башлады; **впередú ~ла рекá** алда елга ялтырап күренә башлады

заблудúться *сов.* адашу, юлдан язу; **~ в лесý** урманда адашу

заблýдш||ий, -ая, -ее әхлаксыз, бозык юлга кергән, юлдан язган ♦ **~ая овцá** юлдан язган кеше

заблуждáться *несов.* ялгышу, ялгыш фикердә булу; **вы глубокó ~етесь** сез бик нык ялгышасыз

заблуждéни||е *с* ялгышлык, ялгыш фикер, ялгыш караш; **впасть в ~е** ялгышлыкка төшү; **находúться в ~и** ялгыш фикердә булу; **ввестú в ~е** ялгыштыру

забодáть *сов. кого* сөзү, сөзеп үтерү

забóй I *м горн.* забой (*шахтада кумер, руда чыгару урыны*)

забой II *см.* **забúть** I; 5

забóйный, -ая, -ое, забой ...ы, забойдагы ...; **~ механúзм** забой механизмы

забóйщик *м* забойчы (*забойда эшләүче эшче*)

заболáчивание *с см.* **заболóтить, заболóтиться**

заболáчивать *несов. см.* **заболóтить**

заболевáемост||ь *ж* авырулар саны; **снижéние ~ и** авырулар саны кимү

заболевáние *с* **1.** (*болезнь*) авыру, чир, сырхау; **серьёзное ~** каты авыру **2.** (*возникновение болезни*) авырый башлау, чирли башлау; **~ грúппом** грипп белән авырый башлау

заболевáть I *несов. см.* **заболéть** I

заболевáть II *несов. см.* **заболéть** II

заболé||ть I *сов.* **1.** авырый башлау, авырып китү, чирли башлау, чирләп китү; **~ть грúппом** грипп белән авырый башлау **2.** *чем* кызыксынып китү, мавыга башлау; **он ~л мóрем** ул диңгез белән кызыксына башлады

заболé||ть II *сов.* авырта [сызлый] башлау; **гóрло ~ло** тамак авырта башлады

зáболонь *ж* төчлегән (*агачның кайры астындагы йомшаграк катлавы*)

заболóтить *сов. что* сазлыкка әйләндерү, саз хәленә китерү

заболóти||ться *сов.* сазлану, сазга әйләнү; **луг ~лся** болын сазланды

заболóченный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заболóтить**; **2.** сазланган, сазга әйләнгән; **~ луг** сазланган болын

заболтáть I *сов. что, разг.* (*размешать*) туглау; болгату, туглап катнаштыру; **~ яйцó в суп** ашка йомырка туглау

заболтáть II *сов.* (*начать болтать*) селки башлау, болгый башлау; **~ ногáми** аякларны селки башлау

заболтáть III *сов. разг. см.* **заговорúть**

заболтáться I *сов. разг.* (*увлечься болтовнёй*) лыгырдау белән мавыгып китү

заболтáться II *сов. разг.* (*начать болтаться*) болгана башлау, чайкала башлау, селкенә башлау

забóр *м* койма

забóрист||ый, -ая,-ое *прост.* **1.** көчле, куәтле, зәһәр, үткен, каты; **~ый табáк** каты тәмәке **2.** *перен.* чәнечкеле; тупас; **~ое словцó** үткен сүз

забóрн||ый, -ая, -ое койма ...ы; **~ый столб** койма баганасы

забороня́ть *сов. что* тырмалау, тырмалап бетерү; **~ пóле** басуны тырмалап бетерү

забóт||а *ж* **1.** (*мысль или деятельность*) кайгырту, борчылу; мәшәкать, эш; **~а о своём бýдущем** үзеңнең киләчәгең турында кайгырту **2.** (*уход, внимание*) кайгырту, хәстәрен күрү; игътибар; **окружúть ребёнка ~ой** бала турында кайгырту ♦ **[вот] нé было ~ы!** шул гына җитмәгән иде!

забóти||ть *несов. кого-что* (*беспокоить*) борчу, тынычсызлау, мәшәкатьләү; **егó э́то мáло ~т** бу хәл аны бик аз борчый

забóтиться *несов. о ком-чём* кайгыртучанлык күрсәтү, игътибар бирү; кайгырту; **~ о здорóвье детéй** балаларның сәламәтлеге турында кайгыртучанлык күрсәтү

забóтлив||ый, -ая, -ое кайгыртучан, хәстәрен күрүчән; игътибарлы; **~ый хозя́ин** кайгыртучан хуҗа; **~ый ухóд** игътибарлы тәрбия; **~ые рýки** кайгыртучан куллар

забраковáть *сов. кого-что* браккa чыгару, яраксызга чыгару

забрáло *с* битлек (*металл шлемның битне каплый торган пәрдәсе*) ♦ **выступúть с откры́тым ~м** битлекне алып ташлау, ачыктан-ачык чыгу, үз фикереңне турыдан-туры әйтеп бирү

забрáсывать I *несов. см.* **забросáть**

забрáсывать II *несов. см.* **забросúть**

забрá||ть *сов.* **1.** *кого-что* алу; **~ть с собóй кни́ги** китапларны үзең белән алу **2.** *кого-что, раз.* (*арестовать*) кулга алу **3.** *что* җыю, тарайту; **~ть шов** җәйне тарайту ♦ **забралá охóта** (*что-л. делать*) теләк туды, ...сы килеп китте; **~ло егó за живóе** авырткан җиренә тиде; күңеленә тиде; **~ть себé в гóлову** *что* башка кертеп урнаштыру (*берәр фикерне*); **~ть в рýки** *кого-что кемне булса да* кулда тоту

забрá||ться *сов.* **1.** (*вверх*) менү; (*вглубь*) керү; **~ться под одея́ло** юрган астына керү **2.** *разг.* ерак китү, ераклларга барып чыгу; **он ~лся далекó на Сéвер** ул ерак Төньякка барып чыкты

забредáть *несов. см.* **забрестú**

забрéзжи||ть *сов.* **1.** яктыра башлау, таң ата башлау, таң беленә башлау; **~л рассвéт** таң беленә башлады **2.** җемелдәп күренә башлау; **вдалú ~л огонёк** ерактa ут җемелдәп күренә башлады

забрестú *сов. разг.* (*йөри торгач*) барып керү, килеп керү; адашып барып керү; **~ глубóкó в лес** урман эченә адашып барып керү

забривáть *несов. см.* **забри́ть**

забри́ть *сов. кого, уст.* кыру, солдатка алу

забронировáть *сов. что* бронялау, броня белән каплау

забронúровать *сов. кого-что* бронировать итү, бронълау; **~ мéсто в гостúнице** кунакханәдә урын бронировать итү

забронировáться *сов.* **1.** бронялану, броня белән каплану **2.** *перен. разг.* (*оградить, обезопасить себя чем-л.*) куркынычтан үзеңне саклау, хәвефсез урынга урнашу

забрóс: в ~е [быть] *разг.* ташландык хәлдә булу (*мәс. алма бакчасы*)

забросá||ть *сов. кого-что чем* **1.** күмү, күмеп ташлау, күп ташлау; **артúстов ~ли цветáми** артистларны чәчәкләргә күмделәр **2.** *перен.* яудыру; **~ть вопрóсами** сораулар яудыру

забрóси||ть *сов.* **1.** *что* ыргыту; (*удочку*) салу; **~ть мяч в кусты́** тупны куак арасына ыргыту **2.** *кого-что, разг.* кертеп ташлау; төшерү, ташлау; **~ть чемодáн в гостúницу** чемоданны кунакханәгә кертеп ташлау; **~ть десáнт в тыл врагá** дошман тылына десант төшерү **3.** *кого-что* ташлау; караучысыз калдыру; **~ть детéй** балаларны ташлау; **~ть чтéние** укуны ташлау; **он ~л спорт** ул спортны ташлады

забрóшенный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **забрóсить**; **2.** ташландык; караучысыз калдырылган, ташландык хәлгә китерелгән ; **~ сад** ташландык бакча

забры́згать I *сов. кого-что* чәчрәтеп пычрату, чәчрәтеп пычратып бетерү; **~ стол черни́лами** кара чәчрәтеп өстәлне пычратып бетерү

забры́зга||ть II *сов.* (*начать брызгать*) чәчрәтә башлау, бөркы башлау, сибәли башлау; **~л дождь** яңгыр сибәли башлады

забры́згивать *несов. см.* **забры́згать** I

забубённ||ый, -ая, -ое: **~ая голо́вушка** *прост.* үтә тәвәккәл кеше

забуксова́ть *сов.* буксовать итә башлау

забулды́га *м, ж прост.* азгын, бозык исерекбаш

забурли́ть *сов.* **1.** гөбер-гөбер килә башлау (*мәс. су кайнаганда*) **2.** *перен.* шау-гөр килә башлау (*мәс. халык торкеме*)

забуртова́ть *сов. что* (*заложить на хранение в бурты*) буртлау, буртларга өю, өемнәргә өю (*бәрәңгене, чөгендерне һ.б.ш.*)

забути́ть *сов. что* таш тутырып ныгыту; **~ фунда́мент до́ма** йорт нигезен таш тутырып ныгыту

забу́ха||ть *сов.* гөрселдәү; **~ли пу́шки** туплар гөрселди башлады

забуха́ть *несов. см.* **забу́хнуть**

забу́х||нуть *сов.* бүртү, күбенү; **бо́чка ~ла** мичкә бүртте

забыва́ть *несов. см.* **забы́ть**

забы́вчивый, -ая, -ое онытучан, хәтерсез

забы́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **забы́ть; 2.** онытылган; **~ая мело́дия** онытылган көй

забы́||ть *сов.* **1.** *кого-что, о ком-чём* оныту, истән чыгару, хәтердән чыгару; **~ть но́мер до́ма** йорт номерын хәтердән чыгару **2.** *кого-что* онытып калдыру, оныту; **я ~л до́ма очки́** мин өйдә күзлегемне онытып калдырганмын ◆ **что ты там ~л?** нәрсән калган анда синең? **не ~ть себя́** үзеңне онытып калдырмау (*өлештән читтә калмау*); **и ду́мать забу́дь** *о ком-чём берәр кеше, нәрсә* турында уйлап та карама; башыңа да китермә; **~ть доро́гу** *к кому, куда* (*берәр җиргә*) йөрмәс булу

забыть||ё *с* **1.** (*беспамятство*) аңны югалту, һуштан язу **2.** (*дремота*) йокымсырап тору, йокымсырап китү; **лежа́ть в ~и** йокымсырап яту

забы́||ться *сов.* **1.** (*задремать*) йокы басу, йокымсырап китү **2.** (*впасть в задумчивость, отвлечься*) онытылу, уйга чуму, уйга бату **3.** *разг.* онытылып китү, арттырып җибәрү, әдәп чигеннән чыгу; **он так ~лся, что стал груби́ть ста́ршим** ул әдәп чигеннән чыкты, хәтта өлкәннәргә тупаслык күрсәтә башлады

зав *м разг. см.* **заве́дующий**

зава́жничать *сов. разг.* эреләнә башлау, тәкәбберләнә башлау; эреләнеп китү, тәкәбберләнеп китү, әлләкем булу

зава́л *м* **1.** өем; (*снежный*) көрт; **лесно́й ~** ауган агач өеме **2.** *перен. разг.* төрәлеп тору, алга бармау; **у меня́ сейча́с с рабо́той ~** минем эшем алга бармый хәзер

зава́ливать *несов. см.* **завали́ть**

зава́ливаться *несов.* **1.** *см.* **завали́ться; 2.** *страд. от* **зава́ливать**

зава́линка *ж* нигез туфрагы, ниргә бүе

завали́||ть *сов.* **1.** *прям., перен. кого-что* тутыру, күмү; **~ть я́му** чокырны күмү; **~ть рабо́той** эш белән күмү **2.** *кого-что* ишелеп төшеп каплау; **доро́гу ~ло обва́лом** тау ишелеп юлны каплаган **3.** *что* жимерү, аудару; **~ть сте́ну** диварны жимерү **4.** *перен. что, прост.* жимерү, харап итү; тапшыра алмау; **~ть де́ло** эшне харап итү; **~ть экза́мен** имтиханны тапшыра алмау

завали́||ться *сов.* **1.** төшү, төшеп китү; **свёрток ~лся за сунду́к** төргәк сандык артына төшеп китте **2.** *прост.* яту; **он ~лся спать** ул йокларга ятты **3.** жимерелеп төшү, ишелеп төшү; **стена́ ~лась** дивар ишелеп төште **4.** *прост.* (*потерпеть неудачу*) эш барып чыкмау, уңышсызлыкка очрау

зава́ля||ться *сов. разг.* (*пролежать без употребления*) озак аунап яту

зава́ля||щий, -ая, -ее *прост.* начар, яраксыз, кирәксез; **~ това́р** начар товар

зава́ривать *несов. см.* **завари́ть**

зава́риваться *несов.* **1.** *см.* **завари́ться; 2.** *страд. от* **зава́ривать**

завари́ть *сов. что* **1.** пешерү; **~ чай** чәй пешерү **2.** *тех.* эретеп ябыштыру, коеп тутыру (металлдагы ярыкларны *һ.б.ш.*) ◆ **~ ка́шу** эшне куертып җибәрү, эшне бозып җибәрү

завари́||ться *сов.* **1.** пешү, пешеп житү; **чай ~лся** чәй пеште **2.** *перен. прост.* куерып китү, бозылып китү (*эш һ.б.ш.*); **ка́ша ~лась** эш бозылып китте

заварн||о́й, -а́я, -о́е **1.** заварной, кайнар суга басылган; **~о́е те́сто** кайнар суга басылган камыр **2.** кайнату ...ы; **~о́й котёл** кайнату казаны

завару́ха *ж прост.* четерекле эш, буталчык эш

заведе́ние *с* оешма, йорт; **вы́сшее уче́бное ~** югары уку йорты

заве́дование *с см.* **заве́довать**

заве́довать *несов. чем* идарә итү, җитәкчелек итү; **~ отде́лом** бүлек белән идарә итү

заве́домо *нареч.* күрә торып, белә торып, күрәләтә; **~ невёрные све́дения** күрәләтә ялган мәгълүматлар

заве́дом||ый, -ая, -ое билгеле, һәркемгә билгеле, күренеп тора торган; чеп-чи; **~ый лентя́й** һәркемгә билгеле ялкау; **~ая ложь** чеп-чи ялган

заве́дующий *м* мөдир

завезти́ *сов.* **1.** *кого-что* (*барышлый*) кертеп чыгу; **~ письмо́** хат кертеп чыгу **2.** *кого-что* илтү, илтеп ташлау; **~ в глушь** караңгы почмакка илтеп ташлау **3.** *что* китерү, кайтару; **~ това́ры в магази́н** кибеткә товарлар китерү

завербова́ть *сов. кого-что* вербовкалау, вербовка ясау; **~ рабо́чую си́лу** эшче көчләргә вербовка ясау

завере́ние *с* ышандыру

заве́рить *сов.* **1.** *кого-что в чём* (*уверить, убедить*) ышандыру, раслау; **~ в свое́й пре́данности и дру́жбе** үзеннең бирелгәнлегеңне һәм дуслыгыңны раслау **2.** *что* раслау; **~ по́дпись** имзаны раслау

заверну́||ть *сов.* **1.** *кого-что* төрү, урау, чорнау; **~ть кни́гу в бума́гу** китапны кәгазьгә төрү; **~ть ребёнка в одея́ло** баланы юрганга төрү **2.** *что* борып кую; **~ть кран** кранны борып кую **3.** *что* кайтару, кайтарып кую; **~ть рука́в** җинне кайтару **4.** борылу, борылып керү; **~ть за́ угол** почмак артына борылып керү **5.** [үтеп барышлый] кереп чыгу, сугылу; **~ть к прия́телю** үтеп барышлый иптәшеңә кереп чыгу

заверну́||ться *сов.* **1.** төренү; **~ться в одея́ло** юрганга төренү **2.** кайтарылу; **рука́в ~лся** җиң кайтарылган **3.** борылу, бикләнү, ябылу; **кран ~лся** кран ябылды

заверте́||ть I *сов.* (*увлечь, захватить*) *кого-что, разг.* башын әйләндерү; **жизнь его́ ~ла** тормыш аның башын әйләндерде

заверте́||ть II *сов. что, чем* (*начать вертеть*) әйләндерә башлау, болгый башлау, селкетә башлау; **~ть колесо́** тәгәрмәчне әйләндерә башлау; **соба́ка ~ла хвосто́м** эт койрыгын болгый башлады

заверте́||ться I *сов.* җәфаланып бетү, интегеп бетү, эштән чыгу; **~ться с дела́ми** эшләр белән интегеп бетү

заверте́||ться II *сов.* (*начать вертеться*) әйләнә башлау; **колесо́ ~лось** тәгәрмәч әйләнә башлады

завёртка *ж* **1.** *см.* **заверну́ть** 1-2; **2.** *разг.* төргәк

завёртывать *несов. см.* **заверну́ть**

завёртываться *несов.* **1.** *см.* **заверну́ться; 2.** *страд. от* **завёртывать**

завершá́ть *несов. см.* **заверши́ть**

завершá́ться *несов.* **1.** *см.* **заверши́ться; 2.** *страд. от* **завершá́ть**

заверши́ть *сов. что* **1.** тәмамлау, тәмам итү, төгәлләү; **~ рабо́ту** эшне төгәлләү **2.** очлау, очлап чыгу; **~ ба́шню шпи́лем** манараны шпиль белән очлау

заверши́||ться *сов.* төгәлләнү, тәмамлану, очлану, бетү; **строи́тельство ~лось** төзелеш тәмамланды

заверя́ть *несов. см.* **заве́рить**

заве́с||а *ж* чаршау, пәрдә; **~а тума́на** томан пәрдәсе; **~а ды́ма** төтен пәрдәсе ◆ **приподня́ть (приоткры́ть) ~у** ачыклау, серен ача төшү

заве́сить *сов. что* пәрдә кору, пәрдә (чаршау) корып кую

заве́ситься *сов.* каплану (*пәрдә, чаршау һ.б.ш. белән*)

завести́ *сов.* **1.** *кого-что* алып керү; илтеп ташлау; **~ в боло́то** сазлыкка алып керү **2.** *кого-что* кертеп кую, кертеп чыгу; (*мимоходом*) кертеп калдыру; **~ маши́ну в гара́ж** машинаны гаражга кертеп кую; **~ дете́й в шко́лу** балаларны мәктәпкә кертеп калдыру **3.** *что* (*устроить*) кору. булдыру, корып җибәрү, салу **4.** *кого-что* булдыру; (*приобрести*) алу; **~ но́вое обору́дование** яңа җиһаз булдыру; **~ соба́ку** эт алу **5.** *что* урнаштыру, кертү; **~ но́вые поря́дки** яңа тәртипләр кертү **6.** *что* башлап җибәрү; **~ разгово́р** сүз башлап җибәрү **7.** *что* бору, җибәрү, борып җибәрү, кабызу; **~ часы́** сәгатьне борып җибәрү; **~ мото́р** моторны кабызу

заве||сти́сь *сов.* 1. була башлау, күренә башлау, үрчи башлау; **в кварти́ре ~ли́сь мы́ши** квартирда тычканнар күренә башлады; **~ли́сь де́ньги** акча була башлау; **~ли́сь знако́мства** танышлар була башлау 2. *разг.* керү, урнашу; **~ли́сь но́вые поря́дки** яңа тәртипләр урнашты 3. эшли башлау; **мото́р завёлся** мотор эшли башлады 4. *перен. прост.* (*начать горячиться, спорить*) кыза башлау, кызып китү, бәхәскә керү

заве́т *м высок.* васыять; **вели́кие ~ы** бөек васыятьләр

заве́тн||ый, -ая, -ое 1. кадерле, күңел түрендәге, изге; **~ые мечты́** күңел түрендәге хыяллар 2. аеруча истәлекле, аеруча кыйммәт; **~ое кольцо́** аеруча истәлекле балдак 3. яшерен; серле; **~ый клад** яшерен хәзинә

заве́тренн||ый, -ая, -ое жилгә аркан, ышык; **~ая сторона́** ышык як

заве́шать *сов. что чем* элеп тутыру, элеп каплап бетерү; **~ сте́ны карти́нами** стеналарга картиналар элеп тутыру

заве́шивать I *несов. см.* **заве́сить**

заве́шивать II *несов. см.* **заве́шать**

заве́шиваться *несов.* 1. *см.* **заве́ситься**; 2. *страд. от* **заве́шивать** I

завеща́ние *с* васыять; васыять язуы, васыятьнамә

завеща́тель *м* васыять итүче, васыять әйтеп калдыручы

завеща́тельница *ж* васыять итүче хатын (кыз)

завеща́||ть *сов. и несов.* 1. *кого-что кому* васыять итү; **~ть иму́щество сы́ну** мал-мөлкәтне улына васыять итү 2. *что кому и с неопр.* әйтеп калдыру, васыять итү; **учёный ~л продолжа́ть де́ло свои́м ученика́м** галим эшен дәвам иттерүне үзенең шәкертләренә әйтеп калдырды

завзя́тый, -ая, -ое *разг.* бик һәвәс, бик бирелгән, башы белән чумган; **~ охо́тник** бик һәвәс аучы

завива́ть *несов. см.* **зави́ть**

завива́ться *несов.* 1. *см.* **зави́ться**; 2. *страд. от* **завива́ть**

зави́вка *ж* 1. *см.* **зави́ть, зави́ться**; 2. завивка; **шестиме́сячная ~** алты айлык завивка

зави́деть *сов. кого-что* ерактан күрү, күреп алу

зави́дно *нареч.* 1. соклангыч, гаҗәп; сокланып, кызыгып; **он ~ мо́лод** ул гаҗәп яшь 2. *в знач. сказ. безл. кому* көнләшә, көнчелеге килә; **мне ~** минем көнчелегем килә

зави́дн||ый, -ая, -ое сокланырлык, кызыгырлык, көнләшерлек; **~ое здоро́вье** сокланырлык сәламәтлек

зави́довать *несов. кому-чему* көнчелек килү, көнләшү; кызыгу

завиду́ш||ий, -ая, -ее *прост.* комсыз, көнче; **глаза́ ~ие** көнче күзләр

завизи́ровать *сов. что* виза салу (*документка*)

зави́нтить *сов. что* борып кертү, борып кую; **~ га́йку** гайканы борып кую

зави́нчивать *несов. см.* **зави́нтить**

завира́льн||ый, -ая, -ое *разг.* ялган, буш; **~ые мы́сли** ялган фикерләр; **~ые иде́и** буш идеяләр

завира́ться *несов. см.* **завра́ться**

зави́с||еть *несов. от кого-чего* 1. (*находиться в подчинении*) буйсынган булу, бәйле булу 2. бәйле булу, бәйләнгән булу; **успе́х де́ла ~ит от нас сами́х** эшнең уңышлы чыгуы безнең үзебезгә бәйле

зави́симост||ь *ж* 1. бәйле (бәйләнгән) булу, торышына бәйле булу; **в ~и от реа́льных усло́вий** реаль шартларның торышына карап 2. бәйлелек, бәйле булу, буйсынган булу, ирексезлек; **крепостна́я ~** крепостной бәйлелек; **~ от нача́льника** начальникка буйсынган булу

зави́сим||ый, -ая, -ое бәйле, буйсынган, ирексез; буйсынган кеше; **~ые стра́ны** бәйле илләр

зави́стливый, -ая, -ое көнче, көнләшүчән; **~ челове́к** көнче кеше; **~ взгляд** көнче караш

зави́стник *м* көнче

зави́стница *ж* көнче хатын (кыз)

за́висть *ж* көнчелек; **смотре́ть с ~ю** *на что-л. берәр нәрсәгә* көнчелек белән карау ◆ **на ~** көнләшерлек нәрсә

завито́й, -ая, -ое бөдрәләгән, бөдрәләндерелгән, көдрә

завито́к *м* 1. бөтеркә; **~ воло́с** чәч бөтеркәсе 2. бөтеркә бизәк; **~ капите́ли коло́нны** колонна капителенә ясалган бөтеркә бизәк 3. чорнам; **~ спира́ли** спираль чорнамы

завиту́шка *ж разг. см.* **завито́к** 1, 2

зави́ть *сов. что* бөдрәләү, көдрәләү; **~ во́лосы** чәчне бөдрәләү ◆ **~ го́ре верёвочкой** *прост. шутл.* кайгырудан туктау, кайгырмый башлау

зави́ться *сов.* 1. бөдрәләнү, көдрәләнү; **во́лосы завили́сь** чәч бөдрәләнде 2. бөдрәләтү, көдрәләтү; **~ в парикма́херской** чәчтарашханәдә чәчне бөдрәләтү

завихре́ние *с спец.* бөтерелү; **~ воды́** суның бөтерелүе; **~ во́здуха** һаваның бөтерелүе

завихри||ться, завихри́ться *сов.* бөтерелү, бөтерелеп күтәрелү; **сухи́е ли́стья ~лись по доро́ге** юлда коры яфраклар бөтерелә

завко́м *м* (*до 1982 г.*) завком (*завод комитеты*)

завладева́ть *несов. см.* **завладе́ть**

завладе́ть *сов. кем-чем* 1. (*взять, захватить*) тартып алу, кулга төшерү 2. *перен.* үзенә карату, үзенә тарту; үзенә буйсындыру, үз ягына аудару; **~ внима́нием слу́шателей** тынлаучыларның дикъкатен үзенә тарту

завлека́тельный, -ая, -ое мавыктыргыч; кызыклы, күңелле; **~ расска́з** мавыктыргыч хикәя

завлека́ть *несов. см.* **завле́чь**

завле́чь *сов. кого-что* 1. алдап алып керү; кызыктырып алып керү; **~ врага́ в лес** дошманны алдап урманга алып керү 2. *перен.* (*сильно заинтересовать*) мавыктыру, кызыксындыру, кызыксындырып үзенә карату ◆ **~ *кого* в свой се́ти** *берәр кешене* алдап үз тозагына төшерү

заво́д I *м* завод; **металлурги́ческий ~** металлургия заводы; **ко́нный ~** ат заводы (*нәселле атлар урчету предприятиесе*)

завод II *м* 1. *см.* **завести́** 7; 2. кору (бору) механизмы; **часово́й ~** сәгатьнең кору механизмы ◆ **[и] в ~е нет** *прост.* юк һәм булганы да юк

заводи́ла *м, ж прост.* (*берәр нәрсәне*) башлап җибәрүче, узаман, оештыручы

заводи́ть *несов. см.* **завести́**

заводи́ться *несов.* 1. *см.* **завести́сь**; 2. *страд. от* **заводи́ть**

заводн||о́й, -а́я, -о́е 1. борып хәрәкәтләндерелә торган; **~а́я игру́шка** борып хәрәкәтләндерелә торган уенчык 2. бора торган, кора торган; **~а́я ру́чка** бора торган тотка (*мәс. моторны кабызу өчен*); **~о́й ключ** бора торган ачкыч (*мәс. пружиналы сәгатьтә*); **~а́я пружи́на** бора торган пружина 3. *прост.* шук, шаян, кабынып китүчән; **~а́я девчо́нка** кабынып китүчән кызый

заводоуправле́ние *с* завод идарәсе

заво́дский, -ая, -ое, **заводск||о́й,** -а́я, -о́е завод ...ы; **~ие воро́та** завод капкасы; **~о́й двор** завод ишегалды

заводча́не *мн. разг.* завод эшчеләре, завод хезмәткәрләре

заво́дчик *м* завод хуҗасы

за́водь *ж* кечкенә култык (*елгада яки күлләрдә*)

завоева́ни||е *с* 1. *см.* **завоева́ть**; 2. казаныш, уңыш; **вели́кие ~я** бөек казанышлары

завоева́тель *м* яулап алучы, сугышып алучы, илбасар

завоева́ть *сов.* 1. *кого-что* (*захватить войной*) яулап алу, сугышып алу 2. *перен. что* яулап алу, казану, ирешү; **~ свобо́ду** азатлык яулап алу; **~ дове́рие избира́телей** сайлаучыларның ышанычын казану

завоёвывать *несов. см.* **завоева́ть**

завоз *м см.* **завезти́**; **~ горю́чего** ягулык кайтарту

завози́ть I *несов. см* **завезти́**

завози́ть II *сов. что, прост.* (*испачкать*) аунатып бетерү, пычратып бетерү

завола́кивать *несов. см.* **заволо́чь**

завола́киваться *несов.* 1. *см.* **заволо́чься**; 2. *страд. от* **завола́кивать**

заволнова́ться *сов.* 1. (*о море, о реке*) дулкынлана башлау 2. (*о человеке*) борчыла башлау, тынычсызлана башлау, дулкынлана башлау

заволо́чь *сов. что* каплау, каплап алу, томалау; **тучи заволокли́ не́бо** болытлар күк йөзен каплап алды; **глаза́ заволокло́ слеза́ми** *безл.* күз яшьләре күзләрне томалады

заволо́чься *сов.* каплану, томалану; **глаза́ заволокли́сь слеза́ми** күзләр яшь белән капланды

завопи́ть *сов. разг.* акыра-бакыра башлау, акыра башлау

заворáживать *несов. см.* **заворожи́ть**

заворáчивать *несов.* **1.** *см.* **завернýть; 2.** *чем, прост.* җитәкчелек итү, идарә итү; ~ **больши́ми делáми** зур эшләр белән җитәкчелек итү

заворожи́ть *сов. кого-что* үзенә каратү, әсир итү, сөйдерү; сихерләү

заворóт *м разг.* кискен борылыш, кискен тайпылыш; ~ **реки́** елганың кискен борылышы ♦ **зáворот кишóк** эчәкләр чуалу

заворóчаться *сов.* боргалана башлау (*тынычсызлыктан, уңайсызлыктан*)

завráться *сов. разг.* чамадан тыш ялганлау, үтә ялганчылыкка сабышу

завсегдáтай *м* һәрвакыт килә торган кеше, һәрвакыт йөри торган кеше; **театрáльный** ~ һәрвакыт театрга йөри торган кеше

зáвтра *нареч.* **1.** иртәгә; ~ **пойдём в теáтр** иртәгә театрга барырбыз **2.** *в знач. сущ. с нескл.* киләчәк **шагнýть в** ~ киләчәккә атлау

зáвтрак *м* иртәнге аш ♦ **кормúть ~ами** иртәгә-иртәгә дип алдап йөртү

зáвтракать *несов.* иртәнге аш ашау

зáвтрашн||ий, -яя, -ее иртәгә, иртәгесе; **на ~ий день** иртәгә көнгә; **с ~его дня** иртәгесе көннән ♦ **~ий день** (*будущее*) киләчәк, иртәгәсе көн

завуалúровать *сов. что* томалау, томалап кую, каплап кую, каплау (*мәс. фактларны, фикерләрне, кимчелекләрне*)

завши́веть *сов.* бетләү, бетләп бетү

завывá||ть *несов.* улау; **вóлки ~ют** бүреләр улый; **вéтер ~ет** җил улый

завы́сить *сов. что* чамадан тыш күтәрү; артык күтәрү; ~ **цéны** бәяләрне артык күтәрү; ~ **оцéнку** югары билге кую

завы́ть *сов.* улый башлау, үкерә башлау

завышáть *несов. см.* **завы́сить**

завязáть *сов. что* **1.** (*закрепить узлом и т.п.*) бәйләү, бәйләп кую **2.** төреп бәйләү, урап бәйләү; ~ **пакéт** пакетны төреп бәйләү **3.** башлау, керешү, башлап җибәрү; ~ **перестрéлку** атыша башлау

завязá||ться *сов.* **1.** бәйләнү; **гáлстук плóхо ~лся** галстук начар бәйләнгән **2.** башлану,башланып китү; **~лся бой** сугыш башланып китте **3.** төймәләнү; **плод ~лся** җимеш төймәләнде

завя́зка *ж* **1.** *см.* **завязáть** 1, 2; **2.** (*шнурок, бечёвка*) бау, бәйләвеч **3.** (*начало*) төенләнеш; ~ **дрáмы** драманың төенләнеше

завя́знуть *сов. прям., перен.* бату, батып калу; бату, чуму; ~ **в болóте** сазга бату; ~ **в долгáх** бурычка бату

завя́зывание *с см.* **завязáть, завязáться**

завя́зывать *несов. см.* **завязáть**

завя́зываться *несов.* **1.** *см.* **завязáться; 2.** *страдат. от* **завя́зывать**

зáвязь *ж бот.* җимшән; җимешлек

завя́знуть *сов.* шину, кору, сулу, шиңеп (корып, сулып) бетү

загадá||ть *сов.* **1.** *что* әйтү; ~**ть загáдку** табышмак әйтү **2.** *что и без доп.* уйлау; ~**йте какóе-нибудь числó** нинди дә булса сан уйлагыз **3.** *разг.* (*задумать что-л. сделать*) фараз итү, гоман итү, алдан чамалап кую

загáдить *сов. что, разг.* пычрату, пычратып бетерү, шакшылап бетерү

загáдка *ж* **1.** табышмак **2.** *перен.* сер; ~ **и прирóды** табигать серләре

загáдочн||ый, -ая, -ое серле, аңлаешсыз, билгесез; ~**ое явлéние** серле күренеш

загáдывать *несов. см.* **загадáть**

загáживать *несов. см.* **загáдить**

загазóванность *ж* газлар белән пычранган булу; ~ **вóздуха** һаваның газлар белән пычранган булуы

загазóванный, -ая, -ое газлар белән пычранган

загáр *м* кояш ашау, тән каралу

загасúть *сов. что* сүндерү, сүндереп бетерү; ~ **лáмпу** лампаны сүндерү

загáс||нуть *сов.* сүнеп бетү; **свечá ~ла** шәм сүнде

загатúть *сов. что* чыбык-чабык түшәү (*сазлы урынга*)

загвóздка *ж разг.* комачау[лык], читенлек, кыенлык; хикмәт; **вот в чём ~!** менә кайда икән хикмәт!

загерметизúровать *сов. что* герметик каплау (томалау)

загúб *м* **1.** бөгелеш, бөкләнгән урын; ~ **листá** кәгазь битенең бөкләнгән урыны **2.** *перен. разг.* тайпылыш

загибáть *несов. см.* **загнýть**

загибáться *несов.* **1.** *см.* **загнýться 2.** *страд. от* **загибáть**

загипнотизúровать *сов. кого-что* гипнозлау, гипноз белән йоклату

загла́вие *с* исем, баш; ~ **романа́** романның исеме

загла́вный, -ая, -ое: ~**ая бу́ква** баш хәреф; ~**ый лист** беренче бит (*китапның яки булекнең беренче бите*); ~**ая роль** баш роль

загла́дить *сов. что* **1.** тигезләү; үтүкләп тигезләү; ~ **скла́дку на брю́ках** чалбардагы бөгәрләнгән урынны үтүкләп тигезләү **2.** *перен.* йомшарту, төзәтү; ~ **свою́ вину́** үзеңнең гаебеңне төзәтү

загла́ди||ться *сов.* **1.** тигезләнү, тигезгә әйләнү; үтүкләнү; **скла́дки хорошо́ ~лись** бөгәрләнгән урыннар яхшы үтүкләнделәр **2.** *перен.* (*смягчиться*) төзәлү, йомшару

загла́живать *несов. см.* **загла́дить**

загла́зн||ый, -ая, -ое *разг.* күз артында; үзе югында, үзеннән башка; ~**ое обвине́ние** үзе югында гаеплү

заглáтывать *несов. см.* **заглотáть**

заглотáть *сов. кого-что* (*проглотить — о рыбе*) йоту, йотып җибәрү

заглóх||нуть *сов.* **1.** акрынлану, тыну, ишетелми башлау, тынып калу; **зву́ки ~ли** тавышлар тынды **2.** томалану, каплану, ташландык хәлгә килү; **сад заглóх** бакча ташландык хәлгә килгән

заглуби́ть *сов. что, спец.* тирәнәйтү, тирәнгәрәк төшерү, эчкәрәк кертү; ~ **нефтепровóд** нефть үткәргечне тирәнгәрәк төшерү

заглубля́ть *несов. см.* **заглуби́ть**

заглуша́ть *несов. см.* **заглуши́ть**

заглуши́||ть *сов. что* **1.** каплау; басу; **оркéстр ~л гóлос певцá** оркестр җырчының тавышын басты **2.** басу, томалау, каплау, томалап китү, басып китү; **сорня́ки́ ~ли пóле** кырны үлән баскан **3.** сүндерү; ~**ть самовáр** самавырны сүндерү **4.** *перен.* басу, киметү; ~**ть бóль** авытуны басу; ~ **тоскý** сагышны киметү **5.** *перен.* басу, томалау; ~**ть инициати́ву** инициативаны басу

загляде́нье *с разг.* карап туйгысыз, күз алгысыз, сокландырлык; **карти́на** — ~**!** карап туйгысыз картина!

загляде́ться *сов. на кого-что* кызгалмыйча карап тору, ис китеп карап тору, сокланып карап тору, шаккатып карап тору

загля́дывать *несов. см.* **загляну́ть**

загля́дываться *несов. см.* **загляде́ться**

загляну́ть *сов.* **1.** күз салу, күз төшерү, карап алу; ~ **в окнó** тәрәзәгә күз салу **2.** *разг.* (*зайти*) кереп чыгу; ~ **к прия́телю** иптәшенә кереп чыгу ♦ ~ **в ду́шу** *кому* эченә (күңеленә, йөрәгенә) керү

загна́ть *сов.* **1.** *кого-что* кертү, куып кертү; ~ **ове́ц в сара́й** сарыкларны сарайга куып кертү **2.** *кого-что* куып ардыру, куып хәлдән тайдыру; ~ **зверя** җәнлекне куып ардыру **3.** *что, прост.* кагып кертү; ~ **гвоздь в до́ску** кадакны тактага кагып кертү **4.** *кого-что. прост.* (*продать*) сату, сатып җибәрү; биетү

загнива́ние *с см.* **загни́ть**

загнива́ть *несов. см.* **загни́ть**

загни́||ть *сов.* черү; **капу́ста ~ла́** кәбестә черегән

загнои́||ть *сов. что, разг.* **1.** (*довести до гниения*) черетү **2.** (*довести до нагноения*) эренләндерү

загнои́||ться *сов.* эренли башлау, үлекли башлау, эрен белән тулу; **ра́на ~лась** җәрәхәт эренли башлады

загну́||ть *сов.* **1.** *что* бөгү; бөкләү, бөкләп кую; кайтару; ~**ть страни́цу кни́ги** китап битен бөкләп кую **2.** *разг.* борылу, борылып керү; ~**ть за́ угол** почмак артына борылып керү **3.** *что и без доп., прост.* әйтеп салу, әйтеп ташлау; ~**ть слове́чко** урынсыз сүз әйтеп ташлау; **ну, ты и ~л!** әйттең дә соң инде!

загну́ться *сов.* **1.** бөгелү, бөкләнү **2.** *прост.* аяк сузу, үлү

заговáривать I *несов. с кем* сүз башлап җибәрү; ~ **с прохóжими** узгынчылар белән сүз башлап җибәрү

заговáривать II *несов. см.* **заговори́ть** I

заговáриваться *несов.* **1.** *см.* **заговори́ться; 2.** мәгънәсез сүз[ләр] сөйләү; сүздә буталу

зáговор I *м* заговор (*билгеле бер сәяси максатка яисә башка берәр максатка ирешү өчен бергәләп эш итү турында сүз куешу*) ♦ ~ **молчáния** эндәшмәскә сүз куешу

зáговор II *м* өшкерү, әфсен-төфсен, әфсенләү; ~ **от болéзни** авырудан өшкерү

заговори́ть I *сов. кого-что* **1.** *разг.* (*утомить разговорами*) сөйли-сөйли

ялыктырып бетерү, сөйләп ардыру **2.** (*заколдовать*) өшкерү, әфсенләү

заговори́||ть II *сов.* **1.** (*начать говорить*) сөйли башлау **2.** *перен.* уяну, уянып китү, кузгалу; **в нём вдруг ~ла со́весть** кинәт аның вөжданы уянып китте

заговори́||ться *сов.* сүзгә мавыгып китү; **~лись мы с ва́ми** без сезнең белән сүзгә мавыгып киткәнбез

загово́рщик *м* заговорчы, заговорга катнашучы

загово́рщицк||ий, -ая, -ое *разг.*, **заго-во́рщическ||ий,** -ая, -ое заговорчылар ...ы, заговорчылык ...ы; **~ая де́ятельность** заговорчылык эшчәнлеге

загогота́ть *сов.* **1.** (*о гусях*) каңгылдау, каңгылдашу **2.** (*захохотать*) шаркылдап көлү

загогу́лина *ж прост.* кәкре-бөкре сызыклар

заголо́вок *м см.* **загла́вие**

заголо́вочный, -ая, -ое бүлек башы ...ы; **~ шрифт** бүлек башы хәрефе

заголубе́ть *сов.* **1.** (*показаться — о чём-л. голубом*) күк булып күренә башлау, күк төстә күренә башлау,күк төскә керү **2.** (*начать голубеть*) күгәрә башлау, күк төскә керә башлау

заго́н *м* **1.** *см* **загна́ть** 1; **2.** киртә абзар, ялан абзар, тышкы абзар, кура; **~ для коро́в** сыерлар өчен киртә абзар ♦ **быть в ~е** кыерсытылу; ташландык хәлдә булу

заго́нщик *м* куучы, куып китерүче (*ауда җәнлекне*)

загоня́ть I *несов. см.* **загна́ть**

загоня́||ть II *сов. кого-что, разг.* (*изнурить, утомить работой*) арыту, алҗыту, хәлдән тайдыру

загора́живать *несов. см.* **загороди́ть**

загора́живаться *несов.* **1.** *см.* **загороди́ться; 2.** *страд. от* **загора́живать**

загора́||ть *несов.* **1.** *см.* **загоре́ть 2.** *перен. прост. шутл.* эшсез утыру, эшсез утырырга мәҗбүр булу; **горю́чее ко́нчилось, шофёр ~ет** ягулык бетте, шофер эшсез утырырга мәҗбүр

загора́ться *несов см* **загоре́ться**

загорди́ться *сов. разг.* тәкәбберләнеп китү, эреләнеп китү, кәпрәеп китү, масаеп китү, кукраеп китү

загоре́ть *сов.* кояшта каралу, яну

загоре́||ться *сов.* **1.** яна башлау, янып китү, кабыну; кабынып китү; **дрова́ ~лись** утыннар янып китте **2.** ялтырый (яна) башлау; **глаза́ у него́ ~лись** аның күзләре ялтырый башлады **3.** *перен. чем, от чего и без доп.* (*покрыться румянцем*) кызарыну, кызарынып китү; барлыкка килү (*кызыллык*) **4.** *безл. кому с неопр.* ашкыну, ...сы килә башлау; **~лось ему́ е́хать** ул китәргә ашкына **5.** *перен.* кызып китү, башлану; **~лся спор** бәхәс кызып китте

загороди́ть *сов.* **1.** *кого-что* әйләндереп алу, койма тоту, каплап кую; **~ двор забо́ром** ишегалдын койма белән әйләндереп алу; **~ собо́й свет** гәүдән белән утны каплау; **~ дверь сту́льями** ишекне урындыклар белән каплап кую **2.** *что* каплау, бикләү; **~ доро́гу** юлны каплау

загороди́ться *сов.* **1.** (*поставить ограду*) койма кору **2.** каплану; **~ руко́й от со́лнца** кояштан кул белән каплану

загоро́дка *ж разг.* койма, киртә, читән

за́городный, -ая, -ое шәһәр читендәге, шәһәр тышындагы; **~ дом** шәһәр читендәге йорт

загости́ться *сов. разг.* озак кунак булу, кунакта озак булу

заготавливать *несов. см.* **загото́вить**

заготови́тель *м* хәзерләүче (*кеше яки учреждение*)

загото́вить *сов. что, чего* әзерләү, хәзерләү,хәзерләп кую; **~ все спра́вки** барлык белешмәләрне хәзерләп кую; **~ дров на́ зиму** кышка утын хәзерләү

загото́вка *ж* **1.** *см.* **загото́вить; ~ сельхозпроду́ктов** авыл хуҗалыгы азыкларын хәзерләү **2.** заготовка (*әзерләнгән материал*)

заготовля́ть *несов. см.* **загото́вить**

загото́вщик *м* **1.** *см.* **заготови́тель; 2.** (*в обувной промышленности*) заготовщик, заготовкалар кисүче

заграба́стать *сов. кого-что, прост.* тартып алу, талап алу, эләктереп алу

загради́тель *м мор.* заградитель (*миналар яки ятьмәләр кую судносы*)

загради́тельн||ый, -ая, -ое киртәләү ...ы; тоткарлау ...ы; комачаулау ...ы; каплап тору ...ы; **~ые сооруже́ния** киртәләү корылмалары

заградить *сов. что* бикләү, ябу, киртәләү, каплау; **~ путь** юлны каплау

заграждать *несов. см.* **заградить**

заражде́ни||е *с* **1.** *см.* **заградить; 2.** киртә, заграждение; **ми́нные ~я** миналар заграждениеләре

заграни́ц||а *ж* чит ил[ләр]; **торго́вля с ~ей** чит илләр белән сәүдә итү

загреба́ть *несов.* **1.** *что* көрәп алу, җыю, җыеп алу; **~ се́но** печән җыю **2.** (*ишкәк белән*) ишү; **глубо́ко́ ~** тирән батырып ишү

загребн||о́й, -а́я, -о́е **1.: ~о́е весло́** ишә торган ишкәк; **~а́я сторона́** ишә торган як (*сул як*) **2.** *в знач. сущ.* **~о́й** *м* койрыктагы ишкәкче

загребу́щ||ий, -ая, -ее *прост.*: **ру́ки ~ие** комсыз кеше хакында

загреме́ть I *сов. прост.* (*упасть со стуком*) лап итеп егылу, мәтәлеп төшү, шап итеп барып төшү; **~ с ле́стницы** баскычтан мәтәлеп төшү

загреме́||ть II *сов.* **1.** күкри башлау, гөрелди башлау, дөберди башлау; **~л гром** күк күкри башлады **2.** *чем* шалтырап китү, шалтыр-шолтыр килә башлау; **~ посу́дой** савыт-саба шалтырап китү

загрести́ *сов. см.* **загреба́ть**

загри́в||ок *м* **1.** (*у лошади*) ял төбе **2.** *прост.* муен тамыры; **дать по ~ку** муен тамырына тондыру

загримирова́ть *сов. кого-что* грим салу

загримирова́ться *сов.* гримлану, үзеңә грим салу

загриппова́ть *сов. разг.* грипп белән авырып китү, салкын тидерү

загро́бн||ый, -ая, -ое теге дөньядагы, ахирәттәге; **~ый мир** теге дөнья; **~ая жизнь** теге дөньяда яшәү ♦ **~ый го́лос** саңгырау тавыш

загромажда́ть *несов. см.* **загромозди́ть**

загромозди́ть *сов. что* **1.** каплау, томалау, тутыру; **~ вы́ход** чыгу юлын каплау **2.** *перен.* тутыру, тутырып бетерү (*мәс. хикәяне артык җентекләүләр белән*)

загромыха́ть *сов.* дөберди башлау, шалтырый башлау

загрохота́ть *сов.* дөбер-шатыр килә башлау

загрубе́л||ый, -ая, -ое каты, кытыршы, тупасланган; **~ые ру́ки** тупасланган куллар

загрубе́||ть *сов.* тупаслану, кытыршылану, бирчәю; **ко́жа ~ла** тире тупасланды

загружа́ть *несов. см.* **загрузи́ть**

загру́женность, загружённость *ж* **1.** йөкнең күп булуы; **~ желе́зных доро́г** тимер юлларда йөкнең күп булуы **2.** *перен.* күп булу; **~ рабо́той** эшнең күп булуы

загрузи́ть *сов.* **1.** *что* төяү, тутыру, тутырып бетерү; **~ автомаши́ну капу́стой** автомашинага кәбестә төяү **2.** *перен. кого-что* җитәрлек эш йөкләү, эш белән тәэмин итү, җитәрлек эш бирү; **~ преподава́телей** укытучыларга җитәрлек эш йөкләү

загрунтова́ть *сов. что* грунтлау, грунт салу; **~ пол** идәнне грунтлау

загрусти́ть *сов.* ямансулый башлау, сагына башлау, юксына башлау

загры́з||ть *сов.* **1.** *кого-что* талап үтерү, чәйнәп үтерү **2.** *перен. кого, разг.* җәфалап бетерү, интектереп бетерү, газаплау; **со́весть ~ла** вөждан газаплап бетерде

загрязне́ние *с см.* **загрязни́ть, загрязни́ться; ~ морско́й воды́** диңгез суының пычрануы

загрязни́ть *сов. что* пычрату, каралту, керләндерү; **~ пол** идәнне пычрату; **~ оде́жду** киемне керләндерү

загрязни́ться *сов.* пычрану, каралу, керләну, пычранып бетү

загрязня́ть *несов. см.* **загрязни́ть**

загрязня́ться *несов.* **1.** *см.* **загрязни́ться; 2.** *страд. от* **загрязня́ть**

заг *м* заг (*гражданлык актларын теркәү булеге*)

загуби́ть *сов. разг.* **1.** *кого-что* харап итү, һәлак итү, башына җиту, башын ашау **2.** *что, разг.* әрәм итү; туздыру; **~ мно́го де́нег** күп акча туздыру

загудрони́ровать *сов. что* гудронлау, гудрон сибеп катыру

загуля́ть *сов. прост.* эчкечелеккә бирелеп китү, эчәргә сабышу, типтерә башлау

загуля́||ться *сов. разг.* [озак] йөрү, йөрү белән мавыгу; **де́ти ~лись** балалар озак йөрделәр

загусте́ть *сов.* куеру, куерып китү

загусти́ть *сов. что* артыграк куертып җибәрү; **~ кра́ску** буяуны артыграк куертып җибәрү

зад *м* **1.** арт, арт як; **~ автомоби́ля** автомобильнең арт ягы **2.** (*задняя часть туловища*) арт, арт сан **3.** *мн.* **~ы́** *прост.* абзар арты, бакча арты

зада́бривать *несов. см.* **задо́брить**

задава́ть *несов. см.* **зада́ть**

задава́ться I *несов.* **1.** *см.* **зада́ться; 2.** *страд. от* **задава́ть**

задава́ться II *несов. прост.* масаю, борын күтәрү, кәпрәю

задави́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*придавить насмерть*) басып үтерү, сытып үтерү, таптатып үтерү **2.** *кого-что* (*задушить*) *прост.* буып үтерү **3.** *перен. что* (*подавить, заглушить*) басу, ирек бирмәү; **~ в себе́ тяжёлое чу́вство** үзендәге авыр хисне басу

зада́ние *с* бирем, йөкләмә, задание; **~ пятиле́тки** бишьеллык заданиесе; **пла́новое ~** план заданиесе

за́данн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **зада́ть; 2.** алдан билгеләнгән (күрсәтелгән); **соверши́ть поса́дку в ~ом райо́не** алдан билгеләнгән районга төшү

зада́ривать *несов. см.* **задари́ть**

задари́ть *сов. кого-что* **1.** (*поднести много подарков*) мул итеп бүләкләү, күп бүләк бирү, бүләкләр белән күмү **2.** *уст.* (*подкупить*) бүләк биреп сатып алу, бүләк биреп үз ягына аудару, үзенә карату

зада́ром *нареч. прост.* **1.** (*очень дёшево*) бик арзанга, шалкан бәясенә; **я купи́л э́то ~** мин моны бик арзанга сатып алдым **2.** (*напрасно*) юкка, юкка гына; **он пострада́л ~** ул юкка гына рәнҗетелде, тиккә зыян күрде

зада́т||ок *м* **1.** задатка (*әйбер өчен түләнәчәк акчаның алдан бирелә торган өлеше*); **внести́ (дать) ~ок** задатка бирү; **получи́ть ~ок** задатка алу **2.** *мн.* **~ки** сәләт чаткысы, сәләтлелек билгеләре; **хоро́шие ~ки** яхшы сәләтлелек билгеләре

зада́ть *сов.* **1.** *что кому* бирү, тапшыру; **~ рабо́ту** эш бирү **2.** *что, разг.* оештыру, ясау; **~ бал** мәҗлес оештыру **3.** *что, чего кому* бирү, салу; **~ ло́шади овса́** атка солы салу **4.** *что, чего кому, разг.* кирәген бирү; **я тебе́ зада́м** мин синең кирәгенне бирермен! ♦ **~ ба́ню** *кому* мунча кертү (*кыздыру, бик нык шелтәләү, бик нык тиргәү*); **~ вопро́с** сорау, сорау бирү; **~ жа́ру** *кому* кирәген бирү, арт сабагын укыту; **~ пе́рцу** *кому* кирәген бирү; **~ стра́ху** *кому* котын алу, котын чыгару; **~ стрекача́** үкчәне күтәрү, табан ялтырату, таю, шылу; **~ тон** тон бирү, үрнәк булу; **~ храпака́** *прост.* хырылдап (гырылдап) йоклау

зада́||ться *сов.* **1.** *чем, разг.* ... итеп кую; **~ться це́лью изучи́ть языки́** телләр өйрәнүне максат итеп кую **2.** *прост.* булып чыгу, барып чыгу; **де́ло ему́ не ~ло́сь** аның эше барып чыкмады

зада́ч||а *ж* **1.** бурыч, йомыш, вазифа; **очередны́е ~и городско́го строи́тельства** шәһәр төзелешенең чираттагы бурычлары **2.** мәсьәлә; **арифмети́ческая ~а** африфметик мәсьәлә

зада́чник *м* мәсьәләләр җыентыгы

задвига́ть *несов. см.* **задви́нуть**

задви́гать *сов. чем* (*начать двигать*) этә башлау, шудыра башлау

задви́гаться *сов.* (*начать двигаться*) хәрәкәтләнә башлау, бара башлау

задвига́ться *несов.* **1.** *см.* **задви́нуться; 2.** (*быть задвижным*) шудырылу, эшерелү **3.** *страд. от* **задвига́ть**

задви́жк||а *ж* эшермә, эшермә бик; **закры́ть дверь на ~у** ишекне эшермә бик белән бикләү

задвижн||о́й, -а́я, -о́е эшермәле, шудырмалы; **~а́я дверь** шудырмалы ишек

задви́нуть *сов. что* **1.** этеп кертү, этеп кую; **~ чемода́н под крова́ть** чемоданны карават астына этеп кертү **2.** каплау, каплап кую; **~ окно́ шка́фом** тәрәзәне шкаф белән каплап кую

задви́ну||ться *сов.* ябылу; эшерелү; **я́щик ~лся** тартма ябылды

задво́рк||и *только мн.* абзар арты, өй арты ♦ **быть на ~ах** *чего* иң артта булу, күләгәдә булу

задева́ть I *несов. см.* **заде́ть**

задева́||ть II *сов. прост.* кую; **куда́ ты ~л мою́ ша́пку?** кая куйдың син минем бүрекне?

задева́||ться *сов. прост.* китү, югалу; **куда́ ~лась кни́га?** кая киткән китап?

заде́л *м* запаска (маяга) эшләнгән эш, башлап куелган эш; **созда́ть ~ на сле́дующий кварта́л** киләсе квартал өчен башлап куелган эш

заде́лать *сов. что* томалау, томалап кую; **~ ще́ли в полу́** идәндәге ярыкларны томалау; **~ посы́лку** посылканы кадаклап кую

заде́латься *сов. кем, прост.* булу; **~ меха́ником** механик булу

заде́лывать *несов. см.* **заде́лать**

задёрганный, -ая, -ое (*измученный*) интеккән, интегеп беткән, чыгырыннан чыгарылган, җәфаланган

задёргать I *сов. кого-что, разг.* интектереп бетерү, теңкәгә тию; **~ кого-л. приди́рками** юк-барга бәйләнеп *кемнең дә булса* теңкәсенә тию

задёргать II *сов. что, чем* тарткалый башлау, йолыккалый башлау; **~ во́жжи (вожжа́ми)** дилбегәне тарткалый башлау

задёрга||ться *сов.* тартыша башлау, калтырана башлау; **гу́бы у него́ ~лись от оби́ды** үпкәләүдән аның иреннәре калтырана башлады

задёргивать *несов. см.* **задёрнуть**

задержа́||ть *сов.* **1.** *кого-что* тоткарлау, тотып калу; **~ть по́езд** поезды тоткарлау; **меня́ ~ли дела́** мине эшләр тоткарлады **2.** *что* (*отсрочить*) кичектерү, соңгарак калдыру; **~ть вы́садку деса́нта** десант төшерүне кичектерү; **дожди́ ~ли сев** яңгырлар чәчүне соңгарак калдырды **3.** *что* туктату, әкренәйтү; **~ть дыха́ние** сулыш алуны туктатып тору (тоткарлау); **~ть шаги́** адымнарны акрынайту **4.** *кого-что* тоту, кулга алу; **~ престу́пника** жинаятьчене кулга алу **5.** (*не отдать вовремя*) вакытында кайтармау, озак тоту; **~ть долг, зарплату** бурычны, хезмәт хакын вакытында кайтармау, бирмәү; **~ть кни́гу** китапны озак тоту, китапны вакытында кайтармау

задержа́||ться *сов.* тотылып тору; тоткарлану; **~ться у вхо́да** ишек янында тоткарлану; **~ться в доро́ге** юлда тоткарлану; **нача́ло конце́рта ~лось** концертның башлануы тоткарланды

заде́рживать *несов. см.* **задержа́ть**

заде́рживаться *несов.* **1.** *см.* **задержа́ться; 2.** *страд. от* **заде́рживать**

заде́ржк||а *ж* **1.** *см.* **задержа́ть** 1-3; **2.** (*промедление*) соңару, тоткарлану, кичегү, соңга калу; **рабо́тать без ~ек** тоткарланмыйча эшләү

заде́рнуть *сов. что* (*пәрдәне*) тарту, каплау

заде́рну||ться *сов.* каплану, томалану, ябылу; **скло́ны гор ~лись ды́мкой** тау битләре төтен белән капланды; **за́навес ~лся** пәрдә ябылды

заде́||ть *сов.* **1.** *что, за что* эләгү, эләктерү, бәрелү, бәрелеп китү, орыну, тию, тиеп китү; **~ть за гвоздь** кадакка эләгү; **пу́ля ~ла кость** пуля сөяккә тигән **2.** *перен. кого-что* (*обидеть*) кәефкә тию, хәтер калдыру; **его́ выступле́ние си́льно меня́ ~ло** аның чыгышы минем хәтеремне бик нык калдырды **3.** *перен. кого-что* (*взволновать, затронуть*) дулкынландыру, кузгату ♦ **~ть за живо́е** зур тәэсир калдыру

зади́ра *м, ж разг.* бәйләнчек, сугыш чукмары

зади́рать *несов.* **1.** *см.* **задра́ть**; **2.** *кого* (*приставать, дразнить*) (*кешегә*) бәйләнү, (*кешене*) котырту, үртәү

задира́ться 1. *см.* **задра́ться; 2.** *к кому* (*приставать*) бәйләнү, котырту, үртәү **3.** *страд. от* **задира́ть**

зади́ристый, -ая, -ое *разг.* бәйләнчек, талашырга яратучан

за́дне- *кушма сүзләрнең беренче кисәге, мәс.* **заднебо́льшый** арткы аңкау ... ы; **заднеязы́чный** тел арты...ы

за́дн||ий, -яя, -ее арткы, арт...; **~ее колесо́** арткы тәгәрмәч ♦ **быть без ~их ног** бик нык ару, арып егылу, аяксыз калу; **~ий прохо́д** *анат.* арт юл; **~им число́м** үткән число белән; **~им умо́м кре́пок** туйдан соң дөмбергә; **~яя мысль** астыртын уй, яшерен фикер; **на ~их ла́пках стоя́ть (ходи́ть)** *перед кем* табан ялау, тәлинкә тоту, ялагайлану

за́дник *м* **1.** (*у обуви*) задник, үкчә арты **2.** *театр.* задник (*сәхнәнең арткы планы*)

задо́брить *сов. кого-что* юмалау, юмалап үзенә карату

задо́к *м* арт, арткы як; **~ теле́ги** арба арты

задо́лго *нареч.* күп элек, бик күп алдан; **~ до о́сени** көз башланудан күп элек

задолжа́ть *сов. что кому-чему и без доп., разг.* бурычка керү, әҗәткә керү, бурычка бату

задолже́нность *ж* бурыч, бирәчәк, бирәсе; **больша́я ~** күп бурыч; **пога си́ть ~** бирәчәкне түләү

задо́лжник *м разг.* бурычлы, бирәчәге булган кеше

за́дом *нареч.* арт белән, артка таба; **дви́гаться ~** артка таба хәрәкәтләнү; **~ наперёд** артын алга

задо́р *м* **1.** (*пылкость*) дәрт, ялкын; **ю́ношеский ~** яшьлек дәрте **2.** (*запальчивость*) кызулык, кызу канлылык, ярсып китүчәнлек

задо́ринк||а *ж*: **ни сучка́ ни ~ и** шома гына, шоп-шома, бик шома; ул-бусыз гына, хәвеф-хәтәрсез

задо́рный, -ая, -ое **1.** (*пылкий*) дәртле, ялкынлы; **~ взгляд** дәртле караш **2.** (*запальчивый*) кызу, кызу канлы, кызып китүчән, ярсып китүчән

задохну́ться *сов.* **1.** (*умереть*) тончыгып үлү, тын бетеп үлү **2.** тын бетү, сулыш тараю, тын кысылу; **~ от бе́га** йөгерүдән тын бетү

задразни́ть *сов. кого-что, разг.* үртәп йөдәтеп бетерү, үртәп теңкәсенә тию, үчекләп йөдәтеп бетерү, үчекләп теңкәсенә тию

задра́ить *сов. что, мор.* ныгытып ябу, ныгытып бикләү; **~ иллюмина́торы** иллюминаторларны ныгытып ябу

задрапирова́ть *сов. что* дапировкалау, тукымалар белән бизәү (каплау, бөркәү)

задрапирова́ться *сов.* драпировкалану, пәрдәләр (чаршаулар) белән бизәлү; бөркәну

задрапи́ровывать *несов. см.* **задрапирова́ть**

задрапи́ровываться *несов.* **1.** *см.* **задрапирова́ться; 2.** *страд. от* **задрапи́ровывать**

задра́||ть *сов.* **1.** *что, разг.* күтәрү, кайтару; **~ть го́лову** башны күтәрү **2.** тырнау, сыдыру; **~ть ко́жицу на па́льце** бармак тиресен сыдыру **3.** *кого-что* үтерү; буу, буып үтерү; **волк ~л овцу́** бүре сарыкны буып үтергән ♦ **~ть нос** борын күтәрү (чәю), үзен әллә кемгә саный башлау

задра́||ться *сов. разг.* **1.** суелу, сыдырылу; **ко́жица на па́льце ~ла́сь** бармак тиресе сыдырылган **2.** кайтарылу, күтәрелү; **пла́тье ~ло́сь кве́рху** күлмәк итәге югарыга күтәрелгән

задре́мать *сов.* йокымсырау, йокымсырый башлау, йокымсырап китү, йокыга китә башлау

задрожа́||ть *сов.* тетри башлау, селкенә башлау; (*о людях и животных*) калтырый башлау, калтырана башлау

задубе́||ть *сов. прост.* (*стать жёстким*) кату; **плащ ~л** плащ каткан

задува́ть I *несов. см.* **заду́ть** I

задува́ть II *несов. см.* **заду́ть** II

задува́||ть III *несов.* **1.** (*дуть — о ветре*) исү, өрү **2.** [җил] өреп керү, өрү; **в щель ~ет** ярыктан өрә **3.** *что* өреп тутыру; **ве́тер ~л снег под кры́шу** җил түбә астына кар өреп тутырган

заду́мать *сов.* **1.** *что и с неопр.* уйлау, исәп итү, ниятләү; **~ е́хать в Москву́** Мәскәүгә барырга исәп итү **2.** уйлап кую, күңелдән уйлау; **~ како́е-ли́бо число́** нинди дә булса бер сан уйлау

заду́ма||ться *сов.* **1.** *над чем, о чём* уйлау, уйлану, уйга калу, уйга бату, уйга чуму; **~ться о бу́дущем** киләчәк турында уйлау; **он глубоко́ ~лся** ул тирән уйга калды **2.** *с неопр. и с отриц., разг.* җөрьәт итү, кыю; **он не ~лся сказа́ть пра́вду в глаза́** ул дөреслекне туп-туры әйтергә кыймады

заду́мка *ж прост.* зур теләк; **была у него́ ~ на ро́дину съе́здить** аның туган якка кайтырга зур теләге бар иде

заду́мчивость *ж* уй; **впасть в ~** уйга бату

заду́мчивый, -ая, -ое уйчан, уйланучан; **~ челове́к** уйчан кеше; **~ взгляд** уйчан караш

заду́мывать *несов. см.* **заду́мать**

заду́мываться *несов. см.* **1. заду́маться; 2.** *страд. от* **заду́мывать**

заду́ть I *что* сүндерү, өреп сүндерү; **~ свечу́** шәмне өреп сүндерү

заду́ть II *сов. что, тех.* кабызып җибәрү, яндырып җибәрү; **~ до́мну** домнаны кабызып җибәрү

заду́||ть III *сов.* **1.** (*начать дуть*) исә башлау, өрә башлау; **~л ве́тер** җил исә башлады **2.** *что* өреп тутыру; **ве́тер ~л снег в чула́н** җил чоланга кар өреп тутырган

заду́шевный, -ая, -ое эчкерсез, чын, чын күңелдән; **~ друг** чын дус; **~ разгово́р** чын күңелдән сөйләшү

заду́ши́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*умертвить*) буып үтерү **2.** *перен. что* (*подавить, уничтожить*) буу, кысу, басу

задыми́ть I *сов. что, разг.* (*закоптить*) төтен белән тутыру, төтен белән каралтып бетерү; **~ потоло́к** түшәмне төтен белән каралтып бетерү

задыми́ть II *сов.* (*начать дымить*) төтенли башлау

задыми́||ться I *сов.* (*закоптиться*) *разг.* корымлану, корым белән каплану; **потоло́к ~лся** түшәм корым белән капланган

задыми́||ться II *сов.* төтен чыга башлау; **тру́бы ~лись** торбалардан төтен чыга башлады

задыха́ться *несов. см.* **задохну́ться**

задыша́||ть *сов.* сулый башлау, тын ала башлау, сулыш ала башлау; **больно́й тяжело́ ~л** авыру авыр сулыш ала башлады

заеда́ть *несов. см.* **зае́сть**

зае́зд *м* **1.** *см.* **зае́хать** 1-4; **2.** *спорт.* заезд; **пе́рвый ~** беренче заезд

зае́здить *сов. кого-что* **1.** (*лошадь*) йөртеп алҗыту, йөртеп өшәндерү **2.** *перен. прост.* (*измучить*) алҗытып бетерү, интектереп бетерү, теңкәгә тию

зае́здом *нареч. разг.* үтеп барышлый, узышлый, узып барышлый, юл уңаена

заезжа́ть *несов. см.* **зае́хать** 1-5

зае́зженн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** *прич. от* **зае́здить**; **2.** (*изнурённый*) алҗыган, интеккән, арыган **3.** *перен.* тапталган, күп чәйнәлгән, күптән билгеле; **~ая остро́та** тапталган мәзәк

зае́зжий *м разг.* узгынчы, юлаучы, [вакытлыча] килгән кеше

заём *м* заём

заёмн||ый, -ая, -ое *спец.* бурычка алуны раслау ...ы, бурыч ...ы; **~ое письмо́** бурычка алуны раслау язуы

зае́||сть *сов.* **1.** *кого-что* үтерү, буып үтерү; **волк ~л овцу́** бүре сарыкны буып үтергән **2.** *перен. кого* (*замучить*) интектереп бетерү, җәфалау, теңкәгә тию, үзәккә үтү **3.** *что чем* артыннан ... кабу, кабып җибәрү; **~сть лека́рство конфе́той** дару артыннан конфет кабып җибәрү **4.** *обычно безл. что, разг.* кысу, кыстыру, эләктерү; **бло́ком ~ло верёвку** чыгыр бауны кыстырды **5.** *безл. кого, прост.* горурлыгына тию; **меня́ э́то ~ло** бу минем горурлыгыма тиде

зае́сться *сов. прост.* талымлау, тәмле тамакланып китү

зае́хать *сов.* **1.** (*куда-л., к кому-л.*) керү; (*мимоходом*) узып барышлый керү (кереп чыгу); **~ во двор** ишегалдына керү; **~ к знако́мым** узып барышлый танышларга керү **2.** *за кем-чем* алырга керү; **~ за детьми́** балаларны алырга керү **3.** әйләнеп керү, урап керү; **~ со стороны́ са́да** бакча ягыннан әйләнеп керү **4.** барып керү, барып төшү; **~ в кана́ву** канауга барып керү **5.** *кому во что, прост.* кундыру, менеп төшү; **~** *кому-л.* **в физионо́мию** *берәр кешенең* яңагына кундыру

зажа́ривать *несов. см.* **зажа́рить**

зажа́риваться *несов.* **1.** *см.* **зажа́риться 2.** *страд. от* **зажа́ривать**

зажа́рить *сов. кого-что* кыздыру, кыздырып пешерү; куыру, куырып пешерү

зажа́риться *сов.* кыздырылып җитү; куырылып җитү

зажа́ть *сов.* **1.** *кого-что* кысып тоту, кысу, кыстыру; **~ болт в тиски́** болтны эскәнҗәгә кыстыру **2.** *что* каплау, томалау; **~ у́ши** колакларны каплау **3.** *перен. кого-что* басу, кысу, юл куймау, томалау; **~ инициати́ву** инициативаны кысу **4.** *что, прост.* яшереп калдыру; **~ де́ньги** акчаны яшереп калдыру ♦ **~ рот** *кому* авызын каплау

зажда́ться *сов. кого-чего, разг.* көтә-көтә арып бетү, көтә-көтә көтек булу

зажелте́ть *сов.* **1.** (*показаться — о чём-л. жёлтом*) сагаеп күренү **2.** (*начать желтеть*) саргая башлау

зажелти́ть *сов. что* (*закрасить жёлтым*) сарыга буяу, сарыга ману; (*испачкать жёлтым*) сарыга пычратып бетерү, сарыга буяп бетерү

зажёчь *сов.* **1.** *что* кабызу, яндыру, кабызып җибәрү, яндырып җибәрү; **~ спи́чку** шырпы кабызу **2.** *перен. кого-что* дәртләндерү, дәртләндереп җибәрү; дикъкатьне җәлеп итү; **~ слу́шателей ре́чью** речь сөйләп тыңлаучыларның дикъкатен җәлеп итү

заж||ёчься *сов.* **1.** кабыну, янып китү, кабынып китү; **~гли́сь огни́** утлар кабынып китте **2.** *перен. чем* уянып китү, дәртләну, яну, кабыну, кабынып китү; **~ёчься жа́ждой борьбы́** көрәшкә омтылыш белән яну

зажже́ние *с см.* **зажёчь; ~ олимпи́йского огня** Олимпия утын яндыру

зажива́ть *несов. см.* **зажи́ть** I

ЗАЖ-ЗАЙ

заживáться *несов. см.* **зажи́ться**

заживи́ть *сов. что* [дәвалап] төзәтү; ~ **ра́ну** җәрәхәтне төзәтү

заживля́ть *несов. см.* **заживи́ть**

за́живо *нареч.* тереләй, тере килеш, тереләтә; ~ **погребённый** тереләтә күмелгән

зажига́лка *ж* **1.** зажигалка, уткабызгыч **2.** *разг.* яндыргыч бомба

зажига́ние *с* **1.** *см.* **зажéчь**; **2.** (*устройство в двигателях внутреннего сгорания*) кабызу, зажигание

зажига́тельный, -ая, -ое **1.** яндыра торган; ~ **ая бóмба** яндыра торган бомба **2.** *перен.* ялкынлы, ялкынландыра торган, дәртләндергеч, җилкенләндерә торган; ~ **ая речь** ялкынлы нотык

зажига́ть *несов. см.* **зажéчь**

зажига́ться *несов.* **1.** *см.* **зажéчься**; **2.** *страд. от* **зажига́ть**

зажи́м *м* **1.** *см.* **зажáть** 1, 3; **2.** кыскыч, кыстыргыч, зажим

зажима́ть *несов. см.* **зажáть**

зажи́мщик *м разг.* кысучы; ~ **кри́тики** тәнкыйтьне кысучы

зажире́ть *сов. разг.* симерү, көрәю, май басу

зажи́точность *ж* таза хәллелек, бай тормыш, таза тормыш

зажи́точный, -ая, -ое таза тормышлы, нык тормышлы, иркен (мул) тормышлы; ~ **колхóз** таза тормышлы колхоз

зажи́ть I *сов.* төзәлү, төзәлеп җитү; **ра́на зажила́** яра төзәлде

зажи́ть II *сов.* (*начать жить*) тора башлау, яши башлау, тормыш корып җибәрү; ~ **хорошó** яхшы тормыш корып җибәрү

зажи́ться *сов. разг.* озак тору, озак яшәү; ~ **в дере́вне** авылда озак тору

зажму́рить *сов. что*: ~ **глаза́** *см.* **зажму́риться**

зажму́риться *сов.* күзне кысу, күзне йомып тору

зажурча́||ть *сов.* челтерәп ага башлау; ~ **ли ручьи́** чишмәләр челтерәп ага башлады

зазва́ть *сов. кого-что*, *разг.* кыстап чакыру, кыстап чакырып китерү; ~ **в го́сти** кунакка кыстап чакыру

зазвене́||ть *сов.* шалтырый башлау, чылтырый башлау; яңгырый башлау; ~ **л колоко́льчик** кынгырау шалтырый башлады; ~ **ли голоса́** тавышлар яңгырый башлады

зазвони́||ть *сов.* шалтырый башлау, чылтырый башлау; ~ **ть в ко́локол** кыңгырау шалтырый башлады; ~ **л телефóн** телефон шалтырый башлады

зазвуча́||ть *сов.* **1.** яңгырый башлау; **вдали́** ~ **ли голоса́** еракта тавышлар яңгырый башлады **2.** ишетелү, сизелү; **в его́ го́лосе** ~ **ла ра́дость** аның тавышында шатлык ишетелде

заздра́вн||ый, -ая, -ое исәнлек теләп; ~ **ый тост** исәнлек теләп әйтелгән тост; ~ **ая пе́сня** исәнлек теләп җырланган җыр

зазева́ться *сов. разг.* як-якка каранып дәньяны оныту, каранып бара-бара дәньяны оныту, авыз ачып йөреп дәньяны оныту

зазелене́||ть *сов.* **1.** (*показаться — о чем-л. зелёном*) яшелләнеп күренә башлау **2.** (*начать зеленеть*) яшел үлән (яфрак) белән каплану; ~ **ли луга́** болынлар яшел үлән белән капландылар

зазелени́ть *сов. что, разг.* яшелгә буяу, яшелгә пычрату; ~ **пла́тье трáвой** күлмәкне үлән яшеленә пычрату

заземле́ние *с* **1.** *см*; **заземли́ть**; **2.** *тех.* җир белән тоташтыру чыбыгы

заземли́ть *сов. что* җиргә тоташтыру (*мәс. антеннаны*)

заземля́ть *несов. см.* **заземли́ть**

зазимова́ть *сов.* кышларга калу, кышка калу, кышлау

зазнава́ться *несов. см.* **зазна́ться**

зазна́йка *м, ж разг.* масаючы, борын күтәрүче, тәкәббер кеше

зазна́йство *с разг.* масаю, мин-минлек, борын күтәрү

зазна́ться *сов. разг.* масая башлау, масаеп китү, борын күтәрү, әллә кем булып китү, кәпрәеп китү

зазно́ба *ж уст.* җанкай, сөйгән яр, җанкай-җанаш

зазóр *м спец.* ярык, аралык (*ике деталь арасындагы ачыклык*)

зазóрн||ый, -ая, -ое *прост.* хурлыклы, оятлы, оят; ~ **ое дéло** хурлыклы эш

зазре́ни||е *с*: **без** ~ **я со́вести** вөҗдансыз рәвештә, оятсыз рәвештә, намуссыз рәвештә

зазýбренный I, -ая, -ое **1.** *прич. от* **зазубри́ть** I, **зазýбрить**; **2.** кыршалган, үтмәсләнгән, тешләнгән; ~ **топóр** үтмәсләнгән балта

зазýбренный II, -ая, -ое **1.** *прич. от* **зазубри́ть** II; **2.** ятланган, күңелгә бикләнгән; ~ **ответ** күңелгә бикләнгән җавап

зазýбривать I *несов. см.* **зазубри́ть** I, **зазýбрить**

зазýбривать II *несов. см.* **зазубри́ть** II

зазýбриваться *несов.* **1.** *см.* **зазубри́ться, зазýбриться**; **2.** *страд. от* **зазýбривать** I

зазýбрина *ж*: **нож с** ~ **ми** йөзе кителеп беткән пычак, кыршылган пычак

зазубри́ть I, **зазýбрить** *сов. что* китеп бетерү, кыршылдыру; ~ **нож** пычакны кыршылдыру

зазубри́ть II *сов. что* ятлау, аңламыйча ятлау, күңелдән бикләү

зазубри́||ться, зазýбри||ться *сов.* кыршылып бетү, кителеп бетү; **нож** ~ **лся** пычак кыршылып беткән

зазыва́ть *несов. см.* **зазва́ть**

заигра́ть I *сов.* **1.** *что* (*истрепать*) уйнап туздыру, уйный-уйный таушалдырып бетерү; ~ **ка́рты** уйный-уйный кәртләрне таушалдырып бетерү **2.** күп уйнап тәмен (кызыгын) җибәрү; ~ **пье́су** күп уйнап пьесаның кызыгын җибәрү

заигра́||ть II *сов.* **1.** (*начать играть*) уйный башлау, уйнарга тотыну; ~ **ла му́зыка** музыка уйный башлады **2.** (*засверкать*) ялтырый башлау, ялт-йолт килү, җем-җем итү; **со́лнце** ~ **ло в ка́плях росы́** чык бөртекләрендә кояш нурлары җем-җем итәләр **3.** *перен.* алсулык уйнау, алсу төс[кә] керү; **на щека́х** ~ **л румя́нец** битләренә алсу төс керде

заигра́||ться *сов.* уен белән мавыгып калу, уен белән онытылып китү, бик озак уйнау; **де́ти** ~ **лись** балалар уенга мавыктылар

заи́грывание *с см.* **заи́грывать** II

заи́грывать I *несов. см.* **заигра́ть** I

заи́грывать II *несов.* с *кем, разг.* **1.** (*кокетничать*) татлы теллеләнү, ягымлылык күрсәтү, якты (ачык) чырай күрсәтү **2.** (*заискивать*) ялагайлану, ярарга тырышу, тәлинкә тоту, юмакайлану, табанын ялау

заи́грываться *несов. см.* **заигра́ться**

заи́ка *м, ж* тотлыгып сөйләүче, бертәк

заика́ние *с см.* **заика́ться**

заика́||ться *несов.* **1.** тотлыгу, тотлыгып сөйләү; **ребёнок** ~ **ется** бала тотлыгып сөйләшә **2.** *перен. о ком-чём, разг.* телгә алу, авыз ачу; **он и не** ~ **лся о поéздке** китү турында ул телгә дә алмады

заик||нýться *сов. см.* **заика́ться** 2

заи́мка *ж* заимка, тарлау (**1.** *ист. берәр кеше тарафыннан беренче тапкыр үзләштерелгән җир участогы* **2.** *Себердә кайбер кечкенә авылларның исеме*)

заимода́вец *м уст.* бурычка бирүче, әҗәткә биреп торучы

заимообра́зный, -ая, -ое көтәргә (бурычка, әҗәткә) алынган яки бирелгән

заи́мствовани||е *с* **1.** *см.* **заи́мствовать**; ~ **е сюже́та** сюжет алу **2.** алынма; **иноязы́чные** ~ **я** *лингв.* чит телләрдән алынмалар, чит телләрдән кергән сүзләр

заи́мствовать *сов.*, *несов. что* алу, үзләштерү; ~ **сло́во** (*башка телләрдән*) сүз алу

заи́ндевелый, -ая, -ое бәсләнгән, бәс кунган

заи́ндеветь *сов.* бәсәрү, сыкылану, бәс белән каплану, сыкы белән каплану

заинтересóванность *ж* кызыксыну; ~ **в де́ле** эш белән кызыксыну

заинтересова́ть *сов. кого-что* кызыксыну тудыру, кызыксыну уяту; кызыксындыру; ~ **слу́шателей расска́зом** хикәя белән тыңлаучыларда кызыксыну уяту

заинтересова́ться *сов. кем-чем и без доп.* кызыксыну; ~ **кни́гой** китап белән кызыксыну

заинтересóвывать *несов. см.* **заинтересова́ть**

заинтригова́ть *сов. кого-что* кызыксындыру, кызыксыну тудыру

заискивать *несов. перед кем-чем* ялагайланып ярарга тырышу, ялагайлану, куштанланып ярарга тырышу

заи́скивавший, -ая, -ее **1.** *прич. от* **заи́скивать**; **2.** (*подобострастный*) ялагай, куштан

за́ймов||ый, -ая, -ое заём ...ы; ~ **ые опера́ции** заём операцияләре

займодержа́тель *м* заём тотучы, заёмнары булган кеше

зайти́ *сов.* 1. керү, кереп чыгу; ~ **ве́чером** кичен кереп чыгу 2. *за кем-чем* алырга керү, алып чыгарга керү; ~ **за това́рищем** иптәшне алырга керү 3. керү, барып керү; ~ **за́ угол** почмак артына барып керү; **со́лнце зашло́ за ту́чи** кояш болытлар артына керде 4. әйләнеп керү; читләтеп керү; ~ **спра́ва** уң яктан әйләнеп керү 5. бату, баю; **со́лнце зашло́** кояш баеды; **луна́ зашла́** ай батты 6. башлану, башланып китү; **разгово́р зашёл о ...** сүз ... турында башланып китте ♦ **де́ло зашло́ сли́шком далеко́** эш бик тирәнгә кереп китте

зайти́сь *сов. прост.* ою, катып калу; **ру́ки зашли́сь от хо́лода** салкыннан куларым катты ♦ **дух зашёлся** тын кысылды; **се́рдце зашло́сь** йөрәк туктагандай булды, йөрәк кысылды

зайча́тина *ж* куян ите

за́йчик *м* 1. *уменьш. от* **за́яц**; куянкай, кечкенә куян 2. нур шәүләсе; ~ **и на стене́** стенада нур шәүләләре

зайчи́ха *ж* ана куян

зайчо́нок *м* куян баласы

закабали́ть *сов. кого-что* кабалага төшерү, коллыкка төшерү

закабали́ться *сов.* кабалага төшү, коллыкка төшү

закабаля́ть *несов. см.* **закабали́ть**

закабаля́ться *несов.* 1. *см.* **закабали́ться**; 2. *страд. от* **закабаля́ть**

закады́чный, -ая, -ое *разг.*: ~ **друг (прия́тель)** якын (җан) дус; ахирәт дус

зака́з *м* заказ; **получи́ть** ~ *на что-л. нәрсәгә булса да* заказ кабул итү; **о́бувь на** ~ заказ буенча эшләнгән аяк киеме

заказа́ть *сов. что* заказ бирү, заказать итү; ~ **костю́м** костюмга заказ бирү

зака́зник *м* заказник (*вакытлыча аучылык, агач кисү тыелган урман яки сулыклар*)

заказн||о́й I, -а́я, -о́е 1. (*сделанный на заказ*) заказ белән эшләнгән 2. заказной; ~ **о́е письмо́** заказной хат

заказно́й II, -а́я, -о́е (*заповедный*) тыелулы; ~ **лес** тыелулы урын (*аучылык һәм агачлар кисү тыелган урман яки сулыклар*)

зака́зчик *м* заказ бирүче

зака́зчица *м* заказ бирүче хатын (кыз)

зака́зывать *несов. см.* **заказа́ть**

зака́л *м* 1. *см.* **закали́ть** I; ~ **ста́ли** корычны чыныктыру 2. чыныкканлык, чыныккан булу; **сталь кре́пкого** ~**а** нык чыныккан корыч 3. *перен.* (*выносливость*) ныклык, чыныкканлык ♦ **челове́к ста́рого** ~**а** иске тәрбия алган кеше, иске гореф-гадәтләрне саклаучы кеше

закалённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **закали́ть**; 2. (*стойкий, выносливый*) ныгыган, чыныккан

зака́ливание *с см.* **закали́ть, закали́ться**; ~ **организ́ма** организмны чыныктыру

зака́ливать *несов. см.* **закали́ть**

зака́ливаться *несов.* 1. *см.* **закали́ться**; 2. *страд. от* **зака́ливать**

закали́ть *сов.* 1. *что* чыныктыру (*мәс. металлны*) 2. *перен. кого-что* чыныктыру, ныгыту; ~ **здоро́вье** сәламәтлекне ныгыту

закали́||ться *сов.* 1. чыныгу; **сталь** ~**лась** корыч чыныкты 2. *перен.* ныгу, чыныгу; **а́рмия** ~**лась в боя́х** армия сугышларда чыныкты

зака́лка *ж* 1. *см.* **закали́ть, закали́ться**; ~ **ста́ли** корычның чыныгуы 2. чыныкканлык; **иде́йно-полити́ческая** ~ **молодёжи** яшьләрнең идея-сәяси яктан чыныкканлыгы

зака́лывать *несов. см.* **заколо́ть** I

зака́лываться *несов.* 1. *см.* **заколо́ться**; 2. *страд. от* **зака́лывать**

закаля́ть *несов. см.* **закали́ть**

закаля́ться *несов.* 1. *см.* **закали́ться**; 2. *страд. от* **закаля́ть**

зака́нчивать *несов. см.* **зако́нчить**

зака́нчиваться *несов.* 1. *см.* **зако́нчиться**; 2. *страд. от* **зака́нчивать**

зака́пать I *сов.* 1. *кого-что* чәчрәтеп пычрату, чәчрәтеп пычратып бетерү; ~ **стол черни́лами** кара чәчрәтеп өстәлне пычратып бетерү 2. *что, разг.* тамызу, тамызып салу; ~ **лека́рство в нос** борынга дару тамызу

зака́пать II *сов.* (*начать капать*) тама башлау, тамчылый башлау, төшә башлау, төшкәли башлау; тамгалый башлау; **дождь** ~**л** яңгыр тамгалый башлады

зака́пывать I *несов. см.* **зака́пать** I

зака́пывать II *несов. см.* **закопа́ть**

зака́пываться *несов.* 1. *см.* **закопа́ться**; 2. *страд. от* **зака́пывать** II

зака́рмливать *несов. см.* **закорми́ть**

зака́т *м* 1. бату, баю; ~ **со́лнца** кояш баюы 2. (*время*) шәфәкъ, кояш баю, кояш баешы; **верну́ться на** ~**е** шәфәкъ вакытында әйләнеп кайту 3. (*эшнең, гомернең*) азагы, соңы; **на** ~**е дней** гомернең азагында

зака́тать *сов.* 1. *кого-что во что* төрү, төреп кую, чорнап кую, урап кую; ~ **в полоте́нце** сөлге белән чорнап кую 2. *что* (*заровнять*) каток белән тигезләү 3. *что, разг.* сызгану; ~ **рукава́** җиңнәрне сызгану 4. *что* (*герметически закрыть*) ныгытып ябу, капкач белән ябу, һава кермәслек итеп томалау (*мәс. кайнатма савытларын*)

зака́тить *сов. что* тәгәрәтеп кертү; ~ **мяч под дива́н** тупны диван астына тәгәрәтеп кертү ♦ ~ **глаза́** күзне акайту; ~ **исте́рику** ярсып елый башлау; ~ **пир горо́й** зур кәеф-сафа мәҗлесе үткәрү; ~ **пощёчину** яңагына күндыру, яңагына чалтырату, яңагына салып җибәрү

зака́ти||ться *сов.* 1. тәгәрәп керү; **мяч** ~**лся в у́гол** туп почмакка тәгәрәп керде 2. баю, бату; **со́лнце** ~**лось** кояш баеды 3. *перен.* сүну, югалу; **сла́ва его́** ~**лась** аның даны сүнде ♦ ~**ться сме́хом** эч катып көлә башлау; **глаза́** ~**лись** күзләре зур ачылды (*куркудан, гаҗәпләнүдән һ.б.ш.*)

зака́т||ный, -ая, -ое 1. шәфәкъ ...ы; ~**ые лучи́** шәфәкъ нурлары 2. кояш бату ...ы; кояш баю ...ы; ~**ый час** кояш баю вакыты

зака́тывать I *несов. см.* **закати́ть**

зака́тывать II *несов. см.* **закати́ть**

зака́тываться *несов.* 1. *см.* **закати́ться**; 2. *страд. от* **зака́тывать** II

зака́ч||ать I *сов. кого* 1. (*убаюкать*) тирбәтә башлау; атындыра башлау 2. тирбәтеп арыту, тирбәтеп башын әйләндерү; чайкалудан (чайкалып) күңел болгану; в **ло́дке меня́** ~**ло** *безл.* көймәдә чайкалып күңелем болганды

закача́ть II *сов.* (*начать качать*) селкетә башлау, селки башлау, тирбәтә башлау; ~ **голово́й** башны селки башлау

закача́||ться *сов.* тирбәлә башлау; селкенә башлау; чайкала башлау, атына башлау ♦ ~**ешься!** *прост.* исең-акылың китәр!, егылып китәрсең!

зака́шлять *сов.* йөткерә башлау, йөткерергә тотыну, ютәлли башлау

зака́шляться *сов.* буылып йөткерә башлау; ~ **от ды́ма** төтеннән буылып йөткерә башлау

зака́я||ться *сов. разг.* сүз бирү, тәүбә итү; **он** ~**лся кури́ть** ул тәмәке тартмаска сүз бирде

заква́сить *сов. что* ачыту, оету; ~ **те́сто** камыр ачыту; ~ **молоко́** катык оету

заква́ск||а *ж* 1. *см.* **заква́сить**; 2. (*вещество*) оеткы (*катык өчен*), чүпрә, ачыткы, баш, камыр башы (*куәс төбендә калдырылган камыр*)

заква́шивать *несов. см.* **заква́сить**

закида́ть *сов. см.* **заброса́ть**

заки́дывать *несов. см.* **закида́ть**

заки́нуть *сов.* 1. *см.* **забро́сить** I; 2. *что* салу, асу; ~ **ружьё за́ спину** мылтыкны аркага асу 3. өскә күтәрү, артка ташлау; ~ **го́лову** башны артка ташлау ♦ ~ **у́дочку** кылын тартып карау, ниятен белү

заки́ну||ться *сов.* 1. ташлану, артка ташлану; **голова́ у него́** ~**лась** башы артка ташланган 2. *спец.* (*о лошади*) буйлау (*чапканда атның юлдан читкә кереп китүе*)

закипа́ть *несов. см.* **закипе́ть**

закипе́||ть *сов. прям., перен.* кайный башлау; **вода́** ~**ла** су кайный башлады; **рабо́та** ~**ла** эш кайный башлады

заки́сать *несов. см.* **заки́снуть**

заки́с||нуть *сов.* 1. әчү, ою; **те́сто** ~**ло** камыр әчеде 2. *перен. разг.* (*стать вялым, безразличным*) мүкләнеп бетү, җебеп бетү, мәлҗерәү

за́кись *ж хим.* закись; ~ **азо́та** азот закисе

заклад *м уст. см.* **зало́г** I 1 ♦ **би́ться (поби́ться) об** ~ берер әйбердән бәхәсләшү

закла́дка *ж* 1. *см.* **заложи́ть** 1-7, 11; ~ **фунда́мента** нигез салу 2. (*напр. в книге*) билге; кыстыргыч (*кәгазь кисәге яки тасма*)

закладна́я *ж уст.* заклад язуы (*залогка салынган мөлкәт язуы*)

закла́дывать *несов. см.* **заложи́ть**

закла́ние *с*: **на** ~ *ирон.* һәлакәткә, газапка, үлемгә; **идти́ на** ~ үлемгә бару

заклева́||ть I *см. кого-что* 1. чукып үтерү; **я́стреб** ~**л цыплёнка** карчыга чебешне чукып үтергән 2. *перен. разг.* (*извести придирками*) кыерсыту, талау, кагу

заклева́ть II *сов.* (*начать клевать*) (*о птице*) чүпли башлау; (*о рыбе*) чиртә башлау

заклёвывать *несов. см.* **заклева́ть** I

закле́ивать *несов. см.* **закле́ить**

закле́иваться *несов.* **1.** *см.* **закле́иться; 2.** *страд. от* **закле́ивать**

закле́ить *сов. что* ябыштыру, ябыштырып кую; **~ письмо́** хатны ябыштыру; **~ ра́мы бума́гой** рамнарга кәгазь ябыштыру

закле́и||ться *сов.* ябыштырылу, ябыштырып куелу; **конве́рт ~лся** конверт ябыштырылды

заклейми́ть *сов. кого-что* **1.** (*поставить клеймо*) кәләмә сугу, кәләмәләү, тамга салу, тамгалау **2.** *перен.* [хурлык] тамгасы салу, тирән нәфрәт бәлдерү; **~ позо́ром** хурлык тамгасы салу

заклепа́ть *сов. что* (*кадакның, болтның башын*) чүкәп (яньчеп) беркетү, беркетеп кую, заклепкалау

заклёпка *ж* **1.** *см.* **заклепа́ть; 2.** заклёпка; **ме́дная ~** бакыр заклёпка

заклёпывать *несов. см.* **заклепа́ть**

заклина́ни||е *с* **1.** *см.* **заклина́ть; 2.** (*слова́*) әфсен; **произноси́ть ~я** әфсен уку

заклина́тель *м* әфсенләүче, өшкерүче, тылсымчы, тылсымлаучы; **~ змей** еланнарны тылсымлаучы

заклина́ть *несов. кого-что* **1.** ялвару, ялварып сорау; **~ па́мятью отца́** әтисе истәлеге исеменнән ялварып сорау **2.** сихерләү, тылсымлау, әфсенләү; сихерләп (әфсенләп) буйсындыру; **~ змей** еланнарны тылсымлау

закли́нивать *несов. см.* **заклини́ть, закли́нить**

заклини́ть, закли́нить *сов. что* **1.** (*вбить клин*) чәй кагу; **~ бревно́** бүрәнәгә чәй кагу **2.** (*лишить возможности двигаться*) (*руль*) борылмау, кысылу, ачылмау (*ватылу сәбәпле*)

заклини́ться, закли́ниться *сов.* ачылмау, кысылу (*мәс. йозак, винтовканың затворы һ.б.ш. ватылу* сәбәпле)

заклуби́||ться *сов.* бөтерелеп һавага күтәрелә башлау; **пыль ~лась по доро́ге** юл буйлап тузан бөтерелеп һавага күтәрелә башлады

заключа́ть *несов. см.* **заключи́ть ♦ ~ в себе́** эченә алу

заключа́||ться *несов.*, **1.** гыйбарәт булу, тору; **де́ло ~ется в сле́дующем** эш шуннан гыйбарәт **2.** тәмамлану, тәмам ителү, төгәлләнү; **письмо́ ~лось и́скренними пожела́ниями** хат ихлас теләкләр белән тәмамланган иде

заключе́ни||е *с* **1.** *см.* **заключи́ть** 1, 3, 4; **2.** төрмә; ябылуда булу; **находи́ться в ~и** төрмәдә булу **3.** нәтиҗә, йомгак; **~е коми́ссии** комиссия нәтиҗәсе **4.** (*вывод*) бәяләмә **5.** (*последняя часть чего-л.*) соңгы өлеш, йомгак өлеш **♦ в ~е** сүзнең ахырында, соңгы сүз итеп, ахырда

заключённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заключи́ть**; **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* кулга алынган кеше, тоткын, тоткындагы кеше

заключи́тельн||ый, -ая, -ое ахыргы, соңгы; тәмамлау ...ы; йомгаклау ... ы, **~ые слова́** соңгы сүз, йомгаклау сүзе (*мәс. докладчыныкы*); **~ый конце́рт** йомгаклау концерты

заключи́||ть *сов.* **1.** *кого-что* ябу, ябып кую, утыртy; **~ть в тюрьму́** төр-мәгә ябу **2.** нәтиҗә ясау, нәтиҗә чы-гару; нәтиҗәгә килү; **я ~л, что он прав** мин ул хаклы дигән нәтиҗәгә килдем **3.** *что чем* тәмамлау, бетерү, төгәлләү; **~ть докла́д приве́тствиями** докладны котлау сүзләре белән тәмамлау **4.** *что* төзү; **~ть до́говор** договор төзү **♦ ~ть в объя́тия** *кого* кочакка алу, кочаклау; **~ть в ско́бки** *что* җәяләр эченә алу

закля́тие *с уст.* (*клятва, зарок*) тәүбә, ант, сүз бирү

закля́тый, -ая, -ое: **~ враг** явыз (гомерлек) дошман

заков|а́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*надеть кандалы*) богаулау, богау кидерү **2.** *кого, вет.* дагалап бозу (*атның аягын*)

зако́вывать *несов. см.* **заков|а́ть**

заковыля́ть *сов. разг.* аксаклап бара башлау, титаклап китү, көчкә өстерәлеп бару

заковы́рист||ый, -ая, -ое *прост.* чәтерекле, катлаулы, хикмәтле, әкәмәт; **~ая зада́ча** чәтерекле мәсьәлә

закоди́ровать *сов. что* кодка салу, кодлаштыру: **~ текст** текстны кодка салу

заколáчивать *несов. см.* **заколоти́ть** I 1, 2

заколдо́ванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заколдова́ть; 2.** (*в сказках*) сихерләнгән, тылсымланган; сихерле, тылсымлы **♦ ~ круг** ерып чыга алмаслык хәл, очына чыга алмаслык хәл, буталчык мәсьәлә

заколдова́ть *сов. прям., перен. кого-что* сихерләү, сихерләп үзенә карату

заколдо́вывать *несов. см.* **заколдова́ть**

зако́лка *ж* (*для волос*) заколка, кадагыч (*чәч кыстыру очен*)

заколоти́ть I *сов.* **1.** *что* кагып кую, кадаклап (томалап) кую; **~ окно́ доска́ми** тәрәзәне такталар белән кадаклап кую **2.** *что* кагу, кагып кертү; **~ клин** чәй кагып кертү **3.** *кого-что* (*забить до смерти*) үтергәнче кыйнау, тукмаклау

заколоти́||ть II *сов.* (*начать колотить*) шакылдата (дөбердәтә) башлау; **в дверь ~ли** ишекне шакылдата башладылар

заколо́ть I *сов.* **1.** *кого* (*убить чем-л. острым*) чәнчеп (кадап) үтерү **2.** *кого-что* сую, чалу; **~ свинью́** дуңгыз сую **3.** *что* чәнчеп (кадап) кую; **~ во́лосы шпи́льками** чәчне шпилькалар белән кадап кую

заколо́||ть II *сов. безл.* (*начать колоть*) чәнчешә башлау; **у меня́ ~ло в спине́** аркам чәнчешә башлады

заколо́ться *сов.* чәнчелеп үлү

заколыха́ть *сов.* җилферди башлау, җилфердәтә башлау

заколыха́||ться *сов.* җилферди башлау; **~лись знамёна** байраклар җилферди башлады

закомпости́ровать *сов. что* компостерлап кую

зако́н *м в разн. знач.* закон, канун; **~ы борьбы́** көрәш законнары; **~ы приро́ды** табигать кануннары; **Конститу́ция — основно́й ~ госуда́рства** Конституция — дәүләтнең төп законы; **~ всеми́рного тяготе́ния** *физ.* бөтен дөнья тартылу законы; **~ сохране́ния и превраще́ния эне́ргии** *физ.* энергиянең саклану һәм әверелү законы; **~ы обще́ственного разви́тия** иҗтимагый үсеш законнары

зако́нность *ж* законлылык, законлы булу; **~ тре́бований** таләпләрнең законлылыгы

зако́нн||ый, -ая, -ое **1.** законлы, законга каршы килми торган, законга туры килә торган, законча...; **на ~ом основа́нии** закон нигезендә **2.** урынлы, хаклы; **~ое возмуще́ние** урынлы ачу

законове́д *м* закончы, законнар белгече

законода́тель *м* **1.** законнар чыгаручы **2.** *перен.* яңалык кертүче; яңа гадәтләр урнаштыручы; **~ мод** яңа модалар кертүче

законода́тельный, -ая, -ое законнар чыгара торган; законнар чыгаруга хокуклы; **~ о́рган** законнар чыгара торган орган

законода́тельств||о *с* **1.** законнар төзү, законнар чыгару; **вопро́сы ~а** законнар чыгару мәсьәләләре **2.** *собир.* законнар; законнар җыелмасы

закономе́рность *ж* закончалык

закономе́рн||ый, -ая, -ое **1.** законлы; закончалыклы; **~ое явле́ние** закончалыклы күренеш **2.** закончалы, законга ярашлы; **~ое тре́бование** законлы таләп

законопа́тить *сов. что* мүкләү

законопа́чивать *несов. см.* **законопа́тить**

законоположе́ние *с* закон, закон кагыйдәсе, законнар (*аерым мәсьәләгә караган закон*)

законопрое́кт *м* закон проекты

законсерви́ровать *сов. что* консервалап кую; **~ тома́ты** томатларны консервалап кую

законспекти́ровать *сов. что* конспектлау, конспектлап кую; **~ ле́кцию** лекцияне конспектлау

законспири́ровать *сов. кого-что и без доп.* конспирацияләү

законтрактова́ть *сов. кого-что* контрактацияләү, контрактация шартнамәсе төзү; **~ урожа́й** игенне контрактацияләү

зако́нченность *ж* тәмамланганлык, төгәлләнгәнлек; тулылык, бөтенлек; **~ мы́сли** фикернең тәмамланганлыгы

зако́нченн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **зако́нчить**; **2.** тәмамланган, төгәлләнгән, эшләнеп беткән; тулы, бөтен, һәр яктан җитеш; **~ая мысль** тәмамланган фикер **3.** җитлеккән, үсеп җиткән; **~ый худо́жник** җитлеккән рәссам **4.** чиктән ашкан, чиктән тыш; **~ый негоди́й** чиктән ашкан кабахәт кеше

зако́нчить *сов. что* бетерү, тәмамлау, төгәлләү; **~ рабо́ту** эшне тәмамлау

зако́нчи||ться *сов.* бетү, тәмамлану, төгәлләнү; **совеща́ние ~лось** киңәшмә тәмамланды

закопа́ть *сов.* **1.** *кого-что* күмү, күмеп кую; ~ **клад** хәзинәне күмеп кую **2.** *что* күмү, күмеп тигезләү; ~ **я́му** чокырны күмеп тигезләү

закопа́ться *сов.* күмелү; ~ **в песо́к** комга күмелү

закопоши́||ться *сов. разг.* кайнаша башлау, мыж килә башлау; **муравьи́ ~лись** кырмыскалар мыж килә башладылар

закопте́лый, -ая, -ое корымланган, корымга баткан; ~ **потоло́к** корымланган түшәм

закопте́ть *сов. см.* **закопти́ться** 1

закопти́||ть I *сов. что* **1.** каклау, каклап хәзерләү, ыслау; ~ **ть ры́бу** балык ыслау **2.** корымлау, корым белән каплау; ~**ть стекло́** пыяланы корымлау

закопти́||ть II *сов.* (*начать коптить*) төти башлау; **ла́мпа ~ла** лампа төти башлады

закопти́||ться *сов.* **1.** корым белән каплану, корымланып бетү; **стёкла ~лись** пыялалар корымланып бетте **2.** (*о рыбе, мясе*) ыслану

закорене́л||ый, -ая, -ое **1.** тамыр җәйгән, нык урнашкан; ~**ые привы́чки** нык урнашкан гадәтләр **2.** ашып узган, төзәлмәслек; ~**ый престу́пник** төзәлмәслек җинаятьче

закорене́ть *сов. в чём* бик нык бирелү (*берәр ярамас гадәткә*); ~ **в предрасу́дках** юк-бар ышануларга бик нык бирелү

зако́рк||и *мн. прост.*: **сесть на ~и** җилкәгә утыру; **нести́ на ~ах** җилкәгә атландырып алып бару

закорми́ть *сов. кого-что* артык ашату, чамадан тыш ашату, күп ашатып зарар китерү, үтләту

закорю́чка *ж разг.* **1.** ыргак, эләктергеч **2.** (*уловка*) хәйлә, хәйләле әмәл

закосне́лый, -ая, -ое *см.* **закорене́лый**; ~ **негодя́й** төзәлмәслек явыз

закосне́ть *сов. в чём* катып калу, батып калу; ~ **в неве́жестве** наданлыкка батып калу

закостене́ть *сов.* кату, катып калу, күшегү; ~ **от хо́лода** салкыннан кату

зако́ул||ок *м* **1.** (*глухой переулок*) аулак тыкрык **2.** *разг.* караңгы почмак, аулак почмак; **обыска́ть все ~ки** барлык караңгы почмакларны актарып чыгу

закочене́вш||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **закочене́ть**; **2.** тунган, өшегән, күшеккән, каткан; ~**ие па́льцы** күшеккән бармаклар

закочене́ть *сов*; туну, кату, өшү, күшегү; ~ **от хо́лода** суыктан өшү

закра́дываться *несов. см.* **закра́сться**

закра́сить *сов. что* буяу, буяп кую, буяп каплау; ~ **пя́тна** тапларны буяп каплау

закра́ситься *сов.* буялу, буялып чыгу, буялып бетү

закрасне́ть *сов.* **1.** (*показаться — о чем-л. красном*) кызарып күренә башлау **2.** (*стать красным*) кызара башлау (*мәс. шәфәкъ кызыллыгы*)

закрасне́||ться *сов. разг.* **1.** *см.* **закрасне́ть** I; **2.** оялудан кызарыну, кызарып китү; **де́вушка ~лась** кыз оялуыннан кызарып китте

закра́||сться *сов.* (*көтмәгәндә*) туу, төшү, барлыкка килү; ~**лось подозре́ние** шик төште

закра́шивать *несов. см.* **закра́сить**

закрепи́тель *м* ныгытқыч; беркеткеч, фиксаж (*фото эшендә*)

закрепи́тельный, -ая, -ое ныгыта (беркетә) торган, беркетү ...ы; ~ **талóн** беркетү талоны

закрепи́ть *сов.* **1.** *что* ныгыту, беркетү, ныгытып (беркетеп) кую; ~ **гвоздём** кадак белән ныгыту **2.** *перен. что* ныгыту; ~ **успе́хи** уңышларны ныгыту **3.** *что, фото* фиксажлау **4.** *кого-что за кем-чем* беркетү; ~ **тра́ктор за трактори́стом** тракторны тракторчыга беркетү **5.** *что* ныгыту, нормаль хәлгә китерү; ~ **желу́док** ашказанын ныгыту (*эч китүдән*)

закрепи́||ться *сов.* **1.** беркетелү, беркетеп куелу; **дета́ль плóхо ~лась** деталь начар беркетелде **2.** ныгу, нык урнашу; ~**ться на пози́ции** позициядә нык урнашу

закре́пка *ж* беркеткеч, ныгыткыч

закрепле́ние *с см.* **закрепи́ть, закрепи́ться**; ~ **ка́дров** кадрларны беркетү

закрепля́ть *несов. см.* **закрепи́ть**

закрепля́ться *несов.* **1.** *см.* **закрепи́ться**; **2.** *страд. от* **закрепля́ть**

закрепля́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **закрепля́ть**; **2.** ныгыта (беркетә) торган, ныгыткыч, беркеткеч; ~**ее сре́дство** ныгыта торган чара

закрепости́ть *сов. кого-что*, крепостнойлыкка төшерү; коллыкка (кабалага) төшерү

закрепощáть *несов. см.* **закрепости́ть**

закристаллизова́ть *сов. что* кристаллга әверелдерү, кристаллаштыру; ~ **раство́р** эремәне кристаллаштыру

закристаллизова́||ться *сов.* кристаллану, кристаллга әверелү, кристаллашу; **раство́р ~лся** эремә кристаллашты

закро́ечный, -ая, -ое кием кисә торган, кием кисү ...ы; ~ **цех** кием кисү цехы

закро́йн||ый, -ая, -ое кием кисә торган, кием кисү ...ы; ~**ые но́жницы** кием кисә торган кайчы; ~**ый цех** кием кисү цехы

закро́йщик *м* кисүче, кием кисүче; аяк кием кисүче

закро́йщица *ж см.* **закро́йщик**

за́кром *м* бура, ашлык бурасы, өсәк; ~**á государ́ства** дәүләт амбарлары

закругле́ние *с* **1.** *см.* **закругли́ть**; **2** (*место*) борылыш, борылган урын

закруглённость *ж* **1.** түгәрәклек, йомрылык **2.** *перен.* (*стиля*) шомалык

закруглённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич.* **от закругли́ть**; **2.** (*округлый*) түгәрәк, йомры **3.** *перен.* шома; ~**ые фра́зы** шома фразалар

закругли́ть *сов. что* **1.** түгәрәкләү, түгәрәк итү; ~ **у́гол** почмакны түгәрәкләү **2.** *перен.* төзекләндерү, шомарту, түгәрәкләндерү; ~ **фра́зу** фразаны төзекләндерү

закругли́||ться *сов.* **1.** түгәрәкләнү **2.** *перен. прост. шутл.* сүзне кыскарту, түгәрәкләү, тизрәк сөйләп бетерү; **докла́дчик ~лся** докладчы сүзен кыскартты

закругля́ть *несов. см.* **закругли́ть**

закругля́ться **1.** *см.* **закругли́ться**; **2.** *страд. от* **закругля́ть**

закружи́ть *сов. кого-что* хәлдән тайганчы әйләндерү, башын әйләндерү

закружи́ться *сов.* **1.** хәлдән тайганчы әйләнү **2.** *перен. разг.* баш әйләнү, баш әйләнә башлау, баш әйләнеп бетү; ~ **в хло́потах** мәшәкатьләрдән баш әйләнеп бетү

закружи́||ться II *сов.* (*начать кружиться*) әйләнә башлау, бөтерелә башлау; ♦ **у меня́ голова́ ~лась** минем башым әйләнә

закрути́ть *сов. что* **1.** бору, борып кую; бөтерү, бөтереп кую; ~ **га́йку** гайканы борып кую; ~ **усы́** мыекны бөтереп кую **2.** каерып бәйләү; ~ **ру́ки наза́д** кулларны артка каерып бәйләү

закрути́||ться *сов.* әйләнү, борылу, бөтерелү; **га́йка ~лась** гайка борып куелды

закру́чивать *несов. см.* **закрути́ть**

закру́чиваться *несов.* **1.** *см.* **закрути́ться**; **2.** *страд. от* **закру́чивать**

закрыва́ть *несов. см.* **закры́ть** ♦ ~ **глаза́** *на что* күз йому, күрмәмешкә салыну

закрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **закры́ться**; **2.** *страд. от* **закрыва́ть**

закры́ти||е *с см.* **закры́ть**; ~**е вы́ставки** күргәзмәнең ябылуы; ~**е журна́ла** журналның чыгудан туктавы

закры́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **закры́ть**; **2.** (*крытый*) ябык; бөркәүле; ~**ая маши́на** ябык машина **3.** ябык; ~**ое партийное собра́ние** ябык партия җыелышы **4.** *мед.* эчкә, эчтә ..., эчтән ...; ~**ый перело́м** эчтә сыну **5.** ябык; ~**ое пла́тье** ябык күлмәк ♦ **в ~ом помеще́нии** бина эчендә (*тышта түгел*); ~**ое голосова́ние** яшерен тавыш бирү; ~**ое мо́ре** ябык диңгез; **при ~ых дверя́х** үзара гына, чит кешеләрне катнаштырмыйча; **с ~ыми глаза́ми** (*идти на что-л.*) тәвәккәлләп, күз йомып

закры́||ть *сов.* **1.** *что* ябу, ябып кую; ~**ть окно́** тәрәзәне ябып кую **2.** *кого-что* каплау, томалау, томалап алу; ~**ть лицо́ руко́й** битне уч белән каплау; **ту́ча ~ла не́бо** болыт күк йөзен каплады **3.** *что* йому; ~**ть глаза́** күзләрне йому **4.** *что* (*запереть*) бикләү, бикләп кую **5.** туктату; ~**ть журна́л** журналны чыгудан туктату **6.** *что* ябу; ~**ть заседа́ние** утырышны ябу **7.** *что* ябу; ~**ть во́ду** суны ябу ♦ ~**ть глаза́** *кому* үлгәндә янында булу

закры́||ться *сов.* **1.** ябылу; **дверь ~лась** ишек ябылды **2.** томалану, капланы, каплап алыну; **не́бо ~лось облака́ми** күк йөзе болытлар белән каплап алынды **3.** бикләнү, бикләп куелу; **сейф ~лся** сейф бикләнде **4.** тукталу; **журна́л ~лся** журнал чыгудан туктады; **5.** ябылу; **заседа́ние ~лось** утырыш ябылды **6.** йомылу; **глаза́ ~лись** күзләр йомылды **7.** (*о ране*) бөтәшү, төзәлү

ЗАК-ЗАЛ

закули́сн||ый, -ая, -ое (*тайный*) яшерен, астыртын; **~ые перегово́ры** яшерен сөйләшүләр

закупа́ть *несов. см.* **закупи́ть**

закупи́ть *сов.* **1.** *кого-что* сатып алу, күпләп сатып алу; **~ всю проду́кцию** барлык продукцияне берьюлы сатып алу **2.** *что, чего* сатып алып кую, сатып алып хәзерләү; **~ дров на́ зиму** кышка утын сатып алып кую

заку́пка *ж см.* **закупи́ть; ~ зерна́ госуда́рством** дәүләтнең ашлык сатып алуы

заку́поривать *несов. см.* **заку́порить**

заку́пориваться *несов.* **1.** *см.* **заку́пориться; 2.** *страд. от* **заку́поривать**

заку́порить *сов. что* бөкеләү, бөке тыгу, бөке тыгып кую; **~ буты́лку** шешәнең авызына бөке тыгып кую

заку́пори||ться *сов.* бөке белән ныгытылу, бөкеләнү; (*о венах*) тыгылу, томалану; **буты́лка ~лась** шешә бөкеләнде

заку́порка *ж см.* **заку́порить, заку́пориться; ~** вен вәналарның томалануы

заку́почн||ый, -ая, -ое сатып алу...ы; **~ая цена́** сатып алу бәясе

заку́пщик *м* сатып алучы, сатып алып жыючы

заку́ривать *несов. см.* **закури́ть**

заку́риваться *несов.* **1.** *см.* **закури́ться; 2.** *страд. от* **заку́ривать**

закури́ть *сов. что и без доп.* тәмәкене кабызып җибәрү; тарта башлау; **~ тру́бку** трубка тарта башлау

закури́||ться *сов.* **1.** көйри башлау, яна башлау; **папиро́са ~лась** папирос яна башлады **2.** (*задымиться*) төтен чыга башлау; **~лась изба́** өйдән төтен чыга башлады

закуса́||ть *сов. кого-что, разг.* тешләп интектереп бетерү; талау, талап бетерү; **меня́ ~ли комары́** мине озынборыннар тешләп интектереп бетерделәр

закуси́ть I *сов. что* тешләү; **~ гу́бы** иреннәрне тешләү; **~ удила́** 1) (*о лошади*) авызлыкны тешләү; 2) *перен.* (*выйти из повиновения*) тезгеннән (бәйдән) ычкыну, тузынып китү

закуси́ть II *сов.* **1.** *чем и без доп.* (*поесть немного, наскоро*) капкалап алу, ашап алу, бераз ашап алу, тамак ялгау **2.** *что чем* артыннан кабу, артыннан кабып җибәрү; **~ лека́рство конфе́той** дару артыннан конфет кабу

заку́ск||а *см.* **1.** *см.* **закуси́ть II; 2.** закуска, [җиңелчә] ашамлык; **холо́дные ~и** салкын ашамлыклар

заку́сочная *ж* закусочный

заку́сывать I *несов. см.* **закуси́ть** I

заку́сывать II *несов. см.* **закуси́ть** II

заку́тать *сов. кого-что* төрү, чорнау, урау, калын итеп киендерү; **~ но́ги** аякларны төрү; **~ ребёнка в одея́ло** баланы юрганга төрү

заку́та||ться *сов.* төренү, чорналу, урану; **он ~лся шу́бой** ул тунга төренде; **~ться в одея́ло** юрганга төренү

заку́тывать *несов. см.* **заку́тать**

заку́тываться *несов.* **1.** *см.* **заку́таться; 2.** *страд. от* **заку́тывать**

зал *м* зал; **зри́тельный ~** тамаша залы; **чита́льный ~** уку залы; **~ ожида́ния** көтү залы

за́ла *ж уст.* зал

зала́ди||ть *сов. разг.* **1.** *что и без доп.* такылдау, кат-кат әйтү; **~ть одно́ и то́ же** һаман бер нәрсә турында такылдау **2.** с *неопр.* (*делать одно и то же*) гадәтләнү, өйрәнеп китү, гадәтләнеп китү; **он ~л ходи́ть в кино́** кинога йөрергә гадәтләнеп китте

зала́ди||ться *сов. разг.* җайлану, уңайлану, җайга салыну, рәткә керү; **рабо́та не ~лась** эш җайланмады

зала́мывать *несов. см.* **заломи́ть** I

заласка́ть *сов. кого, разг.* сөеп интектереп бетерү

залата́ть *сов. что, прост.* ямау, ямау салу

зала́ять *сов.* өрә башлау, өрергә тотыну

залега́ние *с* **1.** *см.* **зале́чь; 2.** *геол.* яткан урыны, яту шартлары; **~ го́рных поро́д** тау токымнарының яткан урыны

залега́ть *несов. см.* **зале́чь**

заледене́л||ый, -ая, -ое **1.** (*покрытый льдом*) бозлы, бозланган, бозланып каткан, боз белән капланган **2.** боз кебек салкын; **~ые руки́** боз кебек салкын куллар

заледене́ть *сов.* **1.** (*покрыться льдом*) бозлану, боз белән каплану **2.** (*окоченеть*) туңу, боз кебек кату

залежа́л||ый, -ая, -ое *разг.* озак яткан, яткан, чамадан тыш күп яткан, озак ятып бозылган; **~ая колбаса́** озак ятып бозылган колбаса; **~ый това́р** озак яткан товар

залежа́||ться *сов.* **1.** (*долго пролежать*) озак яту, артык яту, чамадан тыш күп яту (*авырып яки ялкауланып*) **2.** (*испортиться от лежания*) озак ятып бозылу; **крупа́ ~лась** ярма озак ятып бозылган

залёживаться *несов. см.* **залежа́ться**

за́лежн||ый, -ая, -ое: **~ые зе́мли** яткын җирләр

за́лежь *ж* **1.** ятма, ятым; **~и ка́менного у́гля** ташкүмер ятмалары **2.** (*не обрабатываемая долго земля*) калдау җир, яткын җир, кысыр җир **3.** *мн.* **~и** озак яткан өемнәр; **~и това́ров** озак яткан товар өемнәре

залеза́ть *несов. см.* **зале́зть**

зале́зть *сов.* **1.** *на что* үрмәләп менү, менү; **~ на де́рево** агач башына менү **2.** *разг.* керү; **~ в во́ду** суга керү; **~ под стол** өстәл астына керү **3.** (*тайком войти*) керү, яшеренеп керү ♦ **~ в долги́** бурычка бату

залепи́||ть *сов. что* **1.** сылау, сылап кую; **~ть дыру́ гли́ной** тишекне кызыл балчык белән сылап кую **2.** ябыштыру, ябыштырып кую, ябыштырып каплау; **~ть разби́тое окно́ бума́гой** ватык тәрәзәне кәгазь белән ябыштырып кую **3.** *разг.* ябыштырып бетерү; **~ть всю сте́ну афи́шами** стенага афишалар ябыштырып бетерү **4.** каплау; **глаза́ мне ~ло сне́гом** *безл.* минем күзләремне кар каплады

залепля́ть *несов. см.* **залепи́ть**

залета́ть *несов. см.* **залете́ть**

залете́||ть *сов.* **1.** очып барып чыгу, очып мену; очып керү; **пти́ца ~ла в окно́** кош тәрәзәдән очып керде; **~ть за ли́нию гор** таулар аръягына очып барып чыгу **2.** [очып барышлый] кереп чыгу, сугылу, туктаклыш ясау; **~ть на попу́тный аэродро́м** юл уңаендагы аэродромда туктаклыш ясау

залётн||ый, -ая, -ое [очраклы] очып килгән; **~ая пти́ца** очып килгән кош

зале́чивать *несов. см.* **зале́чить**

зале́чиваться *несов.* **1.** *см.* **зале́читься; 2.** *страд. от* **зале́чивать**

зале́чить *сов.* **1.** *что* дәвалап төзәтү; **~ ра́ну** җәрәхәтне дәвалап төзәтү **2.** *кого-что, разг.* (*измучить лечением*) ялгыш дәвалап сәламәтлеген начарлату; белмичә дәвалап эштән чыгару

залечи́||ться *сов.* төзәлү; **ра́на ~лась** яра төзәлде

зал||е́чь *сов.* **1.** яту, озакка кереп яту; **медве́дь ~ёг в берло́гу до весны́** аю язга кадәр оненә кереп ятты **2.** яту, яшеренеп кереп яту; **разве́дчики ~егли́ в куста́х** разведкачылар куаклыкка яшеренеп кереп яттылар **3.** яту, урнашу; **руда́ ~егла́ здесь неглубо́ко** руда монда тирән ятмый

зали́в *м* култык

залива́ть *несов. см.* **зали́ть**

залива́ться I *несов.* **1.** *см.* **зали́ться; 2.** *страд. от* **залива́ть**

залива́ться II *несов. см.* **зали́ться** II

заливно́е *с* дерелдәвекле ашамлык, койкалы ашамлык

заливн||о́й, -а́я, -о́е **1.** су баса торган, су астында кала торган; **~о́й луг** су баса торган болын **2.** койкалы, дерелдәвекле (*ашамлык*); **~а́я ры́ба** койкалы балык

зализа́||ть *сов. что* **1.** ялап тазарту; ялап төзәтү; **соба́ка ~ла ра́ну** эт ярасын ялап төзәтте **2.** *разг.* (*пригладить*) тел белән ялау (*чәчне, йонны*)

зализывать *несов. см.* **зализа́ть**

зали́||ть *сов. что* **1.** басу; **вода́ залила́ луга́** су болыннарны басты **2.** түгеп пычрату; **~ть ска́терть черни́лами** кара түгеп ашъяулыкны пычрату **3.** салу, тутыру; **~ть бензи́н в бак** бакка бензин салу **4.** су сибеп сүндерү; **~ть ого́нь** утны су сибеп сүндерү **5.** коеп ямау, эретеп ямау; **~ть свинцо́м** кургаш коеп ямау ♦ **~ть гало́ши** галош ямау

зали́||ться I *сов.* **1.** [су] басу, [су астында] калу, [су белән] каплану; **луга́ ~ли́сь водо́й** болыннарны су баскан **2.** агып керү; **вода́ ~ла́сь за воротни́к** су яка астына агып керде

зали́ться II *сов. чем* яңгыратып ...а башлау; **~ сме́хом** кычкырып көлә башлау; **~ пе́сней** яңгыратып җырлый башлау

залихва́тск||ий, -ая, -ое *разг.* бик җилле, җор, чая, егетләрчә; **~ий вид** егетләрчә кыяфәт; **~ая пе́сня** җор җыр

зало́г I *м* **1.** залог, закладка салу; **~ имущества** мөлкәтне закладка салу; **отда́ть в ~** *кого-что-л.* залогка бирү **2.** *перен.* дәлил, ышаныч; **~ дру́жбы** дуслык дәлиле

зало́г II *м грам.* юнәлеш; **возвра́тный ~** кайтым юнәлеше

зало́г||ый I, -ая, -ое залог ...ы; **~ая квита́нция** залог квитанциясе

зало́г||ый II, -ая, -ое *грам.* юнәлеш ...ы; **~ые отноше́ния** юнәлеш мөнәсәбәтләре

заложе́ни||е *с спец.* урнашу; **ша́хта глубо́кого ~я** тирәндә урнашкан шахта

заложи́||ть *сов.* **1.** *что* (*артына*) кую; **~ть поду́шку за́ спину** мендәрне арка артына кую **2.** *что* (*әллә кая*) кую, (*каядыр*) кую; **~ть куда́-то кни́гу** китапны әллә кая кую **3.** *что* тутыру, тутырып бетерү; **~ть стол кни́гами** өстәлне китаплар белән тутыру **4.** *что* томалау, каплау, томалап (каплап) кую; **~ть щель ка́мнем** ярыкны ташлар белән томалап кую **5.** *что* салу, сала башлау; **~ть дом** йорт сала башлау **6.** *перен. что* урнаштыру, тудыру; **~ть в ду́шу ребёнка любо́вь к труду́** баланың күнелендә хезмәткә мәхәббәт тудыру **7.** *что* сакларга салу; **~ть карто́фель на́ зиму** кышка сакларга бәрәңге салу **8.** *кого-что* (*запрячь*) җигү; **~ть тро́йку** тройка җигү **9.** *кого-что* закладка салу; **~ть часы́** сәгатьне закладка салу **10.** *безл. что, разг.* тыгылу, томалану; **мне ~ло нос** минем борыным томаланды **11.** *что* билге салып кую, кәгазь (тасма) кыстыру; **~ть страни́цу** китап битләре арасына билге салып кую

зало́жник *м* заложник (*берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен дошман якларның яки узара сугышучы илләрнең берсе тарафыннан үзендә тотылган каршы як кешесе*)

заломи́ть I *сов. что, прост.* (*запросить высокую цену*) каеру ♦ **~ ша́пку** бүрекне кыңгыр салып кию; **~ ру́ки** кулларны артка каеру

заломи́||ть II *сов. безл.* (*начать ломить*) сызлый башлау, авырта башлау; **у него́ ~ло но́ги** аның аяклары сызлый башлады

залосни́||ться *сов.* каешланып бетү; майланып бетү; **рукава́ ~лись** җиңнәре каешланып беткән

залп *м* залп; **дать ~** залп бирү

за́лпом *нареч.* **1.** залп белән; **вы́стрелить ~** залп белән ату **2.** *перен. разг.* берьюлы, бердән, дәррәү; **вы́палить всё ~** барысын берьюлы әйтеп бетерү; **вы́пить ~** дәррәү эчеп җибәрү

залуча́ть *несов. см.* **залучи́ть**

залучи́ть *сов. кого-что, разг.* чакырып алып керү; алдап кертү; **~** *кого-л.* **в го́сти** *берәр кешене* кунакка чакырып алып керү

залы́сина *ж* пеләш, такыр баш

залюбова́ться *сов. кем-чем* сокланып карап тору, ис китеп карап тору

заля́пать *сов. что чем, прост.* пычратып бетерү; **~ костю́м** костюмны пычратып бетерү

зама́зать *сов. что* **1.** буяу белән каплау, буяп кую **2.** сылау, сылап кую; **~ о́кна** тәрәзәләрне сылау **3.** *перен. разг.* яшерү, каплау, каплап калдыру; **~ недоста́тки в рабо́те** эштәге кимчелекләрне яшерү

зама́заться *сов. разг.* буялу, пычрану, пычранып бетү

зама́зка *ж* **1.** *см.* **зама́зать 2; ~ о́кон** тәрәзәләрне сылау **2.** замазка; **~ для о́кон** тәрәзә замазкасы

зама́зывание *с см.* **зама́зать**

зама́зывать *несов. см.* **зама́зать**

зама́зываться *несов.* **1.** *см.* **зама́заться; 2.** *страд. от* **зама́зывать**

зама́лчивать *несов. см.* **замолча́ть** II

зама́нивать *несов. см.* **замани́ть**

замани́ть *сов. кого-что* кызыктырып алып керү; алдап китерү, хәйләләп кертү; **~ врага́ в лову́шку** дошманны тозакка хәйләләп кертү

зама́нчив||ый, -ая, -ое кызыгырлык, кызыктырырлык, кызыктыра торган, кызыктыргыч; **~ое предложе́ние** кызыктыргыч тәкъдим

замара́ть *сов. кого-что, разг.* **1.** пычратып бетерү **2.** *перен.* пычрату, тап төшерү, хур итү, йөзгә кара ягу; **~ репута́цию** репутациягә тап төшерү

замара́ться *сов. разг.* **1.** (*запачкаться*) буялып бетү, пычранып бетү **2.** *перен.* (*обесславить себя*) пычрану, үз-үзен пычрату; адәм хуры булу

замара́ш||к||а *м*, *ж разг.* шапшак; **ходи́ть ~ой** шапшак булу

замарино́вать *сов. что* маринадлау, маринадлап кую

замарино́ваться *сов.* маринадлану, маринадлап куелу

замаскиро́ванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **замаскирова́ть; 2.** (*тайный*) яшерен, маскировкаланган

замаскирова́ть *сов. кого-что* маскировкалап кую, яшереп кую

замаскирова́ться *сов.* маскировкалану, яшеренү

замаскиро́вывать *несов. см.* **замаскирова́ть**

замаскиро́вываться *несов.* **1.** *см.* **замаскирова́ться; 2.** *страд. от* **замаскиро́вывать**

зама́слить *сов. кого-что* майландырып бетерү, пычратып бетерү, майга буяп бетерү; **~ оде́жду** киемне майга пычратып бетерү

зама́сли||ться *сов.* **1.** майланып бетү, майга буялып бетү; **у него́ вся оде́жда ~лась** аның бөтен киеме майланып беткән **2.** (*заблестеть от удовольствия, вожделения — о глазах*) ялтырый башлау, майлану

заматрици́ровать *сов. что, полигр.* матрицага салып чыгу; **~ набо́р** җыелган наборны матрицага салып чыгу

зама́тывать *несов. см.* **замота́ть**

зама́тываться *несов.* **1.** *см.* **замота́ться; 2.** *страд. от* **зама́тывать**

замахну́ться *сов.* **1.** *чем, на кого и без доп.* кизәнү, селтәнү; **~ па́лкой** таяк белән кизәнү **2.** *перен. на что* җәрьәт итү; **~ на но́вую те́му** яңа тема алырга җәрьәт итү

зама́шки *мн. разг.* гадәт, кылану, кыланыш; **ба́рские ~** байларча кылану

зама́яться *сов. прост.* интегеп бетү, җәфаланып бетү, хәлдән таю, алҗып бетү, тинтерәп бетү

замедле́ние *с см.* **заме́длить, заме́длиться**

заме́дленн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заме́длить; 2.** акрын, әкрен, акрынайтылган, әкренәйтелгән; **идти́ ~ым ша́гом** акрын адым белән бару ♦ **ми́на (бо́мба) ~ого де́йствия** билгеле вакыт узгач шартлый торган мина (бомба)

заме́длить *сов.* **1.** *что* акрынайту, киметү; **~ шаг** адымны акрынайту **2.** *что* кичектерү; **~ выполне́ние реше́ния** карарны үтәүне кичектерү **3.** *что, чем, с чем и с неопр.* кичегү; озакка сузу; **~ с отве́том** җавапны озакка сузу

заме́дли||ться *сов.* акрыную, әкренәю, акрынлану; әкренләнү; **движе́ние ~лось** хәрәкәт акрынайды

замедля́ть *несов. см.* **заме́длить**

замедля́ться *несов.* **1.** *см.* **заме́длиться; 2.** *страд. от* **замедля́ть**

замелька́ть *сов.* күренеп китү, чагылып китү

заме́н||а *ж* **1.** *см.* **замени́ть; 2.** алмаш; **найти́ себе́ ~у** үзенә алмаш табу

замени́мый, -ая, -ое алмаштырырлык, алыштырырлык

замени́тель *м* алмаштыргыч; **~ ко́жи** күнне алмаштыргыч (*ясалма кун*)

замени́ть *сов.* **1.** *что* алмаштыру, урынына кую; **мета́лл ~ пласта́ссой** металлны пластмасса белән алмаштыру **2.** *кого-что* алмашка килү; алыштыру, алмаштыру; **~ на рабо́те заболе́вшего това́рища** эштә авырып киткән иптәшенне алмаштыру

замена́ть *несов. см.* **замени́ть**

заме́р *м см.* **заме́рить; ~ длины́ трубы́** торбаларның озынлыгын үлчәү ; **~ объема** күләмен үлчәү

замере́ть *сов.* **1.** катып калу, тынсыз калу, тын да чыгармау; **~ от стра́ха** куркудан катып калу; **се́рдце за́мерло** йөрәк тынсыз калды **2.** *перен.* сүну, тукталу, тукталып калу; **движе́ние на у́лицах за́мерло** урамнарда хәрәкәт тукталды **3.** *перен.* тыну, басылу; **зву́ки за́мерли** тавышлар тынды

замерза́ни||е *с см.* **замёрзнуть; то́чка ~я** *физ.* кату ноктасы

замерза́ть *несов. см.* **замёрзнуть**

замёрз||нуть *сов.* **1.** туңу, кату; **река́ ~ла** елга туңган **2.** туңу, өшү; **у меня́ ру́ки ~ли** минем кулларым туңды **3.** (*погибнуть от холода*) туңу, туңып һәлак булу; туңып үлү, катып үлү

заме́рить *сов. что* үлчәү, үлчәп чыгу, үлчәп карау; **~ давле́ние га́за** газның басымын үлчәп карау

за́мертво *нареч.* үлектәй, үлгән кебек; һушын югалтып, һуштан язып; **упасть ~** һуштан язып егылу

замеси́ть *сов. что* басу; **~ те́сто** камыр басу

ЗАМ-ЗАМ

заме||сти́ *сов.* 1. *что* себерү, себереп өю; **~ сти́ сор в у́гол** чүпне почмакка себереп өю 2. *кого-что* [себереп] каплау, күмү, басу; **вью́га ~ ла́ доро́гу** буран юлны каплаган ♦ **~ сти́ следы́** эзне яшерү, эзне югалту; **~ сти́ следы́ преступле́ния** жинаятьнең эзен яшерү

замести́тел||ь *м* 1. (*преемник*) урынына калган кеше, урынына калырлык кеше; **найти́ себе́ ~я** урынына калырлык кеше табу 2. урынбасар, ярдәмче; **~ь дире́ктора** директор урынбасары

замести́тельство *с* (*берәунең урынында*) вакытлыча эшләп тору

замести́ть *сов. см.* **замеща́ть** 2

замеща́ть I *несов. см.* **замести́**

замета́ть II *сов. что* типчү, типчеп чыгу, күкләү, күкләп чыгу; **~ рукава́** җиңнәрне типчеп чыгу

замета́ться *сов.* әрле-бирле йөри башлау; үрсәләнеп йөри башлау, әрле-бирле сугылу; **~ в отча́янии** нишләргә белмичә әрле-бирле сугылу

заме́ти||ть *сов.* 1. *кого-что* күрү, күреп алу, сизү; **~ть дымо́к на горизо́нте** офыкта төтен күреп алу 2. *кого-что* (*запомнить*) билгеләп кую, искә алып кую, хәтердә калдыру; **~ть у́лицу** урамны хәтердә калдыру 3. әйтү, дию; «**Ве́рно**», — **~л он** «Дөрес», — диде ул

заме́тк||а *ж* 1. билге, тамга; **~а на де́реве** агачка ясалган тамга 2. кыска гына язма; **~а в блокно́те** блокнотка язылган кыска гына язма 3. кыска мәкалә; **газе́тная ~а** газета мәкаләсе ♦ **взять (брать) на ~у** язып кую; хәтердә (истә) калдыру

заме́тно *нареч.* 1. сизелерлек дәрәҗәдә; шактый; **он ~ похуде́л** ул шактый ябыккан 2. *в знач. сказ. безл.* сизелү, сизелеп тору; **было ~ , что он рад** анын шат булуы сизелеп тора иде

заме́тный, -ая, -ое 1. сизелерлек, сизелеп тора торган, күренеп (беленеп) тора торган; **~ след ране́ния** күренеп тора торган яра эзе 2. күренекле, билгеле; **он челове́к ~** ул билгеле кеше

замётывать *несов. см.* **замета́ть** II

замеча́ни||е *с* 1. искәрмә, күрсәтмә; **ве́рное ~е** дөрес күрсәтмә 2. (*выговор*) шелтә, кисәтү; тәнбиһ, замечание; **стро́гое ~е** каты кисәтү 3. *мн.* **~я** (*критические суждения*) күрсәтмәләр, күрсәтелгән кимчелекләр

замеча́тельный, -ая, -ос искитәрлек, искиткеч, бик яхшы, бик әйбәт, бик шәп; **~ тала́нт** искиткеч талант; **~ писа́тель** бик яхшы әдип

замеча́ть *несов. см.* **заме́тить**

замеча́||ться *несов.* 1. күренү, күзгә ташлану; сизелү, сизелеп тору; **~ются при́знаки утомле́ния** арыганлык билгеләре сизелеп тора 2. *страд. от* **замеча́ть**

замечта́ться *сов.* хыялга чуму, уйга бату, хыяллану; онытылып тору

замеша́тельство *с* 1. буталчыклык, чуалчыклык, тәртипсезлек; **внести́ ~ в неприя́тельские ряды́** дошман сафларына тәртипсезлек кертү 2. (*смущение*) каушау, каушап калу, аптыраш

замеша́ть *сов. кого-что во что* (*вовлечь*) катнаштыру, тарту, тартып кертү, бутау (*җинаятькә, начар эшкә*)

замеша́ться *сов. разг.* 1. катнашу (*берәр начар эшкә*); **~ в неприя́тную исто́рию** хәвефле эшкә катнашу 2. кереп югалу; **~ в толпе́** халык арасына кереп югалу

заме́шивать I *несов. см.* **замеси́ть**

заме́шивать II *несов. см.* **замеша́ть**

заме́шиваться *несов.* 1. *см.* **замеша́ться**; 2. *страд. от* **заме́шивать** II

заме́шкаться *сов. разг.* озаклау, соңга калу, тоткарлану; юанып калу, мавыгып калу, акрын кыймылдау; **~ с отве́том** җавапны тоткарлау; **~ у прия́теля** иптәшең янында мавыгып калу

замеща́ть *несов.* 1. *кого-что* алыштыру, алмаштыру, урынына калу; **~ дире́ктора** директор урынына калу 2. *что* (*занять свободную должность*) булып урнашу, булып керү; **~ до́лжность секретаря́** секретарь булып керү

замига́||ть *сов.* 1. күзләрне бер ачып бер йому, бер ачып бер йома башлау 2. җемелди башлау, җем-җем итә башлау; бер яныш бер сүнә башлау; **сигна́льная ла́мпа ~ла** сигнал лампасы бер яныш бер сүнә башлады

замини́ровать *сов. что* миналау, миналар куеп чыгу

замо́нк||а *ж* 1. тоткарлык, комачау; **в де́ле вы́шла ма́ленькая ~а** эштә аз гына тоткарлык килеп чыкты 2. төртелеп тору; ык-мык итү, тотлыгу; **говори́ть с ~ой** тотлыгып сөйләү; **отвеча́ть без ~и** төртелеп тормыйча җавап бирү

замира́ние *с см.* **замере́ть** ♦ **с ~м се́рдца** бик нык дулкынланып; коты алынып

замира́ть *несов. см.* **замере́ть**

за́мкнутость *ж* 1. йомыклык, аралашмау, ялгызлыкны ярату; җәмгыятьтән читләшү; **~ хара́ктера** характерның йомыклыгы 2. чикләнгәнлек; **~ простра́нства** пространствоның чикләнгәнлеге

за́мкнут||ый, -ая, -ое 1. аралаш-маучы, үз-үзенә бикләнгән, җәмгы-ятьтән читләшкен; **~ый челове́к** йомы-кый кеше, ялгызлыкны яратучан кеше 2. йомык, тар, чикләнгән; **~ый круг** тар даирә; **~ая среда́** тар мохит; **~ое простра́нство** чикләнгән урын

замкну́ть *сов. что* 1. *прост.* бикләү; **~ дверь** ишекне бикләү 2. тоташтыру; **~ круг** түгәрәкне тоташтыру; **~ цепь** *эл.* чылбырны тоташтыру

замкну́||ться *сов.* 1. *прост.* бикләнү; **замо́к ~лся** йозак бикләнде 2. тоташу; **цепь ~лась** *эл.* чылбыр тоташты 3. *во что, в чём* йомыклану, аралашмау, бикләнеп яшәү, кеше белән аралашмау; **~ться в семе́йном кругу́** үз гаиләңдә бикләнеп яшәү

замоги́льный, -ая, -ое *разг.* (*о голосе*) калын, карлыккан (*тавыш турында*)

за́мок *м* замок; **кня́жеский ~** князь замогы; **средневеко́вый ~** урта гасырлар замогы

зам||о́к *м* 1. йозак, бик, бикләвеч; **дверно́й ~ок** ишек йозагы; **держа́ть под ~ко́м** бикләп тоту 2. (*пулемёт, орудие h.б.ш.*) затворы; замок ♦ **грани́ца на ~ке́** чик буе ныклы сак астында

замо́к||нуть *сов.* бүртү, җебү; **ко́жи ~ли** күннәр җебеде; **бельё ~ло** керләр җебеде

замо́лвить *сов. что, разг.*: **~ сло́во (слове́чко)** сүз салу, сүз салып карау, сүз кату (*берәр нәрсә үтенеп*)

замоли́ть *сов. что, уст.* ярлыкау, кичерү; **~ грехи́** [дога укып] гөнаһларны ярлыкау

замолка́ть *несов. см.* **замо́лкнуть**

замо́лк||нуть *сов.* тынып калу, тыну, туктау, ...дан туктау; **ребёнок замо́лк** бала елаудан туктады; **зву́ки ~ли вдали́** еракта тавышлар тынып калды

замолча́||ть I *сов.* 1. сөйләүдән туктау, сүзеннән туктау; **расска́зчик ~л** сөйләүче сүзеннән туктады 2. *перен.* язмый башлау, хат язудан туктау; **неприя́тельская батарея́ ~ла** дошман батареясы тынып калды

замолча́ть II *сов. что, разг.* белә торып әйтми калдыру, эндәшми калу, эчтән тынып калу; **~ неприя́тный инциде́нт** күңелсез вакыйга турында эндәшми калу

замора́живание *с см.* **замороз́ить**; туңдыру, катыру; **~ ры́бы** балыкны туңдыру; **~ зарпла́ты** эш хакын арттырмау

замора́живать *несов. см.* **замороз́ить**

заморга́ть *сов.* йому, йомгалау, челт-челт йому (*күзләрне*)

замордова́ть *сов. кого-что, прост.* җәфалау, газаплау, интектерү

замори́ть *сов. разг.* 1. *кого-что* үтерү, агулау; **~ тарака́нов** тараканнарны агулау 2. *кого-что* (*измучить*) газаплау, җәфалау, интектереп бетерү 3. *что* куәтләү, куәтен арттыру; **~ горчи́цу** горчицаның куәтен арттыру ♦ **~ червя́чка** тамак ялгау, капкалап алу, йөрәк ялгап алу

замороз́ить *сов.* 1. *кого-что* туңдыру, катыру; **~ ры́бу** балыкны туңдыру 2. *что, разг.* бик нык суыту 3. *перен. что* арттырмау, элеккечә (үзгәрешсез) калдыру; файдаланмыйча калдыру; **~ зарпла́ту** хезмәт хакын арттырмау; **~ сре́дства** бирелгән акчаны файдаланмыйча калдыру

за́морозки *мн.* кырау, суыклар; **весе́нние ~** язгы кыраулар; **осе́нние ~** көзге кыраулар

заморо́чить *сов. кого-что, разг.* алдап саташтыру, башны әйләндерү

замо́рск||ий, -ая, -ое *уст.* диңгез аръягындагы ..., чит илләрдәге ..., чит илләрдән китерелгән (килгән); **~ие това́ры** чит илләрдән китерелгән товарлар

замо́рыш *м разг.* бүлтерек, көзге чебеш (*усми калган терлек, кош-корт яки кеше турында*)

замости́ть *сов. что* таш җәю, таш түшәү

замота́ть I *сов.* 1. *что* урау, чорнау; урап (чорнап) кую; **~ плато́к** яулыкны урап кую 2. *кого-что, прост.* (*утомить, измучить*) ардыру, ялыктыру

замота́ть II *сов. чем, разг.* (*начать мотать*) болгый башлау, селки башлау, чайкый башлау; ~ **голово́й** башны чайкый башлау

замота́ться *сов.* **1.** *во что, чем, разг.* чорналу, уралу **2.** *прост.* (*утомиться, измучиться*) алжып бетү, хәлдән таю, арып бетү

замочи́ть *сов. что* **1.** (*сделать мокрым*) чылату, юешләтү, юешләү **2.** чылату, жебетү, суга салу; ~ **лён** житен чылату; ~ **бельё** кер жебетү

за́муж *нареч.*: **вы́йти (выходи́ть)** ~ кияүгә бару, кияүгә чыгу, иргә чыгу; **отда́ть (вы́дать)** ~ кияүгә бирү

за́мужем *нареч.* кияүдә, ирдә; **быть** ~ кияүдә булу

заму́жество *с* ирдә булу, ир белән яшәү; **счастли́вое** ~ ир белән бәхетле яшәү

заму́жн||ий, -яя, -ее ирле, ирдәге, иргә чыккан; ир белән яшәү ...ы; ~**яя же́нщина** иргә чыккан хатын; ~**яя жизнь** ир белән яшәү

заму́рзанн||ый, -ая, -ое *прост.* пычрак, шапшак, әшәке, алама, пычранган; ~**ая оде́жда** пычранган кием; ~**ый вид** алама кыяфәт

замурлы́кать *сов.* **1.** (*о кошке*) мырылдый башлау **2.** *перен. что* (*тихо запеть*) шыңшып жырлый башлау, авыз эченнән генә жырлау

замурова́ть *сов. кого-что* томалау, томалап яшерү (*таш стена эченә урнаштырып, өстеннән сылап томалау*); ~ **окно́** тәрәзәне томалау

замурóвывать *несов. см.* **замурова́ть**

замусóливать *несов. см.* **замусóлить**

замусóливаться *несов.* **1.** *см.* **замусóлиться; 2.** *страд. от* **замусóливать**

замусóлить *сов. что, разг.* селәгәйләндереп бетерү, селәгәйгә катыру, пычрату, пычратып бетерү; майландырып бетерү, майга катырып бетерү

замусóлиться *сов. разг.* селәгәйгә кату, селәгәйләнеп бетү; пычрану, пычраныш бетү, кату

заму́соривание *с см.* **заму́сорить**

заму́сорить *сов. что* чүпләп бетерү, чүп белән тутыру

заму́сориться *сов.* чүпләнеп бетү, чүп белән тулу

замути́ть *сов. что* болганчыкландыру, болганчыкландырып бетерү; **си́льно** ~ **во́ду** суны бик каты болганчыкландырып бетерү

замути́||ться *сов.* болганчыклану, болганчыкланып бетү; **вода́ по́сле дожде́й** ~**лась** янгырдан соң су болганчыкланды

замутне́ние *с см.* **замутне́ть**

замутне́ть *сов.* болганчыклану

замухры́шка *м, ж прост.* хәчтерүш, өтек, мәхлук (*кеше турында*)

заму́чи||ть *сов. кого-что* **1.** (*лишить жизни*) азаплап үтерү, җәзалап үтерү **2.** интектерү, интектереп бетерү, җәфалау, җәфалап бетерү; **боле́знь** ~**ла ребёнка** баланы авыру интектереп бетерде

заму́чи||ться *сов.* азапланып (җәфаланып) бетү, интегеп (йөдәп) бетү

за́мш||а *ж* замша (*йомшак күн*); **ту́фли из** ~**и** замша туфли

за́мшев||ый, -ая, -ое замша ..., замшадан тегелгән; ~**ые перча́тки** замша перчатка

замше́лый, -ая, -ое мүкләнгән, мүк белән капланган; ~ **пень** мүк белән капланган агач төбе

замыва́ть *несов. см.* **замы́ть**

замы́зганный, -ая, -ое *прост.* **1.** *прич. от* **замы́згать; 2.** керле, пычрак; ~ **костю́м** керле костюм

замы́згать *сов. что, прост.* пычратып бетерү, туздырып бетерү; ~ **костю́м** костюмны пычратып бетерү

замы́згивать *несов. см.* **замы́згать**

замыка́ние *с см.* **замкну́ть** ♦ **коро́ткое** ~ *эл.* кыска ялганыш

замыка́ть *несов.* **1.** *см.* **замкну́ть; 2.** *что* артында (иң ахырында) булу, артында (иң ахырында) бару; ~ **отря́д** отрядның артында бару

замыка́ться *несов.* **1.** *см.* **замкну́ться; 2.** *страд. от* **замыка́ть**

за́мысел *м* **1.** уй, теләк, ният; **осуществи́ть** ~ теләгенне тормышка ашыру **2.** (идея) төп фикер, төп идея; ~ **пье́сы** пьесаның төп идеясе

замы́слить *сов. что и с неопр.* уйлау, уйлап кую, ниятләү

замыслова́тый, -ая, -ое башваткыч, хикмәтле, әкәмәт, кыен аңлаешлы; ~ **вопро́с** башваткыч мәсьәлә

замы́ть *сов. что* юып бетерү; ~ **пя́тно** тапны юып бетерү

замыча́ть *сов.* мөгри башлау

замышля́ть *несов. см.* **замы́слить**

замя́ть *сов. что, разг.* йомып калдыру, туктату, каплап калдыру; ~ **де́ло** эшне йомып калдыру

замя́||ться *сов. разг.* ни әйтергә белмичә тукталып калу, сүз таба алмый калу; **он** ~**лся и замолча́л** ул ни әйтергә белмичә тукталып калды һәм тынды

за́навес *м* пәрдә (*театр сахнәсендә*); **дать** ~ пәрдәне төшерү ♦ **под** ~ берәр эшнең ахырында, азагында

занаве́сить *сов. что* пәрдә кору; ~ **окно́** тәрәзәгә пәрдә кору

занаве́ска *ж* пәрдә; чаршау; **око́нная** ~ тәрәзә пәрдәсе

занаве́шивать *несов. см.* **занаве́сить**

зана́шивать *несов. см.* **заноси́ть** II

занеме́||ть *сов.* ою; **рука́** ~**ла** кул оеды

занемо́чь *сов. уст.* авырып китү

занесе́ние *с см.* **занести́**

зан||ести́ *сов.* **1.** *кого-что* (*узын барышлый, юл уңаенда*) кертү, кертеп чыгу; **това́рищ** ~**ёс мне кни́гу** иптәшем миңа китап кертеп чыкты **2.** *кого-что* кертү, теркәү, язып кую; ~**сти́ в спи́сок** исемлеккә кертү; ~**сти́** *чьё-л.* **мне́ние в протоко́л** *берәр кешенең* фикерен беркетмәгә язып кую **3.** *безл. кого-что* басу, каплау; **сне́гом** ~**есло́ доро́гу** юлны кар баскан **4.** *что* күтәрү; ~**сти́ ру́ку для уда́ра** сугарга кул күтәрү **5.** *что* күчереп кую, күтәреп күчереп кую; ~**сти́ коне́ц бревна́** бүрәнәнең башын күтәреп күчереп кую **6.** *кого-что* илтеп кертү; ~**есло́ его́ в са́мую гу́щу толпы́** аны халык төркеменең иң тыгыз жиренә илтеп керттеләр

занести́сь *сов. разг.* (*зазнаться*) әреләнеп (масаеп, тәкәбберләнеп) китү

занижа́ть *несов. см.* **зани́зить**

заниже́ние *с см.* **зани́зить; ~ норм** нормаларны киметү

зани́женн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **зани́зить; 2.** төшерелгән, киметелгән, түбәнәйтелгән; ~**ые оце́нки** киметелгән билгеләр

зани́зить *сов. что* киметү, түбәнәйтү; ~ **но́рмы вы́работки** эшләп чыгару нормаларын киметү

занима́тельн||ый, -ая, -ое кызыклы, күңелле; ~**ая кни́га** кызыклы китап

занима́ть *несов. см.* **заня́ть** I

занима́ть II *несов. см.* **заня́ть** II

занима́||ться I **1.** *см.* **заня́ться I; 2.** уку, шөгыльләнү, хәзерләнү; **де́ти** ~**ются** балалар хәзерләнәләр; ~**ться в библиоте́ке** китапханәдә хәзерләнү

занима́ться II *несов. см.* **заня́ться** II

за́ново *нареч.* яңадан, яңабаштан; **сде́лать рабо́ту** ~ эшне яңабаштан эшләү

зано́з||а *ж* **1.** шырпы; **вы́тащить** ~**у из па́льца** бармакка кадалган шырпыны тартып чыгару **2.** *м, ж прост.* (*о язвительном человеке*) бәйләнчек, сагыз

зано́зистый, -ая, -ое *разг.* бәйләнчек; ~ **челове́к** бәйләнчек кеше

занози́ть *сов. что* шырпы керү; ~ **па́лец** бармакка шырпы керү

зано́с *м* (*снежный*) көрт, өем; кар басу; (*песчаный*) ком басу

заноси́ть I *несов. см.* **занести́**

заноси́ть II *сов. что* киеп туздыру, таушалдырып бетерү; пычратып бетерү; ~ **пальто́** пальтоны туздыру

заноси́ться I *несов. см.* **занести́сь**

заноси́||ться II *сов.* кия-кия тузу, киелеп тузу, киелеп пычрану; **бельё** ~**лось** күлмәк-ыштан киелеп тузды

зано́счивость *ж* тәкәбберлек, эрелек, һавалылык; масаю, кәпрәю; **отлича́ться** ~**ю** тәкәбберлек белән аерылып тору

зано́счивый, -ая, -ое һавалы, тәкәббер, эреләнүчән, масаючан, кәпрәючән, масаюлы; ~ **челове́к** тәкәббер кеше; ~ **отве́т** масаюлы җавап

заночева́ть *сов.* куну, кунып калу, кунарга калу; ~ **в лесу́** урманда кунарга калу

зано́шенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заноси́ть** II; **2.** киелгән, тузган, пычранган; ~**ая руба́шка** тузган күлмәк

зану́да *м, ж прост.* эчпошыргыч кеше, ялыктыргыч кеше

занумерова́ть *сов. что* номерлап чыгу, номерлар куеп чыгу

заны́||ть *сов.* **1.** сызлый (әрни) башлау, сыкрый башлау; ~**ла больна́я нога́** авырткан аяк сызлый башлады **2.** (*захныкать*) шыңшый башлау **3.** *разг.* (*жаловаться*) сукрана башлау

заня́ти||е *с* **1.** *см.* **заня́ть** II 1-3, 5; ~**е кре́пости** крепостьны алу **2.** эш, һөнәр;

выбира́ть себе́ ~е үзенә һөнәр сайлау **3.** *мн.* **~я** укулар, шөгыльләр; **~я в шко́ле начина́ются в во́семь часо́в** мәктәптә укулар сәгать сигездә башлана

заня́тный, -ая, -ое *разг.* күңелле, кызыклы; **~ расска́з** кызыклы хикәя

занято́й, -ая, -ое эшле, эше күп; **~ челове́к** эше күп кеше

за́нятость *ж* эшле булу, эш күплек, эш белән тәэмин ителгәнлек; **ссыла́ться на ~** эш күплеккә сылтау

за́нятый, -ая, -ое *прич. от* **заня́ть II**; **он за́нят свое́й рабо́той** ул үз эше белән мәшгуль; **на фа́брике за́нято бо́лее ста челове́к** фабрикада йөздән артык кеше эшли; **телефо́н за́нят** телефон буш түгел; **в за́нятой дере́вне** сугышып алынган авылда

заня́ть I *сов. что* (*взять взаймы*) бурычка алу, көтәргә алу, әҗәткә алу

заня́||ть II *сов.* **1.** *что* алу, алып тору, тутыру; **кни́ги за́няли всю по́лку** китаплар бөтен шүрлекне тутырганнар; **рабо́та заняла́ весь день** эш бөтен көнне алды **2.** *что* урнашу, алу, керү; **~ть ме́сто** урын алу; **батаре́я заняла́ пози́цию** батарея позициягә урнашты **3.** *кого-что* күнелен ачу; **~ть гостей** кунакларның күнелен ачу **4.** *кого-что* кызыксындыру, мавыктыру; **его́ заняла́ мысль о пое́здке в Москву́** аны Мәскәүгә бару турындагы фикер кызыксындырды **5.** *что* алу, сугышып алу; **~ть неприя́тельский го́род** дошман шәһәрен алу

заня́ться I *сов.* **1.** *чем* шөгыльләнә башлау, керешү, ...а башлау; **~ рабо́той** эшкә керешү; **~ спо́ртом** спорт белән шөгыльләнә башлау; **~ чте́нием** укырга керешү **2.** *с кем* булышу, житәкчелек итү; **~ с детьми́** балаларга булышу (*берәр эштә, уенда*) **3.** *кем-чем* игътибар итү; **пора́ вам ~ свои́м здоро́вьем** сезгә сәламәтлелегезгә игътибар итәргә вакыт

заня́ться II *сов.* **1.** яна башлау, кабынып китү; **костёр заня́лся** учак кабынып китте **2.** таң ата башлау; **заря́ заняла́сь** таң ата башлады

заоблачн||ый, -ая, -ое **1.** болытлар артындагы, болытлар аръягындагы, болытлардан биек; **~ые верши́ны** болытлардан биек тау түбәләре **2.** *перен.* буш; **~ые мечты́** буш хыяллар

заодно́ *нареч.* **1.** бергәләп, берьяклы булып, бергәләшеп; **действовать ~** *с кем-л. берәр кеше белән* бергәләп эш итү **2.** бер уңайдан, берраттән; **купи́те ~ и кни́гу** бер уңайдан китап та сатып алыгыз

заокеа́нск||ий, -ая, -ое океан артындагы, океан аръягындагы; **~ие стра́ны** океан артындагы илләр

заострённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **заостри́ть**; **2.** очлы, очланган; **~ сук** очлы ботак

заостри́ть *сов. что* **1.** очлау; очын үткенләү; **~ каранда́ш** карандаш очлау **2.** *перен.* кискенләштерү, басым ясау; **~ вопро́с** мәсьәләгә басым ясау ◆ **~ внима́ние** *на чём* игътибарны юнәлтү

заостри́||ться *сов.* **1.** очланып (очлаеп) калу; **у больно́го нос ~лся** авыруның борыны очлаеп калды **2.** *перен.* җитдиләшү, кискенләшү; **вопро́с ~лся** мәсьәлә җитдиләште

заостря́ть *несов. см.* **заостри́ть**

заостря́ться *несов.* **1.** *см.* **заостри́ться; 2.** *страд. от* **заостря́ть**

зао́чник *м* заочник, читтән торып укучы

зао́чница *ж* читтән торып укучы кыз

зао́чн||ый, -ая, -ое **1.** үзе югында, үзеннән башка; **~ый суд** үзеннән башка ясалган суд **2.** читтән торып ...; **~ое обуче́ние** читтән торып уку

запа́вш||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **запа́сть**; **2.** эчкә баткан; **~ие щёки** эчкә баткан яңаклар

за́пад *м* **1.** (*страна света*) көнбатыш **2.** (*с прописной*) Көнбатыш, Көнбатыш Европа илләре

запада́ть *несов. см.* **запа́сть**

за́падник *м* көнбатышчы (*көнбатышчылык тарафдары*)

за́падничество *с* көнбатышчылык (*19 гасырның 40-50нче еллардагы Россиядә иҗтимагый агым, бу агым вәкилләре, славянофиллардан аермалы буларак, көнбатыш Европадагы капиталистик усеш юлы Россия өчен дә ярый дип санаганнар*)

за́падн||ый, -ая, -ое **1.** көнбатыш ...ы; көнбатыштан ...; көнбатыштагы ...; **~ый ве́тер** көнбатыштан исә торган җил; **~ая грани́ца** көнбатыш чик **2.** Көнбатыш ...ы; **~ая литерату́ра** Көнбатыш әдәбияты

западн||я́ *ж* **1.** (*для птиц*) тозак; (*для зверей*) капкын **2.** *перен.* тозак; **попа́сть в ~ю́** тозакка эләгү, тозакка төшү

запа́здывание *с см.* **запозда́ть**

запа́здывать *несов. см.* **запозда́ть**

запа́ивать *несов. см.* **запая́ть**

запаковáть *сов. что* төреп бәйләү, төреп бәйләп кую; **~ ве́щи** әйберләрне төреп бәйләп кую

запако́вывать *несов. см.* **запаковáть**

запа́костить *сов.* что, *прост.* пычратып (шакшыландырып) бетерү; **~ пол** идәнне пычратып бетерү

запа́л I *м* **1.** запал, кабызгыч (*шартлаучан матдәләрне кабызып җибәрү җайланмасы*) **2.** *разг.* дәрт, гайрәт, омтылыш, кабынып китүчәнлек ◆ **говори́ть в ~е** кызып сөйләү

запа́л II *м* (*одышка у животных*) үпкә авыруы (*атларда һәм башка хайваннарда*)

запа́ливать *несов. см.* **запали́ть I**

запали́ть I *сов. что, прост.* кабызып җибәрү, ут төртү; **~ соло́му** саламга ут төртү

запали́ть II *сов. кого-что, спец.* (*опоить лошадь*) ат аягына су төшерү, атны яндыру

запа́льник *м* уткабызгыч (*эчке янулы двигательләрдә сыек ягулыкны кабызып җибәрү эсбабы*)

запа́льчивость *ж* кызулык, кызып китү, кызуканлылык, тиз кабынып китү, тиз ачулану; **отве́тить с ~ю** кызып китеп җавап бирү

запа́льчивый, -ая, -ое **1.** кызу, тиз кабынып китүчән, тиз ачуланучан, кызуканлы; **~ челове́к** кызу кеше **2.** ачулы, ярсулы; **~ отве́т** ачулы җавап

запа́мятовать *сов. что, уст.* оныту, хәтердән (истән) чыгару

запанибра́та *нареч. разг.* агай-эне-ләрчә, тартынмыйча, тартынып-нитеп тормыйча

запа́ривать *несов. см.* **запа́рить**

запа́рить *сов.* **1.** *кого-что, прост.* (*в бане*) мунчада чабындырып хәлдән тайдыру **2.** *что* (*обдать кипятком*) пешекләү, пешекләп йомшарту; **~ ткань** тукыманы пешекләп йомшарту **3.** *кого-что, прост.* (*загнать лошадь*) (*атны куып*) күбеккә батыру

запа́риться *сов.* **1.** *прост.* (*париться до изнеможения*) чабынып хәлдән таю, хәлдән тайганчы чабыну **2.** *разг.* (*покрыться по́том — о лошади*) тиргә бату, шабыр тиргә бату, манма тиргә бату **3.** *прост.* (*сильно устать*) арып бетү, эштән чыгу, хәлдән таю

запа́рка I *ж* (*обработка паром*) парлау, пешекләү

запа́рка II *ж прост.* (*спешка*) эш күплек, киренкелек (*эштә*)

запаршиве́ть *сов. разг.* тазлану, кырчын басу, корчаңгылану

запа́с *м* **1.** запас; **~ това́ров** товарлар запасы; **шить с ~ом** запас калдырып тегү; **~ы не́фти** нефть запаслары **2.** *воен.* запас (*гаскәри хезмәттән запаска җибәрелгән кешеләр*); **уво́лить в ~** запаска җибәрү ◆ **про ~** кирәк була калса дип

запаса́ть *несов. см.* **запасти́**

запаса́ться *несов.* **1.** *см.* **запасти́сь; 2.** *страд. от* **запаса́ть**

запа́сливость *ж* хәстәрлелек, хәстәрен күрүчәнлек, хәстәрчеллек

запа́сливый, -ая, -ое запас хәзерләүчән, запаслы, саклыклы, хәстәрчел, хәстәрен күрүчән; **~ хозя́ин** хәстәрен күрүчән хуҗа

запа́сник I *м разг.* запастагы гаскәри

запа́сник II *м* запасник, саклагыч; **в ~е мно́го карти́н** саклагычта картиналар күп

запасн||о́й, -а́я, -о́е **1.** запас ...ы; **~ы́е ча́сти маши́ны** машинаның запас частьлары **2.** *воен.* запастагы ...; **~о́й кома́ндный соста́в** запастагы командирлар составы **3.** *в знач. сущ.* **~ о́й** *м воен.* запаста торучы; **призы́в ~ы́х** запаста торучыларны [армиягә] чакыру

запа́сный, -ая, -ое *см.* **запасно́й** 1, 2; **~ вы́ход** запас чыгу ишеге

запасти́ *сов. что, чего* хәзерләү, хәстәрләү, хәзерләп кую; **~ дрова́ (дров) на́ зиму** кышка утын хәзерләү

запасти́сь *сов. чем* хәзерләп кую, хәстәрләп кую; **~ дрова́ми** утын хәзерләп кую ◆ **~ терпе́нием** чыдарга әзер булып тору

запа́||сть *сов.* **1.** *разг.* төшү, төшеп китү; **в проре́ху карма́на ~ла моне́та** кесә тишегеннән вак акча төшеп киткән **2.** эчкә бату; **глаза́ у него́ ~ли** күзләре эчкә баткан **3.** *перен.* үтеп керү, урнашу, сеңү; **слова́ его́ глубоко́ ~ли мне в ду́шу** аның сүзләре минем күңелемдә нык урнашып калды

запатентова́ть *сов. что* патент алу, үз исеменә беркетү

за́пах *м* ис; **прия́тный ~** хуш ис; **~ цвето́в** чәчкәләр исе

запаха́ть *сов. что* **1.** сөрү; **~ по́ле** басуны сөрү **2.** (*завалить землёй при вспашке*) сөреп күмү

запа́хивать I *несов. см.* **запаха́ть**

запа́хивать II *несов. см.* **запахну́ть**

запа́хиваться *несов.* **1.** *см.* **запахну́ться; 2.** *страд. от* **запа́хивать** II

запа́х||нуть *сов.* ис килә башлау; **~ло ды́мом** төтен исе килә башлады

запахну́ть *сов. что* чабуны каплау (ябу); **~ шу́бу** тун чабуын каплау

запахну́ться *сов.* төренү; **~ в халя́т** халатка төренү

запа́чкать *сов. кого-что* **1.** пычрату, пычратып бетерү, каралту **2.** *перен.* (*опозорить*) кара ягу, пычрату

запа́чкаться *сов.* пычрану, пычранып бетү

запа́шка *ж с.-х.* **1.** *см.* **запаха́ть; 2.** (*количество запаханной земли*) сөрә торган җир

запа́шник *м* запашник (*сай сөрә торган сабан*)

запая́ть *сов. что* паять итү, паять итеп ямау, кургаш эретеп ямау; **~ кастрю́лю** кәстрүлне паять итеп ямау

запе́в *м* җыр башы

запева́ла *м, ж* башлап җырлаучы (*хор белән җырлаганда*)

запева́ть *несов. что и без доп.* җырлый башлау, җырлап җибәрү

запе́вка *ж* запевка, җырның башы

запека́нка *ж* запеканка (**1.** *ярмадан яки бәрәңгедән кызыда пешерелгән ашамлык* **2.** *җиләк аракысы*)

запека́ть *несов. см.* **запе́чь**

запека́ться *несов.* **1.** *см.* **запе́чься; 2.** *страд. от* **запека́ть**

запелена́ть *сов. кого-что* биләү, биләүсәгә төрү, биләп кую

запеленгова́ть *сов. что, спец.* пеленгын билгеләү, пеленглау

запе́нить *сов. что* күбекләндерү

запе́ни||ться *сов.* күбекләнә башлау; **вино́ ~лось** шәраб күбекләнә башлады, шәраб кайный башлады

запере́ть *сов.* **1.** *что* бикләү, бикләп кую; **~ дверь** ишекне бикләү **2.** *кого-что* ябып кую, бикләп кую; **~ ко́шку в чула́не** мәчене чуланга ябып кую **3.** *перен. кого-что* камап алу, юлын бикләү; **~ флот неприя́теля** дошман флотын камап алу

запере́ться *сов.* **1.** бикләнү, бикләнеп калу; **~ в ко́мнате** бүлмәдә бикләнеп калу **2.** *разг.* (*не сознаться*) гаепне танымау, гаепне инкарь итү

заперши́||ть *сов. безл.* кытыклау, ачыта башлау, ачыттыру; **у меня́ ~ло в го́рле** минем тамагым кычыта башлады

запестре́||ть *сов.* **1.** (*показаться — о чём-л. пёстром*) чуарланып күренә башлау; **пе́ред глаза́ми ~ли поля́** күз алдында басулар чуарланып күренә башлады **2.** [еш] күренә башлау; **его́ и́мя ~ло во всех газе́тах** аның исеме барлык газеталарда күренә башлады

запе́ть *сов.* **1.** *что и* без *доп.* (*начать петь*) җырлый башлау, җырлап җибәрү **2.** (*о птицах*) сайрый башлау, сайрап җибәрү; (*о петухе*) кычкыра башлау, кычкырып җибәрү

запеча́тать *сов. что* **1.** печатьләү, печатьләп кую; **~ конве́рт сургуче́м** конвертны сургуч белән печатьләү **2.** ябыштырып кую; **~ письмо́** хатны конвертка салып ябыштырып кую

запечатлева́ть *несов. см.* **запечатле́ть**

запечатлева́ться *несов.* **1.** *см.* **запечатле́ться; 2.** *страд. от* **запечатлева́ть**

запечатле́ть *сов. кого-что* **1.** гәүдәләндерү, чагылдыру; **~ собы́тие на карти́не** вакыйганы картинада гәүдәләндерү **2.** *перен.* [күңелдә] калдыру, истә калдыру; **~ в па́мяти** берәр нәрсәне күңелдә калдыру

запечатле́ться *сов.* (*глубоко войти, укрепиться*) [күңелгә] сеңеп калу, истә калу

запека́тывать *несов см.* **запека́тать**

запе́чь *сов. что* **1.** (*испечь в тесте*) камырга төреп пешерү **2.** кызыда пешереп кызарту (кызартып алу); **~ макаро́ны** макаронны кызыда пешереп кызарту

запе́||чься *сов.* **1.** кызыда пешеп кызару; **карто́шка ~кла́сь** бәрәңге кызыда пешеп кызарган **2.** оешу, укмашу, куеру; **кровь ~кла́сь** кан оешкан **3.** (*пересохнуть — о губах*) ярылып бетү, ярганланып бетү

запива́ть *несов. см.* **запи́ть**

запина́ть *несов. см.* **запну́ть**

запи́нк||а *ж:* **говори́ть без ~и** тотлыкмыйча (төртелмичә) сөйләү

запира́тельство с гаепне танымау, гаепне инкарь итү

запира́ть *несов. см.* **запере́ть**

запира́ться *несов.* **1.** *см.* **запере́ться; 2.** *страд. от* **запира́ть**

записа́ть *сов. кого-что* **1.** язу, язып алу; **~ ле́кцию** лекцияне язып алу; **~ на магнитофо́н** магнитофонга язып алу **2.** теркәү, язып кую, теркәп кую, исемлеккә кертү; **~ на приём** кабул итү исемлегенә язып кую; **~ в расхо́д** *бухг.* чыгымга язып кую

записа́ться *сов.* язылу; **~ на приём к врачу́** табибка керү өчен язылу

запи́ск||а *ж* **1.** записка, язу; **служе́бная ~а** рәсми язу **2.** *мн.* **~и** язмалар; **учёные ~и университе́та** университетның гыйльми язмалары; **путевы́е ~и** юл язмалары **3.** *мн.* **~и** (*воспоминания, мемуары*) истәлекләр, хатирәләр

записн||о́й: ~а́я кни́жка язу дәфтәре, куен дәфтәре

запи́сывать *несов. см.* **записа́ть**

запи́сываться *несов.* **1.** *см.* **записа́ться; 2.** *страд. от* **записа́ть**

за́пис||ь *ж* **1.** *см.* **записа́ть; ~ь наро́дных ска́зок** халык әкиятләрен язып алу **2.** язма, язу; **тетра́дь с ~ями** язулы дәфтәр

запи́ть I *сов. что чем* ... артыннан эчү; **~ лека́рство водо́й** дару артыннан су эчү

запи́ть II *сов. разг.* (*запьянствовать*) эчә башлау, эчкечелеккә бирелү, баш күтәрмичә эчә башлау

запиха́ть *сов. кого-что, разг.* тыгызлап тутыру, тыгызлап тыгып кую; **~ бума́ги в портфе́ль** кәгазьләрне портфельгә тыгызлап тутыру

запи́хивать *несов. см.* **запиха́ть**

запихну́ть *сов. см.* **запиха́ть**

запла́кать *сов.* елый башлау, елап җибәрү; **~ от оби́ды** гарьлектән елап җибәрү

запланиро́вать *сов. что* планлаштыру, планлаштырып кую

запла́т||а *ж* ямаулык, ямау; **наложи́ть ~у** ямау салу

запла́тить *сов.* **1.** *что и* без *доп.* түләү; **~ за това́р** товар өчен түләү **2.** *чем* корбан итү, фида кылу; **~ жи́знью** җанын корбан итү ♦ **~ голово́й** башы белән җавап бирү; **~ добро́м за добро́** кунак ашы кара-каршы

запла́тка *ж уменьш. от* **запла́та**

заплева́ть *сов. кого-что* төкереп тутыру, төкереп пычрату; **~ пол** идәнне төкереп пычрату

заплёвывать *несов. см.* **заплева́ть**

заплеска́ть *сов. кого-что, разг.* чәчрәтеп бетерү, чәчрәтеп чылатып бетерү, түгеп юешләп бетерү; **~ водо́й** *кого-л.* су сибеп *кемне дә булса* юешләп бетерү

заплёсневелый, -ая, -ое күгәргән; **~ кусо́к сы́ра** күгәргән сыр кисәге

заплёсневе||ть *сов.* күгәрү; **бу́лка ~ла** калач күгәргән

заплесну́||ть *сов. кого-что* чәчрәү, чәчрәп керү; **ло́дку ~ло водо́й** *безл.* көймәгә су чәчрәде

заплести́ *сов. что* **1.** үрү, үреп кую; **~ ко́су** чәч толымын үрү **2.** (*оплести, покрыть чем-л. вьющимся*) чорналып каплау, үрмәләп каплау

заплета́ть *несов. см.* **заплести́**

заплета́||ться *несов.* **1.** көчкә генә атлау; **у него́ но́ги ~ются от уста́лости** арудан аның аяклары көчкә генә атлый **2.** бәйләнү, көрмәкләнү; **у него́ от волне́ния язы́к ~ется** дулкынланудан аның теле бәйләнә **3.** *страд. от* **заплета́ть**

заплёчный, -ая, -ое арка ...ы; **~ мешо́к** арка капчыгы

заплёчье с *прост.* муен тамыры

запломбирова́ть *сов. что* пломбалау, пломба кую, пломба куйдыру; **~ зуб** тешкә пломба кую; **~ ваго́н** вагонны пломбалау

запломбиро́вывать *несов. см.* **запломбирова́ть**

заплута́ться *сов. прост.* адашу, юлдан язу; **~ в лесу́** урманда адашу

заплы́в *м* йөзү, йөзү ярышы; **~ на дли́нную диста́нцию** ерак арага йөзү

заплыва́ть I *несов. см.* **заплы́ть** I

заплыва́ть II *несов. см.* **заплы́ть** II

заплы́ть I *сов.* йөзеп китү (*еракка*); йөзеп барып керү; **~ на середи́ну реки́** елга уртасына йөзеп китү; **~ в купа́льню** купальняга йөзеп барып керү

заплы́||ть II *сов. чем* каплау, басу; **глаза́ ~ли жи́ром** күзләрен май баскан

запну́ться *сов.* **1.** абыну, сөртенү; **~ о поро́г** бусагага абыну **2.** *перен.* тотлыгу; төртелеп калу; **~ на пе́рвом же сло́ве** беренче сүздән үк төртелеп калу

запове́дник *м* заповедник, тыюлык, тыслган урын

запове́дн||ый, -ая, -ое **1.** тыелулы; тыелган; **~ый лес** тыелган урман **2.** яшерен, сер итеп саклана торган; **~ые мы́сли** яшерен уйлар

за́поведь *ж* **1.** дини канун, дин кушуы **2.** *перен. высок.* бурыч, васыять

заподо́зрить *сов. кого-что в чём* шикләнү, шикләнә башлау, шиккә төшү, шик тота башлау; **~** *чью-л.* **правди́вость** *кемнең дә булса* хаклы булуына шикләнү

запо́ем *нареч.* **1.** тыелгысыз [рәвештә], тыелмыйча, бертуктаусыз, баш күтәрмичә; **пить ~** тыелгысыз эчү **2.** *перен. разг.* баш күтәрмичә, йотылып; **чита́ть ~** баш күтәрмичә уку

запозда́л||ый, -ая, -ое кичеккән, соңлаган, соңга калган, вакыты үткән; **~ая по́мощь** кичеккән ярдәм

запозда́ть *сов.* кичегү, кичегә төшү, соңга калу, бераз соңга калу; **~ к обе́ду** көндезге ашка соңга калу

запо́||й *м* тыелгысыз эчү, баш күтәрмичә эчү; **страда́ть ~ем** тыелгысыз эчү белән җәфалану

заполáскивать *несов. см.* **заполоска́ть**

запо́лза||ть *сов.* үрмәли башлау, шуыша башлау, үрмәләп йөри башлау; төрле якка үрмәләү; **муравьи́ ~ли** кырмыскалар төрле якка үрмәли башладылар

заползáть *несов. см.* **заползти́**

заползти́ *сов.* үрмәләп керү, үрмәләп кереп китү; шуышып керү, шуышып кереп китү; **~ под дива́н** диван астына үрмәләп керү

заполни́тель *м спец.* тутырма (*узле массага өстәлә торган матдә*)

запо́лни||ть *сов. что* **1.** тутыру; **~ть вы́боину ще́бнем** казылмага вак таш тутыру; **~ть анке́ту** анкета тутыру **2.** тулу, шыгрым тулу; **зри́тели ~ли зал** тамашачылар залга кереп тулдылар

запо́лни||ться *сов.* тулу, шыгрым тулу; **пло́щадь ~лась наро́дом** мәйдан халык белән тулды

заполня́ть *несов. см.* **запо́лнить**

заполня́ться *несов.* **1.** *см.* **запо́лниться; 2.** *страд. от* **заполня́ть**

заполони́ть *сов. разг. см.* **запо́лнить 2**

заполоска́ть *сов. что, прост.* чайкап юу; **~ пелёнку** бала чүпрәген чайкап юу

заполучи́ть *сов. кого-что, прост.* алу, алып кую; табу; **~ це́нного рабо́тника** бик кирәкле хезмәткәрне табу

заполыха́||ть *сов. разг.* **1.** (*пылать*) ялкынланып яна башлау; **~л пожа́р** янгын ялкынланып яна башлады **2.** (*ярко краснеть, гореть*) яна башлау, кыпкызыл булу

заполя́рный, -ая, -ое Поляр түгәрәге аръягындагы; **~ го́род** Поляр түгәрәгенең аръягындагы шәһәр

запомина́ть *несов. см.* **запо́мнить** I

запомина́ться *несов. см.* **запо́мниться**

запо́мнить I *сов. кого-что* күңелдә (истә) калдыру, хәтердә калдыру; **~ стихи́** шигырьләрне күңелдә калдыру

запо́мн||ить II *несов. кого-что* с *отриц.* хәтерләү

запо́мниться *сов.* хәтердә калу, истә калу

за́понка *ж* запонка

запо́р I *м* бик, кслә, бикләвеч; **дверь без ~а** биксез ишек

запо́р II *м* эч кибү, эч кату; **страда́ть ~ом** эч кату белән җәфалану

запоро́жец *м ист.* Запорожье казагы

запоро́ть I *сов. кого-что, разг.* (*засечь до смерти*) үтергәнче кыйнау, кыйнап үтерү

запоро́ть II *сов.* что, *прост.* (*начар эшләп*) бозу; **~ обраба́тываемую дета́ль** эшкәртелә торган детальне бозу

запороши́||ть *сов.* [ком, тузан, кар] каплау; **~л снежо́к** җир йомшак кар белән капланды

запотева́ть *несов. см.* **запоте́ть**

запоте́л||ый, -ая, -ое буланган, парланган, тирләгән; **~ые стёкла** парланган пыялалар

запоте́||ть *сов.* парлану, тирләү, буланы; **о́кна ~ли** тәрәзәләр тирләде

заправи́ла *м разг.* эшкуар, эшмәкәр; башлап йөрүче

запра́вить *сов. что* **1.** тыгып кую, тыгу; **~ брю́ки в сапоги́** чалбар балакларын итек кунычына тыгып кую **2.** салу, тәмләндерү; **~ суп тома́том** ашка томат салу **3.** салу; **~ ла́мпу** лампага керосин салу; **~ автомоби́ль бензи́ном** автомобильгә бензин салу **4.** җыештыру; **~ ко́йку** койканы җыештыру

запра́виться. *сов.* **1.** *разг.* бензин салу (*уз автомобилеңә*) **2.** *прост. шутл.* туйганчы ашап-эчү

запра́вка *ж* **1.** *см.* **запра́вить, запра́виться; 2.** тәмләткеч, тәмкерткеч

заправля́||ть *несов.* **1.** *см.* **запра́вить 2.** *прост.* (эшне) алып бару, башкару; **в до́ме всем ~ет ба́бушка** өйдә барлык эшләрне әби башкара

заправля́ться *несов.* **1.** *см.* **запра́виться; 2.** *страд. от* **заправля́ть** I

запра́вский, -ая, -ое *разг.* оста, менә дигән; **~ игро́к** менә дигән уйнаучы

запра́вщик *м* заправщик (*ягулык сала торган машина; ягулык җибәреп торучы кеше*)

запра́шивать *несов. см.* **запроси́ть**

запре́т *м* тыю; **наложи́ть ~** *на что ни дә булса эшләүне* тыю

запрети́ть *сов. кому что и с неопр.* тыю, рөхсәт итмәү; **~ кури́ть** тәмәке тартуны тыю

запре́тн||ый, -ая, -ое тыелган, тыюлы; ябык; **~ая зо́на** тыюлы зона

запреща́ть **1.** *несов. см.* **запрети́ть**

запреща́||ться 1. *несов.* тыелу, ярамау, рөхсәт ителмәү; **ходи́ть по газо́нам ~ется** газоннар өстеннән йөрү тыела **2.** *страд. от* **запреща́ть**

запреми́ть *сов. кого-что, прост.* күреп алу, сизеп алу; истә калдыру, хәтердә калдыру; **~** *кого-л.* **в толпе́** халык арасыннан *кемне дә булса* күреп алу

заприхо́довать *сов. что* приходка кертү, керемгә язып кую, керемгә алу

запрограмми́ровать *сов.* что программалаштыру, программага салу

запродава́ть *несов. см.* **запрода́ть**

запрода́ть *сов. кого-что* алдан сату, алдан сатып кую

запроекти́ровать *сов. что* проектлаштыру, проектка кертү

запроки́дывать *несов. см.* **запроки́нуть**

запроки́нуть *сов. что, разг.* артка ташлау; артка салу; **~ го́лову** башны артка ташлау

запроки́ну||ться *сов. разг.* артка ташлану; артка салыну; **голова́ ~лась** башы артка ташланган

запропасти́ться *сов. прост.* әллә кая китү, юкка чыгу, юк булу, югалу, олагу

запропа́сть *сов. см.* **запропасти́ться**

запро́с *м* **1.** запрос, сорау; **сде́лать ~** запрос ясау; **посла́ть ~ в учрежде́ние** учреждениегә сорау җибәрү **2.** *разг.* (*назначение чрезмерной цены*) артык бәя сорау, чиксез зур бәя сорау, арттырып сорау **3.** *обычно мн.* **~ы** ихтыяҗлар, таләпләр; **культу́рные ~ы** мәдәният ихтыяҗлары ♦ **це́ны без ~а** үз бәясе

запроси́ть *сов.* **1.** *кого-что, офиц.* сорау, сорату, соратып алу, соратып алдыру; **~ мне́ние реда́кции** редакциянең фикерен сорау **2.** *что* (*назначить чрезмерную цену*) артык бәя сорау, чамадан тыш сорау (*бәя*)

за́просто *нареч. разг.* болай гына, үз итеп кенә, тартынмый-нитми генә, тәкәллефсез генә; **~ прийти́ в го́сти** кунакка үз итеп кенә килү

запротестова́ть *сов.* протест ясый (белдерә) башлау

запротоколи́ровать *сов. что* беркетмәгә язу, беркетмәгә язып кую

запру́да *ж* буа, бөя

запруди́||ть *сов. что* **1.** буу, буып (бөяп) кую; **ре́чку ~ли** инешне буып куйдылар **2.** *перен.* тутыру, каплап алу; **толпа́ ~ла всю у́лицу** халык бөтен урамны тутырды

запру́живать *несов. см.* **запруди́ть**

запряга́ть *несов. см.* **запря́чь**

запря́жка *ж* **1.** җигү; **~ цу́гом** (*атларны*) очлап җигү **2.** (*повозка*) җигүле арба (чана)

запря́тать *сов. кого-что, разг.* яшерү, яшереп кую, җыеп кую; **~ де́ньги** акчаны яшереп кую

запря́таться *сов. разг.* яшеренү, качу, посу

запря́тывать *несов. см.* **запря́тать**

запря́тываться *несов.* **1.** *см.* **запря́таться; 2.** *страд. от* **запря́тывать**

запря́чь *сов. прям., перен. кого-что* җигү, җиген кую; **~ ло́шадь** атны җигү; **~ теле́гу** арба җигү; **~ в рабо́ту** эшкә җигү

запу́ганный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **запуга́ть; 2.** куркынган, куркак; **~ ребёнок** куркак бала

запуга́ть *сов. кого-что* куркыту, куркытып бетерү, котын алу, котын чыгару, өркетү; **~ ребёнка** баланы куркыту

запу́гивать *несов. см.* **запуга́ть**

запу́дривать *несов. см.* **запу́дрить**

запу́дрить *сов. что* пудра (кершән) сөртү, пудра (кершән) ягу, пудралау, кершән белән ягыну; ~ **весну́шки** сипкелләргә кершән ягу

за́пуск *м см.* **запусти́ть** I 1-3, 6; ~ **иску́сственного спу́тника** ясалма иярчен җибәрү

запуска́ть I *несов. см.* **запусти́ть** I

запуска́ть II *несов. см.* **запусти́ть** II

запусте́ни||е *с* ташландык хәлдә булу, вәйранлык; **дом в ~и** йорт ташландык хәлдә

запусти́||ть I *см.* **1.** *что, чем разг.* томыру, ыргыту, җибәрү; **~ть ка́мень (ка́мнем)** таш белән җибәрү; **~ть иску́сственный спу́тник** ясалма иярчен җибәрү **2.** *что* очыру; **~ть зме́я** очыртқыч очыру **3.** *что, разг.* җибәрү, эшләтә башлау; кабызып җибәрү; **~ть мото́р** моторны җибәрү **4.** *что, разг.* тыгу; **~ть ру́ку в карма́н** кулны кесәгә тыгу **5.** *что, разг.* батыру; **ко́шка глубоко́ ~ла когти** мәче тырнакларын тирән батырды **6.** *кого-что, разг.* җибәрү; **~ть карасе́й в пруд** буага табанбалыклар җибәрү

запусти́ть II *сов, что* **1.** ташландык хәлгә китерү, төшенкелек хәленә китерү, рәтен җибәрү; ~ **хозя́йство** хуҗалыкны ташландык хәлгә китерү; ~ **дела́** эшнең рәтен җибәрү **2.** аздыру; ~ **боле́знь** авыруны аздыру

запу́танный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **запу́тать**; **2.** *перен.* буталчык, чуалчык; ~ **вопро́с** буталчык мәсьәлә

запу́тать *сов.* **1.** *что* чиялəндерү, чәбәләндерү, чуалту; ~ **верёвку** бауны чәбәләндерү **2.** *что* бутау, чуалту; ~ **де́ло** эшне чуалту **3.** *кого-что, разг.* (*сбить с толку*) аптырату, аптыратып бетерү, йөдәтеп бетерү, башны әйләндереп бетерү

запу́та||ться *сов.* **1.** чиялəнү, чәбәләнү, чуалу; **верёвка ~лась** бау чуалды **2.** *в чём* эләгү; уралу; **го́лубь ~лся в силке́** күгәрчен тозакка эләкте; **~ться в по́лах халата́** халат чабуларына уралу **3.** *разг.* (*сбиться в речи, мыслях*) буталу, буталып бетү; **свиде́тель ~лся** шаһит буталып бетте **4.** *в чём и без доп., разг.* бату; **~ться в долга́х** бурычка бату

запу́тывать *несов. см.* **запу́тать**

запу́тываться *несов.* **1.** *см.* **запу́таться**; **2.** *страд. от* **запу́тывать**

запуши́||ть *сов. что* каплау, каплап алу; бәсләнү; **и́ней ~л окно́** тәрәзәне бәс каплаган; **ресни́цы ~ло** *безл.* керфекләр бәсләнде

запу́щенность *ж* **1.** (*напр. хозяйства*) ташландыклык, ташландык хәлдә булу **2.** (*напр. болезни*) азган булу, озак дәваламаган булу

запу́щенный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **запусти́ть** II; **2.** каралмаган, ташландык хәлгә килгән; ~ **сад** ташландык бакча **3.** азган, озак дәваламаган; ~ **бронхи́т** озак дәваламаган бронхит

запча́сти *только мн.* запас частьләр

запыла́||ть *сов.* **1.** дөрләп яна башлау, ялкынланып яна башлау; дөрләп янып китү; **~л костёр** учак дөрләп янып китте **2.** кызару, уттай яну; **щёки ~ли** битләре уттай яна башлады

запыли́ть *сов. что* (*покрыть пылью*) тузанландыру, тузан белән каплау

запыли́||ться *сов.* тузанлану, тузан белән каплану; **оде́жда ~лась** кием тузанланды

запыха́ться *несов. разг.* сулыш тыгылу, тын бетү, сулыш тараю; ~ **от бе́га** йөгерүдән тын бетү

запыхте́||ть *сов. разг.* **1.** мышный башлау **2.** ухылдый башлау; **парово́з ~л** паровоз ухылдый башлады

запя́стье *с* (*часть руки*) беләзек сөяге

запят||а́я *ж* өтер; **поста́вить ~ую** өтер кую

запя́тки *только мн.* арт басма (*карета артында лакейлар басып бару очен*)

запятна́||ть *сов.* **1.** *прям., перен. кого-что* пычрату, тап төшерү; **я не ~ю своё и́мя** мин [үземнең] исемемне пычратмам **2.** *кого, разг.* (*в игре — ударить рукой, мячом*) [туп белән] бәрү

зараба́тывать *несов. см.* **зарабо́тать** I

зарабо́тать I *сов. что* **1.** эшләп табу; ~ **де́ньги че́стным трудо́м** намуслы хезмәт белән акча эшләп табу **2.** *прост. ирон.* алу, эләктерү; ~ **вы́говор** шелтә алу

зарабо́та||ть II *сов.* (*начать работать*) эшли башлау; **маши́на ~ла** машина эшли башлады

зарабо́та||ться *сов. разг.* **1.** (*устать от долгой работы*) күп (озак) эшләп ару, эшли-эшли арып бетү **2.** эш белән мавыгып ... сизми калу; **я ~лся до полу́ночи** эш белән мавыгып ярты төн җиткәнен сизми дә калдым

за́работн||ый, -ая, -ое: **~ая пла́та** эш хакы, хезмәт хакы

за́работ||ок *м* эш хакы, хезмәт хакы; **годово́й ~ок** еллык хезмәт хакы; **уходи́ть на ~ки** *уст.* читкә акча эшләргә китү

зара́внивать *несов. см.* **заровня́ть**

заража́ть *несов. см.* **зарази́ть**

заража́ться *несов.* **1.** *см.* **зарази́ться; 2.** *страд. от* **заража́ть**

зараже́ние *с см.* **зарази́ть** 1, **зарази́ться** 1; ~ **гри́ппом** грипп эләктерү; ~ **во́здуха** һаваның агулануы; ~ **кро́ви** кан йогышлану; **радиоакти́вное ~ ме́стности** урынның радиоактив зарарлануы

заражённый, -ая, -ое **1.** *прич.* от **зарази́ть**; **2.** агуланган; ~ **во́здух** агуланган һава

зара́з *нареч. разг.* берьюлы; **съесть всё ~** берьюлы барысын да ашап бетерү

зараз||а *ж* йогышлы авыру, йогышлы чир; **исто́чники ~ы** йогышлы чир чыганаклары

зарази́тельн||ый, -ая, -ое **1.** йогышлы, йогучан; **э́та боле́знь ~а** бу авыру йогышлы **2.** *перен.* тәэсир итүчән, тәэсир итә торган; тиз таралучан; **~ый приме́р** тәэсир итә торган үрнәк; **дурны́е приме́ры ~ы** начар үрнәкләр тиз таралучан

зарази́ть *сов.* **1.** *кого-что чем* йоктыру; ~ **гри́ппом** грипп йоктыру **2.** *что чем* агулау, пычрату; ~ **во́здух** һаваны агулау **3.** *перен. кого-что чем* тәэсир итү, мавыктырып үзенә иярту

зарази́ться *сов. чем* **1.** йоктыру, иярту, эләктерү; ~ **гри́ппом** грипп йоктыру **2.** *перен.* бирелү, кушылу, уртаклашу; ~ **о́бщей ра́достью** гомуми шатлыкка бирелү

зара́зн||ый, -ая, -ое йогышлы; **~ая боле́знь** йогышлы авыру; **~ый больно́й** йогышлы авыру белән авыручы

зара́нее *нареч.* алдан, алдан ук; ~ **подгото́виться** *к чему-л.* алдан ук хәзерләнеп кую

зарапортова́ться *сов. разг.* буталып калу, тиешеннән артыгын сөйләү, кирәкмәс сүзләр сөйләп ташлау

зараста́ть *несов. см.* **зарасти́**

зар||асти́ *сов.* **1.** *чем и без доп.* каплану, [үлән] басу; **~асти́ мхом** мүк белән каплану; **тропи́нка ~осла́** сукмакны үлән баскан; **~асти́ бородо́й** сакал басу **2.** йомылу, төзәлү, бөтәшү; **ра́на ~осла́** яра бөтәшкән

зарва́ться *сов. разг.* арттырып җибәрү, ашып китү

зарде́||ться *сов.* кызару, кызарып китү; **де́вушка ~лась** [оялудан] кызый кызарып китте

зареве́||ть *сов.* **1.** үкерә (акыра) башлау; **зверь ~л** ерткыч хайван үкерә башлады **2.** *разг.* (*заплакать*) кычкырып елап җибәрү, үкереп елап җибәрү; **де́ти ~ли** балалар үкереп елап җибәрделәр

за́рево *с* шәүлә; кызыллык (*сияние зари*) шәфәкъ алсулыгы; ~ **пожа́ра** янгын шәүләсе

зарегистри́ровать *сов. кого-что* теркәү, теркәп кую, регистрация ясау, регистрацияләү, хисапка алу

зарегистри́роваться *сов.* **1.** (*встать на учёт*) теркәлү, регистрацияләнү **2.** *с кем* язылышу; ~ **в за́гсе** загста язылышу

заре́з *м в знач. сказ. разг.* бәла, эш харап, аптыраш; **без де́нег пря́мо ~** акчасыз бөтенләй эш харап ♦ **до ~у** бик; **до ~у ну́жно** бик кирәк

заре́зать *сов. кого* сую, чалу, бугазлау; ~ **ягнёнка** бәрән сую ♦ **хоть заре́жь[те]** башка чыдар әмәл юк

заре́заться *сов. разг.* үзен-үзе сую, суелып үлү

зарезерви́ровать *сов. кого-что* соңыннан әйтү хокукын калдыру

зареко́маться *несов. см.* **заре́чься**

зарекомендова́||ть *сов.*: **~ть себя́** үзен таныту, үзен күрсәтү; **он ~л себя́ хоро́шим рабо́тником** ул үзен яхшы хезмәткәр итеп танытты

заре́чный, -ая, -ое елга артындагы, елга аръягындагы

заре́чье *с* елга арты, елга аръягы

заре́чься *сов.* тәүбә итү, ...маска ант итү, сүз бирү; ~ **кури́ть** тәмәке тартмаска сүз бирү

заржа́веть *сов.* тутыгу, күгәрү

заржа́вленный, -ая, -ое тутыккан, күгәргән; ~ **нож** тутыккан пычак

заржа́ть *сов*, кешнәп җибәрү

зарисова́ть *сов. кого-что* рәсемен ясау, рәсемен төшерү

зарисо́вка *ж* **1.** *см.* **зарисова́ть; 2.** рәсем

зарисо́вывать *несов. см.* **зарисова́ть**

за́риться *несов. на кого-что, прост.* кызыгу, күз кызу; **~ на чужо́е добро́** кеше байлыгына кызыгу

зарни́ц||а *ж* арыш камчылау, ажаган, нәжәгай, елдырым; **вспы́хивают ~ы** ажаган ялтырый

заровня́ть *сов. что* тигезләү, күмеп тигезләү; **~ я́му** чокырны күмеп тигезләү

зароди́ть *сов. что* тудыру, уяту; **~ наде́жду** *в ком-л. кемдә дә булса* өмет тудыру

зароди́||ться *сов.* туу, барлыкка килү; уйга килү; **у него́ ~лась иде́я** аңарда бер идея туган

заро́дыш *м* **1.** (*человека, животного*) яралгы; (*растения*) бәбәк, бәбәнәк **2.** *перен.* башлангыч чор; **подави́ть дурну́ю привы́чку в ~е** начар гадәтне башлангыч чорында ук юкка чыгару

заро́дышев||ый, -ая, -ое яралгы ...ы, бәбәк ...ы; **~ые кле́тки** яралгы күзәнәкләре

зарожда́ть *несов. см.* **зароди́ть**

зарожда́ться *несов.* **1.** *см.* **зароди́ться; 2.** *страд. от* **зарожда́ть**

зарозове́||ть *сов.* **1.** (*показаться — о чем-л. розовом*) алсуланып күренү **2.** (*начать розоветь; стать розовым*) алсулана башлау; алсулану; **щёки у нее ~ли** аның битләре алсуланды

заро́к *м* вәгъдә, сүз, ант (*берәр нәрсәне эшләмәскә сүз бирү*); **дать ~** сүз бирү

зарокота́||ть *сов.* шаулый башлау; **мо́ре ~ло** диңгез шаулый башлады

зарони́ть *сов. что* кузгату, тудыру; **~ подозре́ние** шик тудыру; **~ наде́жду** өмет тудыру

за́рос||ль *ж* куаклык, әрәмәлек; куе үсемлекләр; **~и оре́шника** чикләвек куаклыгы

зарпла́т||а *ж разг.* эш хакы, хезмәт хакы; **получи́ть ~у** хезмәт хакы алу

зарубáть *несов. см.* **зарубúть** 2

зарубе́жн||ый, -ая, -ое чит, чит ил[ләр]...ы; чит илләрдәге..., чит арыягындагы...; **~ая печа́ть** чит ил матбугаты; **~ые стра́ны** чит илләр

заруби́ть *сов.* **1.** *кого-что* чабып үтерү **2.** *что* (*сделать зарубку*) киртек ясау, киртләү, киртекләү; **~ бревно́** бүрәнәне киртләү ♦ **~ себе́ на лбу (на носу́)** колакка киртеп кую, маңгайга язып кую

зару́бка *ж* тамга, киртек; **~ на де́реве** агачка салынган тамга

зарубцева́||ться *сов.* төзәлү, йомылу, бетәшү; **ра́на ~лась** яра бөтәште

зарубцо́вываться *несов. см.* **зарубцева́ться**

зарумя́ни||ть *сов. что* **1.** кызарту, алсуландыру, алсу төскә кертү; **моро́з ~л щёки** суык битләрне алсуландырды **2.** кызарту; **~ть пиро́г** бәлешне кызарту

зарумя́ни||ться *сов.* **1.** кызару, алсулану, алсу төскә керү; **~ться от моро́за** суыктан кызару **2.** кызару; **бу́лки ~лись** күмәчләр кызарган

заруча́ться *несов. см.* **заручи́ться**

заручи́ться *сов.* чем [ризалыгын] алу; [вәгъдәсен] алып кую; **~ согла́сием** ризалыгын алу

зарыва́ть *несов. см.* **зары́ть**

зарыва́ться I *несов.* **1.** *см.* **зары́ться; 2.** *страд. от* **зарыва́ть**

зарыва́||ться II *несов. см.* **зарва́ться; не ~йся!** артыгын кыланма!

зарыда́ть *сов.* кычкырып елый башлау, үксеп елый башлау

зарыси́||ть *сов.* юырта башлау; **ло́шадь ~ла по доро́ге** ат юл буйлап юырта башлады

зары́ть *сов. кого-что* күмү, күмеп кую ♦ **~ свой тала́нт в зе́млю** үзеңнең талантыңны җиргә күмү

зары́ться *сов.* күмелү, каплану ♦ **~ в кни́ги** китапка чуму (*йотылып уку*)

зар||я́ *ж* **1.** (*утренняя*) таң, иртәнге шәфәкъ; (*вечерняя*) шәфәкъ; **встать с ~ёй** таңнан тору; **~я́ занима́ется** таң беленә башлады **2.** *перен.* таң; **на ~е но́вой жи́зни** яңа тормыш таңында; **~я свобо́ды** ирек таңы ♦ **от ~и́ до ~и́** кояш батканнан алып кояш чыкканга кадәр

зарябúть I *сов. что* (*покрыть рябью*) шадраландыра башлау, җыерчыкландыра башлау (*мәс. су өстен*)

зачи́слиться *сов.* керү, кабул ителү, алыну; ~ **в аспиранту́ру** аспирантурага алыну

зачисля́ть *несов. см.* **зачи́слить**

зачисля́ться *несов.* **1.** *см.* **зачислиться; 2.** *страд. от* **зачисля́ть**

зачи́стить *сов. что* чистарту, чистартып алу; ~ **края́** кырыйларын чистарту

зачита́|ть *сов. что* **1.** уку, укып чыгу, укып игълан итү; ~**ть протоко́л** беркетмәне уку **2.** *разг.* югалту, кайтарып бирмәү; **он** ~**л мою́ кни́гу** ул минем китапны кайтарып бирмәде

зачита́ться *сов.* онытылып (йотылып) уку, уку белән мавыгу; ~ **до утра́** иртәнгә кадәр онытылып уку

зачи́тывать I *несов. см.* **зачесть**

зачи́тывать II *несов. см.* **зачита́ть**

зачи́тываться I *несов.* **1.** *см.* **зачесться; 2.** *страд. от* **зачи́тывать I**

зачи́тываться II *несов.* **1.** *см.* **зачита́ться; 2.** *страд. от* **зачи́тывать II**

зачища́ть *несов. см.* **зачи́стить**

зачумлённый, -ая, -ое чума йоктырган, чумалы

зачу́ять *сов. кого-что, разг.* сизенү, тою, сизеп (белеп) алу; ~ **дичь** кыргый җәнлек барын сизеп алу

зашага́ть *сов.* атлый башлау, бара башлау

зашо́рка|ть *сов. что, разг.* таптап бетерү; **ве́сь по́л** ~**ли** бөтен идәнне таптап бетергәннәр

зашвы́ривать *несов. см.* **зашвырну́ть**

зашвырну́ть *сов. что, разг.* атып бәрү, ташлау, тотып ату, ыргытып җибәрү; ~ **мя́чик** тупны ыргытып җибәрү

зашвыря́ть *сов. кого-что, разг.* яудыру; ташлау; ~ **камня́ми** ташлар яудыру

зашевели́ть *сов. чем* кыймылдата (хәрәкәтләндерә) башлау; ~ **па́льцами** бармакларны кыймылдата башлау

зашевели́|ться *сов.* хәрәкәткә килү, селкенә (кыймылдый) башлау; **толпа́** ~**лась** халык төркеме хәрәкәткә килде

заше́йный, -ая, -ое муен артындагы

зашелесте́|ть *сов. чем и без доп.* кыштырдый (кыштырдата, кыштыр-кыштыр килә) башлау; **ли́стья** ~**ли** яфраклар кыштырдый башлады; ~**ть страни́цами кни́ги** китап битләрен кыштырдата башлау

зашелуди́вать *сов. прост.* корчаңгылану, күтәр белән каплану

зашепта́ть *сов. что и без доп.* пышылдый башлау, чыш-пыш сөйләшә башлау

зашерша́веть *сов.* кытыршылану

зашиби́ть *сов. что, прост.* **1.** бәрү, сугу, бәреп (сугып) егу **2.** акча эшләү, каеру, акча төшерү; ~ **деньгу́** акча төшерү

зашива́ть *несов. см.* **заши́ть**

заши́ть *сов.* **1.** *что* ямау, ямап кую; ~ **мешо́к** капчык ямау **2.** *кого-что во что* тегү, тегеп кую; ~ **посы́лку в холст** посылканы киндергә тегеп кую

заши́ться *сов. прост.* [башкарып] өлгерә алмау (*эштә*)

зашифрова́ть *сов. что* шифрлау, шифр белән язу (*шартлы билгеләр белән язу*)

зашифро́вывать *несов. см.* **зашифрова́ть**

зашнурова́ть *сов. что* шнурлау, шнур белән бәйләү (бәйләп кую)

зашнуро́вывать *несов. см.* **зашнурова́ть**

зашпаклева́ть *сов. что* шпаклевать итү, сылап тигезләп кую; ~ **ще́ли** ярыкларны шпаклевать итү

зашпи́ливать *несов. см.* **зашпи́лить**

зашпи́ливаться *несов.* **1.** *см.* **зашпи́литься; 2.** *страд. от* **зашпи́ливать**

зашпи́лить *сов. что* шпилька (булавка) кадап кую; ~ **во́лосы** чәчкә шпилька кадап кую

зашпи́литься *сов.* шпилька (булавка) кадап куелу

шта́тный, -ая, -ое; ~ **го́род** *уст.* өяз үзәге булмаган шәһәр (*революциягә кадәрге Россиядә*)

заштемпелева́ть *сов. что* штемпель басу (сугу)

заштопа́ть *сов. что* тупчу, тупчып ямау

заштопывать *несов. см.* **заштопа́ть**

заштори́вать *несов. см.* **заштори́ть**

заштори́ть *сов. что, разг.* шторлау, штор белән каплап кую; ~ **о́кна** тәрәзәләрне штор белән каплап кую

заштрихова́ть *сов. что* штрихлау

заштрихо́вывать *несов. см.* **заштрихова́ть**

заштукату́ривать *несов. см.* **заштукату́рить**

заштукату́рить *сов. что* штукатурлау, штукатурлап чыгу

заштукова́ть *сов. что, портн.* җөе беленмәслек итеп тегү (тупчу)

заштуко́вывать *несов. см.* **заштукова́ть**

защебета́|ть *сов.* **1.** чыр-чыр килә башлау, черелди башлау; **пти́цы** ~**ли** кошлар черелди башлады **2.** *перен.* чөкерди (чөкердәшә, тәтелди) башлау; **де́ти** ~**ли** балалар тәтелди башладылар

защекота́ть *сов. кого* кытыклап хәлдән тайдыру, кытыклап интектерү

защёлка *ж* **1.** (*часть замка*) йозак теле **2.** (*щеколда*) келә, капка келәсе

защёлка|ть *сов.* **1.** чутылдый башлау, чут-чут итеп сайрый башлау; **солове́й** ~**л** сандугач чут-чут итеп сайрый башлады **2.** *чем* шартлата башлау; ~**ть па́льцами** бармак шартлата башлау

защёлкивать *несов. см.* **защёлкнуть**

защёлкиваться *несов.* **1.** *см.* **защёлкнуться; 2.** *страд. от* **защёлкивать**

защёлкнуть *сов. что* шалт итеп бикләү, шалт итеп ябып кую

защёлкну|ться *сов.* шалт итеп бикләнү (ябылу); **замо́к** ~**лся** йозак шалт итеп бикләнде

защеми́ть I *см. что* кыстыру, кыстырып кую; ~ **па́лец** бармакны кыстыру

защеми́|ть II *сов. безл.* (*начать щемить*) кыса (чәнчешә) башлау; ~**ло грудь** күкрәгем кыса башлады

защемля́ть *несов. см.* **защеми́ть I**

защипа́ть *сов. кого, разг.* чеметеп бетерү, интектереп бетерү

защипну́ть *сов. что, чего* кыстырып алу, эләктереп алу (*кыскыч белән*); чеметеп алу

защи́пывать *несов. см,* **защипну́ть**

защи́т||а *ж* **1.** *см.* **защити́ть, защити́ться, защища́ть** 2; ~**а ми́ра** тынычлыкны саклау **2.** саклану; **противота́нковая** ~**а** танклар һөжүменнән саклану **3.** арка таянычы, терәк, таяныч; **сын — моя́** ~**а** улым — минем таянычым **4.** *собир. юр.* яклаучылар, яклаучы як; **свиде́тели** ~**ы** яклаучы як шаһитлары **5.** *спорт.* сакчылар; сак; ~**а игра́ла хорошо́** сакчылар яхшы уйнады ♦ **брать (взять) под [свою́]** ~**у** *кого-что* канат астына алу

защити́тельн||ый, -ая, -ое яклау ...ы; ~**ая речь** яклау рече

защити́ть *сов.* **1.** *кого-что* саклау; ~ **от врага́** дошманнан саклау **2.** *что* яклау; ~ **свою́ то́чку зре́ния** үз карашыңны яклау **3.** *кого-что* саклау, ышыклау; ~ **себя́ от со́лнца** үзеңне кояш нурларыннан саклау **4.** *что* яклау; ~ **дипло́м** диплом яклау

защити́ться *сов.* **1.** саклану; ~ **от неприя́теля** дошманнан саклану; ~ **от обвине́ния** гаепләүдән саклану **2.** *разг.* диссертация яклау

защи́тник *м* **1.** саклаучы, яклаучы; **сла́вные** ~**и Ро́дины** Ватанның данлыклы саклаучылары **2.** *юр.* защитник, яклаучы (судта) **3.** *спорт.* сакчы

защи́тница *ж см.* **защи́тник I**

защи́тн||ый, -ая, -ое **1.** саклау ...ы, саклагыч, саклый торган; ~**ое приспособле́ние** саклау әсбабы; ~**ые сооруже́ния** саклагыч корылмалар; ~**ая окра́ска** (җәнварларны) саклый торган **2.** (*о цвете*) соргылт яшел

защища́ть *несов.* **1.** *см.* **защити́ть;** ~ **Оте́чество** Ватанны саклау; ~ **мир** тынычлыкны саклау (яклау); ~ **диссерта́цию** диссертация яклау **2.** *кого-что, юр.* яклау, якларга алыну

защища́ться *несов.* **1.** *см.* **защити́ться; 2.** *страд. от* **защища́ть**

заяви́тель *м офиц.* гариза бирүче

заяви́тельница *ж см.* **заяви́тель**

заяви́|ть *сов.* **1.** *что, о чём и с союзом «что»* белдерү, әйтү, хәбәр итү; ~ **о своём согла́сии** үзеңнең ризалыгың турында белдерү **2.** күрсәтү, таныту; **худо́жник** ~**л себя́ как тала́нтливый пейзажи́ст** рәссам үзен сәләтле пейзажчы буларак танытты

заяви́|ться *сов. разг.* килеп керү, килеп чыгу, кайтып керү; **он** ~**лся в пе́рвом часу́ но́чи** төнге сәгать беренчедә кайтып керде

заявка *ж* гариза, заявка; ~ **на то́пливо** ягулыкка гариза бирү; ~ **на земе́льный уча́сток** җир участогына заявка бирү

заявле́ние *с* **1.** белдерү; ~ **правительства** хөкүмәт белдерүе **2.** гариза; **пода́ть ~ об о́тпуске** ялга чыгу турында гариза бирү

заявля́ть *несов. см.* **заяви́ть**

заявля́ться *несов. см.* **заяви́ться**

зая́длый, -ая, -ое *разг.* хирыс, һәвәс, чәмлс; ~ **игро́к** хирыс уенчы

за́яц *м* **1.** куян; ~**-беля́к** аккуян; ~**-руса́к** үр куяны; **за двумя́ за́йцами погоня́шься, ни одного́ не пойма́ешь** *посл.* ≈ ике көймәнең койрыгын тота алмассың **2.** *разг.* билетсыз пассажир

за́яч||ий, -ья, -ье куян ...ы; куян тиресеннән тегелгән; ~**ья шку́ра** куян тиресе; ~**ья шу́ба** куян тиресеннән тегелгән тун ♦ ~**ья душа́** куркак, куян йөрәк; ~**ья губа́** китек ирен

зва́ни||е *с* **1.** исем; ~ **Геро́я Социалисти́ческого Труда́** Социалистик Хезмәт Герое исеме; **присво́ить почётное** ~ мактаулы исем бирү **2.** звание; ~ **капита́на** капитан званиесе **3.** *уст.* чин, дәрәҗә ♦ **то́лько [одно́] зва́нье** исеме генә бар, җисеме юк; **одно́ ~ осталось** исеме генә калды

зва́н||ый, -ая, -ое **1.** чакырылган; ~**ые го́сти** чакырылган кунаклар **2.** чакырулы; ~**ый обе́д** чакырулы аш мәҗлесе

зва́тельный, -ая, -оу; ~ **паде́ж** *грам.* эндәшү килеше

звать *несов. кого-что* **1.** чакыру; ~ **в теа́тр** театрга чакыру; ~ **на по́мощь** ярдәмгә чакыру **2.** *кем* атау, исемләү ♦ **как тебя́ зову́т?** синең исемең ничек? син кем атлы?; **[и] помина́й как зва́ли** жилләр искән; эзе (әсәре) дә калмаган

зва́ться *несов.* аталу, исемләнү; **Крым зовётся всесою́зной здра́вницей** Кырым бөтенсоюз сәламәтлек саклау урыны дип атала

звезд||а́ *ж в разн. знач.* йолдыз; **Поля́рная ~а́** Тимер казык йолдызы; **пятиконе́чная ~а́** биш канатлы йолдыз; **ма́ршальская ~а́** маршал йолдызы; **морска́я ~а́** *зоол.* дингез йолдызы; ~**а́ пе́рвой величины́** беренче зурлыктагы йолдыз ♦ ~**а́ экра́на** аткалы киноактриса; **звёзд с не́ба не хвата́ет** арты белән киртә жимерми, гадәти кеше; **ве́рить в свою́ ~у́** үз бәхетенә ышану; **роди́ться под счастли́вой ~о́й** бәхетле булып туу

звёздн||ый, -ая, -ое **1.** йолдыз[лар] ...ы; ~**ая систе́ма** йолдызлар системасы **2.** йолдызлы, йолдызлар белән капланган; ~**ая ночь** йолдызлы төн ♦ ~**ый год** *астр.* йолдыз елы; ~**ый дождь** метеорлар яңгыры; ~**ый проби́рг** үзәккә таба йөгерү ярышы; ~**ый час** киеренке вакыт

звездолёт *м* звездолёт (*космоска очу аппараты*)

звездолётчик *м* йолдызга очучы

звездочёт *м уст. см.* **астро́лог**

звен||е́ть *несов.* шалтырау, шылтырау, чылтырау, чыңлау, шыңгырдау; ~**ит колоко́льчик** кыңгырау шалтырый; ~**еть моне́тами** акчалар чылтырату ♦ **в уша́х (в у́хе, в голове́)** ~**ит** колагы шаулый (шаулап тора), колагы чыңлап тора

звено́ с **1.** (*часть цепи*) буын, божра **2.** *перен.* буын, бүлек; **основно́е ~ произво́дства** производствоның төп буыны **3.** звено; **пионе́рское ~** пионерлар звеносы **4.** (*в деревянном срубе*) ниргә

звеньев||о́й -ая, -о́е **1.** звено[лар] ...ы; ~**ая систе́ма** звено системасы **3.** *в знач. сущ.* ~**о́й** *м*, ~**а́я** *ж* звено башлыгы; **колхо́зный ~о́й** колхоз звено башлыгы

зверёнок, зверёныш *м разг.* җанлек баласы, ерткыч хайван баласы

звере́ть *несов.* ерткычлану, кансызлану

зверине́ц *м уст.* зверинец (*ерткыч җанварларны, җәнлекләрне халыкка күрсәтү өчен асрау урыны*)

звери́н||ый, -ая, -ое **1.** җәнлек ...ы; ерткыч хайван ...ы; ~**ые следы́** җәнлек эзләре **2.** ерткычларча ..., ерткычлык ...ы; ~**ая не́нависть** ерткычларча нәфрәт **3.** (*жестокий, свирепый*) рәхимсез, каты ♦ ~**ый стиль (орна́мент)** җәнлек сынлы стиль (*борынгы сынлы сәнгатьтә ерткыч җәнлекләр рәсеменнән файдаланган стиль*)

зверобо́й I *м* (*охотник*) җәнлек аулаучы, аучы

зверобо́й II *м* **1.** *бот.* сары мәтрүшкә **2.** (*водка*) зверобой

зверобо́йный, -ая, -ое җәнлек аулау ...ы; ерткыч хайваннар аулау ...ы; ~ **про́мысел** җәнлек аулау кәсебе

зверово́д *м* җәнлек асрау белгече, җәнлек асраучы

зверово́дство *с* җәнлек үрчетү (асрау), җәнлек асраучылык

зверово́дческий, -ая, -ое җәнлек үрчетү ...ы, җәнлек асрау ...ы; ~ **совхо́з** җәнлек үрчетү совхозы

звероло́в *м* җәнлек аулаучы (*җәнлекләрне тере килеш тотучы*)

звероло́вн||ый, -ая, -ое җәнлек аулау ...ы; ~**ый про́мысел** җәнлек аулау кәсебе; ~**ые сна́сти** җәнлек аулау кораллары

звероло́вство *с* җәнлек аулау кәсебе

звероподо́бный, -ая, -ое ерткыч хайванга охшаган (*явыз кеше турында*)

зве́рск||ий, -ая, -ое **1.** (*жестокий*) ерткычларча ...; аяусыз **2.** *разг.* бик көчле, бик яхшы, бик зур; **у него́ ~ий аппети́т** аның аппетиты бик яхшы

зве́рство *с* ерткычлык, вәхшилек, кансызлык, рәхимсезлек

зве́рствовать *несов.* ерткычлану, ерткычларча эш итү, кансызлану, явызлану

зве́р||ь *м* **1.** ерткыч, ерткыч хайван; җәнлек **2.** кансыз (явыз, ерткыч) кеше ♦ **смотре́ть ~ем** ачулы караш; **буди́ть** *в ком* ~**я** *кемнең дә булса* жен ачуын чыгару

зверьё *с собир.* ерткыч хайваннар (җәнлекләр)

зверю́га *м, ж разг. см.* **зверь**

звон *м* чың, шалтырау, шалтырау тавышы, чылтырау, чыңлау; шыңгырдау; ~ **ко́локола** кыңгырау чыңы ♦ ~ **в уша́х** колак шаулый; **пошёл ~ по всему́ го́роду** *прост.* хәбәр бөтон шәһәргә таралды

звона́рь *м* чиркәүдә чаң кагучы

звони́||ть *несов.* **1.** шалтырату, кагу; ~**ть в ко́локол** чаң кагу **2.** шалтырау, чалтырау; **телефо́н ~т** телефон шалтырый **3.** *кому* шалтырату; **я ~л сестре́** мин сеңелемә шалтыраттым ♦ ~**ть во все колокола́** *прост.* бөтен дөньяга тарату, бөтен дөньяга белдерү

звоно́к||ий, -ая, -ое яңгыравыклы, яңгыравык; ~**ие голоса́** яңгыравык тавышлар ♦ ~**ая моне́та** металл акча; ~**ая фра́за** буш сүзләр, куплы сүзләр; ~**ие согла́сные** *лингв.* яңгырау тартыклар

звонкоголо́с||ый, -ая, -ое яңгыравык тавышлы; ~**ая детвора́** яңгыравык тавышлы балалар

звоннца *ж* чаң манарасы; ~ **Ива́на Вели́кого** Иван Великийның чаң манарасы

звон||о́к *м* **1.** звонок; **дверно́й ~о́к** ишек звоногы; **электри́ческий ~о́к** электр звоногы **2.** шалтырау (кыңгырау) тавышы, звонок; **разда́лся ~о́к** кыңгырау тавышы яңгырады; **заня́тия начина́ются по ~ку́** дәресләр звонок белән башлана ♦ **от ~ка́ до ~ка́** башыннан азагына кадәр

звук *м* **1.** тавыш; **ско́рость ~а** тавыш тизлеге; ~ **шаго́в** аяк тавышы; **музыка́льный ~** музыка тавышы **2.** *лингв.* аваз; **гла́сные ~и** сузык аваз ♦ **без ~а согласи́ться** бер сүзсез риза булу; **ни ~а** 1) тып-тын; **в лесу́ ни ~а** урман тып-тын; 2) тынын да чыгармый; **зову́ его, а он ни ~а** мин аны чакырам, а ул тынын да чыгармый; **пусто́й ~** мәгънәсез сүз, буш сүз

звуко- *рус телендәге кушма сүзләрнең «тавыш», «аваз» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **звукоизмере́ния** тавыш үлчәү

звуков||о́й, -а́я, -о́е **1.** *физ.* тавыш ...ы; ~**ы́е во́лны** тавыш дулкыннары **2.** тавышлы; ~**о́е кино́** тавышлы кино

звукозапи́сывающ||ий, -ая, -ее тавыш язу ...ы, тавыш яза торган; ~**ая аппарату́ра** тавыш язу аппаратлары

звукоза́пись *ж* тавыш язу (*сөйләмне, музыканы плёнкага, пластинкага язу*)

звуконепроница́емый, -ая, -ое тавыш үткәрми торган

звукоопера́тор *м* тавыш операторы

звукоподража́ние *с* **1.** (*воспроизведение звучания*) аваз иярteме (*мәс. кыйгак-кыйгак, мияу-мияу*) **2.** *лингв.* тавышка охшатып ясалган сүз (*мәс. кәккук, кыштырдау*)

звукоподража́тельн||ый, -ая, -ое тавышка охшатып ясалган; аваз иярteме ...ы, аваз ...ы; ~**ое сло́во** аваз иярteме

звукопрово́дность *ж* тавыш үткәрүчәнлек

звукопроводя́щ||ий, -ая, -ее тавыш үткәрә торган; ~**ая среда́** тавыш үткәрә торган мохит

звукопроница́емость *ж* тавыш үткәрүчәнлек

звукопроница́емый, -ая, -ое тавыш үткәрә торган

звукоря́д *м муз.* авазлар рәте

звукоула́вливатель *м* тавыштоткыч

звуча́ние *с* **1.** *см.* **звуча́ть 1**; **2.** (*звуки*) яңгырау, яңгыраш ♦ **широ́кое общественное ~** киң иҗтимагый яңгыраш

звуч||а́ть *несов.* **1.** яңгырау, яңгырап тору, ишетелү; **вдали́ ~ а́т голоса́** ерактан тавышлар ишетелә **2.** сизелеп (беленеп) тору; **в его́ го́лосе ~ а́ла ра́дость** аның тавышында шатлык сизелеп тора иде ♦ **~ а́ть в уша́х (в па́мяти, в се́рдце)** йөрәктә нык саклану

зву́чный, -ая, -ое яңгыравыклы, яңгыравык; көчле тавышлы; **~ го́лос** яңгыравыклы тавыш; **~ ко́локол** яңгыравыклы чаң

звя́кать *несов. чем и без доп.* шалтырату; шалтырау, чылтырау; **~ ключа́ми** ачкычлар шалтырату

звя́кнуть *сов. однокр. чем и без доп.* шалтыратып (чылтыратып) кую; шалтырап (чылтырап) кую

зги́: ни ~ не ви́дно дөм караңгы, күзгә төртсәң күренми, бернәрсә дә күренми

зда́ни||е *с* бина, йорт; **обще́ственные ~я** җәмәгать биналары

здесь *нареч.* **1.** (*в этом месте*) монда, биредә; **я живу́ ~ давно́** мин монда күптән торам **2.** (*в этот момент*) шунда; шул чакта; **~ он ка́шлянул** шул чакта ул йөткереп куйды **3.** (*в этом случае*) монда, бу очракта; **~ я ничем не могу́ помо́чь** бу очракта мин берни белән дә ярдәм итә алмыйм

здо́ш||ний, -яя, -ее мондагы, монда..., биредәге; **~не жи́тели** монда яшәүчеләр

здоро́ваться *несов.* исәнләшү, күрешү; **~ за́ руку** кул бирешеп исәнләшү

здорове́нн||ый, -ая, -ое *прост.* **1.** таза, зур гәүдәле; **~ый па́рень** таза егет **2.** зур, бик зур, таза, көчле; **~ая дубина́** бик зур күсәк

здорове́ть *несов.* тазара төшү, ныгый төшү, көрәя төшү

здо́рово *нареч. прост.* **1.** (*очень сильно*) бик нык, бик каты; **ему́ ~ попа́ло** аңа бик нык эләкте **2.** (*искусно*) бик оста, бик шәп, бик яхшы; **~ сде́лано** бик оста эшләнгән

здоро́во *межд. прост.* исәнме, саумы, нихәл; **~ живёшь (живёте)**! исәнме[сез]!, сәлам сезгә! ♦ **[за] ~ живёшь** һичбер сәбәпсез, бер дә юкка, тикътомалга; **пострада́л за ~ живёшь** бер дә юкка зыян күрдем

здоро́в||ый, -ая, -ое **1.** исән, сау, сәламәт, таза; **~ый ребёнок** таза бала; **~ый вид** сәламәт кыяфәт **2.** файдалы, саф, шифалы; **~ая пи́ща** файдалы азык **3.** *перен.* дөрес, гадел, аек; **~ая кри́тика** гадел тәнкыйть **4.** *прост.* таза, көчле; **~ый па́рень** таза егет **5.** *прост.* каты, көчле; **~ый моро́з** каты суык **6.** *прост.* бик оста; **здоро́в пляса́ть!** биергә бик оста! ♦ **бу́дь[те] здоро́в[ы]!** исән бул[ыгыз]!; сау бул[ыгыз]!; хуш[ыгыз]! **в ~ом те́ле ~ый дух** *погов.* тәне сауның җаны сау

здоро́вь||е *с* саулык, сәламәтлек, исәнлек-саулык, тазалык; **охра́на ~я** сәламәтлек саклау ♦ **на [до́брое] ~!** исәнлеккә-саулыкка; **[за] ва́ше (твоё) ~!** сезнең (синең) исәнлеккә!

здоровя́к *м разг.* тап-таза, бик таза, имәндәй таза кеше

здра́ви||е *с уст. см.* **здоро́вье** ♦ **во ~е** исәнлеккә-саулыкка; **~я жела́ю (жела́ем)!** *воен.* исәнлек телим (телибез)!; **нача́ть за ~е, а ко́нчить за упоко́й** мактау белән башлап, яманлап бетерү; күнелле итеп башлап, күңелсез бетерү

здра́виц||а *ж* исәнлек тосты; **провозгласи́ть ~у за наро́д** халык исәнлегенә тост тәкъдим итү

здра́вница *ж* дәвалану һәм ял итү урыны

здравомы́слие *с* сау (сәламәт) фикерлелек, дөрес уйлау

здравомы́слящий, -ая, -ее аек фикерле, дөрес уйлаучы, акыллы

здравоохране́ни||е *с* сәламәтлекне саклау; **министе́рство ~я** сәламәтлек саклау министрлыгы

здравоохрани́тельн||ый, -ая, -ое сәламәтлек саклау ...ы; **~ое учрежде́ние** сәламәтлек саклау учреждениесе

здра́вств||овать *несов.* имин яшәү, бәла-казасыз яшәү, хәвеф-хәтәрсез яшәү, сау-сәламәт яшәү; **он и доны́не ~ует** ул әле дә сау-сәламәт яшәп ята ♦ **да ~ует!** яшәсен!; **~уйте!** исәнмесез!

здра́в||ый, -ая, -ое төпле, дөрес, акыллы; **~ый ум** төпле акыл; **~ая мысль** акыллы фикер ♦ **здрав и невреди́м** исән-сау; в **~ом уме́ и твёрдой па́мяти** аек фикерле һәм сәламәт зиһенле

зе́бра *ж* зебра

зев *м* **1.** йоткылык, тамак **2.** *уст.* (*пасть*) авыз; **~ льва** арыслан авызы

зева́ка *м, ж разг.* авыз ачып карап торучы, ачыгавыз

зева́ть *несов.* **1.** иснәү; **~ спроса́нья** йокыдан торып-тормас иснәү **2.** *разг.* авыз ачып (күтәреп) карап тору; **~ по сторона́м** авыз ачып як-якка карап тору; **3.** *разг.* (*быть невнимательным, пропускать*) авыз ачып калу, күрми калу

зевну́ть *сов. однокр.* **1.** иснәп кую (авыз ачып) **2.** *что и без доп., разг.* күрми калу (калып ялгышу) (*мәс. шахмат уенында*)

зево́та *ж* иснәү; иснәтү; **~ напа́ла** иснәтә башлады

зелене́||ть *несов.* **1.** яшелләнү, күгәрү, тутыгу; **бро́нза ~ет** бронза яшелләнә **2.** (*быть в зелени*) яшелләнү, яшел үлән белән каплану; **поля́ ~ют** кырлар яшелләнә **3.** (*виднеться — о чём-л. зелёном*) яшел булып күренү, яшелләнеп күренеп тору; **вдали́ ~ет лес** ераста урман яшелләнеп күренә

зелени́ть *несов. что* яшелгә буяу, яшел төскә буяу

зелёнка *ж разг,* яшел су (*дару*)

зелён||ый, -ая, -ое **1.** яшел; **~ая трава́** яшел үлән; **~ый лес** яшел урман **2.** пешмәгән, өлгермәгән, яшел; **~ое я́блоко** өлгермәгән алма **3.** *перен.* яшь, тәҗрибәсез; **~ый юне́ц** тәҗрибәсез үсмер; **мо́лодо-зе́лено** бик яшь, тәҗрибәсез ♦ **до ~ого зми́я [допи́ться]** лаякый булганчы, эчеп акылын югалту; **~ая тоска́** тирән сагыш; **~ая у́лица** яшел урам; юл ачык; **~ые щи** кузгалактан (кычытканнан) пешерелгән аш; **~ый горо́шек** яшел борчак, баллы борчак; **~ый конве́йер** яшел конвейер (*терлекләрне яшел үлән белән өзлексез тәэмин итү*); **~ый чай** күк чәй

зе́лень *ж* **1.** (*зелёный цвет*) яшеллек, яшел төс **2.** (*растительность*) үлән, яшел үлән, яшеллек **3.** *собир.* (*овощи, травы*) яшелчә

зелен́я *только мн.* яшел ужым

зе́лье *с* **1.** (*ядовитый напиток*) эчемлек, агулы эчемлек; (*настой на травах*) дару, дару эчемлеге, төнәтмә **2.** *уст.* (*лекарство*) дару

земе́льн||ый, -ая, -ое җир ...ы; **~ая рефо́рма** җир реформасы; **~ый уча́сток** җир участогы

земле- *рус телендәге кушма сүзләрнең «җир» дигән мәгънәдәге беренче кисәге, мәс.* **землевёд** җир белгече

землеве́дение *с* җирне өйрәнү, җир белеме (*җир йөзенең гомуми физик-географик закончалыкларын өйрәнә торган фән, физик географиянең бер тармагы*); **косми́ческое ~** космостан торып җирне өйрәнү

землевладе́лец *м* җир хуҗасы (биләүче); **кру́пный ~** эре җир биләүче

землевладе́льческ||ий, -ая, -ое җир биләүче ...ы; **~ие дохо́ды** җир биләүче керемнәре

землевладе́ние *с* **1.** (*владение землёй*) җир биләү **2.** *офиц.* (*земельный участок*) (*берәр кеше милкендә булган*) җир участогы

земледе́лец *м* игенче, крестьян

земледе́ли||е *с* игенчелек; **высо́кая культу́ра ~я** югары культуралы игенчелек

землеко́п *м* җир казучы (*эшче*)

землеме́р *м уст.* землемер, җир бүлеп бирүче

землеме́рн||ый, -ая, -ое җир үлчәү ...ы; **~ые инструме́нты** җир үлчәү инструментлары

землепа́шество *с см.* **земледе́лие**; **примити́вное ~** артта калган игенчелек

землепа́шец *м см.* **земледе́лец**

землепо́льзование *с* җирдән файдалану, җирдән файдалану тәртибе; **рефо́рма ~ия** җирдән файдалану реформасы

землепрохо́д||ец *м* илгизәр, сәяхәтче; **ру́сские ~цы** рус сәяхәтчеләре

землеро́йка *ж* җир тычканы

землеро́йн||ый, -ая, -ое җир казу ...ы; җир казый торган; **~ая маши́на** җир казу машинасы

землесо́с *м* комсуыргыч, комказыгыч (*су төбеннән яки яр буеннан су белән бергә ком, балчык суырып күчерә торган машина*)

землетрясе́ние *с* җир тетрәү (селкенү)

землеустрои́тель *м* җир төзүче

землеустрои́тельн||ый, -ая, -ое җир төзү ...ы; **~ые рабо́ты** җир төзү эшләре

ЗЕМ-ЗЛО

землеустро́йство *с* жир төзү, жир төзүчелек (*җирдән файдалануны тәртипкә салу чаралары, системасы*)

землечерпа́лка *ж* комсоскыч, балчыксоскыч (*су төбен казый торган машина*)

землечерпа́тельн||ый, -ая, -ое комсоскыч ...ы, комказыгыч ...ы; **~ая маши́на** комсоскыч машинасы

земли́стый, -ая, -ое **1.** балчыклы, туфраклы; **~ песо́к** балчыклы ком **2.** (*о цвете лица*) аксыл соры, жир төсле (*авыру кеше турында*)

земл||я́ *ж* **1.** (*с прописной*) Жир, Жир шары; **Земля́ враща́ется вокру́г Со́лнца** Жир Кояш тирәсендә әйләнә **2.** жир, кары жир; **моряки́ увидели́ на горизо́нте зе́млю** диңгезчеләр офыкта кары жир күрделәр **3.** туфрак, жир, балчык; **обрабо́тка ~и́** жир эшкәртү **4.** *высок.* ил, жир; **Татарста́нская ~я** Татарстан иле **5.** (*территория*) жир; **цели́нные зе́мли** чирәм җирләр ♦ **~и́ под собо́й не слу́шать (не чу́ять)** күккә ашкандай булу (*бик нык шатлану*); **за три́девять земе́ль** җәһәннәм астына; **~я́ гори́т под нога́ми** кая керергә тишек тапмый; **~я́ обетова́нная** бәхет иле; **[как, то́чно] сквозь зе́млю провали́лся** әллә җир упты инде, әллә кая юкка чыкты; **сло́вно из ~и́ (из-под ~и́) вы́расти** күктән төшкәндәй булу

земля́к *м* якташ

земля́не *мн.* Жир кешеләре, Жирдә яшәүчеләр

земля́ника *ж* каен җиләге (*үсемлеге һәм җиләге*)

земля́нин *м* Жир кешесе, Жирдә яшәүче (*кеше*)

земля́нка *ж* жир йорт, землянка (*җир казып ясалган торак, абзар*)

землян||о́й, -а́я, -о́е **1.** жир казу ...ы; жир ...ы; **~ы́е рабо́ты** жир казу эшләре **2.** туфрак ..., туфрактан ясалган; балчык ...; **~а́я плоти́на** туфрак буа; **~а́я на́сыпь** туфрак вал

земля́чество *с* землячество (*якташ студентлар оешмасы*)

земля́чка *ж* якташ хатын (кыз)

земново́дн||ый, -ая, -ое **1.** жир-су ...ы; **~ые живо́тные** жир-су хайваннары; **~ые расте́ния** жир-су үсемлекләре **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. зоол.* жир-су хайваннары

земно́й, -а́я, -о́е **1.** жир ...ы; **~ шар** Жир шары **2.** *перен.* (*обыденный*) жирдәге, жир йөзендәге ♦ **~ покло́н** бил бөгеп сәламләү

зе́мск||ий, -ая, -ое **1.** *ист.* земский; **Зе́мский собо́р** Земский собор **2.** земство ...ы; земский; земство карамагындагы; **~ий врач** земство табибы; **~ий нача́льник** земский начальник; **~ая шко́ла** земство карамагындагы мәктәп

земснаря́д *м* комсуыргыч, балчыксуыргыч, земснаряд

зе́мство *с* земство (**1.** *революциягә кадәр Россиядә дворяннар һәм буржуазия кулындагы җирле идарә системасы* **2.** *шул идарә итү системасының губерна һәм өяз куләмендәге аерым учреждениесе*)

зе́мщина *ж ист.* земщина (*Иван Грозный чорында Рус Дәүләтенең боярлар тарафыннан идарә ителгән өлеше*)

зени́т *м* **1.** *астр.* зенит **2.** *перен. высок.* иң югары ноктa; **в ~е сла́вы** даннның иң югары ноктасында

зени́тка *ж* разг. зенит тубы

зени́тн||ый, -ая, -ое **1.** *астр.* зенит ...ы; **~ое расстоя́ние** зенит ераклыгы **2.** *воен.* зенит ...ы, зенит тубы ...ы; **~ая артилле́рия** зенит артиллериясе

зени́тчик *м* зенитчы (*зенит тубыннан атучы артиллерист*)

зени́тчица *ж* зенитчы хатын (кыз)

зени́ц||а *ж уст.* күз карасы, күз бәбәге, күз ♦ **бе́речь (храни́ть) как ~у о́ка** күз карасы кебек саклау

зе́ркало *с* **1.** көзге; **сте́нное ~** стена көзгесе **2.** *перен.* өслек, көзге; **~ реки́** елга суының өслеге

зерка́льн||ый, -ая, -ое **1.** көзге ...ы; **~ое произво́дство** көзге производствосы **2.** көзгеле; **~ый шкаф** көзгеле шкаф **3.** *перен.* көзге кебек шома, ялтырап тора торган: **~ый парке́т** ялтырап тора торган паркет ♦ **~ое стекло́** шомартылган калын пыяла; **~ый карп** таңкәсез карп

зерни́ст||ый, -ая, -ое бөртекле, ярмалы; **~ый известня́к** бөртекле известьташ ♦ **~ая икра́** кара уылдык

зерно́ *с* **1.** (*семя злаков*) ашлык бөртеге, орлык, бөртек (*бер бөртек орлык*) **2.** *собир.* ашлык, иген, бөртекле ашлык; **това́рное ~** товарлыклы ашлык; **мешо́к с ~м** бер капчык ашлык **3.** бөртек; **жемчу́жное ~** энҗе бөртеге **4.** *перен. книжн.* асыл, яралгы, башлангыч; **~ и́стины** хакыйкать яралгысы

зернов||о́й, -а́я, -о́е **1.** бөртекле, ашлык ...ы; **~о́е хозя́йство** бөртекле ашлык хуҗалыгы; **~ы́е зла́ки** бөртекле ашлыклар **2.** *в знач. сущ.* **~ы́е** *мн.* бөртеклеләр, бөртекле ашлык; **убо́рка ~ы́х** бөртекле ашлыкны урып-җыю

зернодроби́лка *ж* орлыкваклагыч

зернодроби́льн||ый, -ая, -ое орлык ваклый торган, орлык ваклау ...ы; **~ая маши́на** орлык ваклау машинасы

зерноочисти́тельн||ый, -ая, -ое орлык чистарту ...ы, ашлык тазарту ...ы; **~ая маши́на** ашлык тазарту машинасы

зерносуши́лка *ж* ашлыккиптергеч

зерноулови́тель *м* бөртектоткыч (*комбайнда*)

зернохрани́лище *с* ашлык саклау урыны; ашлык амбары

зерноя́дный, -ая, -ое *зоол.* орлык ашаучы, орлык белән туенучы (*кошлар һәм хайваннар*)

зефи́р *м* (*род пастилы*) зефир

зигза́г *м* зигзаг

зигзагообра́зн||ый, -ая, -ое зигзагсыман; **~ое движе́ние** зигзагсыман хәрәкәт

зи́ждиться *несов. на чём, книжн.* нигезләнү, корылу, таяну; **его мне́ние зи́ждется на до́лгом о́пыте и глубо́ких зна́ниях** аның фикере бай тәҗрибәгә һәм тирән белемгә нигезләнгән

зима́ *ж* кыш; **суро́вая ~** суык кыш ♦ **зи́му и ле́то** һәрвакыт, кышын-җәен, ел әйләнәсендә

зи́мн||ий, -яя, -ее кышкы; **~ий ве́чер** кышкы кич; **~яя оде́жда** кышкы кием

зимова́ть *несов.* кышлау (*бер урында кышны уткару*) ♦ **я тебе́ покажу́, где ра́ки зиму́ют!** мин сиңа күрмәгәненне күрсәтермен!, мин сиңа җиде бабаңны танытырмын!

зимо́вк||а *ж* **1.** *см.* **зимова́ть; ~а скота́** терлекләрнең кышлавы; **расположи́ться на ~у** кышлау урынына урнашу; **подгото́виться к ~е** кышка хәзерләнү **2.** (*место*) кышлау, кышлау урыны

зимо́вщик *м* кышлаучы

зимо́вье *с* кышлау, кышлау урыны

зимо́й *нареч.* кышын, кыш көне, кыш көнендә; **~ и ле́том одни́м цве́том** *погов.* кышын-җәен бер төсле

зимосто́йкий, -ая, -ое (*о растениях*) суыкка чыдам; **~ сорт я́блонь** алмагачларның суыкка чыдам сорты

зипу́н *м уст.* чикмән, әрмәк

зия́ние I *с лингв.* ике сузыкның рәттән килүе

зия́ние II *с см.* **зия́ть**

зия́ть *несов. книжн.* ярылып яту, ачылып яту, убылып тору (*мәс. чокыр, тишек турында*)

зла́ки *мн. бот.* кыяклылар, кыяклы ашлык; **луговы́е ~** болын кыяклылары

зла́ков||ый, -ая, -ое кыяклы; **~ые расте́ния** кыяклы үсемлекләр

зла́то *с уст.* алтын

злато́й, -а́я, -о́е *уст. см.* **золото́й**

златоку́др||ый, -ая, -ое *уст.* алтынсыман бөдрә чәчле; **~ая де́вушка** алтынсыман бөдрә чәчле кыз, алтынчәч

злато́уст *м уст. и ирон.* тасма тел, тел бистәсе

зла́чн||ый, -ая, -ое: **~ое ме́сто** *шутл.* кәеф-сафа кору урыны, бозыклык оясы, типтерү урыны

злить *несов. кого-что* ачуын китерү, ачуын кабарту, котырту; **~ соба́ку** этне котырту

зли́т||ься *несов.* **1.** ачу килү, ачулану, зәһәрләнү, усаллану **2.** *перен.* котырыну, дулау; **вью́га ~ся** буран котырына

зло *с* **1.** явызлык, усаллык, яманлык; **причини́ть ~** *кому-л. кемгә булса да* усаллык эшләү **2.** бәла, фетнә, афәт, бәхетсезлек; **из двух зол выбира́ть ме́ньшее** ике бәланең кечерәген сайлау **3.** (*досада*) ачу, ачу тойгысы, гарьлек; **~ берёт** ачуым килә, **сорва́ть ~** *на ком-л. кемнән булса да* ачуны алу ♦ **употреби́ть во ~** явызлык максаты белән файдалану

зло́б||а *ж* ачу, усаллык, явызлык, кинә; **по ~е** ачудан ♦ **на ~у дня** көн үзәгендә тора торган (*мәсьәлә*), ин әһәмиятле (*мәсьәлә*), көнүзәк (*мәсьәлә*)

зло́бный, -ая, -ое усал, ачулы, явыз; **~ взгляд** усал караш; **~ враг** явыз дошман

злободне́вный, -ая, -ое бик мөһим, бик әһәмиятле, актуаль, көнүзәк ..., көн үзәгендәге; **~ вопро́с** бик әһәмиятле мәсьәлә

зло́бствовать *несов.* явызлану, усаллану, явызлык уты белән яну

злове́щ||ий, -ая, -ее куркыныч, дәһшәтле, шомлы; **~ая тишина́** шомлы тынлык

злово́ние *с* яман ис, сасы ис

злово́нн||ый, -ая, -ое сасы, сасы исле, яман исле; ~ **ое боло́то** сасы сазлык

зловре́дн||ый, -ая, -ое үтә зарарлы; усал ниятле, мәкерле, яман (явыз) уйлы; ~ **ый челове́к** усал ниятле кеше; ~ **ые мы́сли** үтә мәкерле уйлар

злоде́й *м* явыз, явыз кеше, явыз җан

злоде́йка *ж* явыз хатын (кыз)

злоде́йск||ий, -ая, -ое явыз[лар] ...ы; явызларча ...; ~ **ое уби́йство** явызларча үтерү

злоде́йство *с* явызлык, усаллык; **соверши́ть** ~ явызлык кылу

злоде́йствовать *несов.* явызлык эшләү, усаллык эшләү

злодея́ние *с см.* **злоде́йство; чудовищное** ~ коточкыч явызлык

злой, -а́я, -о́е **1.** усал, ачулы; ~ **челове́к** усал кеше; ~ **взгляд** усал караш; **он зол на всех** ул бөтенесенә дә ачулы **2.** явыз, яман; ~ **у́мысел** яман уй **3.** *разг.* ачы; ~ **пе́рец** ачы борыч **4.** *перен.* ачы, көчле, чеметтереп ала торган; **зла́я карикату́ра** чеметтереп ала торган карикатура **5.** ачы, каты; ~ **моро́з** каты суык ◆ ~ **дух** явыз рух; ~ **на рабо́ту (до рабо́ты)** женләнеп эшли торган, баш күтәрмичә эшли торган; **злы́е языки́** ачы телле кешеләр, гайбәтчеләр

злока́чественн||ый, -ая, -ое яман; яман сыйфатлы; ~ **ая о́пухоль** яман шеш

злоключе́ние *с* бәла, каза, бәхетсезлек, афәтле мәҗара

злонаме́ренный, -ая, -ое *книжн.* усал ниятле, явыз ният белән эшләнгән; ~ **посту́пок** явыз ният белән эшләнгән эш

злонра́вие *с уст.* усаллык, әхлаксызлык

злонра́вный, -ая, -ое *уст.* усал, әхлаксыз, яман холыклы

злопа́мятность *ж см.* **злопа́мятство**

злопа́мятный, -ая, -ое кара эчле, эчкерле, ачу саклаучан, кинә тотучан; ~ **челове́к** ачу саклаучан кеше

злопа́мятство *с* кара эчлелек, эчкерлелек, ачу саклау, кинә тоту; **отлича́ться** ~м кинә куу

злополу́чный, -ая, -ое бәлалс, бәхетсез, уңышсыз; ~ **день** бәлале көн

злопыха́тель *м* явызлык уты белән янучы, дошманлык уты белән янучы

злопыха́тельство *с* дошманлык (явызлык) уты белән яну

злопыха́тельствовать *несов.* явызлык (дошманлык) күрсәтү

злора́дн||ый, -ая, -ое кеше кайгысына сөенү ...ы; яманга сөенү ...ы, кеше бәхетсезлегенә шатлану ...ы; ~ **ое чу́вство** кеше кайгысына сөенү хисе; ~ **ый смех** яманга сөенеп көлү

злора́дство *с* кеше кайгысына сөенү, яманга сөенү ...ы, кеше бәхетсезлегенә шатлану

злора́дствовать *несов.* кеше кайгысына шатлану (сөенү), кеше бәхетсезлегенә шатлану

злосло́вие *с* гайбәт

злосло́вить *несов.* яманлау, яман телләнү, яманлап сөйләү, гайбәтен сату

зло́стн||ый, -ая, -ое **1.** ачулы, явыз, усал; ~ **ое наме́рение** явыз ният **2.** явыз, төзәлмәс; ~ **ый престу́пник** төзәлмәс җинаятче

злость *ж* явызлык, усаллык, ачу; **говори́ть со** ~ю усаллык белән сөйләү; ~ **берёт** ачу килә

злосча́стн||ый, -ая, -ое *уст.* бәхетсез, начар нәтиҗәле; ~ **ая любо́вь** бәхетсез мәхәббәт

злоумы́шленник *м уст.* җинаятче, явыз уйлы җинаятче

злоумы́шленница *ж уст.* җинаятче хатын (кыз)

злоумы́шленный, -ая, *-ое уст.* яман уй белән эшләнгән, явыз ният белән эшләнгән

злоупотреби́ть *сов, чем* **1.** кирәгеннән артык мавыгу, чиктән тыш күп куллану; ~ **цита́тами** өземтәләрне кирәгеннән артык куллану; ~ **вре́менем слу́шателей** тыңлаучыларның вакыты белән исәпләшмәү; ~ **вла́стью** хакимияттән законсыз файдалану **2.** ...га хыянәт итү; ~ **дове́рием** ышанычка хыянәт итү

злоупотребле́ни||е *с* **1.** *см.* **злоупотреби́ть;** ~ **е вре́менем** вакыт белән исәпләшмәү; ~ **е вла́стью** хакимияттән законсыз файдалану **2.** *обычно мн.* ~ **я** гаеп эшләр; законсызлыклар; җинаять; **вскрыть** ~ **я** гаеп эшләрен ачу

злоупотребля́ть *несов. см.* **злоупотреби́ть**

злоязы́чие *с уст.* гайбәт, ачы (усал) теллелек

злоязы́чный, -ая, -ое *уст.* гайбәтче ..., ачы (усал) телле

злю́ка *м, ж разг.* ачулы (усал) кеше

злю́чка *м, ж см.* **злю́ка**

злю́щий, -ая, -ее *разг.* бик усал, үтә явыз

змеевико́н||ый, -ая, -ое елансыман, елан төсле; уралмалы; ~ **ая тру́бка** уралмалы көпшә; ~ **ый брасле́т** елансыман беләзек

змеевик *м* **1.** (*изогнутая труба*) уралма көпшә, борма көпшә, змеевик (*сыекчаны куу эшендә кулланыла*) **2.** *бот.* бүре тырнагы (күзе)

змеело́в *м* еланнар тотучы (*фәнни максат белән*)

змеи́н||ый, -ая, -ое **1.** елан ...ы; ~ **ая ко́жа** елан кабыгы **2.** *перен.* зәһәр, зәһәрле, мәкерле, агулы; ~ **ая улы́бка** мәкерле елмаю ◆ ~ **ая му́дрость** елан акылы, зирәк акыл

змейться *несов.* борыла-борыла бару (агу, сузылу)

змей *м* **1.** *уст. см.* **змея́**; **2.** *миф.* аждаһа **3.** (*игрушка*) очыргыч, очырткыч (*балалар уенчыгы*)

зме||я́ *ж* елан; **очко́вая** ~ **я́** күзлекле елан; **гремя́чая** ~ **я́** гөберле елан; **ядови́тая** ~ **я́** агулы елан ◆ ~ **я́ подколо́дная** зәһәр елан, кара елан (*явыз кеше турында*); ~ **ю́ на груди́ отогре́ть (пригре́ть)** күенда зәһәр елан асрау

зми||й *м уст. см.* **змей** 1, 2 ◆ **до зелёного** ~ **я [допи́ться]** лаякыл булганчы [эчү]

знак *м* **1.** билге; ~ **ра́венства** *мат.* тигезлек билгесе; **вопроси́тельный** ~ сорау билгесе; ~ **и препина́ния** тыныш билгеләре **2.** тамга, келәймә; билге; **фабри́чный** ~ фабрика келәймәсе; **Госуда́рственный** ~ **ка́чества** Дәүләт сыйфат билгесе **3.** ым, ишарә; **пода́ть** ~ ым кагу; **подава́ть** ~ **руко́й** кул белән ишарә ясау ◆ **в** ~ *чего берәр нәрсә* йөзеннән; **в** ~ **проте́ста** протест йөзеннән; **водяны́е** ~ **и** су билгеләре (*яхшы сыйфатлы кәгазьләрдә яктыга карагач кына күренә торган билге*); ~ **и отли́чия** батырлык билгеләре (*орденнар һәм медальләр*); ~ **и разли́чия** чин билгеләре (*значоклар, погоннар, петлицалар*); ~ **почто́вой опла́ты** почта түләве билгесе; **под** ~**ом** *чего* билгесе астында; **под** ~**ом борьбы́** көрәш билгесе астында

знако́мить *несов. кого-что, с кем-чем* таныштыру; ~ **с но́вым сотру́дником** яңа хезмәткәр белән таныштыру

знако́миться *несов. с кем-чем* танышу; ~ **с но́выми това́рищами** яңа иптәшләр белән танышу; ~ **с обстано́вкой** тирә-юнь белән танышу

знако́мств||о *с* **1.** (*круг знакомых*) танышлык; танышлар, таныш-белешләр; **завяза́ть** ~**о** танышлык булдыру; **у него́ больши́е** ~**а** аның танышлары күп; **порва́ть** ~**о** танышлыкны өзү **2.** таныш булу, белү; ~**о с литерату́рой** әдәбият белән таныш булу ◆ **по** ~**у** танышлык (буенча) белән; **ша́почное** ~**о** болай гына танышлык, якын булмаган танышлык

знако́м||ый, -ая, -ое **1.** таныш, белү; ~ **ый по́черк** таныш кул; ~ **ая пе́сня** таныш җыр **2.** *в знач. сущ.* ~ **ый** *м,* ~ **ая** *ж* таныш, белеш

знамена́тел||ь *м мат.* ваклаучы; бүлүче ◆ **привести́ к одному́ (к о́бщему)** ~**ю** тигезләү, уртак фикергә килү

знамена́тельн||ый, -ая, -ое **1.** әһәмиятле, мөһим, истәлекле; ~ **ое собы́тие** әһәмиятле вакыйга **2.** *лингв.* мөстәкыйль; ~ **ые слова́** мөстәкыйль сүзләр

знаме́ние *с уст.* билге ◆ ~ **вре́мени** *книжн.* билгеле чор өчен характерлы ижтимагый күренеш; чорның иң мөһим күренеше

знамени́тость *ж* атаклы (данлыклы) кеше

знамени́тый, -ая, -ое атаклы, күренекле, данлыклы; ~ **по́ст** атаклы шагыйрь

знамен||ова́ть *несов. что, книжн.* белдерү, билгеләү, күрсәтү, билгесе булып тору, күрсәтеп тору; **событие,** ~**ующее побе́ду** җиңүне билгеләгән вакыйга

знаменосец *м* байрак йөртүче ◆ ~ **ми́ра** тынычлык байрагын йөртүче

зна́менщик *м* байрак йөртүче (*солдат яки офицер*)

зна́м||я *с* байрак; әләм; **кра́сное** ~ **я** кызыл байрак; **переходя́щее** ~ **я** күчмә байрак; **полково́е** ~ **я** полк байрагы ◆ **высоко́ держа́ть** ~ **я** *чего* байракны югары тоту; **подня́ть** ~ **я** *чего* көрәш башлау; **стать (встать) под** ~ **я (знамёна)** билгеле якта торып көрәшү; **под** ~**енем** *чего* байрагы астында

зна́ни||е *с* 1. (*осведомлённость*) белү, танып белү; **хоро́шее ~е предме́та** фәнне яхшы белү; **~е языка́** телне белү 2. фән, гыйлем; **ва́жная о́бласть ~я** фәннең мөһим өлкәсе 3. *обычно мн.* **~я** белем; **обла́дать ~ями** белемгә ия булу

зна́тность *ж* мәшһүрлек, билгелелек

зна́тный, -ая, -ое 1. атаклы, күренекле, данлыклы; **~ трактори́ст** атаклы тракторчы 2. аксөяк[ләр] ...ы; **~ род** аксөякләр нәселе

знато́к *м* күп белүче, яхшы белүче, оста; **~ своего́ де́ла** үз эшенең остасы; **~ литерату́ры** әдәбиятны яхшы белүче

зна||ть I *несов.* 1. *кого-что, о ком-чем* белү, ишетү; **~ть уро́к** дәресне белү; **~ть о noé3дке** юлга чыгу турында ишетү; **~ть** *кого-л.* **с де́тства** *кемне дә булса* кечкенәдән белү 2. *что* тату, баштан кичерү, күрү; **в де́тстве я ~л мно́го ра́достей** бала чагымда мин күп шатлыклар баштан кичердем ♦ **~й на́ших!** күрдегезме инде безне!, менә без нинди егетләр!; **~ть все ходы́ и вы́ходы** урын белән яхшы таныш булу, әмәлен белү, җаен белү; **~ть доро́гу** юлын (әмәлен, җаен) белү; **~ть ме́ру** чамасын белү; **~ть не ~ю** күргәнем дә, ишеткәнәм дә юк; **~ть своё ме́сто** үз урыныңны белү, тыйнак булу; **~ть со́весть** тыйнак булу, артыгына үрелмәү; **~ть толк** *в чём* рәтен белү; **~ть це́ну** *кому-чему* кадерен белү; **кто его́ ~ет** кем белгән аны, шайтан белә аны; **не ~ть ве́ку (изно́су)** *прост.* мәңге тузасы юк; **не ~ть, куда́ дева́ться** кая барырга урын тапмау, кая керергә тишек тапмау; **не ~ть, куда́ глаза́ деть** күзне яшерү (оялудан, уңайсызланудан); **не ~ть, куда́ деть себя́** үзеңне кая куярга белмәү; **не могу́ ~ть** *уст.* белмим; мин каян белим ди

зна́ть II *ж* аксөякләр, аристократлар

зна́ться *несов. с кем-чем, разг.* таныш булу, белү, аралашу; **он ни с кем не хо́чет ~** үл беркем белән дә аралашырга теләми

зна́харка *ж см.* **зна́харь**

зна́харск||ий, -ая, -ое имче ...ы, имтомчы ...ы; имчелек ...ы; **~ие приёмы** имчелек алымнары

зна́харство *с* им-том итү

зна́харь *м* им-том итүче, өшкерүче

значе́ни||е *с* 1. мәгънә; **~е сло́ва** сүзнең мәгънәсе 2. әһәмият, мөһимлек, кирәклек; **это не име́ет никако́го ~я** моның бернинди дә әһәмияте юк; **вопро́сы ме́стного ~я** аерым бер урын өчен әһәмияте булган мәсьәләләр; **вопро́сы междунаро́дного ~я** халыкара әһәмияте булган мәсьәләләр

зна́чимость *ж* әһәмиятлелек, мөһимлек; **социа́льная ~** *чего-л.* иҗтимагый әһәмиятлелек

зна́чим||ый, -ая, -ое мәгънәле, мәгънә аңлата торган; **~ые ча́сти сло́ва** сүзнең мәгънәле кисәкләре

зна́чит *вводн. сл.* димәк, шулай булгач; **~, пора́ е́хать** димәк, китәргә вакыт

значи́тельность *ж* 1. (*большая величина чего-л.*) шактый зур булу 2. (*важность*) әһәмиятлелек, мөһимлек, әһәмиятле булу

значи́тельн||ый, -ая, -ое 1. шактый зур; **~ый урон** шактый зур югалту 2. әһәмиятле, мөһим; **~ое собы́тие** әһәмиятле вакыйга 3. мәгънәле; **~ый взгляд** мәгънәле караш

зна́чить *несов.* 1. *что и с неопр.* (*означать*) белдерү, аңлату, тәгъбир итү, дигән сүз; **что э́то зна́чит?** бу ни дигән сүз! 2. әһәмиятле (мөһим) булу; **реше́ние э́того вопро́са мно́го зна́чит** бу мәсьәләнең хәл ителүе бик әһәмиятле

зна́читься *несов.* саналу, тору: **~ в отпуску́** ялда саналу; **~ в спи́ске** исемлектә тору

значо́||к *м* 1. значок; **университе́тский ~к** университет значогы 2. билге; **поста́вить ~ки на поля́х кни́ги** китап бите кырыйларына билгеләр кую

зноби́ть *несов. безл. кого* туңдыру, калтырату

зной *м* эсселек, кызулык; **полу́денный ~** төш вакытындагы эсселек

зно́йный, -ая, -ое эссе, кызу; **~ день** эссе көн

зоб *м* 1. (*напр. у птиц*) бүксә 2. (*болезнь*) зоб, базед авыруы

зоба́стый, -ая, -ое зур бүксәле

зов *м* 1. (*призывный звук*) чакыру тавышы 2. (*приглашение*) чакыру, дәшү, эндәшү; **прийти́ по пе́рвому ~у** беренче чакыру белән килү

зодиа́к *м астр.* зодиак; **зна́ки ~а** зодиак тамгалары

зодиака́льн||ый, -ая, -ое *астр.* зодиак ...ы, зодиакаль; **~ые созве́здия** зодиак йолдызлыклары

зо́дческ||ий, -ая, -ое төзелеш ...ы; архитектура ...ы; **~ое иску́сство** төзелеш сәнгате

зо́дчество *с* төзелеш сәнгате; архитектура

зо́дчий *м* төзүче; архитектор

зола́ *ж* көл

золи́ть *несов. что, спец.* көлләү (*тиренең йонын кою өчен известь катнаштырып көл сибү*)

золо́вка *ж* (*младшая*) каен сеңел; (*старшая*) каенигәч

золоти́ст||ый, -ая, -ое алтынсыман, алтын төсле, алтын ...; **~ый ко́лос** алтын башак; **~ые во́лосы** алтын чәч

золоти́ть *несов. что, прям., перен.* алтынлау, алтынга ману, алтын йөгертү; **~ ло́жки** кашыкларга алтын йөгертү; **со́лнце золоти́т лес** кояш урманны алтынга мана

золот||и́ться *несов.* 1. (*становиться золотистым*) алтын төсенә керү, сарга(ю; **~и́тся рожь** арыш саргая инде 2. (*виднеться — о чём-л. золотистом*) сары булып күренү, алтын кебек ялтырап күренү (яту); **вдали́ ~и́тся пески́** ераклардагы алтын кебек комлык ялтырап ята 3. *страд. от* **золоти́ть**

золотни́к I *м* мыскал (*электә авырлык үлчәве — 4,26 грамм*) ♦ **мал ~, да дорог** *погов.* кечкенә булса да, төш кенә; энже бөртеге зур булмый

золотни́к II *м* золотник (*җылылык, гидравлик һәм пневматик машиналарда пар, сыеклык яки газ агышын автоматик идарә итү җайланмасы*)

зо́лот||о *с* 1. алтын; **черво́нное ~о** кызыл алтын 2. *собир.* (*монеты*) алтын акча; **уплати́ть ~ом** алтын белән түләү 3. *собир.* (*золотые вещи, изделия*) алтын әйберләр (*алка, балдак һ.б.ш.*) 4. (*позолоченные нити*) ука; **шить ~ом** ука белән чигү ♦ **бе́лое ~о** ак алтын (*мамык*); **мя́гкое ~о** йомшак алтын (*мех*); **на вес ~а** алтын бәясенә, бик кыйбатка; **суса́льное ~о** юка кәгазь сыман алтын; **чёрное ~о** кара алтын (*нефть*)

зо́лото² *кушма сүзләрнең «алтын» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **золотомо́йка** алтын юу җайланмасы; **золотоволо́сый** алтын чәчле; **золотогри́вый** алтын яллы

золотоиска́тель *м* алтын эзләүче

золотоиска́тельск||ий, -ая, -ое алтын эзләү ...ы; **~ая па́ртия** алтын эзләү партиясе

золот||о́й, -а́я, -о́е 1. алтын ...ы; алтыннан коелган; **~о́й рубль** алтын бер сумлык; **~о́й сли́ток** алтын коелма 2. алтын ..., алтын йөгертелгән, алтынга манылган; **~ы́е часы́** алтын сәгать; **~о́е кольцо́** алтын балдак 3. алтын ...ы, алтынлы; **~о́й песо́к** алтын комы ♦ **~а́я молодёжь** кәеф-сафа чигеп яшәүче яшьләр (*буржуаз-дворяннар катлавында*); **~а́я о́сень** алтын көз (*агач яфраклары саргайган чак*); **~а́я пора́** бәхетле чак; **~а́я сва́дьба** алтын туй; **~а́я середи́на** алтын урталык (*кыю, тәвәккәл эшләр эшләүдән тыелып тору*); **~о́е дно** төшемле урын, табышлы урын; **~ое сло́во** *фольк.* хак сүз, алтын сүз; **~о́й век** бай чор, рәхәт вакытлар; **~о́й дождь** зур керем, зур табыш; **~о́й мешо́к** алтын капчыгы, акчалы кеше; **~о́й мой!** кадерлем минем!, алтыным минем!; **~о́й рабо́тник** бик яхшы хезмәткәр; **~о́й теле́ц** алтын, алтын-байлык, алтын-көмеш; **~о́й фонд** алтын фонды (*дәүләт байлыгы*); **~ы́е призёры** алтын медаль призёрлары; **~ы́е ру́ки** алтын куллар (*эшкә оста кеше*); **~ы́х дел ма́стер** алтынчы, көмешче; **обеща́ть (сули́ть) ~ы́е го́ры** алтын таулар вәгъдә итү, күпне ышандыру

золотоно́сный, -ая, -ое алтынлы, алтын чыга торган, алтынга бай; **~ песо́к** алтынга бай ком

золотопромы́шленник *м* 1. алтын приискасы эшчесе 2. алтын приискасы хуҗасы

золотопромы́шленность *ж* алтын промышленносте

золототы́сячник *м бот.* алтынбаш

золотошве́йн||ый, -ая, -ое укалап чигү ...ы; **~ая мастерска́я** укалап (ука белән) чигү мастерское

золоту́ха *ж* золотуха, төче авыруы

золочён||ый, -ая, -ое алтын йөгертелгән, алтынга манылган; **~ые ло́жки** алтын йөгертелгән кашыклар

зо́льник *м* 1. (*нижняя часть топки*) көллек, көл төшә торган урын (*мич астында*) 2. (*известковый раствор*)

көлле известь суы **3.** (*чан*) тире иләү чаны

зо́на *ж* зона; **~ расти́тельности** үсемлекләр зонасы; **пограни́чная ~** чик буе зонасы; **приго́родная ~** шәһәр тирәсе зонасы; **запре́тная ~** керү тыелган зона; **~ о́тдыха** ял итү зонасы

зона́льн||ый, -ая, -ое зона ...ы; *берәр* зонада урнашкан, *берәр* зонага хас, зональ; **~ая расти́тельность** *берәр* зонага хас үсемлекләр; **~ые соревнова́ния** зона ярышлары

зонд *м* зонд (**1.** *мед. кешенең ашказаны суын ала торган һәм ашказанын юдыру өчен кулланыла торган көпшә* **2.** *һава шартларын тикшерә торган шар* **3.** *җир катламнарын тикшерә торган җайланма*)

зонди́ровать *несов.* **1.** *кого-что* зонд белән тикшерү; **~ ра́ну** җәрәхәтне зонд белән тикшерү **2.** *перен. что* (*предварительно разузнавать*) алдан сынап карау, чамалап карау, кылын тартып карау, тикшереп карау ♦ **~ по́чву** кылын тартып карау

зо́нный, -ая, -ое зона ...ы; **~ тари́ф** зона тарифы

зонт *м* **1.** *см.* **зо́нтик** I; **2.** (*навес*) япма, түбә, чатыр

зо́нтик *м* **1.** зонтик **2.** *бот.* чатыр чәчәк, зонт чәчәк

зоо- *кушма сүзләрнең «зоология, зоологик» мәгънәсендәге беренче кисәге, мәс.* **зоогеогра́фия** зоологик география

зоо́лог *м* зоолог, зоология белгече

зоологи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** зоология ...ы; **~ий сад** зоология бакчасы **2.** *перен. разг.* хайвани, хайваннарча ...; хайваннар ...ы; **~ие нра́вы** хайваннарча тупас гадәтләр

зооло́гия *ж* зоология

зоомагази́н *м* зоомагазин

зоопа́рк *м* зоопарк

зооте́хник *м* зоотехник, зоотехника белгече

зооте́хника *ж* зоотехника (*терлекларне үрчету, дөрес асрау һәм дөрес файдалану турындагы фән*)

зоотехни́ческ||ий, -ая, -ое зоотехника ...ы, зоотехник; **~ая лаборато́рия** зоотехник лаборатория

зо́рк||ий, -ая, -ое **1.** үткен; **~ие глаза́** үткен күзләр **2.** *перен.* (*проницательный*) сизгер

зрачко́в||ый, -ая, -ое күз карасы ...ы, бәбәк ...ы; **~ые не́рвы** күз карасы нервлары

зрачо́к *м* күз карасы, бәбәк

зре́лищ||е *с* **1.** күренеш; **необыкнове́нное ~е** гаҗәп күренеш **2.** тамаша; **ма́ссовые ~а** массовый тамашалар

зре́лищн||ый, -ая, -ое тамаша ...ы; **~ые предприя́тия** тамаша предприятиеләре

зре́лость *ж* **1.** (*спелость*) өлгерү, пешү, үсеп житү, өлгерү (пешү) дәрәҗәсе **2.** (*зрелый возраст*) җитлегү, балигъ булу **3.** *перен.* өлгерү, төгәллек, камиллек; **~ мы́сли** фикернең камиллеге

зре́л||ый, -ая, -ое **1.** өлгергән, пешкән, өлгереп (пешеп) җиткән; **~ые я́блоки** өлгергән алмалар **2.** (*о возрасте*) буйга җиткән, үсеп җиткән, балигъ булган **3.** *перен.* житлеккән, тәжрибәле; **~ый учёный** тәжрибәле галим; **~ое произведе́ние** җитлеккән әсәр **4.** *перен.* тирәнтен уйланган, төпле; **~ое реше́ние** тирәнтен уйланган карар; **~ая мысль** төпле фикер

зре́ни||е *с* күрү, күрү сәләте; **потеря́ть ~е** сукыраю ♦ **изложи́ть свою́ то́чку ~я** үз фикереңне әйтү; **под угло́м ~я** карашыннан чыгып, билгеле бер ноктадан чыгып; **по́ле ~я** күз күреме; **то́чка ~я** караш, фикер, караш ноктасы

зре||ть I *несов.* өлгерү, өлгереп килү, пешү, житешү; **~ют хлеба́** ашлыклар өлгерә; **я́блоки ~ют** алмалар пешә

зреть II *несов. уст.* **1.** *кого-что* (*видеть*) күрү **2.** *кого-что, на кого-что* (*смотреть*) карау, карап тору

зри́м||ый, -ая, -ое **1.** күз күрергә мөмкин булган; **~ое простра́нство** күз күрерлек пространство **2.** *перен.* сизелерлек, күзгә күренерлек; күзгә бәрелеп (күренеп) тора торган; **~ые сдви́ги в учёбе** укуда сизелерлек үзгәрешләр

зри́тель *м* тамашачы, караучы, тамаша караучы

зри́тельница *ж* тамашачы хатын (кыз)

зри́тельн||ый, -ая, -ое **1.** күрү ...ы; **~ая па́мять** күрү хәтере **2.** тамаша ...ы; **~ый зал** тамаша залы

зря *нареч. разг.* юкка, юкка (бушка) гына, тиктомалга, файдасызга, заяга ♦ **почём ~** ничек кирәк алай

зря́чий, -ая, -ее күзле, күрә торган, күрә ала торган

изоли́рованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **изоли́ровать; 2.** аерым, аерым торган; **~ая ко́мната** аерым бүлмә **3.** *тех.* изоляцияләнгән; **~ый про́вод** изоляцияләнгән үткәргеч

изоли́ровать *сов., несов.* **1.** *кого-что* изоляцияләү, аеру, аерып урнаштыру, бергә яшәргә бирмәү; **~ больно́го** авыруны изоляцияләү **2.** *что, тех.* изоляцияләү; **~ электри́ческий про́вод** электр чыбыгын изоляцияләү

изоли́роваться 1. *сов., несов.* изоляцияләнү; ераклашу, аерылу **2.** *несов. страд. от* **изоли́ровать**

изолиро́вка *ж см.* **изоли́ровать** 2; **~ про́вода** үткәргечне изоляцияләү

изолиро́вочн||ый, -ая, -ое *тех.* изоляцияли торган, изоляцияләү ...ы; **~ые материа́лы** изоляцияләү материаллары

изоля́тор *м* изолятор (**1.** *электр тогын үткәрми торган материал* **2.** *тех. электр үткәргечен беркетә торган пыяла яки ролик* **3.** *йогышлы авырулар белән авыручыларны яки акылдан шашканнарны урнаштыру өчен хастаханәдә аерым бүлмә* **4.** *кулга алынган җинаятьчеләрне урнаштыру урыны*)

изоляцио́нн||ый, -ая, -ое изоляция ...ы, изоляцияләү ...ы; **~ая ле́нта** изоляцияләү тасмасы

изоля́ция *ж* **1.** *см.* **изоли́ровать, изоли́роваться; ~ за́разных больны́х** йогышлы авыруларны изоляцияләү **2.** *тех.* изоляция; **рези́новая ~** резин изоляция

изоморфи́зм *м хим.* изоморфизм (*химик составы белән бер үк типта булган матдәләрнең эремәдән катнаш составлы кристаллар булеп чыгару сәләте*)

изорва́ть *сов. что* ертып (ерткалап) бетерү

изорва́ться *сов.* ертылып (тузып) бетү

изоте́рма *ж геогр.* изотерма (*картада бер үк температура була торган урыннарны тоташтыручы сызык*)

изото́п *м* изотоп; **радиоакти́вные ~ы** радиоактив изотоплар; **~ы ура́на** уран изотоплары

изощрённость *ж* үткенлек, сизгерлек; камиллек

изощрённый, -ая, -ое үткен, артык сизгер, нечкә, камилләшкән; **~ум** камилләшкән акыл

изощри́ть *сов. что, книжн.* камилләштерү, үткенләштерү, артык сизгер итү, үстерү; **~ слух** ишетү сәләтен камилләштерү

изощри́ться *сов.* камилләшү, үткенләшү, шомару, үсү; **~ в филосо́фских спо́рах** философик бәхәсләрдә камилләшү

изощря́ть *несов. см.* **изощри́ть**

изощря́ться *несов.* **1.** *см.* **изощри́ться; 2.** *страд. от* **изощря́ть**

из-под *предлог с род.п.* **1.** (*при обозначении направленности действия из какого-л. места*) астыннан; **вы́лезти ~ стола́** өстәл астыннан чыгу **2.** (*при определении вместилища*) ...дан бушаган; **горшо́к ~ молока́** сөттән бушаган чүлмәк **3.** (*при обозначении появления из какого-л. населённого места*) тирәсеннән, яныннан; **прие́хал ~ Москвы́** Мәскәү яныннан кайтты ◆ **~ но́су** борын астыннан; **~ па́лки** мәҗбүр итеп, мәҗбүр ителеп

изразе́ц *м* чынаяк кирпеч, кафель

изразцо́в||ый, -ая, -ое чынаяк кирпеч ...ы; чынаяк кирпеч белән тышланган, чынаяк кирпеч җәелгән; **~ая печь** чынаяк кирпеч белән тышланган мич

израильтя́не *мн.* израильләр (*Израиль халкы*)

изра́нить *сов. кого-что* яралап (җәрәхәтләп) бетерү

израсхо́довать *сов. что* тотып бетерү, сарыф итү, сарыф итеп бетерү (*мәс. акчаны*)

израсхо́доваться *сов.* тотылып бетү, сарыф ителеп бетү

и́здредка *нареч.* сирәк кенә, ара-тирә, әллә нигә бер, сирәк-мирәк, анда бермонда бер, анда-санда

изрежённ||ый, -ая, -ое сирәк тишелгән, сирәк шытып чыккан; **~ые всхо́ды карто́феля** бәрәңгенең сирәкләтелгән шытымнары

изре́за||ть *сов.* **1.** *что* (*разрезать на части*) турап (тураклап, телгәләп) бетерү **2.** *кого-что* кискәләп бетерү; кискәләп яралап бетерү; **~ть стол ножо́м** өстәлне пычак белән кискәләп бетерү; **~ть ру́ку** кулны кискәләп яралап бетерү **3.** *перен. что* ергалап бетерү; **бу́хты ~ли бе́рег** бухталар ярны ергалап бетергән

изре́зывать *несов. см.* **изре́зать**

изрека́ть *несов. см.* **изре́чь**

изрече́ние *с* әйткән сүз; хикмәтле фикер (сүз)

изре́чь *сов. что и без доп., уст.* сөйләп бирү, әйтү, әйтеп бирү; **~ и́стину** хакыйкать әйтеп бирү

изрешети́ть *сов. кого-что* тишкәләп бетерү; челтәрләп бетерү; **~ пу́лями** пуляләр белән тишкәләп бетерү

изруба́ть *несов. см.* **изруби́ть**

изруби́ть *сов. кого-что* **1.** кискәләп ваклап бетерү; тураклап бетерү **2.** (*убить*) кырып (үтереп) бетерү

изруга́ть *сов. кого-что* бик нык сүгеп ташлау, эт итеп сүгү, эт итеп сүгеп ташлау

изрыга́||ть *несов. что, книжн.* атып чыгару; ургылдыру, ургылдырып чыгару; **пу́шки ~ли ого́нь** пушкалар ут ургылдыралар иде

изры́||ть *сов. что* актарып ташлау, чокырлап бетерү; **снаря́ды ~ли по́ле** снарядлар кырны чокырлап бетергәннәр ◆ **лицо́ ~то о́спой** чәчәктән соң шадраланган бит

изря́дн||ый, -ая, -ое шактый, зур гына, көчле генә, шактый күп, шактый зур; **~ая су́мма де́нег** шактый күп акча; **~ая ску́ка** зур гына сагыш; **~ый хо́лод** көчле генә суык

изувёр *м* явыз, кансыз

изуве́рский, -ая, -ое явызларча ..., үтә шәфкатьсез

изуве́рство *с* явызларча кыланыш, кансызлык, үтә шәфкатьсезлек

изуве́рствовать *несов.* явызларча кылану (эш итү)

изуве́чивать *несов. см.* **изуве́чить**

изуве́чиваться *несов.* **1.** *см.* **изуве́читься; 2.** *страд. от* **изуве́чивать**

изуве́чить *сов. кого-что* имгәтү, имгәтеп бетерү (ташлау), гарипләп бетерү

изуве́читься *сов.* имгәнү, имгәнеп бетү, гарипләнү

изукра́сить *сов. кого-что* пычратып бетерү; ямьсезләп бетерү; **всё лицо́ себе́ ~л са́жей** бөтен битен корым буяп пычратып бетергән

изуми́тельный, -ая, -ое искиткеч, таңга калырлык, шаккатырлык, сокланырлык, гаҗәп

изуми́ть *сов. кого-что* таңга калдыру, шаккатыру, гаҗәпкә калдыру

изуми́ться *сов.* таңга калу, шаккату, гаҗәпкә калу, ис китү

изумле́ние *с* таңга калу, шаккату; **прийти́ в ~** таңга калу

изумля́ть *несов. см.* **изуми́ть**

изумля́ться *несов. см.* **изуми́ться**

изумру́д *м* зәбәрҗәт

изумру́дн||ый, -ая, -ое **1.** зәбәрҗәт ...ы; **~ые ко́пи** зәбәрҗәт шахталары **2.** зәбәрҗәтле; зәбәрҗәт кашлы; **~ое кольцо́** зәбәрҗәт кашлы йөзек **3.** (*о цвете*) ачык яшел, зәбәрҗәт төсле; **~ая вода́** зәбәрҗәт төсле су

изуро́дованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **изуро́довать; 2.** ямьсезләнеп беткән, гарипләнеп беткән; **~ое лицо́** ямьсезләнеп беткән бит

изуро́довать *сов. кого-что* **1.** (*обезобразить*) ямьсезләү, ямьсезләп бетерү **2.** (*искалечить*) гарипләү, гарипләп бетерү, имгәтеп бетерү **3.** (*испортить*) бозу, бозып бетерү; **~ дете́й плохи́м воспита́нием** начар тәрбияләп балаларны бозу

изуро́доваться *сов.* имгәнеп бетү, гарипләнеп бетү

изу́стн||ый, -ая, -ое телдән телгә күчә торган, телдән сөйләнә торган; **~ое преда́ние** телдән телгә күчә торган хикәя

изуча́ть *несов. см.* **изучи́ть**

изуче́ние *с см.* **изучи́ть**

изу́ченный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **изучи́ть; 2.** өйрәнелгән, тикшерелгән, яхшы таныш, билгеле

изучи́ть *сов.* **1.** *что* өйрәнү, җентекләп өйрәнү, өйрәнеп җитү; **~ иностра́нный язы́к** чит тел[не] өйрәнү **2.** *что* (*исследовать*) тикшерү, өйрәнү **3.** *кого-что* өйрәнү, күзәтеп белү, күзәтеп аңлау; **~ челове́ка** кешене күзәтеп белү; **~ ме́стность** урынны өйрәнү

изъеда́ть *см.* **изъе́сть**

изъе́здить *сов. что* **1.** йөреп (гизеп) чыгу; **~ всю́ страну́** бөтен илне йөреп чыгу **2.** (*привести в негодность*) йөреп бозып (ергалап) бетерү; **~ доро́гу** йөреп (*мәс. трактор белән йөреп*) юлны ергалап бетерү

изъе́||сть *сов. что* **1.** кимереп (кисеп) бетерү; **моль ~ла мех** көя мехны кисеп бетергән **2.** (*о едких веществах*) яндыру, кисү, яндырып бетерү

изъяви́тельн||ый, -ая, -ое: **~ое наклоне́ние** *грам.* хикәя фигыль

изъяви́ть *сов. что, книжн.* белдерү, әйтү; **~ жела́ние** теләк белдерү

изъявля́ть *несов. см.* **изъяви́ть**

изъя́н *м* кимчелек, житешсезлек; зыян

изъясня́||ться *несов.* сөйләшә белү, сөйләшү; **он хорошо́ ~лся по-францу́зски** ул французча яхшы сөйләшә иде

изъя́тие *с см.* **изъя́ть**

изъя́ть *сов. что, книжн.* алу; алып ташлау, кулланудан чыгарып ташлау, гамәлдән чыгару; тартып алу; **~ что-л. из обраще́ния** *нәрсәне дә булса* әйләнештән алу

изыма́ть *несов. см.* **изъя́ть**

изыска́ни||е *с* **1.** *см.* **изыска́ть; ~е дополни́тельных сре́дств** өстәмә средствалар табу **2.** *обычно мн.* **~я** эзләү, тикшерү; эзләнү, тикшеренү; **геологи́ческие ~я** геологик эзләнүләр

изы́сканный, -ая, -ое купшы, нәфис; **~ нара́д** нәфис кием

изыска́тель *м* тикшеренүче, эзләнүче

изыска́тельск||ий, -ая, -ое тикшеренүче[ләр] ...ы, эзләнүче[ләр] ...ы; **~ая па́ртия** тикшеренүчеләр төркеме

изыска́ть *сов. что* табу, эзләп табу; **~ сре́дства на постро́йку до́ма** йорт салу өчен средстволар эзләп табу

изыска́||ться *сов.* табылу, эзләп табылу; **~лись но́вые исто́чники государ́ственных дохо́дов** дәүләт керемнәренең яңа чыганаклары табылды

изы́скивать *несов.* **1.** *см.* **изыска́ть 2.** *что* (*производить исследования*) тикшерү, эзләнү, тикшеренү үткәрү

изы́скиваться *несов.* **1.** *см.* **изыска́ться; 2.** *страд. от* **изы́скивать**

изю́бр *м зоол.* изюбр

изю́м *м* йөзем

изю́мина *ж* йөзем, йөзем бөртеге, бер бөртек йөзем

изю́минк||а *ж уменьш. от* **изю́мина ♦ челове́к с ~ой** үзенчәлекле кеше, күркәм кеше

изя́щество *с* нәфислек, гүзәллек, зифалык, матурлык

изя́щн||ый, -ая, -ое нәфис, гүзәл, зифа, матур; **~ое пла́тье** нәфис күлмәк; **~ая фигу́ра** зифа буй **♦ ~ая литерату́ра** *уст.* нәфис әдәбият

ика́ть *несов.* очкылык тоту

ика́ться *несов. безл. кому, разг.* бер туктаусыз очкылык тоту

ико́та *ж* очкылык, очкылык тоту

икра́ *ж* **1.** уылдык; **зерни́стая ~** бөртекле уылдык **2.** (*кушанье*) икра; **баклажа́нная ~** баклажан икрасы

икри́нка *ж* уылдык бөртеге

икри́ст||ый, -ая, -ое күп уылдыклы; **~ая рыба** күп уылдыклы балык

икрометá́ние *с рыб.* уылдык чәчү

и́кры *мн.* (*ед.* **икра́** *ж*) балтыр, балтыр ите; чәлтер

икря́н||ой, -а́я, -о́е уылдыклы; **~а́я ры́ба** уылдыклы балык

икс *мат.* икс

ил *м* ләм, лай (*диал.*), утырма, дуен

и́ли *союз* **1.** *разд.* яки, яисә, әллә ..., я, я булмаса; **вам ча́ю ~ ко́фе?** сезгә чәйме, я кофеме? **2.** *поясн.* ягъни, башкача, икенче сүз белән әйткәндә; **аэропла́н, ~ самолёт** аэроплан, ягъни самолёт **3.** *присоед.* яисә, я булмаса, яки; **поищи́ в шкафу́ ~ на по́лке** шкафтан яки киштәдән эзлә **4.** *вопр.* мени, ...ме әллә; **~ ты не зна́ешь об э́том?** син бу турыда белмисең мени? **5.** *против.* югыйсә, юкса; **уйди́, ~ наговорю́ тебе́ ли́шнего** кит моннан, юкса артык сүз әйтеп ташлармын

и́лист||ый, -ая, -ое ләмле, лайлалы; **~ое дно** ләмле су төбе

иллюзиони́ст *м* иллюзияче

иллю́зия *ж* иллюзия (**1.** *тойгының алдавы сәбәпле чынбарлыкны бозып күз алдына китерү* **2.** *перен. тормышка ашуы мөмкин булмаган хыял, буш хыял*)

иллюзо́рн||ый, -ая, -ое хыялый, буш, тормышка ашмый торган; **~ые наде́жды** хыялый өметләр

иллюмина́тор *м* иллюминатор (*судноларда, самолётта, космик корабльдә һ.б.ш. түгәрәк тәрәзә*)

иллюминацио́нн||ый, -ая, -ое *спец.* иллюминация ...ы; иллюминациялә ...ы; **~ые огни́** иллюминация утлары

иллюмина́ция *ж* иллюминация (*бәйрәм уңае белән урамнарны һәм йортларны төрле төстәге утлар белән яктырту, бизәү*)

иллюмини́ровать *сов., несов. что* иллюминациялә, утлар белән бизәү, яктырту

иллюстрати́вность *ж* иллюстративлык, күрсәтмәлелек

иллюстрати́вный, -ая, -ое иллюстратив, күрсәтмәле, күрсәтмә ...; **~ ме́тод** иллюстратив метод; **~ материа́л** күрсәтмә материал

иллюстра́тор *м* иллюстратор (*китапларны иллюстрацияләүче рәссам*)

иллюстра́ция *ж* **1.** *см.* **иллюстри́ровать; 2.** иллюстрация; **кни́га с ~ми** иллюстрацияле китап

иллюстри́рование *с см.* **иллюстри́ровать; ~ книг** китапларны иллюстрацияләү

иллюстри́рованный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **иллюстри́ровать; 2.** иллюстрацияле; **~ журна́л** иллюстрацияле журнал

иллюстри́ровать *сов. несов. что* **1.** иллюстрацияләү, рәсемнәр урнаштыру **2.** *перен.* (*пояснить*) (*мисал белән*) аңлату, раслау; (*күргәзмә материал өстендә*) аңлату; **~ свою́ мысль приме́ром** үзеңнең фикереңне мисаллар белән аңлату

иловат||ый, -ая, -ое ләмлерәк, лайлырак; **~ая по́чва** ләмлерәк туфрак

иль *разг. см.* **и́ли**

и́лька *ж* **1.** (*зверь*) Америка көзәне **2.** (*мех*) Америка көзәненең мехы

и́льковый, -ая, -ое Америка көзәне ...ы; **~ мех** Америка көзәне мехы

ильм *м* элмә, элмә агачы

имажини́зм *м лит.* имажинизм

имажини́ст *м* имажинизм тарафдары

има́м *м* имам (**1.** *мәхәллә мулласы* **2.** *кайбер мәселман илләрендә: дин һәм дәүләт башында торучы* **3.** *гомумән мөселманнарда дин башлыгы*)

имби́рн||ый, -ая, -ое имбир ...ы; имбирлы; **~ое ма́сло** имбир мае

имби́рь *м бот.* имбир

име́ние *с* утар, имение

именны́к *м* исем бәйрәмен үткәрүче

именны́ница *ж* исем бәйрәмен үткәрүче хатын(кыз)

имени́ны *только мн.* исем бәйрәме

имени́тельный: ~ паде́ж *грам.* баш килеш

имени́тый, -ая, -ое атаклы, танылган, олы; **~ гость** олы кунак

и́менно *частица* **1.** атап әйткәндә, ягъни; **ли́ственные дере́вья, а ~: дуб,**

берёза, оси́на, ли́па и др. яфраклы агачлар, ягъни: имән, каен, усак, юкә h.б.ш. **2.** нәкъ, нәкъ менә, нәкъ үзе; **я об э́том ~ и прошу́** мин нәкъ шул турыда үтенәм дә ♦ **вот ~** нәкъ менә шулай; **кто ~?** кем соң?; **ско́лько ~** күпме соң?

именн||о́й, -а́я, -о́е **1.** исемле, исеме куелган, исеме аталган; **~о́е кольцо́** исеме куелган балдак **2.** *грам.* исем ...ы; **~ое склоне́ние** исем төрләнеше

именова́ть *несов. кого-что* атау, исемләү, исем бирү, исем кушу

именова́ться *несов.* аталу, исемләнү; ... дип йөртелү

име́||ть *несов. кого-что* (*обладать, располагать*) булу, бар булу, ...лы булу, ия булу; (*с отрицанием*) юк, булмау; **он ~ет дете́й** аның балалары бар; **ты ~ешь возмо́жность** синең мөмкинлегең бар; **это ~ло большо́е значе́ние** моның зур әһәмияте бар иде; **не ~ю вре́мени** вакытым юк; **не ~л вре́мени** вакытым булмады ♦ **~ет быть** булачак; **за́втра ~ет быть собра́ние** иртәгә жыелыш булачак; **~ет значе́ние** әһәмияте бар; **~ет отноше́ние** мөнәсәбәте бар, бәйләнеше бар; **~ет приме́нение** кулланыла; **~ть в виду́** күздә тоту; **~ть де́ло** *с кем-чем* эш итү; **~ть му́жество** батырлык житү; **~ть под руко́й** үз янында булу; **~ть це́лью** омтылу, максат итеп кую

име́||ться *несов.* бар [булу]; (*с отрицанием*) юк; **~ются ли у вас но́вые све́дения?** сездә яңа мәгълүматлар бармы?; **препя́тствий не ~ется** каршылыклар юк ♦ **~ться в виду́** күз алдында тотылу

имита́тор *м* имитатор (*берәр кеше сөйләвенә охшатып сөйләүче; хайваннар, кошлар тавышына охшатып кычкыручы*)

имита́ция *ж* **1.** *см.* **имити́ровать; 2.** (*подделка*) охшатып ясалган әйбер; **~ кра́сного де́рева** кызыл агачка охшатып ясалган әйбер

имити́ровать *несов.* **1.** *кого-что* имитацияләү, охшатып сөйләү (кылану, кычкыру, сайрау) **2.** *что* (*подделывать*) охшатып ясау, имитацияләү

иммане́нтн||ый, -ая, -ое *книжн.* имманент ..., эчке (*әйбернең үзенең эчке табигатенә хас булган*); **~ая причи́на** имманент сәбәп

иммигра́нт *м* иммигрант (*даими яшәү өчен берәр илгә күчеп килгән чит ил кешесе*)

иммигра́нтка *ж* иммигрант хатын (кыз)

иммигра́нтск||ий, -ая, -ое иммигрант[лар] ...ы; **~ие права́** иммигрантлар хокукы

иммиграцио́нн||ый, -ая, -ое иммиграцион, иммиграция ...; **~ые зако́ны** иммиграция законнары

иммигра́ция *ж* **1.** иммиграция (*даими яшәү өчен берәр чит илгә күчеп килү*) **2.** *собир.* иммигрантлар

иммигри́ровать *сов., несов.* иммиграцияләү, иммиграцияргә килү, чит илгә күчеп килү

иммортéль *ж бот.* үлмәс гөл

иммунизацио́нн||ый, -ая, -ое *мед.* иммунизация ...ы; **~ые сре́дства** иммунизация чаралары

иммуниза́ция *ж мед.* иммунизация (*организмны авыру йогудан саклау*)

иммунизи́ровать *сов., несов. кого-чего, мед.* иммунизацияләү, иммунизация ясау, иммунитет булдыру; **~ орга́низм** организмда иммунитет булдыру

иммунитéт *м* иммунитет (**1.** *мед., биол. организмның йогышлы авыруларга каршы тора алучанлыгы* **2.** *юр. аерым кешеләрнең, мәсәлән, дипломатия вәкилләренең кайбер гомуми законнарга буйсынмау хокукы*)

иммунóлог *м* иммунолог

иммунóлогия *ж* иммунология (*кешеләрнең һәм хайваннарның йогышлы авыруларга бирешмәве турында фән*)

императи́в *м* **1.** *книжн.* (*повеление*) императив, катгый таләп **2.** *грам.* боерык фигыль

импера́тор *м* император

импера́торский, -ая, -ое император ...ы; **~ дворе́ц** император сарае

императри́ца *ж* **1.** (*жена императора*) император хатыны **2.** (*титул*) император хатын; әби патша (*уст.*)

империали́зм *м* империализм

империали́ст *м* империалист

империалисти́ческ||ий, -ая, -ое империализм ...ы, империалистик, империалистлар ...ы; **~ая поли́тика** империалистик сәясәт

импе́рия *ж* империя (**1.** *башында император булган монархия дәүләте* **2.** *империалистик зур колониаль дәүләт*)

импе́рск||ий, -ая, -ое империя ...ы, империя карамагындагы; **~ая а́рмия** империя армиясе

импоза́нтность *ж* мәһабәтлек, мәһабәт булу; могтәбәр булу

импоза́нтн||ый, -ая, -ое мәһабәт; могтәбәр; **~ая фигу́ра** мәһабәт кыяфәт

импони́ровать *несов. кому-чему и без доп.* яхшы караш тудыру, үзенә җәлеп итү, үзенә карату

и́мпорт *м эк.* импорт

импортёр *м эк.* импортёр

импорти́ровать *сов., несов. кого-что* чит илләрдән товар кертү

и́мпортный, -ая, -ое импорт ...ы, чит илләрдән кертелгән; **~ това́р** импорт товары

импоте́нт *м* импотент

импоте́нция *ж* импотенция (*ирләрдә була торган җенси көчсезлек*)

импреса́рио *м нескл.* импресарио (*буржуаз илләрдә концертлар оештыручы профессиональ артист*)

импрессиони́зм *м иск.* импрессионизм (*19 йөзнең икенче яртысында сәнгатьтә һәм әдәбиятта барлыкка килгән агым*)

импрессиони́ст *м* импрессионист, импрессионизм тарафдары

импрессионисти́ческ||ий, -ая, -ое *иск.* импрессионизм ...ы; импрессионистик, импрессионизм белән сугарылган; **~ая му́зыка** импрессионистик музыка

импрессиони́стск||ий, -ая, -ое *иск.* импрессионизм ...ы; импрессионист[лар] ...ы; импрессионистларга хас, импрессионистларча ...; **~ие тенде́нции в литерату́ре** әдәбиятта импрессионизм тенденцияләре

импровиза́тор *м* чичән, импровизатор (*импровизация ясарга сәләтле кеше*)

импровиза́торский, -ая, -ое чичән ...ы, импровизатор ...ы; импровизаторлык ...ы; **~ тала́нт** импровизаторлык таланты

импровиза́ция *ж* **1.** *см.* **импровизи́ровать; 2.** импровизация (*алдан хәзерләнмичә, башкару моментында гына уйлап, шигырь язу яки көй чыгару*)

импровизи́рованный, -ая, -ое алдан әзерләнмәгән; бик тиз генә оештырылган; **~ конце́рт** бик тиз генә оештырылган концерт

импровизи́ровать *сов., несов. что и без доп.* импровизацияләү, импровизация ясау

и́мпульс *м* импульс (**1.** *нинди дә булса эшкә дәртләндерүче сәбәп, көч* **2.** *физиол. нерв ярсыткычларының эшчәнлеге аркасында барлыкка килеп иректән эшләнә торган хәрәкәт*)

импульси́вность *ж* **1.** импульсивлык, артык хәрәкәтчәнлек **2.** *физиол.* импульсивлык, ихтыярсыз ясалганлык, кинәт ясалганлык

импульси́вн||ый, -ая, -ое **1.** импульсив; артык хәрәкәтчән; **~ый челове́к** импульсив кеше **2.** *физиол.* импульсив, иректән ясалган; **~ое движе́ние** импульсив хәрәкәт

и́мпульсн||ый, -ая, -ое *эл., радио* импульс ...ы; импульслы; **~ая радиосвязь** импульслы радиоэлемтә

иму́щественный, -ая, -ое милек ...ы, мөлкәт ...ы, милеккә бәйләнгән, милеккә карата булган; **~ ценз** мөлкәт цензы (*капиталистик илләрдә: сайлауларда катнашу өчен билгеле бер күләмдә мөлкәтнең булуын таләп итә торган закон*)

иму́щество *с* милек, мал-мөлкәт; **госуда́рственное ~** дәүләт милке; **дви́жимое ~** күчә торган милек; **недви́жимое ~** күчми торган милек

иму́щ||ий, -ая, -ее мал-мөлкәтле, хәлле, бай; **~ие кла́ссы** бай сыйныфлар

и́мя *с* **1.** исем, ат; **как его́ и́мя?** аның исеме ничек?; **на и́мя** *кого-л.* исеменә; **заявле́ние на и́мя дире́ктора заво́да** завод директоры исеменә язылган гариза; **и́мени** *кого-чего-л.* исемендәге; **теа́тр и́мени Галиаскáра Камáла** Галиәскәр Камал исемендәге театр **2.** ат, дан, шөһрәт; **гро́мкое и́мя** данлыклы исем; **учёный с больши́м и́менем** дан алган галим **3.** *грам.*: **и́мя существи́тельное** исем; **и́мя прилага́тельное** сыйфат; **и́мя числи́тельное** сан; **и́мя де́йствия** исем фигыль; **и́мя со́бственное** ялгызлык исеме ♦ **во и́мя** *кого-чего* хакына; **во и́мя дру́жбы** дуслык хакына; **от и́мени** *кого* исеменнән; **проси́ть от и́мени отца́** әти исеменнән үтенү

имяре́к *м нескл.* исемен атый, исемен күрсәтә (*берәр кешенең исемен алыштыра торган сүз*)

инакомы́слящий, -ая, -ее башкача уйлый торган, башкача уйлаучы, башкача фикерләүче, башкача фикер йөртүче

ина́че, и́наче *нареч.* 1. башкача, бүтәнчә, икенче төрле, башка төрле; **на́до сде́лать ~** башкача эшләргә кирәк 2. *в знач. против. союза* юкса, югыйсә; **беги́, ~ опозда́ешь** йөгер, юкса соңга калырсың ♦ **так и́ли ~,** *в знач. вводн. сл.* ничек кенә булса да, ничек булса да, ничек кенә булмасын, алаймы-болаймы; **так и́ли ~, я при́ду** ничек кенә булмасын, мин килермен

инвали́д *м* инвалид, гарип; **~ труда́** хезмәт инвалиды; **~ войны́** сугыш инвалиды

инвали́дност||ь *ж* инвалидлык, гариплек; **перейти́ на ~ь** инвалидлыкка күчү; **получа́ть пе́нсию по ~и** инвалидлык буенча пенсия алу

инвали́дн||ый, -ая, -ое инвалид[лар] ...ы; гарип[ләр] ...ы; **~ая арте́ль** инвалидлар артеле

инвентариза́ция *ж* 1. (*внесение в опись*) инвентаризация, инвентарьлар исемлегенә кертү 2. (*проверка*) инвентаризация үткәрү

инвентаризи́ровать, инвентаризова́ть *сов., несов. что* инвентаризация ясау (үткәрү)

инвента́рь *м* инвентарь; **живо́й ~** аяклы мал, тере инвентарь; **мёртвый ~** җансыз инвентарь; **соста́вить ~** инвентарь төзү

инве́рсия *ж лингв., лит.* инверсия (*җөмләдәге сүзләрнең гадәттәге тәртибен үзгәртү*)

инвести́ровать *сов., несов. что, эк.* капитал салу (*чит илдәге яки үз илендәге берәр предприятиегә*)

ингала́тор *м* ингалятор, ингаляция приборы

ингаля́ция *ж* ингаляция (*пар, газ хәлендәге даруны яки пар хәленә китерелгән сыек даруны ингалятор ярдәмендә сиптереп иснәтеп дәвалау*)

ингреди́ент *м* ингредиент (*берәр катлаулы матдәнең, кушылманың состав өлеше*)

ингу́ш *м* ингуш

ингуши́ *мн.* ингушлар

ингу́шка *ж* ингуш хатыны (кызы)

ингу́шский, -ая, -ое ингуш[лар] ...ы; **~ язы́к** ингуш теле

индевé́ть *несов.* бәсәрү, бәсләну, сыкылану

инде́йка *ж* 1. (*птица*) ана күркә 2. (*мясо*) күркә ите

инде́йск||ий, -ая, -ое индеец[лар] ...ы; **~ие языки́** индеецлар телләре

инде́йцы *мн.* индеецлар (*Америкада яшәүче төп җирле халыклар*)

и́ндекс *м* индекс (1. *берәр нәрсәнең исемлеге, күрсәткече* 2. *эк. цифрлы белешмә, күрсәткеч*)

индетермини́зм *м филос.* индетерминизм (*табигатьтәге һәм җәмгыяттәге күренешләр арасында сәбәп бәйләнешләре һәм закончалык барлыгын инкарь итә торган идеалистик юнәлеш*)

индиа́нка I *ж* һинд хатыны (кызы)

индиа́нка II *ж* индеец хатыны (кызы)

индивидуализа́ция *ж см.* **индивидуализи́ровать**

индивидуализи́ровать *сов., несов. кого-что* индивидуальләштерү (*шәхесне, предметны үзенә генә хас булган билгеләр буенча аерып алу, аның белән аерым эш итү*)

индивидуали́зм *м* индивидуализм (*шәхси интересларны җәмгыять интересларына каршы куючы буржуаз караш*)

индивидуали́ст *м* индивидуалист

индивидуалисти́чески||ий, -ая, -ое 1. индивидуализм ...ы, индивидуалистик; индивидуализмга нигезләнгән; **~ая филосо́фия** индивидуалистик философия 2. индивидуалистик, индивидуалистларча ...; **~ий подхо́д к де́лу** эшкә индивидуалистларча мөнәсәбәт

индивидуали́стка *ж* индивидуалист хатын (кыз)

индивидуа́льность *ж* 1. индивидуальлек, үзенә бер төрлелек (*характерның һәм психик төзелешнең бер шәхесне икенче шәхестән аера торган үзенчәлекләре*) 2. (*личность*) шәхес, аерым шәхес

индивидуа́льн||ый, -ая, -ое 1. индивидуаль, шәхси, бер шәхескә хас; **~ые осо́бенности ученико́в** укучыларның индивидуаль үзенчәлекләре 2. индивидуаль, аерым; **~ое жили́щное строи́тельство** индивидуаль торак төзелеше; **~ое хозя́йство** аерым хуҗалык 3. аерым; сирәк; индивидуаль; **~ый слу́чай** аерым очрак; **~ый план** индивидуаль план; **~ое обуче́ние** индивидуаль укыту

индиви́дуум *м* аерым кеше, шәхес, зат

инди́го *с нескл.* индиго (*карасу-күк буяу*)

инди́ец *м* һинд, Һинд кешесе

и́ндий *м хим.* индий (*металл*)

инди́йск||ий, -ая, -ое Индия ...ы, Һиндстан ...ы, Һинд ...ы; **~ие языки́** һинд телләре

инди́йцы *мн.* һиндләр, Һинд халкы

инди́катор *м* индикатор (1. *тех. пешкәкле машиналарның цилиндрларындагы басымны үлчи торган әсбап* 2. *хим. реактив берәр химик процессның, күренешнең үзлекләрен күрсәтә торган матдә*)

индифферéнтность *ж* индифферентлык; игътибарсызлык, илтифатсызлык

индифферéнтн||ый, -ая, -ое индифферент; игътибарсыз, илтифатсыз; **~ое отноше́ние** илтифатсыз мөнәсәбәт

индонези́ец *м* индонезияле, Индонезия кешесе

индонези́йка *ж* индонезияле хатын (кыз)

индонези́йск||ий, -ая, -ое Индонезия ...ы; **~ие языки́** Индонезия телләре

индонези́йцы *мн.* индонезиялеләр, Индонезия халкы

индуи́зм *м* индуизм (*һиндләр арасында иң киң таралган дин*)

индуи́стски||ий, -ая, -ое индуизм ...ы; **~ая рели́гия** индуизм дине

индукти́вн||ый, -ая, -ое 1. *лог.* индуктив, индукциягә нигезләнгән; **~ый ме́тод** индуктив метод 2. *физ.* индукция ...ы; **~ое сопротивле́ние** индукция каршылыгы

инду́ктор *м* индуктор (*алмаш токлы кечкенә генә электромагнит машина*)

индукцио́нный, -ая, -ое *физ.* индукция ...ы: **~ ток** индукция тогы

инду́кция *ж* индукция (1. *лог. аерым фактларга нигезләп гомуми нәтиҗә чыгару методы* 2. *физ. нинди дә булса үткәргечне магнит кырында хәрәкәт иттергәндә, шул үткәргечтә электр тогы барлыкка килү*)

индульге́нция *ж* индульгенция (*чиркәү файдасына эшләнгән зур эш өчен гөнаһларны йолу турында папа грамотасы*)

нидустриализа́ция *ж* индустриализация, индустрияләштерү, индустриализацияләү; **~ се́льского хозя́йства** авыл хуҗалыгын индустрияләштерү

индустриализи́ровать, индустриализова́ть *сов., несов. что* индустриализацияләү, индустрияләштерү

индустриа́льн||ый, -ая, -ое индустриаль; **~ая страна́** индустриаль ил

инду́стрия, индустри́я *ж* индустрия; **тяжёлая ~** авыр индустрия; **лёгкая ~** җинел индустрия

инду́сы *мн.* 1. һиндлар, индуслар (*Һиндстанның җирле халыклары*) 2. *рел.* индуслар (*индуизм тарафдарлары*)

индю́к *м* күркә

индюша́тина *ж* күркә ите

индюша́чий, -ья, -ье күркә ите ...ы

индю́шеч||ий, -ья, -ье күркә ...ы; **~ьи я́йца** күркә йомыркалары

индю́шка *ж* ана күркә

и́не||й *м* бәс, сыкы; **дере́вья в ~е** бәсләнгән агачлар

ине́ртность *ж* инертлык, сүлпәнлек, дәртсезлек

ине́ртн||ый, -ая, -ое 1. *физ.* инерцияле 2. дәртсез, сүлпән; инерт; **~ый челове́к** сүлпән кеше ♦ **~ые га́зы** *хим.* инерт газлар

ине́рци||я *ж* 1. *физ.* инерция; **дви́гаться по ~и** инерция буенча хәрәкәт итү 2. *перен.* дәртсезлек, сүлпәнлек, хәрәкәтсезлек, инициативасызлык ♦ **по ~и** гадәт буенча, аңсыз рәвештә

инже́ктор *м тех.* инжектор (*пар казанына су бирә торган насос*)

инже́нер *м* инженер

инжене́рно-техни́ческ||ий, -ая, -ое инженерлык техникасы ...ы; **~ие комму́никации** инженерлык техникасы коммуникацияләре

инженéрн||ый, -ая, -ое инженерлык ...ы; инженер[лар] ...ы; **~ое де́ло** инженерлык эше

инжи́р *м* 1. (*плод*) инжир 2. (*дерево*) инжир агачы

инжи́рн||ый, -ая, -ое инжир ...ы, инжирдән әзерләнгән; **~ое варе́нье** инжир вареньесе

инициа́лы *мн.* инициаллар (*кеше һәм аның әтисе исеменең беренче хәрефләре*)

инициати́ва *ж* инициатива (**1.** *берәр яңа эшне үз теләгең белән башлап җибәру* **2.** *берәр эштә җитәкчелек роле* **3.** *үзлегеңнән актив эшләр башлап җибәрүгә булдыклылык, сәләтлелек*)

инициати́вн||ый, -ая, -ое **1.** инициативалы: **~ый челове́к** инициативалы кеше **2.** башлап җибәрүчеләр ...ы, инициаторлар ...ы; **~ая гру́ппа** инициаторлар группасы

инициа́тор *м* инициатор, башлап җибәрүче

инкасса́тор *м* инкассатор (*түләнергә, тапшырылырга тиешле акчаны гадәттә банктан чыгарга документ белән кабул итүче*)

инкасси́ровать *сов., несов. что, фин.* инкассирлау, кассага алу (*акча түләнергә тиешле документ буенча акча алу*)

инквизи́тор *м* **1.** инквизитор, инквизиция судьясе **2.** *перен.* аяусыз кеше, кансыз кеше, газаплаучы

инквизи́торский, -ая, -ое **1.** инквизитор ...ы **2.** *перен.* инквизиторларча...; аяусыз, каты, шәфкатьсез; **~ взгля́д** аяусыз караш

инквизицио́нный, -ая, -ое инквизиция ...ы; **~ суд** инквизиция суды

инквизи́ция *ж* **1.** инквизиция (*дин дошманнарына каршы көрәшү өчен католик дине тарафыннан оештырылган һәм үзенең ерткычлыклары белән танылган хөкем итү һәм җәзалау органы*) **2.** *перен.* аяусыз каты җәзалау, шәфкатьсез газаплау, каты җәфалау

и́нки *мн.* инклар (*Перу территориясендә яшәгән югары мәдәниятле борынгы халык*)

инко́гнито 1. *нареч.* яшертен, яшерен исем белән, үз исемен яшереп; **путеше́ствовать ~** яшертен сәяхәт итү **2.** *с нескл.* (*пребывание под вымышленным именем*) яшерен исем белән яшәү, яшертен яшәү; **его́ ~ раскры́лось** аның яшерен исем белән яшәве билгеле булды

инкримини́ровать *сов., несов. что кому-чему* гаеп тагу, *кемне дә булса* гаепле дип санау, жинаятьтә гаепләү

инкруста́ци||я *ж* инкрустация (*агачтан, сөяктән яки таштан ясалган әйберләргә чокып урнаштыру өчен төрле материалдан ясалган бизәкләр*); **сто́лик с перламу́тровой ~ей** перламутр инкрустацияле өстәл

инкрусти́ровать *сов., несов. что* инкрустация белән бизәү

инкуба́тор *м* инкубатор

инкубато́рий *м* инкубаторий (*инкубаторлар өчен махсус җиһазландырылган бина*)

инкуба́торн||ый, -ая, -ое инкубатор ...ы; **~ая ста́нция** инкубатор станциясе; **~ые цыпля́та** инкубатор чебешләре

инкубацио́нный, -ая, -ое *мед.* инкубация ...ы; **~ пери́од** инкубация чоры

инкуба́ция *ж* инкубация (**1.** *мед. йогышлы авыруның йоккан моментыннан алып беренче билгеләре күренә башлаганга кадәр үткән вакыт* **2.** *с.-х. инкубаторларда чебешләр чыгару*)

инкуна́була *ж* инкунабула (*1500нче елга кадәр Көнбатыш Европада типография хәрефләре белән басылган беренче китаплар*)

иново́рец *м уст.* башка диндәге кеше, кяфер

иногда́ *нареч.* (*в нек-рых случаях*) кайчакта, кайбер чакта; кайвакыт, кайвакытларда; (*время от времени*) вакыт-вакыт, ара-тирә; **он ~ прихо́дит** ул кайчакта килә; **~ он ошиба́ется** кайчакта ул хата ясый

иногоро́дн||ий, -яя, -ее башка шәһәрдәге, башка шәһәрдә торучы; **~ие подпи́счики журна́ла** журналга башка шәһәрдән язылучылар

инозе́мец *м уст. см.* **иностра́нец**

инозе́мный, -ая, -ое *см.* **иностра́нный I**

ино́й, -ая, -ое **1.** башка, бүтән, икенче төрле; **у него́ ~е мне́ние** аның фикере башка **2.** кайбер, кайсыбер, нинди дә булса, ниндидер; **~й раз на́до и отдохну́ть** кайбер очракта ял итеп алырга да кирәк **3.** *в знач. сущ.* **~й** *м* берсе, берәү; икенчесе; **~му нра́вится, ~му нет** берәүгә ошый, икенчесенә ошамый

и́нок *м уст. см.* **мона́х**

иноплане́тный, -ая, -ое башка планета[лар] ...ы

инопланетя́не *мн.* башка планетада яшәүчеләр

иноплеме́нный, -ая, -ое *уст.* башка кабилә ...ы; бүтән кабиләгә караган; башка халык ...ы

иноро́дн||ый, -ая, -ое ят, чит, башка; **~ые явле́ния** ят күренешләр; **~ое те́ло** чит җисем

иносказа́ни||е *с лит.* читләтеп әйтелгән сүз, киная; **говори́ть ~ями** кинаяләп сөйләү

иносказа́тельн||ый, -ая, -ое читләтеп әйтелгән, кинаяле; **~ое выраже́ние** кинаяле тәгъбир

иностра́нец *м* чит ил кешесе

иностра́нка *ж* чит ил хатыны (кызы)

иностра́нн||ый, -ая, -ое **1.** чит; чит ил ...ы; **~ые това́ры** чит ил товарлары; **~ые языки́** чит телләр **2.** чит ил эшләре ...ы; **министе́рство ~ых дел** чит ил эшләре министрлыгы

инохо́дец *м* юрга, юрга ат

и́ноходь *ж* юргалау

иноязы́чн||ый, -ая, -ое **1.** чит (башка) телдә сөйләшә торган; **~ое населе́ние** башка телдә сөйләшә торган халык **2.** чит тел ...ы; **~ые слова́** чит тел сүзләре

инсинуа́ция *ж книжн.* инсинуация, ялган сүзләр; яла

инсинуи́ровать *сов., несов. книжн.* яла ягу, ялган сөйләү

инспекти́ровать *несов. кого-что* тикшерү; **~ учёбные заведе́ния** уку йортларын тикшерү

инспе́ктор *м* инспектор

инспе́кторск||ий, -ая, -ое инспектор ...ы, инспекторлар ...ы, инспекторлык ...ы; **~ая прове́рка** инспекторлык тикшерүе

инспе́кция *ж* **1.** *см.* **инспекти́ровать; 2.** (*учреждение*) инспекция

инспира́тор *м книжн.* инспиратор, коткы салучы, котыртучы, яшерен коткы салучы

инспири́ровать *сов., несов.* **1.** *кого-что* коткы салып йогынты ясау, котырту, вәсвәсәләү; **~ общественное мне́ние** коткы салып җәмәгать фикеренә йогынты ясау **2.** *что* коткы салып китереп чыгару, коткы белән китереп чыгару; **~ конфли́кт** коткы белән конфликт китереп чыгару

инста́нция *ж* инстанция (*идарә итү органнары системасында үзара бер-беренә буйсынган баскычлардан гыйбарәт суд учреждениесе яки административ учреждение*)

инсти́нкт *м* **1.** *биол.* инстинкт; **~ самосохране́ния** үз-үзеңне саклау инстинкты **2.** (*внутреннее чутьё*) табигый тойгы, эчке сизем

инстинкти́вный, -ая, -ое **1.** *биол.* инстинкт ...ы; инстинктка нигезләнгән **2.** (*непроизвольный*) инстинктив, инстинктив рәвештә эшләнгән, үзеннән-үзе эшләнгән

институ́т *м* институт

институ́тск||ий, -ая, -ое институт ...ы; **~ая програ́мма** институт программасы

инструкта́ж *м* инструктаж, инструкция бирү, күрсәтмәләр бирү; **провести́ ~** инструктаж үткәрү

инструкти́вный, -ая, -ое *книжн.* инструктив, җитәкче күрсәтмәләр бирә торган; **~ докла́д** инструктив доклад

инструкти́ровать *сов., несов. кого-что* инструкция ясау, инструкция үткәрү, күрсәтмәләр бирү

инстру́ктор *м* инструктор; **~ райко́ма** райком инструкторы; **~ по стрельбе́** ату буенча инструктор

инстру́кция *ж* инструкция, күрсәтмәләр

инструме́нт *м* инструмент, корал, әсбап; **хирурги́ческие ~ы** хирургия әсбаплары; **столя́рные ~ы** балта остасы кораллары; **музыка́льные ~ы** музыкаль инструментлар

инструменталист *м* инструменталист (*музыкант*)

инструмента́льн||ый, -ая, -ое **1.** инструмент ...ы, инструментлар ...ы; **~ая сталь** инструмент корычы **2.** инструментлар ясый торган; **~ая мастерска́я** инструментлар ясый торган мастерской **3.** инструменталь, инструментта уйнала торган; **~ая му́зыка** инструменталь музыка

инструмента́льщик *м* инструментчы, инструментлар ясаучы

инструментова́ть *сов., несов. что, муз.* инструментовка ясау

инструменто́вка *ж* инструментовка (**1.** *муз. музыкаль әсәрне оркестр белән башкаруга яраклаштыру* **2.** *музыка теориясендә музыкаль инструментларның оркестрда катнашу принципларын өйрәнә торган бүлек*)

инсу́льт *м мед.* инсульт (*мидәге кан әйләнешенең бик нык бозылуы*)

инсцени́ровать *сов., несов. что* **1.** сәхнәләштерү (*әдәби әсәрне сәхнәгә куярга яраклаштыру*) **2.** *перен.* булып кылану; **~ о́бморок** хуш киткән булып кылану

инсцениро́вка *ж* **1.** *см.* **инсцени́ровать; 2.** (*постановка*) инсценировка, сәхнәләштерелгән әсәр

интегра́л *м мат.* интеграл

интегра́льн||ый, -ая, -ое **1.** *мат.* интеграль; **~ые уравне́ния** интеграль тигезләмәләр **2.** *книжн.* (*единый, целый*) бердәм, тоташ

интегра́ция *ж см.* **интегри́ровать**

интегри́рование *с см.* **интегри́ровать**

интегри́ровать *сов., несов. что, мат.* интегралын табу

интелле́кт *м* интеллект, фикерләү сәләте; **челове́к с высо́ким ~ом** югары интеллектлы кеше

интеллектуа́л *м разг.* интеллектуал, интеллектлы кеше

интеллектуа́льн||ый, -ая, -ое интеллектуаль, рухи, акыл ...ы; **~ые запро́сы** интеллектуаль ихтыяҗлар

интеллиге́нт *м* зыялы, интеллигент, укымышлы

интеллиге́нтность *ж* зыялылык, интеллигентлык, укымышлылык

интеллиге́нтный, -ая, -ое **1.** интеллигент...; укымышлы; **~ челове́к** интеллигент кеше **2.** интеллигент..., интеллигентларга хас; **~ вид** интеллигентларга хас кыяфәт

интенда́нт *м* интендант (*интендантствода хезмәт итүче*)

интенда́нтск||ий, -ая, -ое интендантлык ...ы, интендант ...ы; **~ая слу́жба** интендантлык хезмәте

интенда́нтство *с* интендантлык (*армиядә хуҗалык эшләрен алып бара торган оешма*)

интенси́вность *ж* интенсивлык, көчлелек, киреңкелек

интенси́вн||ый, -ая, -ое **1.** интенсив, көчле, киреңке; **~ый труд** интенсив хезмәт **2.** интенсив, күп җитештерүчән; **~ая систе́ма се́льского хозя́йства** авыл хуҗалыгының интенсив системасы

интенсифика́ция *ж см.* **интенсифици́ровать; ~ произво́дства** җитештерүне интенсивлаштыру; **~ земледе́лия** игенчелекне интенсивлаштыру

интенсифици́ровать *сов., несов. что, книжн.* интенсивлаштыру, интенсивлыгын арттыру, көчәйтү; **~ се́льское хозя́йство** авыл хуҗалыгын интенсивлаштыру

интерва́л *м* **1.** интервал, ара; **рабо́тать с ~ами** интервал ясый-ясый эшләү **2.** *муз., физ.* интервал; **~ в полто́на** ярты тон озынлыгындагы интервал

интерве́нт *м* интервент

интерве́нци||я *ж* интервенция; **борьба́ с ~ей** интервенция белән көрәш

интерви́дение *с* интервидение (*халыкара тапшырулар системасы һәм тапшыруларның үзе*)

интервью́ *с нескл.* интервью; **брать ~** интервью алу; **дава́ть ~** интервью бирү

интервьюи́ровать *сов., несов. кого-что* интервью алу

интере́с *м* **1.** кызыксыну, игътибар, дикъкать итү; **э́то собы́тие вызыва́ет о́бщий ~** бу вакыйга гомуми кызыксыну тудыра **2.** (*значительность*) әһәмият, мөһимлек **3.** файда, мәгънә; **нет никако́го ~а е́хать туда́** анда барудан бер файда да (бер мәгънә дә) юк **4.** *обычно мн.* **~ы** мәнфәгать, ихтыяҗ, кирәклек; **в ~ах трудя́щихся** хезмәт ияләренең ихтыяҗларыннан чыгып

интере́сн||ый, -ая, -ое **1.** кызык, кызыклы, кызыгырлык, кызыксынырлык: **~ый расска́з** кызыклы хикәя; **~ая рабо́та** кызыгырлык эш **2.** (*привлекательный, красивый*) ягымлы, сөйкемле; чибәр, матур

интересова́ть *несов. кого-что* кызыктыру, кызыксындыру

интересова́ться *несов. кем-чем* кызыксыну; **~ матема́тикой** математика белән кызыксыну

интерме́дия *ж* интермедия (*спектакльнең пәрдәләре арасында башкарыла торган кечкенә генә көлкеле пьеса*)

интерна́т *м* интернат

интернационал́ *м* **1.** (*международное объединение*) интернационал **2.** (*с прописной — гимн*) Интернационал

интернационализа́ция *ж* интернационализация, интернациональләштерү (*берәр территориядән, корылмадан, елгадан һ.б.ш. бертигез шартларда файдалануга барлык дәүләтләргә шартнамә буенча хокук бирү*)

интернационализи́ровать *сов., несов. что* интернациональләштерү, (*берәр нәрсәгә*) интернационализация игълан итү

интернационали́зм *м* интернационализм

интернациона́льный, -ая, -ое *книжн.* интернациональ, халыкара; **~ конгре́сс** халыкара конгресс

интерни́рование *с см.* **интерни́ровать**

интерни́ровать *сов., несов. кого-что* интернировать итү, иректән мәхрүм итү (**1.** *сугышучы дәүләтнең дошман як гражданнарын кулга алып бер җиргә дә җибәрми тотуы* **2.** *нейтраль дәүләтнең сугышучы дәүләт гаскәрләрен коралсызландыруы һәм вакытлыча үз дәүләтеннән чыгармый тотуы*)

интерпрета́тор *м книжн.* интерпретатор, интерпретацияләүче, аңлатучы, ачыклап бирүче

интерпрета́ция *ж книжн.* интерпретация (**1.** *берәр нәрсәне аңлату, мәгънәсен ачып бирү* **2.** *үзеңнең аңлатмаңа нигезләнеп берәр музыкаль, әдәби әсәрне яки драматик рольне иҗади башкару*)

интерпрети́ровать *сов., несов. что, книжн.* интерпретация ясау, аңлату, ачыклап бирү, мәгънәсен ачып бирү

интерфере́нция *ж физ.* интерференция (*төрле чыганаклардан чыга торган аваз, яктылык дулкыннарының һ.б.ш. үзара тәэсир итешүләре*)

интерье́р *м* интерьер (*бинаның эчке ягы*)

инти́мность *ж* интимлык, якын дуслык, ахирәтлек, чын күңелдән якынлык

инти́мный, -ая, -ое **1.** интим, чын (ихлас) күңелдән ...; **~ разгово́р** ихлас күңелдән сөйләшү **2.** интим, иң якын; ахирәт; **~ друг** иң якын дус

интоксикацио́нный, -ая, -ое *мед.* интоксикация ...ы, интоксикацион, интоксикациядән булган; **~ психо́з** интоксикациядән булган психик авыру

интоксика́ция *ж мед.* интоксикация, агулану; **лека́рственная ~** дарудан агулану

интона́ци||я *ж в разн. знач.* интонация; **вопроси́тельная ~я** *лингв.* сорау интонациясе; **с шутли́вой ~ей** шаяру интонациясе белән; **фальши́вая ~я** *муз.* хата интонация

интони́ровать *несов. книжн.* (*берәр*) интонация белән әйтү (башкару, җырлау, уйнау); **непра́вильно ~** ялгыш интонация белән башкару

интри́га *ж* **1.** интрига, астыртын эш; мәкер **2.** *лит.* интрига (*драмада яки романда төп вакыйгаларның үсеше*)

интриган́ *м* интригачы, интриган, интрига белән шөгыльләнүче, астыртын эш йөртүче

интригова́||ть *несов.* **1.** *против кого-чего* интрига алып бару, интрига кору, хәйлә кору **2.** *кого-что* кызыксындыру, кызыксыну уяту, кызыксыну тудыру; **всех ~л его́ таи́нственный вид** аның серле кыяфәте бөтен кешеләрдә кызыксыну тудыра иде

introду́кция *ж муз.* интродукция (*музыкаль әсәрнең кереш өлеше*)

интуити́вн||ый, -ая, -ое интуитив, интуициягә нигезләнгән; **~ое чу́вство** интуитив тойгы

интуи́ция *ж* интуиция (*элекке тәҗрибәгә таянып дөрес сиземләү*); **у него́ то́нкая ~** аның интуициясе көчле

инфантили́зм *м мед.* инфантилизм (*калкансыман бизнең эшчәнлеге җитәрлек булмау сәбәпле өлкәннәрдә балалардагы кебек физик һәм психик яктан артта калу*)

инфанти́льность *ж книжн.* инфантильлек

инфанти́льный, -ая, -ое *книжн.* **1.** инфантиль, җитлекмәгән **2.** балаларга хас, балаларча ...; **~ тон** балаларга хас тон

инфа́ркт *м* инфаркт

инфекцио́нн||ый, -ая, -ое йогышлы; **~ые заболева́ния** йогышлы авырулар

инфе́кция *ж* инфекция, йогыш

инфильтра́т *м биол., мед.* инфильтрат

инфильтра́ция *ж биол., мед.* инфильтрация (*тән тукымаларының табигый состав өлеше булмаган теге я бу элементларның тукымаларга үтеп керүләре һәм анда тупланулары*)

инфинити́в *м грам.* инфинитив; **глаго́л в фо́рме ~а** инфинитив формасындагы фигыль

инфля́ция *ж эк.* инфляция (*илдә чамадан тыш күп чыгарылу нәтиҗәсендә кәгазь акчаның бәясе төшү*)

информати́вность *ж* информативлык

информати́вный, -ая, -ое информатив, информациягә бай

информа́тор *м* информатор, информация биреп торучы, хәбәр итеп торучы

информацио́нн||ый, -ая, -ое информацион ..., информация ...ы; **~ый отде́л** информация бүлеге; **~ое сообще́ние** информацион белдерү

информа́ци||я *ж* **1.** *см.* **информи́ровать; 2.** информация, белдерү, хәбәр; **кра́ткая ~я** кыска информация; **дать ~ю** информация ясау

информи́ровать *сов., несов. кого-что* информация ясау, белдерү, белдереп тору, хәбәр итү

инфракра́сн||ый, -ая, -ое: **~ые лучи́** *физ.* инфракызыл нурлар; **~ое излуче́ние** *физ.* инфракызыл нурланыш

инфузо́рия *ж* инфузория (*бер күзәнәкле микроскопик су хайваны*)

инциде́нт *м* инцидент, бәрелеш; аңлашылмау; **пограни́чный ~** чик буенда булган вакыйга ♦ **~ исче́рпан** бәрелеш бетте

инъе́кци||я *ж* инъекция; дару җибәрү: **сде́лать ~ю** инъекция ясау

ио́н *м физ.* ион

ионриза́ция *ж физ.* ионизация; ионлашу, ионизацияләну; **~ га́зов** газларның ионизацияләнүе

ионизи́ровать *сов, несов. физ.* ионлаштыру, ионизацияләү

ио́нн||ый, -ая, -ое *физ.* ион ...ы, ионнар ...ы; **~ая реа́кция** ионнар реакциясе

ипоте́ка *ж эк.* ипотека (*күчми торган милекне закладка салу, шул заклад өчен алынган ссуда*)

ипохо́ндрик *м* ипохондрик, ипохондрия белән авыручы

ипохо́ндрия *ж* ипохондрия, күңел төшенкелеге, өметсезлек, ямансулау

ипподро́м *м* ипподром (*атлар чабыштыру мәйданы*)

ипри́т *м* иприт (*агулы газ*)

ира́кский, -ая, -ое гыйрак ...ы; Гыйрак ...ы

ира́кцы *мн.* гыйраклылар

ирани́ст *м* иранист (*иран телләрен һәм мәдәниятен өйрәнүче галим*)

ира́нск||ий, -ая, -ое Иран ...ы; **~ие языки́** Иран телләре

ира́нцы *мн.* ираннар, иранлылар

и́рис *м* **1.** ирис (*сары һәм шәмәхә төсле эре чәчәкле үсемлек*) **2.** (*нитки*) ирис

ири́с *м* ирис (*конфет*)

ирла́ндский, -ая, -ое ирланд ...ы; Ирландия ...ы; **~ язы́к** ирланд теле

ирла́ндцы *мн.* ирландиялеләр

иронизи́ровать *несов. над кем-чем* мыскыллап көлү, кимсетеп көлү, ирония белән көлү

ирони́ческ||ий, -ая, -ое иронияле, астыртын көлеп, астыртын мыскыллап; **~ая улы́бка** астыртын мыскыллап елмаю

ио́ния *ж* ирония (*оста итеп астыртын көлү*) ♦ **~ судьбы́** язмыш ирониясе

иррационали́зм *м филос.* иррационализм

иррациона́льность *ж филос., мат.* иррациональлек

иррациона́льный, -ая, -ое иррациональ (**1.** *филос. идеалистик философиядә: логик төшенчә белән аңлатып биру мөмкин булмаган, акыл ирешә алмый торган; мистик* **2.** *мат. берәмлек белән улчәнми торган*)

ирреа́льный, -ая, -ое *книжн.* иррациональ, реаль булмаган; чынбарлыкта булмый торган

иррегуля́рн||ый, -ая, -ое *книжн.* иррегуляр, регуляр булмаган; **~ые войска́** иррегуляр гаскәрләр

иррига́тор *м* ирригатор, сугару белгече

ирригацио́нн||ый, -ая, -ое ирригация ...ы, сугару ...ы; **~ая систе́ма** ирригация системасы

иррига́ция *ж* ирригация, сугару

иск *м* дәгъва (*судка мөрәҗәгать итү*)

искажа́ть *несов. см.* **искази́ть**

искажа́ться *несов.* **1.** *см.* **искази́ться; 2.** *страд. от* **искажа́ть**

искаже́ни||е *с* **1.** *см.* **искази́ть, искази́ться; 2.** ялгыш, хата; **гру́бые ~я в те́ксте** текстта гыру тупас хаталар

искажённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **искази́ть; 2.** (*извращённый*) бозылган, бозык **3.** (*изменившийся — о лице, наружности*) бик нык үзгәргән

искази́ть *сов. что* **1.** бозу, бозып күрсәтү **2.** бик нык үзгәртү, сыту (*чырайны*)

искази́ться *сов.* **1.** бозылу **2.** бик нык үзгәрү; сытылу (*чырай турында*)

искале́ченн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **искале́чить; 2.** гарип, гарипләнгән, имгәнгән; **~ая рука́** имгәнгән кул **3.** *перен.* бозылган; **~ая жизнь** бозылган тормыш

искале́чи||ть *сов. кого-что* **1.** имгәтү, гарипләү **2.** *перен.* бозу; **дурно́е воспита́ние ~ло ребёнка** начар тәрбия баланы бозды

искале́читься *сов.* имгәнү, гарипләну, гарипләнеп бетү

иска́ни||е *с* **1.** *см.* **иска́ть 1; 2.** *мн.* **~я** эзләнүләр; **твóрческие ~я** ижади эзләнүләр

иска́тел||ь *м* **1.** эзләүче, эзләп йөрүче; **~и женьше́ня** женьшень эзләүчеләр **2.** *тех.* эзләгеч ♦ **~ь приключе́ний** мажаралар эзләүче

иска́тельный, -ая, -ое яраргa тырышучан; ялагайланулы; ялагай; **~ взгляд** ялагайланулы караш

иска́ть *несов. кого-что, чего* эзләү; **~ по́вод** сылтау эзләү; **~ ссо́ры** ызгыш эзләү; **~ спасе́ния** котылу юлын эзләү ♦ **ищи́-свищи́** *разг.* җилләр искән

исклева́ть *сов.* **1.** *кого-что* чукып бетерү, чукып яралап бетерү **2.** *что* (*всё съесть — о птицах*) чукып ашап бетерү

исключа́ть *несов. см.* **исключи́ть**

исключа́я 1. *деепр. от* **исключи́ть; 2.** *предлог с род.п.* ... башка[лар]; **~ меня́** миннән башка

исключе́ни||е *с* **1.** *см.* **исключи́ть 1; 2.** чыгарма; читләшү; **нет пра́вила без ~я** чыгармасыз кагыйдә булмый; **ни для кого́ не мо́жет быть ~я** беркем дә читләшә алмаячак

исключи́тельно *нареч.* **1.** искиткеч, гажәп, аеруча, бигрәк тә; **~ вку́сное блю́до** искиткеч тәмле аш **2.** *в знач. частицы выделит.-огранич.* фәкать, бары, тик, бары тик, гына; **пре́мию получи́ли ~ отли́чники** премияне тик отличниклар гына алды

исключи́тельность *ж* **1.** үзенчәлекле булу, аерымлылык; **~ явле́ния** күренешнең үзенчәлекле булуы **2.** (*замкнутость, обособленность*) өстенлекле булу, өстенлелек

исключи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** махсус, үзенә бер аерым; **~ые права́** махсус хокуклар **2.** гадәттән тыш; **~ый слу́чай** гадәттән тыш вакыйга **3.** *разг.* бик яхшы, искиткеч, бик шәп; **изде́лия ~ого ка́чества** бик яхшы сыйфатлы әйберләр

исключи́ть *сов.* **1.** *кого-что* чыгару, чыгарып ташлау, төшерү; **~ из спи́сков** исемлекләрдән чыгару; **~ из шко́лы** мәктәптән чыгару **2.** *что* (*не допустить, устранить*) юл куймау, юл калдырмау, мөмкинлек калдырмау; **~ возмо́жность невыполне́ния пла́на** планның үтәлми калу мөмкинлегенә юл куймау ♦ **э́то исключено́** моңа урын юк

искове́рканн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **искове́ркать; 2.** (*сломанный, изломанный*) ватылган, ватык, җимерек **3.** *перен.* бозылган; бозык; **~ая жизнь** бозылган тормыш

искове́ркать *сов.* **1.** *что* (*сломать, испортить*) ватып бетерү, вату **2.** *перен. кого-что* бозу, бозып бетерү; **~ чью-л. фами́лию** *кемнең дә булса* фамилиясен бозу

иско́в||ый, -а́я, -о́е дәгъва ...ы; **~о́е заявле́ние** дәгъва гаризасы

исколеси́ть *сов. что* йөреп чыгу; **~ всю о́бласть** бөтен өлкәне йөреп чыгу

исколоти́ть *сов.* **1.** *кого* кыйнап ташлау, тукмап ташлау **2.** *что* кага-кага ватып бетерү, бозып бетерү; **~ сте́ну гвоздя́ми** стенаны кадаклар кага-кага бозып бетерү

исколо́ть *сов. кого-что* чәнечкәләп бетерү, чәнчеп [тишкәләп] бетерү, чәнчеп [яралап] бетерү; **~ все па́льцы** барлык бармакларны чәнчеп бетерү

исколо́ться *сов.* чәнчелеп яралану, чәнчелеп [яраланып] бетү

иско́м||ый, -ая, -ое **1.** *мат.* эзләнә торган, табылырга тиеш булган; **~ая величина́** эзләнә торган зурлык **2.** (*нужный, требуемый*) эзләнә торган, ачыкланырга тиеш булган

исконни́ *нареч. уст.* борын-борыннан, элек-электән, бик, күптәннән; **эти́ поря́дки существова́ли ~** бу тәртипләр борын-борыннан килә иде

иско́нн||ый, -ая, -ое күптәнге, күптәннән..., тәп; **~ое пра́во** күптәнге хокук; **~ый жи́тель** күптәннән торучы

ископа́ем||ый, -ая, -ое **1.** казылма, казып табыла торган; **~ые минера́лы** казып табыла торган минераллар **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* казылмалар, казылма әйберләр; **поле́зные ~ые** файдалы казылмалар **3.** *геол.* казылмаларда табыла торган; **~ые живо́тные** казылмаларда табыла торган хайваннар

ископа́||ть *сов. что* казу, казып бетерү; **они́ ~ли весь двор** бөтен ишек алдын казып бетергәннәр

искорёжить *сов. что, прост.* калҗайту, калҗайтып бетерү; вату, ватып бетерү

искорёжиться *сов. прост.* калҗаеп бетү, ватылу

искорене́ние *с см.* **искорени́ть, искорени́ться**

искорени́ть *сов. что* тамырын корыту, юк итү, юкка чыгару, бетерү; **~ недоста́тки** кимчелекләрнең тамырын корыту

искорени́ться *сов.* бөтенләй юкка чыгу, тамыры кору, бетү

искореня́ть *несов. см.* **искорени́ть**

искореня́ться *несов.* **1.** *см.* **искорени́ться**; **2.** *страд. от* **искореня́ть**

и́скоса *нареч. разг.* кырыннан, астан гына, күз кырые белән генә; **~ взгляну́ть** күз кырые белән генә карау

и́скр||а *ж* **1.** очкын, чаткы; **электри́ческая ~а** электр очкыны **2.** *перен.* чаткы; **~ы наде́жды** өмет чаткылары **3.** энҗедәй бөртек; **~ы сне́га** энҗедәй кар бөртекләре ◆ **~ы из глаз посы́пались** күздән утлар күренде

и́скренн||ий, -яя, -ее эчкерсез, саф, керсез, саф күңелле, турылыклы, ихлас күңелле; **~ий челове́к** эчкерсез кеше; **~яя ра́дость** эчкерсез шатлык

и́скренность *ж* эчкерсезлек, саф күңеллелек, турылыклылык, ихлас күңеллелек

искриви́ть *сов. что* **1.** кәкрәйтү; бөгү; **~ гвоздь** кадакны кәкрәйтү **2.** (*лицо*) бозу, сыту (*чырайны*)

искриви́||ться *сов.* **1.** кәкрәю, бөгелү; **гвоздь ~лся** кадак кәкрәйде **2.** (*о лице*) бозылу; үзгәреп китү

искривле́ние *с* **1.** *см.* **искриви́ть, искриви́ться**; **2.** (*искривлённое место*) кәкрәйгән урын, бөгелгән урын **3.** *полит.* (*кабул ителгән төп юнәлештән*) тайпылу, читләшү; тайпылыш; (төп юнәлешне) бозу

искривля́ть *несов. см.* **искриви́ть**

искри́ст||ый, -ая, -ое **1.** чемердәп тора торган, уйнап тора торган; **~ое вино́** чемердәп тора торган шәраб **2.** җемелдәп торган, җем-җем итә торган; **~ый снег** җемелдәп торган кар

искри́ть *несов. эл.* очкын чыгару, чаткы чыгару

и́скри||ться, искри́||ться җемелдәү, җемелдәп тору, ялтырау, ялтырап тору; **снег ~тся** кар җемелди

и́скровец *м* искрачы (*1900нче елда В.И. Ленин тарафыннан оештырылган «Искра» газетасы төркеменә кергән революционер*)

искрово́й, -а́я, -о́е **1.** очкын ...ы, чаткы ...ы **2.** очкынлы, чаткылы; **~ разря́д** чаткылы бушану; **~ переда́тчик** очкынлы тапшыргыч

искромётный, -ая, -ое үткен; янып торган; **~ взгляд** үткен караш

искромса́ть *сов. что, разг.* ботарлап бетерү, кискәләп бетерү, тураклап бетерү

искроши́ть *сов.* **1.** *что* ваклау, ваклап бетерү, турап бетерү, тураклап бетерү **2.** *перен. кого-что* (*изрубить*) [кылыч белән] чапкалап (турап) бетерү, тураклап бетерү

искупа́ть I *несов. см.* **искупи́ть**

искупа́ть II *сов.* (*вы́купать*) коендырып алу, коендырып чыгару

искупа́ться *сов.* коенып алу, коенып чыгу; **~ в реке́** елгада коенып алу

искупи́ть *сов. что* йолу, йолып алу; гафу ителү; **~ свою́ вину́** үз гаебеңне йолу

искупле́ние *с* йолу, гафу ителү; **~ вины́** гаепне йолу

иску́с, и́скус *м книжн.* сынау; **тяжёлый ~** авыр сынау; **вы́держать ~** сынаудан узу

искуса́ть *сов. кого-что* тешләп бетерү, тешләп (чәйнәп) бетерү, талау

искуси́тель *м книжн.* [күнел] аздыручы, вәсвәсәче, вәсвәсә салучы, коткы салучы

иску́сник *м* оста; **большо́й ~ в своём де́ле** үз эшенең зур остасы

иску́сница *ж* оста хатын (кыз)

иску́сн||ый, -ая, -ое **1.** оста; **~ый портно́й** оста тегүче **2.** оста эшләнгән, оста башкарылган; **~ая рабо́та** оста башкарылган эш

иску́сственность *ж* ясалмалык, рыялылык, эчкерлелек

иску́сственн||ый, -ая, -ое **1.** ясалма, табигый булмаган; **~ые цветы́** ясалма чәчәкләр **2.** рыялы, ялган; **~ая улы́бка** рыялы елмаю

иску́сств||о *с* **1.** сәнгать; **изобрази́тельное ~о** сынлы сәнгать; **произве́дения ~а** сәнгать әсәрләре **2.** (*мастерство*) осталык; **с большо́м ~ом** зур осталык белән ◆ **из любви́ к ~у** сәнгатькә мәхәббәт йөзеннән

искусствове́д *м* сәнгать белгече, сәнгать белеме галиме

искусствове́дение *с* сәнгать белеме, сәнгать фәне, сәнгать турындагы фән

искусствове́дческ||ий, -ая, -ое сәнгать ...ы, сәнгать фәне ...ы; сәнгать фәннәре ...ы; **~ие нау́ки** сәнгать фәннәре

искуша́ть *несов. кого-что* вәсвәсә салу, вәсвәсәләндерү, коткы салу ◆ **~ судьбу́** язмышны сынап карау

искуше́ни||е *с см.* **искуша́ть; подда́ться ~ю** коткыга бирелү; **вводи́ть в ~е** коткы салу

искушённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **искуша́ть**; **2.** остарган, шомарган; **~ в спо́рах** бәхәсләрдә шомарган; **~ о́пытом** тәжрибәле, күпне күргән

ислам́ *м* ислам, ислам дине

исла́ндский, -ая, -ое исланд ...ы; Исландия ...ы; **~ язы́к** исланд теле

исла́ндцы *мн.* исландлар, исландияләр, Исландия халкы

испа́костить *сов. что, прост.* (*загрязнить*) шакшылап (пычратып) бетерү

испа́нец *м* испан, испанияле, Испания кешесе

испа́нка I *ж* испан хатын (кыз)

испа́нка II *ж* испанка (*грипп авыруы төре*)

испа́нский, -ая, -ое испан ...ы; Испания ...ы; **~ язы́к** испан теле

испа́нцы *мн.* испаннар, испанияләр, Испания халкы

испаре́ни||е *с книжн.* **1.** *см.* **испари́ть, испари́ться** I; **2.** *обычно мн.* **~я** парлар, булар; **вре́дные ~я** зарарлы парлар

испа́рин||а *ж* тир; **покры́ться ~ой** тиргә бату

испари́тель *м* буга (парга) әйләндергеч

испари́ть *сов. что* буга (парга) әйләндерү (әверелдерү)

испари́||ться *сов.* **1.** буга (парга) әйләнү (әверелү) **2.** *перен. шутл.* сызу, шылу, таю; (*о деньгах*) бетү; **он то́тчас же ~лся** ул шунда ук сызды

испаря́ть *несов. см.* **испари́ть**

испаря́ться *несов.* **1.** *см.* **испари́ться**; **2.** *страд. от* **испаря́ть**

испа́чкать *сов. кого-что* буяп (пычратып) бетерү

испа́чкаться *сов.* буялып (пычранып) бетү

испепели́ть *сов. кого-что* [яндырып] көлгә әйләндерү, көл итү ◆ **~ гне́вом** ачу белән көйдерү; **~ взгля́дом** караш белән көйдереп алу

испепеля́ть *несов. см.* **испепели́ть**

испестри́ть *сов. что* чуарлау, чуарлап бетерү

испе́чь *сов. что* пешерү, пешереп житкерү

испе́чься *сов.* пешү, пешеп җитү

испещри́ть *сов. что* чуарлап бетерү (*таплар белән*); **~ стол черни́льными пя́тнами** өстәлне кара таплары белән чуарлап бетерү

испещря́ть *несов. см.* **испещри́ть**

исписа́ть *сов. что* **1.** язып тутыру, язып бетерү; **~ лист бума́ги** кәгазь битен язып тутыру **2.** (*истратить*) язуга тотып бетерү (*мәс. карандашны, кәгазьне, караны*)

исписа́||ться *сов.* **1.** яза-яза бетү; **каранда́ш ~лся** карандаш яза-яза бетте **2.** *перен. разг.* яза-яза эштән чыгу, яза алмас хәлгә килү (*язучылар һ.б.ш. турында*)

испи́сывать *несов. см.* **исписа́ть**

испит||о́й, -а́я, -о́е *разг.* ябык, арык, чандыр, йончыган; **~о́е лицо́** ябык бит

испове́дание *с книжн.* дин, иман

испове́дать *сов. разг. см.* **испове́довать**

испове́даться *сов. разг. см.* **испове́доваться**

испове́дник *м.* **1.** (*священник*) тәүбә иттерүче **2.** (*тот, кто пришёл на исповедь*) тәүбәче, тәүбә-истигъфарчы

испове́довать 1. *несов. что* (*юлын, динен*) тоту, (*диненэ*) ышану; ~ **ислáм** ислам динен тоту 2. *сов., несов. кого-что* тәүбәгә китерү, тәүбә иттерү

испове́доваться *сов., несов.* 1. тәүбә-истигъфар кылу, тәүбә иту 2. *разг. шутл.* (*ачыктан-ачык*) сөйләп бирү

и́споведь *ж* 1. тәүбә-истигъфар, тәүбә, тәүбә иту 2. *перен.* чын күңелдән әйтеп бирү, чын күңелдән ачып салу

и́сподволь *нареч. разг.* алдан акрынлап, азлап-азлап; **он ~ стал гото́виться к отъе́зду** ул алдан ук акрынлап юлга чыгарга хәзерләнә башлады

испо́длобья *нареч.* маңгай астыннан, каш җыерып; **смотре́ть ~** маңгай астыннан карау

испо́дниз(у) *нареч. разг.* астан, (*берәр нәрсә*) астыннан

испо́дн||ий, -яя, -ее *прост.* 1. эчке; **~яя руба́шка** эчке күлмәк 2. *в знач. сущ.* **~ее** *с* күлмәк-ыштан

испо́дтишка́ *нареч.* астыртын, яшертен; **де́йствовать ~** астыртын эш итү

испоко́н: ~ ве́ку (ве́ков) күптәннән, борын-борыннан, элек-электән, мәңгедән

исполи́н *м* 1. (*великан, богатырь*) алып, батыр, әзмәвер 2. *перен.* зур кеше, дәһи; **~ы нау́ки** фән дәһилары

исполи́нск||ий, -ая, -ое 1. алып ...ы, әзмәвер ...ы; гадәттән тыш зур; **челове́к ~ого ро́ста** гадәттән тыш озын буйлы кеше 2. бик зур, гадәттән тыш зур колач; **~ие пла́ны** бик зур планнар

исполко́м *м* башкарма комитет

исполне́ни||е *с* 1. *см.* **испо́лнить** I; **прове́рка ~я** үтәлешне тикшерү ◆ **во ~е** *чего* тормышка ашыру максаты белән, үтәү йөзеннән

испо́лненный, -ая, -ое 1. *прич. от* **испо́лнить** II; 2. тулган, чолгап алган, сугарылган; **~ гне́ва** ачу белән сугарылган

исполни́м||ый, -ая, -ое үтәлерлек, бышкарылырлык, тормышка ашырырлык; **~ое жела́ние** үтәлерлек теләк

исполни́тель *м* үтәүче; башкаручы ◆ **суде́бный ~** суд исполнителе

исполни́тельница *ж* башкаручы хатын (кыз), үтәүче хатын (кыз)

исполни́тельность *ж* эшне төгәл үтәүчәнлек, эшне төгәл башкаручанлык

исполни́тельный, -ая, -ое 1. башкаручы, башкарма, башкара торган; тормышка ашыручы; **~ комите́т** башкарма комитет 2. (*старательный*) эшне төгәл үтәүчән, эшне төгәл башкаручан ◆ **~ лист** башкару кәгазе

испо́лнить I *сов. что* 1. үтәү, тормышка ашыру; башкару; **~ прика́з** приказны үтәү 2. башкару, уйнау; **~ роль** рольне башкару

испо́лнить II *сов. кого-что, уст.* сугару, тутыру; рухландыру; **~ се́рдце наде́ждой** күңелне өмет белән рухландыру

испо́лни||ться I *сов.* 1. үтәлү, тормышка ашу; башкарылу; **жела́ние моё ~лось** минем теләгем тормышка ашты 2. *кому-чему* үтү, тулу, булу; **ма́льчику ~лось де́сять лет** малайга ун яшь тулды

испо́лни||ться II *сов. чем, чего* тулу; сугарылу; **душа́ её ~лась ра́достью** аның күңеле шатлык белән тулды

исполня́ть I *несов. см.* **испо́лнить** I

исполня́ть II *см.* **испо́лнить** II

исполня́ться I *несов.* 1. *см.* **испо́лниться** I; 2. *страд. от* **исполня́ть** I

исполня́ть II *несов. см.* **испо́лниться** II

исполосова́ть *сов. разг.* 1. *что* телгәләп бетерү, тураклап бетерү; **~ мате́рию** материяне телгәләп бетерү 2. *кого-что* (*избить*) камчы белән кыйнау, чыбыркылау, яру

и́сполу *нареч. уст.* уртакка, уртагына; **обраба́тывать зе́млю ~** җирне уртакка эшкәртү

испо́льзовать *сов. несов. кого-что* файдалану, куллану; **~ те́хнику** техниканы куллану; **~ достиже́ния нау́ки** фән казанышларын файдалану

испо́льз||оваться *несов.* 1. файдаланылу, кулланылу; **на произво́дстве ~уется но́вая те́хника** производствода яңа техника кулланыла 2. *страд. от* **испо́льзовать**

испо́льн||ый, -ая, -ое *уст.* уртакка эшләү ...ы, уртакка эшләнә торган; **~ая систе́ма** уртакка эшләү системасы

испо́льщик *м уст.* уртакка эшләүче (*крестьян*)

испо́льщина *ж уст.* уртакка эшләү испольщина (*уңышның яртысын җирнең хуҗасына түләүдән гыйбарәт булган аренда төре*)

испо́ртить *сов.* 1. *что* бозу, бозып бетерү; эштән чыгару, харап итү; **~ механи́зм** механизмны бозу; **~ отноше́ния** мөнәсәбәтләрне бозу 2. *кого-что* бозу; **~ плохи́м воспита́нием** начар тәрбиялә бозу

испо́ртиться *сов.* 1. бозылу, бозылып бетү; эштән чыгу 2. (*нравственно*) бозылу

испо́рченность *ж* бозыклык, әхлаксызлык

испо́рченн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **испо́ртить**; 2. бозылган, бозык; ватык, ватылган; **~ый замо́к** ватык йозак 3. бозык, әхлаксыз; эштән чыккан; **~ый челове́к** бозык кеше 4. (*гнилой*) черегән, исләнгән, бозылган; **~ое мя́со** исләнгән ит

исправи́м||ый, -ая, -ое төзәлерлек; төзәтелерлек, төзәтергә ярарлык; **э́то де́ло ~ое** бу эш төзәтелерлек

исправи́тельно-трудов||о́й, -а́я, -о́е хезмәт белән төзәтү ...ы; **~-а́я коло́ния** хезмәт белән төзәтү колониясе

исправи́тельн||ый, -ая, -ое төзәтү ...ы, төзәтә торган; **~ые ме́ры** төзәтү чаралары

испра́вить *сов.* 1. *что* төзәтү; **~ замо́к** йозакны төзәтү 2. *кого-что* төзәтү; яхшырту; **~ хара́ктер** характерны төзәтү

испра́виться *сов.* төзәлү, яхшыру

исправле́ни||е *с* 1. *см.* **испра́вить, испра́виться**; 2. төзәтмә, төзәтү; **внести́ ~я в текст** текстка төзәтмәләр кертү

исправля́ть *несов. см.* **испра́вить**

исправля́ться *несов.* 1. *см.* **испра́виться**; 2. *страд. от* **исправля́ть**

испра́вник *м* исправник (*революциягә кадәрге Россиядә өяз полициясе начальнигы*)

испра́вност||ь *ж* төзеклек, эшкә яраклылык; эшкә ярарлык хәл; **~ь маши́ны** машинаның төзеклеклеге; **содержа́ть обору́дование в ~и** җиһазны эшкә ярарлык хәлдә тоту

испра́вный, -ая, -ое 1. төзек, эшкә яраклы; **~ мото́р** эшкә яраклы мотор 2. тыңлаучан; тырыш, күңел биреп эшли торган; **~ рабо́тник** тырыш хезмәткәр

испражне́ни||е *с* 1. *см* **испражня́ться**; 2. *мн.* **~я** тизәк, тәрәт

испражня́ться *несов.* тышка чыгу, тәрәт итү, зур йомышны үтәү

испро́бова||ть *сов. что* 1. сынау, сынап карау; **~ть но́вый инструме́нт** яңа коралны сынап карау 2. сынап карау; **он ~л мно́го профе́ссий** ул күп профессияләрне сынап карады 3. тату, татып карау; **~ть ку́шание** ашны татып карау

испроси́ть *сов. что, уст.* сорап алу; юллап алу; **~ разреше́ние** юллап рөхсәт алу

испу́г *м* курку, куркыну, шүрләү, кот чыгу, кот очу; (*о животном*) өркү; **с ~у** куркудан; **брать на ~** куркытып алдыру (җинү)

испу́ганный, -ая, -ое 1. *прич. от* **испуга́ть**; 2. куркулы; (*обычно о животном*) өркүле; **~ вид** куркулы кыяфәт

испуга́ть *сов. кого-что* куркыту, котын алу, котын очыру; (*обычно животное*) өркетү

испуга́ться *сов. кого-чего* курку, кот чыгу, кот очу; (*о животном*) өркү

испуска́ть *несов. см.* **испусти́ть**

испусти́ть *сов. что* (*запах*) аңкыту, тарату; (*звук*) тавыш бирү, кычкыру; **~ крик** тавыш бирү ◆ **~ дух (после́дний вздох)** *уст.* үлү, вафат булу; соңгы сулышны алу

испыта́ние *с* 1. *см.* **испыта́ть**; **~ дви́гателя** двигательне сынап карау 2. (*экзамен*) имтихан, сынау 3. (*невзгоды*) авыр сынау, авырлык

испы́танн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **испыта́ть**; 2. эштә тикшерелгән, сыналган; **~ый бо́ец** сыналган сугышчы; **~ое сре́дство** сыналган чара

испыта́тельный, -ая, -ое сынау ...ы, сынап карау ...ы; **~ срок** сынау срогы

испыта́ть *сов.* 1. *кого-что* сынау, сынап карау, тикшерү; **~ мото́р** моторны сынап карау 2. *что* кичерү, баштан кичерү, баштан үткәрү ,тату; **~ го́лод** ачлыкны баштан кичерү; **~ ра́дость** шатлык кичерү

испыту́емый, -ая, -ое сынала торган, тикшерелә торган; **~ матери́ал** сынала торган материал

испыту́ющий, -ая, -ее сынап ..., тикәп ..., сынаулы; **~ взгляд** сынап карау

испы́тывать *несов. см.* **испыта́ть**

иссека́ть *несов. см.* **иссе́чь** I

и́ссера- соргылт; **~-голубо́й** соргылт зәңгәр

иссе́чь I *сов. что* **1.** (*вытесать*) уеп ясау, юнып ясау **2.** *мед.* кисеп алу,кисеп ташлау; **~ о́пухоль** шешне кисеп ташлау

иссе́чь II *сов. кого-что* (*избить кнутом, плетью и т.п.*) кыйнау, тукмау, камчылау, чыбыркылау

и́ссиня- зәңгәрсу; **~-чёрный** зәңгәрсу кара

исследи́ть *сов. что, разг.* таптап бетерү, таптап пычратып бетерү

иссле́дование *с* **1.** *см.* **иссле́довать**; **2.** тикшеренү, фәнни хезмәт, фәнни әсәр; **~ по ру́сскому языку́** рус теле буенча фәнни хезмәт

иссле́дователь *м* тикшеренүче, тикшерүче, өйрәнүче

иссле́довательск||ий, -ая, -ое тикшеренү ..ы, тикшерү ...ы, фәнни тикшеренү ...ы, фәнни тикшерү ...ы; **~ая рабо́та** фәнни тикшеренү эше; **~ий институ́т** тикшеренү институты

иссле́довать *сов., несов.* **1.** *что* фәнни тикшерү, фәнни яктан тикшерү; **~ зако́ны приро́ды** табигать законнарын фәнни тикшерү **2.** *кого-что* (*җентекләп*) карау, (*җентекләп*) тикшерү, (*җентекләп*) карап чыгу; **~ ме́стность** тирәякны тикшереп чыгу; **~ больно́го** авыруны тикшерү

иссо́х||нуть *сов.* **1.** кибү, кибеп бету; **ре́ки ~ли** елгалар кибеп беткән **2.** *перен.* ябыгу, ябыгып бетү, кибү; **~нуть от тоски́** сагыштан кибү

и́сстари *нареч.* борынгыдан, электән, искедән; **так ~ ведётся** борынгыдан шулай килә

исстрада́ться *сов.* җәфаланып бетү, йончып бетү

исстреля́ть *сов. что* **1.** атып бетерү, атуга тотып бетерү; **~ все патро́ны** барлык патроннарны атып бетерү **2.** атып тишкәләп бетерү; **~ всю ми́шень** бөтен мишеньне атып тишкәләп бетерү

исступле́ни||е *с* чиксез ярсу, шашыну, котыру; **в ~и** шашынып, чиксез ярсып, шашынган хәлдә; **до ~я** шашынганчы, шаштырганчы

исступлённость *ж* чиксез ярсыганлык, шашынганлык, котыру

исступлённый, -ая, -ое чиксез ярсыган, шашынган; чиксез ярсулы; **~ крик** шашынып кычкыру

иссуша́ть *несов. см.* **иссуши́ть**

иссуши́||ть *сов.* **1.** *что* киптереп бетерү; **жара́ ~ла боло́то** эсселек сазлыкны киптереп бетергән **2.** *перен. кого-что* ябыктырып бетерү; арыкландырып бетерү, киптерү; **го́ре ~ло его́** кайгы аны ябыктырып бетергән

иссыха́ть *несов. см.* **иссо́хнуть**

иссяка́ть *несов. см.* **исся́кнуть**

исся́к||нуть *сов.* **1.** кору, корып бетү; кибү, кибеп бетү; юкка чыгу; **исто́чник исся́к** чишмә кибеп беткән **2.** *перен.* бетү; **си́лы врага́ ~ли** дошманның көчләре бетте; **терпе́ние моё ~ло** минем чыдамым бетте

иста́птывать *несов. см.* **истопта́ть**

иста́сканн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **истаска́ть**; **2.** тузган; таушалган; **~ые сапоги́** тузган итекләр **3.** *перен.* таушалган, таушалып беткән; **~ое лицо́** таушалып беткән йөз

истаска́ть *сов. что, разг.* (*износить*) киеп туздыру, киеп туздырып бетерү, киеп таушалдырып бетерү

истаска́ться *сов.* **1.** (*износиться*) киелеп тузып бетү, киелеп искереп бетү **2.** *перен.* таушалу, таушалып бетү

иста́чивать *несов. см.* **источи́ть**

иста́ять *сов.* **1.** (*растаять*) бөтенләй эреп бетү **2.** *перен.* ябыгып бетү; сызып бетү; **~ от тоски́** сагыштан ябыгып бетү

истека́ть *несов. см.* **исте́чь**

исте́кш||ий, -ая, -ее үткән, узган; тәмамланган; **в ~ем году́** үткән елда

истере́ть *сов. что* **1.** кыру, кырып бетерү; **~ морко́вь на тёрке** кишерне кыргычта кырып бетерү **2.** ышкый-ышкый бетерү (юкка чыгару); **~ рези́нку** резинканы ышкый-ышкый бетерү

истере́ться *сов.* ышкый-ышкый бетү (юкка чыгу); ышкылып тузып бетү; **подо́шва истёрлась** олтан ышкылып тузып бетте

исте́рзанный, -ая, -ое **1.** ерткаланып беткән, тетелеп (теткәләнеп) беткән; **~ вид** киеме ерткаланып беткән кыяфәт **2.** *перен.* җәфаланып беткән, газапланып беткән; йончыган; **~ го́рем** кайгыдан җәфаланып беткән

истерза́||ть *сов. кого-что* җәфалап бетерү, йончыту, газаплап бетерү; **го́ре ~ло его́** аны кайгы җәфалап бетергән

истерза́ться *сов.* җәфаланып (йончып, газапланып) бетү

исте́рик *м разг.* истерик, истерика белән авыручы

исте́рика *ж* истерика, шашыну

истери́ческ||ий, -ая, -ое **1.** истерия ...ы, **~ий припа́док** истерия өянәге **2.** истерик, истерия белән авыручы; **~ая же́нщина** истерик хатын **3.** истерик, шашынулы; **~ий смех** шашынулы көлү

истери́чка *ж разг.* истерик хатын (кыз)

истери́чный, -ая, -ое *см.* **истери́ческий** 2,3

истери́я *ж* истерия (*нерв. авыруы*) ◆ **вое́нная ~** хәрби истерия (*империалистик илләрдә сугышка өндәү һәм шашынып кораллану*)

исте́ц *м юр.* дәгъвачы (*суд эшендә*)

истече́ни||е *с см.* **исте́чь**; **по ~и полóженного сро́ка** билгеләнгән срок беткәч, беткәннән соң; **~е сро́ка полномо́чий** вәкаләтнең срогы чыгу

ист||е́чь *сов.* бетү, тәмамлану, чыгу, үтү, тулу; **срок ~ёк** срок утте ◆ **~е́чь кро́вью** 1) күп кан югалту; 2) *высок.* (*сугышта*) зур югалтуларга дучар булу

и́стин||а *ж* **1.** *филос.* хакыйкать; **объекти́вная ~а** объектив хакыйкать **2.** дөреслек; хакыйкать; хаклык; **скрыва́ть ~у** дөреслекне яшерү; **доби́ться ~ы** хакыйкатькә ирешү ◆ **напра́вить (иста́вить) на путь ~ы** дөрес юлга чыгару (өндәү)

и́стинн||ый, -ая, -ое **1.** дөрес, чын, хак; **~ая пра́вда** чын дөреслек **2.** чын; **~ый друг** чын дус

истира́ть *несов. см.* **истере́ть**

истира́ться *несов.* **1.** *см.* **истере́ться**; **2.** *страд. от* **истира́ть**

исти́ца *ж юр.* дәгъвачы хатын (кыз)

истлева́ть *несов. см.* **истле́ть**

истле́||ть *сов.* **1.** череп бетү; черү; **мате́рия ~ла** материя череп беткән **2.** пыскып янып бетү, пыскып көлгә әйләнү; **у́гли ~ли** кумерләр янып беткәннәр

и́стовый, -ая, -ое *уст.* (*усердный*) чын күңелдән эшләнгән, ихлас күңелдән эшләнгән

исто́к *м* **1.** чыганак, су башы, елга башы, чишмә башы; **от ~а до у́стья** елга башыннан тамагына кадәр **2.** *обычно мн.* **~и** *перен. чего* башлангыч, башлангыч чор; барлыкка килү; **у ~ов цивилиза́ции** цивилизациянең башлангыч чорында

истолкова́ние *с см.* **истолкова́ть**; **дать ~** *чему-л. бирәр нәрсәгә* аңлатма бирү

истолкова́тель *м* аңлатып бирүче, комментатор

истолкова́ть *сов. что* аңлату, аңлатып бирү, төшендерү, төшендереп бирү; тәгъриф итү; **~ смысл выраже́ния** тәгъбирнең мәгънәсен аңлатып бирү

истолко́вывать *несов. см.* **истолкова́ть**

истоло́чь *сов. что* төеп ваклау, ваклап бетерү

исто́м||а *ж* рәхәт изрәү, рәхәт ою; **в сла́дкой ~е** тәмле итеп рәхәт изрәү

истоми́ть *сов. кого-что* хәлдән тайдыру, йончытып (зарыктырып) бетерү; **~ ожида́нием** көттереп зарыктырып бетерү

истоми́ться *сов.* хәлдән таю, йончып (зарыгып) бетү

истопи́ть I *сов. что* **1.** (*печку*) ягу, ягып җылыту **2.** *разг.* ягып бетерү, ягуга тотып бетерү; **~ кубоме́тр дров** бер кубометр утын ягып бетерү

истопи́ть II *сов. что, разг.* эретеп бетерү; **~ весь воск** бөтен балавызны эретеп бетерү

истопи́||ться I *сов.* [ягудан] җылыну; ягылып бетү; **печь ~лась** мич янып бетте

истопи́ться II *сов. разг.* (*расплавиться*) эреп бетү

истопни́к *м.* мич ягучы

истопни́ца *ж* мич ягучы хатын (кыз)

истопта́ть *сов. что* **1.** таптап бетерү; **~ траву́** үләнне таптап бетерү **2.** *разг.* (*испачкать следами*) таптап пычратып бетерү **3.** *разг.* (*износить обувь*) туздырып бетерү (*аяк киемен*)

исторга́ть *несов. см.* **исто́ргнуть**

исто́ргнуть *сов. что, уст.* бәреп чыгару; **вулка́н исто́рг ла́ву** вулкан лаваны бәреп чыгара ◆ **~ крик** кычкырып җибәрү

истори́зм *м* тарихилык

исто́рик *м* тарихчы

исто́рико-революцио́нный, -ая, -ое тарихи-революцион

историо́граф *м* историография белгече

ИСТ-ИТО

историогра́фия *ж* историография (*тарих белеме үсешен һәм тарихи чыганакларны өйрәнә торган фән*)

истори́ческ||ий, -ая, -ое **1.** тарих ...ы; **~ая нау́ка** тарих фәне **2.** тарихи; **~ий рома́н** тарихи роман; **~ая да́та** тарихи дата

истори́чный, -ая, -ое тарихи дөрес, тарихи фактларга туры килә торган

исто́ри||я *ж* **1.** *в разн. знач.* тарих; **зако́ны ~и** тарих законнары; **~я сре́дних веко́в** урта гасырлар тарихы; **~я на́шей дру́жбы** безнең дуслыкның тарихы **2.** вакыйга, хәл; **попа́сть в неприя́тную ~ю** күңелсез хәлгә очрау ♦ **~я ума́лчивает** *о чём, шутл.* бу турыда бернәрсә дә сөйләмиләр

истосковáться *сов. по кому-чему и без доп., разг.* сагыну, сагынып бетү, сагынып-саргаеп бетү; ямансулау

исто́чать *несов. что, книжн.* аңкыту, тарату

исто́чи||ть *сов. что* **1.** кайрый-кайрый юкартып бетерү; **~ть нож** пычакны кайрый-кайрый юкартып бетерү **2.** тишкәләп бетерү; ашап бетерү; **жучо́к ~л де́рево** коңгыз агачны тишкәләп бетергән

исто́чник *м* **1.** чишмә, кизләү, чыганак; **~ не́фти** нефть чыганагы **2.** *перен.* чыганак, нигез; **со́лнце — ~ све́та и тепла́** кояш яктылыкның һәм җылылыкның чыганагы **3.** (*письменный памятник*) язма чыганак ♦ **~ всех зол (бед)** бөтен бәлаләрнең башы

исто́шн||ый, -ая, -ое *разг.* ачы, йөрәк өзгеч, йөрәк яргыч, йөрәк әрнеткеч; **крича́ть ~ым го́лосом** ачы тавыш белән кычкыру

истощáть *несов. см.* **истощи́ть**

истощáться *несов.* **1.** *см.* **истощи́ться 2.** *страд. от* **истощáть**

истоще́ние *с* **1.** ябыгу; арыгаю, арыклану; **по́лное ~ организ́ма** организмның тулысынча арыкларуы **2.** бик нык кимү; бетү, тотылып бетү; **~ припа́сов** азыкларның тотылып бетүе **3.** (*почвы*) ярлылану, бетү (*азык матдәләре*)

истощённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **истощи́ть**; **2.** ябыккан, арык, арыкланган; **~ вид** ябыккан кыяфәт **3.** (*о почве*) ярлыланган, уңдырышлылыгы беткән

истощи́||ть *сов.* **1.** *кого-что* ябыктыру, арыгайту, арыкландыру; **боле́знь кра́йне ~ла его́** авыру аны бик нык ябыктырган **2.** *что* бик нык киметү; бетерү, калдырмау; **~ть запа́сы** запасларны бик нык кимету **3.** (*почву*) ярлыландыру, уңдырышлыгын бетерү

истощи́||ться *сов.* **1.** (*изнуриться*) ябыгу, арыгаю, арыклану **2.** бетү, калмау, тотылып бетү; **запа́сы продово́льствия ~лись** азык запаслары тотылып бетте; **терпе́ние его́ ~лось** түземлеге калмады **3.** (*о почве*) ярлылану, уңдырышлылыгы бетү

истра́тить *сов. что* **1.** тотып бетерү; сарыф итү; **~ де́ньги** акчаны тотып бетерү **2.** түгү, салу, сарыф итү, кую; **~ си́лы** көч түгү; **~ вре́мя** вакыт сарыф итү

истреби́тель *м* **1.** кырып бетерүче, үтереп бетерүче; **~ грызуно́в** кимерүчеләрне кырып бетерүче **2.** (*боевой самолёт*) истребитель

истреби́тельн||ый, -ая, -ое **1.** һәлак итә торган, һәлак иткеч; кыра торган; **~ый ого́нь артилле́рии** артиллериянең һәлак иткеч уты **2.** истребительләр ...ы, истребительләрдән торган; **~ый отря́д** истребительләр отряды; **~ая авиа́ция** истребительләр авиациясе

истреби́ть *сов. кого-что* кырып бетерү, үтереп бетерү, юк итү, бетерү

истребля́ть *несов. см.* **истреби́ть**

истрепа́ть *сов. что, разг.* туздырып бетерү, таушалдырып бетерү; **~ кни́гу** китапны таушалдырып бетерү; **~ пальто́** пальтоны туздырып бетерү ♦ **~ не́рвы** нервларны бетерү

истрепа́||ться *сов. разг.* тузып бетү, таушалып бетү; искереп бетү ♦ **не́рвы у него́ ~лись** аның нервлары беткән

истре́скаться *сов. разг.* чатнап ярылып бетү, яргаланып бетү

истука́н *м* **1.** (*изваяние*) тораташ, балбал, пот **2.** *бран.* бүкән; күзле бүкән ♦ **стоя́ть ~ом** *или* **как ~** тораташ кебек басып тору, багана кебек катып тору

иступи́ть *сов. что* үтмәсләндереп бетерү; **~ нож** пычакны үтмәсләндереп бетерү

иступи́ться *сов.* үтмәсләнеп бетү

и́стый, -ая, -ое чын; **~ учёный** чын галим

исты́кать *сов. кого-что, разг.* чәнечкәләп бетерү, чәнчеп (кадап) тишкәләп бетерү; **~ игóлкой** инә белән чәнечкәләп бетерү

истяза́тель *м* газаплаучы, интектерүче, җәфалаучы

истяза́ть *несов. кого-что* бик каты газаплау, интектеру. җәфалау

исхлеста́ть *сов. кого-что* камчылау, камчы белән кыйнау

исхлёстывать *несов. см.* **исхлеста́ть**

исхлопота́ть *сов. что* юллап алу, артыннан йөреп алу; **~ разреше́ние** рөхсәт юллап алу

исхо́д *м* тәмамлану, бетү; нәтиҗә; **~ де́ла** эшнең нәтиҗәсе; **на ~е дня** көн ахырында; **де́ньги на ~е** акча бетеп бара

исходáтайствовать *сов. что, книжн.* юллап алу, артыннан йөреп алу; **~ пе́нсию** пенсия юллап алу

исходи́ть I *сов. что, разг.* йөреп чыгу, җәяү йөреп чыгу; **~ все окре́стные леса́** әйләнә-тирәдәге урманнарны җәяү йөреп чыгу

исходи́ть II *несов.* **1.** *от кого, из чего* ...дан чыгу; таралу, алыну; **све́дения исхо́дят из ве́рных исто́чников** мәгълүматлар дөрес чыганаклардан чыга **2.** *из чего* ...дан чыгу, ... [дан чыгып] эш итү; **~ из учёта всех обстоя́тельств** барлык шартларны исәпкә алып эш итү

исходи́ть III *несов. см.* **изойти́**

исхо́дн||ый, -ая, -ое чыгыш ...ы; баштагы, элекке; **~ый пункт** чыгыш пункты; **~ая то́чка зре́ния** баштагы караш

исходя́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **исходи́ть** II; **2.** (*учреждениедән һ.б.ш.*) җибәрелә торган, чыга торган; **~ая бума́га** җибәрелә торган кәгазь

исхуда́лый, -ая, -ое бик ябык, бик арык, ябыккан, арыгайган

исхуда́ть *сов.* бик нык ябыгу, бик нык арыклану

исцара́пать *сов. кого-что* тырнап бетерү

исцара́пывать *несов. см.* **исцара́пать**

исцеле́ние *с см.* **исцели́ть, исцели́ться**

исцели́тель *м книжн.* сәләмәтләндерүче, савыктыручы

исцели́ть *сов. кого-что, книжн.* сәләмәтләндерү, савыктыру, терелтү

исцели́ться *сов. книжн.* сәләмәтләнү, савыгу, терелү

исцеля́ть *несов. см.* **исцели́ть**

исцеля́ться *несов.* **1.** *см.* **исцели́ться; 2.** *страд. от* **исцеля́ть**

иса́дие *с уст.*: **~ сатаны́** иблис токымы; **~ а́да** тәмуг кисәве

исчеза́ть *несов. см.* **исче́знуть**

исче́знуть *сов.* бетү, югалу, юкка чыгу, юк булу

исчёркать, исчёркать *сов. что, разг.* сызгалап бетерү (*кәгазьне*)

исчёркивать *несов. см.* **исчёркать**

исче́рпать *сов. что* **1.** тотып бетерү; сарыф итеп бетерү; **~ все сре́дства** бөтен средстваларны тотып бетерү **2.** (*выполнить*) карап бетерү, тәмам итү, тәмамлау

исче́рпывать *несов. см.* **исче́рпать**

исче́рпывающий, -ая, -ее тулы; **~ отве́т** тулы җавап

исчерти́ть *сов. что* **1.** сызгалап бетерү, сызыклар белән тутыру (*кәгазьне*) **2.** сызып бетерү, сызуга тотып бетерү; **~ весь мел** акбурны сызуга тотып бетерү

исче́ртить *несов. см.* **исчерти́ть**

исчи́ркать *сов. что, разг.* сызып бетерү, кабызып бетерү (*шырпыны*)

исчи́слить *сов. что* исәпләп чыгару

исчисля́ть *несов. см.* **исчи́слить**

исчисля́||ться *несов.* **1.** исәпләнү; **запа́сы хле́ба ~ются миллио́нами тонн** икмәк запаслары миллионнарча тонналар белән исәпләнә **2.** *страд. от* **исчисля́ть**

ита́к *союз* димәк, шулай итеп; **~ вопро́с решён** шулай итеп, мәсьәлә хәл ителде

италья́нец *м* италияле, Италия кешесе

италья́нка *ж* италияле хатын (кыз) Италия хатыны (кызы)

италья́нский, -ая, -ое итальян ...ы, италиялеләр; Италия ...ы; **~ язы́к** итальян теле

италья́нцы *мн.* итальяннар, италиялеләр, Италия халкы

ито́г *м* **1.** (*общая сумма*) барысы, барлыгы **2.** нәтиҗә, йомгак; **~ и перегово́ров** сөйләшүләрнең йомгаклары ♦ **в ~е** нәтиҗәдә

итого́ *нареч.* (*в итоге*) барысы, барлыгы, бөтенесе

итого́в||ый, -ая, -ое **1.** барлык, бөтен; **~ая су́мма** барлык сумма **2.** йомгак, йомгаклау ...ы; **~ые заня́тия** йомгаклау дәресләре

иу́да *м бран.* (*предатель, изменник*) хыянәтче, сатлык, иуда

иудаи́зм *м* иудаизм, яһүд дине

иуде́и *мн.* яһүдләр

иуде́й *м* яһүд, яһүд кешесе

иуде́йка *ж* яһүд хатыны (кызы)

ихтиоза́вр *м* ихтиозавр (*казылдык диңгез хайваны*)

ихтио́л *м* ихтиол (*майсыман дару*)

ихтио́лов||ый, -ая, -ое ихтиол ..ы; **~ая мазь** ихтиол мае

ихтио́лог *м* ихтиолог, ихтиология белгече

ихтиологи́ческий, -ая, -ое ихтиология ...ы; **~ отде́л музе́я** музейның ихтиология бүлеге

ихтиоло́гия *ж* ихтиология (*балыкларны өйрәнү фәне*)

ишА́к *м* ишәк

и́шиас *м* янбаш сызлау, ишиас

ишь *частица прост.* кара, кара син аны, әнә; **~ ты како́й бы́стрый!** кара, нинди тиз син!

ищЕ́**йка** *ж* **1.** (*собака*) ищейка, эзләүче эт **2.** *перен. разг.* (*сыщик*) шымчы

ию́ль *м* июль, июль ае

ию́льск||ий, -ая, -ое июль ...ы; **~ие дни** июль көннәре

ию́нь *м* июнь, июнь ае

ию́ньский, -ая, -ое июнь ...ы

Й

йог *м* йог (*һиндстандагы дини һәм философик тәгълиматьнең иярчене: кешенең психикасы һәм физиологиясе белән идарә итү турындагы өйрәтмә һәм методлар тарафдары*)

йогу́рт *м* йогырт, болгар катыгы

йод *м* йод

йо́дист||ый, -ая, -ое йодлы; **~ая соль** йодлы тоз

йо́дный, -ая, -ое йод ...ы; **~ раство́р** йод эремәсе

йодофо́рм *м* йодоформ (*йодтан ясалган препарат*)

йот *м* йот (*латин алфавитында «j», рус алфавитында «й» хәрефе белән бирелә торган тартык аваз*)

йо́т||а *ж* йота (*грек алфавитында «и» хәрефе*) ◆ **ни на ~у** аз гына да

йоти́рование *с см.* **йоти́ровать**

йоти́рованн||ый, -ая, -ое *лингв.* йотлаштырылган; **~ая гла́сная** йотлаштырылган сузык

йоти́ровать *сов., несов. что, лингв.* йотлаштыру (*йот авазы белән әйтү*)

К, (ко) *предлог с дат. п.* **1.** ...га; **обраща́ться к друзья́м** дусларга мөрәҗәгать итү; **гото́виться к экза́менам** имтиханнарга хәзерләнү; **к шести́ приба́вить семь** алтыга жидене кушу; **приго́дный к употребле́нию** файдаланырга яраклы; **присоедини́ться к большинству́** күпчелеккә кушылу; **приходи́ть к ука́занному сро́ку** күрсәтелгән вакытка килү; **позва́ть к телефо́ну** телефонга чакыру; **к оруже́ию!** коралга! **2.** ...га, ...га [таба]; **плыть к бе́регу** ярга [таба] йөзү; **напра́виться к ле́су** урманга [таба] юнәлү; **к ве́черу похолода́ло** кичкә [таба] салкынайтты **3.** ...янына, ... кырына; **подойти́ к столу́** өстәл янына килү; **он подсе́л ко мне** минем кырыма утырды **4.** ...га карата, турында; **к вопро́су разви́тия языка́** тел үсеше мәсьәләләренә карата; **к столе́тию писа́теля** язучының йөз еллыгына карата **5.** ...га каршы; **к сча́стью** бәхеткә каршы; **к вели́кому сожале́нию** зур үкенечкә каршы ◆ **к приме́ру** мисал өчен, мисалга; **к сло́ву [сказа́ть]** сүз уңаеннан; *кем-нәрсә* дигәннән; **к сло́ву, где он сейча́с рабо́тает?** дигәннән, хәзер ул кайда эшли?; **к тому́ же** шуның өстенә

-ка *частица разг.* әле, ...чы, ...сәнә; **спо́й-ка** җырлачы; **ну́-ка покажи́** я әле, күрсәт; **напишу́-ка я письмо́** хат язып ташлыйм әле

каба́к *м уст.* кабак (*революциягә чаклы иксерткечлар сату урыны*)

кабал||а́ *ж* **1.** *ист.* кабала, коллык **2.** кабала, тулы бәйлелек; **попа́сть в ~у́** кабалага эләгү

кабали́стика *ж* кабалистика (*урта гасырларда еврейларның төрле хорафатларга һәм мистикага нигезләнгән йолалары*)

каба́льн||ый, -ая, -ое **1.** *ист.* кабала ...ы; **~ая за́пись** кабала язмасы **2.** *ист.* кабаладагы; бәйле; **~ые холо́пы** кабаладагы хезмәтчеләр **3.** (*тяжёлый, изнурительный*) кабалалы; авыр

каба́н *м* **1.** (*дикий*) кабан дуңгызы **2.** (*самец домашней свиньи*) ата дуңгыз

каба́н||ий, -ья, -ье кабан дуңгызы ...ы; кабан дуңгызлары ...ы; **~ье ста́до** кабан дуңгызлары көтүе

кабарга́ *ж зоол.* кабарга

кабарди́нец *м* кабардалы; кабарда

кабарди́нка *ж* кабарда хатыны (кызы)

кабарди́нский, -ая, -ое кабарда ...ы; кабардалы ...; Кабарда ...ы

кабарди́нцы *мн.* кабардалылар, кабардалар

кабаре́ *с нескл.* кабаре (*эстрадалы кечкенә ресторан*)

кабачко́в||ый, -ая, -ое ташкабак ...ы; **~ая икра́** ташкабак икрасы

кабачо́к I *м* кечкенә кабак

кабачо́к II *м* (*овощ*) ташкабак (*яшелчә*)

ка́бель *м* кабель (*изоляция белән тышланган электр уткәргече*); **телефо́нный ~** телефон кабеле

ка́бельн||ый, -ая, -ое кабель ...ы; **~ая ли́ния** кабель линиясе; **~ый заво́д** кабель заводы

каби́на *ж* кабина; **~ лётчика** очучы кабинасы; **~ самосва́ла** үзбушаткыч кабинасы; **~ для перегово́ров по телефо́ну** телефоннан сөйләшү кабинасы

кабине́т *м в разн. знач.* кабинет; **~ дире́ктора** директор кабинеты; **зубоврачебный ~** теш врачы кабинеты; **~ мини́стров** министрлар кабинеты

кабине́тн||ый, -ая, -ое **1.** кабинет ...ы; **~ая ме́бель** кабинет мебеле **2.** *перен.* практикадан ерак (аерылган), практикага нигезләнмәгән; **~ый учёный** практикадан аерылган галим

каблогра́мма *ж спец.* каблограмма (*кабель буенча тапшырылган телеграмма*)

каблу́к *м* үкчә (*аяк киемендә*); **ту́фли на высо́ких ~а́х** биек үкчәле туфли ◆ **быть под ~о́м** *у кого кемнең дә булса* олтырагы булу (*ихтыярына тулысынча буйсыну турында*)

кабота́ж *м мор.* каботаж (*бер үк диңгез яки дәүләтнең портлары арасында йөри торган яр буе судночылыгы*)

кабриоле́т *м* кабриолет (*ике тәгәрмәчле җиңел арба*)

кабы́ *союз прост.* әгәр, әгәр дә

кавале́р I *м* кавалер (**1.** *парлы танецта хатын-кыз белән биюче ир кеше* **2.** *хатын-кызга аеруча илтифат курсәтеп, аның кәефен табарга тырышучы ир кеше*)

кавале́р II *м* кавалер (*орден белән бүләкләнгән кеше*); **~ о́рдена Оте́чественной войны** Ватан сугышы ордены кавалеры

кавалерга́рд *м* кавалергард (*патша армиясендә атлы гвардия полкында хезмәт итүче солдат яки офицер*)

кавалери́йский, -ая, -ое кавалерия ...ы; кавалерист[лар] ...ы; **~ полк** кавалерия полкы

кавалери́ст *м* кавалерист

кавале́рия *ж* кавалерия, атлы гаскәр; **лёгкая ~** җиңел кавалерия

кавалька́да *ж* кавалькада, атлылар (җайдаклар) төркеме

каварда́к *м разг.* тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык, ыгы-зыгы

ка́верза *ж разг.* мәкер, хәйлә

ка́верзн||ый, -ая, -ое **1.** буталчык, четерекле, кыен чишелешле; **~ое де́ло** буталчык эш; **~ый вопро́с** четерекле мәсьәлә **2.** мәкерле; **~ый челове́к** мәкерле кеше

каве́рна *ж* **1.** *мед.* каверна (*берәр авыру тәэсирендә организмның таркалуыннан барлыкка килгән бушлык*); **~ в лёгких** үпкә кавернасы **2.** *геол.* куышлык, мәгарә

кавка́зск||ий, -ая, -ое: **~ие языки́** кавказ телләре

кавка́зцы *м* кавказлылар, кавказ халкы

кавы́чк||и *мн.* куш җәяләр (тырнаклар); **взять в ~и** куш җәяләр эченә алу ◆ **в ~ах** *ирон.* куш җәяләрдә

КАГ-КАК

кагóр *м* кагор (*шәраб*)

кадéт I *м воен. уст.* кадет, кадетлар корпусында укучы

кадéт II *м* кадет (*революциягә чаклы Россиядә конституцион-демократик партия дип аталган партия вәкиле*)

кади́ло *с* кадило (*чиркәүдә ладан яндырып төтәсли торган металл савыт*)

кади́ть *несов. церк.* ладан төтене белән ыслау, төтәсләү

ка́дка *ж* кисмәк

ка́дмий *м* кадмий (**1.** *химик элемент, ялтыравыклы йомшак ак металл* **2.** *шул металлдан ясалган сары буяу*)

кадр *м* кадр (**1.** *кино яки фотоплёнкадагы аерым сурәт* **2.** *кинофильмнан аерым сцена яки эпизод*)

кадри́ль *ж* кадриль (*алты кешелек танец һәм шул танецның музыкасы*)

кадрови́к *м разг.* кадровик (**1.** *кадровый хезмәткәр* **2.** *кадрлар бүлеге хезмәткәре*)

ка́дров||ый, -ая, -ое **1.** кадровый, регуляр, даими; **~ый офице́р** кадровый офицер; **~ая а́рмия** даими армия **2.** кадровый, төп, хәзерлекле; **~ый рабо́чий** төп эшче

ка́др||ы *только мн.* **1.** кадр (*хәрби частьларның тыныч вакыттагы даими составы*) **2.** *собир.* кадрлар (*берәр эштә, производствода эшләүчелер составы*) ◆ **отдéл ~ов** кадрлар бүлеге

кадýшка *ж* кечкенә кисмәк

кадык *м* бугаз төене, чалу сөяге

каёмка *ж* кайма

каждоднéвный, -ая, -ое һәр көнге, көндәлек, көн саен була торган; **~ труд** көндәлек хезмәт

ка́жд||ый, -ая, -ое *мест.* **1.** һәр, саен; һәрберсе, һәркайсы; **~ый день** һәр көн көн саен **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* һәркем; **э́то зна́ет ~ый** моны һәркем белә ◆ **на ~ом шагу́** адым саен, һәр адымда

каза́к *м* казак; **донско́й ~** Дон казагы ◆ **во́льный ~** ирекле кеше

казаки́н *м* кәзәки (*киен*)

каза́н *м* казан, зур казан

каза́рма *ж* казарма

каза́рменн||ый, -ая, -ое казарма ...ы, казармадагы ◆ **быть на ~ом положе́нии** казармада яшәү

каза́ть *несов. кого-что, прост.*: **не ~ глаз (но́су)** күренмәү, эзе дә булмау

каза́ться *несов.* **1.** *кем-чем* күренү, булып күренү; **~ ста́рше свои́х лет** үзенең яшенә караганда өлкәнрәк булып күренү **2.** *безл. кому* кебек тоелу; **мне ка́жется, кто́-то стучи́т** миңа кемдер шакылдый кебек тоела **3.** *в знач. вводн. сл.* **ка́жется** бугай, ахры, ахрысы, булса кирәк; **он ~, согла́сен?** ул риза бугай?

каза́х *м* казах, казакъ, казах кешесе

каза́хи *мн.* казахлар, казакълар, казах халкы

каза́хск||ий, -ая, -ое казах[лар] ...ы; **~ие сте́пи** казах далалары

каза́цк||ий, -ая, -ое казак ...ы; **~ая са́бля** казак кылычы

каза́чество *с собир.* казаклар

каза́ч||ий, -ья, -ье казак[лар] ...ы; **~ьи пе́сни** казак җырлары; **~ий ата́ман** казаклар атаманы

каза́чка *ж* казак хатыны (кызы)

казачо́к *м* **1.** *уст.* казачок, хезмәтче малай **2.** казачок (*тизләнешле бию һәм шул биюнең музыкасы*)

каза́шка *ж* казах хатыны (кызы)

казе́ин *м* казеин (*сөт составындагы аксым матдәсе*)

казе́иновый, **-**ая, -ое казеин ...ы казеинлы; казеиннан ясалган; **~ клей** казеиннан ясалган җилем

казема́т *м* казамат (**1.** *төрмә камерасы* **2.** *артиллерия һәм авиация утыннан саклану өчен бетон корылма*)

казённ||ый, -ая, -ое **1.** казна ...ы; **~ое иму́щество** казна милке **2.** *перен.* формаль, бюрократларча ...; **~ый подхо́д к де́лу** эшкә формаль мөнәсәбәт **3.** *перен.* гади, гадәти; коры, ярлы, төссез; **~ый стиль** коры стиль; **~ый язы́к** коры тел ◆ **~ая пала́та** казна палатасы (*революциягә кадәрге Россиядә: губернада акчалата салымнарны җыю белән идарә иткән учреждение*); **~ая часть** *воен.* (*мылтыкның яки орудиенең*) арткы өлеше

казёнщина *ж разг.* коры формальлек (формализм); казенлылык

казна́ *ж уст.* **1.** (*государственное имущество*) казна, дәүләт **2.** (*деньги*) милек, хәзинә, акча

казначе́й *м* казначей (*учреждение, оешмалар акчасын саклаучы*); **~ профко́ма** профком казначее

казначе́йск||ий, -ая, -ое **1.** казначейлык ...ы; **~ая до́лжность** казначейлык вазифасы **2.** казна ...ы, казначей ...ы; **~ие биле́ты** казначей билетлары

казначе́йство *с* казначейство (*кайбер илларда җирле финанс органы*)

казни́ть **1.** *сов., несов. кого-что* җәзалап үтерү **2.** *несов. перен. кого-чем и без доп.* газаплау, җәзалау; **~ презре́нием** нәфрәтле караш белән газаплау

казни́ться *несов.* үтә газаплану, артык борчылу

казнокра́д *м уст.* казна талаучы, дәүләт милкен үзләштерүче

казнь *ж* үлем җәзасы, җәзалап үтерү

казуи́ст *м* казуист (*ялган һәм шикле дәлилләр китерергә оста кеше*)

казуи́стика *ж* казуистика (**1.** *гомуми догматик схоластик положениеләрне аерым хосусый очракларга карата куллану теориясе* **2.** *перен. ялган яки шикле положениеләрне исбат итүдә осталык, тапкырлык*)

ка́зус *м* казус, катлаулы (буталчык) вакыйга

ка́зусный, -ая, -ое катлаулы, буталчык, четерекле

ка́ин *м* хаин, канечкеч (*кан коючы, зур җинаятьче турында*)

кайла́ *ж*, **кайло́** *с* кәйлә

кайм||а́ *ж* кайма; **плато́к с ~о́й** каймалы яулык

кайнозо́йск||ий, -ая, -ое: **~ая э́ра** *геол.* кайнозой эрасы (*Җирнең геологик тарихында иң яңа эра*)

как **1.** *нареч. вопр. и относ.* ничек; **~ э́то случи́лось**? бу эш ничек булды?; **я забы́л, ~ э́то называ́ется** мин моның ничек аталганын онытттым **2.** *нареч. опред.* нинди; **~ краси́во!** нинди матур! **3.** *нареч.* бик, шул тикле; **~ я рад тебя́ ви́деть** сине күрүемә бик шатман **4.** *частица* кинәт; **она́ ~ закрича́ла!** ул кинәт кычкырып җибәрмәсенме! **5.** *частица воскл.* (*выражает негодование, удивление, сожаление и т.п.*) ничек, бәй; **~! Ты ещё здесь!** бәй! Син мондамыни әле **6.** *союз сравн.* кебек, сыман, шикелле, ...дай; **бе́лый ~ снег** кар шикелле ак **7.** *союз присоед.* буларак, булу ягыннан; **Пу́шкин ~ ли́рик** Пушкин лирик буларак **8.** *союз временной* ...гач та, ...у белән; **~ прие́дешь домо́й сообщи́** кайту белән хәбәр ит **9.** *союз временной* ...ганнан соң, ...ганнан бирле, ...ганга; **прошёл год, ~ мы ви́делись** без күрешкәннән бирле бер ел узды ◆ **вот ~!** шулаймыни!, алай икән!, менә ничек!; **~ бу́дто** әйтерсең, гүя, гүяки, ...дай, ...ган шикелле, бугай; **бежа́л так бы́стро, ~ бу́дто за ним гнали́сь** шул чаклы каты йөгерде, гүяки артыннан куалар; **ка́к бы** ...а, алса ярар иде; **ка́к бы нам упра́виться с рабо́той к сро́ку** эшне үз вакытында үти алсак ярар иде; **ка́к бы не** 1) ...а күрмәсен[нәр]; **боюсь, ка́к бы не стал он брани́ться** куркам, ул сүгенә күрмәсен; 2) ...магае; **ка́к бы не́ было дождя́** яңгыр булмагае, яңгыр яумагае; **ка́к бы не так!** шулай, булмыйни!, булмый торсын әле!; **ка́к бы то ни́ было** ничек кенә булмасын, ничек кенә булса да; **~ вдруг** көтмәгәндә, искәрмәстән, искәрмәгәндә, кинәт; **~ ви́дно** күрәсең, мөгаен, ахрысы; **~ есть** *прост.* нәкъ, чеп-чи; **он ~ есть болва́н** ул чеп-чи тинтәк; **ка́к же** әлбәттә; **вы испо́лнили мою́ про́сьбу? — А ка́к же!** сез минем үтенечемне үтәдегезме? — Әлбәттә!; **~ наро́чно** үч иткәндәй, юри эшләгәндәй; **~ ни говори́** ни генә әйтсәң дә; **~ мо́жно** *или* **~ нельзя́** мөмкин кадәр; **~ мо́жно ча́ще** мөмкин кадәр еш рак; **~ нельзя́ лу́чше** мөмкин кадәр яхшырак; **как ра́з** нәкъ, таман, чак; **ка́к так?** ничек инде ул?, ничек инде ул алай?; **~ то́лько** ...гач та, ...гач ук, ...у белән; **~ то́лько вернёшься**... кайткач та; **~ сле́дует** тиешенчә, җитәрлек; **~ сказа́ть** анда күз күрер, анысы икеле әле; **~ ско́ро** (*уст. когда*) кайчан ...; **~ ..., так и** *союз перечисл.* ...да ...да; **вы́полним план ~ пе́рвого, так и второ́го кварта́ла** беренче квартал планын да, икенче квартал планын да үтәрбез

какаду́ *м нескл.* какаду (*бүрекле попугай*)

какао́ *с нескл.* **1.** какао, шоколад агачы **2.** какао (*порошок һәм эчемлек*)

ка́к-либо *нареч. см.* **ка́к-нибудь** I

ка́к-нибудь, как-нибу́дь *нареч.* **1.** ничек (кенә) булса да, ничек тә; **на́до ~ помо́чь ему́** ничек кенә булса да аңа ярдәм итәргә кирәк **2.** *разг.* кайчан да булса (ничек тә булса) бер вакыт табып; **зайди́те ко мне ~ на той неде́ле** киләсе атнада ничек тә булса бер вакыт табып миңа

кереп чыгарсыз әле **3.** *разг.* ничек җитте (шулай) алай; **он всё де́лает ~** ул барлык эшне ничек җитте алай гына эшли

как-ника́к *нареч. разг.* ничек кенә булмасын

како́в *мест. в знач. сказ. см.* **како́й** 1

каково́ *нареч. см.* **как** 1

каково́||й *мест. уст.* ...ган, ...а торган; **заявле́ние, ~е препровожда́ется на́ми** безнең тарафтан җибәрелә торган гариза

как||о́й, -ая, -о́е *мест.* **1.** *вопр.* нинди, ничек; **~ а́я сего́дня пого́да?** бүген һава ничек? **2.** *вопр.* кайсы, ничәнче; **в ~ о́м году́ он роди́лся?** ул ничәнче елны туган? **3.** *опред.* нинди; **~ а́я ра́дость!** нинди шатлык! **4.** *неопр.* ниндидер, нинди дә булса, берәр төрле; **нет ли у вас ~ о́го вопро́са?** сезнең нинди дә булса соравыгыз юкмы? ♦ **~ о́й тако́й?** ниндирәк?, ул тагын нинди?; **пришёл Ива́нов? — Како́й тако́й Ива́нов?** Иванов килдеме? — Ул тагын нинди Иванов?; **~ о́е там!** кая анда!; **ты отдохну́л? — Како́е там!** син ял иттеңме? — Кая анда ял!; **~ о́й ни [на] е́сть** теләсә нинди, нинди дә булса; **дай мне ~ у́ю ни на е́сть кни́гу** миңа нинди дә булса бер китап бир әле; **ни в ~ у́ю** һич тә, һичбер, бөтенләй; **он ни в ~ у́ю не согла́сен** һич тә риза түгел; **~ о́й-никако́й** нинди генә булса да (булмасын); **~ о́й-никако́й, а всё-таки за́работок** нинди генә булса да, хезмәт хакы инде ул

како́й-либо *мест. см.* **како́й-нибудь** 1

како́й-нибудь *мест.* **1.** нинди дә булса бер; **найти́ ~ вы́ход из положе́ния** бу хәлдән нинди дә булса бер чыгу юлын табарга **2.** *разг.* чамасы, нибары, күп булса; **оста́лся ~ киломе́тр пути́** күп булса бер километр җир калгандыр

како́й-то *мест.* **1.** ниндидер, нинди дә булса бер; **~ челове́к** ниндидер бер кеше **2.** *разг.* ниндидер ...шунда, ...га охшаган ...шунда; **он ~ чуда́к** ул сәер кеше **3.** ниндирәк; **~ урожа́й ны́нче бу́дет?** уңыш быел ниндирәк икән?

какофо́ния *ж* какофония, аһәңсезлек, колакка ятышсызлык

ка́к-то *нареч.* **1.** *неопр.* ничектер; **он ~ суме́л ула́дить де́ло** ул ничектер эшне җайга сала алды **2.** *вопр.* ничек, ничек итеп; **посмо́трим, ~ они́ нас встре́тят?** күрербез, алар безне ничек каршы алырлар икән? **3.** *относ. разг.* бервакыт, кайчандыр; **я ~ раз был у него́** мин кайчандыр аңарда булдым **4.** *в знач. союза* мәсәлән; **все предприя́тия, ~: строи́тельные, тексти́льные...** барлык предприятиеләр, мәсәлән: төзү, текстиль предприятиеләре...

ка́ктус *м* кактус

ка́ктусов||ый, -ая, -ое **1.** кактус ...ы; **~ые за́росли** кактус куаклары **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. бот.* кактусчалар, кактус үсемлекләре

кал *м* тизәк

каламбу́р *м* каламбур (*мәзәк өчен төрле мәгънәдәге аваздаш сузлардан торган тәгәрмәч, мәс. яхшылыкка эреп китәм — балавыз мин, мактап сөйлим изге эшне — бал авыз мин*)

каламбу́рить *несов.* сүз уйнату, каламбурлар сөйләү (язу)

каламя́нка *ж* ныклы киндер тукыма

каланча́ *ж* **1.** каланча, каравыл манарасы **2.** колга, икенде күләгәсе (*артык озын буйлы кеше турында*)

кала́ч *м* калач, күмәч, ак икмәк ♦ **~ о́м не зама́нишь** *кого* берни белән дә кызыктыра алмассың; **тёртый ~** шомарган таш (*күпне күргән кеше турында*)

кала́чиком *нареч.*: **лежа́ть (свернну́ться) ~** бөгәрләнеп яту

калейдоско́п *м* **1.** калейдоскоп (*оптик прибор*) **2.** *перен. чего* өзлексез үзгәреп тору, тиз алмашыну; **~ собы́тий** вакыйгаларның өзлексез үзгәреп торуы

кале́ка *м, ж* гарип, зәгыйфь

календа́рный, -ая, -ое календарь ...ы; календарь ...; **~ листо́к** календарь бите; **~ план** календарь план

календа́рь *м* календарь; **насто́льный ~** өстәл календаре; **~ футбо́льных игр** футбол уеннары календаре

кале́ни||е *с см.* **кали́ть** ♦ **довести́ до бе́лого ~я** *кого* бик ныклы ачуын китерү, ярсыту

калён||ый, -ая, -ое **1.** кыздырылган; **~ое желе́зо** кыздырылган тимер **2.** кыздырылган, куырылган; **~ые оре́хи** кыздырылган чикләвек ♦ **~ым желе́зом вы́жечь** *что* төбе-тамыры белән бетерү (*рәхимсез рәвештә юк итү*)

кале́чить *несов. кого-что* **1.** (*делать калекой*) гарип итү, гарипләү, имгәтү, зәгыйфьләтү **2.** бозу; **~ ребёнка непра́вильным воспита́нием** баланы ялгыш тәрбияләп бозу

кали́бр *м* калибр (**1.** *воен. ату коралы көпшәсенең эчке диаметры* **2.** *тех. эшләп чыгарыла торган әйберләрнең төгәл зурлыгын үлчи торган инструмент*)

калиброва́ть *несов. что* калибрлау (**1.** *калибрын үлчәү яки берәр нәрсәгә тиешле калибр бирү* **2.** *нинди дә булса үлчәү приборының буленеш шкаласын тикшерү*)

ка́лиев||ый, -ая, -ое *хим.* калий ...ы; калийлы; **~ая сели́тра** калий селитрасы; **~ые удобре́ния** калийлы ашламалар

ка́лий *м хим.* калий

кали́йный, -ая, -ое *см.* **ка́лиевый**

кали́льн||ый, -ая, -ое кыздыра торган; эретә торган, эретү ...ы; **~ая печь** эретү миче

кали́на *ж* балан (*агачы һәм җимеше*)

кали́тка *ж* кечкенә капка, ян капка

кали́ть *несов. что* **1.** кыздыру; **~ желе́зо** тимер кыздыру **2.** куыру, кыздыру; **~ оре́хи** чикләвекне кыздыру

кали́ф *м*: **~ на час** бер сәгатьлек хәлифә (*кыска вакытка гына хакимияткә менгән кеше*)

каллигра́ф *м* каллиграф (*матур язучы*)

каллиграфи́ческий, -ая, -ое каллиграфик, матур; **~ по́черк** каллиграфик почерк

каллигра́фия *ж* каллиграфия, матур язу

калмы́к *м* калмык, калмык кешесе

калмы́ки *мн.* калмыклар, калмык халкы

калмы́цкий, -ая, -ое калмык[лар] ...ы; **~ язы́к** калмык теле

калмы́чка *ж* калмык хатыны (кызы)

калори́йность *ж* калориялелек, калорияләр микъдары; **~ пи́щи** азыкның калориялелеге

калори́йн||ый, -ая, -ое калорияле; **~ая пи́ща** калорияле азык

калори́метр *м* калориметр (*җылылык микъдарын үлчәү приборы*)

калори́фер *м* калорифер (*бинаны җылыту өчен прибор*)

кало́рия *ж* калория (*җылылыкны үлчәү берәмлеге*)

кало́ш||а *ж* калош ♦ **посади́ть в ~у** *кого* төпсез чанага утыру; ≈ кәкре каенга терәтү; **сесть в ~у** төпсез чанага утыру; уңышсызлыкка очрау

калы́м *м* **1.** калым (*кайбер көнчыгыш халыкларында ыруглык йоласының калдыгы: кияү тарафыннан кәләшнең ата-аналарына түләнә торган акча, мал*) **2.** *прост.* калым, чумара (*җәмгыятькә зарарлы эштән килгән табыш, керем*)

калы́мить *несов. прост.* чумара эшләү (*законсыз табыш алу*)

калы́мщик *м прост.* калымчы, чумарачы

ка́лька *ж* калька (**1.** *сызымнардан, рәсемнәрдән күчермә алу өчен кулланыла торган үтә күренмәле кәгазь* **2.** *шундый кәгазьгә алынган күчермә* **3.** *лингв. икенче бер телдән туп-туры тәрҗемә итеп алынган сүз яки тәгъбир*)

кальки́ровать *несов. что* калькалаштыру (**1.** *калька ярдәмендә төгәл күчермәсен алу* **2.** *лингв. икенче бер телдән туп-туры тәрҗемә итеп сүз ясау*)

калькули́ровать *несов. что* калькуляцияләү, калькуляция ясау

калькуля́тор *м* калькулятор, калькуляция ясаучы

калькуля́ция *ж* калькуляция (*товарның, продукциянең үзкыйммәтен һәм сату бәясен исәплән чыгару*)

кальма́р *м* кальмар (*диңгез моллюскысы*)

кальсо́н *только мн.* ирләр ыштаны, кальсон

ка́льциев||ый, -ая, -ое *хим.* кальций ...ы; **~ые со́ли** кальций тозлары

ка́льций *м хим.* кальций

каль́ян *м* кальян, хурхур

кама́ринская *ж* камаринская (*рус халык бию көе һәм бию*)

ка́мбала *ж* камбала (*балык*)

ка́мбуз *м* камбуз (*суднолардагы кухня*)

камво́льн||ый, -ая, -ое **1.** камволь ..., тәрәшләнгән йоннан эшләнгән; **~ые тка́ни** тәрәшләнгән йоннан эшләнгән тукымалар **2.** камволь ...ы; камволь тукымалар эшләп чыгара торган; **~ый комбина́т** камволь тукымалар эшләп чыгара торган комбинат

каме́дь *ж* чәер, сагыз

КАМ-КАН

каме́лия *ж* камелия (*агачы һәм чәчәге*)

камене́||ть *несов.* **1.** ташка әверелү (әйләнү) **2.** *перен.* тораташ булып кату, хәрәкәтсез калу; **лицо́ его́ ~ло** йөзе тораташ булып катты **3.** *перен.* рәхимсезләнү, каты күңеллеләнү, күңел кату

каменѝст||ый, -ая, -ое ташлы, таш ...; **~ая по́чва** ташлы туфрак; **~ая доро́га** таш юл

ка́менка *ж* кара мунча миче; әвен миче

каменноуго́льный, -ая, -ое ташкүмер ...ы; **~ бассе́йн** ташкүмер бассейны

ки́па *ж* **1.** (*связка*) төргәк, кип **2.** өем; **~ вещ**е́й әйберләр өеме
кипари́с *м* кипарис (*агач*)
кипари́сов||ый, -ая, -ое кипарис ...ы; **~ое ма́сло** кипарис мае **2.** кипарис ..., кипаристан ясалган; **~ая шкату́лка** кипаристан ясалган тартма
кипе́ни||е *с см.* **кипе́ть** 1; **то́чка ~я** *физ.* кайнау ноктасы ♦ **~е страсте́й** хисләрнең ташуы
кип||е́ть *несов.* **1.** *прям., перен.* кайнау; кайнап тору; **самова́р ~и́т** самовар кайный; **вода́ ~и́т** су кайный; **рабо́та ~и́т** эш кайнап тора **2.** *чем* ургылу, кайнау, ташырга тору (*мәс. берәр тойгы*); **~е́ть негодова́нием** нәфрәт кайный
кипре́й *м бот.* кырлыган
кипу́ч||ий, -ая, -ее *прям., перен.* кайнап (күбекләнеп) тора торган; **~ий пото́к** күбекләнеп тора торган агым; **~ая жизнь** кайнап тора торган тормыш
кипяти́льник *м* [су] кайнаткыч
кипяти́льный, -ая, -ое [су] кайнату ...ы; кайната торган; **~ котёл** су кайнату казаны
кипяти́ть *несов. что* кайнату; **~ молоко́** сөт кайнату
кипят||и́ться *несов.* **1.** кайнау, кайнатылу; **вода́ ~и́тся** су кайный; **бельё ~и́тся** кер кайнатыла **2.** *перен. разг.* кызу, ачулану, чәпчү; **не ~и́сь, говори́ споко́йно** кызма, тыныч кына сөйлә **3.** *страд. от* **кипяти́ть**
кипят||о́к *м* кайнар су; кайнаган су; **ошпа́рить ~ко́м** кайнар су белән пешекләү
кипячён||ый, -ая, -ое кайнаган; **~ая вода́** кайнаган су
кира́са *ж воен. ист.* кираса (*кукрәкне һәм арканы саклый торган металл кием*)
кираси́р *м воен. ист.* кирасир (**1.** *атлы армиядә кираса кигән җәйдәк* **2.** *иске рус һәм кайбер Көнбатыш Европа армияләрендә парад формалары кирасалы булган кавалерия полклары солдаты яки офицеры*)
киргиз *м* кыргыз, кыргыз кешесе
киргизка *ж* кыргыз хатыны (кызы)
киргизский, -ая, -ое кыргыз[лар] ...ы; **~ язы́к** кыргыз теле
киргизы *мн.* кыргызлар, кыргыз халкы
ки́рза *ж* кирза (*кун урынына кулланыла торган тыгыз тукыма*)
ки́рзов||ый, -ая, -ое кирза ...; кирзадан тегелгән; **~ые сапоги́** кирза итек
кири́ллица *ж* кириллица (*славян алифбаларының берсе*)
кирка́ *ж* кирка, кәйлә
кирпи́ч *м* кирпеч; **кра́сный ~** кызыл кирпеч; **торф в ~а́х** кирпеч торф
кирпи́ч||ный, -ая, -ое кирпеч ...ы; **~ое произво́дство** кирпеч производствосы **2.** кирпеч ...; кирпечтән ясалган; **~ая стена́** кирпеч дивар **3.** (*о цвете*) кирпеч төсендәге ♦ **~ый чай** такта чәй
кисе́йн||ый, -ая, -ое кисея ...; кисеядән тегелгән; **~ый шарф** кисея шарф ♦ **~ая ба́рышня** назлы кыз, кыланчык кыз
кисе́ль *м* кесәл
кисе́т *м* янчык, тәмәке янчыгы
кисея́ *ж* кисея
кис-ки́с *межд.* пес-пес
кисли́нк||а *ж*: **с ~ой** *разг.* әчкелтем; **я́блоко с ~ой** әчкелтем алма
кисли́||ть *несов.* әчкелтем тәм килү; **я́блоко немно́го ~т** алмадан бераз әчкелтем тәм килә
кисли́ца *ж бот.* кымызлык
кислоро́д *м* кислород
кислоро́дн||ый, -ая, -ое кислород ...ы, кислородлы; **~ые соедине́ния** кислородлы кушылмалар ♦ **~ая поду́шка** кислород мендәре
ки́сло-сла́дк||ий, -ая, -ое әчелтем-төчкелтем; **~ое я́блоко** әчкелтем-төчкелтем алма
кислота́ *ж хим.* кислота; **се́рная ~** күкерт кислотасы
кисло́тность *ж* кислоталылык; **повы́шенная ~ желу́дочного со́ка** ашказаны сыекчасының кислоталылыгы артык булу
кисло́тн||ый, -ая, -ое *хим.* кислоталы; **~ые соедине́ния** кислоталы кушылмалар
ки́сл||ый, -ая, -ое **1.** әче; **~ое я́блоко** әче алма **2.** әче, әчеткән; **~ое те́сто** әче камыр **3.** (*прокисший*) әчегән, әчеп бозылган; (*о молоке*) катык **4.** *перен. разг.* (*о настроении*) төшенке, борчылулы; (*напр. о лице*) чытык, сытык **5.** *хим.* кислоталы; **~ые раство́ры** кислоталы эремәләр
кисля́тина *ж разг.* әче нәрсә
ки́сн||уть *несов.* **1.** әчү; **молоко́ ~ет** сөт әчи **2.** *перен.* боегу, кайгыру, боегып (кайгырып) тору; **не́чего ~уть, на́до бра́ться за рабо́ту** боегып торырга вакыт юк, эшкә тотынырга кирәк
киста́ *ж мед.* киста, су тулган шеш
кистево́й, -а́я, -о́е кул чугы ...ы; **~ суста́в** кул чугы буыны
кисте́нь *м* кистән, чукмарлы таяк (*борынгы сугыш коралы*)
ки́сточк||а *ж* **1.** *уменьш.-ласк. от* **кисть**; **2.** чук, чачак; **ша́почка с ~ой** чуклы башлык **3.** тәлгәш; **~а виногра́да** йөзем тәлгәше
кист||ь *ж* **1.** (*часть руки*) кул чугы **2.** (*напр. для краски*) пумала, буяучы пумаласы **3.** чук, чачак; **што́ры с ~я́ми** чачаклы пәрдәләр **4.** тәлгәш; **~и виногра́да** йөзем тәлгәшләре
кит *м* кит
кита́ец *м* кытай, Кытай кешесе
кита́йстика *ж* китаистика (*Кытай әдәбияты, тарихы, мәдәнияте, теле турындагы фәннәр*)
кита́йск||ий, -ая, -ое кытай[лар] ...ы; Кытай ...ы; **~ий язы́к** кытай теле ♦ **~ая гра́мота** буталчык язу, аңлашылмый торган язу
кита́йцы *мн.* кытайлар, кытай халкы
кита́янка *ж* кытай хатыны (кызы)
ки́тель *м* китель
китобо́й *м* кит аулаучы
китобо́йн||ый, -ая, -ое кит аулау ...ы; **~ое су́дно** кит аулау судносы
кито́вый, -ая, -ое кит ...ы; **~ жир** кит мае; **~ ус** кит мыегы
китово́вый, -ая, -ое кит аулау ...ы; **~ про́мысел** кит аулау промыселы
кичи́ться *несов. кем-чем* масаю, шапырыну, борын күтәрү, эреләнү, кылтаю
кичли́вый, -ая, -ое масаючан, эреләнүчән, борын күтәрүчән, кылтаючан
киш||е́ть *несов.* **1.** мыжлап тору, гөж килеп тору; **муравьи́ ~а́т в муравье́йнике** кырмыска оясында кырмыскалар мыжлап тора **2.** *кем-чем* тулып яту, исәбе-хисабы булмау; **ту́ндра ~и́т комара́ми** тундрада озынборыннар тулып ята
кише́чник *м анат.* эчәкләр
кише́чн||ый, -ая, -ое эчәк ...ы; **~ые заболева́ния** эчәк авырулары
кишка́ *ж* **1.** *анат.* эчәк; **прямая́ ~** туры эчәк **2.** *разг.* насос эчәгесе, янгын шлангысы ♦ **~ тонка́** *у кого* хәленнән килмәс, буыннарын сыек
кишла́к *м* кышлак (*авыл*)
кишми́ш *м* кишмиш (*төшсез йөзем*)
кишмя́: ~ кише́ть *разг.* мыжлап тору
клавеси́н *м* клавесин (*борынгы кыллы-клавишлы музыка коралы*)
клавиату́ра *ж* клавиатура (*музыка коралында, язу машинкасында һ.б.ш барлык клавишлар рәте*)
кла́виш *м*, **кла́виша** *ж* клавиш (*музыка коралы, язу машинкасы кебек әйберләрдә бармак белән басу өчен җайланган төймә, пластинка*)
кла́вишный, -ая, -ое клавишлы; **~ инструме́нт** клавишлы инструмент
клад *м* хәзинә; **найти́ ~** хәзинә табу
кла́дбище *с* каберлек, зират; *уст.* мазар
кладби́щенский, -ая, -ое каберлек ...ы; зират ...ы; **~ сто́рож** каберлек сакчысы
кла́дезь *м*: **~ premу́дрости** *шутл.* акыл капчыгы (*күп белемле кеше турында*)
кла́дка *ж* **1.** *см.* **кладь** 6; **~ стен** стеналар салу **2.** өю: **~ дров** утын өю **3.** (*часть сооружения из камня, кирпича*) корылма
кладова́я *ж* кладовой, келәт
кладо́вка *ж разг.* келәт, чолан
кладовщи́к *м* кладовщик, кладовой мөдире

кладовщи́ца *ж* кладовщик хатын (кыз)

кладь *ж собир.* йөк, төен; **ручна́я ~** кул йөге

клаксо́н *м* клаксон (*автомобильдә тавыш сигналы җайланмасы*)

клан *м ист.* клан (*борынгы заманда шотландиялеләрдә һәм ирландиялеләрдә ыруг общинасы*)

кла́ня||ться *несов.* **1.** *кому-чему* (*приветствовать поклоном*) баш ию, котлау, сәламләү **2.** *кому-чему* (*передавать привет*) сәлам әйтү (тапшыру); **~йтесь ему́ от меня́** аңа миннән сәлам тапшырыгыз **3.** *перен. кому, перед кем* (*униженно просить*) ялыну, ялварып сорау ♦ **переста́ть ~ться** *или* **не ~ться** *с кем* танышлыкны өзү; **честь име́ю ~ться** сау булыгыз, хушыгыз

кла́пан *м* **1.** *тех.* клапан **2.** *анат.* клапан; **серде́чный ~** йөрәк клапаны **3.** (*напр. на кармане*) каплавыч, япкыч (*мәс. кесә авызында*)

кларне́т *м* кларнет (*музыка коралы*)

кларнети́ст *м* кларнетчы, кларнетта уйнаучы

класс *м* **1.** сыйныф; **рабо́чий ~** эшчеләр сыйныфы **2.** класс; **учени́к пе́рвого ~а** беренче класс укучысы **3.** класс, төркем; **~ млекопита́ющих** имезүчеләр классы **4.** класс; **кают второ́го ~а** икенче класс каютасы **5.** класс, уку бүлмәсе; **сиде́ть в ~е** класста утыру **6.** класс, дәрәҗә; **специали́ст вы́сшего ~а** югары дәрәҗәле белгеч; **игра́ высо́кого ~а** югары класслы уен

кла́ссик *м* классик; **~и маркси́зма-лениниз́ма** марксизм-ленинизм классиклары; **чита́ть ~ов** классикларны уку

кла́ссика *ж* классика, классик әсәрләр

классификацио́нн||ый, -ая, -ое классификация ...ы, классификацион; **~ая коми́ссия** классификацион комиссия

классифика́ция *ж* **1.** *см.* **классифици́ровать; 2.** (*система*) классификация; **~ расте́ний** үсемлекләр классификациясе

классифици́ровать *сов., несов. кого-что* классификацияләү; классларга (бүлекләргә, бүлекчәләргә, төркемнәргә) аеру

классици́зм *м* классицизм (*17 йөз һәм 18 йөз башы сәнгатендә антик урнәкләргә ияреп эш итүгә нигезләнгән юнәлеш*)

класси́ческ||ий, -ая, -ое **1.** классик, классиклар иҗат иткән; **~ая му́зыка** классик музыка **2.** (*типичный*) типик, характерлы, ачык; **~ий приме́р рассе́янности** таркаулыкның ачык мисалы **3.** антик, классик; **~ие языки́** классик телләр

кла́ссн||ый, -ая, -ое **1.** класс ...ы; **~ая доска́** класс тактасы **2.** бик яхшы, үрнәк булырлык; **~ая игра́** бик яхшы уйнау

кла́ссовый, -ая, -ое сыйнфый; **~ая борьба́** сыйнфый көрәш; **~ое о́бщество** сыйнфый җәмгыять

класть *несов.* **1.** *кого-что* кую; (*укладывать, положить*) яткыру, салу; **~ *что-л.* на своё ме́сто** *берәр нәрсәне* үз урынына кую; **клади́ кни́ги на стол** китапларны өстәл өстенә куй; **~ ребёнка спать** баланы йокларга яткыру **2.** *кого-что* салу; **~ плато́к в карма́н** яулыкны кесәгә салу; **~ в портфе́ль** портфельгә салу **3.** *кого-что* урнаштыру, салу; **~ в больни́цу** хастаханәгә салу; **~ де́ньги в сбербанк** акчаны саклык банкына салу **4.** *что* салу; **~ в ка́шу ма́сло** ботказа май салу **5.** *что* салу; чыгару; **~ фунда́мент** нигез салу; **~ пе́чку** мич чыгару **6.** *что* ягу, буяу; **~ кра́ску** буяу ягу; **~ пу́дру** кершән ягу ♦ **~ в осно́ву** нигез итеп алу; **~ в рот** *кому* чәйнәп бирү (каптыру); **~ жизнь (го́лову)** *за кого-что кем-нәрсә өчен* корбан булу; **~ зу́бы на по́лку** авызны чөйгә элү; **~ нача́ло** *чему* башлап җибәрү; **~ [се́бе] в карма́н** [үз] кесәсенә салу; **~ я́йца** йомырка салу

клёв *м см.* **клева́ть 3; сего́дня хоро́ший ~** бүген балык яхшы чиртә

клева́ть *несов.* **1.** *кого-что* ашау, чукып ашау, чүпләү; **ку́ры не клюю́т э́того ко́рма** тавыклар бу азыкны ашамыйлар **2.** (*ударять клювом*) чуку **3.** *без доп.* (*о рыбе*) чиртү, кабу, эләгү ♦ **~ но́сом** йокымсырап (оеп) утыру, калыгу

клева́ться *несов.* **1.** чуку, чукышу **2.** (*клевать друг друга*) чукышу, сугышу

кле́вер *м* тукранбаш, клевер

кле́верн||ый, -ая, -ое тукранбаш ...ы; клевер ...ы; **~ое по́ле** клевер кыры

клевета́ *ж* яла, гайбәт, ялган; **на́глая ~** оятсыз яла

клевета́ть *несов. на кого-что* яла ягу, ялган (гайбәт) тарату

клеветни́к *м* яла ягучы, ялганчы, гайбәтче

клеветни́ческ||ий, -ая, -ое яла ..., ялган, гайбәт ...; **~ие слу́хи** ялган хәбәрләр

клеев||о́й, -а́я, -о́е җилем ...ы; җилемле; **~а́я кра́ска** җилемле буяу

клеёнка *ж* клеёнка

клеёнчатый, -ая, -ое клеёнка ...; клеёнкадан ясалган; клеёнка белән тышланган; **~ портфе́ль** клеёнка портфель; **~ дива́н** клеёнка белән тышланган диван

клеён||ый, -ая, -ое җилемле, җилемләнгән, җилем белән ябыштырылган; **~ая фане́ра** җилем белән ябыштырылган фанер

кле́ить *несов. что* ябыштырып ясау, җилемләү; **~ коро́бки** тартмаларны ябыштырып ясау

кле́ит||ься *несов.* **1.** ябышу; **бума́га хорошо́ ~ся** кәгазь яхшы ябыша **2.** *перен.* уңайга бару, барып чыгу; **де́ло не ~ся** эш уңайга бармый **3.** *страд. от* **кле́ить**

клей *м* җилем; **столя́рный ~** агач җилеме

кле́йка *ж см.* **кле́ить**

кле́йк||ий, -ая, -ое ябышучан, ябышкак; **~ая бума́га** ябышкак кәгазь

клейкови́на *ж* клейковина, җилемчә (*ашлык бөртегендә була торган аксым матдәсе*)

клейме́ние *с см.* **клейми́ть** 1, 2

клеймёный, -ая, -ое келәймәле, келәймәләнгән, келәймә сугылган; тамгалы, тамгаланган, тамга салынган; **~ скот** тамгалы терлек

клейми́ть *несов.* **1.** *что* келәймәләү, келәймә сугу; **~ това́р** товарга келәймә сугу **2.** *кого-что* тамгалау, тамга салу; **~ скот** терлеккә тамга салу **3.** *перен. кого-что* фаш (хур) итү, гаебен ачу ♦ **~ позо́ром** хурлык баганасына терәү, хур итү

клеймо́ *с* **1.** келәймә, тамга **2.** *перен. книжн.* билге, тамга, эз; **~ позо́ра** хурлык билгесе

кле́йстер *м* клейстер (*крахмалдан яки оннан ясалган җилем*)

клёкот *м* коркылдау; **~ орла́** каракош коркылдавы

клекота́ть *несов.* коркылдау (*каракош һәм башка эре кошлар кычкыруы*)

клён *м* өрәңге, чаган

клено́вый, -ая, -ое **1.** өрәңге ...ы; чаган ...ы; **~ лист** өрәңге яфрагы **2.** өрәңге ..., өрәңгедән ясалган; **~ стол** өрәңге өстәл

клёпаный, -ая, -ое заклёпкалап ясалган; **~ котёл** заклёпкалап ясалган казан

клепа́ть *несов. что* заклёпкалау, чүкеп беркетү (*металл әйберләрне*)

клёпка I *ж см.* **клепа́ть**

клёпка II *ж* кисмәк (мичкә) тактасы, клёпка

клёпочный, -ая, -ое клёпка ...ы; клёпка ясау ...ы; **~ стано́к** клёпка ясау станогы

клептома́ния *ж* клептомания (*гел урлашудан гыйбарәт булган психик авыру*)

клерика́л *м* клерикал, клерикализм тарафдары

клерикали́зм *м* клерикализм (*буржуаз илләрдә сәяси һәм мәдәни тормышын чиркәү оешмалары җитәкчелегенә бирергә омтыла торган реакцион сәяси агым*)

клерика́льн||ый, -ая -ое клерикаль; **~ая па́ртия** клерикаль партия

клерк *м* клерк (*Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә һәм Америкада контора хезмәтчесе*)

клёст *м* чукыр

кле́тк||а *ж* **1.** (*для птиц и животных*) читлек **2.** шакмак; **ткань в ~у** шакмаклы тукыма

кле́тк||а II *ж биол.* күзәнәк; **не́рвные ~и** нерв күзәнәкләре

кле́точн||ый, -ая, -ое *биол.* күзәнәк ...ы; **~ая протопла́зма** күзәнәк протоплазмасы

клету́шка *ж разг.* кечкенә бүлмә

клетча́тка *ж* клетчатка (*үсемлек күзәнәкләренең тышчасы составында була торган матдә*)

кле́тчат||ый I, -ая, -ое шакмаклы, шакмак бизәкле; **~ое пальто́** шакмаклы пальто

кле́тчат||ый II, -ая, -ое *биол.* күзәнәкле; **~ое строе́ние расти́тельной ткани** үсемлек тукымасының күзәнәкле төзелеше

клеть *ж* 1. *обл.* (*кладовая*) келәт 2. *горн.* клеть (*шахтада кешеләрне һәм йөкләрне күтәрә-төшерү җайланмасы*)

клёцки *мн.* чумар, умач

клёш *м и неизм. прил.* клёш; **брю́ки ~** клёш чалбар; **ю́бка ~** клёш юбка

клешня́ *ж* кыскыч

клещ *м* урман бете, талпан

клещеви́на *ж* кәнә уты, кастор үләне

клещи́, кле́щи *только мн.* келәшчә

клие́нт *м* клиент (1. *парикмахерга, адвокатка һ.б.ш эш-йомыш, үтенеч белән килүче* 2. *заказ бирүче, сатып алучы*)

клие́нтка *ж* клиент хатын (кыз)

клиенту́ра *ж собир.* клиентлар

кли́зма *ж* клизма

кли́ка *ж* клика, өер (*явыз максат белән оешкан кешеләр төркеме*)

кли́||кать *несов.* 1. *кого-что, прост.* (*громко сзывать*) кычкырып чакыру, кычкырып дәшү 2. *без доп.* кыйгаклау, каңгылдау; **ле́беди ~чут** аккошлар каңгылдый

кли́кнуть *сов. однокр. разг. кого-что*, чакырып алу, чакырып китерү

клику́ша *ж* бума авырулы хатын (кыз)

клику́шество *с* (*заболевание*) бума авыруы (*хатын-кызларда*)

кли́макс *м* климакс (*то же, что* **климакте́рий**)

климакте́рий *м мед.* климактерий (*хатыннарның өлкән яшьтә күрем күрүдән туктатылу чоры*)

климактери́ческий, -ая, -ое *мед.* климактерий ...ы, климактерик; **~ пери́од** климактерик чор

кли́мат *м* климат

климати́ческ||ий, -ая, -ое климат ...ы; **~ие усло́вия** климат шартлары

климатологи́ческий, -ая, -ое климатология ...ы, климатологик; **~ куро́рт** климатология курорты

климатоло́гия *ж* климатология (*климатның төрләрен, аларның формалашуын һәм географик таралышын һәм органик тормышка тәэсирен өйрәнә торган фән*)

клин *м* 1. чәй; **дубо́вый ~** имән чәй 2. (*в одежде*) ялгау, чөйсыман ялгау; **вшить ~** ялгау кертеп тегү 3. *с.-х.* басу, кыр ♦ **~ ~ом вышиба́ют** чәйне чәй белән бәреп чыгаралар

кли́ника *ж* клиника

клиници́ст *м* клиницист (*клиникада дәвалау эшләре белән бергә фәнни тикшеренүләр дә алып баручы табиб*)

клини́ческ||ий, -ая, -ое клиника ...ы. клиник; **~ое лече́ние** клиникада дәвалау, **в ~их усло́виях** клиник шартларда ♦ **~ая смерть** клиник үлем

кли́нкер *м спец.* клинкер (*утка чыдам, су сеңдерми торган кирпеч яки цементтан ясалган материал*)

клиновиднЦый, -ая, -ое чөйсыман, чөй шикелле; **~ая боро́дка** кәҗә сакал

клино́к *м* 1. йөз (*кылычның, пычакның һ.б.ш. кисә торган өлеше*) 2. кылыч

клинообра́зный, -ая, -ое *см.* **клинови́дный**

клинопи́сный, -ая, -ое чөй язулы; **~ текст** чөй язулы текст

кли́нопись *ж* 1. (*способ письма*) чөй язу (*хәрефләре чөйсыман билгеләрдән торган борынгы язу*) 2. (*текст*) чөй язулы текст

кли́пер *м* клипер (*тиз йөрешле, өч мачталы җилкәнле судно*)

кли́псы *мн.* клипслар, алка (*тишелмәгән колак яфрагына тагыла*)

кли́ринг *м фин.* клиринг (*исәп-хисапның акчасыз төре*)

кли́рос *м* клирос (*чиркәүдә алтарь каршында хорда җырлаучылар өчен биек урын*)

клич *м* кычкырып чакыру, өндәү ♦ **кли́кнуть ~** оран салу

кли́чка *ж* 1. (*имя домашнего животного*) исем (*йорт хайваннарына кушыла*) 2. (*прозвище*) кушамат

клише́ *с нескл. полигр.* клише (*типографиядә басу өчен металлга, ташка, агачка төшерелгән рәсем, сызым*)

клоа́ка *ж* клоака (1. *шакшы су агызу өчен җир асты каналы* 2. *пычрак урын, шакшы урын; бозык җәмгыять, бозык мохит* 3. *биол. кайбер хайваннарда арт юл*)

клобу́к *м* монах бүреге

кло||к *м* 1. тотам, учма; **~к ше́рсти** бер тотам йон 2. кисәк, кыйпык, кыйпылчык; **разорва́ть бума́гу в ме́лкие ~чья** кәгазьне вак кисәкләргә ерткалап бетерү

клокота́нье *с см.* **клокота́ть** 1, 2

клокота́||ть *несов.* 1. шаулап кайнау, ургылып кайнау, быгырдау, гөбердәп кайнау; **вода́ в котле́ ~ла** казанда су шаулап кайный иде 2. *обычно безл.* гырылдау, гыжлау, гыр-гыр (гыж-гыж) килү; **в груди́ клоко́чет** күкрәк гырылдый 3. *перен.* ярсу, ярсып (кайнап) тору; **всё в нём ~ ло от гне́ва** ачуыннан ул тәмам ярсыган иде

клони́ть *несов.* 1. *кого-что* ию, бөгү, кырынайту, кыйшайту, авыштыру; **ве́тер клони́т верху́шки дере́вьев** җил агач башларын ия; **ло́дку клони́т на́бок** *безл.* көймә бер якка авыша 2. *перен. что к чему и без доп.* тарту, юнәлдерү, алып бару; **~ де́ло к разры́ву** эшне өзүгә таба алып бару; ♦ **меня́ ко сну (в сон) клони́т** минем йокым килә, мин йокымсырап торам

клони́ться *несов.* 1. иелү, бөгелү, сыгылу; **де́рево клони́тся к земле́** агач җиргә бөгелә 2. *перен. к чему* якынлашу, якынлашып килү, авышу; ...га таба бару; **день клони́тся к ве́черу** көн кичкә авыша; **де́ло клони́тся к развя́зке** эш хәл ителүгә якынлашып килә

клоп *м* 1. кандала, кибәк 2. *шутл.* (*о малыше*) кечкенәм, нәнием (*балаларга карата яратып әйтелә*)

клопи́ный, -ая, -ое кандала ...ы; **~ уку́с** кандала тешләве

клопо́вник *м* 1. *прост.* кандала оясы (*кандала күп булган бүлмә яки йорт җиһазы*) 2. *бот.* кандала үләне

клопо́вый, -ая, -ое *см.* **клопи́ный**

кло́ун *м* клоун, шамакай

клоуна́да *ж* клоунада (*цирката клоуннар кашнашы белән башкарыла торган чыгыш*)

кло́унск||ий, -ая, -ое клоун ...ы; клоуннарча ...; **~ие вы́ходки** клоуннарча кыланышлар

клохта́ть *несов.* кытаклау, кытнау, кыткылдау

клочкова́т||ый, -ая, -ое өзек-өзек, укмаш-укмаш; **~ая шерсть** укмаш-укмаш йон; **~ые облака́** өзек-өзек болытлар

клочо́к *м* 1. *уменьш. от* **клок**; **~ бума́ги** кәгазь кисәге; **~ се́на** бер уч печән 2. кисәк, карыш; **~ земли́** жир кисәге

клуб I *м* клуб

клуб II *м* өермә; **~ы пы́ли** тузан өермәләре; **дым из трубы́ вали́л ~а́ми** төтен моржадан бөтерелеп (ургылып) чыга иде

клу́бень *м* бүлбе; **~ карто́феля** бәрәңге бүлбесе

клуби́||ть *несов. что* өереп (бөтереп) күтәрү; **ве́тер ~т пыль** җил тузанны өереп күтәрә

клуби́т||ься *несов.* бөтерелеп күтәрелү; **пыль ~ся по доро́ге** юлда тузан бөтерелеп күтәрелә

клубнепло́ды *мн.* бүлбетамыр (*бәрәңге, җир грушасы һ.б.ш.*)

клубни́ка *ж* җир җиләге

клубни́чн||ый, -ая, -ое җир җиләге ...ы; **~ое варе́нье** җир җиләге кайнатмасы

клу́бн||ый. -ая, -ое клуб...ы; **~ая сце́на** клуб сәхнәсе

клубо́к *м* 1. йомгак; **~ ни́ток** җеп йомгагы 2. *перен.* төен, йомгак; **~ противоре́чий** каршылыклар төене

клу́мба *ж* клумба, чәчәклек, чәчәк түтәле

клык *м* казык теш

клыка́стый, -ая, -ое *разг.* зур казык тешле (*мәс. буре турында*)

клюв *м* томшык, кош борыны

клюка́ *ж* кәкре башлы таяк

клю́ква *ж* мүк җиләге

клю́квенный, -ая, -ое мүк җиләге ...ы; **~ кисе́ль** мүк җиләге кесәле

клю́нуть *сов. однокр. кого-что* 1. (*о птице*) чуку, чукып алу 2. (*о рыбе*) чиртү, чиртеп кую

ключ I *м* 1. *в разн. знач.* ачкыч; **~ от две́ри** ишек ачкычы; **га́ечный ~** гайка ачкычы; **~ для часо́в** сәгать ачкычы; **~ к ши́фру** шифр ачкычы; **найти́ ~ к сердца́м люде́й** кешеләр йөрәгенә ачкыч табу 2. *муз.* ключ; **скрипи́чный ~** скрипка ключе

ключ II *м* (*родник*) чишмә, кизләү

ключев||о́й I, -а́я, -о́е 1. ачкыч ...ы; **~о́е отве́рстие** ачкыч тишеге 2. *воен.* төп, ин мөһим; **~ы́е пози́ции** төп позицияләр

ключев||о́й II, -а́я, -о́е чишмә ...ы; **~а́я вода́** чишмә суы

ключи́ца *ж* умрау, умрау сөяк, ядәч сөяге

ключи́чный, -ая, -ое умрау сөяге ...ы

клю́шка *ж* кәшәкә; **хокке́йная ~** хоккей кәшәкәсе

кля́кса *ж* тап, кара табы

кля́нчить *несов. что и без доп., прост.* теләнеп (ялынып) сорау; сорап йөдәтү

кляп *м* келәп

клясть *несов. кого-что* каргау, каһәрләү, ләгънәт уку, бәддога кылу

кля́ться *несов. в чём, чем и с неопр.* ант итү, антлы вәгъдә бирү

кля́тв||а *ж* ант; **дать ~у** ант итү; **нару́шить ~у** антны бозу; **взять ~у** ант иттерү

кля́твенн||ый, -ая, -ое антлы, ант белән ныгытылган; **~ое обеща́ние** антлы вәгъдә

клятвопреступле́ние *с книжн.* антны бозу, антка хыянәт итү

клятвопресту́пник *м книжн.* антын бозучы, антына хыянәт итүче

кля́уза *ж разг.* әләк, гайбәт, яла

кля́узник *м разг.* әләкче, гайбәтче, яла ягучы

кля́узница *ж разг.* әләкче хатын (кыз)

кля́узничать *несов. разг.* әләкләү, гайбәт сату (тарату)

кля́узн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** дәгъвалы; **~ое де́ло** дәгъвалы эш **2.** бәйләнчек, гайбәтчел, вакчыл; **~ый челове́к** бәйләнчек кеше

кля́ча *ж* арык ат; ат кисәге

кни́га *ж* **1.** китап **2.** кенәгә, дәфтәр; **ка́ссовая ~** касса кенәгәсе; **~ жа́лоб и предложе́ний** шикаятьләр һәм тәкъдимнәр кенәгәсе

книгове́дение *с* китап белеме (*китаплар турындагы барлык мәгълүматларны эченә алган фән*)

книгоизда́тельск||ий, -ая, -ое китап бастыру ...ы; китап бастыручылык ...ы; **~ое де́ло** китап бастыручылык эше

книгоизда́тельство *с* китап бастыручылык, китап бастыру оешмасы, нәшрият

книголю́б *м* китап һәвәскәре (сөюче)

книгоно́ша *м, ж* **1.** (*распространитель книг*) китап таратучы **2.** (*продавец*) китаплар сатып йөрүче

книгопеча́тание *с* китап басу

книготорго́вля *ж* китап сәүдәсе

книготорго́в||ый, -ая, -ое китап сәүдәсе ...ы; **~ые организа́ции** китап сәүдәсе оешмалары

книгохрани́лище *с* **1.** китап саклау урыны **2.** зур китапханә

кни́жка *ж* **1.** *уменьш. от* **кни́га**; **2.** кенәгә; **сберега́тельная ~** саклык кенәгәсе

кни́жник *м* **1.** китап сөюче (һәвәскәре) **2.** *разг.* китап сәүдәсендә эшләүче

кни́жн||ый, -ая, -ое **1.** китап ...ы; **~ая по́лка** китап киштәсе **2.** китаби, китапча..., китап ...ы; **~ый стиль** китапча стиль ♦ **Кни́жная пала́та** Китаплар палатасы

кни́зу *нареч.* аска, түбәнгә, аска (түбәнгә) таба; **опусти́ть го́лову ~** башны аска ию

кно́пка *ж* **1.** (*канцелярская*) кнопка **2.** (*на одежде*) каптырма **3.** (*напр. звонка*) төймә

кнут *м* чыбыркы

кнутови́ще *с* чыбыркы сабы

княги́ня *ж* князь хатыны

кня́жеский, -ая, -ое князьлек ...ы; князь[ләр] ...ы; **~ дом** князь йорты; **~ род** князьләр нәселе

кня́жество *с* князьлек

кня́жить *несов.* князьлек итү

кня́жич *м* князь малае, князь улы

княжна́ *ж* князь кызы

князь *м* князь

ко *см.* **к**

коалицио́нн||ый, -ая, -ое коалиция ...ы, коалицион; **~ое прави́тельство** коалицион хөкүмәт

коали́ция *ж* коалиция (*гомуми максатларга ирешү өчен илләрнең, төрле караштагы төркемнәрнең берләшүе*)

ко́бальт *м* кобальт (**1.** *химик элемент, көмешсыман ак металл* **2.** *карасу күк буяу*)

ко́бальтов||ый, -ая, -ое **1.** кобальт ...ы; **~ый цвет** кобальт төсе **2.** кобальтлы; **~ая сталь** кобальтлы корыч

кобе́ль *м* ата эт

ко́бза, кобза́ *ж* кобза (*украин думбырасы*)

кобза́рь *м* кобзарь (*кобзада үзе уйнап җырлаучы украин халык җырчысы*)

ко́бра *ж* күзлекле елан, кобра

кобура́ *ж* кобура (*револьвер, пистолет, маузер һ.б.ш. кабы*)

ко́бчик *м зоол.* ягылбай

кобы́ла *ж* **1.** бия; (*до трёх лет*) байтал **2.** *прост.* сыер (*зур, тупас гәүдәле хатын-кыз турында*)

кобы́л||ий, -ья, -ье бия ...ы; **~ье молоко́** бия сөте

кобыли́ца *ж см.* **кобы́ла** 1

кобы́лка *ж* **1.** *уменьш.-ласк. от* **кобы́ла** 1; бия тай **2.** алаша (*кыллы музыка инструментларында кыллар астына куела торган агач терәк*) **3.** *зоол.* алаша

ко́ваный, -ая, -ое **1.** чүкеп ясалган, таптатып эшләнгән; **~ меч** чүкеп ясалган кылыч **2.** тимер белән тышланган; **~ сунду́к** тимер белән тышланган сандык **3.** (*о лошади*) дагаланган

кова́рн||ый, -ая, -ое мәкерле, эчкерле, хәйләкәр, явыз ниятле; **~ый враг** мәкерле дошман; **~ая улы́бка** мәкерле елмаю

кова́рство *с* мәкер, эчкерлелек, явыз ният, астыртын хәйлә

кова́ть *несов.* **1.** *что* чүкү, чүкеп ясау, таптату, таптатып ясау; **~ желе́зо** тимер чүкү **2.** *кого-что* дагалау; **~ коня́** атны дагалау **3.** *перен. что, высок.* яулау, көч куеп ирешү, өзлексез тырышып ирешү; **~ побе́ду** җиңү яулау ♦ **куй желе́зо, пока́ горячо́** *погов.* тимерне кызуында сук

ковбо́й *м* ковбой (*Төньяк Америкада атлы көтүче*)

ковбо́йка *ж разг.* ковбойка (*шакмаклы күлмәк*)

ковбо́йск||ий, -ая, -ое ковбой ...ы; **~ие фи́льмы** ковбой фильмнары

ковёр *м* келәм, хәтфә келәм, палас ♦ **~-самолёт** *фольк.* оча торган палас

кове́ркать *несов.* **1.** *кого-что* вату, бозу, җимерү; **~ маши́ну** машинаны вату; **~ ребёнка непра́вильным воспита́нием** баланы дөрес тәрбияләмичә бозу **2.** *что* бозып әйтү (сөйләү); **~ слова́** сүзләрне бозып әйтү

коверко́т *м* коверкот (*тукыма*)

коверко́тов||ый, -ая, -ое коверкот ..., коверкоттан тегелгән; **~ое пальто́** коверкот пальто

ко́вка *ж см.* **кова́ть** 1, 2

ко́вкий, -ая, -ое чүкүгә бирелүчән, чүкелүчән; **~ мета́лл** чүкелүчән металл

ко́вкость *ж* чүкелүчәнлек

коври́га *ж* бөтен икмәк, бер бөтен ипи

коври́жк||а *ж* прәннек ♦ **ни за каки́е ~и** һичбер, һич тә, бер дә, гомердә дә; дисәләр дә

ковро́вщица *ж* келәмче, келәм тукучы; палас тукучы хатын (кыз)

ковчег *м*: **Но́ев ~** *миф.* Нух көймәсе

ковш *м* **1.** чүмеч, соскы **2.** *тех.* чүмеч; **~ экскава́тора** экскаваторның чүмече

ко́вшик *м уменьш. от* **ковш** 1

кovы́ль *м* кылган

кovы́л||ьий, -ья, -ье кылган ..., кылганлы; **~ые сте́пи** кылганлы далалар

кovыля́ть *несов. разг.* тыйтаклап (чатанлап, аксаклап) бару (*аякларны көчкә сөйрәп, акрын бару*)

кovырну́ть *сов. однокр. что, в чём* казып (куптарып) алу

кovыря́ть *несов. что, в чём* казу, казып куптару, актару; **~ зе́млю** җир актару, туфрак актару; **~ в зуба́х** тешләрне казу

кovыря́ться *несов.* **1.** *в чём, разг.* казыну, чокыну; **~ в песке́** комда казыну, актарыну **2.** *прост.* (*возиться*) акрын кыймылдау, акрын эшләү, казыну

когда́ **1.** *нареч. вопр., относ.* кайчан; кайвакытта; **~ ты уе́дешь?** син кайчан китәсең?; **я не зна́ю, ~ он прие́дет** мин аның кайчан киләсен белмим **2.** *нареч. неопр. прост.* берәр вакыт, кайчан да булса; **жил ли ты ~ на Се́вере?** кайчан да булса Төньякта торганың бармы? **3.** *нареч. неопр. прост.* кайчакта; **~ мо́жно, ~ нельзя́** кайчак ярый, кайчакта ярамый **4.** *союз временной* ...гач, ...нан соң, ...ганда, ...ган чакта; чакта, вакытта; **отдохнём, ~ зако́нчим рабо́ту** эшне бетергәч ял итәрбез **5.** *союз усл.* әгәр ...са, әгәр дә ...икән; **рабо́та спори́тся, ~ ясна́ цель** әгәр максат ачык булса, эш яхшы бара ♦ **когда́ ка́к** кайчан ничек; **~ бы ни...** кайчан гына булмасын ...; **ре́дко ~** бик сирәк

когда́-либо, когда́-нибудь *нареч.* кайчан да булса, кайчан булса да, берәр вакытны

когда́-то *нареч.* кайчандыр; **~ мы бы́ли знако́мы** кайчандыр без таныш идек

когóрта *ж* когорта (**1.** *борынгы Римда легионның уннан бер өлеше* **2.** *перен. высок. бердәм тупланган кешеләр төркеме*)

ко́готь *м* тырнак (*кошларда һәм җәнлекләрдә*)

когти́стый, -ая, -ое үткен тырнаклы

код *м* код (*шартлы кыскартмалар исемлеге, мәс. телеграф эшендә, төрле сигналлар бирүдә*)

ко́декс *м прям., перен.* кодекс; **граждáнский ~** гражданлык кодексы; **угóловный ~** җинаятьләр кодексы; **нрáвственный ~** әхлак кодексы; **морáльный ~** мораль кодексы

кодúровать *несов., сов. что, спец.* кодка салу

кодификáция *ж юр.* кодификация

кодифици́ровать *сов., несов. что, юр.* кодификацияләү, кодекска туплау

ко́е-где́ *нареч.* кайбер урыннарда, кайбер җирләрдә; анда-монда, анда-санда, ара-тирә, урыны-урыны белән

ко́е-ка́к *нареч.* 1. көчкә-көчкә генә, чак-чак кына, көч-хәл белән; **~ мы дошли́** көч-хәл белән барып җиттек 2. ничек итте шулай, алай-болай гына, әштер-өштер генә, әштер-өштер китереп; **они́ сде́лали э́то ~** алар моны әштер-өштер генә эшләгәннәр

ко́е-как||о́й *мест.* 1. кайбер; **позво́льте обрати́ться к вам с ~и́ми про́сьбами** сезгә кайбер үтенечләр белән мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез 2. азмаз, вак-төяк, бераз, беркадәр; **завели́сь ~и́е деньжо́нки** кулга аз-маз акча да керде

ко́е-когда́ *нареч.* кайчакта, ара-тирә

коé-кто́ *мест.* кемнәрдер, кайберәүләр, кайбер кешеләр

ко́е-куда́ *нареч.* берәр җиргә

ко́ечн||ый, -ая, -ое койка ...ы; **~ая се́тка** койка челтәре

ко́е-что́ *мест.* нәрсәдер, нидер; кайбер әйберләр

ко́ж||а *ж* 1. (*человека, животного*) тире 2. (*выделанная шкура*) күн 3. *разг.* (*кожура*) кабык ◆ **~а да ко́сти** тире дә сөяк кенә; **из ~и [вон] лезть** җанфәрманга тырышу, тиргә батып тырышу

ко́жанка *ж разг.* күн пальто (куртка)

ко́жан||ый, -ая, -ое күн ...; күннән тегелгән; күн белән тышланган; **~ая о́бувь** күннән тегелгән аяк киеме; **~ое кре́сло** күн белән тышланган кәнәфи

кожéвенн||ый, -ая, -ое күн ..., күн ...ы; **~ый заво́д** күн заводы; **~ые това́ры** күн товарлар

кожéвник *м* күнче

кожими́т *м уст.* кожимит (*ясалма күн*)

ко́жистый, -ая, -ое калын тиреле; тыгыз тиреле (*мәс. фил турында*); калын кабыклы, тыгыз кабыклы (*мәс. бәрәңге, карбыз*)

ко́жица *ж* 1. *ласк. от* **ко́жа** 1, 3; юка тире 2. яры, кабык: **~ молодо́го листа́** яшь яфракның ярысы

ко́жник *м разг.* тире авырулары табибы

ко́жн||ый, -ая, -ое тире ...ы; **~ые боле́зни** тире авырулары

кожура́ *ж* кабык

кожу́х *м* 1. (*тулуп*) толып 2. *тех.* кожух, капкач, каплавыч, япма

коз||а́ *ж* кәҗә; **дома́шняя ~а́** йорт кәҗәсе; **ди́кая ~а́** кыр кәҗәсе ◆ **драть как си́дорову ко́зу** *кого* эштән чыгарып кыйнап ташлау, эт урынына кыйнау, тетмәсен тетү; **на ~е́ не объе́дешь** *кого* ≈ кәкре каенга терәтә алмассың

коз||ёл *м* 1. кәҗә тәкәсе 2. *спорт.* кәҗә ◆ **~ёл отпуще́ния** бәлаләр сәбәпчесе (*бутәнәрнәң гаебе, җәваплылыгы һәрвакыт аның өстенә төшә торган мәхлук кеше турында әйтелә*); **[от него́] как от ~ла́ молока́** *погов.* аңардан он да юк, сөт тә юк; **пусти́ть ~ла́ в огоро́д** кәҗәне кәбестә сакларга кую

козеро́г *м* 1. *зоол.* кыргый кәҗә 2. (*с прописной*) *астр.* Кәҗәмөгез; **тро́пик Козеро́га** Кәҗәмөгез тропигы

ко́з||ий, -ья, -ье кәҗә ...ы; **~ье молоко́** кәҗә сөте ◆ **~ья но́жка** кәҗә тоягы (*кулдан махсус төрелгән тәмәке*)

козлёнок *м* кәҗә бәтие (*бәрәне*)

козли́н||ый, -ая, -ое 1. кәҗә ...ы; кәҗә тиресеннән тегелгән; **~ая доха́** кәҗә тиресеннән тегелгән доха 2. кәҗә ...; кәҗә ...ы; **~ая боро́дка** кәҗә сакал; **~ым го́лосом** кәҗә тавышы белән

козло́в||ый, -ая, -ое кәжүл ..., кәҗә күненнән эшләнгән; **~ые сапоги́** кәҗүл итек

ко́злы *только мн.* 1. кузла, ат башы (*экипажда күчер урыны*) 2. (*для пилки дров*) кузла, дүртаяк ◆ **соста́вить (поста́вить) ру́жья (винто́вки) в ~** мылтыкларны (винтовкаларны) көпшәләрен (штыкларын) югары каратып, бер-берсенә сөяп кую

козля́тина *ж* кәҗә ите

ко́зни *только мн.* явыз уйлар (ниятләр), хәйләләр, мәкерләр

козодо́й *м* төн күгәрчене

козырёк *м* козырёк (*мәс. кепкада, тәрәзәләр өстендә*)

козырно́й, -а́я, -о́е козырь ...ы; **~ туз** козырь тузы

козырну́ть I *сов.* 1. *однокр. от* **козыря́ть** I 1; *перен. чем* шапырынып алу (кую), мактанып алу (кую)

козырну́ть II *сов. однокр. от* **козыря́ть** II

козы́рный, -ая, -ое *см.* **козырно́й**

ко́зыр||ь *м* 1. козырь, уен кәрте; **ходи́ть с ~я** уен кәрте белән йөрү 2. *перен.* чара, өстенлек; **после́дний ~ь** соңгы чара

козыря́ть I *несов. разг.* 1. (*ходить с козыря*) уен белән йөрү, козырь белән йөрү, уен картасы белән чыгу 2. *перен. чем* мактану, кәпрәю, шапырыну; **~ свои́ми зна́ниями** үзеңнең белемең белән шапырыну

козыря́ть II *несов. кому-чему, разг.* честь бирү

козя́вка *ж разг.* вак бөҗәк, вак корт

кой *мест.*: **ни в ко́ем слу́чае** бер вакытта да; һичкайчан, һич ярамый

кой-где́ *разг. см.* **ко́е-где**

ко́йка *ж* койка, ятак

кой-ка́к *ж разг. см.* **ко́е-ка́к**

кой-како́й *разг. см.* **ко́е-како́й**

кой-когда́ *разг. см.* **ко́е-когда́**

кой-кто́ *разг. см.* **ко́е-кто́**

кой-куда́ *разг. см.* **ко́е-куда́**

кой-что́ *разг. см.* **ко́е-что́**

кок I *м* кок (*күпертелгән чәч бөтеркәсе*)

кок II *м мор.* кок (*судно пешекчесе*)

кокаи́н *м* кокаин (*наркотик*)

кокаини́ст *м* кокаинчы

ко́ка-ко́ла *ж* кока-кола (*хәл кертә торган эчемлек*)

кока́рда *ж* кокарда (*баш киеменең маңгай турысына кадап куела торган значок*)

кокéтка *ж* 1. кокетка, кыланчык, чытлык 2. (*часть одежды*) кокетка

кокéтлив||ый, -ая, -ое кыланчык; чытлык; **~ая де́вушка** кыланчык кыз; **~ая улы́бка** кыланчык елмаю

кокéтничать *несов. с кем-чем и без доп.* кыланчыклану, чытлыклану

кокéтство *с* кыланчыклык, чытлыклык

ко́кки *мн. мед.* кокк (*шарсыман микроблар*)

коклю́ш *м* бума ютәл, коклюш

коклю́шка *ж* җияк, тамбур энәсе (*челтәр бәйләү өчен*)

коклю́шный, -ая, -ое бума ютәл ...ы; бума ютәлле, коклюшлы; **~ ка́шель** бума ютәл; **~ ребёнок** бума ютәлле бала

ко́кон *м* кузы, кокон; **шелкови́чный ~** ефәк кузысы; **~ ба́бочки** күбәләк кузысы

кокóс *м* кокос (*пальма агачы һәм чикләвеге*)

кокóсов||ый, -ая, -ое кокос ...ы; **~ое ма́сло** кокос мае; **~ый оре́х** кокос чикләвеге

кокóшник *м уст.* кокошник (*хатын-кызларның бизәкле баш киеме*)

кокс *м* кокс (*ташкүмернең махсус кыздырып хәзерләнгән төре*)

кок-сагы́з *м* күк сагыз

коксова́льн||ый, -ая, -ое *тех.* кокслау ...ы; **~ая печь** кокслау миче

коксова́ние *с см.* **коксова́ть**

коксова́ть *несов. что, тех.* кокслау, кокска әйләндерү (*ташкүмерне*)

коксу́ющ||ийся, -аяся, -еюся кокс бирә торган, коксланa торган; **~ийся у́голь** коксланa торган ташкүмер

кокте́йль *м* коктейль (*шәраб, сок һәм тәмләткечләр салынган исерткеч яки сусауны баса торган салкын эчемлек*)

кол *м* 1. (*мн.* **ко́лья**) казык; **дубо́вый ~** имән казык 2. (*мн.* **колы́**) *разг.* (*оценка*) берле билгесе (*мәктәптә иң түбән билге*) ◆ **хоть ~ на голове́ теши́** *кому, прост.* әйттең ни, әйтмәдең ни, барыбер файдасы юк (*аңгыра, кире, уҗәт кеше турында*); **ни ~а́ ни двора́** *у кого* бернәрсәсе дә юк; фәкыйрь

ко́лба *ж* колба (*химик савыт*)

колбаса́ *ж* колбаса; казылык; (*национальное кушанье*) тутырма; **копчёная ~** ысланган казылык

колба́сн||ый, -ая, -ое колбаса ...ы; казылык ...ы; **~ые изде́лия** колбаса әйберләре, колбасалар

колго́тки *только мн.* колготки (*оеклары белән тоташ ыштан*)

колдова́ть *несов.* 1. сихерләү, сихерчелек итү, күз буу 2. *над кем-чем и без доп., разг.* маташу, маташтыру

колдовство́ *с* сихерчелек
колду́н *м* сихерче
колду́нья *ж* сихерче хатын (кыз)
колеба́ни||е *с* **1.** *см.* **колеба́ться** 1; **~е ма́ятника** маятникның тирбәнүе **2.** (*сомнение*) икеләнү **3.** үзгәреш, алышыну, алмашыну, үзгәреп тору; **~е цен** бәяләрнең үзгәреп торуы; **~я температу́ры** температураның үзгәреп торуы
колеба́тельн||ый, -ая, -ое тирбәлү ...ы; тирбәнү ...ы; **~ые движе́ния** тирбәнү хәрәкәтләре
колеба́ть *несов. что* **1.** тирбәтү, тирбәлдерү, селкетү, хәрәкәтләндерү, дулкынландыру; **ве́тер коле́блет верху́шки дере́вьев** җил агач башларын селкетә **2.** какшату; **~ обще́ственные усто́и** иҗтимагый нигезләрне какшату
колеба́||ться *несов.* **1.** (*раскачиваться, мерно двигаться*) тирбәлү, селкенү, дулкынлану **2.** (*быть в нерешительности*) икеләнү, икеләнеп тору; шикләнү, шөбһәләнү **3.** какшау, төшү; **в после́днее вре́мя его́ авторите́т стал ~ться** аның абруе соңгы вакытта какшый башлады **4.** үзгәреп тору; **це́ны коле́блются** бәяләр үзгәреп тора **5.** *страд. от* **колеба́ть** 1
коле́нка *ж разг.* тез; **сиде́ть** *у кого-л.* **на ~х** *кемнең дә булса* тезләре өстендә утыру
коленко́р *м* коленкор (*тукыма*) ◆ **совсе́м друго́й ~** бөтенләй башка нәрсә (эш)
коленко́ровый, -ая, -ое коленкор ...ы; коленкор ...; коленкордан эшләнгән; **~ переплёт** коленкор тышлык
колéнн||ый, -ая, -ое тез ...ы; **~ая ча́шка** *анат.* тез капкачы
колéн||о *с* **1.** (*мн.* **~и**) тез, тез буыны **2.** (*мн.* **~ья**) буын, буынтык, кисәк; **~ья бамбу́ка** бамбук буыннары; **~ья желе́зной трубы́** тимер торбаның буынтыклары **3.** (*мн.* **~а**) борылма, борылыш; **в ~е реки́** елга борылмасында **4.** (*мн.* **~а**) (*поколение*) буын ◆ **выде́лывать ~а** (*в танце*) төрле фигуралар ясап бию; **вы́кинуть (отмочи́ть) ~о** мәгез чыгару; **поста́вить на ~и** *кого-что* тез чүктерү, баш идерү
коленопреклоне́ние *с высок.* тез чүгеп тору, тез чүгү, тезләнү
колéнчатый, -ая, -ое буынлы, буыннардан торган; терсәкле; **~ ствол** буынлы кәүсә; **~ вал** *тех.* терсәкле вал
ко́лер *м спец.* төс, төсмер
колеси́ть *несов. разг.* [әйләнеч юлдан] йөрү; [төрле юнәлешләрдә] күп йөрү; **~ по доро́гам** юлларда күп йөрү
коле́сник, колёсник *м* көпчәкче, көпчәк ясаучы оста
колесни́ца *ж уст.* зур экипаж
колёсный, -ая, -ое **1.** тәгәрмәч ...ы; көпчәк ...ы; **~ ма́стер** тәгәрмәч ясау остасы **2.** тәгәрмәчле, көпчәкле; **~ тра́ктор** тәгәрмәчле трактор
колес||о́ *с* **1.** тәгәрмәч, көпчәк; **~о́ ваго́на** вагон тәгәрмәче; **зубча́тое ~о́** тешле тәгәрмәч; **веду́щее ~о́** йөртүче тәгәрмәч **2.** (*мельницы*) чарык ◆ **на колёсах [жить, быть]** һәрвакыт юлда булу; **но́ги ~о́м** камыт аяклы
колесова́ть *сов., несов. кого уст.* җәзалау (*махсус тәгәрмәчтә*)
коле||я́ *ж* **1.** (*след колеса*) эз, тәгәрмәч эзе **2.** *ж.-д.* колея ◆ **вы́йти (вы́биться) из ~и́** чыгырыннан чыгу; **жизнь вошла́ в обы́чную ~ю́** тормыш гадәттәге эзенә төште
ко́ли (коль) *союз уст.* әгәр, әгәр дә, әгәренки, ...сың икән; **~ лю́бишь...** яратасың икән ...
коли́бри *м, ж нескл.* колибри (*бик кечкенә кошчык*)
ко́лики *мн.* чәнчү, чәнчү алу; **~ в живото́** эчне чәнчә
коли́т *м мед.* колит (*юан эчәкнең ялкынсынуы*)
коли́честв||о *с* **1.** *филос.* микъдар, сан; **перехо́д ~а в ка́чество** сан сыйфатка күчү **2.** (*число, величина*) микъдар, күләм, сан
ко́лка *ж см.* **коло́ть** II; **~ дров** утын яру
ко́лк||ий I, -ая, -ое **1.** чәнчүчән, кадалучан; **~ая хво́я** кадалучанылыс **2.** *перен.* чәнчүле, ачы, зәһәрле; **~ое замеча́ние** чәнчүле кисәтү
ко́лк||ий II, -ая, -ое *разг.* ярылучан, тиз ярылучан; ватылучан; **~ие дрова́** тиз ярылучан утын
ко́лкость *ж* **1.** зәһәрлек, чәнчүчәнлек; **~ замеча́ний** кисәтүләрнең зәһәрлеге **2.** зәһәр сүз; чәнчүле сүз; **сказа́ть** *кому-л.* **~** *кемгә дә булса* зәһәр сүз әйтү
коллаборацио́нист *м книжн.* коллаборационист (*икенче бөтендонья сугышы чорында фашист гаскәрләре оккупациясендә үз ватанына хыянәт итеп, оккупантларга хезмәт иткән кеше*)
колле́га *м, ж* коллега, иптәш, хезмәттәш
коллегиа́льност||ь *ж* коллегиальлек, бергәлек (*мәсьәләләрне бергәләп хәл итү*); **при́нцип ~и** коллегиальлек принцибы
коллегиа́льн||ый, -ая, -ое коллегиаль, бергәләп ...; **~ое реше́ние** бергәләп чишү
колле́гия *ж* коллегия (**1.** *учреждение хезмәткәрләренең барлык составы* **2.** *Россиядә 18 гасырда: дәүләтнең үзәк учреждениеләренең исеме* **3.** *берничә кеше составында төзелгән, киңәшү яки карар чыгару органын тәшкил итә торган төркем*)
ко́лледж *м* колледж (*урта һәм югары уку йортларының исеме*)
колле́ж *м* коллеж (*Франциядә, Бельгиядә, Швейцариядә урта уку йортларының исеме*)
коллекти́в *м* коллектив
коллективиза́ция *ж* коллективлаштыру, коллективлашу
коллективизи́ровать *сов., несов. что* коллективлаштыру; **~ се́льское хозя́йство** авыл хуҗалыгын коллективлаштыру
коллективи́зм *м* коллективизм, күмәкчеллек
коллективи́ст *м* коллективчы, бергәлекне яклаучы
коллекти́вн||ый, -ая, -ое коллектив ..., гомуми, уртак ..., күмәк ..., бергәләп эшләнгән; **~ый труд** коллектив хезмәт; **~ое выступле́ние** күмәк чыгыш
колле́ктор *м* коллектор (**1.** *тех. төрле торбалардан килгән сыекчаларны, газларны җыеп, кая да булса җибәрү өчен канал яки юан торба* **2.** *тех. динамомашинада алмаш токны даими токка әйләндерү җайланмасы* **3.** *китапханәләргә китаплар тарату эше белән шөгыльләнә торган оешма*)
коллекционе́р *м* коллекционер
коллекциони́ровать *несов. что* коллекцияләү; **~ ста́рые кни́ги** иске китаплар җыю
колле́кция *ж* коллекция; **~ дре́вних моне́т** борынгы акчалар коллекциясе
колли́зия *ж книжн.* коллизия (*капма-каршы көчләрнең, омтылышларның, интересларның бәрелеше*)
колло́дий *м* коллодий (*медицинада һәм фотографиядә кулланыла торган куе ябышкак эремә*)
колло́ид *м хим.* коллоид (*кристаллашмый торган матдә*)
колло́идн||ый, -ая, -ое *хим.* коллоид ..., коллоидлы; **~ый раство́р** коллоид эремә; **~ые вещества́** коллоидлы матдәләр
колло́квиум *м* коллоквиум (*укучыларның белемнәрен сынау өчен укытучының алар белән әңгәмә үткәрүе*)
колобро́дить *несов. прост.* тик (буталып, бушка) йөрү
коловоро́т *м* коловорот, борау
коло́да I *ж* **1.** (*обрубок бревна*) түмәр, бүкән, кискә **2.** улак, ялгаш; **водопо́йная ~** су эчерү ялгашы
коло́да II *ж* колода (*уен кәртләренең тулы комплекты*)
коло́дезн||ый, -ая, -ое кое ...ы; **~ая вода́** кое суы
коло́дец *м* **1.** кое; **артези́анский ~** артезиан коесы **2.** *спец.* чокыр, кое; **ша́хтный ~** шахта коесы
коло́дк||а *ж* **1.** *сапожн.* калып, аяк киеме калыбы **2.** кыса; **~а щётки** щётка кысасы **3.** *обычно мн.* **~и** (*ножные оковы*) агач богау **4.** колодка (*орден, медальләр тагу өчен яки шуларның тасмаларын беркетү өчен металл планка*)
коло́дник *м уст.* агач богаулы тоткын
кол||о́к *м* боргыч; **~ки́ скри́пки** скрипка боргычлары
ко́локол *м* **1.** кыңгырау; чаң **2.** колокол, калпак; **водола́зный ~** водолазлар колоколы (*су төбенә төшү җайланмасы*)
колоко́льный, -ая, -ое кыңгырау ...ы; чаң ...ы; **~ звон** чаң тавышы
колоко́льн||я *ж* чиркәү манарасы ◆ **со свое́й ~и смотре́ть** *на что* үз күзлегеннән генә карау (*гомуми фикер белән исәпләшмәү*)
колоко́льчик *м* **1.** *уменьш. от* **ко́локол** 1; шөлдер **2.** *бот.* кыңгырау чәчәк
колониа́льн||ый, -ая, -ое **1.** колониаль, колониячелек ...ы; **~ая поли́-**

тика колониаль сәясәт **2.** колония биләүче ...; **~ые стра́ны** колония биләүче дәүләтләр

колониза́тор *м* колонизатор (**1.** *колония халыкларын изү, кысу сәясәте алып баручы, колонияләрдә хезмәт ияләрен коллыкка төшерүче* **2.** *буш яткан җирләргә халык урнаштыруны оештыручы*)

колониза́торск||ий, -ая, -ое колонизаторлык ...ы; **~ая поли́тика** колонизаторлык сәясәте

колониза́ция *ж* **1.** (*захват чужой страны*) колонияләштерү, колонияга әйләндерү **2.** (*заселение колонистами*) колонизацияләү, халык (колонистлар) күчереп утырту

колониза́ционн||ый, -ая, -ое колонизацияләү ...ы; колонияләштерү ...ы; колонизацион; **~ая поли́тика** колонизацияләү сәясәте

колонизи́ровать, колонизова́ть *сов., несов. что* колонияләштерү, колонияга әйләндерү

колони́ст *м* колонист (**1.** *башка илдән, башка өлкәдән күчеп килгән кеше* **2.** *колониядә яшәүче кеше*; *см.* **коло́ния** 2, 4)

колони́стка *ж* колонист хатын (кыз)

коло́ния *ж* колония (**1.** *империалистик дәүләт тарафыннан басып алынган ил яки өлкә* **2.** *бер дәүләт җиренән икенче дәүләт җиренә күчеп утырган кешеләр төркеме* **3.** *чит шәһәрдә, чит илдә яшәүче якташлар төркеме* **4.** *махсус максатларны күздә тотып, мәс. аерым группа кешеләрне дәвалау, тәрбияләү, төзәтү өчен оештырылган бергә яшәү урыны* **5.** *биол. бергә укмашып яшәүче микроблар, бөҗәкләр төркеме*)

коло́н||ка *ж* **1.** *в разн. знач.* колонка; **га́зовая ~ка** газ колонкасы; **бензи́новая ~ка** бензин колонкасы; **пойти́ к ~ке за водо́й** колонкага суга бару **2.** багана; **газе́та в пять ~ок** биш баганалы газета

коло́нна *ж* **1.** колонна; **~ демонстра́нтов** демонстрантлар колоннасы; **~ автомаши́н** автомашиналар колоннасы **2.** колонна, терәк, багана; **дом с ~ми** колонналы йорт

колонна́да *ж* колонналар тезмәсе

коло́нный, -ая, -ое колонналы; **~ зал** колонналы зал

колоно́к *м* **1.** (*животное*) себер көзәне **2.** (*мех*) себер көзәне тиресе

колонти́тул *м полигр.* колонтитул (*китап битенең югарыгы башына басылган сүзләр*)

колонци́фра *ж полигр.* колонцифр (*китап битләренә куела торган цифрлар*)

колорату́ра *ж муз.* колоратура (*вокаль партияне техник яктан кыен булган тавыш калыратулар, моңнар белән бизәү*)

колори́т *м* **1.** колорит (*сәнгать әсәрләрендә, мәс. картинада буяуларның тон һәм төс тулылыгы ягыннан бер-берсенә мөнәсәбәтләре*) **2.** *перен.* төс, колорит; **расска́зчик прида́л э́тому собы́тию юмористи́ческий ~** хикәяләүче бу вакыйгага юмористик төс биргән

колори́тн||ый, -ая, -ое **1.** колоритлы **2.** *перен.* характерлы, үзенә бертөрле, үзенчәлекле; **~ая фигу́ра** үзенчәлекле кеше

ко́лос *м* башак, баш

колоси́стый, -ая, -ое зур (эре) башаклы, башлы (*иген турында*)

колоси́ться *несов.* башаклану, башак (баш) чыгару (кысу)

колосники́ *мн.* **1.** рәшәткә (*нава керсен һәм көл коелып төшсен өчен мич төбенә куела торган чуен рәшәткә*) **2.** сәндерә (*колмак, көлтә кебекләрне элеп яки өеп киптерү өчен колгалардан аралап ясалган сәндерә*) **3.** *театр.* колосниклар (*театрда сәхнәнең декорацияләрен югарыдан беркетеп кую өчен хезмәт итә торган агач рәшәткәләр*)

колосов||о́й, -а́я, -о́е **1.** башаклы; **~ы́е культу́ры** башаклы культуралар **2.** *в знач. сущ.* **~ы́е** *мн. бот.* башаклылар, башаклы культуралар

коло́сс *м* **1.** колосс (*бик зур статуя яки бик зур багана*) **2.** *перен. высок.* гаять зур (мәһабәт) (*кеше турында*); **~ мы́сли** бик зур фикер иясе ♦ **~ на гли́няных нога́х** камыр батыр (*гаять зур, ләкин зәгыйфь кем-нәрсә турында*)

колосса́льн||ый, -ая, -ое бик зур, ифрат (гаять, галәмәт) зур; **~ые запа́сы не́фти** гаять зур нефть запаслары; **~ый успе́х** гаять зур уңыш

колот||и́ть *несов.* **1.** *по чему, во что* сугу, шакылдату, кагу; **~и́ть в дверь** ишек кагу **2.** *кого-что, разг.* кыйнау, тукмау, дөмбәсләү, төю **3.** *что* вату, җимерү; **~и́ть посу́ду** савыт-саба вату **4.** *кого-что, разг.* калтырату; **его́ коло́тит лихора́дка** аны бизгәк калтырата

колоти́ться *несов.* **1.** (*биться обо что-л.*) бәрелү **2.** (*о сердце*) дөп-дөп тибү

колоту́ш||ка *ж* **1.** (*деревянный молоток*) тукмак **2.** (*ночного сторожа*) шакылдавык **3.** *прост.* йодрык белән сугу; **надава́ть ~ек** бик каты йодрыклау

ко́лот||ый I, -ая, -ое чәнчүдән булган; **~ая ра́на** чәнчүдән булган яра

ко́лот||ый II, -ая, -ое **1.** ярылган, тырачланган; **~ые дрова́** ярылган утын **2.** ватылган, шакмаклы; **~ый са́хар** ватылган шикәр

кол||о́ть I *несов.* **1.** *кого-что* чәнчү, кадау; **~о́ть игло́лкой** энә белән чәнчү; **~о́ть копьём** сөнге белән кадау **2.** *безл. что, в чём* чәнчешү; **у меня́ в груди́ ко́лет** минем күкрәгем чәнчешә **3.** (*резать скот*) сую, чалу, бугазлау ♦ **~о́ть глаза́** *кому чем* битәрләү, оялту; **[темно́], хоть глаз ~и́** күзгә төртсән дә күренмәслек (карангы)

коло́ть II *несов. что* яру, тураклау, вату; **~ дрова́** утын яру; **~ лёд** боз вату; **~ са́хар** шикәр вату; **~ оре́хи** чикләвек вату

коло́ться I *несов.* чәнчү; **хво́я ко́лется** ылыс чәнчә

коло́ться II *несов.* **1.** ярылу, ватылу; **дрова́ ко́лются** утын ярыла; **~ са́хар ко́лется** шикәр ватыла **2.** *страд. от* **коло́ть** II

колоше́ние *с см.* **колоси́ться**

колпа́к *м* **1.** (*головной убор*) калпак **2.** (*покрышка*) капкач, япкыч

колту́н *м вет., мед.* чәч киезләнү (*авыруның бер төре*)

колумба́рий *м* колумбарий (*крематорийда яндырылган мәетләрнең көле салынган тартмаларны саклау урыны*)

колу́н *м* колун, калын балта, утын яру балтасы

колхо́з *м* колхоз

колхо́зник *м* колхозчы

колхо́зница *ж* колхозчы хатын (кыз)

колча́н *м* ук савыты, ук кынысы, садак

колчедан́ *м мин.* колчедан

колчено́гий, -ая, -ое *прост.* аксак, чатан; **~ стул** чатан урындык

колыбе́л||ь *ж* **1.** (*детская*) бишек, бәллү **2.** *перен. высок.* ватан, бишек; **~ь о́перного иску́сства** опера сәнгатенең ватаны ♦ **с ~и** туган көненнән үк, кече яшьтән үк

колыма́га *ж ирон.* зур авыр арба

колыха́ть *несов. что* тирбәтү, селкетү, тирбәлдерү, чайкалдыру, җилфердәтү; **ве́тер колы́шет занаве́ску** җил пәрдәне җилфердәтә

колыха́ться *несов.* тирбәлү, селкенү, чайкалу, җилфердәү; **рожь колы́шется от ве́тра** җилдән арышлар чайкала

колыхну́ть *сов. однокр. что* тирбәтеп (селкетеп, җилфердәтеп) кую, чайкалдырып алу

колыхну́ться *сов. однокр.* тирбәлеп (селкенеп, чайкалып, җилфердәп) кую, тирбәлеп (селкенеп, чайкалып, җилфердәп) алу

коль *см.* **ко́ли** ♦ **~ ско́ро** әгәр ...а икән; **~ ско́ро вы согласи́тесь, я гото́в примири́ться** әгәр сез риза буласыз икән, мин татулашырга әзер

колье́ *с нескл.* колье, муенса

кольну́||ть *сов. однокр.* **1.** *кого-что* чәнчеп (кадап, төртеп) алу **2.** *безл. что, в чём* (*об ощущении боли*) чәнчеп алу (кую); **у меня́ ~ло в боку́** *безл.* кабыргам чәнчеп куйды **3.** *перен. кого-что* чәнечкеле (төртмәле) сүз әйтеп кую

кольра́би *ж нескл.* кольраби (*кәбестәнең бер сорты*)

кольт *м* кольт (*револьверның яки пулемётның бер төре*)

кольцева́ние *с см.* **кольцева́ть; ~ птиц** кошларны бөжралау

кольцева́ть *сов., несов.* **1.** *кого-что* (*птиц, рыб*) бөжралау, бөжра (балдак) кидерү **2.** *что* (*обмазывать ствол дерева вкруговую*) бөжралау, балдаклау (*корткычлар үрмәлән менүдән саклау өчен агачның кәүсәсен сумала яки башка берәр ябышкак нәрсә белән бөжралап буяу*) **3.** *что* (*снимать кору кольцом*) [кайрыны] бөжралап куптарып алу

кольцев||о́й, -а́я, -о́е **1.** бөжра ...ы; балдак ...ы; **~о́е отве́рстие** бөжра тишеге **2.** түгәрәк ясап ...; әйләнеш ясап ...; әйләнешле; **~о́е движе́ние** түгәрәк ясап хәрәкәт итү

кольц||о́ *с* **1.** бөжра, алка; **~о́ для ключе́й** ачкыч бөжрасы; **цепно́е ~о́** чылбыр алкасы; **~о́ парашю́та** парашют алкасы **2.** балдак, йөзек; **обруча́льное ~о́** никах балдагы **3.** *перен. чего* бөжра, алка; **~о́ блока́ды** блокада бөжрасы **4.** (*конечный пункт маршрута*)

әйләнеш; **на трамва́йном ~е́** трамвай әйләнешендә ♦ **годи́чные ко́льца** *бот.* еллык бөжралар

ко́льчат||ый, -ая, -ое **1.** бөжралардан тора торган; **~ая цепо́чка** бөжралардан тора торган чылбыр **2.** *зоол.* бөжралы, балдаклы; **~ые че́рви** бөжралы суалчаннар

кольчу́га *ж* көбә кием, көбә (*вак металл бөжралардан эшләнгән борынгы сугыш киеме*)

колю́ч||ий, -ая, -ее **1.** чәнечкеле; чәнчи торган; **~ая про́волока** чәнечкеле тимерчыбык; **~ие расте́ния** чәнечкеле үсемлекләр; **~ая борода́** чәнчи торган сакал **2.** чәнчүле, чәнчеп (чеметтереп) ала торган; **~ий моро́з** чеметтереп ала торган суык **3.** *перен.* (*язвительный*) агулы, зәһәр, чәнечкеле, ачы ♦ **~ая аку́ла** *зоол.* чәнечкеле акула; **боя́рышник ~ий** *бот.* чәнечкеле дүләнә

колю́чка *ж* чәнечке, энә, шырпы; **~ чертополо́ха** шайтан таягының чәнечкесе

коляда́ *ж* коляда (*рождество бәйрәме вакытында җырлар белән үткәрелә торган йола*)

коля́ска *ж* **1.** сиртмәле арба **2.** балалар арбасы, коляска

ком *м* **1.** кантар, төер, кисәк; **~ сне́га** кар кисәге ♦ **~ в го́рле [стои́т, застря́л]** тамакка төер утырды (тыгылды)

кома́нд||а *ж* **1.** команда, боерык; **раздала́сь ~а** команда яңгырады **2.** команда, төркем; **футбо́льная ~а** футбол командасы ♦ **как по ~е** бердәм, дәррәү

командо́р *м* командир

командирова́ть *сов., несов. кого-что* командировкага җибәрү

командиро́вк||а *ж* **1.** *см.* **командирова́ть; 2.** (*служебное поручение*) командировка: **получи́ть ~у** командировка алу; **нау́чная ~а** фәнни командировка **3.** (*поездка*) командировка; **находи́ться в ~е** командировкада булу **4.** *разг.* (*удостоверение*) командировка таныклыгы; **вы́писать ~у** командировка таныклыгы язу

командиро́вочн||ый, -ая, -ое **1.** командировка ...ы; **~ое удостовере́ние** командировка таныклыгы **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* командировка акчасы; **я получи́л ~ые** мин командировка акчасы алдым

командо́рск||ий, -ая, -ое **1.** командир[лык] ...ы; **~ие обя́занности** командирлык вазифалары **2.** *перен.* командирлар ...ы; **~ий вид** командирлар кыяфәте

командо́рша *ж разг.* кушып, боерып торырга яратучы хатын (кыз)

кома́нд||ный, -ая, -ое **1.** команда ...ы; **~ые состяза́ния** команда ярышлары **2.** командир[лык] ...ы; командир[лар] ...ы; **~ый соста́в** командирлар составы; **~ая до́лжность** командирлык вазифасы **3.** өстен, өстенлек итүче; **заня́ть ~ое положе́ние** өстен урын алу, өстенлек алу ♦ **~ые выс|о́ты** 1) *воен.* иң биек урыннар; 2) *перен.* иң мөһим участок, кирәкле пункт

кома́ндование *с* **1.** *см.* **кома́ндовать** 2; **2.** *собир.* командирлар, командование; **~ полка́** полкның командирлары

кома́ндовать *несов.* **1.** команда бирү **2.** *кем-чем* командалык итү, җитәкчелек итү; **~ полко́м** полк белән җитәкчелек итү **3.** *кем-чем, над кем и без доп., разг.* боерык бирә тору; **он привы́к до́ма ~** өендә боерык бирә торырга күнеккән

командо́р *м* командор (**1.** *ист.* рыцарьлар союзларында югары дәрәҗә **2.** *спорт* оешмаларында башлык)

кома́ндующий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **кома́ндовать; 2.** *в знач. сущ. м* командующий (*зур гаскәри берләшмә начальнигы*)

кома́р *м* озынборын, черки ♦ **~ но́са не подто́чит** *погов.* ≈ менә дигән, менә дигән итеп эшләнгән, тел тидермәслек

комари́ный, -ая, -ое черки ...ы, озынборын ...ы; **~ уку́с** озынборын тешләве

комба́йн *м* комбайн

комба́йнер *м* комбайнчы

комба́йнов||ый, -ая, -ое **1.** комбайн ...ы; **~ый заво́д** комбайн заводы **2.** комбайн белән ...; **~ая убо́рка хле́ба** игенне комбайн белән урып җыю

комбико́рм *м* комбиазык (*катнаш мал азыгы*)

комбина́т *м* комбинат; **~ бытово́го обслу́живания** көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты; **учёбный ~** уку комбинаты

комбина́тор *м разг.* комбинатор (*комбинацияләр һәвәскәре, комбинацияләр ясарга оста кеше; хәйләле юллар белән үз дигәненә ирешүче*)

комбинато́рн||ый, -ая, -ое *спец.* комбинатор ...; **~ый ана́лиз в матема́тике** математикада комбинатор анализ; **~ые измене́ния зву́ков** авазларның комбинатор үзгәрешләре

комбинацио́нн||ый, -ая, -ое комбинацион, комбинацияле, комбинацияләргә нигезләнгән; **~ая игра́** *спорт.* комбинацион уен

комбина́ция *ж* **1.** комбинация; **хи́трая ~** хәйләле комбинация; **ша́хматная ~** шахмат уены комбинациясе **2.** комбинация, эчке күлмәк (*хатын-кызларда*)

комбинезо́н *м* комбинезон (*курткасы белән чалбары тоташ тегелгән кием*)

комбини́рованный, -ая, -ое катнаш, комбинацияләрдән торган; **~ ме́тод** катнаш метод

комбини́ровать *несов.* **1.** *что* (*соединять*) кушу, катнаштыру, берләштерү **2.** *разг.* (*строить комбинации*) төрлечә исәпләп (эшләп) карау

комедиа́нт *м* **1.** *уст.* уйнаучы, уенчы; кәмитче **2.** *презр.* икейөзле кеше, монафыйк

комедиа́нтство *с презр.* икейөзлелек, монафыйклык

комедиа́нтка *ж уст.* артист хатын (кыз), актриса

коме́дия *ж* **1.** *лит.* комедия **2.** *презр.* икейөзлелек, монафыйклык

ко́мель *м* аскы өлеш, төп (*үсемлек сабагының, агачның, чәчнең, мөгезнең, каурыйның тамырга тоташкан аскы өлеше*)

комендáнт *м* комендант; **~ кре́пости** крепость комендантлары; **~ общежи́тия** тулай торак комендантлары

комендáнтский, -ая, -ое комендант ...ы ♦ **~ час** комендант сәгате (*курсәтелгән сәгатьләрдә урамга чыгарга яраамый торган вакыт арасы*)

комендату́ра *ж* комендатура; **вое́нная ~** хәрби комендатура

коме́та *ж* комета, койрыклы йолдыз

ко́ми *мн. нескл.* (*ед.* **ко́ми** *м, ж*) комилар, коми халкы

коми́зм *м* көлкелек; **~ игры́ актёра** актер уенының көлкелеге

ко́мик *м* **1.** комик (*көлкеле рольләр башкаручы артист*) **2.** *разг.* мәзәк (мәзәкчел, уенчак) кеше

ко́микс *м* комикс (*кайбер илләрдә маҗараларга корылган кечкенә күләмле рәсемле китап*)

комисса́р *м* комиссар

комиссариа́т *м* комиссариат

комиссионе́р *м* комиссионер (*базарга корылган җәмгыятьтә сәүдә эшләрендә, сәүдә килешүләрендә арадашлык итүче*)

комиссио́нн||ый, -ая, -ое **1.** комиссион; **~ые това́ры** комиссион товарлар; **~ые це́ны** комиссион бәяләр **2.** комиссион (*арадашчы*); **~ый магази́н** комиссион кибет **3.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* комиссия (комиссионлык) әҗере

коми́сси||я *ж в разн. знач.* комиссия; **избира́тельная ~я** сайлау комиссиясе; **манда́тная ~я** мандат комиссиясе; **сдать това́р на ~ю** товарны комиссиягә бирү (кую)

комите́т *м* комитет; **Исполни́тельный ~ Сове́та наро́дных депута́тов** Халык депутатлары Советының башкарма комитеты

коми́ческ||ий, -ая, -ое **1.** көлкеле, көлдергеч; **~ая роль** көлкеле роль **2.** көлке; **~ая исто́рия** көлке вакыйга **3.** комиклык ...ы; **~ий тала́нт** комиклык таланты

коми́чн||ый, -ая, -ое көлке; **~ая исто́рия** көлке вакыйга

ко́мкать *несов. что* **1.** йомарлау, йомарлап укмаштыру **2.** *перен. разг.* ашыгып кыскартып бозу; **~ ле́кцию** лекцияне ашыгып кыскартып бозу

комкова́т||ый, -ая, -ое кантарлы, тигезсез; **~ая земля́** кантарлы туфрак

ко́млевый, -ая, -ое: **~ коне́ц ствола́** кәүсәнең төп башы, юан башы, юан очы (*агач, бүрәнә, каурый һәм мөгез турында*)

коммента́ри||й *м* комментарий, аңлатма, ачыклама, шәрех ♦ **~и изли́шни** аңлатманың кирәге юк, болай да аңлашыла

коммента́тор *м* комментатор, аңлатма бирүче, шәрехләүче

коммента́ровать *сов., несов. что* аңлатма бирү, комментарий бирү, шәрехләү; **~ текст** текстка аңлатма бирү

коммерса́нт *м* коммерсант, эре сәүдәгәр

комме́рция *ж* коммерция, тижарәт сәүдә, сәүдә эшләре

комме́рческ||ий, -ая, -ое коммерция ...ы, тижарәт сәүдә ...ы; **~ие дела́** коммерция эшләре; **~ое предприя́тие** сәүдә предприятиесе ◆ **~ий дире́ктор** коммерция директоры (*предприятиенең хуҗалык-финанс эшләрен алып баручы директор*)

коммивояжёр *м* коммивояжёр (*берәр сәүдә, промышленность предприятиесенең товар урнәкләрен, каталогларын күрсәтеп йөреп заказлар җыючы агент*)

комму́на *ж* коммуна ◆ **Пари́жская ~** *ист.* Париж коммунасы

коммуна́льн||ый, -ая, -ое коммуналь; **~ое хозя́йство** коммуналь хуҗалык; **~ые услу́ги** коммуналь хезмәт күрсәтү ◆ **~ая кварти́ра** коммуналь квартир

коммуна́р *м* коммунар (**1.** *Париж коммунасында катнашкан кеше* **2.** *коммуна әгъзасы*)

коммуни́зм *м* коммунизм ◆ **первобы́тный ~** иң борынгы коммунизм; **вое́нный ~** хәрби коммунизм (*1918-1920 е.*)

коммуника́бельный, -ая, -ое коммуникабель ...; җиңел аралаша торган

коммуникати́вн||ый, -ая, -ое *лингв.* фикерләрне тапшыру ...ы; фикерләрне белдерү ...ы; **сло́во есть ~ое сре́дство** сүз — фикерләрне тапшыру чарасы ул

коммуникацио́нн||ый, -ая, -ое *спец.* коммуникация ...ы; элемтә ...ы; коммуникацион; **~ая ли́ния** элемтә линиясе

коммуника́ци||я *ж* **1.** *спец.* коммуникация, багланыш, элемтә **2.** *лингв.* аралашу; **речь как сре́дство ~и** аралашу чарасы буларак сөйләм

коммуни́ст *м* коммунист

коммунисти́ческ||ий, -ая, -ое коммунистик, коммунист[лар] ...ы; **~ое о́бщество** коммунистик җәмгыять

коммута́тор *м* коммутатор (**1.** *электр тогы үтә торган линияне тоташтыру һәм өзү, шулай ук токның юнәлешен үзгәртү приборы* **2.** *телефон станцияләрендә, оешмаларда абонементларны тоташтыру үзәге*)

коммюнике́ *с* коммюнике (*дәүләтләр арасында алып барылган сөйләшүләр, төзелгән килешүләр турында хөкүмәтнең рәсми белдерүе*)

ко́мната *ж* бүлмә

ко́мнатн||ый, -ая, -ое бүлмә ...ы; **~ая температу́ра** бүлмә температурасы; **~ая соба́чка** бүлмә эте

комо́д *м* комод

комо́л||ый, -ая, -ое мүкләк, мөгезсез; **~ая коро́ва** мүкләк сыер

компа́ктность *ж* компактлык, тыгызлык, җыйнаклык

компа́ктный, -ая, -ое компакт[лы], җыйнак, тыгыз; тыгыз укмашкан (береккән)

компане́йский, -ая, -ое *разг.* аралашучан, компаниячел; **~ челове́к** компаниячел кеше

компа́ния *ж* **1.** компания, төркем **2.** компания, ширкәт (*сәүдә яки промышленность ширкәте*); **э́кспортная ~** экспорт компаниясе

компаньо́н *м* **1.** (*член торгового предприятия*) компаньон, ширкәттә катнашучы **2.** иптәш, мәҗлестәш

компаньо́нка *ж уст.* компаньонка (*байлар йортында бикәләргә хезмәт итүче, аларның күңелен ачучы хатын-кыз*)

компа́ртия *ж* компартия

ко́мпас *м* компас

ко́мпасн||ый, -ая, -ое компас ...ы; **~ая стре́лка** компас угы

компенса́ция *ж* **1.** компенсация, түләү, каплау; **~ убы́тков** зарарларны каплау; **де́нежная ~** акчалата түләү **2.** компенсацияләү, әлекке хәленә кайтару; **~ поро́ка се́рдца** йөрәк авыруын компенсацияләү

компенси́ровать *сов., несов. что* **1.** компенсацияләү, компенсация рәвешендә бирү, түләү; **~ убы́тки** зарарларны компенсацияләү **2.** (*уравновесить*) әлекке хәленә кайтару, компенсацияләү

компете́нтность *ж* **1.** *книжн.* компетентлык, хәбәрдарлык, белемлелек; **~ в вопро́сах поли́тики** сәясәт мәсьәләләрендә хәбәрдарлык **2.** нигезлелек, төплелек; компетентлылык; **~ сужде́ния** фикер йөртүнең нигезлелеге **3.** *юр.* тулы хокуклылык, тулы хокуклы булу

компете́нтн||ый, -ая, -ое *книжн.* **1.** хәбәрдар, белемле, компетентлы, компетенцияле; **~ый врач** белемле табиб **2.** нигезле, төпле, компетентлы, авторитетлы; **~ое мне́ние** нигезле фикер **3.** *юр.* тулы хокуклы

компете́нция *ж книжн.* компетенция (**1.** *киң мәгълүматлы булу* **2.** *учреждение яки аерым кешенең эш йөртүгә хакы булган мәсьәләләре, өлкәсе, мәйданы*)

компили́ровать *несов. что, книжн.* компиляцияләү, компиляция ясау (*башка авторлар тарафыннан язылган әсәрләрдән чүпләп берәр нәрсә язу*)

компиляти́вный, -ая, -ое *книжн.* компилятив, компиляция юлы белән төзелгән, компиляциягә нигезләнгән

компиля́тор *м книжн.* компилятор, компиляция белән шөгыльләнүче

компиля́ция *ж книжн.* компиляция (*башка авторларның әсәрләреннән чүпләп төзелгән әсәр*)

ко́мплекс *м* комплекс; **архитекту́рный ~** архитектура комплексы; **~ гимнасти́ческих упражне́ний** гимнастик күнегүләр комплексы

ко́мплексн||ый, -ая, -ое комплекс ...ы, комплексы; **~ый обе́д** комплексы төшке аш

компле́кт *м* комплект; **~ бельё** эчке киемнәр комплекты; **~ запчасте́й** запас частьлар комплекты

комплекта́ция *ж* комплектация (*берәр объектны тулы комплектлы җиһазлар, конструкцияләр, детальләр һ.б.ш. белән тәэмин итү*)

компле́ктность *ж* комплектлык, комплектлану; **~ гото́вых изде́лий** әзер эшләнмәләрнең комплектлыгы

комплектова́ть *несов. что* **1.** туплау, комплектлаштыру, комплектка тутыру, тиешле санына җиткерү; **~ соста́в слу́жащих** хезмәткәрләр составын туплау **2.** комплект төзү; **~ журна́лы** журналлар комплектын төзү

компле́кция *ж* комплекция, тән төзелеше; гәүдә; **ту́чная ~** симез гәүдә

компли́мент *м* комплимент, мактау сүзе

компози́тор *м* композитор

компози́торский, -ая, -ое композитор[лар] ...ы; композиторлык ...ы; **~ тала́нт** композиторлык таланты

композицио́нн||ый, -ая, -ое композиция ...ы; композицион; **~ая те́хника** композиция техникасы; **~ое строе́ние** композицион төзелеш

компози́ция *ж* композиция (**1.** *музыка әсәрләре төзү теориясе* **2.** *әдәби әсәрләрнең, картиналарның һ.б.ш. төзелеше* **3.** *шахмат мәсьәләләре һәм этюдлары төзү*)

компоне́нт *м* компонент, состав элемент; состав кисәк

компонова́ть *несов. что* төзү, әзерләү; **~ нау́чную статью́** гыйльми мәкалә төзү

компо́ст *м спец.* компост (*төрле үсемлек ташландыкларын черетеп хәзерләнгән ашлама, туфрак ашламасы*)

компо́стер *м* компостер (*билетка, пломбага һ.б.ш. тишеп яки яньчеп билге салу өчен кулланыла торган келәшчә сыман прибор*)

компости́ровать *несов. что* компостер белән билге (тамга) салу

компо́т *м* компот

компре́сс *м* компресс; **ста́вить ~** компресс кую

компре́сснн||ый, -ая, -ое компресс ...ы; **~ая бума́га** компресс кәгазе

компре́ссор *м* компрессор (**1.** *һаваны яки башка газны кысып тыгызлау машинасы* **2.** *операция вакытында кан тамырын кысып тоту өчен кулланыла торган прибор*)

компре́ссорн||ый, -ая, -ое компрессор[лар] ...ы; **~ый заво́д** компрессорлар заводы; **~ая устано́вка** компрессор корылмасы

компромети́ровать *несов. кого-что* оятлы итү, уңайсыз хәлдә калдыру, яман атын чыгару

компроми́сс *м* компромисс, килешү, юл куешып килешү

компроми́ссн||ый, -ая, -ое компромисслы, килешүле; **~ое предложе́ние** компромисслы тәкъдим

комсомо́л *м* комсомол

комсомо́лец *м* комсомолец

комсомо́лия *ж разг.* комсомолия, комсомоллар

комсомо́лка *ж* комсомолка

комсомо́льско-молодёжн||ый, -ая, -ое комсомол-яшьләр ...ы; **~ая брига́да** комсомол-яшьләр бригадасы

комсо́рг *м* комсорг

комфо́рт *м* комфорт (*көнкүрештә яки юлда йөрү өчен тудырылган уңайлыклар җыелмасы*)

комфорта́бельный, -ая, -ое уңайлы, комфортлы

кон *м* кон (**1.** *кузна, чүрәкәй һ.б.ш. уеннарда аткы барып төшәргә тиеш урын* **2.** *акчалы отыш уенында акча салына торган урын* **3.** *кәрт, шахмат һ.б.ш. уеннарның бер партиясе*)

конве́йер *м* конвейер

конве́нт *м ист.* конвент (*кайбер илләрдә конституция төзү яки аны үзгәртү өчен чакырыла торган дәүләт вәкилләре җыелышы*)

конвенцио́нный, -ая, -ое конвенцион, конвенция белән билгеләнгән, аерым килешү буенча эшләнгән

конве́нция *ж* конвенция, килешү (*нинди дә булса махсус мәсьәлә буенча төзелгән халыкара шартнамә*)

конве́рсия *ж* конверсия, үзгәртү

конве́рт *м* конверт

конверти́ровать *сов., несов. что, эк.* конверсия ясау, конверсияләү

конвои́р *м* конвойчы (**1.** *төткыннарны, әсирләрне саклап озатучы кеше* **2.** *сәүдә судноларын дошманнан саклап озата торган суднолар яки самолётлар*)

конвои́ровать *несов. кого-что* саклап озата бару, конвоирлау (*мәс. әсирләрне, төткыннарны*)

конво́й *м* конвой (**1.** *төткыннарны, әсирләрне саклап озата баручы кораллы отряд* **2.** *сәүдә судноларын дошманнан саклап озата бара торган суднолар яки самолётлар*)

конвульси́вн||ый, -ая, -ое конвульсия ...ы, көзән җыерулы, тартышулы; конвульсив; **~ое движе́ние** көзән җыерулы хәрәкәт

конву́льсия *ж* көзән җыеру, тартышу, конвульсия

конгениа́льный, -ая, -ое *книжн.* конгениаль, бердәй, охшаш, тәңгәл, бик якын, туры килә торган; **перево́д, ~ оригина́лу** оригиналга туры килә торган тәрҗемә

конгломера́т *м* конгломерат (**1.** *книжн. төрле кисәкләрнең һәм әйберләрнең тәртипсез кушылмасы* **2.** *геол. төрле-төрле аерым кисәкләрдән укмашкан тау токымы*)

конголе́зцы *мн.* конголылар, Конго халкы

конгре́сс *м* конгресс (**1.** *зур, гадәттә халыкара съезд, киңәшмә* **2.** *АКШта һәм кайбер Латин Америкасы илләрендә закон чыгару органының атамасы*)

конгрессме́н *м* конгрессмен, конгресс әгъзасы

кондач||о́к: с ~ка́ *разг.* өстән-өстән генә, әштер-әштер генә, аңламастан; **реша́ть де́ло с ~ка́** мәсьәләне өстән-өстән генә хәл итү

конденса́т *м спец.* конденсат (*конденсация ысулы белән алынган продукт*)

конденса́тор *м* конденсатор (**1.** *электр корылмалары туплау приборы* **2.** *парны сыекчага әйләндерү приборы*)

конденсацио́нн||ый, -ая, -ое **1.** конденсация ...ы, конденсацияләү ...ы; **~ая устано́вка** конденсация җайланмасы **2.** конденсацион, конденсация юлы белән алынган; **~ая вода́** конденсацион су

конденса́ция *ж см.* **конденси́ровать, конденси́роваться** 1, 2

конденси́ровать *сов., несов. что, тех.* **1.** (*накопить*) туплау, җыю; **~ эне́ргию** [электр] энергиясе туплау **2.** (*превратить в жидкость*) куерту, сыекчага әйләндерү

конденси́роваться *сов., несов. тех.* **1.** (*накопиться*) туплану, җыелу **2.** (*превратиться в жидкость*) куеру, сыекчага әйләнү **3.** *страд. от* **конденси́ровать**

конди́тер *м* кондитер

конди́терская *ж* кондитер [әйберләр] кибете

конди́терск||ий, -ая, -ое кондитер ...ы, татлы ашамлыклар ...ы; **~ая фа́брика** кондитер фабрикасы ♦ **~ие изде́лия** татлы ашамлыклар

кондицио́нер *м* кондиционер (*биналарда тиешле температура, дымлылык һәм һава составын тәэмин итә торган прибор*)

кондицио́нн||ый, -ая, -ое кондицион, яхшы сыйфатлы, кондицияле; **~ое зерно́** кондицияле (яхшы тишелешле) орлык; **~ые това́ры** яхшы сыйфатлы товарлар

конди́ция *ж спец.* кондиция (*продукцияне тиешле таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәгә китерү шартлары, нормалары*)

конво́ый, -ая, -ое таза үзагачлы, ныклы үзагачлы; **~ лес** таза үзагачлы агач материалы

ко́ндор *м зоол.* кондор

кондра́шка *м:* **~ хвати́л** *кого, разг.* үз чире тоту

кондуи́т *м ист.* кондуит (*укучыларның яки гаскәриләрнең үзләрен тотуда булган җитешсезлекләре языла торган журнал*)

конду́ктор *м* кондуктор

конду́кторск||ий, -ая, -ое кондукторлык ...ы; кондуктор[лар] ...ы; **~ая брига́да** кондукторлар бригадасы

конево́д *м* ат[лар] үрчетүче

конево́дство *с* ат үрчетүчелек

конёк *м* **1.** *уменьш. от* **конь** 1; **2.** (*на крыше*) атчык (*ат башына охшатып ясалган бизәк*) **3.** сырт такта, сырт (*түбә сырты буйлап кадакланган такта*) ♦ **это его́** ~ бу аның яраткан нәрсәсе

кон||ёц *м* **1.** оч; **~ёц па́лки** таяк очы; **~ёц верёвки** бау очы **2.** азак, ахыр; **~ёц го́да** ел ахыры; **к ~цу́ дня** көн азагына таба **3.** (*концовка*) ахыр, азак, соңгы өлеш **4.** *перен.* үлем **5.** чик; **положи́ть ~ёц** *чему-л. нинди дә булса* эшкә чик кую ♦ **без ~ца́** бик күп, иге-чиге юк, бик озак; **в ~це́ ~цо́в** ахыр чиктә, ниһаять, бара торгач; **до ~ца́** ахырына кадәр, беткәнче; **из ~ца́ в ~ёц** бер башыннан икенче башына, аркылыгабуйга; **~цо́в не найти́** очына чыга алмау, рәтен таба алмау, рәтенә чыга алмау; **~цы́ в во́ду** эзе дә калмас, эзе дә калмады; **[ни] ~ца́ [ни] кра́ю нет** *чему* (*берәр әйбернең, эшнең*) очы-кырые күренмәү; бик күп булу, бетәсе юк; **оди́н ~ёц** ни булса ул, ни генә булса да барыбер; **под ~ёц** ахырда, ниһаять; **свести́ (своди́ть) ~цы́ с ~ца́ми** тартып-сузып житкерү, ничек кирәк алай житкерү; **со всех ~цо́в** һәр (төрле) яктан

коне́чно *частица и вводн. сл.* шиксез, әлбәттә, билгеле; әйе, сүз дә юк

коне́чности *мн.* (*ед.* **коне́чность**) очлык, кул-аяк; **ни́жние ~** түбән очлыклар

коне́чн||ый, -ая, -ое **1.** чикле; **жизнь челове́ка ~а** кеше гомере чикле **2.** ахыргы, соңгы, актыккы, азаккы; **~ая остано́вка** соңгы тукталыш **3.** төп, иң мөһим, хәл иткеч; **~ая причи́на** төп сәбәп ♦ **в ~ом счёте** ахыр чиктә

кони́на *ж* ат (елкы) ите

кони́ческ||ий, -ая, -ое **1.** конус ...ы, коник; **~ая пове́рхность** конус өслеге; **~ое сече́ние** коник кисем **2.** конуссыман, конус рәвешендәге; **~ая ко́лба** конуссыман колба

ко́нка *ж уст.* атлы трамвай

конкретиза́ция *ж см.* **конкретизи́ровать**

конкретизи́ровать *сов., несов. что* конкретлаштыру, аныклау, ачыклау

конкре́тный, -ая, -ое конкрет, анык, реаль, билгеле; **~ приме́р** конкрет мисал; **~ предме́т** билгеле әйбер

конкуре́нт *м* конкурент, көндәш

конкуре́нци||я *ж* конкуренция ♦ **вне ~и** чагыштыргысыз яхшы

конкури́ровать *несов. с кем-чем в чём* конкуренция алып бару, көрәшү

ко́нкурс *м* конкурс

ко́нкурсн||ый, -ая, -ое **1.** конкурслы; **~ые экза́мены** конкурслы имтиханнар **2.** конкурс ...ы; конкурс өчен язылган (хәзерләнгән); **~ая коми́ссия** конкурс комиссиясе; **~ое сочине́ние** конкурс өчен язылган сочинение

ко́нник *м* атлы сугышчы, атлы гаскәри

ко́нница *ж* атлы гаскәр

коннозаво́дство *с* яхшы токымлы атлар үрчетү

ко́нный, -ая, -ое **1.** ат ...ы; **~ заво́д** ат заводы **2.** атлы; **~ отря́д** атлы отряд

конова́л *м* коновал, ат печүче, ат табибы, байтар

коново́д I *м воен.* коновод (*атлар караучы*)

коново́д II *м прост.* узаман, башлап йөрүче, житәкче

ко́новязь *ж* атлар бәйләү баганасы (*тышта, урамда*)

конокра́д *м* ат карагы

конопа́тить *несов. что* мүкләү (*тишек, ярык урыннарны сүс, чүбек, мүк белән тыгызлап томалау*)

конопа́тый, -ая, -ое *прост.* **1.** (*веснушчатый*) сипкелле **2.** (*рябой*) шадра

конопля́ *ж* киндер, киндераш

конопля́ник *м* киндер басуы

конопля́нка *ж зоол.* киндер чыпчыгы

конопля́н||ый, -ая, -ое киндер ..., киндер ...ы; **~ое ма́сло** киндер мае

консерва́тивн||ый, -ая, -ое консерватив, кадим ..., иске карашлы, яңалыкка каршы ♦ **~ое лече́ние** консер-

ватив дәвалау (*хирургик операциядән башка уткәрелә торган*)

консервати́зм *м* консерватизм, консервативлык, кадимчелек

консерва́тор *м* консерватор (**1.** *консерватив карашлы кеше, кадимче* **2.** *реакцион, консерватив сәяси партия әгъзасы*)

консервато́рия *ж* консерватория

консервато́рск||ий, -ая, -ое консерватория ...ы; **~ое образова́ние** консерватория белеме

консерва́ция *ж см.* **консерви́ровать**

консерви́ровать *несов. что* **1.** консервлау; **~ грибы́** гөмбә консервлау **2.** (*предохранять от порчи*) черүдән саклау, бозылудан саклау **3.** *перен.* вакытлыча туктату (*берәр нәрсәнең үсешен, эшен*)

консе́рвный, -ая, -ое консерв ...ы; **~ заво́д** консерв заводы

консе́рвы *только мн.* консерв, консерва; **ры́бные ~** балык консервалары

конси́лиум *м* консилиум (*авыруны ачыклау һәм аны дәвалау юлларын, ысулларын билгеләү өчен берничә табибның киңәшмәсе*)

консисте́нция *ж физ.* консистенция (*сыек һәм каты җисемнәрнең йомшаклык, тыгызлык, катылык, ныклык дәрәҗәсе*)

ко́нск||ий, -ая, -ое ат ...ы; **~ий во́лос** ат кылы; **~ая сбру́я** ат җигү дирбиясе

консолиди́ровать *сов., несов. что* **1.** консолидацияләү, бергә туплап нығыту; **~ все си́лы** барлык көчләрне бергә туплап нығыту **2.** *фин.* сроглы озайту, кыска сроклы йөкләмәләрнең сроглы озайту; **~ за́ймы** заемнарның түләү срогын озайту

консолиди́роваться 1. *сов., несов.* консолидацияләнү, бергә тупланып нығу **2.** *несов. страд. от* **консолиди́ровать**

консо́ль *ж архит.* консоль

консона́нс *м муз.* консонанс, аһәң

консонанти́зм *м лингв.* консонантизм, тартык авазлар системасы

конспе́кт *м* конспект

конспекти́вный, -ая, -ое конспектив, кыска, кыскача, конспект характерындагы; **~ обзо́р после́дних собы́тий** соңгы вакыйгаларга кыскача күзәтү

конспекти́ровать *несов. что* конспектлау, конспектлаштыру, конспект төзү

конспирати́вн||ый, -ая, -ое конспирация ...ы, конспиратив, яшерен, яшертен; **~ое совеща́ние** конспиратив киңәшмә

конспира́тор *м* конспиратор, яшертен эш итүче

конспира́ция *ж* конспирация (*үзенең эшен сер итеп тоту һәм әгъзаларын яшерү өчен легаль булмаган оешма тарафыннан кулланыла торган методлар; астыртынлык, сер итеп саклау*)

конспири́ровать *несов. кого-что и без доп.* конспирация оештыру, конспирация методларын куллану

конста́нта *ж мат., физ.* константа, даими зурлык

конста́нтный, -ая, -ое *мат., физ.* константа, даими, үзгәрми торган, тотрыклы

констати́ровать *сов., несов. что* (*нәрсәне дә булса*) констатацияләү, билгеләү, билгеләп үтү, әйтеп үтү, раслау; **~ факт** фактны билгеләп үтү

конституцио́нн||ый, -ая, -ое **1.** конституция ...ы, конституцион; **~ый зако́н** конституция законы **2.** конституцион, конституциягә нигезләнгән ♦ **~ая мона́рхия** конституцион монархия

конститу́ция *ж* **1.** конституция (*дәүләтнең төп законы*); **День Конститу́ции** Конституция көне **2.** төзелеш, структура; **~ органи́зма** организм төзелеше

конструи́ровать *сов., несов. что* **1.** төзү, планын төзү, конструкциясен төзү, конструкцияләү; **~ маши́ну** машинаның конструкциясен төзү **2.** оештыру, төзү; **~ прави́тельство** хөкүмәт оештыру

конструктиви́зм *м* конструктивизм (*сәнгатьтә һәм әдәбиятта иң чик техницизмны алга сөрүче формалистик агым*)

конструкти́вн||ый, -ая, -ое **1.** конструктив, конструкциягә караган; **~ые недоста́тки сооруже́ния** корылманың конструктив кимчелекләре **2.** конструктив, нигез булырга яраклы, уңышлы, файдалы; **~ое предложе́ние** конструктив тәкъдим

констру́ктор *м* конструктор (**1.** *конструкцияләр төзүче, конструкцияләүче* **2.** *һәртөрле предметлар, корылмалар ясау өчен кирәкле вак детальләрдән торган җыелма — балалар уенчыгы*)

констру́кторск||ий, -ая, -ое конструкторлык ...ы; конструктор[лар] ...ы; **~ое бюро́** конструкторлык бюросы

констру́кция *ж* конструкция, төзелеш, корылыш, ясалыш

ко́нсул *м* консул (**1.** *дип. чит илдә үз дәүләтенең һәм аның гражданнарының мәнфәгатьләрен яклый торган хөкүмәт вәкиле* **2.** *ист. борынгы Рим республикасында, Франциядә иң югары дәрәҗәле дәүләт эшлеклесе*)

ко́нсульск||ий, -ая, -ое консул ...ы, консуллык ...ы; **~ие полномо́чия** консуллык вәкаләтләре; **~ие представи́тели** консуллык вәкилләре

ко́нсульство *с в разн. знач.* консуллык

консульта́нт *м* консультант, консультация бирүче

консульта́ци||я *ж в разн. знач.* консультация; **юриди́ческая ~я** юридик консультация; **расписа́ние ~й** консультацияләр расписаниесе; **получи́ть ~ю** консультация алу

консульти́ровать *несов. кого-что и без доп.* консультация бирү, киңәш бирү

консульти́роваться *несов. с кем* консультация алу, киңәш алу

конта́кт *м* **1.** *тех.* контакт (*электр үткәргечләрнең тоташкан урыны*) **2.** *перен.* бәйләнеш, үзара бәйләнеш, аралашу, контакт; **вступи́ть в ~** *с кем-л. берәр кеше белән* бәйләнешкә керү

конта́ктн||ый, -ая, -ое *тех.* ялганма, контактлы; **~ый ток** ялганма ток; **~ое напряже́ние** контактлы көчәнеш

конте́йнер *м* контейнер (*тимер юл платформаларында товар төяп йөртү өчен кулланыла торган стандарт зур ящик*)

конте́кст *м* контекст (*язма сөйләмнең тәмамланган бер кисәге*)

континге́нт *м* контингент (**1.** *книжн. берәр коллективның, учреждениенең, оешманың, предприятиенең, армиянең һ.б.ш. үз эченә алган барлык кешеләре* **2.** *эк., ком.* куелган чик, норма)

контине́нт *м* континент

континента́льный, -ая, -ое континенталь, континентка хас; **~ кли́мат** континенталь климат

конто́ра *ж* контора; **~ заво́да** завод конторы

конто́рка *ж* конторка (**1.** *биек эш өстәле* **2.** *контора урнашкан кечкенә бина*)

контраба́нда *ж* контрабанда (*пошлина салына торган яки чыгаруы тыелган товарларны яшерен рәвештә бер илдән икенче илгә чыгару; шулай чыгарылган товарлар*)

контрабанди́ст *м* контрабандист, контрабандачы (*контрабанда белән шөгыльләнүче*)

контраба́ндный, -ая, -ое контрабанда ...ы; **~ това́р** контрабанда товары

контраба́с *м* контрабас (*музыка кораллы*)

контраге́нт *м спец.* контрагент (*шартнамә нигезендә үз өстенә нинди дә булса йөкләмәләр алган кеше яки учреждение*)

контр-адмира́л *м* контр-адмирал

контра́кт *м* контракт (*язма договор, килешү*)

контрактова́ть *несов. кого-что* контрактацияләү, контракт буенча җыю; **~ рабо́чих** контракт буенча эшчеләр җыю

контра́льто *с нескл.* контральто (**1.** *хатын-кызларда иң калын тавыш* **2.** *шундый тавышлы җырчы хатын-кыз*)

контрама́рка *ж* контрамарка (*билет урынына бирелә торган талон*)

контрапу́нкт *м муз.* контрапункт

контра́ст *м* контраст, кискен каршылык, капма-каршылык

контрасти́ровать *несов. с кем-чем* капма-каршы булу, капма-каршы булып тору

контра́стн||ый, -ая, -ое контраст ..., контрастлы, капма-каршы; **~ые цвета́** контраст төсләр

контрата́ка *ж* контратака, каршы атака, каршы һөҗүм

контратакова́ть *сов., несов. кого-что* контратака (каршы һөҗүм) ясау

контрибу́ция *ж* контрибуция (*сугышта җиңелгән дәүләт тарафыннан җиңүче дәүләткә түләнә торган әйберләр яки акча*)

контрманёвр *м* контрманёвр, каршы манёвр

контрнаступле́ние *с* каршы һөҗүм

контролёр *м* контролёр, тикшерүче

контроли́ровать *несов. кого-что* тикшерү, тикшереп (күзәтеп) тору

КОН-КОН

контро́ль *м* 1. контроль, тикшерү, күзәтеп тору 2. *собир.* контролёрлар 3. (*учреждение*) контроль; **государ́ственный ~** дәүләт контроле

контро́льн||ый, -ая, -ое контроль ...; контроль ...ы; тикшерү ...ы; **~ая коми́ссия** тикшерү комиссиясе; **~ая рабо́та** (*в школе*) контроль эш; **~ые ци́фры** контроль саннар

контрразве́дка *ж* контрразведка

контрразве́дчик *м* контрразведкачы, контрразведчик, контрразведкада эшләүче

контрреволюционе́р *м* контрреволюционер, контрреволюциядә катнашучы, контрреволюция тарафдары

контрреволюцио́нный, -ая, -ое контрреволюция ...ы, контрреволюцион; **~ мятёж** контрреволюцион фетнә

контрреволю́ция *ж* контрреволюция

контрудар́ *м* контрудар, каршы һөҗүм

контузи́ть *сов. кого* контузия алу, контужен булу

контузи́я *ж* контузия (*организмның тыштан яраланмыйча гына имгәнүе, мәс. сугышта*)

ко́нтур *м* контур (*әйбернең тышкы сызымы, әйбернең сызыклар белән генә ясалган рәсеме*)

конура́ *ж* 1. эт оясы 2. *перен. разг.* җимерек йорт, начар бүлмә

ко́нус *м* конус

конфедера́ция *ж* конфедерация, берләшмә; **~ труда́** хезмәт *конфедерациясе* (*Франциядә профсоюзлар берләшмәсе*)

конферан́с *м* конферанс

конферансье́ *м нескл.* конферансье

конфере́нц-за́л *м* конференц-зал (*тантаналы утырышлар залы*)

конфере́нция *ж* конференция; **нау́чная ~** фәнни конференция

конфе́та *ж* конфет, кәнфит

конфетти́ *с нескл.* конфетти (*балларда, маскарадларда кешеләр өстенә сибәр өчен вакланып, түгәрәкләп киселгән төрле тостәге кәгазь кисәкләре*)

конфигура́ция *ж* 1. (*внешнее очертание*) конфигурация, кыяфәт, күренеш 2. (*расположение предметов*) конфигурация (*әйберләрнең үзара тәртипле рәвештә куелышы, урнашуы*)

конфиденциа́льный, -ая, -ое *книжн.* конфиденциаль, яшерен, сер итеп саклана торган; **~ разгово́р** сер итеп саклана сөйләшү

конфиска́ция *ж* конфискация (*закон нигезендә берәүнең мал-мөлкәтен яки акча-алтыннарын тартып алу*)

конфискова́ть *сов., несов. кого-что* конфискацияләү, [мал-мөлкәтен] тартып алу, конфискация ясау (*рәсми карар нигезендә*)

конфли́кт *м* конфликт, низаг, бәрелеш, бәхәс

конфли́ктн||ый, -ая, -ое конфликтлы, низаглы, бәхәсле; **~ое де́ло** конфликтлы эш ♦ **~ая коми́ссия** конфликт комиссиясе

конфликтова́ть *несов. с кем, разг.* конфликтка (бәхәскә) керү, низаглашу

конфо́рка *ж* конфорка

конформи́зм *м* конформизм (*карышылыкларны шомарту, аермалыкларны бетерү; бертөрлелек, стандартлык*)

конфронта́ци||я *ж* конфронтация, капма-каршы кую, бәрелеш; **поли́тика ~и** конфронтация сәясәте

конфу́з *м разг.* конфуз, уңайсыз хәл; аптыраш

конфу́зить *несов. кого-что* оятлы итү, көлкегә калдыру, йөзен кызарту

конфу́зиться *несов.* тартыну, оялу, уңайсызлану; **он вас конфу́зится** ул сездән ояла

конфу́зливый, -ая, -ое оялчан, тартынучан

конфу́зный, -ая, -ое *разг.* оятка калырлык, йөз кызарырлык; **~ слу́чай** оятка калырлык очрак

концев||о́й, -а́я, -о́е очтагы, ахырдагы, актыккы; соңгы; **~а́я строка́** соңгы юл (*китапта*)

концентра́т *м* концентрат (1. *баетылган руда* 2. *терлек азыгы — түп, ашлык һ.б.ш.* 3. *прессланган коры әзер азык продукты*)

концентрацио́нный, -ая, -ое: **~ ла́герь** концентрацион лагерь

концентра́ц||ия *ж* 1. *см.* **концентри́ровать, концентри́роваться; ~ия населе́ния** халык тупланышы; **~ия руды́** руда концентрациясе; **~ия раство́ра** эремәнең концентрациясе 2. *хим.* концентрация, тупланыш; куелык дәрәҗәсе; **раство́р си́льной ~ии** концентрациясе көчле эремә

концентри́рованн||ый, -ая, -ое 1. тупланган, оешкан; **~ые си́лы врага́** дошманның тупланган көчләре 2. туклыклы, концентрацияле; **~ые корма́** туклыклы азыклар; **~ые удобре́ния** концентрацияле ашламалар 3. *хим.* куертылган, туендырылган; **~ый раство́р** туендырылган эремә 4. *горн.* баетылган; **~ая руда́** баетылган руда

концентри́ровать *несов.* 1. *кого-что* жыю, туплау; **~ войска́** гаскәрне туплау 2. *перен. что* юнәлтү, юнәлдерү, туплау; **~ внима́ние** игътибарны юнәлдерү 3. *что, хим.* туендыру, куерту 4. *что, горн.* баету

концентри́роваться *несов.* 1. туплану, җыелу 2. *перен.* юнәлү, туплану (*мәс. игътибар турында*) 3. *хим.* туену, куеру 4. *горн.* баю, баету 5. *страд. от* **концентри́ровать**

концентри́ческ||ий, -ая, -ое, **концентри́чный,** -ая, -ое 1. үзәктәш; **~ие круги́** үзәктәш түгәрәкләр 2. концентрик, концентрларга бүленгән; **~ая систе́ма преподава́ния** укытуда концентрик система

конце́нтры *мн.* (*ед.* **конце́нтр**) *мат.* концентрик (үзәктәш) түгәрәкләр

конце́пция *ж* концепция (*төрле мәсьәләләргә, чынбарлыкта булып тора торган хәл һәм күренешләргә карашлар системасы*)

концерн *м* концерн (*капиталистик монополияләрнең бер төре*)

конце́рт *м* концерт; **симфони́ческий ~** симфоник концерт

концерти́ровать *несов.* концертлар бирү

концертме́йстер *м* концертмейстер (1. *оркестрда уйнаучылар төркеменең җитәкчесе* 2. *концертта башкарылачак партияләрне җырчылар белән бергә өйрәнүче пианист-аккомпаниатор*)

концессионе́р *м* концессионер, концессия хуҗасы

концессио́нн||ый, -ая, -ое концессиягә бирелгән; **~ая фа́брика** концессиягә бирелгән фабрика ♦ **~ый догово́р** концессия шартнамәсе

конце́ссия *ж* концессия (1. *берәр дәүләт белән аерым капиталист арасында промышленность предприятиесе төзү өчен билгеле бер шартларда килешү* 2. *шул килешү нигезендә төзелгән һәм эшли торган предприятие*)

концла́герь *м* концлагерь (*концентрацион лагерь*)

концо́вка *ж* 1. *полигр.* концовка (*китап яки аның аерым бүлегенең ахырында куела торган рәсем-бизәк*) 2. *см.* **коне́ц** 3; **~ рома́на** романның соңгы өлеше

конча́ть *несов. см.* **ко́нчить**

конча́ться *несов. см.* **ко́нчиться**

ко́нчено *в знач. сказ. разг.* җитәр, житте; бетте

ко́нченый, -ая, -ое *разг.* хәл ителгән, беткән ♦ **~ челове́к** беткән кеше

ко́нчик *м уменьш. от* **коне́ц**

кончи́на *ж высок.* үлем, вафат булу

ко́нчить *сов.* 1. что бетерү, төгәлләү, тәмамлау, очлау, тәмам итү; **~ ремо́нт** ремонтны тәмамлау; **~ ве́чер та́нцами** кичәне биюләр белән төгәлләү; **~ университе́т** университетны бетерү 2. *что, на чём, чем и с неопр.* өзү, туктату; **~ разгово́р** сөйләшүне туктату 3. *когочто, прост.* үтерү ♦ **~ плохо́ (сквёрно)** 1) түбәнлеккә төшү, кызганыч хәлдә калу; 2) үзенне-үзең үтерү

ко́нчи||ться *сов.* 1. бетү, төгәлләнү, тәмамлану, очлану, тәмам булу; **уро́к ~лся** дәрес тәмамланды; **де́ло ~лось ми́рно** эш килешү белән бетте

конъюнкту́ра *ж книжн.* конъюнктура (1. *берәр эшнең нәтиҗәсенә тәэсир итә торган барлык шартлар* 2. *эк. товар хуҗалыгының торышын билгели торган барлык шартлар*)

конъюнкту́рщик *м* конъюнктурачы (*җил кай яктан иссә, шуңа карап эш итүче принципсыз кеше*)

кон||ь *м* 1. ат, елкы; **боево́й ~ь** сугыш аты 2. *шахм.* ат; **ход ~ём** ат белән йөрү (*шахматта*) ♦ **куда́ ~ь с копы́том, туда́ и рак с клешнёй** ≈ чүлмәкчедән күрмәкче; эт чаба дип бет чаба; **не в ~я́ корм** файдасыз нәрсә; **~ь не валя́лся** *погов.* эш әле башланмаган да, бернәрсә дә әзер түгел

коньки́ *мн.* тимераяк, коньки

конькобе́жец *м* тимераякта шуучы, конькида шуучы

конькобе́жный, -ая, -ое тимераякта шуу ...ы; конькида шуу ...ы; **~ спорт** тимераякта шуу спорты

конья́к *м* коньяк
ко́нюх *м* ат караучы, конюх
коню́шня *ж* ат абзары, конюшня
коня́га *м, ж прост.* эш аты
кооперати́в *м* кооператив; **жили́щный ~** торак кооперативы
кооперато́р *м* кооператор (*кооперация өлкәсендә эшләүче, кооперативта эшләүче*)
кооперация *ж* кооперация; **промысло́вая ~** һөнәрчелек кооперациясе
кооперировать *сов., несов. кого-что* 1. кооперацияләштерү (*бергәләп эшләү нигезендә берләштерү*); **~ *чей-л.* труд** *кемнең дә булса* хезмәтен кооперацияләштерү 2. кооперациягә әгъзалыкка тарту; **~ населе́ние** халыкны кооперациягә әгъзалыкка тарту
кооптация *ж книжн.* кооптация (*сайлану юлы белән эшли торган оешмаларга сайлаучыларга мөрәҗәгать итмичә генә яңа членнар кабул итү*)
кооптировать *сов., несов. кого-что, книжн.* кооптацияләү (*яңа әгъза кабул итү*)
координа́тор *м книжн.* координатор, координация эшләрен башкаручы
координа́ты *мн.* 1. координатлар (*ноктаның яссылык өстендәге яки пространстводагы торышын билгели торган зурлыклар*) 2. координатлар (*тору урыны, адрес*); **сообщи́те свои́ ~** үз координатларыгызны хәбәр итегез
координацио́нный, -ая, -ое координация ...ы, координацион; **~ центр** координация үзәге
координа́ция *ж* 1. *см.* **координи́ровать**; 2. координация, үзара килешкәнлек, ярашканлык; **~ движе́ний** хәрәкәт координациясе
координи́ровать *сов., несов. что* координацияләү, яраштыру, яраклаштыру, килештерү
копа́л *м спец.* копал (*лак ясауга китә торган сумала*)
копа́ловый, -ая, -ое *спец.* копалдан ясалган; **~ лак** копалдан ясалган лак
копа́ть *несов. что* 1. казу; **~ я́му** чокыр казу 2. казып йомшарту, казып күпертү; **~ огоро́д** бакча казу 3. алу, казып алу; **~ карто́фель** бәрәңге алу
копа́ться *несов.* 1. *в чём* казыну; **~ в навозе** тиреслектә казыну 2. *в чём* актарыну; **~ в сундуке́** сандыкта актарыну 3. *перен. в чём* чокчыну; **~ в свои́х пережива́ниях** үз кичерешләрендә чокчыну 4. *с чем и без доп., разг.* (*делать медленно*) казыну, кайнашу, маташу, озакка сузу 5. *страд. от* **копа́ть**
копе́ечк||а *ж уменьш. от* **копе́йка ♦ в ~у стать (вскочи́ть, обойти́сь, влете́ть)** бик кыйбатка төшү
копе́ечн||ый, -ая, -ое 1. бер тиенлек, бер тиен тора торган; **~ая моне́та** бер тиенлек монета 2. *разг.* вак-төяк; **~ые расхо́ды** вак-төяк чыгымнар 3. *перен. разг.* бик вакчыл, бик саран; **~ая душа́** бик саран кеше
копе́йк||а *ж* бер тиен, бер тиенлек акча **♦ без ~и** бер тиенсез; **до [после́дней] ~и** тиененә кадәр; **~а в ~у** тиенгә тиен; **на ~у** бик аз, бер тиенлек
копёр *м* копёр (1. *субай кагу машинасы* 2. *шахта өстендә күтәргечне урнаштыру корылмасы*)
ко́пи *мн. уст.* копи
копи́лка *ж* копилка (*акча җыю өчен ясалган тишекле кечкенә тартма*)
копи́рка *ж разг.* копирка, күчергеч, копировка кәгазе
копирова́льн||ый, -ая, -ое копировка ...ы; **~ые черни́ла** копировка карасы; **~ая бума́га** копировка кәгазе
копи́ров||ать *несов.* 1. *что* (*снимать или делать копию*) копиясен алу, күчермәсен алу 2. *кого-что* (*подражать*) ... булып кылану, ...ча кылану
копиро́вочный, -ая, -ое *разг. см.* **копирова́льный**
копиро́вщик *м* копиясен алучы, күчермәсен алучы
копи́ть *несов. что* 1. саклыкка җыю, запас туплау 2. *перен.* җыю, җыеп саклау, туплау; **~ си́лы** көч туплау
копи́ться *несов.* 1. җыелу, җыела бару, җыела килү, җыела тору 2. *страд. от* **копи́ть**
ко́пия *ж* 1. копия, күчермә 2. *перен.* нәкъ үзе, копиясе; **ма́льчик — соверше́нная ~ отца́** малай нәкъ әтисе
копн||я́ *ж* чүмәлә **♦ ~я́ воло́с** куе тузгак чәч
копни́тель *м* чүмәлә салу машинасы
копни́ть *несов. что* чүмәлә кую
копну́ть *сов. однокр.* казып карау
ко́поть *ж* корым, сөрем
копош||и́ться *несов.* 1. кыймылдау, мыж килү, кайнашу; **муравьи́ ~а́тся во́зле мураве́йника** кырмыскалар оялары янында мыж киләләр 2. (*возиться*) маташу, маталану, ыгы-зыгы килү 3. *перен. разг.* (*о мыслях, чувствах*) буталу, чуалу
копте́ть *несов.* (*испускать копоть*) корымлану, корым белән каплану, ыслану, сөремләнү
коптилка *ж разг.* сукыр лампа
копти́льн||ый, -ая, -ое ыслау ...ы; **~ая печь** ыслау миче
копти́льня *ж* ыслау цехы
копти́||ть *несов.* 1. (*испускать копоть*) төтәү, сөрем чыгару; **ла́мпа ~т** лампа төти 2. *кого-что* (*мясо, рыбу*) каклау, ыслау 3. *что* (*покрывать копотью*) корымлау; **~ть стекло́ для наблюде́ния со́лнечного затме́ния** кояш тотылуын күзәтү өчен пыяланы корымлау
копу́ша *м, ж разг.* сүлпән кеше, мыштырдык, әкрен кыймылдаучан кеше
копче́ни||е *с* 1. *см.* **копти́ть** 2, 3; 2. *обычно мн.* **~я** (*копчёные продукты*) ыслаган ашамлыклар
копчёности *мн.* ысланган ризыклар, каклаган ашамлыклар, ыслап какланган азыклар
копчён||ый, -ая, -ое ысланган, ыслап хәзерләнгән; **~ая колбаса́** ыслап хәзерләнгән колбаса
ко́пчик *м* койрык сөяге, койрык умырткасы
копчу́шка *ж разг.* ыслап хәзерләнгән вак балык
копы́то *с* тояк

копь||ё I *с* сөңге; **мета́ние ~я́** сөңге ыргыту **♦ ко́пья лома́ть** *из-за чего* бәхәсләшү, әрепләшү
копь||ё II *с*: **ни ~я́** *прост.* сукыр тиен дә юк
кора́ *ж* 1. кабык, кайры; **~ сосны́** нарат кайрысы 2. каплам, катлау; **ледяна́я ~** боз капламы; **земна́я ~** *геол.* җир кабыгы **♦ ~ головно́го мо́зга** *анат., физиол.* баш мие кабыгы
кораве́л *м разг.* корабел, суднолар төзүче
кораве́льн||ый, -ая, -ое корабль ...ы; кораблькәр ...ы; **~ая верфь** кораблькәр верфы **♦ ~ый лес** корабль ясауга яраклы агач материаллары
кораве́льщик *м* 1. *уст.* корабль хуҗасы 2. моряк, диңгезче
кораблевожде́ние *с* корабль йөртү (*кораблькәр йөртү кагыйдәләрен өйрәтә торган фән*)
кораблекруше́ние *с* корабль һәлакәте
кораблестрое́ние *с* кораблькәр төзү
кораблестрои́тель *м* кораблькәр төзүче
кора́бл||ь *м* корабль; **боево́й ~ь** хәрби корабль; **возду́шный ~ь** һава корабле; **косми́ческий ~ь** космик корабль **♦ сжига́ть (жечь) свои́ ~и** үзенә чигенү юлын калдырмау; ныклы бер фикергә килү, искегә кайтырга юл калдырмау
кора́бль-спу́тник *м* корабль-иярчен (*орбитага чыгарылган космик корабль*)
кора́лл *м* мәрҗән, коралл
кора́ллов||ый, -ая, -ое 1. мәрҗән ...ы; **~ый о́стров** мәрҗән утравы 2. җете кызыл; **~ые гу́бы** җете кызыл иреннәр
Коран *м* Коръән
корве́т *м* корвет (*өч мачталы борынгы хәрби җилкәнле судно*)
ко́рда *ж спец.* озын тезген (*чабыш һәм җайдак атларын түгәрәктә йөртеп өйрәтү өчен кулланыла торган озын бау — тезген*)
кордебале́т *м* кордебалет (*балетта төркемле биюләр башкаручы артистлар составы*)
кордо́н *м* кордон (1. *юлны саклап торучылар яки чик сакчылары отряды* 2. *чик буе сакчылары, урман каравылчылары һ.б.ш. торган, яшәгән урын*)
корев||о́й, -ая, -о́е кызамык ...ы; **~а́я сыпь** кызамык тимгеле
корёжи||ть *несов. прост.* 1. *что* калҗайту, бөгү; **фане́ру ~т от сы́рости** дым фанерны калҗайта, фанер юешлектән калҗая 2. *кого* (*сводить судорогами*) көзән җыеру 3. *перен. кого-что* ачуландыру, ачуны кабарту; **меня́ ~т вся́кая гру́бость** һәрбер тупаслык минем ачуымны кабарта
корёжит||ься *несов.* 1. калҗаю, бөгелү; **переплёт ~ся** тышлык калҗая 2. *перен.* боргалану, бөгәрләну; **~ься от бо́ли** авыртудан боргалану
коре́ец *м* кореялы, Корея кешесе
коре́йка *ж* түш ите (*дуңгызныкы, бозауныкы*)

коре́йский, -ая, -ое корея ...ы; Корея ...ы; ~ **язы́к** корея теле

коре́йцы *мн.* кореялылар, Корея халкы

корена́стый, -ая, -ое **1.** киң җилкәле, таза гәүдәле, базык; ~ **ма́льчик** таза гәүдәле малай **2.** таза, зур тамырлы; ~ **дуб** зур тамырлы имән

корен||и́ться *несов.* **1.** *в чём* ...дан килү; ...дан килеп чыгу; нигезләнү; **суеве́рия ~ я́тся в неве́жестве** хорафатларга ышанулар наданлыктан килеп чыга **2.** *в ком-чём* булу; **в нём ~ я́тся поро́ки** аның бозыклыклары бар

коренни́к *м* төпкә җигелгән ат

коренн||о́й, -а́я, -о́е **1.** күптәнге, төп, даими; **~ые жи́тели го́рода** шәһәрнең төп халкы **2.** тирән, төп, иң әһәмиятле; **~ы́е измене́ния** тирән үзгәрешләр ♦ **~ы́е зу́бы** азу (азау) тешләр; **~ы́м о́бразом** тирән рәвештә, төптән, тамырыннан

ко́р||ень *м* **1.** тамыр, төп (*үсемлекнең, тешнең, чәчнең һ.б.ш.*) **2.** *перен.* нигез, башлангыч, чыганак; **~ень зла** явызлыкның башлангычы **3.** *грам.* тамыр; **~ень сло́ва** сүзнең тамыры **4.** *мат.* тамыр; **квадра́тный ~ень** квадрат тамыр ♦ **в ~не** бөтенләй, бөтенләйгә; **на ~ню́** урылмаган, үсеп утырган хәлдә (*ашлык*); **пусти́ть ~ни** тамыр җәю, нык нигезләнү; **в ~ень смотре́ть** мәсьәләнең асылына төшенү; **с ~нем вы́рвать** *что* бөтенләй юк итү; төбе-тамыры белән йолкып ташлау; **до ~не́й воло́с красне́ть (покрасне́ть)** кып-кызыл булу (*оятыннан*)

коре́нья *мн.* аштамыр (*кайбер азык яшелчәләренең тамырлары*)

ко́реш *м прост.* дус, әшнә

корешо́к *м* **1.** тамырчык; кечкенә төп (*тешнең, тырнакның*) **2.** (*переплёта*) төпсә; ~ **кни́ги** китап төпсәсе; ~ **тетра́ди** дәфтәр төпсәсе **3.** (*квитанции и т. п.*) төп

кореянка *ж* кореялы хатын (кыз)

корж *м* кабартма

ко́ржик *м* коржик

корзи́на *ж* кәрзин

корзи́нка *ж уменьш. от* **корзи́на**; корзинка, кәрзинкә

коридо́р *м* коридор

коридо́р||ный, -ая, -ое **1.** коридор ...ы; **~ая дверь** коридор ишеге **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м* коридорчы (*кунакханәдә берничә номерга хезмәт курсәтүче кеше*) ♦ **~ая систе́ма** коридор системасы

кори́нка *ж* кара йөзем (*киптерелгән вак төшсез йөзем*)

кори́ть *несов. кого-что, разг.* шелтәләү, әрләү, тиргәү, битәрләү; ~ **за гру́бость** тупаслык өчен әрләү

корифе́й *м высок.* корифей (*фәннең, сәнгатьнең күренекле эшлеклесе*)

кори́ца *ж* дарчын

кори́чнев||ый, -ая, -ое кызгылт көрән, коңгырт сары; дарчын төсендәге ♦ **~ая чума́** көрән чума (*фашистлар турында*)

кори́чн||ый, -ая, -ое дарчын ... ы; **~ое ма́сло** дарчын мае

ко́рк||а *ж* **1.** кабык; **~а апельси́на** әфлисун кабыгы **2.** кайры, кабык; **~а хи́нного де́рева** хина агачы кайрысы **3.** (*хлеба*) икмәк катысы ♦ **от ~и до ~и** (*прочитать*) башыннан ахырына кадәр (*укып чыгу*)

ко́рков||ый, -ая, -ое *анат.* ми сүрүе ...ы; **~ые це́нтры** ми сүрүе үзәкләре

корм *м* **1.** (*пища*) терлек азыгы; җим **2.** (*кормление*) ашату, туйдыру; **останови́ться для ~а лошаде́й** атларны ашатырга туктау

корма́ *ж* арткы өлеш, койрык өлеш (*суднолың, транспорт самолётының*)

кормёжка *ж* **1.** *разг.* ашату; ~ **лошаде́й** атларны ашату **2.** *прост.* ашамлык, ризык

корми́лец *м* туйдыручы, ашатучы, азыкландыручы

корми́лица *ж* сөт анасы, дая

корми́л||о *с уст.* судно койрыгы, судно руле ♦ **у ~а вла́сти** (*стоять, быть*) *высок.* хакимият башында (*тору, булу*)

корми́ть *несов.* **1.** *кого-что* (*давать пищу, корм*) ашату, карау; ~ **скот** малларны ашату; ~ **больно́го с ло́жечки** авыруны кашыктан ашату **2.** *кого-что и без доп.* (*питать*) ашату; **в столо́вой хорошо́ ко́рмят** ашханәдә яхшы ашаталар **3.** *кого* (*грудью*) имезү; ~ **ребёнка гру́дью** бала имезү (*кукрәк сөте белән*) **4.** *перен. кого-что* туйдырып тору; ~ **всю семью́** бөтен гаиләне туйдырып тору ♦ ~ **обеща́ниями** ялган вәгъдәләр бирү

корми́ться *несов.* **1.** туклану, туену, азыклану; **ло́шадь ко́рмится на лугу́** ат болында туклана **2.** *чем* тору, яшәү; ~ **свои́м трудо́м** үз көчең белән тору

кормов||о́й I, -а́я, -о́е азык ...ы; **~а́я свёкла** азык чөгендере

кормово́й II, -а́я, -о́е койрык ...ы; койрыктагы ...; ~ **флаг** койрыктагы флаг

кормозаготови́тельный, -ая, -ое мал азыгы әзерләү ...ы; ~ **цех** азык әзерләү цехы

кормоку́хня *ж* мал азыгы кухнясы; ~ **на звероферме́** җәнлек фермасында азык кухнясы

кормопрово́д *м* мал азыгы үткәргеч (*азыкны утлыкларга автоматик рәвештә бирү җайланмасы*)

кормопроизво́дство *с* мал азыгы әзерләү эше

кормораздато́чн||ый, -ая, -ое мал азыгын бүлеп бирү ...ы; мал азыгы салу ...ы; **~ая маши́на** мал азыгын салу машинасы

кормораздато́чик *м* мал азыгын бүлгеч (*корм бүлеп салу механизмы*)

кормосмеси́тель *м* мал азыгын болгаткыч (*механизм*)

кормоце́х *м* мал азыгы цехы

корму́шка *ж* **1.** утлык, улак, ялгаш (*терлек азыгы өчен*) **2.** *перен. разг.* җылы урын, төшемле урын

ко́рмчий *м* **1.** *уст.* койрыкчы, койрык тотучы; кораблне йөртүче **2.** *высок.* җитәкче, җитәкчелек итүче

корна́ть *несов. кого-что, прост.* үтә кыска яки тигезсез итеп кырку, аннанмоннан кырку (*чәчне, ат койрыгын*)

корневи́ще *с* **1.** тамыр-сабак **2.** (*основной корень дерева*) үзәк тамыр

корнев||о́й, -а́я, -о́е **1.** тамыр ...ы; **~о́е ответвле́ние** тамыр тармагы **2.** *грам.* тамыр ..; **~ые слова́** тамыр сүзләр

корнепло́д *м* тамыразык (*чөгендер, кишер кебек яшелчәләр*)

корнепло́дн||ый, -ая, -ое тамыразык ...; **~ые расте́ния** тамыразык яшелчәләр (*чөгендер, кишер һ.б.ш.*)

корне́т I *м уст. воен.* корнет

корне́т II *м* корнет (*быргы сыман тынлы музыка коралы*)

корнишо́н *м* корнишон (*маринадланган вак кыяр*)

корноу́хий, -ая, -ое *разг.* китек колаклы, өтек колаклы

ко́роб *м* чуман, әрҗә (*кабыктан яки каен тузыннан эшләнә*) ♦ **с три ~а наговори́ть (наказа́ть)** бик күп сөйләү, күп лыгырдау

коробе́йник *м уст.* кырык тартмачы, асламчы

коро́би||ть *несов.* **1.** *что* калҗаю, калтаю; калҗайту, калтайту; **до́ски ~т от сы́рости** юештән такталар калҗая **2.** *перен. кого-что* тайчандыру, чиркандыру, жирәндерү; **меня́ ~т от его́ гру́бостей** аның тупаслыклары мине тайчандыра

коро́биться *несов.* калҗаю, калтаю

коро́бка *ж* тартма, кечкенә әрҗә; кап; ~ **спи́чек** бер кап шырпы ♦ ~ **скоросте́й** *тех.* тизлекне алмаштыру тартмасы (*мәс. автомашинада*)

коробо́к *м* кечкенә тартма; кап; **спи́чечный ~** шырпы кабы

коро́бочн||ый, -ая, -ое тартма ...ы; **~ая мастерска́я** тартма остаханә

коро́бчатый, -ая, -ое *спец.* тартмасыман; ~ **свод** тартма сыман түбә, (гөмбәз)

коро́ва *ж* сыер; **бодли́вая ~** сөзгәк сыер ♦ **морска́я (сте́ллерова)** ~ диңгез сыеры (*диңгезләрдә яшәгән имезүче хайван*)

коро́вник *м* сыер абзары

коро́вница *ж уст.* сыерлар караучы хатын-кыз

корое́д *м* кайры корты, кайрыашар, кайры коңгызы, эчертмән

корола́ *ж* **1.** хатын-кыз король, әби патша **2.** король хатыны **3.** *шахм.* ферзь

корола́вич *м* король улы

корола́вна *ж* король кызы

корола́вство *с* корольлек

корола́к *м* королёк (**1.** *кызыл итле татлы әфлисун* **2.** *борчак зурлыгындагы затлы металл эретмәсе*)

коро́л||ь *м в разн. знач.* король; **англи́йский ~ь** Англия короле; **нефтяно́й ~ь** нефть короле; **де́лать ход ~ём** *шахм.* король белән йөрү; **бубно́вый ~ь** *карт.* буби короле

коромы́сло *с* **1.** (*для вёдер, у весов*) көянтә **2.** (*у колодца*) сиртмә **3.** *зоол.* (*насекомое*) энәкарак

коро́н||а *ж* **1.** *прям., перен.* таҗ; **борьба́ за ~у** таҗ (тәхет) өчен көрәш,

хакимият өчен көрәш **2.** *астр.* таж, ореол; **со́лнечная ~а** кояш тажы

корона́ция *ж* таж кию, тәхеткә утыру

коро́нка *ж* **1.** (*наружная часть зуба*) тешнең тышкы катлавы **2.** коронка (*бозыла башлаган тешне саклау өчен киертелә торган металл тышча*)

коро́нн||ый, -ая, -ое *уст.* хөкүмәт ...ы; дәүләт ...ы; **~ая слу́жба** дәүләт хезмәте (*башында патша торган илләрдә*) ♦ **~ая роль** иң уңышлы роль, иң яхшы роль (*артистлар репертуарында*)

коронова́ние *с см.* **корнова́ть**

коронова́ть *сов., несов. кого* таҗ кидерү, тәхеткә утырту

коронова́ться *сов., несов.* таҗ кию, тәхеткә утыру

коро́ста *ж* кутыр, корчаңгы кутыры

коростель *м* тартар

корота́ть *несов. что, разг.* уздыру (*эч пошканны басу өчен берәр нәрсә белән шөгыльләнеп, гомерне уздыру*); **~ вре́мя за ша́хматами** вакытны шахмат уйнап уздыру

коро́тк||ий, -ая, -ое **1.** кыска; **~ие во́лосы** кыска чәч; **~ого ро́ста** кыска буйлы; **бег на ~ую диста́нцию** кыска арага йөгерү **2.** (*о времени*) аз, кыска, бераз, беркадәр; **на ~ий срок** кыска вакытка; **за ~ое вре́мя** аз вакыт эчендә **3.** (*близкий, дружественный*) якын; **быть в ~их отноше́ниях** якын мөнәсәбәттә булу **4.** (*быстрый, решительный*) каты, кискен; **~ая распра́ва** каты җәза; **~ий уда́р** кискен һөҗүм ♦ **быть на ~ой ноге́** *с кем* яхшы әшнә булу; **~ая волна́** [радио] кыска дулкын; **~ая па́мять** тиз онытучанлык, хәтерсезлек; **~ое замыка́ние** *физ.* кыска ялгану; **ум коро́ток** зәгыйфь акыл турында

коротко* *кушма сүзләрдә «кыска» мәгънәсендәге беренче кисәк, мәс.* **коротковоло́сый** кыска чәчле; **коротконо́гий** кыска аяклы; **короткошёрстный** кыска йонлы

коротковолнови́к *м* кыска дулкынларда эшләүче (*радио һәвәскәре*)

коротково́лновый, -ая, -ое кыска радиодулкыннарда эшли торган; **~ приёмник** кыска дулкыннарда эшли торган радиоалгыч

короткометра́жка *ж разг.* кыска кинофильм

короткометра́жный, -ая, -ое кыска метражлы; **~ фильм** кыска кинофильм

коротышка *м, ж разг.* тәбәнәк (карсак) кеше

корпе́ть *несов. над чем и без доп., разг.* бирелеп эшләү, тырышып эшләү, баш күтәрмичә эшләү

ко́рпия *ж* чүпрәктән чүпләнгән җеп (*электә мамык урынына кулланылган*)

корпорати́вн||ый, -ая, -ое корпорация ...ы; тар группачылык ...ы; **~ые интере́сы** тар группачылык интересларе

корпора́ция *ж* корпорация (*бер үк профессиягә, бер үк сословиегә һ.б.ш. керә торган кешеләрнең берләшмәсе, союзы*)

корпу́нкт *м* корпункт (*газета корреспондентларының информация алу һәм тапшыру пункты*)

ко́рпус *м* **1.** гәүдә **2.** *в разн. знач.* корпус; **~ часо́в** сәгать корпусы; **заводски́е ~а́** завод корпуслары, завод биналары; **та́нковый ~** танк корпусы; **дипломати́ческий ~** дипломатлар корпусы; **каде́тский ~** кадетлар корпусы

корректи́в *м* корректив, төзәтмә, төзәтү; **внести́ ~ы в ру́копись** кульязмага тиешле төзәтмәләр кертү

корректи́ровать *несов. что* **1.** (*поправлять*) коррективлар кертү; төзәтү, төзәтмәләр кертү; **~ стрельбу́** төз атуга төзәтмәләр кертү **2.** корректура уку

корректи́ровщик *м* корректировщик (*корректировка ясаучы артиллерист, очучы һәм самолёт*)

корре́ктность *ж* нәзакәтлелек, әдәплелек, үзен-үзе тота белү; нәзакәтле мөнәсәбәт

корре́ктный, -ая, -ое нәзакәтле, кече күңелле, әдәпле

корре́ктор *м* корректор, корректура укучы

корре́кторск||ий, -ая, -ое корректорлык ...ы; корректорлар ...ы; **~ая рабо́та** корректорлык эше

корректу́ра *ж* корректура (**1.** *набордагы хаталарны төзәтү* **2.** *төзәтү өчен бастырып алынган текст*)

корреляти́вн||ый, -ая, -ое *книжн.* коррелятив, үзара бәйләнгән, үзара бәйләнешле; **~ые поня́тия** үзара бәйләнешле төшенчәләр

корреляцио́нн||ый, -ая, -ое *книжн.* корреляцион; **~ая зави́симость** корреляцион бәйлелек

корреля́ция *ж книжн.* корреляция, үзара бәйлелек

корреспонде́нт *м* **1.** (*переписывающийся с кем-л.*) корреспондент, хатлар язышучы, хәбәрләшүче **2.** (*автор статьи*) корреспондент, хәбәрче, мәкалә авторы

корреспонде́нция *ж* корреспонденция (**1.** *газета мәкаләсе* **2.** *почта аша язышу, хәбәрләшү*)

корри́да *ж* коррида (*тореадорның үгезгә каршы сугышуы*)

корро́зия *ж спец.* коррозия, ашалу, тутыгу

корру́пция *ж* коррупция, ришвәт биреп сатып алу, кызыктыру (*хезмәт урынындагы кешеләрне*)

корса́ж *м* корсаж (**1.** *хатын-кызлар кулмәгенең муеннан билгә кадәр булган өлеше* **2.** *юбка поясы*)

корса́р *м* корсар (*диңгез юлбасары, пират*)

корсе́т *м* корсет (**1.** *гәүдәне зифа итеп күрсәтү өчен киелә торган киң пояс* **2.** *дәвалану максаты белән киелә торган каты бандаж*)

корт *м* корт (*теннис уены өчен мәйданчык*)

корте́ж *м* кортеж (*тантаналы процессия*)

ко́ртик *м* кортик, хәнҗәр (*нава һәм диңгез флоты командирлары тагып йөри*)

ко́рточк||и: сиде́ть на ~ах чүгәләп утыру; **сесть (присе́сть) на ~и** чүгәләү

кору́нд *м мин.* корунд

кору́ндов||ый, -ая, -ое **1.** корунд ...ы; **~ые месторожде́ния** корунд ятмалары **2.** корунд ...; **~ая игла́** корунд энә

корча́га *ж* зур чүлмәк

корчева́льн||ый, -ая, -ое урман төпләү ...ы; **~ая маши́на** урман төпләү машинасы

корчева́ть *несов. что* урман (куак) төпләү, төп чыгару

корчёвка *ж см.* **корчева́ть**

ко́рч||и *мн. разг.* көзән, көзән җыеру; **му́читься в ~ах** көзән җыеру белән азаплану

ко́рч||ить *несов* **1.** *безл. кого* боргалану, өзгәләнү; **его́ ~ит от бо́ли** авыртудан ул өзгәләнә **2.** *перен. кого-что, разг.* ... булып кылану; **~ить из себя́ знатока́ му́зыки** музыка белгән булып кылану

ко́рчиться *несов.* боргалану, бөгәрләнү, өзгәләнү (*авыртудан*)

корчма́ *ж уст.* корчма, трактир

корчма́рь *м уст.* корчма хуҗасы

ко́ршун *м* тилгән ♦ **~ом налете́ть** *на кого* карчыга кебек ташлану

корыстн||ый, -ая, -ое **1.** файда итү ...ы; **с ~ой це́лью** файда итү өчен **2.** *см.* **корыстолюби́вый**

корыстолю́бец *м* комсыз кеше, ач күз, акчага хирыс кеше, карун

корыстолюби́вый, -ая, -ое комсыз, ач күзле, карун, акчага хирыс

корыстолю́бие *с* комсызлык, карунлык, ач күзлелек, акчага хирыслык

корысть *ж* табыш, файда

корыт||о *с* тагарак, ялгаш ♦ **у разби́того ~а оста́ться (оказа́ться)** ≈ төпсез чуманга утырып калу, төтенгә тотынып калу

корь *ж* кызамык (*балалар авыруы*)

корьё *с собир* кайры, кабык-кайры

ко́рюшка *ж* корюшка (*вак балык*)

коря́в||ый, -ая, -ое **1.** кәкре-бөкре; **~ое де́рево** кәкре-бөкре агач **2.** кытыршы; **~ые ру́ки** кытыршы куллар **3.** *перен. разг.* ямьсез, тупас; **~ый стиль** кытыршы стиль; **~ый по́черк** ямьсез язу

коря́га *ж* суга баткан ботаклы-чатаклы агач

коря́ки *мн.* коряклар, коряк халкы

коря́кский, -ая, -ое коряк[лар] ...ы; **~ язы́к** коряк теле

коса́ I *ж* толым; **заплести́ ко́су** чәч үрү, толымнарны үрү

коса́ II *ж с.-х.* чалгы ♦ **нашла́ ~ на ка́мень** *погов.* чалгы ташка туры килү

коса́ III *ж* (*отмель*) борын (*елгада, диңгездә: очлаеп кергән коры җир*)

коса́рь I *м* печән (иген) чабучы

коса́рь II *м* (*нож*) чыра пычагы, зур пычак

ко́свенн||ый, -ая, -ое **1.** турыдан-туры булмаган, турыдан-туры аңа карамаган; **~ые доказа́тельства** турыдан-туры аңа карамаган дәлилләр **2.** *грам.* кыек; **~ая речь** кыек сөйләм; **~ое дополне́ние** кыек тәмамлык

косе́ц *м* чабучы (*чалгы белән*)

коси́лка *ж* чапкыч, косилка

коси́ть I *несов.* **1.** *что* чабу, **~ се́но** печән чабу **2.** *перен. кого-что* (*губить*) кыру, үтерү, һәлак итү

кос||и́ть II *несов.* **1.** *что, чем* кыегайту, кыйшайту, чалышайту; **~ и́ть рот** авызны чалышайту; **~ и́ть глаза́ми** күзләрне кыйшайту **2.** кыйшаеп (чалышаеп) тору; **юбка спе́реди ~ и́т** ал яктан итәге кыйшаеп тора **3.** кылый күзле булу, кылый карау; **оди́н глаз у него́ ~ и́т** бер күзе кылый карый

коси́т||ься *несов.* **1.** кыйшаеп тору; **дверь ~ся от сы́рости** дымлылыктан ишек кыйшаеп тора **2.** *на кого-что* кырын карау **3.** *перен. на кого-что, разг.* яратмау, кырын карау, үз итмәү, читләтеп карау

коси́ца *ж разг.* **1.** *уменьш. от* **коса́** I; **2.** (*прядь волос*) бер учма (тотам) чәч, сирәк чәч

коси́чка *ж разг. уменьш. от* **коса́** I; чәч толымчыгы

коса́тить *несов. кого-что, разг.* чәчне тузгыту (тырпайту, тузгакландыру)

коса́тый, -ая, -ое **1.** (*с лохматой шерстью*) йонлач, озын куе йонлы **2.** (*с лохматыми волосами*) тузгак чәчле

косме́тика *ж* косметика (**1.** *бизәнү* **2.** *собир. бизәнү әйберләре: крем, кершән, помада һ.б.ш.*)

космети́ческ||ий, -ая, -ое бизәнү әйберләре ...ы; косметика ...ы; бизәнү ...ы; **~ий кабине́т** бизәнү кабинеты; **~ие сре́дства** бизәнү әйберләре

космети́чка *ж разг.* косметика остасы

космето́лог *м* косметолог, косметика белгече

косметоло́гия *ж* косметология (*дәвалау һәм декоратив косметиканы өйрәнү фәне*)

косми́ческ||ий, -ая, -ое **1.** космик; **~ий полёт** космик очыш; **~ий кора́бль** космик корабль; **~ая метеоста́нция** космик метеостанция **2.** *перен.* ифрат зур, чиктән тыш зур; **~ий масшта́б** ифрат зур масштаб

космови́дение *с* космостан телетапшыру

космогони́ческий, -ая, -ое космогония ...ы, космогоник, дөнья яралуга караган

космого́ния *ж* космогония (*астрономиядә: кук җисемнәренең килеп чыгуын һәм үсешен өйрәнә торган бүлек*)

космогра́фия *ж уст.* космография (*Җир шары һәм галәм турындагы фән*)

космодро́м *м* космодром

космона́вт *м* космонавт

космона́втика *ж* космонавтика (*махсус очу аппаратларында космик пространствода хәрәкәт итү теориясе һәм практикасы*)

космона́втка *ж* космонавтка

космооткрыва́тель *м высок.* космоскаюл ачучы

космопла́вание *с* космосәяхәт (*то же, что* **космона́втика**)

космополи́т *м* космополит

космополити́зм *м* космополитизм, космополитлык

космополити́ческ||ий, -ая, -ое космополитик, космополитлык ...ы; **~ие взгля́ды** космополитик карашлар

космопсихо́лог *м* космопсихолог, космик психология белгече

ко́смос *м* космос, галәм

космофи́зик *м* космофизик, космик физика белгече

космофи́зика *ж* космофизика

космофизи́ческий, -ая, -ое космофизик, космофизика ...ы; **~ институ́т** космофизика институты

космохи́мик *м* космохимик, космик химия белгече

космохими́ческий, -ая, -ое космохимик, космохимия ...ы

космохи́мия *ж* космохимия

космоце́нтр *м* космоүзәк (*космик очышларны әзерләү һәм үткәрү үзәге*)

ко́смы *мн. прост.* чәч учмасы (тотамы)

косне́||ть *несов. в чём и без доп., уст.* батып калу; **~ть в неве́жестве** наданлыкта батып калу ♦ **язы́к ~ет** тел көрмәкләнә

ко́сность *ж* катып калганлык, рухи торгынлык

косноязы́кий, -ая, -ое *см.* **косноязы́чный**

косноязы́чие *с* сакаулык

косноязы́чный, -ая, -ое сакау

коснýться *сов. кого-чего* **1.** (*дотронуться*) орынып (кагылып, тиеп) китү (алу, кую) **2.** (*затронуть*) искә алып китү, хәтерләп үтү; **~ воспомина́ний вое́нных лет** сугыш еллары хатирәләрен искә алып үтү

ко́сный, -ая, -ое искелегендә катып калган, үҗәт, тискәре; хәрәкәтсез; **~ум** катып калган акыл

кособо́к||ий, -ая, -ое чалыш, кыеш; **~ая избу́шка** чалыш өй

косови́ца *ж* печән өсте, печән чабу вакыты

косови́ще *с* чалгы сабы

косоворо́тка *ж* кыек якалы ирләр күлмәге

косогла́зие *с* кылыйлык, кылый күзлелек

косогла́зый, -ая, -ое кылый (чалыш) күзле

косого́р *м* тау бите, сөзәк тау бите

кос||о́й, -а́я, -о́е **1.** кыек төшкән, кыйгач; **~ые лучи́ со́лнца** кояшның кыйгач нурлары; **~о́й до́ждь** кыйгач яңгыр **2.** кырын, кыек, авыш; **~о́й пол** кыек идән **3.** кылый; кылый күзле, чалыш күзле; **~ые глаза́** кылый күзләр; **~о́й мальчик** кылый күзле малай **4.** *перен.* (*недружелюбный*) шөбһәле, шикле, ышанычсыз, кырын (*караш, күз карашы турында*) ♦ **~а́я саже́нь в плеча́х** алыптай зур гәүдәле кеше, әзмәвердәй таза кеше; **~о́й во́рот** кыек яка; **~о́й па́рус** кыек җилкән; **~о́й у́гол** *мат.* кыек почмак

косола́пый, -ая, -ое **1.** чалыш аяклы; **~ медве́дь** чалыш аяклы аю **2.** *перен. разг.* (*неуклюжий*) килбәтсез, шыксыз

косоуго́льный, -ая, -ое кыек почмаклы

костёл *м* костёл (*католиклар чиркәве*)

костене́ть *несов.* **1.** (*о трупе*) сөяк кебек кату, катып калу **2.** (*оцепенеть от холода*) шакыраеп туңу (кату)

костёр *м* костёр, учак, ут

кости́ст||ый, -ая, -ое **1.** сөякләре беленеп торган, сөякчел; **~ые ру́ки** сөякчел куллар **2.** кылчыклы; **~ый лещ** кылчыклы корбан балык

костля́вый, -ая, -ое **1.** үтә арык, үтә ябык, коры сөяккә калган, шыр сөяк **2.** *см.* **кости́стый** 2

ко́стный, -ая, -ое **1.** сөяк ...ы; **~ туберкулёз** сөяк туберкулёзы **2.** сөяктән ясалган; **~ клей** сөяктән ясалган җилем ♦ **~ мозг** *анат.* җелек

костое́да *ж* сөяк черү авыруы

костопра́в *м уст.* тайган сөякне утыртучы, чыккан сөякне утырта белүче

косторе́з *м* сөяктән әйбер эшләүче

ко́сточка *ж* **1.** *уменьш. от* **кость**; **2.** (*в плодах*) төш (*җимешләрдә*) **3.** (*на счётах*) төймә

ко́сточков||ый, -ая, -ое *бот.* төшле; **~ые плоды́** төшле җимешләр

костра́ *ж спец.* талкыш

костре́ц *м* **1.** *анат.* оча сөягенең аскы өлеше **2.** (*часть туши*) бот ите, сум ите

костри́ка *ж см.* **костра́**

костровóй *м разг.* учак ягучы, утаман

костыль *м* **1.** култык таягы **2.** (*большой гвоздь*) ыргаклы кадак (чөй) **3.** *спец.* терәк (*төзелештә, тау эшләрендә кулланыла*)

кост||ь *ж* **1.** сөяк **2.** кылчык (*балыкларда*) **3.** (*игральная*) шакмак (*уен ташы*) **4.** (*шарик на счётах*) төймә ♦ **до ~е́й промо́кнуть** җеп бөртеге дә калмыйча чылану, манма су булу

костю́м *м* костюм

костюме́р *м театр.* костюмер

костюме́рша *ж см.* **костюме́р**

костюми́рованный, -ая, -ое маскарад костюмлы; театр костюмлы; **~ бал** маскарад костюмлы бал

костюмирова́ть *сов., несов. кого-что* маскарад костюмы кидерү; театр костюмы кидерү

костя́к *м* **1.** скелет, гәүдәнең барлык сөякләре **2.** *перен.* нигез; **~ организа́ции** оешманың нигезе (*төп кешеләре*)

костяни́ка *ж бот.* кызыл бөрлегән

костян||о́й, -а́я, -о́е **1.** сөяк ...; сөяктән ясалган; **~о́й нож** сөяк пычак **2.** сөяк ...ы; **~а́я мука́** сөяк оны

костя́шка *ж разг.* **1.** (*сустав*) сөяк кисәге, сөяк кыйпылчыгы **2.** (*на счётах*) төймә

косу́ля *ж* кыр кәҗәсе

косы́нка *ж* косынка, өч почмаклы (кыек) яулык

косьба́ *ж см.* **коси́ть** I 1

кося́к I *м* тәрәзә яңагы; ишек яңагы

кося́к II *м* **1.** (*гурт кобыл*) көтү, бер айгырлы бияләр өере **2.** (*стая рыб*) балыклар өере; (*стая птиц*) кошлар төркеме

кот *м* ата мәче ♦ **~ напла́кал** *кого-чего* бер тамчы, бик аз, энә очы хәтле; **~ в мешке́** билгесез нәрсә; **не всё ~у ма́сленица, бу́дет и вели́кий пост** *посл.*

≈ һәрвакыт майлы ботка булмый; **покупа́ть (купи́ть) ~ á в мешкé** әйберне күрмичә алу; күзне йомып сатып алу

котёл *м* казан

котело́к *м* котелок (**1.** *гаскәриләр өчен кечкенә металл савыт, аш савыты* **2.** *туңгәрәк түбәле каты эшләпә*)

кото́льная *ж* пар казаннары бинасы

кото́льн||ый, -ая, -ое казан ...ы, казан ясый торган; **~ый заво́д** казаннар ясау заводы; **~ое желе́зо** казаннар ясый торган тимер

кото́льщик *м* **1.** казаннар ясау остасы **2.** пар казаннары белгече

котёнок *м* мәче (песи) баласы

ко́тик I *м уменьш. от* **кот**

ко́тик II *м* **1.** (*животное*) котик, диңгез мәчесе **2.** (*мех*) котик мехы

ко́тиков||ый, -ая, -ое **1.** котик ...ы; **~ый про́мысел** котик промыселе **2.** котик ...; котик мехыннан эшләнгән; **~ая ша́пка** котик бүрек

коти́ровать *сов., несов. что, фин.* котировать итү, бәя кую (*процентлы кәгазьләргә*)

коти́роваться *несов.* **1.** *фин.* бәяләнү (*процентлы кәгазьләр турында*) **2.** *фин.* биржада йөрү (*процентлы кәгазьләр турында*) **3.** *перен.* бәясе булу, дәрәҗәсе булу, бәяләнү (*халык тарафыннан, халык каршында*) **4.** *страд. от* **коти́ровать**

коти́ться *несов.* (*напр. о кошке*) балалау; (*напр. о козе, овце*) бәрәнләү

котле́та *ж* котлет

котлова́н *м* котлован, нигез чокыры

котлови́на *ж* тирән сөзәк чокыр

кото́мка *ж* биштәр

кото́р||ый, -ая, -ое *мест.* **1.** (*по порядку*) ничәнче, ничә; **~ый час?** сәгать ничә? **2.** (*какой именно*) кайсы; **~ая шля́па тебé бóльше нрáвится?** кайсы эшләпә сиңа ошыйрак төшә?

кото́рый-либо, кото́рый-нибудь *мест.* кайсы да булса берсе, кайсы булса да

котте́дж *м* коттедж (*бер гаиләлек өй*)

ко́фе *м, с нескл.* кофе

кофева́рка *ж* кофекайнаткыч (*аппарат*)

кофеи́н *м* кофеин (*наркотик матдә*)

кофе́йник *м* кофе чәйнеге, кофейник

кофе́йница *ж* **1.** (*ручная мельница*) кофе тегермәне **2.** (*коробка*) кофе тартмасы

кофе́йн||ый, -ая, -ое **1.** кофе ...ы; **~ые планта́ции** кофе плантацияләре **2.** кофеле; **~ый торт** кофеле торт **3.** кофе ...ы; **~ый серви́з** кофе сервизы **4.** (*о цвете*) көрән, кофе төсе

кофе́йня *ж уст.* кофеханә

кофемо́лка *ж* кофетарткыч (*аппарат*)

ко́фта *ж* кофта

ко́фточка *ж уменьш. от* **ко́фта**

коча́н *м* бер баш (кәбестә), күчән

кочева́ть *несов.* **1.** (*вести кочевой образ жизни*) күченеп йөрү, күчмә тормыш алып бару **2.** *разг.* (*часто менять местожительство*) күчеп йөрү (*мәс. бер булмәдән икенче булмәгә*)

кочéвники *мн.* күчмә халык, күчмәләр

кочев||óй, -áя, -óе күчмә; **~ы́е племена́** күчмә кабиләләр; **~óй óбраз жи́зни** күчмә тормыш

кочéвье *с* күчмә халыкларның туктау урыны; күчеп йөрү урыны

кочега́р *м* кочегар

кочега́рка *ж* кочегарка (*пар машинасының казаннары һәм ягулыклары урнашкан бина*)

кочене́ть *несов.* күшегү, өшү, туну, кату

кочерга́ *ж* кисәү агачы

кочеры́жка *ж* күчән, кәбестә күчәне

ко́чка *ж* түмгәк, түндәк

кочкова́т||ый, -ая, -ое түмгәкле, түмгәкләр белән капланган; **~ое боло́то** түмгәкләр белән капланган баткаклык

кошáра *ж* сарык абзары

кошáчий, -ья, -ье мәче ...ы ♦ **~ конце́рт** мәчеләр мияулавы

кошелёк *м* акча янчыгы, калта

кошёлка *ж разг.* кәрзин

ко́шечий, -ья, -ье *см.* **кошáчий**

ко́шк||а *ж* **1.** мәче, песи, ана мәче (песи) **2.** *спец.* (*небольшой якорь*) өч-дүрт япле ыргак **3.** *мн.* **~и** *тех.* тырнак, ыргак (*баганаларга менү өчен*) **4.** (*ремённая плеть*) берничә япле камчы ♦ **как ~а с соба́кой [живу́т]** эт белән мәче кебек, этле-мәчеле; **~и скребу́т на се́рдце** *у кого* эч пошу, йөрәк әрнү

кошмá *ж* киез, тула

кошмáр *м* **1.** бастырылу (*куркыныч төш*) **2.** *перен. разг.* коточкыч вакыйга, коточкыч нәрсә, авыр кичереш

кошмáрн||ый, -ая, -ое *разг.* коточкыч авыр, начар; **~ое впечатле́ние** коточкыч авыр тәэсир; **~ая пого́да** начар һава

кощéй *м* **1.** (*с прописной*) Кощей (*рус халык әкиятләрендә мифик зат; озын гомерлелек серен белә торган явыз карт*) **2.** *перен.* (*о тощем человеке*) ябык, озын буйлы кеше

кощу́нственн||ый, -ая, -ое мыскыллы, мәсхәрәле

кощу́нство *с* мыскыл, мәсхәрә

кощу́нствовать *несов. над чем и без доп.* мыскыллау, мәсхәрәләү, көлү

коэффицие́нт *м мат., физ.* коэффициент ♦ **~ поле́зного де́йствия** файдалы эш коэффициенты

краб *м* краб, диңгез кысласы

кра́ги *мн.* краги (**1.** *куннән эшләнгән балтыр кунычы* **2.** *перчатканың киң озын беләзеге*)

кра́ден||ый, -ая, -ое **1.** урланган **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* урланган әйберләр

кра́дучись *нареч. разг.* посып, яшереневеп, яшертен, сиздермәстән

краевéд *м* крайны өйрәнүче

краевéдение *с* крайны өйрәнү

краевéдческий, -ая, -ое крайны өйрәнү ...ы; **~ музéй** крайны өйрәнү музее

краевóй, -áя, -óе край ...ы; **~ испóлком** край башкарма комитеты

краеугóльный, -ая, -ое *книжн.*: **~ вопрóс** иң мөһим мәсьәлә; **~ кáмень** төп идея, төп нигез, нигез ташы

кра́жа *ж* урлау, урлану

кра||й *м* **1.** кырый, чит; **~й столá** өстәл кырые; **он живёт на ~ю гóрода** ул шәһәр читендә тора **2.** ил, өлкә; **тёплые ~я́** җылы илләр (өлкәләр) **3.** край; **Краснода́рский ~й** Краснодар крае ♦ **~ем у́ха слы́шать** колак чите белән генә ишетү; **на ~ю моги́лы** кабер якасында, үлем алдында; **хвати́ть че́рез ~й** кирәкмәс сүз әйтеп ташлау (салу), ычкындыру

кра́йне *нареч.* чиктән тыш, үтә, бик, артык

кра́йн||ий, -яя, -ее **1.** кырыйдагы, кырый, читтәге, чит; **~ий дом** кырыйдагы өй **2.** ерак, ерактагы; **Кра́йний Се́вер** Ерак Төньяк **3.** чик, иң соңгы; **~ие ме́ры** иң соңгы чаралар; **~ий срок** чик срок, соңгы срок ♦ **в ~ем слу́чае** ахыр чиктә, бер дә булмаса; **по ~ей ме́ре** ичмаса; һәрхәлдә

кра́йност||ь *ж* **1.** (*чрезмерное проявление чего-л.*) чик, ахыр (соң) чик **2.** *перен.* каршылык, капма-каршылык; **впада́ть в ~ь** каршылыкларга бирелү (юлыгу); **в его хара́ктере сочета́ются две ~и** аның характерында ике капма-каршылык яраша (берләшә)

крамо́ла *ж уст.* крамола, фетнә

крамо́льник *м уст.* крамольник, фетнәче

крамо́льничать *несов. уст.* крамола (фетнә) оештыру

кран I *м* кран, борын; **самова́рный ~** самовар борыны

кран II *м тех.* кран; **подъёмный ~** күтәрү краны

крановщи́к *м* кранчы, күтәрү кранында эшләүче

крановщи́ца *ж* кранчы хатын (кыз)

крап *м* **1.** (*мелкие пятна*) бөрчек, вак таплар; **бе́лый мра́мор с се́рым ~ом** соры бөрчекле ак мәрмәр **2.** (*расцветка*) тимгел-тимгел бизәк (*уен кәртләрендә, китапның читләрендә*)

кра́пать *несов.* сибәләп яву, сибәләп явып тору (*яңгыр турында*)

крапи́ва *ж* кычыткан

крапи́вница *ж* **1.** (*болезнь*) кычыткан бизгәге, бүре уы **2.** (*бабочка*) кычыткан күбәләге

крапи́вн||ый, -ая, -ое кычыткан ...ы; **~ый ожóг** кычыткан чагуы ♦ **~ая лихора́дка** *см.* **крапи́вница** 1

кра́пина, кра́пинка *ж* кечкенә тап, тимгел, бөрчек

краплёный, -ая, -ое (*о картах*) тамгалы

краса́ *ж* **1.** *уст.* матурлык, ямьлелек **2.** *высок.* ямь, күрек; **~ и го́рдость шко́лы** мәктәпнең күрке һәм мактанычы

краса́вец *м* **1.** (*о мужчине*) матур, чибәр, гүзәл **2.** *перен.* матур, гүзәл, күркәм, мәһабәт; **~ го́род** гүзәл шәһәр

краса́вица *ж* **1.** (*о женщине*) матур, чибәр, гүзәл, сылу **2.** *перен.* матур, гүзәл, күркәм, мәһабәт; **~ Во́лга** мәһабәт Идел

краса́вчик *м разг.* матур, чибәр

краси́в||ый, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* матур, сылу, гүзәл, чибәр; килешле,

килбәтле; **~ые дéвушки** сылу кызлар; **э́то плáтье ~о** күлмәге килешле тегелгән; **~ый гóлос** матур тавыш **2.** (*нравственно прекрасный*) күркәм, гүзәл; **~ый постýпок** күркәм эш **3.** *перен.* (*эффектный*) матур, ялтыравыклы; **~ые словá** матур сүзләр

краси́льный, -ая, -ое буяу ...ы; **~ цех** буяу цехы

краси́льня *ж* буяу бүлмәсе, буяу цехы, буяу мастерское

краси́льщик *м* буяучы

краси́тель *м* буяу, буяу матдәсе

крáси||ть *несов.* **1.** *что* буяу, ману (*буяуга*) **2.** *кого-что* матурлау, бизәү; **труд ~т нáшу жизнь** хезмәт безнең тормышыбызны бизи

крáсит||ься *несов.* **1.** (*подвергаться окраске*) буялу, буяу сеңү (керү) **2.** (*пачкаться*) буялу, буявы йогу (чыгу); **э́та ткань ~ся** бу тукыманың буявы йога **3.** (*подкрашивать волосы, лицо*) буяну, бизәнү **4.** *страд. от* **крáсить** 1

крáск||а *ж* **1.** буяу (*матдәсе*) **2.** *обычно мн.* **~и** (*колорит, тон*) буяулар төсе (*колориты, тоны*) **3.** *обычно мн.* **~и** *перен.* (*выразительные средства*) буяу, бизәк, тасвир; **рассказáть в я́рких ~ах** ачык тасвирлар белән сөйләп бирү

красне́||ть *несов.* **1.** кызару; **ви́шня уже́ ~ет** чия кызара инде; **ру́ки ~ют от моро́за** салкыннан куллар кызара **2.** *перен.* оялу, кызару, кызарыну **3.** (*виднеться — о чём-л. красном*) кызарып тору, кызарып күренү

красне́ться *см.* **красне́ть** 3

красноарме́ец *м* кызылармеец, кызылармияче

красноарме́йск||ий, -ая, -ое кызылармеец[лар] ...ы; **~ая пе́сня** кызылармиячеләр җыры

краснобáй *м пренебр.* тел бистәсе, тасма тел

красногвардéец *м ист.* кызылгвардеец, кызылгвардияче

красногвардéйский, -ая, -ое *ист.* кызылгвардия ...ы; **~ отря́д** кызылгвардия отряды

краснодере́вец, краснодере́вщик *м* агач остасы (*кыйммәтле мебель ясаучы столяр*)

краснозвёздный, -ая, -ое (*обычно о самолётах*) кызыл йолдызлы

краснознáменный, -ая, -ое Кызыл Байрак орденлы

красноко́ж||ий, -ая, -ее **1.** кызыл тәнле **2.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* кызыл тәнлеләр (*Төньяк һәм Көньяк Америкада яшәүче җирле халык, индеецлар*)

краснолéсье *с* нарат урманы, ылыслы агачлар урманы

краснопёрка *ж* кызылканат (*балык*)

краснопёрый, -ая, -ое (*о птицах*) кызыл каурыйлы; (*о рыбах*) кызыл канатлы

красноречи́в||ый, -ая, -ое **1.** оста телле, матур сөйләүчән; **~ый ора́тор** оста телле оратор **2.** *перен.* мәгънәле, [хисләрне] аңлатып бирүче; **~ый взгляд** мәгънәле караш **3.** *перен.* ачык, ап-ачык; **~ые фáкты** ачык фактлар; **~ый жест** ап-ачык ишарә

красноре́чие *с* сүзгә осталык, оста теллелек

краснотá *ж* кызыллык; тәндәге кызыл тимгел

краснофло́тец *м* кызылфлотчы

краснофло́тский, -ая, -ое **1.** кызылфлотчы ...ы **2.** (*относящийся к Красному Флоту*) Кызыл флот ...ы

краснощёкий, -ая, -ое алсу яңаклы, алсу битле

красну́ха *ж мед.* кызылча

крáсн||ый, -ая, -ое **1.** кызыл; **~ая крáска** кызыл буяу **2.** *фольк.* матур, гүзәл, сылу, чибәр; **~ая дéвица** гүзәл кыз **3.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* кызыллар; **гóрод зáнят ~ыми** шәһәр кызыллар кулында ◆ **Крáсная Áрмия** Кызыл Армия; **~ая ры́ба** кызыл балык; **~ая строкá** кы́зыл юл; **~ая цена́** тияр бәясе, иң кыйбаты, иң кыйбат дигәндә; **~ого петухá пусти́ть** кызыл әтәч җибәрү; **~ое дéрево** кызыл агач (*кыйммәтле агач*); **~ой ни́тью проходи́ть** кызыл җеп булып сузылып бару (*берәр фикернең, идеянең ачык булып аерылып торуы*); **~ый уголóк** кызыл почмак; **для ~ого словцá** сөйләмне бизәү өчен, сүз җилеме итеп [өчен]

красова́ться *несов.* **1.** (*выделяться красотой*) матур булып күренеп тору, матурланып күренү **2.** (*любоваться собой*) үзен күрсәтергә тырышу, кылану, масаю

крас||отá *ж* **1.** матурлык, чибәрлек, гүзәллек, ямьлелек; **~отá приро́ды** табигатьнең матурлыгы; **отлича́ться ~отóй** чибәрлеге белән аерылып тору **2.** *мн.* **~о́ты** матур урыннар; **~о́ты приро́ды** табигатьнең матур урыннары **3.** *прост.* (*о чём-л. приятном*) менә дигән, шәп; **~отá!** шәп!

краса́тка *ж разг.* матуркай, чибәркәй, чибәр кыз

крáсочн||ый, -ая, -ое **1.** буяу ...ы; **~ая промы́шленность** буяу промышленносте **2.** төсле буялар белән эшләнгән; **~ый портрéт** төсле буялар белән эшләнгән портрет; **~ые табли́цы** төсле буялар белән эшләнгән таблицалар **3.** *перен.* колоритлы, тасвирлы, ачык, характерлы; **~ый стиль** тасвирлы стиль

красть *несов. кого-что* урлау

крáсться *несов.* (*пробираться тайком*) посып бару, яшеренеп бару; (*подкрадываться*) посып (яшеренеп) якынаю

крáсящ||ий, -ая, -ее буяу ...ы; буйый торган; **~ие веществá** буяу матдәләре

крат: вó сто ~ йөз тапкыр (мәртәбә, кабат)

крáтер *м* кратер (*янар тау авызы*)

крáтк||ий, -ая, -ое **1.** кыска, аз гына ...; **~ая встрéча** кыска очрашу; **~ий разговóр** аз гына сөйләшү **2.** кыскартылган, кыскача; **~ий курс хи́мии** химиянең кыскача курсы **3.** *лингв.* кыска; **~ие глáсные** кыска сузыклар

кратковре́менный, -ая, -ое кыска вакытлы

краткосро́чный, -ая, -ое кыска сроклы, кыска вакытлы

крáткость *ж* кыскалык

крáтный, -ая, -ое *мат.* кабатлы, калдыксыз бүленә торган

кратча́йший, -ая, -ее иң кыска; иң якын; **~ путь** иң кыска юл

крах *м* **1.** (*разорение*) бөлү **2.** *перен.* тулы уңышсызлык, һәлакәт, бетү; **потерпéть ~** тулы уңышсызлыкка очрау

крахмáл *м* крахмал

крахмáлистый, -ая, -ое күп крахмаллы, крахмалга бай

крахмáлить *несов. что* крахмаллау, крахмаллы суга ману

крахмáльный, -ая, -ое **1.** крахмал ...ы; **~ завóд** крахмал заводы; **~ клéйстер** крахмал клейстеры **2.** крахмаллы, крахмалланган; **~ воротни́к** крахмалланган яка

крáшеный, -ая, -ое буялган, буяуга манылган; **~ пол** буялган идән

краю́ха, краю́шка *ж прост.* кибән башы

креату́ра *ж книжн.* креатура (*сүзе үтүчән берәр кешенең яки сүзе үтүчән иҗтимагый даирәләрнең ярдәме белән зур урынга куелган кеше*)

кре́дит *м бухг.* кре́дит

креди́т *м* **1.** креди́т, бурычка бирү, бурыч; **долгосро́чный ~** озак сроклы кредит; **купи́ть в ~** кредиткa сатып алу **2.** *мн.* **~ы** (*ассигнования*) кредит, акча (*берәр ихтыяҗга җибәрелгән акча*)

креди́тный, -ая, -ое кредит ...ы

кредитова́ть *сов., несов. кого-что* кредит бирү, акча бирү (*берәр нәрсә төзү өчен*)

кредитова́ться 1. *сов., несов.* бурычка алу, кредит алу **2.** *несов. страд. от* **кредитова́ть**

кредито́р *м* кредитор, бурычка бирүче

кредитоспосо́бный, -ая, -ое бурыч түләүгә сәләтле

кре́до *с нескл. книжн.* кредо, фикерләр, карашлар; **изложи́ть своё ~** үзеңнең фикерләреңне әйтеп бирү

кре́йсер *м* крейсер

кре́йсерск||ий, -ая, -ое крейсер ...ы; **~ая эска́дра** крейсер эскадрасы

крейси́ровать *несов.* **1.** йөрү, йөреп тору, рейслар ясау **2.** *воен.* хәрби күзәтү алып бару (*берәр диңгездә, елгада*)

кре́кер *м* крекер (*әче камырдан әзерләнгән коры печенье*)

кре́кинг *м тех.* крекинг (**1.** *махсус җайланмаларда нефть, мазут һ.б.ш. эшкәртү* **2.** *шул максат өчен эшләнгән корылма, җайланма*)

крем *м* крем (**1.** *татлы ашамлык* **2.** *косметик май* **3.** *аяк киемнәре чистарту мае*)

крематóрий *м* крематорий (*мәет яндыру бинасы*)

кремацио́нн||ый, -ая, -ое мәет яндыру ...ы; **~ая печь** мәет яндыру миче

крема́ция *ж* мәетләрне яндыру (*махсус мичләрдә*)

кремéнь *м* **1.** чакма ташы **2.** *разг.* кремень, корыч кеше

кремúровать *сов., несов. кого-что* кремацияләү, мәетне яндыру

кремлёвский, -ая, -ое кремль ...ы; **Кремлёвские курáнты** Кремль курантлары

кремль *м* кремль (*борынгы шәһәрләрдә крепость, ныгытма*); **Москóвский Кремль** Мәскәү Кремле

кремнёв||ый, -ая, -ое чакматаш ...ы, чакмалы, чакма ташлы; **~ая глы́ба** зур чакматаш кисәге; **~ое ружьё** чакматашлы мылтык

кремнезём *м мин.* кремнезём (*кремнийның кислород белән кушылмасы*)

крéмниев||ый, -ая, -ое кремнийлы; **~ые сóли** кремнийлы тозлар

крéмний *м хим.* кремний

кремни́ст||ый I, -ая, -ое (*кремнистый*) ташлы, комташлы; **~ая дорóга** ташлы юл

кремни́ст||ый II, -ая, -ое **1.** кремнийлы; **~ые соедине́ния** кремнийлы кушылмалар; **~ая сталь** кремнийлы корыч **2.** кремнезёмлы; **~ые порóды** кремнезёмлы токымнар; **~ая пóчва** кремнезёмлы туфрак

крéмов||ый, -ая, -ое **1.** кремлы; **~ое пирóжное** кремлы пирожный **2.** (*о цвете*) аксыл сары

крем-сóда *ж* крем-сода (*татлы эчемлек*)

крен *м* кырынаю, авышу, янтаю (*судно, самолётлар*)

крéндел||ь *м* крендель ♦ **~я́ выпи́сывать** алпан-тилпән бару

крени́||ть *несов. что* кырынайту, кыйшайту, янтайту; **вéтер ~т лóдку** җил көймәне кырынайта

крени́ться *несов.* кырынаю, кыйшаю, янтаю (*судно, самолёт турында*)

креозóт *м* креозот (*агач яки ташкүмерне корылай куганда табыла торган майсыман сыеклык*)

креóлы *мн.* креоллар (**1.** *Латин Америкасында: элек Европадан күчеп килгән кешеләр нәселеннән булган ак тәнле кешеләр* **2.** *ата-анасы ике төрле расадан булган кешеләр*)

креп *м* креп (**1.** *кытыршы өслекле ефәк яки йон тукыма* **2.** *үтә күренмәле кара тукыма; шуннан эшләнгән матәм бәйләвеч*)

крепдеши́н *м* крепдешин

крепдеши́нов||ый, -ая, -ое крепдешин; **~ое пла́тье** крепдешин күлмәк

крепёж *м собир.* ныгыткыч, беркеткеч; терәк (*баганалар, болтлар һ.б.ш.*)

крепёжный, -ая, -ое ныгыту ...ы; **~ лес** (*шахталарны*) ныгыту агачлары

крепи́тельн||ый, -ая, -ое *уст.* эчне ныгыту ...ы; эч китүне туктату ...ы; **~ые лека́рства** эчне ныгыту дарулары

крепи́ть *несов. что* **1.** *прям., перен.* ныгыту; **~ на́бережную** яр буйларын ныгыту; **~ оборóну** оборонаны ныгыту **2.** ныклап бәйләп кую; **~ кана́т** арканны ныклап бәйләп кую **3.** (*вызывать запор*) эчне катыру

крепи́ться *несов.* **1.** (*проявлять выдержку*) тыелып тору, үзеңне-үзең тыеп тору, чыдамлык күрсәтү **2.** *страд. от* **крепи́ть** 1, 2

крéпк||ий, -ая, -ое **1.** (*прочный, твёрдый*) каты, нык, саглам **2.** (*целый, неизношенный*) таза, нык (*аяк киеме, өс киеме турында*) **3.** (*здоровый, физически сильный*) таза, көчле, нык **4.** *перен.* (*стойкий, непоколебимый*) чыдам, түземле, нык; **~ий челове́к** нык кеше **5.** каты, көчле; **~ий моро́з** каты салкын; **~ий ве́тер** көчле жил **6.** куе, каты, куәтле; **~ий раство́р** *хим.* куе эретмә; **~ий чай** каты чәй; **~ое вино́** куәтле шәраб ♦ **~ая дисципли́на** каты (нык) тәртип; **~ие напи́тки** спиртлы эчемлекләр, исерткеч эчемлекләр; **~ий на́ ухо** колакка каты (сак); **~ий сон** каты йокы; **~ое словцо́** сүгенү сүзе

крепкоголо́вый, крепколо́бый, -ая, -ое *разг.* аңгыра, миңгерәү, тинтәк

крепле́ни||е *с* **1.** *см.* **крепи́ть** 1, 2; **~е свай** свайларны ныгыту; **~е парусо́в** парусларны беркетеп кую **2.** *горн.* ныгытма (*шахталарда җимерелмәс өчен куела торган терәкләр*) **3.** беркеткеч; **лы́жные ~я** чаңгы беркеткечләре

кре́пнуть *несов.* ныгу, тазару, көчәю

кре́пов||ый, -ая, -ое креп ...; крептан эшләнгән; **~ая повя́зка** креп бәйләвеч

крепостни́к *м ист.* крепостник, крепостное правоны яклаучы

крепостни́ческ||ий, -ая, -ое *ист.* крепостник[лар] ...ы; крепостниклык ...ы; **~ое хозя́йство** крепостник хуҗалыгы

крепостн||о́й I, -а́я, -о́е *ист.* **1.** крепостной; **~о́й крестья́нин** крепостной крестьян **2.** *в знач. сущ.* **~о́й** *м*, **~а́я** *ж* крепостной, крепостной крестьян ♦ **~о́е пра́во** крепостной хокук

крепостн||о́й II, -а́я, -о́е крепость ...ы; **~а́я стена́** крепость дивары

кре́пость I *ж* **1.** катылык, ныклык; **~ мета́лла** металлның катылыгы; **~ верёвки** бауның ныклыгы **2.** тазалык, көчлелек; **~ организ́ма** организмның тазалыгы **3.** *перен.* чыдамлылык, түземлелек, ныклык; **~ хара́ктера** характерның ныклыгы **4.** куелык, катылык, куәтлелек; **~ табака́** тәмәкенең катылыгы

кре́пость II *ж* крепость, ныгытма ♦ **лета́ющая ~** очма крепость (*ерак арага очучы дурт моторлы авыр бомбардировщик турында*)

крепча́||ть *несов.* көчәю, куәтләнү, ныгаю; **моро́з ~ет** салкын көчәя

крепы́ш *м разг.* таза, нык (*гадәттә балалар турында*)

крепь *ж см.* **крепле́ние** 2

кре́сло *с* кресло, кәнәфи

кре́сло-крова́ть *с* кресло-кровать

крест *м* **1.** тәре, тәре сурәте, хач; **~ на це́ркви** чиркәү гөмбәзендәге тәре **2.** *перен.* авыр язмыш, интегү; **нести́ свой ~** авыр язмыш кичерү ♦ **~ á нет** *на ком, уст.* мәрхәмәтсез, кансыз кеше турында; **~ -на́крест** аркылы-торкылы; **Óбщество Кра́сного Креста́** Кызыл Хач җәмгыяте; **поста́вить ~** *на ком-чём* өмет өзү, булмаганга санау, беткәнгә исәпләү

крестец *м анат.* оча башы сөяге, койрык төбе сөяге, әвернә сөяк

крести́ны *только мн.* чукындыру йоласы

крести́ть *кого-что* **1.** *сов., несов.* (*совершать обряд крещения*) чукындыру **2.** *сов., несов.* (*обращать в христианство*) чукындыру **3.** *несов.* (*делать знак креста над кем-чем-л.*) чукындыру, төртендерү

крести́ться 1. *сов., несов.* (*подвергаться обряду крещения*) чукындырылу **2.** *несов.* (*креститься себя*) чукыну, төртенү

кре́стник *м* крестник (*чукындырылган ир бала — исем атасына һәм исем анасына карата*)

кре́стница *ж* крестница (*чукындырылган кыз бала — исем атасына һәм исем анасына мөнәсәбәттә*)

кре́стный, -ая, -ое: **~ ход** *церк.* байрак, тәре һәм иконалар күтәреп, тантаналы бару

крёстн||ый, -ая, -ое: **~ый оте́ц** исем атасы; **~ая мать** исем анасы; **~ый сын** *см.* **кре́стник; ~ая дочь** *см.* **кре́стница**

крестови́к *м зоол.* агулы үрмәкүч

крестови́на *ж* **1.** әвернә (*бер-беренә аркылы куеп ныгытылган ике агач*) **2.** *ж.-д.* крестовина (*рельслы юлларда бер юлдан икенче юлга күчерү җайланмасы*)

крестóв||ый: ~ые похóды *ист.* тәре походлары

крестья́нин *м* крестьян

крестья́нка *ж* крестьян хатын (кыз)

крестья́нск||ий, -ая, -ое крестьян [-нар] ...ы; **~ое хозя́йство** крестьян хуҗалыгы

крестья́нство *с* **1.** *собир.* крестьяннар; **колхóзное ~** колхозчы крестьяннар **2.** игенчелек, игенче хезмәте; **занима́ться ~м** игенчелек белән шөгыльләнү

крестья́нствовать *несов.* иген игү, игенчелек белән шөгыльләнү

кретúн *м* **1.** *мед.* кретин **2.** *бран.* аңгыра, тинтәк

кретúнка *ж см.* **кретúн**

кретини́зм *м мед.* кретинлык

кретóн *м* кретон (*тукыма*)

крéчет *м* шоңкар (*лачынның бер төре*)

креще́ние *с* **1.** (*обряд*) чукындыру, чукыну (*христиан динендәге кешеләрнең йоласы*) **2.** (*праздник*) крещение (*христиан динен тотучыларның зур бәйрәме*) ♦ **боевóе ~** 1) беренче башлап сугышта катнашу; 2) берәр эштә беренче җитди сынау

крив||а́я *ж* кәкре, кәкре сызык; **провести́ ~у́ю** кәкре сызык үткәрү; **~а́я сниже́ния цен** бәяләр төшү кәкресе ♦ **куда́ ~а́я вы́везет (вы́несет)** көтелмәгән берәр җай ярдәм итәр

кри́вда *ж уст.* кыңгыр эш, ялган хәбәр

кривизна́ *ж* **1.** (*искривлённость*) кәкрелек, чалышлык **2.** (*кривое место*) кәкрәйгән урын, чалышайган урын

крити́ть *несов. что* кәкрәйтү, кыегайту, чалышайту, кыңгырайту ♦ **~ душо́й** алдашу, ялганлау, ялган сөйләү

криви́ться *несов.* 1. (*становиться изогнутым*) кәкрәю, кыегаю, чалышаю, кыйшаю, кыңгыраю 2. *разг.* (*в знак неудовольствия*) чырай сыту, йөз чыту, чырай бозу

кривля́ка *м, ж разг.* кыланчык [кеше]

кривля́ться *несов. разг.* боргалану-сыргалану, кылану, кыланчыклану, чытлыклану

криво- *кушма сүзләрдә «кәкре», «чалыш», «кыек» мәгънәсендәге беренче кисәк, мәс.* **кривоно́гий** кәкре аяклы

кривобо́кий, -ая, -ое кәкре гәүдәле

крив||о́й, -а́я, -о́е 1. (*изогнутый*) кәкре, чалыш, кыңгыр, кыйшык 2. *разг.* (*одноглазый*) сукыр (*бер күзе*), сыңар күзле ♦ **~а́я ули́ца (усме́шка)** мәсхәрәле елмаеп кую; **~о́е зе́ркало** кыеш көзге

криволине́йный, -ая, -ое кәкре сызыклы

кривоно́гий, -ая, -ое кәкре аяклы

кривоно́сый, -ая, -ое кәкре борынлы

криворо́тый, -ая, -ое чалыш авызлы

кривото́лки *только мн.* имеш-мимешләр, ялган хәбәрләр, гайбәт сүзләр

кривоше́ий, -яя, -ее кәкре муенлы

кривши́п *м тех.* кривошип

кри́зис *м в разн. знач.* кризис; **экономи́ческий ~** икътисадый кризис; **фина́нсовый ~** финанс кризисы; **~ боле́зни** авыру кризисы; **духо́вный ~** рухи кризис; **полити́ческий ~** сәяси кризис; **правительственный (министе́рский) ~** хөкүмәт (министрлык) кризисы

крик *м* тавыш, каты тавыш, кычкыру тавышы, аваз ♦ **~ души́** җан әрнүе (*сыкравы*); **после́дний ~ мо́ды** иң соңгы мода

крикли́вость *ж* 1. кычкыручан булу, чәрелдәклек; елаклык 2. ачылык, катылык, кискенлек, үткенлек 3. *перен.* артык кычкырып тору, күзгә бик ныклы бәрелү

крикли́вый, -ая, -ое 1. күп кычкыручан, чәрелдәк, елак; **~ ребёнок** елак бала 2. (*резкий*) ачы, каты, кискен, үткен (*тавыш, авазлар турында*); **~ го́лос** ачы тавыш 3. *перен.* кычкырып торган, күзгә ташланып торган; **~ наря́д** кычкырып торган кием

кри́кнуть *сов. однокр.* 1. кычкырып җибәрү 2. (*позвать громко*) кычкырып чакыру, кычкыру 3. *на кого-что* җикерү, җикереп кую

крику́н *м разг.* 1. кычкыручан кеше; ачы тавышлы кеше 2. *перен.* бушбугаз, лыгырдык

крими́нал *м разг.* криминал, җинаятьле эш

криминали́стика *ж* криминалистика (*хокук фәненең җинаятьларне тикшерү методларын өйрәнә торган бүлеге*)

кримина́льный, -ая, -ое җинаять ...ы; җинаятьчел; **~ слу́чай** җинаять вакыйгасы

кримпле́н *м* кримплен

кри́нка *ж* тар муенлы чүлмәк

криптогра́мма *ж* криптограмма, яшерен язу

криптографи́ческ||ий, -ая, -ое криптография ...ы, криптографик; **~ое письмо́** криптографик язу

криптогра́фия *ж* криптография (*шартлы язма, яшерен язу*)

криптон́ *м хим.* криптон (*газ*)

крист́алл *м* кристалл

кристаллиза́ция *ж* кристаллашу; **~ соле́й** тозның кристаллашуы

кристаллизова́ть *сов., несов. что* кристаллаштыру, кристалларга әверелдерү

кристаллизова́||ться *сов., несов.* 1. кристалларга әверелү, кристаллашу 2. *перен. книжн.* кристаллашу; формалашу; **~лись но́вые фо́рмы бы́та** көнкүрешнең яңа формалары кристаллашты

кристалли́ческ||ий, -ая, -ое кристалл ...ы; кристаллы, кристаллык; **~ое состоя́ние вещества́** матдәнең кристалл хәле; **~ие поро́ды** кристаллы токымнар; **~ая структу́ра мета́ллов** металларның кристаллык төзелеше

кристаллогра́фия *ж* кристаллография (*кристаллар турында фән*)

кристаллографи́ческ||ий, -ая, -ое кристаллографик; **~ая систе́ма** кристаллографик система

крист́альн||ый, -ая, -ое 1. *уст.* кристалл ...ы; **~ая фо́рма** кристалл формасы 2. *перен.* үтә күренмәле; **~ая вода́** үтә күренмәле су 3. *перен.* саф, пакь, саф күңелле; **~ая душа́** саф күңелле кеше

крите́рий *м* критерий (*берәр нәрсәгә бәя бирү өчен, төркемләү өчен нигез булып тора торган билге*)

кри́тик *м* тәнкыйтьче, тәнкыйть итүче

кри́тик||а *ж* тәнкыйть, кимчелекләрне күрсәтү; **справедли́вая ~а** гадел тәнкыйть; **исто́рия ру́сской ~и** рус тәнкыйте тарихы; **не выде́рживает [никако́й] ~и** *или* **ни́же вся́кой ~и** бернинди тәнкыйтьне күтәрми *яки* тәнкыйтьтән түбән

критика́н *м пренебр.* урынсыз тәнкыйтьләүче

критика́нство *с пренебр.* урынсыз тәнкыйтьләүче (тәнкыйтьләү)

критикова́ть *несов. кого-что* тәнкыйть, тәнкыйть итү

крити́ческий I, -ая, -ое 1. тәнкыйть ...ы; **~ отде́л журна́ла** журналның тәнкыйть бүлеге 2. тәнкыйтьчел, тәнкыйтькә сәләтле; **~ ум** тәнкыйтьчел акыл

крити́ческ||ий II, -ая, -ое 1. кискен, критик; **~ий моме́нт** кискен момент 2. бик кыен, куркыныч; **~ое положе́ние** куркыныч хәл ♦ **~ое состоя́ние вещества́** *физ.* матдәнең критик халәте; **~ая температу́ра** *физ.* критик температура

крити́чный, -ая, -ое *см.* **крити́ческий** I 2

крича́ть *несов.* 1. кычкыру, акыру, аваз бирү (салу); **~ от бо́ли** авыртудан кычкыру; **~ «ура́»** «ура» кычкыру 2. (*говорить громко*) кычкырып сөйләү, кычкыру 3. (*громко звать кого-л.*) кычкырып чакыру 4. *на кого-что* (*бранить*) акырыну, кычкырыну, җикеренү 5. *о ком-чём, разг.* (*много говорить*) сөйләү, шаулау; **об э́той кни́ге давно́ крича́т** бу китап турында күптән шаулыйлар

крича́щий, -ая, -ое 1. *прич. от* **крича́ть;** 2. артык ачык, күзгә бәрелеп тора торган; **~ наря́д** артык ачык кием

кров *м высок.* өй, тору урыны, сыеныр урын

крова́в||ый, -ая, -ое канлы, канга буялган; **~ое пятно́** канлы тап 2. канлы; **~ая би́тва** канлы сугыш 3. (*о цвете*) кан ...ы ♦ **Крова́вое воскресе́нье** *ист.* Канлы якшәмбе

крова́ть *ж* карават

кровезамени́тель *м мед.* каналмаштыргыч (*канны алыштыра торган ясалма состав, препарат*)

кро́вельн||ый, -ая, -ое түбә ...ы; түбә ябу ...ы; **~ое желе́зо** түбә калае; **~ые рабо́ты** түбә ябу эшләре

кро́вельщик *м* түбә ябучы

кровено́сн||ый, -ая, -ое кан ...ы; кан йөреше ...ы; **~ые сосу́ды** кан тамырлары; **~ая систе́ма** кан йөреше системасы

кровя́нка *ж разг.* кан тамчысы

кро́вля *ж* түбә, өй түбәсе, каралты түбәсе

кро́вн||ый, -ая, -ое 1. кан ...ы, кан [кардәш]...; **~ое родство́** кан кардәшлеге 2. *перен.* кардәшлек ...ы; туганлык ...ы, бик якын; **~ая связь** кардәшлек бәйләнеше 3. *перен.* мөһим, иң кирәкле; **~ый интере́с** иң кирәкле интерес 4. нәселле юртак ♦ **~ая оби́да** жаны-тәне белән рәнҗү; **~ые де́ньги** үз көче белән тапкан акча, хәләл акча; **~ый враг** кан дошманы

кровожа́дный, -ая, -ое канечкеч, канга сусаган, аяусыз

кровоизлия́ние *с* кан йөгерү, кан саву, кан бәрү, кан төшү; **~ в мозг** мигә кан йөгерү

кровообраще́ние *с* кан йөреше, кан әйләнеше

кровоостана́вливающий, -ая, -ее кан туктата торган

кровопи́йца *м, ж* аяусыз (канечкеч, рәхимсез) кеше

кровоподте́к *м* кан укмашу, кан төйнәлү; кара яну (*бәрелү-сугылудан*)

кровополи́тн||ый, -ая, -ое канкойгыч; **~ое сраже́ние** канкойгыч сугыш

кровопуска́ние *с* кан алдыру (*авыруның хәлен җиңеләйтү өчен*)

кровосо́сн||ый, -ая, -ое кан суыра торган, кан суыргыч; **~ая ба́нка** кан суыргыч банка

кровоте́чение *с* кан агу, кан китү

кровоточи́в||ый, -ая, -ое канап торган, кан агып (саркып) торган (*мәс. җәрәхәт*); **~ая ра́на** канап торган яра

кровоточи́ть *несов.* канау, канап (кан агып) тору

кровоха́рканье *с* кан төкерү (какыру), кан косу

кров||ь *ж* 1. кан; **истека́ть ~ью** кан күп агу, кансырау; **пуска́ть ~ь** кан җибәрү 2. нәсел, токым; **каза́х по ~и**

казакъ нәселеннән; **конь хоро́ших ~ е́й** яхшы токымлы ат ◆ **~и жа́ждать** үч алырга ашкыну; **~ь за ~ь** канга кан, үлемгә үлем; **~ь с молоко́м** чиртсәң, каны чыгар; **~ь уда́рила (бро́силась) в го́лову** бик нык ярсыдым; ачуымнан шартлый яздым; **лить (проли́вать) ~ь** 1) (*свою*) кан кою, корбан булу; 2) (*чью-л.*) кеше канын кою, үтерү; **~ь леденеет (сты́нет) в жи́лах** җан өши; кан ката, кан калтырау

кровяни́ст||ый, -ая, -ое канлы; **~ое мя́со** канлы ит

кровян||о́й, -а́я, -о́е **1.** кан ...ы; **~о́е давле́ние** кан басымы **2.** кан ...ы, канлы, каннан ясалган; **~о́е удобре́ние** кан ашламасы

крои́льный, -ая, -ое кием кисү ...ы; **~ стол** кием кисү өстәле

крои́ть *несов. что* кисү (*өс киеме, аяк киеме тегү өчен материяне, кунне кису*)

кро́йк||а *ж см.* **кроить, ку́рсы ~и и шитья́** кисү һәм тегү курсы

крокет *м спорт.* крокет (**1.** *уен* **2.** *шул уен өчен кирәкле әсбаплар җыелмасы* **3.** *шул уен мәйданчыгы*)

крокет||ный, -ая, -ое крокет ...ы; **~ые шары́** крокет шарлары

крокирова́ть *сов., несов. что* крокирлау (*крокет уйнаганда үз шарың белән башка кеше шарына бәрдерү*)

крокоди́л *м* крокодил, тимсах

крокоди́лов: ~ы слёзы юри елау, елаган булып ышандырырга тырышу, ялган яшь кою

крокоди́лов||ый, -ая, -ое крокодил ...ы; **~ая ко́жа** крокодил тиресе; **~ый чемода́н** крокодил тиресеннән эшләнгән чемодан

кро́лик *м* **1.** йорт куяны **2.** (*мех*) йорт куяны тиресе

кроликово́д *м* йорт куяннары үрчетүче

кроликово́дство *с* йорт куяннары үрчетүчелек

кроликово́дческ||ий, -ая, -ое йорт куяннары үрчетү ...ы; **~ое хозя́йство** йорт куяннары үрчетү хуҗалыгы

кро́ликов||ый, -ая, -ое *см.* **кро́личий; ~ая ша́пка** куян бүрек

кро́личь||ий, -ья, -ье куян ..., йорт куяны ...ы; **~ье мя́со** йорт куяны ите

крольча́тник *м* йорт куяннары үрчетү фермасы

крольчи́ха *ж* әнкә йорт куяны, ана куян

кро́ме *предлог с род. п.* **1.** (*за исключением*) ...дан башка, ...дан бүтән; **~ него́ я никого́ не ви́дел** аннан башка беркемне дә күрмәдем **2.** (*в добавление*) ...дан тыш, ...ның өстенә; **~ окла́да я получи́л пре́мию** хезмәт хакыннан тыш премия акчасы алдым ◆ **~ шу́ток** *в знач. вводн. сл.* һич шаярусыз, чыннан да; **~ шу́ток, я хочу́ уе́хать** чыннан да, мин китәргә уйлыйм; **~ того́** *в знач. вводн. сл.* моннан тыш, шуның өстенә

кроме́шн||ый, -ая, -ое: **ад ~ый** мәхшәр, түзеп тора алмаслык хәл; **тьма ~ая** дөм караңгы[лык]

кро́мка *ж* кырый, чит; **~ льда** боз чите

кромса́ть *несов. что, разг.* ботарлау, кискәләү, тураклау; кисәкләп (ваклап) бозу, вак кисәкләргә телгәләп бозу

крон *м* крон (*хромлы минераль буяу*)

кро́на I *ж* ябалдаш (*агач башында*)

кро́на II *ж* крона (*кайбер Европа илләрендә акча берәмлеге*)

кронци́ркуль *м* кронциркуль (*бик кечкенә тугәрәкләр сызу өчен кулланыла торган циркуль*)

кронште́йн *м* кронштейн (*берәр нәрсәне, мәс. балконны терәтү өчен стенага беркетелгән терәк*)

кропа́ть *несов. что, ирон.* [белербелмәс] эшләп (*язып һ.б.ш.*) маташу: **~ письмо́** хат язып маташу

кропи́ть *несов.* **1.** *кого-что* (*обрызгивать*) бөркеп чылату, сибеп чылату **2.** (*о дожде*) сибәләп яву, пыскаклап яву; сибәләп тору

кропотли́вый, -ая, -ое **1.** (*усердный*) тырыш, төпченүчән, җентекләүчән, басылып эшләүчән **2.** (*о деле, работе*) күп көч таләп итә торган, тырышлык сорый торган, басылып эшләүне таләп итә торган

кросс *м спорт.* кросс

крот *м* **1.** сукыр тычкан **2.** (*мех*) сукыр тычкан мехы

кро́ткий, -ая, -ое юаш, басынкы, сабыр, түземле

кротово́й||ый, -ая, -ое **1.** сукыр тычкан ...ы; **~ая шку́ра** сукыр тычкан тиресе **2.** (*из меха крота*) сукыр тычкан тиресеннән тегелгән

кро́тость *ж* юашлык, басынкылык, сабырлык, түземлелек

кро́ха *м, ж разг.* бәби, бәләкәч, сабый

кроха́ *ж* валчык, бөртек

крохобо́р *м* вакчыл кеше

крохобо́рничать *несов. см.* **крохобо́рствовать**

крохобо́рство *с* вакчыллык

крохобо́рствовать *несов.* вакчыллану

кро́хотный, -ая, -ое *разг.* бик кечкенә, бик вак, валчыктай гына, энә очы кадәрле генә

кро́шево *с прост.* турама (*төрле азыклардан турап әзерләнгән ашамлык*)

кро́шечный, -ая, -ое *разг.* бик кечкенә, кечкенә генә, валчыктай гына, энә очы кадәр генә

кроши́ть *несов.* **1.** *что* (*измельчить*) турау, тураклау, ваклау **2.** *чем и без доп.* чүпләү; **не кроши́ на пол** идәнне чүпләмә; валчыкларыңны идәнгә койма **3.** *перен. кого-что* тар-мар итү, кыру-себерү, тураклау; **~ врага́** дошманны тар-мар итү

кроши́ться *несов.* **1.** кителү, ваклану; **зу́бы кроша́тся** тешләр кителә **2.** *страд. от* **кроши́ть** 1

кро́шк||а I 1. *ж* валчык; **~и хле́ба** икмәк валчыклары **2.** *ж собир. спец.* (*о мелко раздробленных веществах*) вак; **мра́морная ~а** мәрмәр вагы **3.** *м, ж разг.* (*малютка*) балакай, бәләкәч ◆ **ни ~и** аз гына да, бер бөртек тә, [бер] тамчы да; **ни ~и не испуга́лся** тамчы да курыкмадым; **нет ни ~и** бөртек тә юк

кро́шк||а II *ж* **1.** *см.* **кроши́ть** 1; **~а и су́шка цико́рия** һиндыбаны тураклау һәм киптерү **2.** туралган сорт; **таба́к ме́лкой ~и** вак туралган тәмәке (*тәмәкенең вак туралган сорты*)

круг *м* **1.** (*часть плоскости*) түгәрәк; **начерти́ть ~** түгәрәк сызу; **пло́щадь ~а** *мат.* түгәрәкнең мәйданы; **стать в ~** түгәрәккә басу **2.** түгәрәк, бөжра; **~ сы́ра** бер түгәрәк сыр **3.** (*сфера, область*) өлкә, вазифа; **~ де́ятельности** эшчәнлек өлкәсе; **~ обя́занностей** хезмәт вазифалары **4.** (*перечень чего-л.*) тезмә, төркем; **~ тем** темалар тезмәсе; **~ вопро́сов** сораулар төркеме **5.** ара, эч; **в ~у́ друзей** дуслар арасында; **в семе́йном ~у́** гаилә эчендә **6.** *мн.* **~и́** даирә **в литерату́рных ~а́х** әдәби даирәләрдә ◆ **на ~** уртача, якынча; **на ~ вы́шло 2000 рубле́й** уртача 2000 сум туры килде

кру́гленьк||ий, -ая, -ое *уменьш. от* **кру́глый; ~ая су́мма** шактый зур сумма (акча)

кругле́ть *несов.* түгәрәкләну, түгәрәкләнә төшү (бару), йомрылану

круглогоди́чн||ый, -ая, -ое, **круглогодов||о́й**, -а́я, -о́е ел буе ..., ел буена сузылган, ел әйләнәсендәге; **~а́я рабо́та экспеди́ции** экспедициянең ел буе эшләве; **~ые наблюде́ния** ел әйләнәсендәге күзәтүләр

круглоли́ций, -ая, -ее түгәрәк йөзле (битле)

круглосу́точный, -ая, -ое тәүлек буена сузыла торган

кру́гл||ый, -ая, -ое **1.** түгәрәк; йомры; **~ый стол** түгәрәк өстәл; **~ая голова́** йомры баш; **~ый ка́мень** йомры таш **2.** тулы; түгәрәк; **~ые ци́фры** тулы цифрлар ◆ **~ый год** ел буе, ел буена, ел тәүлеге; **~ый дура́к** шыр тиле; **~ые су́тки** тәүлек буена; **~ый отли́чник** отличного гына укучы; **~ый сирота́** бөтенләй ятим; **для ~ого счёта** тулы исәп өчен

круговёрть *ж разг. см.* **круговоро́т** 2

кругов||о́й, -а́я, -о́е әйләнүле, әйләнмәле, түгәрәк буенча ...; **~о́е движе́ние** әйләнүле хәрәкәт, түгәрәк буенча хәрәкәт ◆ **~а́я пору́ка** 1) бердәм җаваплылык (*группа, коллектив эше өчен*); 2) берсен берсе яклау, кимчелекләрне яшерү

круговоро́т *м* **1.** өзлексез хәрәкәт, өзлексез (тукталышсыз, даими) әйләнеп тору, әйләнеш; **~ во́ды в приро́де** суның табигатьтә өзлексез әйләнеше **2.** өзлексез үзгәреп тору; **~ собы́тий** вакыйгаларның өзлексез үзгәреп торуы

кругозо́р *м* **1.** күз күреме, горизонт **2.** *перен.* белем, белем дәрәҗәсе; **широ́кий ~** киң белем

кру́гом *нареч.*: **голова́ идёт ~** башым катты, башым әйләнеп бетте

круго́м *нареч.* **1.** түгәрәк ясап, кругом; **поверну́ться ~** кругом әйләнү **2.** әйләнә-тирәдә; **нет ни лесо́в, ни гор** әйләнә-тирәдә урманнар да, таулар да юк **3.** *перен.* бөтенләй, тулысынча,

hәрьяклап; ~ **винова́т** hәр яктан гаепле

кругообора́т *м* әйләнеш; ~ **капита́ла** *фин.* капитал әйләнеше

кругообра́зн||ый, -ая, -ое түгәрәксыман, түгәрәккә охшаган; ~**ое движе́ние** түгәрәксыман хәрәкәт

кругосве́тн||ый, -ая, -ое җир шары тирәли; җир шарын әйләнеп чыгу ...ы; ~**ое путеше́ствие** җир шары тирәли сәяхәт

кружа́ло *с спец.* кружало, мич калыбы

кружева́ *мн.* челтәр

кружевни́ца *ж* челтәр бәйләү остасы, челтәр бәйләүче (*хатын-кыз*)

кружевн||о́й, -а́я, -о́е **1.** челтәр бәйләү ...ы; ~**а́я мастерска́я** челтәр бәйләү остаханәсе **2.** челтәр ...; ~**о́й воротни́к** челтәр яка

кру́жево *с см.* **кружева́**

кружи́||ть *несов.* **1.** *кого-что* әйләндерү, әйләндереп йөртү, бөтерелдерү **2.** әйләну, әйләнеп йөрү; **я́стреб ~и́л над цыпля́тами** карчыга чебешләр турысында әйләнеп оча иде **3.** *разг.* адашып йөрү, юл язып йөрү; ~**и́ть по́ лесу** урманда адашып йөрү ♦ ~**и́ть го́лову** *кому* башын әйләндерү

кружи́т||ься *несов.* **1.** әйләну; ~**ься в ва́льсе** вальс биеп әйләну **2.** бөтерелү, бөтерелеп очу, өерелү; **пыль ~ся столбо́м** тузан өермә булып бөтерелә

кру́жка *ж* кружка

кружко́вец *м разг.* түгәрәк әгъзасы

кружковщи́на *ж неодобр.* түгәрәкчелек, кружковщина (*вак-тояк төркемнәргә бүленеп, коллективтан аерылуга йөз тоту, коллектив интереслары белән исәпләшмәү*)

кру́жн||ый, -ая, -ое: ~**ым путём** 1) әйләнеч юл белән; 2) *перен.* читләтеп, читтән ишетеп; **узна́ть** *что-л.* ~**ым путём** *берәр нәрсәне* читләтеп белү, читтән ишетеп белү

кружо́к *м* **1.** *уменьш. от* **круг** 1, 2; **2.** түгәрәк; **физкульту́рный** ~ физкультура түгәрәге

круи́з *м* круиз, диңгез сәяхәте

круп I *м* (*лошади*) савыр, арт сан, койрык өсте (*атларда*)

круп II *м мед.* круп, тамак шешү (*бугазның лайлалы ярасы ялкынсыну*)

крупа́ *ж* **1.** ярма; **гре́чневая** ~ карабодай ярмасы **2.** *перен.* (*о снеге*) ярма кар

крупени́к *м* эремчекле карабодай боткасы

крупи́нка *ж* бөртек; бөртекчә; ~ **со́ли** тоз бөртеге; ~ **зо́лота** алтын бөртекчәсе

крупи́тчат||ый, -ая, -ое *разг.*: ~**ая мука́** крупчатка

крупи́ц||а *ж* энә очы кадәр генә, бер бөртек, аз гына; **ни ~ы тала́нта** ник энә очы кадәр генә талант булсын

крупне́ть *несов.* эреләну, зураю, эреләнә бару (төшү) (*мәс. терлек, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.ш. турында*)

крупнозерни́ст||ый, -ая, -ое эре бөртекле; ~ **песо́к** эре бөртекле ком

крупнокали́берн||ый, -ая, -ое зур калиберлы; ~ **пулемёт** зур калиберлы пулемёт

крупномасшта́бный, -ая, -ое **1.** эре (зур) масштаблы (*географик, топографик һ.б.ш. карталар, планнар турында*) **2. реша́ть ~ые пробле́мы** зур колачлы мәсьәләләр өстендә эшләү

крупнопане́льный, -ая, -ое эре панельле (*мәс. йортлар турында*)

крупнопло́дный, -ая, -ое эре җимешле (*мәс. милаш турында*)

крупноразме́рный, -ая, -ое зур үлчәүле, зур размерлы (*мәс. төзелеш детальләре турында*)

кру́пн||ый, -ая, -ое **1.** эре; ~**ый песо́к** эре ком; ~**ое предприя́тие** эре предприятие **2.** эре гәүдәле, зур гәүдәле; ~**ый ребёнок** зур гәүдәле бала **3.** зур; ~**ый учёный** зур галим **4.** мөһим, җитди, зур; ~**ая неприя́тность** шактый зур күңелсезлек; ~**ый разгово́р** җитди сөйләшү ♦ ~**ые де́ньги** эре акча; ~**ый рога́тый скот** мөгезле эре терлек; ~**ым пла́ном** эре планда

крупо́зн||ый, -ая, -ое *мед.* шешү ...ы; шешеп ...; ~**ое воспале́ние лёгких** үпкәнең шешеп ялкынсынуы

крупору́шка *ж* яргыч, ярма яргыч

крупча́тка *ж* крупчатка (*ак онның иң яхшы сорты*)

крупча́тый, -ая, -ое таралучан, ярма сыман, ярмалы; ~ **мёд** ярмалы бал

крупье́ *м* крупье (*отыш уеннары уйнала торган йортта банк тотучы һәм уенның барышын күзәтеп торучы*)

крупян||о́й, -а́я, -о́е ярма ...ы; ярмалы; ~**о́е произво́дство** ярма производствосы; ~**о́й суп** ярмалы аш; ~**ые культу́ры** ярма культуралар

крутизна́ *ж* **1.** тикәлек; ~ **подъёма** күтәрелү тикәлеге **2.** (*крутой спуск*) тикә урын

крути́ть *несов.* **1.** *что* әйләндерү; ~ **ру́чку се́ялки** җилгәргечнең тоткасын әйләндерү **2.** *что* чирату, кату; (*усы*) бөтерү **3.** *что* чорнау, төрү; ~ **самокру́тку** тәмәке төрү **4.** *что* туздыру, өеперү күтәрү; **ве́тер кру́тит пыль по доро́ге** җил юлдагы тузанны туздыра **5.** *прост.* боргалану, хәйләләү; **говори́ пра́вду, не крути́** боргаланма, дөресен сөйлә

крути́ться *несов.* **1.** бөтерелү, әйләну; **колесо́ кру́тится** тәгәрмәч әйләнә **2.** *перен. разг.* бөтерелеп йөрү, мәш килү **3.** *страд. от* **крути́ть** 1-3

крут||о́й, -а́я, -о́е **1.** тикә; ~**о́й бе́рег** тикә яр; ~**а́я скала́** тикә кыя **2.** капыл, кинәт, кисәк; ~**о́й поворо́т собы́тий** вакыйгаларның кинәт үзгәрүе **3.** (*суровый, резкий*) кырыс, кискен; ~**о́й хара́ктер** кырыс характер; ~**о́й челове́к** кырыс кеше **4.** (*решительный, жестокий*) каты, кискен; ~**ые ме́ры** каты чаралар **5.** каты; ~**о́е те́сто** каты камыр; ~**а́я ка́ша** бик куе ботка; ~**о́е я́йцо́** каты пешкән йомырка ♦ ~**о́й кипято́к** шау кайнар су

кру́ча *ж* тикә яр, тикә кыя

кручён||ый, -ая, -ое чиратылган, катылган, бөтерелгән; ~**ые ни́тки** чиратылган җеп

кручи́на *ж поэт.* кайгы, сагыш, хәсрәт

кручи́ниться *несов. поэт.* кайгыру, хәсрәтләну, кайгыга бирелү, сагышлану, пошыну

круше́ние *с прям., перен.* һәлакәт, җимерелү, бетү, юкка чыгу; **парохо́д потерпе́л** ~ пароход һәлакәткә дучар булды; ~ **наде́жд** өметләр җилгә очу

круши́на *ж бот.* эт шомырты

круши́||ть *несов. кого-что* **1.** вату, җимерү, кыру-сындыру; **урага́н ~л дере́вья** өермә (урманда) агачларны кыра-сындыра иде **2.** *перен. высок.* тар-мар итү, кыру, җимерү; ~**ть врага́** дошманны тар-мар итү

крыжо́венн||ый, -ая, -ое крыжовник ...ы; ~**ое варе́нье** крыжовник кайнатмасы

крыжо́вник *м* крыжовник (*куагы һәм җимеше*)

крыла́тка *ж уст.* киң пальто (*ирләр пальтосы*)

крыла́т||ый, -ая, -ое **1.** канатлы; ~**ые раке́ты** канатлы ракеталар **2.** *перен.* ирекле; канатлы; ~**ые мечты́** канатлы хыяллар ♦ ~**ые слова́** канатлы сүзләр, тапкыр тәгъбирләр

крыл||о́ *с* **1.** канат; ~**о́ пти́цы** кош канаты; ~**о́ самолёта** самолёт канаты; **су́дно на подво́дных кры́льях** су асты канатлы судно **2.** (*группировка*) канат, өлеш, катлау

кры́лышко *с уменьш. от* **крыло́** 1 ♦ **под** ~**м** *кого, чьим кемнең дә булса* канаты астында

кры́льцо *с* өйалды баскычы, болдыр

кры́нка *ж см.* **кри́нка**

кры́са *ж* күсе, комак

крысёнок *м* күсе баласы

крыси́ный, -ая, -ое күсе ...ы; күселәр ...ы; ~ **хвост** күсе койрыгы

крысоло́в *м* күсе тотучы (*күселәрне бетерү, кыру белән шөгыльләнүче*)

крысоло́вка *ж* **1.** (*ловушка*) күсе тәбесе **2.** (*собака*) күсе эте (*күсе аулый торган эт*)

кры́тый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **крыть**; **2.** түбәсе ябылган, ябулы, каплаулы, ябык; ~ **ры́нок** түбәсе ябылган базар

крыть *несов.* **1.** *что* ябу, каплау; ~ **изно́ву тёсом** өй түбәсен такта белән ябу **2.** *что* тышлау; ~ **шу́бу сукно́м** тунны постау белән тышлау **3.** *что, карт.* ябу, сугу, каплау **4.** *кого-что, прост.* кирәген бирү, тиргәү, сүгү; **кре́пко** ~ бик каты тиргәү ♦ ~ **не́чем** *кому берни дә* әйтеп булмый; дөрес сүзгә җавап юк

кры́ться *несов.* **1.** *в чём* гыйбарәт, гыйбарәт булу; тору; **в чём кро́ется причи́на э́того явле́ния?** бу күренешнең сәбәбе нәрсәдән гыйбарәт? **2.** *страд. от* **крыть** 1-3

кры́ш||а *ж* түбә; **желе́зная** ~ калай түбә ♦ **под одно́й** ~**ей** бер өйдә, бер түбә астында

кры́шка *ж* капкач, каплавыч ♦ ~**!** *кому* бетте, һәлак булды!

крюк *м* ыргак, элгеч ♦ **сде́лать** ~ *или* **дать** ~**у** уратып бару, әйләнеч юлдан бару

крючкова́тый, -ая, -ое кәкре, ыргаксыман; ~ **нос** кәкре борын

крючкотво́рство *с презр.* юри тоткарлык ясау, юри эшне чуалту

крючо́к *м* кечкенә ыргак, эләктергеч; (*дверной*) келә; (*рыболовный*) кармак; (*у одежды*) каптырма

крюшо́н *м* крюшон (*җимештән ясалган шәрабның ром яки коньяк белән катнашмасы*)

кря́ду *нареч. разг.* тоташтан, беррәттән, өзми-куймый

кряж *м* **1.** (*цепь гор*) тәбәнәк, таулар тезмәсе **2.** (*обрубок*) кискә, түмәр

кря́жистый, -ая, -ое **1.** (*о дереве*) нык, юан; **~ дуб** юан имән **2.** (*о человеке*) таза, нык

кря́кать *несов.* **1.** бакылдау (*үрдәк турында*) **2.** *разг.* (*о человеке*) тамак кыру; **~ от удово́льствия** канәгатьлек белдереп тамак кыру

кря́ква *ж* кыр үрдәге

кря́кнуть *сов. однокр.* **1.** бакылдап кую (*үрдәк турында*) **2.** *разг.* (*о человеке*) тамак кырып кую

кряхте́ть *несов. разг.* ахылдау, ухылдау; ыңгырашу

ксёндз *м* ксёндз (*поляклларда католик рухание*)

ксилогра́фия *ж* ксилография (**1.** *агачны чокып рәсемнәр төшерү* **2.** *шундый рәсемнәр*)

ксилофо́н *м* ксилофон (*музыка коралы*)

кста́ти *нареч.* **1.** урынлы, бик урынлы; вакытлы, бик вакытлы; **сказа́ть ~** бик урынлы әйтү **2.** *в знач. вводн. сл.* бер уңайдан, уңае килгәндә, туры килгәндә; **~, зайди́ и за кни́гами** бер уңайдан китаплар алырга да кереп чык **3.** *в знач. вводн. сл.* сүз жаенда, сүз уңаенда; **~, когда́ вы ви́делись с ним в после́дний раз?** сүз уңаенда, сез аның белән соңгы тапкыр кайчан күрештегез?

кто *мест.* **1.** *вопр.* кем, кемнәр; **~ вам сказа́л об э́том?** сезгә бу турыда кем әйтте? **2.** *разд.* берәү, берәүләр; **~ ждал пи́сем, ~ газе́т** берәүләр хат, берәүләр газета көтә иде **3.** *относ.* кем ... шул; **пусть идёт, ~ жела́ет** кем тели, килсен; **~ и́щет, тот ...** кем эзли, шул... **4.** *неопр.* берәр кеше, кем дә булса; **е́сли ~ придёт, скажи́, что я на рабо́те** әгәр берәр кеше килсә, мине эштә диген ♦ **~ в лес, ~ по дрова́** *погов.* ≈ Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә; **~ [его] зна́ет** кем белсен [аны]; **~ бы ни ...** кем генә ...сын

кто́-либо, кто́-нибудь *мест.* кем булса да, кем дә булса, берәрсе

кто́-то *мест.* **1.** кемдер, берәү, бер кеше **2.** *см.* **кто́-либо, кто́-нибудь**

куб I *м* (*сосуд*) куб; **кипяти́льный ~** су кайнату кубы

куб II *м в разн. знач.* куб; **~ дров** бер куб (метр) утын; **два в ~е** *мат.* ике кубта

куба́нка *ж разг.* кубанка (**1.** *мех кырпулы, яссы түбәле бүрек* **2.** *бодайның бер сорты*)

ку́барем *нареч. разг.* мәтәлеп, мәтәлчекләп, мәтәлчек атып; **~ скати́ться** мәтәлчек атып төшеп китү

кубату́ра *ж* кубатура (*өй, бүлмә кебекләрнең кубик күләме*)

ку́бик *м* **1.** шакмак; **игра́ть в ~и** шакмак [уены] уйнау **2.** *разг.* (*мера объёма*) кубик; **два ~а кро́ви** ике кубик кан

куби́нец *м* кубалы, Кубада яшәүче

куби́нка *ж* кубалы хатын (кыз)

куби́нский, -ая, -ое Куба ...ы; **~ флаг** Куба флагы

куби́нцы *мн.* кубалылар, Куба халкы

куби́ческ||ий, -ая, -ое кубик; **~ая фо́рма** кубик форма; **~ий метр** кубик метр

ку́бковый, -ая, -ое кубок ...ы; **~ турни́р** кубок турниры

ку́бов||ый, -ая, -ое җете зәңгәр, куе зәңгәр, зәп-зәңгәр; **~ая кра́ска** зәңгәр буяу

ку́бок *м* кубок (**1.** *зур бокал рәвешендәге* **2.** *спорт. ярышларында җиңүчегә бирелә торган булак, приз*)

кубоме́тр *м* кубометр, кубик метр

ку́брик *м мор.* кубрик (*судноның команда урнашкан өлеше*)

кубы́шка *ж* **1.** акча чүлмәге **2.** *перен. прост.* ит бүкәне (*юан, тупас хатын-кыз турында*)

кува́лда *ж* зур, авыр чүкеч, кувалда

кувши́н *м* тар муенлы, тоткалы чүлмәк, кувшин

кувши́нка *ж бот.* ак төнбоек

кувыка́ться *несов. разг.* мәтәлү, мәтәлчек ату

кувыркну́ться *сов. однокр. разг.* мәтәлеп төшеп (егылып) китү

кувырко́м *нареч. разг.* мәтәлеп, мәтәлчекләп

кугуа́р *м зоол.* (*пума*) кугуар (*зур кыргый мәче*)

куда́ *нареч.* **1.** *вопр., относ.* кая, кай төшкә; **~ вы идёте?** сез кая барасыз? **2.** *вопр. разг.* нәрсәгә?; **~ вам сто́лько де́нег?** нәрсәгә сезгә шулкадәр акча? **3.** (*с восклицанием*) кая инде ул!; **~ тебе́ сла́дить с ним!** кая инде ул сиңа аны җиңү! **4.** *разг.* шактый, күп тапкыр[лар], чагыштырмасыз; **~ дешёвле** шактый арзан **5.** *неопр. разг.* берәр җиргә, кая да булса; **е́сли ~ пойдёте, скажи́те мне** кая да булса барсагыз, миңа әйтегез ♦ **~ как** бик, үтә; **~ ни кинь** кая гына карама, һәр җирдә; **~ ни шло** булмаса булган икән; әйдә ярый; каян килеп кая китмәгән; **~ [уж] там** барып чыкмаячак, уйлап та торасы юк

куда́-либо, куда́-нибудь *нареч.* кая булса да, кая булса, берәр җиргә

куда́-то *нареч.* каядыр, кая булса да

куда́хтать *несов.* кытаклау

куде́ль *ж* тәрәшле сүс

куде́сник *м* тылсымчы, сихерче

кудла́тый, -ая, -ое *разг.* йонлач, чәчби, тузган чәчле, пумала баш

ку́дри *только мн.* кодрә чәч, бөдрә чәч

кудря́виться *несов.* кодрәләнү, бөдрәләнү

кудря́в||ый, -ая, -ое **1.** кодрә, бөдрә; **~ые во́лосы** кодрә чәч; **~ая берёза** бөдрә каен; **~ая кали́на** кодрә балан **2.** кодрә (бөдрә) чәчле; **~ый ма́льчик** бөдрә чәчле малай **3.** *перен.* кирәгеннән артык бизәкле (тасвирлы); **~ый стиль** кирәгеннән артык бизәкле стиль

кузе́н *м* тудыка, туганнан туган (*абый яки эне*)

кузи́на *ж* тудыка, туганнан туган (апа *яки* сеңел)

кузне́ц *м* тимерче

кузне́чик *м* чикерткә, сикерткә

кузне́чн||ый, -ая, -ое **1.** тимерче [ләр] ...ы; **~ый мо́лот** тимерче чүкече; **~ый цех** тимерчеләр цехы **2.** тимерчелек ...ы; **~ое ремесло́** тимерчелек һөнәре

ку́зница *ж* **1.** тимерче алачыгы **2.** *перен. чего, высок.* чыныктыру (хәзерләү) урыны; **~ тала́нтов** талантлар чыныктыру урыны

ку́зов *м* кузов (*автомобильдә*); читән

ку́зька *м зоол.* иген коңгызы

кукаре́кать *несов.* кикрикүк дип кычкыру

кукареку́ *звукоподр.* кикрикүк (*әтәч кычкыруы*)

ку́киш *м разг.* кәжә тоягы, кукиш; **показа́ть ~** кәжә тоягы күрсәтү

ку́кл||а *ж* курчак; **игра́ть в ~ы** курчак уйнау; **теа́тр ~ол** курчак театры

кукловод *м* курчаклар уйнатучы артист

куково́ать *несов.* кәккүк дип кычкыру

ку́колка *ж* **1.** *уменьш. от* **ку́кла**; **2.** (*о девочке*) курчак (*матур киенгән кыз бала*) **3.** *зоол.* (*личинка*) кузы эчендәге корт

ку́коль *м бот.* бакра (*чүп үләне*)

ку́кольный, -ая, -ое курчак ...ы; **~ теа́тр** курчак театры ♦ **~ая коме́дия** курчак кәмите (*ясалма тантана турында*)

ку́кситься *несов. разг.* чырай сыту, каш җыеру, кәефсезләну

кукуру́за *ж* кукуруз

кукуру́зник *м разг.* кукурузник (*самолёт*)

кукуру́зн||ый, -ая, -ое **1.** кукуруз ...ы; **~ая мука́** кукуруз оны; **~ые початки** кукуруз чәкәннәре **2.** кукуруз ...ы; кукуруздан пешерелгән; **~ый хлеб** кукуруздан пешерелгән икмәк

куку́шеч||ий, -ья, -ье күке ...ы; кәккүк ...ы; **~ье яйцо́** күке йомыркасы

куку́шка *ж* күке, кәккүк

кула́к I *м* **1.** йодрык; **погрози́ть ~о́м** йодрык күрсәтү, йодрык белән янау **2.** *перен.* йодрык (*бергә тупланган сугышчан көч*); **уда́рный ~** сугышчан йодрык **3.** *тех.* йодрыкча (*машина детале*)

кула́к II *м* (*богатый крестьянин*) кулак, байгура

кула́цк||ий, -ая, -ое кулак ...: кулак[лар] ...ы; **~ое хозя́йство** кулак хуҗалыгы

кула́чество *с собир.* кулаклар

кула́чк||и: би́ться (дра́ться) на ~и (~ах) йодрык сугышы, йодрыкка йодрык килеп сугышу

кулачко́вый, -ая, -ое *тех.* йодрыкчалы; **~ вал** йодрыкчалы вал

кула́чный, -ая, -ое йодрык ...ы; **~ бой** йодрык сугышы

КУЛ-КУП

кулачо́к *м* **1.** *уменьш. от* **кула́к** I 1; **2.** *см.* **кула́к** I 3

кулебя́ка *ж* итле бәлеш; озынча бөккән

кул||ёк *м* **1.** кечкенә кап **2.** кәгазь пакет ♦ **из ~ька́ в рого́жку попа́сть** каш төзәтәм дип күз чыгару; төтеннән котылам дип утка керү

куле́ш *м прост.* өйрә, сыек ботка

ку́ли *м нескл.* кули, йөк ташучы (*көнчыгыш илләрдә*)

кули́к *м* шөлди (*кош*)

кулина́р *м* кулинар, аш остасы

кулина́рия *ж* кулинария (**1.** *аш хәзерләү осталыгы* **2.** *ашамлыклар; ашамлык әйберләре*)

кулина́рный, -ая, -ое кулинария ...ы; **~ реце́пт** кулинария рецепты

кули́са *ж* ян декорация; **за ~ми** 1) сәхнә артында; 2) *перен.* яшертен, яшерен рәвештә

кули́ч *м* кулич (*пасха бәйрәме кумәче*)

кули́чк||и: к чёрту на ~и җәһәннәм артына; **у чёрта на ~ах** җәһәннәм артында

куло́н I *м* кулон (*чылбырга тагылган яки муенсага тезелгән кыйммәтле асылташ*)

куло́н *м* II *физ.* кулон

кулуа́рн||ый, -ая, -ое кулуардагы..., кулуарда эшләнгән; **~ые встре́чи** кулуардагы очрашулар

кулуа́ры *только мн.* кулуар[лар] (**1.** *парламентта, театрда, съездларда утырышлар яки тамашачылар залы тышындагы булмәләр, коридорлар* **2.** *книжн. парламентта, съездда алып барылган эшнең рәсми булмаган ягы*)

куль *м* зур капчык (*из рогожи*), кап

кульминацио́нн||ый, -ая, -ое кульминация ...ы, кульминацион, иң югары, иң югарыгы; **~ая то́чка** кульминацион нокта

кульмина́ция *ж* кульминация (**1.** *куктәге яктырткычның меридиан аша үтүе* **2.** *перен. книжн. әдәби әсәрдәге вакыйгалар усешендә иң киеренке момент*)

культ *м* **1.** *рел.* гыйбадәт, табыну; **служи́тели ~а** руханилар (*поплар, муллалар, мәзиннәр һ.б.ш.*) **2.** *перен.* культ, артык олылау, табыну

культива́тор *м* культиватор (*сөрелгән җирне йомшарту коралы*)

культива́ция *ж* культивацияләү, культивация ясау

культиви́ровать *несов. что* **1.** *с.-х.* культивацияләү, культивация ясау (үткәрү) **2.** (*разводить*) үстерү, үрчетү; **~ со́ю** соя үстерү **3.** *перен.* (*развивать*) җәелдерү, тарату, гадәткә кертү; **~ рациона́льные спо́собы рабо́ты** эшнең рациональ ысулларын җәелдерү

культпохо́д *м* культпоход

культу́р||а *ж* **1.** мәдәният, культура; **~ а наро́да** халык мәдәнияте; **челове́к высо́кой ~ы** югары мәдәниятле кеше; **2.** үсеш дәрәҗәсе, культура; **~а ре́чи** сөйләм культурасы; **~а земледе́лия** җир эшкәртү культурасы **3.** культура, игеп үстерелгән үсемлек; **сельскохозя́йственные ~ы** авыл хуҗалыгы культуралары **4.** үрчетү; **~а бакте́рий** бактерияләр үрчетү (*лабораторияләрдә*)

культури́зм *м* культуризм (*авыр гимнастик кунегуләр системасы*)

культури́ст *м* культурист (*культуризм белән шөгыльләнүче*)

культу́рно-бытов||о́й, -а́я, -о́е мәдәни-көнкүреш ...ы; **~ые учрежде́ния** мәдәни-көнкүреш учреждениеләре

культу́рно-воспита́тельн||ый, -ая, -ое мәдәни-тәрбия ...ы; **~ая рабо́та** мәдәни-тәрбия эшләре

культу́рно-ма́ссов||ый, -ая, -ое мәдәни-масса ...ы; **~ая рабо́та** мәдәни-масса эшләре

культу́рно-просвети́тельн||ый, -ая, -ое мәдәни-агарту ...ы; аң-белем тарату ...ы; **~ые мероприя́тия** аң-белем тарату чаралары

культу́рность *ж* культуралылык, югары мәдәниятлелек

культу́рн||ый, -ая, -ое **1.** мәдәният ...ы; культура өлкәсендәге; **~ый у́ровень** мәдәният дәрәҗәсе **2.** культуралы; **~ый челове́к** культуралы кеше **3.** аң-белем тарату ...ы; культура ...ы; **~ая рабо́та** аң-белем тарату эше **4.** культуралы, игеп үстерелә торган; игүгә яраклы; **~ые расте́ния** игеп үстерелә торган үсемлекләр; **~ уча́сток земли́** игүгә яраклы җир участогы ♦ **~ый слой земли́** *археол.* туфракның культуралы катлавы (*элек кешеләр яшәгән булуны раслый торган әйберләр сакланган җир катлавы*)

культя́ *ж разг.* гарип кул калдыгы; гарип аяк калдыгы

кум *м* кум (*исем атасына чукындырылган баланың ата-аналары һәм исем анасы эндәшә торган сүз*)

кума́ *ж* кума (*исем анасына чукындырылган баланың ата-аналары һәм исем атасы эндәшә торган сүз*)

кума́ч *м* комач, бурлат

кума́чн||ый, -ая, -ое, **кумачо́в||ый**, -ая, -ое комач ...; **~ая руба́ха** комач күлмәк

куме́кать *несов. прост.* төшенү, абайлап алу

куми́р *м прям., перен.* кумир

кумовство́ *с* **1.** кумлык **2.** *перен.* кодакодагыйлык, яклашу

ку́мушка *ж* **1.** *ласк. от* **кума́**; **2.** *перен. разг.* гайбәтче хатын

кумы́к *м* комык, комык кешесе

кумы́ки *мн.* комыклар, комык халкы

кумы́кский, -ая, -ое комык[лар] ...ы; **~ язы́к** комык теле

кумы́с *м* кымыз

кумысолече́бница *ж* кымыз санатории

кумысолече́бн||ый, -ая, -ое кымыз белән дәвалау ...ы; кымыз белән дәвалый торган; **~ое заведе́ние** кымыз белән дәвалау йорты

кумысолече́ние *с* кымыз белән дәвалау

кумы́чка *ж* комык хатыны (кызы)

куна́к *м* кунак (*Кавказның тау халыкларында һәм төрки халыкларда дус кеше, якын иптәш, хәл белеп ял итәргә килгән кеше*)

кунжу́т *м* көнҗәт (*үсемлек*)

кунжу́тн||ый, -ая, -ое көнҗәт ...ы; **~ое ма́сло** көнҗәт мае

ку́ний, -ья, -ье сусар ...ы; **~ мех** сусар тиресе

куни́ца *ж* **1.** сусар **2.** (*мех*) сусар тиресе

кунстка́мера *ж уст.* кунсткамера (*сирәк очрый торган әйберләр җыелмасы; шундый әйберләрне саклау урыны; музей*)

купа́льник *м разг.* коену костюмы

купа́льный, -ая, -ое коену ...ы; **~ сезо́н** коену сезоны

купа́льня *ж* купальня (*су коену өчен ясалган махсус корылма*)

купа́льщик *м* су коенучы

купа́льщица *ж* су коенучы хатын (кыз)

купа́ть *несов. кого-что* коендыру

купа́ться *несов.* коену, су коену, су керү

купе́ *с* купе (*вагон бүлмәсе*)

купе́йный, -ая, -ое купелы; **~ ваго́н** купелы вагон

купе́ль *ж церк.* купель (*чиркәүдә бала чукындыру йоласын үтәгәндә аны коендыра торган ләгән*)

купе́ц *м* сәүдәгәр

купе́ческ||ий, -ая, -ое сәүдәгәрләр ...ы; сәүдәгәрлек ...ы; **~ое сосло́вие** сәүдәгәрләр катлавы

купе́чество *с* **1.** *собир.* сәүдәгәрләр **2.** (*сословие*) сәүдәгәрләр катлавы

купидо́н *м миф.* купидон (*римлылар мифологиясендә: кулына җәя һәм сөңге тоткан малай сурәтендәге мәхәббәт алласы*)

купи́рованный, -ая, -ое купелы, купеларга бүленгән; **~ ваго́н** купелы вагон

купи́ть *сов. кого-что* **1.** сатып алу **2.** *разг.* (*подкупить*) [ришвәт биреп] сатып алу

купле́т *м* **1.** (*строфа*) куплет (*җыр, шигырь строфасы*) **2.** *только мн.* **~ы** куплетлар, җырлар; **петь ~ы** куплетлар җырлау

куплети́ст *м* куплетчы, такмазачы (*эстрада артисты*)

ку́пля *ж см.* **купи́ть** 1 ♦ **~-прода́жа** сату-алу

ку́пол *м* гөмбәз

куполообра́зный, -ая, -ое гөмбәзсыман

купо́н *м* купон (**1.** *кыйммәтле кәгазьләрнең процентын алу өчен киселә торган талон* **2.** *бер костюмлык, юбкалык тукыма кисәге*)

купоро́с *м* купорос; **ме́дный ~** күкташ, бакыр купоросы; **желе́зный ~** тимер купоросы

ку́пч||ий, -ая, -ее: **~ая кре́пость** *уст.* купчий кәгазе (*күчми торган милек сатып алуны раслап, нотариус тарафыннан бирелгән документ*)

купчи́ха *ж* **1.** (*женщина из купеческого сословия*) сәүдәгәр хатын **2.** (*жена купца*) сәүдәгәр хатыны

купю́ра I *м* купюра (*әдәби, фәнни, музыкаль әсәрләрдә кыскартылган урыннар*)

купю́ра II *ж фин.* купюра (*кыйммәтле кәгазь — облигация яки акча*)

кур *м*: **как ~ во́ щи попа́л** *разг.* көтелмәгән бер бәлагә, күңелсезлеккә очрады

курага́ *ж собир.* күрәгә (*төше алып киптерелгән өрек*)

кура́житься *несов. над кем и без доп., прост.* тәрбиясезләнү, оятсызлану, бәйләнчекләнү, эре кылану, тупас кылану

кура́нты *только мн.* курант (*манарага куела торган музыкалы сәгать*); **Кремлёвские ~** Кремль курантлары

кура́тор *м* куратор (*кемне яки нәрсәне күзәтү эше йөкләнган зат*)

курга́н *м* **1.** (*насыпь*) курган (*борынгы каберлек өстендә өелеп, калкып тора торган биеклек*) **2.** (*холм*) таучык, кечкенә тау

кургу́зый, -ая, -ое **1.** кыска, тар (*кием турында*) **2.** кыска койрыклы, көтек койрыклы (*хайваннар турында*)

ку́рдский, -ая, -ое көрд[ләр] ...ы; **~ язы́к** көрд теле

ку́рды *мн.* көрдләр, көрд халкы (*Иранда, Төркиядә, Гыйракта, өлешчә Азәрбайҗанда, Әрмәнстанда һәм Төркмәнстанда яши торган халык*)

курдю́к *м* курдюк, койрык мае

курдю́чн||ый, -ая, -ое койрык ...ы; курдюк ...ы; курдюклы; **~ое са́ло** койрык мае; **~ая овца́** курдюклы сарык

ку́рево *с прост.* тәмәке

куре́ние *с* **1.** *см.* **кури́ть**; **2.** (*вещество*) хуш ис чыгару өчен яндырыла торган матдә

куре́нь *м ист.* курень (*Запорожье казакларының хәрби стан бүлеге*)

курза́л *м* курзал (*курортларда концертлар залы*)

кури́лка I *ж прост.* тәмәке тарту бүлмәсе

кури́лка II *ж:* **жив ~!** әле дә яши!, әле дә исән!

кури́льня *ж* наркотиклар тарту урыны (*әфьюн, нәшә һ.б.ш. тарту урыны*)

кури́льщик *м* тәмәкече, тәмәке тартучы

кури́льщица *ж* тәмәкече хатын (кыз)

кури́н||ый, -ая, -ое тавык ...ы; **~ый бульо́н** тавык шулпасы ♦ **~ая слепота́** 1) *мед.* тавык күзе (*авыру*); 2) *бот.* (*куреслен*) кузаяк, сары чәчәк; **~ая па́мять** *или* **~ые мозги́** начар хәтер, тавык хәтере

кури́тельн||ый, -ая, -ое **1.** тәмәке ...ы; **~ая бума́га** тәмәке кәгазе **2.** тәмәке тарту ...ы; **~ая ко́мната** тәмәке тарту бүлмәсе **3.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж* тәмәке тарту бүлмәсе

кури́ть *несов.* **1.** *что и без доп.* тарту, тәмәке тарту **2.** *что, чем* (*сжигать*) яндырып хуш-ис тарату; **~ арома́тными смо́лами** хуш исле сумала яндыру **3.** *что* (*добывать перегонкой*) куу; **~ смолу́** сумала куу

кури́||ться *несов.* **1.** тартылу; **сыро́й таба́к пло́хо ку́рится** чи тәмәке начар тартыла **2.** төтенләп тору; томанланып тору; **вулка́н ~тся** вулкан төтенли; **река́ ~лась** елга өсте томанланып тора иде **3.** *страд. от* **кури́ть** 1

ку́рица ж **1.** тавык **2.** *см.* **куря́тина**

ку́рия *ж* курия (*кайбер илләрнең сайлау системасында дәрәҗәләренә, байлыкларына карап сайлаучылар бүленә торган разрядларның исеме*)

курко́в||ый, -ая, -ое чакмалы; **~ое ружьё** чакмалы мылтык

курлы́кать *несов. разг.* торкылдау, каңгылдашу (*торналар турында*)

курн||о́й, -а́я, -о́е кара, морҗасыз; **~а́я изба́** кара өй

курно́сый, -ая, -ое **1.** почык; **~ нос** почык борын **2.** песи борынлы; **~ ма́льчик** песи борынлы малай

куровóдство *с* тавык үрчетү , тавыкчылык

куровóдческ||ий, -ая, -ое тавыклар үрчетү ...ы; **~ое хозя́йство** тавыклар үрчетү хуҗалыгы

куро́к *м* курок, тәте, чакма

куроле́сить *несов. прост.* шаяру, ду килү, ду күтәрү, шаталаклану

куропа́тка *ж* кыр тавыгы

куро́ртник *м разг.* курортчы

куро́ртница *ж разг.* курортчы хатын (кыз)

куро́ртн||ый, -ая, -ое курорт[лар]...ы; **~ое управле́ние** курортлар идарәсе

курортоло́гия *ж* курортология (*табигатьнең дәвалау факторларын өйрәнү фәне*)

куросле́п *м бот.* казаяк, сары чәчәк

курс *м* **1.** курс, юл; **держа́ть ~ на юг** көньякка таба юл тоту; **~ на индустриализа́цию** индустрияләштерүгә курс **2.** курс; **перейти́ на четвёртый ~** дүртенче курска күчү; **3.** курс, кыйммәт, бәя; **~ рубля́** сумның курсы **4.** *мн.* **~ы** курслар; **~ы по подгото́вке трактори́стов** тракторчылар хәзерләү курслары ♦ **в ~е** *чего* **[быть]** хәбәрдар булу,белеп тору

курса́нт *м* курсант

курси́в *м* курсив (*язма хәрефкә охшаган авыш басма хәреф, типография хәрефе*)

курси́вный, -ая, -ое курсив ...; курсивтан җыелган; **~ шрифт** курсив хәреф

курси́ровать *несов.* йөреп тору, йөрү (*билгеле пунктлар арасында йөри торган транспорт турында*)

курси́стка *ж ист.* курсистка (*революциягә кадәр Россиядә хатын-кызларның югары курсларында укучы*)

курсо́вка *ж* курсовка (*санаторий торагыннан читтә яшәп, курортта дәваланырга һәм тукланырга хокук бирә торган документ*)

курсов||о́й, -ая, -о́е курс ...ы; курслар ...ы; **~о́е собра́ние** курс җыелышы; **~а́я рабо́та** курс эше

курсо́вочник *м разг.* курсовкачы

куртиза́нка *ж уст.* куртизанка, аксөяк фахишә

ку́ртка *ж* куртка

курча́виться *несов.* бөтеркәләнү, бөдрәләнү, кодрәләнү

курча́в||ый, -ая, -ое **1.** бөдрә, кодрә; **~ые во́лосы** бөдрә чәч **2.** бөдрә (кодрә) чәчле; бөдрә (кодрә) йонлы; **~ый па́рень** бөдрә чәчле егет; **~ый бара́н** бөдрә йонлы тәкә

курьёз *м* кызык вакыйга, көлке, мәзәк; **ра́ди ~а** мәзәк өчен

курьёзный, -ая, -ое кызык, мәзәк, кызыклы, көлкеле; **~ слу́чай** көлкеле хәл

курье́р *м* **1.** курьер, йомышчы (*эш кәгазьләре ташучы*) **2.** *дип.* курьер

курье́рск||ий, -ая, -ое курьерлык...ы; йомышчы ...ы; **~ие обя́занности** курьерлык вазыйфалары ♦ **~ий по́езд** курьер поезды

куря́тина *ж* тавык ите

куря́тник *м* тавык кетәге, тавык абзары

куса́||ть *несов.* **1.** *кого-что* тешләү; **э́та соба́ка не ~ет дете́й** бу эт балаларны тешләми **2.** *что* (*сжимать зубами*) чәйнәү, тешләү; **~ть гу́бы** иреннәрне чәйнәү **3.** *кого-что* (*о насекомых*) тешләү, талау **4.** *кого-что, разг.* (*жалить, напр. о крапиве, морозе*) чагу, өтү **5.** *что* тешләп алу; **~ть са́хар** шикәр тешләп алу

куса́||ться *несов.* **1.** (*иметь привычку кусать*) тешләү, тешләшү; **соба́ка ~ется** эт тешләшә **2.** *разг.* (*кусать друг друга*) тешләшү **3.** (*напр. о крапиве, морозе*) чагу, өтү

куса́чки *только мн.* тешләгеч, кусачки, кәләшчә

кусков||о́й, -а́я, -о́е кисәкле, шакмаклы; **~о́е мы́ло** кисәкле сабын; **~о́й са́хар** шакмаклы шикәр

кусну́ть *сов. однокр. кого-что* тешләп алу

кус||о́к *м* **1.** кисәк, өлеш; **изре́зать что-л. на ~ки́** *берар нәрсәне* кисәкләргә кискәләү **2.** шакмак, кисәк; **~о́к са́хару** бер шакмак шикәр **3.** кисәк, телем, сыныкъ; (*мяса*) калҗа; **~о́к хле́ба** бер телем икмәк; **~о́к арбу́за** бер телем карбыз **4.** оч, кисәк; **~о́к холста́** бер оч киндер **5.** *перен. разг.* (*пропитание*) тамак, азык ♦ **~о́к в го́рло не идёт** тамакка аш бармый

куст *м* **1.** куак **2.** *перен.* (*объединение*) куст, берләшмә ♦ **спря́таться (уйти́) в ~ы́** шүрләү, качу, сызу

куста́рник *м* **1.** *см.* **куст** 1; **2.** *собир.* куаклык

куста́рников||ый, -ая, -ое куак ...ы, куак ...; **~ое расте́ние** куак үсемлек

куста́рничать *несов.* **1.** (*быть кустарём*) кустарьлык итү, кул һөнәре белән шөгыльләнү **2.** *перен.* (*заниматься кустарщиной*) вак һөнәрчеләрчә эшләү

куста́рн||ый, -ая, -ое **1.** кустарь..; **~ая промы́шленность** кустарь промышленность **2.** *перен.* вак һөнәрчеләрчә..., примитив

куста́рщина *ж разг.* кустарьчылык, вак һөнәрчелек

куста́рь *м* кустарь, вак һөнәрче

куст||и́ст||ый, -ая, -ое куаклы, тармаклы; **~ая рожь** тармаклы арыш

кусти́ться *несов.* куаклану, тармаклану, тармаклар җибәрү

ку́тать *несов. кого-что* урау, чорнау, төрү, кат-кат киендерү

ку́таться *несов.* урану, төренү, артык җылы киенү

кутёж *м* типтерү, әйттерү; эчкечелек мәҗлесе

кутерьма́ *ж разг.* ыгы-зыгы, шау-шу, чуалыш

кути́ла *м разг.* типтерүче, әйттерүче; эчкече

кути́ть *несов.* типтерү, әйттерү, эчү

кутну́ть *сов. однокр.* типтереп алу, әйттереп алу

кутья́ *ж* баллы ботка, йөземле дөге боткасы (*православныйларда улгән кешене искә алу вакытында пешерелә*)

кухáрка *ж* кухарка, ашлар пешерүче, пешекче

кухми́стерская *ж уст.* кечкенә ресторан, ашханә

ку́хня *ж* **1.** кухня, аш өе **2.** (*кушанья*) ашамлыклар, ашлар, азыклар **3.** *перен.* (*скрытая, закулисная сторона*) кухня

ку́хонный, -ая, -ое кухня ...ы; **~ нож** кухня пычагы; **~ гарнитýр** кухня гарнитуры

ку́ц||ый, -ая, -ее **1.** койрыксыз; өтек койрыклы (*хайваннар турында*) **2.** *разг.* кыска, кыска чабулы (*кием турында*) **3.** *перен. пренебр.* сай, өтек; **~ые мы́сли** өтек фикерләр

ку́ча *ж* **1.** өем; **~ песку́** ком өеме **2.** *кого-чего, разг.* бер көтү, бик күп; **у них ~ дете́й** аларның балалары бер көтү ♦ **~ мала́** бик күп, өсте-өстенә өелгән, тәртипсез өем

кучев||о́й, -а́я, -о́е: **~ы́е облака́** өем болытлар

ку́чер *м* кучер, ат тотучы

ку́чный, -ая, -ое куе, еш; **~ полёт дро́би** ядрәләрнең куе булып очуы

куш *м разг.* зур сума, зур табыш,зур калҗа

куша́к *м* билбау, пута

ку́шанье *с* ашамлык, азык, аш

ку́шать *несов. что* ашау, туклану, ризыклану

куше́тка *ж* кушетка (*артсыз диван, бер очы кутәренке ятак*)

кхме́рский, -ая, -ое кхмер[лар]...ы; **~ язы́к** кхмер теле

кхме́ры *мн.* кхмерлар, Кампучий халкы

кш *межд.* көш-көш (*кошларны куркыту яки куып җибәру ымлыгы*)

кювéт *м* кювет; **маши́на съе́хала в ~** машина кюветка төшеп китте

кювéтка *ж* кюветка (*фото материалларны эшкәрту савыты*)

кюре́ *м нескл.* кюре (*Франциядә, Бельгиядә католик чиркәү рухание*)

Л

лаба́з *м уст.* лабаз (*базарда бөртекле ашлык, он сату урыны, ябык бина*)

лаба́зник *м уст.* лабазчы (*лабаз тотучы, лабаз хуҗасы яки лабазда сату итүче*)

лабиализа́ция *ж лингв.* лабиализация, иренләштерү, иренләшү

лабиа́льн||ый, -ая, -ое *лингв.* лабиаль, ирен ...ы; **~ые зву́ки** ирен авазлары (*мәс. «п», «б»*)

лабири́нт *м* лабиринт (**1.** *борынгы Грециядә һәм Мисырда: бик куп булмәләре һәм буталчык коридорлары булган зур бина* **2.** *перен. утә катлаулы, буталчык нәрсә* **3.** *анат. колакның эчке өлеше*)

лабора́нт *м* лаборант

лабора́нтка *ж* лаборантка

лаборато́рия *ж* лаборатория; **орбита́льная косми́ческая ~** орбиталь космик лаборатория

лаборато́рн||ый, -ая, -ое лаборатория ...ы, лабораториядә ясала (үткәрелә) торган, лаборатор; **~ые рабо́ты студе́нтов** студентларның лаборатор эшләре; **~ая посу́да** лаборатория савытлары

ла́ва I *ж* лава (*янар таудан атылып чыга торган, эрегән тау токымнары массасы*)

ла́ва II *горн.* лава

лава́нда *ж бот.* лаванда; ала миләүшә

лави́н||а *ж* **1.** лавина, кар ишелмәсе (*тау башларыннан шуып төшә торган зур-зур кар кантарлары*) **2.** *перен.* ташкын; өем; **~а бума́г** кәгазь ташкыны **3.** *в знач. нареч.* **~ой** ташкын кебек, ташкындай, ташкын сыман, ташкын булып

лави́ровать *несов.* **1.** лавировать итү, борыла-сарыла жилгә каршы бару (*җилкәнле судно, көймә турында*) **2.** *перен.* лавировать итү, боргалану-сыргалану, оста җайлашу; **~ в поли́тике** сәясәттә лавировать итү

ла́вка I *ж* эскәмия; ян сәке

ла́вка II *ж* кибет; **кни́жная ~ писа́телей** язучыларның китап кибете

ла́вочник *м уст.* кибетче

ла́вочница *ж уст.* кибетче хатын (кыз)

лавр *м* **1.** дәфнә агачы, лавр **2.** *мн.* **~ы** (*венок*) лавр веногы ♦ **~ы *чьи* не даю́т спать** *кому кемгә дә булса бирәунең* уңышлары тынычлык бирми; **пожина́ть ~ы** рәхәтен күрү, нәтиҗәсен күрү; **почи́ть на ~ах** ирешелгән уңышлардан тынычланып яту, алга [таба] омтылмау

ла́вра *ж* лавра, зур монастырь

лавро́вишня *ж* чия-дәфнә (*агач яки куак үсемлек*)

ла́вровый, -ая, -ое, **лавро́вый,** -ая, -ое дәфнә агачы ...ы; лавр ...ы; **ла́вровая ве́тка** дәфнә агачы ботагы; **лавро́вый лист** лавр яфрагы, дәфнә агачы яфрагы (*аштәмләткеч*) ♦ **лавро́вый вено́к** лавр веногы, җиңү тажы

лавса́н *м* лавсан (*тукыма*)

лавса́нов||ый, -ая, -ое лавсан ...ы; лавсан ...; **~ая руба́шка** лавсан күлмәк

лаг *м мор.* лаг (*суднoның йөрү тизлеген күрсәтә торган прибор*)

ла́герный, -ая, -ое лагер ..ы; **~ режи́м** лагерь режимы

ла́герь *м в разн. знач.* лагерь; **укреплённый ~** ныгытылган лагерь; **концентрацио́нный ~** концентрацион лагерь; **антивое́нный ~** сугышка каршы лагерь

лагу́на *ж* лагуна, диңгез култыгы

лад *м* **1.** (*согласие, мир*) татулык, дуслык; дус булу, тату булу; **жить в ~ý (~а́х)** *с кем-л.* [үзара] дус яшәү; **они живу́т не в ~ý** алар дус яшәмиләр; **он не в ~а́х с фи́зикой** ул физика белән дус түгел **2.** юл, ысул, үрнәк; **на все ра́зные) ~ы́** төрлечә; **на друго́й ~ сде́лать** *что-л. берәр нәрсәне* икенче ысул белән ясау; **на но́вый ~** яңача **3.** *муз.* лад (*музыкаль әсәрнең төзелеше*) **4.** *обычно мн.* **~ы́** лад (*кыллы инструментларның грифларындагы булекләр*) **5.** *обычно мн.* **~ы́** (*клавиши гармоники*) тел ♦ **дела́ иду́т на ~** эшләр уңайга бара, эшләр җайлана

ла́дан *м* ладан (*чиркәүдә гыйбадәт кылганда төтәтелә торган хуш исле сумала*) ♦ **боя́ться как чёрт ~а** шайтан яшеннән курыккандай курку; **бежа́ть как чёрт от ~а** шайтан яшеннән качкандай качу

ла́данка *ж* бөти

ла́д||ить *несов. разг.* **1.** *с кем-чем* дус тору (яшәү), тату тору (яшәү); **они́ ~ят ме́жду собо́й** алар үзара тату яшиләр; **с ним тру́дно ~ить** аның белән уртак тел табуы кыен **2.** *что, прост.* (*налаживать*) көйләү, көйгә салу; **~ить балала́йку** балалайканы көйләү **3. ~ить одно́ и то́ же** *прост.* бер үк нәрсәне кабатлау, бер балык башын чәйнәү

ла́ди||ться *несов.* **1.** уңайга бару, җайга бару, җайлану; **у него́ рабо́та не ~тся** аның эше җайланмый; **жизнь у них не ~тся** аларның тормышлары җайланмый; **де́ло не ~тся** эш җайга бармый **2.** *страд. от* **ла́дить** 2

ла́дно *нареч. в знач. частицы* ярый, ярар; **ска́жешь, ~?** әйтерсең, ярыймы?; **~, скажу́** ярый, әйтермен ♦ **да ~ тебе́!** ярар инде сиңа!, җитәр инде сиңа!

ла́дн||ый, -ая, -ое *разг.* буйга-сынга матур, зифа, зифа буйлы, матур сынлы, сылу; **~ая фигу́ра** зифа буй; **~ый па́рень** зифа буйлы егет

ладо́н||ь *ж* уч төбе ♦ **быть ви́дным как на ~и** уч төбендәгедәй ачык күренү

ладо́ши *мн.*: **в ~ бить (ударя́ть, хло́пать)** кул чабу

ладья́ I *ж поэт.* каек, зур көймә

ладья́ II *ж шахм.* ладья

лаз *м* **1.** *см.* **лазе́йка** 1; **2.** *спец.* (*ход*) җәнлекләр сукмагы

лазаре́т *м* лазарет

лазе́йк||а *ж* **1.** (*утеп йөрерлек*) тишек; **~а в забо́ре** койма тишеге **2.** *перен.* котылу юлы, котылу чарасы (*берәр төрле авыр хәлдән*); чигенү юлы; **найти́ ~у** котылу чарасын табу; **оста́вить себе́ ~у** үзенә чигенү юлы калдыру

ла́зер *м физ.* лазер

ла́зерный, -ая, -ое *физ.* лазер ...ы; **~ луч** лазер нуры

ла́зить *несов.* **1.** менеп йөрү, [үрмәләп] менү, менеп төшеп йөрү; [үрмәләп] йөрү; **~ по гора́м** тауларга менеп йөрү; **~ по дере́вьям** агачларга менү **2.** кереп йөрү, кереп-чыгып йөрү; **~ в окно́** тәрәзәдән кереп йөрү **3.** керү; **~ в карма́н** кесәгә керү

лазо́ревка *ж зоол.* зәңгәр чыпчык

лазу́рн||ый, -ая, -ое, зәңгәр, аксыл-зәңгәр, зәңгәрсу; **~ое не́бо** зәңгәр күк; **~ое мо́ре** зәңгәр диңгез

лазу́рь *ж* **1.** (*светло-синий цвет*) аксыл-зәңгәр төс, зәңгәрсу төс **2.** (*синева*) зәңгәрлек **3.** (*краска*) лазурь, зәңгәрсу [төстәге] буяу

лазу́тчик *м уст.* лазутчик (*дошман тылында разведчик*)

лай *м* өрү, һаулау; өрү тавышы, өргән тавыш; **соба́чий ~** эт өргән тавыш

ла́йка I *ж* лайка (*эт токымы*)

ла́йка II *ж* лайка (*йомшак күннең бер төре*)

ла́йков||ый, -ая, -ое лайка..., лайкадан тегелгән; **~ые перча́тки** лайкадан тегелгән перчаткалар

ла́йнер *м* лайнер (**1.** *зур диңгез судносы* **2.** *зур пассажир самолёты*)

лак *м* лак

лака́ть *несов. что* эчү, ялап эчү (*эт, мәче турында*)

лаке́й *м* **1.** лакей, ялчы **2.** лакей, ялчы, ялагай, тәлинкә тотучы

лаке́йск||ий, -ая, -ое **1.** лакей ...ы, ялчы ...ы; **~ая ливре́я** лакей ливреясы **2.** *перен. пренебр.* ялагай ...ы, лакей ...ы, ялагайларга (ялчыларга) хас; **~ая нату́ра** ялагайларга хас табигать

лаке́йство *с* **1.** *уст.* (*служба лакея*) лакейлык, ялчылык, лакей (ялчы) булып хезмәт итү **2.** *перен. пренебр.* лакейлык, ялагайлык

лаке́йствовать *несов. перед кем, пренебр.* лакейлык күрсәтү, лакейлык итү, лакейлану, ялагайлану

лакиро́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **лакирова́ть**; **2.** лаклы, лак белән капланган; **~ые ту́фли** лаклы туфлиләр

лакирова́ть *несов. что* **1.** (*покрывать лаком*) лаклау, лак белән каплау (ялтыратыр өчен) **2.** *перен.* (*приукрашивать*) шомартып күрсәтү, артык матурлап (яхшыртып) күрсәтү; **~ действи́тельность** чынбарлыкны артык матурлап күрсәтү

лакиро́вка *ж* **1.** *см.* **лакирова́ть**; **2.** ялтыравык, лак; **ту́склая ~** тоныклак

ла́кмус *м* (*красящее вещество*) лакмус

ла́кмусов||ый, -ая, -ое лакмус ...ы, лакмуслы, лакмус сеңдерелгән; **~ая бума́га** лакмуслы кәгазь

ла́ков||ый, -ая, -ое лак ...ы; лаклы; **~ые ту́фли** лаклы туфлиләр

ла́комиться *несов. чем* сыйлану (*тәмле нәрсәләр*) ашау; **~ варе́ньем** варенье белән сыйлану

ла́комка *м, ж* тәмлетамак, татлытамак

ла́комств||о *с* **1.** *обычно мн.* **~а** (*сладости*) тәмле (татлы) ашамлыклар, тәмтом **2.** (*вкусная пища*) тәмле аш

ла́ком||ый, -ая, -ое тәмле, татлы; **~ое блю́до** тәмле аш ◆ **~ый кусо́к (кусо́чек)** симез калҗа, майлы калҗа

лакони́зм *м* лаконизм, лакониклык, кыскалык һәм ачыклык (*мәгънәне аз гына сүз белән ачык итеп аңлатып бирү*)

лакони́чный, -ая, -ое лаконик, кыска һәм ачык, аз сүзле; **~ отве́т** кыска һәм ачык җавап

лакри́ца *ж*, **лакри́чник** *м* татлы тамыр (*усемлек һәм аның тамыры*)

лакри́чный, -ая, -ое: **~ ко́рень** татлы тамыр; **~ поро́шок** татлы тамыр порошогы (оны)

лактацио́нный, -ая, -ое *физиол.* лактация ...ы, сөт бирү ...ы; **~ пери́од** сөт бирү чоры (*мәс. сыерның*)

лакта́ция *ж физиол.* лактация, сөт бирү

лакто́за *ж* лактоза, сөт шикәре

ла́ма I *ж* лама (*хайван*)

ла́ма II *м* лама (*монах*)

ламаи́зм *м* ламаизм (*буддизмның Тибетта, Монголиядә һ.б.ш. таралган аерым бер төре*)

ламаи́ст *м* ламаист, ламаизм динен тотучы

ла́мпа *ж* лампа

лампа́да *ж* **1.** лампада (*икона алдына яндырып куела торган лампа, тәре лампасы*) **2.** *поэт.* яктырткыч, яктылык чыганагы

лампа́с *м* лампас (*форма чалбарына буйдан-буйга тегеп куела торган төсле тасма*)

ла́мпов||ый, -ая, -ое лампа ...ы, лампалы; **~ое стекло́** лампа пыяласы; **~ый радиоприёмник** лампалы радиоалгыч

ла́мпочка *ж* **1.** *уменьш. от* **ла́мпа**; **2.** электр лампасы

ланге́т *м* лангет (*озынча юка ит кисәкләреннән хәзерләнгән ашамлык*)

ландша́фт *м геогр.* ландшафт

ла́ндыш *м* ландыш, энҗе чәчәк

ла́ндышев||ый, -ая, -ое ландыш ...ы; энҗе чәчәк ...ы; **~ые ка́пли** ландыш тамчысы (*дару*)

ланце́т *м* ланцет (*хирургиядә кулланыла торган кечкенә пычак*)

лань *ж* болан, нәфис болан

лао́сский, ая, -ий лаослы[лар] ...ы; лаос ...ы; **~ язы́к** лаослылар теле

лао́сцы *мн.* лаослылар, Лаос халкы

лаотя́не *мн.* лаотянлар, Лаос халкы

ла́па *ж* **1.** (*птиц, животных*) аяк **2.** *прост.* (*большая рука*) зур кул; (*большая нога*) зур аяк **3.** (*ветвь хвойного дерева*) ылыслы агач ботагы

лапида́рный, -ая, -ое *книжн.* лапидар, кыска һәм ачык, кыска һәм аңлаешлы

ла́пник *м собир.* (*ельник*) киселгән чыршы ботаклары

ла́поть *м* чабата

лапта́ *ж* лапта (*туп уенының бер төре һәм шул уенда кулланыла торган таяк яки такта кисәге*)

ла́пчатый, -ая, -ое **1.** җәенке, җәелеп тора торган; **~ лист** җәелеп тора торган яфрак **2.** (*о птицах*) яры аяклы

лапша́ *ж* токмач

ларёк *м* ларёк, кечкенә кибет

ларе́ц *м* кечкенә тартма (*кыйммәтле нәрсәләр саклау өчен бизәп ясалган була*)

ларинги́т *м мед.* ларингит, тамак шешү, тамак ялкынсыну

ларь *м* **1.** лар; бура, өсәк; **~ с мукой** он салып куелган лар **2.** *тех.* улак, чан; **~ для промы́вки руды́** руда юа торган улак

ла́ска I *ж* **1.** (*проявление нежности*) иркәләү, наз, иркә, сөю; **материнская ~** ана назы **2.** (*доброе отношение*) йомшак мөгамәлә, якты йөз, ачык чырай

ла́ска II *ж зоол.* ләтчә

ласка́тельн||ый, -ая, -ое *грам.* иркәләү ...ы; **~ые су́ффиксы** иркәләү кушымчалары

ласка́ть *несов. кого-что* иркәләү, назлау, сөю; **~ ребёнка** баланы иркәләү

ласка́ться *несов. к кому и без доп.* иркәләнү, назлану, иркәләнеп сыену; **~ к ма́тери** әнисенә иркәләнү

ла́сков||ый, -ая, -ое **1.** ягымлы, ачык йөзле; **~ая де́вочка** ягымлы кыз бала **2.** сөйкемле, ягымлы, йомшак, мөлаем; **~ое сло́во** йомшак сүз; **~ый го́лос** ягымлы тавыш **3.** *перен.* йомшак, җылы; **~ый ве́тер** йомшак җил; **~ое со́лнце** җылы кояш

лассо́ *с нескл.* лассо, корык, элмәкле аркан (*Америка аучыларының арканы*)

ласт *м* **1.** ишкәк аяк (*тюлень, морж кебек су хайваннарының аягы*) **2.** *мн.* **~ы** ластлар (*суда йөзгәндә аякка киелә торган җайланма*)

ла́стик *м разг.* ластик (*гадәттә кием эчлегенә куела торган киҗе-мамык тукыма*)

ла́ститься *несов. разг. см.* **ласка́ться**

ластоно́гие *мн. зоол.* ишкәк аяклылар (*тюлень, морж кебек су хайваннары*)

ла́сточка *ж* карлыгач; **дереве́нская ~, береговáя ~** яр карлыгачы, керәшә; **пе́рвая ~** *прям., перен.* беренче карлыгач; **одна́ ~ весны́ не де́лает** *посл.* бер карлыгач яз ясамый

ла́таный, -ая, -ое *прост.* ямаулы

лата́ть *несов. что, прост.* ямау, ямау салу

латиниза́ция *ж см.* **латинизи́ровать, латинизи́роваться; ~ алфави́та** латин алфавитына күчү

латинизи́ровать *сов., несов.* **1.** *кого-что* (*привить латинскую культуру*) латинлаштыру (*латин телен, мәдәниятен көчләп кертү, тагу*) **2.** *что* (*ввести латинский алфавит*) латинлаштыру, латин алфавитына күчерү

латинизи́роваться **1.** *сов., несов.* латинлашу (*латин телен, мәдәниятен үзләштерү*) **2.** *несов. страд. от* **латинизи́ровать**

латини́зм *м* латин сүзе (тәгъбире)

латини́ст *м* латин теле белгече

лати́ница *ж* латин алфавиты; латинча язу

лати́нск||ий, -ая, -ое **1.** латин ...ы; **~ий алфави́т** латин алфавиты **2.** *уст.* (*католический*) католик[лар] ...ы; **~ая це́рковь** католиклар чиркәве

латифу́ндия *ж ист.* латифундия, зур имение

ла́тка *ж прост.* ямау, ямаулык

ла́тник *м* (*воин в латах*) көбәле сугышчы

лату́нь *ж* җиз

ла́ты *только мн.* көбә, көбә кием; лат (*борын заманда салкын коралдан саклану өчен гаскәриләр кия торган корыч кием*)

латы́нь *ж* латин теле

латы́ш *м* латыш

латыши́ *мн.* латышлар, латыш халкы

латы́шка *ж* латыш хатыны (кызы)

латы́шский, -ая, -ое латыш[лар] ...ы; Латвия ...ы; ~ **язы́к** латыш халкы

лауреа́т *м* лауреат; ~ **Ле́нинской пре́мии** Ленин премиясе лауреаты

лафе́т *м* лафет (*артиллерия тубының станы*)

лафе́тн||ый, -ая, -ое: ~ **ая жа́тка** лафетлы ургыч

ла́цкан *м* кайтарма (*киемнең күкрәк турындагы кайтармасы.*)

лачу́га *ж* алачык, кечкенә начар өй

ла́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **ла́ять**; **2.** (*о голосе, звуках*) өзек-өзек, карлыккан

ла́ять *несов.* өрү; **соба́ка ла́ет, ве́тер но́сит** *погов.* эт өрер, бүре йөрер

лгать *несов.* ялганлау, ялган сөйләү

лгун *м* ялганчы, алдакчы

лгу́нья *ж* ялганчы хатын (кыз), алдакчы хатын (кыз)

лебеда́ *ж* алабута

лебеди́н||ый, -ая, -ое **1.** аккош ...ы; ~ **ое яйцо́** аккош йомыркасы **2.** салмак, мәһабәт; ~ **ая по́ступь** салмак йөреш; ~ **ая ше́я** озын матур муен ◆ ~ **ая пе́сня** аккош жыры, талантының соңгы чагылышы, үз гомерендә булган соңгы жыры (*ягъни гомеренең соңында талантлы язылган әсәре, башкарган роле, жыры һ.б.ш.*)

лебёдка I *ж* ана аккош

лебёдка II *ж* лебёдка, катлаулы чыгыр

ле́бедь *м* аккош

лебези́ть *несов. перед кем и без доп., разг.* ялагайлану, юмакайлану, юмалану, төче теллеләнү, тәлинкә тоту, яхшатлану

лебя́жий, -ья, -ье аккош ...ы; ~ **пух** аккош мамыгы

лев I *м* арыслан

лев II *м* лев (*Болгариядә акча берәмлеге*)

лева́цкий, -ая, -ое *разг.* [артык] сул (*ялган радикаль, оппортунистик, вак буржуаз эчтәлеген революцион фразалар астына яшерә торган*)

лева́ть *несов.* суллашу, суллаша бару (*политикада, карашларда*)

левизна́ *ж* суллык (*политикада, карашларда*)

левко́й *м* левкой, шеббуй

левобере́жный, -ая, -ое сул як ярдагы..., сул як ярга урнашкан

левофланго́вый, -ая, -ое сул флангтагы...

левша́ *м, ж* сулагай

ле́в||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* сул; ~ **ая рука́** сул кул; ~ **ый бок** сул як; ~ **ые фра́кции парла́мента** парламентның сул фракцияләре; ~ **ый уклон в па́ртии** *ист.* партиядә сул тайпылыш

лега́вый, -ая, -ое легавый (*ау этенең бер токымы*)

легализа́ция *ж см.* **легализова́ть, легализова́ться**

легализи́ровать *сов., несов. см.* **легализова́ть**

легализи́роваться *сов., несов. см.* **легализова́ться**

легализова́ть *сов., несов. кого-что* легальләштерү, легаль хәлгә күчерү, рәсмиләштерү, законлаштыру, законлы дип тану

легализова́ться *сов. несов.* легальләшү, легаль хәлгә күчү, законлашу

лега́льн||ый, -ая, -ое легаль, закон тарафыннан танылган; ~ **ое положе́ние** легаль хәл ◆ ~ **ый ма́ркси́зм** *ист.* легаль марксизм

леге́нда I *ж* **1.** (*сказание*) легенда, риваять **2.** (*вымысел*) уйдырма, әкият

леге́нда II *м* (*пояснительный текст*) легенда, анлатма (*картага, рәсемгә*)

легенда́рн||ый, -ая, -ое **1.** (*являющийся легендой*) легендар; ~ **ый расска́з** легендар хикәя **2.** легендар, гадәттән тыш, тиңе булмаган; ~ **ая ли́чность** легендар шәхес **3.** *перен.* (*неправдоподобный*) уйдырма ..., ялган, кеше ышанмаслык ...

легио́н *м* **1.** легион; **иностра́нный** ~ чит ил легионы **2.** *перен.* легион, чиксез күп; **на́ших сторо́нников** — ~ безнең тарафдарларыбызның саны легион

легионе́р *м* легионер, легион солдаты

лёгк||ий, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* жинел; ~ **ие ве́щи** жиңел әйберләр; ~ **ое отноше́ние к жи́зни** тормышка жиңел караш; ~ **ая доро́га** жиңел юл; ~ **ое наказа́ние** жиңел җәза; ~ **ая оде́жда** жиңел кием; ~ **ое пальто́** жиңел пальто; ~ **ий спо́соб** жиңел (ансат) юл; **челове́к с** ~ **им хара́ктером** жиңел характерлы кеше **2.** йомшак [кына], аз гына, сизелер-сизелмәс кенә, жиңелчә [генә]; ~ **ий ветеро́к** йомшак җил; ~ **ая голо́вная боль** аз гына баш авырту; ~ **ий за́пах** аз гына ис; ~ **ий моро́з** жиңелчә салкын; ~ **ий покло́н** жиңелчә генә баш ию; ~ **ое прикоснове́ние** йомшак кына кагылу; ~ **ий тума́н** аз гына томан; ~ **ая усме́шка** сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәп кую ◆ ~ **ая рука́** *у кого* кулы жиңел; **же́нщина** ~ **ого поведе́ния** бозык хатын, фахишә; **лёгок на поми́не** гомере озын булыр (*сөйләп торганда килеп керде*); **с** ~ **им па́ром** жиңел пар белән; **с** ~ **им се́рдцем** уйлап-нитеп тормыйча, куркусыз

легко́ *нареч.* **1.** жиңел; ~ **танцева́ть** жиңел бию **2.** *в знач. сказ.* жиңел, ансат; **э́то сде́лать** ~ моны эшләүе жиңел ◆ **ле́гче на поворо́тах** *прост.* саграк кылан, сак бул (сүзендә, эшендә)

легкоатле́т *м* жиңел атлет

легкоатле́тическ||ий, -ая, -ое жиңел атлетика ...ы; ~ **ие соревнова́ния** жиңел атлетика ярышлары

легкове́рие *с* тиз (жиңел) ышанучанлык, беркатлылык

легкове́рный, -ая, -ое тиз (жиңел) ышанучан, беркатлы

легкове́сн||ый, -ая, ое **1.** жиңел, гадәттәгедән жиңелрәк; ~ **ая моне́та** гадәттәгедән жиңелрәк акча **2.** *перен.* жиңел, житди булмаган, сай, өстән-өстән генә; ~ **ая нату́ра** жиңел табигать; ~ **ое сужде́ние** өстән-өстән генә фикерләү

легково́й, -а́я, -о́е жиңел; ~ **автомоби́ль** жиңел автомобиль ◆ ~ **изво́зчик** *уст.* кешеләр утыртып йөртүче извозчик

лёгк||ое *с* үпкә; **воспале́ние** ~ **их** үпкәләр ялкынсынуы

легкомы́сленн||ый, -ая, -ое **1.** өстән (жиңел) уйлаучан, һәрнәрсәгә жиңел караучан, житди булмаган, төпле булмаган, җилкуар, җилбәзәк; ~ **ый челове́к** өстән уйлаучан кеше; ~ **ая же́нщина** жилбәзәк хатын **2.** уйламыйча эшләнгән, сай, төпсез; ~ **ый сове́т** уйламыйча бирелгән киңәш; ~ **ое сужде́ние** өстән-өстән генә фикерләү

легкомы́слие *с* өстән (жиңел) уйлау, һәрнәрсәгә жиңел карау, җилкуарлык, жилбәзәклек

легкопла́вкий, -ая, -ое жиңел (тиз) эрүчән; ~ **мета́лл** тиз эрүчән металл

лёгкость *ж* жиңеллек; ансатлык

лёгочн||ый, -ая, -ое үпкә ...ы; ~ **ое заболева́ние** үпкә авыруы; ~ **ый больно́й** үпкә авырулы авыру

легча́||ть *несов. прост.* **1.** (*слабеть*) йомшару, басыла төшү; **моро́з** ~ **ет** салкыннар йомшара **2.** *безл. кому и без доп.* жиңеләю, яхшыру; **больно́му не** ~ **ет** авыруның хәле жиңеләми

лёд *м* боз ◆ ~ **разби́т (сло́ман)** беренче адым ясалды, юл ачылды; ~ **тро́нулся** боз кузгалды

леденё||ть *несов.* **1.** (*покрываться льдом*) туңу, боз белән каплану; **2.** (*коченеть*) туңу, өшү, боз кебек кату; **ру́ки** ~ **ют** куллар туңа

ледене́ц *м* леденец (*конфетның бер төре*)

ледени́ст||ый, -ая, -ое боз ...ы; бозлы, бозсыман; ~ **ая ма́сса** бозсыман масса

ледени́||ть *несов. что* **1.** туңдыру, өшетү; **ве́тер** ~ **т лицо́** җил битне өшетә **2.** *перен.* әрнетү, өшетү, кисү; **страх** ~ **т се́рдце (ду́шу)** курку хисе йөрәкне (жанны) әрнетә, жанны өшетә

ледери́н *м* ледерин (*ясалма кун*)

ле́ди *ж нескл.* леди (*мәс. лорд хатыны*)

ле́дник *м* (*погреб*) кар базы; ледник (*махсус шкаф яки вагон*)

ледни́к *м* бозлык, глетчер

леднико́в||ый, -ая, -ое бозлык ...ы; ~ **ый пери́од** *геол.* бозлык чоры; ~ **ые озёра** бозлык күлләре

ледо́в||ый, -ая, -ое **1.** боз ...ы, боз өстеннән (бозлыктан) үтә торган, бозлар арасыннан уза торган; ~ **ая тра́сса** боз өстеннән үтә торган трасса **2.** бозлар арасында ...; ~ **ые пла́вания** бозлар арасында йөзүләр

ледоко́л *м* бозваткыч; **а́томный** ~ атом бозваткычы

ледоре́з *м* **1.** (*морское судно*) бозкискеч, бозъяргыч **2.** (*сооружение на реке*) бозваткыч, бозлан саклагыч

ледору́б *м* (*инструмент*) боз балтасы (киркасы), боз чаба торган балта (кирка)

ледоста́в *м* боз туктау, боз кату (*елгада*)

ледохо́д *м* боз китү, боз агу (*елгада*)
леды́шка *ж разг.* боз кисәге
ледян||о́й, -ая, -о́е **1.** боз ..., боз ...ы; **~о́й зато́р** боз килеп тыгылу; **~а́я ко́рка** боз катлавы; **~а́я сосу́лька** боз сөңгесе **2.** боз белән капланган, бозлы; **~ы́е верши́ны** боз белән капланган тау түбәләре **3.** боз кебек салкын, бик салкын; **~а́я вода́** боз кебек салкын су; **~ы́е па́льцы** боз кебек салкын бармаклар **4.** *перен.* салкын; **~о́й тон** салкын тон **5.** *перен.* ваемсыз, салкын; **~о́е споко́йствие** салкын тынычлык
лежа́к *м* **1.** ятак (*ачык һавада, пляжда ятып ял итү өчен*) **2.** (*лежащее бревно*) ятма бүрәнә, ятма борыс
лежа́л||ый, -ая, -ое озак яткан, озак ятып бозылган; **~ый това́р** озак [сатылмый] яткан товар; **~ая мука́** озак ятып бозылган он
лежа́нка *ж* мич ятагы (*мич буена кирпечтән салынган тәбәнәк чыгынты*)
леж||а́ть *несов.* **1.** яту, ятып тору; **~а́ть на земле́** җирдә яту **2.** яту, авырып яту; **~а́ть в лихора́дке** бизгәк белән авырып яту **3.** (*находиться в неподвижном положении*) яту; **кни́га ~и́т на столе́** китап өстәлдә ята **4.** (*быть, находиться*) булу; яту; **ключ ~и́т в карма́не** ачкыч кесәдә [ята] **5.** (*быть расположенным*) урнашу, утыру; **го́род ~и́т в доли́не** шәһәр үзәндә урнашкан **6.** (*иметь направление*) бару, карау; **путь ~ на се́вер** юл төньякка таба бара **7.** *перен. на ком* төшү, йөкләнү; **на нём ~а́т все забо́ты** барлык мәшәкатьләр аның өстенә төшә ♦ **душа́ (се́рдце) не ~и́т** *к кому-чему* күңел тартмый; **и ря́дом не ~а́л** *с чем* якын да килми; **~а́ть на боку́ (на печи́)** мич башында яту, эшсез яту; **~а́ть пласто́м** сузылып яту, кыймылдый алмый яту; **~а́ть в осно́ве** *чего берәр нәрсәнең* нигезендә яту; **на лице́ её ~и́т печа́ть страда́ния** аның йөзенә газаплану билгеләре чыккан
лежа́ться *несов.*: **не лежи́тся (не лежа́лось)** *кому* ятасы килми [иде], ятарга мөмкинлек юк [булмады], ятып торырга мөмкинлек юк [булмады]
лежа́ч||ий, -ая, -ее **1.** яткан; **в ~ем положе́нии** яткан хәлдә; **~ий больно́й** урында (түшәктә) ятып авыручы авыру; **под ~ий ка́мень вода́ не течёт** *посл.* ≈ яткан таш мүкләнә, йөргән таш шомара; ≈ еламаган балага имчәк бирмиләр **2.** ауган, егылган; **~ие дере́вья** ауган агачлар
ле́жбище *с* туплавык, яткылык; **~ ко́тиков** котиклар яткылыгы
лежебо́ка *м, ж разг.* тик ятучы, эшлексез, ялкау, яткалак
лёжк||а *ж* **1.**: **испо́ртиться от ~и** *прост.* озак ятып бозылу, озак ятудан бозылу; **лежа́ть в ~у** *прост.* тора алмыйча яту, бик авыр хәлдә яту **2.** *см.* **ле́жбище**
лежмя́ *нареч. прост.*: **~ лежа́ть** бер дә тормыйча яту, бик авыр хәлдә яту
ле́звие *с* **1.** йөз; **~ ножа́** пычак йөзе **2.** (*для безопасной бритвы*) лезвие
лезги́н *м* **1.** лезгин, лезгин кешесе
лезги́нка I *ж* лезгин хатыны (кызы)
лезги́нка II *ж* лезгинка (*кавказлылар бию; шул биюнең көе*)
лезги́нский лезгин[нар] ...ы; **~ язы́к** лезгин теле
лезги́ны *мн.* лезгиннар, лезгин халкы (*Дагстанда яшәүче халык*)
ле́з||ть *несов.* **1.** мену, үрмәләп менү; **~ть в го́ру** тауга менү; **~ть на де́рево** агачка менү **2.** (*пробираться*) керү; төшү; **~ть в окно́** тәрәзәдән керү **3.** *разг.* тыгылу,керү; **~ть в карма́н** кесәгә тыгылу **4.** *на кого-что* (*быть впору*) сыю, керү; **сапо́г не ~ет на́ ногу** итек аякка сыймый **5.** *к кому с чем* (*приставать*) бәйләну, йөдәтү, теңкәгә тию; **~ть с пусты́ка́ми** юк-бар нәрсәләр белән йөдәтү **6.** *разг.* (*сползать, налезать*) төшү; **ша́пка ~ет ему́ на глаза́** бүреге күзләренә төшә **7.** (*выпадать — о волосах*) коелу **8.** *разг.* (*расползаться — о материи*) сыпылу, сизрәү, тетелү **9.** *во что* (*вмешиваться*) тыгылу; **~ть не в своё де́ло** кеше эшенә тыгылу ♦ **[без мы́ла] ~ть в ду́шу** эченә-бавырына керү; **~ть из ко́жи [вон]** бөтен көчне кую, бөтен көчне салу; **~ть на глаза́ (в глаза́)** күзгә керү, авызга керү (*тыйнаксызлык турында*); **~ть на рожо́н** *прост.* утка керү; **не ~ть за сло́вом в карма́н** сүз сорап күршегә кермәү, тапкыр булу, сүзгә бай булу
лей *м см.* **ле́я**
лейбори́ст *м* лейборист, лейбористлар партиясе әгъзасы
ле́йка I *ж* **1.** (*для поливки*) лейка, сусипкеч **2.** (*черпак*) чүмеч (*су түгә торган*)
ле́йка II *ж* лейка (*фотоаппарат*)
лейкоци́ты *мн. физиол.* ак кан тәнчекләре, лейкоцитлар
лейтена́нт *м* лейтенант
лейтмоти́в *м* **1.** *муз.* лейтмотив, төп көй **2.** *перен.* лейтмотив, төп тема; **~ произведе́ния** әсәрнең төп темасы
лека́ло *с* лекало (**1.** *кәкре сызыклар сызу өчен махсус сызгыч* **2.** *катлаулы әйберләр эшләүдә кулланыла торган махсус модель, үрнәк, өлге, калып*)
лека́льщик *м* лекальщик, лекалолар ясаучы белгеч (эшче)
лека́рственн||ый, -ая, ое дару ...ы, дару ясый торган; **~ое расте́ние** дару үләне
лека́рство *с* дару; **приня́ть ~** дару эчү ♦ **~ от всех бед** һәртөрле бәладан коткару чарасы, әҗәл даруы
ле́карь *м уст.* табиб
ле́ксика *ж* лексика, сүзлек составы; **ру́сская ~** рус теленең лексикасы; **~ татарского языка́** татар теленең лексикасы
лексико́граф *м* лексикограф, сүзлекче, лексикография белгече
лексикографи́ческ||ий, -ая, -ое лексикографик, лексикография ..ы, лексикографиягә караган; **~ие труды́** лексикографиягә караган хезмәтләр; **~ий отде́л** лексикография бүлеге
лексикогра́фия *ж* лексикография (*сүзлекләр төзү теориясе һәм практикасы*)
лексико́лог *м* лексиколог, лексикология белгече.

лексикологи́ческ||ий, -ая, -ое лексикологик, лексикология ...ы; лексикологиягә караган; **~ие иссле́дования** лексикологик тикшеренүләр
лексиколо́гия *ж* лексикология (*тел белеменең телнең сүзлек составын өйрәнә торган тармагы*)
лексико́н *м* **1.** (*запас слов*) сүз запасы; **у него́ бе́дный ~** аның сүз запасы ярлы **2.** *уст.* (*словарь*) сүзлек; камус (*уст.*)
лекси́ческ||ий, -ая, -ое лексик, сүз ...ы; **~ое бога́тство языка́** телнең лексик байлыгы
ле́ктор *м* лектор, лекция сөйләүче, лекция укучы
лекто́рий *м* лекторий
лекцио́нн||ый, -ая, -ое лекция[ләр] ...ы, лекцияләр укый (укыла) торган; **~ый зал** лекцияләр залы; **~ые часы́** лекция сәгатьләре
ле́кци||я *ж* лекция; **чита́ть ~и** лекцияләр уку
леле́ять *несов. кого-что* кадерләү, иркәләү, назлау; **~ ребёнка** баланы иркәләү ♦ **~ мечту́** бик зур теләк белән яшәү, бик зур өмет белән яшәү; хыяллану; **~ наде́жду** өметләнү, өметләнеп тору, өмет (ышаныч) баглау; **~ мысль** уйлау; **~ слух** колакны хозурландыру (рәхәтләндерү, ләззәтләндерү), колакка ләззәт бирү
ле́мех, леме́х *м* төрән (*сабанда*)
леме́шн||ый, -ая, -ое төрәнле; **~ые ору́дия** төрәнле кораллар
ле́мма *ж мат.* лемма, ярдәмче теорема
лен *м ист.* лен (**1.** *урта гасырларда: вассалга бирелә торган поместье һәм шундый поместьены биләү хокукы* **2.** *шундый поместьены беләүченең йөкләмәләре*)
лён *м* җитен
лени́вец *м* **1.** *книжн.* ялкау, эшлексез, иренчәк **2.** *зоол.* ай-ай (*хайван*)
лени́вица *ж книжн. см.* **лени́вец** 1
лени́в||ый, -ая, -ое **1.** ялкау, иренчәк; **~ый учени́к** ялкау укучы **2.** сүлпән, әкрен; **~ые движе́ния** сүлпән хәрәкәтләр ♦ **~ые щи** свежий кәбестәдән пешерелгән щи; **~ые варе́ники** тышсыз эремчек пилмәне
ле́нинец *м* ленинчы, ленинизм тарафдары
лениниа́на *ж* лениниана
ленини́зм *м* ленинизм
лени́ться *несов.* ялкаулану, иренү; **эта де́вочка ле́нится** бу кыз бала ялкаулана
ле́нник *м ист.* ленчы (*урта гасырларда: ленга бирелгән поместьены биләүче*)
ле́нн||ый, -ая, -ое *ист.* ленга нигезләнгән; **~ая зави́симость** ленга нигезләнгән бәйлелек; **~ое владе́ние** ленга нигезендә җир биләү
ле́ность *ж* ялкаулык, иренчәклек
ле́нт||а *ж* **1.** тасма; **шёлковая ~а** ефәк тасма; **с телета́йпной ~ы** телетайп тасмасыннан **2.** (*фильм*) кинолента

ЛЕН-ЛЕТ

ле́нто *муз.* **1.** әкрен, салмак, сузып-сузып **2.** ленто (*әкрен, сузып-сузып башкарыла торган музыкаль пьесса яки анын бер өлеше*)

лентообра́зный, -ая, -ое тасмасыман; **~ые че́рви** тасмасыман суалчаннар

ле́нточник *м* тасма тукучы, тасма җитештерү эшчесе

ле́нточница *ж см.* **ле́нточник**

ле́нточн||ый, -ая, -ое **1.** тасма ...ы; **~ое произво́дство** тасма производствосы **2.** (*в форме ленты*) тасма ...; **~ые че́рви** тасма суалчаннар

лентя́й *м* ялкау, иренчәк [кеше]

лентя́йка *ж см.* **лентя́й**

лентя́йничать *несов. разг.* ялкаулану, ялкаулыкка бирелү (сабышу), ялкауланып яту

ленц||а́ *ж разг.*: **челове́к с ~о́й** ялкауракеше; **рабо́тать с ~о́й** ялкауланыбрак эшләү

ле́нчик *м* (*основа седла*) ияр тактасы, ияр агачы

лень *ж* **1.** ялкаулык, иренү; **побороть ~** ялкаулыкны җиңү **2.** *в знач. сказ. кому, разг.* иренә, ...сы килми; **~ идти́** барасы килми; **на́до бы пойти́, да ~** барырга иде дә, иренәм (барасым килми); **всё, кому́ не ~, его руга́ют** теләсә кем аны тирги

леопа́рд *м* каплан, леопард

лепестко́вый, -ая, -ое таҗ яфракчыклы, аерчалы

лепестко́к *м* таҗ яфракчыгы, аерча

ле́пет *м*: **де́тский ~** 1) баланың бытылдавы; 2) *перен.* балаларча бытылдау; **не́жный ~** гөрләшү, чөкердәшү; **~ ручья́** инешнең чылтырап агуы

лепета́ть *несов. что и без доп* **1.**(*о детях*) тәтелдәү **2.** *перен.* чылтырау, челтерәү; лыпыр-лыпыр килү

лепёшк||а *ж* **1.** (*мучное изделие*) көлчә, җәймә, юка **2.** сәдәп дару, таблетка; **мя́тные ~и** мятный таблеткалар

лепи́ть *несов.* **1.** *кого-что* (*статую, бюст*) әвәләү, әвәләп ясау **2.** *что* ясау, сылап ясау; **~ со́ты** кәрәз ясау; **~ гнездо́** оя ясау **3.** *что, разг.* ябыштыру; **~ ма́рки на конве́рты** конвертларга маркалар ябыштыру

лепи́ться *несов.* сырышып (сыланып) тору, ябышкан кебек тору; **по гора́м лепя́тся хи́жины** тауларга алачыклар сырышып тора

ле́пк||а *ж* **1.** *см.* **лепи́ть** 1; **уро́к ~и** әвәләп ясау дәресе **2.** (*то, что вылеплено*) әвәләп ясалган әйбер

лепн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*изготовленный лепкой*) әвәләп ясалган, сылап ясалган, күпертеп сылап ясалган; **~ые украше́ния** күпертеп сылап ясалган бизәкләр **2.** (*с украшениями*) сылап ясалган бизәкле, калку бизәкле; **~о́й потоло́к** сылап ясалган бизәкле түшәм **3.** әвәләп ясау ...ы; **~о́е иску́сство** әвәләп ясау сәнгате; **~ые рабо́ты** әвәләп ясау эшләре

лепрозо́рий *м* лепрозорий (*махау авыруы белән авыручыларны дәвалау учреждениесе*)

ле́пт||а *ж прям., перен,* өлеш; **внести́ свою́ ~у** *во что-л. берәр нәрсәгә* үз өлешеңне кертү

лес *м* **1.** урман; **сме́шанный ~** катнаш урман **2.** *собир.* (*срубленные деревья*) агач, агачлар (*материал*); **гнать ~** агач агызу **3.** *перен.* чиксез күп, бик күп, хисапсыз күп; **~ штыко́в** хисапсыз күп штык ♦ **как в ~у́** бернәрсә дә аңламыйча, бернәрсә дә белмичә; **кто в ~, кто по дрова́** *погов.* төрлесе төрлечә; кем ничек тели, шулай; ≈ Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә

леса́ I, **ле́са** *ж* кармак җебе

леса́ II *мн.* басма[лар], күперчә (*салына яки ремонтлана торган бина тирәли такталардан һ.б.ш. ясалган вакытлыча корылма*); **зда́ние в ~х** басмалар белән уратып алынган бина

леси́на *ж* (*срубленное дерево*) бүрәнә (*төзү эшенә китә торган киселгән агач*)

леси́стый, -ая, -ое урманлы

ле́ска *ж см.* **леса́** I

лесни́к *м* урманчы, урман каравылчысы

лесни́чество *с* лесничество

лесни́ч||ий *м* лесничий; урманчы хезмәткәр; **его́ назна́чили ~им** аны лесничий итеп билгеләделәр

лесн||о́й, -а́я, -о́е **1.** урман ...ы; **~о́й уча́сток** урман участогы; **~ые ресу́рсы** урман ресурслары **2.** урманлы; **~о́й райо́н** урманлы район **3.** (*связанный с лесоводством*) урманчылык ...ы; **~о́е де́ло** урманчылык эше **4.** агач ...ы; **~о́й склад** агач склады

лесово́д *м* урманчы, урманчылык белгече

лесово́дство *с* **1.** (*наука*) урманчылык, урманчылык фәне **2.** (*выращивание леса*) урманчылык, урманчылык эше

лесово́з *м* агач ташучы судно (машина); агач ташыгыч

лесово́зн||ый, -ая, -ое агач ташый торган; **~ые доро́ги** агач ташый торган юллар

лесозаво́д *м* агач заводы

лесозаготови́тельный, -ая, -ое агач хәзерләү ...ы, агач хәзерли торган; **~ пункт** агач хәзерләү пунктлары

лесозагото́вки *мн.* агач хәзерләү, агач материаллары хәзерләү (*дәүләт тарафыннан*)

лесозащи́тн||ый, -ая, -ое **1.** урман саклау ...ы; **~ая зо́на** урман саклау зонасы **2.** кыр (*тимер юл, сугару каналларын һ.б.ш.*) ышыклау ...ы; **~ая полоса́** кыр ышыклау урман полосасы (*буй урманнар*)

лесонасажде́ни||е *с* **1.** (*посадки леса*) урман утырту, агач[лар] утырту **2.** *обычно мн.* **~я** утыртма урман, утыртылган урман участогы; **полезащи́тные ~я** кыр ышыклау урманнары

лесопа́рк *м* урман-парк

лесопи́лка *ж разг.* такта яру заводы

лесопи́льный, -ая, -ое такта яру ...ы; **~ заво́д** такта яру заводы

лесопи́льня *ж разг.* (*артык зур булмаган*) такта яру заводы

лесополоса́ *ж* урман полосасы

лесопоса́дочн||ый, -ая, -ое урман утырту ...ы, агач утырту ...ы; **~ые рабо́ты** урман утырту эшләре

лесопромы́шленник *м* урман промышленнигы

лесопромы́шленность *ж* урман промышленосте

лесопромы́шленный, -ая, -ое урман промышленносте ...ы; **~ ко́мплекс** урман промышленносте комплексы

лесоразрабо́тки *мн.* агач хәзерләү эшләре

лесору́б *м* урман кисүче

лесору́бный, -ая, -ое урман кисү ...ы, урман кисә торган; **~ инструме́нт** урман кисү инструменты

лесосе́ка *ж* урман бүлемтеге; диләнке

лесоспла́в *м* сал агызу

лесоспла́вн||ый, -ая, -ое сал агызу ...ы; сал агыза торган, сал агызучы; сал агызу белән шөгыльләнүче; **~ая конто́ра** сал агызу конторасы

лесостепн||о́й, -а́я, -о́е урман-дала ...ы; урманлы дала ...ы; **~а́я зо́на** урман-дала зонасы

лесосте́пь *ж* урман-дала, урманлы дала

лесоту́ндра *ж* урман-тундра, урманлы тундра

лёсс *м* (*желтозём*) лёсс (*ачык сары төстәге тау токымы, сары туфрак*)

ле́стниц||а *ж* баскыч ♦ **поднима́ться по служе́бной ~е** хезмәт баскычыннан күтәрелү

ле́стничн||ый, -ая, -ое баскыч ...ы; **~ая ступе́нька** баскыч басмасы; **~ая кле́тка** баскыч урнашкан жир (*купкатлы йортларда*)

ле́стн||ый, -ая, -ое **1.** (*содержащий похвалу*) мактаулы, мактап ...; **~ый о́тзыв** мактап сөйләү **2.** (*дающий удовлетворение самолюбию*) горурланырлык; **~ое предложе́ние** горурланырлык тәкъдим

лесть *ж* ялагайланып мактау, яраргатырышып мактау, юмалау

лесхо́з *м* лесхоз, урман хуҗалыгы

лёт *м*: **по́сле не́скольких часо́в ~а** берничә сәгать очканнан соң; **на лету́** очканда, очып барганда, һавада; **хвата́ть на лету́** [сүз] авыздан чыгу белән аңлап алу, бик тиз аңлау

Ле́та *ж*: **кануть в Ле́ту** эссез югалу

лет||а́ *мн.* **1.** (*годы*) ел; **че́рез не́сколько лет** берничә елдан соң **2.** (*возраст*) яшь; **его́ до́чери пять лет** аның кызына биш яшь; **ему́ лет под шестьдеся́т** аңарга алтмыш яшьләр бар[дыр]; **они́ одни́х лет** алар яшьтәшләр; **сре́дних лет** урта яшьтәге; **мужчи́на сре́дних лет** ир уртасы; **в ~а́х** яше бар инде, олы яшьтә инде; **на́ших лет** безнең яшьләрдә; **он вы́глядит моло́же свои́х лет** ул яшенә караганда яшьрәк күренә; **с ма́лых лет** кечкенәдән [бирле], яшьтән [бирле]; **с де́тских лет** балачактан [бирле]; **войти́ в ~а́** яше бар инде, олыгаю, зураю; **он уже́ вы́шел из э́тих лет** аның яше чыккан инде; **во цве́те лет** чәчәк аткан чагында; **на скло́не (ста́рости) лет** карт көнендә, картаймыш көнендә; **по мо́ло-**

дости лет яшьлектән, яшьлеге белән, яшь булу сәбәпле; **ско́лько лет, ско́лько зим** күпме сулар акты, күпме вакыт үзды

лета́льный, -ая, -ое *мед.*: **~ исхо́д** үлем

летарги́ческий: **впасть в ~ сон** мәрткә китү

летаргия́ *ж* летаргия, мәрткә китү

лета́тельный, -ая, -ое очу ...ы, оча торган; **~ аппара́т** очу аппараты

лета́ть *несов.* очу, очып йөру

лет||е́ть *сов.* **1.** (*вообще*) очу; (*сюда*) очып килү; (*туда*) очып бару; **пти́ца ~и́т** кош оча; **пу́ля ~и́т** пуля оча; **самолёт ~и́т** самолёт оча **2.** (*мчаться*) очу, очкандай [тиз] чабу; (*сюда*) очкандай [тиз] чабып килү; (*туда*) очкандай [тиз] чабып бару; **~е́ть в автомоби́ле** автомобильдә очкандай чабу **3.** *разг.* (*падать*) егылу, егылып төшү, төшү; **~е́ть со сту́ла** урындыктан егылып төшү; **кни́ги ~я́т с по́лки** китаплар киштәдән төшә **4.** бик тиз үтү, бик тиз узу, очу; **вре́мя ~и́т** вакыт бик тиз уза **5.** *перен. разг.* бик тиз [югары] күтәрелү; бик тиз [түбән] төшү; **температу́ра ~и́т вверх** температура бик тиз югары күтәрелә; **а́кции ~я́т вниз** акцияләрнең курсы бик тиз төшә

лётка *ж* мич авызы (*домнада*)

ле́тн||ий, -яя, -ее җәйге; **~ий день** җәйге көн; **~ее пальто́** җәйге пальто

ле́тники *мн.* бер еллык бакча үсемлекләре

лётн||ый, -ая, -ое **1.** [самолётлар] очу өчен үнайлы; **~ая пого́да** очу өчен унайлы һава **2.** лётчик ...ы, очучы ...ы; **~ый костю́м** лётчик костюмы **3.** очучылар ...ы, очучылар әзерли торган; очучылык ...ы; **~ая шко́ла** очучылар мәктәбе; **~ое иску́сство** очучылык осталыгы

ле́то *с* җәй

лето́к *м* умарта тишеге, умарта авызы

ле́том *нареч.* җәен, җәй көне, җәй көнендә

летописа́ние *с* елъязмалар язу

летопи́сец *м* елъязмачы

летопи́сн||ый, -ая, -ое елъязма[лар] ...ы; **~ые сво́ды** елъязмалар җыелмалары

ле́топись *ж* елъязма

летосчисле́ние *с* **1.** ел исәбе

лету́н *м разг.* **1.** (*о птице*) яхшы очучан, яхшы очучы; (*о коне*) чапкын, йөгерек **2.** (*о человеке*) очкалак, летун

лету́нья *ж см.* **лету́н** 1

лету́честь *ж* (*быстрая испаряемость*) тиз очып бетүчәнлек

лету́ч||ий, -ая, -ое **1.** (*способный носиться в воздухе*) очучан, һавада оча торган, очып йөри торган, җиңел **~ий песо́к** һавада оча торган ком **2.** *перен.* (*способный быстро передвигаться*) күчмә ..., бер урыннан икенче урынга тиз күчеп йөри торган; **~ий отря́д** бер урыннан икенче урынга тиз күчеп йөри торган отряд **3.** *спец.* (*легко испаряющийся*) тиз очып бетүчән, тиз очып бетә торган, тиз очучан; **~ие масла́** тиз очып бетүчән майлар **4.** (*быстро проходящий*) тиз бетә торган, тиз утә торган; **~ая сыпь** тиз бетә торган тимгел **5.** кыска, ашыгыч [рәвештә ...ган]; **~ее собра́ние** ашыгыч [рәвештә оештырылган] җыелыш ♦ **~ая мышь** ярканат

лету́чка *ж разг.* **1.** летучка (*ашыгыч рәвештә оештырылган кыска җыелыш*); **редакцио́нная ~** редакция летучкасы **2.** (*подвижной отряд*) [*бер урыннан икенче урынга*] күчеп йөри торган отряд; күчмә отряд; **ремо́нтная ~** күчеп йөреп ремонт ясаучы эшчеләр төркеме

лётчик *м* очучы, лётчик; **~-космона́вт** очучы-космонавт

лётчица *ж* очучы хатын (кыз)

лече́бница *ж* дәвалау йорты; шифаханә

лече́бн||ый, -ая, -ое (*аврупарны*) дәвалау ...ы, дарулау ...ы, дәвалану...ы, дарулану ...ы; **~ые учрежде́ния** дәвалау учреждениеләре

лече́ни||е *с см.* **лечи́ть, лечи́ться**; **амбулато́рное ~е** амбулаториядә дәвалау, амбулаториягә йөреп дәвалану; **~е туберкулёза** туберкулёздан дәвалау; **курс ~я** дәвалау курсы

лечи́ть *несов. кого-что* дәвалау, дарулау

лечи́ться *несов.* дәвалану, дарулану

лечь *сов.* **1.** яту; **~ на дива́н** диванга яту **2.** (*расположиться спать*) яту, йокларга яту; **де́ти уже́ легли́** балалар йокларга яттылар инде **3.** (*распространиться на поверхности*) төшү, яту; **на мо́ре лёг тума́н** диңгез өстенә томан төште; **снег лёг пелено́й** ак япма булып кар төште **4.** *перен. на кого-что* төшү; **ответственность ля́жет на тебя́** җаваплылык синең өстеңә төшәчәк; **вся тя́жесть рабо́ты легла́ на его́ пле́чи** эшнең бөтен авырлыгы аның җилкәсенә төште **5.** **~ на но́вый курс** яңа курс (юнәлеш) алу (*самолёт, судно турында*); **~ в дрейф** дрейфка кую (*корабльне*) ♦ **~ костьми́** баш кую, һәлак булу

ле́ший *м* шүрәле, урман иясе

лещ *м* корбан балыгы

лещи́на *ж* (*орешник*) чикләвек куагы

ле́я *ж* лея (*Румыниядә акча берәмлеге*)

лжесвиде́тель *м юр.* ялган шаһит, ялган танык

лжесвиде́тельница *ж см.* **лжесвиде́тель**

лжесвиде́тельство *с юр.* ялган шаһитлык

лжесвиде́тельствовать *несов. юр.* ялган шаһитлык итү, ялган күрсәтүләр бирү

лжеуче́ние *с* ялган тәгълимат

лжец *м* ялганчы, алдакчы

лжи́в||ый, -ая, -ое **1.** ялганчы, алдакчы, ялганларга яратучан; **~ый челове́к** ялганчы кеше **2.** ялган, алдаулы; **~ое сообще́ние** ялган хәбәр **3.** ясалма; **~ая улы́бка** ясалма елмаю

ли (ль) *частица и союз* ...мы; **придёшь ли ты?** килерсеңме син?; **ра́но ли, по́здно ли, но приду́** иртәме, соңмы, килермен

лиа́на *ж* лиана (*эссе якларда үсә торган үрмәле үсемлек*)

либерали́зм *м* **1.** *полит.* либерализм **2.** (*снисходительность*) либераллык, принципсызлык; **гнило́й ~** черек либерализм

либера́льничать *несов. разг.* либераллык күрсәтү

либера́льн||ый, -ая, -ое **1.** *полит.* либерализм ...ы, либерал[лар] ...ы; **~ая па́ртия** либераллар партиясе **2.** либераль, либералларча ...; **~ые взгля́ды** либералларча карашлар

ли́бо *союз разд.* я, яисә, яки; **~ пан, ~ пропа́л** *погов.* ≈ я уңа, я туңа

либретти́ст *м* либретточы, либретто язучы

либре́тто *с нескл.* либретто

ли́вень *м* койма яңгыр, коеп яуган яңгыр; **хлы́нул ~** яңгыр коеп ява башлады

ли́вер *м* ливер (*суйган хайванның үпкә-бавыры, йөрәге һәм талагы*)

ливре́йн||ый, -ая, -ое ливрея ...ы; ливреялы, ливрея кигән; **~ лаке́й** ливреялы лакей

ливре́я *ж* ливрея (*швейцарлар, лакейлар, кучерлар кия торган укалы махсус кием*)

ли́га *ж* лига, берләшмә; **Ли́га на́ций** *ист.* Милләтләр лигасы

лигату́ра *ж* лигатура (**1.** *хим. алтынга яки көмешкә эретеп катыштырылган бакыр яки аккургаш* **2.** *филол. хәрефләрне бер-берсенә керештереп язу* **3.** *мед. операция вакытында кан тамырларын бәйли торган ефәк җеп яки кетгут*)

ли́дер *м* **1.** лидер, җитәкче, җитәкләүче, әйдәп баручы **2.** лидер, алдан баручы, беренче булып баручы (*спортта*)

ли́дерство *с* лидерлык; **борьба́ за ~** лидерлык өчен көрәш

лиди́рование *с см.* **лиди́ровать**

лиди́ровать *несов.* лидер булып бару, беренче булып бару, алда бару

лиза́ть *несов. кого-что* ялау; **~ таре́лку** тәлинкә ялау; **ого́нь ли́жет сте́ны до́ма** ялкын өйнең стеналарын ялый

лизну́ть *сов. однокр. кого-что* ялап алу (кую)

лизоблю́д *м разг. презр.* тәлинкә ялаучы (тотучы), ялагай

лизо́л *м* лизол (*дезинфекция ясау өчен кулланыла торган сыекча*)

лик I *м* **1.** *поэт.* йөз **2.** *перен.* йөз, тышкы күренеш; **~ луны́** айның йөзе

лик II *м уст.*: **причи́слить к ~у свяще́нных** изгеләр арасына кертү, изгеләрдән исәпләү

ликбе́з *м ист.* ликбез (*грамотасызлыкны бетерү, укый-яза белмәүне бетерү*)

ЛИК-ЛИС

ликвида́тор *м ист.* ликвидатор, ликвидаторлык яклы кеше

ликвида́торство *с* ликвидаторлык

ликвидацио́нн||ый, -ая, -ое бетерү (ябу) ...ы, ликвидация ...ы; **~ая коми́ссия** ликвидация комиссиясе

ликвида́ция *ж* **1.** (*прекращение деятельности*) бетерү, ябу; **~ тре́ста** тресты ябу **2.** (*уничтожение*) бетерү, юкка чыгару; **~ негра́мотности** грамотасызлыкны бетерү

ликвиди́ровать *сов., несов. что* **1.** бетерү, ябу; **~ отде́л** бүлекне ябу **2.** бетерү, юкка чыгару; **~ отстава́ние** артта калуны бетерү

ликвиди́рова||ться *сов., несов.* бетү, ябылу; **фи́рма ~лась** фирма ябылды

ликёр *м* ликёр

ликёрный, -ая, -ое ликёр ..ы; **~ заво́д** ликёр заводы

ликова́ние *с см.* **ликова́ть**

ликова́ть *несов.* шатлану, куану, сөенү

лиле́йн||ый, -ая, -ое **1.** *поэт.* ап-ак, лалә кебек ак; **~ое чело́** ап-ак йөз **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *бот.* лаләчәләр

лилипу́т *м* лилипут, кәрлә

лилипу́тка *ж* лилипут, кәрлә хатын (кыз)

ли́лия *ж* лалә ♦ **~ водяна́я** төнбоек

лилове́ть *несов.* аксыл шәмәха төскә керү

лило́вый, -ая, -ое аксыл шәмәха, миләүшә төсле

лима́н *м* лиман (*култык*)

лими́т *м* лимит, чик норма

лимити́ровать *сов., несов. что* лимит билгеләү, чик норма билгеләү, чикләү

лими́т||ный, -ая, ое лимит ...ы; лимит ...; **~ые це́ны** лимит бәяләр

лимо́н *м* лимон (*агачы һәм җимеше*) ♦ **как вы́жатый ~** сәләте (көче) беткән, хәлдән тайган кеше

лимона́д *м* лимонад

лимо́нн||ый 1. лимон ...ы; **~ое де́рево** лимон агачы **2.** (*о цвете*) лимон төсле, ачык сары төсле

лимузи́н *м* лимузин (*җиңел автомобильнең бер төре*)

ли́мфа *ж* лимфа

лимфати́ческ||ий, -ая, -ое лимфа...ы; **~ие же́лезы** лимфа бизләре

лингви́ст *м* лингвист, телче, тел белгече

лингви́стика *ж* лингвистика, тел белеме, тел гыйлеме

лингвисти́ческ||ий, -ая, -ое лингвистика ...ы; лингвистик; **~ие иссле́дования** лингвистик тикшеренүләр

лине́йк||а I *ж* **1.** сызык; **тетра́дь в ко́сую ~у** кыек сызыклы дәфтәр **2.** сызгыч, линейка; **масшта́бная ~а** масштаб линейкасы; **деревя́нная ~а** агач сызгыч **3.** линейка; **вече́рняя ~а** кичке линейка

лине́йка II *ж уст.* линейка (*экипажның бер төре*)

лине́йн||ый, -ая, -ое **1.** (*имеющий вид линии*) сызыклы, сызыксыман; **~ая мо́лния** сызыклы яшен **2.** (*состоящий из линий*) сызык-сызык, сызыклардан торган, сызылмалы; **~ый орна́мент** сызылмалы орнамент **3.** *уст.* (*пограничный*) чик буендагы, ил чигендәге, чик буенда урнашкан; **~ый каза́к** ил чигендә торучы казак; **~ая стани́ца** чик буендагы станица **4.** *уст.* регуляр; **~ые войска́** регуляр гаскәрләр **5.** линия...ы, линиядә эшләүче; **~ый связи́ст** линиядә эшләүче элемтәче ♦ **~ая ско́рость** *физ.* сызыкча тизлек; **~ые ме́ры** озынлык үлчәве берәмлекләре; **~ые ли́стья** кыяк яфраклар

лине́йчатый, -ая, -ое *бот.* җыерчыклы, сызыклы-сызыклы; **~ лист** сызыклы-сызыклы яфрак

линёк I *м уменьш. от* **линь I**

линёк II *м уменьш. от* **линь II**

ли́нза *ж* линза, ясмык пыяла (*кабарынкы яки батынкы оптик пыяла*)

ли́ни||я *ж* **1.** сызык; **прямо́я ~я** туры сызык; **провести́ ~ю** сызык сызу **2.** сызык, юнәлеш, юл; **~я горизо́нта** офык сызыгы; **береговáя ~я** яр сызыгы; **~я прице́ла** төзәү сызыгы **3.** саф, рәт; **постро́ить дома́ в одну́ ~ю** йортларны бер рәткә салу **4.** юл; **возду́шная ~я** һава юлы; **трамва́йная ~я** трамвай юлы **5.** линия; **телегра́фная ~я** телеграф линиясе **6.** як; тараф; **родня́ по ~и отца́** ата ягыннан кардәш **7.** *перен.* линия, юнәлеш (*карашта, эштә, уз-үзен тотышта*); **генера́льная ~я па́ртии** партиянең генераль линиясе; **~я поведе́ния** үзен тотышы **8.** *перен.* өлкә; **рабо́тать по профсою́зной ~и** профсоюз өлкәсендә эшләү ♦ **вести́ (гнуть) свою́ ~ю** үзенекен итү, үзенекен итәргә тырышу; **по ~и наиме́ньшего сопротивле́ния** иң жиңел юлдан

линко́р *м* линкор

линова́ть *несов. что* сызу, сызыклар сызу

лино́леум *м* линолеум

линоти́п *м* линотип (*наборны юлы-юлы белән коеп җыя торган типография машинасы*)

линоти́пный, -ая, -ое линотипта җыелган; **~ набо́р** линотипта җыелган набор

линчева́ть *сов. несов. кого-что* судсыз җәзалау, кыйнап үтерү, линчевать итү

линь I *м* карабалык

линь II *м мор.* бау, нечкә аркан

линю́чий, -ая, -ое *разг.* тиз уңучан,тиз уңа торган, төсен тиз югалта торган; **~ си́тец** төсен тиз югалта торган ситсы

линя́л||ый, -ая, -ое *разг.* [төсе] уңган, төсе киткән; **~ая мате́рия** төсе уңган тукыма

линя́||ть *несов.* **1.** уңу, төс китү, төсен югалту; **пла́тье ~ет** күлмәк уңа **2.** (*о коровах, лошадях и т.п.*) йон кою, ябага кою; (*о зайцах*) төстән чыгу, төс алмаштыру; (*о змеях*) кабык салу; (*о птицах*) йон кою

ли́па I *ж* (*дерево*) юкә, юкә агачы

ли́па II *ж прост.* ялган (*ялган кәгазь, сүз, вәгъдә һ.б.ш.*)

ли́пк||ий, -ая, -ое ябышучан, ябышкак, сыланучан, ябыша торган, сылана торган; **~ая гли́на** сылана торган балчык

ли́пн||уть *несов* **1.** *к кому-чему* ябышу, сылану; **грязь ~ет к нога́м** аякларга пычрак ябыша **2.** *перен. к кому-чему, разг.* (*неотвязно приставать*) бәйләнү, сагыз булу, ябышу **3.** *разг.* бер-берсенә ябышу; **гу́бы ~ут** иреннәр бер-берсенә ябыша

ли́пов||ый I, -ая, -ое юкә ...ы; **~ый мёд** юкә балы; **~ая алле́я** юкә аллеясы

ли́пов||ый II, -ая, -ое *прост.* ялган ...; **~ое удостовере́ние** ялган таныклык

липу́чий, -ая, -ее *прост. см.* **ли́пкий**

липу́чка *ж разг.* ябыша торган кәгазь (*пластырь һ.б.ш.*)

ли́ра I *ж* лира, саз (*музыка коралы*)

ли́ра II *ж* лира (*Италиядә һәм Төркиядә акча берәмлеге*)

лири́зм *м* **1.** (*лирическое содержание*) лиризм, лириклык; **~ му́зыки Чайко́вского** Чайковский музыкасының лиризмы **2.** (*лирическое настроение*) лирик настроение, нечкә хисләр; **впасть в ~** нечкә хисләргә бирелү

ли́рик *м* лирик, лирик шагыйрь

ли́рика *ж* **1.** лирика (*поэзиянең төре һәм шундый әсәрләр җыелмасы*) **2.** *разг.* лирика, хис

лири́ческ||ий, -ая, -ое *в разн. знач.* лирика ...ы; лирик; **~ая поэ́зия** лирик поэзия; **~ое настрое́ние** лирик настроение; **~ое сопра́но** *муз.* лирик сопрано ♦ **~ое отступле́ние** *лит.* лирик чигенеш (чигенү)

лири́чность *ж* лирикалылык, хисләргә бирелүчәнлек

лири́чный, -ая, -ое лирик, лирикалы, хисле, лирик настроениеле, күтәренке-эмоциональ; **~ тон** лирик тон

лис *м* ата төлке

лиса́ *ж* **1.** төлке; **хи́трый как ~** төлке кебек хәйләкәр, хәйләкәр төлке **2.** (*мех*) төлке мехы

лисёнок *м* төлке баласы

ли́с||ий, -ья, -ье **1.** төлке ...ы; **~ья нора́** төлке өне; **~ий след** төлке эзе **2.** төлке ...; **~ья шу́ба** төлке тун **3.** *перен.* хәйләкәр, хәйләле, ялагай, ялагайланып ...

лиси́н||ый, -ая, -ое *см.* **ли́сий** 1; **~ая нора́** төлке өне (оясы)

лиси́ца *см.* **лиса́**

лиси́чка *ж* **1.** *уменьш.-ласк. от* **лиси́ца 2.** (*гриб*) этәч гөмбәсе

лист *м* **1.** (*мн.* **~ья** и **~ы**) яфрак; **дубо́вый ~** имән яфрагы **2.** (*мн.* **~ы**) табак; (*напр. тетради*) бит; **оди́н ~ бума́ги** бер табак кәгазь; **~ желе́за** бер табак калай; **кни́га в деся́ть печа́тных ~о́в** ун басма табаклы китап ♦ **с ~а́ [игра́ть, петь]** алдан хәзерлексез, алдан хәзерләнмичә, нотадан карап кына [уйнау, жырлау]

листа́ж *м* листаж (*китапның куләмен билгели торган басма табаклар саны*)

листа́ть *несов. что* актару, ачкалау, ачып-ачып ябу (*китап битләрен*)

листва́ *ж собир.* яфраклар

ли́ственница *ж* карагач

ли́ственн||ый, -ая, -ое **1.** яфраклы; **~ое де́рево** яфраклы агач **2.** яфраклы

агачлар ...ы; **~ый лес** яфраклы агачлар урманы

листóвка *ж* листовка

листов||óй, -áя, -óе **1.** яфрак ...; **~óй табáк** яфрак тәмәке **2.** табаклы; **~óе желéзо** табаклы калай

листóк *м* **1.** *уменьш. от* **лист**; **2.** (*бланк*) кәгазь; **контрóльный ~** контроль кәгазе

листопáд *м* яфрак коелу

литáвры *мн.* литавра (*музыка коралы*)

литéйн||ый, -ая, -ое **1.** металл кою ...ы; **~ый цех** металл кою цехы; **~ое дéло** металл кою эше **2.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж* металл кою эшләре мастерское

литéйщик *м* металл коючы, металл кою белгече

лúтер *м* литер (*юлда йөргәндә билет хакын бөтенләй түләмәү яки льгота белән файдалану хокукы бирә торган таныклык*)

лúтера *ж* **1.** *уст.* (*буква*) хәреф **2.** *полигр.* металл хәреф

литерáтор *м* **1.** (*писатель*) әдип, язучы **2.** (*литературовед*) әдәбиятчы

литерáтур||а *ж в разн. знач.* әдәбият; **рýсская ~а** рус әдәбияты; **теóрия ~ы** әдәбият теориясе; **политúческая ~а** политик әдәбият

литерáтурн||ый, -ая, -ое **1.** (*относящийся к художественной литературе*) әдәби; **~ые круги́** әдәби даирәләр; **~ое произведéние** әдәби әсәр **2.** (*писательский*) язучы ...ы; әдип ...ы; **~ый труд** язучы хезмәте **3.** әдәби; **~ый стиль** әдәби стиль **4.** әдәбият ...ы; **~ый вéчер** әдәбият кичәсе ♦ **~ый язы́к** әдәби тел

литературовéд *м* әдәбиятчы, әдәбият белгече

литературовéдение *с* әдәбият белеме

литературовéдческ||ий, -ая, -ое әдәбият белеме ...ы; **~ие нáуки** әдәбият белеме фәннәре

лúтерный I, -ая, -ое (*льготный*) литерлы; **~ биле́т** литерлы билет

литéрн||ый II, -ая, -ое *разг.* литерлы, хәреф белән билгеләнгән; **~ая лóжа** литерлы ложа

лúтий *м хим.* литий

литóвец *м* литвалы, Литва кешесе

литóвка *ж* литвалы хатын (кыз)

литóвский, -ая, -ое литвалы[лар] ...ы, Литва ...ы; **~ язы́к** литвалылар теле

литóвцы *мн.* литвалылар, Литва халкы

литóграф *м* ташбасмачы, литограф

литографúровать *сов., несов. что* ташбасмада басу, литография юлы белән басу, литографиядә басу

литогрáфия *ж* **1.** (*способ печатания*) литография, ташбасма **2.** (*оттиск*) литография (*ташбасма ысулы белән төшерелгән рәсем*) **3.** (*мастерская*) литография, ташбасмада басу мастерское, ташбасмаханә

лит||óй, -áя, -óе эретеп коелган, коеп ясалган, коелма; **~áя сталь** эретеп коелган корыч; **~ы́е издéлия** коеп ясалган әйберләр

литр *м* литр

литрáж *м* литраж

литрóвый, -ая, -ое бер литрлы, бер литр сыешлы

лить *несов.* **1.** *что* агызу, кою, түгү; салу, сибу, **~ вóду из лéйки** лейкадан су агызу **2.** (*литься*) агу, агып тору; кою; **водá льёт из крáна** су кранннан агып тора; **дождь льёт как из ведрá** яңгыр чиләкләп коя **3.** *перен.* (*о свете, запахе*) чәчү, тарату **4.** *что* (*эретеп*) кою, коеп ясау; **~ медáль** медаль кою ♦ **~ вóду** *на чью мéльницу бирәүнең* тегермәненә кою; **~ слёзы** күз яшьләре түгү (кою)

лить||ё *с* **1.** *см.* **лить** 4; **машúна для ~я́ метáлла** металл кою машинасы **2.** *собир.* коелма, (*металлдан*) коеп ясалган әйберләр; **чугýнное ~ё** чуеннан коеп ясалган әйберләр

лúть||ться *несов.* **1.** агу, түгелү; **из крáна льётся водá** кранннан су ага; **водá льётся чéрез край** читеннән су түгелә; **слёзы лью́тся из глаз** күзләрдән яшь ага; **кровь ~ лáсь рекóй** дәрья булып кан акты **2.** *перен.* (*раздаваться*) яңгырау; **пéсни лью́тся** җырлар яңгырый **3.** *перен.* (*о свете, запахе*) сибелү, чәчелү, төшү **4.** *перен.* (*свободно излагаться — о речи, слоге*) агылу **5.** *страд. от* **лить** 1, 3, 4

лиф *м* лиф

лифт *м* лифт

лифтёр *м* лифтчы, лифтта эшләүче

лифтёрша *ж разг.* лифтчы хатын (кыз)

лúфчик *м* лифчик

лихáч *м* лихач; **шофёр- ~** лихач шофёр

лихáчество *с* лихачлык

лихв||á *ж*: **с ~óй** артыгы белән

лúх||о *с прост.* явызлык, яманлык, бәхетсезлек ♦ **поминáть ~ом** *кого-что* начарлык белән искә алу, начар сүз белән искә алу; **хватúть (хлебнýть) ~а** бик күп кайгы-хәсрәт чигү, авырлыклар күрү

лихоúмец *м уст.* ришвәтче, взятка алучы

лихоúмство *с уст.* ришвәтчелек, взятка алу[чылык]

лих||óй I, -áя, -óе *уст.* **1.** (*злой*) явыз яман; **~óй человéк** явыз кеше **2.** (*трудный*) авыр, начар; **~áя годúна** авыр ел ♦ **~á бедá начáло** бер башлап җибәрүе генә кыен

лих||óй II, -áя, -óе *разг.* **1.** (*смелый*) җилле, куркусыз, кыю, чая, тәвәккәл; **~óй пáрень** җилле егет; **~áя атáка** кыю атака **2.** (*быстрый*) кызу, тиз; **~áя ездá** кызу бару **3.** (*искусный*) оста, житез, җилле; **~óй танцóр** оста биюче **4.** (*бойкий*) ялкынлы, җилле; **~áя пéсня** ялкынлы җыр

лихолéтье *с уст.* авыр замана, авыр еллар (*төрле чуалышлар, тынычсызлыклар, авырлыклар һ.б.ш чоры*)

лихорáд||ить *несов.* **1.** өшетү, бизгәк тоту; **больнóй ~ит** авыруны бизгәк тота **2.** *безл. кого-что* туңдыру, калтырату; **меня́ ~ит** мине туңдыра **3.** *перен. безл. кого-что* буталчыклык (тәртипсезлек) тудыру, ыгы-зыгы чыгару; дер китерү; **стрóйку ~ит** төзелешне дер китерә

лихорáдка ж **1.** (*болезнь*) бизгәк; өшетү **2.** *разг.* (*сыпь на губах*) чабырткы

3. *перен.* ыгы-зыгы, буталчыклык; **биржевáя ~** биржадагы ыгы-зыгы

лихорáдочн||ый -ая, -ое **1.** (*страдающий лихорадкой*) бизгәк белән авыручы; **~ый больнóй** бизгәк белән авыручы **2.** (*бывающий при лихорадке*) бизгәк тотканда була торган; **~ый бред** бизгәк тотканда була торган саташу **3.** *перен.* ярсулы, ашыгыч, шашынулы; ашыгыч рәвештә ..., шашынып ...; **~ая дéятельность** шашынып эшләү; **~ые приготовлéния** шашынулы әзерләнүләр

лицевáть *несов. что* **1.** (*перелицовывать*) әйләндереп тегү, тискәре ягын әйләндереп тегү **2.** *спец.* (*облицовывать*) тышлау

лицев||óй, -áя, -óе **1.** бит ...ы; йөз ..ы; **~ы́е кóсти** бит сөякләре **2.** тышкы, өске, алгы, уң; **~áя сторонá матéрии** тукыманың уң ягы; **~áя сторонá здáния** бинаның алгы ягы **3.** *спец.* (*иллюстрированный*) рәсемле, бизәкле; **~áя рýкопись** рәсемле кулъязма ♦ **~óй счёт** *фин.* шәхси счёт (*билгеле бер кешенең исемена ачылган счёт*)

лицедéйство *с уст.* **1.** (*театральное представление*) тамаша **2.** (*притворство*) икейөзлелек, монафыйклык, ялган кыланыш

лицезрéть *несов. кого-что, книжн.* күрү, үз күзе белән күрү

лицéйст *м* лицейда укучы, лицейда тәрбияләнүче

лицéй *м* лицей

лицемéр *м* икейөзле, монафыйк [кеше]; риялы (*редко*)

лицемéрие *с* икейөзлелек, монафыйклык; рия, риялылык (*редко*)

лицемéрить *несов.* икейөзлеләнү, монафыйклану, икейөзлелек (монафыйклык) күрсәтү; риялану (*редко*)

лицемéрка *ж* икейөзле (монафыйк) хатын (кыз)

лицемéрн||ый, -ая, -ое **1.** икейөзле, монафыйк; риялы (*редко*); **~ая жéнщина** икейөзле хатын **2.** монафыйкларча ..., икейөзлеләнеп эшләнгән, икейөзлеләнеп ...; **~ый постýпок** икейөзлеләнеп эшләнгән эш

лицéнзия *ж спец.* лицензия (*берәр төрле товарны чит илгә чыгару яки чит илдән керту хокукы; шушы хокукны раслый торган документ*)

лицеприя́тн||ый, -ая, -ое *книжн.* яклаулы, яклауга нигезләнгән; **~ое решéние** яклауга нигезләнгән карар

лиц||ó *с* **1.** бит, йөз, чырай; **мýскулы ~á** бит мускуллары; **знакóмое ~ó** таныш йөз; **знать** *кого-л.* **в ~ó** күреп белү; **с ~á некрасúв** төскә-биткә ямьсез; **с румя́ным ~óм** алсу йөзле; **человéк с привéтливым ~óм** ачык чырайлы кеше **2.** *перен.* (*индивидуальность*) йөз; **политúческое ~ó áвтора** авторның политик йөзе; **не имéть своегó ~á** үз йөзе булмау, шәхси йөзе булмау **3.** (*человек*) шәхес, кеше; **историúческое ~ó** тарихи шәхес;

ЛИЧ-ЛОГ

официа́льное ~ó рәсми кеше; **физи́ческое** ~ó физик шәхес (*җәмгыятнең тулы хокуклы кешесе*); **юриди́ческое** ~ó юридик шәхес (*хокуклары һәм бурычлары булган оешма, предприятие, учреждение*) **4.** тышкы (өске, алгы) як; **гла́дить матери́ю с** ~á тукыманы уң ягыннан үтүкләү **5.** *грам.* зат; **пе́рвое** ~ó беренче зат ♦ **в** ~é *кого* йөзендә; **в** ~ó **[говори́ть, брани́ть]** *что* ачыктан-ачык, йөзенә бәреп әйтү; **с** ~á **не во́ду пить** *посл.* ≈ төсне табакка куймыйлар; **смотре́ть (гляде́ть) в** ~ó *чему* күзенә карау; кыю булу; **стере́ть (смести́) с** ~á **земли́** җир йөзеннән себереп ташлау, юк итү, бетерү

личи́н||а *ж* **1.** битлек, маска; **под** ~**ой** *чего-л.* маскасы астында; **сорва́ть** ~**у** *с кого-л.* битлеген ачу, фаш итү; **сбро́сить** ~**у** битлекне алып ташлау **2.** (*у замка*) йозак йөзлеге

личи́нка I *ж* корт, личинка

личи́нка II *ж* **1.** *см.* **личи́на** 2; **2.** *воен.* личинка (*мылтык затворының бер өлеше*)

ли́чно *нареч.* үзе (*с аффиксами принадлежности*); **переда́й** ~ **ему́** аңарга үзенә тапшыр; **ответственность па́дает** ~ **на Вас** җаваплылык Сезнең үзегезгә төшә

личн||о́й, -а́я,-о́е бит ...ы; ~**о́е мы́ло** бит сабыны; ~**о́е полоте́нце** бит сөлгесе

ли́чность *ж* шәхес, кеше; **неприкоснове́нность** ~**и** шәхеснең кагылгысызлыгы; **удостовере́ние** ~**и** шәхес таныклыгы; **установи́ть** ~**ь** *кого-л. берәүнең* кемлеген билгеләү ♦ **прошу́ без** ~**ей!** аерым шәхесләргә (кешеләргә) кагылмавыгызны үтенәм!

ли́чн||ый, -ая, -ое **1.** (*осуществляемый лично*) үз; шәхси; ~**ая инициати́ва** шәхси инициатива; **необходи́мо его́** ~**ое прису́тствие** аның үзенең булуы кирәк **2.** (*касающийся одного лица*) шәхси; ~**ая жизнь** шәхси тормыш; ~**ое де́ло** шәхси эш **3.** *грам.* зат ...ы: ~**ые местоиме́ния** зат алмашлыклары ♦ ~**ый соста́в** эшләүчеләр составы, хезмәт итүчеләр составы (*учреждениедә, предприятиедә, армиядә*)

лиша́й *м* **1.** *см.* **лиша́йник; 2.** тимрәү (*авыру*)

лиша́йник *м бот.* лишайник, мүк

лиша́ть *несов. см.* **лиши́ть**

лиша́ться *несов.* **1.** *см.* **лиши́ться; 2.** *страд. от* **лиша́ть**

лише́ни||е *с* **1.** *см.* **лиши́ть, лиши́ться; ~е свобо́ды** иректән мәхрүм итү; ~**е избира́тельных прав** сайлау хокукыннан мәхрүм итү **2.** *обычно мн.* ~**я** мохтаҗлык[лар], авырлыклар[лар], кыенлык-[лар]

лиши́ть *сов. кого-что, кого-чего* мәхрүм итү, алу, ...сыз калдыру; ~ **свобо́ды** иректән мәхрүм итү; ♦ ~ **жи́зни** үтерү; ~ **себя́ жи́зни** үзенә кул салу, үз-үзеңне үтерү; ~ **сло́ва** сүз бирмәү; **он не лишён чу́вства ю́мора** аңарда юмор юк түгел

лиши́ться *сов. кого-чего* югалту, ...сыз калу, мәхрүм булу, мәхрүм калу; ~ **дове́рия** ышанычны югалту; ~ **зре́ния** сукыраю; ~ **поко́я** тынычлыкны югалту; ~ **рассу́дка** акылдан язу; ~ **сна** йокысыз калу; ♦ ~ **чувств** аңын югалту, һуштан язу

ли́шн||ий, -яя, -ее **1.** (*избыточный*) артык; ~**ие де́ньги** артык акча **2.** (*ненужный*) артык, кирәксез, кирәге булмаган; ~**ие ве́щи** кирәге булмаган әйберләр **3.** (*дополнительный*) тагы; **взгляну́ть** ~**ий раз** тагы бер тапкыр карап алу ♦ **без** ~**их слов (рассужде́ний)** күп сөйләнеп тормастан; **бы́ло бы не** ~**им...** ... артык булмас иде; **говори́ть (сказа́ть)** ~**ее** артык сөйләү; **не** ~**ее** артык булмас; **позво́лить себе́** ~**ее** артык кылану; **с** ~**им** ...дан артык; **два кило́ с** ~**им** ике килодан артык

лишь 1. *частица огранич.* (*только*) гына, бары ... гына, бары тик ...гына, тик ... гына; фәкать; **одного́** ~ **нет** берәве генә юк, берсе генә җитми; ~ **бы не опозда́л** ул соңга гына калмасын иде; **он всего́** ~ **како́й-то секрета́рь** ул бары тик секретарь гына **2.** *союз присоед.* (*едва, как только*) ...ган гына иде, ..гач та, ...ү белән; ~ **показа́лась ста́нция, пассажи́ры засуети́лись** станция күренү белән пассажирлар ыгы-зыгы килә башлады; ~ **то́лько** *см.* **лишь** 2

лоб *м* маңгай; **высо́кий** ~ киң маңгай ♦ **на лбу́ напи́сано** *у кого что* маңгаена язган, йөзеннән беленеп (күренеп) тора; **в** ~ 1) *воен.* турыдан, турыдан-туры; 2) *мор.* каршы, хәрәкәткә каршы; **что в** ~**, что по́ лбу** *погов.* [нишләсәң дә] барыбер

лоба́стый, -ая, -ое *прост.* киң маңгайлы

лобза́ть *несов. кого-что, уст.* үбү

ло́бзик *м* лобзик (*кысалы кечкенә нечкә пычкы*)

лобко́в||ый, -ая, -ое *анат.* касык...ы; ~**ые ко́сти** касык сөякләре

ло́бн||ый -ая, -ое маңгай ...ы; ~**ая кость** маңгай сөяге ♦ ~**ое место́** *уст.* 1) патша боерыгын игълан итү урыны; 2) җәзалау урыны, җәза мәйданы

лобов||о́й, -а́я, -о́е *спец.* **1.** (*направленный в упор*) каршы; турыдан-туры, туры; ~**о́й ве́тер** каршы җил; ~**а́я ата́ка** туры атака **2.** (*передний*) алгы; ~**о́е стекло́** алгы пыяла

лобогре́йка *ж* лобогрейка, ургыч машина

лобо́к *м анат.* касык, касык сөяге

лоботря́с *м см. прост.* эшлексез, ялкау

лоботря́сничать *несов. прост.* эшсез йөрү, ялкаулыкка бирелү

лобыза́ть *несов. см.* **лобза́ть**

лов *м см.* **лови́ть** 1; ~ **ры́бы** балык тоту

ловела́с *м* ловелас (*хатын-кызлар артыннан йөрүче, хатын-кызларны алдаучы*)

лове́ц *м* (*рыболов*) балыкчы, балык тотучы; (*охотник*) аучы, сунарчы; **на** ~**ца́ и зверь бежи́т** *погов.* ≈ кулга үзе килеп керде

лови́ть *несов. кого-что* **1.** тоту, тотып алу; ~ **птиц** кошлар тоту; ~ **мяч** туп тоту **2.** *перен.* тоту; туры китерү; ~ **на лжи** ялганын тоту **3.** тоту, аулау; ~ **такси́** такси тоту; ~ **жениха́** кияү аулау ♦ ~ **ка́ждое сло́во** *кого* авызана карап тору; ~ **на сло́ве** *кого* әйткәнен үтәргә мәҗбүр итү; ~ **слу́чай (моме́нт)** моментны туры китерү

лови́ться *несов.* **1.** (*попадаться в силок, сеть и т.п.*) эләгү, тотылу **2.** *страд. от* **лови́ть**

ловка́ч *м разг.* елгыр, елгыр кеше, үткен кеше

ло́вк||ий, -ая, -ое **1.** оста; җитез; ~**ие движе́ния** оста хәрәкәтләр; ~**ий па́рень** җитез егет **2.** *разг.* (*изворотливый*) елгыр, мут, оста, хәйләкәр; ~**ий плут** оста алдакчы **3.** *разг.* (*удобный*) уңайлы; ~**ое седло́** уңайлы ияр

ло́вля *ж см.* **лови́ть** 1

лову́шк||а *ж* **1.** ау, тозак; капкын; (*яма*) чокыр, баз; (*для мышей*) тәбе; ~ **для птиц** кошлар өчен тозак **2.** тозак; **ми́нная** ~**а** миналардан корылган тозак **3.** *перен.* ау, тозак; **попа́сть в** ~**у** тозакка эләгү (төшү); **поста́вить** ~**у** тозак салу

ло́вч||ий, -ая, -ее **1.** ау ...ы; ~**ие пти́цы** ау кошлары (*лачын һ.б.ш.*) **2.** (*служащий для ловли*) җәнлек аулау (тоту) өчен ясалган (эшләнгән, корылган); ~**ая я́ма** җәнлек тоту өчен казылган чокыр **3.** *в знач. сущ.* ~**ий** *м* ловчий (*электә алпавытларда аучылык эшләрен алып баручы*)

ловчи́ть *несов. прост.* хәйләләү (*хәйләле юллар белән максатына ирешергә тырышу*)

лог *м* сыза, үзән

логари́фм *м мат.* логарифм

логарифми́ровать *сов., несов. что, мат.* логарифмын табу

логарифми́ческ||ий, -ая, -ое *мат.* логарифмик, логарифм ...ы; ~**ая табли́ца** логарифмик таблица; ~**ая лине́йка** логарифм сызгычы

ло́гика *ж в разн. знач.* логика; **диалекти́ческая** ~ диалектик логика; **у него́ своя́** ~ аның үз логикасы [бар]; ул үзенчә фикер йөртә; ~ **собы́тий** вакыйгаларның эзлеклелеге

логи́ческ||ий, -ая, -ое логик, логикага нигезләнгән; ~**ий вывод** логик нәтиҗә ♦ ~**ое ударе́ние** *лингв.* логик басым

логи́чн||ый, -ая, -ое логикалы, логикага нигезләнгән, акылга ятышлы, эзлекле; ~**ое рассужде́ние** эзлекле фикер йөртү

ло́говище, ло́гово *с прям., перен.* оя, өн; ~ **врага́** дошманның өне

логопе́д *м* логопед, логопедия белгече

логопе́дия *ж* логопедия (*сөйләү җитешсезлекләрен, мәс. тел тотлыгуны, сакаулыкны бетерү турындагы фән*)

ло́дка *ж* көймә, каек; **па́русная ~** җилкәнле көймә; **подво́дная ~** суасты көймәсе

ло́дочки *мн.* (*туфли*) лодочки

ло́дочник *м* көймәче; каекчы

ло́дочн||ый, -ая, -ое көймә[ләр] ...ы; көймәдә ...; **~ая ста́нция** көймәләр станциясе; **~ые го́нки** көймәдә узышлар

лоды́жка *ж* тубык сөяге

ло́дырничать *несов. разг.* эшсез йөрү, ялкаулану, ялкаулыкка бирелү

ло́дыр||ь *м разг.* ялкау, эшлексез ◆ **~я гоня́ть** эшсез йөрү, ялкаулану, тырай тибү

ло́жа I *ж* **1.** (*в театре*) ложа **2.** ложа (*масоннар оешмасы булеге*)

ло́жа II *ж* (*у ружья*) көбәк, ложа

ложби́на *ж* уйсулык, иңкүлек, уйсу (иңкү, иңсү) җир

ло́же *с* **1.** (*место для сна, отдыха*) урын, түшәк, ятак **2.** (*русло реки*) елга узәне, елга юлы

ло́жечк||а *ж уменьш. от* **ло́жка** 1 ◆ **под ~ой боли́т (щеми́т)** күкрәк авызы авырта (әрни)

ло́жечник *м* **1.** (*мастер*) кашыкчы, кашык ясаучы **2.** кашыклар шакылдатып уйнаучы

ложи́ться *несов. см.* **лечь**

ло́жк||а *ж* **1.** кашык; **ча́йная ~а** балкашык, бал кашыгы **2.** *мн.* **~и** кашыклар (*кашыксыман гади музыкаль инструмент*)

ло́жн||ый, -ая, -ое **1.** (*содержащий ложь*) ялган; **~ые слу́хи** ялган хәбәрләр **2.** (*ошибочный*) ялгыш; **~ый шаг** ялгыш адым; **стоя́ть на ~ом пути́** ялгыш юлда булу **3.** ялган, ясалма, тышкы; **~ая скро́мность** ясалма тыйнаклык

ложь *ж* ялган

лоза́ *ж* **1.** чыбык; **и́вовая ~** тал чыбыгы **2.** (*ива*) тал

лози́на *ж разг.* **1.** *см.* **лоза́** 2; **2.** (*ивовый прут*) тал чыбыгы

лозня́к *м* таллык

ло́зунг *м* лозунг; **вы́двинуть ~** лозунг ташлау

локализа́ция *ж см.* **локализова́ть, локализова́ться**

локализова́ть *сов., несов. что* локальләштерү, җәелдермәү, чыккан урынында туктату; чикләп алу; **~ эпиде́мию** эпидемияне локальләштерү

локализова́||ться 1. *сов., несов.* локальләшү, җәелмәү; урнашу, туплану; **эпиде́мия ~лась** эпидемия локальләште (җәелмәде) **2.** *несов. страд. от* **локализова́ть**

лока́льн||ый, -ая, -ое локаль, җирле, билгеле бер урынга хас; **~ая война́** локаль сугыш

лока́ут *м* локаут (*капиталистларның завод-фабрикаларны ябып, эшчеләрне масса күләмендә эштән чыгаруы*)

локаути́ровать *сов., несов. кого-что* локаут игълан итү

лока́ция *ж спец.* локация

локомоби́ль *м* локомобиль

локомоти́в *м* локомотив

ло́кон *м* локон, чәч бөтеркәсе

ло́к||оть *м* терсәк ◆ **~ти [себе́] куса́ть** терсәкне тешләү

лом I *м* лом; **ска́лывать лёд ~ом** бозны лом белән вату

лом II *м собир.* ватык[лар]; **металли́ческий ~** металл ватыклары

лома́ка *м, ж разг.* кыланчык, кыланучан кеше

ло́ман||ый, -ая, -ое **1.** сынган, сынык, ватык, ватылган, җимерек; **~ые ве́щи** ватык әйберләр **2.** бозык, бозылган; **говори́ть на ~ом языке́** ватып-сындырып сөйләү ◆ **~ая ли́ния** *мат.* сынык сызык; **~ого гроша́ не сто́ит** сукыр бер тиенгә тормый

лома́ть *несов.* **1.** *что* сындыру; вату, **~ сук** ботак сындыру; **~ лёд** боз вату; **~ таба́к** *спец.* тәмәке өзү **2.** *что* вату, бозу, яраксыз хәлгә китерү; **~ игру́шки** уенчыкларны вату **3.** *перен. что* җимерү; **~ ста́рые поря́дки** иске тәртипләрне җимерү **4.** *перен. кого-что* бозу; **~ свою́ жизнь** үз тормышыңны бозу ◆ **~ го́лову** *над чем* баш вату; **~ ша́пку** *перед кем* ялынып каршысына бару, баш ию, баш ору

лома́||ться *несов.* **1.** сыну; ватылу, җимерелү; **ве́тка ~ется** ботак сына; **лёд ~ется** боз ватыла **2.** *перен.* бозылу, җимерелү; **его́ хара́ктер ~ется** аның характеры бозыла **3.** (*жеманничать*) кылану, боргалану-сыргалану; назланып кылану; киреләнү **4.** (*о голосе*) үзгәрү **5.** *страд. от* **лома́ть**

ломба́рд *м* ломбард

ломи́ть *несов.* **1.** *что, прост.* бөгү, сыгу; **ве́тер ло́мит дере́вья** җил агачларны бөгә **2.** *прост.* бәреп-ватып керү; җимереп керү; этешеп-төртешеп керү; **наро́д ло́мит в воро́та** халык капкадан этешеп-төртешеп керә **3.** *безл. что и без доп.* сызлау; **у меня́ ло́мит поясни́цу** билем сызлый

ломи́ться *несов.* **1.** сыгылу, бөгелү; **ве́тви ло́мятся от я́блок** ботаклар алмалардан сыгылалар **2.** *разг.* бәреп (ватып, җимереп) керү; **~ в дверь** ишекне бәреп керү ◆ **~ в откры́тую дверь** ачык ишекне кагу (*һәркемгә билгеле булган нәрсәне исбат итү*)

ло́мкий, -ая, -ое [тиз] ватылучан, [тиз] сынучан, уалучан

ломови́к *м разг.* ломовой, йөк ташучы извозчик

ломов||о́й, -а́я, -о́е йөк ...ы; **~а́я ло́шадь** йөк аты ◆ **~о́й изво́зчик** *уст.* йөк ташучы извозчик

ломо́та *ж* сызлау, сөяклəр сызлау

ломо́ть *м* телем, сынык ◆ **отре́занный ~** кискән икмәк

ло́н||о *с поэт.* кочак, куен ◆ **на ~е приро́ды** табигать кочагында

ло́пастн||ый, -ая, -ое **1.** калаклы, канатлы; **~ое колесо́** калаклы көпчәк **2.** калаксыман; **~ые ли́стья** калаксыман яфраклар

ло́пасть *ж* **1.** калак; **~ лопа́ты** көрәк калагы **2.** калак, канат; **~ пропе́ллера** пропеллер калагы

лопа́т||а *ж* көрәк; **деревя́нная ~а** агач көрәк ◆ **борода́ ~ой** көрәк сакал

лопа́тк||а *ж* **1.** *уменьш. от* **лопа́та**; **2.** калак сөяге ◆ **бежа́ть (гнать) во все ~и** җан-фәрманга йөгерү (куу)

ло́пать *несов. что, прост.* бүсү, тыгыну (*комсызланып ашау*)

ло́паться *несов. см.* **ло́пнуть**

ло́пну||ть *сов.* **1.** (*о полых предметах*) шартлау, чатнау, ярылу; (*о натянутых предметах*) өзелү; **стака́н ~л** стакан чатнады; **струна́ ~ла** кыл өзелде **2.** *перен. разг.* шартлау, бөлү; **банк ~л** банк бөлде ◆ **~ть со́ смеху** эч катып көлү

лопота́ть *несов. разг.* бытылдау, лыкылдау, такылдау

лопоу́хий, -ая, -ое *разг.* **1.** салпы колаклы, салынкы колаклы; **~ щено́к** салпы колаклы көчек **2.** *прост.* (*простоватый — о человеке*) салпы колак, ачык авыз

лопу́х *м* **1.** әрекмән, тигәнәк **2.** *прост.* (*о глупом человеке*) беркатлы кеше, ачык авыз

лорд *м* лорд

лорне́т *м* лорнет

лоси́н||а *ж* **1.** (*выделанная лосиная кожа*) поши күне **2.** *мн.* **~ы** *уст.* поши күненнән тегелгән чалбар **3.** (*лосиное мясо*) поши ите

лоси́ха *ж* ана поши

лоск *м прям., перен.* ялтыравык; **сапоги́ с ~ом** ялтыравыклы итек; **навести́ ~** *на что-л. бирәр нәрсәне* ялтырату; *перен.* ялтыратып курсәту

лоску́т *м собир.* кисәкләр, корама, калдык-постыклар (*мәс. кун промышленностендә*)

ло́скут *м* кисәк, корама

лоску́т||ый, -ая, -ое корама ...; **~ое одея́ло** корама юрган

лосн||и́ться *несов.* ялтырау, ялтырап тору; **рукава́ ~я́тся** җиңнәре ялтырап тора

лососи́на *ж* сөләйман балыгы ите

лосо́сь, ло́сось *м* сөләйман балыгы

лось *м* поши

лот *м мор.* лот

лотере́я *ж* лотерея

лото́ *с* лото (*уен*)

лото́к *м* **1.** лоток (*урамда сату итү өчен ачык прилавка*) **2.** улак; **ме́льничный ~** тегермән улагы

ло́тос *м бот.* лотос

лото́чник *м* лотокчы (*урамда лотокта сату итүче*)

лото́чница *ж* лотокчы хатын (кыз)

лото́чн||ый, -ая, -ое лоток ...ы; локтан ...; лотоктан сатыла торган; **~ая торго́вля** лотоктан сату итү

лоха́нка *ж см.* **лоха́нь**

лоха́нь *ж* лакан

лохма́тить *несов. кого-что, разг.* туздыру, тузгыту

лохма́титься *несов. разг.* тузу; тузгу, тузгаклану

лохма́тый, -ая, -ое **1.** йонлы, йонлач, йөнтәс; **~ пёс** йөнтәс эт **2.** тузган

ЛОХ-ЛЫЖ

чәчле, тузгыган чәчле, тузгак чәчле; ~ **па́рень** тузган чәчле егет

лохмо́тья *только мн.* **1.** (*изношенная и изорванная одежда*) сәләмә, сәләмә кием, иске-москы кием; **он оде́т в ~** сәләмә кием кигән **2.** (*клочья*) кисәкләр

ло́хмы *только мн. прост.* киезләнгән чәч; киезләнгән йон

ло́ция *ж спец.* лоция

ло́цман *м* лоцман (**1.** *фарватерны яхшы белүче һәм аннан суднолар үткәруче* **2.** *диңгез балыгының бер төре*)

лошади́н||ый, -ая, -ое **1.** ат ...ы; **~ая голова́** ат башы **2.** (*как у лошади*) атныкы кебек ♦ **~ая до́за** ат дозасы (*чамадан тыш зур доза*); **~ая си́ла** *физ.* ат егәрлеге, ат көче

лоша́дник *м разг.* **1.** (*любитель лошадей*) ат һәвәскәре, ат яратучы кеше **2.** (*торговец лошадьми*) ат сәүдәгәре, атсатар

ло́шадь *ж* ат; **верхова́я ~** менге ат; **ездова́я ~** җигү аты; **ломова́я ~** йөк аты; **рабо́чая ~** эш аты; **осёдланная ~** иярле ат

лоша́к *м* качыр

лощён||ый, -ая, -ое **1.** шома, ялтыравык, ялтыравыклы; **~ая бума́га** ялтыравыклы кәгазь **2.** *перен.* купшы; **~ый молодо́й челове́к** купшы егет

лощи́на *ж* ялпылык, уйсулык, уйсу жир (*киң иңкү җир*)

лощи́ть *несов. что* ялтырату; шомарту; ~ **бума́гу** кәгазьне ялтырату

лоя́льность *ж* лояльлек

лоя́льн||ый, -ая, -ое лояль; **~ый челове́к** лояль кеше; **~ое отноше́ние** лояль мөнәсәбәт

луб *м* **1.** (*волокно растений*) җепсел **2.** (*кора*) кабык, кайры; (*лыко*) юкә, курыс, юкәр **3.** *спец.* (*волокно льна, конопли и т. п.*) сүс

лубо́к *м* **1.** (*пласт волокна растения*) кайры кисәге, кабык кисәге **2.** *мед.* кабык **3.** *иск.* лубок

лубо́чн||ый, -ая, -ое **1.** *см.* **лубя́ной** 1; **2.** лубоктан төшерелгән, төшереп алынган; **~ые карти́нки** лубоктан төшереп алынган рәсемнәр **3.** урам ...ы; тупас; **~ая литерату́ра** урам әдәбияты

лубя́н||о́й, -а́я, -о́е **1.** кабык ..., кабыктан ясалган; **~ые изде́лия** кабыктан ясалган әйберләр **2.** сүсле; **~ые культу́ры** сүсле культуралар

луг *м* болын

лугови́на *ж разг.* кечкенә болын

лугов||о́й, -а́я, -о́е болын ...ы; **~а́я трава́** болын үләне

луди́ть *несов. что* кургаш йөгертү, лудить итү

лу́ж||а *ж* **1.** күлләвек, җыелган су (*мәс. яңгырдан соң яки кар эрегәндә*) **2.** күл; **~а на полу́** идәндә күл булган ♦ **сесть в ~у** төпсез чанага утыру, уңайсыз хәлдә калу

лужа́йка *ж* чирәмлек, алан, кечкенә болын

лужён||ый, -ая, -ое кургаш йөгертелгән, лудить ителгән ♦ **~ая гло́тка** *прост.* кушбугаз (*кычкырынырга, акырып җырларга яки күп эчәргә яратучы кеше турында*)

лу́за *ж* луза (*бильярд өстәлендә шар төшерү өчен ясалган кечкенә капчык*)

лузга́ *ж собир.* кабык (*мәс. көнбагыш кабыгы*)

лу́згать *несов. что, прост.* яру, ашау (*мәс. чикләвекне, көнбагышны*)

лук I *м* суган; **~ ре́пчатый** башлы суган; **ди́кий ~** юа, кыр суганы

лук II *м* җәя; **туго́й ~** кереше ныклы киерелгән җәя; **стреля́ть из ~а** җәядән ату

лука́ *ж* **1.** борылыш; **~ реки́** елга борылышы **2.** (*у седла*) ияр кашы, ияр очы

лука́вец *м* хәйләкәр кеше, наян кеше

лука́винк||а *ж разг.* бераз (аз гына) хәйлә, бераз (аз гына) хәйләкәрлек; **с ~ой** аз гына хәйлә белән; **с ~ой во взгля́де** хәйләле караш белән

лука́вить *несов.* хәйләләү, наянлану, алдашу

лука́вство *с* **1.** (*хитрость*) хәйлә; хәйләкәрлек, наянлык **2.** (*игривость*) шаянлык, уенчаклык

лука́вый, -ая, -ое **1.** хәйләкәр, наян; хәйләле; **~ челове́к** хәйләкәр кеше; **2.** шаян, уенчак, хәйләле; **~ взгляд** уенчак караш **3.** *в знач. сущ. м прост.* шайтан, иблис; **~ попу́тал** шайтан котырткан

лу́ковица *ж* **1.** суганча, суганбаш; **~ тюльпа́на** лалә суганчасы **2.** (*головка лука*) бер баш суган **3.** *анат.* тамыр, төпсә; **~ во́лоса** чәч тамыры **4.** (*круглый церковный купол*) чиркәү гөмбәзе

лу́ковичн||ый, -ая, -ое **1.** суганчалы, суганбашлы; **~ые расте́ния** суганчалы үсемлекләр **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. бот.* суганчалылар

лукомо́рье *с уст.* диңгез култыгы

луко́шко *с* тубал, тырыс, козау

луку́ллов: ~ пир гадәттән тыш бай (мул) мәҗлес

луна́ *ж* **1.** ай; **по́лная ~** тулган ай; **~ на ущёрбе** ай ким башлаган **2.** *астр.* (*спутник планеты*) иярчен; **де́вять лун Сатурна** Сатурнның тугыз иярчене

лунати́зм *м мед. уст.* лунатиклык

луна́тик *м разг.* лунатик

лу́нка *ж* чокырчык, кечкенә чокыр; куыш; ~ **зу́ба** теш чокыры

лу́нник *м разг.* лунник (*Айга җибәрелгән космик аппарат*)

лу́нн||ый, -ая, -ое ай ...ы, ай ...; айлы; **~ый свет** ай яктысы; **~ое затме́ние** ай тотылу; **~ая ночь** айлы төн; **~ый грунт** ай туфрагы ♦ **~ый ка́мень** ай ташы (*кыр шпатының бер төре*)

лунохо́д *м* луноход

лунь *м* саз карчыгасы ♦ **седо́й (бе́лый) как ~** ап-ак чәчле, чәчләре кар кебек ап-ак

лу́па *ж* лупа

лупи́ть *несов. прост.* **1.** *что* (*отдирать кору*) каезлау, кайры куптару, кайры салдыру; (*отдирать лыко*) курыс төшерү **2.** *что* (*очищать от шелухи*) кабыгын арчу **3.** *кого-что* (*сильно бить*) чыбыклау, тукмау, дөмбәсләү, яру, кисү (*кыйнау мәгънәсендә*)

лупи́ться *несов. разг.* **1.** кубу; **ко́жа лу́пится** тире куба **2.** *страд. от* **лупи́ть** 1, 2

лупогла́зый, -ая, -ое *прост.* акай (акайган) күзле, чекрәйгән күзле

луч *м прям., перен.* нур; **со́лнечный ~** кояш нуры; **рентге́новские ~и** *физ.* рентген нурлары; **~ сча́стья** бәхет нуры

лучев||о́й, -а́я, -о́е **1.** *физ.* нур ...ы; **~а́я эне́ргия** нур энергиясе; **~а́я боле́знь** нур авыруы **2.** нурсыман, нур кебек ..., төрле якка чәчелгән (сибелгән, юнәлтелгән); **~ы́е про́секи** төрле якка юнәлтелгән урман ысаннары ♦ **~а́я кость** *анат.* беләк сөяге, орчык сөяк

лучеза́рн||ый, -ая, -ое **1.** нурлы, нур сибеп торган; **~ое со́лнце** нурлы кояш **2.** *перен.* нурлы, якты, шатлыклы, куанычлы; **~ая улы́бка** шатлыклы елмаю

лучеиспуска́ние *с физ.* нур чәчү, нур тарату, нур чыгару, нур чыгарыш

лучепреломле́ние *с физ.* нур сынышы

лучи́н||а *ж* чыра; **щепа́ть ~у** чыра яру

лучи́ст||ый, -ая, -ое **1.** нурлы; **~ые глаза́** нурлы күзләр **2.** *физ.* нур ...ы; **~ая эне́ргия** нур энергиясе

лучи́ть *несов. кого* төнне яктылык ярдәмендә чәнчеп тоту (*балыкны*)

луч||и́ться *несов.* нур чәчү; нур сибү; нур тарату, нурланып тору; **его́ глаза́ ~а́тся** аның күзләре нурланып тора

лучко́в||ый, -ая, -ое *спец.* җәясыман, җәяле; **~ая пила́** җәяле пычкы

лу́чник *м* җәяче, җәядән атучы

лу́чше 1. *сравн. ст. от* **хоро́ший** *и* **хорошо́** яхшырак, әйбәтрәк; **твоё пла́тье ~** синең күлмәгең яхшырак; **он отве́тил ~** ул яхшырак җавап бирде **2.** *в знач. сказ. безл. кому* яхшырак, әйбәтрәк; **сего́дня ему́ ~** бүген аның хәле әйбәтрәк **3.** *вводн. сл.* я булмаса; **говори́ и́ли, ~, я расскажу́** сөйлә, я булмаса, мин сөйлим **4.** *в знач. частицы усил.* ... да; я булмаса; **~ не говори́** әйтеп тә торма; я булмаса, әйтеп тә торма ♦ **~ всего́** иң яхшысы

лу́чш||ий, -ая, -ее **1.** *сравн. ст. от* **хоро́ший** [моннан да] яхшырак, [моннан да] әйбәтрәк; **~ его рабо́тника, чем он, не найти́** моннан да әйбәтрәк эшче табып булмас **2.** *превосх. ст. от* **хоро́ший** иң яхшы, иң әйбәт; **~не лю́ди завода́** заводның иң яхшы кешеләре; **са́мый ~ий** иң яхшы ♦ **в ~ем ви́де** (*сделать*) бик әйбәт итеп (*эшләү*)

лущёный, -ая, -ое кабыгыннан арчылган

лущи́льн||ый, -ая, -ое *с.-х.* туфрак йомшарткыч, туфрак йомшарта торган; **~ая маши́на** туфрак йомшарта торган машина

лущи́ть *несов. что* **1.** [кабыгыннан] арчу; ~ **горо́х** борчакны кабыгыннан арчу **2.** яру, ашау; ~ **се́мечки** көнбагыш яру **3.** *с.-х.* туфракны йомшарту (*уңышны җыеп алганнан соң*)

лы́ж||и *мн.* чаңгы; **во́дные ~и** су чаңгысы; **ката́ться на ~ах** чаңгы шуу

лы́жник *м* чаңгычы

лы́жница *ж* чаңгычы хатын (кыз)

лы́жный, -ая, -ое **1.** чаңгы ...ы; **~ спорт** чаңгы спорты **2.** чаңгычы[лар] ...ы; **~ костю́м** чаңгычылар костюмы; **~ отря́д** чаңгычылар отряды

лыжня́ *ж* чаңгы эзе

лы́к||о *с* курыс, кабык, юкә кабыгы; **драть ~о** курыс төшеру ♦ **~а не вя́жет** *прост.* теле бәйләнә, теле дә әйләнми (*лаякыл исерек*); **не вся́кое ~о в стро́ку** *погов.* барлык вак-төякне гаепкә санап булмый; **не ~ом шит** төшеп калганнардан түгел

лысе́||ть *несов.* пеләшләнү; **голова́ его́ ~ет** аның башы пеләшләнә

лы́сина *ж* **1.** (*у человека*) пеләш **2.** (*белое пятно на лбу животного*) кашка

лы́с||ый, -ая, -ое **1.** (*о голове*) пеләш ...; (*о человеке*) пеләш башлы **2.** *перен.* ялан, ялангач, ачык; **~ая гора́** ялан тау

ль *см.* **ли**

львёнок *м* арыслан баласы

льви́н||ый, -ая, -ое арыслан ...ы; **~ая шку́ра** арыслан тиресе ♦ **~ая до́ля** иң зур өлеш; **~ая гри́ва** куе, күпереп торган чәч; **~ый зев** *бот.* арыслан авызы

льви́ца *ж* ана арыслан

льго́та *ж* льгота, өстенлек

льди́на *ж* зур боз кисәге, боз

льди́стый, -ая, -ое бозлы, боз белән капланган

льново́д *м* житенче, җитен үстерү эше белгече

льново́дн||ый, -ая, -ое *см.* **льново́дческий**; **~ая зо́на** җитенчелек зонасы

льново́дство *с* җитенчелек, җитен үстерүчелек

льново́дческий, -ая, -ое җитенчелек ...ы; **~ совхо́з** җитенчелек совхозы

льнокомбина́т *м* җитен комбинаты

льнопряди́льн||ый, -ая, -ое җитен эрләү ...ы; **~ая фа́брика** җитен эрләү фабрикасы

льнотереби́лка *ж* җитен йолыккыч, җитен йолку машинасы

льнотрепа́лка *ж* җитен талкыгыч, җитен талку машинасы

льнуть *несов. к кому-чему* сыену, сарылу, сырышу; **~ к ма́тери** анасына сарылу

льнян||о́й, -а́я, -о́е **1.** җитен ..., җитен ...ы; **~о́е полотно́** җитен тукыма; **~о́е по́ле** җитен басуы; **~о́е ма́сло** җитен мае **2.** җитен ..., җитен төсле; **~ы́е во́лосы** җитен төсле чәч

льстец *м* ялагай, юмакай телле; ялагайланып (яларга тырышып) мактаучы

льсти́в||ый, -ая, -ое ялагай, юмакай телле, юмакай; ялагайланулы, ялагайланып ...; **~ая же́нщина** ялагай хатын; **~ый взгляд** ялагайланулы караш; **~ые слова́ (ре́чи)** ялагайланып әйтелгән сүзләр; **~ая улы́бка** ялагайланып елмаю

льстить *несов.* **1.** *кому и без доп.* (*лицемерно хвалить*) ялагайлану, ялагайланып (икейөзлеләнеп) мактау, юмалау, юма телләнү **2.** *кому-чему* (*доставлять удовлетворение*) күңел күтәрү, куандыру, шатландыру, күңелгә ошау; канәгатьләнү хисе тудыру ♦ **~ себя́ наде́ждой** үзеңне өмет белән юату

льсти́ться *несов. уст.:* **~ наде́ждой** *то же, что* **льстить себя́ наде́ждой** (*см.* **льстить**)

люб *в знач. сказ. уст.* ошый; **он мне ~** ул миңа ошый

любвеобиль||ый, -ая, -ое мәхәббәткә бай; күп кешене яратучан; **у него́ ~ое се́рдце** ул күп кешеләрне ярата

любе́зничать *несов. с кем, разг.* ягымлы сүзләр сөйләү; илтифат күрсәтү

любе́зност||ь *ж* **1.** (*предупредительность*) кече күңеллелек, кечелеклелек, ачык йөзлелек, ачык күңеллелек **2.** *обычно мн.* **~и** ягымлы сүзләр; яхшы мөгамәлә; **наговори́ть ~ей** ягымлы сүзләр сөйләп ташлау **3.** (*услуга*) илтифат, ярдәм, булышлык, яхшылык; **оказа́ть ~ь** *кому-л.* ярдәм (булышлык) күрсәтү

любе́зн||ый, -ая, -ое **1.** (*предупредительный, учтивый*) кечелекле, кече күңелле, ачык йөзле, ачык күңелле; **~ый хозя́ин** кече күңелле хуҗа **2.** (*выражающий приветливость*) ягымлы, йомшак, мөлаем; **~ые слова́** ягымлы сүзләр ♦ **бу́дьте ~ы** рәхим итеп, зинһар

люби́тель *м* **1.** *чего и с неопр.* яратучы, сөюче, һәвәс кеше; **~ книг** китап яратучы кеше **2.** һәвәскәр; **садово́д-~** һәвәскәр бакчачы

люби́тельница *ж* **1.** *чего и с неопр.* яратучы хатын (кыз) **2.** һәвәскәр хатын (кыз)

люби́тельский, -ая, -ое һәвәскәр-[ләр] ...ы; **~ спекта́кль** һәвәскәрләр спектакле

люби́ть *несов. в разн. знач. кого-что* ярату, сөю; **~ Ро́дину** туган нләңне ярату; **~ сво́й наро́д** үз халкыңны ярату; **~ дете́й** балаларны ярату; **~ приро́ду** табигатьне ярату; **~ же́нщину** хатын кешене сөю; **~ вку́сно пое́сть** тәмле ашарга ярату; **он лю́бит охо́титься** ул аучылык итәргә ярата; **люблю́, когда́ во всём поря́док** бар нәрсәдә дә тәртип булганны яратам; **цветы́ лю́бят со́лнце** чәчәкләр кояш яктысын яраталар; **лю́бишь ката́ться, люби́ и са́ночки вози́ть** *посл.* ≈ рәхәтен күргәч, михнәтенә дә түз

лю́бо *в знач. сказ. безл. с неопр. разг.* күңелле; **~ посмотре́ть** каравы күңелле ♦ **~-до́рого** бик күңелле

любова́ться *несов. кем-чем, на кого-что* **1.** (*рассматривать*) сокланып карау, сокланып (кызыксынып, искитеп) карап тору; **~ восхо́дом со́лнца** кояш чыгуын сокланып карап тору **2.** (*испытывать удовлетворение*) карап сөенү (куану); **~ на свои́х сынове́й** уларына карап сөенү

любо́вник *м* сөяркә

любо́вница *ж* сөяркә

любо́вн||ый, -ая, -ое **1.** мәхәббәт ...ы; сөю ...ы; **~ое письмо́** мәхәббәт хаты **2.** яратып ..., сөеп; **~ое отноше́ние к де́лу** эшеңә яратып карау **3.** *уст.* мәхәббәт ...ы, сөйдергеч ...; **~ый напи́ток** сөйдергеч эчемлек (*кара ышануда*)

люб||о́вь *ж* **1.** мәхәббәт, ярату; сөю; **~ о́вь к Ро́дине** Ватанга мәхәббәт **2.** (*любовное отношение*) гыйшык, мәхәббәт; **огóнь ~ви́** гыйшык уты **3.** (*интерес*) ярату; **~ о́вь к му́зыке** музыканы ярату

любозна́тельность *ж* кызыксынучанлык, белемгә омтылу[чанлык]

любозна́тельный, -ая, -ое кызыксынучан, кызыксынучы, белемгә омтылучан

люб||о́й, -а́я, -о́е **1.** теләгән, теләсә нинди, теләсә кайсы, һәртөрле; **в ~о́е вре́мя** теләгән вакытта; **за ~у́ю це́ну** хакыннан тормыйча; **~о́й ценó́й** теләсә нинди юллар белән **2.** *взнач. сущ.* **~о́й** *м*, **~а́я** *ж*, **~о́е** *с* һәркем, теләсә кем, теләсә кайсы; **~о́й из нас э́то мо́жет сде́лать** моны теләсә кайсыбыз эшли ала; **рассказа́ть ~о́му** теләсә кемгә сөйләү

любопы́тный, -ая, -ое **1.** кызыксынучан, кызыксынучы; **~ челове́к** кызыксынучан кеше **2.** кызыксынып ..., кызыксынулы; **~ взгля́д** кызыксынып карау **3.** кызык, кызыклы; **~ слу́чай** кызыклы вакыйга

любопы́тство *с* кызыксынучанлык, кызыксыну

любопы́тствовать *несов.* кызыксыну, белергә тырышу (омтылу)

люд *м собир. разг.* халык, кешеләр; **крестья́нский ~** крестьян халкы

лю́ди *мн.* **1.** (*мн. ч. к* **челове́к**) кешеләр, халык; **~и на́уки** фән кешеләре; **молоды́е ~и** яшьләр, егетләр; **ста́рые ~и** картлар, карт кешеләр **2.** *уст.* (*прислуга, работники в барском доме*) асраулар, ялчылар, хезмәтчеләр ♦ **вы́йти (вы́биться) в ~и** кеше булу, аякка басу; **на ~ях** (*среди людей, в обществе*) кешеләр арасында; **быва́ть на ~ях** кеше (халык) арасында булу

лю́дн||ый, -ая, -ое күп кешеле, күп халыклы; **~ый го́род** халкы күп булган шәһәр; **~ая у́лица** халык күп йөри торган урам; **~ое собра́ние** күп кеше катнашкан җыелыш

людое́д *м* кеше ашаучы

людск||о́й, -а́я, -о́е **1.** кеше[ләр] ...ы; халык ...ы; **~о́й род** кешеләр токымы; **~а́я молва́** халык сүзе, кеше сүзе; **~и́е сла́бости** кешеләрнең йомшак яклары **2.** *в знач. сущ.* **~а́я** *ж уст.* ялчылар (хезмәтчеләр, асраулар) тора торган йорт; ялчылар (хезмәтчеләр, асраулар) бүлмәсе

люк *м* люк

люкс I *м физ.* люкс (*яктыртылу дәрәҗәсен улчәү берәмлеге*)

люкс II *м* люкс (*иң яхшы җиһазландырылган гостиницаны һ.б.ш. шулай атыйлар*)

лю́лька *ж* бишек; **де́тская ~** бала бишеге

лю́мпен-пролетариа́т *м* люмпен-пролетариат

лю́стра *ж* люстра, кандил

лютера́нин *м* лютеран, лютеран динен тотучы

лютера́нка *ж* лютеран хатын (кыз)

лютера́нство *с* лютеранлык (*протестант динендә бер мәзһәп*)

лю́тик *м* казаяк

лю́тня *ж* лютня (*музыка коралы*)

лют||ова́ть *несов. прост.* **1.** (*зверствовать*) ерткычлану, кансызлану, ерткычларча кылану, ерткычлык (кансызлык) күрсәтү, явызлану **2.** котырыну; **~ у́ют моро́зы** салкыннар котырына

лю́т||ый, -ая, -ое **1.** ерткыч ..., кансыз, явыз; **~ый враг** явыз дошман **2.** зәһәр, ачы, коточкыч каты, бик каты, бик көчле; **~ый хо́лод** зәһәр салкын, зәмһәрир суыгы; **~ая зима́** коточкыч салкын кыш; **~ая зло́ба** зәһәр ачу

люце́рна *ж бот.* люцерна

ля *с нескл.* ля (*музыка гаммасында алтынчы нота*)

ляга́ть *несов. кого-что* тибү

ляга́ться *несов.* **1.** (*напр. о лошади*) тибү **2.** (*лягать друг друга*) тибешү

лягну́ть *сов. однокр. кого-что* тибү, тибеп җибәрү

лягуша́ч||ий, -ья, -ье, **лягу́шеч||ий,** -ья, -ье бака[лар] ...ы; **~ья икра́** бака уылдыгы

лягуши́ный, -ая, -ое *разг. см.* **лягуша́чий**

лягу́шка *ж* бака; **зелёная ~** яшел бака, саз бакасы; **травяна́я ~** җир бакасы; **древе́сная ~** агач бакасы

лягушо́нок *м* бака баласы

ляду́нка *ж* лядунка (*атлы гаскәринең патрон сумкасы*)

ля́жка *ж разг.* бот

лязг *м см.* **ля́згать; ~ цепе́й** чылбырлар[ның] шылтыравы

ля́зга||ть *несов.* **1.** *чем* шылтырату, шалтырату, чыңгылдату; (*зубами*) шакылдату; **~ть це́пью** чылбыр шылтырату **2.** шылтырау, шалтырау, чыңгылдау; (*о зубах*) шакылдау; **~ют листы́ желе́за** калай табаклары шалтырый

ля́згнуть *сов. однокр.* **1.** *чем* шылтырату, шалтырату, чыңгылдату, шылтыратып (шалтыратып, чыңгылдатып) кую; (*зубами*) шакылдату, шакылдатып кую **2.** шылтырау, шалтырау, чыңгылдау, шылтырап (шалтырап, чыңгылдап) кую; (*о зубах*) шакылдау, шакылдап кую

ля́псус *м* ялгышлык, ялгыш җибәрелгән хата, ялгыш ычкынган сүз

ля́сы: точи́ть ~ *прост.* юк-барны сөйләү, ләчтит сату, лыкылдау, сафсата сату

М

мавзоле́й *м* мавзолей; **Мавзоле́й В.И.Ле́нина** В.И.Ленин Мавзолее

маврита́нский, -ая, -ое мавр[лар] ...ы, мавритан ...ы; Мавритания ...ы; **~ стиль в архитекту́ре** архитектурада мавритан стиле

ма́вры *мн.* маврлар (*төньяк-көнбатыш Африкада яшәүче төп кабиләләрнең борынгы исеме*)

маг *м* сихерче, тылсымчы ♦ **~ и волше́бник** *шутл.* тылсым иясе, булдыклы кеше

магази́н *м* **1.** кибет; **фи́рменный ~** фирма кибете; **продово́льственный ~** азык-төлек кибете **2.** магазин; **~ сопротивле́ний** *тех.* каршылыклар магазины; **~ винто́вки** винтовканың магазины

магази́нн||ый, -ая, -ое **1.** магазин ...ы, кибет ...ы; **~ая вы́веска** магазин вывескасы **2.** магазинлы; **~ое ружьё** магазинлы мылтык ♦ **~ая коро́бка** *воен.* магазин тартмасы (*винтовканың патроннар куела торган тартмасы*)

магара́джа *м* магараджа, өлкән раджа (*Һиндстанда князь титулы һәм шул титулдагы кеше*)

магары́ч *м прост.* мөгәрич, чәйлек

маги́стр *м* магистр (**1.** *чит илларнең кайберләрендә, элекке Россиядә гыйльми дәрәҗә һәм шундый дәрәҗә алган кеше* **2.** *ист. урта гасырларда руханый рыцарьлар орденының башлыгы*)

магистра́ль *ж* магистраль; **железнодоро́жная ~** тимер юл магистрале; **гла́вная ~** төп магистраль

магистра́льный, -ая, -ое магистраль ...; төп; **~ ка́бель** төп кабель

магистра́т *м* магистрат (*кайбер илләрдә шәһәр идарәсе һәм шул идарә урнашкан бина*)

маги́ческ||ий, -ая, -ое **1.** магик, магия... ы; сихерләү ...ы; **~ие приёмы** сихерләү алымнары **2.** *перен.* чиктән тыш көчле (йогынтылы); **его́ слова́ произвели́ ~ое де́йствие** аның сүзләре чиктән тыш көчле йогынты ясады

ма́гия *ж прям., перен.* магия, сихер, тылсым; **чёрная ~** кара магия; **~ слов** сүзләр тылсымы

ма́гма *ж геол.* магма (*Җир шарының каты катламы астындагы эрегән кайнар сыек масса*)

магмати́ческ||ий, -ая, -ое *геол.* **1.** магма ...ы, магмалы; **~ие поро́ды** магмалы тау токымнары **2.** магматик, кызып эрегән, кайнар сыек; **~ое состоя́ние поро́ды** тау токымының магматик хәлдә булуы

магна́т *м* магнат (*эре капиталист; эре җир биләүче*)

магнези́т *м мин.* магнезит

магне́зия *ж* магнезия; **жжёная ~** яндырылган магнезия (*магний окисе*); **бе́лая ~** ак магнезия (*магний тозы*)

магнети́зм *м* магнетизм (**1.** *магнит үзенчәлеге* **2.** *магнит күренешләре турындагы өйрәтмә* **3.** *уст. тарту, җәлеп итү көче, йогынты сәләте*)

магнети́т *м мин.* магнетит

магне́то *с нескл.* магнето (*эчкә янулы двигательләрдә очкын барлыкка китерә торган электромагнитлы прибор*)

ма́гниев||ый, -ая, -ое магний ...ы; **~ая вспы́шка** магний яктылыгы, магний уты; **~ые ру́ды** магний рудалары

ма́гний *м хим.* магний

магни́т *м* магнит; **иску́сственный ~** ясалма магнит

магни́тн||ый, -ая, -ое **1.** магнит ...ы; **~ые сво́йства** магнит үзлекләре; **~ое по́ле** магнит кыры **2.** магнитлы; **~ый железня́к** магнитлы тимерташ ♦ **~ая анома́лия** магнит аномалиясе; **~ая бу́ря** магнит давылы; **~ый мериди́ан** *физ.* магнит меридианы

магнитофо́н *м* магнитофон; **записа́ть конце́рт на ~** концертны магнитофонга язып алу

магнитофо́нн||ый, -ая, -ое магнитофон ...ы; **~ая за́пись** магнитофон язмасы

магно́лия *ж* магнолия (*агач яки куак*)

магомета́нин *м уст.* мөселман

магомета́нка *ж уст.* мөселман хатыны (кызы), мөслимә

магомета́нство *с* мөселманлык, ислам дине

мада́м *ж нескл.* мадам, ханым

мадемуазе́ль *ж нескл.* мадемуазель, туташ

маде́ра *ж* мадера (*аракы*)

мадо́нна *ж* мадонна (*католикларда: алла анасы*)

мадрига́л *м* мадригал (*кечкенә генә мактау шигыре, гадәттә берәр ханымга багышлап язылган*)

мадья́ры *мн.* мадьярлар, мадьяр халкы; мажарлар, мажар халкы

маёвка *ж* маевка (*революциягә чаклы Россиядә эшчеләрнең беренче май көнендә шәһәр читенә чыгып уткәрә торган яшерен җыелышлары*)

маета́ *ж прост.* матавык. мәшәкать, ардыра торган авыр (мәшәкатьле, йөдәткеч) эш

ма́етный, -ая, -ое *прост.* ардыргыч, ялыктыргыч, мәшәкатьле

мажо́р *м* **1.** *муз.* мажор **2.** *перен.* күтәренке күңел, дәрт; **быть в ~е** күтәренке күңелле булу

мажо́рный, -ая, -ое **1.** *муз.* мажорлы, мажор ...ы; **~ая га́мма** мажорлы гамма **2.** *перен.* күтәренке [күңелле], дәртле; **~ое настрое́ние** күтәренке кәеф

ма́занка *ж* балчык өй, саман өй

ма́зать *несов.* **1.** *что* сылау, майлау, [май] сөртү, [май] ягу; **~ хлеб ма́слом** икмәккә май ягу **2.** *кого-что и без доп., разг.* (*пачкать, грязнить*) буяу, пычрату **3.** *перен. что. разг.* (*неумело рисовать*) буяштыру (*ясый белмәгән килеш, начар итеп рәсем ясау*) **4.** *прост.* (*делать промахи*) кыек ату, тидерә алмау (*берәр уенда яки мылтыктан атканда*)

ма́заться *несов.* **1.** *разг.* (*натираться чем-л.*) буяну, сөртену, ягыну **2.** *разг.* (*пачкаться*) пычрану, буялу **3.** *разг.* йогу, пычрану; **стена́ ма́жется** стенаның буявы йога **4.** *страд. от* **ма́зать** 1

мази́ла *м, ж прост.* булдыксыз (*спортсмен турында*)

мазну́ть *сов. однокр.* **1.** *что* майлап алу, сылап җибәрү **2.** *кого-что, разг.* (*испачкать*) пычратып кую, пычрату

мазня́ *ж разг.* начар рәсем; начар итеп рәсем ясау; начар эш

мазо́к *м* **1.** буялыш, буяу төшерү **2.** *мед.* мазок; **взять ~** мазок алу

мазу́рик *м прост.* карак, алдакчы

мазу́рка *ж* мазурка (*поляклярның милли биюе һәм шул биюнең музыкасы*)

мазу́т *м* мазут

мазу́тн||ый, -ая, -ое мазут ...ы; **~ое пятно́** мазут табы

маз||ь *ж* **1.** мазь, май (*дару*); **се́рная ~ь** күкертле май **2.** май; **колёсная ~ь** арба мае ◆ **на ~и́** ≈ шәп, эш пешә, майлагандай (җайлы) бара; **де́ло на ~и́** эш майлагандай бара

майс *м* маис, кукуруз, кәгъбә бодае

май *м* май, май ае

ма́йка *ж* майка

ма́йна *межд.* майна, төшер

майо́лика *ж* майолика (*балчыктан эшләнеп яндырылган һәм глазурь йөгертелгән яки буяу белән буялган әйберләр*)

майоне́з *м* майонез

майо́р *м* майор

майора́т *м* майорат (**1.** *мирас системасы; бу система буенча мирас тулысы белән олы улга яки нәселдәге олы кешегә күчә* **2.** *шул рәвешле мирас булып калган җир*)

ма́йский, -ая, -ое май ...ы; **~ день** май көне ◆ **~ жук** май коңгызы

мак *м* мәк (*үсемлеге һәм орлыгы*)

мака́ка *ж* макака (*маймылның бер төре*)

макаро́нник *м* макаронник (*макароннан пешерелгән ашамлык*)

макаро́нн||ый, -ая, -ое **1.** макарон ...ы; **~ая фа́брика** макарон фабрикасы **2.** макаронлы; **~ая запека́нка** макаронлы запеканка

макаро́ны *мн.* макарон

мака́ть *несов. что* ману, манчу; **~ блины́ в смета́ну** беленнәрне каймакка ману

македо́нский, -ая, -ое македон[нар] ...ы; **~ язы́к** македон теле

македо́нцы *мн.* македоннар, македониялеләр, Македония халкы

маке́т *м* макет; **~ декора́ции** декорация макеты; **~ кни́ги** китап макеты

маке́тн||ый, -ая, -ое макет ...ы; **~ая мастерска́я** макет мастерское

макинто́ш *м* макинтош

ма́клер *м* маклер (*сатучы белән сатып алучы арасында арадашлык итүче кеше*)

ма́клерство *с* маклерлык

макну́ть *сов. однокр. что* манып алу, манчып алу

ма́ков: как ~ цвет мәк чечәге сыман (төсле)

ма́ковка *ж* **1.** (*семенная коробочка*) мәк башы **2.** *разг.* (*купол церкви*) гөмбәз **3.** *см.* **маку́шка** 1

ма́ков||ый, -ая, -ое **1.** мәк ...ы; **~ое се́мя** мәк орлыгы **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *бот.* мәкчәчәклеләр

макре́ль *ж* макрель (*балык*)

макроко́см, макроко́смос *м книжн.* дөнья, галәм

макроскопи́ческий, -ая, -ое *книжн.* макроскопик, гади күзгә күренерлек

максимали́зм *м* максимализм (*реаль чынбарлык белән акланмаслык гаять зур таләпләр кую*)

максимали́ст *м* максималист, максимализм яклы кеше

максима́льный, -ая, -ое максималь, максимум, иң зур, иң югары; **~ за́работок** иң югары эш хакы

ма́ксимум *м* **1.** максимум, иң зур; **проявить ~ эне́ргии** иң зур көч кую **2.** *в знач. нареч.* максимум; иң күбе[се], иң зуры[сы], күп дигәндә; **~ сто рубле́й** иң күбесе йөз сум

максу́н *м* максун (*балык*)

макулату́ра *ж* макулатура (**1.** *яңадан кәгазь ясау өчен җибәрелә торган ташландык китаплар, кәгазьләр* **2.** *перен. сай эчтәлекле, буш әдәби әсәр*)

маку́шка *ж* **1.** түбә, оч; баш; **~ горы́** тау башы (түбәсе); **~ де́рева** агач очы **2.** баш түбәсе

мала́га *ж* малага (*аракы*)

мала́йский, -ая, -ое малайлы ...ы, малайя ...ы; Малайя ...ы; **~ язы́к** малайя теле

мала́йцы *мн.* малайялылар, малайялар, Малайя халкы

малаха́й *м* **1.** (*шапка*) колаклы бүрек, колакчын бүрек **2.** (*одежда*) киң чикмән

малахи́т *м мин.* малахит

малахи́тов||ый, -ая, -ое малахит ...ы; малахит ...; малахиттан ясалган; **~ая шкату́лка** малахит тартма; **~ый зал** малахит зал

малева́ть *несов. кого-что и без доп., разг.* төрле төсләргә буяу

мале́йш||ий, -ая, -ее чак кына, аз гына, бик аз, иң кечкенә, иң аз, печтек кенә; **не име́ть ни ~его представле́ния** аз гына да күз алдына китерә алмау

малёк *м* маймыч

ма́леньк||ий, -ая, -ое **1.** кечкенә, бәләкәй, нәни; **~ий до́мик** кечкенә өй **2.** кечкенә буйлы, кыска буйлы, карсак; **~ий челове́к** кыска буйлы кеше **3.** ящь, сабый; **~ие де́ти** сабый балалар **4.** кечкенә генә, бераз, аз гына, аз, бик аз; **~ая неприя́тность** аз гына күңелсезлек ◆ **моё де́ло ~ое** минем эшем түгел

мали́на *ж* кура җиләгә (*куагы һәм җимеше*)

мали́нник *м* куралык, кура җиләклек, кура җиләге куаклыгы

мали́новка *ж* кура җиләк чыпчыгы

мали́нов||ый, -ая, -ое **1.** кура җиләге ...ы; кура җиләгеннән ясалган; **~ое варе́нье** кура җиләге вареньесы **2.** (*о цвете*) куе алсу төстәге ◆ **~ый звон** ягымлы нәфис кыңгырау тавышы (*кыңгырау чылтыравы турында*)

ма́лица *ж* малица (*болан тиресеннән тегелгән эче-тышы мех кием*)

ма́ло *нареч. и в знач. сказ. в разн. знач.* аз; җитми; **~ сде́лал** аз эшләдем; **мне э́того ~** бу гына миңа җитми; **~ ли** азмыни; **~ ли у нас хоро́ших люде́й?** бездә яхшы кешеләр азмыни? ◆ **~ ли что!** булмагае!, булса соң! **~-~** чак-чак кына; **~ того́ ...** *в знач. вводн. сл.* аннан башка. ...дан башка; ...ның өстенә тагын, ...дан тыш; ...ы җитмәгән

мало- *кушма сүзләрдә «аз», «җитәрлек түгел» мәгънәсен белдерган беренче кисәк, мәс.* **малообразо́ванный** аз белемле; **малоизве́данный** җитәрлек тикшерелмәгән; **малоиссле́дованный** аз тикшерелгән, җитәрлек өйрәнелмәгән; **малодохо́дный** аз керемле; **малоэта́жный** аз катлы; **мало́важный** әһәмияте аз булган

мало́ва́т, -а, -о *разг.* кечкенәрәк, бәләкәйрәк; таррак, кыскарак; **ро́стом ~** буйга кыскарак

малове́р *м* ышанып җитмәүче кеше

мало́во́дье *с* **1.** (*низкий уровень воды в реках, озёрах*) су азлык (*елга һәм күлдә*) **2.** су җитмәү; **борьба́ с ~м** су җитмәүгә каршы көрәш

малогабари́тный, -ая, -ое кечкенә габаритлы, тәбәнәк; **~ стано́к** кечкенә габаритлы станок

малоговоря́щий, -ая, -ее аз аңлата торган, ачыклап бирми торган, ышандыргыч булмаган; **~ факт** ышандыргыч булмаган факт

малогра́мотность *ж* аз белемлелек

малогра́мотный, -ая, -ое **1.** аз белемле, аз грамоталы; **~ челове́к** аз белемле кеше **2.** начар сыйфатлы, белеп эшләнмәгән; **~ прое́кт** начар сыйфатлы проект

малоду́шествовать *несов.* төшенкелеккә бирелү; югалып калу; куркып калу, аптырап калу; **~ в мину́ту опа́сности** куркыныч минутта югалып калу

малоду́шие *с* кыюсызлык, йөрәксезлек, куркаклык, төшенкелеккә бирелүчәнлек, җебегәнлек

малоду́шничать *несов. разг. см.* **малоду́шествовать**

малоду́шный, -ая,-ое йөрәксез, куркак, йомшак характерлы, төшенкелеккә бирелүчән; кыюсыз, икеләнүчән; **~ челове́к** куркак кеше; **~ посту́пок** кыюсыз эш-кыланыш

малоёзж||ий, -ая, -ее аз йөрелә торган; **~ая доро́га** аз йөрелә торган юл

малоземе́лье *с* аз җирлелек, җир җитмәү

малоземе́льный, -ая, -ое аз җирле, җире аз булган; **~ крестья́нин** аз җирле крестьян

малознако́мый, -ая, -ое аз таныш, начар таныш; **~ челове́к** аз таныш кеше

малозна́чащий, -ая, -ее, **малозначи́тельный,** -ая, -ое әһәмиятсез, артык әһәмияте булмаган

малоизве́стный, -ая, -ое артык билгеле түгел, аз билгеле, аз танылган; **~ая кни́га** аз билгеле китап

малоизу́ченный, -ая, -ое аз тикшерелгән, аз өйрәнелгән; **~ вопро́с** аз тикшерелгән мәсьәлә; **~ райо́н** аз өйрәнелгән район

малоиму́щий, -ая, -ее аз милекле, фәкыйрь

малоинтере́сный, -ая, -ое артык кызыклы булмаган, кызыксыз

малокали́берный, -ая, -ое *см.* **ме́лкокалиберный**

малокалори́йн||ый, -ая, -ое аз калорияле, туклыксыз; **~ая пи́ща** туклыксыз азык

малокро́вие *с* аз канлылык, кан азлык; **страда́ть ~м** аз канлылык белән интегү

малокро́вный, -ая, -ое кан азлык белән авыручы

малокульту́рный, -ая, -ое культурасы түбән, тәрбиясез; **~ челове́к** тәрбиясез кеше

малоле́сный, -ая, -ое аз урманлы, урманнары аз булган; **~ райо́н** аз урманлы район

малоле́тка *м, ж см.* **малоле́ток**

малоле́тн||ий, -яя, -ее сабый, яшь; **~ие де́ти** яшь балалар

малоле́ток *м разг.* сабый, яшь бала

малоле́тство *с разг.* сабый чак, балачак

малолитра́жка *ж разг.* малолитражка (*ягулык аз китә торган җиңел автомобиль*)

малолитра́жный, -ая, -ое **1.** аз сыешлы; **~ бак** аз сыешлы бак **2.** ягулык аз китә торган; **~ автомоби́ль** ягулык аз китә торган җиңел автомобиль

малолю́дный, -ая, -ое кеше (халык) аз була торган, аз кешеле; **~ райо́н** халык аз яши торган район

малолю́дье *с* кеше аз булу, кеше җитмәү

мало-ма́льски *нареч. разг.* аз гына, бераз гына, аз-маз, азмы-күпме

маломо́льск||ий, -ая, -ое *разг.* бик аз, аз гына, кечкенә генә; **проявйть ~ое внима́ние** аз гына игътибар итү

маломе́рн||ый, -ая, -ое кечкенә, кечкенә үлчәүле, аз керәшле, аз сыешлы; **~ая о́бувь** кечкенә үлчәүле аяк киеме

малометра́жн||ый, -ая, -ое кечкенә, аз метражлы; **~ая кварти́ра** кечкенә квартира

маломо́щн||ый, -ая, -ое **1.** (*физически слабый*) көчсез, хәлсез **2.** (*экономически слабый*) ярлы, хәлсез; **~ое хозя́йство** ярлы хуҗалык **3.** аз егәрле, куәтсез, егәрлеге аз булган; **~ый дви́гатель** аз егерле двигатель

малонадёжный, -ая, -ое аз ышанычлы, ышану шикле булган

малонаселённый, -ая, -ое халык аз утырган, халкы аз булган

малоо́пытный, -ая, -ое аз тәжрибәле, тәжрибәсе житәрлек түгел

малоподви́жный, -ая, -ое аз хәрәкәтле, аз йөри торган

ма́ло-пома́лу *нареч. разг.* азлап-азлап, әкрепләп, әкрен-әкрен, ашыкмыйча

малопоня́тный, -ая, -ое аңлашылмый торган, аз аңлаешлы

малопри́быльный, -ая, -ое аз керемле (табышлы), файдасыз

малопригóдный, -ая, -ое эшкә яраксыз диярлек

малопродукти́вный, -ая, -ое **1.** аз нәтиҗәле, нәтиҗәсе (файдасы) аз булган; **~ труд** аз нәтиҗәле хезмәт **2.** аз продукцияле, аз продуктлы, продукцияне аз бирә торган; **~ скот** продукцияне аз бирә торган терлек

малора́звит||ый, -ая, -ое **1.** (*недоразвитый*) җитлегеп җитмәгән, үсеп җитмәгән **2.** аз үсеш алган, [үсештә] артта калган; **~ая промы́шленность** үсештә артта калган промышленность **3.** (*недостаточно образованный*) сай (аз) белемле, белеме сай (аз)

малоразгово́рчивый, -ая, -ое аз сөйләшүчән, сүзгә саран

малоро́слый, -ая, -ое (*о людях и животных*) кечкенә буйлы, кечкенә гәүдәле, кыска буйлы, карсак; (*о растениях*) кыска, тәбәнәк

малосеме́йный, -ая, -ое аз семьялы, кечкенә семьялы

малосодержа́тельный, -ая, -ое эчтәлексез, файдасыз, мәгънәсе аз булган; **~ разгово́р** файдасыз сөйләшү

ма́л||ый I, -ая, -ое **1.** кечкенә, бәләкәй; **~ый разме́р** кечкенә размер **2.** яшь; **~ые де́ти** яшь балалар **3.** *только кратк. ф.* **мал, ~á, ~ó** кысан, кечкенә, бәләкәй; **пальто́ мне ~ó** пальто миңа кечкенә ♦ **без ~ого...** диярлек, ...га якын; **без ~ого сто рубле́й** йөз сум диярлек, йөз сумга якын; **за ~ым де́ло ста́ло** эш юктан гына тора, эш бик кечкенә генә нәрсәгә терәлде; **~ая механиза́ция** өлешчә механикалаштыру; **мал золотни́к, да до́рог** кечкенә булса да төш кенә; алтын кечкенә дә— түшкә кадыйлар; **мал ~á ме́ньше** берсеннән берсе кечкенә (*балалар турында*); **от ~а до вели́ка** кечкенәсеннән алып зурысына кадәр, олысы-кечесе; **са́мое ~ое** аз дигәндә, иң азында, иң кимендә; **са́мое ~ое двóе су́ток пробу́ду в доро́ге** аз дигәндә, юлда ике тәүлек булырмын; **с ~ых лет** кечкенәдән үк, яшьтән үк, бала чактан ук

ма́лый II *м разг.* егет, үсмер егет, яшь егет; **двадцатиле́тний ~** егерме яшьлек егет; **сла́вный (до́брый) ~** шәп (менә дигән) кеше, әйбәт (уңган) егет

малы́ш *м разг.* сабый, яшь бала, кечкенә бала, бәләкәч

малы́шка *м, ж см.* **малы́ш**

малышня́ *ж собир. прост.* бала-чага, балалар, сабыйлар

малышо́в||ый, -ая, -ое бәлекәчләр ...ы; **~ая гру́ппа в де́тском саду́** балалар бакчасында бәләкәчләр группасы

ма́льва *ж* мальва, бояр гөле

ма́льчик *м* ир бала, малай ♦ **~ с па́льчик** бармак зурлыгындагы малай; орчык кадәр малай, бер карышлы малай (*рус халык әкиятләрендә*)

мальчико́в||ый, -ая, -ое ир балалар ...ы; малайлар ...ы; **~ое пальто́** малайлар пальтосы

мальчи́шеский, -ая, -ое **1.** ир бала [-лар] ...ы; малай[лар] ...ы; **~ вид** малайлар кыяфәте **2.** *перен.* малайларча...; **~ посту́пок** малайларча кыланыш

мальчи́шество *с* **1.** балалык, балачагалык, балаларча кыланыш **2.** (*нелепость, легкомыслие*) беркатлылык, җиңел акыллылык; **что за ~?** бу нинди җиңел акыллылык?

мальчи́шечий, -ья, -ье *разг. см.* **мальчи́шеский** 1

мальчи́шка *м разг.* малай

малю́тка *м, ж* сабый, кечкенә бала, имчәк баласы

маля́вка *ж см.* **малёк**

маля́р *м* буяучы, маляр

маляри́йн||ый, -ая, -ое **1.** малярия ...ы; бизгәк ...ы; **~ый при́ступ** бизгәк пристубы; **~ый комáр** малярия озынборыны **2.** малярия белән ...ы; **~ый больнóй** малярия белән авыручы **3.** малярияга каршы көрәш ...ы; **~ая ста́нция** малярияга каршы көрәш станциясе

маляри́я *ж* малярия, бизгәк; **тропи́ческая ~** тропик бизгәк

маля́рничать *несов. разг.* малярлык итү, маляр булып эшләү

маля́рн||ый, -ая, -ое маляр[лык] ...ы; буяу ...ы; **~ые рабóты** малярлык эшләре; **~ая кисть** маляр (буяу) пумаласы

ма́ма *ж* әни, әнкәй

мама́ша *ж разг.* **1.** *см.* **ма́ма**; **2.** (*при обращении к пожилой женщине*) апа

ма́менькин, -а, -о *разг. уст.*: **~ сынóк** иркә бала, иркәләп бозылган ящусмер, иркә егет; **~а дóчка** иркә кыз, иркәләп бозылган кыз

ма́монт *м* мамонт

манга́л *м* мангал (*ризык кыздыру миче*)

ма́нго *с нескл.* манго (*тропик агач һәм аның җимеше*)

мангу́ст *м*, **мангу́ста** *ж* мангуста (*тропик җәнлек*)

мандари́н I *м* мандарин (*борынгы Кытайның зур түрәләренә европалылар тарафыннан бирелгән исем*)

мандари́н II *м* мандарин (*цитрус агач һәм аның җимеше*)

манда́т *м* мандат

манда́тн||ый, -ая, -ое мандат ...ы, мандатлы; **~ая комúссия** мандат комиссиясе

мандоли́на *ж* мандолина

манёвр *м* **1.** *воен.* манёвр (*сугыш вакытында гаскәрләрнең дошманга һөҗүм итү өчен җайлырак булган урынга күчүләре*) **2.** *обычно мн.* **~ы** *воен.* манёврлар (*гаскәрләрнең сугыш шартларына якынайтылган обстановкада тактик өйрәнүләр үткәрүе*) **3.** *перен.* оста хәрәкәт, хәйлә **4.** *мн.* **~ы** *ж.-д.* манёврлар (*тимер юл станциясендә поездлар төзү өчен вагоннарны юлдан юлдан-юлга күчереп йөрту*)

манёвренн||ый, -ая, -ое *воен.* манёврлы; **~ая та́ктика** манёврлы тактика; **~ая война́** манёврлы сугыш

маневри́ровать *несов.* **1.** *воен., ж.-д.* манёвр[лар] ясау **2.** (*лавировать*) оста хәрәкәт итү, манёврлау **3.** *перен.* (*действовать ловко, хитро*) хәйлә белән хәрәкәт итү, хәйлә белән читен хәлдән чыгарга тырышу **4.** *перен.* чем оста файдалану, эшне белеп идарә итү; **~ сре́дствами** средстволарны оста файдалану

маневро́вый, -ая, -ое *ж.-д.* манёврлар ясау ...ы; ~ **паровоз** манёврлар ясау паровозы

мане́ж *м* манеж (**1.** *атка атланып йөрү һәм гаскәрнең кунегу занятиеләрен үткәру өчен махсус җиһазландырылган бина яки урын* **2.** *цирк аренасы* **3.** *тәпи йөрергә өйрәнә башлаган балалар өчен күчерелмә мәйданчык*)

манеке́н *м* манекен

манеке́нщик *м* манекенчы (*күргәзмәдә киемнәр киеп күрсәтүче кеше*)

манеке́нщица *ж* манекенчы хатын (кыз)

мане́р *м разг.*: **таки́м ~ом** шулай, шул рәвешчә; **на но́вый ~** яңача; **на ста́рый ~** искечә; **сде́лать узело́к на ~ба́нта** бант шикелле итеп төен ясау

мане́ра *ж* **1.** гадәт; **~ вести́ себя́** үзүзеңне тоту гадәте **2.** манера, рәвеш; **~ пе́ния** җырлау манерасы

мане́рничать *несов. разг.* кылану, боргалану-сыргалану

мане́рн||ый, -ая, -ое ясалма; табигый булмаган; **~ые же́сты** ясалма кул хәрәкәтләре; **~ый стиль** ясалма стиль

манже́та *ж* манжет (*кулмәк яки блуза җиңе очына эләктереп яки тегеп куела торган җиңсә*)

маниака́льн||ый, -ая, -ое мания белән авыру ...ы; маниакаль; **~ое состоя́ние** мания белән авыру халәте

маникю́р *м* маникюр; **сде́лать ~** маникюр ясау

маникю́рн||ый, -ая, -ое маникюр ...ы; **~ые но́жницы** маникюр кайчысы

маникю́рша *ж* маникюрша, маникюрчы

мани́ловщина *ж неодобр.* маниловчылык, буш хыялга бирелү

манипули́ровать *несов. чем и без доп.* **1.** (*кул белән эшләгәндә*) катлаулы хәрәкәтләр ясау **2.** *перен.* алдау, хәйлә кору

манипуля́тор *м тех.* манипулятор (**1.** *катлаулы производство һәм контроль процессларын регулярлау приборы* **2.** *телеграф сигналларын тапшыру ачкычы*)

манипуля́ция *ж* **1.** (*кул белән эшләгәндә*) катлаулы хәрәкәт, катлаулы алым **2.** *перен. разг. пренебр.* алдау, хәйлә, ялган эш

мани́ть *несов. кого-что* **1.** [ымлап] чакыру; **~ щенка́** эт баласын чакыру **2.** *перен.* үзенә тарту, күңелне җилкендерү; җәлеп итү; **меня́ ма́нит мо́ре** мине диңгез үзенә тарта

мани́фест *м* манифест

манифеста́ция *ж* манифестация; **~ проте́ста** протест манифестациясе

манифести́ровать *несов.* манифестациядә катнашу

мани́шка *ж* күкрәкчә, манишка

ма́ния *ж* **1.** мания (*психик авыру*); **~ пресле́дования** эзәрлекләү маниясе (*кемнәрдер эзәрлекли дип саташу*) **2.** *перен.* (*берәр нәрсәгә*) бик нык бирелү, (*берәр нәрсә белән*) артык мавыгу; **~ писа́ть стихи́** шигырьләр язу белән артык мавыгу

ма́нка *ж* манный ярмасы

манки́ровать *сов., несов. чем и доп.* игътибарсыз (салкын) карау; игътибарсыз булу; гамьсезлек (ваемсызлык) күрсәтү; **~ рабо́той** эшкә салкын карау

ма́нн||а *ж*: **как ~ы небе́сной ждать** бик нык (түземсезлек белән, бик зарыгып) көтү; **~ой небе́сной пита́ться** *шутл.* авызны чөйгә элү

ма́нн||ый, -ая, -ое манный; **~ая крупа́** манный ярмасы; **~ая ка́ша** манный боткасы

манове́ни||е *с книжн.* кул болгау, изәү; ишарә итү (*баш яки кул белән*) ♦ **бу́дто (сло́вно, то́чно) по ~ю волше́бного же́зла или волше́бной па́лочки** күз ачып йомганчы

мано́к *м охот.* алдавыч сыбызгы (*кыргый җәнлекләрне, киек кошларны җәлеп итү өчен*)

мано́метр *м* манометр

манса́рда *ж* чарлак, чарлактагы торак бүлмә

ма́нси *мн. нескл.* (*ед.* **ма́нси** *м, ж*) мансилар, манси халкы

мансие́ц *м* манси, манси кешесе

мансийка *ж* манси хатыны (кызы)

мансийский, -ая, -ое манси[лар] ...ы; **~ язы́к** манси теле

ма́нси́йцы *мн. см.* **ма́нси**

ма́нтия *ж* **1.** мантия (*плащ сыман киң озын кием*) **2.** *зоол.* ябынча (*кайбер умырткасыз моллюскларда тире җыерчыгы*) **3.** *геол.* мантия (*Җир кабыгы астындагы эчке сфера*)

манто́ *с нескл.* манто (*хатын-кызлар кия торган, гадәттә мехтан тегелгән киң пальто*)

манускри́пт *м книжн.* [борынгы] кулъязма

мануфакту́ра *ж* мануфактура (**1.** *хезмәт бүленешенә нигезләнгән капиталистик предприятие* **2.** *уст.* текстиль фабрикасы **3.** *уст. тукымалар, тукылган әйберләр*)

маньчжу́рский, -ая, -ое маньчжур [-лар] ...ы; **~ язы́к** маньчжур теле

маньчжу́ры *мн.* маньчжурлар, маньчжур халкы

манья́к *м* маньяк

маня́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **мани́ть**; **2.** кызыктыргыч, мавыктыргыч; **~ие перспекти́вы** кызыктыргыч перспективалар

марабу́ *м* марабу (*озын томшыклы кош*)

мара́зм *м* маразм; **ста́рческий ~** картлык маразмы

мара́л *м* марал (*болан*)

мара́ть *несов. разг.* **1.** *что* пычрату, буяу; **~ пла́тье** күлмәкне пычрату **2.** *перен. кого-что* пычрату, кара ягу, пычрак ату; **~ че́стное и́мя** намуслы исемгә кара ягу **3.** *что* (*неряшливо писать, рисовать*) язгалап маташу, буяп маташу; **~ стихи́** шигырьләр язгалап маташу **4.** *что* язылганны сызу

мара́ться *несов.* **1.** *разг.* (*пачкаться*) буялу, пычрану **2.** *перен. прост.* (*ввязываться в неприятную историю*) тыгылу, пычрану; **~ не хо́чется** пычранасы килми; **не сто́ит ~** кул пычратуның кирәге юк

марафо́н *м* марафон; **лы́жный ~** чаңгы марафоны

марафо́нец *м* марафончы

марафо́нский: ~ бег марафон йөгерешe (*42 километр 195 метрдан гыйбарәт булган иң озын дистанциягә йөгерү*)

ма́рганец *м хим.* марганец

ма́рганцев||ый, -ая, -ое **1.** марганец ...ы; **~ое месторожде́ние** марганец чыганагы **2.** марганецлы; **~ая руда́** марганецлы руда; **~ая сталь** марганецлы корыч

марганцо́вка *ж разг.* марганцовка

марганцо́вый, -ая, -ое марганцовкалы; **~ раство́р** марганцовкалы эремә

маргари́н *м* маргарин

маргари́тка *ж бот.* маргаритка

ма́рево *с* **1.** (*мираж*) сагым **2.** (*дымка, туман*) рәшә, һаваның тоныклыгы

маре́на *ж* марена (*үлән*)

маре́нго *неизм. прил.* соргылт кара; **костю́м ~** соргылт кара костюм

ма́ри *мн. нескл.* (*ед.* **ма́ри** *м, ж*) марилар, мари халкы

мари́ец *м* мари, мари кешесе

мари́йка *ж* мари хатыны (кызы)

мари́йский, -ая, -ое мари[лар] ...ы; **~ язы́к** мари теле

мари́йцы *мн. см.* **ма́ри**

марина́д *м* маринад (**1.** *ашамлыкка тәм кертү өчен серкә, зәйтүн мае һ.б.ш. катнаштырып хәзерләнгән сыекча* **2.** *маринадланган ашамлык*)

марини́ст *м* мариначы, маринист (*диңгез күренешләре сурәтләнгән картиналар ясаучы рассам*)

маринова́ние *с см.* **маринова́ть**

маринова́ть *несов.* **1.** *что* маринадлау, мариновать итү; **~ грибы́** гөмбә маринадлау **2.** *перен. кого-что, разг.* юри кичектерү, тоткарлап тору, хәрәкәтсез яткыру; **~ де́ло** эшне озак тоткарлап тору

марионе́тка *ж* **1.** марионетка, курчак **2.** *перен.* марионетка

марионе́точн||ый, -ая, -ое марионетик, марионетка ...; **~ое прави́тельство** марионетик хөкүмәт

марихуа́на *ж* марихуана (*наркотик матдә*)

ма́рк||а I *ж* **1.** марка; **почто́вая ~а** почта маркасы **2.** келәймә; тамга; **фабри́чная ~а** фабрика келәймәсе **3.** сорт, сыйфат; **това́р вы́сшей ~и** иң яхшы сыйфатлы товар **4.** (*престиж, репутация*) дәрәҗә, абруй, репутация; **держа́ть ~у** дәрәҗәне төшермәү, үзеңне тота белү

ма́рка II *ж* марка (*Германиядә һәм Финляндиядә акча берәмлеге*)

маркёр I *м уст.* маркёр (*бильярд уенында хезмәт күрсәтүче һәм уен исәбен алып баручы кеше*)

маркёр II *м с.-х.* маркёр (*яшелчә утырту өчен оялар билгели яки сызык сыза торган авыл хуҗалыгы машинасы*)

марки́з *м* маркиз (*кайбер көнбатыш илләрендә дворянлык титулы һәм шул титулны алган кеше*)

марки́за *ж* маркиза (*маркиз хатыны яки кызы*)

маркизе́т *м* маркизет (*тукыма*)

ма́рк||ий, -ая, -ое кер күтәрми торган, тиз керләнүчән, тиз буялучан; **~ая мате́рия** кер күтәрми торган тукыма

маркирова́ть I *сов., несов. что, спец.* (*поставить клеймо*) келәймә сугу, тамга сугу, маркалау, келәймәләү

маркирова́ть II *сов. несов. что, с.-х.* маркировкалау, маркёр белән оялар билгеләү, сызыклар сызу

маркиро́вка I *ж* **1.** *см.* **маркирова́ть** I; **2.** (*знак, клеймо*) билге; келәймә, тамга

маркиро́вка II *ж см.* **маркирова́ть** II

маркиро́вщик *м* маркировкачы, келәймә сугучы, маркировкалаучы

маркси́зм *м* марксизм

марксизм-ленини́зм *м* марксизм-ленинизм

марксист *м* марксист

марксисти́ско-ле́нинск||ий, -ая, -ое марксистик-ленинчыл; **~ая идеоло́гия** марксистик-ленинчыл идеология

маркше́йдер *м* маркшейдер

ма́рлев||ый, -ая, -ое марля ...ы, марля... ; **~ая повя́зка** марля бәйләвеч

ма́рля *ж* марля

мармела́д *м* мармелад

мародёр *м* мародёр (*сугыш кырында яралы яки үлгән сугышчыларның әйберләрен талаучы; сугыш вакытында халыкны талау белән шөгыльләнүче*)

мародёрство *с* мародёрлык

мародёрствовать *несов.* мародёрлык итү

марокка́нский, -ая, -ое марокколы[лар] ...ы; Марокко ...ы; **~ наро́д** Марокко халкы

марокка́нцы *мн.* мароккалылар

ма́рочн||ый, -ая, -ое маркалы; **~ая сталь** маркалы корыч ♦ **~ые ви́на** маркалы шәрабләр

Марсельёза *ж* Марсельеза (*Франциянең милли гимны*)

март *м* март, март ае

марте́н *м* мартен (**1.** *мартен корычы* **2.** *мартен миче*)

марте́новск||ий, -ая, -ое мартен ...ы; **~ая печь** мартен миче

ма́ртовск||ий, -ая, -ое март ...ы; **~ое со́лнце** март кояшы

мартышка *ж* мартышка (маймыл)

мартышкин, -а, -о: **~ труд** файдасыз эш, мәгънәсез эш

марш I *м в разн. знач.* марш; **церемониа́льный ~** церемониаль марш; **похоро́нный ~** матәм маршы; **трёхдне́вный ~** өч көнлек марш

марш II *межд.* марш, кузгал (*хәрби команда сүзе*) ♦ **~ отсю́да!** ычкын моннан!, марш моннан!, үкчәңне күтәр!

ма́ршал *м* маршал; **~ Сове́тского Сою́за** Советлар Союзы маршалы; **~ артилле́рии** артиллерия маршалы

ма́ршальск||ий, -ая, -ое маршал ...ы; маршаллык ...ы; **~ая звезда́** маршал йолдызы

ма́ршевый, -ая, -ое **1.** марш ...ы; **~ поря́док строя** сафның марш тәртибе **2.** фронтка озатыла торган; фронтка баручы; **~ батальо́н** фронтка баручы батальон

марширова́ть *несов.* маршировкалау, марш атлау

маршру́т *м* маршрут; **тури́стский ~** туристлык маршруты

маршру́тн||ый, -ая, -ое маршрут ...ы, маршрутлы; **~ое такси́** маршрутлы такси

ма́ск||а *ж* **1.** *в разн. знач.* маска, битлек; **маскара́дная ~а** маскарад маскасы; **фехтова́льная ~а** фехтование маскасы; **посме́ртная ~а** үлгәч (үлгәннән соң) алынган маска **2.** *перен.* ясалма тышкы күренеш, хәйләле тышкы кыяфәт ♦ **наде́ть [на себя́] ~у** битлек кию, икейөзлеләнү; **сбро́сить [с себя́] ~у** битлекне салу, чын йөзеңне күрсәтү; **сорва́ть ~у** *с кого* чын йөзен ачу, фаш итү

маскара́д *м* маскарад

маскара́дный, -ая, -ое маскарад ...ы; **~ костю́м** маскарад костюмы

маскирова́ть *несов.* **1.** *кого-что* маскировкалау; **~ ору́дие** орудиене маскировкалау **2.** *перен. что* яшерү, каплау; **~ свои́ наме́рения** үз теләкләреңне яшерү

маскирова́ться *несов.* **1.** маска кию, маскарад костюмы кию **2.** *перен.* (*притворяться*) битлек кию, икейөзлеләнү **3.** *воен.* (*делаться незаметным*) маскировкалану **4.** *страд. от* **маскирова́ть**

маскиро́вка *ж* **1.** *см.* **маскирова́ть, маскирова́ться; 2.** маскировка (*ныгытмаларны, коралларны һ.б.ш. дошманнан яшерү өчен кулланыла торган әйберләр*)

маскиро́вочный, -ая, -ое маскировка ...ы; **~ хала́т** маскировка халаты

ма́сленица *ж* масленица, май чабу (*борынгы славяннарда кышны озату бәйрәме; соңыннан христиан чиркәве үз йоласына әйләндергән*)

маслёнка *ж* май савыты, маслёнка

маслёнок *м* майлы гөмбә

надᵃ (надоᵉ) *приставка* **1.** *фигыльләр ясый, аның мәгънәләре татар теленә түбәндәгечә тәрҗемә ителә*: 1) *«өстән», «өстәмә рәвештә», «...п озынайту» сүзләре ярдәмендә яки төп фигыльне тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **надвязáть** өстән бәйләү; **надклéить** ябыштыру; **надстáвить** ялгап озынайту; **надстрóить** өстән төзү; 2) *«бераз гына», «аз гына», «читеннән [генә]», «читеннән аз гына», «өстән [генә]», «өстән аз гына» сүзләре ярдәмендә яки төп фигыльне тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **надкуси́ть** тешләп кую; **надрéзать** өстән аз гына кисү **2.** *исем һәм сыйфатлар ясый, мәс.* **надбро́вье** каш өсте; **надзéмный** җир өсте ...ы; **надкóстница** сөяк өслеге

надава́ть *сов. что, чего, разг.* күп итеп бирү, берничә тапкыр бирү; ~ **подáрков** күп итеп бүләкләр бирү; ~ **обещáний** бик күп вәгъдәләр бирү

надави́ть *сов.* **1.** *что, на что* җиңелчә генә (акрын гына) басу; ~ **кнóпку (на кнóпку)** акрын гына кнопкага басу **2.** *что, чего* (*берникадәр*) сыгу, сыгып җыю; ~ **стакáн лимóнного сóку** бер стакан лимон суы сыгу

надáвливать *несов. см.* **надави́ть**

надáивать *несов. см.* **надои́ть**

надари́ть *сов. что, чего, разг.* бик күп [бүләк] бирү; ~ **подáрков** бик күп бүләк бирү

надáривать *несов. см.* **надари́ть**

набáвить *сов. разг. см.* **набáвить**

надбáвка *ж разг. см.* **набáвка**

надбавля́ть *несов. см.* **надбáвить**

надбива́ть *несов. см.* **надби́ть**

надби́ть *сов. что, разг.* китү, китеп төшерү; чатнату; ~ **тарéлку** тәлинкәне чатнату

надбро́вн||ый, -ая, -ое *анат.* каш ...ы; каш өстендәге; ~**ые дýги** каш кыйгачлары

надбро́вье *с анат.* каш өсте

надвига́ть *несов. см.* **надви́нуть**

надвига́||ться *несов.* **1.** *см.* **надви́нуться; 2.** *страд. от* **надвигáть**

надви́нуть *сов. что* этәреп каплау (каплап кую); ~ **ша́пку на лоб** бүрекне мангаена кадәр батырып кию

надви́ну||ться *сов. прям., перен.* акрынлап якынлашу (җитү); [килеп] җитү; ~**лась зимá** кыш килеп җитте; ~**лась ночь** төн җитте; ~**лась стáрость** картлык якынлашты; ~**лись ту́чи** кара болытлар акрынлап якынлаштылар

надво́дн||ый, -ая, -ое **1.** су өсте ...ы, су өстендәге; ~**ая часть а́йсберга** айсбергның су өстендәге өлеше **2.** су өсте ...ы; ~**ый флот** су өсте флоты

НАД-НАД

на́двое *нареч.* икегэ, урталайга; **расколо́ть ~** икегэ яру

надво́рн||ый, -ая, -ое: **~ые постро́йки** каралтылар

надвяза́ть *сов. что* **1.** бәйләп озынайту **2.** ялгап озынайту; **~ верёвку** бауны ялгап озынайту

надвя́зка *ж* **1.** *см.* **надвяза́ть; 2.** (*надвязанная часть*) бәйләп өстәлгән өлеш (кисәк)

надвя́зывать *несов. см.* **надвяза́ть**

надгортáнник *м анат.* бугаз өслеге, бугаз өстендәге кимерчәк

надгро́бие *с* ташбилге, кабер ташы, кабер өстенә куелган һәйкәл; **мра́морное ~** кабер өстенә куелган мәрмәр һәйкәл

надгро́бн||ый, -ая, -ое **1.** кабер ...ы, кабер өстенә куелган; **~ый па́мятник** кабер ташы **2.** кабер ташына ...ган; **~ая на́дпись** кабер ташына язылган сүзләр **3.** мәет күмгәндә (җирләгәндә) ...а торган; **~ое сло́во** мәет күмгәндә әйтелә торган сүзләр

надгрыза́ть *несов. см.* **надгры́зть**

надгры́зть *сов. что* өстән кимерү, тешләп алу, читен тешләп алу

наддава́ть *сов. что, чего, разг.* бераз өстәү, өсти төшү, шәбәйтү, арттыру, арттыра төшү; **~ жа́ру** эссе салу (өстәү)

надебоши́рить *сов. разг.* җәнҗал (тавыш, гауга) чыгару

надёванн||ый, -ая, -ое *разг.* киелгән; **~ое пла́тье** киелгән күлмәк

надева́ть *несов. см.* **наде́ть**

надева́ться *несов.* **1.** *см.* **наде́ться; 2.** *страд. от* **надева́ть**

наде́жд||а *ж* өмет, ышаныч; **на него́ нет ни мале́йшей ~ы** зәррә кадәр дә ышаныч юк аңарга ◆ **в ~е** *на что* ...га ышанып, ...га ышаныч белән; **в ~е на твою́ по́мощь** синең ярдәмеңә ышанып; **возлага́ть ~у (~ы)** *на кого-что* ...га өмет баглау; **вселя́ть ~у** *в кого-что* өметләндерү, өмет уяту; **оправда́ть ~ы** *чьи* өметен (ышанычын) аклау; **пита́ть ~у (~ы)** өметләну, ышану, өметләнеп (ышанып) тору; **подаёт ~ы** *кто* өметләндерә, ышаныч уята; **потеря́ть ~у** *на что* өметне өзү, ышанычны югалту, өмет киселү

наде́жность *ж* ышанычлылык; **~ механи́зма** механизмның ышанычлылыгы

наде́жный, -ая, -ое ышанычлы, өметле

наде́л *м* **1.** *см.* **наделя́ть; 2.** (*участок земли*) имана, имана җире

наде́лать *сов. что, чего* **1.** (*бернакадәр*) ясау, ясап кую; **~ игру́шек** уенчыклар ясау **2.** (*күңелсез яки ямьсез*) эш эшләү, эшләп ташлау, (*күңелсез яки ямьсез*) эш тудыру, чыгару, китереп чыгару; **~ глу́постей** ахмаклыклар эшләп ташлау; **~ хлопо́т** мәшәкатьләр тудыру; **~ шу́му** шау-шу чыгару

наделя́||ть *сов. кого-что* **1.** бирү, бүлеп бирү, өлеш чыгару; **~ть землёй** җир бирү **2.** *перен.* бирү; **приро́да ~ла его́ тала́нтом** табигать аңа талант биргән; **~ть про́звищем** *кого-л. берәүгә* кушамат бирү (тагу)

наде́льный, -ая, -ое имана ...ы; **~ая земля́** имана җир

наделя́ть *несов. см.* **наде́лить**

надёргать *сов. что, чего* **1.** (*бернакадәр*) йолку; **~ льна** (*бернакадәр*) җитен йолку **2.** *перен. разг.* аннан-моннан йолку, йолкып алу; **~ цита́т** аннан-моннан цитаталар йолкып алу

надёргивать I *несов. см.* **надёргать**

надёргивать II *несов. см.* **надёрнуть**

надёрзить *сов. кому, разг.* каты (тупас, начар) сүзләр әйтеп ташлау

надёрнуть *сов. что, разг.* тиз генә тартып ябу (кию); **~ на себя́ одея́ло** юрганны тиз генә тартып ябыну

наде́ть *сов. что* **1.** (*на себя*) кию; (*на кого-что-либо*) кигезү, кидерү, киертү; **~ пальто́** пальто кию; **~ ша́пку** бүрек кию; **~ очки́** күзлек кию; **~ кольцо́ на па́лец** бармакка йөзек кию; **~ чехо́л на дива́н** диванга тышлык киертү **2.** (*прикрепить*) тагу; **~ орде́на и меда́ли** орден һәм медальләрне күкрәккә тагу

наде́||ться *сов. разг.* киелү; **сапоги́ легко́ ~лись** итекләр җинел киелделәр

наде́яться *несов.* **1.** *на что* (*рассчитывать*) ышану, өмет итү, өметләнү, өмет баглау **2.** *на кого-что* (*полагаться*) таяну, ышану ◆ **~ как на ка́менную го́ру** *погов.* тауга (ташка) ышангандай ышану

надзе́мн||ый, -ая, -ое җир өстендәге, җир өсте ...ы; **~ые сооруже́ния** җир өсте корылмалары; **~ая часть расте́ния** үсемлекнең җир өстендәге өлеше

надзира́тель *м* күзәтүче; назир (*уст.*)

надзира́ть *несов. за кем-чем* күзәтү, күзәтеп (тикшереп) тору

надзо́р *м* **1.** *см.* **надзира́ть; 2.** *собир.* күзәту; **техни́ческий ~** техник күзәту; **прокуро́рский ~** прокурор күзәтуе; **суде́бный ~** суд күзәтуе

надиви́ться *сов. кому-чему, на кого-что, разг.*: **не могу́ ~** карап (тыңлап) туя алмыйм

надка́лывать *несов. см.* **надколо́ть**

надка́лываться *несов.* **1.** *см.* **надколо́ться; 2.** *страд. от* **надка́лывать**

надкла́ссовый, -ая, -ое сыйныфлардан тыш, сыйныфларга бәйләнмәгән

надкле́ивать *несов. см.* **надкле́ить**

надкле́ить *сов. что* ябыштыру, ябыштырып кую (озынайту)

надко́л *м* (*надколотое место*) кителгән урын, китек; (*надтреснутое место*) ярык, ярылган (чатнаган) урын

надколе́нн||ый, -ая, -ое: **~ая кость** тез капкачы

надколо́ть *сов. что* **1.** (*расщепить*) аз гына яру, яра төшү; **~ бревно́** бүрәнәне аз гына яру **2.** (*проколоть*) [җиңелчә генә] чәнчеп тишү

надколо́||ться *сов.* аз гына (бераз) ярылу, ярыла төшү; **оре́х ~лся** чикләвек бераз ярылды

надко́стница *ж анат.* сөяк өслеге

надко́стный, -ая, -ое сөяк өстендәге ..., сөяк өсте ...ы

надкры́ль||я *мн.* (*ед.* **~е** *с*) канат өслекләре; **~я жука́** коңгызның канат өслекләре

надку́с *м* (*надкушенное место*) тешләгән (тешләп алган) урын

надкуси́ть *сов. что* [читеннән] тешләп алу (кую)

надку́сывать *несов. см.* **надкуси́ть**

надла́мывать *несов. см.* **надломи́ть**

надла́мываться *несов.* **1.** *см.* **надломи́ться; 2.** *страд. от* **надла́мывать**

надлежа́щ||ий, -ая, -ее тиешле; **приня́ть ~ие ме́ры** тиешле чаралар күрү; **~им о́бразом** тиешенчә, тиешле рәвештә

надлежи́т *безл. кому-чему и с неопр., книжн.* тиеш, кирәк; **~ яви́ться в ука́занный срок** күрсәтелгән вакытта килергә кирәк

надло́м *м* **1.** *см.* **надломи́ть, надломи́ться; 2.** (*надломленное место*) чатнаган (кителгән, сынган) урын ◆ **душе́вный ~** күңел төшенкелеге (сыныклгы, китеклеге), рух төшү

надломи́||ть *сов.* **1.** *что* бераз сындыру, бераз китү; чатнату; **~ть ве́тку** ботакны бераз сындыру **2.** *перен. кого-что* какшату, вату, [көчен] бетерү, [хәлен] бетерү; **го́ре его́ ~ло** кайгы-хәсрәт аны бетергән; **~ть си́лы** көчен какшату

надломи́||ться *сов.* **1.** бераз сыну, бераз кителү; **зуб ~лся** теш чатнаган **2.** *перен.* (*душевно*) рухсызлану; (*физически*) какшау, начарлану, бетерену

надло́мленн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **надломи́ть; 2.** *перен.* (*душевно*) рухсыз, рухсызланган, күңелсез, төшенке рухлы, рухы төшкән; (*физически*) какшаган

надме́нность *ж* тәкәбберлек, киберлек, эрелек, һавалылык

надме́нн||ый, -ая, -ое тәкәббер, кибер, эре, һавалы; **с ~ым ви́дом** тәкәббер кыяфәт белән

надмоги́льный, -ая, -ое *см.* **надгро́бный**

на́до I *в знач. сказ. безл. кому-чему, с неопр., кого-что, кого-чего* кирәк; **так и ~** шулай кирәк; **не ~ спеши́ть** ашыкмаска кирәк; **сообщи́ть кому́ ~** кирәк кешесенә хәбәр итү ◆ **~ ду́мать, дождя́ не бу́дет** яңгыр яумас ахрысы; 2) (*конечно*) шиксез, әлбәттә, билгеле; **что ~!** *прост.* (*очень хороший, очень хорошо*) менә дигән!, бик яхшы!

на́до II *см.* **над**

на́добност||ь *ж* кирәклек, кирәк булу; ихтыяж, хаҗәт, мохтаҗлык, мохтаҗ булу; **в слу́чае ~и** кирәк булган хәлдә; **в э́том нет никако́й ~и** моңа бернинди хаҗәт юк; **име́ть ~ь** *в чём-л. берәр нәрсәгә* мохтаҗ булу; **нет ~и** *в чём-л. берәр нәрсәнең* кирәге (хаҗәте) юк ◆ **по како́й ~и?** нинди эш (йомыш) белән?

надоеда́ть *несов. см.* **надое́сть**

надоеда́лив||ый, -ая, -ое йөдәтүчән, йөдәткеч, бәйләнчек, басымчак, тенкә корткыч, тенкәгә тиючән, туйдырып бетерә торган; **~ый челове́к** бәйләнчек кеше; **~ая про́сьба** тенкә корткыч сораулар

надое́||сть *сов. кому-чему* туйдыру, йөдәтү, туйдырып (йөдәтеп) бетерү, теңкәгә тию (тиеп бетү); **мне ~ло чита́ть** мин укып туйдым

надои́ть *сов. что, чего* савып алу

надо́й *м с.-х.* савым; **дневно́й ~** көнлек савым; **ежедне́вный ~** көндәлек савым

на́долба *ж* (*җиргә казып утыртылган*) кыска багана

надо́лго *нареч.* озакка, озак вакытка

надо́мник *м* өйдә эшләүче (*предприятие, артель тарафыннан бирелгән эшне*)

надо́мница *ж* өйдә эшләүче хатын (кыз)

надорва́ть *сов. что* **1.** бераз ерту, ерта төшү, читен ерту; **~ паке́т** пакетның читен ерту **2.** *перен.* зыян китерү, имгәтү; какшату; **~ го́лос** тавышын бетерү (карлыктыру); **~ здоро́вье** сәламәтлекне какшату; **~ си́лы** хәлдән таю ♦ **~ живо́т (живо́тики) со́ смеху (от хо́хота)** *прост.* эч катып (катканчы) көлү

надорва́||ться *сов.* **1.** бераз ертылу, ертыла төшү, чите ертылу; **мешо́к ~лся** капчык бераз ертылган **2.** *перен.* имгәнү, эчкә зыян китерү, сәламәтлекне какшату; өзлегү; **~ться, поднима́я мешо́к** капчык күтәргәндә эчкә зыян китерү; **~ться на тяжёлой рабо́те** авыр эштә сәламәтлекне какшату

надоу́мить *сов. кого-что, разг.* өйрәтү, акыл өйрәтү, акыл бирү, киңәш бирү

надпа́рывать *несов. см.* **надпоро́ть**

надпи́л *м* **1.** *см.* **надпили́ть; 2.** (*место*) пычкы белән киселгән урын

надпи́ливать *несов. см.* **надпили́ть**

надпили́ть *сов. что* өстән аз гына пычкы белән кису, киселә кую

надписа́ть *сов. что* **1.** өстенә (тышына) язу, язып кую; **~ а́дрес** адрес язу; **~ кни́гу** китапның тышына язу; **~ фотогра́фию** рәсемнең артына язу **2.** (*выше написанного ранее*) өскәрәк язу

надпи́сывать *несов. см.* **надписа́ть**

на́дпис||ь *ж* язма, язу; **да́рственная ~ь** бүләк язуы; **древнетю́ркские ~и** борынгы төрки язмалар

надпоро́ть *сов. что* аз гына сүтү (*тегелгәнне*); сүтә төшү, читен сүтү

надпо́чечники *мн.* (*ед.* **надпо́чечник** *м*) *анат.* бөер өстә бизләре

надпо́чечн||ый, -ая, -ое бөер өстә ...ы; **~ые же́лезы** бөер өстә бизләре

надра́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) каезлау, төшерү, салдыру; **~ мно́го лы́ка** бик күп курыс төшерү ♦ **~ у́ши** *кому* колакны бору

надре́з *м* **1.** *см.* **надре́зать; 2.** (*место*) кирт, киртек; киселгән урын, кисек; **глубо́кий ~** тирән кисек

надре́зать *сов. что* өстән аз гына кисү, киселә кую

надреза́ть *несов. см.* **надре́зать**

надре́зывать *несов. см.* **надре́зать**

надруба́ть *несов. см.* **надруби́ть**

надруби́ть *сов. что* өстән аз гына балта белән чабу (чабып кую)

надруга́тельство *с* мәсхәрә, мыскыл, мәсхәрә итү, мыскыл итү

надруга́ться *сов. над кем-чем, книжн.* мәсхәрә (мыскыл) итү, намуска тию, мәсхәрәләү, мыскыллау

надры́в *м* **1.** *см.* **надорва́ть** 1; **2.** (*место*) ертылган урын, ертык ♦ **говори́ть с ~ом** ярсып сөйләү

надрыва́ть *несов. см.* **надорва́ть** ♦ **~ гло́тку (го́рло)** *прост.* тамак ерту, акыру, акырып сөйләү (җырлау)

надрыва́||ться *несов.* **1.** *см.* **надорва́ться** 1; **2.** *перен. над чем и без доп.* (*работать через силу*) бик каты эшләү; бөтен көчне кую (куеп тырышу), бик нык тырышу **3.** (*кричать изо всех сил*) акыру, бик каты кычкыру **4.** *страд. от* **надрыва́ть ♦ се́рдце (душа́) ~ется** йөрәк (күңел) әрни

надры́вистый, -ая, -ое ярсулы, үксеп ..., өзгәләнеп ...; өзек-өзек, көчәнүле; **~ плач** үксеп елау; **~ ка́шель** өзек-өзек ютәл

надры́вный, -ая, -ое эч катып ..., эч катканчы...; **~ смех** эч катып көлү

надсма́дный, -ая, -ое *разг.* каты, буылып-буылып ...; **~ ка́шель** буылып-буылып ютәлләү

надсмо́трщик *м* тикшереп-күзәтеп торучы; күзәтеп эшләтүче; назир *уст.*

наста́вить *сов. что* ялгау, ялгап озынайту

наста́вка *ж* **1.** *см.* **наста́вить; 2.** (*надставленный кусок*) ялгау; өскуйма

надставля́ть *несов. см.* **надста́вить**

надстра́ивать *несов. см.* **надстро́ить**

надстро́ечн||ый, -ая, -ое *полит.* өскорма ...ы; өскормага хас [булган]; **~ые явле́ния** өскормага хас күренешләр

надстро́ить *сов. что* өстәп кору, өстәп төзү, (*бинаны*) биегәйтеп төзү

надстро́йка *ж* **1.** *см.* **надстро́ить; 2.** (*надстроенная часть*) өске корылма **3.** *полит.* өскорма; **ба́зис и ~** базис һәм өскорма

надстро́чный, -ая, -ое юл (язу юлы) өстендәге, юл өсте ...ы; **~ знак** юл өстендәге билге

надтре́снутый, -ая, -ое **1.** аз гына чатнаган, ярык; **~ стака́н** аз гына чатнаган стакан **2.** *перен.* калтыравык, калтыравыклы; **~ го́лос** калтыравыклы тавыш

надтре́снуть *сов.* бераз (аз гына) чатнау

надува́тельство *с разг.* алдау, алдашу

надува́ть *несов. см.* **наду́ть**

надува́ться *несов.* **1.** *см.* **наду́ться; 2.** *страд. от* **надува́ть**

надувн||о́й, -а́я, -о́е өреп кабартылган, өреп һава тутырылган, өреп кабартыла торган; **~а́я ло́дка** өреп кабартыла торган көймә

наду́манный, -ая, -ое уйдырма, уйлап чыгарылган; уйланма; ясалма; **~ о́браз** ясалма образ

наду́ма||ть *сов. что и с неопр., разг.* уйлау, [уйлап] билгеле бер карарга (фикергә) килү, карар бирү; ...макчы булу, ...рга булу; уйлап чыгару; **я ~л заня́ться матема́тикой** мин математика белән шөгыльләнергә булдым; **он ~л уе́хать** ул китәргә булды

наду́мывать *несов. см.* **наду́мать**

наду́тый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **наду́ть** 1, 2; **2.** (*набухший*) кабарган, күбенгән, бүртkән **3.** *перен. разг.* (*высокомерный*) тәкәббер, һавалы, кәпрәйгән **4.** *перен. разг.* (*высокопарный*) күперенке **5.** *перен. разг.* (*обиженный*) турсайган, үпкәләгән, хәтере калган; (*сердитый*) төмсә, күңелсез, караңгы чырайлы, ачулы

наду́||ть *сов.* **1.** *что* һава тутырып кабарту, өреп кабарту, өреп [һава] тутыру; **~ть мяч** тупны һава тутырып кабарту **2.** *что, чего* өреп китерү, өреп кертү, өреп кундыру; **ве́тром ~ло пы́ли** *безл.* җил өреп тузан керткән **3.** *кого-что, прост.* (*обмануть*) утырту, алдау ♦ **мне ~ло в у́хо** колагыма җил өргән; **~ть гу́бы** авыз турсайту

наду́ться *сов.* **1.** (*о мяче*) кабару; (*о парусе*) киерелү **2.** *перен. разг.* (*обидеться*) авыз турсайту, үпкәләү

надуши́ть *сов. кого-что* ислемай сөртү, хушбуй сөртү

надуши́ться *сов.* ислемай сөртенү, хушбуй сөртенү

надхво́стье *с зоол.* койрык өсте (*кошларда*)

надшива́ть *несов. см.* **надши́ть**

надши́ть *сов. что* ялгау, ялгап тегү, ялгап [тегеп] озынайту

надыми́||ть *сов. чем и без доп.* төтен чыгару, төтен белән тутыру; **печь ~ла** мичтән төтен чыккан; **~ть сигаре́той** сигарет тартып [бүлмәне] төтен белән тутыру

надыша́||ть *сов.* **1.** сулыш белән җылыту; **в ко́мнате ~ли** бүлмәне сулыш белән җылыткannар **2.** *на что* өреп парландыру; **~ть на стекло́** өреп пыяланы парландыру

надыша́ться *сов.* туйганчы сулау, сулап тую; бик күп сулау ♦ **не надыши́тся** *или* **не мо́жет ~** *на кого-что* карап (күреп) туя алмый

наеда́ться *несов. см.* **нае́сться**

наедине́ *нареч.* күзгә-күз [карап] икәүдән-икәү [генә], аулакта; **поговори́ть ~** икәүдән-икәү генә сөйләшү; **~ с сами́м собо́й** бер үзе, япа-ялгыз

нае́зд *м* **1.** *см.* **нае́хать; 2.** *в знач. нареч.* **~ом (~ами)** узганда-барганда, узышлый, узып барышлый **3.** *уст.* (*кавалерийский набег*) (*көтмәгәндә ясалган*) атлы гаскәр һөжүме, баскын

нае́зд||ить *сов. что* **1.** [барлыгы] узу, үтү; **шофёр ~ил тысячу киломе́тров** шофёр барлыгы мең километр узган **2.** [күп йөреп] юл салу; [йөри-йөри] юл салу; [күп йөреп] юлны такырайту, тигезләү; **~ить доро́гу** күп йөреп юл салу **3.** *кого-что, спец.* [атны] йөрергә өйрәту; **~ить рысака́** юртакны йөрергә өйрәту

нае́здиться *сов. разг.* туйганчы йөрү, йөреп тую (*атта, машинада*)

нае́здник *м* **1.** (*специалист по верховой езде*) атта оста йөрүче, атта йөрергә һәвәс кеше **2.** (*жокей*) ат өйрәтүче, атны йөрергә өйрәтүче, жокей **3.** (*в цирке*) наездник

наéздница *ж см.* **наéздник** 1, 3

наезжáть I *несов. см.* **наéздить**

наезжáть II *несов.* **1.** *см.* **наéхать; 2.** *разг.* (*посещать время от времени*) килгәләү, кереп чыккалау, узганда-барганда кереп чыккалау

наём *м см.* **нанять; рабóтать по нáйму** ялланып эшләү

наёмник *м* **1.** (*наёмный солдат*) яллы гаскәри **2.** *уст.* (*наёмный работник*) ялчы **3.** *перен.* сатлык жан; ялчы

наёмн||ый, -ая, -ое **1.** ялланган, ялланып эшләүче, яллы, ялланулы; **~ый рабóчий** яллы эшче; **~ый солдáт** яллы гаскәри; **~ый труд** яллы хезмәт **2.** хак бирепбакытлыча алынган, вакытлыча файдалануга алынган; **~ая дáча** вакытлыча файдалануга алынган дача

наéсться *сов.* **1.** *чего* [туйганчы] ашау; **~ дóсыта** туйганчы ашау; **~ слáдкого** туйганчы татлы әйберләр ашау **2.** *чем и без доп.* ашап тую; **~ хлéбом** ипи ашап тую

наéха||ть *сов.* **1.** *на кого-что* барып (килеп) бәрелү; таптату; бәрдерү; **машúна ~ла на столб** машина баганага барып бәрелгән **2.** *разг.* бик күп килеп төшү; **~ло гостéй** бик күп кунак килеп төште

нажáловаться *сов. кому* зарлану, шикаять итү, жалоба бирү

нажáривать *несов. см.* **нажáрить**

нажáрить *сов. что, чего* (*берникадәр*) кыздыру, кыздырып кую; **~ картóшки** бәрәңге кыздыру

нажáриться *сов. прост.* туйганчы кояшта кызыну

нажáтие *с см.* **нажáть** I 1

нажáть I *сов.* **1.** *что, на кого-что* басу; кысу; **~ на звонóк** звонокка басу; **~ на кнóпку** кнопкага басу **2.** *перен. на кого-что, прост.* басым ясау, кысу, мәҗбүр итү; **~ на лентяéв** ялкауларны эшләргә мәҗбүр итү **3.** *что, чего* (*берникадәр*) сыгу, сыгып чыгару; **~ лимóнного сóку** лимон суы сыгып чыгару **4.** *перен. на что, прост.* басым ясау, кызурак эшли башлау, эшне кызулый төшү; **~ на учёбу** укуга басым ясау

нажáть II *сов. что, чего* (*берникадәр*) уру, урып алу; **~ сóтню снопóв** йөз көлтә уру

наждáк *м* наждак, комкайрак

наждáчн||ый, -ая, -ое **1.** наждак ...ы; **~ая пыль** наждак тузаны **2.** наждаклы; **~ая бумáга** наждаклы кәгазь

наж||éчь *сов.* **1.** *что, чего* (*наготовить пережиганием*) (*берникадәр*) яндыру, яндырып хәзерләү **2.** (*сжечь, израсходовать в каком-л. количестве*) (*берникадәр*) яндыру, ягу **3.** *что* артык кыздырып зарар китерү; **сóлнцем емý ~гло лицó** аның бите кояшта пешкән

нажéчься *сов. разг.* (*сильно нагреться, обычно на солнце*) бик нык кызыну

нажúв||а *ж* жиңел табыш; **в погóне за ~ой** жиңел табыш артыннан куып; **любúтель лёгкой ~ы** жиңел табыш яратучы

наживáть *несов. см.* **нажúть**

наживáться *несов.* **1.** *см.* **нажúться; 2.** *страд. от* **наживáть**

наживúть *сов. что, рыб., охот.* җим кигезү (кую)

нажúвка *ж* җим

наживля́ть *несов. см.* **наживúть**

наживн||óй I, -áя, -óе: **э́то дéло ~óе** ирешеп була торган нәрсә, булдырып була торган эш

наживнóй II, -áя, -óе (*с наживкой*) җимле, җим куелган; **~áя ры́ба** җимгә куела торган балык; **~áя снасть** җим куелган балык тоту җайланмасы

нажигáть *несов. см.* **нажéчь**

нажигáться *несов.* **1.** *см.* **нажéчься; 2.** *страд. от* **нажигáть**

нажúм *м см.* **нажáть** I 1, 2 ♦ **пóчерк без ~а** басмыйча язу; **писáть с ~ом** басып язу

нажимáть *несов. см.* **нажáть** I

нажúн *м с.-х.* урым

нажинáть *несов. см.* **нажáть** II

нажúть *сов. что* **1.** табу, булдыру, җыю; **~ всё своúм трудóм** бөтен нәрсәне үз көчең белән табу **2.** *перен.* (*авыру*) алу, (*авыруга*) сабышу; **~ себé ревматúзм** ревматизм алу ♦ **~ неприя́тность** күңелсезлеккә тару; **~ себé врагóв** үзеңә дошман җыю

нажúться *сов.* **1.** (*обогатиться*) баю, байлык җыю; күп акча җыю **2.** *разг.* (*долго прожить*) озак тору (яшәү)

назáвтра *нареч. разг.* иртәгә, иртәгесен

назáд *нареч.* **1.** артка, артка таба; **оглянýться ~** артына борылып карау; **сдéлать шаг ~** бер адым артка чигенү **2.** кире, кирегә, эллеке урынына, иске урынына; **вернýться ~** кире кайту; **взять своё слóво ~** сүзеңне кире кайтарып алу **3.** элек; **два дня ~** ике көн элек

назализáция *ж лингв.* борынлашу

назализúровать *сов., несов. что, лингв.* борынлаштыру

назализúроваться *сов., несов. лингв.* борынлашу

назализóванный, -ая, -ое *лингв.* борынлашкан; **~ звук** борынлашкан аваз

назализовáть *сов., несов. см.* **назализúровать**

назализовáться *сов. несов. см.* **назализúроваться**

назвáнивать *несов. разг.* өзлексез (бертуктамый) шалтырату

назвáние *с* исем, ат

назвáн||ый, -ая, -ое *уст.*: **~ый брат** ахирәт; **~ая сестрá** ахирәт; **~ая дочь** тәрбиягә алынган кыз бала; **~ый сын** тәрбиягә алынган ир бала

назвáть I *сов. кого-что* **1.** (*дать имя, название*) атау, ат (исем) кую (кушу, бирү); (*дать прозвище*) атау, кушамат бирү, урам аты бирү **2.** (*охарактеризовать*) атау; **~ своúм учúтелем** үзеңнең остазың дип атау **3.** (*указать*) күрсәтү, атау; **~ кандидáтов в комúссию** комиссияга кандидатлар күрсәтү **4.** (*произнести имя, название*) атау, исемен атау; (*представить кого-л.*) таныштыру **5.** атау, әйтү, әйтеп бирү; **~ цéну** хакын әйтеп бирү **6.** (*перечислить*) атап чыгу, исемләп атап чыгу; **~ крýпные рéки Сибúри** Себердәге иң зур елгаларны атап чыгу

назвáть II *сов. кого-что* (*берникадәр*) чакыру, җыю; **~ гостéй** кунаклар чакыру

назвá||ться *сов.* **1.** *кем-чем* үзен ... дип атау (таныту, әйтү); **~ться врачóм** үзен врач дип таныту **2.** үзенең исемен әйтү (әйтеп бирү), кем булуын әйтү; **вошéдший ~лся** керүче үзенең исемен әйтте

наздравствовáться *сов.*: **на вся́кое чиха́нье не ~уешься** *погов.* һәрбер төчкерүгә исәнлек теләп бетерә алмассың (*ягъни һәр нәрсәгә игътибар итеп яисә әһәмият биреп бетерә алмассың*)

назéмн||ый, -ая, -ое **1.** жир өстендәге; **назéмные сооружéния** жир өсте корылмалары **2.** коры жир ...ы; **~ые войскá** коры жир гаскәрләре

нáземь *нареч.* жиргә; идәнгә

назидáн||ие *с книжн.* үгет, нәсихәт, үгет-нәсихәт; сабак, гыйбрәт; **он в ~ях не нуждáется** ул үгет-нәсихәткә мохтаҗ түгел; **в ~е всем** барсы өчен дә гыйбрәт булсын өчен

назидáтельный, -ая, -ое *книжн.* **1.** нәсихәтле, нәсихәт биргән, нәсихәт бирү ...ы; **~ тон** нәсихәт биргән тон **2.** гыйбрәтле, сабак булырлык; **~ слýчай** гыйбрәтле хәл

назлó, нáзло *нареч.* юри, ачу итеп, үч итеп

назначáть *несов. см.* **назнáчить**

назначéни||е *с* **1.** *см.* **назнáчить; 2.** эшкә билгеләнү; **нóвое ~е** яңа эшкә билгеләнү; **получúть ~е в сéльскую мéстность** эшкә авыл җиренә билгеләнү **3.** бурыч, максат; **высóкое ~е писáтеля** язучының бөек бурычы; **отря́д осóбого ~я** махсус эш йөкләнгән отря́д; **испóльзовать по ~ю** урынлы файдалану, тиешенчә файдалану

назнáчить *сов. кого-что, в разн. знач.* билгеләү; **~ к врачý** врачка билгеләү; **~ пéнсию** пенсия билгеләү; **~ цéну** хак билгеләү; **~ день отъéзда** китү көнен билгеләү; **~ на рабóту** эшкә билгеләү

назóйливый, -ая, -ое бәйләнчек, йөдәтүчән, йөдәткеч, теңкәгә тиючән, теңкә коры тыкыч

назревáть *несов. см.* **назрéть**

назрé||ть *сов.* **1.** (*созреть*) өлгерү, пешү; җитү; (*о нарыве*) тулу, тулып җитү **2.** *перен.* якынлашу, килеп җитү; **событúя ~ли** вакыйгалар якынлашты

назубóк *нареч. разг.* бик яхшы, менә дигән иттереп; яттан; **вы́учить ~** яттан бикләү; **знать ~** бик яхшы белү; **знать стихотворéние ~** шигырьне яттан белү

называ́||ть I *несов. см.* **назвáть** I ♦ **~ть вéщи своúми именáми** һәрнәрсәне үз исеме белән атау (*хакыйкатьне яшермичә әйтү*); **так ~емый** ...дип атала (йөртелә) торган, ...дип аталган, ...дигән

называ́ть II *несов. см.* **назвáть** II

называ́||ться *несов.* **1.** *см.* **назвáться** I; **2.** аталу, ... дип аталу; **как ~ется э́то явлéние?** бу күренеш ничек атала? **3.**

страд. от **называ́ть** I ♦ **а ещё до́ктор ~ется!** *ирон.* ә бит доктор исемен күтәрә!; **сде́лал ~ется!** *ирон.* эшләгән имештер!

наи- *приставка, сыйфат һәм рәвешләргә кушылып, артыклык һәм аерым очракларда чагыштыру дәрәҗәләре ясый; татар теленә аның мәгънәсе «иң» кисәкчәсе ярдәмендә тәрҗемә ителә, мәс.* **наилу́чший** иң яхшы; **наиталáнтливейший** иң сәләтле

наибо́лее *нареч.* иң, бигрәк тә, аеруча; **~ уда́чный спо́соб** иң уңышлы ысул

наибо́льший, -ая, -ее иң зур

най|вничать *несов. разг.* беркатлылану, беркатлылык күрсәтеп маташу, беркатлы булып күренергә маташу

най|вность *ж* беркатлылык, хәйләсезлек; тәҗрибәсезлек

най|вный, -ая, -ое **1.** беркатлы, хәйләсез; тормыш тәҗрибәсе булмаган; **~ ребёнок** беркатлы бала **2.** беркатлылыкны күрсәтә (белдерә) торган, беркатлылык белән ...ган; тәҗрибәсезлекне күрсәтеп (белдереп) торган; **~ вопро́с** беркатлылык белән бирелгән сорау

наивы́сший, -ая, -ее иң бөек, иң югары, иң зур

най|гранн||ый, -ая, -ое ясалма, ялган; **~ая весёлость** ясалма күңел күтәренкелеге

наигра́ть *сов. что* **1.** уйнау, уйнап күрсәтү; **~ но́вую мело́дию** яңа көйне уйнап күрсәтү **2.** уйнаган көйне (*пластинкага*) яздыру; **~ пласти́нку** уйнаган көйне пластинкага яздыру

наигра́ться *сов.* туйганчы уйнау, уйнап тую

най|грывать *несов. см.* **наигра́ть**

на́игрыш *м* **1.** (*народная мелодия; обычно плясовая*) көй, халык көе **2.** (*неестественность*) ясалмалылык (*артист уеныңк табигый булмавы турында*)

наизна́нку *нареч.* тискәре ягы белән, тискәре ягына, тискәресенә; **наде́ть пла́тье ~** күлмәкне тискәре ягы белән кию

наизу́сть *нареч.* күңелдән, яттан

наилу́чший, -ая, -ее иң яхшы, иң шәп

наиме́нее *нареч.* иң, иң аз; **~ интере́сный** [арада] иң кызыксызы; **~ опа́сный** [арада] иң куркынычсызы

наименова́ние *с* исем, ат

наиме́ньший, -ая, -ее иң кечкенә; иң кыска; иң аз

наискосо́к, на́искось *нареч.* кыйгач, кыйгачлап, кыйгач итеп; чатлаш

найти||е *с книжн.* илһам; эчке сиземләү, эчтән сизү; **по ~ю** эчке сиземләү белән

наиху́дший, -ая, -ее иң начар, иң яман

найдёныш *м уст.* табылдык бала

наймúт *м пренебр.* ялчы, сатлык жан, сатылган кеше

найти́ I *сов.* **1.** *кого-что* табу, эзләп табу; **~ гриб** гөмбә табу; **~ поте́рянную вещь** югалган әйберне [эзләп] табу **2.** *что* уйлап табу, ачу; **~ но́вый спо́соб приготовле́ния** *чего-л. берәр нәрсәне* әзерләүдә яңа ысул уйлап табу **3.** *что* табу, күрү, сизү; **не ~ [и] те́ни прито́рства** бернинди дә хәйлә сизмәү **4.** *кого-что* очрату, туры китерү; **~ в столе́ ста́рые пи́сьма** өстәлдә иске хатларны туры китерү **5.** *кого-что* табу; **~ утеше́ние в чте́нии** китап укуда үзеңә юаныч табу; **я нашёл ну́жным зайти́** керергә кирәк дип таптым **6.** *кого-что* табу, исәпләү; **врач нашёл его́ здоро́вым** табиб аны сәламәт дип тапты ♦ **~ себе́ смерть (моги́лу)** *где* үлем табу, башын салу, үлеп калу; **~ о́бщий язы́к** уртак тел табу, уртак фикергә килү; **нашёл чем хва́статься!** *ирон.* тапкан нәрсә белән мактанырга!

найти́ II *сов.* **1.** *на кого-что* бәрелү, барып бәрелү, барып төртелү; **~ на де́рево** агачка барып бәрелү **2.** *на что* каплау, басу; **ту́ча нашла́ на луну́** айны болыт каплады **3.** (*прийти, собраться*) җыелу, килеп җыелу; килеп тулу **4.** тулу; **нашло́ мно́го ды́му** бик күп төтен тулган ♦ **нашёл страх** курку басты, курку алды; **нашла́ тоска́** хәсрәт басты; **нашло́ весе́лье** күңелләре ачылып шау-гөр килде[ләр]

найти́сь *сов.* **1.** табылу; **пропа́жа нашла́сь** югалган әйбер табылды; **нашли́сь жела́ющие** теләүчеләр табылды **2.** аптырамау, аптырап (югалып) калмау, аптырашта калмау; **он не нашёлся, что отве́тить** ул җавап бирә алмыйча аптырап калды

нака́з *м* **1.** наказ, теләкләр һәм таләпләр; **~ы избира́телей** сайлаучыларның наказлары **2.** *уст.* боерык, күрсәтмә; үгет; **отцо́вский ~** ата боерыгы

наказа́ни||е *с* **1.** җәза; җәза бирү; **тяжёлое ~е** авыр җәза; **в ~е** өчен; **в ~е за опозда́ние** соңга калып килгән өчен; **подве́ргнуть ~ю** җәзага тарту **2.** *разг.* бәла; **~е мне с ним** бер бәла булды инде ул минем өчен; **вот ~е!** менә тагы бәла!; **что за ~е!** бу нинди бәла тагы!

наказа́ть *сов. кого-что* җәза бирү; **~ винóвных** гаепләргә җәза бирү

наказу́емый, -ая, -ое *юр.* җәза бирелә торган

нака́зывать *несов. см.* **наказа́ть**

нака́л *м* **1.** *см.* **накали́ть, накали́ться; 2.** накал, кызу..., яктырту ...; **ла́мпочка гори́т по́лным ~ом** лампочка тулы кызу белән яна

накалённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **накали́ть; 2.** кызу ..., кызган; **~ая атмосфе́ра** кызу атмосфера

нака́ливание *см.* **накали́ть, накали́ться**

нака́ливать *несов. см.* **накали́ть**

нака́ливаться *несов.* **1.** *см.* **накали́ться; 2.** *страд. от* **нака́ливать**

накали́ть *сов. что* кыздыру, бик нык кыздыру

накали́ться *сов.* кызу, бик нык кызу

нака́лывать I *несов. см.* **наколо́ть** I

нака́лывать II *несов. см.* **наколо́ть** II

нака́лываться *несов.* **1.** *см.* **наколо́ться; 2.** *страд. от* **нака́лывать** II

накаля́ть *несов. см.* **накали́ть**

накаля́ться *несов.* **1.** *см.* **накали́ться; 2.** *страд. от* **накаля́ть**

накану́не 1. *нареч.* бер көн элек; **я прие́хал ~** бер көн элек килдем **2.** *предлог с род. п.* ...га каршы, көненә каршы, алдыннан; **~ выходно́го дня** ял көненә каршы; **~ пра́здника** бәйрәм алдыннан; **~ Но́вого го́да** Яңа елга каршы

нака́пать *сов. что, чего* тамызу

нака́пливать *несов. см.* **накопи́ть**

нака́пливаться *несов.* **1.** *см.* **накопи́ться; 2.** *страд. от* **нака́пливать**

нака́пывать I *несов. см.* **нака́пать**

нака́пывать II *несов. см.* **накопа́ть**

нака́т *м* **1.** *см.* **наката́ть** I, 3; **2.** түшәмә, түшәлмә (*берәр нәрсә өстенә түшәлгән бүрәнәләр, калын такталар*); **блинда́ж с двойны́м ~ом** ике кат бүрәнә түшәлгән блиндаж

наката́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернидер*) тәгәрәтеп китерү, тәгәрәтеп китереп кую; **~ брёвна (брёвен)** бүрәнәләр тәгәрәтеп китерү **2.** *что, чего* (*бернидер*) тәгәрәтү; **~ бельё** кер тәгәрәтү **3.** *что* буяу белән каплау; [тәгәрәтеп] сырлау (ялтырату); **~ типогра́фский набо́р** типография наборын буяу белән каплау **4.** *что* [юл] салу, йөреп [юл] салу; **~ доро́гу по́ полю** басу аша юл салу **5.** *что, чего, прост.* тиз генә язып (сызгалап) ташлау; **~ письмо́** тиз генә хат сызгалап ташлау

наката́ться *сов.* (*на коньках, лыжах*) туйганчы шуу, шуып тую; (*на машине, лошади и т.п.*) туйганчы утырып йөрү

накати́||ть *сов.* **1.** *что, чего* (*прикатить*) (*бернидер*) тәгәрәтеп китереп кую; тәгәрәтеп кертү (кертеп кую) **2.** *что* тәгәрәтеп мендерү (мендереп кую); **~ть бо́чку на платфо́рму** мичкәне платформага тәгәрәтеп мендерү **3.** *перен. на кого-что, прост.* кинәт каплап алу, чолгап алу, басу, басып алу; **на него́ ~ла тоска́** кинәт аның эче поша башлады; **на него́ ~л страх** кинәт аны курку басты

накати́||ться *сов.* [тәгәрәп] килеп бәрелү; **~лась волна́** дулкын килеп бәрелде

нака́тывать I *несов. см.* **наката́ть**

нака́тывать II *несов. см.* **накати́ть**

накача́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернидер*) суыртып тутыру, качать итеп тутыру, качать итеп кую; **~ бо́чку воды́** бер мичкә су качать итеп кую **2.** *что* (*газ, һава, сыекча*) тутырып кабарту, качать итеп кабарту

нака́чивать *несов. см.* **накача́ть**

наква́сить *сов. что, чего* тозлау, тозлап кую; **~ капу́сты** кәбестә тозлау

наква́шивать *несов. см.* **наква́сить**

накида́ть *сов. что, чего* (*бернидер*) ташлау, ыргыту, ату, атып бәрү

наки́дка *ж* **1.** накидка, япма (*җилкәгә салына торган җиңсез кием*); **мехова́я ~** мех накидка **2.** (*для подушек*) мендәр өслеге, җәймә, япма

наки́дывать I *несов. см.* **накида́ть**

наки́дывать II *несов. см.* **наки́нуть**

наки́дываться *несов.* **1.** *см.* **наки́нуться**; **2.** *страд. от* **наки́дывать** II

наки́нуть *сов. что* **1.** салу, ябу; ~ **шаль** шәл ябу **2.** *разг.* өстәү, арттыру; ~ **рубль** бер сум өстәү

наки́нуться *сов. см.* **набро́ситься**

накипа́ть *несов. см.* **накипе́ть**

накипе́||ть *сов.* **1.** (*о пене*) күбек күтәрелү (*мәс. ит шулпасы өстенә*); (*о накипи*) юшкын утыру **2.** *перен.* кайнау; ярсу; **на душе́ у меня́** ~**ло** ачуым эчемә сыймый; йөрәгемә кабынды

на́кипь *ж* **1.** (*пена, грязь*) күбек **2.** (*осадок*) юшкын

накла́д *м*: **в** ~**е не бу́дешь (не оста́нешься)** *прост.* берни югалтмассың, зыян күрмәссең

накла́дка *ж* **1.** (*мәс. парик*) ясалма чәч **2.** *тех.* ишек биге планкасы

накла́дно *в знач. сказ. разг.* табышсыз, файдасыз; бик кыйбат; **э́то ему́ бу́дет** ~ бу аның өчен кыйбатка төшәчәк

накладн||о́й, -а́я, -о́е **1.** йөгертелгән, ябыштырылган; **ножи́** ~**о́го серебра́** көмеш йөгертелгән пычаклар **2.** ябыштырылган, ясалма, ялганма; ~**а́я борода́** ясалма сакал **3.** *в знач. сущ.* ~**а́я** *ж* накладной (*товар яки йөк белән бергә җибәрелә торган документ*) ♦ ~**ы́е расхо́ды** өстәмә чыгымнар

накла́дывать *несов. см.* **наложи́ть**

наклевета́ть *сов. на кого-что* яла ягу

наклёвываться *несов. см.* **наклю́нуться**

накле́ивать *несов. см.* **накле́ить**

накле́иваться *несов.* **1.** *см.* **накле́иться**; **2.** *страд. от* **накле́ивать**

накле́ить *сов.* **1.** *что* ябыштыру, ябыштырып кую; ~ **ма́рку** ма́рка ябыштыру **2.** *что, чего* (*берникадәр*) ябыштырып ясау (ясап кую); ~ **мно́го игру́шек** бик күп уенчыклар ябыштырып ясап кую

накле́иться *несов.* ябышу

накле́йка *ж* **1.** *см.* **накле́ить** 1; **2.** (*то, что наклеено*) ябыштырып куелган нәрсә (*кәгазь һ.б.ш.*)

наклепа́ть I *сов. что, тех.* чүкеп ябыштыру, чүкеп ябыштырып кую; чүкеп ялгау

наклепа́ть II *сов. на кого, прост.* яла ягу, яла тарату, ялган хәбәр тарату

наклёпка *ж* **1.** *см.* **наклепа́ть** I; **2.** (*то, что наклёпано*) чүкеп ябыштырылган нәрсә (өлеше)

наклёпывать *несов. см.* **наклепа́ть** I

наклёпываться *несов.* **1.** (*приклёпываться*) чүкелеп ябышу **2.** *страд. от* **наклёпывать**

накли́кать *сов. что, чего, прост.*: ~ **беду́** алдан юрап башка бәла китерү

накликать *несов. см.* **накли́кать**

наклон *м* **1.** *см.* **наклони́ть, наклони́ться**; **2.** (*покатая поверхность*) авышлык, сөзәклек **3.** (*наклонное положение*) авыш булу, авышканлык

наклоне́ние *с грам.* төркемчә, наклонение; **изъяви́тельное** ~ хикәяләү наклонениесе; **повели́тельное** ~ боерык наклонениесе; **жела́тельное** ~ теләк наклонениесе; **усло́вное** ~ шарт наклонениесе

наклони́ть *сов. что* (*нагнуть*) авыштырү, янтайту, кыйшайту; (*согнуть*) бөгү, ию, сыгу; ~ **столб** баганаңы авыштыру; ~ **ве́тку** ботакны ию

наклони́||ться *сов.* **1.** авышу, янтаю, кыйшаю; салыну, салынып төшү; **столб** ~**лся** багана кыйшайган; **ве́тви** ~**лись** ботаклар салынган **2.** (*о человеке*) бөгелү, иелү; ~**ться над ка́ртой** карта өстенә иелү

наклóнность||ь *ж* **1.** һәвәслек; омтылыш; ~**ь к му́зыке** музыкага һәвәслек **2.** *обычно мн.* ~**и** гадәтләр; **дурны́е** ~**и** начар гадәтләр

наклóнн||ый, -ая, -ое авыш, сөзәк; ~**ая пло́скость** авыш яссылык

наклоня́ть *несов. см.* **наклони́ть**

наклоня́ться *несов.* **1.** *см.* **наклони́ться**; **2.** *страд. от* **наклоня́ть**

наклю́ну||ться *сов.* **1.** (*о цыплёнке*) борынлау **2.** *перен. прост.* чиертү, [очраклы рәвештә] килеп чыгу, түры килү; ~**лось вы́годное де́льце** файдалы эш килеп чыкты

наклю́зничать *сов. прост.* әләкләү

накова́льня *ж* **1.** (*кузнечная*) сандал, тимерче сандалы **2.** *анат.* сандал сөяк (*урта колакта*)

накова́ть *сов.* **1.** *что* (*приделать ковкой*) кыздырып чүкеп ябыштырү (ялгау) **2.** *что, чего* (*наготовить ковкой*) чүкеп ясау

нако́вывать *несов. см.* **накова́ть**

нако́жн||ый, -ая, -ое тире ...ы; ~**ые боле́зни** тире авырулары

наколáчивать *несов. см.* **наколоти́ть**

наколе́нник *м* (*накладка, предохраняющая от удара*) тез калканы, тез саклагыч

наколе́нный, -ая, -ое тезгә каплана торган, тезгә бәйли (киелә) торган

нако́лка *ж* наколка, бизәндек (*хатын-кыз чәчендә*)

наколоти́ть *сов. см.* **наби́ть** 2, 3

наколо́ть I *сов. что, чего* **1.** (*берникадәр*) яру, ярып кую, ярып әзерләп кую; ~ **дров** утын ярып кую **2.** (*берникадәр*) вату, ватып кую; ~ **са́хару** шикәр ватып кую

наколо́ть II *сов.* **1.** *что. чего* (*приколоть*) (*берникадәр*) кадау, кадап кую **2.** *что, кого-чего* сую, суеп кую; ~ **на́ зиму гусе́й** кышкылыкка казлар сую **3.** *что, чего* чәнчеп (чәнечкәләп) ясау; төшерү; ~ **узо́р** чәнечкәләп бизәк төшерү **4.** *что* кадалу, керү; ~ **ру́ку иго́лкой** кулга энә кадалу

наколо́ться *сов.* кадалу

комáрник *м* битлек (*озынборыннан саклагыч*)

наконе́ц *нареч.* **1.** ниһаять, ахырда, ахыр чиктә; ~ **он догада́лся** сизеп алды ниһаять **2.** *в знач. вводн. сл.* тагын, шуның өстенә, өстәвенә, һич югында, ниһаять

наконе́чник *м* очлык; ~ **для каранда́ша** карандаш очлыгы; ~ **стрелы́** ук очлыгы

накопа́ть *сов. см.* **нары́ть**

накопи́ть *сов. прям., перен. что, чего* җыю, туплау; ~ **де́нег** акча җыю; ~ **о́пыт** тәҗрибә туплау

накопи́ться *сов. прям., перен.* җыелу, туплану

накопле́ни||е *с* **1.** *см.* **накопи́ть, накопи́ться**; **2.** *мн.* ~**я** түпланыш; җыелган акчалар *һ.б.ш.*

накопт||и́ть *сов.* **1.** төтәп сөрем чыгару; **ла́мпа** ~**ла** лампа төтәп сөрем чыгарган **2.** *что, чего* (*берникадәр*) ыслау, ыслап әзерләп кую; ~**ть колба́с** казылык ыслау

накорми́ть *сов. кого-что* ашату, туйганчы ашату, туйдыру; (*младенца*) имезү; ~ **семью́** гаиләне ашату

накорчева́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) урман төпләү; төп чыгару

накоси́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) чабу, чабып алу; чабып әзерләп кую; ~ **травы́** улән чабу

нако́стн||ый, -ая, -ое сөяк өсте ...ы, сөяк өстендәге, сөяк өстендә була торган; ~**ая о́пухоль** сөяк өстендәге шеш

накра́пыва||ть *несов.* сибәләү, сибәләп тору; ~**ет дождь** янгыр сибәли

накра́сить *сов.* **1.** *что* буяу, [иннек] ягу; ~ **гу́бы** иреннәрне буяу **2.** *что, чего* (*берникадәр*) буяу, буяп чыгу

накра́ситься *сов.* буяну, [иннек] ягыну

накра́сть *сов. что, чего* урлап җыю

накрахма́лить *сов. что, чего* крахмаллау, крахмаллап кую

накра́шивать *несов. см.* **накра́сить**

накра́шиваться *несов.* **1.** *см.* **накра́ситься**; **2.** *страд. от* **накра́шивать**

накрени́ть *сов. что* кырынайту, кыйшайту, янтайту

накрени́ться *несов.* кырынаю, янтаю, кыйшаю

накреня́ть *несов. см.* **накрени́ть**

накреня́ться *несов.* **1.** *см.* **накрени́ться**; **2.** *страд. от* **накреня́ть**

на́крепко *нареч.* **1.** (*прочно, наглухо*) нык итеп, ныклап; **закры́ть** ~ ныклап ябу **2.** *разг.* (*решительно*) каты [итеп], каттый (кискен) рәвештә

на́крест *нареч.* аркылы-торкылы, әвернәсыман итеп

накрича́ть *сов. на кого-что* кычкырыну, акырыну

накрои́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) кисү, кисеп кую, кисеп әзерләп кую (*кием-салым турында*)

накромса́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) кискәләү, кискәләп ташлау, тураклау, тураклап ташлау (бетерү)

накроши́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) турау, турап кую (ташлау, салу), ваклау, ваклап кую (ташлау, салу)

накрути́ть *сов.* **1.** *что* (*намотать*) (*берникадәр*) урау, урап (чорнап) кую **2.** *что, чего* (*изготовить кручением*) (*берникадәр*) кату, катып кую, бөтереп әзерләп кую; ишү, ишеп кую

накру́чивать *несов. см.* **накрути́ть**

накрыва́ть *несов. см.* **накры́ть**

накрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **накры́ться**; **2.** *страд. от* **накрыва́ть**

накры́ть *сов. кого-что* **1.** ябу, каплау; ~ **мешки́ бреzéнтом** капчыкларны

брезент белән каплау; ~ **стол ска́тертью** өстәлгә эскәтер җәю **2.** *разг.* тоту, өстенә барып чыгу; ~ **престу́пника** җинаятьчене тоту ♦ ~ **стол (на стол)** табын җәю, табын әзерләү

накры́ться *сов.* каплану, ябыну, бөркәнү; ~ **одея́лом** юрган ябыну

накупа́ть *несов. см.* **накупи́ть**

накупа́ться *сов.* туйганчы су коену (керү); ~ **в ре́чке** туйганчы инештә су коену

накупи́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) сатып алу (алып кую)

наку́ривать *несов. см.* **накури́ть**

наку́риваться *несов. см.* **накури́ться**

накури́ть *сов.* **1.** *чем и без доп.* тәмәке төтене белән тутыру; тәмәке тарту; ~ **в ко́мнате** бүлмәне тәмәке төтене белән тутыру **2.** *что, чего* (*берникадер*) куу, куып әзерләү; ~ **смолы́** сумала куу

накури́ться *сов.* туйганчы тәмәке тарту

накуроле́сить *сов. прост.* [шаярып] әкәмәтләр эшләп ташлау

накуса́ть *сов. что. разг.* тешләү, тешләп бетерү

наку́тать *сов. что. чего на кого, разг.* кат-кат киендерү, кат-кат кидерү

наку́тывать *несов. см.* **наку́тать**

налага́ть *несов. см.* **наложи́ть** 3

нала́дить *сов. что* **1.** көйләү, рәтләү, көйгә (рәткә) салу, төзәтү, ипләү; ~ **маши́ну** машинаны көйләү; ~ **станки́** станокларны төзәтү **2.** оештыру, юлга (җайга) салу; ~ **произво́дство запчасте́й** запас частьләр җитештеруне юлга салу

нала́ди||ться *сов.* җайлану, җайланып китү, юлга (җайга) салыну, юлга салынып китү, рәткә салыну; **рабо́та ~лась** эш җайланды

нала́дка *ж тех. см.* **нала́дить** 1

нала́дчик *м* көйләүче, төзәтүче; ~ **станко́в** станоклар көйләүче

нала́живание *с см.* **нала́дить, нала́диться; ~ ми́рных отноше́ний** тыныч мәнәсәбәтләр урнаштыру

нала́живать *несов. см.* **нала́дить**

нала́живаться *несов.* **1.** *см.* **нала́диться; 2.** *страд. от* **нала́живать**

нала́мывать *несов. см.* **наломи́ть**

налга́ть *сов.* **1.** (*наговорить лжи*) [әллә-ниләр] ялганлау, ялган сөйләү **2.** *на кого-что* (*наклеветать*) яла ягу, нахак бәла тагу

нале́во *нареч.* **1.** (*куда*) сулга, сулга таба, сул якка таба, **сверну́ть** ~ сулга борылу **2.** (*где*) сулда, сул якта; ~ **лес** сул якта урман

налега́ть *несов. см.* **нале́чь**

налегке́ *нареч.* **1.** (*без ноши*) җиңелчә [генә], әйберсез генә, йөксез **2.** (*в лёгкой одежде*) җиңелчә (җиңел) генә киенеп, җиңел киемнән

на́ледь *ж* **1.** боз өстенә чыккан су **2.** су өстендәге боз катламы

належа́ться *сов.* туйганчы яту

налеза́ть *несов. см.* **нале́зть**

нале́з||ть *сов. на кого-что и без доп., разг.* **1.** [үрмәләп менеп] сырып алу, каплап алу, сырышу, [үрмәләп] кереп тулу; этеп-төртеп менү, өелү, күтәрелү; **2.** (*об одежде, обуви*) керү, сыю, таман булу

налепи́ть *сов.* **1.** *что, разг.* ябыштыру, ябыштырып кую; ~ **на сте́ну афи́шу** стенага афиша ябыштырып кую **2.** *что, чего* (*берникадәр*) әвәләү, әвәләп ясау, әвәләп ясап кую; ~ **фигу́рок из гли́ны** балчыктан төрле сыннар әвәләп ясау

налепля́ть *несов. см.* **налепи́ть** 1

налёт *м* **1.** *см.* **налете́ть** 3, 5; **2.** (*авиации, конницы и т.п.*) һөҗүм **3.** (*вооружённое нападение*) басу, талау **4.** катлам, кунык; ~ **пы́ли** тузан куныгы **5.** *мед.* катлау; **у него́ ~ в го́рле** аның тамагында эренле катлау (*мәс. ангина белән авырганда була*) ♦ **с ~а (у)** 1) очып (йөгереп, ашыгып) барганда; **с ~а уда́риться** *обо что* йөгереп барганда бәрелү; 2) *перен.* (*не раздумывая*) уйлапнитеп тормыйча

налета́ть 1 *несов. см.* **налете́ть**

налета́||ть II *сов. что. чего* (*берникадәр*) очу; **лётчик ~л сто ты́сяч киломе́тров** лётчик йөз мең километр очкан

налете́||ть *сов.* **1.** *на кого-что* (*летя, натолкнуться*) очып барганда (килгәндә) бәрелү **2.** *перен. на кого-что, разг.* ашыгып барганда (килгәндә) бәрелү, барып (килеп) бәрелү; **~ть на столб** ашыгып барганда баганага бәрелү **3.** *на кого-что* (*напасть с воздуха*) ыргылу, ташлану, кинәт (көтмәгәндә) һөҗүм итү **4.** *перен. на кого-что* ташлану; **~ть с угро́зами** янап ташлану **5.** (*о ветре, буре*) кинәт чыгу, кубу, күтәрелү **6.** очып (кереп) җыелу, очып (кереп) тулу; **в ко́мнату ~ли му́хи** бүлмәгә чебен кереп җыелган **7.** куну, утыру; **на стёкла ~ла пыль** пыялаларга бик күп тузан кунган

налётчик *м* талаучы, басқынчы, йортлар талаучы, йортлар басучы

нале́чь *сов.* **1.** *на кого-что* [өстенә] яту, таяну, басу, этү; ~ **плечо́м на дверь** иңбашы белән ишекне этү **2.** *перен. на что* тырышу, тырышып ...а башлау; ~ **на учёбу** тырышып укый башлау; ~ **на вёсла** тырышып ишә башлау **3.** *перен. на кого-что, прост.* (*нажать*) кысрыклау, кысу, (*берәр нәрсә эшләргә*) мәҗбүр итү; ~ **на помо́щников** ярдәмчеләрне кысу

нали́в *м* **1.** *см.* **нали́ть** 1; **2.** җиту, пешү, өлгерү; **я́блоки хо́рошего ~а** яхшы өлгергән алмалар

наливá́ть *несов. см.* **нали́ть**

наливá́ться *несов.* **1.** *см.* **нали́ться; 2.** *страд. от* **наливá́ть**

нали́вка *ж* төнәтмә (*җиләк-җимеш салып төнәтелгән аракы*)

наливн||о́й, -а́я, -о́е **1.** сыеклык ...ы, сыекчалар салып ташый торган; **~ы́е суда́** сыекчалар салып ташый торган суднолар **2.** су ...ы, су әйләндерә торган; **~а́я ме́льница** су тегермәне **3.** тулып пешкән; **~о́е я́блоко** тулып пешкән алма

нали́м *м* җумба, шамбы

нали́м||ий, -ья, -ье җумба (шамбы) ...ы; **~ья ухá** җумба шулпасы

налинова́ть *сов. что, чего* [сызыклар] сызу, [сызыклар] сызып чыгу

налипа́ть *несов. см.* **нали́пнуть**

нали́пнуть *сов.* [өстенә] ябышу

налит||о́й, -а́я, -о́е **1.** тулып пешкән; **~о́е я́блоко** тулып пешкән алма **2.** (*о плечах, руках и т.п.*) тулы, симез; (*о человеке*) тыгыз тәнле, ныК

нали́ть *сов., что, чего* **1.** салу, тутыру, салып (тутырып) кую; ~ **чай в ча́шку** чынаякка чәй салу; ~ **стака́н молока́** бер стакан сөт салу **2.** (*пролить*) түгү **3.** (*изготовить литьём*) (*берникадәр*) кою, коеп ясау, коеп (әзерләп) кую

нали́ться *сов.* **1.** тулу, керү, кереп (үтеп) керү; **в ло́дку налила́сь вода́** көймәгә су кергән **2.** җитү, пешү, өлгерү, тулып пешү; **сли́вы налили́сь** сливалар өлгергән

налицо́ *нареч. в знач. сказ.* биредә, монда; бар; күз алдында; күренеп тора; **доказа́тельства ~** дәлилләр бар; **результа́ты ~** нәтиҗәләре күз алдында

нали́чествовать *несов. книжн.* булу, күз алдында булу, күренеп тору

нали́чи||е *с* барлык; булу; бар булу, урынында (кулда, күз алдында) булу; **при ~и** булса, булганда; булган хәлдә ♦ **быть (оказа́ться) в ~и** булу, күз алдында булу

нали́чник *м* йөзлек (*тәрәзәдә, ишектә*)

нали́чност||ь *ж* **1.** *см.* **нали́чие**; **все маши́ны в ~и** барлык машиналар [да] бар **2.** (*хәзерге вакытта*) булган кадәресе (күләме); **~ь това́ров в магази́не** кибеттәге товарларның булган кадәресе **3.** булган акча; **~ь ка́ссы** кассада булган акча ♦ **быть (оказа́ться) в ~и** *то же, что* **быть (оказа́ться) в нали́чии** *см.* **нали́чие**

нали́чн||ый, -ая, -ое **1.** булган, кулда булган, кулдагы; **~ый капита́л** кулда булган капитал; **~ые де́ньги** кулда булган акча **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* кулда булган акчалар ♦ **за ~ый расчёт** *фин.* саф акчага

нало́бник *м* **1.** (*в конской узде*) маңгайча **2.** (*налобная повязка*) маңгай бәйләвече

нало́бн||ый, -ая, -ое маңгайдагы, маңгай ...ы; **~ая повя́зка** маңгай бәйләвече; **~ый реме́нь** (*в узде*) маңгайча

налови́ть *сов. что, кого-чего* (*берникадәр*) тоту, тотып алу; ~ **ры́бы** балык тоту

наловчи́ться *сов. с неопр., в чём и без доп., разг.* остару, остарып (өйрәнеп) китү

нало́г *м* салым, түләү; **подохо́дный ~** керемгә карап алына торган салым; **обложи́ть ~ом** салым салу; **плати́ть ~** салым түләү

нало́гов||ый, -ая, -ое салым[нар] ...ы, түләү[ләр] ...ы; **~ая систе́ма** салымнар системасы

налогоплате́льщик *м* салым (түләү) түләүче

налогоплате́льщица *ж* салым түләче хатын (кыз)

наложи́ть *сов.* 1. *что* (*сверху*) кую, салу, өстенә кую (салу); ~ **компре́сс** компресс кую 2. *что, чего* (*на поверхность*) (*берникадәр*) өю, өеп кую; тутырү; (*внутрь*) төяү, төяп кую; тутыру; ~ **книг на стол** өстәлгә китаплар өеп кую; ~ **корзи́ну я́блок** бер көрзин алма тутыру 3. *что* басу, салу, кую; ~ **печа́ть** печать басу; ~ **аре́ст на иму́щество** милеккә арест салу; ~ **ви́зу** виза салу; ~ **штраф** штраф салу 4. *мед.* ~ **бинт** бинтлау, бинт белән бәйләү; ~ **гипс на́ руку** кулын гипска салу; ~ **жгут** жгут салу; ~ **пла́стырь** пластырь ябу; ~ **щипцы́** кыскыч(лар) белән кыстыру ◆ ~ **на себя́ ру́ки** *прост.* үзенә кул салу, үз-үзен үтерү; ~ **печа́ть (отпеча́ток)** *на кого-что* эз калдыру, йогынты ясау; ~ **ру́ку (ла́пу)** *на что* үз кулына алу, үз ихтыярына буйсындыру

нало́жница *ж книжн.* кәнизәк

наломáть *сов. что, чего* (*берникадәр*) сындыру, сындырып хәзерләү ◆ ~ **дров** ахмаклыклар эшләп ташлау

налощи́ть *сов. что* ялтырату, ялтыратып чыгу

налу́щивать *несов. см.* **налущи́ть**

налущи́ть *сов. что, чего* (*луща, насорить*) кабыгы белән чүпләп бетерү; (*луща, наготовить*) кабыгыннан (кузагыннан) әрчү, әрчеп кую

налюбова́ться *сов. на кого-что* сокланып түйганчы карап тору; (*с отриц. «не»*) сокланып (карап) туя алмау; **не налюбу́юсь на дете́й** балаларга карап туя алмыйм

намагни́тить *сов. что* магнитлау, магнитландыру

намагни́чивать *несов. см.* **намагни́тить**

намагни́чиваться *несов.* 1. магнитлану 2. *страд. от* **намагни́чивать**

намаз́ *м* намаз; **у́тренний** ~ иртәнге намаз

намáзать *сов.* 1. *что* сылау, сөртү, ягу; ~ **хлеб ма́слом** ипигә май ягу 2. *что, разг.* буяу; ~ **гу́бы** иреннәрне буяу 3. *что, чего и без доп., разг.* (*плохо нарисовать, написать*) буяштыргалау; сызгалау; эштер-өштер китерү

нама́заться *сов.* буяну, сөртенү, ягыну; ~ **кре́мом** крем ягыну; ~ **ма́зью** мазь белән сөртенү

нама́зывать *несов. см.* **нама́зать** 1, 2

нама́зываться *несов.* 1. *см.* **нама́заться**; 2. *страд. от* **нама́зывать**

намалева́ть *сов. кого-что, разг.* белер-белмәс рәсем ясау

нама́лывать *несов. см.* **намоло́ть**

намарино́вать *сов. что, чего* (*берникадәр*) маринадлау, маринадлап кую (әзерләү)

намарино́вывать *несов. см.* **намарино́вать**

нама́тывать *несов. см.* **намота́ть**

нама́тываться I *несов.* 1. *см.* **намота́ться** 1; 2. *страд. от* **нама́тывать**

нама́тываться II *несов. см.* **намота́ться** II

нама́чивать *несов. см.* **намочи́ть**

нама́чиваться *несов.* 1. *см.* **намочи́ться**; 2. *страд. от* **нама́чивать**

нама́яться *сов. прост.* 1. (*очень устать*) бик нык ару, арып (интегеп) бетү 2. (*намучиться*) бик интегү, бик күп җәфа чигү

намежева́ть *сов. что, чего* ызан (межа) салып (сызып) чыгу

намежёвывать *несов. см.* **намежева́ть**

намёк *м* ишарә, киная, кинаяле сүз, читләтеп әйтелгән сүз; **сде́лать** ~ сиздерү, сиздереп кую

намека́||ть *несов. на кого-что и без доп.* ишарә итү, читләтеп әйтү (сөйләү), кинаяле сөйләү, сиздерү, сиздереп әйтү; **я дога́дался, на что́ он** ~**ет** аның тел төбе кая берганын мин сизеп алдым

намекну́ть *сов. однокр. на кого-что и без доп.* [читләтеп] сиздереп кую, [читләтеп] әйтеп кую, сиздерү, сиздереп кую

намели́ть *сов. что* акбурлау, акбур белән буяп кую, акбурлап кую

намéнивать *несов. см.* **наменя́ть**

наменя́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) алыштыру, алыштырып алу

намерева́||ться *несов.* ниятләү, исәп тоту, чамалау, чамалап тору (йөрү), җыену, уйлау, ...макчы булу; **я** ~**юсь уе́хать** китәргә җыенам

наме́рение *с* ният, исәп, теләк; **благи́е** ~**я** изге ниятләр

наме́ренный, -ая, -ое белеп (белә торып, юри) эшләнгән, алдан белеп (үйлап) ...ган, аңлы рәвештә ...ган; ~ **посту́пок** аңлы рәвештә эшләнгән эш

намерза́ть *несов. см.* **намёрзнуть**

намёрз||нуть *сов.* [өстенә] кату, күп бүлып кату; **на окне́ намёрз лёд** тәрәзәгә боз каткан

намёрзнуться *сов. разг.* бик [нык] туңу, туңып бетү, бик өшү, өшеп (катып) бетү; ~ **в пути́** юлда бик нык туңу

наме́ривать *несов. см.* **наме́рить**

наме́рить *сов. что, чего* (*берникадәр*) үлчәү, үлчәп [әзерләп] кую; ~ **мешо́к муки́** бер капчык он үлчәп кую; ~ **де́сять ме́тров полотна́** ун метр киндер үлчәп әзерләп кую

на́мертво *нареч. разг.* нык итеп, ачылмаслык (сүтелмәслек, аерылмаслык *h.б.ш.*) итеп; **соедини́ть** ~ *что-л.* нык итеп тоташтыру

намеря́ть *несов. см.* **наме́рить**

намеси́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) изү, басу, изеп (басып) кую; ~ **те́ста** камыр изеп кую; ~ **гли́ны** балчык изеп кую

наме||сти́ *сов.* 1. *что, чего* (*берникадәр*) себереп өеп кую; ~**сти́ ку́чу му́сора** чүпне себереп өеп кую 2. *безл. что* (*өреп китереп*) өю, җыю; ~**ло́ мно́го сне́гу** бик күп кар китереп өйгән

наме́стник *м* наместник (1. *ист. борынгы Русьта җирле идарә башлыгы* 2. *18нче гасырда бер яки берничә губерна башлыгы* 3. *19-20нче гасырларда Россиядә кырый төбәкләрдә — Кавказда, Польшада — башлык*)

наме́стничество *с* наместниклык (*Россиядә 18нче гасыр ахырыннан 20нче гасыр башына кадәр административ-территориаль берәмлек*)

намёт *м* 1. *рыб.* сөрәкә (*озын сапка утыртылган капчыксыман җәтмә*) 2. (*сеть для ловли птиц*) тозак

наметáть I *сов. см.* **намести́**

наметá||ть II *сов.* 1. *что, чего* (*берникадәр*) өю, салу, кую; ~**ть пя́ть стого́в** биш кибән кую; ~**ть се́на** печән өю 2. *что, кого-чего* (*произвести на свет*) (*о рыбе*) чәчү; (*о нек-рых животных*) балалау, бала китерү 3. *что* күнектерү, өйрәтү; ~**ть глаз** күзләрне күнектерү; ~**ть ру́ку** кулны күнектерү

наметáть III *сов.* 1. *что* типчү, күкләү; ~ **швы** җөйләрне типчү 2. *что, чего* (*берникадәр*) типчү, күкләү, типчеп (күкләп) чыгу; ~ **не́сколько пла́тьев** берничә күлмәкне күкләп чыгу

наме́тить I *сов. что* 1. (*поставить метку*) билге салу (кую), билге[ләр] салып (куеп) чыгу 2. (*обозначить штрихами*) сызып чыгу (билгеләү)

наме́тить II *сов. что* билгеләү; күздә тоту; ~ **день отъе́зда** китү көнен билгеләү

намётывать I *несов. см.* **наметáть** II

намётывать II *несов. см.* **наметáть** III

намечáть I *несов. см.* **наме́тить** I

намечáть II *несов. см.* **наме́тить** II

намешáть *сов. что, чего, разг.* катнаштырү, кушу, кушып туглау

наме́шивать I *несов. см.* **наме́сить**

наме́шивать II *несов. см.* **намешáть**

наминáть *несов. см.* **намя́ть**

намоги́льный, -ая, -ое кабер ...ы, кабер өсте ...ы; ~ **па́мятник** кабер ташы

намозо́лить *сов. что, разг.* сөялләндерү, сөялләндереп бетерү; ~ **ру́ки** кулларны сөялләндереп бетерү; ~ **глаза́** *кому прост.* күзгә кергән чүп булу, туйдырып бетерү

намокáть *несов. см.* **намóкнуть**

намóкнуть *сов.* чылану, юешләну, жебү

намола́чивать *несов. см.* **намолоти́ть**

намоло́т *м с.-х.* 1. *см.* **намолоти́ть**; 2. (*количество намолоченного зерна*) сугып алынган игеннең күләме

намолоти́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) сугып алу (кую); ~ **по со́рок це́нтнеров зерна́ с гекта́ра** гектарыннан кырыгар центнер иген сугып алу

намоло́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) тарттырү, тарттырып алу (кую); ~ **мешо́к муки́** бер капчык он тарттырып алу

намóрдник *м* борынчык, борындык

намор||и́ть *сов. что, кого-чего* агулап үтереп бетерү; ~ **тарака́нов** тараканнарны агулап үтереп бетерү

намóрщить *сов. что* җыерү; ~ **лоб** маңгай җыерү

намóрщиться *сов.* (*о коже лба, носа*) җыерылу

намости́ть *сов. что* [таш, такта *h.б.ш.*] җәю, түшәү, җәеп (түшәп) чыгу; ~ **доро́гу** юлга таш түшәү

намотáть *сов. что, чего* (*берникадәр*) чорнау, урау, чорнап (урап) кую; чорнап (әзерләп) кую; сару; ~ **ни́тки на шпу́льку** кәтүккә жеп чорнау; ~ **не́сколько клубко́в ше́рсти** берничә йомгак йон чорнау ◆ ~ **[себе́] на ус** мыекка

чорнап кую, ≈ колакка салып (киртеп) кую

намота́ться I *сов.* чорналу, уралу, чорналып (уралып) бетү; сарылу

намота́ться II *сов. прост.* (*устать*) ару, арып бетү, арып хәлдән таю

намо́тка *ж* **1.** *см.* **намота́ть**; **2.** *разг.* (*моток*) киләп

намочи́ть *сов.* **1.** *что* чылату, җебетү, чылатып (җебетеп) кую; **~ бельё в кори́те** тагараста кер чылату **2.** *что, чего* (*берникадәр*) җебетү, җебетеп кую; **~ я́блок на́ зиму** кышлыкка алма җебетеп кую

намудри́ть *сов. разг.* бутап (буташтырып, катлауландырып) бетерү

наму́сорить *сов. разг.* чүпләү, чүпләп бетерү

намути́ть *сов. что* болгату, болганчыкландыру, болганчыкландырып бетерү; **~ во́ду** суны болгату

наму́читься *сов. разг.* бик күп җәфа чигү, интегү, җәфаланып (интегеп) бетү

намы́в *м* **1.** *см.* **намы́ть** 2, 3; **~ гру́нта** грунт юдырту **2.** китерелмә, утырым, дуен, балчык (*елга ярының агым сулар алып килгән туфрактан, комнан һ.б.ш. барлыкка килгән өлеше*)

намыва́ть *несов. см.* **намы́ть**

намыва́ться *несов.* **1.** *см.* **намы́ться**; **2.** *страд. от* **намыва́ть**

намывн||о́й, -а́я, -о́е **1.** юдыртылган, юдыртып өйдерелгән; **~о́й песо́к** юдыртып өйдерелгән ком **2.** юдыртып корылган (төзелгән, ясалган); **~о́е сооруже́ние** юдыртып төзелгән корылма

намы́каться *сов. прост.* күп авырлыклар (кыенлыклар) күрү, күп кайгы-хәсрәт чигү, азап чигү; интегү, интеген бетү; **~ по бе́лу свету́** илдән илгә йөреп интеген бетү

намы́ливать *несов. см.* **намы́лить**

намы́ливаться *несов.* **1.** *см.* **намы́литься**; **2.** *страд. от* **намы́ливать**

намы́лить *сов. кого-что* сабынлау, сабын сөртү; **~ ру́ки** кулга сабын сөртү ♦ **~ го́лову** *кому* кирәген бирү, арт сабагын укыту

намы́литься *сов.* сабынлану, сабын сөртенү

намы́ть *сов.* **1.** *что, чего, разг.* (*берникадәр*) юу, юып кую; **~ мно́го посу́ды** бик күп савыт-саба юу **2.** *что, чего* юу, юып алу, юып аеру, юып табу; **~ зо́лота** алтын юу **3.** *что* юдырту, юдыртып өю (кору, төзу, ясау); **~ да́мбу** юдыртып дамба төзү

намы́ться *сов. разг.* (*напр. в бане*) әйбәтләп юыну, туйганчы юыну

намя́ка́ть *несов. см.* **намя́кнуть**

намя́кнуть *сов.* җебеп йомшару, җебеп изрәү

нама́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*берникадәр*) изү, изеп кую, изеп әзерләп кую; (*лён*) талку; **~ гли́ны** балчык изеп әзерләп кую **2.** *что, разг.* кырдыру, кырдырып авырттыру (чиләндерү, суйдыру), кысып авырттыру; **~ плечо́** җилкәне кысып авырттыру ♦ **~ бока́** *кому, прост.* кабыргаларын санау (*кыйнап ташлау*)

нана́ец *м* нанай, нанай кешесе

нана́йка *ж* нанай хатыны (кызы)

нана́йский -ая, -ое нанай[лар] ...ы; **~ язы́к** нанай теле

нана́йцы *мн.* нанайлар, нанай халкы

нана́шивать *несов. см.* **наноси́ть** I

нанес||ти́ *сов.* **1.** *что, чего* (*берникадәр, күп итеп*) китерү, китереп өю (түтыру; ташу); **~ти́ книг** бик күп китап китерү **2.** *безл. что, чего* (*җил, агым белән*) илтеп (китереп) өю; илтеп (китереп) ташлау; **ве́тром ~ло́ сугро́б** җил көрт китереп өйгән **3.** *безл. кого-что разг.* (*натолкнуть с разгона*) китереп бәрдерү, илтеп бәрдерү **4.** *что* сөртү, каплау; **~ти́ сма́зочное ма́сло на дета́ль** детальне майлау **5.** *что* төшерү; **~ти́ го́род на ка́рту** шәһәрне картага төшерү; **~ти́ чертёж на ка́льку** сызымны калькага төшерү **6.** *что, чего* (*берникадәр*) йомырка салу; **~ти́ я́йц** йомырка салу **7.** **~ти́ оби́ду** хәтер калдыру, үпкәләтү; **~ти́ оскорбле́ние** мәсхәрә итү; **~ти́ пораже́ние** җиңү; **~ти́ ра́ну** яралау; **~ти́ уда́р** сугу; **~ти́ уро́н** зыян китерү, зарар китерү ♦ **~ти́ визи́т** *кому* визит ясау, зиярәт кылу

нанизу́ть *сов. что. чего* [җепкә] тезү; [җепкә] тезеп кую; **~ же́мчуг на нить** җепкә энҗе тезү

нани́зывать *несов. см.* **нанизу́ть**

нанима́тель *м* яллаучы

нанима́тельница *ж* яллаучы хатын (кыз)

нанима́ть *несов. см.* **наня́ть**

нанима́ться *несов.* **1.** *см.* **наня́ться**; **2.** *страд. от* **нанима́ть**

на́нка *ж уст.* нанка (*тукыма*)

нано́с *м* **1.** *см.* **нанести́** 2; **2.** китерелмә, утырым, дуен, балчык (*су агымы, җил китергән нәрсәләр өеме*)

наноси́ть I *сов. что, чего* (*берникадәр*) ташу, ташып кую, берничә тапкыр китерү; **~ камне́й** таш ташып кую

наноси́ть II *несов. см.* **нанести́**

нано́сн||ый, -ая, -ое **1.** китерелмә ..., су агымы (җил) белән китерелгән; **~ый песо́к** китерелмә ком **2.** *перен.* үзенә хас булмаган, очраклы; тышкы; **~ое влия́ние** тышкы йогынты

на́нсук *м* нансук (*тукыма*)

нанюха́ться *сов. чего, разг.* **1.** (*понюхать вдоволь*) иснәп тую, туйганчы иснәү **2.** (*нюхая, опьянеть*) иснәп исерү, исергәнче иснәү; **~ эфи́ра** эфир иснәп исерү

наня́ть *сов.* **1.** *кого-что* яллау; **~ рабо́чих** эшчеләр яллау **2.** *что* [хак түләп вакытлыча файдалануга] алу; яллау; **~ кварти́ру** хак түләп вакытлыча файдалануга квартира алу

наня́ться *сов.* яллану

наобеща́ть *сов. что, чего* күпне ышандыру, күп вәгъдәләр бирү ♦ **~ с три ко́роба** тау хәтле вәгъдәләр бирү

наборо́т *нареч.* **1.** киресенчә; **поступа́ть ~** киресенчә эш итү **2.** кирегә; **прочита́ть сло́во ~** сүзне кирегә уку (*ягъни ахырыннан башына таба*)

наобу́м *нареч. разг.* уйламыйча, уйлап-нитеп тормастан, дуамал; **отве́тить ~** уйламыйча җавап бирү

наора́ть *сов. на кого-что, прост.* кычкырыну, акырыну, акырыну-бакырыну

на́отмашь *нареч.* кизәнеп; **уда́рить ~** кизәнеп сугу

наотре́з *нареч.* кискен (катгый) рәвештә, кырт кисеп, кистереп, өзеп; **отказа́ться ~** катгый рәвештә баш тарту

напада||ть *сов.* (*напр. о листьях*) бик күп коелу; (*напр. о снеге*) бик күп төшү (яву)

напада́ть I *несов. см.* **напа́сть** I

напада́ть II *несов. см.* **напа́сть** II

напада́ющий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **напада́ть** I; **2.** *в знач. сущ. м спорт.* һөҗүмче

нападе́ние *с* **1.** һөҗүм, һөҗүм итү; **вооружённое ~** кораллы һөҗүм **2.** *спорт.* һөҗүмчеләр

напа́дки *только мн.* һөҗүм, бәйләнү[ләр], гаеп ташлау[лар], [нахак] бәлалар ягу; **необосно́ванные ~** урынсызга бәйләнүләр

напа́ивать I *несов. см.* **напои́ть**

напа́ивать II *несов. см.* **напая́ть** I

напа́йка *ж* **1.** *см.* **напая́ть**; **2.** (*напаянная часть*) паять итеп ябыштырылган кисәк

напа́лм *м* напалм (*яндыра торган матдәләрдән ясалган куе катнашма*)

напа́лмов||ый, -ая, -ое напалмлы; **~ая бо́мба** напалмлы бомба

напа́ривать *несов. см.* **напа́рить**

напа́риваться *несов.* **1.** *см.* **напа́риться**; **2.** *страд. от* **напа́ривать**

напа́рить *сов.* **1.** *что, чего* (*берникадәр*) парда пешерү; **~ ты́квы** парда кабак пешерү **2.** *кого-что, разг.* (*в бане*) [әйбәтләп] чабу

напа́риться *сов. разг.* әйбәтләп мунчада чабыну, туйганчы мунчада чабыну

напа́рник *м разг.* кулдаш

напа́рница *ж разг.* кулдаш хатын (кыз)

напа́рывать *несов. см.* **напоро́ть** I

напа́рываться *несов. см.* **напоро́ться**

напаса́ть *несов. см.* **напасти́**

напаса́ться *несов.* **1.** *см.* **напасти́сь**; **2.** *страд. от* **напаса́ть**

напасти́ *сов. что, чего* (*берникадәр*) әзерләү, хәстәрләү, әзерләп (хәстәрләп) кую

напас||ти́сь *сов. чего, разг.* (*обычно в отриц. ф.*) житәрлек итеп әзерләү (әзерләп кую); **на тебя́ не ~ёшься** төткәрә алмассың сиңа

напа́||сть I *сов. на кого-что* **1.** һөҗүм итү, ташлану; **~сть на неприя́тельскую кре́пость** дошман крепостена һөҗүм итү **2.** *разг.* (*обрушиться с упрёками*) ташлану; бәйләнү **3.** очрату, тап булу; **~сть на интере́сную мысль в кни́ге** китапта кызыклы фикер очрату ♦ **~ла грусть** кинәт моңсу бүлып китте; **~ла лень** ялкаулык басты; **~ла тоска́** эч поша башлады; **~л страх** курку басты; **~сть на след** *чей, кого* эзенә төшү

напа́сть II *сов. см.* **напа́дать**

напа́сть III *ж разг.* (*беда*) бәла, бәлаказа, бәхетсезлек, күңелсезлек

напаха́ть *сов. что, чего* (*берникадәр жирне*) сөрү, сукалау

напа́хивать *несов. см.* **напаха́ть**

напа́чкать *сов.* пычрату, пычратып бетерү

напа́ять *сов.* **1.** *что* (*припаять сверху*) паять итү, паять итеп ябыштыру **2.** *что, чего* (*наготовить паянием*) паять итеп (*берникадәр*) әзерләү

напе́в *м* көй; моң; **наро́дные ~ы** халык моңнары

напева́ть *несов.* **1.** *см.* **напе́ть**; **2.** *что и без доп.* акрын гына көйләү (җырлау), авыз эченнән генә көйләү (җырлау)

напе́вн||ый, -ая, -ое көйле, моңлы, аһәңле; ягымлы; **~ая речь** көйле сөйләм

напека́ть *несов. см.* **напе́чь**

наперебо́й *нареч. разг.* бер-берсен бүлеп, бер-берсенең сүзен бүлдереп

наперевес *нареч.* алга каратып; **с ружьём ~** мылтыкны алга каратып

наперегонки́, наперего́нки *нареч. разг.* куышып, узышып, берсен берсе узарга тырышып

наперекор **1.** *предлог с дат. п.* каршы, ... белән исәпләшмичә; **~ желáниям** теләкләргә каршы **2.** *нареч.* каршы, каршы барып, киресенчә; **дéлать ~** киресенчә эшләү

наперере́з *нареч.* юлын аркылы кисеп, юлына аркылы төшеп; **бежáть ~** *кому-чему* юлын аркылы кисеп йөгерү

напере́ть *сов. на кого-что, прост.* [бөтен көч белән] этү

наперехва́т *нареч. прост. см.* **наперере́з**

наперечёт *нареч.* **1.** барысын да, бетенесен дә, берсен-бер калдырмый; **я зна́ю всех ~** мин барысын да беләм **2.** *в знач. сказ.* аз, бик аз, күп түгел; **таки́е лю́ди ~** мондый кешеләр бик аз

напе́рник *м разг.* сүрү

напе́рсник *м уст.* яраткан ышанычлы кеше; сердәш

напе́рсница *ж уст.* сердәш хатын (кыз)

напёрсток *м* уймак

наперстя́нка *ж бот.* уймак чәчәк

напе́рчивать *несов. см.* **напе́рчить**

напе́рчить *сов. что* [күп итеп] борычлау, борыч салу

напе́ть *сов. что разг.* көйләп (җырлап) күрсәтү; **~ пе́сню** җыр җырлап күрсәтү; **~ мотúв** көй көйләп күрсәтү **2.** (*җырлаганны пластинкага*) яздыру; **~ а́рию на пласти́нку** арияне пластинкага яздыру

напеча́тать *сов. что* **1.** басу, басып чыгару; бастыру, бастырып чыгару; **~ кни́гу** китап басу; **~ статью́ в журна́ле** журналда мәкалә бастырып чыгару **2.** *фото* ясау; **~ фотогра́фию** фоторәсем ясау

напеча́та||ться *сов.* **1.** *разг.* басылу, чыгу; **рису́нки ~лись отчётливо** рәсемнәр ачык чыкканнар **2.** басылып чыгу; **~ в журна́ле** журналда (*мәкалә, әсәрең һ.б.ш.*) басылып чыгу

напе́чь *сов.* **1.** *что, чего* (*берникадәр*) пешерү, пешереп кую, пешереп әзерләп кую; **~ пирого́в** бәлешләр пешерү **2.** *безл. что, разг.* эссе кабу, кызу кабу; **мне́ напекло́ го́лову** башыма эссе капты

напива́ться *несов. см.* **напи́ться**

напи́ливать *несов. см.* **напили́ть**

напили́ть *сов. что, чего* (*берникадәр*) кисү, кисеп кую, кисеп әзерләп кую (*пычкы белән*)

напира́ть *несов.* **1.** *см.* **напере́ть**; **2.** *на кого-что, разг.* (*теснить, наступать*) кысу, кысрыклау **3.** *на что, разг.* (*делать упор*) басым ясау, басым ясап әйтү (сөйләү)

написа́ние *с* язылыш, язылу; **пра́вильное ~ сло́ва** сүзнең дөрес язылышы

написа́ть *сов. что* **1.** язу; **~ письмо́** хат язу **2.** рәсем ясау; **~ портре́т** портрет ясау

напита́ть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* (*накормить*) ашату, түйдыру, түкландыру **2.** *что* (*пропитать жидкостью*) сеңдерү

напита́ться *сов.* (*пропитаться жидкостью*) [үзенә] сеңдерү, тарту, суыру

напи́т||ок *м* эчемлек; **прохлади́тельный ~ок** салкын эчемлек; **спиртны́е ~ки** спиртлы эчемлекләр

напи́тывать *несов. см.* **напита́ть** 2

напи́тываться *несов.* **1.** *см.* **напита́ться**; **2.** *страд. от* **напи́тывать**

напи́ться *сов.* **1.** *чего и без доп.* туйганчы эчү, эчеп тую; **~ ча́ю** туйганчы чәй эчү **2.** (*опьянеть*) исергәнче эчү, эчеп исерү

напиха́ть *сов. что, чего* тыгызлап (дыңгычлап) тутыру; теләсә ничек тутыру

напи́хивать *несов. см.* **напиха́ть**

напи́чкать *сов. кого-что, разг.* **1.** көчләп ашату, кирәгеннән артык ашату, тыгындыру; **~ ребёнка конфе́тами** балага кирәгеннән артык конфет ашату **2.** *перен.* бик күп бирү, [башына] дыңгычлап тутыру; **~ сове́тами** бик күп киңәшләр бирү

напла́ваться *сов.* туйганчы йөзү, йөзеп тую

напла́вить *сов.* **1.** *что, тех.* (*өстенә*) эрегән металл йөгертү **2.** *что, чего* (*берникадәр*) эретү, эретеп чыгару, эретеп әзерләү; **~ о́лова** аккургаш эретү

напла́виться *сов.* (*берникадәр*) эрү, эреп чыгу

наплавля́ть *несов. см.* **напла́вить**

наплавля́ться *несов.* **1.** *см.* **напла́виться**; **2.** *страд. от* **наплавля́ть**

наплавно́й, -а́я, -о́е йөзмә (*көймәләргә, понтонларга һ.б.ш. салынган*); **~ мост** йөзмә күпер

напла́кать *сов. что, разг.* күп елап [күзләрне] кызартып (шештереп) бетерү; **~ глаза́** күп елап күзләрне кызартып бетерү

напла́каться *сов.* (*много поплакать*) бик күп елау; (*вдоволь поплакать*) туйганчы елау, елап тую

напласта́ть *сов. что, чего, разг.* юка кисәкләргә кисү (кискәләү), юка кисәкләргә кисеп (кискәләп) кую, юка-юка гына итеп кисеп (кискәләп) кую; **~ ры́бу (ры́бы)** балыкны юка-юка гына итеп кискәләп кую

напластова́ние *с* **1.** *см.* **напластова́ть, напластова́ться; 2.** *геол.* катлам **3.** *перен.* (*наслоение*) катлам, үзенчәлек (*мәс. культурада, аңда, характерда*)

напластова́ть *сов. что, чего* **1.** (*наложить слоями*) катлау, катлам-катлам итеп салу (кую, өю) **2.** (*разделить на слои*) катламлау, катламнарга аеру

напластова́ться *сов.* катлам-катлам булып урнашу, катлану

напласто́вывать *несов. см.* **напластова́ть**

напласто́вываться *несов.* **1.** *см.* **напластова́ться; 2.** *страд. от* **напласто́вывать**

наплева́тельск||ий, -ая, -ое *разг.* салкын, игътибарсыз, төкереп ...; **~ое отноше́ние к своему́ де́лу** үз эшеңә салкын карау

наплева́ть *сов. прям., перен. на кого-что* төкерү, төкереп пычратып бетерү, төкереп тутыру

наплеска́ть *сов. что, чего* чәчрәтү, чәчрәтеп бетерү

наплёскивать *несов. см.* **наплеска́ть**

наплести́ *сов. что, чего* (*берникадәр*) үрү, үреп кую, үреп ясау; **~ корзи́н** кәрзиннәр үреп ясау

наплета́ть *несов. см.* **наплести́**

наплёчн||ый, -ая, -ое җилкә ...ы, җилкәгә (иңбашка) киелә торган; иңбашка тегеп куелган; **~ые реми́ни** җилкә каешлары

наплоди́ть *сов. что, кого-чего, разг.* бик күп тудыру, үрчетү

наплоди́ться *сов. разг.* бик күп туу; үрчү

наплы́в *м* **1.** *см.* **наплы́ть** 2; **2.** *перен.* агылу, агылыш, күп санда керү (килү); **~ посети́телей** килүчеләрнең агылуы **3.** (*болезненный нарост, напр. на стволе*) оры **4.** (*болезненный нарост на копытах*) шеш **5.** *кино* акрын гына алышыну

наплыва́ть *несов. см.* **наплы́ть**

наплы́||ть *сов.* **1.** *на кого-что* [йөзеп барганда] бәрелү, [йөзеп килгәндә] бәрелү; барып керү; **~ть на ка́мень** [йөзеп барганда] ташка бәрелү; **~ть на ме́ль** сайлыкка барып керү **2.** [бик күп] агып килеп җыелу, утыру; **~ло мно́го ти́ны** бик күп ләм утырган **3.** *перен.* (*о туче, облаке и т. п.*) каплау; **о́блако ~ло на со́лнце** ак болыт кояшны каплады

наповáл *нареч.*: **уби́ть ~** бер сугуда (атуда) үтерү

наподо́бие *предлог с род. п.* кебек, шикелле, төсле, ...сыман; **вдалеке́ вид-не́ется что́-то ~ ло́дки** еракта көймәсыман бер нәрсә күренә

напои́ть *сов.* **1.** *кого-что* эчерү, эчәргә бирү; **~ коня́** атны эчерү **2.** *кого-что* (*спиртными напитками*) исерткәнче эчерү **3.** *перен. что* сугару, туендыру, сеңдерү; **во́здух напоён за́пахом хво́йных дере́вьев** һава ылыслы агачлар исе белән тулган

напока́з *нареч.* **1.** (*для показа*) күрсәтер өчен; **вы́ставить това́ры ~** товарларны күрсәтү өчен чыгарып кую **2.** күрсәтү өчен генә, игътибарны җәлеп итү өчен, мактану өчен; күз буяу өчен; **всё де́лать ~** һәр нәрсәне күрсәтер

өчен генә эшләү; **он лю́бит вы́ставить себя́** ~ ул үзен күрсәтергә ярата

наполза́ть *несов. см.* **наползти́**

наполз||ти́ *сов. разг.* **1.** *на кого-что* үрмәләп барганда бәрелү, үрмәләп килеп бәрелү, шуышып барганда бәрелү, шуышып барып (килеп) бәрелү **2.** килеп каплау; **густо́й тума́н напо́лз на лес** урманны куе томан килеп каплады **3.** [үрмәләп] кереп тулу; **муравьи́ ~ ли́ в вареньe** кырмыскалар вареньега кереп тулганнар

наполирова́ть *сов.* **1.** *что* шомартып ялтырату (ялтыратып кую); ~ **ме́бель** мебельне шомартып ялтырату **2.** *что, чего* (*берникадәр*) шомартып ялтырату; ~ **шкату́лок** шкатулкалар шомартып ялтырату

напо́лни||ть *сов. что* **1.** тутыру, тутырып салу, түбәләмә тутыру; ~**ть корзи́ну гриба́ми** кәрзинне гөмбә белән тутыру **2.** тулу, кереп тулу; **вода́ ~ла я́му** су чокырга тулды **3.** сугару, туендыру, сендерү, тутыру; **во́здух был наполне́н арома́том цвето́в** һава чәчәкләрнең һуш исе белән тулган иде ♦ **ра́дость ~ла се́рдце** күңелем шатлык белән тулды; **оби́да ~ла ду́шу** бөтен күңелем белән рәнжедем

напо́лни||ться *сов.* тулу; **ко́мната ~лась ды́мом** бүлмәгә төтен тулды

наполня́ть *несов. см.* **напо́лнить**

наполня́ться *несов.* **1.** *см.* **напо́лниться**; **2.** *страд. от* **наполня́ть**

наполови́ну *нареч.* **1.** яртылаш, яртыга-ярты; **у́дочка с поплавко́м ~ кра́сным, ~ си́ним** яртысы кызыл, яртысы күк калкавычлы кармак **2.** (*не до конца*) яртылаш, ярты-йорты; ярым-йорты, ярым; **рабо́та сде́лана ~** эш яртылаш [кына] эшләнгән; ~ **забы́тое** ярым онытылган

напома́дить *сов. что* помадалау, помада сөртү

напома́диться *сов.* помадалану, помада сөртену

напома́живать *несов. см.* **напома́дить**

напома́живаться *несов. см.* **напома́диться**

напомина́ние *с* **1.** *см.* **напо́мнить**; **2.** искәртмә

напомина́ть *несов.* **1.** *см.* **напо́мнить**; **2.** *кого-что* (*иметь сходство*) охшау, хәтерләтү

напо́мни||ть *сов.* **1.** *кого-что, о комчём* (*заставить вспомнить*) искә төшерү, хәтергә төшерү **2.** *кого-что* хәтерләтү, искә төшерү; **она́ ~ла мне мою́ мать** үл минә анамны хәтерләтте

напо́р *м* **1.** басым; этем; ~ **воды́** су басымы **2.** *перен.* (*нажим*) басым, кысрыклау, һөжүм

напо́ристость *ж* үз дигәнендә нык торучанлык; тырышлык

напо́ристый, -ая, -ое үз дигәнендә нык торучы (торучан); тырыш

напоро́ть I *сов. что, разг.* яралау (*берәр уткен нәрсәгә бәрелеп яки басып*); ~ **но́гу на гво́здь** кадакка басып аякны яралау

напоро́ть II *сов. что, чего* **1.** (*распороть*) (*берникадәр*) сүтү, сүтеп ташлау (*тегелгән әйберне*) **2.** *перен. разг.* [төрле] юк-барны сөйләп [эшләп] ташлау; ~ **чепуху́** юк-бар сүзлар сөйләп ташлау

напоро́ться *сов.* **1.** *на что, разг.* яралану (*берәр уткен нәрсәгә бәрелеп яки басып*); ~ **на стекло́** пыялага басып яралану **2.** *перен. на кого-что* туры килү, тап булу, очрау, өстенә барып чыгу; ~ **на заса́ду** засадага очрау; ~ **на негодя́я** кабахәт кешегә туры килү

напороши́||ть *сов. безл. чего* аз гына явып үтү (*кырпак кар турында*); ~**ло снегу́** аз гына кырпак кар явып үткән

напо́ртить *сов. разг.* **1.** *что, чего* (*испортить*) (*берникадәр*) бозу, бозып ташлау; ~ **бума́г** кәгазь пычратү **2.** *кому-чему* (*причинить вред*) зарар (зыян) китерү

напосле́док *нареч. разг.* ахырда, соңыннан, актыкта

напра́вить *сов.* **1.** *что* юнәлтү, юнәлдерү; ~ **ору́жие на врага́** коралны дошманга таба юнәлтү; ~ **внима́ние на что-л.** игътибарны *берәр нәрсәгә* юнәлтү; ~ **все си́лы на выполне́ние пла́на** бөтен көчне планны үтәүгә юнәлтү **2.** *кого-что* җибәрү; ~ **к юри́сту** юристка җибәрү; ~ **заявле́ние на и́мя дире́ктора** гаризаны директор исеменә җибәрү **3.** *что* (*наточить*) янау, чарлау, кайрау, үткенләү **4.** *перен. что* җайлау, җайга салу, юлга салу, юлга салып җибәрү, рәтләү, рәткә салу; ~ **рабо́ту** эшне юлга салып җибәрү ♦ ~ **путь (шаги́, сто́пы** *и т.п.*) юнәлү, китеп бару; ~ **на и́стинный путь** *или* **на путь и́стины** дөрес юлга салу (бастыру)

напра́виться *сов.* юнәлү, юл тоту, китү; ~ **в го́род** шәһәргә юнәлү

напра́вка *ж см.* **напра́вить** 3

напра́вле́ни||е *с* **1.** *см.* **напра́вить** 1, 2; ~**е на рабо́ту** эшкә җибәрү **2.** юнәлеш, як, тараф, таба; **идти́ по ~ю к ...** ...га таба бару; **идти́ по ~ю к го́роду** шәһәргә таба бару; **се́верное ~е** төньяк юнәлеш **3.** юнәлеш; **дать пра́вильное ~е в рабо́те** эштә дөрес юнәлеш бирү; **реали́стическое ~е в иску́сстве** сәнгатьтә реалистик юнәлеш; ~**е поли́тики** сәясәтнең юнәлеше **4.** (*документ*) направление; юллама; **дать ~е на заво́д** заводка юллама бирү

напра́вленность *ж* юнәлеш, юнәлгәнлек; максат; **иде́йная ~** идея юнәлеше

направля́ть *несов. см.* **напра́вить**

направля́ться *несов.* **1.** *см.* **напра́виться**; **2.** *страд. от* **направля́ть**

напра́во *нареч.* **1.** (*куда*) уңга, уңга таба; **свернýть ~** уңга борылу **2.** (*где*) уңда, уң якта; ~ **шко́ла** уң якта мәктәп

напрактикова́ться *сов.* остарып китү, өйрәнеп җитү, тәжрибә туплау

напра́слин||а *ж разг.* нахак бәла, яла, хаксызга гаепләү; **возводи́ть ~у** хаксызга гаепләү (рәнҗетү)

напра́сно *нареч. и в знач. сказ.* юкка, бушка, әрәмгә, заяга, файдасызга; киреккәскә; **всё бы́ло ~** барысы да бушка гына булды

напра́сн||ый -ая, -ое **1.** файдасыз, файдасызга (әрәмгә, заяга) киткән, әрәмгә (юкка, бушка) китә торган; ~**ые стара́ния** файдасызга тырышулар **2.** урынсыз[ча], нигезсез, юкка; ~**ый страх** урынсызча курку

напра́шива||ться *несов.* **1.** *см.* **напроси́ться**; **2.** туу, килеп чыгу; уйга (башка) килү; **вы́воды ~ются са́ми собо́й** нәтижәләр үзеннән-үзе килеп чыга

наприме́р *вводн. сл.* мәсәлән; әйтик

напрока́зить *сов. прост. см.* **напрока́зничать**

напрока́зничать *сов. разг.* шуклыклар эшләп ташлау

напока́т *нареч.* [акча түләп] вакытлыча файдалануга, бераз вакытка (вакытлыча) файдаланып торырга

напролёт *нареч. разг.* буе, буенча, буена; **но́чи ~** төннәр буе; **все дни ~** көннәр буе

напроло́м *нареч. разг.* турыдан-туры, туп-туры, һичнәрсәгә карамастан, һичнәрсә белән исәпләшмичә ♦ **идти́ (рва́ться** *и т.п.*) ~ һичнәрсә белән исәпләшмичә алга бару

напропалу́ю *нареч. разг.* уйлап-нитеп тормастан, ни булса да булыр дип, беткән баш беткән дип

напроси́ться *сов. разг.* **1.** тагылу; ~ **в го́сти** кунакка барам дип тагылу **2.** *на что* әйттерү, әйтергә мәҗбүр итү; ~ **на комплиме́нт** үзенә комплимент әйттерү; ~ **на оскорбле́ния** үзеңне хурлату

напро́тив **1.** *предлог с род. п.* каршыда; ~ **до́ма** өй каршында **2.** *нареч.* каршыда, каршы якта; **он живёт ~** ул каршыда тора **3.** *частица противит.* (*совсем нет, наоборот*) киресенчә

на́прочь *нареч. прост.* бөтенләйгә

напру́живать *несов. см.* **напру́жить**

напру́живаться *несов.* **1.** *см.* **напру́житься**; **2.** *страд. от* **напру́живать**

напру́жить *сов. разг. см.* **напря́чь** 1

напру́житься *сов. разг. см.* **напря́чься**

напры́гаться *сов. разг.* туйганчы сикерү (сикеренү), сикереп (сикеренеп) тую

напры́скать *сов. что, чего, разг.* бөркү; ~ **духо́в на плато́к** яулыкка ислемай бөркү

напры́скивать *несов. см.* **напры́скать**

напряга́ть *несов. см.* **напря́чь**

напряга́ться *несов.* **1.** *см.* **напря́чься**; **2.** *страд. от* **напряга́ть**

напряже́ни||е *с* **1.** *см.* **напря́чь, напря́чься**; ~**е го́лоса** тавышны көчәйтү **2.** игътибар, дикъкать; **слу́шать с ~ем** игътибар белән тыңлау **3.** киренкелек; **твóрческое ~е** иҗади киренкелек **4.** *физ.* көчәнеш; **ток высо́кого ~я** югары көчәнешле ток

напряжённост||ь *ж в разн. знач.* киренкелек; ~**ь труда́** хезмәт киренкелеге; ~**ь внима́ния** игътибарның киренкелеге; **вну́тренняя ~ь** эчке киренкелек; **ослабле́ние междунаро́дной ~и** халыкара киренкелекнең йомшаруы

напряжённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **напря́чь**; **2.** киренке, тырыш; ~**ый**

труд киеренке хезмәт **3.** көчәнеп..., теләмичә..., теләр-теләмәс..., ясалма; **~ая улы́бка** теләмичә елмаю

напрями́к *нареч. разг.* **1.** турыга, турыдан, туп-туры; **иди́ ~** турыга бар **2.** *перен.* ачыктан-ачык, турыдан-туры, яшермичә; **сказа́ть ~** турыдан-туры әйтү

напря́чь *сов. что* **1.** киерү; **~ му́скулы** мускулларны киеру; **ве́тер напря́г паруса́** җил җилкәннәрне киерде **2.** көчәйтү, арттыру, тырышып эшләү (карау, тынлау *h.б.ш.*); **~ внима́ние** игътибарны көчәйтү; **~ зре́ние** тырышып карау; **~ па́мять** искә төшерергә тырышу; **~ си́лы** бөтен көчне кую; **~ слух** игътибар белән тыңлау, колакларны торгызу

напря́чься *сов.* **1.** киерелү; **мы́шцы напрягли́сь** мускуллар киерелде **2.** көчәнү; **~, поднима́я груз** йөк күтәргәндә көчәнү

напуга́ть *сов. кого-что* куркыту, өркетү; кот[ны] алу

напуга́ться *сов.* курку, өрку; кот алыну

напу́дривать *несов. см.* **напу́дрить**

напу́дриваться *несов.* **1.** *см.* **напу́дриться**; **2.** *страд. от* **напу́дривать**

напу́дрить *сов. кого-что* пудралау, кершән (пудра) ягу, пудра сөртү

напу́дриться *сов.* пудралану, кершән (пудра) ягыну, пудра сөртенү

напуска́ть *несов. см.* **напусти́ть**

напуска́ться *несов.* **1.** *см.* **напусти́ться**; **2.** *страд. от* **напуска́ть**

напускн||о́й, -а́я, -о́е ясалма, тышкы, күрсәтмә; **~о́е споко́йствие** ясалма тынычлык

напусти́ть *сов.* **1.** *что, кого-чего* [күп итеп] жибәрү, кертү, кертеп тутыру; **~ в зал наро́ду** залга халык кертеп тутыру **2.** *что, чего* [күп итеп] җибәрү, агызу, тутыру; **~ воды́ в бак** бакка су агызу; **~ ды́му в ко́мнату** бүлмәгә төтен тутыру **3.** *разг.* ... булып кылану, үзен ... итеп күрсәтү; **~ на себя́ стро́гость** таләпчән булып кылану **4.** *кого-что, разг.* өстерү, өстенә җибәрү; **~ соба́к на зве́ря** җәнлеккә этләрне өстерү ♦ **~ стра́ху** *на кого* курку салу; **~ [в глаза́] тума́ну** күзгә төтен җибәрү, күзгә көл сибү

напусти́ться *сов. на кого-что, разг.* өстенә ыргылу; кычкырынып (каты сүзләр әйтеп) ташлану

напу́тать *сов.* **1.** *что, чего* чуалту, чуалтып бетерү; **~ ни́ток** җепләрне чуалтып бетерү **2.** бутау, бутап (буташтырып) бетерү; хата җибәрү; **~ в дела́х** эшләрне бутап бетерү

напу́тствие *с* юл теләкләре (*юлга чыгучыга яки яңа эш башлап җибәручегә әйтелә торган сүзләр*)

напу́тствовать *сов., несов. кого-что* хәерле юл теләп калу; үгет-нәсихәтләр әйтеп озату; уңышлар теләү

напу́тывать *несов. см.* **напу́тать**

напуха́ть *несов. см.* **напу́хнуть**

напу́хнуть *сов. разг.* шешеп чыгу, кабару, кабарып чыгу

напы́житься *сов. разг.* **1.** (*напрячься*) көчәнү, бөтен көчне кую **2.** *перен.* (*принять важный вид*) кабарыну, кәпрәю, тәкәбберләнү

напыли́ть *сов. разг.* тузан чыгару (туздыру, очырту)

напы́щенный, -ая, -ое **1.** кукрайган, кәпрәйгән, һавалы; **~ вид** кукрайган кыяфәт **2.** күперенке; **~ стиль** күперенке стиль

напя́ливать *несов. см.* **напя́лить**

напя́ли||ть *сов.* **1.** *что на что, спец.* (*натянуть на пяльцы, раму*) киерү, тарту **2.** *что на кого-что, разг.* [тартып-сузып] кию, сыйдыру; **он е́ле ~л пиджа́к** ул пиджагын көчкә киде **3.** *что, прост.* кию, өстерлә кию (ямьсез, килешмәгән әйбер); **она́ ~ла жёлтую ко́фту** ул сары кофта өстенә кигән шунда

нараба́тывать *несов. см.* **нарабо́тать**

нараба́тываться *несов.* **1.** *см.* **нарабо́таться**; **2.** *страд. от* **нараба́тывать**

нараба́тывать *сов. что, чего, разг.* (*заработать*) [акча] эшләү, [акча] эшләп алу; **~ де́нег** акча эшләп алу

нарабо́таться *сов.* туйганчы эшләү; эшләп тую

наравне́ *нареч.* **1.** бертигез; бер үк югарылыкта (тирәнлектә *h.б.ш.*); **самолёт шёл ~ с облака́ми** самолёт болытлар белән бер үк югарылыкта оча иде **2.** бертигез, беррәттән, бер (үк) дәрәҗәдә; **рабо́тать ~ со взро́слыми** олылар белән бертигез эшләү

нара́доваться *сов. на кого-что и без доп.*: **не ~** карап, шатланып туя алмау, сөенеп туя алмау

нараспа́шку *нареч. разг.* җилбәгәй, төймәләмичә; **в пальто́ ~** пальтосын төймәләмичә

нараспе́в *нареч.* сузып-сузып, көйләп, көйләгәндәй итеп

нарастá||ть *несов.* **1.** *см.* **нарасти́**; **2.** арта бару, көчәя бару; **си́лы ~ют** көчләр арта бара; **зву́ки ~ют** тавышлар көчәя бара

нарасти́ *сов.* **1.** [өстенә] үсү, [өстенә] үсеп чыгу, [өстенә] үсеп каплау; **бы́ли бы ко́сти — мя́со нарастёт** *погов.* сөяге булса, [өстенә] ите үсәр; **на камня́х наро́с мох** ташлар өстенә мүк үскән **2.** [бик күп] үсү, үсеп чыгу; **наросло́ мно́го травы́** бик күп үлән үскән **3.** арту, үсү; **нароспи́ проце́нты** проценты арткан

нарасти́ть *сов.* **1.** *что, разг.* үстерү; **~ му́скулы** мускуллар үстерү **2.** *что* ялгап озынайту (озайту); **~ верёвку** бауны ялгап озынайту **3.** *перен. что* үстерү, арттыру; **~ темп** темпны арттыру; **~ мо́щности** көчләрне арттыру **4.** *что, чего, разг.* (*берникадәр*) үстерү; **~ усто́в** куаклар үстерү

нарасхва́т *нареч. разг.* тарткалашып, тарткалашып-йолыккалашып, бик тиз алып бетерү; **но́вая кни́га была́ ~** яңа китапны бик тиз алып бетерделәр

нара́щивание *с см.* **нарасти́ть**; **~ экономи́ческой мо́щи** икътисадый куәтне арттыру

нара́щивать *несов. см.* **нарасти́ть** 1-3

нарва́ть I *сов. что, чего* **1.** (*берникадәр*) өзү, өзеп җыю, йолку, йолкып җыю; **~ мно́го травы́** бик күп үлән йолкып җыю **2.** ерту, ерткалау; **~ бума́ги** кагазь ерткалау

нарва́||ть II *см.* эренләү, эрен җыю, үлекләү, үлек җыю, шешеп эренләү; **у меня́ па́лец ~л** бармагым эренләгән

нарва́ться *сов.* очрау, туры килү, тап булу, көтмәгәндә юлыгу, очрату, өстенә барып чыгу; **~ на неприя́теля** көтмәгәндә дошманны очрату

наре́з *м* кирт, киртек; сыр

наре́за||ть *сов.* **1.** *что, чего* (*берникадәр*) кисү, кисеп кую, турау, турап кую; **~ть хле́ба** ипи кисү; **~ть мя́са** ит турап кую **2.** *что, чего* (*берникадәр*) кисү, кисеп әзерләп кую; **~ть ве́ток** ботаклар кисеп әзерләп кую **3.** *что, чего* кисү, кисеп бирү, бүлеп бирү; **~ть уча́сток земли́** җир кисеп бирү **4.** *кого-чего* (*берникадәр*) сую, чалу; **~ть свине́й** дуңгызлар сую **5.** *что* киртләү, киртләп ясау, киртекләү, сырлау, сырлап ясау; **~ть винт** винт сырлау **6.** *что* кису; **ремни́ рюкзака́ ~ли пле́чи** рюкзакның каешлары иңбашларны кискән

нарезáть *несов. см.* **наре́зать**

наре́за||ться *сов.* киселү; **сыр то́нко ~лся** сыр юка киселгән

нарезáться *несов. см.* **наре́заться**

наре́зка *ж* **1.** *см.* **наре́зать**; **2.** *см.* **наре́з**; **винтова́я ~** винтсыман сыр; винт сыры

нарезно́й, -а́я, -о́е сырлы; **~ ствол** сырлы көпшә

наре́зывать *несов. см.* **наре́зать**

наре́зываться *несов. см.* **нарезáться**

нарека́ние *с* (*упрёк*) битәр; (*порицание*) шелтә, орышу, әрләү; (*обвинение*) гаепләү

нарека́ть *несов. см.* **наре́чь**

нарека́ться *несов.* **1.** *см.* **наре́чься**; **2.** *страд. от* **нарека́ть**

наре́чие I *с лингв.* шивә

наре́чие II *с грам.* рәвеш

наре́чь *сов. кого-что, уст.* исем кую (кушу, бирү), ат кую, атау

наре́чься *сов. уст.* үзенә исем алу, үзен атау

нарза́н *м* нарзан

нарисова́ть *сов. кого-что* **1.** рәсем (сүрәт) төшерү (төшереп кую), рәсем (сүрәт) ясау (ясап кую); **~ карикату́ру** карикатура ясау **2.** *перен.* (*образно описать*) тасвирлау, гәүдәләндерү, чагылдыру, сүрәтләү

нарица́тельн||ый, -ая, -ое: **и́мя ~ое** *грам.* күмәклек исем, уртаклык исем; **~ая сто́имость** *эк.* өстенә язылган бәя, күрсәтелгән хак (*акча яки кыйммәтле кәгазьләрнең өстенә язып куелган бәясе*)

нарко́з *м* наркоз; **дать ~** наркоз бирү

нарко́лог *м* нарколог, наркология белгече

наркологи́ческий, -ая, -ое: **~ кабине́т** наркология кабинеты

нарколо́гия *ж* наркология (*медицинаның наркотиклар куллануның нәтиҗәләрен һәм наркоманнарны дәвалауны өйрәнә торган булеге*)

наркома́н *м* наркоман; әфиюнчы (*уст.*)

наркома́ния *ж* наркомания (*наркотикларга һәвәслек*)

наркома́нка *ж* наркоман хатын (кыз); әфиюнчы хатын (кыз) (*уст.*)

нарко́тики *мн.* наркотик[лар] (*исертә яки башны томаландыра торган матдәләр — медицинада авыртуны басу өчен яки йокламыч дару буларак кулланыла*)

наркоти́ческ||ий, -ая, -ое наркотик, наркотик матдәләр алына торган; **~ие вещества́** наркотик матдәләр

наро́д *м в разн. знач.* халык; **сове́тский ~** совет халкы; **татарский ~** татар халкы; **трудово́й ~** хезмәт халкы; **на собра́нии бы́ло мно́го ~у** жыелышта бик күп халык булды

народи́ть *сов. кого-чего, разг.* (*куп яки бернич*) [бала] тудыру

народи́||ться *сов.* **1.** туу, туып үсү; **~лось молодо́е поколе́ние** яшь буын туып үсте **2.** *перен.* туу, барлыкка килү; **~лись но́вые о́трасли промы́шленности** промышленностьның яна тармаклары барлыкка килде

наро́дник *м ист.* народник, народниклык тарафдары, халыкчы

наро́дническ||ий, -ая, -ое *ист.* народниклык ...ы, халыкчылык ...ы; народниклар ...ы, халыкчылар ...ы; **~ие взгля́ды** народниклар карашлары

наро́дничество *с ист.* народниклык, халыкчылык

наро́дно-демократи́ческий, -ая, -ое халык-демократик; **~ строй** халык-демократик төзелеш

наро́дност||ь *ж* **1.** халык; **~и Се́вера** Төньяк халыклары **2.** (*национальная, народная самобытность*) халыкчанлык; **~ь поэ́зии Пу́шкина** Пүшкин поэзиясенең халыкчанлыгы

народнохозя́йственный, -ая, -ое халык хуҗалыгы ...ы; **~ план** халык хуҗалыгы планы

наро́дн||ый, -ая, -ое **1.** *в разн.. знач.* халык ...ы; **~ое тво́рчество** халык иҗаты; **~ое хозя́йство** халык хуҗалыгы; **~ый контро́ль** халык контроле; **~ый суд** халык суды; **~ый арти́ст респу́блики** республиканың халык артисты **2.** халыкчан; **поэ́зия Пу́шкина глубоко́ ~а** Пушкинның поэзиясе тирәнтен халыкчан ◆ **~ая дружи́на** халык дружинасы; **~ая демокра́тия** халык демократиясе

народовла́сти||е *с* халык хакимияте; **о́рганы ~я** халык хакимияте органнары

народово́лец *м ист.* народоволец (*«Народная воля» партиясе әгъзасы*)

народонаселе́ние *с* (*бер илдә яшәүче*) халык, бер ил халкы

нарожда́ться *несов. см.* **народи́ться**

наро́ст *м* **1.** катлам; **ледяны́е ~ы** боз катламнары **2.** утырма, юшкын; **на сте́нках котла́ образова́лся ~** казанның стеналарына юшкын утырган **3.** (*на растениях*) оры, үскен; (*на живых организмах*) шеш

нарочи́т||ый, -ая, -ое юри эшләнгән, ясалма; **~ое безрази́чие** ясалма ваемсызлык

наро́чно *нареч.* **1.** (*с целью*) юри, махсус; атап **2.** (*вопреки чему-л.; назло*) юри, ачу итеп **3.** *разг.* (*в шутку*) юри [генә], болай [гына], шаярып [кына], уйнап [кына]; **он ~ сказа́л, не оби́жа́йтесь** хәтерегез калмасын, ул уйнап кына әйтте ◆ **как (бу́дто, сло́вно, то́чно) ~** үч иткәндәй, әйтерсең[лә] юри

на́рочный *м* йомыш белән жибәрелгән кеше; атчабар (*аһәмиятле ашыгыч хәбәр яки йомыш белән җибәрелгән кеше*)

нарсу́д *м* халык суды

на́рты *мн.* (*ед.* **на́рта** *ж*) нарта (*болан яки этләр җигеп йөри торган чана*)

нарубать *несов. см.* **нарубить**

нарубить *сов. что, чего* **1.** (*бернидәр*) кисү, кисеп кую; **~ ве́ток** ботаклар кисү **2.** (*бернидәр*) турау, чабу, турап (чабып) кую; кисү, кисеп кую; **~ дров** утын кисеп кую

нару́жность *ж* **1.** (*внешность*) тышкы кыяфәт, килеш-килбәт; (*черты лица*) төс **2.** (*внешний вид*) тышкы күренеш, тышкы як

нару́жн||ый, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* тышкы **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* [тәнгә] сөртә торган дару

нару́жу *нареч.* тышка, тышкы якка, өскә, өске якка

нарука́вник *м* җиңсә, беләксә

нарука́вный, -ая, -ое җиңгә беркетелә торган, җиңгә [бәйләп] куела торган; **~ая повя́зка** җиңгә бәйләп куела торган тасма

нарумя́нивать *несов. см.* **нарумя́нить**

нарумя́ниваться *несов.* **1.** *см.* **нарумя́ниться**; **2.** *страд. от* **нарумя́нивать**

нарумя́нить *сов. что* **1.** (*вызвать румянец*) кызарту, алсуландыру **2.** (*покрыть румянами*) иннек ягу, иннек сөртү, иннек сөртеп алсуландыру

нарумя́ниться *сов.* иннек ягыну

нару́чники *мн.* кул богавы

нару́чн||ый, -ая, -ое кул ...ы; **~ые часы́** кул сәгате

наруша́ть *несов. см.* **нару́шить**

наруше́ние *с см.* **нару́шить**, **нару́шиться**; **~ дисципли́ны** тәртип бозу

наруши́тель *м* бозучы

наруши́тельница *ж* бозучы хатын (кыз)

нару́шить *сов. в разн. знач. что* бозу; **~ *чей-л.* поко́й** тынычлыкны бозу; **~ поря́док** тәртип бозу; **~ грани́цу** чикне бозу

нару́ши||ться *сов.* бозылу; **сон ~лся** йокы бозылды

нарци́сс *м* нәркис, суган гөле

на́ры *только мн.* нар; [ян]сәке

нарыв *м* чуан, эренле шеш, үлекле шеш

нарыва́ть I *несов. см.* **нары́ть**

нарыва́ть II *несов. см.* **нарва́ть** II

нарыва́ться *несов. см.* **нарва́ться**

нарывно́й, -а́я, -о́е: **~ пла́стырь** эрен (үлек) суырта торган пластырь

нары́ть *сов. что, чего* **1.** (*бернидәр*) казу, казып алу; **~ карто́феля** бәрәңге казып алу **2.** (*бернидәр*) казу, казып кую; **~ ям** чокырлар казу

наря́д I *м* (*одежда*) кием, киемсалым

наря́д II *м в разн. знач.* наряд; **~ на у́голь** ташкүмергә наряд; **~ мили́ции** милиция наряды; **еди́ный ~** бердәм наряд; **быть в ~е** *воен.* нарядта булу

наряди́ть I *сов. кого-что* **1.** киендерү; **~ кло́уном** клоун итеп киендерү **2.** кидерү, кигезү; **~ в шу́бу** тун кигезү **3.** бизәү; **~ ёлку** чыршы бизәү

наряди́ть II *сов. кого-что* (*назначить в наряд*) нарядка жибәрү (билгеләү)

наряди́ться *сов.* **1.** (*нарядно одеться*) матур (купшы) киенү; киенү-бизәнү **2.** *кем* киенү; **~ кло́уном** шамакай булып киенү **3.** кию; **~ в но́вый костю́м** яңа костюм кию

наря́дн||ый, -ая, -ое **1.** матур (купшы) киенгән; **~ые де́вушки** матур киенгән кызлар **2.** матур, купшы; **~ое пла́тье** матур күлмәк

наряду́ *нареч. с кем-чем* беррәттән, бергә; бертигез; **же́нщины рабо́тали ~ с мужчи́нами** хатын-кызлар ирләр белән беррәттән эшләделәр; **~ с э́тим** моның белән бергә

наря́дчик *м* нарядчы, нарядка жибәрүче, нарядка билгеләүче; эшкә жибәрүче

наряжа́ть I *несов. см.* **наряди́ть** I

наряжа́ть II *несов. см.* **наряди́ть** II

наряжа́ться *несов.* **1.** *см.* **наряди́ться**; **2.** *страд. от* **наряжа́ть** I

насади́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернидәр*) утырту; **~ сморо́дину (сморо́дины)** кара карлыган утырту **2.** *что* утырту, кую, саплау; **~ топо́р на топори́ще** балта саплау **3.** *кого-что, кого-чего* сугу, кигезү; **~ о́бруч на бо́чку** мичкәгә коршау кигезү; **~ нажи́вку на крючо́к** кармакка жим кигезү **4.** *см.* **насажда́ть**

насажа́ть *сов. см.* **насади́ть** I

насажда́ть *несов. что, книжн.* тарату, кертү, тамыр җәйдерү (*идея, белем, дин һ.б.ш. турында*)

насажде́ни||е *с* **1.** *см.* **насажда́ть**; **2.** *обычно мн.* **~я** утыртма, утыртылган агачлар

наса́живать *несов. см.* **насади́ть** 1-3

наса́живаться *несов. см.* **насе́сть** I

наса́ливать *несов. см.* **насоли́ть**

наса́сывать *несов. см.* **насоса́ть**

наса́сываться *несов.* **1.** *см.* **насоса́ть**-**ся**; **2.** *страд. от* **наса́сывать**

наса́харивать *несов. см.* **наса́харить**

наса́харить *сов. что* шикәрләү, шикәр сибү (салу)

насве́рливать *несов. см.* **насверли́ть**

насверли́ть *сов. что, чего* бораулап тишекләр тишү, бораулап тишеп чыгу

насвиста́ть, **насвисте́ть** *сов. что, разг.* (*передать свистом мелодию*) сызгыру, сызгырып көй чыгару, сызгырып көйләү

насви́стывать *несов. см.* **насвиста́ть**, **насвисте́ть**

насева́ть *несов. см.* **насе́ять**

наседа́ть *несов.* **1.** *см.* **насе́сть** 2, 3, 4; **2.** *на кого-что, разг.* (*теснить, наступая*) кысрыклау, кысу

насе́дка *ж* утыра торган тавык, утырган тавык

насека́ть *несов. см.* **насе́чь**

насеко́мое *с* бөҗәк

насекомоя́дный, -ая, -ое *бот., зоол.* бөҗәкләр белән тукланучы

населе́ние *с* халык; кешеләр; **~ го́рода** шәһәрнең халкы; **ме́стное ~** җирле халык

населённость *ж* (*билгеле бер территориядә яшәүче*) халыкның тыгызлыгы

населённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **насели́ть**; **2.** (*халык*) яши торган, (*халык*) утырган; күп кеше яши торган ♦ **~ пункт** торак пункт (*мәс. авыл, шәһәр һ.б.ш.*)

насели́ть *сов. что* **1.** (*занять жителями*) (*халык*) утырту, (*кешеләр*) урнаштыру **2.** (*поселившись, занять*) утыру, урнашу

населя́||ть *несов.* **1.** *см.* **насели́ть**; **2.** яшәү, тору; **Сре́днюю А́зию ~ют мно́гие наро́ды** Урта Азиядә күп төрле халыклар яши

насе́ст *м* кунача

насе́||сть *сов.* **1.** [бик күп] утыру, [бик күп] керү, кереп тулу; **в ло́дку ~ло мно́го люде́й** көймәгә бик күп кеше утырды **2.** куну, утыру; **~ла пыль** тузан утырган **3.** *на кого, разг.* (*навалиться*) яту, басу; бөтен көчкә эту **4.** *перен. на кого, разг.* (*с просьбами, требованиями*) кысу, бәйләну, ябышу

насе́чка *ж* **1.** *см.* **насе́чь** 1, 2; **2.** (*зарубка, нарезка*) кирт, сыр **3.** (*украшение*) бизәк, сыр

насе́чь *сов.* **1.** *что, чего* кирт салу, киртләү, киртләп (билге салып) чыгу; **~ ме́тки на брёвнах** бүрәнәләргә киртләп билгеләр салып чыгу **2.** *что* тешәү; **~ напи́льник** игәүне тешәү **3.** *что, чего* [вак кына итеп] тапау, тапап кую; **~ капу́сты** кәбестәне вак кына итеп тапап кую

насе́ять *сов. что, чего* **1.** (*бернекадәр*) чәчү; **~ пшени́цы** бодай чәчү **2.** (*просеять*) (*бернекадәр*) иләү, иләп күю

насиде́ть *сов. что* (*о птицах*) (*чебиләрне чыгарганчы*) басу, утыру, (*чебиләрне*) чыгару

насиде́ться *сов.* туйганчы утыру, утырып тую

наси́женн||ый, -ая, -ое: **~ое ме́сто** җылы урын (*озак вакытлар эшләп яки яшәп ияләнгән урын*); **~ое я́йцо** (*тавык һ.б.ш.*) баскан йомырка

наси́живать *несов. см.* **насиде́ть**

наси́лие *с* **1.** (*применение физической силы*) көчләү, көч куллану **2.** (*принуждение*) ирексезләү, мәҗбүр итү **3.** (*притеснение*) золым, җәбер, җәбер-золым

наси́ловать *несов.* **1.** *кого* көчләү; масхәрәләү **2.** *кого-что* җәбер итү, золым итү, җәберләү; ирексезләү; мәҗбүр итү; **~** *чью-л.* **во́лю** *берәүне* ирексезләү

наси́лу *нареч. разг.* көчкә, көч-хәл белән, читенлек белән

наси́льник *м* көчләүче, ирексезләүче; җәберләүче, залим

наси́льнический, -ая, -ое көчләп (ирексезлеп) эшләнгән

наси́льно *нареч.* көчләп, ирексезләп; акыртып, кычкыртып; **~ мил не бу́дешь** *погов.* ≈ күңелсезгә күлмәк кидермиләр

наси́льственн||ый, -ая, -ое көчләү ...ы, көчләүле, көчләп, көч кулланып (эшләнгән); мәҗбүри; **~ые ме́ры** көчләү чаралары; **~ым путём** көч кулланып ♦ **~ая сме́рть** үтерелү (*үз улеме белән үлмәү*)

наска́бливать *несов. см.* **наскобли́ть**

наказа́ть *сов. что, чего* күп сөйләү, күп сөйләп ташлау

наска́кивать *несов. см.* **наскочи́ть**

наска́льн||ый, -ая, -ое кыялар өстендәге, кыяларга төшерелгән; **~ые рису́нки** кыяларга төшерелгән рәсемнәр

наскандали́ть *сов.* гауга куптару, җәнҗал күтәрү, тавыш чыгару, дау кубару

насквозь *нареч.* **1.** үтәдән-үтә, үтәли; **проби́ть кры́шу ~** түбәне үтәли тишеп чыгу; **прогни́ть ~** үтәдән-үтә черү; **промо́кнуть ~** үтәдән-үтә чылану, манма су булу **2.** *перен. разг.* үтәдән-үтә, баштан-аяк, тулысынча, бөтенләй; **~ лжи́вое обеща́ние** үтәдән-үтә ялган вәгъдә ♦ **ви́деть (знать) ~** *кого берәүне* үтәдән-үтә күрү, үтәдән-үтә белү, бик яхшы күрү, бик яхшы белү

наскобли́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернекадәр*) кырү, кырып хәзерләп кую; **~ сыр (сы́ру)** сыр кыру **2.** *что* кыру, кырып юу; **~ поли́** идәнне кыру

наско́к *м* **1.** *разг.* (*налёт*) көтелмәгән һөҗүм, көтмәгәндә һөҗүм итү; **кавале́рийский ~** атлы гаскәр һөҗүме **2.** *перен.* (*грубый выпад*) тупас [рәвештә] бәйләну, ерынсызга бәйләну, тупас [рәвештә] ташлану ♦ **с ~а (~у)** алдан хәзерләнмичә, уйлап-нитеп тормыйча

наско́лько *нареч.* нихәтле, ни дәрәҗәдә, никадәр, ни чамада; ...ынча; **~ возмо́жно** мөмкин булганынча; **~ здесь лу́чше** ни дәрәҗәдә биредә яхшырак; **~ хва́тит сил** көч җиткәненчә; **~ я по́нял (понима́ю)** минем аңлавымча

на́скоро *нареч. разг.* тиз (генә), тиз-тиз [генә], ашыгычлык белән, ашыгып, ашык-пошык, ашыгыч кына; **~ пое́сть** ашык-пошык ашап алу

наскочи́ть *сов. на кого-что* **1.** (*йөгергәндә, йөзгәндә, сикергәндә һ. б.ш.*) барып бәрелү, килеп бәрелү; [өстенә] барып чыгу; **~ на столб** баганага килеп бәрелү **2.** (*напасть*) йөгереп (сикереп) килеп ташлану, көтмәгәндә һөҗүм итү **3.** *перен. разг.* бәйләну, тупас рәвештә бәйләну, [тупас сүзләр белән] ташлану; **~ с упрёками** шелтәләү

наскрести́ *сов. что, чего* **1.** (*бернекадәр*) кырып-себереп җыю, кырып җыеп алу; **~ муки́** [калдык-постык] онны кырып-себереп җыеп алу **2.** *перен.* (*бернекадәр*) кырып-себереп җыю, җыеп алу; **~ де́нег** кырып-себереп акча җыю

наску́чить *сов. кому и без доп., разг.* туйдыру, туйдырып бетерү, күңелне кайтару, ялыктыру, эч пошыру

наслади́ться *сов. кем-чем и без доп.* ләззәтләнү, ләззат табу, хозурлану, рәхәт табу, рәхәтләнү, кәефләнү

наслажда́ться *несов. см.* **наслади́ться**

наслажде́ние *с* рәхәт, рәхәтләнү, ләззәт, ләззәтләнү, хозур, хозурлык, хозурлану; **с ~м** ләззәт белән, ләззәтләнеп; хозурланып; **испы́тывать ~** хозурлану, ләззәтләнү

насла́ивать *несов. см.* **наслои́ть**

насла́иваться *несов.* **1.** *см.* **наслои́ться; 2.** *страд. от* **насла́ивать**

насла́ть *сов. что, кого-чего* [күп итеп] җибәрү

насле́дие *с* мирас; **иде́йное ~ революцио́нных демокра́тов** революцион демократларның идея мирасы

насле́дить *сов. чем и без доп., разг.* эз калдыру, таптап пычрату; **~ мо́крыми сапога́ми** юеш итекләр белән эз калдыру; **~ на полу́** идәнне таптап пычрату

насле́дник *м* **1.** варис, мирас алучы; **зако́нный ~** законлы варис **2.** *перен.* варис, дәвам иттерүче; **~ и культу́рных тради́ций** мәдәни традицияләрне дәвам иттерүчеләр

насле́дница *ж* варис хатын (кыз)

насле́дный, -ая, -ое тәхеткә утырырга тиешле; **~ принц** тәхеткә утырырга тиешле принц

насле́дова||ть *сов., несов. что* мирас итеп алу; **он ~л э́тот дом от отца́** бу йортны ул әтисеннән мирас итеп алган

насле́дственность *ж* нәселдәнлек, нәселдән булу, нәселдән килү, нәселдән-нәселгә күчү

насле́дственн||ый, -ая, -ое **1.** мирас ...ы, мираска калган, мирас итеп калдырылган; **~ое иму́щество** мирас итеп калдырылган мал **2.** нәселдән-нәселгә күчкән, нәселдән килгән, нәселдән килә торган, ата-бабадан калган (килгән, күчкән); **~ые черты́ хара́ктера** характерның нәселдән килгән үзенчәлекләре; **~ая боле́знь** нәселдән килгән авыру

насле́дств||о *с* мирас (*васыять итеп калдырылган мал*); **получи́ть в ~о** *кого-что* мирас итеп алу; **права́ ~а** *юр.* мирас итеп алу хокукы

наслое́ние *с* **1.** *см.* **наслои́ть, наслои́ться**; **~ гру́нта** грунтның катлам-катлам булып утыруы **2.** *геол.* катлам; **песча́ное ~** ком катламы **3.** *перен.* (*особенность, черта*) катлам, үзенчәлек (*культурада, характерда, аңда һ.б.ш.*)

наслои́ть *сов. что, чего* **1.** катлам-катлам итеп салу (кую); катламлау, катлам-катлам итеп өю; **~ те́сто** камырны катлам-катлам итеп салу **2.** (*бернича*) катларга бүлү (аеру), (*бернича*) катларга бүлгәләү (аергалау); катламнарга аеру; **~ слюды́** слюданы катламнарга аеру

наслои́ться *сов. на что* катлам-катлам булып утыру

наслу́шаться *сов. кого-чего* **1.** күп ишетү; **~ ра́зных расска́зов** күп төрле

хәбәрләр ишетү **2.** (*насладиться*) туйганчы тыңлау; тыңлап тую; **~ му́зыки** туйганчы музыка тыңлау

наслу́шиваться *несов. см.* **наслу́шаться**

наслы́шан *в знач. сказ. о ком-чём, разг.* ишетеп яхшы беләм; ишетү буенча беләм: **я о вас мно́го ~** мин сезне ишетеп яхшы беләм

наслы́шаться *сов. о ком-чём* күп ишетү

наслы́шк||а *ж*: **по ~е** ишетеп, ишетү буенча; **зна́ть по ~е** ишетеп белү

наслюни́ть *сов. что* селәгәйләү, селәгәйләп [пычратып] бетерү

насма́рку *нареч. разг.*: **идти́ (пойти́) ~** җилгә очу, җилгә китү, әрәмгә китү, бушка чыгу

на́смерть *нареч.*: **ра́нить ~** яралап үтерү; **испуга́ть ~** *прост.* котын алу, бик нык куркыту; **стоя́ть ~** җанын кызганмыйча каршы тору

насмеха́ться *несов. над кем-чем* мыскыллау, мыскыл итү, мыскыллап көлү, мыскыл итеп көлү, мәсхәрәләп көлү

насмеши́ть *сов. кого-что* көлдерү

насме́шк||а *ж* көлү, мәсхәрәләп көлү, мыскыл, мыскыл итү, мәсхәрә; **подве́ргать ~ам** мыскыл ителү; **сказа́ть** *что-л.* **в ~у** көлеп *берәр нәрсә* әйтү

насме́шлив||ый, -ая, -ое **1.** мыскыл итүчән, мыскыл итәргә яратучан, мәсхәрә итүчән, кешедән көләргә яратучан; **~ый челове́к** мыскыл итәргә яратучан кеше **2.** мәсхәрәле, мыскыллаучан; **~ая улы́бка** мәсхәрәле елмаю

насме́шник *м* мыскыл итүчән [кеше], мыскылларга яратучан [кеше], кешедән көләргә яратучан [кеше]

насме́шница *ж* кешедән көләргә яратучан хатын (кыз)

насмея́ться *сов.* **1.** *разг.* (*вдоволь посмеяться*) көлеп тую, туйганчы көлү **2.** *над кем-чем* [мәсхәрәләп] көлү, [мыскыллап] көлү; **~ над чы́ими-л. чу́вствами** *берәүнең* тойгыларыннан мәсхәрәләп көлү

на́сморк *м* томау

насмотре́||ться *сов.* **1.** *на кого-что* карап тую; **не могу́ ~ться на тебя́** сина карап туя алмыйм **2.** *кого-чего* күп күрү **~лся но́вых карти́н** бик күп яна картиналар күрү

насова́ть *сов. что, чего, разг.* тыгу, тутыру; **~ конфе́т в карма́ны** кесәләргә конфет тутыру

насове́товать *сов. что, чего, разг.* киңәшләр бирү

насо́вывать *несов. см.* **насова́ть**

насоли́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернигадәр*) тозлау, тозлап кую; **~ огурцо́в** кыяр тозлау **2.** *что, разг.* [кирәгеннән] артык тоз салу; **~ суп** ашка артык тоз салу **3.** *перен. кому-чему, разг.* канга тоз салу, ачу китерү, начарлык эшләү

насори́ть *сов.* чүпләү, чүпләп бетерү; **~ в ко́мнате** бүлмәне чүпләү

насо́с *м* насос; **поршнево́й ~** пешкәкле насос

насоса́ть *сов. см.* **накача́ть** I

насоса́ться *сов.* туйганчы имү, имеп тую

насочини́ть, насочиня́ть *сов. что, чего, разг.* ялган сөйләү, уйлап чыгару, уйдырмалар кору, үзеннән чыгарып сөйләү, юк-барны сөйләү (язу); **~ вся́кой чепухи́** төрле юк-бар сүзләр уйлап чыгару

насочи́ться *сов. разг.* тамып җыелу, саркып җыелу

на́спех *нареч.* ашыгып, ашык-пошык, тиз-тиз генә, ашыгычлык белән, ашыгыч кына, тиз арада; **де́лать ~** ашыгып эшләү; **~ пое́сть** ашык-пошык ашау

наспиртова́ть *сов. что* спиртлау, спирт сеңдерү

наспиртова́ться *сов.* спирт сеңдерү (сеңү)

наспирто́вывать *несов. см.* **наспиртова́ть**

наспирто́вываться *несов.* **1.** *см.* **наспиртова́ться**; **2.** *страд. от* **наспирто́вывать**

наспле́тничать *сов.* гайбәт сату (сөйләү)

наст *м* бозлавык, кар кабыгы (*җәпшек көннән соң кар өстенә катканда юка боз катламы*)

наставля́ть *несов. см.* **наста́ть**

настави́тельный, -ая, -ое үгетләү ...ы, нәсихәт (киңәш) бирү ... ы, вәгазьләү ...ы; **~ тон** үгетләү тоны

наста́вить I *сов.* **1.** *что, кого-чего* (*берникадәр*) тезү, тезеп чыгу (кую); **~ сту́льев** урындыклар тезү **2.** *что* ялгау, ялгап озынайту; **~ кусо́к тка́ни к рукаву́** җиңгә тукыма кисәге ялгау; **~ пла́тье** күлмәкне ялгап озынайту **3.** *что, разг.* төзәү, төбәү, юнәлтү; **~ ружьё** мылтык төзәү ♦ **~ рога́** *кому* мөгез кую (*иргә хыянәт итү*)

наста́вить II *сов. кого-что на что* үгетләү, үгет (нәсихәт, үгет-нәсихәт) бирү; вәгазьләү; **~ на ум** акыл бирү, акыл өйрәтү; **~ на и́стинный путь** *или* **на путь и́стины** дөрес юлга бастыру (кертү)

наста́вка *ж* **1.** *см.* **наста́вить** I 2; **2.** (*наставленная часть*) ялгау, ялганма

наставле́ние *с* **1.** *см.* **наста́вить** II; **2.** үгет, нәсихәт, үгет-нәсихәт, киңәш; вәгазь; **отцо́вское ~** ата үгет-нәсихәте **3.** (*инструкция*) кулланма

наставля́ть I *несов. см.* **наста́вить** I

наставля́ть II *несов. см.* **наста́вить** II

наста́вник *м* остаз; **~ молодёжи** яшьләрнең остазы ♦ **кла́ссный ~** класс тәрбиячесе (*революциягә кадәр гимназияләрдә, реальный училищеләрдә һ.б.ш.*)

наста́вница *ж* остаз хатын (кыз); тәрбияче хатын (кыз)

наста́внический, -ая, -ое үгетләү ..ы, үгет-нәсихәт бирү ...ы; өйрәтү ...ы; остазларча ..., остазларга хас булган; **~ тон** үгетләү тоны

наста́вничеств||о *с* остазлар ...ы; **движе́ние ~а** остазлар хәрәкәте; **шко́ла ~а** остазлар мәктәбе

наставн||о́й, -а́я, -о́е **1.** ялгаулы, ялгап озынайтылган, ялганмалы, **~ые рукава́** ялгап озынайтылган җиңнәр **2.** өстәмә; **~а́я труба́** өстәмә труба

наста́ивать I *несов. см.* **настоя́ть** I

наста́ивать II *несов. см.* **настоя́ть** II

наста́иваться *несов.* **1.** *см.* **настоя́ться** II; **2.** *страд. от* **наста́ивать** II

наста́||ть *сов.* җитү, килеп җитү; **~ло ле́то** җәй җитте; **~ла тишина́** тынлык урнашты

настега́ть I *сов.* **1.** *что на что* типчү, типчеп кую; **~ ва́ту на подкла́дку** мамыкны эчлеккә типчеп кую **2.** *что, чего* (*берникадәр*) сыру, сырып кую, сырып әзерләп кую; **~ одея́л** юрганнар сырып кую

настега́ть II *сов. кого-что, прост.* (*отхлестать*) камчылау, чыбыркылау, суктыру

настёгивать I *несов. см.* **настега́ть** I

настёгивать II *несов. см.* **настега́ть** II

на́стежь *нареч.* бөтенләй [ачык], шар [ачык], төбенә кадәр [ачык]; **две́ри ~** ишекләр бөтенләй ачык

настели́ть *сов. см.* **настла́ть**

насте́нный, -ая, -ое стена ...ы, стенага эленә (тагыла) торган; **~ календа́рь** стена календаре

настига́ть *несов. см.* **насти́чь, насти́гнуть**

насти́гнуть *сов. см.* **насти́чь**

насти́л *м* **1.** *см.* **настла́ть; ~ поло́в** идән җәю **2.** түшәмә; **деревя́нный ~** агач түшәмә; **бревёнчатый ~** бүрәнәдән эшләнгән түшәмә

настила́ть *несов. см.* **настла́ть**

насти́лка *ж см.* **насти́л**

настира́ть *сов. что, чего, разг.* (*берникадәр кер*) юу, уу, юып (уып) кую, [керләр] юу (уу), [керләр] юып (уып) кую

насти́рывать *несов. см.* **настира́ть**

насти́чь *сов. кого-что* куып җитү

настла́ть *сов.* **1.** *что* җәю, түшәү; **~ пол** идән җәю; **~ парке́т** паркет түшәү **2.** *что, чего* (*берникадәр*) җәю, җәеп чыгу (кую); түшәү, түшәп чыгу (кую); **~ досо́к** такта түшәү

насто́й *м* тәнәтмә; **~ рома́шки** ромашка тәнәтмәсе; **~ кре́пкого ча́я** куе чәй

насто́йка *ж* **1.** *см.* **насто́й**; **2.** тәнәтмә (*эчемлек*)

насто́йчивость *ж* үз дигәнендә ныклык тору[чанлык], үзсүзлелек, әйткәненнән ныклык тору[чанлык], үз дигәнен булдыру

насто́йчив||ый, -ая, -ое **1.** үз дигәнендә ныклык торучан, үз дигәнен булдыручан, үзсүзле, әйткәненнән ныклык торучан; ныклык; **~ый па́рень** үз дигәнен булдыручан егет **2.** катгый, каты, категорик; ныгытып ..., бик ялыныпъ; **~ая про́сьба** бик ялыныпъ сорау; **~ое тре́бование** катгый таләп

насто́лько *нареч.* шул кадәр, шул хәтле, шул дәрәҗәдә; **не насто́лько, ... что́бы** дәрәҗәдә үк ... түгел; **он не ~ умён, что́бы поня́ть э́то** ул моны аңарлык дәрәҗәдә үк акыллы түгел; **~-то** ул кадәр генә; **~-то я и сам понима́ю по-францу́зски** ул кадәр генә мин үзем дә французча аңлыйм

насто́льн||ый, -ая, -ое **1.** өстәл ...ы: өстәлгә куела торган; **~ая ла́мпа** өстәл лампасы **2.** *перен.* кулланма..., һәрвакыт кирәк була торган; **~ая кни́га** кулланма китап ♦ **~ый те́ннис** өстәл теннисы

настора́живать *несов. см.* **насторожи́ть**

настора́живаться *несов. см.* **насторожи́ться**

настороже́ *нареч.* сагаеп, сак, әсәреп; **быть ~** сак булу

насторо́женность, настороже́нность *ж* сагаю, әсәрү

насторо́женный, -ая, -ое, **настороже́нный,** -ая, -ое сагайган; сагаеп...; **~ взгляд** сагаеп карау; **~ вид** сагайган кыяфәт

насторожи́ть *сов. кого-что* сагайту, сак (игъгибарлы) булырга мәҗбүр итү ♦ **~ внима́ние** игътибарны көчәйтү, игътибар белән тыныл башлау; **~ у́ши (слух)** колакларны торгызу

насторожи́ться *сов.* сагаю, әсәрү; колак торгызу, игътибарны көчәйтү, игътибар белән тыныл башлау

настоя́ние *с* катгый таләп, катгый үтенеч

настоя́тель *м* **1.** монастырь башлыгы (*ирләр монастыре башлыгы*) **2.** өлкән поп (*чиркәүдә*)

настоя́тельница *ж* монастырь башлыгы (*хатын-кызлар монастыре башлыгы*)

настоя́тельн||ый, -ая, -ое **1.** катгый, таләпчән, бик нык, ныклап ...; **~ая про́сьба** бик нык үтенү **2.** котылгысыз, бик мөһим, бик зур; **~ая необходи́мость** котылгысыз зарурлык

настоя́ть I *сов. на чём* үз дигәнендә (сүзендә) тору, үзенекен итү, ...дертү; **~ на своём** үзенекен итү

настоя́ть II *сов. что на чём* төнәтү; **~ во́дку на ви́шне** аракыны чия салып төнәтү

настоя́ться I *сов.* (*долго простоять*) озак вакыт басып тору; басып торып ару

настоя́ться II *сов.* чыгу, чыгып житу; төнәү, төнәп житу; **чай хорошо́ ~лся** чәй яхшы чыккан; **во́дка ~лась** аракы төнәп җиткән

настоя́щ||ий, -ая, -ее **1.** хәзерге; **в ~ее вре́мя** хәзерге вакытта, хәзерге көндә, хәзер; **до ~его вре́мени** хәзергә кадәр **2.** *в знач. сущ.* **~ее** *с* бүгенге көн; **жить ~им** бүгенге көн белән яшәү **3. в ~ей статье́ речь идёт о ...** бу мәкаләдә сүз ... турында бара **4.** чын, чын мәгънәдә ...; **~ий челове́к** чын кеше; **он ~ий учёный** ул чын галим ♦ **~ее вре́мя** *грам.* хәзерге заман; **~им о́бразом** чынлап, чын-чынлап, житди рәвештә; **по- ~ему** тиешенчә, чынлап, чын-чынлап

настра́гивать *несов. см.* **настрога́ть**

настрада́ться *сов.* бик күп җәфа (газап) чигү, бик интегү; күп кайгы-хәсрәт чигү

настра́ивать I *несов. см.* **настро́ить** I

настра́ивать II *несов. см.* **настро́ить** II

настра́иваться *несов.* **1.** *см.* **настро́иться; 2.** *страд. от* **настра́ивать** II

настра́чивать *несов. см.* **настрочи́ть**

настре́ливать *несов. см.* **настрели́ть**

настрели́ть *сов. что, кого-чего* (*бернакадәр*) ату, атып алу; **~ ди́чи** киек кошлар ату

на́стриг *м*: **~ ше́рсти** кыркылган йон (йонның микъдары)

настрига́ть *несов. см.* **настри́чь**

настри́чь *сов. что, чего* (*бернакадәр*) кырку, кыркып алу; **~ килогра́мм ше́рсти** бер килограмм йон кыркып алу

настрога́ть *сов. что, чего* (*бернакадәр*) ышкылап (струклап) кую, ышкылап (струклап) әзерләп кую

на́строго *нареч. разг.* каты итеп, катгый рәвештә

настрое́ни||е *с* **1.** кәеф, күңел, рух; **припо́днятое ~е** күтәренке күңел; **испо́ртить ~е** *кому-л.* кәефен бозу; **не в ~и** кәефе бозылган; **привести́ в хоро́шее ~е** *кого-л.* кәефен күтәрү **2.** настроение; рух; **~е общественности** җәмәгатьчелекнең рухы **3.** *с неопр.* теләк; **нет у меня́ ~я игра́ть** уйнарга теләгем юк, уйныйсым килми ♦ **челове́к ~я** настроение кешесе

настро́енность *ж* рух

настро́ить I *сов. что, чего* [бик күп] төзү, салу; **~ дома́ (домо́в)** бик күп йортлар салу

настро́ить II *сов. что* **1.** көйләү, көйгә салу; **~ить гита́ру** гитараны көйләү **2.** көйләү, көйгә салу, җайлау, җайга салу, җайга салып җибәрү, рәтләү; **~ить стано́к** станокны җайлау **3.** кору, корып җибәрү, көйләү; **~ить радиоприёмник** радиоалгычны көйләү **4.** (*берәр төрле*) хис туу, барлыкка килү; (*берәр төрле*) хискә бирелү; **он был ~ен про́тив меня́** ул миңа каршы иде; **он был ~ен дру́жески** аңарда дуслык хисе туган иде

настро́и||ться *сов.* **1.** корылу, көйләнү; җайлану; **роя́ль ~лся** рояль көйләнде **2.** (*берәр төрле*) хис туу (барлыкка килү); (*берәр төрле*) хискә бирелү; **~ться про́тив** *кого-л. берәүгә каршы* дошманлык хисе туу **3.** *с неопр., на что* (*берәр нәрсә*) эшләргә теләк (ният) туу, ниятләнү; **он ~лся бы́ло поговори́ть** ул сөйләшергә ниятләнгән генә иде

настро́йщик *м* көйләүче, көйгә салучы; төзәтүче; **~ роя́лей** рояльләр көйләүче

настрочи́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернакадәр*) каю, каеп чыгу; **~ воротнико́в** якалар каю **2.** *перен. что, чего, разг.* тиз-тиз генә язып ташлау, тиз-тиз генә сызгалау (сызгалап ташлау); **~ письмо́** тиз-тиз генә хат сызгалап ташлау

настря́пать *сов. что, чего* [куп итеп] пешереп кую, пешереп әзерләп кую, пешерену

настуди́ть *сов. что, прост.* бик нык суыту, суытып бетерү; **~ ко́мнату** бүлмәне бик нык суыту

насту́живать *несов. см.* **насту́дить**

наступа́тельный, -ая, -ое һөҗүм ...ы, һөҗүмле, һөҗүмчән; **~ бой** һөҗүм сугышы

наступа́ть I *несов.* **1.** *см.* **наступи́ть** I; **2.** һөҗүм итү, алга бару

наступа́||ть II *несов.* житу, житеп килү; башлану; **~ет весна́** яз житеп килә

наступи́ I *сов. на кого-что* басу; өстенә басу; **~ на лягу́шку** бакага басу; **~ на́ ногу** *кому* аягына басу ♦ **~ на любимую мозо́ль** авырткан җиргә кагылу; **~ на хвост** *кому* ≈ үкчәсенә басу

наступи́||ть II *сов.* житу, килеп житу; башлану, башланып китү; **~л ве́чер** кич житте; **~ла зима́** кыш житте; **~ли холода́** салкыннар башланды; **~л день** көн туды; **~ла темнота́** караңгы төште; **~ла тишина́** тынлык урнашты

наступле́ние I *с прям., перен.* һөҗүм, һөҗүм итү; **~ войск** гаскәрләрнең һөҗүме; **~ на А́рктику** Арктикага һөҗүм итү

наступле́ние II *с см.* **наступи́ть** II; **с ~ем ле́та** җәй житу белән; **с ~м темноты́** караңгы төшү белән; **с ~м у́тра** иртә белән; **с ~м холодо́в** салкыннар башлану белән

насту́рция *ж* латин чәчәге, настурция

настыва́ть *несов. см.* **насты́ть**

насты́||ть *сов. разг.* **1.** (*стать холодным*) суыну; **ко́мната ~ла за́ ночь** бүлмә төн эчендә суынган **2.** (*примёрзнуть*) кату; **на поро́ге ~л лёд** бусагага боз каткан

насу́пить *сов. что*: **~ бро́ви** каш жыеру (жимерү)

насу́пи||ться *сов.* **1.** [каш] жыеру; [каш] жимерү; **бро́ви его́ ~лись** аның кашлары жыерылды **2.** каш жыеру, чырай сыту; **он сиде́л ~вшись** кашларын жыерып утыра иде

насу́пленный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **насу́пить; 2.** (*о бровях*) жыерылган **3.** (*насупившийся*) кашларын жыерган; күңелсез; кырыс

насу́пливать *несов. см.* **насу́пить**

насу́пливаться *несов. см.* **насу́питься**

насурьми́ть *сов. что* сөрмә тарту, сөрмәләү

насурьми́ться *сов.* сөрмә тарту

на́сухо *нареч.* коп-коры итеп, коп-коры булганчы, корытканчы

насу́чивать *несов. см.* **насучи́ть**

насучи́ть *сов. что, чего* [жепне] катып әзерләп кую, чиратып әзерләп кую; **~ ни́ток** жеп катып әзерләп кую

насу́шивать *несов. см.* **насуши́ть**

насуши́ть *сов. что, чего* (*бернакадәр*) киптерү, киптереп кую, киптереп әзерләп кую; **~ грибо́в** гөмбә киптереп кую

насу́щность *ж* әһәмиятлелек, тормыш өчен әһәмиятле булу, әһәмияте зур булу, әһәмияткә ия булу; **~ зада́ч** бурычларның әһәмиятлелеге

насу́щн||ый, -ая, -ое бик мөһим, бик әһәмиятле, бик кирәкле, тормыш өчен әһәмиятле (әһәмияте зур булган), әһәмияткә ия булган; **~ая потре́бность** бик мөһим ихтыяж

насчёт *предлог с род. п. разг.* турында, хакында; **говори́ть ~ рабо́ты** эш турында сөйләү

насчита́ть *сов. что* санап чыгару; **~ бо́лее десяти́ оши́бок** уннан артык хата санап чыгару

насчи́тыва||ть *несов.* **1.** *см.* **насчита́ть; 2.** саналу, исәпләнү, бар булу; **строй-**

отря́д ~ ет не́сколько со́тен бойцо́в төзелеш отрядында берничә йөз гаскәри бар

насчи́тыва||ться *несов.* саналу, булу; бар [булу]; **в райо́не ~ются деся́тки школ** районда дистәләрчә мәктәп бар

насыла́ть *несов. см.* **насла́ть**

насы́пать *сов.* **1.** *что, чего* салу, тутыру, салып кую, тутырып кую; **~ крупы́** ярма салу; **~ три мешка́ муки́** өч капчык он салып кую **2.** *что, чего* (*рассыпать*) чәчү, чәчеп җибәрү; кою **3.** *что, чего* сибү, сибеп чыгу; **~ песо́к (песку́) на доро́гу** юлга ком сибеп чыгу **4.** *что* өю, өеп кую; **~ курга́н** курган өю

насыпа́ть *несов. см.* **насы́пать**

насы́па||ться *сов.* коелу, коелып төшү; **~лось мно́го сне́га** бик күп кар коелган

насыпа́ться *несов.* **1.** *см.* **насы́паться; 2.** *страд. от* **насыпа́ть**

насы́пн||о́й, -а́я, -о́е өеп ясалган; **~а́я плоти́на** өеп ясалган буа

на́сыпь *ж* **1.** насыпь, өем; **железнодоро́жная ~** тимер юл насыпе **2.** *в знач. нареч.* **~ю** чәчелгән хәлдә, тәрәгә (*капчык, тартма һ.б.ш.*) салмыйча; **у́голь перево́зят ~ю** ташкүмерне тәрәгә салмыйча ташыйлар

насы́тить *сов.* **1.** *кого-что* туйганчы ашату **2.** *что, хим.* туендыру; **~ раство́р** эремәне туендыру

насы́ти||ться *сов.* **1.** (*наесться досыта*) туйганчы ашау; туклану **2.** *перен.* (*вполне удовлетвориться*) канәгатьләнү **3.** тулу, туену; **земля́ ~ вла́гой** җир дымга туенган

насыща́ть *несов. см.* **насы́тить**

насыща́ться *несов.* **1.** *см.* **насы́ститься; 2.** *страд. от* **насыща́ть**

насы́щенност||ь *ж хим.* туендырылганлык, туендырылу, куелык; **сте́пень ~и раство́ра** эремәнең туендырылу дәрәҗәсе

насы́щенный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **насы́тить; 2.** *хим.* туендырылган, куе; **~ раство́р** туендырылган эремә **3.** *перен.* (*содержательный, богатый*) бай, тулы, бай эчтәлекле; сугарылган

ната́лкивать *несов. см.* **натолкну́ть**

ната́лкиваться *несов.* **1.** *см.* **натолкну́ться; 2.** *страд. от* **ната́лкивать**

ната́пливать I *несов. см.* **натопи́ть** I

ната́пливать II *несов. см.* **натопи́ть** II

ната́пливаться I *несов.* **1.** *см.* **натопи́ться** I; **2.** *страд. от* **ната́пливать** I

ната́пливаться II *несов.* **1.** *см.* **натопи́ться** II; **2.** *страд. от* **ната́пливать** II

ната́птывать *несов. см.* **натопта́ть**

натаска́ть I *сов.* **1.** *что, кого-чего* (*берникадәр*) ташу, ташып кую; **~ дров** утын ташып кую **2.** *перен. что, чего, разг.* (*берничә чыганактан, китаптан һ.б.ш.*) йолкып алу, йолыккалау; **~ цита́т** (*берничә китаптан*) цитаталар йолкып алу **3.** *что, кого-чего, разг.* (*украсть*) урлап ташу

натаска́ть II *сов. кого-что* **1.** *охот.* (*собаку*) җәнлек ауларга өйрәтү, ауга өйрәтү **2.** *разг.* өстән-өстән [генә] әзерләү; **~ ученико́в к экза́мену** укучыларны имтиханга өстән-өстән әзерләү

ната́скивать I *несов. см.* **наташи́ть**

ната́скивать II *несов. см.* **ната́скать** II

наташи́ть *сов.* **1.** *что, кого-чего* ташу, ташып кую; китерү; **~ гли́ны и песку́** балчык һәм ком ташып кую **2.** *что, разг.* тартып ябыну; **~ на себя́ одея́ло** юрганны тартып ябыну

ната́я||ть *сов.* **1.** *что, чего* (*бернидәр*) эретү; **~ть сне́гу** кар эретү **2.** *безл.* эрү; **~ло мно́го сне́гу** бик күп кар эрегән

натвори́ть I *сов. что, чего, разг.* эшләп ташлау; **~ вся́ких глу́постей** төрле ахмаклыклар эшләп ташлау

натвори́ть II *сов. что, чего, спец.* (*бернидәр*) изү, изеп кую; **~ мно́го те́ста** бик күп камыр изү

на́те *частица разг.* мәгез ◆ **~ вам** менә сиңа кирәк булса

натёк *м* **1.** *геол.* утырма, җыелма **2.** агып (саркып) чыккан, агып (саркып) җыелган; **~ смолы́ на сосне́** нарат агачыннан агып чыккан сагыз катламы

натека́ть *несов. см.* **нате́чь**

нате́льн||ый, -ая, -ое эчке; **~ое бельё** эчке күлмәк-ыштан

натереби́ть *сов. что, чего, с.-х.* (*бернидәр*) йолку, йолкып әзерләп кую; **~ льна** җитен йолку

натере́ть *сов.* **1.** *что, чем* сөртү, сөртеп кую; уу, ышку; **~ ру́ки кре́мом** кулларга крем сөртү; **~ спи́ну скипида́ром** арканы скипидар белән уу **2.** *что* ышкып ялтырату; **~ поль́і** идәнне ышкып ялтырату **3.** *что* (*причинить боль*) суйдыру, кабарту, чиләтү **4.** *что, чего* (*на тёрке*) кыру, кырып кую

натере́ться *сов. чем, разг.* сөртенү, уыну

натерпе́ться *сов. чего, разг.* бик күп газап (җәфа) чигү, бик интегү; **~ стра́ху** бик ныклы курку, кот алыну

натеса́ть *сов. что, чего* (*бернидәр*) юну, юнып кую, юнып әзерләп кую

натёсывать *несов. см.* **натеса́ть**

нате́чь *сов.* сарку, саркып җыелу, агып җыелу

нате́шиться *сов. разг.* туйганчы уйнау, күңел ачу, туйганчы шаяру

натира́ть *несов. см.* **натере́ть**

натира́ться *несов.* **1.** *см.* **натере́ться; 2.** *страд. от* **натира́ть**

на́тиск *м* һөҗүм; кысрыклау, кысу

нати́скать *сов. что, чего, разг.* дыңгычлап тутыру, басып тутыру, тыгызлап тутыру; **~ вещёй в рюкза́к** рюкзакка дыңгычлап әйбер тутыру

нати́скивать *несов. см.* **нати́скать**

натка́ть *сов. что, чего* (*бернидәр*) туку, сугу, тукып (сугып) кую, тукып (сугып) әзерләп кую; **~ полотна́** киндер сугу

наткну́ть *сов. кого-что* чәнчеп кую, кадап кую; кигезеп кую, кидереп кую; **~ ба́бочку на була́вку** күбәләкне булавка белән кадап кую

наткну́ться *сов. разг.* **1.** *на что* барып кадалу, барып чәнчелү; **~ на гвоздь** кадакка барып кадалу **2.** *на кого-что* барып (килеп) төртелү, барып (килеп) бәрелү; **~ на столб** баганага барып бәрелү **3.** *перен. на что, разг.* [көтмәгәндә] очрау, туры килү, тап булу; **~ на заса́ду** засадага очрау

натолкну́ть *сов.* **1.** *кого-что на кого-что, разг.* бәрдерү, китереп бәрү; **~ ло́дку на мель** этә-этә көймәне сайлыкка утыртү **2.** *кого-что на что* (*навести на мысль, идею и т. п.*) фикергә китерү, фикер (идея) тудыру, фикер (идея) тууга ярдәм итү

натолкну́ться *сов. см.* **наткну́ться** 2, 3

натоло́чь *сов. что, чего* (*бернидәр*) төеп кую, төеп әзерләп кую

натопи́ть I *сов. что* ягып җылыту, ягып кыздыру; **~ ко́мнату** бүлмәне ягып җылыту

натопи́ть II *сов. что, чего* **1.** (*бернидәр*) эретеп кую, эретеп әзерләп кую; **~ ма́сла** май эретеп кую **2.** (*бернидәр*) кайнату, кайнатып кую; **~ молока́** сөт кайнатып кую

натопи́||ться I *сов. разг.* яхшы кызу; **пе́чка ~лась** мич яхшы кызды

натопи́||ться II *сов. разг.* эрү, [эреп] чыгу; **~лось мно́го жи́ру** туңмай күп чыккан; **из сне́га ~лось ведро́ воды́** кардан бер чиләк су эрегән

натопта́ть *сов. разг.* **1.** *чем и без доп.* (*нагрязнить*) таптап пычратып бетерү **2.** *что* (*проторить*) йөри-йөри юл (сукмак) салу, таптап йөреп юл салу

наторгова́ть *сов. разг.* **1.** *что, чего* (*выручить от торговли*) сәүдә итеп (*бернидәр*) акча табу **2.** *на что ...* сумлык сату, сату итү; **~ на две́сти рубле́й** ике йөз сумлык сату итү

наточи́ть *сов. что, чего* чарлау, кайрау, үткенләү, чарлап (кайрап, үткенләп) кую; (*косу*) янау, янап кую

натощак *нареч.* ач карынга, ач килеш

натр *м уст. хим.* натр

натрави́ть *сов.* **1.** *кого-что на кого-что* өстерү; **~ соба́ку на за́йца** этне куянга өстерү **2.** *перен. кого-что на кого-что, разг.* (*подстрекнуть*) өстерү, котырту **3.** *кого* (*бернидәр*) агулап үтерү, агулап үтереп бетерү, кырып бетерү; **~ тарака́нов** тараканнарны агулап үтереп бетерү **4.** *что, чего, спец.* (*вытравить*) рәсем төшерү (*мәс. кислота белән*)

натра́вливать *несов. см.* **натрави́ть**

натравля́ть *несов. см.* **натрави́ть** 4

натрениро́ванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **натренирова́ть; 2.** яхшы күнеккән, күнегеп (өйрәнеп) җиткән; **~ спортсме́н** яхшы күнеккән спортсмен

натренирова́ть *сов. кого-что* күнектереп (өйрәтеп) җиткерү

натренирова́ться *сов.* күнегеп (өйрәнеп) җиту

на́трий *м хим.* натрий

на́трое *нареч.* өчкә, өч кисәккә, өч өлешкә

натруди́ть *сов. что, разг.* ардыру, арыту, ялыктыру, талчыктыру, авыртыру (*озак яки авыр эш эшләп*); **~ ру́ки** кулларны талчыктыру

натруди́ться *сов. разг.* **1.** (*утомиться*) ару, талчыгу, талу, ялыгу, авырту (*озак*

яки авыр эшләүдән) **2.** (*вдоволь поработать*) туйганчы эшләү, җитәрлек эшләү

натру́живать *несов. см.* **натруди́ть**

натруси́ть *сов. что, чего, прост.* [селкеп] кою, [селкеп] төшерү, [кагып] төшерү

натрясти́ *сов. что, чего* [селкеп] кою, [селкеп] төшерү, [кагып] төшерү; **~ опи́лок на́ пол** идәнгә пычкы чүбе кою

натряс||ти́сь *сов. разг.* **1.** бик нык селкетү, дыңгырдату; **~ти́сь в доро́ге** юлда бик нык селкетү **2.** (*бик нык яки озак вакыт*) калтырау, калтырап тору; **~ти́сь от стра́ха** куркудан бик озак калтырап тору; **~ти́сь на моро́зе** салкында озак вакыт калтырап тору **3.** коелу, селкенеп коелу; **~ло́сь мно́го пы́ли** бик күп тузан коелган; **~ло́сь мно́го груш** бик күп груша коелган

нату́г||а *ж разг.* көчәнү; **рабо́тать без ~и** көчәнмичә эшләү; **кра́сный от ~и** көчәнүдән кып-кызыл (булган); **с ~ой** көчәнеп, кыенлык белән

на́туго *нареч. разг.* бик нык кысып, бик нык тартып, тыгызлап

нату́живать *см.* **нату́жить**

нату́живаться *несов. см.* **нату́житься**

нату́жить *сов. что, разг.* киерү; **~ му́скулы** мускулларны киерү

нату́житься *сов. разг.* көчәнү, киерелү

нату́жный, -ая, -ое *разг.* көчәнеп..., көчәнүле; **~ ка́шель** көчәнүле ютәл

натýр||а *ж* **1.** (*характер, нрав*) табигать, холык **2.** *иск.* (*живой образец*) натура, табигый үрнәк **3.** *кино* табигый шартлар (*павильон түгел*); **снять фильм на ~е** фильмны табигый шартларда төшерү **4.** *эк.* натура; **плати́ть ~ой** натуралата түләү **5.** *уст.* (*природа*) табигать

натурализа́ция *ж* натурализация (*чит ил кешесенә гражданлык хокукы бирү яки чит ил гражданлыгын кабул итү*)

натурали́зм *м* натурализм (*әдәбияттә һәм сәнгатьтә төшенкелеккә бирелүнең нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән һәм чынбарлыкны, идея ягына игътибар итмичә, тышкы яктан гына төгәл тасвирларга омтыла торган юнәлеш*)

натурализова́ть *сов., несов. кого-что* [чит ил кешесенә] гражданлык хокукы бирү

натурализова́ться *сов., несов.* [чит ил] гражданлыгын кабул итү

натурали́ст *м* **1.** (*естествоиспытатель*) натуралист, табигатьне өйрәнүче **2.** (*последователь натурализма*) натурализм тарафдары

натурали́стическ||ий, -ая, -ое **1.** натурализм ...ы; **~ое направле́ние в жи́вописи** рәсем сәнгатендә натурализм юнәлеше **2.** (*с бытовыми деталями*) натуралистик

натура́льн||ый, -ая, -ое **1.** табигый, чын; **~ый мёд** чын бал; **~ый шёлк** чын ефәк; **~ый цвет** табигый төс **2.** табигый; **портре́т в ~ую величину́** табигый зурлыктагы портрет **3.** *эк.* натуралата түләнә торган, натураль (*акчалата түгел*); **~ый нало́г** натуралата түләнә торган салым **4.** *уст.* табигать белеме ...ы; **~ая исто́рия** табигать белеме тарихы ◆ **~ое хозя́йство** натураль хуҗалык

натýрн||ый, -ая, -ое: **~ый класс** *иск.* натурадан төшерү классы; **~ая съёмка** *кино* табигый шартларда [фильм] төшерү

натурпла́та *ж* натуралата түләү

натурфилосо́фия *ж* натурфилософия (*табигатьне бер бөтен итеп карап, аны коры акылга гына нигезләнеп аңлату; табигать философиясе*)

нату́рщик *м* натурщик

нату́рщица *ж* натурщица

наты́кать *сов. что, чего, разг.* (*бернидәр*) кадап кую, кадап чыгу

наты́кать *несов.* **1.** *см.* **наты́кать; 2.** *см.* **наткну́ть**

наты́каться *несов. см.* **наткну́ться**

натюрмо́рт *м иск.* натюрморт

натя́гивать *несов. см.* **натяну́ть**

натя́гиваться *несов.* **1.** *см.* **натяну́ться; 2.** *страд. от* **натя́гивать**

натяже́ние *с* **1.** *см.* **натяну́ть, натяну́ться; ~ струн** кыллар тарту; **~ ве́рёвки** бау тарту **2.** *мед.* (*раны*) каплану, тартылу, бетәшү

натя́жк||а *ж* **1.** *см.* **натяну́ть, натяну́ться; ~ шин** шиннар тарттыру **2.** тарту-сузу; **поста́вить с ~ой тро́йку** тартып-сузып өчле билгесе кую

натяжн||о́й, -а́я, -о́е тартып (тартырып) киертелә (кидерелә) торган; **~ы́е ши́ны** тарттырып киертелә торган шиннар

натя́нутость *ж* киеренкелек; ясалмалылык

натя́нут||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **натяну́ть; 2.** киеренке, тартынкы; ясалма; **~ые отноше́ния** киеренке мөнәсәбәтләр; **~ая улы́бка** ясалма елмаю

натяну́ть *сов. что* **1.** тарту; **~ ве́рёвку** бау тарту; **~ во́жжи** дилбегәне тарту **2.** кию, тартып кию; **~ сапо́г на́ ногу** итекне аякка тартып кию **3.** тартып ябыну, ябыну; **~ одея́ло** юрганны тартып ябыну **4.** *разг.* (*завысить оценку*) тартып-сузып... кую

натяну́ться *сов.* тартылу, киерелү

науга́д *нареч.* ни булса ул булыр дип, уйлап-нитеп тормыйча, тәвәккәлләп; **идти́ ~** тәвәккәлләп бару

наугóльник *м* почмаклык (*тәрәзә рамы, ящик һ.б.ш. почмагына бизәү яки ныгыту өчен куела торган нәрсә*)

наугóльный, -ая, -ое почмакка куела торган, почмакка куелган

наудалу́ю *нареч. разг.* дуамал кыюлык белән; **ри́нуться ~** дуамал кыюлык белән ташлану

науда́чу *нареч.* тәвәккәлләп, уңса уңар дип, уйлап-нитеп тормыйча; **идти́ ~** ни булса ул булыр дип бару

науди́ть *сов. что, кого-чего* кармак белән тоту, кармак белән тотып алу; **~ ры́бы** кармак белән балык тоту

нау́живать *несов. см.* **науди́ть**

нау́к||а *ж* **1.** фән, гыйлем; **сове́тская ~а** совет фәне; **обще́ственные ~и** иҗтимагый фәннәр; **по ~е** *разг.* фән тәлпләренә туры китереп **2.** (*назидание*) сабак, гыйбрәт

наукообра́зный, -ая, -ое фәнсыман; фәнгә охшаш

нау́ськать *сов. кого-что на кого-что, разг.* өстерү, өстереп җибәрү; **~ соба́к** этләрне өстерү

нау́ськивать *несов. см.* **нау́ськать**

наутёк *нареч. разг.*: **пусти́ться (бро́ситься) ~** сызу, таю, шылу

нау́тро *нареч.* иртә белән, иртәгә иртән, иртәгә иртә белән, иртәгесен

научи́ть *сов.* **1.** *кого-что•чему и с неопр.* өйрәтү; **~ ребёнка пла́вать** баланы йөзәргә өйрәтү **2.** *кого-что, разг.* (*подготовить*) [астыртын] котырту, акыл бирү; акыл өйрәтү

нау́читься *сов. чему и с неопр.* өйрәнү; **~ пла́вать** йөзәргә өйрәнү

нау́чно-иссле́довательский, -ая, -ое фәнни-тикшеренү ...ы; **~ институ́т** фәнни-тикшеренү институты; **~ое су́дно** фәнни-тикшеренү судносы

нау́чно-популя́рный, -ая, -ое фәнни-популяр; **~ фильм** фәнни-популяр фильм

нау́чно-произво́дственн||ый, -ая, -ое фәнни-производство ...ы; **~ое объедине́ние** фәнни-производство берләшмәсе

нау́чно-техни́ческ||ий, -ая, -ое фәнни-техник; **~ая библиоте́ка** фәнни-техник китапханә; **~ая револю́ция** фәнни-техник революция

нау́чно-фантасти́ческий, -ая, -ое фәнни-фантастик; **~ рома́н** фәнни-фантастик роман

нау́чн||ый, -ая, -ое **1.** фәнни, гыйльми; **~ая де́ятельность** фәнни эшчәнлек; **~ый рабо́тник** гыйльми хезмәткәр; **~ая организа́ция труда́** хезмәтне фәнни оештыру **2.** фәнни яктан ..., фәнни; **~ое обоснова́ние** фәнни яктан нигезләү

нау́шник *м разг.* (*доносчик*) әләкче, әләкче капчыгы, суз йөртүче

нау́шники *мн.* (*ед.* **нау́шник** *м*) **1.** (*части тёплой шапки*) колакчын[нар] **2.** (*прибор*) наушниклар

нау́шничать *несов. разг.* астыртын әләкләү, астыртын сүз йөртү

нау́шничество *с разг.* астыртын әләкләү, астыртын сүз йөртү

нащени́||е *с*: **по ~ю** *кого, уст. берәүнең* коткысы белән (буенча)

нафабрикова́ть *сов. что, чего* уйлап чыгару (*мәс. ялган хәбәрләр*); әвәләү, эшләү, ясау; язу; **~ стате́ек** мәкаләләр әвәләү

нафтали́н *м* нафталин

нафтали́нный, -ая, -ое, **нафтали́новый**, -ая, -ое нафталин ...ы; **~ за́пах** нафталин исе

наха́л *м* оятсыз, әрсез, сөмсез, битсез [кеше]

наха́лка *ж* оятсыз (әрсез, сөмсез, битсез) хатын (кыз)

наха́льничать *несов. разг.* оятсызлану, әрсезләнү, йөзсезләнү

наха́льный, -ая, -ое оятсыз, әрсез, сөмсез, битсез

наха́льство *с* оятсызлык, әрсезлек, сөмсезлек, йөзсезлек

нахами́ть *сов. кому и без доп., прост.* дорфалык (тупаслык) күрсәтү (эшләү), оятсыз кылану

наха́пать *сов. что, чего, прост.* урлап җыю, комсызланып җыю

нахва́ливать *несов. см.* **нахвали́ть**

нахвали́ть *сов. кого-что, разг.* [кирәгеннән] артык мактау, чиктән тыш мактау

нахвали́ться *сов. разг.* артык (бик күп) мактану ♦ **не ~** *кем-чем* мактанып [мактап] бетерә алмау; **он им не нахва́лится** ул аны мактап бетерә алмый

нахва́стать *сов. разг.* мактанып ташлау, шапырынып ташлау

нахва́статься *сов. разг.* бик күп (чиктән тыш) мактану, шапырыну

нахвата́ть *сов. что, чего, разг.* (*бернигадәр*) җыю, эләктерү ♦ **~ зна́ний** аннан-моннан гына белем алу

нахвата́ться *сов.*: **~ зна́ний** *то же, что* **нахвата́ть зна́ний** (*см.* **нахвата́ть**)

нахва́тывать *несов. см.* **нахвата́ть**

наха́мовец *м* нахимовчы

наха́мовский, -ая, -ое: **наха́мовское учи́лище** нахимовский училище

нахле́бник *м* **1.** (*приживальщик*) әрәмтамак, кеше җилкәсен кимерүче **2.** *уст.* нахлебник (*аш һәм торак өчен акча түләп квартирда торучы*); **взять** *кого-л.* **в ~и** нахлебник итеп алу

нахлеста́ть *сов. кого-что, разг.* камчылау, чыбыклау (*кыйнау мәгънәсендә*); **~ по щека́м** яңаклау

нахлеста́ться *сов. прост.* туйганчы чабыну, чабынып тую (*мунчада*)

нахлёстывать *несов. см.* **нахлеста́ть**

нахлобу́чивать *несов. см.* **нахлобу́чить**

нахлобу́чиваться *несов.* **1.** *см.* **нахлобу́читься; 2.** *страд. от* **нахлобу́чивать**

нахлобу́чить *сов. что, разг.* басып (батырып) кию; **~ ша́пку** бүрекне басып кию

нахлобу́читься *сов. разг.* (*о головном уборе*) маңгаена төшү (төшеп тору), маңгаен каплау (*баш киеме турында*)

нахлобу́чк||а *ж разг.* каты шелтә; тиргәү; **получи́ть ~у** шелтә алу

нахлы́ну||ть *сов.* **1.** ыргылып (ургылып) килеп бәрелү, ишерелеп килеп менү; **~ла волна́** дулкын ургылып килеп [ярга] бәрелде **2.** ябырылу, ябырылып килеп тулу; **~ла толпа́** халык ябырылып килеп тулды **3.** *перен.* чолгап алу; **~ли воспомина́ния** истәлекләр чолгап алды

нахму́ривать *несов. см.* **нахму́рить**

нахму́риваться *несов. см.* **нахму́риться**

нахму́рить *сов. что* (*брови*) җыеру, җимерү; (*лицо*) сыту, төмсәләндерү, йөз чыту (сыту)

нахму́риться *сов.* **1.** (*о бровях*) җыерылу, җимерелү; (*о лице*) сытылу, караңгылану, төмсәләнү **2.** *перен.* (*напр. о небе*) караңгылану, төмсәләнү

находи́ть I *несов. см.* **найти́** I

находи́ть II *несов. см.* **найти́** II

находи́||ться I *несов.* **1.** *см.* **найти́сь; 2.** булу; **да́ча нахо́дится недалеко́ от ста́нции** дача станциядән ерак түгел

находи́ться II *сов. разг.* (*вдоволь походить*) арыганчы йөрү, йөреп ару; туйганчы йөрү, йөреп тую

нахо́дк||а *ж* **1.** (*найденная вещь*) табылдык, табылган әйбер **2.** (*нечто удачно найденное*) табыш; ачыш; **режиссёрские ~и** режиссёр ачышлары

нахо́дчивость *ж* тапкырлык

нахо́дчивый, -ая, -ое тапкыр; **~ челове́к** тапкыр кеше; **~ отве́т** тапкыр җавап

нахожде́ние *с см.* **находи́ть** I 1, **находи́ться** I 2

нахо́хливать *несов. см.* **нахо́хлить**

нахо́хливаться *несов. см.* **нахо́хлиться**

нахо́хлить *сов. что* йоннарын (канатларын) тырпайту, йоннарын (канатларын) кабарту

нахо́хлиться *сов.* **1.** (*о птицах*) кабарыну, йоннарын (канатларын) кабарту, йоннарын (канатларын) тырпайту **2.** *перен. разг.* (*о человеке*) чырай караңгылану (сытылу, төмсәләнү)

нахра́пистый, -ая, -ое *прост.* ертлач

нацара́пать *сов. что, разг.* **1.** тырнап язу; **~ на́дпись на стене́** тырнап стенага язу **2.** (*плохо написать*) начар итеп язу (язып ташлау)

нацеди́ть *сов. что, чего* агызып (саркытып) алу; сөзеп алу

нацеди́ться *сов.* агу, сарку, агып (саркып) җыелу

наце́живать *несов. см.* **нацеди́ть**

наце́живаться *несов.* **1.** *см.* **нацеди́ться; 2.** *страд. от* **наце́живать**

наце́ливать *несов. см.* **наце́лить**

наце́ливаться *несов.* **1.** *см.* **наце́литься; 2.** *страд. от* **наце́ливать**

наце́лить *сов.* **1.** *что* төзәү, төбәү, юнәлтү; **~ ору́дие** орудиене төзәү **2.** *перен. кого-что* (*направить к какой-л. цели*) юнәлтү, юнәлдерү, юнәлеш бирү

наце́литься *сов.* **1.** *в кого-что и без доп.* (*прицелиться*) төзәү, төбәү, юнәлтү **2.** *перен. на что, с неопр. и без доп, разг.* (*собраться, приготовиться сделать что-л.*) җыену, әзерләнү; **~ уе́хать** китәргә җыену; **~ прыгать** сикерергә җыену

на́цело *нареч. разг.* калдыксыз, тулысынча; **число́ де́лится ~** сан калдыксыз бүленә

нацо́нк||а *ж торг.* **1.** [хакларны] арттыру, [хакларны] күтәрү; **произвести́ ~у на това́ры** товарларның хакларын арттыру **2.** өстәмә (өстәлгән) хак; **~а на това́ры** товарларга өстәлгән хак

нацепи́ть *сов. что* **1.** эләктерү, элү, тагу, эләктереп (элеп, тагып) кую; **~ ведро́ на коромы́сло** чиләкне көянтәгә тагу **2.** *разг.* кадау, кадап кую; **~ бант** бант кадау

нацепля́ть *несов. см.* **нацепи́ть**

наци́зм *м* нацизм

национализа́ция *ж* национализация, национализациләү

национализи́ровать *сов., несов. что* национализацияләү, национализация ясау (үткәрү)

национали́зм *м* милләтчелек

национализова́ть *сов., несов. см.* **национализи́ровать**

национали́ст *м* милләтче

национали́стический, -ая, -ое, милләтчелек ...ы; милләтче[ләр] ...ы; милләтче[ләр]гә хас; **~ие тенде́нции** милләтчелек тенденцияләре

национали́стичн||ый, -ая, -ое *см.* **национали́стический; ~ые взгля́ды** милләтчеләргә хас карашлар

национали́стка *ж* милләтче хатын (кыз)

национали́стский, -ая, -ое милләтче[ләр] ...ы; **~ая группиро́вка** милләтчеләр төркемчәсе

национа́льно-освободи́тельн||ый, -ая, -ое милли азатлык ...ы; милли азатлык өчен ...; **~ая борьба́** милли азатлык өчен көрәш

национа́льност||ь *ж* **1.** милләт; **он по ~и ру́сский** ул милләте ягыннан рус **2.** миллилек; **~ь иску́сства** сәнгатьнең миллилеге

национа́льн||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* милли; **~ый вопро́с** милли мәсьәлә; **~ое движе́ние** милли хәрәкәт; **~ый дохо́д** *эк.* милли табыш; **~ая культу́ра** милли мәдәният; **~ые обы́чаи** милли йолалар; **~ая оде́жда** милли кием; **~ый о́круг** (*до 1977 г.*) милли округ

наци́ст *м* нацист

на́ция *ж* милләт ♦ **Организа́ция Объединённых На́ций (ООН)** Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО)

начади́ть *сов. чем и без доп.* сөремләү, сөремләп бетерү, сөрем чыгару, сөрем белән тутыру

нача́л||о *с* **1.** баш; **~о кни́ги** китапның башы; **~о рабо́ты** эшнең башы; **~о уче́бного го́да** уку елының башы; **брать ~о** *откуда-л.*, **вести́ своё ~о** *откуда-л.* башлану, башланып китү; **дать (положи́ть) ~о** *чему-л. бирәр нәрсәнең* нигезе булып тору, *бирәр нәрсәгә* нигез салу **2.** (*источник, основа чего-л.*) башлангыч, баш, нигез; сәбәп; **организу́ющее ~о** оештыручы нигез **3.** *мн.* **~а** (*основы*) нигез[ләр]; **~а хи́мии** химия [фәненең] нигезләре; **на ~ах ра́венства** тигез хокуклылык нигезендә ♦ **для ~а** башлап җибәрү өчен; **до ~а** башлаганчы, башланганчы; **под ~ом** *чьим, у кого берәүнең* кул астында, җитәкчелегендә

нача́льник *м* башлык, түрә (*уст.*)

нача́льница *ж разг.* башлык хатын (кыз)

нача́льнический, -ая, -ое башлыкларга хас; түрәләрчә ... (*уст.*); **~ тон** башлыкларга хас тон

нача́льн||ый, -ая, -ое башлангыч; **~ый пери́од** башлангыч чор; **~ое образова́ние** башлангыч белем; **~ая шко́ла** башлангыч мәктәп

нача́льственный, -ая, -ое *см.* **нача́льнический**

нача́льств||о *с* **1.** *собир.* башлыклар, җитәкчеләр, түрәләр (*уст.*); **по распо-**

ряжéнию ~а башлыкларның күрсәтмәсе буенча **2.** җитәкчелек; **принять ~о над учреждéнием** учреждение белән җитәкчелек итүне кабул итү; **служúть под** *чьим-л.* **~ом** *берәүнен* кул астында хезмәт итү

нача́льствовать *несов. над кем-чем, уст.* башлык булып тору (эшләү); идарә итү, җитәкчелек итү

нача́льствующ||ий, -ая, -ее *офиц.* башлыклар ...ы, җитәкчеләр ...ы; **~ий соста́в а́рмии** армиянең башлыклар составы; **~ие ли́ца** башлыклар, җитәкчеләр

нача́тки *мн.* башлангыч мәгълүматлар; башлангыч нигезләр; **~ зна́ний** башлангыч белемнәр

нача́ть *сов.* **1.** *в разн. знач. что и с неопр.* башлау, керешү; **~ стро́ить** төзи башлау; **на́чало накра́пывать** [яңгыр] сибәли башлады; **~ красне́ть** кызара башлау **2.** *что, чем, с кого-чего* башлап җибәрү; **~ речь приве́тствием** нотыкны тәбрик сүзе белән башлап җибәрү; **~ день с заря́дки** көнне зарядка белән башлап җибәрү; **с кого́ начнём?** кемнән башлап җибәрәбез?

нача́ться *сов. с чего, чем и без доп.* башлану, башланып китү

начека́нивать *несов. см.* **начека́нить**

начека́нить *сов. что, чего* [акча] сугу

начеку́ *нареч.* әзер, сак, уяу; **быть ~** әзер тору

начерка́ть *сов. разг.* **1.** *что* (*небрежно написать, нарисовать*) тиз-тиз генә сызгалау, сызгалап ташлау **2.** *что, чего* (*исчеркать*) сызгалау, сызгалап бетерү, сызгалап пычратып бетерү

начерни́ть *сов. что* каралту, карага буяу

на́черно *нареч.* карага, караламага, каралама итеп; **написа́ть ~** караламага язу

начерня́ть *несов. см.* **начерни́ть**

наче́рпать *сов. что, чего* чумырып алып тутыру, сосып алып тутыру

наче́рпывать *несов. см.* **наче́рпать**

начерта́ние *с* язылыш, язылу; **~ ру́сских бу́кв** рус хәрефләренең язылышы

начерта́ть *сов. что, высок.* **1.** (*написать*) язу; (*нарисовать*) сурәт төшерү **2.** *перен.* (*указать, определить*) алдан әйтеп кую, алдан билгеләп кую, алкурсәтү

начерти́ть *сов. что, чего* сызу, сызып [әзерләп] кую; **~ ли́нию** сызык сызу; **~ мно́го карт** күп карта сызу

наче́рчивать *несов. см.* **начерти́ть**

начёс *м* **1.** *см.* **начеса́ть; 2.** (*род причёски*) кабартылган чәч **3.** (*ворс*) төк, йон **4.** *спец.* (*начёсанное волокно, шерсть*) тәрәшле

начеса́ть *сов.* **1.** *что, чего* тарау, тарап кую; тәрәшләү; **~ пенькú** сүс тәрәшләү **2.** *что, чего* тарап төшерү; **~ воло́с** чәч тарап төшерү **3.** *что, разг.* кашып суйдыру; **~ но́гу до́ крови** аякны канатканчы кашып суйдыру

наче́сть *сов. что, бухг.* [дөрес тотылмаган] чыгымны кайтарту, исәбенә язу

начёсывать *несов. см.* **начеса́ть**

начёт *м бухг.* начёт, кирс кайтарып бирелергә тиеш акча (*дөрес тотылмаган чыгым исәбенә*)

начётничество *с* начётниклык, хәреф ятлаучылык

начётчик *м* хәреф ятлаучы

начина́ни||е *с* башлап җибәрелгән эш, башлангыч; инициатива; **поддержа́ть ~я передовико́в** алдынгыларның инициативасын хуплау

начина́ть *несов. см.* **нача́ть**

начина́ться *несов.* **1.** *см.* **нача́ться; 2.** *страд. от* **начина́ть**

начина́ющий, -ая, -ое **1.** *прич. от* **начина́ть; 2.** яңа гына (*укый, эшли һ.б.ш.*) башлаучы, яңа гына (*эшкә һ.б.ш.*) керешүче (керешкән); яшь, тәҗрибәсез; **~ худо́жник** яшь рәссам

начини́ть I *сов. что чем* эченә салу, эченә кую; **~ пирожки́ мя́сом** сумсалар эченә ит салу

начини́ть II *сов. что, чего разг.* **1.** (*берникадәр*) ямау, ямап чыгу (кую); **~ белья́** күлмәк-ыштаннар ямап кую **2.** (*берникадәр*) очлау, очлап кую; **~ карандаше́й** карандашлар очлап кую

начи́нка *ж* эч (*сумса, конфет һ.б.ш. эченә салынган нәрсә*); **~ пирога́** бәлеш эче

начиня́ть *несов. см.* **начини́ть** I

начи́ркать *сов. что, чего, разг.* (*спичек*) сызып бетерү, сызгалау

начисле́ние *с* **1.** *см.* **начи́слить; 2.** *бухг.* (*начисленная сумма*) өстәп исәпләнгән сумма, өстәлгән сумма

начи́слить *сов. что, бухг.* **1.** исәпләп чыгару (өстәү, өстәп кую), өстәп исәпләү; **~ пе́ню** пенясын исәпләп чыгару **2.** исәпләп язу (кую); **~ за́работную пла́ту** эш хакын исәпләп язып кую

начисля́ть *несов. см.* **начи́слить**

начи́стить *сов.* **1.** *что, чего* (*берникадәр*) арчу, арчып кую, арчып әзерләп кую; **~ карто́феля** бәрәңге арчып кую **2.** *что, разг.* яхшылап (әйбәтләп) чистарту, тазарту, чистартып (тазартып) кую; **~ сапоги́** итекләрне яхшылап чистартып кую

начи́ститься *сов. разг.* яхшылап (әйбәтләп) чистарту (*мәс. киемне*)

на́чисто *нареч.* **1.** (*набело*) акка; **переписа́ть ~** акка күчереп язу **2.** *разг.* (*совсем, решительно*) бөтенләйгә; кырт кисеп; катгый рәвештә; **~ отказа́ться** *от чего-л. берәр нәрсәдән* катгый рәвештә баш тарту **3.** *разг.* (*целиком*) бөтенләйгә, бернәрсә калдырмыйча; **~ огра́бить** бернәрсә калдырмайча талау **4.** *прост. см.* **начисто́**

начисто́ *нареч.* ачыктан-ачык, турыдан-туры, бернәрсә дә яшермичә; **рассказа́ть всё ~** бөтенесен ачыктан-ачык сөйләп бирү

начи́танность *ж* күп [китап] укыганлык

начи́танный, -ая, -ое күп [китап] укыган, мәгълүматлы, укымышлы

начита́ть *сов. что, чего, разг.* (*берникадәр*) уку, укып чыгу; **~ за́ год мно́го ле́кций** бер ел эчендә бик күп лекцияләр уку

начита́ться *сов. чего* бик күп уку, бик күп укып чыгу

начи́тывать I *несов. см.* **наче́сть**

начи́тывать II *несов. см.* **начита́ть**

начиха́ть *сов. на кого-что, прост.* төчкереп чәчрәтү

начища́ть *несов. см.* **начи́стить**

начища́ться *несов.* **1.** *см.* **начи́ститься; 2.** *страд. от* **начища́ть**

начуди́ть *сов. разг.* төрле юләрлекләр (мәзәкләр) эшләп ташлау

наш *мест.* **1.** безнең; безнең ...[ы] быз; **~и це́ли** безнең максатларыбыз; **~ сын** безнең улыбыз **2.** *в знач. сущ.* **~е** *с разг.* безнекеләр; **~е никуда́ не уйдёт** безнеке беркая да китмәс; **вы зна́ете ме́ньше ~его** сез бездән азрак беләсез **3.** *в знач. сущ.* **~и** *мн. разг.* безнекеләр; **~и рабо́тают лу́чше** безнекеләр яхшырак эшли **4.** *в знач. сущ.* **~** *м*, **~а** *ж прост.* безнеке; **~ у́чится хорошо́** безнеке яхшы укый ♦ **~ брат** безнең агайэне, безнең кеше, үз кеше; **~а берёт (взяла́)** өстенлекне без алабыз (алдык), без өстен чыгабыз (чыктык); **и ~им и ва́шим** ике яклы пәке, һәркемгә дә ярый; **~е вам!** *прост. шутл.* сәлам бирдек!

на́ша *ж см.* **наш**

нашали́ть *сов.* шаяру, шуклыклар эшләп ташлау

наша́ривать *несов. см.* **наша́рить**

наша́рить *сов. что, разг.* кармалап эзләп табу

наша́ркать *сов. разг.* таптап пычрату, таптап [пычратып] бетерү

нашаты́рный, -ая, -ое нашатырь ...ы; нашатырьлы; **~ спирт** нашатырьлы спирт

нашаты́рь *м* нашатырь (**1.** *химик матдә* **2.** *разг. нашатырьлы спирт*)

нашвыря́ть *сов. что, чего, разг.* (*күп итеп*) ташлау, ыргыту, ыргытып тутыру; **~ бума́г** кәгазьләр ташлау (ыргыту)

на́ше *с см.* **наш**

нашепта́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*наговорить шёпотом*) пышылдап сөйләү, пышылдап сөйләп бирү **2.** *уст.* (*насплетничать*) әләкләү, яла ягу; (*внушить тайно*) астыртын котырту **3.** *на что, уст.* (*наколдовать*) өшкерү

нашёптывать *несов. см.* **нашепта́ть**

наше́ствие *с* ябырылу, басып керү, яу булып килү; һөҗүм, һөҗүм итү

на́ши *с см.* **наш**

нашива́ть *несов. см.* **наши́ть**

наши́вка *ж* **1.** *см.* **наши́ть; 2.** нашивка (*җиңгә яки погонга теккән куелган билге*)

нашивн||о́й, -а́я, -о́е өстән тегеп куелган, өстән каелган; тышкы; **~ы́е карма́ны** тышкы кесәләр

нашинкова́ть *сов. что, чего* (*тар, озынча кисәкләргә*) турау, турап кую

наши́ть *сов.* **1.** *что* [өстенә] тегү, тегеп кую; **~ карма́н** кесә тегеп кую **2.** *что, чего* (*берникадәр*) тегү, тегеп кую, тегеп әзерләп кую; **~ пла́тьев** күлмәкләр тегеп кую

нашлёпать *сов. кого-что, разг.* чәбәкләү, чәбәкләп алу (*кыйнау мәгънәсендә*)

нашпиговáть *сов.* 1. *кого-что* (*начинить шпиком*) шпиклау 2. *что, чего* (*шпигуя, наготовить*) шпиклап әзерләп кую

нашпиго́вывать *несов. см.* **нашпиговáть**

нашпи́ливать *несов. см.* **нашпи́лить**

нашпи́лить *сов. кого-что* (*шпилькага, булавкага*) кадау, кадап кую; ~ **ба́бочку** күбәләкне булавка белән кадап кую

нашуме́ть *сов.* 1. (*произвести шум*) тавыш куптару, тавыш чыгару, тавышлану, шаулау 2. *перен.* (*вызвать толки*) шаулату, дөнья шаулату

нащёлкать *сов, что, чего, разг.* (*берникадәр*) яру, ашау, ватып ашау; ~ **оре́хов** чикләвек ватып ашау

нащепáть *сов. что, чего* (*берникадәр чыра*) телгәләү, телгәләп (телеп) кую, телгәләп әзерләп кую; ~ **лучи́ны** чыра телеп кую

нащипáть *сов. что, чего* (*берникадәр*) йолку, йолкып җыю; ~ **травы́** үлән йолкып җыю

нащу́пать *сов. что* 1. капшап (кармалап) табу; ~ **пульс** пульсны капшап табу 2. *перен.* табу, эзләп табу; ~ **по́чву для перегово́ров** сөйләшүләр алып бару өчен нигез табу; ~ **сла́бые места́ в рабо́те** эштә йомшак якларны табу

нащу́пывать *несов. см.* **нащу́пать**

наэлектризовáть *сов.* 1. *что* (*зарядить электричеством*) электрлау, электрландыру 2. *перен. кого-что* тәэсирләндерү, тәэсир итү; дәрт уяту, дәртләндерү

наэлектризовáться *сов.* 1. (*зарядиться электричеством*) электрлану 2. *перен.* тәэсирләну, дәртләну

наэлектризо́вывать *несов. см.* **наэлектризовáть**

наэлектризо́вываться *несов.* 1. *см.* **наэлектризовáться**; 2. *страд. от* **наэлектризо́вывать**

наябедничать *сов. на кого, разг.* әләкләү, яла ягу

наяву́ *нареч.* өндә (*төштә түгел*)

не I *частица* 1. (*отриц. при гл.*) ...ма; **не признаёт** танымый; **не прихо́дит** килми; **не возьмёт** алмаячак 2. (*при неопр.ф. гл.*) ...а алмау; **тебе́ его́ не догна́ть** син аны куып җитә алмассың 3. (*при противопоставлении*) түгел; **не брат, а друг** абыйсы (энесе) түгел, ә дусты 4. (*при неопределённом, неполном отриц.*) түгел; **не вполне́ здоро́в** бик үк сәламәт түгел; **пиджа́к не пиджа́к, пальто́ не пальто́** пиджак дисәң пиджак түгел, пальто дисәң пальто түгел; **сон не в сон** йокысы йокы түгел; **чай не в чай** чәе чәй булмады 5. (*при выраж. утвердительного знач.*) ...ме; **не дать ли?** бирмәскәме?; **нельзя́ не люби́ть** яратмаска мөмкин түгел; **не мог не знать** белмәскә мөмкин түгел иде; **как не полю́бишь его́!** ничек яратмыйсың аны! 6. (*при огранич. утверждении*): **не без** ...мыйча түгел, шактый ...п; **не без бо́язни** курыкмыйча түгел; **не без смуще́ния** шактый тартынып; **чуть (едва́) не...** аз гына ...мау, аз гына ...мый калу, ...а язу; **он едва́ не поги́б** ул аз гына һәлак булмый калган, ул һәлак була язган; **я чуть бы́ло не упа́л** мин егыла яздым; **едва́ ли не ...** ...мавы шикле; ...вы бик мөмкин; **он говори́т едва́ ли не на всех языка́х** барлык телләрдә диярлек сөйләшә белә ♦ **не наста́лько ..., что́бы не ...** ...маслык дәрәҗәдә түгел; **не наста́лько бо́лен, что́бы не прийти́ на рабо́ту** ул эшкә бармаслык дәрәҗәдә авыру түгел; **не то ..., не то ...** әллә [инде] ..., әллә [инде] ...; **не то остава́ться, не то нет** әллә калырга, әллә юк; **не то́лько** гына түгел; **не то́лько де́ти** балалар гына түгел; **не то́лько ..., но и ...** гына түгел, ...да; **не что ино́е как ...** ...дан башка бернәрсә түгел; ... гына, башка берни түгел; **э́то не что ино́е как насме́шка** бу мәсхәрәләү генә, башка берни түгел; **тем не ме́нее** шулай да, шулай булуга карамастан; **хотя́ и не ..., но ...** ...маса да; **хотя́ и не хо́лодно, но он оде́лся тепло́** суык булмаса да, ул җылы киенде

не II (*всегда ударное*; *в сочет. с предлогами является отделяемой частью мест. «некого», «нечего»*) юк; **выбира́ть не́ из чего** сайлап алырлыгы юк; **не́ с кем говори́ть** сөйләшергә кеше юк; **не́ к кому и не́кому прие́хать** килерлек кеше дә килә торган кеше дә юк

не- *приставка; исемнәр һәм сыйфатлар ясый, тубәндәге мәгънәләрне белдерә*: 1. *сүзнең бу приставкадан башка белдергән мәгънәсенә капма-каршы мәгънәне, мәс.* **непра́вда** ялган; **непри́ятель** дошман; **невесёлый** күңелсез; **недо́брый** усал, явыз, яман; **невысо́кий** тәбәнәк; түбән 2. *билгесе, сыйфаты чикле булган, тулы булмаган каршы мәгънәне, мәс.* **невнима́тельный** игътибарсыз, дикъкатьсез, саксыз; **неглу́пый** шактый акыллы; акыллы гына; акылсыз түгел, башсыз түгел; **неплохо́й** начар булмаган, шактый яхшы, яхшы гына, ярыйсы гына; начар түгел 3. *сүзнең приставкадан башка белдергән мегъ-нәсенең булмавын, мәс.* **необосно́ванность** нигезсезлек, дәлилсезлек; **ненау́чный** фәнни булмаган; **нече́стный** намуссыз, гаделлексез

неаккура́тность *ж* пөхтәсезлек; шапшаклык

неаккура́тный, -ая, -ое 1. (*неисполнительный*) вакытында ...маучан, тәртипсез, тәртипкә буйсынмаучан 2. *разг.* (*небрежно сделанный*) пөхтә (җиренә җиткереп, төгәл) ...маган; ~**ая рабо́та** җиренә җиткереп эшләнмәгән эш 3. (*неопрятный*) шапшак, җыйнаксыз, йобалгы

небез- (небес-) *приставка; исемнәрдән теге яки бу билгегә берникадәр ия диган мәгънәдәге сыйфатлар ясый, мәс.* **небезвре́дный** бөтенләй үк зарарсыз түгел, шактый зарарлы; **небезуспе́шный** бөтенләй үк уңышсыз тугел, шактый уңышлы

небезызве́стный, -ая, -ое *ирон.* шактый танылган, даны таралган, атаклы; ~ **спле́тник** атаклы гайбәтче

небезынтере́сный, -ая, -ое бөтенләй үк кызыксыз түгел, шактый кызыклы, берникадәр кызыклы

небе́сн||ый, -ая, -ое 1. күктәге, күк ...ы; ~**ый свод** күк гөмбәзе; ~**ые свети́ла** күктәге йолдызлар; ~**ая сфе́ра** *астр.* күк йөзе 2. (*о цвете*) аксыл күк, аксыл зәңгәр, күк төсендәге ♦ ~**ый мериди́ан** *астр.* күк меридианы

неблагови́дный, -ая, -ое гаеп итәрлек, ямьсез, шыксыз, начар; ~ **посту́пок** ямьсез кыланыш

неблагода́рность *ж* яхшылыкның кадерен белмәү; **отплати́ть чёрной** ~**ю** яхшылыкны яманлык белән кайтару

неблагода́рн||ый, -ая, -ое 1. яхшылыкның кадерен белмәүче (белмәүчән), яхшылыкны белмәүче; ~**ый учени́к** яхшылыкның кадерен белмәүче шәкерт 2. нәтиҗәсез, файдасыз, әрәм; ~**ый труд** нәтиҗәсез хезмәт 3. *разг.* яраксыз, туры килми торган; ~**ая для сце́ны вне́шность** сәхнә өчен туры килми торган кыяфәт

неблагозву́чие *с*, **неблагозву́чность** *ж* аһәңсезлек

неблагозву́чный, -ая, -ое аһәңсез, колакка ятышсыз

неблагонадёжность *ж* ышанычсызлык, шик астына алынганлык (*революцияга кадәрге Россиядә*)

неблагонадёжный, -ая, -ое ышанычсыз, шикле, шик астына алынган (*революцияга кадәрге Россиядә*)

неблагополу́чие *с* уңышсызлык, бәхетсезлек, күңелсезлек

неблагополу́чно *нареч.* 1. уңышсыз, начар 2. *в знач. сказ. безл.* начар, әйбәт (шәптән) түгел, имин (тыныч) түгел; тынычлык юк, тәртип юк, рәт юк; **у них в семье́** ~ аларның гаиләсендә хәлләр шәптән түгел

неблагополу́чный, -ая, -ое уңышсыз, начар; ~ **исхо́д де́ла** эшнең уңышсыз тәмамлануы

неблагопристо́йный, -ая, -ое *уст.* әдәпсез, тәрбиясез; килешсез, ямьсез, оятсыз

неблагоприя́тн||ый, -ая, -ое 1. начар, күңелсез; ~**ая пого́да** начар һава 2. уңайсыз, җайсыз, тискәре; ~**ый отве́т** тискәре җавап

неблагоразу́мный, -ая, -ое акылсыз, дуамал, акылга сыймаслык; уйламыйча эшләнгән; ~ **челове́к** акылсыз кеше; ~ **посту́пок** дуамал кыланыш

неблагоустро́енн||ый, -ая, -ое төзек булмаган, төзекләндерелмәгән; уңайлыклары булмаган; ~**ая кварти́ра** уңайлыклары булмаган квартир

нёбн||ый, -ая, -ое аңкау ...ы; ~**ая занаве́ска** *анат.* аңкау пәрдәсе; ~**ые зву́ки** *лингв.* аңкау авазлары

нёбо *с* күк, күк йөзе; **си́нее** ~**о** зәңгәр күк ♦ **до** ~**е́с вознести́ (превознести́)** күкләргә күтәрү (чөю); навага күтәреп мактау; **как** ~**о от земли́ [отлича́ться]** *или* ~**о и земля́** җир белән күк арасы кебек (*зур аерма*); **ме́жду** ~**ом и**

землёй җир бсләи күк арасында калу (*тораксыз калу*); **на седьмо́м ~е** ≈ түбәсе күккә тигән; **~еса́ развёрзлись** күк төбе тишелде; **~о с овчи́нку показа́лось** котым очты; **под откры́тым ~ом** ачык һавада; **с ~а свали́ться (упа́сть)** күктән төшү; **упа́сть (сойти́) с ~а на зе́млю** күктән җиргә төшү (*хыялардан арыну*)

нёбо *с анат.* аңкау

небольш||о́й, -а́я, -о́е **1.** зур булмаган, кечкенә; **~а́я ко́мната** зур булмаган бүлмә; **~о́й отря́д** кечкенә [бер] отряд **2.** аз гына; **за ~о́й отре́зок вре́мени** аз гына вакыт эчендә ♦ **за ~и́м де́ло ста́ло** эш кечкенәдән калды, эш аздан гына калды; **с ~и́м** аз гына артык, аз гына артыграк; **заплати́ть три́дцать рубле́й с ~и́м** утыз сумнан аз гына артыграк түләү

небосво́д *м* күк гөмбәзе, күк йөзе

небоскло́н *м* күк йөзе (*күкнең офык өстендәге өлеше*)

небоскрёб *м* небоскрёб (*бик биек, күп катлы йорт*)

небо́сь *частица прост. в знач. вводн. сл.* мәгаен, әлбәттә, инде; **она́, ~, краса́вица?** мәгаен, чибәр кыз ул?

небре́жничать *несов. разг.* салкын карау, игътибарсызлык (саксызлык) күрсәтү

небре́жност||ь *ж* **1.** игътибарсызлык, [эшенә] игътибарсыз (салкын) карау (караш); **допусти́ть оши́бку по ~и** игътибарсызлык аркасында хата җибәрү **2.** (*неряшливость выполнения*) начар (ничек җитте алай) эшләнгәнлек, җиренә җиткереп (күңел биреп, тырышып) эшләнмәгәнлек; шапшаклык

небре́жн||ый, -ая, -ое **1.** илтифатсыз, кимсетеп (түбәнсетеп) карауны белдергән, кимсетүле мәнәсәбәтне белдергән; **~ый тон** илтифатсыз тон **2.** аннанмоннан (ничек җитте алай) эшләнгән, тырышып (күңел биреп) эшләнмәгән; шапшак; **~ая рабо́та** ничек җитте алай эшләнгән эш

небыва́лый, -ая, -ое әлегәчә булмаган, күр[ел]мәгән, гомердә булмаган, гадәттән тыш; искиткеч, охшашы-тиңдәше булмаган; **~ слу́чай** әлегәчә булмаган хәл

небыли́ца *ж* **1.** (*выдумка*) ялган, уйдырма **2.** (*сказка*) әкият

небытие́ *с* юклык, яшәешнең юклыгы

нева́жн||ый, -ая, -ое **1.** (*несущественный*) әһәмиятсез, кечкенә, вак **2.** бертөрле, уртача; начар, шәптән түгел, әйбәт түгел; **~ое здоро́вье** сәламәтлеге шәптән түгел

невали́шка *ж разг.* аумас курчак

невдалеке́ *нареч.* якында, шунда гына, ераста түгел; **он живёт ~** ул ерак тормый

невдомёк *нареч. в знач. сказ. кому, разг.* сизмәү, сизенмәү, башына да килмәү; уйламау да, уена да килмәү; **ему́ и ~** аның башына да килми

неве́дени||е *с* белмәү, хәбәрдар булмау, хәбәрсезлек, мәгълүматсызлык; **пребыва́ть в ~и** хәбәрдар булмау

неве́домо *нареч. разг.* белмим, әллә; **~ кто** белмим кем

неве́дом||ый, -ая, -ое **1.** билгесез, билгеле булмаган, белмәгән, күрмәгән-белмәгән; **~ые края́** күрмәгән-белмәгән илләр **2.** гаҗәп, серле, сихри; **~ая си́ла** гаҗәп бер көч

неве́жа *м, ж* тупас, дорфа

неве́жда *м, ж* надан, белемсез, томана; **кру́глый ~** чеп-чи надан

неве́жественный, -ая, -ое надан, белемсез, томана

неве́жество *с* **1.** (*незнание*) наданлык, белемсезлек, томаналык **2.** *разг. см.* **неве́жливость**

неве́жливость *ж* әдәпсезлек, тәрбиясезлек, нәзакәтсезлек, тупаслык, дорфалык

неве́жливый, -ая, -ое әдәпсез, тәрбиясез, нәзакәтсез, тупас, дорфа; **~ отве́т** тупас җавап; **~ челове́к** дорфа кеше

невезе́ние *с разг.* уңышсызлык, эшләрнең гел уңмавы, бәхет киregә китү, киregә китеп тору

невели́чка *м, ж*: **ро́стом ~** *разг.* кечкенә буйлы, тәбәнәк буйлы; **пти́чка-~** кошчык, кечкенә кош

неве́рие *с* ышанмау[чылык]; **~ в со́бственные си́лы** үз көченә ышанмау

неве́рность *ж* **1.** хаталык, ялгышлык, хата (ялгыш) булу, дөрес түгеллек; **~ перево́да** тәржемәнең хаталыгы **2.** ялганлык, ялган булу; **~ полу́ченного сообще́ния** алынган хәбәрнең ялган булуы **3.** (*измена, напр. в любви*) ышанычсызлык, тугрылыксызлык, хыянәтчеллек, ышанычсыз булу

неве́рн||ый, -ая, -ое **1.** хата ..., ялгыш; дөрес түгел; **~ый вы́вод** ялгыш нәтиҗә **2.** ялган, дөрес булмаган; **~ое сообще́ние** ялган хәбәр **3.** ышанычсыз, тугрылыксыз, хыянәтче, хыянәт итүче; **~ый сою́зник** ышанычсыз союздаш; **~ый муж** [үз хатынына] хыянәт итүче ир **4.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж уст. рел.* башка дин тотучы ♦ **у него́ ~ый глаз** аның күз үлчәме начар; **Фома́ ~ый** бернәрсәгә дә ышанмаучан кеше; берәр нәрсәгә ышандыруы кыен булган кеше

невероя́тност||ь *ж* кеше ышанмаслык булу, акылга сыймаслык булу ♦ **до ~и** кеше ышанмаслык дәрәҗәдә, чиктән тыш

невероя́тн||ый, -ая, -ое **1.** кеше ышанмаслык, акылга сыймаслык; **~ый слух** кеше ышанмаслык хәбәр **2.** гадәттән тыш зур (көчле), бик зур; **~ая ско́рость** бик зур тизлек

неве́рующий, -ая, -ое динсез, алласыз, дәһри, аллага (дингә) ышанмаучы

невесёл||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* күңелсез; шатлыксыз; **~ая улы́бка** күңелсез елмаю; **~ый челове́к** күңелсез кеше; **~ая доро́га** күңелсез юл

невесо́мост||ь *ж* авырлыксызлык, авырлыгы булмау, авырлык югалу; **состоя́ние ~и** авырлык югалу хәле; **усло́вия ~и** авырлык югалу шартлары

невесо́м||ый, -ая, -ое **1.** (*лёгкий*) авырлыксыз, авырлыгы булмаган; җиңел; **~ые облака́** [бик] җиңел болытлар **2.** *перен.* әһәмиятсез, игътибар итмәслек, бик җиңел; **~ые аргуме́нты** әһәмиятсез аргументлар

неве́ста *ж* **1.** ярәшкән кыз, кәләш **2.** *разг.* (*совершеннолетняя девушка*) буйга җиткән кыз

неве́ст||а *ж* (*жена сына или младшего брата*) килен; (*жена старшего брата*) җиңгә; (*жёны братьев по отношению друг к другу*) килендәш ♦ **~е в отме́стку** үч итеп

неве́сть *нареч. прост.* әллә; **~ что** әллә нәрсә; **~ кто** әллә кем; **~ ско́лько** әллә никадәр; **~ како́й** әллә нинди

невзви́деть *сов.*: **~ све́та** 1) (*от боли, страха*) һичнәрсә күзгә күренмәү, күзгә ак-кара күренмәү (*авыртудан, куркудан*); 2) (*от гнева, злобы*) шартлый язу; дөньяны күрәсе килмәү (*ачудан*)

невзго́ды *мн.* авырлыклар, кыенлыклар; кайгы-хәсрәт, бәлалар, бәхетсезлекләр

невзира́я: **~ на** *предлог с вин. п.* карамастан; **критикова́ть ~ на ли́ца** кемнең кем булуына карамастан тәнкыйтьләү

невзлюби́ть *сов. кого-что* күрә алмау, яратмау

невзнача́й *нареч. разг.* көтмәгәндә, искәрмәгәндә, искәрмәстән, абайламастан, абайламыйча; **встре́титься ~** көтмәгәндә очрашу

невзно́с *м офиц.* [акча] түләмәү, [акча] кертмәү; **~ кварти́рной пла́ты** торак өчен [акча] түләмәү

невзра́чность *ж* ямьсезлек, килбәтсезлек, шыксызлык

невзра́чн||ый, -ая, -ое ямьсез, килбәтсез, шыксыз, күрексез; **~ая вне́шность** шыксыз кыяфәт

невзыска́тельность *ж* талымсызлык

невзыска́тельный, -ая, -ое талымсыз; **~ вкус** талымсызлык

не́видаль *ж разг. ирон.*: **вот ~!, что за ~!** *или* **э́кая ~!** искиткеч нәрсә икән!, искиткеч хәл икән!, исең киткән икән!

неви́данный, -ая, -ое искиткеч зур (күп), гаҗәп зур (күп), әлегәчә (моңарчы) булмаган; моңарчы күрелмәгән; **собра́ть ~ урожа́й** искиткеч зур уңыш җыеп алу

невиди́мка **1.** *м, ж фольк.* күзгә күренмәс, күзгә күренми торган нәрсә (жан иясе) **2.** *ж* (*шпилька*) бик нечкә шпилька

неви́димый, -ая, -ое күзгә күренми торган, күзгә күренмәс

неви́дный, -ая, -ое *разг.* **1.** (*недоступный зрению*) күзгә күренми торган, күзгә күренмәс **2.** (*незначительный*) кечкенә, әһәмиятсез, әһәмияте булмаган **3.** *разг.* (*невзрачный*) күзгә ташланмый торган, күрексез

неви́дящий, -ая, -ое: **~ взгляд (взор)** томанлы караш

неви́нность *ж* **1.** *см.* **невино́вность**; **2.** (*наивность*) беркатлылык, эчкерсезлек, саф күңеллелек **3.** (*девственность*) сафлык, гыйффәтлелек

неви́нн||ый, -ая, -ое **1.** (*невиновный*) гаепсез, гөнаһсыз, языксыз **2.** (*наивный*) беркатлы, эчкерсез, саф күңелле **3.** (*безвредный, безобидный*) эчкерсез, беркатлы, гөнахсыз, гаеп итмәслек, гаепкә алмаслык, зыянсыз, зарарсыз **4.** (*девственный*) саф, гыйффәтле

невино́вность *ж* гаепсезлек, гөнаһсызлык, языксызлык

невино́вный, -ая, -ое гаепсез, гөнаһсыз, языксыз

невку́сный, -ая, -ое тәмсез

невменя́емость *ж* үз-үзен белештермәү [хәле]; ни эшләгәнен белмәү (*психик хәл*)

невменя́емый, -ая, -ое үз-үзен белештерми торган; ни эшләгәнен белмәгән

невмеша́тельств||о *с* катнашмаучылык, тыгылмау, катышмаучылык; **поли́тика ~а** катнашмаучылык сәясәте; **~о во вну́тренние дела́ страны́** илнең эчке эшләренә тыгылмау

невмоготу́ *нареч. в знач. сказ. кому, разг.* чыдар хәл калмады, чыдар хәл юк; түземлек калмады, ...лык калмады; **~ ждать** көтәрлек хәл калмады; **ста́ло ~** чыдар хәл калмады

невмо́чь *прост. см.* **невмоготу́**

невнима́ни||е *с* **1.** игътибарсызлык, дикъкатьсезлек; **сде́лать оши́бку по ~ю** игътибарсызлык аркасында хата ясау **2.** илтифатсызлык; **~е к ста́ршим** өлкәннәргә карата илтифатсызлык

невнима́тельность *ж см.* **невнима́ние** 2

невнима́тельн||ый, -ая, -ое **1.** игътибарсыз, дикъкатьсез; саксыз; **~ый студе́нт** игътибарсыз студент; **~ое чте́ние** игътибарсыз уку **2.** илтифатсыз; **~ый хозя́ин** илтифатсыз хуҗа **3.** илтифатсыз, салкын, ваемсыз; **~ое отноше́ние** илтифатсыз караш (мөнәсәбәт)

невня́тность *ж* ишетелер-ишетелмәс булу, аңлашылыр-аңлашылмас булу, аңлаешсызлык

невня́тн||ый, -ая, -ое (*плохо слышный*) ишетелер-ишетелмәс, аңлашылыр-аңлашылмас; (*невразумительный*) аңлаешсыз; ачык түгел; **~ая речь** аңлаешсыз сөйләү

не́вод *м* җылым, шәпкә, зур җәтмә

невозврати́м||ый, -ая, -ое, **невозвра́тн||ый**, -ая, -ое [кире] кайтмас, кайтаруы мөмкин булмаган, кире кайтмый торган, [кире] кайтаргысыз; **~ая поте́ря** кире кайтаргысыз югалту; **~ое вре́мя** [кире] кайтмас вакыт

невозде́ланн||ый, -ая, -ое эшкәртелмәгән; **~ые зе́мли** эшкәртелмәгән җирләр

невозде́ржанность *ж* тотнаксызлык, тыйнаксызлык; саксызлык

невозде́ржанный, -ая, -ое тотнаксыз, тыйнаксыз; саксыз; **~ в пи́ще** ашауда тыйнаксыз; **~ на язы́к** телгә саксыз

невозмо́жно *в знач. сказ. безл.* мөмкин түгел

невозмо́жност||ь *ж* мөмкин булмау, мөмкин түгеллек ◆ **до ~и** бик, чиктән тыш

невозмо́жн||ый, -ая, -ое **1.** (*неосуществимый*) мөмкин булмаган, тормышка ашырыла алмаслык **2.** *разг.* чиктән тыш көчле (каты, авыр, зур *һ.б.ш. турында*); **~ая духота́** чиктән тыш бөркү һава; **~ый хара́ктер** чиктән тыш авыр характер; **~ая боль** чиктән тыш көчле авырту **3.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* мөмкин булмаган нәрсә; **~ое ста́ло возмо́жным** мөмкин булмаган нәрсә мөмкин булды; **нет ничего́ ~ого** һичбер мөмкин булмаган нәрсә юк

невозмути́м||ый, -ая, -ое **1.** тыныч, борчылмаган, борчылмый (пошынмый, каушамый, каушап калмый) торган, исе китмәүчән; **~ый тон** тыныч тон **2.** тулы; **~ая тишина́** тулы тынлык

невознагради́м||ый, -ая, -ое *высок.* **1.** түләп бетергесез, кайтарып бетергесез, кайтарып (түләп) бетерә алмаслык; бик зур; **~ая услу́га** кайтарып бетерә алмаслык ярдәм **2.** кайтмас, кайтара алмаслык, бик зур; **~ая поте́ря** кайтмас югалту

нево́лить *несов. кого-что, разг.* ирексезләү, көчләү, мәҗбүр итү

нево́льник *м* **1.** (*раб*) кол **2.** *уст.* (*пленник*) тоткын, әсир

нево́льница *ж* **1.** кол хатын (кыз) **2.** *уст.* әсир хатын (кыз)

нево́льничий, -ья, -ье коллар ...ы; әсирләр ...ы; **~ труд** коллар хезмәте; **~ ры́нок** коллар базары (*коллар сата торган базар*)

нево́льн||ый, -ая, -ое **1.** ихтыярсыз, ихтыярдан тыш эшләнгән; **~ая ложь** ихтыярдан тыш алдашу; **~ая оби́да** ихтыярдан тыш үпкәләтү **2.** (*вынужденный*) мәҗбүри, мәҗбүр ителгән; **~ая поса́дка самолёта** самолётның мәҗбүри җиргә (төшеп) утыруы

нево́л||я *ж* (*рабство*) коллык; (*плен*) тоткынлык, әсирлек

невообрази́мый, -ая, -ое күз алдына да китергесез (китерә алмаслык); гадәттән тыш, искиткеч

невооружённ||ый, -ая, -ое коралсыз, коралланмаган ◆ **~ым гла́зом** гади күз белән (*оптик приборлар ярдәменнән башка*)

невоспи́танность *ж* тәрбиясезлек

невоспи́танный, -ая, -ое тәрбиясез, әдәпсез; **~ челове́к** тәрбиясез кеше

невосполни́м||ый, -ая, -ое *высок.* һичнәрсә (һичкем) белән алмаштыра алмаслык; зур; **~ая поте́ря** һичнәрсә белән алмаштыра алмаслык югалту

невостре́бованный, -ая, -ое (*адресат тарафыннан*) алынмаган, алынмый калган; **~ груз** алынмый калган йөк

невпопа́д *нареч. разг.* урынсыз, вакытсыз; урынсызга, тиешсезгә; ялгыш, хата ...; **отвеча́ть ~** ялгыш җавап бирү

невпроворо́т *нареч. в знач. сказ. безл. прост.* бик күп, эшләп бетергесез, муеннан; **дел ~** эшләп бетергесез күп эш

невразуми́тельн||ый, -ая, -ое аңлаешсыз, буталчык; ышандырырлык булмаган; **~ отве́т** буталчык җавап

невралги́ческий, -ая, -ое *мед.* невралгия ...ы, невралгия характерындагы

невралги́я *ж мед.* невралгия

невраstéник *м* неврастеник, неврастения белән авыручы

неврастени́ческ||ий, -ая, -ое **1.** *мед.* неврастения ...ы, неврастеник; **~ие симпто́мы** неврастения симптомнары **2.** неврастеник, неврастеникларга хас; **~ое лицо́** неврастеникларга хас йөз

неврастени́чный, -ая, -ое *мед.* неврастения белән авыручы

неврастени́я *ж мед.* неврастения

невреди́мый, -ая, -ое сау-сәламәт, исән-сау, зыянсыз, имин

невре́дн||ый, -ая, -ое зарарсыз, зыянсыз; **~ые вещества́** зарарсыз матдәләр

неври́т *м мед.* неврит

невро́з *м мед.* невроз

невроло́гия *ж* неврология

невропато́лог *м* невропатолог, невропатология белгече

невропатоло́гия *ж* невропатология

невтерпёж *нареч. в знач. сказ.* чыдар (түзәр) хәл калмады, чыдарлык (түзәрлек) калмады, сабырлыгы төкәнде, чыдар (түзәр) хәл юк; **ей ~ получи́ть ве́сточку** аңын бик тә хәбәр аласы килә

невы́годно *нареч.* **1.** файдасыз; буш, мәгънәсез **2.** *в знач. сказ.* (*без прибыли*) файдасыз, табышсыз; **держа́ть капита́л без движе́ния ~** капиталны хәрәкәтсез тоту файдасыз **3.** *в знач. сказ.* (*без пользы*) файдасыз

невы́годность *ж* **1.** файдасызлык, төшемсезлек; **~ де́ла** эшнең төшемсезлеге **2.** уңайсызлык, җайсызлык; **~ положе́ния** хәлнең уңайсызлыгы

невы́годн||ый, -ая, -ое **1.** (*убыточный*) файдасыз, төшемсез, зыянлы; **~ое де́ло** төшемсез эш **2.** уңайсыз, җайсыз; **~ое положе́ние** уңайсыз хәл **3.** (*о внешности*) күренексез, ягымсыз

невы́езд *м* китмәү; **дать подпи́ску о ~е** китмәү турында кул кую

невыноси́мо *нареч.* **1.** түзә алмаслык [дәрәҗәдә], чыдый алмаслык [дәрәҗәдә]; **~ жа́рко** түзә алмаслык эссе **2.** *в знач. сказ.* түзә алмаслык кыен (авыр, көчле), бик кыен (авыр, көчле); **ви́деть э́то ~** моны күрүе бик авыр; **остава́ться здесь ~** монда калуы (калып торуы) бик кыен

невыноси́м||ый, -ая, -ое түзә (чыдый) алмаслык, түзеп торгысыз (тора алмаслык); бик көчле (авыр, кыен *һ.б.ш. турында*); **~ая боль** түзеп тора алмаслык авырту; **~ый хара́ктер** бик авыр характер

невыполне́ние *с* үтәмәү, тутырмау; үтәлмәү, тутырылмау

невыполни́м||ый, -ая, -ое үти алмаслык, үтәп булмый торган; **~ое усло́вие** үтәп булмый торган шарт

невырази́м||ый, -ая, -ое әйтеп (сөйләп) бетергесез, сүз (тел) белән аңлатып бирерлек булмаган; **~ая краса́** әйтеп бетергесез матурлык

невысо́к||ий, -ая, -ое **1.** (*о предметах*) тәбәнәк; биек түгел; (*о человеке*) тәбәнәк буйлы; уртача буйлы **2.** түбән, шактый түбән; югары түгел; **~ая пла́та** шактый түбән хак; **~ая температу́ра** шактый түбән температура; **~ое ка́чество** түбән сыйфат; **челове́к ~ой культу́ры** культурасыз, мәдәниятсез,

(мәдәният өлкәсендә) артта калган кеше; **~ая до́лжность** шактый түбән хезмәт урыны; **быть ~ого мне́ния** *о ком-л.* түбән фикердә булу **3.** *муз.* (*о звуке, голосе*) уртача югарылыктагы

невы́ход *м* **1.** (*неявка на работу*) чыкмау, эшкә чыкмау **2.** (*печатного издания*) чыкмау, басылып чыкмау

не́га *ж* **1.** (*полное довольство*) рәхәт (мул, иркен) тормыш **2.** (*наслаждение*) рәхәт, рәхәтлек, хозурлык, сафа сөрү **3.** (*нежность*) наз; иркәлек

негати́в *м фото* негатив

негативи́зм *м* негативизм (*нәрсәне дә булса артык нигезләмичә яки бөтенләй инкарь итү*)

негати́вн||ый I, -ая, -ое *фото* негатив ...ы; негатив; **~ое изображе́ние** негатив сүрәт

негати́вный II, -ая, -ое кире, тискәре; **~ отве́т** кире җавап

негашён||ый, -ая, -ое: **~ая и́звесть** сүндерелмәгән известь; **~ая ма́рка** файдаланылмаган марка

не́где *нареч.* урын (җир) юк; **~ отдохну́ть** ял итәргә урын юк; **~ жить** торыр җир юк

негиб||и́ть, -ая, -ое **1.** бөгелми торган, сыгылмый торган; **~ие ве́тки** бөгелми торган ботаклар **2.** *перен.* сыгылмалы булмаган, үткен булмаган; **~ий ум** үткен булмаган акыл

негла́сный, -ая, -ое яшерен

негли́пый, -ая, -ое шактый акыллы; акыллы гына; акылсыз (башсыз) түгел

него́дник *м разг.* юньсез

него́дница *ж разг.* юньсез хатын (кыз)

него́дность *ж* яраксызлык; яраксыз хәл; **прийти́ в ~** яраксыз хәлгә килү; **привести́ в ~** яраксыз хәлгә китерү

него́дный, -ая, -ое **1.** (*непригодный*) яраксыз **2.** *разг.* юньсез; **~ мальчи́шка** юньсез малай

негодова́ние *с* көчле (тирән) ачу, ярсу; чиктән тыш зур ризасызлык

негодова́ть *несов.* бик нык ачулану, ярсу; ачу кабару

негоду́ющий, -ая, -ее ачулы, ярсулы, нәфрәтләнеп (бик нык ачуланып) ...ган; **~ проте́ст** бик нык ачуланып белдерелгән протест

негоду́й *м* явыз, кабахәт, бәдбәхет

негоду́йка *ж* кабахәт хатын (кыз)

негр *м* негр

негра́мотность *ж* **1.** наданлык, белемсезлек; **полити́ческая ~** сәяси наданлык **2.** хаталылык; грамотасызлык; **~ сочине́ния** сочинениенең грамотасызлыгы

негра́мотн||ый, -ая, -ое **1.** (*не умеющий читать и писать*) укый-яза белмәгән (белми торган), укый-яза белмәүче, надан, грамотасыз **2.** надан, аз белемле, белемсез; **~ый те́хник** аз белемле техник **3.** хаталы, хаталары (ялгышлары) күп булган; **~ая речь** хаталы сөйләм

негрите́нка *ж* негр хатыны (кызы)

негрите́нск||ий, -ая, -ое негр[лар] ...ы; **~ие пе́сни** негр җырлары

не́гры *мн.* негрлар, негр халкы

не́гус *м ист.* негус (*Эфиопия патшасы титулы*)

неда́вн||ий, -яя, -ее **1.** күптән түгел генә булган, якын арада гына булган; **~ее собы́тие** күптән түгел генә булган вакыйга; **до ~его вре́мени** соңгы вакытка кадәр; **с ~его вре́мени** соңгы вакытларда гына **2.** күптән түгел генә [әле]... булган; баягы; **~ий шко́льник** күптән түгел генә әле мәктәп укучысы булган [кеше]

неда́вно *нареч.* күптән түгел генә, бая гына; якын (шушы) арада гына, яңарак кына

недалёк||ий, -ая, -ое **1.** якындагы, якын; ерак түгел; **~ий путь** якын юл **2.** күптән түгел генә булган, якын арада гына булган; **в ~ом про́шлом** күптән түгел генә **3.** (*только кратк. ф.*) ...дан ерак түгел, ...га якын; **недалёк от и́стины** хакыйкатьтән ерак түгел **4.** *перен.* акылга сай (таман); **~ий челове́к** акылга таман кеше

недалеко́, недалёко *нареч.* **1.** якын, якындагы... **2.** *в знач. сказ.* ерак түгел; **лес отсю́да ~** урман моннан ерак түгел

недальнови́дность *ж* алдан күрмәү, алдан күрә алмау

недальнови́дный, -ая, -ое алдан күрмәүчән (күрә алмаучан)

неда́ром *нареч.* юкка (бушка) гына ...мау, юкка гына ... түгел, сәбәпсез түгел, берәр максат белән; **он пришёл ~** ул юкка гына килмәгән

недви́жимость *ж юр.* күчми торган милек, күчемсез милек

недви́жимый, -ая, -ое **1.** (*неподвижный*) хәрәкәтсез **2.** *юр.* (*об имуществе*) күчми торган

недвижи́мый, -ая, -ое *уст. см.* **недви́жимый** I

недвусмы́сленн||ый, -ая, -ое ике төрле аңлашылмый торган; **~ый отве́т** ачык җавап; **са́мым ~ым о́бразом** һич тә ике төрле аңларга урын калдырмыйча

недееспосо́бность *ж* **1.** эшкә (эш-чәнлеккә) сәләтсезлек **2.** *юр.* юридик сәләтсезлек, хокукка сәләтсезлек (*мөстәкыйль рәвештә юридик эшләр йөртергә һәм үз эшләре өчен җавап бирергә сәләтсез булу*)

недееспосо́бн||ый, -ая, -ое **1.** эшкә сәләтсез, эшкә яраксыз; **~ая организа́ция** эшкә сәләтсез оешма **2.** *юр.* хокукка сәләтсез

недействи́тел||ьный, -ая, -ое гамәлдән чыккан, көче беткән, яраксыз; **биле́т ~ен** билет гамәлдән чыккан

неделика́тный, -ая, -ое әдәпсез, нәзакәтсез, тупасрак

недели́м||ый, -ая, -ое **1.** бүленми торган; **~ый фонд** *фин.* бүленми торган фонд **2.** *мат.* бүленмәүчән; **~ое число́** бүленмәүчән сан

неде́льный, -ая, -ое бер атналык; **в ~ срок** бер атна эчендә; **~ срок** бер атналык срок, бер атна вакыт

неде́л||я *ж* атна; **чере́з ~ю** бер атнадан; **раз в ~ю** атнага бер [тапкыр]; **~я францу́зских фи́льмов** француз фильмнары атналыгы

недержа́ние *с*: **~ мочи́** *мед.* бәвелен (боелыгын) тота алмау (*авыру*)

недисциплини́рованность *ж* дисциплинасызлык, тәртипсезлек

недисциплини́рованный, -ая, -ое дисциплинасыз, тәртипсез

недо- *кушма алкушымча; эш-хәрәкәтнең яки сыйфатның тулы, тулысынча булмавын белдерә, мәс.* **недопе́чь** пешереп җиткермәү; **недопи́ть** эчеп бетермәү

недобо́р *м* җыеп җиткермәү, алып җиткермәү; (*недобранное количество*) җыеп җиткерелмәгән өлеш; **~ при приёме в те́хникум** техникумга кабул иткәндә [студентларны] тиешле санда алып җиткермәү

недобра́ть *сов. что, кого-чего* җыеп җиткермәү; алып җиткермәү

недоброжела́тель *м* дошман, усаллык теләүче, кара йөрәк

недоброжела́тельница *ж* дошман хатын (кыз)

недоброжела́тельн||ый, -ая, -ое **1.** усаллык теләүче, дошман күрүче, кара йөрәкле, усал (яман, начар) ниятле; **~ый челове́к** усал кеше **2.** усал, начар, дошманча ..., дошманлыкны ...ган; **~ый взгляд** усал караш; **~ое отноше́ние** начар мөнәсәбәт

недоброжела́тельство *с* усаллык, дошманлык; явыз уйлылык

недоброка́чественн||ый, -ая, -ое начар сыйфатлы, бозылган, яраксыз; бозык; **~ый материа́л** начар сыйфатлы материал; **~ые проду́кты** бозылган ашамлыклар

недобросо́вестн||ый, -ая, -ое **1.** эшенә игътибарсыз (салкын) караучы, күңел бирмәүче; вөждансыз, намуссыз; **~ый челове́к** намуссыз кеше **2.** начар эшләнгән; игътибарсыз эшләнгән; күңел биреп (тырышып) эшләнмәгән; **~ая рабо́та** күңел биреп эшләнмәгән эш, начар эшләнгән эш

недо́бр||ый, -ая, -ое **1.** (*злой*) усал, явыз, яман; начар **2.** күңелсез, начар; хәерсез; **~ая весть** начар хәбәр, күңелсез хәбәр; **в ~ый час** хәерсез сәгатьтә **3.** дошманлык ...ы; **~ое чу́вство** дошманлык хисе **4.** яман, начар, күңелсез; **~ая молва́** начар (күңелсез) сүзләр; **оста́вить по себе́ ~ю па́мять** үзе турында начар истәлек калдыру **5.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* начар эш, усаллык, усал ният; **заподо́зрить ~ое** күңелгә шик төшү ♦ **~ой па́мяти** *кто-что* күңелсез истәлекле

недова́ривать *несов. см.* **недовари́ть**

недовари́ть *сов. что* пешереп җиткермәү; кайнатып җиткермәү; **~ мя́со** итне пешереп җиткермәү; **~ варе́нье** вареньене кайнатып җиткермәү

недовари́||ться *сов.* пешеп җитмәү; **мя́со ~лось** ит пешеп житмәгән

недове́рие *с* ышанмау, шөбһә, шик, шикләнү; **вы́разить ~** 1) шик белдерү, шик астына алу, шикләнү; 2) *полит.* ышанмаучылык белдерү, ышанычсызлык белдерү; **отнести́сь с ~м** шикләнеп карау, шик белдерү; **пита́ть ~** ышанмау, ышанып карамау, шикләнү

недове́рчивость *ж* ышанмаучылык, шикләнүчәнлек

недове́рчивый, -ая, -ое **1.** ышанмаучан, шикләнүчән; **~ челове́к** ышанмаучан кеше **2.** шөбһәле, шикле, ышанмауны (шикләнүне) чагылдырган; **бро́сить ~ взгляд** шикле караш ташлау

недове́с *м* **1.** *см.* **недове́сить; 2.** (*недостаток в весе*) ким үлчәү, үлчәве җитмәү

недове́сить *сов. что, чего* ким үлчәү, ким итеп үлчәү, үлчәвен җиткермәү

недове́сок *м разг.* ким үлчәүле ...; **мешо́к-~** ким үлчәүле капчык

недове́шивать *несов. см.* **недове́сить**

недово́льный, -ая, -ое **1.** (*о человеке*) ризасыз, канәгатьсез, риза (канәгать) булмаган **2.** (*выражающий недовольство*) канәгатьсез, канәгатьсезлекне (ризасызлыкны) белдерә торган

недово́льство *с* канәгатьсезлек, ризасызлык; канәгатьсез (ризасыз) булу; **вы́разить ~** канәгатьсезлек белдерү; **вы́звать ~** канәгатьсезлек тудыру; **~ собо́й** үз-үзеңнән канәгать булмау

недовыполне́ние *с* **1.** *см.* **недовы́полнить; 2.** (*берәр нәрсәнең*) үтәлеп җитмәгән өлеше, үтәлми калган өлеше, үтәлмәгән өлеше; **~ составля́ет пять проце́нтов пла́на** планның үтәлми калган өлеше биш процент тәшкил итә

недовы́полнить *сов. что* үтәп җиткермәү, тулысынча үтәмәү, үтәми калдыру, тутырып җиткермәү; **~ план** планны үтәп җиткермәү

недовыполня́ть *несов. см.* **недовы́полнить**

недогляде́ть *сов. разг.* **1.** *что, чего и без доп.* күрми калдыру, күреп (карап) җиткермәү; ычкындыру; **~ оши́бки** хаталарны күрми калдыру **2.** *за кем-чем* яхшы[лап] карамау; **~ за ребёнком** баланы яхши карамау

недогова́ривать *несов. см.* **недогвори́ть**

недоговорённость *ж* **1.** (*несогласованность*) алдан сөйләшеп (килешеп) куймау, үзара алдан килешмәү **2.** (*умалчивание*) әйтеп бетермәү (җиткермәү), ачык итеп әйтмәү

недоговори́ть *сов. что, чего и без доп.* әйтеп бетермәү (җиткермәү), ачык итеп әйтмәү

недоде́лка *ж* **1.** (*незаконченность*) эшләнеп бетмәү, тәмамланып җитмәү **2.** (*изъян*) кимчелек, житешсезлек

недоеда́ние *с* ачлы-туклы яшәү

недоеда́ть *несов.* **1.** *см.* **недое́сть; 2.** (*жить впроголодь*) ачлы-туклы яшәү

недодержа́ть *сов. что, фото* аз тоту, тотып җиткермәү (*выдержка турында*)

недоде́рживать *несов. см.* **недодержа́ть**

недоде́ржка *ж см.* **недодержа́ть**

недое́сть *сов.* (*поесть недостаточно*) туйганчы ашамау, аз ашау

недозво́ленный, -ая, -ое тыелган, ярамаган; **~ приём** тыелган алым

недозре́л||ый, -ая, -ое пешмәгән, өлгермәгән; **~ое я́блоко** өлгермәгән алма

недои́мка *ж* недоимка (*салымның вакытында түләнми калган өлеше*)

недои́мщик *м* недоимщик (*салымны вакытында тулысынча түләп бетермәүче кеше*)

недолга́: [вот] и вся ~ [менә] шуның белән бетте китте дә, вәссәлам

недо́лг||ий, -ая, -ое аз [гына], кыска [гына]; **~ое вре́мя** аз [гына] вакыт; **по́сле ~ого колеба́ния** аз гына икеләнеп торганнан соң

недо́лго *нареч.* **1.** аз [гына], аз вакыт, озак (күп) ...мау; **бой дли́лся ~** сугыш озакка сузылмады; **~ ду́мая** күп уйлап тормастан **2.** *в знач. сказ. разг.* озак түгел; **и утону́ть ~** батып китүең дә озак түгел

недолёт *м воен.* очып барып җитмәү, җитә алмау, якынрак төшү (*пуля, снаряд һ.б.ш. турында*)

недоли́в *м* ким салу, ким агызу

недолю́бливать *несов. кого-что* яратып җиткермәү (бетермәү), өнәмәү, өнәп бетермәү

недоме́ривать *несов. см.* **недоме́рить**

недоме́рить *сов. что, чего* ким үлчәү, үлчәп җиткермәү

недоме́рок *м* үлчәве (күләме) ким булган әйбер

недомога́ние *с* хәлсезлек, сихәтсезлек, бераз хәл китеп тору, бераз хәлсезләнеп (кәеф китеп, авырып) тору; **лёгкое ~** бераз хәлсезлек; **испы́тывать ~** бераз хәл китеп тору

недомога́ть *несов.* хәлсезлек сизү, хәлсезләнеп торү, кәеф китеп тору, бераз авырып тору, сырхау булу

недомо́лвка *ж* әйтеп бетермәгән сүз (уй, фикер), әйтелеп бетмәгән сүз (уй, фикер); әйтеп бетермәү

недомы́слие *с* тиешенчә уйлап җиткермәү; ахмаклык, юләрлек

недоно́сок *м* җитлекми туган [бала], җитлеклмәгән бала

недоно́шенный, -ая, -ое җитлекми туган; **~ ребёнок** җитлекми туган бала

недооце́нивать *несов. см.* **недооцени́ть**

недооцени́ть *сов. кого-что, чего* бәя биреп җиткермәү, бәя бирмәү

недооце́нка *ж см.* **недооцени́ть**

недопусти́мый, -ая, -ое ярамаган, [һич тә] ярамый торган

недора́звитость *ж* **1.** (*животного, растения*) җитлекмәгәнлек, үсми калганлык, үсеп җитмәгәнлек **2.** (*человека*) акыл ягыннан артта калганлык

недора́звитый, -ая, -ое **1.** (*о животных и растениях*) җитлекмәгән, үсми калган, үсеп җитмәгән **2.** (*о человеке*) акыл ягыннан артта калган

недоразуме́н||ие *с* **1.** (*путаница, ошибка*) аңлашмау[чылык], аңлашылмау [-чылык], аңлап җиткермәү; ялгышлык, хаталык; **по ~ю** ялгышлык белән **2.** (*несогласие*) үзара килешмәү, аңлашмау, аңлашмаучылык; каршылыклар; (*ссора*) орыш-талаш, тавыш

недоро́д *м см.* **неурожа́й**

не́доросль *м* **1.** *ист.* балигъ булмаган яшүсмер (*18 гасырда Россиядә: балигъ булмаган һәм әле дәүләт хезмәтенә кермәгән яшь дворян*) **2.** *разг. ирон.* аңгырарак надан яшүсмер

недосмо́тр *м* карап җиткермәү; игътибар белән карамау, игътибарсызлык; **по ~у** игътибарсызлык аркасында

недосмотре́ть *сов. см.* **недоглядéть**

недосо́л *м* тозлап җиткермәү, тозланып җитмәү, тозы җиңел булу

недоставá||ть *несов. безл. кого-чего* **1.** җитмәү, җитешмәү, җитеп бетмәү; тётмәү; **у него́ ~ло терпе́ния** аның түземлеге җитми иде **2.** булмау, юк булу, җитмәү; **на руке́ у него́ ~ло па́льца** кулының бер бармагы юк иде ♦ **э́того [ещё, то́лько] ~ло!** шул гына җитмәгән иде!

недоста́т||ок *м* **1.** җитмәү, җитешмәү, җитәрлек булмау, аз булу, азлык; тарлык, тар булу; кытлык; **~ок во́здуха** һаваның аз булуы; **за ~ком вре́мени** вакыт җитмәү аркасында; **~ок рабо́чей си́лы** эшче көчләрнең җитешмәве **2.** *обычно мн.* **~ки** *разг.* (*нужда*) мохтаҗлыклар; кысынкылык; кытлык **3.** (*изъян*) кимчелек, җитешсезлек; чатаклык; кимчелекле як, җитешсез як ♦ **нет ~ка** *в ком-чём* мохтаҗлык юк, җитәрлек

недоста́точно *нареч.* **1.** бик ук яхшы ...мау, җитәрлек [дәрәҗәдә] ...мау; **ты его́ ~ зна́ешь** син аны бик ук яхшы белмисең; **он знал язы́к ~ твёрдо** телне ул бик ук яхшы белми иде **2.** *в знач. сказ. безл.* аз, ким, җитеп бетми; **э́того ~** бу гына җитеп бетми

недоста́точность *ж* **1.** азлык, җитәрлек булмау; **~ при́нятых мер** күрелгән чараларның җитәрлек булмавы **2.** канәгатьләндерерлек булмау; **~ отве́та** җавапның канәгатьләндерерлек булмавы ♦ **серде́чная ~** *мед.* йөрәк эшчәнлегенең житкелекле булмавы

недоста́точн||ый, -ая, -ое **1.** (*не удовлетворяющий потребности*) аз, җитәрлек булмаган, җитәрлек ...мау; җитәрлек түгел **2.** канәгатьлән[дер]ерлек (җитәрлек, тулы) булмаган; канәгатьлән[дер]ерлек (тулы) түгел; **~ые све́дения** тулы булмаган мәгълүматлар; **отве́т был соверше́нно ~ым** җавап һич тә канәгатьләнерлек түгел иде

недоста́ть *сов. см.* **недоставáть**

недоста́ч||а *ж разг.* ким чыгу, өстенә чыгу; җитмәү, җитешмәү, чыкмау; **~а в семь рубле́й** өстенә жиде сум акча чыккан; **обнару́жить ~у** акча (материал, продукт *һ.б.ш.*) ким чыгу, өстенә чыгу

недостаю́щ||ий, -ая, -ее булмаган, җитмәгән; **~ая страни́ца** җитмәгән бит

недостижи́м||ый, -ая, -ое ирешә алмаслык, ирешүе мөмкин булмаган, ирешерлек булмаган; тормышка ашмаслык; **~ая цель** ирешә алмаслык максат

недосто́йный, -ая, -ое **1.** *кого-чего* лаек булмаган; лаек түгел; **~ внима́ния факт** игътибарга лаек булмаган факт **2.** түбән, ихтирамга лаек булмаган; **~ челове́к** түбән кеше **3.** килешмәгән,

әдәпсез, түбән; ~ **посту́пок** әдәпсез кыланыш

недосу́г *м разг.* вакыт булмау, вакыт юклык; вакыт юк; **ему́** ~ аның вакыты юк; **за** ~**ом** вакыт булмау сәбәпле

недосчита́ться *сов.* ким чыгу, житмәү, чыкмау

недосчи́тываться *несов. см.* **недосчита́ться**

недосяга́ем||ый, -ая, -ое *см.* **недостижи́мый**

недотёпа *м, ж прост.* аңгыра, җебегән, булмаган, булдыксыз, мәми авыз

недотро́га *м, ж разг.* сүз күтәрми, чебен тимәс чер итә, серкәсе су күтәрми (*бик тиз хәтере калучан кеше турында*)

недоу́здок *м* нукта (*авызлыксыз йөгән*)

недоумева́ть *несов.* аңлап житкерә алмау, төшенеп житә алмау, аптырау, аптырап (аптырашта) калу, гаҗәпләнү

недоуме́ни||е *с* аптырау, аптыраш; **быть в** ~**и** аптырау; **смотре́ть с** ~**ем** аптырап карап тору

недоу́чка *м, ж разг.* сай белемле, төпле белем алмаган, надан кеше

недочёт *м* **1.** җитмәү, кимлек, ким булу; ~ **су́ммы** сумманың ким булуы **2.** *обычно мн.* ~**ы** житешсезлекләр, кимчелекләр; ялгышлыклар; **вы́явить** ~**ы в рабо́те** эштәге җитешсезлекләрне ачу

не́дра *только мн.* жир асты; **в** ~**х земли́** жир астында; **земны́е** ~ жир асты; **развёдка недр** жир асты байлыкларын тикшерү

недрема́нн||ый, -ая, -ое *уст.*: ~**ое о́ко** *ирон.* уяу (сизгер) күзәтче

недре́млющий, -ая, -ее уяу, сизгер

не́друг *м* дошман

неду́г *м* авыру, сырхау, чир

недурн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*неплохой*) шактый яхшы, яхшы гына; начар түгел **2.** (*довольно красивый*) матур (сылу) гына, чибәр (күркәм) генә

недю́жинн||ый, -ая, -ое *см.* **незауря́дный**; ~**ые спосо́бности** гадәттән тыш зур сәләт

неесте́ственн||ый, -ая, -ое **1.** (*деланный*) ясалма, табигый булмаган **2.** көчләп ...г; **он у́мер** ~**ой сме́ртью** ул үз үлеме белән үлмәгән

нежда́нно *нареч.*: ~**-нега́данно** һич тә көтмәгәндә, уйламаган җирдән, уйламаганда

нежда́нный, -ая, -ое көтелмәгән

нежела́ние *с* теләмәү, теләк булмау

нежела́тельн||ый, -ая, -ое күңелсез, теләмәгән, күңелгә ятмаган, кирәкмәгән; ~**ые после́дствия** кирәкмәгән нәтиҗәләр

не́жели *союз. уст.* ...га караганда, ...да; **он умне́е,** ~ **брат** ул энесеннән акыллырак

нежена́тый, -ая, -ое буйдак, өйләнмәгән

не́женка *м, ж разг.* иркә, назлы бикә

нежив||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*мёртвый*) җансыз, үле, үлгән **2.** (*неорганический*) җансыз, терек булмаган; ~**а́я приро́да** җансыз табигать **3.** *перен.* (*лишённый жизненности*) җансыз, сүлпән, сүрән; ~**о́й взгляд** җансыз караш

нежил||о́й, -а́я, -о́е **1.** кеше тормый [яшәми] торган, буш; ~**о́й дом** кеше тормый торган өй **2.** (*не предназначенный для жилья*) кеше торыр өчен корылмаган (төзелмәгән); ~**о́е помеще́ние** кеше торыр өчен төзелмәгән бина

не́жить *несов. кого-что* иркәләү, назлау, наз итү

не́житься *несов.* иркәләнү, назлану

не́жничать *несов. с кем и без доп., разг.* иркәләү, назлау, иркәләү сүзләре сөйләү (әйтү), ягымлы сүзләр әйтү; иркәләнү, назлану

не́жност||ь *ж* **1.** наз, ягымлылык, мөлаемлык; ~**ь взгля́да** карашның мөлаемлыгы **2.** (*мягкость, приятность*) нәфислек **3.** *обычно мн.* ~**и** (*нежные слова*) иркәләү сүзләре, ягымлы (татлы, назлы) сүзләр; **говори́ть** ~**и** ягымлы сүзләр сөйләү ♦ **что за** ~**и!** бу нинди назланулар тагы!

не́жн||ый, -ая, -ое **1.** назлы, ягымлы, мөлаем; иркәләү ...ы; ~**ый взгляд** мөлаем караш; ~**ый го́лос** ягымлы тавыш; ~**ые слова́** ягымлы сүзләр **2.** нәфис; ~**ый арома́т** нәфис ис; ~**ый цвет** нәфис төс; ~**ый цвето́к** нәфис чәчәк; ~**ая ко́жа** нәфис тире (тән) **3.** (*изнеженный*) иркә, назлы; ~**ый ма́льчик** назлы малай ♦ ~**ый во́зраст** сабый (бала, яшь) чак

незабве́нный, -ая, -ое *высок.* [мәңге] онытылмас[лык]

незабу́дка *ж* күгәрчен күзе, чыпчык күзе (*чәчәк*)

незабыва́емый, -ая, -ое онытылмас[лык], тирән тәэсирле

незави́дн||ый, -ая, -ое кызыксыз, кызыгырлык булмаган; кызыгырлык түгел, начар; ~**ое положе́ние** кызыксыз хәл; **игра́ть** ~**ую роль** *в чём берәр нәрсәдә* начар роль уйнау

незави́симост||ь *ж* бәйсезлек, мөстәкыйльлек; **экономи́ческая** ~**ь** икътисадый бәйсезлек; **полити́ческая** ~**ь** сәяси бәйсезлек; **провозглаше́ние** ~**и** бәйсезлек игълан итү

незави́сим||ый, -ая, -ое **1.** бәйсез, мөстәкыйль; ирекле, хәр; **быть** ~**ым** бәйсез булу; ~**ые стра́ны** бәйсез илләр; ~**ый хара́ктер** мәстәкыйль характер **2.** (*обособленный*) бәйле булмаган

независи́сящ||ий, -ая, -ее: **по** ~**им обстоя́тельствам** ...га бәйле булмаган сәбәпләр (хәлләр) аркасында

незада́ча *ж разг.* уңышсызлык, эш уңмау

незада́чливый, -ая, -ое *разг.* **1.** уңышсыз, бәхетсез; ~ **день** уңышсыз көн **2.** *см.* **неуда́чливый**

незадо́лго *нареч.* алдыннан [гына]; ~ **до войны́** сугыш башланыр алдыннан

незаконнорождённ||ый, -ая, -ое никахтан тыш туган

незамедли́тельный, -ая, -ое тоткарсыз, кичектерүсез, кичекмәстән ..., тиз; **дать** ~ **отве́т** тоткарсыз җавап бирү

незаменим||ый, -ая, -ое алмаштыргысыз, алыштыргысыз, алмашы булмаган, бик кирәкле; ~**ая вещь** бик кирәкле әйбер

незаме́тно *нареч.* **1.** сиздермичә [генә], сиздермәстән, белдермичә [генә], шыпырт кына; акырын гына; ~ **вы́йти из ко́мнаты** сиздермичә генә бүлмәдән чыгып китү **2.** сизелмичә, сизмәстән, тоймастан; **вре́мя прошло́** ~ вакыт сизелмичә үтеп китте; ~ **мы спра́вились с э́той рабо́той** бу эшне без үзебез дә сизмәстән башкарып чыктык **3.** *в знач. сказ. безл.* сизелми, беленми, күренми; **по его́ ви́ду** ~**, что он уста́л** аның кыяфәтеннән аруы сизелми

незаме́тный, -ая, -ое **1.** (*неприметный*) беленмәслек, күзгә күренмәслек, беленми торган, күзгә күренми (ташланмый) торган; беленер-беленмәс; ~**шов** беленер-беленмәс җәй **2.** (*неощутимый*) сизмәслек, сизелмәслек, сизелми торган; сизелер-сизелмәс[лек] **3.** *перен.* күренексез, күзгә ташланмый торган, башкалардан аерылмый торган, урта кул ...; ~ **рабо́тник** урта кул эшче

незаму́жняя, -ее кияүгә чыкмаган, иргә бармаган

незамыслова́тый, -ая, -ое гади, катлаулы булмаган; ~ **узо́р** гади бизәк

незапа́мятн||ый, -ая, -ое бик күптәнге, бик борын[гы]; **с** ~**ых времён** бик борын заманнан

незапланиро́ванный, -ая, -ое планда каралмаган, планлаштырылмаган

незапя́тнанный -ая, -ое тапсыз, тап төшмәгән, саф, керсез; ~**ая репута́ция** керсез репутация

незара́зный, -ая, -ое йогышсыз, йогышлы булмаган

незаслу́женный, -ая, -ое тиешсез, урынсыз, урынсызга ...; нахакка, хаксызга

незате́йливый, -ая, -ое гади, артык катлаулы булмаган

незауря́дный, -ая, -ое гадәттән тыш [зур], башкалардан аерылып тора торган

не́зачем *нареч.* кирәге юк, мәгънә юк; **остава́ться там** ~ анда калуның кирәге юк

незва́ный, -ая, -ое чакырылмаган, чакырылмый (чакырусыз) килгән; ~ **гость** чакырылмаган кунак

нездорови́ться *несов. безл. кому* авырып тору, авырыксынып тору, хәлсезләнеп тору, хәл булмау, кәеф булмау

нездоро́в||ый, -ая, -ое **1.** авыру, чирле; саулыксыз, саусыз, сихәтсез; ~**ый вид** авыру кыяфәт **2.** сәләмәтлек өчен зарарлы, саулык өчен зарарлы; ~**ый кли́мат** саулык өчен зарарлы климат **3.** сау (сәламәт) түгел, авырый, чирли, авырып (чирләп) тора; **он сего́дня нездоро́в** ул бүген авырып тора **4.** *перен.* начар, нормаль булмаган; ~**ые отноше́ния** нормаль булмаган мөнәсәбәтләр; ~**ая обстано́вка** начар обстановка

нездоро́вье *с* саулыксызлык, саусызлык, сәләмәтсезлек, хәлсезлек

незло́бивость, незлоби́вость *ж* эчкерсезлек, йомшак күңеллелек; юашлык

незло́бивый, -ая, -ое, **незлоби́вый**, -ая, -ое эчкерсез, йомшак күңелле; юаш

незло́бный, -ая, -ое эчкерсез, йомшак күңелле, шәфкатьле; юаш; усалтүгел

незлопа́мятный, -ая, -ое кинә тотмаучан (сакламаучан), эчкерсез

незнако́мец *м* таныш булмаган кеше, ят [бер] кеше, чит [бер] кеше

незнако́мка *ж* ят хатын (кыз)

незнако́м||ый, -ая, -ое **1.** таныш булмаган, белмәгән, күрмәгән, ят, чит; **~ый челове́к** таныш булмаган кеше; **~ое чу́вство** чит бер хис **2.** белми; **вы ~ы с жи́знью** сез тормышны белмисез **3.** танымый, белми; таныш түгел; **мы с ним ~ы** без аның белән таныш түгел

незна́ние *с* белмәү[челек], хәбәрдар булмау

незна́чащий, -ая, -ее әһәмиятсез, буш; **~ разгово́р** буш сүз

незначи́тельный, -ая, -ое **1.** (*небольшой*) кечкенә, аз; зур түгел, күп түгел; юклы-барлы; **~ая су́мма** кечкенә сумма **2.** (*маловажный*) әһәмиятсез, әһәмияте аз булган, әһәмияте булмаган; исәпкә алынмаслык, игътибарга алынмаслык, кечкенә, вак; **~ое обстоя́тельство** кечкенә бер сәбәп; **~ые ро́ли** кечкенә рольләр **3.** кечкенә [генә]; **оказа́ть ~ую услу́гу** кечкенә генә хезмәт күрсәтү; **~ая про́сьба** кечкенә бер үтенеч

незре́лость *ж* **1.** пешмәгәнлек, пешеп җитмәгәнлек, өлгермәгәнлек, яшеллек **2.** *перен.* җитлекмәгәнлек, чиле-пешле булу

незре́л||ый, -ая, -ое **1.** пешмәгән, пешеп җитмәгән, өлгермәгән, яшел; **~ое я́блоко** өлгермәгән алма **2.** *перен.* җитлекмәгән, чиле-пешле; **~ый рома́н** чиле-пешле роман

незри́мый, -ая, -ое (*невидимый*) сизелмәс[лек], беленмәс[лек], күзгә күренмәс[лек], күзгә ташланмый торган

незы́блем||ый, -ая, -ое *книжн.* какшамас, җимерелмәс, нык; **~ая осно́ва** какшамас нигез

неизбе́жность *ж* котылгысызлык

неизбе́жный, -ая, -ое котылгысыз

неизбы́вн||ый, -ая, -ое *книжн.* онытылмас, онытылмый торган, бетмәс, бетми торган, узмый торган; **~ая тоска́** онытылмас сагыш

неизве́данн||ый, -ая, -ое **1.** тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән; **~ый край** өйрәнелмәгән як **2.** сыналмаган, белмәгән, билгесез, [баштан] кичермәгән, баштан узмаган; **~ое чу́вство** кичермәгән бер тойгы

неизве́стно *нареч. в знач. сказ. безл.* билгеле (мәгълүм) түгел, билгесез; белми, хәбәрдар түгел; **мне э́то ~** бу турыда мин белмим; **что да́лее произошло́, ~** соңыннан ни булганы билгеле түгел; **э́то ещё ~!** монысы әле билгеле түгел!

неизве́стность *ж* **1.** билгесезлек, билгеле (мәгълүм, таныш) булмау **2.** (*скромное существование*) күренексез булу, танылмаган булу, мәшһүр булмау; тыйнак (билгесезлектә) яшәү

неизве́стн||ый, -ая, -ое **1.** билгесез, билгеле (мәгълүм, таныш) булмаган, белмәгән; ят; билгеле (мәгълүм, таныш) түгел; **~ая доро́га** белмәгән юл; **~ые зе́мли** таныш булмаган җирләр; **~ое чу́вство** таныш булмаган бер хис **2.** күренексез, күренекле булмаган, билгесез, танылмаган; **~ый худо́жник** билгесез рәссам; **~ый арти́ст** танылмаган бер артист **3.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* таныш булмаган кеше, ят [бер] кеше, чит [бер] кеше, белмәгән кеше **4.** *в знач. сущ.* **~ое** *с мат.* билгесез

неизглади́м||ый, -ая, -ое онытылмас[лык], хәтердән чыкмас[лык], тирән; **~ое впечатле́ние** тирән тәэсир

неизлечи́м||ый, -ая, -ое төзәлми (бетми) торган, дәвалап булмый торган; **~ая боле́знь** дәвалап булмый торган авыру

неизме́нн||ый, -ая, -ое **1.** (*не меняющийся*) үзгәрми торган, үзгәрмәс, үзгәрешсез, үзгәртелми торган, даими; **~ое пра́вило** үзгәрми торган кагыйдә; **~ая величина́** *мат.* үзгәрмәс зурлык **2.** гадәттәге, һәрвакыттагы, һәрвакыт ...а торган; **на нём был ~ый халат** аның өстендә һәрвакыт кия торган халаты иде ◆ **~ый друг** чын дус

неизменя́ем||ый, -ая, -ое үзгәрми торган, үзгәрмәс; төрләнми торган; **~ые ча́сти ре́чи** *грам.* төрләнми торган сүз төркемнәре

неизмери́м||ый, -ая, -ое чагыштыргысыз, чагыштыргысыз дәрәҗәдә зур (күп, көчле *һ.б.ш.*), үлчәп (санап, исәпләп) бетерә алмаслык, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз; **~ая ра́зница** чагыштыргысыз дәрәҗәдә зур аерма; **~ые простра́нства** иксез-чиксез киңлекләр

неизъясни́мый, -ая, -ое аңлатып бирә алмаслык, аңлатып булмый торган, аңлатылмаслык, сүз (тел) белән аңлатып бирә алмаслык

неиме́ни||е *с*: **за ~ем** *кого-чего* булмау сәбәпле, ... юклыгы аркасында

неимове́рн||ый, -ая, -ое чиктән тыш зур (күп), гадәттән тыш зур (күп); **с ~ой быстрото́й** чиктән тыш зур тизлек белән; **с ~ым трудо́м** чиктән тыш зур кыенлык белән

неиму́щий, -ая, -ее ярлы, фәкыйрь

неинтере́сн||ый, -ая, -ое **1.** кызыксыз, кызыклы (кызыктырырлык, кызыксынырлык, кызыксындырырлык) булмаган; **~ая кни́га** кызыксыз китап **2.** сөйкемсез, матур (чибәр) булмаган; **~ая же́нщина** сөйкемсез хатын

неискорени́мый, -ая, -ое нык тамыр җәйгән (җибәргән), нык урнашкан, төзәтүе кыен булган, бетерелмәс[лек]

нейскренний, -яя, -ее **1.** икейөзле, риялы, эчкерле; **~ челове́к** икейөзле кеше **2.** чын (ихлас, саф) күңелдән булмаганлык; ясалмалылык; икейөзлелек, эчкерлелек

неискушённость *ж* тәжрибәсезлек, тәжрибәсе булмаганлык

неискушённый, -ая, -ое тәжрибәсез, тәжрибәсе булмаган; **~ в поли́тике челове́к** сәясәттә тәжрибәсе булмаган кеше

неисполне́ние *с* үтәмәү

неисполни́м||ый, -ая, -ое үти алмаслык, үтәлмәслек, үтәве (үтәлүе) мөмкин булмаган; тормышка ашмаслык (ашмый торган); **~ая мечта́** тормышка ашмаслык теләк

неиспо́рченный, -ая, -ое бозылмаган, әхлаклы, саф

неисправи́мый, -ая, -ое төзәлмәс, төзәтүе мөмкин булмаган, төзәтүе кыен булган

неиспра́вность *ж* ватыклык, бозык булу, эшкә ярамау, эшкә яраксыз булу, [эшкә] яраксызлык

неиспра́вный, -ая, -ое **1.** ватык, бозык, [эшкә] яраксыз; **~ механи́зм** бозык механизм **2.** игътибарсыз, вакытында ...маучы; **~ плате́льщик** түләүләрен вакытында түләмәүче

неиссле́дованный, -ая, -ое **1.** [фәнни яктан] тикшерелмәгән, өйрәнелмәгән **2.** (*о местности*) тикшереп (карап) чыгылмаган

неиссяка́ем||ый, -ая, -ое бетмәс, бетмәс-төкәнмәс, беткесез, чиктән тыш күп (зур); **~ые бога́тства** бетмәс-төкәнмәс байлыклар; **~ая эне́ргия** бетмәс-төкәнмәс энергия

нейстовство *с* **1.** котырыну, ярсу, ду килү; **приходи́ть в ~** ярсу; **приводи́ть в ~** ярсыту **2.** (*жестокость*) ерткычлык, вәхшилек, кансызлык, рәхимсезлек

нейстовствова||ть *несов.* **1.** котыру, котырыну, ярсу, ду килү; **пу́блика в теа́тре ~ла** театрдагы халык ду килде **2.** (*зверствовать*) ерткычлык (вәхшилек) күрсәтү, кансызлык (рәхимсезлек) күрсәтү

нейстов||ый, -ая, -ое ярсулы, котырынкы, котырынган; **~ые аплодисме́нты** ярсулы алкышлар; **~ая бу́ря** котырынган буран

неистощи́м||ый, -ая, -ое беткесез, бетмәс, бетмәс-төкәнмәс, иксез-чиксез [күп], чиксез[күп]; **~ые бога́тства** бетмәс-төкәнмәс байлыклар; **~ый вы́думщик** сүзе бетмәс-төкәнмәс мәзәкче

неистреби́мый, -ая, -ое бетерә алмаслык, бетмәс, кырып бетергесез (бетерә алмаслык), юк ителмәслек

неисчерпа́емый, -ая, -ое *см.* **неистощи́мый**

неисчисли́мый, -ая, -ое санап бетергесез, исәпсез күп, исәпсез-хисапсыз, бихисап

нейло́н *м* нейлон

нейло́нов||ый, -ая, -ое нейлон ...; **~ые чулки́** нейлон оеклар

нейро́н *м* нейрон (*нерв күзәнәге*)

нейрохиру́рг *м* нейрохирург

нейрохиру́ргия *ж* нейрохирургия (*медицинаның нерв системасындагы органик авыруларны хирургия методы белән дәвалауны өйрәнә торган бүлеге*)

нейрохирурги́ческий, -ая, -ое нейрохирургик, нейрохирургия ...ы

нейтрализа́ция *ж см.* **нейтрализова́ть**

нейтрализова́ть *сов., несов. кого-что* нейтральләштерү, нейтрализацияләү

нейтралите́т *м* нейтралитет, катнашмаучылык, битарафлык

нейтра́льность *ж* нейтральлек, нейтраль булу, битарафлык

нейтра́льн||ый, -ая, -ое **1.** нейтраль, битараф; **~ое госуда́рство** нейтраль дәүләт **2.** *хим.* нейтраль; **~ый раство́р** нейтраль эремә

нейтри́но *с физ.* нейтрино

нейтро́н *м физ.* нейтрон

некази́стый, -ая, -ое *разг.* күрексез, шыксыз, килбәтсез; күренексез

некапиталисти́ческий, -ая, -ое капиталистик булмаган; **~ путь разви́тия** үсешнең капиталистик булмаган юлы

нека́чественный, -ая, -ое сыйфаты начар булган, сыйфатсыз; **~ това́р** сыйфатсыз товар

не́кий *мест.* **1.** *см.* **не́который** 1; **2.** ... исемле (дигән) ниндидер бер кеше; ... исемле (дигән) берәү; **пришёл ~ Ивано́в** Иванов дигән ниндидер бер кеше килде; **~ арти́ст** ниндидер бер артист

некла́ссовый, -ая, -ое сыйнфый булмаган; **~ подхо́д** *к чему-л.* сыйнфый булмаган мөнәсәбәт

не́когда I *нареч. в знач. сказ.* вакыт юк; **ему́ сего́дня ~** бүген аның вакыты юк

не́когда II *нареч.* (*давно*) кайчандыр, әллә кайчан, бик күптән

не́кого *мест.* ...лык кеше юк; ...ырга кеше юк; ...р кеше юк; **~ посла́ть** җибәрерлек кеше юк

некомпете́нтность *ж* компетентлы (компетенцияле) булмаганлык, компетентсызлык

некомпете́нтный, -ая, -ое компетентлы (компетенцияле) булмаган, компетентсыз

некомпле́ктный, -ая, -ое комплектсыз, тулы комплектлы булмаган

некорре́ктный, -ая, -ое **1.** нәзакәтсез, әдәпсез; **~ посту́пок** нәзакәтсез кыланыш, нәзакәтсезлек **2.** *шахм.* ялгыш, дөрес исәпләнмәгән

не́которы||й, -ая, -ое *мест.* **1.** беркадәр, берникадәр; **~ое вре́мя** берникадәр вакыт; **~ое расстоя́ние** берникадәр ара; **чу́вствовать ~ую нело́вкость** берникадәр уңайсызлык сизү **2.** *мн.* **~ые** (*не все, отдельные*) кайбер; **~ые друзья́** кайбер дуслар **3.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* кайберәүләр; **~ые из нас** кайберләребез ◆ **в ~ом ро́де** билгеле бер дәрәҗәдә, күпмедер дәрәҗәдә, берникадәр; **~ым о́бразом** берникадәр [дәрәҗәдә], күпмедер дәрәҗәдә

некраси́вый, -ая, -ое **1.** ямьсез, шыксыз, килбәтсез, күрексез; матур түгел **2.** *разг.* ямьсез; **~ посту́пок** ямьсез кыланыш

некро́з *м мед.* некроз (*тукыманың үлүе*)

некроло́г *м* некролог

некро́поль *м* некрополь (*борынгыда зур зират, каберлек*)

некста́ти *нареч.* (*не вовремя*) вакытсыз; (*не к месту*) урынсыз

нектар *м бот.* нектар

не́кто *мест.* **1.** (*кто-то*) кемдер, ниндидер бер кеше **2.** ...исемле (дигән) берәү, ...исемле (дигән) ниндидер бер кеше; **прихо́дил ~ Ивано́в** Иванов дигән берәү килгән иде

не́куда *нареч. с неопр.* **1.** [һичкая] ...ыр урын юк, [һичкая] ...ыр җир юк; **е́хать ~** [һичкая] барыр урын юк **2.** *разг.* моннан да ...рак булырга мөмкин түгел; **сильне́е ~** моннан да көчлерәк булырга мөмкин түгел ◆ **~ торопи́ться** ашыгырга урын юк

некульту́рность *ж* мәдәниятсезлек, мәгърифәтсезлек, тәрбиясезлек, дорфалык

некульту́рн||ый, -ая, -ое **1.** (*отсталый*) мәдәниятсез, мәгърифәтсез, надан, белемсез; укымышлы түгел **2.** тәрбиясез, гадәтсез, дорфа; **~ый челове́к** дорфа кеше **3.** тәрбиясез (дорфа) кешегә хас; дорфа; **~ые привы́чки** дорфа гадәтләр **4.** (*о растениях*) культуралаштырылмаган, кыргый

нела́дн||ый, -ая, -ое *разг.* ямьсез, шыксыз, килбәтсез, начар ◆ **будь он нела́ден** кәһәр суккыры; **произошло́ что́-то ~ое** ниндидер күңелсезлек килеп чыккан

нелады́ *только мн. разг.* **1.** (*ссоры*) ызгыш, орыш-талаш, үзара тынышмау[чылык] **2.** (*неудачи*) уңышсызлыклар **3.** (*неполадки*) җитешсезлекләр, кимчелекләр

нелега́льность *ж* легаль булмаганлык, легаль булмау

нелега́льный, -ая, -ое легаль булмаган, яшерен

нелёгк||ий, -ая, -ое **1.** (*значительный по весу*) шактый авыр **2.** (*трудный*) шактый авыр, шактый кыен ◆ **~ая принесла́** *кого, прост.* кирәге бер тиен иде, пычагыма килдеме (*вакытсыз килү турында*)

нелепи́ца *ж разг. см.* **нелепость** 2

нелепост||ь *ж* **1.** мәгънәсезлек, тозсызлык; **~ь слу́хов** хәбәрләрнең мәгънәсезлеге **2.** мәгънәсезлек, мәгънәсез кыланыш (*сүз һ.б.ш.*); тозсыз сүз; **говори́ть ~и** мәгънәсез сүзләр сөйләү

нелеп||ый, -ая, -ое **1.** (*бессмысленный*) мәгънәсез, тозсыз **2.** шыксыз, ятышсыз, килешсез, килбәтсез; **~ая фигу́ра** шыксыз фигура

нелёт||ый, -ая, -ое очарга ярамый торган, очу өчен яраксыз; **~ая пого́да** очарга ярамый торган һава

неликви́д *м фин.* неликвид

неликви́дн||ый, -ая, -ое *фин.* файдаланылмау сәбәпле сатылырга тиешле; **~ые материа́лы** файдаланылмау сәбәпле сатылырга тиешле материаллар

нелицеприя́тн||ый, -ая, -ое *книжн.* гадел, риясыз, туры; кемнең кем булуына карамастан...; **~ая кри́тика** риясыз тәнкыйть

нели́шне *нареч. в знач. сказ. с неопр. разг.* артык булмас, зарары булмас

нело́вк||ий, -ая, -ое **1.** (*неуклюжий*) авыр хәрәкәтле; авыр сөякле; авыр **2.** (*неудобный*) уңайсыз, җайсыз, ипсез **3.** (*неприятный*) күңелсез, уңайсыз; килешсез, килешмәгән; **попа́сть в ~ое положе́ние** уңайсыз хәлгә калу

нело́вко *нареч.* **1.** уңайсыз, җайсыз **2.** *в знач. сказ. безл.* уңайсыз, җайсыз, ипсез; **на э́том сту́ле сиде́ть ~** бу урындыкта утыруы җайсыз **3.** *в знач. сказ. безл. кому* уңайсыз; **мне ~ говори́ть об э́том** бу турыда сөйләп торуы миңа уңайсыз

нело́вкост||ь *ж* **1.** авыр хәрәкәтлелек; авыр сөяклелек; авырлык; җайсызлык, уңайсызлык, ипсезлек; **~ь движе́ний** хәрәкәтләрнең җайсызлыгы **2.** килешмәгән эш (кыланыш, сүз); **соверши́ть ряд ~ей** килешмәгән эшләр эшләп ташлау **3.** уңайсызлык; **чу́вствовать ~ь** уңайсызлык сизү, уңайсызлану

нелоги́чный, -ая, -ое логикасыз, эзлексез, акылга сыймаган, акылга ятышсыз; **~ посту́пок** логикасыз кыланыш

нельзя́ *нареч. в знач. сказ.* **1.** ярамый; **здесь кури́ть ~** биредә тәмәке тартырга ярамый **2.** мөмкин түгел, ...ып булмый; **~ не согласи́ться** килешмичә мөмкин түгел ◆ **как ~ лу́чше** мөмкин кадәр яхшырак; **~ ли?** ярамасмы?, мөмкин булмасмы?; **~ сказа́ть, что́бы ...** ... дип әйтеп булмый

не́льма *ж* нельма (*балык*)

нелюбо́вь *ж* яратмау, сөймәү, күрә алмау

нелюди́м *м* кыргый, кешедән качучан, кешеләр белән аралашмаучан [кеше]

нелюди́мый, -ая, -ое **1.** кыргый, кешедән качучан, кешеләр белән аралашмаучан; **~ челове́к** кешеләр белән аралашмаучан кеше **2.** (*безлюдный*) тын, тыныч, аулак, кешесез

нема́ло *нареч.* шактый күп, байтак; аз түгел

немалова́жн||ый, -ая, -ое шактый әһәмиятле, мөһим, әһәмиятсез түгел; **~ое обстоя́тельство** шактый мөһим сәбәп

нема́л||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* байтак, шактый күп (зур); аз ...мау, кечкенә (кыска) ...мау; аз (кечкенә, кыска) түгел; **заплати́ть ~ые де́ньги** шактый күп акча түләү; **вло́жен ~ый труд** шактый зур хезмәт куелган; **~ый срок** кыска срок түгел

неме́дленно *нареч.* тоткарсыз [рәвештә], ашыгыч [рәвештә], кичектерүсез..., кичектермичә, хәзер үк

неме́дленный, -ая, -ое тоткарсыз, ашыгыч, кичектергесез, кичектерүсез, тиз

неме́для *нареч. см.* **неме́дленно**

неме́ркнущ||ий, -ая, -ое *высок.* сүнмәс; **~ая сла́ва** сүнмәс дан

немета́ллы *мн.* металл булмаган материаллар

неме́||ть *несов.* **1.** *прям., перен.* телдән язу, телдән калу; **~ть от стра́ха** куркудан телдән язу **2.** *перен.* (*терять чувствительность*) ою; **но́ги ~ют от хо́лода** суыктан аяклар ойый

неме́ц *м* немец

неме́цкий, -ая, -ое немец ...ы; **~ язы́к** немец теле

немилосе́рдн||ый, -ая, -ое **1.** *уст.* (*чуждый милосердия*) каты күңелле, рәхимсез, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез, миһербансыз, аяусыз **2.** *перен. разг.* рәхимсез, бик көчле; **~ая боль** бик көчле авырту

неми́лость *ж* кайһәр, яратмау; начар караш, начар мөнәсәбәт; **впасть в ~** кайһәргә тару; **заслужи́ть ~** хаклы рәвештә кайһәргә эләгү

немину́емый, -ая, -ое котылгысыз

не́мка *ж* немка, немец хатыны (кызы)

немно́г||ий, -ая, -ое **1.** *мн.* **~ие** аз санлы, бик аз, аз гына, берничә, кайбер; **в ~их шко́лах** кайбер мәктәпләрдә; **в ~их слова́х** берничә сүз белән генә; **за ~им исключе́нием** берничә ...дан кала, берничә **2.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* кайберәүләр [генә]; **~ие остава́лись до́ма** өйдә кайберәүләр генә калган иде **3.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* аз-маз [булган], аз [булган]; **забы́л всё то ~ое, что знал** аз-маз белгәнен дә оныткан **4.** (*незначительно, ненамного*) аз гына, бераз; **~им бо́льше** аз гына күбрәк; **~им ме́ньше** аз гына азрак, аз гына кимрәк; **~им ста́рше** аз гына өлкәнрәк (олырак) ♦ **за ~им де́ло ста́ло** эш кечкенәдән (аздан) калды

немно́го *нареч.* аз [гына], бераз, беркадәр, берникадәр; күп түгел; **я ~ уста́л** бераз арыдым; **рабо́ты у нас ~** эшебез күп түгел; **возьми́ ещё ~** тагын бераз ал; **наро́ду там ~** халык анда күп түгел; **совсе́м ~** бик аз

немногосло́вный, -ая, -ое аз сүзле; кыска; **~ челове́к** аз сүзле кеше; **~ отве́т** кыска җавап

немногочи́сленн||ый, -ая, -ое аз санлы; сан ягыннан аз (кечкенә); **~ое о́бщество** аз санлы җәмгыять

немо́жется *несов. безл. кому, прост.* хәле юк, кәефе юк, авырып тора, хәлсезләнеп тора

нем||о́й, -а́я, -о́е **1.** телсез **2.** *в знач. сущ.* **~ о́й** *м*, **~ а́я** *ж* телсез **3** *перен.* (*безмолвный*) сүзсез; яшерен, эчке; **~о́й вопро́с** сүзсез сорау; **~о́й уко́р** сүзсез шелтә **4.** *перен.* тын; **~о́й лес** тын урман; **~а́я ночь** тын төн ♦ **~а́я ка́рта** сукыр карта (*контурлы карта*); **~а́я сце́на** сүзсез күренеш; **~о́й фильм** *или* **~о́е кино́** тавышсыз кино; **он нем как моги́ла (рыба)** ул сер сыя торган кеше

немолодо́й, -а́я, -о́е яшь булмаган, урта яшьләрдәге; яшь түгел

немота́ *ж* телсезлек; **врождённая ~** тумыштан телсезлек

не́мочь *ж*: **бле́дная ~** *уст. мед.* аз канлылык (*гадәттә хатын-кызларда була торган авыру*)

не́мощный, -ая, -ое хәлсез, бетерешкән, көчсез

не́мощь *ж* хәлсезлек; авыру, чир, сырхау, хаста

немудрён||ый, -ая, -ое гади, катлаулы булмаган, катлаулы түгел; җиңел; **де́ло ~ое** җиңел эш

не́мцы *мн.* немецлар, немец халкы

немы́слимый, -ая, -ое акылга сыймаслык, кешс ышанмаслык, булуы мөмкин булмаган

ненави́деть *несов. кого-что* дошман күрү, яратмау; нәфрәт белән карау, күрә алмау, җене сөймәү

ненави́стник *м* дошман күрүче, күрә алмаучы

ненави́стничество *с* дошманлык, күрә алмау[чылык]

ненави́стный, -ая, -ое **1.** (*вызывающий ненависть*) дошман ..., нәфрәт тудыргыч ..., нәфрәт тудыра (уята) торган, явыз **2.** (*выражающий ненависть*) дошман ..., нәфрәтле, нәфрәт тулы, нәфрәт белдергән

не́нависть *ж* дошманлык, нәфрәт, күрә алмау[чылык]

ненагля́дн||ый, -ая, -ое (*любимый, дорогой*) сөекле, кадерле

нена́добност||ь *ж* кирәксезлек, кирәксез булу, кирәге булмау, кирәге юклык; **по ~и** *или* **за ~ью** кирәге булмау сәбәпле, кирәге булмаганга [күрә]

ненадо́лго *нареч.* кыска вакытка, аз гына вакытка; озакка түгел

ненападе́ни||е һөҗүм итмәү, сугыш ачмау, сугыш башламау; **догово́р о ~и** сугыш башламау турында килешү

ненаро́ком *нареч. разг.* ялгышлык белән, ялгыш, хаталык белән, белмичә; очраклы рәвештә

нена́стный, -ая, -ое явым-төшемле, явым-чәчемле, яңгырлы, бозык; **~ день** яңгырлы көн

нена́стье *с* бозык һава, явым-төшемле (явым-чәчемле, карлы-буранлы *h.б.ш.*) көн[нәр]; **осе́ннее ~** көзге явым-төшемле көннәр

ненасы́тн||ый, -ая, -ое (*прожорливый*) туймас тамак ..., мәңге туймас, туюны белмәс, туемсыз, ач күзле, комсыз **2.** *перен.* мәңге туймас, һич тә канәгатьләнмәс, канәгатьсез; бертуктаусыз; **~ая жа́жда зна́ний** бертуктаусыз белемгә омтылу

не́нец *м* ненец

не́нецкий, -ая, -ое ненец[лар] ...ы; **~ язы́к** ненец теле

не́нка *ж* ненка, ненец хатыны (кызы)

ненорма́льность||ь *ж* **1.** (*отклонение от нормы*) нормаль булмау (булмаганлык, түгеллек) **2.** *разг.* акылга зәгыйфьлек; акылдан язганлык (язган булу); **психи́ческая ~ь** психик яктан нормаль булмау **3.** нормаль булмаган күренешләрне бетерү

ненорма́льн||ый, -ая, -ое **1.** нормаль булмаган; **~ая толщина́** нормаль булмаган калынлык **2.** *разг.* (*психически больной*) акылга зәгыйфь, акылдан язган

нену́жн||ый, -ая, -ое кирәксез, кирәкмәгән, кирәге булмаган; **~ая тра́та вре́мени** вакытны бушка үткәрү

не́нцы *мн.* ненецлар, ненец халкы

необду́манн||ый, -ая, -ое җитди (төптән) уйлан[ыл]маган, уйлап җиткерелмәгән, уйламый ...ган, дуамал; **~ый посту́пок** уйламый эшләнгән эш; **~ое реше́ние** уйлап җиткерелмәгән карар

необита́емый, -ая, -ое кеше яшәми (тормый) торган; **~ о́стров** кеше яшәми торган утрау

необозри́мость *ж* күз җитмәслек булу, очсыз-кырыйсыз булу, очсыз-кырыйсызлык, иге-чиге булмау, иксез-чиксезлек

необозри́мый, -ая, -ое күз күреме житмәс[лек] ..., күз җитмәслек, чиксез, очсыз-кырыйсыз, иге-чиге булмаган, иксез-чиксез

необрабо́танн||ый, -ая, -ое эшкәртелмәгән; **~ые зе́мли** эшкәртелмәгән җирләр; **~ая ко́жа** эшкәртелмәгән тире

необразо́ванный, -ая, -ое белем алмаган, укымаган, белемсез, надан

необрати́м||ый, -ая, -ое кайтмас, кире (элекке хәленә) кайтмый торган; **~ый проце́сс** кайтмас процесс; **~ая реа́кция** кайтмас реакция

необремени́тельный, -ая, -ое җинел, кыен булмаган; кыен түгел

необстре́лянный, -ая, -ое **1.** (*не побывавший в бою*) сугышта булмаган, сугышка кермәгән, ут астында булмаган, дары иснәмәгән **2.** *перен.* (*неопытный*) дөнья күрмәгән, ачысын-төчесен татымаган, тәҗрибәсез

необу́зданный, -ая, -ое тыйнаксыз, тотнаксыз, йөгәнсез, тезгенсез; котырынкы

необходи́мо *нареч. в знач. сказ. с неопр.* кирәк; **~ приня́ть ме́ры** чаралар күрергә кирәк

необходи́мост||ь *ж* **1.** кирәклек, кирәклелек, кирәкле булу, хажәт; зарурлык; **предме́ты пе́рвой ~и** беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарлар **2.** *филос.* зарурлык, зарурат

необходи́м||ый, -ая, -ое **1.** [бик] кирәкле, үтә кирәкле; кирәк булган; зарур; **~ый све́дения** кирәкле мәгълүматлар **2.** *филос.* зарури

необщи́тельность *ж* аралашмаучанлык, кыргыйлык

необщи́тельный, -ая, -ое аралашмаучан, катнашмаучан, кыргый

необъекти́вность *ж* объективсызлык, объектив булмау

необъекти́вный, -ая, -ое объектив булмаган; **~ая кри́тика** объектив булмаган тәнкыйть

необъясни́мый, -ая, -ое аңлатып бирерлек (бирүе мөмкин) булмаган, аңлатылмаслык, аңлашылмый торган, аңлашылмаслык

необъя́тный, -ая, -ое чиксез зур (киң), иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз, колач житмәслек; хисапсыз киң

необыкнове́нн||ый, -ая, -ое гадәттән (чиктән) тыш, искиткеч, искитәрлек, гажәп; **~ое происше́ствие** искиткеч

бер вакыйга; **~ое легкомы́слие** гажәп бер җиңел уйлаучанлык

необыча́йн||ый, -ая, -ое гадәттән тыш зур (көчле), искиткеч, искитәрлек, гажәп; **~ое волне́ние** гадәттән тыш көчле дулкынлану

необы́чный, -ая, -ое гадәттә булмаган, гадәти (таныш) булмаган; күнегелмәгән; гадәттән тыш; **~ тон** гадәти булмаган тон

неоднокра́тн||ый, -ая, -ое кат-кат ..., берничә тапкыр кабатланган, кат-кат кабатланган; **~ые напомина́ния** кат-кат искә төшерүләр

неодобре́ние *с* хупламау, яраклы (яхшы) дип тапмау, яраксыз дип табу, мактамау; тискәре бәя; уңай карамау

неодобри́тельн||ый, -ая, -ое **1.** начар, тискәре; **~ая оце́нка** тискәре бәя **2.** шелтәле; яратмыйча ..., ризасызлык белдереп..., риза булмауны (хупламауны) белдереп...; **~ый взгляд** шелтәле караш

неодоли́м||ый, -ая, -ое җиңә алмаслык, җиңелмәс, җиңеп булмый торган; **~ая си́ла** җиңә алмаслык көч; **~ая стра́сть** җиңеп булмый торган хис (дәрт)

неодушевлённ||ый, -ая, -ое җансыз, терек булмаган; **~ые имена́ существи́тельные** җансыз зат исемнәре

неожи́данност||ь *ж* **1.** көтелмәгәнлек, көтелмәгән булу; **~ь встре́чи** очрашуның көтелмәгән булуы **2.** көтелмәгәнлек, көтелмәгән хәл (вакыйга); **возмо́жны вся́кие ~и** төрле көтелмәгән хәлләр булырга мөмкин; **вздро́гнуть от ~и** көтелмәгәнлектән сискәнеп китү

неожи́данный, -ая, -ое көтелмәгән, көтмәгәндә ...ган, искәрмәстән ...ган, көтмәгәндә ..., кинәт ...; уйламаган; **~ прие́зд** көтмәгәндә кайтып килү

неоколониали́зм *м полит.* неоколониализм

неоли́т *м археол.* неолит

неологи́зм *м лингв.* неологизм

нео́н *м хим.* неон

неонаци́зм *м полит.* неонацизм

нео́нов||ый, -ая, -ое неон ...ы; **~ая ла́мпа** неон лампасы; **~ый свет** неон яктысы

неопису́ем||ый, -ая, -ое **1.** сүз белән әйтеп (аңлатып) бирүе мөмкин булмаган, сөйләп (тасвирлап) бирерлек булмаган, сөйләп бетергесез **2.** искиткеч зур, бик зур, гажәп зур; **~ая ра́дость** искиткеч зур шатлык

неопла́тн||ый, -ая, -ое: **быть в ~ом долгу́** *перед кем-л. берәү каршында* бик зур бурычлы булу

неопределённость *ж* **1.** (*неясность*) билгесезлек, аныксызлык **2.** (*неопределённое положение*) билгесезлек

неопределённ||ый, -ая, -ое **1.** билгесез, аныксыз; **в ~ом направле́нии** билгесез юнәлештә **2.** ачык булмаган, турыдан-туры ...маган, икеле-микеле; **~ый отве́т** ачык булмаган җавап ◆ **~ое местоиме́ние** *грам.* билгесезлек алмашлыгы; **~ая фо́рма глаго́ла** *грам.* фигыльнең инфинитив формасы

неопредели́мый, -ая, -ое билгеләү мөмкин булмаган, билгеләп булмый торган

неопровержи́м||ый, -ая, -ое кире какмаслык (каккысыз), инкарь ителмәслек, инкарь итүе мөмкин булмаган; **~ые доказа́тельства** кире каккысыз дәлилләр

неопря́тность *ж* пөхтәсезлек, җыйнаксызлык; шапшаклык; җыештырылмаганлык (*мәс, бүлмә турында*)

неопря́тный, -ая, -ое (*нечистоплотный*) шапшак, пычрак; (*неряшливый*) җыйнаксыз, җыйнак (пөхтә) булмаган; (*неприбранный*) җыештырмаган

неорга́ническ||ий, -ая, -ое **1.** (*неживой*) терек булмаган **2.** органик булмаган; **~ие удобре́ния** органик булмаган ашламалар ◆ **~ая хи́мия** органик булмаган химия

неосла́бный, -ая, -ое өзлексез, бертуктаусыз, даими, нык; **~ контро́ль** даими контроль

неосмотри́тельный, -ая, -ое **1.** артын-алдын уйламый[ча] эш итүче..., эшнең ахырын уйламаучы, саксыз, дуамал; **~ челове́к** артын-алдын уйламыйча эш итүче кеше **2.** ахырын (артын-алдын) уйламый[ча] эшләнгән, саксыз эшләнгән, дуамал; **~ посту́пок** артын-алдын уйламый эшләнгән эш

неоспори́мый, -ая, -ое бәхәссез, шөбһәсез, дәгъвасыз, бәхәсләшүгә (дәгъва итүгә) урын калдырмый торган, ачык; **~ факт** бәхәссез факт, ачык факт

неосторо́жность *ж* саксызлык, дуамаллык, абайсызлык

неосторо́ж||ый, -ая, -ое саксыз, дуамал; **~ое движе́ние** саксыз хәрәкәт

неосуществи́м||ый, -ая, -ое тормышка ашмаслык (ашырылмаслык); **~ое жела́ние** тормышка ашмаслык теләк

неосяза́емый, -ая, -ое сизелмәслек, сизмәслек, сизелми (тоелмый) торган

неотврати́мость *ж* котылгысызлык

неотврати́мый, -ая, -ое котылгысыз

неотвя́зный, -ая, -ое бәйләнчек, баштан чыкмый торган

неотдели́мый, -ая, -ое аерылмас, аерылмый торган, аергысыз, аерылмаслык

неотёсанный, -ая, -ое **1.** шомартылмаган, кырылмаган, юнылмаган, тасланмаган; **~ ка́мень** шомартылмаган таш **2.** *перен. разг.* тупас, дорфа, тәрбиясез; **~ челове́к** тупас кеше

не́откуда *нареч.* ... урын юк, ... җир юк; **пи́сем ждать ~** хатлар көтәр урын юк

неотло́жка *ж прост.* ашыгыч медицина ярдәме

неотло́жн||ый, -ая, -ое кичектергесез, ашыгыч; кичектерелми торган; **~ая по́мощь** ашыгыч ярдәм

неотлу́чн||ый, -ая, -ое **1.** аерылмас, аерылмый торган; **~ый спу́тник** аерылмас юлдаш **2.** беркая китми[чә] ...; **~ое дежу́рство** беркая китми дежур тору

неотрази́м||ый, -ая, -ое **1.** каршы торып булмый торган, җиңүе мөмкин булмаган; кире кагылмаслык; **~ые аргуме́нты** кире кагылмаслык дәлилләр **2.** *перен.* сокландыргыч; бик зур, бик көчле; **~ое впечатле́ние** бик көчле тәэсир

неотсту́пн||ый, -ая, -ое **1.** бертуктаусыз, даими, читкә тайпылмый[ча]; **~ое пресле́дование** бертуктаусыз эзәрлекләү **2.** туктаусыз, бәйләнчек, баштан чыкмый торган, һәрвакыт борчып тора торган; **~ая мысль** бәйләнчек уй

неотъе́млем||ый, -ая, -ое тартып (аерып) алгысыз, тартып (аерып) алынмый торган; аерылгысыз; **~ые права́** аерылгысыз хокуклар

неофициа́льный, -ая, -ое рәсми булмаган

неохо́т||а *ж* **1.** (*нежелание*) теләмәү; **пойти́ с ~ой** теләмичә бару **2.** *в знач. сказ. кому, с неопр., разг.* ...сы килми, теләк юк; **~ а разгова́ривать** сөйләшәсе килми

неоцени́м||ый, -ая, -ое бәя биреп бетергесез, бик кыйммәтле; бик мөһим (әһәмиятле); **~ая услу́га** бик мөһим ярдәм

непарнокопы́тные *мн. зоол.* тактояклылар

непа́рн||ый, -ая, -ое сыңар; **~ая о́бувь** сыңар аяк киеме; **~ые плавники́** сыңар йөзгечләр

непартийн||ый, -ая, -ое **1.** (*не состоящий в партии*) партиясез **2.** партия әгъзасына килешмәгән (ярамаган); партия әгъзасы өчен хас булмаган; **~ посту́пок** партия әгъзасы өчен хас булмаган кыланыш

непереводи́м||ый, -ая, -ое тәржемә ителми торган; **~ое выраже́ние** тәржемә ителми торган тәгъбир

непередава́ем||ый, -ая, -ое сөйләп биреп булмый торган, сөйләп бирә алмаслык; сүз (тел) белән аңлатып бирә алмаслык [зур, көчле]; **~ое впечатле́ние** сүз белән аңлатып бирә алмаслык көчле тәэсир

неперехо́дн||ый, -ая, -ое *грам.* күчемсез; **~ые глаго́лы** күчемсез фигыльләр

неперспекти́вный, -ая, -ое перспектив булмаган, перспективасыз, перспективасы булмаган, киләчәгә өметсез

непеча́тный, -ая, -ое *разг.* (*о словах*) сүгенү ...ы; пычрак, китапка басарга ярамый торган

непи́саный, -ая, -ое язылмаган, гадәткә кереп киткән; **~ зако́н** язылмаган закон

неплатёж *м* түләмәү

неплатёжеспосо́бность *ж* түли алмаучылык, түләргә сәләтсезлек (*мәс. бурычны*)

неплатёжеспосо́бный, -ая, -ое түли алмый торган, түләргә сәләтсез (*мәс. бурычны*)

неплате́льщик *м офиц.* түләмәүче

неплохо́й, -а́я, -о́е начар булмаган, шактый яхшы, яхшы гына, ярыйсы гына; начар түгел; **~ отве́т** шактый яхшы җавап; **~ урожа́й** шактый яхшы уңыш

непобеди́мость *ж* җиңелмәслек, җиңелмәс булу

непобеди́мый, -ая, -ое җиңелмәс, җиңелми торган

непови́нный, -ая, -ое гаепсез, гөнаһсыз

неповинове́ние *с* буйсынмау, баш бирмәү, тыңламау, карышу, каршы тору

неповоро́тливость *ж* авыр сөяклелек, акрын кыймылдаучанлык, акрынлык, сүлпәнлек

неповоро́тливый, -ая, -ое авыр сөякле, акрын кыймылдаучан, акрын, сүлпән

неповтори́мый, -ая, -ое үзенә бертөрле, охшашы булмаган, тиңе булмаган, кабатлануы мөмкин булмаган, кабатланмас

непого́да *ж* бозык һава; явым-төшемле (явым-чәчемле, җилле-буранлы, карлы-буранлы *һ.б.ш.*) көн[нәр]

непогреши́мый, -ая, -ое *книжн.* **1.** (*такой, который не ошибается*) ялгышмый торган, ялгышмаучан **2.** һичшиксез дөрес, шик тудырмый торган; **~ вы́вод** һичшиксез дөрес нәтиҗә

неподалёку *нареч.* якында, шушы тирәдә [генә]

неподви́жность *ж* хәрәкәтсезлек

неподви́жный, -ая, -ое **1.** (*не двигающийся*) хәрәкәтсез, хәрәкәтләнмәүчән **2.** (*малоподвижный*) аз хәрәкәтле; (*медлительный*) авыр сөякле, акрын хәрәкәтле, сүлпән **3.** (*застывший — о взгляде, выражении лица и т.п.*) катып калган

неподде́льный, -ая, -ое **1.** (*подлинный*) чын **2.** (*искренний, непритворный*) ясалма булмаган; чын [ихлас] күңелдән булган; самими, риясыз, эчкерсез

неподку́пный, -ая, -ое ришвәт алмый торган, сатылмас, намуслы, турылыклы; сатлык түгел

неподража́емый, -ая, -ое тиңдәшсез, тиңдәше (охшашы) булмаган; искиткеч шәп (яхшы)

непозволи́тельный, -ая, -ое *см.* **недопусти́мый**

непоколеби́м||ый, -ая, -ое нык, нык торучан, буйсынмас, какшамас, какшамаслык; **~ая ве́ра** какшамас ышаныч

непола́дки *мн. разг.* **1.** җитешсезлекләр, кимчелекләр; **~ в рабо́те тра́нспорта** транспорт эшендәге җитешсезлекләр **2.** (*ссоры*) ызгыш, орышталаш; (*недоразумения*) аңлашылмаучылык(лар)

неполноце́нный, -ая, -ое кимчелекле, түбән (начар) сыйфатлы; җирәнә җиткереп эшләнмәгән

непоме́рн||ый, -ая, -ое чамасыз, чиксез, артык зур, чамадан тыш [зур], чиктән тыш [зур]; **~ые тре́бования** артык зур таләпләр

непоня́тливый, -ая, -ое аңсыз, аңгыра, зиһенсез

непоня́тн||ый, -ая, -ое **1.** аңлаешсыз, аңлашылмаган, аңлашылмый торган; **~ое сло́во** аңлаешсыз сүз **2.** (*загадочный*) сәер, аңлаешсыз, аңлашылмый торган; **~ый слу́чай** сәер вакыйга

непоправи́мость *ж* төзәтелмәслек булу, төзәтеп булмау

непоправи́м||ый, -ая, -ое төзәлмәс, төзәтергә мөмкин булмаган, төзәтеп булмый торган; төзәтергә кыен булган; **~ая оши́бка** төзәтергә мөмкин булмаган хата

непоро́чность *ж* гөнаһсызлык, гаепсезлек; сафлык

непоро́чный, -ая, -ое гөнаһсыз, гаепсез; гыйффәтле

непоря́док *м* тәртипсезлек, тәртип юклык, тәртип булмау

непосе́да *м, ж разг.* тиктормас, йөремсәк, кыбырсык (*кеше*); тынгысыз кеше

непосе́дливый, -ая, -ое тиктормас, йөремсәк, кыбырсык; тынгысыз; **~ ребёнок** тиктормас бала

непоси́льн||ый, -ая, -ое көчтән (хәлдән, кулдан) килми торган (килмәслек), көчтән (хәлдән) тыш; **~ая рабо́та** кулдан килмәслек эш

непосле́довательность *ж* эзлексезлек

непосле́довательный, -ая, -ое эзлексез

непослуша́ние *с* тыңламау, буйсынмау, итәгатьсезлек

непосло́ушный, -ая, -ое тыңлаусыз, тыңламаучан, буйсынмаучан, итәгатьсез

непосре́дственность *ж* **1.** (*естественность*) табигыйлык **2.** (*непосредственное поведение*) беркатлылык, эчкерсезлек; **де́тская ~** балаларча беркатлылык

непосре́дственн||ый, -ая, -ое **1.** турыдан-туры; **~ый винО́вник** турыдан-туры гаепле кеше **2.** беркатлы, эчкерсез; **~ый челове́к** эчкерсез кеше **3.** якыннан ..., якыннан торып ...; **~ая по́мощь** якыннан ярдәм

непостижи́мый, -ая, -ое акыл ирешмәслек, акылга (башка) сыймаслык, акылга сыймаган (сыймый торган)

непостоя́нный, -ая, -ое **1.** үзгәрүчән, алмашынучан; **~ кли́мат** үзгәрүчән климат **2.** үз фикерендә (сүзендә) нык тормаучан, аумакай; **~ челове́к** үз сүзендә нык тормаучан кеше

непостоя́нство *с* **1.** (*изменчивость*) үзгәрүчән булу **2.** (*поведения, характера*) үз фикерендә (сүзендә) нык тормау[чылык], аумакайлык

непотре́бн||ый, -ая, -ое *уст.* пычрак, бозык, әшәке; **~ые слова́** пычрак сүзләр

непоча́т||ый, -ая, -ое башланмаган, тотылмаган, кул тимәгән; ачылмаган; **~ая коро́бка конфе́т** [әле] ачылмаган конфет тартмасы ◆ **~ый край** *кого-чего* бик күп, чиктән тыш күп

непочте́ние *с* хөрмәт күрсәтмәү, олыламау, санга сукмау

непочти́тельность *ж* санга сукмау, хөрмәт күрсәтмәү, олыламау, итәгатьсезлек

непочти́тельный, -ая, -ое санга сукмый торган, санга сукмаучан, хөрмәт күрсәтмәүчән, итәгатьсез

непра́вда *ж* (*ложь*) ялган; (*обман*) алдау

непревзойдённый, -ая, -ое иң яхшы, иң югары дәрәҗәдәге, иң камил; **~ ма́стер** иң яхшы оста

непредви́денн||ый, -ая, -ое алдан күрелмәгән, күздә тотылмаган, уйланылмаган, уйламаган; **~ые обстоя́тельства** көтелмәгән хәлләр; **~ое де́ло** уйламаган эш

непрезента́бельный, -ая, -ое сөйкемсез, килбәтсез, шыксыз, күрексез; **~ вид** шыксыз кыяфәт

непрекло́нн||ый, -ая, -ое нык, каты, буйсынмас; **~ая во́ля** ныклы ихтыяр; **~ый хара́ктер** нык характер

непрело́жн||ый, -ая, -ое *высок.* **1.** бозылмас, үзгәртелмәс, бозылмый (үзгәртелми) торган; **~ый зако́н** үзгәртелми торган канун **2.** кире кагып булмый торган, бәхәс итмәслек, бәхәссез; **~ая и́стина** бәхәссез хакыйкать

непреме́нн||ый, -ая, -ое котылгысыз, мәҗбүри, иң кирәкле, зарури; **~ое усло́вие** зарури шарт, мәҗбүри шарт

непреобори́мый, -ая, -ое *высок. см.* **непреодоли́мый**

непреодоли́м||ый, -ая, -ое **1.** җиңелмәс, җиңелми торган, җиңеп (ерып) чыга алмаслык, каршы тора алмаслык; **~ое препя́тствие** җиңеп чыга алмаслык киртә **2.** үтә алмаслык; **~ое расстоя́ние** үтә алмаслык [зур] ара

непререка́емый, -ая, -ое бәхәссез, бәхәс ителмәслек, каршы төшмәслек (килмәслек); **~ авторите́т** бәхәссез абруй

непреры́вность *ж* өзлексезлек, тоташтан булу, даимилек

непреры́вн||ый, -ая, -ое тоташ, өзлексез, туктаусыз, тоташтан, даими; **~ые дожди́** туктаусыз [яуган] яңгырлар; **~ый пото́к маши́н** машиналарның өзлексез агылуы

непреста́нный, -ая, -ое туктаусыз, даими

непривы́чк||а *ж разг.*: **с ~и** күнекмәгәнгә, күнекмәгәнлектән

непривы́чн||ый, -ая, -ое күнегелмәгән, ияләшмәгән, күнекмәгән, гадәткә кермәгән, гадәти булмаган, чит; **~ая карти́на** күңелсез күренеш

неприка́янный, -ая, -ое *разг.*: **хо́дит как ~** үз-үзенә урын тапмый йөри

неприкоснове́нность *ж* **1.** иминлек, кагылгысызлык; **~ ли́чности** шәхес иминлеге **2.** кагылгысызлык, кагылмый (тиелми) торган булу; **~ запа́са** запасның кагылмый торган булуы

неприкоснове́нн||ый, -ая, -ое **1.** кагылгысыз; **~ая ли́чность** кагылгысыз шәхес **2.** кагылгысыз, кагылырга ярамый торган; **~ый запа́с** кагылгысыз запас

неприкра́шенный, -ая, -ое табигый, саф, чын, матурлап күрсәтелмәгән

неприкры́т||ый, -ая, -ое чын, апачык, чеп-чи; **~ая ложь** чеп-чи ялган

неприли́чие *с* әдәпсезлек, оятсызлык, килешсезлек

неприли́чный, -ая, -ое килешми торган, килешмәгән, килешсез; әдәпсез, оятсыз

неприме́тный, -ая, -ое **1.** (*незаметный*) күзгә күренми (ташланмый) торган; күзгә ташланмаслык, беленми торган, беленмәслек; (*неощутимый*) сизелмәслек, сизелми торган **2.** (*непримечательный*) күренекле булмаган, күренексез, билгесез, танылмаган

непримири́мость *ж* (*непримиримые отношения*) килешмәслек булу, килешеп булмау

непримири́м||ый, -ая, -ое **1.** килешмәүчән, килешүчән булмаган; **~ый враг** кан дошман, җан дошман **2.** килештереп булмый торган, килештергесез, килештерә алмаслык; **~ые противоре́чия** килештерә алмаслык каршылыклар

непринуждённость *ж* үзен иркен тоту, тартынмау, тәкәллефсезлек

непринуждённый, -ая, -ое табигый, иркен, тартынмаучан, тәкәллефсез

присоедини́вш||ийся, -аяся, -еяся; **~иеся стра́ны** [хәрби-сәяси блокларга] кушылмаган илләр

непристо́йность *ж* **1.** (*неприличие*) оятсызлык, әдәпсезлек, килешмәгәнлек **2.** (*непристойное слово, поступок*) әдәпсез (оятсыз, килешмәгән) сүз (кыланыш)

непристо́йный, -ая, -ое оятсыз, әдәпсез, килешмәгән, килешсез; әшәке

непристу́пность *ж* (*гордость*) тәкәбберлек, әрелек, һавалылык; кырыслык

непристу́пн||ый, -ая, -ое **1.** якын барырлык булмаган; якын барырлык түгел; һичкем ала алмаслык; **~ый утёс** якын барырлык булмаган кыя таш; **~ая кре́пость** һичкем ала алмаслык крепость **2.** *перен.* (*надменный*) тәкәббер, әрс, һавалы; кырыс

непритво́рн||ый, -ая, -ое *книжн.* риясыз, эчкерсез, ихлас күңелдән ..., чын күңелдән ..., табигый; **~ое удивле́ние** чын күңелдән гаҗәпләнү

неприхотли́вость *ж* (*нетребовательность*) талымсызлык; таләпчән булмау; әрсезлек

неприхотли́вый, -ая, -ое **1.** (*нетребовательный*) талымсыз; аз (кечкенә *һ.б.ш.*) белән канәгатьләнүчән **2.** [бик] гади, артык катлаулы булмаган; **~ рису́нок** бик гади рәсем

неприя́зненность *ж см.* **неприя́знь**

неприя́зненный, -ая, -ое [эчке] дошманлыкны чагылдырган, дошманнарча ..., күрәлмауны (яратмауны) белдергән; **~ тон** күрәлмауны чагылдырган тон

неприя́знь *ж* эчке дошманлык, күрәлмау, күрәлмаучанлык

неприя́тель *м* дошман

неприя́тельск||ий, -ая, -ое дошман ...ы; **~ие войска́** дошман гаскәрләре

неприя́тность *ж* күңелсезлек, күңелсез хәл (вакыйга)

неприя́тный, -ая, -ое **1.** начар; **~ за́пах** начар ис **2.** күңелсез, күңелгә ошамый торган, күңелгә ятышсыз; **~ слу́чай** күңелсез вакыйга

непробу́дный, -ая, -ое: **~ сон** уянмас йокы

непроводни́к *м физ.* үткәрмәүче (*электр, җылылык үткәрми торган матдә*)

непрогля́дн||ый, -ая, -ое: **~ый мрак** *или* **~ая тьма (те́мень)** дөм-карангы; күзгә төртсәң, күренмәс; **~ая ночь** кап-караңгы төн; **~ый тума́н** бик куе томан

непроизводи́тельн||ый, -ая, -ое файдасыз, нәтиҗәсез, әрәм; **~ая тра́та вре́мени** вакытны әрәм итү

непроизво́льный, -ая, -ое ирексез, ихтыярсыз (ихтыярдан тыш) эшләнгән

непромока́емый, -ая, -ое су (дым, юеш) үткәрми торган

непроница́ем||ый, -ая, -ое **1.** үткәрмәүчән, үткәрми торган (су, дым, тавыш *һ.б.ш.*); **~ая перегоро́дка** тавыш үткәрми торган бүлге **2.** кап-караңгы, дөм-караңгы; **~ая мгла** кап-караңгы; **~ая те́мень** дөм-караңгы **3.** *перен.* яшерен; **~ая та́йна** яшерен сер, йәрәк [түрендәге] сер

непропорциона́льный, -ая, -ое пропорциональ булмаган, пропорциясез

непрости́тельный, -ая, -ое гафу ит[ел]мәслек, кичерелмәслек, гафу ителми (кичерелми) торган

непроходи́мость *ж* **1.** үтә алмаслык булу; **~ боло́т** сазларның үтә алмаслык булуы **2.** *мед.* үткәрмәүчәнлек; **~ кише́чника** эчәкләрнең үткәрмәүчәнлеге

непроходи́м||ый, -ая, -ое **1.** үтә (кичә) алмаслык; ерып чыга алмаслык; **~ые боло́та** кичә алмаслык сазлыклар **2.** *перен. разг.* чеп-чи, чиктән тыш ..., чиктән ашкан, шыр; **~ая глу́пость** чиктән тыш ахмаклык; **~ый дура́к** шыр тиле; **~ое неве́жество** чеп-чи наданлык

непро́шен||ый, -ая, -ое **1.** чакырусыз килгән, чакырмый(ча) килгән; чакырылмаган; **~ый гость** чакырылмаган кунак **2.** кирәге булмаган, кирәкмәгән, кирәксез, урынсызга ...; **~ое вмеша́тельство** урынсызга [кеше эшенә] тыгылу **3.** ихтыярсыз, ихтыярдан тыш ...ган, ирексез ...ган; **~ые слёзы** ихтыярдан тыш чыккан яшьләр

непутёвый, -ая, -ое *прост.* юлдан язган, бозык, азгын; юньсез; **~ па́рень** юлдан язган егет

неработоспосо́бный, -ая, -ое эшкә яраксыз (сәләтсез)

нерабо́ч||ий, -ая, -ее **1.** эшче булмаган; эшчеләрдән түгел; **~ий челове́к** эшче булмаган кеше **2.** эшкә җигелми торган; **~ий скот** эшкә җигелми торган терлек **3.** эшләми торган, эштән буш; ял ...ы; **~ий день** ял көне; **~ее вре́мя** эштән буш вакыт ♦ **~ее настрое́ние** эшлисе килмәү, эшләргә теләк булмау

нера́венство *с* **1.** тигезсезлек; тинсезлек; **социа́льное ~** социаль тигезсезлек **2.** *мат.* тигезсезлек

неравноду́шный, -ая, -ое яратучан, яратучы, ярата торган

неравноме́рный, -ая, -ое тигезсез

неравнопра́вие *с* хокукта тигезсезлек

неравнопра́вный, -ая, -ое хокуклары тигез булмаган, тигез хокуклы булмаган

нера́вн||ый, -ая, -ое тигезсез, [үзара] тигез (тиң) булмаган; тигез (тиң) түгел; **~ые величи́ны** *мат.* тигезсез зурлыклар; **~ые си́лы** тигез булмаган көчләр

неради́вый, -ая, -ое гамьсез, ваемсыз, эшкә салкын караучы, ялкау; **~ рабо́тник** ялкау эшче

неразбери́ха *ж* чуалчык[лык], буталчыклык

неразбо́рчивость *ж* **1.** (*невнятность*) аңлашылыр-аңлашылмаслык булу, ишетелер-ишетелмәслек булу, аңлаешсызлык; (*почерка*) танылмаслык булу **2.** (*в еде и т.п.*) талымсызлык, сайланмаучанлык; җирәнмәүчәнлек **3.** (*беспринципность*) талымсызлык

неразбо́рчивый, -ая, -ое **1.** (*невнятный*) аңлашылыр-аңлашылмас, ишетелер-ишетелмәс, аңлаешсыз; (*о почерке*) танылмый торган, танылмаслык **2.** (*неприхотливый*) талымсыз, сайланмаучан; (*небрезгливый*) җирәнмәүчән ♦ **~ в сре́дствах** максатына ирешү өчен бернәрсәдән дә тартынмаучан

нераздели́мый, -ая, -ое аерылмый торган; аерылгысыз; бердәм, бер бөтен

неразде́льный, -ая, -ое **1.** (*такой, крый не подлежит разделу*) бүленми торган, бүленергә тиеш булмаган; **~ уча́сток** бүленми торган участок **2.** *см.* **нераздели́мый**

неразличи́м||ый, -ая, -ое **1.** күзгә күренмәслек, күреп җиткереп булмый торган; **~ые очерта́ния** күзгә күренмәслек сызымталар **2.** бер-береннән аера алмаслык, аеруы кыен булган, бер-беренә бик якын; **~ые отте́нки** бер-беренә бик якын төсмерләр

неразу́мный, -ая, -ое **1.** акылсыз; **~ый челове́к** акылсыз кеше **2.** акылга сыймаган, акылга ятышсыз, акыл белән эшләнмәгән; **~ посту́пок** акыл белән эшләнмәгән эш

нерасположе́ние *с* күңел ятмау, яратмау, ошатмау

нерасторжи́м||ый, -ая, -ое бозылмас, боза алмаслык, аера алмаслык, өзелмәс, аерылгысыз; **~ые у́зы** өзелмәс бәйләнешләр

нерасчётливость *ж* исәпсезлек

нерв *м в разг. знач.* нерв; **больны́е ~ы** авыру нервлар

нервúровать *несов. кого-что* нервыгатию, ачу китерү

нé|рвничать *несов.* нервланы, борчылу, көйсезләнү, холыксызлану

нервнобольнóй, -áя, -óе нерв авырулы, нервлары авыру

нéрвн||ый, -ая, -ое **1.** нерв ...ы; **~ые клéтки** нерв күзәнәкләре **2.** нервлы, тиз кызучан (кызып китүчән), кызу канлы; тиз ярсып китүчән; холыксыз; **~ый человéк** тиз кызып китүчән кеше **3.** борчулы, борчылган; **~ое состоя́ние** борчулы хәл **4.** *разг.* борчулы, тыныч-сыз; **~ая рабóта** борчулы эш ♦ **~ый припáдок** нервысы тоту

нервóзн||ый, -ая, -ое **1.** (*болезненно-раздражительный*) тиз кызучан, тиз кызып китүчән, кызу канлы; холыксыз **2.** борчылган, борчылуны белдергән; **в ~ом состоя́нии** борчылган хәлдә, борчылып **3.** борчулы, тынычсыз, тыныч булмаган; **~ая обстанóвка** борчулы обстановка

нервотрёпка *ж разг.* нервларны бозу, нервларны какшату

нереáльный, -ая, -ое реаль булмаган; тормышка ашмаслык, үтәлмәслек

нéрест *м рыб.* уылдык чәчү

нерести́лище *с рыб.* уылдык чәчү урыны

нерести́ться *несов. рыб.* уылдык чәчү

нерешúмост||ь *ж*: **в ~и** икеләнеп, кыюсызланып

нерешúтельн||ый, -ая, -ое кыюсыз, юаш, икеләнүчән, тартынучан, икеләнгән; **~ый пáрень** кыюсыз егет; **~ый вид** кыюсыз кыяфәт; **с ~им ви́дом** тартынып кына

нержавéющ||ий, -ая, -ее тутыкмас, тутыкмый торган; күгәрми торган; **~ая сталь** тутыкмас корыч

нерóбк||ий, -ая, -ое кыю, чая, куркусыз; юаш түгел; **он ~ого деся́тка** ул куркаклардан түгел

нерóвня, неровня́ *м, ж разг.* тиң булмаган, иш булмаган; тиң түгел, тиңдәш түгел, иш түгел

нéрпа *ж зоол.* нерпа

нéрпичий, -ья, -ье, **нéрповый**, -ая, -ое нерпа ...ы

нерýдный, -ая, -ое руда булмаган (*балчык, ком һ.б.ш. турында*)

нерукотвóрный, -ая, -ое *высок.* кеше кулы белән эшләнмәгән, кеше кулы белән эшләнерлек булмаган

нерушúм||ый, -ая, -ое бозылмас, җимерелмәс; (*который не может быть нарушен*) какшамас, ныык

неря́ха *м, ж* шапшак, пычрак; җыйнаксыз [кеше]

неря́шество *с*, **неря́шливость** *ж* шапшаклык, пычраклык; җыйнаксызлык

неря́шлив||ый, -ая, -ое **2.** шапшак, пычрак; җыйнаксыз; **~ый человéк** шапшак кеше **2.** игътибарсыз (шапшак) эшләнгән, тырышып (күңел биреп) эшләнмәгән; **~ая рабóта** игътибарсыз эшләнгән эш

несбы́точн||ый, -ая, -ое тормышка ашмас[лык], тормышка ашмый торган; буш; **~ые мечты́** тормышка ашмаслык теләкләр

несваре́ние *с*: **~ желу́дка** *мед.* ашказаны эшләмәү

несгибáем||ый, -ая, -ое **1.** бөгелми торган, бөгүе кыен булган **2.** *перен.* ныык, ныык торучан, какшамас, баш имәс, буйсынмаучан; **~ая вóля** ныык ихтыяр

несгорáемый, -ая, -ое [утта] янмый торган, янмас; **~ шкаф** янмый торган шкаф

несдоброва́ть *сов.* бәлага юлыгу (тару), уңышсызлыкка очрау, күңелсезлеккә дучар булу, начар булу

несказáнн||ый, -ая, -ое *высок.* искиткеч зур, гадәттән тыш зур, әйтеп (сөйләп) бетергесез; **~ая рáдость** искиткеч зур шатлык

нескла́дн||ый, -ая, -ое шыксыз, килешсез, килбәтсез, ямьсез; **~ый пáрень** килбәтсез егет; **~ая фигýра** килешсез фигура

нéсколь||о I *числ.* берничә; **~ о человéк** берничә кеше ♦ **в ~их слова́х** берничә сүз белән, кыскача гына

нéсколько II *нареч.* бернигадәр, бераз, аз гына, чак кына; **он ~ успокóился** ул бераз тыныч-ланды

несконча́емый, -ая, -ое бетмәс-төкәнмәс, беткесез; бертуктаусыз, өзлексез, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз; **~ пото́к маши́н** машиналарның иксез-чиксез агылуы

нескро́мный, -ая, -ое **1.** тыйнак булмаган, инсафсыз, тыйнаксыз; **~ челове́к** тыйнаксыз кеше **2.** тупас, дорфа; әдәп сакламыйча ...ган; **~ вопро́с** тупас сорау **3.** әдәпсез, оятсыз; **~ жест** әдәпсез хәрәкәт

неслы́ханный, -ая, -ое ишетелмәгән, әлегәчә (моңарчы) булмаган, гадәттән тыш, чиктән тыш

неслы́шн||ый, -ая, -ое тавышсыз, акрын, тын, ишеттермичә ...; **подойти́ ~ыми шага́ми** акрын гына атлап янына килү

несмéтн||ый, -ая, -ое иксез-чиксез [күп, зур], исәпсез-хисапсыз [күп, зур], сансыз, исәпсез; **~ые бога́тства** исәпсез байлыклар; **~ое коли́чество книг** исәпсез-хисапсыз күп китап

несмолка́емый, -ая, -ое [бер] туктаусыз, өзлексез, озакка сузылган

несмотря́ *предлог с вин. п.* ...га карамастан; **~ на шум** шау-шуга карамастан; **~ ни на что́** һичнәрсәгә карамастан

несмыва́ем||ый, -ая, -ое **1.** юылмый торган, бетми торган; **~ые кра́ски** бетми торган буяулар **2.** *перен.* мәңге юылмас, мәңгелек, мәңге онытылмас; **~ый позо́р** мәңгелек хурлык

несмышлёныш *м разг.* аңгыра, аңсыз (*бала*)

несно́сный, -ая, -ое эчпошыргыч, авыр; **~ хара́ктер** авыр характер

несовершеннолéт||ий, -ая, -ее *и в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~яя** *ж* яше җитмәгән, балигъ булмаган

несовершéнный I, -ая, -ое камилләшмәгән, камилләшеп җитмәгән, бик үк камил булмаган, җиренә җитмәгән, җиренә җиткереп эшләнмәгән; **~ рису́нок** җиренә җиткереп эшләнмәгән рәсем

несовершéнный II, -ая, -ое: **~ вид** *грам.* тәмамланмаган төр

несовершéнство *с* камил булмау; җиренә җиткерелмәү, җиренә җиткереп эшләнмәү

несовмести́мость *ж* [үзара] сыешмау[чанлык]; **~ тка́ней** *биол.* тукымаларның үзара сыешмаучанлыгы; **психологи́ческая ~** психологик яктан сыешмау

несовмести́мый, -ая, -ое капмакаршы; [үзара] сыеша алмый торган, [үзара] сыешмаучан

несогла́сие *с* **1.** (*разногласие*) үзара килешмәү, килешмәүчелек **2.** (*отказ*) риза булмау, баш тарту

несогласо́ванность *ж* бердәмлек булмау, бердәмлек юклык; үзара килешенмәгәнлек

несогласо́ванн||ый, -ая, -ое **1.** үзара килешенмәгән (килешмичә эшләнгән); **~ая рабóта** үзара килешмичә эшләнгән эш **2.** яраштырылмаган; **~ый прое́кт** яраштырылмаган проект

несоизмери́м||ый, -ая, -ое чагыштыргысыз, үлчәүдәшсез, үлчәүдәше булмаган; **~ые величи́ны** үлчәүдәшсез зурлыклар

несокруши́мый, -ая, -ое нык, какшамас, җимерелмәс

несо́лоно *нареч.*: **~ хлеба́вши [уйти́]** *прост.* буш (коры) кул белән [китү]

несомне́нный, -ая, -ое һичшиксез, шөбһәсез, ап-ачык; бәхәссез; **~ успе́х** һичшиксез уңышлык

несоразмéрность *ж* (*бер-берсенә*) туры килмәү, пропорциональ булмау, пропорциональ түгеллек

несоразмéрный, -ая, -ое (*бер-берсенә*) туры килми торган, пропорциональ булмаган

несостоя́тельн||ый, -ая, -ое **1.** дәүлатсез, ярлы, бай булмаган; **~ые лю́ди** ярлы кешеләр **2.** [бурычларын] түләргә хәле җитмәгән; **~ый должни́к** бурычларын түләргә хәле җитмәгән кеше **3.** *перен.* нигезсез, нигезләнеп җитмәгән; **~ый до́вод** нигезсез дәлил

несправедли́вость *ж* гаделсезлек, гаделлексезлек, турылыксызлык; нахаклык

несправедли́вый, -ая, -ое гаделсез, гаделлексез, турылыксыз; нахак; **~ челове́к** гаделлексез кеше; **~ приговóр** гаделсез хөкем

неспроста́ *нареч. разг.* юкка гына түгел, бушка гына түгел, юкка ...мау, бушка ... мау; **он ~ улыбну́лся** ул юкка гына елмаймады

несравне́нно *нареч.* (*при сравн. ст.*) чагыштыргысыз [дәрәҗәдә]; күп мәртәбә; **~ краси́вее** күп мәртәбә матуррак

несравне́нный, -ая, -ое чагыштыргысыз, тиңсез, тиңе булмаган, охшашы (тиңдәше) булмаган; **~ го́лос** тиңдәше булмаган [матур] тавыш

несравни́м||ый, -ая, -ое **1.** (*очень хороший*) (*ничбер нәрсә белән*) чагыштыргысыз, чагыштырмаслык, тиңдәш-

сез; охшашы (тиңдәше) булмаган **2.** (*непохожий*) чагыштырырга мөмкин булмаган, чагыштырылмаган, бөтенләй охшаш булмаган; **~ые вели́чины** *мат.* чагыштыргысыз зурлыклар

нестанда́ртный, -ая, -ое стандартсыз

нестерпи́мый, -ая, -ое *см.* **невыноси́мый**

нес||ти́ *сов.* **1.** *кого-что* күтәреп бару (килү, кайту, илтү); **~ти́ чемода́н** чемодан күтәреп бару **2.** *кого-что* бик тиз (очыртып) алып бару (килү); **ло́шади ~у́т теле́гу по́д гору** атлар арбаны тау астына таба очыртып алып баралар **3.** *кого-что* куу, куып алып бару (килү); **ве́тер ~ёт ту́чи** җил болытларны куып алып бара **4.** *перен. что* (*идеи, знания*) тарату **5.** *перен. что* (*влечь за собой*) [үзе белән] алып килү, китерү; **о́сень ~ёт дожди́** көз яңгырлар алып килә **6.** *безл. чем, разг.* ис килү, ис килеп тору, аңку, аңкып тору; **от него́ ~ёт лу́ком** аңардан суган исе килеп тора **7.** *что* үтәү, башкару, алып бару; **~ти́ обя́занности дире́ктора** директор вазифасын үтәү **8.** *что* күрү; **~ти́ уро́н** зарар күрү; **~ти́ наказа́ние** җәза күрү **9.** *безл. чем* [җил] исү, исеп тору, [җил] килү, килеп тору; **из-под по́ла несёт** идән астыннан [җил] исеп тора **10.** *что* (*класть яйца*) [йомырка] салу ♦ **высоко́ (го́рдо) ~ти́ го́лову** үзеңне горур тоту; **куда́ тебя́ [нелёгкая] ~ёт?** ни шайтаныма чабасың (барасың)?; **~ти́ ответственность** жаваплы булу; **~ти́ чепуху́ (вздор)** юк-бар сүзләр сөйләү, төрле ахмаклыклар сөйләү

нести́сь *несов.* **1.** (*быстро передвигаться*) очкандай чабу, бик тиз чабу, җилү, җил кебек очу **2.** *перен.* (*о звуках, запахах*) килү, килеп тору **3.** *перен.* (*о слухах, сведениях и т.п.*) таралу **4.** (*о времени, событиях*) тиз узу, узып китү, үтү, үтеп китү **5.** (*класть яйца — о птицах*) [йомырка] салу **6.** *страд. от* **нести́** 1, 4, 10

нестроево́й, -а́я, -о́е нестроевой, строевой хезмәткә яраксыз

несура́зн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** мәгънәсез, бәйләнешсез, ятышсыз; **~ые слова́** мәгънәсез сүзләр **2.** ямьсез, шыксыз, килешсез, килбәтсез; **~ая оде́жда** килешсез кием

несусве́тн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** күз алдына китерә алмаслык, ис-акыл китмәс, акылга сыймаслык, искиткеч; **~ый вздор** искиткеч мәгънәсез сүзләр **2.** чиктән тыш ...; **жара́ ~ая** чиктән тыш эссе

несча́стный, -ая, -ое бәхетсез; мескен, бичара ♦ **~ слу́чай** бәхетсезлек, һәлакәт

несча́сть||е *с* бәхетсезлек ♦ **к ~ю** *или* **на ~е** бәхетсезлеккә каршы, гөнаһ шомлыгына каршы

несчётный, -ая, -ое санаусыз, исәпсез-хисапсыз, бик күп

нет *частица* **1.** *отриц.* юк; **~, не приду́** юк, килмәм **2.** *в знач. сказ. безл. кого-чего* юк; **у меня́ ~ вре́мени** минем вакытым юк ♦ **а [то] ~?** *прост.* шулай түгелме әллә?, шулай түгелмени?; **~ да ~** *или* **~ и ~** юк та юк, һаман да юк; **~ как ~** [бөтенләй] юк; **~-~ да и** юк-юк та, сирәк-мирәк кенә булса да ...; **~ [того́] что́бы ...** ...у урынына; **~ того́, что́бы помо́чь** ярдәм итү (итәсе) урынына; **ника́к ~** һич тә юк; **чего́ [то́лько] ~** нәрсә генә юк, ни генә юк; **свести́ на ~** юкка чыгару

нетакти́чный, -ая, -ое тәкәллефсез, әдәпсез, гадәтсез, тәрбиясез; **~ челове́к** тәкәллефсез кеше

не́тель *ж* башмак тана; кысыр тана

нетерпе́ни||е *с* түземсезлек, сабырсызлык, чыдамсызлык

нетерпи́мость *ж* **1.** (*недопустимость*) түзә (чыдый) алмаслык булу **2.** (*нетерпимое отношение*) кеше [фикере] белән санашмаучанлык; түзмәүчелек

нетерпи́м||ый, -ая, -ое **1.** түзә (чыдый) алмаслык, түзеп (чыдап) торгысыз, түзеп (чыдап) тормаслык; **~ое поведе́ние** үзен түзеп тормаслык дәрәҗәдә начар тоту; **~ое положе́ние** түзеп тора алмаслык хәл **2.** кеше [фикере] белән исәпләшмәүчән; **~ый челове́к** кеше фикере белән исәпләшмәүчән кеше

нетле́нный, -ая, -ое *книжн.* (*вечный*) мәңгелек, мәңге онытылмый торган, мәңге онытылмас (бетмәс)

нетопы́рь *м зоол.* зур ярканат

нетро́нут||ый, -ая, -ое кул тимәгән, бөтен, башланмаган, [һичкем] кагылмаган; **~ая еда́** [һичберкем] кагылмаган аш

нетрудов||о́й, -а́я, -о́е **1.** үз көче белән яшәмәүче, эшләмәгән, эшләмәүче, эшләми торган; **~а́я часть населе́ния** халыкның эшләми торган өлеше **2.** хезмәт (көч) куймыйча табылган, эшләми табылган (алынган); **~о́й дохо́д** эшләми алынган керем

нетрудоспосо́бный, -ая, -ое хезмәткә яраксыз

не́тто *неизм. прил. и нареч. торг.* нетто, саф авырлык

не́ту *в знач. сказ. безл. кого-чего, разг. см.* **нет** 2

неуваже́ние *с* ихтирам итмәү, олылamау, санга сукмау (алмау)

неувяда́ем||ый, -ая, -ое, **неувяда́ющ||ий**, -ая, -ее **1.** сулмый торган, сулмас, мәңге сулмас; **~ая красота́** мәңге сулмас матурлык (гүзәллек) **2.** *перен.* мәңгелек, гомерлек, мәңге онытылмас (сүнмәс, сулмас); **~ая сла́ва** мәңге сулмас дан

неувя́зка *ж разг.* (*несогласованность*) бердәмлек булмау, бердәмлек юклык; (*недоразумение*) аңлашылмаучылык

неугаси́мый, -ая, -ое *прям., перен. высок.* мәңге сүнмәс, сүнми торган

неугомо́нный, -ая, -ое тынгысыз, тынгылыксыз, тынгылыкны белмәүчән (белми торган), ару-талуны белмәгән, тиктормас; **~ ребёнок** тиктормас бала

неуда́ч||а *ж* уңышсызлык, моратка ирешмәү; **потерпе́ть ~у** уңышсызлыкка очрау

неуда́чливый, -ая, -ое [бервакытта да] эше уңмый торган, морадына ирешмәүчән; бәхетсез

неуда́чник *м* эше уңмый торган кеше, морадына ирешмәүче кеше, бәхетсез кеше

неуда́чница *ж* эше уңмый торган хатын (кыз)

неуда́чный, -ая, -ое уңышсыз, начар; **~ фотосни́мок** уңышсыз фоторәсем

неудержи́м||ый, -ая, -ое тыелгысыз, тыеп булмый торган, тыя алмаслык, бик көчле; **~ое жела́ние** бик көчле теләк

неудо́бн||ый, -ая, -ое **1.** уңайсыз, җайсыз, ипсез; **~ое ме́сто** уңайсыз урын **2.** *перен.* (*неприятный*) уңайсыз, күңелсез; (*затруднительный*) кыен, читен

неудо́бств||о *с* уңайсызлык, җайсызлык; **испы́тывать ~а** уңайсызлыклар кичерү

неудовлетвори́тельно *нареч.* канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә ...мау, канәгатьләнерлек итеп ...мау; **отве́тить ~** канәгатьләндерерлек итеп җавап бирмәү

неудовлетвори́тельный, -ая, -ое канәгатьләнерлек (канәгатьләндерерлек) булмаган, канәгатьләндерерлек итеп ...маган; **~ отве́т** канәгатьләндерерлек итеп бирелмәгән җавап

неудово́льствие *с* ризасызлык, риза булмау, риза түгеллек, канәгатьсезлек, канәгать булмау

неуёмный, -ая, -ое *разг.* (*неугомонный*) ару-талуны белмәгән (белмәс, белмәүче), тынгысыз, тиктормас, тынгылыксыз

неуже́ли *частица вопр.* [әллә] чынлап та ...мы; **~ он уе́хал?** чынлап та ул киттеме? ♦ **~!** китсәнә!, булмас ла!

неужи́вчивый -ая, -ое [кеше белән] тынышмаучан, сыешмаучан, тар холыклы, кеше белән тату тора аламаучан; **~ челове́к** тар холыклы кеше; **~ хара́ктер** тынышмаучан холык

неу́жто *частица прост. см.* **неуже́ли**

неузнава́емост||ь *ж*: **до ~и** танымаслык дәрәҗәдә

неузнава́емый, -ая, -ое танымаслык, таный алмаслык

неукло́нный, -ая, -ое (*неизменный, постоянный; непоколебимый*) тайпылусыз, тайпылышсыз; даими, өзлексез

неуклю́ж||ий, -ая, -ое **1.** (*неповоротливый*) авыр гәудәле, авыр сөякле, авыр хәрәкәтле, акрын кыймылдаучан **2.** (*о движении, походке*) авыр; шыксыз, ямьсез, килбәтсез **3.** *перен.* колакка ятышсыз, ямьсез; **~ие выраже́ния** колакка ятышсыз сүзләр

неукосни́тельн||ый, -ая, -ое *книжн.* тайпылышсыз, тайпылусыз, мәҗбүри; **~ое соблюде́ние дисципли́ны** тәртипне тайпылусыз саклау

неукроти́мый, -ая, -ое тыелгысыз, ярсулы, котырынкы; дуамал; **~ гнев** тыелгысыз ачу

неулови́м||ый, -ая, -ое **1.** тотылмаучан, тотылмас, тотып булмый торган, тотуы кыен булган; очратып (туры китереп) булмый торган; **~ый челове́к** тотып булмый торган кеше **2.** *перен.* беленми торган, сизелер-сизелмәс,

беленер-беленмәс, күренер-күренмәс; **~ая ра́зница** сизерлер-сизелмәс аерма

неуме́ренный, -ая, -ое чамадан тыш зур (көчле, күп)

неуме́стный, -ая, -ое урынсыз, урынсызга ...ган, урынлы-урынсыз ...ган, килешсез; **~ вопро́с** урынсыз сорау

неумоли́мый, -ая, -ое **1.** (*непреклонный*) үзсүзле, кире, үз дигәнендә (сүзендә, фикерендә) нык торучан, сүзеннән (фикереннән) кайтмаучан **2.** (*выражающий непреклонность*) сүзендә (фикерендә) нык торучанлыкны белдергән (чагылдырган), сүзеннән (фикереннән) кайтмаячагын белдергән (чагылдырган) **3.** *перен.* ныклы, котылгысыз; **~ приговор** котылгысыз хөкем

неумо́лчный, -ая, -ое *см.* **несмолка́емый**

неуравнове́шенный, -ая, -ое тотрыксыз табигатьле, холыксыз; **~ челове́к** тотрыксыз табигатьле кеше; **~ хара́ктер** тотрыксыз табигать (характер)

неурожа́й *м* уңыш булмау, иген (ашлык, җимеш *һ.б.ш.*) уңмау; кытлык

неурожа́йн||ый, -ая, -ое: **~ый год** иген (ашлык, җимеш *һ.б.ш.*) уңмаган ел; **~ая земля́** уңыш бирми торган җир

неуро́чн||ый, -ая, -ое: **в ~ое вре́мя** вакытсыз, билгеләнгән вакыттан тыш; **прийти́ в ~ый час** вакытсыз килү

неуря́диц||а *ж разг.* килешмәүчелек, үзара тынышмау, тынычлык булмау, тиргәшү, ызгыш, орыш-талаш; **семе́йные ~ы** гаиләдә тынычлык булмау

неуспева́емость *ж* өлгермәү, начар өлгереш (*укуда*)

неуспева́ющ||ий, -ая, -ее **1.** өлгермәүче, начар өлгерешле; **~ий ученик** өлгермәүче укучы **2.** *в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~ая** *ж* өлгермәүче [укучы], начар өлгерешле [укучы]

неуста́нн||ый, -ая, -ое бертуктаусыз, өзлексез, армый-талмый; арымас-талмас ...; **~ая борьба́** бертуктаусыз көрәш, армый-талмый көрәшү

неусто́йк||а *ж* неустойка (*килешү шартларын үтәмәгән өчен түләнә торган штраф*); **уплати́ть ~у** неустойка түләү

неусто́йчивый, -ая, -ое **1.** какшау ..., селкенеп тора торган, селкенә торган, тотрыксыз; **~ стул** селкенә торган урындык **2.** *перен.* (*часто меняющийся*) үзгәреп торучан, үзгәрүчән, тотрыксыз **3.** *перен.* сүзендә (фикерендә) тормаучан, аумакай; **~ хара́ктер** аумакай характер

неустрани́м||ый, -ая, -ое котылгысыз, котылып булмый торган; **~ые поме́хи** котылгысыз комачаулар

неустраши́мый, -ая, -ое куркусыз, куркуны белми торган, кыю, йөрәкле, батыр йөрәкле; **~ во́ин** батыр йөрәкле сугышчы

неустро́йство *с* тәртипсезлек, тәртип булмау; тәртипкә (җайга) салынмау

неусы́пный, -ая, -ое уяу, бертуктаусыз, даими, бик дикъкатлә ...; **~ надзо́р** бертуктаусыз күзәтү

неутоми́тельный, -ая, -ое борчулы

неуте́шн||ый, -ая, -ое юанычсыз; **~ое го́ре** юанычсыз кайгы

неутоли́м||ый, -ая, -ое басылмас [лык], бик көчле, бик нык; **~ая жа́жда** басылмас сусау

неутоми́мость *ж* ару-талуны белми эшләү, армый-талмый эшләү; ару-талуны белмәү

неутоми́мый, -ая, -ое армый-талмый (эшли) торган, ару-талуны белмәгән (белми торган), ару-талуны белмәүчән

не́уч *м разг.* надан, томана, укымаган

неучти́вый, -ая, -ое ихтирамсыз, әдәпсез, тәрбиясез, итәгатьсез, нәзакәтсез; **~ челове́к** нәзакәтсез кеше; **~ отве́т** әдәпсез җавап

неуязви́м||ый, -ая, -ое ышанычлы, тел тидергесез; яхшы нигезләнгән, нык; **~ое доказа́тельство** яхшы нигезләнгән дәлил

нефри́т I *м мед.* нефрит (*бөер авыруы*)

нефри́т II *м мин.* нефрит

нефтеналивн||о́й, -а́я, -о́е нефть ...ы, нефть ташый торган; **~ы́е суда́** нефть ташый торган суднолар

нефтено́сн||ый, -ая, -ое нефть табыла (чыга) торган; нефтьле; **~ые пласты́** нефтьле катламнар

нефтеперего́нный, -ая, -ое нефть куа торган, нефть куу ...ы; **~ заво́д** нефть куа торган завод

нефтеперераба́тывающий, -ая, -ее нефть эшкәртә торган

нефтепрово́д *м* нефтьүткәргеч

нефтепро́мысел *м* нефть промыселы

нефтескважи́на *ж* нефть скважинасы

нефтехими́ческ||ий, -ая, -ое нефть химиясе ...ы; **~ая промы́шленность** нефть химиясе промышленносте

нефтехрани́лище *с* нефть саклау урыны; нефть саклагыч (*махсус корылма*)

нефть *м* нефть

нефтя́ник *м* нефтьче

нефтян||о́й, -а́я, -о́е нефть ...ы; **~а́я сква́жина** нефть скважинасы; **~а́я вы́шка** нефть вышкасы; **~а́я промы́шленность** нефть промышленносте

нехва́тка *ж разг.* җитешмәүчелек, җитешмәү, җитмәү, кытлык, тарлык; **~ вре́мени** вакытның тарлыгы

неходово́й, -а́я, -о́е *разг.* үтми торган, үтмәс, сатылмый торган; начар сатыла торган; **~ това́р** үтмәс товар

нехо́женный, -ая, -ое *разг.* кеше аягы басмаган, кеше басмаган, кеше йөрмәгән; кеше аз йөргән; аз йөрелгән (*юл, сукмак турында*)

нехоро́ший, -ая, -ее **1.** (*плохой*) начар; (*недобрый*) усал, яман, явыз; (*зловещий*) шомлы, куркыныч, дәһшәтле **2.** ямьсез, шыксыз, сөйкемсез; **он нехоро́ш собо́й** ул төскә-башка ямьсез

нехорошо́ *нареч.* **1.** начар; **чу́вствовать себя́ ~** үзеңне начар хис итү **2.** *в знач. сказ. безл.* (*не заслуживает одобрения*) начар, яхшы түгел, ярамый, килешми **3.** *в знач. сказ. безл.* (*о плохом самочувствии*) хәле (кәефе) начар, хәле (кәефе) яхшы түгел; **ему́ ста́ло ~** анын кәефе начарланып китте; **у него́ ~ на душе́** аның күңеле (жаны) тыныч түгел

нехотя *нареч.* теләмичә, теләр-теләмәс

нецелесообра́зн||ый, -ая, -ое файдасыз, максатка туры килмәгән (яраш-лы, максатчан булмаган), мәгънәсез, исраф ителгән; **~ая тра́та вре́мени** вакытны бушка исраф итү; **~ое реше́ние** мәгънәсез карар

нецензу́рн||ый, -ая, -ое әдәпсез, авызга алмаслык, оятсыз; **~ые слова́** әдәпсез сүзләр

неча́янн||ый, -ая, -ое **1.** көтелмәгән, көтмәгән, көтмәгәндә ..., кинәт булган; **~ая встре́ча** көтелмәгән очрашу **2.** (*случайный*) ялгыш ..., ялгышлык белән ..., сизмәстән ..., абайламыйча ...; **~ый вы́стрел** ялгыш атып жибәрү

не́чего I *мест.* ...асы ... юк, ...ыр [лык] ... юк; **~ рассказа́ть** сөйләр сүз юк; **выбира́ть не́ из чего** сайларлыгы юк ◆ **~ греха́ таи́ть** яшерен-батырын түгел; **~ сказа́ть** 1) әйтер сүз юк; 2) әйтәсе дә юк (түгел) инде, сөйләп тә торасы юк (түгел) инде, әйтерлек тә түгел; **от ~ де́лать** эш юктан эш итеп, эш юктан эш табып

не́чего II *в знач. сказ. с неопр., разг.* **1.** (*не следует*) ...асы булмау; **~ спать** йоклыйсы булма **2.** (*не надо, незачем*) ...п та торасы юк, ...п та торасы түгел; **~ об э́том толкова́ть** бу турыда сөйләп тә торасы юк

нечелове́ческ||ий, -ая, -ое **1.** (*не свойственный человеку*) кешегә хас булмаган **2.** кеше хәленнән (көченнән, күлыннан) килмәслек (килми торган), кеше хәленнән (көченнән) тыш, кеше булдыра алмаслык, чиктән тыш зур; **~ие уси́лия** чиктән тыш зур тырышлык

нечернозёмн||ый, -ая, -ое кара туфраклы булмаган; **~ая зо́на** кара туфраклы булмаган зона

нечёсаный, -ая, -ое чәче таралмаган, тузгак, чәче тузган

нечести́вый, -ая, -ое *уст.* гөнаһлы, бозык

нече́стный, -ая, -ое намуссыз, вөждансыз, турылыксыз, гаделлексез

не́чет *м разг.* так; **чёт и́ли ~?** такмы, җөпме?

нечётный, -ая, -ое так, икегә бүленми торган

нечистопло́тн||ый, -ая, -ое *прям., перен.* шапшак, шакшы, пычрак, нәжес; **~ые приёмы** пычрак алымнар

нечисто́ты *мн.* шакшылар, нәжесләр

нечи́ст||ый, -ая, -ое **1.** керле; **~ый плато́к** керле яулык **2.** пычрак, шапшак, шакшы, нәжес; **~ый двор** пычрак ишегалды **3.** (*с примесью*) катнаш, саф булмаган, саф түгел; (*о воздухе*) тынчу, тынчыган; (*о цвете*) тонык; (*о коже*) бетчәле, сыткылы; (*нечистокровный*) саф токымлы булмаган, саф нәселле булмаган, саф канлы булмаган; **~ая гли́на** катнаш балчык **4.** (*о произношении*) бик үк саф (дөрес) булмаган **5.** *разг.* (*неточно выполненный*) пөхтә булмаган, жиренә жит-кереп эшләнмәгән, начар **6.** *перен.* алдаулы, алдауга корылган; **~ые дела́**

алдаулы эшләр; **у него́ со́весть ~ а́** аның вөжданы пакъ түгел ◆ **на́ руку нечи́ст (~ый)** кулы озын, кулы кәкре; **~ый дух** *или* **~ая си́ла** *прост.* жен, шайтан, пәри

не́чисть *ж собир. прост.* **1.** *фольк.* (*нечистые дýхи*) җен-пәриләр, шайтаннар **2.** *перен.* хәшәрәтләр, жирәнечләр (*җирәнеч хайван, бөҗәк һәм түбән кешеләр турында*)

нечленораздéльн||ый, -ая, -ое аңлаешсыз; **~ые звýки** аңлаешсыз авазлар

нéчто *мест.* нәрсәдер, нидер, әллә нәрсә, бернәрсә

нещáдный, -ая, -ое аяусыз, рәхимсез, шәфкатьсез, кызганусыз

нея́вка *ж* килмәү

нея́сный, -ая, -ое **1.** (*неотчётливо слышимый*) иштелер-ишетелмәс, тоныק **2.** (*о речи, мыслях, чувствах и т.п.*) аңлаешсыз, аңлаешлы булмаган, аңлашылмый торган, ачык булмаган, тоныק

нея́сыть *эк. зоол.* соры ябалак

ни I **1.** *частица усил.* (*в отриц. предложениях*) ...да, бер генә ...дә; **ни сло́ва не изменю́** бер генә сүзен дә үзгәртмәм; **ни одного́ знако́мого не встре́тил** бер генә танышымны да очратмадым **2.** *частица усил.* (*в придаточных предложениях*) ...гына ...масын, ...гына ...са да; **кто ни уви́дит, удиви́тся** кем генә күрмәсен, [барысының да] исе китәр **3.** *союз* (*при перечислении однородных членов*) ... да, ... да; **на не́бе ни ме́сяца, ни звёзд** күк йөзендә ай да, йолдызлар да юк ◆ **ни взад ни вперёд** ни алга, ни артка; **ни-ни́** *или* **ни-ни-ни́** 1) (*при выражении категорического запрещения*) һич тә, һич тә ярамый; 2) (*при обозначении полного отсутствия действия*) һич [тә] юк, һич тә түгел; **ни ша́гу наза́д!** бер адымга да артка чигенмәскә!

ни II (*без ударения; в сочет. с предлогами является отделяемой частью отриц. мест.*) һичбер, бер ... дә; **ни от кого́ я не слыха́ла** һичбер кемнән ишетмәдем; **ни с ке́м он не разгова́ривал** һичберкем белән ул сөйләшмәде

ни́в||а *ж* I кыр, басу; **колхо́зные ~ы** колхоз кырлары **2.** *перен.* өлкә, мәйдан, юл; **на ~е просвеще́ния** мәгариф өлкәсендә

нивели́р *м геод.* нивелир (*прибор*)

нивели́ровать *сов., несов. что* **1.** *геод.* нивелирлау (*махсус прибор ярдәмендә җир өстендәге ноктaларны чагыштырып, аларның биеклеген билгеләү*) **2.** *перен. книжн.* тигезләү, аермасын бетерү, аермасын күрсәтмәү; **~ осо́бенности** үзенчәлекләр арасындагы аерманы бетерү

нивели́роваться 1. *сов., несов.* тигезләнү, аерма бетү **2.** *несов. страд. от* **нивели́ровать**

нивелиро́вщик *м* нивелирлаучы

нивх *м* нивх

ни́вхка *ж* нивх хатыны (кызы)

ни́вхи *мн.* нивхлар, нивх халкы

ни́вхский, -ая, -ое нивх[лар] ...ы; **~ язык** нивх теле

нигдé *нареч.* һичкайда, [бер] кайда да, һичбер җирдә, бер җирдә дә

нигили́зм *м* нигилизм

нигили́ст *м* нигилист

ниже- *кушма сүзләрнең беренче өлеше «түбәндә», «түбәндәрәк», «сөңрак»* (*текстның, сөйләмнең моннан яки шуннан соңгы олешендә*) *дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **~ука́занный** түбәндә күрсәтелгән; **~ска́занный** түбәндә әйтелгән; **~подписа́вшийся** түбәндә кул куйган

ни́ж||ний, -яя, -ее **1.** түбәнге, аскы; **~ний эта́ж** аскы кат; **~яя ступе́нька** түбәнге баскыч **2.** *разг.* астагы, аскы каттагы, аста торучы; **~ие жильцы́** аскы катта торучылар **3.** түбән, түбәнге; **~ее тече́ние реки́** елганың түбән агымы **4.** эчке; **~яя руба́шка** эчке күлмәк

низ *м* **1.** (*нижняя часть*) ас, аскы як, аскы өлеш **2.** *мн.* **~ы́** *уст.* (*низшие слои общества*) түбәнге катлау (*буржуаздворяннар җәмгыятендә*) **3.** *мн.* **~ы́** *муз.* түбән ноталар

низа́ть *несов. что* [җепкә] тезү

низверга́ть *несов. см.* **низве́ргнуть**

низверга́ться *несов.* **1.** *см.* **низве́ргнуться; 2.** *страд. от* **низверга́ть**

низве́ргнуть *сов. кого-что, книжн.* бәреп төшерү; атып бәрү

низве́ргнуться *сов. книжн.* төшү, егылып төшү

низи́на *ж* уйсулык, уйсу җир, уйсу урын, түбән җир

ни́зк||ий, -ая, -ое **1.** тәбәнәк; карсак; **~ий забо́р** тәбәнәк койма; **~ий каблу́к** тәбәнәк үкчә; **челове́к ~ого ро́ста** тәбәнәк буйлы кеше **2.** түбән; **~ое ка́чество** түбән сыйфат; **~ая температу́ра** түбән температура; **~ие це́ны** түбән хаклар **3.** түбән, нәкәс, нәҗес; **~ий челове́к** түбән кеше; **~ий посту́пок** түбән эш **4.** түбән, калын; **~ая но́та** *муз.* түбән нота; **~ий го́лос** калын тавыш ◆ **~ий лоб** тар маңгай; **~ий покло́н** түбәнчелек белән баш ию

ни́зко *нареч.* **1.** түбән; түбәннән; **самолёт пролете́л ~** самолёт түбән очып узды **2.** түбән, намуссыз; **он поступи́л ~** ул түбәнлек күрсәтте **3.** *в знач. сказ.* түбән, җир якын; **о́кна ~ от земли́** тәрәзәләре җир якын ◆ **~ кла́няться** түбәнчелек белән баш ию

низпокло́нник *м* ялагай, юмакай, тәлинкә тоткы, баш июче

низкопокло́нничать *несов.* ялагайлану, юмакайлану, тәлинкә тоту, баш ию

низкопокло́нство *с* ялагайлык, юмакайлык, тәлинкә тоту, баш ию

низкопро́бн||ый, -ая, -ое **1.** түбән пробалы; **~ое серебро́** түбән пробалы көмеш **2.** *перен. разг.* түбән сыйфатлы, начар

низкоро́слый, -ая, -ое тәбәнәк [буйлы], карсак

низкосо́ртный, -ая, -ое түбән сортлы, түбән сыйфатлы

низлага́ть *несов. см.* **низложи́ть**

низложи́ть *сов. прям., перен. кого-что, книжн.* [бәреп] төшерү; **~ мона́рха** монархны тәхеттән төшерү; **~ чей-л. авторите́т** абруен төшерү

ни́зменность *ж* (*низменная местность*) түбәнлек, иңкү җир, иңкүлек, уйсу җир, үзәнлек, уйсулык

ни́зменн||ый, -ая, -ое **1.** түбән, иңкү, иңсү, үзәнсу, уйсу; **~ое ме́сто** иңкү жир **2.** *перен.* түбән, кабахәт, нәкәс; **~ые интере́сы** түбән интереслар

низов||о́й, -а́я, -о́е: **~о́й ве́тер** түбәннән искән җил; **~ые города́** елга тамагына якын урнашкан шәһәрләр, түбәнге шәһәрләр; **~ы́е организа́ции** башлангыч оешмалар; **~а́я печа́ть** урындагы матбугат; **~а́я трава́** уйсулыкта үскән үлән

низо́вье *с* түбән агым, түбәнге агым; түбәнге өлеш; **~ Ка́мы** Каманың түбәнге өлеше

ни́зом *нареч.* астан, түбән юл белән, аскы юл белән

ни́зость *ж* түбәнлек, кабахәтлек, нәкәслек

ни́зш||ий, -ая, -ее **1.** *превосх. ст. от* **ни́зкий** 2; **~ий сорт** ин түбән сорт **2.** түбән төзелешле, садә; **~ые расте́ния** түбән төзелешле үсемлекләр **3.** түбән; **~ее зва́ние** түбән дәрәҗә **4.** башлангыч; **~ее образова́ние** башлангыч белем

ника́к I *нареч.* ничек тә, берничек тә, һич тә; **вот э́того я ~ не понима́ю** менә моны мин һич тә аңлый алмыйм ◆ **~ нет** һич тә юк, һич тә түгел (*түбәнчелек белән бирелгән җавап*)

ника́к II *частица и вводн. сл. прост.* ахрысы, бугай, күрәсең, булса кирәк; **ты, ~, заболе́л?** син авырдың ахрысы?

никак||о́й, -а́я, -о́е *мест.* **1.** һичбер, һичбер нинди, бернинди дә, һичбер төрле; **нет ~о́го сомне́ния** һичбер [нинди] шик юк **2.** (*никуда не годный*) *разг.* бернәрсәгә яраксыз, бернигә дә ярамый торган, начар; **шахмати́ст он ~о́й** ул бернигә яраксыз шахматчы, ул һичбер нинди шахматчы түгел ◆ **без ~и́х!** *или* **и [бо́льше] ~и́х!** ≈ әйткән-беткән, бетте-китте; вәссәлам!; **~ не...** һич тә ... түгел; **он ~ не врач** ул һичбер нинди врач түгел; **~их гвозде́й!** әйткән-беткән!, бетте-китте!; вәссәлам!

ни́келев||ый, -ая, -ое **1.** никель ...ы; **~ая руда́** никель рудасы **2.** никель ..., никельдән ясалган; никель йөгертелгән; **~ый ча́йник** никель чәйнек

никелирова́ть *несов. что* никель йөгертү, никельләү

никелиро́вка *ж* **1.** *см.* **никелирова́ть; ~ дета́лей** детальләрне никельләү **2.** (*никелевое покрытие*) никель катлавы, никель йөгертелгән катлау

никелиро́вочный, -ая, -ое никель йөгертү ...ы, никельләү ...ы; **~ цех** никельләү цехы

ни́кель *м хим.* никель

ни́кнуть *несов.* **1.** (*о растениях*) шиңү, шиңеп төшү, шиңеп салынып төшү (бөгелү, сыгылу), сулу **2.** *перен.* (*терять силы*) зәгыйфьләнү, хәлсезләнү, хәлсезләнеп китү, хәлсезләнеп сыгылып төшү

никогда́ *нареч.* бервакытта [да], һичбер вакытта [да], беркайчан [да]; **лу́чше по́здно, чем ~** *погов.* һич булганчы, кич булсын; соң булса да уң булсын ◆ **как**

~ бервакытта да булмагандай, бервакытта да булмаган кебек (шикелле, дәрәҗәдә)

нико́||й: ~им о́бразом һич тә, һичбер хәлдә дә, әллә нигә дә

никоти́н *м* никотин

никоти́нный, -ая, -ое никотин ...ы, никотинлы; **~ раство́р** никотин эремәсе

никоти́нов||ый, -ая, -ое никотин ...ы, никотинлы; **~ая кислота́** никотин кислотасы

никто́ *мест.* **1.** беркем дә, һичкем, берәү дә; **~ меня́ не ждёт** беркем дә мине көтми **2.** *в знач. сущ.* **~** *м нескл. разг.* беркеме дә түгел (туган тиешле түгел); **он мне ~** ул минем беркемем дә түгел

никуда́ *нареч.* һичкая, беркая да; **~ не пое́ду** беркая да бармыйм ♦ **~ не годи́тся** бернәрсәгә (бернигә) дә ярамый; **~ не го́дный** бернәрсәгә (бернигә) яраксыз, бернәрсәгә дә ярамый торган

никуды́шный, -ая, -ое *прост.* бернәрсәгә яраксыз, һичнәрсәгә яраксыз, бернәрсәгә дә ярамый торган

никчёмн||ый, -ая, -ое *разг.* файдасыз, кирәксез, кирәкмәгән, [бернигә дә] кирәге булмаган; **~ая кни́га** бернигә дә кирәге булмаган китап; **~ый вопро́с** кирәкмәгән сорау

нима́ло *нареч.* һич тә, аз гына да, бер дә; **ваш вопро́с его́ ~ не смути́л** биргән соравыгыз аны һич тә уңайсызландырмады

нимб *м* нур, нурлы алка (*иконалардагы, антик сыннарның башы тирәсендәге*)

ни́мфа *ж миф.* нимфа

ниоткуда́ *нареч.* беркайдан да, һичкайдан, бер җирдән дә, һичбер җирдән

нипочём *нареч. в знач. сказ. кому-чему, разг.* берни түгел, берни тормый; зарарсыз, зарары (зыяны) юк; **моро́зы ему́ ~** салкыннар аның өчен берни түгел

нисколько *нареч.* бер дә, һич [тә], һичбер

ниспада́ть *несов. книжн.* салынып тору (төшеп тору)

ниспровергну́ть *несов. см.* **ниспове́ргнуть**

ниспове́ргнуть *сов. прям., перен. кого-что, книжн.* [бәреп] төшерү; **~ авторите́т** абруен төшерү

нисходя́щ||ий, -ая, -ее кимеп бара торган, кимеп баручы ♦ **~ее ударе́ние** *лингв.* төшерелмә басым

нитеви́дный, -ая, -ое җепсыман, җептәй ♦ **~ пульс** *мед.* җепсыман пульс, сизелер-сизелмәс пульс

ни́тк||а *ж* **1.** җеп; **вдеть ~у в иго́лку** энәгә җеп саплау **2.** бер тезмә; **~а би́сера** бер тезмә сәйлән ♦ **до [после́дней] ~и обобра́ть** ялангач калдыру, [талап] алып бетерү

нитроглицери́н *м* нитроглицерин

нитча́тка *ж* **1.** *бот.* бака ефәге **2.** *зоол.* җеп суалчан

ни́тчатый, -ая, -ое *см.* **нитеви́дный**

нит||ь *ж* **1.** *см.* **ни́тка; 2.** *перен.* җепсел; **не́рвные ~и** нерв җепселләре **3.** *перен.* җеп, тезмә; чылбыр; **~и дру́жбы** дуслык җепләре; **~и воспомина́ний** истәлекләр чылбыры; **потеря́ть ~ь разгово́ра** сүзнең җеп очын югалту

ни́тян||ый, -ая, -ое киже-мамык ..., киже-мамык җептән бәйләнгән; **~ые перча́тки** киже-мамык перчаткалар

ниц *нареч. книжн.* йөзтүбән; **па́дать ~** йөзтүбән егылу

ничего́ *нареч. разг.* **1.** (*довольно сносно*) ярыйсы [гына], бертөрле **2.** *в знач. сказ.* (*пусть*) ярый, ярар; (*мало что значит*) зарар (зыян) юк, берни түгел; (*всё равно*) барыбер, берни түгел, исе дә китми; **пусть придёт, ~** берни түгел, килә бирсен ♦ **~ подо́бного** һич тә алай түгел

ничегонеде́лание *с разг.* бушка вакыт үткәрү, эшсезлек, эшсез яту, тик яту, түшәмгә төкереп яту, буш йөрү

нич||ей́, -ья́, -ьё *мест.* **1.** һичкемнеке, берәүнеке дә [булмаган], [бер] кемнеке дә [булмаган], хуҗасыз, иясез; **~ья́ соба́ка** иясез эт **2.** (*чей бы то ни было*) һичкемнең [дә], беркемнең [дә], берәүнең [дә]; **не ну́жно мне ~и́х сове́тов** һич беркемнең киңәше кирәк түгел миңа **3.** *в знач. сущ.* **~ья́** *ж спорт.* бер якның да отмавы, уртак нәтиҗә; **согласи́ться на ~ью́** уртак нәтиҗәгә килешү

ничей́н||ый, -ая, -ое **1.** *разг. см.* **ничей́** 1; **~ая земля́** хуҗасыз җир **2.** *спорт.* бер якның да отмавы белән ...ган; **~ая па́ртия** бер якның да отмавы белән тәмамланган партия

ничко́м *нареч.* йөзтүбән

ничто́ *мест.* **1.** һичнәрсә, һичбер нәрсә, һични, бернәрсә дә; **его́ ~ не интересу́ет** аны бернәрсә дә кызыксындырмый; **он ничего́ не по́нял** ул һичнәрсә аңламады **2.** *в знач. сущ. м нескл.* берни түгел; **без труда́ челове́к ~** хезмәттән башка кеше беркем дә түгел ♦ **преврати́ться (обрати́ться) в ~** юкка чыгу, бетү, төмам таркалу

ничто́же: ~ сумня́шеся *шутл.* һич тә икеләнмичә, һич тә шикләнмичә, һич тә уйлап-нитеп тормыйча

ничто́жество *с* бик түбән (вак) кеше, вак жанлы кеше, чүп [кеше]; нәҗес

ничто́жн||ый, -ая, -ое **1.** бик аз (кечкенә), чиктән тыш аз (кечкенә); **~ая часть** *чего-л. берәр нәрсәнең* бик кечкенә өлеше **2.** бик әһәмиятсез, бик кечкенә; бик түбән; **~ая причи́на** бик кечкенә сәбәп **3.** бик түбән, бик вак, вак җанлы; **~ый челове́к** бик түбән кеше

ничу́ть *нареч. разг.* бер дә, һич [тә], һичбер ♦ **~ не быва́ло** һич тә юк, һич тә [алай] түгел

ни́ша *ж* куыш; уем; чокыр

нища́ть *несов.* фәкыйрьләнү, фәкыйрьлеккә төшү, хәерчеләнү, хәерчелеккә төшү

ни́щенка *ж разг.* теләнче хатын (кыз), хәерче хатын (кыз)

ни́щенск||ий, -ая, -ое **1.** теләнче ...ы, хәерче ...ы; **~ое существова́ние** хәерче тормышы **2.** *перен.* бик аз (кечкенә, түбән); **~ая пла́та** бик түбән хак (бәя)

ни́щенство *с* теләнчелек, хәерчелек; фәкыйрьлек

ни́щенствовать *несов.* **1.** (*жить подаянием*) хәерчелек иту, хәер сорау, хәер эстәү, соранып йөрү **2.** (*жить в нищете*) фәкыйрьлектә яшәү, хәерчелектә яшәү

нищета́ *ж* **1.** (*крайняя бедность*) хәерчелек, фәкыйрьлек **2.** *перен.* фәкыйрьлек; **духо́вная ~** рухи фәкыйрьлек **3.** *собир. разг.* хәерчеләр, теләнчеләр; фәкыйрьләр

ни́щ||ий, -ая, -ее **1.** (*крайне бедный*) фәкыйрь, бик ярлы **2.** *в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~ая** *ж* теләнче, хәерче

но I 1. *союз* ләкин, әмма; әмма ләкин, мәгәр; **не то́лько ты, но и я** син генә түгел, мин дә; **он не то́лько писа́ть, но да́же и чита́ть не уме́ет** ул яза гына түгел, хәтта укый да белми **2.** *в знач. сущ. с нескл.* ләкин; **одна́ко здесь есть одно́ «но»** әмма биредә бер «ләкин» бар

но II *межд.* **1.** (*при понукании лошади*) на-а-а **2.** (*выражает предостережение, угрозу*) ну-ну

нова́тор *м* новатор, яңалык кертүче, яңалыкчы; **~ы произво́дства** производство новаторлары

нова́торск||ий, -ая, -ое новаторлык ...ы, новаторларча ..., яңалык кертүчеләрчә ...; **~ое отноше́ние к труду́** хезмәткә новаторларча мөнәсәбәт

нова́торство *с* новаторлык, яңалык кертү, яңалыкчылык

нове́лла *ж лит.* новелла (*кыска хикәя*)

новелли́ст *м* новеллачы

но́веньк||ий, -ая, -ое *разг.* **1.** өр-яңа; **~ий костю́м** өр-яңа костюм **2.** *в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~ая** *ж см.* **новичо́к**

новизна́ *ж* яңалык

нови́нк||а *ж* яңалык (*яңа әйбер, яңа хәбәр*); **кни́жные ~и** яңа китаплар ♦ **в ~у** яңалык [булу, булып тору]

новичо́к *м разг.* яңа кеше (*эшкә яңа кергән кеше*); яңа укучы (*мәктәпкә яңа кергән укучы*)

новобра́нец *м* новобранец (*яңа гына хәрби хезмәткә алынган кеше*)

новобра́чн||ый, -ая, -ое **1.** яңа гына өйләнгән (өйләнешкән), яңа гына никахлашкан **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м* яңа гына өйләнгән; **~ая** *ж* яңа гына кияүгә чыккан

нововведе́ние *с* яңалык

новогóдн||ий, -ая, -ее яңа ел ...ы; **~ий пода́рок** яңа ел бүләге; **~ее поздравле́ние** яңа ел белән котлау; **~яя ночь** яңа ел төне

новоиспечённый, -ая, -ое *шутл.* яңа гына ...ган; **~ прое́кт** яңа гына төзелгән проект; **~ студе́нт** яңа гына студент булган [кеше]

новолу́ние *с* яңа ай, ай башы

новообразова́ние *с* **1.** яңа форма (элемент *һ.б.ш.*) барлыкка килү; **~ минера́лов** яңа минераллар барлыкка килү **2.** *мед.* шеш **3.** *лингв.* яңа сүз (берәмлек *һ.б.ш.*)

новорождённ||ый, -ая, -ое **1.** яңа туган **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* яңа туган бала

новосёл *м* яңа урынга күчеп килгән кеше, яңа өйгә күчеп килгән кеше

новосе́лье *с* [яна] өй туе; **пригласи́ть на ~** өй туена чакыру

новостро́йка *ж* **1.** (*строительство*) яңа төзелеш, яңа корылыш **2.** (*здание*) яңа корылма

но́вост||ь *ж* **1.** яңалык; **~и нау́ки и те́хники** фән һәм техника яңалыклары **2.** хәбәр; **прия́тная ~ь** күңелле хәбәр ◆ **вот [ещё] ~ь (~и)!** *или* **что за ~ь (~и)!** ни дигән сүз тагы!

новоте́льная *с.-х.*: **~ коро́ва** 1) яңа гына бозаулаган сыер; 2) беренче бозау анасы (*беренче тапкыр бозаулаган сыер турында*)

новоя́вленный, -ая, -ое *ирон.* яңа гына барлыкка (дөньяга) килгән; өр-яңа; **~ защи́тник** өр-яңа яклаучы

но́вшество *с* яңалык

но́в||ый, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* яңа; **~ый костю́м** яңа костюм; **~ые иде́и** яңа идеялар; **~ая исто́рия** яңа тарих; **~ая поро́да скота́** яңа нәселле терлек; **~ая мо́да** яңа мода; **~ый учёбник** яңа дәреслек; **~ый учени́к** яңа укучы; **~ое вре́мя** яңа вакыт; **он здесь челове́к ~ый** биредә ул яңа кеше; **~ые места́** яңа урыннар **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* яңалык; **чу́вство ~ого** яңалыкны тою ◆ **~ое сло́во** *с чём* яңалык, яңа сүз; **Но́вый год** Яңа ел

новь *ж* (*целина*) чирәм җир, сөрелмәгән җир

ног||а́ *ж* аяк ◆ **без (за́дних) ног** бик нык арып; **вверх ~а́ми** баштүбән; **в ~а́х** аяк очында; **е́ле но́ги унести́** көчкә качып котылу (китү); **е́ле но́ги переставля́ть** көчкә-көчкә гегә атлап бару, аякны чак сөйрәп бару; **на ~а́х** аякта, аяк өстендә; **на ~а́х не стои́т** аяк өстендә басып тора алмый (*бик арыган яисә исерек*); **ни ~о́й** аяк[та] басмаячакмын; **ног под собо́й не чу́ять (не слы́шать)** 1) (*от усталости*) әйтерсең лә, аяклар үзеннеке түгел; 2) (*от радости*) аяк[лар] җиргә тимәү, кая басарга белмәү; түбәсе күккә тию; **~и́ не бу́дет** (*о себе*) аяк [та] басмаячакмын; (*о другом*) аяк [та] бастырмаячакмын; **одна́ ~а́ здесь, друга́я — там** бер аягы анда, берсе монда (*бик тиз барып кайту турында*); **одно́й ~о́й в моги́ле** бер аягы җирдә [түрдә], икенчесе — гүрдә; **под ~а́ми** аяк астында; аста, түбәндә; **со всех ног [броса́ться, кида́ться]** җанфәрманга [ташлану]

нога́ец *м* нугай, нугай кешесе

нога́йка *ж* нугай хатыны (кызы)

нога́йский, -ая, -ое нугай[лар] ...ы; **~ язык** нугай теле

нога́йцы *мн.* нугайлар, нугай халкы

ноготки́ *мн. бот.* тырнак гөл

но́г||оть *м* тырнак ◆ **до ко́нчиков (до конца́) ~тей** ≈ баштан аяк, башыннан аягына кадәр, үтәдән-үтә; **~тя его́ не сто́ит** [аның] кисәп ташлаган тырнагына да тормый

нож *м* пычак ◆ **без ~а́ заре́зать** пычаксыз сую, харап итү; **быть на ~а́х** *с кем* пычакка пычак килеп тору (*дошман булу*); **~ в спи́ну** аркага пычак кадау, арттан китереп пычак кадау; **~ о́стрый** үткен пычактай (*бик зур куңелсезлек, бик авыр, куңелсез нәрсә турында*)

ножев||о́й, -ая, -о́е пычак ...ы; **~а́я ра́на** пычак ярасы

но́жик *м* пәке, пычак; **перочи́нный ~** карандаш очлый торган пәке

но́жк||а *ж* **1.** *уменьш. от* **нога́; прыга́ть на одно́й ~е** бер аякта сикерү, титаклау **2.** аяк; **~а стола́** өстәл аягы **3.** *бот.* сабак; **~а одува́нчика** тузганак сабагы

но́жницы *только мн.* кайчы

но́жны, ножны́ *только мн.* кын

ножо́вка *ж* кул пычкысы

ноздрева́тый, -ая, -ое тишекле-тишекле, тишек-тишек, күзле-күзле, күзәнәкле; **~сыр** күзәнәкле сыр

ноздря́ *ж* борын тишеге

нока́ут *м спорт.* нокаут (*бокста*)

нокаути́ровать *сов., несов. кого, спорт.* нокаут ясау, нокаутка жибәрү (*бокста*)

нокда́ун *м спорт.* нокдаун (*бокста*)

ноктю́рн *м муз.* ноктюрн

ноль *м* ноль

номенклату́ра *ж* номенклатура, исемлек, исемнәр җыелмасы

номенклату́рный, -ая, -ое номенклатура ...ы, номенклатур; **~ рабо́тник** номенклатур работник

но́мер *м* **1.** *в разн. знач.* номер; **~ биле́та** билет номеры; **~ автомоби́ля** автомобиль номеры; **просто́рный ~** иркен номер; **хорово́й ~** хор номеры **2.** сан; **после́дний ~ журна́ла** журналның соңгы саны

номеро́к *ж* **1.** *уменьш. от* **но́мер** 1; **2.** (*жетон с цифрой*) номер

номина́л *м* номинал (*товарның, акчаның күрсәтелгән бәясе*)

номина́льный, -ая, -ое номиналь, өстенә куелган (язылган)

нонпаре́ль *ж полигр.* нонпарель (*петиттан ваграк шрифт*)

нора́ *ж* өң, җәнлек оясы

норве́жец *м* норвегияле, норвегияле кеше

норве́жка *ж* норвегияле хатын (кыз)

норве́жский, -ая, -ое норвегиялеләр ...ы; Норвегия ...ы; **~ язы́к** норвегиялеләр теле

норве́жцы *мн.* норвегиялеләр, Норвегия халкы

норд *м* **1.** (*северное направление*) төньяк **2.** (*северный ветер*) төньяк жиле

норд-ве́ст *м* **1.** (*северо-западное направление*) төньяк-көнбатыш **2.** (*северо-западный ветер*) төньяк-көнбатыш жиле

норд-о́ст *м* **1.** (*северо-восточное направление*) төньяк-көнчыгыш **2.** (*северо-восточный ветер*) төньяк-көнчыгыш жиле

но́рка I *ж уменьш. от* **нора́**

но́рка II *ж зоол.* чәшке (*җәнлек*)

но́рков||ый, -ая, -ое **1.** чәшке ...ы; **~ая шку́рка** чәшке тиресе **2.** чәшке механнан тегелгән, чәшке ...; **~ая ша́пка** чәшке бүрек

но́рм||а *ж* **1.** норма, кагыйдә; **~ы литерату́рного языка́** әдәби тел нормалары **2.** норма, күләм; **~ а вы́работки** эшләп чыгару нормасы

нормализова́ть *сов., несов. что* нормальләштерү

нормализова́ться 1. *сов., несов.* нормальләшү **2.** *несов. страд. от* **нормализова́ть**

норма́льный, -ая, -ое **1.** нормаль, гадәттәге; **~ вес** нормаль авырлык **2.** (*психически здоровый*) нормаль, психик [яктан] сәламәт

норма́нны *мн.* норманнар (*урта гасырларда Скандинавиядә яшәгән кабиләләрнең гомуми исеме*)

норма́тив *м* норматив; **техни́ческие ~ы** техник нормативлар

норма́тивн||ый, -ая, -ое норматив; **~ые показа́тели** норматив күрсәткечләр; **~ая грамма́тика** норматив грамматика

нормирова́ть *сов., несов. что* нормалаштыру, нормага кую (салу)

нормиро́вщик *м* нормировщик

нормиро́вщица *ж* нормировщик хатын (кыз)

но́ров *м прост.*: **с ~ом** тискәре, кире, үзсүзле

норови́стый, -ая, -ое *прост.* (*о лошади*) чыгымчы; (*о человеке*) тискәре, кире, үзсүзле

нрови́ть *несов. разг.* (*стремиться сделать что-л.*) тырышу, омтылу, матавыш; (*стремиться стать кем-л.*) ... булырга тырышу (маташу, омтылу), ...лыкка омтылу

нос *м в разн. знач.* борын; **~ с горби́нкой** бөкре (кәкре) борын; **курно́сый ~** почык (тупыйк) борын; **~ ло́дки** көймәнең борыны ◆ **на ~ý** борын төбендә, җитеп (якынлашып) килә; **зима́ на ~ý** кыш борын төбендә; **~ к ~у** *или* **~ом к ~у** ≈ маңгайга-маңгай, йөзгә-йөз , кара-каршы; **~ не доро́с** башың яшь әле; **под [са́мым] ~ом** *у кого* борын төбендә, борын астында (*якында*); **с ~а (~у)** *прост.* борын (кеше) башыннан; **в ~ говори́ть** борын аша сөйләү, борын белән сөйләү; тынкыш сөйләү, тынкышлану; **~а не каза́ть (не пока́зывать)** борынны да күрсәтмәү, [күзгә дә] күренмәү, килмәү; **по́д нос говори́ть (бормота́ть** *и т.п.*) борын астыннан сөйләү (мыгырдану)

носа́стый, -ая, -ое *прост.*, **носа́тый**, -ая, -ое *разг.* зур борынлы

но́сик *м* **1.** *уменьш. от* **нос; 2.** (*у чайника, у обуви*) борын

носи́лки *только мн.* носилка

носи́льн||ый, -ая, -ое өскә кия (киелә) торган; **~ое бельё** эчке киемнәр; **~ые ве́щи** өс киемнәре

носи́тель *м книжн.* **1.** ия, вәкил; таратучы; **~ культу́ры** мәдәният таратучы **2.** *мед.* таратучы; **~ дифтери́и** дифтерия таратучы **3.** сойләшүче; **~ тата́рского языка́** татар телендә сөйләшүче

носи́тельница *ж см.* **носи́тель**

носи́||ть *несов.* **1.** *кого-что* йөртү, күтәреп йөртү; **~ть портфе́ль под мы́шкой** портфельне култык астына кыстырып йөртү **2.** ташу; **~ть дрова́** утын ташу **3.** *кого-что, разг.* (*о бере-*

менной) күтәрү; **~ть ребёнка** бала күтәрү (*йөкле булу*) **4.** *что* кию, киеп йөрү, йөртү; (*медали, украшения и т.п.*) тагу, тагып йөртү; **~ть чёрное пла́тье** кара күлмәк киеп йөрү; **~ть кольцо́** йөзек кию; **~ть тёмные очки́** кара күзлек кию **5.** (*о волосах, бороде, усах*) йөртү **6.** *что* йөрү, йөртү; **~ть де́вичью фами́лию** кыз чагындагы фамилияңне йөртү **7.** булу, бару; **спор ~л бу́рный хара́ктер** бәхәс кызу характерда булды ♦ **~ть в себе́** *что* эчендә саклау (*кешегә сөйләмәү*); **~ть на рука́х** *кого* ≈ уч төбендә генә йөртү; ≈ өрмәгән урынга утыртмау (*бик кадерләү*); **высоко́ (го́рдо) ~ть го́лову** башны югары тоту (*үзен горур тоту*)

носи́ться *несов.* **1.** [ашыгып, ашыкпошык] йөрү, чабып йөрү, (*берәр нәрсәгә утырып*) тиз-тиз йөрү; чабу; **~ на мотоци́кле** мотоциклда чабу **2.** (*находиться в но́ске*) кияргә ярау, киелү; (*быть принятым модой*) йөртелү, киелү, кию модасы югалмау (саклану); **костю́м но́сится до сих по́р** костюм хәзергә кадәр киелә **3.** *с кем-чем, разг.* ис китеп йөрү, мавыгып йөрү, әвәрә килү; **~ с но́вым пла́ном** яңа план белән мавыгып йөрү **4.** *страд. от* **носи́ть** I ♦ **~ в во́здухе** сизелеп тору; **~ как с пи́саной то́рбой** әвәрә килү (*берәр әһәмиятсез нәрсә белән*)

носки́ *мн.* оекбаш

но́ск||ий, -ая, -ое **1.** *разг.* (*об одежде, обуви*) нык, чыдам **2.** (*о птицах*) күп йомырка салучы, күп йомырка сала торган

носоглото́тка *ж* йоткылык өсте

носо́к *м* (*ступни*) баш, оч; (*обуви, чулка и т.п.*) баш, оч, борын

носоро́г *м* мәгезборын, кәркәдән

ностальги́я *ж* җирсү, җирсетү, туган илне сагыну

но́т||а I *ж муз.* нота; **игра́ть по ~ам** нотага карап уйнау ♦ **как по ~ам разыгра́ть** шоп-шома (ул-бусыз) үткәреп җибәрү

но́та II *ж дип.* нота

нотариа́льн||ый, -ая, -ое **1.** нотариус ...ы, нотариаль; **~ая конто́ра** нотариаль контора **2.** нотариуста таныкланган; **~ая ко́пия** нотариуста таныкланган күчермә

нота́риус *м* нотариус

нота́ци||я I *ж* үгет, нәсихәт, үгет-нәсихәт; акыл өйрәтү, вәгазьләү; **чита́ть ~ю** үгет-нәсихәт бирү

нота́ция II *ж спец.* нотация (*шартлы билгеләр системасы*)

но́тн||ый, -ая, -ое нота[лар] ...ы; **~ая тетра́дь** нота дәфтәре

ночева́||ть *сов., несов.* куну, төн үткәрү, йоклау ♦ **и не ~ло** *что* ≈ эзе (әсәре) дә юк, эзе дә булмаган; кереп тә чыкмаган

ночёвк||а *ж* куну; **прие́хать с ~ой** куна килү

ночле́г *м* **1.** куну урыны, кунар җир (урын), куна торган җир (урын); **найти́ себе́ ~** үзенә куну урыны табу **2.** куну; **останови́ться на ~** куна керү

ночле́жка *ж разг.* ночлежка (*капиталистик илләрдә куну урыннары булмаган шәһәр ярлылары өчен кунып чыгу йорты*)

ночле́жный, -ая, -ое куну ...ы, кунып чыгу ...ы; **~ дом** кунып чыгу йорты

ночни́к *м* төнге лампа

ночни́ца *ж* **1.** (*бабочка*) төн күбәләге **2.** (*мелкая летучая мышь*) ярканат

ночн||о́й, -а́я, -о́е **1.** төн ...ы; төнге; **~о́й мрак** төн караңгысы; **~о́й сон** төнге йокы; **в ~о́е вре́мя** төнлә, төнлө белән **2.** төнге; **~а́я рабо́та** төнге эш **3.** *в знач. сущ.* **~о́е** *с* куна бару; **отпра́виться в ~о́е** [ат ашатырга] куна бару ♦ **~а́я ба́бочка** *зоол.* төн күбәләге; **~а́я краса́вица** *бот.* төн гүзәле

ноч||ь *ж* төн; **всю ~ь** төн буе; **глубо́кая ~ь** кара төн, җиде төн уртасы; **глубо́кой ~ью** җиде төн уртасында; **день и ~ь** көне-төне; **под покро́вом ~и** төн пәрдәсе астында, төнлә; **це́лыми ~а́ми** төннәр буе ♦ **на́ ночь** төнгә, төнгегә; **чита́ть на́ ночь** йокы алдыннан уку; **на́ ночь гля́дя** төнгә каршы; **споко́ной ~и!** тыныч йокы!

но́чью *нареч.* төнлә белән

но́ша *ж прям., перен.* йөк ♦ **свои́ ~ не тя́нет** *погов.* үз сеягең үзеңә авыр түгел

но́шеный, -ая, -ое киелгән; кулланылган; тотылган; **~ костю́м** киелгән костюм

ноя́брь *м* ноябрь, ноябрь ае

ноя́брьск||ий, -ая, -ое ноябрь ...ы; ноябрь аендагы ...; **~ие холода́** ноябрь аендагы салкыннар

нрав *м* **1.** холык, табигать; **до́брый ~** йомшак табигать **2.** *обычно мн.* **~ы** гадәтләр, гореф-гадәтләр; **стари́нные ~ы** борынгы гадәтләр ♦ **по ~у** ошый, күңелгә ошый, күңелгә хуш килә; **пришло́сь по ~у** күңелгә ошады

нра́вит||ься *несов.* **1.** *кому-чему* ошау, күңелгә ошау, хуш килү, күңелгә яту **2.** *безл. кому-чему и с неопр.* ошау, ярату; **ему́ ~ся е́здить верхо́м** ул атка атланып йөрергә ярата

нравоуче́ние *с* үгет-нәсихәт, вәгазь

нравоучи́тельный, -ая, -ое үгет-нәсихәтле, үгет-нәсихәт биргән

нра́вственность *ж* әхлаклылык, әхлак; әдәп

нра́вственн||ый, -ая, -ое **1.** әхлак ...ы, әхлакый; **~ые но́рмы** әхлак нормалары; **~ое воспита́ние** әхлак тәрбиясе; **~ый долг** әхлакый бурыч **2.** әхлаклы, тәүфыйклы, әдәпле; **~ый челове́к** тәүфыйклы кеше; **~ый посту́пок** әхлаклылык күрсәтү **3.** мораль, рухи, эчке; **~ые муче́ния** рухи газаплар

ну I *межд.* **1.** (*выражает побуждение к действию*) я; әйдә; **ну, расска́зывай** я, сөйлә **2.** кит[егез] әле; **ну тебя́, не меша́й!** кит әле, комачаулама! **3.** (*выражает удивление*) әй, искиткеч, исең китәр, ... дә соң ...ы; **ну и дождь!** көчле дә соң яңгыры!

ну II *частица* **1.** *вопр.* (*неужели*) китсәнә, китче, булмас ла **2.** *усил.* я; я ...ди, инде; **ну, а да́льше что?** я, аннан соң?; **ну, коне́чно!** билгеле инде! **3.** *в знач. союза* (*указывает на вывод, заключение или вводное замечание*) әйс; кыскасы; я, димәк; **ну, я пошёл** я, мин киттем **4.** (*в знач. «начал», «стал»*) ...а башлады (башладылар); **вошли́ в ко́мнату — и ну крича́ть** бүлмәгә керделәр дә кычкыра башладылар ♦ **ну и ну!** исең китәр!

ну́дный, -ая, -ое *разг.* эчпошыргыч, ялыктыргыч, күңелсез

нужд||а́ *ж* **1.** (*бедность*) мохтаҗлык, ярлылык, фәкыйрьлек **2.** (*потребность в чём-л.*) ихтыяҗ, хаҗәт; мохтаҗлык; йомыш, кирәк [нәрсә]; **без ~ы́** булмаса; тик торганда; **в слу́чае ~ы́** кирәк булган хәлдә (очракта), кирәк була калса; **нет ~ы́** хаҗәте юк, кирәге юк; **нет ~ы́ приводи́ть приме́ры** мисаллар китерүнең кирәге юк; **ну́жды и запро́сы трудя́щихся** хезмәт ияләренең ихтыяҗлары һәм таләпләре; **скоре́е по привы́чке, чем по ~е́** кирәк булудан бигрәк гадәт буенча; **испы́тывать ~у́ в** *чём-л. берәр нәрсәгә* мохтаҗ булу

нуждаемость *ж* мохтаҗлык

нужда́ться *несов.* **1.** (*жить в бедности*) мохтаҗлыкта яшәү, фәкыйрьлектә яшәү **2.** *в ком-чём* мохтаҗ булу, ихтыяҗың булу, ихтыяҗың төшү, кирәксенү, кирәк булу; **~ в по́мощи** ярдәмгә мохтаҗ булу; **ни в ко́м не ~** беркемдә дә ихтыяҗың булмау

ну́жно *в знач. сказ. безл.* кирәк; **~ торопи́ться** ашыгырга кирәк; **мне ~ идти́** мина китәргә кирәк ♦ **о́чень ~!** бик кирәк иде!, бик кирәге бар иде!

ну́жн||ый, -ая, -ое кирәкле, кирәк; зарур; **~ые ве́щи** кирәкле әйберләр

ну́-ка *межд. разг. см.* **ну** I 1

ну́кать *несов.* «я әле», «я әле» дип тору

нулев||о́й, -а́я, -о́е нуль ...ы; **~а́я сте́пень** нуль дәрәҗәсе

нул||ь *м* нуль ♦ **свести́ к ~ю** юкка чыгару

нумера́ция *ж* **1.** *см.* **нумерова́ть; 2.** номерлар; **~ домо́в** өйләрнең номерлары

нумерова́ть *несов. кого-что* номерлау, номерлар сугу (сугып чыгу)

нумизма́т *м* нумизмат

нумизма́тика *ж* нумизматика (*борынгы акчаларны һәм медальләрне өйрәнә торган фән*)

ну́трия *ж* нутрия, саз кондызы

нутр||о́ *с* **1.** *прост.* (*внутренние органы*) эч, карын **2.** *разг.* (*внутренняя часть чего-л.*) эч **3.** *перен. разг.* (*внутренняя сущность чего-л.*) (*берәр нәрсәнең*) асылы, йөзе **4.** *перен.* (*чутьё, инстинкт*) күңел; **~о́м угада́л** күңеле сизде ♦ **не по ~у́** күңелгә ошамый, күңелгә ятмый; **по ~у́** күңелгә хуш килә, күңелгә ята

нутря́н||ой, -а́я, -о́е эч ...ы; **~о́е са́ло** эч мае

ны́не *нареч. уст. см.* **ны́нче**

ны́нешний, -ая, -ое *разг.* (*теперешний*) хәзерге; (*относящийся к этому году*) быелгы; **~ урожа́й** быелгы уныш

ны́нче *нареч. разг.* **1.** (*теперь*) хәзер, әле **2.** (*сегодня*) бүген ♦ **не ~ — за́втра** бүген-иртәгә, тиз арада, шушы арада

нырну́ть *сов. однокр. см.* **ныря́ть**

ныро́к *м* (*вид утки*) чүрәкәй

ныря́ть *несов.* чуму

ны́тик *м разг.* һәрвакыт сукранучан, һәрвакыт зарланучан

ныть *несов.* **1.** (*болеть*) сызлау, әрнү; **у меня́ зуб но́ет** минем тешем сызлый; **се́рдце но́ет** 1) йөрәк әрни; 2) *перен.* күңел әрни **2.** (*надоедливо жаловаться*) сукрану, зарлану; шыңшу **3.** *разг.* (*издавать жалобные звуки*) җан әрнеткеч тавыш[лар] чыгару, күңелне сызландыра (әрнетә) торган тавыш[лар] чыгару

нюа́нс *м книжн.* төсмер, нюанс

нюни *только мн. прост.*: **распусти́ть ~** селәгәйләрне агызу, селәгәйләрне агызып елау

нюня *м, ж разг.* **1.** (*плакса*) елак **2.** (*слабовольный человек*) жебегән, жебегән авыз, мәми авыз

нюх *м разг.* **1.** (*обоняние*) ис тою (ис сизү) сәләте **2.** *перен.* (*чутьё*) сизгерлек, сизем, тою, сиземләү; **у него́ ~ на всё но́вое** ул һәртөрле яңалыкны тиз тоя (сиземли)

нюха́тельный, -ая, -ое: **~ таба́к** борын төмәкесе, насвай

нюха́ть *несов. что* (*обонять*) иснәү; (*вдыхать*) сулау

ня́нчить *несов. кого-что* бала карау, бала багу

ня́нчиться *несов. с кем-чем* **1.** *см.* **ня́нчить; 2.** *разг.* (*уделять много внимания*) назлау, иркәләү; маташу, кайнашу

ня́нька *ж разг. см.* **ня́ня**

ня́ня *ж* **1.** бала караучы, бала багучы **2.** *разг.* (*санитарка*) няня (*авырулар караучы*)

О

о I (об, обо) *предлог* **1.** *с вин. к.* (*при обознач. соприкосновения, столкновения и т.п.*) ...га; **опере́ться о край стола́** өстәл кырыена таяну; **споткну́ться о ка́мень** ташка абыну **2.** *предл. п.* (*при указ. на то, что составляет предмет, цель чего-л.*) турында, турыда, хакында; **ле́кция о ко́смосе** галәм турында лекция; **па́мять о про́шлом** үткәннәр турында истәлек; **о чём вы говори́ли?** сез нәрсә турында сөйләштегез? **3.** *с предл. п. уст.* (*при указ. на наличие однородных частей, деталей*) ...лы; **стол о трёх но́жках** өч аяклы өстәл

о II *межд.* **1.** (*при обращении*) и, әй, их; **о, Ро́дина-мать!** и, туган Ватаным! **о, друзья́!** их, дуслар! **2.** (*при выражении какого-л. сильного чувства*) их, әй; **о, е́сли бы ты знал!** их, белсәң иде син! **о, как здесь хорошо́!** әй, матур да соң монда! **3.** (*при усилении утверждения, отрицания*) ә, и; о, нет! ә, юк!; о, да! ә, шулай!

о² (обо², объ²) *алкушымча*; *аның белән ясалган фигыльләр татар теленә тубәндәге чаралар ярдәмендә тәрҗемә ителәләр:* 1) *«чыгу», «бетерү» кебек дәрәҗә фигыльләре ярдәмендә, мәс.* **оклеи́ть** ябыштырып чыгу; **осмотре́ть** карап бетерү; 2) *«узу», «уту» кебек дәрәҗә фигыльләре ярдәмендә, мәс.* **обогна́ть** куып узу; **обскака́ть** чаптырып узу (узып китү); 3) *«ким» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **обве́сить** ким үлчәү; 4) *«артык» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **обкорми́ть** артык ашату; 5) *төп фигыльнең узен тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **озвере́ть** ерткычлану; **озелени́ть** яшелләндерү; 6) *«ялгыш» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **ослы́шаться** ялгыш ишетү; **оступи́ться** ялгыш басу

об *см.* **о**

о́ба *м, с числ. собир.* ике, икәве дә, икесе дә, һәр икесе; **~ гла́за** ике күзе дә; **~ у́ха** ике колагы да; **~ сы́на** ике улы да; **пришли́ ~** икесе дә килде ♦ **гляде́ть (смотре́ть) в ~** сак булу, алдыңны-артыңны карап йөрү

обагри́ть *сов. кого-что, высок.* **1.** (*окрасить в красный цвет*) кызарту, кара кызыл төскә кертү **2.** (*окровавить*) канга буяу, канландыру

обагри́ться *сов. высок.* **1.** кызару, кара кызыл төскә керү **2.** канга буялу, канлану

обагря́ть *несов. см.* **обагри́ть**

обагря́ться *несов.* **1.** *см.* **обагри́ться; 2.** *страд. от* **обагря́ть**

обалдева́ть *несов. прост. см.* **обалде́ть**

обалде́лый, -ая, -ое *прост.* исәңгерәгән, миңгерәүләнгән, тилергән, аптыраган; **~ вид** аптыраган кыяфәт

обалде́ть *сов. прост.* исәңгерәү, аптырап калу, аңгыралану, миңгерәүләнү

обанкро́титься *сов.* **1.** бөлү, банкротка әйләнү, малыннан язу, шартлау, яфрак астына керү **2.** *перен.* (*потерпеть крах*) тулы уңышсызлыкка очрау, банкротлашу

обая́ни||е *с* сөйкемлелек, сөйкемле булу, мөлаемлык, мөлаем булу, тәэсир; **~е мо́лодости** яшьлек тәэсире; **находи́ться под ~ем** *кого-чего-л. берәр кешенең, берәр нәрсәнең* тәэсиренә бирелү

обая́тельность *ж* сөйкемлелек, ягымлылык, мөлаемлык

обая́тельный, -ая, -ое сөйкемле, ягымлы, мөлаем; **~ челове́к** сөйкемле кеше

обва́л *м* **1.** (*падение*) ишелү, ишелеп төшү, убылу, убылып (җимерелеп) төшү; **зда́ние грози́т ~ом** йорт җимерелеп төшәргә тора **2.** (*груда камней, земли*) ишелеп төшкән өем (*мәс. кар, кыялар*)

обва́ливать I *несов. см.* **обвали́ть**

обва́ливать II *несов. см.* **обваля́ть**

обва́ливаться *несов.* **1.** *см.* **обвали́ться; 2.** *страд. от* **обва́ливать** I

обвали́ть *сов. что* (*обрушить*) ишеп төшерү, җимереп төшерү, төртеп аудару

обвали́||ться *сов.* җимерелү, ишелү, җимерелеп төшү; коелып төшү, ишелеп төшү, убылу; **потоло́к ~лся** түшәм җимерелеп төшкән; **штукату́рка ~лась** штукатурка коелып төшкән

обваля́ть *сов. что в чём* әвәләү; **~ котле́ту в муке́** котлетны онда әвәләү

обва́ривать *несов. см.* **обвари́ть**

обва́риваться *несов.* **1.** *см.* **обвари́ться; 2.** *страд. от* **обва́ривать** (*см.* **обвари́ть** 1)

обвари́ть *сов.* **1.** *что* (*обдать кипятком*) пешекләү, кайнар су белән юу **2.** *кого-что* пешерү; **~ себе́ но́гу кипятко́м** аякны кайнар суга пешерү

обвари́ться *сов.* пешү; **~ кипятко́м** кайнар суга пешү

обвева́ть *несов. см.* **обве́ять** I

обвенча́ть *сов. кого, церк.* никахландыру, никах уку (укыту)

обвенча́ться *сов. церк.* никахлашу, никах укыттыру

обверну́ть *сов. кого-что, разг.* төрү, урау, чорнау, төреп (урап, чорнап) тышлау; тышлау; **~ кни́гу в бума́гу** китапны кәгазь белән тышлау

обвёртывать *несов. см.* **обверну́ть**

обве́с *м* ким үлчәү, ким үлчәп бирү (*алдап*)

обве́сить I *сов. кого-что, разг.* алдап ким үлчәү; **~ покупа́теля** сатып алучыны алдап ким үлчәү

обве́сить II *сов. см.* **обве́шать**

обве́ситься I *сов. разг.* (*ошибиться при взвешивании*) ялгыш үлчәү, үлчәгәндә ялгышу

обве́ситься II *сов. разг. см.* **обве́шаться**

обвести́ *сов.* **1.** *кого-что* (*вокруг чего-л.*) тирәли йөртеп чыгу, уратып чыгу, әйләндереп йөртеп чыгу **2.** *кого-что* (*оглядеть*) күздән кичерү, [күз] йөртеп чыгу; **~ глаза́ми ко́мнату** бүлмәне күздән кичерү **3.** *что чем* әйләндереп алу, [койма] тоту, киртәләп чыгу; **~ сад забо́ром** бакчаны койма белән әйләндереп алу **4.** *что чем* (*очертить*) түгәрәкләп чыгу, тирәли сызып чыгу, йөртеп чыгу; **~ чертёж ту́шью** сызымны тушь белән йөртеп чыгу **5.** *кого, спорт.* уратып үтү; **~ защи́тника** сакчыны уратып үтү ♦ **~ вокру́г па́льца** ≈ кәкре каенга терәтү; төпсез чанага утырту

обве́тренн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **обве́трить; 2.** җил ашаган, җилдән тупасланган (кытыршыланган, ярылган); **~ое лицо́** җил ашаган бит

обве́треть *сов. см.* **обве́триться**

обве́тривать *несов. см.* **обве́трить**

обве́триваться *несов.* **1.** *см.* **обве́триться; 2.** *страд. от* **обве́тривать**

обве́тр||ить *сов. что* җил ашау; җилдән ярылу; **~ить лицо́** битне җил ашау; **мне ~ило гу́бы** *безл.* минем иреннәрем җилдән ярылган

обве́триться *сов.* җил кагу, җил ашау; җилдән тупаслану (кытыршылану)

обветша́л||ый, -ая, -ое искергән, тузган, тузып беткән; **~ая кро́вля** искергән түбә

обветша́ть *сов.* искерҙ, тузу, искереп (тузып) бетҙ

обве́шать *сов. кого-что чем* элеп чығу (бетерҙ), тағып бетерҙ; ~ **сте́ны карти́нами** стенаға картиналар элеп бетерҙ

обве́шаться *сов.* тағу, асу, өстенә асу, өстенә тағып бетерҙ; ~ **ору́жием** өстенә кораллар тағып бетерҙ

обве́шивать I *несов. см.* **обве́сить** I

обве́шивать II *несов. см.* **обве́шать, обве́сить** II

обве́шиваться I *несов.* 1. *см.* **обве́ситься** I; 2. *страд. от* **обве́шивать** I

обве́шиваться II *несов.* 1. *см.* **обве́шаться, обве́ситься** II; 2. *страд. от* **обве́шивать** II

обве́ять *сов.* 1. *кого-что чем* (*обдать ветром и т. п.*) бәрҙ, исҙ, бәреп (исеп) кую 2. *что, с.-х.* (*вея, очистить*) ҙилгәрҙ

обвива́ть *несов. см.* **обви́ть**

обвива́ться *несов.* 1. *см.* **обви́ться; 2.** *страд. от* **обвива́ть**

обвине́ни||е *с* 1. *см.* **обвини́ть; ~е в нейскренности** ихлас күңелле булмауда ғаепләү; **предъяви́ть ~е** ғаепләүне белдерҙ 2. *уст.* (*приговор*) ғаепләү карары; **вы́нести ~е** ғаепләү карары чығару 3. *юр.* (*обвиняющая сторона*) ғаепләүче як; **свиде́тель ~я** ғаепләүче якның шаһиты

обвини́тель *м юр.* ғаепләүче; **государ́ственный ~** дәүләт ғаепләүчесе; **обще́ственный ~** ҙәмәғатьчелек ғаепләүчесе

обвини́тельный, -ая, -ое ғаепләү ...ы; ~ **приго́вор** ғаепләү карары; ~ **акт** ғаепләү акты

обвини́ть *сов. кого-что в чём* 1. ғаепләү, ғаеп ташлау (тагу); ~ **в неблагода́рности** яхшылыкның кадерен белмәүҙә ғаепләү 2. (*осудить*) ғаепләү, ғаепләү карары чығару, ғаепле дип табу; хөкем итү

обвиня́емая *ж юр.* ғаепләнүче хатын (кыҙ)

обвиня́емый *м юр.* ғаепләнүче

обвиня́ть *несов. см.* **обвини́ть**

обвиса́ть *несов. см.* **обви́снуть**

обви́сл||ый, -ая, -ое *разг.* салынкы, салынып төшкән; сәлперәеп төшкән; ~**ые усы́** салынып төшкән мыҡлар; ~**ые щёки** салынып төшкән яңаклар

обви́с||нуть *сов.* салпылану, салынып (асылынып) төшү, салпыланып тору; сәлперәеп төшү; **поля́ шля́пы ~ли** эшләпәнең читләре салынып төшкән

обви́ть *сов.* 1. *что* чорнау, чорнап алу (кую), урау, урап алу (кую); ~ **ко́су вокру́г головы́** ҡәҙ толымын башҡа урап кую 2. *кого-что* (*обнять, охватить*) кочаҡлау, кочаҡлап алу, уратып алу

обви́ться *сов.* 1. уралу, чорналу, урап алыну 2. (*охватив, сомкнуться*) уралып алыну, кочаҡлап алыну

обво́д *м* 1. *см.* **обвести́; 2.** (*линия, кайма*) кайма, сызык

обводи́ть *несов. см.* **обвести́**

обводне́ние *с см.* **обводни́ть**

обводни́тельн||ый, -ая, -ое суландыру ...ы; ~**ый кана́л** суландыру каналы; ~**ые рабо́ты** суландыру эшләре

обводни́ть *сов. что, спец.* сугару, суландыру, су белән тәэмин итү; ~ **степь** даланы суландыру

обво́дный, -ая, -ое әйләнмә, әйләнеп уза торған; ~ **кана́л** әйләнеп уза торған канал

обводня́ть *несов. см.* **обводни́ть**

обвола́кивать *несов. см.* **обволо́чь**

обвола́киваться *несов.* 1. *см.* **обволо́чься; 2.** *страд. от* **обвола́кивать**

обволо́чь *сов. кого-что* каплау, томалау, каплап (томалап) алу; **ту́чи обволокли́ не́бо** болытлар күк йөзен каплап алды

обволо́чься *сов.* каплап (томалап) алыну, томалану, каплану; **река́ обволокла́сь густы́м тума́ном** елга куе томан белән капланган

обворова́ть *сов. кого-что, разг.* әйберен урлап чығу (китү)

обворо́вывать *несов. см.* **обворова́ть**

обворожи́тельность *ж* сокландырғыч булу, сокландырғычлылык

обворожи́тельн||ый, -ая, -ое сокландырғыч, сокланырлық, искиткеч, таңға калдырырлық; ~**ая улы́бка** сокландырғыч елмаю; ~**ый ребёнок** искиткеч бала

обворожи́ть *сов. кого-что* сокландыру, таң калдыру, искитерҙ, әсир итү; ~ **свое́й игро́й** үзенең яхшы уйнавы белән сокландыру

обвяза́ть *сов.* 1. *кого-что* урап бәйләү, урап бәйләп кую; ~ **го́лову ша́рфом** башны шарф белән урап бәйләп кую 2. *что* тоту; ~ **плато́к кружева́ми** яулык читенә челтәр тоту

обвяза́ться *сов.* урану, үзен уратып бәйләү, уратып бәйләп кую; ~ **верёвкой** үзен бау белән уратып бәйләп кую

обвя́зка *ж* 1. *см.* **обвяза́ть; ~ я́блони соло́мой** алмагачларны салам белән урап бәйләү 2. *тех.* беркеткеч

обвя́зывать *несов. см.* **обвяза́ть**

обвя́зываться 1. *см.* **обвяза́ться; 2.** *страд. от* **обвя́зываться**

обгла́дывать *несов. см.* **обглода́ть**

обглода́ть *сов. что* кимерҙ, кимереп бетерҙ, кимереп чығу; ~ **мя́со с косте́й** сөйәкнең итен кимереп бетерҙ

обгова́ривать *несов. см.* **обговори́ть**

обговори́ть *сов. что, разг.* (*обсудить*) фикер алышыу, уйлашыу, һәрьяктан тикшерҙ

обго́н *м см.* **обогна́ть; ~ сле́ва** [машинаны] сул яктан узыу; ~ **запрещён** узыу тыела

обгоня́ть *несов. см.* **обогна́ть**

обгора́ть *несов. см.* **обгоре́ть**

обгоре́лый, -ая, -ое янған, көйгән, күмерләнгән

обгоре́||ть *сов.* 1. янып көю, өсте яну, янып көеп бетҙ, янып күмерләнҙ; **забо́р ~л** койма янып күмерләнгән 2. (*получить сильные ожоги*) яну, тән пешҙ, пешеп бетҙ

обгрыза́ть *несов. см.* **обгры́зть**

обгры́зть *сов. что* кимерҙ, тирәяктан кимереп бетерҙ, кимереп алу; ~ **кожуру́ с я́блока** алманың кабығын кимереп алу

обдава́ть *несов. см.* **обда́ть**

обда́ть *сов. кого-что чем* 1. коендыру, коендырып алу; өстенә сиптерҙ; ~ **холо́дной водо́й** салкын су белән коендыру; ~ **фру́кты горя́чей водо́й** ҡимешләргә ҡайнар су белән сиптерҙ 2. *перен. безл.* (*охватить, пронизать*) бәрҙ; килеп бәрелҙ; **меня́ обда́ло хо́лодом** тәнгә салкын йөгерде ♦ ~ **презре́нием** *кемгә дә булса* нәфрәтле караш ташлау

объём *м* **1.** күләм; **~ зда́ния** бинаның күләме; **измере́ние ~а** күләмен үлчәү **2.** *перен.* зурлык, күләм; **~ рабо́т** эш күләме; **~ зна́ний** белемнәр күләме

объёмист||ый, -ая, -ое *разг.* күләмле, зур күләмле, бик зур; **~ая ру́копись** зур күләмле кулъязма

объёмный, -ая, -ое **1.** күләм ...ы; күләм ягыннан; **~ ана́лиз** *хим.* күләм ягыннан анализ **2.** күләмле, зур күләмле; **~ рису́нок** күләмле рәсем

объе́сть *сов. что* (*обглодать*) чит-читләрен ашау, тирәли ашап бетерү; [читләрен] кимереп чыгу

объе́сться *сов.* ашап гарык булу, чиктән тыш күп ашау, үтләгәнче ашау

объе́хать *сов. кого-что* **1.** (*проехать стороной*) урап үтү, уратып (читләтеп) үтү; **~ боло́то** сазны урап үтү **2.** (*перегнать*) узып (үтеп) китү; **~ тролле́йбус** троллейбусны узып китү **3.** (*побывать во многих местах*) йөреп (гизеп, әйләнеп) чыгу; **~ весь мир** бөтен дөньяны йөреп чыгу

объяви́ть *сов.* **1.** *что, о чём* белдерү, игълан итү, әйтү; **~ о нача́ле заня́тий** укулар башлану турында белдерү; **~ ко́нкурс** конкурс игълан итү; **~ бойко́т** бойкот игълан итү **2.** *что* белдерү; бирү; **~ вы́говор** шелтә бирү **3.** *кого-что кем-чем, каким* игълан итү, [рәсми рәвештә] белдерү; **~ собра́ние откры́тым** җыелышны ачык дип игълан итү

объяви́ться *сов. разг.* (*обнаружиться*) килеп чыгу, табылу

объявле́ние *с* **1.** *см.* **объяви́ть; ~ войны́** сугыш игълан итү **2.** (*извещение*) игълан, белдерү; **пове́сить ~** (*стенага*) игълан элеп кую; **дать ~ в газе́ту** газетка белдерү бирү

объявля́ть *несов. см.* **объяви́ть**

объявля́ться *несов.* **1.** *см.* **объяви́ться**; **2.** *страд. от* **объявля́ть**

объясне́ни||е *с* **1.** *см.* **объясни́ть; 2.** (*оправдание, признание в чём-л.*) аңлатма, аңлату язуы; **предста́вить свои́ ~я** аңлатма язып бирү **3.** (*причина*) сәбәп; **тру́дно приду́мать ~е э́тому фа́кту** бу фактның сәбәбен аңлату кыен ◆ **~е в любви́** мәхәббәтеңне белдерү

объясни́мый, -ая, -ое аңлаешлы, аңлатып була торган, аңлашыла торган

объясни́тельн||ый, -ая, -ое аңлатма ...ы, аңлатма бирә торган; **~ая запи́ска** аңлатма язуы

объясни́ть *сов. что* аңлату, аңлатма бирү, төшендерү, төшендереп бирү, ачыклау, аңлаешлы итү; **~ пра́вило** кагыйдәне аңлатып бирү

объясни́ться *сов.* (*переговорив, объяснить что-л.*) аңлашу, сөйләшү ◆ **~ в любви́** мәхәббәтеңне белдерү

объясня́ть *несов. см.* **объясни́ть**

объясня́||ться *несов.* **1.** *см.* **объясни́ться; 2.** сөйләшү, аңлашу; **глухонемы́е ~ются же́стами и зна́ками** чукрак-телсез кешеләр ишарә һәм ым белән сөйләшәләр **3.** *чем* аңлатылу, бәйләнгән булу; **э́то ~ется це́лым ря́дом причи́н** бу күп сәбәпләргә бәйләнгән **4.** *страд. от* **объясня́ть**

объя́ти||е *с* кочак, колач ◆ **приня́ть (встре́тить) с распростёртыми ~ями** *кого* кочак җәеп каршы алу; ≈ биш куллап каршы алу; ≈ ачык чырай белән каршы алу

объя́||ть *сов. кого-что, уст.* уратып (чолгап) алу; **дом ~т пла́менем** өйне ялкын чолгап алган

обыва́тель *м* обыватель (*тар карашлы кеше*)

обыва́тельница *ж* обыватель хатын (кыз)

обыва́тельск||ий, -ая, -ое обыватель[ләр] ...ы, обывательләрчә ...; **~ие взгля́ды** обывательләрчә караш

обыва́тельщина *ж* обывательлек, тар карашлылык

обыгра́ть *сов.* **1.** *кого-что* оту, җиңеп чыгу; **~ в ша́хматы** шахмат уенында җиңеп чыгу **2.** *что, муз.* уйнап тавышын яхшырту; **~ скри́пку** уйнап скрипканың тавышын яхшырту **3.** *что, разг.* үз файдасына куллану, файдалану; **~ оши́бку собесе́дника в спо́ре** бәхәстә катнашучының хатасыннан файдалану

обы́грывать *несов. см.* **обыгра́ть**

обы́денность *ж* гадәтилек, гадәттәгелек, көндәгечә булу

обы́денный, -ая, -ое гадәттәге, көндәге, көндәлек ..., көн дә очрый торган; һәрвакыттагы, һәрвакытта була торган

обыдёнщина *ж* көн саен кабатланган торган нәрсә

обыкнове́ни||е *с* гадәт, гадәттәге тәртип; **по ~ю** гадәттәгечә; **про́тив ~я** гадәттәгегә каршы

обыкнове́нно *нареч. разг.* (*как правило*) гадәттә, гадәтчә; **~ он прихо́дит по́здно** гадәттә ул соң килә (кайта)

обыкнове́нность *ж* гадәтилек, гадәти булу

обыкнове́нный, -ая, -ое **1.** (*постоянный, обычный*) гадәти, көндәлек ..., көн дә (һәрвакыт) була торган, гадәткә кереп киткән **2.** (*заурядный*) гади, урта кул ...

о́быск *м* тентү

обыска́ть *сов.* **1.** *кого-что* тентү, тентеп чыгу **2.** *что* (*ища, осмотреть всё*) эзләү, эзләп бетерү, актарып чыгу, карап бетерү

обы́скивать *несов. см.* **обыска́ть**

обы́чай *м* йола, гореф, гореф-гадәт

обы́чно *нареч.* гадәттә; **как ~** гадәттәгечә; **пра́здники ~ прохо́дят ве́село** гадәттә бәйрәмнәр күңелле үтә

обы́чн||ый, -ая, -ое **1.** (*постоянный, привычный*) ияләшкән, гадәттәге, һәрвакыттагы; **~ым слу́чай** гадәттәге хәл **2.** *юр.* йола ...ы, йола буенча килгән; **~ое пра́во** йола буенча килгән хокук

обюрокра́титься *сов.* бюрократлашу, бюрократка әйләнү

обя́занность *ж* бурыч, вазифа, йөкләмә; **вмени́ть в ~** бурыч итеп кую

обя́занн||ый, -ая, -ое **1.** *с неопр.* тиеш, тиешле; бурычлы; **гра́ждане Респу́блики Татарста́н обя́заны соблюда́ть Конститу́цию и зако́ны РТ (Конст. РТ, ст. 52)** Татарстан Республикасы гражданнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә бурычлы; **я обя́зан помо́чь ему́** мин аңа ярдәм итәргә тиеш **2.** *кому-чему чем* бурычлы, рәхмәт әйтергә тиешле; **я вам о́чень обя́зан** мин сезгә бик бурычлымын; **быть ве́чно ~ым** гомер буе бурычлы булу

обяза́тельность *ж* мәҗбүрилек

обяза́тельн||ый, -ая, -ое **1.** мәҗбүри, бурыч ителгән; **всео́бщее ~ое сре́днее образова́ние** гомуми мәҗбүри урта белем бирү **2.** (*услужливый*) һәрвакыт булышырга әзер, ярдәмчел

обяза́тельств||о *с* **1.** йөкләмә, бурыч, вәгъдә; **вы́полнить свои́ ~а** йөкләмәләреңне үтәү **2.** (*денежный заёмный документ*) бурычнамә (*облигациянең бер төре*)

обяза́ть *сов. кого-что* (*заставить сделать*) йөкләү, йөкләтү, мәҗбүр итү ◆ **вы меня́ о́чень обя́жете** мин үземне сезнең каршыда бурычлы дип санармын

обяза́ться *сов.* йөкләмә [өскә] алу, вәгъдә бирү

обя́зывать *несов. см.* **обяза́ть**

обя́зываться *несов. см.* **обяза́ться**

ова́л *м* озынча, озынча түгәрәк, овал; **краси́вый ~ лица́** матур озынча түгәрәк бит

ова́льный, -ая, -ое озынча түгәрәк, овал; **~ стол** озынча түгәрәк өстәл

ова́ци||я *ж* алкыш, алкышлау; көчле кул чабулар (*җыелышларда*); **бу́рные ~и** көчле алкышлар

овдове́ть *сов.* тол калу

О́вен *м астр.* Овен

овёс *м* солы

ове́ч||ий, -ья, -ье сарык ...ы; **~ья шерсть** сарык йоны; **~ий сыр** сарык сөтеннән ясалган сыр

ове́чк||а *ж* **1.** *уменьш.-ласк. от* **овца́**; **2.** *перен.* юаш кеше, юаш, мәхлук; **прики́нуться ~ой** мәхлук булып кылану

овеществи́ть *сов. что, книжн.* матдиләштерү, матди хәлгә китерү

овеществи́ться *сов. книжн.* матдиләшү, матди хәлгә килү

овеществле́ние *с см.* **овеществи́ть, овеществи́ться**

овеществля́ть *несов. см.* **овеществи́ть**

овеществля́ться *несов. см.* **овеществи́ться**

ове́я||ть *сов. кого-что чем* **1.** (*обдать струёй воздуха, ветра и т. п.*) бәру, исү **2.** *перен.* күмелү; **э́ти боевы́е знамёна ~ны сла́вой** бу сугышчан байраклар данга күмелгән

ови́н *м* әвен

овладева́ть *несов. см.* **овлада́ть**

овладе́ние *с см.* **овлада́ть**; **~ те́хникой** техникага ия булу

овлад||е́ть *сов.* **1.** *кем-чем* (*захватить*) алу, басып алу, биләү, ия булу,

кулга төшерү **2.** *перен. кем-чем* (*подчинить себе*) буйсындыру, үзенә карату; кулга алу; **3.** *перен. кем* биләп алу, чолгап алу, басу; **им ~л страх** аны курку басты **4.** *перен. чем* үзләштерү, өйрәнү; **~ть зна́ниями** белемнәрне үзләштерү; **~ть тата́рским языко́м** татар телен үзләштерү ♦ **~ть собо́й** үзеңне кулга алу

о́вод *м* кигәвен, бөгәлчән

овощево́д *м* яшелчәче, яшелчә үстерүче

овощево́дство *с* яшелчәчелек, яшелчә үстерүчелек

овощево́дческий, -ая, -ое яшелчәчелек ...ы; **~ совхо́з** яшелчәчелек совхозы

овощемо́йка *ж* яшелчә югыч

овощере́зка *ж* яшелчә турагыч

овощехрани́лище *с* яшелчә саклагыч, яшелчә[ләр] саклау урыны

о́вощ||и *мн.* яшелчә; **ра́нние ~и** иртә өлгерә торган яшелчәләр; **суп из ~е́й** яшелчә ашы ♦ **вся́кому ~у своё вре́мя** *посл.* ≈ һәр эшнең үз вакыты бар

овощн||о́й, -а́я, -о́е яшелчә ...ы; **~о́й магази́н** яшелчә кибете; **~ы́е консе́рвы** яшелчә консервлары

овра́г *м* чокыр, ерым, ерынты

овра́жистый, -ая, -ое (*изобилующий оврагами*) чокырлы, чокырлы-чакырлы, ерынтылы

овся́ной I *ж разг.* **1.** (*крупа*) солы ярмасы **2.** (*каша*) солы боткасы

овся́нка II *ж* (*птица*) солы чыпчыгы

овсян||о́й, -а́я, -о́е солы ...ы; **~о́е по́ле** солы басуы

овся́н||ый, -ая, -ое **1.** *см.* **овсяно́й; 2.** солы ...ы; **~ая ка́ша** солы боткасы

овца́ *ж* сарык; **тонкору́нная ~** нәзек йонлы сарык; **стри́жка ове́ц** сарык кырку; **курдю́чная ~** куй, куй сарыгы; **кара́кульская ~** каракүл сарык

овцебы́к *м* сарык-үгез

овцево́д *м* сарыкчылык белгече, сарык үрчетүче (*белгеч*)

овцево́дство *с* сарыкчылык, сарык үрчетү, сарык асраучылык

овцево́дческий, -ая, -ое сарыкчылык ...ы; **~ совхо́з** сарыкчылык совхозы

овцема́тка *ж* ана сарык

овцефе́рма *ж* сарык фермасы

овча́р *м* сарык караучы

овча́рка *ж* овчарка (*эт токымы*)

овча́рня *ж* сарык абзары

овчи́на *ж* иләнгән сарык тиресе

овчи́нка *ж уменьш. от* **овчи́на ♦ ~ вы́делки не сто́ит** биш тиенлек куян — ун тиенлек зыян (*эшләгән хакы да булмау*)

овчи́нный, -ая, -ое сарык тиресеннән тегелгән; **~ тулу́п** сарык тиресеннән тегелгән толып

ога́рок *м* шәм төпчеге, шәм калдыгы

огиба́ть *несов. см.* **обогну́ть**

оглавле́ние *с* эчтәлек, бүлекләр исемлеге

огласи́ть *сов. что* **1.** игълан итү, укып чыгу; **~ прое́кт резолю́ции** резолюция проектын укып чыгу **2.** яңгырату; **~ лес кри́ками** кычкырып урман яңгырату **3.** *уст.* (*разгласить*) фаш итү, белдерү, ачу; **~ чужу́ю та́йну** кеше серен ачу

огласи́||ться *сов.* **1.** яңгырау, яңгырап китү; **лес ~лся кри́ками** кеше тавышларыннан урман яңгырады **2.** *уст.* (*разгласиться*) ачылу, фаш ителү; **та́йна ~лась** сер ачылды

огла́ск||а *ж* фаш булу (ителү), фашлану; **де́ло полу́чило ~у** эш фашланды

оглаша́ть *несов. см.* **огласи́ть**

оглаша́ться *несов.* **1.** *см.* **огласи́ться; 2.** *страд. от* **оглаша́ть**

оглаше́ни||е *с см.* **огласи́ть** 1, 3; **~ю не подлежи́т** кешеләргә белдерү өчен түгел

оглу́бля *ж* тәртә

оглу́шить *сов. кого, прост.* (*ударить по голове*) сугып һуштан яздыру, сугып һушын алу

огло́хнуть *сов.* чукраклану, сангыраулану

оглупля́ть *несов.* **1.** *кого-что* юләр итеп күрсәтү, юләрләндерү, аңгыраландыру **2.** *что* (*сознательно искажать*) юри бозып күрсәтү, бозу

оглуша́ть *несов. см.* **оглуши́ть**

оглуши́тельный, -ая, -ое колак тондыргыч, бик каты; **~ взрыв** колак тондыргыч шартлау тавышы

оглуши́ть *сов. кого-что* **1.** (*лишить слуха*) саңгырауландыру, колак тондыру **2.** (*лишить сознания*) [бик каты сугып] миңгерәүләтү, һуштан яздыру, исәңгерәтү **3.** *перен. разг.* (*ошеломить*) аптыратыр кадыру, таң калдыру

огляде́ть *сов. кого-что* карап чыгу, күз йөртеп чыгу

огляде́ться *сов.* **1.** (*осмотреться*) карану, каранып алу **2.** *разг.* (*в темноте*) [караңгыга] күз ияләнү, күз күнегү **3.** *перен.* (*освоиться*) ияләшү, күнегү, өйрәнү

огля́дк||а *ж* **1.** *см.* **огляну́ться; без ~и** алдына-артына карамый; артына борылып карамыйча; **бежа́ть без ~и** артына борылып карамыйча чабу **2.** (*осторожность в действиях*) саклык; абайлылык; **де́йствовать с ~ой** саклык белән эш итү

огля́дывать *несов. см.* **огляде́ть**

огля́дываться *несов.* **1.** *см.* **огляде́ться** 1, **огляну́ться; 2.** *на кого-что и без доп., прост.* (*действовать осторожно*) абай булу, сак булу; кемгә дә булса карап сак эш итү

огляну́ться *сов.* **1.** (*посмотреть назад*) артка борылып карау, әйләнеп карау **2.** *разг.* (*посмотреть вокруг себя*) карану, каранып алу ♦ **~ не успе́ешь, как ...** күз ачып йомганчы ...

огне- *кайбер кушма сүзләрнең «ут» мәгънәсен аңлаткан береңче кисәге, мәс.* **огнезащи́тный** уттан саклый торган

огневи́к *м разг.* утчы (*артиллерист, миномётчы*)

огнёвка *ж зоол.* утчыл (*күбәләк*)

огнев||о́й, -а́я, -о́е **1.** ут ...ы, ату ...ы; **~а́я то́чка** *воен.* ут ноктасы; **~ы́е сре́дства** ату кораллары **2.** *перен.* (*сверкающий, жгучий; пылкий, страстный*) ялкынлы, кызу; **~о́й хара́ктер** кызу характер

огнедыша́щ||ий, -ая, -ее (*извергающий огонь*) ут бөркеп тора торган, ут пошкырып тора торган ♦ **~ая гора́** *уст. то же, что* **вулка́н**

огнемёт *м воен.* утаткыч, огнемёт

о́гненн||ый, -ая, -ое **1.** ут ...ы, ялкын ...ы; **~ый столб** ялкын баганасы **2.** (*о цвете*) ут төсле, кызыл **3.** *перен.* ялкынлы; **~ый взгляд** ялкынлы караш; **~ые ре́чи** ялкынлы нотыклар

огнеопа́сн||ый, -ая, -ое янгыннан хәтәрле, янгыннан (уттан) куркынычлы, тиз кабына торган; **~ая жи́дкость** тиз кабына торган сыекча

огнепокло́нник *м* утка табынучы кеше

огнепокло́нничество, огнепокло́нство *с разг.* утка табыну[чылык]

огнеприпа́сы *только мн.* ату кирәк-яраклары (*патрон, снаряд, бомба һ.б.ш.*)

огнесто́йк||ий, -ая, -ое утка чыдам [-лы], янмый торган; **~ие сооруже́ния** утка чыдамлы корылмалар

огнесто́йкость *ж* утка чыдамлылык, янмый торган булу

огнестре́льн||ый, -ая, -ое ату ...ы, ата торган; **~ое ору́жие** ату коралы ♦ **~ая ра́на** пуля (снаряд китеге, кыйпылчыгы) ярасы

огнетуши́тель *м* ут сүндергеч

огнеупо́рность *ж* утка чыдамлылык, янмый торган булу

огнеупо́рный, -ая, -ое утка чыдам [-лы], янмый торган; **~ кирпи́ч** утка чыдамлы кирпеч

огнеупо́ры *только мн.* утка чыдам [-лы] материаллар

огни́во *с* чакма корычы, чакма таш

огни́ще *с* **1.** (*костёр*) учак урыны **2.** ышна, ышна җире, яныk (*урманны төпләгәннән соң яки яндыргаННан соң сөрү өчен билгеләнгән урын*)

ого́ *межд.* әй, әһә; **~, как ты вы́рос!** әһә, нинди булып үскәнсең!

огова́ривать *несов. см.* **оговори́ть**

огова́риваться *несов.* **1.** *см.* **оговори́ться; 2.** *страд. от* **огова́ривать**

оговор *м разг.* (*клевета*) яла

оговори́ть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* (*оклеветать*) яла ягу, (*кеше*) өстенә сөйләү **2.** *что* (*заранее условиться*) алдан сөйләшеп кую, алдан килешү

оговори́ться *сов.* **1.** (*объяснить заранее*) искәртеп китү, әйтеп китү **2.** (*обмолвиться*) ялгыш әйтеп кую (җибәрү), сүздә ялгышу, ялгыш сүз ычкындыру

огово́рка *ж* **1.** (*дополнительное замечание*) төзәтмә, өстәмә **2.** (*обмолвка*) ялгыш сүз, сүз хатасы

оголе́ние *с см.* **оголи́ть**

оголённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **оголи́ть; 2.** ялангач, шәрә, шәрә калган; ачык калдырылган; **~ая ше́я** ачык калдырылган муен **3.** яфрагы коелган, яфраксыз; **~ые дере́вья** яфрагы коелган агачлар **4.** тышсыз; **~ый про́вод** тышсыз тимерчыбык

оголи́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*обнажить*) ачу **2.** *что* (*лишить листвы*) ялангач калдыру, ялангачландыру; яфракларын кою **3.** *что* тышсыз калдыру, тышын

алу; ~ **про́вод** тимерчыбыкны тышсыз калдыру **4.** *что* ачу, ачык (саксыз) калдыру; ~ **ле́вый фланг** сул флангны ачык калдыру

оголи́||ться *сов.* **1.** (*обнажиться*) ачылу, ачык калу **2.** ялангачлану, яфраклары коелу; **дере́вья ~лись** агачларның яфраклары коелган **3.** тышсыз калу; **про́вод ~лся** тимерчыбык тышсыз калган **4.** ачык (саксыз) калу; **фланг ~лся** фланг ачык калды

оголте́лый, -ая, -ое *разг.* котырынган, шашынган, оятсызланган; ~ **враг** котырынган дошман

оголя́ть *несов. см.* **оголи́ть**

оголя́ться *несов.* **1.** *см.* **оголи́ться; 2.** *страд. от* **оголя́ть**

огонёк *м* **1.** *уменьш.-ласк. от* **ого́нь** 1; **2.** *перен. разг.* дәрт, чаткы; **рабо́тать с огонько́м** дәрт белән эшләү ♦ **зайти́ (забежа́ть) на** ~ үтеп барышлый керү, тәрәзәдән ут күрсәтү

ого́нь *м* **1.** (*пламя*) ут, ялкын **2.** (*свет*) якты, яктылык, ут яктысы; **огни́ большо́го го́рода** зур шәһәр утлары; **заже́чь** ~ ут кабызу **3.** *воен.* атыш, ут; **откры́ть** ~ ут ачу ♦ **днём с огнём не найдёшь** көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың; **из огня́ да в полы́мя** бер уттан икенче утка; **ме́жду двух огне́й** ике ут арасында; **огнём и мечо́м** кырып-үтереп, ут һәм кылыч белән; **пройти́ ~, во́ду и ме́дные тру́бы** дөньяның әчесен-төчесен тату

огора́живать *несов. см.* **огородить**

огора́живаться *несов.* **1.** *см.* **огороди́ться**; **2.** *страд. от* **огора́живать**

огоро́д *м* яшелчәлек, яшелчә бакчасы

огороди́ть *сов. что* киртәләү, киртәләп алу, киртә тоту, койма тоту, иҗаталау

огороди́ться *сов.* киртә тоту, киртә белән бүленү

огоро́дник *м* яшелчәче, яшелчә бакчасында эшләүче бакча хуҗасы

огоро́дничать *несов. разг.* яшелчә үстерү, яшелчәчелек белән шөгыльләнү

огоро́дничество *с* яшелчә үстерүчелек, яшелчә бакчачылыгы, яшелчәчелек

огоро́дн||ый, -ая, -ое яшелчә ...ы, яшелчә бакчасы ...ы; ~**ые расте́ния** яшелчә бакчасы үсемлекләре

огоро́шить *сов. кого-что, разг.* аптыратып калдыру, шаккаттыру, хәйран калдыру

огорча́ть *несов. см.* **огорчи́ть**

огорча́ться *несов. см.* **огорчи́ться**

огорче́ние *с* күңелсезлек, күңелсезләнү, кәеф китү

огорчи́тельн||ый, -ая, -ое күңелсезләндерә (кәеф җибәрә) торган, күңелсез; ~**ое изве́стие** күңелсез хәбәр

огорчи́ть *сов. кого-что* күңелсезләндерү, кәефне җибәрү, кәеф бозу

огорчи́ться *сов.* күңел китү, күңелсезләнү, кәеф китү (бозылу)

ограби́ть *сов. кого-что* талау, талап алу (чыгу)

ограбле́ние *с см.* **ограби́ть**

ограда́ *ж* киртә, койма; **ка́менная ~** таш койма

огради́ть *сов.* **1.** *что* киртәләү, коймалау, киртә тоту **2.** *перен. кого-что* саклап калу, чик кую; ~ **больно́го от волне́ний** авыруны борчылулардан саклап калу

огражда́ть *несов. см.* **огради́ть**

огражде́ние *с* **1.** *см.* **огради́ть**; **2.** (*ограда*) киртә, ихата, койма; текмә, читән

огра́нивать *несов. см.* **огрaни́ть**

огрaни́ть *сов. что* кырлау, кырлар ясау, кырлап шомарту; ~ **хруста́ль** хрустальны кырлап шомарту

ограничéни||е *с* **1.** *см.* **огрaни́чить**; **2.** чикләү, чик кую; чикләмә; **торгова́ть без вся́ких ~й** һичбер чикләүсез сәүдә итү

огрaни́ченность *ж* **1.** чикләнгәнлек, чикле булу, аз булу; ~ **де́нежных средств** акчаның аз булуы **2.** *перен.* тарлык, тар карашлылык, сайлык; ~ **ума́** акыл тарлыгы

огрaни́ченн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **огрaни́чить**; **2.** чикләнгән, чикле күләмдәге, аз; ~**ые сре́дства** чикле күләмдәге акча **3.** *перен.* тар карашлы, тар фикерле; ~**ый челове́к** тар карашлы кеше

огрaни́вать *несов. см.* **огрaни́чить**

огрaни́чиваться *несов.* **1.** *см.* **огрaни́читься**; **2.** *страд. от* **огрaни́чивать**

огрaничи́тель *м тех.* чикләгеч; ~ **хо́да** йөреш чикләгече

огрaничи́тельный, -ая, -ое чикләүче, чикли торган, чик куя торган

огрaни́чить *сов. кого-что* чикләү, чик кую; кыса төшү

огрaни́читься *сов.* **1.** (*удовлетвориться*) канәгатьләнү, канәгать булу **2.** чикләнү; ~ **кра́тким выступле́нием** кыска гына чыгыш белән чикләнү

огре́ть *сов. кого, прост.* (*сильно ударить*) тондыру, кундыру, бик каты сугу

огре́х *м* **1.** чи, чи калган урын; **паха́ть без ~ов** чи калдырмый сөрү **2.** *прост.* (*недоделка*) чи эш, чилепешле эш, чи

огро́мн||ый, -ая, -ое бик зур, гаять зур, чиксез зур; ~**ое зда́ние** бик зур бина; ~**ая а́рмия борцо́в за мир** тынычлык өчен көрәшчеләрнең чиксез зур армиясе; ~**ое влия́ние** гаять зур тәэсир

огрубе́лый, -ая, -ое тупасланган, кытыршыланган, кытырланган

огрубе́ние *с см.* **огрубе́ть**; ~ **го́лоса** тавыш калынаю, тавыш тупаслану

огрубе́||ть *сов.* тупаслану, дорфалану, кытыршылану; **ко́жа ~ла** тире кытыршыланды

огрыза́ться *несов. см.* **огрызну́ться**

огрызну́ться *сов. однокр.* **1.** (*о собаке*) ырылдап кую, ырлап кую **2.** *перен. разг.* (*грубо ответить*) ырылдап кую, тупас җавап бирү, тупас итеп әйтеп кую

огры́зок *м* кимерек; калдык, калдыкпостык; кисәк; ~ **я́блока** алма калдыгы; ~ **карандаша́** карандаш кисәге

огу́зок *м* **1.** (*мясо*) арт сан ите, сум ит **2.** (*шкура*) арт сан тиресе

огу́лом *нареч. разг.* тикшерми-нитми; [бөтенесен] бергә, берьюлы; **вини́ть всех** ~ бар кешене бергә гаепләү

огу́льн||ый, -ая, -ое дәлилсез, нигезсез; ~**ое обвине́ние** дәлилсез гаепләү

огуре́ц *м* кыяр

огуре́чный, -ая, -ое кыяр ...ы; ~ **рассо́л** тозлы кыяр суы

о́да *ж* мәдхия, ода, мактау шигыре

ода́лживать *несов. см.* **одолжи́ть**

одали́ска *ж книжн.* кәнизәк

одарённость *ж* сәләтлелек, таланлылык

одарённый, -ая, -ое сәләтле, таланлы; ~ **компози́тор** сәләтле композитор

ода́ривать *несов. см.* **одари́ть**

одари́||ть *сов. кого-что чем* **1.** (*подарить многим*) бүләкләү, бүләк биреп чыгу, бүләкләр өләшеп чыгу **2.** *перен.* бирү, күп итеп бирү; **приро́да ~ла его́ умо́м** табигать аңа күп итеп акыл биргән

одаря́ть *несов. см.* **одари́ть**

одева́ть *несов.* **1.** *см.* **оде́ть**; **2.** *кого-что* киендерү; ~ **дете́й со вку́сом** балаларны зәвык белән киендерү

одева́ться *несов.* **1.** *см.* **оде́ться**; **2.** киенү, киенә белү, киенеп йөрү; ~ **про́сто** гади генә киенеп йөрү; **уме́ть** ~ киенә белү **3.** *страд. от* **одева́ть**

оде́жд||а *ж* **1.** кием, кием-салым, өсбаш; **ве́рхняя ~а** өске кием; **зи́мняя ~а** кышкы кием; **отде́л мужско́й ~ы** ирләр киеме бүлеге **2.** *спец.* (*покрытие дороги*) каплам

одёжк||а *ж разг. уменьш.-ласк. от* **оде́жда** 1 ♦ **по ~е протя́гивай но́жки** *погов.* ≈ юрганыңа карап аягыңны суз

одеколо́н *м* одеколон, ислемай

оделí́ть *сов. кого-что чем* биреп чыгу, [бүләк] өләшү, [бүләк итеп] бирү

оделя́ть *несов. см.* **оделí́ть**

одёр *м разг.* (*изнурённая лошадь*) карт ат

одёргивать *несов. см.* **одёрнуть**

одеревене́лость *ж* катып калу, агач кебек булу; аяк-кул ою

одеревене́л||ый, -ая, -ое (*нечувствительный*) каткан, катып калган, агач кебек булган; ~**ые па́льцы** каткан бармаклар

одеревене́ть *сов.* кату, катып калу, ою, сизмәс хәлгә килү

одержа́ть *сов.*: ~ **верх** өстен чыгу; ~ **побе́ду** җиңү, җиңеп чыгу

оде́рживать *несов. см.* **одержа́ть**

одержи́мость *ж* мавыгучанлык; нык бирелгәнлек

одержи́м||ый, -ая, -ое **1.** (*всецело охваченный чем-л.*) бик нык мавыккан; бирелгән, нык бирелгән; ~**ый стра́хом** куркуга бирелгән **2.** *в знач. сущ.* ~**ый** *м*, ~**ая** *ж уст.* (*безумный*) шашкан, юләрләнгән, котырынган

одёрнуть *сов.* **1.** *что* тартып кую (рәтләү) **2.** *перен. кого-что, разг.* (*призвать к порядку*) туктату, тыю, тәртипкә чакыру

оде́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **оде́ть**; **2.** киенгән, киеме бар кеше; киенгән килеш; **хорошо́ ~ый** яхшы киенгән; **он лежа́л ~ый** ул киенгән килеш ята иде

одéть *сов.* **1.** *кого-что* киендерү; ябу, төрү; **~ ребёнка тепло́** баланы җылы киендерү **2.** *кого-что* (*снабдить одеждой*) өс-башын бөтенәйтү, киендерү **3.** *перен. что* (*покрыть*) каплау, каплап алу

одéться *сов.* **1.** киенү; ябыну, төренү; **~ тепло́** җылы киенү **2.** (*приобрести одежду*) киенү, кием-салым алу; өс-башны яңарту **3.** *перен.* (*покрыться*) каплану

одея́ло *с* юрган, одеял

одея́ние *с уст. и шутл. см.* **оде́жда** 1

оди́н *числ.* **1.** (*число*) бер **2.** *в знач. прил.* (*без других, в отдельности*) бердәнбер, бер үзе, үзе генә, ялгыз; **он живёт ~** ул бер үзе генә тора; **ребёнок оста́лся до́ма ~** бала өйдә ялгыз калды **3.** *в знач. мест.* (*какой-то, некий*) бере, берәү; бер кеше; кемдер; **в ~ прекра́сный день** көннәрнең берендә; **приходи́л ~ челове́к** бер кеше килгән иде **4.** *в знач. прил.* (*тот же самый, одинаковый*) бер, бер үк, шул үк; **в ~ и то́т же час** бер үк сәгәттә; **стоя́ть на одно́м ме́сте** бер урында басып тору **5.** *в знач. мест.* (*только, исключительно*) ...гына, бары, тик, фәкать; **в ва́зе одни́ я́блоки, груш нет** вазада алмалар гына, груша[лар] юк; **ходи́ть в одно́й руба́шке** күлмәкчән генә йөрү; **меня́ одно́ беспоко́ит** мине фәкать бер нәрсә борчый **6.** *в знач. мест.* (*какой-л. в ряду сходных*) бер, берәү, берсе; **то ~, то друго́й** я берсе, я икенчесе; **одно́ друго́му не меша́ет** берсе икенчесенә комачауламый ♦ **все до одного́** барысы да; **все как ~** барысы да бер кеше кебек; **ни ~** һичкем, бер кеше дә; **одно́ и то́ же** бер үк нәрсә; **~ за други́м** берәм-берәм, бер-бер артлы; **~ на ~** икәү генә, бергә бер, күзгә-күз килеп; **одно́ к одному́** берсе өстенә берсе; **одно́ из двух** икенең берсе

одина́ков||ый, -ая, -ое бертөрле, бердәй, бертигез, бертөсле, бертиң; **~ого разме́ра** бертигез зурлыкта; **~ый взгляд на ве́щи** әйберләргә бертөсле караш

одина́рн||ый, -ая, -ое бер иңле; **~ая ра́ма** бер иңле рам

одиннадцатиле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) унберьеллык ... **2.** (*о возрасте*) унбер яшьлек

оди́ннадцатый, -ая, -ое *числ.* унберенче

оди́ннадцать *числ.* унбер

одино́кий, -ая, -ое **1.** ялгыз; **~ до́мик** ялгыз өй **2.** (*не имеющий семьи*) буйдак, ялгыз, ялгызак

одино́чество *с* ялгызлык

одино́чк||а 1. *м, ж* (*один, без других*) ялгыз, ялгыз кеше; ялгыз эшләүче; **куста́рь-~а** ялгыз эшләүче кустарь **2. ~а** *ж разг.* (*тюремная камера*) одиночка, бер кешелек камера **3. ~а** *ж* (*гоночная лодка*) бер кешелек байдарка ♦ **в ~у** бер үзе, япа-ялгыз

одино́чн||ый, -ая, -ое **1.** ялгыз; **~ый полёт** ялгыз очу **2.** (*для одного*) бер кешелек; **~ый но́мер** (*в гостинице*) бер кешелек номер **3.** (*отдельный*) аерым, берән-сәрән; **~ые вы́стрелы** берәм-сәрәм атулар

одио́зность *ж книж.* әшәкелек, үтә начарлык

одио́зн||ый, -ая, -ое *книжн.* әшәке, үтә начар; **~ая ли́чность** әшәке кеше

одича́л||ый, -ая, -ое **1.** (*ставший диким*) кыргыйланган, кыргыйлашкан; **~ая ко́шка** кыргыйлашкан мәче **2.** (*выражающий дикость*) кыргый, кырыс; **~ый взгляд** кырыс караш

одича́ние *с см.* **одича́ть**

одича́ть *сов.* **1.** (*стать диким*) кыргыйлану, кыргыйлашу **2.** *перен.* (*отвыкнуть от людей*) кешедән бизү, кыргыйлану

одна́жды *нареч.* **1.** (*один раз*) бер тапкыр, бер кат, бер кабат **2.** (*как-то раз*) бервакыт, бермәл, берчак; көннәрдән бер көн

одна́ко 1. *союз против.* ләкин, әмма, мәгәр **2.** *вводн. сл.* (*тем не менее, всё же*) шулай да, шулай булса да, шуңа карамастан; **вы, ~, не забу́дьте обе́щанного** шулай да сез вәгъдә иткән нәрсәне онытмагыз **3.** *межд.* (*выражает удивление, возмущение*) ай-һай; **~! И вы хороши́!** ай-һай! Сез үзегез дә шәп инде!

одно- *кайбер кушма сүзләрнең «бер» һәм «...даш» мәгънәләрен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **одноглáзый** бер күзле; **однокла́ссник** класташ; **одновёсельный** бер ишкәкле

одноа́ктн||ый, -ая, -ое бер пәрдәле; **~ая пье́са** бер пәрдәле пьеса

однобо́к||ий, -ая, -ое берьяклы, бер яктан гына чыгып; **~ое сужде́ние** берьяклы фикер йөртү

однобо́кость *ж* берьяклылык, берьяклы булу

однобо́ртный, -ая, -ое бер капламалы, бер генә якка төймәләнә торган; **~ пиджа́к** бер капламалы пиджак

одновреме́нно, одновре́менно *нареч.* бер үк вакытта; берьюлы; **нача́ть ~** бер үк вакытта башлау

одновреме́нность, одновре́менность *ж* бер үк вакытта булу

одновреме́нный, одновре́менный, -ая, -ое бер үк вакыттагы, бер үк вакытта була торган

одноглáзый, -ая, -ое бер күзле, сыңар күзле

одногоди́чн||ый, -ая, -ое берьеллык ...; бер елга сузыла торган, бер ел эчендә була торган; **~ые ку́рсы** берьеллык курслар

одного́док *м см.* **однолéток**

одноголо́сие *с муз.* бер тавышлы булу, бер тавыштан тору

одноголо́сый, -ая, -ое *муз.* бер тавышлы, бер тавыштан торган

одного́рбый, -ая, -ое бер өркәчле; **~ верблю́д** бер өркәчле дөя

однодне́вка *ж* **1.** *зоол.* бер көнлек күбәләк; бер генә көн яши торган бөҗәк **2.** *разг.* (*существующий очень недолго*) бер көнлек, тиз искерүчән

однодне́вный, -ая, -ое **1.** бер көнлек ...; **~ дом о́тдыха** бер көнлек ял йорты **2.** бер көнлек ..., бер көн өчен; **~ за́работок** бер көнлек эш хакы

однодо́льный, -ая, -ое *бот.* сынар орлыклы (*үсемлек турында*)

однодо́мный, -ая, -ое *бот.* бер өйле (*төрле җенесле чәчәкләре бер үк төптә була торган үсемлек турында*)

однозву́чный, -ая, -ое бертөрле тавышлы; **~ колоко́льчик** бертөрле тавышлы кыңгырау

однозна́чн||ый, -ая, -ое **1.** (*тождественный по смыслу*) мәгънәдәш, бер мәгънәле, мәгънәсе бер; **~ые формули́ровки** мәгънәдәш формулировкалар **2.** (*с одним значением*) бер мәгънәле; **~ое сло́во** бер мәгънәле сүз **3.** *мат.* бер урынлы; **~ое число́** бер урынлы сан

одноимённый, -ая, -ое исемдәш, бер үк исемдәге

однокали́берный, -ая, -ое бер үк калибрлы, калибрлары бертөрле булган

однока́шник *м разг.* (*товарищ по учению и т. п.*) шәрик, сабакташ, бергә укыган кеше

однокла́ссник *м* сыйныфташ, сабакташ

однокла́ссница *ж* сыйныфташ кыз, сабакташ кыз

однокле́точн||ый, -ая, -ое *биол.* бер күзәнәкле; **~ые организмы́** бер күзәнәкле организмнар

однокл́убник *м* клубташ, бер үк клуб спортчысы

одноколе́йка *ж разг.* бер колеялы тимер юл

одноколе́йный, -ая, -ое бер колеялы

одноко́лка *ж* бер күчәрле арба

одноко́мнатн||ый, -ая, -ое бер бүлмәле; **~ая кварти́ра** бер бүлмәле квартир

одноко́нный, -ая, -ое бер атлы, бер ат җигә торган

однокопы́тные *мн. зоол.* так (сынар тояклылар (*ат, качыр һ.б.ш.*)

однокра́тн||ый, -ая, -ое бер тапкыр (*эшләнгән*), бер кабат (*булган*); **~ое посеще́ние больно́го** авыру янында бер тапкыр булу ♦ **~ый глаго́л** *грам.* кабатлаусыз фигыль

однокýрсник *м* курсташ

однокýрсница *ж* курсташ кыз

однола́мповый, -ая, -ое бер лампалы; **~ приёмник** бер лампалы радиоалгыч

однолеме́шный, -ая, -ое бер төрәнле; **~ плуг** бер төрәнле сабан

однолéтка *ж см.* **однолéток**

однолéтн||ий, -яя, -ее: **~ие расте́ния** берьеллык үсемлекләр

однолéтник *м бот.* берьеллык үсемлек

однолéток *м разг.* яшьтәш

однолю́б *м* бер генә хатын-кызны яраткан (ярата торган) кеше

одномáчтов||ый, -ая, -ое бер мачталы; **~ое су́дно** бер мачталы судно

одноме́стн||ый, -ая, -ое бер урынлы, бер кешелек ...; **~ая кают́а** бер урынлы каюта

одномото́рный, -ая, -ое бер моторлы; **~ самолёт** бер моторлы очкыч

однонóгий, -ая, -ое бер аяклы, сынар аяклы

однообра́зие *с* бертөрлелек, бертөслелек; **томи́тельное ~** эч пошыргыч бертөрлелек

однообра́зный, -ая, -ое бертөрле, бертөсле, үзгәрешсез

одноо́сный, -ая, -ое бер күчәрле

однопала́тн||ый, -ая, -ое *полит.* бер палаталы; **~ая парла́ментская систе́ма** бер палаталы парламент системасы

однопа́лубн||ый, -ая, -ое бер палубалы; **~ое су́дно** бер палубалы судно

однопа́лый, -ая, -ое бер бармаклы; **~ челове́к** бер бармаклы кеше

однополча́нин *м* полкташ

однопо́л||ый, -ая, -ое *бот.* бер женесле; **~ое расте́ние** бер женесле үсемлек

однопу́тка *ж разг. см.* **одноколе́йка**

одноро́дность *ж* бертөрлелек, бертөслелек, беришлелек

одноро́дн||ый, -ая, -ое бертөрле, бертөсле, беришле; **~ые явле́ния** бертөрле күренешләр ♦ **~ые чле́ны предложе́ния** *грам.* җөмләнең тиңдәш кисәкләре

однору́кий, -ая, -ое бер куллы, сынар куллы

односельча́нин *м* авылдаш, бер авылда туган, бер авылда яшәүче

односельча́нка *ж* авылдаш хатын (кыз)

односло́жн||ый, -ая, -ое **1.** бер ижекле; **~ое сло́во** бер ижекле сүз **2.** *перен.* (*короткий*) өзек-өзек, кыска; **~ый отве́т** кыска җавап

односпа́льн||ый, -ая, -ое бер кешелек ..., бер генә кеше йокларлык ...; **~ая крова́ть** бер кешелек карават

одноство́льн||ый, -ая, -ое бер көпшәле; **~ое ружьё** бер көпшәле мылтык

одноство́рчатый, -ая, -ое бер генә якка ачыла торган

односторо́нн||ий, -яя, -ее **1.** (*о ткани*) берьяклы, ике ягы ике төрле **2.** берьяклы; **~ий плеври́т** берьяклы плеврит **3.** бер якка таба; **~ее движе́ние тра́нспорта** транспортның бер якка таба хәрәкәт итүе **4.** *перен.* берьяклы, тар, чикләнгән; **~ее реше́ние вопро́са** мәсьәләне берьяклы хәл итү

односторо́нность *ж* тар карашлылык, чикләнгән караш, берьяклылык

одноступе́нчат||ый, -ая, -ое бер буынлы; **~ая раке́та** бер буынлы ракета

однотипность *ж* бертөрле булу, бер үк типта булу

одноти́пн||ый, -ая, -ое бер типтагы, бер формадагы; **~ые маши́ны** бер типтагы машиналар

одното́мник *м* бер томлык

одното́мный, -ая, -ое бер томлы; **~ слова́рь** бер томлы сүзлек

однофа́зный, -ая, -ое *эл.* бер фазалы

однофами́лец *м* фамилиядәш, бер үк фамилияле

однофами́лица *ж* фамилиядәш хатын (кыз)

одноцве́тн||ый, -ая, -ое бер генә төстәге, бер төсле, бер генә буяулы; **~ые обо́и** бер генә төстәге обойлар

одночле́н *м мат.* бербуын

одноэта́жный, -ая, -ое бер катлы; **~ дом** бер катлы йорт

одобре́ние *с* (*похвала*) мактау, хуплау, хуплау сүзе

одобри́тельный, -ая, -ое мактаулы, яхшы (яраклы) дип танылган; **~ о́тзыв** яхшы бәяләмә

одо́брить *сов. кого-что* хуплау, хуп күрү, яраклы дип табу, яхшы дип табу; риза булу, рөхсәт бирү

одобря́ть *несов. см.* **одо́брить**

одолева́ть *несов. см.* **одоле́ть**

одоле́||ть *сов.* **1.** *кого-что* (*побороть*) җиңү, җиңеп (өстен) чыгу **2.** *перен. что, разг.* үзләштерү, өйрәнү, ия булу; **~ть матема́тику** математиканы үзләштерү **3.** *перен. кого* тулысынча буйсындыру, басу; **лень ~ла его́** аны ялкаулык баскан **4.** *кого, разг.* (*замучить*) борчып бетерү, җәфалау, йөдәтү, йөдәтеп бетерү, теңкәгә тию, аптырату; **комары́ ~ли** черкиләр йөдәтеп бетерде

одолже́ние *с* ярдәм, яхшылык эшләү, яхшылык күрсәтү, булышлык

одолжи́ть *сов. что кому* (*дать взаймы*) бурычка (әҗәткә, үтечкә) бирү; файдаланырга биреп тору

одр *м уст.* түшәк, ятак; **на сме́ртном ~е́** үлем түшәгендә

одряхле́ние *с см.* **одряхле́ть: преждевре́менное ~** вакытсыз картаю

одряхле́ть *сов.* картаю, картаеп какшау

одува́нчик *м* тузганак, йонлыбаш

оду́маться *сов.* акылга килү; уеннан кире кайту, фикереннән кайту, фикерен үзгәртү

оду́мываться *несов. см.* **оду́маться**

одура́чивать *несов. см.* **одура́чить**

одура́чить *сов. кого-что, разг.* ахмакка салдыру, алдап көлкегә калдыру

одуре́лый, -ая, -ое *разг.* юләрләнгән, исәрләнгән, миңгерәгән

одуре́ние *с разг.* баш кату

одуре́ть *сов. разг.* миңгерәүләнү, юләрләнү, исәрләнү

одурма́нивать *несов. см.* **одурма́нить**

одурма́нить *сов. кого-что* исертү, башны томаландыру (әйләндерү)

о́дурь *ж разг.* баш кату, баш томалану, миңгерәүлек

одуря́ть *несов. кого-что, разг.* исертү, башны әйләндерү; миңгерәүләндерү

одутлова́тость *ж* кабарынкылык, шешенгәнсыманлык

одутлова́тый, -ая, -ое тиресе салынып төшкән, шешенгәнсыман

одухотворённость *ж* дәртлелек, күтәренке рухлылык

одухотворённый, -ая, -ое дәртле, күтәренке рухлы

одухотвори́ть *сов. кого-что* **1.** (*воодушевить*) рухландыру, рухын күтәрү, дәртләндерү, дәрт кертү **2.** (*природу, животных*) җанландыру, аңлы дип санау; **~ приро́ду** табигатьне җанландыру

одухотворя́ть *несов. см.* **одухотвори́ть**

одушеви́ть *сов. что* (*наделить свойствами живого существа*) җанлы дип тану, җанландыру (*борынгы кешеләр уйлавынча*)

одушеви́ться *сов. чем* рухлану, рух күтәрелү, дәртләну

одушевле́ние *с книжн.* **1.** *см.* **одушеви́ть**; **2.** (*подъём духа*) күтәренке рух, дәрт

одушевлённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **одушеви́ть**; **2.** *книжн.* (*исполненный одушевления*) күтәренке рухлы, дәртле **3.** (*относящийся к миру живых существ*) җанлы, тере **4.** *грам.* җанлы; **~ые предме́ты** җанлы предметлар

одушевля́ть *несов. см.* **одушеви́ть**

одушевля́ться *несов.* **1.** *см.* **одушеви́ться**; **2.** *страд. от* **одушевля́ть**

оды́шк||а *ж* тын бетү, тын кысылу, күкрәк кысу, сулыш кысылу; **страда́ть ~ой** тын бетеп җәфалану

ожереби́ться *сов.* колынлау

ожере́лье *с* муенса; **жемчу́жное ~** энҗе муенса

ожесточа́ть *несов. см.* **ожесточи́ть**

ожесточа́ться *несов.* **1.** *см.* **ожесточи́ться**; **2.** *страд. от* **ожесточа́ть**

ожесточе́ние *с* **1.** *см.* **ожесточи́ть; 2.** *разг.* (*упорство, крайнее напряжение*) шәфкатьсезләнү, рәхимсезләнү, аяусызлану, аяусызлык

ожесточённость *ж* шәфкатьсезлек, аяусызлык

ожесточённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **ожесточи́ть**; **2.** каты, шәфкатьсез, аяусыз; **~ бой** каты сугыш

ожесточи́ть *сов. кого-что* шәфкатьсезләндерү, явызландыру, рәхимсезләндерү, усалландыру, аяусызландыру

ожесточи́ться *сов.* шәфкатьсезләнү, рәхимсезләнү, усаллану, аяусызлану, явызлану

ожёчь *сов. см.* **обже́чь**

ожёчься *сов. см.* **обже́чься**

оживи́ть *несов. см.* **ожи́ть**

оживи́||ть *сов.* **1.** *кого-что* (*возвратить к жизни*) терелтү, җан кертү **2.** *кого-что* җанландыру; яктыртып җибәрү; **ра́дость ~ла его́ лицо́** шатлык аның чыраен яктыртып җибәрде **3.** *что* җанландыру, дәртләндерү, җанландырып (дәртләндереп) җибәрү; **~ть рабо́ту кружка́** түгәрәкнең эшен җанландыру

оживи́||ться *сов. в разн. знач.* җанлану, дәртләнү, җанланып (дәртләнеп) китү; яктырып китү; **больно́й ~лся** авыру җанланып китте; **лицо́ его́ ~лось** аның йөзе яктырып китте; **у́лицы ~лись** урамнар җанланды

оживле́ние *с* **1.** *см.* **оживи́ть, оживи́ться; 2.** кызу хәрәкәт; **пра́здничное ~** бәйрәмдә була торган кызу хәрәкәт

оживлённость *ж* җанлылык, күңеллелек

оживлённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **оживи́ть**; **2.** җанлы, күтәренке рухлы, күтәренке күңелле, дәртле, кызу; **~ый спор** кызу бәхәс **3.** хәрәкәт кызу булган, кызу хәрәкәтле; тормыш кайнап торган; **~ая у́лица** хәрәкәт кызу булган урам

оживля́ть *несов. см.* **оживи́ть**

оживля́ться *несов.* **1.** *см.* **оживи́ться**; **2.** *страд. от* **оживля́ть**

ожида́ни||е *с* **1.** *см.* **ожида́ть**; **2.** *обычно мн.* **~я** (*надежды на что-л.*) өмет, көткән нәрсә

ожида́ть *несов. кого-что, чего* көтү, көтеп тору (яту); **~ по́езда** поездны көтү; **~ уда́бного слу́чая** уңай очрак көтеп тору

ожида́||ться *несов.* **1.** көтелү; **~ется дождь** яңгыр көтелә **2.** *страд. от* **ожида́ть**

ожире́ние *с см.* **ожире́ть**; **~ се́рдца** йөрәкне май каплау

ожире́ть *сов.* симерү, симереп китү, май басу (каплау)

ожи́ть *сов.* **1.** (*воскреснуть*) терелү, яңадан терелү **2.** *перен.* (*наполниться жизнью*) җанлану, дәртләнү, җанланып (дәртләнеп) китү **3.** *перен.* күз алдына килеп басу, искә төшү; **о́жили воспомина́ния о про́шлом** үткәннәр күз алдына килеп басты

ожо́г *м* **1.** пешү, пешерү; **~ руки́** кулны пешерү **2.** (*обожжённое место*) пешкән урын, пешкән җәрәхәт

озабо́тить *сов. кого-что* мәшәкатьләү, борчу, борчылдыру

озабо́титься *сов. чем* кайгырту, хәстәрен күрү; **~ заго́товкой то́плива** ягулык хәзерләүне кайгырту

озабо́ченность *ж* борчылу, борчылганлык; кайгыртучанлык; **проявля́ть ~** кайгыртучанлык күрсәтү

озабо́ченный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **озабо́тить**; **2.** борчулы, борчылган, тынычсыз, хафалы; **~ вид** борчылган кыяфәт

озагла́вить *сов. что* исем кую, исем бирү; **~ кни́гу** китапка исем бирү

озагла́вливать *несов. см.* **озагла́вить**

озада́ченность *ж* аптыраганлык

озада́ченный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **озада́чить**; **2.** аптыраган, аптырашка калган, аптыраулы, аптырау хәлендәге

озада́чивать *несов. см.* **озада́чить**

озада́чить *сов. кого-что чем* аптырату, аптырашка калдыру

озаре́ние *с книжн. см.* **озари́ть, озари́ться**

озари́||ть *сов.* **1.** *что* (*ярко осветить*) яктырту, балкыту **2.** *перен. кого-что* җанландыру, нурландыру, балкыту, яктыртып җибәрү; **улы́бка ~ла его́ лицо́** аның йөзен елмаю яктыртып җибәрде **3.** *перен. кого-что* (*неожиданно прийти на ум*) башка килү, уйга килү

озари́||ться *сов. высок.* **1.** яктыру, яктырып (балкып) китү, балку **2.** *перен.* җанлану, нурлану, балку, балкып (яктырып) китү; **лицо́ ~лось улы́бкой** йөзе елмаюдан балкып китте

озаря́ть *несов. см.* **озари́ть**

озаря́ться *несов.* **1.** *см.* **озари́ться**; **2.** *страд. от* **озаря́ть**

озвере́лый, -ая, -ое ерткычланган, ерткыч .., котырынган; **~ враг** ерткычланган дошман

озвере́ть *сов.* ерткычлану, котыру

озвуче́ние, озву́чивание *с см.* **озву́чить**

озву́чивать *несов. см.* **озву́чить**

озву́чить *сов. что* тавышлыландыру, тавышлы итү; **~ фильм** фильмны тавышлыландыру

оздорови́тельн||ый, -ая, -ое савыктыргыч, савыктыру ...ы, сәламәтләндерү ...ы; **тури́стский ~ый ла́герь** савыктыргыч туристик лагерь; **~ые мероприя́тия** савыктыру чаралары

оздорови́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*сделать здоровым*) сәламәтләндерү, савыктыру **2.** *перен. что* яхшырту, тәртипкә кертү, юлга салу; **~ междунаро́дную обстано́вку** халыкара хәлне яхшырту

оздоровле́ние *с см.* **оздорови́ть**

оздоровля́ть *несов. см.* **оздорови́ть**

озелене́ние *с см.* **озелени́ть**

озелени́тельн||ый, -ая, -ое яшелләндерү ...ы, агачлар утырту ...ы; **~ые рабо́ты** яшелләндерү эшләре

озелени́ть *сов. что* яшелләндерү, агачлар утырту

озеленя́ть *несов. см.* **озелени́ть**

о́земь *нареч. уст.* җиргә; **грохну́ться ~** гөрселдәп җиргә егылу

озёрн||ый, -ая, -ое **1.** күл ...ы; **~ая вода́** күл суы **2.** күлле, күлләргә бай; **~ый край** күлләргә бай як

о́зеро *с* күл

ози́мы||й, -ая, -ое **1.** уҗым ...ы; **~ая пшени́ца** уҗым бодае; **~ые поля́** уҗым басулары **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* көзге игеннәр

о́зимь *ж* **1.** (*всходы*) уҗым, көзге чәчүлек **2.** (*поле*) уҗым басуы

озира́ть *несов. кого-что, книжн.* күздән кичерү, күз йөртеп чыгу

озира́ться *несов.* карану, карангалау; **~ по сторона́м** тирә-якка карану

озло́бить *сов. кого-что* ачуландыру, ачуын кабарту, үчектерү

озло́биться *сов.* ачулану, ачу кабару, ачу килү, үчегү

озлобле́ние *с* **1.** *см.* **озло́бить, озло́биться; 2.** (*злость*) ачу, ачу килү

озло́бленность *ж* ачулылык, ачулы булу

озло́бленный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **озло́бить**; **2.** ачулы, ачуланган, ачуы килгән

озлобля́ть *несов. см.* **озло́бить**

озлобля́ться *несов.* **1.** *см.* **озло́биться**; **2.** *страд. от* **озлобля́ть**

ознако́мить *сов. кого-что с чем* таныштыру, таныштырып чыгу

ознако́мить *сов. с кем-чем* танышу, танышып чыгу

ознакомле́ние *с см.* **ознако́мить, ознако́миться; подро́бное ~ с рабо́той** эш белән җентекләп таныштыру

ознакомля́ть *несов. см.* **ознако́мить**

ознакомля́ться *несов.* **1.** *см.* **ознако́миться**; **2.** *страд. от* **ознакомля́ть**

ознаменова́ние *с см.* **ознаменова́ть** ♦ **в ~ *чего*** билгеләп үтү йөзеннән

ознаменова́ть *сов. что* (*тантаналы рәвештә*) билгеләү, билгеләп үтү; хәрмәтләп искә алу, каршылау

ознаменова́ться *сов.* (*тантаналы рәвештә*) билгеләнү, билгеләнеп үтелү

означа́||ть *несов. что* (*обозначать*) белдерү, аңлату; күрсәтү, күрсәтеп тору; ... дигән сүз; **что э́то ~ет?** бу ни дигән сүз?

озна́ченный, -ая, -ое *уст.* югарыда әйтелгән, югарыда искә алынган; **в ~ день** югарыда әйтелгән көнне

озно́б *м* туңып калтырау, дерелдәү (*мәс. бизгәк вакытында*)

озокери́т *м мин.* тау балавызы, озокерит

озолоти́ть *сов. кого-что, разг.* (*щедро одарить деньгами*) баету, алтынга күмү

озо́н *м* озон

озона́тор *м* **озона́тор** (*наваны озонлап чистарту приборы*)

озони́рование *с см.* **озони́ровать**

озони́ровать *сов., несов. что* **1.** *хим.* озонга әверелдерү **2.** озон белән чистарту, озонлау; **~ во́ду** суны озон белән чистарту

озорни́к *м* шук, шаян, наян

озорни́ца *ж* шук (шаян, наян) кыз

озорнича́ть *несов.* шаяру, шаянлану, шуклану

озорно́й, -а́я, -о́е шаян, шук; **~ ребёнок** шук бала

озорство́ *с* шаяру, шуклык, шаянлык

озя́бнуть *сов. разг.* күшегү, туңып бетү, өшеп бетү

ой *межд.* (*выражает испуг*) ай, абау; **ой, как напуга́л!** абау, ничек куркытты!

оказа́ние *с см.* **оказа́ть**; **~ по́мощи** ярдәм күрсәтү

оказа́ть *сов. что* күрсәтү, белдерү, ясау, итү; **~ по́мощь** ярдәм күрсәтү; **~ дове́рие** ышаныч белдерү; **~ влия́ние** *на кого-л. берәр кешегә* йогынты ясау ♦ **~ предпочте́ние** артык (өстен) күрү; **~ раду́шный приём** якты йөз белән каршы алу

оказа́||ться *сов.* **1.** булып чыгу, икән: **трево́га ~лась ло́жной** тревога ялган булып чыкты; **он ~лся мои́м ста́рым знако́мым** ул минем күптәнге таныш булып чыкты **2.** табылу, булу; **в гости́нице не ~лось мест** кунакханәдә урын булмады **3.** барып (килеп) чыгу; әлегү, тару, очрау; калу; **~ться на незнако́мой у́лице** таныш булмаган урамга барып чыгу; **~ться в беде́** бәлагә очрау; **~ться в смешно́м положе́нии** көлкегә калу

оказа́зия *ж* **1.** (*удобный случай*) уңайлы очрак, җае чыгу (туры килү) **2.** *разг.* гаҗәп хәл, әкәмәт; **что за ~!** бу нинди әкәмәт!

оказа́зывать *несов. см.* **оказа́ть**

оказа́зыва||ться *несов.* **1.** *см.* **оказа́ться**; **2.** *в знач. вводн. сл.* **~ется** икән; **он, ~ется, у́чится в Москве́** ул Мәскәүдә укый икән **3.** *страд. от* **оказа́зывать**

окаймити́ть *сов. что* **1.** (*обвести каймой*) каймалау, каймалап (кайма тотып) чыгу **2.** *перен.* (*окружить*) уратып (әйләндереп) алу

окаймля́ть *несов. см.* **окаймити́ть**

окали́на *ж тех.* янык, касмак; **желе́зная ~** тимер касмагы

окамене́лость *ж* **1.** ташка әйләнгәнлек (әверелгәнлек) **2.** (*окаменелое животное или растение*) ташка әверелгән хайван (үсемлек)

окамене́л||ый, -ая, -ое **1.** ташка әйләнгән (әверелгән); **~ые оста́тки дре́вних живо́тных** ташка әверелгән борынгы хайван калдыклары **2.** *перен.*

(*неподвижный, безжизненный*) туң, җансыз, катып калган; **~ый взор** җансыз караш

окамене́ть *сов.* **1.** ташка әйләнү (әверелү) **2.** *перен.* таш кебек катып калу, тораташ кебек кату; **~ от стра́ха** куркудан катып калу

окантова́ть *сов. что* **1.** кант тотып чыгу, зияк (кайма) тотып чыгу **2.** *спец.* дүрткырлап таслап (юнып) чыгу; **~ бревно́** бүрәнәне дүрткырлап юнып чыгу

окантовка *ж* **1.** *см.* **окантова́ть; 2.** кант, кайма; **краси́вая ~** матур кайма

окантовывать *несов. см.* **окантова́ть**

ока́нчивать *несов. см.* **око́нчить**

ока́нчиваться *несов.* **1.** *см.* **око́нчиться; 2.** *страд. от* **ока́нчивать**

ока́пывать *несов. см.* **окопа́ть**

ока́пываться *несов.* **1.** *см.* **окопа́ться; 2.** *страд. от* **ока́пывать**

окати́ть *сов. кого-что* (*облить*) кою, коендыру; **~ из ведра́** чиләктән су белән коендыру

окати́ться *сов.* коену; **~ холо́дной водо́й** салкын су белән коену

о́кать *несов.* олаштырып сөйләү (*төньяк рус диалектларында*)

ока́янный, -ая, -ое *каһәр суккан, ләгънәт төшкән, мәлгун*

океа́н *м* **1.** океан **2.** *перен.* чиксез күп, әйтеп бетергесез күп; **людско́й ~** чиксез күп кеше

океана́вт *м* (*исследователь океана*) океанчы, океан тикшеренүчесе, океанавт

океана́рий *м* океанарий (*см.* **океана́риум**)

океана́риум *м* океанариум (*диңгез хайваннарын һәм балыкларны урчету һәм аларның яшәешен күзәту өчен җиһазланган бассейн*)

океани́ческ||ий, -ая, -ое *спец.* океан ...ы; океанда ...ы; **~ое рыболо́вство** океанда балык тоту эше

океанологи́ческ||ий, -ая, -ое океанология ...ы, океанологик; **~ие иссле́дования** океанологик тикшеренүләр

океаноло́гия *ж* океанология (*диңгез һәм океаннарны өйрәнә торган фән*)

океа́нский, -ая, -ое океан ...ы; **~ ла́йнер** океан лайнеры

оки́дывать *несов. см.* **оки́нуть**

оки́нуть *сов.*: **~ взо́ром (взгля́дом, глаза́ми)** *кого-что* күз йөртеп алу, карап алу, күз ташлау

о́кисел *м хим.* окисел

окисле́ние *с хим.* оксидлашу, окисьлашу; **~ мета́лла** металлның окисьлашуы

окисли́тель *м хим.* оксидлаштыручы

окисли́тельный, -ая, -ое *хим.* оксидлаштыра торган

окисли́ть *сов. что хим.* оксидлаштыру

окисли́ться *сов. хим.* оксидлашу

окисля́ть *несов. см.* **окисли́ть**

окисля́ться *несов.* **1.** *см.* **окисли́ться; 2.** *страд. от* **окисля́ть**

о́кись *ж хим.* окись, оксид

окку́льтный, -ая, -ое *рел.* аңлатып булмый торган, серле, гайре табигый

оккупа́нт *м* илбасар, басып алучы, оккупант

оккупацио́нн||ый, -ая, -ое оккупация ...ы, оккупацион; **~ые войска́** оккупацион гаскәрләр

оккупа́ция *ж* басып алу, оккупация

оккупи́ровать *сов., несов. что* басып алу, оккупацияләү

оклад *м* **1.** хезмәт хакы; **ме́сячный ~** айлык хезмәт хакы **2.** *фин.* (*налог*) салым, түләү күләме, салым күләме

оклади́ст||ый, -ая, -ое: **~ая борода́** көрәк сакал

оклевета́ть *сов. кого-что* яла ягу, кара ягу, каралау

оклеи́вать *несов. см.* **оклеи́ть**

оклеи́ть *сов. что* ябыштыру, ябыштырып чыгу; **~ сте́ны обо́ями** стеналарга обой ябыштырып чыгу

оклейка *ж см.* **оклеи́ть**

о́клик *м* эндәшү, тавыш бирү; эндәшү тавышы

окрика́ть *несов. см.* **окли́кнуть**

окли́кнуть *сов. кого* кычкырып (эндәшеп) туктату, чакырып алу, чакыру

окн||о́ *с* **1.** тәрәзә; **слухово́е ~о́** жилләтү тәрәзәсе; **откры́ть ~о́** тәрәзәне ачу **2.** *разг.* (*подоконник*) тәрәзә төбе; **цветы́ на ~е́** тәрәзә төбендәге гөлләр **3.** (*просвет, отверстие в чём-л.*) ачыклык, ачык урын; **~о́ ме́жду ту́чами** болытлар арасындагы ачыклык **4.** *разг.* (*промежуток времени*) буш сәгать, тәрәзә; **~о́ ме́жду ле́кциями** ике лекция арасындагы буш сәгать

о́ко *с уст.* күз ◆ **~ за ~, зу́б за́ зуб** ≈ ашка аш, ташка таш

окова́ть *сов. что чем* [тимер белән] тышлау, [калай белән] тышлау; **~ сунду́к желе́зом** сандыкны тимер белән тышлау

око́вка *ж см.* **окова́ть**

око́вы *только мн.* **1.** (*кандалы*) богау, зынҗыр **2.** *перен.* богау; **на́ли ~ ра́бства** коллык богаулары өзелеп төште

око́вывать *несов. см.* **окова́ть**

окола́чиваться *несов. прост.* буталу, буталып йөрү

околдова́ть *сов. кого* **1.** сихерләү, күз буу (*хорафат карашлар буенча*) **2.** *перен.* (*очаровать*) сокландыру, сихерләү, сокландырып үзенә карату

околдо́вывать *несов. см.* **околдова́ть**

околева́ть *несов. см.* **околе́ть**

околе́сиц||а *ж разг.* буш сүз, юк-бар сүз, сафсата; **нести́ ~у** юк-бар сүз сөйләү

околе́ть *сов.* үлү (*хайваннар турында*)

око́лиц||а *ж* басу киртәсе; басу капкасы; **вы́йти за ~у** басу капкасы артына чыгу

околи́чност||ь *ж уст.* читләтеп әйтелгән сүз, киная; **говори́ть без ~ей** кинаясез сөйләү

о́коло *предлог с род. п.* **1.** (*поблизости, рядом с кем-чем-л.*) янында, тирәсендә; **сядь ~ меня́** минем яныма утыр **2.** (*почти, приблизительно*) чамасы, чамасында, диярлек; тирәсендә; **они́ шли ~ ча́са** алар бер сәгать чамасы бардылар; **мы встре́тились ~ десяти́ часо́в ве́чера** без кичке сәгать уннар тирәсендә очраштык

околозвёздн||ый, -ая, -ое йолдыз янындагы, йолдыз әйләнә-тирәсендәге; **~ые миры́** йолдыз әйләнә-тирәсендәге галәмнәр

околозе́мн||ый, -ая, -ое Җир шары янындагы, Җир тирәсендәге; **вы́вести раке́ту на ~ую орби́ту** ракетаны Җир тирәсендәге орбитага чыгару

окололу́нн||ый, -ая, -ое Ай янындагы, Ай тирәсендәге; **~ая орби́та** Ай тирәсендәге орбита

околопло́дник *м бот.* җимеш тирәлеге

околопло́дн||ый, -ая, -ое *физиол., анат.* тума тирәсендәге, яралгы тирәсендәге, яралгыны саклый торган; **~ые во́ды** яралгыны саклый торган сыекча

околосерде́чн||ый, -ая, -ое *анат.* йөрәк тирәсендәге, йөрәк янындагы; **~ая су́мка** йөрәк тирәсендәге букча

около́т||ок *м уст.* **1.** (*окрестность*) тирә, тирә-як, тирә-юнь; **в на́шем ~ке** безнең тирәдә **2.** околоток (*революциягә кадәрге Россиядә: полиция булекчәсе*)

около́точный *м уст.* околоточный, околоток полицейские

околоу́шн||ый, -ая, -ое *анат.* колак яны ...ы, колак янындагы; **~ая железа́** колак яны бизе

околоцве́тник *м бот.* чәчәк тирәлеге

околпа́чивать *несов. см.* **околпа́чить**

околпа́чить *сов. кого-что, прост.* алдау, утырту

око́лыш *м* кырпу; **фура́жка с ~ем** кырпулы фуражка

око́лышек *м см.* **око́лыш**

око́льн||ый, -ая, -ое **1.** әйләнеч, урау; **~ая доро́га** әйләнеч юл **2.** *перен.* астыртын, хәйләле, яшерен; **вы́ведать** *что-л.* **~ым путём** *берәр нәрсәне* астыртын юллар белән белү

окольцева́ть *сов.* **1.** *кого-что* балдаклау, балдак кидерү; **~ пти́цу** кошның аягына балдак кидерү **2.** *что* (*дерево*) бөжралау, бөжра ясау

окольцо́вывать *несов. см.* **окольцева́ть**

оконе́чность *ж* чит, кырый, оч

око́нн||ый, -ая, -ое тәрәзә ...ы; **~ая ра́ма** тәрәзә рамы

оконфу́зить *сов. кого-что, разг.* оялту, оятка калдыру, оятлы итү, хур итү

оконфу́зиться *сов. разг.* оялу, оятлы булу, оятка калу, хур булу

оконча́ни||е *с* **1.** (*завершение*) бетү, тәмамлану, тәмам булу, төгәлләнү **2.** (*конец чего-л.*) ахыр, соң, азак, актык; **~е рома́на** романның ахыры **3.** *грам.* кушымча; **паде́жные ~я** килеш кушымчалары

оконча́тельн||ый, -ая, -ое **1.** (*последний*) соңгы, ахыргы, азаккы; **~ый вы́вод** соңгы нәтиҗә **2.** (*не подлежащий пересмотру*) катгый, өзеп; **~ое реше́ние** катгый карар **3.** (*полный*) тулы, тулысынча, тәмам; **~ое сверже́ние** тулысынча бәреп төшерү

око́нчить *сов. что* бетерү, төгәллә, тәмамлау, очлау, тәмамлап (очлап) чыгу; ~ **чте́ние** укып бетерү; ~ **институ́т** институт тәмамлау

око́нчи||ться *сов.* бетү, тәмамлану; **заседа́ние ~лось по́здно** утырыш соң бетте

око́п *м воен.* окоп

окопа́ть *сов. что* [тирәли] казу, казып чыгу; ~ **я́блоню** алмагачның төбен тирәли казып чыгу

окопа́ться *сов.* **1.** *воен.* окоп казып урнашу **2.** *перен. разг.* (*найти пристанище*) җылы (тыныч) урынга урнашу

око́пн||ый, -ая, -ое окоп ...ы; ~ **ая ли́ния** окоп линиясе ♦ ~ **ая война́** окоп сугышлары

о́корок *м* окорок, бот ите (*мәс. дуңгыз боты*); **копчёный** ~ ысланган окорок

окостенева́ть *несов. см.* **окостене́ть**

окостене́лый, -ая, -ое **1.** (*превратившийся в кость*) сөякка әйләнгән (әверелгән) **2.** *перен.* каткан, катып калган; туңып каткан, искергән; ~ **ум** катып калган акыл

окостене́ние *с см.* **окостене́ть**; ~ **хрящево́й ткани** кимерчәк тукымасының сөякләнүе

окостене́||ть *сов.* **1.** (*превратиться в кость*) сөякләнү, сөякка әйләнү (әверелү) **2.** *прям., перен.* туңу, кату, катып калу, туңып кату; **ру́ки ~ли на хо́лоде** салкында куллар катты

око́т *м см.* **окоти́ться**

окоти́ться *сов.* балалау (*песи, куян, тиен, арслан турында*); бәрәнләү (*сарык, кәҗә һ.б.ш. хайваннар турында*)

окочене́л||ый, -ая, -ое күшеккән, туңган, каткан; ~ **ые па́льцы** туңган бармаклар

окочене́ть *сов.* өшү, күшегү, туңу, кату, катып калу

око́шко *с разг.* тәрәзә, кечкенә тәрәзә

окра́ина *ж* **1.** чит, кырый; ~ **го́рода** шәһәр чите **2.** (*пограничная область*) чик өлкә, чиктәге район, чик җирләр

окра́инн||ый, -ая, -ое читтәге, читендәге; ~ **ые райо́ны го́рода** шәһәр читендәге районнар

окра́сить *сов. что* **1.** (*покрыть краской*) буяу, ману **2.** (*сделать красным — о лучах солнца, огне и т. п.*) кызгылт төскә кертү, кызылландыру, алсуландыру

окра́ситься *сов.* буялу, манылу

окра́ска *ж* **1.** *см.* **окра́сить**; **2.** *биол.* төс; **защи́тная** ~ саклагыч төс **3.** *перен. книжн.* төсмер, төс, үзенчәлек; **стилисти́ческая** ~ **сло́ва** сүзнең стилистик төсмере

окра́шивать *несов. см.* **окра́сить**

окра́шиваться *несов.* **1.** *см.* **окра́ситься**; **2.** *страд. от* **окра́шивать**

окре́пнуть *сов.* **1.** (*стать прочнее*) ныгу, ныгып җитү, чыныгу **2.** (*стать здоровее*) тазару, тазарып китү **3.** (*усилиться*) көчәю; көчәеп китү; **ве́тер окре́п** җил көчәйде

окрести́ть *сов.* **1.** *кого, рел.* чукындыру **2.** *кого-что кем-чем, разг.* (*назвать*) атау, исем бирү

окре́стност||ь *ж* тирә-як, тирә-юнь, әйләнә-тирә; **в ~ях столи́цы** башкаланың әйләнә-тирәсендә

окре́сти||ый, -ая, -ое тирә-яктагы, тирә-юньдәге, әйләнә-тирәдәге; ~ **ые дере́вни** тирә-яктагы авыллар

окриве́ть *сов. разг.* бер күзе сукыраю

о́крик *м* **1.** *см.* **о́клик**; **2.** кычкырган тавыш, җикергән (акырган) тавыш, акырыну, җикеренү; **гру́бый** ~ тупас акырыну

окри́кнуть *сов. разг. см.* **оклика́ть**

окрова́вить *сов. кого-что* канландыру, канга буяу; канга батыру

окрова́виться *сов.* канга буялу (буялып бетү); канга бату

окрова́вленный, -ая, -ое канлы, канланган, канга баткан; ~ **бинт** канланган бинт

окро́л *м спец.* (*роды у крольчихи*) (*йорт куяны*) балалау

окропи́ть *сов. кого-что* бөркү, сибү

окропля́ть *несов. см.* **окропи́ть**

окро́шка *ж* **1.** окрошка (*куаска ит, йомырка, төрле яшелчә турап ясалган салкын аш*) **2.** *разг.* (*беспорядочная смесь*) чуалчыклык, буталчыклык

о́круг *м* округ; **избира́тельный** ~ сайлау округы; **вое́нный** ~ хәрби округ; **автоно́мный** ~ автономияле округ

окру́га *ж разг.* әйләнә-тирә, тирә-як, тирә-юнь

округле́ние *с см.* **округли́ть**, **округли́ться**

округле́ть *сов. разг.* түгәрәкләнү, түгәрәкләнеп китү

округли́ть *сов. что* **1.** (*сделать круглым*) түгәрәкләндерү, түгәрәкләү; йомрыландыру **2.** (*выразить в круглых цифрах*) түгәрәкләү, түгәрәкләп исәпләү

округли́||ться *сов.* **1.** (*стать круглым*) түгәрәкләнү; шар булу, йомрылану; **глаза́ ~лись от стра́ха** куркудан күзләре шар булды **2.** түгәрәкләнү; түгәрәкләп исәпләнү; **счёт ~лся** исәп түгәрәкләнде **3.** *перен. разг.* (*увеличиться*) күбәю, зураю; **капита́л ~лся** капитал күбәйде

кру́глост||ь *ж* **1.** түгәрәклек; йомрылык **2.** (*выпуклость*) кабарынкылык; ~ **и фигу́ры** фигураның кабарынкылыклары

кру́гл||ый, -ая, -ое түгәрәк, йомры; ~ **ое лицо́** түгәрәк йөз

округля́ть *несов. см.* **округли́ть**

округля́ться *несов. см.* **1. округли́ться; 2.** *страд. от* **округля́ть**

окружа́||ть *несов.* **1.** *см.* **окружи́ть**; **2.** *перен. кого* арасында яшәү; чолгау, әйләндереп алу, уратып алу; **его́ ~ют друзья́** ул дус-ишләр арасында яши; **село́ ~ли го́ры** авылны таулар уратып алган

окружа́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **окружа́ть**; **2.** тирә-яктагы, тирә-юньдәге, якын-тирәдәге, әйләнә-тирәдәге; ~ **ая среда́** әйләнә-тирәдәге мохит **3.** *в знач. сущ.* ~ **ее** *с* тирәлек, мохит, әйләнә-тирәдәге (тирә-юньдәге) нәрсәләр; **он тяготи́лся всем ~им** ул әйләнә-тирәдәге барлык нәрсәләрдән авырсына иде **4.** *в знач. сущ.* ~ **ие** *мн.* тирәдәгеләр; тирәдәге кешеләр, тирә-яктагылар; **скрыть своё го́ре от ~их** үз кайгы-хәсрәтеңне тирәдәге кешеләргә белдермәү

окруже́ни||е *с* **1.** *см.* **окружи́ть**; **2.** чолганыш, камалыш; **попа́сть в ~е** чолганышка эләгү; **вы́рваться из ~я** чолганыштан чыгып котылу **3.** (*окружающая обстановка*) чолганыш; **капиталисти́ческое ~е** капиталистик чолганыш **4.** (*окружающие лица, среда*) даирә; **литерату́рное ~е** әдәби даирә; ~ **е президе́нта** президент кешеләре ♦ **в ~и** *кого-чего, в знач. предлога* белән бергә, арасында

окружи́ть *сов.* **1.** *кого-что* чолгап (әйләндереп, уратып, сырып, камап) алу; ~ **проти́вника** дошманны камап алу **2.** *перен. кого чем* күрсәтү; ~ **внима́нием и забо́той** игътибар һәм кайгыртучанлык күрсәтү **3.** *кого чем* чолгатып алу; ~ **себя́ подхали́мами** үзен ялагайлар белән чолгатып алу

окружн||о́й, -а́я, -о́е **1.** округ ...ы; ~ **а́я избира́тельная коми́ссия** округ сайлау комиссиясе **2.** урап уза торган, әйләнеп үтә торган; ~ **а́я желе́зная доро́га** әйләнеп үтә торган тимер юл

окру́жност||ь *ж* **1.** әйләнә; **длина́ ~и** әйләнә озынлыгы **2.** әйләнә; **воро́нка пяти́ ме́тров в ~и** әйләнәсе биш метр булган чокыр

окрути́ть *сов.* **1.** *кого-что чем* (*обмотать*) урап (чорнап) кую **2.** *кого, прост. уст.* (*обвенчать*) никах укыту, өйләндерү

окрылённый, -ая, -ое канатланган, дәртләнгән, рухланган, рухы күтәрелгән; ~ **успе́хами** уңышлардан рухы күтәрелгән

окрыли́ть *сов. кого-что* (*воодушевить*) канатландыру, дәртләндерү, рухын күтәрү, дәрт бирү, рухландыру; ~ **наде́ждой** өметләндереп дәрт бирү

окрыля́ть *несов. см.* **окрыли́ть**

окры́ситься *сов. на кого, прост.* ачуланып җавап кайтару

оксиди́рование *с см.* **оксиди́ровать**

оксиди́ровать *сов., несов. что, тех.* оксидлау, оксидлаштыру

оксидиро́вка *ж тех.* **1.** *см.* **оксиди́ровать**; **2.** (*оксидированный слой*) оксидлаштырылган катлам

окта́ва *ж* октава (**1.** *муз. гамманың сигезенче буыны, шулай ук беренче һәм сигезенче тон авазлары арасындагы интервал* **2.** *бик калын тавыш* **3.** *лит. шигырьдә үзенә махсус рифмалы сигез юллы строфа*)

окта́н *м хим.* октан

окта́эдр *м мат.* октаэдр

октя́брь *м* октябрь, октябрь ае

октя́брьск||ий, -ая, -ое октябрь ...ы; ~ **ие дни** октябрь көннәре

оку́кливаться *несов. см.* **оку́клиться**

оку́клиться *сов. зоол.* күрчаклану, күрчакка әйләнү (*бөҗәк турында*)

окули́ровать *сов., несов. что, сад.* бөре ялгау (*җимеш агачына*)

окулиро́вка *ж см.* **окули́ровать**

окули́ст *м* күз табибы

окульту́ривать *несов. см.* **окульту́рить**

окульту́рить *сов. что* культуралаштыру; ~ **ди́кую я́блоню** кыргый алмагачны культуралаштыру

окуля́р *м* окуляр; ~ **телеско́па** телескоп окуляры

окуна́ть *несов. см.* **окуну́ть**

окуна́ться *несов.* **1.** *см.* **окуну́ться**; **2.** *страд. от* **окуна́ть**

окуну́ть *сов. кого-что* чумдырып алу, [суга] тыгып алу; манып (батырып) алу; ~ **го́лову в во́ду** башны суга тыгып алу

окуну́ться *сов.* **1.** чуму, чумып алу **2.** *перен.* күмелү, бирелү, чуму; **с голово́й ~ в рабо́ту** эшкә баш белән чуму

о́кунь *м* алабуга

окупа́емость *ж* хакы чыгарылу, чыгымы (расходы) каплану

окупа́ть *несов. см.* **окупи́ть**

окупа́ться *несов. см.* **окупи́ться**

окупи́ть *сов. что* (*возместить истраченное*) хакын (чыгымын) каплау, расходын кайтару

окупи́ться *сов.* хакы чыгарылу, чыгымы (расходы) кайтарылу

оку́ривание *с см.* **оку́рить**

оку́ривать *несов. см.* **оку́рить**

оку́рить *сов. кого-что* төтәсләү, төтен җибәрү, ыслау; ~ **у́лей** умартаны төтәсләү

оку́рок *м* төпчек, тәмәке (*папирос, сигарет*) төпчеге

оку́тать *сов. кого-что* **1.** *чем* (*кутая, обернуть*) төрү, урау **2.** *перен.* (*обволочь*) чолгап (урап) алу, каплау, өртү

оку́таться *сов.* **1.** (*закутаться*) урану, төренү **2.** *перен.* каплану, чолгану, төренү, каплап (чолгап) алыну, өртелү; ~ **тума́ном** томанга өртелү

оку́тывать *несов. см.* **оку́тать**

оку́тываться *несов.* **1.** *см.* **оку́таться**; **2.** *страд. от* **оку́тывать**

оку́чивание *с см.* **оку́чить**; ~ **карто́шки** бәрәңге күмү

оку́чивать *несов. см.* **оку́чить**

оку́чить *сов. что* (*усемлекнең төбен*) күмү, өю; ~ **карто́фель** бәрәңге күмү

оку́чка *ж см.* **оку́чить**

оку́чник *м* төп өйгеч, күмгеч, күмдергеч

ола́дья *ж* коймак

олеа́ндр *м* талгөл

оледене́лый, -ая, -ое **1.** *см.* **обледене́лый**; **2.** (*окоченевший*) туңган, туңып каткан

оледене́ние *с см.* **оледене́ть**

оледене́ть *сов.* **1.** *см.* **обледене́ть**; **2.** (*окоченеть*) боз кебек кату, туңу, өшү

олеи́нов||ый, -ая, -ое: ~**ая кислота́** олеин кислотасы

оленево́д *м* болан үрчетүче

оленево́дство *с* боланчылык, болан үрчетү (асраучылык)

оленево́дческий, -ая, -ое болан үрчетү ...ы, боланчылык ...ы, болан асраучылык ...ы; ~ **колхо́з** боланчылык колхозы

оленёнок *м* болан баласы

оле́н||ий, -ья, -ье болан ...ы; ~**ьи рога́** болан мөгезләре

олени́на *ж* болан ите

оле́нь *м* болан

олеографи́ческий, -ая, -ое олеография ...; олеографик; ~ **спо́соб** олеографик исул

олеогра́фия *ж* олеография (*төрле буяу белән таш басмада сурәт басуның борынгы исулы*)

оли́ва, **оли́вка** *ж* зәйтүн (*агачы һәм җимеше*)

оли́вков||ый, -ая, -ое **1.** зәйтүн ...ы; ~**ое ма́сло** зәйтүн мае **2.** (*о цвете*) саргылт яшел, зәйтүн төсендәге

олигархи́ческ||ий, -ая, -ое олигархик, олигархия ...ы; ~**ий строй** олигархик строй; ~**ое прави́тельство** олигархия хөкүмәте

олига́рхия *ж* олигархия (**1.** *югары катлау аристократларның хакимлегенә нигезләнгән дәүләт* **2.** *бер төркем монополистик капитал вәкилләренең сәяси һәм икътисади хакимлеге*)

оли́мп *м* **1.** (*с прописной*) *миф.* Олимп (*борынгы грек мифологиясендә: аллалар торган урын һәм аларның җыелышы*) **2.** *перен. шутл.* олимп; **литерату́рный** ~ әдәби олимп

олимпиа́да *ж* олимпиада; **Бе́лая Олимпиа́да** Ак (*кышкы*) олимпиада

олимпи́ец *м* **1.** *миф.* олимпчы **2.** *книжн.* олимпияче, олимпия уенчысы

олимпи́йск||ий, -ая, -ое Олимпия ...ы; **Олимпи́йские и́гры** Олимпия уеннары; **Междунаро́дный** ~**ий комите́т** Халыкара Олимпия комитеты ◆ ~**ое споко́йствие** мәнәбәт салкын канлылык

оли́фа *ж* олиф (*кайнатылган үсемлек мае*); **натура́льная** ~ натураль олиф

олицетворе́ние *с* **1.** *см.* **олицетвори́ть**; **2.** *чего* (*воплощение*) гәүдәләнеш, җанлы гәүдәләнеш; **Плю́шкин — ~ ску́пости** Плюшкин — саранлыкның җанлы гәүдәләнеше

олицетвори́ть *сов. кого-что* (*воплотить в какой-л. форме*) күрсәтү, сурәтләү; гәүдәләндерү

олицетворя́ть *несов. см.* **олицетвори́ть**

о́лово *с* аккургаш

оловя́нн||ый, -ая, -ое **1.** аккургаш ...ы; ~**ая руда́** аккургаш рудасы **2.** аккургаш ..., аккургаштан ясалган; ~**ая ло́жка** аккургаш кашык

о́лух *м разг.* аңгыра, ахмак, тинтәк, мәнсез; ачык авыз ◆ ~ **царя́ небе́сного** шыр тиле

ольха́ *ж* зирек; ~ **бе́лая** ак зирек; ~ **чёрная** кара зирек

ольхо́вый, -ая, -ое зирек ...ы; ~ **лист** зирек яфрагы

ольша́ник *м* зиреклек, зирек урманы

ом *м* ом (*электр каршылыгы берәмлеге*)

ома́р *м* омар (*диңгез кысласы*)

оме́га *ж* омега (*грек алфавитында иң соңгы хәреф*)

оме́ла *ж бот.* чыпчык җилеме

омерзе́ни||е *с* җирәнү, чиркану; **чу́вство** ~**я** җирәнү тойгысы

омерзе́ть *сов. кому, прост.* җирәндерү, җирәнү тойгысы тудыру; тәмам туйдыру

омерзи́тельный, -ая, -ое җирәнеч, чирканыч; ~ **посту́пок** җирәнеч эш

омертве́лость *ж* үлгәнлек, үлгән булу; сизү сәләтен югалтканлык

омертве́л||ый, -ая, -ое үле, үлек, үлгән; сизү сәләтен югалткан; ~**ые кле́тки** үле күзәнәкләр

омертве́ние *с см.* **омертве́ть**; ~ **тка́ней** тукымаларның үлүе

омертве́||ть *сов.* ою, сизү сәләте югалу; үлү, үлеккә әйләнү; **рука́** ~**ла** кул оеды

омертви́ть *сов. что* **1.** (*сделать нечувствительным*) сизү сәләтен бетерү; үлеккә әйләндерү; үтерү **2.** *перен.* (*исключить из хозяйственного оборота*) хуҗалык оборотыннан чыгару; ~ **капита́л** капиталны хуҗалык оборотыннан чыгару

омертвля́ть *несов. см.* **омертви́ть**

омёт *м* салам эскерте, салам өеме

омеща́ниться *сов. разг.* мещанлашу, мещанга әйләнү

омле́т *м* йомырка тәбәсе, омлет

о́мнибус *м уст.* (*многоместный конный экипаж*) омнибус

омове́ние *с* тәһарәт алу (*мөселманнарда*)

омола́живание *с см.* **омолоди́ть**

омола́живать *несов. см.* **омолоди́ть**

омола́живаться *несов.* **1.** *см.* **омолоди́ться**; **2.** *страд. от* **омола́живать**

омолоди́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*сделать более молодым*) яшәртү, яшәртеп җибәрү **2.** *что* (*ввести молодёжь в состав чего-л.*) яшәртү, яшьләрне кертү, яшьләрне алу

омолоди́ться *сов.* **1.** яшәрү, яшәреп китү **2.** (*стать более молодым по составу*) яшәрү, яшьләр күбәю

омоложе́ние *с биол.* яшәрү

омо́ним *м лингв.* аваздаш сүз, омоним

омоними́ческ||ий, -ая, -ое *лингв.* омоним ..., омонимик; ~**ие слова́** омонимик сүзләр

омонимия́ *ж лингв.* омонимия

омочи́ть *сов. что, уст.* чылату, юешләү, дымландыру

омрача́ть *несов. см.* **омрачи́ть**

омрача́ться *несов.* **1.** *см.* **омрачи́ться**; **2.** *страд. от* **омрача́ть**

омрачи́ть *сов. что* күңелсезләү, күңелсезләндерү, хәсрәткә төшерү, кайгыга калдыру; бозу; ~ **настрое́ние** кәефне бозу

омрачи́||ться *сов.* күңелсезләну, хәсрәткә төшү, караңгылану, караңгыланып китү, кәефе бозылу; **лицо́ его́ ~лось** чырае караңгыланып китте

о́муль *м* омуль (*балык*)

о́мут *м* **1.** (*водоворот*) упкын, әйләнмә **2.** (*яма на дне реки*) чоңгыл **3.** *перен.* (*то, что затягивает*) баткаклык, сазлык

омша́ник *м* умарта өе

омыва́||ть *несов.* **1.** *см.* **омы́ть**; **2.** *что* әйләндереп алу; **мо́ре ~ет о́стров** диңгез утрауны әйләндереп алган

омыва́ться *несов.* **1.** *см.* **омы́ться**; **2.** *страд. от* **омыва́ть** 1

омы́ть *сов. кого-что, книжн.* юу, юып чистарту

ОМЫ-ОПЕ

омы́ться *сов. см.* **обмы́ться**

он (его́, ему́, его́, им, о нём) *м мест.* ул

она́ (её, ей, её, ёю, о ней) *ж см.* **он**

онагр *м зоол.* онагр (*кыргый ишәк*)

онани́зм *м мед.* кул зинасы, онанизм

онани́ст *м* онанизм белән шөгыльләнүче

ондатра *ж зоол.* ондатра (*кыйммәт тиреле күсе һәм шулай ук аның тиресе*)

онеме́л||ый, -ая, -ое оеган, катып калган; **~ые но́ги** оеган аяк

онеме́ние *с см.* **онеме́ть**

онеме́||ть *сов.* ою, сизү сәләтен югалту; **рука́ ~ла** кул оеды

они́ (их, им, их, и́ми, о них) *мн. см.* **он**

о́никс *м мин.* оникс (*ахакның бер төре*)

онко́лог *м* онколог, онкология табибы, онкология белгече

онкологи́ческий, -ая, -ое онкологик, онкология ...ы; **~ кабине́т** онкология кабинеты; **~ больно́й** онкологик авыру

онколо́гия *ж* онкология (*яман шеш авырулары һәм аларны дәвалау методлары турында фән*)

оно́ *с мест.* **1.** *см.* **он; 2.** *нескл. разг.* (*это*) ул, бу; **так ~ и вы́шло** ул нәкъ шулай килеп чыкты **3.** *нескл. в знач. частицы усил. прост.* анысы шулай; димәк; **~, коне́чно, ты говори́шь пра́вильно** анысы шулай, әлбәттә, син дөрес сөйлисең; **так вот ~ что!** эш, димәк, менә нәрсәдә!

онома́стика *ж лингв.* **1.** ялгызлык исемнәре, ономастика **2.** ономастика (*тел фәненең ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган булеге*)

онтогене́з *м биол.* онтогенез (*организмның индивидуаль үсеше*)

ону́ча *ж* чолгау, ыштыр

о́ный, -ая, -ое *мест. уст.* (*тот самый, вышеупомянутый*) шул, теге, ул; искә алынган, югарыда әйтелгән

опада́ть *несов. см.* **опа́сть**

опа́здывать *несов. см.* **опозда́ть**

опа́ивать *несов. см.* **опои́ть**

опа́л *м мин.* ак ахак; **кольцо́ с ~ом** ак ахак кашлы йөзек

опа́л||а *ж* **1.** патша җәзасы (җәбере), опала; **ца́рская ~а** патша җәбере; **быть в ~е** патша тарафыннан җәберләнү **2.** *перен.* (*немилость*) күрә алмау, яратмау

опа́ливать *несов. см.* **опали́ть**

опали́ть *сов.* **1.** *кого-что* өтү, өтәләү; **~ гу́ся** казны өтү **2.** *что* көйдерү, яндыру, көйдереп (яндырып) алу; **~ бро́ви** кашларны яндыру **3.** *что* (*иссушить кожу*) жил ашау, яндыру

опали́ться *сов.* яну, пешү

опа́ловый, -ая, -ое **1.** *мин.* ак ахак ...; ак ахактан ясалган; **~ пе́рстень** ак ахак йөзек **2.** (*о цвете*) [ак] ахак төсле

опа́льный, -ая, -ое патша җәберенә дучар булган, патша җәзасына эләккән; **~ боя́рин** патша җәзасына эләккән бояр

опа́мятоваться *сов. разг.* (*опомниться*) аңга (исенә, һушына) килү; айну

опа́р *ж* апара, сыек камыр

опарши́веть *сов. прост.* тазлану, тазга әйләнү; кутырлап бетү, корчаңгыланып бетү

опаса́ться *несов.* **1.** *кого-чего и с неопр.* (*бояться*) курку, шикләнү, хәвефләнү **2.** *чего и с неопр.* (*остерегаться, предохранять себя от чего-л.*) курку, саклану; **~ просту́ды** салкын тиюдән саклану

опасе́ние *с* курку, шикләнү, хәвеф, хәвефләнү, шөбһә, шом; саклану; **вызыва́ть ~** хәвефкә салу

опа́ск||а *ж разг.* курку, шикләнү, саклык; **де́йствовать с ~ой** саклык белән эш итү

опа́сливый, -ая, -ое *разг.* (*настороженный, недоверчивый*) сак; куркак, куркып ..., куркучан; **~ взгляд** куркучан караш

опа́сность *ж* куркыныч, куркынычлык, хәвеф-хәтәр; **~ минова́ла** куркыныч үтте

опа́сн||ый, -ая, -ое куркыныч, куркынычлы, хәвефле, хәтәр[ле], хәвеф-хәтәрле; **~ая доро́га** куркынычлы юл; **~ый челове́к** куркыныч кеше; **~ое положе́ние** куркыныч хәл

опа́||сть *сов.* **1.** коелу, коелып төшү; **ли́стья ~ли** яфраклар коелды **2.** кимү, кайту; **о́пухоль ~ла** шеш кимеде

опаха́ло *с* (*род веера*) җилпәзә, җилләткеч

опаха́ть *сов. что* (*вспахать вокруг*) тирәли сөреп чыгу

опа́хивать *несов. см.* **опаха́ть**

опе́к||а *ж* **1.** *юр.* опека (*балаларны, психик авыруларны, картларны тәрбияләү эшен өскә алу һәм шулай ук аларның шәхси һәм милек хокукларын саклауны кайгырту*); **взять под ~у** опекага алу **2.** *собир.* (*ли́ца или учреждения*) опекуннар, опекунлык **3.** (*забота, попечение*) кайгырту-күзәтү; карау; **роди́тельская ~а** ата-аналарның кайгырту-күзәтүе

опека́ть *несов. кого-что* **1.** *юр.* (*осуществлять опеку*) опекага алу, опекунлык итү **2.** (*заботиться*) кайгырту, карау, кайгырту-күзәтү; **~ мла́дших** кечкенәләрне кайгырту-күзәтү

опеку́н *м* опекун, опекага алган кеше

опеку́нск||ий, -ая, -ое опекун[нар] ...ы; **~ие права́** опекун хокуклары

опеку́нство *с* опекунлык, опекунлык вазифасы

опеку́нша *ж* опекун хатын (кыз)

опёнок *м* баллы гөмбә

о́пер||а *ж* **1.** опера **2.** (*оперный театр*) опера театры **♦ из друго́й ~ы** *или* **не из той ~ы** дуга белән печән чабу (*бөтенләй башка нәрсә турында*)

операти́вка *ж разг.* оператив кинәшмә, оперативка

операти́вник *м разг.* оперативник (*милиция органнарында җинаятьләрне ачу һәм булдырмау эшләре белән шөгыльләнүче хезмәткәр*)

операти́вность *ж* оперативлык; җитезлек, өлгерлек; **прояви́ть ~** өлгерлек күрсәтү

операти́вн||ый, -ая, -ое **1.** оператив; **~ый штаб** оператив штаб; **~ая рабо́та** оператив эш; **~ая сво́дка** оператив сводка **2.** (*действительный*) житез, өлгер, оператив; **~ое руково́дство** оператив җитәкчелек **3.** *мед.* операция ...ы; **удали́ть о́пухоль ~ым путём** шешне операция юлы белән киселә алу

опера́тор *м* оператор

опера́торский, -ая, -ое оператор ...ы

операцио́нная *ж* операция ясау бүлмәсе

операцио́нн||ый, -ая, -ое операция ...ы; **~ый стол** операция өстәле; **~ое отделе́ние** операция бүлеге

опера́ци||я *ж* операция (**1.** *хирургия юлы белән ярдәм итү* **2.** *бер максатка ирешүгә юнәлдерелгән барлык сугыш чаралары* **3.** *сәүдә, финанс, почта һ.б.ш. эшләре буенча эшләнгән эш* **4.** *технологик процессның тәмамланган аерым бер өлеше*)

опереди́ть *сов. кого-что* **1.** узу, узып китү, алга чыгу **2.** *йперен.* өстен чыгу, узып китү; **~ в уче́бе** укуда узып китү

опережа́ть *несов. см.* **опереди́ть**

опереже́ние *с см.* **опереди́ть**; **~ гра́фика** графиктан алда бару

опере́ние *с* (*покров из перьев*) (*кошларның*) каурыйлары

опере́точный, -ая, -ое оперетта ...ы; **~ актёр** оперетта артисты

опере́тта *ж муз.* оперетта

опере́ть *сов. что* терәү, сөяү, терәп (терәтеп, сөяп) кую; **~ ло́кти на стол** терсәкләрне өстәлгә терәү

опере́ться *сов.* **1.** *на кого-что, обо что* терәлү, сөялү; таяну **2.** *перен. на кого-что* (*найти поддержку*) таяну; таянып эш итү; **~ на това́рищей** иптәшләргә таяну

опери́ровать 1. *сов. несов. кого-что* операция ясау; **~ больно́го** авыруга операция ясау **2.** *несов.* (*действовать*) эш итү, эш алып бару; **~ в тылу́ проти́вника** дошманның тылында эш алып бару **3.** *несов. чем* таяну, китерү, файдалану, таянып эш итү; **~ то́чными све́дениями** төгәл мәгълүматларга таянып эш итү

опери́ться *сов.* **1.** (*покрыться оперением*) каурый чыгу; йон чыгу **2.** *перен.* (*возмужать*) үсеп җитү, җитлегү

о́перный, -ая, -ое опера ...ы; **~ теа́тр** опера театры

оперуполномо́ченный *м* оперуполномоченный (*милиция органнарының оператив хезмәткәре*)

опря́ться *несов. см.* **опери́ться**

опеча́ленный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **опеча́лить**; **2.** кайгылы, хәсрәтле, кайгыга төшкән (калган); **~ вид** кайгылы кыяфәт

опеча́лить *сов. кого-что* кайгыга (хәсрәткә) төшерү, кайгыга калдыру (салу)

опеча́литься *сов.* кайгыга төшү, кайгыга (хәсрәткә) калу

опеча́тать *сов. что* печатьләп алу (кую); **~ ко́мнату** бүлмәне печатьләп кую

опеча́тка *ж* хата, басмадагы хата

опеча́тывание *с см.* **опеча́тать**; **~ кварти́ры** квартирны печатьләп кую

опеча́тывать *несов. см.* **опеча́тать**

опе́шить *сов. разг.* аптырап калу, каушап төшү, каушап китү (*көтмәгән нәрсәдән, куркудан*)

опива́ться *несов. см.* **опи́ться**

опи́вки *только мн. разг.* эчемлек калдыгы

о́пий *м* әфьюн

о́пийный, -ая, -ое әфьюн ...ы

опи́лки *только мн.* пычкы чүбе, такта ярмасы

опира́ть *несов. см.* **опере́ть**

опира́ться *несов.* **1.** *см.* **опере́ться**; **2.** *страд. от* **опира́ть**

описа́ние *с* **1.** *см.* **описа́ть** 1, 2; **2.** (*сочинение, изложение*) тасвир, тасвирлама

описа́тельн||ый, -ая, -ое тасвирлы, тасвирый; **~ая часть иссле́дования** тикшеренүнең тасвирый өлеше

описа́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*изобразить средствами языка*) тасвирлау, тасвирлап (сурәтләп) бирү; язып бирү, сөйләп бирү **2.** *что* язу, язып чыгу (алу); **~ ме́стный го́вор** җирле сөйләмне язып алу **3.** *что* (*сделать письменный перечень чего-л.*) опись ясау, язып алу **4.** *что, мат.* камап ... үткәрү (сызу), камап сызып алу, уратып сызу; **~ окру́жность вокру́г квадра́та** квадратны камап әйләнә үткәрү

описа́ться *сов.* ялгыш язу, хәреф төшереп калдыру, хәреф хатасы җибәрү (*язуда*)

опи́ска *ж* язудагы хата, ялгыш язу

опи́сывать *несов. см.* **описа́ть**

опи́сываться *несов.* **1.** *см.* **описа́ться**; **2.** *страд. от* **опи́сывать**

о́пись *ж* **1.** *см.* **описа́ть** 3; **2.** (*список*) исемлек, опись (*әйберләрне, милекне, документларны һ.б.ш. хисапка алу өчен төзелгән исемлек*)

опи́ться *сов. разг.* артык эчү, чиктән тыш күп эчү

о́пиум *м* **1.** әфьюн **2.** агу, әфьюн

опла́кать *сов. кого-что* күз яше түгү, кайгыдан елау, кайгырып елау

опла́кивать *несов. см.* **опла́кать**

опла́та *ж* **1.** *см.* **оплати́ть**; **~ труда́** хезмәткә түләү; **~ почто́вых расхо́дов** почта чыгымнарын түләү **2.** түләү, түләнә торган акча; **сде́льная ~** эш башыннан түләү

оплати́ть *сов. что* түләү; **~ счёт** счёт буенча түләү

опла́ченный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **оплати́ть**; **2.** түләгән, түләнгән; **~ долг** түләнгән бурыч

опла́чивать *несов. см.* **оплати́ть**

оплева́ть *сов. кого-что* **1.** *разг.* (*покрыть плевками*) төкереп (төкереп пычратып) бетерү **2.** *перен. прост.* (*оскорбить*) хур (мәсхәрә) итү, пычрак ташлау

оплёвывать *несов. см.* **оплева́ть**

оплести́ *сов.* **1.** *что* чорнап (урап) кую, чорнап (уратып) кую; **~ бутылку соло́мой** шешәне салам белән чорнап кую **2.** *перен. кого, прост.* (*опутать, обмануть*) алдау, башны-күзне әйләндерү

оплета́ть *несов. см.* **оплести́**

оплеу́ха *ж прост.* **1.** (*пощёчина*) яңакка чабу, яңакка сугу **2.** *перен.* (*оскорбление*) мәсхәрә, хурлык

оплеши́веть *сов. разг.* пеләшләнү, пеләшләнеп бетү

оплодотворе́ние *с см.* **оплодотвори́ть**

оплодотвори́ть *сов. кого-что* аталандыру; серкәләндерү (*үсемлекләрдә*)

оплодотвори́ться *сов.* аталану; серкәләнү (*үсемлекләр турында*)

оплодотворя́ть *несов. см.* **оплодотвори́ть**

оплодотворя́ться *несов.* **1.** *см.* **оплодотвори́ться**; **2.** *страд. от* **оплодотворя́ть**

опломби́ровать *сов. что* пломбалау, пломбалап алу, пломба салу; **~ склад** складны пломбалап алу

опло́т *м высок.* (*надёжная защита, твердыня, опора*) таяныч, терәк

оплоша́ть *сов. разг.* хата җибәрү, ялгышлык ясау; сизми (абайламый) калу

опло́шность *ж* хата, ялгышлык; **допусти́ть ~** хаталану

оплыва́ть I *несов. см.* **оплы́ть** I

оплыва́ть II *несов. см.* **оплы́ть** II

оплы́ть I *сов. что и без доп.* (*плывя, обогнуть*) йөзеп әйләнеп (урап) чыгу

оплы́||ть II *сов.* **1.** (*ожиреть*) симерү; шешенү, җилсенү **2.** (*о свече*) эреп агу **3.** (*обрушиться от оползня*) юылып ишелеп төшү; **бе́рег ~л** яр юылып ишелеп төшкән

оповести́ть *сов. кого-что* хәбәр итү, белдерү

оповеща́ть *несов. см.* **оповести́ть**

оповеще́ние *с* **1.** *см.* **оповести́ть**; **2.** (*известие*) хәбәр, хәбәр итү

опога́нивать *несов. см.* **опога́нить**

опога́нить *сов. кого-что, разг.* пычрату, шакшылау, шакшылату

опо́ек *м* (*кожа*) бозау тиресе, бозау күне

опозда́ни||е *с* соңгару, соңга калу, кичегү; **яви́ться без ~й** соңга калмый килү; **прийти́ с ~ем** соңгарып килү

опозда́ть *сов.* **1.** кичегү, соңга калу, соңгару, соңлау; **~ на по́езд** поездга кичегеп килү **2.** (*своевременно не выполнить*) кичектерү, соңлату; **~ с отчётом** отчетны соңлату

опознава́ние *с см.* **опозна́ть**

опознава́тельн||ый, -ая, -ое тану ...ы; **~ые зна́ки** тану билгеләре

опознава́ть *несов. см.* **опозна́ть**

опознание *с см.* **опозна́ть**

опозна́ть *сов. кого-что* тану; **~ престу́пника** җинаятьчене тану

опозо́рить *сов. кого-что* хур итү, оятка калдыру, мәсхәрә (рисвай) итү

опозо́риться *сов.* хур булу, хурлыкка (оятка) калу, мәсхәрә (рисвай) булу

опои́ть *сов. кого* **1.** аягына су төшерү; **~ ло́шадь** атның аягына су төшерү (*атка эсселәгән килеш су эчереп*) **2.** *уст.* (*отравить*) эчереп агулау, агу эчертү

опо́й *м* атның аягына су төшү

опо́йков||ый, -ая, -ое бозау тиресеннән эшләнгән, бозау күненнән тегелгән; **~ые сапоги́** бозау күненнән тегелгән итек

опо́ка *ж тех.* опока, металл кою тартмасы

оползать *несов. см.* **ползти́**

о́ползень *м* ишелү, ишелеп төшү, җир шуышу, убылма

ополз||ти́ *сов.* (*осесть, обвалиться*) ишелү, ишелеп төшү, җимерелеп төшү; убылу, шуып төшү; **берега́ ~ли́** ярлар ишелеп төшкән

ополосну́ть *сов. что* чайкап алу, чайкап җибәрү; **~ буты́лку водо́й** шешәне су белән чайкап җибәрү

ополоу́меть *сов. прост.* акылдан шашу, тилерү, юләрләнү

ополча́ться *несов. см.* **ополчи́ться**

ополче́нец *м* ополченец, ополчениедә хезмәт итүче

ополче́ние *с* ополчение; **наро́дное ~** халык ополчениесе

ополчи́ть *сов. кого-что на кого-что, против кого-чего* дошманлаштыру, каршы итү, каршы котырту

ополчи́ться *сов. на кого-что, против кого-чего* каршы чыгу, каршы төшү

опо́мниться *сов.* **1.** аңга (искә) килү, һушка килү; **~ по́сле о́бморока** һуш китүдән соң аңына килү **2.** (*одуматься*) акылга килү, айну; үзеңне кулга алу

опо́р *м*: **во весь ~ [скака́ть, мча́ться, нести́сь]** жан-фәрманга, бөтен көче белән (чабу, йөгерү)

опо́ра *ж* **1.** терәк, таяныч **2.** *перен.* ярдәмче, таяныч; **ста́рший сын — ~ для семьи́** олы ул — гаилә таянычы

опора́жнивать *несов. см.* **опорожни́ть, опоро́жнить**

опора́жниваться *несов.* **1.** *см.* **опорожни́ться, опоро́жниться**; **2.** *страд. от* **опора́жнивать**

опо́рки *мн.* иске аяк киеме, искереп беткән аяк киеме

опо́рн||ый, -ая, -ое терәк ...ы, таяныч ...ы; төп; **~ая ба́лка** төп өрлек; **~ый пункт** терәк пункт

опорожни́ть, опоро́жнить *сов. что* бушату; бушатып кую; **~ буты́лку** шешәне бушату

опорожни́||ться, опоро́жни||ться *сов.* бушау; **бо́чка ~лась** мичкә бушады

опорожня́ть *несов. см.* **опорожни́ть, опоро́жнить**

опорожня́ться *несов.* **1.** *см.* **опорожни́ться, опоро́жниться**; **2.** *страд. от* **опорожня́ть**

опоро́с *м* дуңгыз балалавы

опороситься *сов.* балалау (*дуңгыз турында*)

опоро́чивать *несов. см.* **опоро́чить**

опоро́чить *сов. кого-что* исемен сату, яман атын сату, хур итү

опосре́дствованный, -ая, -ое *книжн.* (*данный через посредство чего-л. другого*) турыдан-туры булмаган, берәр нәрсә аркылы эшләнгән

опостылеть *сов. кому, разг.* биздерү, туйдыру, күңел кайтару, ялыктыру

опохмели́ться *сов. разг.* баш төзәтү

опохмеля́ться *несов. см.* **опохмели́ться**

ОПО-ОПР

опочива́льня *ж уст.* йокы бүлмәсе (*гадәттә, патша сараенда, боярлар йортында*)

опошле́ние *с см.* **опошля́ть, опошли́ться**

опо́шлить *сов.* **1.** *кого-что* (*сделать пошлым, исказить*) әшәкеләндерү, бозып күрсәтү **2.** *что* (*сделать избитым, банальным*) кадерсезләү, кадерен жибәрү, күп чәйнәү

опо́шлиться *сов.* **1.** (*стать пошлым*) әшәкеләнү, оятсызлану, әхлаксызлану **2.** (*стать избитым, банальным*) кадерсезләнү, күп чәйнәлү

опошля́ть *несов. см.* **опо́шлить**

опошля́ться *несов.* **1.** *см.* **опо́шлиться**; **2.** *страд. от* **опошля́ть**

опоэтизи́ровать *сов. кого-что* поэтиклаштыру, шигъриятле итеп күрсәтү

опоя́са||ть *сов.* **1.** *кого-что* билгә тагу, билгә буу **2.** *перен. что* (*окружить собой*) әйләндереп алу, уратып алу; чолгап алу; **река́ ~ла го́род** елга шәһәрне әйләндереп алган

опоя́саться *сов.* билен буу

опоя́сывать *несов. см.* **опоя́сать**

опоя́сываться *несов.* **1.** *см.* **опоя́саться**; **2.** *страд. от* **опоя́сывать**

оппозиционе́р *м* оппозицияче, оппозиционер, оппозиция тарафдары

оппозицио́нн||ый, -ая, -ое оппозиция ...ы, оппозицион; **~ый блок** оппозиция блогы; **~ая па́ртия** оппозицион партия

оппози́ция *ж* **1.** (*противодействие из-за несогласия с чем-л.*) оппозиция, каршы тору, каршылык күрсәтү **2.** (*сопротивление большинству группой лиц*) оппозиция (*берәр партия, оешма һ.б.ш. эчендә күпчелекнең карашларына, сәясәтенә уз карашларын, сәясәтен каршы куючы кешеләр төркеме*); **парла́ментская ~** парламент оппозициясе

оппоне́нт *м* оппонент

оппони́ровать *несов. кому* оппонент булу, каршы чыгып сөйләү (*берәр диспутта, гыйльми бәхәстә*)

оппортуни́зм *м* оппортунизм (*эшчеләр хәрәкәтендә марксизм-ленинизмга дошман юнәлеш*)

оппортуни́ст *м* оппортунист, оппортунизм яклы кеше

оппортунисти́ческ||ий, -ая, -ое оппортунизм ...ы, оппортунистик, оппортунистлар ...ы; **~ое тече́ние** оппортунистик агым

оппортуни́стск||ий, -ая, -ое оппортунистик, оппортунистлар ...ы; **~ая гру́ппа** оппортунистлар төркеме

опра́ва *ж* кыса, рам, тубырча; **~ для очко́в** күзлек кысасы

оправда́ние *с* **1.** *см.* **оправда́ть**; **2.** (*приговор суда*) аклау, гаепсез дип тану; **~ обвиня́емого суде́бным** судның гаепләнүчене аклавы **3.** (*довод*) акланү өчен дәлил, сәбәп, сылтау; **найти́ ~** акланы өчен дәлил табу

оправда́тельный, -ая, -ое аклау ...ы, акланы ...ы, аклый торган, раслый торган; **~ приго́во́р** аклау хөкеме; **~ докуме́нт** раслый торган документ

оправда́ть *сов.* **1.** *кого-что, юр.* аклау, гаепсез дип табу **2.** *что чем* (*признать допустимым*) яклау, дөрес дип табу **3.** *что* аклау, раслау; **~ дове́рие** ышанычны аклау **4.** *что* каплау, кире кайтару; **~ расхо́ды** чыгымнарны каплау **5.** *что чем* (*удостоверить*) раслау, исбат итү; **~ расхо́ды счета́ми и расписками** чыгымнарны счётлар һәм распискалар белән раслау

оправда́||ться *сов.* **1.** (*доказать свою правоту*) аклану, гаепсез булуны исбат итү **2.** (*оказаться правильным*) дөрескә чыгу, дөрес булып чыгу, раслану; **предсказа́ния ~лись** алдан әйткән сүзләр дөрес булып чыкты **3.** каплану, кире кайту; **затра́ты ~лись** тотылган акчалар кире кайтты

опра́вдывать *несов. см.* **оправда́ть**

опра́вдываться *несов.* **1.** *см.* **оправда́ться**; **2.** *страд. от* **опра́вдывать**

опра́вить I *сов. что* (*привести в порядок*) тәртипкә китерү, төзәтү, төзәтеп кую, рәтләү, рәтләп кую, ипләп кую; **~ пла́тье** күлмәкне рәтләү

опра́вить II *сов. что* (*вставить в оправу*) кысалау, рамкага утырту, кысага утырту; тубырчага кую

опра́виться *сов.* **1.** төзәтенү, киемен рәтләү; **~ пе́ред зе́ркалом** көзге алдында төзәтенү **2.** *от чего* сәламәтләнү, савыгу, тазару, сихәтләнү; рәтләнү, аякка басу; **~ от боле́зни** авырудан сәламәтләнү; **~ от после́дствий пожа́ра** янгыннан соң аякка басу **3.** *разг.* (*отправить естественную надобность*) тышка чыгу, бушану

оправля́ть I *несов. см.* **опра́вить** I

оправля́ть II *несов. см.* **опра́вить** II

оправля́ться *несов.* **1.** *см.* **опра́виться**; **2.** *страд. от* **оправля́ть** I

опра́шивать *несов. см.* **опроси́ть**

определе́ние *с* **1.** *см.* **определи́ть** 1-3, 5; **определи́ться** 2; **2.** билгеләмә; **дать нау́чное ~** гыйльми билгеләмә бирү **3.** *юр.* карар, хөкем; **~ суда́** суд карары **4.** *грам.* аергыч

определённость *ж* ачыклык, билгелек, аныклык

определённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **определи́ть**; **2.** билгеле, билгеләнгән; **существу́ет ~ый поря́док** билгеле бер тәртип бар **3.** аныкь, ачык, анлаешлы; **дать ~ый отве́т** ачык җавап бирү **4.** билгеле, билгеле бер, мәгълүм, кайбер; **в ~ых слу́чаях** билгеле бер шартларда **5.** *разг.* һичшиксез, ачыктан-ачык; **э́то ~ый успе́х** бу һичшиксез уңыш

определи́тель *м* **1.** билгеләгеч **2.** (*книга, таблица*) белешмә; **~ расте́ний** үсемлекләр турында белешмә

определи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** *грам.* аергыч ...; **~ое предложе́ние** аергыч җөмлә **2.** билгеләү ...ы, билгеләгеч ...; **~ые фу́нкции** билгеләгеч функцияләр

определи́||ть *сов.* **1.** *что* (*установить*) билгеләү; **~ть обя́занности ка́ждого** һәркемнең вазифасын билгеләү **2.** *что* (*раскрыть содержание*) билгеләмә бирү, аныклау, эчтәлеген ачып бирү, билгеләү; **~ть како́е-либо поня́тие** берәр төшенчәне аныклау **3.** *что* (*назначить*) билгеләү, карар чыгару; **~ть ме́ру наказа́ния** нинди җәза бирүне билгеләү **4.** *что* (*обусловить*) сәбәп булу, тәэмин итү; **хоро́шая подгото́вка ~ла успе́х** яхшы хәзерлек уңышны тәэмин итте **5.** *кого, уст.* (*назначить, устроить*) урнаштыру, (*эшкә, укырга*) кертү; **~ на слу́жбу** хезмәткә урнаштыру

определи́||ться *сов.* **1.** (*стать ясным*) билгеләнү, билгеле булу, аныклану, ачыклану; **це́ли ~лись** максатлар ачыкланды **2.** (*определить своё положение*) үзеннең урынынны (кайда икәнлегенне) билгеләү; **лётчик ~лся при по́мощи прибо́ров** очучы приборлар ярдәмендә узенең кайда икәнлеген билгеләде **3.** *уст.* (*поступить куда-л.*) (*эшкә*) урнашу, (*эшкә*) керү

определя́ть *несов. см.* **определи́ть**

определя́ться *несов.* **1.** *см.* **определи́ться**; **2.** *страд. от* **определя́ть**

опресне́ние *с см.* **опресни́ть**

опресни́тель *м* су төчеләндергеч

опресни́тельный, -ая, -ое суны төчеләндерә торган; **~ аппара́т** суны төчеләндерә торган аппарат

опресни́ть *сов. что* төчеләндерү, тозын аерып алу; **~ морску́ю во́ду** дингез суын төчеләндерү

опресня́ть *несов. см.* **опресни́ть**

оприходовать *сов. что* керемгә язып кую

опри́чник *м ист.* опричник (*опричнинада хезмәт иткән кеше*)

опри́чнина *ж ист.* опричнина (1. *Иван Грозныйның бояр-князьләр оппозициясен тар-мар итү һәм үзәкләштерелгән дәүләтне ныкыту өчен уткәргән гадәттән тыш чаралар системасы* **2.** *шул замандагы махсус гаскәрләр*)

опро́бование *с см.* **опро́бовать**

опро́бовать *сов. что* сынап карау; **~ но́вую маши́ну** яңа машинаны сынап карау

опровергать *несов. см.* **опровергнуть**

опровергнуть** *сов. что* кире кагу, юкка чыгару, дөрес түгеллеген исбат итү

опроверже́ние *с* **1.** *см.* **опровергнуть**; **2.** кире кагу, юкка чыгару (*берәр нәрсәнең дөрес түгеллеген исбат итеп язылган мәкалә, хәбәр*)

опрокидно́й, -а́я, -о́е *тех.* (*могущий опрокидываться*) аударыла торган, түнтәрелә торган, аударма; **~ ку́зов** аударма кузов

опроки́дыватель *м тех.* аударгыч, бушаткыч (*механизм*)

опроки́дывать *несов. см.* **опроки́нуть**

опроки́дываться *несов.* **1.** *см.* **опроки́нуться**; **2.** *страд. от* **опроки́дывать**

опроки́нуть *сов.* **1.** *кого-что* аудару, түнтәрү, йөзтүбән каплау, каплап аударып кую; **~ стол** өстәлне аудару **2.** *перен. кого-что* (*заставить отступить*) чигендерү, чигенергә мәҗбүр итү, куып җибәрү; **~ войска́ проти́вника** дошман гаскәрләрен куып җибәрү **3.** *перен. что* (*опровергнуть, разрушить*) юкка чыгару, жимерү; **~ пла́ны врага́** дошманның планнарын юкка чыгару

опроки́ну||ться *сов.* аву; түнтәрелү, асты өскә таба килү; **теле́га ~лась** арба ауды

опроме́тчивость *ж* дуамаллык, уйламый эшләү

опроме́тчивый, -ая, -ое дуамал, уйламый эшләнгән; **~ посту́пок** уйламый эшләнгән эш

о́прометью *нареч.* бик тиз, бик ашыгыч, жан-фәрманга, бар көченә, атылып; **вы́бежать ~** атылып чыгып китү

опро́с *м см.* **опроси́ть**; **~ свиде́телей** шаһитләрдән сорау алу

опроси́ть *сов. кого-что* сорашу, сорашып чыгу, жавап алу, белемен тикшерү, дәрес сорау

опро́сный, -ая, -ое сорау алу ...ы; **~ лист** сорау алу кәгазе

опрости́ться *сов.* гадиләшү, үзеңне тотуда (*киенүдә һ.б.ш.*) халыкча булу

опростоволо́ситься *сов. разг.* ялгышлык ясау, зур хата эшләү, абайламый калу, махы бирү

опротестова́ть *сов. что* протест белдерү, протест язу, ризасызлык белдерү

опротесто́вывать *несов. см.* **опротестова́ть**

опроти́веть *сов.* биздерү, туйдыру, күнел бизү (кайту), күрәсе килмәү

опрощáться *несов. см.* **опрости́ться**

опрощéни||е *с см.* **опрости́ться**; **про́поведь ~я** гадиләшүгә өндәү

опры́скать *сов. кого-что* сибү, сиптерү, бөркү, сибеп (сиптереп, бөркеп) чыгу

опры́скаться *сов.* үзенә бөркү, сөртү; сөртенү; **~ духа́ми** хушбуй бөркенү

опры́скивание *с см.* **опры́скать, опры́скаться**; **~ дере́вьев** агачларны бөркү

опры́скиватель *м* бөркегеч, сиптергеч; **садо́вый ~** бакча сиптергече

опры́скивать *несов. см.* **опры́скать**

опры́скиваться *несов.* **1.** *см.* **опры́скаться**; **2.** *страд. от* **опры́скивать**

опря́тность *ж* пөхтәлек, җыйнаклык

опря́тный, -ая, -ое пөхтә, җыйнак

о́птик *м* оптика фәне белгече

о́птика *ж* оптика (**1.** *физиканың яктылык күренешләрен һәм үзенчәлекләрен өйрәну бүлеге* **2.** *собир. оптик приборлар һәм инструментлар*)

оптима́льный, -ая, -ое *книжн.* иң уңайлы, иң яраклы, оптималь

оптими́зм *м* оптимизм, оптимистлык (*киләчәккә ышаныч белән карау, тормышка өмет белән карау*)

оптими́ст *м* оптимист

оптимисти́ческ||ий, -ая, -ое, **оптимисти́чн||ый**, -ая, -ое оптимистик, оптимистларча; **~ое отноше́ние к жи́зни** тормышка оптимистларча мөнәсәбәт

оптими́стка *ж* оптимист хатын (кыз)

опти́ческ||ий, -ая, -ое **1.** оптик; оптика ...ы; оптик приборлар ...ы; **~ий прибо́р** оптик прибор **2.** (*световой, зрительный*) оптик; күз ...ы; **~ий обма́н** күз алдавы; **~ий центр ли́нзы** линзаның оптик үзәге; **~ая ось** оптик күчәр

оптови́к *м уст.* эре сәүдәгәр, күмәртәләп сату итүче

опто́в||ый, -ая, -ое күмәртәләп ..., күпләп ..., күмәртәләп алына һәм сатыла торган; **~ая торго́вля** күмәртәләп сату итү

о́птом *нареч.* **1.** (*большими количествами*) күпләп, күмәртәләп **2.** *перен. разг.* (*всё сразу*) берьюлы, тоташ, бердән

опубликова́ние *с см.* **опубликова́ть; ~ прое́кта но́вой Конститу́ции** яңа Конституция проектын бастырып чыгару

опубликова́ть *сов. что* [матбугатта] бастыру, бастырып чыгару

опублико́вывать *несов. см.* **опубликова́ть**

о́пус *м* **1.** *муз.* опус **2.** *шутл.* (*сочинение, труд*) язма, әсәр

опуска́ть *несов. см.* **опусти́ть**

опуска́ться *несов.* **1.** *см.* **опусти́ться**; **2.** *страд. от* **опуска́ть**

опускн||о́й, -а́я, -о́е төшә торган, төшерелә торган; **~ы́е две́ри** төшерелә торган ишекләр

опусте́лый, -ая, -ое буш, бушап калган; ташландык, ташланган; **~ сад** ташландык бакча

опусте́||ть *сов.* бушау, буш (бушап) калу; **у́лицы ~ли** урамнар буш калды

опусти́ть *сов.* **1.** *кого-что* төшерү; **~ ребёнка с рук на́ пол** баланы кулдан идәнгә төшерү; **~ флаг** флагны төшерү **2.** *что* ию, түбән ию, түбән салындыру; **~ го́лову** башны түбән ию **3.** *кого-что во что* аска кую, төшереп кую; батыру; **~ ру́ку в во́ду** кулны суга батыру; **~ гроб в моги́лу** табутны кабергә төшереп кую **4.** *что* салу, тыгу; **~ письмо́ в я́щик** хатны тартмага салу; **~ ру́ку в карма́н** кулны кесәгә тыгу **5.** *что* төшерү, кайтарып кую; **~ воротни́к** яканы төшерү **6.** *что* төшереп калдыру; **при чте́нии ~ три стро́чки** укыганда өч юл төшереп калдыру ♦ **~ ру́ки** өметсезлеккә бирелү, эшсезлеккә бирелү

опусти́ться *сов.* **1.** (*переместиться ниже*) төшү **2.** утыру; **уста́ло ~ на стул** хәлсезләнеп урындыкка утыру **3.** (*наклониться*) иелү, түбән иелү **4.** *перен.* (*пасть, стать неряшливым*) түбәнгә төшү; кыяфәтен югалту, кеше кыяфәтен югалтмау, кеше карарлык жире калмау ♦ **~ на коле́ни** тезләнү

опустоша́ть *несов. см.* **опустоши́ть**

опустоше́ние *с см.* **опустоши́ть**

опустоше́нный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **опустоши́ть**; **2.** рухы төшкән, рухсыз; **~ челове́к** рухсыз кеше

опустоши́тельн||ый, -ая, -ое һәлакәтле, жимергеч, бөлдергеч; **~ые во́йны** һәлакәтле сугышлар

опустоши́||ть *сов.* **1.** *что* һәлак итү, кыру, корыту, харап итү, бөлдерү, бөлгенлеккә төшерү; **саранча́ ~ла поля́** саранча басуларны һәлак итте **2.** *перен. кого-что* рухын төшерү (сүндерү)

опу́тать *сов. кого-что* **1.** урау, чорнау, урап (чорнап) алу; **~ колю́чей про́волокой** чәнечкеле тимерчыбык белән урап алу **2.** *перен.* буйсындыру; башын-күзен әйләндерү; **~ свои́ми ча́рами** сөйкемлелеге белән башын-күзен әйләндерү **3.** *перен. прост.* (*надуть, обмануть*) алдалау, утырту

опу́тывать *несов. см.* **опу́тать**

опуха́ть *несов. см.* **опу́хнуть**

опу́хнуть *сов.* шешү, шешенү, кабару, кабарып чыгу

о́пухоль *ж* шеш; кабарчык; **злока́чественная ~** яман шеш

опуша́ть *несов. см.* **опуши́ть**

опуши́||ть *что* **1.** (*обшить мехом*) кырпу тоту, кырпу тотып чыгу **2.** бәсләнү, бәсәрү; [бәс] каплау, карлану, кар утыру; **усы́ и бо́роду ~ло сне́гом** *безл.* сакал-мыек карланган; **и́ней ~л дере́вья** агачларны бәс каплаган

опу́шка I *ж* (*меховая обшивка*) кырпу

опу́шка II *ж* (*край леса*) урман буе, урман авызы (кырые, чите)

опуще́ние *с мед.* төшү; **~ пе́чени** бавыр төшү

опыле́ние *с* **1.** *бот.* серкәләнү, серкәләндерү **2.** *см.* **опыли́ть**

опыли́тель *м* (*прибор, машина*) тузанлагыч, сиптергеч

опыли́тель *м* серкәләгеч, серкәләүче (*умарта корты, бөҗәк, җил, су турында*)

опыли́ть *сов. что* **1.** (*произвести опыление*) серкәләндерү, серкәләү **2.** (*покрыть растения особым составом*) сибү, сиптерү

опыли́ться *сов.* серкәләнү, серкәгә утыру

опыля́ть *несов. см.* **опыли́ть**

опыля́ться *несов.* **1.** *см.* **опыли́ться**; **2.** *страд. от* **опыля́ть**

о́пыт *м в разн. знач.* тәжрибә; сынау; **жи́зненный ~** тормыш тәжрибәсе; **обме́н ~ом** тәжрибә уртаклашу; **чу́вственный ~** *филос.* сизеп беленә торган тәжрибә; **хими́ческие ~ы** химик тәжрибәләр; **провести́ ~** тәжрибә ясау; **пе́рвый ~ молодо́го писа́теля** яшь язучының беренче тәжрибәсе

о́пытник *м* тәжрибәче

о́пытность *ж* тәжрибәлелек

о́пытн||ый, -ая, -ое **1.** тәжрибә ...ы; **~ая ста́нция** тәжрибә станциясе **2.** тәжрибәле; **~ый врач** тәжрибәле табиб

опьяне́ни||е *с прям., перен.* исерек, исереклек; **в состоя́нии си́льного ~я** дөм исерек хәлдә; **любо́вное ~е** мәхәббәт исереклеге

опьяне́ть *сов. прям., перен.* исерү; **~ от любви́** мәхәббәттән исерү

опьяни́ть *сов. прям., перен. кого-что* исертү

опьяня́ть *несов. см.* **опьяни́ть**

опя́ть *нареч.* тагын, тагы да, янә, кабат ♦ **~-таки́** шуның өстәвенә, тагы да

ора́ва *ж прост.* бер көтү, бер өер, бер төркем; **~ ребя́т** бер көтү бала-чага

ора́кул *м* **1.** оракул (*алла исеменнән киләчәк турында хәбәр биреп утыручы жрец — борынгы Грециядә һәм Римда*) **2.** *перен. книжн.* күрәзә, алдан әйтеп бирүче, оракул

орангута́н[г] *м* орангутан[г]

ора́нжевый, -ая, -ое кызгылт сары, әфлисун төсле

оранжере́йн||ый, -ая, -ое оранжерея ...ы; оранжереяда үстерелгән; **~ые цветы́** оранжереяда үстерелгән чәчәкләр

оранжере́я *ж* оранжерея

ора́тор *м* оратор, оста сөйләүче

ората́рия *ж* оратория (*зур музыкаль-драматик әсәр*)

ора́торск||ий, -ая, -ое оратор[лык] ...ы, ораторлык ..., ораторларча ...; **~ое иску́сство** ораторлык сәләте

ора́торствовать *несов. разг.* ораторлык итү, ораторларча кылану, оста сөйләргә маташу

ора́ть *несов.* кычкыру, акыру, бакыру; кычкырыну, жикерү; акырып җырлау

орби́та *ж* **1.** *астр.* орбита; **~ Земли́** Жир орбитасы; **круговая́ ~** түгәрәк орбита **2.** *перен. чего, какая, книжн.* даирә; **~ влия́ния** йогынты даирәсе **3.** (*глазница*) күз чокыры

орбита́льн||ый, -ая, -ое орбиталь; **~ая нау́чная ста́нция** орбиталь фәнни станция

орг= *кайбер кушма сүзләрнең «оештыру», «оешкан», «оешкан рәвештә» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **оргбюро́** оештыру бюросы; **оргкомите́т** оештыру комитеты; **оргнабо́р** оешкан рәвештә эшче көче җыйнау; **орграбо́та** оештыру эше

о́рган *м* **1.** әгъза, о́рган; **~ зре́ния** күрү органы; **~ слу́ха** ишетү органы; **вну́тренние ~ы** эчке әгъзалар **2.** *перен.чего* (*орудие, средство*) корал, чара, орган **3.** (*учреждение, организация*) орган; **партийные ~ы** партия органнары

орга́н *м муз.* орга́н

организа́тор *м* оештыручы

организа́торский, -ая, -ое оештыру ...ы; оештыручанлык ...ы; **~ тала́нт** оештыру таланты

организацио́нн||ый, -ая, -ое оештыру ...ы; **~ые вопро́сы** оештыру мәсьәләләре

организа́ция *ж* **1.** *см.* **организова́ть, организова́ться; нау́чная ~ труда́** хезмәтне фәнни оештыру **2.** (*внутренняя дисциплина*) оешканлык **3.** оешма; **парти́йная ~** партия оешмасы

организ́м *м* **1.** (*живое целое*) организм, тереклек иясе; **живы́е ~ы** тере организмнар **2.** (*совокупность свойств человека*) организм; **кре́пкий ~** нык организм **3.** (*сложное единство*) организм

организо́ванность *ж* оешканлык, оештырылганлык, тәртиплелек, оешкан булу

организо́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **организова́ть**; **2.** (*сплочённый*) оештырылган, оешкан; **~ый коллекти́в** оешкан коллектив **3.** (*планомерный*) оештырып алып барылган, бердәм, тәртипкә салынган; **~ая борьба́** оештырып алып барылган көрәш **4.** (*дисциплинированный*) тәртип белән эш итә торган, дисциплиналы; **~ый челове́к** тәртип белән эш итә торган кеше

организова́ть *сов., несов.* **1.** *что* оештыру; **~ но́вое министе́рство** яңа министрлык оештыру **2.** *что* (*подготовить, наладить*) оештыру, юлга салу; **~ доста́вку** *чего-л.* **на́ дом** *нинди дә булса нәрсәне* өйгә китереп тапшыруны оештыру **3.** *кого-что* оештыру, берләштерү, туплау; **~ молодёжь** яшьләрне оештыру **4.** *что* (*упорядочить*) тәртипкә (рәткә) салу, оештыру; **пра́вильно ~ свой рабо́чий день** эш көнеңне дөрес оештыру

организова́ться **1.** *сов. несов.* (*возникнуть, создаться*) оешу; оештырылу, барлыкка килү **2.** *сов. несов.* (*объединиться*) берләшү, оешу **3.** *несов. страд. от* **организова́ть**

организо́вывать *несов. см.* **организова́ть**

организо́вываться *несов.* **1.** *см.* **организова́ться**; **2.** *страд. от* **организо́вывать**

органи́ст *м* орга́нчы, орга́нда уйнаучы

органи́ческ||ий I, -ая, -ое органик, терек; **~ая приро́да** терек табигать; **~ие соедине́ния** органик кушылмалар; **~ие удобре́ния** органик ашламалар (*мәс. тирес, торф, кош тизәге һ.б.ш.*) ♦ **~ая хи́мия** органик химия

органи́ческ||ий II, -ая, -ое **1.** орган ...ы, әгъза ...ы; органга караган, органик; **~ий поро́к се́рдца** органик йөрәк авыруы **2.** (*внутренний, коренной*) эчке, табигый; **~ая потре́бность** эчке ихтыяж; **~ая связь** табигый бәйләнеш; **~ий недоста́ток** табигый кимчелек

органи́чн||ый, -ая, -ое табигый, табигатенә хас булган; **тя́га к культу́ре у люде́й ~а** мәдәниятка омтылу кешенең табигатенә хас

орга́нн||ый, -ая, -ое орга́н ...ы; **~ая му́зыка** орган музыкасы

о́ргия *ж* котырынкы эчү мәҗлесе, оргия

орда́ *ж* **1.** урда (*борынгы төрки халыкларда дәүләт берләшмәсе*) **2.** *перен.* өер; илбасарлар [өере] **разгро́м фаши́стских орд** фашист илбасарларын тар-мар итү

о́рден *м* **1.** (*мн. ~á*) орден; **~ Дру́жбы наро́дов** Халыкара дуслыгы ордены **2.** (*мн. ~ы*) орден; **~ иезуи́тов** иезуитлар ордены

орденоно́сец *м* орденлы, орден алган, орден белән бүләкләнгән (*кеше яки оешма*)

орденоно́сный, -ая, -ое орденлы; **~ заво́д** орденлы завод

о́рденск||ий, -ая, -ое орден ...ы; **~ая ле́нта** орден тасмасы

о́рдер *м* ордер; **~ на кварти́ру** квартирга ордер

ордина́рец *м воен.* ординарец

ордина́рный, -ая, -ое (*обыкновенный*) гадәти, гадәттә була торган; **~ челове́к** гадәти кеше

ордина́тор *м* (*лечащий врач*) ординатор

ординату́ра *ж* **1.** ординатор вазифасы **2.** ординатура (*практик медицина аспирантурасының бер төре*)

орёл *м* **1.** бөркет, каракош **2.** *перен.* бөркет, батадир; кыю егет ♦ **~ и́ли ре́шка?** ≈ иләкме, күнме?

орео́л *м* **1.** (*световая кайма*) нурлы божра, ореол, яктылык каймасы **2.** *перен.* хөрмәт, дан; **~ геро́я** каһарман даны

оре́х *м* **1.** чикләвек; **гре́цкий ~** әстерхан чикләвеге **2.** (*дерево*) чикләвек агачы; **шкаф из ~а** чикләвек агачыннан ясалган шкаф ♦ **под ~ разде́лать (отде́лать)** *кого* бик нык тиргәү, арт сабагын укыту

оре́хов||ый, -ая, -ое **1.** чикләвек ...ы; чикләвекле; **~ое де́рево** чикләвек агачы; **~ый торт** чикләвекле торт **2.** чикләвек агачыннан ясалган; **~ый стол** чикләвек агачыннан ясалган өстәл

оре́шек *м уменьш. от* **оре́х** I ♦ **твёрдый (тру́дный, кре́пкий) ~** 1) үзсүзле кеше; 2) авыр мәсьәлә

оре́шник *м* чикләвек куагы; чикләвеклек

оригина́л *м* **1.** төп нөсхә, оригинал; **~ статьи́** мәкаләнең төп нөсхәсе **2.** *разг.* (*своеобразный человек*) сәер кеше, гажәп (әкәмәт) кеше

оригина́льничать *несов. разг.* үзенчә кылану, башкаларга охшамаска тырышу

оригина́льность *ж* **1.** (*подлинность*) оригинальлек, күчереп алынмаган **2.** (*самобытность*) үзенә бертөрле булу, оригиналь булу **3.** (*своеобразие*) үзенчәлелек, башка бер төрле булу

оригина́льный, -ая, -ое **1.** (*подлинный*) күчереп алынмаган; төп, оригиналь **2.** үзенчәлекле, мөстәкыйль рәвештә башкарылган; **~ мысли́тель** үзенчәлекле фикер иясе **3.** (*своеобразный*) үзенә хас, башкаларга охшамаган, оригиналь

ориенталис́т *м* көнчыгыш белгече, ориенталист

ориенталис́тика *ж* көнчыгыш белеме, ориенталистика

ориента́льный, -ая, -ое көнчыгыш ...ы, көнчыгыш илләренә хас, ориенталь; **~ стиль** көнчыгыш стиле

ориента́ция *ж* **1.** (*определение местонахождения*) үзеңнең торган урыныңны (кайда икәнлегеңне) билгеләү, ориентация **2.** (*умение разобраться*) белү, аңлау **3.** *на кого-что* (*направленность деятельности*) исәп тоту, күздә тотып эш итү

ориенти́р *м* ориентир; **вы́брать пра́вильный ~** дөрес ориентир сайлау

ориенти́рование *с см.* **ориенти́ровать, ориенти́роваться** 1, 2; **~ на ме́стности** торган урыныңны билгеләү

ориенти́ровать *сов., несов. кого-что* **1.** юнәлдерү, юнәлеш бирү; ориентацияләү; **~ косми́ческий кора́бль** космик корабльне юнәлдерү **2.** *на что, в чём* төшендерү, юнәлеш бирү, аңлату; **~** *кого-л.* **в вопро́сах поли́тики** *кемгә дә булса* сәяси мәсьәләләрне аңлату

ориенти́роваться 1. *сов., несов.* юл таба алу, ориентлашу, ориентация алу; ~ **в темноте́** караңгыда юл таба алу 2. *сов., несов. прям., перен. на кого-что* юнәлеш тоту, юнәлеш алу, күздә тоту; ~ **на мая́к** маякка юнәлеш алу; ~ **на ма́ссового чита́теля** киң катлам укучыны күздә тоту 3. *несов. страд. от* **ориенти́ровать** 1

ориентиро́вка *ж см.* **ориенти́ровать, ориенти́роваться** 1, 2; ~ **в лесу́** урманда юлны жиңел таба белү

ориентиро́вочный, -ая, -ое 1. танышу өчен; ~ **полёт** танышу өчен очу 2. якынча ..., чама белән билгеләнгән; ~ **план** якынча план

оркéстр *м* 1. оркестр; **симфони́ческий** ~ симфоник оркестр; **духово́й** ~ тынлы оркестр 2. (*место для музыкантов*) музыкантлар урыны (*сәхнә алдындагы*)

оркестра́нт *м* оркестрда уйнаучы

оркестра́нтка *ж* оркестрда уйнаучы хатын (кыз)

оркестрова́ть *сов., несов. что, муз.* оркестрга салу

оркестро́вка *ж см.* **оркестрова́ть**

оркестро́в||ый, -ая, -ое оркестр ...ы, оркестр өчен язылган; ~**ая му́зыка** оркестр өчен язылган музыка

орла́н *м зоол.* диңгез бөркете

орлёнок *м* яшь бөркет, каракош баласы

орли́н||ый, -ая, -ое 1. бөркет ...ы; ~**ое гнездо́** бөркет оясы 2. *перен.* кыю гайрәтле, батыр; ~**ый взор** кыю караш ♦ ~**ый нос** кәкре борын

орли́ца *ж* ана бөркет, ана каракош

орна́мент *м* орнамент

орнамента́льн||ый, -ая, -ое 1. орнамент ...ы, орнаментлау ...ы, орнамент ясау ...ы; ~**ые рабо́ты** орнаментлау эшләре 2. *иск., лит.* орнаментлы, орнаментка бай, артык бизәкле; ~**ый стиль** орнаментлы стиль

орнаменти́ровать *сов., несов. что* орнаментлау, орнамент белән бизәкләү, бизәк төшерү; ~ **сте́ны** стеналарга бизәк төшерү

орнаментиро́вка *ж см.* **орнаменти́ровать**

орнито́лог *м* орнитология белгече, орнитолог

орнитологи́ческ||ий, -ая, -ое орнитологик, орнитология ...ы; ~**ие иссле́дования** орнитологик тикшеренүләр

орнитоло́гия *ж* орнитология (*зоологиянең кошларны өйрәнә торган бүлеге*)

оробе́лый, -ая, -ое курыккан, каушаган, шүрләгән

оробе́ть *сов.* куркып (каушап) китү, каушап калу, шүрләү

орогове́ть *сов.* мөгезләнү, мөгез матдә белән капланү

орографи́ческ||ий, -ая, -ое орографик, орография ...ы; ~**ая ка́рта** орографик карта

орогра́фия *ж* орография (*физик географиянең җир өсте рельефын, тауларны өйрәнә торган бүлеге*)

ороси́тельн||ый, -ая, -ое сугару ...ы; ~**ый кана́л** сугару каналы; ~**ая систе́ма** сугару системасы

ороси́||ть *сов. что* 1. дымландыру, юешләндерү; **дождь** ~**л зе́млю** яңгыр җирне дымландырды 2. сугару; ~**ть поля́** басуларны сугару

ороси́ться *сов.* (*пропитаться влагой*) юешләну, дымлану

ороша́ть *несов. см.* **ороси́ть**

ороша́ться *несов.* 1. *см.* **ороси́ться**; 2. *страд. от* **ороша́ть**

орошéние *с см.* **ороси́ть; иску́сственное** ~ ясалма сугару

ортодо́кс *м книж.* ортодокс, ортодоксаль карашлы кеше

ортодоксáльность *ж книжн.* ортодоксальлек

ортодоксáльн||ый, -ая, -ое *книжн.* ортодоксаль, эзлекле; ~**ые взгля́ды** ортодоксаль карашлар

ортодо́ксия *ж книжн.* (*приверженность к чему-л.*) ортодоксия (*берәр нәрсәгә нык ышанганлык, берәр нәрсәгә ортодоксаль бирелгәнлек*)

ортопéд *м* ортопедия белгече, ортопед

ортопеди́ческ||ий, -ая, -ое ортопедия ...ы, ортопедик; ~**ая о́бувь** ортопедик аяк киеме

ортопéдия *ж* ортопедия (*хирургиянең умырткалык һәм кул-аякларның кәкрәюен дәвалау белән шөгыльләнә торган бүлеге*)

оруди||е *с* 1. корал; ~**е труда́** хезмәт коралы; **прицепны́е** ~**я** тагылма кораллар 2. *перен.* чара; **язы́к** — ~**е общéния людéй** тел — кешеләрнең аралашу чарасы 3. туп, орудие; **дальнобóйное** ~**е** ераккa ата торган орудие

оруди́йный, -ая, -ое орудие[ләр] ...ы, туп ...ы; орудиеләрдән ..., туплардан ...; ~ **расчёт** орудие расчёты; **откры́ть** ~ **огóнь** орудиеләрдән ут ачу

оруёвать *несов. разг.* 1. *чем* эшләү, эш итү; **ло́вко** ~ **топоро́м** балта белән оста эш итү 2. (*распоряжаться, действовать*) эш алып бару, эш йөртү

оружéйник *м* мылтык остасы, корал остасы

оружéйный, -ая, -ое корал ...ы; ~ **заво́д** корал заводы ♦ **Оружéйная пала́та** Кораллар палатасы (*Мәскәү Кремлендәге борынгы музей*)

оруженóсец *м ист.* корал йөртүче (*урта гасырда*)

ору́жие *с прям., перен.* корал, сугыш коралы; **холо́дное** ~ салкын корал (*кылыч, хәнҗәр, пычак һ.б.ш.*); **стрелко́вое** ~ ату коралы (*мылтык, револьвер һ.б.ш.*); **печа́ть — могу́чее** ~ матбугат — бик көчле корал

орфографи́ческ||ий, -ая, -ое орфография ...ы, орфографик; ~**ий слова́рь** орфографик сүзлек; ~**ая оши́бка** орфографик хата

орфогра́фия *ж* орфография, дөрес язу кагыйдәләре

орфоэпи́ческ||ий, -ая, -ое орфоэпия ...ы, орфоэпик; ~**ие но́рмы** орфоэпик нормалар

орфоэ́пия *ж* орфоэпия, [сүзләрне] дөрес әйтү кагыйдәләре

орхиде́я *ж бот.* күке яше

оса́ *ж* шөпшә, сагызак

оса́да *ж* камау, чолгау, камап (чолгап) алу; камалыш, чолганыш

осади́ть I *сов.* 1. *что* (*подвергнуть осаде*) камау, чолгау, камап (чолгап) алу 2. *перен. кого чем, разг.* (*обременить просьбами*) теңкәгә тию, йөдәтү, йөдәтеп бетерү

осади́ть II *сов. что* (*заставить осесть*) тондыру, төпкә утырту; ~ **муть** болганчыклыкны тондыру

осади́ть III *сов.* 1. *кого-что* (*остановить*) кинәт туктату; чигендерү, артка чигендерү; ~ **ло́шадь** атны чигендерү 2. *перен. кого разг.* (*дать отпор кому-л.*) отпор бирү, башына сугу; ~ **наха́ла** оятсыз кешегә отпор бирү

оса́дка *ж* 1. (*постепенное оседание*) утыру; ~ **зда́ния** бинаның утыруы 2. *мор.* (*глубина погружения судна*) суднoның батып торуы (*суда утыру тирәнлеге*)

оса́дки *только мн.* явымнар, явым-төшем

оса́док *м* 1. утырма, утырым, юшкын 2. *перен.* (*тяжёлое чувство*) авыр тәэсир, начар тәэсир

оса́дочн||ый, -ая, -ое 1. утырма ...ы; ~**ые го́рные поро́ды** утырма тау токымнары 2. явым-төшем ...; ~**ые явле́ния** явым-төшем күренешләре

осаждáть I *несов. см.* **осади́ть** I

осаждáть II *несов. см.* **осади́ть** II

осаждáться *несов.* 1. (*выделяться из жидкости*) төпкә утыру, тону 2. (*падать на землю*) яву, жиргә төшү (*яңгыр, кар һ.б.ш. турында*) 3. *страд. от* **осаждáть** II

осаждéние *с см.* **осади́ть** II, **осаждáться** 1, 2

оса́живать *несов. см.* **осади́ть** III

оса́нистость *ж* мәһабәтлек, мәһабәт кыяфәтлелек

оса́нистый, -ая, -ое мәһабәт, мәһабәт кыяфәтле

оса́нка *ж* (*внешность*) кыяфәт, сын-гәүдә; **краси́вая** ~ матур сын-гәүдә

осатанéлый, -ая, -ое *разг.* котырынган, саташкан, явыз; ~ **враг** котырынган дошман

осатанéть *сов. разг.* котырыну, саташып китү, явызлану, ерткычлану

осва́иваться *несов.* 1. *см.* **освои́ться**; 2. *страд. от* **осва́ивать**

осведоми́тель *м* белдереп торучы, хәбәр итеп торучы

осведоми́тельн||ый, -ая, -ое (*содержащий сообщения о чём-л.*) белдерү ...ы, таныштыру ...ы; ~**ая рабóта** таныштыру эше

освéдомить *сов. кого-что* белдерү, хәбәр итү, таныштыру

освéдомиться *сов.* сорашу, белешү, сорашып белү

осведомлéние *с см.* **освéдомить, освéдомиться**

осведомлённость *ж* хәбәрдар булу, хәбәрдарлык

осведомлённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **осве́домить 2.** белә торган, хәбәрдар, таныш; **хорошо́ ~ челове́к** яхшы хәбәрдар кеше

осведомля́ть *несов. см.* **осве́домить**

осведомля́ться *несов.* **1.** *см.* **осве́домиться**; **2.** *страд. от* **осведомля́ть**

освежа́ть *несов. см.* **освежи́ть**

освежа́ться *несов.* **1.** *см.* **освежи́ться**; **2.** *страд. от* **освежа́ть**

освежева́ть *сов. что* тиресен тунау

освежи́||ть *сов.* **1.** *что* (*сделать свежим*) сафландыру, чистарту; яңарту; (*воздух*) җилләтү, алмаштыру **2.** *кого-что* көч кертү, көч бирү; яшәртеп җибәрү; **о́тдых ~л меня́** ял мине яшәртеп җибәрде **3.** *что* яңарту, искә төшерү, хәтергә төшерү; **~ть свои́ зна́ния** [үзеннең] белемнәреңне яңарту

освежи́||ться *сов.* **1.** (*стать свежим*) сафлану, чистару **2.** (*восстановиться в памяти*) искә төшү, яңару **3.** (*восстановить свои силы*) яшәреп китү; көч алу

осветри́тель *м театр.* яктыртучы, сәхнә яктыртучы

осветри́тельн||ый, -ая, -ое яктырта торган, яктырту ...ы, яктылык бирү ...ы; **~ые прибо́ры** яктырту приборлары; **~ая сеть** яктылык бирү челтәре

осве́тить *сов.* **1.** *кого-что* яктырту; **~ у́лицы электри́чеством** урамнарны электр белән яктырту **2.** *перен. что* (*объяснить, изложить*) яктырту; аңлатып бирү; сөйләп бирү

осве́титься *сов.* (*стать светлым*) яктыру, балку, яктырып (балкып) китү

освеща́ть *несов. см.* **осве́тить**

освеща́ться *несов.* **1.** *см.* **осве́титься**; **2.** *страд. от* **освеща́ть**

освеще́ние *с* **1.** *см.* **осве́тить**; **~ зда́ний** биналарны яктырту **2.** (*свет*) яктылык, яктыртылу; **иску́сственное ~** ясалма яктылык; **вече́рнее ~ ко́мнаты** бүлмәнең кичке яктыртылуы **3.** *перен.* яктырту; **но́вое ~ собы́тий** вакыйгаларны яңача яктырту

освещённость *ж физ.* яктыртылу, яктылык, яктылык дәрәҗәсе, яктыртылганлык

освиде́тельствование *с см.* **освиде́тельствовать**

освиде́тельствовать *сов. кого-что* карау, карап чыгу, тикшереп чыгу; **~ больно́го** авыруны карап чыгу

освиста́ть *сов. кого-что* сызгырып мәсхәрә итү, сызгырып куу

осви́стывать *несов. см.* **освиста́ть**

освободи́тель *м* азат итүче, коткаручы, ирекkә чыгаручы

освободи́тельн||ый, -ая, -ое азатлык ...ы, ирек ...ы; азат итә торган, азатлык китерә торган, азатлык өчен алып барылган; **~ое движе́ние** азатлык хәрәкәте

освободи́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*сделать свободным*) азат итү, ирекkә чыгару, коткарып коткару **2.** *что* (*вернуть обратно*) азат итү, кире сугышып алу; **~ го́род** шәһәрне азат итү **3.** *кого-что* (*избавить*) азат итү, коткару; **~ от дежу́рства** дежурлыктан азат итү **4.** *кого-что* (*уволить*) азат итү, (*эштән*) чыгару, алу, бушату; **~ от занима́емой до́лжности** хезмәт урыныннан чыгару **5.** *что* бушату; **~ кни́жный шкаф** китап шкафын бушату; **~ ко́мнату** бүлмәне бушату

освободи́ться *сов.* **1.** (*получить свободу*) азат булу, ирекkә чыгу, коткынлыктан (коллыктан) котылу **2.** (*избавиться от чего-л. вредного, нежелательного*) бушау, арыну, котылу **3.** (*избавиться от дел*) котылу, азат булу; **~ от заве́дования** житәкчелек эшеннән котылу **4.** (*стать пустым; стать свободным*) бушау, арыну

освобожда́ть *несов. см.* **освободи́ть**

освобожда́ться *несов.* **1.** *см.* **освободи́ться**; **2.** *страд. от* **освобожда́ть**

освобожде́ние *с см.* **освободи́ть, освободи́ться; борьба́ за ~** азат итү өчен көрәшү

освое́ние *с см.* **осво́ить**; **~ цели́нных земе́ль** чирәм җирләрне үзләштерү

осво́ить *сов. что* үзләштерү; **~ но́вое произво́дство** яңа производствоны үзләштерү

осво́иться *сов.* (*привыкнуть*) күнегү, ияләшү, үзләшү

освяти́ть *сов. что, церк.* изгеләндерү

освяща́ть *несов. см.* **освяти́ть**

освяще́ние *с см.* **освяти́ть**

оседа́ть *несов. см.* **осе́сть**

оседла́ть *сов.* **1.** *кого* иярләү; **~ коне́й** атларны иярләү **2.** *перен. кого-что, разг.* атланып утыру; **~ стул** урындыкка атланып утыру **3.** *перен. кого-что, разг.* (*подчинить себе*) муенына атланып алу, буйсындыру

осе́длость *ж* утраклык, бер урында яшәү

осёдлывать *несов. см.* **оседла́ть**

осе́дл||ый, -ая, -ое утрак, даими бер җирдә яши торган; **~ые племена́** утрак кабиләләр; **~ая жизнь** утрак тормыш

осека́ться *несов. см.* **осе́чься**

осёл *м* ишәк

осело́к *м* **1.** (*точильный камень*) кайрак, беләү **2.** *спец.* (*кыйммәтле металларны*) сынау ташы

осемене́ние *с см.* **осемени́ть; иску́сственное ~ живо́тных** хайваннарны ясалма рәвештә аталандыру

осемени́ть *сов. кого-что, биол., с.-х.* ясалма орлыкландыру (аталандыру) (*хайваннарны*)

осеменя́ть *несов. см.* **осемени́ть**

осени́||ть *сов. кого* кинәт башка килү, кинәт искә төшү; **меня́ ~ла блестя́щая иде́я** башка кинәт бик яхшы фикер килде

осе́нний, -яя, -ее көзге

о́сень *ж* көз

о́сенью *нареч.* көз көне, көзен, көзлектә

осеня́ть *несов. см.* **осени́ть**

осе́||сть *сов.* **1.** басылу, инү; **фунда́мент ~л** фундамент ингән; **земля́ ~ла** җир басылган **2.** утыру; **на дно стака́на ~ла соль** стаканның төбенә тоз утырган **3.** урнашу, утырып калу, торырга калу; **~сть на Се́вере** Төньякта торырга калу

осети́н *м* осетин

осети́ны осетиннар, осетин халкы

осети́нка *ж* осетин хатыны (кызы)

осети́нский, -ая, -ое осетин[нар] ...ы; **~ язы́к** осетин теле

осётр *м* осётр, мәрсин балыгы

осетри́на *ж* мәрсин балыгы ите, осётр балыгы ите

осетро́в||ый, -ая, -ое **1.** мәрсин балыгы ...ы, осётр ...ы; **~ая икра́** осётр уылдыгы **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. зоол.* осётрчалар

осе́чк||а *ж* **1.** атылмый калу, осечка: **ружьё дало́ ~у** мылтык атылмый калды **2.** *перен. разг.* (*неудача*) уңышсызлыкка очрау, эш барып чыкмау

осе́чься *сов.* **1.** (*запнуться*) тотлыгып калу, сүзендә тукталып калу **2.** *разг.* (*потерпеть неудачу*) абыну, уңышсызлыкка очрау

оси́ливать *несов. см.* **оси́лить**

оси́лить *сов.* **1.** *кого-что* җиңү, җиңеп чыгу, өстен чыгу; **врагу́ нас не ~** дошман безне җиңеп чыга алмаячак **2.** *что, разг.* ерып чыгу; **~ матема́тику** математиканы ерып чыгу

оси́на *ж* усак

оси́нник *м* усаклык, усак урманы

оси́новый, -ая, -ое усак ...ы; **~ лист** усак яфрагы

оси́н||ый, -ая, -ое шөпшә ...ы; **~ое гнездо́** 1) шөпшә оясы; 2) *перен.* бозыклыклар оясы

оси́плый, -ая, -ое карлыккан; **~ го́лос** карлыккан тавыш

оси́пнуть *сов.* карлыгу, карлыгып бетү

осироте́лый, -ая, -ое **1.** ятим, ятим калган, үксез **2.** *перен.* иясез (буш) калган, ташланган; **~ дом** буш калган йорт

осироте́||ть *сов.* **1.** ятим калу **2.** *перен.* буш калу; яме китү; **дом ~л без хозя́ина** хуҗасыз йортның яме китте

оска́л *м* ыржайган авыз

оска́ливать *несов. см.* **оска́лить**

оска́лить *сов. что*: **~ зу́бы** тешләрне ыржайту

оска́литься *сов.* тешләрне ыржайту

оскальпи́ровать *сов. кого-что* баш тиресен тунап алу

оскандали́ться *сов.* хур булу, оятка (көлкегә) калу

осквернение *с см.* **осквернить**

осквернитель *м* мәсхәрә итүче, шакшылаучы, нәҗесләүче

осквернить *сов. кого-что* мәсхәрә итү, кара ягу, нәҗесләү

осквернять *несов. см.* **осквернить**

оскла́бить *сов. что*: **~ лицо́** (**рот**) *прост.* авыз ерып көлү

оскла́биться *сов. прост.* (*широко улыбнуться*) авыз ерып көлү

оско́лок *м* кыйпылчык, китек, ватык, ярчык; **ми́нный ~** мина ярчыгы

оско́лочн||ый, -ая, -ое **1.** ярчык ...ы; **~ое ране́ние** ярчык ярасы **2.** ярчыклы; **~ая бо́мба** ярчыклы бомба

оско́мин||а *ж*: **набить ~у** 1) теш каманы, теш камаштыру; 2) *перен.* тәнкәгә тию, туйдырып [йөдәтеп] бетерү

оскопи́ть *сов. кого* печү

оскопля́ть *несов. см.* **оскопи́ть**

оскорби́тельный, -ая, -ое хурлыклы, мыскыллы, мәсхәрәле, намуска тия торган

оскорби́ть *сов. кого-что* хурлау, мыскыллау, мыскыл итү, мәсхәрә итү, намусына тию ♦ **~ де́йствием** кыйнау, яһаклау

оскорби́ться *сов.* хурлану, гарьләнү, рәнҗү, рәнҗетелү

оскорбле́ни||е *с* **1.** *см.* **оскорби́ть**; **2.** хурлау, мыскыллау, рәнҗетү; **осы́пать ~ями** хурлап ташлау

оскорбля́ть *несов. см.* **оскорби́ть**

оскорбля́ться *несов.* **1.** *см.* **оскорби́ться**; **2.** *страд. от* **оскорбля́ть**

оскудева́ть *несов. см.* **оскуде́ть**

оскуде́ть *сов.* ярлылану, фәкыйрьләнү

ослабева́ть *несов. см.* **ослабе́ть**

ослабе́лый, -ая, -ое көчсезләнгән, хәлсезләнгән

ослабе́||ть *сов.* **1.** көчсезләнү, хәлсезләнү, зәгыйфьләнү; гажизләнү, мәлҗерәү; **больно́й ~л** авыру хәлсезләнде; **па́мять ~ла** хәтер зәгыйфьләнде **2.** басылу, йомшару, кимү, басыла (йомшара, кими) төшү; **ве́тер ~л** җил басыла төште **3.** бушаю; **реме́нь ~л** каеш бушайган

осла́би||ть *сов.* **1.** *кого-что* көчсезләндерү, хәлсезләндерү; зәгыйфьләндерү; какшату; **боле́знь ~ла его́** авыру аны хәлсезләндергән **2.** *что* кимету, йомшарту; **~ть внима́ние** игътибарны йомшарту; **~ть рабо́ту** эшне йомшарту **3.** *что* бушайту, бушайта төшү; **~ть реме́нь** каешны бушайту

ослабле́ние *с* **1.** *см.* **осла́бить**; **2.** *см.* **ослабе́ть**; **~ дисципли́ны** тәртипнең йомшаруы

осла́бля́ть *несов. см.* **осла́бить**

осла́бнуть *сов. разг. см.* **ослабе́ть**

осла́вить *сов. кого-что*, *разг.* исемен сату, данын чыгару, гайбәт тарату

ослепи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** (*очень яркий*) күз чагылдыра торган, күзне чагылдырырлык, күз явын алырлык **2.** *перен.* искиткеч, шаккатырлык; **~ая красота́** искиткеч матурлык

ослепи́||ть *сов. кого-что* **1.** (*сделать слепым*) сукырайту, күзсез калдыру **2.** (*временно притупить зрение*) күзне чагылдыру; **свет ~л меня́** яктылык күземне чагылдырды **3.** *перен.* (*поразить*) хәйран калдыру, таң калдыру, шаккаттыру, сокландыру **4.** *перен.* күзне томалау, акылын югалту, ялгыштыру; **ре́вность ~ла её** көнчелектән аның күзе томаланган

ослепле́ни||е *с* **1.** *см.* **ослепи́ть**; **2.** *перен.* күз томалану, нәрсә эшләгәнен белмәү; **де́йствовать в ~и** нәрсә эшләгәнен белмичә эш итү

ослепля́ть *несов. см.* **ослепи́ть**

осле́пнуть *сов.* **1.** (*лишиться зрения*) сукыраю, күзсез калу, күздән язу **2.** (*временно потерять способность видеть*) күз чагылу

осли́злый, -ая, -ое лайлалы; тайгак

осли́знуть *сов.* лайлалану; тайгаклану

осли́н||ый, -ая, -ое ишәк ...ы; **~ые у́ши** ишәк колагы

осли́ца *ж* ана ишәк

осложне́ние *с* **1.** *см.* **осложни́ть, осложни́ться**; **2.** (*препятствие*) тоткарлык, комачау, кыенлык, читенлек, авырлык; катлаулану **3.** өзлегү, авыру өстәлү; **~ по́сле гри́ппа** грипптан соң өзлегү

осложни́ть *сов. что* кыенлаштыру, читенләштерү, катлауландыру, авырлаштыру

осложни́||ться *сов.* кыенлашу, читенләшү, катлаулану, авыраю; **де́ло ~лось** эш кыенлашты **2.** *мед.* (*о болезни*) өзлегү, өзлегеп китү

осложня́ть *несов. см.* **осложни́ть**

осложня́ться *несов.* **1.** *см.* **осложни́ться**; **2.** *страд. от* **осложня́ть**

ослу́шаться *сов. кого-чего*, *разг.* сүз тыңламау, буйсынмау, карышу, киреләнү

осло́шаться *сов.* ялгыш ишетү, ишетеп җиткермәү

осма́ливать *несов. см.* **осмоли́ть**

осма́тривать *несов. см.* **осмотре́ть**

осма́триваться *несов.* **1.** *см.* **осмотре́ться**; **2.** *страд. от* **осма́тривать**

осме́ивать *несов. см.* **осмея́ть**

осмеле́ть *сов.* кыюлану, кыюланып китү

осме́ливаться *несов. см.* **осме́литься**

осме́л||иться *сов. на что и с неопр.* базу, батыраю, кыюлану, батырчылык итү ♦ **~юсь доложи́ть** *уст.* рөхсәт итегез әйтергә

осмея́ни||е *с см.* **осмея́ть; подве́ргнуться ~ю** адәм көлкесенә калу

осмея́ть *сов. кого-что* көлү, көлкегә калдыру

осмоли́ть *сов. что* сумалалау, сумалап чыгу, сумала белән каплау

осмо́лка *ж см.* **осмоли́ть**; **~ челна́** каекны сумала белән каплау

осмо́тр *м см.* **осмотре́ть; ~ багажа́ в тамо́жне** таможняда багажны тикшереп чыгу; **техни́ческий ~** [машиналарны] техник карау; **врачебный ~** табибның каравы (*мәс. авыруны*)

осмотре́ть *сов. кого-что* **1.** күздән кичерү, күз йөртеп чыгу; карап чыгу; **~ музе́й** музейны карап чыгу **2.** карау, тикшерү; **~ больно́го** авыруны карау

осмотре́ться *сов.* **1.** тирә-якка карану, як-якка каранып алу **2.** *перен.* (*привыкнуть*) күнегү, ияләшү; **~ в но́вом го́роде** яңа шәһәргә ияләшү

осмотри́тельность *ж* зур саклык; **де́йствовать с ~ю** зур саклык белән эш итү

осмотри́тельный, -ая, -ое бик сак, алдын-артын уйлап эш итүче

осмо́тров||ый, -ая, -ое карап тикшерү ...ы; **~ая я́ма** карап тикшерү чокыры (*автомашиналар өчен*)

осмо́трщик *м* тикшерүче, тикшереп карап торучы; **~ ваго́нов** вагоннарны тикшереп карап торучы

осмысле́ние *с см.* **осмы́слить; ~ фа́ктов** фактларны аңлап җиткерү

осмы́сленность *ж* уйлап эшләнгәнлек, акыл белән эшләнгәнлек, мәгънәлелек

осмы́сленный, -ая, -ое аңлы, акыллы, мәгънәле, акыл белән эшләнгән; **~ отве́т** мәгънәле җавап

осмы́сливать *несов. см.* **осмы́слить**

осмы́слить *сов. что* аңлау, төшенү, аңлап (төшенеп) җиткерү

осмысля́ть *несов. см.* **осмы́слить**

оснасти́ть *сов. что* **1.** җиһазлау, җиһазландыру; **~ су́дно** судноны җиһазландыру **2.** *перен.* коралландыру; **~ а́рмию** армияне коралландыру; **~ наро́дное хозя́йство передово́й те́хникой** халык хуҗалыгын алдынгы техника белән коралландыру

осна́стка *ж* **1.** *см.* **оснасти́ть**; **2.** *мор.* (*такелаж, снасти*) җиһаз, оснастка **3.** *тех.* (*оснащение*) барлык җиһаз; **~ станко́в** станокларның барлык җиһазы

оснаща́ть *несов. см.* **оснасти́ть**

оснаще́ние *с* **1.** *см.* **оснасти́ть** 2; **2.** (*оборудование*) барлык корал; җиһаз; **но́вое ~ заво́да** заводның барлык яңа җиһазы

оснащённость *ж* кораллану, җиһазланыш; коралланган булу, җиһазланган булу

осно́в||а *ж* **1.** (*остов*) нигез, төп; кыса; **2.** нигез; **нау́чная ~а** гыйльми нигез; **экономи́ческая ~а социалисти́ческого строя** социалистик төзелешнең икътисади нигезе **3.** *мн.* **~ы** (*главные положения*) нигезләр; **~ы филосо́фии** философия нигезләре **4.** *текст.* буйлык, буй җеп (*туку эшендә*) **5.** *грам.* нигез ♦ **брать за ~у** *или* **класть (положи́ть) в ~у** *что* нигез итеп алу; **лежа́ть (быть) в ~е** *чего* (*быть главным*) нигез булып тору; **на ~е** *чего в знач. предлога* ... таянып

основа́ни||е *с* **1.** *см.* **основа́ть**; **2.** салу, салыну, барлыкка килү; **восемьсо́тпятидесяти́летие ~я Москвы́** Мәскәү салынуның сигез йөз илле еллыгы **3.** (*фундамент*) нигез **4.** *мат.* нигез; **~е треуго́льника** өчпочмак нигезе **5.** (*причина, повод*) нигез, сәбәп; сылтау; **без вся́кого ~я** нигезсез; **на како́м ~и?** ни сәбәптән? **6.** *хим.* нигез; **органи́ческие ~я** органик нигезләр ♦ **до ~я** беткәнче, нигезенә кадәр; **кре́пость разру́шена до ~я** крепость нигезенә кадәр җимерелгән

основа́тель *м* нигез [ташын] салучы, оештыручы, башлап җибәрүче

основа́тельность *ж* нигезлелек, төплелек, нигезле (төпле) булу

основа́тельн||ый, -ая, -ое **1.** (*разумный, веский*) нигезле, төпле; **~ый до́вод** нигезле дәлил **2.** *разг.* (*дельный, положительный*) төпле, ышанычлы, эшлекле; **~ый челове́к** төпле кеше **3.** (*крепкий*) ныклы; **~ое сооруже́ние** ныклы корылма **4.** *разг.* (*большой по размеру, весу*) шактый зур, шактый авыр; **~ый груз** шактый авыр йөк

основа́ть *сов. что* **1.** нигез салу, кору, төзү, оештыру; **~ музе́й** музей оештыру; **~ го́род** шәһәргә нигез салу **2.** *на чём* нигезләү, дәлилләү; **~ свои́ вы́воды**

на фа́ктах үзең ясаган нәтиҗәләрне фактлар белән дәлилләү

основа́||ться *сов.* **1.** барлыкка килү, нигез салыну, корылу, төзелү; **~ лось но́вое о́бщество** яңа җәмгыять барлыкка килде **2.** *разг.* (*расположиться, поселиться*) нигезләнү, урнашу, төпләнү

основн||о́й, -а́я, -о́е **1.** төп, иң мөһим, иң әһәмиятле, асыл; **~ о́й при́нцип** төп принцип; **~ а́я зада́ча** төп бурыч **2.** *в знач. сущ.* **~ о́е** *с* төп мәсьәлә, төп нәрсә, эшнең асылы; **~ о́е уже́ сде́лано** төп нәрсә эшләнгән инде ♦ **в ~ о́м** (*в общих чертах*) нигездә, гомумән алганда; **~ о́й капита́л** *эк.* төп капитал

осно́вн||ый I, -ая, -ое *текст.* буй ..., буйлык ...; **~ые ни́ти** буйлык җепләре (*туку эшендә*)

осно́вный II, -ая, -ое *хим.* нигез ...ы, нигезле

основополага́ющ||ий, -ая, -ее төп, нигез сала торган, нигез булып торучы (тора торган); **~ие труды́** нигез булып торучы әсәрләр

основополо́жник *м* нигез салучы

осно́вывать *несов. см.* **основа́ть**

осно́вываться *несов.* **1.** *см.* **основа́ться**; **2.** *на чём* нигезләнү, таяну; **~ на фа́ктах** фактларга нигезләнү **3.** *страд. от* **осно́вывать**

осо́ба *ж ирон.* шәхес, кеше, бер кеше; **изве́стная ~** билгеле кеше; **подозри́тельная ~** шикле бер кеше

осо́бенно *нареч.* **1.** (*не как все; не как обычно*) аеруча, бик үк; **~ ва́жный** аеруча мөһим **2.** (*в особенности*) бигрәк тә, аеруча; **он ~ люби́л ру́сские пе́сни** ул аеруча рус җырларын ярата иде ♦ **не ~** бик үк ... түгел; **не ~ тала́нтливый челове́к** бик үк талантлы кеше түгел

осо́бенност||ь *ж* үзенчәлек, башкачылык, аерымлылык ♦ **в ~и** (*преимущественно*) аеруча, аерата, бигрәк тә

осо́бенн||ый, -ая, -ое үзенчәлекле, үзенә бер төрле, үзенә башка; **отлича́ться ~ой доброто́й** үзенә бер төрле яхшылык белән аерылып тору

особня́к *м* (*кирәк-яраклары җитешле*) аерым йорт

особняко́м *нареч.* аерым, ялгыз, бер-үзе, башкалардан читтә; **держа́ться ~** үзен башкалардан читтә тоту

осо́б||ый, -ая, -ое **1.** (*особенный*) аерым, үзенә бер төрле, үзенә башка; **совсе́м ~ый цвет** бөтенләй үзенә башка бер төс **2.** (*отдельный*) аерым, махсус; **~ая ко́мната** аерым бүлмә; **~ые права́** махсус хокуклар ♦ **~ое мне́ние** аерым фикер

о́собь *ж биол.* шәхес, зат, аерым бер нәрсә

осове́лый, -ая, -ое *разг. см.* **осолове́лый**

осове́ть *сов. прост.* мәлҗерәү, мәлҗерәп төшү

осовреме́нивать *несов. см.* **осовреме́нить**

осовреме́нить *сов. что* заманча итү, хәзерге заманга туры китерү; **~ тема́тику иссле́дований** фәнни хезмәтләрнең тематикасын хәзерге заманга туры китерү

осознава́ть *несов. см.* **осозна́ть**

осознава́ние *с см.* **осознава́ть; ~ необходи́мости учи́ться** укырга кирәклекне аңлап җиткерү

осозна́ть *сов. что* аңлау, төшенү, аңлап (төшенеп) җитү; **~ своё положе́ние** үз хәленне аңлау

осо́ка *ж* кыяк, күрән

осоко́рник *м* кара тирәклек

осоко́рь *м бот.* кара тирәк, кара тополь

осолове́ть *сов.* мәлҗерәү, изрәү, йокымсырау

осолове́л||ый, -ая, -ое (*полусонный*) мәлҗерәп төшкән, мәлҗерәгән; тонган; **~ый вид** мәлҗерәгән кыяфәт; **~ые глаза́** тонган күзләр

осо́т *м* билчән

о́сп||а *ж* чәчәк (*авыру*); **приви́ть ~у** чәчәк салу

оспа́ривать *несов.* **1.** *см.* **оспо́рить**; **2.** *что* даулау, дәгъвалау, алырга тырышу; **~ пе́рвую пре́мию** беренче премияне дәгъвалау

о́спенный, -ая, -ое чәчәк ...ы

о́спина *ж* шадра, чәчәк шадрасы

оспо́рить *сов. что* каршы килү, килешмәү, ризасызлык белдерү, бәхәсле дип игълан итү

осрами́ть *сов. кого-что* оятка калдыру, оятлы итү, хур итү

осрами́ться *сов.* оятка калу, оятлы булу, хур булу

остава́ться *несов. см.* **оста́ться**

оста́вить *сов.* **1.** *кого-что* калдыру; онытып калдыру; **~ ребёнка до́ма** баланы өйдә калдыру; **~ чемода́н в ваго́не** вагонда чемоданны онытып калдыру **2.** *что* (*сохранить, приберечь*) калдыру; **~ *для кого-л.*** **биле́т в теа́тр** театрга *кемгә дә булса* билет калдыру; **~ хлеб на у́жин** кичке ашка икмәк калдыру **3.** *кого-что* калдыру; **~ пол некра́шеным** идәнне буямый калдыру; **~ зако́н в си́ле** законны көчендә калдыру; **~ вопро́с откры́тым** мәсьәләне ачык калдыру **4.** *что* (*передать*) калдыру; **~ насле́дство** мирас калдыру **5.** *кого-что* калдыру, алып калу; **~ госте́й ночева́ть** кунакларны кунарга алып калу **6.** *кого-что* ташлау, ташлап [калдырып] китү; калдыру; **~ семью́** гаиләсен ташлап китү **7.** *что* (*прекратить*) ташлау; туктату; **~ разгово́ры** сөйләшүне туктату **8.** *кого-что без чего* ...сыз калдыру; **~ без хле́ба** икмәксез калдыру; **~ про́сьбу без внима́ния** үтенечне игътибарсыз калдыру ♦ **~ дурако́м (в дурака́х)** ≈ төпсез чанага утырту; ≈ кәкре каенга терәтү; **~ с но́сом** коры калдыру; **~ по себе́ па́мять** исем калдыру; **не ~ ка́мня на ка́мне** ≈ көлен күккә очыру

оставля́||ть *несов. см.* **оста́вить** ♦ **~ет жела́ть лу́чшего** шәптән түгел

остальн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*прочий*) калган, башка, бүтән **2.** *в знач. сущ.* **~ о́е** *с* калган[ы], бүтән[е], башка[сы]; **~ о́е возьмём за́втра** калганын иртәгә алырбыз **3.** *в знач. сущ.* **~ы́е** *мн.* башкалар, калганнар, бүтәннәр; **ну́жно дожда́ться ~ы́х** башкаларны көтәргә кирәк

остана́вливать *несов. см.* **останови́ть**

остана́вливаться *несов.* **1.** *см.* **останови́ться**; **2.** *страд. от* **остана́вливать**

оста́нки *только мн.* үлек, мәет

останови́ть *сов.* **1.** *кого-что* туктату; **~ по́езд** поездны туктату; **~ рабо́ту заво́да** заводны эштән туктату **2.** *кого-что* (*сдержать*) тыю; **~ шалуна́** шаяннны тыю **3.** *что* (*направить на кого-что-л.*) төшерү, ташлау, юнәлтү; **~ взгляд** *на чём-л. берәр нәрсәгә* күз төшерү

останови́ться *сов.* **1.** туктау, тукталу, туктап (тукталып) калу; **~ на перекрёстке** урам чатында туктап калу **2.** туктау, тукталу, төшү; **~ у знако́мых** танышларга төшү **3.** *на чём* (*задержаться*) тукталу, тукталып китү; **останови́мся на сле́дующих фа́ктах** түбәндәге фактларга тукталыйк **4.** *на ком-чём* (*прийти к заключению, склониться к чему-л.*) нәтиҗәгә килү, риза булу, күну

остано́вк||а *ж* **1.** *см.* **останови́ть** I; **останови́ться** I; **2.** (*перерыв, пауза*) тукталу, туктап тору (*суздә, хәрәкәттә һ.б.ш.*); **говори́ть без ~и** тукталмыйча сөйләү **3.** (*место*) тукталыш, туктау урыны; **трамва́йная ~а** трамвай тукталышы ♦ **~а за** *кем-чем* эш нәрсәдә тора

остано́вочный -ая, -ое туктау ...ы, тукталу ...ы; **~ пункт** туктау пункты

оста́т||ок *м* **1.** калдык, калган өлеш; **~ок обе́да** төшке аш калдыклары **2.** *обычно мн.* **~ки** калдыклар; **~ки крепостно́й стены́** крепость диварының калдыклары **3.** *обычно мн.* **~ки** (*отбросы*) калдык, калдык-постык; сайландык; **нефтяны́е ~ки** нефть калдыклары **4.** калган өлеш; **~ок жи́зни** гомернең калган өлеше; **~ок дня** көннең калган өлеше **5.** *мат.* калдык ♦ **без ~ка** калдыксыз; тулысынча, бөтенләй

оста́точн||ый, -ая, -ое калдык; **~ые су́ммы** калдык суммалар; **~ые о́рганы** калдык әгъзалар (рудиментлар)

оста́ться *сов. в разн. знач.* калу; **~ на́ зиму в дере́вне** кышка авылда калу; **~ на второ́й год** класстан күчми калу; **~ при пре́жнем мне́нии** элекке фикерендә калу; **~ без де́ла** эшсез калу; **~ живы́м** исән калу; **~ позади́** артка калу; **~ в живы́х** үлми калу ♦ **~ на бума́ге** кәгаздә калу, эшкә ашмау; **~ на боба́х** төп башына утырып калу; **~ в дурака́х** ≈ төпсез чанага утыру; **~ ни с че́м** коры калу; **~ при пи́ковом интере́се** коры калу, уңышсызлыкка очрау

остекленéть *сов.* тону; пыялалану (*күз турында*)

остекли́ть *сов. что* пыялалау, пыяла кую; **~ о́кна** тәрәзәләргә пыяла кую

остекля́ть *несов. см.* **остекли́ть**

остеолóгия *ж* остеология (*анатомиянең сөякләрнең формасын һәм төзелешен өйрәнә торган булеге*)

остепени́ть *сов. кого* басынкыландыру, акылга утырту

остепени́ться *сов.* басынкылану, акылга утыру

остепеня́ть *несов. см.* **остепени́ть**

остепеня́ться *несов. см.* **остепени́ться**

остервене́лый, -ая, -ое *разг.* (*неистовый, исступлённый*) котырган, шашкан, ярсыган

остервене́ть *сов.* котыру, шашу

остервени́ться *сов.* котырыну, шашыну

остерега́ть *несов. см.* **остере́чь**

остерега́||ться *несов. кого-чего* сакланy, сак булу; **~ться просту́ды** салкын тиюдән саклану; **~йся э́того челове́ка!** бу кешедән сак бул!

остере́чь *сов. кого* (*предупредить, предостеречь*) искәртү, кисәтү, алдан әйтеп кую

остере́чься *сов. см.* **остерега́ться**

о́стов *м* остов, каркас; **~ корабля́** корабль каркасы

остолбене́лый, -ая, -ое *разг.* катып калган

остолбене́ть *сов.* катып калу, багана кебек кату

остоло́п *м бран.* аңгыра, мәнсез, тинтәк, күзле бүкән

осторо́жничать *несов. разг.* артык сак булу, артык сак кылану, артык саклык күрсәтү

осторо́жность *ж* саклык, сак булу, абайлылык

осторо́жн||ый, -ая, -ое сак, сакланучан, абай; **~ый челове́к** сак кеше; **быть ~ым** абай булу

осточерте́ть *сов. кому, прост.* биздерү, туйдыру, туйдырып бетерү

остраки́зм *м книжн.* (*изгнание, гонение*) илдән сөрү; эзәрлекләү, кысу, җәберләү

остра́стк||а *ж разг.* куркыту; **побо́и́ть для ~и** куркыту өчен генә кыйнап ташлау

остре́ц *м бот.* кыяк үлән

острига́ть *несов. см.* **остри́чь**

острига́ться *несов.* 1. *см.* **остри́чься**; 2. *страд. от* **острига́ть**

остриё с 1. оч; йөз, үткен як; **~ штыка́** штык очы; **~ са́бли** кылыч йөзе 2. *перен.* оч, иң үткен як; ук; **~ кри́тики** тәнкыйть угы (үткен ягы)

остри́ть I *несов. что* (*делать острым*) очлау; үткенләү, чарлау, кайрау

остри́ть II *несов.* (*говорить остроты*) тапкыр сүзләр әйтү, үткен сүзләр әйтү, җорлану

остри́чь *сов.* 1. *что* алу, алдыру; кырку, кыркып алу; кисү; **~ во́лосы** чәч алдыру; **~ но́гти** тырнак кисү 2. *кого-что* йонын алу, чәчен алу; **~ овцу́** сарыкның йонын алу

остри́чься *сов.* чәч алдыру, чәч кистерү

о́стров *м* утрау, атау; **необита́емый ~** кеше яшәми торган утрау

островёрх||ий, -ая, -ое очлы башлы; **~ая ба́шня** очлы башлы манара

островитя́нин *м* утрау кешесе, утрауда яшәүче

островитя́нка *ж* утрауда яшәүче хатын (кыз)

островн||о́й, -а́я, -о́е утрау ...ы; утраудагы, утрауга урнашкан; **~ о́й жи́тель** утрау кешесе; **~ о́е госуда́рство** утраудагы дәүләт

острово́к *м уменьш. от* **о́стров**; утраучык ◆ **~ безопа́сности** куркынычсызлык мәйданы (*транспорт юлында*)

остро́г *м уст.* төрмә, зиндан, баструк

остро́га *ж* чәнечке, балык чәнчү кораллы

острогла́зый, -ая, -ое *разг.* үткен күзле; зирәк, очлы күзле

острогу́бцы *только мн.* (*кусачки*) каргаборын

остродефици́тный, -ая, -ое гаять җитешми торган, үтә дефицит ...; **~ това́р** гаять җитешми торган товар

остроза́разный, -ая, -ое үтә йогышлы

острозу́бый, -ая, -ое үткен (очлы) тешле

остроконе́чн||ый, -ая, -ое очлы, очлы башлы; **~ая ба́шня** очлы башлы манара

остроли́ст *м бот.* очлы яфрак (*мәңге яшел үсемлек*)

остроли́цый, -ая, -ое озынча битле

остроно́с||ый, -ая, -ое 1. очлы борынлы; (*о птицах*) очлы томшыклы; **~ый мальчуга́н** очлы борынлы малай 2. очлы башлы; **~ые боти́нки** очлы башлы ботинка

остросло́в *м* җор кеше, тапкыр сүзле кеше

остросло́вие тапкыр сүзлелек

остросло́вить *несов. см.* **остри́ть** II

остро́та *ж* тапкыр сүз, үткен сүз, җор сүз

острота́ *ж* 1. үткенлек; **~ ножа́** пычакның үткенлеге 2. *перен.* үткенлек, зирәклек; **~ ума́** акыллның зирәклеге; **~ зре́ния** күзнең үткенлеге 3. (*пряность*) ачылык, кыркулык; **~ со́уса** соусның ачылыгы 4. *перен.* (*крайняя напряжённость*) киренкелек, кискенлек; **~ положе́ния** хәлнең кискенлеге

остроуго́льник *м мат.* кысынкы почмаклык

остроуго́льный, -ая, -ое *мат.* кысынкы почмаклы; **~ треуго́льник** кысынкы почмаклы өчпочмак

остроу́мие *с* тапкырлык, тапкыр сүзлелек; үткен акыллылык

остроу́мничать *несов. разг.* үткен акыллы булып күренергә тырышу, тапкырлык күрсәтергә маташу

остроу́мн||ый, -ая, -ое үткен сүзле, үткен телле; тапкыр, җор; **~ое выраже́ние** тапкыр әйтем

о́стр||ый, -ая, -ое 1. үткен; **~ый нож** үткен пычак 2. очлы, очлы башлы; **~ый нос ло́дки** көймәнең очлы борыны 3. *перен.* үткен, зирәк; очлы; **~ый ум** зирәк акыл; **~ый глаз** очлы күз 4. *перен.* чәнечкеле, зәһәрле, үткен, әче; **~ый язы́чо́к** әче тел; **~ая шу́тка** зәһәрле шаярту 5. *перен.* әче, ачы; **~ый за́пах** ачы ис 6. *перен.* көчле, каты; кискен; **~ая боль** каты авырту ◆ **~ый у́гол** *мат.* кысынкы почмак

остря́к *м разг.* җор кеше, үткен телле, тапкыр сүзле кеше

остуди́ть *сов. что* суыту, салкынайту

остужа́ть *несов. см.* **остуди́ть**

оступа́ться *несов. см.* **оступи́ться**

оступи́ться *сов.* 1. (*неудачно ступить*) ялгыш басу, сөртенү 2. *перен.* (*совершить ошибку*) ялгышу, ялгышлык ясау

остыва́ть *несов. см.* **остыть, остыну́ть**

остыну́ть *сов. см.* **остыть**

остыть||ть *сов.* 1. суыну; **чай ~л** чәй суынды 2. *к кому-чему и без доп.* (*охладеть*) күнел салкынаю, күнел кайту, басылу

ость *ж* 1. (*у злаков*) кылчык, башак кылчыгы 2. (*в мехе*) кыл

осуди́ть *сов.* 1. *кого-что* (*признать дурным*) гаепләү, гаепле дип табу, начар дип табу 2. *кого, юр.* хөкем итү; **~ престу́пника** җинаятьчене хөкем итү 3. *перен. кого-что на что* (*обречь на что-л.*) дучар итү

осужда́ть *несов. см.* **осуди́ть**

осужде́ние *с* 1. *юр.* хөкем итү, гаепләп карар чыгару 2. (*порицание*) шелтә, хурлау, начар дип табу

осуждённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **осуди́ть**; 2. *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* хөкем ителгән

осу́нуться *сов.* бик ябыгу, суырылу, бетеренү

осуша́ть *несов. см.* **осуши́ть**

осуше́ние *с см.* **осуши́ть** I; **~ боло́т** сазлыкларны киптерү

осуши́тельный, -ая, -ое киптерү ...ы, корыту ...ы; **~ кана́л** киптерү каналы

осуши́ть *сов. что* 1. киптерү, корыту; **~ боло́то** сазлыкны киптерү 2. *разг.* (*выпить содержимое*) эчәп бетерү, беткәнче эчү ◆ **~ слёзы** *кому кемне дә булса* юату; **~ глаза́** елап [елаудан] туктау

осу́шка *ж см.* **осуши́ть** I

осуществи́мость *ж* тормышка (гамәлгә) ашырырлык булу, үтәлерлек булу, кулдан килерлек булу

осуществи́м||ый, -ая, -ое тормышка ашырырлык, тормышка ашырылырлык, булдыра алырлык, кулдан килерлек; **~ые пла́ны** тормышка ашырырлык планнар

осуществи́ть *сов. что* тормышка (гамәлгә) ашыру, үтәү

осуществи́||ться *сов.* тормышка (гамәлгә) ашу, үтәлү; **мечта́ ~лась** хыял тормышка ашты

осуществле́ние *с см.* **осуществи́ть, осуществи́ться**; **~ прое́кта** проектның тормышка ашырылуы

осуществля́ть *несов. см.* **осуществи́ть**

осуществля́ться *несов.* 1. *см.* **осуществи́ться**; 2. *страд. от* **осуществля́ть**

осциллогра́мма *ж физ.* осциллограмма

осциллогра́ф *м физ.* осциллограф (*электрик процессларның вакытка карап үзгәруен яза торган автомат прибор*); **электро́нный ~** электроник осциллограф

осчастли́вить *сов. кого-что* бәхетле итү

осчастли́вливать *несов. см.* **осчастли́вить**

осы́па||ть *сов.* **1.** *кого-что* (*покрыть сыпучим*) сибу, сибеп чыгу **2.** *кого-что* (*сплошь покрыть*) [тоташ] каплау, сибелу; **не́бо ~но звёздами** күктә йолдызлар сибелгән **3.** *перен. кого-что чем* күмү, күмеп ташлау; **~ть пода́рками** бүләккә күмү **4.** *что* кою; **дере́вья ~ли свои́ ли́стья** агачлар яфракларын койдылар **5.** *что* (*развалить что-л. сыпучее*) тарату, ишү; **~ть ку́чу песка́** ком өемен ишү

осыпа́ть *несов. см.* **осы́пать**

осы́па||ться *сов.* **1.** (*обвалиться*) җимерелү, ишелү, җимерелеп (ишелеп) төшү **2.** коелу, коелып бетү (төшү); **лепестки́ ~лись** таҗ яфракчыклары коелган

осыпа́ться *несов.* **1.** *см.* **осы́паться**; **2.** *страд. от* **осыпа́ть**

о́сыпь *ж геол.* ишелмә (*тау токымнарының таркалуыннан барлыкка килгән өем*)

ось *ж* **1.** (*стержень*) күчәр; **пере́дняя ~** алгы күчәр **2.** (*воображаемая прямая линия*) күчәр, үзәк; **~ враще́ния Земли́** Җирнең әйләну күчәре; **~ симме́трии** *мат.* симметрия күчәре; **о́си координа́т** *мат.* координат күчәрләре **3.** *перен.* үзәк

осьминóг *м зоол.* сигезаяк

осяза́емость *ж* сизелүчәнлек, сизелә торган булу

осяза́ем||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **осяза́ть; 2.** капшап сизелә (сизә) торган **3.** *перен.* сизелерлек, сизелеп торган; **~ые успе́хи** сизелерлек уңышлар

осяза́ни||е *с* тиеп (капшап) сизү; сизем, сиземләү, тою; **о́рганы ~я** тою органнары

осяза́тельный, -ая, -ое **1.** (*служащий для осязания*) сизә торган, сизү ...ы, тою ...ы; **~ о́рган** тою әгъзасы **2.** *перен.* (*значительный*) сизелерлек, күзгә күренерлек; **~ результа́т** сизелерлек нәтиҗә

осяза́ть *несов. кого-что* капшап (тиеп) сизү, тою, сиземләү

от (ото) *предлог с род. п.* **1.** (*при указ. на исходную точку чего-л.*) ...дан, ...дан алып; **отплы́ть ~ бе́рега** яр буеннан йөзеп китү; **~ восьми́ до десяти́** сигездән алып унга кадәр **2.** (*при указ. на источник чего-л.*) ...дан; **узна́ть** *что-л.* **~ дру́га** *берәр нәрсәне* дустыңнан ишетеп белү **3.** (*при указ. на целое, которому принадлежит часть*) ...ы; **пу́говица ~ пальто́** пальто төймәсе; **ключ ~ замка́** йозак ачкычы **4.** (*при указ. на что-л. удаляемое, избегаемое*) ...дан, каршы; **лека́рство ~ ка́шля** ютәлгә каршы дару; **защи́та ~ врага́** дошманнан саклану **5.** (*при указ. на причину, основание чего-л.*) ...дан; **петь ~ ра́дости** шатлыктан җырлау **6.** (*при указ. на предмет, к-рый противопоставляется первому*) ...дан; **отлича́ть добро́ ~ зла** яхшылыкны яманлыктан аеру **7.** (*при обознач. даты документа*) ...да язылган; **прика́з ~ пе́рвого а́вгуста** беренче августта язылган приказ **8.** (*при указ. на временну́ю последовательность*) ...дан ...га; **год ~ го́ду** елдан елга; **день ото дня́** көннән көнгә ♦ **вре́мя ~ вре́мени** вакыт-вакыт; **~ ма́ла до вели́ка** яшәкарты, һәммәсе; **~ всей души́** чын күңелдән

от- (ото-, отъ-) *фигыль ясагыч приставка* **1.** *«берәр эшне тәмамлау, төгәллә, хәрәкәтне ахырга китереп җиткерү, туктату» дигән мәгънәне белдереп, татарчага «бетерү» дигән ярдәмче фигыль аша тәрҗемә ителә, мәс.* **отдежу́рить** дежурить итеп бетерү; **отрабо́тать** эшләп бетерү **2.** *«ерагаю, ераклашу, читләшү, читкә китү» мәгънәләрен белдереп, «китү» дигән ярдәмче фигыль аша тәрҗемә ителә, мәс.* **отлете́ть** очып китү; **отбежа́ть в сто́рону** читкә йөгереп китү; **отплы́ть от бе́рега** яр буеннан йөзеп китү **3.** *«бер бөтеннән аерым кисәген яки икенче берәр әйберне аеру» мәгънәсен аңлатып, «алу» дигән ярдәмче фигыль аша тәрҗемә ителә, мәс.* **отре́зать кусо́к хле́ба** бер телем икмәк кисеп алу; **отклей́ить ма́рку** марканы куптарып алу **4.** *фигыльдә «-ся» суффиксы булса һәм ул «берәр нәрсәдән баш тарту» мәгънәсен аңлатса, «котылу», «сылтау табу» сүзләре ярдәмендә тәрҗемә ителә, мәс.* **отписа́ться** язып котылу; **отговори́ться** сылтаулар табып баш тарту

ота́ва *ж с.-х.* курпы

ота́пливать *несов. см.* **отопи́ть**

ота́плива||ться *несов.* ягылу, ягып җылытылу; **дом не ~ется** өй ягылмый

ота́ра *ж* сарык көтүе

отба́вить *сов. что, чего* киметү, азайту, киметә (азайта) төшү

отба́вка *ж см.* **отба́вить**

отбавля́||ть *несов. см.* **отба́вить**; **хоть ~й** кирәгеннән артык күп, кая куяр җир юк

отбараба́нивать *несов. см.* **отбараба́нить**

отбараба́нить *сов.* **1.** (*кончить барабанить*) барабан кагудан туктау **2.** *что и без доп., прост.* [ашык-пошык] уйнап алу; **~ вальс** ашык-пошык вальс уйнап алу

отбега́ть *несов. см.* **отбежа́ть**

отбежа́ть *сов.* йөгереп (чабып) китү

отбе́ливать *несов. см.* **отбели́ть**

отбели́ть *сов. что* агарту, акшарлау, агартып (акшарлап) чыгу

отбе́лка *ж см.* **отбели́ть; ~ холста́** киндер агарту

отбе́льный, -ая, -ое *спец.* агарту ...ы; агартылган; **~ цех** агарту цехы

отбива́ть *несов.* **1.** *см.* **отби́ть; 2.** тыкылдату, шак-шак иттерү ♦ **~ шаг** шак-шак басып атлау; **~ дробь** тыкылдату

отбива́ться *несов.* **1.** *см.* **отби́ться; 2.** *страд. от* **отбива́ть**

отби́вка *ж см.* **отби́ть** 6, 7

отбивн||о́й, -а́я, -о́е отбивной, тапалган (*итне суккалап, йомшартып ясалган*); **~а́я котле́та** отбивной котлет

отбира́ть *несов. см.* **отобра́ть**

отби́ть *сов.* **1.** *что* (*отразить*) кире кайтару, сугып кире кайтару (җибәрү); **~ нападе́ние** һөҗүмне кире кайтару **2.** *кого-что* (*вернуть с боем*) сугышып алу, сугышып кире алу; **~ го́род** шәһәрне сугышып кире алу **3.** *кого, разг.* үзенә карату; үзенә тартып алу **4.** *что* китеп төшерү, ватып (сындырып) төшерү; **~ ру́чку у ча́йника** чәйнекнең тоткасын ватып төшерү **5.** *перен. что, разг.* (*удалить, уничтожить*) бетерү; **~ за́пах** ис килүне бетерү **6.** *что* (*наточить*) таптау; **~ кос** чалгы таптау **7.** *что* (*обозначить ударами, звоном*) сугу, көй чыгарып сугу; жеп сугу; **~ такт руко́й** кул белән көй чыгарып сугу **8.** *что* (*повредить*) бәреп имгәтү; суга-суга авырттырып бетерү; суга-суга авырттыру; **~ ладо́ни** суга-суга уч төпләрен авырттыру

отби́ться *сов.* **1.** һөҗүмне кире кайтару; **~ от врага́** дошманның һөҗүмен кире кайтару **2.** *разг.* аерылу, аерылып калу; **~ от табуна́** көтүдән аерылып калу **3.** (*отломаться*) кителеп төшү, сынып төшү, ватылып төшү ♦ **~ от рук** кулдан ычкыну, буйсынмый башлау, сүз тыңламый башлау; **~ от до́ма** өйдән бизү

отблагодари́ть *сов. кого-что за что* рәхмәт әйтү (белдерү), яхшылык белән җавап кайтару

о́тблеск *м* чагылыш, шәүлә, ут шәүләсе; **~и пла́мени** ялкын шәүләләре

отбо́||й *м* **1.** *см.* **отби́ть** 1, 6, **отби́ться** 1; **2.** (*сигнал*) отбой ♦ **~ю нет** *от кого-чего* бик күп, чиксез күп

отбо́йный, -ая, -ое вата торган; **~ мо́лот[о́к]** вата торган чүкеч

отбомби́ться *сов. разг.* бомбалауны тәмамлау, бомбаларны ташлап бетерү

отбо́р *м см.* **отобра́ть** ♦ **есте́ственный ~** табигый сайланыш; **иску́сственный ~** ясалма сайланыш (*токымны яхшырту өчен*)

отбо́рн||ый, -ая, -ое **1.** сайланма, ин яхшы, сайлап алынган; **~ые я́блоки** сайланма алмалар **2.** *разг.* (*неприличный*) әшәке, оятсыз; **~ая ру́гань** оятсыз сүгенү

отбо́рочн||ый, -ая, -ое сайлап алу ...ы; сайлап ала торган, сайлап алу өчен үткәрелгән; **~ые соревнова́ния** сайлап алу ярышлары; **~ая коми́ссия** сайлап ала торган комиссия

отбра́сывать *несов. см.* **отбро́сить**

отбрива́ть *несов. см.* **отбри́ть**

отбри́ть *сов. кого-что, прост.* (*резко ответить*) кырт кисеп җавап бирү

отбро́с *м* ташландык, калдык-постык, чүп-чар ♦ **~ы о́бщества** түбәнлеккә төшкән кешеләр

отбро́сить *сов.* **1.** *кого-что* алып ташлау, читкә ыргыту; **~ ка́мень с доро́ги** ташны юлдан алып ташлау **2.** *перен. кого-что* (*заставить отступить*) чигендерү, чигенергә мәҗбүр итү **3.** *перен. что, разг.* кире кагу, [алып] ташлау, ваз кичү; **~ сомне́ния** шикшөбһәләрне алып ташлау **4.** *что* (*свет, тень*) төшерү

отбукси́ровать *сов. что* буксир белән алып китү, буксирга алып илтеп кую

отбыва́ние *с см.* **отбы́ть** 2; **~ пови́нности** хезмәт йөкләмәсен үтәү

отбыва́ть *несов. см.* **отбы́ть**

отбы́тие *с см.* **отбы́ть**; ~ **по́езда** поездның китүе

отбы́ть *сов.* 1. китү, китеп бару; **делега́ция отбыла́ на ро́дину** делегация туган иленә кайтып китте 2. *что* (*пробыть определённый срок*) үтәү, срогын тутыру, ...да булып кайту; ~ **ва́хту** вахтада булып кайту; ~ **срок наказа́ния** җәзалау срогын тутыру

отва́га *ж* батырлык, кыюлык, гайрәт

отва́дить *сов. кого-что от чего, прост.* биздерү, ташлату; ~ **от куре́ния** тәмәке тартуны ташлату

отва́живать *несов. см.* **отва́дить**

отва́живаться *несов. см.* **отва́житься**

отва́житься *сов. на что и с неопр.* кыюлык (батырчылык) итү, тәвәккәллек итү, базу

отва́жность *ж* батырлык, кыюлык, йөрәклелек, гайрәтлелек

отва́жный, -ая, -ое батыр, кыю, тәвәккәл, йөрәкле, гайрәтле, курыкмас; ~ **во́ин** батыр сугышчы

отва́л *м* 1. *см.* **отвали́ть** 1, 3; ~ **пласто́в** катламнарны әйләндереп салу 2. (*пласт земли*) өем, чокыр казыганда читкә өелгән өем 3. (*насыпь из пустых пород*) ташландык тау токымы өеме ♦ **до ~а (~у)** гарык булганчы; **нае́сться до ~а** гарык булганчы ашау

отва́ливать *несов. см.* **отвали́ть**

отва́ливаться *несов.* 1. *см.* **отвали́ться**; 2. *страд. от* **отва́ливать**

отвали́ть *сов. что* 1. читкә аударып ташлау, читкә этәреп кую; әйләндереп салу; ~ **ка́мень от вхо́да** керү юлыннан ташны читкә этәреп кую 2. *прост.* (*расщедриться*) чыгарып салу, чыгарып бирү; ~ **миллио́н рубле́й** миллион сум чыгарып салу 3. *без доп.* (*отчалить*) кузгалып китү (*суднолар турында*)

отвали́||ться *сов.* 1. кубу, кубып төшү; **штукату́рка ~лась** штукатурка кубып төшкән 2. *разг.* (*откинуться*) гәүдәне артка ташлау 3. *прост.* (*насытившись, отодвинуться*) туеп читкә тайпылу

отва́р *м* шулпа; **ри́совый ~** дөге шулпасы

отва́ривать *несов. см.* **отвари́ть**

отва́риваться *несов.* 1. *см.* **отвари́ться**; 2. *страд. от* **отва́ривать**

отвари́ть *сов. что* пешерү, пешереп алу; ~ **мя́со** ит пешерү

отвари́ться *сов.* пешү, пешеп җитү, кайнап җитү

отварн||о́й, -а́я, -о́е пешкән, пешер[ел]гән; ~**о́е мя́со** пешкән ит

отве́дать *сов. что, чего, уст.* (*попробовать*) татып карау, ашап (эчеп, кабып) карау, авыз итү

отве́дывать *несов. см.* **отве́дать**

отвезти́ *сов. кого-что* 1. (*доставить*) илтү, илтеп кую, илтеп тапшыру 2. (*везя, убрать*) читкә алып китү, илтеп ташлау, алып китеп ташлау; ~ **ка́мни в сто́рону от доро́ги** ташларны юлдан читкә алып китү

отверга́ть *несов. см.* **отве́ргнуть**

отве́ргнуть *сов. кого-что* кире кагу, кабул итмәү; ~ **по́мощь** ярдәмне кабул итмәү

отвердева́ть *несов. см.* **отверде́ть**

отверде́лость *ж* каткан урын, катыланган җир

отверде́л||ый, -ая, -ое каткан, катыланган; катып калган; ~**ая о́пухоль** каткан шеш

отверде́ние *с* 1. *см.* **отверде́ть**; 2. *см.* **отверде́лость**

отверде́ть *сов.* кату, катылану, катып калу

отве́рженность *ж книжн.* читләтелгәнлек, читкә кагылганлык

отве́рженный, -ая, -ое *книжн.* читкә кагылган; читләтелгән

отверну́ть *сов. что* 1. (*повернуть в сторону*) читкә бору; ~ **лицо́** битне (йөзне) читкә бору 2. кайтару, кайтарып кую; ~ **полу́ шу́бы** тунның чабуын кайтарып кую 3. (*открыть*) бору, ачу, борып ачу; ~ **кран** кранны борып ачу 4. (*отвинтить*) борып алу, борып чыгару 5. *разг.* (*оторвать*) каерып алу, каерып чыгару; өзеп алу; ~ **ку́кле но́гу** курчакның аягын өзеп алу

отверну́||ться *сов.* 1. (*повернуться в сторону*) борылу, читкә борылу 2. кайтарылу; **пола́ шу́бы ~лась** тунның чабуы кайтарылды 3. (*открыться*) ачылу, борылып ачылу; **кран ~лся** кран ачылган 4. (*отвинтиться*) борылып чыгу 5. *перен. от кого* (*перестать общаться*) читләшү, араны өзү

отве́рстие *с* 1. тишек, тишем, ярык; ~ **в стене́** стенадагы тишек; ~ **руже́йного ду́ла** мылтык көпшәсенең тишеге; **сквозно́е ~** үтәли тишем

отверте́ть *сов. разг. см.* **отверну́ть** 4

отверте́ться *сов.* 1. *разг. см.* **отверну́ться** 4; 2. *от чего, прост.* (*уклониться*) сылтау табып баш тарту, хәйләләп котылу

отвёртка *ж* отвёртка, шәреп боргыч

отвёртывать *несов. см.* **отверну́ть**

отвёртываться *несов.* 1. *см.* **отверну́ться**; 2. *страд. от* **отвёртывать**

отве́с *м* 1. *тех.* шакул, асма (*вертикаль юнәлешне билгеләү өчен*) 2. (*вертикальный склон*) текә яр

отве́сить *сов.* 1. *что, чего* (*взвесить*) үлчәп бирү 2. *что, прост.* (*нанести удар*) салып җибәрү, сугып җибәрү, кундыру ♦ ~ **покло́н** сәламләп баш ию, иелеп сәлам бирү

отве́сн||ый, -ая, -ое текә; ~**ая скала́** текә кыя

отвести́ 1. *кого-что* илтеп кую (*җитәкләп, ияртеп*); ~ **ребёнка в шко́лу** баланы мәктәпкә илтеп кую 2. *кого-что* (*увести*) [читкә] алып китү; күчерү; ~ **собесе́дника к окну́** әңгәмәдәшне тәрәзә янына алып китү; ~ **войска́** гаскәрләрне күчерү 3. *что* (*изменить направление движения*) читкә юнәлдерү, читкә борып җибәрү; ~ **ре́ку** елганы читкә юнәлдерү 4. *перен. кого-что* кире кагу; отвод ясау; ~ *чью-л.* **кандидату́ру** *кемнең дә булса* кандидатурасын кире кагу 5. *что* (*отдать в пользование*) бирү, аерып бирү, бүлеп бирү; ~ **уча́сток под огоро́д** яшелчә бакчасына җир бүлеп бирү ♦ ~ **ду́шу** күңелне бушату; эч серләрен сөйләү; ~ **глаза́** *кому* игътибарны читкә юнәлтү

отве́т *м в разн. знач.* җавап; **получи́ть ~ на письмо́** хатка җавап алу; **дать ~** җавап бирү; **написа́ть ~** җавап язу; **получи́ть пра́вильный ~** *мат.* дөрес җавабын табу (дөрес чишү); **призва́ть к ~у** җавапка тарту; **держа́ть ~** җавап тоту ♦ **в ~ на** *что, в знач. предлога* бирәр нәрсәгә җавап итеп; **ни ~а ни приве́та** хәбәр-хәтер булмау

ответви́ть *сов. что, спец.* тармакландыру, тармакларга аерып җибәрү; ~ **оросительные кана́лы** сугару каналларыннан тармаклар аерып җибәрү

ответви́||ться *сов.* тармаклану, аерылып чыгу; ботаклану; **от магистра́ли ~лось не́сколько доро́г** тәп (зур) юлдан берничә юл аерылып чыккан

ответвле́ни||е *с* 1. *см.* **ответви́ть, ответви́ться**; 2. (*боковая ветвь*) ботак 3. (*боковая часть дороги, реки и т.п.*) тармак

ответвля́ть *несов. см.* **ответви́ть**

ответвля́ться *несов.* 1. *см.* **ответви́ться**; 2. *страд. от* **ответвля́ть**

отве́тить *сов.* 1. *что, на что, чем и без доп.* җавап бирү, җавап кайтару; сөйләп бирү; ~ **на вопро́с** сорауга җавап бирү; ~ **уро́к** дәресне сөйләп бирү 2. *за кого-что* (*понести наказание*) җавап бирү, җавапка тартылу

отве́тн||ый, -ая, -ое җавап ...ы; җавап рәвешендә ...ган; ~**ый покло́н** җавап сәламе; ~**ая но́та** җавап нотасы; ~**ое письмо́** җавап хаты

отве́тственност||ь *ж* җаваплылык; **мора́льная ~ь** әхлакый җаваплылык; **материа́льная ~ь** материаль җаваплылык; **взять ~ь на себя́** җаваплылыкны өстенә алу; **привле́чь к суде́бной ~и** суд җаваплылыгына тарту

отве́тственн||ый, -ая, -ое 1. җаваплы; ~**ый реда́ктор** җаваплы мөхәррир; ~**ая до́лжность** җаваплы урын 2. җаваплы, [зур] җаваплылык белән ...; ~**ое отноше́ние к де́лу** эшкә зур җаваплылык белән карау 3. (*очень серьёзный*) җаваплы, мөһим; ~**ая зада́ча** җаваплы бурыч

отве́тчик *м* 1. *юр.* җавапчы, җавапка тартылучы 2. *разг.* (*несущий ответственность*) җавап бирүче, җаваплы кеше

отве́тчица *ж см.* **отве́тчик** 1

отвеча́ть *несов.* 1. *см.* **отве́тить**; 2. *за кого-что* җаваплы булу; ~ **за пору́ченное де́ло** тапшырылган эшкә җаваплы булу 3. *чему* (*соответствовать*) туры килү, ярау ♦ ~ **голово́й** башың белән җавап бирү

отве́шивать *несов. см.* **отве́сить**

отви́ливать *несов. см.* **отвильну́ть**

отвильну́ть *сов. разг.* хәйләләп котылу, хәйләләп баш тарту; ~ **от поруче́ния** йомыш үтәүдән хәйләләп баш тарту

отвинти́ть *сов. что* борып алу (чыгару); ~ **га́йку** гайканы борып алу

отвинти́ться *сов.* борылып алыну, борылып чыгу

отви́нчивать *несов. см.* **отвинти́ть**

отви́нчиваться *несов.* **1.** *см.* **отвинти́ться; 2.** *страд. от* **отви́нчивать**

отвиса́ть *несов. см.* **отви́снуть**

отвисе́ться *сов. разг.* (*о платье и т. п.*) эленеп торып тигезләнү

отви́сл||ый, -ая, -ое *разг.* салынкы, салынып төшкән; салпы; **~ые гу́бы** салпы иреннәр

отви́снуть *сов.* салыну, салынып төшү; салпылану, салпыланып тору

отвлека́ть *несов. см.* **отвле́чь**

отвлека́ться *несов.* **1.** *см.* **отвле́чься** 1; **2.** *страд. от* **отвлека́ть**

отвлече́ние *с* **1.** *см.* **отвле́чь, отвле́чься**; **2.** абстракция, абстракт төшенчә

отвлечённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **отвле́чь**; **2.** (*теоретический*) гомуми, абстракт; **~ое поня́тие** абстракт төшенчә **3.** (*мало конкретный*) конкрет булмаган, абстракт; **говори́ть об ~ых предме́тах** конкрет булмаган әйберләр турында сүз йөртү ♦ **~ое и́мя существи́тельное** *грам.* абстракт исем

отвле́чь *сов.* **1.** *кого-что от чего* читкә юнәлдерү; бүлдерү, аеру; **~ внима́ние** игътибарны читкә юнәлдерү; **~ от рабо́ты** эштән бүлдерү **2.** *что от чего, книжн.* (*абстрагировать*) абстрактлаштыру; аерып алу, аерып алып карау

отвле́чься *сов.* **1.** *от чего* бүленү; читкә китү; **~ от рабо́ты** эштән бүленү; **~ от те́мы** темадан читкә китү **2.** (*абстрагироваться*) аерып алып күз алдына китерү, (*берәр нәрсәне*) абстракт рәвештә күз алдына китерү

отво́д *м* **1.** *см.* **отвести́** 2-5; **2.** (*заявление об отстранении*) кире кагу, каршы чыгу, отвод ясау; **дать ~** отвод бирү; ♦ **для ~а глаз** күз буяу өчен

отводи́ть *несов. см.* **отвести́**

отводно́й, -а́я, -о́е читкә җибәрә (чыгара) торган; **~ кана́л** читкә җибәрә торган канал

отво́док *м бот.* тамырланма ботак, үренте

отвоева́ть *сов.* **1.** *кого-что* сугышып кайтарып алу, сугышып кире кайтару; **~ го́род у врага́** дошманнан шәһәрне сугышып кайтарып алу **2.** *без доп. разг.* (*кончить воевать*) сугышып туктау

отвоева́ться *сов. разг.* сугышып туктау

отвоёвывать *несов. см.* **отвоева́ть**

отвози́ть *несов. см.* **отвезти́**

отвола́кивать *несов. см.* **отволо́чь**

отволо́чь *сов. кого-что, прост.* (*оттащить*) сөйрәп илтү, сөйрәп илтеп ташлау

отвора́чивать *несов. см.* **отверну́ть** 1, 2

отвора́чиваться *несов.* **1.** *см.* **отверну́ться** 1, 2, 5; **2.** *страд. от* **отвора́чивать**

отвори́ть *сов. что* ачу, ачып кую, ачып җибәрү; **~ ворота́** капканы ачу

отвори́ться *сов.* ачылу, ачылып китү

отворо́т *м* кайтарма

отворя́ть *несов. см.* **отвори́ть**

отворя́ться *несов.* **1.** *см.* **отвори́ться**; **2.** *страд. от* **отворя́ть**

отврати́тельн||ый, -ая, -ое бик начар, әшәке, күңел кайтаргыч, җирәнгеч; **~ый за́пах** җирәнгеч ис; **~ая пого́да** бик начар һава

отврати́ть *сов. что, высок.* (*не дать осуществиться*) булдырмау, булдырмый калу; **~ беду́** бәлане булдырмау

отвраща́ть *несов. см.* **отврати́ть**

отвраще́ни||е *с* җирәнү; нәфрәт; **чу́вство ~я** җирәнү хисе

отвыка́ть *несов. см.* **отвы́кнуть**

отвы́кнуть *сов.* **1.** *от чего и с неопр.* бизү, күңел бизү; **~ от куре́ния** тәмәке тартудан бизү **2.** *от кого-чего* (*стать далёким, чужим*) бизү, оныту, ташлау; суыну

отвяза́ть *сов. кого-что* чишү, чишеп алу; бәйдән ычкындыру; чишеп (ычкындырып) җибәрү

отвяза́||ться *сов.* **1.** чишелү; бәйдән ычкыну; **верёвка ~лась** бау чишелгән **2.** *перен. от кого, прост.* (*перестать надоедать*) бәйләнмәү, тыныч калдыру **3.** *перен. от кого-чего, прост.* (*отделаться*) котылу

отвя́зывать *несов. см.* **отвяза́ть**

отвя́зываться *несов.* **1.** *см.* **отвяза́ться**; **2.** *страд. от* **отвя́зывать**

отгада́ть *сов. что* табу, белү, белеп (аңлап) алу; **~ зага́дку** табышмакны табу

отга́дка *ж* **1.** *см.* **отгада́ть**; **2.** (*ответ на загадку*) табышмакның жавабы

отга́дчик *м разг.* табышмак табучы; белүче; [төш] юраучы

отга́дывать *несов. см.* **отгада́ть**

отгиба́ть *несов. см.* **отогну́ть**

отгиба́ться *несов.* **1.** *см.* **отогну́ться**; **2.** *страд. от* **отгиба́ть**

отглаго́льн||ый, -ая, -ое *грам.* фигыльдән ясалган; **~ое существи́тельное** фигыльдән ясалган исем

отгла́дить *сов. что* яхшылап үтүкләү, үтүкләп алу

отгла́диться *сов.* үтүкләнү

отгла́живать *несов. см.* **отгла́дить**

отгла́живаться *несов.* **1.** *см.* **отгла́диться**; **2.** *страд. от* **отгла́живать**

отгнива́ть *несов. см.* **отгни́ть**

отгни́||ть *сов.* череп төшү; череп ишелү; **ве́тки ~ли** ботаклар череп төшкән

отгова́ривать *несов. см.* **отговори́ть**

отгова́риваться *несов.* **1.** *см.* **отговори́ться**; **2.** *страд. от* **отгова́ривать**

отговори́ть *сов. кого от чего и с неопр.* күндерү, үгетләп күндерү (*берәр нәрсәне эшләмәскә*), үгетләп тыеп калу, баш тарттыру; **~ е́хать** бармаска күндерү

отговори́ться *сов.* сылтау табу, сылтау табып котылу, сылтау табып баш тарту; **~ нездоро́вьем** авыруга сылтап баш тарту

отгово́рка *ж* сылтау, юк сәбәп, юкбар сәбәп

отголо́с||ок *м* **1.** (*отзвук*) яңгыраш, кайтаваз **2.** *перен.* яңгыраш, нәтиҗә; эз; тәэсир; **~ки неда́вних собы́тий** күптән түгел булган вакыйгаларның тәэсире

отго́н *м* **1.** *см.* **отогна́ть** 1, 3; **2.** *с.-х.* (*пребывание на пастбищах — о скоте*) көтүдә йөрү (йөртү) **3.** (*продукт отгонки*) куудан калган продукт

отго́нка *ж см.* **отогна́ть** 3; **~ ма́сел из не́фти** нефтьтән май чыгару

отго́нн||ый, -ая, -ое *с.-х.* күчмә көтүлекле; **~ое животново́дство** күчмә көтүлекле терлекчелек

отгоня́ть *несов. см.* **отогна́ть**

отгора́живать *несов. см.* **отгороди́ть**

отгора́живаться *несов.* **1.** *см.* **отгороди́ться**; **2.** *страд. от* **отгора́живать**

отгора́ть *несов. см.* **отгоре́ть**

отгоре́ть *сов.* **1.** (*кончить гореть*) янып бетү, янудан туктау, сүнү **2.** (*перегорев, отвалиться*) янып төшү, янып өзелеп төшү

отгороди́ть *сов. кого-что* бүлеп алу, бүлеп кую, киртәләп (коймалап) алу

отгороди́ться *сов.* **1.** (*отделить себя*) бүленү, бүлеп алыну (*койма, киртә һ.б.ш. белән*) **2.** *перен. разг.* (*изолировать себя*) читләшү, араны өзү

отграниче́ние *с см.* **отграни́чить**

отграни́чивать *несов. см.* **отграни́чить**

отграни́чить *сов. что* чикләү, чик куеп аеру, чикләп (чиген билгеләп) чыгу

отгреба́ть *несов. см.* **отгрести́**

отгреме́||ть *сов.* **1.** (*кончить греметь*) күкрәп туктау **2.** *перен.* туктау, бетү; **~ли бои́** сугышлар бетте

отгрести́ *сов.* **1.** *что* көрәп ташлау; читкә тырмап кую; **~ снег** карны көрәп ташлау **2.** (*отплыть*) ишеп китү, ишкәк белән китү

отгро́ха||ть *сов.* **1.** *разг.* гөрселдәүдән туктау, гөрселдәми башлау; **пу́шки ~ли** пушкалар гөрселдәүдән туктадылар **2.** *что, прост.* кору, шәп итеп салу; оештыру, шаулатып үткәрү; **~ть сва́дьбу** шаулатып туй үткәрү

отгружа́ть *несов. см.* **отгрузи́ть**

отгрузи́ть *сов. что* төяп озату (җибәрү); **~ у́голь** күмер төяп җибәрү

отгру́зка *ж см.* **отгрузи́ть**

отгрыза́ть *несов. см.* **отгры́зть**

отгры́зть *сов. что* чәйнәп өзү, чәйнәп өзеп алу; кимереп өзү, кимереп (тешләп) өзеп чыгару

отгу́л *м* ял, отгул (*эш вакытыннан тыш эшлагән өчен бирелә торган ял*)

отгу́ливать *несов. см.* **отгуля́ть** 2

отгуля́ть *сов. разг.* **1.** (*кончить гулять*) күңел ачып йөреп кайту **2.** *что, разг.* (*за сверхурочную работу*) ял итү, эш вакытыннан тыш эшләгән өчен ял итү **3.** *что, прост.* (*отпраздновать*) [бәйрәм] уздыру, бәйрәм итү; **~ сва́дьбу** туй уздыру

отда||ва́ть *несов.* **1.** *см.* **отда́ть**; **2.** *безл. чем, разг.* (*иметь привкус, запах*) тәм килү; ис килү **3.** *перен. чем, разг.* (*иметь оттенок*) охшау, бераз охшау; ... сыман булу; сизелү; **э́то ~ёт старино́й** бу борын замандагыга охшый

отдава́ться *несов.* **1.** *см.* **отда́ться**; **2.** *страд. от* **отдава́ть** 1

отдави́ть *сов. что* (*ногу, руку*) басып имгәтү, басып (кысып) авырттыру

отда́вливать *несов. см.* **отдави́ть**

отда́ивать *несов. см.* **отдои́ть** 1

отдале́ни||е *с* 1. *см.* **отдали́ть, отдали́ться**; 2. ераклык, ерак ара, ерак; **остановúться в ~и** ераста туктап калу

отдалённость *ж* ераклык, ерак булу; **~ от це́нтра** үзәктән ерак булу

отдалённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **отдали́ть**; 2. ерак, эрактагы; **~ый райо́н** ерак район 3. *перен.* бик ерак, бик аз, аз гына; **~ое схо́дство** бик аз охшашлык

отдали́ть *сов. кого-что* ераклаштыру, ерагайту, кичектерү, соңлату; читләштерү, читләтү; **~ встре́чу** очрашуны кичектерү; **~ друзе́й** дусларны читләштерү

отдали́ться *сов. что от кого-чего* ераклашу, ерагаю; соңлау, читләшү; читкә китү; **~ от те́мы** темадан читкә китү; **~ от бе́рега** ярдан ерагаю

отдаля́ть *несов. см.* **отдали́ть**

отдаля́ться *несов.* 1. *см.* **отдали́ться**; 2. *страд. от* **отдаля́ть**

отда́ривать *несов. см.* **отдари́ть**

отдари́ть *сов. кого-что, разг.* бүләккә каршы бүләк бирү

отда́ть *сов.* 1. *кого-что* бирү; кайтару, кайтарып бирү; **~ долг** бурычны кайтару 2. *кого-что* бирү; **~ жизнь за свобо́ду Ро́дины** Ватанның азатлыгы өчен гомерен бирү 3. *что* (*заплатить*) түләү 4. *кого кому, за кого, уст.* (*выдать замуж*) кияүгә бирү 5. *кого-что* (*вручить; поместить куда-л.*) бирү, (*берәр җиргә*) урнаштыру; **~ кни́гу в переплёт** китапны төпләргә бирү; **~ ребёнка в де́тский сад** баланы балалар бакчасына бирү 6. *кого-что, разг.* (*продать*) бирү, сату; **~ за бесце́нок** бик арзан бәягә сату 7. *что* бирү; **~ прика́з** боерык бирү 8. (*об оружии при выстреле*) сугу, бәрү; **ружьё о́тдало в плечо́** мылтык иңбашына бәрде 9. *что* (*освободить, отвязать*) ташлау; **~ я́корь** якорь ташлау ♦ **~ бо́гу ду́шу** *уст.* үлү; гүр иясе булу; **~ до́лжное** дөрес бәя бирү, бәяләп җиткерү; **~ после́дний долг** (*үлгән кеше белән*) соңгы мәртәбә хушлашу (*кумәргә бару, кумудә катнашу*); **~ себе́ отчёт** аңлау, төшенү

отда́||ться *сов.* 1. *кому-чему, на что* бирелү; буйсыну; **~ться на во́лю победи́теля** жиңүче ихтыярына бирелү; **~ться мра́чным ду́мам** ямьсез уйларга бирелү 2. *кому-чему* (*посвятить себя*) бирелү; **~ться спо́рту** спортка бирелү 3. *кому* (*о женщине*) бирелү, җенси мөнәсәбәткә керү 4. *перен.* (*о звуке*) бәрү, яңгырау, яңгырап китү; **в лесу́ ~ло́сь э́хо** урманда кайтаваз ишетелде

отда́ч||а *ж* 1. *см.* **отда́ть** 1-5, 7-9; 2. (*коэффициент полезного действия*) бирем, файдалы эш коэффициенты 3. *перен.* нәтиҗәлелек, [эштә] файдалы нәтиҗә; **рабо́тать с по́лной ~ей** зур нәтиҗәлелек белән эшләү

отдвижно́й, -а́я, -о́е этеп йөртелә торган, шудырмалы

отдежу́рить *сов.* 1. (*кончить дежурить*) дежур торуны тәмамлау 2. *что* (*нек-рое время*) дежур тору, дежурда булу

отде́л *м* 1. бүлек; бүлекчә; **~ ка́дров** кадрлар бүлеге; **~ наро́дного образова́ния** халык мәгарифе бүлеге 2. (*часть книги, газеты*) бүлек

отде́лать *сов.* 1. *что* (*придать законченный вид*) эшен бетерү, эшен төгәлләү; эшкәртеп чыгу, җиренә җиткерү; **~ статью́** мәкаләне эшкәртеп чыгу 2. *что чем* (*украсить*) бизәкләү, матурлау; **~ пла́тье вы́шивкой** күлмәкне чигеп бизәкләү 3. *кого, прост.* (*выругать, избить*) бик ныкы тиргәү (сүгү)

отде́латься *сов. разг.* 1. *от кого-чего* котылу, ерып (ерынып) чыгу; **~ от уро́ков** дәресләрдән котылу 2. *чем* чикләнү; **~ одни́ми обеща́ниями** коры вәгъдәләр белән генә чикләнү 3. *чем* котылу; **~ лёгким испу́гом** (*берәр нәрсә булмыйча калып*) шүрләп кенә котылу

отделе́ни||е *с* 1. *см.* **отдели́ть, отдели́ться**; 2. *обычно мн.* **~я** бүлендек; **гно́йные ~я** эренле бүлендек 3. бүлек; **райо́нное ~е мили́ции** милициянең район бүлеге 4. (*часть концерта, вечера*) бүлек, бүлем 5. *воен.* отделение 6. бүлек; бүлекчә, бүлемтек; **маши́нное ~е** машина бүлеге; **~е в бума́жнике** бумажник бүлемтеге

отдели́тельн||ый, -ая, -ое бүлү ...ы, бүлә торган; **~ая ли́ния** бүлү сызыгы

отдели́ть *сов.* 1. *что* аеру, аерып алу, аерып кую; **~ мя́со от косте́й** итне сөяктән аерып кую 2. *что* бүлү, бүлеп кую; бүлеп алу, бүлеп бирү; **~ часть ко́мнаты** бүлмәнең бер өлешен бүлеп алу 3. *кого, уст.* (*обособить*) башка чыгару

отдели́ться *сов. от кого-чего* 1. аерылу, аерылып чыгу, бүленү; **~ от толпы́** халык төркеменнән аерылу 2. *уст.* (*обособиться*) башка чыгу

отде́лка *ж* 1. *см.* **отде́лать** 1, 2; **оконча́тельная ~** соңгы эшкәртү 2. (*то, чем украшают*) бизәк, отделка

отде́лочн||ый, -ая, -ое эшкәртү ...ы, бизәкләү ...ы; **~ый цех** эшкәртү цехы; **~ые рабо́ты** бизәкләү эшләре

отде́лывать *несов. см.* **отде́лать**

отде́лываться *несов.* 1. *см.* **отде́латься**; 2. *страд. от* **отде́лывать**

отде́льност||ь *ж*: **в ~и** (*обособленно*) аерым рәвештә; үзенә башка, аерым алганда; хосусан

отде́льн||ый, -ая, -ое 1. аерым, үзенә башка; **~ая кварти́ра** аерым квартир 2. аерым, кайбер; **~ые крити́ческие замеча́ния** кайбер тәнкыйть искәрмәләре

отделя́ть *несов.* 1. *см.* **отдели́ть**; 2. *что от чего* (*служить границей*) аерып (бүлеп) тору, чикләү

отделя́ться *несов.* 1. *см.* **отдели́ться**; 2. *страд. от* **отделя́ть**

отдёргивать *несов. см.* **отдёрнуть**

отдёрнуть *сов. что* тартып кую, тартып алу; тартып ачу (ачып кую); **~ ру́ку** кулны тартып алу; **~ занаве́ску** пәрдәне тартып ачу

отдира́ть *несов. см.* **отодра́ть**

отдира́ться *несов.* 1. *см.* **отодра́ться**; 2. *страд. от* **отдира́ть**

отдои́ть *сов.* 1. *кого-что и без доп.* (*закончить дойку*) савып бетерү 2. *что, чего* (*подоить немного*) савып алу, бераз савып алу; **~ молока́** бераз сөт савып алу

отдохну́ть *сов.* ял итү, ял алу

отдуба́сить *сов. кого, прост.* дөмбәслән (тукмаклап) ташлау

отдува́ться *несов.* 1. *разг.* (*тяжело дышать*) авыр сулау, авыр сулыш алу 2. *перен. прост.* җавап бирү, авырлыгын күтәрү

отду́шина *ж* 1. төннек, җиллек, юллык; **~ в пе́чи** мичнең юллыгы 2. *перен.* юану, юаныч

о́тдых *м* ял, ял итү; **день ~а** ял көне; **дом ~а** ял йорты

отдыха́ть *несов. см.* **отдохну́ть**

отдыха́ющ||ий, -ая, -ое 1. *прич. от* **отдыха́ть**; 2. *в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~ая** *ж* ял итүче

отдыша́ться *сов.* тын алу, тын ала башлау, тыныч сулый башлау; **~ по́сле бе́га** йөгергәннән соң тын алу

отёк *м* җилсенү, шешенү, шеш, сары су төшү; **~ ног** аяклар шешенү

отека́ть *несов. см.* **оте́чь**

отёл *м* бозаулау

отели́ться *сов.* бозаулау

оте́ль *м* отель (*гостиница*)

отепли́тельный, -ая, -ое җылыту ...ы, җылыта торган; **~ материа́л** җылыту материаллары

отепли́ть *сов. что* җылыту; **~ зда́ние** бинаны җылыту

отепля́ть *несов. см.* **отепли́ть**

отере́ть *сов. что* сөртү, сөртеп алу; **~ слёзы** күз яшьләрен сөртеп алу

отере́ться *сов.* сөртенү

отеса́ть *сов. см.* **обтеса́ть**

отёсывать *несов. см.* **отеса́ть**

оте́ц *м* 1. ата, атай 2. *перен. мн.* **отцы́** (*предки*) ата-бабалар 3. *перен.* (*основоположник*) ата, нигез салучы; **Циолко́вский — ~ космона́втики** Циолковский — космонавтика атасы 4. *разг.* (*при обращении*) агай, абзый ♦ **~ семе́йства** балалар атасы

оте́ческ||ий, -ая, -ое аталарча; **прояви́ть ~ую забо́ту** аталарча кайгыртучанлык күрсәтү

оте́чественн||ый, -ая, -ое ватан ...ы, туган ил ...ы; үз илебез ...ы; **това́ры ~ого произво́дства** үз илебездә җитештерелгән товарлар ♦ **Оте́чественная война́** Ватан сугышы; **Вели́кая Оте́чественная война́** Бөек Ватан сугышы

оте́чество *с высок.* ватан, туган ил

отёчн||ый, -ая, -ое җилсенгән, шешенгән; **~ое лицо́** җилсенгән йөз

отёчь *сов.* 1. шешенү, җилсенү; **но́ги отекли́** аяклар шешенде 2. (*о свече*) шәм эреп төшү

отжа́ть I *сов.* 1. *что* сыгу, сыгып чыгару (бетерү); **~ бельё** керне сыгу 2. *кого-что, разг.* (*отделить, оттеснить*) кысрыклау, кысрыклап чыгару

отжа́ть II *сов. что* (*закончить жатву*) ураклы тәмамлау, урып бетерү; **~ пшени́цу** бодайны урып бетерү

отже́чь *сов. что, тех.* (*произвести отжиг*) яндыру, яндырып чыныктыру (*металл эшкәртүдә*)

отжива́ть *несов. см.* **отжи́ть**

отжи́вш||ий, -ая, -ое **1.** *прич. от* **отжи́ть; 2.** искергән, иске; **~ие поня́тия** искергән төшенчәләр

о́тжиг *м тех.* яндыру; **~ ста́ли** корычны яндыру

отжига́ть *несов. см.* **отже́чь**

о́тжим *м см.* **отжа́ть** I 1

отжима́ть *несов. см.* **отжа́ть** I 1

отжи́мка *ж см.* **отжа́ть** I 1

отжи́ть *сов.* **1.** *что* гомер узу, [яшен] яшәү; **он о́тжил свой век** ул үз гомерен яшәгән **2.** (*устареть*) искерү, кулланудан чыгу

отзва́нивать *несов. см.* **отзвони́ть**

отзвене́ть *сов.* **1.** (*прозвенеть*) шалтырау, шалтырап бетү **2.** (*перестать звенеть*) шалтырап туктау, яңгырап туктау (тыну)

отзвони́ть *сов.* чаң сугып туктау, чаң сугудан туктау; шалтыратып туктау

о́тзвук *м* **1.** (*эхо*) кайтаваз, яңгыравык, яңгыраш **2.** (*звук издалека*) яңгырау; **~ пальбы́** атыш яңгыравы **3.** *перен.* (*ответное чувство*) яңгыраш; теләктәшлек **4.** *перен. чего* чагылыш; эз, калдык; **~ и про́шлого** үткән заманның чагылышлары

отзвуча́ть *сов.* яңгырап туктау, тыну, тынып калу

отзови́зм *м ист.* отзовизм

отзови́ст *м ист.* отзовизм яклы кеше, отзовизм тарафдары, отзовист

отзо́л *м* **1.** *см.* **отзоли́ть; 2.** (*раствор с золой*) селте

отзоли́ть *сов. что, спец.* селтеләү, (*тире илә́гәндә*) селтедә эшкәртү

отзо́лка *ж см.* **отзоли́ть**

отзо́льный, -ая, -ое *спец.* селте ...ы, селтеләү ...ы; **~ чан** селтеләү чаны

о́тзыв *м* **1.** *см.* **отозва́ть** 2; **2.** (*отклик*) җавап **3.** (*рецензия*) бәя, бәяләмә, фикер **4.** (*ответ на пароль*) отзыв, парольга җавап сүзе

отзыва́ть *несов. см.* **отозва́ть**

отзыва́ться *несов.* **1.** *см.* **отозва́ться**; **2.** *страд. от* **отзыва́ть**

отзывн||о́й, -ая, -о́е *дип.* чакыртып алу ...ы; чакыртып кире кайтару ...ы; **~ая гра́мота** чакыртып кайтару грамотасы

отзы́вчивость *ж* ярдәмчеллек, кеше хәлен уртаклашу, кеше хәленә керү

отзы́вчивый, -ая, -ое ярдәмчел, кеше кайгысын уртаклашучан, кеше хәленә керүчән

отира́ть *несов. см.* **отере́ть**

отира́ться *несов.* **1.** *см.* **отере́ться**; **2.** *страд. от* **отира́ть**

отка́з *м* **1.** *см.* **отказа́ть** I, **отказа́ться; 2.** туктау, эшләүдән туктау, тукталу; тоткарлык; **маши́на де́йствует без ~а** машина тоткарсыз эшли ♦ **до ~а** шыгрым тулы; бик күп итеп; ахыр чиккәчә, актык чиккә кадәр

отказа́||ть I *сов.* **1.** *кому в чём* кире кагу, үтенечне үтәмәү; **~ть в про́сьбе** үтенечне кире кагу **2.** *кому от чего, уст.* (*уволить*) чыгару (*эштән, урыннан, хезмәттән һ.б.ш.*) **3.** *перен. кому в чём* инкарь итү, мәхрүм итү; **ему́ нельзя́ ~ть в тала́нте** аның талантын инкарь итеп булмый **4.** (*перестать действовать*) эшләүдән туктау, эшләми башлау; **мото́р ~л** мотор эшләми башлады ♦ **не откажи́[те]** *в чём и с неопр.* зинһар, зинһар өчен; **~ть от до́ма** *кому, уст.* танышлыкны өзү, килеп йөрмәскә кушу

отказа́ть II *сов. кого-что, уст.* (*отдать по завещанию*) васыять итү, мирас итеп калдыру; **~ иму́щество де́тям** милекне балаларга васыять итү

отказа́||ться *сов.* **1.** *от чего и с неопр.* баш тарту, ваз кичү; фикереннән түнү; **~ться пое́хать** барудан баш тарту; **~ться от свои́х слов** үз сүзеннән баш тарту **2.** *с неопр. разг.* (*перестать действовать*) ватылу, эшләми башлау; бозылу

отка́зывать I *несов. см.* **отказа́ть** I

отка́зывать II *несов. см.* **отказа́ть** II

отка́зываться *несов.* **1.** *см.* **отказа́ться; 2.** *прост.* (*не признаваться, отпираться*) тану

отка́лывать I *несов. см.* **отколо́ть** I

отка́лывать II *несов. см.* **отколо́ть** II

отка́лываться I *несов.* **1.** *см.* **отколо́ться** I; **2.** *страд. от* **отка́лывать** I

отка́лываться II *несов.* **1.** *см.* **отколо́ться** II; **2.** *страд. от* **отка́лывать** II

отка́пывать *несов. см.* **откопа́ть**

отка́рмливание *с см.* **откорми́ть**

отка́рмливать *несов. см.* **откорми́ть**

отка́т *м* **1.** *см.* **откати́ть, откати́ться**; **2.** *воен.* кире тибү, кире китү, артка чигү; **~ору́дия** орудиенең кире кайтуы (*атканнан соң*)

откати́ть *сов.* **1.** *что* тәгәрәтү, тәгәрәтеп кую, тәгәрәтеп җибәрү; **~ бревно́** бүрәнәне читкә тәгәрәтү **2.** *разг.* (*быстро отъехать*) тиз генә китеп бару

откати́||ться *сов.* **1.** тәгәрәп китү, читкә тәгәрәү; **колесо́ ~лось** тәгәрмәч тәгәрәп китте **2.** *перен.* (*быстро отступить*) чигенү; **враг ~лся** дошман чигенде

отка́тчик *м горн.* откатчик, [күмер, руда] ташучы (*шахталарда*)

отка́тывать *несов. см.* **откати́ть** I

отка́тываться *несов. см.* **откати́ться**; **2.** *страд. от* **отка́тывать**

откача́ть *сов.* **1.** *что* (*выкачать насосом*) суыртып алу, суыртып чыгару; **~ во́ду** суны суыртып чыгару **2.** *кого* (*привести в чувство тонувшего*) һушка китерү (*ясалма сулыш ясап*)

отка́чивание *с см.* **откача́ть**; **~ во́здуха** һаваны суыртып чыгару

отка́чивать *несов. см.* **откача́ть**

отка́чка *ж разг. см.* **откача́ть** 1; **~ воды́** су суыртып алу

откачну́ть *сов. кого-что, разг.* селкетеп (чайкалдырып) җибәрү

откачну́||ться *сов. разг.* селкенеп читкә тайпылу (авышу), селкенеп читкә китү; **ма́ятник ~лся** маятник селкенеп читкә тайпылды

отка́шливать *несов. см.* **отка́шлянуть**

отка́шливаться *несов.* **1.** *см.* **отка́шляться**; **2.** *страд. от* **отка́шливать**

отка́шлянуть *сов. что* йөткереп (какырып) чыгару (*тамакка утырган какрыкны һ.б.ш.*)

отка́шляться *сов.* **1.** (*откашлянуть*) йөткерү, йөткереп (какырып) чыгару **2.** (*прочистить горло*) тамак кырып кую, йөткереп алу

откида́ть *сов. что* алып ташлау (ыргыту); **~ ка́мни с доро́ги** юлдан ташларны алып ташлау

откидн||о́й, -а́я, -о́е күтәрелмәле, ачылмалы, күтәреп куела торган; **~о́е сиде́нье** күтәреп куела торган урындык

отки́дывать *несов. см.* **откида́ть, отки́нуть**

отки́дываться *несов.* **1.** *см.* **отки́нуться**; **2.** *страд. от* **отки́дывать**

отки́нуть *сов.* **1.** *кого-что* (*отбросить*) ташлау; читкә алып ташлау **2.** *что* төшерү; күтәрү; кайтарып кую; ачу, ачып кую; **~ воротни́к** яканы төшерү; **~ порть́е́ру** портьераны ачып кую **3.** *что* артка ташлау; **~ го́лову** башны артка ташлау **4.** *перен.* (*отказаться; пренебречь*) баш тарту, алып ташлау

отки́нуться *сов.* артка ташлану; **~ на спи́нку кре́сла** кәнәфинең артына сөялү

откла́дывать *несов. см.* **отложи́ть**

откла́ниваться *несов. см.* **откла́няться**

откла́няться *сов. уст.* саубуллашу, хушлашу

откле́ивать *несов. см.* **откле́ить**

откле́иваться *несов.* **1.** *см.* **откле́иться; 2.** *страд. от* **откле́ивать**

откле́ить *сов. что* куптару, кубару, куптарып (кубарып) алу; **~ ма́рку** марканы куптарып алу

откле́иться *сов.* кубу, кубып төшү, кубып чыгу

отклепа́ть *сов. что* чүкеп төшерү (алу), куптарып төшерү (алу)

отклёпывать *несов. см.* **отклепа́ть**

о́тклик *м* **1.** (*ответ на зов*) җавап, җавап тавышы, эндәшү **2.** *перен.* яңгыравык, яңгыраш; тәэсир, эз; **~ и про́шлых собы́тий в пье́се** пьесада үткән вакыйгаларның яңгырашы **3.** *перен.* бәя, бәя бирү, бәяләү; **благоприя́тные ~ и на кни́гу** китапка уңай бәяләр

откликáться *несов. см.* **откли́кнуться**

откли́кнуться *сов. на что* **1.** (*ответить на зов*) җавап бирү (кайтару), тавыш бирү **2.** *перен.* фикерен әйтү; карашын белдерү, мөнәсәбәтен белдерү; **~ на собы́тия** вакыйгалар турында үз фикерен әйтү

отклоне́ние *с* **1.** *см.* **отклони́ть, отклони́ться; ~ стре́лки** укның тайпылуы **2.** читкә чыгу, тайпылу, тайпылыш; **~ от но́рмы** нормадан читкә чыгу

отклони́ть *сов. что* **1.** (*отвести в сторону*) бер якка авыштыру, тайпылдыру **2.** (*отвергнуть*) кабул итмәү, кире кагу; **~ чью-л. кандидату́ру** *берәүнең* кандидатурасын кире кагу

отклони́ться *сов.* **1.** (*сдвинуться в сторону*) авышу, тайпылу **2.** *перен.*

читкэ китү (чыгу); башкага күчү; ~ от ку́рса курсыннан читкэ китү; ~ от те́мы темадан читкэ китү

отклоня́ть *несов. см.* **отклони́ть**

отклоня́ться *несов.* **1.** *см.* **отклони́ться; 2.** *страд. от* **отклоня́ть**

отключа́тель *м тех.* аергыч, өзгеч

отключа́ть *несов. см.* **отключи́ть**

отключи́ть *сов.* өзү, кисү, аеру; ~ **телефо́н** телефонны өзү

откова́ть *сов. что* **1.** (*изготовить ковкой*) чүкеп ясау (эшләү) **2.** (*отбить*) чүкеп төшерү, чүкеп алу; ~ **подко́ву** даганы чүкеп төшерү

отко́вывать *несов. см.* **откова́ть**

отковы́ривать *несов. см.* **отковырну́ть**

отковырну́ть *сов. однокр. см.* **отковыря́ть**

отковыря́ть *сов. что, разг.* куптару, куптарып алу

отказыря́ть *сов. кому* (*в знак приветствия*) честь бирү, кулны козырёкка алу

отколо́чивать *несов. см.* **отколоти́ть** I

отколоти́ть *сов. разг.* **1.** *что* (*отделить*) кага-кага куптарып алу, суккалап алу **2.** *кого* (*сильно побить*) тукмау, тукмап ташлау, кыйнап ташлау

отколо́ть I *сов.* **1.** *что* (*отделить от целого*) ватып (китеп) алу, ярып алу **2.** *перен. кого-что* (*заставить порвать с кем-л.*) аерып алу **3.** *что, прост.* эйтеп ташлау; эшләп ташлау; ~ **глу́пость** ахмаклык эшләп ташлау

отколо́ть II *сов. что* ычкындыру; ~ **бант** бантны ычкындыру

отколо́ться I *сов.* **1.** (*отделиться, отпасть*) кителеп төшү; ватылып (сынып) төшү **2.** *перен.* (*утратить связь*) аерылу, мөнәсәбәтне өзү, бәйләнешне өзү

отколо́||ться II *сов.* ычкыну; **була́вка ~лась** булавка ычкынган

откомандирова́ть *сов. кого-что* икенче урынга (эшкә) күчерү, җибәрү

откомандиро́вывать *несов. см.* **откомандирова́ть**

откопа́ть *сов. кого-что* **1.** (*копая, извлечь*) казып алу (чыгару) **2.** *перен. разг.* (*найти*) табу, эзләп табу, чокып чыгару

отко́рм *м* симертү, көрәйтү, симертү өчен ашату; **поста́вить свине́й на** ~ дуңгызларны симертү өчен ашату

откорми́ть *сов. кого-что* симертү, симергәнче ашату, сугымга симертү

откорми́ться *сов. разг.* симерү, көрәю

отко́рмленный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **откорми́ть; 2.** симертелгән, симез, көр

отко́рмочн||ый, -ая, -ое симертә торган, симертү ...ы; ~**ая ба́за** симертү базасы

откорректи́ровать *сов. что* төзәтү, төзәтмәләр керту; корректив кертү, корректировкалап бетерү

отко́с *м* **1.** (*покатый спуск*) сөзәк җир, авыш җир, сөзәк урын **2.** (*дорожная насыпь*) юл өеме, откос; яр (*тимер юлда*); **пусти́ть по́езд под** ~ поездны [рельслы юлдан] яр астына җибәрү

откочева́ть *сов.* күчен китү, күченеп китү

откочёвывать *несов. см.* **откочева́ть**

открепи́тельный, -ая, -ое учёттан төшерү ...ы; ~ **тало́н** учёттан төшерү талоны

открепи́ть *сов.* **1.** *что* (*отвязать, отделить*) чишү, аеру, чишеп (аерып) алу; ~ **ло́дку** көймәне чишеп алу **2.** *кого, офиц.* (*снять с учёта*) учёттан төшерү

открепи́ться *сов.* **1.** чишелү, аерылу **2.** учёттан төшү

открепле́ние *с см.* **открепи́ть, открепи́ться**

открепля́ть *несов. см.* **открепи́ть**

открепля́ться *несов.* **1.** *см.* **открепи́ться; 2.** *страд. от* **открепля́ть**

откре́щиваться *несов. от кого-чего, разг.* котылырга тырышу, (*төрле юллар белән*) баш тартырга тырышу

открове́ние *с* яңалык, яңа нәрсә, ачыш; **э́ти слова́ — по́лное** ~ **для всех** бу сүзләр — барыбыз өчен дә зур яңалык

открове́нничать *несов. с кем, разг.* серләрне ачып салу, эч серләрен сөйләү, ачыктан-ачык сөйләү

открове́нность *ж* яшермичә сөйләү; эчкерсезлек, саф күңеллелек

открове́нный, -ая, -ое **1.** (*искренний*) ачыктан-ачык, ихлас, эчкерсез, саф күңелле, чын күңелдән; ~ **разгово́р** чын күңелдән сөйләшү **2.** (*нескрываемый*) ачыктан-ачык, шәрран яра

откромса́ть *сов. что, разг.* каерып алу, каерып кисеп алу, умырып алу

открути́ть *сов. что* борып алу (ачу, чыгару); сүтү; ~ **кран** кранны борып алу; ~ **верёвку** ишелгән бауны сүтү

открути́ться *сов.* **1.** борылып чыгу **2.** *перен. прост.* (*отделаться от чего-л.*) хәйлә табып котылу (читтә калу)

откру́чивать *несов. см.* **открути́ть**

откру́чиваться *несов.* **1.** *см.* **открути́ться; 2.** *страд. от* **откру́чивать**

открыва́лка *ж разг.* ачкыч; ~ **для консе́рвов** консерв[ы] савытының ачкычы

открыва́ть *несов. см.* **откры́ть**

открыва́ться *несов.* **1.** *см.* **откры́ться; 2.** *страд. от* **открыва́ть**

откры́тие 1. *см.* **откры́ть; ~ кла́пана** клапанның ачылуы; ~ **съе́зда** съезд ачылу **2.** ачу, ачыш, уйлап табу; **нау́чное** ~ фәнни ачыш; **географи́ческое** ~ географик ачыш; **сде́лать** ~ яңа нәрсә ачу

откры́тка *ж* ачык хат, открытка

откры́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **откры́ть; 2.** ачык; ялан; ~**ая ме́стность** ялан җир; **под** ~**ым не́бом** ачык һавада **2.** (*доступный для всех желающих*) ачык; ~**ый уро́к** ачык дәрес **3.** (*явный, нескрываемый*) ачыктан-ачык; **вы́ступить с** ~**ым проте́стом** ачыктан-ачык протест белән чыгу; ~**ая вражда́** ачыктан-ачык дошманлык **4.** (*искренний, откровенный*) эчкерсез, саф күңелле **5.** *горн.* җир өстендәге; ~**ые го́рные рабо́ты** җир өстендәге казу эшләре ♦ **в** ~**ую** ачыктан-ачык; ~**ая ра́на** ачык яра; ~**ое письмо́** ачык хат; ~**ый вопро́с** хәл ителмәгән мәсьәлә; ~**ый лоб** кин маңгай; **при** ~**ых две́рях** халык алдында (*суд утырышы турында*); **с** ~**ыми глаза́ми** аңлап, белеп

откры́ть *сов. что* **1.** ачу; ~ **дверь** ишекне ачу **2.** (*сделать доступным*) ачу; ~ **путь** юл ачу **3.** (*обнажить*) ачу **4.** ачу, ачып җибәрү; ~ **зо́нтик** зонтикны ачып җибәрү; ~ **глаза́** 1) күзне ачу; 2) *перен. кому кемнеңдер* күзен ачу, *кемгәдер* аңлатып бирү; ~ **кни́гу** китапны ачу **5.** (*пустить, ввести в действие*) җибәрү; ~ **во́ду** су җибәрү; ~ **газ** газ җибәрү **6.** (*обнаружить, сообщить*) ачу, әйтү, игълан итү; ~ **пра́вду** дөреслекне ачу; ~ **своё и́мя** үзенең исемен әйтү **7.** (*предоставить*) бирү; ~ **возмо́жность** мөмкинлек бирү **8.** (*положить начало*) башлап җибәрү, ачу; ~ **заседа́ние** утырышны ачу; ~ **теа́тр** театр ачу; ~ **ого́нь** ут ачу **9.** (*установить наличие чего-л.*) ачу; табу; ~ **за́говор** заговор ачу; ~ **дре́внюю ру́копись** борынгы кулъязманы табу ♦ ~ **Аме́рику** Американы ачу (*куптән билгеле булган әйберне яңа әйбер дип сөйләү*)

откры́||ться *сов.* **1.** ачылу; **окно́** ~**лось** тәрәзә ачылды **2.** (*перестать заживать*) ачылу; ~**лась ста́рая ра́на** элекке ярасы ачылган **3.** *перен.* (*стать видным*) күренү, ачылу; күренә башлау; **пе́ред на́ми** ~**лся краси́вый вид** безнең алда матур күренеш ачылды **4.** *разг.* (*обнаружиться, стать явным, очевидным*) башлану **5.** *кому* (*раскрыть мысли, тайны*) ачыктан-ачык сөйләп бирү, серләрен сөйләү

отку́да *нареч.* кайдан, кай җирдән, кай урыннан; ~ **ты идёшь?** син кайдан киләсең?; **возвраща́йся,** ~ **прие́хал** кай җирдән килсән, шунда кит ♦ ~ **ни возьми́сь** көтмәгәндә, көтмәгән жирдән, уйламаган җирдән

отку́да-либо, отку́да-нибудь *нареч.* кайдан да булса

отку́да-то *нареч.* кайдандыр

о́ткуп *м ист.* откуп (*аерым бер кешегә дәүләт доходларын җыярга бирелгән хокук*) ♦ **взять на** ~ *что* откупка алу; **отда́ть на** ~ *что* откупка бирү (*бер әр нәрсәне берәүнең карамагына тулысынча бирү яки алу*)

откупи́ться *сов. от кого-чего, уст.* түләп котылу, түләп иреккә чыгу

отку́поривать *несов. см.* **отку́порить**

отку́порить *сов. что* ачу, бөкесен алу, бөкесен чыгару; ~ **буты́лку** шешәне ачу

отку́порка *ж см.* **отку́порить**

откупщи́к *м ист.* откупчы, откуп иясе

откуси́ть *сов. что, чего* **1.** тешләп алу; ~ **кусо́к хле́ба** бер кисәк икмәк тешләп алу **2.** *тех.* (*кыскыч белән*) өзеп алу, элəктереп өзеп чыгару; ~ **коне́ц про́волоки** тимерчыбык очын өзеп алу

отку́сывать *несов. см.* **откуси́ть**

отлага́тельство *с*: **без вся́ких отлага́тельств** һич кичектермәстән

отлага́ть *несов. см.* **отложи́ть**

отлага́ться *несов.* **1.** *см.* **отложи́ться; 2.** *страд. от* **отлага́ть**

ОТЛ-ОТМ

отлакирова́ть *сов. что* лаклап кую, лак белән ялтыратып кую

отла́мывать *несов. см.* **отлома́ть, отломи́ть**

отла́мываться *несов.* 1. *см.* **отлома́ться, отломи́ться**; 2. *страд. от* **отла́мывать**

отлежа́ть *сов. что* [җайсыз ятып] оету; ~ **но́гу** аякны оету

отлежа́||ться *сов. разг.* 1. (*отдохнуть*) ял итү, ятып хәл алу; тернәкләнү 2. ятып өлгерү, ятып өлгерә төшү; **пусть я́блоки ~тся** алмалар ятып өлгерә төшсеннәр

отлёживать *несов. см.* **отлежа́ть**

отлёживаться *несов.* 1. *см.* **отлежа́ться**; 2. *страд. от* **отлёживать**

отлепи́ть *сов. что* куптару, кубару, куптарып (кубарып) алу

отлепи́ться *сов.* кубу, кубып төшү (чыгу)

отлепля́ть *несов. см.* **отлепи́ть**

отлепля́ться *несов.* 1. *см.* **отлепи́ться**; 2. *страд. от* **отлепля́ть**

отлёт *м см.* **отлете́ть** 1; **вре́мя ~а птиц на юг** кошларның көньякка очып китү вакыты ◆ **на ~е** читтә, бер як читтәрәк

отлета́||ть I *сов.* 1. (*кончить летать*) очып туктау, очудан туктау 2. *что, разг.* (*пробыть в авиации*) очучы булып эшләү; **он де́сять лет ~л** ул ун ел очучы булып эшләде

отлета́ть II *см.* **отлете́ть**

отлета́ться *сов. разг.* (*о лётчике*) очудан туктау

отлете́||ть *сов.* 1. (*улететь*) очып китү 2. *разг.* кире сикерү, (очып) китү; сикереп [кире] китү; **мяч ~л от стены́** туп стенага бәрелеп кире китте 3. *разг.* өзелеп төшү; **пу́говица ~ла** төймә өзелеп төште

отле́||чь *сов. безл.* җиңеләю, басылу, җиңеләеп китү; **от се́рдца ~гло́** йөрәгем җиңеләеп китте

отли́в *м* 1. *см.* **отли́ть**; 2. *мор.* су чигенү, су чигенеше; су кайту (*океан һәм ачык диңгез суларының күтәрелеп яңадан кимуе*) 3. (*оттенок цвета*) ...сыман төсмер; **с серебри́стым ~ом** көмешсыман төсмерле

отлива́||ть *несов.* 1. *см.* **отли́ть**; 2. *чем* ...сыман ялтырау; **~ет зо́лотом** алтынсыман ялтырый

отлива́ться *несов. см.* **отли́ться**

отли́вка *ж* 1. *см.* **отли́ть** 3; 2. (*изделие*) коелма, коеп ясалган әйбер; **чугу́нная ~** чуеннан коеп ясалган әйбер

отлипа́ть *несов. см.* **отли́пнуть**

отли́п||нуть *сов. разг.* кубып төшү; **накле́йка ~ла** ябыштырган әйбер кубып төште

отли́ть *сов.* 1. *что, чего* [бераз] агызу, салу, агызып (салып) алу; **~ немно́го молока́** бераз сөт салып алу 2. (*отхлынуть*) кире китү, кире агып китү 3. *что* (*изготовить литьём*) кою, коеп ясау

отли́ться *сов.* (*принять форму, вид*) гәүдәләнү, гәүдәләнеш табу, формасын алу ◆ **отолью́тся слёзы** *чьи кому* каргышы [яше] төшәр әле, күрәчәген күрер әле

отлича́ть *несов. см.* **отличи́ть**

отлича́ться *несов.* 1. *см.* **отличи́ться**; 2. *чем* (*выделяться*) аерылу, аерылып тору, аермасы булу 3. *страд. от* **отлича́ть**

отли́чи||е *с* аерма, аерымлык, үзгәлек, башкалык; **суще́ственное ~е** иң әһәмиятле аерма; **незначи́тельные ~я** кечкенә аермалар ◆ **в ~е от** *чего берәр нәрсәдән* аермалы буларак; **дипло́м с ~ем** кызыл диплом; **зна́ки ~я** орденнар-медальләр

отличи́тельн||ый, -ая, -ое 1. аеру ..ы, аера торган; **~ый знак** аеру билгесе; **~ый при́знак** аера торган билге 2. (*характерный*) мөһим, әһәмиятле, характерлы; **~ая осо́бенность** характерлы үзенчәлек

отличи́ть *сов. кого-что* 1. аеру, аера белү; ~ **хоро́шее от плохо́го** яхшыны яманнан аеру 2. (*наградой выделить*) бүләкләү; бүләк бирү; ~ **храбреца́** батырны бүләкләү

отличи́ться *сов.* 1. өстен чыгу, осталык (батырлык) күрсәтү; ~ **в бою́** сугышта батырлык күрсәтү 2. *шутл.* кызык эш эшләү, кызык итү

отли́чник *м* отличник, бишлегә генә укучы

отли́чница *ж* отличник кыз

отли́чно *нареч.* 1. (*очень хорошо*) бик яхшы, бик шәп, бик әйбәт 2. *разг.* (*выражение согласия*) бик әйбәт, бик яхшы, әйбәт 3. *в знач. сущ. с нескл.* (*отметка*) отлично, бик яхшы; **учи́ться на ~** бик яхшыга уку

отли́чный, -ая, -ое 1. *от кого-чего* (*отличающийся*) аерылып тора торган 2. (*очень хороший*) бик яхшы, бик шәп; ~ **рабо́тник** бик яхшы хезмәткәр

отло́в *м см.* **отлови́ть** 2

отлови́ть *сов.* 1. *кого-что и без доп.* (*кончить ловить*) тотудан туктау, тотмый башлау 2. *кого-что* (*выловить*) тотып бетерү; тотып алу

отло́гий, -ая, -ое сөзәк; ~ **бе́рег** сөзәк яр

отложе́ние *с* 1. *см.* **отложи́ть** 3, 4; **отложи́ться**; ~ **соле́й в органи́зме** организмга тоз утыру 2. *геол.* утырма, катлам

отложи́ть *сов. что* 1. читкә алып кую, аерып алып кую; ~ **ну́жную кни́жку** кирәкле китапны аерып алып кую 2. җыеп кую; ~ **де́ньги на пое́здку** юлга акча җыеп кую 3. *биол.* салу; ~ **я́йца** күкәй салу (*мәс. бөҗәкләр турында*) 4. кичектерү; ~ **реше́ние вопро́са** мәсьәләне хәл итүне кичектерү 5. (*опустить*) кайтарып кую, төшереп кую; ~ **воротни́к** яканы төшереп кую ◆ ~ **в до́лгий я́щик** бик озакка сузу

отложи́ться *сов.* 1. (*осесть в виде слоя*) утыру, утырма тәшкил итү 2. *перен.* сенү, тирән утыру; ~ **в па́мяти** хәтергә тирән утыру

отложно́й, -а́я, -о́е; ~ **воротни́к** кайтарма яка

отлома́ть *сов. что* сындырып алу, ватып төшерү; ~ **ру́чку две́ри** ишек тоткасын сындырып төшерү

отлома́ться *сов.* сынып (ватылып, кыйпылып) төшү

отломи́ть *сов. что* сындырып (ватып) төшерү, сындырып (ватып) алу

отломи́ться *сов.* сынып (ватылып) төшү

отлупи́ть *сов. кого, прост.* тукмап (кыйнап) ташлау, дәмбәсләү

отлуча́ть *несов. см.* **отлучи́ть**

отлуча́ться *несов.* 1. *см.* **отлучи́ться**; 2. *страд. от* **отлуча́ть**

отлуче́ние *с см.* **отлучи́ть**; ~ **от це́ркви** чиркәүдән куу, динсез дип игълан итү

отлучи́ть *сов. кого от чего, уст.* (*изгнать*) аеру, куу, сөрү

отлучи́ться *сов. разг.* китеп тору; чыгып керү, барып кайту

отлу́чка *ж* китү, китеп тору; **самово́льная ~** рөхсәтсез китү

отлы́нивать *несов. разг.* [сылтау табып] баш тарту

отма́лчиваться *несов. см.* **отмолча́ться**

отма́тывать *несов. см.* **отмота́ть**

отмаха́||ть *сов. что, прост.* узу, үтү; **мы ~ли со́рок киломе́тров** кырык километр җир үттек

отма́хивать *несов.* 1. *см.* **отмаха́ть**; 2. *см.* **отмахну́ть**

отма́хиваться *несов. см.* **отмахну́ться**

отмахну́ть *сов. однокр. что* (*отогнать*) кул селтәп куып җибәрү

отмахну́ться *сов.* 1. *однокр.* (*отогнать от себя*) кул селтәп куып җибәрү 2. *перен. разг.* (*оставить без внимания*) кул селтәү (*ризасызлык белдереп*), игътибарсыз карау

отма́чивать *несов. см.* **отмочи́ть**

отмежева́ние *с см.* **отмежева́ть, отмежева́ться**

отмежева́ть *сов. что* (*отделить*) межалау, межа белән аерып алу, межалап бүлеп алу, чик белән аеру

отмежева́ться *сов. от кого-чего* 1. (*отделиться межой*) межа белән аерылу, ызан [чик билгесе] белән аерылу 2. *перен.* (*отделиться*) аерылу, аерылып чыгу 3. *перен.* (*прекратить общение*) аралашмый башлау; араны өзү

отмежёвывать *несов. см.* **отмежева́ть**

отмежёвываться *несов.* 1. *см.* **отмежева́ться**; 2. *страд. от* **отмежёвывать**

о́тмель *ж* сайлык, сай урын, сай җир (*яр буендагы*)

отме́на *ж* 1. *см.* **отмени́ть**; ~ **спекта́кля** спектакльне үткәрмәскә булу

отмени́ть *сов. что* бетерү, юкка чыгару, гамәлдән чыгару; булдырмау, үткәрмәү; үткәрмәскә булу; ~ **зако́н** законны юкка чыгару; ~ **заседа́ние** утырышны үткәрмәскә булу

отме́нный, -ая, -ое бик яхшы, бик әйбәт, бик шәп, менә дигән

отменя́ть *несов. см.* **отмени́ть**

отмере́ть *сов.* 1. (*омертветь*) кору 2. *перен.* юкка чыгу, бетү

отмерза́ть *несов. см.* **отмёрзнуть**

отмёрзнуть *сов.* туңу, туңып кору, туңып һәлак булу; өшү, өшеп сизми башлау

отме́ривать *несов. см.* **отме́рить**

отме́рить *сов. что* үлчәп алу, үлчәп бирү (кую)

отмеря́ть *несов. см.* **отме́рить**

отмести́ *сов. что* **1.** себереп ташлау, себереп кую (төшерү); **~ сор в у́гол** чүпне почмакка себереп кую **2.** *перен.* (*отвергнуть*) кире кагу, юкка чыгару; **~ все непра́вильные до́воды** дөрес булмаган барлык дәлилләрне кире кагу

отме́стк||а *ж*: **сде́лать в ~у** үч итеп эшләү

отмета́ть *несов. см.* **отмести́**

отме́тить *сов.* **1.** *кого-что* билгеләү, билгеләп кую; тамгалау, тамга салу; **~ отсу́тствующих** килмәгән кешеләрне билгеләү **2.** *кого-что* (*заметить*) билгеләү, күреп алу, игътибар итү; **~ досто́инства статьи́** мәкаләнең уңай якларына игътибар итү **3.** *что* (*подчеркнуть значение*) билгеләү, искә алу, күрсәтеп китү; **~ *чьи-л.* достиже́ния** *кемнең дә булса* казанышларын искә алып китү **4.** *что*, *разг.* (*отпраздновать*) билгеләп үтү, бәйрәм итү

отме́титься *сов.* билгеләнү, үзен билгеләтү; **~ в спи́сках избира́телей** сайлаучылар исемлегендә үзен билгеләтү

отме́тк||а *ж* **1.** *см.* **отме́тить** 1; **2.** (*знак*) билге, тамга; **~а в ве́домости** ведомостьтагы билге **3.** билге; **получи́ть хоро́шую ~у** яхшы билге алу

отмеча́ть *несов. см.* **отме́тить**

отмеча́||ться *несов.* **1.** *см.* **отме́титься**; **2.** (*обнаруживаться*) бар булу, күренү, беленү; **~ются кру́пные успе́хи в нау́ке** фәндә зур уңышлар барлыгы күренә **3.** *страд. от* **отмеча́ть**

отмира́ние *с см.* **отмере́ть**

отмира́ть *несов. см.* **отмере́ть**

отмобилизова́ть *сов. кого-что* тулысынча мобилизацияләү

отмобилизова́ться *сов.* тулысынча мобилизацияләнү

отмока́ть *несов. см.* **отмо́кнуть**

отмо́к||нуть *сов.* **1.** (*отсыреть*) юешләнеп җебү, юешләнү **2.** юешләнеп кубу; **ма́рка ~ла** марка юешләнеп купкан

отмолча́ться *сов. разг.* дәшми калу, җавап бирмәү, җавап бирми калу

отмора́живать *несов. см.* **отморо́зить**

отморо́зить *сов. что* өшетү, туңдыру; **~ па́лец** бармакны туңдыру

отмота́ть *сов. что, чего* сүтү, сүтеп алу (*ураланны*); **~ бинт** бинтны сүтеп алу

отмочи́ть *сов. что* **1.** (*намочив, отделить*) юешләп куптарып алу, чылатып куптарып алу **2.** *спец.* җебетү; **~ ко́жу** күнне җебетү

отму́читься *сов. разг.* интегеп туктау, интегүдән котылу, газапланудан туктау

отмще́ние *с* үч алу

отмыва́ть *несов. см.* **отмы́ть**

отмыва́ться *несов.* **1.** *см.* **отмы́ться**; **2.** *страд. от* **отмыва́ть**

отмыка́ть *несов. см.* **отомкну́ть**

отмыка́ться *несов.* **1.** *см.* **отомкну́ться**; **2.** *страд. от* **отмыка́ть**

отмы́ть *сов.* **1.** *кого-что* юу, юып тазарту, юып алу **2.** *что* юу, юып төшерү; **~ грязь с рук** кулдагы пычракны юып төшерү

отмы́ться *сов.* юылу, юылып чистару, юылып бетү

отмы́чка *ж* отмычка (*теләсә нинди йозакны ача торган корал*)

отмыка́ть *несов. см.* **отмя́кнуть**

отмя́кнуть *сов.* җебү, йомшау

отне́киваться *несов. разг.* ык-мык итү, риза булмау, баш тарту, киреләнү

отнести́ *сов. кого-что* **1.** (*доставить*) илтү, илтеп кую, илтеп бирү; кертеп кую, алып барып кую **2.** (*переместить*) алып китү; күчереп кую; **ве́тер отнёс парашю́т в сто́рону** җил парашютны читкә алып китте **3.** *перен.* (*причислить*) исәпләү, ... дип карау; **~ ру́копись к 15 ве́ку** кулъязманы 15 гасырныкы дип карау; **~ расхо́ды на счёт учрежде́ния** чыгымнарны учреждение хисабына исәпләү

отнести́сь *сов. к кому-чему* карау, мөгамәлә күрсәтү; **внима́тельно ~ к больно́му** авыруны игътибар белән карау

отникелирова́ть *сов. что* никельләп чыгу, никель йөгертеп чыгу

отнима́ть *несов. см.* **отня́ть**

отнима́ться *несов.* **1.** *см.* **отня́ться**; **2.** *страд. от* **отнима́ть**

относи́тельно **1.** *нареч.* (*сравнительно*) чагыштырмача, азмы-күпме; **вы́слушать** *что-л.* **~ споко́йно** *берәр нәрсәне* азмы-күпме тынычлык белән тыңлау **2.** *предлог с род. п.* (*по поводу*) карата, турында, хакында; **~ его́ прие́зда ничего́ неизве́стно** аның килүе турында бернәрсә дә билгеле түгел

относи́тельност||ь *ж* нисбәтлелек, чагыштырмалылык, чагыштырмалы булу; **теори́я ~и** чагыштырмалылык теориясе

относи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** чагыштырмача ...; нисбәтле, артык зур булмаган, чамалы; **~ая вла́жность** чагыштырма дымлылык; **~ая уда́ча** артык зур булмаган уңыш **2.** *грам.* нисби; **~ое прилага́тельное** нисби сыйфат

относи́ть *несов. см.* **отнести́**

относи́ться *несов.* **1.** *см.* **отнести́сь**; **2.** *к кому-чему* (*иметь касательство*) бәйләнеше (кагылышы) булу, кагылу; **э́то к де́лу не отно́сится** моның эшкә бәйләнеше юк

отноше́ни||е *с* **1.** *см.* **отнести́сь** 1, **относи́ться** 2; **бе́режное ~е** *к чему-л.* сакчыл мөнәсәбәт **2.** бәйләнеш; **письмо́ име́ет прямо́е ~е к де́лу** хатның эшкә турыдан-туры бәйләнеше бар; **~е ме́жду двумя́ величи́нами** ике зурлык арасындагы үзара бәйләнеш **3.** *мат.* чагыштырма; **~е двух чи́сел** ике сан чагыштырмасы **4.** мөнәсәбәт; **дру́жеские ~я** дуслык мөнәсәбәтләре; **дипломати́ческие ~я** дипломатик мөнәсәбәтләр **5.** (*официальная бумага*) отношение, рәсми кәгазь ◆ **во всех ~ях** (*с любой стороны*) төрле яктан, һәр яктан да; **в ~и** *каком, чего* (*в смысле*) бу яктан; **в э́том ~и я согла́сен с ним** бу яктан мин аның белән риза; **в ~и** *кого-чего, предлог с род. п.* (*берәр кеше, нәрсә турында*) *или* **по ~ю** *к кому-чему, предлог с дат. п.* ...га карата; **по ~ю к коллекти́ву** коллективка карата

отны́не *нареч.* бүгеннән алып, бүгенге көннән [алып], хәзердән алып, моннан соң

отню́дь *нареч.* (*совсем*) бер дә, һич; бөтенләй, һич тә; **~ нет** һич юк

отня́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*взять силой*) көчләп (тартып) алу; талап алу **2.** *что* (*поглотить*) алу; **~ мно́го вре́мени** бик күп вакыт алу **3.** *что* (*убрать, отделить*) алып кую, аерып алып кую **4.** *что* (*ампутировать*) кисү, кисеп алу **5.** *кого* (*лишить материнского молока*) аеру; **~ ребёнка от груди́** баланы имүдән аеру **6.** *что*, *разг.* (*вычесть*) алу; **от сорока́ ~ два́дцать** кырыктан егермене алу ◆ **~ жизнь** гомерен өзү; **~ наде́жду** өметен өзү

отня́||ться *сов.* ...сыз калу; эшләми башлау, йөрми башлау; **но́ги отняли́сь** аяксыз калды; **язы́к ~лся** телсез калган

ото *см.* **от**

отобе́дать *сов.* **1.** (*кончить обедать*) төшке ашны ашап бетерү **2.** *уст.* (*пообедать*) аш ашау, төшке аш ашау

отобража́ть *несов. см.* **отобрази́ть**

отображе́ние *с* **1.** *см.* **отобрази́ть**; **2.** (*изображение*) тасвир, гәүдәләнеш, чагылыш, сурәтләнеш

отобрази́ть *сов. кого-что* сурәтләү, тасвирлау, гәүдәләндерү, чагылдыру

отобра́ть *сов. кого-что* **1.** (*взять обратно*) алу, кире алу, кайтарып алу, тартып алу **2.** (*выделить*) сайлап алу, аерып алу

отова́ривание *с см.* **отова́рить**

отова́ривать *несов. см.* **отова́рить**

отова́рить *сов. что*, *спец.* товар бирү, товар белән тәэмин итү

отовсю́ду *нареч.* һәрьяктан, һәр җирдән

отогна́ть *сов.* **1.** *кого-что* куу, куалау, куып җибәрү **2.** *перен. что* баштан чыгару, баштан чыгарып ташлау; **~ тяжёлые мы́сли** авыр уйларны баштан чыгару **3.** *что*, *спец.* (*добыть перегонкой*) куу, чыгару, куып табу; **~ скипида́р** скипидар куу

отогну́ть *сов. что* **1.** (*распрямить*) турайту, турайтып кую; төзәйтү; кайтарып кую, сызгану **2.** (*в сторону, вверх, вниз*) ию, бөгү, иеп (бөгеп) кую, күтәрү, күтәреп кую; кайтару

отогну́ться *сов.* **1.** (*распрямиться*) тураю; төзәю **2.** (*вверх*) күтәрелү, күтәрелеп китү; (*в сторону, вниз*) кайтарылу

отогрева́ть *несов. см.* **отогре́ть**

отогрева́ться *несов.* **1.** *см.* **отогре́ться**; **2.** *страд. от* **отогрева́ть**

отогре́ть *сов. кого-что* җылыту, җылытып алу; **~ ру́ки** кулларны җылыту

ОТО-ОТП

отогре́ться *сов.* җылыну, җылынып алу

отодвига́ть *несов. см.* **отодви́нуть**

отодвига́ться *несов.* **1.** *см.* **отодви́нуться**; **2.** *страд. от* **отодвига́ть**

отодви́нуть *сов.* **1.** *кого-что* (*переместить*) этү, этәрү, этеп (этәреп) кую; күчерү, күчереп кую **2.** *перен. что, разг.* (*перенести*) кичектерү, күчерү; **~ срок** срогын кичектерү

отодви́нуться *сов.* **1.** күчү, күчеп утыру, читкәрәк китү, ...га таба китү; **~ к окну́** тәрәзәгә таба күчеп утыру **2.** *перен. разг.* (*отдалиться по времени*) кичегү, кичектерелү, күчерелү

отодра́ть *сов.* **1.** *что* (*оторвать*) кубару, куптару, кубарып (куптарып) алу, каезлау, каезлап алу **2.** *кого, прост.* (*высечь*) кыйнау, кыйнап ташлау, каезлау; **~ за́ уши** колагын бору

отодра́||ться *сов. прост.* кубып төшү; **подмётки ~лись** олтаннары кубып төшкән

отождестви́ть *сов. см.* **отожествля́ть**

отождествле́ние *с см.* **отождестви́ть**

отождествля́ть *несов. см.* **отождестви́ть**

отожестви́ть *сов. кого-что* тиңләү, тиңләштерү, тиң дип тану (карау), тиң итеп күрү

отожествле́ние *с см.* **отожестви́ть**

отожествля́ть *несов. см.* **отожестви́ть**

отозва́ть *сов. кого-что* **1.** чакырып алу, чакырып китерү; **~** *кого-л.* **в сто́рону** *берәр кешене* читкә чакырып алу **2.** кайтару, чакырып кайтару; **~ посла́** илчене чакырып кайтару

отозва́||ться *сов.* **1.** җавап бирү, җавап кайтару; **никто́ не ~лся** беркем дә җавап кайтармады **2.** *о ком-чём* фикерен әйтү, бәяләү, бәя бирү; **хорошо́ ~ться о кни́ге** китапка яхшы бәя бирү **3.** *на ком-чём* (*оказать влияние на кого-что-л.*; *отразиться, сказаться*) тәэсир итү

отойти́ *сов.* **1.** китү; **~ в сто́рону** читкә китү; **по́езд отошёл но́чью** поезд төнлә китте **2.** *от кого-чего* чигенү, кире кайту; **~ от пре́жних взгля́дов** элекке карашлардан кире кайту **3.** кубу, кубып чыгу, аерылу; **обо́и отошли́ от стены** обойлар стенадан купкан **4.** (*исчезнуть*) бетү, юкка чыгу; **пятно́ отошло́** тап бетте **5.** (*прийти в обычное состояние*) язылу, җылыну, җылы керү, сизә башлау; басылу, тынычлану; **ру́ки отошли́ от хо́лода** куллар җылынды **6.** тию, күчү; **дом отошёл к сы́ну** йорт улына күчте **7.** чыгу, бүленеп чыгу (*эшкәртәндә*); **от творога́ отошла́ сы́воротка** эремчектән әйрән бүленеп чыкты ♦ **~ в ве́чность** мәңгелеккә күзләрен йому; **~ в про́шлое** онытылу; **~ ко сну** йокыга китү

отоларинго́лог *м* отоларинголог (*колак, тамак, борын авырулары табибы*)

отомкну́ть *сов. что* **1.** *разг.* (*отпереть*) ачу **2.** (*снять примкнутое*) ычкындыру, ычкындырып алу; **~ штык** штыкны ычкындыру

отомкну́ться *сов. разг.* ачылу (*бикләнгән нәрсә*)

отомсти́ть *сов. кому-чему* үч алу, үч кайтару

отопи́тельн||ый, -ая, -ое җылыту ...ы; ягу ...ы; **~ая систе́ма** җылыту системасы; **~ый сезо́н** ягу сезоны

отопи́ть *сов. что* җылыту, ягып җылыту

отопле́ние *с* **1.** *см.* **отопи́ть**; **2.** җылыту, ягу, ягып җылыту; **дровяно́е ~** утын ягып җылыту

ора́чивать *несов. см.* **оторо́чить**

от о́рванность *ж* (*отчуждённость*) бәйләнеш юклык, аерылганлык, ялгызлык

оторва́ть *сов.* **1.** *что* өзү, өзеп алу; ертып алу; **~ пу́говицу** төймәне өзеп алу; **~ листо́к** бер бит кәгазь ертып алу **2.** *кого-что от чего* алу; аеру; **~ глаза́ от кни́ги** китаптан күзне алу; **~ от рабо́ты** эштән аеру **3.** *кого* (*разлучить*) аеру; **~ от семьи́** гаиләсеннән аеру

оторва́||ться *сов.* **1.** *от кого-чего* (*отделиться*) өзелү, өзелеп төшү, өзелеп (ертылып) чыгу, [бәйдән] ычкыну **2.** *от чего* күтәрелеп китү; **самолёт ~лся от земли́** очкыч җирдән күтәрелеп китте **3.** *от кого, воен.* артта калу, аерылу (*гаскәрләр турында*) **4.** *от кого-чего* аерылу, бәйләнешне югалту; **~ться от друзе́й** дуслардан аерылу **5.** *от чего* аерылу; туктау; **я не смог ~ться от интере́сной кни́ги** кызыклы китаптан аерыла алмадым

ороп е́лый, -ая, -ое *разг.* аптыраган, каушаган, аптырап (каушап) калган

ороп е́ть *сов. разг.* аптырау, каушау, аптырап (каушап) калу

о́торопь *ж разг.* аптырау, каушау; **~ взяла́** каушап киттем

оторочи́ть *сов. что* (*тканью*) кайма тотып чигү; (*мехом*) зияклөү, кырпу тотып чыгу

оторо́чка *ж* (*ткань*) кайма; (*мех*) кырпу, зияк

отосла́ть *сов. кого-что* **1.** җибәрү; **~ де́ньги** акча җибәрү **2.** (*велеть уйти*) җибәрү **3.** (*предложить обратиться куда-л.*) киңәш бирү, җибәрү

отоспа́ться *сов.* туйганчы йоклау, йокы тую (туйдыру)

отоща́ть *сов. разг.* ябыгу, арыгаю, арыклану

отпада́ть *несов. см.* **отпа́сть**

отпа́ивать I *несов. см.* **отпои́ть**

отпа́ивать II *несов. см.* **отпая́ть**

отпа́иваться *несов.* **1.** *см.* **отпая́ться**; **2.** *страд. от* **отпа́ивать** II

отпа́ривать *несов. см.* **отпа́рить**

отпари́ровать *сов. прям., перен. что* юкка чыгару, кире кагу; **~ все возраже́ния** каршы әйткәннәрнең барын да кире кагу

отпа́рить *сов. что* **1.** (*отутюжить*) юеш чүпрәк аша үтүкләп чыгу **2.** (*размягчить паром*) пешекләү, пешекләп алу

отпа́рывать *несов. см.* **отпоро́ть**

отпа́рываться *несов.* **1.** *см.* **отпоро́ться**; **2.** *страд. от* **отпа́рывать**

отпа́||сть *сов.* **1.** (*отделиться*) кубу, кубып төшү; өзелеп (коелып) төшү **2.** *уст.* (*выйти из состава*) чыгу, төшеп калу **3.** *перен.* көчен югалту, юкка чыгу, бетү; **обвине́ние ~ло** гаеплөү юкка чыкты; **жела́ние ~ло** теләк бетте

отпая́ть *сов. что* эретеп алу (төшерү)

отпая́ться *сов.* эреп төшү (кубу)

отпева́ние *с церк.* женаза, женаза уку (*христианнарда*)

отпева́ть *несов. см.* **отпе́ть** 2

отпере́ть *сов. что* ачу (*бикләнгән әйберне*); **~ чемода́н** чемоданны ачу

отпере́ться *сов.* **1.** (*открыться*) ачылу, ачылып китү **2.** *разг.* (*не сознаться*) тану, инкарь итү; **~ от свои́х слов** үз сүзеңнән баш тарту

отпе́тый, -ая, -ое (*неисправимый*) очына чыккан, ашып киткән, аша узган, төзәлмәслек

отпе́ть *сов.* **1.** (*кончить петь*) җырлап туктау, җырлаудан туктау; сайрап (кычкырып) туктау **2.** *кого, церк.* женаза уку

отпеча́тать *сов. что* **1.** (*закончить печатание*) бастырып бетерү (чыгару); басып бетерү **2.** (*сделать отпечаток*) эз калдыру **3.** (*раскрыть*) мөһерен [алып] ачу, мөһерен ватып ачу; **~ помеще́ние** бинаның мөһерен алып ачу

отпеча́та||ться *сов.* эз калу; **на песке́ ~лись следы́ ног** комда аяк эзләре калган

отпеча́т||ок *м* **1.** эз; **~ки па́льцев** бармак эзләре **2.** *перен. чего* эз, әсәр; тәэсир, йогынты; **~ок гру́сти на лице́** йөзендә сагыш эзе

отпеча́тывать *несов. см.* **отпеча́тать**

отпеча́тываться *несов.* **1.** *см.* **отпеча́таться**; **2.** *страд. от* **отпеча́тывать**

отпива́ть *несов. см.* **отпи́ть**

отпи́ливать *несов. см.* **отпили́ть**

отпили́ть *сов. что* (*пычкы белән*) кисү, пычу, киселеп алу (төшерү), киселеп ташлау

отпира́тельство *с* тану, инкарь итү; баш тарту

отпира́ть *несов. см.* **отпере́ть**

отпира́ться *несов.* **1.** *см.* **отпере́ться**; **2.** *страд. от* **отпира́ть**

отписа́ть *сов. что, уст.* **1.** (*завещать*) мирас итеп калдыру, васыять итү **2.** (*отобрать*) тартып алу, алу; **~ име́ние в казну́** имениене казнага алу

отписа́ться *сов. разг.* формаль җавап язу

отпи́ска *ж* формаль җавап, формаль язу

отпи́сывать *несов. см.* **отписа́ть**

отпи́сываться *несов.* **1.** *см.* **отписа́ться**; **2.** *страд. от* **отпи́сывать**

отпи́ть *сов. что, чего* (*выпить немного*) [бераз] эчү; [бераз] эчеп җибәрү

отпи́хивать *несов. см.* **отпихну́ть**

отпи́хиваться *несов.* **1.** *см.* **отпихну́ться**; **2.** *страд. от* **отпи́хивать**

отпихну́ть *сов. кого-что, разг.* этеп (этәреп) җибәрү, төртеп җибәрү

отпихну́ться *сов. разг.* этәрелеп китү; **~ весло́м от бе́рега** ишкәк белән ярдан этәрелеп китү

отпла́та *ж см.* **отплати́ть**

отплати́ть *сов.* **1.** *кому чем* җавап кайтару; түләү; **~ добро́м за добро́** яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтару **2.** *кому* (*отомстить*) үч алу, үч кайтару ♦ **~ то́й же моне́той** ≈ ашка аш белән, ташка таш белән

отпла́чивать *несов. см.* **отплати́ть**

отплева́ться *сов. см.* **отплёвываться**

отплёвывать *несов. см.* **отплю́нуть**

отплёвываться *несов.* **1.** төкереңү; төкереп чыгарылу **2.** *страд. от* **отплёвывать**

отплёскивать *несов. см.* **отплесну́ть** 2

отплесну́ть *сов.* **1.** (*скатиться назад — о воде, волне*) кире китү; кире чәчрәү **2.** *что, чего, разг.* (*отлить, плеснув*) түгә төшү, түгеп киметә төшү

отплести́ *сов. что* (*урелгәнне*) сүтеп алу, сүтү

отплета́ть *несов. см.* **отплести́**

отплыва́ть *несов. см.* **отплы́ть**

отплы́ти||е *с* китү, кузгалып китү, йөзеп китү; **кора́бль гото́в к ~ю** корабль кузгалып китәргә әзер

отплы́ть *сов.* йөзеп китү, китү, кузгалып китү; **~ от бе́рега** ярдан йөзеп китү

отплю́нуть *сов. что, разг.* төкереп чыгару, төкереп ташлау

отпляса́ть *сов. разг.* **1.** *что* (*сплясать*) биеп алу **2.** (*кончить плясать*) биюдән туктау, биеп туктау

отпля́сывать *несов.* **1.** *см.* **отпляса́ть** 1; **2.** *разг.* бик бирелеп бию, дәртләнеп бию

о́тповедь *ж* кискен җавап; ачы җавап, кире кагу; **стро́гая ~** катгый рәвештә кире кагу

отпои́ть *сов. кого-что* **1.** (*кончить поить*) эчертеп бетерү, эчертү; **~ лошаде́й** атларны эчертү **2.** (*вырастить на жидкой пище*) эчереп үстерү; **~ телёнка молоко́м** бозауны сөт эчереп үстерү **3.** *разг.* (*вылечить*) эчереп савыктыру, эчереп сәламәтләндерү; эчереп терелтү

отпола́скивать *несов. см.* **отполоска́ть** 1

отполза́ть *несов. см.* **отползти́**

отползти́ *сов.* шуышып китү, үрмәләп китү

отполирова́ть *сов. что* ялтырату, ялтыратып чыгу

отполи́ровывать *несов. см.* **отполирова́ть**

отполоска́ть *сов. разг.* **1.** *что* чайкап алу, чайкап юу **2.** *что и без доп.* (*кончить полоскать*) чайкап бетерү

отпо́р *м* кискен каршылык күрсәтү, кире кагу, отпор; **дать ~ врагу́** дошманга отпор бирү

отпоро́ть *сов. что* сүтү, сүтеп алу (ташлау) (*тегелгәнне*)

отпоро́ться *сов.* сүтелү, сүтелеп чыгу (төшү)

отпотева́ть *несов. см.* **отпоте́ть**

отпоте́ть *сов. разг.* тирләү, булану, парлану

отпочкова́ться *сов. биол.* бөреләнеп аерылып чыгу; тармакланып бүленү

отпочко́вываться *несов. см.* **отпочкова́ться**

отправи́тель *м* җибәрүче; **~ гру́за** йөк җибәрүче

отправи́тельница *ж* җибәрүче хатын (кыз)

отпра́вить *сов.* **1.** *кого-что* җибәрү, салу, озату; **~ письмо́** хат салу; **~ семью́ в дере́вню** гаиләне авылга озату **2.** *что* җибәрү, китәргә рөхсәт итү; **~ по́езд** поездны җибәрү ♦ **~ на тот свет** теге дөньяга җибәрү

отпра́ви||ться *сов.* китү, китеп бару; кузгалып китү; **по́езд ~тся че́рез час** поезд бер сәгатьтән китә ♦ **~ться на тот свет** теге дөньяга китү

отпра́вка *ж см.* **отпра́вить, отпра́виться**; **~ пи́сем** хат җибәрү

отправле́ние I *с* **1.** *см.* **отпра́вить, отпра́виться; ~ по́езда** поезднын кузгалып китүе **2.** (*почтовое*) җибәрелгән әйбер (*бандероль, хат, посылка h.б.ш.*)

отправле́ни||е II *с* эшчәнлек, эшләү; **~ я организ́ма** организмның эшчәнлеге

отправля́ть *несов.* **1.** *см.* **отпра́вить; 2.** *что офиц.* (*выполнять, осуществлять*) башкару, алып бару, үтәү; **~ обя́занности секретаря́** секретарьлык эшләре алып бару

отправля́ться *несов.* **1.** *см.* **отпра́виться**; **2.** *перен. от чего* (*исходить*) ...дан чыгып эш итү, ...га таянып эш итү; **~ от прове́ренных да́нных** тикшерелгән мәгълүматларга таянып эш итү **3.** *страд. от* **отправля́ть**

отправно́й, -а́я, -о́е башлангыч, башлап китә торган; нигез итеп алынган; **~ те́зис** нигез итеп алынган тезис; **~ пункт** башлангыч пункт

отпра́здновать *сов.* **1.** *что* бәйрәм итү; бәйрәмен үткәрү **2.** (*кончить праздновать*) бәйрәм итеп туктау

отпра́шиваться *несов. см.* **отпроси́ться**

отпрессова́ть *сов. что* пресслау, пресс белән кыстыру

отпроси́ться *сов.* рөхсәт алып китү, сорап китү; **~ с рабо́ты** эштән сорап китү

отпры́гивать *несов. см.* **отпры́гнуть**

отпры́гнуть *сов.* [читкә] сикерү; сикереп китү, кире сикерү; **~ в сто́рону** читкә сикерү

о́тпрыск *м* **1.** *бот.* үренте, яшь ботак **2.** *перен. ирон.* (*потомок*) токым, нәсел

отпряга́ть *несов. см.* **отпря́чь**

отпря́нуть *сов.* читкә тайпылу; артка (читкә) сикереп китү; **в стра́хе ~** куркудан читкә тайпылу

отпря́чь *сов. кого-что* туару; **~ ло́шадь** атны туару

отпу́гивать *несов. см.* **отпугну́ть**

отпугну́ть *сов. кого-что* **1.** куркыту, куркытып җибәрү; өркетү **2.** *перен.* куркыту, үзеннән читләштерү

о́тпуск *м* **1.** *см.* **отпусти́ть** 3, 5, 6, 10; **~ това́ров** товар җибәрү **2.** ял; **ме́сячный ~** бер айлык ял; **быть в ~е** ялда булу

отпуска́ть *несов. см.* **отпусти́ть**

отпускни́к *м* отпусктагы кеше, ялдагы (ялга чыккан) кеше

отпускни́ца *ж* ялдагы хатын (кыз)

отпускн||о́й, -а́я, -о́е **1.** ял ...ы; **~о́е вре́мя** ял вакыты **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* (*деньги*) ял акчасы **3.** *экс.* (*о ценах*) сату ...ы

отпусти́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*разрешить идти*) җибәрү, кайтару, китәргә (кайтарга) рөхсәт бирү **2.** *кого-что* (*выпустить*) җибәрү, азат итү, [иреккә] чыгарып җибәрү; **~ пти́цу из кле́тки** кошны читлектән чыгарып җибәрү **3.** *что* (*ослабить*) бушайту, бушайта төшү; **~ реме́нь** каешны бушайта төшү **4.** *перен. безл. кого-что* (*о боли*) ычкындыру, җибәрү **5.** *что* җибәрү; **~ това́р** товар җибәрү **6.** *что* (*назначить, выдать*) җибәрү, бирү; **~ сре́дства на наро́дное образова́ние** халык мәгарифе эшләренә акча бирү **7.** *что* үстерү, җиткерү, җибәрү; **~ бо́роду** сакал җибәрү; **~ во́лосы** чәч үстерү **8.** *что, разг.* ычкындырып җибәрү, әйтеп салу, әйтеп җибәрү; **~ о́строе слове́чко** тапкыр сүз әйтеп салу **9.** *что, уст.* кичерү; **~ грехи́** гөнаһларны кичерү **10.** *что, тех.* (*уменьшить хрупкость*) кайтару (*уалучанлыгын кимету*); **~ сталь** корычны кайтару

отпуще́ние *с*: **~ грехо́в** *уст.* гөнаһларны кичерү

отраба́тывать *несов. см.* **отрабо́тать** 1, 2, 4, 5

отрабо́танный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **отрабо́тать; 2.** (*использованный*) файдаланылган, бер кат файдаланылган; **~ газ** бер кат файдаланылган газ

отрабо́тать *сов.* **1.** *что* (*возместить трудом*) эшләп түләү, (*бурычны*) эш белән түләү **2.** *что* эшләү, эшләп үткәрү (*берникадәр вакыты*) **3.** (*кончить работать*) эшләп бетерү, эшне бетерү, эштән туктау **4.** *что* эшкәртеп җиткерү; **~ прое́кт** проектны эшкәртеп җиткерү **5.** *что* (*изучить*) өйрәнү, яхшы өйрәнү, үзләштерү

отрабо́тка *ж см.* **отрабо́тать** 1, 4, 5

отра́ва *ж* агу, зәһәр

отрави́тель *м* агулаучы

отрави́ть *сов.* **1.** *кого-что* агулау, агулап үтерү, агу биреп үтерү **2.** *что* (*примешать отраву*) агулау, агу салу, агу кушу **3.** *перен. кого-что* агулау, зарарлау **4.** *перен. что* бозу, [ямен] җибәрү, [ямен] китәрү; **~ удово́льствие** рәхәтен бозу

отрави́ться *сов.* **1.** (*принять яд*) агу эчү, агу эчеп үлү **2.** агулану, агуланып үлү; **~ гриба́ми** гөмбә ашап агулану

отравле́ние *с см.* **отрави́ть** 1-3, **отрави́ться**

отравля́ть *несов. см.* **отрави́ть**

отравля́ться *несов. см.* **отрави́ться; 2.** *страд. от* **отравля́ть**

отравля́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **отрави́ть; 2.** агулаучы, агулый торган; **~ие вещества́** агулый торган матдәләр

отра́да *ж* куаныч, сөенеч, шатлык, кинәнү

отра́дн||ый, -ая, -ое куанычлы, сөенечле, шатлыклы; **~ое явле́ние** куанычлы хәл

отража́тель *м тех.* чагылдыргыч, кайтаргыч (*яктылык, җылылык нурларын, электромагнитик дулкыннарны кайтара торган җайланма*); **зерка́льный ~** чагылдыргыч көзге

отража́тельн||ый, -ая, -ое *физ., тех.* чагылдыргыч, кайтаргыч; **~ые при́змы** чагылдыргыч призмалар

отража́ть *несов. см.* **отрази́ть**

отража́ться *несов.* **1.** *см.* **отрази́ться; 2.** *страд. от* **отража́ть**

отраже́ние *с* **1.** *см.* **отрази́ть, отрази́ться; ~ нападе́ния** һөҗүмне кире кайтару; **~ све́та** яктылыкның чагылуы **2.** чагылу, чагылыш, чагылма, гәүдәләнү, гәүдәләнеш; **~ в зе́ркале** көзгедә чагылу

отрази́ть *сов.* **1.** *кого-что* кире кайтару; кире кагу; **~ ата́ку** атаканы кире кайтару **2.** *что* (*о гладкой поверхности*) чагылдыру, күрсәтү **3.** *кого-что* гәүдәләндерү, чагылдыру, тасвирлау; **~ жизнь в иску́сстве** тормышны сәнгатьтә чагылдыру

отрази́||ться *сов.* **1.** (*на гладкой поверхности*) чагылу **2.** беленү, күренү, сизелү, чагылу; **в его́ глаза́х ~лась трево́га** аның күзендә шом сизелә иде **3.** *на ком-чём* тәэсир итү, йогынты ясау; **уси́ленная рабо́та ~лась на здоро́вье** күп эшләү сәламәтлеккә тәэсир итте

отрапортова́ть *сов. о чём* рапорт бирү

отраслев||о́й, -а́я, -о́е тармак ...ы, тармаклы, хуҗалыкның бер тармагына караган; **~о́е совеща́ние** тармак киңәшмәсе

о́трасль *ж* тармак; **но́вая ~ зна́ний** белемнең яңа тармагы; **~ промы́шленности** промышленность тармагы

отраста́ть *несов. см.* **отрасти́**

отрасти́ *сов.* үсү, үсеп чыгу, үсеп җитү

отрасти́ть *сов. что* үстерү, җибәрү; **~ дли́нные усы́** озын мыек җибәрү

отра́щивать *несов. см.* **отрасти́ть**

отреаги́ровать *сов. на что* игътибар итү, жавап кайтару

отре́бье *с собир. презр.* адәм актыклары, кабәхәтләр; **фаши́стское ~** фашист кабәхәтләре

отрегули́ровать *сов. что* рәтләү, ипләү, көйләү, ипкә китерү, җайга салу

отредакти́ровать *сов. что* редакцияләп чыгу

отре́з *м* **1.** *см.* **отре́зать** 1, 2; **2.** кисәк, отрез; **~ на пальто́** пальтолык кисәк **3.** *спец.* (*место отрезания*) киселгән урын, кисем

отре́зать *сов.* **1.** *что, чего* (*разрезать*) кисү, кисеп алу **2.** *что, чего* (*отделить межеванием*) кисеп бирү, җир кисү **3.** *перен. кого-что* кисү, юлын кисү; **~ путь к отступле́нию** чигенү юлларын кисү **4.** (*резко ответить*) кырт кисү, кырт киселән җавап бирү

отреза́ть *несов. см.* **отре́зать**

отрезве́ть *сов. прям., перен.* айну, аеклану

отрезви́тельный, -ая, -ое айныткыч, айныта торган; **~ напи́ток** айныта торган эчемлек

отрезви́ть *сов. прям., перен. кого-что* айныту, аекландыру

отрезви́ться *сов.* айну, аеклану, аегу

отрезвле́ние *с см.* **отрезви́ть, отрезви́ться**

отрезвля́ть *несов. см.* **отрезви́ть**

отрезвля́ться *несов.* **1.** *см.* **отрезви́ться; 2.** *страд. от* **отрезвля́ть**

отрезно́й, -а́я, -о́е киселмәле, киселә алына торган; **~ тало́н** киселә алына торган талон

отре́зок *м* **1.** (*небольшой кусок*) кисәк, кайпык, кайпылчык **2.** *мат.* кисемтә **3.** бер өлеш; бер ара, кисәк; **~ пути́** юлның бер өлеше

отрека́ться *несов. см.* **отре́чься**

отрекомендова́ть *сов. кого-что* (*познакомить*) таныштыру

отрекомендова́ться *сов.* исемен әйтү, таныш

отремонти́ровать *сов. что* ремонтлау, ремонт ясау, ремонтлап бетерү; көйләү, төзәтү

отрепети́ровать *сов. что* өйрәнү, өйрәнеп алу; репетиция ясап өйрәнү; **~ роль** рольне репетиция ясап өйрәнү

отре́пье *с собир.,* **отре́пья** *мн. разг.* (*лохмотья*) иске-москы, чүпрәк-чапрак, сәләмә кием

отрече́ние *с* **1.** *см.* **отре́чься; 2.** (*документ*) ваз кичү кәгазе (*үзенең хокукларыннан*)

отре́чься *сов.* **1.** *от кого-чего* (*отказаться*) ваз кичү, баш тарту; тану **2.** *от чего, уст.* баш тарту; **~ от престо́ла** тәхеттән баш тарту

отреша́ться *несов. см.* **отреши́ться**

отрешённость *ж* читләшкәнлек, ераклашканлык

отрешённый, -ая, -ое читләшкән, ераклашкан; кызыксынусыз, салкын; **~ взгляд** кызыксынусыз караш

отреши́ться *сов. книжн.* (*отказаться, освободиться*) котылу; ваз кичү

отрица́ни||е *с* **1.** *см.* **отрица́ть; 2.** *филос.* инкарь, инкарь итү; **~е ~я** инкарьне инкарь итү **3.** *грам.* юклык сүзе

отрица́тельн||ый, -ая, -ое **1.** кире, тискәре, каршы; **~ый отве́т** кире җавап **2.** кире, әшәке, начар; **~ый тип** кире тип; **~ая характери́стика** начар характеристика **3.** *мат.* тискәре; **~ое число́** тискәре сан **4.** *физ.* кире; **~ый заря́д** кире корылма

отрица́ть *несов. что* инкарь итү, кире кагу, юкка чыгару, тану; **~ свою́ вину́** үз гаебеңне инкарь итү

отро́г *м геогр.* тау тармагы; **~и Карпа́т** Карпат тавы тармаклары

о́троду *нареч. разг.* ничбер; туганнан бирле, тумыштан; гомердә

отро́дье *с разг.* шайтан токымы, әшәке кеше

отройть *сов. кого-что, пчел.* ил (күч) аеру

отро́иться *сов. пчел.* ил (күч) булып аерылу, аерылып чыгу

о́трок *м уст.* яшүсмер

отро́сток *м* **1.** (*молодой побег*) яңа сабак, үренте **2.** *анат.* үсенте, берәр әгъза тармагы; **~ слепо́й кишки́** сукыр эчәк үсентесе

о́троческ||ий, -ая, -ое яшүсмер ...ы, яшүсмерлек ...ы; **~ие го́ды** яшүсмерлек еллары

о́трочество *с* үсмерлек, үсмерлек чоры, яшүсмер чак

о́труб *м ист.* отруб (*община җиреннән киселә алып, аерым крестьяннарның хосусый милкенә бирелгән җир участогы — 1906-1916 елларда*)

отру́б *м* кисем (*агачның киселгән урыны*)

отруба́ть *несов. см.* **отруби́ть**

о́труби *только мн.* көрпә, он көрпәсе, илмәтек

отруби́ть *сов.* **1.** *что* чабу, кисү, чабып (киселә) алу, чабып (киселә) төшерү (ташлау) **2.** *перен. разг.* (*резко ответить*) кырт кисү, кырт киселә әйтү, кырт киселә җавап бирү

отрубн||о́й, -а́я, -о́е *ист.* отруб ...ы; **~о́е хозя́йство** отруб хуҗалыгы

о́трубный, -ая, -ое көрпә ...ы; **~ корм** көрпә азык

отруга́ть *сов. кого-что, разг.* тиргәп (сүгеп) ташлау

отрули́ть *сов.* **1.** *что* (*о лётчике*) очкычны илтеп кую **2.** (*о самолёте*) читкә борылу (*җир өстендә*)

отры́в *м см.* **оторва́ть** 2, 3, **оторва́ться** 2, 3, 4; **~ от масс** массалардан аерылу ◆ **без ~а от произво́дства** эштән аерылмыйча

отрыва́ть I *несов. см.* **оторва́ть**

отрыва́ть II *несов. см.* **отры́ть**

отрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **оторва́ться; 2.** *страд. от* **отрыва́ть** I

отры́вистость *ж* өзек-өзек булу

отры́вист||ый, -ая, -ое өзек-өзек, кисәк-кисәк, өзеп-өзеп; **~ые зву́ки** өзек-өзек авазлар; **~ая речь** өзеп-өзеп сөйләү

отрывно́й, -а́я, -о́е ертып алына торган; **~ календа́рь** ертып алына торган календарь

отры́вок *м* өзек, өземтә, парча; **~ из рома́на** романнан өзек

отры́вочность *ж* өзек-өзек булу, ярты-йорты булу

отры́вочн||ый, -ая, -ое өзек-өзек, ярты-йорты, тулы булмаган; **~ые све́дения** тулы булмаган мәгълүматлар

отры́гивать *несов. см.* **отрыгну́ть**

отры́гиваться *несов.* **1.** *см.* **отрыгну́ться; 2.** *страд. от* **отры́гивать**

отрыгну́ть *сов. что, чего, разг.* кикерү, кикереп чыгару

отрыгну́ться *сов. разг.* кикереп чыгарылу

отры́жка *ж* кикерү, кикерек, үтләвек

отры́ть *сов.* **1.** *что* (*вырыть*) казу, чоку, казып [чокып] бетерү; **~ око́п** окоп казу **2.** *кого-что* (*роя, освободить*) казып чыгару, казып алу

отря́д *м в разн. знач.* отряд; **партиза́нский ~** партизаннар отряды; **продово́льственный ~** *ист.* азык отряды; **~ грызуно́в** *зоол.* кимерүчеләр отряды

отряди́ть *сов. кого-что* җибәрү, билгеләп җибәрү; **~ бойцо́в в разве́дку** сугышчыларны разведкага җибәрү

отря́дный, -ая, -ое отряд ...ы; **~ сбор** отряд җыелышы

отряжа́ть *несов. см.* **отряди́ть**

отря́хивать *несов. см.* **отряхну́ть**

отря́хиваться *несов.* 1. *см.* **отряхну́ться**; 2. *страд. от* **отря́хивать**

отряхну́ть *сов. что* кагу, селкү, кагып (селкеп) алу (төшерү)

отряхну́ться *сов.* кагыну, кагынып алу

отсади́ть *сов.* 1. *кого-что* аерып утырту; **~ шалуна́** шаянны аерып утырту 2. *что* (*растение*) күчереп утырту, аерып алып утырту

отса́дка *ж* см. **отсади́ть** 2

отса́живать *несов. см.* **отсади́ть**

отса́живаться *несов. см.* **отсе́сть**

отсалютова́ть *сов. кому-чему* салют бирү

отса́сывать *несов. см.* **отсоса́ть** 1

отсве́т, о́тсвет *м* яктылык чагылышы, чагылган яктылык, ут шәүләсе

отсве́чивать *несов.* (*давать отсвет*) яктылык чагылдыру, ялтырап тору

отсебя́тина *ж разг.* (*слова́*) үзеннән сүз өстәү, уйдырма; (*поступки*) үз белдеге белән эшләү (эшләнгән эш)

отсе́в *м* 1. *см.* **отсе́ять, отсе́яться** 1, 2; 2. (*то, что отсеялось*) иләк асты 3. [укудан] төшеп калу, [укуны] ташлау; **~ уча́щихся** укучыларның укуны ташлавы

отсева́ть *несов. см.* **отсе́ять** 1

отсева́ться *несов.* 1. *см.* **отсе́яться** 1; 2. *страд. от* **отсева́ть**

отсе́вки *только мн.* иләк асты, иләгәннән соң калган нәрсә

отсе́ивать *несов. см.* **отсе́ять**

отсе́иваться *несов.* 1. *см.* **отсе́яться** 1, 2; 2. *страд. от* **отсе́ивать**

отсе́к *м* бүлек, бүлмә (*корабльдә, очкычта h.б.ш.*); **мото́рный ~** мотор бүлеге (*автомобильдә*)

отсека́ть *несов. см.* **отсе́чь**

отсели́ть *сов. кого-что* күчерү, күчереп урнаштыру

отсели́ться *сов.* күчү, күчеп урнашу

отселя́ть *несов. см.* **отсели́ть**

отселя́ться *несов.* 1. *см.* **отсели́ться**; 2. *страд. от* **отселя́ть**

отсе́сть *сов.* ераграк барып (күчеп) утыру

отсече́ние *с см.* **отсе́чь** 1

отсе́чь *сов.* 1. *что* (*отрубить*) кисеп (чабып) алу, чабып (кисеп) төшерү 2. *перен. кого-что* аеру, бүлеп алу, кисү; **~ пехо́ту от та́нков** пехотаны танклардан аеру

отсе́ять *сов.* 1. *что* иләү, иләп аеру; **~ сор** чүпне иләп аеру 2. *перен. кого-что* иләк аша үткәрү; сайлап төшереп калдыру, сайлап чыгару

отсе́я||ться *сов.* 1. (*отделиться*) иләнү, иләнеп аерылу; **о́труби ~лись** көрпә иләнеп аерылган 2. *перен.* төшеп калу; укуны ташлау, укуны ташлап китү 3. (*закончить сев*) чәчүне тәмамлау

отсиде́ть *сов. что* 1. утырып оету; **~ но́гу** утырып аякны оету 2. *разг.* (*просидеть назначенный срок*) утырып үткәрү (чыгу)

отсиде́ться *сов. разг.* качып утырып калу, качып [үзен саклап] калу

отси́живать *несов. см.* **отсиде́ть**

отси́живаться *несов. см.* **отсиде́ться**

отска́бливать *несов. см.* **отскобли́ть**

отска́бливаться *несов.* 1. *см.* **отскобли́ться**; 2. *страд. от* **отска́бливать**

отскака́ть *сов.* чаптырып китү, чаптырып читкә китү

отска́кивать I *несов. см.* **отскака́ть**

отска́кивать II *несов. см.* **отскочи́ть**

отскобли́ть *сов. что* кырып алу (төшерү); **~ кра́ску** буяуны кырып алу

отскобли́ться *сов.* кырып алыну, кубып (кырылып) төшү

отскочи́||ть *сов.* 1. читкә сикерү, сикереп китү; кире сикерү; **мяч ~л от стены́** туп стенадан кире сикереп төште 2. *разг.* (*отделиться*) төшү, кубып төшү; ычкынып китү

отскреба́ть *несов. см.* **отскрести́**

отскрести́ *сов. что* кырып алу (төшерү)

отсла́ивать *несов. см.* **отслои́ть**

отсла́иваться *несов.* 1. *см.* **отслои́ться**; 2. *страд. от* **отсла́ивать**

отслое́ние *с* 1. *см.* **отслои́ть, отслои́ться**; 2. (*слой*) төпкә утырган катлау

отслои́ть *сов. что* катлау-катлау итеп кубарып алу; катлау-катлау итеп төпкә утыру; **~ коры́** кайрыны катлау-катлау итеп кубарып алу

отслои́ться *сов.* катлау-катлау булып төпкә утыру; катлау-катлау булып кубып төшү

отслужи́ть *сов.* 1. *что, воен.* хезмәт итеп кайту, хәрби хезмәт срогын тутыру 2. *что* (*проработать нек-рое время*) хезмәт итү, эшләү; хезмәттә булу 3. (*стать непригодным*) яраксыз хәлгә килү, искерү, тузу 4. *что, церк.* гыйбадәт кылып бетерү

отсня́ть *сов. что* төшерү, төшереп алу; **~ фильм** фильм төшереп алу

отсове́товать *сов. кому с неопр.* (*берәр нәрсәне эшләмәскә*) киңәш бирү, күндерү

отсоедини́ть *сов. что* өзү; **~ прово́дку** чыбыклар челтәрен өзү

отсоединя́ть *несов. см.* **отсоедини́ть**

отсортирова́ть *сов. что* сортларга аеру (аерып кую), сайлап алу; **~ я́блоки** алмаларны сортларга аерып кую

отсортиро́вывать *несов. см.* **отсортирова́ть**

отсоса́ть *сов.* 1. *что, чего* (*убавить*) суыру, суырып алу; имү, имеп алу 2. (*кончить сосать*) суырып туктау (бетерү); имеп бетерү, имүдән туктау

отсо́х||нуть *сов.* 1. (*увянуть*) кору, корышу, корып (корышып) бетү 2. *прост.* (*перестать действовать*) кору; **рука́ ~ла** кулы корыган

отсро́чивать *несов. см.* **отсро́чить**

отсро́чить *сов. что* 1. (*перенести*) кичектерү, соңгарту; **~ платёж** түләүне кичектерү 2. (*продлить срок*) вакытын (срогын) озайту; **~ па́спорт** паспортның срогын озайту

отсро́чк||а *ж* 1. *см.* **отсро́чить**; **~а платежа́** түләү срогын кичектереп тору 2. отсрочка; **получи́ть ~у** отсрочка алу

отстава́ние *с* 1. *см.* **отста́ть**; 2. артта калу, артта калганлык; **ликвиди́ровать ~** артта калуны бетерү

отстава́ть *несов. см.* **отста́ть**

отста́вить *сов.* 1. *что* (*отодвинуть*) читкә этәреп кую, читкә алып кую 2. *кого, уст.* (*уволить*) чыгару; **~ от до́лжности** урыннан чыгару ♦ **~!** *бирелгән командаңы «утәмәскә» мәгънәсендә*

отста́вк||а *ж* отставка; **вы́йти в ~у** отставкага чыгу ♦ **~а прави́тельства** хөкүмәтнең отставкага китүе

отставля́ть *несов. см.* **отста́вить**

отставно́й, -а́я, -о́е отставкадагы ..., отставкага чыккан; **~ офице́р** отставкадагы офицер

отста́ивание I *с см.* **отстоя́ть** I; **~ де́ла ми́ра** тынычлык эшен яклау

отста́ивание II *с см.* **отстоя́ться**; **~ раство́ра** эремәнең тонуы

отста́ивать I *несов. см.* **отстоя́ть** I

отста́ивать II *несов. см.* **отстоя́ть** II

отста́иваться *несов. разг. см.* **отстоя́ться**

отста́лость *ж* артталык, артта калганлык

отста́лый, -ая, -ое арттагы, артта калган

отста́||ть *сов.* 1. *от кого-чего* (*остаться позади*) артта калу 2. *от чего* (*остаться на месте*) калу, торып калу; **~ть от по́езда** поезддан торып калу 3. *перен.* артта калу; **~ть от ве́ка** заманнан артта калу 4. (*о часах*) артка калу 5. (*отделиться, отвалиться*) кубу, кубып төшү, кубып чыгу; **обо́и ~ли** обойлар кубып төшкән 6. *от кого, разг.* (*перестать надоедать*) мәшәкатьләмәү, бәйләнмәү, борчымау

отстега́ть *сов. кого-что* чыбыркылау, чыбыклау, сугу, суктыру

отстёгивать *несов. см.* **отстегну́ть**

отстёгиваться *несов.* 1. *см.* **отстегну́ться**; 2. *страд. от* **отстёгивать**

отстегну́ть *сов. что* чишү, ычкындыру, чишеп (ычкындырып) җибәрү

отстегну́||ться *сов.* чишелү, ычкыну; **пу́говица ~лась** төймә ычкынган

отстира́ть *сов. что* юып чистарту, юып бетерү, юып китәрү; **~ пятно́** тапны юып бетерү

отстира́||ться *сов.* югач бетү; **пятно́ ~лось** тап югач бетте

отсти́рывать *несов. см.* **отстира́ть**

отсти́рываться *несов.* 1. *см.* **отстира́ться**; 2. *страд. от* **отсти́рывать**

отстой *м* утырма, турта (*төпкә утырып калган нәрсә*)

отстойник *м тех.* тондыру бассейны

отстоя́ть I *сов. кого-что* (*защитить*) яклау, яклап калу; саклап калу

отстоя́ть II *сов. что и без доп.* (*простоять до конца*) басып тору (уздыру), ахырына кадәр (беткәнче) басып тору; **~ на нога́х весь конце́рт** концертның ахырына кадәр басып тору

отсто||я́ть III *несов. от кого-чего* арырак (читтәрәк) тору (булу); **дере́вня ~и́т от ста́нции на киломе́тр** авыл станциядән бер километр читтәрәк

отстоя́ться *сов.* **1.** (*о жидкости*) тону **2.** *перен.* (о *взглядах, мнениях и т. п.*) ныгу, ныгып җитү

отстрада́ть *сов.* җәфалар чигү; җәфалар чигеп бетерү, газап чигү

отстра́ивать *несов. см.* **отстро́ить**

отстра́иваться *несов.* **1.** *см.* **отстро́иться**; **2.** *страд. от* **отстра́ивать**

отстране́ние *с см.* **отстрани́ть, отстрани́ться** 2; **~ от до́лжности** эшеннән чыгару

отстрани́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*отодвинуть*) этү, этәрү, читкә этеп (этәреп) җибәрү **2.** *кого* (*уволить*) алу, чыгару; **~ от рабо́ты** эштән алу

отстрани́ться *сов.* **1.** читкә китү (ташлану, тайпылу); **~ от уда́ра** сугудан читкә тайпылу **2.** (*уклониться*) катнашмау, катнашмый башлау; баш тарту; **~ от всех хлопо́т** барлык мәшәкатьләрдән баш тарту

отстраня́ть *несов. см.* **отстрани́ть**

отстраня́ться *несов.* **1.** *см.* **отстрани́ться**; **2.** *страд. от* **отстраня́ть**

отстре́л *м см.* **отстре́ливать** 2, **отстреля́ть; ~ лосе́й** пошиларны ату (*ауда*)

отстре́ливать *несов.* **1.** *см.* **отстрели́ть, отстреля́ть; 2.** *кого-что* (*охотиться*) аулау, рөхсәт буенча аулау

отстре́ливаться *несов.* **1.** *см.* **отстреля́ться** 1; **2.** *страд. от* **отстре́ливать**

отстрели́ть *сов. что* (*оторвать*) атып өздерү; **~ па́лец** бармакны атып өздерү

отстреля́ть *сов. кого, охот.* аулап атып үтерү, атып бетерү; **~ волко́в** бүреләрне аулап атып бетерү

отстреля́ться *сов.* **1.** *от кого-чего* (*отбиться стрельбой*) ата-ата котылу, каршы атып котылу **2.** (*закончить стрельбу*) атып бетерү, атуны тәмамлау, атудан туктау

отстрига́ть *несов. см.* **отстри́чь**

отстри́чь *сов. что* кырку, кыркып (кисеп) алу, кыркып (кисеп) ташлау

отстро́ить *сов. что* **1.** (*закончить постройку*) төзеп бетерү, корып (салып) бетерү **2.** (*восстановить*) яңадан төзү, яңадан кору, яңадан салу

отстро́иться *сов. разг.* **1.** төзеп бетерү, корып (салып) бетерү (*узең өчен өйне h.б.ш.*) **2.** яңадан төзелү; яңадан салу (*узең өчен*)

отсту́кать *сов. что, разг.* **1.** шакылдатып уйнау; **~ такт мело́дии** шакылдатып көй тактын уйнау **2.** (*на машинке*) шакылдатып алу, шакылдатып басып алу

отсту́кивать *несов. см.* **отсту́кать**

о́тступ *м полигр.* буш урын, ара, аралык (*текстны башлап китәр алдыннан буш калдырылган урын*)

отступа́тельный, -ая, -ое (*являющийся отступлением*) чигенү ...ы

отступа́ть *несов. см.* **отступи́ть**

отступа́ться *несов. см.* **отступи́ться**

отступи́ть *сов.* **1.** чигү, чигенү; **~ на шаг** бер адымга чигү; **~ с бо́ями** сугышып чигенү **2.** *перен. перед чем* чигенеп калу; **~ пе́ред тру́дностями** авырлыклардан чигенеп калу **3.** *от чего и без доп.* кире кайту, түнү; **~ от свои́х убежде́ний** үзенең карашларыннан кире кайту **4.** *от чего* читкә китү (чыгу); **~ от те́мы** темадан читкә китү **5.** *от чего* (*сделать отступ*) буш урын калдыру, буш урын калдырып яза башлау

отступи́||ться *сов. от кого-чего, разг.* **1.** (*отказаться*) баш тарту; сүзендә тормау, тану, түнү **2.** (*перестать общаться*) ташлау, араны өзү, бәйләнешне өзү; **друзья́ ~лись от него́** дуслары аның белән араны өзделәр

отступле́ние *с* **1.** *воен.* чигенү, чигенеш **2.** (*отклонение*) чигенеш, тайпылу; **лири́ческое ~** лирик чигенеш **3.** (*нарушение*) читкә китү, тайпылу; **~ от пра́вил** кагыйдәләрдән читкә китү

отсту́пник *м* мөртәт, ваз кичүче

отсту́пница *ж* мөртәт хатын (кыз), ваз кичүче хатын (кыз)

отсту́пничество *с* мөртәтлек

отступн||о́й, -а́я, -о́е *уст.* ваз кичү ...ы, ваз кичкән өчен бирелә торган; **~ы́е де́ньги** ваз кичкән өчен бирелгән акча

отступя́ *нареч.* (*бераз*) ара калдырып, (*бераз*) читтәрәк

отсту́чать *сов. см.* **отсту́кать**

отсу́тствие *с* юклык, юк булу, булмау; **~ де́нег** акча булмау; **в моё ~** мин юк чакта

отсу́тствовать *несов.* булмау, килмәү; **~ на собра́нии** җыелышта булмау

отсу́тствующ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **отсу́тствовать**; **2.** (*безразличный*) салкын, пассив; **~ий взгляд** салкын караш **3.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* булмаганнар, килмәгәннәр; **отмеча́ть ~их** килмәгәннәрне билгеләү

отсчита́ть *сов.* **1.** *кого-что* санап бирү; санап аерып кую; **~ пятьсо́т ты́сяч рубле́й** биш йөз мең сум акча санап бирү **2.** *от чего* (*сосчитать*) ... башлап санау; **~ пять шаго́в от де́рева** агачтан башлап биш адым санау

отсчи́тывать *несов. см.* **отсчита́ть**

отсыла́ть *несов. см.* **отосла́ть**

отсы́лка *ж* **1.** *см.* **отосла́ть; ~ паке́тов** пакетларны биреп җибәрү **2.** (*в тексте*) отсылка, күрсәтү, чыганакка җибәрү

отсы́пать *сов. что, чего* (*бер өлешен*) бушатып алу, бушатып бирү; салып алу, салып бирү (*он, ярма h.б.ш. турында*); **~ крупы́** (*бераз*) ярма салып алу

отсыпа́ть *несов. см.* **отсы́пать**

отсы́паться *сов. разг.* сибелү, түгелү, чәчелү

отсыпа́ться I *несов. см.* **отоспа́ться**

отсыпа́ться II *несов.* **1.** *см.* **отсы́паться**; **2.** *страд. от* **отсыпа́ть**

отсыре́лый, -ая, -ое юешләнгән, дымланган, юеш, дымлы; **~ таба́к** дымланган тәмәке

отсыре́ть *сов.* юешләнү, дымлану

отсыха́ть *несов. см.* **отсо́хнуть**

отсю́да *нареч.* **1.** моннан, биредән, шушы урыннан, бу җирдән **2.** *перен.* (*по этой причине*) шул сәбәптән, шунлыктан, моннан; **~ заключа́ем сле́дующее...** моннан түбәндәге нәтиҗәне чыгарабыз...

отта́ивать *несов. см.* **отта́ять**

отта́лкивать *несов. см.* **оттолкну́ть**

отта́лкиваться *несов.* **1.** *см.* **оттолкну́ться**; **2.** *страд. от* **отта́лкивать**

отта́лкивающий, -ая, -ее чирканыч, җирәнеч, биздергеч, сәйкемсез; **~ вид** сәйкемсез кыяфәт

отта́птывать *несов. см.* **оттопта́ть**

оттаска́ть *сов.* **1.** *что* (*оттащить*) сөйрәп илтеп кую, ташып кую **2.** *кого, прост.* (*за́ волосы, уши*) кирәген бирү, тарту (*колагын*)

отта́скивать *несов. см.* **оттаска́ть** 1, **оттащи́ть**

отта́чивать *несов. см.* **отточи́ть**

отта́чиваться *несов.* **1.** *см.* **отточи́ться**; **2.** *страд. от* **отта́чивать**

оттащи́ть *сов. кого-что* **1.** өстерәп илтеп кую, сөйрәп [өстерәп] читкә алып китү **2.** *перен.* аеру, аерып алу

отта́я||ть *сов.* **1.** (*разморозиться*) эрү, эреп төшү; **о́кна ~ли** тәрәзәләр эрегән **2.** *что* эретү; **~ть мя́со** итне эретү

оттека́ть *несов. см.* **отте́чь**

оттени́ть *сов. что* **1.** күләгәләү, күләгә төшерү; каралту, каралта төшү; **~ ко́нтуры на рису́нке** рәсем контурларын каралту **2.** *перен.* (*сделать более заметным*) басым ясап әйтү, ачыклау, ачык итеп күрсәтү

отте́н||ок *м прям., перен.* төс, төсмер; **ро́зы све́тлых ~ков** ачык төстәге роза чәчәкләре; **но́вые ~ки в значе́нии сло́ва** сүз мәгънәсенең яңа төсмерләре

оттеня́ть *несов. см.* **оттени́ть**

о́ттепель *ж* җепшек көн

оттере́ть *сов.* **1.** *что* ышкып (уып) чистарту, ышкып (уып) бетерү; **~ грязь** ышкып чистарту **2.** *кого-что* уу, ышку; **~ сне́гом обморо́женное у́хо** өшегән колакны кар белән уу **3.** *кого-что, прост.* (*отеснить*) кысрыклап чыгару, читкә этәреп чыгару

оттере́ться *сов.* уып төшерелү; ышкылып чистару

оттесни́ть *сов. кого-что* кысрыклау, кысрыклап чыгару; чигендерү, куып чыгару

оттесня́ть *несов. см.* **оттесни́ть**

отте́чь *сов.* агып китү, [читкә] агып китү

оттира́ть *несов. см.* **оттере́ть**

оттира́ться *несов.* **1.** *см.* **оттере́ться**; **2.** *страд. от* **оттира́ть**

о́ттиск *м* **1.** (*отпечаток*) эз; **~ башмака́** башмак эзе **2.** оттиск; **корректу́рный ~** корректура оттискы **3.** оттиск (*басылып чыккан мәкаләнең аерым тапланган данәсе*); **~ статьи́** мәкаләнең оттискы

отти́скивать *несов. см.* **отти́снуть**

отти́снуть *сов.* **1.** *кого-что* (*оттеснить*) кысрыклап чыгару, этеп чыгару **2.** *что, полигр.* (*отпечатать*) бастырып алу, оттиск алу

оттого́ *нареч.* шунлыктан, шуңа күрә, ...лыктан, ...ганга күрә ♦ **~ что** *союз* чөнки

оттолкну́ть *сов. кого-что* **1.** этәреп жибәрү, тибәрү **2.** (*отдалить от себя*) читләтү, биздерү, ераклаштыру; **~ от себя́ друзе́й** дусларны үзеңнән биздерү

оттолкну́ться *сов.* **1.** *от кого-чего* этәрелү, этеп кузгалып китү; **~ весло́м от бе́рега** ишкәк белән этеп ярдан кузгалып китү **2.** *перен. от чего* таянып эш итү; ...дан чыгып эш итү

оттома́нка *ж* оттоманка, төрек диваны

оттопта́ть *сов. что, разг.* басып авырттыру; китереп басу; **~ но́гу** *кому-л. кемнең дә булса* аягына басып авырттыру

оттопы́ривать *несов. см.* **оттопы́рить**

оттопы́риваться *несов.* **1.** *см.* **оттопы́риться; 2.** *страд. от* **оттопы́ривать**

оттопы́рить *сов. что, разг.* тырпайту, кабарту; торгызу, турсайту; **~ карма́н** кесәне кабарту; **~ гу́бы** иренне турсайту

оттопы́риться *сов. разг.* тырпаеп тору, тырпаеп кабарып чыгу; кабарып тору; турсаю

отторгну́ть *несов. см.* **отто́ргнуть**

отто́ргнуть *сов. кого-что книжн.* аерып алу, тартып алу; **~ зе́мли** [чит] жирләрне тартып алу

отторже́ние *с см.* **отто́ргнуть**

отточи́ть *сов. что* **1.** (*сделать острым*) үткенләү, үткенләп алу; кайрау, чарлау, беләүләү; кайрап, чарлап алу; очлау (*карандашны*) **2.** *перен.* (*сделать чётким*) шомарту (*сүзне, әйтемне һ.б.ш.*)

отточи́ться *сов.* үткенләнү, кайралу, чарлану; (*о карандаше*) очлану

отто́чка *ж см.* **отточи́ть**

оттрепа́ть *сов. кого-что, разг.* тарту, тарткалау; бору; **~ за́ ухо** колагын бору

отту́да *нареч.* аннан, шуннан, тегеннән, шул яктан, шул җирдән, шул урыннан

оття́гивать *несов. см.* **оттяну́ть**

оття́гиваться *несов.* **1.** *см.* **оттяну́ться; 2.** *страд. от* **оття́гивать**

оття́жк||а *ж* **1.** *см.* **оттяну́ть** 1-3; **2.** (*үзеңә таба*) тартып сугу; **удо́рить с ~ой** үзеңә таба тартып сугу

оттяну́ть *сов.* **1.** *что* (*берәр якка*) тарту, тартып кую; **~ куро́к** курокны тартып кую **2.** *кого-что* (*отвести*) күчерү, алып китү, читкә алып китү; **~ полк** полкны күчерү **3.** *перен. что* (*отсрочить*) кичектерү, соңарту, озакка сузу **4.** *что* салындыру, салындырып төшерү; **~ карма́н** кесәне салындырып төшерү **5.** *что, разг.* (*причинить боль*) авырттыру (*авыр нәрсә күтәреп*)

оттяну́ться *сов.* **1.** *воен.* артка чигенү, читкә китү **2.** (*стать отвислым*) салынып төшү

оття́пать *сов. что, прост.* **1.** (*отсечь*) чабып (кисеп) алу, чабып (кисеп) төшерү **2.** (*отнять*) тартып алу, тартып кайтарып алу

оття́пывать *несов. см.* **оття́пать**

оту́жинать *сов.* **1.** (*кончить ужинать*) кичке ашны ашап бетерү **2.** *уст.* (*поужинать*) кичке аш ашап алу

отума́нивать *несов. см.* **отума́нить**

отума́ниваться *несов.* **1.** *см.* **отума́ниться; 2.** *страд. от* **отума́нивать**

отума́н||ить *сов. кого-что* [зиһенен] чуалту, башын әйләндерү, аңгы-миңге китерү; **вино́ ~ло созна́ние** шәраб зиһенне чуалтты

отума́н||иться *сов.* зиһене чуалу, башы әйләнү, аңгы-миңге килү; **созна́ние ~лось** зиһен чуалды

отупе́лый, -ая, -ое *разг.* аңгыраланган, мингерәүләнгән; аңгыра

отупе́ние *с см.* **отупе́ть**

отупе́ть *сов.* аңгыралану, миңгерәүләнү

отутю́живать *несов. см.* **отутю́жить**

отутю́жить *сов. что* үтүкләп кую, үтүкләп алу

отуча́ть *несов. см.* **отучи́ть**

отуча́ться *несов.* **1.** *см.* **отучи́ться** I; **2.** *страд. от* **отуча́ть**

оту́чивать *несов. см.* **оту́чить**

оту́чиваться *несов. см.* **оту́читься** 1

отучи́ть *сов. кого-что от чего и с неопр.* ташлату, биздерү

отучи́ться *сов.* **1.** *от чего и с неопр.* (*отвыкнуть*) ташлау, бизү **2.** (*кончить учиться*) укып бетерү, укуны тәмамлау

отформова́ть *сов. что, тех.* калыпка салып ясау, калыпка сугу, калыплау

отформо́вывать *несов. см.* **отформова́ть**

отфутбо́ливать *несов. см.* **отфутбо́лить**

отфутбо́лить *сов. кого-что, прост.* борып чыгару; башкага жибәрү (*бер инстанциядән икенчесенә җибәрү*)

отфы́ркиваться *несов. разг.* пошкырып кую (алу)

отфы́ркнуться *сов. однокр. см.* **отфы́ркиваться**

отха́живать *несов. см.* **отходи́ть** II

отха́ркать *сов. что* какыру, какырып чыгару (ташлау)

отха́ркаться *сов.* **1.** (*очистить горло от мокроты*) какырып чыгару **2.** (*отделиться — о мокроте*) какырып чыгарылу

отха́ркивать *несов. см.* **отха́ркать, отхаркну́ть**

отха́ркиваться *несов.* **1.** *см.* **отха́ркаться, отхаркну́ться; 2.** *страд. от* **отха́ркивать**

отха́ркнуть *сов. см.* **отха́ркать**

отха́ркнуться *сов. см.* **отха́ркаться**

отхвати́ть *сов.* **1.** *что, разг.* өзеп (чабып) алу, киселп алу (төшерү); тешләп алу; умырып алу; **~ па́лец топоро́м** балта белән бармакны кисеп төшерү **2.** *кого-что, прост.* (*приобрести*) эләктереп калу, эләктерү; **~ себе́ костю́м** үзеңә костюм эләктереп калу

отхва́тывать *несов. см.* **отхвати́ть**

отхлебну́ть *сов. что, чего, разг.* чөмерү, чөмереп (эчеп) җибәрү

отхлёбывать *несов. см.* **отхлебну́ть**

отхлеста́ть *сов. кого-что, разг.* камчылау, чыбыркылау, чыбыркы (чыбык) белән кыйнау

отхлёстывать *несов. см.* **отхлеста́ть**

отхло́пать *сов. что, разг.* (*ру́ки*) чаба-чаба авырттыру, чабып авырттырып бетерү (*кулны*)

отхло́пывать *несов. см.* **отхло́пать**

отхлы́ну||ть *сов.* **1.** кире китү, кире агып китү (*су турында*) **2.** *перен.* кинәт чигенү, читкә ташлану, читкә тайпылу; **толпа́ ~ла** халык төркеме читкә тайпылды

отхо́д *м см.* **отойти́** 1, 2, 6, 7; **~ по́езда** поездның китүе

отходи́ть I *несов. см.* **отойти́**

отходи́ть II *сов. кого, разг.* (*вылечить*) карап сәламәтләндерү, тәрбияләп савыктыру

отходи́ть III *сов.* **1.** *разг.* (*кончить ходить*) йөрми башлау, йөрүдән туктау **2.** *что, разг.* (*нек-рое время*) йөреп алу, йөреп үткәрү **3.** *что, прост.* (*утомить*) йөреп талдыру, йөреп авырттыру (авыртырып бетерү)

отхо́дная *ж рел.* (*христианнарда*) кеше үлгәндә укыла торган дога; (*мөселманнарда*) ясин чыгу, ясин чыгу догасы

отхо́дчивый, -ая, -ое ачуы тиз басыла торган

отхо́ды *мн.* калдыклар, калдык-постык; **нефтяны́е ~** нефть калдыклары

отхо́ж||ий, -ая, -ее: **~ий про́мысел** *уст.* читкә китеп эшләү; **~ее ме́сто** бәдрәф, әбрәкәй

отцвести́ *сов.* **1.** чәчәк атып бетерү **2.** *перен.* сүну, бетү

отцвета́ть *несов. см.* **отцвести́**

отцеди́ть *сов.* **1.** *что, чего* (*отлить*) сөзеп агызып алу **2.** *что* (*пропустить через что-л.*) сөзеп алу, сөзеп чистарту

отцежи́вать *несов. см.* **отцеди́ть**

отцепи́ть *сов. что* ычкындыру, ычкындырып алу (җибәрү); **~ парово́з** паровозны ычкындыру

отцепи́ться *сов.* **1.** (*отделиться*) ычкыну, ычкынып китү **2.** *перен. прост.* бәйләнми башлау, теңкәгә тими башлау, бәйләнмәү

отцепля́ть *несов. см.* **отцепи́ть**

отцепля́ться *несов.* **1.** *см.* **отцепи́ться; 2.** *страд. от* **отцепля́ть**

отцеуби́йство *с* үз атасын үтерү

отцеуби́йца *м, ж* үз атасын үтерүче, атасын үтергән кеше

отциклева́ть *сов. что* цикля белән эшкәртү, шомарту; **~ парке́т** паркетны шомарту

отцо́вск||ий, -ая, -ое ата ...ы; аталык ...ы; **~ий дом** ата йорты; **~ие чу́вства** аталык хисләре

отцо́вство *с* аталык, ата булу

отча́иваться *несов. см.* **отча́яться**

отча́ливать *несов. см.* **отча́лить**

отча́л||ить *сов.* **1.** *что, мор.* (*отвязать причал*) чалкаларны чишү (чишеп җибәрү) **2.** (*отплыть*) кузгалу, кузгалып китү (*пароход, көймә һ.б.ш. турында*) ♦ **~вай!** *прост.* тай моннан!, ычкын!, үкчәңне күтәр!

отча́сти *нареч.* берникадәр, бераз, өлешчә

отча́яние *с* өметсезлек, өмет өзү; төшенкелек, рухи төшенкелеге

отча́янность *ж разг.* үтә тәвәккәллек, үтә кыюлык, чаялык

ОТЧ-ОТЪ

отча́янн||ый, -ая, -ое **1.** өметсез; **~ый взгляд** өметсез караш **2.** бик авыр; **~ое положе́ние** бик авыр хәл **3.** (*очень смелый*) артык кыю, үтә тәвәккәл, чая **4.** *разг.* чиктән ашкан, актык чиккә җиткән, өметсез; **~ый картёжник** чиктән ашкан кәртче

отча́яться *сов. в чём и с неопр.* өмет өзү, өметсезләнү, өметсезлеккә бирелү; рух төшү

отчего́ 1. *нареч.* нигә, нилектән, ни сәбәптән, ни өчен; **не зна́ю, ~ он не пришёл** аның ни өчен килмәгәнен белмим **2.** *союз* (*вследствие чего*) шул сәбәптән, шуның аркасында

отчего́-либо, отчего́-нибудь *нареч.* берәр сәбәптән, берәр сәбәп аркасында, ни өчен дә булса

отчего́-то *нареч.* ни сәбәптәндер, нигәдер, ни өчендер

отчека́нивать *несов. см.* **отчека́нить**

отчека́нить *сов.* **1.** *что* кою, сугу; **~ моне́ту** акча сугу **2.** *перен. что и без доп.* ачык итеп әйтеп бирү, аермачык итеп әйтү, һәр авазын ачык итеп әйтү; **~ ка́ждое сло́во** һәр сүзне ачык итеп әйтү

отчёркивать *несов. см.* **отчеркну́ть**

отчеркну́ть *сов. что* сызып кую, сызып билгеләү, сызык белән аерып алу

отчерпну́ть *сов. что, чего* сосып алу, сосып алып киметү, сосып алып киметә төшү

отчёрпывать *несов. см.* **отчерпну́ть**

о́тчество *с* отчество, атасының исеме (*Сергеевич, Николаевич h.б.ш*)

отчёт *м* отчёт; хисап; **ава́нсовый ~** аванс отчёты; **годово́й ~** еллык отчёт; **дава́ть ~** отчёт бирү ♦ **дать (отда́ть) себе́ ~** *в чём* үз-үзеңә хисап бирү; **не дава́я (не отдава́я) себе́ ~а** *в чём* аңсыз рәвештә, белештермичә, уйлап-нитеп тормыйча

отчётливость *ж* ачыклык, аныклык, анык булу

отчётлив||ый, -ая, -ое **1.** ачык, анык; **~ый по́черк** ачык почерк; **~ое произноше́ние** ачык ишетелә торган әйтелеш **2.** ачык, аңлаешлы; **~ое изложе́ние** ачык итеп сөйләп бирү

отчётно-вы́борн||ый, -ая, -ое отчёт-сайлау ...ы; **~ое собра́ние** отчёт-сайлау җыелышы

отчётность *ж* **1.** (*документы*) отчёт, отчёт документлары **2.** (*проведение отчётов*) отчёт (хисап) бирү

отчётный, -ая, -ое отчёт ...ы; **~ докла́д** отчёт доклады; **~ пери́од** отчёт чоры

отчи́зна *ж высок.* ватан, туган ил

о́тчий, -ая, -ее *высок.* ата ...ы; **~ дом** ата йорты

о́тчим *м* үгеи ата

отчисле́ни||е *с* **1.** *см.* **отчи́слить; 2.** *обычно мн.* **~я** бүлеп алып калынган сумма, аерып бирелгән сумма; **~я на строи́тельство** төзелешкә бүленгән суммалар

отчи́слить *сов.* **1.** *что* (*вычесть, удержать*) чигерү, тотып алып калу, бүлеп алып калу, аерып бирү; **~ ты́сячу рубле́й** мең сум тотып алып калу **2.** *кого-что* (*исключить*) чыгару

отчи́слиться *сов.* чыгу, чыгып китү (*эштән һ.б.ш.*), укуны ташлау; хезмәттән китү

отчисля́ть *несов. см.* **отчи́слить**

пло́дн||ый, -ая, -ое *биол.* **1.** аталанган; **~ое я́йцо** аталанган йомырка **2.** җимешле, җимеш бирә торган, токым бирә торган; **~ая ви́шня** җимеш бирә торган чия

плодо- *кушма сүзләрнең «җимеш» мәгънәсен аңлата торган беренче өлеше, мәс.* **плодообразова́ние** җимеш хасил булу; **плодопито́мник** җимеш питомнигы

плодови́тость *ж* **1.** җимешлелек, җимешне мул бирүчәнлек; **~ расте́ния** үсемлекнең җимешне мул бирүчәнлеге **2.** (*способность быстро размножаться*) үрчемлелек, үрчемне күп бирүчәнлек **3.** *перен.* күп иҗат итүчәнлек

плодови́тый, -ая, -ое **1.** (*о растениях*) җимешле, җимешне мул бирә торган **2.** (*о людях, животных*) үрчемле, үрчемне күп бирә торган, тиз үрчи торган **3.** *перен.* күп әсәрләр бирүче, күп иҗат итүче; **~ писа́тель** күп әсәрләр бирүче язучы

плодово́дство *с* җимеш үстерүчелек, җиләк-җимеш үстерү, җимешчелек

плодово́дческий, -ая, -ое җимеш үстерү[челек] ...ы, җиләк-җимеш үстерү ...ы, җимешчелек ...ы; **~ совхо́з** җимеш үстерү совхозы

плодо́в||ый, -ая, -ое **1.** җимеш ...ы, җимеш бирә торган; **~ые дере́вья** җимеш агачлары **2.** җимештән хәзерләнгән (ясалган), җиләк-җимеш ...ы; **~ые консе́рвы** җиләк-җимеш консервлары

плодоно́жка *ж бот.* җимеш сабы, җимеш сабагы

плодоноси́ть *несов.* җимеш бирү, җимеш бирергә сәләтле булу

плодоно́с||ный, -ая, -ое җимешле, җимеш бирә торган; **~ые расте́ния** җимеш бирә торган үсемлекләр

плодоноше́ние *с см.* **плодоноси́ть**

плодоовощно́й, -а́я, -о́е җимеш-яшелчә ...ы, җимеш-яшелчә үстерә торган; **~ магази́н** җимеш-яшелчә кибете; **~ колхо́з** җимеш-яшелчә үстерә торган колхоз

плодоро́дие *с* уңдырыш, уңдырышлылык, уңыш бирүчәнлек, уңыш бирү; **~ по́чвы** туфракның уңдырышлылыгы

плодоро́дн||ый, -ая, -ое уңдырышлы, уңдыручан, мул уңыш бирүчән; **~ая по́чва** уңдырышлы туфрак

плодосбо́р *м* җимеш җыю, җимеш җыйнау

плодотво́рность *ж* нәтиҗәлелек, уңышлылык, нәтиҗәле булу

плодотво́рный, -ая, -ое нәтиҗәле, уңышлы, җимешле; **~ труд** нәтиҗәле хезмәт

плодохрани́лище *с* җимеш саклау урыны (бинасы)

плодоя́годн||ый, -ая, -ое җиләк-җимеш ...ы, җиләк-җимештән хәзерләнгән (ясалган); **~ое вино́** җиләк-җимеш аракысы; **~ые консе́рвы** җиләк-җимештән хәзерләнгән консервлар

пло́мб||а *ж в разн. знач.* пломба; **наложи́ть ~у** пломба салу (*мәс. бикле ишеккә*); **положи́ть ~у** пломба белән ямау (*тешне*)

пломби́р *м* пломбир (*морожный*)

пломбирова́ние *с см.* **пломбирова́ть**

пломбиро́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **пломбирова́ть**; **2.** пломбаланган, ямалган; **~ые зу́бы** пломбаланган тешләр

пломбирова́ть *несов. что* **1.** пломбалау, пломба сугу (салу), пломба белән печатьләү; **~ това́ры** товарларга пломба сугу; **~ваго́н** вагонны пломбалау **2.** ямау, пломбалау, пломба кую; **~ зу́бы** тешләргә пломба кую

пломбиро́вка *ж см.* **пломбирова́ть**

пло́ск||ий, -ая, -ое **1.** яссы, ялпак, тигез, такыр; **~ая кры́ша** яссы түбә **2.** җәенке, җәйпәк, сай; **~ая таре́лка** сай тәлинкә **3.** *перен.* тупас, кызыксыз, үткенлеге булмаган, буш; **~ая шу́тка** кызыксыз мәзәк

плоско- *кушма сүзләрнең «яссы» мәгънәсен аңлата торган беренче өлеше, мәс.* **плосковёрхий** яссы өсле; **плоскозу́бый** яссы тешле

плоского́рье *с* яссы тау, яссы таулык

плоскогру́дый, -ая, -ое яссы (такта) күкрәкле

плоскогу́бцы *только мн.* каргаборын, үрдәкборын

плоскодо́нка *ж* яссы төпле кәймә

плоскодо́нн||ый, -ая, -ое яссы төпле; **~ая ло́дка** *см.* **плоскодо́нка**

плоскосто́пие *с мед.* яссы табанлылык, җәенке табан, җәйпәк табан

пло́скост||ь *ж* **1.** *мат.* яссылык; **пересече́ние ~е́й** яссылыкларның кисешүе **2.** *перен.* караш ноктасы, юнәлеш, план, өлкә, сфера; **рассмотре́ть вопро́с в друго́й ~и** мәсәләне башка юнәлештә тикшерү (*мәсьәләгә башкачарак якын килү*) **3.** *ав.* (*крыло самолёта*) самолёт канаты ♦ **кати́ться (ска́тываться) по наклонно́й ~и** түбән таба тәгәрәү

плот *м* сал

плотва́ *ж* чабак (*балык*)

плоти́на *ж* буа, бөя, плотина; **бетóнная ~** бетон плотина

плоти́нный, -ая, -ое плотина ...ы; **~ шлюз** плотина шлюзы

пло́тник *м* балта остасы, плотник

пло́тничать *несов.* балта остасы булып эшләү, плотник булып эшләү; балта эшендә эшләү

пло́тническ||ий, -ая, -ое балта оста [-лар]ы ...ы; балта осталыгы ...ы; **~ий инструме́нт** балта остасы инструменты; **~ое ремесло́** балта остасы һөнәре

пло́тнич||ий, -ья, -ье балта оста [-лар]ы ...ы; балта осталыгы ...ы; **~ья арте́ль** балта осталары артеле; **~ье де́ло** балта осталыгы эше

пло́тничн||ый, -ая, -ое балта ...ы, балта осталыгы ...ы; **~ые рабо́ты** балта эшләре

пло́тно *нареч.* **1.** тыгыз, тыгыз итеп, тыгызлап; **~ утрамбова́ть грунт** җирне тыгызлап таптау (төю) **2.** янәшә үк китереп, бик якын китереп, терәп; **приста́вить шкаф ~ к стене́** шкафны стенага терәп үк кую **3.** нык итеп, ныгытып; **~ закры́ть** дверь ишекне ныгытып ябу **4.** *разг.* бик яхшылап, бик шәп итеп, туйганчы; **я ~ пое́л** мин бик шәп итеп ашап алдым

пло́тность *ж* **1.** *физ.* тыгызлык; **~ вещества́** матдәнең тыгызлыгы **2.** калынлык, тыгызлык, ныклык; **~ тка́ни** тукыманың тыгызлыгы **3.** (*телосложения*) тулылык, тыгыз төнлелек, базыклык ♦ **~ населе́ния** халыкның тыгызлыгы

пло́тн||ый, -ая, -ое **1.** тыгыз, куе; **~ая ма́сса** куе масса; **~ый дым** куе төтен **2.** калын, тыгыз, нык; **~ая ткань** тыгыз тукыма **3.** тулы, тыгыз (таза) тәнле, ныкча, базык; **~ый мужчи́на** тыгыз тәнле ир кеше **4.** *разг.* туклыклы, туйдыра торган, мул [итеп хәзерләнгән]; **~ый за́втрак** мул итеп хәзерләнгән иртәнге аш

плотвод́ *м спец. см.* **плотого́н**

плотовщи́к *м* **1.** салчы, сал бәйләүче, сал агызучы **2.** (*работающий на переправе*) су аркылы чыгаручы (*сал белән*)

плотого́н *м* салчы, сал куучы, сал агызучы

плотоя́дность *ж* **1.** ерткычлык, ит белән туенучылык **2.** *перен.* җенси теләк булу, хайвани теләк булу

плотоя́дн||ый, -ая, -ое **1.** ерткыч, ит белән туенучы; **~ый зверь** ерткыч җанвар **2.** *перен.* җенси хис белән ..., хайвани теләк белән..., күзләрне майландырып ...; **~ая улы́бка** җенси хис белән елмаю

пло́тск||ий, -ая, -ое *уст.* женси, бәдәни, бәдән ...ы; **~ие жела́ния** бәдәни теләкләр

плот||ь *ж уст.* тән, гәүдә, җисем, бәдән ♦ **~ь и кровь** туган балам, йөрәк парәм; **~ью от ~и** *кого, высок.* үз каны, үз баласы

пло́хо *нареч.* **1.** начар, яман, алама; **~ обраща́ться** *с кем-л. кем белән* дә булса начар мөгамәлә итү **2.** *в знач. сказ. безл. кому* начар, авыр; **ему́ ~** аның хәле авыр ♦ **~ лежи́т** күренеп ята, җыеп куелмаган

плох||о́й, -а́я, -о́е *в разн. знач.* начар, яман, алама, койты, хәрти, кәй; **~о́й челове́к** яман кеше; **~о́й таба́к** начар тәмәке; **~а́я оде́жда** алама кием; **~а́я привы́чка** алама гадәт; **~о́й това́р** койты товар; **~а́я пого́да** начар һава; ♦ **на него́ ~а́я наде́жда** аңа ышанырга ярамый; **больно́й о́чень плох** авыруның хәле бик авыр

пло́шка *ж* **1.** *прост.* (*сосуд*) кәнди, кечкенә сай савыт **2.** (*для освещения*) шәм савыты

площа́дка *ж* **1.** кечкенә мәйдан, мәйданчык; **спорти́вная ~** спорт мәйданчыгы; **ста́ртовая ~** старт мәйданчыгы **2.** площадка (*вагонның алгы һәм арткы өлеше*); **пере́дняя ~ трамва́я** трамвайның алгы площадкасы

площадн||о́й, -а́я, -о́е тупас, әдәпсез, эшәке; **~а́я брань** тупас сүгенү сүзләре

пло́щадь *ж в разн. знач.* мәйдан; йөззурлык; **Кра́сная ~** Кызыл мәйдан; **посевна́я ~** чәчү мәйданы; **~ треуго́льника** *мат.* өчпочмакның йөззурлыгы; **жила́я ~** торак мәйданы

плуг *м* сабан; **тра́кторный ~** трактор сабаны

плугово́й, -а́я, -о́е сабан ...ы; **~ ле́мех** сабан төрәне

плу́жн||ый, -ая, -ое сабан ...ы; сабан белән ...; **~ая обрабо́тка земли́** җирне сабан белән эшкәртү

плут *м* **1.** (*обманщик*) алдакчы **2.** (*хитрец*) хәйләкәр

плута́ние *с см.* **плута́ть**

плута́ть *несов. разг.* адашып йөрү, юлдан язып йөрү; **~ по ле́су** урманда адашып йөрү

плу́тни *только мн. разг.* хәйлә, алдау, мәкер

плутова́тость *ж* хәйләкәрлек, алдашучанлык, мутлык

плутова́тый, -ая, -ое **1.** хәйләкәр, алдакчы, мут; **~ челове́к** мут кеше **2.** хәйләле; **~ взгляд** хәйләле караш

плутова́ть *несов. разг.* хәйләләү, алдау, алдашу, хәрәмләшү; **~ при игре́ в ка́рты** кәрт уенында хәрәмләшү

плутовка *м см.* **плут**

плутовск||о́й, -а́я, -о́е **1.** хәйләле, мәкерле, алдаулы, алдакчыларга хас [булган]; **~ие приёмы** алдакчыларга хас булган алымнар **2.** хәйләле, хәйлә белдерә торган; **~о́й взгляд** хәйләле караш

плутовство́ *с* **1.** (*обман*) алдау, алдашу, ялган **2.** (*хитрость*) хәйлә, мәкер, мутлык

плутокра́тия *ж книжн.* плутократия (*сәяси хакимият тулысы белән бай сыйныфлар кулында булган дәүләт төзелеше*)

плыву́н *м* сулы лай катлавы (*туфрак астындагы*)

плыть *несов.* **1.** йөзү, йөзеп бару, йөзеп килү; **~ про́тив тече́ния** агымга каршы йөзү **2.** агу, агып бару, агып килү; **по реке́ плыву́т бре́вна** елга буйлап бүрәнәләр агып бара **3.** утырып бару, йөрү, бару; **~ на теплохо́де** теплоходка утырып бару **4.** *перен.* йөзү, агылу; **луна́ плывёт по не́бу** күктә ай йөзә; **ту́чи плыву́т** болытлар агыла **5.** *перен.* йөзгәндәй булып күренү; **всё плывёт пе́ред глаза́ми** күзгә бөтен нәрсә йөзгәндәй булып күренә

плюга́вый, -ая, -ое *прост.* килбәтсез, шыксыз, сөйкемсез

плю́нуть *сов. однокр. см.* **плева́ть** ♦ **раз ~** *кому, прост.* берни тормый, бик ансат (*эшләве, башкаруы*); **~ не́куда (не́где)** *прост.* шыгрым тулы, энә төртерлек тә урын юк

плюрали́зм плюрализм; **плюрали́зм мне́ний** фикерләр төрлелеге

плюс *м* **1.** *мат.* (*знак*) плюс, кушу билгесе **2.** *нескл. мат.* кушу, плюс; **два ~ три равня́ется пяти́** икегә өчне кушсаң биш була **3.** *перен. разг.* плюс, өстенлек, артыклык, уңай як, файда; **э́тот прое́кт име́ет мно́го ~ов** бу проектның уңай яклары күп **4.** *в знач. союза разг.* өстәвенә, шуның өстенә; **он у́чится, ~ ещё вся́кие нагру́зки** үзе укый, өстәвенә тагын әллә нинди өстәмә эшләр дә йөкләгәннәр үзенә **5.** плюс; **на со́лнце ~ де́сять [гра́дусов]** кояшта плюс ун градус

плюсна́ *ж анат.* табан

плюснев||о́й, -а́я, -о́е *анат.* табан ... ы; **~ые ко́сти** табан сөякләре

плю́хаться *несов. см.* **плю́хнуться**

плю́хнуться *сов. прост.* лап итеп утыру (егылу), шап итеп егылу, лач итеп барып төшү; **~ в грязь** лач итеп пычракка барып төшү

плюш *м* хәтфә, плюш

плю́шев||ый, -ая, -ое плюш ..., хәтфә ..., плюш (хәтфә) белән тышланган; **~ый воротни́к** плюш яка;

плю́шка *ж* күмәч

плющ *м* чормавык, үрмәле гөл

плю́щить *несов. что* яссылау, чүкеп яссылау, юкарту, җәю; **~ желе́зо** тимерне чүкеп яссылау

пляж *м* пляж; **песча́ный ~** комлы пляж

пля́жный, -ая, -ое пляж ...ы, пляжда кия торган; **~ костю́м** пляжда кия торган костюм

пляс *м разг. см.* **плеса́ть**; **пусти́ться в ~** бии башлау

плеса́ть *несов.* **1.** *что и без доп.* бию; **~ вприся́дку** чүгә-чүгә бию **2.** *перен. разг.* биешү; **стре́лки на прибо́рах пля́шут** приборларның уклары биешәләр ♦ **~ под ду́дку** *чью-л. кемнең дә булса* кубызына бию

пля́ска *ж* **1.** *см.* **плеса́ть; 2.** (*танец*) бию

пля́сов||о́й, -а́я, -о́е **1.** бию ...ы; **~а́я му́зыка** бию музыкасы **2.** *в знач. сущ.* **~а́я** *ж* бию көе

пляcу́н *м разг.* биюче, оста биюче

пляcу́нья *ж разг.* биюче хатын (кыз)

пневма́тика *ж* пневматик механизмнар (әйберләр)

пневмати́ческий, -ая, -ое пневматик, кысылган һава көче белән эшли торган; **~ насо́с** пневматик насос

пневмони́я *ж мед.* пневмония, үпкә ялкынсыныу

пнуть *сов. кого-что, прост.* тибү, тибеп жибәрү

по *предлог* **1.** *с дат.п.* (*при обознач. предмета, места на поверхности к-рого происходит действие*) ...га; **хло́пнуть по спине́** җилкәгә сугу; **уда́рить по столу́** өстәлгә бәрү; **расста́вить кни́ги по по́лкам** китапларны киштәләргә урнаштырып чыгу **2.** *с дат.п.* (*при обознач. места, предмета, в границах к-рого происходит действие*) ...дан, буйлап; **идти́ по доро́ге** юлдан бару; **гуля́ть по го́роду** шәһәр буйлап сәйран кылып йөрү **3.** *с дат.п.* (*в направлении чего-л., следуя чему-л.*) уңаена, белән; **гла́дить по ше́рсти** йон уңаена сыпыру; **плыть по тече́нию** агым уңаена йөзү; **идти́ по следа́м зве́ря** җәнлекнең эзе белән бару **4.** *с дат.п.* (*о местах, к-рые неоднократно посещаются*) ...дан ...га; **ходи́ть по теа́трам** театрдан театрга йөрү **5.** *с дат.п.* ...ны; **скуча́ть по де́тям** балаларны сагыну; **тоска́ по ро́дине** ватанны юксыну **6.** *с дат.п.* буенча, ягыннан; **чемпио́н по ша́хматам** шахмат буенча чемпион; **специали́ст по не́фти** нефть буенча белгеч; **учи́тель по профе́ссии** профессиясе ягыннан укытучы; **ста́рший по во́зрасту** яшь ягыннан өлкәне; **ро́дственник по ма́тери** әни ягыннан кардәш **7.** *с дат.п.* (*в соответствии с чем-л., согласно чему-л.*) буенча, нигезендә, ...га карап; **рабо́тать по пла́ну** план буенча эшләү; **де́йствовать по зако́ну** закон нигезендә эш итү; **суди́ть по вне́шности** тышкы кыяфәткә карап фикер йөртү **8.** *с дат.п.* ...ча; **отвеча́ть по уста́ву** уставча жавап бирү; **оде́т по мо́де** модача киенгән **9.** *с дат.п.* (*вследствие, в результате*) аркасында, сәбәпле; **ошиби́ться по рассе́янности** хәтерсезлек аркасында ялгышу; **он не прие́хал в срок по боле́зни** авыру сәбәпле вакытында килә алмаган **10.** *с дат.п.* (*при указ. на предмет, посредством к-рого совершается действие*) белән, аркылы, аша, ...дан; **посла́ть по по́чте** почта белән жибәрү; **переда́ть по ра́дио** радио аша тапшыру; **говори́ть по телефо́ну**

телефоннан сөйләшү **11.** *с дат.п.* (*при указ. на меру времени, срок*) буе, буена; **не писа́ть по месяца́м** айлар буе хат язмау; **я не видал его́ по це́лым неде́лям** аны атналар буе күрми тора идем **12.** *с дат.п.* (*при* обознач. *отрезка времени, в течение к-рого регулярно совершается действие*) ...ларын; **по вечера́м** кичләрен **13.** *с дат.п.* ...лап; **клева́ть по зёрнышку** бөртекләп чүпләү; **плати́ть по часа́м** сәгатьләп түләү **14.** *с дат.п.* ...ар; **занима́ться по ча́су в день** көненә берәр сәгать эшләү **15.** *с вин.п.* кадәр, хәтле, тикле, тиңентен; **стоя́ть по по́яс в воде́** билгә кадәр су эчендә тору; **по коле́но** тез тиңентен: **прочита́ть с пе́рвой по деся́тую главу́** беренче бүлектән унынчы бүлеккә хәтле уку; **по сей день** шушы көнгә тикле **16.** *с вин.п. прост.* ...га; **сходи́ть по́ воду** суга барып килү; **идти́ по я́годы** жиләк җыярга бару **17.** *с дат., вин.п.* (*в сочет. с числ. при обознач. количества*), ...арлап, ...шарлап; **по́ два** икешәрләп; **по́ три** өчәрләп; **по четы́ре** дүртәрләп; **по пяти́** бишәрләп; **по шести́** алтышарлап; **по восьми́** сигезәрләп; **по девяти́** тугызарлап **18.** *с предл.п.* ...дан соң; ...гач; **по истече́нии сро́ка** срок үткәннән соң; **по оконча́нии рабо́ты** эш беткәннән соң ◆ **по го́рло за́нят** эш муеннан (*бик күп*); **по душе́** күнелгә ошый; **по мне** миңа калса (килгәндә)

по- *приставка* **1.** *фигыль ясауда кулланылып, түбәндәге чаралар ярдәмендә бирелә*: 1) *«алу» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **покра́сить** буяп алу; **попе́ть** җырлап алу; **пола́комиться** сыйланып алу; 2) *«китү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **полете́ть** очып китү; **поле́зть** менеп китү; 3) *«башлау» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **поду́ть** исә башлау; **побежа́ть** йөгерә башлау; 4) *«бетерү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **попря́тать** яшереп бетерү; 5) *кабатлаулы фигыльләр белән килгәндә, «...гала» кушымчасы ярдәмендә, мәс.* **покри́кивать** кычкыргалау; **позва́нивать** шалтыраткалау; **попива́ть** эчкәләү; 6) *«сирәк-мирәк», «ара-тирә», «әледән-әле» кебек парлы рәвешләр ярдәмендә, мәс.* **поку́ривать** сирәк-мирәк [тәмәке] тарту; **поста́нывать** әледән-әле ыңгырашу; 7) *кайбер приставкалы фигыльләрнең бары төп фигылен генә тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **позелене́ть** яшелләнү; **побуре́ть** көрәнләнү **2.** *сыйфат, рәвеш, исем ясауда кулланылып, түбәндәге чаралар ярдәмендә тәрҗемә ителә*: 1) *«...лап» кушымчасы ярдәмендә, мәс.* **постране́чный** битләп; **почасово́й** сәгатьләп; 2) *«соңгы» дигән сыйфат ярдәмендә, мәс.* **пооктя́брьский** октябрьдан соңгы; **порефо́рменный** реформадан соңгы; **посме́ртный** үлгәннән соңгы; 3) *«буендагы» дигән сыйфат ярдәмендә, мәс.* **погрpreа́ничный** чик буендагы; **пово́лжский** Идел буендагы; **помо́рский** диңгез буендагы; 4) *чагыштыру дәрәҗәсен белдерүче «...рак» кушымчасы ярдәмендә, мәс.* **по-бо́льше** зуррак; **полу́чше** яхшырак; **по-нове́е** яңарак; 5) *рәвеш ясаучы «...ча» суффиксы ярдәмендә, мәс.* **по-ру́сски** русча; **по-но́вому** яңача; **по-во́лчьи** бүреләрчә

побагрове́||ть *сов.* кызару; кызарып (кызылланып, кызарынып) китү; күгәренеп китү; **не́бо ~ло от пожа́ра** янгыннан күк йөзе кызылланып киткән; **~ть от гне́ва** ачудан кызарынып китү

поба́иваться *несов. разг.* куркыбрак тору, шүрләбрәк тору; **~ ходи́ть по́ лесу́ но́чью** төнлә урманда йөрергә шүрләбрәк тору

побалагу́рить *сов. разг.* мәзәк [сүзләр] сөйләп алу, такмаза сатып тору

поба́ливать||ся *несов. разг.* авырткалап тору, әледән-әле авыртып алу, сирәк-мирәк авыртып китү; **у меня́ ~ет поясни́ца** билем авыткалап тора

побалова́ться *сов. разг.* шаярып алу, бераз шукланып алу, шаяргалау

побасёнка *ж разг.* **1.** (*забавный рассказ*) такмаза, мәзәк **2.** (*небылица*) тузга язмаган сүз, сафсата

побе́г I *м* качу, качып китү; **~ из тюрьмы́** төрмәдән качу

побе́г II *м* бәбәк, яшь ботак, үренте

побе́гать *сов.* йөгергәләү, бераз йөгереп йөрү, бераз йөгереп алу

побегу́шк||и *только мн.*: **быть на ~ах** *разг.* йомышчы булу, вак-тәяк йомышларга йөрү, йомышка-юлга йөрү

побе́д||а *ж* жиңү, жиңеп чыгу, жиңеш; **одержа́ть ~у в бою́** сугышта жиңеп чыгу; ◆ **пи́ррова ~а** Пирр жиңуе (*акланмаслык корбаннар бәрабәренә яуланган жиңү*)

победи́тель *м* жиңүче, жиңеп чыгучы, өстен чыгучы; **~ в соревнова́ниях** ярышларда жиңеп чыгучы

победи́ть *сов.* **1.** *кого-что* жиңү, жиңеп чыгу, өстен чыгу; **врага́** дошманны жиңеп чыгу **2.** *перен. что, книжн.* жиңү, юк итү, бетерү, басу; **~ за́суху** корылыкны жиңү; **~ страх** куркуны басу

побе́дный, -ая, -ое *высок.* жиңү ...ы; **~ гимн** жиңү гимны

победоно́сн||ый, -ая, -ое **1.** жиңү белән тәмамланган; **~ая война́** жиңү белән тәмамланган сугыш **2.** жиңүчән, жиңүле, жиңелмәс; **~ые войска́** жиңелмәс гаскәр **3.** *перен. разг.* жиңүчеләргә хас булган, үзенең өстенлеген тоя торган; **говори́ть с ~ым ви́дом** жиңүчеләргә хас кыяфәт белән сөйләү

побежа́||ть *сов.* **1.** (*передвигаться бегом*) йөгерә башлау, йөгерергә тотыну, йөгереп китү, йөгерү **2.** (*обратиться в бегство*) качу, качып китү **3.** ага башлау; **с гор ~ли ручьи́** таулардан гөрләвекләр ага башлады

побежда́ть *несов. см.* **победи́ть**

побеле́ть *сов.* агару, агарып китү

побели́ть *сов. что* агартып алу, агарту, акшарлау; **~ потоло́к** түшәмне агартып алу

побе́лка *ж см.* **побели́ть; ~ зда́ния** бинаны агарту

побере́жье *с* яр буе; **морско́е ~** диңгез яр буе

побере́||чь *сов. кого-что* **1.** (*приберечь*) саклап тору, күз-колак булып тору **2.** саклау, кадерләү; **~ги́ своё здоро́вье** сәламәтлегеңне сакла

побере́чься *сов.* саклану, сак булу

побесе́довать *сов.* сөйләшеп (гәпләшеп) алу, бераз әңгәмә корып алу

побеспоко́ить *сов. кого-что* бераз тынычсызлау, бераз тынгысызлау, борчу, мәшәкатьләү

побеспоко́иться *сов.* **1.** (*поволноваться*) тынычсызланып алу, бераз борчылып алу **2.** кайгырту, хәстәрен күрү, мәшәкатьләнү; **ты сам до́лжен об э́том ~** бу турыда син үзең кайгыртырга тиеш

побира́ться *несов. разг. уст.* теләнү, сорану, теләнеп (соранып) йөрү, хәер эстән көн күрү

поби́||ть *сов.* **1.** *кого-что* (*избить*) кыйнап (тукмап) ташлау, кыйнау, тукмау **2.** *кого-что* (*убить всех, многих*) кырып (үтереп) бетерү **3.** *кого-что, разг.* (*победить, напр. в соревновании*) жиңеп чыгу, жиңү, өстен чыгу **4.** *что* ватып (кырып) бетерү; **~ть всю посу́ду** барлык савыт-сабаны кырып бетерү **5.** *что* сугу, сугып китү; **гра́дом ~ло рожь** арышны боз суккан

поби́||ться *сов.* **1.** изелү, изелеп бетү; **я́блоки ~лись в доро́ге** юлда килгәндә алмалар изелеп беткән **2.** ватылып (кырылып) бетү, ватылу, кырылу; **вся посу́да ~лась** бөтен савыт-саба ватылып беткән ◆ **~ться об закла́д** *уст.* әйбер салып бәхәсләшү

поблагодари́ть *сов. кого-что* рәхмәт әйтү (белдерү); **~ за внима́ние** игътибар иткән өчен рәхмәт белдерү

побла́жк||а *ж разг.* үзсендерү, үзындыру, иркәләү, артык яклау; **дава́ть ~и** *кому-л. кемне дә булса* үзсендерү

побледне́ть *сов.* агарынып китү, агарыну, чырае китү, йөзеннән кан качу, төсе китү, төссезләнеп калу

побле́кл||ый, -ая, -ое шиңеп беткән, шиңгән, сулган, пәжгән; төссезләнгән, уңган; **~ые цветы́** сулган чәчәкләр

побле́кнуть *сов.* шиңеп бетү, шиңү, сулу, пәжү; төссезләнү, тоныклану, уңу

побле́скивать *несов.* елкылдап кую, ялтыр-йолтыр килеп кую

побли́зости *нареч.* якында, якынтирәдә, тирәсендә, якын жирдә; **~ от до́ма** өй тирәсендә

побожи́ться *сов.* ант итеп алу, карганып алу

побо́||и *только мн.* кыйнау, сугу, тукмау; **следы́ ~ев** суккан эзләр

побо́ище *с* **1.** (*битва*) зур сугыш, бәрелеш **2.** *разг.* (*жестокая драка*) кыйнаш, сугыш, орыш

поболе́||ть I *сов.* авыртып алу; **голова́ с утра́ ~ла, а к ве́черу прошла́** иртәнге якта башым авыртып алды, кичкә таба бетте

поболе́||ть, II *сов.* авырып алу (яту); **он ~л о́коло ме́сяца** ул бер ай чамасы авырып ятты

поболта́ть I *сов.* **1.** *что, разг.* (*размешать*) болгатып алу, болгаткалап кую, болгатып жибәрү, туглаштыру **2.** *чем*

селкеткәләп алу; ~ **нога́ми** аякларны селкеткәләп алу

поболта́ть II *сов. разг.* (*поговорить о чём-л. несерьёзном*) сөйләшеп алу, лыгырдап (такылдап) алу; сафсата сатып алу

побо́рник *м высок.* яклаучы, яклап көрәшүче; ~ **демокра́тии и прав челове́ка** демократияне һәм кеше хокукларын яклап көрәшүче

побороть *сов.* 1. *кого-что* җиңү, җиңеп чыгу, өстен чыгу; ~ **проти́вника** каршы якны җиңү 2. *перен. что* басу, җиңү; ~ **страх** куркуны җиңү

побороться *сов. с кем* көрәшү, тартышу, алышу, каршылык күрсәтү

побо́ры *мн. уст.* бик зур салым

побо́чный, -ая, -ое 1. икенче дәрәҗәдәге, өстәмә; ~ **проду́кт произво́дства** җитештерүнең өстәмә продукты 2. *уст.* никахсыз туган; ~ **сын** никахсыз туган улы

побоя́ться *сов. с неопр.* курку, шүрләү, йөрәк житмәү; ~ **сказа́ть пра́вду** дөресен әйтеп бирергә йөрәк житмәү

побрани́ть *сов. кого-что* сүгеп (ачуланып, тиргәп, әрләп, орышып) алу

побрани́ться *сов. с кем и без доп.* сүгешеп (тиргәшеп, әрләшеп) алу

побрата́ться *сов.* дуслашу, туганлашу, дуслашып (туганлашып) китү, татулану

побрати́м *м* ахирәт дус, жан дусы; тугандаш, берадәр; **городá-~ы** тугандаш шәһәрләр

побрати́мство *с* ахирәт дуслыгы, жан дуслыгы (*электә: славяннарда дуслыкны кардәшлек дәрәҗәсенә җиткерү йоласы*)

побре́згать *сов.* жирәнү, жирәнеп тору, чиркану

побрести́ *сов.* салмак (акрын) атлап китеп бару

побри́ть *сов. кого-что* кырып ташлау (алу), китәрү (*сакалны, мыекны, чәчне*)

побри́ться *сов.* кырыну, кырынып алу, чәч-сакал алдыру

поброди́ть *сов.* йөрү, әрле-бирле йөрү, тик йөрү; ~ **по́ лесу** урманда әрле-бирле йөрү

поброса́ть *сов.* 1. *что* ыргыткалау, аткалап бетерү, теләсә кайда ташлау; ~ **ве́щи** әйберләрне теләсә кайда ташлау 2. *кого-что* (*оставить без надзора, поддержки*) ташлап китү

побры́з||гать *сов. кого-что, на кого-что и без доп.* сибәләү, сипкәләү, сибәләп (сипкәләп) алу; **до́ждик ~л** яңгыр сибәләп алды; **~ть водо́й** су сипкәләп алу

побры́згаться *сов.* су сибешеп (чәчрәтешеп) алу

побрюзжа́ть *сов. разг.* мыгырданып (сукранып) алу (*бераз вакыт*)

побря́кать *сов. разг.* шалтыратып (шылтыратып, чылтыратып, дыңгырдатып) алу (*бераз вакыт*)

побря́кивание *с* 1. *см.* **побря́кивать;** 2. (*звуки*) шалтыраган (дыңгырдаган, шылтыраган) тавыш

побря́кивать *несов. разг.* вакыт-вакыт шалтыратып кую, әледән-әле шылтыратып кую, дыңгырдаткалау

побрякýшка *ж разг.* шылтыравык, шалтыравык

побуди́тельн||ый, -ая, -ое *книжн.* кузгатучы, уяутучы, этәргеч, мәҗбүр итүче; ~**ая причи́на** мәҗбүр итүче сәбәп

побуди́ть I *сов. кого-что, разг.* 1. (*будить нек-рое время*) уяту, уятып карау 2. (*всех, многих*) уятып бетерү

побуди́ть II *сов. кого-что, книжн.* мәҗбүр итү, теләк тудыру, дәртләндерү, сәбәп булу; ~ **де́йствовать** хәрәкәт итәргә теләк тудыру

побу́дка *ж* (*сигнал к подъёму*) уяту сигналы; **у́тренняя ~** иртәнге уяту сигналы

побужда́ть *несов. см.* **побуди́ть** II

побужде́ни||е *с книжн.* 1. *см.* **побуди́ть** II; 2. теләк, дәрт, уй, ният; **до́брые ~я** изге ниятләр

побуре́ть *сов.* көрәнләну, көрән төскә керү

побыва́ть *сов.* 1. (*поездить по многим местам*) булу, булгалау, йөреп (барып) кайту 2. (*пожить*) булу, бераз тору, торып кайту; ~ **на ю́ге** көньякта торып кайту 3. катнашу, булу; ~ **на войне́** сугышта катнашу 4. *разг.* кереп чыгу, кагылу, сугылу; **хочу́ ~ у ста́рого дру́га** иске дустым янына кереп чыкмакчы булам ♦ ~ **в переде́лке** күпне күрү; баштан күпне кичерү, бик күп җәфа чигү

побы́вк||а *ж разг.*: **на ~у** кыска вакытлы ялга; **прие́хать домо́й на ~у** өйгә кыска вакытлы ялга кайту

побы́ть *сов.* бераз тору (торып китү), беразга калу; **он по́был у нас два дня** ул бездә ике көн торып китте

пова́диться *сов. с неопр., разг.* өйрәнеп (ияләшеп, гадәтләнеп) китү (*начар эшкә*)

пова́дк||а *ж* гадәт; **я все его́ ~и зна́ю** аның бөтен гадәтләрен беләм

пова́дно *нареч.*: **что́бы не́ было ~** *разг.* биздерү өчен, икенче тапкыр эшләмәслек итү өчен, сабак булсын өчен

повали́||ть I *сов. кого-что* аудару, аударып ташлау, егу, егып салу; төшерү, төшереп җибәрү; **ве́тер ~л де́рево** җил агачны аударган

повали́||ть II *сов.* 1. *разг.* агыла башлау, агылу, ябырылу; **наро́д ~л на пло́щадь** халык мәйданга агыла башлады 2. (*о дыме, паре*) ургылып чыга башлау; (*о снеге*) ишелеп ява башлау

повали́ться *сов.* аву, авып китү, егылу, ишелү, егылып (ишелеп) төшү

пова́льн||ый, -ая, -ое берсен дә калдырмый торган; гомуми; ~**ое увлече́ние** гомуми мавыгу ♦ ~**ая боле́знь** *уст.* (*эпидемия*) үләт, кизү

повали́ть *сов. что* әвәләү, әвәләп алу, тәгәрәтү, тәгәрәтеп йөртү; ~ **те́сто в муке́** камырны онда әвәләү

повали́ться *сов.* 1. аунау, аунап алу; ~ **на се́не** печән өстендә аунап алу 2. *разг.* аунап яту, тормыйча яту, тик яту; ~ **на дива́не** диванда тик яту

по́вар *м* аш пешерүче, повар, пешекче

пова́ренн||ый, -ая, -ое аш ...ы, аш пешерү ... ы; ашка сала торган; пешекче ...ы; ~**ая соль** аш тозы; ~**ая кни́га** пешекче китабы

поварёнок *м* пешекче малай, аш пешерүче малай, повар ярдәмчесе

поварёшка *ж разг.* бакрач, аш чүмече

повари́ть *сов. что* пешерә төшү, пешерү, кайнаты төшү, кайнату

повари́ться *сов.* пешә төшү, кайный төшү

повари́ха *ж* пешекче (аш пешеруче) хатын (кыз)

поварск||о́й, -а́я, -о́е пешекче ...ы, повар ...ы; ~**о́й нож** пешекче пычагы; ~**о́е иску́сство** пешекче осталыгы

пове́дать *сов. что, о чём, книжн.* белгертү, сөйләү, сөйләп (әйтеп) бирү; ~ **свою́ та́йну** *кому-л.* үзеңнең эч сереңне *кемгә дә булса* сөйләп бирү

поведе́ние *с* тәртип, үз-үзенне тотыш, гадәт

повез||ти́ *сов.* 1. *кого-что* алып китү, илтү (*ат, машина һ.б.ш. белән*); ~**ти́ ве́щи на вокза́л** әйберләрне вокзалга алып китү 2. *безл. кому* уңышлы чыгу, уңай туры килү, эш уңу; **ему́ ~ло́** аның эше уңган

повелева́ть *несов.* 1. *кем-чем, уст.* идарә итү, хакимлек итү, әмер биреп тору, боерык биреп тору 2. *см.* **повеле́ть**

повеле́ние *с см.* **повеле́ть**

повеле́||ть *сов. с неопр., книжн.* боеру, кушу

повели́тель *м высок.* әмер бирүче, боеручы, падишаһ

повели́тельн||ый, -ая, -ое боеру ...ы, боеручан, боера торган, әмер бирә торган; **говори́ть ~ым то́ном** боеручан тонда сөйләү ♦ ~**ое наклоне́ние** *грам.* боерык фигыль

повенча́ть *сов. кого, церк.* никахландыру, никах уку

повенча́ться *сов. церк.* никахлану, никахланышу, никахка керү, никах укыту

поверга́ть *несов. см.* **пове́ргнуть**

поверга́ться *несов.* 1. *см.* **пове́ргнуться;** 2. *страд. от* **поверга́ть**

пове́рг||нуть *сов.* 1. *кого-что во что, высок.* дучар итү, төшерү; **э́та весть ~ла меня́ в отча́яние** бу хәбәр мине өметсезлеккә төшерде 2. *кого-что, уст.* (*повалить*) аудару, егу, аударып (егып) ташлау

пове́ргнуться *сов. уст.* дучар булу, төшү; тару, эләгү; ~ **в отча́яние** өметсезлеккә дучар булу

пове́ренн||ый *м* 1. вәкил; ~**ый по торго́вым дела́м** сәүдә эшләре буенча вәкил 2. ышанычлы кеше, сердәш; **избра́ть** *кого-л.* **свои́м ~ым** *кемне дә булса* үзеңә сердәш итеп сайлау

пове́ри||ть *сов.* 1. *кому-чему, в кого-что* ышану, инану; **э́тому тру́дно ~ть** моңа ышану кыен; **он ~л в э́того челове́ка** шушы кешегә ышанган ул 2. *кому что* ышанып әйтеп (сөйләп) бирү; ~**ть** *кому-л.* **свою́ та́йну** *кемгә дә булса* ышанып эч сереңне сөйләп бирү

пове́рка *ж* 1. тикшерү; ~ **вре́мени** вакытны тикшерү 2. (*перекличка с целью*

проверки) барлау, тикшерү, исемлек тикшерү

поверн||у́ть *сов.* **1.** *кого-что* бору, борып (әйләндереп) кую, әйләндереп салу; **~ у́ть кран** кранны борып кую; **~ у́ть больно́го на друго́й бок** авыруны икенче ягына әйләндереп салу **2.** *кого-что и без доп.* бору; борылу; **шофёр ~ у́л маши́ну нале́во** шофёр машинаны сулга борды; **когда́ дойдёшь до угла́, ~ и́ напра́во** чатка җиткәч, уңга борылырсың **3.** *перен. что* бору, борып җибәрү; **~ у́ть разгово́р в другу́ю сто́рону** сүзне икенчегә бору

поверну́||ться *сов.* **1.** борылу, әйләнү; **он ~ лся ко мне** ул миңа таба борылды; **~ ться на друго́й бок** икенче якка әйләнеп яту **2.** *перен.* үзгәрү, борылу, [башка] төс алу, [башка] юнәлеш алу; **де́ло ~ лось ина́че** эш башкачарак төс алды

пове́рочн||ый, -ая, -ое барлау ...ы, тикшерү ...ы, тикшерү өчен эшләнә торган; **~ ые испыта́ния** тикшерү сынаулары

поверте́ть *сов. кого-что* боргалау, әйләндергәләү, боргалап (әйләндергәләп) алу

поверте́||ться *сов.* **1.** әйләнү, бөтерелү, бераз әйләнү; **колесо́ ~ лось и останови́лось** тәгәрмәч бераз әйләнде дә туктады **2.** *разг.* борылгалап (әйләнгәләп) тору, уралу; **он пришёл, ~ лся и ушёл** ул килеп, бераз әйләнгәләп торды да китеп тә барды

повёртывать *несов. см.* **поверну́ть**

повёртываться *несов.* **1.** *см.* **поверну́ться; 2.** *страд. от* **повёртывать**

пове́рх *предлог с род.п.* **1.** өстеннән, өстенә, өстән; **наде́ть плащ ~ костю́ма** костюм өстеннән плащ кию **2.** өстеннән; **посмотре́ть ~ очко́в** күзлек өстеннән карау

пове́рхностность *ж* төпле булмау, өстән-өстән генә булганлык, сайлык; **~ зна́ний** белемнәрнең сайлыгы

пове́рхностн||ый, -ая, -ое **1.** өске, өстәге, өстә яткан; **~ ый слой по́чвы** туфракның өске катлавы **2.** *перен.* төпле (ныклы) булмаган, өстән-өстән генә эшләнгән (булган), җиңелчә, сай, сыек; **~ ые зна́ния** төпле булмаган белем; **~ ое сужде́ние** өстән-өстән генә фикер йөртү

пове́рхност||ь *ж* **1.** *мат.* өслек; **~ ь ша́ра** шар өслеге **2.** өс, йөз; **~ ь воды́** су өсте; **~ ь земли́** җир йөзе ♦ **скользи́ть по ~ и** *чего* өстән-өстән генә алдырту, өстән йөзү

по́верху *нареч. разг.* **1.** өстән, өске яктан; **кры́ша ~ кры́та желе́зом** түбә өстән калай белән ябылган **2.** *перен.* өстән генә, асылына төшенеп тормастан

пове́рь||е *с* ышану (*юк-барларга*); **стари́нные ~ я** борынгы ышанулар

поверя́ть *несов. см.* **пове́рить** 2

пове́са *м разг.* җилкуар, җилбәзәк, сөрхәнтәй

повесели́ть *сов. кого-что* күңелен ачу (күтәрү); кәефен күтәрү

повесели́ться *сов.* бераз күңел ачу (ачып алу), кәеф-сафа сөрү, кәефләнеп алу

пове́сить *сов.* **1.** *что* элү, асу, элеп (асып) кую; **~ карти́ну** картинаны элеп кую **2.** *кого* (*лишить жизни*) асу, асып үтерү; ♦ **~ го́лову (нос)** башны (борын) салындыру (*төшенкелеккә бирелү*)

пове́ситься *сов.* асылынып үлү, асылыну

пове́сничать *несов. разг.* җилбәзәкләнеп йөрү, тырай тибеп йөрү

повествова́ние *с* **1.** *см.* **повествова́ть; 2.** *лит.* (*рассказ*) хикәя

повествова́тельн||ый,-ая,-ое хикәя ...ы, хикәяләү ...ы, сөйләп бирү ...ы; **~ ый стиль** хикәяләү стиле ♦ **~ ое предложе́ние** *грам.* хикәя җөмлә

повествова́ть *несов. о чём, книжн.* хикәя итү, хикәяләү, сөйләп бирү, сөйләү, бәян итү (*телдән яки язма рәвештә*)

пове||сти́ *сов.* **1.** *кого-что* (җитәкләп, иартеп) алып китү, илтә китү; **~ сти́ ребёнка к врачу́** баланы врачка алып китү **2.** *кого-что* алып чыгу, китереп чыгару; **тропи́нка ~ ла́ нас к до́му** сукмак безне йорт янына китереп чыгарды **3.** *чем* сикертү, сикертеп кую (алу), селкетү, селкетеп кую; **~ сти́ бровя́ми** каш сикертү; **~ сти́ плечо́м** иңбашларын селкетеп кую **4.** *чем по чему* йөртеп чыгу; **~ сти́ смычко́м по стру́нам** смычокны кыллар буйлап йөртеп чыгу **5.** *безл. что* калжаю; **до́ску ~ ло́ от сы́рости** такта юешлектән калҗайган ♦ **~ сти́ себя́** (*каким-л. образом*) үз-үзеңне тоту, үзен тоту; **в э́том де́ле он повёл себя́ благоро́дно** бу эштә ул үзен яхшы тотты

пове||сти́сь *сов.* **1.** (*стать обычным*) гадәткә кереп китү, гадәт булып китү; **и́здавна так ~ ло́сь** электән үк шулай гадәт булып киткән **2.** *с кем* (*начать дружить*) дуслашу, татулашу, дуслашып (татулашып) китү; **с кем ~ дёшься, от того́ и наберёшься** *посл.* ≈ кем чанасына утырсан, шуның жырын жырларсың

пове́стка *ж* **1.** чакыру кәгазе, повестка; **~ в суд** суд повесткасы **2.** *разг.* (*распорядок дня*) көн тәртибе

по́весть *ж* повесть, озын хикәя

пове́трие *с* **1.** *уст.* (*эпидемия*) киң таралган чир, кизү, эпидемия **2.** *перен.* шаукым, кизү, чир (*киң таралган тискәре куренеш яки йогынты*)

пове́шение *с* асу, асып үтерү, дар агачына асу

пове́я||ть *сов.* **1.** (*подуть*) исә башлау, исеп кую **2.** обычно *безл. прям., перен. чем* килә башлау; **~ ло весно́й** яз исе килә башлады

повзво́дно *нареч.* взводлап, взвод-взвод булып, взвод артыннан взвод; **стро́иться ~** взвод артыннан взвод тезелү

повзди́рить *сов.* ызгышып (тиргәшеп, әрләшеп) алу

повзросле́ть *сов.* балигъ булу; өлкәнәя төшү

повива́льн||ый, -ая, -ое: **~ ая ба́бка** кендек әбисе

повида́ть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* очрату, күрү, күреп сөйләшү **2.** *что* (*пережить*) күпне күрү

повида́ться *сов. с кем и без доп., разг.* очрашу, күрешү, күреп сөйләшү

по-ви́димому *вводн. сл.* күрә[м]сең, төсле, ахрысы, бугай, булса кирәк; **весна́, ~, бу́дет ра́нняя** күрәсең, яз иртә килер

пови́дло *с* повидло

пови́згивание *с см.* **пови́згивать**

пови́згивать *несов.* вакыт-вакыт чинап кую, әледән-әле чинап алу, чинаштыргалау

пови́ливать *несов. см.* **пови́лять**

пови́лика *ж бот.* кычыткан ефәге, чормавык

повиля́||ть *сов.* **1.** *чем* болгау, селтәү, болгап (селтәп) кую; **собака ~ ла хвосто́м** эт койрыгын болгап куйды **2.** *перен. разг.* (*похитрить*) койрык болгау

повини́ться *сов.* гаепне тану, үзеңне гаепле дип тану (санау)

пови́нность *ж* бурыч, йөкләмә; **трудова́я ~** хезмәт йөкләмәсе

пови́н||ный, -ая, -ое гаепле, гаепле дип табылган; **он ни в чём не ~ ен** ул бөтенләй гаепле түгел ♦ **прийти́ (яви́ться) с ~ ной** гаепне тану, гаебеңне икърар итү; **~ ную го́лову меч не сечёт** *посл.* иелган башны кылыч кисми

повинова́ться *несов. кому-чему* буйсыну, сүзен тыңлау; **~ роди́телям** атаананың сүзен тыңлау

повинове́ние *с* буйсынучылык, буйсыну; **беспрекосло́вное ~** берсүзсез буйсыну

повиса́ть *несов. см.* **пови́снуть**

повисе́ть *сов.* [бераз] асылынып (эленеп) тору

пови́с||нуть *сов.* **1.** асылынып тору, асылыну, эләгеп калу, сарылу; **ребёнок пови́с на ше́е ма́тери** бала әнисенең муенына сарылды **2.** салынып төшү; **во́лосы ~ ли пря́дями** чәчләре учмачума булып салынып төшкән ♦ **~ нуть в во́здухе** һавада асылынып калу (*берәр эшнең билгесезлек аркасында эшләнми ятуы, хәрәкәтсез ятуы*)

повитру́ха *ж уст. см.* **повива́льный**: **повива́льная ба́бка**

повлажне́ть *сов.* дымлана төшү, дым тарту, юешләнә төшү

повле́чь *сов. что* китерү, китереп чыгару, сәбәп булу, тудыру; **тако́й посту́пок мо́жет ~ за собо́й тяжёлые после́дствия** болай эш итүнең күңелсез нәтиҗәләргә китерүе мөмкин

повлия́ть *сов. на кого-что* тәэсир итү, йогынты ясау

по́вод I *м* тезген, йөгән тезгене ♦ **быть на ~ у́** *у кого берәүнең* кубызына бию, *берәүнең* ихтыярына буйсынып яшәү

по́вод II *м* сәбәп, сылтау; **без вся́кого ~ а** бернинди сәбәпсез; **~ для ссо́ры** җәнҗал чыгуга сәбәп ♦ **по ~ у** *предлог с род.п.* турысында, хакында, уңае бе-

лән; **разгово́р шёл по ~у но́вой кни́ги** сүз яңа китап хакында барды

поводи́ть I *сов.* **1.** *кого-что* йөрткәләү, йөртү, йөртеп чыгу (алу), җитәкләп йөртеп алу; **~ ло́шадь** атны җитәкләп йөртеп алу **2.** *чем по чему* йөртү, йөртеп алу; **~ па́льцем по стеклу́** пыяла өслəтеп бармак йөртеп алу

поводи́ть II *несов. см.* **повести́** 3

повод|о́к *м* **1.** (*для лошади*) кыска тезген **2.** муенчаклы бау (*мəс. эт бəйлəп йөртү өчен*)

поводы́рь *м* йөртүче, җитәкләп йөртүче; **~ слепо́го** сукыр кешене җитәкләп йөртүче; **соба́ка-~** [сукырларны] йөртүче эт

повоева́ть *сов.* сугышу, сугышып алу, бераз вакыт сугышта булу

повози́ть *сов. кого-что* [бераз вакыт] йөртеп алу, [бераз] утыртып йөртү; [бераз] ташу, ташып алу; **~ по го́роду** бераз вакыт шəһəр буйлап йөртеп алу; **~ се́но** бераз печән ташып алу

повози́ться *сов.* **1.** (*поворочаться*) əйләнгəләп (тулгангалап) йөрү, [бераз] əйләнеп-тулганып йөрү **2.** *с кем-чем, разг.* мəшəкатьләнү, мəшəкатьләнеп вакыт үткəрү, булышу, маташу; **он о́чень люби́л ~ с сы́ном** ул улы белəн булышырга бик тə ярата торган иде

пово́зка *ж* йөк арбасы, арба, повозка

пово́йник *м уст.* повойник (*электə рус крестьян хатын-кызларының баш киеме*)

поволо́к||а *ж*: **глаза́ с ~ой** талгын назлы күзлəр, ягымлы моңсу күзлəр

поволочи́ть *сов.* сөйрəп (өстерəп) бару (*бераз вакыт*)

поволочи́ться *сов.* **1.** сөйрəлеп (өстерəлеп) бару (*бераз вакыт*) **2.** *за кем, разг.* [бераз вакыт] артыннан йөрү, сөйрəлү

поволо́||чь *сов. кого-что. разг.* сөйрəп (өстерəп) алып китү; **он ~к мешо́к в подва́л** ул капчыкны өстерəп подвалга алып китте

повора́чивать *несов. см.* **повернýть**

повора́чиваться *несов.* **1.** *см.* **повернýться ; 2.** *страд. от* **повора́чивать**

поворожи́ть *сов. разг.* күрəзəлек (багучылык) итеп алу, фал ачып алу

поворо́т *м* **1.** *см.* **повернýть, повернýться; 2.** борылыш, борылма, борылу урыны; **на ~е доро́ги** юл борылмасында **3.** *перен.* борылыш, кискен үзгəреш; **~ судьбы́** язмышның кискен үзгəреше

поворо́тливый, -ая, -ое *разг.* җиңел сөякле, житез, елгыр, өлгер, булган, булдыклы

поворо́тный, -ая, -ое **1.** (*служащий для поворота*) бору ...ы, əйләндерү ...ы, борылу ...ы, əйләнү ...ы **2.** *перен.* борылыш ...ы, кискен үзгəреш ...ы; **пункт в разви́тии** *чего-л. берəр нəрсə* үсешендəге борылыш пункты

повороши́ть *сов. что, разг.* [бераз] кабарту, кабартып алу, əйләндерү, кузгату; **~ се́но** бераз печән əйләндерү

поворча́ть *сов.* ырлап алу, ырылдап кую (тору) (*мəс. эт турында*); мыгырданып (сукранып) алу, мыгырданып кую (*кеше турында*)

повреди́ть *сов.* **1.** *кому-чему* зыян китерү, зарар китерү **2.** *что* яралау, җəрəхəтләү, имгəтү; бозу, эштəн чыгару, рəтен китерү, вату; **~ но́гу** аякны имгəтү; **~ замо́к** йозакның рəтен китерү

повреди́ться *сов.* **1.** (*поломаться*) бозылу, ватылу **2.** *прост.* (*пораниться*) имгəнү; зыян китерү (*мəс. берəр əгъзаңа*) ♦ **~ в уме́** *прост.* акыл чуалу, акыл җиңелəю

повержда́ть *несов. см.* **повреди́ть** 1

повержда́ться *несов.* **1.** *см.* **повреди́ться; 2.** *страд. от* **повержда́ть**

повреждéние **1.** *см.* **повреди́ть, повреди́ться; 2.** (*повреждённое место, поломка*) ватык урын, ватылган җир

повремени́ть *сов. с чем и без доп., разг.* бераз көтү, бераз кичектерү, бераз сабыр итү, юану; **~ с отъéздом** китүне бераз кичектерү; **~ нéсколько дней** берничə көнгə кичектерү

повремéнн||ый, -ая, -ое **1.** вакытлы; **~ые изда́ния** вакытлы басмалар **2.** вакытка карап исəпləнə торган, вакыт исəбеннəн түләнə торган; **~ая опла́та** вакыт исəбеннəн түләү

повседнéвность *ж* көндəлек; гадəтилек

повседнéвный, -ая, -ое көн саен була (кабатлана) торган, көндəлек, гадəти

повсемéстность *ж* һəр җирдə булу

повсемéстн||ый, -ая, -ое һəр җирдə (урында) була торган; **~ое явлéние** һəр җирдə дə була торган күренеш

повскака́||ть *сов. разг.* сикерешеп тору, торып басу (*бер-бер артлы*); **все ~ли с мест** барысы да урыннарыннан сикерешеп тордылар

повска́кивать *сов. разг. см.* **повскака́ть**

повста́нец *м* баш күтәрүче, баш күтәрүдə катнашучы

повста́нческий, -ая, -ое баш күтәрүчеләр ...ы; **~ отря́д** баш күтәрүчеләр отряды

повстреча́ть *сов. кого-что, разг.* очрату, туры китерү

повстреча́ться *сов. с кем, разг.* очрашу

повсю́ду *нареч.* һəр (бар, һəммə) җирдə, бөтен урында, һəркайда

повторéни|е *с* **1.** *см.* **повори́ть, повори́ться**; **2.** кабатлаулар, кабатлана торган күренешләр, кабатланган урыннар, тəкърарлар; **в статье́ есть ~я** мəкаләдə кабатланган урыннар бар

повори́ть *сов. что* **1.** (*сделать ещё раз то же самое*) кабатлау, тəкърарлау, кабатлап эшләү; кабатлап əйтү **2.** (*возобновить в памяти*) кабатлау, кабатлап искə төшерү

повори́||ться *сов.* кабатлану; **ста́рое не ~тся** үткəннəр кабатланмас

повто́рный, -ая, -ое кабат, икенче кат ...ган, икенче кат, кабаттан, яңадан; **~ зака́з** икенче кат бирелгəн заказ

повторя́ть *несов. см.* **повори́ть**

повторя́ться *несов.* **1.** *см.* **повори́ться; 2.** үз-үзен кабатлау; **писа́тель стал ~** язучы үз-үзен кабатлый башлады **3.** *страд. от* **повторя́ть**

повы́сить *сов.* **1.** *что* күтәрү, биегәйтү, күтəрə (биегəйтə) төшү; **~ у́ровень воды́ в бассе́йне** бассейндагы суның биеклеген күтəрə төшү **2.** *что* күтəрү, арттыру, күтəрə (арттыра) төшү; **~ производи́тельность труда́** хезмəт җитештерүчəнлеген күтəрү; **~ за́работную пла́ту** эш хакын арттыру **3.** *что* көчəйтү, арттыру, яхшырту; **~ ка́чество проду́кции** продукциянең сыйфатын яхшырту; **~ зна́ния** белемнəрне арттыру **4.** *кого* (*по службе, в звании*) үстерү [югарырак урынга] күтəрү (*хезмəт урынында*) ♦ **~ го́лос** җикеренə башлау, ачудан кычкырып сөйли башлау

повы́си||ться *сов.* **1.** күтəрелү, күтəрелə төшү, арту; **у́ровень воды́ в реке́ ~лся** елганың суы арткан **2.** көчəю, арту, яхшыру; **~лось ка́чество проду́кции** продукциянең сыйфаты яхшырды **3.** *в чём* үсү, үсеп китү, дəрəҗə күтəрелү; **~ться в обще́ственном мне́нии** җəмəгатьчелек алдында дəрəҗə күтəрелү **4.** үсү, [югарырак урынга] күтəрелү; **~ться по слу́жбе** хезмəттə югарырак урынга күтəрелү

повыша́ть *несов. см.* **повы́сить**

повыша́ться *несов.* **1.** *см.* **повы́ситься; 2.** *страд. от* **повыша́ть**

повыше́ние *с* **1.** *см.* **повы́сить, повы́ситься; ~ урожа́йности** уныш бирүчəнлекнең күтəрелүе; **~ зарпла́ты** эш хакының артуы **2.** (*возвышение*) калкурак урын, югарырак урын, биегрəк урын

повы́шенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **повы́сить; 2.** күтəренке, югары; **~ые обяза́тельства** күтəренке йөкләмəләр; **~ая температу́ра** югары температура

повяза́ть *сов.* **1.** *кого-что* бəйләү, бəйлəп кую, чорнау, урау; **~ го́лову платко́м** башка яулык бəйләү **2.** *что* тагу; **~ га́лстук** галстук тагу

повяза́ться *сов. чем* бəйләү, бəйлəп алу, чорнау, урау; буу; **~ платко́м** яулык бəйләү

повя́зка *ж* бəйләвеч, повязка

повя́зывать *несов. см.* **повяза́ть**

повя́зываться *несов.* **1.** *см.* **повяза́ться; 2.** *страд. от* **повя́зывать**

повя́||нуть *сов.* шиңү, сулу, шинеп (сулып, корып) бетү; **цветы́ ~ли** гөлләр шиңеп беткән

погада́ть *сов.* күрəзəлек (багучылык) итеп алу, фал ачу

пога́нить *несов. что, прост.* пычрату, шакшылау, əшəкеләү, əшəкеләндерү

пога́нка *ж* **1.** (*гриб*) агулы гөмбə **2.** (*утка-нырок*) чумгалак, чүрəкəй (*үрдəк*)

пога́н||ый, -ая, -ое **1.** ашарга ярамый торган, ашалмый торган, агулы; **~ый гриб** ашарга ярамый торган гөмбə **2.** *разг.* пычрак, шакшы, шакшы сулар сала торган; **~ое ведро́** шакшы сулар сала торган чиләк **3.** *прост.* начар, яман, бозык; **~ое настрое́ние** начар кəеф **4.** *уст. рел.* хəрам; **~ая пи́ща** хəрам ризык

по́гань *ж прост.* шакшы (əшəке, кабахəт) нəрсə[ләр]

погаса́ть *несов. см.* **пога́снуть**

погаси́ть *сов. что* **1.** сүндерү; **~ ла́мпу** лампаны сүндерү **2.** түләү, түләп бетерү, кайтару, кайтарып бирү; **~ задо́лженность** бирәчәкне түләп бетерү

пога́с||нуть *сов.* **1.** сүну, сүнеп калу; **костры́ ~ли** учаклар сүнгән **2.** *перен.* сүну, сүнеп бетү, юкка чыгу, бетү; **в нём все стра́сти ~ли** аның бөтен дәрте сүнеп беткән

погаша́ть *несов. см.* **погаси́ть** 2

погаше́ние *с см.* **погаси́ть** 2; **~ за́йма** заёмны түләү

пога́шенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **погаси́ть; 2.** түләнгән, кире кайтарылган; **~ая облига́ция** кире кайтарылган облигация

погиба́ть *несов. см.* **поги́бнуть**

поги́бель I *ж уст.* һәлакәт, үлем

поги́бел||ь II *ж*: **гнуть в три ~и** *кого, разг.* бик каты җәберләү, изү; **гну́ться (согну́ться) в три ~и** *разг.* 1) бишкә бөгелү; 2) *перед кем* ялагайлану, тәлинкә тоту

поги́бнуть *сов.* һәлак булу, кырылып бетү, үлү, үлеп бетү; **~ сме́ртью хра́брых** батырларча һәлак булу

поги́бший, -ая, -ее **1.** *прич. от* **поги́бнуть**; **2.** эштән чыккан, кешелектән чыккан; беткән; **он челове́к ~** ул беткән кеше

погла́дить *сов.* **1.** *что, разг.* (*утюгом*) үтүкләп алу, үтүкләп бетерү **2.** *кого-что* сыпырып (сыйпап) кую, сыпырып алу; **~ по голове́** башыннан сыйпап кую

погла́живать *несов. кого-что* сыйпаштыргалап (сыпыргалап) кую, сыйпаштыргалап алу

поглазе́ть *сов. прост.* [бераз вакыт] хәйран калып карап тору, [бераз вакыт] авыз ачып карап тору

поглода́ть *сов. разг.* **1.** *что, чего* (*немного*) бераз кимереп алу **2.** *что* (*всё, многое*) кимереп бетерү

поглота́ть *сов. что, разг.* (*всё, многое*) йотып бетерү

поглоти́тель *м хим.* йоткыч, сеңдергеч

поглоти́||ть *сов.* **1.** *что* йоту, сеңдерү, сеңдереп бетерү, үзләштерү; **~ вла́гу** дым сеңдерү **2.** *перен.* (*принять в себя*) йоту, үбү; **мо́ре ~ло кора́бль** диңгез корабльне йоткан **3.** *перен. кого-что* бик нык мавыктыру, мавыктырып җибәрү, бик тә кызыктыру, үзенә тарту, жәлеп итү; **но́вая иде́я ~ла его́** яңа идея аны мавыктырып җибәрде **4.** *перен. что* убу, йоту, ашау, талап итү; **рабо́та ~ла все си́лы** эш бар булган көчне таләп итте

поглоща́ть *несов. см.* **поглоти́ть**

поглоще́ние *с см.* **поглоти́ть**; **~ све́та** яктылыкның йотылуы; **~ вла́ги** дымның сеңүе

поглуми́ться *сов. над кем-чем* мыскыл итү, мәсхәрәләп алу, мәсхәрәләү

поглупе́ть *сов.* аңгыралана төшү, аңгыралану, миңгерәүләнү, ахмаклану, тинтәкләнү

погляде́ть *сов.* **1.** карап алу, күз салу (ату), күз төшереп (ташлап) алу; **~ в окно́** тәрәзәдән карап алу; **~ с удивле́нием** гаҗәпсенеп карап кую **2.** *за кем-чем, разг.* күзәтеп (карап) тору, күз-колак булып тору; **~ за ребёнком** балага күз-колак булып тору

погляде́ться *сов. во что* каранып алу; **~ в зе́ркало** көзгегә каранып алу

погля́дывать *несов.* **1.** караштыргалап кую, карап-карап алу, күз төшергәләп алу; **~ по сторона́м** як-якка күз төшергәләп алу **2.** *за кем-чем, разг.* караштыргалап (күзәткәләп) тору, күз-колак булгалап тору; **~ за детьми́** балаларга күз-колак булгалап тору

погна́ть *сов. кого-что* **1.** куып алып китү, куа китү; **~ ста́до в по́ле** көтүне кырга куып алып китү **2.** куалау, куа башлау, каулау, чаптыру; **~ лошаде́й вскачь** атларны куып чаптыра башлау

погна́ться *сов.* **1.** *за кем* куып китү, куа башлау, куа китү; **~ за за́йцем** куян артыннан куа китү **2.** *за чем, разг.* куу; **~ за сла́вой** дан артыннан куу

погни́ть *сов. разг.* черү, череп бетү

погну́ть *сов. что* бөгү, ию, кәкрәйтү

погну́ться *сов.* бөгелү, иелү, кәкрәю, сыгылу

погнуша́ться *сов.* җирәнү, чиркану; хурлык дип санау

говова́рива||ть *несов. о ком-чём и с союзом «что», разг.* сөйләшкәләү, сөйләштергәләү, сөйләү, хәбәр таралу, сүз йөрү; **~ют, что он же́нится** ул өйләнә икән дип сөйлиләр

поговори́ть *сов.* сөйләшеп (гәпләшеп) алу; киңәшеп алу; **~ о дальне́йшей рабо́те** киләчәктә ничек эшләү турында сөйләшеп алу

говó́рк||а *ж* әйтем; **войти́ в ~у** әйтем булып китү

пого́да *ж* һава, һава хәле, һава торышы, көн; **хоро́шая ~** яхшы һава; **дождли́вая ~** яңгырлы көн

погоди́ть *сов. разг.* бераз көтү, сабыр итү; **погоди́, сейча́с приду́** бераз көт, хәзер киләм ♦ **немно́го погоди́я** бераздан, беравыктан

пого́дн||ый I, -ая, -ое еллык ..., еллап алып барыла торган; **~ые за́писи** еллык язмалар

пого́дн||ый II, -ая, -ое һава ...ы; **~ые усло́вия** һава шартлары

пого́док *м* бер яшькә соң туган; бер яшькә элек туган (*сеңеле, энесе яки апасы, абыйсы*)

пого́ж||ий, -ая, -ее яхшы, ачык, аяз; **~ие дни** аяз көннәр

поголо́вный, -ая, -ое **1.** баш исәбеннән (исәбен) ...; **~ счёт скота́** терлекләрнең баш исәбен алу **2.** гомуми, тулаем; **~ учёт** гомуми учёт

поголо́вье *с* баш исәбе (саны), сан; **~ скота́** терлекләр саны; **ко́нское ~** атларның баш исәбе

поголода́ть *сов.* [бераз] ачлы-туклы тору, [бераз] ачлы-туклы яшәү

поголубе́ть *сов.* зәңгәрләнә (күгелҗемләнә) төшү

пого́н *м* погон; **офице́рские ~ы** офицер погоннары

пого́нн||ый, **-**ая, -ое озынлыгы ..., буе ..., озынлыгы (буе) ягыннан; **пять ~ых ме́тров** озынлыгы биш метр

пого́нщик *м* куучы, куып баручы, әйдәкче, әйдәүче

пого́н||я *ж* **1.** *за кем-чем* куа китү (бару); бастырып бару (килү); **пусти́ться в ~ю** *за кем-л. кемне дә булса* куа китү **2.** куучылар, эзәрлекләүчеләр, куа баручылар төркеме: **за ним по пята́м гнала́сь ~я** аның артыннан бастырып куа баручылар чаба иде **3.** *перен.* куу, чабу, омтылу; **~я за при́былью** табыш артыннан куу; **~я за сла́вой** шөһрәт артыннан куу

погоня́ть I *несов. кого-что* **1.** куу, куалау; **~ лошаде́й** атларны куалау **2.** *перен. разг.* ашыктыру, ашыктырып тору, куу, кызулату, тизләтү; **его́ ~ не прихо́дится** аны ашыктырып торасы юк

погоня́ть II *сов. кого-что, разг.* чаптыру, чаптырып бару; **~ коня́ два часа́** атны ике сәгать буе чаптырып бару

погоня́ться *сов. за кем-чем, разг.* куып йөрү, артыннан чабып йөрү; **~ за за́йцем** куян куып йөрү

погорева́ть *сов.* кайгырып (көенеп, сагышланып) алу, бераз хәсрәт чигеп алу

погоре́лец *м* [йорт-җире] янган (янып бөлгән) кеше, мал-мөлкәте янган кеше

погоре́||ть *сов.* **1.** (*сгореть целиком или в большом количестве*) яну, янып йорт-җирсез калу, янгында мал-мөлкәтсез калу, янып бөлү **2.** (*лишиться имущества*) янып бетү, янып көлгә әйләнү **3.** (*засохнуть от зноя*) көю, кору, көеп (корып) бетү **4.** (*сгнить, сопреть*) черү, череп бетү, кызып черү **5.** яну, [бераз] янып тору; **ла́мпа ~ла и пога́сла** лампа бераз янды да сүнде **6.** *перен. на чём и без доп., прост.* уңышсызлыкка очрау, бәлагә тару, яну

погорячи́||ться *сов.* кызып (ярсып) китү, ачу кабару; **я зря ~лся** юкка гына кызып киткәнмен

пого́ст *м* каберлек, авыл зираты

погости́||ть *сов.* бераз кунак булу (булып китү); **~те у нас немно́го** бездә бераз кунак булып китегез

погран- кушма сүзләрнең *«чик саклаучы», «чик буендагы» мәгънәләрен аңлаткан береңче өлеше, мәс.* **погранзаста́ва** чик буендагы застава; **погранотря́д** чик саклаучы отряд

пограни́чник *м* чик сакчысы, пограничник

пограни́чн||ый, -ая, -ое **1.** чик буе ...ы, чик буендагы ...ы, чик ...ы; **~ая зо́на** чик буе зонасы; **~ый столб** чик баганасы **2.** чик сакчылары ...ы; **~ая фо́рма** чик сакчылары формасы

по́греб *м* баз; кар базы, нәүрәп; **поста́вить ма́сло в ~** майны кар базына төшереп кую; **порохово́й ~** дары базы

погреба́льный, -ая, -ое күмү ...ы, мәет күмү ...ы, жирләү ...ы; **~ обря́д** мәет күмү йоласы

погреба́ть *несов. см.* **погрести́** I

погребе́ни||е *с см.* **погрести́** I; **ме́сто ~я** күмү урыны, күмелгән урын

погребе́ц *м уст.* бәләкәй сандык, юл сандыгы

погрему́шка *ж* шалтыравык, шыл-тыравык (*уенчык*)

погрести́ I *сов.* **1.** *кого-что* (*похоронить*) күмү, күмеп кую, җирләү, мәет кую (күмү) **2.** *перен. что* (*укрыть, скрыть*) яшерү, күмү **3.** *кого-что* (*засы́пать, завалить*) күмеп (каплап, басып) китү

погрести́ II *сов.* (*веслом*) ишеп алу, бераз ишү, ишкәк ишеп алу; (*граблями*) бераз тырмалап җыю (*мәс. печәнне*)

погре́сть *сов. кого-что и без доп.* җылытып алу, бераз җылыту; **~ во́ду** су җылытып алу

погре́ться *сов.* җылынып алу, бераз җылынып алу

погреши́ть *сов. против чего, чем* хаталану, ялгышу, бозу, каршы килү, хилафлык кылу; **~ про́тив и́стины** хакыйкатькә хилафлык кылу

погре́шнос||ть *ж* ялгышлык, ялгыш, хата, кимчелек, җитешсезлек, төгәлсезлек; **рабо́та не име́ла никаки́х ~тей** эштә бернинди дә хата юк иде

погрози́ть *сов. кому и без доп.* куркыту, янау, куркытып (янап) кую

погро́м *м* погром (*берәр милләт халкын яки халыкның берәр төркемен талаудан, җәберләүдән, күплән утерүдән гыйбарәт булган шовинистик хәрәкәт*)

погро́мн||ый, -ая, -ое погромга чакыра торган, погром оештырырга өнди торган; **~ые выступле́ния** погромга өнди торган чыгышлар

погро́мщик *м* погромчы, погромда катнашучы

погрубе́||ть *сов.* тупаслана (калыная) төшү, тупасланып (калынаеп) китү, тупаслану, дорфалану, калынаю; **ко́жа ~ла** тире тупаслана төшкән; **у него́ го́лос ~л** аның тавышы калыная төшкән

погружа́ть *несов. см.* **погрузи́ть**

погружа́ться *несов.* **1.** *см.* **погрузи́ться; 2.** *страд. от* **погружа́ть**

погруже́ние *с см.* **погрузи́ть, погрузи́ться; ~ подво́дной ло́дки** су асты көймәсенең чумуы

погрузи́ть *сов.* **1.** *кого-что* төяү, йөк төяү; **~ това́р на парохо́д** товарны пароходка төяү **2.** *кого-что во что* батыру, чумдыру, күмү; **~ в во́ду** суга чумдыру; **~ но́ги в песо́к** аякларны комга күмү

погрузи́||ться *сов.* **1.** төялү, утыру, утырышу; **пассажи́ры ~лись в вагоны** пассажирлар вагоннарга утырыштылар **2.** бату, чуму, күмелү; **ведро́ ~лось в во́ду** чиләк суга батты **3.** *перен. во что* бирелү, бату, чуму, талу; **~ться в сон** йокыга талу; **~ться в чте́ние** укуга бирелү

погру́зка *ж см.* **погрузи́ть** 1, **погрузи́ться** 1; **~ у́гля** күмер төяү

погру́зочн||ый, -ая, -ое йөк төяү ...ы, йөк төйи торган; **~ые рабо́ты** йөк төяү эшләре; **~ые маши́ны** йөк төйи торган машиналар

погру́зчик *м* төягеч, йөк төягеч машина (*йөк төяу-бушату җайланмасы*)

погрусти́ть *сов.* ямансулап (пошыныпп, кайгырып) алу, ямансулап (сагынып) кую

погры́зть *сов. что* **1.** (*нек-рое время*) кимереп алу, [бераз] кимерү (*мәс. сөякне*); [бераз] ярып (ашап) алу (*мәс. чикләвекне*) **2.** *разг.* (*всё, многое*) кимереп бетерү (*мәс. сөякне*); ярып бетерү (*мәс. чикләвекне*)

погры́зться *сов.* **1.** (*о животных*) талашып (тешләшеп, чәйнәшеп) бетү **2.** *перен. разг.* тиргәшеп (талашып, әрләшеп, кычкырышып) бетү

погрязна́ть *несов. см.* **погря́знуть**

погря́знуть *сов. в чём прям., перен.* бату, чуму, батып (чумып) калу

погуби́ть *сов. кого-что* һәлак (харап) итеп ташлау, башын ашау, башына җитү, җаның кыю

погуде́ть *сов.* гүелдәү, гүелдәп алу, кычкырту, кычкыртып алу, (бераз) кычкыртып тору

погу́ливать *несов. разг.* (*изредка кутить*) типтергәләү, әйттергәләү

погуля́ть *сов.* **1.** йөрү, йөреп алу, ачык һавада йөреп алу, сәйран кылу; **~ пе́ред сном** йокларга ятар алдыннан ачык һавада йөреп алу **2.** *разг.* күңел ачып алу, әйттерү; типтерү; **~ на сва́дьбе** туйда әйттерү

под I *м* мич төбе

под II (подо) *предлог* **1.** *с вин.п.* (*на вопрос «куда»*) астына, төбенә; **поста́вить ~ стол** өстәл астына кую; **положи́ть ~ го́лову** баш астына салу; **смотре́ть по́д ногти** аяк астына карау; **спуститься ~ во́ду** су төбенә төшү **2.** *с вин.п.* астына, ...га; **взять ~ свою́ защи́ту** үз канатың астына алу; **отда́ть ~ суд** судка бирү; **взять ~ стра́жу** сак астына алу **3.** *с вин.п.* (*близко к чему-л. по времени*) алдыннан, ...га таба, ...га каршы, якын; **~ пра́здник** бәйрәм алдыннан; **в ночь ~ Но́вый год** Яңа елга каршы төндә; **~ у́тро** таң алдыннан; **~ ве́чер** кичкә таба, кичкырын **4.** *с вин.п.* (*при указ. на возраст*) чамасы, тирәсе, якын; **ему́ лет ~ шестьдеся́т** аңа алтмыш яшьләр чамасы **5.** *с вин.п.* (*в сопровождении чего-л.*) астында, ...га кушылып; **~ аплодисме́нты** кул чапкан тавышлар астында; **петь ~ гита́ру** гитарага кушылып җырлау **6.** *с вин.п.* (*наподобие*) ...га охшатып, ...на туры китереп; **отде́лать ~ кра́сное де́рево** кызыл агачка охшатып эшкәртү; **подобра́ть ~ цвет** төсенә туры китереп сайлап алу **7.** *с вин.п.* (*при указ. на назначение предмета*) ...га дигән, салырга дигән; өчен; **бо́чка предназна́чена ~ вино́** аракы салырга дигән мичкә **8.** *с тв.п.* астында, астыннан, төбендә; **идти́ ~ дождём** яңгыр астында бару; **ло́дка прохо́дит ~ мостом** көймә күпер астыннан үтеп бара; **~ огнем проти́вника** дошман уты астында **9.** *с тв.п.* астында, ...ендә; **~ надзо́ром** күзәтү астында; **находи́ться ~ защи́той свои́х друзе́й** үзеңнең дусларың яклавы астында булу **10.** *с тв.п.* (*при указ. места*) янында, якынында, тирәсендә; **жить ~ Москво́й** Мәскәү тирәсендә яшәү; **~ го́родом** шәһәр янында **11.** *с тв.п.* (*в результате, вследствие*) астында, ...дан; **~ впечатле́нием пое́здки** йөреп кайту тәэсиреннән; **~ де́йствием тепла́** җылылык тәэсиреннән **12.** *с тв.п.* (*при указ. на характерный признак*) ...лы; **дом ~ желе́зной кры́шей** калай түбәле йорт; **ла́мпа ~ абажу́ром** абажурлы лампа; **ло́дка ~ паруса́ми** җилкәнле көймә; **ры́ба ~ со́усом** соуслы балык **13.** *с тв.п.* (*при выделении из числа других предметов*) астында, белән; **писа́ть ~ псевдони́мом** псевдоним белән язу **14.** *с тв.п.* (*при разъяснении смысла*) ...дан, астында; **что понима́ть ~ э́тим сло́вом?** бу сүздән ни аңларга соң? ♦ **взять по́д руку** култыклап алу; **~ зало́г** залогка әйбер куеп; **~ распи́ску** кул куйдырып; **~ че́стное сло́во** сүзенә ышанып; **спря́тать ~ замо́к** бикләп кую; **стричь ~ маши́нку** чәчне машинка белән алу; **храни́ть ~ замко́м** бикләп саклау; **э́то ему́ не ~ си́лу** моңа аның көче житмәс, моны ул булдыра алмый

под- (подо-, подъ-) *приставка* **1.** *фигыль ясаганда кулланылып, түбәндәге чаралар ярдәмендә бирелә*: 1) *«астына» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **подложи́ть** астына салу; **подста́вить** астына кую; **подстели́ть** астына җәю; **подкле́ить** астына ябыштыру; 2) *«янына» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **подбежа́ть** янына йөгереп килү; **подползти́** янына үрмәләп килү; **подвести́** янына алып килү; 3) *«өстәп» дигән хәл фигыль ярдәмендә, мәс.* **подли́ть** өстәп кою; **подкача́ть** өстәп суырту; **подсы́пать** өстәп сибү; 4) *«бераз» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **подгни́ть** бераз черү; **подлечи́ться** бераз дәвалану; **подмо́кнуть** бераз юешләну; 5) *«төшү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **подвинти́ть** бора төшү; **подсласти́ть** тәмләләндерә төшү; **подкрути́ть** бөтерә төшү; 6) *«астыртын» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс.* **подговори́ть** астыртын котырту; **подслу́шать** астыртын тыңлап ишетү; **подсмотре́ть** астыртын карап күреп алу; **подсказа́ть** астыртын әйтү; 7) *«кушылып» дигән хәл фигыль ярдәмендә, мәс.* **подпе́ть** кушылып җырлау; **подыгра́ть** кушылып уйнау; 8) *«җибәрү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **подбро́сить** чөеп җибәрү; **подхвати́ть** күтәреп җибәрү; **подморо́зить** суытып җибәрү; 9) *кайбер приставкалы фигыльләрнең бары төп фигылен генә тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **подгото́вить** хәзерләү; **подмести́** себерү; **подогреть** җылыту **2.** *исем һәм сыйфат ясаганда кулланылып, түбәндәге чаралар ярдәмендә тәрҗемә ителә*: 1) *«астындагы» дигән сыйфат ярдәмендә, мәс.* **поджелу́дочный** ашказаны астындагы; **подстро́чный** юл астындагы; **подко́жный** тире астындагы; 2) *«янындагы» дигән сыйфат ярдәмендә, мәс.* **подмоско́вный** Мәскәү янындагы; **подгоро́дный** шәһәр янындагы; 3) *«кече» дигән сыйфат ярдәмендә, мәс.* **подкла́сс** кече класс; **подста́нция** кече станция 4) *«ярдәмчесе» дигән исем ярдәмендә, мәс.* **подмасте́рье** мастер ярдәмчесе; **подпа́сок**

көтүче ярдәмчесе; 5) *исем ясагыч «...ча» кушымчасы ярдәмендә, мәс.* **подгру́ппа** төркемчә; **подотдéл** бүлекчә; **подви́д** төрчә

подава́ть *несов. см.* **пода́ть** ♦ ~ **надéжды** өметле генә күренү; **молодóй музыка́нт подаёт надéжды** яшь музыкант өметле генә күренә

подава́ться *несов.* **1.** *см.* **пода́ться; 2.** *страд. от* **подава́ть**

подави́ть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* сытып (изеп) бетерү; изеп вату; ~ **всех мух** барлык чебеннәрне сытып бетерү **2.** *что, на что* (*берникадәр вакыт*) басып (кысып) тору; ~ **больно́е ме́сто** авыртканурынны бераз басып тору **3.** *что* сыгып (кысып) алу; ~ **лимо́н** лимонны сыгып алу **4.** *прям., перен. кого-что* бастыру, жиңү; ~ **восста́ние** восстаниене бастыру; ~ **страх** курку хисен жиңү **5.** *кого-что чем* буйсындыру; ~ **свои́м авторите́том** үзеңнең авторитетыңа буйсындыру **6.** *кого-что* (*привести в мрачное состояние*) боектыру; күңел төшенкелегенә китерү

подави́ться *сов.* тончыгу, тамакка тыгылу (утыру, кадалу)

подавле́ние *с см.* **подави́ть** 4

пода́вленность *ж* рухи изелгәнлек (төшенкелек), күңел төшенкелеге, боеклык, кәефсезлек, күңелсезлек

пода́вленн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **подави́ть; 2.** басынкы, тонык, тыенкы, ишетелер-ишетелмәс; ~ **ый стон** басынкы ыңгырашу тавышы **3.** төшенке, боек, күңелсез, рухи изелгән; ~ **ое настрое́ние** төшенке күңел

подавля́ть *несов. см.* **подави́ть** 4, 5, 6

подавля́ющ||ий, -ая. -ее **1.** *прич. от* **подавля́ть; 2.** иң зур; ~ **ее большинство́** иң зур күпчелек

пода́вно *нареч.* бигрәк тә, әйтеп тә торасы юк, һичшиксез, күптән; **он согла́сен, а я и** ~ ул риза, мине әйтеп тә торасы юк

пода́гра *ж* подагра (*тоз утыру авыруы*)

пода́грик *м* подагра белән авыручы, подагра авырулы кеше

подагри́ческ||ий, -ая, -ое подагра ...ы, подагра авырулы; ~ **ие но́ги** подагра авырулы аяклар

пода́льше *нареч. разг.* тагын да арырак (ераграк), тегендәрәк, арырак ♦ **от греха́** ~ бәладән баш-аяк

подари́ть *сов. кого-что* бүләк итү, бүләк итеп бирү; ~ *что-л.* **на па́мять** истәлеккә *берәр әйбер* бүләк итү

пода́рок *м* бүләк, сөенче, ядкарь; **сде́лать** ~ бүләк бирү ♦ ~ **судьбы́** бәхет басу, көтелмәгән бәхет

пода́рочн||ый, -ая, -ое бүләклек, бүләккә дигән, бүләк итеп бирелгән; ~ **ое изда́ние** бүләккә дигән басма

пода́тель *м офиц.* (*берәр нәрсә*) тапшыручы, бирүче; ~ **письма́** хат тапшыручы

пода́тельница *ж* (*берәр нәрсә*) тапшыручы хатын (кыз)

пода́тливость *ж* **1.** бөгелүчәнлек, сыгылучанлык, үзелек, пешелек **2.** (*уступчивость*) сүзгә күнүчәнлек, юл куючанлык, иплелек

пода́тлив||ый, -ая, -ое **1.** бөгелүчән, сыгылучан, пеше, үзле; ~ **ый материа́л** бөгелүчән материал; ~ **ая гли́на** үзле балчык **2.** сүзгә күнүчән, ипле, юл куючан, сүз тыңлаучан, карышмаучан, карусыз; ~ **ый хара́ктер** ипле характер

по́дать *ж ист.* имана, салым, ясак

пода́||ть *сов.* **1.** *кого-что* алып (китереп) бирү, бирү; ~ **ть стака́н воды́** бер стакан су китереп бирү **2.** *что* китереп кую, китерү, табынга китереп кую; **гостя́м по́дали плов** кунакларга пылау китерделәр **3.** *что* китерү, китереп туктату; ~ **ть по́езд к платфо́рме** поездны платформа янына китереп туктату **4.** *что* ташып кую, күчереп өлгертү, китереп (илтеп) җиткерү; **во́время** ~ **ть материа́лы** материалларны вакытында китереп җиткерү **5.** *кого-что* күчереп кую, этәрү, чигерү, сузу; җибәрү; ~ **ть ло́шадь наза́д** атны артка чигерү; ~ **ть патро́н в кана́л ствола́** патронны көпшәнең каналына җибәрү **6.** *что и без доп.* бирү, язып бирү; ~ **ть заявле́ние** гариза язып бирү **7.** *что и без доп.* (*милостыню*) хәер (сәдака) бирү ♦ ~ **ть го́лос** тавыш бирү; ~ **ть кома́нду** команда бирү; ~ **ть мяч** тупны интәшеңә тапшыру; ~ **ть приме́р** үрнәк күрсәтү; ~ **ть по́мощь** ярдәм күрсәтү; ~ **ть ру́ку** кул бирү; кул сузу

пода́||ться *сов.* **1.** кузгалып китү, тайпылу, чигенү; **толпа́** ~ **ла́сь в сто́рону** халык төркеме бер читкәрәк тайпылды **2.** урынныннан кузгалу, ачылу, ачылып китү; **дверь** ~ **ла́сь под уда́рами** бәрә торгач, ишек ачылып китте **4.** *разг.* (*согласиться на что-л.*) күнү, риза булу ♦ ~ **ться не́куда** бернидә эшләп булмый; барып җир юк

пода́чка *ж разг.* **1.** сынык, кисәк (*эткә, терлеккә ташланган ашамлык кисәге*) **2.** *перен.* хәер, сәдака; **жить** ~ **ми** хәер эстәп көн күрү

пода́яние *с уст.* хәер, сәдака

подава́ть *сов. что, чего* өстәү, өстәп салу, өсти төшү, кушу; ~ **са́хару в ко́фе** кофега шикәр өстәү

подава́ка *ж разг.* **1.** *см.* **подава́ть; 2.** (*то, что прибавлено*) өстәмә, өстәлгән әйбер, өстәп салынган әйбер

подавля́ть *несов. см.* **подава́ть**

подавля́ться *несов.* **1.** *см.* **подава́ться; 2.** *страд. от* **подавля́ть**

подба́дривать *несов. см.* **подбодри́ть**

подба́дриваться 1. *см.* **подбодри́ться; 2.** *страд. от* **подба́дривать**

подба́лтывать *несов. см.* **подболта́ть**

подбега́ть *несов. см.* **подбежа́ть**

подбежа́ть *сов.* **1.** *к кому-чему* йөгереп (чабып) килү, йөгереп (чабып) килеп җитү; ~ **ть к до́му** йорт янына йөгереп килеп җитү **2.** *подо что* йөгереп (чабып) астына керү

подбе́ливать *несов. см.* **подбели́ть**

подбели́ть *сов. что* **1.** [бераз] агартып алу, агарта төшү, әзрәк акшарлап алу; ~ **печь** мичне әзрәк акшарлап алу **2.** *разг.* (*сметаной, молоком*) [бераз] сөт салып җибәрү (*чәйгә*), [бераз] каймак кату, [әзрәк] катык кату (*ашка*)

подберёзовик *м* каен гөмбәсе

подбива́ть *несов. см.* **подби́ть**

подби́вка *ж см.* **подби́ть** 1, 2

подбира́ть *несов. см.* **подобра́ть**

подбира́ться *несов.* **1.** *см.* **подобра́ться; 2.** *страд. от* **подбира́ть**

подби́ть *сов.* **1.** *что* [астына] кагу (сугу, салу), олтан салу, ас[лык] сугу, төп кую; ~ **сапоги́** итеккә олтан салу **2.** *что* астарлау, астар кую, эчлек кую, эчләү; ~ **пальто́ ме́хом** пальтога мех эчлек кую **3.** *кого-что* бәреп (атып) төшерү; ~ **самолёт** самолётны атып төшерү **4.** *что* бәреп (сугып) җәрәхәтләү (яралау); ~ **глаз** күзне бәреп җәрәхәтләү **5.** *кого-что на что и с неопр., разг.* котырту, кыздыру, дәртләндерү; ~ **на ша́лость** шаянланырга котырту

подбодри́ть *сов. кого-что, разг.* күңелен күтәреп җибәрү, рухландырып (дәртләндереп) җибәрү; ~ **больно́го** авыруның күңелен күтәреп җибәрү

подбодри́ться *сов.* күңел күтәрелеп китү, рух күтәрелү, дәртләнеп китү

подбодря́ть *несов. см.* **подбодри́ть**

подбодря́ться *несов.* **1.** *см.* **подбодри́ться; 2.** *страд. от* **подбодря́ть**

подболта́ть *сов. что, чего, разг.* кушып болгату, кушып туглау; ~ **молока́ в суп** ашка сөт кушып туглау

подбо́р *м* **1.** *см.* **подобра́ть;** ~ **ка́дров** кадрлар сайлау **2.** сайланыш, сайлап алынган нәрсәләр; **интере́сный** ~ **книг** китапларның кызыклы сайланышы ♦ **как на** ~ сайлап алынган шикелле, сайлап алгандай

подбо́рка *ж* **1.** *разг. см.* **подобра́ть** 1, 3; ~ **материа́лов** материал сайлау **2.** подборка (*газетада уртак бер темага язылган вак мәкаләләр тезмәсе*)

подборо́дник *м* (*часть конской узды*) сагалдырык

подборо́док *м* ияк

подборо́дочн||ый, -ая, -ое ияк ...ы; ~ **ая мы́шца** ияк мускулы

подбо́рщик *м* **1.** сайлаучы; сортларга аеручы, сортлаучы; ~ **мехо́в** мех сайлаучы **2.** (*в комбайне*) жыйгыч (*җайланма*); ~ **бараба́нный** барабанлы жыйгыч

подбоче́ниваться *несов. см.* **подбочени́ться**

подбочени́ться *сов. разг.* билгә таяну, бөергә таяну

подбра́сывание *с см.* **подбро́сить**

подбра́сывать *несов. см.* **подбро́сить**

подбрива́ть *несов. см.* **подбри́ть**

подбри́ть *сов. кого-что* ян-якларын кырып ташлау, чит-читләрен кырып ташлау

подбро́сить *сов.* **1.** *кого-что* (*вверх*) чөю, чөеп җибәрү, югары чөю, югары ыргыту; (*подо что-л.*) [астына] ташлау. [астына] ыргыту; **высоко́** ~ **мяч** тупны бик югары чөю; ~ **мяч под дива́н** тупны диван астына ыргыту **2.** *что, чего* өстәп салу (җибәрү), өсти төшү, өстәү; ~ **дров в печь** мичкә утын өстәп җибәрү **3.** *кого-что, чего, разг.* җибәрү, өстәмә

рәвештә җибәрү; ~ **сре́дства** өстәмә рәвештә средстволар җибәрү **4.** *кого-что* (*тайком подложить*) ташлап (калдырып) китү, китереп ташлау (*яшертен рәвештә*); ~ **письмо́** хат калдырып китү **5.** *кого-что, прост.* утыртып бару, илтеп кую (ташлау); ~ *кого-л.* **до ста́нции** *кемне дә булса* станциягә хәтле утыртып бару

подбрю́шник *м* түшлек, бавыргалык

подва́л *м* **1.** подвал, идән асты **2.** (*в газете*) подвал (*газета битенең аскы өлеше*)

подва́ливать *несов. см.* **подвали́ть**

подвал||и́ть *сов.* **1.** *что, чего* янына өю (аудару, бушату); ~ **и́ть к забо́ру песку́** койма янына ком китереп аудару **2.** *что, чего* өстәп салу (җибәрү), өсти төшү, өстәү; ~ **и́ть в костёр хво́росту** учакка чыбык-чабык өстәп җибәрү **3.** *безл. кого-чего, прост.* өстәлү, өсте-өстенә килү, килеп җыелу, тагын килү; **наро́ду** ~ **и́ло** халык килеп җыелды

подва́льн||ый, -ая, -ое подвал ...ы, подвалдагы; ~**ое помеще́ние** подвалдагы бина

подва́ривать *несов. см.* **подвари́ть**

подва́риваться *несов.* **1.** *см.* **подвари́ться; 2.** *страд. от* **подва́ривать**

подвари́ть *сов. чего, разг.* булган өстенә кайнату, тагын кайнату, өстәмә рәвештә кайнату; ~ **варе́нья** өстәмә рәвештә варенье кайнату

подва́хтенный, -ая, -ое вахтага басу чираты җиткән, вахтада торучыны алмаштырырга тиеш булган; ~ **матро́с** вахтага басу чираты җиткән матрос

подведе́ние *с см.* **подвести́; ~ ито́гов** нәтиҗә чыгару

подве́домственн||ый, -ая, -ое карамагындагы, карамагында булган; **учрежде́ния, ~ые министе́рству** министрлык карамагындагы учреждениеләр

подвезти́ *сов.* **1.** *кого-что* илтеп җиткерү, китереп җиткерү, утыртып алып бару, китерү; **шофёр подвёз меня́ до го́рода** шофёр мине шәһәргә кадәр утыртып алып барды **2.** *кого-что, чего* китерү, алып килү; ~ **дров** утын китерү **3.** *см.* **повезти́** 2

подвене́чн||ый, -ая, -ое никах ...ы, никахланышу вакытында кигән (кия торган); ~**ое пла́тье** никахланышу вакытында кия торган күлмәк

подверга́ть *несов. см.* **подве́ргнуть**

подверга́ться *несов.* **1.** *см.* **подве́ргнуться; 2.** *страд. от* **подверга́ть**

подве́ргнуть *сов. кого-что чему* дучар итү, тарту, ...га кую, астына кую; ~ **прое́кт обсужде́нию** проектны тикшерүгә кую; ~ **свою́ жизнь опа́сности** тормышыңны куркыныч астына кую; ~ **наказа́нию** җәзага тарту

подве́ргнуться *сов.* дучар булу, дучар ителү, тару, төшү, тартылу, эләгү; ~ **кри́тике** тәнкыйтькә эләгү; ~ **опа́сности** куркынычка тару

подве́рженный, -ая, -ое дучар булган, дучар ителгән, ...га тиз бирелүчән, ...чан; **челове́к, ~ боле́зням** еш авыручан кеше

подверну́ть *сов. что* **1.** [кайтарып] бөкләп кую, [кайтарып] кыстырып кую; ~ **одея́ло** юрганны кайтарып кыстырып кую **2.** сызгану, сызганып (бөкләп, кайтарып) кую; ~ **брю́ки до коле́н** балакны тезгә хәтле кайтарып кую **3.** бора төшү, ныграк борып кую; ~ **винт** винтны ныграк борып кую ♦ ~ **но́гу** аякны каймыктыру

подверну́||ться *сов.* бөкләнеп аста калу; **одея́ло ~лось** юрган бөкләнеп аста калды **2.** *перен. разг.* туры килү, очрау; ~**лась интере́сная кни́га** кызыклы китап очрады ♦ **нога́ ~лась** аяк каймыкты

подвёртывание *с см.* **подверну́ть**

подвёртывать *несов. см.* **подверну́ть**

подвёртываться *несов.* **1.** *см.* **подверну́ться; 2.** *страд. от* **подвёртывать**

подве́сить *сов. кого-что* асып (элеп, тагып) кую; ~ **ла́мпу под потолко́м** лампаны түшәмгә асып кую ♦ **язы́к хорошо́ подве́шен** *у кого* телгә беткән

подве́ситься *сов. разг.* асылыну

подве́ска *ж* **1.** *см.* **подве́сить; 2.** (*украшение*) асма бизәк, асылмалы бизәк

подвесн||о́й, -а́я, -о́е асылмалы, асып куела торган, асма; ~**а́я ла́мпа** асылмалы лампа; ~**а́я доро́га** асылмалы юл

подве́сок *м разг. см.* **подве́ска** 2

подвести́ *сов.* **1.** *кого-что* алып килү, китерү, китереп җиткәрү, җитәкләп алып килү; ~ **ло́шадь к крыльцу́** атны баскыч янына китерү **2.** *что подо что* [астына] кую, [астына] салу; ~ **фунда́мент** фундамент кую **3.** *перен. что подо что* нигезләү, дәлилләү; ~ **нау́чную ба́зу под свои́ рассужде́ния** фикер йөртүләреңне фәнни яктан нигезләү **4.** *что* чыгару; ~ **ито́ги се́ссии** сессиянең йомгакларын чыгару, сессияне йомгаклау **5.** *перен. кого-что, разг.* уңайсыз хәлдә калдыру, утырту, кызык итү, алдау; ~ **това́рища** иптәшеңне уңайсыз хәлдә калдыру **6.** *что* җиткерү, китереп җиткерү, сузу; ~ **доро́гу к заво́ду** юлны заводка кадәр китереп җиткерү **7.** *что* сөрмә тарту, буяу; ~ **бро́ви** кашка сөрмә тарту **8.** *безл. кого-то, разг.* тартылу, кысылу, кысылып бетү; **живот от го́лода подвело́** ачыгудан эч кысылып беткән ♦ ~ **часы́** сәгатьнең телен күчерү; ~ **под монасты́рь** авыр хәлгә кую

подве́тренн||ый, -ая, -ое җил тими торган, җилдән ышык булган, ышык; ~**ая сторона́** ышык як

подве́шивание *с см.* **подве́сить**

подве́шивать *несов. см.* **подве́сить**

подве́шиваться *несов.* **1.** *см.* **подве́ситься; 2.** *страд. от* **подве́шивать**

подвздо́шн||ый, -ая, -ое *анат.* кабырга белән эч арасындагы ♦ ~**ая кость** янбаш сөяге

подвива́ть *несов. см.* **подви́ть**

подвива́ться *несов.* **1.** *см.* **подви́ться; 2.** *страд. от* **подвива́ть**

по́двиг *м* батырлык, каһарманлык; **во́инский** ~ хәрби батырлык; **трудово́й** ~ хезмәт батырлыгы

подви́гать *сов.* **1.** *чем* селкетеп (кымшатып, сикертеп) кую; ~ **па́льцами** бармакларны селкетеп кую **2.** *что* (*некрое время*) күчереп кую, бераз күчерү, шудырып кую

подвига́ть *несов. см.* **подви́нуть**

подви́гаться *сов.* йөреп алу, [бераз] йөрү, [бераз] кыймылдап алу

подвига́ться *несов.* **1.** *см.* **подви́нуться; 2.** *страд. от* **подвига́ть**

подви́д *м биол.* төрчә, төрчек

подви́жник *м высок.* батыр, каһарман, фидакарь; ~ **нау́ки** фән каһарманы

подви́жническ||ий, -ая, -ое *высок.* батырларча ..., каһарманнарча..., фидакарьләрчә...; ~**ое отношение к труду́** хезмәткә фидакарьләрчә караш

подви́жничество *с высок.* батырлык, каһарманлык, фидакарьлек

подвижн||о́й, -а́я, -о́е **1.** күчмә, күчерелмәле, хәрәкәтчел, хәрәкәтчән, кузгатыла торган; ~**о́й блок** күчмә блок **2.** күчмә, күчеп йөри торган; ~**о́й го́спиталь** күчмә госпиталь **3.** хәрәкәтчән, тиз хәрәкәт итә торган; ~**ые гру́ппы войск** гаскәрләрнең хәрәкәтчән төркемнәре ♦ ~**о́й соста́в** *ж.-д.* хәрәкәттәге состав; ~**ые и́гры** хәрәкәтле уеннар

подви́жность *ж* **1.** күчмәлек, күчерелмәле булу, хәрәкәтчәнлек **2.** күчмәлек, күчеп йөри торган булу **3.** хәрәкәтчәнлек, тиз хәрәкәт итә торган булу **4.** елгырлык, җитезлек

подви́жный, -ая, -ое елгыр, җитез; ~ **ребёнок** елгыр бала

подвиза́ться *несов. книжн.* хезмәт итү, эшләп килү, эш күрсәтеп килү; маташу; ~ **в нау́ке** фән өлкәсендә эшләп килү

подвинти́ть *сов. что* **1.** бора төшү, тыгызлый төшү, ныграк бору; ~ **га́йку** гайканы бора төшү **2.** борып беркетү, [астан] борып кую; ~ **конько́в к боти́нкам** конькиларны ботинкаларга борып беркетү

подви́нуть *сов.* **1.** *кого-что* күчереп кую, күчерү, шудырып (тартып, этеп) кую; ~ **стол к окну́** өстәлне тәрәзә янына күчереп кую **2.** *перен. что* алга җибәрү (этәрү); ~ **рабо́ту** эшне алга җибәрү

подви́ну||ться *сов.* **1.** күчә төшү, якынрак килү, күчү, шуышу, кузгалу; **он ~лся ко мне** ул миңа якынрак килде **2.** *перен.* алга китү, алга бару; **рабо́та значи́тельно ~лась** эш шактый алга китте

подви́нчивать *несов. см.* **подвинти́ть**

подви́ть *сов. что* [бераз] көдрәләтү, [бераз] бөдрәләү, җиңелчә көдрәләтеп җибәрү; ~ **во́лосы** чәчне җиңелчә көдрәләтеп җибәрү

подви́ться *сов.* җиңелчә көдрәләп алу, чәчнең бөдрәсен төзәткәләп алу

подвла́стный, -ая, -ое хакимлегендәге, кул астындагы, кулындагы, буйсынган, бәйле, властендагы

подво́д *м см.* **подвести́** 1-3

подво́да *ж* олау

ПОД-ПОД

подводи́ть *несов. см.* **подвести́**

подво́дка *ж см.* **подвести́** 1-3

подво́дник *м* подводник (**1.** *су астылары көймәсендә хезмәт итүче* **2.** *водолазлык эшләре белгече*)

подводн||о́й, -а́я, -о́е тоташтыра торган, тоташтыргыч; **~ые тру́бы** тоташтыргыч торбалар

подво́дн||ый I, -ая, -ое су астындагы, су төбендәге, су асты ...ы; **~ые расте́ния** су асты үсемлекләре; **~ая ло́дка** су асты көймәсе; **~ое пла́вание** су астында йөзү

подво́дн||ый II, -ая, -ое: **~ая повы́нность** *ист.* олаучылык йөкләмәсе

подво́з *м см.* **подвезти́** 1, 2

подвози́ть *несов. см.* **подвезти́** 1,2

подво́зка *ж разг. см.* **подвезти́** 1, 2

подво́зчик *м* ташучы, ташып (китереп) торучы

подво́й *м сад.* ялганма (*үзенә икенче бер сорт ялгана торган жимеш агачы*)

подво́рн||ый, -ая, -ое *ист.* йорт башыннан ..., йорт (капка) башыннан салына торган; **~ая по́дать** йорт башыннан салына торган салым

подворотничо́к *м* яка тасмасы, яка астары, яка эчлеге

подворо́тня *ж* **1.** капка асты **2.** (*доска*) капка астына куела торган такта **3.** (*проём в стене дома для прохода, проезда*) капка, капка төбе

подво́рье *с уст.* **1.** (*постоялый двор*) мөсафирханә **2.** (*усадьба*) йорт

подво́х *м разг.* хәйләле алдау, хәйләгә корылган алдау, мәкер, усаллык, явызлык, этлек; **от него́ то́лько и жди ~а** аның берәр төрле этлек эшләячәген көтеп кенә тор

подвыва́ние *с разг. см.* **подвыва́ть**

подвыва́||ть *несов. разг.* **1.** кушылып улау, ияреп улау; **волчи́ца ~ет во́лку** ана бүре ата бүрегә кушылып улый **2.** (*выть время от времени*) жиңелчә генә улау, улап-улап кую

подвы́пить *сов. разг.* [бераз] салып алу, [бераз] эчү, [бераз] төшереп алу, эчеп жиңелчә исерү

подвяза́ть *сов. что* бәйләп (тагып) кую, [бәйләп] асып кую, тагу; **~ колоко́льчик к дуге́** дугага кыңгырау тагу; **~ больну́ю ру́ку** авырткан кулны асып кую

подвяза́ться *сов.* буу, бәйләү; **~ кушако́м** билбау буу; **~ платко́м** яулык бәйләү

подвя́зка *ж* **1.** *см.* **подвяза́ть**; **2.** (*для чулок*) бәйләвеч, оек бәйләвече (бавы), будыргыч

подвя́зывать *несов. см.* **подвяза́ть**

подвя́зываться *несов.* **1.** *см.* **подвяза́ться**; **2.** *страд. от* **подвя́зывать**

подгада́||ть *сов. разг.* житешү, өлгерү; **я как ра́з ~л к по́езду** мин поездга нәкъ вакытында өлгердем

подга́дывать *несов. см.* **подгада́ть**

подгиба́ть *несов. см.* **подогну́ть**

подгиба́ться *несов.* **1.** *см.* **подогну́ться**; **2.** *страд. от* **подгиба́ть**

подгла́дить *сов. что, разг.* яңадан үтүкләп алу, тагын бер кат үтүкләү

подгла́живать *несов. см.* **подгла́дить**

подглазни́чн||ый, -ая, -ое, **подгла́з||ный,** -ая, -ое күз төбендәге..., күз төбе ...ы; **~ые же́лезы** күз төбе бизләре; **~ые мешки́** күз төпләре шешенгән

подгла́зье *с* күз төбе, күз чокыры

подгляде́ть *сов. см.* **подгля́дывать**

подгля́дывание *с см.* **подгля́дывать**

подгля́дывать *несов.* астыртын [яшереneп] карап тору, караштыргалап тору

подгнива́ть *несов. см.* **подгни́ть**

подгни́||ть *сов.* **1.** (*сгнить в нижней части*) астан (төптән) черү **2.** [бераз] черү, чери башлау; муртау; **я́годы ~ли** жиләкләр чери башлаган

подгова́ривать *несов. см.* **подговори́ть**

подговори́ть *сов.* димләү, өндәү, котkы салу, котырту, котыртып эшләтү; **~ ребя́т на ша́лость** малайларны шуклык эшләргә котырту

подголо́вник *м* **1.** (*подставка под подушку*) ястык тактасы, баш асты тактасы (*ятканда баш асты түбән булмасын әчен салына торган авыш такта*) **2.** (*на кресле*) баш терәгеч, баш куйгыч (*теш табиблары, парикмахерлар креслосында*)

подголо́с||ок *м* **1.** *муз.* өстәмә (иярчен, ярдәмче) тавыш (*жырда төп тавышка ияреп жырлаучы тавыш*) **2.** *перен.* жырын жырлаучы, көен көйләүче, куштан, ялагай (*берәүгә ялагайланып аның фикерләрен кабатлаучы*)

подго́н *м см.* **подогна́ть** 1, 3

подго́нка *ж см.* **подогна́ть** 3

подго́нщик *м* жайлаучы, көйләүче, ипләүче

подгоня́ть *несов. см.* **подогна́ть**

подгора́ть *несов. см.* **подгоре́ть**

подгоре́л||ый, -ая, -ое көйгән, асты көйгән; көек тәме кергән; **~ая котле́та** асты көйгән котлет; **~ое молоко́** көек тәме кергән сөт

подгоре́||ть *сов.* көю, асты (төбе) көю; **хлеб ~л** ипинең асты көйгән

подго́рн||ый, -ая, -ое тау итәгендәге, тау астындагы; **~ые райо́ны** тау итәгендәге районнар

подгоро́дный, -ая, -ое шәһәр янындагы, шәһәр тирәсендәге, шәһәр буендагы; **~ уча́сток** шәһәр янындагы участок

подго́рье *с* тау итәге, тау асты

подгота́вливать *несов. см.* **подгото́вить**

подгота́вливаться *несов.* **1.** *см.* **подгото́виться**; **2.** *страд. от* **подгота́вливать**

подготови́тельн||ый, -ая, -ое хәзерлек ...ы, хәзерләү ...ы; **~ые ку́рсы** хәзерлек курслары

подгото́вить *сов.* **1.** *что* хәзерләү, хәзерләп кую, хәстәрләү, хәстәрен күрү **~ кни́гу к печа́ти** китапны бастырырга хәзерләү **2.** *кого-что* хәзерләү, хәзерләп чыгару; **~ к экза́менам** имтиханга хәзерләү; **~ специали́стов** белгечләр хәзерләп чыгару **3.** *кого-что* хәзерләү, алдан хәзерләп кую; **~ кого-л. к неприя́тному изве́стию** күңелсез хәбәр әйтер алдыннан *кемне дә булса* хәзерләп кую

подгото́виться *сов.* хәзерләнеп кую, алдан хәзерләнеп тору, хәзерләнү, жыену

подгото́вка *ж* **1.** *см.* **подгото́вить, подгото́виться**; **~ к се́ву** чәчүгә хәзерләнү **2.** (*запас знаний*) белем, укып алган белем

подгото́вленность *ж* хәзерләнгәнлек, хәзерлеклелек

подготовля́ть *несов. см.* **подгото́вить**

подготовля́ться *несов.* **1.** *см.* **подгото́виться**; **2.** *страд. от* **подготовля́ть**

подгреба́ть *несов. см.* **подгрести́**

подгрести́ *сов.* **1.** *что* (*напр. сор*) көрәп өеп (жыеп) кую; (*напр. сено*) тырмап өеп (жыеп) кую **2.** ишә-ишә якынаю, ишеп якына килү, ишеп буена килү; **~ к бе́регу** ишә-ишә ярга якынаю

подгру́док *м* күкрәк асты, тамак асты, муен асты (*кайбер хайваннарның тамак астында асылынып тора торган тире*)

по́дгруздь *м* нарат гөмбәсе

подгру́ппа *ж* төркемчә

подгу́зник *м* бала чүпрәге, аслык

подгуля́ть *сов. прост.* **1.** эчеп бераз исерү, кызмачалану **2.** *шутл.* (*не удаться*) уңышсыз чыгу, уңышлы чыкмау, унмау, барып чыкмау

поддава́ть *несов. см.* **подда́ть**

поддава́ться *несов. см.* **подда́ться**

поддавки́ *только мн.*: **в ~ [игра́ть]** суктырып уйнау, бирешле уйнау, ашатып уйнау (*шашка уенында шакмакларны тизрәк суктырып бетерергә тырышып уйнау*)

подда́кивать *несов. кому-чему, разг.* сүзен (җөпләп) тору, әйе-әйе дип тору; **~ расска́зчику** сөйләүченең сүзен җөпләп тору

по́дданный *м* подданный, граждан (*билгеле бер дәүләт гражданлыгындагы кеше*)

по́дданство *с* гражданлык, гражданлыгында булу; **перемени́ть ~** гражданлыкны үзгәртү

подда́||ть *сов.* **1.** *что* чөеп жибәрү, югарыга ыргыту; **~ мяч** тупны чөеп жибәрү **2.** *что, разг.* (*в игре*) суктыру, ашату, бирү; **~ ша́шку** шашканы суктыру **3.** *чего, разг.* өстәү, арттыру, арттыра төшү; **~ па́ру** 1) парны арттыра төшү (*мунчада*); 2) *перен.* кызурак (җәһәтрәк) эшли башлау **4.** *кому, прост.* сугып (салып) жибәрү, берне кундыру

подда́||ться *сов.* **1.** бирелү, бирешү; **дверь с трудо́м ~ла́сь** ишек кыенлык белән генә бирелде (*ачылды*) **2.** *перен.* бирелү, бирешү; күнү, риза булу; **~ться на угово́ры** димләүләргә күнү **3.** *разг.* бирелү, буйсыну, жиңдерү, жиңелү; **не ~ться проти́внику** дошманга бирелмәү **4.** *разг.* (*в игре*) юри оттыру

подда́ча *ж разг. см.* **подда́ть** 1-3, **подда́ться** 3, 4

поддева́ть *несов. см.* **подде́ть**

поддёвка *ж* кәзәки (*биле бөрмәле итеп тегелгән ирләр киеме*)

подде́лать *сов. что* алдап ясау, охшатып ясау, ялган ... ясау; охшатып ... кую; **~ докуме́нт** ялган документ ясау; **~ чью-л. по́дпись** *кемнең дә булса* имзасына охшатып имза кую

подде́латься *сов. под кого-что* (*подражать*) охшарга тырышу, ... булып

кылану; ~ **под де́тскую речь** балаларга охшарга тырышып сөйләшү

подде́лка *ж* **1.** *см.* **подде́лать**; **2.** охшатып ясалган нәрсә (әйбер), ялган әйбер; ~ **под же́мчуг** энҗегә охшатып ясалган әйбер

подде́лывать *несов. см.* **подде́лать**

подде́лываться *несов.* **1.** *см.* **подде́латься**; **2.** *страд. от* **подде́лывать**

подде́льный, -ая, -ое ялган, охшатып ясалган; ~ **докуме́нт** ялган документ

поддёргивать *несов. см.* **поддёрнуть**

поддержа́ть *сов.* **1.** *кого-что* тотып алу; ~ **больно́го по́д руку** авыруны култыгыннан тотып алу **2.** *перен. кого-что* ярдәм итү, булышлык күрсәтү, булышу; ~ **дру́га в тру́дную мину́ту** кайгылы вакытта дустына ярдәм итү **3.** *перен. кого-что* яклау, куәтләү, хуплау; ~ *чью-л.* **кандидату́ру** *кемнең дә булса* кандидатурасын яклау **4.** *что* саклау; дәвам иттерү, туктатмау; ~ **разгово́р** сөйләшүне дәвам иттерү; ~ **поря́док** тәртип саклау

поддержа́ние *с см.* **поддержа́ть**; ~ **свя́зи** элемтәне туктатмау

поддержа́ва||ть *несов.* **1.** *см.* **поддержа́ть**; **2.** *что* тотып тору; **ба́лки ~ют потоло́к** матчалар түшәмне тотып торалар

поддержк||а *ж* **1.** *см.* **поддержа́ть**; **2.** ярдәм, булышлык; **оказа́ть ~у** *кому-л. кемгә дә булса* ярдәм күрсәтү **3.** *прям., перен.* (*опора*) таяныч, терәк; **он — моя́ ~а** ул — минем таянычым

поддёрнуть *сов. что, разг.* күтәрә төшү, тартып (күтәреп) кую, өскәрәк тартып кую; ~ **чуло́к** оекны өскәрәк тартып кую

подде́ть I *сов.* **1.** *кого-что* (*зацепив, поднять*) чәнчеп элеп (күтәреп) алу, күтәреп алу **2.** *перен. кого-что и без доп., разг.* төрттереп әйтү, [сүз белән] тешләү, эләктерү, чәнчеп кую; ~ *кого-л.* **в разгово́ре** сөйләшеп торганда *кемгә дә булса* төрттереп әйтү

подде́ть II *сов. что* эчтән кию, киемне икенче кием эченнән кию; ~ **сви́тер под пальто́** пальто эченнән свитер кию

поддо́нник *м* аслык, аскуйма (*мәс. гөл чүлмәге өчен*)

поддра́знивать *несов. см.* **поддразни́ть**

поддразни́ть *сов. кого-что, разг.* [бераз] үчекләп (ирештереп, котыртып) алу

поддува́ло *с* җиллек (*мичтә*)

поддува́||ть *несов. безл.* [бераз] өрү, [бераз] җил өрү; **из-под по́ла ~ет** идән астыннан җил өрә

подейство́ва||ть *сов. на кого-что и без доп.* тәэсир итү, йогынты ясау; **лека́рство хорошо́ ~ло** дару яхшы тәэсир итте

подека́дн||ый, -ая, -ое һәр ункөнлектә була торган, ун көн саен була торган; ~**ые совеща́ния** ун көн саен була торган киңәшмәләр

поде́ла||ть *сов. что, разг.* эшләү, [бераз] эшләп алу; **что бы нам тепе́рь ~ть?** нәрсә генә эшләп алырга икән безгә хәзер? ♦ **ничего́ не ~ешь** берни эшләр хәл юк, берни эшләп булмый

подели́ть *сов. кого-что* бүлү, бүлеп бирү, бүлешү

подели́||ться *сов. чем с кем* **1.** бүлешү; **де́ти ~лись конфе́тами** балалар конфетларын бүлештеләр **2.** *перен.* уртаклашу; ~**ться ра́достью со свои́м това́рищем** шатлыгыңны иптәшең белән уртаклашу

поде́лк||а *ж* **1.** (*мелкая работа*) вактәяк эш **2.** *обычно мн.* ~**и** вак-тәяк әйберләр

подело́м *нареч. разг.* урынлы, эшенә күрә таман, шул кирәк; ~ **ему́** аңа шул кирәк

поде́лочн||ый, -ая, -ое *спец.* вактәяккә китә торган, вак-тәяк эшләргә китә торган, вак-тәяк әйберләр ясауга китә торган; ~**ое де́рево** вак-тәяк әйберләр ясауга китә торган агач

поде́лыва||ть *несов. разг.* эшләштерү, эш бетерү; **что ~ете?** ни эшләп ятасыз?, ни эшләр бетерәсез?

подёнка *ж* (*насекомое*) көньяшәр (*бөҗәк*)

подённ||ый, -ая, -ое **1.** көнлекле; ~**ая рабо́та** көнлекле эш **2.** көнлекләп түләнә торган; ~**ая пла́та** көнлекләп түләнә торган хак **3.** *в знач. сущ.* ~**ая** *ж разг.* көнлекле эш

подёнщик *м уст.* көнлекче, көнлекләп эшләүче

подёнщина *ж уст.* көнлекле эш

подёнщица *ж уст.* көнлекче хатын (кыз)

подёргать *сов.* **1.** *кого-что* тарткалау, тарткалап кую (алу); ~ **за́ волосы** чәчне тарткалау **2.** *что* (*всё, многое*) йолку, суыру, йолкып (суырып) бетерү

подёргивание *с см.* **подёргивать, подёргиваться; не́рвное ~** нервланып тартышып-тартышып кую

подёргива||ть *несов.* **1.** *что* тарткалап (йолыккалап) алу; ~**ть боро́дку** сакалны тарткалап алу **2.** *чем* сикерткәләп (җыергалап) кую; ~**ть бро́вью** каш сикерткәләп кую **3.** *безл. кого-что* калтырану, көзән җыеру, тән тартышу

подёргиваться *несов.* тартышу, калтырану; **не́рвно ~** нервланып калтырану

подержа́ние *с*: **на ~** вакытлыча файдаланырга; **взять на ~** вакытлыча файдаланырга алу

поде́ржанный, -ая, -ое тотылган, киелгән, кулланылган булган; **купи́ть ~ пиджа́к** киелгән пиджак сатып алу

подержа́ть *сов. кого-что* тотып тору [бераз] тоту; ~ **ребёнка** баланы тотып тору; ~ **о́кна откры́тыми** тәрәзәләрне бераз ачык килеш тоту

подержа́ться *сов.* [күпмедер вакыт] тотынып тору, [бераз] тору

подёрну||ть *сов. что чем* каплап алу, ябу, пәрдәләү; **ре́ку ~ло льдом** *безл.* елганы боз каплап алган

подёрну||ться *сов. чем* **1.** каплану, ябылу, пәрдәләнү; **река́ ~лась льдом** елга боз белән капланган **2.** *перен.* өртелү; **взгляд ~лся печа́лью** күз карашы сагышка өртелгән

подешеве́ть *сов.* арзаная (очсызлана) төшү, арзанаю, очсызлану

поджа́ривание *с см.* **поджа́ривать**

поджа́ривать *несов. см.* **поджа́рить**

поджа́риваться *несов.* **1.** *см.* **поджа́риться**; **2.** *страд. от* **поджа́ривать**

поджа́рист||ый, -ая, -ое йөзе килеп пешкән, кызарып пешкән, яхшы кыздырылган; ~**ая бу́лка** йөзе килеп пешкән булка

поджа́рить *сов. что* кыздыру, кыздыра (кызарта) төшү, куыру, йөзен китерә төшү; ~ **мя́со** итне кыздыра төшү; ~ **хлеб** ипинең йөзен китерә төшү

поджа́ри||ться *сов.* кыздырылып (куырылып) житү, куырылу; **ры́ба уже́ ~лась** балык куырылып житкән инде

поджа́рка *ж* (*кушанье*) куырдак, куырма (*юка итеп телемлән кыздырылган ит*)

поджа́рый, -ая, -ое *разг.* чандыр; эче эчкә ябышкан

поджа́ть *сов.* **1.** *что* бөкләү, аска бөкләү; ~ **под себя́ но́ги** аяк бөкләп утыру **2.** *что* кысу; ~ **гу́бы** иреннәрне кысу; ~ **хвост** 1) койрыкны кысу; 2) *перен.* койрыгын кысу, шым булу

поджелу́дочн||ый, -ая, -ое ашказаны асты ...ы, ашказаны астындагы; ~**ая железа́** ашказаны асты бизе; ~**ый сок** ашказаны асты бизе согы

подже́чь *сов. что* **1.** яндыру, кабызу, ут төртеп җибәрү, ут кабызып җибәрү; ~ **дрова́** утынга ут төртеп җибәрү **2.** ут төртү, ут салу; ~ **сара́й** сарайга ут төртү

поджива́ть *несов. см.* **поджи́ть**

поджига́тел||ь *м* ут төртүче, ут салучы ♦ ~**и войны́** сугыш уты кабызучылар (*сугыш коткысы таратучылар*)

поджига́тельница *ж* ут төртүче хатын (кыз)

поджига́тельский, -ая, -ое ут төртүче[ләр] ...ы; сугышка өндәү ...ы

поджига́ть *несов. см.* **подже́чь**

поджида́ть *несов. кого-что, разг.* көтеп (сагалап) тору; ~ **го́стя** кунак килгәнне көтеп тору

поджи́лки *только мн. разг.* тез буыны, тез асты сеңере ♦ ~ **трясу́тся** тез буыннары калтырый

поджима́ть *несов. см.* **поджа́ть**

поджи́||ть *сов. разг.* төзәлү, бетәшү; **ра́на уже́ ~ла́** яра төзәлде инде

поджо́г *м* ут төртү, ут салу

подзабо́рный, -ая, -ое *разг.* йортсызҗирсез, сукбайлыкта ...; ~ **пёс** йортсыз-җирсез ата эт

подзабыва́ть *несов. см.* **подзабы́ть**

подзабы́||ть *сов. кого-что, разг.* онытып җибәрү, истән (хәтердән) чыгу, хәтерләп бетермәү; **я мно́гое ~л** бик күбесен онытып җибәргәнмен

подзаголо́вок *м* өстәмә бүлек башы, бүлекчә исеме, китапның өстәмә исеме

подзадо́ривать *несов. см.* **подзадо́рить**

подзадо́рить *сов. кого-что, разг.* котырту, коткы салу, дәртләндерү, гайрәтләндерү

ПОД-ПОД

подзаработа́тать *сов. что, чего и без доп.* [бераз] акча эшләп алу

подзатыльник *м разг.* муен тамырына кундыру, арт чүмеченә тондыру; **дать** *кому-л.* ~ *кемнең дә булса* муен тамырына кундыру

подзащи́тная *ж* якланучы хатын (кыз)

подзащи́тный *м* якланучы, яклана торган кеше

подземе́лье *с* җир асты [куышлыгы], җир эчендәге магарә

подзе́мн||ый, -ая, -ое җир астындагы, җир астында ...; җир асты ...ы; **~ый ход** җир асты юлы; **~ое о́зеро** җир астындагы күл; **~ые рабо́ты** җир астында алып барыла торган эшләр; **~ый перехо́д** җир асты юлы (*җәяүлеләргә урам аркылы чыгу өчен*)

подзерка́льник *м* көзге асты, көзге өстәле (*зур көзге астына куела торган өстәлчек*)

подзо́л *м* (*почва*) көлсу туфрак

подзо́листый, -ая, -ое көлсу; **~ая по́чва** көлсу туфрак

подзо́льный, -ая, -ое көлсу туфраклы

подзо́р *м* **1.** (*резной карниз*) челтәр кәрниз; сырлы кәрниз; **о́кна с ~ами** челтәр кәрнизле тәрәзәләр **2.** (*кружева*) челтәр, кайма; **покрыва́ло с ~ом** челтәрле җәймә

подзо́рн||ый, -ая, -ое күзәтү ...ы, ерактан күзәтә торган; **~ая труба́** күзәтү торбасы

подзу́живать *несов. кого-что и без доп., разг.* (*подстрекать*) котырту

подзыва́ть *несов. см.* **подозва́ть**

поди́ *прост.* **1.** *повел. от* **пойти́**; **~ сюда́** бире кил; **~ прочь** кит моннан **2.** *вводн. сл.* (*вероятно, пожалуй*) бугай, әллә, күрәсең, мөгаен, булыр, ихтимал; **ты, ~, всю рабо́ту уже́ сде́лал** син, мөгаен, эшләреңне бетергәнсеңдер инде

подивя́ть *сов. кого-что, разг.* гаҗәпләндерү, тан (хәйран, гаҗәпкә) калдыру, шаккатыру, искитәрү

подивя́ться *сов. разг.* гаҗәпкә (таңга, хәйран) калу, соклану, шаккату, искитү

подира́||ть *несов.*: **моро́з по ко́же ~ет** *разг.* суык тәнне чеметтерә

подка́лывание *с см.* **подколо́ть**

подка́лывать *несов. см.* **подколо́ть**

подка́пывание *с см.* **подкопа́ть, подкопа́ться**

подка́пывать *несов. см.* **подкопа́ть**

подка́пываться *несов.* **1.** *см.* **подкопа́ться**; **2.** *страд. от* **подка́пывать**

подкарау́ливать *несов. см.* **подкарау́лить**

подкарау́лить *сов. кого-что, разг.* сагалап (көтеп) тору, сагалап торып көтеп алу

подка́рмливание *с см.* **подкорми́ть**

подка́рмливать *несов. см.* **подкорми́ть**

подка́рмливаться *несов.* **1.** *см.* **подкорми́ться; 2.** *страд. от* **подка́рмливать**

подкати́||ть *сов.* **1.** *кого-что* тәгәрәтеп китерү; **~ть бо́чку к подва́лу** мичкәне подвал янына тәгәрәтеп китерү **2.** *разг.* (*быстро подъехать*) чаптырып килеп туктау, җилдереп барып җитү, бик җәһәт килеп туктау; **к до́му ~ла маши́на** өи янына машина килеп туктады **3.** *обычно безл. разг.* (*о боли и т.п.*) (*тамакка, йөрәккә*) килеп тыгылу, килеп терәлү, төер булып утыру; **~ло к го́рлу** тамакка төер булып утырды

подкати́||ться *сов.* **1.** тәгәрәп килеп җитү, тәгәрәп кереп кит; **мяч ~лся под стол** туп өстәл астына тәгәрәп кереп китте **2.** *к кому, прост.* (*напр. с просьбой*) җаен табып мөрәҗәгать итү, юмакайланып мөрәҗәгать итү, кылын тартып карау

подка́тывать *несов. см.* **подкати́ть**

подка́тываться *несов.* **1.** *см.* **подкати́ться; 2.** *страд. от* **подка́тывать**

подкача́||ть *сов.* **1.** *что, чего* суыртып өстәү, качать итеп өстәү; **~ть воды́ в котёл** казанга бераз суыртып су өстәү **2.** *прост.* сынату, мах бирү; **он не ~л, зада́ние вы́полнил** ул сынатмады, заданиене үтәде

подка́чивание *с см.* **подкача́ть** 1

подка́чивать *несов. см.* **подкача́ть** 1

подка́чка *см.* **подкача́ть** 1

подка́шивать *несов. см.* **подкоси́ть**

подка́шиваться *несов.* **1.** *см.* **подкоси́ться; 2.** *страд. от* **подка́шивать**

подка́шливание *с см.* **подка́шливать**

подка́шливать *несов. разг.* тамак кырып тору, тамак кыргалау

подкидно́й, -а́я, -о́е: **~ дура́к** подкидной уены (*кәрт уенының бер төре*)

подки́дывание *с см.* **подки́нуть**

подки́дывать *несов. см.* **подки́нуть**

подки́дыш *м* ташландык бала

подки́нуть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* (*вверх*) чөеп җибәрү, югары чөю (ыргыту) **2.** *что, чего* өстәп салу, өсти төшү, өстәү; **~ дров в печь** мичкә утын өстәү **3.** *кого-что, чего, разг.* җибәрү, өстәмә рәвештә җибәрү; **~ резе́рвы на фронт** фронтка өстәмә рәвештә резервлар җибәрү **4.** *кого-что* ташлау, ташлап китү, [яшертен рәвештә] калдырып китү; **~ письмо́** яшертен рәвештә хат калдырып китү

подкла́дка *ж* астар, эчлек, инеч; **шёлковая ~** ефәк эчлек

подкладн||о́й, -а́я, -о́е аска салына торган, аска куела торган; **~о́е су́дно** (*для больных*) аска куела торган судно (*мәрәт савыты*)

подкла́дочный, -ая, -ое эчлек ..., астарлык ..., инечлек ..., астарга (эчлеккә) куя торган; **~ материа́л** эчлек материал

подкла́дывание *с см.* **подложи́ть**

подкла́дывать *несов. см.* **подложи́ть**

подкла́сс *м биол.* кече класс

подкле́ивать *несов. см.* **подкле́ить**

подкле́ить *сов. что* **1.** астына ябыштыру; эчтән ябыштыру; ябыштырып кую, ябыштыру; **~ подо́шву** олтанны ябыштырып кую **2.** ябыштырып төзәтеп кую, ябыштырып рәтләп кую, ябыштырып кую; **~ разо́рванную страни́цу** ертылган битен ябыштырып кую

подкле́йка *ж* **1.** *см.* **подкле́ить**; **2.** астар, эчлек, [эчтән] ябыштырылган әйбер; **бума́жная ~ переплёта** китап тышлыгына ябыштырылган кәгазь

подкле́ть *ж* аскы өй, түбән өй (*агач йортның аскы каты*)

подключа́ть *несов. см.* **подключи́ть**

подключа́ться *несов.* **1.** *см.* **подключи́ться**; **2.** *страд. от* **подключа́ть**

подключе́ние *с см.* **подключи́ть**

подключи́||ть *сов.* **1.** *что* тоташтыру, тоташтырып кую; **~ть телефо́н** телефонны тоташтыру **2.** *кого-что* кушу, китереп кушу; **к рабо́те ~ли о́пытных мастеро́в** эшкә тәжрибәле мастерларны куштылар

подключи́ться *сов.* **1.** тоташу; **~ к телефо́нной се́ти** телефон челтәренә тоташу **2.** *разг.* (*стать участником*) кушылу, кушылып китү

подключи́чн||ый, -ая, -ое *анат.* умрау асты ...ы, умрау сөяге астындагы; **~ая арте́рия** умрау сөяге астындагы артерия

подкова́ *ж* дага

подкова́ть *сов. кого-что* **1.** дагалау; **~ ло́шадь** ат дагалау **2.** *перен. разг.* хәзерләү, белем белән коралландыру, өйрәтү

подкова́ться *сов. прост.* белем белән кораллану, хәзерлек алу, өйрәнү

подко́вн||ый, -ая, -ое дага ...ы, дагалык ..., дага ясауга китә торган; **~ые гво́зди** дага кадаклары; **~ое желе́зо** дага ясауга китә торган тимер

подковообра́зный, -ая, -ое дагасыман, дага рәвешендәге (формасындагы); **~ магни́т** дагасыман магнит

подко́вывать *несов. см.* **подкова́ть**

подко́вываться *несов.* **1.** *см.* **подкова́ться; 2.** *страд. от* **подко́вывать**

подковы́ривать *несов. см.* **подковырну́ть**

подковы́рк||а *ж разг.*: **сло́ва не ска́жет без ~и** төрттермичә бер генә сүз дә әйтмәс

подковырну́ть *сов.* **1.** *что* казгычлап куптару; **~ боля́чку** кутырны казгычлап куптару **2.** *перен. кого-что, разг.* төрттереп әйтү, чәнчүле сүз әйтү, сүз белән чагу

подко́жн||ый, -ая, -ое тире асты ...ы, тире астындагы, тире астына ...; **~ый жирово́й слой** тире астындагы май катламы; **~ое впры́скивание** тире астына дару жибәрү

подколе́нн||ый, -ая, -ое *анат.* тез астындагы, тез асты ...ы; **~ые мы́шцы** тез асты мускуллары

подколо́дн||ый, -ая, -ое: **змея́ ~ая** *разг.* юха елан, зәһәрле елан (*мәкерле кеше турында*)

подколо́ть *сов.* **1.** *что* кадап (чәнчеп) кую; теркәп кую; **~ подо́л** итәкне [кайтарып] кадап кую; **~ спра́вку к заявле́нию** справканы гаризага теркәп кую **2.** *перен. кого-что, разг.* төрттереп әйтү, [сүз белән] тешләү, чәнчү, чәнчеп кую

подкоми́ссия *ж* подкомиссия, ярдәмче комиссия

подконтро́льн||ый, -ая, -ое контроль астындагы, контроль астына алынган, контрольлегендәге; **~ые министе́рству**

о́рганы министрлык контрольлегендәге органнар

подко́п *м* **1.** *см.* **подкопа́ть, подкопа́ться; 2.** (*казып ясалган*) җир асты юлы; **~ под крепостно́й стено́й** крепость стенасы астыннан үтә торган җир асты юлы **3.** *перен. разг.* хәйлә, чокыр казу, баз казу, тозак

подкопа́ть *сов. что* **1.** (*раскопать*) астан казу, җир астыннан юл яру **2.** *разг.* (*вырыть часть клубней от куста картофеля*) казып (ачтарып) алу

подкопа́||ться *сов.* **1.** *подо что* казып астына керү, казып керү; **крот ~лся под де́рево** сукыр тычкан агач астына казып кергән **2.** *перен. под кого-что, разг.* казыну, чокыну, гаеп эзләү, батырырга тырышу

подко́рм *м* **1.** *см.* **подкорми́ть; 2.** өстәмә азык; **жи́дкий ~** сыек өстәмә азык

подкорми́ть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* [өстәмә] ашату, [өстәмә] тукландыру; **~ больно́го ребёнка** авыру баланы өстәмә ашату **2.** *что, с.-х.* өстәмә тукландару, өстәмә рәвештә ашлама кертү; **~ озимые** уҗымнарны өстәмә тукландыру

подкорми́ться *сов. разг.* [яхшы ашап] тазарып (көрәеп, ныгып) китү

подко́рмка *ж* **1.** *см.* **подкорми́ть** 2; **2.** *см.* **подко́рм** 2

подкороти́ть *сов. что, разг.* [бераз] кыскарта төшү, кыскарту; **~ пла́тье** күлмәкне кыскарта төшү

подко́с *м* **1.** *см.* **подкоси́ть** 1; **2.** *тех.* терәү, авыш тәрәк, таяу

подкоси́||ть *сов.* **1.** *что* [чалгы белән] чабу, чабып ташлау; **~ крапи́ву у забо́ра** койма буендагы кычытканны чабып ташлау **2.** *перен. кого-что* егу, аяктан егу, аудару; **пу́ля его́ ~ла** пуля аны аяктан екты **3.** *перен. кого-что* хәлдән тайдыру, йончыту; **го́ре его́ ~ло** аны хәсрәт йончыткан

подкоси́||ться *сов.* тез буыннары йомшарып китү; **но́ги у него́ ~лись от стра́ха** куркудан аның тез буыннары йомшарып китте

подкра́дываться *несов. см.* **подкра́сться**

подкра́сить *сов. что* [бераз] буяп алу, [бераз] буяп җибәрү, җиңелчә генә буяу; **~ гу́бы** иренне бераз буяп җибәрү

подкра́ситься *сов. разг.* [бераз] буяну, [бераз] бизәнү, җиңелчә генә бизәнү, бизәнү-ясану

подкра́||сться *сов.* **1.** сиздермичә килү (бару), посып килү (бару), кача-поса килү (бару); **~сться к окну́** кача-поса тәрәзә янына килү **2.** *перен.* көтмәгәндә килү, капылдан килү; **смерть ~лась внеза́пно** үлем көтмәгәндә килде

подкра́шивать *несов. см.* **подкра́сить**

подкра́шиваться *несов.* **1.** *см.* **подкра́ситься; 2.** *страд. от* **подкра́шивать**

подкрепи́||ть *сов.* **1.** *что* ныгыту, ныгытып кую, ныгыта төшү; **~ть забо́р подпо́ркой** койманы терәү куеп ныгыта төшү **2.** *кого-что* хәл кертү, хәлләндерү; **сон ~л его́** йокы аңа хәл кертте **3.** *перен. что* ныгыту, нигезләү, дәлилләү; **~ть своё мне́ние ве́скими до́водами** үз фикереңне төпле дәлилләр белән ныгыту

подкрепи́ться *сов.* тамак ныгытып (ялгап) алу, бераз ашап алу; **~ пе́ред доро́гой** юлга чыгар алдыннан тамак ялгап алу

подкрепле́ние *с см.* **подкрепи́ть, подкрепи́ться; 2.** (*о людских резервах*) өстәмә көч, ярдәм

подкрепля́ть *несов. см.* **подкрепи́ть**

подкрепля́ться *несов.* **1.** *см.* **подкрепи́ться; 2.** *страд. от* **подкрепля́ть**

подкрути́ть *сов. что* бора төшү, ныграк бору; бәтерә (чираклandыра) төшү, ныграк бәтерү; **~ га́йку** гайканы бора төшү

подкру́чивать *несов. см.* **подкрути́ть**

подкру́чиваться *несов.* **1.** *см.* **подкрути́ться; 2.** *страд. от* **подкру́чивать**

подкузьми́ть *сов. кого-что, прост.* алдау, кыен хәлдә калдыру

подкула́чник *м ист.* кулак иярчене кулак җырын җырлаучы кулак куштаны

по́дкуп *м см.* **подкупи́ть** I

подкупа́ть *несов. см.* **подкупи́ть**

подкупи́||ть *сов.* **1.** *кого-что* сатып алу, үз ягыңа аудару (*акча яки булэк биреп, сыйлап*); **~ть свиде́телей** шаһитләрне сатып алу **2.** *перен. кого-что* үзенә карату, үз ягына аудару, җәлеп итү; **он ~л всех своей доброто́й** киң күңелле булуы белән ул барысын да үзенә каратты **3.** *что, чего* тагын бераз сатып алу, өстәмә рәвештә сатып алу; **~ть са́хару** бераз шикәр сатып алу

подкупно́й, -а́я, -о́е сатлык, акчага сатылучан, сатыла торган; **~ свиде́тель** сатлык шаһит

подку́ривать *несов. см.* **подкури́ть**

подкури́ть *сов. кого-что* [бераз] тәтен җибәрү, [бераз] тәтәслә; **~ пчёл** бал кортларын бераз тәтәслә

подла́дить *сов. что, разг.* **1.** (*настроить голос или музыкальный инструмент*) көйләү, ...га туры китереп көйләү; **~ скри́пку под роя́ль** скрипканы рояль тавышына көйләү **2.** (*приспособить*) яраклаштыру, җайлаштыру, ипләү

подла́диться *сов. к кому-чему, разг.* **1.** җайлашу, яраклашу, ияләшү, күнегү, ипләшү, көйләнү; **~ к рабо́те напа́рника** кулдашының эшенә җайлашу **2.** *перен.* [берәр кешегә] ялагайланып ярау, куштанланып үз ягына аудару

подла́живать *несов. см.* **подла́дить**

подла́живаться *несов.* **1.** *см.* **подла́диться; 2.** *страд. от* **подла́живать**

подла́мывать *несов. см.* **подломи́ть**

подла́мываться *несов.* **1.** *см.* **подломи́ться**; **2.** *страд. от* **подла́мывать**

подлата́ть *сов. что, разг.* ямау салып кую, ямап кую, ямау салу

по́дле *предлог с род.п.* янында, якынында, тирәсендә; **усади́ть ~ себя́** үз янына утырту

подлёдн||ый, -ая, -ое боз асты ...ы, боз астындагы; боз астында башкарыла торган; **~ая вода́** боз астындагы су; **~ый лов ры́бы** боз астыннан балык тоту

подлеж||а́ть *несов. чему, офиц.* тиеш булу; **э́тот докуме́нт не ~и́т оглаше́нию** бу документ игълан ителергә тиеш түгел ◆ **не ~и́т сомне́нию** шикләнергә урын юк

подлежа́щее *с грам.* ия

подлеза́ть *несов. см.* **подле́зть**

подле́зть *сов.* үрмәләп (шуышып) керү, астына керү; **~ под стол** өстәл астына үрмәләп керү

подле́сок *м*, **подле́сье** *с* куаклык, вак агачлар (*урман-әчендәге*)

подлета́ть *несов. см.* **подлете́ть**

подлете́||ть *сов.* **1.** очып килү; **пти́ца ~ла к гнезду́** кош оясы янына очып килде **2.** (*вверх*) сикерү, сикереп менү, күтәрелү **3.** *перен. разг.* (*подбежать, быстро подойти*) җан-фәрманга йөгереп килеп җитү, атылып килеп җитү

подле́ц *м* адәм актыгы, хәсис

подле́чивать *несов. см.* **подлечи́ть**

подле́чиваться *несов.* **1.** *см.* **подлечи́ться; 2.** *страд. от* **подле́чивать**

подлечи́ть *сов. кого-что, разг.* [бераз] дәвалап алу, дәвалаштыру; **~ ста́рую ра́ну** электән калган яраны бераз дәвалап алу

подлечи́ться *сов. разг.* [бераз] дәвалану, [бераз] дәваланып алу; **~ на куро́рте** курортта бераз дәвалану

подле́щик *м* вак корбан балыгы

подли́ва *ж см.* **подли́вка**

подлива́ть *несов. см.* **подли́ть**

подли́вка *ж кул.* аш тәмләткеч, соус

подли́за *м, ж разг.* ялагай, тәлинкә тотучы, куштан, юха

подлиза́ть *сов. что* ялап кую, ялап чистартып кую

подлиза́ться *сов. к кому, разг.* ялагайлану, тәлинкә тоту, куштанлану, юхалану

подли́зывать *несов. см.* **подлиза́ть**

подли́зываться *несов.* **1.** *см.* **подлиза́ться; 2.** *страд. от* **подли́зывать**

по́длинник *м* төп нөсхә, оригинал

по́длинность *ж* дөреслек, чынлык, дөрес (чын) булу, төп нөсхә булу; **установи́ть ~ докуме́нта** документның төп нөсхә икәнлеген ачыклау

по́длинн||ый, -ая, -ое **1.** чын, асыл, үз кулы белән язылган, үз кулы куелган; **~ое письмо́ Пу́шкина** Пушкинның үз кулы белән язылган хаты **2.** чып-чын, чын мәгънәсендә; **он ~ый поэ́т** ул чын мәгънәсендә шагыйрь

подли́ть *сов. чего* өстәп салу (кою); **~ молока́ в ко́фе** кофега сөт өстәп салу ◆ **~ ма́сла в ого́нь** утка керосин сибү (*дошманлык мөнәсәбәтләрен тагын да кискенләштерү*)

по́дличать *несов. разг.* әшәкеләнү, кабахәтләнү, әшәкелек (кабахәтлек) эшләү

подлови́ть *сов. кого-что, разг.* тоту; **~ такси́ на шоссе́** шоссе юлда такси тоту; **~ *кого-л.* на сло́ве** *кемне дә булса* сүзендә тоту

подло́г *м* алдау, алдап ясау, ялган ... ясау; **~ докуме́нтов** ялган документ ясау

ПОД-ПОД

подложи́ть *сов.* **1.** *что* [астына] салу, [астына] кую; ~ **поду́шку под го́лову** баш астына мендәр салу **2.** *что, чего* өстәү, өстәп салу; ~ **дров в печь** мичкә утын өстәү **3.** *что* яшертен кую, астыртын рәвештә кую, сиздермичә кую; ~ **анони́мное письмо́** сиздермичә генә имзасыз хат кую ♦ ~ **свинью́** *кому* ≈ этлек эшләү

подло́жный, -ая, -ое ялган, охшатып ясалган; ~ **докуме́нт** ялган документ

подлоко́тник *м* култыкса, таянса (*кәнәфидә h.б.ш.*)

подломи́ть *сов. что* астан сындыру, астан сындырып алу; ~ **сук** ботакны астан сындырып алу

подломи́||ться *сов.* ватылу, ярылу, чатнау, сыну, астан сыну; **лёд ~лся под нога́ми** басып торган җирдә боз ватылды ♦ **но́ги ~лись** тез буыннары йомшады

по́длость *ж* кабахәтлек, әшәкелек, этлек; **сде́лать ~** этлек эшләү

подлу́нный, -ая, -ое *уст.*: ~ **мир** дөнья, җир йөзе

по́длый, -ая, -ое әшәке, кабахәт; ~ **посту́пок** кабахәт эш

подлю́га *м, ж прост. см.* **подле́ц**

подма́зать *сов.* **1.** *что* (*слегка смазать*) [астына] сөртү, [бераз] майлау, сылау, [бераз] сылап кую **2.** *перен. кого-что, прост.* майлау, ришвәт бирү

подма́заться *сов.* **1.** *разг.* (*подкрасить губы, лицо*) буяну, бизәнү, ясану, ягыну **2.** *к кому, прост.* ялагайлану, кыштанлану

подма́зка *ж см.* **подма́зать**

подма́зывать *несов. см.* **подма́зать**

подма́зываться *несов.* **1.** *см.* **подма́заться 2.** *страд. от* **подма́зывать**

подмалева́ть *сов. кого-что, разг.* [бераз] буяп алу [бераз] буяп җибәрү, җиңелчә генә буяп кую

подмалёвывать *несов. см.* **подмалева́ть**

подманда́тн||ый, -ая, -ое мандат нигезендә идарә ителә торган; ~**ая террито́рия** *уст.* мандат нигезендә идарә ителә торган территория

подма́нивать *несов. см.* **подмани́ть**

подмани́ть *сов. кого-что, разг.* кызыктырып чакыру (чакырып китерү), ым кагып чакыру; ~ **котёнка** мәче баласын кызыктырып чакырып китерү

подмаре́нник *м бот.* йогырт

подма́сливать *несов. см.* **подма́слить**

подма́слить *сов.* **1.** *что* май өстәү, [бераз] май салу; ~ **ка́шу** боткага май өстәү **2.** *перен. кого-что, прост. см.* **подма́зать** 2

подмасте́рье *м* мастер ярдәмчесе, өйрәнчек

подма́хивать *несов. см.* **подмахну́ть**

подмахну́ть *сов. что, разг.* укып тормастан кул кую, җиңел кулдан кул кую, ашыгычлык белән кул кую; ~ **заявле́ние** гаризага җиңел кулдан кул кую

подма́чивать *несов. см.* **подмочи́ть**

подме́н *м,* **подме́на** *ж см.* **подмени́ть**

подме́нивать *несов. см.* **подмени́ть**

подмени́ть *сов.* **1.** *кого-что* алыштыру, сиздерми алыштырып кую; ~ **ка́рту** сиздерми генә кәртне алыштырып кую **2.** *что* алмаштыру; ~ **настоя́щую рабо́ту суето́й** чын эшне ыгы-зыгы белән алмаштыру **3.** *кого-что* алыштырып тору (*вакытлыча*); ~ **дежу́рного** дежурныйны алыштырып тору

подменя́ть *несов. см.* **подмени́ть**

подмерза́ть *несов. см.* **подмёрзнуть**

подмёрз||нуть *сов.* **1.** чирату, чиратып җиберү, бераз туңу; **на у́лице ~ло** *безл.* урамда чиратып җибәргән **2.** [бераз] өшү, туңудан бозыла башлау, өшеп бозыла башлау; **овощи ~ли** яшелчәләр өшеп бозыла башлаган

подмести́ *сов. что, чего* [бераз] өстәп басу, [бераз] кушып басу; ~ **муки́ в те́сто** камырга бераз он кушып басу

подмести́ *сов. что* **1.** себерү, себереп чыгару; ~ **ко́мнату** бүлмәне себереп чыгару **2.** [астына] себереп кертү; ~ **му́сор под крыльцо́** болдыр астына чүпне себереп кертү

подмета́ть I *сов. что* типчү, күкләү, типчеп (күкләп) чыгу; ~ **подкла́дку** астарны типчеп чыгу

подмета́ть II *несов. см.* **подмести́**

подме́тить *сов. кого-что* табу, күрү, күреп алу; ~ **недоста́тки** җитешсезлекләрне күреп алу

подмётк||а *ж* олтан, подметка ♦ **он ему́ в ~и не годи́тся** ул аның олтырагына да тормый

подмётн||ый, -ая, -ое *уст.* яшерен (белдермичә) ташлап кителгән; ~**ое письмо́** яшерен ташлап кителгән хат

подмётывать *несов. см.* **подмета́ть** I

подмеча́ть *несов. см.* **подме́тить**

подмеша́ть *сов. что, чего* [бераз] өстән болгату, [бераз] катнаштырып бутау, кушып болгату; ~ **песку́ в цеме́нт** цементка ком кушып болгату

подме́шивать I *несов. см.* **подмеси́ть**

подме́шивать II *несов. см.* **подмеша́ть**

подми́гивание *с см.* **подми́гивать**

подми́гивать *несов. см.* **подмигну́ть**

подмигну́ть *сов. однокр. кому* күз кысып алу (кую); каш сикертеп алу

подмина́ть *несов. см.* **подмя́ть**

подмо́г||а *ж разг.* ярдәм, булышлык; **идти́ на ~у** ярдәмгә килү

подмока́ть *несов. см.* **подмо́кнуть**

подмо́кнуть *сов.* астан дым тартып юешләну, асты чылану (сулану), асты чыланып бозылу; [бераз] юешләну, [бераз] дымлану, юешләнә төшү

подмора́живать *несов. см.* **подморо́зить**

подморо́зи||ть *сов.* **1.** *что* [бераз] өшетеп алу, өшетү, [бераз] туңдырып алу; ~ **ть мя́со** итне бераз туңдырып алу **2.** *безл.* суытып (салкынайтып) җибәрү, суыта төшү; **к ве́черу ~ло** кичко таба салкынайтып җибәрде

подмо́стки *только мн.* **1.** басма, басмача **2.** сәхнә; **театра́льные ~** театр сәхнәсе

подмо́ченн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **подмочи́ть; 2.** *разг.* тапланган, яман аты чыккан, абруе төшкән; ~**ая репута́ция** тапланган репутация

подмочи́ть *сов. кого-что* [астан] юешләү, дымландыру, [астын] чылату; юешләп бозу, юешләп эштән чыгару; ~ **таба́к** тәмәкене дымландыру

подмыва́||ть *несов.* **1.** *см.* **подмы́ть; 2.** *безл. кого-что* кызыктыру, ...сы килү (килеп тору); ...сыны китерү; **так и ~ет сказа́ть** әйтеп җибәрәсе килеп кенә тора

подмыва́ться *несов.* **1.** *см.* **подмы́ться; 2.** *страд. от* **подмыва́ть** I

подмы́||ть *сов.* **1.** *кого-что* юып алу, [тиешле урыннарын] юу; ~**ть ребёнка** баланың тиешле урыннарын юып алу **2.** *что. разг.* бераз юып алу, югалау, югалаштыру, аннан-моннан гына юып алу; ~**ть пол** идәнне аннан-моннан гына юып алу **3.** *что* ашау, астан ашау; **волно́й ~ло скалу́** *безл.* кыяны астан дулкын ашаган

подмы́ться *сов.* юынып алу

подмы́шечн||ый, -ая, -ое култык асты ...ы, култык астындагы; ~**ая впа́дина** култык асты чокыры

подмы́шки *мн.* култык асты

подмы́шник *м* кештәк, култык асты кештәге

подмя́ть *сов. кого-что* өстенә егылып изү, аска салып изү, [басып] сыту, [басып] изү, яньчү

поднадзо́рный, -ая, -ое күзәтү астындагы, күзәтүдәге

поднажа́ть *сов.* **1.** *на кого-что, разг.* ныграк этү, этә төшү; ~ **на дверь** ишекне ныграк этү **2.** *перен. на кого-что и без доп.* кыса төшү, кысрыклый төшү, басым ясау; ~ **на ле́нтяев** ялкауларны кыса төшү **3.** *перен. на что и без доп.* (*приналечь*) тырышарак төшү, күбрәк тырышлык кую, күбрәк көч кую

поднака́пливать *несов. см.* **поднакопи́ть**

поднакопи́ть *сов. что, чего, прост.* [бераз] җыю, [бераз] туплау, [бераз] запаска җыю; ~ **деньжа́т** бераз акча җыю

поднаторе́ть *сов. в чём, прост.* [бераз] күнегеп (остарып) китү, шомара (өйрәнә) төшү; ~ **в столя́рном де́ле** столярлык эшендә остарып китү

поднату́живаться *несов. см.* **поднату́житься**

поднату́житься *сов. разг.* [бераз] көчәнә төшү, [тагын да] киерелә төшү

подна́чивать *несов. см.* **подна́чить**

подна́чить *сов. кого-что, прост.* котырту, коткы салу

поднебе́сн||ый, -ая, -ое **1.** күктәге, күк ...ы, бик биектәге, иксез-чиксез; ~**ая высота́** иксез-чиксез биеклек **2.** *в знач. сущ.* ~**ая** *ж уст.* дөнья, жиһан, җир йөзе

поднебе́сье *с* күк йөзе, һава; югарылык, биеклек

поднево́льный, -ая, -ое **1.** (*зависимый*) буйсынган, буйсынып яшәүче, иректсез, кул астындагы, бәйле **2.** (*принудительный*) иректсезләп тагылган, көчләп тагылган, мәҗбүри

поднесе́ние *с см.* **поднести́** 3

поднести́ *сов.* **1.** *кого-что* якынрак китерү, якынрак алып килү (*күтәреп, кулга тотып*); **~ кни́гу к глаза́м** китапны күзгә якынрак китерү; **~ ребёнка к окну́** баланы тәрәзәгә якынрак алып килү **2.** *что* [күтәреп] китерү, [күтәреп] илтү, ташу; **~ патро́ны в око́пы** окопларга патрон илтү **3.** *что. чего* бирү, бүләк итеп бирү, сыйлап бирү; **~ буке́т цвето́в** чәчәк букеты бүләк итү

поднима́ть *несов. см.* **подня́ть**

поднима́ться *несов.* **1.** *см.* **подня́ться; 2.** *страд. от* **поднима́ть**

подновля́ть *несов. см.* **подновя́ть**

подновя́ть *сов. что* яңарта төшү, яңа төскә кертү, төзәтү, яңарту; **~ кра́ски на карти́не** картинаның буяуларын яңарта төшү

подноготн||ая *ж разг.*: **узна́ть всю ~ую** бөтен яшерен серләрен белү

подно́жи||е *с* **1.** итәк; **~е горы́** тау итәге, тау асты **2.** төп, нигез; **положи́ть цветы́ к ~ю па́мятника** һәйкәл төбенә чәчәкләр кую

подно́жк||а *ж* **1.** баскыч, басма, асылма баскыч; **~а трамва́я** трамвай баскычы **2.** *разг.* аяк чалу; **дать ~у** *кому-л. кемгә дә булса* аяк чалу

подно́жный, -ая, -ое: **~ корм** аяк астындагы азык

подно́с *м* поднос

подноси́ть *несов. см.* **поднести́**

подно́счик *м* ташучы, китереп торучы; **~ патро́нов** патрон ташучы

подноше́ние *с* (*подарок*) бүләк, бүләк итеп бирелгән әйбер

подныривать *несов. см.* **подныря́ть**

подныря́ть *сов.* [астына] чумып керү, чуму; **~ под ло́дку** көймә астына чумып керү

подня́тие *с см.* **подня́ть, подня́ться; ~ тя́жестей** авыр әйберләр күтәрү

подня́ть *сов.* **1.** *кого-что* күтәрү, күтәреп алу; иелеп алу; **~ мешо́к** капчыкны күтәреп алу; **~ двухпудо́вую ги́рю** ике потлы герне күтәрү; **мне тебя́ не ~** мин сине күтәрә алмам **2.** *кого-что* менгерү, күтәрү; **~ ве́щи на тре́тий эта́ж** әйберләрне өченче катка менгерү; **~ флаг** флаг күтәрү; **~ я́корь** якорьны күтәрү **3.** *кого-что* күтәреп торгызу, аягына бастыру, торгызу; **~ упа́вшего** егылган кешене күтәреп торгызу; **~ повали́вшийся забо́р** ауган койманы торгызу **4.** *кого-что, разг.* (*вылечить*) аякка бастыру, терелтү; **~ больно́го** авыруны аякка бастыру **5.** *перен. кого-что* кузгату, күтәрү; **~ полк в ата́ку** полкны атакага күтәрү **6.** *что* биегәйтү, күтәрү; **~ у́ровень воды́** сунын биеклеген күтәрү **7.** *кого-что* (*разбудить*) уяту, торгызу; **поднима́ть меня́ в семь часо́в утра́** миңе иртәнге җидедә уят **8.** *перен. кого-что* күтәрү; **~ ма́ссы на досро́чное выполне́ние пла́на** планны срогыннан алда үтәү өчен көрәшкә массаларны күтәрү **9.** *перен. что* арттыру, күтәрү; **~ це́ны** бәяләрне арттыру; **~ производи́тельность труда́** хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү **10.** *перен. что* яхшырту; әйбәтләндерү, күтәрү; **~ настрое́ние** кәефне яхшырту; **~ дух** рухны күтәрү **11.** *что* үстерү, күтәрү, яхшырту; **~ хозя́йство** хуҗалыкны үстерү; **~ дела́ в колхо́зе** колхозда эшләрне яхшырту **12.** *что, с.-х.* күтәрү, сөрү; **~ пар** пар күтәрү; **~ целину́** чирәм күтәрү **13.** *кого-что, разг.* (*вырастить, воспитать*) тәрбияләп үстерү, аякка бастыру ♦ **~ восста́ние** восстание күтәрү; **~ глаза́** күтәрелеп карау; **~ го́лову** башны күтәрү (югары тоту); **~ го́лос** өзеп әйтү, кистереп әйтү (*уз фикереңне*); **~ го́лос в защи́ту** *кого кемне дә булса* яклап чыгу; **~ де́ло** *против кого берәр кешегә каршы* эш кузгату; **~ на [до́лжную] высоту́** тиешле югарылыкка күтәрү; **~ на́смех** *кого* көлкегә калдыру, мәсхәрәләү; **~ на щит** *кого* артык мактау, күкләргә күтәреп мактау; **~ ору́жие** корал күтәрү, корал тотып каршы чыгу

подня́||ться *сов.* **1.** (*переместиться вверх, взойти*) күтәрелү, менү; **~ться на пя́тый эта́ж** бишенче катка менү; **~ться на́ гору** тауга менү **2.** күтәрелү, калку, чыгу; **луна́ ~ла́сь** ай калыкты **3.** тору, аякка басу, торып китү (басу); **~ться со сту́ла** урындыктан торып китү; **~ться по́сле боле́зни** авырудан соң аякка басу **4.** кузгалу, кузгалып китү, күтәрелү; **~ться в ата́ку** атакага күтәрелү **5.** *перен.* күтәрелү; **~ться на борьбу́** көрәшкә күтәрелү **6.** арту, күтәрелү; **вода́ ~ла́сь** су арткан; **баро́метр ~лся** барометр күтәрелгән **7.** *перен.* арту, күтәрелү, үсү; **значи́тельно ~ла́сь производи́тельность труда́** хезмәт җитештерүчәнлеге шактый артты; **це́ны ~ли́сь** бәяләр күтәрелде **8.** *перен.* яхшыру, әйбәтләнү, күтәрелү; **настрое́ние ~ло́сь** көеф күтәрелде **9.** ныгу, ныгый төшү, әйбәтләнә төшү, күтәрелү; **хозя́йство ~ло́сь** хуҗалык ныгый төште **10.** кабару, күперү; **те́сто ~ло́сь** камыр кабарган **11.** кубу, кузгалу, күтәрелү; **~лся шум** тавыш купты; **~ла́сь бу́ря** давыл кузгалды ♦ **~ться с посте́ли** 1) йокыдан тору, урыннан тору; 2) сәламәтләнү, авырудан терелеп йөри башлау

подо́ *см.* **под**

подоба́||ть *несов. безл. кому-чему с неопр.* килешү, лаек булу, ятышлы булу, тиеш булу; **так поступа́ть не ~ет** алай кылану килешми, алай кылану тиеш түгел

подоба́ющ||ий, -ая, -ое лаеклы, тиешле, ятышлы; **заня́ть ~ее положе́ние** лаеклы урынны алу

подо́бие *с* **1.** охшашы, кәмәше, аламасы, күчермәсе **2.** *мат.* охшашлык; **~ двух треуго́льников** ике өчпочмакның охшашлыгы

подо́блачный, -ая, -ое болытлар янындагы, болыт астындагы

подо́бно *предлог с дат.п.* сыман, шикелле, кебек

подо́бн||ый, -ая, -ое **1.** *кому-чему* (*сходный, похожий*) охшашлы, ...га охшаш булган, ...га тиң булган **2.** мондый, моңа охшаган, моңа охшаш булган; **я не встреча́л ~ых стате́й** моңа охшаш булган мәкаләләрне укыганым юк **3.** *мат.* охшаш, үзара охшаш булган; **~ые треуго́льники** охшаш өчпочмаклар ♦ **ничего́ ~ого** һич, бер дә, һич тә алай түгел; **и тому́ ~ое** (*и т.п.*) һәм башка шундыйлар (*һ.б.ш.*)

подобостра́стие *с*, **подобостра́стность** *ж* ялагайлык, куштанлык, колларча баш ию

подобостра́стный, -ая, -ое ялагай, колларча буйсынулы; **~ взгляд** колларча буйсынулы күз карашы

подо́бранность *ж* купшылык, жыйнаклык, пөхтәлек, ыктыматлык

подо́бранный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **подобра́ть; 2.** купшы, җыйнак, пөхтә, ыктымат; **~ вид** ыктымат кыяфәт

подобра́ть *сов.* **1.** *что* (*поднять, собрать*) җыеп алу, җыеп кую, чүпләп алу **2.** *кого* (*взять на своё попечение*) үзеңә алу, үзең белән алу; **~ щенка́** көчекне үзеңә алу **3.** *что* төзәтеп (рәтләп, кыстырып) кую **4.** *кого-что* сайлап алу, сайлау; **~ хоро́ших рабо́тников** яхшы работниклар сайлап алу; **~ ключ** ачкыч сайлау, ачкыч ярату

подобра́||ться *сов.* **1.** туплану, оешу, төзелү, җыелу; **~лся хоро́ший коллекти́в** менә дигән коллектив тупланды **2.** (*подкрасться*) шыпырт кына килү, сиздермичә генә килү, тавыш-тынсыз гына килү

подобре́||ть *сов.* яхшылана төшү, әйбәтләнә төшү; йомшак күңеллеләнә төшү, киң күңеллеләнеп китү

подобру́-поздорову́ *нареч. разг.* яхшы чагында, берәр хәл булмас борын; **уходи́ ~** яхшы чагында кит

подо́вый, -ая, -ое **1.** мич төбе ...ы; **~ кирпи́ч** мич төбе кирпече **2.** мичкә салып пешерелгән, мич төбендә пешкән; **~ пиро́г** мич төбендә пешкән бәлеш

подогна́ть *сов.* **1.** *кого-что* куып китерү (кертү), китерү; **~ коро́в к реке́** сыерларны елга буена куып китерү **2.** *кого-что и без доп., разг.* куалау, әйдәкләү, ашыктыру, куалый (әйдәкли, ашыктыра) тору; **~ отстаю́щих** артта калучыларны ашыктыру **3.** *что* (*приладить*) җайлау, ипләү, җайлап (ипләп) кую, ярату, тигезләү, сыярлык (кереп утырырлык) хәлгә китерү; **~ стекло́ к ра́ме** пыяланы рамга җайлап кую

подогну́ть *сов. что* бөкләү, [аска] бөкләп кую, бөгү; **~ но́ги под себя́** аяк бөкләп утыру

подогну́||ться *сов.* бөкләнү, бөгелү, иелү; **поля́ шля́пы ~лись** эшләпәнең читләре бөкләнгән ♦ **но́ги (коле́ни) ~лись** буыннар йомшаган (хәлсезләнгән) (*арудан, талчыгудан*)

подогре́в *м см.* **подогре́ть, подогре́ться; бассе́йн с ~ом** җылытыла торган бассейн

подогрева́ние *с см.* **подогре́ть**

подогрева́тель *м* җылыткыч, җылыту приборы

подогрева́тельный, -ая, -ое җылыткыч ..., җылыта торган; **~ аппара́т** җылыткыч аппарат

подогрева́ть *несов. см.* **подогре́ть**

подогрева́ться *несов.* **1.** *см.* **подогре́ться; 2.** *страд. от* **подогрева́ть**

подогре́ть *сов. что* **1.** жылыту, жылыта төшү, жылытып алу, кайнарлату; **~ суп** аш жылыту **2.** *перен. разг.* ярсыту, кыздыру, теләк уяту; **~ стра́сти** дәртен кыздыру

подогре́||ться *сов.* жылыну, кайнарлану; **ча́йник ~лся** чәйнек жылынган

пододвига́ть *несов. см.* **пододви́нуть**

пододвига́ться *несов.* **1.** *см.* **пододви́нуться; 2.** *страд. от* **пододвига́ть**

пододви́нуть *сов. кого-что* якынрак китерү (күчерү), якынайта төшү; **~ стул к столу́** урындыкны өстәлгә якынрак китерү

пододви́нуться *сов.* якынрак килү (күчү), якыная төшү

пододея́льник *м* юрган аслык, пододеяльник

подожда́ть *сов.* **1.** *кого-что, чего и без доп.* көтеп тору, бераз көтү; **~ дру́га** дусны көтеп тору; **~ по́езд** поезд килгәнне көтеп тору **2.** *с неопр., с чем и без доп.* бераз кичектерү, бераз кичектереп тору, бераз сабыр итү, торып тору; **~ с отве́том** җавап бирүне бераз кичектереп тору

подозва́ть *сов. кого-что* чакырып китерү (алу)

подозрева́||ть *несов.* **1.** *кого-что в чём* шикләнү, шик тоту, шөбһәләнү; **~ть в обма́не** ялганлый дип шикләнү **2.** *что и с союзом «что»* ... дип уйлау, ... дип гөман итү; **я не ~л, что вы уже́ прие́хали** сез инде килгәнсездер дип уйламаган да идем

подозрева́||ться *несов.* шик тоту, ... дер дип шикләнү; **он ~лся в ра́зных неблагови́дных дела́х** аннан төрле ярамаган эшләр эшләгәндер дип шикләнәләр иде

подозре́ни||е *с* шик, шөбһә; **необосно́ванное ~е** нигезсез шик; **есть ~е на корь** кызамык булмагае дигән шик бар; **быть под ~ем** *или* **на ~и** шик тудыру, шик астында булу

подозри́тельность *ж* шиклелек, шикләнүчәнлек, шикләнүчән булу, шомланучан булу; **изли́шняя ~** чиктән тыш шикләнүчәнлек

подозри́тельный, -ая, -ое **1.** шикле, шик тудыра торган, шөбһәле; **~ челове́к** шикле кеше **2.** шикләнүчән, шикләнеп караучан, шик астына алучан; **~ хара́ктер** шикләнүчән характер

подои́ть *сов. кого* саву, савып алу

подо́йник *м* сөт чиләге, сөт сава торган чиләк

подойти́ *сов.* **1.** якын килү, [янына] килү, килеп җитү (туктау); **~ к до́му** йорт янына килү **2.** *перен.* барып (килеп) тоташу, барып (килеп) терәлү, терәлеп тору; **лес подошёл к са́мой доро́ге** урман юлга ук килеп тоташа **3.** керешү, тотыну, ...а башлау; **~ к изуче́нию** *чего-л. берәр нәрсәне* өйрәнергә керешү **4.** карау, якын килү; **крити́чески ~ к сужде́ниям а́втора** автор фикерләренә тәнкыйть күзлегеннән якын килү **5.** ярау, яраклы булу, туры килү, килешү; **э́то пальто́ мне подойдёт** бу пальто миңа ярар **6.** *разг.* кабару, күперү; **те́сто подошло́** камыр кабарган ♦ **~ к концу́** бетеп килү

подоко́нник *м* тәрәзә төбе (тупсасы)

подо́л *м* итәк

подо́лгу *нареч.* озаклап, бик озак; озак-озак; **он ~ жил в Москве́** ул бик озак вакытлар Мәскәүдә яшәде

подольсти́ться *сов. к кому, разг.* ялагайлык белән ярау, ялагайлык белән ышаныч казану

подо́нки *мн.* **1.** *разг.* калдык, төптә калган калдык, утырым; **~ ква́са в бо́чке** мичкә төбендә калган квас утырымы **2.** *перен.* адәм актыклары, әтрәк-әләмнәр

подопе́чн||ый, -ая, -ое **1.** опекага алынган, опекун карамагындагы; **~ый ребёнок** опекага алынган бала; **~ые террито́рии** *спец.* опекага алынган территорияләр **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* опекадагы кеше, опекага алынган кеше

подопле́ка *ж* сер, яшерен сәбәп, чын сәбәп

подопрева́ть *несов. см.* **подопре́ть**

подопре́л||ый, -ая, -ое бурсый (күкси, күгәрә, чери) башлаган; **~ое се́но** күгәрә башлаган печән

подопре́||ть *сов.* **1.** бурсый (күкси, кыза, күгәрә) башлау; астан бурсу (кызу); **се́но ~ло** печән бурсый башлаган **2.** пышлыгу; **ребёнок ~л** бала пышлыккан

подо́пытн||ый, -ая, -ое тәжрибә ...ы, тәжрибә өчен тотыла торган, тәжрибә ясала торган, тәжрибә алып барыла торган; **~ые живо́тные** тәжрибә ясала торган хайваннар

подорва́ть *сов.* **1.** *кого-что* шартлату, шартлатып җимерү, шартлатып актарып ташлау, шартлатып күтәртү; **~ мост** күперне шартлату **2.** *перен. что* какшату, зыян китерү; төшерү; **~ здоро́вье** сәламәтлекне какшату; **~ чей-л. авторите́т** *кемнең дә булса* абруен төшерү

подорва́||ться *сов.* **1.** шартлаудан җимерелү, шартлаудан һәлак булу **2.** *перен.* какшау, зыян килү; төшү; **здоро́вье его́ ~лось** сәламәтлеге какшады; **его́ авторите́т ~лся** аның абруе төште

подорожа́ть *сов.* кыйбатлана (кыйммәтләнә) төшү, кыйбатлану, кыйммәтләнү, бәясе (базары) күтәрелү

подоро́жная *ж ист.* юл кәгазе, юл таныклыгы, юл йөрү язуы (*электә юлаучыларга почта атларын файдалану хокукы бирә торган махсус таныклык*)

подоро́жник *м бот.* бака яфрагы

подоро́жный, -ая, -ое юл буе ...ы, юл буендагы; **~ столб** юл будендагы багана

подоса́довать *сов. разг.* [бераз] көенеп алу, [бераз] үкенеп алу

подосино́вик *м* усак гөмбәсе, кызыл гөмбә

подосла́ть *сов. кого-что* яшерен рәвештә җибәрү, астыртын эш белән җибәрү

подосно́в||а *ж* **1.** *текст.* аскы буй (*ике кат буйлы тукымаларда*) **2.** *перен.* (*истинная причина*) төп сәбәп, нигез

подоспе́||ть *сов. разг.* [вакытында] килеп җитү, өлгерү, җитешү; **по́мощь ~ла во́время** ярдәм вакытында килеп җитте

подостла́ть *сов. что* [астына] җәю, [астына] түшәү; **~ простыню́** простыня җәю

подоткну́ть *сов. что* кыстырып кую, кыстыру; **~ подо́л пла́тья** күлмәк итәген кыстырып кую

подотчётность *ж* отчёт бирергә тиешлек; **~ руководя́щих о́рганов** җитәкче органнарның отчёт бирергә тиешлеге

подотчётн||ый, -ая, -ое **1.** соңыннан отчёт бирү шарты белән алынган; **~ые де́ньги** соңыннан отчёт бирү шарты белән алынган акча **2.** отчёт бирергә тиешле; **~ые организа́ции** отчёт бирергә тиешле оешмалар

подо́х||нуть *сов.* **1.** үлү, кырылу, үлеп (кырылып) бетү (*хайваннар турында*); **о́вцы ~ли** сарыклар үлеп беткән **2.** *прост.* дәмегү, кату, тончыгу (*кешеләр турында*)

подохо́дный, -ая, -ое керем ...ы, табыш ...ы, төшем ...ы, керемгә (табышка) карап салынган; **~ нало́г** керемгә карап салына торган налог

подо́шва *ж* **1.** *разг.* (*ноги*) табан асты **2.** олтан, табан; **ко́жаная ~** күн табан **3.** итәк; **~ го́ры** тау итәге

подо́швенн||ый, -ая, -ое олтанлык ..., олтанга китә торган; **~ая ко́жа** олтанлык күн

подпада́ть *несов. см.* **подпа́сть**

подпа́ивать I *несов. см.* **подпая́ть**

подпа́ивать II *несов. см.* **подпои́ть**

подпа́ливать *несов. см.* **подпали́ть**

подпа́лина *ж* **1.** *разг.* өтелгән урын, янган урын, көйгән җир **2.** (*пятно на шерсти*) тимгел, тап, сары тимгел (*хайван тиресе өстендәге сары тап*)

подпали́ть *сов. что* **1.** *см.* **поджёчь** I, 2; **2.** [бераз] өтеп алу, [бераз] көйдерү; **~ усы́** мыекны бераз көйдерү

подпа́рывать *несов. см.* **подпоро́ть**

подпа́рываться *несов.* **1.** *см.* **подпоро́ться; 2.** *страд. от* **подпа́рывать**

подпа́сок *м* көтүче ярдәмчесе, көтүче малай

подпа́сть *сов. подо что* ...га бирелү, ...га буйсыну, ...га төшү, эләгү; **~ под чьё-л. влия́ние** *кемнең дә булса* тәэсиренә бирелү

подпая́ть *сов. что* паять итү, паять итеп төзәтү

подпева́ла *м, ж* **1.** кушылып җырлаучы, көйләүче **2.** *перен.* [берәүнең] җырын җырлаучы, [берәүнең] көен көйләүче; [берәүнең] кубызына бию

подпева́ть *несов. кому* **1.** кушылып җырлау [көйләү] **2.** *перен. разг. неодобр.* [берәүнең] җырын җырлау, [берәүнең] көен көйләү; [берәүнең] кубызына бию

подпере́ть *сов. что чем* терәтеп кую (терәү), терәү салу; таяну; **~ забо́р ко́льями** койманы казыклар белән терәтеп кую; **~ щёку руко́й** яңакка таяну

подпере́ться *сов. разг.* таяну, сөялү, терәлү

подпи́ливать *несов. см.* **подпили́ть**

подпили́ть *сов. что* **1.** (*пычкы белән*) астан (төбеннән) кисү, аскы яктан кисү; киселе егу **2.** (*пычкы белән*) киселе кыскарту, киселе кыскарта төшү; **~ но́жки стола́** өстәлнең аякларын киселе кыскарта төшү **3.** *разг.* игәүләү, игәүләп тигезләү; **~ но́гти** тырнакларны игәүләп тигезләү

подпи́лка *ж см.* **подпили́ть**

подпи́лок *м разг.* игәү

подпира́ть *несов. см.* **подпере́ть**

подпира́ться *несов.* **1.** *см.* **подпере́ться; 2.** *страд. от* **подпира́ть**

подписа́ние *с см.* **подписа́ть; ~ догово́ра** договорга кул кую

подписа́ть *сов.* **1.** *что* кул (имза) кую; **~ прика́з** приказга имза кую **2.** *что* язып кую; **~ а́дрес на конве́рте** конвертка адрес язып кую **3.** *кого-что на что, разг.* язу, языдыру, подписчиклар исемлегенә теркәү; **~ на газе́ту** газетага язылдыру

подписа́ться *сов.* **1.** кул (имза) кую; **~ под дове́ренностью** ышаныч языына кул кую **2.** *на что* язылу, алу; **~ на журна́л** журналга язылу

подпи́ск||а *ж* **1.** *см.* **подписа́ть, подписа́ться; ~а на газе́ты** газетларга язылу; **объяви́ть ~у** подписка игълан итү **2.** подписка, язма рәвештә алынган (бирелгән) йөкләмә; **дать ~у о невы́езде** бер җиргә дә китмәү турында подписка бирү

подписн||о́й, -а́я, -о́е **1.** язылу ...ы; **~а́я цена́** язылу бәясе **2.** подписка белән алына торган, подписка нигезендә килә торган, язылу буенча җибәрелә торган; **~о́е изда́ние** язылу буенча җибәрелә торган басма ♦ **~о́й лист** имзалар кәгазе (җыю кәгазе) (*кемгә дә булса ярдәм итү өчен акча җыйганда акча бирүчеләр кул кую өчен махсус кәгазь*)

подпи́счик *м* алдыручы, язылып алдыручы, подписчик; **постоя́нный ~ журна́ла** даими рәвештә журнал алдыручы

подпи́сывать *несов. см.* **подписа́ть**

подпи́сываться *несов.* **1.** *см.* **подписа́ться; 2.** *страд. от* **подпи́сывать**

по́дпись *ж* **1.** *см.* **подписа́ть; отда́ть бума́ги на ~** кәгазьләрне кул куярга бирү **2.** (*берәр нәрсә астына*) язылган сүз, язу; **~ под карти́ной** артина астына язылган язу **3.** имза; **поста́вить сво́ю ~** үзеннең имзанны кую

подпи́ти||е *с*: **в ~и** *разг.* кызмача хәлдә, җиңелчә исергән хәлдә

подпи́хивать *сов. см.* **подпихну́ть**

подпихну́ть *сов. разг.* **1.** *кого-что* этеп (төртеп) җибәрү; **~ в ваго́н** вагон эченә таба этеп җибәрү **2.** *что* [астына] тыгып (кыстырып) кую; **~ корзи́ну под стол** кәрҗинне өстәл астына тыгып кую

подплести́ *сов. что* (*вплести дополнительно*) кушып үрү

подплета́ть *несов. см.* **подплести́**

подплыва́ть *несов. см.* **подплы́ть**

подплы́ть *сов.* **1.** [янына] йөзеп килү (килеп җитү); **~ к бе́регу** яр кырыена йөзеп килү **2.** йөзеп [астына] керү, астына йөзеп керү; **~ под плот** йөзеп сал астына керү; **~ под мост** күпер астына йөзеп керү

подпои́ть *сов. кого-что, разг.* исерткәнче эчертү, эчертү, исертү

по́дпол *м прост. см.* **подпо́лье** 1

подполза́ть *несов. см.* **подползти́**

подползти́ *сов.* **1.** үрмәләп килү, шуышып килү, [янына] үрмәләп килү, шуышып ... килү; **~ к око́пу** шуышып окоп янына килү **2.** [астына] шуышып керү, [астына] үрмәләп керү; **~ под стол** үрмәләп өстәл астына керү

подполко́вник *м* подполковник

подпо́лье *с* **1.** идән асты, өй базы; **храни́ть о́вощи в ~** яшелчәләрне өй базында саклау **2.** подполье; **революцио́нное ~** революцион подполье; **уйти́ в ~** подпольега күчү

подпо́льн||ый, -ая, -ое **1.** (*находящийся под полом*) идән асты ...ы, идән астындагы **2.** яшерен, подпольедагы; **~ая типогра́фия** яшерен типография; **~ый кружо́к** подпольедагы түгәрәк

подпо́льщик *м* яшерен эш алып баручы, подпольеда эшләүче, подпольщик

подпо́льщица *ж* подпольщик хатын (кыз)

подпо́ра, подпо́рка *ж* терәү, терәвеч, терәк, таяу, таяныч

подпо́рн||ый, -ая, -ое терәүгә куелган, терәү итеп куелган, таяу булып хезмәт итә торган, терәп тора торган; **~ая доска́** терәүгә куелган такта

подпоро́ть *сов. что* сүтү, [җәйне] астан сүтеп чыгу, бераз сүтеп җибәрү; **~ подкла́дку** эчлекне астан сүтеп чыгу

подпоро́||ться *сов.* бераз сүтелү, астан сүтелү, астан сүтелә башлау; **подкла́дка ~лась** эчлек астан сүтелә башлаган

подпо́ртить *сов. что, разг.* бераз бозу, җиңелчә генә бозу, бераз эшәкеләү, бераз начарлау

подпо́ртиться *сов. разг.* бераз бозылу, бозыла төшү, бераз начарлану, начарлана төшү

подпору́чик *м уст. воен.* подпоручик

подпо́чва *ж* туфрак асты (*туфракның өске катлавы астындагы җир*)

подпо́чвенн||ый, -ая, -ое туфрак асты ...ы, туфрак асты катлавы ...ы, туфрак астындагы; **~ые во́ды** туфрак асты сулары; **~ый слой** туфрак астындагы катлау

подпоя́сать *сов. кого-что* биленә бәйләү, билен буу; **~ реме́нь** биленә каеш бәйләү

подпоя́саться *сов.* билне буу, билбау бәйләү, билгә бәйләү; **~ ремнём** билгә каеш буу

подпоя́сывать *несов. см.* **подпоя́сать**

подпоя́сываться *несов.* **1.** *см.* **подпоя́саться; 2.** *страд. от* **подпоя́сывать**

подпра́вить *сов. что* төзәтә төшү, төзәткәләп җибәрү (алу); **~ рису́нок** рәсемне төзәткәләп җибәрү

подправля́ть *несов. см.* **подпра́вить**

подпра́порщик *м уст. воен.* подпрапорщик

подпрева́ть *несов. см.* **подопре́ть**

подпру́г||а *ж* ызма, аел, ыңгырчак (ияр) бавы; **подтяну́ть ~у** ызманы кысыбрак бәйләү

подпры́гивание *с см.* **подпры́гнуть**

подпры́гивать *несов. см.* **подпры́гнуть**

подпры́гнуть *сов.* сикереп кую (китү), сикерү; **~ до потолка́** түшәмгә кадәр сикерү; **~ от ра́дости** куанычтан сикереп кую

подпряга́ть *несов. см.* **подпря́чь**

подпряга́ться *несов.* **1.** *см.* **подпря́чься; 2.** *страд. от* **подпряга́ть**

подпря́чь *сов. кого-что* кушып (өстәп, мичәп) җигү

подпря́чься *сов. разг.* кушылып җигелү, җигелү

по́дпуск *м* **1.** *см.* **подпусти́ть** 1-3; **2.** (*рыболовная снасть*) төплек, подпуск (*берничә кармак тагылган озын җеп*)

подпуска́ть *несов. см.* **подпусти́ть**

подпусти́||ть *сов.* **1.** *кого-что* якын (янына) җибәрү, якын килергә юл кую, җибәрү, якынрак килгәнен көтү; **охо́тник ~л медве́дя побли́же** аучы аюның якынрак килгәнен көтте **2.** *кого-что* кушу, имәргә кушу (җибәрү); **~ть телёнка к коро́ве** бозауны сыергә кушу **3.** *что, чего, разг.* бераз өсти төшү, бераз кушу, өстәп салу; **~ть бели́л в кра́ску** буяуга бераз ак буяу кушу **4.** *что, разг.* әйтеп ташлау, (*уңай моментын*) туры китереп әйтеп кую; **~ть шу́тку** мәзәк сүз әйтеп ташлау

подража́тывать *несов. см.* **подража́ть**

подража́ть *сов. разг.* **1.** *что, чего* эшләп алу, [бераз] эшләп алу, өстәмә рәвештә эшләп алу; **~ де́нег** өстәмә рәвештә акча эшләп алу **2.** *что* эшләп хәзерләп кую, хәзерләү; **~ резолю́цию** резолюцияне хәзерләп кую

подража́тка *ж см.* **подража́ть**

подра́внивать *несов. см.* **подровня́ть**

подра́вниваться *несов.* **1.** *см.* **подровня́ться; 2.** *страд. от* **подра́внивать**

подра́гивать *несов. разг.* калтырату, дерелдәтү; калтырап-калтырап китү, тетрәнеп кую, дерелдәп-дерелдәп кую

подража́ние *с* **1.** *см.* **подража́ть; ~ го́лосу птиц** кошлар тавышына охшатырга тырышу; **~ взро́слым** өлкәннәргә охшарга тырышу **2.** (*имитация*) охшатып эшләнгән әйбер, ияреп эшләнгән нәрсә

подража́тельн||ый, -ая, -ое ияреп эшләнгән, охшатырга тырышып эшләнгән; **~ая литерату́ра** ияреп язылган әдәбият

подража́ть *несов. кому-чему* иярү, охшарга тырышу, охшатып кабатлау, ... булып кылану; **~ *чьей-л.*** **похо́дке** *кемнең дә булса* йөрүенә охшатырга тырышып йөрү; **~ в игре́ изве́стному арти́сту** уенда күренекле артистка охшарга тырышу

подразде́л *м* бүлекчә, кечкенә бүлек

подразделе́н||ие *с* **1.** *см.* **подразде́лить; 2.** бүлекчә, кечкенә бүлек; **глава́ име́ет не́сколько ~ий** бүлек берничә бүлекчәдән тора **3.** *воен.* подразделение

ПОД-ПОД

подразделя́ть *сов. кого-что* бүлгәләү, бүлү; ~ **главу́ на пара́графы** бүлекне параграфларга бүлгәләү

подраздел|я́ть||ся *несов.* **1.** бүленү, бүлгәләнү; **батальо́н ~ется на ро́ты** батальон роталарга бүленә **2.** *страд. от* **подразделя́ть**

подра́знивать *несов. кого-что, разг.* үртәштергәләү, үчекләштергәләү

подразни́ть *сов. кого-что* үчекләп алу, үртәп алу, мыскыллап алу

подразумева́|ть *несов. кого-что* күз алдында тоту, күздә тоту; **что вы ~ете под э́тими слова́ми?** бу сүзләр белән сез нәрсәне күз алдында тотасыз?

подразумева́|ться *несов.* **1.** күз алдында тотылу, фараз кылыну, хисапланылу **2.** *страд. от* **подразумева́ть** ♦ **э́то само́ собо́й. ~ется** бу үзеннән-үзе аңлашыла

подра́мник, подра́мок *м спец.* картина рамы, рам (*картина төшереләчәк киндерне тарттырып кую өчен ясалган агач рам*)

подра́нить *сов. кого-что* җиңелчә яралау (*кошны яки җәнлекне*)

подра́нок *м охот.* яраланган кош (җәнлек) (*аучы атып яралаган кош яки җәнлек*)

подраста́ние *с см.* **подрасти́**

подраста́ть *несов. см.* **подрасти́**

подраста́ющ|ий, -ая, -ее үсеп килә торган, яшь; **~ее поколе́ние** үсеп килә торган буын

подрасти́ *сов.* үсә төшү, үсеп китү, үсү, исәю, исәя төшү; **де́ти подросли́** балалар исәя төшкәннәр; **трава́ подросла́** үләннәр үсеп киткән

подрасти́ть *сов. кого-что* үстерү, үстерә төшү; ~ **цветы́** чәчәкләр үстерү; ~ **цыпля́т** чебиләрне үстерә төшү

подра́ться *сов.* сугышу, сугышып китү; бераз кыйнашып алу, бераз якалашып алу

подра́щивать *несов. см.* **подрасти́ть**

подрёберн|ый, -ая, -ое кабырга астындагы, кабырга асты ...ы; **~ые мы́шцы** кабырга астындагы мускуллар

подреза́ние *с см.* **подре́зать**

подре́зать *сов.* **1.** *что* кисеп (кыркып) кыскарту, кисү, кыскарту; ~ **во́лосы** чәчне кыскарту; ~ **дере́вья в саду́** бакчадагы агачларны кыркып кыскарту **2.** *что* астан (төптән) кисү (кисеп алу); ~ **сте́бель** сабакны төптән кисеп алу **3.** *чего, разг.* өстәмә рәвештә турау, тагын бераз турау (кисү); ~ **хле́ба** тагын бераз ипи турау ♦ ~ **кры́лья** *кому* канатларын сындыру (кисү) (*берәүне көчтән, узенең эшчәнлегеннән, сәләтен киң җәеп җибәрү мөмкинлегеннән мәхрүм итү*)

подреза́ть *несов. см.* **подре́зать**

подре́зка *ж см.* **подре́зать**

подре́зывать *несов. см.* **подре́зать**

подрема́ть *сов.* [бераз] йоклап алу, черем итеп алу, [бераз] баш төртеп алу

подремонти́ровать *сов. что, разг.* [бераз] ремонтлап алу, [бераз] ремонтлау, [бераз] төзәткәләп алу

подрёмывать *несов. разг.* әледән-әле йокымсырап алу, черем иткәләп алу

подреше́тина *ж спец.* шикмә

подреше́тник *м спец.* шикмәләрдән җәелгән түшәмә, шикмәләр түшәмәсе

подрисова́ть *сов. что* **1.** төзәтә төшү, ачыкландыра төшү (*рәсемне*); ~ **портре́т** портретны ачыкландыра төшү **2.** өстәп ясау, өстәп төшерү (*рәсемгә*); ~ **усы́ на портре́те** портретка мыек өстәп ясау

подрисо́вывать *несов. см.* **подрисова́ть**

подро́бнос|ть *ж* **1.** тулылык, җентекләлек, бәйнә-бәйнәлек, тәфсиллек; **~ть описа́ния** сурәтләүнең тулылыгы **2.** вак-төяк, кечкенә деталь (нәрсә), ваклык; **рассказа́ть во всех ~тях** бөтен вагы-төяге белән сөйләп бирү; **не вдава́ться в ~ти** бөтен ваклыкларына тукталып тормаска

подро́бн|ый, -ая, -ое тулы, җентекле, тәфсилле, бәйнә-бәйнә [сөйләнгән], түкми-чәчми [сөйләнгән]; **~ое описа́ние** тәфсилле сурәтләү

подровня́ть *сов. что* тигезләү, тигезли төшү; ~ **кра́я матери́и** тукыманың читләрен тигезли төшү; ~ **во́лосы** чәчне тигезләү

подровня́ться *сов.* тигезләнү; ~ **по правофланго́вым** уң флангтагыларга карап тигезләнү

подро́сток|ый, -ая, -ое үсмерләр ...ы, яшүсмерләр ...ы; **~ая о́бувь** яшүсмерләр аяк киеме

подро́сток *м* үсмер, яшүсмер

подруба́ть I *несов. см.* **подруби́ть** I

подруба́ть II *несов. см.* **подруби́ть** II

подруби́ть I *сов.* **1.** *что* төптән кисү (киселеп чыгару); ~ **дуб** имәнне төптән кисү **2.** *что* кисеп кыскарту (кыскарта төшү); ~ **но́жки стола́** өстәлнең аякларын кисеп кыскарту **3.** *что, чего* чабу, кисү; ~ **то́нну угля́** бер тонна күмер чабу **4.** *что, чего* бераз турау, өстәмә рәвештә чабу; ~ **капу́сты** бераз кәбестә турау

подруби́ть II *сов. что* бөгеп тегү, читен бөгү, каю, каеп чыгу; ~ **носово́й плато́к** кулъяулыкның читен бөгеп тегү

подру́бка I *ж см.* **подруби́ть** I

подру́бка II *ж см.* **подруби́ть** II

подру́га *ж* иптәш кыз, дус кыз, дус хатын; иптәш, дус, ахирәт (*хатын-кызга карата әйтелә*) ♦ ~ **жи́зни** тормыш иптәше (*хатын хакында*)

подружи́ться *сов. с кем* дуслашу, дуслашып китү; татулашу

подру́жка *ж разг. ласк. от* **подру́га**

подру́ливать *несов. см.* **подрули́ть**

подрули́ть *сов.* **1.** *что и без доп.* (*самолёт, машину и т.п.*) (*рулен борып*) алып килү, китерү, якын китерү **2.** *ав.* (*подкатить — о самолёте*) килү, якын килү

подрумя́нивать *несов. см.* **подрумя́нить**

подрумя́ниваться *несов.* **1.** *см.* **подрумя́ниться; 2.** *страд. от* **подрумя́нивать**

подрумя́ни|ть||ться *сов.* **1.** *кого-что* бераз кызарту, алсуландыру; **моро́з ~л ему́ щёки** салкын аның яңакларын алсуландырган **2.** *кого-что* (*подкрасить*) [бераз] иннек ягу, [бераз] иннек сөртү **3.** *что* (*поджарить*) йөзен китерү, кызартып пешерү

подрумя́ни|ть||ться *сов.* **1.** кызару, алсулану; **щёки ~лись на моро́зе** салкында яңаклар кызарган **2.** (*подкраситься*) бераз иннек ягыну, бераз иннек сөртену **3.** (*поджариться*) йөзе килү, кызарып пешү

подру́чный, -ая, -ое **1.** кул астындагы, һәрвакыт кирәк була торган; ~ **инструме́нт** кул астындагы инструмент **2.** *в знач. сущ. м* булышчы, ярдәмче; ~ **сле́саря** слесарь ярдәмчесе

подры́в *м см.* **подорва́ть; ~ ска́лы** кыяны шартлатып актарту; ~ **авторите́та** авторитетын төшерү

подрыва́ть I *несов. см.* **подорва́ть**

подрыва́ть II *несов. см.* **подры́ть**

подрыва́ться I *несов.* **1.** *см.* **подорва́ться; 2.** *страд. от* **подрыва́ть** I

подрыва́ться II *несов.* **1.** *см.* **подры́ться; 2.** *страд. от* **подрыва́ть** II

подрывни́к *м* шартлатучы, шартлату эшләре белгече

подрывн|о́й, -а́я, -о́е **1.** шартлату ...ы, шартлаткыч; **~ы́е рабо́ты** шартлату эшләре **2.** *перен.* җимерү ...ы, какшату ...ы, өзеклек кертү ...ы, корткычлык ...ы; **~а́я де́ятельность** җимерү эшчәнлеге

подры́ть *сов. что, чего* төптән (төбен, астын) казу; тирәнрәк итеп казу; [бераз] казу; ~ **де́рево** агач төбен казу; ~ **кана́ву** канауны тирәнрәк итеп казу; ~ **земли́** бераз җир казу

подры́|ться *сов.* [астына] казып керү; **крот ~лся под ка́мень** сукыр тычкан таш астына казып кергән

подрыхли́ть *сов. что, разг.* казып йомшарта (көпшәкләндерә) төшү; ~ **зе́млю** җирне казып көпшәкләндерә төшү

подрыхля́ть *несов. см.* **подрыхли́ть**

подря́д I *м* подряд (**1.** *тиешле хак өчен билгеле бер эшне башкарып чыгарга алынган йөкләмә, килешү* **2.** *шундый килешү нигезендә алынган эш*)

подря́д II *нареч.* бер-бер артлы, рәттән, бер буйдан, тоташтан; **я прочёл ~ сто страни́ц** рәттән йөз бит укыдым

подряди́ть *сов. кого-что, разг.* яллау; ~ **во́зчиков** олаучылар яллау

подряди́ться *сов. с неопр., разг.* ялланып, килешеп эш алу, берәр эшкә алыну; ~ **вози́ть дрова́** утын ташырга яллану

подря́дн|ый, -ая, -ое подряд белән алынган, подрядка алынган, подряд тәртибендә ...ган, килешеп алынган; **~ые рабо́ты** подряд тәртибендә башкарыла торган эшләр

подря́дчик *м* подрядчы, подрядчик (*килешү нигезендә берәр эш алып баручы оешма яки аерым кеше*)

подряжа́ть *несов. см.* **подряди́ть**

подряжа́ться *несов.* **1.** *см.* **подряди́ться; 2.** *страд. от* **подряжа́ть**

подряхле́ть *сов. разг.* картая төшү, бетерешә төшү; тузып бетү

подса́д *м* **1.** (*пух*) мамык йон, терлек мамыгы **2.** подсад, яшь агачлар (*урмандагы башка токымнан булган яшь агачлар*)

подсади́ть *сов.* **1.** *кого-что* менеп утырырга булышу, утырту, менгереп утырту; атландыру; **~ старика́ в ваго́н** картка вагонга менеп утырырга булышу; **~ на ло́шадь** атка атландыру **2.** *кого-что* (*посадить рядом*) янына (янәшә, кырыена) утырту **3.** *кого-что* (*в качестве попутчика*) үзенә юлдаш итеп алу, утыртып алып киту (*машинага, атка һ.б.ш.*) **4.** *что, чего* өстәп утыртып чыгу; **~ капу́сты** өстәмә рәвештә кәбестә утырту **5.** *что, спец.* ялгап үстерү, (*икенче бер урыннан кисеп алып*) ябыштырып үстерү

подса́дка *ж* **подсади́ть** 4, 5

подса́живать *несов. см.* **подсади́ть**

подса́живаться *несов.* **1.** *см.* **подсе́сть**; **2.** *страд. от* **подса́живать**

подса́ливать I *несов. см.* **подса́лить**

подса́ливать II *несов. см.* **подсоли́ть**

подса́лить *сов. что, разг.* майлау, туңмай салу, бераз туңмай кушу, туңмай белән бераз майлау

подсвети́ть *сов. что* астан яктырту, астан яктырта төшү; **~ декора́ции** декорацияләрне астан яктырта төшү

подсвéчивать *несов. см.* **подсвети́ть**

подсвéчник *м* шәмдәл, шәм савыты; **ме́дный ~** бакыр шәмдәл

подсви́нок *м* яшь дуңгыз, дуңгыз баласы (*4-10 айлык*)

подсви́стывать *несов. кому-чему* кушылып сызгыру, көй уңаена сызгыру; **~ пою́щему** жырлаучыга кушылып сызгыру

подсе́в *м см.* **подсе́ять**; **2.** (*то, что посеяно добавочно*) өстәп чәчелгән культура

подсева́ть *несов. см.* **подсе́ять**

подсевн||о́й, -а́я, -о́е аралаштырып чәчелгән, өстәп чәчелгән; **~а́я трава́** өстәп чәчелгән үлән

подседе́льник *м* ызма, ияр (ыңгырчак) каешы

подседе́льн||ый, -ая, -ое **1.** иярле, иярләнген; **~ая ло́шадь** иярләнгән ат **2.** ияр (ыңгырчак) астына салына торган; **~ый во́йлок** ияр астына салына торган киез **3.** ияр (ыңгырчак) сукканнан хасил булган; **~ая ссади́на** ыңгырчак сукканнан хасил булган яра

подседла́ть *сов. кого* иярләү, ияр кидерү; **~ коня́** атны иярләү

подсёдлывать *несов. см.* **подседла́ть**

подсе́ивать *несов. см.* **подсе́ять**

подсе́ка *ж с.-х.* ышна (*чәчүлек өчен урманнан арчылган яңа җир*)

подсека́ть *несов. см.* **подсе́чь**

подсе́кция секциянең бер тармагы, секция бүлекчәсе

подсели́ть *сов. кого-что, разг.* янына (якынына) урнаштыру; бергә урнаштыру; кертү

подселя́ть *несов. см.* **подсели́ть**

подсемéйство *с биол.* семьяның бәр тармагы, кече семья (*усемлек һәм хайваннар систематикасында*)

подсе́сть *сов.* [янына] утыру, барып утыру, якынрак килеп утыру; **~ к столу́** өстелгә якынрак килеп утыру

подсе́чка *ж см.* **подсе́чь**; **~ ле́са** урман төпләү

подсе́чь *сов. что* **1.** төптән кисеп (кыеп) ташлау, астан кисеп егу; **~ крапи́ву косо́й** кычытканны чалгы белән төптән кыеп ташлау **2.** *спец.* җир арчу, [урман] төпләү, ышна ачу; **~ лес** урман төпләү **3.** *рыб.* кинәт тартып кую (*кармакны*)

подсе́ять *сов. что, чего* **1.** өстәп чәчү, өстәмә рәвештә чәчү, тагын бераз чәчү; **~ пшени́цы** тагын бераз бодай чәчү **2.** (*траву между всходами*) аралаштырып чәчү, катнаштырып чәчү, арасына чәчү (*мәс. уҗымга аралаштырып күпъеллык үлән чәчү*)

подсиде́ть *сов. кого, прост,* төп башына утырту, утырту, этлек эшләү, алдау, бәлагә төшерү

подси́живать *несов. см.* **подсиде́ть**

подсини́вать *несов. см.* **подсини́ть**

подсини́ть *сов. что* **1.** зәңгәрләү, зәңгәрли төшү; **~ во́ду** суны зәңгәрли төшү **2.** синькалау, синькага ману; **~ бельё** керне синькалау

подскáбливать *несов. см.* **подскобли́ть**

подсказа́||ть *сов. что кому и без доп.* **1.** әйтеп тору (утыру), астыртын әйтү **2.** *перен.* күрсәтү, күрсәтеп бирү, ярдәм итү, юл ачу; **о́пыт ~л мне пра́вильное реше́ние** тәжрибәм миңа [мәсьәләне] дөрес хәл итү юлын күрсәтеп бирде

подска́зка *ж см.* **подсказа́ть**

подска́зывать *несов. см.* **подсказа́ть**

подскака́ть *сов.* чаптырып килеп җитү, чабып килү

подска́кивать I *несов. см.* **подскака́ть**

подска́кивать II *несов. см.* **подскочи́ть**

подскобли́ть *сов. что* [бераз] кырып алу, кыру, кырып төшерү (чистарту)

подскочи́||ть *сов.* **1.** йөгереп (чабып, атылып, томырылып) килеп җитү; **~ть к две́ри** ишек янына атылып килеп җитү **2.** сикереп кую, өскә таба ыргылу, югарыга ыргу; **~ть от ра́дости** шатлыктан сикереп кую **3.** *перен. разг.* кинәт күтәрелү, бик нык күтәрелү; **температу́ра ~ла** температура кинәт күтерелде; **це́ны ~ли** бәяләр бик күтәрелде **4.** *прост.* (*забежать ненадолго*) кереп чыгу, сугылу, кагылу

подскреба́ть *несов. см.* **подскрести́**

подскрести́ *сов. что, разг.* кырып чистарту (тазарту); кырып алу; **~ сково́родку** табаны кырып чистарту; **~ ка́шу со сково́родки** табадагы ботканы кырып алу

подсласти́ть *сов. что* татлыландыра (баллыландыра, тәмләндерә) төшү, баллый төшү; **~ компо́т** компотны татлыландыра төшү

подсла́щивать *несов. см.* **подсласти́ть**

подсле́дственн||ый, -ая, -ое **1.** тикшерүдәге, тикшерү астындагы, суд тикшерүенә бирелгән **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* тикшерү астындагы кеше

подслепова́тый, -ая, -ое зегыйфь күзле, күрә караучы, күзләре күрми башлаган; **~ стари́к** күзләре күрми башлаган карт

подслу́шать *сов. кого-что* яшеренеп (астыртын) тыңлап ишетү, качып тыңлап тору; **~ чужу́ю та́йну** чит кешеләрнең сер сөйләгәнен качып тыңлап тору

подслу́шивание *с см.* **подслу́шать**

подслу́шивать *несов. см.* **подслу́шать**

подсма́тривать *несов. что* яшеренеп (астыртын) карап тору, качып карап тору, караштыргалау

подсмéиваться *несов. над кем-чем* көлү, мыек астыннан көлү, мыскыллап көлү, ирештерү

подсмея́ться *сов. см.* **подсмéиваться**

подсмотре́ть *сов. что* яшерен (астыртын) карап (күзәтеп) күрү; **~ в щёлочку** ярыктан яшерен күзәтеп күрү

подсне́жник *м* умырзая, умырзая чәчәге, эргәзембай

подсне́жн||ый, -ая, -ое кар астындагы, кар астыннан чыккан

подсоби́ть *сов. кому, прост.* булышу, ярдәм итү

подсобля́ть *несов. см.* **подсоби́ть**

подсо́бник *м разг.* ярдәмче эшче

подсо́бница *ж разг.* ярдәмче эшче хатын (кыз)

подсо́бн||ый, -ая, -ое ярдәмче, булышчы; **~ое хозя́йство** ярдәмче хуҗалык

подсо́вывать *несов. см.* **подсу́нуть**

подсоедини́ть *сов. что, разг.* тоташтыру, тоташтырып кую, ялгау; **~ приёмник к электросе́ти** алгычны электр челтәренә тоташтыру

подсоединя́ть *несов. см.* **подсоедини́ть**

подсозна́ние *с* ачыкланып җитмәгән уй-фикерләр (күзаллаулар), томанлы хисләр

подсозна́тельн||ый, -ая, -ое аңда ачыкланып җитмәгән, аңга-фикергә нигезләнмәгән, томанлы, иистинктив; **~ое движе́ние** инстинктив хәрәкәт

подсока *ж спец.* уем, киртек, кирт (*агачның, мәсәлән, каенның суын агызу өчен кәүсәгә ясалган уем*)

подсократи́ть *сов. что, прост.* [бераз] кыскарта (киметә) төшү; **~ рукопись** кулъязманы бераз кыскарта төшү; **~ расхо́ды** чыгымнарны бераз киметә төшү

подсоли́ть *сов. что* **1.** өстәп тоз салу (сибу), тоз өстәү; **~ карто́шку** бәрәңгегә өстәп тоз салу **2.** *что, чего, разг.* тагын бераз тозлау, өстәмә рәвештә тозлау; **~ огурцо́в** тагын бераз кыяр тозлау

подсо́лнечник *м* көнбагыш, айбагар

подсо́лнечн||ый I, -ая, -ое кояш төшә (кыздыра) торган, кояш карый торган, кояшлы, кояшка каршы, кояш астындагы; **~ая сторона́** кояш төшә торган як

подсо́лнечн||ый II, -ая, -ое, көнбагыш ...ы, айбагар ...ы, **~ое ма́сло** көнбагыш мае

подсо́лнух *м разг. см.* **подсо́лнечник**

подсо́сн||ый, -ая, -ое, *с.-х.* **1.** имүдән аермаган, әле имезә торган; **~ые свиномáтки** әле балаларын имезә торган дуңгызлар **2.** имүдән аерылмаган, әле анасын имә торган; **~ый телёнок** имүдән аерылмаган бозау

подсо́х||нуть *сов.* кипшерү, кибә төшү, сурыгу; **земля́ ~ла** җир сурык-

кан; **грязь во дворе́ ~ла** ишек алдындагы пычрак кипшергән

подсочи́ть *сов. что, спец.* киртләү, чоку (*сагызы яки суы аксын өчен агач кәүсәсен чокып кирт ясау*)

подсо́чка *ж см.* **подсо́чить**

подспо́рье *с разг.* ярдәм, булышлык, таяныч; **огоро́д — большо́е ~ в хозя́йстве** яшелчә бакчасы — хуҗалык өчен зур ярдәм

подспу́дн||ый, -ая, -ое, кулланылмый яткан, хәрәкәтсез яткан; **~ые си́лы** кулланылмый яткан көчләр

подста́ва *ж уст.* (*сменные лошади*) алмаш, алмаш ат (*юлда арыган атны алмаштыру өчен хәзерләп куелган ат*)

подста́вить *сов.* **1.** *кого-что* [астына] кую, [астына] утырту; **~ ведро́ под водосто́чную трубу́** чиләкне су ага торган торба астына кую **2.** *что* [якынрак] китереп кую, янына кую; **~ ле́стницу к окну́** баскычны тәрәзәгә якынрак китереп кую **3.** *что* сугу, кую; **~ подпо́рку** терәү кую **4.** *перен. кого-что* кую, калдыру; **~ фланг проти́внику** флангны сакчысыз калдыру; **~ пе́шку под уда́р** пешканы һөҗүм астына кую **5.** *кого-что* алмаштыру, алмаштырып кую; **~ чи́сла в бу́квенные алгебраи́ческие выраже́ния** хәрефләр белән билгеләнгән алгебраик аңлатманы саннар белән алмаштыру ♦ **~ но́жку** *кому* аяк чалу, берәр эшкә комачаулык китерү

подста́вка *ж* **1.** (подпорка) терәк, терәү, таяу **2.** (*приспособление*) аслык, аскуйма (*берәр әйбер астына кую өчен жайланма*)

подставля́ть *несов. см.* **подста́вить**

подстав||но́й, -ая, -о́е **1.** аска (янәшә, янга) куела торган; сәяп (терәп) куела торган; **~а́я скаме́ечка** янга куела торган бәләкәй утыргыч; **~а́я ле́стница** сәяп куела торган баскыч **2.** чын урынына куелган, ялган; **~о́й свиде́тель** ялган шаһит

подстака́нник *м* стакан савыты, стакан асты

подстано́вка *ж см.* **подста́вить** 5

подста́нция *ж* ярдәмче станция, подстанция; **телефо́нная ~** ярдәмче телефон станциясе

подста́ть *в знач. сказ. разг.* шундый ук, үзенә иш; **~ ему́ была́ и жена́ его́** аның хатыны да үзенә иш иде

подстега́ть *сов. что* сырган эчлек кую; **~ пальто́** пальтога сырган эчлек кую

подстёгивать I *несов. см.* **подстега́ть**

подстёгивать II *несов. см.* **подстегну́ть** I

подстёгивать III *несов. см.* **подстегну́ть** II

подстегну́ть I *сов.* астан төймәләп кую, эчтән каптырып (электереп) кую; **~ к пальто́ тёплую подкла́дку** пальтога эчтән жылы эчлек каптырып кую

подстегну́ть II *сов. кого-что* **1.** сыдырып җибәрү, чыбыркылау, чыбыркы белән сугып алу; **~ коня́** атка чыбыркы белән сугып алу **2.** *перен. прост.* куалау, ашыктыру, ашыктыра төшү; **~ отстаю́щих** артка калучыларны ашыктыра төшү

подстели́ть *сов. см.* **подстла́ть**

подстерега́ть *несов. см.* **подстере́чь**

подстере́чь *сов. кого-что* сагалап тору, посып килгәнең көтеп тору, качып саклап тору; **~ зве́ря** ерткыч хайванны сагалап тору

подсти́л *м спец. см.* **подсти́лка**

подстила́ть *несов. см.* **подстла́ть**

подсти́лка *ж см.* **подстла́ть**; **2.** (*то, что подостлано*) аслык, түшәмә, көрпә (*аска җәелгән әйбер*)

подсти́лочный, -ая, -ое аска җәелә торган, аска җәюгә китә торган, аслык өчен булган; **~ материа́л** аска җәюгә китә торган материал

подсторожи́ть *сов. см.* **подстере́чь**

подстра́ивать *несов. см.* **подстро́ить**

подстра́иваться *несов.* **1.** *см.* **подстро́иться**; **2.** *страд. от* **подстра́ивать**

подстрахова́ть *сов. кого-что* саклык чарасы күрү (*мәс. гимнастика күнегүләре башкаручы егылып төшмәсен өчен*)

подстрека́тель *м* коткы таратучы (салучы), котыртучы, вәсвәсәче

подстрека́тельница *ж* котыртучы хатын (кыз)

подстрека́тельство *с* коткы тарату (салу), котырту, вәсвәсәләү, вәсвәсә салу; коткы

подстека́ть *несов. см.* **подстрекну́ть**

подстрекну́ть *сов.* **1.** *кого-что к чему* коткы салу, котырту; **~ к ссо́ре** ызгышырга котырту **2.** *что* кузгату, уяту, тудыру; **~ чьё-л. любопы́тство** *кемдә дә булса* кызыксыну тудыру

подстре́ливать *несов. см.* **подстрели́ть**

подстрели́ть *сов. кого* [мылтыктан] атып егу (үтерү, төшерү, яралау)

подстрига́ть *несов. см.* **подстри́чь**

подстрига́ться *несов.* **1.** *см.* **подстри́чься**; **2.** *страд. от* **подстрига́ть**

подстри́чь *сов. кого-что* тигезләп кырку, [чәчне] кыркып төзәтү, кырку; кисү; **~ ребёнка** баланың чәчен тигезләп кырку; **~ во́лосы** чәчне кыркып төзәтү; **~ но́гти** тырнак кисү

подстри́чься *сов.* чәчне кыркып төзәттерү, чәчне тигезләп кыркыту, чәч алдыру; **~ в парикма́херской** парикмахерскийда чәч алдыру

подстрога́ть *сов. что* ышкылап тигезли төшү; ышкылап шомарта төшү; **~ до́ску** тактаны ышкылап шомарта төшү

подстро́ить *сов. что* **1.** янәшә (терәп) салу, терәп җиткерү; **~ терра́су к до́му** йортка терәп терраса җиткерү **2.** ...га карап көйләү, тавышына туры китереп көйләү; **~ гита́ру под роя́ль** гитараны рояль тавышына карап көйләү **3.** *перен. разг.* [астыртын рәвештә] эшләү, берәр этлек эшләү, хәйлә кору; **~ шу́тку** астыртын рәвештә кызык эшләү

подстро́иться *сов. разг.* (*присоединиться*) кушылу

подстро́чник *м* сүзгә-сүз тәрҗемә, подстрочник

подстро́чн||ый, -ая, -ое **1.** юл астындагы, аска төшерелгән; **~ое приме́чание** аска төшерелгән искәрмә **2.** сүзгә-сүз, юлга-юл, хәрефкә-хәреф; **~ый перево́д** сүзгә-сүз тәрҗемә

подстуга́ть *сов. разг. см.* **подстога́ть**

подстру́гивать *несов. см.* **подстуга́ть**

по́дступ *м* якын бару юлы; якынлашу юлы, барып керү юлы; **бой на ~ах к го́роду** шәһәргә барып керү юлларындагы сугышлар ♦ **~а нет** *к кому кемгә дә булса* якын килерлек тә түгел, мөрәҗәгать итеп тә булмый

подступа́ть *несов. см.* **подступи́ть**

подступа́ться *несов. см.* **подступи́ться**

подступи́||ть *сов.* **1.** *к кому-чему* якын килү, килеп җитү; **войска́ ~ли к го́роду** гаскәрләр шәһәр янына килеп җиткәннәр **2.** (*оказаться в непосредственной близости*) янында ук булу, терәлеп үк диярлек тору; **дере́вня ~ла к реке́** авыл елгага терәлеп үк диярлек тора **3.** *к кому, разг.* мөрәҗәгать итү, берәр үтенеч белән килү, янына бару; **сего́дня к нему́ и ~ть нельзя́** бүген аның янына барырлык та түгел **4.** *перен. к чему, подо что* төшү, тыгылу; **боль ~ла под са́мое се́рдце** авырту йөрәккә төште; **слёзы ~ли к глаза́м** күзләргә яшь тыгылды

подступи́ться *сов. разг. см.* **подступи́ть** 3; **к нему не подсту́пишься** аңа якын килерлек тә түгел

подсуди́мая *ж* гаепләнүче хатын (кыз)

подсуди́м||ый *м* гаепләнүче; **допроси́ть ~ого** гаепләнүчедән сорау алу

подсу́дность *ж* судта каралырга тиешлек, суд жаваплылыгына тартылырга тиеш булу; **установи́ть ~ де́ла** эшнең судта каралырга тиешлеген билгелеү

подсу́дн||ый, -ая, -ое, суд карамагына тапшырылырга тиеш булган, судта каралырга тиеш булган; **~ое де́ло** судта каралырга тиеш булган эш

подсу́живать *несов. кому, разг.* (*в спорте*) яклашу, ...ны яклау

подсу́мок *м* патрон сумкасы, подсумок

подсу́нуть *сов.* **1.** *кого-что* аска салып кую, [астына] тыгып кую; **~ ве́щи под скаме́йку** әйберләрне эскәмия астына тыгып кую **2.** *что, разг.* (*подложить тайком*) сиздермичә салу, белдермәстән кую, искәрмәстән кую; белдермичә тоттыру **3.** *кого-что* алдап башка нәрсә бирү; **~ гнило́й това́р** алдап черек товар бирү

подсурьми́ть *сов. что, уст.* сөрмә тарту; **~ бро́ви** кашка сөрмә тарту

подсу́шивать *несов. см.* **подсуши́ть**

подсу́шиваться *несов.* **1.** *см.* **подсуши́ться**; **2.** *страд. от* **подсу́шивать**

подсуши́ть *сов. что* киптерә (корыта, жилләтә) төшү, [бераз] киптереп алу; **~ бельё** керләрне киптерә төшү; **~ хлеб** ашлыкны җилләтә төшү

подсуши́||ться *сов., разг.* кибә (жилли) төшү; **бельё ~лось** керләр жилли төшкәннәр

подсу́шка *ж см.* **подсуши́ть**

подсчёт *м* **1.** *см.* **подсчита́ть**; **~ голосо́в** тавышларны санау **2.** *мн.* **~ы** исәпләүләр нәтиҗәсе, исәпләп чыгару нәтиҗәсе; **прове́рить ~ы** исәпләүләр нәтиҗәсен тикшерү

подсчита́ть *сов. кого-что* исәпләп (санап) чыгару, исәбен алу, санау; ~ **расхо́ды** чыгымнарны исәпләп чыгару

подсчи́тывание *с см.* **подсчита́ть**

подсчи́тывать *несов. см.* **подсчита́ть**

подсыла́ть *несов. см.* **подосла́ть**

подсы́пать *сов. что, чего* **1.** өстәп салу (сибү), өстәү, сала төшү; ~ **со́ли в суп** ашка тоз өстәү **2.** (*сделать выше, насыпав дополнительно*) өстәп өю, өеп биегәйтә төшү **3.** (*всыпать тайно*) сиздермичә салу, астыртын салу (сибү)

подсыпа́ть *несов. см.* **подсы́пать**

подсыха́ть *несов. см.* **подсо́хнуть**

подта́ивать *несов. см.* **подта́ять**

подта́лкивание *с см.* **подтолкну́ть**

подта́лкивать *несов. см.* **подтолкну́ть**

подта́пливать I *несов. см.* **подтопи́ть** I

подта́пливать II *несов. см.* **подтопи́ть** II

подтасова́ть *сов. что* **1.** *карт.* хәрәмләү максаты белән буташтыру, хәрәмләп аралаштыру **2.** *перен.* бозу, бозып күрсәтү; ~ **фа́кты** фактларны бозып күрсәтү

подтасо́вка *ж см.* **подтасова́ть**

подтасо́вывать *несов. см.* **подтасова́ть**

подтача́ть *сов. что* ас салу, олтан салу; астар салу

подта́чивать I *несов. см.* **подтача́ть**

подта́чивать II *несов. см.* **подточи́ть**

подтащи́ть *сов. кого-что* өстерәп (сөйрәп) китерү, сөйрәп илтү; ~ **мешо́к к две́ри** капчыкны ишек янына сөйрәп китерү

подта́я||ть *сов.* эри башлау, эреп ага башлау, [бераз] эри төшү, бераз эрү; җебетү, жепшетү; **лёд** ~**л** боз эри башлаган; **на дворе́** ~**ло** *безл.* тышта җепшетеп җибәргән

подтверди́тельн||ый, -ая, -ое раслау ...ы, раслаучы, дәресләүче, раслый (дәресли) торган; ~**ая телегра́мма** раслау телеграммасы

подтверди́ть *сов. что* дәресләү, раслау; ~ **прика́з** приказны раслау

подтверди́||ться *сов.* раслану, дәрес булып чыгу, дәрескә чыгу, рас килү; **все на́ши предположе́ния по́лностью** ~**лись** безнең барлык фаразларыбыз да тулысынча расланды

подтверждА́ть *несов. см.* **подтверди́ть**

подтверждА́ться *несов.* **1.** *см.* **подтверди́ться; 2.** *страд. от* **подтверждА́ть**

подтвержде́ние *с* **1.** *см.* **подтверди́ть 2.** дәресләүче факт, раслаучы факт

подтёк *м* **1.** (*на теле*) кара янган (көйгән) җир, күгәреп чыккан урын, кан сауган урын (*тәндә*) **2.** (*берәр нәрсә*) агып төшкән эз; ~**и на обо́ях** обойлардагы су агып төшкән эзләр

подтека́ть *несов. см.* **подте́чь**

подте́кст *м книжн.* төптә яткан мәгънә, подтекст

подтексто́вка *ж муз.* **1.** (*сочинение текста*) җыр музыкасы өчен текст язу **2.** (*стихи для музыки*) җыр музыкасы өчен язылган текст

подтёлок *м* бер яшьлек тана, бер яшьлек бозау

подтере́ть *сов. что* сөртеп алу, корытып сөртеп алу (чыгу); ~ **пол** идәнне корытып сөртеп алу

подтеса́ть *сов. что* [бераз] юнып (таслап) алу, таслап шомарта төшү; чутлап алу (*стена бурәнәсен эчке яктан*); ~ **бревно́** бүрәнәне бераз юнып алу

подтёсывать *несов. см.* **подтеса́ть**

подте́||чь *сов.* [астына] агып керү, [аска] агып керү, [астына] саркып керү; **вода́** ~**кла́ под шкаф** су шкаф астына агып кергән

подтира́ть *несов. см.* **подтере́ть**

подти́рка *ж см.* **подтере́ть**

подтолкну́ть *сов. кого-что* **1.** төртеп кую, җиңелчә генә этеп җибәрү; ~ **ло́ктем сосе́да** терсәк белән күршеңә төртеп кую **2.** *разг.* этеп күчерү, этеп шудыру; ~ **к вы́ходу** этеп ишеккә таба күчерү **3.** *перен. разг.* этәрү, этәргеч бирү, тизләтү, ашыктыру

подтопи́ть I *сов. что, разг.* [бераз] ягып алу, өстәп ягу; ~ **печь** мичкә өстәп ягу

подтопи́ть II *сов. что, чего* эретү, өстәп эретү, [бераз] эретеп алу; ~ **ма́сла** тагын бераз май эретеп алу

подто́пка *ж* **1.** *см.* **подтопи́ть** I; **2.** (*растопка*) кабызгыч, тергезгеч (*чыра, туз һ.б.ш.*)

подточи́||ть *сов.* **1.** *что* үткенли төшү, [бераз] кайрап үткенләп алу; ~**ть нож** пычакны бераз кайрап үткенләп алу **2.** *что* (*о насекомых, грызунах*) астан ашау, астан кимерү **3.** *что* астан ашап җимерү, астан ашап ишү; **водо́й** ~**ло скалу́** *безл.* кыяны астан су ашаган **4.** *перен. кого-что* какшату, йончыту, хәлсезләндерү; **боле́знь** ~**ла его́** авыру аны йончыткан

подтру́нивать *несов. над кем-чем, разг.* шаярту, [үчекләп] көлү, ирештерү

подтыка́ть *несов. см.* **подото́кнуть**

подтя́гивание *с см.* **подтяну́ть, подтяну́ться**

подтя́гивать *несов. см.* **подтяну́ть**

подтя́гиваться *несов.* **1.** *см.* **подтяну́ться; 2.** *страд. от* **подтя́гивать**

подтя́жки *мн.* подтяжка (*чалбар төшмәсен өчен аңа эләктереп җилкә аркылы киелә торган тарттыргыч тасма*)

подтя́нутость *ж* җыйнаклык, пөхтәлек, ыкыматлык

подтя́нутый, -ая, -ое ыкымат, пөхтә, җыйнак; **у него́ всегда́** ~ **вид** аның кыяфәте һәрвакыт җыйнак

подтяну́ть *сов.* **1.** *что* кыса (тарта, тарттыра) төшү, кысыбрак буу; ~ **по́яс** билбауны кыса төшү **2.** *кого-что* тартып (сөйрәп, өстерәп) китерү; ~ **ло́дку к бе́регу** көймәне яр кырыена тартып китерү **3.** *кого-что* туплау, җыю, китерү; ~ **резе́рвы к фро́нту** фронтка резервлар китерү; ~ **войска́ к перепра́ве** гаскәрләрне кичүгә туплау **4.** *перен. кого-что, разг.* алга этәрү (чыгару, сөйрәү, әйдәү); ~ **отстаю́щих** артта калучыларны алга әйдәү **5.** *кому и без доп.* (*подпеть*) кушылып җырлау, җырга кушылу, кушылып китү

подтяну́||ться *сов.* **1.** күтәрелү; ~**ться на турнике́** турникта күтәрелү **2.** тупланы, җыелу; **войска́** ~**лись к грани́це** гаскәрләр чик буена тупланды **3.** *перен. разг.* куып җитү, яхшырак эшли башлау, тырыша башлау, алдынгылар рәтенә басу; **отстаю́щие** ~**лись** артта калучылар яхшырак эшли башладылар

поду́ма||ть *сов.* **1.** уйлау, уйлап карау, уй йөртү; **на́до** ~**ть об э́том предложе́нии** бу тәкъдим турында уйлап карарга кирәк **2.** (*быть в размышлении*) уйга чуму, уйга талу; башка китерү **3.** ~**ешь,** ~**йте** *в знач. вводн. сл.* харап икән, йсен киткән икән; ~**ешь, како́й знато́к!** йсен киткән икән, нинди белдекле (имеш)! ◆ ~**ть то́лько** исәпләсәң исең китәр; ~**ть то́лько, уже́ весна́!** исәпләсәң, исең китәр: инде яз да җитте!

поду́мыва||ть *несов.* **1.** уйлаштыргалау, вакыт-вакыт уйлап кую; ~**ть об отъе́зде** китү турында уйлаштыргалау **2.** ниятләү, исәп тоту, уйга (фикергә) килү; **я давно́** ~**л уе́хать** күптән инде китәргә ниятләгән идем

подура́читься *сов.* [бераз] шаярып алу, [бераз] котырып алу; (*берәр кешене*) мыскыллап көлү, котырту

подурне́||ть *сов.* ямьсезләнә төшү, ямьсезләнү; **лицо́ её** ~**ло** йөзе ямьсезләнә төшкән

поду́сники *мн.* мыек асты, мыек чите (*мыек читләрендәге төкләр, бала йоннары*)

поду́||ть *сов.* **1.** исә (өрә) башлау; ~**л се́верный ве́тер** төньяк җиле исә башлады **2.** [бераз вакыт] исеп (өреп) тору; **ве́тер** ~**ет и переста́нет** җил бераз исәр дә туктар

поду́чивать *несов. см.* **подучи́ть**

поду́чиваться *несов.* **1.** *см.* **подучи́ться; 2.** *страд. от* **поду́чивать**

подучи́||ть *сов.* **1.** *кого-что* [бераз] өйрәтеп алу, өйрәтә төшү, өйрәтү; ~**ть молодо́го рабо́чего** яшь эшчене [бераз] өйрәтеп алу **2.** *что* өйрәнә төшү, яхшырак өйрәнү; ~**ть уро́к** дәресне яхшырак өйрәнү **3.** *кого-что и с неопр.* өйрәтү, котырту; **он меня́** ~**л совра́ть** ул мине ялганларга котыртты

подучи́ться *сов.* [бераз] уку, [бераз] укып белем алу; [бераз] өйрәнү, [бераз] өйрәнеп алу

поду́шечк||а *ж* **1.** *уменьш. от* **поду́шка** 1; **2.** *мн.* ~**и** (*вид конфет*) мендәр конфет

поду́ши||ть I *сов. кого* буып бетерү (үтерү), буып үтереп бетерү; **лиса́** ~**л мно́го кур** төлке бик күп тавыкны буып үтергән

поду́ши́ть II *сов. кого-что* хушбуй сөртеп алу, ислемай бөркеп алу

поду́ши́ться *сов.* бераз хушбуй сөртенү, ислемай сөртеп алу

поду́шка *ж* **1.** мендәр, күпчек; **пухо́вая** ~ мамык мендәр **2.** *спец.* нигез, терәк (*төрле корылмаларда, механизмнарда*)

поду́шн||ый, -ая, -ое *ист.* жан башыннан салына (түләнә) торган; ~**ая по́дать** жан башыннан түләнә торган салым, имана

ПОД-ПОД

подфа́рник *м* подфарник, ярдәмче фара

подхали́м *м* ялагай, куштан, тәлинкә тотучы

подхалима́ж *м см.* **подхали́мство**

подхали́мка *ж* ялагай (куштан) хатын (кыз)

подхали́мничать *несов. разг.* ялагайлану, куштанлану, тәлинкә тоту

подхали́мство *с* ялагайлык, куштанлык, тәлинкә тоту

подхвати́ть *сов.* **1.** *кого-что* тотып алу, эләктереп тоту (алу); **~ больно́го под мы́шки** авыруны култыгыннан эләктереп тоту **2.** *перен. что, разг.* эләктерү; **~ грипп** грипп эләктерү **3.** *перен. что* эләктереп алу; **~ чужу́ю мысль** чит кеше фикерен эләктереп алу **4.** *что* күтәреп җибәрү (алу), кушылып җырлый башлау, кушылып китү; **дру́жно ~ пе́сню** җырны бердәм күтәреп җибәрү **5.** *перен. что* куәтләү, күтәреп алу; **~ инициати́ву масс** массаларның инициативасын куәтләү; **~ о́пыт передовико́в** алдынгылар тәжрибәсен күтәреп алу

подхва́тывать *несов. см.* **подхвати́ть**

подхихи́кивать *несов. прост.* астыртын гына хихылдап алу, мыек астыннан гына мыскыллап көлү

подхлестну́ть *сов. кого* камчылау, чыбыркы белән сыптырып алу; **~ коня́** атка чыбыркы белән сыптырып алу

подхлёстывать *несов. см.* **подхлестну́ть**

подхо́д *м* **1.** *см.* **подойти́** 1, 3, 4; **2.** якынаю юлы, килү юлы; бару юлы, юл; **удо́бный ~ к пози́циям** позицияләргә алып бара торган уңай юл **3.** якын килү, караш, мөнәсәбәт; **пра́вильный ~ к де́лу** эшкә дөрес якын килү

подхо́д||ец *м*: **с ~цем** *разг.* читләтеп, уратып, хәйлә белән; **де́йствовать с ~цем** хәйлә белән эш ите

подходи́ть *несов. см.* **подойти́** ♦ **~ к концу́** тәмамланып килү, бетеп килү

подходя́щ||ий, -ая, -ое **1.** *прич. от* **подходи́ть**; **2.** кулай, уңайлы, туры килә торган, яраклы; **~ий моме́нт** уңайлы момент; **~ее помеще́ние** яраклы бина

подхому́тник *м* бөят

подхору́нжий *м уст. воен.* подхорунжий

подцепи́ть *сов.* **1.** *кого-что* [астан] эләктерү; **~ бревно́ багро́м** бүрәнәне астан багор белән эләктерү; **~ груз крюко́м** йөкне ыргак белән астан эләктерү **2.** *что* эләктерү, тагу; **~ ваго́н к по́езду** вагонны поездга тагу **3.** *перен. что. разг.* эләктерү; **~ на́сморк** томау эләктерү

подцепи́ться *сов.* артына ябышу, [астан] ябышып асылыну, артына асылыну

подцепля́ть *несов. см.* **подцепи́ть**

подцепля́ться *несов.* **1.** *см.* **подцепи́ться**; **2.** *страд. от* **подцепля́ть**

подча́ливать *несов. см.* **подча́лить**

подча́лить *сов.* **1.** килеп туктау; **~ к при́стани** пристаньга килеп туктау **2.** *что* [эләктереп] тартып алу, тартып китерү, китереп туктату (*суда йөзеп барган әйберне*); **~ ло́дку к ба́рже́** көймәне баржа янына китереп туктату; **~ бревно́ к ло́дке** бүрәнәне көймә янына тартып китерү

подча́литься *сов. спец. см.* **подча́лить** 1

подча́с *нареч.* вакыт-вакыт, кайвакыт[та], кайчакларда, әледән-әле; **~ быва́ет тру́дно** кайчакларда кыен була

подча́сок *м* подчасок, часовой ярдәмчесе (*хәрби каравылда*)

подчелюстн||о́й, -а́я, -о́е *анат.* казналык асты ...ы; **~ы́е же́лезы** казналык асты бизләре

подчёркивать *несов. см.* **подчеркну́ть**

подчёркнут||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **подчеркну́ть**; **2.** сизелеп тора торган, күзгә бәрелеп тора торган, кычкырып тора торган, аеруча; **слу́шать с ~ым внима́нием** аеруча игътибар белән тыңлау

подчеркну́ть *сов. что* **1.** астына сызу; **~ в ру́кописи осо́бенно ва́жные места́** кулъязмада аеруча мөһим урыннарның астына сызу **2.** *перен.* ассызымлау, басым ясау, басым ясап әйтү (күрсәтү); **~ ва́жность вопро́са** мәсьәләнең мөһимлегенә басым ясау

подчерни́ть *сов. что* каралту, карага буяу, каралта төшү; **~ бро́ви** кашны каралту

подчине́ние *с* **1.** *см.* **подчини́ть, подчини́ться; 2.** *грам.* ияртүле бәйләнеш, иярту, ияртелү; **~ прида́точного предложе́ния гла́вному** иярчен җөмләнең баш җөмләгә ияртелүе

подчинённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **подчини́ть; 2.** *в знач. сущ. м* буйсынган кеше, буйсынулы кеше, кул астындагы кеше, бәйле кеше

подчини́тельный, -ая, -ое: **~ сою́з** *грам.* ияртүче теркәгеч

подчини́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*покорить*) буйсындыру, баш идеру, кул астына алу **2.** *что кому-чему* буйсындыру, хезмәт иттерү; **~ свои́ ли́чные интере́сы обще́ственным** үз кирәкләреңне гомумхалык интересларына буйсындыру **3.** *кого-что* карамагына тапшыру, буйсындыру; **~ отде́льные учрежде́ния министе́рствам** кайбер учреждениеләрне министрлыклар карамагына тапшыру **4.** *что, грам.* иярту

подчини́ться *сов.* буйсыну, баш ию, карамагында булу; **~ прика́зу** приказга буйсыну; **~ го́лосу со́вести** вөждан кушуына буйсыну

подчиня́ть *несов. см.* **подчини́ть**

подчиня́ться *несов.* **1.** *см.* **подчини́ться; 2.** *страд. от* **подчиня́ть**

подчи́стить *сов.* **1.** *что* чистарту, чистартып җибәрү, тазарту; **~ доро́жки** паласларны чистартып җибәрү **2.** *что* кырып ташлау (төзәтү); **~ оши́бочно напи́санную бу́кву** ялгыш язылган хәрефне кырып ташлау; **~ ци́фру** цифрны бозып төзәтү **3.** *чего* [тагын] бераз чистарту, [тагын] бераз әрчү; **~ карто́шки** тагын бераз бәрәңге әрчү **4.** *что, разг.* тотып (алып) бетерү, ашап бетерү, чистарту; **~ все запа́сы** бар булган запасны тотып бетерү

подчи́стка *ж см.* **подчи́стить** 1, 2, 4

подчисту́ю *нареч. прост.* барын да, барысын да, тулысынча, берсен дә калдырмыйча; **взя́ли всё ~** берсен дә калдырмыйча алып киткәннәр

подчита́ть *сов. что* **1.** *разг.* тагын бераз уку; **на́до ещё ~, пре́жде чем выступа́ть с докла́дом** доклад белән чыкканга кадәр әле тагын бераз укырга кирәк **2.** *спец.* кычкырып уку, чагыштырып уку (*копияне оригинал белән чагыштыру өчен икенче берәунең кычкырып укуы*)

подчища́ть *несов. см.* **подчи́стить**

подшёрсток *м* йон мамыгы, мамык, йон (*мәс. кәҗә мамыгы*)

подше́фный, -ая, -ое шефка алынган, шефлыкка алынган; **~ колхо́з** шефка алынган колхоз; **~ де́тский дом** шефлыкка алынган балалар йорты

подшиба́ть *несов. см.* **подшиби́ть**

подшиби́ть *сов. прост.* **1.** *что* бәреп (сугып) имгәту, бәреп (сугып) күгәрту; **~ глаз** сугып күзен күгәрту **2.** *кого-что* бәреп (сугып) төшерү; атып төшерү; **~ го́лубя ка́мнем** күгәрченне таш атып бәреп төшерү; **~ неприя́тельский самолёт** дошман самолётын атып төшерү

подшива́ние *с см.* **подши́ть**

подшива́ть *несов. см.* **подши́ть**

подши́вка *ж* **1.** *см.* **подши́ть; 2.** *разг.* төпләмә, тегелмә, подшивка (*җыелтөпләнгән газеталар, журналлар яисә документлар*)

подши́пник *м* подшипник; **ша́риковый ~** шарлы подшипник

подши́пниковый, -ая, -ое подшипник[лар] ...ы; **~ заво́д** подшипник заводы

подши́ть *сов. что* **1.** астарлау, эчлек кую; **~ подкла́дку к пальто́** пальтога эчлек кую **2.** астына салу, ас салу, олтан салу; **~ ва́ленки** итеккә олтан салу **3.** читен бөгү, каю; **~ носовы́е платки́** кулъяулыкларның читләрен бөгү **4.** теркәп (тегеп, төпләп) кую, төпләү; **~ докуме́нты к де́лу** документларны делога теркәп кую; **~ газе́ты за ме́сяц** бер айлык газеталарны төпләп кую

подшки́пер *м* шкипер ярдәмчесе

подшле́мник *м* подшлемник (*шлем яки каска эченнән киелә торган башлык*)

подшпи́ливать *несов. см.* **подшпи́лить**

подшпи́лить *сов. что* кадап кую, астан кадап кую; шпилька белән кадап кую; **~ во́лосы** чәчне шпилька белән кадап кую

подшта́нники *только мн. прост.* ыштан, ирләр ыштаны

подшто́пать *сов. что* тупчып кую, тупчып ямау (ямап кую); **~ чулки́** оекны тупчып ямап кую

подшто́пывать *несов. см.* **подшто́пать**

подштукату́ривать *несов. см.* **подштукату́рить**

подштукату́рить *сов. что* штукатурасын төзәткәләү, урыны-урыны белән штукатурлап алу; **~ потоло́к** түшәмне урыны-урыны белән штукатурлап алу

подшту́рман *м* штурман ярдәмчесе

подшути́ть *сов. над кем-чем* шаярту, шаяртып алу, иреште рү, кызык итү; **~ над прия́телем** дустын кызык итү

подшу́чивать *несов. см.* **подшути́ть**

подъеда́ть *несов. см.* **подъе́сть**

подъе́зд *м* **1.** *см.* **подъе́хать** 1, 2; **2.** (*место*) килү юлы, ...га илтә торган юл, ...га керү юлы; **~ к мосту́** купергә керү юлы **3.** йорт ишеге, урам як ишек, ишек; **пара́дный ~** урам яктагы ишек

подъе́здить *сов. кого, спорт.* ат өйрәтү (*яшь атны җигүгә, атланып йөрүгә өйрәтү*)

подъе́здн||о́й, -а́я, -о́е (*берәр җиргә*) керә торган, илтә торган; (*берәр җирдән*) чыга торган; **~ы́е пути́** керә торган юллар

подъезжа́ть *несов. см.* **подъе́хать**

подъём *м* **1.** *см.* **подня́ть, подня́ться**; **2.** үр; **поло́гий ~** сөзәк үр **3.** *перен.* үсеш, алга китеш; **~ наро́дного хозя́йства** халык хуҗалыгының үсеше **4.** *перен.* күтәренке рух, күтәренкелек, дәртлелек; **говори́ть с ~ом** күтәренке рух белән сөйләү, дәртләнеп сөйләү **5.** аяк йөзе; **сапо́г жмёт в ~е** бер итек аяк йөзен кыса ♦ **тяжёл на ~** авыр сөякле, әкертен кеше, акрын кыймылдаучан, авыр уйлаучан; **лёгок на ~** җиңел сөякле

подъёмник *м* күтәргеч, күтәртү механизмы, лифт; **гидравли́ческий ~** гидравлик күтәргеч

подъёмн||ый, -ая, -ое **1.** күтәрү ...ы, күтәрткеч ...; **~ый механи́зм** күтәрткеч механизм; **~ый кран** күтәрү краны **2.** күтәртелә торган, күтәрелә торган, күтәрелмә; **~ый мост** күтәрелмә күпер **3.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* яңа урынга бару акчасы

подъесау́л *м уст. воен.* подъесаул (*патша армиясендәге казачи гаскәрләрдә штабс-капитан дәрәҗәсендәге офицерлык званиесе*)

подъе́||сть *сов. что, прост.* **1.** төптән кимерү, астан кимерү, төбен тишү; **кры́сы ~ли мешо́к с муко́й** күселәр он капчыгының төбен тишкәннәр **2.** ашап бетерү; **все пироги́ ~ ли** бөтен бәлешләрне ашап бетергәннәр

подъе́хать *сов.* **1.** *к кому-чему* ... [янына] килү, ... [янына] килеп җитү, якын килү (*атка; машинага һ.б.ш. утырып*); **~ к крыльцу́** болдыр янына килеп җитү **2.** *подо что* барып керү, барып эләгү; **~ под мост** купер астына барып керү **3.** *перен. к кому, разг.* җаен табып мәрәҗәгать итү, юмакайланып мәрәҗәгать итү, кылын тартып карау

подъязы́чн||ый, -ая, -ое *анат.* тел асты ...ы, тел астындагы; **~ая железа́** тел асты бизе

подъяре́мный, -ая, -ое *уст.* коллыктагы, коллыкка төшерелгән, кол ителгән, кол хәленә калдырылган, ирексез; **~ труд** ирексез хезмәт

подыгра́ть *сов. кому* **1.** кушылып уйнау, җырлаучыга кушылып уйнау; **~ певцу́ на гита́ре** җырлаучыга кушылып гитарада уйнау **2.** *перен.* яраргa тырышу, куштанлану **3.** (*помочь партнёру*) уенда иптәшеңә булышу, уеның белән партнёрыңа ярдәм итү

подыгрывать *несов. см.* **подыгра́ть**

подыска́ть *сов. кого-что* эзләү, табу, эзләп табу; сайлап алу; **~ ну́жного рабо́тника** кирәкле работникны эзләп табу

подыска́ть *несов. см.* **подыска́ть**

подыто́живать *несов. см.* **подыто́жить**

подыто́жить *сов. что* йомгаклау, йомгак ясау, нәтиҗә чыгару; **~ расхо́ды** чыгымнарга йомгак ясау

подыха́ть *несов. см.* **подо́хнуть**

подыша́ть *сов.* **1.** бераз сулыш алу, тын алу, бераз сулап йөрү; **~ све́жим во́здухом** бераз саф һава сулап йөрү **2.** (*несколько раз дохнуть*) өрү, өргәләп алу

поеда́ть *несов. см.* **пое́сть** 2, 3

поеди́нок *м* **1.** (*дуэль*) бергә бер чыгып атышу, дуэль **2.** алышу, көрәш; **~ боксёров** боксёрлар көрәше; **слове́сный ~** сүз көрәштерү, бәхәс

поедо́м *нареч.*: **~ есть** *кого, прост.* көн күрсәтмәү, теңкәгә тию

поёживаться *несов. см.* **поёжиться**

поёжиться *сов.* бөрешү, бөрешеп (куырылып) тору, куырылу, йомарлану

по́езд *м* **1.** поезд; **ско́рый ~** тиз йөрешле поезд; **~ метро́** метро поезды **2.** кәрван; бер-бер артлы тезелгән арбалар; **сва́дебный ~** туй кәрваны ♦ **~ дру́жбы** дуслык поезды

пое́здить *сов. разг.* йөреп (барып) кайту, сәфәр йөреп кайту (*бернича тапкыр*), [дөнья] гизү; **~ по стране́** ил буйлап йөреп кайту

пое́здка *ж* йөреп (барып) кайту, юл йөрү, сәяхәт, сәфәр; **~ на юг** көньякка барып кайту

поездн||о́й, -а́я, -о́е поезд ...ы; **~ а́я брига́да** поезд бригадасы

поёмн||ый, -ая, -ое су баса торган, язгы ташкын суы астында кала торган; **~ые луга́** су баса торган болыннар

пое́сть *сов.* **1.** *чего и без доп.* бераз ашап алу, капкалап алу, тамак ялгап алу; **~ пе́ред доро́гой** юлга чыгар алдыннан капкалап алу **2.** *кого-что* ашап бетерү; **кры́сы пое́ли всю крупу́** куселәр бөтен ярманы ашап бетергәннәр; **ко́шка пое́ла всех цыпля́т** мәче бөтен чебиләрне ашап бетергән **3.** *что* кисү, кисеп бетерү; **моль пое́ла мех** мехны көя кисеп бетергән

пое́ха||ть *сов.* **1.** китү, китеп бару, бару; **~ть на по́езде** поездга утырып китеп бару; **~ть в дом о́тдыха** ял йортына китү **2.** *перен. разг.* шуу, таю, салулау, салулап китү; **са́нки ~ли в сто́рону** чана бер читкә салулап китте

пожа́дничать *сов.* саранлану, комсызлану, ачкүзләләнү, комагайлану

пожале́ть *сов.* **1.** *кого-что* кызгану, аяу, жәлләү **2.** *о чём* үкенү; **~ о поте́рянном вре́мени** вакыт әрәмгә киткәнгә үкенү

пожа́л||овать *сов. уст.* **1.** *кого чем, кому что* бүләк итү (итеп бирү), бүләкләү, яхшылык эшләү **2.** *повел.* **~ уйте** рәхим итегез; **~ уйте ко мне в ко́мнату** миңем бүлмәгә рәхим итегез ♦ **добро́ ~ловать**! хуш киләсез!, рәхим итегез!

ПОД-ПОЖ П

пожа́ловаться *сов.* **1.** зарланып алу, зарлану, сукрану; **~ на головну́ю боль** баш авыртудан зарлану **2.** (*подать жалобу*) жалоба бирү, шикаять итү **3.** *на кого-что* (*высказать недовольство*) әләкләү, чагу

пожа́луй *вводн.сл.* ихтимал, мөгаен, бугай, ахры, бәлки, шулайдыр, булса кирәк; **он, ~ придёт** аның килүе ихтимал

пожа́луйста *частица* **1.** (*вежливое обращение*) ...чы, рәхим итеп ...чы; **да́йте мне, ~, листо́к бума́ги** миңа бер бит кәгазь бирегезче **2.** (*просьба не делать чего-л.*) зинһар; **~ не шуми́те** зинһар шауламагыз **3.** (*вежливое выражение согласия*) рәхим итегез; **мо́жете переда́ть мне нож? — Пожа́луйста!** миңа пычакны алып бирә алмассызмы? — Рәхим итегез! ♦ **скажи́те ~!** *в знач. вводн. сл.* менә сиңа мә!, менә тагын!

пожа́р *м прям., перен.* янгын, ут, пожар; **туши́ть ~** янгын сүндерү; **~ войны́** сугыш уты ♦ **как на ~ бежа́ть (лете́ть** *и т.п.*) артына ут капкандай чабу, ут чыккандай йөгерү

пожа́рить *сов.* **1.** *что, чего* кыздырып (куырып) алу; **~ карто́шки** бәрәңге кыздырып алу **2.** *что, разг.* кыздырып (куырып) бетерү; **~ все котле́ты** барлык котлетларны кыздырып бетерү

пожа́рище *с* **1.** зур янгын **2.** янгын урыны, янгын хәрабәләре, пожар булган җир

пожа́рник *м* янгын сүндерүче, пожарник

пожа́рн||ый, -ая, -ое **1.** янгын [сүндерү] ...ы, пожар ...ы; **~ая кома́нда** янгын сүндерү командасы **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м см.* **пожа́рник ♦ в ~ом поря́дке** бик зур ашыгычлык белән; **на вся́кий ~ый слу́чай** кирәк була калса дип

пожа́ть I *сов. что* кысу; **~ ру́ку** кул кысу ♦ **~ плеча́ми** иңбашны сикертеп кую

пожа́ть II *сов. что* **1.** уру; **~ рожь** арыш уру; **что посе́ешь, то и пожнёшь** *посл.* ни чәчсәң, шуны урырсың **2.** *перен. высок.* казану, ирешү, игелеген күрү; **~ плоды́ свои́х трудо́в** үз хезмәтеңнең игелеген күрү

пожа́ться *сов.* бөрешү, бөкшәю; **~ от хо́лода** суыктан бөкшәю

пожева́ть *сов.* **1.** *что* (*жевать некрое время*) [бераз] чәйнәп алу, [бераз] күшәп алу **2.** *что, чего и без доп.* (*поесть немного*) [бераз] ашап алу, капкалап алу

пожела́ни||е *с* теләк, сорау, тәкъдим; **~ я трудя́щихся** хезмәт ияләренең теләкләре

пожела́ть *сов. что, чего* теләү, теләктә булу (тору); **~ счастли́вого пути́** хәерле юл теләү

пожелте́л||ый, -ая, -ое саргайган, сары; **~ые ли́стья** саргайган яфраклар

пожелте́||ть *сов.* саргаю, сары төскә керү; **ли́стья уже́ ~ли** яфраклар саргайды инде

пожелти́ть *сов. что, разг.* саргайту, саргайта төшү; **~ пол** идәнне саргайта төшү

пожени́ть *сов. кого-что, кого с кем, разг.* өйләндерү, башлы-күзле итү

пожени́ться *сов. разг.* өйләнешү, башлы-күзле булу

пожéртвован||ие *с* **1.** *см.* **пожéртвовать**; **2.** ярдәм, бүләк, иганә; **сбор ~ий** иганә җыю

пожéртвовать *сов.* **1.** *что* (*принести в дар*) бүләк итү (итеп бирү) **2.** *перен. кем-чем* корбан итү, фида кылу, аямау; **~ жи́знью** тормышыңны корбан итү

пожéчь *сов. что* **1.** (*истребить огнём, зноем и т.п.*) яндырып (көйдереп) бетерү, көлгә әйләндерү; **~ бума́ги** кәгазьләрне яндырып бетерү **2.** *разг.* ягып бетерү; **~ все дровá** бар булган утынны ягып бетерү

пожи́ва *ж разг.* җиңел табыш, файда, чумара

пожива́||ть *несов. разг.* яшәү, гомер итү (кичерү), көн итү (курү); **как ~ете?** ничек яшисез?

пожи́ться *сов. чем, разг.* файда итү, байлык табу, байлык җыю, табыш итү; **~ за чужóй счёт** башкалар хисабына файда итү

пожи́зненн||ый, -ая, -ое гомерлек ...; **~ая пéнсия** гомерлек пенсия

пожилóй, -áя, -óе өлкән, өлкән яшьтәге, олыгайган, олыгая төшкән; **~ человéк** өлкән яшьтәге кеше

пожима́ть *несов. см.* **пожáть** I

пожима́ться *несов. см.* **пожáться**

пожина́ть *несов. см.* **пожáть** II 2 ♦ **~ лáвры** дан казану

пожира́||ть *несов. кого-что* **1.** *см.* **пожрáть**; **2.** *перен.* ялмап (чолгап) алу; **плáмя ~ет дом** ялкын йортны ялмап ала **3.** *перен.* җәлеп итү, үзенә тарту, биләп алу; **егó ~ет любопы́тство** аны кызыксыну биләп алган ♦ **~ть глáзами** *кого-что* күзләре белән йотардай итеп карау

пожи́тки *только мн. разг.* йорт кирәк-ярагы, вак-төяк мөлкәт, кирәк-ярак

пожи́||ть *сов.* **1.** гомер итү, яшәү, тору, көн күрү; **он мáло пóжил** ул бик аз яшәде **2.** *разг.* (*насладиться жизнью*) дөньяның рәхәтен күрү, рәхәт яшәү ♦ **~вём — увúдим** *погов.* исән булсак, күрербез

пожрáть *сов. прост.* **1.** *чего и без доп.* [бераз] ашап алу, капкалап алу, тамак ялгап алу; тыгыну **2.** *кого-что* (*о животных*) ашап бетерү, комсызланып ашап бетерү, ялмап ташлау

пожурúть *сов. кого-что, разг.* битәрләп (шелтәләп, әрләп, тиргәп, орышып) алу

пожýхнуть *сов.* кибеп төсен югалту, кибеп саргаю, тоныклану

пóз||а *ж* **1.** гәүдә торышы, кыяфәт, поза; **велúчественная ~а** мәһабәт кыяфәт **2.** *перен.* (*притворство*) кыланчыклык, кылтаю, кылану; **он не тéрпит ~ы** ул кылтаюны күрә алмый

позабáвить *сов. кого-что* бераз күңелен күтәрү, күңелен ачу, юату; **~ детéй** балаларның бераз күңелен күтәрү

позабáвиться *сов.* [бераз] күңел күтәреп алу, [бераз] күңел ачып алу

позабóтиться *сов. о ком-чём* кайгырту, кайгыртучанлык күрсәтү, хәстәрен күрү

позабывáть *несов. см.* **позабы́ть**

позабы́||ть *сов. кого-что, разг.* **1.** оныту, истән (хәтердән) чыгару; **ты совсéм ~л нас** син безне бөтенләй оныткансың **2.** онытып калдыру, оныту; **я где-то ~л свой шарф** мин шарфымны кайдадыр онытып калдырганмын

позавúдовать *сов. кому-чему* көнчелек килү, көнләшү, кызыгу, хөсетләнү

позáвтракать *сов.* иртәнге ашны ашау (ашап алу)

позавчерá *нареч.* өченче көн, [моннан] бер көн элек

позавчерáшний, -яя, -ее өченче көнге; **~яя газéта** өченче көнге газета; **~ий разговóр** өченче көнге сөйләшү

позадú **1.** *предлог с род.п.* артта, азакта, артыннан, арттан; **он шёл ~ всех** ул барысыннан да артта бара иде **2.** *нареч.* артта, арт якта; **он сидéл ~** ул артта утыра иде **3.** *нареч. перен.* артта, үтелгән; **сáмое трýдное ужé ~** ин кыены инде үтелгән

позаúмствовать *сов. что* **1.** алу, үзләштерү; **~ мéтод рабóты** эш методын үзләштерү **2.** *разг.* (*взять в долг*) әҗәткә (бурычка, көтәчәккә, үтечкә) алу

позанимáться *сов. разг.* [бераз] эшләп алу, [бераз] шөгыльләнеп алу

позапрóшлый, -ая, -ое үткәннән элекке, үткәннең үткәне, өчәнче; **~ год** өченче ел; **~ мéсяц** үткән айдан элекке ай

позарéз *нареч. прост.* бик, үтә, чиктән тыш

позáриться *сов. на кого-что, разг.* кызыгу, күз төшү (кызу, ату)

позвáть *сов. кого-что* чакыру, дәшү, чакырып (дәшәп) алу; **~ друзéй в гóсти** дусларыңны кунакка чакыру

позволéни||е *с книжн.* рөхсәт, ризалык; **получúть ~е** рөхсәт алу; **с вáшего ~я** сезнең ризалык белән ♦ **с ~я сказáть** әгәр алай дип әйтергә яраса

позвóли||ть *сов. кому-чему, что и с неопр.* **1.** рөхсәт итү (бирү) юл кую, ирек бирү; **~ть закурúть** тәмәке тартырга рөхсәт итү **2.** мөмкинлек бирү; **болéзнь не ~ла мне вы́йти из́ дому** авыруым миңа өйдән чыгарга мөмкинлек бирмәде ♦ **позвóль[те]** гафу итәсез (*әдәпле тонда кире кагу сүзе*); **позвóльте, я не согла́сен с ва́ми** гафу итәсез, мин сезнең белән килешә алмыйм

позволя́ть *несов. см.* **позвóлить**

позвон||и́ть *сов.* **1.** шалтырату **2.** [телефоннан] шалтырату; **я ~ю́ вам за́втра** мин сезгә иртәгә шалтыратырмын

позвонóк *м* умыртка, умыртка сөяге; **шéйный ~** муендагы умыртка сөяге

позвоно́чник *м* умырткалык, умыртка баганасы

позвоно́чн||ый, -ая, -ое умыртка ...ы; **~ый столб** умыртка баганасы **2.** умырткалы; **~ые живóтные** умырткалы хайваннар **3.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. зоол.* умырткалылар

позднéйш||ий, -ая, -ее иң соңгы; **~ие достижéния** иң соңгы казанышлар

пóздн||ий, -яя, -ее **1.** соң, соңгы, ахыры, азагы; **~яя ночь** төн азагы **2.** соңга калып килгән, сонгарган, соңлаган; **в э́том году́ о́сень ~яя** быел көз соңга калып килде **3.** соң өлгерә торган, соң өлгерешле; **~ие сóрта я́блок** алманың соң өлгерә торган сортлары

пóздно *нареч.* **1.** азагында, ахырында; **~ о́сенью** көз ахырында **2.** соң, соңга калып, соңлап, кичегеп; **он ~ верну́лся домóй** ул өйгә соң кайтты; **я́блоки созре́ли ~** алмалар соңга калып өлгерде; **~ лечь** соң яту

поздоро́ваться *сов.* күрешү, исәнләшү; исәнлек-саулык сорашу

поздорове́ть *сов.* савыгу, тазару, тазарып китү, сәламәтләнү, сихәтләнү

поздоро́ви||ться *сов. безл.*: **не ~тся** *кому, разг.* яхшы булмас, авырга [туры] килер, рәхмәт әйтмәсләр, башыннан сыйпамаслар

поздрави́тельн||ый, -ая, -ое котлау ...ы, тәбрикләү ...ы; **~ая телегра́мма** котлау телеграммасы

поздра́вить *сов. кого-что с чем* котлау, тәбрикләү, тәбрик итү; **~ с пра́здником** бәйрәм белән тәбрик итү

поздравлéни||е *с* котлау сүзе; котлау кәгазе; тәбрикләү, котлау; **~е с пра́здником** бәйрәм унае белән тәбрикләү; **принима́ть ~я** котлаулар кабул итү

поздравля́ть *несов. см.* **поздра́вить**

позева́ть *сов.* иснәү, иснәп алу (*мәс. йокы килгәндә авызны тутырып ачып*)

позёвывать *несов. разг.* әледән-әле иснәп алу, ара-тирә иснәп кую

позелене́||ть *сов.* **1.** яшелләнү, яшәрү, ямь-яшел булу; **луга́ ~ли** болыннар ямь-яшел булган **2.** *разг.* агарыну, күгәренү; **~ть от доса́ды** ачудан күгәренү **3.** күгәрек басу, тутыгу, яшелләнү; **подсве́чник ~л** шәмдәлне күгәрек баскан

позём *м* (*навоз для удобрения*) тирес, җир ашламасы

поземе́льный, -ая, -ое җир ...ы, җир [биләгән] өчен салына торган; **~ нало́г** җир өчен салына торган налог

позёмка *ж* җәяүле буран

позёр *м книжн*, позёр, кыланчык

позёрство *с книжн.* позёрлык, кыланчыклык

пóзже *нареч.* соңрак, соңга табарак, кичегебрәк; **он пришёл ~ меня́** ул миннән соңрак килде

пози́ровать *несов.* **1.** бер позада тору, (*сурәт яки сын ясаучыга*) күчергеч булып тору **2.** *перен. книжн.* кыланчыклану

позити́в *м фото* позитив

позитиви́зм *м филос.* позитивизм (*философия агымы*)

позитиви́ст *м филос.* позитивист

позитиви́стск||ий, -ая, -ое *филос.* позитивист ...ы, позитивизм ...ы; **~ие взгля́ды** позитивизм карашлары

позити́вн||ый, -ая, -ое **1.** *фото* позитив ...; **~ое изображéние** позитив сурәт **2.** фактларга нигезләнгән, тәэҗрибәгә

нигезләнгән, позитив ...; **~ая програ́мма** тәэрибәгә нигезләнгән программа **3.** уңай формада белдерелгән, уңай, позитив ...; **~ое сужде́ние** уңай фикер йөртү

позитро́н *м физ.* позитрон

позицио́нн||ый, -ая, -ое позицион; **~ая война́** позицион сугыш (*ике яктан да ныгытылган позициядән торып сугышу*)

пози́ци||я *ж* **1.** позиция, тоткан урын; **вы́годная ~я** уңай позиция **2.** позиция, сугыш мәйданы; **артиллери́йская ~я** артиллерия позициясе; **на передовы́х ~ях** алгы позицияләрдә **3.** *перен.* позиция, караш, тоткан юл; **отста́ивать свою ~ю** үз карашыңны яклау **4.** *муз., спорт.* позиция, торыш; **си́льная ~я ладьи́ в ша́хматной па́ртии** шахмат партиясендә ладьяның көчле позиция алуы

позли́ть *сов. кого-что, разг.* [бераз вакыт] үчекләп тору, [бераз вакыт] ачуын китерү (кабарту), [бераз вакыт] ачуландыру

позли́ться *сов. разг.* [бераз вакыт] ачуланып тору, [бераз] усалланып тору

позлора́дствовать *сов.* кеше кайгысына шатланып тору

позлосло́вить *сов.* яманлап сөйләп алу, гайбәтен сату

познава́емость *ж книжн.* танып беленерлек булу, танып беленә алырлык булу, танып беленүчәнлек; **~ ми́ра** дөньяның танып беленүчәнлегә

познава́емый, -ая, -ое *книжн.* танып белергә мөмкин булган, танып беленә алырдай, танып беленерлек

познава́тельн||ый, -ая, -ое танып белү ...ы; **~ый проце́сс** танып белү процессы **2.** танып белүгә ярдәм итү ...ы, белемне арттыру ...ы; **~ое значе́ние литерату́ры** әдәбиятның танып белүгә ярдәм итү әһәмияте

познава́ть *несов. см.* **позна́ть**

позна||ва́ться *несов.* **1.** беленү, танылу, сыналу; **друзья́ ~ю́тся в беде́** дуслар бәлагә тарыганда сынала **2.** *страд. от* **познава́ть**

познако́мить *сов. кого* **1.** *с кем* таныштыру, таныштырып алу (чыгу, кую) **2.** *с чем* таныштыру; **~ с исто́рией кра́я** крайның тарихы белән таныштыру

познако́миться *сов.* **1.** *с кем* танышу, танышып алу (чыгу) **2.** *с чем* танышу; **~ с обстано́вкой** шартлар белән танышу

позна́ни||е *с* **1.** *см.* **позна́ть** 1, 2; **~е зако́нов приро́ды** табигать законнарын танып белү; **тео́рия ~я** танып белү теориясе **2.** *обычно мн.* **~я** белем; **на́ши ~я в о́бласти астроно́мии расширя́ются** безнең астрономия өлкәсендәге белемнәребез киңәя

позна́ть *сов. книжн.* **1.** *что* танып белү; **~ приро́ду** табигатьне танып белү; **~ су́щность веще́й** әйберләрнең асылын танып белү **2.** *кого-что* белү, белеп житкәрү, тану, сынау, аңлау, төшенү; **~ жизнь** тормышны аңлау **3.** *что* кичерү, тату, баштан үткәрү; **~ ра́дость** шатлык кичерү; **~ го́речь разлу́ки** читтә яшәүнең ачысын тату

позоло́та *ж* (*бер әр нәрсәгә*) йөгертелгән алтын, алтын катлавы

позолоти́ть *сов. что* алтынлау, алтынга манып алу, алтын йөгертеп җибәрү ♦ **~ пилю́лю** юмалау

позоло́ченн||ый, -ая, -ое алтынланган, алтынга манылган, алтын йөгертелгән; **~ые ло́жки** алтын йөгертелгән кашыклар

позонди́ровать *сов. что* (*предварительно выяснить*) чамалап карау, алдан сынап карау

позо́р *м* хурлык, рисвайлык, мәсхәрә, оят, йөз карасы; **клейми́ть ~ом** хурлык тамгасы салу; **покры́ть себя́ ~ом** хурлыкка калу

позо́рить *несов. кого-что* хурлыкка төшерү, оятка калдыру, адәм мәсхәрәсенә калдыру; **~ чьё-л. до́брое и́мя** *кемнең дә булса* керсез исеменә тап төшерү

позо́риться *несов.* хурлыкка калу; оятка калу, адәм мәсхәрәсенә калу

позо́рище *с разг.* хурлыклы күренеш, хурлык, мәсхәрә

позо́рный, -ая, -ое хурлыклы, мәсхәрәле; **~ слу́чай** хурлыклы хәл

позуме́нт *м* кәйтән, укалы тасма

позы́в *м* теләү, ...сы килү; **~ на рво́ту** косасы килү

позыва́||ть *несов. безл. кого-что* теләү, ...сы килү; **~ет на рвоту** косасым килә

позывн||о́й, -а́я, -о́е **1.** чакыру ...ы, дикъкатьне тарту ...ы; **~о́й сигна́л** чакыру сигналы **2.** *в знач. сущ.* **~ы́е** *мн.* позывнойлар (*радиостанцияне яки судноны таныту өчен хезмәт итә торган сигналлар*)

поигра́ть *сов.* уйнап алу, бераз уйнау, уйнап бераз вакыт уздыру; **~ с детьми́** балалар белән бераз уйнап алу

пои́грывать *несов. разг.* уйнаштыргалау, вакыт-вакыт уйнап алу; **~ на балала́йке** балалайка уйнаштыргалау

поиздева́ться *сов. над кем-чем* [бераз] мыскыл итеп алу, [бераз] мәсхәрәләп алу, [бераз] хурлап алу

поиздержа́ться *сов. разг.* [шактый акчаны] тотып бетерү, [шактый акчаны] туздырып бетерү, [шактый акчаны] сарыф итеп бетерү

поизмыва́ться *сов. разг. см.* **поиздева́ться**

поизноси́ться *сов. разг.* тузып (искереп) бетү

пои́лец *м:* **~ и корми́лец** *уст.* туйдыручы, ашатучы-эчертүче

пои́лка *ж* су эчергеч, эчергеч; **автомати́ческая ~** автомат су эчергеч

поимённо *нареч.* исемнәрен атап, бер-бер артлы исемнәрен әйтеп; **вызыва́ть ~** бер-бер артлы исемнәрен әйтеп чакыру

поимённ||ый, -ая, -ое исемләп, исемнәрен атап төзелгән; **~ый спи́сок** исемнәрен атап төзелгән исемлек; **~ое голосова́ние** исемләп тавышка кую

поименова́ть *сов. кого-что, офиц.* исемнәрен атап чыгу, исемнәрен әйтеп санап чыгу; **~ всех прису́тствующих** барлык катнашучыларны исемнәрен әйтеп санап чыгу

пои́мка *ж см.* **пойма́ть** 1; **~ престу́пника** җинаятьчене тоту

поиму́щественный, -ая, -ое милек ...ы, мал-мөлкәттән алына торган; **~ нало́г** милек налогы

поинтересова́ться *сов. чем* кызыксыну күрсәтү, кызыксыну, беләсе килү; **~ успе́хами сы́на** улыңның уңышларын белән кызыксыну

по́иск *м* **1.** эзләү, эзләнү; **~ и ре́дкой кни́ги** сирәк очрый торган китап эзләү **2.** эзләнү; **геологи́ческий ~** геологик эзләнү **3.** *спец.* разведка; **ночно́й ~** төнге разведка

поиска́ть *сов. кого-что* эзләп карау, эзләү; **~ себе́ помо́щника** үзеңә ярдәмче эзләп карау

по́исков||ый, -ая, -ое, **поиско́в||ый**, -ая, -ое эзләнү ...ы, эзләнүләр алып бара торган; **~ые рабо́ты** эзләнү эшләре; **~ая па́ртия** эзләнүләр алып бара торган партия

пои́стине *нареч. книжн.* чыннан да, чынлап та, дөрестән дә, чын мәгънәсендә; **э́то ~ гениа́льное произведе́ние** бу чыннан да гениаль әсәр

поистра́титься *сов. см.* **поиздержа́ться**

пои́ть *несов. кого-что* **1.** эчерү, эчертү, сугару; **~ ча́ем** чәй эчерү; **~ лошаде́й** атларны сугару **2.** *разг.* (*аракы*) эчерү, сыйлау ♦ **~ и корми́ть** ашатып эчертеп тоту, асрау, карау, тәрбияләү

по́йло *с* ашлы су (*мал-туарга эчертү өчен*)

по́йма *ж* тугай, су баса торган болын

пойма́ть *сов.* **1.** *кого-что* тоту, тотып алу, элэктерү, каптыру; **~ пти́цу** кош тоту; **~ во́ра** каракны элэктерү **2.** *перен. что* туры китерү, тотып алу; **~ взгляд** күз карашын тотып алу **3.** *что* файдалану, туры китерү; **~ удо́бный моме́нт** уңайлы моментны туры китерү ♦ **~ на у́дочку** кармакка электерү, алдау

по́йменн||ый, -ая, -ое су баса торган, су астында кала торган; **~ые луга́** су баса торган болыннар

по́йнтер *м* пойнтер (*эт токымы*)

пойти́ *сов.* **1.** китеп бару, китү, бару; **я пошёл по́лем** мин ялан буйлап киттем; **он попроща́лся и пошёл** ул саубуллашты да китеп барды **2.** кузгалу, кузгалып китү, китү; **лёд на реке́ пошёл** елгада боз кузгалды **3.** йөри башлау; **ребёнок пошёл** бала тәпи йөри башлады; **часы́ пошли́** сәгать йөри башлады **4.** чыга башлау, ага башлау; **из трубы́ пошёл дым** морҗадан төтен чыга башлады; **из ра́ны пошла́ кровь** ярадан кан ага башлады **5.** ява башлау; **пошёл си́льный дождь** көчле яңгыр ява башлады **6.** китү, бару; **да́льше доро́га пошла́ ле́сом** аннан соң юл урман эчләтеп барды **7.** кабу, элэгү; **на таки́х черве́й ры́ба пойдёт хорошо́** мондый суалчанга балык яхшы каба **8.** керү, укырга керү; **он пошёл в медици́нский институ́т** ул медицина институтына керде **9.** үтү, үтә башлау, сатыла башлау; **това́р пошёл хорошо́** товар яхшы сатыла башлады **10.** бирелү, тапшырылу, җибәрелү; **бума́га пошла́ на по́дпись** кәгазь кул кую өчен

ПОК-ПОК

бирелде **11.** китү, тотылу, кирәк булу; **на халáт пошлó мнóго шёлка** халатка бик күп ефәк китте **12.** килешү; **э́та шля́па пошлá бы вам** бу эшләпә сезгә килешер иде **13.** куела башлау, күрсәтелә башлау; **сегóдня пойдёт нóвая картúна** бүген яңа картина куела башлый **14.** керү, кагылу; **гвоздь не пойдёт в стéну** кадак стенага кермәс ♦ **~ по плохóй (дурнóй) дорóге** начар юлга керү, бозыклык юлына керү; **пошёл вон!** кит моннан, югал күз алдымнан!; **éсли на то пошлó** әгәр аңа калса, әгәр алай кирәк икән; **он пошёл в отцá** ул атасына охшаган

покá **1.** *нареч.* хәзергә, әлегә, әле; **~ он у́чится** ул әле укый; **~ ничегó не извéстно** хәзергә бер нәрсә дә билгеле түгел **2.** *союз временной* ...ганда, ...ган чагында, ...ган арада; **~ он у́чится, нáдо емý помóчь** укыган чагында аңа ярдәм итәргә кирәк **3.** *союз временной* ...ганчы, ...ганга хәтле; **сиди́ здесь, ~ я не приду́** мин килгәнче шушында утыр **4.** *частица* хәзергә хуш, хәзергә сау булып тор; **ну, ~!** ярый, хәзергә хуш! ♦ **~ что** хәзергә; **~ что дово́лен** хәзергә канәгать

показ *м см.* **показáть** 1, 2, 3

показáн||ие *с* **1.** сөйләү, күрсәтү; **~ия совреме́нников** замандашларның сөйләве **2.** алынган мәгълүмат, алынган җавап; **пи́сьменные ~ия подсуди́мого** гаепләнүчедән алынган язма мәгълүматлар **3.** күрсәтү; **~ие термóметра** термометрның күрсәтүе

показáте||ль *м* **1.** *мат.* күрсәткеч **2.** күрсәткеч, билге; **~ли культу́рного ро́ста** культура үсешенен күрсәткечләре

показáтельн||ый, -ая, -ое **1.** гыйбрәт алырлык, үрнәккә алырлык; **~ый при́знак** үрнәккә алырлык сыйфат **2.** күрсәтмә; **~ый суд** күрсәтмә суд; **~ые выступле́ния фигури́стов** фигуристларның күрсәтмә чыгышлары **3.** үрнәк, үрнәк [булырлык]

показá||ть *сов.* **1.** *кому на кого-что* төртеп күрсәтү, күрсәтү **2.** *кого-что кому* күрсәтү; **~ть спекта́кль** спектакль күрсәтү; **~ть ученика́м музе́й** укучыларга музей күрсәтү **3.** *кого-что* таныту, күрсәтү; **~ть себя́ хоро́шим рабо́тником** үзенне яхшы работник итеп таныту **4.** *с союзом «что»* күрсәтү; **свиде́тель ~л, что зна́ет обвиня́емого** шаһит гаепләнүчене белгәнлеген күрсәтте

показá||ться *сов.* **1.** (*появиться*) күренү, пәйда булу; **из-за гор ~лась луна́** таулар артыннан ай күренде **2.** (*почудиться*) күренү, тоелу; **день ~лся мне óчень дóлгим** көн миңа бик озын [булып] тоелды **3.** (*явиться, прийти*) күренү, килү; **~ться впервы́е по́сле боле́зни** авырганнан соң әле беренче тапкыр күренү **4.** *кому* (*прийти для осмотра*) күренү, каралу; **~ться врачу́** врачка күренү

показн||о́й, -áя, -óе **1.** үрнәк, күрсәтмә; **~ó́й това́р** күрсәтмә товар **2.** ясалма, тышкы, риялы, күз буяу өчен генә [эшләнгән]; **~ы́е слёзы** ясалма күз яше

показýх||а *ж разг.* күз буяу, барысын да ал да гөл итеп күрсәтергә тырышу, яхшы атлы булып күренергә маташу; **устро́или ~у пе́ред нача́льством** начальниклар алдында барысын да ал да гөл итеп күрсәтергә тырыштылар

пока́зывать *несов. см.* **показáть**

пока́зываться *несов.* **1.** *см.* **показáться** 1, 3, 4; **2.** *страд. от* **пока́зывать**

покалéчить *сов. кого-что, разг.* имгәтү, гарип итү, гарипләндерү

покалéчиться *сов.* имгәнү, гарипләнү

пока́лыва||ть *несов. что, в чём, разг.* чәнчеп-чәнчеп алу, чәнчү алу, чәнчеп авырту; **бок (в боку́) ~ет** янбашларым чәнчеп авырта

покарáть *сов. кого-что* җәзалау, җәза бирү

покатáть *сов. кого-что* [бераз] йөртү, йөртеп алу, йөртеп китерү; **~ детéй на маши́не** балаларны машинада бераз йөртү; **~ на велосипéде** велосипедта йөртеп китерү

покатáться *сов.* [бераз] йөреп килү, йөреп алу; утырып йөрү; шуып алу; **~ на ло́дке** көймәгә утырып йөрү; **~ на лы́жах** чаңгы шуып алу

покати́||ть *сов.* **1.** *что* тәгәрәтү, тәгәрәтеп җибәрү, тәгәрәтеп алып китү, тәгәрәтеп илтү; **~ть бóчку к маши́не** мичкәне машинага таба тәгәрәтү **2.** *разг.* (*быстро поехать*) китү, китеп бару; **он ~л в го́род** ул шәһәргә китеп барды

покати́||ться *сов.* **1.** тәгәрәү, тәгәрәп китү; **мяч ~лся** туп тәгәрәп китте **2.** тәгәрәп төшү, шуып төшү; **~ться с горы́** таудан тәгәрәп төшү ♦ **~ться со́ смеху** *разг.* кычкырып көлеп җибәрү, эч катып көлү, егылып көлү

пока́тый, -ая, -ое сөзәк; **~ холм** сөзәк калкулык

покача́ть *сов.* **1.** *кого-что* тирбәтеп (атындырып) алу, бераз тирбәтү, бераз атындыру; **~ ребёнка** баланы тирбәтеп алу **2.** *чем* селеккәләп кую, чайкау, селкү; **~ голово́й** башны селкеп кую **3.** *что* [бераз] качать итеп алу; **~ во́ду** бераз су качать итеп алу

покача́ться *сов.* тирбәнеп (атынып) алу, бераз тирбәнү, бераз атыну; бераз чайкалу; **~ на каче́лях** бераз таган атыну

пока́чивать *несов.* **1.** *кого-что, чем* [бераз] тирбәткәләү, [бераз] тирбәндерү, тирбәтеп тору; жинелчә атындыру; селеккәләү; **~ голово́й** башны селеккәләү **2.** *безл.* (*о качке на воде*) чайкалдыру

пока́чива||ться *несов.* **1.** (*слегка качаться*) беркадәр тирбәлү, беркадәр чайкалу, тирбәлеп (чайкалып, атынып) тору **2.** (*при ходьбе*) алпан-тилпән килү; ава-түнә бару (килү); **он шёл, си́льно ~ясь** ул ава-түнә бара иде

покачну́||ть *сов. что* **1.** (*слегка качнуть*) селкетеп кую, тирбәтеп (чайкалдырып, селкетеп) җибәрү **2.** (*накренить*) кыйшайту; **бу́ря ~ла столб** давыл багананы кыйшайткан

покачну́ться *сов.* чайкалып (селкенеп) китү

пока́шливать *несов.* йөткергәләү, ютәлләштерү

пока́шлять *сов.* йөткергәләп алу, йөткереп-йөткереп алу, бераз ютәлләү, бераз йөткерү, ютәлләп йөрү

покая́ние *с книжн.* тәүбә, тәүбә итү, тәүбәгә килү

покая́нн||ый, -ая, -ое *книжн.* тәүбә ...ы, тәүбә итү ...ы; **~ые слова́** тәүбә итү сүзләре; **~ое письмó** тәүбә хаты

пока́яться *сов.* тәүбә итү; үкенү

поквита́ться *сов. разг.* **1.** (*отдать долг сполна*) исәпләшү, бурычны түләп бетерү **2.** *перен.* (*отомстить*) үч алу, үч кайтару, исәпләшү

покива́ть *сов.* баш селкеп (селеккәләп) кую, каккалап кую

покида́ть I *сов. разг. см.* **побросáть**

покида́ть II *несов. см.* **поки́нуть**

поки́ну||ть *сов. кого-что* **1.** ташлап китү, ташлау; **~ть го́род** шәһәрне ташлап китү **2.** *перен.* калмау, бетү; **си́лы ~ли его́** аның көче бетте ♦ **~ть на произво́л судьбы́** язмыш иркенә ташлау

покладáя: не ~ рук бертуктамый, армый-талмый, баш күтәрми; **рабóтать не ~ рук** бертуктамый эшләү

покла́дистый, -ая, -ое күндәм, сүз тыңлаучан, юл куючан

покла́жа *ж разг.* йөк; **тяжёлая ~** авыр йөк

поклева́ть *сов.* **1.** *что* (*склевать всё*) чүпләү, чүпләп (чукып) бетерү **2.** *что, чего* (*склевать немного*) чукыштырып (чүпләштергәләп) алу, бераз чукыштыру

поклёп *м разг.* яла, әләк; **возводи́ть ~** яла ягу

покло́н *м* **1.** баш иеп сәлам бирү, баш ию **2.** сәлам; **переда́ть ~** сәлам әйтү ♦ **идти́ на ~ [с ~ом]** барып баш ию, ялыну, ялварып сорау

поклоне́ние *с* табыну; баш ию

поклони́ться *сов. кому-чему* **1.** баш иеп сәламләү, баш ию **2.** *перен.* (*попросить*) ялынып сорау, ялыну, ялварып сорау

покло́нник *м* **1.** (*почитатель*) табынучы, хөрмәтләүче, баш июче **2.** (*влюблённый*) гашыйк булган кеше, сөюче, яратучы; мәгъшук

покло́нница *ж* **1.** (*почитательница*) табынучы хатын (кыз), хөрмәтләүче хатын (кыз); **~ джáзовой мýзыки** джаз музыкасына табынучы кыз **2.** (*влюблённая*) гашыйк булган хатын (кыз), сөюче хатын (кыз)

поклоня́ться *несов. кому-чему, высок.* **1.** баш ию, табыну, соклану; **~ тала́нту писа́теля** язучының талантына баш ию **2.** табыну; **~ и́долам** потка табыну; **~ огню́** утка табыну

покля́сться *сов. в чём, с союзом «что» и с неопр.* ант итү; **~ отомсти́ть** үч алырга ант итү

поко́ит||ься *несов. книжн.* **1.** *на чём* өстендә тору; нигезләнү; **зда́ние ~ся на про́чном фунда́менте** бина нык фундамент өстендә тора **2.** (*быть похороненным*) [кабердә] яту

поко́||й *м* 1. тынычлык, хәрәкәтсезлек, тынгылык; **в приро́де нет абсолю́тного ~я** табигатьтә абсолют хәрәкәтсезлек юк 2. тынычлык, тынлык, тынгы, маза; **больно́му ну́жен ~й** авыруга тыныч лык кирәк

поко́йник *м* 1. (*труп*) үлек, мәет 2. (*умерший как лицо, о к-ром упоминают*) мәрхүм

поко́йница *ж* 1. *см.* **поко́йник** 1; 2. (*умершая как лицо, о к-ром упоминают*) мәрхүмә

поко́йницкая *ж* үлекләр куя торган бина, мәетлек (*хастаханәдә*)

поко́йн||ый, -ая, -ое 1. (*спокойный*) тыныч, сабыр; **~ая ста́рость** тыныч картлык 2. (*удобный*) уңайлы; **~ый дива́н** уңайлы диван 3. (*умерший*) үлгән, мәрхүм 4. *в знач. сущ.* **~ый** *м* мәрхүм; **~ая** *ж* мәрхүмә; **почти́ па́мять ~ого** мәрхүмне хәтерләп искә алу ♦ **~ой но́чи** тыныч йокы

поколеба́ть *сов.* 1. *что* (*покачать*) бераз селкетү, бераз тирбәндерү 2. *перен. что* какшату, төшерү; **~ авторите́т** абруйны какшату 3. *перен. кого* (*вызвать в ком-л. сомнение*) икеләндерү, шикләндерү, шиккә төшерү

поколеба́||ться *сов.* 1. бераз селкенү, бераз тирбәну 2. *перен.* какшау; төшү; **его́ авторите́т ~лся** аның абруе төште 3. *перен.* икеләнеп тору; шикләну, шиккә төшү; **~ться не́сколько мину́т** берничә минут икеләнеп тору

поколе́ни||е *с* буын; **тре́тье ~е** өченче буын; **но́вое ~е тата́рских учёных** татар галимнәренең яңа буыны ♦ **из ~я в ~е** (*по наследству*) нәселдән нәселгә; (*по традиции*) буыннан буынга

поколоти́ть *сов.* 1. *что, по чему, во что и без доп.* бәргәләп (суккалап) алу; суккалап карау 2. *кого, разг.* (*побить*) дәмбәсләү, тукмау, кыйнау 3. *что, прост.* (*разбить всё, многое*) кырып (ватып) бетерү

поко́нчить *сов.* 1. *что, с чем* бетерү, тәмамлау, төгәлләү, очына чыгу; **~ с дела́ми** эшләрне бетерү; 2. *с кем-чем* бетерү, юк итү; **~ с враго́м** дошманны юк итү ♦ **~ с собо́й (с жи́знью)** үзеңүзе үтерү

покорёжить *сов. что, прост.* бөгәрләп бетерү; калҗайту, калҗайтып бетерү; кәкрәйтеп бетерү

покорёжи||ться *сов. прост.* бөгәрләнеп бетү; калҗаю, калҗаеп бетү; кәкрәю; **обло́жка кни́ги ~лась** китапның тышы бөгәрләнеп беткән

покоре́ние *с см.* **покори́ть**; **~ приро́ды** табигатьне буйсындыру

покори́тел||ь *м* 1. (*завоеватель*) яулап (сугышып) алучы 2. *перен.* җиңүче, буйсындыручы; **~и ко́смоса** галәмне буйсындыручылар; **~и целины́** чирәм җирләрне буйсындыручылар ♦ **~ь серде́ц** *шутл.* хатын-кызларны үзенә каратучы

покори́тельница *ж* буйсындыручы хатын (кыз), җиңүче хатын (кыз); **Валенти́на Терешко́ва — ~ ко́смоса** Валентина Терешкова — галәмне буйсындыручы хатын ♦ **~ серде́ц** *шутл.* ир-егетләрне үзенә каратучы хатын (кыз)

покори́ть *сов. кого-что* 1. (*завоевать*) яулап (сугышып) алу, чит илне яулап алу 2. *перен.* буйсындыру 3. *перен.* (*очаровать*) үзенә карату, таңга калдыру, күңелен бәйләү, әсир итү ♦ **~ се́рдце** үзеңне сөйдерү, мәхәббәтеңә ирешү

покори́ться *сов. кому-чему* буйсыну, баш ию, бирелү; **~ судьбе́** язмышка баш ию

покорми́ть *сов. кого-что* ашату, ашатып алу, бераз ашату; **~ ребёнка** баланы ашатып алу

покорми́ться *сов. разг.* ашау, ашап алу, туену, туклану

поко́рность *ж* буйсынучанлык, карусызлык, күндәмлек; **прояви́ть ~** күндәмлек күрсәтү

поко́рный, -ая, -ое буйсынучан, тыңлаучан, карусыз, күндәм ♦ **ваш ~ слуга́** *уст.* сезгә хөрмәт белән караучы, сезне ихтирам итүче

покоро́би||ть *сов.* 1. *что* (*от сырости и т.п.*) калҗайту, калҗайтып бетерү, калтайту, чалышайту; бөгәрләп бетерү 2. *перен. кого, разг.* күңелгә тию, жирәндерү, чиркандыру; жирәндергеч тәэсир итү: **всех ~ло от э́тих слов** *безл.* бу сүзләр бөтен кешегә жирәндергеч тәэсир итте

покоро́биться *сов.* калҗаю, калтаю, чалышаю; бөгәрләнеп бетү

покоря́ть *несов. см.* **покори́ть**

покоря́ться *несов.* 1. *см.* **покори́ться**; 2. *страд. от* **покоря́ть**

поко́с *м* 1. (*косьба*) печән чабу 2. (*время косьбы*) печән өсте, печән чабу вакыты 3. (*место косьбы*) чабулык, чабын, чабынлык

покоси́ть I *сов.* 1. *что* (*скосить, выкосить*) чабу, чабып алу 2. *что и без доп.* (*нек-рое время*) бераз чабу

покоси́||ть II *сов.* 1. *безл. что* кыйшайту, кыегайту; **око́нную ра́му ~ло** тәрәзә рамы кыйшайган 2. *что, чем* (*посмотреть искоса*) кырын карау

покоси́ться *сов.* 1. (*искривиться*) кыйшаю, кыегаю, янтаю 2. (*косо посмотреть*) кырын карау, кырын карап кую

покра́пать *сов.* сибәләү, сибәләп яву

покра́пывать *несов.* сибәләп тору, пыскаклап яву

покра́сить *сов.* 1. *что* буяу, буяп алу, буяп кую (чыгу) 2. *что и без доп.* (*некрое время*) ману, манып алу

покра́ска *ж см.* **покра́сить** 1; **~ двере́й** ишекләрне буяу

покрасне́ние *с* 1. *см.* **покрасне́ть**; 2. (*место*) кызарган урын

покрасне́ть *сов.* кызару, кызарып китү, кызара төшү, кызылсу төс керү; **гу́сто ~** кып-кызыл булып кызару

покрасова́ться *сов. разг.* кылану, кылангалап алу, купшылану

покрахма́лить *сов. что* [бераз] крахмаллау, крахмаллап алу; **~ бельё** керне крахмаллап алу

покриви́ть *сов.*: **~ душо́й** алдашу, ялганлау, ялган сөйләү

покриви́ться *сов.* 1. кәкрәю, кыегаю, чалышаю, кыйшаю 2. *разг.* (*сделать гримасу*) чырай бозу, чырай сыту

покри́кивать *несов.* кычкыргалап кую, кычкыргалау

покритикова́ть *сов. кого-что, разг.* тәнкыйтьләү, тәнкыйтьләп алу, тәнкыйть итеп алу

покро́в *м* каплам; япма; **расти́тельный ~** үсемлекләр япмасы; **сне́жный ~** кар капламы; **волосяно́й ~** йон (тәк) капламы ♦ **под ~ ом но́чи** төн караңгылыгыннан файдаланып

покрови́тель *м* яклаучы, канат астына алучы, химаяче

покрови́тельница *ж* яклаучы хатын (кыз)

покрови́тельственн||ый, -ая, -ое яклый торган, химаячел; **~ый вид** яклый торган кыяфәт ♦ **~ая окра́ска** *то же, что и* **мимикри́я**

покрови́тельство *с* яклау, канат астына алу

покрови́тельствовать *несов. кому-чему* яклау, канат астына алу, химая итү

покро́й *м* тегелеш, өлге, калып; **~ пла́тья** күлмәк тегелеше

покроши́ть *сов. что, чего* (*накрошить в каком-л. количестве*) [бераз] турау (тураклау), ваклау

покрыва́ло *с* япма, япкыч, җәймә

покрыва́ть *несов. см.* **покры́ть**

покрыва́ться *несов.* 1. *см.* **покры́ться**; 2. *страд. от* **покрыва́ть**

покры́||ть *сов.* 1. *кого-что* ябу, жәю, бөркәү, өртү, каплау; **~ть стол ска́тертью** өстәлгә ашъяулык жәю; **~ть ребёнка одея́лом** балага юрган ябу 2. *что* тышлау; **~ть шу́бу сукно́м** тунны постау белән тышлау 3. *что* каплау, томалау, каплап алу; **ту́чи ~ли не́бо** болытлар күк йөзен каплады 4. *что* каплау, түләп бетерү, кайтару; **~ть заду́лженность** бурычны каплау 5. *что* (*заглушить*) басу, басып китү, күмеп китү; **го́лос opа́тора ~л шум в за́ле** ораторның тавышы залдагы шау-шуны басты 6. *перен. кого-что* (*помочь скрыть*) яшерү, каплау, яшереп (каплап) калу; **~ть вину́** гаепне яшерү 7. *что* (*преодолеть какое-л. расстояние*) үтү, узу 8. *что, карт.* басу; ябу; **~ть вале́та тузо́м** валетны туз белән ябу 9. *кого, спец.* (*оплодотворить*) каплату, чаптыру ♦ **~ть позо́ром** *кого-что* хур итү, хурлыкка төшерү; **~ть сла́вой** *кого-что* данга күмү; **~ть та́йной** *кого-что* сер итү, яшерү

покры́||ться *сов.* 1. ябыну, бөркәнү; **~ться одея́лом** юрган ябыну; **~ться платко́м** яулык бөркәнү 2. каплану; **не́бо ~лось ту́чами** күк йөзе болытлар белән капланды; **лоб ~лся морщи́нами** маңгайны жыерчыклар каплаган

покры́шка *ж* 1. *разг.* (*крышка*) капкач, каплавыч 2. покрышка; **автомоби́льная ~** автомобиль покрышкасы

покупа́тель *м* сатып алучы, алучы

покупа́тельница *ж* сатып алучы хатын (кыз)

покупа́тельн||ый, -оя, -ое сатып алу ...ы; **~ая спосо́бность населе́ния** халыкның сатып алу сәләте

покупа́тельск||ий, -ая, -ое сатып алучы[лар] ...ы; **~ая конфере́нция** сатып алучылар конференциясе

покупа́ть *несов. кого-что* сатып алу

поку́пка *ж* **1. покупа́ть; ~ книг** китап[лар] сатып алу **2.** (*купленная вещь*) сатып алынган әйбер (товар)

покупно́й, -а́я, -о́е (*купленный*) сатып алынган; **~ хлеб** сатып алынган икмәк

поку́ривать *несов. что и без доп., разг.* тәмәке тарту (тарткалау), ашыкмыйча тәмәке тарту

покури́ть *сов. что и без доп.* [бераз] тәмәке тартып алу; **дава́й поку́рим** әйдә, тәмәке тартып алыйк

покуса́ть *сов. кого-что* тешләү, тешләп-тешләп алу, тешләштереп алу; (*о пчёлах*) чагу, чагып бетерү

покуси́ться *сов. на кого-что и с неопр.* (*попытаться что-л. сделать*)...га тырышып карау; хаслану, кул сузу, кул сузып карау; **~ на чужо́е иму́щество** кеше милкенә кул сузу

поку́сыва||ть *несов. кого-что* тешләштерү, тешләштергәләү; (*о пчёлах*) чакклау; **комары́ ~ют** черкиләр тешләштерә

поку́шать *сов., что, чего* ашау, ашап алу; ашап бетерү

покуша́ться *несов. см.* **покуси́ться**

покуше́ние *с* **1.** *см.* **покуси́ться 2.** (*попытка убить*) үтермәкче булу, үтерергә омтылып карау

пол I *м* (*мн.* **~ы́**) идән, идән сайгаклары; **деревя́нный ~** агач идән

пол II *м* (*мн.* **по́лы**) җенес ♦ **прекра́сный (сла́бый) ~** *шутл.* хатын-кызлар; **си́льный ~** *шутл.* ирләр

пол-, **пол-** *кайбер кушма сүзләрнең «ярты», «ярым» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **полпя́того** бишенче ярты; **полдере́вни** ярты авыл; **пол-я́блока** ярты алма; **пол-оборо́та** ярым әйләнеш (борылыш); **пол-ли́тра** ярты литр

пол||а́ *ж* чабу, итәк; **пра́вая ~а́** уң чабу ♦ **из-под ~ы́** итәк астыннан (*яшереп, астыртын*)

полага́||ть *несов.* ... дип уйлау (санау, белү, исәпләү); фараз итү; **мы ~ли совсе́м друго́е** без бөтенләй башкача уйлаган идек; **~ют, что он в Москве́** аны Мәскәүдә дип саныйлар

полага́ться I *несов. см.* **положи́ться**

полага́||ться II *несов.* тиеш булу, ярау; **кури́ть не ~ется** тәмәке тартырга ярамый; **мне ~ются отпускны́е [де́ньги]** миңа ял акчасы түләргә тиешләр

пола́ди||ть *сов. с кем-чем* килешү; тыныша алу, татулашу; **мы с ним всегда́ ~м** без аның белән һәрвакыт килешербез

пола́комиться *сов.* [бераз] сыйлану, сыйланып алу

пола́ти *только мн.* сәндерә

по́лба *ж бот.* борай

полбеды́ *нескл. в знач. сказ. разг.* зур бәла түгел; әллә ни зур бәла түгел; **э́то ещё ~** анысы әллә ни зур бәла түгел

по́лдень *м* көн уртасы (үзәге), төш, төш вакыты, өйлә

полдне́вный, -ая, -ое көн уртасындагы, төш вакытындагы, төшке; **~ зной** көн уртасындагы эсселек

по́лдник *м* полдник, кичке әбәт (*төшке аштан соң ашала торган җиңел аш*)

полдоро́г||и *ж* ярты юл; **останови́ться на ~е** ярты юлда туктап калу

по́л||е *с* **1.** (*засеянное*) кыр, басу; **па́хотное ~е** иген игәргә яраклы кыр; **ржано́е ~е** арыш басуы; **о́пытное ~е** тәжрибә кыры **2.** кыр, ялан; **бескра́йние ~я́** иксез-чиксез яланнар **3.** *перен.* мәйдан; **обши́рное ~е де́ятельности** кин эш мәйданы **4.** *обычно мн.* **~ я́** кырый, чит; **заме́тки на ~я́х тетра́ди** дәфтәр читендәге билгеләр; **шля́па с ~я́ми** кырыйлы эшләпә ♦ **лётное ~е** очыш кыры; **~е бра́ни** *уст.*, **~е би́твы** *высок.* сугыш кыры, сугыш мәйданы; **~е зре́ния** күз күреме, күрү мәйданы; **футбо́льное ~е** футбол кыры

полёвка *ж* кыр тычканы

полево́д *м* кырчы, кырчылык белгече

полево́дство *с* кырчылык

полево́дческ||ий, -ая, -ое кырчылык ...ы, кыр эшләре ...ы; **~ая брига́да** кырчылык бригадасы

полев||о́й, -а́я, -о́е **1.** кыр ...ы, басу ...ы; **~о́й стан** кыр станы; **~ы́е рабо́ты** кыр эшләре; **~ы́е цветы́** кыр чәчәкләре **2.** *воен.* кыр ...ы, хәрби; **~а́я артилле́рия** кыр артиллериясе; **~а́я по́чта** хәрби почта ♦ **~а́я пра́ктика** кырда үткәрелә торган практика

полега́ние *с с.-х.* сөрлегү; егылу; яту; **~ хлебо́в** ашлыкларның сөрлегүе

полега́ть *несов. см.* **поле́чь** 2

полего́ньку *нареч. разг.* акрын гына, ашыкмыйча, җайлап кына, ипләп кенә

полегча́ть *сов.* җиңеләю, җиңеләя төшү, җиңеләеп китү

полежа́ть *сов.* яту, ятып алу, ятып торып алу

полёживать *несов. разг.* ятып тору; яткалап алу

полезащи́тн||ый, -ая, -ое кыр саклау ...ы, кыр ышыклау ...ы; **~ые лесонасажде́ния** кыр ышыклау урманнары

поле́зность *ж* файдалылык; **~ но́вого препара́та** яңа дарунның файдалылыгы

поле́зн||ый, -ая, -ое **1.** файдалы; **~ое расте́ние** файдалы үсемлек **2.** файдалы, файдаланырга яраклы; **~ая жила́я пло́щадь** файдалануга яраклы торак мәйданы; **~ые ископа́емые** файдалы казылмалар

поле́зть *сов. разг.* **1.** (*начать лезть*) менә башлау, менеп китү **2.** (*войти, вступить*) керү, кереп китү; **~ в во́ду** суга кереп китү **3.** *за чем-л.* керү, тыгылу, кул тыгу; **~ в карма́н за спи́чками** кесәгә шырпы алырга тыгылу; **~ в шкаф за кни́гой** китап эзләп шкафка тыгылу **4.** *прост.* тотыну, башлау; **~ в дра́ку** сугышырга тотыну

полемизи́ровать *несов. с кем и без доп.* бәхәсләшү, сүз көрәштерү, моназара кылу

поле́мика *ж* моназара, бәхәс, сүз көрәштерү, полемика

полеми́ст *м* бәхәсче, моназарачы, полемикачы, полемикага оста булган кеше

полеми́ческ||ий, -ая, -ое **1.** бәхәсле, бәхәс тудыра торган, полемик...; **~ая статья́** бәхәсле мәкалә **2.** *см.* **полеми́чный**

полеми́чный, -ая, -ое сүз көрәштерә торган, бәхәскә хас, бәхәсләшә торган; бәхәсләшүчән; **~ тон** бәхәсләшкән тон

полени́ться *сов.* ялкаулану, ирену, авырсыну, [берникадәр вакыт] иренеп тору

поле́нница *ж* әрдәнә, утын өеме

поле́но *с* утын агачы, пүлән

поле́сье *с* сазлыклы әрәмәлек

полёт *м* очу, очыш; **~ на Луну́** Айга очу ♦ **~ мы́сли** фикерләр омтылышы; **~ фанта́зии** хыял диңгезендә йөзү

полета́ть *сов.* бераз очу, очып алу, очып йөрү

полете́ть *сов.* **1.** очу, очып китү **2.** *перен.* (*помчаться*) чабу, йөгерү, чабып китү **3.** *перен. разг.* (*свалиться*) егылып китү (төшү), төшеп китү **4.** (*начать быстро протекать — о времени*) бик тиз үтә башлау, бик тиз үтеп китү

поле́чь *сов.* **1.** *разг.* яту, ятып бетү; **все полегли́ спать** барысы да йокларга яттылар **2.** сөрлегү; егылу; **пшени́ца полегла́** бодай сөрлеккән **3.** (*быть убитым — о многих*) ятып калу, үлеп калу

по́лзать *несов.* **1.** шуышу, үрмәләү, шуышып (үрмәләп) йөрү **2.** *перен. разг.* (*унижаться*) табан ялау, төлинкә тоту; **~ в нога́х** *у кого кемнең дә булса* табанын ялау ♦ **~ на четвере́ньках** мүкәләп йөрү

ползко́м *нареч.* шуышып, үрмәләп; **продвига́ться ~** шуышып бару

ползт||и́ *несов.* **1.** (*о пресмыкающихся*) шуышу, шуышып бару (килү); (*о человеке*) үрмәләү, үрмәләп бару (килү) **2.** *перен.* акрын бару (килү); **по́езд е́ле ~ёт** поезд бик акрын бара **3.** (*о растениях*) үрмәләп үсү (*мәс. чормавык турында*) **4.** *перен.* таралу; **~у́т слу́хи, оди́н друго́го неле́пее** берсеннән-берсе мәгънәсезрәк хәбәрләр тарала **5.** (*о тесте*) ташу, ташып чыгу **6.** *разг.* (*о ткани*) сыпылу, таралу

ползу́н *м* **1.** *разг.* (*о детях*) шуышып йөргән бала, шуышып йөрүче **2.** *тех.* шудырма (*машинаның шуышып йөри торган кисәге*)

ползун||о́к *м* **1.** *см.* **ползу́н** 1; **2. ~ки́** *мн.* ползунок (*кечкенә балалар киеме*)

ползу́ч||ий, -ая, -ее **1.** сөйрәлүче, шуышучы **2.** *бот.* җиргә ятып үсә торган; **~ие расте́ния** җиргә ятып үсә торган үсемлекләр

поли- *кушма сүзләрнең «күп», «төрле» мәгънәсен аңлата торган беренче кисәге, мәс.* **полифони́я** күп тавышлылык; **полиартри́т** буыннар шешү, буыннар сызлавы

поли́в *м см.* **поли́ть** 1; **бороздово́й ~** буразнаны сугару

полива́ть *несов. см.* **поли́ть** 1

поливитами́ны *мн.* поливитаминнар

поли́вка *ж см.* **поли́ть**

поливн||о́й, -а́я, -о́е **1.** сугарыла торган, су сибелэ торган; **~ы́е поля́** сугарыла торган басулар **2.** сугарылмалы; **~ о́е земледе́лие** сугарылмалы игенчелек

поли́вочн||ый, -ая, -ое су сибэ торган, сугара торган; **~ая маши́на** су сибэ торган машина

полига́мия *ж* күп никахлылык йоласы (*күп ирлелек яки күп хатынлылык*), полигамия

полигло́т *м* күп телләр белүче кеше, полиглот

полигО́н *м воен.* полигон; **артиллери́йский ~** артиллерия полигоны

полиграфи́ческ||ий, -ая, -ое полиграфия ...ы; **~ая промы́шленность** полиграфия промышленносте; **~ий комбина́т** полиграфия комбинаты

полиграфи́я *ж* полиграфия (*китап, журнал, газета һ.б.ш. нәрсәләр бастыру производствосы*)

поликли́ника *ж* сырхауханә, поликлиника; **де́тская ~** балалар поликлиникасы

полиме́рн||ый, -ая, -ое полимер ...; **~ые вещества́** полимер матдәләр

полиме́ры *мн.* полимерлар (*молекулаларындагы атомнар саны төрлечә булу белән аерыла торган бер үк химик төзелешле матдәләр*)

полиморфи́зм *м* полиморфизм (**1.** *биол. бер үк төрдәге тереклек ияләре яки үсемлекләр арасында бер-береннән бик нык аерыла торган индивидлар булу* **2.** *хим. бер үк матдәнең төрлечә кристаллаша алу үзлеге*)

полиня́л||ый, -ая, -ое уңган, төсе киткән; **~ая занаве́ска** уңган тәрәзә пәрдәсе

полиня́ть *сов.* **1.** (*напр. о ткани*) уңу, төсе китү **2.** (*о животных*) ябагасын кою; (*о животных, птицах*) йонын кою; (*о пресмыкающихся*) кабык салу

полиомиели́т *м мед.* полиомиелит (*арка миендәге соры матдәнең ялкынсынуы*)

поли́п *м* полип (**1.** *зоол. кузгалмыйча бер җирдә яши торган диңгез хайваны* **2.** *мед. тәннең лайлалы ярысы өстенә чыга торган кечкенә шешәсыман үсенте*)

полирО́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **полирова́ть; 2.** полировкаланган; шомартып ялтыратылган; **~ая ме́бель** полировкаланган мебель

полирова́ть *несов. что* полировкалау; шомартып ялтырату; **~ ме́бель** мебельне полировкалау

полиро́вка *ж* **1.** *см.* **полирова́ть; 2.** ялтыравык; **~ стола́ потре́скалась** өстәлнең ялтыравыгы чатнаган

полиро́вщик *м* полировкалаучы; шомартып ялтыратучы

по́лис *м* полис (*милекне, тормышны страховкалау турында документ*)

полисме́н *м* полисмен (*Англиядә һәм АКШта полицейский*)

политᵃ *кушма сүзләрдә «политик», «сәяси» мәгънәсен белдерә торган кыскартма, мәс.* **политрабо́та** сәяси эш; **политрабо́тник** сәяси-тәрбия эшләрен алып баручы кеше; **политру́к** политрук; **политуправле́ние** сәяси идарә итү, политуправление

политбюро́ *с нескл. ист.* политбюро

политехниза́ция *ж см.* **политехнизи́ровать**

политехнизи́ровать *сов., несов. что* политехникалаштыру, политехнизацияләү, политехнизм керту; **~ шко́лу** мәктәпне политехникалаштыру

политéхникум *м* политехникум (*урта техник белем бирә торган уку йорты*)

политехни́ческий, -ая, -ое политехника ...ы, политехник ...; **~ институ́т** политехник институт

политзаключённый *м* сәяси тоткын

политзаня́тия *мн.* сәяси укулар

поли́тик *м* политик, сәяси эшлекле; сәясәтче

поли́тик||а *ж* **1.** сәясәт; **ми́рная ~а** тынычлык сәясәте **2.** *перен. прост.* ният, хәйлә; **я твою́ ~у зна́ю** мин синең хәйләңне беләм

политика́н *м* политикан (*хәйлә коручы, принципсыз, мәкерле кеше*)

политика́нство *с* политиканлык, политикан булу, үзен политиканнарча тоту, сәясәтчәнлек

поли́тико-воспита́тельн||ый, -ая, -ое сәяси тәрбия ...ы; **~ая рабо́та** сәяси тәрбия эшләре

политинформа́тор *м* политинформатор, политинформацияләр үткәрүче

политинформа́ция *ж* политинформация

полити́ческ||ий, -ая, -ое сәясәт, сәяси, сәясәт белән бәйләнешле; **~ий строй** сәяси төзелеш; **~ая борьба́** сәяси көрәш; **~ие права́** сәяси хокуклар ♦ **~ая эконо́мия** *см.* **политэконо́мия**

полити́чный, -ая, -ое *разг.* бик нечкәләп уйланылган; алдын-артын уйлап эш итә торган, үзен-үзе тота белә торган, тактлы

политу́ра *ж* политура (*полировка өчен спиртлы лак*)

политучёба *ж* сәяси уку, сәяси белем алу

поли́||ть *сов.* **1.** *кого-что* сибү, су сибү; сугару; **~ть цветы́** чәчәкләргә су сибү **2.** *без доп.* (*начать лить*) ява башлау, коеп ява башлау; **неожи́данно ~л дождь** көтмәгәндә яңгыр коеп ява башлады

поли́||ться *сов.* **1.** (*начать литься*) ага башлау; **из кра́на ~ла́сь вода́** кранннан су ага башлады **2.** (*полить себя*) коену, өстенә су кою **3.** *перен.* башлану; **~ла́сь бесе́да** әңгәмә башланды

политэконо́мия *ж* политэкономия, политик экономия

полифони́ческ||ий, -ая, -ое *муз.* күп тавышлы, полифоник, полифониягә бәйләнешле; **~ая му́зыка** полифоник музыка

полифони́я *ж муз.* күп тавышлылык, полифония

полице́йск||ий, -ая, -ое **1.** полиция ...ы; **~ий чино́вник** полиция чиновнигы **2.** *в знач. сущ.* **~ий** *м* полицейский **3.** полиция ...ы, полициягә таянган, башбаштаклыкка корылган; **~ие ме́тоды управле́ния** идарә итүдә полиция методлары

поли́ция *ж* полиция (**1.** *кайбер илләрдә: тәртипне саклау органы* **2.** *собир. полицейскийлардан торган кораллы отряд*)

поли́чн||ое *с*: **поймА́ть с ~ым** җинаять өстендә тоту

полиэтиле́н *м* полиэтилен (*утә куренмәле каты полимер*)

полиэтиле́новый, -ая, -ое полиэтилен..., полиэтилен ...ы; полиэтиленнан эшләнгән; **~ паке́т** полиэтилен пакет

полк *м* **1.** *воен.* полк **2.** *перен.* өер, көтү, төркем; **це́лый ~ проси́телей** бер төркем сораучылар ♦ **на́шего ~ý при́было** безнең сафта кеше артты, арабызга тагын берәү өстәлде

по́лка I *ж* **1.** шүрлек, киштә; **кни́жная ~** китап киштәсе **2.** урын, полка, (*вагонда*); **ни́жняя ~** аскы урын

по́лка II *ж см.* **поло́ть**; **~ карто́феля** бәрәңге утау

полко́вник *м* полковник

полково́дец *м* полководец, гаскәр башлыгы

полков||о́й, -а́я, -о́е *воен.* полк ...ы; **~ о́е зна́мя** полк байрагы

полне́ть *несов.* калынаю, юанаю, симерү

полни́||ть *несов. кого-что, разг.* юанайту, юан итеп күрсәту; **э́то пла́тье её ~т** бу күлмәк аны юан итеп күрсәтә

по́лнит||ься *несов.*: **слу́хом земля́ ~ся** хәбәр дөньяга тиз тарала

по́лно *в знач. сказ. с неопр., разг.* җитте, җитәр, җитәрсәнә, ташла, куй; **~ пла́кать** җитәр, елама

полно́ *нареч. разг.* тулы, туп-тулы; **в клу́бе ~ наро́ду** клубта кеше тып-тулы

полно- *кайбер кушма сүзләрнең «тулы» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **полноли́цый** тулы йөзле

полнове́сность *ж* тиешле авырлылык, тулы авырлыклылык

полнове́сный, -ая, -ое **1.** тиешле авырлыктагы, тулы авырлыклы **2.** *перен. разг.* (*сильный*) авыр, каты; **~ уда́р** каты сугу

полновла́стие *с* тулы властьлылык

полновла́стный, -ая, -ое тулы властьлы

полново́дн||ый, -ая, -ое күп сулы, тулы сулы; **~ая река́** күп сулы елга

полново́дье *с* ташу; **весе́ннее ~** язгы ташу

полногла́сие *с лингв.* тулы сузыклылык (*борынгы славян телендәге ра, ла, ре, ле урынына рус, украин, белорус телләрендә -оро-, -оло-, -ере-, -еле-, -елотезмәсе килү, мәс.* **зла́то — зо́лото, град — го́род, брег — бе́рег, мле́чный — моло́чный, шлем — шело́м**)

полнозву́чный, -ая, -ое тулы яңгырашлы; **~ го́лос** тулы яңгырашлы тавыш

полнокро́вие *с* тулы канлылык, кан күплек

полнокро́вн||ый, -ая, -ое **1.** тулы канлы **2.** *перен.* тулы канлы, вакыйгаларга бай; **~ая жизнь** тулы канлы тормыш

полнолу́ние *с* тулы ай, тулган ай

полнометра́жный, -ая, -ое *кино* тулы метражлы; **~ фильм** тулы метражлы фильм

полномо́чи||е *с* полномочие, хокук, вәкаләт; **превы́сить свои́ ~я** үз вәкаләтеннән узып китү

полномо́чный, -ая, -ое тулы хокуклы, тулы вәкаләтле, тулы вәкаләт бирелгән; **~ представи́тель** тулы хокуклы вәкил

полнопра́вие *с* тулы хокуклылык, тулы хокуклы булу

полнопра́вный, -ая, -ое тулы хокуклы; **~ граждани́н** тулы хокуклы гражданин

по́лностью *нареч.* тулысынча, тулысы белән, бөтенләй, барын да

полноте *см.* **по́лно; ну, ~, что за счёты!** ташлагыз инде, нинди исәпләшү ди ул!

полноце́нн||ый, -ая, -ое **1.** тулы кыйммәтле; **~ая валю́та** тулы кыйммәтле валюта **2.** яхшы сыйфатлы, бик яхшы; **~ая рабо́та** яхшы сыйфатлы эш

полно́чный -ая, -ое төн уртасы ...ы, ярты төн ...ы

по́лночь *ж* төн уртасы, ярты төн

по́лн||ый, -ая, -ое **1.** тулы; **~ый стака́н** тулы стакан **2.** симез, юан; **~ый мужчи́на** юан ир кеше **3.** тулы, бөтенләй, тулысынча; **~ое разоруже́ние** тулысынча коралсызлану; **~ая тишина́** тулы тынлык; **~ый отве́т** тулы җавап ◆ **в ~ом разга́ре** иң кызган чакта; **в ~ом расцве́те сил** чәчәк аткан чагында; **в ~ом смы́сле сло́ва** чыннан да, чын мәгънәсендә, тулысынча, бөтенләе белән; **на ~ом ходу́** бик кызу барганда; **~ы́м- ~о́** бик күп; туп-тулы, шыгрым тулы

по́ло *с нескл. спорт.* поло (*ат атланып туп уйнау*)

полови́к *м* идән кәләме (паласы)

полови́н||а *ж* **1.** ярты, яртысы; ярым; **~а я́блока** ярты алма; **~а девя́того** тугызынчы ярты; **два с ~ой** ике ярым **2.** як; **пере́дняя ~а до́ма** өйнең алгы ягы **3.** урта, ярты; **в пе́рвой ~е двадца́того ве́ка** егерменче гасырның беренче яртысында **4.** *шутл.* (*о жене*) җәмәгать, иптәш

полови́нн||ый, -ая, -ое ярты; **купи́ть за ~ую сто́имость** ярты хакына сатып алу

полови́нчатость *ж* ярым-йортылык; икеле-микеле булу

полови́нчатый, -ая, -ое ярым-йорты, ярты-йорты; икеле-микеле; аныксыз, ачык булмаган; **~ отве́т** икеле-микеле җавап

полови́ц||а *ж* идән тактасы, сайгак; **скрипу́чие ~ы** шыгырдык сайгаклар

поло́вник *м разг.* аш чүмече

полово́дье *с* ташу, ташкын, су ташу; **весе́ннее ~** язгы ташу

полов||о́й I, -а́я, -о́е идән ...ы; **~а́я тря́пка** идән чүпрәге

полов||о́й II, -а́я, -о́е җенес ...ы, җенси ...; **~ы́е о́рганы** җенси органнар

по́ловцы *мн.* половецлар, кыпчаклар (*борынгы төрки халык*)

по́лог *м* **1.** чыбылдык, чаршау **2.** *перен. поэт.* караңгылык; **под ~ом но́чи** төн караңгылыгында

поло́гий, -ая, -ое сөзәк; **~ бе́рег** сөзәк яр

поло́гость *ж* сөзәклек

положе́ни||е с **1.** торыш, урын; **определи́ть ~е плане́ты** планетаның урынын билгеләү **2.** (*поза*) килеш, торыш, көй; **в лежа́чем ~и** яткан килеш **3.** (*состояние*) хәл; халәт; **войти́** *в чьё-л.* **~е** *кемнең дә булса* хәленә керү **4.** тоткан урын, урын, дәрәҗә; хәл; **семе́йное ~е** гаилә хәле; **социа́льное ~е** социаль хәл **5.** хәл; **междунаро́дное ~е** халыкара хәл **6.** (*свод правил*) кагыйдәнамә, кагыйдәләр; **~ о вы́борах** сайлаулар турында кагыйдәнамә **7.** (*тезис*) төп фикер; **основны́е ~я кни́ги** китапның төп фикерләре ◆ **в ~и** йөкле, балага узган

поло́женный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **положи́ть**; **2.** тиешле, билгеләнгән, билгеләп куелган; **в ~ час** билгеләнгән сәгатьтә

положи́тельно *нареч.* **1.** (*утвердительно*) уңай, яхшы; **отве́тить ~** уңай җавап бирү **2.** *в знач. частицы* (*совершенно*) бөтенләй, һич; **он ~ ничего́ не зна́ет** ул бөтенләй бернәрсә дә белми

положи́тельн||ый, -ая, -ое **1.** уңай; **~ый результа́т** уңай нәтиҗә; **~ое влия́ние** уңай тәэсир **2.** яхшы, төпле, эшлекле; **~ый челове́к** яхшы кеше **3.** *мат., физ.* уңай, позитив; **~ое число́** уңай сан; **~ый по́люс** уңай полюс; **~ый заря́д** уңай корылма ◆ **~ая сте́пень сравне́ния** *грам.* гади дәрәҗә

положи́ть *сов.* **1.** *кого-что* салу, кую; урнаштыру; **~ са́хар в чай** чәйгә шикәр салу; **~ вещь на своё ме́сто** әйберне үз урынына кую; **~ де́ньги в сберба́нк** акчаны саклык банкысына салу; **~ больно́го в больни́цу** авыруны хастаханәгә салу **2.** *в знач. вводн. сл.* **поло́жим, поло́жим, что ...** әйтик ... ди, шулай булды ди ..., шулай да булсын ...; **поло́жим, что мы оши́блись** әйтик, без ялгышканбыз ди ◆ **положа́ ру́ку на́ сердце** чын күңелдән; **~ жизнь** *за кого-что* башын салу, корбан булу, җанын фида кылу; **~ коне́ц** бетерү, чик кую; **~ на о́бе лопа́тки** 1) көрәштә җиңү (җиңеп чыгу); 2) *перен.* бәхәстә җиңү (җиңеп чыгу); **~ нача́ло** *чему* башлап җибәрү

положи́ться *сов.* ышану, таяну; **я на вас всегда́ могу́ ~** мин сезгә һәрвакыт таяна алам

по́лоз I *м* (*у саней*) чана табаны; **скрип поло́зьев** чана табанының шыгырдавы

по́лоз II *м зоол.* полоз (агусыз елан)

поломать **1.** *что* вату, сындыру, ватып (сындырып) бетерү **2.** *перен. кого-что* җимерү, вату, изү; **~ жизнь** *кому* тормышын җимерү

поломаться *сов.* **1.** сыну, ватылу, сынып (ватылып) бетү **2.** *перен. разг.* (*покривляться*) кылану, киреләнү

поло́мка *ж* **1.** *см.* **поломать** 1; **2.** (*повреждённое место*) ватылган урын, ватык, ватык җир, сынык җир

полоне́з *м* полонез (*танец*)

поло́ний *м хим.* полоний

полоса́ *ж* **1.** полоса, тар кисәк, буй; **~ же́сти** калай полосасы **2.** буй, сызык, буй сызык, эз; **обо́и с голуби́ми ~ми** зәңгәр буй төшкән обойлар **3.** полоса, зона; **лесозащи́тная ~** ышыклау урман полосасы; **чернозёмная ~** кара туфраклы зона; **~ оборо́ны** оборона полосасы **4.** *уст.* (*земельный участок*) җир, басу **5.** *перен.* (*период времени*) вакыт, дәвер, чор; **счастли́вая ~ в жи́зни** тормышның бәхетле чоры **6.** *полигр.* бит, сәхифә, полоса

полоса́т||ый, -ая, -ое буйлы, буй-буй, юллы-юллы; **~ый халя́т** буй-буй халат; **~ые обо́и** буйлы обой

поло́ск||а *ж уменьш. от* **полоса́** 1, 2, 4; **~а бума́ги** тар гына кәгазь кисәге ◆ **в ~у** буй-буй

полоска́ние *с* **1.** *см.* **полоска́ть** 1; **~ белья́** кер чайкау **2.** (*лекарство*) авыз чайкау даруы

полоска́тельница *ж* савыт-саба, юу савыты

полоска́ть *несов.* **1.** *что* чайкау; **~ бельё** кер чайкау; **~ рот** авыз чайкау **2.** *перен. что, чем* җилфердәтү, чайкалдыру; **ве́тер поло́щет знамёна** җил байракларны җилфердәтә

полоска́ться *несов.* **1.** чупырдашып су коену, чупырдашу **2.** *перен.* (*развеваться на ветру*) җилфердәү, чайкалу

полосну́ть *сов. кого-что, прост.* сыдырып җибәрү; **~ кнуто́м** чыбыркы белән сыдырып җибәрү

полосова́ть *несов.* **1.** *что, тех.* буй-буй итеп кисү, буй-буй итеп телү; **~ жесть** калайны буй-буй итеп кисү **2.** *кого, прост.* (*бить, оставляя рубцы*) яру, кыйнау

полосов||о́й, -а́я, -о́е *тех.* буй, тасмасыман; **~о́е желе́зо** тасмасыман калай

по́лость I *ж анат.* куышлык; **~ рта** авыз куышлыгы

по́лость II *ж* ябу, ябулык, япма (*чанада, арбада*)

полоте́нечн||ый, -ая, -ое сөлгелек ...; **~ая ткань** сөлгелек тукыма

полоте́нце *с* сөлге, тастымал; **ручно́е ~** кул сөлгесе

полотёр *м* полотёр, идән ялтыратучы

поло́тнищ||е *с* ин; **па́рус в четы́ре ~а** дүрт инле җилкән

полотно́ *с* **1.** (*ткань*) киндер, киндер тукыма; тукыма **2.** *жив.* полотно, рәсем (*гадәттә киндергә ясала торган*); **~ Ре́пина** Репин рәсеме **3.** *ж.-д.* полотно **4.** *тех.* тасма; **~ конве́йера** конвейер тасмасы

полотня́н||ый, -ая, -ое полотно ...ы, киндер ...; **~ая руба́ха** киндер күлмәк

поло́ть *несов. что* утау

полоу́мный, -ая, -ое *разг.* ярты акыллы, акылга сай, тиле-миле; акылдан язган, юләр, тиле

полпути́ *м нескл.* ярты юл; **останови́ться на ~** ярты юлда туктап калу

полсло́в||а *с* **1.** сүзнең яртысы, ярты сүз; **останови́ться на ~е (полусло́ве)** ярты сүздә туктау; **с ~а (полусло́ва) понима́ть** беренче сүздән үк аңлау; **ни ~а от него́ не услы́шишь** аңардан бер авыз сүз дә ишетә алмассың

полти́нник *м разг.* илле тиен, ярты сум, ярты тәнкә; илле тиен көмеш

полтор||а́ *м, с числ.* бер ярым; **~а́ ме́тра** бер метр ярым; **в ~а́ ра́за бо́льше** бер ярым мәртәбә күбрәк

полтора́ста *числ.* йөз илле; **~ рубле́й** йөз илле сум

полторы́ *ж см.* **полтора́; ~ ты́сячи** мең ярым

полу- *кайбер кушма сүзләрнең «ярым», «ярты», «яртылаш» яки «тулысынча булмаган, ...диярлек» мәгънәсен аңлаткан кисәге, мәс.* **полуоткры́тый** яртылаш ачык, азрак ачылган; **полуофициа́льный** ярым рәсми; **полушерстяно́й** ярым йон, йон катыш

полуботи́нки *мн.* сай ботинка, кунычсыз ботинка, полуботинка

полугла́сный, -ая, -ое *лингв.* ярым сузык

полуго́дие *с* ярты ел, ярты еллык елнын яртысы; **пе́рвое ~ уче́бного го́да** уку елының беренче яртысы

полугоди́чн||ый, -ая, -ое ярты еллык ...; **~ые ку́рсы** ярты еллык курслар

полугодова́лый, -ая, -ое ярты яшьлек ..., ярты яшьтәге; **~ ребёнок** ярты яшьлек бала

полугодово́й, -а́я, -о́е ярты еллык ...; **~ отчёт** ярты еллык отчёт

полуголо́дн||ый, -ая, -ое **1.** ачлы-туклы, ярым ач; **~ое существова́ние** ачлы-туклы яшәү **2.** туяр-туймас; **встава́ть из-за стола́ ~ым** өстәл яныннан туяр-туймас торып китү

полуго́лый, -ая, -ое ярым ялангач, ялангач диярлек

полугра́мотный, -ая, -ое ярым-йорты белемле, бик аз грамоталы, көчкә укый-яза белә торган

полу́да *ж* **1.** (*лужение*) кургаш йөгертү **2.** (*слой олова*) полуда, кургаш катлавы (*металл өстенә йөгертелгән*)

полу́денный, -ая, -ое төш вакытындагы, көн уртасындагы, төшке; **~ зной** көн уртасындагы эсселек

полуди́к||ий, -ая, -ое ярым кыргый, ярым вәхши; **~ие племена́** ярым вәхши кабиләләр

полузабы́т||ый, -ая, -ое яртылаш онытылып барган, онытылган; **~ые стихи́** яртылаш онытылган шигырьләр

полузащи́та *ж спорт.* ярым сак (*футбол яки хоккейда*), полузащита

полузащи́тник *м спорт.* ярым сакчы

полукро́вка *ж с.-х.* ярым (яртылаш) яхшы токымлы (*кубесенчә ат турында*)

полукро́вный, -ая, -ое *с.-х.* ярым (яртылаш) яхшы токымлы (*мал турында*)

полукру́г *м* ярты (ярым) түгәрәк; түгәрәкнең яртысы

полукру́гл||ый, -ая, -ое ярты (ярым) түгәрәк ...; **~ое окно́** ярым түгәрәк тәрәзә

полулежа́ть *несов.* кырын ятып тору, яртылаш ятып тору

полума́ска *ж* ярым маска (битлек)

полумгла́ *ж* ярым караңгылык

полуме́ра *ж* ярым-йорты чара; **поли́тика полуме́р** ярым-йорты чаралар сәясәте

полуме́сяц *м* ярым (ярты) ай

полумра́к *м* ярым караңгы[лык], эңгер-меңгер

полуно́чник *м разг.* төн кошы, төн пәрие, төнлә йөрүче

полуно́чница *ж* төнлә йөрүче хатын (кыз)

полуно́чничать *несов. разг.* ярты төнгә кадәр эшләү, ярты төнгә кадәр йөрү

полуоборо́т *м* ярым борылыш, ярты әйләнеш

полуосвещённ||ый, -ая, -ое ярым яктыртылган, аз гына яктыртылган

полуо́стров *м* ярымутрау

полупальто́ *с* кыска пальто

полуподва́л *м* ярым подвал

полуподва́льн||ый, -ая, -ое ярым подвал...; **~ое помеще́ние** ярым подвал бина

полупроводнико́вый, -ая, -ое ярымүткәргечле, ярымүткәргеч ...ы, ярымүткәргеч ...; **~ радиоприёмник** ярымүткәргечле радиоалгыч

полупусты́ня *ж* ярымчүл

полуразру́шенный, -ая, -ое яртылаш җимерек, ярым җимерек; **~ дом** ярым җимерек өй

полусапо́жки *мн.* кыска кунычлы итек

полусве́т *м* эңгер-меңгер, ярым яктылык, караңгылы-яктылы

полусло́в||о *с:* **на ~е** ярты сүздән; **оборва́ть на ~е** ярты сүздән бүлү (туктату); **с ~а** ярты сүздән; **поня́ть с ~а** ярты сүздән үк аңлау

полусме́рт||ь *ж:* до **~и** үләр хәлгә җиткәнче

полусо́н *м* ярым (яртылаш) йокы, уяулы-йокылы хәл

полусо́нн||ый, -ая, -ое йоклар-йокламас, уяулы-йокылы; **~ое состоя́ние** уяулы-йокылы хәл

полуста́нок *м ж.-д.* кечкенә станция (*тимер юлда*)

полуте́нь *ж* ярым күләгә (шәүлә)

полуто́н *м* **1.** *муз.* ярым тон **2.** *жив.* полутон ачык төс

полу́тора- *кушма сүзләрнең «ярым» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **полуторагоди́чный** ел ярымлык ...; **полуторагодова́лый** яшь ярымлык ...

полу́торка *ж разг.* полуторка, тонна ярымлык автомашина

полу́торн||ый, -ая, -ое бер ярымлык ..., бер ярым ...; **в ~ом разме́ре** бер ярым зурлыкта

полутьма́ *ж* ярым караңгылык

полуфабрика́т *м* ярымфабрикат

полуфина́л *м спорт.* ярым финал; **вы́йти в ~** ярым финалга чыгу

полуфина́льный, -ая, -ое *спорт.* ярым финал ...ы, ярым финалда ...

получасов||о́й, -а́я, -о́е ярты сәгатьлек ...; **~а́я речь** ярты сәгатьлек нотык

получа́тель *м* алучы; **~ почто́вого перево́да** почта белән җибәрелгән акчаны алучы

получа́ть *несов. см.* **получи́ть**

получа́ться *несов.* **1.** *см.* **получи́ться; 2.** *страд. от* **получа́ть**

получа́тельница *ж* алучы хатын (кыз)

получе́ни||е *с см.* **получи́ть; распи́ска в ~и де́нег** акча алу турында расписка

получи́ть *сов.* **1.** *кого-что* алу; **~ зарпла́ту** эш (хезмәт) хакы алу; **~ пода́рок** бүләк алу; **~ письмо́** хат алу; **~ о́рден** орден алу; **~ дипло́м** диплом алу **2.** *что* (*принять для исполнения*) алу; **~ зака́з** заказ алу **3.** *что* алу, чыгару, ясау; **~ бензи́н из не́фти** нефтьтән бензин алу **4.** *что* эләктерү, йоктыру; **~ на́сморк** томау эләктерү **5.** *что* алу; **~ вы́говор** шелтә алу ♦ **~ изве́стность** дан казану; **~ поврежде́ние** имгәнү; **~ по ше́е** *прост.* муен тамырына берне алу; **~ призна́ние** танылу; **~ примене́ние** кулланыла башлау; **~ распростране́ние** таралу; **~ удово́льствие** хозурлану

получи́||ться *сов.* чыгу, килеп чыгу; **~лся отли́чный результа́т** үтә яхшы нәтиҗә килеп чыкты; **~лось недоразуме́ние** аңлашылмау килеп чыкты

полу́чка *ж* **1.** *см.* **получи́ть** 1; **2.** *разг.* (*заработная плата*) получка, [алынган] эш хакы, хезмәт хакы

полуша́лок *м прост.* кечкенә шәл

полуша́рие *с* ярымшар; **ю́жное ~** көньяк ярымшар

полушёлков||ый, -ая, -ое ярым ефәк, ефәк катыш; **~ая мате́рия** ярым ефәк материя

полушерстян||о́й, -а́я, -о́е ярым йон, йон катыш; **~а́я ткань** ярым йон тукыма

полу́шк||а *ж уст.* чирек тиен (акча); **[нет] ни ~и** сукыр бер тиен дә юк

полушу́бок *м* кыска тун

полушутя́ *нареч.* ярым шаяртып; **сказа́ть ~** ярым шаяртып әйтү

полцены́ *ж* ярты бәясенә, бик арзанга; **прода́ть** *что-л.* **за ~** *нәрсәне дә булса* ярты бәясенә сату

полчаса́ *м* ярты сәгать

по́лчищ||е *с* **1.** (*войско*) дошман явы, бик күп гаскәр **2.** *мн.* **~а** (*множество*) бер көтү; дөнья; **~а комаро́в** черкиләр чирүе

полшага́ *м* ярты адым

по́л||ый, -ая, -ое **1.** куыш, куыш эчле, эче куыш; **~ый шар** эче куыш шар **2.** язгы ташу ...ы, язгы ташкын ...ы; **~ая вода́** язгы ташкын суы

по́лынь *ж уст.* ялкын, ут

полы́нн||ый, -ая, -ое **1.** әрем ...ы; **~ый за́пах** әрем исе **2.** әремгә төнәтелгән; **~ая во́дка** әремгә төнәтелгән аракы

полы́нь *ж* әрем

полынь́я *ж* җылу (*елгада, күлдә кыш көне су катмаган ачык урын*)

полисе́ть *сов.* пеләшләнү, пеләшләнә төшү, пеләшләнеп бетү

полыха́||ть *несов. см.* **полыхну́ть**; **ого́нь ~л с невероя́тной си́лой** ут бик каты дөрләп янды

полыхну́ть *сов. однокр.* дөрләп янып китү, ялкынланып яна башлау, кабынып китү

по́льза *ж* файда; **~ спо́рта** спортның файдасы

по́льзовани||е *с см.* **по́льзоваться**; **находи́ться в о́бщем ~и** гомуми файдалануда булу; **пра́во ~я** файдалану хокукы

по́льзоваться *несов. чем* **1.** файдалану; **~ электри́чеством** электрдан файдалану **2.** (*применять*) куллану; **~ хирурги́ческим инстру́ментом** хирургия коралы белән файдалану ♦ **~ уваже́нием** хөрмәт ителү; **~ успе́хом** уңыш казану; **~ популя́рностью** популяр булу

по́лька I *ж* поляк хатыны (кызы)

по́лька II *ж* полька (*бию һәм шуның өчен язылган музыкаль әсәр*)

по́льский, -ая, -ое поляк[лар] ...ы; Польша ...ы; **~ язы́к** поляк теле

польсти́||ть *сов. кому-чему* **1.** (*лицемерно похвалить*) ялагайланып мактау, ярарга тырышып мактау, салпы ягына салам кыстыру **2.** күңелен күтәрү, куандыру; **ему́ ~ло всео́бщее внима́ние** гомуми игътибар аны бик куандырды

польсти́ться *сов. на что* кызыгу, күз кызу

полюби́ть *сов. кого-что* сөю, ярату, гашыйк булу

полюби́||ться *сов. кому, разг.* яратылу, ошау, күңелгә ошау; **он мне давно́ ~лся** ул минем күңелгә күптән ошады

полюб||ова́ться *сов.* сокланып карап тору, кызыгып карау ♦ **~у́йтесь** менә карагыз инде!, менә күрегез инде!

полюбо́вный, -ая, -ое дусларча ..., дуслык нигезендә ..., татулык белән ...; **~ разде́л** *чего-л.* татулык белән бүлешү

полюбопы́тствовать *сов.* кызыксыну, беләсе килү

по-людски́ *нареч. разг.* кешечә, кешеләрчә, кешеләрдәй, адәмчә; **у тебя́ всё не ~** синең бер генә эшең дә кеше[ләр]чә түгел

по́люс *м* **1.** *геогр.* котып **2.** *физ.* полюс; **положи́тельный ~** уңай полюс; **отрица́тельный ~** тискәре полюс

поля́к *м* поляк, поляк кешесе

поля́ки *мн.* поляклар, поляк халкы

поля́на *ж* алан, аклан

поля́рник *м* котыпчы, полярник

поля́рность *ж* капма-каршылык; **~ мне́ний** фикерләрнең капма-каршылыгы

поля́рн||ый, -ая, -ое **1.** поляр ...; **~ая ста́нция** поляр станция; **~ое сия́ние** поляр балкыш; **~ый день** поляр көн; **~ая ночь** поляр төн; **Поля́рный круг** Поляр түгәрәк **2.** *перен.* (*противоположный*) капма-каршы; **~ые мне́ния** капма-каршы фикерләр

пома́да *ж* иннек, помада

пома́дить *несов. что* иннек (помада) сөртү

пома́диться *несов. разг.* иннек (помада) сөртенү

пома́дка *ж* помадка (*конфетның бер төре*); **фрукто́вая ~** жимеш помадкасы

пома́зать *сов. что* буяу, майлау, сөртү, ягу; **~ хлеб ма́слом** икмәккә май ягу

пома́заться *сов. разг.* сөртенү, бизәнү

помазо́к *м* майлавыч, пумалачык, помазок

помале́ньку *нареч. разг.* акрынлап, әкренләп; ашыкмыйча гына; аз-азлап кына; **живём ~** акрынлап яшәп ятабыз

пома́лкивать *несов. разг.* эндәшмәү, бер сүз дә әйтмәү, дәшми тору

поманя́ть *сов. кого-что* ымлап чакыру, ымлап чакырып алу

пома́рка *ж* төзәтмә, төзәтелгән урын (язуда)

пома́слить *сов. что* майлау, бераз май ягу (сөртү)

помаха́ть *сов. чем* болгау, болгап алу, болгап кую; селтәү, селтәп алу; **~ платко́м** яулык болгау

пома́хивать *несов. чем* селкеп-селкеп кую, болгап-болгап кую, селтәштерү, селеккәләү, болгаштыру, селеккәләп тору; **~ хвосто́м** койрык болгаштыру

поме́длить *сов.* көттерү, кичектерү; көтә төшү, сабыр итү; **~ с отве́том** җавапны көттерү

помело́ *с редко* пумала, мич пумаласы

поменя́ть *сов. кого-что* алмашу, алышу, алмаштыру, алыштыру, алмашып алу

поменя́ться *сов. чем* алмашу, алышу, алмаштыру, алыштыру

помера́нец *м бот.* тәрәнҗе (ачы әфлисун)

помера́нцев||ый, -ая, -ое *бот.* тәрәнҗе ...ы; **~ая ве́тка** тәрәнҗе ботагы

помере́ть *сов. разг.* үлү, үлеп калу ♦ **~ со́ смеху** эч катып көлү, үлә язып көлү

помере́щи||ться *сов. кому, разг.* күренгән шикелле булу, шулай булып күренү; **э́то тебе́ ~лось** бу сиңа шулай булып күренгән

помёрзнуть *сов. разг.* **1.** (*погибнуть от мороза*) өшеп (туңып) бетү; өшеп (туңып) һәлак булу **2.** (*берникадәр вакыт*) салкында тору, туңу

поме́рить *сов. что* (*примерить*) үлчәп карау, киеп карау

поме́риться *сов.* **1.** үлчәшү, үлчәшеп карау; **~ ро́стом** буйны үлчәшеп карау **2.** сынашу, сынашып карау; **~ си́лами** көч сынашып карау

поме́рк||нуть *сов. прям., перен.* сүну, яктылыгы бетү, тонykланып китү; **звёзды ~ли** йолдызлар сүнде; **сла́ва его́ ~ла** аның даны сүнде

помертве́л||ый, -ая, -ое үлек төсе кергән, көл кебек агарган; **с ~ым лицо́м** үлек төсе кергән йөз белән

помертве́ть *сов.* **1.** (*онеметь — о частях тела*) кату, күшегү, төймас булу **2.** катып калу, аптырап китү, үзгәрешсез хәлдә калу; **~ от стра́ха** куркудан катып калу

помести́тельный, -ая, -ое күп сыя торган; иркен, зур

помести́ть *сов.* **1.** *кого-что* урнаштыру, кую; **~ тури́стов в гости́ницу** туристларны кунакханәгә урнаштыру **2.** *что* салу; **~ де́ньги в сбербе́нк** акчаны саклык банкысына салу **3.** *что* (*опубликовать*) урнаштыру, бастырып чыгару; **~ объявле́ние в газе́те** газетга игълан урнаштыру

помести́ться *сов.* **1.** урнашу; **~ в ма́ленькой ко́мнате** кечкенә бүлмәгә урнашу **2.** сыю; **все ве́щи в чемода́н не помести́тся** әйберләрнең барысы да чемоданга сыймас

поме́стн||ый, -ая, -ое поместьелы; **~ые дворя́не** поместьелы дворяннар

поме́стье *с* поместье, алпавыт җире

по́месь *ж* **1.** азман, кушылгак **2.** *перен. разг.* (*смесь, смешение чего-л.*) кушылма

поме́сячн||ый, -ая, -ое айлык ...; ай исәбеннән түләнә торган; **~ая зарпла́та** айлык эш хакы

помёт I *м* бер оя бала (*хайваннарның бер тудыруда китергән балалары*)

помёт II *м* тизәк; **пти́чий ~** кош тизәге

поме́та *ж* билге; **граммати́ческая ~** грамматик билге; **стилисти́ческая ~** стилистик билге

поме́тить *сов. кого-что* билгеләү, билге кую; тамга салу, тамгалау

поме́тк||а *ж* билге; **де́лать ~и на поля́х кни́ги** китап читенә билгеләр кую

поме́ха *ж* комачау[лык], киртә, тоткарлык

помеча́ть *несов. см.* **поме́тить**

поме́шанный, -ая, -ое **1.** акылдан язган, тилергән, шашкан **2.** *перен. на ком-чем* саташкан, бик ныk мавыккан, бик ныk бирелгән; **~ на футбо́ле** футбол уены белән саташкан

помеша́тельство *с* акылдан язу, тилерү, акылдан шашу

помеша́ть I *сов. кому-чему* комачаулау, борчу

помеша́ть II *сов. что* [бераз] болгату, болгатып алу; **~ ка́шу** ботканы болгатып алу

помеша́ться *сов.* **1.** акылдан язу, акылдан шашу, тилерү; акылга жиңелүю **2.** *перен. на ком-чем, разг.* саташу, һәвәсләнеп китү, бик ныk бирелеп китү, бик ныk мавыгу; **~ на лошаде́й** атлар белән бик ныk мавыгу

поме́шивать *несов. что и без доп.* болгаткалау, бутау

помеща́ть *несов. см.* **помести́ть**

помеща́ться *несов.* **1.** *см.* **помести́ться**; **2.** (*находиться*) урнашу, урнашкан булу **3.** *страд. от* **помеща́ть**

помеще́ние *с* **1.** *см.* **помести́ть**; **~ статьи́ в газе́ту** мәкаләне газетка урнаштыру **2.** бина, йорт; **жило́е ~** торак йорт

поме́щик *м* алпавыт

поме́щица *ж* **1.** (*владелица поместья*) алпавыт хатын **2.** *разг.* (*жена помещика*) алпавыт хатыны

поме́щич||ий, -ья, -ье алпавыт ...ы; алпавытлар ...ы; **~ий гнёт** алпавыт изүе; **~ья земля́** алпавыт җире

помидо́р *м* помидор, томат

помидо́рн||ый, -ая, -ое помидор ...ы; томат ...ы; **~ый со́ус** помидор соусы; **~ая расса́да** помидор үрентесе

поми́ловани||е *с см.* **поми́ловать**; **про́сьба о ~и** гаепне гафу итүне үтенү

поми́ловать *сов. кого-что* гафу итү, кичерү, гаебен кичереп азат итү; **~ осуждённого** хөкем ителгән кешенең гаебен кичереп азат итү ◆ **поми́луй[те]** тукта[гыз] әле, нишләп алай булсын ди

поми́мо *предлог с род.п.* ...дан башка, ...мастан, исәпләшмичә, карамастан; **~ его́ жела́ния** аның теләге белән исәпләшмичә; **~ всего́ про́чего** боларның һәммәсеннән башка

поми́н *м*: **[и] в ~е нет** *кого-чего* юк, булганы да юк; **лёгок на ~е** *кто* гомерең озын булыр, сине генә сөйләп тора идек

прика́тывать *несов. см.* **прикати́ть**

прика́тываться *несов.* **1.** *см.* **прикати́ться; 2.** *страд. от* **прика́тывать**

прики́дка *ж разг. см.* **прики́нуть**

прики́дывать *несов. см.* **прики́нуть**

прики́дываться *несов.* **1.** *см.* **прики́нуться; 2.** *страд. от* **прики́дывать**

прики́нуть *сов. разг.* **1.** *что, чего* (*прибавить*) өстәү **2.** *что* (*примерить*) киеп (бөркәнеп, ябынып, ябып *h.б.ш.*) карау; **~ костю́м** костюмны киеп карау **3.** *что* салып ...ып карау; **~ на веса́х** үлчәүгә салып үлчәп карау; **~ на счётах** счётка салып исәплән карау **4.** *что и без доп.* уйлап (исәпләп, чамалап) карау; **~ в уме́** уйлап карау; **~ на гла́з** күз белән чамалап карау; **~ на руке́** кулга салып чамалап карау

прики́нуться *сов. кем-чем, разг.* булып кылану, салыну, салыну; **~ больны́м** авыруга салышу

прикипа́ть *несов. см.* **прикипе́ть**

прикипе́ть *сов. разг.* касмакланып ябышу, көеп ябышу, көю

прикла́д *м* **1.** (*ружья*) мылтык түтәсе, приклад **2.** *портн.* астар, төймә *h.б.ш.*

прикладн||о́й, -а́я, -о́е кулланма ... практик, гамәли; **~ые нау́ки** практик фәннәр; **~ а́я матема́тика** гамәли математика ◆ **~о́е иску́сство** кулланма сәнгать

прикла́дывать *несов. см.* **приложи́ть**

прикла́дываться *несов.* **1.** *см* **приложи́ться; 2.** *страд. от* **прикла́дывать**

прикле́ивать *несов. см.* **прикле́ить**

прикле́иваться *несов.* **1.** *см.* **прикле́иться; 2.** *страд. от* **прикле́ивать**

прикле́иться *сов. что* ябыштыру, ябыштырып кую; җилемләп ябыштыру

прикле́ить *сов.* ябышу, ябышып калу

прикле́йка *ж* **1.** *см.* **прикле́ить; 2.** (*то, что приклеено*) ябыштырып куелган нәрсә, ябыштырма

приклепа́ть *сов. что* клёпкалап беркетү (металл әйберләрне)

приклепа́ться *сов.* клёпкалап беркетелү

приклёпка *ж* **1.** *см.* **приклепа́ть; 2.** (*то, что приклёпано*) клёпкалап беркетелгән нәрсә (*кисәк, өлеш h.б.ш.*)

приклёпывать *несов. см.* **приклепа́ть**

приклёпываться *несов.* **1.** *см.* **приклепа́ться; 2.** *страд. от* **приклёпывать**

приклони́ть *сов. что, разг.* ию; **~ ве́тки де́рева к земле́** агач ботакларын җиргә [таба] ию ◆ **не́где (не́куда) го́лову ~** сыеныр урын юк, баш куяр урын юк

приклони́ться *сов.* иелү

приклоня́ть *несов. см.* **приклони́ть**

приклоня́ться *несов.* **1.** *см.* **приклони́ться; 2.** *страд. от* **приклоня́ть**

приключа́ть *несов. см.* **приключи́ть**

приключа́ться *несов. см.* **приключи́ться**

ПРИ-ПРИ

приключе́ние *с* **1.** (*происшествие*) вакыйга, хәл **2.** (*похождение*) мажара

приключе́нческий, -ая, -ое мажаралы; ~ **рома́н** мажаралы роман

приключи́ть *сов. что, тех.* тоташтыру, ялгау; кушу

приключи́||ться *сов. разг.* булу, очрау, килеп чыгу, баштан үтү; **что с ним ~лось?** аңа ни булды?; **~лась неприя́тность** күңелсезлек килеп чыкты

прикова́||ть *сов.* **1.** *кого-что* (*ковкой соединить*) чүкеп беркету; (*цепями*) чылбырлау, чылбырлап (богаулап) кую **2.** *что, перен.* җәлеп итү; **~ть к себе́ всео́бщее внима́ние** барлык кешенең игътибарын үзенә җәлеп итү ♦ **боле́знь ~ла его́ к посте́ли** авыру аны урынга яткырды; **страх ~л его́ к ме́сту** куркудан ул баскан (утырган) җирендә катып калды

прикова́ться *сов.* **1.** (*прикрепиться посредством ковки*) чүкеп беркетелү **2.** *перен.* (*о внимании, взгляде и т.п.*) текәлү, төбәлү, юнәлү

прико́вывать *несов. см.* **прикова́ть**

прико́вываться *несов.* **1.** *см.* **прикова́ться; 2.** *страд. от* **прико́вывать**

прико́л *м* казык, субай (*гадәттә берәр нәрсәне бәйләп кую өчен хезмәт итә торган*); **на ~е** бәйләп куелган; **стоя́ть на ~е** 1) (*стоять на причале*) причалда тору; 2) *перен.* (*находиться в бездействии*) туктап тору

прикола́чивать *несов. см.* **приколоти́ть**

прикола́чиваться *несов.* **1.** *см.* **приколоти́ться; 2.** *страд. от* **прикола́чивать**

приколоти́ть *сов. что* кадаклау, кадаклап кую; **~ до́ску** тактаны кадаклап кую

приколоти́ться *сов. разг.* кадаклану

приколо́ть *сов. что* кадау, кадап кую; **~ бро́шку** брошка кадау

приколо́ться *сов. разг.* кадалу, кадап беркетелү

прикомандирова́ть *сов. кого-что* вакытлыча беркетү (*хәрби частька, учреждениегә h.б.ш.*)

прико́нчи||ть *сов. разг.* **1.** *что* (*закончить*) бетерү; **мы ~ли все запа́сы** без бөтен запасларны бетердек **2.** *кого-что* үтерү, үтереп ташлау; **~ть зве́ря** җәнлекне үтерү

прико́рм (*для скота*) азык; (*для птицы*) җим

прикорми́ть *сов. кого-что* ашатып ияләштерү; **~ воробьёв** чыпчыкларны ашатып ияләштерү

прико́рмка *ж см.* **прико́рм**

прикорну́ть *сов. разг.* (*скорчившись, прилечь*) бөгәрләнеп яту; баш кую, аз гына баш куеп алу

прикоснове́ние *с см.* **прикосну́ться**

прикосну́ться *сов. к кому-чему* кагылу, кагылып китү; орыну, тию **не ~к еде́** ашка кагылмау

прикра́сить *сов. что, разг.* (*рассказывая, преувеличить, приукрасить*) арттырып (күпертеп) сөйләү, матурлап сөйләү, үзеннән кушып сөйләү

прикра́сы *мн. разг.* **1.** (*преувеличения*) арттыру, күпертү (*сөйләгәндә*) **2.** (*приукрашивания*) матурлау, бизәү, шомарту (*сөйләгәндә*) ♦ **без прикра́с** булганынча, арттырмыйча, күпертмичә

прикра́шивать *несов. см.* **прикра́сить**

прикрепи́тельный, -ая, -ое беркетү ...ы; **~ тало́н** беркетү талоны

прикрепи́ть *сов. кого-что* **1.** беркетү, беркетеп кую; **~ что-л. була́вкой** булавка белән беркетеп кую **2.** беркетү; **~ зе́ркало к стене́** көзгене стенага беркетү **3.** беркетү; теркәү, теркәп кую; **~ к поликли́нике** поликлиникага беркетү

прикрепи́ться *сов.* **1** (*прочно приделаться*) беркетелү **2.** (*стать на учёт*) беркетелү; теркәлү

прикрепля́ть *несов. см.* **прикрепи́ть**

прикрепля́ться *несов.* **1.** *см.* **прикрепи́ться; 2.** *страд. от* **прикрепля́ть**

прикри́кивать *несов. на кого-что* кычкыру, кычкырып-кычкырып кую, акырыну, кычкырыну (*берәр кешене куркыту яки мәҗбүр итү максаты белән*)

прикри́кнуть *сов. на кого-что* кычкыру, акыру, кычкырып (акырып) кую

прикрути́ть *сов. разг.* **1.** *кого-что к чему* (*привязать*) боргычлау, боргычлап кую, боргычлап бәйләп кую **2.** *что, разг.* (*убавить, уменьшить*) төшерү, төшерә төшү, бераз төшерү; баса төшү; **~ фити́ль** филтәне баса төшү

прикрути́ться *сов. разг.* басылу, төшү, басыла (төшә) төшү

прикру́чивать *несов. см.* **прикрути́ть**

прикру́чиваться *несов.* **1.** *см.* **прикрути́ться; 2.** *страд. от* **прикру́чивать**

прикрыва́ть *несов. см.* **прикры́ть**

прикрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **прикры́ться; 2.** *страд. от* **прикрыва́ть**

прикры́тие *с* **1.** *см.* **прикры́ть, прикры́ться; 2.** (*укрытие*) йышык **3.** (*защита, охрана*) саклау **4.** *воен.* прикрытие, йышыклау; **артиллери́йское ~** артиллерия прикрытиесе

прикры́ть *сов.* **1.** *кого-что* [өстен] ябу, каплау; **~ кастрю́лю кры́шкой** кастрюльнең капкачын каплау **2.** *перен. кого-что* (*скрыть*) каплау, каплап калу, [каплап] калдыру, яшерү, яшереп калдыру; **~ чей-л. обма́н** *берәүнең* ялганын яшерү **3.** *кого-что* (*заслонить собой*) йышыклау, каплау; артына яшерү; каплау (*воен.*); **~ ле́вый фланг** сул флангны каплау **4.** *что* (*неплотно закрыть*) яба (каплый) төшү; кыса төшү, кысып кую; **~ дверь** ишекне кыса төшү **5.** *что, прост.* ябу, туктату; **~ торго́влю** сәүдәне ябу

прикры́ться *сов.* **1.** (*накрыться*) ябыну **2.** *перен. разг.* (*замаскироваться*) качып (яшеренеп) калу; йышыклану, йышыкланып калу **3.** (*заслониться от чего-л.*) йышыклану, каплану; артына яшеренү (качу) **4.** (*неплотно закрыться*) яхшы ябыла (кысыла) төшү

прикупа́ть *несов. см.* **прикупи́ть**

прикупи́ть *сов. кого-что, чего* өстәмә рәвештә сатып алу, тагы бераз сатып алу

прику́ривать *несов. см.* **прикури́ть**

прикури́ть *сов. что и без доп.* [тәмәке] кабызу, кабызып алу

прикуси́ть *сов. что* тешләү, тешләп алу; **~ губу́** иренен тешләү; **~ язы́к** *прям., перен.* телен тешләү

прику́сывать *несов. см.* **прикуси́ть**

прила́в||ок *м* прилавка (*кибеттә, базарда*) ♦ **рабо́тник ~ка** сатучы (*кибеттә*)

прилага́тельн||ый, -ая, -ое: **и́мя ~ое** *грам.* сыйфат

прилага́ть *несов. см.* **приложи́ть** 2, 3

прилага́||ться *несов.* : **при сём ~ется** [моңа] теркәлә

прилада́ть *сов. что* җайлау, рәтләү, кую, [җайлап, рәтләп, ипләп, ясап] кую; **~ замо́к к две́ри** ишеккә йозак кую

прила́живать *несов. см.* **прила́дить**

приласка́ть *сов. кого-что* иркәләү, сөю; **~ ребёнка** баланы иркәләү

приласка́ться *сов. к кому* иркәләну, иркәләнеп сыену; **~ к ма́тери** әнисенә иркәләнеп сыену

прилега́||ть *несов. к чему* **1.** барып (килеп) тоташу, орынып тору, чиктәш булу; янәшә[сендә] булу; **по́ле ~ет к ле́су** басу урманга барып тоташа **2.** (*об одежде*) утыру; сыланып (ятып) тору

прилежа́ние *с* тырышлык; тырышу, эшкә күңел биреп (куеп) эшләү; **отлича́ться ~м** тырышлыгы белән аерылып тору

прилежа́щий, -ая, -ее *мат.* эргәдәш; **~ у́гол** эргәдәш почмак

приле́жный, -ая, -ое тырыш, тырышучан; **~ учени́к** тырыш укучы

прилепи́ть *сов. что* ябыштыру, ябыштырып кую; **~ ма́рку на конве́рт** конвертка марка ябыштыру; **~ пла́стырь** пластырь ябыштыру

прилепи́||ться *сов. к чему* **1.** ябышу; **пла́стырь ~лся** пластырь ябышты **2.** *разг.* урнашу, сыену, сыенып тору; **до́мик ~лся к скале́** өй кыяга сыенып тора

прилепливать *несов. см.* **прилепи́ть**

прилепливаться *несов.* **1.** *см.* **прилепи́ться; 2.** *страд. от* **прилепливать**

прилепля́ть *несов. см.* **прилепи́ть**

прилепля́ться *несов.* **1.** *см.* **прилепи́ться; 2.** *страд. от* **прилепля́ть**

прилёт *м см.* **прилете́ть; ~ птиц** кошлар кайту; **по́сле на́шего ~а** без [очып] кайтканнан соң

прилета́ть *несов. см.* **прилете́ть**

прилете́||ть *сов.* [очып] килү; **самолёт ~л** самолёт килде

прилётн||ый, -ая, -ое (*о птицах*) күчмә ...

прили́||чь *сов.* **1.** (*лечь ненадолго*) [бераз] яту, ятып тору (алу) **2.** (*пригнуться*) сөрлегү; **рожь по́сле дождя́ ~гла́** арышлар яңгырдан соң сөрлеккән **3.** (*осесть*) утыру; **пыль ~гла́** тузан утырган

прили́в *м* **1.** (*морской*) [су] күтәрелү, су күтәрелеше; **~ и отли́в** суның күтәрелеше һәм чигенеше **2.** агылыш, агылу, агылып килү; агылып килеп җыелу; **~ наро́ду** халыкның агылып килеп җыелуы **3.** *мед.* [кан] менү (күтәрелү) (*башка*); [кан] йөгерү (*биткә*) **4.** *перен.* (*нарастание, усиление*) арту, кабару; тулу; күтәрелү, күтәрелеш; көчәю; ~

гне́ва ачу кабару; ~ **эне́ргии** энергия арту; ~ **молоды́х сил** яшь көчләрнең килеп кушылуы

приliва́ть *несов. см.* **прили́ть**

прилиза́||ть *сов. что* 1. ялау, ялап тигезләү; **ко́шка ~ла шерсть** мәче ялап йонын тигезләде 2. *перен.* (*гладко причесать*) ялагандай итеп тарап кую, шоп-шома итеп тарап кую

прилиза́ться *сов.* чәчне ялагандай итеп тарап кую

прили́зывать *несов. см.* **прилиза́ть**

прили́зываться *несов.* 1. *см.* **прилиза́ться**; 2. *страд. от* **прили́зывать**

прилипа́ть *несов. см.* **прили́пнуть**

прили́п||нуть *сов.* 1. ябышу, сылану, ябышып (сыланып) калу; **руба́шка ~ла к те́лу** күлмәге тәненә ябышкан; **грязь ~ла к сапога́м** итекләргә балчык сыланган 2. *перен. разг.* (*надоесть*) бәйләнү, ябышу, тагылу

прили́пчив||ый, -ая, -ое 1. (*легко прилипающий*) тиз ябыша торган, ябышкак, ябышучан 2. *перен. разг.* йогышлы, йогучан; **~ая боле́знь** йогышлы авыру 3. *перен. разг.* (*навязчивый, надоедливый*) бәйләнчек, бәйләнүчән, ябышкак

прили́ть *сов.* 1. (*притечь — о жидкости*) агып килеп (барып) җитү; (*о крови*) (*башка*) кан йөгерү, кан күтәрелү; (*бит*) кызару 2. *перен.* (*о чувствах*) кабару, арту; тулу; чолгап алу

прили́чи||е *с* әдәп; тәрбия; нәзәкать; **для (ра́ди) ~я** әдәп йөзеннән, әдәп саклап; **пра́вила ~я** әдәп кагыйдәләре

прили́чн||ый, -ая, -ое 1. (*пристойный*) әдәпле, тәрбияле 2. *разг.* (*довольно хороший*) яхшы гына, шактый яхшы; юньле; начар түгел; (*напр. о сумме*) шактый зур (югары); **~ым костю́м** яхшы гына костюм; **~ый с ви́ду** тышкы яктан шактый яхшы; **~ая зарпла́та** шактый югары хезмәт хакы

приловчи́ться *сов. разг.* җайлашу, күнегеп (остарып, өйрәнеп) җитү

приложе́ние *с* 1. *см.* **приложи́ть**; **~ теорети́ческих зна́ний на пра́ктике** теоретик белемнәрне практикада куллану 2. (*к журналу и т.п.*) кушымта, өстәмә 3. *грам.* өстәмә сүз

прилож||и́ть *сов. что* 1. кую; **~и́ть ру́ку ко лбу́** кулны маңгайга кую 2. теркәү; **~и́ть к письму́ ко́пию удостовере́ния** хатка таныклыкның күчермәсен теркәү 3. куллану; кую; салу; **~и́ть уси́лия** көч салу; **~и́ть все си́лы** бөтен көчне кую ♦ **~и́ть печа́ть** печать басу; **~и́ть ру́ки** *к чему* (*принять участие в чём-л.*) кулы уйнау, катнашу (*гаеп итәрлек эштә*); **~и́ть ру́ку** (*подписаться под чем-л.*) кул кую, имза салу; **ума́ не ~ю́** [ничбер] акылым җитми, аңлый алмыйм, башыма (акылыма) сыймый

приложи́ться *сов.* 1. кую; **~ ю́хом к две́ри** колакны ишеккә кую 2. (*поцеловать*) үбү, олылап үбү; **~ ко лбу́** маңгаеннан үбү 3. (*прицелиться*) төзәү, төбәү ♦ **остально́е [всё] прило́жится** калганы (ничшиксез, үзеннән үзе) булыр

прилуни́ться *сов. разг.* Айга төшү

прильну́||ть *сов. к кому-чему* 1. сыену, сарылу, сырышу, елышу; **ребёнок ~л к ма́тери** бала анасына сыенды 2. күзен кую; **~ть к замо́чной сква́жине** йозак тишегенә күзен кую

при́ма *ж муз.* прима (1. *гамманың беренче, төп авазы* 2. *кыллы музыкаль инструментның беренче нечкә кылы* 3. *ансамбльдә яисә хорда беренче партияне башкаручы кеше яки музыка коралы*)

при́ма-балери́на *ж* прима-балерина (*беренче рольләрне башкаручы балерина*)

примадо́нна *ж театр. уст.* примадонна (*операда беренче рольләрне башкаручы җырчы*)

прима́нивать *несов. см.* **примани́ть**

приман||и́ть *сов. кого-что* (*кызыктырып, ымлап һ.б.ш.*) чакыру, чакырып китерү; ~ **кур** тавыкларны чакырып китерү

прима́нка *ж* 1. (*для животных*) жим, алдавыч жим 2. *перен.* (*соблазн*) кызыктыргыч [нәрсә], алдавыч

прима́т *м филос.* примат, беренчеллек, өстенлек

прима́ты *мн. зоол.* приматлар (*иң югары төзелешле имезүчеләр — маймыллар, ярыммаймыллар һәм кешеләр*)

прима́щиваться *несов. см.* **примости́ться**

примелька́ться *сов. разг.* таныш булып бетү, танышка әйләнү, күз ияләнеп бетү (*еш күрү, очрашу, еш күзгә чалыну сәбәпле*)

применени||е *с см.* **примени́ть, примени́ться**; **~е минера́льных удобре́ний** минераль ашламалар куллану; **находи́ть ~е** кулланыш табу ♦ **в ~и к...** ...га карата [алганда], ...га карап, туры китереп [алганда]

примени́ть *сов. что* 1. куллану, файдалану; ~ **на пра́ктике** практикада куллану; ~ **стро́гие ме́ры** катгый чаралар куллану (күрү) 2. (*приспособить*) җайлаштыру; ~ **ору́дия к ме́стности** тупларны урынга җайлаштыру

примени́ться *сов. к кому-чему* җайлашу, иплешү; ~ **к усло́виям** шартларга җайлашмакчы булу

применя́ть *несов. см.* **примени́ть**

применя́ться 1. *несов. см.* **примени́ться**; 2. *страд. от* **применя́ть**

приме́р *м* 1. үрнәк; **брать (взять) ~** үрнәк алу; **по ~у** үрнәгендә; **подава́ть ~** үрнәк күрсәтү; **служи́ть ~ом** үрнәк булып тору; **ста́вить в ~** үрнәк итеп кую 2. мисал; **взять для ~а** мисал итеп алу; **привести́ ~** мисал китерү 3. *мат.* мисал ♦ **для ~а** [башкаларга] гыйбрәт өчен; **к ~у [сказа́ть]** мәсәлән; **не в ~** 1) *кому-чему* аермалы буларак; 2) *при сравн. ст.* күп тапкырлар, шактый; **не в ~ лу́чше** күп тапкырлар яхшырак

примерза́ть *несов. см.* **примёрзнуть**

примёрзнуть *сов.* туңып ябышу (кату)

приме́ривать *несов. см.* **приме́рить**

приме́риваться *несов.* 1. *см.* **приме́риться**; 2. *страд. от* **приме́ривать**

приме́рить *сов. что* киеп карау; үлчәү, үлчәп карау; киеп карау; (*при шитье*) примерка ясау, киеп (кигезеп) карау

приме́риться *сов. разг.* җайлашу, җайлашып карау, җаен табу; чамалау, чамалап карау

приме́рк||а *ж* 1. *см.* **приме́рить**; 2. киеп (кидереп) карау; **сде́лать ~у** кидереп карау

приме́рн||ый, -ая, -ое 1. үрнәк ..., үрнәк булырлык; **~ый учени́к** үрнәк булырлык укучы; **~ое поведе́ние** үзеңне үрнәк булырлык итеп тоту 2. якынча ..., чама белән ...ган; **~ый подсчёт расхо́дов** чыгымнарны якынча исәплү

примеря́ть *несов. см.* **приме́рить**

примеря́ться *несов.* 1. *см.* **приме́риться**; 2. *страд. от* **примеря́ть**

при́мес||ь *ж* катышма, кушылма, катнаш; **без ~и** катышмасыз; **гли́на без ~и песка́** комсыз балчык; **мука́ с ~ью отрубе́й** көрпә катыш он

приме́т||а *ж* 1. билге, тамга; **осо́бые ~ы** махсус билгеләр 2. (*в суеверных представлениях*) галәмәт 3. *обычно мн.* **~ы** сынамышлар; **[су́дя] по ~ам** сынамышларга караганда ♦ **на ~е (быть, име́ться)** *у кого* күз алдында булу; **на ~е име́ть (держа́ть)** *кого-что* күз алдында тоту, күздә тоту

приmета́ть *сов. что* күкләү, типчү күкләп (типчеп) кую; ~ **рука́в** җиңне типчеп кую

приме́тить *сов. кого-что* (*заметить*) күрү, сизү, күреп (сизеп) алу, игътибар итү

приме́тный, -ая, -ое 1. (*заметный*) күзгә ташлана (ташланып тора) торган, беленеп (сизелеп) тора торган; бик ачык; ~ **след** бик ачык эз 2. (*имеющий приметы*) аерым билгеләре булган, тамгалы 3. (*выделяющийся среди других*) билгеле, күренекле

примётывать *несов. см.* **приmета́ть**

примеча́ние *с* искәрмә

примеча́тельн||ый, -ая, -ое игътибар итәрлек, игътибарга лаек (лаеклы); **~ые места́ го́рода** шәһәрнең игътибарга лаек урыннары; **в нём нет ничего́ ~ого** аның игътибар итәрлек бернәрсәсе дә юк; **~ое собы́тие** игътибарга лаек вакыйга

примеча́ть *несов. см.* **приме́тить**

примеша́ть *сов.* 1. *что, чего* (*мешая, прибавить*) кушу, катыштыру, катнаштыру; салу, салып катыштыру 2. *кого-что, перен. разг.* (*вовлечь*) катнаштыру, катыштыру

примеша́ться *сов.* кушылу, өстәлү

приме́шивать *несов. см.* **примеша́ть**

приме́шиваться *несов.* 1. *см.* **примеша́ться**; 2. *страд. от* **приме́шивать**

примире́нец *м* килешүче

примире́нческ||ий, -ая, -ое килешүчәнлек ...ы; **~ая поли́тика** килешүчәнлек сәясәте

примире́нчество *с* килешүчәнлек

примири́тельн||ый, -ая, -ое татулаштыра (килештерә) торган, татулаштыруга (килештерүгә) юнәлдерелгән, килешүчән; ~ **тон** килешүчән тон

примири́ть *сов. кого-что* 1. (*помирить*) килештерү, татулаштыру 2.

(*вызывать терпимое отношение*) килешергә мәҗбүр итү; буйсындыру, баш идерү

примири́ться *сов.* **1.** *с кем-чем и без доп., разг.* (*помириться*) килешү, татулашу **2.** *с чем* килешү, ризалашу, риза булу; буйсыну, баш ию; **~ с судьбо́й** язмышка буйсыну

примиря́ть *несов. см.* **примири́ть**

примиря́ться *несов.* **1.** *см.* **примири́ться; 2.** *страд. от* **примиря́ть**

примити́в *м* примитив (*гади, садә нәрсә*)

примитиви́зм *м* примитивлык

примити́вность *ж* **1.** (*простота, несложность*) гадилек, садәлек **2.** примитивлык; **~ взгля́дов** карашларның примитивлыгы

примити́вн||ый, -ая, -ое **1.** (*простой, несложный*) примитив, гади, садә; (*упрощённый*) примитив, гадиләштерелгән, сай; **~ая те́хника** примитив техника; **~ые доказа́тельства** примитив дәлилләр **2.** (*неразвитый*) гади, түбән культуралы, примитив **3.** (*первобытный*) примитив, борынгы

примкну́ть *сов. к кому-чему* **1.** (*присоединиться*) кушылу, арага керү, ияру **2.** *перен.* (*стать на чью-л. сторону*) ягына (тарафына) күчү, ягын (тарафын) алу

приме́лкнуть *сов. разг.* тыну, тынып калу; (*сөйләшүдән, елаудан һ.б.ш.*) туктау, шып туктау

приме́рский, -ая, -ое диңгез буе ...ы; диңгез буендагы, диңгез буена урнашкан; **~ го́род** диңгез буена урнашкан шәһәр

приме́рье *с* диңгез буе

примости́ть *сов. кого-что, разг.* урнаштыру, кую (*җайсыз урынга*)

примости́ться *сов. разг.* урнашу, җирләшү (*җайсыз урынга*)

приме́ч||а *ж* примочка; **сде́лать ~у** примочка кую (ясау)

при́мула *ж бот.* навруз чәчәге, примула

при́мус *м* примус

примча́ть *сов. кого-что, разг.* чаптырып (очыртып, бик тиз) китереп җиткерү

примча́ться *сов.* чабып (чаптырып, очыртып, бик тиз) килеп җитү

примыка́ние *с грам.* янәшәлек [бәйләнеше]

примыка́||ть *несов.* **1.** *см.* **примкну́ть; 2.** (*прилегать*) барып (килеп) тоташу, орынып тору, чиктәш булу; янәшә[сендә] булу; янында булу; **к до́му ~ет сад** өй янында бер бакча [бар] **3.** *грам.* янәшәлек юлы белән бәйләнү

приме́ть *сов. что* изү; таптау; **~ поду́шку** мендәрне изү; **~ траву́** үләнне таптау

приме́ться *сов.* изелү; тапталу

принадлеж||а́ть *несов.* **1.** *кому-чему* ...ныкы булу; кайтып калу, карау; **кни́га ~и́т мне** китап минеке; **не́дра земли́ ~а́т госуда́рству** җирнең эчке байлыклары дәүләтнеке; **э́та иде́я ~и́т не ему́** бу идея аныкы түгел **2.** *к кому-чему* ...дан исәпләнү (саналу); ...дан булу; мөнәсәбәттә булу; карау; **~а́ть к выдаю́щимся де́ятелям** күренекле эшлеклеләрдән исәпләнү ♦ **~а́ть исто́рии** тарихта калу

принадле́жность||ь *ж* **1.** кирәк-яраклар, әсбаплар, [кирәкле] әйберләр; **пи́сьменные ~и** язу әсбаплары **2.** *к чему* булу, ...дан исәпләнү (саналу); ...дан булу; мөнәсәбәттә булу, карау; **~ь к па́ртии** партияле булу ♦ **по ~и (отпра́вить, переда́ть** *и т.п.*) тиешлесенә, тиешле урынга (җибәрү, бирү *һ.б.ш.*)

принаряди́ть *сов. кого-что, разг.* матур (купшы) итеп киендерү, киендерү-ясандыру

принаряди́ться *сов. разг.* матур (купшы) итеп киену, киенү-ясану

принаряжа́ть *несов. см.* **принаряди́ть**

принаряжа́ться *несов. от* **1.** *см.* **принаряди́ться; 2.** *страд. от* **принаряжа́ть**

принево́ливать *несов. см.* **принево́лить**

принево́лить *сов. кого-что, разг.* ирексезләү, мәҗбүр итү

принести́ *сов. кого-что* **1.** *прям., перен.* китерү, алып килү (кайту) **~ ве́щи домо́й** әйберләрне өйгә алып кайту; **~ стака́н ча́ю** бер стакан чәй китерү; **~ ра́достную весть** шатлыклы хәбәр алып килү **2.** (*родить — о животных*) китерү, балалау, тудыру; (*уродить — о растениях*) бирү **3.** бирү, китерү, ясау; **~ дохо́д** табыш бирү; **~ вред** зарар китерү; **~ по́льзу** файда китерү **4.** *в сочет. с нек-рыми сущ.* итү; **~ в дар** бүләк итү; **~ кля́тву** ант итү, ант эчү; **~ покая́ние** тәүбә итү; **~ же́ртву** *кому-чему* корбан итү; **~ в же́ртву** 1) *кого-что* корбан итү; 2) *что* бүләк итеп бирү, иганә итү

принести́сь *сов. разг.* йөгереп килеп җитү

принижа́ть *несов. см.* **прини́зить**

прини́женн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **прини́зить; 2.** (*смиренный*) кимсетелгән, кимсенүле; **~ый вид** кимсенүле кыяфәт **3.** (*унизительный*) кимсетә торган, кимсетүле, кимсетелгән; түбәнсетә торган; **~ое положе́ние** кимсетелгән хәл

прини́зить *сов. кого-что* **1.** (*унизить*) кимсетү, түбәнсетү **2.** түбәнәйтү, кечерәйтү, кечерәйтеп күрсәтү, кимтеп күрсәтү; **~ досто́инства кни́ги** китапның уңай якларын кечерәйтеп күрсәтү

приника́ть *несов. см.* **прини́кнуть**

прини́кнуть *сов.* **1.** *к кому-чему* сыену, сырышу; (*башны, колакны*) кую; **~ у́хом к две́ри** колакны ишеккә кую **2.** *перен. разг.* (*притихнуть, притаиться*) тыну, тынып калу; посу

принима́ть *несов. см.* **приня́ть; ~ чёрное за бе́лое** акны карадан аермау; **~ *что-л.* за чи́стую моне́ту** *берәр нәрсәне* чынга алу, чынга тарту, чын дип ышану (уйлау)

принима́ться *несов.* **1.** *см.* **приня́ться; 2.** *страд. от* **принима́ть**

принора́вливать *несов. см.* **приноров и́ть**

принора́вливаться *несов.* **1.** *см.* **приноров и́ться; 2.** *страд. от* **принора́вливать**

приноров и́ть *сов. что, разг.* җайлаштыру, җайлау, ипләү , туры китерү

приноров и́ться *сов. к кому-чему, разг.* җайлашу, ипләшү; **~ к обстоя́тельствам** шартларга җайлашу

приноравля́ться *несов. см.* **приноров и́ться**

приноси́ть *несов. см.* **принести́**

приноси́ться *несов.* **1.** *см.* **принести́сь; 2.** *страд. от* **приноси́ть**

приноше́ние *с* бүләк

принуди́тельность *ж* мәҗбүрилек, мәҗбүри булу

принуди́тельн||ый, -ая, -ое көчләүле, мәҗбүри; **~ые ме́ры** мәҗбүри чаралар; **~ый труд** мәҗбүри хезмәт; **~ым путём** мәҗбүри рәвештә

прину́дить *сов. кого-что, к чему и с неопр.* мәҗбүр итү, көчләү, ирексезләү

принужда́ть *несов. см.* **прину́дить**

принужде́ние *с см.* **прину́дить**

принуждённость *ж* ясалмалык

принуждённ||ый. -ая, -ое **1.** *прич. от* **прину́дить; 2.** ясалма, табигый булмаган, көчәнеп ..., көчәнүле; **~ая улы́бка** ясалма елмаю

принц *м* принц

принцесса *ж* принцесса

при́нцип *м* принцип; **основны́е ~ы иску́сства** сәнгатьнең төп принциплары; **~ы жи́зни** тормыш (яшәеш) принциплары; **приде́рживаться твёрдых ~ов** принципта нык тору ♦ **в ~е** нигездә, асылда; **в ~е я согла́сен** нигездә мин риза; **из ~а** принциптан чыгып

принципиа́льность||ь *ж* принципиальлек, принципиаль булу, принциплылык; **не хва́тает ~и** принциплылык җитми

принципиа́льн||ый, -ая, -ое **1.** принциплы; **~ый вопро́с** принципиаль мәсьәлә **2.** принципиаль, принциплы; **~ый челове́к** принципиаль кеше; **~ая поли́тика** принципиаль сәясәт **3.** принципиаль, принципиаль рәвештә ...ган; **име́ется его́ ~ое согла́сие** аның принципиаль ризалыгы бар

прину́хать *сов. к чему, разг.* **1.** (*привыкнуть к запаху*) [искә] ияләшү, өйрәнү, күнегү **2.** (*различить запах*) [исне] аеру, [исне] тану

прину́хиваться *несов. см.* **прину́хать**

приня́ть *сов.* **1.** *кого-что* алу, кабул итү (итеп алу); **~ пода́рок** бүләкне кабул итү **2.** *в разл. знач. кого-что* кабул итү; **~ това́р** товар кабул итү; **~ полк** полкны кабул итү; **~ в университе́т** университетка кабул итү; **~ посла́** илчене кабул итү; **~ госте́й** кунаклар кабул итү; **~ больно́го** авыруны кабул итү; **~ *чей-л.* сове́т** кинәшне кабул итү; **~ зако́н** закон кабул итү; **~ резолю́цию** резолюция кабул итү; **~ лека́рство** дару кабул итү **3.** *что* (*совершить, осуществить то, что выражено сущ.*): **~ ме́ры** чаралар күрү; **~ на себя́ обяза́тельства** өстенә бурыч итеп алу, йөкләмә алу; **~ прися́гу** ант итү, присяга бирү, ант эчү;

~ **реше́ние** карар итү (чыгару, кабул итү); ~ **смерть** үлү, вафат булу; ~ **уча́стие** катнашу **4.** *что* алу, керү; ~ **друго́й вид** икенче төрле төс алу; ~ **официа́льный хара́ктер** рәсми характер алу **5.** *что* (*претерпеть*) кичерү, күтәрү, чигү; ~ **му́ки** җәфа чигү **6.** *кого-что за кого-что* дип белү (уйлау, исәпләү, санау); охшату; **его́ при́няли за знако́мого** аны таныш кеше дип уйлаганнар **7.** *что воен.* кабатлау; ~ **кома́нду** команданы кабатлау ♦ ~ **бо́й** сугышка керү; ~ **[бли́зко] к се́рдцу** күңелгә якын алу; ~ **в до́лю** өлешкә кертү; ~ **во внима́ние** игътибарга алу; ~ **в расчёт** исәпкә алу; ~ **к све́дению** исәпкә алу; ~ **на свой счёт** үзеңә алу, үз исәбенә алу; ~ **на себя́** үз өстенә алу

приня́ться *сов.* **1.** *за. что и с неопр.* керешү, башлау, тотыну; ~ **за еду́** ашый башлау; ~ **за рабо́ту** эшкә керешү; ~ **за уро́ки** дәресләрне әзерли башлау **2.** (*о растении*) тамырлану, тамыр җибәрү; үсеп китү, төпләнү; үсә башлау **3.** чыгу; **о́спа приняла́сь** чәчәк чыккан

приободри́ть *сов. кого-что* [бераз] дәртләндереп (рухландырып) җибәрү, [бераз] рухын (дәртен, күңелен) күтәреп җибәрү

приободри́ться *сов.* [бераз] дәртләнеп (рухланып) китү, [бераз] дәрте (рухы) күтәрелеп китү, [бераз] күңеле күтәрелеп китү; күңеле үсеп китү

приободря́ть *несов. см.* **приободри́ть**

приободря́ться *несов. см.* **приободри́ться**

приобрести́ *сов. кого-что* **1.** алу, булдыру; сатып алу; ~ **кни́гу** китап алу **2.** *разг.* (*завести*) булдыру; ~ **друзе́й** дуслар булдыру **3.** (*усвоить, получить*) казану, алу, туплау; ~ **зна́ния** белем алу; ~ **о́пыт** тәҗрибә туплау; ~ **но́вое значе́ние** яңа мәгънә алу **4.** казану; ~ **авторите́т** авторитет казану; ~ **уваже́ние** ихтирам казану; ~ **сла́ву** дан казану; ~ **дурну́ю репута́цию** яман аты чыгу

приобрета́ть *несов. см.* **приобрести́**

приобрете́ние *с* **1.** *см.* **приобрести́; 2.** (*покупка*) сатып алган (алынган) әйбер **3.** табыш, казаныш; **це́нное ~** кыйммәтле казаныш

приобща́ть *несов. см.* **приобщи́ть**

приобща́ться *несов.* **1.** *см.* **приобщи́ться; 2.** *страд. от* **приобща́ть**

приобщи́ть *сов.* **1.** *кого-что* тарту, җәлеп итү, якынайту, катнаштыру; таныштыру; ~ **широ́кие ма́ссы к культу́ре** киң массаларны мәдәнияткә җәлеп итү **2.** *что к чему* (*приложить*) теркәү, теркәп кую, беркетү, беркетеп кую; ~ **заявле́ние к де́лу** гаризаны делога теркәп кую

приобщи́ться *сов. к чему* катнашу, аралашу, кушылу

приоде́ть *сов. кого-что. разг.* (*принарядить*) киендерү-ясандыру; матур итеп киендерү, яхшы кием кидеру

приоде́ться *сов. разг.* (*принарядиться*) киенү-ясану, матур итеп киенү, яхшы кием кию

приорите́т *м* **1.** (*первенство*) приоритет, беренчелек **2.** (*первенствующее значение*) приоритет, өстенлек

приоса́ниваться *несов. см.* **приоса́ниться**

приоса́ниться *сов. разг.* мәһабәтләнү, мәһабәт кыяфәт алу, мәһабәт кыяфәткә керү

приостана́вливать *несов. см.* **приостанови́ть**

приостана́вливаться *несов.* **1.** *см.* **приостанови́ться; 2.** *страд. от* **приостана́вливать**

приостанови́ть *сов. что* туктату, туктатып тору; ~ **движе́ние** хәрәкәтне туктату; ~ **рабо́ту** эшне туктатып тору

приостанови́ться *сов.* тукталу, тукталып тору (калу)

приостано́вка *ж см.* **приостанови́ть, приостанови́ться; ~ вое́нных де́йствий** сугыш хәрәкәтләренең тукталып торуы

приотвори́ть *сов. что* бераз ачу, ачып кую, ача төшү

приотвори́ться *сов.* бераз ачылу, ачыла төшү

приотворя́ть *несов. см.* **приотвори́ть**

приотворя́ться *несов.* **1.** *см.* **приотвори́ться; 2.** *страд. от* **приотворя́ть**

приоткрыва́ть *несов. см.* **приоткры́ть**

приоткрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **приоткры́ться; 2.** *страд. от* **приоткрыва́ть**

приоткры́ть *сов. что* аз гына ачу, ача төшү ♦ ~ **заве́су** *берникадәр* серен ачу (ача төшү)

приоткры́ться *сов.* аз гына ачылу, бераз ачылу, ачыла төшү

приохо́тить *сов. кого-что к чему, разг.* теләк уяту (тудыру), дәрт кузгату, һәвәсләндерү, өйрәтеп җибәрү

приохо́титься *сов. к чему, разг.* өйрәнеп китү, һәвәсләнү

припада́ть *несов.* **1. см. припа́сть; 2.** *разг.* (*прихрамывать*) аксаклау, аз гына аксаклау; титаклау; ~ **на ле́вую но́гу** сул аякка аксаклау ♦ ~ **к ногам́ (стопам́)** *чьим, уст.* аягына егылу

припа́д||ок *м* өянәк; [авыру] тоту ♦ **в ~ке гне́ва** бик нык ачуы килгән чакта (хәлдә), бик зур ачу катыш; **в ~ке сме́ха** эче катып көлгән чакта

припа́дочный, -ая, -ое *разг.* өянәк авырулы, өянәкле; зыяндаш авырулы, үзчирле, үзавырулы

припа́рк||а *ж* кайнар компресс; **де́лать ~ и** кайнар компресслар кую

припаса́ть *несов. см.* **припасти́**

припасти́ *сов. что, чего, разг.* алдан әзерләү (әзерләп кую); ~ **де́нег** алдан акча әзерләп кую

припа́сть *сов. к кому-чему, на что* сыену, яту; сарылу; ~ **к земле́** җиргә яту; ~ **на пере́дние ла́пы** алгы аякларына яту

припа́сы *мн.* **1.** азык, азык-төлек, ашамлыклар; **съестны́е ~** ашамлыклар, азык-төлек **2.** припаслар; **боевы́е ~** сугыш припаслары (*снарядлар, патроннар һ.б.ш.*)

припа́хива||ть *несов. разг.* **1.** *чем* (*слегка пахнуть*) бераз ... исе килү, исе килеп тору; **чай ~ет мы́лом** чәйдән бераз сабын исе килеп тора **2.** (*о портящихся продуктах*) ис керә башлау, исләнә башлау, сасый башлау; **ры́ба ~ет** балыкка ис керә башлаган

припая́ть *сов. что* пайкалау, пайкалап (эретеп) ябыштыру; ~ **но́сик к ча́йнику** чәйнекнең борынын пайкалау

припая́ться *сов.* [эреп] ябышу, паять ителү

припёв *м* кушымта (*җырда*)

припева́ть *несов. разг.* (*берәр төрле эш эшләгәндә*) җырлау, көйләү; ~ **за рабо́той** җырлый-җырлый эшләү

припева́ючи *нареч. разг.*: **жить ~** рәхәт яшәү, мул [тормышта] яшәү, иркен (ал да гөл) яшәү

припёк I *м* кояш (көн) кызуы; **сиде́ть на ~е** кояш кызуында утыру

припёк II *м* (*при выпечке хлеба*) артым

припёка *ж*: **сбо́ку ~** *прост.* (*о ком-л.*) кирәкле кишер яфрагы; (*о чём-л.*) читтә [булу], читләтелү, кирәге булмау

припека́ть *несов. см.* **припе́чь**

припере́ть *сов. разг.* **1.** *что чем* терәү, терәтү, терәтеп кую; ~ **дверь па́лкой** ишекне таяк белән терәтеп кую **2.** *кого-что* (*прижать*) кысу, китереп (илтеп) кысу; ~ **к забо́ру** коймага китереп кысу ♦ ~ **к стене́ (сте́нке)** *кого* стенага терәү

припе́чь *сов. кого-что и без доп.* (*о солнце*) бик нык кыздыру

припира́ть *несов. см.* **припере́ть**

приписа́ть *сов.* **1.** *что и без доп.* өстәп язу, өстәмә рәвештә язу; ~ **не́сколько строк** берничә юл өстәп язу **2.** *кого-что* теркәү, язу, беркетү, теркәп (язып, беркетеп) кую; ~ **к призывно́му уча́стку** призыв участогына теркәп кую **3.** *кому-чему* ...дан күрү, сылтау, кайтарып калдыру; япсару, ягу; ~ **неуда́чу** *чьим-л.* **про́искам** уңышсызлыкны *кемнең дә булса* казынуларыннан күрү **4.** (*счесть принадлежащим кому-л.*) ...ныкы дип күрсәтү, ...га кайтарып калдыру; ~ **стихи́ друго́му а́втору** шигырьләрне икенче бер авторга кайтарып калдыру

приписа́ться *сов.* теркәлү, язылу

припи́ск||а *ж* **1.** *см.* **приписа́ть** 1, 2; **2.** (*дополнение к написанному*) өстәп язылган язу **3.** *обычно мн.* ~**и** (*заведомо ложные показатели*) ялган күрсәткечләр

приписн||о́й, -а́я, -о́е: ~**о́е свиде́тельство** теркәлү турындагы таныклык, теркәлү таныклыгы

припи́сывать *несов. см.* **приписа́ть**

припи́сываться *несов.* **1.** *см.* **приписа́ться; 2.** *страд. от* **припи́сывать**

припла́та *ж* **1.** *см.* **приплати́ть; 2.** өстәмә [хак], өстәү; **больша́я ~** зур өстәү

приплати́ть *сов. что* өстәп түләү, өстәү бирү

припла́чивать *несов. см.* **приплати́ть**

приплести́ *сов.* **1.** *что* кушып үрү; ~ **ле́нту к венку́** веноккa тасма кушып үрү **2.** *перен. кого-что, прост.* арага кыстыру, арага кыстырып әйтү (сөйләү), арага китереп кыстыру; **он приплёл заче́м-то и моё и́мя** нигәдер минем исемемне дә китереп кыстырды

приплета́ть *несов. см.* **приплести́**

припло́д *м* үрчем

приплыва́ть *несов. см.* **приплы́ть**

ПРИ-ПРИ

приплы́ть *сов.* (*вплавь*) йөзеп килү (килеп җитү); (*на лодке и т.п.*) килеп җитү

приплю́снутый, -ая, -ое яньчек, басынкы; ~ **нос** басынкы борын

приплю́снуть *сов. что* яньчү, җәлпәйтү, ямьшәйтү, изеп яссылату

приплюсова́ть *сов. что* өстәү, кушу

приплюсо́вывать *несов. см.* **приплюсова́ть**

приплю́щивать *несов. см.* **приплю́снуть**

припля́сывать *несов.* биештергәләп тору, биештергәләү

приподнима́ть *несов. см.* **приподня́ть**

приподнима́ться *несов.* **1.** *см.* **приводня́ться; 2.** *страд. от* **приподнима́ть**

припо́днят||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **приподня́ть; 2.** (*радостно возбуждённый*) күтәренке; ~**ое настрое́ние** күтәренке күңел **3.** (*торжественный*) купшы, тантаналы; ~**ый стиль** купшы стиль

приподня́ть *сов. кого-что* бераз күтәрү, аз гына күтәрү, күтәрә төшү ◆ ~ **заве́су** *то же, что* **приоткры́ть заве́су** *см.* **приоткры́ть**

приподня́ться *сов.* бераз күтәрелү, аз гына күтәрелү, күтәрелә төшү

припо́й *м тех.* ябыштыргыч эретмә, пайкалау эретмәсе

приползá́ть *несов. см.* **приползти́**

приползти́ *сов.* шуышып (үрмәләп, сөйрәлеп) килү (килеп җитү)

припомина́ть *несов. см.* **припо́мнить** 1

припомина́ться *несов. см.* **припо́мниться**

припо́мн||ить *сов.* **1.** *кого-что* (*вспомнить*) искә төшерү, хәтерләү, күңелгә китерү; (*узнать*) тану, төсмерләү **2.** *что кому, разг.* (*отомстить*) исенә төшерү, кирәген бирү; **я э́то тебе́** ~**ю** мин моны синең исеңә төшерермен әле

припо́мниться *сов.* искә төшү, хәтергә килү (төшү)

припра́ва *ж* аш тәмләткеч

припра́вить *сов. что чем* (*положить приправу*) тәмләткеч салу

приправля́ть *несов. см.* **припра́вить**

припры́гать *сов. разг.* сикереп (сикергәләп, сикерә-сикерә) килеп җитү

припры́гивать *несов.* **1.** *см.* **припры́гать, припры́гнуть; 2.** (*подпрыгивать*) сикереп-сикереп кую, сикергәләү, сикергәләнү

припры́гнуть *сов. разг.* сикереп килеп җитү

припря́тать *сов. кого-что, разг.* яшерү, яшереп кую, яшерепә җыеп кую

припря́тывать *несов. см.* **припря́тать**

припу́гивать *несов. см.* **припугну́ть**

припугну́ть *сов. кого-что* куркыту, өркетү

припу́дривать *несов. см.* **припу́дрить**

припу́дривать *несов.* **1.** *см.* **припу́дриться; 2.** *страд. от* **припу́дривать**

припу́дрить *сов. что* бераз пудралау, бераз пудра (кершән) ягу (ягып алу)

припу́дриться *сов.* бераз пудралану, пудраланып алу, кершән ягыну

припуска́ть *несов. см.* **припусти́ть**

припуска́ться *несов.* **1.** *см.* **припусти́ться; 2.** *страд. от* **припуска́ть**

припусти́ть *сов.* **1.** *кого-что к кому-чему, разг.* (*подпустить*) җибәрү; (*напр. телёнка к корове*) имәргә җибәрү, кушу; (*допустить к случке*) каплату, чаптыру, йөгертү **2.** *кого-что и без доп., разг.* (*погнать*) куа төшү, чаптыру; ~ **коня́** атны куа төшү **3.** *разг. см.* **припусти́ться; 4.** (*усилиться — о дожде*) шәбәю, көчәя төшү **5.** *что и без доп., разг.* (*при раскрое*) киңрәк (озынрак) итеп кисү, киңрәк (озынрак) итеп алу

припусти́ться *сов. разг.* [тагы да] кызурак йөгерә (чаба) башлау

припуха́ть *несов. см.* **припу́хнуть**

припу́хлость *ж* шешенкелек, җилсенгәнлек

припу́хлый, -ая, -ое бераз шешенкерәгән, бераз шешкән, шешенке, бераз җилсенгән, бераз кабарган

припу́хнуть *сов.* бераз шешү (шешенү), шешә төшү, шешенкерәү, бераз җилсенү, бераз кабару

прираба́тывать *несов. см.* **прираба́тать**

прираба́тать *сов. что, чего* өстәмә рәвештә акча эшләү (эшләп табу, эшләп алу); ~ **де́нег** өстәмә рәвештә акча эшләү

при́работок *м* өстәмә рәвештә эшләп табылган (алынган) акча

прира́внивать I *несов. см.* **приравня́ть**

прира́внивать II *несов. см.* **прировня́ть**

прира́вниваться *несов.* **1.** тиң булу, тиңләшү, тиңләнү; **2.** *страд. от* **прира́внивать I**

приравня́ть *сов. кого-что к кому-чему* тиң күрү, тиңләү, тиңләштерү, тигезләү, [бер] тигез күрү

прираста́ть *несов. см.* **прирасти́**

прирасти́ *сов.* **1.** *к чему* (*срастись*) ябышып (кушылып) үсү; ялганып үсү **2.** *перен. к чему* (*остаться неподвижным*) катып (ябышып) калу; **он сло́вно приро́с к ме́сту** урнында катып калгандай булды **3.** (*увеличиться*) арту, үрчү; күбәю

прире́зать *сов.* **1.** *кого-что* (*умертвить*) сую; бугазлау **2.** *что, чего* өстәп кисү; кисеп өстәү (кушу); ~ **уча́сток к огоро́ду** бакчага жир кисеп кушу

приреза́ть, прире́зывать *несов. см.* **прире́зать**

прировня́ть *сов. что* тигезләү, тигезләп чыгу; ~ **до́ски по́ла** идән такталарын тигезләү

приро́д||а *ж* **1.** табигать; **жива́я** ~**а** жанлы табигать; **мёртвая** ~**а** җансыз табигать; **зако́ны** ~**ы** табигать законнары; **явле́ния** ~**ы** табигать күренешләре; **на ло́не** ~**ы** табигать кочагында; **изуча́ть** ~**у** табигатьне өйрәнү **2.** (*сущность*) табигать, асыл, нигез, төп үзлек; **челове́ческая** ~**а** кеше табигате; ~**а све́та** яктылыкның үзлеге; ~**а да́нного явле́ния** шушы күренешнең төп үзлеге **3.** *разг.* (*характер*) табигать; холык, характер; **э́то в твое́й** ~**е** бу синең табигатеңдә, синең характерыңда; **по** ~**е он до́брый** табигате белән ул йомшак күңелле ◆ **в** ~**е вещей́** табигый, шулай булырга тиеш тә: **от** ~**ы** тумыштан

приро́дн||ый, -ая, -ое **1.** табигый; ~**ые бога́тства на́шей страны́** безнең илнең табигый байлыклары; ~**ый газ** табигый газ **2.** табигый, тумыштан килгән; ~**ый тала́нт** табигый сәләт **3.** (*по рождению*) тумыштан ...

прирождённый, -ая, -ое **1.** (*врождённый*) табигый, тумыштан килгән **2.** (*подлинный*) чын, чын мәгънәдә, тумыштан ...ы; ~ **худо́жник** туганда ук рәссам булып туган

приро́ст *м* үрчем, артым, үсеш; үрчү, арту, кубәю, үсү; ~ **населе́ния** халыкның артуы; ~ **дохо́дов** керемнәрнең артуы

прируча́ть *несов. см.* **приручи́ть**

прируча́ться *несов.* **1.** *см.* **приручи́ться; 2.** *страд. от* **прируча́ть**

приручи́ть *сов. кого-что* **1.** кулга өйрәтү (ияләштерү); ~ **медвежо́нка** аю баласын кулга ияләштерү **2.** *разг.* (*сделать послушным*) [үзенә] ияләштерү, [үзенә] җәлеп итү

приручи́||ться *сов.* **1.** кулга өйрәнү (ияләшү); **волчо́нок** ~**лся** бүре баласы кулга ияләште **2.** *разг.* (*стать послушным*) ияләшү

приса́живаться *несов. см.* **присе́сть** 2

приса́сываться *несов. см.* **присоса́ться**

присва́ивать *несов. см.* **присво́ить**

при́свист *м* сызгыру, сызгырган тавышлар чыгару; **дыша́ть с** ~**ом** сызгырган тавышлар чыгарып сулау

присви́стнуть *сов. однокр.* сызгыру, сызгырып кую

присви́стывать *несов.* **1.** (*посвистывать*) сызгыру, сызгырып-сызгырып кую (җибәрү), сызгыргалау **2.** (*говорить с присвистом*) сызгырган тавышлар чыгарып сөйләү, сызгырып сөйләү

присво́ить *сов.* **1.** *кого-что* үзләштерү, хуҗа булу; учка йому; (*выдать за своё*) үзенеке итеп күрсәтү, үзләштерү; ~ **чужу́ю вещь** кеше әйберен үзләштерү **2.** *что кому-чему, офиц.* бирү; ~ **зва́ние "Заслу́женный де́ятель нау́ки Татарста́на"** "Татарстан атказанган фән эшчесе" исеме бирү

приседа́ть *несов. см.* **присе́сть** 1

присе́ст *м*: **в (за) оди́н** ~ *разг.* бер утыруда

присе́сть *сов.* **1.** чүгәләү; ~ **на ко́рточки** чүгәләү **2.** [аз гына вакытка] утыру, бераз утырып алу; ~ **отдохну́ть** ял итәргә утыру

при́сказка *ж* әкият башы, әкияткә кереш

прискака́ть *сов.* **1** сикереп (сикерә-сикерә) килеп җитү; (*о лошади*) чабып килеп җитү; ~ **на одно́й ноге́** бер аякта сикереп килеп җитү **2.** (*приехать вскачь*) чаптырып килеп җитү **3.** *разг.* (*быстро прибыть*) [бик тиз] килеп җитү, чабып килеп җитү

прискó|рби||е *с*: **к** ~**ю** үкенечкә каршы, кызганычка каршы; **с [глубо́ким]** ~**ем** [тирән] кайгы белән

прискó|рбный, -ая, -ое үкенечле, кайгылы, аянычлы, кызганыч; ~ **слу́чай** үкенечле вакыйга

прискýчи||ть *сов. разг.* туйдыру, туйдырып бетерү; ~**ли одни́ и те́ же раз-**

говóры бер үк төрле сүзләр туйдырып бетерде

прислáть *сов. кого-что, чего* җибәрү, җибәреп кую; салу; ~ **письмó** хат җибәрү; ~ **дéньги (дéнег)** акча салу

прислóвье *с разг.* тапкыр сүз, хикмәтле сүз

прислонúть *сов. кого-что* сөяү, сөяп кую; ~ **дóску к забóру** тактаны коймага сөяп кую

прислонúться *сов.* сөялү, терәлү; ~ **к стенé** стенага сөялү

прислоня́ть *несов. см.* **прислонúть**

прислоня́ться *несов.* 1. *см.* **прислонúться; 2.** *страд. от* **прислоня́ть**

прислýга *ж* **1.** *уст.* (*служанка*) асрау, хезмәтче хатын-кыз **2.** *собир. уст.* (*слуги*) асраулар; ялчылар **3.** *собир. воен.* прислуга, расчёт; **пулемётная** ~ пулемёт расчёты

прислýживать *несов. кому* хезмәт күрсәтү, хезмәт күрсәтеп йөрү; ~ **за столóм** өстәл тирәсендә хезмәт күрсәтеп йөрү

прислýживаться *несов.* ялагайлану, ялагайланып ярарга тырышу

прислýжник *м* ялагай, тәлинкә тотучы, ялчы

прислýжница *ж* ялагай хатын (кыз)

прислýшаться *сов. к кому-чему* **1.** тынлау, колак салу; ~ **к разговóру** сөйләшүләргә колак салу **2.** *перен.* игътибарга алу, колак салу, игътибар итү; ~ **к совéтам друзéй** дусларның киңәшләренә колак салу; ~ **к мнéнию читáтелей** укучыларның фикерен игътибарга алу **3.** *разг.* ияләшеп (күнегеп) бетү, күнегү; ~ **к úличному шýму** урамдагы тавышларга ияләшеп бетү

прислýшиваться *несов. см.* **прислýшаться**

присмáтривать *несов.* **1.** *см.* **присмотрéть; 2.** *кого-что* эзләү, караштыргалау; ~ **себé рабóту** үзенә эш эзләү; ~ **кóмнату** бүлмә караштыргалау

присмáтриваться *несов.* **1.** *см.* **присмотрéться; 2.** *страд от* **присмáтривать**

присмирéть *сов.* (*стать смирным*) тынычлану, юашлану, тыйнаклану, басынкылану; (*примолкнуть*) басылу, тынып калу, тавышланмый башлау

присмóтр *м* күзәтү, күз-колак булу; карау; **быть под** ~**ом** күзәтү астында булу; **остáвить без** ~**а** караучысыз калдыру

присмотрéть *сов.* **1.** *за кем-чем* күзәтү, күз-колак булу (булып тору), күзәтеп тору, карау; ~ **за детьмú** балаларга күз-колак булу **2.** *кого-что* (*выбрать*) сайлау; күзләү; (*подыскать*) эзләү, эзләп табу (табып кую); ~ **невéсту** кыз күзләү; ~ **кóмнату** бүлмә эзләп табу

присмотрéться *сов. к кому-чему и без доп.* **1.** (*внимательно всмотреться*) игътибар (дикъкать) белән карау, текәлеп карау; (*наблюдая, понять*) игътибар белән күзәтү, танышып җитү, аңлау **2.** (*привыкнуть*) күнегеп (ияләшеп, танышып) җитү; ~ **к рабóте** эш белән танышып җитү; ~ **в темнотé** күзләр караңгыга ияләшеп җитү

присни́ться *сов.* төштә күрү, төшкә керү

присовокупи́ть *сов. что, книжн.* **1.** теркәү, беркетү, теркәп (беркетеп) кую; ~ **докумéнт к дéлу** документны делога теркәп кую **2.** (*сказать в добавление*) өстәү, өстәп әйтү

присовокупля́ть *несов. см.* **присовокупи́ть**

присоедини́тельн||ый, -ая, -ое **1.** тоташтыру ...ы, тоташтыра торган, тоташтыргыч ...; ~ **ая цепь** тоташтыра торган чылбыр **2.** *грам.* өстәлмә ...; ~**ые словá** өстәлмә сүзләр

присоедини́ть *сов. что* **1.** (*соединить*) кушу, беркетү, берләштерү **2.** *эл.* тоташтыру, тоташтырып кую, ялгау; ~ **прóвод к электри́ческой сéти** үткәргечне электр чылбырына тоташтыру **3.** кушу, [эченә] кертү; ~ **райóн к другóй óбласти** районны икенче бер өлкәгә кушу

присоедини́ться *сов.* **1.** кушылу, ияру; ~ **к толпé** халык төркеменә ияру **2.** (*стать на чью-л. сторону*) кушылу, ягын алу

присоединя́ть *несов. см.* **присоедини́ть**

присоединя́ться *несов.* **1.** *см.* **присоедини́ться 2.** *страд. от* **присоединя́ть**

присóс *м* **1.** *см.* **присоса́ться; 2.** *см.* **присóска**

присоса́||ться *сов.* ябышу, кадалу; **пия́вки** ~**лись** сөлекләр кадалды

присосéдиться *сов. к кому-чему, разг.* янына (янәшәсенә) утыру; күрше булу; күршегә урнашу

присóска *ж*, **присóсок** *м* имгеч

присóхнуть *сов.* ябышып кибү

приспé||ть *сов. разг.* (*настать — о времени*) килү, [килеп] җитү; **врéмя** ~**ло** вакыт җитте

приспéшник *м книжн.* иярчен, ялчы

приспосáбливать *несов. см* **приспосóбить**

приспосáбливаться *несов.* **1.** *см.* **приспосóбиться; 2.** *страд. от* **приспосáбливать**

приспосóбить *сов. кого-что* яраклаштыру, җайлау, җайлап кую, яраклы итү, ипләү; ~ **здáние под шкóлу** бинаны мәктәпкә яраклаштыру

приспосóбиться *сов.* күнегү, ияләшү, ияләнү, өйрәнү; җайлашу, ипләшү; муафыйклашу; ~ **к нóвым услóвиям** яна шартларга җайлашу

приспособлéнец *м презр.* җайлашучы (*икейозле кеше турында*)

приспособлéние *с* **1.** *см.* **приспосóбить, приспосóбиться; 2.** (*устройство*) җайланма

приспосóбленность *ж* ярашканлык; җайлашканлык; ~ **организ́ма к окружáющей срéде** организмның мохиткә җайлашканлыгы

приспособлéнческ||ий, -ая, -ое *презр.* җайлашучанлык ...ы, җайлашучылык, җайлашучы[лар] ...ы; ~**ая полúтика** җайлашучылар сәясәте

приспособлéнчество *с презр.* җайлашучылык, җайлашучанлык

приспособля́емость *ж* күнегә (җайлаша) алу, җайлашучанлык, ярашучанлык; ~ **организ́мов к окружáющей срéде** организмнарның мохиткә ярашучанлыгы

приспособля́ть *несов. см.* **приспосóбить**

приспособля́ться *несов.* **1.** *см.* **приспосóбиться; 2.** *страд. от* **приспособля́ть**

приспускáть *несов. см.* **приспустúть**

приспустúть *сов. что* (*немного опустить*) бераз төшерү, төшерә төшү; (*убавить*) басу, төшерү, кимету, баса (төшерә, киметә) төшү; ~ **флаг** флагны төшерә төшү; ~ **фитúль** филтәне баса төшү; ~ **температýру котлá** казанның температурасын киметә төшү

приспустúться *сов.* бераз төшү, төшә төшү

прúстав *м уст.* пристав

приставáть *несов. см.* **приста́ть** 1-5

приста́вить *сов.* **1.** *кого-что* (*придвинуть*) [янына] кую, терәп кую; (*прислонить*) терәү, сөяү, терәп (сөяп) кую; ~ **стол к стенé** өстәлне стена янына кую; ~ **лéстницу к стенé** баскычны стенага сөяп кую **2.** *что* (*пришить, удлиняя*) ялгау, ялгап кую, ялгап озынайту **3.** *кого-что, разг.* (*для надзора, ухода*) кую, билгеләү

приста́вка *ж* **1.** *см.* **приста́вить** 2; **2.** *грам.* алкушымча

приставля́ть *несов. см.* **приста́вить**

приставн||óй, -áя, -óе өстәп куелган, өстәмә ...; сөяп куела торган; ~**ые местá** (*в театре, кинозале*) өстәмә урындыклар; ~**áя лéстница** сөяп куела торган баскыч

приста́вочный, -ая, -ое *грам.* алкушымча ...; алкушымчалы; ~**ые глагóлы** алкушымчалы фигыльләр

приста́нище *с* сыеныр (торыр) урын

пристанцио́нн||ый, -ая, -ое станция янындагы, станция ...ы; ~**ая у́лица** станция урамы

прúстань *ж* пристань ♦ **ти́хая (ми́рная)** ~ тыныч җир (урын)

приста́||ть *сов.* **1.** *к кому-чему* ябышу, сылану; **грязь** ~**ла к одéжде** киемгә пычрак ябышкан **2.** *к кому, разг.* (*о болезни*) йогу **3.** *к кому-чему, разг.* (*начать, надоедать*) бәйләнү, каныгу; йөдәтү; **что ты ко мне** ~**л?** нәрсә син миңа бәйләндең әле? **4.** *к кому-чему, разг.* (*присоединиться*) ияру; **к нам** ~**ла чужáя собáка** кеше эте иярде безгә **5.** *к чему* (*причалить*) туктау, килеп туктау **6.** *безл.* (*обычно с отриц.*) *разг.* килешү; **вам э́то не** ~**ло** бу килешми сезгә (*кыланыш, сүз турында*); **вам не** ~**ло так говори́ть** болай сөйләү сезгә килешми

пристегáть *сов. что* күкләү, типчү, күкләп (типчеп) кую; ~ **подклáдку** инечен типчеп кую

пристёгивать I *несов. см.* **пристегáть**

пристёгивать II *несов. см.* **пристегнýть**

пристёгиваться *несов.* **1.** *см.* **пристегнýться; 2.** *страд. от* **пристёгивать** II

ПРИ-ПРИ

пристегну́ть *сов.* 1. *что* (*прикрепить*) төймәләү, каптыру, эләктерү, төймәләп (каптырып, эләктереп) кую 2. *кого-что, разг.* (*припрячь*) кушып җигү, янга (прәшкәгә) җигү

пристегну́||ться *сов.* төймәләнү; каптырылу; эләктерелү; **воротничо́к ~лся** яка каптырылды

пристежно́й, -а́я, -о́е каптырып (эләктереп) куела торган; **~ воротни́к** каптырып куела торган яка

присто́йный, -ая, -ое әдәпле, тәрбияле; килешле, күркәм

приста́ивать *несов. см.* **приstро́ить**

приста́иваться *несов.* 1. *см.* **приstро́иться**; 2. *страд. от* **приста́ивать**

приста́стие *с* 1. мәхәббәт, бик ярату, һәвәслек; омтылыш; **~ к теа́тру** театрны бик ярату 2. (*предвзятое отношение*) гаделсезлек, берьяклылык, объектив булмаучылык; **~ в суждениях** фикер йөртүдә берьяклылык [күрсәтү] ♦ **с ~м** жентекләп, вак-төягенә кадәр

пристрасти́ть *сов. кого-что, разг.* кызыксындыру, һәвәсләндерү, дәртен кузгату; **~ к чте́нию** [китап] укуга һәвәсләндерү

пристрасти́ться *сов. к чему, разг.* һәвәсләнү, мавыгу, бирелү, һәвәсләнеп (мавыгып, бирелеп) китү; **~ к кни́гам** китаплар белән мавыгып китү

приста́стность *ж см.* **приста́стие** 2

приста́стн||ый, -ая, -ое гаделсез, гаделлексез, берьяклы, объектив булмаган; **~ое мне́ние** берьяклы фикер; **~ый челове́к** гаделлексез кеше

приста́чивать *несов. см.* **приstрочи́ть**

приstре́ливать I *несов. см.* **приstрели́ть**

приstре́ливать II *несов. см.* **приstреля́ть**

приstре́ливаться *несов.* 1. *см.* **приstреля́ться**; 2. *страд. от* **приstре́ливать** II

приstрели́ть *сов. кого-что* атып үтерү

прота́пливаться *несов.* **1.** аз-маз (сирәк-мирәк) ягылу; аз-азлап (сирәк кенә) ягылу **2.** *страд. от* **прота́пливать**

прота́птывать *несов. см.* **протопта́ть**

протара́нивать *несов. см.* **протара́нить**

протара́нить *сов. что* таранлау

прота́скивать *несов. см.* **протащи́ть**

прота́чивать *несов. см.* **проточи́ть**

протащи́ть *сов. кого-что* **1.** (*волоком*) сөйрәп узу (узып китү), өстерәп узу (узып китү), сөйрәп алып китү **2.** (*пронести через что-л.*) сөйрәп [алып] кертү (чыгару, үткәрү); **~ мешо́к в дверь** капчыкны ишектән сөйрәп кертү **3.** *перен. разг.* (*провести обманным путём*) үткәрү, кертү; **~ свой план** үз планын үткәрү **4.** *перен. разг.* (*подвергнуть критике*) эләктерү, тәнкыйтьләп язу (сөйләү)

прота́я||ть *сов.* **1.** (*растаять*; *оттаять*) эрү, эреп бетү **2.** *что* (*растопить*) эретү, эретеп бетерү **3.** (*берникадәр вакыт*) эрү; **снег ~л с ме́сяц** кар бер айга якын эреде

протеже́ *м, ж нескл. книжн.* протеже (*протекция белән файдаланучы, берәүнең канат астындагы кеше*)

протежи́ровать *несов. кому, книжн.* яклау, канат астына алу

проте́з *м* протез

протези́ровать *сов., несов. кого-что, спец.* протез кую (ясау), протезлау

проте́зн||ый, -ая, -ое протез[лар] ясау ...ы; **~ая мастерска́я** протезлар ясау мастерское

протека́ть *несов. см.* **проте́чь**

протектора́т *м* протекторат (*формаль яктан мөстәкыйль булган бер илнең икенче кайбер зур илдән бәйле булуы*; *шундый бәйлелектәге ил*)

протекциони́зм *м* **1.** *эк.* протекционизм (*кайбер илләрдә чит илләрдән кертелә торган товарларга зур пошлиналар салып, үзләренең промышленностен чит ил конкурентларыннан саклау сәясәте*) **2.** протекционизм, протекция ясау (*хезмәттә дус-ишләрне яклаучылык, кода-кодагыйлык, агай-энечелек мөнәсәбәтләре курсәтү*)

протекциони́ст *м* протекционист, протекционизм тарафдары (*см.* **протекциони́зм** 1)

протекциони́стск||ий, -ая, -ое протекционизм ...ы; **~ая поли́тика** протекционизм сәясәте

проте́кция *ж* протекция, яклау, канат астына алу

протере́ть *сов. что* **1.** (*до дыр*) ышкып тишү, ышкып (ышкый-ышкый) тишеп чыгару **2.** (*вытирая, очистить*) сөртү, сөртеп чыгу, [сөртеп] чистарту; **~ окно́ тря́пкой** тәрәзәне чүпрәк белән сөртү **3.** (*сквозь сито, решето*) үткәрү; (*сквозь тёрку*) кыру ◆ **~ глаза́** 1) (*проснуться*) йөкыдан күзне ачу, уяну; 2) (*опомниться*) күзе ачылу, аңга килү

протере́ться *сов.* ышкылып (ышкыла-ышкыла) тишелү, ышкылып (ышкыла-ышкыла) тишелеп чыгу (бетү)

протеса́ть *сов. что* юну, юнып ясау (алу), таслау, таслап ясау (алу); **~ паз** юнып ырмау ясау

проте́ст *м* протест; **заяви́ть ~** протест белдерү; **~ прокуро́ра** прокурор протесты

протеста́нт *м* **1.** *рел.* протестант (*протестантлыкны тотучы*) **2.** *книжн.* протест белдерүче

протеста́нтка *ж рел.* протестант хатын (кыз)

протеста́нтский, -ая, -ое *рел.* протестант[лар] ...ы; **~ая ве́ра** протестантлар дине

протеста́нтство *с рел.* протестантлык

протестова́ть *несов.* протест белдерү, ризасызлык белдерү

протёсывать *несов. см.* **протеса́ть**

проте́чь *сов.* **1.** (*о реке, ручье*) агу **2.** (*просочиться*) сарку, саркып керү (үтү), керү; **вода́ протекла́ в трюм** трюмга су кергән **3.** су үтү; **кры́ша протекла́** түбәдән су үткән **4.** (*о времени*) үтү, узып китү **5.** *перен.* (*пройти*) үтү, узу; **собра́-**

ние протекло́ споко́йно җыелыш тыныч үтте

про́тив *предлог с род.п.* **1.** *в разн. знач.* каршы; **сиде́ть ~ све́та** яктыга каршы утыру; **сиде́ть друг ~ дру́га** кара-каршы утыру; **плыть ~ тече́ния** агымга каршы йөзү; **~ ве́тра** җилгә каршы; **поступи́ть ~ со́вести** вөҗданга каршы бару; **выступа́ть ~ докла́дчика** докладчыга каршы чыгу **2.** турысына; **поста́вить то́чку ~ чье́й-либо фами́лии** берәүнең фамилиясе турысына нокта кую **3.** ...дан; **лека́рство ~ ка́шля** йөткерүдән дару **4.** *разг.* (*по сравнению*) караганда, чагыштырганда; **~ пре́жнего** элеккегә караганда; **~ вчера́шнего** кичәгегә караганда **5.** *в знач. сказ.* каршы; **ты согла́сен? — Нет, я ~** син килешәсеңме? — Юк, мин каршы **6.** *в знач. сущ.* каршы як; **за и ~** уңай һәм каршы яклар

про́тивень *м* калай таба

противи́тельный, -ая, -ое: **~ сою́з** *грам.* каршы куючы теркәгеч

проти́виться *несов. кому-чему* каршылык күрсәтү, каршы тору (килү, төшү), карышу, карулашу; **~ наси́лию** көчләүгә каршылык күрсәтү

проти́вник *м* **1.** (*враг*) дошман, каршы кеше **2.** (*в спорте*) каршы як; көндәш **3.** *собир.* (*неприятель*) дошман; **разби́ть ~а** дошманны тар-мар итү

проти́вн||ый I, -ая, -ое *в разн. знач.* каршы; **~ая сторона́** каршы як; **~ый ве́тер** каршы җил; **~ым зако́ну** законга каршы; **в ~ом слу́чае** шулай булмаганда, әгәр шулай булмаса, югыйсә, киресенчә булганда; **доказа́тельство от ~ого** *мат.* каршысыннан исбатлау

проти́вный II, -ая, -ое күңел болгандыргыч, жирәнеч; **~ за́пах** күңел болгандыргыч ис

противоа́томн||ый, -ая, -ое атомнан ..., атом коралыннан; **~ая защи́та** атомнан саклану

противоболев||о́й, -а́я, -о́е авыртудан ..., авыртуга каршы [кулланыла торган]; **~ы́е сре́дства** авыртуга каршы чаралар

противобо́рствовать *несов. кому-чему, уст.* каршы көрәшү, каршы тору

противове́с *м тех.* каршылама, каршы авырлык **♦ в ~** *кому-чему* ...га каршы, каршы буларак

противовозду́шн||ый, -ая, -ое һава һөҗүменә каршы; **~ая оборо́на** һава һөҗүменә каршы оборона

противога́з *м* противогаз

противога́зн||ый, -ая, -ое противогаз ...ы; **~ая су́мка** противогаз букчасы

противога́зов||ый, -ая, -ое газдан саклый торган; **~ые сре́дства** газдан саклый торган чаралар

противоде́йствие *с* каршылык, каршы эш-рәрәкәт; каршы тәэсир; **оказа́ть ~ *чему-л. берәр нәрсәгә*** каршылык күрсәтү

противоде́йствовать *несов. кому-чему* каршылык күрсәтү, каршы килү (төшү), каршы чара күрү, карышу

противоесте́ственность *ж* гайре табигыйлык, табигый булмаганлык

противоесте́ственн||ый, -ая, -ое гайре табигый, табигый булмаган; **~ая скло́нность** табигый булмаган омтылыш

противозако́нн||ый, -ая, -ое законга каршы [булган], законга сыймый торган; **~ые де́йствия** законга каршы эшләр

противозача́точн||ый, -ая, -ое бала булдырмый торган, балага узудан саклану ...ы; **~ые сре́дства** балага узудан саклану чаралары

противолежа́щий, -ая. -ое *мат.* каршыдаш; **~ у́гол** каршыдаш почмак

противопожа́рный, -ая, -ое янгынга каршы; **~ые мероприя́тия** янгынга каршы чаралар

противопоказа́ние *с* **1.** *юр.* капма-каршысын күрсәтү (сөйләү), киресен күрсәтү (сөйләү) **2.** *мед.* [даруның, дәвалауның] зарарлы булуын (килешмәвен, ярамавын) күрсәтә торган билге

противопока́занный, -ая, -ое *мед.* зарарлы, ярамаган

противополага́ть *несов.* каршы (капма-каршы) кую

противополо́жность *ж* **1.** каршылык, капма-каршылык, капма-каршы булу; **~ мне́ний** фикерләрнең капма-каршылыгы **2.** ... капма-каршысы, ... киресе; **он по́лная ~ своему́ отцу́** ул атасының капма-каршысы **3.** *филос.* капма-каршылык **♦ в ~ *кому-чему*** ...га капма-каршы буларак, ...дан аермалы буларак

противополо́жный, -ая, -ое **1.** каршы, каршы яктагы; **~ый бе́рег** каршы яктагы яр **2.** каршы, капма-каршы; **~ое мне́ние** капма-каршы фикер

противопоста́вить *сов. кого-что кому-чему* **1.** (*сравнить*) каршы кую; чыгыштыру **2.** каршы кую; **~ себя́ коллекти́ву** үзеңне коллективка каршы кую

противопоставля́ть *несов. см.* **противопоста́вить**

противораке́тный, -ая, -ое ракеталарга каршы ...; **~ая оборо́на** ракеталарга каршы оборона

противоречи́в||ый, -ая, -ое каршылыклы, капма-каршы [килә торган]; **~ые мне́ния** капма-каршы фикерләр

противоре́чие *с в разн. знач.* каршылык; **~я во взгля́дах** карашлардагы каршылыклар; **кла́ссовые ~я** сыйнфый каршылыклар; **впасть в ~е** үзеңә үзең каршы килү

противоре́ч||ить *несов.* **1.** *кому* (*возражать*) карышу, каршы килү (төшү); карулашу; каршы әйтү; **~ить ста́ршим** олыларга каршы әйтү **2.** *чему* каршы килү, капма-каршы килү; **показа́ния ~ат друг дру́гу** күрсәтүләр бер-берсенә каршы килә

противостоя́ние *с астр.* кара-каршы торыш, каршыда торыш

противостоя́||ть *несов. кому-чему* **1.** каршы тору, каршылык күрсәтү; **~ть ве́тру** җилгә каршы тору **2.** [бер-берсенә] каршы килү (булу, тору), [бер-берсенә] каршы куелу; **~щие мне́ния** бер-берсенә каршы килгән фикерләр

противота́нков||ый, -ая, -ое танкка каршы; **~ая артилле́рия** танкка каршы артиллерия

противохими́ческ||ий, -ая, -ое агулы газларга (матдәләргә) каршы, агулы газлардан (матдәләрдән) саклый торган; **~ая защи́та** агулы матдәләрдән саклану

противоя́дие *с* **1.** *мед.* агу кайтаргыч **2.** *перен* агу кайтаргыч чара

протира́ть *несов. см.* **протере́ть**

протира́ться *несов.* **1.** *см.* **протере́ться; 2.** *страд.от* **протира́ть**

проти́рка *ж* **1.** *см.* **протере́ть** 2, 3; **~ стёкол** пыялаларны [сөртеп] чистарту **2.** *воен.* чистарткыч (*ату коралын чистарту өчен хезмәт итә торган чүпрәк һ.б.ш.*)

проти́рочн||ый, -ая, -ое сөртә торган, сөртеп чистарта торган

проти́скаться *сов. разг. см.* **проти́снуться**

проти́скивать *несов. см.* **проти́снуть**

проти́скиваться *несов.* **1.** *см.* **проти́снуться; 2.** *страд.от* **проти́скивать**

проти́снуть *сов. кого-что, разг.* тыгу, кертү, төртеп (этеп-төртеп) кертү

проти́снуться *сов. разг.* этеп-төртеп (этешеп-төртешеп) керү (чыгу, үтү), кысылып (кысыла-кысыла) керү (чыгу); **~ вперёд** этешеп-төртешеп алга үтү

проткну́ть *сов. что* үчпләмләү, үчпләмлап туку; **~ край ковра́ кра́сным шёлком** паласның читен кызыл ефәк белән үчпләмләп туку

проткну́ть *сов. кого-что* чәнчеп (кадап) тишү

протодья́кон *м церк.* протодъякон

протоиере́й *м церк.* протоиерей

протоисто́рия *ж* кешелек дөньясының тарихкача булган чоры

прото́к *м* **1.** ермак **2.** *анат.* юл, канал; **жёлчный ~** үт юлы

протоко́л *м в разн. знач.* беркетмә; **писа́ть ~** беркетмә язу; **записа́ть в ~** беркетмәгә теркәү (язып кую)

протоколи́ровать *сов. несов. что* (*составить протокол*) беркетмә язу, беркетмәгә теркәү

протоко́льн||ый, -ая, -ое **1.** беркетмә ...ы; **~ая за́пись** беркетмә язуы, беркетмә **2.** беркетмә ...ы, беркетмәгә хас, коры; **~ый стиль** беркетмә стиле

протолка́ть *сов. кого-что, разг.* этеп (этеп-төртеп) кертү

протолка́ться *сов. разг.* (*пробраться через толпу*) этеп-төртеп узу (керү, чыгу), ерып чыгу

протолкну́ть *сов.* **1.** *кого-что* төртеп кертү (чыгару), этеп кертү (чыгару); (*пробку*) төртеп төшерү; **~ вперёд** этеп алга чыгару **2.** *перен что, разг.* (*ускорить*) тизләтү, кузгатып жибәрү; **~ де́ло** эшне тизләтү

прото́н *м физ.* протон

прото́пать *сов. разг.* (*пройти, пробежать, топая*) дап-доп [итеп] узып (үтеп) китү

протопи́ть *сов.* что [яхшылап] ягу, [ягып] жылыту, [ягып] кыздыру; **~ печь** мичне яхшылап ягу

протопи́||ться *сов.* узу, янып бетү; **печь ~лась** мич узды

протоплазма *ж биол.* протоплазма

протопта́ть *сов. что* **1.** күп йөреп (*юл, сукмак*) салу, йөри-йөри (*юл, сукмак*) салу; **~ доро́жку** йөри-йөри юл салу **2.** *разг.* (*протереть ходьбой*) таптап кырып бетерү; (*обувь*) туздырып бетерү, тишеп чыгару, тишеп бетерү

проторы́ть *сов. что* йөреп (*юл, сукмак*) салу, йөри-йөри (*юл, сукмак*) салу; **~ доро́гу** йөреп юл салу

проторча́ть *сов. прост.* (*берникадәр вакыт*) *берәр җирдә* булу, тору, (*берникадәр вакытны*) *берәр җирдә* уздыру, үткәрү

проторя́ть *несов. см.* **проторы́ть**

прототи́п *м. лит.* прототип, беренче үрнәк

прото́чина *м* **1.** (*червоточина*) корт юлы, корт ашаган урын **2.** (*промоина*) су юган юл (тишек); ерганак

проточи́ть *сов. что* **1.** (*о червях, насекомых, грызунах*) [ашап] тишү, [ашап] тишкәләп бетерү; (*о моли*) кисү **2.** (*о воде*) юу, юдыру, еру **3.** *тех.* (*на токарном станке*) тишү, кырып тишү (ясау)

прото́чн||ый, -ая, -ое **1.** агым ..., агар; **~ая вода́** агым су **2.** агым сулы; **~ый пруд** агым сулы суы буа **3.** *тех.* су (пар) үтә торган; **~ая часть турби́ны** турбинаның су үтә торган өлеше

протра́ва *ж* **1.** *см.* **протрави́ть; 2.** *хим.* протрава (*буяуга манылачак әйберне эшкәртә торган химик препарат*)

протрави́тель *м* **1.** (*препарат*) орлык агулагыч **2.** (*машина*) орлык агулау машинасы

протрави́ть *сов. что* **1.** (*выжечь*) [кислота белән] ашатып бизәк төшерү **2.** (*обработать протравой*) протрава белән эшкәртү **3.** *с.-х.* (*семена*) агулау

протра́вливать *несов. см.* **протрави́ть**

протравля́ть *несов. см.* **протрави́ть**

протра́ливать *несов. см.* **протра́лить**

протра́лить *сов. что мор.* миналарны траллау, [трал белән] миналардан чистарту; **~ зали́в** диңгез култыгын трал белән миналардан чистарту

протрезви́ть *сов. кого-что* айныту (*исерек кешене*)

протрезви́ться *сов.* айну (*исерек кеше турында*)

протрезвля́ть *несов. см.* **протрезви́ть**

протрезвля́ться *несов.* **1.** *см.* **протрезви́ться; 2.** *страд.от* **протрезвля́ть**

протуха́ть *несов. см.* **проту́хнуть**

проту́хнуть *сов.* сасу, бозылу, сөрсү, сасып (бозылып, сөрсеп) бетү

протыка́ть *несов. см.* **проткну́ть**

протя́гивать *несов. см.* **протяну́ть**

протя́гиваться *несов.* **1.** *см.* **протяну́ться; 2.** *страд.от* **протя́гивать**

протяже́ни||е *с* буй; **на всём ~и от дере́вни до го́рода** авылдан шәһәргә кадәр бөтен юл буена; **~е в длину́** озынлыгы, буе; **~е в ширину́** киңлеге, ине; **~е в высоту́** биеклеге ♦ **на ~и** 1) буена; **на ~и всего́ пути́** юл буена; 2) буена, дәвамында; **на ~и пяти́ лет** биш ел буена, биш ел дәвамында; **на ~и веко́в** гасырлар буена

протяжённость *ж* озынлык; **~ городско́й га́зовой се́ти** шәһәр газ челтәренең озынлыгы

протя́жн||ый, -ая, -ое сузып-сузып ..., сузынкы; озын; **~ый стон** сузып-сузып ыңгырашу; **~ая пе́сня** озын кәй

протяну́ть *сов.* **1.** *что* сузу, тарту, үткәрү; **~ верёвку** бау тарту; **~ телефо́нную ли́нию** телефон линиясе үткәрү **2.** *кого-что* сузу; **~ ру́ку** кул сузу **3.** *что, разг.* озакка сузу; **~ де́ло** эшне озакка сузу **4.** *что* сузып әйтү; **~ звук** авазны сузып әйтү **5.** *разг.* сузу, тору, яшәү; **больно́й недо́лго протя́нет** авыру озакка сузмас ♦ **~ но́ги** *прост.* аякларны сузу (*үлү*); **~ ру́ку [по́мощи]** *кому* ярдәм кулы сузу

протяну́ться *сов. в разн. знач.* сузылу; **в окно́ ~лась чья́-то рука́** тәрәзәдән кемнеңдер кулы сузылды; **доро́га ~лась на со́тни киломе́тров** юл йөзләрчә километрга сузылган; **докла́д до́лго не протя́нется** доклад озакка сузылмас

проу́чивать *несов. см.* **проучи́ть** I

проучи́ть *сов.* **1.** *кого-что, разг.* акылга өйрәтү, арт сабагын укыту, кирәген бирү; әдәпкә өйрәтү; **~ть озорника́** шаянның кирәген бирү **2.** (*берникадәр вакыт*) өйрәнү, өйрәнеп утыру, (*берникадәр вакытны*) өйрәнеп үткәрү; **весь ве́чер я ~л уро́ки** кич буе дәресләремне өйрәнеп утырдым

проучи́ться *сов.* (*берникадәр вакыт*) уку

проу́шина *ж* тишек; колак (*бау керту өчен*)

профа́н *м* надан, надан баш, томана, профан

профана́ция *ж книжн.* профанация, кадерен җибәрү (китәрү), кимсетү, түбәнсетү, бозу, хурлау; **~ нау́ки** фәннең кадерен китәрү

профани́ровать *сов., несов. что, книжн.* кадерен җибәрү (китәрү), кимсетү, түбәнсетү, бозу, хурлау

профессиона́л *м* профессионал

профессиона́льн||ый, -ая, -ое профессия ...ы; профессиональ; **~ый сою́з** профессиональ союз; **~ая ориента́ция** профессиональ ориентация; **~ый революционе́р** профессиональ революционер

профе́ссия *ж* профессия, һөнәр; кәсеп (*разг.*)

профе́ссор *м* профессор

профе́ссорство *с* профессорлык, профессор вазифасы

профессу́ра *ж* **1.** *книжн.* (*звание*) профессорлык, профессорлык вазифасы **2.** *собир.* профессорлар

профила́ктика *ж* профилактика

профилакти́ческий, -ая, -ое профилактика ...ы, профилактик; **~ осмо́тр** профилактик тикшерү

профилакто́рий *м* профилакторий

профили́ровать *сов., несов. что, спец.* **1.** дөрес профиль бирү (*мәс. юлга*) **2.** [детальне] билгеле бер формага салу (китерү)

про́филь *м* профиль

профильтрова́ть *сов. что* фильтрлау

профко́м *м* профком

профо́рг *м* профорг

профо́рм||а *ж разг.* проформа, тышкы формальлек; күз буяу; **соблюсти́ ~у** тышкы формальлекне саклау; **для (ради) ~ы** күз буяу өчен

профсою́з *м* профсоюз, профессиональ союз

профсою́зн||ый, -ая, -ое профсоюз ...ы; **~ое собра́ние** профсоюз җыелышы

прохаживаться *несов. см.* **пройти́сь**

прохвати́||ть *сов. кого-что* **1.** *разг.* (*пронизать — о холоде, сырости и т.п.*) үзәккә үтү, жилеккә үтү, үтәдән-үтү **2.** (*продуть*) салкын тию (бәрү); җил тию; **меня́ ~ло на сквозня́ке** миңа үтәли җилдә салкын тигән **3.** *перен. прост.* (*подвергнуть резкой критике*) эләктерү, нык тәнкыйтләү

прохва́тывать *несов. см.* **прохвати́ть**

прохвора́ть *сов. разг.* (*берникадәр вакыт*) авыру, чирләү, авырып (чирләп) яту

прохво́ст *м бран.* кабахәт, әшәке; юньсез

прохла́да *ж* салкынча һава; жиләс һава; **у́тренняя ~** иртәнге салкынча һава

прохла́д||ец *м*: **с ~цем** *разг.* 1) (*вяло, без усердия, не торопясь*) сүлпән генә, ашыкмыйча; 2) (*равнодушно*) салкын [гына], күңел бирмичә

прохлади́тельн||ый, -ая, -ое **1.** салкын; салкынайтып җибәрә торган, хәл керткеч, хәл кертә торган; **~ый напи́ток** салкын эчемлек **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* салкын эчемлек

прохлади́ться *сов. разг.* суыну; саф һава алу; **я вы́шел ~ на у́лицу** урамга саф һава суларга чыктым

прохла́дно *нареч. в знач. сказ. безл.* салкынча; жиләс; **сего́дня ~** бүген салкынча

прохла́дн||ый, -ая, -ое **1.** салкынча, жиләс; **~ый день** салкынча көн; **~ая вода́** салкынча су **2.** *перен.* салкын; **~ые отноше́ния** салкын мөнәсәбәтләр

прохла́дц||а *ж*: **с ~ей** *то же, что с* **прохла́дцем** (*см.* **прохла́дец**)

прохлажда́ться *несов. разг.* **1.** *см.* **прохлади́ться; 2.** (*неторопливо делать что-л.*) акрын кыймылдау, акрын маташу **3.** (*бездельничать*) эшләмичә кайгысыз яшәү; кәеф-сафа чигү

прохо́д *м* **1.** *см.* **пройти́** 1; **2.** юл, үтеп йөрү юлы, үтү юлы, үтә торган юл; **го́рный ~** таулар арасыннан үтә торган юл ♦ **за́дний ~** *анат.* арт юл; **~а (~у) нет** *от кого-что* котылыр хәл юк; **~а (~у) не дава́ть** *кому* тынычлык бирмәү

проходи́мец *м разг.* юньсез, эт кеше; әшәке кеше

проходи́мость *ж* **1.** үтәрлек булу, үтеп йөрерлек булу, үтә алырлык булу; **~ боло́т** сазлыкларның үтеп йөрерлек булуы **2.** *мед.* үткәрү; **плоха́я ~ кише́чника** эчәкләрнең начар үткәрүе **3.** төрле җирдән үтә алу; үтү сәләте, үтүчәнлек; **~ тракторо́в** тракторларның төрле җирдән үтә алуы

проходи́мый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **проходи́ть** 1; **2.** үтәрлек, үтә алырлык, үтеп йөрерлек; **~ые боло́та** үтеп йөрерлек сазлыклар

проходи́ть I *несов. см.* **пройти́**

ПРО-ПРО

проходи́||ть II *несов. в разн. знач.* (*берникадәр вакыт*) йөрү, (*берникадәр вакытны*) йөреп үткәрү; **я три часа ~л по у́лице** өч сәгать буена урамда йөрдем; **часы́ ~ли оди́н день** сәгать бер көн йөрде

прохо́дка *ж горн.* казу, казып бару; **~ шахт** шахталар казу

проходн||о́й, -а́я, -о́е (*служащий для прохода*) аркылы үтеп йөри торган, үтәли (үтеп) йөрелмәле; **~о́й двор** үтеп йөрелмәле ишек алды **2.** *в знач. сущ.* **~а́я** *ж* проходной

прохо́дческ||ий, -ая, -ое *горн.* проходчик[лар] ...ы; **~ая брига́да** проходчиклар бригадасы

прохо́дчик *м горн.* проходчик; казучы

прохо́ж||ий, -ая, -ее **1.** узып баручы, узгынчы, юлаучы (җәяүләп); **~ий челове́к** узып баручы кеше **2.** *в знач. сущ.* **~ий** *м*, **~ая** *ж* узып баручы [кеше], узгынчы, юлаучы; **спроси́ть у ~его** узып баручыдан сорау

прохрупи́**ть** *сов.* **1.** (*издать хриплый звук*) хырылдап кую **2.** (*сказать хриплым голосом*) карлыккан тавыш белән әйтеп кую **3.** (*берникадәр вакыт*) карлыккан товыш белән сөйләү

прохуди́ться *сов. прост.* тузу, тишелү; **сапоги́ ~лись** итекләр тишелгән

процве||сти́ *сов.* (*берникадәр вакыт*) чәчәк ату; **георги́ны ~ли́ всё ле́то** дәлияләр җәй буе чәчәк атты

процвета́||ть *несов.* (*успешно развиваться*) чәчәк ату, гөрләп алга бару, гөрләп үсү; (*благоденствовать*) рәхәтләнеп яшәү; **страна́ ~ет** ил гөрләп алга бара; **нау́ки ~ют** фәннәр гөрләп үсә

процеди́ть *сов.* **1.** *что* сөзү, сөзеп алу; үткәрү; **~ молоко́** сөт сөзү **2.** *перен. что и без доп.* [теш арасыннан гына] әйтү, әйтеп кую; [теш арасыннан гына] чыгару; **~ сквозь зу́бы** теш арасыннан гына әйтеп кую

процеду́р||а *ж* процедура; эзлекле тәртибе; **~а голосова́ния** тавыш бирү процедурасы; **~а подписа́ния догово́ра** договорга кул кую процедурасы **2.** *мед.* процедура; **лече́бные ~ы** дәвалау процедуралары; **ходи́ть на ~ы** процедурага йөрү

процеду́рн||ый, -ая, -ое **1.** процедура[лар] ...ы; **~ый вопро́с** процедура мәсьәлә; **~ые пра́вила** процедура кагыйдәләре **2.** процедура[лар] ...ы; **~ый кабине́т** процедуралар кабинеты

проце́живать *несов. см.* **процеди́ть**

проце́нт *м в разн. знач.* процент; **вы́полнить план на сто ~ов** планны йөз процентка үтәү; **де́ньги лежа́т в ба́нке и даю́т четы́ре ~а дохо́да** акча банкта ята һәм дүрт процент табыш бирә ♦ **на [все] сто ~ов** йөз процентка, тулысынча

проце́нтн||ый, -ая, -ое **1.** процент белән исәпләнгән; процентлы, процент...; **~ая но́рма** процент белән исәпләнгән норма; **~ое содержа́ние желе́за в руде́** рудадагы тимернең процент составы **2.** процентлы, процент бирә торган; **~ые бума́ги** процент бирә торган кәгазьләр

проце́сс *м* **1.** процесс, барыш; **~ рабо́ты** эшнең барышы; **в ~е борьбы́** көрәш процессында; **произво́дственный ~** производство процессы; **~ разви́тия расте́ний** үсемлекләрнең үсеш процессы **2.** *мед.* процесс; **воспали́тельный ~** ялкынсыну процессы **3.** *юр.* процесс, суд; **уголо́вный ~** җинаять тикшерү процессы; **суде́бный ~** суд процессы; **выступа́ть на ~е** судта чыгыш ясау

проце́ссия *ж* процессия (*тантаналы йөреш*)

процессуа́льн||ый, -ая, -ое *юр.* процессуаль; **~ые сро́ки** процессуаль сроклар

проци́ровать *сов. кого-что* өземтә китерү (алу), өзек китерү (алу), цитата китерү (алу); **~ Бели́нского** Белинскийның әсереннән өзек китерү

про́черк *м* сызык

прочёркивать *несов. см.* **прочеркну́ть**

прочеркну́ть *сов. что* [буйдан-буйга] сызу, [буйдан-буйга] сызып чыгу

прочерти́ть *сов.* **1.** *что* сызу; **~ кривы́ю** кәкре сызык сызу **2.** *что и без доп.* (*провести черту*) сызык сызу **3.** *что и без доп.* (*берникадәр вакыт*) сызу, (*берникадәр вакытны*) сызып үткәрү; **~ весь день** көн буе [сызым *h.б.ш.*] сызу

прочёрчивать *несов. см.* **прочерти́ть** 1, 2

процеса́||ть *сов. что* **1.** тәрәшләү; тарау, тарап чистарту; **~ть шерсть** йон тарау **2.** *перен. разг.* җентекләп тикшереп чыгу, карап чыгу; **пехо́та ~ла лес** пехота урманны җентекләп тикшереп чыкты

проче́сть *сов. что и без доп. разг. см.* **прочита́ть**

прочёсывать *несов. см.* **процеса́ть**

про́ч||ий, -ая, -ее **1.** башка, бүтән, калган; **~ие лю́ди** калган кешеләр **2.** *в знач. сущ.* **~ее** *с* башкасы, калганы **3.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* (*о людях*) башкалар, бүтәннәр, калганнар; **не в приме́р ~им** башкалардан аермалы буларак ♦ **и ~ее** һәм башка

проче́стить *сов. что* чистарту, тазарту; **~ трубу́** моржа чистарту; **~ желу́док** эчне чистарту

прочита́ть *сов.* **1.** *что и без доп.* уку; **~ сло́во** сүзне уку; **~ по-францу́зски** французча уку **2.** *кого-что* (*книгу, статью и т.п.*) уку, укып чыгу; **~ газе́ту** газета уку **3.** *перен. что* күрү, сизү, белү, аңлау, күреп (белеп, сизеп) алу, аңлап алу; **~ на лице́ испу́г** йөзенә курку чыкканны күрү; **~ весь ход мы́слей** барлык уйларының агышын аңлап алу **4.** *кого-что* (*вслух*) уку, кычкырып уку **5.** *что* уку; **~ нота́цию** нотация уку **6.** *что и без доп.* (*берникадәр вакыт*) уку, (*берникадәр вакытны*) укып үткәрү

прочи́тывать *несов. см.* **прочита́ть** 1, 2

про́чить *несов. кого-что, разг.* ... булыр дип уйлау; ... булыр дип исәпләү; күздә тоту; **~ блестя́щее бу́дущее** [аның] киләчәге бик матур булыр дип исәпләү; **~ кого-л. в заве́дующие** *берәр кешене* мөдир итеп куюны күздә тоту

прочища́ть *несов. см.* **проче́стить**

прочиха́ться *сов. разг.* төчкерү, төчкереп [борын-йоткылыкны] чистарту

про́чн||ый, -ая, -ое **1.** нык, таза, чыдам, чыдамлы; **~ая ткань** нык тукыма **2.** *перен.* нык, какшамас; **~ый мир** какшамас тынычлык; **~ая семья́** нык гаилә

прочу́вствованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **прочу́вствовать; 2.** чын күңелдән ...ган, тирән хис белән сугарылган; **~ые слова́** чын күңелдән әйтелгән сүзләр

прочу́вствовать *сов. что* **1.** (*воспринять чувствами*) тирәнтен аңлау, тирәнтен төшенү **2.** (*испытывать какое-л. чувство*) кичерү, баштан үткәрү

прочь *нареч.* **1.** читкә; **отбро́сить ~** читкә ташлау **2.** *в знач. сказ.* кит, югал, ычкын, юк бул; **~ с доро́ги!** кит юлымнан! **~ с глаз мои́х!** югал күземнән! ♦ **не ~** (*согласен*) каршы түгел, риза

проше́дш||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **пройти́; 2.** үткән, үтеп киткән, узган; **~ий год** үткән ел **3.** *в знач. сущ.* **~ее** *с* (*минувшее событие*) [булып] үткәннәр, үткәндәгеләр; (*минувшее время*) үткән заман, элекке заман; **вспомина́ть ~ее** үткәннәрне искә төшерү ♦ **~ее вре́мя** *грам.* үткән заман

проше́ние *с уст.* үтенеч язуы, гариза; **пода́ть ~** үтенеч язуы бирү

прошепта́ть *сов. что* пышылдап әйтү (әйтеп кую); **~ ла́сковое сло́во** пышылдап яхлмы сүз әйтү

проше́стви||е *с*: **по ~и** *чего* узгач, үткәч, узганнан (үткәннән) соң; **по ~и го́да** бер ел үткәч, бер елдан соң

прошиба́ть *несов. см.* **прошиби́ть**

прошиб||и́ть *сов. разг.* **1.** *что* (*пробить ударом*) бәреп (сугып) тишү; бәреп (сугып) вату **2.** *кого-что* (*пронять*) җиңү; **его́ ниче́м не ~ёшь** аны һичбер нәрсә белән җиңә алмыйсың **3.** бәреп чыгу; **пот прошиб** тир бәреп чыкты

прошива́ть *несов. см.* **проши́ть**

проши́вка *ж* **1.** *см.* **проши́ть** 1, 2; **2.** (*кружево*) (*кулмәккә h.б.ш. тегелгән*) челтәр **3.** *тех.* (*обработка металла*) тишү **4.** *тех.* (*инструмент*) тишкеч

прошивно́й, -а́я, -о́е **1.** (*прошитый насквозь*) үтә тегелгән, үтә тегелмәле **2.** (*снабжённый прошивкой*) челтәр салынган, челтәрле **3.** *тех.* тишә торган; тишкеч ...; **~ пресс** тишә торган пресс (эскәнҗә)

проши́ть *сов.* **1.** *что* (*пришить*) тегү, тегеп чыгу; **~ подо́шву** олтанны тегеп чыгу **2.** *что* (*проткнуть*) каю, каеп чыгу; **~ воротни́к** яканы каю **3.** *тех. что* тишү **4.** *кого-что, разг.* тишкәләп бетерү; **~ пу́лями** пулялар белән тишкәләп бетерү

прошлогодн||ий, -ая, -ее **1.** былтыргы, узган (үткән) ел[да]гы; **~яя листва́** былтыргы яфраклар **2.** былтыргы, узган (үткән) ел[да]гы, былтыр булып үткән; **~яя встре́ча** былтыр үткән очрашу ♦ **ну́жен как ~ий снег** былтыргы кардай кирәк (*әһәмиятсез, кирәксез нәрсә турында*)

про́шл||ый, -ая, -ое **1.** үткән, узган; **~ый год** үткән ел **2.** (*предыдущий*) [моннан] алдагы, [моннан] элекке, үткәндәге; **в ~ый раз** үткәндә **3.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* (*минувшее событие*) [булып]

үткәннәр, үткәндәгеләр; (*минувшее время*) үткән заман, элекке заман; **вспомина́ть ~ое** үткәннәрне искә төшерү; **далёкое ~ое** бик күптән үткән заман ♦ **отойти́ в ~ое** (*о нравах, обычаях*) онытылу, онытылып бетү

прошмы́гивать *несов. см.* **прошмыгну́ть**

прошмыгну́ть *сов. разг.* тиз генә (сиздермичә генә) үтеп (кереп, чыгып) китү; елт итеп кереп китү; **~ в дверь** сиздермичә генә ишектән кереп китү

прошнурова́ть *сов. что* шнурлау, шнурлап чыгу, шнур үткәреп чыгу; **~ тетра́дь** дәфтәрне шнурлау

прошнурóвывать *несов. см.* **прошнурова́ть**

прошпаклева́ть *сов. что* шпаклёвкалау, шпаклёвкалап чыгу, [шпаклёвка белән] сылап чыгу; **~ сте́ны** стеналарны [шпаклёвка белән] сылап чыгу

прошпаклёвывать *несов. см.* **прошпаклева́ть**

прошпигова́ть *сов. что* шпиклау, шпиклап чыгу

прошпигóвывать *несов. см.* **прошпигова́ть**

проштра́фиться *сов. в чём* гаепле булу, ялгышлык эшләп ташлау, хаталык эшләү

проштуди́ровать *сов. кого-что* өйрәнү, тырышып өйрәнү; жентекләп өйрәнү; **~ матема́тику** математиканы тырышып өйрәнү

проштукату́рить *сов. что* штукатурлау, штукатурлап чыгу; **~ сте́ны** стеналарны штукатурлау

проща́льный, -ая, -ое саубуллашу ...ы, хушлашу ...ы, аерылышу ...ы; **~ приве́т** саубуллашу сәламе; **~ обе́д** саубуллашу мәҗлесе

проща́ние *с см.* **проста́ться ♦ на ~** аерылышу алдыннан; аерылышканда

проща́ть *несов. см.* **прости́ть**

проща́ться *несов.* **1.** *см.* **прости́ться; 2.** *страд. от* **проща́ть**

проще́ние *с* **1.** *см.* **прости́ть; 2.** гафу итү, кичерү; **проси́ть ~я** гафу үтенү

прощу́пать *сов.* **1.** *что* капшап (кармалап) карау, капшап (кармалап) чыгу; **~ карма́ны** кесәләрне капшап чыгу **2.** *что* капшап (кармалап) табу; **о́пухоль** шешне капшап табу **3.** *перен. кого-что* (*составить себе представление*) сынау ♦ **~ по́чву** ачыклап (тикшереп) карау; кылын тартып карау

прощу́пывать *сов. см.* **прощу́пать**

прощу́пываться *несов.* **1.** капшаганда сизелү (тоелу, белену); **о́пухоль ~ется** шеш капшаганда беленә **2.** *страд. от* **прощу́пывать**

проэкзаменова́ть *сов. кого-что* имтихан алу; сынау алу; **~ ученика́** укучыдан имтихан алу

проэкзаменова́ться *сов.* имтихан бирү (тапшыру), сынау бирү (тапшыру)

прояви́тель *м фото* ачыгайткыч

прояви́ть *сов. что* **1.** күрсәтү; **~ геро́изм** геройлык күрсәтү **2.** *фото* ачыгайту; **~ сни́мок** рәсемне ачыгайту ♦ **~ себя́** үзен күрсәтү

прояви́||ться *сов.* **1.** беленү, сизелү, ачылу, күренү; туу, ...а башлау; **у него́ ~лся интере́с к жи́вописи** ул сынлы сәнгать белән кызыксына башлады **2.** *фото* ачыклану

проявля́ть *несов. см.* **прояви́ть**

проявля́ться *несов.* **1.** *см.* **прояви́ться; 2.** *страд. от* **проявля́ть**

прояснé||ть *сов. разг.* **1.** ачылу, яктыру; **нéбо ~ло** күк йөзе ачылды **2.** *безл.* аязлану; **к вéчеру ~ло** кичкә таба аязды

проясне́||ть *сов.* **1.** ачыклану; **мы́сли ~ли** фикерләр ачыкланды **2.** ачылу, яктыру, ачылып (яктырып) китү; **глаза́ ~ли** күз карашы яктырып китте

проя́снивать *несов. см.* **проя́снеть** 2

проя́снить *сов. см.* **проя́снеть**

проясни́||ться *сов.* **1.** ачылу; **кра́ски ~лись** буяулар ачылды; **нéбо ~лось** күк йөзе ачылды **2.** ачыклану; **положе́ние ~лось** хәл ачыкланды **3.** (*о сознании*) ачылу; яктыру **4.** ачылу, яктыру, ачылып китү, яктырып китү; **лицó егó ~лось** аның йөзе яктырып китте

проясня́ться *несов. см.* **проясни́ться**

пруд *м* буа

пруди́ть *сов. что* буа буу ♦ **хоть пруд пруди́** *кого-что* буа буарлык, бик күп, иксез-чиксез күп

пружи́на *ж* пружина

пружи́нист||ый, -ая, -ое сыгылмалы, пружинасыман; пеше; **~ые мýскулы** пружинасыман мускуллар; **~ая похóдка** сыгылмалы салмак йөреш

пружи́н||ить *несов.* [пружина сыман] сыгылу; **рессóры хорошó ~ят** рессорлар яхшы сыгылалар

пружи́ниться *несов. разг. см.* **пружи́нить**

пружи́нный, -ая, -ое пружиналы; **~ матра́ц** пружиналы матрац

прусáк *м* кызыл таракан

прут *м* **1.** чыбык; **берёзовый ~** каен чыбыгы **2.** (*тонкий металлический стержень*) юан тимерчыбык

прутя́н||óй, -á я, -óе чыбыктан үреп ясалган, чыбыктан үрелгән; **~áя корзи́на** чыбыктан үреп ясалган кәрзин

прыг *межд. в знач. сказ. разг.* сикерде менде, сикерде төште, тотты да сикерде, сикерде куйды; **он ~ в вóду** ул суга сикерде төште

пры́га||ть *несов. в разн. знач.* сикерү; **~ть чéрез барьéр** барьер аша сикерү; **сéрдце ~ет от рáдости** шатлыктан йөрәк сикерә; **мяч хорошó ~ет** туп яхшы сикерә

пры́гнуть *сов. однокр. см.* **пры́гать**

прыгýн *м* **1.** (*тот, кто хорошо прыгает*) яхшы сикерүче, яхшы сикерүчән **2.** *спорт.* сикерүче

прыгýнья *ж* сикерүче хатын (кыз)

прыжóк *м* сикерү, сикереш; **~ в вóду** суга сикерү; **дéлать ~** сикерү

пры́скать *несов. см.* **пры́снуть**

пры́скаться *несов. чем, разг.* үзенә сибү, бөркү; **~ одеколóном** үзенә одеколон бөркү

пры́снуть *сов. разг.* **1.** сибү, бөркү; **~ одеколóном** одеколон сибү; **~ на цветы́ водóй** чәчәкләргә су сибү **2.** пырхылдап [көлеп] жибәрү; **~ со́ смеху** пырхылдап көлеп жибәрү

пры́ткий, -ая, -ое *разг.* житез, елдам, өлгер, тере; **~ мальчугáн** тере малай

прыть *ж разг.* (*быстрота*) тизлек, кызулык; (*проворство*) житезлек, елдамлык, өлгерлек, елгырлык, терелек; **обнару́жить большу́ю ~** бик зур житезлек күрсәтү ♦ **во всю ~** җан-фәрманга, бөтен көчкә

прыщ *м* сыткы, бетчә

прыща́в||ый, -ая, -ое *разг.* сыткылы, бетчәле, сыткы баскан; **~ое лицó** сыткылы бит

прыщева́тый, -ая, -ое *разг.* бераз (азмаз) сыткылы (бетчәле); **~ нос** аз-маз сыткылы борын

прюне́лев||ый, -ая, -ое прюнель ..., прюнельдән тегелгән; **~ые ту́фли** прюнель туфлилар

прюне́ль *ж* прюнель (*аяк киеме тегүгә һәм мебель тышлауга китә торган махсус тукыма*)

пря́дать *несов. см.* **пря́нуть ♦ ~ ушáми** колакларны торгызу (*ат турында*)

пряде́ние *с см.* **прясть**

пря́ден||ый, -ая, -ое эрләгән; **~ая шерсть** эрләгән йон

пряди́льный, -ая, -ое [җеп] эрләү ...ы; **~ цех** җеп эрләү цехы

пряди́льня *ж уст.* [җеп] эрләү фабрикасы, [җеп] эрләү мастерское

пряди́льщик *м* эрләүче, җеп эрләүче

пряди́льщица *ж* эрләүче хатын (кыз), җеп эрләүче хатын (кыз)

прядь *ж* **1.** бер тотам, учма; **седáя ~** бер тотам чал чәч **2.** *спец.* (*скрученная нить, верёвка*) катылган җеп (бау)

пря́жа *ж* эрләген җеп

пря́жка *ж* пряшка

пря́лка *ж* (*ручная*) каба; (*с ножным приводом*) җеп эрләгеч машина

прямизнá *ж* турылык, төзлек

прямикóм *нареч. разг.* турыга; турыдан; **идти́ ~** турыга бару

пря́мо *нареч.* **1.** турыга; **идти́ ~** турыга бару **2.** туры; **сиде́ть ~** туры утыру; **держа́ться ~** узеңне туры тоту **3.** туп-туры, турыдан-туры; **нача́ть ~ с гла́вного вопро́са** турыдан-туры төп мәсьәләдән башлау **4.** турыдан-туры, туп-туры, ачыктан-ачык; **говори́ть ~** туп-туры әйтү **5.** *в знач. частицы усил.* чын-чыннан; чын мәгънәдә; **он ~ геро́й** ул чын-чыннан герой; **~-таки** *то же, что* **пря́мо** 5

прямо- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче өлеше, татар теленә «туры» сүзе белән тәрҗемә ителә, мәс.* **прямокры́лые** *зоол.* турыканатлылар; **прямоуго́льный** турыпочмаклы

прямоду́шие *с* турылык, туры (ачык) күңеллелек, самимилек

прямоду́шный, -ая, -ое туры, туры (ачык) күңелле, самими; **~ челове́к** ачык күңелле кеше

прям||óй, -á я, -óе **1.** туры; **~áя ли́ния** туры сызык; **~áя доро́га** туры юл; **~áя кишкá** *анат.* туры эчәк; **~ые вóлосы** туры чәч (*бөдрә түгел*) **2.** турыдан-туры, турыдан-туры ...ган; **~ые вы́боры** турыдан-туры сайлаулар; **~ые указа́ния** турыдан-туры бирелгән күрсәтмәләр;

~ óе обращéние к мáссам массаларга турыдан-туры мөрәҗәгать итү; **э́то егó ~ áя обя́занность** бу турыдан-туры аның бурычы; **~ óй наслéдник** турыдан-туры варис **3.** туры, туры (ачык) күңелле, туры сүзле, эчкерсез, самими; **~ óй человéк** туры кеше **4.** турыдан-туры, ачыктан-ачык; **~ óй обмáн** ачыктан-ачык алдау; **~ óй вы́зов** ачыктан-ачык каршы чыгу **5.** (*подлинный, настоящий*) чын, чын-чыннан ..., чын мәгънәдә ...; **~ áя опáсность** чын мәгънәдә куркыныч; **~ áя измéна** чын мәгънәдә хыянәт [итү] **6.** (*несомненный*) һичшиксез; **~ óй расчёт éхать пóездом** поезд белән бару һичшиксез уңайлырак; **~ áя пóльза** һичшиксез файда **7.** *в знач. сущ.* **~ áя** *ж мат.* туры сызык **8.** *мат.* туры; **~ áя пропóрция** *грам.* туры сөйләм; **в ~ óм смы́сле слóва** чын-чыннан, чын мәгънәдә; **~ óе дополнéние** *грам.* туры тәмамлык; **~ óе попадáние** турыдан-туры тию, туры тидерү; туп-туры төшү (*бомба, снаряд, мина турында*); **~ óй вóрот** утыртма яка; **~ óй у́гол** *мат.* туры почмак

прямолинéйн||ый, -ая, -ое **1.** туры; **~ ы́е у́лицы** туры урамнар **2.** туры, хәйләсез; **~ ы́й человéк** туры кеше; **~ ы́й отвéт** туры җавап

прямотá *ж* турылык, хәйләсезлек; **~ отвéта** җавапның турылыгы; **~ характéра** характерның турылыгы

прямоугóльник *м* турыпочмаклык

прямоугóльный, -ая, -ое турыпочмаклы

пря́ник *м* прәннек

пря́ничный, -ая, -ое **1.** прәннек ...ы, прәннек пешерү ...ы; **~ цех** прәннек пешерү цехы **2.** прәннек ...; **~ петýх** прәннек әтәч

пря́ность *ж* тәмләткеч (*борыч, канәфер, керән кебек ачы яки хуш исле аш тәмләткечләр*)

пря́н||ый, -ая, -ое **1.** үткен, ачы; хуш исле; **~ ый зáпах** үткен ис **2.** тәмләткеч[ләр] салып әзерләнгән, тәмләткеч[ләр] салынган; **~ ые блю́да** тәмләткечләр салынган ашамлыклар

прясть *несов. что и без доп.* эрләү; **~ шерсть** йон эрләү

пря́тать *несов. прям., перен. кого-что* яшерү; качыру; **~ ключи́** ачкычларны яшерү

пря́таться *несов.* **1.** яшеренү, качу, посу, яшеренеп (качып, посып) тору; **~ в кустáх** куаклар арасында качып тору **2.** *перен. разг.* качу, качып йөрү, күренмәскә тырышып йөрү; **~ от знакóмых** танышлардан качып йөрү

пря́тки *только мн.* качыш, кач-кач уены, качышлы уены; **игрáть в ~** *прям., перен.* качышлы [уены] уйнау, кач-кач уйнау

пря́ха *ж* [жеп] эрләүче

псалóм *м рел.* псалом (*дини җыр, псалтырьның бер өлеше*)

псалóмщик *м* псаломчы

псалты́рь *ж* псалтырь (*Библиянең бер өлеше, псаломнар китабы*)

псáрня *ж* эт абзары

псарь *м* этләр караучы, этбагар

псевдо- *күшма сүзләрнең беренче өлеше, татар теленә «ялган» сүзе белән тәрҗемә ителә, мәс.* **псевдоклассúческий** ялган классик; **псевдонáука** ялган фән; **псевдоучéние** ялган тәгълимат

псевдоним *м* псевдоним (*язучының, артистның үзенә алган исеме*)

псúна *ж разг.* **1.** (*мясо*) эт ите **2.** (*запах*) эт исе

психастенúческ||ий, -ая, -ое психастеник, психастения ...ы; **~ие симптóмы** психастения билгеләре (симптомнары)

психастенúя *ж* психастения (*психик авыру*)

психиáтр *м* психиатр

психиатрúческ||ий, -ая, -ое психиатрия ...ы, психиатрик, психик авыруларны дәвалау ...ы; **~ая больни́ца** психик авыруларны дәвалау больницасы

психиатрúя *ж мед.* психиатрия

псúхика *ж* психика, рухи халәт; **здорóвая ~** сәламәт психика

психúческ||ий, -ая, -ое психика ...ы, психик; **~ие болéзни** психик авырулар ◆ **~ая атáка** *воен.* психик атака

психóз *м мед.* психоз, психик авыру

психóлог *м* психолог, психология белгече

психологúческий, -ая, -ое психология ...ы, психологик; **~ анáлиз** психологик анализ; **~ романá** психологик роман

психолóгия *ж* психология; **дéтская ~** балалар психологиясе; **твóрчества ~** иҗат психологиясе

психопáт *м* психопат, психик авыру [кеше]

психопáтия *ж* психопатия (*рухның, акылның сәламәт булмавы*)

психопáтка *ж* психопат хатын (кыз)

психопатологúческ||ий, -ая, -ое психопатология ...ы, психопатологик; **~ие иссле́дования** психопатологик тикшеренүләр

психопатолóгия *ж* психопатология (*психик авырулар турындагы фән*)

псóв||ый, -ая, -ое эт ...ы; этләр белән ...; **~ая охóта** этләр белән ауга чыгу

птáшка *ж* кошчык, кечкенә кош

птенéц *м* кош баласы

птúц||а *ж* **1.** кош; **домáшние ~ы** йорт кошлары; **пéвчие ~ы сайрар** кошлар **2.** *в знач. собир.* кош, кошлар **3.** *ирон.* кеше, кем; **не великá ~а** әллә кем түгел [әле]; **вáжная ~а** әллә кем, әһәмиятле кеше, зур кеше

птицевóд *м* кошчы; кошчылык белгече

птицевóдство *с* кошчылык, кош асраучылык

птицевóдческ||ий, -ая, -ое кошчылык ...ы, кош асраучылык ...ы; **~ая фéрма** кошчылык фермасы

птицелóв *м* кош аулаучы (*башлыча сайрар кошларны аулау белән шөгыльләнүче кеше*)

птицелóвство *с* кош аулау (*һөнәр, кәсеп*)

птицефéрма *ж* кошчылык фермасы; **колхóзная ~** колхозның кошчылык фермасы

птúч||ий, -ья, -ье **1.** кош ...ы; **~ий корм** кош азыгы; **~ье гнездó** кош оясы **2.** кошныкысыман, кош ...ы кебек; кошныкына охшаш (охшаган); **~ий нос** кош томшыгы сыман борын ◆ **~ий базáр** кошлар базары; **~ий двор** кетәк, кетәклек, кош абзары; **на ~ьих правáх** хокуксыз; **жить на ~ьих правáх** хокуксыз яшәү; **с (высоты́) ~ьего полёта** кош очкан югарылыктан; **(тóлько) ~ьего молокá недостаёт (не хватáет)** күгәрчен сөте генә җитми [юк]; ≈ елан мөгезе генә юк

птúчка *ж* **1.** *уменьш. от* **птúца** 1; кошчык, кечкенә кош **2.** птичка (*билге*)

птúчник *м* **1.** (*постройка*) кетәк, кетәклек, кош абзары **2.** (*работник*) кош караучы

птúчница *ж* кош караучы хатын (кыз)

пуáнты *только мн.* пуант[лар] (*балерина өчен махсус аяк киеме*)

пýблика *ж собир.* **1.** тамашачылар, публика **2.** *разг.* халык; кешеләр

публикáция *ж* **1.** бастырып чыгару; **~ архúвных докумéнтов** архив документларын бастырып чыгару **2.** (*то, что опубликовано*) басылып чыккан әсәрләр (хезмәтләр *һ.б.ш.*) **3.** (*объявление*) игълан, белдерү, белдермә

публикováть *несов. что* бастыру, бастырып чыгару; **~ статью́** мәкаләләр бастыру

публици́ст *м* публицист

публици́стика *ж* публицистика

публицисти́ческий, -ая, -ое публицистика ...ы; публицист[лар] ...ы; публицистик; **~ жанр** публицистика жанры

публи́чн||ый, -ая, -ое халык алдында ...; ачык; **~ое выступлéние** халык алдында чыгыш ясау ◆ **~ый дом** фахешханә (*капиталистик илләрдә*); **~ая жéнщина** фахишә; **~ые торги́** аукцион

пýгало *с прям., перен.* карачкы

пýган||ый, -ая, -ое курыккан, курытылган; **~ая воро́на куста́ бои́тся** *посл.* ≈ курыкканга куш күренә

пугáть *несов. кого-что* куркыту, өркетү

пугáться *несов.* курку, өркү; шүрләү

пугáч *м* пугач (*уенчык пистолет*)

пугли́вый, -ая, -ое **1.** куркак, өркәк, куркучан; **~ ребёнок** куркак бала; **~ конь** өркәк ат **2.** куркак, куркып ...; **~ взгля́д** куркып карау

пýговица *ж* төймә, сәдәф

пýговичн||ый, -ая, -ое төймә ...ы, сәдәф ...ы; **~ое произвóдство** төймә производствосы

пуд *м* [бер] пот; **~ мукú** бер пот он

пýдель *м* пудель, йөнтәс эт

пýдинг *м* пудинг (*ашамлык*)

пудóвый, -ая, -ое бер потлы

пýдра *ж* пудра, кершән

пýдреница *ж* пудра (кершән) савыты

пу́дрен||ый, -ая, -ое пудраланган, кершән якан, пудра ягылган (сөртелгән); **~ое лицо́** пудраланган бит

пу́дрить *несов. кого-что* пудралау, кершән ягу, пудра ягу (сөртү); **~ нос** борынга пудра сөртү

пу́дриться *несов.* пудралану, кершән ягыну, пудра ягыну (сөртенү)

пуза́тый, -ая, -ое *прям., перен.* зур корсаклы; кап корсак; **~ челове́к** зур корсаклы кеше; **~ самова́р** зур корсаклы самовар

пузырёк *м* **1.** *уменьш. от* **пузы́рь** 1, 2; **2.** (*маленькая бутылочка*) кечкенә шешә

пузыри́ться *несов. разг.* **1.** (*покрываться пузырями*) куыклану; күбекләнү **2.** (*топорщиться — об одежде*) куыклану, өрелү

пузы́рчатый, -ая, -ое куыклы, куыклы-куыклы

пузы́рь *м* **1.** куык; **мы́льный ~** сабын куыгы; **~ в стекле́** пыяла эчендәге куык **2.** *разг.* куык, кабарчык; **~ от ожо́га** пешкән җиргә чыккан кабарчык **3.** *анат.* куык, капчык; **жёлчный ~** үт куыгы **4.** куык; **~ со льдом** боз тутырылган резин куык

пук *м* бер бәйләм, бер тотам, бер учма; **~ соло́мы** бер учма салам; **~ бума́г** бер бәйләм кәгазь

пулев||о́й, -а́я, -о́е пуля ...ы, пулядан булган; **~а́я ра́на** пуля ярасы

пулемёт *м* пулемёт

пулемётн||ый, -ая, -ое **1.** пулемётчылар ...ы; **~ая ро́та** пулемётчылар ротасы **2.** пулемёт[лар] ...ы; **~ая ле́нта** пулемёт тасмасы

пулемётчик *м* пулемётчы

пулемётчица *ж* пулемётчы хатын (кыз)

пульвериза́тор *м* пульверизатор, сиптергеч, бөркегеч

пульс *м прям., перен.* пульс; **норма́льный ~** нормаль пульс; **сла́бый ~** зәгыйфь пульс; **прове́рить ~** пульсны тикшерү (тотып карау); **~ обще́ственной жи́зни** иҗтимагый тормыш пульсы

пульса́ция *ж* **1.** тибү, тибеш; **~ се́рдца** йөрәк тибеше **2.** *тех.* пульсация; **~ то́ка** ток пульсациясе; **~ ско́рости** тизлек пульсациясе

пульси́р||овать *несов.* **1.** (*о сердце, сосудах, крови*) тибү **2.** *тех.* пульсацияләү; **ток ~ует** ток пульсацияли

пульт *м в разн. знач.* пульт; **дирижёрский ~** дирижёр пульты; **~ управле́ния** идарә итү пульты; **диспе́тчерский ~** диспетчер пульты

пу́ля *ж* пуля

пуля́рка *ж* симертелгән тавык

пу́ма *ж зоол.* пума (*зур кыргый мәче*)

пункт *м в разн. знач.* пункт, нокта; **стратеги́ческий ~** стратегик пункт; **наблюда́тельный ~** күзәтү ноктасы; **населённый ~** торак пункты (*авыл, шәһәр һ.б.ш.*); **соглаше́ние из пяти́ ~ов** биш пунктан торган килешү; **кульминацио́нный ~** кульминацион пункт; **са́мый высо́кий ~** **ме́стности** урынның иң югары ноктасы ♦ **по ~ам** *или* **~ за ~ом** җентекле итеп, тәртип белән, пунктлап

пу́нктик *м* **1.** *уменьш.-ласк. от* **пункт** 1; **2.** *перен. шутл.* (*причуда*) сәер кыланыш; **челове́к с ~ом** сәер кыланышлы кеше, [бик] сәер кеше

пунктир *м* пунктир, нокталы сызык; **поме́тить ~ом** ноктаклы сызык белән билгеләү

пункти́рн||ый, -ая, -ое пунктир ..., пунктир белән сызылган; **~ая ли́ния** пунктир белән сызылган сызык

пунктуа́льный, -ая, -ое пунктуаль, җиренә җиткереп эшләүчән, төгәл үтәүчән

пунктуацио́нн||ый, -ая, -ое *грамм.* пунктуация ...ы, пунктуацион; **~ые пра́вила** пунктуация кагыйдәләре

пунктуа́ция *ж грамм.* пунктуация

пунцо́вый, -ая, -ое җете кызыл, кансу кызыл

пунш *м* пунш (*исерткеч эчемлек*)

пу́ншев||ый, -ая, -ое пунш ...ы, пуншлы; **~ая конфе́та** пуншлы конфет

пуп *м разг. см.* **пупо́к**

пупови́на *ж анат.* кендек

пупо́к *м* кендек

пупо́чн||ый, -ая, -ое кендек ...ы; **~ая гры́жа** кендек бүсере

пупы́рышек *м разг.* сыткы, бетчә

пурга́ *ж* буран, кар бураны

пури́зм *м* пуризм, пуристлык (**1.** *артык әхлакый сафлыкка омтылу* **2.** *телнең сафлыгын саклау өчен, аны башка телләрдән керган сүзләрдән кирәгеннән артык арындырырга тырышу*)

пури́ст *м* пурист, пуризм тарафдары

пури́стка *ж* пурист хатын (кыз)

пурита́нин *м* пуритан (**1.** *16-17 йөзләрдә Англия буржуазиясе арасында таралган дини-сәяси агымда катнашучы* **2.** *перен. көнкүрештә, әхлакта үтә тыйнаклыкны яклаучы кеше*)

пурита́нка *ж* пуритан хатын (кыз)

пурита́нство *с* пуританлык

пу́рпур *м* пурпур (**1.** *җете кызыл яки куе кызыл буяу* **2.** *җете кызыл яки куе кызыл төс* **3.** *уст. куе кызыл тукыма һәм шундый тукымадан тегелгән кием*)

пурпу́рный, -ая, -ое, **пурпу́ровый,** -ая, -ое куе кызыл

пуска́й *частица и союз разг. см.* **пусть**

пуска́ть *несов. см.* **пусти́ть**

пуска́ться *несов.* **1.** *см.* **пусти́ться; 2.** *страд. от* **пуска́ть**

пусково́й, -а́я, -о́е **1.** сафка кертелә торган; **~ объе́кт** сафка кертелә торган объект **2.** сафка керү (кертү) ...ы, эшли башлау ...ы; **~ пери́од** сафка кертү чоры **3.** хәрәкәткә китерә торган, [эшләтеп] җибәрү ...ы, эшләтә башлый торган; **~ механи́зм** хәрәкәткә китерә торган механизм

пустельга́ *ж зоол.* торымтай (*кош*)

пусте́||ть *несов.* бушау, бушап калу, буш калу; **но́чью у́лицы ~ют** төнлә урамнар бушыйлар

пусти́ть *сов.* **1.** *кого-что* җибәрү; **~ пти́цу на во́лю** кошны иреккә җибәрү; **~ в о́тпуск** отпускка җибәрү **2.** *кого-что* җибәрү, керту; **~ в ваго́н** вагонга керту; **~ ночева́ть** кунарга кертү; **~ квартира́нта** фатирчы кертү **3.** *что* җибәрү, эшләтә башлау, сафка кертү; **~ турби́ну** турбинаны җибәрү; **~ зово́д** заводны сафка кертү; **~ во́ду** су җибәрү **4.** *что* җибәрү, йөртә башлау; **~ авто́бус ме́жду го́родом и вокза́лом** шәһәр белән вокзал арасында автобус йөртә башлау **5.** *что, разг.* тарату; **~ спле́тню** гайбәт тарату **6.** *что, чем* җибәрү, тондыру, ыргыту; **~ ка́мень (ка́мнем) в окно́** тәрәзәгә таш ыргыту ♦ **~ ко́рни** тамыр җибәрү; **~ кра́сного петуха́** кызыл әтәч җибәрү (*ут төртү*); **~ на дно** төпкә җибәрү, батыру; **~ по́ миру** хәерчелеккә калдыру (төшерү); **~ пыль в глаза́** күзгә төтен җибәрү, күз буяу; **~ слезу́** яшь чыгару (*елау*)

пусти́ться *сов. разг.* **1.** [юлга] чыгу, чыгып китү, [юл] тоту, юнәлү, китү; **~ в путь** юлга чыгу; **~ в пого́ню** куа китү **2.** *во что или неопр.* башлау, керешү; **~ в пляс** бии башлау; **~ в рассужде́ния** сүз куерта башлау; **~ бежа́ть** йөгерә башлау **3.** *на что* (*отважиться*) батырчылык итү ♦ **~ во все тя́жкие** бозыклыкка бирелү; **~ на хи́трость** хәйлә кору, хәйләләү

пустова́ть *несов.* буш булу (тору, яту); **ко́мната пусту́ет** булмә буш тора

пустоголо́вый, -ая, -ое *разг.* мәгънәсез, буш, кибәк баш (*кеше турында*)

пустозво́н *м разг.* бушбугаз, лыгырдык, коры (буш) куык

пустозво́нить *несов. разг.* лыгырдау, корыга (бушка) такылдау

пустозво́нство *с разг.* бушбугазлык, корыга (бушка) лыгырдау; буш сүзләр

пуст||о́й, -а́я, -о́е **1.** буш; **~а́я бо́чка** буш мичкә; **~о́й дом** буш өй **2.** *перен.* буш, мәгънәсез; **~о́й челове́к** буш кеше; **~ы́е слова́** буш сүзләр **3.** (*полый внутри*) куыш; **~о́й шар** куыш шар **4.** *перен.* эчтәлексез, мәгънәсез, буш; **~а́я кни́га** эчтәлексез китап **5.** *перен.* (*незначительный*) кечкенә, әһәмиятсез; **~о́й по́вод** кечкенә сәбәп ♦ **[переливáть] из ~о́го в поро́жнее** юкны бушка аудару; **~а́я зате́я** юк эш, юк нәрсә, кирәкмәгән эш; **~а́я поро́да** *горн.* буш токым, кысыр токым; **~а́я тра́та вре́мени** вакытны бушка әрәм итү; **~о́е де́ло** юк эш, юк нәрсә; **~о́е ме́сто** буш кеше; әһәмиятсез кеше; **~о́й звук** буш сүз; **~о́й карма́н** буш кесә (акчасыз); **с ~ы́ми рука́ми [прийти́, яви́ться, уйти́** *и т.п.*] буш кул белән [килү, китү *һ.б.ш.*]

пустоме́ля *м, ж разг. см.* **пустосло́в**

пустопоро́жн||ий, -яя, -ее *разг.* буш, мәгънәсез, эчтәлексез; **~ие разгово́ры** буш сүзләр

пустосло́в *м разг.* бушбугаз, лыгырдык, буш сүзле кеше, ләчтә сатучы

пустосло́вие *с разг.* ләчтит, сафсата, юк-бар сүзләр

пустосло́вить *несов. разг.* юк-барны сөйләү, ләчтит (сафсата) сату, лыгырдау, лаф ору

пустота́ *ж* **1.** бушлык; **~ до́ма** өйнең бушлыгы **2.** бушлык, мәгънәсезлек; **~ жи́зни** тормышның мәгънәсезлеге **3.** куышлык; **~ ша́ра** шарның куышлыгы

ПУС-ПУШ

4. *перен.* (*душевная опустошённость*) өметсезлек, рухи бушлык (төшенкелек) **5.** *тех.* куышлык

пустоцве́т *м* **1.** *бот.* буш чәчәк, кысыр чәчәк **2.** *перен.* (*о человеке*) буш кеше, булдыксыз (файдасыз) кеше

пу́стошь *ж* буш яткан җир, буш җир

пусты́нник *м книжн.* дәрвиш

пусты́нн||ый, -ая, -ое **1.** чүл ...ы; **~ый барс** чүл барсы **2.** кешесез, кеше[ләр] яшәми торган; **~ый о́стров** кеше[ләр] яшәми торган утрау **3.** буш, кеше йөрми торган; кеше аз йөри торган; **~ые у́лицы** кеше аз йөри торган урамнар

пусты́ня *ж* чүл, сахра

пустырь *м* ташландык урын (җир)

пусты́шка *ж разг.* **1.** (*полый предмет*) эче куыш әйбер **2.** (*соска*) имезлек **3.** *перен.* (*о человеке*) буш кеше; мәгънәсез кеше

разверну́||ться *сов.* **1.** (*о чём-л. свёрнутом, скатанном*) сүтелү, чишелү, чишелеп (сүтелеп) китү; ачылу **2.** җәелү, җәелеп китү; таралу; **флаг ~лся** флаг җәелде **3.** *воен.* җәелү, тезелү; **строй ~лся** строй җәелде **4.** *воен.* (*перестроиться*) әйләнү, әверелү **5.** (*подготовиться к действию*) эш башлап җибәрү, ачылу; **медсанба́т ~лся за реко́й** елганың теге ягында медсанбат үзенең эшен башлап җибәрде **6.** *перен.* (*получить развитие*) җәелү, киңәю, җәелеп китү; **в го́роде широко́ ~лось строи́тельство** шәһәрдә төзелеш киң җәелеп китте **7.** *перен.* (*проявить свои силы*) үсеп китү; үзен (үзеңне) күрсәтү; **его́ тала́нт ~лся** аның таланты үсеп китте **8.** (*сделать оборот*) борылу, борылып кую; **ло́дка ~лась** көймә борылды **9.** *прост.* (*размахнуться*) кизәнү, селтәнү

разверста́ть *сов.* **1.** *кого-что* бүлү, бүлеп чыгу, бүлеп бирү, бүлеп кую; **~ сре́дства на строи́тельство** төзелешкә средстволарны бүлеп кую **2.** *что, полигр.* (*разъединить*) верстканы сүтү

развёрстка *ж* (*плановое распределение*) бүлү, бүлеп бирү

развёрстывать *несов. см.* **разверста́ть**

разверте́ть *сов. что* **1.** (*расширить*) бораулап киңәйтү, бора-бора зурайту; **~ отве́рстие** тишекне бора-бора киңәйтү **2.** (*раскрутить*) кызу әйләндереп жибәрү, әйләндерә-әйләндерә кыздырып жибәрү; **~ колесо́** тәгәрмәчне әйләндереп жибәрү

разверте́||ться *сов.* **1.** (*расшириться*) борудан зураю, борудан киңәю; **отве́рстие ~лось** тишек зурайган **2.** (*приобрести скорость*) кызу әйләнә башлау; **колесо́ ~лось** тәгәрмәч кызу әйләнә башлады

развёртывать *несов. см.* **разверну́ть**

развёртываться *несов.* **1.** *см.* **разверну́ться; 2.** *страд. от* **развёртывать**

разве́рчивать *несов. см.* **разверте́ть**

разве́рчиваться *несов.* **1.** *см.* **разверте́ться; 2.** *страд. от* **разве́рчивать**

развеселя́ть *сов. кого-что* күңелен күтәрү, күңелләндерү, күңелен ачу; **~ компа́нию** компаниянең күңелен күтәрү

развеселя́ться *сов.* күңеллеләнеп китү, күңел күтәрелү, кәефләнеп китү

развесёл||ый, -ая, -ое *разг.* бик күңелле, бик кәефле; **~ые друзья́** бик кәефле дуслар

разве́систый, -ая, -ое салынкы ботаклы, җәенке ботаклы, киң ябалдашлы; **~ дуб** җәенке ябалдашлы имән

разве́сить I *сов. что* үлчәп бүлү, үлчәп бүлеп чыгу, ваклап үлчәү; **~ са́хар** шикәрне үлчәп бүлү

разве́си||ть II *сов. что* **1.** элеп чыгу, элеп бетерү, таратып элү; **~ть бельё** керләрне элеп чыгу **2.** җәеп җибәрү, җәенкеләндереп җибәрү; салынкыландырып җибәрү; **де́рево ~ло ве́тви** агач ботакларын җәеп җибәргән ♦ **~ть у́ши** *ирон.* колак торгызу

развесно́й, -а́я, -о́е үлчәүле, үлчәп сатыла торган, үлчәнмәле; **~ са́хар** үлчәп сатыла торган шикәр

разве||сти́ *сов. кого-что* **1.** тарату, таратып чыгу, илтеп кую; **~сти́ дете́й по кла́ссам** укучыларны классларга таратып чыгу **2.** (*направить в разные стороны*) ачу, күтәртү, аеру (*ике якка*) разводлау; **~сти́ мост** күперне аеру **3.** (*разъединить*) аеру, аерып җибәрү; **судьба ~ла́ друзе́й** язмыш дусларны аерды; **~сти́ супру́гов** ир белән хатынны аеру **4.** (*растворить*) эретү **5.** (*заняться выращиванием*) үрчетү, асрау; үстерү; **~сти́ коро́в** сыерлар асрау; **~сти́ сад** бакча үстерү **6.** су кушу; **~сти́ рассо́л** тозлыкка су кушу **7.** яндыру, яндырып җибәрү, кабызу; кабызып җибәрү; **~сти́ костёр** учак кабызып җибәрү ♦ **~сти́ кани́тель** ыгы-зыгы куптару, ыгы-зыгы килү; **~сти́ пилу́** пычкыны разводлау; пычкының тешләрен аеру; **~сти́ рука́ми** кулларны җәю, хәйранга калу

разве||сти́сь *сов.* **1.** (*расторгнуть брак*) аерылышу, аерылу **2.** (*размножиться, расплодиться*) үрчү, үрчеп китү, күбәеп китү

разветви́||ться *сов.* **1.** ботаклану, ботаклар үсеп чыгу; **ли́пы ~лись** юкәләр ботаклана **2.** тармаклану, тармакланып китү, аерылып китү; **доро́га ~лась** юл аерылды

разветвле́ни||е *с* **1.** *см.* **разветви́ться; 2.** (*место*) аерма, тармакланган урын, аерылган җир; **на ~и доро́ги** юл аермасында

разветвлённ||ый, -ая, -ое киң тармакланган, киң тармаклы; **~ая сеть желе́зных доро́г** тимер юлларның киң тармакланган челтәре

разветвля́ться *несов.* **1.** *см.* **разветви́ться; 2.** *страд. от* **разветвля́ть**

разве́шать *сов. что* элеп чыгу, элеп бетерү, асып чыгу, элеп кую, таратып элү; **~ карти́ны** рәсемнәрне элеп кую

разве́шивать I *несов. см.* **разве́сить** I

разве́шивать II *несов. см.* **разве́сить** II, **разве́шать**

разве́ять *сов. что* **1.** очырып бетерү, туздыру, тарату; **~ дым** төтенне тарату **2.** *перен.* юкка чыгару, тарату, бетерү; **~ сомне́ния** шик-шөбһәләрне тарату

разве́я||ться *сов.* **1.** таралу, таралып бетү очып бетү; **дым ~лся** төтен таралып бетте **2.** *перен.* юкка чыгу, бетү, таралу; **го́ре ~лось** кайгы юкка чыкты **3.** *разг.* (*развлечься*) юану, күңел ачу

развива́ть *несов. см.* **разви́ть**

развива́||ться *несов.* **1.** *см.* **разви́ться; 2.** бару; **де́йствие ~ется в дере́вне** вакыйга авылда бара **3.** *страд. от* **развива́ть**

развизжа́ться *сов.* бик каты чиный башлау, чыелдый башлау

разви́лин||а *ж* **1.** (*дерева*) куш кәүсә; ике яңьле ботак **2.** (*место*) чат, аерма, тармакланган урын; **на ~е** юл чатында

разви́листый, -ая, -ое тармаклы, тармаклы-тармаклы, яңьле; **~ сук** яңьле ботак

разви́лка *ж*, **разви́лок** *м разг. см.* **разви́лина**; **мы подошли́ к разви́лке доро́ги** юл чатына килеп чыктык

развинти́ть *сов. что* борып алу, борып чыгару (*винтны*)

развинти́||ться *сов.* **1.** бушаю, какшау; **га́йка ~лась** гайка бушайган **2.** *перен.* йомшау, бозылу, рәте китү, какшау; **не́рвы ~лись** нервлар йомшаган

разви́нченный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **развинти́ть; 2.** (*невыдержанный — о людях*) [нервлары] йомшаган, какшаган, рәте киткән **3.** (*о походке, движениях*) сүлпән, алпан-тилпән

разви́нчивать *несов. см.* **развинти́ть**

разви́нчиваться *несов.* **1.** *см.* **развинти́ться; 2.** *страд. от* **разви́нчивать**

разви́ть *с* **1.** *см.* **развива́ть, разви́ться; ~ па́мяти** хәтерне үстерү; **~ промы́шленности** промышленностьнең алга китүе; **~ сотру́дничества** хезмәттәшлекнең үсүе **2.** үсеш, алгарыш, алга китеш, алга барыш; **истори́ческие ~ тарихи үсеш 3.** рухый үсеш, аң дәрәҗәсе, аң үсеше; **полити́ческое ~** сәяси аң үсеше

развит||о́й, -а́я, -о́е **1.**(*физически*) нык үскән, зур үскән; **~ы́е му́скулы** нык үскән мускуллар **2.** зур үсеш алган, алга киткән, нык алга киткән; **~а́я промы́шленность** зур үсеш алган промышленность; **~ы́е стра́ны** зур үсеш алган илләр **3.** (*духовно зрелый*) аңлы, җитлеккән, киң белемле **4.** *в знач. сказ.* киң җәелгән, киң таралган; **в э́том кра́е ра́звито скотово́дство** бу өлкәдә терлекчелек киң таралган

разви́ть *сов. что* (*раскрутить*) сүтү; **~ верёвку** арканны сүтү **2.** *что* үстерү, арттыру, зурайту, ныгайту; **~ машинострое́ние** машина төзелешен үстерү; **~ мускулы** мускулларны ныгыту; **~ па́мять** хәтерне үстерү **3.** *кого-что* (*духовно, умственно*) рухый яктан үстерү **4.** *что* (*широко развернуть*) җәелдерү, киңәйту; **~ бу́рную де́ятельность** көчле эшчәнлек җәелдерү **5.** *что* (*углубить*) алга сөрү, үстереп җибәрү; **~ чью-л. мысль** фикерен үстереп җибәрү

разви́||ться *сов.* **1.** (*расплестись*) сүтелү **2.** (*окрепнуть*) үсү, ныгу, үсеп китү, ныгып китү **3.** (*дойти до высокой степени*) киң үсеш алу, зур үсү, алга китү; **в на́шей стране́ ~лась энерге́тика** безнең илебездә энергетика зур үсте **4.** (*духовно, умственно*) рухый яктан үсү, үсеп китү, рухый җитлегү

развлека́тельн||ый, -ая, -ое мавыктыргыч, күңел юатқыч, мавыктыра торган, юата торган, кызыклы; **~ые и́гры** мавыктыргыч уеннар

развлека́ть *несов. см.* **развле́чь**

развлека́ться *несов.* **1.** *см.* **развле́чься; 2.** *страд. от* **развлека́ть**

развлече́ни||е *с* **1.** *см.* **развле́чь, развле́чься; 2.** юаныч, күңел ачу; уен-көлке; **ма́ссовые ~я** күмәк күңел ачулар

развле́чь *сов. кого-что* **1.** (*отвлечь*) юату, юандыру **2.** (*повеселить*) күңелен ачу, күңелен күтәрү, кәефен күтәрү, кайгысын тарату; **~ дете́й** балаларның күңелен ачу

развле́чься *сов.* **1.** (*отвлечься*) юану, юаныч табу **2.** (*повеселиться*) күңел ачу, хозурлану, кызык табу

разво́д *м* **1.** *см.* **развести́** 1-3, 5; **~ часовы́х** сакчыларны постларга кую **2.** *воен.* развод, развод ясау; **~ кара́улов** каравылларга развод ясау **3.** аерылышу, аерылу (*ир белән хатын турында*); **дать ~** аерылышу

разводи́ть *несов. см.* **расвести́**

разводи́ться *несов.* **1.** *см.* **развести́сь; 2.** *страд. от* **разводи́ть**

разво́дка *ж* **1.** *см.* **развести́** 2; **~ моста́** күперне күтәртү **2.** (*инструмент*) разводка, тсш аергыч (*пычкы өчен*)

разводно́й, -а́я, -о́е җәелмәле; **~ ключ** җәелмәле ачкыч (*төрле гайкаларга ярый торган*) ♦ **~ мост** ачыла торган күпер

развод||но́й, -ая, -ое аерылышу ...ы, аерылышу турындагы, аерылышуга караган; **~ое свиде́тельство** аерылышу турындагы таныклык

разво́ды *только мн.* **1.** (*узоры*) бизәкләр, нәкыш; рәсемле бизәкләр **2.** (*пятна*) таплар, җәелгән таплар; **ма́сляные ~** май таплары

разво́дье *с* **1.** (*пространство воды между льдами*) күзләвек; ачык урын (*бозлар арасында*) **2.** *диал.* (*половодье*) ташкын, язгы ташкын

разводя́щий *м воен.* разводящий, посткә куючы (*сакчыларны постларга куючы*)

развоева́ться *сов. разг.* дулап китү, дулый башлау, шау-шу күтәрү

развоз *м см.* **развезти́** 1; **~ гру́зов** йөкләрне йөреп тарату

развози́ть *несов. см.* **развезти́**

развози́ться *несов. разг.* ыгы-зыгы килә башлау, мәш килә башлау

развозн||о́й, -а́я, -о́е **1.** ташу ...ы, ташып тарату өчен; **~а́я теле́жка** ташу арбасы **2.** ташыла торган, ташып таратыла торган; **~ы́е това́ры** ташып таратыла торган товарлар

развозчик *м* ташучы, ташып таратучы

разволнова́||ть *сов. кого-что* тынычсызландыру, борчу, борчу салу; дулкынландыру; **изве́стие его́ ~ло** хәбәр аны дулкынландырды

разволнова́ться *сов.* тынычсызлану, борчыла башлау, дулкынлану

разволо́чь *сов. прост. что* өстерәп тарату, таратып ташлау; **~ загоре́в-**

шийся сара́й яна башлаган сарайны таратып ташлау

разворáчивать *несов. см.* **разворотúть, развернýть**

разворáчиваться *несов.* **1.** *см.* **развернýться; 2.** *страд. от* **разворáчивать**

разворовáть *сов. что* урлап бетерү, урлап алып бетерү

разворóвывать *несов. см.* **разворовáть**

разворóт *м* **1.** *разг. см.* **развернýть** 1-8, **развернýться** 1-7, 9; **~ полевы́х рабóт** кыр эшләренең җәелүе; **~ строи́тельства** төзелешнең киңәюе; **~ та́нка** танкның борылуы; **~ самолёта** самолётның борылуы **2.** (*поворот*) борылма; **~ доро́ги** юл борылмасы **3.** эчке ягы (*китап тышлыгының һ.б.ш.*); **на ~е** эчке ягында

разворотúть *сов. что* **1.** актарып ташлау, әйләндереп ташлау, таратып ташлау; **~ ку́чу камне́й** таш өемен актарып ташлау **2.** (*разрушить*) җимерү, җимереп ташлау

разворошúть *сов. что* әйләндерү, әйләндереп ташлау; таратып ташлау; **~ сéно** печәнне әйләндерү

разворчáться *сов. разг.* мыгырдана (сукрана) башлау

разврáт *м* **1.** (*половая распущенность*) уйнаш, фәхеш, җенси бозыклык **2.** (*испорченность нравов*) әхлаксызлык, бозыклык **3.** *разг.* (*избалованность*) бозыклык, азгынлык

развратúтель *м* аздыручы, юлдан яздыручы, уйнашка тартучы

развратúть *сов. кого-что* **1.** (*сделать развратным*) аздыру, уйнашчы итү, җенси бозыклыкка өйрәтү **2.** (*морально разложить*) бозу, юлдан яздыру, бозып бетерү, аздыру

развратúться *сов.* **1.** (*стать развратным*) уйнашчыга әйләнү, җенси бозыклыкка бирелү; фәхишкә әйләнү **2.** (*морально разложиться*) бозылу, юлдан язу, азу; әхлаксызлану, череп таркалу

разврáтник *м* уйнашчы кеше, бозык (азгын) кеше, фахиш

разврáтница *ж* уйнашчы хатын, бозык (азгын) хатын, фахишә

разврáтничать *несов.* уйнаш белән шөгыльләнү, уйнашлык итү, фахишлек итү

разврáтный, -ая, -ое уйнашчы ..., азгын, бозык, фахиш; **~ челове́к** бозык кеше

развращáть *несов. см.* **развратúть**

развращáться *несов.* **1.** *см.* **развратúться; 2.** *страд. от* **развращáть**

развращённость *ж* **1.** бозыклык, фахишлек азгынлык **2.** (*испорченность нравов*) әхлаксызлык

развращённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **развратúть; 2.** бозык, азгын, фахиш, әхлаксыз

развью́чивать *несов. см.* **развью́чить**

развью́чить *сов. кого-что* йөген алу (төшерү, бушату); **~ верблю́да** дөянең йөген бушату

развяза́ть *сов.* **1.** *кого-что* чишү, чишеп ташлау, чишеп җибәрү; сүтү; **~ тесёмку** тасманы чишү; **~ у́зел** төенне чишү **2.** *перен. что* мөмкинлек бирү, ирек бирү; бушайту; **~ тво́рческие си́лы наро́да** халыкның иҗади көчләренә ирек бирү ♦ **~ войну́** сугыш башлап җибәрү; **~ ру́ки** *кому* кулны бушату, мөмкинлек алу, ирек бирү; **~ язы́к** 1) (*заставить рассказать*) телен чиштерү, сөйләргә мәҗбүр итү, сөйләтү; 2) (*разговориться*) телгә ирек бирү

развяза́||ться *сов.* **1.** чишелү, чишелеп китү; сүтелү; **у́зел ~лся** төен чишелде **2.** *перен.* бушау, котылу; араны өзү; **~ться с дела́ми** эшләрдән котылу ♦ **язы́к ~лся** теле чишелде

развя́зка *ж* **1.** (*завершение*) тәмамлану, чишелеш, тәмамланыш; **неожи́данная ~** көтелмәгән рәвештә тәмамлану **2.** *лит.* чишелеш; **~ дра́мы** драманың чишелеше

развя́зность *ж* тәкәллефсезлек, йөгәнсезлек, тотнаксызлык; **~ мане́р** кыланышларның тәкәллефсезлеге

развя́зн||ый, -ая, -ое тәкәллефсез, тотнаксыз, йөгәнсез, артык иркен; **~ый челове́к** тәкәллефсез кеше; **~ые мане́ры** артык иркен кыланышлар

развя́зывать *несов. см.* **развяза́ть**

развя́зываться *несов.* **1.** *см.* **развяза́ться; 2.** *страд. от* **развя́зывать**

разгада́ть *сов.* **1.** *что* уйлап табу, җавабын табу; чишү; **~ зага́дку** табышмакның җавабын табу **2.** *кого-что* аңлау, аңлап (сизеп, белеп) алу; **~ чьи-л. наме́рения** ниятләрен сизеп алу

разга́дка *ж* **1.** *см.* **разгада́ть; 2.** җавап, чишелеш; **~ зага́дки** табышмакның җавабы

разга́дчик *м разг.* җавабын табучы; уйлап табучы; сизеп алучы, белүче

разга́дчица *ж см.* **разга́дчик**

разга́дывать *несов. см.* **разгада́ть**

разга́р *м* кызу чак, кызу вакыт, кызган вакыт, кызган чак; **убо́рка в ~е** урып жыюның кызу чагы

разги́б *м* **1.** *см.* **разогну́ть; 2.** (*место*) турайган (турайтылган, төзәйтелгән) урын

разгиба́||ть *несов. см.* **разогну́ть ♦ не ~я спины́ [рабо́тать, труди́ться]** баш күтәрми эшләү

разгиба́||ться *несов.* **1.** *см.* **разогну́ться; 2.** *страд. от* **разгиба́ть ♦ не ~ясь [рабо́тать, труди́ться]** баш күтәрми эшләү

разгильдя́й *м разг.* эшлексез, ачык авыз, җобалгы

разгильдя́йка *ж разг.* эшлексез хатын (кыз)

разгильдя́йничать *несов. разг.* эленке-салынкы кылану, җобалгылану; бернәрсә дә эшләмәү

разгильдя́йство *с разг.* эленке-салынкылык, җобалгылык

разглагóльствовать *несов.* күп сөйләү, акыл сату, сафсата сату

разгла́дить *сов. что* **1.** үтүкләү, үтүкләп чыгу; **~ бри́ки** чалбар үтүкләү **2.** тигезләү, төзәйтү; шомарту; **~ смя́тый конве́рт** бөгәрләнгән конвертны тигезләү

разгла́ди||ться *сов.* тигезләнү, төзәю; шомару; язылу; **морщи́ны на лбу ~лись** маңгайдагы җыерчыклар тигезләнде

разгла́живать *несов. см.* **разгла́дить**

разгла́живаться *несов.* **1.** *см.* **разгла́диться; 2.** *страд. от* **разгла́живать**

разгласúть *сов.* **1.** *что* (*сделать известным*) ачып салу, фаш итү, сөйләү; **~ та́йну** серне ачып салу **2.** *о чём* (*рассказать*) хәбәр тарату, сөйләп йөрү, чәчеп йөрү

разглашáть *несов. см.* **разгласúть**

разглашéние *с см.* **разгласúть**

разглядéть *сов.* **1.** *кого-что* күреп алу, танып алу, карап аеру, карап тану; **~ *кого-л.* в потёмках** караңгыда *кемне булса да* танып алу **2.** *перен. что, разг.* (*понять*) аңлап алу, төшенү, сизеп (төшенеп) алу

разгля́дывать *несов. кого-что* карау, җентекләп карау, тикәлеп карау; **~ прохо́жих** узып баручыларны тикәлеп карау

разгнéванный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **разгнéвать; 2.** бик нык ачуланган, ачуы кабарган, бик нык ачуы килгән, ачулы; **~ го́лос** ачулы тавыш; **~ оте́ц** ачуы кабарган ата

разгнéвать *сов. кого-что* бик нык ачуын китерү, бик нык ачуландыру, ачуын кабарту

разгнéваться *сов.* бик нык ачу килү; бик нык ачулану, ачу кабару

разговáривать *несов. с кем, о ком-чём и без доп.* сөйләшү, гәпләшү, сөйләшеп тору; **~ по-ру́сски** русча сөйләшү; **~ с дру́гом** дустың белән сөйләшү

разгово́р *м* **1.** сөйләшү, әңгәмә, гәп, сүз алышу; **~ по телефо́ну** телефоннан сөйләшү **2.** *обычно мн.* **~ы** *разг.* (*слухи*) гайбәт, сүз[ләр], имеш-мимеш, хәбәр ♦ **без ли́шних ~ов** артык сүз куертмыйча; **и ~у нет, ~а быть не мо́жет** сүз дә юк, сүз дә булырга мөмкин түгел

разговори́ть *сов. кого-что* (*заставить вступить в разговор*) сүзгә тарту, сөйләштерү; **его́ нелегко́ ~** аны сөйләштерүе авыр

разговори́ться *сов.* **1.** *с кем и без доп.* (*завязать беседу*) сөйләшеп китү, сөйләшә башлау **2.** (*увлечься разговором*) сүзгә бирелү, сүз белән мавыгу

разгово́рник *м* (*пособие*) сөйләүлек, сөйләшү китабы (*берәр телне өйрәну өчен кулланма*)

разгово́рн||ый, -ая, -ое **1.** сөйләм ...ы, сөйләшү ...ы; **~ый язы́к** сөйләү теле **2.** *разг.* (*предназначенный для разговоров по телефону*) сөйләшү өчен билгеләнгән, сөйләшү ...ы; **~ая бу́дка** сөйләшү будкасы **3.** сөйләшү ...ы; **~ый уро́к** сөйләшү дәресе **4.** (*имеющий характер разговора*) сөйләшү ...ы, сөйләшүгә нигезләнгән; **~ый жанр** сөйләшү жанры

разгово́рчивость *ж* сүзчәнлек, телчәнлек, сүзгә әвәслек

разгово́рчивый, -ая, -ое сүзчән, сүзгә әвәс, телчән, сөйләргә яратучан; **~ ма́льчик** сөйләргә яратучан малай

разгово́рчики *мн.* сөйләнү, буш сүз; **прекрати́ть ~!** сөйләнүләрне туктатырга!

разго́н *м* 1. *см.* **разогна́ть**; ~ **демонстра́ции** демонстрацияне куып тарату 2. (*разбег*) чабып бару, йөгереп бару, бик шәп бару; тизлекне арттыру; **прыжо́к с ~а** йөгереп барып сикерү 3. *спец.* (*промежуток*) ара, ераклык; ~ **ме́жду столба́ми** баганалар арасындагы ераклык ♦ **в ~е** *в знач. сказ.* барысы да юлдалар, барысы да чыгып киткәннәр; **с ~а (~у)** чабып барган килеш, чабып барганда

разго́нист||ый, -ая, -ое *разг.* сирәк, тарау, аралы; **писа́ть ~ым по́черком** сирәк почерк белән язу

разго́нка *ж* 1. *разг. см.* **разогна́ть**; 2. *тех.* чүкеп җәю 3. *хим.* кабат куу

разгоня́ть *несов. см.* **разогна́ть**

разгоня́ться *несов.* 1. *см.* **разогна́ться**; 2. *страд. от* **разгоня́ть**

разгора́живать *несов. см.* **разгороди́ть**

разгора́живаться *несов.* 1. *см.* **разгороди́ться**; 2. *страд. от* **разгора́живать**

разгора́ться *несов. см.* **разгоре́ться**

разгоре́||ться *сов.* 1. кызу яна башлау, яхшы яна башлау, янып китү; **костёр ~лся** учак кызу яна башлады 2. *перен.* кызару, кызарып китү; уттай яну; **щёки ~лись** яңаклар яна башлады 3. *перен.* кызу, кызып китү; **бой ~лся** сугыш кызып китте

разгороди́ть *сов. что* бүлү, бүлеп алу (*мәс. бүлмәне*); ~ **амба́р** келәтне бүлү

разгороди́ться *сов.* (*перегородкой*) бүленү, бүленеп алу; ~ **с сосе́дями** күршеләр белән бүленү

разгорячи́ть *сов. кого-что* 1. кыздыру, кыздырып жибәрү 2. *перен.* ярсыту; ~ **коня́** атны ярсыту

разгорячи́ться *сов.* 1. кызу, эсселәү, кызып (эсселәп) китү; тән кызу 2. *перен.* (*возбудиться*) ярсу, ярсып китү; кан кызу

разгра́бить *сов. что* талау, талап алу; талап бетерү

разграбле́ние *с см.* **разгра́бить**

разграниче́ние *с см.* **разграни́чить, разграни́читься; ~ земе́льных уча́стков** җир бүлемнәрен чикләү; ~ **поня́тий** төшенчәләрне аныклау

разграни́чивать *несов. см.* **разграни́чить**

разграни́чиваться *несов.* 1. *см.* **разграни́читься**; 2. *страд. от* **разграни́чивать**

разграничи́тельн||ый, -ая, -ое чикләү ...ы, бүлү ...ы, бүлә (чикли) торган; ~**ая ли́ния** чикләү линиясе

разграни́чить *сов. что* 1. чикләү, аеру, чикләрен билгеләү, чик билгеләп чыгу; ~ **зе́мли** җирләрнең чикләрен билгеләү 2. чикләү, чикләп кую, аныклау, аеру; ~ **поня́тия** төшенчәләрне чикләү

разграни́чится *сов.* чикләнү, аерылу

разграфи́ть *сов. что* графалап чыгу, графалап сызу, графаларга бүлеп чыгу; ~ **бума́гу** кәгазьне графалап чыгу

разграфля́ть *несов. см.* **разграфи́ть**

разгреба́ть *несов. см.* **разгрести́**

разгрести́ *сов. что* көрәп ташлау, тарату, таратып ташлау (*көрәк, тырма белән*); ~ **снег** карны көрәп ташлау

разгро́м *м* 1. тар-мар итү, юк итү, юкка чыгару; ~ **врага́** дошманны тар-мар итү 2. (*разорение*) бөлгенлеккә төшерү

разгроми́ть *сов.* 1. *кого-что* (*разбить наголову*) тар-мар итү, юк итү; ~ **вра́жескую а́рмию** дошман армиясен тар-мар итү 2. *что* (*разрушить, разорить*) жимерү, юкка чыгару, бөлгенлеккә төшерү

разгружа́ть *несов. см.* **разгрузи́ть**

разгружа́ться *несов.* 1. *см.* **разгрузи́ться**; 2. *страд. от* **разгружа́ть**

разгрузи́ть *сов.* 1. *что* [йөген] бушату, йөген алу, йөген төшерү; ~ **ваго́н** вагон бушату 2. *перен. кого-что* [эшен] киметү, [эшен] азайту, бушату (*эштән*)

разгрузи́||ться *несов.* 1. йөгеннән бушау, йөге бушатылу; **ваго́ны ~лись** вагоннарның йөге бушатылды 2. *перен.* бушау, бушап калу (*эштән*); эш кимү

разгру́зочн||ый, -ая, -ое йөк бушату ...ы, йөк бушата торган; ~**ая брига́да** йөк бушату бригадасы ♦ ~**ые дни** ашауны бик нык киметү көннәре

разгрыза́ть *несов. см.* **разгры́зть**

разгры́зть *сов. что* тешләп кимерү, тешләп вату, тешләп өзү; ~ **оре́х** чикләвекне тешләп вату

разгу́л *м* 1. котырыну, шашу; ~ **реа́кции** реакциянең котырынуы 2. (*кутёж*) типтерү, әйттерү, эчкечелек; **предава́ться ~у** типтерү

разгу́ливать I *несов. см.* **разгуля́ть**

разгу́ливать II *несов.* (*гулять не спеша*) йөрү, йөреп тору; ~ **по па́рку** парк буйлап йөрү

разгу́ливаться *несов. см.* **разгуля́ться** 2-5

разгу́лье *с* типтерү, кәеф-сафа сөрү; күңел ачу

разгу́льн||ый, -ая, -ое типтереп ..., типтерү ...ы, әйттерү ...ы; типтерүчеләр ...ы; эчкечеләр ...ы; ~**ая жизнь** типтереп яшәү; ~**ая компа́ния** типтерүчеләр компаниясе

разгуля́ть *сов. разг.* 1. *кого-что* йокысын ачу, йокысын качыру; ~ **ребёнка** баланың йокысын качыру 2. *что* (*рассеять*) тарату, бетерү; ~ **тоску́** хәсрәтне тарату

разгуля́||ться *сов.* 1. (*начать кутить*) типтерә башлау, әйттерә башлау 2. (*о буре, ветре*) көчәю, көчәеп китү 3. (*развернуться*) иркенләп эш итү, җәелеп китү 4. йокы ачылу, йокы качу; **ребёнок ~лся** баланың йокысы качты 5. аязыту, (*кук йөзе*) ачылу; **день ~лся** көн аязытты

раздава́ть I *несов. см.* **разда́ть** I

раздава́ть II *несов. см.* **разда́ть** II

раздава́ться I *несов. см.* **разда́ться** I

раздава́ться II *несов. см.* **разда́ться** II

раздави́||ть *сов.* 1. *что* таптатып изү, таптатып жимерү; кысып сыту; ~**ть помидо́р** помидорны кысып сыту 2. *кого-что* (*придавить, искалечить*) таптатып үтерү, таптатып имгәтү; изү, басу 3. *перен. кого-что* тар-мар итү, юк итү; ~**ть врага́** дошманны тар-мар итү 4. *перен. кого-что* изү; **изве́стие ~ло его́** хәбәр аны изде

раздави́вать *несов. см.* **раздави́ть**

разда́ивать *несов. см.* **раздои́ть**

разда́иваться *несов.* 1. *см.* **раздои́ться**; 2. *страд. от* **разда́ивать**

разда́лбливать *несов. см.* **раздолби́ть**

разда́ривать *несов. см.* **раздари́ть**

раздари́ть *сов. кого-что* бүләк итеп тарату (өләшү), бүләк итеп бетерү, бүләк итеп өләшеп бетерү; ~ **игру́шки** уенчыкларны бүләк итеп тарату

разда́точный, -ая, -ое тарату ...ы, өләшү ...ы; тарата торган, өләшә торган; ~ **пункт** өләшү пункты

разда́тчик *м* таратучы, өләшүче

разда́тчица *ж* өләшүче хатын (кыз)

разда́ть I *сов. кого-что* тарату, өләшү, бүлү, таратып чыгу (бетерү), өләшеп чыгу (бетерү); ~ **игру́шки** уенчыкларны өләшү; ~ **ро́ли актёрам** актёрларга рольләрне бүлү

разда́ть II *сов. что* (*расширить*) киерү, тарттыру, киңәйтү; ~ **сапоги́ на коло́дке** итекне калыпта тарттыру

разда́||ться I *сов.* (*прозвучать*) яңгырау, яңгырап китү, ишетелү, ишетелеп китү; тавыш таралу; ~**лся го́лос** тавыш яңгырады

разда́||ться II *сов.* 1. юл бирү, икә якка аерылу; **толпа́ ~ла́сь** халык төркеме икә якка аерылды 2. (*расшириться*) киңәю, киңәеп китү, иркенәю; ~**ться в плеча́х** җилкәләре киңәю; **сапоги́ разда́лись** итек киңәйде 3. *разг.* (*потолстеть*) юанаю, юанаеп китү, калынаю, калынаеп китү

раздва́ивать *несов. см.* **раздвои́ть**

раздва́иваться *несов.* 1. *см.* **раздвои́ться**; 2. *страд. от* **раздва́ивать**

раздвига́ть *несов. см.* **раздви́нуть**

раздвига́||ться *несов.* 1. *см.* **раздви́нуться**; 2. (*быть раздвижным*) ачыла торган булу, ачылу, җәелә торган булу, җәелү; **стол ~ется** өстәл ачыла 3. *страд. от* **раздвига́ть**

раздвижно́й, -а́я, -о́е ачылмалы, җәелмәле, шудырмалы; ~ **стол** җәелмәле өстәл

раздви́нуть *сов.* 1. *что* тартып ачу; аеру, аерып кую, ачып кую; ~ **занаве́ски** пәрдәләрне тартып ачу 2. *что* этәрү, этәреп кую; ~ **сту́лья** урындыкларны этәреп кую 3. *кого-что* икә якка аеру; ~ **толпу́** халык төркемен икә якка аеру 4. *что* җәю; ~ **стол** өстәлне җәю;

раздви́ну||ться *сов.* 1. ачылу, аерылу, ачылып китү, аерылып китү; **занаве́ски ~лись** пәрдә ачылды 2. икә якка аерылу , чигенү, юл бирү; **толпа́ ~лась** халык төркеме икә якка аерылды

раздвои́ть *сов. что* икегә аеру, икегә бүлү; икегә яру

раздвои́||ться *сов.* икегә аерылу (бүленү); **доро́га ~лась** юл икегә аерылды

раздева́лка *разг.*, **раздева́льня** *ж* чишенү бүлмәсе, чишенмәлек

разде́вать *несов. см.* **разде́ть**

раздева́ться *несов.* 1. *см.* **разде́ться**; 2. *страд. от* **раздева́ть**

разде́л *м* 1. *см.* **раздели́ть** 1, **раздели́ться** 3; ~ **иму́щества** мөлкәтне бүлү 2. бүлек; ~ **геоме́трии** геометриянең бүлеге; ~ **кни́ги** китапның бүлеге 3. (*граница*) чик, чикләмә

разде́лать *сов. что* 1. (*обработать*) эшкәртү, әзерләү, ясау; ~ **гря́дку** түтәл ясау; ~ **селёдку** селёдканы эшкәртү 2. *подо что* охшатып ясау (эшләү); ~ **под дуб** имән агачына охшатып ясау ♦ ~ **под оре́х** *кого* пыр туздыру, тетеп салу, тетмәсен тетү

разде́латься *сов.* 1. *с кем-чем* (*покончить*) исәп-хисапны өзү, араны өзү; эшне бетерү; котылу; ~ **с долга́ми** бурычтан котылу; ~ **с поруче́ниями** йомышларны үтәп бетерү; ~ **сози́мыми** ужым игене белән эшне бетерү 2. *перен. с кем* (*свести счёты*) үч алу, исәп-хисапны өзү; ~ **с оби́дчиком** рәнҗетүчедән үч алу

разделе́ние *с* 1. *см.* **разели́ть, разделя́ть**; 2. бүленү, бүленеш, аерылу; ~ **труда́** хезмәтнең бүленеше

разделя́тельн||ый, -ая, -ое бүлү ...ы, аеру ...ы, бүлгеч ..., бүлүче ..., бүлә торган, аера торган; ~ **ый знак** аеру билгесе ♦ ~ **ый сою́з** *грам.* бүлүче теркәгеч

разделя́||ть *сов.* 1. *что* бүлү, бүлеп кую, бүлеп бетерү, бүлеп чыгу; ~ **ть зе́млю на уча́стки** җир мәйданын участокларга бүлү; ~ **ть я́блоко на четы́ре ча́сти** алманы дүрт өлешкә бүлү 2. *кого-что* аеру, аерып кую; икегә аеру; **толпа́ их** ~ **ла** халык төркеме аларны аерды 3. *что с кем-чем* уртаклашу, бүлешү; ~ **ть с това́рищем обе́д** төшке ашны иптәшең белән уртаклашу 4. *что* (*выразить согласие*) риза булу, кушылу, уртаклашу; ~ **ть** *чьё-л.* **мне́ние** *кемнең дә булса* фикеренә кушылу 5. *что, мат.* бүлү

разделя́||ться *сов.* 1. аерылу, икегә аерылу; **тропи́нка** ~ **лась** сукмак икегә аерылды 2. бүленү, бүленешү; **охо́тники** ~ **лись по́ двое** аучылар икешәргә бүленештеләр; **мне́ния** ~ **лись** фикерләр аерылды 3. (*разделить имущество между собой*) аерылып чыгу, бүленешү, мал-мөлкәтне бүлеп аерылышу 4. *мат.* бүленү

разде́лывать *несов. см.* **разде́лать**

разде́лываться *несов.* 1. *см.* **разде́латься**; 2. *страд. от* **разде́лывать**

разде́льн||ый, -ая, -ое 1. аерым, аерып ...; аеры; ~ **ое жи́тельство** аерым тору; ~ **ое написа́ние** аерым язу; ~ **ый сану́зел** аерым санузел 2. (*чёткий*) ачык, аныk, аерып..., өзеп-өзеп ...; ~ **ое произноше́ние** ачык итеп әйтү 3. *с.-х.* аеры ...; ~ **ая убо́рка** аеры урып жыю 4. (*с перерывами, паузами*) өзек-өзек; ~ **ые вы́стрелы** өзек-өзек атышулар

разделя́ть *несов. см.* **разели́ть**

разделя́||ться *несов.* 1. *см.* **разели́ться**; 2. бүленү, аерылу; **насеко́мые** ~ **ются на ночны́х и дневны́х** бөҗеклөр көндезгеләргә һәм төнгеләргә бүленәләр 3. *страд. от* **разделя́ть**

раздёргать *сов. что, разг.* тартып чыгару, тартып чыгарып бетерү (*мәс. җепләрне тукымадан*)

раздёргивать *несов.* 1. *см.* **раздёргать**; 2. *см.* **раздёрнуть**

раздёрнуть *сов. что, разг.* тартып ачу, тартып ачып җибәрү, тартып ачып кую, тарту; ~ **занаве́ски** пәрдәне тартып ачып җибәрү

разде́т||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **разде́ть**; 2. өс киемен салган, чишенгән, өстен салган; киенмәгән килеш; **вы́йти на у́лицу** ~ **ым** урамга киенмәгән килеш чыгу

разде́ть *сов. кого-что* 1. (*снять одежду*) чишендерү, өстен салдыру 2. (*ограбить*) киемен салдырып алу, киемен талау

разде́ться *сов.* чишенү, өстен салу, киемен салу

раздира́||ть *несов.* 1. *см.* **разодра́ть**; 2. *перен. что* (*вызывать внутренний разлад*) телгәләү, эчтән таркату, өзгәләү 3. *что* телү, өзү, әрнетү; **тоска́ ~ ет се́рдце** сагыш йөрәкне әрнетә

раздира́ться *несов.* 1. *см.* **разодра́ться** 2. *страд. от* **раздира́ть**

раздобре́ть *сов. разг.* юанаю, юанаеп китү, симерү, симереп китү

раздо́биться *сов.* күнел йомшару, юмартлану, юмартланып китү, шәфкать уяну

раздобыва́ть *несов. см.* **раздобы́ть**

раздобы́ть *сов. кого-что* табу, табып алу, эзләп табу; кулга төшерү; ~ **кни́гу** китапны кулга төшерү

раздои́ть *сов. кого-что* сөтен арттыру (күбәйтү); савымын арттыру

раздои́ться *сов.* сөте арту (күбәю); савымы арту

раздолби́ть *сов. что* 1. чокып киңәйтү, чокып зурайту; ~ **отве́рстие** тишекне чокып зурайту 1. (*испортить*) чокып вату (җимерү)

раздо́лье *с* 1. киңлек, киң мәйдан 2. *перен.* иркенлек, иркен тормыш

раздо́льн||ый, -ая, -ое киң, иркен; ~ **ая степь** киң дала 2. *перен.* иркен; ~ **ая жизнь** иркен тормыш

раздо́р *м* ызгыш, талаш, гауга; **прекрати́ть** ~ **ы** ызгышны туктату

раздоса́довать *сов. кого-что* ачуландыру, ачуын китерү, гарьләндерү; кәефен җибәрү, кәефен бозу

раздража́ть *несов. см.* **разражи́ть**

раздража́ться *несов.* 1. *см.* **раздражи́ться**; 2. *страд. от* **раздража́ть**

раздражённый, -ая, -ое 1. *прич. от* **раздражи́ть**; 2. ярсыган, ачуы кузгалган; ярсулы, ачулы; ~ **тон** ярсулы тон

раздражи́тель *м* ярсыткыч; **хими́ческий** ~ химик ярсыткыч

раздражи́тельный, -ая, -ое тиз кызып китүчән, кабынып китүчән, ярсып китүчән; тиз ачуланучан, ачулы; ~ **хара́ктер** тиз кызып китүчән характер; ~ **челове́к** ярсып китүчән кеше

раздражи́ть *сов.* 1. *кого-что* (*привести в раздражение*) ачуландыру, ачуын китерү, ачуын кузгату, ярсыту 2. *что* ярсыту, тынычсызлау, ярсу уяту; ~ **нерв** нервны ярсыту 3. *что* (*вызвать боль, зуд*) эчеттерү, кычытыру; ялкынсындыру; ~ **глаза́** күзләрне эчеттерү

раздража́ться *сов.* 1. ачу килү, ачу кузгалу, ярсып китү 2. (*воспалиться*) ялкынсыну, пешегү

раздра́знивать *несов. см.* **раздразни́ть**

раздразни́ть *сов. кого-что* 1. үртәү, үртәп ярсыту, үртәп ачуын кузгату, үртәп ачуландыру; ~ **соба́к** этләрне үртәп ярсыту 2. кузгату, уяту; ~ **аппети́т** аппетит кузгату

раздрако́нивать *несов. см.* **раздраконить**

раздрако́нить *сов. кого-что, разг.* 1. (*разругать*) ник тиргәү, сүгеп ташлау 2. *перен.* юкка чагыру, бетереп ташлау; ~ **прое́кт** проектны бетереп ташлау

раздроби́ть *сов. что* 1. (*расколоть*) вату, ватып ташлау, ватып баклау, ваклап бетерү 2. (*повредить*) чәрдәкләү; ~ **кость** сөякне чәрдәкләү 3. *перен.* (*расчленить*) бүлгәләү, ваклау; ~ **си́лы** көчләрне бүлгәләү 4. (*преобразовать*) әйләндерү; ~ **ме́тры в сантиме́тры** метрларны сантиметрларга әйләндерү

раздроби́||ться *сов.* 1. ватылу, ваклану; **ка́мень** ~ **лся** таш ватылды 2. (*напр. о кости*) чәрдәкләну; 3. *перен.* (*разделиться*) бүленү, аерылу; ~ **ться на гру́ппы** төркемнәргә бүленү

раздро́бленн||ый , -ая, -ое, **раздроблённ||ый,** -ая, -ое 1. *прич. от* **раздроби́ть**; 2. ватылган, ватылып вакланган; ~ **ый каме́нь** ватылып вакланган таш 3. чәрдәкләнгән, чәрдәкләнеп беткән; ~ **ая кость** чәрдәкләнгән сөяк 4. таркау, вакланган, бүлгәләнеп беткән; ~ **ое хозя́йство** бүлгәләнеп беткән хуҗалык

раздробля́ть *несов. см.* **раздроби́ть**

раздробля́ться *несов.* 1. *см.* **раздроби́ться**; 2. *страд. от* **раздробля́ть**

раздружи́ться *сов. с кем-чем* дуслыкны өзү; ~ **с това́рищем** иптәш белән дуслыкны өзү

раздува́||ть *несов.* 1. *см.* **разду́ть**; 2. *что* җилфердәтү, җилбердәтү; **ве́тер** ~ **ет флаги́** җил флагларны җилфердәтә

раздува́ться *несов.* 1. *см.* **разду́ться**; 2. *страд. от* **раздува́ть**

разду́ма||ть *сов. с неопр.* кире уйлау, фикердән кире кайту, ...маска булу; **я** ~ **л е́хать** бармаска булдым

разду́мывать *несов.* (*долго думать*) уйлану, уйлау, баш вату

разду́м||ье *с* уй; уйланып тору, уйга бату; **го́рькие** ~ **ья** кайгылы уйлар

разду́т||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **разду́ть**; 2. шешенгән, зурайган, күбенгән; ~ **ое лицо́** шешенгән бит 3. *перен.* артык зурайтылган, чамадан тыш арттырылган; күпертелгән; ~ **ые шта́ты** чамадан тыш арттырылган штатлар

разду́||ть *сов. что* 1. өреп очыру, тарату, **ве́тер** ~ **л ту́чи** җил болытларны таратты; ~ **ть пе́пел** көлне өреп очыру 2. (*разжечь*) өреп үрләтү, өреп дөрләтү, өреп кабызып җибәрү 3. (*надуть*) өреп кабарту; ~ **ть пу́зырь** куыкны өреп кабарту 4. *безл.* шешенү, күбенү, шешеп чыгу, күбеп чыгу; **щёку** ~ **ло** яңагы шешеп чыкты 5. *перен.* арттыру, арт-

тырып күрсәтү, [бик нык] күпертү, күпертеп күрсәтү; **~ть шта́ты** штатларны күпертү

разду́||ться *сов.* **1.** (*надуться*) өрелеп кабару **2.** кабару, кабарып чыгу; **карма́н ~лся** кесә кабарып чыкты **3.** (*распухнуть*) шешү, күбү, шешеп чыгу

разева́ть *несов. см.* **разину́ть**

разжа́лобить *сов. кого-что* жәлләтү, жәлләү, кызгану хисе уяту, күнелен йомшарту

разжа́лобиться *сов.* жәлләү, кызгану хисе уяну, күнел йомшару

разжа́ловать *сов. кого-что, уст.* чинын алу, чиныннан төшерү, чинын түбәнәйтү; урынныннан алу

разжа́ть *сов. что* **1.** ачып кую, җәеп кую, аеру, аерып кую, ачу, жәю, җәеп җибәрү; **~ кула́к** йодрыкларны ачу **2.** язу, язып җибәрү; бушайту; **~ пружи́ну** пружинаны бушайту

разжа́||ться *сов.* **1.** ачылу, язылу, ачылып (җәелеп) китү; **па́льцы ~лись** бармаклар аерылды **2.** язылу, язылып китү, **пружи́на ~лась** пружина язылып китте

разжева́ть *сов. что* **1.** (*размельчить во рту*) чәйнәү, чәйнәп ваклау (изү) **2.** *перен. разг.* (*хорошо объяснить*) аңлатып (төшендереп) бирү; чәйнәп бирү; **~ и в рот положи́ть** *шутл.* чәйнәп авызына салу

разжёвывать *несов. см.* **разжева́ть**

разже́чь *сов. что* **1.** яндырып җибәрү, дөрләтәп яндырып җибәрү; **~ огóнь** утны дөрләтеп яндырып җибәрү **2.** *перен.* кабызып җибәрү, кабызу, көчәйтеп җибәрү; **~ не́нависть** нәфрәт кабызып жибәрү

разже́чься *сов.* дөрләп янып китү, дөрләп яна башлау

разжи́в||а *ж разг.* табыш, файда; **заня́ть де́нег на ~у** файда ясау өчен бурычка акча алып тору

разжива́ться *несов. см.* **разжи́ться**

разжига́ть *несов. см.* **разже́чь**

разжига́ться *несов.* **1.** *см.* **разже́чься; 2.** *страд. от* **разжига́ть**

разжиди́ть *сов. что* сыеклау, сыегайту; су кушу; **~ квас** кваска су кушу

разжиди́||ться *сов.* сыеклану, сыегаю; **кисе́ль ~лся** кесәл сыегайды

разжижа́ть *несов. см.* **разжиди́ть**

разжижа́ться *несов.* **1.** *см.* **разжиди́ться; 2.** *страд. от* **разжижа́ть**

разжима́ть *несов. см.* **разжа́ть**

разжима́ться *несов.* **1.** *см.* **разжа́ться; 2.** *страд. от* **разжима́ть**

разжире́ть *сов.* симерү, симереп китү; көрәсп китү

разжи́ться *сов.* **1.** *разг.* (*разбогатеть*) баю, баеп китү; байлык җыю **2.** (*начать жить без нужды*) яхшы яши башлау, яхшы яшәп китү **3.** *чем* табу, табып алу, кулга төшерү; **~ деньга́ми** кулга акча төшерү

разжужжа́||ться *сов.* бик нык безелди башлау, бызылдый башлау; **пчёлы ~лись** бал кортлары бик нык безелди башладылар

раззадо́ривать *несов. см.* **раззадо́рить**

раззадо́риваться *несов.* **1.** *см.* **раззадо́риться; 2.** *страд. от* **раззадо́ривать**

раззадо́рить *сов. кого-что* дәрт уяту, дәртләндереп (җилкендереп) җибәрү, теләк уяту; ярсытып җибәрү

раззадо́риться *сов.* дәрт уяну, дәртләнеп (җилкенеп) китү, теләк уяну, ярсып китү

раззва́нивать *несов. см.* **раззвони́ть**

раззвони́ть *сов. о ком-чём и без доп.* хәбәр тарату, сүз тарату, сөйләп йөрү, сөйләп чыгу; шалтырау; **~ о свои́х наме́рениях** үзеңнең теләкләреңә турында сөйләп йөрү

раззнако́мить *сов. кого-что* таныш-лыкны өзү, танышлыкны бетерү; ташлаттыру, араны өзү

раззнако́миться *сов. с кем-чем* ташлашу, танышлыкны өзү, танышлыкны бетерү, араны өзү

раззола́чивать *несов. см.* **раззолоти́ть**

раззолоти́ть *сов. что* алтынлау, алтын йөгертү, алтынга ману, алтын белән каплау

раззоло́ченн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **раззолоти́ть; 2.** *разг.* алтын белән капланган, алтын йөгертелгән, алтынга манылган, алтынланган; **~ое ору́жие** алтын йөгертелгән корал

раззуде́||ться *сов. разг.* **1.** бик нык сызлый башлау, сулкылдап сызлый башлау; әрни башлау; **но́ги ~лись** аяклар бик нык сызлый башлады **2.** *перен.* бик нык теләү (*берәр эш эшләргә*), зур теләк уяну; кул кычыту

рази́нуть *сов. что* зур итеп ачу (*авызны*) ♦ **~ рот** (*удивиться*) авыз ачып тору; таңга калу

рази́ня *м, ж разг.* ачык авыз, мәми авыз, жебегән

рази́тельный, -ая, -ое ачык, искиткеч зур, гажәеп; **~ приме́р** ачык мисал

рази́ть I *несов. кого-что* (*поражать*) юк итү; кыру, кырып салу; **~ врага́** дошманны кыру

рази́ть II *несов. чем, разг.* (*пахнуть*) аңку, аңкып тору, ис килү

разлага́ть *несов. см.* **разложи́ть** 5, 6

разлага́ться *несов.* **1.** *см.* **разложи́ться** 2, 3, 4; **2.** *страд. от* **разлага́ть**

разла́д *м* **1.** бозылыш; туры килмәү; **~ в рабо́те** эштәге бозылыш **2.** низагъ, көйсезлек, бозылыш, татусызлык; **семе́йный ~** гаиләдәге татусызлык

разла́дить *сов. что* **1.** (*испортить*) бозу, бозып кую, эштән чыгару, ватау; **~ маши́ну** машинаны ватау **2.** (*расстроить*) бозу, таркату; көйсезләү; **~ де́ло** эшне бозу

разла́ди||ться *сов.* **1.** (*испортиться*) бозылу, ватылу **2.** (*расстроиться*) таркалу, бозылу; **де́ло ~лось** эш бозылды **3.** (*о музыкальных инструментах*) көйсезләнү, бозылу

разла́живать *несов. см.* **разла́дить**

разла́живаться *несов.* **1.** *см.* **разла́диться; 2.** *страд. от* **разла́живать**

разла́мывать *несов. см.* **разлома́ть, разломи́ть**

разла́мываться *несов.* **1.** *см.* **разлома́ться, разломиться; 2.** *страд. от* **разла́мывать**

разлежа́ться *сов.* озак яту, иренеп ята бирү, нәкъәлләнеп яту, аунап яту

разлеза́ться *несов. см.* **разле́зться**

разле́з||ться *сов.* **1.** (*о ткани, одежде*) сыпылу, сизрәү, сизрәп бетү, тетелү, тетелеп бетү; таралу (*җәй буенча*) **2.** (*развалиться*) җимерелү, ишелү

разле́ниваться *несов. см.* **разлени́ться**

разлени́ться *сов.* бөтенләй ялкалану, ялкауга әйләнү, ялкауланып бетү; хөрәсәнләнү

разлепи́ть *сов. что* (*ябышканны*) кубару, кубарып аеру, куптарып алу; аеру; **~ скле́ившиеся страни́цы кни́ги** ябышкан китап битләрән аеру

разлепи́||ться *сов.* (*ябышкан җиреннән*) кубу, кубып чыгу, аерылу; **конве́рт ~лся** конверт купкан

разлепля́ть *несов. см.* **разлепи́ть**

разлепля́ться *несов.* **1.** *см.* **разлепи́ться 2.** *страд. от* **разлепля́ть**

разлёт *м* очып таралу; **~ птиц** кошларның очып таралуы ♦ **с ~а** (**у**) очып барган шәпкә, чапкан шәпкә; кызу барган чакта

разлета́ться I *несов. см.* **разлете́ться**

разлета́ться II *сов.* (*увлечься полётами*) очу белән мавыгу, мавыгып китү

разлете́||ться *сов.* **1.** очып китү, очып таралу; **пти́цы ~лись** кошлар очып таралдылар **2.** (*разойтись*) таралу; төрле якка китү **3.** (*разбиться на части*) ватылу, ватылып чәчрәү, чәлпәрәмә килү **4.** *перен.* (*напр. о мечтах*) юкка чыгу, җимерелү, бетү **5.** кызу бара башлау, кызу очып бару, кызу йөгереп (чабып) бару; **~вшись, уда́риться о столб** кызу чабып барып баганага бәрелү **6.** *перен.* (*распространиться — напр. о новости*) йөгереп бару (килү), чабып бару (килү), очып бару (килү)

разле́чься *сов.* ташланып яту, җәелеп яту; сузылып яту

разли́в *м* **1.** *см.* **разли́ть** 2, **разли́ться** 3, 4; **~ вина́ в буты́лки** шәрабны бутылкаларга агызу **2.** (*половодье*) ташу, ташкын

разливан||ный, -ая, -ое: **~ое мо́ре** *шутл.* аракы диңгезе, аракы дәрьясы

разлива́ть *несов. см.* **разли́ть**

разлива́||ться *несов.* **1.** *см.* **разли́ться; 2.** сайрау, жырлау; **солове́й ~ется** сандугач сайрый **3.** *разг.* (*много говорить*) тәмле теллән, күп сөйләү, сайрау **4.** *разг.* (*сильно плакать*) кычкырып елау **5.** *страд. от* **разлива́ть**

разливн||о́й, -ая, -о́е **1.** *спец.* бүлеп агызу ...ы; **~а́я маши́на** бүлеп агызу машинасы **2.** агызып сатыла торган; агызып тутырыла торган; **~о́е вино́** агызып сатыла торган шәраб

разлинова́ть *сов. что* сызыклар сызу (сызып чыгу)

разли́||ть *сов. что* **1.** (*расплескать*) түгү, түгеп жибәрү; **~ть молоко́** сөт түгү **2.** (*налить*) агызу, агызып салу, агызып бүлү; бүлеп салу; **~ть чай** чәй ясау **3.** *перен.* (*распространить*) жәю, тарату, сибү, чәчү ♦ **румя́нец ~т по всему́ лицу́** бөтен битенә кызыллык йөгергән (чыккан)

разли́ться *сов.* **1.** (*расплескаться*) түгелү, түгелеп китү, түгелеп бетү **2.** (*по*

разным сосудам) агызылу, агызып тутырылу, бүлеп агызылу, бүлеп салыну **3.** (*выйти из берегов*) ташу, ташып чыгу, ярларыннан чыгу **4.** *перен.* (*распространиться*) таралу, җәелү; сибелү, чәчелү

различа́ть *несов. см.* **различи́ть**

различа́ться *несов.* **1.** аерылу, аерылып тору; **~ по во́зрасту** яшь ягыннан аерылу **2.** *страд. от* **различа́ть**

разли́чи||е *с* аерма, аермалык, аерымлык; аеру; **без ~я** аермыйча, бердәй күреп; **зна́ки ~я** аеру билгеләре; **кла́ссовые ~я** сыйнфый аермалыклар

различи́тельный, -ая, -ое аеру ...ы, аера торган, аеручы...; **~ знак** аера торган билге

различи́ть *сов. кого-что* аеру, тану, танып алу, аерып алу; **~ в темноте́ челове́ка** караңгыда кешене танып алу; **~ сорта́ това́ров** товарларның сортын аеру

разли́чн||ый, -ая, -ое **1.** (*разный*) төрле, бер-беренә охшамаган; **~ые мне́ния** төрле-төрле фикерләр **2.** (*разнообразный*) һәртөрле, төрле-төрле, күптөрле; **~ые причи́ны** һәртөрле сәбәпләр

разложе́ние *с* **1.** *см.* **разложи́ть** 5, 6; **~ на множи́тели** *мат.* тапкырлаучыларга таркату **2.** (*внутренний распад*) эчтән (череп) таркалу, тәртипсезлек

разложи́ть *сов.* **1.** таратып салу, таратып кую; **~ ве́щи на столе́** әйберләрне өстәлгә салу **2.** *что* (*развернув, положить*) җәеп салу, җәеп кую, җәю **3.** *что* (*зажечь*) яндырып җибәрү, кабызып җибәрү; **~ большо́й костёр** зур учак яндырып җибәрү **4.** *что* (*распределить*) бүлү, бүлеп салу, бүлеп чыгу **5.** *что, спец.* таркату; **~ во́ду на кислоро́д и водоро́д** суны кислородка һәм водородка таркату; **~ число́** санны таркату **6.** *перен. кого-что* (*дезорганизовать*) таркаулык (тәртипсезлек) кертү, таркату

разложи́ться *сов.* **1.** (*разместиться*) килеп урнашу; үз әйберләреңне, урнаштыру, таратып салу **2.** (*разделиться на части*) *спец.* таркалу **3.** (*подвергнуться гниению*) черү, череп таркалу **4.** *перен.* (*дезорганизоваться*) таркалу, таркаулык керү, бозылу, череп таркалу (*мораль якган*)

разло́м *м* **1.** *см.* **разлома́ть, разломи́ть, разлома́ться, разло́миться; ~ льда** бозның ватылуы **2.** (*место*) сынган урын, ватылган урын, ярылган урын; **~ земно́й коры́** җир кабыгының ярылган урыны; **ли́ния ~а** ярылган урын линиясе

разлома́ть *сов. что* **1.** (*ломая, разделить*) сындыру, сындырып чыгару, сындырып бетерү; **2.** вату, жимерү, ватып ташлау, жимерү; **~ ста́рый сара́й** иске сарайны вату

разлома́||ться *сов.* сыну, сынып чыгу, ватылу, жимерелү; **забо́р ~лся** койма жимерелде

разломи́ть *сов. что* сындыру, сындырып чыгару; бүлү; вату; **~ хлеб** икмәкне сындыру

разломи́ться *сов.* сыну, сынып чыгу, ватылып чыгу

разлу́к||а *ж* **1.** аерым яшәү, читтә яшәү; **жить в ~е** аерым яшәү **2.** (*расставание*) аерылу, аерылышу

разлуча́ть *несов. см.* **разлучи́ть**

разлуча́ться *несов.* **1.** *см.* **разлучи́ться; 2.** *страд. от* **разлуча́ть**

разлучи́ть *сов. кого-что* аеру, читләштерү, читләшергә мәҗбүр итү

разлучи́ться *сов.* аерылу, аерылышу; **~ с бли́зкими** үз якыннарыңнан аерылышу

разлюби́ть *сов. кого-что и с неопр.* яратмый башлау, сөйми башлау; мәхәббәт суюну

размагни́тить *сов.* **1.** *что* магнитсызландыру, магнитын бетерү **2.** *перен. кого, разг.* мәлҗерәйтү, җебегәнгә әйләндерү

размагни́титься *сов.* **1.** магнитсызлану, магниты бетү **2.** *перен. разг.* мәлҗерәю, мәлҗерәп (җебеп) төшү

размагни́чивать *несов. см.* **размагни́тить**

размагни́чивать *несов.* **1.** *см.* **размагни́тить; 2.** *страд. от* **размагни́чивать**

разма́зать *сов. что* буяу, пычрату; җәелдерү (*мәс. тапны*); **~ грязь по лицу́** биткә пычрак буяу

разма́заться *сов.* буялу, буялып бетү; җәелү, җәелеп китү

размазня́ *разг.* **1.** *ж* (*жидкая каша*) сыек ботка, үрә **2.** *м, ж* (*о человеке*) җебегән кеше, булдыксыз, уңмаган кеше

разма́зывать *несов. см.* **разма́зать**

разма́зываться *несов.* **1.** *см.* **разма́заться; 2.** *страд. от* **разма́зывать**

размалева́ть *сов. кого-что* ала-кола [рәсем] ясау, буяп ясау, буяу

размалёвывать *несов. см.* **размалева́ть**

разма́лывать *несов. см.* **размоло́ть**

разма́ривать *несов. см.* **размори́ть**

разма́тывать I *несов. см.* **размота́ть** I

разма́тывать II *несов. см.* **размота́ть** II

разма́тываться *несов.* **1.** *см.* **размота́ться 2.** *страд. от* **разма́тывать** I

разма́х *м* **1.** *см.* **разма́хивать, размахну́ться** 1; **2.** арадагы киңлек, ара; колач; **~ кры́льев самолёта** самолёт канатлары арасының киңлеге **3.** (*амплитуда*) тибрәнү киңлеге, колач **4.** *перен.* колач, киңлек, җәелеш; **строи́тельство получи́ло широ́кий ~** төзелеш киң колач алды **♦ с ~а (~у)** селтәнеп, кизәнеп; **броса́ть с ~у** селтәнеп ташлау

размаха́ться *сов.* селтәнә башлау, болгый башлау

разма́хивать *несов. чем* селтәү, болгау; изәү; **~ рука́ми** кулларны селтәү

размахива́ться *несов. см.* **размахну́ться**

размахну́ть *сов. чем* селтәү, селтәп жибәрү; **~ кнуто́м** чыбыркы селтәү

размахну́ться *сов.* **1.** кизәнү; **си́льно ~** каты кизәнү **2.** *перен. разг.* эшне киң итеп җәеп жибәрү, киң колач жәю (*эштә*)

разма́чивать *несов. см.* **размочи́ть**

разма́чиваться *несов.* **1.** *см.* **размочи́ться; 2.** *страд. от* **разма́чивать**

разма́шист||ый, -ая, -ое **1.** киң, эре; **~ый шаг** эре адым **2.** (*о почерке и т.п.*) киң, аралы, сирәк **3.** киң иркен; **~ые движе́ния** иркен хәрәкәтләр

размежева́ние *с см.* **размежева́ть, размежева́ться**

размежева́ть *сов. что* **1.** межалап чыгу, ызанлап чыгу, ызан билгеләп бүлү, чикләрен билгеләү; **~ зе́млю** жирне ызан билгеләп бүлү **2.** *перен.* аеру, чикләрен билгеләү

размежева́ться *сов.* **1.** чик билгеләп бүленү, ызан билгеләп бүленү, чик билгеләп аерылу **2.** *перен.* (*в деловых отношениях*) чикләрен билгеләү, чикләрен ачыклау **3.** *перен.* (*идеологически*) фикер аерылу, фикердә аерылышу

резмежёвывать *несов. см.* **размежева́ть**

резмежёвываться *несов.* **1.** *см.* **размежева́ться; 2.** *страд. от* **размежёвывать**

размельча́ть *несов. см.* **размельчи́ть**

размельча́ться *несов.* **1.** *см.* **размельчи́ться; 2.** *страд. от* **размельча́ть**

размельчи́ть *сов. что* вакландыру, ваклау, ваклап бетерү, уалдыру

размельчи́ться *сов.* ваклану, вакланып бетү, уалу

разме́н *м см.* **разменя́ть, разменя́ться** 1; **~ де́нег** акча алыштыру

разме́нивать *несов. см.* **разменя́ть**

разме́ниваться *несов.* **1.** *см.* **разменя́ться; 2.** *страд. от* **разме́нивать**

разме́нн||ый, -ая, -ое ваклау ...ы, вак; **~ая ка́сса** ваклау кассасы; **~ая моне́та** вак акча

разменя́ть *сов. что* ваклау, вату, вакка алмаштыру; **~ де́ньги** акча вату **♦ ~ шесто́й деся́ток** илледән узу

разменя́ться *сов.* **1.** (*произвести обмен*) алышу, алмаштыру **2.** (*растратить силы*) көченне бетерү, көченне сарыф итү

разме́р *м* **1.** зурлык; **~ ко́мнаты** бүлмәнең зурлыгы **2.** микъдар, күләм; **~ зарпла́ты** эш хакы күләме **3.** *перен.* күләм; **в широ́ких ~ах** киң күләмдә **4.** үлчәү, үлчәм, размер; **~ костю́ма** костюмның үлчәме **5.** *лит., муз.* үлчәү

разме́ренность *ж* салмаклык, ритмлык, талгынлык

разме́ренный, -ая, -ое салмак, талгын, ритмлы; **~ шаг** салмак адымлар

разме́рить *сов. что* үлчәп билгеләү, үлчәп чыгу; **~ ме́сто для постро́йки** корылма өчен үлчәп урын билгеләү

разме́рность *ж физ.* үлчәнеш

размеря́ть *несов. см.* **разме́рить**

размеси́ть *сов. что* изү, изеп кую, басу, басып кую; **~ те́сто** камыр басу

размести́ *сов. что* **1.** себереп чыгу, себереп кую, себерү; **~ доро́жку** юлны себереп чыгу **2.** (*разгрести в стороны*) көрәү, көрәп чыгу, көрәп чистарту; **~ снег** карны көрәп чыгу

размести́ть *сов. кого-что* **1.** урнаштыру, урнаштырып чыгу (кую, бетерү); **~ пассажи́ров** пассажирларны урнаштыру; **~ това́ры по по́лкам** товарларны киштәләргә урнаштыру **2.** тарату, таратып чыгу; **~ лотере́йные биле́ты** лотерея билетларын тарату

размести́ться *сов.* урнашу, урнашып бетү; урын алу

разметáть I *несов. см.* **размести́**

разметáть II *сов. что* **1.** туздырып ташлау, туздыру, таратып җибәрү; **~ сéно для просу́шки** печәнне киптерү өчен туздырып ташлау **2.** (*ру́ки, но́ги*) җәю, җәеп җибәрү

разметáться *сов.* җәелеп яту, ташланып яту; **~ на посте́ли** түшәктә җәелеп яту

разме́тить *сов. что* билгелеп чыгу, билге куеп чыгу, билгеләү; **~ уча́сток** участокны билгелеп чыгу

разме́тка *ж* **1.** *см.* **разме́тить; 2.** (*метка, знак*) билге, тамга

разме́тчик *м* билге куючы, билгеләүче

разме́тчица *ж* билге куючы хатын (кыз)

размечáть *несов. см.* **разме́тить**

размечтáться *сов.* хыяллана башлау, хыялга бирелеп китү, хыялга чуму

размешáть *сов. что* болгату, болгатып эретү, тугылау; **~ са́хар в ча́е** чәйдә шикәрне болгатып эретү

размешáться *сов.* болгатудан эрү; болгатудан кушылу

размéшивать I *несов. см.* **размеси́ть**

размéшивать II *несов. см.* **размешáть**

размéшиваться *несов.* **1.** *см.* **размешáться; 2.** *страд. от* **размéшивать** II

размещáть *несов. см.* **размести́ть**

размещáться *несов.* **1.** *см.* **размести́ться; 2.** *страд. от* **размещáть**

размеще́ни||е *с* **1.** *см.* **размести́ть; ~е люде́й** кешеләрне урнаштыру **2.** (*порядок, система*); **~е производи́тельных сил** җитештерүче көчләрнең урнашуы **3.** *мн.* **~я** *мат.* тоташтырма

разминáть *несов. см.* **размя́ть**

разминáться *несов.* **1.** *см.* **размя́ться; 2.** *страд. от* **разминáть**

размини́ровать *сов., несов. что* миналардан арындыру (чистарту, арчу); миналарын алу; **~ по́ле** кырны миналардан арындыру

размúнка *ж см.* **размя́ть** 3, **размя́ться** 2

размину́ться *сов.* **1.** *с кем-чем, разг.* (*не встретиться*) аймылыш булу, аймыл булу, очраша алмау **2.** (*разойти́сь, не задев*) юл биреп үтү, үтеп китү, юл биреп узу

размножáть *несов. см.* **размно́жить**

размножáться *несов.* **1.** *см.* **размно́житься; 2.** *биол.* (*о животном и растительном организме*) үрчү, үрчеп китү; үсү, үсеп китү; **~ деле́нием** бүленү юлы белән үрчү **3.** *страд. от* **размножáть**

размноже́ние *с* **1.** *см.* **размно́жить, размно́житься; 2.** *биол.* үрчү; **беспо́лое ~** женессез үрчү

размно́жить *сов.* **1.** *что* күбәйтү, ишәйтү; бастырып күбәйтү; **~ те́зисы на пи́шущей маши́нке** тезисларны язу машинкасында бастырып күбәйтү **2.** *кого-что* (*расплодить*) үрчетү, үстерү; **~ кро́ликов** кроликлар үрчетү

размно́житься *сов.* **1.** (*увеличиться в количестве*) күбәю, арту, ишәю **2.** (*расплодиться, развестись*) үрчү, үсү, үрчеп китү, үсеп китү

размозжи́ть *сов. что* сугып изү (чәрдәкләү, яру)

размозжи́ться *сов.* чәрдәкләнү, ярылу, изелү (*сугудан*)

размо́ина *ж* су ашаган урын, ерма

размокáть *несов. см.* **размо́кнуть**

размо́кнуть *сов.* җебү, җебеп китү, юешләнү, чылану; бүртеп китү (чыгу)

размóл *м* **1.** *см.* **размоло́ть; ~ зерна́ на ме́льнице** тегермәндә ашлык тарттыру **2.** (*качество размолотого зерна*) тарттырылу, тарттырылыш, тарттырылу сыйфаты; **мука́ гру́бого ~а** эре тарттырылган он

размóлвка *ж* ара бозылу, дуслык китү, бозылыш, сүзгә килешү

размоло́ть *сов. что* **1.** тарттыру, онга әйләндерү; **~ пшени́цу** бодай тарттыру **2.** төю, порошокка әйләндерү; **~ ко́фе** кофе төю

размори́||ть *сов. кого-что* әлсерәтү, әлсерәтеп җибәрү, хәлсезләндерү, хәлдән тайдыру; **ребёнка ~ло на со́лнце** *безл.* кояшта бала әлсерәгән

размори́ться *сов.* әлсерәү, әлсерәп китү, хәлсезләнү, хәлдән таю

размотáть I *сов. что* **1.** сүтү, сүтеп алу, сүтеп җибәрү (*уралган әйберләрне*); **~ клубо́к** йомгакны сүтү **2.** *перен. разг.* ачыклау, очына чыгу

размотáть II *сов. что, прост.* (*растратить*) туздырып бетерү, исраф итеп бетерү, җилгә очыру

размотá||ться *сов.* сүтелү, сүтелеп китү, сүтелеп бетү; **клубо́к ~лся** йомгак сүтелде

размóтка *ж см.* **размотáть** I; **~ пря́жи** җепне сүтү

размочáливать *несов. см.* **размочáлить**

размочáливаться *несов.* **1.** *см.* **размочáлиться; 2.** *страд. от* **размочáливать**

размочáлить *сов. что* сүсәртү, сүсәртеп бетерү, мунчалаландыру, мунчалаландырып бетерү

размочáлиться *сов.* сүсәрү, сүсәреп бетү, мунчалалану, мунчалаланып бетү

размочи́ть *сов. что* җебетү, җебетеп бетерү; **~ сухари́** кәтермәчне җебетү

размочи́ться *сов.* җебү, бүртү, җебеп (бүртеп) китү

размусóливать *несов. см.* **размусóлить**

размусóлить *сов. что* **1.** (*размазать слюну по чему-л.*) селәгәйләү, селәгәйләп пычрату, селәгәйгә катыру **2.** *перен.* артык тәфсилләп сөйләү, бик озын итеп сөйләү, бик озынга сузу (*сузне*)

размы́в *м* **1.** *см.* **размы́ть, размы́ться; ~ плоти́ны** буаны су юып алып китү **2.** (*место*) су ашаган урын, су юып алган урын

размывáть *несов. см.* **размы́ть**

размывáться *несов.* **1.** *см.* **размы́ться; 2.** *страд. от* **размывáть**

размыкáние *с см.* **разомкну́ть; ~ контáктов** контактларны аеру

размы́кать *сов. что, разг.* тарату, онытту; **~ го́ре** кайгыны тарату

размыкáть *несов. см.* **разомкну́ть**

размыкáться *несов.* **1.** *см.* **разомкну́ться; 2.** *страд. от* **размыкáть**

размы́слить *сов. о ком-чём, разг.* (*обдумать*) фикер йөртү, уйлап алу, баш йөртеп алу

размы́ть *сов. что* су юып ашау (ишү); су юып аудару, су юып алып китү

размы́||ться *сов.* су юып ашалу (ишелү); су юып ашалып бетү; **бе́рег ~лся** яр су юып ашалган

размышлéни||е *с* **1.** *см.* **размышля́ть** 2; **дать вре́мя на ~е** уйлар өчен вакыт бирү **2.** (*мысль*) уй, фикер; **погрузи́ться в ~я** уйга бату

размышля́ть *несов.* **1.** *см.* **размы́слить; 2.** уйлау, уйлану, фикер йөртү, уйга бирелү; **~ о своём бу́дущем** үзеннең киләчәгең турында уйлану

размягчáть *несов. см.* **размягчи́ть**

размягчáться *несов.* **1.** *см.* **размягчи́ться; 2.** *страд. от* **размягчáть**

размягчи́ть *сов.* **1.** *что* йомшату, йомшарту; **~ ко́жу** күнне йомшарту **2.** *перен. кого-что* күңелен йомшарту, күңелне нечкәртү (эретү)

размягчи́||ться *сов.* **1.** йомшару, йомшау, йомшарып китү; **шку́ра ~лась** тире йомшарды **2.** *перен.* күңел йомшару (эрү)

размякáть *несов. см.* **размя́кнуть**

размя́кнуть *сов.* **1.** йомшару, җебү, изелү **2.** *перен.* изрәү, җебү, изрәп (җебеп) китү, йомшау

размя́ть *сов. что* **1.** (*сделать мягким*) уу, уып йомшарту; **~ папиро́су** папиросны уу **2.** (*сделать однородным*) изү, изеп кую; **~ гли́ну** балчыкны изү **3.** (*части тела*) язылдыру, канны тарату; **~ но́ги** аякларны язылдыру

размя́ться **1.** (*стать мягким*) йомшару, уылып йомшару **2.** *перен.* әгъзаларны язылдыру, канны тарату; **пройти́сь, что́бы ~** әгъзаларны язылдыру өчен йөреп алу

разнаря́дка *ж* разнарядка (*материаллар, әйберләр булеп бирү кәгазе*)

разна́шивать *несов. см.* **разноси́ть** I

разна́шиваться *несов.* **1.** *см.* **разноси́ться** I; **2.** *страд. от* **разна́шивать**

разне́живать *несов. см.* **разне́жить**

разне́жить *сов. кого* **1.** (*приучить к неге*) назландыру, иркәгә әйләндерү, иркәләп бетерү, иркәләп бозу **2.** (*привести в умиление*) күңелен эретү, күңелен йомшату, күңелен нечкәртү

разне́житься *сов.* **1.** (*привыкнуть к неге*) назлану, иркәгә әйләнү, иркәләнеп бетү, иркәләнеп бозылу **2.** (*прийти в умиление*) күңел эрү, күңел йомшау, күңел нечкәрү

разне́жничаться *сов.* артык иркәләнү (иркәләнеп китү)

разнес||ти́ *сов.* **1.** *кого-что* йөреп тарату, йөреп таратып чыгу, өләшү, өләшеп чыгу, тарату, таратып бетерү; **~ти́ пи́сьма** хатларны йөреп тарату **2.** *что* (*распределить*) язып теркәү; **~ти́ по гра́фам** аерым графаларга язып кую **3.** *что* (*развеять*) очырып тарату, очырып таратып җибәрү; **~ти́ обры́вки бума́ги** кәгазь чүпләрен очырып тарату

4. *перен. что* (*распространить*) тарату; **~ти́ зара́зу** йогышлы авыру тарату; **~ти́ вести** хәбәр тарату **5.** *что* (*разрушить*) вату, жимерү **6.** *что* (*разорвать*) ерткалап бетерү, өзгәләү, өзгәләп бетерү **7.** *кого-что* (*ругать*) тиргәү, тиргәп ташлау, тиргәп алу **8.** *безл. что* кабару, шешү, шешеп чыгу; **щёку ~ло́** яңак шешеп чыкты

разнес||ти́сь *сов.* **1.** таралу, таралып китү; **весть ~ла́сь** хәбәр таралды **2.** (*раздаться — о звуке*) ишетелү, яңгырау, яңгырап китү

разнима́ть *несов. см.* **разня́ть**

разнима́ться *несов.* **1.** *см.* **разня́ться; 2.** *страд. от* **разнима́ть**

ра́зн||иться *сов. книжн.* аерылу, аерылып тору, үзгә булу, башка булу; **они́ о́чень ~ятся по взгля́дам** алар карашлары буенча бер-берсеннән нык аерылалар

ра́зница *ж* аерма, аермалык, үзгәлек, башкалык; **больша́я ~** зур аерма бар; **кака́я ~?** нинди аерма бар соң?, барыбер түгелмени?

разно = *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге татар теленә «төрле», «төрлечә», «төрле-төрле» кебек сүзләр белән тәрҗемә ителә, мәс.* **разнокали́берный** төрле калибрлы

разнобо́й *м* төрлелек, аерымлык, каршылык (*фикердә яки эштә*); **~ в правописа́нии** орфографиядәге төрлелек

разнове́с *м собир.* вак герләр

разнови́дность *ж* **1.** *биол.* төрчә, төрдәш; **~ я́блони** алмагач төрчәләре **2.** төр, аерым төр, үзенә бер төр

разнови́дн||ый, -ая, -ое төрле, төрле-төрле; **~ суда́** төрле суднолар

разновреме́нн||ый, -ая, -ое төрле вакытка караган, төрле вакыттагы (замандагы); төрле вакытта булган; **~ые собы́тия** төрле вакыттагы вакыйгалар

разногла́си||е *с* **1.** фикер каршылыгы, фикер башкалыгы, төрле карашлылык; **~я по основны́м вопро́сам** төп мәсьәләләр буенча фикер каршылыклары; **име́ются ~я** фикер каршылыклары була **2.** (*противоречие*) каршылык, туры килмәү; **~я в показа́ниях свиде́телей** шаһитлар күрсәтмәләрендәге каршылыклар

разноголо́сица *ж* **1.** (*нестройное пение*) төрлесе төрлечә җырлау, төрлечә җырлау **2.** *перен.* күп төрле фикерләр, каршылыклы фикерләр

разноголо́с||ый, -ая, -ое **1.** аһәңсез, көйсез, төрлесе төрлечә; **~ое пе́ние** төрлесе төрлечә җырлау **2.** (*с разными голосами*) төрле тавышлы; **~ые пти́цы** төрле тавышлы кошлар

разнокали́берн||ый, -ая, -ое **1.** төрле калибрлы, төрле калибрдагы...; **~ые винто́вки** төрле калибрдагы винтовкалар **2.** *перен. разг.* төрле-төрле, төрле зурлыктагы..., һәртөрле; **~ая посу́да** төрле-төрле савыт-саба

разнома́стн||ый, -ая, -ое **1.** (*о животных*) төрле төстәге, төрле төсле; (*о картах*) төрле мачтагы **2.** *перен. разг.* төрле-төрле, һәртөрле, төрле төрдәге; **~ая пу́блика** төрле-төрле халык

разномы́слие *с книжн.* төрле фикерлелек, төрле караш, төрле фикердә булу

разнообра́зие *с* күптөрлелек, төрле-төрле булу; **~ я́год** җиләкләрнең күптөрлелеге; **~ впечатле́ний** тәэсирләрнең күптөрлелеге

разнообра́зить *сов. что* төрлеләндерү, төрләндерү, төрле-төрле итү; **~ меню́** менюне төрләндерү

разнообра́зиться *сов. книжн.* төрлеләнү, төрләнү; башкага әйләнү

разнообра́зн||ый, -ая, -ое төрле, төрле-төрле, күп төрле; **~ые впечатле́ния** төрле-төрле тәэсирләр

разноплемённ||ый, -ая, -ое төрле кабиләле, төрле халыклы, төрле кабиләләрдән торган, төрле халыклардан торган; **~ое населе́ние** төрле кабиләләрдән торган халык

разнораб|о́чий *м* квалификациясез эшче, разнорабочий

разноречи́в||ый, -ая, -ое каршылыклы, төрлечә ..., бер-берсенә капма-каршы, төрле-төрле; **~ые слу́хи** бер-берсенә капма-каршы булган хәбәрләр

разноро́дн||ый, -ая, -ое төрле, төрле-төрле, һәртөрле; **~ые вещества́** төрле-төрле матдәләр

разно́с *м* **1.** *см.* **разнести́** 1, 2, 4, 7; **~ пи́сем** хатларны тарату; **~ счето́в по бухга́лтерским кни́гам** счетларны бухгалтер кенәгәләренә язып кую **2.** *разг.* шелтәләү, тиргәү, шелтә, тиргәш; **сде́лать ~** *кому кемне дә булса* тиргәү

разноси́ть I *сов. что* (*обувь*) киеп иркенәйтү, кия-кия иркенәйтү, киеп киңәйтү

разноси́ть II *несов. см.* **разнести́**

разноси́ться I *сов.* (*об обуви*) иркенәю, киңәю (*киюдән*), кия-кия иркенәю

разноси́ться II *несов.* **1.** *см.* **разнести́сь; 2.** *страд. от* **разноси́ть** II

разно́ска *ж см.* **разнести́** 1, 2, 4, 7

разносклоня́ем||ый, -ая, -ое *грам.* төрлечә төрләнә торган, төрлечә төрләнүче; **~ые существи́тельные** төрлечә төрләнә торган исемнәр

разносо́лы *мн* **1.** (*соленья, маринады*) тозланган яшелчәләр, тозланмалар **2.** *разг.* (*изысканная еда*) тәмле ашамлыклар, тәмле ризыклар, нәзакәтле азыклар

разнососло́вный, -ая, -ое төрле сословиегә караган, төрле сословиедәге ...

разноспряга́емый, -ая, -ое (*о глаголе*) төрлечә төрләнә торган, төрлечә төрләнүче

разносторо́нн||ий, -яя, -ее **1.** *мат.* төрле кырлы, төрле яклы; **~ий треуго́льник** төрле кырлы өчпочмак **2.** күпьяклы, күптөрле, төрле яклы; **~яя де́ятельность** күпьяклы эшчәнлек

разносторо́нность *ж* **1.** *мат.* төрле яклылык, төрле кырлылык; **~ треуго́льников** өчпочмакларның төрле яклылыгы **2.** күпьяклылык, төрле яклылык; **~ тала́нта** талантның күпьяклылыгы

ра́зность *ж* **1.** (*различие*) аерма, төрле булу; **~ хара́ктеров** характерларның төрле булуы **2.** *мат.* аерма, калдык; **~ двух чи́сел** ике сан аермасы

разно́счик *м* **1.** таратучы, таратып йөрүче; **~ кни́г** китапларны таратучы; **му́ха — ~ зара́зы** чебен — йогышлы чир таратучы **2.** (*продавец*) асламчы, кырыктартмачы

разноти́пн||ый, -ая, -ое төрле тип ..., төрле төрдәге ..., төрле типтагы ...; **~ые суда́** төрле типтагы суднолар

разнохаракте́рн||ый, -ая, -ое **1.** төрле, төрле-төрле **2.** *театр.* төрле характердагы; **игра́ть ~ые ро́ли** төрле характердагы рольләрне уйнау

разноцве́тн||ый, -ая, -ое төрле төстәге, төрле төсле

разночи́нец *м ист.* разночинец (*Россиядә 19 нчы йөздә: дворян булмаган сыйныфлардан килеп чыккан интеллигент*)

разночте́ние *с спец.* текст варианты (*икенче төрле укылышлы нөсхә, икенче төрле укылыш*)

разношёрстн||ый, -ая, -ое **1.** (*разномастный*) төрле төстәге йонлы, төрле төстәге ...; **~ые соба́ки** төрле төстәге этләр **2.** *перен. разг.* чуар, төрле-төрле; төрле составлы, төрле составтагы ...; **~ая пу́блика** чуар публика

разноязы́чн||ый, -ая, -ое төрле телдә сөйләшә торган, төрле телле, төрле телдә язылган; **~ое населе́ние** төрле телле халык

разну́здани||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **разнузда́ть; 2.** авызлыксыз, авызлыкланмаган, авызлыгы салдырылган; **~ые ко́ни** авызлыкланмаган атлар **3.** *перен.* котырынган, азган, йөгәнсез, бозык; **~ое поведе́ние** йөгәнсез тәртип

разнузда́ть *сов. кого-что* авызлыгын салдыру, авызлыгын төшерү

разнузда́|ться *сов.* **1.** авызлыгы салыну, авызлыгы ычкыну, авызлыгы төшү; **ло́шадь ~лась** атның авызлыгы төшкән **2.** *перен.* котырыну, йөгәнсезләнү, азу

разну́здывать *несов. см.* **разнузда́ть**

разну́здываться *несов.* **1.** *см.* **разнузда́ться; 2.** *страд. от* **разну́здывать**

ра́зн||ый, -ая, -ое **1.** *в разн. знач.* төрле, башка төрле; **~ые взгля́ды** төрле карашлар; **~ые лю́ди** төрле кешеләр; **~ые ве́щи** төрле әйберләр; **буке́т из ~ых цвето́в** төрле чәчәкләрдән букет; **~ые глаза́** төрле күзләр **2.** (*иной*) икенче, башка, үзенә башка; **э́ти ве́щи ~ые** бу әйберләр үзенә башка

разню́хать *сов. разг.* **1.** *что* (*распознать по запаху*) иснәп табу, иснәп белү **2.** *перен. что, о чём и без доп.* иснәнеп белү, сизеп алу, белеп алу (*астыртын рәвештә*)

разню́хивать *несов. см.* **разню́хать**

разня́ть *сов. кого-что* **1.** (*разъединить*) аеру, аерып алу, аерып чыгару **2.** аралау, аеру, аерып алу; **~ дера́щихся** кыйнашучыларны аралау

разня́ться *сов. разг.* аерылу, аерылып чыгу

разоби́деть *сов. кого-что* каты үпкәләтү, хәтерен калдыру

разоби́деться *сов.* каты үпкәләү, хәтер калу

разоблача́ть *несов. см.* **разоблачи́ть**

разоблача́ться *несов.* **1.** *см.* **разоблачи́ться; 2.** *страд. от* **разоблача́ть**

разоблаче́ние *с* фаш итү, фаш ителү, ачып салу, ачып салыну

разоблачи́тель *м книжн.* фаш итүче, ачып салучы, фашлаучы

разоблачи́ть *сов.* **1.** *кого, шутл.* (*раздеть*) өстен салдыру, чишендерү **2.** *кого-что* фаш итү, ачып салу, фашлау; **~ про́иски врагов** дошманнарның казынуларын фаш итү **3.** *кого, церк.* (*снять ризу с кого-л.*) гыйбадәт киемен салдыру (*попларның*)

разоблачи́ться *сов.* **1.** *шутл.* (*раздеться*) өстен салу, чишенү **2.** (*раскрыться*) фаш ителү, беленү, ачыклану **3.** *церк.* гыйбадәт киемен салу

разобра́||ть *сов.* **1.** *что* сүтү, сүтеп кую, сүтеп алу; **~ть пулемёт** пулемётны сүтү **2.** *кого-что* алу, алып бетерү; **кни́ги разо́браны из библиоте́ки** китапханәдән китаплар алып бетерелгән **3.** *что* (*раскупить*) сатып алу, сатып алып бетерү **4.** *что* (*привести в порядок*) тәртипкә китерү, тәртипкә салу, рәтләү, рәткә салу; **~ть ве́щи** әйберләрне тәртипкә китерү **5.** *перен. что* (*дать оценку, исследовать*) тикшерү, тикшереп ачыклау; **~ть по́му** поэманы тикшерү; **~ть предложе́ние** *грам.* җөмлә тикшерү **6.** *перен. что* (*распознать*) тану, белү, аеру, аңлау, төшенү; **~ть по́черк** почеркны тану **7.** *кого, разг.* (*о сильном чувстве, желании*) чолгап алу; уяну, туу; **его́ ~ло зло** аңарда ачу уянды

разобра́ться *сов.* **1.** (*привести в порядок*) әйберләрне тәртипкә китерү, тәртипкә салу **2.** *в ком-чём, с кем-чем* аңлау, төшенү, аңлап алу, ачыклау, тикшереп белү, аңлап бетерү; **~ в де́ле** эшне ачыклау **3.** (*построиться*) тезелү, тезелешү; үз урынын табу

разобща́ть *несов. см.* **разобщи́ть**

разобща́ться *несов.* **1.** *см.* **разобщи́ться; 2.** *страд. от* **разобща́ть**

разобще́ние *с см.* **разобщи́ть**

разобщи́||ть *сов. кого-что* **1.** (*разъединить*) аеру, икегә аеру **2.** читләштерү, араларын өзү, ераклаштыру; **обстоя́тельства их ~ли** вакыйгалар аларны читләштерде

разобщи́ться *сов.* **1.** (*разъединиться*) аерылу, икегә аерылу; бүленү **2.** (*потерять связь*) читләшү, ара өзелү, ераклашу

ра́зовый, -ая, -ое бер тапкырга яраклы; бер керелек, бер юллык; бер тапкыр [була торган]; **~ биле́т** бер юллык билет; **~ сбор** бер тапкыр җыю

разогна́ть *сов. кого-что* **1.** куып җибәрү, куып тарату, тарату, куу; **~ толпу́** халык төркемен куып тарату **2.** кызулату, артык шәбәйтү, бик ныклы тизләтү; **~ автомоби́ль** автомобильне кызулату ♦ **~ кровь** канны тарату; **~ тоску́** кайгыны тарату

разогна́ться *сов.* кызулатып җибәрү, бик тиз (шәп) бара башлау, тизлеген арттыру

разогну́ть *сов. что* турайту, төзәйтү, язу, җәю, турайтып (төзәйтеп) кую; **~ гво́зди** кадакны төзәйтү; **~ спи́ну** билне язу

разогну́ться *сов.* тураю, төзәю, язылу

разогрева́ть *несов. см.* **разогре́ть**

разогрева́ться *несов.* **1.** *см.* **разогре́ться; 2.** *страд. от* **разогрева́ть**

разогре́ть *сов. что* **1.** җылыту, җылытып җибәрү; кайнарлату; **~ суп** аш җылыту **2.** кыздыру, эсселәтү; **~ мото́р** моторны кыздыру; **~ коня́** атны кыздыру

разогре́ться *сов.* **1.** җылыну, җылынып китү; кайнарлану **2.** тән кызу, эсселәнү, эсселәнеп китү

разоде́т||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** *прич. от* **разоде́ть; 2.** киенгән-ясанган, бик купшы киенгән; **~ая пу́блика** киенгән-ясанган халык төркеме

разоде́ть *сов. кого-что* купшы итеп киендерү, [бик матур итеп] киендерү, киендерү-ясандыру; **~ ребёнка как ку́клу** баланы курчак кебек киендерү

разоде́ться *сов.* купшы итеп киенү, бик матур итеп киенү, киенү-ясану

разодра́ть *сов. кого-что* ертып бетерү, ертып чыгару, умырып алу (чыгару), өзеп алу (чыгару)

разодра́ться *сов.* (*порваться*) ертылып бетү; ертылып чыгу, ертылып китү, ертылып өзелү

разозли́ть *сов. кого-что* бик каты ачуландыру, ачуландырып җибәрү, зәһәрен (җенен) чыгару

разозли́ться *сов.* бик каты ачулану, ачуланып китү, зәһәре (җене) чыгу

разо||йти́сь *сов.* **1.** таралу, таралышу, таралып бетү; **го́сти ~шли́сь** кунаклар таралышып беттеләр; **ту́чи ~шли́сь** болытлар таралдылар **2.** сатылып бетү, сатып таратылу; **кни́ги бы́стро ~шли́сь** китаплар тиз сатылып бетте **3.** тотылу, тотылып бетү; **де́ньги ~шли́сь сра́зу** акча шунда ук тотылып бетте **4.** (*раствориться, растаять*) эреп бетү, эрү **5.** (*не встретиться*) аймыл булу, аймылыш булу, аймылышу, очрашмыйча үтү (узу) **6.** ташлашу, аерылу, аерылышу; **~ йти́сь с жено́й** хатын белән аерылышу **7.** *прям., перен.* аерылу, аерылып китү; тармаклану, тармакланып китү; **на́ши доро́ги ~шли́сь** безнең юллар аерылды; **доро́га ~шла́сь на́ две** юл икегә аерылды **8.** аерылып китү, ачылу, җәелү, аерылу; **по́лы пальто́ ~шли́сь** пальто чабулары ачылып китте; **швы ~шли́сь** җәе киткән **9.** көчәеп китү, шәбәеп китү; **дождь ~шёлся** яңгыр шәбәеп китте **10.** *перен.* (*напр. развеселиться, разозлиться*) кызып китү, ярсу; ярсып китү

разо́м *нареч. разг.* **1.** (*одновременно*) берьюлы, бер үк вакытта; **подня́ться [всем] ~** бер үк вакытта күтәрелү **2.** (*в один приём*) бердән, бертоташтан; **вы́пить ~** бер тоташтан эчү **3.** (*мгновенно*) шунда ук, күз ачып йомганчы; **~ прийти́ в себя́** шунда ук аңга килү

разомкну́ть *сов. что* **1.** (*разъединить*) өзү, өзеп кую; ычкындыру, ычкындырып җибәрү; **~ электри́ческую цепь** электр чылбырын өзү **2.** (*раздвинуть*) аеру, аерып кую; ачу, ачып кую; **~ ве́ки** күз кабакларын ачу; **~ воро́та шлю́за** шлюзларның капкаларын ачып кую **3.** *воен.* (*образовать интервалы*) сирәгәйтү, сирәкләндерү; **~ строй** стройны сирәкләндерү

разомкну́||ться *сов.* **1.** (*разъединиться*) өзелү, өзелеп китү, өзелеп чыгу **2.** (*раскрыться*) аерылу, аерылып китү; ачылу, ачылып китү; **ве́ки ~лись** күз кабаклары ачылдылар **3.** *воен.* (*образовать интервалы*) сирәкләнү, сирәгәю

разомле́ть *сов. разг.* әлсерәү, әлсерәп китү, хәлсезләнү, хәлсезләнеп китү; изрәп төшү; **~ от зно́я** җәйге эсседән әлсерәү

разонра́виться *сов. разг.* ошамый башлау

разо́превать *несов. см.* **разопре́ть**

разопре́||ть *сов.* **1.** изелеп пешү, таралып пешү, бүртеп пешү; **ка́ша ~ла** ботка изелеп пешкән **2.** *прост.* (*сильно вспотеть*) тиргә бату, шабыр тирләү

разора́ться *сов.* **1.** (*громко кричать*) кычкыра башлау, акыра башлау, акырыну, кычкырыну **2.** *на кого* (*начать браниться*) кычкырып тирги башлау, кычкырып тиргәү

разо́рванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **разорва́ть; 2.** ертылган, ерткаланган, өзгәләнгән; **~ый чуло́к** ертылган оек **3.** өзек-өзек, бәйләнешсез, бәйләнеше булмаган; **~ые фра́зы** өзек-өзек җөмләләр

разорва́||ть *сов.* **1.** *что* ерту, ертып бетерү, ертып ташлау; өзү, өзеп бетерү, өзеп ташлау; **~ть письмо́** хатны ертып ташлау; **~ть цепь** чылбырны өзү **2.** *кого-что* (*растерзать*) ботарлау, ботарлап бетерү, ботарлап ташлау **3.** *кого-что* шартлау, җимертү, ваттыру; **котёл ~ло** *безл.* казан шартлаган **4.** *перен.* өзү, туктату (*бәйләнешне*); **~ть дипломати́ческие отноше́ния** дипломатик мөнәсәбәтләрне өзү ♦ **чтоб тебя́ ~ло!** *прост.* чәнчелеп кит! ; дөмек!

разорв||а́ться *сов.* **1.** ертылу, ертылып чыгу, ертылып китү; өзелү, өзелеп чыгу, өзелеп китү; **карма́н ~а́лся** кесә ертылып чыккан; **арка́н ~а́лся** бау өзелеп чыккан **2.** шартлау, ярылу, ярылып китү; **снаря́д ~а́лся** снаряд шартлады **3.** *перен.* (*прекратиться*) өзелү, туктау (*мөнсәбәтләр, бәйләнешләр*) ♦ **хоть ~и́сь!** шартлап! ярыл! ярылып үл!

разоре́ни||е *с см.* **разори́ть, разори́ться; спасти́сь от ~я** бөлүдән котылу

разори́тель *м* бөлдерүче, талаучы, бөлгенлеккә төшерүче

разори́тельный, -ая, -ое бөлгенлеккә төшерә торган, бөлгенлеккә төшерүче ... бөлдергеч, бөлдерә торган

разори́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*довести до нищеты*) бөлдерү, бөлгенлеккә төшерү; талау, фәкыйрьләндерү **2.** *что* (*разрушить*) туздыру, җимерү, туздырып бетерү; **~ гнездо́** ояны туздыру

разори́ться *сов.* 1. (*обеднеть*) бөлүү, бөлгенлеккә төшү; талану, фәкыйрьләнү 2. (*потратить деньги*) акча тоту, тотыну

разоружа́ть *несов. см.* **разоружи́ть**

разоружа́ться *несов.* 1. *см.* **разоружи́ться**; 2. *страд. от* **разоружа́ть**

разоруже́ни||е *с* коралсызлану, коралсызландыру; **~ е а́рмии проти́вника** дошман армиясен коралсызландыру; **по́лное ~ е** тулысынча коралсызлану; **пробле́мы ~ я** коралсызлану мәсьәләләре; **всеобщая конфере́нция по ~ ю** коралсызлану буенча гомум конференция

разору́жить *сов. кого-что* 1. коралсызландыру, коралын тартып алу; **~ банди́та** бандитның коралын тартып алу 2. *перен.* көрәшкә ихтыярын бетерү; коралсызландыру; **иде́йно ~** идея ягыннын коралсызландыру

разоружи́ться *сов.* 1. коралсызлану, корал ташлау 2. *перен.* көрәштән баш тарту, көрәштән ваз кичү; коралсызлану; **иде́йно ~** идея ягыннан коралсызлану

разоря́ть *несов. см.* **разори́ть**

разоря́ться *несов.* 1. *см.* **разори́ться**; 2. *страд. от* **разоря́ть**

разосла́ть *сов. кого-что* 1. җибәрү, тарату; **~ пи́сьма** хатлар җибәрү; **~ пригласи́тельные биле́ты** чакыру билетлары тарату 2. (*отправить всех*) җибәреп бетерү, таратып бетерү

разоспа́ться *сов. разг.* озак йоклау, нык йоклау

разостла́ть *сов. что* 1. җәю, җәеп җибәрү, җәеп кую; **~ ска́терть** эскәтер җәю 2. таратып җәю, җәеп салу; **~ лён** житенне таратып җәю 3. түшәү; җәю; **~ посте́ль** урын җәю

разостла́||ться *сов.* җәелү, таралу, түшәлү, җәелеп китү, таралып китү; **тума́н ~ лся по лу́гу** болын буйлап томан җәелде

разоткрове́нничаться *сов. разг.* эч серләрен ачып салу, ачыктан-ачык сөйләп бирү, эч бушату

разохо́тить *сов. кого, разг.* теләк уяту, кызыктыру, кызыктырып җибәрү, һәвәсләндерү, ...сы китерү

разохо́титься *сов. разг.* теләк уяну, кызыгып китү, һәвәсләнеп китү, ...сы килү

разочарова́ние *с* 1. (*чувство неудовлетворённости*) хыял юкка чыгу, өмет өзелү; канәгатьсезлек 2. *в ком-чём* (*потеря веры*) ышаныч бетү

разочаро́ванн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **разочарова́ть**; 2. хыялы юкка чыккан, өмете өзелгән, ышаныч югалган; канәгатьсезлекне белдереп торган, өмет өзелүне чагылдыра торган; **~ ый челове́к** өмете өзелгән кеше; **~ ое лицо́** өмет өзелүне чагылдыра торган чырай

разочарова́ть *сов. кого-что* хыялын юкка чыгару, өметен өзү, күңелен кайтару

разочарова́ться *сов. в ком-чём и без доп.* хыял юкка чыгу, өмет өзелү, күңеле кайту, күңел суыну

разочаро́вывать *несов. см.* **разочарова́ть**

разочаро́вываться *несов.* 1. *см.* **разочарова́ться**; 2. *страд. от* **разочаро́вывать**

разраба́тывать *несов.* 1. *см.* **разрабо́тать**; 2. *горн.* чыгару, табу; эшләп чыгару; **~ известня́к** известь ташы чыгару

разрабо́тать *сов. что* 1. (*тщательно обработать*) эшкәртү, эшләп яраклы итү; **~ зе́млю под огоро́д** җирне бакча өчен эшкәртү 2. эшкәртү, тикшерү, тирәнтен тикшерү, тирәнтен өйрәнү; **~ вопро́с** мәсьәлне тирәнтен тикшерү 3. (*отделать*) эшләү, үстерү, камилләштерү; **~ ми́мику** мимиканы камилләштерү 4. *горн.* чыгарып бетерү, алып бетерү (*рудниктагы казылма байлыкны чыгарып бетерү*)

разрабо́тк||а *ж* 1. *см.* **разрабо́тать**; **~ а пла́нов** планнар эшләү; **~ а ка́менного угля́** ташкүмер чыгару 2. (*способ добычи*) чыгару ысулы, чыгару юлы, эшкәртелеш; **откры́тая ~ а** (*казылма байлыкларны*) ачык юл белән чыгару 3. *мн.* **~ и** чыгару, чыгару урыны; **торфяны́е ~ и** торф чыгару урыны

разра́внивать *несов. см.* **разровня́ть**

разража́ться *несов. см.* **разрази́ться**

разрази́ться *сов.* 1. (*о грозе, буре*) башлану, башланып китү, ...рга тотыну 2. (*о гёбре, беде и т.п.*) килеп чыгу, башка төшү 3. *перен. чем* ...а башлау; **~ бра́нью** тирги башлау; **~ рыда́ниями** үксеп елый башлау; **~ прокля́тиями** ләгънәтләр яудыру

разраста́ться *несов. см.* **разрасти́сь**

разрасти́сь *сов.* 1. үсеп китү, үсеп җәелү, үсеп зураю; **куста́рник разро́сся** куаклык үсеп җәелгән 2. *перен.* киңәю, җәелү; киңәеп (җәелеп) китү; ишәю, күбәю, ишәп (күбәеп) китү; **го́род разро́сся** шәһәр киңәйгән; **семе́йство разрослось** гаилә ишәеп китте

разреве́||ться *сов.* үкереп (акырып) елый башлау; **малы́ш ~ лся** сабый үкереп елый башлады

разреди́ть *сов. что* 1. сирәкләү, сирәкләтү, сирәкләндерү, сирәкләп утырту; **~ реди́ску** редисканы сирәкләү 2. сирәгәйтү; сыеклау; **~ во́здух** һаваны сирәгәйтү

разреди́||ться *сов.* 1. (*стать реже*) сирәкләнү, сирәкләп утыртылу 2. сирәгәю; сыеклану; **во́здух ~ лся** һава сирәгәйде

разрежа́ть *несов. см.* **разреди́ть**

разрежа́ться *несов.* **разреди́ться** 2. *страд. от* **разрежа́ть**

разрежённый, -ая, -ое 1. *прич. от* **разреди́ть** 2. сирәкләтелгән, сирәк, сирәк утыртылган (чәчелгән) 3. сирәк; **~ воздух** сирәк һава

разре́з *м* 1. *см.* **разре́зать**; **~ шку́рок** тиреләрне кису 2. (*место*) ерык, кисек, уем, ерылган, (киселгән, уелган) урын; киселеш, уелыш 3. кисем; **попере́чный ~** аркылы кисем 4. *мат.* киселмә ♦ **в разре́зе** *чего* ... күзлегеннән карап, ... чыгып

разре́за||ть *сов. что* 1. кису, телү, кисеп ташлау, кискәләп бетерү, кисеп бетерү; **~ ть хлеб** ипи телү 2. *перен.* (*рассечь водную гладь — о судне*) яру, ярып бару 3. кисеп ачу, яру, ярып җибәрү; **~ ть живо́т** эчне яру 4. (*разделить на части*) икегә аеру, уртага бүлү; **река́ ~ ла го́род на́ две ча́сти** елга шәһәрне икегә аерган

разреза́ть *несов. см.* **разре́зать**

разрезн||о́й, -а́я, -о́е 1. кису ...ы, кисә (телә) торган; **~ о́й стано́к** телә торган станок 2. (*с разрезами*) ерыклы, ерылган, ерык итәкле; **~ а́я ю́бка** ерык итәкле юбка

разреклами́ровать *сов. кого-что* бик күп рекламалау, артык мактау (мактап җибәрү); **~ това́р** товарны бик күп рекламалау

разреша́ть *несов. см.* **разреши́ть**

разреша́||ться *несов.* 1. *см.* **разреши́ться**; 2. *безл.* рөхсәт ителү; **здесь кури́ть не ~ ется** биредә тәмәке тартырга рөхсәт ителми 3. *страд. от* **разреша́ть**

разреше́ни||е *с* 1. *см.* **разреши́ть**; **~ е противоре́чий** каршылыкларны чишү 2. рөхсәт язуы, рөхсәт кәгазе, рөхсәт; **полу́чить ~ е** рөхсәт алу ♦ **с ва́шего ~ я** сезнең рөхсәтегез белән

разреши́мый, -ая, -ое чишә алырлык, чишеп була торган; хәл итә алырлык, хәл итәрлек; **~ вопро́с** хәл итәрлек мәсьәлә

разреши́||ть *сов. что* 1. (*дать согласие*) рөхсәт итү, рөхсәт бирү, ирек бирү, хокук бирү 2. (*найти ответ, рассудить*) чишү, тикшереп чишү; хәл итү; хәл кылу; ачыклау; **~ ть нау́чный вопро́с** фәнни мәсьәлә хәл итү; **~ ть спор** бәхәсне хәл кылу 3. *повел.* **~ те** рөхсәт итегез, рөхсәтме ♦ **~ ть сомне́ния** шикшөбһәләрне юкка чагыру

разреши́||ться *сов.* 1. чишелү, хәл ителү, ачыклану; **вопро́с ~ лся** мәсьәлә чишелде 2. (*закончиться*) хәл ителү, хәл кылыну; бетү, тәмамлану, төгәлләнү; **де́ло ~ лось** эш хәл ителде 3. *кем и без доп., уст.* (*родить*) бала табу, бала китерү; бала тудыру; **~ ться ма́льчиком** ир бала табу

разрисова́ть *сов. кого-что* 1. рәсемнәр ясау, бизәү, бизәкләү, бизәп бетерү; **~ сте́ны** станаларга рәсемнәр ясау 2. *перен. разг.* тасвир итү, сөйләп бирү (*гадәттә начар яктан*); яманлау

разрисо́вывать *несов. см.* **разрисова́ть**

разровня́ть *сов. что* тигезләү, тигезләп чыгу, тигезләп кую; **~ зе́млю** җирне тигезләп чыгу

разроди́ться *сов. разг.* бала табу, бала китерү

разро́зненн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **разро́знить**; 2. (*разобщённый*) таркау, аерым-аерым, берләшмәгән; **~ ые отря́ды** аерым-аерым отрядлар 3. (*неполный*) тулы булмаган; җитешмәгән; **~ ый компле́кт** тулы булмаган комплект 4. ишле-ишсез, сыңарлы-сыңарсыз; **~ ая посу́да** ишле-ишсез савыт-саба

разро́знить *сов. что* ишле-ишсез ясау, ишсезләндерү; бөтенлеген бозу; **~ колле́кцию** коллекциянең бөтенлеген бозу

разро́зни||ться *сов.* ишсезләнү, комплекты бозылу, комплекты юкка чыгу; **серви́з ~лся** сервиз ишсезләнде

разруба́ть *несов. см.* **разруби́ть**

разруби́ть *сов. что* кисеп чыгару, чабу; чабып өзү, тураклау, тураклап бетерү; **~ мясо** ит чабу

разруга́ть *сов. кого-что* сүгү, тиргәү, сүгеп ташлау, тиргәп ташлау, бик нык тәнкыйтьләү; **~ пье́су** пьесаны сүгү

разруга́ться *сов. с кем* тиргәшү, тиргәшеп ара бозу, тиргәшеп араны өзү

разрумя́нивать *несов. см.* **разрумя́нить**

разрумя́нить *сов. кого-что* алсуландыру, алсуландырып җибәрү, кызарту

разрумя́ни||ться *сов.* алсулану, алсуланып китү, кызыллык йөгерү, кызару; **лицо́ ~лось** битенә кызыллык йөгерде

разру́||ха *ж* җимереклек, бөлгенлек; **боро́ться с ~ой** бөлгенлеккә каршы көрәшү

разруша́ть *несов. см.* **разру́шить**

разруша́ться *несов.* **1.** *см.* **разру́шиться; 2.** *страд. от* **разруша́ть**

разрушени||е *с* **1.** *см.* **разру́шить, разру́шиться; ~е го́рода** шәһәрне җимерү; **~е организ́ма** организмның таркалуы **2.** җимереклек; хәрабә; **землетрясе́ние причини́ло ~я** җир тетрәү җимерекләр барлыкка китерде

разруши́тель *м* җимерүче, таркатучы, юкка чыгаручы, бозучы

разруши́тельн||ый, -ая, -ое җимергеч, һәлакәтле, афәтле; **~ая си́ла** җимергеч көч

разру́шить *сов. что* **1.** җимерү, җимереп ташлау, җимереп бетерү, ватып ватып ташлау; **~ постро́йку** корылманы җимерү **2.** *перен.* (*привести к разрухе*) таркату, бөлдерү, бөлгенлеккә төшерү **3.** *перен.* бозу, юкка чыгару, бетерү; **~ здоро́вье** сәламәтлекне бетерү; **~ пла́ны** планнарны юкка чыгару

разру́ши||ться *сов.* **1.** җимерелү, ватылу, җимерелеп бетү; **часть зда́ния ~лась** бинаның бер өлеше җимерелде **2.** (*прийти в упадок*) таркалу; бөлгенлеккә төшү, бөлү; **хозя́йство ~лось** хуҗалык бөлде **3.** *перен.* бозылу, юкка чыгу, бетү; **здоро́вье окончи́тельно ~лось** сәламәтлек тәмам бетте; **все его́ пла́ны ~лись** аның барлык планнары юкка чыкты

разры́в *м* **1.** *см.* **разорва́ть** 4, **разорва́ться; ~ дипломати́ческих отноше́ний** дипломатик мөнәсәбәтләрне өзү; **~ пря́жи** эрләнгән җепнең өзелүе; **~ грана́ты** гранатаның шартлавы **2.** (*место*) җимерек урын, өзелгән урын, җимерек ара; **найти́ ~ про́вода** чыбыкның өзелгән урынын табу **3.** *перен.* (*отсутствие согласованности*) аерма, аерылу, туры килмәү; **~ ме́жду спро́сом и предложе́нием** сорау белән тәкъдим арасындагы аерма

разрыва́ть I *несов. см.* **разорва́ть**

разрыва́ть II *несов. см.* **разры́ть**

разрыва́||ться *несов.* **1.** *см.* **разорва́ться; 2.** *страд. от* **разрыва́ть** I ◆ **душа́ (се́рдце) ~ется** йөрәгем телгәләнә; **~ться на ча́сти** кырыкка ярылу

разрывн||о́й, -а́я, -о́е шартлый торган, шартлаулы, ярыла торган; **~о́й заря́д** шартлый торган заряд; **~а́я пу́ля** ярыла торган пуля

разрыда́ться *сов.* елый башлау, үксеп елап җибәрү, сулкылдап елый башлау

разры́ть *сов. что* **1.** казу, казып ташлау, казып бетерү; чоку, чокып бетерү; **~ зе́млю** җирне казып бетерү **2.** (*привести в беспорядок*) актару, актарып ташлау; **~ все бума́ги** бөтен кәгазьләрне актарып ташлау

разрыхли́тель *м* көпшәкләгеч, туфрак йомшарткыч

разрыхли́ть *сов. что* көпшәкләндерү, йомшарту; **~ зе́млю** җирне көпшәкләндерү

разрыхли́ться *сов.* көпшәкләнү, йомшару, көпшәкләнеп (йомшарып, күперсп) китү

разрыхля́ть *несов. см.* **разрыхли́ть**

разрыхля́ться *несов.* **1.** *см.* **разрыхли́ться; 2.** *страд. от* **разрыхля́ть**

разря́д I *м* **1.** (*категория*) төркем, катлау; бүлек, төр **2.** разряд, дәрәҗә; **спортсме́н пе́рвого ~а** беренче разрядлы спортчы **3.** *мат.* разряд

разря́д II *м* **1.** *см.* **разряди́ть** II 1-3; **~ ружья́** мылтыкның патронын алу; **~ батаре́и** батареянең бушануы

разряди́ть I *сов. кого-что, разг.* (*нарядить*) бик купшы итеп киендерү, киендерү-ясандыру, бик яхшы итеп киендерү

разряди́ть II *сов. что* **1.** патронын (снарядын, зарядын) алу; **~ ми́ну** минаның зарядын алу **2.** (*выстрелить*) атып бушандыру (*зарядтан*); **~ ружьё** мылтыкны атып бушандыру **3.** *физ.* бушандыру; **~ аккумуля́тор** аккумуляторны бушандыру **4.** *перен.* йомшарту, йомшартып җибәрү, (киеренкелекне) киметү, бетерү; жиңеләйтү; **~ напряжённость** киеренкелекне йомшартып җибәрү **5.** *полигр.* сирәкләп җыю

разряди́||ться I *сов.* (*нарядиться*) бик купшы, киенү, киенү-ясану, бик яхшы киенү

разряди́ться II *сов.* **1.** заряды алыну, патроны алу **2.** *физ.* бушану; **конденса́тор ~лся** конденсатор бушанды **3.** *перен.* юкка чыгу, бетү, [киеренкелек] кимү; жиңеләю

разря́дка *ж* **1.** *см.* **разряди́ть** II 1-3; **~ ружья́** мылтыкның патронын алу; **~ аккумуля́тора** аккумуляторның бушануы **2.** *перен.* йомшару, йомшарту; **~ междунаро́дной напряжённости** халыкара киеренкелекнең йомшаруы **3.** *полигр.* сирәкләү, сирәкләп җыю

разря́дник I *физ.* бушандыргыч; **искрово́й ~** очкынлы бушандыргыч

разря́дник II разрядник (*спортчы*)

разряжа́ть I *несов. см.* **разряди́ть** I

разряжа́ть II *несов. см.* **разряди́ть** II

разряжа́ться I *несов.* **1.** *см.* **разряди́ться** I **2.** *страд. от* **разряжа́ть** I

разряжа́ться II *несов.* **1.** *см.* **разряди́ться** II; **2.** *страд. от* **разряжа́ть** II

разубеди́ть *сов. кого-что в чём* фикереннән дүндерү, фикереннән (уеннан) кире кайтару, фикереннән үзгәртү, башкага ышандыру; ниятен үзгәртү

разубеди́ться *сов.* фикереннән (уеннан) кире кайту, фикерен үзгәртү, фикердән дүнү, башкага ышану

разубежда́ть *несов. см.* **разубеди́ть**

разубежда́ться *несов.* **1.** *см.* **разубеди́ться; 2.** *страд. от* **разубежда́ть**

разува́ть *несов. см.* **разу́ть**

разува́ться *несов.* **1.** *см.* **разу́ться; 2.** *страд. от* **разува́ть**

разуве́рить *сов. кого-что в чём* фикереннән (уеннан) кире кайтару, ышанычын бетерү, ышанычын юкка чыгару, фикереннән дүндерү

разуве́риться *сов.* фикереннән (уеннан) кире кайту, ышаныч бетү (юкка чыгу), фикереннән дүнү

разуверя́ть *несов. см.* **разуве́рить**

разуверя́ться *несов.* **1.** *см.* **разуве́риться; 2.** *страд. от* **разуверя́ть**

разузнава́ть *несов. см.* **разузна́ть**

разузна́ть *сов. что, о ком-чём* сорашып белү, тикшереп белү, белеп бетерү, белеп алу; мәгълүмат җыю

разукра́сить *сов. кого-что* бизәү, бизәкләү, бизәп чыгу (бетерү), чуарлау

разукра́ситься *сов.* бизәлү, чуарлану, чуарланып (бизәлеп) бетү; ямьләнү, матурлану

разукра́шивать *несов. см.* **разукра́сить**

разукра́шиваться *несов.* **1.** *см.* **разукра́ситься; 2.** *страд. от* **разукра́шивать**

разукрупне́ние *с см.* **разукрупни́ть, разукрупни́ться; ~ райо́нов** районнарны кечерәйтү

разукрупни́ть *сов. что* кечерәйтү, бәләкәйтү, ваклау; бүлү, бүлгәләү (*ваграк берәмлекләргә*); **~ брига́ды** бригадаларны кечерәйтү

разукрупни́||ться *сов.* кечерәю, бәләкәйләнү, ваклану; бүленү, бүлгәләнү; **райо́н ~лся** район бүленде

разукрупня́ть *несов. см.* **разукрупни́ть**

разукрупня́ться *несов.* **1.** *см.* **разукрупни́ться; 2.** *страд. от* **разукрупня́ть**

ра́зум *м* гакыл, аң, акыл, зиһен; **учи́ть уму́ ~у** акылга өйрәтү, акыл бирү

разуме́ни||е *с* **1.** (*мнение*) фикерләү, төшенү, аңлау, караш; **по его́ ~ю** аның аңлавынча **2.** *уст.* (*способность понимать*) аңлау көче, аңлау дәрәҗәсе, аңлау куәте, төшенү сәләте

разуме́ть *несов. что, уст.* аңлау, төшенү, аңлап (төшенеп) алу; асылын белү; **~ де́ло** эшнең асылын белү

разуме́||ться *несов.* **1.** (*подразумеваться*) аңлашылу, күздә тотылу **2.** *в знач. вводн. сл.* **~ется** әлбәттә, билгеле, аңлашыла

разу́мник *м разг.* акыллы (*күбрәк балалар турында*)

разу́мница *ж см.* **разу́мник**

разу́мность *ж* гакыллылык, акыллылык

разу́мн||ый, -ая, -ое **1.** (*обладающий разумом*) акыллы, акылга ия булган,

акылы булган; **~ое существо́** акылга ия булган зат **2.** (*логичный*) акыллы, акылга яраклы, акылга муафыйк; нигезле; **~ые до́воды** акылга яраштыр дәлилләр **3.** (*рассудительный*) төпле, төпле акыллы; **~ый челове́к** төпле кеше

разу́ть *сов. кого-что* аяк киемен салдыру, аягын салдыру

разу́ться *сов.* аяк киемен салу (*үзеңнең*), аягыңны салу

разухá|бист||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** (*задорный*) бик дәртле, бик ялкынлы, гайрәтле, бик җилле; **~ая пля́ска** бик җилле бию **2.** (*развязный*) тупас; дорфа, әдәпсез, тыйнаксыз; **~ые мане́ры** тупас кыланышлар

разу́чивать *несов. см.* **разучи́ть**

разу́чиваться *несов.* **1.** *см.* **разучи́ться; 2.** *страд. от* **разу́чивать**

разучи́ть *сов. что* ятлау, ятлап алу, ятлап истә калдыру, ятлап өйрәтү; **~ но́вое стихотворе́ние** яңа шигырьне ятлап алу

разучи́ться *сов.* оныту, онытып бетерү (*белгәнне, өйрәнгәнне*); **~ пляса́ть** биюне онытып бетерү

разъеда́ть *несов.* **1.** *см.* **разъе́сть; 2.** *перен. что* (*губительно действовать*) ашау, бетерү, һәлак итү, харап итү

разъеда́ться *несов.* **1.** *см.* **разъе́сться; 2.** *страд. от* **разъеда́ть**

разъедине́ние *с см.* **разъедини́ть, разъедини́ться; ~ про́вода** үткәргечне аеру

разъедини́тель *м физ.* өзгеч, аергыч

разъедини́ть *сов.* **1.** *кого-что* аеру, аерып алу, өзү, өзеп кую; **~ провода́** тимерчыбыкларны аеру **2.** (*разлучить*) аеру, аерып алу; бәйләнешен өзү

разъедини́|ться *сов.* **1.** аерылу, аерылып чыгу; **провода́ ~лись** тимерчыбыклар аерылды **2.** *перен. с кем* (*потерять связь*) бәйләнеш өзелү

разъединя́ть *несов. см.* **разъедини́ть**

разъединя́ться *несов.* **1.** *см.* **разъедини́ться; 2.** *страд. от* **разъединя́ть**

разъе́зд *м* **1.** *см.* **разъезжа́ть, разъе́хаться** 1, 3, 4; **~ делега́тов** делегатларның китүе **2.** *мн.* **~ы** сәфәр, юл, юлда булу, юл йөрү, юлда йөрү; **~ы по райо́нам** районнар буенча юлда йөрү **3.** разъезд (*бер колеялы тимер юлда каршы килә торган поездларны үткәреп җибәрә торган икенче юл*; *кечкенә станция*)

разъе́здить *сов. что* **1.** (*автомашинада*) йөреп юл салу; йөреп таптау, йөреп такырайту (*юлны*) **2.** (*испортить ездой*) (*автомашинада*) йөреп бозу, йөреп бозып бетерү (*юлны*)

разъе́здиться *сов.* күп йөри башлау, еш йөри башлау

разъездн|о́й, -а́я, -о́е **1.** күчеп йөри торган, урыннарда йөрүче; **~о́й аге́нт** урыннарда йөрүче агент **2.** юл ...ы; юл йөрү ...ы; **~ы́е расхо́ды** юл чыгымнары **3.** *ж.-д.* (*юлда*) аерылышу ...ы; **~о́й путь** аерылышу юлы

разъезжа́ть *несов.* юл йөрү, йөрү, сәфәрдә йөрү; **~ по стране́** ил буйлап йөрү

разъезжа́ться *несов. см.* **разъе́хаться**

разъе́сть *сов. что* (*о едких веществах*) ашау, кисү, ашап (кисеп) бетерү

разъе́сться *сов.* ашап көрәю, ашап симерү, ашап юанаю

разъе́ха|ться *сов.* **1.** (*автомашинада*) таралу, китү, китеп бетү, таралышу, таралып бетү; **студе́нты ~лись** студентлар китеп бетте **2.** *с кем и без доп., разг.* аерылышу; ташлашу; **~ться с му́жем** ир белән аерылышу **3.** (*разминуться*) аймыл булу, аймылыш булу; **~ться с товаро́м** иптәшең белән аймылыш булу **4.** (*дать дорогу*) юл бирешү, юл сабышу **5.** (*ике якка*) аерылу, аерылып китү; **ноги́ ~лись на льду́** боз өстендә аяклар аерылып киттеләр **6.** *перен. разг.* (*развалиться от ветхости*) тузу, сыпылу, ватылу

разъярённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **разъяри́ть; 2.** ачуы кабарган, ярсыган, ярсып киткән, котырынган, шашкан; **~ зверь** ярсыган ерткыч

разъяри́ть *сов. кого-что* ачуын кабарту, ярсыту, ярсытып җибәрү, шашындыру, шаштыру

разъяри́ться *сов.* ачу кабару, ярсу, шашу, ярсып китү, котырыну, шашып китү

разъаря́ть *несов. см.* **разъяри́ть**

разъаря́ться *несов.* **1.** *см.* **разъяри́ться; 2.** *страд. от* **разъаря́ть**

разъясне́ни|е *с* **1.** *см.* **разъясни́ть, разъясни́ться; ждать ~я** аңлатканны көтү; **~е зада́чи** мәсьәләне аңлату **2.** аңлатма, аңлатма бирү, аңлату; **дава́ть ~я** аңлатмалар бирү

разъясни́тельн|ый, -ая, -ое аңлату ...ы, төшендерү ...ы, аңлатма ...ы; **~ая рабо́та** аңлату эшләре

разъясни́ть *сов. безл. разг.* (*о погоде*) аязу, аязып китү, көн ачылу

разъясни́ть *сов. что* аңлату, аңлатып бирү, төшендерү, төшендереп бирү, ачыклау, ачыклап бирү; **~ зада́чу** мәсьәләне аңлатып бирү

разъясни́ться *сов. разг.* (*о погоде*) *см.* **разъясни́ть**

разъясни́|ться *сов.* аңлашылу, ачыклану; **де́ло ~лось** эш ачыкланды

разыгра́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*исполнить совместно*) уйнау, уйнап күрсәтү; башкару, кую; **~ спекта́кль** спектакль кую **2.** *перен. кого-что* ...булып кылану, ...булып күренү, ...га салышу ...итеп күрсәтү; **~ простачка́** беркатлы булып кылану **3.** *что* уйнап бетерү, уйнап алу, уйнап чыгу; **~ па́ртию в ша́хматы** бер партия шахмат уйнап бетерү **4.** *что* уйнау, уйнату; **~ по жре́бию** жирәбәгә салу; **~ меда́ли** *спорт.* медальләр уйнату **5.** *кого-что* шаярту, шаяртып көлкегә калдыру, шаяртып көлү; **~ прия́теля** дустыңны шаяртып көлкегә калдыру ♦ **~ дурака́** ахмаклану, ахмаклык эшләү, ахмак булып кылану

разыгра́|ться *сов.* **1.** (*увлечься игрой*) уенга бирелү, уенга бирелеп китү, уен белән мавыгу (мавыгып китү), уенга кызыгып китү **2.** (*играть непринуждённо*) кызып (дәртләнеп) уйный башлау; **пиани́ст ~лся** пианист кызып уйный башлады **3.** (*усилиться*) кызып китү; көчәеп китү; **~лась головна́я бо́ль** баш авыртуы көчәеп китте **4.** *перен.* (*проявиться бурно*) кубу, башлану, килеп чыгу; **~лась бу́ря** давыл купты; **~лся бой** сугыш башланды

разы́грывать *несов. см.* **разыгра́ть**

разы́грываться *несов.* **1.** *см.* **разыгра́ться; 2.** *страд. от* **разы́грывать**

разыска́ние *с* **1.** (*поиски*) эзләү, эзләп табу **2.** *книжн.* (*исследование*) эзләнү, тикшерену; фәнни әсәр

разыска́ть *сов. кого-что* табу, эзләп табу; **~ пропа́вшую кни́гу** югалган китапны эзләп табу; **~ ро́дственников** туганнарны эзләп табу

разыска́|ться *сов.* табылу, эзләп табылу; **соба́ка ~лась** эт табылды

разы́скивать *несов. кого-что* эзләү; табарга тырышу; **~ щенка́** көчекне эзләү

рай *м прям., перен.* оҗмах, жәннәт; **земно́й ~** жирдәге оҗмах

райисполко́м *м* райисполком, райбашкарма

райко́м *м* райком

райо́н *м* **1.** район; **Ки́ровский ~ го́рода Каза́ни** Казан шәһәренең Киров районы **2.** *разг.* район, район үзәге; **вы́ступить в ~е с докла́дом** район үзәгендә доклад белән чыгу **3.** район, өлкә; төбәк; **ю́жные ~ы** көньяк өлкәләр; **аграрные ~ы** аграр районнар

райони́ровать *сов., несов. что* **1.** (*подразделять на районы*) районнарга бүлү, районнарга аеру **2.** (*распределять по районам*) районлаштыру (*яраклаштыру, җайлаштыру, мәс. игеннәрне*); **~ пшени́цу** бодайны районлаштыру

райо́нный, -ая, -ое райондагы..., район ...ы; **~ агроно́м** район агрономы; **~ центр** район үзәге

рак I *м* **1.** кысла **2.** (*с прописной*) *астр.* Кысла ♦ **когда́ [на горе́] ~ сви́стнет** *погов.* ≈ кызыл кар яугач; **показа́ть, где ~ и зиму́ют** күрмәгәнен күрсәтү ≈ жиде бабасын таныту

рак II *м* яман шеш, рак; рак авыруы

раке́т|а *ж в разн. знач.* ракета; **косми́ческая ~а** космик ракета; **сигна́льная ~а** сигнал ракетасы; **~ы сре́дней да́льности** урта ераклыкка оча торган ракеталар

раке́та-носи́тель *ж* йөрткеч ракета

раке́тка *ж спорт.* ракетка, теннис калагы

раке́тница *ж* ракетница (*сигнал ракеталарын ату пистолеты*)

раке́тно-я́дерн|ый, -ая, -ое ракета-төш ...ы; **~ое ору́жие** ракета-төш коралы

раке́тн|ый I, -ая, -ое *в разн. знач.* ракета ...ы, ракеталар ...ы; **~ое ору́жие** ракета коралы; **~ая те́хника** ракета техникасы; **~ое то́пливо** ракета ягулыгы; **~ый дви́гатель** ракета двигателе; **~ые войска́** ракета гаскәрләре

раке́тн|ый II, -ая, -ое *спорт.* ракетка ...ы; **~ая се́тка** ракетка челтәре

ракетодро́м *м* ракетодром

ракетоно́сец, ракетоноси́тель *м* ракета йөртүче

ракетострое́ние *с* ракеталар төзү, ракеталар ясау

раке́тчик *м* ракетачы, ракетчик

раки́та *ж* өянке, тирәк

раки́тник *м* өянкелек, тирәклек

раки́тов||ый, -ая, -ое өянке ...ы, тирәк ...ы; **~ые ве́тки** өянке ботаклары

ра́ковина *ж* **1.** кабырчык, кабык; **~ули́тки** әкәм-төкәмнең кабырчыгы **2.** раковина (*су краны астындагы махсус савыт*) **3.** (*пустота в отлитом металле*) бушлык, куышлык, күзәнәк

ра́ков||ый I, -ая, -ое **1.** кысла ...ы; **~ая скорлупа́** кысла кабыгы **2.** кысла итеннән пешерелгән (хәзерләнгән); кысла ...ы; **~ый суп** кысла шулпасы

ра́ков||ый II, -ая, -ое рак ...ы, яман шеш ...ы; **~ая о́пухоль** яман шеш

ракообра́зные *мн. зоол.* кысласыманнар

ра́курс *м* ракурс (*фигураларның яки предметларның перспективада сурәтләнүе*)

раку́шечник *м* кабырчык токым (*кабырчыклардан барлыкка килгән токым*)

раку́шка *ж см.* **ра́ковина** I

ра́лли *с нескл. спорт.* ралли

ра́м||а *ж* **1.** рам, кыса; **зе́ркало в ~е** касыга утыртылган көзге **2.** (*оконный переплёт со стеклом*) рам, тәрәзә; **двойны́е ~ы** ике кат тәрәзә **3.** *тех.* рам; **~а автомоби́ля** автомобиль рамы

рамаза́н *м* рамазан, рамазан ае

ра́м||ка *ж* **1.** рамка, кечкенә рам; **портре́т в ~ке** рамкадагы портрет **2.** *перен.* чик, чит; **вы́йти из ~ок те́мы** темадан читкә чыгу; **в ~ках** *чего-л.* чикләрендә, нигезендә

ра́мпа *ж театр.* рампа (*сәхнәне яктырта торган лампаларны тамашачылардан каплаучы, сәхнә алдындагы тәбәнәк барьер*)

ра́на *ж прям., перен.* яра, җәрәхәт; **сердéчная ~** йөрәк ярасы

ранг *м* ранг (*дәрәҗә, чин, звание*); **капита́н второ́го ~а** икенче ранглы капитан

рагоу́т *м* рангоут (*корабльләрдә җилкәнне, сигнал билгеләрен күтәрү җайланмасы*)

рандеву́ *с нескл.* күрешү, очрашу

ра́нее *см.* **ра́ньше** 1, 2

ране́ние *с* **1.** *см.* **ра́нить**; **2.** (*рана*) яра, җәрәхәт; **получи́ть ~** яралану

ра́нен||ый, -ая, -ое **1.** яралы, яраланган, җәрәхәтләнгән; **~ые бойцы́** яралы сугышчылар **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* яралы

ране́т *м* ранет (*алма сорты*)

ра́нец *м* ранец, букча

ранжи́р: по ~у 1) (*по росту*) буйга (озынлыкка) карап; 2) (*по значению*) әһәмиятенә карап

рани́м||ый, -ая, -ое тиз рәнҗи торган; **~ая нату́ра** тиз рәнҗи торган кеше

ра́нить *сов., несов.* **1.** *кого* яралау, җәрәхәтләү; **~ в но́гу** аякны яралау **2.** *перен. кого-что* азаплау, интектерү, җәфалау; **~ ду́шу** күңелне җәфалау

ра́нн||ий, -яя, -ее **1.** иртә килгән (булган, төшкән, яуган, узган); **~яя весна́** иртә килгән яз **2.** вакытыннан элек, иртә; **в ~ий час** иртә сәгатьтә **3.** (*первый по времени*) баштагы, беренче, башлангыч; **~ие произведе́ния Пу́шкина** Пушкинның беренче әсәрләре **4.** (*бывающий раньше других*) иртә өлгерә (пешә) торган; **~ие сорта́ я́блок** алманың иртә пешә торган сортлары ♦ **~яя пти́чка** таң кошы (*иртә тора торган кеше турында әйтелә*)

ра́но *нареч.* **1.** иртә; **яви́ться ~** иртә килү **2.** бик иртә, вакытыннан элек, тиз; **~ состари́ться** бик иртә картаю **3.** иртүк; **~ у́тром** иртән иртүк **4.** (*в самом начале какого-л. периода*) башында; **~ весно́й** яз башында ♦ **~ и́ли по́здно** иртәме, соңмы (*ягъни киләчәктә*)

рант *м* рант; **боти́нки с ~ом** рантлы ботинка

ра́нтов||ый, -ая, -ое рантлы; **~ые сапоги́** рантлы итекләр

рантье́ *м нескл.* рантье, сорыкорт (*капиталистик җәмгыятьтә — көч түкмичә алынган доходка, рентага яшәүче*)

рань *ж* иртә таң, бик иртә [ватык]

ра́ньше *нареч.* **1.** *сравн. ст. от* **ра́но** 1; **2.** (*до какого-л. момента*) алда, элегрәк; **де́лать ~ сро́ка** вакытыннан алда эшләү **3.** (*сначала*) башта, алда; **~ вы́слушай, пото́м говори́** башта тыңла, аннан соң сөйлә **4.** (*прежде*) электә, элек, элекке вакытта; **~ они́ дружи́ли** элек алар дус иделәр

рапи́ра *ж* рапира (*фехтованиеда кулланыла торган дурт кырлы корал*)

ра́порт *м* рапорт; **пода́ть ~ командо́ру** командирга рапорт бирү

рапорти́чка *ж* рапортичка, кыскача отчёт

рапортова́ть *сов., несов. кому, о чём* рапорт бирү, хәбәр итү, белдерү; **~ командо́ру** командирга рапорт бирү; **~ о происше́дшем** булган вакыйга турында хәбәр итү

рапсо́дия *ж* рапсодия (*халык җырлары темаларына язылган музыкаль әсәр*)

ракрите́т *м* раритет (*утә сирәк очрый торган әйбер*); **колле́кция ~ов** үтә сирәк очрый торган әйберләр коллекциясе

ра́са *ж* раса

раси́зм *м* расачылык, расизм

раси́ст *м* расачы, расачылык тарафдары

раси́стск||ий, -ая, -ое расачылык ...ы, расизм ...ы, расачы ...ы; **~ая тео́рия** расачылык теориясе

раскабали́ть *сов. кого-что* кабаладан азат итү, кабаладан коткару

раскабали́ться *сов.* кабаладан азат ителү, кабаладан котылу

раска́иваться *несов. см.* **раска́яться**

раскалённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **раскали́ть**; **2.** кызган, кыздырылган, эссе; **~ая печь** кызган мич; **~ый во́здух** кызу һава

раскали́ть *сов. что* кыздыру, бик нык кыздыру; **~ желе́зо** тимерне кыздыру

раскали́||ться *сов.* кызу, кызып җитү, бик нык кызу; эсселәнү; **печь ~лась** мич бик нык кызган

раска́лывать *несов. см.* **расколо́ть**

раска́лываться *несов.* **1.** *см.* **расколо́ться**; **2.** *страд. от* **раска́лывать**

раскаля́ть *несов. см.* **раскали́ть**

раскаля́ться *несов.* **1.** *см.* **раскали́ться**; **2.** *страд. от* **раскаля́ть**

раска́пывать *несов. см.* **раскопа́ть**

раска́рмливать *несов. см.* **раскорми́ть**

раскасси́ровать *сов. кого-что уст.* тарату, бетерү (*хәрби частьне, берәр подразделениене, торкемне*); **~ полк** полкны тарату

раска́т *м* **1.** (*прерывистый гул*) гөрелдәү, гөрселдәү, гөрелте; яңгырау тавышы; **~ы гро́ма** күк күкрәү гөрелтесе **2.** (*раскатанное место*) кагылма, салу; **~ы на доро́ге** юлдагы кагылмалар **3.** (*скорость*) кызу бару, тиз бару; **са́ни перевернý лись на всём ~е** чана бик кызу барганда әйләнеп китте

раската́ть *сов. что* **1.** җәю, тарату, җәеп җибәрү, таратып җибәрү, сүтү (*төргәнне*); **~ ковёр** келәмне җәю **2.** (*направить в разные стороны*) (*төрле якка*) тәгәрәтү, тәгәрәтеп җибәрү; **~ брёвна** бүрәнәләрне төрле якка тәгәрәтеп җибәрү **3.** (*бельё*) тәгәрәтү, тәгәрәтеп алу **4.** җәю, җәеп кую; **~ те́сто** камыр җәю

раската́||ться *сов.* **1.** таралу, җәелеп китү, сүтелү (*урап төрелгән әйбер турында*); **ковёр ~лся** келәм сүтелде **2.** (*стать тонким от катания*) җәелү (*мәс. камыр турында*)

раска́тистый, -ая, -ое **1.** гөрелдәүле, гөрелтеле, гөрелдәп китә торган; **~ гром** гөрелтеле күк күкрәү **2.** яңгыравыклы, яңгырап китә торган; **~ смех** яңгыравыклы көлү тавышы

раскати́ть *сов. что* **1.** (*придать скорость*) тизләтеп җибәрү, кыздырып җибәрү; кызу итеп әйләндереп җибәрү **2.** (*катя, разъединить*) (*төрле якка*) тәгәрәтү, тәгәрәтеп җибәрү, тәгәрәтеп ташлау

раскати́||ться *сов.* **1.** (*приобрести скорость*) кызу бара башлау, шәп килә башлау; кызулап китү **2.** (*төрле якка*) тәгәрәү, тәгәрәп китү; **я́блоки ~лись по́ полу** идән буйлап алмалар тәгәрәп китте **3.** (*прозвучать громко*) яңгырау, яңгырап китү; **вы́стрел ~лся по реке́** елга буйлап ату тавышы яңгырап китте

раска́тывать *несов.* **1.** *см.* **раскати́ть**; **2.** *см.* **раскати́ть**; **3.** күп йөрү, еш йөрү; **~ на велосипе́де** велосипедта күп йөрү

раскача́ть *сов.* **1.** *что* тибрәндереп җибәрү, тирбәлдереп җибәрү, атындырып җибәрү, чайкалдырып җибәрү; **~ ма́ятник** маятникны тирбәлдереп җибәрү **2.** *кого-что* селкү, чайкау, селкеп җибәрү; **подня́ть, ~ и бро́сить** күтәреп чайкап ташлау **3.** *что* (*расшатать*) селкетеп какшату, кузгату, селкетеп бушайту **4.** *перен. кого-что* кузгату, кузгатып җибәрү; **его́ тру́дно ~, о́чень уж тяжёл на подъём** аны кузгатып җибәрүе кыен, бик инде ул авыр сөякле

раскача́||ться *сов.* **1.** тирбәлә башлау, тибрәнә башлау, чайкала башлау; **ма́ятник ~лся** маятник тибрәнә башлады **2.** (*расшататься*) кузгалу, селкенә башлау; **столб ~лся** багана селкенә баш-

лады 3. *перен.* кузгалу, селкенә башлау, активлашу

раска́чивать *несов.* 1. *см.* **раскача́ть**; 2. *чем* селкү, чайкау, тирбәлдерү; ~ **ноги́ми** аяк селкү

раска́чиваться *несов.* 1. *см.* **раскача́ться**; 2. *разг.* алпан-тилпән килү 3. *страд. от* **раска́чивать**

раска́шляться *сов.* йөткерә башлау, йөткеренергә тотыну, ютәлли башлау

раска́яние *с* үкенеч, тәүбә

раска́яться *сов.* үкенү, тәүбә итү; офтану

расквартирова́ть *сов. кого-что* квартирларга урнаштыру, квартирларга кую

расквартирова́ться *сов.* квартирларга урнашу, квартирларга керү

расквартиро́вывать *несов. см.* **расквартирова́ть**

расквартиро́вываться *несов.* 1. *см.* **расквартирова́ться**; 2. *страд. от* **расквартиро́вывать**

раскваси́ть *сов. что, прост.* сугып канату, сугып изү, сугып канга батыру; ~ **нос** борынны сугып канату

раскваши́вать *несов. см.* **раскваси́ть**

раскви́таться *сов. с кем* 1. (*расплатиться*) исәпне өзү, исәп-хисапны өзү; исәпләшү, бурычны түләп бетерү 2. (*отомстить*) үч алу, үч кайтару, исәпләшү

раскида́||ть *сов. прям., перен. кого-что* тарату, туздыру, таратып ташлау, туздырып ташлау, таратып җибәрү, туздырып җибәрү; ~**ть наво́з по́ полю** тиресне бөтен басу буйлап таратып ташлау; **жизнь** ~**ла друзе́й** тормыш дусларны төрле якка тараты

раскида́ться *сов.* 1. (*увлечься киданием*) тарата башлау, туздыра башлау 2. (*разметаться*) җәелеп яту, җәелеп утыру

раски́дистый, -ая, -ое киң ябалдашлы, җәелеп үскән; ~ **дуб** җәелеп үскән имән

раскидно́й, -а́я, -о́е җәелмә ..., җәелмәле; ~ **стол** җәелмәле өстәл

раски́дывать *несов.* 1. *см.* **раскида́ть**; 2. *см.* **раски́нуть**

раски́дыва||ться *несов.* 1. *см.* **раскида́ться**; 2. *см.* **раски́нуться 1, 3**; җәелү; **стол** ~**ется** өстәл җәелә 3. *страд. от* **раски́дывать**

раски́нуть *сов. что* 1. (*ру́ки, но́ги*) җәю, җәеп кую (җибәрү); аеру, аерып кую (җибәрү) 2. (*разложить*) җәю, җәеп салу, түшәү; ~ **ковёр** келәмне җәю 3. (*поставить*) кору, корып җибәрү; ~ **пала́тку** палатка кору 4. җәеп җибәрү, җәелдерү; **ши́ре** ~ **сеть торго́вли** сәүдә челтәрен киңрәк җәелдерү ◆ ~ **умо́м (мозга́ми)** баш йөртеп карау, акыл бизмәненә салып карау

раски́ну||ться *сов.* 1. (*лечь*) җәелеп яту, сузылып яту 2. җәелү, җәелеп китү, сузылу, сузылып китү; урнашу; **на берегу́** ~**лся го́род** яр буйлап шәһәр сузылган

раскиса́ть *несов. см.* **раски́снуть**

раски́с||нуть *сов.* 1. әчү, әчеп кабару, әчеп чыгу; күпчү; **те́сто** ~**ло** камыр әчеп кабарды 2. (*разбухнуть*) җебү, җебеү; бүртү, бүртенү; **сапоги́** ~**ли** итекләр җебегән 3. (*о дороге*) изелү, баткакка әйләнү 4. *перен.* мәлҗерәү, мәлҗерәп төшү, мәлҗү, әлсерәү; җебеп төшү; **совсе́м** ~**нуть от жары́** эсседән тәмам әлсерәде

раскла́дка *ж* 1. *см.* **разложи́ть**; 2. (*развёрстка*) бүлү, бүлешү, өләшү

раскладн||о́й, -а́я, -о́е җәелмәле, ачылмалы, җәелә торган, ачыла торган; ~ **о́е кре́сло** җәелмәле кресло

раскладу́шка *ж разг.* раскладушка, җәелмәле кровать

раскла́дывать *несов. см.* **разложи́ть**

раскла́дываться *несов.* 1. *см.* **разложи́ться** 1; *страд. от* **раскла́дывать**

раскла́ниваться *несов. см.* **раскла́няться**

раскла́няться *сов. с кем* (*при встрече*) баш иеп исәнләшү, баш иеп сәлам бирү; (*при прощании*) баш иеп хушлашу, баш иеп саубуллашу

раскле́вать *сов. что* 1. (*пробить клювом*) чукып тишү, чукып тишеп бетерү 2. (*склевать всё*) чукып ашап бетерү; чукып бетерү

раскле́вывать *несов. см.* **раскле́вать**

раскле́ивать *несов. см.* **раскле́ить**

раскле́иваться *несов.* 1. *см.* **раскле́иться**; 2. *страд. от* **раскле́ивать**

раскле́ить *сов. что* 1. (*разъединить склеенное*) куптару, куптарып алу, аерып алу; ачу (*ябыштырганны яки ябышканны*); ~ **конве́рт** конвертны ачу 2. ябыштырып чыгу, ябыштырып бетерү; ~ **объявле́ния** белдерүләр ябыштырып чыгу

раскле́и||ться *сов.* 1. кубып чыгу, кубып төшү, кубып таралу, аерылу (*ябыштырган яки ябышкан әйберләр турында*) **стул** ~**лся** урындык кубып чыкты 2. *перен.* бозылу, сүтелү, җимерелү, барып чыкмау, рәте китү; **де́ло** ~**лось** эшнең рәте китте 3. *перен.* (*разболеться*) хәлсезләнү, хәлсезләнеп китү, чирләп китү

раскле́йка *ж см.* **раскле́ить**

раскле́йщик *м* ябыштыручы (*афишалар, белдерүләр ябыштырып йөрүче*)

раскле́йщица *ж* ябыштыручы хатын (кыз)

расклепа́ть *сов. что* 1. (*разъединить на части*) заклёпкаларын чыгарып кисәкләргә аеру, сүтү; ~ **котёл** казанны заклепкаларын чыгарып сүтү 2. (*расплющить*) сугып яньчү

расклепа́ться *сов.* клёпкалары кубып сүтелү, клёпкалары чыгып таралу (*клёпкаланган әйберләр турында*)

расклёпывать *несов. см.* **расклепа́ть**

расклёпываться *несов.* 1. *см.* **расклепа́ться**; 2. *страд. от* **расклёпывать**

расклёшить *сов. что* (*түбән ягын*) киңрәк итеп кису, киңрәк итеп тегү (*күлмәкне, юбканы*)

раскли́нивать *несов. см.* **раскли́нить**

раскли́ниваться *несов.* 1. *см.* **раскли́ниться**; 2. *страд. от* **раскли́нивать**

раскли́нить *сов. что* 1. (*выбить из чего-л. клин*) чөен чыгару, чөен бәреп чыгару 2. (*вбив клин, раздвинуть*) чөй кагып киңәйтү, чөй кагып аеру, чөй кагып яру

раскли́ниться *сов.* киңәю, аерылу, ярылу (*чөй кагудан*)

раскова́ть *сов.* 1. *кого-что* (*лошадь*) дагасын алу, дагасын салдыру 2. *кого-что* (*освободить от оков*) богавын алу, богавын салдыру 3. *что, тех.* (*сплющить*) чүкеп җәю, чүкеп юкарту, чүкеп яньчү

раскова́ться *сов.* (*потерять подкову — о лошади*) дагасы төшү, дагасы төшеп калу

раско́вывать *несов. см.* **раскова́ть**

раско́вываться *несов.* 1. *см.* **раскова́ться**; 2. *страд. от* **раско́вывать**

расковы́ривать *несов. см.* **расковыря́ть**

расковыря́ть *сов. что* 1. чокып тишеп чыгару, чокып тишү, чокып зурайту (киңәйтү); ~ **дыру́** тишекне чокып киңәйтү 2. чокып алу (чыгару), тырнап алу; ~ **пры́щик** бетчәне чокып чыгару

раско́л *м* 1. *см.* **расколо́ть, расколо́ться**; ~ **мра́мора** мәрмәрнең ватылуы 2. *рел.* раскол (*Россиядә 17нче гасырда барлыкка килгән һәм рәсми чиркәүгә каршы чыккан берничә мәзһәп барлыкка китергән дини-иҗтимагый хәрәкәт*)

раскола́чивать *несов. см.* **расколоти́ть**

расколоти́ть *сов. что* 1. *разг.* (*сколоченное*) суккалап ачу (вату), суккалап кисәкләргә аеру 2. *разг.* бәреп вату, челпәрәмә китерү; ~ **стака́н** стаканны бәреп вату

расколо́ть *сов. что* 1. яру, ярып ташлау, ваклау; вату, ватып ташлау; ~ **дрова́** утын ярып ташлау 2. *перен.* (*нарушить единство*) аеру, таркату, бүлү

расколо́||ться *сов.* 1. ярылу, ярылып бетү, ярылып китү, ватылу; **поле́но** ~**лось** түмәр ярылды 2. *перен.* [икегә] аерылу, таркалу, бүленү

раско́льник *м* 1. раскольник, расколчы (*аерым бер дини мәзһәптә торучы*) 2. *перен.* расколчы, таркатучы

раско́льница *ж* расколчы хатын (кыз)

раско́п *м археол. см.* **раско́пка** 3

раскопа́||ть *сов.* 1. *что* казу, көрәү, казып ташлау, көрәп ташлау; ~**ть я́му** чокыр казу 2. *что* казып табу; казып чыгару; казып алу; ~ **ть родни́к** чишмә казып чыгару 3. *перен. кого-что, разг.* табу, табып алу; **где** ~**ли тако́го спортсме́на?** мондый спортчыны каян таптыгыз?

раско́пк||а *ж* 1. *см.* **раскопа́ть**; 2. *мн.* ~**и** казу эше, казу эшләре, казу; **заня́ться** ~**ами** казу эшләре белән шөгыльләнү 3. *мн.* ~**и** казылма[лар]; **археологи́ческие** ~**и** археологик казылмалар

раскорми́ть *сов. кого-что* ашатып симертү, ашатып көрәйтү; ~ **ло́шадь** атны ашатып көрәйтү

раскорчева́ть *сов. что* төп чыгару, төпләү; ~ **куста́рники** куакларны төпләү

раскорчёвывать *несов. см.* **раскорчева́ть**

раскоря́ка *м, ж прост.* кәкре аяк, чалыш аяк; камыт аяк

раскоря́чивать *несов. см.* **раскоря́чить**

раскоря́чить *сов. что, прост.* җәю, чалышайту, җәеп кую, чалышайтып кую; ~ **но́ги** аякларны җәеп кую

раскоря́читься *сов. прост.* аякларны чалышайту, аякларны еру (ерып кую)

раско́с *м* (*распорка*) терәү, терәк, кыек терәк

раско́с||ый, -ая, -ое **1.** кысык, кысык күзле; ~**ые глаза́** кысык күзләр **2.** кылый күзле; ~**ый ма́льчик** кылый күзле малай

раскоше́ливаться *несов. см.* **раскоше́литься**

раскоше́литься *сов.* юмартланып китү, янчык чишү; акча тоту; ~ **на подаро́к** бүләккә акча тоту

раскра́дывать *несов. см.* **раскра́сть**

раскра́ивать *несов. см.* **раскрои́ть**

раскра́||сить *сов. кого-что* буяу, буяп бетерү, буяп чыгу (*төрле буяулар белән*)

раскра́ска *м* **1.** *см.* **раскра́сить; 2.** буялыш, буялу; бизәлеш; **краси́вая ~ стены́** стенаның матур буялуы

раскрасне́ться *сов.* кызару, кызарып китү, кызыллык йөгерү (*биткә*)

раскра́сть *сов. кого-что, разг.* урлап бетерү, чәлдерп бетерү

раскра́шенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **раскра́сить; 2.** буялган, төрле буяулар белән буялган; ~**ая карти́нка** төрле буяулар белән буялган рәсем

раскра́шивание *с см.***раскра́сить**

раскра́шивать *несов. см.* **раскра́сить**

раскрепи́ть *сов. что, спец.* **1.** ныгыту, терәтеп ныгыту, ныгытып кую; ~ **ша́хты бето́нными ба́лками** шахталарны бетон өрлекләр белән ныгыту **2.** аеру, аерып алу; ~ **ба́лки** өрлекләрне аерып алу

раскрепи́||ться *сов. спец.* бушаю, бушаеп китү, аерылу, аерылып китү, таралу, таралып китү; **балка ~лась** өрлек бушайган

раскрепля́ть *несов. см.* **расрепи́ть**

раскрепля́ться *несов.* **1.** *см.* **раскрепи́ться; 2.** *страд. от* **раскрепля́ть**

раскрепости́||ть *сов. кого-что* **1.** *ист.* крепостнойлыктан азат итү; ~**ть крестья́н** крестьяннарны крепостнойлыктан азат итү **2.** *перен.* азат итү, изелүдән коткару; ~ **же́нщину** хатын-кызны изелүдән коткару

раскрепоща́ть *несов. см.* **раскрепости́ть**

раскритикова́ть *сов. кого-что* каты тәнкыйть итү, каты тәнкыйтләү; ~ **поэ́му** поэманы каты тәнкыйтләү

раскрича́||ться *сов.* **1.** каты кычкыра башлау; **ребёнок ~лся** бала каты кычкыра башлады **2.** *на кого* җикерү, кычкыру; җикеренү, кычкырыну

раскрои́ть *сов. что* **1.** кисү; ~ **ткань на руба́шку** тукымадан күлмәк кисү **2.** *разг.* яру, ярып чыгару; кисеп чыгару; ~ **че́реп** баш сөяген ярып чыгару

раскромса́ть *сов. что* кискәләп бетерү, тураклап бетерү

раскроши́ть *сов.что* ваклау, валчыклау, ваклап бетерү; ~ **хлеб** ипине ваклау

раскроши́ться *сов.* ваклану, валчыкланы, вакланып бетү

раскрути́ть *сов. что* **1.** сүтү, сүтеп бетерү; ~ **верёвку** арканны сүтү **2.** кызу итеп эйләндереп җибәрү, кызу итеп әйләндерә башлау; ~ **колесо́** тәгәрмәчне кызу итеп әйләндерә башлау

раскрути́||ться *сов.* **1.** сүтелү, сүтелеп китү (чыгу, бетү); **верёвка ~лась** аркан сүтелде **2.** кызу әйләнә башлау, кызу әйләнеп китү; **колесо́ ~лось** көпчәк кызу әйләнә башлады

раскру́чивать *несов. см.* **раскрути́ть**

раскру́чиваться *несов.* **1.** *см.* **раскрути́ться; 2.** *страд. от* **раскру́чивать**

раскрыва́ть *несов. см.* **раскры́ть**

раскрыва́ться *несов.* **1.** *см.* **раскры́ться; 2.** *страд. от* **раскрыва́ть**

раскры́ть *сов.* **1.** *что* ачу, ачып кую, ачып җибәрү; ~ **глаза́** *прям., перен.* күзләрне ачу; ~ **дверь** ишекне ачып кую; ~ **конве́рт** конвертны ачу; ~ **сунду́к** сандыкны ачып кую **2.** *что* җәю, җәеп җибәрү; ачу; ~ **зонт** зонтны ачу **3.** *кого-что* ачу, ачып салу; фаш итү; ~ **та́йну** серне ачып салу; ~ **за́говор** заговорны фаш итү

раскры́||ться *сов.* **1.** ачылу, ачылып китү; **окно́ ~лось** тәрәзә ачылып китте; **для него́ ~лся но́вый мир** аның өчен яңа дөнья ачылды **2.** ачылу, фаш булу; **та́йна ~лась** сер фаш булды; **его́ хара́ктер ~лся до конца́** аның характеры тулысынча ачылды **3.** эч серен ачып салу; **~ться до конца́** бөтен эч серен ачып салу **4.** *карт.* йбып бетерү (*кәрт уенында*)

раскудахта||ться *сов.* **1.** кытаклый башлау, кытаклап җибәрү; **ку́ры ~лись** тавыклар кытаклый башлады **2.** *перен. прост.* (*разворчаться*) сукрана башлау

раскула́чивать *несов. см.* **раскула́чить**

раскула́чить *сов. кого-что* раскулачить итү

раскупа́ть *несов. см.* **раскупи́ть**

раскупи́ть *сов. что* сатып алып бетерү, алып бетерү; ~ **кни́ги** катапларны сатып алып бетерү

раску́поривать *несов. см.* **раску́порить**

раску́пориваться *несов.* **1.** *см.* **раску́пориться; 2.** *страд. от* **раску́порить**

раску́порить *сов. что* ачу, бөкесен чыгару, бөкесен алу; ~ **буты́лку** шешәне ачу

раску́пориться *сов.* ачылу, бөкесе чыгу

раску́ривать *несов. см.* **раскури́ть**

раску́риваться *несов.* **1.** *см.* **раскури́ться; 2.** *страд. от* **раску́ривать**

раскури́ть *сов. что* **1.** кабызу, кабызып җибәрү, кабызып алу; ~ **папиро́су** папиросны кабызып алу **2.** *разг.* тартып бетерү; ~ **весь таба́к** бөтен тәмәкене тартып бетерү

раскури́||ться *сов.* кабыну, кабынып китү; **тру́бка ~лась** трубка кабынды

раскуси́ть *сов. кого-что* **1.** тешләп алу, тешләп аеру, тешләп аерып чыгару; ~ **ко́рку** ипи катысын тешләп алу **2.** *перен. разг.* (*распознать*) төшенеп алу, сизеп (белеп, аңлап) алу

раску́сывать *несов. см.* **раскуси́ть**

раску́тать *сов. кого-что* чишү, чишеп җибәрү; киемен салдыру; сүтү, сүтеп җибәрү; ~ **шаль** шәлне чишү; ~ **ребёнка** баланың киемен салдыру

раску́таться *сов.* чишенү, өстендәген салу

раску́тывать *несов. см.* **раску́тать**

раску́тываться *несов.* **1.** *см.* **раску́таться; 2.** *страд. от* **раску́тывать**

ра́сов||ый, -ая, -ое **1.** раса ...ы; ~**ые при́знаки** раса билгеләре **2.** расачылык ...ы; ~**ая тео́рия** расачылык теориясе

распа́д *м см.* **распа́сться; радиоакти́вный ~** радиоактив таркалыш

распада́ться *несов. см.* **распа́сться**

распакова́ть *сов. что* чишү, сүтү, чишеп (сүтеп) алу (*төрелгән әйберләрне*); ~ **ве́щи** әйберләрне чишеп алу

распакова́||ться *сов.* **1.** үз әйберләрен чишү (чишеп алу), үз әйберләрен сүтү (сүтеп алу); **прие́хав, мы сра́зу ~лись** килеп житкәч, без шунда ук әйберләрне чишеп алдык **2.** ачылу, сүтелү; **паке́т ~лся** пакет сүтелде

распако́вывать *несов. см.* **распакова́ть**

распако́вываться *несов.* **1.** *см.* **распакова́ться; 2.** *страд. от* **распако́вывать**

распали́||ть *сов.* **1.** *что, прост.* кыздыру, бик нык кыздыру; **со́лнце ~ло ка́мни** кояш ташларны кыздырган **2.** *перен. кого-что* дөрләтеп җибәрү, кыздырып җибәрү; ярсытып җибәрү; ~**ть воображе́ние** хыялны дөрләтеп җибәрү

распали́||ться *сов.* **1.** *прост.* кызу, бик нык кызу; **песо́к ~лся на со́лнце** ком кояшта кызган **2.** *перен.* кабынып китү, кызып китү, ярсып китү, дөрләп китү; ~**ться от гне́ва** ачудан ярсып китү

распаля́ть *несов. см.* **распали́ть**

распаля́ться *несов.* **1.** *см.* **распали́ться; 2.** *страд. от* **распаля́ть**

распа́ривать *несов. см.* **распа́рить**

распа́риваться *несов.* **1.** *см.* **распа́риться; 2.** *страд. от* **распа́ривать**

распа́рить *сов.* **1.** *что* пешекләү; ~ **ве́ник** миннекне пешекләү **2.** *что, разг.* парда (буда) йомшарту; ~ **ста́рые ко́сти** карт сөякләрне парда йомшарту **3.** *кого, разг.* (*разогреть до пота*) тирләтү, тирләтеп җибәрү; эсселәндерү, эсселәтеп җибәрү

распа́ри||ться *сов.* **1.** пешекләну, йомшару (*парда, кайнар суда*); **горо́х ~лся** борчак йомшарды **2.** *разг.* тирләү, тирләп китү; эсселәну; ~**ться в ба́не** мунчада тирләү

распа́рывать *несов. см.* **распоро́ть**

распа́рываться *несов.* **1.** *см.* **распоро́ться; 2.** *страд. от* **распа́рывать**

распа́||сться *сов.* **1.** (*развалиться*) таркалу, ватылу **2.** таркалу, бүленешү, аерылу (*состав кисәкләргә*); **моле́кулы ~лись на а́томы** молекулалар атомнарга таркалды **3.** *перен.* өзелү, бозылу; **дру́жба ~лась** дуслык өзелде

распаха́ть *сов. что* сөрү, сөреп чыгу, сукалап чыгу; ~ **целину́** чирәм җирне сөреп чыгу

распа́хивать I *несов. см.* **распаха́ть**

распа́хивать II *несов. см.* **распахну́ть**

распа́хиваться *несов.* **1.** *см.* **распахну́ться; 2.** *страд. от* **распа́хивать** II

распахну́ть *сов. что* ачып җибәрү, ачып кую, ачу; җилбәгәй җибәрү; ~ **воро́та** капканы ачып кую; ~ **пальто́** пальтоны җилбәгәй җибәрү

распахну́||ться *сов.* 1. ачылып китү, ачылу; **дверь ~лась** ишек ачылып китте 2. (*распахнуть на себе одежду*) җилбәгәй җибәрү, ачып җибәрү

распашн||о́й I, -а́я, -о́е *диал.* сөрүле, сөрелә торган; ~**а́я земля́** сөрүле җир

распашн||о́й II, -а́я, -о́е 1. *уст.* җилбәгәй, төймәсез; ~**а́я блу́за** төймәсез блуза; ~**а́я шу́ба** җилбәгәй тун 2. *спец.* ике якка ачыла торган, ике якка ачылмалы; ~**ые воро́та** ике якка ачыла торган капка ♦ ~**о́е весло́** ике калаклы ишкәк

распашо́нка *ж* бәби күлмәге

распая́ть *сов. что* эретеп куптару, эретү

распая́ться *сов.* эреп кубу, эреп кубып чыгу, эрү

распева́||ть *несов. что и без доп.* җырлау; сайрау; **соловьи́ ~ет** сандугач сайрый; ~**ть весёлые пе́сни** күңелле җырлар җырлау

распека́ть *несов. см.* **распе́чь**

распелена́ть *сов. кого-что* биләвен чишү, биләүсәсен чишеп алу; ~ **ребёнка** баланың биләүсәсен чишеп алу

распере́ть *сов. обычно безл. что, разг.* (*киңәюдән*) ватылу, (*киңәйтеп*) вату; **льдом распёрло бо́чку** боз мичкәне ватканы

распетуши́ться *сов. разг.* әтәчләнеп китү, әтәчләнә башлау

распе́ть *сов. что* 1. *муз.* җырлап өйрәнү, өйрәнү өчен җырлау; ~ **хо́ром пе́сню** хор белән җырны өйрәнү өчен җырлау 2. *разг.* җырлап ачу, җырлап ачып җибәрү; ~ **го́лос** тавышны җырлап ачу

распе́ться *сов.* 1. (*увлечься пением*) җырга бирелеп китү, дәртләнеп җырлый башлау; (*о птицах*) мавыгып сайрау 2. (*начать петь хорошо*) яхшы җырлый башлау, җырлый-җырлый тавыш яхшыру; яхшы сайрый башлау

распеча́тать *сов. что* 1. печатен алып ачу, печатен ватып ачу; ~ **кварти́ру** квартирның печатен ватып ачу 2. (*ябыштырылган берәр нәрсәне*) ачу; ~ **конве́рт** конвертны ачу

распеча́таться *сов.* ачылу (*ябыштырылган, печатьләнгән әйберләр турында*)

распеча́тывать *несов. см.* **распеча́тать**

распеча́тываться *несов.* 1. *см.* **распеча́таться**; 2. *страд. от* **распеча́тывать**

распе́чь *сов. кого-что, разг.* (*отругать*) пешерү, орышу, тиргәү

распива́ть *несов.* 1. *см.* **распи́ть**; 2. *что* (*пить долго*) озаклап эчү, озаклап эчеп утыру

распи́л *м* 1. *см.* **распили́ть**; 2. кисү ысулы, яру рәвеше; кисү, яру; **попере́чный ~** аркылыга кисү; **продо́льный ~** буйга яру 3. (*место*) кисем, киселгән урын

распи́ливать *несов. см.* **распили́ть**

распили́ть *сов. что* (*пычкы белән*) кисү, киселеп чыгару; пычу; такта яру

распи́лка *ж см.* **распили́ть**

распило́вщик *м* такта яручы

распина́ть *несов. см.* **распя́ть**

распина́ться *сов. разг.* (*берәр кеше яки нәрсә өчен*) көчәнү, тырышу, мәшәкатьләнү

распира́||ть *несов.* 1. *см.* **распере́ть**; 2. *что* (*о чувстве и т.п.*) (*кукрәктән*) ташу, ташып чыгу, күңел тулу; чәнчү; **его́ ~ет от ра́дости** *безл.* шатлыктан аның күңеле тула

расписа́ние *с* расписа́ние; ~ **поездо́в** поездлар расписаниесе; ~ **уро́ков** дәресләр расписаниесе

расписа́ть *сов.* 1. *кого-что* (*записать в разные места*) язып чыгу, язып кую 2. *что* бүлеп язып кую (*мәс. вакытны*) 3. *что* рәсем белән бизәү, бизәк төшерү, рәсем ясау, бизәкләү; ~ **потоло́к** түшәмне бизәкләү 4. *перен. что, о чём* (*красочно рассказать*) бизәп сөйләү, арттырып сөйләү

расписа́ться *сов.* 1. кул кую, имза кую; ~ **в ве́домости** исемлеккә кул кую 2. *с кем и без доп.* язылышу (*өйләнуне рәсми рәвештә теркәү*) 3. *разг.* (*увлечься писанием*) язу белән мавыгып китү, язаяза мавыгып китү

расписк||а *ж* 1. *см.* **расписа́ть, расписа́ться** 1; ~**а стен фре́сками** стеналарны рәсем белән бизәү 2. расписка, алу кәгазе; **дать ~у** расписка бирү

расписно́й, -а́я, -о́е бизәк төшерелгән, бизәкле, бизәкле-бизәкле, бизәлгән; ~ **потоло́к** бизәк төшерелгән түшәм

распи́сывать *несов. см.* **расписа́ть**

распи́сываться *несов.* 1. *см.* **расписа́ться**; 2. *страд. от* **распи́сывать**

распи́ть *сов. что, разг.* (*бергәләп*) эчеп бетерү, бергәләп эчү; ~ **буты́лку вина́** бер шешә шәраб эчеп бетерү

распиха́ть *сов. разг.* 1. (*растолкать*) *кого-что* этеп-төртеп юл яру, юл ачу (*этеп-төртеп юл бирергә мәҗбүр итү*) 2. *что* тыгып бетерү, тыгып чыгу; ~ **ме́лкие ве́щи по карма́нам** кечкенә әйберләрне кесәләргә тыгып бетерү

распи́хивать *несов. см.* **распиха́ть**

распла́вить *сов. что* эретү, эретеп алу; ~ **свине́ц** аккургашны эретү

распла́виться *сов.* эрү, эреп чыгу

распла́каться *сов.* елап җибәрү, бик ныклы елый башлау

распланир||ова́ть *сов. что* 1. планлаштыру, планлаштырып чыгу; ~**овать своё вре́мя** үз вакытыңны планлаштыру 2. план буенча билгеләү, бүлеп чыгу, бүлү, план буенча урнаштыру; **пра́вильно ~ованные у́лицы** план буенча дөрес бүленгән урамнар

распланирова́ть *сов. см.* **распланир||ова́ть** 2

распласта́ть *сов.* 1. *что* (*разнять на пласты*) телү, яру, телгәләп бетерү, телемнәргә тураклау; ~ **ры́бу** балыкны телү 2. *кого-что* җиргә салу (җәеп салу) 3. *что* җәю, ачу; ~ **кры́лья** канатларны җәю

распласта́ться *сов.* җәелеп (сузылып) яту, җиргә яту

распла́стывать *несов. см.* **распласта́ть**

распла́стываться *несов.* 1. *см.* **распласта́ться**; 2. *страд. от* **распла́стывать**

распла́т||а *ж* 1. *см.* **расплати́ться** 1; 2. *перен.* җәза; үч алу; **придёт день ~ы** үч алу көне бер килер әле

расплати́ться *сов.* 1. *с кем-чем и без доп.* түләү, түләп бетерү, исәп-хисапны өзү; ~ **за обе́д** төшке аш өчен түләү; ~ **с долга́ми** бурычларны түләп бетерү 2. *перен. с кем и без доп., разг.* үч алу, үч кайтару; ~ **за ста́рую оби́ду** элек рәнҗеткән өчен үч алу 3. *перен. разг.* (*понести наказание*) җәза алу, җәзага дучар булу; җавап бирү; ~ **за ша́лость** шаянлык өчен җәза алу; ~ **за преступле́ния** жинаять өчен җәза алу

распла́чиваться *несов. см.* **расплати́ться**

расплеска́ть *сов. что* чайпалдыру, чайкалдырып түгү (түгеп бетерү), чайкалдырып чәчрәтү

расплеска́ться *сов.* чайкалу, чайкалып түгелү, чайкалып түгелеп китү, чайкалып чәчрәү

расплёскивать *несов. см.* **расплеска́ть**

расплёскиваться *несов.* 1. *см.* **расплеска́ться**; 2. *страд. от* **расплёскивать**

расплести́ *сов. что* сүтү, сүтеп ташлау; ~ **верёвку** арканны сүтү

распле||сти́сь *сов.* сүтелү, сүтелеп китү; **ко́сы ~лись** толымнар сүтелеп китте

расплета́ть *несов. см.* **расплести́**

расплета́ться *несов.* 1. *см.* **расплести́сь**; 2. *страд. от* **расплета́ть**

расплоди́ть *сов. кого-что* 1. үрчетү, үстерү; ~ **порося́т** дуңгыз балаларын үрчетү 2. *перен. разг.* үрчетү, тудыру

расплоди́||ться *сов.* үрчү, ишәю, үрчеп китү, ишәеп китү; **кро́лики ~лись** йорт куяннары үрчеп киттеләр

расплыва́ться *несов. см.* **расплы́ться**

расплы́вчатый, -ая, -ое 1. (*неясный*) ачык булмаган, томанлы, тоныкъ; ~ **рису́нок** тоныкъ рәсем 2. *перен.* ачык булмаган, аныкъ булмаган; ~ **отве́т** аныкъ булмаган җавап

расплы́||ться *сов.* 1. җәелеп китү, җәелү; **черни́ла ~лись** кара җәелеп китте 2. таралып китү, таралу; **таба́чный дым ~лся** тәмәке төтене таралды 3. йөзеп таралышу, йөзеп таралышып китү; **гу́си ~лись по о́зеру** казлар күл буйлап йөзеп таралыштылар 4. *перен.* ачыклыгын югалту, томанлы булып күренү, томанлану; **фигу́ры люде́й ~лись в темноте́** кешеләрнең фигуралары караңгыда ачыклыгын югалттылар 5. *перен.* (*располнеть*) җәелү, юанаю, җәелеп (юанаеп) китү, калынаю

расплю́щивать *несов. см.* **расплю́щить**

расплю́щиваться *несов.* 1. *см.* **расплю́щиться**; 2. *страд. от* **расплю́щивать**

расплю́щить *сов. что* чүкеп җәю, чүкеп яньчү, сугып ямьшәйтү; ~ **шля́пку гвоздя́** кадак башын чүкеп җәю

расплю́щи||ться *сов.* яньчелү, ямьшәю; җәелү (*чүкүдән, сугудан*); **гвоздь ~лся** кадак яньчелде

распого́ди||ться *сов. безл. разг.* аязу, көн ачылу; **к ве́черу ~лось** кичкә таба аязды

распознава́ть *несов. см.* **распозна́ть**

распозна́ть *сов. кого-что* белеп алу, аеру, белү, сизеп алу, аңлап алу; **~ ви́ды у́ток** үрдәкләрнең төрен аеру; **~ боле́знь** авыруны белү

располага́ть I *несов. см.* **расположи́ть**

располага́||ть II *несов. книжн.* **1.** *кем-чем* булу; ия булу; **~ть свобо́дным вре́менем** буш вакыт булу; **~ть деньга́ми** акча булу **2.** *к чему* ярдәм итү, булышу; **све́жий во́здух ~ет ко сну́** саф һава йокыга китәргә ярдәм итә

располага́ться *несов.* **1.** *см.* **расположи́ться; 2.** *страд. от* **располага́ть** I

располага́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **располага́ть** I; **2.** җәлеп итә торган, үзенә тарта торган; **~ая вне́шность** үзенә тарта торган кыяфәт

расползáться *несов. см.* **расползти́сь**

располз||ти́сь *сов.* **1.** үрмәләп таралу, төрле якка үрмәләп китү; **ра́ки ~ли́сь** кыслалар үрмәләп тарадылар **2.** *перен. разг.* җәелү, җәелеп китү; **черни́ла ~ли́сь** карасы җәелгән (*мәс. кәгазьдә*) **3.** *разг.* бозылу, бозылып бетү, изрәп бетү; **колеи́ на доро́ге ~ли́сь от дождя́** юлдагы арба эзләре яңгырдан изрәп беткәннәр **4.** *разг.* тузу, ертылу, сыпылу; **башмаки́ ~ли́сь** башмак тузган **5.** *перен. разг.* (*располнеть*) калынаю, юанаю, җәелү

располне́ть *сов.* юанаеп китү, калынаеп китү, тулыланып китү

расположе́ни||е *с* **1.** *см.* **расположи́ть; ~е дета́лей** детальләрне урнаштыру **2.** урнашу; **ме́сто ~я ро́ты** рота урнашкан жир **3.** (*порядок размещения*) урнашу тәртибе, урнаштырылу **4.** (*хорошее отношение к кому-либо*; *симпатия*) күңел яту, күңелгә ошау **5.** теләк; **нет ~я игра́ть** уйнарга теләк юк **6.** бирешүчәнлек; **~е к просту́де** томауга бирешүчәнлек

расположе́нный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **расположи́ть; 2.** теләктәш булган, күңеле белән теләктәш; күңеленә ошаган, күңеле яткан; **он всей душо́й располо́жен ко мне** ул бөтен күңеле белән миңа теләктәш **3.** теләгә булган; **ребёнок не располо́жен игра́ть** малайның уйнарга теләге юк

расположи́ть *сов.* **1.** *что* урнаштыру, урнаштырып кую; җайлап урнаштыру; **~ ме́бель** мебельне урнаштыру **2.** *кого-что* үзенә карату, күңелен җәлеп итү; **~ к себе́ сосе́дей** күршеләрнең күңелен үзенә җәлеп итү

расположи́||ться *сов.* урнашу, урнашып алу; килеп урнашу; **пу́тники ~лись у ручья́** юлчылар инеш янына килеп урнаштылар

располосова́ть *сов. разг.* **1.** *что* аерым буйларга кисү (телү); **~ ткань** тукыма кисәген аерым буйларга кисү **2.** *что* (*поранить*) кан чыкканчы яру, кисү; **~ спи́ну** кан чыкканчы яру

распо́р *м тех.* басу көче (*корылмаларда*: *вертикаль юнәлештәге көчләрнең тәэсире нәтиҗәсендә басымның горизонталь юнәлештә җәелүе*)

распо́рка *ж* терәк, терәү; ныгыткыч

распоро́ть *сов. что* **1.** сүтү, сүтеп җибәрү; **~ поду́шку** мендәрне сүтү **2.** ерту, ертып җибәрү; **~ шку́ру** тирене ерту **3.** (*сильно поранить чем-л. острым*) кадау, кисү

распоро́||ться *сов.* сүтелү, сүтелеп китү; **рука́в ~лся** җиң сүтелгән

распоряди́тель *м* башлык, җитәкче, җаваплы оештыручы

распоряди́тельный, -ая, -ое эш йөртә белүчән, оештыра белүче...; җитәкчелек итә белүче...; **~ командир** оештыра белүче командир

распоряди́ться *сов.* **1.** (*приказать*) боеру, кушу, әмер бирү, боерык бирү; **~ об отъе́зде** китү турында боерык бирү **2.** *чем* (*устроить, организовать*) оештыру, шөгыльләнү, эш йөртү; идарә итү **3.** *чем* тоту, файдалану; эш итү, бүлү; **~ деньга́ми** акчадан файдалану; **~ иму́ществом** мөлкәт белән эш итү

распоря́д||ок *м* тәртип; **пра́вила вну́треннего ~ка** эчке тәртип кагыйдәләре

распоряжа́ться *несов.* **1.** *см.* **распоряди́ться; 2.** *чем и без доп.* (*управлять*) идарә итү, баш булып тору; эш алып бару

распоряже́ние *с* **1.** *см.* **распоряди́ться; 2.** күрсәтмә, әмер, боерык; **отда́ть ~** боерык бирү ♦ **в ~** *кого-чего* карамагына, карамагында

распоя́сать *сов. кого-что* билбавын чишү, путасын чишү, билбавын чишеп алу

распоя́саться *сов.* **1.** үз билбавын чишү, үз билбавын чишеп ташлау, үз путасын чишү **2.** *перен. разг.* йөгәнсезләнү, йөгәнсезләнеп китү; азып китү

распоя́сывать *несов. см.* **распоя́сать**

распоя́сываться *несов.* **1.** *см.* **распоя́саться; 2.** *страд. от* **распоя́сывать**

распра́ва *ж* үч алу; җәбер, җәзалау; **кровава́я ~** канлы үч алу

распра́вить *сов. что* төзәйтү, турайту, тигезләү; **~ бант** бантны тигезләү; **~ морщи́ны** җыерыкларны тигезләү ♦ **~ кры́лья** канатларны җәю; **~ плечи́** кулбашларны турайту; **~ спи́ну** билне турайту (язу)

распра́ви||ться I *сов.* тураю, төзәю, тигезләнү, язылу; **морщи́ны на лбу́ ~лись** маңгайдагы җыерыклар тигезләнделәр

распра́виться II *сов.* **1.** *с кем-чем* үч алу, җәзага тарту, җәза бирү, исәпхисапны өзү; эшне бетерү, эшне өзү **2.** *перен. разг.* [эшне] бетерү (төгәлләү); **~ с арбу́зом** карбыз белән эшне бетерү

расправля́ть *несов. см.* **распра́вить**

расправля́ться I *несов.* **1.** *см.* **распра́виться I; 2.** *страд. от* **расправля́ть**

расправля́ться II *несов. см.* **распра́виться II**

распредели́тель *м* **1.** бүлүче, бүлеп бирүче, өләшүче, таратучы **2.** *тех.* бүлгеч (*машиналарда һәм двигательләрдә газ, пар һ.б.ш. бүлүче прибор*)

распредели́тельный, -ая, -ое бүлү ...ы, бүлгеч..., бүлә торган; **~ пункт** бүлү пункты

распредели́ть *сов. кого-что* **1.** бүлү, бүлеп кую; бүлеп бирү, тарату; **~ дете́й по кла́ссам** балаларны сыйныфларга бүлү; **~ дохо́ды** табышны бүлү **2.** (*направить на работу*) билгеләү, җибәрү (*мәс. укып бетергәннән соң*)

распредели́||ться *сов.* **1.** бүленү, бүленешү; **экскурса́нты ~лись по гру́ппам** экскурсантлар төркемнәргә бүленештеләр **2.** *разг.* билгеләнү, җибәрелү (*мәс. укуны тәмамлаганнан соң*)

распределя́ть *несов. см.* **распредели́ть**

распределя́ться *несов.* **1.** *см.* **распредели́ться; 2.** *страд. от* **распределя́ть**

распродава́ть *несов. см.* **распрода́ть**

распрода́ть *сов. что* сатып бетерү; **все биле́ты распро́даны** барлык билетлар сатып бетерелгәннәр

распропаганди́ровать *сов. кого-что* пропагандалап ышандыру, үгетләп күндерү

распростере́ть *сов. что* **1.** җәю, җәеп җибәрү (*ике якка*); **~ кры́лья** канатларны җәю **2.** *перен.* җәелдерү, чолгап алу; киңәйтү; **~ своё влия́ние** үз йогынтыңны җәелдерү

распростере́ться *сов.* **1.** (*упасть, раскинув руки*) сузылып барып төшү, кулларны җәеп барып төшү **2.** җәелеп китү, җәелү; **пе́ред ним распростёрлась степь** аның алдында дала җәелеп китте **3.** *перен.* (*распространиться*) таралу, җәелү

распростира́ть *несов. см.* **распростере́ть**

распростира́ться *несов.* **1.** *см.* **распростере́ться; 2.** *страд. от* **распростира́ть**

распрости́ться *сов. прям., перен. с кем-чем и без доп.* саубуллашу, саубуллашып китү; хушлашу; **~ со ста́рыми друзья́ми** элекке дуслар белән саубуллашу; **~ с мечто́й** хыял белән саубуллашу

распространённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **распространи́ть; 2.** киң таралган, еш очрый торган; **~ое мне́ние** киң таралган фикер ♦ **~ое предложе́ние** җәенке җөмлә

распространи́тель *м* таратучы, таратучы кеше; **~ печа́ти на заво́де** заводта матбугат таратучы

распространи́тельница *ж* таратучы хатын (кыз)

распространи́ть *сов. что* **1.** җәелдерү; **~ своё влия́ние** үз йогынтыңны җәелдерү **2.** (*сделать доступным, известным*) тарату; **~ газе́ту** газета тарату; **~ весть** хәбәр тарату; **~ о́пыт передовико́в** алдыңгыларның тәҗрибәсен тарату **3.** (*наполнить запахом*) тарату

распростра́н||ться *сов.* **1.** җәелү; **иде́и но́вого мышле́ния ~лись по всему́ ми́ру** яңача фикерләү идеяләре бөтен дөньяга җәелде **2.** җәелеп (сузылып) китү; **леса́ ~лись далеко́ на се́вер** урманнар төньякка таба ераккка җәелеп киткән **3.** таралу; **слу́хи ~лись** хәбәрләр таралды; **сла́ва ~лась** даны таралды **4.** аңку, таралу; **по ко́мнате ~лся за́пах цвето́в** бүлмә эчендә чәчәкләр исе таралды **5.** *разг.* бәйнәбәйнә сөйләү, җәелеп сөйләү; **~ться о**

свои́х дела́х үз эшләрең турында җәелеп сөйләү

распространя́ть *несов. см.* **распространи́ть**

распространя́ться *несов.* **1.** *см.* **распространи́ться; 2.** *страд. от* **распространя́ть**

распроща́ться *сов. см.* **распроща́ться**

распры́скать *сов. что, разг.* бөркеп бетерү, сибеп бетерү; **~ духи́** хушбуйны бөркеп бетерү

распры́скиватель *м* бөркегеч

распры́скивать *несов. см.* **распры́скать**

ра́спря *ж* ызгыш, талаш, низагъ

распряга́ть *несов. см.* **распря́чь**

распряга́ться *несов.* **1.** *см.* **распря́чься; 2.** *страд. от* **распряга́ть**

распрями́ть *сов. что* турайту, төзәйтү; язу; **~ про́волоку** тимерчыбыкны язу; **~ спи́ну** арканы турайту

распрями́||ться *сов.* тураю, төзәю; язылу; **гвоздь ~лся** кадак турайды

распрямля́ть *несов. см.* **распрями́ть**

распрямля́ться *несов.* **1.** *см.* **распрями́ться; 2.** *страд. от* **распрямля́ть**

распря́чь *сов. кого-что* туару, тугару, туарып (тугарып) кую

распря́чься *сов.* туарылу, тугарылу, тугарылып китү

распуга́ть *сов. кого-что* куркыту, куркытып тарату; **~ кур** тавыкларны куркытып тарату

распу́гивать *несов. см.* **распуга́ть**

распугну́ть *сов. однокр. кого-что* куркытып җибәрү, куркытып таратып җибәрү

распуска́ть *несов. см.* **распусти́ть**

распуска́ться *несов.* **1.** *см.* **распусти́ться; 2.** *страд. от* **распуска́ть**

распусти́ть *сов.* **1.** *кого-что* тарату, җибәрү, таратып җибәрү, кайтарып җибәрү; **~ шко́льников на кани́кулы** укучыларны каникулга җибәрү **2.** *что* ычкындыру, бушайту, җибәрә төшү, чишү; **~ реме́нь** каешны бушайту **3.** *что (раскрыть, развернуть)* ачу, җәю; **~ зо́нтик** зонтикны ачу **4.** *что* сүтү; **~ чуло́к** оекны сүтү **5.** *кого-что, разг. (ослабить дисциплину)* тәртипсезләндерү, узындыру, азындыру **6.** *что, разг.* тарату, сөйләү; **~ спле́тню** гайбәт тарату **7.** *что, разг.* эретү; **~ кра́ску в воде́** буяуны суда эретү ♦ **~ слю́ни** селәгәй агызу; **~ язы́к** телгә салыну, күп сөйләү

распусти́||ться *сов.* **1.** ачылу, чәчәк ату; яфрак яру; **ро́за ~лась** роза ачылды; **ли́пы ~лись** юкәләр яфрак ярды **2.** *разг.* ычкыну, бушаю, бушая төшү, чишелү; **по́яс ~лся** билбау бушайган **3.** сүтелү; **чуло́к ~лся** оек сүтелде **4.** *разг. (потерять выдержку, силу воли)* ихтыяр югалу, күнел йомшару **5.** *разг.* тәртипсезләнү, узыну, азыну; **ученики́ ~лись** укучылар тәртипсезләнделәр **6.** *разг. (раствориться)* эрү, изелү

распу́тать *сов.* **1.** *что* чишү, сүтү; **~ у́зел** төенне чишү **2.** *кого-что* тышавын чишеп алу, богавын ачып алу; **~ ло́шадь** атның тышавын чишеп алу **3.** *перен. что* чишү, ачыклау; очына чыгу; **~ сло́жный вопро́с** катлаулы мәсьәләнең очына чыгу

распу́та||ться *сов.* **1.** чишелү, сүтелү, чишелеп китү, сүтелеп китү; **у́зел ~лся** төен чишелеп китте **2.** тышавы чишелү (чишелеп китү), тышавын салу, тышавы төшү; **ло́шадь ~лась** атның тышавы чишелгән **3.** *перен. разг.* ачыкланы, чишелү; **де́ло ~лось** эш ачыкланды **4.** *перен. с кем-чем и без доп. разг.* котылу, ерып чыгу, бушану; **~ться с долга́ми** бурычлардан котылу

распу́тица *ж* юл өзек чак, юл өзеклеге; ни арба, ни чана вакыт; **весе́нняя ~** язгы юл өзеклеге

распу́тник *м* фахиш кеше, бозык кеше, азгын кеше

распу́тница *ж* бозык хатын, азгын хатын, фахишә

распу́тничать *сов.* азып-тузып йөрү, типтереп яшәү

распу́тный, -ая, -ое бозык, азгын, азгынлыкка бирелгән, азып-тузып йөргән; **~ челове́к** бозык кеше

распу́тств||о *с* бозыклык, азгынлык; **предава́ться ~у** азгынлыкка бирелү

распу́тывать *несов. см.* **распу́тать**

распу́тье *с* юл чаты, юл аермасы, аерма ♦ **быть на ~** ике юл чатында тору, аптыраштa калу, икеләнеп тору

распуха́ть *несов. см.* **распу́хнуть**

распу́х||нуть *сов.* **1.** шешү, шешеп чыгу, шешенү; **щека́ ~ла** яңагы шешеп чыкты **2.** *перен. разг.* кабару, кабарып чыгу, зураю

распуши́ть *сов. что* кабарту, кабартып җибәрү; **~ усы́** мыекны кабартып җибәрү

распуши́ться *сов.* **1.** (*стать пушистым*) кабару, йоны кабару **2.** (*встопорщить перья, шерсть*) каурыйларын (йонын) кабарту

распу́щенность *м* **1.** (*недисциплинированность*) тәртипсезлек, йөгәнсезлек **2.** бозыклык, азгынлык; **~ нра́вов** әхлакның бозыклыгы

распу́щенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **распусти́ть; 2.** тәртипсез, йөгәнсез; **~ый ребёнок** тәртипсез бала **3.** бозык, азгын, әхлаксыз; **~ые нра́вы** бозык әхлаклар

распыле́ние *с см.* **распыли́ть, распыли́ться: ~ удобре́ний** ашламаларны сибү

распыли́тель *м* бөркегеч (*порошокны яки сыекчаны бөркү әсбабы*)

распыли́ть *сов. что* **1.** бөркү, сиптерү; **~ удобре́ния** ашламалар сибү **2.** *перен.* таркату, таркатып бетерү, ваклау, бүлгәләү; **~ си́лы проти́вника** дошманның көчләрен таркату

распыли́||ться *сов.* **1.** (*рассеяться*) сибелү, бөркелү **2.** *перен.* ваклану, бүлгәләнеп, бетү, бүлгәләнү; таркалып бетү; **си́лы ~лись** көчләр бүлгәләнеп бетте

распыля́ть *несов. см.* **распыли́ть**

распыля́ться *несов.* **1.** *см.* **распыли́ться; 2.** *страд. от* **распыля́ть**

распы́ливать *несов. см.* **распы́лить**

распы́лить *сов. что* киерү, киереп кую; **~ шку́ру** тирене киерү

распы́тие *с церк.* распятие, тәре (*кулъяклары аркылы-торкылы агачка кадакланган Гайса сурәте төшерелгән тәре*)

распя́ть *сов. кого-что* тәрегә кадаклау, кул-аякларны тәрегә кадаклау (*борынгы җәза ысулы*)

расса́да *ж* рассада, үренте; **помидо́рная ~** помидорлар рассадасы

рассади́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*усадить*) утыртып чыгу (бетерү), утырту **2.** *кого-что* (*посадить отдельно*) аерым утырту, аерып утырту **3.** *что* сирәкләп утырту (утыртып чыгу); **~ клубни́ку** җир жиләген сирәкләп утыртып чыгу

рассса́дник *м* **1.** үрентелек, рассадник; **~ цвето́в** чәчәкләр рассаднигы **2.** *перен. чего* (*источник*) чыганак, тарату чыганагы

рассса́живать *несов. см.* **рассади́ть**

рассса́живаться *несов.* **1.** *см.* **рассе́сться** 1, 2; **2.** *страд. от* **рассса́живать**

рассса́сывать *несов. см.* **рассоса́ть**

рассса́сываться *несов.* **1.** *см.* **рассоса́ться; 2.** *страд. от* **рассса́сывать**

рассве́рливать *сов. см.* **рассверли́ть**

рассверли́ть *сов. что* бораулап киңәйтү (зурайту); **~ отве́рстие** тишемне бораулап зурайту

рассве||сти́ *сов. безл.* яктыру, таң ату; **давно́ ~ло** күптән таң атты

рассве́т *м прям., перен.* таң; **с ~ом** таң белән; **до ~а** таң атканчы; **на ~е жи́зни** гомер таңында

рассвета́ть *несов. см.* **рассвести́**

рассвирепе́ть *сов.* ярсып (котырынып, шашып) китү

рассева́ть *несов. см.* **рассе́ять**

расседла́ть *сов. кого-что* иярен салдыру, иярен алу; **~ ло́шадь** атның иярен алу

расседла́||ться *сов.* иярен салу, иярен төшерү; **ло́шадь ~лась** ат иярен салган

рассе́ивать *несов. см.* **рассе́ять**

рассе́иваться *несов.* **1.** *см.* **рассе́яться; 2.** *страд. от* **рассе́ивать**

рассека́ть *несов. см.* **рассе́чь**

рассека́ться *несов.* **1.** *см.* **рассе́чься; 2.** *страд. от* **рассека́ть**

рассекре́тить *сов.* **1.** *что* (*сделать несекретным*) секретлыгын бетерү, сер булуын бетерү, секретсыз итү **2.** *кого-что, разг.* секрет эштән бушату, секрет эштән алу; яшертен эштән алу

рассекре́чивать *несов. см.* **рассекре́тить**

рассселе́ние *с см.* **расселя́ть, расселя́ться**

рассе́лин||а *ж* ярык; тау ярыгы; җир ярыгы; **ключ бьёт из ~ы горы́** чишмә тау ярыгыннан агып чыга

расселя́ть *сов. кого-что* **1.** урнаштыру, таратып урнаштыру; таратып утырту; **~ по кварти́рам** квартирларга таратып урнаштыру **2.** (*поселить порознь*) аерып утырту (урнаштыру)

расселя́ться *сов.* **1.** урнашу, килеп урнашу; килеп утыру; **~ вдоль реки́** елга буена килеп урнашу **2.** (*поселиться порознь*) аерым (аерылып) урнашу

расселя́ть *несов. см.* **расселя́ть**

расселя́ться *несов.* **1.** *см.* **расселя́ться; 2.** *страд. от* **расселя́ть**

рассерди́ть *сов. кого-что* ачуландыру, ачуын китерү; ачуын кабарту

рассерди́ться *сов. на кого-что и без доп.* ачулану, ачу килү, ачу кабару

рассе́||ться *сов.* **1.** утырышу, утырышып (утырып) бетү; **~ться по места́м** урыннарга утырышып бетү **2.** *разг.* (*сесть непринуждённо*) җәелеп утыру; киңәеп утыру **3.** (*дать трещину*) ярылу; бүселү, бүселеп чыгу; **лёд ~лся на́двое** боз икегә ярылды

рассече́ние *с см.* **рассе́чь; ~ тру́па** *анат.* мәетне яру

рассе́чь *сов.* **1.** *кого-что* кисү, яру, кисеп (ярып) чыгару; **~ поле́но** түмәрне ярып чыгару; **~ ту́шу** түшкәне кисү **2.** *что* (*поранить*) яру, кисү; **~ губу́** иренне кисү; **~ лоб** маңгайны яру **3.** *перен. что* кисеп үтү; кискәләү, кискәләп (бүлгәләп) бетерү

рассе́чься *сов.* ярылу, кисәкләргә аерылу, сыпылу (*чәч, җеп турында*)

рассе́янность *ж* зиһенсезлек, игътибарсызлык, зиһен чуалганлык; **отлича́ться ~ю** зиһенсезлек белән аерылып тору

рассе́янн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **рассе́ять**; **2.** сибелган, сибелеп утырган; **~ое населе́ние** сибелеп утырган халык **3.** чәчелгән; сибелгән; **~ый свет** чәчелгән яктылык **4.** игътибарсыз, тарау, зиһенсез, зиһене чуалган, тиз онытучан; **~ый челове́к** тарау кеше **5.** хозур, кәеф-сафадан гыйбарәт, күңел ачудан гыйбарәт; **~ый о́браз жи́зни** күңел ачудан гыйбарәт тормыш

рассе́ять *сов.* **1.** *что* чәчү, сибү, чәчеп (сибеп) чыгу; чәчү үткәрү; **~ семена́** орлык чәчү **2.** *кого-что* (*расположить на большом пространстве*) сибү, таратып (сибеп) урнаштыру **3.** *что* тарату, сибелдерү; **~ лучи́** нурларны сибелдерү **4.** *кого-что* (*разогнать*) куып жибәрү, тарату, таратып җибәрү **5.** *что* тарату, юкка чыгару, бетерү; **~ подозре́ния** шик-шөбһәләрне тарату

рассе́я||ться *сов.* **1.** (*разместиться в разных местах*) сибелеп урнашу, сибелү, таралып урнашу **2.** таралу, юкка чыгу, бетү; **тума́н ~лся** томан таралды **3.** таралу, сибелү; **коло́нна неприя́теля ~лась** дошманның колоннасы таралды **4.** (*отвлечься*) кайгыны тарату; борчуларны бетерү; күңел ачу

рассиде́ться *сов. разг.* озаклап утыру, озак утыру; **~ в гостя́х** кунакта озак утыру

расска́з *м* **1.** *см.* **рассказа́ть; продолжа́ть ~** сөйләүне дәвам иттерү **2.** хикәя; **~ы М.Го́рького** М.Горький хикәяләре

рассказа́ть *сов. что, о ком-чём* сөйләү, сөйләп бирү, бәян итү, хикәя кылу (итү); **~ о пое́здке в го́род** шәһәргә бару турында сөйләп бирү

расска́зчик *м* хикәяче, сөйләүче, хикәяләүче, хикәя итүче

расска́зчица *ж см.* **расска́зчик**

расска́зывать *несов. см.* **рассказа́ть**

рассказа́ться *сов. разг.* ник чаба (чаптыра) башлау

расслабева́ть *несов. см.* **расслабе́ть**

расслабе́ть *сов. см.* **расслаби́ть**

расслаби́ть *сов. кого-что* хәлсезләндерү, хәлсезләндереп җибәрү, көчсезләндерү, йомшарту; **~ чью-л. во́лю** *кемнең дә булса* ихтыярын йомшарту; **~ мы́шцы** мускулларның киренкелеген бетерү

расслаблённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **расслаби́ть; 2.** хәлсез, көчсез, хәлсезләнгән; **~ организ́м** хәлсез организм

расслабля́ть *несов. см.* **расслаби́ть**

расслаби́ться *сов. разг.* хәлсезләну, хәлсезләнеп китү; көчсезләну, йомшап китү, йомшау

расслаи́ть *сов. кого-что, уст.* хәбәрен тарату, яман атын сату, данын чыгару

расслаи́вать *несов. см.* **расслои́ть**

расслаи́ваться *несов.* **1.** *см.* **расслои́ться; 2.** *страд. от* **расслаи́вать**

расследова́ние *с см.* **расследова́ть; ~ преступле́ния** жинаять эше буенча тикшерү үткәрү

расследова́ть *сов., несов. что* **1.** *книжн.* тәфсилләп (һәрьяклап) тикшерү, тирәнтен тикшерү; **~ вопро́с** мәсьәләне һәрьяклап тикшерү **2.** *юр.* тикшерү, следствие үткәрү (алып бару); **~ де́ло** эш буенча следствие үткәрү

расслои́||ть *сов.* **1.** *что* катлауларга аеру, катлау; **~ть карто́н** картонны катлауларга аеру **2.** *перен. кого-что* социаль катлауларга аеру (бүлү); **капитали́зм ~л крестья́нство** капитализм крестьяннарны социаль катлауларга аерды

расслои́||ться *сов.* **1.** катлауларга аерылу (бүленү), катлаулану; **слюда́ ~лась** слюда катлауларга аерылды **2.** *перен.* (*разделиться на социальные группы*) социаль катлауларга аерылу (бүленү)

расслы́шать *сов. кого-что* ишетү, ачык (яхшылап) ишетү

рассма́тривать *несов.* **1.** *см.* **рассмотре́ть; 2.** карау, санау, исәплә; **ва́ше предложе́ние мо́жно ~ как вполне́ реа́льное** сезнең тәкъдимегезне тулысы белән реаль дип карарга мөмкин

рассмеши́ть *сов. кого-что* көлдерү

рассмея́ться *несов. см.* көлеп җибәрү; шаркылдап көлә башлау

рассмотре́ни||е *с см.* **рассмотре́ть; при внима́тельном ~и** игътибар белән караганда

рассмотре́ть *сов.* **1.** *кого-что* күреп алу, карап күрү, карап табу; **~ в темноте́ фигу́ры люде́й** караңгыда кешеләрнең фигураларын күреп алу **2.** *кого-что* карау; **~ строе́ние листа́ под микроско́пом** яфрак төзелешен микроскопта карау **3.** *что* карау, карап тикшерү; **~ вопро́с** мәсьәләне карап тикшерү

рассова́ть *сов. кого-что, разг.* тыгып (тыккалап) бетерү; **~ вещи́ по карма́нам** әйберләрне кесәләргә тыгып бетерү

рассо́вывать *несов. см.* **рассова́ть**

рассо́л *м* **1.** тозлык, тозлы су; **огуре́чный ~** кыяр тозлыгы **2.** (*на солеварнях*) тоз суы, тозлы су **3.** *тех.* тозлар эремәсе

рассо́льник *м* рассольник (*аш*)

рассо́рить *сов. кого-что* араларын бозу, ызгыштыру, ачуланыштыру

рассо́риться *сов.* ара бозылу, бозылышу, ызгышу; **~ с бра́том** абыйсы белән арасы бозылу

рассортирова́ть *сов. кого-что* сортлау, сортларга аеру; **~ това́ры** товарларны сортка аеру

рассоса́ть *сов. что* суырту, кайтарту; **компре́ссами ~ затверде́ние** шешнс компресслар белән суырту

рассоса́||ться *сов.* **1.** суырылу, кайту, шиңү (*шешләрнең суырылуы, кайтуы турында әйтелә*) **2.** *перен. разг.* әкренләп таралу, әкренләп таралып бетү; **о́чередь ~лась** чират әкренләп таралып бетте

рассо́х||нуться *сов.* коргаксу, кибеп ярылу; **бо́чка ~лась** мичкә коргаксыган

расспра́шивать *несов. см.* **расспроси́ть**

расспроси́ть *сов. кого-что* сорашу, сорашып белү; сораштыру

расспро́сы *мн.* сорашу, сораштыру; **начали́сь ~** сорашулар башланды

рассредото́чивать *несов. см.* **рассредото́чить**

рассредото́чиваться *несов.* **1.** *см.* **рассредото́читься; 2.** *страд. от* **рассредото́чивать**

рассредото́чить *сов. кого-что* тарату, таратып җибәрү, таратып урнаштыру; **~ войска́** гаскәрне таратып урнаштыру

рассредото́читься *сов.* таралып урнашу, таралышып урнаштыру

рассро́чивать *несов. см.* **рассро́чить**

рассро́чить *сов. что* срокларга бүлү, берничә срокка бүлү; срогын озынайту; **~ упла́ту до́лга** бурычны түләүне берничә срокка бүлү

рассро́чк||а *ж см.* **рассро́чить; в ~у** (*купить, продать*) ваклап түләү шарты белән (*сату, алу*)

расстава́ние *с см.* **расста́ться**

расстава́ться *несов. см.* **расста́ться**

расста́вить *сов.* **1.** *кого-что* кую, куеп чыгу, урнаштыру, урнаштырып чыгу; **~ кни́ги на по́лках** китапларны киштәләргә урнаштыру; **~ часовы́х** сакчыларны куеп чыгу; **~ запя́тые** өтерләр куеп чыгу; **пра́вильно ~ ка́дры** кадрларны дөрес кую **2.** *что* салу, кую; **~ се́ти** ятьмә салу **3.** *что* аеру, аерып кую, җәю, җәеп кую; **~ но́жки ци́ркуля** җәзбә аякларын аерып кую **4.** *что, портн.* киңәйтү, ялгап киңәйтү; **~ пла́тье** күлмәкне киңәйтү

расста́ви||ться *сов. разг.* куелу, урнашу, урнаштырылу; **ме́бель удо́бно ~лась** мебель унайлы куелды

расставля́ть *несов. см.* **расста́вить**

расставля́ться *несов.* **1.** *см.* **расста́виться; 2.** *страд. от* **расставля́ть**

расстано́вк||а *ж* **1.** *см.* **расста́вить; 2.** куелыш, урнаштырылу, тәртип; **~а слов в предложе́нии** җөмләдә сүзләрнең урнаштырылуы **3.** тукталыш, тукталыш ясау; **чита́ть с ~ой** тукталыш ясап уку

расста́||ться *сов.* **1.** *с кем-чем и без доп.* (*разойтись, попрощавшись*) саубуллашып аерылышу (китү); **вéчером мы ~лись с друзья́ми** кичен дуслар белән саубуллашып аерылыштык **2.** *с кем-чем и без доп.* (*разлучиться навсегда*) аерылышу, аерылу **3.** *с чем* саубуллашу, хушлашу; **~ться с мечто́й** хыял белән саубуллашу

расстега́й *м* (*пирожок*) бөккән (*вак бәлешнең бер төре*)

расстёгиваться *несов.* **1.** *см.* **расстегну́ться; 2.** *страд. от* **расстёгивать**

расстегну́ть *сов. что* ычкындыру, ычкындырып җибәрү, чишү, чишеп җибәрү (*мәс. төймәсен*)

расстегну́||ться *сов.* **1.** ычкыну, ычкынып китү, чишелү, чишелеп китү; **ремешо́к ~лся** каеш ычкынып китте **2.** (*расстегнуть на себе одежду*) җилбәгәй җибәрү, төймәсен ычкындырып җибәрү

расстели́ть *сов. см.* **разостла́ть**

расстели́ться *сов. см.* **разостла́ться**

расстила́ть *несов. см.* **расстели́ть, разостла́ть**

расстила́||ться *несов.* **1.** *см.* **расстели́ться, разостла́ться; 2.** җәелү, җәелеп китү, җәелеп яту; **пе́ред на́ми ~лось огро́мное о́зеро** безнең алдыбызда зур күл җәелеп ята иде; **тума́н ~ется** томан җәелә **3.** *перен. разг.* (*раболепствовать*) табанын ялау, ялагайлану **4.** *страд. от* **расстила́ть**

расстоя́ни||е *с* ара, аралык, ераклык ♦ **держа́ть** *кого* **на изве́стном ~и** *кемне дә булса* билгеле бер ераклыкта тоту

расстра́ивать *несов. см.* **расстро́ить**

расстра́иваться *несов.* **1.** *см.* **расстро́иться; 2.** *страд. от* **расстра́ивать**

расстре́л *м* (*казнь*) ату (*үлем җәзасы*); **приговори́ть к ~у** атарга хөкем итү

расстре́ливать *несов. см.* **расстреля́ть**

расстреля́ть *сов.* **1.** *кого-что* ату, атып үтерү **2.** *кого-что* утка тоту, ату; **~ вра́жеский кора́бль** дошман кораблен утка тоту **3.** *что* атып бетерү; **~ все патро́ны** бөтен патроннарны атып бетерү

расстро́ить *сов.* **1.** *что* туздыру, таркату; **~ ряды́ проти́вника** дошман сафларын туздыру **2.** *что* көйсезләндерү, көен бозу, рәтен җибәрү; **~ скри́пку** скрипканы көйсезләндерү **3.** *перен. что* (*привести в упадок*) какшату, зыян китерү, таркату **4.** *перен. что* бозу, җимерү, юкка чыгару; **~ здоро́вье** сәламәтлекне бозу; **~ пла́ны** планнарны җимерү **5.** *перен. кого-что* кәефен бозу, күңелен төшерү; **~ плохи́м изве́стием** начар хәбәр әйтеп кәефен бозу

расстро́и||ться *сов.* **1.** таркалу, тузылу; **ря́ды проти́вника ~лись** дошманның сафлары таркалды **2.** көйсезләнү, бозылу, рәте китү; **роя́ль ~лся** рояль көйсезләнде **3.** *перен.* какшау, зыян килү, таркалу; **хозя́йство ~лось** хуҗалык таркалды **4.** бозылу, юкка чыгу, җимерелү; **игра́ ~лась** уен бозылды **5.** *перен.* какшау, бозылу; **здоро́вье ~лось** сәламәтлек какшады **6.** *перен.* (*огорчиться*) кәеф китү, кайгыга төшү, кәеф кырылу

расстро́йство *с* **1.** *см.* **расстро́ить, расстро́иться; 2.** таркалыш, тәртипсезлек, таркалу; **внести́ ~ в ряды́ проти́вника** дошманның сафларына таркалыш кертү **3.** (*плохое настроение*) кәефсезлек, кәеф бозылу **4.** бозылыш, какшау, бозылу, рәте китү; **не́рвное ~** нерв бозылуы ♦ **~ желу́дка** эч китү

расступа́ться *несов. см.* **расступи́ться**

расступи́||ться *сов.* **1.** юл бирү, юл ачу (*ике якка аерылып*); **толпа́ ~лась** халык төркеме ике якка аерылып юл бирде **2.** *перен.* ярылу, ярылып китү; ике якка аерылу; **земля́ ~лась** җир ярылган

расстыкова́ть *сов. что* аеру

расстыкова́ться *сов.* аерылу

расстыко́вка *ж см.* **расстыкова́ть; расстыкова́ться; ~ косми́ческих корабле́й** космик корабльләрнең аерылуы (*бер-берсеннән*)

рассуди́тельный, -ая, -ое уйлап эш итүчән, төпле, акыллы; **~ челове́к** уйлап эш итүчән кеше

рассуди́||ть *сов.* **1.** *кого-что* чишү, хәл итү; **~ть спор** бәхәсне чишү **2.** (*обдумать*) уйлап карау, хәл итү; **~те, как быть** ничек эш итәргә, уйлап карагыз

рассу́д||ок *м* гакыл, акыл; **потеря́ть ~** акылны югалту; **быть в по́лном ~ке** тулы акылында булу

рассу́дочн||ый, -ая, -ое **1.** гакыл ...ы, акыл ...ы; **~ая де́ятельность** гакыл эшчәнлеге **2.** акыл өстен булган, акыл өстенлек иткән; акылга нигезләнгән; **~ая любо́вь** акыл өстенлек иткән мәхәббәт

рассужда́ть *несов.* **1.** (*мыслить*) фикер йөртү, фикерләү **2.** сөйләү, сөйләнү, әңгәмә алып бару; **~ о по́льзе нау́ки** гыйлемнең файдасы турында сөйләү

рассужде́ни||е *с* **1.** фикер йөртү, фикерләү; **пра́вильное ~е** дөрес фикер йөртү **2.** *обычно мн.* **~я** сүз куерту, сөйләшү, сүз көрәштерү; **пусти́ться в ~я** сүз куертырга керешү; **де́лать без ~й** сүз куертмыйча эшләү

рассупо́нить *сов. кого-что* чөелдереген чишү; **~ хому́т** камытның чөелдереген чишү

рассупо́ниться *сов.* чөелдереге чишелү (чишелеп китү, ычкыну)

рассу́чивать *несов. см.* **рассучи́ть**

рассучи́ть *сов. что* сүтү (*ишелгәнне, үрелгәнне*); **~ верёвку** арканны сүтү

рассучи́||ться *сов.* сүтелү, сүтелеп китү; **верёвка ~лась** аркан сүтелде

рассчита́ть *сов.* **1.** *что* исәпләү, хисаплау, исәпләп чыгару, исәпләп (хисаплап) кую, исәпләп (хисаплап) чыгару, исәбен (хисабын) чыгару; **~ де́ньги** акчаны исәпләп чыгару **2.** (*иметь в виду, предусмотреть*) исәп тоту **3.** *кого-что* (*уволить*) эштән чыгару, расчёт бирү **4.** *кого-что, воен.* [тәртип буенча] санату, санатып чыгару; **~ взвод** взводны санату

рассчита́ться *сов.* **1.** *с кем-чем и без доп.* (*расплатиться*) түләп бетерү; исәпне өзү; исәп-хисапны өзү; **~ с долга́ми** бурычларны түләп бетерү **2.** (*уволиться*) эштән чыгу, расчёт алу **3.** *с кем-чем, разг.* (*отомстить*) араны өзү, үч алу; үч кайтару **4.** *воен.* [тәртип буенча] санау (санап чыгу); **~ по поря́дку номеро́в** номерлар тәртибе буенча санау

рассчи́тывать *несов.* **1.** *см.* **рассчита́ть; 2.** *на кого-что* исәп тоту, ышану, өметләнү, өмет итү; **~ на свои́х друзе́й** үз дусларына исәп тоту

рассчи́тываться *несов.* **1.** *см.* **рассчита́ться; 2.** җавап бирү; **~ за свои́ посту́пки** үзеңнең кылган эшләреңә җавап бирү

рассыла́ть *несов. см.* **разосла́ть**

рассы́лка *ж см.* **разосла́ть; ~ пи́сем** хатларны җибәрү

рассы́лочн||ый, -ая, -ое җибәрү ...ы

рассы́льный *м* (*курьер*) йомышчы

рассы́пать *сов.* **1.** *что* чәчү, кою, чәчеп җибәрү, коеп җибәрү, түгү, түгеп җибәрү; **~ крупу́** ярманы түгү **2.** *что* салып чыгу, тутырып чыгу; **~ муку́ по мешка́м** онны капчыкларга салып чыгу **3.** *кого-что, воен.* җәелдерү, тарату; **~ ро́ту в цепь** ротаны цепька җәелдерү

рассыпа́ть *несов. см.* **рассы́пать**

рассы́па||ться *сов.* **1.** коелу, чәчелү, сибелү, түгелү; **горо́х ~лся по земле́** борчак җиргә коелды **2.** сибелү, таралу; **компа́ния ~лась** компания таралды **3.** (*развалиться*) таркалу, ватылу, таралу, җимерелү; **теле́га ~лась** арба таралды **4.** *в чём и без доп., разг.* яудыру, яудыра башлау (*мактау сүзләрен*); **~ться в компли́ментах** мактау сүзләрен яудыра башлау **5.** (*издать переливчатые звуки*) тавыш барлыкка килү; ишетелү, ишетелеп китү

рассыпа́ться *несов.* **1.** *см.* **рассы́паться; 2.** *страд. от* **рассыпа́ть**

рассыпн||о́й, -ая, -о́е сибелә (чәчелә) торган; сибелмә...; **~о́й корм** сибелә торган азык ♦ **~о́й строй** *воен.* сибелмә строй

рассы́пчат||ый, -ая, -ое таралып тора торган; уалып тора торган; (*о картошке*) ярмалы; **~ая ка́ша** таралып тора торган ботка

рассыха́ться *несов. см.* **рассо́хнуться**

раста́лкивать *несов. см.* **растолка́ть**

раста́пливать I *несов. см.* **растопи́ть** I

раста́пливать II *несов. см.* **растопи́ть** II

раста́пливаться I *несов.* **1.** *см.* **растопи́ться I; 2.** *страд. от* **раста́пливать** I

раста́пливаться II *несов.* **1.** *см.* **растопи́ться II; 2.** *страд. от* **раста́пливать** II

раста́птывать *несов. см.* **растопта́ть**

растаска́ть *сов. разг. см.* **растащи́ть; ~ все ве́щи** барлык әйберләрне ташып бетерү

раста́скивать *несов. см.* **растаска́ть**

растасова́ть *сов. что* таслау, бутау, аралаштыру; **~ ка́рты** кәртләрне аралаштыру

раста́чивать *несов. см.* **расточи́ть**

растащи́ть *сов. кого-что* **1.** ташып бетерү, алып китеп бетерү; **~ брёвна** бүрәнәләрне ташып бетерү **2.** *разг.* аеру, аерып җибәрү; **~ дера́щихся** сугышучыларны аеру

раста́я||ть *сов.* **1.** эрү; **снег ~л** кар эреде **2.** *перен.* бетү, югалу, юкка чыгу;

верши́ны гор ~ **ли в темноте́** караңгыда тау түбәләре юкка чыктылар **3.** *перен.* таралып бетү, китеп бетү; **толпа́** ~ **ла** халык төркеме таралып бетте **4.** *что, разг.* эретү; ~ **ть лёд** бозны эретү **5.** *перен.* эрү, эреп китү; ~ **ть от удово́льствия** канәгатьлек хисеннән эреп китү

раство́р I *м* **1.** ачылу киңлеге (*җәзбә аяклары, кайчы очлары арасы*) **2.** ачылу; ачылган урын (*ишекнең, тәрәзәнең*)

раство́р II *м* **1.** эремә; **насы́щенный** ~ туендырылган эремә **2.** измә; **це́ментный** ~ цемент измәсе

раствори́мость *ж* эрүчәнлек; ~ **соле́й** тозларның эрүчәнлеге

раствори́м||ый, -ая, -ое эрүчән, эри ала торган, эри торган; ~**ые вещества́** эри торган матдәләр; ~**ый ко́фе** эри торган кофе

раствори́тель *м* эреткеч

раствори́ть I *сов. что* ачу, ачып җибәрү; ~ **окно́** тәрәзә ачу

раствори́ть II *сов. что* **1.** эретү; ~ **са́хар в ча́е** шикәрне чәйдә эретү **2.** изү, изеп кую; ~ **те́сто** камыр изү

раствори́ть||ся I *сов.* ачылу, ачылып киттү; **окно́** ~**лось** тәрәзә ачылып ките

раствори́ть||ся II *сов.* **1.** эрү, эреп бетү; **соль** ~**лась в воде́** тоз суда эреп бетте **2.** *перен.* югалу, юкка чыгу, бетү; **сады́** ~**лись в темноте́** караңгылыкта бакчалар югалдылар

растворя́ть I *несов. см.* **растворя́ть** I

растворя́ть II *несов. см.* **раствори́ть** II

растворя́ться I *несов.* **1.** *см.* **раствори́ться** I; **2.** *страд. от* **растворя́ть** I

растворя́ться II *несов.* **1.** *см.* **раствори́ться** II; **2.** *страд. от* **растворя́ть** II

растека́ться *несов.* **1.** *см.* **расте́чься; 2.** *перен. разг.* (*излагать пространно*) артык киң итеп сөйләү, җәелеп сөйләү

расте́ни||е *с* үсемлек; **декорати́вные** ~**я** бизәү үсемлекләре; **ядови́тые** ~**я** агулы үсемлекләр

растениево́дство *с* **1.** (*отрасль сельского хозяйства*) үсемлекчелек, үсемлек үстерүчелек, үсемлек үстерү **2.** (*наука*) үсемлекчелек белеме, үсемлекчелек фәне

растереби́ть *сов. разг.* **1.** *что* йолкып туздыру, йолкып туздырып бетерү; ~ **сноп** көлтәне йолкып туздыру **2.** *кого-что* (*побудить к действию*) селкетү, кузгатып җибәрү

растере́ть *сов. что* **1.** уу, уып ваклау; ~ **сухи́е кра́ски** коры буяуларны уып ваклау **2.** сылау; ышкы, ышкып буяу; ~ **мазь на руке́** кулдагы майны ышкы **3.** (*сделать массаж*) сылау, массаж ясау ♦ ~ **в порошо́к** *кого* измәсеи изү

растере́ться *сов. что* **1.** (*размельчиться*) уылу, уылып ваклану **2.** сөртү; ~ **одеколо́ном** үзенә одеколон сөртү **3.** (*обтереть себя, массажируя*) сөртенү, үзеңне ышку; ~ **полоте́нцем** сөлге белән үзеңне ышку

расте́рзанный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **растерза́ть; 2.** өзгәләнеп (тузгып) беткән

растерза́||ть *сов. кого-что* **1.** ботарлау, ботарлап (өзгәләп) ташлау; **во́лки** ~**ли овцу́** бүреләр сарыкны ботарлап ташлаганнар **2.** *перен.* өзгәләндерү, изалау; ~**ть ду́шу** күңелне өзгәләндерү

расте́рянность *ж* аптыраганлык, аптырау; каушаганлык

расте́рянный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **растеря́ть; 2.** аптыраган, каушаган, аптырап (каушап) калган, аптырашта калган; ~ **вид** каушаган кыяфәт

растеря́ть *сов. кого-что* югалтып бетерү, югалту; жую; ~ **кни́ги** китапларны югалтып бетерү

растеря́ться *сов.* **1.** (*пропасть — о многих предметах*) югалып бетү, югалу, җуелу **2.** аптырап (югалып, каушап) калу; ~ **от неожи́данности** көтмәгән хәлдән аптырап калу

расте́||чься *сов.* **1.** (*тёрле якка*) агып китү, агып таралу; **ручьи́** ~**кли́сь** инешләр төрле якка агып киткәннәр **2.** (*расплыться*) җәелү, җәелеп китү; **бу́квы** ~**кли́сь на бума́ге** хәрефләр кәгазьдә җәелделәр **3.** таралу, таралып китү; **толпа́** ~**кла́сь** халык төркеме таралды

раст||и́ *несов.* **1.** *в разн. знач.* үсү; **дере́вья** ~**у́т ме́дленно** агачлар акрын үсәләр; ~**и́ в дере́вне** авылда үсү; ~**и́ на рабо́те** эштә үсү; **в ту́ндре** ~**ёт мох** тундрада мүк үсә **2.** арту, үсү, зураю; күбәю; ~**ёт благосостоя́ние наро́да** халык байлыгы арта; **го́род** ~**ёт** шәһәр үсә

растира́ть *несов. см.* **растере́ть**

растира́ться *несов.* **1.** *см.* **растере́ться; 2.** *страд. от* **растира́ть**

расти́скивать *несов. см.* **расти́снуть**

расти́тельность *ж* **1.** үсемлекләр, үсемлекләр дөньясы; ~ **Ура́ла** Уралның үсемлекләр дөньясы **2.** (*на голове*) чәч; (*на теле*) йон; (*на лице*) сакал-мыек

расти́тельн||ый, -ая,-ое **1.** үсемлек [-ләр] ...ы; ~**ый мир** үсемлекләр дөньясы; ~**ое ма́сло** үсемлек мае **2.** *книжн.* үсү ...ы; ~**ый проце́сс** үсү процессы

расти́ть *несов. кого-что* үстерү, тәрбияләү, тәрбияләп үстерү; ~ **дете́й** балалар тәрбияләп үстерү; ~ **ка́дры** кадрлар тәрбияләү

растлева́ть *несов. см.* **растли́ть**

растле́нный, -ая, -ое черек, бозык, череп таркалган

растли́ть *сов. кого-что* **1.** гыйффәтен бозу, көчләү (*яшь кызны*) **2.** *перен.* бозу, аздыру, юлдан яздыру; ~ **ду́шу** йөрәкне аздыру

растолка́ть *сов. кого-что* **1.** этеп тарату; этеп юл ачу, як-якка эту; ~ **толпу́** халык төркемен этеп юл ачу **2.** этеп уяту, төртеп уяту; ~ **спя́щего** йоклаган кешене төртеп уяту

растолкова́ть *сов. что* аңлатып (төшендереп) бирү, аңлату; ~ **содержа́ние кни́ги** китапның эчтәлеген аңлатып бирү

растолко́вывать *несов. см.* **растолкова́ть**

растоло́чь *сов. что* төю, төеп ваклау, төеп онга әйләндерү; ~ **пе́рец** борычны төю

растолсте́ть *сов.* юанаю, юанаеп китү, калынаю

растопи́ть I *сов. что* ягу, ягып җибәрү, яндырып җибәрү; ~ **пе́чку** мичкә ягып җибәрү

растопи́ть II *сов. что* эретү, эретеп алу; ~ **воск** балавыз эретү

растопи́||ться I *сов.* янып китү, дөрләп яна башлау, кызып яна башлау; **печь** ~**лась** мич дөрләп яна башлады

растопи́||ться II *сов.* эрү, эреп бетү; **воск** ~**лся** балавыз эреде

расто́пка *ж* **1.** *см.* **растопи́ть** I; ~ **пече́й** мичләргә ягу **2.** *собир. разг.* чыра, кабызгыч (*туз, йомычка һ.б.ш.*)

растопта́ть *сов. кого-что* (*топча, раздавить*) таптап китү (ташлау, изү)

растопта́||ться *сов. прост.* киелә-киелә [киюдән] иркенәю (киңәю); **сапоги́** ~**лись** итекләр киелә-киелә иркенәйде

растопы́ривать *несов. см.* **растопы́рить**

растопы́рить *сов. что, разг.* аеру, тырпайту, аерып кую, тырпайтып кую; (*ногги*) еру, ерып кую; ~ **па́льцы** бармакларны аерып кую

растопы́риться *сов.* аерылу, тырпаю, аерылып китү, тырпаеп китү; (*о ногах*) ерылу, ерылып китү

расторга́ть *несов. см.* **расто́ргнуть**

расто́ргнуть *сов. что* өзү, гамәлдән туктату, юкка чыгару; ~ **до́говор** килешүне өзү

расторгова́ться *сов. прост.* **1.** сату итеп баю, сәүдә итеп баю; **2.** барлык товарны сатып бетерү

расторже́ние *с см.* **расто́ргнуть**

растормоши́ть *сов. кого-что* **1.** (*разбудить*) этеп-төртеп уяту, төрткәләп уяту **2.** *перен.* (*расшевелить*) кузгату, кузгатып җибәрү, селкетү

расторо́пность *ж* өлгерлек, елгырлык, җитезлек; **отлича́ться** ~**ю** өлгерлек белән аерылып тору

расторо́пный, -ая, -ое өлгер, елгыр, җитез; ~ **ма́льчик** өлгер малай

расточа́ть *несов.* **1.** *см.* **расточи́ть** II 1; **2.** *перен. что* юмартлану, юмартлык күрсәтү; ~ **похвалы́** мактаулар яудыру

расточи́тель *м* туздыручы, исраф итүче, әрәм-шәрәм итүче, җилгә очыручы, артык юмарт кеше

расточи́тельница *ж* туздыручы хатын (кыз)

расточи́тельный, -ая, -ое исраф итүчән, әрәм-шәрәм итүчән, туздыручан; артык юмарт

расточи́тельство *с* исраф итүчәнлек, әрәм-шәрәм итү, әрәм-шәрәм итүчәнлек; артык юмартлык

расточи́ть I *сов. что* кырып киңәйтү (зурайту, тирәнәйтү); ~ **отве́рстие** тишемне кырып киңәйтү

расточи́ть II *сов. что* **1.** *книжн.* исраф итү, исраф итеп бетерү, әрәм-шәрәм итеп бетерү, әрәм-шәрәм итү, туздырып бетерү; ~ **насле́дство** мирасны туздырып бетерү **2.** *см.* **расточа́ть** 2

расточи́ться *сов.* кырылып киңәю (зураю, тирәнәю)

расто́чка *ж см.* **расточи́ть** I

растрави́ть *сов.* **1.** *прям., перен. что* ярсыту, ярсытып җибәрү, кузгату; авырт-

тыру; ~ **ра́ну** яраны авырттыру; ~ **го́ре** кайгыны кузгату **2.** *кого-что, разг.* (*раздразнить*) үртәп ярсыту (котырту) **3.** *что, спец.* ую, ашату (*кислота белән*)

растра́вливать *несов. см.* **растрави́ть**

растравля́ть *несов. см.* **растрави́ть**

растранжи́ривать *несов. см.* **растранжи́рить**

растранжи́рить *сов. что, разг.* әрәмшәрәм итеп бетерү, җилгә очыру, тоздырып бетерү; ~ **де́ньги** акчаны әрәмшәрәм итеп бетерү

растра́та *ж* **1.** *см.* **растра́тить; ~ вре́мени** вакытны әрәм итү **2.** (*незаконное расходование денег*) өскә чыгу, өскә чыгару, растрата **3.** (*растраченные казённые деньги*) өскә чыккан акча

растра́тить *сов. что* **1.** тотып бетерү, сарыф итеп бетерү, сарыф итү, тоздыру; түгү; ~ **все де́ньги** барлык акчаны тотып бетерү **2.** *перен.* әрәм (исраф) итү, юкка чыгару; ~ **си́лы** көчне әрәм итү **3.** (*истратить незаконно*) растрата ясау, өскә чыгару

растра́тчик *м* өстенә чыккан кеше, растрата ясаган кеше, исрафчы

растра́чивать *несов. см.* **растра́тить**

растревóжить *сов.* **1.** *кого-что* хәвефкә төшерү, борчу салу, шомландыру; ~ **мать** анага борчу салу **2.** *что* кузгату, ярсыту, борчу; ~ **ра́ну** яраны кузгату

растревóжи||ться *сов.* хәвефләну, шомлану, борчылу, хәвефкә төшү; **стари́к ~лся** карт хәвефкә төште

растрезвóнить *сов. что, разг.* (*разгласить*) хәбәр тарату, шалтырау, сөйләп чыгу

растрёпа *м, ж разг.* (*небрежно одетый, неряшливый*) пөхтә киенмәгән кеше, пөхтәсез [кеше]; (*лохматый*) тузгак баш, пумала баш

растрёпанн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **растрепа́ть; 2.** тетеләп (тузып) беткән; **~ая кни́га** тетеләп (тузып) беткән китап

растрепа́ть *сов. что* **1.** тузгыту, тоздыру; ~ **во́лосы** чәчләрне тузгыту **2.** тетеп (өзгәләп, туздырып) бетерү; ~ **кни́ги** китапларны өзгәләп бетерү **3.** талку, талкып бетерү; ~ **лён** җитенне талкып бетерү

растрепа́||ться *сов.* **1.** тузгу, тузгып бетү, тузылу; **во́лосы ~лись** чәчләре тузгыган **2.** тетеләп (өзгәләнеп) бетү; **кни́га ~лась** китап өзгәләнеп беткән

растре́ска||ться *сов.* чатнап (ярылып) бетү (чыгу); **ко́жа ~лась** тире ярылып беткән

растре́скиваться *несов. см.* **растре́скаться**

растро́ганн||ый, -ая, -ое күңеле йомшаган, дулкынланган, тәэсирләнгән; **сказа́ть ~ым го́лосом** дулкынланган тавыш белән әйтү

растро́гать *сов. кого-что* күңелен йомшарту, дулкынландыру, тәэсирләндерү

растро́гаться *сов.* күңел йомшару, дулкынлану, тәэсирләну

растру́б *м* раструб (*берәр нәрсәнең бүрәнкә сыман киңәеп киткән урыны*)

раструби́ть *сов. что, о ком-чём, разг.* хәбәр тарату, шалтырау, сөйләп йөрү; ~ **но́вость** яңалык турында сөйләп йөрү

раструси́ть *сов. что, разг.* **1.** селкетеп кою, чәчү, түгү; ~ **зерно́ при перево́зке** ташыганда ашлыкны селкетеп кою **2.** кабартып җәю, [кабартып] җәеп ташлау; ~ **соло́му** саламны җәеп ташлау

раструси́||ться *сов.* селкенеп коелу, селкенеп түгелү; селкенеп коелып бетү; **овёс ~лся** солы селкенеп коелды

растрясти́ *сов.* **1.** *что* селкетеп җәеп (таратып) ташлау, селкетеп чәчеп ташлау; ~ **се́но** печәнне селкетеп җәеп ташлау **2.** *кого-что, разг.* селкетеп уяту; ~ **спя́щего** йоклаган кешене селкетеп уяту **3.** *безл. кого-что* (*утомить тряской*) селкетеп йончыту

растушева́ть *сов. что* каралту, карайту (*рәсемне тушь яки карандаш белән*)

растушёвывать *несов. см.* **растушева́ть**

растя́гивать *несов. см.* **растяну́ть**

растя́гиваться *несов.* **1.** *см.* **растяну́ться; 2.** *страд. от* **растя́гивать**

растяжи́м||ый, -ая, -ое **1.** сузып була торган, тартып була торган, сузылмалы, сузылучан, сузыла торган **2.** *перен.* төрлечә аңлап була торган, төрлечә аңлашыла торган; ~**ое поня́тие** төрлечә аңлап була торган төшенчә

растяну́ть *сов. что* **1.** тарттырып сузу, тарттырып киңәйтү, тарттыру, киерү; ~ **шку́ру** тирене киерү **2.** җәеп салу, сузып җәеп салу; ~ **ковёр на полу́** идәнгә паласны җәеп салу **3.** тарттыру, каймыктыру, тарттырып имгәтү; ~ **сухожи́лие** сеңерне каймыктыру **4.** сузу, сузып озынайту; ~ **фронт** фронтны сузып озынайту **5.** сузу; ~ **докла́д** докладны сузу

растяну́||ться *сов.* **1.** киңәю, сузылу, озынаю (*тарттырудан, киерүдән*); **перча́тки ~лись** перчаткалар киңәйде (*тарттырудан*) **2.** сузылу, сузылып китү; ~**тся цепо́чкой** чылбыр булып сузылу **3.** (*лечь во всю длину, вытянуться*) сузылып яту; ~**тся на дива́не** диванга сузылып яту **4.** (*упасть*) барып төшү, лап итеп егылу **5.** сузылу; **рабо́та ~лась на неде́лю** эш бер атнага сузылды **6.** тартылып имгәнү, каймыгу, сузылу; **сухожи́лие ~лось** сеңер каймыкты

растя́па *м, ж разг.* ачык авыз, мәми авыз, пешмәгән кеше

расфасова́ть *сов. что* үлчәп төргәкләү, үлчәп төреп кую; ~ **муку́** онны үлчәп төргәкләү

расфасо́вка *ж см.* **расфасова́ть; ~ крупы́** ярманы үлчәп төргәкләү

расфасо́вывать *несов. см.* **расфасова́ть**

расформирова́ние *с см.* **расформирова́ть**

расформирова́ть *сов. что* тарату, таратып җибәрү; ~ **полк** полкны тарату

расформиро́вывать *несов. см.* **расформирова́ть**

расфранти́ться *сов. разг.* купшы киенү, фырт киенү, көяз киенү, киенү-ясану

расфранчённый, -ая, -ое *разг.* купшы киенгән, фырт киенгән, көяз киенгән, киенгән-ясанган

расфуфы́риться *сов. разг.* әфәләм төрле киенү-ясану, артык купшы киенү

расха́живать *несов.* арлы-бирле йөрү, йөренү; ~ **по ко́мнате** бүлмә буйлап арлы-бирле йөрү

расхва́ливать *несов. см.* **расхвали́ть**

расхвали́ть *сов. кого-что* артык (үтә) мактау; ~ **ученика́** укучыны артык мактау

расхва́статься *сов.* артык (үтә) мактана башлау, шапырына башлау

расхвата́ть *сов. кого-что* сатып алып бетерү, ябырылып алып бетерү; ~ **кни́ги** китапларны сатып алып бетерү

расхва́тывать *несов. см.* **расхвата́ть**

расхвора́ться *сов.* каты авырып китү, каты авырый башлау; хасталанып китү

расхити́тель *м* урлаучы, талаучы (*кубесенчә җәмәгать милкен урлаучыга карата әйтелә*)

расхити́ть *сов. что* урлау, урлап бетерү; талау; ~ **иму́щество** мөлкәтне урлап бетерү

расхища́ть *несов. см.* **расхити́ть**

расхлеба́ть *сов. что разг.* (*распутать неприятное*) ерып чыгу, хәл итү

расхлёбывать *несов. см.* **расхлеба́ть**

расхлопота́ться *сов. разг.* ыгы-зыгы килә башлау, мәш килә башлау

расхля́банность *ж* таркаулык, тәртипсезлек, эленке-салынкылык; **боро́ться с ~ю** таркаулык белән көрәшү

расхля́банный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **расхля́бать; 2.** *разг.* эленке-салынкы, таркау, тәртипсез; ~ **челове́к** таркау кеше

расхля́бать *сов. что, разг.* селкетеп бушайту, селкетеп какшату; ~ **болты́** болтларны селкетеп бушайту

расхля́ба||ться *сов. разг.* селкенеп бушаю (какшау); **га́йка ~лась** гайка селкенеп бушайган

расхо́д *м* **1.** чыгым, расход; **накладны́е ~ы** өстәмә чыгымнар **2.** тоту, тотылу, файдалану; ~ **горю́чего** ягулыкның тотылуы ◆ **вы́вести (пусти́ть, списа́ть) в ~** *кого-что* расходка чыгару (җибәрү)

расходи́||ться I *сов. разг.* **1.** (*начать много ходить*) йөренә башлау, арлы-бирле йөри башлау **2.** (*втянуться в ходьбу*) йөреп кызып китү, йөрергә күнегеп китү, йөрергә өйрәнеп китү **3.** кызып (ярсып) китү; **не́рвы ~лись** нервлар ярсып китте

расходи́ться II *несов. см.* **разойти́сь**

расхо́д||овать *несов. что* **1.** сарыф итү, тоту; акча тоту; ~**овать де́ньги** акча тоту **2.** *разг.* тоту, бетерү; **мото́р ~ует мно́го бензи́на** мотор бензинны күп бетерә

расхо́д||оваться *несов.* **1.** *разг.* (*тратить деньги на что-л.*) акча тоту, расходлану **2.** тотылу, кулланылу, сарыф ителү; **материа́лы ~уются эконо́мно** материаллар саклык белән тотыла **3.** *страд. от* **расхо́довать**

расхожде́ние *с* **1.** *см.* **разойти́сь; ~ лучей из це́нтра** үзәктән нурларның

таралуы; ~ **доро́г** юлларның тармакланып 2. аерма, туры килмәү, аерылу, башкалык; ~ **во взгля́дах** фикерләрдәге башкалык

расхо́жий, -ая, -ое *разг.* 1. көндәлек ..., көн дә кия торган; ~ **костю́м** көн дә кия торган костюм 2. үтемле, үтә торган; ~ **това́р** үтемле товар

расхола́живать *несов. см.* **расхоло́дить**

расхоло́дить *сов. кого-что* күңелен кайтару, суындыру, гайрәтен кайтару, күңелен төшерү

расхоте́ть *сов. что, чего и с неопр., разг.* ...сы килми башлау, теләк бетү, теләми башлау, күңел кайту; ~ **есть** ашыйсы килми башлау

расхоте́||ться *сов. безл. чего и с неопр., разг.* ...сы килми башлау, күңел кайту, теләк бетү; ~ **лось спать** йоклыйсы килми башлау

расхохота́ться *сов.* шаркылдап көлеп җибәрү, шаркылдап көлә башлау

расхрабри́ться *сов. разг.* батырланып китү, батыраю, кыюланып китү

расцара́пать *сов. кого-что* тырнау, тырнап бетерү (ерту); ~ **щёку** яңакны тырнау

расцара́па||ться *сов.* 1. үзен тырнау, үзен тырнап бетерү (ерту); **ребёнок** ~**лся** бала үзен тырнаган 2. (*поцарапать друг друга*) тырнашу, тырнашып бетү

расцара́пывать *несов. см.* **расцара́пать**

расцара́пываться *несов.* 1. *см.* **расцара́паться**; 2. *страд. от* **расцара́пывать**

расцве||сти́ *сов.* 1. чәчәк ату; чәчәкләнү; **цветы́ расцвёл** гөл чәчәк атты 2. *перен.* (*похорошеть*) матурлану, матурланып китү 3. *перен.* чәчәк ату, гөрләп үсү 4. *перен.* балку, балкып китү; **лицо́ его́** ~**ло** аның йөзе балкып китте

расцве́т *м* 1. чәчәк ату, чәчәкләнү 2. *перен. чего* чәчәк ату, гөрләп үсү, зур үсеш; ~ **нау́ки** фәннең чәчәк атуы

расцвета́ть *несов. см.* **расцвести́**

расцвети́ть *сов. что, разг.* бизәү, бизәкләү, чуарлау; буяу; ~ **фла́гами** флаглар белән бизәү

расцве́тка *ж разг.* 1. *см.* **расцвети́ть**; 2. бизәлеш, бизәкләр, буялыш; **пёстрая** ~ чуар бизәкләр

расцве́чивать *несов. см.* **расцвети́ть**

расцелова́ть *сов. кого-что* каты иттереп үбү, үбеп бетерү

расцелова́ться *сов.* каты итеп үбешү, суырып үбешү, үбешеп алу; ~ **с сы́ном** улы белән каты итеп үбешү

расце́нивать *несов. см.* **расцени́ть**

расцени́ть *сов.* 1. *что, спец.* бәясен билгеләү, бәя кую, бәяләү, бәяләп чыгу; ~ **това́р** товарның бәясен билгеләү 2. *перен. кого-что* бәя бирү, бәяләү, ... дип санау; **высоко́** ~ **тала́нт** талантка югары бәя бирү

расце́нка *ж* 1. *см.* **расцени́ть** 1; 2. (*цена, оплата*) бәя, хак

расце́ночн||ый, -ая, -ое бәяләү ...ы, бәя кую ...ы, ~**ая коми́ссия** бәя кую комисссиясе

расцепи́ть *сов. кого-что* ычкындыру, ычкындырып җибәрү, өзү; ~ **вагоны** вагоннарны ычкындыру

расцепи́||ться *сов.* ычкыну, өзелү; **вагоны** ~**лись** вагоннар ычкынганнар

расцепля́ть *несов. см.* **расцепи́ть**

расцепля́ться *несов.* 1. *см.* **расцепи́ться**; 2. *страд. от* **расцепля́ть**

расчека́нить *сов. что, тех.* 1. чүкү, чүкеп бизәк төшерү, сугу 2. чүкеп яньчү, чүкеп яньчеп чыгу; ~ **заклёпочные швы** заклёпка җәйләрен чүкеп яньчеп чыгу

расчерти́ть *сов. что* сызып чыгу (бүлү, бетерү); ~ **ка́рту на квадра́ты** картаны квадратларга сызып чыгу

расчёрчивать *несов. см.* **расчерти́ть**

расчеса́ть *сов. что* 1. тарау, тарап җибәрү (бетерү, кую); ~ **во́лосы** чәчне тарап җибәрү 2. кашып тырнау, тырнап куптару; ~ **ру́ку** кулны кашып тырнау

расчеса́ться *сов. разг.* 1. (*расческой, гребнем*) үз чәчен тарау 2. (*расцарапаться при чесании*) кашына башлау, кашынырга тотыну

расчёска *ж* тарак, чәч тарагы

расчёсть *сов. см.* **рассчита́ть**

расчёстьcя *сов. см.* **рассчита́ться**

расчёсывать *несов. см.* **расчеса́ть**

расчёсываться *несов.* 1. *см.* **расчеса́ться**; 2. *страд. от* **расчёсывать**

расчёт *м* 1. *см.* **рассчита́ть; оши́бка в** ~**е** исәп-хисаптагы хата 2. (*уплата за работу*) түләү, расчёт 3.(*увольнение*) расчёт бирү, расчёт бирепэштән чыгару; расчёт алу; **попроси́ть** ~ расчёт бирүне сорау 4. (*намерение*) исәп, ният уй; ~ **оправда́лся** исәп барып чыкты 5. *разг.* (*польза*) файда, мәгънә; **нет никако́го** ~**а е́хать** барудан бернинди дә мәгънә юк 6. *воен.* расчёт; **пулемётный** ~ пулемёт расчёты 7. *тех.* расчёт, исәпләү, исәпләмә; ~ **мо́щности заво́да** заводның куәтен исәпләү ◆ **в** ~**е** *кто с кем* исәпләштек, араны өздек; **из** ~**а** исәбеннән, исәбеннән чыгып; **приня́ть в** ~ исәпкә алу

расчётливый, -ая, -ое 1. (*бережливый*) саклык белән тотучы ..., саклык белән тота торган, исәп-хисапчыл 2. (*осмотрительный*) уйлап эш итүчән, исәп белән эш итүчән (йөртүчән)

расчётчик *м спец.* исәпче, исәпләүче (*техник расчётлар белгече*)

расчехли́ть *сов. что* чехолын салдыру, ябуын салдыру (алу); ~ **ору́дие** орудиенең чехолын салдыру

расчехля́ть *несов. см.* **расчехли́ть**

расчи́слить *сов. что, разг.* исәпләп чыгару; ~ **годовы́е дохо́ды** еллык табышларны исәпләп чыгару

расчи́стить *сов. что* арчу, тазарту, арчып (тазартып) чыгу; чистартып, чистартып чыгу; юл ачу; ~ **доро́жки** юлларны ачу

расчи́сти||ться *сов.* арчылу, арчылып бетү, чистару; **не́бо** ~**лось от туч** күк йөзе болытлардан арынды

расчиха́ться *сов. разг.* төчкеренергә тотыну, төчкеренә башлау

расчища́ть *несов. см.* **расчи́стить**

расчища́ться *несов.* 1. *см.* **расчи́ститься**; 2. *страд. от* **расчища́ть**

расчлене́ние *с см.* **расчлени́ть**

расчлени́ть *сов. что* 1. бүлеп (бүлгәләп) бетерү, аеру, кисәкләргә аеру; **Се́верная Земля́ расчленена́ проли́вами** Төньяк Җир бугазлар белән бүлгәләнеп беткән 2. (*разбить на составные элементы*) бүлү, аеру; бүлгәләү; ~ **произво́дственный проце́сс** производство процессын бүлү

расчленя́ть *несов. см.* **расчлени́ть**

расчу́вствоваться *сов.* күңеле йомшау (тулу), күңеле йомшарып (тулып) китү

расшали́ться *сов.* каты шаяра (шаярыша) башлау, артык шаярып китү

расша́ркаться *сов.* 1. үкчәләрне бәреп баш ию (*исәнләшү яки саубуллашу*) 2. *перен. перед кем-чем, разг.* иелү-бөгелү, ялагайлану; ~ **пе́ред нача́льством** башлык алдында ялагайлану

расша́ркиваться *несов. см.* **расша́ркаться**

расшата́ть *сов. что* 1. селкетеп кузгату, бушайту, какшату; ~ **забо́р** койманы селкетеп кузгату; ~ **стул** урындыкны какшату 2. *перен.* какшату

расшата́||ться *сов.* 1. селкенеп кузгалу, бушаю, каушау; **теле́га** ~**лась** арба какшаган 2. *перен.* какшау, рәте китү

расша́тывать *несов. см.* **расшата́ть**

расша́тываться *несов.* 1. *см.* **расшата́ться**; 2. *страд. от* **расша́тывать**

расшвы́ривать *несов. см.* **расшвыря́ть**

расшвыря́ть *сов.* 1. *кого-что* ыргытып ташлау; туздырып (актарып) ташлау; ~ **дрова́** утынны туздырып ташлау 2. *перен. что* туздырып бетерү, исраф итү; ~ **все де́ньги** барлык акчаны туздырып бетерү

расшеве́ливать *несов. см.* **расшевели́ть**

расшевели́ть *сов.* 1. *что* кузгатып җибәрү, кузгату; ~ **у́гли в пе́чке** мичтәге күмерне кузгату 2. *перен. кого-что* кузгату, кузгатып җибәрү, хәрәкәткә китерү

расшевели́||ться *сов.* 1. хәрәкәткә килү, кузгалып китү, кыймылдый башлау; **муравьи́** ~**лись** кырмыскалар кыймылдый башладылар 2. *перен.* кузгалу, хәрәкәткә килү

расшиба́ть *несов. см.* **расшиби́ть**

расшиба́ться *несов.* 1. *см.* **расшиби́ться**; 2. *страд. от* **расшиба́ть**

расшиби́ть *сов. что, разг.* 1. бәреп имгәтү, бәреп авырттыру; бәреп изү; ~ **нос** борынны бәреп авырттыру 2. (*разбить*) бәреп вату, җимерү; вату, ватып бетерү; ~ **ло́дку** көймәне бәреп вату

расшиби́ться *сов. разг.* (*получить повреждения*) бәрелеп имгәнү; бәрелеп авырту ◆ ~ **в лепёшку** ярылырга әзер тору

расшива́ть *несов. см.* **расши́ть**

расшива́ться *несов.* 1. *см.* **расши́ться**; 2. *страд. от* **расшива́ть**

расшивн||о́й, -а́я, -о́е чигелгән, чигүләр белән бизәлгән; **~а́я руба́шка** чигелгән күлмәк

расшире́ни||е *с* **1.** *см.* **расши́рить, расши́риться; ~е произво́дства** производствоны киңәйтү; **~е посевны́х площаде́й** чәчү мәйданнарын арттыру **2.** киңәйгән урын, киңәймә; **труба́ с ~ем на конце́** очы киңәйгән торба

расши́ренн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **расши́рить; 2.** киңәйтелгән; **~ое заседа́ние** киңәйтелгән утырыш; **~ая програ́мма** киңәйтелгән программа

расши́ритель *м спец.* киңәйткеч

расши́рить *сов. что* **1.** киңәйтү, киңәйтеп жибәрү; зурайту; **~ у́лицу** урамны киңәйтү; **~ отве́рстие** тишекне зурайту **2.** арттыру, күбәйтү, киңәйтү; **~ сеть библиоте́к** китапханәләр челтәрен арттыру **3.** киңәйтү; **~ свой кругозо́р** дөньяга үз карашны киңәйтү

расши́р||иться *сов.* **1.** киңәю, киңәеп китү; зураю; **отве́рстие ~лось** тишек зурайды **2.** арту, күбәю, зураю, киңәю; **фа́брика ~лась** фабрика зурайды

расширя́ть *несов. см.* **расши́рить**

расширя́ться *несов.* **1.** *см.* **расши́риться; 2.** *страд. от* **расширя́ть**

расши́тый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **расши́ть; 2.** чигелгән, чигеш белән бизәлгән; **~ пере́дник** чигелгән альяпкыч

расши́ть *сов. что* **1.** (*распороть*) сүтү, сүтеп ташлау (бетерү), сүтеп жибәрү **2.** (*вышить*) чигү, чигеш белән бизәү

расши́ться *сов. разг.* (*распороться*) сүтелү, сүтелеп китү

расшифрова́ть *сов. что* **1.** расшифровкалау, шифр белән язылганны уку; шифрын ачу; **~ телегра́мму** телеграмманы расшифровкалау **2.** *перен. разг.* белү, белеп алу, төшенү

расшифро́вка *ж см.* **расшифрова́ть**

расшифро́вщик *м* расшифровщик, шифрлы язуны укып белүче; шифрын ачучы

расшифро́вывать *несов. см.* **расшифрова́ть**

расшнурова́ть *сов. что* шнурын (бавын) чишү, шнурны чишеп жибәрү; **~ боти́нки** ботинканың бавын чишү

расшнурова́||ться *сов.* **1.** шнуры (бавы) чишелү; **боти́нки ~лись** ботинканың бавы чишелде **2.** (*развязать на себе шнуровку*) шнурын чишү, чишеп алу

расшнуро́вывать *несов. см.* **расшнурова́ть**

расшнуро́вываться *несов.* **1.** *см.* **расшнурова́ться; 2.** *страд. от* **расшнуро́вывать**

расшуме́||ться *сов.* **1.** шаулый башлау, шаулаша башлау; **де́ти ~лись** балалар шаулаша башладылар **2.** *перен.* (*начать сильно кричать*) тавыш куптару, шаулый башлау, тавышлана (кычкырына) башлау

расще́дриться *сов.* юмартланып китү, юмартлану

расще́лина *ж* **1.** тарлавык; ярык; тау ярыгы; **~ в скале́** кыя ярыгы **2.** ярык, ярылган урын; чатнаган урын; **~ льда** бозның ярылган урыны

расщёлкать *сов. что, разг.* вату, яру; **~ оре́хи** чикләвек вату

расщёлкивать *несов. см.* **расщёлкать** *и* **расщёлкнуть**

расщёлкнуть *сов. разг. см.* **расщёлкать**

расщеми́ть *сов. что, разг.* ачу, язу; **~ кле́щи** кыпсуырны ачу

расщемля́ть *несов. см.* **расщеми́ть**

расще́п *м спец.* ярык, ярылып киткән урын; **перо́ с ~ом** ярыклы каләм

расщепи́ть *сов. что* **1.** яру, ярып жибәрү; **~ на́двое** икегә яру **2.** яргалап бетерү, телгәләү, телгәләп бетерү; **~ лучи́ну** чыраны телгәләп бетерү **3.** *спец.* таркату, бүлү (*состав кисәкләргә*); **~ а́том** атомны таркату **4.** *спец.* аеру, аерып бетерү; **~ волокна́** жипселләрне аеру

расщепи́||ться *сов.* **1.** ярылу, ярылып китү; **доска́ ~лась** такта ярылып китте **2.** *хим.* таркалу, бүленү (*состав кисәкләргә*) **3.** *спец.* аерылу; **волокно́ ~лось** җепсел аерылды

расщепле́ние *с см.* **расщепи́ть, расщепи́ться; ~ а́томного ядра́** атом төшенең бүленүе

расщепля́ть *несов. см.* **расщепи́ть**

расщепля́ться *несов.* **1.** *см.* **расщепи́ться; 2.** *страд. от* **расщепля́ть**

расщипа́ть *сов. что* җепләрен (җепселләрен) суыру, җепләрен (җепселләрен) суырып чыгару, җепселләргә аеру; **~ полотно́** киндернең җепләрен суырып чыгару

ратин́ *м* ратин (*тукыма*)

ратифика́ция *ж* ратификация (*аерым вәкилләр тарафыннан төзелгән килешүне югары хакимиятнең раславы*)

ратифици́ровать *сов., несов. что* ратификацияләү, раслау

ра́тник *м* **1.** *уст.* (*воин*) сугышчы, яучы **2.** *ист.* ратник (*революциягә кадәрге Россиядә: дәүләт ополчениесе солдаты*)

ра́тный, -ая, -ое *высок.* хәрби; сугыш ...ы; сугышчан; **~ по́двиг** хәрби батырлык

ра́товать *несов. за кого-что, против кого-чего* көрәшү, яклау, яклап чыгу; **~ за пра́вду** дөреслекне яклап чыгу

ра́туша *ж* ратуша (**1.** *18-19нчы гасырларда Европада һәм Россиядә: шәһәр үзидарәсе органы* **2.** *кайбер Европа илләрендә шәһәр үзидарәсе бинасының исеме*)

рать *ж уст.* **1.** (*войско*) чирү, гаскәр, яу **2.** (*битва*) сугыш, яу

ра́унд *м спорт.* раунд (*бокста: көрәш бара торган вакыт арасы, гадәттә 3 минут була*)

ра́ут *м уст.* раут (*тантаналы чакырулы мәҗлес*)

ра́фик *м* рафик (*автомобиль*)

рафина́д *м* рафинад, рафинад шикәр; шакмаклы шикәр

рафини́рованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **рафини́ровать; 2.** тазартылган, чистартылган, арындырылган (*чит катнашмалардан*); **~ое ма́сло** чистартылган май **3.** *перен.* нәзакәтле, нечкә; **~ый вкус** нечкә зәвык

рафини́ровать *сов., несов. что* **1.** чистарту, тазарту, арындыру (*төрле чит катнашмалардан*); **~ медь** бакырны чит катнашмалардан арындыру **2.** рафинадлау, рафинад ясау; **~ са́хар** шикәрне рафинадлау

рахи́т *м* рахит, уа авыруы, уа (*балаларда сәяк авыруы*)

рахи́тик *м разг.* рахит бала, уа авырулы бала

рахити́ческ||ий, -ая, -ое, **рахити́чн||ый,** -ая, -ое рахитлы, уа (рахит) белән авырый торган

рацио́н *м* рацион (*билгеле бер срокка азык*)

рационализа́тор *м* рационализатор, рационаллаштыручы

рационализа́торск||ий, -ая, -ое рационализатор ...ы; **~ое предложе́ние** рационализатор тәкъдим

рационализи́ровать *сов., несов. что* рационаллаштыру, камилләштерү; **~ техноло́гию** технологияне рационаллаштыру

рационали́зм *м* **1.** *филос.* рационализм (*фикерләүне тойгы тәжрибәсеннән аера торган һәм гакылны танып белүнең бердән-бер чыганагы итеп саный торган идеалистик философия агымы*) **2.** (*рассудочность в поступках*) рационализм, акылга нигезләнгән булу

рационали́ст *м* **1.** *филос.* рационализм тарафдары, рационализм яклы кеше **2.** рационалист, акылга нигезләнеп эш итүче

рационалисти́ческ||ий, -ая, -ое **1.** рационализм ...ы; **~ие тео́рии** рационализм теорияләре **2.** акылга нигезләнгән, акылга муафыйк, рационалистик, рациональ...; **~ое сужде́ние** рациональ фикер йөртү

рационалисти́чный, -ая, -ое *см.* **рационалисти́ческий** 2; **~ посту́пок** рациональ кыланыш

рациона́льность *ж* **1.** рациональлек, акылга нигезләнгәнлек **2.** *мат.* рациональлек

рациона́льн||ый, -ая, -ое **1.** рациональ, акылга муафыйк, нигезле, төпле; **~ая мысль** нигезле фикер **2.** *мат.* рациональ; **~ое число́** рациональ сан

ра́ция *ж* рация (*күчмә радиостанция*)

ра́ч||ий, -ья, -ье кысла ...ы; **~ьи клешни́** кысла кыскычлары ♦ **~ьи глаза́** акай күзләр

рачи́тель *м уст.* кайгыртучы

рачи́тельный, -ая, -ое кайгыртучан, сакчыл, тырыш; **~ хозя́ин** сакчыл хуҗа

ра́шпиль *м* рашпиль (*эре сырлы игәү*)

рвану́||ть *сов.* **1.** *кого-что и без доп.* кинәт тарту, тартып жибәрү, тартып алу; **~ть за во́рот** якадан кинәт тарту **2.** кинәт кузгалу, алга ыргылу, кинәт кузгалып китү; **ло́шади ~ли** атлар кинәт кузгалдылар **3.** *разг.* китү, бару; **~ть в лес** урманга бару **4.** *что, разг.* эләктерү, эләктереп алу, кулга төшерү; **~ть изря́дный куш** зур акча кулга төшерү **5.** *что, разг.* тартып жибәрү, уйнап жибәрү; **гармони́ст ~л плясову́ю** гармунчы бию көен тартып жибәрде

рвану́||ться *сов.* ыргылу, атылу, чабып китү; кинәт кузгалып китү; **автомоби́ль ~лся с ме́ста** автомобиль урыннан кинәт кузгалып китте

рва́н||ый, -ая, -ое **1.** өзелгән, өзелеп беткән; **~ые ни́тки** өзелеп беткән жеплэр **2.** ертылып беткән, ертык, өзгәләнеп беткән; **~ая оде́жда** ертылып беткән кием **3.** *перен.* өзгәләнгән; **~ая ра́на** өзгәләнгән яра

рвань *ж собир. разг.* **1.** (*одежда*) ертык кием, тишек аяк киеме, ертык-портык (*ертылып беткән киемяки тишелеп беткән аяк киеме турында әйтелә*) **2.** *собир. спец.* (*остатки пряжи*) калдык-постык (*җеп, сус калдыклары*) **3.** *собир.* (*неимущие люди*) йолкышлар, сәләмәләр

рвать I *несов. что* **1.** суыру, тарту, суырып (тартып) алу; **~ зу́бы** тешләрне суыру **2.** өзү, йолку; **~ цветы́** чәчәкләр өзү **3.** ерту; **~ бума́гу** кәгазь ерту **4.** (*взрывать*) шартлату **5.** *перен.* туктату, бетерү, өзү; **~ отноше́ния** мөнәсәбәтләрне өзү **6.** *прост.* кулга төшерү, эләктерү; **~ куш** зур акча эләктерү **7.** *безл.* (*о жгучей боли*) авырту, авырттыру ♦ **~ го́рло** бугаз киерү; **~ и мета́ть** ≈ утлар чәчү (*бик нык ачулану мәгънәсендә*); **~ на себе́ во́лосы** чәчләрен йолку

рвать II *несов. безл. кого* косу, костыру; **больно́го рвёт** авыруны костыра

рва́ться *несов.* **1.** ертылу, тишелү; **бума́га рвётся** кәгазь ертыла **2.** шартлау, ярылу; **ми́ны рву́тся** миналар ярыла **3.** *перен.* (*нарушаться — о связях, отношениях*) өзелү, өзелеп тору, тукталу **4.** (*стремиться*) атлыгу, омтылу, ашкыну; **~ вперёд** алга атлыгу **5.** ычкынырга тырышу; **соба́ка рвётся с це́пи** эт чылбырдан ычкынырга тырыша **6.** *страд. от* **рвать** I 1-6

рвач *м разг.* ертлач, комсыз, рвач

рва́чество *с разг.* ертлачлык, рвачлык

рве́ние *с* зур тырышлык, ашкыну, атлыгу; **рабо́тать с ~м** ашкынып эшләү

рво́та *ж* косу, косык

рво́тное *с* костыргыч дару, костыра торган дару

рво́тн||ый, -ая, -ое косу ...ы, костыру ...ы; **~ые явле́ния** косу күренешләре

рде||ть, рдéться *несов.* кызару, кызарып тору, алсулану, алсуланып тору; **~ет ряби́на** миләш кызарып тора

ре *с нескл.* ре (*музыка гаммасында икенче нота*)

реабилита́ция *ж* аклау, реабилитация

реабилити́ровать *сов., несов. кого-что* **1.** аклау, реабилитацияләү, яхшы исемен кире кайтару; **~ своё и́мя** үзенең яхшы исемен кире кайтару **2.** (*в правах*) хокукларын кире кайтару, аклау

реабилити́роваться 1. *сов., несов.* аклану, реабилитацияләнү (*урынсыз тагылган гаеп алып ташлану*) **2.** *несов. страд. от* **реабилити́ровать**

реаги́ровать *несов.* **1.** *на что* реакция ясау, тәэсирләнү, каршы җавап бирү; **~ на раздраже́ние** ярсытуга реакция ясау **2.** *на что* илтифат итү, җавап кайтару; **~ на** *чьи-л.* **слова́** *кемнең дә булса* сүзләренә илтифат итү **3.** *хим.* реакциягә керү, реакция ясау

реакти́в *м хим.* реактив (*берәр матдә белән кушылып, реакция ясап, шул юл белән составында эзләнә торган матдәнән бармы-юкмы икәнен белергә мөмкинлек бирә торган матдә*)

реакти́вн||ый, -ая, -ое **1.** *хим.* реактив; **~ые вещества́** реактив матдәләр **2.** реактив (*газ агынтысы ярдәмендә хәрәкәткә килә торган*); **~ый самолёт** реактив самолёт

реа́ктор *м* реактор (*төрле физик-химик реакцияләр бара торган җайланма*); **а́томный ~** атом реакторы

реа́кторный, -ая, -ое реактор ...ы; **~ котёл** реактор казаны

реакцио́нер *м* реакционер, искелекне яклаучы, кадимче

реакцио́нерка *ж* реакционер хатын (кыз)

реакцио́нн||ый, -ая, -ое реакцион, искелек яклы; **~ая печа́ть** реакцион матбугат

реа́кция I *ж* **1.** *биол., физиол.* реакция, реакция ясау, җавап; **~ организ́ма на хо́лод** организмның салкынга реакциясе **2.** *хим.* реакция **3.** (*слабость после напряжения*) хәлсезләнү, хәлсезлек

реа́кция II *ж* реакция, кадимчелек (*җиңелгән яки үлеп бара торган изүче сыйныфларның, үзләренең хокукларын һәм хакимлеген кайтару яки саклау өчен, революцион хәрәкәтне, прогрессны каты бастыру сәясәте*)

реализа́ция *ж* **1.** реальләштерү, тормышка ашыру; **~ пла́на** планны тормышка ашыру **2.** сату, акчага әйләндерү; **~ проду́кции** продукцияне сату

реали́зм *м* **1.** *лит., иск.* реализм; **крити́ческий ~** критик реализм; **~ в иску́сстве** сәнгатьтәге реализм **2.** реализм, реальлек, аеклык, реаль караш; **~ в планиро́вании** планлаштырудагы аеклык

реализова́ть *сов., несов. что* **1.** тормышка (гамәлгә, эшкә) ашыру, үтәү; **~ все пла́ны** барлык планнарны тормышка ашыру **2.** сату, сатып бетерү; акчага әйләндерү, реализацияләү; **~ това́р** товарны сату

реализ||ова́ться 1. *сов., несов.* тормышка (гамәлгә эшкә) ашу; үтәлү; **план ~у́ется** план үтәлә **2.** *сов., несов.* сатылу, акчага әйләнү; **това́р ~у́ется** товар сатыла **3.** *несов. страд. от* **реализова́ть**

реали́ст *м* **1.** реалист, [тормышка] аек караучы; **быть ~ом** реалист булу **2.** *лит., иск.* реалист, реализм тарафдары; **писа́тели-~ы** реалист язучылар

реалисти́ческ||ий, -ая, -ое, **реалисти́чн||ый,** -ая, -ое **1.** реалистик, аек, тормышка аек карауга нигезләнгән; **~ое отноше́ние к жи́зни** тормышка аек карау **2.** реалистик, реализм ...ы, реализмга нигезләнгән; **~ое иску́сство** реализм сәнгате

реа́льност||ь *ж* **1.** чынбарлык; **исходи́ть из ~и** чынбарлыкны исәпкә алу; **объекти́вная ~ь** объектив чынбарлык **2.** реальлек, чынлык; аеклык; **~ь предположе́ния** тәкъдимнең реальлеге

реа́льн||ый, -ая, -ое **1.** реаль, чын, чынбарлыкта булган; **~ая си́ла** реаль көч **2.** аек, дөрес, реаль; **~ая поли́тика** реаль сәясәт **3.** реаль, тормышка ашарлык ..., тормышка аша торган; **~ая зада́ча** тормышка ашарлык бурыч ♦ **~ая за́работная пла́та** реаль эш хакы; **~ое учи́лище** *ист.* реаль училище (*революциягә кадәрге Россиядә: математика һәм табигать фәннәре күбрәк укытыла торган, ә борынгы телләр укытылмый торган урта уку йорты*)

реанима́тор *м* реаниматор, реанимация табибы (белгече)

реанима́ция *ж* реанимация (*клиник үлем хәлендәге организмны тергезү*)

ребёнок *м* бала, сабый, нәни, бәби, нарасый; **грудно́й ~** имчәк баласы

рёберн||ый, -ая, -ое кабырга ...ы; **~ые ко́сти** кабырга сөякләре

ребри́ст||ый, -ая, -ое кабыргалы, сырлы; **~ая пове́рхность** сырлы өслек

ребро́ *с* **1.** *анат.* кабырга **2.** *мат.* кабырга; **~ ку́ба** кубның кабыргасы **3.** кабырга, чит, кырый; **поста́вить до́ску ~м** тактаны кырые белән кую ♦ **одни́ рёбра оста́лись** коры сөяккә калган, кабыргалары күренеп тора; **пересчита́ть рёбра** *кому* кабыргасын санау (*кыйнау мәгънәсендә*); **поста́вить вопро́с ~м** мәсьәләне кабыргасы белән кую

ре́бус *м* ребус, рәсемле табышмак; **разгада́ть ~** ребусны чишү

ребя́та *мн.* **1.** (*дети*) балалар **2.** *разг.* (*молодые люди*) егетләр, яшь-жилкенчәк

ребя́ческий, -ая, -ое **1.** сабый ...ы; бала ...ы; **~ крик** бала тавышы **2.** балаларча ..., балаларга хас; **~ посту́пок** балаларча кыланыш

ребя́чество *с* балалык, балаларча кылану; **впасть в ~** балаларча кылану

ребя́чий, -ья, -ье *см.* **ребя́ческий** 2

ребя́читься *несов. разг.* балалану, бәбиләну, балаларча кылану

ребя́чливый, -ая, -ое балаларча тотучан; балаларга хас, баласыман

рёв *м* **1.** үкерү, акыру; улау; **~ быка́** үгез үкерүе; **~ ве́тра** җилнең улавы **2.** *разг.* үкереп елау, акырып елау; **де́ти по́дняли ~** балалар үкереп елый башладылар

рева́нш *м* реванш, үч кайтару (*җиңелгән өчен үч алу*)

реванши́зм *м полит.* реваншизм (*җиңелгәннән соң өстен чыгарга омтылу*)

реванши́ст *м полит.* реваншчы, үч алучы

реванши́стск||ий, -ая, -ое *полит.* реваншчылык ...ы, үч алучылык ...ы; **~ая поли́тика** реваншчылык сәясәте

рева́нс *м* реванс (*тез үчгә исәнләшү*)

рев||е́ть *несов.* **1.** үкерү, үкерешү; акыру, бакыру; улау; **быки́ ~у́т** үгезләр үкерешә; **бу́ря ~ёт** давыл улый **2.** *разг.* үкерү, үкереп елау, акырып елау; **де́ти ~е́ли** балалар үкереп елыйлар иде

ревизони́зм *м полит.* ревизионизм

ревизони́ст *м полит.* ревизияче, ревизионизмны яклаучы, ревизионизм тарафдары

реви́зия *ж* **1.** (*обследование*) ревизия, ревизияләү, тикшерү **2.** (*пересмотр*)

яңадан карау; ревизияләү; ~ **реше́ний** карарларны яңадан карау **3.** *ист.* сан алу, ревизия (*18 йөздә һәм 19 йөз башларында: имана туләтү өчен авыл һәм шәһәр халкының санын алу*)

ревизова́ть *сов., несов.* **1.** *кого-что* ревизия ясау, ревизияләү, тикшерү; ~ **магази́н** кибеткә ревизия ясау **2.** *что* яңадан карау, ревизияләү; ~ **реше́ния** карарларны ревизияләү

ревизо́р *м* **1.** ревизияче, ревизор, ревизия ясаучы; тикшерүче **2.** ревизор (*тимер юлда контролёр*)

ревко́м *м* ревком (революцион комитет)

ревмати́зм *м* ревматизм, буын сызлау

ревмати́к *м разг.* ревматик, ревматизм белән авыручы; буыны сызлаучы кеше

ревмя́: ~ **реве́ть** *прост.* үкереп елау, үкереп-үкереп слау

ревни́вец *м разг.* көнче, көнче кеше

ревни́вица *ж разг.* көнче хатын (кыз)

ревни́в||ый, -ая, -ое көнләшүчән, көнләү, көнче ..., көнчелекле; ~**ая же́нщина** көнче хатын; ~**ый взгляд** көнчелекле караш

ревни́тель *м книжн.* кайгыртучы, көрәшүче; ~ **просвеще́ния** мәгърифәт өчен көрәшүче

ревнова́ть *несов. кого и без доп.* көнләү, көнләшү

ре́вностный, -ая, -ое *книжн.* тырыш, ихлас, ихлас күңелле; кайгыртучан; ~ **рабо́тник** тырыш хезмәткәр

ре́вность *ж* көнчелек, көнләшү, көнләү

револьве́р *м* револьвер; алтатар *уст.*

револьве́рн||ый, -ая, -ое револьвер ...ы; ~**ая кобура́** револьвер кобурасы

революционе́р *м* инкыйлабчы, революционер, революцияче (**1.** *революциядә катнашучы, революция тарафдары* **2.** *тормышның, фәннең яки мәдәниятнең нинди дә булса өлкәсендә яңа юл ачкан, революция ясаган кеше*)

революционизи́ровать *сов., несов.* **1.** *кого-что* революционлаштыру, революция яклы ясау; ~ **ма́ссы** массаларны революционлаштыру **2.** *что* бөтенләй яңарту; тамырыннан үзгәртү, тамырыннан үзгәртеп кору; ~ **те́хнику** техниканы бөтенләй яңарту

революционизи́роваться 1. *сов., несов.* революционлашу, революция яклы булу **2.** *несов. страд. от* **революционизи́ровать**

революцио́нность *ж* революционлык; ~ **взгля́дов** карашларның революционлыгы

революцио́нн||ый, -ая, -ое революцион; ~**ая борьба́** революцион көрәш

револю́ция *ж* революция; инкыйлаб; **социалисти́ческая** ~ социалистик революция

ревтрибуна́л *м ист.* ревтрибунал (революцион трибунал)

ревю́ *с* ревю (*актуаль темага караган эстрада постановкасы*)

рега́лии *мн. уст.* **1.** регалий (*монарх хакимият символы булып торган әйбер: таҗ, патша таягы һ.б.ш.*) **2.** *разг. шутл.* регалия, регалий (*орденнар, бүләк билгеләре*)

рега́та *ж спорт.* регата (*көймәләр кашнашкан зур ярыш*)

ре́гби *с нескл. спорт.* регби

регенерати́вный, -ая, -ое *тех.* регенерация ...ы, регенератив; ~**ая печь** регенерация миче

регенера́ция *ж* регенерация, регенерацияләү, регенерацияләнү (**1.** *тех. производство отходларын эшкәртеп башта булган продукцияне яңадан табу* **2.** *биол. организм югалткан әгъзаларны, тукымаларны, күзәнәкләрне яңадан торгызу* **3.** *радиоалгычның мөстәкыйль рәвештә радиодулкыннар нурландыруы*)

ре́гент *м* регент (**1.** *полит. монарх урынына вакытлыча патшалык итүче* **2.** *чиркәү дирижёры*)

ре́гентство *с* регентлык (**1.** *полит. монарх урынына вакытлыча идарә итү* **2.** *чиркәүдә дирижёрлык итү*)

регио́н *м* регион

регионáльный, -ая, -ое региональ, җирле; өлкәара; ~ **догово́р** региональ килешү

реги́стр *м* регистр (**1.** *берәр нәрсәнең исемлеге, күрсәткече, теркәү кенәгәсе* **2.** *музыкаль инструментның, тавышның югарылык һәм көч дәрәҗәсе* **3.** *музыкаль инструментларда: тавышның көчен, тембрын, югарылыгын үзгәртү җайланмасы* **4.** *приборларда һәм машиналарда регулятор* **5.** *язу машинкасының клавишлар рәте*)

регистра́тор *м* теркәүче, регистратор, язып торучы; ~ **поликли́ники** поликлиника регистраторы

регистрату́ра *ж* регистратура

регистрацио́нный, -ая, -ое теркәү ...ы, регистрация ...ы, регистрацияләү ...ы; ~ **лист** теркәү кәгазе

регистра́ция *ж см.* **регистри́ровать, регистри́роваться**

регистри́ровать *сов., несов. кого-что* теркәү, язып бару; теркәп тору, язып тору, регистрация ясау, регистрацияләү; ~ **делега́тов** делегатларны регистрацияләү; ~ **поступа́ющие бума́ги** керә торган кәгазьләрне теркәү

регистри́роваться *сов., несов.* **1.** (*записываться*) теркәлү, регистрацияләнү **2.** (*оформлять брак*) язылу, язылышу (*загста*) **3.** *страд. от* **регистри́ровать**

регла́мент *м* регламент; **соблюда́ть** ~ регламент санлау; **установи́ть** ~ регламент билгеләү

регламенти́ровать *сов., несов. кого-что* регламент билгеләү (кую), регламентлаштыру; тәртипкә салу; ~ **выступле́ния** чыгышларга регламент билгеләү

регре́сс *м книжн.* регресс, артка китү, кире китү

регрессúвн||ый, -ая, -ое *книжн.* **1.** регрессив; ~**ый проце́сс** регрессив процесс **2.** регрессив, кадим; ~**ое явле́ние** регрессив күренеш ◆ ~**ая ассимиля́ция** *лингв.* регрессив ассимиляция

регресси́ровать *несов. книжн.* артка китү, кире китү, регресслашу; ~ **в разви́тии** үсештә кире китү

регули́ровать *несов. что* **1.** тәртипкә салу, тәртипкә салып тору, җайга салу, җайга салып тору; ~ **у́личное движе́ние** урам хәрәкәтен тәртипкә салу; ~ **рыночные це́ны** базар хакларын тәртипкә салу **2.** көйләү; ~ **мото́р** моторны көйләү

регулиро́вка *ж см.* **регули́ровать;** ~ **мото́ра** моторны көйләү

регулиро́вщик *м* регулировщик; ~ **у́личного движе́ния** урам хәрәкәте регулировщигы

регулиро́вщица *ж* регулировщик хатын (кыз)

ре́гулы *только мн.* күрем, айлык

регуля́рн||ый, -ая, -ое **1.** регуляр, тәртипле, үз вакытында ...; тәртипле рәвештә ...; ~**ое пита́ние** тәртипле рәвештә туклану **2.** регуляр; ~**ая а́рмия** регуляр армия

регуля́тор *м* **1.** *тех.* көйләгеч, регулятор; ~ **ско́рости** тизлек көйләгече **2.** *перен. книжн.* (*то, что регулирует, направляет*) җайга салучы, җайлаучы; юнәлдерүче көч

=ред *рус телендәге кыскартылма сүзләрнең икенче кисәге, «редактор» дигән мәгънәне белдерә*: **главре́д** баш редактор; **техре́д** техник редактор

ред= *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, «редакция», «редакцион» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **редсове́т** редсовет; **редотде́л** редотдел

редакти́рование *с см.* **редакти́ровать;** ~ **статьи́** мәкаләне редакцияләү

редакти́ровать *сов., несов. что* **1.** редакцияләү, редакция ясау; ~ **статью́** мәкаләне редакцияләү **2.** редакторлык итү, редактор булып эшләү, мөхәррирлек кылу; ~ **газе́ту** газетада редактор булып эшләү

реда́ктор *м* редактор, мөхәррир

реда́кторск||ий, -ая, -ое редактор ...ы, мөхәррир ...ы; ~**ие обя́занности** редактор вазифалары

реда́кторство *с* редакторлык, мөхәррирлек; редактор эше

реда́кторствовать *несов. разг.* редактор (мөхәррир) булып эшләү

реда́кци||я *ж* **1.** (*редактирование*) редакция, редакцияләү; ~**я те́кста** текстны редакцияләү **2.** *в разн. знач.* редакция; **но́вая** ~**я рома́на** романның яңа редакциясе; **уче́бник под** ~**ей профе́ссора** профессор редакциясендәге дәреслек; **гла́вная** ~**я** баш редакция

ред||е́ть *несов.* сирәгәю, сирәкләнү, сирәгә бару, сирәкләнә бару; **лес** ~**е́ет** урман сирәгәя бара; **толпа́** ~**е́ет** халык сирәгәя бара

реди́с *м* төче торма, редис

реди́ска *ж разг.* редиска

ре́дк||ий, -ая, -ое **1.** сирәк; ~**ий гость** сирәк кунак; ~**ие дере́вья** сирәк агачлар **2.** сирәк, сирәк була торган, сирәк табыла (очрый) торган; ~**ая кни́га** сирәк очрый торган китап; ~**ая красота́** сирәк очрый торган матурлык; ~**ий тала́нт** сирәк очрый торган талант;

~ий слу́чай сирәк очрак; **~ие мета́ллы** сирәк металлар

редколе́сье *ж* сирәк урман

ре́дкост||ый, -ая, -ое *см.* **ре́дкий** 2; **~ые спосо́бности** сирәк була торган сәләт

ре́дкость *ж* **1.** сирәк очрау, сирәк булу, сирәк очрый торган хәл; **опозда́ние бы́ло ~ю** соңга калу бик сирәк була иде **2.** (*редкая вещь*) сирәк очрый (табыла) торган әйбер ♦ **на ~** гадәттән тыш, бик; **на ~ сме́лый челове́к** гадәттән тыш кыю кеше

реду́ктор *м* редуктор

реду́кция *ж* **1.** редукция (*катлаулы куренешне гади куренешкә күчерү*) **2.** *тех.* кимү; **~ давле́ния па́ра** пар басымының кимүе **3.** *лингв.* кыскару, редукция; **~ гла́сных** сузыкларның кыскаруы

редупликáция *ж лингв.* редупликация, редупликацияләү, кабатлану

реду́т *м уст. воен.* редут (*хәрби ныгытма*)

редуци́рованный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **редуци́ровать; 2.** *лингв.* кыскарган, кыскартылган; **~ гла́сный** кыскарган сузык

редуци́ровать *сов., несов. что* редукцияләштерү, гадиләштерү, кыскарту, кимету

редуци́роваться 1. *сов., несов.* (*сократиться*) редукцияләнү, гадиләшү, кыскару, кимү **2.** *несов. страд. от* **редуци́ровать**

ре́дька *ж* торма, ачы торма

реéстр *м* исемлек, реестр; **~ докуме́нтов** документлар исемлеге

режи́м *м* **1.** (*государственный строй*) режим; **демократи́ческий ~** демократик режим **2.** тәртип, режим; **~ дня** көн тәртибе **3.** кагыйдә, кагыйдәләр; **~ хране́ния овоще́й** яшелчәләр саклау кагыйдәләре **4.** шарт, режим; **~ рабо́ты обору́дования** җайланманың эшләү шартлары ♦ **~ эконо́мии** экономия режимы

режиссёр *м* режиссёр

режиссёрский, -ая, -ое режиссёр [-лар] ...ы; режиссёрлык; **~ факульте́т** режиссёрлар факультеты

режисси́ровать *несов. что* режиссёрлык итү, режиссёры булу; **~ о́перу** операга режиссёрлык итү

режиссу́ра *ж* **1.** (*деятельность режиссёра*) режиссёрлык, режиссёр эше **2.** (*руководство постановкой*) режиссура, постановка белән җитәкчелек итү **3.** *собир.* режиссёрлар

ре́жущий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **ре́зать; 2.** кисә торган, кисүче; **~ инструме́нт** кисә торган инструмент **3.** (*о боли*) каты, борып ала торган

реза́к *м* **1.** чапкы, зур пычак **2.** көрәкчек (*штукатурларда*) **3.** *тех.* кискеч, чапкыч (*инструментларда, машиналарда*) **4.** *археол.* ташбалта

ре́зальщик *м* **1.** кисүче; **~ стекла́** пыяла кисүче **2.** балык кисүче

ре́зан||ый, -ая, -ое **1.** киселгән; **~ый хлеб** киселгән икмәк; **~ая ра́на** киселгән яра **2.** *спорт.* кистереп ..., кистереп сугылган (бәрелгән); **~ый уда́р** кистереп сугу; **~ый мяч** кистереп сугылган туп

ре́зательный, -ая, -ое кисә торган, чаба торган; **~ стол** кисә торган өстәл

ре́зать *несов.* **1.** *что* кисү, чабу; турау; **~ мя́со** ит кисү; **~ хлеб** икмәк турау **2.** *кого-что, разг.* яру, кисеп ачу; **~ нары́в** чуанны яру **3.** үтү; кису; **но́жницы не ре́жут** кайчы үтми **4.** *кого-что* сую, чалу, бугазлау; **~ гусе́й** казларны сую **5.** *что, по чему, на чём* уеп рәсем ясау, кисеп рәсем төшерү; **~ по де́реву** агачка уеп рәсем ясау **6.** *что и без доп.* бору, чәнчү, авырттыру; **ре́жет в животе́** *безл.* эчне чәнчә **7.** *перен. что* чагылдыру, камаштыру, кису; **свет ре́жет глаза́** яктылык күзне чагылдыра **8.** *перен. что* ярып әйтү, ярып салу, туры әйтү, бәреп әйтү; **~ пра́вду в глаза́** хакыйкатьне күзенә бәреп әйтү **9.** *что, спорт.* кистерү, кистереп бәрү; кистереп сугу; **~ мяч** тупны кистереп сугу ♦ **у́хо ре́жет** колаклы яра

ре́заться *несов.* **1.** (*разделяться на части*) киселү, киселеп чыгу; **мя́со пло́хо ре́жется** ит начар киселә **2.** (*о зубах*) чыгу **3.** *во что, прост.* уйнау, бик каты уйнау; **~ в ка́рты** кәрт уйнау **4.** *страд. от* **ре́зать** 1, 2, 4, 5, 9

резв||и́ться *несов.* чабышып йөрү, уйнау, шаяру; чыр-чу килү; **жереба́та ~я́тся** колыннар чабышып йөриләр; **де́ти ~я́тся** балалар уйныйлар

ре́зв||ый, -ая, -ое **1.** елгыр, җитез, шаян, шук; **~ый ребёнок** шук бала **2.** елдам, шәп; **~ая ло́шадь** елдам ат

резеда́ *ж* резеда, мәхәббәт чәчәге

резе́кция *ж мед.* резекция, кисеп алу (*органның авыру өлешен кисеп алу операциясе*)

резе́рв *м* **1.** резерв; запас; **продово́льственные ~ы** азык запасы **2.** резерв; **кома́ндования** *воен.* командование резервы ♦ **трудовы́е ~ы** хезмәт резервлары (*махсус училищеларда эшче квалификациясе алучы яшьләр; 1959 елга кадәр*)

резерви́ровать *сов., несов. что* резервта саклау (калдыру); **~ запа́сы не́фти** нефть запасларын резервта саклау

резерви́ст *м воен.* резервчы, резервист (*кайбер илләрнең армияләрендә: хәрби хезмәттән соң резервта санала торган кеше*)

резе́рвный, -ая, -ое резервтагы, резерв...; **~ капита́л** резерв капитал; **~ полк** *воен.* резервтагы полк

резервуа́р *м* резервуар, сыем, савыт; **~ для воды́** су саклау резервуары

резе́ц **1.** кискеч; **тока́рный ~** кыру кискече **2.** (*передний зуб*) кискеч теш; алгы теш

резиде́нт *м* резидент (**1.** *посланниктан бер ранг ким булган дипломатия вәкиле* **2.** *чит илдә даими рәвештә яшәүче башка ил гражданины* **3.** *чит илдә разведканың яшерен вәкиле*)

резиде́нция *ж* резиденция (*хөкүмәтнең яки хөкүмәт башлыкларының тора торган урыны*)

рези́нка *ж* **1.** резинка, бозгыч, бетергеч (*язылганны бетерү өчен*); **черни́льная ~** кара белән язылганны бетергеч **2.** резинка (*резинлы яки резин сеңдерелгән тасма яки җеп*)

рези́нов||ый, -ая, -ое **1.** резин ...ы; **~ое произво́дство** резин производствосы **2.** резин, резиннан ясалган; резинлы; **~ый мяч** резин туп

ре́зк||ий, -ая, -ое **1.** кискен, зәһәр, ачы; **~ий ве́тер** кискен җил; **~ий хо́лод** ачы салкын **2.** кинәт, капыл, кисәк кенә; **~ое паде́ние температу́ры** температураның кинәт төшүе **3.** (*слишком яркий — о свете*) күзне чагалдыргыч, күзне камаштыргыч; (*слишком громкий — о голосе, звуке*) ачы, көчле **4.** кискен, тиз; **~ое движе́ние** кискен хәрәкәт **5.** кискен, ачык; **~ие черты́ лица́** кискен кыяфәт **6.** каты, кискен, тупас; **~ая кри́тика** каты тәнкыйть

ре́зкост||ь *ж* **1.** (*напр. ве́тра, хо́лода*) кискенлек, зәһәрлек **2.** (*внезапность*) кинәтлек, капыллык **3.** (*света*) күзне чагылдыргыч (камаштыргыч) булу; (*го́лоса, звука*) ачылык, көчлелек **4.** (*движения*) кискенлек, тизлек **5.** (*напр. критики*) катылык, кискенлек, тупаслык **6.** (*резкие слова*) каты сүз, кискен сүз; **говори́ть ~и** каты сүзләр әйтү

резн||о́й, -а́я, -о́е **1.** киселгән ясалган; **~ы́е ша́хматы** кисеп ясалган шахмат **2.** сырланган, уеп рәсем ясалган, кисеп (уеп) рәсем төшерелгән; сырлы; **~о́й шкаф** уеп рәсем ясалган шкаф

резня́ *ж* суеш, суешу, үтереш; **крова́вая ~** канлы суеш

резолюти́вн||ый, -ая, -ое карар ...ы, резолюция ...ы, резолютив, резолюцияле; **~ая часть постановле́ния** карарның резолюция өлеше

резолю́ци||я *ж* **1.** резолюция; карар; **приня́ть ~ю** карар кабул итү **2.** резолюция; **наложи́ть ~ю** резолюция салу

резо́н *м разг.* мәгънә, нигез; дәлил; **не ~ е́хать** барудан мәгънә юк

резона́нс *м прям., перен.* резонанс, яңгыраш; **в за́ле хоро́ший ~** залның яңгырашы яхшы; **статья́ име́ла большо́й ~** мәкалә зур яңгыраш тапты; **междунаро́дный ~** халыкара резонанс

резона́тор *м физ., тех.* резонатор, тавыш көчәйткеч (*әсбап*)

резонёр *м* **1.** акыл сатучы, ләчтит сатучы, резонёр **2.** *лит., театр.* резонёр (*пьесада, романда: авторның вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен белдергән персонаж*)

резонёрство *с* акыл сату, резонёрлык

резонёрствовать *несов.* акыл сату, ләчтит сату, үгет-нәсихәт уку

резони́р||овать *несов.* **1.** (*давать резонанс*) резонанс бирү, резонанслау; **сте́ны за́ла хорошо́ ~уют** зал стеналары яхшы резонанс бирә **2.** (*получать резонанс*) резонанс алу, көчәю; **зву́ки ~уют** авазлар көчәя

резо́нный, -ая, -ое *разг.* нигезле, төпле, дәлилле; **~ отве́т** дәлилле җавап

результа́т *м* нәтиҗә, сөзәмтә, йомгак; **~ы рабо́ты** эшнең нәтиҗәләре; **~ы спортсме́на** спортсменның нәтиҗәләре;

в ~е 1) (*в итоге*) ахырда, нәтиҗәдә; 2) (*вследствие чего-л.*) нәтиҗәсендә, аркасында; **в ~е боле́зни** авыру аркасында

результати́вн||ый, -ая, -ое нәтиҗәле, нәтиҗәсе булган; **~ая встре́ча** нәтиҗәле очрашу; **~ый игро́к** нәтиҗәле уенчы

ре́зчик *м* **1.** (*резальщик*) кисүче, чабучы, тураучы **2.** уючы, уеп рәсем ясаучы, кисеп бизәк ясаучы; **~ по мра́мору** мәрмәр уючы; **~ по де́реву** агачка уеп рәсем ясаучы

резь *ж* эчне чәнчү, эчне бору; **~ в животе́** эчне бора

резьба́ *ж* **1.** *см.* **резать** 5; **2.** (*узор*) уеп ясалган бизәк, кисеп ясалган рәсем, сырлап ясалган бизәк **3.** *тех.* (*винтовая нарезка*) сыр, винт сыры

резюме́ *с* кыскача йомгак, резюме; **~ докла́да** докладның кыскача йомгагы

резюми́ровать *сов., несов. что* йомгаклау, резюме ясау, кыскача йомгак ясау; **~ ска́занное** әйтелгәннәрне йомгаклау

рейд I *м мор.* рейд (*портта яки порт янында якорь ташлап суднолар торырга уңайлы урын*)

рейд II *м* рейд (**1.** *воен. тиз хәрәкәтле хәрби көчларнең дошман тылына үтеп керүе* **2.** *җәмәгатьчелек вәкилләре тарафыннан үткәрелә торган тикшерү*)

ре́йдер *м* рейдер (*диңгез юлларында мөстәкыйль рәвештә дошманның транспорт, сәүдә судноларын юкка чыгару эшен алып баручы корабль*)

ре́йдов||ый I, -ая, -ое *мор.* рейд ...ы, рейдтагы; **~ая стоя́нка** рейдтагы туктале

ре́йдовый II, -ая, -ое рейд ...ы; **~ отря́д** рейд отряды

ре́йка *ж* **1.** тар такта, тар борыс, рейка **2.** *геод.* рейка; **снегоме́рная ~** карүлчәгеч рейка

рейс *м* рейс, юл; **обра́тный ~** кире юл; **сде́лать оди́н ~** бер рейс ясау

ре́йсовый, -ая, -ое рейс ...ы; **~ самолёт** рейс самолёты

рейсфе́дер *м* рейсфедер (*тушь белән сызу әсбабы*)

рейсши́на *ж* рейсшина (*сызым линейкасы*)

рейту́зы *только мн.* **1.** рейтуз, тар чалбар **2.** рейтуз (*хатын-кызларның яки балаларның бәйләнгән ыштаны*)

рейхста́г *м* рейхстаг

рек||а́ *ж* **1.** елга, дәрья; **бе́рег ~и́** елга яры; **мост че́рез ре́ку** елга аша күпер **2.** *в знач. нареч.* **~о́й** ташкын булып, ташкын кебек; дәрья булып; **слёзы льются ~о́й** күз яшьләре дәрья булып ага

ре́квием *м* реквием (**1.** *католикларда үлгән кешене искә алып гыйбадәт кылу* **2.** *траурлы музыка әсәре*)

реквизи́ровать *сов., несов. кого-что* реквизицияләү, реквизиция ясау

реквизи́т *м театр.* реквизит (*театр уйнаганда кулланыла торган чын яки бутафор җиһазлар*)

реквизи́ция *ж* реквизиция

рекла́ма *ж* реклама; рекламалау; **театра́льная ~** театр рекламасы; **~ но́вых това́ров** яңа товарларны рекламалау

реклама́ци||я *ж* рекламация, дәгъва; **заяви́ть ~ю** рекламация белдерү

реклами́ровать *сов., несов. кого-что* **1.** рекламалау, реклама бирү, реклама ясау, реклама белән игълан итү; **~ това́р** товарны рекламалау **2.** (*чрезмерно расхваливать*) үтә мактау, артык мактау

рекла́мн||ый, -ая, -ое **1.** реклама [-лар] ...ы; **~ый отде́л** реклама бүлеге **2.** рекламалы, рекламадан гыйбарәт, реклама характерындагы; **~ая статья́** рекламадан гыйбарәт мәкалә

рекогносци́ровать *сов., несов. что* рекогносцирлау, рекогносцировкалау, тикшерү; **~ ме́стность** урынны рекогносцировкалау

рекогносцирово́вка *ж см.* **рекогносци́ровать; ~ ме́стности** урынга рекогносцировка ясау

рекоменда́тельн||ый, -ая, -ое рекомендация ...ы, рекомендацияле; **~ое письмо́** рекомендация хаты

рекоменда́ци||я *ж* **1.** (*отзыв*) рекомендация; **дать ~ю** рекомендация бирү **2.** (*совет*) тәкъдим, рекомендация; **~и комиссии** комиссия тәкъдимнәре

рекомендова́ть *сов., несов.* **1.** *кого-что* тәкъдим итү, рекомендация бирү; **~ на рабо́ту** эшкә тәкъдим итү **2.** *что и с неопр.* киңәш бирү, киңәш итү; **~ отдохну́ть** ял итәргә киңәш бирү

реконструи́ровать *сов., несов. что* **1.** (*переустроить*) реконструкцияләү, реконструкция ясау, яңартып төзү (кору) **2.** (*воссоздать*) торгызу, яңадан торгызу (ясау)

реконструи́роваться 1. *сов., несов.* реконструкцияләнү, реконструкция ясалу, яңартып төзелү (корылу) **2.** *несов. страд. от* **реконструи́ровать**

реконстру́кция *ж см.* **реконструи́ровать**

реко́рд *м* рекорд; **мирово́й ~** дөнья рекорды; **установи́ть ~** рекорд кую

рекорди́ст *м* (*о домашнем животном*) рекордист, рекордчы (*үзенең берәр сыйфаты буенча рекорд курсәткечләргә ия йорт хайваны*)

реко́рдн||ый, -ая, -ое рекорд ..., иң югары; **~ый срок** рекорд срок; **~ые достиже́ния** рекорд уңышлар

рекордсме́н *м* рекорд куючы, рекордсмен

рекордсме́нка *ж* рекорд куючы хатын (кыз), рекордсмен хатын (кыз)

ре́крут *м ист.* никрут, рекрут (*элекке Россиядә хәрби хезмәткә чакырылган кеше*)

рекру́тчина *ж разг. уст.* рекрутчина, никрутлык йөкләмәсе

ректифика́т *м хим.* ректификат (*мәс. чиста спирт*)

ректифика́ция *ж хим.* ректификация, ректификацияләү

ректифици́ровать *сов., несов. что, хим.* ректификацияләү, ректификация ясау, тазарту; **~ спирт** спиртны ректификацияләү

ре́ктор *м* ректор

ректора́т *м* ректорат

ре́кторский, -ая, -ое ректор ...ы; **~ кабине́т** ректор кабинеты

ре́кторство *с* ректорлык, ректорлык вазифасы

реле́ *с нескл.* реле (*электр чылбырын автомат рәвештә тоташтыручы яки өзүче чылбыр*)

реле́йн||ый, -ая, -ое реле ...ы; **~ая устано́вка** реле җайланмасы

религио́зн||ый, -ая, -ое **1.** дин ...ы, дини; **~ые обря́ды** дин йолалары; **2.** (*о человеке*) динле, диндар

рели́гия *ж* дин; **мусульма́нская ~** ислам дине; **христиа́нская ~** христиан дине

рели́квия *ж* реликвия, ядкарь, истәлекле әйбер; **семе́йная ~** гаиләнең истәлекле әйбере

рели́кт *м* реликт (*борыннан сакланып калган организм, әйбер, күренеш*)

рели́ктов||ый, -ая, -ое реликт...; **~ое расте́ние** реликт үсемлек

рельє́ф *м* рельеф, өске йөзе; **~ бе́рега** ярның өске йөзе; **~ морско́го дна** диңгез төбе рельефы

рельє́фн||ый, -ая, -ое кабарынкы, чыгып торган, рельефлы; **~ые бу́квы** кабарынкы хәрефләр

рельс *м* рельс; **уложи́ть ~ы** рельс салу ◆ **на ~ы** *чего* (*перейти, перевести*) ... рельсына (*күчү, күчерү*); **поста́вить на ~ы** *что* ходка җибәрү, рельска кую

ре́льсов||ый, -ая, -ое **1.** рельс ...ы; **~ая сталь** рельс корычы **2.** рельслы; **~ая доро́га** рельслы юл

рельсопрока́тный, -ая, -ое рельс прокатлау ...ы; **~ стан** рельс прокатлау станы

реляти́ви́зм *м филос.* релятивизм (*идеалистик фәлсәфи тәгълимат*)

реляти́ви́ст *м филос.* релятивист, релятивизм тарафдары

реляти́вный, -ая, -ое *книжн.* (*относительный*) релятив

реля́ция *ж уст.* реляция (*электә: сугыш барышы турында командирның язма рәвештә хәбәр итүе*)

рема́рка *ж* **1.** (*замечание*) билге, искәрмә **2.** *театр.* ремарка, аңлатма (*авторның обстановка һәм актёрлар үзләрен ничек тотарга тиешлеге турында пьеса текстына биргән аңлатмасы*)

реме́нь *м* **1.** каеш; **пояснóй ~** бил каешы; **~ молоти́лки** суккыч каешы **2.** *мн.* **ремни́** каеш, бау; **ремни́ багажа́** багаж бавы

реме́сленник *м* **1.** һөнәрче; кәсепче; **ме́лкий ~** вак һөнәрче **2.** ремесленник (*1958 елга кадәр һөнәрчелек училищесендә укучы*)

реме́сленничать *несов.* **1.** һөнәрчелек итү, кәсеп итү, һөнәрчелек белән шөгыльләнү **2.** *перен.* һөнәрчеләрчә эшләү, кәсепчеләрчә эшләү (*нинди дә булса иҗади эштә өстән-өстән генә эшләү*)

реме́сленническ||ий, -ая, -ое кәсепчеләрчә..., һөнәрчеләрчә...; **~ое отноше́ние к иску́сству** сәнгатькә кәсепчеләрчә мөнәсәбәт

реме́сленн||ый, -ая, -ое **1.** һөнәрче ...ы, һөнәрчелек ...ы; **~ый труд** һөнәрче

хезмәте **2.** (*неискусный*) кәсепчеләрчә ..., һөнәрчеләрчә ..., тупас ◆ **~ое учи́лище** һөнәрчелек училищесе (*1958 елга кадәр*)

ремесло́ *с* һөнәр, кәсеп, кул эше

реми́з *м* ремиз (**1.** *кайбер кәрт уеннарында: тиешле взятканы җыя алмау яки җыя алмаган өчен штраф* **2.** *фехтованиедә: кисәтү өчен сугу*)

ремилитариза́ция *ж* ремилитаризация, яңадан кораллану, яңадан коралландыру

ремилитаризова́ть *сов., несов. что* яңадан коралландыру, ремилитаризация үткәрү, ремилитаризацияләү

реминисце́нция *ж книжн.* **1.** (*смутное воспоминание*) томанлы хәтерләү, томанлы гына искә төшерү **2.** реминисценция, йогынтысы чагылу (*берәр кешенең художество әсәрендә кемнең дә булса иҗаты йогынтысы чагылышы*)

ремо́нт I *м* ремонт, төзәтү, ямау, салу, сипләү; **~ до́ма** өй сипләү; **часо́в** сәгать төзәтү; **текущи́й ~** агымдагы ремонт

ремо́нт II *м с.-х.* тутыру, тулыландыру; **~ поголо́вья скота́** терлек санын тулыландыру (*яшь терлек исәбенә*)

ремонти́ровать *сов., несов. что* ремонтлау, ремонтлату, ремонт ясау; төзәтү, төзәттерү; ямау, ямату; сипләү, сипләтү; **~ часы́** сәгатьне төзәттерү; **~ школу́** мәктәпне ремонтлату

ремо́нтник *м* ремонтчы, ремонт эшчесе; **брига́да ~ов** ремонтчылар бригадасы

ремо́нтн||ый, -ая, -ое ремонт ...ы, ремонтлау ...ы; **~ые рабо́ты** ремонт эшләре

ренатурализа́ция *ж юр.* гражданлык хокукын кайтару, ренатурализация (*берәр сәбәп белән гражданлык хокукын югалткан кешеләр турында*)

ренатурализова́ть *сов., несов. кого, юр.* гражданлык хокукын кайтару, яңадан гражданлык хокукын бирү, ренатурализацияләү

ренега́т *м* ренегат, мөртәт, хыянәтче, сатлык кеше

ренега́тка *ж* ренегат хатын (кыз), хыянәтче хатын (кыз)

ренега́тство *с* ренегатлык, мөртәтлек, хыянәт

Ренессе́нс *м* Ренессанс (*урта гасырдан соң капиталистик мөнәсәбәтләрнең тууына бәйләнешле рәвештә һәм үзәк Европада фәннәрнең һәм сәнгатьнең чәчәк атуы белән характерлана торган чор*)

рене́т *м см.* **ране́т**

ренкло́д *м* ренклод (*төгәрәк слива*)

ре́нта *ж* рента, табыш (*капиталдан, милектән яки җирдән бернинди дә көч тукмичә килә торган файда*)

рента́бельность *ж* рентабельлелек, табышлылык

рента́бельн||ый, -ая, -ое рентабельле, табышлы, табыш бирә торган, файда бирә торган; **~ое хозя́йство** табыш бирә торган хуҗалык

рентге́н *м разг.* рентген; **пойти́ на ~** рентгенга бару

рентге́нов, -а, -о: **~ы лучи́** рентген нурлары

рентге́новский, -ая, -ое рентген ...ы; **~ кабине́т** рентген кабинеты

рентгеногра́мма *ж* рентгенограмма (*рентген нурлары ярдәмендә алынган фоторәсем*)

рентгеногра́фия *ж* рентгенография (*үтәли куренми торган әйберләрнең эчке төзелешен рентген нурлары ярдәмендә фоторәсемгә төшерү*)

рентгено́лог *м* рентгенолог (*рентгенология һәм рентгенотерапия белгече*)

рентгеноло́гия *ж* рентгенология (*медицина фәненең рентген нурлары һәм аларны дәвалау максатында куллану турындагы бүлеге*)

рентгеноскопи́ческ||ий, -ая, -ое рентгеноскопия ...ы; **~ое иссле́дование** рентгеноскопия белән тикшерү

рентгеноскопи́я *ж* рентгеноскопия (*үтәли куренми торган җисемнәрнең эчке төзелешен өйрәнү, эшләнмәларнең эчке кимчелекләрен күрү, әгъзаларның авыруын билгеләү өчен аларны рентген нурлары ярдәмендә карау*)

рентгенотерапи́я *ж* рентгенотерапия (*рентген белән дәвалау*)

Реомю́р *м* Реомюр (*су туңу ноктасыннан алып кайнау ноктасына кадәр 80 градуска бүленгән термометр*)

реорганизацио́нный, -ая, -ое реорганизация ...ы, реорганизацияләү ...ы; реорганизацион; **~ перио́д** реорганизация чоры

реорганиза́ция *ж см.* **реорганизова́ть**

реорганизова́ть *сов., несов. что* үзгәртеп кору, үзгәртеп төзү, үзгәртеп оештыру; **~ аппара́т управле́ния** идарә аппаратын үзгәртеп кору

реоста́т *м физ.* реостат (*прибор*)

ре́па *ж* шалкан

репара́ции *мн.* репарация, түләтү (*сугыш нәтиҗәсендә күрелгән зарарны җиңүче илнең җиңелүче дәүләттән түләтүе*)

репарацио́нн||ый, -ая, -ое репарация ...ы, репарацион; **~ые платежи́** репарация түләүләре

репатриа́нт *м* репатриант (*туган иленә кайтарылган качак яки әсир һ. б.ш..*)

репатриа́ция *ж* репатриацияләү, репатриация

репатрии́ровать *сов., несов. кого-что,* репатриациялә, туган иленә кайтару (*әсирләрне, качакларны һ.б.ш.*)

репе́й *разг.,* **репе́йник** *м* **1.** (*растение*) әрекмән **2.** (*плод*) тигәнәк, кырмавык

репертуа́р *м* репертуар; **~ теа́тра** театр репертуары

репертуа́рный, -ая, -ое репертуар ...ы; **~ план** репертуар планы

репети́ровать *несов.* **1.** *что и без доп.* репетиция ясау, өйрәнү; **~ пьесу** пьесага репетиция ясау; **~ роль** рольне өйрәнү **2.** *кого-что* өйрәтү, уку эшендә булышу, уку эшендә ярдәм итү; **~ ученика́** укучыга уку эшендә булышу

репети́тор *м* репетитор (*өлгәрмәгән укучыны дәрескә хәзерләүче хосусый укытучы*)

репети́торствовать *несов.* репетитор булып эшләү, репетиторлык итү

РЕМ-РЕС Р

репетицио́нный, -ая, -ое репетиция залы; **~ая рабо́та** репетиция эше

репети́ция *ж* репетиция, репетициялә; **~ пье́сы** пьесаның репетициясе; **генера́льная ~** генераль репетиция

ре́пица *ж анат.* койрык сөяге

ре́плик||а *ж* реплика, каршы сүз; **бро́сить ~у** реплика ташлау

реполо́в *м зоол.* киндер чыпчыгы

репорта́ж *м* репортаж; **газе́тный ~** газетадагы репортаж; **~ о футбо́ле по ра́дио** радио буенча футбол уены турында репортаж

репортёр *м* репортёр, хәбәрче

репортёрский, -ая, -ое репортёр ...ы

репортёрствовать *несов.* репортёрлык итү, репортёр булып эшләү

репресси́вн||ый, -ая, -ое репрессия ..ы, бастыру ...ы, репрессив; **~ые ме́ры** репрессия чаралары

репресси́ровать *сов., несов. кого-что* репрессияләү, бастыру, җәзалау, репрессив чаралар күрү

репре́ссия *ж* репрессия, бастыру, бастыру чарасы, җәза

ре́продуктор *м* репродуктор

репроду́кция *ж* **1.** репродукция, күчермә; **~ изве́стной карти́ны** атаклы картинаның күчермәсе **2.** *полигр., фото* репродукция, күчерү

репс *м* репс (*тукыма*)

репти́лия *ж зоол.* сөйрәлүче, сөйрәлүче хайван

репута́ция *ж* репутация, абруй

ре́пчатый, -ая, -ое: **~ лук** башлы суган

ресни́тчатый, -ая, -ое *биол.* керфекле

ресни́ца *ж* керфек

ресни́чка *ж* **1.** *уменьш. от* **ресни́ца; 2.** *биол.* керфекчек, төк

респекта́бельный, -ая, -ое мәһабәт, дәрәҗәле, могтәбәр; **~ вид** мәһабәт кыяфәт

респира́тор *м* респиратор (*сулыш органнарын агулы газлардан, тузаннардан саклый торган әсбап*)

респу́блика *ж* республика, җөмһүрият

республика́нец *м* **1.** республикачы, республика тарафдары **2.** (*член буржуазной республиканской партии*) республикачы, республика партиясе әгъзасы

республика́нский, -ая, -ое республика ...ы; **~ сове́т профсою́зов** профсоюзларның республика советы

рессо́ра *ж* рессор, сиртмә

рессо́рн||ый, -ая, -ое **1.** рессор ...ы; сиртмә ...ы; **~ая сталь** рессор корычы **2.** рессорлы, сиртмәле; **~ая коля́ска** сиртмәле коляска

реставра́тор *м* реставрацияләүче, реставратор; **~ ста́рых карти́н** иске картиналарны реставрацияләүче

реставра́торство *с* реставраторлык, реставрацияләү эше, яңадан торгызу эше

реставра́ция *ж см.* **реставри́ровать**

реставри́ровать *сов., несов. что* реставрацияләү, реставрация ясау, яңадан торгызу; элекке хәленә кайтару; **~ карти́ну** картинаны реставрацияләү

рестора́н *м* ресторан

ресу́рсы *мн.* ресурс[лар], байлык[лар]; **приро́дные ~** табигать байлыклары

рети́вый, -ая, -ое тырыш, бирелеп эшли торган; **~ рабо́тник** тырыш хезмәтче

рети́на *ж анат.* челтәр катлау (*күздә*)

ретирова́||ться *сов., несов.* **1.** чигенү, качу; **проти́вник ~лся** дошман чигенде **2.** *разг.* (*уйти*) шылу, сызу; табан ялтырату; **~ться незаме́тно** сиздермичә шылу

рето́рта *ж* реторта (*озын кәкре муенлы савыт*)

ретрогра́д *м книжн.* (*противник прогресса*) кадимче, ретроград

ретрогра́дн||ый, -ая, -ое *книжн.* кадимчелек ...ы, ретроград ...; **~ое направле́ние** кадимчелек юнәлеше

ретроспекти́вный, -ая, -ое *книжн.* үткәнгә караган, үткәнгә багышланган; **~ взгляд** үткәнгә караган караш

ретушёр *м* ретушьчы, ретушьлаучы, ретушёр

ретуши́ровать *сов., несов. что* ретушьлау, ретушь төшерү

ре́тушь *ж* ретушь (*фотография негативларын һәм рәсемнәрен матурлау, бизәү*)

рефера́т *м* реферат

референду́м *м* референдум (*мөһим мәсьәлә турында гомуми тавышка кую юлы белән бөтен халыкның фикерен белү*)

референ́т *м* референт (*берәр мәсьәлә турында консультация ясап торучы*)

ре́фери, рефери́ *м нескл.* рефери (*спортта судья*)

рефери́ровать I *сов., несов. что* реферат язу (ясау); **~ диссерта́цию** диссертациянең рефератын язу

рефери́ровать II *сов., несов. спорт.* рефери булу (*судьялык итү*)

рефле́кс *м физиол.* рефлекс; **безусло́вный ~** шартсыз рефлекс; **усло́вный ~** шартлы рефлекс

рефле́ксия *ж книжн.* рефлексия, үзүзен тикшерү (*үзенең эчке кичерешләрен тикшерү*)

рефлекти́вн||ый, -ая, -ое *книжн.* рефлектив, рефлекска нигезләнген, ихтыярсыз; **~ое движе́ние** ихтыярсыз хәрәкәт

рефлекти́ровать *несов. физиол.* рефлекс бирү, рефлекс ясау (*реакция ясау*)

рефле́ктор *м* **1.** рефлектор (*телескоп төре*) **2.** (*отражатель лучей*) яктылык кайтаргыч (*батынкы көзгедән гыйбарәт*) **3.** рефлектор (*җылыту әсбабы*)

рефлекто́рн||ый, -ая, -ое *физиол.* рефлектор ...; **~ое движе́ние** рефлектор хәрәкәт

рефо́рм||а *ж* реформа, реформа ясау; **буржуа́зные ~ы** буржуаз реформалар; **~а правописа́ния** орфографиягә реформа ясау; **де́нежная ~а** акча реформасы

реформа́тор *м* реформа ясаучы, реформатор

Реформа́ция *ж ист.* Реформация (*Көнбатыш Европада 16 йөздәге иҗтимагый-сәяси хәрәкәт*)

реформи́зм *м полит.* реформачылык, реформизм

реформи́ровать *сов., несов. что* реформа ясау, реформа үткәрү, үзгәртеп кору; **~ управле́ние** идарәнс үзгәртеп кору

реформи́ст *м* реформачы, реформа тарафдары, реформа яклы кеше

рефра́ктор *м* рефрактор (*объектив сыйфатында линзалар куелган телескоп*)

рефра́кция *ж физ.* рефракция (*атмосферада нурларның сынуы*)

рефре́н *м* рефрен (**1.** *лит.* шигырьнең кабатланган бер өлеше, кабатланган юлы **2.** *муз.* җырның үзгәрешсез кабатланган бер кисәге, кушымта)

рефрижера́тор *м* **1.** рефрижератор, суыткыч (*суыткыч машинаның сыекчаны парга әйләндерүдән түбән температура барлыкка китерә торган кисәге*) **2.** рефрижератор (*вагон, судно, автомобиль*)

рехну́ться *сов. прост.* акылдан язу, тилерү, юләрләнү

рецензе́нт *м* рецензияче, рецензия язучы, бәяләмәче

рецензи́рование *с см.* **рецензи́ровать**

рецензи́ровать *несов. что* рецензияләү, рецензия язу, бәяләмә язу; **~ кни́гу** китапка рецензия язу

рецензи́я *ж* рецензия, бәяләмә

реце́пт *м* рецепт; **~ лекарства** дару рецепты; **~ блюда** ашамлык рецепты

рецепту́ра *ж мед., фарм.* рецептура (*рецептларны дорес язу һәм дарулар әзерләү кагыйдәләре*)

рецидив *м* кабатлану, рецидив, кайтадан килеп чыгу; **~ боле́зни** авырунын кабатланыу

рецидиви́ст *м юр.* рецидивчы, рецидивист (*кабат җинаять эшләгән кеше*)

речев||о́й, -а́я, -о́е сөйләм ...ы; **~ы́е на́выки** сөйләм күнекмәләре

рече́ние *с уст.* гыйбарә, сүз, әйтем

речи́стый, -ая, -ое *разг.* (*красноречивый*) сүзчән, телчән, сүзгә оста; сөйләмчәк

речитати́в *м* речитатив, көйләп сөйләү

ре́чка *ж* инеш, кечкенә елга

речни́к *м* елгачы (*елга транспортында эшләүче*)

речн||о́й, -а́я, -о́е елга ...ы; **~о́й тра́нспорт** елга транспорты; **~а́я ры́ба** елга балыгы; **~о́й песо́к** елга комы

реч||ь *ж* **1.** сөйләү; сөйләм; **о́рганы ~и** сөйләм органнары; **отчетливая ~ь** ачык сөйләү **2.** сөйләм, тел; **у́стная ~ь** сөйләм теле **3.** *разг.* сөйләшү, гәп, әңгәмә, сүз; **пусты́е ~и** буш сүзләр; **о чём идёт ~ь?** сүз нәрсә турында бара? **4.** речь, речь сөйләү; нотык; **~ь на съе́зде** съезда речь сөйләү

реша́ть *несов.* **реши́ть**

реша́ться *несов.* **1.** *см.* **реши́ться; 2.** *страд. от* **реша́ть**

реша́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **реша́ть; 2.** хәлиткеч, мөһим, төп; **~ая мину́та** хәлиткеч минут

реше́ни||е *с* **1.** *см.* **реши́ть** 2-4; **2.** карар, хөкем; **~е суда́** суд карары **3.** карар, нәтиҗә; **прийти́ к оконча́тельному ~ю** соңгы карарга килү **4.** җавап, чишелеш; **найти́ ~е зада́чи** мәсьәләнең чишелешен табу

решённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **реши́ть** 3, 4; **2.** хәл ителгән, чишелгән; **э́то де́ло ~ое** хәл ителгән эш

реше́тина *ж* шикмә, шикмә тактасы, рәшәткә тактасы

решётк||а *ж* **1.** рәшәткә, текмә **2.** (*ажурное плетение*) челтәр ◆ **за ~у посади́ть** *кого-что* төрмәгә утырту

реше́тник *м собир. спец.* шикмәләр, шикмә тактaлары, бәпкә өслекләре

решето́ *с* иләк ◆ **голова́ как ~** башы иләк кебек (*тиз онытучан кеше турында*); **~м во́ду носи́ть** иләк белән су ташу

решётчат||ый, -ая, -ое, **реше́тчат||ый,** -ая, -ое **1.** рәшәткә ...; **~ая огра́да** рәшәткә киртә **2.** рәшәткәле, челтәрле; **~ое окно́** челтерле тәрәзә

реши́мость *ж* тәвәккәллек, базымлылык, йөрәклелек; **прояви́ть ~** тәвәккәллек күрсәтү

реши́тельно *нареч.* **1.** (*смело*) тәвәккәл, кыю **2.** кискен, кискен рәвештә, катгый, катгый рәвештә; **~ отказа́ться** катгый рәвештә баш тарту **3.** (*совсем, совершенно*) бөтенләй, тулысынча; **я ~ ничего́ не по́нял** бөтенләй бернәрсә дә аңламадым

реши́тельность *ж* **1.** тәвәккәллек, йөрәклелек, базымлылык, кыюлык **2.** катгылык, кискенлек; **~ то́на** тонның кискенлеге

реши́тельн||ый, -ая, -ое **1.** тәвәккәл, йөрәкле, базымлы, кыю; **~ый челове́к** тәвәккәл кеше **2.** катгый, кискен; **~ые ме́ры** кискен чаралар **3.** хәлиткеч, мөһим; **~ый моме́нт** хәлиткеч момент

реши́||ть *сов.* **1.** *с неопр., ...* ырга булу, карар итү (бирү, кылу); **я ~л оста́ться до́ма** өйдә калырга карар иттем **2.** *что и с неопр.* карар чыгару (итү); **~ли созва́ть собра́ние** жыелыш җыярга карар чыгарганнар **3.** *что* хәл итү; **~ть вопро́с** мәсьәләне хәл итү; чишү; **~ть пробле́му** проблеманы чишү **4.** *что* чишү, җавабын табу, чыгару; **~ть зада́чу** мәсьәләне чыгару

реши́||ться *сов.* **1.** *на что и с неопр.* карарга килү, ...ырга булу, базу, батырчылык итү; **он ~лся е́хать** барырга булды **2.** хәл ителү, чишелү, чыгарылу; **спор ~лся в на́шу по́льзу** бәхәс безнең файдага чишелде **3.** *прост.* югалту, язу; **~ться жи́зни** үлү

ре́шка *ж прост.* иләк (*металл акчаның гербына кире ягы*)

реэвакуа́ция *ж* реэвакуация, реэвакуацияләү, кире эвакуацияләү (*эвакуацияләнгән кешеләрне кире үз урыннарына кайтару*)

реэвакуи́ровать *сов., несов. кого-что* реэвакуацияләү, кире эвакуацияләү, кире кайтару

ре́я *ж мор.* рея (*мачталарда шудырмалы аркылы борыс*)

ре́||ять *несов.* **1.** (*пари́ть*) канат җилпемичә генә очу **2.** җилфердәү; **~ют фла́ги** байраклар җилферди

ржа *ж уст. см.* **ржа́вчина**

ржа́веть *несов.* тутыгу, күгәрү

ржа́вить *несов. что* (*делать ржавым*) тутыктыру, күгәртү

ржа́вчина *ж* 1. тутык (*тимердә яки саз суы өстендә*) 2. гөмбә (*бөртекле культураларда һ.б.ш.*)

ржа́в||ый, -ая, -ое 1. (*покрытый ржавчиной*) тутыккан, тутыгып беткән, күгәргән 2. (*о цвете*) кызылкөрән, тутык төсендәге 3. тутыклы; **~ая вода́** тутыклы су

ржа́ние *с см.* **ржа́ть**; **~ коня́** атның кешнәве

ржа́нка *ж* (*птица*) арыш чыпчыгы

ржано́й, -а́я, -о́е арыш ...ы; **~ хлеб** арыш икмәге

ржать *несов.* 1. (*о лошади*) көшнәү, кешнәп тору 2. *прост.* (*громко хохотать*) кешнәп көлү, хыйхылдап көлү

ри́га *ж* әвен

ригори́зм *м книжн.* ригоризм (*әхлак кагыйдәләрен утәүгә, тәртипкә чамадан тыш таләпчәнлек*)

ригори́ст *м книжн.* ригорист, ригоризм тарафдары

ридикю́ль *м уст.* ридикюль (*хатын-кызларның кул сумкасы*)

ри́за *ж* риза (1. *церк. попларның гыйбадәт киеме* 2. *уст.* икона өстенә, сурәтнең йөзе һәм куллары ачык калдырылып, салынган калай) ♦ **до положе́ния риз** (*напиться*) лаякыл, лаякыл булганчы (*эчү*)

ри́зница *ж церк.* ризница (*гыйбадәт киемнәре һәм чиркәү кирәк-яраклары саклана торган бүлмә*)

рикоше́т *м* рикошет (*очып килгән бер әйбернең нинди дә булса бер өслеккә бәрелгәннән соң почмак ясап очуы*); **пу́ля уда́рила ~ом** пуля рикошет ясап килен тиде

ри́кша *м* рикша (*Япониядә һ.б.ш. кайбер илләрдә ике тәгәрмәчле кечкенә арбага җигелеп кеше яки йөк ташучы*)

ри́мляне *мн.* римлылар

ри́мск||ий, -ая, -ое Рим ...ы; **~ий па́па** Рим папасы; **~ие ци́фры** Рим цифрлары; **~ое пра́во** *юр.* Рим хокукы

ринг *м спорт.* ринг

ри́нуться *сов.* атылу, ташлану, ябырылу; **~ в бой** сугышка ташлану

рис *м* дөге

риск *м* 1. хәвеф-хәтәр, куркыныч, хәтәр; **подверга́ть себя́ ~у** үзеңне куркыныч астына кую 2. (*действие наудачу*) тәвәккәлләү, тәвәккәллек ♦ **на свой ~** *или* **на свой страх и ~** тәвәкәлләп

рискну́ть *сов. однокр.* батырчылык итү, базу, тәвәккәлләү, тәвәккәллек итү

риско́ванн||ый, -ая, -ое хәтәр ..., хәтәрле, хәвеф-хәтәрле, куркынычлы; **~ое де́ло** куркынычлы эш

риск||ова́ть *несов.* 1. (*совершать рискованный поступок*) тәвәккәл эш башкару, батырлыклар кылу, тәвәккәлләкләр кылу 2. *кем-чем* куркыныч астына кую; **~ова́ть здоро́вьем** сәламәтлекне куркыныч астына кую 3. *с неопр.* куркыныч булу; **он ~у́ет опозда́ть** аның соңга калу куркынычы бар

рисова́льщик *м* рәсемче, сурәтче, рәсем ясаучы

рисова́льщица *ж* рәсемче хатын (кыз), рәсем ясаучы хатын (кыз)

рисова́ть *несов. кого-что* 1. рәсем ясау, сурәт ясау; **~ го́ры** тауларның рәсемен ясау 2. *перен.* (*описывать*) сурәтләү, тасвирлау

рисова́||ться *несов.* 1. күренү, күренеп тору; **вдали́ ~лись го́ры** еракта таулар күренеп тора иде 2. *перен.* (*представляться в воображении*) хыялга килү, хыялда сурәтләнү 3. *чем и без доп.* кылану, тәкәллефләнү; **~ться на лю́дях** кешеләр янында кылану

рисово́д *м* дөгече, дөге игүче

рисово́дство *с* дөгечелек, дөге игү, дөге үстерү

ри́сов||ый, -ая, -ое 1. дөге ...ы; **~ая соло́ма** дөге саламы 2. дөге ...ы, дөгеле, дөгедән ясалган (пешерелгән); **~ый суп** дөгеле аш

риста́лище *с уст.* ярыш мәйданы, көрәш мәйданы

рису́нок *м* рәсем, сурәт, бизәк

рису́нчат||ый, -ая, -ое рәсемле, сурәтле, рәсем (бизәк) төшерелгән; **~ая мате́рия** бизәкле тукыма

ритм *м прям., перен.* ритм; **~ движе́ний** хәрәкәтләрнең ритмы; **~ стиха́** шигырьнең ритмы; **рабо́чий ~** эш ритмы

ритмиза́ция *ж* ритмлаштыру, ритмлы итү

ритмизи́ровать *сов., несов. что* ритмлаштыру, ритмга салу; **~ де́йствие** хәрәкәтне ритмлы итү

ритмизо́ванн||ый, -ая, -ое ритмлы, ритмлашкан, ритмлаштырылган; **~ые движе́ния** ритмлы хәрәкәтләр

ри́тмик||а *ж в разн. знач.* ритмика; **~а стиха́** шигырьнең ритмикасы; **уро́ки ~и** ритмика дәресләре

ритми́ческ||ий, -ая, -ое, **ритми́чный**, -ая, -ое ритмлы, тигез үлчәүле, тигез; **~ие движе́ния** ритмлы хәрәкәтләр; **~ая рабо́та** ритмлы эшләү

ри́тор *м ист.* оратор, чәчән, тел остасы (*борынгы Грециядә һәм Римда*)

рито́рика *ж* 1. риторика, ораторлык сәнгате 2. *перен.* сафсата, буш сүз, коры сүз

ритори́ческий, -ая,-ое риторик; **~ вопрос** риторик сорау (*сорау формасындагы раслау*)

ритуа́л *м* 1. *рел.* (*совокупность обрядов*) ритуал, йола 2. тәртип, кагыйдәләр; **~ приёма послов** илчеләрне кабул итү кагыйдәләре

риф I *м* риф, су асты кыясы

риф II *м мор.* риф (*аркан белән тартырып көйләү өчен җилкәннең элмәге яки тишеге*)

рифле́ние *с тех.* кытыршылау, сырлау

рифлён||ый, -ая, -ое кытыршы итеп ясалган, сырланган, кытыршы; **~ое стекло́** сырланган пыяла

ри́фма *ж* рифма; **глаго́льная ~** фигыль рифма

рифма́ч *м разг. неодобр.* шигырь үрүче, шигырьче, шагыйрь кисәге, мөтәшагыйрь

рифмова́ть *несов. что* рифмалаштыру, рифмалау, рифмага салу

рифмова́ться *несов.* 1. рифмалашу 2. *страд. от* **рифмова́ть**

рифмо́вка *ж лит.* рифмаланыш, рифмалашу

рифмоплёт *м см.* **рифма́ч**

ро́ба *ж* (*рабочая одежда*) роба, эш киеме

робе́ть *несов.* шүрләү, каушау, кыймау, курку

ро́бк||ий, -ая, -ое кыюсыз, юаш, куркак; **~ий ма́льчик** кыюсыз малай; **не ~ого деся́тка** куркаклардан түгел

ро́бость *ж* кыюсызлык, юашлык, куркаклык

ро́бот *м* робот (*үзенең эшләгән эшләре белән кеше эшләгән кебек тәэсир калдыра торган автомат*)

ров *м* озын чокыр, канау, чокыр; **противота́нковый ~** танкка каршы чокыр

рове́сник *м* яшьтәш, кордаш

росве́сница *ж* яшьтәш хатын (кыз)

ро́вно *нареч.* 1. (*гладко*) тигез 2. *нареч.* (*прямо*) туры, төз 3. (*равномерно*) салмак 4. *в знач. частицы* нәкъ, төгәл; **~ в пять часо́в** төгәл биш сәгатьтә 5. *в знач. частицы разг.* бәтенләй, һич; **он ~ ничего́ не по́нял** бөтенләй бернәрсә дә аңламады

ро́вн||ый, -ая, -ое 1. тигез, тип-тигез; шома; **~ая доро́га** тигез юл 2. төз, туры; **~ая ли́ния** төз сызык 3. салмак; **~ый пульс** салмак пульс 4. сабыр, тыныч; **~ый хара́ктер** сабыр холык ♦ **~ый счёт** түгәрәк исәп; **~ым счётом ничего́** бернәрсә дә, берни дә

ро́вня *м ж разг.* тиң кеше, тиңдәш, иш, тин; **он ей не ~** ул аңа тиң түгел

ровня́ть *несов. что* тигезләү, тигез итү; **~ пло́щадку** мәйданны тигезләү

рог *м* 1. мөгез; **~а́ оле́ня** болан мөгезе 2. мөгез быргы (*музыка яки сигнал коралы*) ♦ **как из ~а изоби́лия** бик күп, бетергесез

рога́стый, -ая, -ое *разг.* зур мөгезле, озын мөгезле; **~ бык** зур мөгезле үгез

рога́тина *ж* аю сөңгесе

рога́тк||а *ж* 1. рогатка (*озын борыска аркылы-торкылы кагылган казыклардан гыйбарәт киртә*) 2. (*для стрельбы*) рәгәтке (*бәрәп нәрсәгә ату өчен балалар уенчыгы*) 3. (*для сбивания масла*) атлавыч, гөбе таягы 4. (*ошейник для скота*) агач муенча (*терлек өчен*) 5. *обычно мн. ~ и перен.* (*препятствия, помехи*) киртә

рога́тый, -ая, -ое 1. мөгезле; **кру́пный ~ скот** мөгезле эре терлек 2. мөгезсыман, ураксыман; **~ ме́сяц** ураксыман ай ♦ **~ муж** хатыны хыянәт иткән ир

рога́ч *м* 1. (*самец оленя*) ата болан 2. (*жук*) мөгезләч, мөгезле коңгыз 3. *разг.* ухват

рогови́ца *ж анат.* мөгез катлау

рого́жа *ж* чыпта

рого́жка *ж* 1. *уменьш. от* **рого́жа**; 2. (*ткань*) сирәк киндер тукыма

рого́з *м бот.* камыш, җикән камышы

рогоно́сец *м разг.* мөгезле ир (*хатыны хыянәт иткән ир*)

рогу́ля *ж разг. и спец.* ике япьле әйбер, ике япьле нәрсә

род *м* 1. (*в первобытном обществе*) ыруг, ыру, кавем 2. нәсел, токым,

нәсел-нәсәп; **из ~а в ~** нәселдән нәселгә 3. *биол.* төркем, ыру 4. төр; **~ оружия** корал төре; **~ занятий** эш төре 5. *лингв.* род, женес; **категория ~а** род категориясе ♦ **без ~у, без племени** нәсел-нәсәпсез; **в некотором ~е** берникадәр, билгеле бер дәрәҗәдә; **в своём ~е** үзенчә, үз алдына, үзенә башка; **в этом (в таком) ~е** шулайрак, шуна якын, шундыйрак; ул шулайрак әйтте; **на ~у написано** язмышы шундый, ана шулай язган; **от роду** туганнан бирле, туганнан башлап; **~ людской** адәм баласы, кешеләр; **своего ~а** үзенә бертөрле, үзенә күрә, үзенчә; **такого ~а** шундый, шулай; **дело такого ~а , что могут быть неприятности** эш шундый, күнелсезлекләр булуы мөмкин

родий *м хим.* родий (*металл*)

родильница *ж* яңа гына бала тапкан хатын

родильн||ый, -ая, -ое 1. бала тудыру ...ы, бала табу ...ы; **~ый дом** бала тудыру йорты 2. бала тапканда була торган; **~ая горячка** бала тапканда була торган кызышу авыруы

родимчик *м разг.* бума авыруы, зыяндаш (*балаларда, бала табучы һәм йөкле хатыннарда*)

родим||ый, -ая, -ое туган, үз; **~ый край** туган як ♦ **~ое пятно** 1) миң; 2) *перен. чего* (*пережиток*) калдык

родина *ж* туган ил, ватан

родинка *ж* миң

родины *мн. уст.* (*роды*) бәби туе

родители *мн.* ата-ана[лар]

родитель *м уст.* (*отец*) ата

родительница *ж уст.* (*мать*) ана

родительный, -ая, -ое: **~ падеж** *грам.* иялек килеше

родительск||ий, -ая, -ое ата-ана ...ы, ата-аналар ...ы; **~ое собрание** ата-аналар җыелышы; **~ие обязанности** ата-ана бурычлары

родить *сов., несов.* 1. *кого* табу, тудыру; **~ ть ребёнка** бала табу 2. *перен. что* (*создать*) барлыкка китерү, ярату, тудыру 3. *что и без доп.* [иген] бирү, үсү, жимеш бирү; **горох хорошо ~т** борчак уңышны яхшы бирә ♦ **в чём мать ~ла** анадан тума, яп-ялангач

родиться *сов., несов.* 1. туу 2. *перен.* барлыкка килү, яралу, туу; **~лась мысль** фикер барлыкка килде 3. үсү; булу, [иген] бирү, жимеш бирү; **рожь хорошо ~лась** арыш яхшы үсте

родич *м* 1. *ист.* (*член рода*) ырудаш 2. *прост.* (*родственник*) кардәш, туган

родник *м* чишмә, кизләү; **горный ~** тау чишмәсе

родников||ый, -ая, -ое чишмә ...ы; **~ая вода** чишмә суы

родни́ть *несов. кого-что с кем-чем* (*создавать близкие отношения*) туганлаштыру, якынлаштыру, якын итү

родни́ться *несов. с кем-чем* (*вступить в отношения родства*) туганлашу

родничок *м анат.* лепкә

родн||о́й, -а́я, -о́е 1. бертуган; **~а́я сестра́** бертуган сеңел (апа) 2. туган, үз; **~а́я страна́** туган ил 3. (*при обращении*) туганкай, кадерлем, туганым 4. *в знач. сущ.* **~ы́е** *мн.* кардәшләр, туган кешеләр

родня́ *ж* 1. *собир.* (*родственники*) туган-тумача, кардәш-ыру, агай-эне; **вся ~ съе́халась** барлык кардәш-ыру җыелды 2. *разг.* (*родственник*) туган, туган тиешле, кардәш; **он мне ~** ул миңа туган тиешле

родови́тый, -ая, -ое зур нәселдән булган, зур нәселле

родов||о́й I, -а́я, -о́е 1. ыруг ...ы, ыруглык ...ы; ыруг вакытында булган; **~о́й строй** ыруглык строе 2. нәселдән килгән, мираска калган; **~о́е имéние** нәселдән килгән утар 3. ыруглык ...ы; **~о́е и видово́е поня́тие** ыруглык һәм төр төшенчәсе ♦ **~ы́е оконча́ния прилага́тельных** сыйфатларның род кушымчалары

родов||о́й II, -а́я, -о́е бала табу ...ы, бала тудыру ...ы; бала тугандагы ...; **~ы́е схва́тки** бала тугандагы тулгак

родовспомога́тельн||ый, -ая, -ое бала табу ...ы, бала тудыру ...ы, бала табарга ярдәм итә торган; **~ые учрежде́ния** бала табарга ярдәм итә торган учреждениеләр

ро́дом *нареч.* чыгышы буенча, чыгышы белән; **он ~ с Ура́ла** чыгышы белән Уралдан ул

родонача́льник *м* 1. төп баба, ыру башлыгы, нәсел башлыгы 2. *перен.* нигез салучы, башлап җибәрүче; ата

родосло́вие *с книжн. см.* **родосло́вный** 2

родосло́вн||ый, -ая, -ое 1. шәҗәрә ...ы; нәсел ...ы; **~ая табли́ца** нәсел җебе 2. *в знач. сущ.* **~ая** *ж* шәҗәрә, нәсел жебе, нәсел агачы ♦ **~ое де́рево** шәҗәрә

ро́дственник *м* кардәш, туган; **да́льний ~** ерак туган

ро́дственница *ж* кардәш хатын (кыз), туган хатын (кыз)

ро́дственн||ый, -ая, -ое 1. кардәшлек ...ы, туганлык ...ы; **~ые отноше́ния** туганлык мөнәсәбәтләре 2. тугандаш ..., кардәш ..., туган; **~ые наро́ды** кардәш халыклар 3. *перен.* (*тёплый, сердечный*) туганнарча ..., туганнарга хас; **~ые чу́вства** *к кому-л. кемгә дә булса* туганнарча хис

родство́ *с* 1. туганлык, кардәшлек, кардәш-ырулык; **бли́зкое ~** якын кардәшлек 2. *собир. разг.* кардәш-ыру, кардәшләр, туган-тумача; **многочи́сленное ~** күп санлы кардәш-ыру 3. *перен.* якынлык, туганлык; **~ взгля́дов** карашларның якынлыгы

ро́ды *только мн.* бала табу, бала тудыру

роёвня *ж пчел.* тубал, корт тубалы (*бал кортларын җыеп алу өчен*)

роение *с см.* **ро́иться**

ро́жа I *ж прост.* 1. (*лицо*) бит, йөз; 2. (*о человеке с некрасивым лицом*) табак бит

ро́жа II *ж мед.* тире кызару авыруы, рожа (*йогышлы чир*)

рожа́ть *несов. см.* **роди́ть** 1, 3

рожда́емост||ь *ж* туучылар саны; туучылар; **рост ~и** туучылар санының артуы

рожда́ть *несов. см.* **роди́ть** 1, 2

рожда́ться *несов.* 1. *см.* **роди́ться; 2.** *страд. от* **рожда́ть**

рождéние *с* 1. *см.* **роди́ть** 1, 2, **роди́ться; ~ сы́на** улның туулы 2. *разг.* туган көн; туган көн бәйрәме; **пригласи́ть на ~** туган көнгә чакыру

рождéственск||ий, -ая, -ое раштуа ...ы; рождество ...ы; **~ие моро́зы** раштуа суыклары

рождество́ *с рел.* раштуа, рождество

рожéница, роженúца *ж* бала табучы [хатын]

рож||о́к *м* 1. (*мн.* **ро́жки**) *уменьш. от* **рог** 1; 2. (*мн.* **~ки́**) мөгез быргы, быргы; **пасту́ший ~о́к** көтүче быргысы 3. (*мн.* **~ки́**) (*для кормления*) бала имезү шешәсе, имезлекле шешә 4. (*мн.* **~ки́**) калакча (*аяк киеме кигәндә кулланыла*) 5. *только мн.* **~ки́** (*макаронные изделия*) рожки ♦ **оста́лись ро́жки да но́жки** бернәрсә калмады, шымытыр

рож||о́н *м*: **како́го ~на́ [на́до]?** *кому, прост.* нәрсә җитми тагын? нәрсә кирәк тагын?; **лезть на ~о́н** утка керү, туры бару

рожь *ж* арыш

ро́за *ж* роза, гөлчәчәк, роза чәчәге ♦ **~ ветро́в** жилләр розасы (*билгеле бер урында билгеле бер вакыт аралыгында җилләрнең агу юнәлешен күрсәткән схема*)

ро́зан *м разг.* роза чәчәге

роза́рий *м* роза бакчасы, роза түтәле, гөлчәчәк бакчасы, гөлчәчәк түтәле

ро́звальни *только мн.* үрәчәле чана

ро́зг||а *ж* 1. (*прут*) чыбык, сыек чыбык (*җәза коралы*) 2. *мн.* **~и** *уст.* (*наказание*) чыбык белән суктыру, чыбык

ро́здых *м разг.* кечкенә ял, ял итеп алу

розео́ла *ж мед.* алсу тап

розе́тка *ж* 1. бик кечкенә тәлинкә, розетка (*варенье, бал очен*) 2. *эл.* розетка 3. *архит.* чәчәк, розетка

розмари́н *м* 1. (*кустарник*) бәбрия, розмарин 2. (*сорт яблок*) розмарин, бәбрия алмасы

ро́зниться *несов. уст.* аерылу, охшаш булмау, аерылып тору

ро́зниц||а *ж*: **покупа́ть в ~у** ваклап алу; **продавать в ~у** ваклап сату

ро́зничн||ый, -ая, -ое данәләп сатыла торган, ваклап сатыла торган, ваклап сату ...ы; ваклап; **~ые това́ры** ваклап сатыла торган товарлар; **~ая прода́жа** ваклап сату

рознь *ж разг.* 1. ызгыш, талаш; **~ в семье́** гаиләдәге ызгыш 2. *в знач. сказ. кому-чему* аерылу, аерылып тору; **рабо́тник рабо́тнику ~** хезмәтче хезмәтчедән аерыла

розове́||ть *несов.* 1. (*виднеться — о чём-л. розовом*) алсуланып тору, алсуланып күренү 2. (*становиться розовым*) алсулану, алсу төскә керү, алсуланып тору, **щёки ~ют от моро́за** яңаклар суыктан алсуланалар

ро́зов||ый, -ая, -ое 1. роза...ы, гөлчәчәк...ы; **~ый куст** гөлчәчәк куагы 2.

ал, алсу төстәге, аксыл кызыл; **~ая ле́нта** алсу тасма **3.** *перен.* ал, яхшы булып күренгән; **~ые мечты́** яхшы булып күренгән хыяллар ♦ **сквозь ~ые очки́ смотре́ть** ал күзлек аша карау, барысы да ал да гөл дип уйлау; **ви́деть всё в ~ом све́те** бөтен нәрсәне ал төстә күрү

ро́зыгрыш 1. *см.* **разыгра́ть** 4, 5; **~ вещево́й лотере́и** әйберләтә лотереяне уйнату; **~ пе́рвенства** беренчелек ярышы **2.** (*ничья*) ике якның да ота алмавы

ро́зыск *м* **1.** *см.* **разыска́ть; ~ това́рища** иптәшне эзләү **2.** *юр.* эзәрләү, эзләү, розыск; **объяви́ть ~** розыск игълан итү

рои́ть *несов. кого-что, пчел.* бер илгә жыю, күчкә туплау (*умарта кортларын*)

рои́ться *несов.* **1.** (*образовывать рой — о пчёлах*) корт аеру, умарта аеру **2.** (*летать роем*) мыж килеп очу, көтү булып очу, күч булып очу (*мәс. черкиләр хакында*) **3.** *перен.* кайнашу; **мы́сли рои́тся** фикерләр кайнаша

рой *м* **1.** (*семья пчёл*) күч, ил (*бер ояда бал корты*) **2.** (*скопление насекомых*) көтү (*мыж килеп очучы бөҗәкләр төркеме*)

рок *м высок.* тәкъдир, язмыш; **по во́ле ~а** тәкъдир кушуы буенча

рокирова́ть *сов., несов. см.* **рокирова́ться**

рокирова́ться *сов., несов. шахм.* рокировка ясау

рокиро́вка *ж шахм.* рокировка, рокировка ясау (*шахмат уенында: билгеле бер тәртиптә бер генә мәртәбә король һәм ладья белән бер үк вакыта йөрү*)

роков||о́й, -а́я, -о́е **1.** *уст.* тәкъдирдә язган, тәкъдирдә язылган; кайгылы; **~а́я весть** кайгылы хәбәр **2.** *уст.* хәлиткеч; **~о́й шаг** хәлиткеч адым **3.** котылгысыз, хәтәр, һәлакәтле; **~а́я боле́знь** һәлакәтле авыру

рококо́ *с нескл.* рококо (*артык купшы архитектура стиле*)

ро́кот *м* шау, шаулау, гөрелдәү, гөрелте; **~ мо́ря** диңгез шаулавы

рокота́ть *несов.* гөрелдәү, шаулау; **море́ рокоче́т** диңгез шаулый

рол *м спец.* рол (**1.** *әйләнә торган вал, цилиндр* **2.** *цилиндр рәвешендә төрелгән калай яки башка материал* **3.** *кәгазь ясаганда эҗепселле материалны тарту өчен машина*)

ро́лик *м* **1.** ролик; **крова́ть на ~ах** роликлы кровать **2.** *эл.* ролик (*электр чыбыгын стенага, түшәмгә һ.б.ш. ныгыту өчен кәтүк формасындагы фарфор изолятор*) **3.** *мн.* **~и** (*коньки*) тәгәрмәчле тимераяк

ро́ликов||ый, -ая, -ое **1.** ролик ...ы **2.** роликлы, ролигы булган; **~ые конько́вки** роликлы тимераяк

рол||ь *ж* **1.** *в разн. знач.* роль; **игра́ть ~ь** роль уйнау; **вы́учить свою́ ~ь** үз ролеңне ятлау; **~ь ли́чности в исто́рии** тарихта шәхеснең роле **2.** роль; сыйфат; **вы́ступить в ~и защи́тника** яклаучы сыйфатында чыгыш ясау

ром *м* ром (*спиртлы эчемлек*)

рома́н *м* **1.** *лит.* роман; **чита́ть ~** роман уку **2.** *разг.* роман, мәхәббәт бәйләнеше (*ир кеше белән хатын арасында*)

романиза́ция *ж* романлашу, романлаштыру (*электә: кайбер Көнбатыш Европа халыкларының латин теле нигезендә барлыкка килгән роман телен һәм мәдәниятен үзләштерүләре*)

романизи́ровать *сов., несов. кого-что* романлаштыру (*роман мәдәниятен һәм телен үзләштерту*)

романизи́роваться 1. *сов., несов.* романлашу (*роман мәдәниятен һәм телен үзләштерү*) **2.** *страд. от* **романизи́ровать**

романизова́ть *сов., несов. см.* **романизи́ровать**

романизова́ться 1. *сов., несов. см.* **романизи́роваться; 2.** *страд. от* **романизова́ть**

романи́ст I *м* (*писатель*) романчы, роман язучы

романи́ст II *м* **1.** романист, роман филологиясе белгече **2.** *юр.* (*специалист по римскому праву*) роман хокуклы, романчы

рома́нс *м* романс; **~ы Гли́нки** Глинка романслары

рома́нск||ий, -ая, -ое роман ...ы; **~ие языки́** роман телләре; **~ая культу́ра** роман мәдәнияте

романти́зм *м* романтизм, романчылык (**1.** *19 йөзнең беренче чиregендәге әдәбиятта һәм сәнгатьтә: уткән заманны идеаллаштыручы, хисләр һәм шәхес культы белән мавыгучы юнәлеш* **2.** *әдәбиятта һәм сәнгатьтә: оптимизм белән сугарылган һәм кешенең бөеклеген ачык образларда бирергә омтылган художество методы* **3.** *книжн.* чынбарлыкны идеаллаштыру, хыялга бирелү)

рома́нтик *м* **1.** *лит., иск.* романтизм тарафдары **2.** (*мечтатель*) хыялга бирелгән кеше, хыялланучан кеше

рома́нтика *ж* **1.** *см.* **романти́зм** 2, 3; **2.** романтика; **~ борьбы́ за свобо́ду** ирек өчен көрәш романтикасы; **~ твóрческих иска́ний** иҗади эзләнүләр романтикасы

романти́ческ||ий, -ая, -ое **1.** романтизм ...ы; **~ая поэ́зия** романтизм поэзиясе **2.** романтик ..., романтика белән сугарылган; **~ая исто́рия** романтик вакыйга

романти́чный, ая, -ое *см.* **романти́ческий** 2

рома́шка *ж* акбаш, акчәчәк

рома́шков||ый, -ая, -ое акбаштан ясалган, акчәчәктән хәзерләнгән; **~ая насто́йка** акбаштан ясалган төнәтмә

ромб *м* (**1.** *мат. бөтен кырлары да тигез, почмаклары туры булмаган параллелограмм* **2.** *1943-нче елда погоннар керткәнче Совет Армиясе югары команда составының аеру билгесе*)

ромште́кс *м кул.* ромштекс (*сыер итеннән кыздырып хәзерләнгән ашамлык*)

ро́ндо *с нескл. муз.* рондо

ронда́ I *с нескл. лит.* рондо (*билгеле бер тәртиптә бер үк юлларның кабатлануына нигезләнгән шигырь*)

ронда́ II *с нескл.* рондо (**1.** *язма һәм басма шрифтның бер төре* **2.** *каләм, тупыйк очлы*)

роня́||ть *несов.* **1.** *кого-что* төшерү, төшереп җибәрү; **~ть посу́ду** савыт-сабаны төшерү **2.** *что* кою, төшерү; **дере́вья ~ют ли́стья** агачлар яфрак коя **3.** *что* төшерү, ию; **~ть го́лову** (*на грудь*) башны ию **4.** *перен. кого-что* (*унижать*) абруен төшерү, дәрәҗәсен төшерү **5.** *перен. что* (*небрежно произносить*) әйтү, ычкындыру

попа́к *м* попак (*диңгездә кабыргасы белән яки текә торган аерым боз*)

по́пот *м* **1.** сукрану, зарлану; рәнҗү сүзләре; **поднялся́ ~** сукрана башладылар **2.** шау, шаулау; челтерәү; **~ ручья́** инеш челтерәве

попта́ть *несов. на кого-что и без доп.* сукрану, зарлану; **~ на судьбу́** язмыштан зарлану

роса́ *ж* чык ♦ **медвя́ная ~** *бот.* бал яву (*үлән бетләре эшләп чыгарган яки авыру сәбәпле үләннәрдә барлыкка килгән лайла*)

роси́нк||а *ж* чык тамчысы, чык бөртеге ♦ **ма́ковой ~и** *или* **ни ~и во рту не́ было** бер тәгәм да капмаган, мәк бөртеге дә капмаган

роси́ст||ый, -ая, -ое чыклы; **~ые тра́вы** чыклы үлән

роско́шество *с* **1.** нәзакәтлелек; **~ в еде́** ризыкта нәзакәтлелек **2.** (*роскошная жизнь*) үтә бай яшәү; үтә зиннәтлелек, үтә купшылык

роско́шествовать *несов.* **1.** үтә бай яшәү; зиннәттә яшәү **2.** *разг.* (*позволять себе лишнее*) артык кылану, артык зиннәтләну

роско́шничать *несов. разг. см.* **роско́шествовать**

роско́шн||ый, -ая, -ое **1.** бай, зиннәтле; **~ое изда́ние** зиннәтле басма; **~ый наря́д** бай кием **2.** *разг.* нәзакәтле, бик яхшы; **~ый за́втрак** бик яхшы иртәнге аш **3.** *уст.* (*расточительный*) исрафчыл, туздырулы, әрәм-шәрәмле **4.** *разг.* бай, шәп; **~ая расти́тельность** бай үсемлекләр дөньясы; **~ые во́лосы** шәп чәч

ро́скош||ь *ж* **1.** зиннәт, артык купшы, зиннәтлелек; артык купшылык; **одева́ться с ~ью** артык купшы киенү **2.** артык муллык; **жить в ~и** артык муллыкта яшәү **3.** байлык, муллык; **~ь ю́жной приро́ды** көньяк табигатенең байлыгы

ро́слость *ж* озын буйлылык

ро́слый, -ая, -ое озын буйлы

росома́ха *ж* росомаха (*сусарның бер төре*)

ро́спись *ж* **1.** *см.* **расписа́ть** 3; **2.** (*стенная живопись*) стена рәсеме; стена бизәге; **древнеру́сская ~** борынгы Русьтагы стена рәсемнәре **3.** *уст.* (*список чего-л.*) исемлек; **~ поку́пок** сатып алган әйберләрнең исемлеге

ро́спуск *м см.* **распусти́ть** I

ро́спуски *только мн.* утын чанасы

росси́йский, -ая, -ое Россия ...ы; **~ пролетариа́т** Россия пролетариаты

россия́нин *м высок.* Россияле, Россия кешесе, Россиядә туган кеше

россия́нка *ж высок.* Россия хатыны (кызы), Россияле хатын (кыз)

ро́сказни *только мн. разг.* имеш-мимеш, әкият; уйдырма

ро́ссып||ь *ж* **1.** чәчелү, сибелеп яту, сибелү, таралу, таралып яту; **~ть гильз** гильзаларның сибелеп ятуы **2.** *геол.* чәчелмә, файдалы казылма табыла торган урын (жир); **золоты́е ~и** алтын табыла торган урын

рост *м* **1.** үсү; **~ трав** үләннәрнең үсүе; **пойти́ в ~** үсә башлау **2.** камилләшү, үсү; арту; **~ благосостоя́ния** тормыш дәрәҗәсенең үсүе; **~ рабо́чего движе́ния** эшчеләр хәрәкәтенең үсүе **3.** буй; **высо́кий ~** озын буй **4.** *уст.* табыш алу, арттыру, процент алу; **дать де́ньги в ~** акчаны арттырырга бирү ◆ **во весь ~** 1) (*выпрямившись*) бөтен буена; 2) (*в стоячем положении*) баскан килеш

ро́стбиф *м кул.* ростбиф (*сыер итеннән кыздырып пешерелгән ашамлык*)

ро́степель *ж диал.* җепшек [көн]

ростов||о́й, -а́я, -о́е *спец.* **1.** үсү ...ы, үсеш ...ы; **~а́я пора́** үсү вакыты **2.** үстерү ...ы, үстерә торган; **~ы́е вещества́** үстерү матдәләре

ростовщи́к *м* рибачы, ростовщик

рост||о́к *м* **1.** үсенте, шытым, мыек; **пе́рвые ~ки** беренче үсентеләр **2.** *обычно мн.* **~ки́** *перен.* шытым, башлангыч үсенте; **~ки́ новой культу́ры** яңа мәдәниятнең башлангыч үсентеләре

ро́стра *ж архит.* ростра, борын (*колоннада борынгы кораблнең борынына охшатып ясалган бизәк*)

ростра́льн||ый, -ая, -ое *архит.* ростралы, роста белән бизәлгән; **~ая коло́нна** ростралы колонна

ро́счерк *м* **1.** (*завиток буквы*) хәреф сыры **2.** (*завиток в последней букве подписи*) имза койрыгы ◆ **[одним] ~ом пера́** бер селтәнү белән (*мәсьәләнең әченә кереп тормыйча*)

рося́нка *ж бот.* чыклы үлән

рот *м* **1.** авыз; **раскры́ть ~** авыз ачу **2.** (*пасть, клюв*) авыз, томшык, авыз тишеге **3.** *перен. прост.* тамак, ашаучы; **в семье́ пять ртов** гаиләдә биш тамак ◆ **в ~ не возьмёшь** авызга алгысыз, тәмсез; **в ~ не идёт** тамакка бармый; **зажа́ть (заткну́ть) ~** *кому* авызын томалау (каплау)

ро́та *ж воен.* рота

ротапри́нт *м полигр.* ротапринт (*типографиядә басу машинасының бер төре*)

рота́тор *м* ротатор (*кулъязмаларны һ.б.ш. күбәйтү аппараты*)

ротацио́нн||ый, -ая, -ое ротация ...ы, ротацион; **~ая маши́на** ротацион машина

рота́ция *ж* **1.** *полигр.* ротация, ротация машинасы **2.** *с.-х.* ротация (*чәчү әйләнеше талəпләренә ярашлы рәвештә барлык басуларга да иген чәчелгән чор*)

ро́тмистр *м ист.* ротмистр (*патша армиясендә кавалериядә хәзерге капитанга тиң чин; жандармериядә офицер чины; шул чины булган кеше*)

ро́тный, -ая, -ое рота ...ы; **~ команди́р** рота командиры

ротозе́й *м разг.* **1.** (*зевака*) ачык авыз **2.** (*разиня*) ачык (мәми) авыз, пешмәгән, җебегән, өшегән авыз

ротозе́йничать *несов. разг.* ачык (мәми) авыз булу

ротозе́йство *с разг.* ачык (мәми) авызлык, җебегәнлек, пешмәгәнлек

ротонда́ *ж* ротонда (**1.** *архит. гөмбәзле һәм колонналы кечкенә түгәрәк бина* **2.** *уст. хатын-кызыларның өске киеме*)

ро́тор *м тех.* ротор (*турбинаның, электр двигателенең әйләнә торган өлеше*)

ро́хля *м, ж разг.* мыштырдык, мыштыр, пешмәгән кеше, җебегән

ро́ща *ж* агачлык, кечкенә урман

рояли́зм *м* роялизм (*король хакимлеген яклау*)

рояли́ст *м* роялизм тарафдары, король хакимлеген яклаучы

роя́л||ь *м* рояль; **игра́ть на ~е** рояльдә уйнау

рту́тн||ый, -ая, -ое терекөмеш...ы; терекөмешле; **~ая руда́** терекөмеш рудасы; **~ый термо́метр** терекөмеш термометры

ртуть *ж хим.* терекөмеш, күнә суы

руба́ка *м разг.* кылыч белән оста эш итүче, кылыч белән кисүче

рубану́ть *сов. кого-что* чабып (кисеп, ярып) жибәрү

руба́ха *ж см.* **руба́шка** 1 ◆ **~-па́рень** *прост.* ачык кеше, эчкерсез кеше

руба́шк||а *м* **1.** күлмәк; **ве́рхняя ~а** күлмәк; **ни́жняя ~а** эчке күлмәк **2.** *карт.* арт як **3.** *спец.* (*масть животного*) төс, тире төсе **4.** *спец.* (*оболочка чего-л.*) яры, кабык, тышча ◆ **в ~е роди́ться** бәхет белән туу, күлмәктә туу; **в одно́й ~е оста́вить** *кого* хәерче хәленә төшерү, бөлдерү, ыштансыз калдыру

рубе́ж *м* **1.** (*граница*) чик, рубеж **2.** *воен.* рубеж, сызык; **оборони́тельный ~** оборона сызыгы **3.** *перен.* (*грань*) чик, сызык ◆ **за ~о́м** чит илдә, чит илләрдә

руберои́д *м* рубероид (*махсус матдә сеңдерелгән катыргы*)

руберои́дн||ый, -ая, -ое, **рубероидов||ый,** -ая, -ое, ребруроид...ы; рубероид ...; **~ый заво́д** рубероид заводы; **~ая изоля́ция** рубероид изоляция

руба́ц *м* **1.** (*шрам*) эз, җөй **2.** *портн.* җөй; **вы́пустить ~** җөйне сүтү **3.** *анат.* кырык карта (*кушәүче хайваннарда*)

руби́льник *м* рубильник, өзгеч

руби́н *м* якут, кызыл якут

руби́нов||ый, -ая, -ое **1.** якут ...ы, кызыл якут ...ы, якут ..., якуттан ясалган, кызыл якут ..., кызыл якуттан ясалган; **~ое ожере́лье** якут муенса **2.** якутлы, кызыл якутлы; **~ый брасле́т** кызыл якутлы беләзек **3.** (*о цвете*) якут төсендәге, кызыл; **~ое вино́** якут төсендәге шәраб

руби́ть *несов.* **1.** *что* кисү, чабу; **~ дрова́** утын кисү **2.** *что* турау; **~ капу́сту** кәбестә турау **3.** *что горн.* чабу; **~ у́голь** күмер чабу **4.** *кого-что* чабу, чабып үтерү; **~ са́блей** кылыч белән чабу **5.** *что* (*строить из брёвен*) бурау, ясау, бура бурау **6.** *перен. что, разг.* (*говорить, действовать прямо, резко*) ярып әйтү

руби́ться *несов.* **1.** кисешү, сугышу (*салкын корал белән*) **2.** *страд от* **руби́ть**

ру́бище *с* сәләмә кием, алама кием, ертык-портык кием

ру́бка I *ж мор.* рубка

ру́бка II *ж см.* **руби́ть** 1, 2, 5

рублёвка *м разг.* бер тәңкә, бер тәңкәлек, бер сумлык

рублёвый, -ая, -ое бер тәңкәлек ..., бер сумлык ...; **~ биле́т** бер тәңкәлек билет

ру́блен||ый, -ая, -ое **1.** туралган, турап ваклынган, тапалган; **~ое мя́со** туралган ит **2.** (*бревенчатый*) бурап салынган, буралган (*бүрәнәдән*); бүрәнәдән салынган

рубль *м* тәңкә, сум

ру́брика *ж* **1.** (*заголовок*) бүлек башы (*газеталарда, журналларда*) **2.** (*графа*) бүлек, рубрика; **разнести́ по ~м** рубрикаларга утыртып чыгу

рубцева́ться *несов.* бөтәшү, төзәлү, бөтәшеп төзәлү (*җәрәхәт турында*)

ру́бчат||ый, -ая, -ое сырланган, сырлы-сырлы; бирчәле; **~ая ткань** сырлы тукыма

ру́бчик *м* **1.** *уменьш. от* **руба́ц** 1; **2.** сыр, бирчә (*тукымаларда*); **ткань в ~** сырлы тукыма

ру́гань *ж* тиргәш, сүгеш, тиргәү (сүгенү) сүз[ләр]е

руга́тельн||ый, -ая, -ое сүгү ..., сүгеш ...ы, тиргәш ...ы; **~ые слова́** сүгү сүзләре

руга́тельский, -ая, -ое *разг.*: **руга́тельски руга́ть (руга́ться)** тетмәсен тетү, бик ныкы тиргәү

руга́тельство *с* сүгенү сүзе, сүгенү

руга́ть *несов. кого-что* тиргәү, сүгү, орышу, әрләү

руга́ться *несов.* тиргәшү, сүгенү, оршышу, әрләшү

ругня́, руготня́ *ж прост. см.* **ру́гань**

руда́ *ж* мәгъдән, руда; **желе́зная ~** тимер рудасы

рудиме́нт *м* **1.** рудимент, калдык *организмның үсеп җитмәгән һәм үзенең башлангыч функциясен югалткан калдык әгъзасы*) **2.** *перен. книжн.* (*след исчезнувшего явления*) калдык, эз

рудимента́рный, -ая, -ое рудиментар ..., калдык ..., рудиментар (калдык) булган; **~ о́рган** рудиментар әгъза

рудни́к *м* мәгъдән учагы, рудник

рудни́чный, -ая, -ое рудник ...ы; **~ во́здух** рудник һавасы

ру́дн||ый, -ая, -ое руда ...ы, мәгъдән ...ы; мәгъдәнле; **~ые месторожде́ния** мәгъдәнле урыннар

рудоко́п *м уст.* руда казучы, руда чыгаручы, мәгъдәнче

рудоно́сный, -ая, -ое рудалы, мәгъдәнле, рудасы булган, мәгъдәне булган

рудоуправле́ние *с* рудаидарә (*рудниклар белән идарә итү органы*)

ружёйник *м* мылтык остасы, мылтыкчы

ружёйн||ый, -ая, -ое мылтык ...ы; **~ое мáсло** мылтык мае

ружьё *с* мылтык

руúны *мн. книжн.* (*развалины*) хәрабә, җимерек, җимереклек

рук||á *ж* **1.** *прям., перен.* кул; **держáть за́ руку** кулдан тоту; **увéренные рýки** ышанычлы куллар; **вестú пóд руки** *кого-то* култыклап алып бару; **идтú пóд руку** *с кем-л.* култыклап бару, култыклашып бару **2.** *мн.* **рýки** (*рабочая сила*) кул, эшче **3.** *перен.* кул; почерк; **э́то вáша ~á?** бу сезнең кулыгызмы? **4.** *перен.* таяныч, терәк, яклаучы, кул; **у негó там своя́ ~á** анда аның яклаучысы бар ♦ **в рýки взять** *кого-что* буйсындыру, кулга алу; **в хорóшие рýки отдáть** *кого-что* яхшы кешегә бирү; **в хорóших ~áх быть (находúться)** яхшы кешедә булу; **из рук вон [плóхо]** бик начар; миннән киткәнче, иясенә җиткәнче; **из пéрвых рук [узнáть]** беренче чыганактан [белү]; **на все рýки мáстер** кулыннан һәртөрле эш килә, бар эшкә дә оста; **нá руку нечúст** кәкре куллы, урлашучан, озын куллы; **нá руку** *кому-чему* файдага, файдасына; **не с ~ú** *кому что* кулай түгел, уңайсыз, кул түгел; **~áми и ногáми** дүрткуллап; **~á óб руку** кулга кул тотынышып; **~á рýку мóет** кул кулны юа (*гаепләрне узара яшерү*); **рýки по швам [держáть, стоя́ть]** кулларны гәүдә буенча төшереп [тору]; **~óй подáть** бик якын, кул сузымында гына; **с рук сбыть** *кого-что* котылу, биреп җибәрү; **с рук сойтú** үтү, үтеп китү (*бернинди җәэасыз*)

рукáв *м* **1.** жин; **корóткие ~á** кыска жин **2.** (*ответвление реки́*) тармак, елга култыгы **3.** (*труба*) җинсә; эчәк (*насоса*) ♦ **спустя́ ~á** ничек җитте, шулай; теләр-теләмәс

рукавúцы *мн.* бияләй

рукáстый, -ая, -ое *разг.* зур куллы

руководúтель *м* җитәкче, башлык, җитәкчелек итүче

руководúтельница *ж* җитәкче хатын (кыз)

руководúть *несов. кем-чем* җитәкләү, җитәкчелек итү, башында тору; **~ колхóзом** колхоз белән җитәкчелек итү

руководúться *несов.* **руковóдствоваться**

руковóдство *с* **1.** җитәкчелек, җитәкчелек эше, җитәкчелек итү **2.** кулланма; **~ по хúмии** химия буенча кулланма **3.** *собир.* җитәкчелек, җитәкчелер, башлыклар; **~ завóда** завод җитәкчелеге

руковóдствоваться *несов. чем* кулланып эш итү, куллану, таянып эш итү, ... буенча эш итү, ...дан чыгып эш итү (эшләү); **~ прáвилами** кагый дәләргә таянып эшләү

руководя́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **руководúть; 2.** җитәкче ..., җитәкчелек итүче ..., җитәкчелек итә торган; **~ие кáдры** җитәкче кадрлар; **~ие указáния** җитәкче күрсәтмәләр

рукоде́л||ие *с* кул эше; **занимáться ~ием** кул эше белән шөгыльләнү; **вы́ставка ~ий** кул эшләре күргәзмәсе

рукоде́льница *ж* кул эше остасы, кул эше эшләүче (*хатын-кыз*)

рукоде́льничать *несов.* кул эше эшләү, кул эше белән шөгыльләнү

рукокры́лые *мн. зоол.* кулканатлылар, ярканатлар

рукомóйник *м* кулъюгыч

рукопáшн||ый, -ая, -ое **1.** кул ...ы, **~ый бой** кул сугышы **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м,* **~ая** *ж* кул сугышы, якыннан торы сугышу (*мәс. штыкка штык килеп сугышу*)

рукопúсный, -ая, -ое **1.** кулъязма ..., кулъязма[лар] ...ы; **~ отдéл библиотéки** китапханәнең кульязмалар бүлеге **2.** кулдан язылган, кулъязма ..., кул белән язылган; **~ текст** кулъязма текст

рýкопис||ь *ж* кулъязма; **дрéвние ~и** борынгы кулъязмалар

рукоплеска́ние *с* алкыш, кул чабу

рукоплеска́ть *несов. кому-чему* кул чабу, чәбәкәйләү, алкышлау

рукопожа́тие *с* кул кысышу, кул бирешү, кул кысу (*исәнләшү, рәхмәт йөзеннән*)

рукоприкла́дство *с разг.* кул тидерү, кул салу (кыйнау)

рукоя́тка, рукоя́ть *ж* **1.** сап; **~ кинжáла** ханҗәр сабы **2.** (*в машинах, приборах*) тотка, тоткыч; (*у цепа*) көбәк

рула́да *ж муз.* рулада (*җырның нинди дә булса бер өлешен бик тиз башкару*)

рулев||óй, -áя, -óе **1.** руль ...ы; **~óе колесó** руль көпчәге **2.** *в знач. сущ.* **~óй** *м* (*на корабле*) рулевой, рульче; (*на лодке*) койрыкчы, койрык тотучы

рулéт *м кул.* **1.** рулет, катлама (*бөккәннең бер төре*) **2.** (*окорок без кости*) рулет (*сөяге алынып түгәрәк форма бирелгән дуңгыз ите*) **3.** рулет (*ашамлык*); **картóфельный ~** бәрәңге рулеты

рулéтка *ж* рулетка (**1.** *үлчәү тасмасы* **2.** *махсус отышлы уен җайланмасы*)

рули́ть *несов.* **1.** руль белән идарә итү, рульдә утыру; (*лодкой*) койрык тоту (*көймәдә*) **2.** *ав.* (*о лётчике*) самолётны җирдән алып бару **3.** *ав.* (*о самолёте*) җирдән бару, җир өстеннән бару

рулóн *м* төргәк, рулон

руль *м* руль

румб *м* румб (*компас түгәрәгендә горизонтның 1/32 өлешенә тигез булган бүлем*)

румы́н *м* румын, румын кешесе

румы́нка *ж* румын хатыны (кызы)

румы́нский, -ая, -ое румын[нар] ...ы; Румыния ...ы; **~ язы́к** румын теле

румы́ны *мн.* румыннар, румын халкы

румя́на *только мн.* иннек

румя́н||ец *м* алсулык; кызыллык, бит кызыллыгы; **зали́ться ~цем** биткә кызыллык йөгерү

румя́ни||ть *несов. кого-что* **1.** алсуландыру, кызарту; **моро́з ~л щёки** суык яңакларны алсуландырган **2.** (*покрывать румянами*) иннек ягу, кызыл сөртү

румя́ни||ться *несов.* **1.** (*становиться румяным*) алсулану, кызару; **лицó ~лось от моро́за** бите суыктан кызарган **2.** (*покрывать лицо румянами*) иннек ягыну, биткә кызыл сөртү **3.** кызару; **пиро́г нача́л ~ться** бөккән кызара башлаган

румя́н||ый, -ая, -ое **1.** алсуланган, кызарган, алсу; **~ое лицó** кызарган бит **2.** кызарган; **~ый пиро́г** кызарган бөккән

руни́ческ||ий, -ая, -ое рун ...ы; **~ие на́дписи** рун язмалары

руно́ *с* йон, сарык йоны; **то́нкое ~** нәзек йон

ру́ны I *мн.* рун язуы, рун язмасы (*күпчелектә скандинавларның ташларда, коралларда һ.б.ш сакланып калган борынгы язулары*)

ру́ны II *мн.* рун, рун җыры (*карел-ларда, финнарда*)

ру́пия *ж* рупия (*Һиндстанда, Бирмада һәм кайбер башка илләрдә акча берәмлеге*)

ру́пор *м* рупор (**1.** *тавыш көчәйтү торбасы* **2.** *перен. кемнең дә булса фикерен җәелдерүче, таратучы*)

руса́к *м* ур куяны, сары куян

руса́лии *только мн.* искә алу бәйрәме (*борынгы славяннарда үлгән кешеләрне искә алу көне*)

руса́лка *ж фольк.* су кызы, су анасы

руси́зм *м лингв.* рус сүзе, русизм (*рус теленнән алынган сүз яки гыйбарә*)

руси́ст *м* русистика белгече; рус теле белгече, рус филологиясе белгече

руси́стика *ж* русистика (*рус телен һәм мәдәниятен өйрәнүче фәннәр*)

русифици́ровать *сов., несов. кого-что* руслаштыру

русифици́роваться *сов., несов.* руслашу **2.** *страд. от* **русифици́ровать**

ру́сло *с* **1.** үзән, елга юлы; **~ рекú** елга юлы **2.** *перен.* юнәлеш; эз; **жизнь вошлá в нормáльное ~** тормыш нормаль эзгә төште

русволо́сый, -ая, -ое коңгырт чәчле, коңгырт сары чәчле

ру́сская I *ж* рус хатыны (кызы)

ру́сская II *ж* (*пляска*) рус биюе

ру́сские *мн.* руслар, рус халкы

ру́сский I *м* рус

ру́сский II, -ая, -ое **1.** рус ...ы; **~ая культу́ра** рус мәдәнияте; **~ая литерату́ра** рус әдәбияты; **~ий язы́к** рус теле **2.** Россия ...ы; Русь ...ы; рус ...ы; **Ру́сское госуда́рство** Русь дәүләте

ру́с||ый, -ая, -ое **1.** коңгырт, коңгырт сары; **~ая борода́** коңгырт сары сакал **2.** коңгырт чәчле, коңгырт сары чәчле; **~ый па́рень** коңгырт чәчле егет

рутéний *м хим.* рутений

рути́на *ж* искелек

рутинёр *м* искелек яклы кеше, искелеккә ябышып ятучы

рутинёрство *с* искелеккә ябышып яту, искелеккә ияреү

ру́хлядь *ж собир. разг.* иске-москы, чүпрәк-чапрак

ру́хну||ть *сов.* **1.** җимерелү, җимерелеп төшү; аву, авып төшү; **дом ~л** өй җимерелде; **дéрево ~ло** агач ауды **2.** (*упасть — о человеке*) егылу, барып төшү, лап итеп егылу **3.** *перен.* җимерелү,

өзелү, юкка чыгу; **наде́жды ~ ли** өметләр өзелде

руча́тельство *с* ышаныч язуы, өстенә алу

руча́||ться *несов. кого-что* (*заверять*) ышандыру, гарантия бирү, жаваплылыкны өстенә алу; йөгенә керү; **~ться за успе́х де́ла** эшнең уңышлы чыгачагына гарантия бирү; **я за него́ ~юсь** аның өчен жаваплылыкны өстемә алам; **~ться голово́й** башны кисәргә бирү

ру́чка 1. *уменьш. от* **рука́** 1; 2. тотка; сап, тоткыч; **дверна́я ~** ишек тоткасы; **~ ножа́** пычак сабы 3. (*для письма*) ручка, каләм сабы 4. култыкса; **~ кре́сла** креслоның култыксасы

руч||но́й, -а́я, -о́е 1. кул ...ы; куллар ...ы; **~о́й стано́к** кул станогы; **~ы́е ча́сы** кул сәгате; **~а́я кладь** кул йөге 2. кул белән ..., куллан ясау (жыю, эшләү) ...: **~о́й набо́р** куллан жыю 3. кулга ияләшкән, ияләштерелген, өйрәтелгән; **~о́й во́рон** кулга ияләшкән козгын

ру́шить *несов. что* 1. жимерү, ишү, вату, жимереп (ишеп, ватып) төшерү; **~ сте́ны** стенаны ишеп төшерү 2. *спец.* кабыгыннан арындыру, ярмага әйләндерү; **~ про́со** тарыны кабыгыннан арындыру

ру́ш||иться *несов.* 1. ишелү, ишелеп төшү, жимерелү, жимерелеп төшү, ватылып төшү; **сте́ны ~ атся** стеналар ишелеп төшәләр 2. *перен.* жимерелү, таркалу, юкка чыгу; **пла́ны ~ атся** планнар жимерелә 3. *страд. от* **ру́шить**

ры́ба *ж* 1. балык; **морска́я ~** дингез балыгы; **хи́щная ~** ерткыч балык 2. *мн.* **Ры́бы** *астр.* Балыклар ♦ **как ~ в воде́** судагы балык кебек; **ни ~ ни мя́со** ни он түгел, ни камыр түгел

рыба́к *м* балыкчы, балык тотучы; **~ а́ ви́дит изда́лека** *посл.* балыкчы балыкчыны еактан күрә

рыба́лк||а *ж* балык тоту; **идти́ на ~у** балык тотарга бару

рыба́ц||кий, -ая, -ое балыкчы ...ы, балыкчылар ...ы, балыкчылык ...ы, балык тоту ...ы; **~ая ло́дка** балыкчы көймәсе; **~ ий колхо́з** балыкчылык колхозы

рыба́чество *с* балык тоту, балык тоту эше

рыба́ч||ий, -ья, -ье балыкчы ...ы, балыкчылар ...ы, балыкчылык ...ы; **~ья ло́дка** балыкчы көймәсе

рыба́чить *несов.* балык тоту (каптыру, аулау)

рыбёшка *ж разг.* вак (бәләкәй, кечкенә) балык

ры́б||ий, -ья, -ье 1. балык ...ы; **~ья чешуя́** балык тәңкәсе; **~ий жир** балык мае 2. *перен.* (*бесстрастный*) салкын канлы, салкын ♦ **на ~ьем меху́** этәч тиресеннән тегелген кием (*салкын кием хакында*); **~ьи глаза́** төссез күзләр

ры́бина *ж разг.* зур балык

ры́бник *м* (*специалист по рыбоводству*) балык белгече; (*работник рыбных промыслов*) балыкчы, балык тотучы

ры́бн||ый, -ая, -ое 1. балык ...ы; балык ...; **~ая ло́вля** балык тоту; **~ая кость** балык сөяге; **~ый за́пах** балык исе 2. балык ...ы; балыктан хәзерләнгән (пешерегән, ясалган); **~ые котле́ты** балык көтлите 3. балыклы, балыгы күп [булган]; **~ое о́зеро** балыклы күл

рыбо́- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, «балык», «балыкка бәйләнешле» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **рыборазведе́ние** балык үрчетү; **рыбозаво́д** балык заводы; **рыбопромы́шленность** балык промышленносте; **рыбохо́д** балык юлы, балык үтү урыны (*буада балык үтү өчен калдырылган урын*)

рыбово́д *м* балык үрчетүче, балык үрчетү белгече

рыбово́дн||ый, -ая, -ое балык үрчетү ...ы; **~ое хозя́йство** балык үрчетү хуҗалыгы

рыбово́дство *с* балык үрчетүчелек, балык үрчетү, балык үрчетү эше

рыбово́дческ||ий, -ая, -ое балык үрчетү ...ы; **~ая фе́рма** балык үрчетү фермасы

рыбозаво́д *м* балык заводы

рыбокомбина́т *м* балык комбинаты

рыболо́в *м* балык тотучы (аулаучы) балыкчы

рыболове́цк||ий, -ая, -ое балыкчылык ...ы, балык тоту ...ы,балык тоту эше белән шөгыльләнүче; **~ая арте́ль** балык тоту артеле

рыболо́вн||ый, -ая, -ое балыкчылык ...ы; балык тоту ...ы, балык ...ы; **~ый сезо́н** балык тоту сезоны; **~ые сна́сти** балык тоту кирәк-яраклары

рыболо́вство *с* балыкчылык, балык тоту, балык тоту эше

рыбопромысло́в||ый, -ая, -ое балык промыселе ...ы; **~ая арте́ль** балык промыселе артеле

рыбхо́з *м* балык хуҗалыгы, балык үрчетү хуҗалыгы

рыв||о́к *м* 1. кинәт тарту, кинәт тартылу; **~о́к вперёд** алга кинәт тарту 2. ыргылыш, ыргылу; **рабо́тать без ~ко́в** ыргылусыз эшләү 3. *спорт.* ыргым

рыга́ть *несов.* кикерү

рыгну́ть *сов. однокр.* кикереп җибәрү, кикереп кую

рыда́ние *с см.* **рыда́ть**

рыда́ть *несов.* иңрәү, иңрәп елау, үксү, үксеп елау

рыдва́н *м уст.* рыдван (*зур юл арбасы*)

рыжеборо́дый, -ая, -ое җирән сакаллы

рыжево́лосый, -ая, -ое җирән чәчле

рыже́||ть *несов.* 1. (*становиться рыжим*) җирәнләнү, җирәнләнә төшү; **во́лосы ~ ют** чәч җирәнләнә 2. (*виднеться — о чём-л. рыжем*) җирән булып күренү, җирәнләнеп тору; **~ла прошлого́дняя трава́** үткән елгы үлән җирән булып күренә иде

ры́ж||ий, -ая, -ее җирән, кызыл сары; **~ая борода́** җирән сакал; **~ий ма́льчик** җирән чәчле малай; **~ий жеребе́ц** җирән айгыр

ры́жик *м* 1. (*растение*) шепкән 2. (*гриб*) нарат гөмбәсе

рык *м* яман акыру, ырылдау, яман тавыш; **льви́ный ~** арысланның яман акыруы

ры́кать *несов.* яман [тавыш белән] акыру, ачы [тавыш белән] үкерү

ры́ло *с* 1. танау, борын; **свино́е ~** дуңгыз борыны 2. *прост.* (*лицо*) бит, кыяфәт, йөз

ры́льце *с* 1. *уменьш.-ласк. от* **ры́ло** 1; 2. *бот.* авызчык 3. (*передняя часть ствола орудия*) авыз ♦ **~ в пуху́** гаебе юк түгел

ры́нок *м* базар; **колхо́зный ~** колхоз базары; **вне́шний ~** *эк.* тышкы базар; **вну́тренний ~** *эк.* эчке базар

ры́ночн||ый, -ая, -ое базар ...ы; **~ые це́ны** базар хаклары

рыса́к *м* юртак

ры́сий, -ья, -ье селәүсен ...ы

рыси́ст||ый, -ая, -ое юртак ...; **~ая ло́шадь** юртак ат

рыси́ть *несов.* 1. (*бежать рысью — о лошади*) юрту, юртып бару, юртаклап бару 2. (*ехать рысью*) юрттыру, юртыпырып бару, юртаклап бару

ры́скать *несов.* 1. эзләнү, эзләнеп йөрү; **волк ры́щет** бүре эзләнеп йөри 2. (*ходить, ездить без определённой цели*) каңгырып йөрү; **~ по све́ту** дөнья буйлап каңгырып йөрү

рысца́ *ж разг.* (*мелкая рысь*) акрын гына юрту, акрын гына юртып бару

рысь I *ж* юрту, юртаклау; **перейти́ на ~** юрта башлау

рысь II *ж зоол.* селәүсен

ры́сью *нареч.* 1. (*аллюром*) юртып, юртаклап 2. *разг.* (*бегом*) йөгереп

ры́твина *ж* сикәлтә, тәгәрмәч чокары (*юлда*)

рыть *несов. что* казу; чоку; **~ карто́фель** бәрәңге казу; **~ я́му** чокыр казу

ры́ться *несов.* 1. казыну, чокыну; **~ в песке́** комда казыну 2. актарыну, эзләнү; чокчыну, (*әйберләрне*) актару; **~ в бума́гах** кәгазьләрне актару

рыхле́||ть *несов.* көпшәкләнү, көпшәкләнә төшү, йомшару, йомшара төшү; **земля́ при обрабо́тке ~ ет** эшкәртүдән жир көпшәкләнә

рыхли́тель *м с.-х.* туфрак йомшарткыч, көпшәкләндергеч (*тагылма машина*)

рыхли́ть *несов. что* көпшәкләндерү, казып йомшарту; **~ зе́млю** жирне казып йомшарту

ры́хлость *ж* көпшәклек, көпшәк булу; **~ по́чвы** туфракның көпшәклеклеге

ры́хл||ый, -ая, -ое 1. көпшәк, йомшак; **~ый снег** көпшәк кар 2. *разг.* (*дряблый*) сәлперәйгән; **~ое те́ло** сәлперәйгән тән

ры́царск||ий, -ая, -ое 1. рыцарь[лар] ...ы; **~ое вооруже́ние** рыцарь кораллары 2. *перен.* рыцарьлык ...ы, рыцарьларча ...; фидакарь; **~ий посту́пок** рыцарьларча эш итү

ры́царство *с* 1. рыцарьлык (*Көнбатыш Европада феодализм чорындагы хәрби-дворян сословие*) 2. *собир. ист.* (*рыцари*) рыцарьлар 3. рыцарьлык;

рыцарь дәрәҗәсе **4.** *перен.* (*самоотверженность*) егетлек, фидакарьлек, үзен аямау; **проявить ~** егетлек күрсәтү

рыцарь *м* **1.** *ист.* рыцарь (*Көнбатыш Европада: хәрби-дворян сословие кешесе*) **2.** *перен.* каһарман, егет, фидакарь хезмәт итүче

рычáг *м* **1.** рычаг; (*для уравновешивания тяжести*) көянтә, рычаг; **~ скóрости** тизлек рычагы; **поднять ~óм** рычаг белән күтәрү **2.** *перен.* (*средство*) чара, этәргеч көч

рычáть *несов.* акыру, бакыру, ырылдау

рьянный, -ая, -ое ихлас күңелдән бирелгән, ихлас күңел белән ..., тырыш, хирыс; **~ рабóтник** тырыш хезмәткәр

рюкзáк *м* рюкзак; биштәр; арка капчыгы

рю́мка *ж* рюмка

рю́хи *мн.* (*городки*) бура, чура; **игрáть в ~** бура сугу

рябéть *несов.* (*покрываться рябью*) шадраланып тору, шадралану

рябúна I *ж* **1.** (*дерево*) миләш, миләш агачы **2.** (*ягоды*) миләш, миләш җиләге

рябúна II *ж* шадра, шадра тап; **лицó с ~ми** шадралы йөз

рябúнник I *м* (*рябиновая роща*) миләшлек, миләш агачлыгы

рябúнник II *м* (*птица*) миләш чыпчыгы

рябúновка *ж* миләш төнәтмәсе, миләштә төнәтелгән аракы

рябúнов||ый, -ая, -ое **1.** миләш ...ы; **~ая корá** миләш кабыгы **2.** миләш ..., миләштән ясалган, миләш ...ы; **~ая настóйка** милеш төнәтмәсе **3.** (*о цвете*) миләш төсендәге ..., аксыл кызыл

рябúть *несов.* **1.** *что* шадраландыру; **ветерóк рябúт водý** җил су өстен шадраландыра **2.** *безл.* чагылу, куз аллары чуарлану; **в глазáх рябúт от мнóжества разноцвéтных огнéй** төрле төстәге утларның күплегеннән күз аллары чуарлана

ряб||óй, -áя, -óе шадра ..., шадралы; **~óе лицó** шадра бит **2.** чуар, ала, алакола, таплы; **~áя кýрица** чуар тавык; **~áя кобы́ла** ала бия

ря́бчик *м* боҗыр

рябь *ж* **1.** шадралану, шадраланып тору, җыерчыклану, җыерчыкланып тору; **óзеро подёрнулось ~ю** күл өсте шадраланып китте **2.** чагылу, чуарлану; **~ в глазáх** күз аллары чуарлана

ря́вкну||ть *несов.* акыру, бакыру, жикерү, ырлау, ырылдау; **медвéдь ~ет** аю акыра

ряд *м* **1.** саф, рәт; **стоя́ть двумя́ ~áми** ике саф булып тору **2.** күп кенә, байтак, берничә; **~ явлéний** берничә күренеш **3.** *мн.* **~ы́** саф; **служи́ть в ~áх а́рмии** армия сафларында хезмәт итү **4.** рәт, кибетләр; **торгóвые ~ы́** сәүдә рәте **♦ из ~а вон [выходя́щий]** гадәттән тыш, бик сирәк була торган; **в ~е случáев** кайбер очракларда

ряднó *с* (*толстый кустарный холст*) киндер, калын киндер

-рядный, -ая, -ое *рус. телендәге сүзләрнең икенче кисәге «...рәттән торган», «шулкадәр» дигән мәгънәне белдәрә, мәс.* **двухря́дный** ике рәтле; **трёхря́дный** өч рәтле

рядов||óй, -áя, -óе **1.** гади; **~óй слýжащий** гади хезмәткәр; **~óй слýчай** гади очрак **2.** (*не являющийся командным*) рядовой; **~óй боéц** рядовой гаскәри **3.** *в знач. сущ.* **~óй** *м* рядовой; **пойти́ на фронт ~ы́м** фронтка рядовой булып бару

ря́дом *нареч.* **1.** янәшәсендә, янәшәдә, якында; **идти́ ~** янәшәсендә бару **2.** (*очень близко*) якында, янында гына; **~ *с кем-чем в знач. предлога*** күршесендә, тирәсендә, янында; **~ с библиоте́кой** китапханә янында **♦ сплошь и (да) ~** атлаган саен, бик еш

ря́женка *ж* ряженка (*катыкның бер төре*)

ря́женый I *м этн.* (*жених*) кияү егет, кияү

ря́женый II, -ая, -ое *уст.* киенгән-ясанган, ... булып киенгән

ря́пушка *ж* ала балык, ряпушка

ря́са *ж* ряса (*православие руханилары-нда киң җиңле озын кием*)

ря́ска *ж бот.* бака тәнкәсе

С

с (с) *предлог* **1.** *с род.п.* (*откуда*) ...дан; **переходи́ть с ме́ста на ме́сто** урыннан урынга күчеп йөрү; **с мое́й стороны́** минем тарафтан; **сорва́ть я́блоко́ с ве́тки** ботактан алма өзеп алу; **упа́сть с кры́ши** түбәдән егылып төшү **2.** *с род.п.* (*при указ. на жительство и т.п.*) ...ы, ...дан килгән, ...лы; **делега́т с Алта́я** Алтайдан килгән делегат; **хлеборо́бы с Украи́ны** украиналы игенчеләр; **цветы́ с ю́га** көньяк чәчәкләре **3.** *с род.п.* (*при обознач. лица, предмета, от к-рого берут что-л.*) ...дан, ... башыннан; **урожа́й с гекта́ра** һәр гектардан алынган иген уңышы **4.** *с род.п.* (*при обознач. начального момента какого-л. действия и в сочет. «с ... до»*) ...дан, ...дан алып, ...дан бирле; **с нача́ла и до конца́** башыннан алып ахырына кадәр; **с тех вре́мён** ул заманнардан бирле; **с утра́ и до́ ночи** иртәдән алып төнгә тикле; **со дня́ на́ день** 1) көннән көнгә; **со дня́ на день откла́дывать** көннән көнгә кичектерә килү; 2) бүген-иртәгә, көннәрдә; **ждать кого́-либо со дня́ на́ день** берәр кешене бүген-иртәгә килер дип көтү **5.** *с род.п.* (*при помощи, каким-л. способом*) ...ып; **взя́ть с бою** сугышып алу; **с ма́ху** кизәнеп; **с разбе́гу** йөгереп килеп; **стреля́ть с колена́** тезләнеп ату **6.** *с род.п.* (*с количественными словами*) ...да; ...белән; **влюби́ться с пе́рвого взгля́да** бер күрүдә гашыйк булу; **уби́ть с пе́рвого вы́стрела** бер атуда үтерү **7.** *с род.п.* (*на основании чего-л.*) белән; **с разреше́ния нача́льника** начальник рөхсәте белән **8.** *с вин.п.* (*приблизительно, почти*) чамасы, чаклы, хәтле, диярлек, ...лап; **величино́й с дом** йорт хәтле зурлыкта; **он получи́л с деся́ток пи́сем** ул унлап хат алды; **с ме́сяц наза́д** бер ай чамасы элек **9.** *с тв.п.* (*при указ. на совместимость*) белән; **говори́ть с това́рищем** иптәшең белән сөйләшү; **оте́ц с ма́терью** атасы белән анасы **10.** *с тв.п.* (*при указ. на наличие чего-л. в чём-л., обладание чем-л.*) ...лы; **до́ждь со сне́гом** карлы яңгыр; **кни́га с иллюстра́циями** рәсемле китап; **челове́к с ружьём** мылтыклы кеше **11.** *с тв.п.* (*при обозначении явления или состояния*) ...ып; **есть с жа́дностью** комсызланып ашау; **слу́шать с восхище́нием** сокланып тыңлау **12.** *с тв.п.* (*при указ. на лицо или предмет, на к-рые распространяется действие, состояние*): **у меня́ пло́хо с се́рдцем** минем йөрәгем начар; **у него́ нелады́ с матема́тикой** ул математика белән дус түгел; **с больны́м случился о́бморок** авыру һушынан язган; **с самолётом произошла́ ава́рия** самолётка авария булган

с- (со-, съ-) *приставка* **1.** *фигыль ясаганда кулланылып, түбәндәге чаралар ярдәмендә бирелә:* 1) *«ташлау» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **сбрить** кырып ташлау; **скоси́ть** чабып ташлау; 2) *«кую» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **ску́чать** өеп кую; **сложи́ть** тезеп кую; **сцепи́ть** эләктереп кую; 3) *«төшү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **све́ситься** салынып төшү; **скати́ться** тәгәрәп төшү; **спры́гнуть** сикереп төшү; **стечь** агып төшү; 4) *«китү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **сойти́ с рельс** рельстан чыгып китү; **сорва́ться с це́пи** чылбырдан ычкынып китү; 5) *«җыелу» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **сбежа́ться** йөгерешеп килеп җыелу; **слета́ться** очып килеп җыелу; **сте́чься** агып килеп җыелу; 6) *«килешү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **сговори́ться** сөйләшеп килешү; **сторгова́ться** сатулашып килешү; 7) *«карау» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **све́рить** чагыштырып карау; **соотнести́** тиңләштереп карау; 8) *«төшү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **сгусти́ться** куера төшү; **смягчи́ться** йомшый төшү; 9) *«кайту» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **сбе́гать** йөгереп барып кайту; **слета́ть** очып барып кайту; 10) *«бетерү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **скорми́ть** ашатып бетерү; **скроши́ть** тураклап бетерү; 11) *«кучереп» дигән хәл фигыль ярдәмендә, мәс.* **списа́ть** күчереп язу; **срисова́ть** күчереп ясау (*рәсемне*); 12) *«бергә» дигән рәвеш ярдәмендә, мәс* **сожи́тельствовать** бергә тору; **сотру́дничать** бергә эшләү; 13) *кайбер приставкалы фигыльләрнең бары төп фигылен генә тәрҗемә итү юлы белән, мәс.* **сде́лать** ясау, эшләү; **сшить** (*платье*) (*кулмәк*) тегү **2.** *исем һәм сыйфатлар ясауда кулланылып, «даш-дәш» кушымчасы ярдәмендә тәрҗәмә ителә, мәс.* **соа́втор** автордаш; **соплеме́нник** кабиләдәш; **собесе́дник** әңгәмәдәш;

саа́мский, -ая, -ое саам[нар] ...ы; ~ **язы́к** саам теле

саа́мы *мн.* саамнар, саам халкы (*Норвегия, Швеция, Финляндиянең төньягында, СССРның Кола ярым атавында яшәүче халык*)

са́бельный, -ая, -ое кылыч ...ы; кылыч белән ...ы; ~ **уда́р** кылыч белән чабу

сабза́ *ж* сабза (*вак сортлы төшсез йөзем*)

са́бля *ж* кылыч

саботаж *м* саботаж, аяк чалу

саботажничать *несов. разг. см.* **саботи́ровать**

саботи́ровать *сов., несов. что и без доп.* саботаж ясау, [берәр эшкә] аяк чалу

са́ван *м* **1.** кәфен, мәет күлмәге **2.** *перен.* яп-ма, җәймә, юрган; **земля́ покры́та бе́лым ~ом** җиргә ак кардан юрган ябылган

сава́нна *ж геогр.* саванна (*экватор поясындагы тропик дала*)

савра́сый, -ая, -ое (*о масти лошади*) кола

са́га *ж лит.* сага (*борынгы Скандинавия һәм борынгы Ирландия халыкларында шигъри риваять*)

сагити́ровать *сов. кого-что* агитацияләп күндерү, димләп күндерү, угетләп күндерү

са́го *с нескл.* саго (*крахмал ярмасы*)

са́гов||ый, -ая, -ое саго ...ы; саголы; **~ая крупа́** саго ярмасы; **пиро́г с ~ой начи́нкой** саголы бәлеш

сад *м* бакча, җимеш бакчасы, баг; **городско́й ~** шәһәр бакчасы; **фрукто́вый ~** җимеш бакчасы; **ботани́ческий ~** ботаника бакчасы; **зоологи́ческий ~** зоология бакчасы; **дом с ~ом** бакчалы өй; ♦ **де́тский ~** балалар бакчасы

садану́ть *сов. однокр. кого-что, прост.* ору, бәрү, кундыру, тамызу

сади́зм *м* **1.** (*половое извращение*) садистлык, женси бозыклык **2.** *перен.* (*жестокость*) залимлек, ерткычлык

сади́ст *м* **1.** садист (*садизмга бирелгән кеше*) **2.** *перен.* залим, ерткыч

сади́стский, -ая, -ое **1.** садист[лар] ...ы, садистларча ... **2.** *перен.* залим [-нәр] ...ы, ерткычларча ..., залимнәрчә ...; **~ посту́пок** ерткычларча кыланыш

сади́ться *несов. см.* **сесть**

сади́ть *несов. обычно безл.* әрнү, әрнеп авырту, кымыршжу, кымыршжып авырту, кычытып авырту; **в го́рле сади́т** тамак төбе кымыршжый

садо́вник *м* бакчачы, җимеш үстерүче

садово́д *м* бакчачы, бакчачылык белгече, җиләк-җимеш үстерүче

садово́дство *с* **1.** (*занятие*) бакчачылык, бакчачылык фәне, җиләк-җимеш үстерү **2.** (*хозяйство*) бакчачылык

садово́дческ||ий, -ая, -ое бакчачылык ...ы, бакчачылар ...ы; **~ие ку́рсы** бакчачылык курслары

садо́в||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* бакча ...ы; **~ая доро́жка** бакча сукмагы; **~ый нож** бакчачы пычагы; **~ая ви́шня** бакча чиясе

садо́к *м* **1.** читлек, оя, бүлем (*хайваннарны, кош-кортларны, балыкларны ябып асрау яки урчету өчен*) **2.** *охот.* (*ловушка*) тозак, капкын; **во́лчий ~** бүре капкыны

са́жа *ж* корым

сажа́лка *ж* утырткыч (*бәрәңге һәм яшельчә утырту машинасы*)

сажа́ть *несов.* **1.** *кого-что* утырту; **~ ребёнка на стул** баланы урындыкка утырту **2.** *что* утырту, төшерү, җиргә төшерү; **~ самолёт** самолётны җиргә төшерү **3.** *кого-что* ябу, утырту; **~ пти́цу в кле́тку** кошны читлеккә ябу; **~ ку́рицу на я́йца** тавыкны чеби чыгарырга утырту **4.** *что* утырту; **~ карто́фель** бәрәңге утырту **5.** *что* тыгу, утырту, салу, кую; **~ хле́бы в печь** ипиләрне мичкә тыгу **6.** *что* тамызу, тамызып тапландыру; **~ кля́ксы** кара тамызып тапландыру

са́жен||ец усенте, үренте; **берёзовые ~цы** каен үсентеләре

сажёнк||и *мн.*: **плыть ~ами** колач салып йөзү

са́жен||ый, -ая, -ое утыртылган, утыртып үстерелгән; **~ые дере́вья** утыртып үстерелгән агачлар

сажёнь, са́жень *ж* сажин (*электә озынлык үлчәве берәмлеге = 2,13 метр чамасы*) ♦ **коса́я са́жень в пле́чах** алыптай зур гәүдәле кеше, әзмәвердәй таза кеше

сазан́ *м* сазан (*балык*)

сайга́ *ж*, **сайга́к** *м зоол.* сайгак, кыр кәҗәсе

са́йка *ж* сайка (*булка*)

са́йра *ж* сайра (*балык*)

сак *м* (*рыболовная снасть*) сөзгеч (*балык тоту эшендә: кыршауга беркетелгән җәтмә*)

саквоя́ж *м* саквояж (*юл сумкасы*)

са́кля *ж* сакля (*Кавказда тау халыкларының өе*)

сакрамента́льн||ый, -ая, -ое *книжн.* изге; тылсымлы; **~ая фра́за** тылсымлы фраза

саксау́л *м* саксаул

саксау́лов||ый, -ая, -ое саксаул ...ы, саксаул ...; **~ые за́росли** саксаул куаклыклары

саксофо́н *м* саксофон (*музыка коралы*)

сала́зки *только мн.* **1.** *разг.* бәләкәй чана, чәнәшкә **2.** *тех.* чана; **~ тока́рного станка́** кыру станогының чанасы

сала́ка *ж* салака, салакуш (*балык*)

саламандра *ж зоол.* саламандра (*җир-су хайваны*)

сала́т *м* **1.** *бот.* салат үләне, салат **2.** салат (*салкын ашамлык*)

сала́тница *ж* салат савыты

сала́тн||ый, -ая, -ое **1.** салат ...ы; **~ая гря́дка** салат тутәле **2.** салатка дигән, салат өчен билгеләнгән; **~ая капу́ста** салатка дигән кәбестә **3.** (*о цвете*) ачык яшел төс, сыек яшел төс

са́лить *несов. кого-что* **1.** майлау, туң май сөртү; майга буяп бетерү, майландыру **2.** (*в детских играть*) әбәкләү

салици́лов||ый: ~ая кислота́ салицил кислотасы (*медицина һәм техникада кулланыла торган органик катнашма*); **~ый натр** салицил натры (*салицил кислотасының тозы*)

са́ло *с* **1.** май, туңмай, терлек мае; **свино́е ~** дуңгыз мае; **нутряно́е ~** эч мае **2.** (*смазочное вещество*) май **3.** (*на воде*) сил, боз пәрдәсе (*катар-катмас вакытта су өстендә хасил була*)

сало́н *м в разн. знач.* салон; **~ да́мской о́буви** хатын-кыз аяк кимнәре салоны; **худо́жественный ~** сәнгать салоны

салфе́тк||а *ж* **1.** (*изделие из ткани*) тастымал, салфетка **2.** (*бумажная*) салфетка **3.** (*скатерть*) бәләкәй ашъяулык; **вы́шитая ~а** чигүле ашъяулык

са́льдо *с нескл. фин.* сальдо

са́льник *м* **1.** *анат.* карын мае, эч мае, эч пәрдәсе **2.** *тех.* сальник

са́льност||ь *ж* **1.** *спец.* майлылык; **устране́ние ~и овчи́ны** сарык тиресенең майлылыгын бетерү **2.** әшәке сүз, оятсыз сүз, әдәпсез сүз; **говори́ть ~и** әшәке сүзләр әйтү

са́льн||ый, -ая, -ое **1.** туң (терлек) май ...ы, терлек маенннан ясалган; **~ая свеча́** терлек маеннан ясалган шәм; **~ое пятно́** туң май табы **2.** (*с высоким содержанием сала*) бик майлы, үтә майлы, чат май; **~ая свинина́** үтә майлы дунгыз ите **3.** майланып беткән, майга катып беткән, каешланып беткән; **~ый воротни́к** каешланып беткән яка **4.** әдәпсез, оятсыз, әшәке; **~ый анекдо́т** әдәпсез анекдот ♦ **~ые же́лезы** *снат.* май бизләре

са́льто-морта́ле *с нескл.* сальто-мортале (*навага сикереп мәтәлчек атудан гыйбарәт булган акробатик күнегү*)

салю́т *м* салют; **артиллери́йский ~** артиллерия салюты; **произвести́ ~** салют бирү

салютова́ть *сов., несов. кому-чему* салют бирү, сәламләү

саля́ми *ж нескл.* салями (*каклаган колбасаның бер төре*)

сам *мест.* **1.** (*лично*) үзем, үзең, үзе; **он ~ это сде́лал** ул үзе ясаган; **он ~ реши́л уе́хать** ул үзе китәргә булды; **я ~ ему́ сказа́л** мин аңа үзем әйттем; **я и ~ не рад** мин үзем дә үкенеп бетә алмыйм **2.** (*для усиления мест. и сущ.*) үзе, үзе үк, ... үк; **~á жизнь э́то подска́зывает** моны тормыш үзе үк әйтеп тора; **~ хара́ктер э́той рабо́ты тако́в** бу эшнең үзенчәлеге үк шундый **3.** *в знач. сущ.* **~á** *ж прост.* үзе (*хуҗа, баш кеше мәгънәсендә*) **4.** (*воплощённый, олицетворённый*) ...ның үзе, ...ның гәүдәләнеше; **он ~á ве́жливость** ул — әдәплелекнең гәүдәләнеше; **э́то ~á поэ́зия** бу — поэзиянең үзе ♦ **быть ~и́м собо́й** үзеңне табигый тоту, кыланмау, ясалмалыкка бирелмәү; **он ~ себе́ голова́** ул үзенә үзе хуҗа; **~ (~á, ~ó) за себя́ говори́т** үзе үк әйтеп тора; **~и с уса́ми** үзебез дә беләбез, үзебезнең дә башка тай типмәгән; **~ не свой, ~á не своя́** үзен үзе белештермичә; **~ (~á, ~ó) по себе́** 1) (*самостоятельно*) үзбаш, үзалдына;

мөстәкыйль рәвештә; 2) үзе үк; **жизнь ~á по себé счáстье** яшәү үзе үк бәхет бит ул; 3) *в знач. сказ.* үзенә башка; **я ~ по себé, а ты ~ по себé** мин үземә башка, ә син үзеңә башка; **~ (~á, ~ó) собóй** үзеннән-үзе; **~ó собóй [разумéется]** үзеннән-үзе [аңлашыла]

самá *м см.* **сам**

самáн *м* саман, саман кирпеч

самáнн||ый, -ая, -ое саман ...; саман кирпечтән салынган; **~ая пострóйка** саман кирпечтән салынган каралты

самбúст *м* самбочы, самбист

сáмбо *с нескл. спорт.* самбо (*көрәшнең бер төре*)

самéц *м* ата, иркәк; **~ олéня** ата болан

сáми *мн. см.* **сам**

сáмка *ж* ана, теше, саулык; **~ лóся** ана поши

самó *с см.* **сам**

самоана́лиз *м* үзанализ (*үз-үзеңә анализ ясау, үзеңнең кылган эшләреңне һәм кимчелекләреңне үзең үк анализлау*)

самобичева́ние *с* үзеңне үзең битәрләү, үзеңне үзең жәзалау (*җибәргән хаталарың өчен вөҗдан газабы кичеру, үкенү, ачыну-сызлану*)

самобра́нка *ж*: **ска́терть-~** тылсымлы ашъяулык (*әкиятләрдә*)

самобы́тность *ж* үзенчәлеклелек, үзенчәлекле булу, үзенә бер төрлелек

самобы́тный, -ая, -ое үзенчәлекле, үзенә бер төрле, үзенә бер, үзенә башка, мөстәкыйль; **~ тала́нт** үзенчәлекле талант

самова́р *м* самавыр; **поста́вить ~** самавыр кую

самова́рный, -ая, -ое самавыр ...ы; **~ кран** самавыр борыны

самовлюблённый, -ая, -ое үзенә-үзе гашыйк булган, үзенә-үзе исе киткән

самовнуше́ние *с* үзеңне-үзең ышандыру (инандыру)

самовозгора́ние *с см.* **самовозгоре́ться**

самовозгора́ться *несов. см.* **самовозгоре́ться**

самовозгоре́ться *сов.* үзлегеннән кабынып китү, үзеннән-үзе яна башлау, үзеннән-үзе кабынып китү

самово́лие *с* үзбелдеклелек, үз белдегенчә генә эш итү, башбаштаклык

самово́льничать *несов.* үз белдегенчә генә эш итү, сансыз кылану

самово́льн||ый, -ая, -ое рөхсәтсез, үз белдеген белән; **~ая отлýчка** рөхсәтсез китү

самовоспита́ние *с* үзеңне-үзең тәрбияләү (тәрбия бирү)

самовосхвале́ние *с* үзеңне-үзең мактау (күкләргә чөю)

самовыраже́ние *с* үз-үзеңне күрсәтү; үз-үзеңне гәүдәләндерү; **~ ли́чности** шәхеснең үз-үзен күрсәтүе

самого́н *м* көмешкә, самогон

самого́нка *ж разг. см.* **самого́н**

самого́нный, -ая, -ое көмешкә ...ы, самогон ...ы; самого́н (көмешкә) куа торган; **~ аппара́т** көмешкә куа торган аппарат

самого́нщик *м разг.* көмешкә кайнатучы, самогон куучы, самогончы

самодви́жущийся, -аяся, -еяся үзе йөри (хәрәкәт итә) торган; үзйөрешле; **~ тра́нспорт** үзйөрешле транспорт

самоде́йствующ||ий, -ая, -ое үзлегеннән хәрәкәт итә торган, автомат рәвештә эшли торган; **~ие аппа́раты** автомат рәвештә эшли торган аппаратлар

самоде́лка *ж разг.* кулдан ясалган (эшләнгән) әйбер; үзең ясаган әйбер

самоде́льный, -ая, -ое үзең ясаган, кулдан ясалган; **~ радиоприёмник** үзең ясаган радиоалгыч

самодержа́вие *с* самодержавие (*революциягә кадәрге Россиядә: патшаның чикләнмәгән хакимияте һәм шул хакимиятка нигезләнгән дәүләт идарәсе системасы*); **ца́рское ~** патша самодержавиесе

самодержа́вный, -ая, -ое самодержавие ...ы; хакимияте чикләнмәгән; **~ строй** самодержавие строе

самоде́ржец *м уст.* патша, монарх (*чикләнмәгән властьлы хөкемдар*)

самоде́ятельност||ь *ж* үзешчән сәнгать; **концéрт ~и** үзешчән сәнгать концерты

самоде́ятельный, -ая, -ое үзешчән сәнгать ...ы; **~ хор** үзешчән сәнгать хоры

самодовле́ющи||ий, -ая, -ее *книжн.* үзенә бер әһәмияте булган, аерым бер әһәмияткә ия булган; **~ая величина́** аерым бер әһәмияткә ия булган зурлык

самодово́льный, -ая, -ое үз-үзеннән бик канәгать булган, үзенә-үзе исе киткән, кәпрәйгән; **~ вид** үз-үзеннән бик канәгать булган кыяфәт

самодово́льство *с* үз-үзеннән бик канәгать булу, үзенә-үзе исе китү, кәпрәйгәнлек

самоду́р *м* дуамал, үзбелдекле, үзсүзле (*кеше*)

самоду́рство *с* дуамаллык, үзбелдеклелек, үзсүзлелек

самоду́рствовать *несов.* дуамаллану, үзбелдеклеләнү, үзсүзләлену

самозабве́ние *с* онытылу, үз-үзеңне оныту, җаның-тәнең белән бирелү; **рабóтать с ~м** җаның-тәнең белән бирелеп эшләү

самозабве́нн||ый, -ая, -ое онытылып ..., үз-үзеңне онытып ..., җаның-тәнең белән бирелеп; **~ая любóвь** җаныңтәнең белән бирелеп ярату

самозаготóвка *ж* үзең әзерләү, үз көчең белән әзерләү

самозаря́дн||ый, -ая, -ое үзлегеннән корыла торган, автоматик корыла торган; **~ая винтóвка** үзлегеннән корыла торган винтовка

самозащи́т||а *ж* үз-үзеңне саклау, саклану, үзеңне (үз-үзеңне) яклау; **инстúнкт ~ы** үз-үзеңне саклау инстинкты

самозва́нец *м* самозванец, ялган исем белән йөрүче

самозва́нка *ж* самозванка, ялган исем белән йөрүче хатын (кыз)

самоиндýкция *ж физ.* үзиндүкция

самока́т *м* самокат

самокле́ющ||ийся, -аяся, -еюся үзе ябыша торган; **~иеся обóи** үзе ябыша торган обой

самоконтро́ль *м* үзконтроль, үз-үзеңә контрольлек итү

самокри́тика *ж* үзара тәнкыйть, үз-үзеңне тәнкыйтләү

самокрити́чность *ж* үзара тәнкыйть белән сугарылганлык, үз-үзен тәнкыйтләү белән сугарылган булу; **~ выступле́ния** чыгышның үзара тәнкыйть белән сугарылганлыгы

самокрити́чн||ый, -ая, -ое үз-үзеңне тәнкыйтләү белән сугарылган, үз-үзеңне тәнкыйтләү ...ы, үзара тәнкыйть рухындагы; **~ое выступле́ние** үз-үзеңне тәнкыйтләү чыгышы

самокру́тка *ж разг.* үзең төргән тәмәке

самолёт *м* самолёт; **пассáжирский ~** пассажир самолёты; **реакти́вный ~** реактив самолёт; **отправиться ~ом** самолёт белән китү

самолётн||ый, -ая, -ое самолёт ...ы; **~ое шасси́** самолет шассие; **~ая разве́дка** самолёт разведкасы

самолётовождение *с* самолёт йөртү эше (*теориясе һәм практикасы*)

самолётострое́ние *с* самолёт төзү, самолёт эшләп чыгару, самолёт ясау

самолётострои́тельный, -ая, -ое самолёт ...ы, самолёт төзү ...ы; **~ заво́д** самолёт төзү заводы

самолече́ние *с* үзеңне-үзең дәвалау (*табиб ярдәменнән башка дәвалану*)

самолюби́вый, -ая, -ое үзен генә сөючән (яратучан), горур, тәкәббер

самолю́бие *с* үзен генә сөю, (ярату), горурлык, тәкәбберлек; **ло́жное ~** ялган горурлык; **заде́ть** *чьё-л.* **~** *кемнең дә булса* горурлыгына кагылу

самомне́ние *с* мин-минлек, үз-үзеңне зурга санау, үзеңне зурга кую, тәкәбберлек

самонаде́янность *ж* үз-үзеңә чиктән тыш ышанганлык, үз көченә чамадан тыш ышану

самонаде́янный, -ая, -ое үз-үзеңә чиктән тыш ышанган, үз көченә чамадан тыш ышанган; **~ вид** үз-үзеңә чиктән тыш ышанган кыяфәт; **~ челове́к** үз көченә чамадан тыш ышанган кеше

самоназва́ние *с* үзенә-үзе биргән исем, үзенә-үзе кушкан исем; **суóми — ~ фúннов** суоми — финнарның үзләреренә биргән исеме

самообладани||е *с* үз-үзеңне тота алу, югалып калмау, аптырап (каушап) калмау; **не теря́ть ~я** үз-үзеңне тота алу сәләтен югалтмау

самоложе́ние *с* үзара салым

самообма́н *м* үз-үзеңне алдау, үзеңүзе алдау

самообольще́ние *с* үз-үзеңне алдап юату (тынычландыру), үз-үзеңне алдау

самооборо́на *ж* үзоборона, үз-үзеңне саклау (*дошман һөҗүменнән*)

самообразова́ние *с* үзлегеннән уку, үзлегеннән [укып] белем алу

самообразова́тельный, -ая, -ое, үзлегеннән укып белем алу ...ы

самообслу́живани||е *с* үзеңә үзең хезмәт күрсәтү; **магази́н ~я** үзеңә үзең хезмәт күрсәтү кибете

самоограниче́ние *с* үз-үзеңне чикләү, үзеңә үзең чик кую

самоокупа́емость *ж эк.* килернең [тотылган] чыгымнарны каплавы; **~ предприя́тий** предприятие килеренең тотылган чыгымнарны каплавы

самооплодотворе́ние *с биол.* үзеннән-үзе аталану, үз-үзен аталандыру, үзлегеннән аталану

самооправда́ние *с* үз-үзеңне аклау

самоопределе́ние *с полит.* үзбилгеләну, үзбилгеләнеш; **пра́во на́ций на ~** милләтләрнең үзбилгеләну хокукы

самоопредели́ться *сов.* **1.** үз урыныңны табу (*тормышта, җәмгыятьтә һ.б.ш.*) **2.** *полит.* үзбелгеләну

самоопределя́ться *несов. см.* **самоопредели́ться**

самопыле́ние *с бот.* үзеннән-үзе (үзлегеннән) серкәләну

самоотве́рженность *ж* үз-үзеңне аямау; фидакарьлек

самоотве́рженный, -ая, -ое **1.** үз-үзен аямый торган; **~ ю́ноша** үз-үзен аямый торган егет **2.** фидакарь; **~ труд** фидакарь хезмәт

самоотво́д *м* үзеңә үзең отвод бирү, үз кандидатураңны үзең кире кагу

самоотравле́ние *с* үзеннән-үзе агулану

самоотрече́ние *с* дөнья рәхәтеннән ваз кичү, дәрвишлеккә бирелү

самоохра́на *ж* үз-үзеңне саклау, үзеңә карата хәвефсезлек чаралары күрү

самооце́нка *ж* үз-үзеңне бәяләү, үзеңә-үзең бәя бирү

самопа́л *м ист.* самопал (*филтә кабызып атыла торган борынгы мылтык*)

самопи́шущ||ий, -ая, -ее үзе яза торган; **~ее устро́йство** үзе яза торган җайланма

самопоже́ртвование *с* үз-үзеңне корбан итү, үз-үзеңне фида кылу

самопозна́ние *с книжн.* үз-үзеңне танып белү

самопроизво́льн||ый, -ая, -ое үзеннән-үзе була торган; үзлегеннән хасил була торган, үзеннән-үзе килеп чыга торган; **~ые движе́ния** үзеннән-үзе була торган хәрәкәтләр

самопря́лка *ж* җеп эрләү машинасы

саморазви́тие *с* **1.** үзлегеннән үсү, үзлегеннән үсеш (*үзлегеңнән укып белемеңне арттыру*) **2.** *философ. см.* **самодвиже́ние**

саморазоблаче́ние *с* үз-үзеңне фаш итү

саморегистри́рующий, -ая, -ее автоматик рәвештә регистрацияли торган

саморегули́рующ||ий, -ая, -ее үзе көйли торган; үзеннән-үзе көйләнә торган; **~ая систе́ма** үзеннән-үзе көйләнә торган система

саморекла́ма *ж* үз-үзеңне мактау, үз-үзеңне күрсәтергә тырышу

саморо́дный, -ая, -ое табигатьтә әзер килеш очрый торган, саф; **~ мета́лл** табигатьтә әзер килеш очрый торган металл

саморо́док, *м* **1.** самородок (*саф килеш табылган металл*) **2.** *перен.* тумыштан талантлы кеше

саморти́зировать *сов.* амортизацияләү, амортизация ясау

самоса́д *м разг.* самосад, үзең үстергән тәмәке

самосбро́ска *ж с.-х.* урак машинасы, [үзе ташлап] ургыч

самосва́л *м* самосвал, үз-бушаткыч (*йөген үзе бушата торган автомобиль, баржа һ.б.ш*)

самосе́в *м бот.* **1.** коелган орлыктан тишелеп үсү **2.** (*растение*) коелган орлыктан тишелеп чыккан үсемлек

самосе́й *м,* **самосе́йка** *ж см.* **самосе́в 2**

самоснабже́ние *с* үз-үзеңне тәэмин итү

самосовершéнствование *с* үз-үзеңне камилләштерү

самосожже́ние *с* үз-үзеңне утта яндыру

самосозна́ние *с* үзаң (*тормышта, җәмгыятьтә үзеңнең әһәмиятеңне, тоткан урыныңны яхшы аңлау*)

самосохране́ни||е *с* үз-үзеңне саклау; **инсти́нкт ~я** үз-үзеңне саклау инстинкты

самостоя́тельность *ж* мөстәкыйльлек, бәйсезлек

самостоя́тельн||ый, -ая, -ое **1.** мөстәкыйль, бәйсез, ирекле; **~ое госуда́рство** мөстәкыйль дәүләт **2.** мөстәкыйль, үзе белеп эш итә торган, мөстәкыйль эш итә ала торган; **~ый челове́к** үзе белеп эш итә торган кеше **3.** чит ярдәмнән башка эшләнгән, мөстәкыйль рәвештә башкарылган; **~ая рабо́та** мөстәкыйль рәвештә башкарылган эш

самостре́л I *м* саплы җәя (*борынгы сугыш коралы*)

самостре́л II *м* үзен-үзе яралаган солдат

самосу́д *м* самосуд, судсыз-нисез җәзалау

самотёк *м* **1.** үз көенә агу; үз җаена агу (*сыекчаның үз авырлыгы тәэсирендә үз уңаена агуы*) **2.** *перен.* үзагым (*берәр эшнәң бернинди плансыз, стихияле рәвештә баруы*); **пусти́ть дело́ на ~** эшне үзагымына кую

самотёком *нареч.* **1.** үз агымы белән, үз җаена агып; **вода́ идёт ~** су үз җаена агып килә **2.** *перен.* үзагымына куелып, стихияле рәвештә

самоуби́йство *с* үз-үзен үтерү, үз-үзеңә кул салу

самоуби́йца *м, ж* үз-үзен үтерүче

самоуваже́ние *с* үз-үзеңне хөрмәтләү (ихтирам итү), үз кадереңне үзең белү

самоуве́ренность *ж* үз-үзеңә [чамадан тыш] ышанганлык

самоуве́ренный, -ая, -ое үз-үзеңә [чамадан тыш] ышынган

самоуниже́ние, самоуничиже́ние *с* үз-үзеңне кимсетү, үз-үзеңне түбәнсетү

самоуничтоже́ние *с* үз-үзеңне һәлак итү

самоуправле́ние *с* үзидарә, ирекле идарә; **студе́нческое ~** студентлар үзидарәсе; **городско́е ~** шәһәр үзидарәсе

самоупра́вный, -ая, -ое башбаштак, үз белдегенчә генә эш итә торган, закон белән исәпләшми торган

самоупра́вство *с* башбаштаклык, үз белдегенчә генә эш итү, закон белән исәпләшмәү

самоупра́вствовать *несов.* башбаштаклык итү, үз белдегенчә генә эш итү, закон тәртибен бозу

самоусовершéнствование *с см.* **самосовершéнствование**

самоуспока́иваться *несов. см.* **самоуспоко́иться**

самоуспокое́ние *с* үз-үзеңне тынычландыру, тынычлыкка бирелү, гамьсезлеккә бирелү

самоуспоко́енность *ж* тынычлыкка бирелгәнлек, гамьсезлеккә бирелгәнлек

самоуспоко́иться *сов.* тынычлыкка бирелү, гамьсезлеккә бирелү, [ирешелгәннәр белән] тынычланып калу

самоустрани́ться *сов.* читләшү, үз эшеңнән читләшү, үз эшеңне кайгыртмый башлау

самоустраня́ться *несов. см.* **самоустрани́ться**

самоутвержде́ние *с* үз-үзеңне раслау, үз шәхесеңне раслау

самоучи́тель *м* самоучитель, үзөйрәткеч

самоу́чка *м, ж* үзлегеннән өйрәнгән (укыган) кеше; **худо́жник ~** үзлегеннән өйрәнгән художник

самохо́д *м* самоход (*үзйөрешле механизм*)

самохо́дка *ж разг. см.* **самохо́д**

самохо́дн||ый, -ая, -ое үзйөрешле, үзе йөри торган; **~ая ба́ржа** үзйөрешле баржа

самоцве́т *м мин.* асылтыш, кыйммәтле таш, ярым кыйммәтле таш

самоцве́тный, -ая, -ое ялтыравыклы, җемелдәвекле, үтә күренмәле (*асылташлар һәм ярым кыйммәтле ташлар турында*)

самоце́ль *ж* үзмаксат

сасмочи́нн||ый, -ая, -ое башбаштаклык белән эшләнгән, законсыз эшләнгән, үз белдегенчә эшләнгән; **~ые де́йствия** законсыз эшләнгән эшләр

самочи́нство *с* башбаштаклык, законсызлык, үз белдегенчә эшләнгән эш

самочу́вствие *с* кәеф, хәл-әхвәл

саму́м *м* сәмум, ком бураны, эссе җил (*Азия һәм Африка чүлләрендә*)

самура́й *м* самурай (**1.** *феодаль Японияда: өстен катлау сугышчысы* **2.** *япон гаскәрие*)

самши́т *м* самшит, самшит агачы

самши́тов||ый, -ая, -ое **1.** самшит ...ы; **~ая ро́ща** самшит куаклыгы **2.** самшиттан эшләнгән

са́м||ый, -ая, -ое *мест.* **1.** (*именно, как раз*) нәкъ менә, нәкъ үзе; **в э́том ~ом ме́сте** нәкъ менә шушы урында **2.** (*прямо, как раз*) нәкъ, үк, үк; **с ~ого утра́** иртәдән үк **3.** (*даже, сам по себе*) үзе, үзе генә дә, үзе үк; **доста́точен ~ый факт**

согла́сия риза булу факты үзе генә дә бик житкән **4.** (*при образовании превосх. ст. прил.*) иң; **~ый бы́стрый** иң житез; **~ый краси́вый** иң чибәр ♦ **в ~ом де́ле** чыннан да, чынлап та; **на ~ом де́ле** асылда, чынлыкта, чынында; **в ~ый раз** 1) (*вовремя*) бик вакытлы, иң кирәк чакта; 2) (*впору*) тап-таман, чак (*мәс. кием турында*)

сан *м* дәрәҗә; исем; **носи́ть высо́кий ~** югары дәрәҗәгә ия булу; **приня́ть мона́шеский ~** монахлык дәрәҗәсе алу

сан- *кушма сүзләрнең «санитария» мәгънәсен белдерә торган беренче өлеше, мәс.* **сандружи́на** санитария дружинасы; **санинспе́ктор** санитария инспекторы

санато́рий *м* санаторий, шифаханә

санато́рно-куро́ртн||ый, -ая, -ое санаторий-курорт; **~ая ка́рта** санаторий-курорт картасы

санато́рный, -ая, -ое санаторий ...ы; **~ врач** санаторий табибы; **~ режи́м** санаторий режимы

сана́ция *ж* санация (**1.** *мед. авыз кушылыгын савыктыру өчен үткәрелә торган дәвалау чаралары* **2.** *эк. капиталистик илләрдә банкларны һәм эре предприятиеләрне банкротлыктан саклау максаты белән дәүләт тарафыннан курелә торган чаралар системасы*)

санба́т *м воен.* санбат

сангви́ник *м* сангвиник (*шат күңелле, житез хәрәкәтле, тышкы тәэсирләргә бик тиз бирелүчән кеше*)

сангвини́ческий, -ая, -ое сангвиник; **~ темпера́мент** сангвиник темперамент

санда́л *м* сандал, бәкам (агач һәм шул агачтан алына торган буяу)

сандале́ты *мн.* сандалет (*җиңел аяк киеме*)

санда́лии *мн.* сандал (*аяк киеме*)

санда́лов||ый, -ая, -ое сандал ...ы; бәкам ...ы; **~ое де́рево** бәкам агачы; **~ое ма́сло** бәкам мае

са́ни *только мн.* чана

сани́ровать *сов., несов. что* санация үткәрү

санита́р *м* санитар

санитари́я *ж* санитария (*чисталык һәм сәламәтлек саклау өчен үткәрелә торган чаралар*)

санита́рка *ж* санитарка, санитар хатын (кыз)

санита́рн||ый, -ая, -ое **1.** санитария ...ы; **~ый надзо́р** санитария күзәтүе; **~ый врач** санитария табибы **2.** санитар; **~ое состоя́ние го́рода** шәһәрнең санитар хәле **3.** (*в армии*) санитария ...ы; **~ый по́езд** санитария поезды; **~ая часть** санитария часте

са́нки *только мн. разг.* чана, бәләкәй чана

санкциони́ровать *сов., несов. что* санкция бирү, санкциялә

са́нкция *ж* санкция (**1.** *югары инстанциянең бирәр нәрсәне раславы, рөхсәт бирүе* **2.** *узара килешүләрне, договорларны бозган якка карата кулланыла торган чаралар*)

са́нно-тра́кторный, -ая, -ое тракторларга тагылган чаналар ...ы; **~ по́езд** тракторларга тагылган чаналар кәрваны

са́нн||ый, -ая, -ое чана ...ы; **~ые поло́зья** чана табаны; **~ый след** чана эзе

санобрабо́тка *ж* санитария эшкәртүе

сано́вник *м уст.* сановник, зур түрә

сано́вный, -ая, -ое *уст.* югары дәрәҗәле, зур чинлы

санпропускни́к *м* санпропускник (*санитария-профилактика чаралары үткәру учреждениесе*)

санскри́т *м* санскрит (*һиндләрнең борынгы әдәби теле*)

санскри́тск||ий, -ая, -ое **1.** санскрит ...ы; **~ий язы́к** санскрит теле **2.** санскрит телендә язылган; **~ая ру́копись** санскрит телендә язылган кулъязма

санте́хника *ж* сантехника

сантехни́ческ||ий, -ая, -ое сантехника ...ы; **~ое обору́дование** сантехника җиһазлары

санти́м *м* сантим (*Франциядә, Бельгиядә һ.б.ш. кайбер илләрдә вак акча*)

сантиме́нты *только мн. ирон.* хисләр, хискә бирелү; **разводи́ть ~** хискә бирелү

сантиме́тр *м* сантиметр

сап *м вет.* маңка авыруы (*атларда була торган йогышлы авыру*)

са́п||а *ж воен.* сапа (*траншеянең бер төре*) ♦ **ти́хой ~ой** астыртынлык белән, искәрмәстән, сиздермәстән

сапёр *м воен.* сапёр

сапёрн||ый, -ая, -ое *воен.* **1.** сапёрлар ...ы; **~ый батальо́н** сапёрлар батальоны **2.** сапёрлык ...ы; **~ое де́ло** сапёрлык эше

сапо́г *м* итек, күн итек ♦ **два ~а́ па́ра** икесе бер чыбыктан сөрелгән; **под ~о́м [быть, находи́ться]** изүе астында булу, буйсынуында булу; **~и́ всмя́тку** юк нәрсә, сафсата; **~и́-скорохо́ды** *фольк.* тылсымлы итек (*әкиятләрдә*)

сапо́жник *м* **1.** итекче, итек тегүче; читекче **2.** *прост.* (*о неумелом человеке*) булдыксыз, пешмәгән (*үз эшен эшли белми тораган кеше турында*)

сапо́жничать *несов.* итек (читек) тегү белән шөгыльләнү; итек (читек) төзәтү белән шөгыльләнү

сапо́жн||ый, -ая, -ое **1.** итек (читек) ...ы; итекче ...ы; **~ая щётка** итек щёткасы; **~ый нож** итекче пычагы **3.** итек тегү ...ы; итек төзәтү ...ы; итек ...ы; **~ая мастерска́я** итек төзәтү мастерское

сапфи́р *м* сапфир, зәңгәр якут

сапфи́рн||ый, -ая, -ое, **сапфи́ров||ый,** -ая, -ое **1.** сапфир ..., зәңгәр якут ..., сапфирдан (зәңгәр якуттан) ясалган; **~ое кольцо́** сапфир балдак **2.** (*цве́та сапфира*) сапфир төсле, зәңгәр

сара́й *м* сарай

саранча́ *ж зоол.* саранча (*корткыч бөҗәк*)

сарафа́н *м* сарафан

сараци́ны *мн. уст.* сарациннар (*электә европалылар мөселманнарны шулай атаганнар*)

сарде́лька *ж* сарделька

сарди́на *ж* сардина (*балык*)

сарди́нка *ж* сардинка (*балык*)

сардони́кс *м мин.* сардоникс

сардони́ческий, -ая, -ое мыскыллы, зәһәрле, ачы, усал, мәсхәрәле; **~ смех** зәһәрле көлү

са́ржа *ж* саржа (*тукыма*)

са́ржев||ый, -ая, -ое саржа ...; **~ая подкла́дка** саржа эчлек

сарка́зм *м* сарказм (**1.** *зәһәрле көлү, чәнечкеле көлү, ачы көлү*; **2.** *мәсхәрәле искәртү*)

саркасти́ческ||ий, -ая, -ое сарказмлы, зәһәрле, чәнечкеле, мәсхәрәле; **~ая улы́бка** мәсхәрәле елмаю

сарко́ма *ж мед.* саркома (*яман шешнең бер төре*)

саркофа́г *м* саркофаг, таш табут

сарма́тск||ий, -ая, -ое сармат ...ы; **~ие племена́** сармат кабиләләре

сарма́ты *мн.* сарматлар (*безнең эрага кадәр б-2нче гасырларда Идел, Кама диңгез, Азов диңгезе буйларында яшәгән күчмә кабиләләр группасы*)

сарпи́нка *ж* сарпинка, сәрфинкә (*тукыма*)

сары́ч *м зоол.* сарыч, елак карчыга

сатана́ *с* иблис, шайтан

сатане́ть *несов. прост.* явызлану, усаллану, котырыну

сатани́нский, -ая, -ое шайтан ...ы; **~ смех** шайтан көлүе

сателли́т *м* сателлит (**1.** *астр. планета иярчене* **2.** *перен. иярчен, башка берәүгә буйсынган, мөстәкыйль булмаган*)

сати́н *м* сатин (*тукыма*)

сати́новый, -ая, -ое сатин ...; сатиннан тегелгән; **~ хала́т** сатин халат

сати́р *м* сатир (*борынгы грек мифологиясендә аракы алласының азгын иярчене*)

сати́ра *ж* сатира

сати́рик *м* сатирик, сатирачы

сатири́ческий, -ая, -ое сатира ...ы, сатирик ..., сатира белән сугарылган; **~ журна́л** сатирик журнал

сатра́п *м* сатрап (**1.** *борынгы Иранда һәм Һиндстанда аерым провинцияләрдә идарә башлыгы* **2.** *перен. залим түрә, деспот, башбаштак түрә*)

сатура́тор *м* сатуратор (*сыеклыкларны газга туендыру аппараты*)

сафья́н *м* сафьян, сәхтиян (*югары сыйфатлы күн*)

сафья́нов||ый, -ая, -ое сафьян ...ы, сәхтиян ...ы, сафьян ..., сәхтиян ...; **~ые сапо́ги** сафьян итек

са́хар *м* шикәр ♦ **не ~** ал да гөл дип әйтеп булмый, менә дигәннәрдән түгел; **хара́ктер у него́ не ~** аның холкы менә дигәннәрдән түгел

сахари́н *м* сахарин

сахари́новый, -ая, -ое сахарин ...ы; **~ порошо́к** сахарин порошогы

са́харистость *ж* шикәрлелек, шикәрлелек дәрәҗәсе; **~ ягод** жиләкләрнең шикәрлеге

са́харист||ый, -ая, -ое **1.** шикәрле, шикәргә бай; **~ые сорта́ свёклы** чөгендернең шикәргә бай сортлары **2.** *спец.* шикәрсыман, шикәр кебек; **~ые вещества́** шикәрсыман матдәләр

са́харница *ж* шикәр савыты

са́харн||ый, -ая, -ое **1.** шикәр ...ы; **~ый песо́к** шикәр комы **2.** шикәрле; **~ая вода́** шикәрле су **3.** шикәр ...ы;

~ая свёкла шикәр чөгендере; **~ый тростни́к** шикәр камышы ♦ **~ая боле́знь** диабет; **~ая кость** кимекле сөяк; **~ые ре́чи** төче сүзләр, төче телләнү, ялагайланып сөйләнү

сахарова́рение *с* шикәр кайнату; шикәр эшләп чыгару

сахаро́за *ж хим.* сахароза (*усемлекләрдә була торган углевод*)

сачо́к *м* ятьмә, бәләкәй сөкә

сба́ви||ть *сов.* **1.** *что, чего и без доп.* (*уменьшить*) киметү, чигерү, төшерү; **~ть полови́ну цены** бәянең яртысын кимету **2.** *что, в чём и без доп.* кимү; **больно́й ~ л в ве́се** авыруның авырлыгы кимегән

сба́вка *ж* **1.** *см.* **сба́вить; ~ в цене́** бәяне кимету **2.** (*то, что сбавлено*) кимителгән өлеш, ташлама

сбавля́ть *несов. см.* **сба́вить**

сбавля́ться *несов.* **1.** *см.* **сба́виться**; **2.** *страд. от* **сбавля́ть**

сба́грить *сов. кого-что, прост.* котылу, аткару, олактыру

сбаланси́ровать *сов.* **1.** тигезлек саклау, тигезлек хәленә китерү **2.** *что бухг.* баланс чыгару, баланс ясау (*исәп-хисап эшендә*)

сба́лтывать *несов. см.* **сболта́ть**

сбе́гать *сов. разг.* йөгереп барып килү (кайту)

сбега́ть *несов. см.* **сбежа́ть**

сбега́ться *несов. см.* **сбежа́ться**

сбежа́||ть *сов.* **1.** йөгереп төшү; **~ть с ле́стницы** баскычтан йөгереп төшү **2.** (*стечь — о жидкости*) агып төшү **3.** (*убежать тайком*) качу, качып китү **4.** *разг.* ташу, ташып түгелеп бетү; **молоко́ ~ло** сөт ташып түгелеп беткән **5.** *перен.* югалу, юкка чыгу; **улы́бка ~ла с лица́** йөзендәге елмаюы юкка чыкты

сбежа́ться *сов.* йөгерешеп килеп житү (җыелу)

сберега́тельн||ый, -ая, -ое саклык ...ы; **~ый банк** саклык банкысы; **~ая кни́жка** саклык кенәгәсе

сберега́ть *несов. см.* **сбере́чь**

сберега́ться *несов.* **1.** *см.* **сбере́чься**; **2.** *страд. от* **сберега́ть**

сбереже́ни||е *с* **1.** *см.* **сбере́чь**; **2.** *обычно мн.* **~я** [саклыкка] җыелган акча, җыйган акча

сбере́чь *сов.* **1.** *кого-что* саклау, саклап тоту; саклап (алып) калу; **~ ну́жные бума́ги** кирәкле кәгазьләрне саклап калу **2.** *что* саклыкка җыю, җыю, туплау; **~ небольшу́ю су́мму де́нег** бераз акча җыю

сбере́чься *сов.* саклану, сакланып калу, янга калу

сберка́сса *ж* саклык кассасы

сберкни́жка *ж* саклык кенәгәсе

сбива́ть *несов. см.* **сбить**

сбива́||ться *несов.* **1.** *см.* **сби́ться**; **2.** *перен. на что, разг.* охшау, хәтерләтү; **расска́з ~ется на ска́зку** хикәя әкиятне хәтерләтә **3.** *страд. от* **сбива́ть**

сби́вчивость *ж* буталчыклык, чуалчыклык

сби́вчивый, -ая, -ое буталчык, чуалчык, өзек-төтек; **~ отве́т** буталчык җавап

сби́тень *м уст.* бал ширбәте (кайнар килеш кулланыла)

сбить *сов.* **1.** *кого-что* сугып (бәреп) чыгару, бәреп (атып, сугып) төшерү; **~ замо́к с две́ри** ишектән йозакны бәреп чыгару; **~ я́блоко с ве́тки** алманы ботагыннан сугып төшерү **2.** *кого-что* бәреп егу; **~ челове́ка с ног** кешене бәреп аяктан егу **3.** *что* кыйшайту, кыегайту, чалышайту; **~ каблуки́** үкчәләрне кыегайту **4.** *что, разг.* кимету, төшерү; **~ це́ну** бәясен кимету **5.** *перен. кого-что* (*запутать*) [юлдан] яздыру, саташтыру, ялгыштыру, бутау, чуалту, аптырашта калдыру **6.** *что* каккалап-суккалап ясау (беркетү), әтмәләү; **~ я́щик из доско́** такталардан әрҗә әтмәләү **7.** *что* язу, атлау; **~ ма́сло** май язу **8.** *что* туглау, күпертү, кабарту; **~ желтки́** йомырка сарысын туглау **9.** *кого-что, разг.* өю, туплау; **~ всех в ку́чу** барысын бер өемгә өю ♦ **~ спесь** кикриген шиндерү; **~ с то́лку** фикерен чуалту

сби́||ться *сов.* **1.** кыегаю, кыйшаю, чалышаю, янтаю; **каблуки́ ~лись** үкчәләре кыйшайган; **шля́па ~лась на́бок** эшләпә янтайган **2.** *с чего и без доп.* [юлдан] язу, адашу; **~ться с доро́ги** юлдан язу **3.** саташу, ялгышу, буталу; **~ться со счёта** санаганда ялгышу **4.** (*о масле*) язылу, атлану **5.** (*о желтках*) туглану, кабару, күперү **6.** *разг.* өелу, туплану; **лю́ди ~лись в ку́чу** кешеләр бер төркем булып өелделәр ♦ **~ться с ног** аяктан язу, хәлдән таю, аяклар калмау; **~ться с ша́га** адымны бозу

сближа́ть *несов. см.* **сбли́зить**

сближа́ться *несов.* **1.** *см.* **сбли́зиться** **2.** *страд. от* **сближа́ть**

сближе́ние *с см.* **сбли́зить, сбли́зиться; ~ двух корабле́й** ике корабльнең үзара якынаюы

сбли́зи||ть *сов. кого-что* **1.** [бер-беренә] якын китерү, [үзара] якынайту; **~ть но́жки ци́ркуля** җәзбәнең япьләрен бер-берсенә якын китерү **2.** араны якынайту, дуслаштыру, татуландыру; **о́бщая рабо́та нас ~ла** уртак эш безне дуслаштырды

сбли́зиться *сов.* **1.** (*приблизиться*) [бер-беренә] якын килу, [үзара] якынаю, якынлашу **2.** (*сдружиться*) дуслашу, дус булып китү, якынлашу

сбой *м* **1.** (*перебой в движении, работе*) тоткарлык, өзеклек, тигезсезлек **2.** *спец.* (*часть туши*) эч-баш, үпкә-бавыр, эчәк-карта, баш-аяк (*суелган терлекнең*)

сбо́ку *нареч.* кырыйдан, яннан, бер читтән, бер яктан ♦ **~ припёка** ≈ кирәкле кишер яфрагы

сболта́ть *сов. что с чем* [кушып] болгату, [кушып] тугылау

сболтну́ть *сов. что, разг.* әйтеп ташлау, ычкындыру; **~ глу́пость** ахмак сүз әйтеп ташлау; **~ ли́шнее** артыгын әйтеп ташлау

сбор *м* **1.** *см.* **собра́ть** 2, **собра́ться** 1; **~ по́дписей** имза җыю; **~ све́дений** мәгълүматлар җыю; **~ урожа́я** уңыш җыю; **~ хло́пка** мамык җыю; **~ на демонстра́цию** демонстрациягә җыелу **2.** (*то, что собрано*) җыем, җыелган акча; **валово́й ~ зерна́** ашлыкның тулай җыемы; **страхово́й ~** страхование өчен җыелган акча **3.** сбор; **пионе́рский ~** пионер сборы **4.** *мн.* **~ы** җыену, әзерләну; **~ы к путеше́ствию** сәяхәткә әзерләну ♦ **все в ~е** һәммәсе дә җыелган

сбо́рище *с разг. неодобр.* өер, төркем, халык төркеме

сбо́рка I *ж см.* **собра́ть** 4; **~ станка́** станокны җыю

сбо́рка II *ж* бөрмә; **ко́фта со ~ми** бөрмәле кофта

сбо́рник *м* **1.** җыентык; **~ пе́сен** җырлар җыентыгы **2.** *спец.* җыйгыч, туплагыч; **~ не́фти** нефть җыйгыч

сбо́рн||ый, -ая, -ое **1.** җыелу ...ы, туплану ...ы; **~ый пункт** җыелу пункты **2.** җыелма; **~ая кома́нда** җыелма команда; **~ые железобето́нные конструкции** җыелма тимер-бетон конструкцияләр

сбо́рочный, -ая, -ое җыю ...ы, кору ...ы; **~ цех** җыю цехы

сбо́рчат||ый, -ая, -ое бөрмәле; **~ая ю́бка** бөрмәле юбка

сбо́рщик *м* **1.** җыючы; **~ взно́сов** взнос җыючы; **~ хло́пка** мамык җыючы **2.** җыючы, коручы, монтажлаучы; **~ мото́ров** моторлар җыючы

сбо́рщица *ж* җыючы хатын (кыз)

сбра́сывание *с см.* **сбро́сить, сбро́ситься; ~ снега с кры́ши** түбәдән кар төшерү

сбра́сыватель *м тех.* ташлаткыч, ыргыткыч; **автомати́ческий ~** автоматик ташлаткыч

сбра́сывать *несов. см.* **сбро́сить**

сбра́сываться *несов.* **1.** *см.* **сбро́ситься**; **2.** *страд. от* **сбра́сывать**

сбреда́ться *несов. см.* **сбрести́сь**

сбрива́ть *несов. см.* **сбрить**

сбрить *сов. что* кыру, китәрү, кырып алу (ташлау); **~ бо́роду** сакал кыру

сброд *м собир. презр.* адәм актыклары, әтрәк-әләмнәр

сброс *м* **1.** *см.* **сбро́сить** 1, 6; **~ га́за** газ агызу **2.** (*отток воды*) агызу; **~ воды́ в о́зеро** суны күлгә агызу **3.** *геол.* убылу, иңү (*җир катламының ярылып аска төшүе*)

сбро́си||ть *сов.* **1.** *кого-что* ташлау, төшереп җибәрү, ыргыту; **~ть ка́мень с горы́** тау башыннан таш ыргыту; **~ть деса́нт** десант төшерү **2.** *что* алып ташлау; **~ть с себя́ оде́яло** өстендәге юрганыңны алып ташлау **3.** *что* салу, салып ташлау, кою; **я́щерица ~ла ко́жу** кәлтә елан кабыгын салган; **~ть листву́** яфрак кою **4.** *перен. кого-что* алып ташлау, бәреп төшерү; **~ть и́го ра́бства** коллык изүен алып ташлау **5.** *что* (*на счётах*) алып ташлау, чигерү **6.** *что* кимету; **~ть давле́ние** басымны кимету

сбро́ситься *сов.* **1.** (*броситься вниз*) ташлану, сикерү **2.** *прост.* акча салышу; **~ по рублю́** берәр сумнан акча салышу

сброшюрова́ть *сов. что* брошюровкалау, брошюровать итү (*китапны, журналны*)

сбру́я *ж* сбруй, дирбия

сбры́згивать *несов. см.* **сбры́знуть**

сбры́знуть *сов. что* сиптерү, сиптереп алу, бөркү, бөркеп алу, чәчрәтеп юешләү; **~ бельё пе́ред гла́жением** үтүкләр алдыннан кергә су бөркеп алу

сбыва́ть *несов. см.* **сбыть**

сбыва́ться *несов.* **1.** *см.* **сбы́ться; 2.** *страд. от* **сбыва́ть**

сбыт *м* [товар] сату; **ры́нок ~а** [товар] сату базары

сбытов||о́й, -ая, -о́е сату ...ы; **~ы́е опера́ции** сату операцияләре

сбыть *сов. разг.* **1.** *кого-что* (*продать*) сату, сатып җибәрү **2.** *что* олактыру, аткару, котылу; **~ нену́жные ве́щи** кирәксез әйберләрдән котылу **3.** (*пойти на убыль — о поднявшейся воде*) кимү, кайту

сбы́ться *сов.* **1.** (*осуществиться*) тормышка ашу, чынга ашу, гамәлгә ашу; **наде́жды сбыли́сь** өметләр чынга ашты **2.** *уст.* (*произойти*) булу; **что с ним сбу́дется?** аңа ни булыр икән?

сва́дебный, -ая, -ое туй ...ы; **~ый пода́рок** туй бүләге; **~ая церемо́ния** туй тантанасы

сва́дьб||а *ж* туй, туй мәҗлесе; **золота́я ~а** алтын туй (*ойләнешеп бергә тора башлауның илле еллыгы*); **серебряная ~а** көмеш туй (*ойләнешеп биргә тора башлауның егерме биш еллыгы*); **спра́вить ~у** туй үткәрү ♦ **до ~бы заживёт** *шутл.* туеңа хәтле төзәлер (*берәр җирен яралаган кешегә карата шаярып әйтелә*)

сва́йный, -ая, -ое **1.** субай сугу ...ы; субай кагу ...ы; **~ые рабо́ты** субай сугу эшләре **2.** субайлар өстенә корылган; **~ая постро́йка** субайлар өстенә корылган каралты

сва́ливать *несов. см.* **свали́ть**

сва́ливаться *несов.* **1.** *см.* **свали́ться; 2.** *страд. от* **сва́ливать**

свали́||ть *сов.* **1.** *кого-что* аудару, егу, аяктан егу; **~ть де́рево** агач аудару; **~ть с ног** аяктан егу **2.** *перен. кого, разг.* (*о сне, болезни*) аяктан егу, аудару; билән алу; **его́ ~ла боле́знь** аны авыру аяктан екты **3.** *кого-что* ташлау, ыргыту, аудару, төшереп җибәру; **~ть но́шу с плеч** йөкне җилкәдән төшереп җибәрү **4.** *что* өю, ташлау, тутыру; **~ть всё в у́гол** һәммәсен бер почмакка китереп ташлау **5.** *перен. что на кого-что, разг.* аудару, сылтау, япсару; **~ть вину́ на друго́го** гаепне икенче берәүгә япсару ♦ **~ть с больно́й головы́ на здоро́вую** ≈ ак эт бәласе кара эткә

свали́||ться *сов.* **1.** егылып төшү; **~ться с кры́ши** түбәдән егылып төшү **2.** аву; **забо́р ~лся** койма ауган **3.** *разг.* (*заболеть*) авырып китү, аяктан егылу **4.** *разг.* салыну, авышу, кыегаю, кыйшаю; **изба́ ~лась на́бок** өй бер якка кыйшайган

сва́лк||а *ж* **1.** *см.* **свали́ть** 1; **2.** чүплек, чүплек башы; **вы́везти му́сор на ~у** чүп-чарны чүплеккә чыгарып ташлау **3.** *разг.* (*драка*) өелешеп сугышу, әүмәкләшеп сугышу, кыйнашу, тукмашу

сва́лочный, -ая, -ое чүп-чар түгелә (ташлана) торган

свали́ть *сов.* **1.** *что* басу; **~ ва́ленки** итек басу **2.** *что и без доп., прост.* (*сделать кое-как*) әвәләп ату, эштерәштер генә эшләп ташлау ♦ **~ дурака́** юләр сату, ахмаклык эшләп ташлау

свали́ться *сов.* **1.** (*об изделиях из шерсти, пуха*) басылу **2.** (*о волосах, шерсти*) үкмашып бетү, чуалып бетү, киезләну

сва́нский, -ая, -ое сван[нар] ...ы; **~ язы́к** сван теле

сва́ны *мн.* сваннар, сван халкы (*көнбатыш Грузиядә яшәүче тау халкы*)

сва́ра *ж прост.* кычкырыш, ызгыш, талаш, гауга, җәнҗал

сва́ривать *несов. см.* **свари́ть** 3

сва́риваться *несов.* **1.** *см.* **свари́ться** 3; **2.** *страд. от* **сва́ривать**

свари́ть *сов. что* **1.** пешерү, пешереп алу; **~ ка́шу** ботка пешерү **2.** кайнату, кайнатып алу; **~ клей** җилем кайнату **3.** *тех.* эретеп ябыштыру; кыздырып ябаштыру; **~ ре́льсы** рельсларны эретеп ябыштыру

свари́||ться *сов.* **1.** пешү, пешеп җиту; **ка́ша ~лась** ботка пеште **2.** кайнау, кайнып чыгу; **клей ~лся** җилем кайнады **3.** *тех.* эреп ябышу; кызып ябышу (берегү, тоташу)

сва́рка *ж тех.* эретеп ябыштыру; кыздырып ябыштыру; сварка; **автоге́нная ~** автоген исулы белән эретеп ябыштыру

сварли́вый, -ая, -ое гаугачыл, бәйләнчек, ызгышучан, тиргәшүчән, талашучан; **~ стари́к** гаугачыл карт

сварн||о́й, -а́я, -о́е *тех.* эретеп ябыштырылган; кыздырып ябыштырылган; **~ы́е тру́бы** эретеп ябыштырылган торбалар

сва́рочн||ый, -ая, -ое эретеп ябыштыру ...ы; **~ые рабо́ты** эретеп ябыштыру эшләре

сва́рщик *м* сварщик, сваркачы (*металлны эретеп ябыштыручы эшче*)

сва́рщица *ж* сварщик хатын (кыз)

сва́стика *ж* свастика (*фашизм эмблемасы*)

сват *м* **1.** яучы, башкода, димче; **засыла́ть ~ов** яучылар җибәрү **2.** (*отец одного из супругов по отношению к родителям другого*) кода

сва́та||ть *несов.* **1.** *кого кому, кого за кого* димләү, кыз димләү **2.** *кого, кого у кого* кодалау, яучылау, яучы җибәрү, кыз сорау; **~ть дочь сосе́да** күршенең кызын яучылау **3.** *перен. кого, разг.* тәкъдим итү, димләү; **~ют нам но́вого специали́ста** безгә бер яңа белгеч димлиләр

сва́таться *несов. к кому, за кого* яучылау, яучы җиберү, кодалау, кыз сорау

сва́тья *ж* (*мать одного из супругов по отношению к родителям другого*) кодагый

сва́ха *ж* яучы хатын, димче хатын

сва́||я *ж* субай; **заби́ть ~ю** субай сугу

све́дени||е *с* **1.** *обычно мн.* **~я** (*известия, сообщения*) хәбәр, мәгълүмат; **по полу́ченным ~ям** алынган хәбәрләргә

сведу́щий, -ая, -ее зур белемле, тирән белемле, мәгълүматлы

свеже- *кушма сүзләрнең «әле генә», «яңа гына» мәгънәләрен аңлаткан беренче өлеше, мәс.* **свежевы́глаженный** әле генә үтүкләнгән; **свежеско́шенный** яңа гына чабылган

свежева́льщик *м* тиресен тунап эчен алучы (*суелган терлекнең*)

свежева́ть *несов. кого-что* тиресен тунап эчен алу (*суелган терлекнең*); **~ ту́шу** түшкәнең тунап эчен алу

свежезаморо́женный, -ая, -ое свежий килеш тундырылган (өшетелгән)

свежеиспечённый, -ая, -ое **1.** яңа пешкән, яңа гына пешеп чыккан; **~ пиро́г** яңа пешкән бәлеш **2.** *перен.* яңа гына өлгереп җиткән, әле генә пичтән чыккан, өр-яңа; **~ инжене́р** яңа гына өлгереп җиткән инженер

све́жест||ь *ж* **1.** сафлык, чисталык; **~ть во́здуха** һаваның сафлыгы **2.** (*прохлада*) салкынчалык, салкынча җил, жиләслек; **~ть ве́тра** җилнең салкынчалыгы; **~ть у́тра** иртәнең җиләслеге; **пахну́ло ~ью** салкынча җил исеп куйды **3.** төсе китмәгәнлек, ачыклык, уңмаганлык; **~ь кра́сок** буяуларның ачыклыгы **4.** тотылмаганлык, киелмәгәнлек, чисталык; **~ь бе́лья** эчке киемнәрнең чисталыгы **5.** *перен.* яңалык; **~ь мы́слей** фикерләрнең яңалыгы ♦ **не пе́рвой ~и** 1) (*лежалый*) бик үк яңа түгел, искергән; 2) (*не очень чистый*) бик үк чиста түгел

свеже́||ть *несов.* **1.** суыта (салкынайта) төшү, салкынчалану, җиләсләну; **к но́чи ~ет** төнгә таба көн суыта төшә **2.** (*становиться здоровее, румянее*) тазарып китү, матурланып китү, яшәреп китү

све́ж||ий, -ая, -ее **1.** яңа ...ган, яңа гына ...ган, әле генә ...гән; **~ее молоко́** яңа сауган сөт; **~ее мя́со** яңа суйган ит; **~ий хлеб** яңа пешкән икмәк **2.** тозланмаган, ысланмаган, какланмаган, свежий; **~ий огуре́ц** яшь кыяр **3.** саф, чиста; **~ий во́здух** саф һава **4.** (*прохладный*) салкынча, җиләс; **~ий ве́тер** салкынча җил **5.** (*не утративший яркости*) төсе китмәгән, уңмаган, ялтыравы бетмәгән; **~ие кра́ски** ялтыравы бетмәгән буяулар **6.** тотылмаган, киелмәгән, керләнмәгән, чиста; **~ая руба́шка** чиста күлмәк **7.** *перен.* яңа, яңарган; **со ~ими си́лами** яңа көч белән **8.** яңа, иң соңгы; **~ая мысль** яңа фикер; караганда; **статисти́ческие ~я** статистик мәгълүматлар **2.** *мн.* **~я** (*познания*) белем; **облада́ть больши́ми ~ями** зур белемгә ия булу **3.** белдерү, игълан итү, таныштыру, хәбәр итү; **довести́ до ~я** таныштыру; **приня́ть к ~ю** исәпкә алу ♦ **к ва́шему ~ю** *в знач. вводн. сл.* сезгә мәгълүм булсын, белеп торыгыз

сведе́ние *с* **1.** *см.* **свести́; ~ пя́тен** тапларны бетерү; **~ диви́зий в а́рмию** дивизияләрне армия итеп берләштерү **2.** (*судорога*) көзән җыеру, тартышу

~ие но́вости иң соңгы хәбәрләр **9.** *перен.* саф; **встал со ~ей голово́й** саф баш белән торды **10.** таза, әйбәт; **у него́ ~ий вид** ул таза кыяфәтле

свежо́ *нареч. в знач. сказ. безл.* салкынча, җиләс; **по утра́м ~** иртәләрен салкынча

свезти́ *сов. кого-что* **1.** илтү, илтеп кую; **~ больно́го в больни́цу** авыруны больницага илтеп кую **2.** төшерү, алып төшү; **~ с горы́** таудан төшерү **3.** алып китү (бетерү), илтеп ташлау; **~ му́сор на сва́лку** чүп-чарны чүплеккә алып китү **4.** (*многое, многих*) илтү, китерү

свёкла *ж* чөгендер; **са́харная ~** шикәр чөгендере; **столо́вая ~** аш чөгендере; **кормова́я ~** мал чөгендере

свеклови́ца *ж* шикәр чөгендере

свеклови́чн||ый, -ая, -ое шикәр чөгендере ...ы, чөгендер ...ы, чөгендер игә торган; **~ые семена́** шикәр чөгендере орлыгы; **~ый са́хар** чөгендер шикәре; **~ый райо́н** чөгендер игә торган район

свекловод *м* чөгендер үстерүче, чөгендер үстерү белгече

свеклово́дство *с* чөгендер үстерү, чөгендер үстерүчелек

свеловодческий, -ая, -ое чөгендер үстерү ...ы; **~ совхо́з** чөгендер үстерү совхозы

свеклокомба́йн *м* чөгендер [алу] комбайны

свеклокопа́тель *м* чөгендер казыгыч (*машина*)

свеклоса́харн||ый, -ая, -ое шикәр чөгендере ...ы, чөгендер эшкәртү ...ы; **~ое произво́дство** чөгендер эшкәртү производствосы

свеклосе́ющий, -ая, -ее чөгендер чәчә торган, шикәр чөгендере үстерә торган, шикәр чөгендере игә торган

свеклоубо́рочн||ый, -ая, -ое чөгендер алу ...ы, чөгендер җыеп алу ...ы; **~ая кампа́ния** чөгендер алу кампаниясе; **~ый комба́йн** чөгендер җыеп алу комбайны

свеко́льник *м* **1.** (*суп*) чөгендер ашы, чөгендерле аш **2.** (*ботва*) чөгендер сабагы, чөгендер яфрагы

свеко́льн||ый, -ая, -ое чөгендер ...ы; **~ая ботва́** чөгендер сабагы

свёкор *м* каенага, биата

свекро́вь *ж* каенана, биана

сверга́ть *несов. см.* **све́ргнуть**

све́ргнуть *сов. кого-что* төшерү, бәреп төшерү; **~ самодержа́вие** самодержавиене бәреп төшерү

сверже́ние *с см.* **све́ргнуть**

све́рить *сов. что* чагыштыру, чагыштырып [тикшереп] чыгу, дөреслеген тикшерү; **~ ко́пию с по́длинником** күчермәне төп нөсхә белән чагыштырып чыгу

све́риться *сов. с чем, разг.* дөреслеген тикшерү, тикшереп белү, белешмә алу; **~ со словаре́м** сүзлектән карап дөреслеген тикшерү

све́рка *ж см.* **све́рить, све́риться; ~ спи́сков избира́телей** сайлаучылар исемлегенең дөреслеген тикшерү

сверка́ние *с* балку, ялтыр-йолтыр итү, ялт-йолт итү, җем-җем итү

сверка́||ть *несов.* **1.** ялтырау, балку, җемелдәү, җем-җем итү; (*о молнии*) яшьнәү; **звёзды ~ют** йолдызлар җемелди **2.** ялт-йолт итү, ялык-йолык килү, ялтырау; **~ют штыки́** штыклар ялык-йолык килә **3.** *перен. чем и без доп.* яну, ялтырау, елтырау; **его́ глаза́ ~ли** аның күзләре елтырый иде

сверкну́||ть *сов.* **1.** *однокр.* балкып (җемелдәп) кую, җем-җем итеп алу **2.** *однокр.* ялтырап китү, ялык-йолык килеп алу **3.** *перен.* кинәт башка килү, кинәт искә төшү; **~ла мысль** кинәт башка бер уй килде ♦ **~ть глаза́ми** күзләрне ялтыратып кына карап алу

сверли́льный, -ая, -ое бораулау ...ы; **~ стано́к** бораулау станогы

сверли́льщик *м* бораулаучы, бораулап тишүче

сверли́||ть *несов.* **1.** *что* бораулау, бораулап тишү, борау белән тишү; **~ть до́ску** тактаны бораулап тишү **2.** *перен. кого-что* тырнап (борчып, тыныч-сызлап, әрнетеп) тору; **~т неотвя́зная мы́сль** бер бәйләнчек фикер тыныч-сызлап тора **3.** чәнчешү, чәнчешеп авырту; **в у́хе ~т** *безл.* колагым чәнчешеп тора

сверло́ *с* борау

сверло́вщик *м см.* **сверли́льщик**

сверну́ть *сов.* **1.** *что* төрү, төреп кую, түгәрәкләп төреп кую; бөтерү; **~ ковёр** келәмне түгәрәкләп төреп кую; **~ папиро́су** тәмәке төрү **2.** *что* (*о растениях — лепестки, листья*) ябу, кысу (*мәс. үсемлек үзенең тәж фракчыгын, чәчәген*) **3.** *перен. что* кыса (тарайта, киметә) төшү; **~ фронт** фронтны тарайта төшү **4.** бер читкә борылу, борылып кереп китү; юл сабу; **~ с доро́ги** юлдан бер читкә борылу **5.** *перен. что* бору; **~ разгово́р на пре́жнее** сүзне искегә бору **6.** *что* (*сломать*) бора-бора рәтен китәру, бора-бора бозып бетерү (*мәс. ачкычны*) ♦ **~ го́лову (ше́ю)** *кому* 1) муенын бору, муенын сындыру; 2) *перен.* харап итү, башына җиту, дәмектерү

сверну́ться *сов.* **1.** төрелү, түгәрәкләнеп төрелү; бөтерелү; **бума́га ~лась** кәгазь бөтерелгән **2.** (*о лепестках, листьях*) йомылу, ябылу, кысылу, бөрешү (*мәс. үсемлекнең яфраклары турында*) **3.** йомарланып (бөгәрләнеп) яту; **~ться клубко́м** *или* **в клубо́к** бөгәрләнеп яту **4.** ою, эрү, оешу; **кровь ~лась** кан оешты; **молоко́ ~лось** сөт эреде **5.** *перен.* кысыла (тарая, кими) төшү; **фронт ~лся** фронт тарая төште **6.** бора-бора бозылу; **ключ ~лся** ачкыч бора-бора бозылган

сверста́ть *сов. что, полигр.* [наборны] биткә салу, версткалау, версткага салу; **~ газе́ту** газетаны версткага салу

све́рстник *м* яшьтәш, кордаш

све́рстница ж яшьтәш хатын (кыз)

свёрток *м* төргәк, төенчек

свёртываемость *ж физиол.* оешучанлык, оючанлык, оешу сәләте, ою сәләте; **~ кро́ви** канның оешу сәләте

свёртывание *с см.* **сверну́ть, сверну́ться**

свёртывать *несов. см.* **сверну́ть**

свёртываться *несов.* **1.** *см.* **сверну́ться**; **2.** *страд. от* **свёртывать**

сверх *предлог с род.п.* **1.** (*поверх чего-л.*) өстеннән, өстенә; **~ костю́ма наде́ть пальто́** костюм өстеннән пальто кию **2.** (*при указании на превышение какой-л. меры, нормы*) ...дан тыш, ...дан артык; **~ пла́на** планнан тыш; **~ шта́та** штаттан тыш **3.** (*кроме, помимо чего-л.*) өстәвенә, ... өстенә; **~ всего́ он не умён** өстәвенә тагын ул акылсыз да әле **4.** (*вопреки чему-л.*) карамастан; **~ ожида́ния** көтәнгә дә карамастан

сверх- *кушма сүзләрнең «гадәттән тыш, үтә, бик, чиктән тыш, ...дан тыш» мәгънәләрен аңлата торган беренче өлеше, мәс.* **сверхме́ткий** үтә төз ата торган; **сверхмо́щный** гадәттән тыш көчле; **сверхшта́тный** штаттан тыш

сверхзвукова́я, -а́я, -о́е тавыш тизлегеннән югарырак тизлек белән оча торган; **~ самоле́т** тавыш тизлегеннән югарырак тизлек белән оча торган самолёт

сверхмо́щности *только мн.* үтә зур куәтләр

сверхно́в||ый, -ая, -ое: **~ая звезда́** *астр.* ультраяңа йолдыз, үтә яңа йолдыз

сверхпла́нов||ый, -ая, -ое планнан тыш [җитештерелгән]; **~ая проду́кция** планнан тыш җитештерелгән продукция

сверхпри́быль *ж эк.* өстәмә табыш, өстәмә килер, өстәмә файда

сверхпроводи́мость *ж физ.* гадәттән тыш үткәрүчәнлек

сверхра́нний, -яя, -ее гадәттән тыш иртә; **~ сев** гадәттән тыш иртә чәчү

сверхскоростно́й, -а́я, -о́е зур тизлекле, гадәттән тыш зур тизлекле; **~ самоле́т** гадәттән тыш зур тизлекле самолёт

сверхсро́чник *м* сверхсрочник (*мәҗбури срогы тулганнан соң үз теләге белән хәрби хезмәттә калган кеше*)

сверхсрочнослу́жащий *м см.* **сверхсро́чник**

сверхсро́чн||ый, -ая, -ое **1.** сроктан тыш, срок тулганнан тыш; **~ая вое́нная слу́жба** сроктан тыш хәрби хезмәт **2.** *разг.* бик ашыгыч, үтә ашыгыч; **~ое зада́ние** үтә ашыгыч задание

све́рху *нареч.* **1.** өстән, югарыдан; **вода́ па́дает ~** су югарыдан төшә: **~ до́низу** өстән аска кадәр **2.** югарыдан, өстән (*җитәкче органнардан*); **директи́ва ~** югарыдан килгән директива **3.** өстән, тыштан; **сыр запле́сневел то́лько ~** сыр тыштан гына күгәргән **4.** (*с верховья реки*) югарыдан, өстән (*елганың югарыгы агымыннан*)

сверхуро́чн||ый, -ая, -ое **1.** эш сәгатеннән тыш [башкарылган]; **~ая рабо́та** эш сәгатеннән тыш башкарылган эш **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен түләнгән акча

сверхчелове́к *м* гайре табигый шәхес, гайре табигый зат (*реакцион философиядә*)

сверхчелове́ческий, -ая, -ое кеше көче җитмәслек, кеше кулыннан килмәслек; **~ труд** кеше көче җитмәслек хезмәт

сверхшта́тный, -ая, -ое штаттан тыш [булган]

сверхъесте́ственн||ый, -ая, -ое **1.** табигатьтән өстен ..., гайре табигый; **~ые си́лы** гайре табигый көчләр **2.** *разг.* гадәттән тыш, искиткеч, гаҗәеп; **~ая ско́рость** гадәттән тыш тизлек

сверчо́к *м* өй чикерткәсе, шөрчек

свершá́ть *несов. см.* **сверши́ть**

свершá́ться *несов.* **1.** *см.* **сверши́ться 2.** *страд. от* **свершá́ть**

сверши́ть *сов. что, высок.* кылу, ясау, эшләү; **~ по́двиг** батырлык эшләү

сверши́ться *сов.* килеп чыгу, булу

све́рщик *м* чагыштыручы, чагыштырып төзәтүче

све́рщица *ж* чагыштыручы хатын (кыз)

сверя́ть *несов. см.* **све́рить**

сверя́ться *несов.* **1.** *см.* **све́риться 2.** *страд. от* **сверя́ть**

све́сить *сов. что* салындыру, салындырып төшерү, асылындыру

све́си||ться *сов.* **1.** (*берәр нәрсә аркылы*) иелү, аска иелү, түбәнгә иелү, асылыну; **~ться че́рез пери́ла** култыкса аркылы иелү **2.** салыну, салынып төшү, салынып тору; **ве́тви ~лись до земли́** ботаклары җиргә кадәр салынып төшкән

свести́ *сов.* **1.** *кого-что* җитәкләп (ияртеп) илтеп кую; **~ ребёнка в шко́лу** баланы мәктәпкә илтеп кую **2.** *кого-что* җитәкләп алып төшү, җитәкләп төшерү; **~ старика́ с ле́стницы** картны баскычтан җитәкләп алып төшү **3.** *кого-что* бору; **~ ло́шадь с доро́ги** атны юлдан читкә бору **4.** *что* бетерү, китәрү; **~ пя́тно** тапны бетерү **5.** *что* тоташтыру, якынлаштыру; **~ бро́ви** кашларны тоташтыру **6.** *кого-что с кем-чем* кавыштыру, очраштыру, күрештерү; **~ друзе́й** дусларны күрештерү **7.** *что* урнаштыру, булдыру; **~ дру́жбу** дуслык урнаштыру **8.** *кого-что во что* кушу, берләштерү, туплау; **~ да́нные в табли́цу** мәгълүматларны таблицага туплау **9.** *что к чему, на что* калдыру, кыскарту; **~ расхо́ды к ми́нимуму** чыгымнарны минимумга калдыру **10.** *что на что* күчерү, күчереп төшерү; **~ рису́нок на ка́льку** рәсемне калькага күчереп төшерү **11.** *кого-что* көзән җыеру, тартыштыру, куырылдыру, җыерылдыру; **су́дорога свела́ лицо́** битне көзән җыерды; **свело́ но́гу** *безл.* аягымны көзән җыерды **12.** *перен. что* бору, борып җибәрү; **~ разгово́р на вчера́шний слу́чай** сүзне кичәге вакыйгага бору ◆ **~ в моги́лу** *кого* кабергә (гүргә) кертү; **~ концы́ с концо́м** [көчкә-көчкә генә] очны очка ялгау, ничек кирәк алай җиткерү; **~ на не́т** юкка чыгару; **~ с ума́** *кого* 1) акылдан яздыру, акылдан шаштыру; 2) әсир итү, хайран калдыру; **~ счёты** *с кем* 1) (*о денежных расчётах*) исәпләшү, исәп-хисапны өзү; 2) (*отомстить*) үч алу, үч кайтару

све||сти́сь *сов. к чему, на что* кайтып калу; **де́ло ~лось к пустяка́м** эш вакытяк нәрсәләргә кайтып калды; **расхо́ды ~лись к ми́нимуму** чыгымнар минимумга кайтып калды

свет I *м* **1.** яктылык, якты; **со́лнечный ~** кояш яктысы; **иску́сственный ~** ясалма яктылык **2.** ут; **заже́чь ~** ут кабызу; **на ~ у́** ут яктысында **3.** яктыру, таң ату; **до ~у** таң атканга кадәр ◆ **в ~е** 1) *чего* яктылыгында; **в ~е после́дних да́нных** соңгы мәгълүматлар яктылыгында; 2) *каком* төстә, тонда; **предста́вить** *что-л.* **в мра́чном ~е** *берәр нәрсәне* күңелсез төстә күз алдына китерү; **ни ~ ни заря́** бик иртә, кара таннан, тан тишегеннән; **чуть ~** таң беленер-беленмәстә; **проли́ть (бро́сить) ~** *на что* ачыклау, ачыклык кертү, төшендереп бирү; **~ ты мой [я́сный]** *уст.* (*при обращении*) күз нурым бит син минем (*иркәләү сүзе*); **то́лько ~у в око́шке, что** ... бар куанычым шул ... инде минем; **то́лько и ~у в око́шке, что до́чка** бар куанычым шул кызым инде минем; **учёнье — ~, а неучёнье — тьма** гыйлемлек — нур, наданлык — хур

свет II *м* **1.** дөнья, җир йөзе, җиһан; **стра́ны ~а** дөнья яклары; **ча́сти ~а** дөнья кисәкләре; **путеше́ствие вокру́г ~а** дөнья әйләнә сәяхәт **2.** (*высшее общество*) югары җәмгыять ◆ **на ~ не гляде́л бы** бер көн дә тормас идем, дөнья йозен күрмәс идем; **нет на ~е** *кого* үлде, дөнья куйды; **ни за что́ на ~е** беркайчан да, һичбер вакытта да; **~ не кли́ном сошёлся на** *ком-чём* дөнья аңа гына терәлмәгән, дөнья аңардан гына тормый

света́ть *несов. безл.* таң ату, яктыра башлау, яктыру

светёлка *ж уст.* гүрнәчә (*өске катлагы кечерәк бүлмә*)

свети́ло *с* **1.** яктырткыч, күк яктырткычы **2.** *перен.* йолдыз, маяк (*берәр өлкәдә дан казанган атаклы кеше*)

свети́льник *м* **1.** зур лампа, яктырткыч (*прибор*) **2.** *уст.* кәндил, шәмдәл (*электә*)

свети́льный, -ая, -ое: **~ газ** яктырткыч газ

свети́ть *несов.* **1.** яктырту, яктылык бирү, яктылык тарату; **зимо́й со́лнце све́тит, но не гре́ет** кышын кояш яктырса да җылытмый **2.** яктыртып тору; **~ фонаре́м** фонарь белән яктыртып тору ◆ **это де́ло мне не све́тит** *прост.* бу эш мине кызыктырмый

свети́||ться *несов.* **1.** яктылык сибү, балку; **в о́кнах ~лись огоньки́** тәрәзәләрдә утлар балкый иде **2.** (*виднеться — о чём-л. светлом*) ялтырау, ялтырап күренү **3.** *перен.* балку, яну, янып (балкып) тору; **в глаза́х ~лась ра́дость** күзләрендә шатлык балкый иде

светле́||ть *несов.* **1.** (*становиться более светлым*) ачыклана төшү, яктыра төшү **2.** *безл.* (*о наступлениии рассвета*) яктыру **3.** *перен.* ачылу, ачыклану, ачыла бару; **взгляд ~ет** йөзе ачыклана **4.** (*виднеться — о чём-л. светлом*) ялтырап күренү (күренеп тору)

светли́ца *ж уст.* **1.** *см.* **светёлка; 2.** ак өй, түр бүлмә

светло́ *нареч.* **1.** якты; **ла́мпа гори́т ~** лампа якты яна **2.** *в знач. сказ. безл.* якты; **здесь о́чень ~** монда бик якты

светло- *кушма сүзләрнең «аксыл, ак» мәгънәләрен аңлата торган беренче өлеше, мәс.* **светлоко́жий** ак тәнле

светло- *кушма сүзләрнең «төп төскә караганда тоныграк, сыеграк» мәгънәләрен аңлата торган беренче өлеше, мәс.* **светло-зелёный** сыек яшел; **све́тло-жёлтый** аксыл сары

светловоло́сый, -ая, -ое аксыл чәчле, сары чәчле

све́тлость *ж*: **ва́ша ~** галижәнап (*электә югары дәрәҗәле кешеләргә мөрәҗәгать иткәндә кулланылган*)

све́тл||ый, -ая, -ое **1.** якты, якты яна торган; **~ая ла́мпочка** якты яна торган лампочка **2.** яп-якты, балкып торган, якты; **~ая ко́мната** яп-якты бүлмә **3.** (*прозрачный — о жидкости*) үтә күренмәле, тонык, топ-тонык **4.** ачык төстәге, аксыл төстәге; **~ый костю́м** ачык төстәге костюм **5.** *перен.* якты, нурлы, шатлыклы, куанычлы; **~ое воспомина́ние** якты истәлек **6.** *перен.* якты, ачык, зирәк, саф; **~ый ум** зирәк акыл ◆ **~ый шрифт** *полигр.* юка шрифт, нәзек хәреф, нечкә хәреф

светля́к, светлячо́к *м зоол.* тычкан уты (*караңгыда яктырып күренә торган бөҗәк*)

светобоя́знь *ж мед.* яктыдан курку, яктыга түзмәү (*яктылыктан куз авырту авыруы*)

светов||о́й, -а́я, -о́е яктылык ...ы; **~ы́е во́лны** яктылык дулкыннары; **~а́я сигнализа́ция** яктылык сигналлары ◆ **~о́й год** *астр.* яктылык елы (*яктылык бер ел эчендә үткән ара*); **~о́й день** көн озынлыгы (*төнлекнең кояш чыкканнан алып батканга кадәр булган арасы*)

светокопирова́льный, -ая, -ое светокопия ала торган

светоко́пия *ж* светокопия (*сызымның яктылыкка сизгер кәгазьгә төшерелгән күчермәсе*)

светолече́ние *с* нур белән дәвалау, яктылык белән дәвалау

светолюби́в||ый, -ая, -ое яктылык сөючән, яктылык яратучан; **~ые расте́ния** яктылык сөючән үсемлекләр

светомаскиро́вка *ж* яктылыкны маскировкалау, ут яктысын күрсәтмәү

светомаскиро́вочный, -ая, -ое яктылык маскировкалау ...ы; **~ материа́л** яктылыкны маскировкалау материалы

светонепроница́емость *ж* яктылык үткәрмәүчәнлек, яктылык үткәрмәү

светонепроница́емый, -ая, -ое яктылык үткәрми торган

светоно́сный, -ая, -ое *книжн.* яктылык чәчә торган, нур тарата торган

светопреставле́ние *с* 1. *рел.* кыямәт көне, ахырзаман 2. *перен. разг.* (*о суматохе, беспорядке*) ыгы-зыгы, шау-шу, буталчыклык, мәхшәр, кыямәт; ата улны, ана кызны белмәү

светоси́ла *ж* 1. (*степень освещённости*) яктылык көче, яктырту дәрәҗәсе 2. *опт.* яктырту сәләте, яктылык үткәрү сәләте

светостойк||ий, -ая, -ое төсен югалтмый торган, [кояшта] уңмый торган, [яктыда] төсе китми торган; **~ие кра́ски** төсен югалтмый торган буяулар

светоте́нь *ж* төрле ачыклыктагы төсләр, яктылык һәм күләгәләр (*рәсем сәнгатендә*)

светоте́хника *ж* яктылык техникасы, яктырту техникасы

светофи́льтр *м спец.* яктылык фильтры, яктылык сөзгеч

светофо́р *м* светофор

све́точ *м чего, книжн.* чыганак, чишмә; таратучы; **кни́га — све́точ зна́ний** китап — белем чишмәсе

светочувстви́тельность *ж* яктылыкка сизгерлек, яктыга сизгерлек

светочувстви́тельн||ый, -ая, -ое яктылык[лык] сизүчән, яктыга сизгер, яктылык тәэсиренә сизгер; **~ая бума́га** яктыга сизгер кәгазь

све́тск||ий, -ая, -ое 1. югары җәмгыять ...ы, асыл затлар ...ы; асыл сөяклеләр ...ы; **~ое о́бщество** асыл сөяклеләр җәмгыяте 2. асыл затларга хас, асыл сөяклеләргә хас; **~ие мане́ры** асыл сөякләргә хас гадәтләр 3. (*не церковный*) дөньяви, дини булмаган; **~ое образова́ние** дөньяви белем

свеча́ *ж* 1. шәм; **стеари́новая ~а́** стеарин шәм 2. *тех.* свеча, ут кабызгыч 3. шәм (*яктылык көчен улчәү берәмлеге*); **электри́ческая ла́мпочка в сто ~е́й** йөз шәмле электр лампасы 4. *мед.* шәм 5. (*крутой подъём, взлёт*) ыргу, ыргылу; **самолёт сде́лал ~у́** самолёт [өскә] ыргыды

свече́ние *с* яктылык сибү, балку, нурланыш

све́чка *ж см.* **свеча́** 1, 4, 5

свечно́й, -а́я, -о́е шәм ...ы; **~ ога́рок** шәм калдыгы

све́шивать *несов. см.* **све́сить**

све́шиваться *несов.* 1. *см.* **све́ситься**; 2. *страд. от* **све́шивать**

свива́льник *м уст.* биләүсә, биләү

свива́ть *несов.* 1. *см.* **свить**; 2. *кого-что, уст.* [биләүгә] биләү; **~ младе́нца** яшь баланы биләү

свива́ться *несов.* 1. *см.* **сви́ться**; 2. *страд. от* **свива́ть**

свида́ни||е *с* күрешү, очрашу; **делово́е ~** эш буенча очрашу; **идти́ на ~е** күрешергә бару; **день ~я с больны́ми** авырулар белән күрешү көне; **до [ско́рого] ~я** исән булыгыз, сау булып торыгыз

свиде́тел||ь *м* шаһит, танык, гуаһ; **быть ~ем** *чего-л. берәр нәрсәнең* шаһиты булу; **допро́с ~ей на суде́** судта шаһитләрдән сорау алу

свиде́тельница *ж* шаһит хатын (кыз)

свиде́тельск||ий, -ая, -ое шаһит ...ы; **~ие показа́ния** шаһит күрсәтүләре

свиде́тельство *с* 1. күрсәтү; **~ очевиде́ц** үз күзләре белән күргән кешеләрнең күрсәтүе 2. (*вещь, факт*) дәлил, таныклаучы факт, раслаучы факт (*мәс. берәр вакыйганы*) 3. (*документ*) таныклык, шәһадәтнамә, таныклык язуы; **~ о рожде́нии** туу турында таныклык

свиде́тельств||овать *несов.* 1. *о чём* таныклау, таныклама бирү, күрсәтү; **~овать об уби́йстве** үтерү турында таныклама бирү 2. *о чём* (*подтверждать*) күрсәтү, күрсәтеп тору, раслау; **э́то произведе́ние ~ует о его́ тала́нте** бу әсәр аның талантын күрсәтеп тора 3. *что офиц.* раслау; **~овать по́дпись** имзаны раслау 4. *что, уст.* карау, тикшерү, карап тикшереп чыгу; **~овать больны́х** авыруларны карап тикшереп чыгу

свиль *ж спец.* 1. (*порок древесины*) эйләнмәлек, әйләнмә катламлылык, кыек катламлылык (*агач җепселләренең бормаланып-сырмаланып урнашкан булуы*) 2. (*прослойка в стекле, керамике*) дулкынлы катлам (*пыялада, керамикада*)

свина́рка *ж* дуңгыз караучы хатын (кыз)

свина́рник *м* дуңгыз абзары, чучка абзары

свина́рня *ж см.* **свина́рник**

свина́рь *м* дуңгыз караучы, чучка караучы

свин||е́ц *м* 1. *хим.* кургаш[ын], кара кургаш[ын] 2. *перен.* пуля; **врага́ встре́тили ~цом** дошманны пуля белән каршы алдылар ♦ **лечь ~цо́м на се́рдце** йөрәккә таш булып утыру; **голова́ как ~цом налита́** башым тубалдай булды

свини́на *ж* дуңгыз (чучка) ите

сви́нка I *ж* колак арты бизе шешү (*балалар авыруы*)

сви́нка II *ж уменьш. от* **свинья́** 1

свиново́д *м* дуңгыз (чучка) үрчетү белгече

свиново́дство *с* дуңгыз үрчетү, чучка асраучылык, дуңгызчылык

свиново́дческий, -ая, -ое дуңгыз асраучылык ...ы; дуңгызчылык ...ы; **~ совхо́з** дуңгызчылык совхозы

свин||о́й, -а́я, -о́е дуңгыз ...ы; чучка ...ы; **~ое са́ло** дуңгыз мае; **~а́я ко́жа** дуңгыз тиресеннән эшләнгән күн ♦ **~ы́е гла́зки** чепи күз

свиномáтка *ж* ана дуңгыз

свинопа́с *м уст.* дуңгыз (чучка) көтүчесе

свинофе́рма *ж* дуңгыз (чучка) фермасы

сви́нский, -ая, -ое *разг.* 1. (*грязный*) шакшы, пычрак, үтә шапшак 2. (*подлый*) кабәхәт, әшәке; **~ посту́пок** кабәхәтлек

сви́нство *с разг.* 1. (*неряшливость*) шакшылык, пычраклык, шапшаклык 2. (*подлость*) кабәхәтлек, әшәкелек, этлек

свинти́ть *сов. что* 1. (*скрепить винтом*) борып кую (тоташтыру, беркетү) 2. *разг.* (*снять*) борып алу, борып чыгару; **~ га́йку** гайканы борып алу

свину́ха, свину́шка *ж* ал гөмбә

свинцо́в||ый, -ая, -ое 1. кара кургаш ...ы; **~ая руда́** кара кургаш рудасы 2. кургаштан ясалган, кара кургаш; **~ая пу́ля** кургаштан ясалган пуля 3. (*о цвете*) кара, кара кучкыл; **~ые ту́чи** кара кучкыл болытлар 4. *перен.* (*тяжёлый, гнетущий*) авыр, газаплы; **~ая тоска́** авыр сагыш

свинча́тка *ж* 1. (*бита*) аткый, кургаш коелган кузна 2. *рыб.* кургаш коелмасы, кисәкле кургаш

сви́нчивать *несов. см.* **свинти́ть**

свинь||я́ *ж* дуңгыз, чучка 2. *перен. разг.* кабәхәт кеше, әшәке кеше, дунгыз ♦ **~ю́ подложи́ть** *кому* этлек эшләү, кабәхәтлек эшләү

свире́ль *ж* курай, сыбызгы

свирепе́ть *несов.* рәхимсезләнү, аяусызлану, кансызлану, мәрхәмәтсезләнү

свире́пость *ж* 1. (*жестокость, беспощадность*) рәхимсезлек, аяусызлык, кансызлык, мәрхәмәтсезлек, шәфкатьсезлек 2. (*гневное состояние*) явызлык, кансызлык, усаллык

скита́льческ||ий, -ая, -ое илдән-илгә күчеп йөрүчеләр ...ы; илгизәрләр ...ы; **~ая жизнь** илгизәрләр тормышы

скита́ние *с см.* **скита́ться**

скита́ться *несов.* **1.** (*бродяжничать*) илдән илгә йөрү, ил гизеп йөрү, каңгырып йөрү **2.** (*не иметь постоянного места жительства*) күчеп йөрү

ски́фск||ий, -ая, -ое скифлар ...ы; **~ие моги́льники** скифлар каберлеге

ски́фы *мн.* скифлар (*безнең эрага кадәр Кара диңгез буенда яшәгән күчмә кабилиләрнең гомуми исеме*)

склад I *м* склад; **заводско́й ~** завод склады; **дровяно́й ~** утын склады

склад II *м* **1.** акыл төзелеше, фикер сөреше, характер; **он челове́к осо́бенного ~а** ул үзенә бертөрле характердагы кеше **2.** *разг.* (*логичность, стройность*) [логик] бәйләнеш, төзеклек, [акылга] ятышлылык; **ни ~у ни ла́ду** бернинди бәйләнешсез, рәте-чираты булмаган

склад III *м*: **чита́ть по ~а́м** иҗеклəп уку

скла́дк||а *ж* **1.** бөрмә; **ю́бка со ~ами** бөрмәле юбка **2.** сыр; **брю́ки с отутю́женными ~ами** сырлары үтүкләнгән чалбар **3.** җыерчык; **~и на лбу́** маңгайдагы җыерчыклар **4.** җыерчык; **~и земно́й коры́** жир кабыгындагы җыерчыклар

складно́й, -а́я, -о́е җыела-языла торган, ачыла-ябыла торган; җыелмалы; **~ стул** җыелмалы урындык; **~ нож** пәке

скла́дн||ый, -ая, -ое **1.** *разг.* зифа, сылу, төз буйлы; **~ый па́рень** төз буйлы егет **2.** *разг.* шома, төзек, килешле; **~ая речь** шома сөйләм

скла́дочн||ый, -ая, -ое склад ...ы, склад итеп тотыла торган; **~ые помеще́ния** склад итеп тотыла торган биналар

складск||о́й, -а́я, -о́е склад ...ы; **~и́е помеще́ния** склад биналары

скла́дчат||ый, -ая, -ое *геол.* җыерчыклы, җыерчыкланып тора торган; **~ые го́ры** җыерчыкланып тора торган таулар

скла́дчин||а *ж* акча (әйбер) салышу; **купи́ть** *что-л.* **в ~у** акча салышып *берәр әйбер* сатып алу

скла́дывание *с см.* **сложи́ть** 1-7, **сложи́ться**

скла́дывать *несов. см.* **сложи́ть** 1-7

скла́дываться *несов.* **1.** *см.* **сложи́ться; 2.** *страд. от* **скла́дывать**

склева́ть *сов. кого-что* чүпләп (ашап) бетерү, чукып (ашап) бетерү

склёвывать *несов. см.* **склева́ть**

скле́ивание *с см.* **скле́ить**

скле́ивать *несов. см.* **скле́ить**

скле́иваться *несов.* **1.** *см.* **скле́иться; 2.** *страд. от* **скле́ивать**

скле́ить *сов.* **1.** *что* ябыштырып ясау, җилемләп ябыштыру; **~ листы́ бума́ги** кәгазь битләрен җилемлеп ябыштыру; **~ коро́бку из карто́на** катыргыдан ябыштырып тартма ясау **2.** *перен. кого-что, разг.* (*наладить, устроить*) җайлау, рәтләү, көйләү

скле́иться *сов.* **1.** (*слипнуться*) ябышу, берегү **2.** *перен. разг.* (*наладиться, устроиться*) җайлану, рәтләнү, көйләнү

склеп *м* төрбә

склепа́ть *сов. что* чүкеп ялгау (беркетү, тоташтыру)

склепа́ться *сов.* чүкеп ялгану (беркетелү, тоташтырылу)

склёпка *ж см.* **склепа́ть; 2.** (*место*) чүкеп ялганган урын, чүкеп беркетелгән урын

склёпывать *несов. см.* **склепа́ть**

склёпываться *несов.* **1.** *см.* **склепа́ться; 2.** *страд. от* **склёпывать**

скле́ра *ж анат.* склера, күз агы

склеро́з *м мед.* склероз (*авыру*); **~ сосу́дов** кан тамырлары склерозы; **~ по́чки** бөер склерозы

склеро́зн||ый, -ая, -ое *мед.* склероз ...ы; **~ые явле́ния** склероз күренешләре

склеро́тик *м разг.* склероз белән авыручы кеше, склероз авырулы кеше

склероти́ческий, -ая, -ое *мед.* склероз ...ы; **~ проце́сс** склероз процессы

склероти́чка *ж разг.* склероз авырулы хатын (кыз)

скли́кать *сов. см.* **скликáть**

скликáть *несов. кого-что, прост.* чакыру, чакырып (дәшеп) җыю, кычкырып чакыру

скло́ка *ж* ызгыш, талаш, гауга, ара бозылу

склон *м* сөзәклек, тау бите, битләү, кашлак; **на ~е горы́** тау битләвендә ♦ **на ~е лет (жи́зни, дней)** *книжн.* картлык көнендә, картаймыш көнендә

склоне́ние *с* **1.** *см.* **склони́ть, склони́ться; 2.** *грам.* төрләнеш, килеш белән төрләнеш; **~ существи́тельных** исемнәрнең килеш белән төрләнеше

склони́ть *сов.* **1.** *что* (*нагнуть*) ию, бөгү, авыштырү, салындырү; **~ го́лову** башны ию **2.** *перен. кого-что* (*расположить к себе*) үз ягына аудару, җәлеп итү **3.** *перен. кого-что, к чему, на что* [өндәп] күндерү, [димләп] ризалату; **~ к побе́гу** качарга күндерү

склони́ться *сов.* **1.** (*нагнуться*) иелү, иелеп төшү, бөгелү, салынып төшү **2.** *перен. к чему, на что* (*согласиться*) күну, риза булу, ризалашу

скло́нность *ж* **1.** һәвәслек, хирыслык, омтылыш; **~ к музыке** музыкага һәвәслек **2.** ...га бирелүчәнлек, ...га тартымлык; **~ к полноте́** юанаюга бирелүчәнлек

скло́нн||ый, -ая, -ое **1.** *к чему* һәвәс, яратучан, мавыгучан, хирыс; **челове́к, ~ый к нау́чным заня́тиям** фәнни эшкә һәвәс кеше **2.** *к чему и с неопр.* теләге бар, нияте бар; **он скло́нен согласи́ться** аның ризалашырга нияте бар **3.** *к чему* ...га бирелүчән, ...га тартым; **~ый к просту́де** салкын тидерүгә бирелүчән

склоня́емость *ж грам.* килеш белән төрләнүчәнлек

склоня́емый, -ая, -ое *грам.* килеш белән төрләнә торган

склоня́||ть *несов.* **1.** *см.* **склони́ть; 2.** *грам.* килеш белән төрләндерү **3.** *перен. кого-что, разг.* бик еш телгә алу, чәйнәү; **его́ ~ют на всех собра́ниях** аны җыелыш саен бик еш телгә алалар

склоня́ться *несов.* **1.** *см.* **склони́ться; 2.** *грам.* [килештә] төрләнү, килеш белән төрләнү

скло́чник *м разг.* җәнҗалчы, гаугачы; ара бозучы, бәлаче

скло́чница *ж разг.* җәнҗалчы хатын (кыз)

скло́чничать *несов. разг.* җәнҗал (гауга) куптару, ызгышу, кычкырышу, талашу; ара бозу

скло́чн||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** гаугачыл, бәлачыл, ара бозарга яратучан, кычкырышырга (талашырга) яратучан; **~ый челове́к** гаугачыл кеше **2.** гаугалы, җәнҗаллы, тавышлы; **~ые отноше́ния** гаугалы мөнәсәбәтләр

скля́нка I *ж* бәләкәй шешә, кечкенә шешә

скля́нк||а II *ж мор.* **1.** склянка (*диңгезчеләрдә: ярты сәгатьлек вакыт*) **2.** *мн.* **~и** (*часы*) склянка (*корабльдәге ком сәгате*)

скоба́ *ж* **1.** тотка; **дверна́я ~** ишек тоткасы **2.** *тех.* атлама, беркеткеч

ско́бель *м* ышкы

ско́бк||а *ж* **1.** *см.* **скоба́; 2.** җәя; **квадра́тные ~и** квадрат җәяләр; **кру́глые ~и** түгәрәк җәяләр; **раскры́ть ~и** җәяләрне ачу ♦ **сказа́ть (заме́тить) в ~ах** сүз арасында гына әйтеп китү

скобли́ть *несов. что* кыру, кырып чистарту,кырып арчу

скобя́н||ой, -а́я, -о́е тимердән ясалган, тимер-томыр ...ы; **~а́я ла́вка** тимер-томыр әйберләр кибете; **~ые това́ры** тимер-томыр товарлары

ско́ванность *ж* иркен булмау (тотмау), тоткарланган булу

ско́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **скова́ть; 2.** *перен.* иркен булмаган (тотмаган), тоткарланган; **~ые движе́ния** иркен булмаган хәрәкәтләр

скова́||ть *сов.* **1.** *что* (*выковать*) чүкеп (тапап) ясау **2.** *что* (*соединить ковкой*) чүкеп тоташтыру (беркетү), тапап ялгау **3.** *кого-что* (*надеть кандалы*) [бергә китереп] богаулау, [уртак] богау салу **4.** *перен. кого-что* (*лишить свободы действий*) тоткарлау, ирек бирмәү **5.** *перен. что* боз белән каплау; **льды ~ли ре́ку** елганы боз белән каплаган **6.** *кого-что, воен.* тоткарлап тору, тыеп тору

сковорода́ *ж* таба

сковоро́дка *ж разг. см.* **сковорода́**

сковоро́дник *м* табагач

ско́вывать *несов. см.* **скова́ть**

сковы́ривать *несов. см.* **сковырну́ть**

сковырну́ть *сов. что* куптарып алу, казгычлап куптару,казгычлап сытып чыгару

сковыря́ть *сов. разг. см.* **сковырну́ть**

скок *м см.* **скака́ть**

скол *м* ватылган урын, кителәп төшкән урын; ~ **на мра́море** мәрмәр өстендәге кителәп төшкән урын

скола́чивать *несов. см.* **сколоти́ть**

ско́л||ок *м* **1.** (*отколовшийся кусок*) кыйпылчык, китек, ярчык **2.** *перен.* кисәк, өзек; ~ **ки чужи́х мы́слей** кеше фикерләренең өзекләре

сколопе́ндра *ж зоол.* сколопендра (*кубаяклылар семьялыгыннан булган агулы хайван*)

сколоти́ть *сов.* **1.** *что* каккалап-суккалап ныгыту; ~ **полови́цы** каккалап-суккалап сайгакларны ныгыту **2.** *что* [каккалап-суккалап] әмәллә, әтмәләү, ясау; ~ **ящик** каккалап-суккалап әрҗә ясау **3.** *кого-что, прост.* оештыру, җыю, туплау; ~ **акти́в** актив туплау **4.** *что, прост.* җыю, туплау, юнәтү; ~ **поря́дочную су́мму де́нег** шактый гына акча туплау

сколо́ть *сов. что* **1.** вату, куптару; ~ **ло́мом лёд с тротуа́ра** лом белән тротуарның бозын вату **2.** (*скопировать накалыванием*) (*энә белән тишкәләп*) күчермәсен алу **3.** кадап [тоташтырып] кую, чәнчеп ялгап кую; ~ **ле́нты була́вкой** тасмаларны булавка белән кадап кую

сколо́||ться *сов.* **1.** (*отколоться*) кубу, ватылу; **лёд легко́** ~ **лся** боз ансат ватылды **2.** (*перевестись при накалывании*) (*энә белән тишкәләп*) күчермәсе алыну **3.** (*скрепиться*) кадап куелу, чәнчеп куелу

сколупну́ть *сов. что, прост.* [казгычлап] куптарып алу, чокып [тырнап] алу; ~ **боля́чку** кутырны казгычлап, куптарып алу

сколу́пывать *несов. см.* **сколупну́ть**

сколь *нареч. книжн.* нинди, никадәр, нихәтле, ничек; ~ **краси́вы го́ры!** таулар нинди матур!

скольже́ние *с см.* **скользи́ть**

скользи́||ть *несов.* **1.** шуу, шуып бару; ~ **ть по льду́** боз өсләтеп шуып бару **2.** шуып төшү; **мо́крое мы́ло** ~ **т из рук** юеш сабын кулдан шуып төшә **3.** таю; **но́ги скользя́т по мо́крой гли́не** юеш балчыкта аяк тая **4.** *перен.* шуышу, салмак кына бару; **ло́дка** ~ **т по воде́** көймә су өсләтеп салмак кына бара **5.** *перен.* [күз] йөгертү, [күз] йөгертеп чыгу; ~ **ть глаза́ми по стро́чкам кни́ги** китап юллары буйлап күз йөгертеп чыгу

ско́льзк||ий, -ая, -ое **1.** тайгак, шома; ~ **ий парке́т** тайгак паркет **2.** *перен.* ышанычсыз, тотрыксыз, тайгак; **вступи́ть на** ~ **ий путь** тайгак юлга басу **3.** *перен.* кинаяле, әдәпсез; кыен; тайгак; ~ **ая те́ма** кыен тема

ско́льзко *в знач. сказ. безл.* тайгак; **на у́лице** ~ урамда тайгак

скользну́ть *сов.* **1.** *однокр. см.* **скользи́ть; 2.** җәһәт кенә кереп китү, сиздермичә генә үтеп китү, ялт итеп үтеп (кереп) китү; ~ **в дверь** ялт итеп ишектән кереп китү

скользя́щий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **скользи́ть; 2.** (*плавный, лёгкий — о движении, походке*) салмак, җиңел, талгын **3.** үзгәрүчән, үзгәреп тора торган; ~ **гра́фик** үзгәреп тора торган график

ско́лько 1. *нареч. вопр. и относ.* күпме, ничә; ~ **сто́ит?** күпме тора?; ~ **вре́мени?** сәгать ничә? **2.** *нареч. и мест. относ.* күпме, нихәтле, никадәр, ничаклы; **ешь,** ~ **хо́чешь** күпме телисең, шулхәтле аша **3.** *нареч.* ‘ча; ~ **по́мню, он всегда́ был тако́й** хәтерләвемчә, ул элек-электән үк шундый иде **4.** *мест. и нареч. определит.* никадәр, нихәтле; ~ **вре́мени потеря́ли!** никадәр вакытны әрәм иттек! ♦ ~ **душе́ уго́дно** җаның теләгәнчә, җаның күпме тели; ~ **лет, зим!** [күрешмәгәнгә] ничә айлар, ничә еллар!; ~ **мо́жно!** кайчанга кадәр түзәргә була!, күпме түзәргә була!

ско́лько-нибу́дь *мест. и нареч.* күпме дә булса, бераз, азмы-күпме, берникадәр; **дать** ~ **де́нег** бераз акча бирү

ско́лько-то *мест. и нареч.* күпмедер, беркадәр, бераз

скома́ндовать *сов. что* команда бирү

скомбини́ровать *сов.* **1.** *что* кушу, катнаштыру, берләштерү **2.** *разг.* (*строить комбинации*) комбинацияләү, комбинацияләр кору

ско́мкать *сов. что* **1.** йомарлап (бөгәрләп) бетерү, укмаштырып бетерү; ~ **бума́гу** кәгазьне бөгәрләп бетерү **2.** *разг.* ашык-пошык тәмамлау, ашык-пошык эшләп бозу; ~ **коне́ц по́вести** повестьның ахырын ашык-пошык тәмамлау

ско́мка||ться *сов.* бөгәрләнү, йомарлану, йомарланып бетү, таушалып бетү; **оде́жда** ~ **лась** киемнәр йомарланып беткән

скоморо́х *м* **1.** скоморох (*борынгы Русьта сәяр җырчы-музыкант; ил гизеп кәмит курсәтеп йоруче*) **2.** *перен. неодобр.* шамакай, сәвәләй

скомороше́ство *с* **1.** сәяр җырчы-музыкант кәсебе (*борынгы Русьта*) **2.** *перен. неодобр.* шамакайлык, сәвәләйлек

скомороши́чать *несов. неодобр.* шамакайлану, сәвәләйләнү, мәзәкче булып кылану

скомпили́ровать *сов. что, книжн.* компиляцияләү, компиляция ясау

скомплектова́ть *сов. что* комплектлау, комплектка тутыру (туплау) комплект төзү

скомпонова́ть *сов. что* төзү, әзерләү, корыштыру, әтмәләү

скомпромети́ровать *сов. кого-что* хурлыкка калдыру, яман атлы итү, уңайсыз хәлдә калдыру

сконструи́ровать *сов. что* конструкцияләү, конструкциясен төзү; ~ **маши́ну** машина конструкцияләү

сконфу́женный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **сконфу́зить; 2.** оялып каушап калган; уңайсызланган; ~ **вид** оялып каушап калган кыяфәт

сконфу́зить *сов. кого-что* оялтып каушату, уңайсыз хәлдә калдыру

сконфу́зиться *сов.* уңайсызланып калу, оялып калу, оялып каушау

сконцентри́ровать *сов.* **1.** *кого-что* җыю, туплау; ~ **войска́** гаскәр туплау **2.** *что* юнәлтү, юнәлдерү, туплау; ~ **внима́ние** игътибарны юнәлдерү

сконцентри́роваться *сов.* туплану, җыелу

скончани||е *с*: **до** ~ **я ве́ка** мәңгегә, гомергә

скончáться *сов.* вафат булу, дөнья кую, гүр иясе булу, үлү

скопа́ *ж зоол.* балыкчы карчыга

ско́па́ть *сов. что* казып тигезләү, казып алып ташлау; ~ **ко́чку** түмгәкне казып ташлау

скопе́ц *м* печелгән ир кеше

скопидо́м *м разг.* чамадан тыш сакчыл кеше, саран кеше

скопидо́мка *ж разг.* чамадан тыш сакчыл хатын (кыз), саран хатын (кыз)

скопидо́мничать *несов. разг.* чамадан тыш сакчыллык күрсәтү, саранлану

скопидо́мство *с разг.* чамадан тыш сакчыллык, саранлык

скопи́ровать *сов.* **1.** *что* копиясен алу, күчермәсен алу **2.** *кого-что* булып кылану, ... кебек булу

скопи́ть *сов. что, чего* туплау, җыю, саклап җыю; ~ **де́нег** акча җыю

скопи́||ться *сов.* җыелу, җыйналу, туплану; **у вхо́да** ~ **лись лю́ди** ишек төбенә халык җыелган; ~ **лось мно́го рабо́ты** бик күп эш җыелган

ско́пище *с* халык төркеме, төркем, өер

скопле́ние *с* **1. скопи́ть, скопи́ться; 2.** (*большое количество кого-чего-л.*) зур төркем, тупланма

скопля́ть *несов. см.* **скопи́ть**

скопля́ться *несов.* **1.** *см.* **скопи́ться; 2.** *страд. от* **скопля́ть**

скопни́ть *сов. что* чүмәләләү, чүмәләгә салу; ~ **се́но** печән чүмәләләү

ско́пом *нареч. разг.*: **всем** ~ күмәкләп, бергәләп, барысы бергә

скорбе́ть *несов. о ком-чём, высок.* кайгыру, авыр хәсрәт кичерү, хәсрәтләну, көену

ско́рбн||ый, -ая, -ое кайгылы, хәсрәтле, көенечле, сагышлы; ~ **ое лицо́** кайгылы чырай; ~ **ая весть** кайгылы хәбәр

скорбу́т *м мед.* зәңгелә, зәңгелә авыруы

скорбь *ж* авыр кайгы, зур көенеч, олы хәсрәт

скоре́е 1. *сравн. ст. от* **ско́рый, ско́ро; 2.** *нареч.* тизрәк, тиз бул ♦ ~ **умрём, чем сдади́мся** үлсәк үләрбез, әмма бирелмәбез; **он** ~ **похо́ж на мать, чем на отца́** әтисеннән бигрәк әнисенә охшаган; ~ **всего́ он сего́дня не придёт** ул бүген килмәстер шикелле

скорлуп||а́ *ж прям., перен.* кабык; **яи́чная** ~ **а** йомырка кабыгы; **спря́таться в свою́** ~ **у́** үз кабыгына бикләнү (*үзеңнең шәхси интересларың белән генә яшәү*)

скорми́ть *сов. кого-что* ашатып бетерү; ~ **карто́фель скоту́** бәреңгене терлеккә ашатып бетерү

скорня́жить *несов.* **1.** (*выделывать шкуры*) тире илəү, тире илəп мех эшләү **2.** *см.* **скорня́жничать**

скорня́жничать *несов.* скорняк булып эшләү, тире иләүче булып эшләү

скорня́жн||ый, -ая, -ое скорняклык ...ы, тире иләү ...ы, мех эшкәртү ...ы; **~ое де́ло** скорняклык эше

скорня́к *м* скорняк, мех эшкәртүче, тире иләүче

ско́ро *нареч* **1.** (*быстро*) тиз, кызу **2.** тиздән, бераздан, озакламый; **~ ночь** озакламый төн җитә; **я ~ прие́ду** мин озакламый кайтармын **3.** (*в короткий срок*) тиз арада, җәһәт, бик тиз; **мы ~ добрали́сь до ме́ста** барасы җиребезгә бик тиз барып җиттек

скорова́рка *ж* тиз пешерә торган кастрюль, тиз пешергеч

скороговóрка *ж* **1.** (*быстрая речь*) ашыгып сөйләү, кызу сөйләү, тиз сөйләү **2.** (*труднопроизносимое сочетание слов*) телкөрмәвеч, тизәйткеч (*мәс. мич башында биш мәче, биш мәченең биш башы*)

скóрбн||ый, -ая, -ое *церк.* **1.** (*христианнарда ураза вакытында*) тыелган, сөтле, итле; **~ая пи́ща** тыелган азык **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* тыелган ашамлык (*сөтле яки итле*)

скоропали́тельность *ж разг.* үтә ашыгычлык, капыл-карсанлык, уйламыйча эшләнгәнлек

скоропалительн||ый, -ая, -ое *разг.* үтә ашыгыч, капыл-карсан, уйлап җиткермичә; **~ое реше́ние** үтә ашыгыч чыгарылган карар

скóропись *ж* кызу (тиз, йөгерек) язу

скоропóртящийся, -аяся, -еюся тиз бозыла торган, тиз әшәкеләнүчән; **~иеся проду́кты** тиз бозыла торган продуктлар

скоропости́жн||ый, -ая, -ое: **~ая смерть (кончи́на)** кинәт үлү, кинәт вафат булу

скоропреходя́щ||ий, -ая, -ое *книжн.* озакка сузылмый торган, тиз үтеп китә торган, бик тиз уза торган; **~ее сча́стье** бик тиз үтеп китә торган бәхет

скоросп|е́лка *ж разг.* иртә өлгергән, иртә пешкән, тиз өлгергән, тиз җитешкән (*җимеш, яшелчә*)

скоросп|е́л||ый, -ая, -ое **1.** иртә өлгергән, иртә өлгерүчән, тиз пешә торган; **~ые я́блоки** иртә өлгерә торган алмалар **2.** *перен. разг.* ашыгыч, уйлап җиткермичә, өлгереп җитмәгән, чиле-пешле; **~ое реше́ние** ашыгыч чыгарылган карар

скоростни́к *м* скоростник; **лётчик-~** очучы-скоростник (*зур тизлек белән очучы*); **строи́тель-~** төзүче-скоростник (*төзү эшләрен тизләтелгән темпта алып баручы*)

скоростн||о́й, -а́я, -о́е **1.** тизлек ...ы; **~а́я едини́ца** тизлек берәмлеге **2.** тиз оча торган, тиз йөри торган; **~о́й самолёт** тиз оча торган самолёт **3.** *спорт.* югары тизлектә, тиз; **~о́й бег на конька́х** конькида тиз шуу **4.** тизләтелгән, тиз башкарыла торган; **~о́е строи́тельство** изләтелгән төзелеш; **~а́я пла́вка** тизләтелгән эретү

скоростре́льн||ый, -ая, -ое *воен.* тиз (кызу, еш) ата торган; **~ая пу́шка** еш ата торган туп

ско́рост||ь *ж в разн. знач.* тизлек; **едини́ца ~и** *физ.* тизлек берәмлеге; **~ь све́та** *физ.* яктылык тизлеге; **~ь зву́ка** *физ.* тавыш тизлеге; **~ь ре́зания мета́лла** металл кисү тизлеге; **~ь полёта** очу тизлеге

скоросшива́тель *м* скоросшиватель (*эш кәгазьләрен беркетеп куя торган папка*)

скорота́ть *сов. что* үткәрү, үткәреп жибәрү, уздыру (*вакытны*)

скороте́чн||ый, -ая, -ое *книжн.* бик тиз уза торган, тиз үтеп китә торган ♦ **~ая чахо́тка** *уст.* үлемгә тиз китерә торган туберкулёз

скорохо́д *м* гаять тиз йөрүче, үтә кызу йөрүче (*мәс. чаңгыда, конькида*)

скорпио́н *м* **1.** *зоол.* чаян **2.** (*с прописной*) *астр.* Чаян

скорректи́ровать *несов. что* коррективлар кертү, төзәтмәләр кертү

ско́рчить *сов.* **1.** *обычно безл. кого-что* (*свести судорогой*) көзән җыеру, тартыштыру **2.** *что* сыту; **~ ро́жу** чырай сыту

ско́рчиться *сов.* бөгәрләнү, куырылу; **~ от бо́ли** авыртудан бөгәрләнү

ско́р||ый, -ая, -ое **1.** (*быстрый*) тиз, кызу, җәһәт, житез **2.** тиз йөрешле; **~ый по́езд** тиз йөрешле поезд **3.** (*близкий по времени*) тиздән булачак, якын арада булачак; **~ый отъе́зд** якын арада булачак китү ♦ **на ~ую ру́ку** аннанмоннан гына, әштер-өштер генә; **~ая по́мощь** 1) ашыгыч медицина ярдәме курсәтү учреждениесе; 2) ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү машинасы; **за ним прие́хала ~ая по́мощь** аны алырга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү машинасы килде

скоси́ть I *сов.* **1.** *что* чабып алу (ташлау, бетерү) **2.** *перен. кого* (*уничтожить*) кырып (үтереп) бетерү

скоси́ть II *сов. что* кыегайту, кыйшайту, чалышайту; **~ глаза́** күзләрне чалышайту, куз кырые белән карау

скот *м* **1.** *собир.* терлек, мал-туар, терлек-туар, мал; **кру́пный рога́тый ~** мөгезле эре терлек; **ме́лкий рога́тый ~** мөгезле вак терлек **2.** *перен. прост.* (*о грубом человеке*) хайван

скоти́на *ж* **1.** *собир.* терлек, мал-туар, терлек-туар, мал **2.** *см.* **скот** 2

ско́тник *м* терлекче, терлек караучы

ско́тница *ж* терлекче хатын (кыз)

ско́тный, -ая, -ое терлек ...ы; **~ двор** терлек абзары (утары)

ско́то- *кушма сүзләрнең «терлек» мәгънәсен аңлата торган беренче өлеше, мәс.* **скотоперего́нный** терлек куып илтә торган

скотобо́ец *м* сугымчы, терлек (мал) суючы

скотобо́йня *ж* терлек (мал) сую урыны

скотово́д *м* терлекче, терлек караучы (үрчетүче, асраучы)

скотово́дство *с* терлекчелек, терлек үрчетү (асрау)

скотово́дческ||ий, -ая, -ое терлекчелек ...ы, терлек үрчетү ...ы, терлек асрау ...ы; **~ий совхо́з** терлекчелек совхозы; **~ая фе́рма** терлекчелек фермасы

скотопромы́шленность *ж* терлек сатып алып сугымга симертү хуҗалыгы

ско́тск||ий, -ая, -ое **1.** терлек ...ы; **~ий зако́н** терлек утары **2.** *перен.* (*грубый, низкий*) тупас, эшәке, хайваннарча, дорфа; **~ое обраще́ние** *с кем-л.* хайваннарча мөгамәлә

ско́тство *с разг.* тупаслык, дорфалык, хайванлык, түбәнлек

скра́дыва||ть *несов. что* каплау, яшерү, сизелмәслек (беленмәслек) иту; **пла́тье ~ет недоста́тки фигу́ры** күлмәк фигураның кимчелекләрен яшерә

скра́дываться *несов.* **1.** (*становиться незаметным*) каплану, сизелмәү, беленмәү **2.** *страд. от* **скра́дывать**

скра́сить *сов. см.* **скра́шивать**

скра́ситься *сов. см.* **скра́шиваться** I

скра́шивать *несов. что* матурлый (әйбәтли) төшү; жиңеләйтә төшү, [кимчелеге] беленмәслек итү; жиңеләйтә (күңеллеләндерә) төшү

скра́шиваться *несов.* **1.** матурлана төшү; әйбәтләнә (күңеллеләнә) төшү **2.** *страд. от* **скра́шивать**

скребко́вый, -ая, -ое кыргычлы; **~ транспортёр** кыргычлы транспортёр

скребни́ца *ж* кыргыч, ат кыргычы

скребо́к *м* кыргыч

скре́жет *м* шыкырдау, шыгырдау; **~ колёс** тәгәрмәчләр шыгырдавы

скрежета́||ть *несов.* **1.** шыгырдау, шыкырдау; **~ли колёса** тәгәрмәчләр шыгырдады **2.** *чем* шыкырдату, шыгырдату; **~ть зуба́ми** теш шыкырдату

скре́па *ж* беркеткеч, тоташтыргыч, ныгыткыч

скре́пер *м* скрепер (*җир казу-транспорт машинасы*)

скрепи́ть *сов.* **1.** *что* беркетү, беркетеп кую, тоташтырып кую; **~ листы́ скре́пками** кәгазь битләрен кыстыргыч белән беркетеп кую **2.** *перен. что* ныгыту; **~ дру́жбу кля́твой** дуслыкны ант белән ныгыту **3.** *что чем, офиц.* раслау, таныклау, кул кую; **~ по́дпись печа́тью** имзаны печать белән раслау ♦ **скрепя́ се́рдце** сыкранып кына, теләмичә генә

скрепи́||ться *сов.* берегү, тоташу; **бру́сья ~лись хорошо́** борыслар яхшы береккән

скре́пка *ж* кыстыргыч, берткеткеч, кәгазь кыстыргыч

скрепле́ни|е *с* **1.** *см.* **скрепи́ть; 2.** *см.* **скрепа́; 3.** *мн.* **~я** *тех.* бергә беркетелгән кисәкләр

скрепля́ть *несов. см.* **скрепи́ть**

скрепля́ться *несов.* **1.** *см.* **скрепи́ться; 2.** *страд. от* **скрепля́ть**

скрести́ *несов.* **1.** *кого-что и без доп.* тырнау; **~ когтя́ми** тырнак белән тырнау **2.** *что, разг.* кыру, ышку; (*скребницей*) кыргычлау; **~ сковоро́дку песко́м** табаны ком белән ышку ♦ **на душе́ (на се́рдце) ко́шки скребу́т** эч яна, үзәк өзгәләнә

скрести́сь *несов.* кыштырдату, шыгырдату, тырнану, кимерү; **мышь скребётся** тычкан тырнана

скрести́ть *сов.* 1. *что* аркылы-торкылы салу, чалыштырып салу, кушыру; **~ ру́ки на груди́** кулларны күкрәккә кушыру 2. *кого-что с кем-чем, биол.* читтән серкәләндерү (аталандыру), катнаш кушылдыру (*яңа төр токым алу өчен*) ♦ **~ мечи́** сугыша башлау; ярыша башлау; бәхәсләшә башлау; **~ шпа́ги** кылычларны чарпашу

скрести́||ться *сов.* 1. аркылы-торкылы килү, кисешү; **доро́ги ~лись** юллар кисеште 2. *перен.* кампа-каршы килү, бәрелешү; **их интере́сы ~лись** интереслары бәрелеште 3. *биол.* (*о растениях, животных*) кушылу 4. *лингв.* (*о языках, говорах*) үзара керешү

скреще́ни||е *с* 1. *см.* **скрести́ть, скрести́ться; ~е языко́в** телләрнең үзара керешүе 2. кисешкән урын, чат; **на ~и доро́г** юллар чатында

скре́щивание *с см.* **скрести́ть, скрести́ться**

скре́щивать *несов. см.* **скрести́ть**

скре́щиваться *несов.* 1. *см.* **скрести́ться**; 2. *страд. от* **скре́щивать**

скриви́ть *сов. что* чалышайту, кыйшайту, кыегайту

скриви́ться *сов.* 1. чалышаю, кыйшаю, кыегаю 2. (*сделать гримасу*) чырай сыту, йөз җыеру

скрижа́л||ь *ж книжн.* 1. скрижаль (*изге язма төшерелгән такта*) 2. *обычно мн.* **~и** *перен.* бит, сәхифә; **на ~ях исто́рии** тарих сәхифәләрендә

скрип *м* шыгырдау тавышы, шыгырдаган тавыш ♦ **со ~ом** көчкә-көчкә генә, теләмичә генә

скрипа́ч *м* скрипкачы, скрипкада уйнаучы

скрипа́чка *ж* скрипкачы хатын (кыз)

скрипе́ние *с см.* **скрипе́ть** 1, 2

скрип||е́ть *несов.* 1. шыгырдау; **сапоги́ ~е́т** күн итек шыгырдый 2. *чем* шыгырдату; **~е́ть зуба́ми** теш шыгырдату 3. *перен. разг. шутл.* ыңгыр-шыңгыр йөрү, шыгыр-мыгыр гына яшәү (йөрү), әл-хәл эчендә булу, жан асрау; **стари́к ещё ~е́т** карт шыгыр-мыгыр гына йөри әле

скрипи́чн||ый, -ая, -ое 1. скрипка ...ы; **~ые стру́ны** скрипка кыллары 2. скрипкада башкарыла торган, скрипка өчен язылган; **~ая сюи́та** скрипка өчен язылган сюита ♦ **~ый ключ** *муз.* скрипка ачкычы (*нота язуында кулланыла*)

скри́пка *ж* скрипка ♦ **пе́рвая ~** башлап йөрүче, баш рольне уйнаучы

скри́пнуть *сов. однокр.* (*напр. дверью*) шыгырдатып кую

скрипу́ч||ий, -ая, -ее шыгырдавык, шыгырдый торган; **~ая дверь** шыгырдый торган ишек; **~ий го́лос** шыгырдавык тавыш

скрои́ть *сов. что* кисү; **~ пальто́** пальто кисү

скро́мник *м* тыйнак кеше

скро́мница *ж* тыйнак хатын (кыз)

скро́мничать *несов. разг.* оялып тору, кыюсызлык күрсәтү, тартынып тору

скро́мность *ж* 1. тыйнаклык, инсафлылык, әдәпплелек; **~ поведе́ния** үзүзен тотышының тыйнаклыгы 2. гадилек, уртачалык; **~ оде́жды** киеменең гадилеге

скро́мн||ый, -ая, -ое 1. тыйнак; **~ый челове́к** тыйнак кеше 2. гади, уртача; **~ая жизнь** уртача тормыш 3. *перен.* зур булмаган, кечкенә, кечкенә генә; **~ый пода́рок** кечкенә генә бүләк

скрупулёзность *ж* гадәттән тыш төгәллек; җентеклелек; **~ ана́лиза** анализның җентеклелеге

скрупулёзный, -ая, -ое гадәттән тыш төгәл, җентекле; **~ ана́лиз** бик җентекле анализ

скрути́||ть *сов.* 1. *что* (*изготовить, свивая, свёртывая*) чирату, кату, ишү; **~ть кре́пкую верёвку** нык бау ишү 2. *кого-что* бик нык итеп бәйләп кую, боргычлап кую; **~ть** *кому-л.* **ру́ки** *кемнең дә булса* кулларын бик нык итеп бәйләп кую 3. *перен. кого-что, разг.* (*заставить повиноваться*) боргычлап алу, буйсындыру, кулга алу, тынлату 5. *перен. кого, разг.* хәлсезләндерү, аяктан егу, бөгү, какшату; **боле́знь его́ ~ла** авыру аны аяктан екты

скрути́ться *сов.* катылу, бөтерелү, ишелү

скру́чивать *несов. см.* **скрути́ть**

скру́чиваться *несов.* 1. *см.* **скрути́ться**; 2. *страд. от* **скру́чивать**

скрыва́ть *несов. см.* **скрыть**

скрыва́||ться *несов.* 1. *см.* **скры́ться**; 2. (*избегать кого-чего-л.*) качып йөрү, яшеренеп яшәү 3. *перен.* яшерену, яшеренеп яту; **что ~ется за э́тими слова́ми?** бу сүзләр артына нәрсә яшеренгән? 4. *страд. от* **скрыва́ть**

скры́тничать *несов. разг.* яшертен эш йөртү, яшереп маташу, сер итеп тоту

скры́тность *ж* астыртынлык, яшертенлек, мыштымлык

скры́тный, -ая, -ое астыртын, яшертен, яшерүчән, мыштым

скры́тый, -ая, -ое 1. *прич. от* **скры́ть**; 2. (*тайный*) яшерен; **~ смысл** яшерен мәгънә

скрыть *сов.* 1. *чего-что* (*спрятать*) яшерү, яшереп кую, качыру 2. *что* яшерү, сер итеп тоту, сиздермәү, белгертмәү; **~ свои́ наме́рения** үз ниятләренне сиздермәү

скры́||ться *сов.* 1. (*спрятаться*) яшеренү, качу, юк булу, күздән югалу; **со́лнце ~лось за горо́й** кояш тау артына төшеп юк булды 2. (*уйти незаметно*) качу, сиздермичә китеп бару 3. *перен.* беленми (сизелми) калу; **от него́ ничего́ не скро́ется** аңа берни дә беленми калмый

скрю́чивать *несов. см.* **скрю́чить**

скрю́чиваться *несов.* 1. *см.* **скрю́читься**; 2. *страд. от* **скрю́чивать**

скрю́чи||ть *сов. кого-что, разг.* кәкрәйтү, бөкрәйтү, тартыштыру, куырылдыру; **су́дорогой ~ло па́льцы** көзән жыерып бармакларын кәкрәйткән; **его́ ~л ревмати́зм** яны ревматизм бөкрәйткән

скрю́читься *сов. разг.* көкрәю, бөкрәю, бөгелү

скря́га *м, ж* үтә саран кеше, карун; туймас күз, ачкүз

скря́жничать *несов. разг.* үтә саранлану, карунлану; ачкүзләнү

скря́жничество *с* үтә саранлык, карунлык

скуде́||ть *несов. книжн.* ярлылану, фәкыйрьләнү, азаю, кимү; **запа́сы не ~ют** запаслары кимеми

ску́дность *ж* ярлылык, фәкыйрьлек, җиткелексезлек

ску́дн||ый, -ая, -ое ярлы, фәкыйрь, җиткелексез, җитәр-җитмәс; **~ые запа́сы** җитәр-җитмәс запас

ску́дость *ж см.* **ску́дность**

скудоу́мие *с* акыл сайлыгы, мокытлык

скудоу́мный, -ая, -ое акылга сай, мокыт

ску́ка *ж* күңелсезлек, эч пошу, яман-сулау, сагыш

скула́ *ж* янак сөяге (калкымы)

скула́стый, -ая, -ое киң (чыгынкы) яңаклы

скули́ть *несов.* 1. (*о собаке*) шыңшу 2. *перен. разг.* (*плакаться, ныть*) шыңшу, сыкрану, зарлану

ску́льптор *м* скульптор

скульпту́ра *ж* скульптура (1. *чокып, уеп, коеп, таслап төрле сыннар ясау сәнгате* 2. *шул рәвешле ясалган әйберләр, сынлы сәнгать әсәрләре*)

скульпту́рн||ый, -ая, -ое скульптура ...ы; **~ое изображе́ние** скульптура сурәте

ску́мбрия *ж* скумбрия (*балык*)

скунс *м* 1. *зоол.* ала көзән, скунс 2. ала көзән мехы, скунс мехы

ску́нсовый, -ая, -ое 1. ала көзән ...ы 2. ала көзән мехыннан эшләнгән, скунс ...; **~ воротни́к** скунс яка

скупа́ть *несов. см.* **скупи́ть**

скупердя́й *м прост.* үтә саран кеше, карун, комсыз, ачкүз, туймас күз

скупе́ц *м* саран (комсыз) кеше, карун

скупи́ть *сов. кого-что* сатып алып җыю, [күп итеп] сатып алу

скупи́ться *сов.* саранлану, саранлык күрсәтү, карунлану ♦ **не ~ на похвалы́** мактауга саранланмау

ску́пка *ж см.* **скупи́ть**; **~ веще́й** әйберләр сатып алу

скуп||о́й, -а́я, -о́е 1. саран, карун; **~о́й челове́к** саран кеше 2. *перен.* зәгыйфь, саран; **~о́й свет ла́мпы** лампаның зәгыйфь яктасы 3. (*на что, в чём*) саран, юмарт түгел; **он скуп на слова́** ул сүзгә саран

ску́пость *ж* саранлык, карунлык

ску́почный, -ая, -ое сатып алу ...ы; **~ магази́н** сатып алу кибете

ску́пщик *м* сатып алып җыючы, алып-сатар

ску́тер *м* скутер (*тиз йөрешле моторлы көймәнең бер төре*)

ску́фья *ж церк.* скуфья (*православие руханилары, монахлары кия торган баш киеме*)

скуча́ть *несов.* 1. эч пошу; **~ от безде́лья** эшсезлектән эч пошу 2. *по ком-*

чём, по кому-чему, о ком-чём ямансулау, сагыну, юксыну, жирсү; ~ **по дéтям** балаларны сагыну; ~ **по знакóмым местáм** таныш урыннарны сагыну

скýченность *ж* тыгыз урнашканлык (утырганлык), тыгызлык; ~ **населéния** халыкның тыгызлыгы

скýченн||ый, -ая, -ое тыгыз урнашкан (утырган); ~**ое населéние городóв** шәһәрләрнең тыгыз урнашкан халкы

скýчивать *несов. см.* **скýчить**

скýчиваться *несов.* 1. *см.* **скýчиться**; 2. *страд. от* **скýчивать**

скýчить *сов. разг.* 1. *что* өеп кую, җыеп өеп кую; ~ **сéно** печәнне җыеп өеп кую 2. *кого-что* (*расположить тесно*) тыгызлап тутыру (урнаштыру)

скýчиться *сов. разг.* бер урынга җыелу, өелү, туплану

скучнéть *несов.* күңелсезләнү

скýчно *нареч.* 1. кызыксыз, күңелсез; ~ **слýшать однóго и тóго же** бер үк нәрсәне тынлау кызыксыз 2. *в знач. сказ. безл. кому* ямансу, күңелсез, эч поша; **мне** ~ минем эчем поша

скýчн||ый, -ая, -ое 1. күңелсез, ямансу; **он сегóдня** ~**ый** ул бүген күңелсез 2. эч пошыргыч, кызыксыз; ~**ая книгá** кызыксыз китап

скýшать *сов. что, чего* ашап бетерү, ашау

слабé||ть *несов.* 1. зәгыйфьләнү, көчсезләнү, хәлсезләнү, начарлану; **пáмять** ~**ет** хәтер начарлана; ~**ть от болéзни** авырудан зәгыйфьләнү 2. басылу, басыла төшү, кимү; **вéтер** ~**ет** җил басыла төшә

слабинá *ж разг.* 1. (*слабое место*) йомшак урын, нык булмаган урын 2. *прост.* (*недостаток*) йомшак як, җитешсезлек

слабúтельн||ый, -ая, -ое *мед.* 1. эч йомшарта торган; ~**ый порошóк** эч йомшарта торган порошок 2. *в знач. сущ.* ~**ое** *с* эч йомшарткыч дару

слáби||ть *несов.* 1. *безл. кого* эч китү, эч йомшару 2. эчне йомшарту; **кастóрка хорошó** ~**т** касторка эчне әйбәт йомшарта

слáбнуть *несов. разг. см.* **слабéть**

слабо- *кушма сүзләрнең «көчсез», «хәлсез», «йомшак», «начар», «буш», «җиңелчә» мәгънәләрен аңлаткан беренче өлеше, мәс.* **слабосолёный** җиңелчә тозланган

слабовóлие *с* ихтыяр йомшаклыгы, ихтыярсызлык

слабовóльный, -ая, -ое йомшак ихтыярлы, ихтыярсыз

слабоду́шие *с* йомшаклык, аумакайлык, җебегәнлек

слабоду́шный, -ая, -ое йомшак, җебегән, аумакай

слабонéрвный, -ая, -ое какшаган нервлы, нервлары какшаган, чәүчәләк, холыксыз

слаборáзвитый, -ая, -ое аз үсеш алган, аз үскән, үсеш ягыннан артта калган

слабоси́льный, -ая, -ое 1. зәгыйфь, хәлсез, көчсез 2. *тех.* аз егәрле, аз куәтле, аз көчле; ~ **мотóр** аз егәрле мотор

слáбость *ж* 1. йомшаклык, зәгыйфьлек, көчсезлек, начарлык; ~ **зрéния** күрүнең начарлыгы 2. (*недостаток физических сил*) хәлсезлек, көчсезлек 3. йомшаклык, йомшак күңеллелек; **прояви́ть** ~ йомшаклык күрсәтү 4. *перен.* (*склонность, привычка*) җитешсезлек, йомшак як; һәвәслек

слабоу́мие *с* акылга зәгыйфьлек, акыл зәгыйфьлеге, акыл сайлыгы

слабоу́мный, -ая, -ое акылга зәгыйфь, җинел акыллы

слабохарáктерность *ж* йомшак характерлылык

слабохарáктерный, -ая, -ое йомшак характерлы, ихтыяр көче булмаган

слáб||ый, -ая, -ое 1. зәгыйфь, йомшак, көчсез, куәтсез; ~**ый гóлос** зәгыйфь тавыш; **ты** ~**ée менá** син миннән көчсезрәк; ~**ые рýки** көчсез куллар 2. (*болезненный, нездоровый*) чирләшкә 3. аз-маз, кечкенә генә, беленер-беленмәс, сизелер-сизелмәс; ~**ая надéжда** аз гына өмет 4. йомшак, ныклы булмаган, тотрыксыз; ~**ый харáктер** йомшак характер 5. начар, йомшак; ~**ый рабóтник** йомшак работник 6. сыек, йомшак; ~**ый табáк** йомшак тәмәке; ~**ый чай** сыек чәй 7. әкрен, салмак, йомшак, начар; ~**ое течéние** әкрен агым; ~**ый свет** начар яктылык, тоныкяктылык 8. буш, салпы; ~**ая струнá** буш кыл ♦ ~**ая сторонá** *или* ~**ое мéсто** *кого-чего, чьё* салпы як, йомшак як, йомшак җир, җитешсезлек; ~**ый пол** хатын-кызлар

слáв||а *ж* 1. дан, шөһрәт, шан; **боевáя** ~**а** сугышчан дан; **трудовáя** ~**а** хезмәт даны 2. *разг.* (*молва*) имеш-мимешләр, юк-бар сүзләр 3. (*репутация*) абруй ♦ **на** ~**у** менә дигән, бик шәп, бик яхшы, гажәп яхшы

славúст *м* славист (*славяннар тарихын, әдәбиятын, телен өйрәнуче белгеч*)

славúстика *ж* славистика (*то же, что* **славяновéдение**)

слáвить *несов. кого-что* 1. дан җырлау, данлыклау, мәдхия уку, мактау 2. *прост.* (*порочить*) яманатын сату, гайбәт тарату

слáвиться *несов.* 1. дан тоту (казану), данлыклы булу, шөһрәт казану 2. *страд. от* **слáвить** 1

слáвка *ж зоол.* чебенче (*кош*)

слáвно *нареч.* 1. яхшы, менә дигән итеп; ~ **порабóтать** менә дигән итеп эшләп алу 2. *в знач. сказ. разг.* бик яхшы, бик һәйбәт; **здесь** ~ монда бик һәйбәт

слáвн||ый, -ая, -ое 1. данлыклы, данлы, шөһрәтле, шанлы, атаклы; ~**ое úмя** данлыклы исем 2. *разг.* менә дигән, бик яхшы, бик һәйбәт, бик шәп; ~**ая дéвушка** менә дигән кыз

славосло́вие *с* чиктән тыш мактау, күкләргә күтәрү, мәдхия

славосло́вить *несов. кого-что и без доп.* чиктән тыш мактау, күкләргә күтәреп мактау, мәдхия уку

славя́не *мн.* славяннар, славян халыклары

славяни́зм *м лингв.* славянизм (1. *славян группасыннан булмаган берәр телгә славян телләренең берсеннән кергән сүз яки тәгъбир* 2. *рус теленә борынгы славян теленнән кергән сүз яки тәгъбир*)

слявяни́н *м* славян, славян кешесе

славя́нка *ж* славян хатыны (кызы)

славяновéдение *с* славяноведение (*славяннар тормышын, аларның тарихын, әдәбиятын, телләрен өйрәнә торган фәннәр*)

славянофи́льство *с* славянофиллык (*19 йөз урталарында рус иҗтимагый хәрәкәтендә туган консерватив агым*)

славя́нск||ий, -ая, -ое славян ...ы; ~**ие языки́** славян телләре

слагáемое *с* 1. *мат.* кушылучы, кушыла торган сан 2. (*составная часть целого*) кушылма, өлеш, кисәк

слагáть *несов. см.* **сложи́ть**; ~ **свои́ полномóчия** вәкаләтләреңне өстеңнән төшерү

слагáться *несов.* 1. *см.* **сложи́ться**; 2. *страд. от* **слагáть**

слад *м*: ~**у нет** *с кем-чем, разг.* һич кенә дә тыеп булмый, буйсындырып булмый, тынлатып булмый

слáдить *сов.* 1. *что, прост.* (*упорядочить, устроить*) көйләү, рәтләү, җайлау, җайга салу, ипләү; ~ **дéло** эшне көйләү 2. *с кем-чем, разг.* (*справиться*) буйсындыру, тыю, тынлату

слáди||ться *сов. прост.* җайлану, көйләнү, рәтләнү, җайга салыну; **дéло** ~**лось** эш рәтләнде

слáдк||ий, -ая, -ое 1. татлы, баллы; ~**ий чай** татлы чәй; ~**ий пирóг** татлы бәлеш 2. *перен.* тәмле, татлы, рәхәт, күңелле; ~**ий сон** татлы йокы 3. *перен. разг.* төче, күңелгә тия торган, күңел болгаткыч; ~**ая улы́бка** төче елмаю 4. *перен. разг.* ялагай, юмакай, икейөзле, төче; ~**ие рéчи** төче телләнүләр

слáдко *нареч.* 1. татлы итеп, тәмләп, тәмле итеп; ~ **потянýться** тәмле итеп киерелү 2. *перен.* (*льстиво*) төчеләнеп, юмакайланып, ялагайланып; **он так** ~ **говори́т** ул шундый төчеләнеп сөйли 3. *в знач. сказ. безл.* татлы; **во рту** ~ авызда татлы тәм килә 4. *в знач. сказ. безл. кому-чему и без доп.* рәхәт, күңелле; **емý не** ~ аңа рәхәт түгел

сладкоéжка *м, ж разг.* тәмле тамак

сладкозвýчный, -ая, -ое *книжн.* нәфис (йомшак, ягымлы) тавышлы

сладкорéчи́вый, -ая, -ое төче (татлы) телле

слáдостный, -ая, -ое *см.* **слáдкий** 2

сладострáстие *с* җенси дәрт, җенси теләк

сладострáстность *ж* җенси дәртлелек, җенси дәрткә бирелү

сладострáстный, -ая, -ое җенси дәртле, җенси дәрткә чиктән тыш бирелүчән

слáдост||ь *ж* 1. татлылык, татлы тәм; ~**ь мёда** балның татлылыгы 2. *мн.* ~**и** тәм-том әйберләре, татлы ашамлыклар

слáженность *ж* көйлелек, иплелек, килешенгәнлек, җайга (тәртипкә)

салынганлык; ~ **рабо́ты** эшнең җайга салынганлыгы

сла́женн||ый, -ая, -ое көйле, ипле, килешенгән, җайга салынган; ~ **ая рабо́та** көйле эш

сла́живать *несов. см.* **сла́дить**

сла́живаться *несов.* **1.** *см.* **сла́диться; 2.** *страд. от* **сла́живать**

сла́зить *сов. разг.* (*вверх*) менеп төшү; (*вниз*) төшеп менү; ~ **на кры́шу** түбәгә менеп төшү; ~ **в по́греб** кар базына төшеп менү

сла́лом *м спорт.* слалом (*спортның бер төре*)

слаломи́ст *м спорт.* слаломчы

сла́мывать *несов. см.* **сломи́ть**

сла́мываться *несов.* **1.** *см.* **сломи́ться; 2.** *страд. от* **сла́мывать**

сла́нец *м геол.* сланец

сла́нцев||ый, -ая, -ое *геол.* сланец ...ы; ~ **ые поро́ды** сланец токымнары

сластёна *м, ж разг.* тәмле тамак, тәм-том әйберләре яратучы, татлы ашамлыклар яратучы

сла́сти *мн.* тәм-том әйберләре, тотлы ашамлыклар

сласти́ть *несов. что* татлыландыру, баллыландыру, шикәрләү, татлы итү

сластолю́бец *м уст.* женси дәрткә чиктән тыш бирелүчән кеше

сластолюби́вый, -ая, -ое *уст. см.* **сладостра́стный**

сластолю́бие *с уст. см.* **сладостра́стие**

слать *несов. кого-что* җибәрү, салу, күндерү; ~ **пи́сьма** хатлар җибәрү; ~ **гонца́** чапкын җибәрү

слаща́вость *ж* (*льстивость*) үтә юмакайлык, төчелек (*кыланышта, сүздә*)

слаща́в||ый, -ая, -ое үтә юмакай, төче; ~ **ая улы́бка** төче елмаю

сле́ва *нареч.* (*где*) сулда, сул якта; (*откуда*) сулдан, сул яктан

слега́ *ж* шикмә, колга

слегка́ *нареч.* җиңелчә, җиңелчә генә, аз гына, бераз; ~ **дрожа́ть** җиңелчә калтырану; **меня́** ~ **зноби́т** бераз тунып торам әле

след *м* **1.** эз; ~ **ноги́ на песке́** ком өстендәге аяк эзе; ~ **ы́ колёс** тәгәрмәч эзләре; **медве́жий** ~ аю эзе; **напа́сть на чей-л.** ~ *прям., перен. кемнең дә булса* эзенә төшү; **идти́ по** ~ **а́м** *прям., перен.* эзеннән бару **2.** *перен.* (*признак*) билге, эз; ~ **ы́ пожа́ра** янгын эзләре **3.** *разг.* (*ноги́ или обуви*) аяк табаны, табан асты; олтан ♦ **без** ~ **а́ исче́знуть** эзсез югалу; **[и]** ~ **просты́л** эзе дә күренми

следи́ть I *несов.* **1.** *за кем-чем* күзәтү, күзәтеп (карап) тору; ~ **за полётом птиц** кошлар очканны күзәтеп тору **2.** *за чем* күзәтү, күзәтеп бару; ~ **за успе́хами нау́ки** фән уңышларын күзәтеп бару **3.** *за кем-чем* (*заботиться, опекать*) карау, күз-колак булу **4.** *за кем-чем* (*наблюдать с целью разоблачения*) эзәрләү, күзәтеп йөрү, күзәтү **5.** *кого-что, охот.* эзәрлекләү, эзеннән барып эзләү ♦ ~ **за собо́й** үзүзеңне карау (*үзеңнең тышкы кыяфәтең яисә сәламәтлегең турында кайгырту*)

следи́ть II *несов. чем и без доп., разг.* (*оставлять следы*) [пычрак] эз калдыру, пычрату

сле́дование *с см.* **сле́довать** 1-3

сле́дователь *м* следователь, суд тикшерүчесе, тикшерүче

сле́довательно *союз и вводн. сл.* димәк, шунлыктан, шуңа күрә, шулай булгач

сле́довательск||ий, -ая, -ое следователь ...ы, тикшерүче ...ы; ~ **ая рабо́та** тикшерүче эше

сле́д||овать *несов.* **1.** *за кем-чем* (*идти следом*) ияреп бару, артыннан бару (килү) **2.** *за чем* [артыннан] килү, булып тору, үтеп тору; **одно́ собы́тие** ~ **ует за други́м** бер вакыйга артыннан икенчесе үтеп тора **3.** бару; **по́езд** ~ **ует до Москвы́** поезд Мәскәүгә хәтле бара **4.** *кому-чему, книжн.* иярү, охшарга тырышу, тоту; **во всём** ~ **овать учи́телю** һәрнәсәдә остазына охшарга тырышу; ~ **овать сове́там дру́га** дустыңның киңәшен тоту **5. отсю́да** ~ **ует вы́вод** моннан шундый нәтиҗә килеп чыга **6.** *безл. с неопр.* кирәк; **рабо́ту** ~ **ует зако́нчить** эшне төгәлләргә кирәк **7.** *безл. с кого-чего и кому* (*причитаться*) тиеш, кирәк; **ско́лько с меня́** ~ **ует?** миннән күпме тиеш?; **ему́** ~ **ует де́сять рубле́й** аңа ун сум бирергә кирәк ♦ **как** ~ **ует** тиешенчә, шәп итеп, яхшылап

сле́дом *нареч.* артыннан ук, шунда ук, калышмыйча, эзенә басып; **идти́** ~ эзенә басып бару

следопы́т *м* **1.** (*охотник*) эзәрләүче **2.** эзтабар; **ю́ные** ~ **ы** яшь эзтабарлар (*революция, сугыш һәм хезмәт ветераннары тормышын өйрәнү белән шөгыльләнүче мәктәп балалары*)

сле́дственн||ый, -ая, -ое *юр.* тикшерү ...ы; ~ **ые о́рганы** тикшерү органнары; ~ **ые докуме́нты** тикшерү документлары

сле́дствие I *с* нәтиҗә; **причи́на и** ~ сәбәп һәм нәтиҗә

сле́дствие II *с юр.* тикшерү, суд тикшерүе; **вести́** ~ тикшерү алып бару; **быть под** ~ **м** суд тикшерүендә булу

сле́дуем||ый, -ая, -ое тиешле, тиеш булган; **получи́ть** ~ **ые де́ньги** тиешле акчаны алу

сле́дующ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **сле́довать; 2.** киләсе, чираттагы, алдагы, моннан соңгы, икенче, башка; **на** ~ **ий день** икенче көнне; **в** ~ **ий раз** башка вакытта **3.** *в знач. мест. определит.* түбәндәге, менә бу, менә мондый; **вызыва́ются** ~ **ие ли́ца** түбәндәге кешеләр чакырыла **4.** *в знач. мест. определит.* ~ **ее** *с см.* ~ **ий** 3; **скажи́те мне** ~ **ее** миңа менә моны әйтегез әле; **от вас тре́буется** ~ **ее** сездән түбәндәгеләр таләп ителә

слежа́||ться *сов.* озак ятып тыгызланы; басылып ятып укмашу; **се́но** ~ **лось** печән басылып ятып тыгызланган

слежéни||е *с см.* **следи́ть** 1; **ста́нция** ~ **я** *спец.* күзәтү станциясе

слёживаться *несов. см.* **слежа́ться**

слéжка *ж см.* **следи́ть** I 1, 4

слеза́ *ж* **1.** яшь, күз яше; **лить слёзы** күз яше түгү **2.** яшь бөртеге, яшь тамчысы; ~ **покати́лась по щеке́** янагы буйлап яшь бөртеге тәгәрәп төште **3.** *мн.* **слёзы** (*плач*) елау, яшь түгү ♦ **сквозь слёзы** яшь аралаш

слеза́ть *несов. см.* **слезть**

слез||и́ться *несов.* яшьләнү, яшь килү; **глаза́** ~ **я́тся от ды́ма** төтеннән күз яшьләнә

слезли́вость *ж* еш елаучан булу, елаклык

слезли́вый, -ая, -ое **1.** (*склонный к слезам*) елак, сытык, еш елаучан, яшь түгүчән, балавыз сыгучан **2.** (*жалобный — о голосе*) елак, еламсыраган, кызганыч

слёзн||ый, -ая, -ое **1.** *анат.* яшь ...ы, күз яше ...ы; ~ **ые жёлезы** яшь бизләре; ~ **ый мешо́к** яшь капчыгы (*күз янында яшь җыела торган капчык*) **2.** *разг.* (*жалобный*) елап, мескенләнеп, күз яше түгеп; ~ **ая про́сьба** елап (мескенләнеп) утенү

слезоотделе́ние *с* күздән яшь килү

слезотече́ние *с* күздән яшь агу (түгелү)

слезоточи́в||ый, -ая, -ое **1.** яшь килә (ага) торган, яшьле; ~ **ые глаза́** яшьле күзләр **2.** яшь китерә торган, күздән яшь агыза торган; ~ **ый газ** күздән яшь агыза торган газ

слезоточ||и́ть *несов.* яшь килү (агу); **глаза́** ~ **а́т** күзләрдән яшь ага

слез||ть *сов.* **1.** (*спуститься*) төшү; ~ **ть с кры́ши** түбәдән төшү **2.** *разг.* (*выйти*) төшеп калу, төшү, чыгу; ~ **ть на пе́рвой остано́вке** беренче тукталышта төшеп калу **3.** кубу, кубып төшү; **ко́жа** ~ **ла** тире кубып төште

сле́пень *м зоол.* бөгәлчән, сукыр кигәвен

слепе́ц *м прям., перен.* сукыр, сукыр кеше

слепи́||ть I *несов. что* күзне чагылдыру (камаштыру, каплау), күзгә бәрү; **снег** ~ **т глаза́** кар күзне чагылдыра

слепи́ть II *сов. что* **1.** әвәләп ясау; ~ **сне́жную бабу́** әвәләп кар бабай ясау **2.** (*склеить*) ябыштыру, җилемләп (сылап) ябыштыру **3.** *перен.* (*сделать кое-как*) әтмәләп кую, эштер-өштер эшләп кую

слепи́ться *сов.* (*слипнуться*) ябышу

слепля́ть *несов. см.* **слепи́ть** II

слепля́ться *несов.* **1.** *см.* **слепи́ться; 2.** *страд. от* **слепля́ть**

сле́пнуть *несов.* сукыраю, күзсез калу

слеп||о́й, -а́я, -о́е **1.** сукыр, күзсез **2.** *в знач. сущ.* ~ **о́й** *м*, ~ **а́я** *ж* сукыр **3.** *перен.* сукырларча, сукыр рәвештә; ~ **о́е подража́ние** сукырларча иярү **4.** (*неотчётливый*) тонык; ~ **о́й шрифт** тонык шрифт **5.** (*без участия зрения*) күрмичә; ~ **о́й полёт** *ав.* (*самолёта*) күрмичә очу ♦ ~ **а́я кишка́** *анат.* сукыр эчәк; ~ **о́й дождь** кояшлы яңгыр

сле́пок *м* күчермә, басып төшерелгән рәсем; ~ **со ста́туи** статуяның күчермәсе

слепорождённый, -ая, -ое тума сукыр, тумыштан сукыр, сукыр булып туган

слепота́ *ж прям., перен.* сукырлык; ~ **на о́ба гла́за** ике күзнең дә сукыр-

лыгы; **полити́ческая** ~ сәяси сукырлык

слеса́рничать *несов. разг.* слесарьлык итү, слесарь булып эшләү

слеса́рн||ый, -ая, -ое **1.** слесарьлык ...ы; **~ое де́ло** слесарьлык эше **2.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж* слесарьлык мастерское

слеса́рня *ж разг. см.* **слеса́рный** 2

сле́сарный, -ая, -ое слесарь ...ы, слесарьлык ...ы; **~ инструме́нт** слесарьлык инструменты

сле́сарь *м* слесарь

слёт *м* **1.** *см.* **слете́ться; 2. слёт; пионе́рский ~** пионерлар слёты

слета́ть I *сов.* **1.** очып барып кайту; **~ в Москву́** Мәскәүгә очып барып кайту **2.** *прост.* (*сбегать, съездить*) бик тиз барып кайту, барып килү

слета́ть II *несов. см.* **слете́ть**

слета́ться *несов. см.* **слете́ться**

слете́||ть *сов.* **1.** *с чего* очып төшү; **го́лубь ~л с крыши на зе́млю** күгәрчен өй түбәсеннән җиргә очып төште **2.** *перен. с чего, разг.* (*упасть*) егылып төшү, төшеп китү; **~ть с крыльца́** болдырдан егылып төшү **3.** *с чего* очып китү; **ба́бочка ~ла с цветка́** күбәләк чәчәктән очып китте **4.** *перен. с кого-чего* (*исчезнуть*) качу, югалу, юк булу; **сон ~л с него́** аның йокысы качты **5.** *перен. с чего* (*быть неожиданно произнесённым*) сүз ычкыну, искәрмәстән әйтеп салу, абайламый әйтеп ташлау

слете́||ться *сов.* **1.** җыелу, очып килеп җыелу; **о́сы ~лись на варе́нье** вареньега шөпшәләр очып килеп җыелды **2.** *перен. разг.* (*сбежаться*) җыелу, йөгереп килеп җыелу

слечь *сов.* (*заболеть*) авырып китү, авырып [урынга] егылу, урын хастасы булу

слив *м* **1.** *см.* **слить** 1-3; **2.** (*сток*) улак

сли́ва *ж* слива, караҗимеш (*агачы һәм җимеше*)

слива́ние *с см.* **слить**

слива́ть *несов. см.* **слить**

слива́ться *несов.* **1.** *см.* **сли́ться; 2.** *страд. от* **слива́ть**

сли́вки *только мн.* **1.** каймак, сөт өстеседә **2.** *перен. книжн.* каймагы, иң яхшы өлеше; **~ о́бщества** җәмгыятнең каймагы

сливн||о́й, -а́я, -о́е **1.** катнаштырылган, (*төрле савытлардан*) бушатылган, кушып җыелган; **~о́е молоко́** кушып җыелган сөт **2.** агызу ...ы, түгү өчен, түгә торган; **~а́я я́ма** юынтык сулар түгә торган чокыр; **~о́й кран** агызу краны **3.** (*для приёма жидкостей*) җыя торган, кабул итә торган; **~о́й моло́чный пункт** сөт җыя торган пункт

сли́вов||ый, -ая, -ое слива ...ы, караҗимеш ...ы; **~ая ко́сточка** караҗимеш төше; **~ое варе́нье** караҗимеш вареньесы

сли́вочник *м* каймак савыты

сли́вочн||ый, -ая, -ое каймаклы, каймактан хәзерләнгән; **~ое моро́женое** каймактан хәзерләнгән мороженое; **~ое ма́сло** атланмай, ак май

слива́нка *ж* сливянка (*аракы*)

слиза́ть *сов. что* ялап алу (чистарту)

сли́зень *м зоол.* лайлач әкәм-төкәм

сли́зист||ый, -ая, -ое лайлалы; **~ая оболо́чка** *анат.* лайлалы тышча, лайлалы яры

слизну́ть *сов. однокр. что* ялап алу

слизня́к *м* **1.** *см.* **сли́зень; 2.** *перен. разг.* (*о безвольном человеке*) селәгәй, җебегән, боламык (*характерсыз кеше хакында*)

сли́зывать *несов. см.* **слиза́ть**

слизь *ж* лайла

слиня́ть *сов.* **1.** *разг.* (*утратить первоначальный цвет*) уңу, төсен җую **2.** (*о наружном покрове животных*) ябага кою, йон кою, кабык салу, төс алмаштыру

слипа́ться *несов.* **1.** (*о глазах*) йомылу **2.** *см.* **сли́пнуться**

сли́п||нуться *сов.* ябышу; **листы́ бума́ги ~лись** кәгазь битләре ябышкан

сли́тн||ый, -ая, -ое кушып, бергә; **~ое написа́ние напре́чий** рәвешләрнен бергә язылуы

сли́ток *м* коелма, кисәк; **~ зо́лота** ялтын коелмасы

слить *сов. что* **1.** саркыту, сөзеп алу; **~ сли́вки с молока́** сөтнең өстен сөзеп алу **2.** (*перелить, вылить*) түгү, бушату **3.** бергә кушу, катнаштыру; **~ молоко́ от ра́зных коро́в** төрле сыерлардан савылган сөтне бергә кушу **4.** *перен.* кушу, берләштерү; **~ два заво́да** ике заводны бергә кушу

сли́||ться *сов.* **1.** (*соединиться*) кушылу, кушылып агу; **два ручья́ ~ли́сь в ре́чку** ике инеш кушылып бер елга хасил иткән **2.** *перен.* берләшү, кушылу; **на́ши уси́лия ~ли́сь** безнең тырышлыклар бергә кушылды; **голоса́ ~ли́сь в о́бщий шум** тавышлар кушылып тоташ бер шау-шуга әйләнде

слича́ть *несов. см.* **сличи́ть**

сличе́ние *с см.* **сличи́ть**

сличи́ть *сов. что* чагыштыру, чагыштырып карау (чыгу); **~ ко́пию с по́длинником** күчермәне төп нөсхә белән чагыштырып чыгу

сли́шком *нареч.* чиктән (чамадан) тыш, кирәгеннән артык, чамасыз, ифрат; **э́то уж ~!** монысы инде чамадан тыш!

слия́ние *с* **1.** *см.* **слить** 4, **сли́ться; 2.** (*место соединения рек*) [бергә] кушылган урын

слобода́ *ж* **1.** *ист.* слобода, зур авыл (*Россиядә крепостное право чорында: крепостной булмаган халык яшәгән авыл*) **2.** *уст.* (*пригород*) бистә (*шәһәр яны посёлогы*)

слободск||о́й, -а́я, -о́е *уст.* слобода ...ы; бистә ...ы; **~о́е населе́ние** бистә халкы

слова́к *м* словак, словак кешесе

слова́ки *мн.* словаклар, словак халкы

слова́рник *м. разг.* сүзлекче (*лексикограф*)

слова́рн||ый, -ая, -ое сүзлек[ләр] ...ы; **~ый соста́в языка́** телнең сүзлек составы; **~ая рабо́та** сүзлек эше

слова́рь *м* **1.** сүзлек, лөгать; **толко́вый ~** аңлатмалы сүзлек **2.** (*лексика*) сүз байлыгы, сүзлек составы (*бирәр телнең яки язучының*)

слова́цкий, -ая, -ое словак[лар] ...ы, Словакия ...ы; **~ язы́к** словак теле

слова́чка *ж* словак хатыны (кызы)

слове́сник *м* телче, әдәбиятчы, тел-әдәбият укытучысы

слове́сн||ый, -ая, -ое телдән әйтелгән, телдән бирелгән; **~ое предупрежде́ние** телдән искәртү

снорóвк||а *ж* осталык, булдыклылык, җитезлек, маһирлык; **э́то де́ло тре́бует ~и** бу эш осталык сорый

снос I *м см.* **снести́** 3, 4, 6

снос II *м:* **~у нет** *чему, разг.* бик нык, тузмый, тузуны белми (*кием турында*)

сно́с||и: на ~ях *прост.* тиздән бәбәйләргә тиеш, тиздән бала табарга тиеш (*көмәнле хатын турында*)

сноси́ть I *сов. что, разг.* (*износить*) туздыру, киеп туздыру (*аяк киемен, өс киемен*)

сноси́ть II *несов. см.* **снести́**

сноси́ться I *сов. разг.* (*прийти в ветхость*) тузу, тузып бетү, киелә-киелә тузу (*аяк киеме, өс киеме турында*)

сноси́ться II *несов. см.* **снести́сь** I

сно́ска *ж* сноска (*китап битенең аскы өлешенә төшереп бирелгән искәрмә*)

сно́сн||ый, -ая, -ое *разг.* канәгатьләнерлек, ярыйсы, чыдарлык, түзәрлек; **~ые усло́вия** канәгатьләнерлек шартлар

снотво́рн||ый, -ая, -ое **1.** йоклаткыч, йоклата торган, йокыны китерә торган; **~ый порошо́к** йоклата торган порошок **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* йоклата торган дару

сноха́ *ж* килен

сноше́ние *с* **1.** *см.* **снести́сь** I; **2.** (*половой акт*) якынлык кылу, җенси мөнәсәбәт

сну́лый, -ая, -ое *спец.* (*о рыбе*) җансыз, йоклаган; тынган

сню́хаться *сов.* **1.** (*о животных*) иснәшү, иснәшеп танышу **2.** *прост. неодобр.* (*о людях*) якынлашу, танышып китү, килешеп китү

сню́хиваться *несов. см.* **сню́хаться**

сня́тие *с см.* **снять**

снят||о́й, -ая, -о́е: **~о́е молоко́** өсте алынган сөт

сня́ть *сов.* **1.** *что* (*отделить*) алу, алып кую; (*сверху*) төшерү, күтәреп төшерү; **~ карти́ну со стены́** картинаны стенадан алып кую **2.** *что* алу; **~ сли́вки с молока́** сөт өстен алу **3.** *что* җыеп алу, җыю; **~ урожа́й** уңышны җыеп алу **4.** *что* (*с себя*) салу, салып кую; (*с кого-л.*) салдыру, салдырып алу **5.** *что* тунау, сую; **~ шку́ру** тиресен тунау **6.** *что* төшерү; **~ с себя́ ответственность** җаваплылыкны өстеңнән төшерү **7.** *что* алу; **~ ко́пию** күчермәсен алу **8.** *что* алу, кире алу, кайтарып алу; **~ своё предложе́ние** тәкъдимеңне кире алу **9.** *что* (*скопировать*) төшерү, төшереп алу; **~ план уча́стка** участокның планын төшереп алу **10.** *что* бетерү, юкка чыгару; **~ вы́говор** выговорны алу **11.** *кого* (*освободить*) алу, төшерү, бушату, чыгару; **~ с рабо́ты** эштән алу **12.** *что* [вакытлыча файдалануга] алу, алып тору; **~ да́чу** дача алып тору ♦ **как рукой сня́ло** *что* кул белән алып ташлагандай булды (*авыру, кайгы-хәсрәт турында*); **~ боль** авыртуны бетерү, авыртуны туктату; **~ го́лову** *с кого* башын кисү; **~ допро́с** допрос алу; **~ обвине́ние** аклау; **~ ло́дку с ме́ли** комга утырган көймәне тартып чыгару; **~ с учёта** учёттан төшерү

сня́||ться *сов.* **1.** алыну; **кры́шка легко́ ~ла́сь** капкач җинел алынды **2.** (*об одежде*) салыну **3.** (*сфотографироваться*) [рәсемгә] төшү; **4.** кузгалып китү; **отря́д ~лся** отряд кузгалып китте; **~ться с я́коря** якорьны күтәреп кузгалып китү ♦ **~ться с учёта** учёттан төшү

со *см.* **с**

соа́втор *м* автордаш

соа́вторство *с* автордашлык

соба́к||а *ж* эт; **охо́тничья ~а** ау эте; **сторожева́я ~а** сакчы эт; **поро́дистая ~а** саф токымлы эт, яхшы нәселле эт; **~а ла́ет, ве́тер но́сит** *погов.* эт өрер, бүре йөрер ♦ **вот где ~а зарыта!** имәндә икән чикләвек!; менә аның сере (хикмәте) кайда икән!; **[как] ~а на се́не** печән өстендәге эт кебек; **как соба́к нере́занных** *кого, неодобр.* эткә типсәң, ...га тия, бик күп, чиктән тыш күп; **соба́к ве́шать** *на кого-что* сүгү, тиргәү, бәла тагу, чүп өю; **~у съел** *на чём* теше төшкән инде, теше коелган инде, азу теш чыккан инде (*берәр өлкәдә озак вакытлар эшләп зур тәҗрибә алу, осталыгы зур булу турында*)

собаково́дство *с* эт асраучылык

соба́ч||ий, -ья, -ье **1.** эт ...ы; **~ий лай** эт өрүе; **~ья конура́** эт оясы **2.** эт тиресеннән тегелгән; **~ьи унты́** эт тиресеннән тегелгән унталар ♦ **~ий хо́лод** зәмһәрир суыгы, катып үләрлек суык; **~ья жизнь** эт тормышы, эт көне (*авыр тормыш*)

соба́чка *ж* **1.** *уменьш.-ласк. от* **соба́ка**; **2.** тияк (*мылтыкта һәм башка төрле механизмнарда махсус җайланма*)

соба́чник *м разг.* эт яратучы кеше

собезья́нничать *сов. разг.* маймыллану, кешегә ияреп кылану

собесе́дник *м* әңгәмәдәш, утырдаш

собесе́дница *ж* әңгәмәдәш хатын (кыз)

собесе́дование *с* әңгәмә, сөйләшү, беседа (*фәнни, политик һ.б.ш. темага*)

собира́тель *м* җыючы, туплаучы; **~ наро́дных ска́зок** халык әкиятләре җыючы

собира́тельница *ж см.* **собира́тель**

собира́тельн||ый **1.** гомумиләштерелгән; **~ый о́браз** гомумиләштерелгән образ **2.** *грам.* җыйма ..., җыю ...: **~ые имена́ существи́тельные** җыйма исемнәр; **~ые числи́тельные** җыю саннары

собира́тельство *с* коллекционерлык, коллекция[ләр] җыю[чылык]

собира́ть *несов.* **1.** *см.* **собра́ться; 2.** *страд. от* **собира́ть**

соблаговоли́||ть *сов. с неопр., ирон.* рәхим итү; **~те отве́тить** рәхим итеп җавап бирегез

собла́зн *м* әгъва, кызыгырлык (кызыктырырлык, кызыктыргыч) нәрсә; вәсвәсә; ымсыну, күңел азу (аздыру), вәсвәсә салу; **вводи́ть** *кого-л.* **в ~** вәсвәсә салу; **впада́ть в ~** кызыгу

соблазни́тель *м* әгъвачы, кызыктыручы, кызыктырып алдаучы, күңел аздыручы, вәсвәсә салучы, вәсвәсәче

соблазни́тельница *ж* әгъвачы хатын (кыз), вәсвәсәче хатын(кыз)

соблазни́тельн||ый, -ая, -ое **1.** кызыгырлык, кызыктырырлык, кызыктыргыч, ымсындыргыч; **~ое предложе́ние** кызыктырырлык тәкъдим **2.** (*обольстительный*) күңел аздыргыч, күңел аздыра торган, вәсвәсәле

соблазни́ть *сов.* **1.** *кого-что чем и с неопр.* (*прельстить*) кызыктыру, ымсындыру; **~ пое́хать на юг** кәньякка барырга кызыктыру **2.** *кого* (*обольстить женщину*) алдау, юлдан яздыру **3.** *кого, уст.* (*вызвать греховные помыслы, желания*) күңел аздыру, юлдан яздыру, вәсвәсәләү, вәсвәсә салу

соблазни́ться *сов. чем, на что и без доп.* кызыгу, күңел төшү, күз кызу; ымсыну; **~ пое́хать на юг** көньякка барырга кызыгу

соблазня́ть *несов. см.* **соблазни́ть**

соблазня́ться *несов.* **1.** *см.* **соблазни́ться; 2.** *страд. от* **соблазня́ть**

соблюда́ть *несов. см.* **соблюсти́**

соблюде́ние *с см.* **соблюсти́; ~ поря́дка** тәртип саклау

соблюсти́ *сов. что* **1.** саклау; тоту; **~ поря́док** тәртип саклау; **~ дие́ту** диета тоту **2.** саклау; үтәү, тоту, җиренә җит-

кереп үтәү; ~ **дө́говө́р** шартнамә шартларын үтәү; ~ **прили́чия** әдәп саклау

соболе́знование *с* кайгысын уртаклашу; тәгъзия (*уст.*); **вы́разить** ~ кайгысын уртаклашу

соболе́зновать *несов. кому-чему* кайгысын уртаклашу; тәгъзия кылу (*уст.*)

собо́л||ий, -ья, -ье 1. кеш ...ы; ~**ья шку́рка** кеш тиресе 2. кеш [мехыннан тегелгән]; ~**ья ша́пка** кеш [мехыннан тегелгән] бүрек

соболи́н||ый, -ая, -ое *см.* **собо́лий** ♦ ~**ые бро́ви** куе кара кашлар

со́боль *м* 1. кеш 2. *обычно мн.* **соболя́** (*мех*) кеш мехы

собо́р *м* собор (1. *ист. иске Россиядә: оештыру һәм идарә мәсьәләләрен хәл итү максаты белән чакырыла торган җыелыш* 2. *югары христиан руханилары җыелышы* 3. *шәһәрнең яки монастырьнең иң зур чиркәве*)

собра́ние *с* 1. җыелыш; **парти́йное** ~ партия җыелышы 2. собрание; **учреди́тельное** ~ учредительное собрание 3. (*совокупность текстов, изданных вместе*) җыелма басма 4. җыелма, тупланма; ~ **ре́дкостей** сирәк очрый торган әйберләр җыелмасы; ~ **моне́т** акчалар коллекциясе

со́бранность *ж* тупланганлык, зиһенне (игътибары) тупланган булу, җыйнаклык

со́бранный, -ая, -ое 1. *прич. от* **собра́ть**; 2. зиһенне (игътибары) тупланган; игътибарлы, җыйнак; ~ **челове́к** җыйнак кеше

собра́т *м* хезмәттәш, иптәш; ~ **по ору́жию** коралдаш

собра́ть *сов.* 1. *кого-что* җыю, туплау; ~ **ученико́в** укучыларны җыю 2. *что* җыю, җыеп алу (кую), туплау, туплап кую; ~ **урожа́й** уңышны җыеп алу; ~ **ве́щи** әйберләрне җыеп кую; ~ **све́дения** мәгълүматлар җыю 3. *кого-что* әзерләү; ~ **в доро́гу** юлга әзерләү; ~ **обе́д** төшке ашны әзерләү 4. *что* җыю, кору; ~ **радиоприёмник** радиоалгычны кору 5. *что, портн.* (*сделать сборки*) бөрү, бөреп тегү, бөрмәләү 6. *перен. что* җыю, туплау; ~ **все свои́ си́лы** бөтен көченне туплау

собра́||ться *сов.* 1. җыелу, туплану; (*о дожде*) җыену; **наро́д** ~**лся** халык җыелды; **собра́ло́сь мно́го книг** [бик] күп китап җыелган 2. (*сжаться; сморщиться*) йомарлану, бөгәрләнү; җыерылу; ~**ться в комо́к** йомарлану 3. (*приготовиться*) әзерләнү, җыену; ~**ться в доро́гу** юлга [чыгарга] җыену; ~**ться уе́хать** китәргә җыену; ~**ться для прыжка́** сикерергә әзерләнү 4. *с чем* җыю, туплау; ~**ться с ду́хом** [бөтен] кыюлыкны җыю (туплау); ~**ться с мы́слями** [бөтен] зиһенне туплау; ~**ться с си́лами** бөтен көчне туплау 5. үзеңне кулга алу, игътибарыңны туплау, зиһенеңне туплау; ~**ться пе́ред выступле́нием** чыгыш ясау алдыннан үзеңне кулга алу

со́бственник *м* 1. (*владелец*) милекче, [милек] биләүче, хосусый милек иясе, хуҗа; **ча́стный** ~ хосусый милекче 2. *перен.* хуҗа

со́бственническ||ий, -ая, -ое хосусый милек ияләренә хас [булган], хосусый милекче[лек] ...ы; ~**ая психоло́гия** хосусый милекчелек психологиясе

со́бственно 1. *вводн. сл.* (*в сущности*) чынында, дөресендә, дөресен әйткәндә; асылда, нигездә; ~ **говоря́** дөресен әйткәндә 2. *частица огранич.* (*в буквальном смысле слова*) чын мәгънәсендә

собственнору́чн||ый, -ая, -ое үз кулы белән ...ган; ~**ая распи́ска** үз кулы белән язылган расписка

со́бственность *ж* милек; **общественная** ~ гомуми милек; җәмәгать милке; **ча́стная** ~ хосусый милек; **ли́чная** ~ шәхси милек

со́бственн||ый, -ая, -ое 1. *в разн. знач.* үз; ~**ая да́ча** үз дачасы; ~**ый корреспонде́нт** үз хәбәрче; **твои́** ~**ые де́ти** үз балаларың; **по** ~**ому жела́нию** үз теләге белән; **спра́виться** ~**ыми си́лами** үз көчең белән башкарып чыгу 2. үз, чын, туры; **в** ~**ом смы́сле сло́ва** сүзнең чын мәгънәсендә

событы́льник *м* шешәдәш, бергә эчкән (эчеп йөрүче) кеше

собы́ти||е *с* 1. вакыйга, хәл; ~**я после́дних дней** соңгы көннәрдә булган хәлләр 2. зур вакыйга; **его́ прие́зд к нам** — ~**е** аның безгә килүе — зур вакыйга

сова́ *ж* ябалак

сова́ть *несов. что, разг.* 1. тыгу; ~ **ру́ки в карма́ны** кулларны кесә[ләр]гә тыгу; ~ **топо́р за по́яс** биленә балта кыстыру 2. төртү, сузу; ~ **ру́ку** (*напр. здороваясь*) кул сузу ♦ ~ **[свой] нос** борын тыгу, тыгылу, тыкшыну (*кеше эшенә*); ~ **под нос** *кому* борынына төртү

сова́ться *несов.* 1. *разг.* тыгылу, тыкшыну, кысылу; ~ **всю́ду** бөтен җиргә тыгылу; ~ **в чужи́е дела́** кеше эшенә тыгылу 2. *страд. от* **сова́ть**

соверша́ть *несов. см.* **соверши́ть**

соверша́ться *несов.* 1. *см.* **соверши́ться**; 2. *страд. от* **соверша́ть**

соверше́нно *нареч.* 1. тулысынча, тәмам, бөтенләй; һич, һич тә, бер дә; **он** ~ **огло́х** ул бөтенләй чукракланган; ~ **не ну́жно** бөтенләй кирәге юк; **ду́мать** ~ **о друго́м** бөтенләй икенче нәрсә турында уйлау; 2.: ~ **бе́лый** ап-пак; ~ **ве́рно** бик дөрес, дөп-дөрес, һичшиксез дөрес; ~ **здоро́вый** сап-сау; ~ **но́вый** өр-яңа; ~ **норма́льный** бик нормаль; ~ **прав** тулысынча хаклы; ~ **слепо́й** дөм-сукыр, тома сукыр

совершенноле́тие *с* буйга җитү, яше җитү, балигъ булу

совершеннолётний, -яя, -ее буйга җиткән, яше җиткән, балигъ булган

соверше́нн||ый I, -ая, -ое 1. камилләшкән, камилләштерелгән; камил, мөкәммәл булып җиткән; ~**ая фо́рма** камил форма 2. (*полный*) тулы, ~**ое схо́дство** тулы охшашлык 3. *разг.* (*подлинный*) чын, чын мәгънәдә, тулысынча, бөтенләй; ~**ое дитя́** чын мәгънәдә бала; ~**ая пра́вда** чын хакыйкать

соверше́нный II, -ая, -ое: ~ **вид** *грам.* тәмамланган төр

соверше́нств||о *с* камиллек, мөкәммәллек; **в** ~**е** бик яхшы; **знать** *что-л.* **в** ~**е** *берәр нәрсәне* бик яхшы белү

соверше́нствовать *несов. что* камилләштерү, яхшырту

соверше́нств||оваться *несов.* 1. камилләшү; камилләшә бару, мөкәммәлләшү; **его́ писа́тельский тала́нт** ~**уется** аның язучылык таланты камилләшә бара 2. *в чём* (*в знаниях, умении и т.п.*) камилләштерү, камилләштерә бару, арттыру 3. *страд. от* **соверше́нствовать**

соверши́||ть *сов. что* 1. кылу, ясау, эшләү; ~**ть оши́бку** хата ясау; ~**ть преступле́ние** җинаять эшләү; ~**ть путеше́ствие** сәяхәт кылу; ~**ть по́двиг** батырлык күрсәтү; **самолёт** ~**л поса́дку** самолёт утырды (җиргә төште) 2. башкару, кылу; ~**ть богослуже́ние** гыйбадәт кылу; ~**ть намо́з** намаз уку 3. (*оформить*) килешү; ~**ть сде́лку** килешү

соверши́ться *сов.* булу, килеп чыгу

со́вестить *несов. кого, разг.* оялту, инсафка китерү

со́веститься *несов. разг.* оялу, тартыну, вөжданы күтәрмәү, намуслану, намуссыну

со́вестливый, -ая, -ое намуслы, вөжданлы, оялучан, оялчан

со́вестно *в знач. сказ. безл. кому* оят, уңайсыз; **как вам не** ~**!** оят түгелмени сезгә!

со́вест||ь *ж* вөждан, намус, оят; **долг** ~**и** вөждан бурычы; **моя́** ~**ь чиста́** вөжданым пакь, йөзем ак; **упрёки** ~**и** вөждан газабы; **име́й же** ~**ь** оятың булсын; **испы́тывать угрызе́ния** ~**и** вөждан газабы кичерү; **ни сты́да ни** ~**и** ояты да юк, хәясе дә юк ♦ **без зазре́ния** ~**и** оятсызланып, оятсыз рәвештә, намуссыз рәвештә; **для очи́стки** ~**и** күңел тынычлыгы өчен, күңелне тынычландыру өчен; **на** ~**ь** (*добросовестно*) намус белән, күңел биреп (яхшы итеп, тырышып) эшләү; **по** ~**и говоря́ (сказа́ть)** *в знач. вводн. сл.* чын күңелдән әйткәндә, дөресен генә әйткәндә, ачыктаначык әйткәндә; **поступи́ть по** ~**и** вөжданың (намусың) кушканча эш итү; **по [чи́стой]** ~**и [жить, поступа́ть** *и т.п.*] намус белән (*яшәү, эш итү h.б.ш.*); **свобо́да** ~**и** вөждан иреге (*дин тоту мәсьәләләренда*); **со споко́йной** ~**ью** тыныч вөждан белән, үзенең хаклылыгына ышанып

сове́т *м* 1. киңәш; мәслихәт; ~**ы врача́** табиб киңәшләре 2. киңәшмә; **на семе́йном** ~**е** гаилә киңәшмәсендә; **держа́ть** ~ киңәшү 3. совет; **Верхо́вный Сове́т** Югары Совет; ~ **трудово́го коллекти́ва** хезмәт коллективы советы; **Сове́т старе́йшин** Старейшиналар советы ♦ ~ **да любо́вь** бәхетле, тату тормыш [телим сезгә]; тату яшәгез

сове́тник *м* киңәшче; ~ **посо́льства** илчелек киңәшчесе

сове́тница *ж разг.* (*жена советника*) киңәшче хатыны

сове́товать *несов. что и с неопр.* киңәш бирү, киңәш итү, мәслихәт бирү; мәслихәт күрү

сове́товаться *несов.* **1.** (*просить совета*) киңәш сорау, киңәшү, киңәш итү **2.** (*обмениваться мнениями*) киңәшү, киңәшләшү, фикер алышу, уйлашу; мәслихәтләшү (*уст.*)

сове́тск‖ий, -ая, -ое совет ...ы; **~ий наро́д** совет халкы; **Сове́тская власть** Совет хакимияте

сове́тчик *м* киңәшче, киңәш бирүче, акыл бирүче; мәслихәтче, мәслихәт бирүче

сове́тчица *ж* киңәшче хатын (кыз)

совеща́ние *с* киңәшмә; **~ в верха́х** югары органнар киңәшмәсе

совеща́тельный, -ая, -ое: **~ го́лос** киңәш хокукы

совеща́ться *несов.* киңәшү, киңәшләшү; фикер алышу

сови́н‖ый, -ая, -ое ябалак ...ы; **~ое гнездо́** ябалак оясы

со́вка *ж зоол.* **1.** (*птица*) ябалак **2.** (*бабочка*) ябалакбаш, ябалакчык (*төнге күбәләк*)

совлада́ть *сов. с кем-чем, разг.* тыеп калу, җиңү, җиңеп калу, тотып калу; **~ с гне́вом** ачуны тыеп калу ♦ **~ с собо́й** үзеңне кулга алу

совладе́лец *м* милектәш, уртак биләүче

совладе́лица *ж* милектәш хатын (кыз)

совмести́мость *ж* бергә сыя (сыеша) алу, [бер-берсенә] туры (тәңгәл) килү; үзара ярашу (сыешу); **~ поня́тий** төшенчәләрнең туры килүе; **психологи́ческая ~** психологик яктан үзара сыешу ♦ **~ кро́ви** *биол.* канның туры килүе (*кан җибәргәндә*)

совмести́мый, -ая, -ое *книжн.* бергә сыя торган, бергә сыя (сыеша) алырлык, сыеша ала торган; [бер-берсенә] туры (тәңгәл) килә торган, үзара яраша торган

совмести́тель *м* [берьюлы] ике эшне башкаручы, ике урында эшләүче

совмести́тельств‖о *с* [берьюлы] ике урында (эштә) эшләү; **рабо́тать по ~у** берьюлы ике урында эшләү

совмести́тельствовать *несов.* берьюлы ике эштә (урында) эшләү

совмести́‖ть *сов.* **1.** *что* бергә (бер үк вакытта) алып бару, берләштерү, бер үк вакытта башкару (үтәү); **~ть рабо́ту с учёбой** бер үк вакытта эшләү дә уку да **2.** *в ком-чём* бер үк вакытта булу; шул ук вакытта булу; **он ~л в себе́ писа́теля и худо́жника** ул бер ук вакытта язучы да рәссам да

совмести́‖ться *сов.* **1.** (*совпасть*) [үзара] тәңгәл килү; [үзара] туры килү; **2.** [бер үк вакытта] булу, берләшү, кушылу; **в нём ~лись больши́е теорети́ческие позна́ния и практи́ческий о́пыт** аңарда бер үк вакытта зур теоретик белем дә практик тәжрибә дә бар **3.** *мат.* тәңгәл килү

совме́стно *нареч.* бергә, бергәләп, бергәләшеп, берлектә, уртак

совме́стн‖ый, -ая, -ое бергә ..., бергәләп ..., бердәм ...; бергәләшеп ..., уртак ...; берләштерелгән, берләшкән, бергә (бергәләп) үткәрелгән; **~ая рабо́та** бергә эшләү; **~ые уси́лия** уртак тырышлык; **~ое заседа́ние** берләштерелгән утырыш

совмеща́ть *несов. см.* **совмести́ть**

совмеща́ться *несов.* **1.** *см.* **совмести́ться; 2.** *страд. от* **совмеща́ть**

совмеще́ние *с см.* **совмести́ть; ~ фигу́р** фигураларның тәңгәл килүе

сово́к *м* соскы, соскыч

совокупи́ться *сов.* якынлык кылу, женси мөнәсәбәттә булу

совокупля́ться *несов.* **1.** *см.* **совокупи́ться; 2.** *страд. от* **совокупля́ть**

совоку́пност‖ь *ж* барлыгы [бергә], барысы [бергә], җыелма; **~ь при́знаков** билгеләр җыелмасы; **~ь да́нных** мәгълүматларның барлыгы бергә; **в ~и** барлыгы (барысы) бергә

совоку́пн‖ый, -ая, -ое бердәм ..., бергәләп ..., берләштерелгән; **~ые уси́лия мно́гих люде́й** күп кешеләрнең бердәм көч куюлары

совпада́ть *несов. см.* **совпа́сть**

совпа́‖сть *сов. с чем* **1.** (*произойти одновременно*) [бер үк вакытка] туры килү, бер үк вакытта булу **2.** үзара тәңгәл килү, туры (тапкыр) килү; **их мне́ния ~ли** аларның фикерләре туры килде **3.** *мат.* тәңгәл килү

соврати́тель *м книжн.* юлдан яздыручы, аздыручы, бозык (начар) юлга кертүче, бозык юлга бастыручы

соврати́тельница *ж книжн.* юлдан яздыручы хатын (кыз)

соврати́ть *сов. кого-что* юлдан яздыру, аздыру, бозык (начар) юлга кертү, бозык (начар) юлга бастыру

совра́ть *сов.* ялганлау, ялган сөйләү, алдау, алдашу

совраща́ть *несов. см.* **соврати́ть**

совраща́ться *несов.* **1.** *см.* **соврати́ться; 2.** *страд. от* **совраща́ть**

совреме́нник *м* замандаш, ... белән бер чор кешесе, бер чорда яшәгән кеше, чордаш; **~и Тука́я** Тукай[ның] замандашлары

совреме́нница *ж* замандаш хатын (кыз)

совреме́нность *ж* хәзерге заман

совреме́нн‖ый, -ая, -ое **1.** *кому-чему* (*относящийся к одному времени*) ...га замандаш..., ...га замандаш булган, ... белән бер чорда яшәгән, ...га чордаш **2.** (*относящийся к настоящему времени*) хәзерге, хәзерге заман ..., хәзерге чор ..., **в ~ых усло́виях** хәзерге шартларда; **~ая эпо́ха** хәзерге чор; **~ая тата́рская литерату́ра** хәзерге татар әдәбияты; **~ая те́хника** хәзерге заман техникасы **3.** (*на уровне своего времени*) заманча, хәзерге заман ...ы, хәзерге заман таләпләренә җавап бирә торган (туры килә торган, туры китереп эшләнгән); **~ое обору́дование** хәзерге заман җиһазлары

совсе́м *нареч.* **1.** (*совершенно*) бөтенләй; **~ но́вая вещь** өр-яңа әйбер; **я ~ забы́л** бөтенләй онытканмын **2.** *разг.* (*навсегда*) бөтенләйгә; **прие́хать ~** бөтенләйгә килү **3.** *в знач. частицы усил.* (*вовсе*) һич тә, бер дә; **~ нет** һич тә юк **4.** *с отриц.* (*не очень, не вполне*) бик үк ... түгел; бик үк ...ып җитмәү (бетермәү); **он не ~ здоро́в** ул бик үк сәламәт түгел; **я не ~ понима́ю** мин бик үк аңлап бетермим

совхо́з *м* совхоз

согбе́нный, -ая, -ое *книжн.* (*сгорбленный*) бөкрәйгән; **~ ста́рец** бөкрәйгән карт

согла́си‖е *с* **1.** (*позволение*) ризалык; күнү **2.** (*соглашение*) килешү **3.** (*единодушие*) бердәмлек, фикер бердәмлеге **4.** (*дружественные отношения*) дуслык, татулык, бердәмлек ♦ **в ~и** *с чем* ...га туры китереп, ...га ярашлы рәвештә, ... буенча, ...га таянып, ...га муафыйк; **в ~и с зако́ном** законга муафыйк

согласи́тельн‖ый, -ая, -ое *юр.* килештерү ...ы; **~ая коми́ссия** килештерү комиссиясе

согласи́ться *сов.* **1.** *на что и с неопр.* (*дать согласие*) риза булу, ризалашу, ризалык бирү (белдерү); күнү; разый булу (*уст.*) **2.** *с кем-чем и без доп.* (*выразить своё согласие*) килешү **3.** *на чём, разг.* (*договориться*) килешү, сөйләшү, сүз куешу

согла́сно **1.** *нареч. разг.* (*дружно*) дус, тату, килешеп **2.** *нареч.* (*единодушно*) бердәм рәвештә **3.** (*согласованно*) [үзара] килешеп **4.** *нареч.* (*гармонично*) аһәңле [итеп] **5.** *предлог* (*соответственно*) ... буенча, ...га муафыйк, ...га ярашлы рәвештә, ...га таянып, ...га туры китереп; ...да карарганча; **~ зако́ну** закон буенча ♦ **~ с чем-л.** *см.* **согла́сно** 5

согла́сный I, -ая, -ое *лингв.* тартык; **~ звук** тартык аваз

согла́сн‖ый II, -ая, -ое **1.** риза [булган], күнгән; разый (*уст.*); **он согла́сен на э́то** ул моңа риза **2.** *с кем-чем* килешкән, уртак фикергә килгән; **я с ва́шим мне́нием согла́сен** мин сезнең фикерегез белән килешәм **3.** гармоник; аһәңле; **~ое пе́ние** аһәңле итеп җырлау

согласо́ванн‖ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **согласова́ть; 2.** үзара килешеп (сөйләшеп) эшләнгән; **~ые де́йствия** үзара килешеп эшләнгән эшләр

согласова́ть *сов. что* **1.** (*привести в соответствие*) яраштыру; килештерү; туры китерү **2.** (*выработать единое мнение*) килешү, уртак фикергә килү, хәл итү; (*получить согласие*) ризалык алу, сөйләшү **3.** *грам.* яраштыру

согла́с‖ова́ться **1.** *сов., несов. с чем* туры килү, каршы килмәү; **э́то постановле́ние не ~у́ется с пре́жним** бу карар элеккесенә каршы килә **2.** *несов. грам.* ярашу

согласо́вывать *несов. см.* **согласова́ть**

соглаша́тель *м полит.* килешүчән, килешүче

соглаша́тельск‖ий, -ая, -ое *полит.* килешүчәнлек ...ы; **~ая поли́тика** килешүчәнлек сәясәте

соглаша́тельство *с* килешүчәнлек

соглаша́ться *несов. см.* **согласи́ться**

соглаше́ние *с* **1.** (*взаимное согласие*) үзара килешү **2.** (*договор*) килешү

соглядатай *м* шымчы

согна́ть *сов.* **1.** *кого-что* куу, куып жибәрү, куып төшерү; ~ **му́ху** чебенне куу **2.** *что* (*уничтожить*) бетерү, юкка чыгару; ~ **весну́шки** сипкелләрне бетерү **3.** *кого-что* (*в одно место*) куып китереп (*бер урынга*) җыю, туплау; (*бер урынга*) куып китерү; ~ **ста́до на опу́шку** көтүне урман авызына куып китерү ◆ ~ **вес** авырлыкны киметү (*махсус чаралар кулланып*); ~ **семь пото́в** *с кого* кара (шабыр) тиргә батыру; ~ **сон** йокысын ачу, йокысын качыру

согну́ть *сов.* **1.** *что* бөгү; ~ **подко́ву** ат дагасын бөгү; ~ **про́волоку** тимерчыбыкны бөгү; ~ **но́гу** аякны бөкләү **2.** *что* (*изготовить путем гнутья*) бөгү, бөгеп ясау **3.** *что* бөгү, ию; ~ **де́ревце** агачны бөгү **4.** *кого-что* (*сгорбить*) бөкрәйтү **5.** *перен. кого* (*покорить, сломить*) бөгү, баш идерү, буйсындыру ◆ ~**ть в бара́ний рог** бишкә бөгү, бөтереп шешәгә тыгу, ике аягын бер кунычка тыгу; ~ **в дугу́ (в три дуги́, в три пого́ибели)** 1) бишкә бөгү (*бик нык бөгү*); 2) *перен.* (*заставить покориться*) *см.* ~ **в бара́ний рог**

согну́||ться *сов.* **1.** бөгелү; **гвоздь ~лся** кадак бөгелде **2.** бөгелү, иелү; **дере́вья ~лись** агачлар иелгән **3.** (*сгорбиться*) бөкрәю **4.** *перен.* (*покориться*) бөгелү, баш ию, буйсыну ◆ ~**ться в дугу́ (в три дуги́, в три пого́ибели)** 1) бишкә бөгелү (*бик нык бөгелү*); 2) *перен. см.* **согну́ться** 4

согрева́тельный, -ая, -ое җылыта торган, җылыткыч, җылы; ~ **компре́сс** җылы компресс

согрева́ть *несов. см.* **согре́ть**

согрева́ться *несов.* **1.** *см.* **согре́ться; 2.** *страд. от* **согрева́ть**

согре́ть *сов. кого-что* **1.** җылыту; ~ **во́ду** су җылыту **2.** *перен.* (*утешить*) күнелен күтәрү (табу), юату

согре́||ться *сов.* җылыну; **пе́чка ~лась** мич җылынды; ~**ться ча́ем** чәй эчеп җылыну

согреши́ть *сов.* гөнаһ кылу (эшләү), языклы булу

со́да *ж* сода

соде́йстви||е *с* ярдәм, булышлык; **при ~и** ярдәме белән

содействовать *сов., несов. кому-чему* ярдәм итү (күрсәтү), булышу, булышлык итү (күрсәтү)

содержа́ни||е *с* **1.** *см.* **содержа́ть; беспри́вязное ~е скота́** терлекне бәйләмичә асрау (тоту) **2.** (*оглавление*) эчтәлек **3.** (*тема*) эчтәлек **4.** күләм, микъдар; **определи́ть ~е са́хара в свёкле** чәгендердәге шикәрнең микъдарын билгеләү **5.** хезмәт хакы; **получи́ть ме́сячное ~е** айлык хезмәт хакын алу ◆ **жить (быть) на ~и** *у кого, уст.* *берәүдә* тәрбияленеп тору; *берәүнең* тәрбиясендә булу; **челове́к с бога́тым вну́тренним ~ем** рухи яктан бай кеше

содержа́нка *ж уст.* сәяркә

содержа́тель *м уст.* тотучы, хуҗа; ~ **рестора́на** ресторан тотучы

содержа́тельный, -ая, -ое эчтәлекле, бай эчтәлекле; ~ **докла́д** бай эчтәлекле доклад

содержа́ть *несов.* **1.** *кого-что* асрау, тәрбияләү, карау; тоту; ~ **роди́телей** ата-ананы тәрбияләү (карау); ~ **семью́** семья асрау **2.** *кого-что* тоту, асрау; ~ **скот в сара́е** терлекне сарайда асрау; ~ **в чистоте́** чиста тоту; ~ **под аре́стом** ябып тоту **3.** *что* ...да булу; **о́вощи соде́ржат мно́го витами́нов** яшелчәләрдә витаминнар күп [була]; **кни́га соде́ржит в себе́ мно́го интере́сного** китапта бик күп кызыклы мәгълүматлар бар; **э́то лека́рство соде́ржит мышья́к** бу даруда мышьяк бар

содержа́ться *несов.* **1.** тотылу; асралу; ~ **под аре́стом** ябып тотылу; **кро́лики соде́ржатся в кле́тках** куяннар читлектә асралалар; ~ **в чистоте́** чиста тотылу **2.** булу; **в кни́ге соде́ржатся ну́жные све́дения** катапта кирәкле мәгълүматлар бар

содержи́мое *с* эчендәге (эченә салынган) нәрсә; эчендәгесе, эче

со́дов||ый, -ая, -ое **1.** сода ...ы; ~**ый раство́р** сода эремәсе **2.** *в знач. сущ.* ~**ая** *ж* содалы су

содокла́д *м* өстәмә доклад

содокла́дчик *м* өстәмә доклад ясаучы

содо́м *м разг.* ыгы-зыгы, гауга, шау-шу, тавыш; **подня́ть ~** гауга чыгару

содра́ть *сов. что* **1.** (*кору*) каезлау, [кайрысын] каезлап алу, [курыс] төшерү, [кабыгын] сую, суеп алу; (*шкуру*) тунау, тунап алу, сую **2.** *разг.* (*поцарапать кожу*) тиресен суйдыру, кырдыру, тырнату **3.** *разг.* (*сорвать, снять*) тартып алу **4.** *перен. прост.* каеру, тунау, сую (*кыйбат алу, кыйммәт бәягә сату, ришвәт алу h.б.ш.*); ~ **втри́дорога** бик кыйбатка сату ◆ ~ **шку́ру** *прост.* тиресен тунау, талау

содра́ться *сов. разг.* (*о коже, кожуре*) суелу, тырналу; сыдырылу

содрога́||ться *несов.* калтырау, калтырану, дерелдәү, тетрәү; селкенү; ~**ться всем те́лом** бөтен тәне калтырау; **земля́ ~ется** җир тетри

содрогну́ться *сов. однокр.* **1.** калтырап кую (китү), калтыранып кую (китү); дерт итеп кую (китү), дерелдәп кую (китү); селкенеп кую **2.** *перен.* тетрәү, тетрәп киту; ~ **от у́жаса** куркудан тетрәү

содру́жество *с* **1.** [үзара] дуслык, бердәмлек; ~ **на́ций** милләтләр дуслыгы; **твóрческое ~** иҗади дуслык **2.** (*общество, объединение*) берләшмә; җәмгыять; **литерату́рное ~** әдәби берләшмә

со́ев||ый, -ая, -ое **1.** соя ...ы; ~**ые бобы́** соя борчагы **2.** соялы; ~**ые конфе́ты** соялы конфетлар

соедине́ние *с* **1.** *см.* **соедини́ть, соедини́ться; 2.** (*место*) ялганма, тоташма, тоташтырма, тоташтырылган җир (урын) **3.** *воен.* берләшмә; **та́нковое ~** танклар берләшмәсе **4.** *хим.* кушылма

соедини́тельн||ый, -ая, -ое: ~**ая ткань** *биол.* тоташтыргыч тукыма; ~**ые сою́зы** *грам.* тезүче теркәгечләр

соедини́ть *сов.* **1.** *кого-что* тоташтыру, тоташтырып кую; ялгау, ялгап кую; ~ **провода́** тимерчыбыкларны ялгап кую **2.** *что* (*установить связь, сообщение*) тоташтыру **3.** *что* кушу, бергә кушу; ~ **кра́ски** буяуларны кушу **4.** *кого-что* берләштерү, бергә кушу; ~ **два отря́да** ике отрядны бергә кушу **5.** *что хим.* кушу

соедини́||ться *сов.* **1.** тоташу, ялгану; **провода́ ~лись** тимерчыбыклар тоташты **2.** сөйләшү; ~**ться по телефо́ну** телефон аша (аркылы) сөйләшү **3.** берләшү, кушылу; **в ней ~лись краса́ и тала́нт** аңарда гүзәллек белән талант берләшкән **4.** *хим.* кушылу

соединя́ть *несов. см.* **соедини́ть**

соединя́ться *несов.* **1.** *см.* **соедини́ться; 2.** *страд. от* **соединя́ть**

сожале́ни||е *с* үкенеч; үкенү; кызгану [хисе]; **вызыва́ть ~е** эч (йөрәк) әрнетү; үкендерү ◆ **к [вели́кому, глубо́кому, кра́йнему] ~ю** кызганычка каршы, [бик зур] үкенечкә каршы

сожале́ть *несов. о ком-чём* үкенү; кызгану

сожже́ние *с см.* **сжечь I**

сожи́тель *м* **1.** (*по комнате*) бергә торучы, бер бүлмәдә торучы **2.** *разг.* (*любовник*) сәяркә; никахсыз ир

сожи́тельница *ж* **1.** *см.* **сожи́тель** 1; **2.** *разг.* (*любовница*) сәяркә; никахсыз хатын

сожи́тельство *с* **1.** (*совместная жизнь*) бергә тору, бер бүлмәдә тору **2.** (*внебрачная связь*) язылышмыйча яшәү (тору); никахсыз яшәү (тору)

сожи́тельствовать *несов.* **1.** (*жить совместно*) бергә тору, бер бүлмәдә тору **2.** *разг.* (*состоять во внебрачной связи*) язылышмыйча яшәү (тору); никахсыз яшәү (тору)

созва́ниваться *несов. см.* **созвони́ться**

созва́ть *сов. кого-что* чакыру, жыю; ~ **друзе́й** дусларны чакыру; ~ **съезд** съезд чакыру; ~ **совеща́ние** киңәшмә жыю

созве́здие *с астр.* йолдызлык; ~ **Близнецо́в** Игезәкләр йолдызлыгы; ~ **Большо́й Медве́дицы** Олы Җидегән йолдыз; ~ **Ма́лой Медве́дицы** Кече Җидегән йолдыз

созвони́ться *сов. разг.* телефоннан (телефон аша) сөйләшү, телефоннан (телефон аша) сөйләшеп килешү

созву́чие *с* **1.** *муз.* аһәң, аһәңдәшлек **2.** (*сходное звучание*) охшаш яңгыраш, охшаш аваз

созву́чн||ый, -ая, -ое **1.** *муз.* аһәңле, аһәңдәш **2.** ярашлы, аһәңле, аһәңдәш; аваздаш, муафыйк, туры килә торган; **произведе́ние, ~ое эпо́хе** заманга муафыйк әсәр

создава́ть *несов. см.* **созда́ть**

создава́ться *несов.* **1.** *см.* **созда́ться; 2.** *страд. от* **создава́ть**

созда́ние *с* **1.** *см.* **созда́ть, созда́ться; 2.** (*произведение, творение*) әсәр **3.** (*о человеке*) зат, адәм, кеше; (*о животном*) жан иясе

созда́тель *м* **1.** (*творец*) булдыручы, тудыручы, иҗат итүче, барлыкка китерүче; төзүче, оештыручы **2.** *рел.* (*бог*) яратучы, алла

созда́ть *сов. что* **1.** булдыру, барлыкка китерү, тудыру, иҗат итү; **труд со́здал челове́ка** кешене хезмәт кеше иткән; **~ поэ́му** поэма иҗат итү **2.** (*организовать*) төзү, оештыру; **~ колхо́з** колхоз төзү

созда́ться *сов.* туу, барлыкка килү

созерца́тель *м книжн.* (*пассивный наблюдатель*) пассив күзәтүче, читтән торып күзәтүче, карап торучы

созерца́тельн||ый, -ая, -ое *книжн.* **1.** читтән торып күзәтү ...ы, читтән карап тору ...ы; читтән торып күзәткән; **~ое настрое́ние** читтән торып күзәтү теләге **2.** хыялга бирелеп ..., хыялга чумып ...; **~ая жизнь** хыялга бирелеп яшәү

созерца́ть *несов. кого-что, книжн.* күзәтү, читтән торып күзәтү, тамаша кылу, тамаша итү

созида́тельный, -ая, -ое *высок.* иҗади, иҗат итү ...ы, барлыкка китерү ...ы, тудыру ...ы; **~ труд** иҗади хезмәт

созида́ть *несов. кого-что, высок.* тудыру, барлыкка китерү, булдыру; төзү

созида́ться *несов. книжн.* **1.** туу, барлыкка килү; төзелү **2.** *страд. от* **созида́ть**

созна||ва́ть *несов. что* аңлау, тану; **~ва́ть опа́сность** куркыныч барлыкны аңлау; **~ва́ть свою́ вину́** үз гаебеңне тану; **больно́й ничего́ не ~ёт** авыру бернәрсә дә аңламый

сознава́ться *несов.* **1.** *см.* **созна́ться; 2.** *страд. от* **сознава́ть**

созна́ни||е *с* **1.** аң, һуш; зиһен; **затемне́ние ~я** зиһен чуалу; **быть без ~я** аңсыз хәлдә булу; **потеря́ть ~е** аңын югалту, һуштан язу **2.** аң; **кла́ссовое ~е** сыйнфый аң; **бытие́ определя́ет ~е** *филос.* аң яшәеш белән билгеләнә **3.** аңлау, тану, икърар итү; **~е своего́ до́лга** үз бурычыңны тану; **~е сво́ей правоты́** үзеңнең хаклылыгыңны аңлау **4.** уй, фикер; **его́ му́чило ~е, что он оши́бся** хата ясадым дигән уй аны борчый иде

созна́тельно *нареч.* аңлы рәвештә, белә торып, аңлап,аңлаган хәлдә

созна́тельность *ж* **1.** аңлы рәвештә эшләнгәнлек, белә торып эшләнгәнлек, белеп эшләнгәнлек; **~ де́йствий** эш-хәрәкәтнең аңлы рәвештә эшләнгәнлеге **2.** аңлылык, аң, аңлы булу; **полити́ческая ~ масс** массаларның сәяси аңлылыгы

созна́тельн||ый, -ая, -ое **1.** (*обладающий сознанием*) аңлы, аңы булган, зиһенле, зиһене булган **2.** (*обладающий сознательностью*) аңлы; **на́до быть ~ым** аңлы булырга кирәк; **~ое отноше́ние** аңлы мөнәсәбәт **3.** аңлы, аңлы рәвештә ..., акыл белән ..., уйлап ..., белә торып ...; **~ый обма́н** белә торып алдау, күрәләтә алдау

созна́ться *сов.* тану, икърар итү, ачыктан-ачык әйтеп (сөйләп) бирү; **~ в свое́й вине́** үз гаебеңне тану

созрева́||ть *несов.* **1.** пешү, өлгерү, җитешү, җитү, пешеп (өлгереп, җитешеп, җитеп) килү; **фру́кты ~ют** җимешләр пешеп килә **2.** (*о человеке*) буйга җитү, буйга җитеп килү, җитлегү, җитлегеп килү **3.** *перен.* (*о плане, решении и т.п.*) туу, туып килү, барлыкка килү; (*о таланте*) үсү, үсеп килү, җитлегү, җитлегеп килү **4.** *спец.* өлгерү, өлгереп килү

созре́||ть *сов.* **1.** пешү, өлгерү, пешеп (өлгереп) җитү; җитешү, җиту; **помидо́ры ~ли** помидорлар өлгергән **2.** (*о человеке*) буйга җитү, җитлегү **3.** *перен.* (*о плане, решении и т.п.*) өлгерү, туу, барлыкка килү; (*о таланте*) үсеп җитү, җитлегү; **~л но́вый план** яңа план туды **4.** *спец.* өлгерү; **вино́ ~ло** кызыл аракы өлгергән; **сыр ~л** сыр өлгергән

созы́в *м* **1.** *см.* **созва́ть; ~ съе́зда** съезд чакыру **2.** чакырылыш; **се́ссия деся́того ~а** унынчы чакырылышның сессиясе

созыва́ть *несов. см.* **созва́ть**

соизволе́ни||е *с ирон.* рөхсәт, ризалык; разыйлык (*уст.*); **с ва́шего ~я** сезнең рөхсәтегез белән

соизво́ли||ть *сов. с неопр., ирон.* (*захотеть*) теләү; риза булу; разый булу (*уст.*); (*соблаговолить*) рәхим итү; **он ~л прийти́** ул рәхим итеп килде

соизволя́ть *несов. см.* **соизво́лить**

соизмери́м||ый, -ая, -ое **1.** *мат.* үлчәүдәш, үзара үлчәнешле; **~ые величи́ны** үзара үлчәнешле зурлыклар **2.** *перен.* үзара чагыштырылык; **~ые поня́тия** үзара чагыштырылык төшенчәләр

соиска́ние *с*: **на ~** алу өчен; **диссерта́ция на ~ учёной сте́пени** гыйльми дәрәҗә алу өчен [язылган] диссертация

соиска́тель *м* (*ученой степени*) [дәрәҗә] алырга теләүче; **~ до́кторской сте́пени** докторлык дәрәҗәсен алырга теләүче

со́йка *ж зоол.* күкшә (*кош*)

сойти́ *сов.* **1.** төшү; **~ с ле́стницы** баскычтан төшү; **~ с ло́шади** аттан төшү; **~ с по́езда** поезддан төшү **2.** [читкә] китү, [читкә] чыгу; **~ с тропи́нки** сукмактан читкә чыгу **3.** (*исчезнуть*) бетү; кайту, китү; (*отпасть*) [кубып] төшү; (*об улыбке, румянце и т.п.*) юкка чыгу; бетү; **вода́ сошла́** су кайткан; **снег сошёл** кар беткән; **кра́ска сошла́** буявы беткән (киткән); **но́готь сошёл** тырнагы төшкән; **~ на нет** *прям., перен.* юкка чыгу **4.** *за кого-что* ... урынына ярау; ... урынына яраклык булу, булып күренү; **~ за молодо́го** яшь кеше булып күренү **◆ сойдёт [и та́к]** [болай да] ярар; **~ в моги́лу** кабергә (түргә) керү; **~ с не́ба на зе́млю** күктән җиргә төшү; **~ со сце́ны** читләшү (*берәр эштән*); **~ с [своего́] пути́** максатыннан баш тарту; **~ с рук** җәзасыз үтү (*берәр ярамаган эш турында*); **~ с ума́** акылдан язу (шашу, сабу)

сойти́сь *сов.* **1.** очрашу; **~ на доро́ге** юлда очрашу **2.** җыелу; **гостей сошло́сь мно́го** бик күп кунак җыелды **3.** *перен.* (*сдружиться*) дуслашу, дуслашып китү, якынлашу **4.** (*вступить в сожительство*) кушылу, язылышмыйча тора башлау; никахсыз тора башлау **5.** *в чём, чем* туры килү; **не ~ хара́ктерами** характерлары туры килмәү **6.** килешү; **~ в цене́** бәясендә килешү **7.** җиту; **реме́нь не сошёлся** каеш җитмәде

сок *м* су, сок; сүл, сыекча; **берёзовый ~** каен суы; **желу́дочный ~** ашказаны сыекчасы **◆ в [са́мом, по́лном] ~у́** яшьнәгән чагы, янып торган чагы, ин таза вакыты

соковáрка *ж* сок кайнаткыч

соковыжима́лка *ж* сок чыгаргыч

со́кол *м* лачын; **ло́вчий ~** ау лачыны; **благоро́дный ~** шоңкар **◆ гол как сокóл** шыр ялангач; үзе дә күзе генә

соколи́н||ый, -ая, -ое **1.** лачын белән ...; **~ая охо́та** лачын белән аучылык итү **2.** *перен.* лачын кебек, лачындай, лачын ...ы; **~ый взгляд** лачын кебек карау

соко́льник *м* лачынчы (*борынгы Русьта*)

соко́льничий *м* сокольничий, лачынчылар башлыгы (*борынгы Русьта*)

сократи́м||ый, -ая, -ое *мат.* кыскартылмалы, кыскартмалы; **~ая дробь** кыскартмалы вакланма

сократи́ть *сов.* **1.** *в разг. знач. кого-что* кыскарту; **~ путь** юлны кыскарту; **~ рабо́чий день** эш көнен кыскарту; **~ шта́ты** штатларны кыскарту; **~ статью́** мәкаләне кыскарту; **~ дробь** вакланманы кыскарту **2.** *что* кыскарту, кимету; **~ расхо́ды** чыгымнарны кимету

сократи́||ться *сов.* **1.** кыскару; **дни ~лись** көннәр кыскарды **2.** кыскару, киму; **расхо́ды ~лись** чыгымнар кимеде **3.** *физиол.* кысылу; **зрачо́к ~лся** күз бәбәге кысылды

сокраща́ть *несов. см.* **сократи́ть**

сокраща́ться *несов.* **1.** *см.* **сократи́ться; 2.** *страд. от* **сокраща́ть**

сокраще́ни||е *с* **1.** *см.* **сократи́ть, сократи́ться; ~е мышц** мускуллар кыскару; **~е шта́тов** штатлар кыскартылу **2.** кыскартма; **спи́сок ~й** кыскартмалар исемлеге

сокращённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **сократи́ть; 2.** кыскартылган, кыска; **~ый рабо́чий день** кыскартылган эш көне; **~ый вариа́нт по́вести** повестьнең кыскартылган варианты; **~ое сло́во** кыскартылган сүз, кыскартма

сокрове́нн||ый, -ая, -ое яшерен, сер итеп саклана торган (сакланган); күңел түрендәге, күңелдәге; **~ая та́йна** яшерен сер, йөрәк (күңел) сере; **~ые мечты́** яшерен хыяллар; **~ый разгово́р** яшерен сөйләшү

сокро́вища *мн.* хәзинә; мал, байлык; **~ культу́ры** мәдәният байлыклары; **◆ ни за каки́е ~** һичбер вакытта, үзе кадәр алтын бирсә[ләр] дә

сокро́вищница *ж* **1.** *уст.* казна **2.** *перен.* хәзинә, байлык; **~ иску́сства** сәнгать әсәрләре хәзинәсе; **~ зна́ний** белем хәзинәсе

сокруша́ть *несов. кого-что* **1.** (*разбивать, разрушать*) җимерү, ватү, тармар итү, юк итү **2.** (*повергать в печаль*) бик зур кайгыга (хәсрәткә) төшерү,

кайгыга (хәсрәткә) салу, ачындыру, көендерү

сокруша́ться *несов.* **1.** бик нык ачыну, көенү, көяләнү, бик нык кайгыру, хәсрәтләнү **2.** *страд. от* **сокруша́ть**

сокруше́ние *с* (*печаль*) бик зур кайгы, каты хәсрәт, көенеч

сокруши́тельный, -ая, -ое җимергеч, җимерә торган, тар-мар итә торган, юк итә торган, кырып бетерә торган; **нанести́ ~ уда́р** тар-мар итү

сокруши́ть *сов. см.* **сокруша́ть**

сокры́тие *с книжн.* яшерү, яшереп калу; **~ преступле́ния** җинаятьне яшерү

солга́ть *сов.* ялганлау, ялган сөйләү; алдау, алдашу

солда́т *м* солдат

солда́тка *ж* солдат хатыны

солда́тск||ий, -ая, -ое солдат ...ы; **~ая слу́жба** солдат хезмәте, солдатта хезмәт итү; **~ий хлеб** *уст.* солдат икмәге

солда́тчина *ж уст.* солдат хезмәте, солдатта хезмәт итү, солдатлык

солдафо́н *м разг. пренебр.* солдафон (*тупас, культурасыз гаскәриләр турында*)

солевaréние *с* тоз кайнату (*диңгез яки тозлы күл суын кайнатып тоз табу*)

солева́ренный, -ая, -ое, **солева́рный**, -ая, -ое тоз кайнату ...ы; **~ заво́д** тоз кайнату заводы

солева́рня *ж* тоз кайнату предприятиесе, тоз табу (чыгару) урыны

соледобыва́ющ||ий, -ая, -ое тоз чыгару ...ы; **~ая промы́шленность** тоз чыгару промышленносте

соле́ние *с* **1.** *см.* **соли́ть; 2.** *разг.* (*продукт*) тозлаган яшелчәләр, тозлы яшелчәләр (*кыяр, кәбестә һ.б.ш.*)

солён||ый, -ая, -ое **1.** тозлы; **~ая вода́** тозлы су; **~ое о́зеро** тозлы күл **2.** тозлы, тозы салынган; **~ый суп** тозы салынган аш **3.** тозлы, тозлаган; **~ая ры́ба** тозлаган балык; **~ые огурцы́** тозлы кыяр **4.** *перен. разг.* тозлы-борычлы, суганлы-борычлы, оятсыз; **~ое словцо́** оятсыз сүз

солидариза́ция *ж см.* **солидариза́ровать, солидаризова́ться**

солидариза́ровать, солидаризова́ться *сов., несов. книжн.* солидарлашу, теләктәшлек белдерү (күрсәтү), фикергә кушылу

солида́рность *ж* **1.** бердәмлек, солидарлык, теләктәшлек, фикердәшлек; **интернациона́льная ~** интернациональ солидарлык **2.** *юр.* уртак җаваплылык

солида́рн||ый, -ая, -ое **1.** теләктәш, теләктәшлек белдерүче (күрсәтүче), фикергә кушылучы; **я солида́рен с докла́дчиком** докладчының фикеренә кушылам **2.** *юр.* уртак; **~ая ответственность** уртак җаваплылык

соли́дность *ж* **1.** төплелек, нигезлелек, җитдилек; төпле (нигезле, җитди) булу; **~ зна́ний** белемнәрнең төплелеге **2.** (*человека*) җитдилек, төплелек, күренеклелек, җитди (төпле, куренекле) булу **3.** (*представительность*) мәһабәтлек, олысымаклык, мәһабәт (олысымак) булу; (*степенность*) җитдилек, сабыр табигатьлелек, салмаклык, җитди (сабыр табигатьле, салмак) булу

соли́дн||ый, -ая, -ое **1.** (*прочный*) нык, нык эшләнгән, шәп итеп эшләнгән; **~ый дом** нык эшләнгән өй **2.** (*глубокий, серьёзный*) төпле, нигезле, җитди; **~ые зна́ния** төпле белемнәр **3.** җитди, төпле; күренекле; **~ый учёный** күренекле галим; **~ый челове́к** төпле кеше; **~ое учрежде́ние** җитди учреждение **4.** (*представительный*) мәһабәт, олысымак; **~ый вид** мәһабәт кыяфәт; (*степенный*) җитди, сабыр табигатьле, салмак **5.** (*крупный, полный*) зур һәм тулы гәүдәле, олы гәүдәле; (*о росте*) озын **6.** (*пожилой — о возрасте*) шактый олы **7.** *разг.* (*значительный по величине*) шактый югары (зур); **~ая су́мма** шактый зур сумма

соли́льный, -ая, -ое тозлый торган, тозлау ...ы; **~ цех** тозлау цехы

соли́ст *м* солист

соли́стка *ж* солистка

солите́р *м* солитер (*эре брильянт*)

солитёр *м зоол.* солитёр (*тасма суалчан*)

соли́ть *несов. что* **1.** тоз салу; **~ суп** шулпага тоз салу **2.** тозлау; **~ огурцы́** кыяр тозлау

соли́ться *несов.* **1.** (*заготавливаться впрок*) тозлану **2.** *страд. от* **соли́ть**

со́лка *ж см.* **соли́ть** 2; **~ огурцо́в** кыяр тозлау

со́лнечно *нареч. в знач. сказ. безл.* кояшлы; **сего́дня ~** буген көн кояшлы

со́лнечн||ый, -ая, -ое **1.** кояш ..., кояш ...ы; **~ое затме́ние** кояш тотылу; **~ая эне́ргия** кояш энергиясе; **~ый луч** кояш нуры **2.** кояшлы, кояш төшә торган; **~ый день** кояшлы көн; **~ая ко́мната** кояшлы бүлмә **3.** *перен.* якты, шатлыклы, шат, күтәренке; **~ое настрое́ние** шат күңел ♦ **Со́лнечная систе́ма** *астр.* Кояш системасы; **~ое сплете́ние** *анат.* кояш үрелмәсе (*корсак куышлыгындагы нервлар үрелмәсе*); **~ые часы́** кояш сәгате; **~ый уда́р** кояш сугу

со́лнц||е *с* кояш; көн (*уст.*); **~е печёт** көн кыздыра; **до ~а** кояш чыкканчы; **по ~у** (*напр. идти, определять время*) кояшка карап; **восхо́д ~а** кояш чыгу; **сиде́ть на ~е** кояшта утыру

солнцепёк *м* кояш кызуы (кыздыруы); кояш кыздыра торган җир (урын); көн бите

солнцестоя́ние *с астр.* кояш торгынлыгы (*җәйгесе 21-22 июньдә, кышкысы 21-22 декабрьда була*)

со́ло *с нескл.* **1.** соло (*бер тавыш яисә бер музыка инструменты өчен язылган музыкаль әсәр яки аның өлеше*) **2.** соло (*бер кеше тарафыннан башкарыла торган бию*) **3.** *в знач. нареч.* ялгыз; **петь ~** ялгыз җырлау; **танцева́ть ~** ялгыз бию

солове́й *м* сандугач, былбыл

солове́ть *несов.* **1.** (*становиться мутным, невыразительным — о глазах*) тону, томанлану **2.** (*становиться сонным — о человеке*) мәлҗерәү, изрәү, йокымсырау

соло́вый, -ая, -ое (*о масти лошади*) кола

соловьи́н||ый, -ая, -ое сандугач ...ы, былбыл ...ы; **~ые тре́ли** сандугач сайравы

со́лод *м* салат (*шыттырып киптерелгән арыш яки арпа оны; сыра кайнатуда кулланыла*)

соло́дка *ж бот.* татлы тамыр, төче тамыр

солодко́вый, -ая, -ое: **~ ко́рень** *см.* **соло́дка**

соло́ма *ж* салам

соло́менн||ый, -ая, -ое **1.** салам ...; **~ая кры́ша** салам түбә **2.** (*о цвете*) салам ...ы; ачык сары ♦ **~ая вдова́** *шутл.* вакытлыча иреннән аерым торучы хатын кеше; **~ый вдове́ц** *шутл.* вакытлыча хатынныннан аерым торучы ир кеше

соло́мина, соло́минка *ж* салам бөртеге, бер бөртек салам

соло́мка *ж* **1.** *ласк. от* **соло́ма**; **2.** соломка (*конфет, печенье, макарон һ.б.ш.*)

соломоре́зка *ж* салам турагыч, салам турау машинасы

солоне́ц *м* катыр, катыр туфрак

солони́на *ж* тозлы ит, тозлаган (тозланган) ит (*гадәттә сыер ите*)

соло́нка *ж* тоз савыты

со́лоно: во рту́ ~ авызымда тоз тәме бар; **не ~ хлеба́вши** коры кул белән, буш кул белән, коры; **~ пришло́сь** *кому-л.* дөньяның ачысын-төчесен татырга туры килде, бик күп кыенлыклар күрергә туры килде, авырга туры килде

солончак *м* тозлак, тозлы туфрак

солончако́в||ый, -ая, -ое тозлы; тозлак...ы; тозлы туфрак ...ы; **~ые по́чвы** тозлы туфраклар, тозлаклар; **~ые зе́мли** тозлы туфраклы җирләр; **~ые расте́ния** тозлы туфракта үсә торган үсемлекләр

соль I *ж* **1.** тоз; **столо́вая (пова́ренная) ~** аш тозы **2.** *перен.* тәм, тоз, асыл, төп, мәгънә, кызык; **~ вопро́са** мәсьәләнең төп мәгънәсе ♦ **~ зе́мли** дөнья тоткасы, дөнья терәге

соль II *с нескл.* соль (*музыка гаммасында бишенче нота*)

соля́нка I *ж* солянка (*ашамлык*)

соля́нка II *ж бот.* тозлак үләне

солян||о́й, -а́я, -о́е **1.** тоз ...ы; **~ые пласты́** тоз катламнары **2.** тозлы, тоз ...ы; **~о́й раство́р** тоз эремәсе; **~о́е о́зеро** тозлы күл **3.** тоз чыгару ...ы; тоз чыгарыла торган; **~ые разрабо́тки** тоз чыгару урыны

соля́н||ый, -ая, -ое: **~ая кислота́** *хим.* тоз кислотасы, хлорид кислотасы

соля́рий *м* солярий (*кояшта кызыну өчен җайлаштырылган мәйданчык*)

сом *ж* җәен, җәен балыгы

сомати́ческ||ий, -ая, -ое *биол., мед.* тән ...ы; **~ие боле́зни** тән авырулары (*психик авырулар түгел*)

сомкну́ть *сов. что* **1.** (*свести вплотную*) янәшә китерү, кысу, тыгызландыру; (*соединить*) тоташтыру; кушу; берләштерү **2.** (*закрыть глаза, рот*) йому; (*створки и т.п.*) ябу ♦ **не ~ глаз** күз дә йоммау, керфек тә какмау (*йоклый алмау*)

сомкну́||ться *сов.* 1. (*сойтись вплотную*) кысылу, тыгызлану; (*соединиться*) тоташу; кушылу; **канáл ~лся с рекóй** канал елга белән тоташты 2. (*закрыться — о глазах и т.п.*) йомылу; (*о створках*) ябылу

сомнáмбула *м, ж* лунатик, лунатизм булән авыручы

сомнамбули́зм *м* лунатиклык

сомнева́||ться *несов.* 1. шикләнү, шикләнеп карау, шик тоту, шөбһәләнү, ышанып җитмәү; **~ться** *в чьих-л.* **слова́х** *берәүнең* сүзләренә шикләнеп карау; **неуже́ли ты ~ешься во мне́?** әллә миңа ышанып җитмисеңме? 2. (*испытывать колебания*) икеләнү

сомне́ни||е *с* шик, шөбһә; шикләнү, шөбһәләнү; **в се́рдце закра́лось ~е** күңелгә шик төште; **вызыва́ть ~е** шик тудыру; **не оставля́ть ~й** һичбер нинди шик калдырмау; **нет ~я, что ...** шик, юк, һичшиксез; **подверга́ть ~ю** *что-л.* шик астына алу, шөбһәләнү ♦ **без (вне) [вся́кого] ~я** һичшиксез

сомни́тельн||ый, -ая, -ое 1. шикле, шөбһәле; **~ое де́ло** шикле эш; **~ые лю́ди** шикле кешеләр 2. шикле, ике төрле анлашыла торган; **~ый компли́мент** шикле комплимент

сомно́житель *м мат.* тапкырлашучы

сон *м* 1. йокы; **глубо́кий ~** тирән йокы; **сквозь ~** йокы аралаш, йокы арасында; **сна ни в одно́м глазу́ [нет]** күземдә йокы әсәре юк, һич тә (бер дә) йоклыйсым килми; **со сна** йокыдан уяну белән, йокыдан уянып-уянмас; **клони́ть ко сну** йокы басу, йокы килү, йоклыйсы килү; **потеря́ть ~** йокы алмау, йокы качу, йоклый алмау; **~ бежи́т** [күзләрдән] йокы кача; **чу́ткий ~** сак йокы 2. (*сновидение*) төш; **ви́деть ~** төш күрү; **ве́рить в сны** төшкә ышану; **~ в ру́ку** *шутл.* төшем дөрескә чыкты (рас килде) ♦ **и во сне не сни́лось** төшендә дә күрмәгән, төшенә дә кермәгән; **как (то́чно, бу́дто) сквозь ~** (*помнить, представлять и т.п.*) төштә күргәндәй; **на ~ грядущий** йокы алдыннан; **ни сном ни ду́хом не виновáт** *в чём* һич тә, һичбер гаебе юк; **ни сном ни ду́хом не знать (не ве́дать)** *чего* һичбер нәрсә белмәү; **~ наяву́** төш кебек (*гаҗәттән тыш нәрсә турында*); **спать (засну́ть, усну́ть) ве́чным (после́дним) сном** мәңгелек йокыга талу

сона́та *ж муз.* соната

соне́т *м лит.* сонет

сонли́вость *ж* йокычанлык; йоклыйсы килеп тору, йокы басып тору

сонли́вый, -ая, -ое 1. (*любящий спать*) йокычан, йокларга яратучан, йокыдан баш күтәрмәүчән 2. йокымсыраган; **~ вид** йокымсыраган кыяфәт

сонм *м уст.* чиктән тыш күп, хисапсыз күп, бихисап, бер көтү ♦ **причи́слить к ~у** *кого* ... рәтенә кертү

со́нник *м уст.* төшлек, төш тәгъбире, тәгъбирнамә, төш юрау китабы

со́нн||ый, -ая, -ое 1. йоклаган, йокыдагы; **в ~ом состоя́нии** йоклаган хәлдә 2. йоклаганда ..., йокы арасында ..., йокы аралаш ...; **~ый бред** йокы аралаш саташу 3. *перен.* йокыга талган (чумган); **~ый ум** йокыга талган акыл 4. йокылы, йокы баскан, йокымсыраган; **~ые глаза́** йокылы күзләр; **~ый вид** йокымсыраган кыяфәт ♦ **~ая арте́рия** *анат.* йокы артериясе

со́ня 1. *м, ж разг.* йокы капчыгы, йокы чүлмәге, йокычан 2. *ж зоол.* йоклач

сообража́ть *несов.* 1. *что* (*понимать*) аңлау, төшенү; башы эшләү, фикер йөртә алу 2. *разг.* (*быть сообразительным*) башлы (зирәк, аңлы) булу, тиз аңлап (төшенеп) алу, фикер йөртә белү 3. *в чём и без доп., разг.* (*быть сведущим*) белү, мәгълүматы булу, аңлау

соображе́ни||е *с* 1. (*способность соображать*) уйлау, аңлау, төшенү, фикер йөртә белү; уйлау сәләте, уйлый белү, уйлый алу 2. (*мысль, мнение*) уй, фикер; **по его́ ~ю** аның фикеренчә; **вы́сказать свои́ ~я** үз фикеренне әйтеп бирү 3. *обычно мн.* **~я** (*расчёты*) исәп, ният, уй

сообрази́тельный, -ая, -ое зирәк, үткен, тапкыр, зиһенле, тиз аңлаучан (төшенүчән)

сообрази́ть *сов. что* (*понять, догадаться*) аңлау, төшенү, анлап (төшенеп) алу; **стара́ться ~** аңларга тырышу

сообра́зно *предлог с дат.п.* күрә, ...га карап, ...да каралганча, ...га муафыйк, ...га туры китереп; **поступа́ть ~ обстоя́тельствам** вакыйгаларның торышына карап эш итү

сообра́зность *ж* максатка туры килү[чәнлек], максатка ярашлылык (муафыйклык), максатка муафыйк булу

сообра́зный, -ая, -ое *с чем* ...га туры килә торган, ярашлы, муафыйк; максатка туры килә торган, максатка ярашлы (муафыйк); акылга сыешлы, акыллы

сообразова́ть *сов., несов. что с чем, книжн.* килештерү, туры китерү; яраштыру, муафыйклаштыру

сообраз||ова́ться *сов., несов. с чем* ...ны истә тотып эш итү, ...дан чыгып эш итү, исәпләшү, санашу; **де́йствовать, ~у́ясь с обстано́вкой** хәлләрнең торышыннан чыгып эш итү

сообразо́вывать *несов. см.* **сообразова́ть**

сообразо́вываться *несов.* 1. *см.* **сообразова́ться**; 2. *страд. от* **сообразо́вывать**

сообща́ *нареч.* бергә, бергәләп, бергәләшеп, берләшеп; **рабо́тать ~** бергә эшләү

сообща́ть *несов. см.* **сообщи́ть**

стекля́нн||ый, -ая, -ое **1.** пыяла ..., пыяладан ясалган; **~ый графи́н** пыяла графин **2.** (*застеклённый*) пыяла ..., пыялалы; **~ая дверь** пыялалы ишек **3.** *перен.* (*неподвижный*) туң; (*безжизненный*) пыяла [кебек], жансыз; **~ый взгляд** туң караш; **~ые глаза́** пыяла күзләр

стекля́рус *м* стеклярус, пыяла мәржән

стекля́шка *ж разг.* пыяла кисәге

стеко́льн||ый, -ая, -ое пыяла ...ы; **~ый заво́д** пыяла заводы; **~ая промы́шленность** пыяла промышленносте

стеко́льщик *м* пыялачы, пыяла куючы

стели́ть *несов. см.* **стлать**

стелла́ж *с* стеллаж; **кни́жный ~** китап стеллажы

сте́лька *ж* олтырак

сте́льная буаз (*сыер турында*)

стемне́ть *сов. безл.* караңгы төшү, караңгылану, караңгыланып җитү

стен||а́ *ж* **1.** стена; дивар (*уст.*); **бревё́нчатые сте́ны** бүрәнә стеналар; **крепостна́я ~а́** крепость стенасы **2.** *перен. чего* киртә, комачау; **ме́жду ни́ми вы́росла ~а́** аларның арасы бозылды **3.** *перен. чего* стена кебек, стенадай, стена сыман, стенага охшаш; **надвига́лась ~а́ тума́на** стенадай куе томан якынлашып килә иде **4.** *перен.* (*в сражении, кулачном бою*) стена кебек тезелешеп, сафларны тыгызландырып; **шли ~о́ю** стена кебек тезелешеп киләләр иде; **ста́ть ~о́й** стена кебек тезелешү ◆ **в ~а́х** *чего* ...да, ...эчендә; **в ~а́х университе́та** уни-

верситетта; **вне стен** ...дан тыш; ...га кермичә; **продолжáть учёбу вне стен тéхникума** укуны техникумнан тыш дәвам иттерү; **как óб стену горóх** колагына да элми, колагына да алмый; стенага борчак сипкәндәй булу; **[и] у стен есть ýши** стенаның да колагы бар; ярык юк димә бүрәнә өстендә, бүре юк димә бүреген астында; яу юк димә бүреген астында, бүре юк димә бүрек астында; **нá стену лезть** күтәрелеп бәрелү; **у стен** *или* **под стéнами** ... янында, ... тирәсендә; **у стен Москвы́** Мәскәү янында; **~á в стéну** 1) (*поблизости*) янәшәдә, күршедә, янында; 2) (*в соседней квартире, доме*) стена артында, янәшәдә, күршедә (күрше квартирда, бүлмәдә, өйдә)

стенáть *несов. книжн.* ыңгырашу, иңрәү; ах-вах килү

стенгазéта *ж* стена газеты

стенд *м* стенд

стéнк||а *м* **1.** *уменьш. от* **стенá**; **2.** (*боковая сторона предмета*) чит, кырый; **~и кастрю́ли** кастрюль читләре **3.** *анат.* тышча; сүрү; **~и желýдка** ашказаны тышчасы

стенн||óй, -áя, -óе **1.** стена ...ы; **~ы́е часы́** стена сәгате **2.** стенага төшерелгән, стенадагы ..., стена ...ы; **~áя рóспись** стенага төшерелгән рәсем[нәр]

стенобúти||ый, -ая, -ое стена вата (җимерә) торган; **~ые орýдия** стена вата торган кораллар

стенограмма *ж* стенограмма

стенóграф *м* стенограф

стенографи́ровать *несов. что* стенографияләү, стенография юлы белән язып алу

стенографи́ст *м* стенографист

стенографи́стка *ж* стенографистка

стенографи́ческий, -ая, -ое стенография ...ы, стенографик; **~ отчёт** стенографик отчёт

стенография *ж* стенография

стенопи́сн||ый, -ая, -ое стенага рәсем (бизәк) төшерү ...ы; стена бизәү ...ы; **~ое иску́сство** стена бизәү сәнгате

стéнопись *ж* стенага төшерелгән рәсем[нәр]

степéнн||ый, -ая, -ое **1.** салмак, сабыр табигатьле, житди, төпле, олысымак; **~ый человéк** сабыр табигатьле кеше **2.** салмак, салмак кына, сабыр гына, олысымакланып...; **~ая похóдка** салмак йөреш **3.** *уст.* урта; **~ый вóзраст** урта яшь

степéн||ь *ж в разн. знач.* дәрәҗә; **возвести́ в ~ь** *мат.* дәрәҗәгә күтәрү; **учёная ~ь** гыйльми дәрәҗә; **~и сравнéния** *грам.* чагыштыру дәрәҗәләре; **дипло́м трéтьей ~и** өченче дәрәҗә диплом; **дости́чь высóких ~éй** югары дәрәҗәләргә ирешү; **в извéстной ~и** билгеле бер дәрәҗәдә

степн||óй, -áя, -óе дала ...ы, даладагы; **~áя расти́тельность** дала үсемлекләре; **~áя дерéвня** даладагы авыл

степня́к *м* **1.** (*человек*) дала кешесе, далада яшәүче кеше **2.** (*лошадь*) дала аты **3.** (*птица*) дала кошы

степь *ж* **1.** дала **2.** *уст.* (*пустыня*) чүл

стервенéть *несов. разг.* ярсу, котырыну; шашу, бик нык ачу килү

стервя́тник *м* үләксә ашаучы (үләксә белән тукланучы) кош; козгын

стереомагнитофóн *м* стереомагнитофон

стереометри́ческий, -ая, -ое стереометрия ...ы, стереометрик

стереоме́трия *ж* стереометрия

стереоско́п *м* стереоскоп (*оптик прибор*)

стереоскопи́ческ||ий, -ая, -ое стереоскопик; **~ое изображéние** стереоскопик сүрәт; **~ое кинó** стереоскопик кино

стереоти́п *м полигр.* стереотип

стереоти́пн||ый, -ая, -ое **1.** *полигр.* стереотип ..., стереотиптан басылган; **~ое издáние** стереотип басма **2.** *перен.* стереотип ..., күп тапкырлар кабатланган, үзгәрешсез, бер үк төрле; **~ая фрáза** күп тапкырлар кабатланган җөмлә

стереофони́ческ||ий, -ая, -ое стереофоник; **~ая аппарату́ра** стереофоник аппаратлар

стерéть *сов. что* **1.** (*вытереть*) сөртү, сөртеп алу; **~ пыль** тузан сөртү **2.** (*уничтожить*) бетерү; **~ рисýнок** рәсемне бетерү **3.** *перен.* (*изгладить*) бетерү, юкка чыгару; югалту; **~ грань** *между кем-чем-л.* ...арасында булган чикне юкка чыгару, ...арасындагы аерманы бетерү **4.** кырдыру, суйдыру; кыру, сую; кырылу, суелу; **~ нóгу** аякны кырдыру **5.** (*измельчить*) изү, изеп ясау, уып ваклау, уып [порошок] ясау; **~ мел в порошóк** акбурны уып порошок ясау; **~ крáску** буяу изү; **~ табáк** тәмәкене уып ваклау ♦ **~ в порошóк** *кого* көлен күккә очыру; **~ *кого* с лицá земли́** җир йөзеннән юк итү, җир йөзеннән себереп түгү (ташлау)

стер||éться *сов.* **1.** сөртелү; **пýдра стёрлась** пудра сөртелгән **2.** кырылу, кырылып бетү, ашалу, ашалып бетү, юкка чыгу; **подóшва óбуви стёрлась** аяк киеменең табаны ашалган; **нáдпись на кáмне стёрлась от врéмени** ташка язылган язу вакыт үтү белән ашалып беткән ♦ **стёрлось в пáмяти** онытылган, хәтердән (истән) чыккан

стерéчь *несов. кого-что* **1.** (*охранять*) саклау, саклап тору; **~ дом** өй саклау; **~ вéщи** әйберләрне саклау **2.** (*подстерегать*) сагалау, сагалап тору

стéржень *м* **1.** стержень; кендек, таяк; **поршневóй ~** пешкәк стержене **2.** үзәк, тамыр; **~ чи́рья** чуан үзәге **3.** *перен. чего* үзәк, нигез; **~ всей рабóты** бөтен эшнең нигезе

стержнев||óй, -áя, -óе **1.** стерженьлы; **~óй трансформáтор** стерженьлы трансформатор **2.** *перен.* үзәк ..., төп ...; **~áя пробле́ма** үзәк проблема

стерилизáтор *м* стерилизатор, стерилизацияләү аппараты

стерилизáция *ж* стерилизация, стерилизацияләү, стерильләштерү

стерилизовáть *сов., несов.* **1.** *что* (*сделать стерильным*) стерилизацияләү, стерильләштерү **2.** *кого-что* (*лишить возможности деторождения*) стерилизацияләү, стерильләштерү (*нәсел арттыру сәләтен бетерү*)

стери́льн||ый, -ая, -ое **1.** стериль, йогышсызландырылган, микробсыз, микроблары бетерелгән (үтерелгән); **~ый бинт** стериль бинт **2.** *биол.* стериль, үрчү (нәсел арттыру) сәләте бетерелгән (булмаган); **~ая клéтка** стериль күзәнәк

стéрлинг *м*: **фунт ~ов** фунт стерлинг (*Англиядә акча берәмлеге*)

стéрлядь *ж* чөгә, чөгә балыгы

стерля́жь||ий, -ья, -ье **1.** чөгә балыгы..., чөгә балыгы ...ы; **~ья икрá** чөгә балыгы уылдыгы **2.** чөгә балыгыннан пешерелгән; **~ья ухá** чөгә балыгыннан пешерелгән шулпа

стернь, стерня́ *ж* **1.** (*сжатое поле*) урылган кыр **2.** *собир.* (*остатки стеблей на корню*) камыл

стерпéть *сов. что* түзү, чыдау, түзеп (чыдап) тору, түзә (чыдый) алу; түзеп (чыдап) калу; үзен тотып калу; **~ боль** авыртуга түзү; **~ обúду** рәнжетүгә түзеп калу; **не ~ оскорблéния** хурлыкка чыдый алмау

стёрт||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **стерéть**; **2.** (*повреждённый трением*) ашалган, кырылган **3.** *перн.* күп тапкырлар кабатланган, күп чәйнәлгән; **~ые фрáзы** күп чәйнәлгән җөмләләр

стесáть *сов. что* юну, юнып алу, юнып төшерү, таслау, таслап төшерү (*балта белән*)

стеснéние *с* **1.** *см.* **стесни́ть, стесни́ться** 3; **~ в груди́** күкрәк кысу **2.** (*застенчивость*) тартыну, тарсыну, оялу

стеснённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **стесни́ть**; **2.** кысынкы, кыен; **в ~ых обстоя́тельствах** кысынкы хәлдә (шартларда) ♦ **у негó ~ое дыха́ние** анын күкрәге кыса, сулышы кысыла

стесни́тельность *ж* оялчанлык, тартынучанлык

стесни́тельный, -ая, -ое (*застенчивый*) оялчан, оялучан, тартынучан

стесни́ть *сов.* **1.** *что* (*сажать*) кысу, кысрыклау; (*сузить*) тарайту **2.** *кого-что* (*заставить потесниться*) кысу, тыгызлау; унайсызлыклар тудыру, комачаулау **3.** *кого-что* (*лишить свободы действий*) комачаулау, мәшәкатьләү, мәшәкать булу (тудыру) **4.** *кого-что* (*ограничить*) кысу, чикләү; **~ себя́ в расхóдах** акча тотуда үзенне чикләү **5.** *что* (*грудь, горло*) кысу

стесни́ться *сов.* **1.** (*тесно сдвинуться*) бераз кысылу, кысыла төшү, тыгызлану, тыгызлана төшү **2.** *разг.* (*ограничить себя*) кысылу, үзен кысу, үзен чикләү **3.** (*о дыхании*) кысылу, тараю, күкрәк кысу

стесня́ть *несов. см.* **стесни́ть**

стесня́ться *несов.* **1.** *см.* **стесни́ться**; **2.** *кого-чего и без доп.* оялу, тарсыну, тартыну; **~ петь** жырларга оялу **3.** *страд. от* **стесня́ть**

стёсывать *несов. см.* **стесáть**

стетоско́п *м мед.* стетоскоп

стечéни||е *с* (*скопление*) [килеп] жыелу; агылып килеп жыелу; **при большóм ~и наро́да** жыелган халык алдында ♦ **~е обстоя́тельств** төрле хәлләрнең бергә туры килүе; **случа́йное ~е обстоя́тельств** төрле хәлләрнең очраклы рәвештә бергә туры килүе

стечь *сов.* агып төшү, агып китү

сте́чься *сов.* **1.** (*о ручьях и т.п.*) [агып килеп бергә] кушылу **2.** *перен.* агылу, жыелу, [агылып] килеп жыелу; **мно́го наро́ду стекло́сь на пло́щадь** мәйданга бик күп халык жыелган

стилиза́тор *м* стилизатор, оста стильләштерүче

стилиза́торский, -ая, -ое стилизатор ...ы, оста стильләштерү ...ы; **~ приём** оста итеп стильләштерү алымы

стилиза́ция *ж* **1.** (*подражание*) стилизация, стильләштерү **2.** (*произведение*) стильләштерелгән әсәр, (*берәр төрле*) стильгә салынган әсәр

стилизова́ть *сов., несов. что* стильләштерү, (*берәр төрле*) стильгә салу

стили́ст *м* стилист, оста каләмле

стили́стика *ж* стилистика

стилисти́ческ||ий, -ая, -ое стилистика ...ы: стилистик; стилистика өлкәсендә алып барыла торган; стиль ...ы; **~ие осо́бенности** стилистик үзенчәлекләр

стил||ь I *м в разн. знач.* стиль; **готи́ческий ~ь** готик стиль; **газе́тный ~** газета стиле; **лакони́ческий ~ь** лаконик стиль; **~ь руково́дства заво́дом** завод белән житәкчелек итү стиле; **э́то не в моём ~е** бу минем стильдә түгел; **рабо́тать над ~ем** стильне эшкәртү

стил||ь II *м* стиль (*ел исәбе төре*); **но́вый ~ь** яңа стиль; **по ста́рому ~ю** иске стиль белән

сти́льн||ый, -ая, -ое стильле, билгеле бер стильдә ...ган; **~ая ме́бель** билгеле бер стильдә ясалган мебель

сти́мул *м* стимул, этәргеч көч; **мора́льный ~** мораль стимул; **материа́льный ~** материаль стимул

стимули́рование *с см.* **стимули́ровать**

стимули́ровать *сов., несов. кого-что* стимуллаштыру, стимул бирү, стимул булып тору, дәртләндерү

стимуля́тор *м спец.* стимулятор

стипендиа́льный, -ая, -ое стипендия ...ы; **~ фонд** стипендия фонды

стипендиа́т *м* стипендиат, стипендия алучы, стипендия алып укучы

стипендиа́тка *ж* стипендия алучы кыз

стипе́ндия *ж* стипендия

стира́льн||ый, -ая, -ое кер ...ы, кер юу ...ы, кер юа торган; **~ая маши́на** кер юу машинасы; **~ый порошо́к** кер юа торган порошок

сти́ран||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** (*выстиранный*) юган, чиста; **~ое бельё** юган кер **2.** (*не новый*) юылган, юуда булган; **~ая руба́ха** юылган күлмәк

стира́ть I *несов. см.* **стере́ть**

стира́ть II *несов. что* юу, уу; **~ носовы́е платки́** кулъяулыкларны юу

стира́ться I *несов.* **1.** *см.* **стере́ться; 2.** *страд. от* **стира́ть** I

стира́ться II *несов.* **1.** (*оттыматься при стирке*) юылу, юылып бетү, юып алыну, югач чистару **2.** *разг.* (*находиться в стирке*) юылу, юуда булу **3.** *страд. от* **стира́ть** II

сти́рка *ж см.* **стира́ть** II

сти́скивать *несов. см.* **сти́снуть**

сти́скиваться *несов. см.* **1.** *см.* **сти́снуться; 2.** *страд. от* **сти́скивать**

сти́снуть *сов. в разн. знач. кого-что* кысу, каты [гына] кысу, каты итеп кысу; **~ в объя́тиях** кочагына алып кысу; **~ ру́ку** кулны каты кысу ♦ **сти́снув зу́бы** тешләрне кысып

сти́снуться *сов. разг.* (*о губах*) кысылу; (*о пальцах*) йомарлану

стих I *м* **1.** шигырь; **~и́ Ле́рмонтова** Лермонтов шигырьләре; **чита́ть ~и́** шигырьләр уку **2.** (*абзац в стихотворном произведении*) бүлекчә; (*в Коране*) аять; (*в Библии*) стих

стих II *м нескл.*: **~ нашёл** *на кого, разг.* 1) ...настроениесе туды, ...настроениесенә бирелде; 2) (*о сумасбродном желании*) дуамаллану

стиха́ть *несов. см.* **сти́хнуть**

стихи́йность *ж* **1.** табигыйлык **2.** *перен.* стихиялелек, оешмаганлык

стихи́йн||ый, -ая, -ое **1.** табигый; **~ое бе́дствие** афәт, бәла-каза **2.** *перен.* стихияле, оешмаган; **~ое движе́ние** стихияле хәрәкәт

стихи́||я *ж* **1.** стихия, табигать көчләре; **борьба́ со ~ей** табигать көчләре белән көрәшү **2.** стихия; **мелкобуржуа́зная ~я** вак буржуаз стихия **3.** *перен.* стихия; **быть в свое́й ~и** үз стихиясендә булу

сти́х||нуть *сов. в разн. знач.* тыну, басылу, тынып калу; тынычлану; **кри́ки ~ли** тавышлар тынды; **ве́тер стих** жил басылды; **пти́цы ~ли** кошлар тынып калды

стихове́дение *с лит.* (*наука о стихе*) шигырь турындагы фән; (*наука о стихосложении*) шигырь язу турындагы фән

стихов||о́й, -а́я, -о́е шигъри; **~а́я речь** шигъри сөйләм

стихоплёт *м разг.* шигырь укмаштыручы, шагыйрь кисәге (*сәләтсез шагыйрь*)

стихосложе́ние *с* **1.** (*сочинение стихов*) шигырь язу **2.** *лит.* (*строй стихотворной речи*) шигырь төзелеше

стихотворе́ние *с* шигырь; **~ в про́зе** нәсер

стихотво́рец *м уст.* шагыйрь, шигырь язучы

стихотво́рный, -ая, -ое шигырь ...ы, шигъри; **~ разме́р** шигырь үлчәве, шигырь вәзене

стихотво́рство *с уст.* шагыйрьлек, шигырь язучылык

стлать *несов. что* җәю, түшәү; **~ ковёр** палас җәю; **~ посте́ль** урын җәю

стла́||ться *несов.* **1.** җәелеп үсү, ятып үсү, үрмәләп үсү; **хмель сте́лется по земле́** колмак җиргә ятып үсә **2.** (*простираться*) җәелү, җәелеп яту **3.** (*распространяться над чем-л.*) җәелү, таралу **4.** *страд. от* **стлать**

сто *числ.* йөз; **~ рубле́й** йөз сум; **~ раз сказа́ть** (*т.е. много раз*) йөз тапкыр әйтү; **на все ~** бик яхшы, менә дигән иттереп

стог *м* печән кибәне, богыл

стогова́ние *с см.* **стогова́ть**

стогова́ть *сов. что* кибән салу (кую), богыл салу (кую), кибәнгә (богылга) салу

стогов||о́й, -а́я, -о́е кибән (богыл) ...ы, кибәнгә (богылга) салынган; **~о́е се́но** богыл печәне

стогомета́тель *м* кибән (богыл) салу машинасы, кибән (богыл) салгыч, кибән куйгыч (*машина*)

сто́ик *м* стоик (**1.** *стоицизм тарафдары* **2.** *перен. нык характерлы кеше, чыдам, тузем кеше*)

сто́имость *ж* **1.** *эк.* кыйммәт; **приба́вочная ~** өстәмә кыйммәт; **менова́я ~** алмашу кыйммәте **2.** хак, бәя; **~ биле́та** билет хакы; **~ ку́пленной ве́щи** сатып алынган әйбернең бәясе; **~ перево́зки** күчеру бәясе; **прода́жная ~** сату бәясе

сто́||ить *несов.* **1.** тору, хакы ... булу, бәясе ... булу; **биле́т ~ит два рубля́** билетның бәясе (хакы) ике сум, билет ике сум тора **2.** *кого-чего* (*быть достойным*) лаек булу; **~ит внима́ния** игътибарга лаек **3.** тору; төшү; **э́то бу́дет ~ить пятьсо́т рубле́й** бу биш йөз сумга төшәчәк; **что ~ят его́ обеща́ния!** аның ышандырулары ни тора!; **э́то ему́ ничего́ не ~ит** бу аңа берни тормый; **э́то тебе́ до́рого бу́дет ~ить** бу сина кыйммәткә төшәчәк; **не ~ит никако́го труда́** hичберни тормый, берни түгел; **я зна́ю, чего́ э́то ему́ ~ило** аңа моның никадәр кыйммәткә төшүен мин беләм **4.** *безл. с неопр.* (*имеет смысл*) ярый; ...ып торасы, ...ып торырга кирәк; ...ып торуның кирәге бар; **э́ту кни́гу ~ит проче́сть** бу китапны укырга ярый; **~ит ли туда́ ходи́ть?** анда барып торасымы [соң]?; **об э́том да́же говори́ть не ~ит** бу турыда сөйләп тә торасы түгел (юк) **5.** *безл. с неопр.* ...дымы, ...ды исә, ...ырга гына [кирәк]; **~ит тебе́ [то́лько] сказа́ть ...** сина бер тапкыр әйтергә генә кирәк ... ♦ **не ~ит** берни түгел; **не ~ит того́, что́бы ...** ... торасы түгел

стоици́зм *м* **1.** *филос.* стоицизм **2.** *перен.* стоиклык, нык характерлылык, зур түземлелек

стои́ческ||ий, -ая, -ое **1.** *филос.* стоиклар ...ы, стоик ...; **~ая филосо́фия** стоик философия, стоицизм **2.** стоик ..., стоикларча ..., стоикларга хас; чыдам (түзем) кешегә хас, нык; **~ий хара́ктер** нык характер; **~ое споко́йствие** стоикларга хас тынычлык

сто́йбище *с* стойбище, торлак (*кучмә халыкларның туктала урыны*)

сто́йк||а I *ж* **1.** *воен., спорт.* [үрә катып] тору, [хәрәкәтсез туп-туры басып] тору; **~а смирно́** үрә катып тору **2.** *спорт.* стойка, баштүбән тору **3.** *охот.* тын калу, хәрәкәтсез (катып) калу (*киекне кургач, ау этенең бер урында хәрәкәтсез туктап калуы*); **сде́лать ~у** катып калу

сто́йка II *ж* 1. (*вертикальный брус*) терәк (*механизмнарда*); багана (*корылмаларда*) 2. стойка, кечкенә буфет

сто́йк||ий, -ая, -ое 1. озак бетми торган, озак саклана торган; озак бетереп булмый торган; ник; **~ий за́пах** озак бетми торган ис; **~ая кра́ска** озак бетми торган буяу; **~ая инфе́кция** озак бетереп булмый торган инфекция; **~ий кирпи́ч** ник кирпеч 2. *перен.* ник; **~ая уве́ренность** ныклы ышаныч 3. *перен.* ник, ник торучан, какшамас, чыдам, чыдамлы, түзем, түземле, тотнаклы; **~ий хара́ктер** ник характер; **~ий челове́к** чыдам кеше

²сто́йкий, -ая, -ое *кушма сузләрнең икенче өлеше; «чыдам» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **морозосто́йкий** салкынга чыдам; **огнесто́йкий** утка чыдам

сто́йло *с* аран (*абзарда бер ат яки бер сыер өчен ясалган урын*)

сто́йлов||ый, -ая, -ое: **~ое содержа́ние скота́** терлекне аранда (абзарда) асрау; **~ый пери́од** терлекне аранда (абзарда) асрау чоры

стоймя́ *нареч.* бастырып; **поста́вить ~** бастырып кую

сток *м* 1. агым, агынты; **~ воды́** су агымы; **~ во́здуха** һава агымы 2. *гидр.* (*билгеле бер вакыт эчендә кулга, елгага яисә океанга*) агып төшкән су микъдары 3. (*канава, труба*) канау, су торбасы, улак, су юлы (*су агып төшә торган юл*) 4. сулар; **вы́пуск в ре́ку ~ов с промы́шленных предприя́тий** промышленность предприятиеләре суларын елгага агызу

стокра́т *нареч. книжн.* йөз тапкыр, йөз кат, йөз мәртәбә, йөзләтә (*күп тапкырлар*)

стокра́тный, -ая, -ое *книжн.* 1. (*увеличенный в сто раз*) йөз тапкыр артык, йөз тапкыр арттырып, йөзләтә ... 2. (*многократный*) күп тапкырлар кабатланган, кат-кат кабатланган

стол *м* 1. өстәл; **обе́денный ~** аш өстәле; **пи́сьменный ~** язу өстәле; **я́щик ~а́** өстәл тартмасы 2. табын, өстәл; **вста́ть из-за ~а́** табын яныннан торып китү; **за ~о́м** табын янында; **пригласи́ть к ~у́** табынга чакыру; **сесть за ~** табынга утыру; **собра́ть на ~** табын әзерләү 3. ашау; **име́ть о́бщий ~** *с кем-л.* бергә ашау; **расхо́ды на ~** ашауга тотылган чыгым 4. азык, ашамлык[лар], аш[лар]; **вегетариа́нский ~** итсез ашамлыклар; **мясно́й ~** итле ашлар; **разнообра́зить ~** аш төрләндерү 5. *чего, какой* өстәл, бүлек; **а́дресный ~** адреслар өстәле; **~ нахо́док** табылдыклар өстәле ♦ **за ~о́м перегово́ров** сөйләшүләр өстәле янында

столб *м* 1. багана; **телегра́фный ~** телеграф баганасы; телеграм баганасы (*уст.*); **верстово́й ~** чакрым баганасы; **позвоно́чный ~** умыртка баганасы 2. *перен. чего* багана; **~ пы́ли** тузан баганасы; **~ ды́ма** төтен баганасы

столбене́ть *несов. разг.* багана булып (баганадай) кату, катып калу

столбе́ц *м* багана (*мәс. газетада*)

столбня́к *м* 1. столбняк (*йогышлы тартышу авыруы*) 2. *разг.* катып калу; **на него́ нашёл ~** ул [баганадай] катып калды

столбня́чный, -ая, -ое столбняк ...ы; **~ микро́б** столбняк микробы

столбов||о́й I, -а́я, -о́е: **~а́я доро́га** *прям., перен.* баганалы юл, олы юл

столбово́й II, -а́я, -о́е: **~ дворяни́н** *ист.* столбовой дворян, ата-бабадан килгән дворян

столе́ти||е *с* 1. (*век*) гасыр, йөз; **в восемна́дцатом ~и** унсигезенче гасырда 2. (*годовщина*) йөз ел, йөз еллык; **~е университе́та** университетның йөз еллыгы

столе́тн||ий, -яя, -ее 1. (*продолжающийся сто лет*) йөз еллык; йөз ел буена дәвам иткән; **~яя война́** йөз еллык сугыш 2. (*о возрасте*) йөз яшьлек; йөз яшәгән, йөз яшәр; (*о возрасте растений*) йөз еллык; **~ий ста́рец** йөз яшьлек карт; **~ий дуб** йөз еллык имән 3. йөз еллык; **~ий юбиле́й** йөз еллык юбилей

столе́тник *м* алоэ; йөзйәшәр, сабур (*чәнечкеле булмә гөле*)

столи́ца *ж* башкала, мәркәз, үзәк шәһәр

столи́чн||ый, -ая, -ое 1. башкала ...ы; үзәк шәһәр ...ы; башкалада ..., башкаладагы; **~ые у́лицы** башкала урамнары; **~ые учрежде́ния** башкаладагы учреждениеләр; **~ый жи́тель** башкала кешесе 2. башкала ...ы, башкалага хас; башкала кешесенә хас; **~ые мо́ды** башкала модалары; **~ый вид** башкала кешесенә хас кыяфәт

столкновени||е *с* 1. *см.* **столкну́ться** 1, 2; 2. (*конфликт*) каршылык 3. бәрелеш, бәрелешү; **рабо́тать без ~я** [үзара] бәрелешмичә эшләү; **вооружённое ~е** кораллы бәрелеш; **кла́ссовые ~я** сыйнфый бәрелешләр

столкну́ть *сов. кого-что* 1. этү, этеп жибәрү; этеп төшерү, төртеп төшерү, бәреп төшерү; **~ ло́дку в во́ду** көймәне суга этеп төшерү; **~ с ле́стницы** баскычтан төртеп төшерү 2. *прям., перен.* [этеп жибәреп] бер-берсенә бәрдерү, кара-каршы китереп бәрдерү; бәрелештерү; **~ лба́ми** маңгайлары белән бәрелештерү; *~ чьи-л.* **интере́сы** *берәүләрнең* интересларын бәрелештерү 3. *прям., перен.* очраштыру, кара-каршы китерү, йөзгә йөз китерү, бәрелештерү; **~ с врагом́** дошман белән йөзгә-йөз китерү; **~ с тру́дностями** кыенлыкларга дучар итү

столкну́||ться *сов.* 1. *прям., перен.* бәрелешү, бер-берсенә бәрелү; **льди́ны ~лись** бозлар бер-берсенә бәрелде; **~ться голова́ми** башлар белән бәрелешү; **~ться во взгля́дах** каршлар туры килмәү 2. *с кем* [көтмәгәндә] очрашу, очрату, бәрелешү; **~ться со ста́рым знако́мым** көтмәгәндә иске танышны очрату; **~ться в дверя́х** ишектән кергәндә очрашу 3. *перен. с чем* (*узнать, испытать*) очрату, очрау; туры килү, дучар булу, танышу; **~ться с тру́дностями** кыенлыкларга очрау; **~ться с но́вым ви́дом рабо́ты** яңа эш белән танышу

столкова́ться *сов. разг.* уртак тел табу, килешү, аңлашу; **~ ме́жду собо́й** үзара аңлашу

столко́вываться *несов. см.* **столкова́ться**

столова́ться *несов.* ашау, ашау-эчү, ашап йөрү; туклану

столо́вая *ж* 1. (*в квартире*) аш бүлмәсе 2. ашханә

столо́в||ый, -ая, -ое 1. аш ...ы; **~ая соль** аш тозы; **~ая ло́жка** аш кашыгы; **~ый прибо́р** савыт-саба; **~ый серви́з** аш сервизы; **~ое серебро́** көмеш кашык-аяк 2. аш ...ы; ашый торган; **~ая свёкла** ашый торган чөгендер; **~ая ты́ква** ашый торган кабак

столонача́льник *м* өстәл начальнигы, бүлек начальнигы (*революциягә кадәрге Россиядә*)

столо́чь *сов. что, разг.* төю, төеп әзерләү; **~ соль** тоз төю

столо́чься *сов. разг.* төелү

столп *м* 1. *уст.* багана 2. *перен.* таяныч, терәк; **~ы́ о́бщества** жәмгыятьнең терәкләре

столпи́ться *сов.* [бер җиргә] җыелу, килеп өелешү; килеп тыгылу

столпотворе́ние *с разг.* бик зур шаулашу, чамасыз ыгы-зыгы, бик зур тәртипсезлек, мәхшәр

столь *нареч.* шул кадәр, ул кадәр; **э́то не ~ ва́жно** бу ул кадәр үк әһәмиятле түгел

сто́лько *мест., нареч.* шулкадәр, бу кадәр, шул чаклы; **ско́лько взял, ~ и о́тдал** никадәр алды, шулкадәр [үк] бирде дә; **где ты был ~ вре́мени?** кайда син шулкадәр [вакыт] тордың?

сто́льник *м ист.* стольник (*Русьта: патша сараенда хезмәт итүче*)

сто́льный, -ая, -ое *уст.*: **~ го́род** башкала

столя́р *м* столяр, агач остасы, агач эше остасы

столя́рничать *несов.* столярлык итү

столя́рн||ый, -ая, -ое агач ..., агачтан ясалган; **~ые изде́лия** агач әйберләр ♦ **~ый клей** агач җилеме

стомато́лог *м* стоматолог

стоматологи́ческ||ий, -ая, -ое стоматология ...ы; стоматологик; **~ая кли́ника** стоматологик хастаханә

стоматоло́гия *ж* стоматология

стон *м* ыңгырашу, ыңгыраш, ыңгырашкан тавыш, ыңгырашу тавышы ♦ **~ стои́т** 1) (*о воплях, жалобах*) бертуктаусыз елау, зарлану тавышлары ишетелеп тора; 2) (*о шуме, гуле*) туктаусыз шау-шу ишетелеп тора

стона́ть *несов. прям., перен.* ыңгырашу; (*о ветре*) улау

стоп *межд.* 1. (*команда*) стоп, тукта, туктагыз 2. *в знач. сказ. разг.* туктады, туктадылар; **е́дем,... вдруг ~** барабыз, кинәт туктадык 3. *в знач. сущ. нескл. спец.* туктату; **сигна́л ~** туктату сигналы

стоп||а́ I *ж* 1. (*часть ноги*) табан, аяк табаны 2. *обычно мн.* **~ы́** *поэт.* (*но́ги*) аяклар; **упа́сть (припа́сть) к ~а́м** аягына егылу ♦ **по ~а́м** *кого, чьим* (*пойти, направиться и т.п.*) эзеннән бару, *берәүдән* үрнәк алу, *берәүгә* иярү

стопа́ II *ж лит.* стопа, ритмик буын (*шигырьдә*)

стопа́ III *ж* **1.** бер өем, бер кочак; **~ книг** бер өем китап **2.** стопа (*1000 табак кәгазь*)

сто́пка I *ж уменьш. от* **стопа́** III

сто́пка II *ж* стопка (*кечкенә стакан — аракы эчү очен*)

стоп-кра́н *м* стоп-кран

сто́пор *м* стопор (*механизмны туктата торган җайланма*)

сто́порить *несов. что* туктату; **~ маши́ну** машинаны туктату

сто́порный, -ая, -ое [машинаны] туктату ...ы, [машинаны] туктата торган; **~ кран** [машинаны] туктата торган кран

стопроце́нтн||ый, -ая, -ое **1.** йөз процентлы; **~ый соля́но́й раство́р** йөз процентлы тоз эремәсе **2.** йөз процентка ...; йөз процент ...; **~ое выполне́ние пла́на** планны йөз процентка үтәү **3.** *разг.* чын [мәгънәдә], чын-чыннан; булып житкән, ашып узган; **~ый жу́лик** чын мәгънәдә жулик, жуликның да жулиры

стопта́ть *сов. что* **1.** (*обувь*) чалышайту, чалышайтып бетерү, таптап бетерү (*аяк киемен*) **2.** *разг.* таптау; **~ овёс** солыны таптау

стопта́ться *сов.* чалышаю, чалышаеп бетү, тапталып бетү (*аяк киеме турында*)

сторгова́ться *сов.* сатулашып килешү (*бәя турында*)

стори́ей, стори́ею *нареч. книжн.* йөзләтә, йөзе белән; күп тапкыр артык; **возда́ть ~** йөзе белән кайтару

сто́рож *м* каравылчы, сакчы

сторожеви́к *м разг.* каравылчы (сакчы) катер

сторожев||о́й, -ая, -о́е **1.** каравыл ...ы; **~а́я вы́шка** каравыл каланчасы **2.** каравыл ...ы; каравылчы ...; сакчы ...; **~о́й ка́тер** сакчы катер; **~о́й отря́д** каравыл отряды

сторожи́ть *несов. кого-что* саклау, саклап тору, каравыллау, каравыллап тору

сторожи́ха *ж* каравылчы хатын

сторо́жка *ж* каравыл өе (алачыгы); каравылчы өе (алачыгы)

сторон||а́ *ж* **1.** *в разн. знач.* як, тараф; **в сто́рону ле́са** урман ягына; **родна́я ~а́** туган як; **ле́вая ~а́** сул як; **подве́тренная ~а́** җил як; **со всех сторо́н** төрле яктан; **лицева́я ~а́ мате́рии** тукыманың ун ягы; **техни́ческая ~а́ прое́кта** проектның техник ягы; **догова́ривающиеся сто́роны** килешүче тарафлар; **вы́слушать о́бе сто́роны** ике якны да тыңлау **2.** чит; **посмотре́ть в сто́рону** читкә борылып карау; **отозва́ть** *кого-л.* **в сто́рону** *берәүне* читкә чакырып алу ◆ **сто́роны треуго́льника** өчпочмакның кырлары; **в ~е́** *от кого* аерым, читтә; **в сто́рону** *в знач. сказ.* (*уклониться от чего-л.*) читкә тайпылды, баш тартты; качты (*җаваплылыктан, җавап бирмәс өчен*); **держа́ться в ~е́** читтә тору (*катнашмау, аралашмау*); **на́ сторону** читкә; **со ~ы́** *чьей, кого* ... ягыннан, ... тарафыннан; **с одно́й ~ы́ ..., с друго́й ~ы́** бер яктан ..., икенче яктан ...

сторони||ться *несов.* **1.** (*отодвигаться в сторону*) читкә тайпылу, читкә китү, читкә китеп юл бирү **2.** *перен. кого-чего* читтә тору, читләшү, аралашмау; якын бармау; ◆ **~сь!** сак бул!, юл бир!

сторо́нний, -яя, -ее *уст.* чит, читтән торып ..., читтән ...ган; **~ наблюда́тель** читтән торып күзәтүче

сторо́нник *м* яклаучы [кеше], ... яклы кеше, тарафдар; **~и ми́ра** тынычлыкны яклаучы кешеләр

сторо́нница *ж* яклаучы хатын (кыз)

сторкова́ться *сов. о ком-чём, по кому-чему, по ком-чём* сагыну, сагынып бетү

сточи́ть *сов. что* **1.** (*снять неровности*) чарлап (кайрап) тигезләү, йөз чыгару **2.** чарлый-чарлый (кайрый-кайрый) юкартып бетерү; **~ нож** кайрый-кайрый пычакны юкартып бетерү

сточи́||ться *сов.* чарлый-чарлый (кайрый-кайрый) ашалып бетү; **но́жик ~лся** кайрый-кайрый пычак ашалып беткән

сто́чн||ый, -ая, -ое **1.** (*стекающий куда-л.*) агып җыела (агып төшә) торган; **~ые во́ды** агып җыела торган сулар **2.** су агыза торган; **~ые тру́бы** су агыза торган торбалар **3.** (*имеющий сток*) агымлы, агым сулы; **~ое о́зеро** агымлы күл

стошни́ть *сов. безл. кого* күңел болганын косып җибәрү

сто́я *нареч.* басып, аягүрә; **чита́ть ~** аягүрә уку

стоя́к *м* (*для опоры*) терәк (*мәс. вертикаль багана, борыс һ.б.ш.*); (*для соединения*) вертикаль торба, көпшә

стоя́л||ый, -ая, -ое: **~ая вода́** торгын су, озак торган су; **~ый мёд** утырган бал, иске бал; **~ый конь** күптән җигелмәгән ат

стоя́нка *ж* **1.** туктау, туктап тору, тукталу; **~ пое́зда пять мину́т** поезд биш минут туктап тора **2.** (*место*) [вакытлыча урнашкан] урын, туктап (тукталып) тору урыны, туктау (тукталу) урыны; **~ зимо́вщиков** кышлаучылар урыны **3.** (*для транспорта*) вакытлыча куеп тору урыны; тукталыш; **~ такси́** таксилар тукталышы **4.** *археол.* [борынгы] кешеләр яшәгән (торган) урын; **~ ка́менного ве́ка** таш дәвере кешеләре торган урын

сто||я́ть *несов.* **1.** басып тору; **~я́ть у окна́** тәрәзә янында басып тору; **~я́ть пе́ред зе́ркалом** көзге каршында басып тору **2.** тору; **~я́ть на коле́нях** тезләнеп тору; **~я́ть на голове́** баштүбән тору **3.** тору; **~я́ть в карау́ле** каравылда тору **4.** урнашу, туктау, тукталу; **~я́ть ла́герем** лагерь булып урнашу; **в дере́вне ~я́л полк** авылда полк урнашкан иде **5.** *перен. за кого-что* яклау; **~я́ть за мир** тынычлыкны яклау; **~я́ть за пра́вду** дөреслекне яклау **6.** *перен. разг.* (*в отриц. ф.*) тормау; карамау; **не ~я́ть за цено́й** хакыннан тормау **7.** үсеп утыру; **у до́ма ~я́ла берёза** өй янында каен үсеп утыра иде **8.** *на чём* куелу; салыну, корылу; **дом ~и́т на фунда́менте** өй фундаментка салынган **9.** басылу, салыну, сугылу; **на бума́ге ~и́т печа́ть** кәгазьгә печать басылган **10.** туктау, туктап тору, тору; **ло́шади не ~я́ли на ме́сте** атлар бер урында тормыйлар иде; **по́езд до́лго ~я́л на ста́нции** поезд станциядә озак туктап торды **11.** туктау, йөрмәү; **часы́ ~я́т** сәгать туктаган **12.** *перен.* тукталу, тукталып тору; **рабо́та ~и́т** эш тукталып тора **13.** [бар] булу; **луна́ ~я́ла высоко́ над до́мом** ай югарыда өй турысында күренә иде; **небольши́е ту́чки ~я́т в не́бе** күктә вак-вак болытлар бар; **~я́ла жара́** эссе иде; **~я́ла зима́** кыш иде **14.** *повел.* **сто́й[те]** тукта[гыз] ◆ **~я́ть во главе́** *кого-чего* башында тору, житәкчелек итү; **~я́ть гру́дью** 1) (*мужественно защищать*) күкрәк киереп каршы тору; бик нык каршылык күрсәтү; 2) (*упорно отстаивать*) җанын фида кылу; **~я́ть как вко́панный** кагып куйган баганамыни, багана шикелле (баганадай) катып тору; **~я́ть как пень** баганадай катып тору (*берни аңлый алмыйча басып тору*); **~я́ть над душо́й** атлы казак кебек өстендә тору; **~я́ть на доро́ге (поперёк доро́ги, на пути́)** *у кого* юлына аркылы төшү; **~я́ть на за́дних ла́пках** *перед кем* тәлинкә тоту, ялагайлану; **~я́ть на ло́жном пути́** ялгыш (хата) юлда булу; **~я́ть на плохо́й (дурно́й) доро́ге, на плохо́м (дурно́м) пути́** начар юлда булу; **~я́ть на ра́вной ноге́** *с кем* тиң булу; **~я́ть на [свои́х, со́бственных] нога́х** аягында нык басып тору; **~я́ть на стра́же** *чего* ... сагында тору; **~я́ть одно́й ногой в моги́ле (в гробу́)** бер аягын белән кабердә тору (булу); **~я́ть на хоро́шей (пра́вильной) доро́ге, на хоро́шем (пра́вильном) пути́** дөрес юлда булу; **~я́ть на часа́х** каравылда тору; **~я́ть поперёк го́рла** бугазына (тамагына) аркылы килү; **~я́ть у вла́сти** власть башында тору (булу); **~я́ть у воро́т (у поро́га)** якынлашып килү, житеп килү

стоя́ч||ий, -ая, -ое **1.** баскан, басып торган, басып тора торган; үрә торган; утыртып куелган; утырма ..., утыртма ...: **~ий воротни́к** утыртма яка **2.** (*не проточный*) агымсыз, суы акмый торган, торгын сулы; (*о воде*) торгын; **~ее боло́то** торгын сулы сазлык

сто́ящ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **сто́ить; 2.** *разг.* игътибарга лаек (лаеклы), әһәмияткә ия; **~ее предложе́ние** игътибарга лаек тәкъдим; **он челове́к ~ий** ул игътибарга лаеклы кеше

трави́ть *сов. кого-что* **1.** (*животных*) өстерү, өстереп чәйнәштерү, өстереп сугыштыру; (*птиц*) сугыштыру **2.** *перен. разг.* (*подстрекнуть*) котырту, котыртып талаштыру (сугыштыру)

тра́вливать *несов. см.* **трави́ть**

тра́гивать *несов. см.* **тро́нуть**

тра́гиваться *несов.* **1.** *см.* **тро́нуться; 2.** *страд. от* **тра́гивать**

страда́ *ж* **1.** (*летняя*) урак өсте, [җәйге] кызу эш вакыты **2.** *перен.* кызу эш өсте, кызу эш вакыты

страда́лец *м* бик күп җәфа (газап, азап) чиккән кеше, бик күп җәфаланган (интеккән) кеше

страда́лица *ж* бик күп җәфа чиккән хатын (кыз)

страда́льческ||ий, -ая, -ое **1.** (*полный страданий*) азаплы, газаплы, җәфалы, интектергеч, интектерә торган; **~ая жизнь** азаплы тормыш **2.** (*выражающий страдание*) азап чиккән, җафаланган, интеккән, интегүле, газаплы; **~ий вид** интеккән кыяфәт; **~ый взгляд** интегүле караш

страда́ние *с* азап, газап, җәфа, азап (газап, җәфа) чигү, газаплану, җәфалану, интегү

страда́тельный, -ая, -ое: **~ зало́г** *грам.* төшем юнәлеше (*фигыльдә*)

страда́||ть *несов.* **1.** *чем, от чего и без доп.* азаплану, җәфалану, интегү, азап (газап, җәфа) чигү; **~ть боле́знью се́рдца** йөрәк авыруы белән җәфалану; **~ть от головны́х бо́лей** баш авырту белән интегү **2.** *от чего и без доп.* (*испытывать нравственные муки*) газаплану, газап чигү; яну; **~ть от мы́сли, что ...** ... дип яну, ... дип газаплану; **~ть от любви́** мәхәббәт (гыйшык) утында яну **3.** *за кого-что, из-за кого-чего* газаплану, җәфалану, интегү, газап (җәфа) чигү; **~ть за убежде́ния** карашлар өчен газап чигү **4.** *за кого-что* (*сочувствовать*) кайгыру, җан әрнү, өзелү, йөрәк өзелү; яну **5.** *перен. чем* кимчелекле [җитешсез, җитешмәгән, кире яклар, начар] сыйфатлар булу; **~ть ра́зными недоста́тками** төрле җитешсез якларын булу **6.** *от кого-чего* (*испытывать затруднения, неудобства*) зарар (зыян) күрү, зарар (зыян) килү, кысынкылык күрү, кыенлыклар күрү; **посе́вы ~ют от сорняко́в** чәчүлекләргә чүп үләннәрдән зыян килә **7.** *разг.* аксау; **у ученика́ ~ет гра́мотность** укучының грамоталылыгы аксый **8.** *по ком-чём, по кому-чему* (*томиться, тосковать*) сагыну, юксыну

стра́дн||ый, -ая, -ое: **~ая пора́** урак өсте, кызу кыр эшләре вакыты; кызу эш вакыты

страж *м* кораллы сакчы

стра́ж||а *ж* кораллы сакчылар ♦ **на ~е** *чего* **(быть, стоя́ть)** сакта тору; **на ~е ми́ра** тынычлык сагында; **на ~у** *чего* сакларга; **под ~ей** ябылуда, төрмәдә

стра́жник *м* стражник (*революциягә кадәрге Россиядә: иң түбән дәрәҗәле авыл полицейские*)

страна́ *ж в разн. знач.* ил; **~ чуде́с** могҗизалар иле; **демократи́ческие стра́ны** демократик илләр; **го́рная ~** таулы ил; **жа́ркие стра́ны** эссе илләр ♦ **стра́ны све́та** дөнья яклары

страни́ц||а *ж* **1.** (*напр. в книге*) бит **2.** *перен.* сәхифә; **~ы исто́рии** тарих сәхифәләре

стра́нник *м* **1.** ил гизүче, илгизәр, юлаучы; мосафир, юл кешесе **2.** *уст.* (*богомолец*) дәрвиш

стра́нница *ж* ил гизүче хатын (кыз)

стра́нност||ь *ж* **1.** сәерлек, гаҗәплек, гаҗәп нәрсә, сәер нәрсә; **~ь взгля́дов** карашларның сәерлеге **2.** *обычно мн.* **~и** сәер кыланышлар (гадәтләр), әкәмәт кыланышлар (гадәтләр); **за ним во́дятся ~и** аңарда сәер гадәтләр бар

стра́нн||ый, -ая, -ое сәер, гажәп; **~ый вид** сәер кыяфәт; ♦ **~ое де́ло** *в знач. вводн. сл.* гаҗәп эш (хәл)

страново́дение *с* илне өйрәнү

стра́нствие *с* ил гизү, сәяхәт итү; сәяхәт

стра́нствовать *несов.* ил гизү, сәяхәт итү, сәяхәттә булу

стра́стн||ый, -ая, -ое **1.** ялкынлы, кызу; **~ая речь** ялкынлы нотык; **~ые спо́ры** кызу бәхәсләр **2.** һәвәс, бирелеп эшләүчән, (*берәр эшкә*) бирелгән, бирелеп...; **~ый люби́тель му́зыки** музыканы бирелеп яратучы; **~ый рыболо́в** балык тотуга һәвәс кеше; **~ая любо́вь к своему́ де́лу** үз эшен бирелеп ярату **3.** дәртле, ялкынлы; **~ый челове́к** дәртле кеше; **~ая любо́вь** ялкынлы мәхәббәт

страст||ь *ж* **1.** дәрт, көчле (ялкынлы) теләк; **обу́здывать свои́ ~и** дәртеңне тыю **2.** (*сильная увлечённость*) дәрт, көчдәрт, бик көчле теләк, рухлану; **де́лать со ~ью** *что-л.* дәртләнеп эшләү, рухланып эшләү **3.** *к чему, с неопр. и без доп.* һәвәс булу, һәвәслек, бирелгәнлек, бирелеп ярату; **~ь к му́зыке** музыкага һәвәслек; **~ь к чте́нию** китап укуга һәвәслек **4.** (*предмет сильного увлечения*) мавыктырган нәрсә, бирелеп яраткан нәрсә **5.** дәртле мәхәббәт, гыйшык; **воспыла́ть ~ью** *к кому-л.* дәртле мәхәббәт кабыну

страте́г *м* стратег, стратегия белгече

стратеги́ческ||ий, -ая, -ое стратегия ...ы, стратегик; **~ое ору́жие** стратегик корал

страте́гия *ж* стратегия (**1.** *сугыш алып бару осталыгы* **2.** *перен. иҗтимагый, сәяси көрәштә җитәкчелек итү осталыгы*)

стратона́вт *м* стратонавт, стратосферага очучы

стратоста́т *м* стратостат

стратосфе́ра *ж* стратосфера (*атмосфераның өске катламы*)

стратосфе́рн||ый, -ая, -ое стратосфера ...ы; **~ые слои́** стратосфера катламнары

стра́ус *с* тәвә кошы

страх *м* **1.** курку, бик ныклы курку, кот очу; куркыныч; **~ смерти** үлем куркынычы; **дрожа́ть от ~а** куркудан калтырау; **наводи́ть ~** *на кого-л.* курку астында тоту, куркытып тоту; **натерпе́ться ~у** бик ныклы курку; бик зур куркуга калу; **перебороть ~** куркуны жиңү **2.** *обычно мн.* **~и** *разг.* куркынычлар, куркыныч нәрсәләр (вакыйгалар); **ночны́е ~и** төнге куркулар ♦ **не за ~, а за со́весть** күңел биреп, чын күңелдән, эш булсынга, тырышып; **под ~ом** *чего* ... куркынычы астында; **под ~ом сме́рти** үлем куркынычы астында; **у ~а глаза́ велики́** *посл.* курыкканга куш, коерыгы белән биш

страхка́сса *ж* страхкасса (*социаль страхование кассасы*)

страхова́ние *с см.* **страхова́ть** 1; **~ жи́зни** тормышны страховкалау ♦ **социа́льное ~** социаль страхование

страхова́тель *м* страховать итүче (*учреждение яки шәхес*)

страхова́ть *несов.* **1.** *кого-что* страховать итү, страховкалау; **~ иму́щество** мөлкәтне страховать итү **2.** *кого, спец.* саклап тору, саклау чарасын күрү, страховкалау; **~ гимна́ста** гимнастны страховкалау **3.** *перен. кого* саклау, саклану чарасын күрү; **~ себя́ от ри́ска** үзенне хәвеф-хәтәрдән саклау

страхова́ться *несов.* **1.** [үзеңне, үз мөлкәтеңне] страховкалау, страховать итү; **~ от пожа́ра** янгыннан страховать итү **2.** *перен. разг.* (*ограждать себя*) саклану чарасын күрү **3.** *страд. от* **страхова́ть**

страхо́вк||а *ж* **1.** *см.* **страхова́ть; 2.** страховка акчасы; **получи́ть ~у** страховка акчасын алу

страхо́вщик *м* страховать итүче (*учреждение яки шәхес*)

страши́лище *м, с разг.* бик куркыныч нәрсә, куркыныч бер нәрсә, коточкыч нәрсә (кеше)

страши́ть *несов. кого-что* куркыту, курку салу, котны очыру (алу)

страши́ться *несов. кого-чего* курку, кот очу (алыну)

стра́шн||ый, -ая, -ое **1.** куркыныч, коточкыч; **~ый сон** куркыныч төш; **~ый вид** куркыныч кыяфәт **2.** *разг.* коточкыч (*зур, көчле, куе һ.б.ш.*); **~ый хо́лод** коточкыч салкын; **~ая боль** коточкыч көчле авырту; **~ый тума́н** коточкыч куе томан

стре́жень *м* ургыл, каты агым (*елганың бик каты аккан тирән урыны*)

стрека́ч *м*: **дать (зада́ть) ~а́** *прост.* табан ялтырату, элдертү, тау, шылу, сызу

стрекоза́ *ж* **1.** (*насекомое*) энә карагы **2.** *перен. разг.* (*о девочке*) кыбырсык, тиктормас, чикерткә

стрекози́||ный, -ья, -ье, **стрекози́н||ый**, -ая, -ое энә карагы ...ы; **~ые кры́лья** энә карагы[ның] канатлары; **~ый стре́кот** энә карыгының черелдәгән тавышы

стре́кот *м* черелдәү, черелдәгән тавыш

стрекота́ние *с см.* **стрекота́ть**

стрекота́ть *несов.* черелдәү

стрекотня́ *ж разг. см.* **стре́кот**

стрел||а́ *ж* **1.** ук; **пусти́ть ~у́** ук ату **2.** *тех.* ук, көянтә; **~а́ кра́на** кран көянтәсе **3.** (*у растений*) сабак; көпшә **4.** *в знач. нареч.* **~о́й** уктай тиз, атылган ук кебек; **лете́ть ~о́й** уктай тиз очу **5.** *в знач. нареч.* **~о́й** (*очень прямо*) ук сыман туп-туры; уктай туп-туры [булып], төптәз булып

стрело́к *м* **1.** стрелец, укчы (*16-17 йөзләрдә Мәскәү Русенда аерым хокуклар белән файдаланган гаскәри*) **2.** (*с прописной*) *астр.* Укчы

стре́лка *ж* **1.** *уменьш. от* **стрела́** 1; **2.** *см.* **стрела́** 3; **3.** ук; **~ часо́в** сәгать угы; **~ ко́мпаса** компас угы **4.** *ж.-д.* стрелка **5.** (*мыс*) борын **6.** (*знак*) ук (*билге*)

стрелко́вый, -ая, -ое **1.** укчы[лар] ...ы; укчы ...; **~ полк** укчы полк **2.** ату ...ы, ату буенча...; **~ спорт** ату спорты

стрелови́дный, -ая, -ое уксыман, очлы, очлаеп тора торган

стрелóк *м* укчы, атучы

стрéлочник *м* стрелочник

стрéлочница *ж* стрелочник хатын (кыз)

стрéлочн||ый, -ая, -ое стрелка күчерү ...ы; **~ые устрóйства** стрелка күчерү жайланмалары

стрельбá *ж* ату, атыш

стрéльбище *с* ату урыны, атарга өйрәнү урыны

стрельнýть *сов. однокр.* **1.** *в кого-что и без доп.* ату, атып җибәрү **2.** *безл.* чатнап китү; **~ло в ýхе** колагы чатнап китте

стрéльчат||ый, -ая, -ое **1.** уксыман, очлаеп [тора] торган; **~ые óкна** очлаеп торган тәрәзәләр **2.** көпшә ..., көпшәле, көпшәгә утырган; **~ый лук** көпшәгә утырган суган

стрéлян||ый, -ая, -ое **1.** атып үтерелгән, атып төшерелгән; **~ая дичь** атып төшерелгән киек кошлар **2.** (*побывавший в сражениях, боях*) ут астында булган, сугыш астында булган, сугышка кергән, сугышта булган, дары исе иснәгән; **~ый солдáт** ут астында булган солдат **3.** атылган, атып файдаланылган; **~ая гúльза** атылган гильза ◆ **~ый воробéй** карт чыпчык (*күпне күргән, тәҗрибәсе бай кеше турында*)

стреля́||ть *несов.* **1.** ату; **~ть из пистолéта** пистолеттан ату; **~ть ýток** үрдәк ату **2.** *безл.* чатнау; **в прáвом ýхе ~ет** уң колагы чатный ◆ **~ть глазáми** күз ату, күзләрне тиз-тиз йөртеп (карап) алу; **~ть из пýшки по воробья́м** *погов.* ат белән чыпчык куу

стреля́ться *несов. разг.* **1.** (*с целью самоубийства*) атылу, атылып үлү, үз-үзен атып үтерү **2.** *с кем и без доп., уст.* дуэльдә атышу **3.** *страд. от* **стреля́ть** 1

стремглáв *нареч.* бик тиз, атылып, күз ачып йомганчы

стременнóй, -ая, -ое *см.* **стремя́нный**

стрéмечко *с анат.* өзәнге сөяк (*колакта*)

стреми́тельн||ый, -ая, -ое **1.** ургылып ...ган; **~ый потóк** ургылып аккан ташкын сулары **2.** ашкынулы, кызу; ашыгучан; **~ый бег** кызу чабу; **~ая жизнь** ашкынулы тормыш

стреми́ться *несов.* омтылу, ашкыну, атлыгу; **~ к знáниям** белемгә омтылу; **~ к влáсти** властька омтылу

стремлéние *с* омтылу, ашкыну, атлыгу; омтылыш; **~ к мúру** тынычлыкка омтылу

стремни́на *ж* **1.** (*в реке*) ургыл, каты (кызу) агым, тиз агым **2.** *уст.* (*обрыв*) текә яр, текә җир; (*прóпасть*) упкын, төпсез чокыр

стрéмя *с* **1.** өзәнге **2.** *см.* **стрéмечко** ◆ **~ в ~ [éхать, скакáть]** янәшә [бару]

стремя́нка *ж* (*переносная*) күчерелмәле баскыч, җыелма баскыч; (*подвесная*) асылмалы (асма) баскыч, бау баскыч

стремя́нн||ый, -ая, -ое **1.** өзәнге ...ы; **~ые ремни́** өзәнге каешлары **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м уст.* менге атны караучы ялчы; өзәңгече (*Мәскәү Русенда: патшаның тантаналы чыгышы вакытында, гадәттә аның өзәңгесе янында торучы сарай хезмәтчесе*)

стреножúть *сов. кого* кешәнләү

стрéпет *м* сиртмә койрык (*кош*)

стрептокóкк *м мед.* стрептококк

стрéсс *м* (*состояние напряжения*) стресс

стрéссов||ый, -ая, -ое стресс ...ы; **~ое состоя́ние** стресс хәле

стрехá *ж* (*край крыши*) өй кыегының читә (кырые), өй түбәсенең читә (кырые)

стречóк *м*: **дать (задáть) стречкá** *прост.* табан ялтырату, элдертү, таю, шылу, сызу

стригýн, стригунóк *м* кырыкмыш тай

стриж *м* керәшә, яр карлыгачы

стри́жен||ый, -ая, -ое **1.** чәчен кыркытткан, кырыккан чәчле, кыска чәчле; **~ая дéвочка** кырыккан чәчле кыз бала **2.** кыркылган; ботаклары киселгән (кыркылган); **~ая трава́** кыркылган үлән; **~ые дерéвья** ботаклары киселгән агачлар

стри́жка *ж* **1.** *см.* **стричь; 2.** [чәч] кырку ысулы; **мóдная ~** модалы итеп чәчне кырку (кыркыту)

стрихни́н *м* стрихнин (*бик кочле агу*)

стричь *несов. кого-что* кырку, кисү; алу; **~ вóлосы** чәч алу; **~ шерсть** йон кырку; **~ травý** үлән кырку; **~ вéтки** ботак кисү; **~ нóгти** тырнак кисү ◆ **~ [всех] под одну́ гребёнку** [бар кешене дә] бер аршинга үлчәү; бер калыпка сугу

стри́чься *сов.* чәч алдыру, чәчне кыркыту (кистерү)

строга́льщик *м* струклаучы, ышкылаучы, ышкылап шомартучы [эшче]; юнучы

строга́ть *несов. что* струклау, ышкылау; юну

строга́ться *несов.* **1.** струклану, ышкылану; юнылу **2.** *страд. от* **строга́ть**

стрóг||ий, -ая, -ое **1.** таләпчән, үтә таләпчән, таләп итүчән; **~ий нача́льник** таләпчән башлык **2.** коры, житди, кырыс, катгый; **~ий тон** коры тон **3.** [төп-]төгәл, [дәп-]дөрес; каты; **~ий учёт** төгәл учёт **4.** каты; **~ие мéры** каты чаралар; **~ий вы́говор** каты шелтә **5.** әдәп кагыйдәләрен нык саклаучы, әдәп кагыйдәләренә нык буйсынучы; **человéк ~их прáвил** әдәп кагыйдәләрен нык саклаучы кеше **6.** дөрес, төз, матур; **~ий прóфиль** матур профиль **7.** гади; купшы булмаган; **~ий костю́м** гади костюм

стрóгост||ь *ж* **1.** таләпчәнлек; **~ь учи́теля** укытучының таләпчәнлеге **2.** корылык, житдилек, кырыслык; катгыйлык; **~ь тóна** тонның кырыслыгы **3.** төгәллек, дөреслек; катылык; **~ь учёта** учётның төгәллеге **4.** *мн.* **~и** *разг.* каты чаралар, каты тәртип; **ввести́ ~и** каты чаралар күрү ◆ **по всей ~и закóна** закон таләпләренә тулысынча туры китереп

строевúк *м* стровик, строевой гаскәри

строев||óй I, -áя, -óе строй ...ы, строевой; **~áя слýжба** строевой хезмәт; **~ы́е чáсти** строевой частьләр

строевóй II, -áя, -óе төзү ...ы, төзү эшенә ярый торган (яраклы), төзү эшенә китә торган агач

строéние *с* **1.** (*здание, постройка*) бина, корылма; каралты **2.** төзелеш; **~ гла́за** күз төзелеше; **~ гóрных пород** тау токымнары төзелеше

строи́тель *м* төзүче

строи́тельн||ый, -ая, -ое төзү ...ы; төзелеш ...ы; **~ые рабóты** төзү эшләре; **~ые организáции** төзелеш оешмалары

строи́тельск||ий, -ая, -ое төзүче ...ы; төзүче ...; **~ие кáдры** төзүче кадрлар

строи́тельств||о *с* **1.** төзү, салу, кору; **~о жилы́х домóв** торак йортлар төзү **2.** *перен. чего, какое* төзү; төзелеш; **культу́рное ~о** культура төзелеше **3.** төзелеш; **рабóтать на ~е** төзелештә эшләү

стрóить *несов.* **1.** *что и без доп.* төзү, кору, салу; **~ дом** өй салу; **~ завóд** завод төзү **2.** *что и без доп.* (*изготовлять*) төзү, ясау, ясап чыгару; **~ тáнки** танклар ясап чыгару **3.** *перен. что* төзү; кору; **~ óбщество** җәмгыять төзү **4.** *что, мат.* ясау, сызу; **~ ромб** ромб сызу **5.** *что* төзү, оештыру; **~ фрáзу** җөмлә төзү; **~ рабóту по плáну** эшне план буенча оештыру **6.** *что* (*основывать на чём-л.*) ясау; **~ вы́воды** нәтиҗә ясау **7.** *что* төзү; **~ плáны** планнар төзү **8.** *что, воен.* сафка тезү; **~ взвод** взводны сафка тезү ◆ **~ воздýшные зáмки** буш хыяллар белән мавыгу, буш хыялларга бирелү; **~ глáзки** *кому* күз уйнату, каш сикертү; **~ из себя́** *кого* үзеңне ... итеп күрсәтергә тырышу, ... булып күренергә тырышу, ... булып кылану, ...га салышу; **~ из себя́ дурáка** тилегә салышу; **~ кáверзы (кóзни)** төрле мәкерлекләр (явызлыклар) эшләү; **~ на песке́** ком өстенә кору (*ныклы нигезе булмаган нәрсәгә карата әйтелә*); **~ рóжу** йөзен җыерып үчекләү

стро́||иться *несов.* **1.** (*строить для себя*) үзеңә йорт салу, каралты[лар] салу; **2.** төзелү, корылу, салыну; **на вéрфи ~ится кора́бль** верфьта корабль төзелә **3.** *перен.* төзелү, корылу; **~ится нóвая жизнь** яңа тормыш төзелә **4.** (*составляться*) төзелү; **~ятся пла́ны** планнар төзелә **5.** *воен.* сафка тезелү **6.** *страд. от* **стро́ить**

строй *м* **1.** строй, саф; **встать в ~** сафка басу **2.** *чего, какой* төзелеш; **грамматúческий ~ языка́** телнең грамматик төзелеше **3.** строй; **социалисти́ческий ~** социалистик строй; **феода́льный ~** феодаль строй **4.** *муз.* көйләнеш

строй² *кушма сүзләрнең беренче өлеше; «төзү» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **стройматериа́лы** төзү материаллары; **стройрабóты** төзү эшләре

²строй *м кушма сүзләрнең икенче өлеше, «төзү», «төзелеш» дигән мәгънәне белдерә, мәс.* **Днепрострóй** Днепрострой; **Метрострóй** Метрострой

стро́йк||а *ж* 1. төзелеш; төзү эше (эшләре); **прибы́ть на ~у** төзелешкә килү; **рабо́тать на ~е** төзелештә эшләү; **уда́рные ~и пятиле́тки** бишьеллыкның удар төзелешләре 2. корылма; **но́вая ~а** яңа корылма

стро́йность *ж* 1. (*фигуры*) зифалык, сылулык, зифа буйлылык 2. (*правильность расположения*) төзлек, төзеклек 3. (*логичность*) төзеклек, матурлык 4. (*гармоничность*) гармониялелек, аһәңлелек

стро́йн||ый, -ая, -ое 1. зифа, сылу, [матур] сынлы, сын-сыйфатлы, зифа буйлы; (*о частях тела*) матур; **~ая де́вушка** матур сынлы кыз; **~ая фигу́ра** зифа буй; **~ые но́ги** матур аяклар 2. тигез, төз, төзек; **~ые ряды́** төз рәтләр 3. төзек, матур, матур итеп төзелгән; **~ый докла́д** матур итеп төзелгән доклад 4. (*гармонический*) гармонияле; аһәңле, ятышлы, килештереп ..., матур итеп ...; **~ое пе́ние** матур итеп җырлау

стройотря́д *м* төзелеш отряды; **студе́нческий ~** студентларның төзелеш отряды

стройплоща́дка *ж* төзелеш мәйданы

строк||а́ *ж* юл ◆ **кра́сная ~а** кызыл юл; **~а́ в ~у́ [пересказа́ть, списа́ть** *и т.п.*] юлын юлга [*бер сүзен дә төшереп калдырмыйча сөйләп биру, кучереп алу һ.б.ш.*]

стро́нуть *сов. кого-что, разг.* [урыныннан] кузгату, кузгатып җибәрү

стро́нуться *сов. разг.* [урыныннан] кузгалу, кузгалып китү

строп *м* строп (*гондола, аэростат, парашютта*: *бау, аркан яки трос*)

стропи́ло *с* атлама, бәпкә, кайчы

стропи́льный, -ая, -ое атламалык ...ы, бәпкәлек ...ы, кайчылык ...ы, атлама (бәпкә, кайчы) ясый торган; **~ материа́л** атламалык материал

стропти́вый, -ая, -ое кире, үзсүзле; **~ хара́ктер** кире характер

строфа́ *ж лит.* строфа

строчёный, -ая, -ое 1. (*прошитый строчкой*) каелган, буйлап тегелгән 2. (*вышитый строчкой*) буйлап чигелгән

строчи́ть *несов.* 1. *что* каю, буйлап тегү; **~ карма́ны** кесәләрне каю 2. *что и без доп., разг.* тегү; **~ на шве́йной маши́нке** тегү машинасында тегү 3. *перен. что и без доп., разг.* тиз-тиз язу, тиз генә язу; **~ письмо́** тиз-тиз хат язу 4. *разг.* (*стрелять*) ут яудыру (сиптерү), ату; **~ из пулемёта** пулемёттан ут яудыру

стро́чка I *ж* 1. *см.* **строчи́ть** I; 2. җөй; **ме́лкая ~** вак җөй

стро́чк||а II *ж см.* **строка́** ◆ **~а в ~у [пересказа́ть, списа́ть** *и т.п.*] *то же, что* **строка́ в строку́** (*см.* **строка́**)

строчн||о́й, -а́я, -о́е: **~а́я бу́ква** юл хәрефе (*язуда, басмада*)

строчо́к *м* кәҗә гөмбәсе

струг I *м* струк (*рубанок, фуганок кебек кораллардың гомуми атамасы*)

струг II *м уст.* (*речное судно*) струг (*ишкәкле һәм паруслы агач судно*)

струга́ть *несов. см.* **строга́ть**

стру́жка *ж* йомычка

струи́ться *несов.* 1. (*о жидкости*) агу, агып тору 2. *перен.* (*о воздухе, свете, аромате и т.п.*) таралу, чәчелү, сибелү, агылу

стру́йка *ж уменьш. от* **струя́** 1

структу́ра *ж* структура, төзелеш; **~ по́чвы** туфрак структурасы

структу́рн||ый, -ая, -ое структуралы; төзелешле, структура ...ы, төзелеш ...ы; **~ые по́чвы** структуралы туфраклар

струна́ *ж* кыл

стру́нк||а *ж уменьш. от* **струна́** ◆ **в ~у стать (вы́тянуться)** туп-туры басып тору; шәм кебек катып калу; **по ~е ходи́ть** песи кебек йөрү (*тулысынча буйсыну*)

стру́нн||ый, -ая, -ое 1. кыллы; **~ые инструме́нты** кыллы музыка кораллары 2. кыллы музыка кораллары ...ы; **~ый орке́стр** кыллы музыка кораллары оркестры

струп *м* кутыр

стру́сить *сов.* куркып (шүрләп) калу

струхну́ть *сов. разг.* бик нык курку

стручко́вый, -ая, -ое кузаклы; **~ пе́рец** кузаклы борыч

стручо́к *м* кузак

струя́ *ж* 1. агым, агынты; **водяна́я ~** су агымы; **~ во́здуха** һава агымы 2. *перен.* (*направление*) юнәлеш; **све́жая ~ в рабо́те** эштә яңа [бер] юнәлеш

стря́пать *несов. что, разг.* 1. аш-су хәзерләү, аш-су пешерү; **~ обе́д** төшке аш әзерләү 2. *перен.* әвәләү, маташтыру, әвеш-түвеш китерү, ...ып маташу; **~ стишки́** шигырьләр әвәләү

стряпн||я́ *ж разг.* 1. *см.* **стря́пать**; 2. аш, аш-су; **невку́сная ~я́** тәмсез аш 3. *перен. пренебр.* (*о грубом сочинении, пьесе и т.п.*) начар язылган әсәр (пьеса, хикәя *һ.б.ш.*), юньсез әсәр; чүп-чар; **не хо́чется смотре́ть э́ту ~ю** бу чүп-чарны карыйсы килми

стря́пчий *м* стряпчий (1. *ист. Мәскәү Русенда*: *патша сараенда хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүче хезмәтче* 2. *19 йөздә Россиядә*: *суд учреждениеләрендә суд эшларен алып бару тәртибен күзәтүче чиновник*)

стрясти́ *сов. что* селкетеп кою, селкетеп төшерү; **~ я́блоки с де́рева** (алмагачларны) селкетеп алмаларын кою

стряс||ти́сь *сов. разг.* булу, туу, килеп чыгу; **что с тобо́й ~лось?** сиңа ни булды?

стря́хивать *несов. см.* **стряхну́ть**

стряхну́ть *сов.* 1. *кого-что* селкеп (кагып) төшерү 2. *перен. что* котылу; **~ с себя́ тяжёлые мы́сли** авыр уйлардан котылу

студени́ст||ый, -ая, -ое койкасыман; **~ое вещество́** койкасыман матдә

студе́нт *м* студент

студе́нтка *ж* студентка

студе́нческ||ий, -ая, -ое 1. студент ...ы, студентлар ...ы; **~ое общежи́тие** студентлар тулай торагы 2. студент ..., студентлык ...ы; **~ие го́ды** студентлык еллары; **в ~е** студент чакта

студёный, -ая, -ое бик салкын, бик суык

сту́день *м* койкá, дерелдәвек

студи́ец *м* студиядә укучы, студия укучысы

студи́йный, -ая, -ое студия ...ы; студиядән тапшырыла торган

студи́ть *несов. что, разг.* суыту

студи́ться *несов. разг.* суыну

сту́дия *ж в разн. знач.* студия; **~ худо́жника** рәссам студиясе; **~ докумéнта́льных фи́льмов** документаль фильмнар студиясе; **музыка́льная ~** музыкаль студия

сту́жа *ж разг.* каты суык; чатлама суык

стук I *м* шакылдау, тукылдату, шакылдату; дыңгырдау, дыңгырдату, шакылдаган (шакылдаткан) тавыш, дыңгырдаган (дыңгырдаткан) тавыш; **войти́ без ~а** шакылдатмыйча керү; **со ~ом** шап(шак) итеп, шакылдатып

стук II *межд.* 1. тук 2. *в знач. сказ.* шап(шак) итеп сукты; **он ~ кулако́м** ул йодрык белән шап итеп сукты

сту́кать *несов. см.* **сту́кнуть** I

сту́каться *несов. см.* **сту́кнуться**

сту́кну||ть *сов.* 1. сугу; **~ть по спине́** аркага сугу; **~ть кулако́м по столу́** йодрык белән өстәлгә сугу 2. шап итеп сугу; **~ть в окно́** тәрәзәгә шап итеп сугу 3. *разг.* (*наступить, исполниться*) тулу; **ему́ ~ло со́рок** *безл.* аңа кырык яшь тулды ◆ **~ло в го́лову** *кому, прост.* башына сукты

сту́кнуться *сов.* бәрелү; бәрелешү

стукотня́ *ж разг.* шакылдаган тавыш

стул *м* 1. урындык, утыргыч 2. *мед.* тәрәт

стульча́к *м* бәдрәф утыргычы

сту́п||а *ж* киле ◆ **в ~е во́ду толо́чь** юкны бушка аудару

ступа́||ть *несов.* 1. *см.* **ступи́ть** 1; 2. *повел.* **~й[те]** кит[егез]!, бар[ыгыз]! **~й вон!** кит моннан!; **~й к отцу́** этиең янына бар

ступе́нчат||ый, -ая, -ое баскыч-баскыч, киртләч-киртләч, баскычлы, киртләчле; **~ые ска́лы** киртләч-киртләч кыялар

ступе́н||ь *ж* 1. (*часть лестницы*) баскыч, басма 2. (*выступ, уступ*) киртләч, баскыч 3. *перен.* (*этап в развитии, степень развития*) баскыч 4. (*разряд*) дәрәҗә; **значо́к ГТО пе́рвой ~и** беренче дәрәҗә ГТО значогы

ступе́нька *ж уменьш. от* **ступе́нь** 1-3

ступи́ть *сов.* 1. (*шагнуть*) атлау, аяк атлау 2. *на что, разг.* (*шагая, стать*) басу 3. (*войти куда-л.*) атлап керү, аяк атлау, барып керү 4. (*очутиться*) аяк басу

ступи́ца *ж* бүкән, тәгәрмәч бүкәне

сту́пка *ж уменьш. от* **сту́па**

ступня́ *ж* табан, аяк табаны

стуча́||ть *несов.* 1. (*производить шум*) шакылдау, шакылдату, тукылдату; дыңгырдау, дыңгырдату (*посудой*) шалтырату; (*о детях*) туку; (*о сердце*) кагу, сикерү; **зу́бы ~т** тешләр шакылдый 2. *безл.* (*в голове, ушах и т.п.*) дөп-дөп итеп тору, шаулау 3. шакылдату, шаку, кагу; **~ть в дверь** ишек кагу

стуча́ться *несов.* **1.** *разг.* (*ударяться*) бәрелү, шап-шап итеп бәрелү **2.** *см.* **стуча́ть** 3 ♦ **~ в дверь** *чью* ишек (ишеген) кагу (*утенеч белән мөрәҗәгать итү*); **~ в откры́тую дверь** ачык ишекне шаку

стушева́ться *сов.* каушап калу, куркып калу, оялып китү

стушёвываться *несов. см.* **стушева́ться**

стыд *м* **1.** оят, оялу, гарьлек; **покрасне́ть от ~а́** оятыннан кызару; **у тебя́ нет ~а́** синең оятың юк; **испы́тывать ~** *или* **чу́вство ~а́** оялу; **потеря́ть [вся́кий] ~** оятсызланып китү; чиктән тыш әрсезләнеп китү (әрсез, оятсыз булу); **сгоре́ть со ~а́** оятыннан җир тишегенә керердәй (керерлек) булу **2.** *разг.* (*позор*) хурлык; **натерпе́ться ~а́** бик зур хурлыклар күрү ♦ **к ~у́ своему́** оятыма каршы

стыди́ть *несов. кого* **1.** оялту; гарьләндерү **2.** *разг.* (*позорить*) хур итү, хурлыкка төшерү; хурлау

стыди́ться *несов. кого-чего, с неопр. и без доп.* оялу, гарьләнү

стыдли́вость *ж* оялчанлык, оялучанлык

стыдли́вый, -ая, -ое оялчан, оялучан

сты́дно *нареч. и в знач. сказ. безл.* оят; **как тебе́ не ~!** оят түгелмени сиңа!

стык *м* (*берәр нәрсәнең*) тоташкан (тоташтырылган, ялганган, беркетелгән) урыны (жирс), ялганыш, ялганма, ялгау урыны

стыко́вка *ж спец.* тоташу; тоташтырылу

стыково́й, -а́я, -о́е *спец.* тоташкан (тоташтырылган, ялганган, беркетелгән) урынындагы (жирендәге); **~ шов** тоташтырылган урындагы җөй

сты́нуть *несов.* суыну

стыть *несов. см.* **сты́нуть**

сты́чка *ж* бәрелеш

стюа́рд *м* стюард (*диңгез судносында яки самолётта — проводник*)

стюарде́сса *ж* стюардесса

стяг *м высок.* байрак, әлəм

стя́гивать *несов. см.* **стяну́ть** 1-8

стя́гиваться *несов.* **1.** *см.* **стяну́ться; 2.** *страд. от* **стя́гивать**

стяжа́тель *м* байлык җыючы, малмөлкәт җыючы

стяжа́тельница *ж* байлык җыючы хатын (кыз)

стяжа́ть *сов. несов. что, книжн.* казану, ирешү, ия булу; **~ сла́ву** дан казану; **~ изве́стность** исеме таныу

стяну́ть *сов.* **1.** *что* (*затянуть*) (*тагы да катырак*) тартып бәйләү (бәйләп кую), тарттырып бәйләү (бәйләп кую) **2.** *что чем* (*туго перевязать*) кысып бәйләү (бәйләп кую), кысып буу; каты итеп тарттырып кую **3.** *кого-что* (*бер урынга*) жыю, туплау, тарттыру; **~ войска́ к перепра́ве** гәскәрләрне кичү төбенә туплау **4.** *что, тех.* (*скрепить*) очларын тарттыру, тарттырып кую, тарттырып ныгытып кую **5.** *что* [текәндә] тарттыру, җыеру; **~ шов при стро́чке** теккәндә җөен җыеру **6.** *что* тартып алу, тартып төшерү; **~ одея́ло** юрганын тартып алу; **~ ска́терть со стола́** эскәтерне өстәлдән тартып төшерү **7.** *что* (*снять с трудом*) тартып-сузып салу (салдыру), көч-хәл белән салу (салдыру), тартып салдырып алу **8.** *кого-что, разг.* (*украсть*) чәлдерү

стяну́||ться *сов.* **1.** (*затянуться*) каты итеп тартылу (тарттырылу), кысылу, кысып бәйләнү **2.** *разг.* (*стянуть себя чем-л.*) кысып бәйләү (бәйләп кую), кысып буу, каты итеп тарттырып кую (*мәс. билне*) **3.** тартылу, җыерылу; **шов ~лся** җөе җыерылды **4.** [бер җиргә] җыелу, туплану; **войска́ ~лись к перепра́ве** гаскәрләр кичү төбенә тупландылар

суббо́та *ж* шимбә [көн]

суббо́тний, -яя, -ее шимбә ...; **~ ве́чер** шимбә кич

суббо́тник *м* шимбә өмәсе, өмә; **предпра́здничный ~** бәйрәм алды өмәсе

субордина́ция *ж* субординация (*хезмәттә түбән чинлыларның югары чинлыларга буйсынуы*)

субсиди́ровать *сов., несов. кого-что* субсидия бирү, акчалата ярдәм бирү

субси́дия *ж* субсидия, акчалата ярдәм

субста́нция *ж* субстанция (**1.** *филос. метафизик философиядә*: *әйберләрнең үзгәрмәс асылы* **2.** *книжн. берәр нәрсәнең асылы, нигезе, төп җирлеге*)

субстра́т *м* **1.** *филос.* субстрат **2.** *спец.* субстрат, җирлек

субти́льный, -ая, -ое нечкә, нәзек

субтро́пики *только мн.* субтропиклар

субтропи́ческий, -ая, -ое субтропик, тропик тирәсендәге; **~ кли́мат** субтропик климат

субъе́кт *м* **1.** *филос., юр., мед.* шәхес **2.** *разг.* зат, кеше **3.** *лог.* субъект **4.** *грам.* ия, субъект

субъективи́зм *м* **1.** *филос.* субъективизм (*философиядә идеалистик юнәлеш*) **2.** (*отсутствие объективности*) субъективлык, берьяклылык

субъективи́ст *м* субъективист, субъективизм тарафдары

субъективи́стск||ий, -ая, -ое *филос.* субъективистик; **~ое толкова́ние** субъективистик аңлау

субъекти́вн||ый, -ая, -ое **1.** *книжн.* субъектив, шәхси; **~ый фа́ктор в исто́рии** тарихта субъектив фактор; **~ые пережива́ния** субъектив кичерешләр **2.** субъектив, берьяклы; **~ое мне́ние** субъектив фикер

сувени́р *м* бүләк, истәлекле бүләк, ядкарь; сагынмалык

суверените́т *м* суверенитет, суверенлык, мөстәкыйльлек

сувере́нн||ый, -ая, -ое суверен, мөстәкыйль; **~ые госуда́рства** суверен дәүләтләр

суво́ровец *м* суворовчы

сувóровск||ий, -ая, -ое: **~ое учи́лище** суворовское училище

сугли́нист||ый, -ая, -ое балчыксыл; **~ые зе́мли** балчыксыл туфраклар

сугли́нок *м* балчыксыл түфрак

сугро́б *м* көрт (*кар өеме*)

суго́уб||ый, -ая, -ое аеруча зур (көчле); **прояви́ть ~ое внима́ние** аеруча зур игътибар күрсәтү

суд *м* **1.** суд; **наро́дный ~** халык суды; **това́рищеский ~** интәшләр суды **2.** *собир.* судьялар; суд; **совеща́ние ~а́** суд киңәшмәсе **3.** (*разбирательство*) суд, хөкем; **отда́ть под ~** судка бирү; **попа́сть под ~** судка эләгү; **привле́чь к ~у́** хөкемгә тарту **4.** (*суждение, мнение*) фикер, хөкем; **отдава́ть на ~** *чей-л.* ~ хөкеменә бирү (тапшыру) ♦ **пока́ ~ да де́ло** ул-бу булганчы, ул-бу булган арада, алай-болай иткәнче

суда́к *м* судак, судак балыгы

суда́рыня *ж уст.* ханым

су́дарь *м уст.* сударь

суда́чить *несов. разг.* гайбәт сату, ләчтит сату

суде́бн||ый, -ая, -ое суд ...ы; **~ое заседа́ние** суд утырышы

суде́йск||ий, -ая, -ое судья[лар] ...ы; **~ие обя́занности** судья вазифалары; **~ая колле́гия** судьялар коллегиясе

суде́йство *с спорт.* судья вазифасы

суди́лище *с ирон.* суд, хөкем

суди́мость *ж* суд хөкеме; хөкемгә тартылу; хөкем ителү; **снять ~** суд хөкемен алу; **име́ть ~** судка (хөкемгә) тартылган булу

суди́ть **1.** *несов. о ком-чём и без доп.* (*составлять мнение*) фикер йөртү, хөкем кылу (итү), бәя бирү, уйлау; **~ по со́бственному о́пыту** үз тәжрибәннән чыгып фикер йөртү; **о челове́ке су́дят по его́ дела́м** эшенә карап кешегә бәя бирәләр **2.** *несов. кого-что* (*осуждать*) яманлау, тикшерү, гаепләү **3.** *несов. кого-что* (*преступника и т.п.*) хөкем итү, суд ясау **4.** *несов. что и без доп., спорт.* судья вазифасын үтәү **5.** *несов., сов. что и с неопр.* язу, насыйп булу, насыйп итү; **мне не суждено́ бо́льше встре́титься с ним** минә аның белән тагын очрашырга язмаган ♦ **~ да ряди́ть** *прост.* төрлечә фикер йөртү

суди́ться *несов. с кем* судлашу

су́дно I *с* судно (*пароход, корабль*)

су́дно II *с* судно, тәрәт савыты (*урында ятып авыручылар өчен*)

су́дный, -ая, -ое: **~ день** *рел.* хисап көне, мәхшәр (кыямәт) көне

судове́рфь *ж* судоверфь, суднолар төзү верфе

судоводи́тель *м* суднолар йөртүче (*белгеч*)

судовожде́ние *с* суднолар йөртү; суднолар йөртү осталыгы

судово́й, -а́я, -о́е судно ...ы, суднода эшләүче; **~ меха́ник** судно механигы; **~ журна́л** судно журналы

суд||о́к *м* **1.** (*чашка, миска*) савыт (*каймак, соус һ.б.ш. савыты*) **2.** (*столовый прибор*) судок (*борыч, серкә, горчица савытларын бергә утыртып йөртә торган ое*) **3.** *мн.* **~ки́** судки (*кайнар аш салып берсе өстенә берсен куеп йөртә торган мискилəр*)

судомо́йка *ж* савыт-саба (кашык-аяк) юучы (*хатын-кыз*)

судопроизво́дство *с* суд эшләрен башкару

судремо́нт *м* суднолар ремонтлау

судремо́нтный, -ая, -ое суднолар ремонтлау ...ы; ~ **заво́д** суднолар ремонтлау заводы

су́дорога *ж* көзән җыеру, тартышу, тамыр тартышу

су́дорож||ный, -ая, -ое **1.** тартышулы, көзән җыерулы; калтыранулы, калтыранып; (*о плаче*) сулкылдап ...; ~**ые движе́ния** калтыранулы хәрәкәтләр **2.** *перен.* ашык-пошык ..., ыгы-зыгылы; ~**ые сбо́ры** ашык-пошык җыенулар

судострое́ние *с* суднолар төзү (ясау)

судоустро́йство *с* суд корылышы, суд төзелеше

судохо́д||ный, -ая, -ое суднолар йөрешле, суднолар йөрерлек, суднолар йөри торган; ~**ая река́** суднолар йөрерлек елга

судохо́дство *с* судночылык, суднолар йөреше; суднолар йөрү; **морско́е** ~ диңгез судночылыгы

судьб||а́ *ж в разн. знач.* язмыш; тәкъдир; **бро́сить на произво́л** ~**ы́** язмыш кочагына [китереп] ташлау; **ве́рить в** ~**у́** язмышка ышану; **жа́ловаться на** ~**у́** язмыштан зарлану; **определи́ть дальне́йшую** ~**у́** язмышын билгелә; **от** ~**ы́ не уйти́** *погов.* язмыштан узмыш юк; **покори́ться** ~**е́** *или* **примири́ться (смири́ться) с** ~**о́й** язмышка буйсыну; **связа́ть свою́** ~**у́** *с кем-л.* язмышларны ... бәйләү ♦ **каки́ми** ~**а́ми?** нинди җилләр ташлады?; **не** ~**а́** [алла] язмаган, тәкъдир түгел

судьби́на *ж уст. см.* **судьба́**; **го́рькая** ~ ачы язмыш

судья́ *м в разн. знач.* судья, хаким; казый (*уст. рел.*); **наро́дный** ~ халык судьясы; ~ **пе́рвой катего́рии** *спорт.* беренче категорияле судья; **он в э́том де́ле не** ~ бу эшне ул белми; бу турыда ул хөкем йөртә алмый

су́дя: ~ **по** *чему* караганда; ~ **по его́ ви́ду** анын кыяфәтенә караганда

суеве́рие *с* хорафат, юк-барга ышану

суеве́рный, -ая, -ое хорафатка (юк-барга) ышанучы, юк-барга ышанучан

суесло́вие *с уст.* юк-бар сүзләр, сафсата, ләчтит; буш сүзләр

суета́ *ж* **1.** (*мелочные дела, интересы*) юк-бар эш, юк-бар нәрсә **2.** (*хлопоты, беготня*) мәшәкать, ыгы-зыгы; ыгы-зыгы килү, ашык-пошык йөрү (йөгерү), әрле-бирле килү ♦ ~ **суе́т** дөнья ыгы-зыгысы, дөнья мәшәкатьләре

суети́ться *несов.* ыгы-зыгы килү, ашык-пошык йөрү (йөгерү), әрле-бирле килү

суетли́в||ый, -ая, -ое **1.** ыгы-зыгы килүчән, тынычсыз, тынгысыз; ~**ый челове́к** ыгы-зыгы килүчән кеше **2.** ашык-пошык килгән, ыгы-зыгылы; ~**ые движе́ния** ыгы-зыгылы хәрәкәтләр

су́етность *ж см.* **суета́** 1

су́етн||ый, -ая, -ое *книжн.* **1.** юк-бар, вак-төяк, буш; ~**ые жела́ния** буш теләкләр **2.** борчулы, ыгы-зыгылы, тынычсыз, тынгысыз; ~**ый день** борчулы көн

суетня́ *ж разг. см.* **суета́** 2

сужа́ть *несов. см.* **су́зить**

сужа́ться *несов.* **1.** *см.* **су́зиться**; **2.** *страд. от* **сужа́ть**

сужде́ние *с* **1.** (*мнение*) фикер, уй, фикер йөртү **2.** (*заключение*) хөкем; **вы́нести на** *чьё-л.* ~ хөкеменә тапшыру, карамагына тапшыру **3.** *лог.* хөкем

су́женая *ж фольк.* кәләш, ярәшкән кыз

суже́ние *с см.* **су́зить, су́зиться**; ~ **ру́сла реки́** елганың тараюы; ~ **пищево́да** *мед.* уңәчнең тараюы

су́женый *м фольк.* кияү буласы кеше; кыз ярәшкән егет

су́живать *несов. см.* **су́зить**

су́живаться *несов.* **1.** *см.* **су́зиться**; **2.** *страд. от* **су́живать**

су́зить *сов. прям., перен. что* тарайту; ~ **пла́тье** күлмәкне тарайту; ~ **значе́ние сло́ва** сүзнең мәгънәсен тарайту

су́зиться *сов. прям., перен.* тараю

сук *м* ботак

су́ка *ж* ана эт, әнчек

сукно́ *с* постау, сукно ♦ **под** ~ **положи́ть** (*дело, просьбу и т.п.*) сукно астына кую

сукнова́льн||ый, -ая, -ое постау (сукно) басу ...ы, постау (сукно) баса торган; постау (сукно) басканда кулланыла торган; ~**ая маши́на** постау басу машинасы; ~**ая гли́на** постау басканда кулланыла торган балчык

сукова́т||ый, -ая, -ое ботаклы, күп ботаклы; ~**ая па́лка** ботаклы таяк

суко́нка *ж* постау (сукно) кисәге

суко́нн||ый, -ая, -ое **1.** постау (сукно) ..., постаудан (сукнодан) тегелгән; ~**ые бро́ки** сукно чалбар **2.** постау (сукно) ...ы, постау (сукно) эшләп чыгара торган; ~**ая фа́брика** постау (сукно) фабрикасы ♦ ~**ый язы́к** ярлы тел

су́кровица *ж* сүл; канлы эрен

су́кровичн||ый, -ая, -ое сүлле, сүл ...ы; канлы эренле, канлы эрен ...ы; ~**ые пя́тна** канлы эрен таплары

сулема́ *ж* сүләмә (*агулы матдә*)

сули́ть *несов.* **1.** *что и с неопр., прост.* (*обещать*) вәгъдә итү, ышандыру **2.** *что* (*предвещать*) [алдан] күрсәтү, күрсәтеп тору; [алдан] әйтү, әйтеп тору, хәбәр бирү

султа́н I *м* (*титул*) солтан

султа́н II *м* (*украшение*) солтан (*баш киеменә яки ат башына кадап куела торган каурыйлар яисә кыл чук*)

сум||а́ *ж уст.* букча; калта ♦ **пусти́ть с** ~**о́й** хәерчелеккә төшерү, бөлдерү; **ходи́ть с** ~**о́й** хәер эстәү, хәер эстәп йөрү, соранып йөрү; ~**а́ перемётная** 1) хурҗин; 2) *перен.* аумакай [кеше]

сумасбро́д *м* дуамал баш, дуамал кеше

сумасбро́дка *ж* дуамал хатын (кыз)

сумасбро́дничать *несов.* дуамаллану

сумасбро́дный, -ая, -ое дуамал

сумасбро́дство *с* дуамаллык

сумасше́дш||ий, -ая, -ее **1.** акылдан язган, дивана, тиле **2.** *в знач. сущ.* ~**ий** *м*, ~**ая** *ж* акылдан язган [кеше], дивана [кеше] **3.** *разг.* (*безрассудный*) акылсыз; дуамал **4.** *разг.* (*невероятный по силе и т.п.*) чиктән тыш зур (югары, көчле), акылга сыймаслык ...; ~**ие це́ны** чиктән тыш югары бәяләр

сумасше́стви||е *с* **1.** (*потеря рассудка*) акылдан язу, акылдан сабу, акылдан язганлык **2.** *разг.* (*безрассудство*) акылсызлык, дуамаллык ♦ **до** ~**я** акылдан язарлык дәрәҗәдә, искиткеч, гажәп

сумато́ха *ж* ыгы-зыгы, шау-шу, мәхшәр

сумато́шливый, -ая, -ое, **сумато́шный**, -ая, -ое *разг.* **1.** (*о человеке*) ыгы-зыгы килүчән, ашык-пошык килүчән (эшләүчән, йөрүчән) **2.** ыгы-зыгылы, шау-шулы; ~ **день** ыгы-зыгылы көн

сумбу́р *м* чиктән тыш буталчыклык, чуалчыклык; мәгънәсезлек

сумбу́рный, -ая, -ое (*путаный*) чиктән тыш буталчык, чуалчык, мәгънәсез

су́меречн||ый, -ая, -ое **1.** эңгер-меңгер, караңгылы-яктылы; ~**ое вре́мя** эңгер-меңгер вакыт (күз бәйләнгән чак) **2.** караңгылы-яктылы, ярым караңгы; төмсә, салынкы; ~**ый день** төмсә көн; ~**ый коридо́р** ярым караңгы коридор **3.** *перен.* (*безрадостный*) күңелсез, рухсыз, җансыз, сүрән; төшенке; ~**ая жизнь** күңелсез тормыш; ~**ое настрое́ние** төшенке күңел **4.** *зоол.* эңгер-меңгер чакта йөрергә чыга торган (*хайван турында*) ♦ ~**ое состоя́ние** *мед.* аңгы-миңге хәл (*кайбер психик авырулар белән авырганда*)

су́мерки *только мн.* эңгер-меңгер; эңгер-меңгер вакыт (чак), караңгылы-яктылы вакыт (чак), күз бәйләнгән чак; икенде ахшам арасы

суме́рничать *несов. разг.* эңгер-меңгер вакытны ут кабызмыйча гына сөйләшеп үткәрү, икенде ахшам арасында ут кабызмыйча сөйләшеп утыру

сумéть *сов. с неопр.* ...а алу, булдыра алу; ~ **отве́тить** җавап бирә алу; ~ **сде́лать** эшли алу

су́мка *ж* букча, сумка

су́мм||а *ж* **1.** *мат.* сумма **2.** (*совокупность*) җыенысы, барлыгы, барысы, җәмгысы, җәмгы; **вся** ~**а челове́ческих зна́ний** кешелек белемнәренең барлыгы **3.** (*количество денег*) сумма, сума, акча ♦ **в** ~**е** барысын бергә алганда, нәтиҗәдә

сумма́рн||ый, -ая, -ое **1.** кушу нәтиҗәсендә (нәтиҗәдә) килеп чыккан; ~**ое коли́чество** кушу нәтиҗәсендә килеп чыккан сан **2.** гомуми, гомуми рәвештә ..., гомумиләштерелгән; ~**ые све́дения** гомумиләштерелгән мәгълүматлар

суммúровать *сов., несов. что* **1.** (*подвести итог*) суммасын чыгару, кушып гомуми суммасын чыгару, хисаплап чыгару; ~ **расхо́ды** чыгымнарның суммасын хисаплап чыгару **2.** (*обобщить*) гомумиләштерү, гомум нәтиҗә чыгару, гомумиләштереп нәтиҗә чыгару; ~ **о́пыт** [алынган] тәжрибәне гомумиләштереп нәтиҗә чыгару

СУМ-СУХ

суммиро́ваться 1. *сов., несов.* гомуми́ләшү 2. *несов. страд. от* **суммиро́вать**

су́мничать *сов. разг.* акыл сату, мәгез чыгару

сумня́ся, сумня́шеся: ничто́же ~ һич тә уйлап-нитеп тормастан, һич тә икеләнмичә, шикләнмичә, шикләнминитми

су́мрак *м* ярым караңгылык

су́мрачность *ж* 1. (*сумрак*) ярым караңгылык 2. *перен.* (*мрачность*) кәефсезлек, күңелсезлек, боеклык, караңгы чырайлылык

су́мрачн||ый, -ая, -ое 1. ярым караңгы, караңгылы-яктылы; **~ая ко́мната** ярым караңгы бүлмә 2. төмсә, салынкы; шыксыз; **~ый день** салынкы көн 3. *перен.* караңгы, төксе, кәефсез, күңелсез; боек, караңгы чырайлы; **~ые мы́сли** күңелсез уйлар; **~ое лицо́** караңгы чырай

су́мчат||ый, -ая, -ое 1. *зоол., бот.* букчалы; **~ые живо́тные** букчалы хайваннар 2. *в знач. сущ.* **~ые** *мн. зоол.* букчалылар

сумя́тица *ж разг.* ыгы-зыгы, шау-шу, гауга, кыямәт, мәхшәр

сундýк *м* сандык

су́нна *ж рел.* сөннәт (*Коръәнгә өстәмәләр һәм аңлатмалар белән бергә Мөхәммәт пәйгамбәр турында риваятьләр*)

су́нуть *сов. см.* **сова́ть**

су́нуться *сов. см.* **сова́ться**

суп *м* шулпа; **го́дный на ~ (для ~а)** шулпалык

супер- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә түбәндәгечә тәрҗемә ителә*: 1) *«кабат, икенче», «икенче тапкыр» дигән сүзләр белән, мәс.* **суперинфе́кция** икенче тапкыр инфекция әләгү; 2) *«баш», «башлык» дигән сүзләр белән*: **суперинтенда́нт** баш интендант; 3) *«иң югары»; «иң зур», «иң яхшы» кебек мәгънәләрне белдергәндә тәрҗемә ителми, мәс.* **суперла́йнер** суперлайнер; **суперцеме́нт** суперцемент; 4) *«бер әр нәрсәнең тышында булуны» белдергәндә шулай ук тәрҗемә ителми, мәс.* **суперобло́жка** супертышлык

суперарби́тр *м* суперарбитр (*иң соңгы карарны чыгаручы арбитр*)

супермен *м ирон.* супермен (*узен бар кешедән дә өстен санаган кеше*)

суперобло́жка *ж* супертышлык (*китапның катыргы тышы өстенә куелган кәгазь тышлык*)

супертáнкер *м* супертанкер (*йөз мең тоннадан артыграк йөк сыешлы танкер*)

суперфосфа́т *м хим.* суперфосфат

су́песок *м* комлы (комсыл) туфрак

супесча́н||ый, -ая, -ое комсу, комсыл; **~ая по́чва** комсу туфрак

су́песь *ж см.* **су́песок**

супов||о́й, -а́я, -о́е 1. шулпа ...ы; **~а́я кастрю́ля** шулпа кастрюле 2. шулпалык; **~о́е мя́со** шулпалык ит

супо́нь *ж* чөелдерек

супоро́сая, супоро́сная *ж* буаз (*дуңгыз турында*)

супоста́т *м уст.* дошман, явыз [кеше]

супру́г *м* ир, [берәүнең] ире

супру́га *ж* хатын, [берәүнең] хатыны

супру́ги *мн.* ирле-хатынлы, ир белән хатын

супру́жеск||ий, -ая, -ое ирле-хатынлы, ир белән хатын ...ы; **~ая жизнь** ир белән хатын тормышы; **~ая па́ра** ир белән хатын

супру́жество *с* (*брак*) өйләнү; кияүгә чыгу, тормышка чыгу; гаилә кору (корып җибәрү); (*брачная жизнь*) ирле-хатынлы булу, ирле-хатынлы яшәү

сургу́ч *м* сургуч, сургыч

сургу́чн||ый, -ая, -ое сургуч ..., сургыч ...; сургучтан (сургычтан) ясалган; **~ая печа́ть** сургыч печать

сурди́нк||а *ж*: **под ~у** яшерен, бердермичә, сиздермичә генә, әкрен генә (*әйтү, эшләү*)

сурдока́мера *ж* сурдокамера (*космонавтларны абсолют тынлыкта эшләргә әзерләү өчен файдаланыла торган махсус бүлмә*)

сурдопедаго́гика *ж* сурдопедагогика (*чукрак, шулай ук начар ишетүче балаларны тәрбияләү һәм укыту турындагы фән*)

суре́пица *ж бот.* 1. шепкән 2. *см.* **суре́пка**

суре́пка *ж бот.* эт какысы

суре́пн||ый, -ая, -ое шепкән ...ы; **~ое ма́сло** шепкән мае

су́рик *м* сурик (*кызгылт-сары яки кызгылт-көрән төстәге буяу*)

су́риковый, -ая, -ое кызгылт-сары, кызгылт-көрән

сурко́в||ый, -ая, -ое байбак ...ы; сөркә ...ы; **~ая но́рка** байбак өне

суро́веть *несов.* кырыслана бару; кискенләшә бару

суро́вость *ж* 1. катылык, салкынлык; **~ зимы́** кышның салкынлыгы 2. авырлык, ачылык; **~ слов** сүзләрнең авырлыгы 3. катылык, кырыслык; **~ хара́ктера** характерның кырыслыгы 4. катылык; **~ кри́тики** тәнкыйтьнең катылыгы

суро́в||ый I, -ая, -ое 1. каты, салкын; **~ая зима́** салкын кыш 2. авыр, ачы; **~ая до́ля** ачы язмыш; **~ые слова́** авыр сүзләр 3. каты, кырыс; **~ый челове́к** кырыс кеше 4. каты; **~ая кри́тика** каты тәнкыйть; **~ый приговóр** каты хөкем

суро́в||ый II, -ая, -ое (*небелёный — о ткани и т.п.*) чи, агартылмаган; **~ое полотно́** агартылмаган киндер; **~ые ни́тки** тегәрҗен

суро́к *м* байбак, сөркә ♦ **спать как ~** байбак кебек йоклау (*уянмыйча йоклау, озак йоклау*)

суррога́т *м* суррогат

суррога́тный, -ая, -ое суррогат ...; **~ проду́кт** суррогат продукт

сурьма́ *ж* сөрмә

сурьми́ть *несов. что* сөрмәләү, сөрмә тарту

суса́льн||ый, -ая, -ое 1. сусаль; **~ое зо́лото** сусаль алтын 2. *перен.* артык төче, сентименталь; **~ые разгово́ры** артык төче сүзләр

су́слик *м* йомран

су́слич||ий, -ья, -ье йомран ...ы; **~ья нора́** йомран өне

су́сло *с* сосла

суста́в *м* буын; буынтык

суставно́й, -а́я, -о́е буын ...ы, буыннарда була торган; **~ ревмати́зм** буын ревматизмы

суста́вчатый, -ая, -ое *биол., тех.* буынлы, буынтыклы, буын-буын..., [аерым] буынтыклардан торган; **~ сте́бель** буынтыклы сабак

сута́ж *м* сутаж (*бизәү өчен кулланыла торган үреп әзерләнгән яссы юка ефәк шнур*)

сута́на *ж* сутана (*католик руханиларының өс киеме*)

сутенёр *м* сутенёр, «ата мәче» (*фахишә акчасына яшәүче ир кеше*)

су́тки *только мн.* тәүлек; **в тече́ние су́ток** бер тәүлек эчендә

су́толока *ж* ыгы-зыгы, шау-шу, этеш-төртеш

су́точн||ый, -ая, -ое 1. тәүлекле, бер тәүлеклек, бер тәүлеккә җитәрлек, бер тәүлек эчендә булган; **~ый запа́с продово́льствия** бер тәүлеклек азык запасы 2. *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* тәүлеклек акча (*командировкада булган көннәр өчен түләнә торган акча*)

суту́лить *несов. что* аз гына бөкрәйтү, аркасын чыгару

суту́литься *несов.* аз гына бөкрәю, бөкрәя төшү, аркасын чыгару

суту́лый, -ая, -ое аз гына бөкре, аз гына аркасы чыккан

сут||ь I *ж* асылы, төп нигезе, төп җирлеге; **~ь де́ла** эшнең асылы; **по ~и де́ла** чынында, асылда

суть II *уст. «быть» фигыленең күплектә кулланыла торган 3-нче зат хәзерге заман формасы;* булу, булып тору; **во́инская учёба и дисципли́на ~ осно́ва боеспосо́бности а́рмии** хәрби уку һәм дисциплина армиянең сугышчанлык сәләтенең нигезе [ул] ♦ **э́то не ~ ва́жно** бу ул кадәр әһәмиятле түгел, моның әһәмияте әллә ни зур түгел

сутя́га *м, ж разг. см.* **сутя́жник**

сутя́жник *м* дәгъвачыл, дәгъвалашып (судлашып) йөрергә яратучы кеше

сутя́жнический, -ая, -ое дәгъвачыл кешегә хас, дәгъвалашып (судлашып) йөрүне яратучыга хас

сутя́жничество *с* дәгъвачыллык, дәгъвалашып (судлашып) йөрергә яратучанлык

суфле́ *с нескл.* суфле (1. *составында тугланган йомырка агы булган төрле кондитер әйберләрнең исеме* 2. *мороженый хәзерләү өчен шикәрле сөт яки сөт осте*)

суфлёр *м* суфлёр

суфлёрск||ий, -ая, -ое суфлёр ...ы; **~ая бу́дка** суфлёр будкасы

суфли́ровать *несов.* суфлёрлык итү, суфлёр булу, суфлёр булып эшләү

су́ффикс *м грам.* суффикс, кушымча

суффикса́льный, -ая, -ое *грам.* суффиксаль, суффиксы булган, суффикслы

сухáрница *ж* сохарый савыты

сухáрный, -ая, -ое сохарый ...ы, сохарыйдан ясалган; **~ квас** сохарый квасы

сухáрь *м* 1. сохарый 2. *разг.* (*о человеке*) коры кеше, каты күнелле кеше

су́хо *нареч.* 1. коры, салкын; **~ приня́ть** *кого-что-л.* салкын кабул итү 2. *в знач. сказ. безл.* коры, кипкән; **на у́лице ~** урамда коры 3. *в знач. сказ. безл.* кибү (*в ф. 3-го л. прош. вр.*); **у меня́ в го́рле ~** тамагым кипкән

сухове́й *м* коры (кызу) җил

сухогру́з *м* коры йөк ташый торган судно (баржа)

сухогру́зн||ый, -ая, -ое коры йөк ташый торган; **~ая ба́ржа** коры йөк ташый торган баржа

суходо́л *м* үзәнлек, коры үзәнлек

суходо́льн||ый, -ая, -ое [коры] үзәнлек ...ы, [коры] үзәнлектә үсә торган; **~ая расти́тельность** үзәнлектә үсә торган үсемлекләр

сухожи́лие *с* сеңер

сух||о́й, -а́я, -о́е 1. (*не содержащий влаги*) коры; **~о́е полоте́нце** коры сөлге; **~и́е дрова́** коры утын; **~о́й по́рох** коры дары; **~а́я доро́га** коры юл; **~о́й кли́мат** коры климат; **~о́е ле́то** коры җәй 2. коры, корыган; **~а́я ве́тка** корыган ботак 3. сусыз, суы беткән, [суы] кипкән, коры; **~о́й коло́дец** сусыз кое 4. кипкән, киптерелгән, киптереп әзерләнгән; **~и́е фру́кты** кипкән җимешләр; **~о́е молоко́** киптереп әзерләнгән сөт 5. *разг.* (*сохощавый*) чандыр, коры сөякле, ябык 6. *перен.* коры, салкын; **~о́й тон** коры тон; **~ой челове́к** коры кеше; **~а́я гроза́** коры яшен; **~а́я перего́нка** корылай куу (*мәс. спиртны*); **~а́я пи́ща** коры аш, корысары; **~о́й зако́н** коры закон (*эчүчелеккә каршы закон*); **~о́й ка́шель** *мед.* коры ютәл; **~о́й ни́тки не оста́лось** *на ком* коры җире калмаган, манма су булган

сухолюби́вый, -ая, -ое *бот.* (*о растениях*) коры җирдә үсә торган, коры җирне ярата торган (яратучан)

сухомя́тка *ж разг.* коры аш, корысары (*ашамлык турында*)

сухопа́рый, -ая, -ое *разг.* чандыр, коры сөякле; ябык; **~ стари́к** чандыр карт

сухопу́тн||ый, -ая, -ое коры җир ...ы; **~ая а́рмия** коры җир армиясе; **~ый тра́нспорт** коры җир транспорты; **~ые живо́тные** коры җир хайваннары

сухопу́тье *с разг.* коры җир юлы (*су юлы түгел*)

сухору́кий, -ая, -ое *разг.* чулак, корыган куллы

сухосто́й *м* 1. *собир.* коры-сары (*тамырында корыган агачлар, куаклар*) 2. *с.-х.* (*период перед отёлом*) сөт ташлаган вакыт, сыер ташлаткан вакыт

сухосто́йн||ый, -ая, -ое 1. тамырында корыган; **~ые дере́вья** тамырында корыган агачлар 2. *с.-х.* сөт ташлаган; **~ый пери́од** сөт ташлаган чор; **~ые коро́вы** сөт ташлаган сыерлар

сухота́ *ж* 1. (*сухость*) кипкәнлек; **~ во рту́** авызның кипкәнлеге 2. *разг.* (*сушь*) корылык, эссе коры һава (*нава торышы турында*)

сухо́тка *ж прост.* корып кибү авыруы

сухофру́кты *только мн.* кипкән җиләк-җимеш, кипкән (киптерелгән) җимешләр

сухоща́вость *ж* чандырлык, ябыклык, коры сөяклелек

сухоща́вый, -ая, -ое чандыр, ябык, коры сөякле

сучёный, -ая, -ое бөтерелгән, катылган (*җеп турында*)

сучи́льный, -ая, -ое җеп бөтерү ...ы, җеп кату ...ы; җеп катлау ...ы; **~ аппара́т** җеп кату аппараты

сучи́ть *несов. что* бөтерү, кату, [җеп] катлау; **~ ни́тки** җеп кату ♦ **~ но́жками** тыпырчыну

су́чка *ж уменьш. от* **су́ка**

сучкова́тый, -ая, -ое ботаклы

сучо́к *м уменьш. от* **сук ♦ без сучка́, без задо́ринки** шоп-шома [гына], улбусыз, һичбер нинди тоткарлыксыз

сушё||ное *с* 1. *см.* **суши́ть** 1; **~ие фру́ктов** җимешләр киптерү 2. *мн.* **~ья** киптерелгән җиләк-җимеш, кипкән җиләк-җимеш

сушён||ый, -ая, -ое киптерелгән; кипкән; **~ые грибы́** кипкән гөмбә; **~ая ры́ба** кипкән балык

суши́лка *ж* 1. (*аппарат*) ашлык киптергеч 2. (*помещение*) ашлык киптерү урыны (*бина, булмә*)

суши́льный, -ая, -ое киптерү ...ы, киптереп әзерләү ...ы; **~ аппара́т** киптерү аппараты

суши́льня *ж см.* **суши́лка**

суши́ть *несов.* 1. *что* киптерү; **~ фру́кты** җимеш киптерү; **~ траву́** үлән киптерү 2. *что* киптерү, корыту; **таба́к су́шит го́рло** тәмәке тамакны киптерә; **пали́ще со́лнце су́шит расти́тельность** кызу кояш үсемлекне корыта 3. *перен. кого* (*делать худым, болезненным*) киптерү, ябыктыру, арыгайту 4. *перен. кого-что* (*делать чёрствым*) каты күңелле итү (ясау), мәрхәмәтсез (шәфкатьсез) итү, мәрхәмәтсезләндерү, шәфкатьсезләндерү

суши́ться *несов.* 1. (*сушить одежду на себе*) өс-башны киптерү, кибенү 2. (*сохнуть*) кибү; **бельё су́шится** кер кибә

су́шка *ж* 1. *см.* **суши́ть** 1, 2; 2. (*баранка*) сушка, коры вак клиндер

сушь *ж разг.* 1. корылык, иң эссе һәм яңгырсыз вакыт, челлә [вакыт]; **ию́льская ~** июль аендагы корылык 2. (*сухая земля, растения и т.п.*) коры җир; корысары, корыган агачлар

суще́ственность *ж* әһәмиятлелек, мөһимлек

суще́ственн||ый, -ая, -ое төп, зур, әһәмиятле, мөһим, житди; **~ый при́знак** *чего-л. бәрәр нәрсәнең* төп билгесе; **~ый вопро́с** мөһим мәсьәлә; **~ая ра́зница** житди аерма

существи́тельное *с грам.* исем; **и́мя ~** исем

существ||о́ I *с* асыл, нигез, төп, төп нигез; **говори́ть по ~у́** төп мәсьәлә буенча сөйләү; **по ~у́ [говоря́]** *в знач. вводн. сл.* асылда, нигездә, чынында

существо́ II *с* зат, адәм, кеше; хайван; тереклек иясе, җан иясе; **живо́е ~** тереклек иясе, җан иясе ♦ **всем ~м** бөтен барлыгы белән

существова́ни||е *с* 1. (*жизнь*) яшәү; яшәеш, тормыш, көнкүреш; **борьба́ за ~е** яшәү өчен көрәш 2. барлык, бар булу, булу; **я забы́л о ~и э́той кни́ги** мин бу китапның барлыгы турында онытканмын

существ||ова́ть *несов.* 1. яшәү, яшәп килү; бар булу; **книгопеча́тание ~у́ет давно́** китап басу куптән яшәп килә 2. *чем, на что* яшәү, тереклек итү, көн күрү; **~ова́ть сво́им трудо́м** үз хезмәте белән көн күрү

су́щ||ий, -ая, -ее чын, чып-чын, чын мәгънәдә ..., хакыйкый; **~ая пра́вда** чын дөреслек (хакыйкать); **~ий вздор** чын мәгънәдә буш сүз; **~ий пусты́к** чын мәгънәдә бик нәрсә (эш)

су́щност||ь *ж* асылы, нигезе, төп нигезе; **~ь явле́ния** күренешнең асылы; **в ~и (говоря́)** *в знач. вводн. сл.* асылда, нигездә, чынында

суя́гная *ж* буаз (*сарык турында*)

сфабрикова́ть *сов. что* ялган хәбәр[ләр] чыгару

сфальши́вить *сов.* 1. көйне бозу (*җырлаганда яки музыкаль инструментта уйнаганда*) 2. *разг.* икейөзлеләнү, икейөзлелек күрсәтү

сфе́р||а *ж* 1. (*шар*) сфера 2. өлкә; **~а де́ятельности** эш өлкәсе; **~а произво́дства** җитештерү өлкәсе 3. (*среда, обстановка*) мохит, тирә-юнь; шартлар ♦ **вы́сшие ~ы** югары даирәләр; **небе́сная ~а** *астр.* күк йөзе

сфери́ческ||ий, -ая, -ое шарсыман, шарга охшаш; сферик; **~ое те́ло** шарсыман җисем

сферо́ид *м мат.* сфероид

сфероида́льный, -ая, -ое *мат.* сфероидаль, сфероид формалы, сфероидка охшашлы

сфи́нкс *м* сфинкс

сфокуси́ровать *сов. что, физ.* бер фокуска җыю, бер ноктага туплау

сфокуси́роваться *сов. физ.* бер фокуска җыелу, бер ноктага туплану

сформирова́ть *сов. что* төзү, кору, оештыру, булдыру; **~ прави́тельство** хөкүмәт төзү; **~ полк** полк оештыру

сформирова́||ться *сов.* 1. барлыкка килү, оешу, формалашып житү; **коллекти́в ~лся** коллектив оешты 2. (*физически развиться*) үсеп житү, житлегү, балигъ булу

сформи́ровывать *несов. см.* **сформирова́ть**

сформи́ровываться *несов.* 1. *см.* **сформирова́ться; 2.** *страд. от* **сформи́ровывать**

сформули́ровать *сов. что* формалаштыру, тәгъбирләү, тәгъбир итү

сфотографи́ровать *сов. кого-что* рәсемгә төшерү, рәсемгә төшереп алу (*фотоаппарат белән*)

сфотографи́роваться *сов.* рәсемгә төшү

схвати́||ть *сов.* 1. *кого-что* эләктерү, эләктереп алу, тоту, тотып алу; **~ть руко́й** кул белән тотып алу; **~ть зуба́ми** тешләр белән эләктерү 2. *кого за что* ...дан эләктерү, ...га ябышу; **~ть за го́рло** бугазына ябышу; **~ть за ши́ворот** якасына ябышу 3. *кого-что, разг.* (*задержать, арестовать*) тоту, тотып алу 4. *что,*

разг. (*болезнь*) эләктерү, йоктыру; тидерү; **~ть на́сморк** томау тидерү **5.** *кого-что* (*о приступе болезни*) кинәт авырып китү; кинәт [авыру] тота башлау; **его ~ла лихора́дка** аны бизгәк тота башлады **6.** *перен. что, разг.* аңлап алу, төшенү, үзләштерү, тотып алу, эләктереп алу; **он бы́стро ~л гла́вную мы́сль** ул төп фикерне бик тиз эләктерсә алды **7.** *безл. что и без доп., разг.* кату; **гипс ещё не ~ло** гипс катмаган әле

схвати́ться *сов.* **1.** *за кого-что* тотыну, тоту; ябышу; **~ за ружьё** мылтыкка тотыну **2.** *разг.* (*вступить в бой, драку, спор*) бер-берсенә ябышу (*сугыша башлау, бәхәсләшә башлау*)

схва́тк||а *ж* **1.** (*бой, ссора, спор*) бәрелеш **2.** *спорт.* көрәш **3.** *обычно мн.* **~и** (*при родах*) тулгак тоту; **начали́сь ~и** тулгак тота башлады

схва́тывать *несов. см.* **схвати́ть**

схва́тываться *несов.* **1.** *см.* **схвати́ться; 2.** *страд. от* **схва́тывать**

схе́м||а *ж* схема; **~а телефо́нного аппара́та** телефон аппараты схемасы; **дать ~у сочине́ния** сочинениенең схемасын бирү

схематизи́ровать *сов., несов. что* схемалаштыру, схемасын бирү, схемасын ясау

схемати́зм *м* схематизм, схемачылык (*әзер схемалар буенча гына фикер йөртү*)

схемати́ческ||ий, -ая, -ое, **схемати́чный,** -ая, -ое схематик, схема рәвешендә бирелгән; **~ие ка́рты** схематик карталар; **~ое изложе́ние** схематик рәвештә сөйләп бирү

схитри́ть *сов.* хәйләләү, хәйләләп алу, хәйләләп кую

схлы́н||уть *сов.* **1.** (*о воде*) кире агып китү, кире китү; кире кайту; бераз кимү **2.** *перен.* (*о массе людей*) кире агылу, кире китү, чигенү; бераз кимү, азаю **3.** *перен.* (*о чувствах*) бетү, юкка чыгу, юк булу; **ра́дость ~ла** шатлык юкка чыкты

сход *м* **1.** *см.* **сойти́** I; **2.** *разг.* төшә торган урын, юл; **крутой ~** текә юл **3.** *уст.* җыен; **се́льский ~** авыл җыены

сходи́ть I *несов.* **1.** *см.* **сойти́** I; **2.** (*с отрицанием*): **[он] не схо́дит с посте́ли** [ул] урыныннан тормый [ята]; **и́мя его́ не схо́дит с языка́** аның исеме телдән төшми; **улы́бка не схо́дит с лица́** йозеннән елмаю китми

сходи́ть II *сов.* **1.** барып кайту, барып килү; **~ на база́р** базарга барып кайту **2.** *за кем-чем* барып алып кайту (килү); **~ за ребёнком** баланы барып алып кайту

сходи́ться *несов. см.* **сойти́сь**

схо́дка *ж уст.* сходка, җыен; **студе́нческая ~** студентлар сходкасы

схо́дни *мн.* басма (*мәс. көймәдән, пароходтан ярга чыгу өчен куела торган басма*)

схо́дность *ж* **1.** охшашлык, үзара охшашлык; **~ характе́ров** характерларның охшашлыгы **2.** [бәясе ягыннан] яраклы булу, кулай булу, кыйбат булмау; **~ цен** бәяләрнең кулай булуы

схо́дн||ый, -ая, -ое **1.** охшаш, үзара охшаш; **~ые характе́ры** охшаш характерлар **2.** *разг.* кул, кулай, яраклы; **~ая цена́** кулай хак; **~ые усло́вия** кулай шартлар

схо́дство *с* охшашлык, үзара охшаш булу; **~ мне́ний** фикерләрнең охшашлыгы; **~ характе́ров** характерларның охшашлыгы

схо́жий, -ая, -ее *разг. см.* **схо́дный** 1

схола́ст *м* **1.** схоласт, схоластика тарафдары **2.** коры фәлсәфәгә бирелүче, коры фәлсәфә белән мавыгучы кеше

схола́стика *ж* схоластика (**1.** *филос. урта гасырларда коры фикерләүгә, формаль логик аргументларга, дин догмаларына нигезләнеп төзелгән, чынбарлыктан ерак булган идеалистик философик система* **2.** *тормыш һәм практикадан ерак булган, тәжрибәдә тикшерелмәгән белем, коры фәлсәфә, мәгънәсез бәхәсләшү*)

схоласти́ческий, -ая, -ое **1.** *филос.* схоластика ...ы, схоластик **2.** схоластик, схоластикага нигезләнгән, формаль

схоласти́чный, -ая, -ое *см.* **схоласти́ческий**

схорони́ть *сов. кого-что* күмү, жирләү

сцара́пать *сов. что* (*напр. скребком*) кыру, кырып алу; (*ногтями, когтями*) тырнау, тырнап алу

сцара́пнуть *сов. однокр. что* (*напр. скребком*) кырып алу; (*ногтями, когтями*) тырнап алу

сцара́пывать *несов. см.* **сцара́пать**

сцеди́ть *сов. что* **1.** (*слить*) саркыту, саркытып алу; сак кына агызу, агызып алу **2.** (*процедить*) сөзү, сөзеп алу

сце́живать *несов. см.* **сцеди́ть**

сцементи́ровать *сов.* **1.** *что* (*скрепить цементом*) цементлау, цементлап ныгыту, цементлаштыру **2.** *перен. кого-что* (*объединить*) бердәмләштерү, берләштерү; ныгыту

сце́н||а *ж* **1.** сәхнә; **театра́льная ~а** театр сәхнәсе **2.** күренеш (*мәс. пьесада, романда*) **3.** вакыйга, очрак, күренеш; **наблюда́ть за у́личной ~ой** урамдагы вакыйганы күзәтү **4.** *разг.* орыш-талаш, кычкырыш; **семе́йная ~а** семьядагы орыш-талаш **◆ сойти́ со ~ы** (*берәр эштән*) читкә китү

сцена́рий *м* сценарий

сценари́ст *м* сценарий авторы; сценарийлар язучы

сцени́ческ||ий, -ая, -ое **1.** сәхнә ...ы; **~ое иску́сство** сәхнә сәнгате **2.** сәхнәдә ...; **~ая де́ятельность** сәхнәдә эшләү

сцени́чн||ый, -ая, -ое сәхнә өчен яраклы, сәхнәдә уйнарлык, сәхнәгә куярлык; **~ая пье́са** сәхнә өчен яраклы пьеса

сцеп *м* **1.** *см.* **сцепи́ть; произвести́ ~ ваго́нов** вагоннарны тоташтыру **2.** *тех.* эләктергеч, тоташтыргыч, ыргак; **ваго́нные ~ы** вагон эләктергечләре **3.** тоташтырма; тоташтырылган (*машиналар һ.б.ш.*)

сцепи́ть *сов. что* тагу, эләктерү, эләктереп кую, тоташтыру; (*зубы*) кысу

сцепи́||ться *сов.* **1.** тоташу, бер-берсенә эләгү, эләктерелү; кысылу; **ваго́ны ~лись** вагоннар тоташты **2.** *прост.* (*в споре, драке и т.п.*) эләгешү, бәрелешү, талаша башлау, сугыша башлау **3.** (*о собаках*) чәйнәшә башлау

сце́пка *ж* **1.** *см.* **сцепи́ть; 2.** *см.* **сце́п** 2

сцепле́ние *с* **1.** *см.* **сцепи́ть, сцепи́ться** 1; **2.** *тех.* тоташтыргыч

сцепля́ть *несов. см.* **сцепи́ть**

сцепля́ться *несов.* **1.** *см.* **сцепи́ться; 2.** *страд. от* **сцепля́ть**

сцепно́й, -а́я, -о́е тоташтыргыч, тоташтыра торган

сце́пщик *м* вагоннар тоташтыручы (*эшче*)

сча́ливать *несов. см.* **сча́лить**

сча́лить *сов.* бер-берсенә (бергә) бәйләп кую, эләктереп бәйләп кую; тоташтыру, тоташтырып кую; **~ ба́ржи** баржаларны бер-берсенә эләктереп бәйләп кую

счастли́вец *м* бәхетле кеше

счастли́вица *ж* бәхетле хатын (кыз)

счастли́вчик *м разг. см.* **счастли́вец**

счастли́в||ый, -ая, -ое бәхетле; **~ый челове́к** бәхетле кеше **◆ ~ого пути́!** хәерле юл! ак юл!, юлың уңсын (уң булсын)!, хәерле сәфәр!; **~ая рука́** *у кого* кулы җиңел

сча́сть||е *с* бәхет **◆ к ~ю** *или* **на ~е** *в знач. вводн. сл.* бәхеткә каршы

счерти́ть *сов. что, разг.* күчереп сызу, сызып күчермәсен алу (*мәс. чертёжный, планның һ.б.ш.*)

счёрчивать *несов. см.* **счерти́ть**

счёс *м см.* **счеса́ть** 1; **~ пу́ха** мамык тарау (тарап алу)

счеса́ть *сов. что, спец.* **1.** (*вычесать*) тарап алу; **~ пух с кро́лика** куянның мамыгын тарап алу **2.** (*очистить*) тәрәшләү, тарау, тарап чистарту; **~ лён** җитен тәрәшләү

счеса́||ться *несов.* таралу, тарап алыну; **~лось две́сти гра́ммов пу́ху** ике йөз грамм мамык тарап алынды

счёска *ж см.* **счеса́ть** 1

счесть *сов. см.* **счита́ть** I 1 **◆ не ~** *кого-чего* санап бетергесез, исәпсез-хисапсыз, чиктән тыш күп

счёсться *сов. см.* **счита́ться** 1

счёсывать *несов. см.* **счеса́ть**

счёсываться *несов.* **1.** *см.* **счеса́ться; 2.** *страд. от* **счёсывать**

счёт *м* **1.** *см.* **счита́ть** I 1, 2; **сби́ться со ~а** саналганда ялгышу **2.** *спорт.* исәп; **зако́нчить матч со ~ом 3:1** матчны 3:1 исәбе белән тәмамлау; **откры́ть ~** исәпне ачу **3.** *бухг.* счёт; **уплати́ть по ~у** счёт буенча түләү; **откры́ть ~ в ба́нке** банкта счёт ачу **◆ без ~а** *или* **~у нет** исәпсез-хисапсыз, исәбе-хисабы юк, исәбе-саны юк; **быть на хоро́шем (плохо́м) счету́** яхшылар (начарлар) исәбендә булу, яхшылардан (начарлардан) саналу; **в два ~а** бик тиз, күз ачып йомганчы; **в коне́чном (после́днем) ~е** нәтиҗәдә, ахыр чиктә; **в ~ чего́** (*выдать, получить*) ...исәбенә, ...хисабына; **в ~ зарпла́ты** эш хакы исәбенә; **для ~а** исәп өчен, хисап өчен; **за (на) ~** *кого-чего* ... исәбенә, ... хисабына; **ли́ч-**

ные ~ы *у кого с кем* үзара исәп-хисап; **на ~** *кого-чего, чей* **говори́ть (ду́мать** *и т.п.*) (*барәр кеше*) турында сөйләү (уйлау *h.б.ш.*); **на счету́** исәптә; **на э́тот (сей) ~** бу яктан; **не в ~** саналмый, исәпкә алынмый (кертелми); **поко́нчить ~ы** *с кем-чем* араны өзү; **приня́ть на свой ~** үз исәбенә алу; **сбро́сить (ски́нуть) со счето́в** *кого-что* исәпкә алмый башлау, исәптән чыгарып ташлау; **свести́ ~ы** *с кем-чем* исәп-хисапны өзү, исәпләшү; үч алу; **теря́ть ~** исәбен югалту, исәбе-хисабы юк, исәпсез-хисапсыз [күп] булу; **что за ~ы!** санашып торасы түгел!

счётн||ый, -ая, -ое исәпләү ...ы, хисаплау ...ы; санау ...у; **~ая коми́ссия** санау комиссиясе; **~ая маши́на** хисаплау машинасы; **~ая табли́ца** исәпләү таблицасы

счетово́д *м* хисапчы

счетово́дн||ый, -ая, -ое исәп-хисап ...ы, хисаплау ...ы, хисап алып бара торган; **~ые кни́ги** исәп-хисап кенәгәләре

счетово́дство *с* хисапчылык

счетово́дческий, -ая, -ое хисапчы-[лар] ...ы; хисапчылык ...ы

счётчик *м* **1.** исәпләүче, санаучы, ... исәбен алучы; **~и по пе́реписи населе́ния** халык исәбен алучылар **2.** счётчик, санагыч, үлчәгеч; **га́зовый ~** газ счётчигы

счёт||ы *только мн.* счёт, чут; **счита́ть на ~ах** чутта санау

счисле́ни||е *с мат.* санау; **десяти́чная систе́ма ~я** унарлы санау системасы; **систе́ма ~я** санау системасы

счи́стить *сов. что* чистарту, чистартып ташлау, тазарту, китәрү, арчу, арчып ташлау; **~ снег с пути́** юлларны кар чистарту; **~ кожуру́ с апельси́на** эфлисун кабыгын арчу

счи́сти||ться *сов.* китү, бетү; (*напр. о кожуре*) арчылу; **кра́ска ~лась** буяу китте

счита́лка *ж разг.* санамыш

счи́танн||ый, -ая, -ое хисаплы, исәпле, санаулы, бик аз; **~ые дни** санаулы көннәр

счита́||ть I *несов.* **1.** *кого-что и без доп.* санау; **~ть до ста** йөзгә кадәр санау; **уме́ть ~ть** саный белү; **~ть де́ньги** акча санау **2.** *что и без доп.* (*производить расчёты*) санау, хисаплау **3.** *что* исәпләү; **~ть в килогра́ммах** килограммлап исәпләү **4.** *что* (*принимать за начало отсчёта*) санау, саный башлау, исәпли башлау; **че́рез год, ~я с э́того дня** бүгеннән [саный] башлап бер елдан **5.** *кого-что* исәпләү, хисаплау, санау, уйлау; **я ~ю его́ хоро́шим челове́ком** мин аны яхшы кеше дип исәплим; **~ю, что ты не прав** син хаклы түгел дип исәплим ♦ **не ~я** *кого-чего* исәпкә алмаганда; **не ~ть де́нег** акчаны исәпләмичә (исәпсез) тоту; **~ть дни (часы́, мину́ты** *и т.п.*) көннәрне (сәгатен, минутын) исәпләү (*туземсезлек белән көтү*); **~ воро́н** авыз ачып тору

счита́ть II *сов. что* чагыштырып уку, чагыштырып укып чыгу; **~ гра́нки с ориги́налом** гранкаларны төп нөсхәсе белән чагыштырып уку

счита́ться *несов.* **1.** *с кем, разг.* исәп-хисапны өзү, араны өзү; **мы с ним ещё не счита́лись** без аның белән араны өзмәдек әле **2.** *с кем-чем* исәпләшү, хисаплашу, исәпкә алу; санашу, санга алу (санау, сугу), игътибарга алу; **~ с тре́бованиями** куелган таләпләрне исәпкә алу; **не ~ ни с ке́м** һичкем белән дә исәпләшмәү **3.** *кем-чем* исәпләнү, саналу; **~ хоро́шим инжене́ром** яхшы инженерлардан исәпләнү **4.** *страд. от* **счита́ть** I 1-4

счи́тывать *несов. см.* **счита́ть** II

счища́ть *несов. см.* **счи́стить**

счища́ться *несов.* **1.** *см.* **счи́ститься; 2.** *страд. от* **счища́ть**

сшиба́ть *несов. см.* **сшиби́ть**

сшиба́ться *несов.* **1.** *см.* **сшиби́ться; 2.** *страд. от* **сшиба́ть**

сшиби́ть *сов. кого-что, разг.* **1.** бәреп төшерү, сугып төшерү, бәреп (бәрдереп) егу, сугып егу; **~ с ног** сугып аяктан егу **2.** бәрелештерү; **~ лба́ми** маңгайлары белән бәрелештерү

сшива́ть *несов. см.* **сшить**

сши́вка *ж* **1.** *см.* **сшить; 2.** (*место, шов*) жөй, тегелгән урын (жир)

сшивно́й, -а́я, -о́е жөйле (*бөтен тугел*); **~ рука́в** жөйле жиң

сшить *сов. что* **1.** ялгау, ялгап тегү, тегеп ялгау, ялгап (тегеп) кую, тегү; **~ кусо́к мате́рии** тукыма кисәкләрен ялгап кую; **~ кни́гу** китапны тегеп кую **2.** (*изготовить шитьём*) тегү; (*у портного*) тектерү; **~ пальто́** пальто тегү **3.** (*клёнкой*) түкеп ялгау; (*гвоздями*) кадаклау

съеда́ть *несов., см.* **съесть**

съеде́ние *с*: **на ~** *кому-л.* **[отда́ть, оста́вить, оста́ться** *и т.п.*] 1) ашарга [бирү, калдыру *h.б.ш.*]; 2) *перен.* бирәүнең ихтыярына [тапшыру, калдыру, калу]

съедо́бный -ая, -ое ашарга яраклы, ашарга ярый торган, ашый торган; **~ гриб** ашарга яраклы гөмбә

съёжи||ться *сов. в разн. знач.* җыерылу, бөрешү, бөгәрләнү, йомарлану; куырылу, корышу; **ли́стья ~лись** яфраклар бөрешкән; **~ться от хо́лода** суыктан бөрешү

съезд *м* **1.** *см.* **съе́хать** 1, 2, **съе́хаться** 2; **~ госте́й** кунаклар җыелу **2.** съезд; **~ учителе́й** укытучылар съезды **3.** (*спуск*) төшү урыны, төшү юлы, түбәнгә төшә торган юл; **~ к реке́** елгага төшү юлы

съе́здить *сов.* (*атка, трамвайга, поездга h.б.ш.*) утырып барып кайту

съезжа́ть *несов. см.* **съе́хать**

съезжа́ться *несов. см.* **съе́хаться**

съёмка *ж* **1.** *см.* **снять** 1-5, 8, 9, 11; **~ плодо́в** җимешләрне җыеп алу; **~ шкур** тиреләр тунау; **~ в ателье́** ательедә рәсемгә төшү; **~ фи́льма** фильм төшерү; **~ с я́коря** якорьны күтәреп кузгалып китү, якорьны күтәрү **2.** *геод.* [планга, картага] төшерү (төшереп алу), план алу

съёмн||ый, -ая, -ое **1.** алынмалы, алына торган, салынмалы, салына торган; **~ая кры́шка** алынмалы капкач; **~ый проте́з** салынмалы протез **2.** *с.-х.* өлгергән, җиткән, өзеп җыярга өлгергән; **~ые я́блоки** өзеп җыярга өлгергән алмалар

съёмочн||ый, -ая, -ое **1.** *геод.* [планга, картага] төшерү (төшереп алу) ...ы, план алу ...ы; **~ые рабо́ты** [планга] төшерү эшләре **2.** кино...; **~ый аппара́т** киноаппарат; **~ая ка́мера** кинокамера

съёмщик *м* **1.** вакытлыча файдалануга алып торучы; **ответственный ~ кварти́ры** квартирны вакытлыча файдалануга алып торучы җаваплы кеше **2.** *геод.* [планга, картага] төшерүче, план төшерүче, план алучы

съестн||о́й, -а́я, -о́е **1.** ашамлык ...ы, ашау ...ы; **~ы́е запа́сы (припа́сы)** ашамлык әйберләре, ашамлыклар, азык-төлек **2.** *в знач. сущ.* **~о́е** *с* ашамлык әйберләре, ашамлыклар, азык-төлек

съесть *сов.* **1.** *что, чего* ашау, ашап бетерү; **~ я́блоко** алманы ашап бетерү **2.** *что* (*известь*) кисү; (*о моли*) тишү; (*о грызунах*) кимерү **3.** *кого-что* (*искусать — о насекомых*) тешләү, тешләп бетерү

съе́ха||ть *сов.* **1.** төшү; (*на машине, лошади и т.п.*) утырып төшү; (*на лыжах и т.п.*) шуып төшү; **грузови́к ~л с горы́** йөк машинасы таудан төште **2.** [торактан] китү, күчеп китү, чыгу, чыгып китү; **~ть с кварти́ры** квартирдан чыгу **3.** *разг.* кыйшаю; төшү; **очки́ ~ли на́нос** күзлеге борын очына төшкән

съе́ха||ться *сов.* **1.** (*встретиться*) (*берәр нәрсәгә утырып*) барганда очрашу **2.** (*берәр нәрсәгә утырып төрле яктан*) килеп җыелу; **делега́ты ~лись со всех концо́в страны́** делегатлар илнең төрле якларыннан килеп җыелган

съехи́дничать *сов. разг.* мыскыллап алу, мыскыллап көлеп алу, чәнчүле (ачы, зәһәр) сүзләр әйтү

съязви́ть *сов. см.* **съехи́дничать**

сыворо́тка *ж* **1.** (*молочная*) эремчек суы **2.** *биол., мед.* сыворотка; сүл

сыгра́ть *сов.* **1.** *во что, на чём и без доп.* уйнау, уйнап алу; **~ в волейбо́л** волейбол уйнау; **~ на скри́пке** скрипкада уйнау **2.** *кого-что* (*на сцене*) уйнау, башкару; **~ роль Хлестако́ва** Хлестаков ролен уйнау ♦ **~ в великоду́шие** киң күңелле булып кылану, киң күңеллелек күрсәтеп маташкан булу; **~ на́ руку** *кому* ... файдасына эшләү; **~ шу́тку** *с кем-чем* шаяртып мыскыллау, шаяртып көлү, *берәр* күңелсезлек эшләп ташлау

сыгра́ться *сов.* бергә уйнап, күнегеп җиту

сы́грываться *несов. см.* **сыгра́ться**

сы́змала *нареч. прост.* яшьтән, яшьтән үк, кече яшьтән бирле, кечкенәдән үк

сы́знова *нареч. разг.* яңадан, яңабаштан, өр-яңадан

сын *м* **1.** (*мн.* **~овья́**) ул; **мой ста́рший ~** минем олы улым **2.** (*мн.* **~ы́**) *чего, высок.* ул; **отва́жные ~ы́ Ро́дины** Илнең батыр уллары; **~ы́ революции** революция уллары; **3.** (*мн.* **~ы́**) (*человек какой-л. эпохи, среды*) ул; **~ своего́ вре́мени** шул заман кешесе

сыно́вий, -ья, -ье *редко см.* **сыно́вний**

сынóвн||ий, -яя, -ее ул ...ы; уллык ...ы, ул[лары] кебек ..., улларча ...; **~ий долг** уллык бурычы; **~яя любóвь** үз улы кебек ярату

сынóк *м разг.* **1.** *уменьш.-ласк. от* **сын** 1; **2.** (*при обращении*) улым

сы́пать *несов.* **1.** *что* салу, тутыру; (*класть*) салу; **~ муку́ в мешóк** капчыкка он салу; **~ соль в суп** шулпага тоз салу **2.** *что, чем* (*разбрасывать что-л. сыпучее*) сибү, сиптерү, яудыру, чәчү **3.** (*об осадках*) сибәләү, яву **4.** *перен. что, чем* яудыру; **~ цита́тами** цитаталар яудыру; **~ остро́тами** тапкыр сүзләр яудыру

сы́п||аться *несов.* **1.** коелу, коелып төшү; чәчелү, сибелү; **пшени́ца ~лется из мешка́** бодай капчыктан коела **2.** (*об осадках*) сибәләү, яву **3.** *перен.* [төрле яктан] яву (явып тору); **предложе́ния ~ались со всех сторо́н** тәкъдимнәр төрле яктан явып [кына] торды **4.** *разг.* (*о звуках, словах*) [төрле яктан, өзлексез] ишетелү, ишетелеп тору, яву, явып тору **5.** *разг.* (*о ткани*) коелу (*чите киселгән тукыманың җепләре турында*) **6.** *страд. от* **сы́пать** 1-3

сыпно́й, -а́я, -о́е: **~ тиф** тимгелле тиф

сыпнотифо́зный, -ая, -ое тимгелле тиф белән авырган (авыручы); **~ больно́й** тимгелле тиф белән авыручы авыру

сыпня́к *м разг.* (*сыпной тиф*) тимгелле тиф

сыпу́ч||ий, -ая, -ее таралучан, чәчелүчән; сибелүчән; сибелмәле, чәчелмәле, бөртекле; **~ие тела́** *физ.* чәчелүчән җисемнәр

сыпь *ж* (*на теле*) тимгел; **корева́я ~** кызамык тимгеле

сыр *м* сыр ♦ **как ~ в ма́сле [ката́ется]** үзе бал-май эчендә генә йөзә; пычагы бал-май эчендә генә йөзә; типтереп яши, кәеф-сафа чига

сыре́ть *несов.* дымлану, дым тарту, дымыгу

сыре́ц *м* чимал, ярым фабрикат

сы́рник *м* сырник

сы́рный, -ая, -ое сыр ...ы; **~ за́пах** сыр исе; **~ заво́д** сыр заводы

сы́ро *в знач. сказ. безл.* дымлы, юеш; дым тарткан; **здесь ~** биредә юеш

сырова́р *м* сыр кайнатучы (ясаучы)

сыровáрение *с* сыр кайнату, сыр ясау

сырова́ренн||ый, -ая, -ое, **сырова́р||ный**, -ая, -ое сыр кайната торган, сыр ясый (эшләп чыгара) торган, сыр ...ы, сыр житештерү ...ы; **~ая промы́шленность** сыр житештерү промышленносте

сырова́рня *ж* сыр кайнату (ясау) предприятиесе

сыроде́льн||ый, -ая, -ое сыр ...ы, сыр ясау (җитештерү) ...ы; **~ая промы́шленность** сыр ясау промышленносте

сыро́ежка *ж* ал гөмбә

сыр||о́й, -а́я, -о́е **1.** дымлы, юеш; **~о́е бельё** дымлы кер; **~ы́е дрова́** юеш утын; **~о́й во́здух** дымлы һава **2.** чи, пешмәгән, кайнамаган; **~ы́е о́вощи** чи яшелчәләр; **~о́е мя́со** чи ит; **~о́е молоко́** кайнамаган сөт; **~а́я вода́** кайнамаган су **3.** *прям., перен.* эшкәртелмәгән, чи; **~о́е литьё** эшкәртелмәгән коелма; **~ы́е материа́лы** эшкәртелмәгән материаллар; **расска́з ещё о́чень ~о́й** хикәя бик чи әле ♦ **сыр-бор загоре́лся** (*откуда или из-за чего*) менә кайдан эш башланып китте, менә ни өчен тавыш (гауга) чыкты

сырóк *м* сырок (*эремчектән тәмләткечләр кушып эзерләнгән ашамлык*)

сыромя́тн||ый, -ая, -ое **1.** дупланмыйча иләнгән; чи (*каеш турында*); **~ая ко́жа** чи каеш **2.** чи каештан эшләнгән; **~ый оше́йник** чи каештан эшләнгән муенчак; **~ый чересседе́льник** чи каештан эшләнгән аркалык **3.** чи каеш эшләп чыгару ...ы, чи каеш ...ы; **~ый цех** чи каеш цехы

сыромя́ть *ж* чи каеш

сы́рость *ж* дым, дымлылык; юешлек; **вече́рняя ~** кичке юеш һава

сырьё *с* чимал (*чи, эшкәртелмәгән продукт*)

сырьев||о́й, -а́я, -о́е чимал ...ы; **~ы́е запа́сы** чимал запаслары; **~а́я ба́за** чимал базасы

сыск *м* [жинаятьчеләрне] эзләү, эзләп табу, тоту, тотып алу

сыска́ть *сов. кого-что, разг.* табу, эзләп табу

сыска́ться *сов. разг.* табылу

сыскн||о́й, -а́я, -о́е: **~а́я поли́ция** жинаятьчеләрне эзләү полициясе

сы́тный, -ая, -ое туклыклы; **~ обе́д** туклыклы төшке аш

сы́тость *ж* туклык; тук булу

сы́т||ый, -ая, -ое **1.** тук; **~ый челове́к** тук кеше **2.** *разг.* (*упитанный*) симез, көр, тук; **~ый скот** көр терлек **3.** *перен. разг.* мул, тук, бай; **~ая жи́знь** мул тормыш ♦ **сыт по го́рло** 1) кабар җирем дә юк, кабар җирем дә калмады, кабасым да килми (*тукмын*); 2) *перен.* тукмын, туйдым (*мәс. эшнең, сузнең һ.б.ш. куплегеннән*); **~ый голо́дного не разуме́ет** *посл.* ач кадерен тук белми

сыч *м* чырайсыз ябалак ♦ **~о́м (как ~) гляде́ть (смотре́ть, сиде́ть)** каранҗы чырай күрсәтеп утыру

сычу́г *м анат.* төп ашказаны, карта (*күшәүче хайваннарда*)

сычу́жина *ж* сычужина (*күшәүче хайванның ашказаны согы ферменты; сыр ясауга китә*)

сы́щик *м* шымчы, яшерен полиция агенты

сэконо́мить *сов.* **1.** *что* (*сберечь*) саклап тотып (бәрәкәтле тотып) янга калдыру, экономия ясау **2.** *в чём, на чём* (*выгадать*) ... исәбенә янга калдыру, ... исәбенә экономия ясау

сэр *м* сэр

сюда́ *нареч.* бире, бирегә, монда; бире таба; **смотри́ ~** бире таба кара; **сади́сь ~** бире утыр

сюже́т *м* сюжет

сюже́тн||ый, -ая, -ое **1.** сюжет ...ы; **~ая ли́ния рома́на** романның сюжет сызыгы **2.** сюжетлы; **~ые пе́сни** сюжетлы җырлар

сюзере́н *м ист.* сюзерен (*феодализм чорында: эре җир биләүче феодал*)

сюзере́нн||ый, -ая, -ое *ист.* сюзерен ...ы, сюзеренлык ...ы; **~ые права́** сюзеренлык хокуклары

сюи́та *ж муз.* сюита

сюрпри́з *м* сюрприз, сөенче; **прия́тный ~** күңелле сюрприз

сюрту́к *м* сюртук

сюсю́кать *несов. разг.* **1.** (*иметь дефект речи*) сакауланып сөйләү (*мәс. «ч, ш» урынына «с» чагарып сөйләү*) **2.** *перен.* (*нежничать*) артык назлау, артык иркәләү

сяк *нареч.*: **и так и ~** алай да, болай да; **то так, то ~** әле болай, әле тегеләй; **та́к-ся́к** *в знач. сказ. разг.* бер төрле, түзәрлек әле

сяко́й, -а́я, -о́е: **тако́й-~** *разг.* фәлән-фәсмәтән

ся́м *нареч.*: **там и ~, та́м-ся́м** анда-монда; **то там, то ~** әле монда, әле тегендә

Т

та *ж см.* **тот**

таба́к *м* тәмәке; **листо́вой ~** яфрак тәмәке; **души́стый ~** *бот.* хуш исле тәмәке; **кури́тельный ~** тарта торган тәмәке; **жева́тельный ~** чәйни торган тәмәке; **нюха́тельный ~** насвай, насвай тәмәкесе; **кури́ть ~** тәмәке тарту

табаке́рка *ж* тәмәке савыты

табаково́д *м* тәмәке үстерү белгече, тәмәке игүче (үстерүче)

табаково́дство *с* тәмәке игү (үстерү, үстерүчелек)

табаково́дческий, -ая, -ое тәмәке игү ...ы, тәмәке үстерүчелек ...ы; **~ совхо́з** тәмәке игү совхозы

таба́нить *несов.* киregә ишү (*көймәдә*)

таба́чник *м* тәмәкече (*тәмәке промышленностенда эшләүче*)

таба́чн||ый, **1.** тәмәке ...ы; **~ая фа́брика** тәмәке фабрикасы; **~ые поля́** тәмәке кырлары; **~ый дым** тәмәке төтене **2.** (*о цвете*) тәмәке төсендәге, яшькелт-коңгырт

та́бель *м в разн. знач.* табель; **~ успева́емости** өлгереш табеле; **ввести́ ~** табель кертү; **~ о ра́нгах** *уст.* ранглар табеле (*Пётр I тарафыннан кертелгән төрле чиннар системасы*)

та́бельн||ый, -ая, -ое табель ...ы; **~ая доска́** табель тактасы; **~ая систе́ма** табель системасы

та́бельщик *м* табельче

та́бельщица *ж* табельче хатын (кыз)

табле́тк||а *ж* таблетка, дару сәдәбе; **приня́ть ~у** таблетка йоту

табли́ца *ж* таблица, җәдвәл; **~ умноже́ния** *мат.* тапкырлау таблицасы; **~ логари́фмов** *мат.* логарифмнар таблицасы; **~ вы́игрышей** отышлар таблицасы

табли́чн||ый, -ая, -ое таблица ...ы; таблицадагы; **~ые све́дения** таблица мәгълүматлары

табло́ *с нескл.* табло; **светя́щееся (световóе) ~** яктыртыла торган табло; **информацио́нное ~** информация таблосы

та́бор *м* табор; **цыга́нский ~** чегән таборы

та́борн||ый, -ая, -ое табор ...ы; **~ая жизнь** табор тормышы

табу́ *с нескл.* тыю, табу; **наложи́ть ~** тыю; табу дию

табу́н *м* **1.** көтү; өер; **~ лошаде́й** ат көтүе **2.** *перен. разг.* (*гурьба, толпа*) көтү, өер

табу́нн||ый, -ая, -ое көтү ...ы, көтү ...; өер ...ы, өер...; **~ый жеребе́ц** өер айгыры; **~ое конево́дство** атларны көтүдә йөртеп асрау

табу́нщик *м* ат көтүчесе, елкычы

табуре́т *м*, **табуре́тка** *ж* урындык, утыргыч, артсыз урындык

таве́рна *ж* таверна (*кечкенә трактир*)

та́волга, таволжа́нка *ж бот.* тубылгы

тавО́т *м тех.* тавот, машина мае

таврёный, -ая, -ое тамгалы, [яндырып] тамга сугылган (салынган); **~ скот** тамгалы мал

таври́ть *несов. кого-что* [көйдереп] тамга салу, [яндырып] тамгалау; **~ скот** малны [яндырып] тамгалау

тавро́ *с* [яндырып салынган] тамга, терлек тамгасы

тавро́в||ый, -ая, -ое тамга ...ы; **~ый знак** тамга билгесе ♦ **~ое желе́зо** *спец.* «Т» хәрефенә охшатып ясалган тимер

тавтологи́ческ||ий, -ая, -ое тавтологик; **~ое определе́ние** тавтологик билгеләмә; **~ая оши́бка** тавтологик хата

тавтоло́гия *ж* тавтология (*мәгънәне ачыкламый торган сүзләрне кабатлау*)

таган *м* өчаяк, таган

таджи́к *м* тажик, тажик кешесе

таджи́кск||ий, -ая, -ое тажик ...ы; Тажикстан ...ы; **~ая литерату́ра** тажик әдәбияты

таджи́чка *ж* тажик хатыны (кызы)

таёжник *м* тайга кешесе, тайгада яшәүче

таёжн||ый, -ая, -ое тайга ...ы, тайгадагы ...; **~ый охо́тник** тайга аучысы; **~ая река́** тайга елгасы; **~ый пожа́р** тайгадагы янгын

таз I *м* ләгән, таз; **ме́дный ~** бакыр ләгән

таз II *м анат.* оча сөяге (*кешедә*); янбаш сөяге (*хайванда*)

та́зов||ый, -ая, -ое *анат.* оча ...ы; **~ые ко́сти** оча сөякләре

тайнственность *ж* серлелек; яшертенлек

тайнственн||ый, -ая, -ое серле; яшертен; **с ~ым ви́дом** серле кыяфәт белән

та́инство *с рел.* (*обряд*) серле йола, тылсымлы йола

таи́||ть *несов. что* **1.** [сер итеп] саклау, яшерү, сер итеп тоту, сиздермәү; **~ть своё го́ре** үзеңнең кайгыңны яшерү; **~ть зло́бу** ачу саклау **2.** бар булу, саклау; **земля́ ~т мно́го бога́тств** җирдә бик күп байлыклар бар; **э́то ~т в себе́ большу́ю опа́сность** моның зур куркынычы бар

таи́т||ься *несов.* **1.** (*скрывать от других*) яшерү, эчендә саклау **2.** (*прятаться, скрываться*) яшеренү, посу, яшеренеп (посып) яту; **в лесу́ тая́тся вся́кие зве́ри** урманда төрле җәнлекләр яшеренеп ята **3.** *в ком-чём* бар булу, яту; **в э́том ~ся кака́я-то зага́дка** монда ниндидер яшерен сер бар

тайга́ *ж* тайга

тайко́м *нареч.* яшерен рәвештә, яшертен, яшерен-батырын, качып, сиздермичә, шыпырт кына; **унести́** *что-л.* **~** *берәр нәрсәне* яшертен алып китү; **уйти́ ~** сиздермичә китү

тайм *м спорт.* тайм; **пе́рвый ~** беренче тайм

та́йн||а *ж в разн. знач.* сер; **заве́тная ~а** йөрәк сере; **вое́нная ~а** хәрби сер; **госуда́рственная ~а** дәүләт сере; **~а успе́ха** уңышның сере; **~ы приро́ды** табигать серләре; **~ы ко́смоса** галәм серләре; **храни́ть ~у** сер саклау; **держа́ть в ~е** сер итү; **раскры́ть** *чью-л.* **~у** *берәр кешенең* серен ачу; **доверя́ть свои́ ~ы** үз серләрен ышанып сөйләү ♦ **не ~а, что ...** һәркемгә мәгълүм ки ...

тайни́к *м* яшерен урын (җир); яшерен бина ♦ **в ~а́х души́** күңел түрендә; **в ~а́х се́рдца** йөрәк түрендә, йөрәкнең яшерен җирләрендә

та́йнопись *ж* шартлы язу, яшерен язу (*аерым кешеләр өчен исәпләнгән*)

та́йн||ый, -ая, -ое **1.** яшерен; **~ое голосова́ние** яшерен тавыш бирү **2.** серле, яшерен; **~ая ра́дость** серле сөенеч; **~ое волне́ние** серле дулкынлану; **~ая мечта́** яшерен хыял; **~ая наде́жда** яшерен өмет; **~ое предчу́вствие** яшерен сизенү **3.** (*не явный*) астыртын, яшертен булган; **~ая вражда́** астыртын дошманлык; **~ое недоброжела́тельство** астыртын усаллык теләү

тайфу́н *м* тайфун, диңгез өермәсе

так 1. *нареч.* (*таким образом*) шулай, болай, алай; **де́ло обстои́т и́менно ~** эш нәкъ менә шулай, болай инде; **де́лай вот ~** менә шулай эшлә **2.** *нареч.* (*настолько*) шулкадәр, шулхәтле; **она́ ~ хороша́!** ул шулкадәр гүзәл!; **я ~ мно́го ходи́л, что уста́л** мин шулкадәр күп йөрдем, арып беттем **3.** *нареч.* (*без последствий, безрезультатно*) болай (алай, шулай) гына, шул көе генә; **э́то тебе́ ~ не пройдёт** бу сина алай гына үтеп китмәс **4.** *нареч.* (*без особого намерения*) тик, болай гына, сүз уңаенда; **я сказа́л э́то про́сто ~** мин аны болай гына әйттем **5.** *частица усил.* дисәң, икән, булгач; **вот э́то маши́на ~ маши́на!** менә бу машина дисәң машина! **6.** *частица огранич.* чамасы, чамасында; тирәсендә; **часа́ ~ в два** сәгать икеләр тирәсендә **7.** *частица* (*например*) шулай, мәсәлән, әйтик; **кли́мат там суро́вый, ~, моро́зы дохо́дят до сорока́ гра́дусов** анда климат бик каты, салкыннар, мәсәлән, кырык градуска кадәр җитә **8.** *союз* (*следовательно, стало быть*) димәк, шулай итеп; **~ ты мне не ве́ришь?** димәк, син миңа ышанмыйсың?; **~ ты согла́сен?** димәк, син риза? **9.** *союз* (*в таком случае, тогда*) икән, ул вакытта, ул чакта; **вам не́чего де́лать, ~ уходи́те** эшегез юк икән, китә бирегез **10.** *союз* (*вследствие этого, потому*) шуңа күрә, инде; **сего́дня хо́лодно, ~ ты оде́нься потепле́е** бүген суык, шуңа күрә син җылы киен **11.** *союз против.* ләкин, әмма; **ведь я говори́л, ~ ты слу́шать не хоте́л** мин әйтеп тордым, ләкин син колак та салмадың ♦ **за ~** *прост.* бушка; **полу́чить (взять) за ~** бушка алу; **и ~** болай да, ансыз да; **и ~ до́лго сиде́ли** болай да озак утырдык; **и ~ да́лее** һәм башкалар; **когда́ (раз, е́сли) ~** (*в таком случае*) алай (шулай) булгач; **как же ~?** ничек инде алай?; **не ~ ли?** шулай түгелме?; **пусть ~** шулай булсын; **я ~ и знал** шулай булыр дип уйлаган идем; **~ бы** тотар идем дә; **~ бы и полете́л!** тотар идем дә очып китәр идем!; **~ вот** шулай менә; **~ называ́емый** ... дип аталган; **~ и** ... да; **слёзы ~ и лью́тся** күз яшьләре ага да ага; **~ и быть** ярый, шулай булсын; **~ и есть** шулай булып чыкты; чыннан да шулай; **~ и́ли ина́че** һәрхәлдә; **~ и ~ (сяк), ~ и́ли э́так** төрлечә, төрле юллар белән; **то ~, то э́так** тегеләй дә, болай да; **та́к как** *союз* чөнки; **~ на ~** *прост.* башма баш (*алышу*), өстәүсез (*алышу*); **~ нет** юк, тыңламады бит; **та́к себе** *разг.* бер көе, бер көе генә, уртача; **~ сказа́ть** *вводн. сл.* әйтик (*әйттек*) ди; **то́лько ~** болай гына; **~-то так** шулаен шулай да; **~-то та́к, но всё-таки я не могу́ с ва́ми согласи́ться** шулаен шулай да, ләкин мин сезнең белән килешә алмыйм; **~ то́чно** *воен.* нәкъ шулай: **~ что** *союз* шуңа күрә; **~ что́бы** *союз* ...сын өчен

такела́ж *м* такелаж (**1.** *мор. судноның аркан, бау кебек барлык җиһазлары* **2.** *тех. йөкне күтәрү һәм бер урыннан икенче урынга күчеру өчен кулланыла торган җайланмалар*)

такела́жник *м* такелажчы

такела́жн||ый, -ая, -ое *мор.* такелаж ...ы; **~ое обору́дование** такелаж кирәк-яраклары; **~ые рабо́ты** такелаж эшләре

та́кже 1. *нареч.* (*тоже, равным образом*) шулай ук, ... да; **он ~ чита́л э́ту кни́гу** бу китапны ул да укыган; **мы ~ согла́сны** без шулай ук риза **2.** *союз присоед.* шулай ук, һәм; **оте́ц, а ~ мать уже́ уе́хали** әти һәм шулай ук әни киттеләр инде

таки, -таки *частица разг.* (*всё же, однако, тем не менее*) шулай да, шулай булса да, тәки; **успе́л- ~ на по́езд** шулай да поездга өлгерде бит

тако́в *мест. в знач. сказ.* шул, шулай, шундый; **~ о́ на́ше мне́ние** безнең фикер менә шундый; **~ы́ фа́кты** хакыйкать менә шундый ♦ **[и] был ~** *разг.* шылды, тайды, табан ялтыратты

таково́й *мест.* (*такой, этот*) шундый, андый, мондый ♦ **как ~** үзе, үзеннән-үзе; **вопро́с как ~ решён** мәсьәлә үзе хәл ителде инде

ТАК-ТАН

так||о́й *мест.* 1. *указ.* шундый, мондый, андый; **~ о́й о́пыт заслу́живает распростране́ния** мондый тәжрибә таратуга лаек 2. *определит.* шундый, шулкадәр; **~ о́й си́льный ве́тер** шулкадәр көчле жил; **там бы́ли ~ е́ краси́вые ве́щи** анда шундый матур әйберләр бар иде 3. *неопр. разг.* шундый, әллә нинди; **лень ~ а́я напа́ла** әллә нинди ялкаулык басты 4. *в знач. сущ.* **~ о́е** *с* шундый, шундый нәрсә; **что же тут ~ о́го?** нәрсә булган соң? ♦ **в ~ о́м слу́чае** алай булгач, ул чагында; **до ~ о́й сте́пени** шулкадәр, бу кадәр; **кто ~ о́й?** кем ул?, ул үзе кем?; **~ и́м о́бразом** *в знач. вводн. сл.* димәк, шулай итеп, шул рәвешчә; **что [же] э́то ~ о́е?** бу нәрсә инде?, бу нинди хәл инде?

тако́й-сяко́й *мест. разг.* фәлән-төгән, фәлән-фәсмәтән

тако́й-то *мест.* фәлән; **~ челове́к** фәлән кеше; **в ~ день** фәлән көнне

та́кс||а I *ж* (*расценка*) рәсми бәя, такса; **пла́та по ~е** такса буенча түләү; **почто́вая ~а** почта таксасы

та́кса II *ж* (*порода собак*) такса

такси́ *с нескл.* такси; **грузово́е ~** йөк таксие; **стоя́нка ~** такси тукталу урыны; **взять ~** такси алу

такси́ст *м разг.* таксичы, такси шофёры

та́ксов||ый, -ая, -ое такса ...ы; **~ая коми́ссия** такса комиссиясе; **~ая цена́** такса бәясе

таксо́метр *м* таксометр (*такси счётчигы*)

таксомото́р *м* таксомотор (*такси*)

таксомото́рный, -ая, -ое таксомотор[лар] ...ы; **~ парк** таксомоторлар паркы

таксопа́рк *м* таксопарк, таксилар паркы; **диспе́тчер ~а** таксопарк диспетчеры

таксофо́н *м* таксофон (*металл акча яки жетон салып сөйләшә торган телефон-автомат*)

та́к-ся́к *в знач. сказ. разг.* (*терпимо*) бер хәл; **ну, э́то ещё ~** анысы әле бер хәл

такт I *м в разн. знач.* такт; **пе́рвый ~** *муз.* беренче такт; **заключи́тельный ~** *муз.* ахыргы такт; **сби́ться с ~а** тактны югалту; **петь в ~** тактка жырлау; **рабо́чий ~** *тех.* эш тактты (*двигательдә*); **~ сжа́тия** *тех.* кысу тактты

такт II *м* (*чувство меры*) әдәп, әдәплелек; **чу́вство ~а** әдәплелек тойгысы; **отсу́тствие ~а** әдәпсезлек; **соблюда́ть ~** үзеңне әдәпле тоту

та́к-таки *частица разг.* шулай да, шулай итеп; шуңа карамастан; тәки; **он ~ не согласи́лся** ул тәки риза булмады; **~ они́ все винова́ты?** шулай да алар барысы да гаеплеме?; **мне ~ пришло́сь е́хать в командиро́вку** тәки миңа командировкага барырга туры килде

та́ктик *м* тактик, тактика белгече

та́ктик||а *ж прям., перен.* тактика; **~а бо́я** сугыш тактикасы; **измени́ть ~у игры́** уен тактикасын үзгәртү

такти́ческ||ий, -ая, -ое *прям., перен.* тактик, тактика ...ы; **~ая подгото́вка бойцо́в** сугышчыларның тактик хәзерлеге; **~ие уче́ния** тактик өйрәнүләр; **~ая зада́ча** тактик бурыч; **~ое руково́дство** тактик җитәкчелек; **~ие разногла́сия** тактик мәсьәләләр буенча каршылыклар

такти́чность *ж* әдәплелек, үзен тота белү, тактлылык, иплелек

такти́чн||ый, -ая, -ое әдәпле, үзен тота белүчән, тактлы, ипле; **~ый челове́к** әдәпле кеше; **быть ~ым** үзеңне тота белү; **сде́лать ~ое замеча́ние** әдәпле итеп искәртү ясау

та́ктов||ый, -ая, -ое *муз.* такт[лар] ...ы; **~ая черта́** такт сызыгы

тал *м см.* **тальни́к**

тала́нт *м* 1. искиткеч зур сәләт, зур сәләтлек, сәләтлелек, талант; **музыка́льный ~** музыкага зур сәләтлек; **организа́торский ~** оештыру сәләте 2. (*талантливый человек*) талант, талант иясе; **молоды́е ~ы** яшь талантлар

тала́нтливость *ж* талантлылык, талантлы булу, талант иясе булу

тала́нтлив||ый, -ая, -ое 1. зур сәләтле, талантлы; **~ый компози́тор** талантлы композитор 2. мөкәммәл, талантлы, бөтен жире килгән; **~ое произведе́ние** мөкәммәл әсәр

та́лер I *м полигр.* талер (*басу машинасының бер өлеше*)

та́лер II *м* (*старинная немецкая монета*) талир, талир тәңкә

талисма́н *м* тылсым, бөти

та́л||я *ж* бил; **то́нкая ~я** нечкә бил; **пла́тье в ~ю** билне кысып тора торган күлмәк; **обня́ть за ~ю** биленнән кочаклап алу

та́ллий *м хим.* таллий

талму́д *м рел.* талмуд (*дингә ышанучы еврейларның дин, хокук, көнкуреш һ.б.ш. мәсьәләләре турындагы кагыйдәләр җыентыгы*)

талмуди́зм *м* талмудчылык, хәрефкә ябышып яту

талмуди́ст *м* 1. *рел.* талмудчы, талмуд белгече 2. *перен.* (*начётчик*) хәрефкә ябышып ятучы

тало́н *м* талон; **~ на бензи́н** бензин талоны; **прикрепи́тельный ~** беркетү талоны; **открепи́тельный ~** исәптән төшү талоны

та́л||ый, -ая, -ое эрегән, эреп йомшаган; жебегән; **~ый снег** эрегән кар; **~ая вода́** кар суы

тальк *м* тальк (*порошоксыман ак минерал*)

тальни́к *м* таллык, тал куаклыгы

тальнико́в||ый, -ая, -ое тал ...ы; **~ые за́росли** тал куаклары

талья́нка *ж прост.* тальян гармун

там 1. *нареч.* (*в том месте*) анда, шунда, тегендә; **~ есть телефо́н?** анда телефон бармы?; **поищи́те ~** тегендә эзләгез; **кни́ги ~, внизу́** китаплар шунда, аста 2. *нареч. разг.* (*потом, затем*) аннары, аннан соң, соңыннан, азактан; **~ ви́дно бу́дет, что де́лать** аннан соң нәрсә эшләргә кирәген күз күрер 3. *частица разг.* (*выражает сомнение, пренебрежение*) кая ул, анда; **каки́е ~ у него́ дела́!** аның анда нинди эше булсын! ♦ **како́е ~!** кая ул!, каян килсен ди!, каян булсын ди!; **~ и тут** тегендә дә, монда да; анда да, монда да; **чего́ ~!** әйдә, игътибар итмә!; **бери́, чего́ ~!** әйдә, ала бир!

тамада́ *м* табын башлыгы, табынчы, тамада

тамари́ск *м бот.* тамариск (*куаклык яки агач*)

та́мбур I *м ж.-д., архит.* тамбур; **стоя́ть в ~е** тамбурда тору

та́мбур II *м* (*вид вышивания или вязания*) тамбур; **вышива́ть ~ом** тамбурлы чигү, күпертеп чигү

тамбу́р *м уст.* тамбур (*то же, что* **бараба́н** I)

тамбури́н *м* 1. (*вид бубна*) шөлдермә 2. (*вид барабана*) тамбурин, озынча барабан

тамо́женник *м* таможнячы, таможня хезмәтчесе

тамо́женн||ый, -ая, -ое таможнялы, таможня ...ы; **~ый сбор** таможня жыемы; **~ый досмо́тр** таможня тикшерүе; **~ые учрежде́ния** таможня учреждениеләре

тамо́жня *ж* таможня (*дәүләт чиге аша үтә торган товарларны карап тикшерү, алардан пошлина алу кебек эшләрне башкаручы учреждение*)

та́мошний, -яя, -ее *разг.* андагы, шундагы, тегендәге; **~ жи́тель** шундагы кеше

тампо́н *м мед.* тампон (*канны тукмату яки яра киптерү өчен куела торган мамык яки марля*)

тампони́ровать *сов., несов. что, мед.* тампон кую, тампон тыгу; **~ ра́ну** ярага тампон кую

та́м-ся́м *нареч. разг.* тегендә-монда

тамта́м *м* (*вид гонга*) тамтам

та́нгенс *м мат.* тангенс

та́нго *с нескл.* танго

та́н||ец *м* бию, танцы; **наро́дные ~цы** халык биюләре; **спорти́вные ~цы на льду** бозда башкарыла торган спорт танцылары; **ве́чер ~цев** бию кичәсе

тани́н *м мед., тех.* танин, саргылт порошок

танк *м* танк

та́нкер *м* танкер

танке́тка *ж воен.* танкетка (*кечкенә тиз йөрешле танк*)

танке́тки *мн.* танкетка (*хатын-кыз аяк киеме*)

танки́ст *м* танкчы, танк йөртүче

та́нков||ый, -ая, -ое танк[лар] ...ы; **~ые ча́сти** танк частьлары; **~ая ата́ка** танклар атакасы

танкодро́м *м* танкодром

танкострое́ние *с* танклар төзү, танклар эшләп чыгару

танкострои́тельный, -ая, -ое танк[лар] төзү ...ы; **~ завод** танк төзү заводы

танта́л *м хим.* тантал

танта́лов: **~ы му́ки** жан газабы

танцева́льн||ый, -ая, -ое бию ...ы, танцы[лар] ...ы; **~ая му́зыка** бию көе; **~ый ве́чер** танцы кичәсе

танцева́ть *несов. что и без доп.* бию, танцевать итү; **~ вальс** вальс танцевать итү ♦ **~ от пе́чки** *ирон.* гадәтләнгән шаблон буенча гына эшләү

танцме́йстер *м уст.* танцыга өйрәтүче, танцмейстер

танцо́вщик *м* балет артисты

танцо́вщица *ж* балет артисткасы

танцо́р *м* биюче, бии белүче; танцевать итүче

танцплоща́дка *ж* танцы мәйданчыгы

танцу́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **танцева́ть**; **2.** биюче, бии торган, танцевать итүче; **идти́ ~ей похо́дкой** биеп бару **3.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* биючеләр, танцевать итүчеләр

тапёр *м* тапёр (*танцы кичәләрендә музыкант*)

тапи́р *м зоол.* тапир (*бер тояклы имезүче хайван*)

та́пки, **та́почки** *мн.* тапочка (*укчәсез җиңел аяк киеме*)

та́ра *ж* тара (*товар салып яки төреп йөртә торган әрҗә, тартма һ.б.ш.*)

тарабани́ть *несов. прост.* дөбердәтү, дөбер-шатыр килеп кагу

тараба́рск||ий, -ая, -ое *разг.* аңлаешсыз, мәгънәсез; **~ая гра́мота** аңлаешсыз бер нәрсә

тарабарщина *ж разг.* аңлаешсыз бер нәрсә, мәгънәсез нәрсә

тарака́н *м* таракан

тара́н *м* таран (**1.** *борынгы сугышларда крепость дивараларын җимерү коралы* **2.** *тех. горизонталь хәлдә эшләүче копёр* **3.** *воен. дошман самолётын, кораблен яки танкын үз самолётың, кораблең яки танкың белән бәрдерү*)

тара́нить *что* **1.** *несов. тех.* таранлау; таран ясау **2.** *несов., сов. воен.* таранлау, таран ясау; **~ самолёт проти́вника** дошман самолётын таранлау

тарантас *м* тарантас, читән арба

тарантелла *ж муз.* тарантелла (*Италиядә тиз темплы халык биюе һәм шул темпта язылган музыка әсәре*)

тара́нтул *м зоол.* тарантул, бүе

тара́нь *ж* тарань балыгы, Азов чабагы

тарара́м *м разг.* шау-шу, дау, җәнҗәл; **подня́ть ~** шау-шу куптару

тарара́хать *несов. см.* **тарара́хнуть**

тарара́хну||ть *сов. разг.* **1.** шатыр-шатыр килү, шатырдау; гөрселдәү; **~л гром** шатыр-шатыр килеп күк күкрәде; **~л вы́стрел** каты ату тавышы ишетелде

тарата́йка *ж* таратайка (*ике тәгәрмәчле җиңел арба*)

тарато́рить *несов. что и без доп., разг.* такылдау, лыкылдау; пытырдау

тарато́рка *м, ж разг.* такылдык, тел бистәсе, лыкылдык

тарахте́ние *с см.* **тарахте́ть**

тарахт||е́ть *несов. разг.* **1.** дыңгырдыңгыр килү, дыңгырдау, дыңгылдау; шалтырау; **вдали́ ~е́ла теле́га** ераста арба дыңгырдый иде **2.** *перен.* такылдау, лыкылдау; **не ~и́, говори́ то́лком** такылдама әле, рәтләп сөйлә

тара́щить *несов. что, разг.* акайту, акайтып карау, чекерәйтү; **~ глаза́** күзләрне акайтып карау

тара́щиться *несов. разг.* **1.** (*широко раскрываться — о глазах*) акаю, чекерәю **2.** *на кого-что* акаеп карау

таре́лк||а *ж* **1.** тәлинкә; **глубо́кая ~а** тирән тәлинкә **2.** *мн.* **~и** *муз.* тарелка (*бер-берсен бәреп уйный торган музыка коралы*) ♦ **не в свое́й ~е** *разг.* кәефсез булу; күңел төшеп тору

тари́ф *м* тариф (*бәяләр һәм түләү хаклары күрсәтелгән рәсми исемлек*); **железнодоро́жный ~** тимер юл тарифы; **почто́вый ~** почта тарифы; **~ы опла́ты труда́** эш хакы тарифлары

тарифика́ция *ж* тарификацияләү, тарификация ясау; тариф билгеләү; **~ за́работной пла́ты** эш хакы тарифларын билгеләү

тарифици́ровать *сов., несов. что* тариф билгеләү, тарификацияләү

тари́фн||ый, -ая, -ое тариф ...ы; тариф буенча билгеләнгән; **~ая ста́вка** тариф буенча билгеләнгән ставка; **~ая се́тка** тариф челтәре

тартары́ *нескл. мн.*: **провали́ться в ~** *разг.* жир йоткыры, җәһәннәмгә киткере

та́ры-ба́ры *мн. нескл. прост.* юк-бар сүз, сафсата

таска́ть *несов.* **1.** *кого-что* ташу, күтәреп йөртү; **~ во́ду** су ташу **2.** *кого* за *что* (*дёргать*) тарту, йолку **3.** *что, разг.* (*носить долго одежду, обувь*) кию, киеп йөрү **4.** *что, разг.* (*носить с собой*) йөртү

таска́ться *несов. разг.* **1.** өстерәлеп (сөйрәлеп) йөрү (бару); **~ без де́ла по у́лицам** урамда эшсез тик йөрү **2.** [*үзе белән*] йөртү, күтәреп йөртү; **~ с су́мкой** сумканы үзе белән күтәреп йөртү **3.** *страд. от* **таска́ть**

тасова́ть *несов. что* аралаштыру, бутау; **~ ка́рты** кәртләрне бутау

тата́рин *м* татар, татар кешесе

тата́рка *ж* татар хатыны (кызы)

тата́рник *м бот.* шайтан таягы, убыр уты

тата́рский, -ая, -ое татар[лар] ...ы; Татарстан ...ы; **~ язы́к** татар теле

татуи́ровать *сов., несов. кого-что* татуировка ясау, тәнгә чәнчеп тушь белән рәсем ясау

татуи́роваться **1.** *сов., несов.* үзеңә татуировка ясау (*тушь белән тәнгә чәнчеп рәсем ясату*) **2.** *несов. страд. от* **татуи́ровать**

татуиро́вка *ж* **1.** *см.* **татуи́ровать**; **2.** (*рисунки*) татуировка

та́у-сагы́з *м* таусагыз

тафта́ *ж* тафта (*юка тукыма*)

тахта́ *ж* тахта (*аркасыз киң диван*)

тачанка *ж* тачанка; **пулемётная ~** пулемёт тачанкасы

тача́ть *несов. что* тегү, каю; **~ сапоги́** итек тегү

та́чка *ж* тачка (*бер тәгәрмәчле кул арбасы*)

таща́ть *несов.* **1.** *кого-что* сөйрәп (өстерәп) алып бару, сөйрәп (өстерәп) алып килү, китерү; **~ бревно́** бүрәнә сөйрәп алып килү **2.** *кого-что, разг.* илтү, алып бару (кайту, китү); **~ поку́пки домо́й** сатып алган әйберләрне өйгә алып кайту **3.** *кого-что, разг.* (*тянуть за собой*) өстерәү, сөйрәү; **куда́ ты меня́ та́щишь?** син мине кая өстерисең? **4.** *что* суыру, суырып алу, тартып чыгару; **~ гвоздь из стены́** стенадан кадак суырып алу **5.** *кого-что, разг.* (*воровать*) чәлдерү, урлау

таща́ться *несов.* **1.** *разг.* (*идти, ехать медленно*) өстерәлеп (сөйрәлеп) бару; (*бик авырлык белән*) атлап бару; **~ в хвосте́** койрыкта сөйрәлеп бару **2.** (*волочиться по земле*) өстерәлү, сөйрәлү, өстерәлеп (сөйрәлеп) бару **3.** *страд. от* **таща́ть**

та́яние *с см.* **та́ять**; **~ снего́в** карлар эрүе

та́ять *несов.* **1.** эрү, эретү; **снег та́ет** кар эри; **сего́дня та́ет** *безл.* бүген эретә **2.** *перен.* (*постепенно исчезать*) бетү, бетә бару, әкренләп тыну, юкка чыгу: **зву́ки та́ют** тавышлар әкренләп тына; **тума́н та́ет** томан әкренләп бетә бара; **де́ньги та́ют** акчалар юкка чыга; **си́лы та́ют** көч бетә бара **3.** *перен.* (*худеть*) ябыгу, сулу, сүнә бару; **~ на глаза́х** күз алдында сула бару **4.** *перен.* эрү, эреп китү, күңел йомшару; **~ от любви́** яратудан эреп китү

тварь *ж* **1.** *уст.* (*живое существо*) жан иясе, җанвар **2.** *прост. бран.* (*о человеке*) хайван

твердёть *несов.* кату, катылану

твердо́ть *несов.* **1.** *что, о чём* туку, кат-кат әйтү (*бер ук нәрсәне*) **2.** *что, разг.* (*заучивать, запоминать*) ятлау (*кат-кат укып*), кабатлау

твердока́менный, -ая, -ое (*непоколебимый*) таштай нык, таш кебек каты, таштай

твердоло́бый, -ая, -ое (*тупой, косный*) ташбаш, ташмаңгай

твёрдость *ж* **1.** ныклык, катылык; **~ древеси́ны** үзагачның катылыгы **2.** *перен.* ныклык, тотрыклылык, какшамаслык; **~ ду́ха** рухның какшамаслыгы

твердото́пливн||ый, -ая, -ое *спец.* каты ягулыклы; **~ые раке́ты** каты ягулыклы ракеталар

твёрд||ый, -ая, -ое **1.** каты; **~ые тела́** *физ.* каты җисемнәр; **~ое состоя́ние** *физ.* каты хәл; **~ый каранда́ш** каты карандаш; **~ый грунт** каты җир; **~ые сорта́ пшени́цы** каты бодайлар **2.** *перен.* ныклы, нык, каты, какшамас; **~ое реше́ние** ныклы карар; **~ые зна́ния** ныклы белем; **~ая уве́ренность** каты ышаныч; **~ые це́ны** үзгәрми торган бәяләр **3.** көчле, ныклы, нык; **~ая во́ля** нык ихтыяр; **~ый хара́ктер** ныклы характер ♦ **~ые согла́сные** *лингв.* калын тартыклар; **~ый знак (ъ)** калынлык билгесе

твердыня *ж высок.* **1.** (*крепость*) ныгытма **2.** *перен.* (*оплот*) ныклы таяныч, терәк; **нау́чно-техни́ческая револю́ция — ~ прогре́сса** фәнни-техник революция — прогресс терәге

твердь *ж уст.*: **~ земна́я** коры җир; **~ небе́сная** күк йөзе

твист *м* твист (*парлы ритмик бию*)

твоё *с см.* **твой**

твои́ *мн. см.* **твой**

тво||й *м мест.* **1.** (*принадлежащий тебе*) синең; **~я́ шко́ла** синең мәктәбең; **~я́ кни́га** синең китабың **2.** *в знач. сущ.* **~ё** *с разг.* синеке, синең әйберең; **~ его́ мне не ну́жно** синеке миңа кирәк түгел **3.** *в знач. сущ.* **~и́** *мн.* (*родные*) синекеләр, үзеңнекеләр; **~и́ до́ма?** синекеләр өйдәме?

творе́ни||е *с* әсәр, иҗади эш; **~я Пу́шкина** Пушкин әсәрләре; **~е рук челове́ческих** кеше кулы эшләгән эш

творе́ц *м высок.* **1.** иҗат итүче, иҗатчы, барлыкка китерүче, тудыручы **2.** *рел.* (*бог*) яратучы, алла, тәңре

твори́тельный: ~ паде́ж *грам.* творительный килеш (чыгыш килеше)

твори́ть I *несов.* **1.** *что и без доп.* (*создавать*) иҗат итү, тудыру, барлыкка китерү, булдыру; кору; **~ но́вую жизнь** яңа тормыш кору **2.** *что* (*делать, совершать*) эшләү, кылу, башкару; ясау; **~ чудеса́** гаҗәеп эшләр эшләү; **~ добро́** яхшылык эшләү; **~ беззако́ния** законсызлыклар кылу

твори́ть II *несов. что* изү; **~ и́звесть** известь изү; **~ те́сто** камыр изү

твори́т||ься *несов.* **1.** *разг.* (*происходить*) булу; үтәлү; эшләнү; **что с ним ~ся?** аңа ни булган?; **что у вас тут ~ся?** ни эшләвегез бу? **2.** *страд. от* **твори́ть**

тво́рог, твороґ *м* эремчек

твороґжист||ый, -ая, -ое эремчексыман, эремчектәй; **~ая ма́сса** эремчексыман масса

творо́жник *м кул.* (*кыздырылган эремчек кабарткасы*) творожник

творо́жн||ый, -ая, -ое эремчектән ясалган, эремчекле, эремчек ...ы; **~ый сыр** эремчектән ясалган сыр; **~ая ма́сса** эремчек массасы

тво́рческ||ий, -ая, -ое иҗат ...ы, иҗади; **~ий путь писа́теля** язучының иҗат юлы; **~ий труд** иҗади хезмәт; **~ая мысль** иҗади фикер; **~ая командиро́вка** иҗат командировкасы; **~ое содру́жество** иҗади дуслык; **~ая акти́вность писа́телей** язучыларның иҗади активлыгы

тво́рчеств||о *с* иҗат; **нау́чное ~о** фәнни иҗат; **худо́жественное ~о** сәнгать иҗаты; **наро́дное ~о** халык иҗаты; **свобо́да ~а** иҗат иреге

твоя́ *ж см.* **твой**

те *мн. см.* **тот**

теа́тр *м* **1.** театр; **о́перный ~** опера театры; **~ ку́кол** курчак театры; **пойти́ в ~** театрга бару **2.** *перен.* (*место действия*) мәйдан; **~ вое́нных де́йствий** сугыш хәрәкәтләре мәйданы

театра́л *м* театр һәвәскәре, театр яратучы

театрализова́ть *сов., несов. что* сәхнәләштерү

театра́льн||ый, -ая, -ое **1.** театр ...ы; **~ое иску́сство** театр сәнгате; **~ое учи́лище** театр училищесы; **~ая ка́сса** театр кассасы **2.** *перен.* (*неестественный*) кыланчыклы; тәкәллефле, театраль, ясалма

театрове́д *м* театр белгече, театр сәнгате белгече

театрове́дение *с* театр сәнгате белеме, театрны өйрәнү фәне

тебенёвка *ж с.-х.* тибәндә йөрү

тевто́нский, -ая, -ое *ист.* тевтон[нар] ...ы; **Тевто́нский о́рден** Тевтоннар ордены

тевто́ны *мн.* тевтоннар (*борынгы герман кабиләләре*)

те́зис *м* тезис; **~ы докла́да** доклад тезислары

тёзка *м, ж* адаш; **он мой (мне) ~** ул минем адаш

тейзм *м рел.* теизм (*алланы акыллы зат итеп күзаллаган дини караш*)

теки́нский, -ая, -ое текин ...ы; **~ ковёр** текин хәтфә келәме

теки́нцы *мн.* текиннар (*төрекмәннәрнең бер өлеше*)

текст *м* текст; **перево́д иностра́нного ~а** чит телдәге текстны тәрҗемә итү; **~ пе́сни** җырның тексты

тексти́ль *м собир.* текстиль, тукыма, тукыма әйберләр

тексти́льн||ый, -ая, -ое туку ...ы, тукыма ..., текстиль ...ы; **~ая фа́брика** туку фабрикасы; **~ые изде́лия** тукыма әйберләр

тексти́льщик *м* тукучы, текстильче, туку промышленносте эшчесе

тексти́льщица *ж* тукучы хатын (кыз)

текстоли́т *м* текстолит (*пластик матдә*)

тексто́лог *м* текстолог, текстология белгече

текстологи́ческ||ий -ая, -ое текстология ...ы, текстологик; **~ое иссле́дование** текстологик тикшеренү

текстоло́гия *ж* текстология (*филологиядә әдәби һ.б.ш. әсәрләрнең текстларын өйрәнү һәм бастырып чыгару белән шөгыльләнә торган булек*)

текстуа́льный, -ая, -ое текстуаль, бермә-бер, сүзгә-сүз; **~ перево́д** сүзгә-сүз тәрҗемә

текто́ника *ж* тектоника (**1.** *җир кабыгының төзелеше һәм анда булып тора торган үзгәрешләр* **2.** *геология фәненең шуларны өйрәнә торган булеге*)

тектони́ческ||ий, -ая, -ое тектоника ...ы, тектоник; **~ие явле́ния** тектоник күренешләр; **~ая ка́рта** тектоника картасы

теку́честь *ж* **1.** *физ.* агучанлык **2.** *перен.* алмашынучанлык, үзгәрүчәнлек, даими булмау; **~ ка́дров** кадрларның алмашынып торуы

теку́ч||ий, -ая, -ее **1.** (*жидкий*) ага торган, агучан, агым ...; сыек; **~ая вода́** агым су; **~ие тела́** *физ.* агучан жисемнәр **2.** *перен.* алмашынып тора торган, үзгәреп тора торган, даими булмаган; **~ий соста́в рабо́тников** хезмәткәрләрнең үзгәреп тора торган составы

теку́чка *ж разг.* көндәлек эш

теку́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **течь** I; **2.** агымдагы; хәзерге, шушы; **~ий моме́нт** агымдагы момент; **в ~ем ме́сяце** агымдагы айда; **~ая рабо́та** агымдагы эш **3.** (*повседневный*) көндәлек, агымдагы; **~ие дела́** көндәлек эшләр ◆ **~ий счёт** агымдагы счёт; **~ий счёт предприя́тия** предприятиенең агымдагы счёты

теле- *кайбер кушма сүзләрнең тубәндәге мәгънәләрдә кулланыла торган беренче кисәге* 1) *«телевидениегә бәйләнешле, телевидениегә караган», мәс.* **тележурна́лист** тележурналист, телевидение журналисты; **телережиссёр** телережиссёр, телевидение режиссёры; 2) *«ерактан торып төрле элемтә чаралары ярдәмендә эшли яки эшләтә торган», мәс.* **телеобъекти́в** телеобъектив

телеавтома́тика *ж* телеавтоматика

телеательé *с нескл.* телеателье (*телевизорлар ремонтлау ателесы*)

телеба́шня *ж* телебашня; **Оста́нкинская ~** Останкино телебашнясы

телевеща́ние *с* телетапшыру

телеви́дение *с* телевидение

телевизио́нн||ый, -ая, -ое **1.** телевидение ...ы; телевизион ...; **~ый центр** телевидение үзәге; **~ая анте́нна** телевидение антеннасы; **~ая програ́мма** телевидение программасы; **~ый худо́жественный фильм** телевизион нәфис фильм; **~ый ко́нкурс** телевизион конкурс **2.** телевидение ярдәме белән; телевидение аша; **~ая переда́ча** телевидение аша тапшыру

телеви́зор *м* телевизор; **цветно́й ~** төсле телевизор

телеви́зорный, -ая, -ое телевизор ...ы; **~ сто́лик** телевизор өстәле

телевы́шка *ж* телевышка

теле́га *ж* арба

телегра́мм||а *ж* телеграмма; **поздрави́тельная ~а** котлау телеграммасы; **~а-мо́лния** бик ашыгыч телеграмма; **дать ~у** телеграмма сугу

телегра́ф *м* телеграф

телеграфи́рование *с см.* **телеграфи́ровать**

телеграфи́ровать *сов., несов. что, о чём* телеграмма жибәрү, телеграмма сугу, телеграмма бирү; **~ о прие́зде** кайту турында телеграмма бирү

телеграфи́ст *м* телеграфчы, телеграфта эшләүче

телеграфи́стка *ж* телеграфчы хатын (кыз)

телегра́фн||ый, -ая, -ое **1.** телеграф ...ы; **~ый бланк** телеграф бланкысы; **~ый аппара́т** телеграф аппараты; **~ое сообще́ние** телеграф хәбәре **2.** телеграф ярдәмендә, телеграф аша; **~ая связь** телеграф аша бәйләнеш ◆ **Телегра́фное аге́нтство** Телеграф агентлыгы

теле́жка *ж* кечкенә (бәләкәй) арба, кул арбасы

тележурна́л *м* телевизион журнал

тележурнали́ст *м* телевидение журналисты

телезри́тель *м* телевизор караучы

телеинтервью́ *с нескл.* телеинтервью

телеинформа́ция *ж* телеинформация

телека́мера *ж* телекамера

телекоммента́тор *м* телевидение комментаторы

телекомпа́ния *ж* телекомпания

телемеха́ника *ж тех.* телемеханика (**1.** *машина, механизм һәм җайланмаларны ерактан торып идарә итү һәм көйләү* **2.** *ерактан торып механизмнар белән идарә итүнең методларын һәм чараларын өйрәнүче фән*)

телёнок *м* **1.** (*детёныш коровы*) бозау; (*детёныш оленя*) болан баласы; (*детёныш лося*) пошый баласы **2.** *перен. разг.* (*о простоватом и доверчивом человеке*) бозау

телеобъекти́в *м* телеобъектив

телеоло́гия *ж филос.* телеология (*табигатьтә бөтен нәрсә максатка туры китереп яратылган һәм һәр усештә алдан билгеләп куелган максат тормышка ашырыла дип раслый торган идеалистик тәгълимат*)

телеопера́тор *м* телеоператор, телестудия операторы

телео́черк *м* телеочерк, телевизион очерк

телепати́ческ||ий, -ая, -ое телепатия ...ы; **~ая связь** телепатия элемтәсе (*бер-береңне ерактан торып аңлау, сизү турында*)

телепа́тия *ж* телепатия (*кеше фикерләренең һәм тойгыларының ерактан сизелүе, фәнни исбатланмаган*)

телепереда́тчик *м* телетапшыргыч

телепостано́вка *ж* телепостановка

телепрогра́мма *ж* телевизион программа

телерепорта́ж *м* телерепортаж; **~ из ко́смоса** галәмнән тапшырылган телерепортаж

телерепортёр *м* телерепортёр

телеса́ *мн. шутл.* симез гәүдә, юан гәүдә

телесвя́зь *ж* телеэлемтә

телеско́п *м* телескоп

телескопи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** телескоп ...ы; телескоп аша гына күренгән; телескоп ярдәмендә ...; **~ая анте́нна** телескоп антеннасы; **~ие плане́ты** телескоп аша гына күреп була торган планеталар; **~ие наблюде́ния Ма́рса** Марсны телескоп ярдәме белән күзәтү **2.** *опт.* телескопик, ныклы зурайтып күрсәтә торган; **~ие очки́** ныклы зурайтып күрсәтә торган күзлек

телеско́пн||ый, -ая, -ое телескоп ...ы; **~ая труба́** телескоп торбасы

теле́сн||ый, -ая, -ое **1.** тән ...ы; **~ые поврежде́ния** тән җәрәхәтләре **2.** (*о цвете*) тән төсендәге, тән төсле; **чулки́ ~ого цве́та** тән төсендәге оек

телеспекта́кль *м* телеспектакль

телета́йп *м* телетайп (*хәрефләр баса торган телеграф аппараты*)

телета́йпн||ый, -ая, -ое телетайп ...ы; **с ~ой ле́нты** телетайп тасмасыннан

телетрансля́ция *ж* телетрансляция

телеустано́вка *ж* телеустановка, тележайланма

телефи́льм *м* телефильм, телевизион фильм

телефо́н *м* телефон; **звони́ть по ~у** телефоннан шалтыратып алу; **~-автома́т** автомат телефон

телефониза́ция *ж* телефонлаштыру, телефон үткәрү

телефони́ровать *сов., несов. что, о чём* телефон аша хәбәр итү, телефоннан әйтү

телефони́ст *м* телефончы, телефонда эшләүче

телефони́стка *ж* телефончы хатын (кыз)

телефо́нн||ый, -ая, -ое **1.** телефон ...ы; **~ый аппара́т** телефон аппараты; **~ая ста́нция** телефон станциясе **2.** телефон аша ...; **~ые перегово́ры** телефон аша сөйләшүләр

телефонограмма *ж* телефонограмма, телефон аша бирелгән хәбәр

Теле́ц *м астр.* Үгезбозау

телецентр *м* телеүзәк, телевидение үзәге

телеэкра́н *м* телевизор экраны

тели́ться *несов.* бозаулау

тёлка *ж* тана, тана бозау; (*двухгодовалая, нетель*) башмак тана; (*до первого отёла*) тана сыер

теллу́р *м хим.* теллур

те́л||о *с* **1.** *физ., мат.* җисем; **твёрдые ~а́** каты җисемнәр; **жи́дкие ~а́** сыек җисемнәр; **газообра́зные ~а́** газсыман җисемнәр; **геометри́ческое ~о** геометрик җисем; **небе́сные ~а́** күктәге җисемнәр **2.** (*человека*) тән, гәүдә, бәдән; **ча́сти ~а** тән әгъзалары **3.** *воен.* көпшә; **~о пулемёта** пулемёт көпшәсе

телогре́йка *ж разг.* сырма, телогрейка

телодвиже́ние *с* тән хәрәкәте

теля́ *м разг. см.* **телёнок**

телосложе́ни||е *с* тән төзелеше, сын, буй-сын; **челове́к кре́пкого ~я** тән төзелеше нык кеше

телохрани́тель *м* тән сакчысы, шәхси сакчы

тельня́шка *ж разг.* тельняшка (*матросларның эчке күлмәге*)

те́льц||е *с* **1.** *уменьш.-ласк. от* **те́ло** 2; **2.** *обычно мн.* **~а́** *биол.* тәнчек; **кра́сные кровяны́е ~а́** кызыл кан тәнчекләре (*эритроцитлар*)

теля́тина *ж* бозау ите

теля́тник *м* **1.** (*хлев*) бозау абзары **2.** (*работник*) бозау караучы

теля́тница *ж* бозау караучы хатын (кыз)

теля́ч||ий, -ья, -ье **1.** бозау ...ы; **~ьи но́жки** бозау аяклары **2.** бозау ите ...ы, бозау итеннән пешерелгән; **~ьи котле́ты** бозау итеннән пешерелгән котлет ◆ **~ий восто́рг** *ирон.* урынсыз шатлану; **~ьи не́жности** *ирон.* төче ягымлылык

тем *союз со сравн. ст.* шул хәтле, шулкадәр, ...ган саен; **чем ночь темне́й, ~ я́рче звёзды** төн никадәр караңгырак булса, йолдызлар шулкадәр яктырак яна ◆ **~ бо́лее** бигрәк тә; **~ лу́чше** бигрәк әйбәт, тагын да яхшырак; **~ не ме́нее** шуңа карамастан, шулай була торып

те́ма *ж* тема (**1.** *әсәрнең, фикерләүнең, иҗатның һ.б.ш. төп эчтәлеге* **2.** *музыка әсәренең төп көе*)

тема́тика *ж* тематика, барлык темалар җыелмасы

тематѝческ||ий, -ая, -ое тематик, тематика ...ы; **~ий план** тематик план; **~ая вы́ставка** тематик күргәзмә

тембр *м* тембр (*һәрбер авазның, тавышның үзенә хас булган сыйфаты*); **~ го́лоса** тавышның тембры

теменн||о́й, -а́я, -о́е *анат.* түбә ...ы; **~а́я кость** түбә сөяге

те́мень *ж разг.* караңгы, караңгылык; **непрогля́дная ~** дөм-караңгы

темля́к *м* темляк, бөлдермә *диал.*; **са́бля с ~о́м** темлякле кылыч

темне́||ть *несов.* **1.** каралу, карала төшү; **серебро́ ~ет** көмеш карала **2.** *безл.* караңгылану, караңгы төшү; **сейча́с ра́но ~ет** хәзер иртә караңгы төшә **3.** (*виднеться — о чём-л. тёмном*) кара булып күренү, кара-кучкылланып тору; **вдали́ ~ет лес** ераткы урман кара булып күренә

темне́ться *несов. разг. см.* **темне́ть** 3

темни́ть *несов. разг.* **1.** *кого-что* (*делать тёмным*) караңгыландыру, каралту **2.** *перен. разг.* (*путать, обманывать*) бутау

темни́||ца *ж уст.* зиндан, төрмә; **посади́ть в ~у** төрмәгә утырту

темно́ *нареч.* **1.** караңгы; **темны́м-~** кап-караңгы, дөм-караңгы **2.** *в знач. сказ. безл.* караңгы; **~, хоть глаз вы́коли** күзгә төртсәң күренмәслек караңгы; **здесь не так ~** монда бик караңгы түгел

темно- *төс белдергән кушма сыйфатларның беренче кисәге, татар теленә «кара», «куе» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.* **~гла́зый** *кара күзле;* **~бро́вый** *кара кашлы*

тёмно- *кайбер кушма сыйфатларның беренче кисәге, татар теленә «куе», «карасу», «коңгырт» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.* **~-голубо́й** куе зәңгәр; **~-зелёный** куе яшел; **~-кра́сный** карасу кызыл

темноволо́сый, -ая, -ое коңгырт чәчле

темноко́жий, -ая, -ее кара тәнле

темнот||а́ *ж* **1.** караңгылык, караңгы; **до наступле́ния ~ы́** караңгы төшкәнче **2.** *перен. разг.* (*невежество*) наданлык, томаналык, каралык, гафиллек

тёмн||ый, -ая, -ое **1.** караңгы; **~ая ко́мната** караңгы бүлмә; **~ая ночь** караңгы төн **2.** (*о цвете*) кара, карасу төстәге, каралҗым **3.** *перен.* (*неясный, непонятный*) аңлаешсыз, томанлы; **~ое ме́сто в те́ксте** текстның аңлаешсыз урыны **4.** *перен.* (*безрадостный*) кара, күңелсез, кайгылы, хәсрәтле, **~ые мы́сли** күңелсез уйлар **5.** *перен.* (*вызывающий подозрение*) шикле, шөбһәле; кара, пычрак, җинаятьчел; **~ая ли́чность** шикле кеше; **~ые дела́** пычрак эшләр **6.** *перен.* (*невежественный*) надан, томана, кара ◆ **от ~а́ до ~а́** иртәдән кичкә кадәр; **~ое пятно́** кара тап, хурлыклы тап; **устро́ить ~ую** *кому, прост.* берәр кешенең башын каплап кыйнау

темп *м* **1.** *муз.* темп **2.** *перен.* тизлек; темп; **бы́стрыми ~ами** тиз темп белән; **~ рабо́ты** эш темпы; **~ы разви́тия**

промы́шленности промышленностьның үсү темплары ♦ **в ~е** тиз-тиз генә, җәһәт кенә

темпера́мент *м* **1.** темперамент; **меланхоли́ческий ~** меланхолик темперамент; **холери́ческий ~** холерик темперамент **2.** дәрт, гайрәт; **поэти́ческий ~** шигъри дәрт; **челове́к с ~ом** гайрәтле кеше

темпера́ментн||ый, -ая, -ое темпераментлы, дәртле; кызу, ялкынлы; **~ый актёр** темпераментлы актёр; **~ая речь** ялкынлы речь

температу́ра *ж* температура; **высо́кая ~** югары температура; **ни́зкая ~** түбән температура; **~ кипе́ния** кайнау температурасы; **~ те́ла** тән температурасы; **повы́шенная ~** күтәренке температура; **норма́льная ~** нормаль температура

температу́рить *несов. разг.* температура күтәрелү, температура күтәрелеп авыру; **больно́й температу́рит** авыруның температурасы күтәрелгән

темь *ж разг. см.* **тьма**

те́мя *с анат.* баш түбәсе, түбә

тенденцио́зность *ж* берьяклылык, тенденциялелек, тенденциозлык

тенденцио́зный, -ая, -ое (*пристрастный, необъективный*) берьяклы, тенденциоз, тенденцияле; **~ подхо́д к пробле́ме** мәсьәләгә берьяклы гына килү

тенде́нци||я *ж* **1.** (*направление развития*) тенденция, үсеш юнәлеше; омтылыш; **прогресси́вные ~и** прогрессив тенденцияләр **2.** (*берәр әсәрдә уткәрелә торган*) төп фикер, төп идея **3.** (*предвзятая мысль*) берьяклы фикер, тенденция

те́ндер *м ж.-д.* тендер (*су, кумер һ.б.ш. өчен махсус вагон яки паровозның шулар өчен җайланган арткы өлеше*)

тенев||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*находящийся в тени*) күләгәле, күләгә төшеп тора торган **2.** *перен.* күләгәле, кире, тискәре; **~а́я сторона́ де́ла** эшнең кире ягы; **~а́я эконо́мика** күләгә икътисады

тенелюби́в||ый, -ая, -ое *бот.* күләгәле жирдә үсә торган, күләгә яратучы ...; **~ые расте́ния** күләгә яратучы үсемлекләр

тенёта *только мн.* ятьмә, ау ятьмәсе; **попа́сть в ~** ятьмәгә эләгү

тени́ст||ый, -ая, -ое күләгәле, күләгә күп төшә торган; **~ый сад** күләгәле бакча; **~ое ме́сто** күләгәле урын

те́ннис *м спорт.* теннис; **насто́льный ~** өстәл теннисы

тенниси́ст *м* теннисчы, теннис уйнаучы

тенниси́стка *ж* теннис уйнаучы хатын (кыз)

те́нниска *ж* тенниска (*кыска җиңле җиңел трикотаж күлмәк*)

те́ннисный, -ая, -ое теннис ...ы; **~ мяч** теннис тубы; **~ корт** теннис корты

те́нор *м* тенор (**1.** *ирләрдә иң югары тавыш* **2.** *шул тавыш белән җырчы*)

тент *м* тент, киндер япма

тен||ь *ж* **1.** күләгә; **~ь от де́рева** агач күләгәсе; **сиде́ть в ~и́** күләгәдә утыру; **2.** (*силуэт*) шәүлә, карамчык **3.** *перен. чего* эз, билге, әсәр; **по его́ лицу́ пробежа́ла ~ь неудово́льствия** аның йөзенә ризасызлык әсәре чыкты **4.** *перен. чего* шәүлә, күләгә, өрәк; **~и про́шлого** үткән заман шәүләләре **5.** *перен.* күләгә, шик; **бро́сить ~ь** *на кого-л. берәүгә* күләгә төшерү ♦ **держа́ться (быть) в ~и́** читтә тору; **одна́ ~ь оста́лась** *от кого* аның коры сөяге генә калган; **оста́ться в ~и́** күләгәдә калу

теодоли́т *м геод., астр.* теодолит

теокра́тия *ж* теократия (*сәяси хакимият дин башлыклары кулында булган идарә формасы*)

тео́лог *м* теолог, теология белгече

теологи́ческий, -ая, -ое теологик

теоло́гия *ж* теология (*алла һәм дин догматлары турында дини тәгълимат*)

теоре́м||а *ж мат.* теорема; **доказа́ть ~у** теореманы исбат итү

теоретизи́ровать *несов.* теоретик мәсьәләләр турында фикер йөртү

теоре́тик *м* теорияче; **~и иску́сства** сәнгать теориячеләре

теорети́ческ||ий, -ая, -ое теория ...ы; теоретик, теориягә нигезләнгән; **~ие вопро́сы** теория мәсьәләләре; **~ая подгото́вка** теоретик әзерлек

теорети́чный, -ая, -ое (*абстрактный*) абстракт, тәҗрибәдән ерак

тео́рия *ж в разн. знач.* теория, тәгълимат; **~ вероя́тностей** *мат.* ихтималлыклар теориясе; **~ позна́ния** *филос.* танып белү теориясе; **~ му́зыки** музыка теориясе

тео́софия *ж* теософия, тасаввыф (*тәгълимат*)

тепе́решн||ий, -яя, -ее *разг.* хәзерге; хәзерге заман ...ы; **в ~ее вре́мя** хәзерге вакытта; **~ие лю́ди** хәзерге заман кешеләре

тепе́рь *нареч.* хәзер; **~ де́ло пойдёт** хәзер инде эш барыр

тёпленьк||ий, -ая, -ое *уменьш.-ласк. от* **тёплый** 1; **вы́дался ~ий денёк** җылы гына көн туры килде ♦ **~ое ме́стечко** *ирон.* җылы урын (*җиңел акча килә торган урын*)

тепл||и́ть *несов.* **1.** җылыну, җылына төшү **2.** *безл.* җылыту, [көн] җылыта төшү; **на у́лице ~ет** тышта җылыта

тёплит||ься *несов.* **1.** (*слабо светиться*) сүнәр-сүнмәс кенә янып тору, көчкә генә янып тору, **~ся свеча́** шәм сүнәр-сүнмәс кенә янып тора **2.** *перен.* бар булу; ... сүнмәү; **жизнь в нём едва́ ~ся** аның чак кына җаны бар; **ещё ~ся наде́жда** әле өмет [чаткысы] бар

тепли́ца *ж* теплица

тепли́чн||ый, -ая, -ое **1.** теплица ...ы; **~ая ра́ма** теплица рамы **2.** теплицада үстерелгән; **~ые огурцы́** теплицада үстерелгән кыяр ♦ **~ое расте́ние** тормышка яраклашмаган кеше

тепл||о́ I *с* **1.** җылы, җылылык; **на у́лице де́сять гра́дусов ~а́** тышта ун градус җылылык; **сиде́ть в ~е́** җылыда утыру **2.** *перен.* (*сердечность*) җылылык, җылы, ягымлылык; **душе́вное ~о́** күңел җылысы

тепло́ II *нареч.* **1.** җылы; **одева́ться ~** җылы киенү **2.** *в знач. сказ. безл.* җылы; **в до́ме ~** өйдә җылы; **сего́дня ~** бүген көн җылы; **мне ~** миңа җылы, мин өшемим **3.** *перен.* җылы, ягымлы; **~ встре́тить** *кого-л. берәр кешене* җылы каршылау

тепло- *кайбер кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «җылы, җылылык» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.*

теплосе́ть җылылык челтәре; **теплогенера́тор** *тех.* җылылык генераторы

тепловóз *м* тепловоз

теплов||о́й, -а́я, -о́е җылылык ...ы; җылылык ярдәмендә ...; **~а́я эне́ргия** җылылык энергиясе; **~о́й дви́гатель** җылылык ярдәмендә эшли торган двигатель; **~о́е излуче́ние** җылылык нурланышы ♦ **~о́й уда́р** эссе кабу

теплоёмкость *ж физ.* җылысыешлык, җылылык сыемы; **уде́льная ~** чагыштырма җылысыешлык; **~ пе́чи** мичнең җылысыешлыгы

теплозащи́та *ж см.* **теплоизоля́ция**

теплозащи́тный, -ая, -ое *см.* **теплоизоляцио́нный**

теплоизоляцио́нный, -ая, -ое *тех.* җылылык үткәрми торган; **~ материа́л** җылылык үткәрми торган материал

теплоизоля́ция *ж тех.* җылылык үткәрмәү, җылылык чыгармау

теплокро́вные *мн. зоол.* җылыканлылар

теплолюби́в||ый, -ая, -ое җылы ярата торган, җылы яратучы, җылыда үсә торган; **~ые культу́ры** җылыда үсә торган үсемлекләр

тепломагистра́ль *ж* җылылык магистрале, үзәк җылы үткәргеч

теплообме́н *м* җылы алмашу, җылылык алмашу

теплоотда́ча *ж физ.* җылыбирешлек, җылы бирү сәләте

теплопрово́дност||ь *ж физ.* җылы үткәрүчелек; **коэффицие́нт ~и** җылы үткәрүчелек коэффициенты

теплопрово́дн||ый, -ая, -ое *физ.* җылылык үткәрә торган, җылы үткәрүче; **~ые тела́** җылы үткәрүче җисемнәр

теплосе́ть *ж* җылылык челтәре

теплосто́йкий, -ая, -ое *тех.* җылыга чыдамлы

теплосто́йкость *ж тех.* җылыга чыдамлык

теплот||а́ *ж* **1.** *физ.* җылылык; **едини́ца ~ы** җылылык берәмлеге; **~а́ парообразова́ния** паръясалу җылылыгы **2.** *перен.* җылылык, ягымлылык; **душе́вная ~а́** күңел җылылыгы

теплотво́рность *ж физ.* җылы бирүчелек, җылылык бирү сәләте; **~ то́плива** ягулыкның җылылык бирү сәләте

теплотво́рный, -ая, -ое *физ.* җылытудыргыч, җылылык хасил итә торган

теплоте́хник *м* теплотехник, теплотехника белгече

теплоте́хника *ж* теплотехника (*техниканың җылылыктан һәм пардан файдалану белән шөгыльләнә торган бүлеге*)

теплотра́сса *ж* җылылык үткәргеч юлы

теплофика́ция *ж* теплофикация (*җылыту системасы уткәру*)

теплофици́ровать *сов., несов. что* теплофикацияләү, үзәктән ягып җылыту системасын үткәру

теплохо́д *м* теплоход

теплоцентра́ль *ж* теплоцентраль (*үзәктән җылыту өчен җылылык энергиясе эшләп чыгара торган станция*)

теплоэлектроцентра́ль *ж* теплоэлектроцентраль (*җылылык һәм электр энергиясе эшләп чыгара торган станция*)

тепли́шка *ж* теплушка (*кешеләр йөртү өчен җайланган товар вагоны*)

тёпл||ый, -ая, -ое **1.** җылы; **~ый кли́мат** җылы климат; **~ая оде́жда** җылы кием **2.** *перен.* җылы, ягымлы; **~ое чу́вство** җылы хис; **~ая встре́ча** җылы каршы алу; **~ые слова́** ягымлы сүзләр **3.** күңелгә ятышлы, матур; **~ые тона́ки** буяуларның матур тоны ♦ **~ая компа́ния** *разг.* әшнәләр төркеме, җылы компания

тепли́нь *ж разг.* бик җылы көн, бик җылы һава, бик җылы

терапе́вт *м* терапевт (*эчке авырулар табибы*)

терапевти́ческ||ий, -ая, -ое терапия ...ы; терапевтик; **~ое отделе́ние больни́цы** хастаханәнең терапия бүлеге

терапи́я *ж* терапия (*медицинаның эчке авыруларны хирургия юлыннан башка дәвалый торган бүлеге*)

тереби́льн||ый, -ая, -ое йолкыла торган; йолку ...ы; **~ая маши́на** йолку машинасы

тереби́льщик *м* киндер (җитен) йолкучы

тереби́льщица *ж* киндер (җитен) йолкучы хатын (кыз)

тереби́ть *несов.* **1.** *что* (*собирая, выдёргивать лён, коноплю*) йолку **2.** *что* тарту; сыйпау; **~ во́лосы** чәчне тарту **3.** *перен. кого* (*приставать, надоедать*) йәдәтү, борчу, тынычсызлау

те́рем *м* терем (*борынгы Русьта йортның өстендәге бина яки манара рәвешендә салынган аерым йорт*)

тере́ть *несов. что* **1.** ышку, уу; **~ глаза́** күз уу; **~ спи́ну** арканы ышку **2.** кыру, ваклау, уу; **~ морко́вь** кишер кыру; **~ таба́к** тәмәке уу **3.** (*вызывать боль*) кыру; **сапо́г трёт но́гу** итек аякны кыра

тере́ться *несов.* **1.** *чем, разг.* ышкыну, сөртенү **2.** *обо что* ышкылу; **жернова́ тру́тся друг о дру́га** тегермән ташлары бер-берсенә ышкыла **3.** *перен. разг.* ышкыну, чуалып йөрү; **котёнок трётся у ног** песи баласы аяк астында ышкынып йөри **4.** *перен.* (*находиться среди кого-чего-л.*) буталып йөрү; кысылып йөрү

терза́ния *мн.* азап, җәфа

терза́ть *несов. кого-что* **1.** (*рвать на части*) ботарлау, өзгәләү **2.** *перен.* азаплау, җәфалау

терза́ться *несов.* азаплану, җәфалану, өзгәләнү; **~ сомне́ниями** шикләрдән азаплану

тёрка *ж* кыргыч, угыч

те́рмин *м* атама, термин; **техни́ческие ~ы** техника терминнары; **лингвисти́ческие ~ы** лингвистик терминнар

терминологи́ческий, -ая, -ое терминологик, терминология ...ы; **~ слова́рь** терминология сүзлеге

терминоло́гия *ж* терминология; **граммати́ческая ~** грамматик терминология

терми́ст *м* термист (*металларны термик юл белән эшкәртүче*)

термит I *м хим.* термит (*янганда бик югары температура бирә торган порошоксыман катнашма*)

термит II *м зоол.* термит (*бөҗәк*)

термо́н||ый, -ая, -ое термит ...ы; термит белән ...; термитлы; **~ая бо́мба** термитлы бомба; **~ая сва́рка** термит белән кыздырып ябыштыру; **~ая смесь** *см.* **термит** I

терми́ческ||ий, -ая, -ое *физ., тех.* термик, термик ысул белән ...; **~ая обрабо́тка мета́ллов** металларны термик ысул белән эшкәртү

термо- *кайбер кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «җылы», «җылылык» сүзе белән тәрҗемә ителә, ә күп кенә вакытта тәрҗемә ителми дә, мәс.* **термостóйкий** җылыга чыдам; **термофосфа́т** термофосфат; **термоантраци́т** термоантрацит; **термотерапи́я** *мед.* термотерапия

термодина́мика *ж* термодинамика (*физика бүлеге*)

термо́метр *м* термометр; **медици́нский ~** медицина термометры; **рту́тный ~** терекөмешле термометр; **поста́вить ~** термометр кую

термообрабо́тка *ж* кыздырып эшкәртү, термик эшкәртү

терморегуля́тор *м* җылы көйләгече, җылылык регуляторы

те́рмос *м* термос

термоста́т *м* термостат (*температураны бер дәрәҗәдә саклау аппараты*)

термостóйкий, -ая, -ое *см.* **теплостóйкий**

термоя́дерн||ый, -ая, -ое термик төш ...ы; атом-төш ...ы; **~ое ору́жие** термик төш коралы; **~ая реа́кция** термик төш реакциясе

тёрн *м* күгән (*усемлеге һәм җимеше*)

терни́стый, -ая, -ое *уст.* чәнечкеле; **~ куст** чәнечкеле куак ♦ **~ путь** авыр юл, кыен юл

терно́вник *м* күгән куагы (агачы)

терно́вый, -ая, -ое чәнечкеле; **~ куст** чәнечкеле куак ♦ **~ вене́ц** *книжн.* чәнечкеле таҗ (*газаплану, газап чигү*)

терпели́вость *ж* түземлелек, чыдамлык, сабырлык

терпели́вый, -ая, -ое түземле, чыдам[лы], сабыр; **~ челове́к** сабыр кеше; **~ больно́й** түземле авыру

терпе́ни||е *с* **1.** түземлек, чыдамлык, сабырлык, тәкать; **запасти́сь ~ем** тәкать тоту; **потеря́ть вся́кое ~е** бөтенләй тәкать калмау; **~е ло́пнуло** чыдар хәл калмады; **вы́вести из ~я** чыдар хәлне калдырмау **2.** түзем, чыдам, тәкать; **облада́ть ~ем** түземле булу; **~е и труд всё перетру́т** *посл.* ≈ тырышкан тапкан, ташка кадак каккан

терп||е́ть *несов.* **1.** *что и без доп.* түзү, чыдау, сабыр итү, түзеп (чыдап) тору; **~е́ть боль** авыртуга түзү; **~е́ть жару́** эссегә чыдау **2.** *кого-что* түзү, чыдау, килешү; **он не те́рпит возраже́ний** ул каршы әйткәнгә түзеп тора алмый **3.** *что* күрү, кичерү; очрау; **~е́ть лише́ния** авырлыклар кичерү; **~е́ть неуда́чу** уңышсызлыкка очрау **4.** көтү, сабыр итү; **де́ло не те́рпит** эш көтми; **вре́мя те́рпит** вакыт бар әле ♦ **~е́ть не могу́** *кого-что, чего берәр кешене, берәр нәрсәне* күрә алмыйм, женем сөймәй

терпе́ться *несов. безл. с отриц. кому и без доп.* түзә алу, чыдый алу, чыдап булу; **не те́рпится сказа́ть** чыдап булмый, әйтәсе килә; **мне не те́рпится приступи́ть к рабо́те** эшкә тотынмый түзә алмыйм

терпи́мость *ж* түземлелек, чыдамлылык, сабырлык; **проявля́ть ~** сабырлык күрсәтү

терпи́м||ый, -ая, -ое **1.** түзәрлек, чыдарлык, түзеп (чыдап) торырлык; **~ые усло́вия** түзәрлек шартлар **2.** түземле, сабыр; **~ый челове́к** сабыр кеше

те́рпк||ий, -ая, -ое авыз камаштыра торган, авыз бөрештерә торган; **~ое я́блоко** авызны камаштыра торган алма

те́рпкость *ж* авыз камаштыра торган булу, авыз бөрештерә торган булу

терпу́г I *м спец.* терпуг (*игәү урынына кулланыла торган эре сырлы корыч кайрак*)

терпу́г II *м* (*рыба*) терпуг

террако́та *ж* терракота (**1.** *яндырылган кызыл яки сары балчык* **2.** *собир. шуннан ясалган әйберләр*)

террако́тов||ый -ая, -ое **1.** терракота ...ы; яндырылган балчыктан ясалган; **~ые изде́лия** терракотадан ясалган әйберләр **2.** (*о цвете*) кызыл кирпеч төсендәге, кызылсу, көрән

терра́рий *м* террарий (*то же, что* **терра́риум**)

терра́риум *м* террариум (*сөйрәлүчеләр өчен махсус бина*)

терра́са *ж* терраса (**1.** *өйгә терәп эшләнгән тубәле җәйге ачык корылма* **2.** *геогр. тау киртләче, киртләч*)

терренку́р *м* терренкур (*махсус оештырылган маршрутлар буенча дозалап йөреп дәвалану методы*)

террико́н *м горн.* террикон

территориа́льно-произво́дственный, -ая, -ое: **~ ко́мплекс** территориаль-производство комплексы

территориа́льн||ый, -ая, -ое территория ...ы, территориаль; **~ый конфли́кт** территория конфликты (*территория мәсьәләсе буенча булган кискенлек, киренкелек*); **~ая це́лостность** территория бөтенлеге; **~ое деле́ние** территориаль бүленеш; **~ые грани́цы** территория чикләре; **~ые диале́кты** җирле сөйләшләр; **~ые во́ды** эчке сулар (*диңгезнең бер дәүләткә караган яр буе сулары*)

террито́рия *ж* территория; **~ страны́** илнең территориясе; **~ завода́** завод территориясе; **~ фе́рмера** фермер территориясе

ТЕР-ТЕЧ

терро́р *м* террор

терроризи́ровать *сов., несов. кого-что* 1. террорлау, террор белән куркыту 2. (*запугивать*) куркыту, курку салу, куркытып бетерү, котын алу

террори́зм *м* террорчылык; **международно́дный** ~ халыкара террорчылык

террори́ст *м* террорчы

террористи́ческий, -ая, -ое террорчы[лар]...ы, террористик, террорчылык ...ы; ~ **акт** террорчылык акты

террори́стка *ж* террорчы хатын (кыз)

тёрт||ый, -ая, -ое 1. уылган, кырылган, кырып хәзерләнгән; ~ **ая морко́вь** кырылган кишер; ~ **ые кра́ски** уылган буяулар 2. *перен. прост.* (*опытный, бывалый — о человеке*) шомарган ♦ ~ **ый кала́ч** шомарган таш, шомарган биш тиен (*күпне күргән кеше турында*)

терце́т *м муз.* терцет (1. *өч тавыштан җырлау өчен язылган музыкаль әсәр* 2. *лит. өч юллы шигырь строфасы*)

те́рция *ж муз.* терция (*диатоник гамманың өченче баскычы*)

терье́р *м* терьер (*эт токымы*)

теря́ть *несов.* 1. *кого-что* югалту; жую; ~ **де́ньги** акча югалту 2. *перен. кого-что* югалту, мәхрүм калу; ~ **дру́га** дусны югалту; ~ **из виду** күздән югалту 3. *что, в чём* кимү, югалту; ~ **в ве́се** авырлык кимү 4. *что* югалту, әрәм итү; ~ **вре́мя** вакыт әрәм итү 5. *что и без доп.* (*терпеть ущерб*) зыян күрү, зарар күрү, югалту ♦ ~ **го́лову** югалып калу; ~ **зре́ние** сукыраю; ~ **наде́жду** өмет өзү; ~ **слух** чукраклану, ишетми башлау; ~ **терпе́ние** түзем бетү (калмау)

теря́||ться *несов.* 1. югалу, юкка чыгу; **ве́щи** ~**ются** әйберләр югала; ~**ться в толпе́** халык арасына кереп югалу 2. (*утрачиваться, ослабевать*) кимү; калмау, бетү; **к ста́рости** ~**ется па́мять** картая башлагач хәтер калмый 3. аптырап калу, каушап калу, югалып калу; ~**ться при посторо́нних** чит кешеләр алдында югалып калу 4. *страд. от* **теря́ть** ♦ ~**ться в дога́дках** аптыраштa калу

тёс *м собир.* такта, такталар, юка такта

теса́к *м* 1. (*плотничий топор*) юнгыч балта 2. (*оружие*) кыска кылыч

теса́ние *с см.* **теса́ть**

тёсан||ый, -ая, -ое юнылган, тасланган; ~**ая доска́** юнылган такта; ~**ое де́рево** юнылган агач

теса́ть *несов. что* юну, таслау; ~ **бревно́** бүрәнә юну; ~ **до́ски** такта таслау

тесёмка *ж разг.* кыска тасма; тар тасма

теси́на *ж* бер такта

тесло́ *с уст.* (*вид плотничьего топора*) аркылы балта, бәлҗә

тесни́на *ж* тарлавык, кысрык

тесни́ть *несов. кого-что* 1. кысу, тыгызлау; ~ **друг дру́га в толпе́** халык арасында бер-береңне кысу 2. кысрыклау; кысрыклап чигендерү; ~ **врага́** дошманны кысрыклау

тесни́||ться *несов.* 1. (*стоять тесно*) өелешеп тору, кысылышып тору, тылкышу; **у две́рей** ~**лся наро́д** ишек янында халык өелешеп тора иде 2. (*ютиться*) кысынкы урында тору [яшәү] 3. *перен.* (*о мыслях, чувствах*) кайнау, кайнашу, башка сыймау

те́сно *нареч.* 1. тыгыз, кысрык, кысынкы; **сиде́ть** ~ тыгыз утыру 2. *в знач. сказ. безл.* тыгыз, тар, кысан; **в ваго́не бы́ло** ~ вагонда бик тыгыз иде

теснот||а́ *ж* тыгызлык, тарлык, кысынкылык, кысрыклык ♦ **в** ~**е́, да не в оби́де** *погов.* ≈ урын тар булса да,күңел киң

те́сн||ый, -ая, -ое 1. тар, кысан; ~**ая ко́мната** тар бүлмә 2. тар, кысынкы; ~**ые боти́нки** тар ботинкалар 3. тыгыз; ~**ые ряды́** тыгыз сафлар 4. *перен.* тыгыз, якын; ~**ая дру́жба** якын дуслык; ~**ая связь** тыгыз бәйләнеш

тесо́в||ый, -ая, -ое такта ..., тактадан ясалган; ~**ые воро́та** такта капка; ~**ая кры́ша** такта түбә

тест *м* (*проба, испытание*) тест

те́сто *с* 1. камыр; **ки́слое** ~ әче камыр; **пре́сное** ~ төче камыр; **меси́ть** ~ камыр басу; **ста́вить** ~ камыр кую 2. *спец.* измә; **цеме́нтное** ~ цемент измәсе

тестообра́зн||ый, -ая, -ое камырсыман; ~**ая ма́сса** камырсыман масса

тесть *м* каената, каенатай

тесьма́ *ж* тасма, зияк

те́терев *м* көртлек, кыр тавыгы; ~**-коса́ч** ата көртлек

тетереви́н||ый, -ая, -ое 1. көртлек ...ы; ~**ый ток** көртлекләрнең уйнау урыны 2. *в знач. сущ.* ~**ые** *мн. зоол.* көртлекчәләр

тетёрка *ж* ана көртлек

тете́ря *ж прост.*: **глуха́я** ~ саңгырау, чукрак; **со́нная** ~ йокы капчыгы

тетива́ *ж* кереш; ~ **лу́ка** җәя кереше

тётка *ж* туган апа, түти, тәтәй

тетра́дка *ж разг.* дәфтәр

тетра́дн||ый, -ая, -ое дәфтәр ...ы; ~**ая бума́га** дәфтәр кәгазе

тетра́дочный, -ая, -ое дәфтәр ...ы; ~ **лист** дәфтәр бите

тетра́дь *ж* дәфтәр; **о́бщая** ~ калын дәфтәр; ~ **в кле́тку** шакмаклы дәфтәр; **но́тная** ~ ноталар дәфтәре; ~ **для рисова́ния** рәсем дәфтәре

тетра́эдр *м мат.* тетраэдр

тётя *ж разг.* тётка

те́фтели *только мн. кул.* тефтели, ит чумары

тех* *кайбер кушма сүзләрнең «техник» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәге, татарчага тәрҗемә ителми, мәс.* **техперсона́л** техник персонал; **техучёба** техниканы өйрәнү

техми́нимум *м* техминимум; **сдать** ~ техминимум буенча имтихан тапшыру

техниза́ция *ж* (*внедрение технических средств*) техник чаралар куллану, техник чаралар белән коралландыру

те́хник *м* техник (1. *урта техник мәгълуматлы белгеч* 2. *техника фәннәре белгече*)

те́хник||а *ж в разн. знач.* техника; **передова́я** ~**а** алдынгы техника; **строи́тельная** ~**а** төзү техникасы; **косми́ческая** ~**а** космик техника; **вое́нная** ~**а** хәрби техника; **раке́тная** ~**а** ракета техникасы; **музыка́льная** ~**а** музыкаль техника; ~**а ша́хматной игры́** шахмат уены техникасы; **овладе́ть** ~**ой** техниканы ия булу; **ремо́нт** ~**и в колхо́зах** колхозларда техниканы ремонтлау ♦ ~**а безопа́сности** куркынычсызлык техникасы

те́хникум *м* техникум; **учи́ться в** ~**е** техникумда уку

техниці́зм *м* техникачылык, техницизм

техни́ческ||ий, -ая, -ое 1. техник, техника ...ы; техника белән ...; ~**ий институ́т** техника институты; ~**ие нау́ки** техника фәннәре; ~**ая литерату́ра** техника буенча әдәбият; ~**ие зна́ния** техник белемнәр; ~**ий проге́сс** техник прогресс; ~**ая оснащённость предприя́тия** предприятиенең техника белән җиһазланган булуы; ~**ий кружо́к** техника түгәрәге 2. техник, техника ...ы; ~**ий отде́л** техника бүлеге; ~**ая документа́ция** техник документация; ~**ий контро́ль** техник контроль; ~**ое усоверше́нствование** техник камилләштерү 3. (*используемый в промышленности*) техник; ~**ие культу́ры** техник культуралар (*мәс. җитен, мамык*); ~**ие масла́** техник майлар; ~**ая вода́** техник су 4. техник; ~**ие прие́мы** техник алымнар; ~**ие на́выки игры́ в ша́хматы** шахмат уйнауда техник осталык 5. техник; ярдәмче; ~**ий секрета́рь** техник секретарь; ~**ий сотру́дник** техник хезмәткәр; ~**ие рабо́тники сце́ны** сәхнәнең ярдәмче эшчеләре ♦ ~**ий реда́ктор** техник редактор (*китап, газета һ.б.ш. полиграфия яктан редакцияләүче*)

техни́чка *ж разг.* техничка, җыештыручы хатын (кыз)

техни́чный, -ая, -ое бик оста, техникага ия булган, техникалы; ~ **хоккеи́ст** техникалы хоккейчы; ~ **уда́р** бик оста сугу

техно́лог *м* технолог

технологи́ческий, -ая, -ое 1. технология ...ы; ~ **институ́т** технология институты 2. технологик; ~ **проце́сс** технологик процесс

технало́гия *ж* технология; **но́вая** ~ **обрабо́тки дета́лей** детальләрне эшкәртүнең яңа технологиясе; **косми́ческая** ~ космик технология; ~ *какого-л.* **произво́дства** житештерүнең технологиясе

технору́к *м* техник житәкче, технорук (*техник, инженер*)

техобслу́живание *с* техник хезмәт күрсәтү (*мәс. автомашиналарны карау, ремонтлау, юу һ.б.ш.*)

техосмо́тр *м* техник карау, техосмотр

тече́ни||е *с* 1. *см.* **течь** I 1, 3-5; 2. агым, су агымы; **морски́е** ~**я** дингез агымнары; **тёплое** ~**е** җылы агым; **грести́ про́тив** ~**я** агымга каршы ишү; **плыть по** ~**ю** *прям., перен.* агым уңаена йөзү;

плыть про́тив ~я *прям., перен.* агымга каршы йөзү **3.** *перен.* агым, юнәлеш; **литерату́рные ~я** әдәби агымнар ♦ **в ~е** *чего, предлог с род.п.* ...да, эчендә, дәвамында; **в ~е ме́сяца** бер ай эчендә; **с ~ем вре́мени** вакыт үтү белән

те́чка *ж биол.* шылтыр, шылтыр килү (*ана терлекләрдә җенси теләк туганда*)

теч||ь I *несов.* **1.** агу, агып тору; **река́ ~ёт** елга ага; **из ра́ны ~ёт кровь** яradан кан ага **2.** су үтү, агу; тишек булу; **кры́ша ~ёт** түбәдән су үтә **3.** *перен.* агу, узу, үтү, бару; **вре́мя ~ёт бы́стро** вакыт бик тиз үтә; **так текли́ год за го́дом** шулай ел артыннан ел агып кына торды **4.** *перен.* агу; **по у́лицам текли́ то́лпы** урамнан халык төркемнәре ага иде **5.** *перен.* агу, агылу, бер-бер артлы (өзлексез) дәвам итү (*сөйләү, сүз, уй турында*); **речь его́ текла́ пла́вно** аның сөйләгән сүзләре салмак кына агып торды

течь II *ж* **1.** су керү, су үтү, ага башлау; **ло́дка дала́ ~** көймәгә су керә башлады **2.** (*пробоина*) су агып керә торган урын, тишек; **заде́лать ~** су агып керә торган урынны томалап кую

те́шить *несов. кого-что* көлдерү, күңелен ачу (табу, күрү), юату; **~ ребя́т** балаларны юату

те́шиться *несов.* **1.** (*забавляться*) юану, күңел ачу **2.** *над кем, разг.* (*издеваться*) көлү, мыскыллап көлү

тёща *ж* каенана, хатынның анасы

ти́гель *м тех.* эретү табасы, тигель

ти́гельный, -ая, -ое *тех.* тигельдә эретелгән, тигельдә коелган

тигр *м* юлбарыс

тигрёнок *м* юлбарыс баласы

тигри́ный, -ая, -ое юлбарыс ...ы; юлбарысча ..., **~ след** юлбарыс эзе

тигри́ца *ж* ана юлбарыс

тигро́в||ый, -ая, -ое *см.* **тигри́ный; ~ая шку́ра** юлбарыс тиресе

тик I *м мед.* тик, (*тән*) тартышу

тик II *м* (*ткань*) тик

ти́канье *с см.* **ти́кать; ~ часо́в** сәгать тикелдәве

ти́кать *несов. разг.* келт-келт йөрү, тек-тек итү, тикелдәү

ти́к-та́к *звукоподр. разг.* тек-тек

ти́льда *ж полигр.* тильда (~ *формасындагы сызык*)

тимофе́евка *ж с.-х.* арышбаш, сүсән

тимпа́н *м* тимпан (*литаврa сыман борынгы музыка коралы*)

тиму́ров||ец *м* тимурчы

тиму́ровск||ий, -ая, -ое Тимур ...ы; **~ая кома́нда** Тимур командасы

тимья́н *м бот.* тимьян (*хуш исле куаклык*)

ти́на *ж* ләм, бака ефәге (*су төбендә*)

ти́нист||ый, -ая, -ое ләмле, лайлы; **~ое о́зеро** лайлы күл; **~ое дно** ләмле су төбе

тип *м* **1.** тип, төр; **~ по́чвы** туфрак төре; **стано́к но́вого ~а** яңа типтагы станок; **~ автомоби́ля** автомобиль тибы **2.** *биол.* тип; **~ цветко́вых расте́ний** чәчәкле үсемлекләр тибы; **~ членистоно́гих живо́тных** буынтыгаяклы хайваннар тибы **3.** *лит., иск.* тип (*язучы, артист, рәссам тарафыннан тудырылган характер, әдәби образ*) **4.** кеше, тип; **заба́вный ~** кызык кеше; **стра́нный ~** сәер кеше; **мра́чный ~** караңгы чырайлы кеше **5.** *род.п. в знач. предлога* **~а** (*вроде*) шикелле, кебек, тибында; **устро́йство ~а центрифу́ги** центрифуга шикелле җайланма

типа́ж *м* **1.** типаж (*берәр нәрсә төрләренең җыелмасы*); **~ самолётов** самолётлар типажы **2.** типаж (*нинди дә булса типны гәүдәләндереп күрсәткән барлык билгеләр*); **я́ркий ~ для кино́** кино өчен бик кулай типаж

типиза́ция *ж см.* **типизи́ровать**

типизи́ровать *сов., несов. что* **1.** (*классифицировать по типам*) типлаштыру, махсуслаштыру **2.** *лит., иск.* типиклаштыру; **~ литерату́рный о́браз** әдәби образны типиклаштыру

типи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** *лит., иск.* типик; **изображе́ние ~их хара́ктеров в ~их обстоя́тельствах** типик характерларны типик шартларда гәүдәләндерү; **~ий о́браз** типик образ **2.** *см.* **типи́чный** 2; **~ие явле́ния** типик күренешләр

типи́чность *ж* типиклык, типик булу; гадәтилек, гадәти булу

типи́чн||ый, -ая, -ое **1.** типик; **~ый ю́жный го́род** типик көньяк шәһәр **2.** (*характерный*) типик, гадәттәге, гадәти; **~ый слу́чай** типик вакыйга; **~ая оши́бка** гадәти хата **3.** *разг.* чын-чынлап; **э́то ~ый карье́ризм** бу чын-чынлап карьеристлык

типов||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*являющийся образцом*) типовой, типлаштырылган, үрнәк; **~о́й прое́кт** типовой проект **2.** (*стандартный*) стандарт, типлаштырылган; **~ы́е дома́** стандарт өйләр

типогра́фия *ж* типография

типогра́фск||ий, -ая, -ое типография ...ы, типографик; **~ий стано́к** типография станогы; **~ая кра́ска** типографик буяу

типолитогра́фия *ж* типолитография (*литография булеге булган типография*)

типоло́гия *ж спец.* типология (*төрле типтагы әйберләрнең яки күренешләрнең классификациясе*)

типу́н *м* төер, тилчә (*кошларның тел очына кимерчәк үсү авыруы*) ♦ **~ тебе́ на язы́к** теленә төер чыккыры

тир *м* тир

тира́да *ж книжн.* тирада, нотык

тира́ж I *м* тираж; **~ госуда́рственного за́йма** дәүләт займының тиражы; **очередно́й ~ «Спортлото́»** «Спортлото»ның чираттагы тиражы ♦ **вы́йти в ~** кулланылмый башлау, искерү, тиражга чыгу

тира́ж II *м* тираж; **~ газе́ты** газетның тиражы

тиражи́ровать *сов., несов. что* тиражын билгеләү, тиражын кую

тира́н *м* **1.** *ист.* тиран **2.** *перен.* изүче, җәфалаучы, газаплаучы, җәберләүче, залим

тира́нить *несов. кого-что, разг.* җәфалау, газаплау, җәберләү; **~ бли́зких** туган-тумачаны җәберләү

тирани́я *ж* **1.** *ист.* тирания (*идарә итү ысулы*) **2.** (*гнёт, насилие*) җәбер, золым, золымлык, залимлек

тира́нство *с разг.* тиранлык, деспотлык, залимлек; җәбер, золым; **терпе́ть *чьё-л.* ~ *кемнең да булса*** җәберенә чыдап тору

тира́нствовать *несов. над кем-чем, разг.* тиранлык итү, залимлек итү; җәфалау, газаплау, җәберләү

тире́ *с нескл.* тире, сызык

тис *м бот.* тис, тиле нарат

ти́скать *несов.* **1.** *кого-что, разг.* кысу, кыскалау **2.** *что, полигр.* басып төшерү, басу, бастыру

тиск||и́ *только мн.* **1.** (*инструмент*) тиски, кыстыргыч, эскәнҗә **2.** *перен.* эскәнҗә, тырнак; кысым; **в ~а́х кла́ссовых противоре́чий** сыйнфый каршылыклар тырнагында

тисне́ние *с* **1.** басып бизәк төшерү; чокырлатып сурәт төшерү; **~ по ко́же** күнгә басып бизәк төшерү **2.** (*узор*) басып төшерелгән бизәк, чокырлатып төшерелгән сурәт

тиснёный, -ая, -ое бизәгә басып төшерелгән, сурәте чокырлатып төшерелгән; **~ переплёт** бизәгә басып төшерелгән китап тышы

ти́снуть *сов.* **1.** *однокр. кого-что, разг.* кысып алу **2.** *что, полигр.* басып алу, басып оттиск алу

тита́н *м* **1.** *миф.* титан **2.** *перен.* титан, зур талант, зур акыл иясе; **~ нау́ки** фәннәр титаны **3.** *хим.* титан **4.** титан (*су кайнаткыч*)

титани́ческ||ий, -ая, -ое *высок.* гаҗәп зур, гаять зур; **~ие уси́лия** гаять зур тырышлыклар

тита́нов||ый, -ая, -ое *хим.* титан ...ы; титанлы; **~ые ру́ды** титанлы рудалар

титр *м* титр (*кинофильм кадрында язма*)

ти́тул *м* **1.** титул (*феодаль һәм буржуаз җәмгыятьтә почётлы исем*); **~ гра́фа** граф титулы **2.** (*наименование, звание*) исем, титул; **~ чемпио́на** чемпион исеме **3.** *полигр.* титул

титулова́ть *сов., несов.* титулы белән әйтү

ти́тульный, -ая, -ое *полигр.* титул ...ы; **~ лист** титул бите

титуля́рный, -ая, -ое: **~ сове́тник** титуляр советник (*революциягә кадәрге Россиядә гражданнар чины*)

тиф *м* тиф; тир хастасы (*уст.*); **брюшно́й ~** корсак тифы; **сыпно́й ~** тимгелле тиф

тифлопедаго́гика *ж* тифлопедагогика (*сукырларны укыту методикасы*)

тифо́зн||ый, -ая, -ое **1.** тиф ...ы; **~ая эпиде́мия** тиф эпидемиясе **2.** тифлы, тиф белән; **~ый больно́й** тиф белән авыручы

ти́х||ий, -ая, -ое **1.** әкрен, акрын; **~ий го́лос** әкрен тавыш **2.** тын, тымызык; **~ая у́лица** тын урам; **~ая ночь** тын төн **3.** тыныч, басынкы, юаш; **~ий нрав** тыныч холык; **~ий челове́к** юаш кеше **4.** әкрен, акрын; **по́езд шёл ~им**

ТИХ-ТОЖ

хо́дом поезд әкрен генә бара идә ♦ **~ий час** ял сәгате; **в ~ом о́муте че́рти во́дятся** *посл.* тымызык күлдә корт ятыр; ≈ юаштан юан чыга

ти́хо *нареч.* **1.** әкрен, акрын, әкертен, акыртын, шыпырт кына, тавышсыз; **~ чита́ть** әкрен уку; **е́хать ~** әкертен генә бару; **сиде́ть ~** шыпырт кына утыру **2.** *в знач. сказ. безл.* тын, тыныч; **на у́лице ~** урам тын

тихомо́лком *нареч. разг.* эндәшмичә, шыпырт, сиздермичә, тавышсыз-тынсыз; **подойти́ ~** сиздермичә янына килү

тихо́н||ия *м, ж разг. неодобр.* мыштым кеше, юаш кеше; **прики́нуться ~ей** юаш кеше булып кылану

тихоокеа́нский, -ая, -ое Тын океан ...ы; **Тихоокеа́нский флот** Тын океан флоты

тихохо́дный, -ая, -ое әкрен йөри торган, әкрен йөрешле; **~ парохо́д** әкрен йөрешле пароход

ти́ше **1.** *сравн. ст. от* **ти́хий, ти́хо; 2.** *в знач. повел. накл.* тавышланмагыз, шауламагыз, үчегез; **~, не меша́йте слу́шать!** шауламагыз, тыңларга ирек бирегез! ♦ **~ воды́, ни́же травы́** *погов.* тыйнак, тавыш-тынсыз

тишин||а́ *ж* тынлык, тынычлык; **ночна́я ~а́** төн тынлыгы; **мёртвая ~а́** кабер тынлыгы; **соблюда́ть ~у́** тынлыкны саклау

тишко́м *нареч. разг.* белдермичә, шыпырт кына, сиздермичә

тиш||ь *ж* тынлык; тыныч-лык; **ночна́я ~ь** төнге тынлык; **жить в ~и́** тыныч яшәү ♦ **~ь да гладь** бик тыныч тормыш, жилсез-давылсыз тормыш

тка́нев||ый, -ая, -ое **1.** тукымалы, тукыма ...ы, тукымадан эшләнгән **2.** *биол.* тукыма ...ы; **~ое дыха́ние** тукыма сулавы ♦ **~ая терапи́я** *мед.* тукыма терапиясе

тка́ный, -ая, -ое тукылган, тукып ясалган; чүпләмле; **~ узо́р** тукып ясалган бизәк

ткан||ь *ж* **1.** тукыма; **шёлковая ~ь** сфәк тукыма; **льняны́е ~и** җитен тукымалар; **синтети́ческие ~и** синтетик тукымалар **2.** *перен.* тукыма; нигез; **~ь расска́за** хикәянең тукымасы; **~ь собы́тий** вакыйгаларның нигезе **3.** *биол., бот.* тукыма; **мы́шечные ~и** мускул тукымалары; **соедини́тельная ~ь** тоташтыргыч тукыма

тканьё *с* **1.** *см.* **ткать** 1; **2.** *собир. разг.* (*изделия*) тукыма әйберләр

ткать *несов. что* **1.** туку, сугу; **~ полотно́** киндер сугу **2.** (*о насекомых*) үрү; **пау́к ткёт паути́ну** үрмәкүч пәрәвез үрә

тка́ц||ий, -ая, -ое туку ...ы; **~ий стано́к** туку станогы; **~ая фа́брика** туку фабрикасы

ткач *м* тукучы

тка́чество *с* тукучылык

ткачи́ха *ж* тукучы хатын (кыз)

ткнуть *сов.* **1.** *кого-что, чем* төртү, төртеп кую (җибәрү) **2.** *что* (*вонзить*) кадау, чәнчү; кадап (чәнчеп) кую

ткну́ться *сов. однокр.* барып төртелү, барып бәрелү

тлен *м уст.* черек, черек көле, черегән нәрсә; фани нәрсә

тле́ние *с см.* **тлеть**; **~ угля́** күмер пыскуы

тле́нный, -ая, -ое *уст.* чери торган, бетә торган; фани; **~ мир** фани дөнья

тлетво́рность *ж книжн.* **1.** череп бозылганлык, черегәнлек **2.** *перен.* зарарлылык, бозылганлык

тлетво́рн||ый, -ая, -ое *книжн.* **1.** (*порождённый тлением*) черетә торган, череткеч, боза торган; черегән, черек **2.** *перен.* зарарлы, зыянлы; **~ое влия́ние** зыянлы тәэсир

тле||ть *несов.* **1.** (*гнить, разлагаться*) черү, череп бетү **2.** (*гореть без пламени*) пыску, пыскып яну; сүнми яну, сүнми яту; **в золе́ ~ют угольки́** көлдә күмерләр сүнми ята **3.** *перен.* сүнмәү; **в душе́ ~ет сла́бая наде́жда** күңелдә аз гына өмет чаткысы сүнми

тля *ж зоол.* гөбләй, бет, үләнбете; **я́блоневая ~** алмагач бете; **капу́стная ~** кәбестә бете

тмин *м* ак әнис, тмин (*үсемлеге һәм орлыгы*)

тми́н||ый, -ая, -ое **1.** ак әнис ...ы, тмин ...ы; **~ые семена́** ак әнис орлыгы **2.** ак әнискә тәнәтелгән; **~ая во́дка** ак әнискә тәнәтелгән аракы

то I *с см.* **тот**

то II *союз* **1.** *разд.* әле ..., әле ...; бер ..., бер ...; йә ..., йә ...; **идёт то снег, то дождь** әле кар, әле яңгыр ява **2.** ул вакытта, ул чакта; **е́сли по́здно, то не приходи́** соң булса, [ул чакта] килмә ♦ **а то** 1) югыйсә, юкса; **спеши́, а то опозда́ешь** ашык, юкса соңга калырсың; 2) (*на самом деле*) чыннан да, дөрестән дә, юкса; **[да] и то** ул да, анысы да; **не ~** (*иначе*) югыйсә, башкача булганда; **то бишь** *уст.* ягъни мәсәлән, ягъни; **то и де́ло** әледән-әле; **то и де́ло раздаю́тся звонки́** әледән-әле шалтыраталар; **то ли де́ло** бөтенләй башкача; **здесь ску́чно, то ли де́ло у нас** монда күңелсез, бездә бөтенләй башкача

-то *частица* **1.** *выдел.* да, бит, икән; **обеща́ть-то обеща́л** ... вәгъдә итүен итте дә; **кни́гу-то я давно́ прочёл** китапны бит мин әллә кайчан укып чыктым **2.** *неопр.* ...дыр; **кто́-то** кемдер; **где́-то** кайдадыр; **что́-то** нәрсәдер; **куда́-то** каядыр; **како́й-то** ниндидер; **когда́-то** кайчандыр

това́р *м* товар; **хоро́ший ~** яхшы товар; **~ы широ́кого потребле́ния** киң куллану товарлары

това́рищ *м* иптәш; **~ по рабо́те** бергә эшләгән иптәш; **~ по шко́ле** мәктәптәш; сабакташ ♦ **~ по несча́стью** бер үк бәхетсезлеккә дучар булган кеше

това́рищеск||ий, -ая, -ое **1.** (*дружеский*) иптәшләргә хас булган, иптәшлек ...ы, иптәшләрчә ...; **~ое отноше́ние** иптәшлек мөнәсәбәте; **~ий посту́пок** иптәшләрчә эшләү; **~ая по́мощь** иптәшләрчә ярдәм **2.** *спорт.* иптәшләрчә; **~ий футбо́льный матч** иптәшләрчә футбол матчы ♦ **~ий суд** иптәшләр суды

това́риществ||о *с* **1.** иптәшлек; **чу́вство ~а** иптәшлек хисе **2.** (*организация*) ширкәт, товарищество; **~о по обрабо́тке земли́** җирне бергәләп эшкәртү ширкәте

това́рность *ж* товарлылык (*сату өчен товар эшләп чыгару сәләте*); **высо́кая ~ се́льского хозя́йства** авыл хуҗалыгының югары товарлылыгы

това́рн||ый, -ая, -ое **1.** товар[лар] ...ы; **~ая ста́нция** товар станциясе; **~ый ваго́н** товар вагоны; **~ый склад** товарлар склады **2.** товарлыклы; сату өчен билгеләнгән; **~ое хозя́йство** товарлыклы хуҗалык; **~ый хлеб** сату өчен билгеләнгән ашлык

товаровёд *м* товар белгече

товарове́дение *с* товар белеме

товарообме́н *м* товар алмашу

товарообо́рот *м* товар әйләнеше

това́ро-пассажи́рский, -ая, -ое товар-пассажир ...ы; товарлар һәм пассажирлар йөртә торган

товаропроизводи́тель *м* товар эшләп чыгаручы

то́г||а *ж* тога (*борынгы римлыларда ирләр кия торган өске кием*) ♦ **ряди́ться в ~у** *кого-что* ... булып күренергә тырышу

тогда́ *нареч.* **1.** (*не сейчас*) ул вакытта, ул чакта **2.** (*в таком случае*) алай булгач, алайса; **уста́л? Тогда́ отдохни́** ардыңмы? Алайса ял ит **3.** *с союзами «когда», «если»* шунда, шул вакытта; **когда́ тебя́ отпуска́ли, ~ на́до бы́ло е́хать** сине кайчан жибәрәләр иде, шул вакытта барырга кирәк иде ♦ **~ как** *союз уступ.* хәлбуки, ...га карамастан, була торып

тогда́шний, -яя, -ее *разг.* ул (шул) чактагы (вакыттагы, замандагы)

того́ *частица прост.* **1.** (*заполняет паузу в речи*) кара; **уж ты, ~, поста́райся** син инде, кара, тырыштыр **2.** *в знач. сказ.* (*глуповат*) җинел акыллы; (*плоховат*) шәптән түгел; (*навеселе*) исерек; **он совсе́м ~** ул бөтенләй җинел акыллы ♦ **не ~** *в знач. сказ.* шәптән түгел; **вид у тебя́ не ~** синең кыяфәтең шәптән түгел

то́ есть **1.** *союз поясн.* (*а именно, вернее*) ягъни, дөресрәге, дөресләп әйткәндә **2.** *частица* (*выражает удивление, непонимание и т.п.*) ягъни мәсәлән; **я не е́ду. — То́ есть как э́то не е́дешь?** мин бармыйм. — Ягъни мәсәлән ничек инде бармыйсың ди?

тождественность *ж* бердәйлек, охшашлык; тигезлек, тәңгәллек

тожде́ственный, -ая, -ое бердәй, бертигез, охшаш, тәңгәл, бертөсле

то́ждество *с* **1.** (*полное сходство*) бердәйлек, бертөслелек, тәңгәллек, охшашлык **2.** *мат.* бердәйлек

то́же **1.** *нареч.* (*также*) да, шулай ук; **я ~ туда́ пойду́** мин дә анда барам **2.** *частица прост.* тагын; **~ сове́тчик нашёлся!** киңәшче табылган тагын!

тожде́ственный, -ая, -ое *см.* **тождественный**

то́жество *с см.* **то́ждество**

ток I *м* (*мн.* ~**и**) 1. *эл.* ток, электр тогы 2. *книжн.* агым, агыш; ~ **во́здуха** һава агымы

ток II *м* (*мн.* ~**á**) 1. *см.* **токова́ть**; 2. *охот.* (*место*) уйнау (гөлдердәү) урыны

ток III *м* (*мн.* ~**и**, ~**á**) *с.-х.* (*площадка для молотьбы*) ындыр, ындыр табагы

тока́рничать *несов. разг.* токарьлык итү, токарь булып эшләү, токарьлык эше белән шөгыльләнү

тока́рн||ый, -ая, -ое токарь ...ы, кыру ...ы, токарьлык ...ы; ~**ый стано́к** кыру станогы; ~**ое де́ло** токарьлык эше

то́карь *м* токарь; ~ **по мета́ллу** металл кыру токаре

токова́ние *с см.* **токова́ть**

токова́ть *несов.* гөлдерәү, гөлдердәү, гөлдерәп чакыру (*ата кошның ана кошны чакыруы*)

токови́ще *с см.* **ток** II 2

токоприёмник *м* ток алгыч

токсико́з *м мед.* токсикоз

токсико́лог *м* токсиколог, токсикология белгече

токсикологи́ческий, -ая, -ое токсикологик, токсикология ...ы

токсиколо́гия *ж* токсикология (*агуларны һәм аларның организмга тәэсирен өйрәнү фәне*)

токси́н *м биол., мед.* токсин (*микроорганизмнар, шулай ук кайбер хайваннар һәм үсемлекләр тарафыннан эшләп чыгарыла һәм авыруга сәбәп була торган агулы матдә*)

токси́ческ||ий, -ая, -ое *биол., мед.* 1. агулы, агулый торган; ~**ие вещества́** агулы матдәләр 2. (*вызываемый действием токсинов*) токсин китереп чыгара торган, токсинлы

токси́чность *ж биол., мед.* агулылык, токсинлылык

токси́чный, -ая, -ое *биол., мед.* агулаучан, агулый торган

тол *м* тол (*шартлаткыч матдә*)

то́лев||ый, -ая, -ое толь...; толь ...ы, тольдән эшләнгән; ~**ая кры́ша** толь түбә

толи́ка *ж*: **ма́лая** ~ *разг.* бераз, әзрәк, аз-маз; **ма́лая** ~ **де́нег** бераз акча

толк *м* 1. *разг.* (*смысл, суть*) мәгънә, рәт, юнь; **рассужда́ть с** ~**ом** мәгънәле итеп фикер йөртү 2. *разг.* (*польза, прок*) мәгънә, файда, эшнең рәте; **ходи́ть бе́з толку** файдасызга йөрү; ~**у не вы́йдет** рәт чыкмас; **знать** ~ эшнең рәтен белү 3. (*направление, учение*) агым (*дини яки сәяси*)

толка́ние *с см.* **толка́ть** 1, 2; ~ **ядра́** ядрә ыргыту

толка́ть *несов.* 1. *кого-что* (*двигать*) этү, этәрү, төртү; ~ **ло́ктем** терсәк белән төртү; ~ **та́чку** тачканы этәрү 2. *что, спорт.* ыргыту; этү, этеп күтәрү; ~ **ядро́** ядрә ыргыту; ~ **што́нгу** штанганы этеп күтәрү 3. *перен. кого-что* (*побуждать к чему-л.*) этәрү, этү, юлына бастыру

толка́ться *несов.* 1. этешү, төртешү 2. *во что, прост.* этү, этеп керергә тырышу; ~ **в дверь** ишекне этеп керергә тырышу 3. *прост.* (*праздно ходить*) тик йөрү, буталып йөрү; ~ **по у́лицам** урамда буталып йөрү 4. *страд. от* **толка́ть**

толка́ч *м* толкач (1. *поездны арттан этеп бара торган ярдәмче паровоз яисә баржа этәруче үзйөрешле судно* 2. *перен. разг. берәр эшне тизләтүче*)

то́лки *только мн. разг.* төрле сүзләр, төрле хәбәрләр, имеш-мимешләр

толкну́ть *сов.* 1. *кого-что* этеп җибәрү, төртеп җибәрү; ~ *кого-л.* **в спи́ну** *берәр кешене* аркасыннан этеп җибәрү 2. *что, спорт.* этү, этеп күтәрү

толкова́ние *с* 1. *см.* **толкова́ть** ; ~ **зако́нов** законнарга аңлатма бирү 2. (*объяснение*) аңлатма, аңлату; **дать но́вое** ~ *чему-л. берәр нәрсәгә* яңа аңлатма бирү

толкова́ть *несов.* 1. *что* аңлату, аңлатып бирү, аңлатма бирү; ~ **значе́ния слов** сүзләрнең мәгънәләрен аңлату 2. *кому, разг.* (*разъяснить*) аңлату, төшендерү 3. *с кем-чем о ком-чём разг.* сөйләшү, фикер алышу; ~ **о дела́х** эш турында сөйләшү

толко́вый, -ая, -ое 1. акыллы, төпле, мәгънәле; ~ **челове́к** акыллы кеше; ~ **сове́т** төпле киңәш 2. аңлаешлы, төшенерлек; ~ **расска́з** аңлаешлы хикәя 3. аңлатмалы; ~ **слова́рь ру́сского языка́** рус теленең аңлатмалы сүзлеге

то́лком *нареч. разг.* яхшылап, рәтләп, юньләп, ипләп; **ты мне** ~ **объясни́** син миңа рәтләп аңлатып бир

толкотня́ *ж разг.* этеш-төртеш, ыгы-зыгы

толку́чка *ж прост.* 1. (*толкотня*) ыгы-зыгы, ыгы-зыгылы урын 2. (*рынок*) талчук, талчук базары

толма́ч *м уст.* тылмач, тәрҗемәче

толокно́ *с* талкан

толокня́нка *ж бот.* турак уты

толокня́ный, -ая, -ое талкан ...ы, талканнан хәзерләнгән

толоко́нный, -ая, -ое: ~ **лоб** *обл.* чүбек баш, тиле, аңгыра, ахмак

толо́чь *несов. что* төю, төеп ваклау; ~ **са́хар** шикәр төю ♦ ~ **во́ду в сту́пе** килегә салып су төю

толо́чься *несов. прост.* буталып йөрү, таптану, таптанып тору; ~ **на ме́сте** бер урында таптанып тору; ~ **у две́рей** бусага таптау

толп||а́ *ж* халык төркеме, төркем; ~**а́ ребя́тишек** бер төркем бала-чага; **стоя́ть** ~**о́й** төркем булып басып тору

толпи́ться *несов.* җыелып (өелешеп, җыелышып)тору

толсте́нн||ый, -ая, -ое *прост.* бик юан; бик калын; ~**ая кни́га** бик калын китап; ~**ое бревно́** бик юан бүрәнә

толсте́ть *несов.* калынаю, юанаю

толсти́ть *несов. кого-что, разг.* калын итеп күрсәтү, юан итеп күрсәтү

толсто- *кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «юан», «калын» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.* ~**но́гий** юан аяклы; ~**пу́зый** кап корсаклы, юан корсаклы; ~**гу́бый** калын иренле

толсто́вка *ж* билбаулы киң озын блуза

толстоко́жий, -ая, -ее 1. (*о животных*) калын тире; (*о фруктах, овощах и т.п.*) калын кабыклы 2. *перен.* (*неотзывчивый*) тиресе калын, эт каешы; калын тире

толстосте́нный, -ая, -ое калын стеналы; ~ **сосу́д** калын стеналы савыт

толстосу́м *м уст.* бай кеше; акча капчыгы

толсту́ха *ж* юан хатын (кыз)

то́лст||ый, -ая, -ое 1. юан; ~**ый челове́к** юан кеше; ~**ые но́ги** юан аяк 2. (*большой в поперечнике*) калын; (*о нитке*) юан, төерем; ~**ая доска́** калын такта; ~**ая кни́га** калын китап; ~**ое сукно́** калын сукно ♦ ~**ая кишка́** *анат.* юан эчәк; ~**ый журна́л** калын журнал (*әдәби-публицистик журнал*)

толстя́к *м* юан кеше

толчёный, -ая, -ое төйгән, төелгән; ~ **пе́рец** төйгән борыч

толчея́ *ж разг.* этеш-төртеш, ыгы-зыгы

толч||о́к *м* 1. этеп җибәрү, төртеп җибәрү; ~**о́к в спи́ну** аркага төртү 2. селкенү, тетрәү; **подзе́мные** ~**ки́** жир асты селкенүләре 3. *спорт.* этеп күтәрү; ыргыту; ~**о́к пра́вой руко́й** уң кул белән этеп күтәрү 4. *перен.* (*побуждение*) этәргеч, сәбәп; ~**о́к к рабо́те** эшкә этәргеч

то́лща *ж* калын катлам; ~ **земно́й кору́** җир кабыгының калын катламы

толщина́ *ж* калынлык, юанлык; ~ **доски́** тактаның калынлыгы; ~ **ствола́** (*дерева*) кәүсәнең юанлыгы

толь *м* толь (*түбә ябу материалы*)

то́лько 1. *частица огранич.* бары, нибары, фәкать, гына, тик ... гына; ~ **он мо́жет э́то сде́лать** моны ул гына эшли ала 2. *союз временной* белән, белән үк, ...кәч үк, ...гач та; **как** ~ **дое́дешь, напиши́ нам** барып җиткәч үк безгә яз 3. *союз против.* әмма, ләкин, тик; **я пойду́,** ~ **не сейча́с** мин барам, ләкин хәзер түгел 4. *частица усил.* (*с «бы» выражает желание*) гына ... инде; ~ **бы не опозда́ть!** соңга гына калмасак инде! 5. *частица усил.* гына; **заче́м** ~ **ты э́то сде́лал?** ни өчен генә син ул эшне эшләдең? 6. *нареч.* (*ещё, пока ещё*) гына әле, генә; **э́то** ~ **нача́ло** бу башы гына әле 7. *нареч.* (*совсем недавно*) әле генә; ~ **прие́хал, а уже́ тя́нет домо́й** әле генә килдем, ә өйгә кайтасы килә ; ♦ ~ **и всего́** бар булганы шул, бары шул гына; ~-~ чак-чак кына, көчкә-көчкә; яңа гына, әле генә; **он** ~-~ **уе́хал** ул әле генә китте; ~ **что** хәзер генә, әле генә, күптән түгел; **он** ~ **что был здесь** ул әле генә монда иде

том *м* том

томага́вк *м* томагавк (*Төньяк Америка индеецларының сугыш коралы*)

тома́т *м* томат (1. *помидор*; 2. *кул. помидордан ясалган соус*)

тома́т||ный, -ая, -ое томат ...ы, томаттан хәзерләнгән; ~**ый сок** томат согы; ~**ое пюре́** томат боткасы

ТОМ-ТОП

томи́тельн||ый, -ая, -ое зарыгып, зарыктыргыч, интектергеч; ялыктыргыч; **~ое ожида́ние** зарыгып көтү

томи́ть *несов.* **1.** *кого-что* зарыктыру, интектерү, талчыктыру, газаплау, аҗыту, тилмертү; **его́ томи́т жа́жда** ул эчәсе килеп интегә **2.** *что, кул.* томалап пешерү; **~ мя́со** итне томалап пешерү

томи́ться *несов.* **1.** зарыгу, интегү, газаплану, тилмерү, зар-интизар булу, талчыгу; **~ ожида́нием** талчыгып көтү, көтеп зарыгу **2.** (*париться в закрытой посуде*) томаланып пешү **3.** *страд. от* **томи́ть** 2

томле́ние *с см.* **томи́ть, томи́ться** 1, 2; **любо́вное ~** сөюдән газаплану

томлёный, -ая, -ое томалап пешерелгән

то́мность *ж* моңсулык, сагышлылык

то́мный, -ая, -ое моңсу, сагышлы; **~ взгляд** моңсу караш

²то́мный, -ая, -ое *кайбер кушма сүзләрнең икенче кисәге, татар теленә «...томлы» сүзе белән тәрҗемә ителә, мәс.* **многото́мное изда́ние** күп томлы басма

тон *м* **1.** (*мн.* **~á, ~ы**) *муз., физ.* тон, тавыш, аваз; **высо́кий ~** нечкә тавыш **2.** (*мн.* **~ы**) *мед.* тон; **~ы се́рдца** йөрәк тоннары **3.** (*мн.* **~á**) *перен.* тон, төсмер; **све́тлые ~á кра́ски** буяуның ачык төсмерләре **4.** *перен.* тавыш; **говори́ть споко́йным ~ом** тыныч тавыш белән сөйләү **3.** *перен.* (*стиль поведения*) мөгамәлә, үзенә тоту, манера; **хоро́ший ~** үзенне яхшы тота белү

тона́льность *ж* **1.** *муз.* тональлек; **~ до мажо́р** до мажор тональлеге **2.** *иск.* тоннар ...ы, буяулар ...ы (*тоннарны бер-берсенә туры китерү, буяуларны бер-берсенә яраштыру*)

тона́льный, -ая, -ое **1.** *муз.* тональ **2.** *иск.* тон[нар] ...ы; буяу[лар]

тонзу́ра *ж* тонзура (*католик руханиларының баш түбәсендә кырып алынган урын*)

тониза́ция *ж см.* **тонизи́ровать**

тонизи́ровать *сов. несов. кого-что, физиол.* тонусны күтәрү; тереклек сәләтен күтәрү

тони́ческий I, -ая, -ое *лит.* тоник (*басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең чиратлашып килуенә нигезләнгән*); **~ стих** тоник шигырь

тони́ческ||ий II, -ая, -ое *физиол.* тонусны күтәрә торган; **~ие сре́дства** тонусны күтәрә торган чаралар

то́нк||ий, -ая, -ое **1.** нечкә, нәзек; юка; **~ая тетра́дь** юка дәфтәр; **~ое сукно́** юка сукно; **~ая ни́тка** нечкә җеп; **~ие па́льцы** нечкә бармаклар **2.** (*высокий — о звуках*) нечкә, югары **3.** (*о чертах лица*) нәфис **4.** нечкә, нәфис, нәзакәтле; нәфис эшләнгән; **~ий за́пах сире́ни** сирень чәчәкләренең нечкә хуш исе; **~ая рабо́та** нәфис эшләнгән эш **5.** әдәпле, нәзакәтле; **~ое обраще́ние** нәзакәтле мөгамәлә **6.** үткен, зирәк, нечкә; **~ий ум** зирәк акыл; **~ий ю́мор** нечкә юмор **7.** (*чуткий*) үткен, сизгер; **~ий слух** үткен колак ♦ **~ая бе́стия** *разг.* хәйләкәр шайтан

тонко- *кайбер кушма сүзләрнең «нәзек, нечкә, юка» мәгънәле беренче кисәге, мәс.* **~бро́вый** нечкә кашлы

тонковолоки́нистый, -ая, -ое нечкә җепселле; **~ хло́пок** нечкә җепселле мамык

тонкоко́жий, -ая, -ее юка тиреле, юка кабыклы; **~ апельси́н** юка кабыклы апельсин

тонконо́гий, -ая, -ое нәзек аяклы, нечкә аяклы; салам сыйрак (*пренебр.*)

тонкору́нн||ый, -ая, -ое нәзек йонлы; **~ая овца́** нәзек йонлы сарык

тонкосло́йный, -ая, -ое юка катламлы

тонкосте́нный, -ая, -ое юка стеналы, юка; **~ сосу́д** юка савыт

то́нкост||ь *ж* **1.** нечкәлек, нәзеклек; юкалык; **~ь ни́ти** җепнең нечкәлеге; **~ь бума́ги** кәгазьнең юкалыгы **2.** (*запаха, вкуса и т.п.*) нечкәлек **3.** (*изысканность, учтивость*) әдәплелек, нәзакәтлелек **4.** (*чувствительность, проницательность*) үткенлек, зирәклек **5.** (*мелкая подробность*) нечкәлек, җентеклелек; **вдава́ться в ~и** җентекләп тикшерү, төпченү ♦ **до ~и знать** *что берәр нәрсәне* энәсеннән җебенә кадәр белү

тонкошёрстный, -ая, -ое, **тонкошёрстый**, -ая, -ое нәзек (нечкә) йонлы

тонме́йстер *м* тонмейстер (*спектакльнең, радиотапшыруның һ.б.ш. тавыш ягын күзәтеп торучы хезмәткәр*)

то́нна *ж* тонна

тонна́ж *м* тоннаж (**1.** *мор. судноларның тонна исәбе белән авырлыгы яки йөк күтәрүчәнлеге* **2.** *спец. автомобильнең, вагонның, самолётның һ.б.ш. тонна исәбе белән йөк күтәрә алу сәләте*)

тонне́ль *м* тоннель; **~ метрополите́на** метрополитен тоннеле

тонне́льный, -ая, -ое тоннельле, тоннель ...ы; **~ уча́сток доро́ги** юлның тоннельле участогы

то́нус *м физиол.* тонус (*организмның яки аның аерым органнарының тереклек эшчәнлеге*)

тону́ть *несов.* **1.** бату; **де́рево не то́нет в воде́** агач суда батмый **2.** *прям., перен.* бату, чуму, күмелү; **~ в снегу́** карга бату; **~ во мно́жестве дел** бик күп эшкә чуму **3.** *перен.* (*становиться незаметным*) чуму, чумып утыру, күмелү; **дома́ то́нут в зе́лени** өйләр яшеллеккә күмелгән

тончáть *несов. разг.* юкару, нечкәрү, нәзегәю

то́ня *ж* **1.** (*участок водоёма для ловли рыбы неводом*) балык тота торган урын **2.** (*невод с уловом*) балыклы ятьмә

топ *в знач. сказ. разг.* тибү, тибеп кую; **он ~ на него́ ного́й** ул аңа аяк тибеп куйды

топа́з *м* топаз (*асылташ*)

топа́зовый, -ая, -ое топаз ...; топаз ...ы, топаздан ясалган

то́панье *с см.* **то́пать**

то́па||ть *несов.* **1.** (*аяк тавышлары чыгарып*) атлау; аяк тибү **2.** *шутл.* (*идти куда-л.*) китү, китә бирү, тәпи-тәпи китү; **~й отсю́да!** кит моннан!

топи́ть I *несов.* **1.** *что* (*печи и т.п.*) ягу **2.** (*обогревать помещение*) ягып җылыту; **в до́ме ста́ли ~** ягып өйне җылыта башладылар

топи́ть II *несов. что* **1.** эретү; **~ ма́сло** май эретү **2.** кайнату; **~ молоко́** сөт кайнату

топи́ть III *несов. кого-что* батыру; **~ неприя́тельские суда́** дошман судноларын батыру **2.** *что* басу; **вода́ то́пит берега́** су ярларны баса **3.** *перен. кого-что, разг.* (*губить*) батыру, харап итү, һәлак итү; **~ живо́е де́ло в бесконе́чных рассужде́ниях** җанлы эшне бетмәс-төкәнмәс сөйләнүләр белән харап итү

топи́ться I *несов.* **1.** яну; **печь то́пится** мич яна **2.** (*отапливаться*) ягылу; **э́тот дом давно́ не то́пится** бу өй күптән ягылмый инде **3.** *страд. от* **топи́ть** I

топи́ться II **1.** эрү; **воск то́пится** балавыз эри **2.** кайнау; **молоко́ то́пится** сөт кайный **3.** *страд. от* **топи́ть** II

топи́ться III *несов.* (*лишать себя жизни*) суга батып үлү, суга ташлану, суга ташланып үлү

то́пка *ж* **1.** *см.* **топи́ть** I; **~ пече́й** мичләр ягу **2.** (*часть печи, котла*) мич, топка; **парово́зная ~** паровоз мичы

то́пк||ий, -ая, -ое баткак, баткаклы, сазлыклы; **~ое ме́сто** сазлыклы урын

топлён||ый, -ая, -ое **1.** эреткән, эретелгән; **~ый воск** эретелгән балавыз; **~ое ма́сло** сары май **2.** кайнаган, кайнаткан; **~ое молоко́** кайнаган сөт

то́пливн||ый, -ая, -ое **1.** ягулык ...ы; **~ый кри́зис** ягулык кризисы **2.** ягулык белән ...; **~ое снабже́ние** ягулык белән тәэмин итү

то́пливо *с* ягулык; **жи́дкое ~** сыек ягулык; **твёрдое ~** каты ягулык; **га́зовое ~** газ ягулыгы

топля́к *м спец.* суга баткан бүрәнә

топо́граф *м* топограф, топография белгече

топографи́ческ||ий, -ая, -ое топография ...ы, топографик; **~ая ка́рта** топографик карта

топогра́фия *ж* топография (**1.** *геодезиянең җир өстен үлчи һәм аны картага, планга төшерә торган бер бүлеге* **2.** *аерым урыннарның җир өсте төзелеше һәм үзара урнашуы*)

то́полевый, -ая, -ое, **тополи́ный**, тополь ...ы, тирәк ...ы; **~ пух** тирәк мамыгы

тополо́гия *ж мат.* топология

то́поль *м* тополь, тирәк; **души́стый ~** исле тирәк; **пирамида́льный ~** пирамидаль тополь

топони́мика *ж* топонимика (**1.** *нинди дә булса илнең яисә урынның географик атамаларының җыелмасы* **2.** *лингв. тел белеменең географик атамаларны өйрәнә торган бүлеге*)

топонимн||и́ческ||ий, -ая, -ое топонимия ...ы, топонимик; **~ие иссле́дования** топонимик тикшеренүләр

топони́мия *ж см.* **топони́мика**

топо́р *м* балта

топо́рик *м уменьш. от* **топо́р**; ~ **для мя́са** ит балтасы

топори́ще *с* 1. (*рукоятка топора*) балта сабы 2. зур балта

топо́рн||ый, -ая, -ое тупас, килбәтсез; ~ **ая рабо́та** тупас эш

топо́рщить *несов. что, разг.* кабарту; тырпайту; ~ **усы́** мыекларны тырпайту

топо́рщ||иться *несов. разг.* 1. кабару, тырпаю, тырпаеп тору; **усы́** ~ ** atся** мыеклар тырпаеп тора 2. кабарыну, тырпаю; сыртын кабарту, йонын кабарту, чәнечкеләрен тырпайту; **ко́шка** ~ **ится** мәче йонын кабарта 3. *перен.* (*упрямиться*) киреләну, тырпаю

то́пот *м* аяк тавышы; **ко́нский** ~ ат аягы тавышы

топта́ние *с см.* топтать, **топта́ться**; ~ **на ме́сте** бер урында таптанып тору

топта́ть *несов.* 1. *кого-что* таптау; ~ **цветы́** чәчәкне таптау 2. *что, разг.* (*пачкать, загрязнять*) таптау, пычрату; ~ **пол** идәнне таптау 3. *что, разг.* (*сношивать обувь*) туздыру, киеп туздыру; кыйшайту

топта́ться *несов.* 1. (*переступать с ноги на ногу*) таптану, таптанып тору 2. *страд. от* **топта́ть** ♦ ~ **на ме́сте** бер урында таптану, эше алга бармау

топ-то́п *межд.* тып-тып; тәпи-тәпи (*нәни бала атлавы турында*)

топча́н *м* такта ятак, топчан

топы́рить *несов. прост. см.* **топо́рщить**; ~ **па́льцы** бармакларны тырпайту

топы́риться *несов. прост.* 1. *см.* **топо́рщиться**; 2. *страд. от* **топы́рить**

топь *ж* сазламык, баткаклык, баткак урын (җир)

то́рба *ж прост.* торба

торг I *м* 1. *см.* **торгова́ть** I, **торгова́ться** I; 2. *уст.* базар

торг II торг (*сәүдә учреждениесе*)

торга́ш *м* 1. вак сәүдәгәр, сәүдәгәр 2. *перен.* торгаш, сәүдәче

торга́шеск||ий, -ая, -ое *разг.* торгашлар ...ы, сәүдәчеләр ...ы, торгашларча..., торгашларга хас; ~ **ие зама́шки** торгашларча кыланышлар

торга́шество *с разг.* сәүдәчелек, торгашлык

торги́ *мн.* торги (1. *берәр мөлкәтне яки товарны халык алдында артыграк бәя бирүчегә сату* 2. *берәр эшне арзанракка эшләргә килешкән кешегә подряд бирү*)

торгова́ть *несов.* 1. *кем-чем, с кем-чем и без доп.* сәүдә итү, сату итү; ~ **хле́бом** икмәк белән сәүдә итү; 2. *перен. кем-чем* (*делать предметом торговли*) сату, акчага сату; сатылу; ~ **свое́й со́вестью** вөжданын акчага сату 3. (*быть торговцем или продавцом*) сәүдә итү; сату итү; **учи́ться** ~ сату итәргә өйрәнү 4. (*быть открытым для торговли*) сату итү, ачык булу; **магази́н торгу́ет до 10 часо́в ве́чера** кибет кичке унга хәтле сату итә 5. *кого-что, прост.* (*договариваться о цене*) сатулашу; ~ **коня́** ат сатулашу

торгова́ться *несов. с кем-чем* (*сговариваться о цене*) сатулашу, сәүдәләшү 2. *перен. разг.* сатулашу, сүз көрәштерү

торго́вец *м* сәүдәгәр, сату итүче

торго́вка *ж* сату итүче хатын (кыз)

торго́вл||я *ж* сәүдә, сәүдә итү, сәүдәгәрлек; сату итү; **ро́зничная** ~ **я** ваклап сату; **вне́шняя** ~ **я** тышкы сәүдә; **занима́ться** ~ **ей** сәүдә итү

торго́в||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* сәүдә ...ы; сату ...ы; ~ **ый капита́л** сәүдә капиталы; ~ **ый догово́р** сәүдә шартнамәсе; ~ **ый флот** сәүдә флоты; ~ **ая сеть** сәүдә челтәре; ~ **ый центр** сәүдә үзәге

торгпре́д *м* сәүдә вәкиле, торгпред

торгпре́дство *с* сәүдә вәкиллеге, торгпредство

тореадо́р *м* тореадор (*Испаниядә: үгез сугышында катнашучы*)

торе́ц *м* 1. (*поперечная грань чего-л.*) аркылы кисем, торец (*бүрәнәнең, борыснык һ.б.ш. аркылы киселгән башы*) 2. (*брусок*) борыс, бүкән, торец 3. (*мостовая из таких брусков*) борыс түшәлгән урам

торже́ственность *ж* тантаналылык; **провести́ пра́здник с большо́й** ~ **ю** бәйрәмне зур тантаналылык белән үткәрү

торже́ственн||ый, -ая, -ое тантаналы; ~ **ое собра́ние** тантаналы җыелыш; ~ **ый вид** тантаналы кыяфәт

торжеств||о́ *с* 1. (*большое празднество*) тантана, бәйрәм; **ма́йские** ~ **а́** Май бәйрәме тантаналары 2. *кого-чего, чьё* (*победа, успех*) тантана, җиңү, өстен чыгу, җиңеп чыгу; ~ **о́ справедли́вости и добра́** гаделлек һәм игелек тантанасы 3. (*радость, удовлетворение*) тантана, шатлык; **воскли́кнуть с** ~ **о́м** шатланып кычкыру

торжествова́ть *несов.* 1. *что, уст.* (*справлять торжество*) бәйрәм итү, тантана итү; ~ **побе́ду** җиңүне бәйрәм итү 2. *над кем-чем* өстен чыгу, өстенлек алу, җиңү, җиңеп чыгу; ~ **над враго́м** дошманны җиңеп чыгу

то́ржище *с уст.* базар, сәүдә урыны

то́рий *м хим.* торий

тори́т *м хим.* торит

торичелли́ев: ~а пустота́ *физ.* Торичелли бушлыгы

торма́шк||и *мн.*: **вверх** ~ **ами** (*лететь*) *разг.* мәтәлеп китү, баш түбән китү

торможе́ние *с* 1. *см.* **тормози́ть**; **э́кстренное** ~ ашыгыч тормозлау; ~ **проце́сса разря́дки** киеренкелекне йомшарту процессын тоткарлау 2. *физиол.* туктау, тоткарлану, тоткарлау; ~ **усло́вных рефле́ксов** шартлы рефлексның туктавы

то́рмоз *м* 1. (*мн.* ~ **á**) *тех.* тормоз; **ножно́й** ~ аяк тормозы; **ручно́й** ~ кул тормозы 2. *перен.* (*мн.* ~ **ы**) (*помеха, препятствие*) тоткарлык, комачау, киртә; ~ **в рабо́те** эштә тоткарлык

тормози́ть *несов.* 1. *что и без доп.* тормоз салу, туктату, тормозлау; ~ **маши́ну** машинаны тормозлау 2. *перен. что* (*задерживать развитие чего-л.*) тоткарлау, аяк чалу, киртә кую 3. *перен. что, физиол.* тоткарлау; ~ **рефле́ксы** рефлексларны тоткарлау

тормози́ться *несов.* 1. тоткарлану, киртә куелу (*берәр эшкә*) 2. *страд. от* **тормози́ть**

тормозн||о́й, -а́я, -о́е тормоз ...ы; тормозлау ...ы; ~ **о́й кран** тормоз краны; ~ **о́й рыча́г** тормоз рычагы; ~ **а́я жи́дкость** тормоз сыекчасы; ~ **о́й проце́сс** тормозлау процессы

тормоши́ть *несов. кого-что, разг.* 1. (*теребить*) тарту; йолку 2. *перен.* йөдәтү; борчу; ~ **пустяко́выми вопро́сами** буш сораулар белән йөдәтү

то́рн||ый, -ая, -ое такыр, тапталган, тигез; ~ **ая доро́га** такыр юл

торова́тый, -ая, -ое *уст.* (*щедрый*) юмарт, киң күнелле

торопи́ть *несов.* 1. *кого-что, кого с чем* ашыктыру, кабаландыру, кызуландыру; тизләтү (*тизрәк башкарырга мәҗбүр итү*); ~ **с выполне́нием зака́за** заказның тизрәк үтәлүен сорау; ~ **коня́** атны ашыктыру 2. *что* (*приближать наступление чего-л.*) тизләтү, тизләттерү; ~ **собы́тия** вакыйгаларны тизләтү

торопи́ться *несов.* ашыгу, кабалану, кызулау; ~ **на рабо́ту** эшкә ашыгу

торопли́вость *ж* ашыгучанлык, кабалану

торопли́в||ый, -ая, -ое ашыгучан, кабаланучан; ашыгыч; ~ **ый челове́к** ашыгучан кеше; ~ **ые шаги́** ашыгыч адымнар

торопы́га *м, ж прост.* ашыгучан кеше, кабаланучан кеше

торо́с *м* боз тавы, көренде, боз өемнәре (*поляр диңгезләрдә*)

тороси́стый, -ая, -ое көренделе, боз өемнәре күп булган

торпе́да *ж* торпеда (*су асты снаряды*)

торпеди́ровать *сов., несов. что* 1. торпедалау, торпеда җибәрү; ~ **кора́бль проти́вника** дошман кораблен торпедалау 2. озу, бозу

торпеди́ст *м* торпедачы

торпе́дный, -ая, -ое торпеда ...ы, торпедалы, торпеда җибәрүче; ~ **ка́тер** торпеда катеры; ~ **уда́р** торпеда һөҗүме

торпедоно́сец *м* торпедоносец, торпеда йөртүче

торпедоно́сный, -ая, -ое торпедалы, торпедалар белән коралланган

торс *м* торс, гәүдә; кеше гәүдәсе

торт *м* торт

торф *м* торф

торфопогру́зчик *м* торф төягеч [машина]

торфоразрабо́тки *мн.* торф чыгару урыны, торфлык

торфяни́к *м* 1. (*торфяное болото*) торфлык, торфлы сазлык, торф сазлыгы 2. (*специалист по торфу*) торфчы, торф белгече; торф чыгаручы эшче

торфяни́ст||ый, -ая, -ое торфлы, торфы булган; ~ **ая по́чва** торфлы туфрак

торфян||о́й, -а́я, -о́е торф ...ы, торфлы; ~ **а́я промы́шленность** торф промышленносте; ~ **ые за́лежи** торф ятмалары; ~ **о́е боло́то** торфлы сазлык

торцева́ние *с см.* **торцева́ть**

торцева́ть *несов. что* 1. (*отпиливать концы брёвен, брусьев*) (бүрәнә, борыс)

ТОР-ТОШ

башын кисү, торец кисү **2.** (*застилать торцами*) бүкән түшәү, борыс түшәү

торцев||о́й, -а́я, -о́е **1.** торец ...ы, торец...; **~о́й разре́з** торец киселеше **2.** (*покрытый торцами*) бүкән җәелгән, борыс түшәлгән; **~а́я мостова́я** бүкән түшәлгән урам

торцо́вка *ж см.* **торцева́ть**

торцо́вый, -ая, -ое *см.* **торцево́й**

торча́||ть *несов.* **1.** чыгып тору, калкып тору; күренеп тору; тырпаеп тору; **бревно́ ~ло из воды́** судан бүрәнә чыгып тора иде; **вихры́ ~т** чәчләре тырпаеп тора **2.** *перен. прост.* (*находиться где-л.*) басып тору, китми тору; **~ть пе́ред глаза́ми** күз алдында басып тору

торчко́м *нареч. разг.*, **торчмя́** *нареч. прост.* тырпаеп [тору]; **усы́ ~** мыеклары тырпаеп тора

торше́р *м* торшер

тоск||а́ *ж* **1.** *по кому-чему* сагыну, юксыну; **~а́ по ро́дине** туган илне сагыну **2.** (*скука, уныние*) ваем, эч пошу; сагыш; **напа́ла ~а́** эч поша башлады; **наводи́ть ~у́** эч пошыру

тоскли́вость *ж* сагышлылык, күңелсезлек, ямансулык

тоскли́в||ый, -ая, -ое **1.** сагышлы, күңелсез, ямансу; **~ый взгляд** сагышлы караш; **~ая жизнь** күңелсез тормыш **2.** (*наводящий тоску*) эчпошыргыч; **~ая пого́да** эчпошыргыч һава

тоскова́ть *несов. о ком-чём, по ком-чём, по кому-чему* сагыну, сагышлану, юксыну, ямансулау; **~ о де́тях** балаларны сагыну; **~ друг о дру́ге** сагынышу

тост *м* тост; **провозгласи́ть ~** тост күтәрү

тот *м мест.* **1.** шул, теге, ул; **в ~ год** шул елда; **~ дом** теге өй; **в ~ раз** ул чакта; **на ~ бе́рег реки́** елганың теге ягына; **в ~ день бы́ло о́чень хо́лодно** ул көнне бик суык иде **2.** (*в составе относ. слов*) шуннан, шуңардан; **спроси́ у того́, кто зна́ет** кем белсә, шуңардан сора **3.** (*не такой, к-рый нужен*) башка, бүтән, икенче; **сел не в ~ ваго́н** башка вагонга утырды; **он сейча́с стал не ~** ул хәзер башка инде **4.** бусы, ансы, монсы, тегесе; **~ и друго́й** бусы да, тегесе дә **5.** (*при перечисл. противопоставляется словам*: *«иной», «другой», «этот»*) ул, теге, тегесе; **ни ~ ни друго́й** ул да түгел, башка да түгел; **не те, так други́е помо́гут** алар булмаса, башкалар ярдәм итәр **6.** *в знач. сущ.* **то с** (*что-л. более отдалённое*) ансы; ул; **то бы́ло вчера́, а э́то сего́дня** анысы кичә булган иде, әмонысы бүген; **то был мой друг** ул минем дустым иде ◆ **ввиду́ того́, что** ...га күрә; **вме́сто того́, что́бы** ... урынына; **вследствие того́, что** ... сәбәпле; **де́ло в том, что** ... эш шунда ки ...; **до того́, что** ...ганчы, шул кадәр; **и без того́** ансыз да, аннан башка да; **и тому́ подо́бное** һәм башка шундыйлар; **и ~, и друго́й** тегесе дә, монысы да; **к тому́ же** шуның өстәвенә, җитмәсә [тагын]; **не до того́** *кому* аның кайгысы юк әле; **ни с того́ ни с сего́** тик торганда, бернинди сәбәпсез; **ни то ни сё** ни он, ни йон; ни аллага, ни муллага; **по́сле того́, как** шуннан соң; **с тем, что́бы** ...мас өчен; **тем не ме́нее** шулай булуга карамастан; **того́ и гляди́ (того́ и жди)** көт тә тор; **то да сё** тегесе-монысы; анысы-монысы; **~ свет** *рел.* теге дөнья

тотализа́тор *м* тотализатор (**1.** *от чабышында кайсы атка һәм барлыгы күпме акча куелганлыгын күрсәткән счётчик* **2.** *ат чабышында отыш уены*)

тоталитари́зм *м книжн.* тоталитаризм, тоталитар режим

тоталита́рность *ж книжн.* тоталитарлык

тоталита́рн||ый, -ая, -ое *книжн.* тоталитар; **~ое госуда́рство** тоталитар дәүләт

тота́льн||ый, -ая, -ое *книжн.* гомуми, тоталь; **~ая война́** тоталь сугыш; **~ая мобилиза́ция** тулы мобилизация үткәрү

тоте́м *м* тотем (*борынгы халыкларда берәр гаиләнең яки кабиләнең табына һәм олылый торган хайваны, үсемлеге яки әйбере*)

тотеми́зм *м* тотемизм, тотемга табыну

тотемисти́ческ||ий, -ая, -ое тотемизм ...ы, тотемистик; **~ое ве́рование** тотемистик ышанулар

то́-то *частица разг.* **1.** (*в том-то и дело, именно*) шулай шул; **вот ~, всё вы зна́ете** менә шулай шул, сез барсын да беләсез **2.** *усил.* (*вот уж*) менә; **~ он удиви́тся!** менә ул гаҗәпләнер инде! **3.** (*так вот почему*) менә ни өчен, шуның өчен; әйтәм; **~ он стал ча́сто боле́ть** әйтәм, ул еш авырый башлады **4.** (*предупреждение, словесная угроза*) кара аны, белеп тор

то́час, тотча́с *нареч.* шунда ук, шул чакта ук; **~ приду́** шунда ук килермен

точён||ый, -ая, -ое **1.** кайралган, чарланган, үткерләнгән; **~ый нож** үткерләнгән пычак **2.** (*выточенный*) кырылган, кырып ясалган; **~ые изде́лия** кырып ясалган әйберләр **3.** *перен.* коеп куйган кебек, нәфис, күркәм; **~ый нос** коеп куйган кебек борын

то́чечн||ый, -ая, -ое нокталы, төрткеле, нокталардан ясалган; **~ая ли́ния** нокталы сызык; **~ый узо́р** төрткеләрдән ясалган бизәк

точи́лка *ж разг.* **1.** беләү, янавыч, кайрак **2.** карандаш очлагыч

точи́ло *с* чар, чар ташы, кайрак

точи́льный, -ая, -ое кайрак ..., кайрый (үткерли) торган; үткерләү ...ы; **~ ка́мень** кайрак таш

точи́льщик *м* үткерләүче, кайракчы, кайраучы (*балта, пычак, кайчы һ.б.ш.ны*)

точи́ть *несов.* **1.** *что* кайрау, чарлау, үткерләү, янау; **~ кось** чалгы янау **2.** *что* (*заострять*) очлау; **~ каранда́ш** карандаш очлау **3.** *что* (*изготовлять*) кыру, кырып ясау; **~ дета́ли** детальләр кырып ясау **4.** *что* (*портить*) кисү, ашау, тишү, **червь то́чит де́рево** корт агачны тишә; **ржа́вчина то́чит желе́зо** тутык тимерне ашый **5.** *перен. кого-что* киптерү, саргайту; **го́ре то́чит** кайгы саргайта ◆ **~ зу́бы** *на кого* теш кайрау; **~ ля́сы** ләчтит сату, сафсата сату

то́чк||а I *ж* **1.** бөрчек, төрткә; **си́тец в кра́сных ~ах** кызыл бөрчекле ситсы **2.** (*знак препинания*) нокта; **поста́вить ~у с запято́й** нокталы өтер кую **3.** (*место в пространстве*) нокта, урын, җир; **са́мая высо́кая ~а горы́** тауның иң биек урыны **4.** нокта; **~а пересече́ния прямы́х** *мат.* туры сызыкларның кисешү ноктасы; **~а опо́ры** таяну ноктасы **5.** (*место расположения*) урын, нокта; **торго́вая ~а** сәүдә ноктасы; **огнева́я ~а** *воен.* ут ноктасы **6.** *физ.* нокта; **~а кипе́ния** кайнау ноктасы; **~а замерза́ния** кату ноктасы; **~а плавле́ния** эрү ноктасы **7.** *разг.* (*кончено*) тәмам, бетте, вәссәлам; **ещё полчаса́ поработа́ю — и ~а** тагын ярты сәгать эшлим дә — вәссәлам ◆ **в са́мую ~у** (*попасть и т.п.*) нәкъ өстенә басу; **~а в ~у** хәрефкә-хәреф

то́чка II *ж см.* **точи́ть** I-3; **~ ножей, бритв** пычак, пәкеләр үткерләү

то́чно 1. *нареч.* төгәл, төгәл итеп, дөрес итеп; **~ переда́ть чьи-либо слова́** кемнең дә булса сүзләрен төгәл итеп сөйләп бирү **2.** *нареч.* (*вполне, совершенно*) нәкъ; **~ тако́й же** нәкъ шундый ук **3.** *частица утверд. прост.* (*да, так, верно*) әйе; дөрес; **~, я здесь был** дөрес, мин монда булдым **4.** *вводн. сл.* (*действительно, в самом деле*) чыннан да, дөрестән дә; **она́, ~, краси́ва** ул чыннан да матур **5.** *союз сравн.* (*как будто, словно*) гүя, кебек, шикелле, сыман, әйтерсең; **кричи́т, ~ сумасше́дший** акылдан язган кеше кебек кычкыра

то́чност||ь *ж в разн. знач.* төгәллек, төгәл булу, дөреслек; **~ь перево́да** тәрҗемәнең төгәллеге; **~ь ве́са** үлчәүнең төгәл булуы; **вы́числить с ~ью до одно́й со́той** йөздән бер өлешкә кадәр дөреслек белән хисаплап чыгару ◆ **в ~и** нәкъ, төп-төгәл

то́чн||ый, -ая, -ое **1.** төгәл, дөрес йөри торган; **~ый перево́д** төгәл тәрҗемә; **~ые прибо́ры** төгәл приборлар; **~ые часы́** дөрес йөри торган сәгать **2.** (*пунктуальный*) төгәл; **~ый челове́к** төгәл кеше ◆ **~ые нау́ки** төгәл фәннәр

точь: ~-в-точь *разг.* төп-төгәл, дөп-дөрес итеп, нәкъ, нәкъ менә, нәкъ үзе кебек итеп, суйган да каплаган, коеп куйган; **пересказа́ть** *что-л.* **~-в-точь** *берәр нәрсәне* төп-төгәл итеп сөйләп бирү; **ма́льчик ~-в-точь оте́ц** малай нәкъ әтисе

тошни́ть *несов. безл. кого* укшыту, күңел болгану, косасы килү

то́шно *в знач. сказ. безл.* **1.** укшыту, күңел болгану, косасы килү **2.** *перен.* (*отвратительно*) авыр, кыен; чирканыч, җирәнгеч; **~ смотре́ть на него́** аңа каравы чирканыч; **~ на се́рдце** эч поша

тошнота́ *ж* күңел болгану, косасы килү, укшу, укшыту

тошнотво́рн||ый, -ая, -ое **1.** (*вызывающий тошноту*) косасы китерә торган, укшыта торган, күңел болгата торган, күңел болгаткыч **2.** *перен.* жи-

рәнгеч, чирканыч, күңел болгаткыч; **~ое зре́лище** җирәнгеч күренеш

то́шный, -ая, -ое *разг.* эчпошыргыч, күңел кайтаргыч

тощ|а́ть *несов. разг.* ябыгу, арыклану

то́щ||ий, -ая, -ее **1.** ябык, арык, йәдәү; **~ий челове́к** ябык кеше **2.** (*пустой*) ач, буш; **на ~ий желу́док** ач карынга; **~ий кошеле́к** буш кесә **3.** (*скудный*) ярлы; ундырышсыз, уңыш бирми торган; **~ая по́чва** уңыш бирми торган туфрак

тпру *межд.* трр ♦ **ни ~ ни ну́** ни алга, ни артка

трав||а́ *ж* үлән; чирәм; **со́рная ~а́** чүп үләне; **одноле́тние тра́вы** берьеллык үләннәр; **коси́ть ~у́** үлән чабу ♦ **~о́й поросло́** күптән булып онытылган; **хоть ~а́ не расти́** *прост.* ни булса да барыбер, ике ятып бер төшенә дә керми; **~а́ ~о́й** *или* **как ~а́** үлән кебек (*бер тәме дә юк*)

травене́ть *несов. спец.* (*зарастать травой*) үлән үсү (басу, басып китү)

тра́верз *м спец.* траверз (*судноның, самолётның алган курсына карата перпендикуляр юнәлеш*)

тра́верс *м спец.* траверс (**1.** *окоп кырыена өелгән туфрак* **2.** *махсус дамба*)

травести́ *с нескл. и неизм.* травести (*хатын-кызлар уйный торган яшүсмер роле*)

трави́нка *ж* үлән сабагы

трави́ть I *несов.* **1.** *кого-что* агулау, агулап үтерү; **~ тарака́нов** тараканнарны агулау **2.** *прям., перен. кого-что, разг.* ярсыту, агулау; **~ ра́ну** яраны ярсыту; **~ организ́м алкого́лем** организмны алкоголь белән агулау **3.** *что* (*делать потраву чего-л.*) таптату, таптау; **~ посе́вы** чәчүлекләрне таптау **4.** *кого-что* (*преследовать*) өстерү, эт белән куу; **~ за́йца** куянны эт белән куу **5.** *перен. кого-что* (*изводить, преследовать*) яла ягу, эзәрлекләү, каныгу, бәйләнү **6.** *что, тех.* ашатып ясау, ашатып рәсем төшерү; **~ узо́ры** ашатып бизәк төшерү

трави́ть II *несов. что, мор.* акрынлап бушайту, акрынлап бушайта төшү; **~ кана́т** арканны акрынлап бушайту

трави́ться *несов.* **1.** *разг.* агу эчү (*үзен-үзе үтерү ниятe белән*) **2.** *страд. от* **трави́ть** I

тра́вленый, -ая, -ое (*изготовленный травлением*) ашатып ясалган, ашатып төшерелгән ♦ **~ волк (зверь)** *прост.* карт төлке (*күпне күргән кеше турында*)

тра́вля *ж см.* **трави́ть** I 4, 5

тра́вма *ж* яра, яралану, җәрәхәт, җәрәхәтләнү, травма; **~ от уши́ба** бәрелеп җәрәхәтләнү; **психи́ческая ~** психик травма

травмати́зм *м* яралану, җәрәхәтләнү, травматизм

травмати́ческий, -ая, -ое травматик, травма ...ы; **~ невро́з** травма неврозы

травмато́лог *м* травматолог, травматология белгече

травматологи́ческий, -ая, -ое травматология ...ы, травматологик; **~ кабине́т** травматология бүлмәсе

травматоло́гия *ж* травматология (*медицинаның травмаларны өйрәнә һәм аларны дәвалый торган бүлеге*)

травми́рование *с см.* **травми́ровать**

травми́ровать *сов., несов. кого-что* травма ясау, травмалау, имгәтү, җәрәхәтләү, яралау

травопо́лье *с* (*система земледелия*) (*басуга*) үлән чәчү, (*басуга*) үлән чәчү системасы

травопо́льный, -ая, -ое үлән чәчүле ..., үлән басулы ...; **~ севообо́рот** үлән басулы чәчү әйләнеше

травосе́яние *с* үлән чәчү

травосто́й *м* үлән торышы, үлән капламы

травоя́дн||ый, -ая, -ое үлән ашаучы, үсемлек белән туенучы; **~ые живо́тные** үлән ашаучы хайваннар

травяни́ст||ый, -ая, -ое **1.** үлән, үләнчел; **~ое расте́ние** үлән үсемлек **2.** үләнле, куе үләнле; **~ая река́** үләнле елга; **~ые луга́** куе үләнле болыннар

травян||о́й, -а́я, -о́е **1.** үлән ...ы; **~а́я по́росль** үлән үсентесе; **~а́я насто́йка** үлән төнәтмәсе **2.** үләнле, үлән баскан; **~о́е боло́то** үлән баскан сазлык

трагеди́йность *ж* трагедиялелек

трагеди́йный, -ая, -ое трагик, трагедияле, трагедия ...ы; **~ актёр** трагедия артисты

траге́дия *ж* **1.** трагедия (*драма әсәренең төре*) **2.** *перен.* фаҗига, һәлакәт, трагедия

траги́зм *м* **1.** трагизм (*әдәби, музыкаль әсәрдә трагик элемент*) **2.** *см.* **траги́чность**

тра́гик *м* трагик, трагик артист

трагикоме́дия *ж* **1.** трагикомедия (*трагедия һәм комедия элементларын эченә алган әсәр*) **2.** *перен.* фаҗигале һәм көлкеле вакыйга (эш, хәл)

трагикоми́ческий, -ая, -ое **1.** трагикомедия ...ы; **~ сюже́т** трагикомедия сюжеты **2.** (*печальный и смешной*) трагикомик; **~ слу́чай** трагикомик хәл

трагикоми́чный, -ая, -ое *см.* **трагикоми́ческий** 2

траги́ческ||ий, -ая, -ое **1.** (*свойственный трагедии*) трагедия ...ы, трагик, трагедияле; **~ий стиль** трагедия стиле; **~ая по́за** трагик поза **2.** (*играющий в трагедиях*) трагик, трагик рольләрне башкаручы **3.** (*ужасный, полный страданий*) фаҗигале, һәлакәтле, дәһшәтле; **~ое зре́лище** фаҗигале күренеш

траги́чность *ж* фаҗигалелек, һәлакәтлелек, дәһшәтлелек

траги́чный, -ая, -ое *см.* **траги́ческий** 3

традицио́нность *ж* традициялелек, гадәткә кергән булу, традиция булып китү

традицио́нн||ый, -ая, -ое традицион, традициягә кергән, традиция (гадәт) булып киткән; **~ый пра́здник** традицион бәйрәм; **~ый сва́дебный обря́д** традициягә кергән туй йоласы; **~ые свя́зи с сосе́дними стра́нами** күрше илләр белән традицион элемтәләр

тради́ци||я *ж* **1.** традиция; **во́инские ~и** хәрби традицияләр **2.** (*обычай*) гадәт, гореф-гадәт; тәртип; **войти́ в ~ю** гадәткә керү

траекто́рия *ж* траектория (**1.** *мат., физ. берәр җисемнең яки ноктаның хәрәкәт юлы* **2.** *воен. пуля яки снарядның очып бару юлы*)

тракт *м* юл, олы юл, тракт ♦ **желу́дочно-кише́чный ~** *анат.* ашказаны-эчәк тракты

тракта́т *м* **1.** (*научное сочинение*) гыйльми әсәр, трактат **2.** *дип.* трактат, халыкара договор; **ми́рный ~** тынычлык трактаты

трактова́ние *с см.* **трактова́ть**; **пра́вильное ~** дөрес аңлату

трактова́ть *несов. что* аңлату, ачып бирү, төшендерү, аңлатма бирү; **~ *что-л.* по-но́вому** *берәр нәрсәне* яңача аңлату

трактова́ться *несов.* **1.** (*получать какое-л. объяснение*) аңлатылу, фикер йөртелү, караш әйтелү **2.** *страд. от* **трактова́ть**

трактов|ка *ж см.* **трактова́ть**

тра́ктор *м* трактор; **гу́сеничный ~** гусеницалы (чылбыр тәгәрмәчле) трактор; **колёсный ~** тәгәрмәчле трактор

трактори́ст *м* тракторчы

трактори́стка *ж* тракторчы хатын (кыз)

тра́кторн||ый, -ая, -ое трактор[лар] ...ы; **~ый мото́р** трактор моторы; **~ый парк** тракторлар паркы; **~ая брига́да** тракторчылар бригадасы

тракторострое́ние *с* тракторлар төзү, тракторлар эшләп чыгару

тракторострои́тельный, -ая, -ое трактор төзү ...ы; трактор эшләп чыгара торган

трал *м* трал (**1.** *суднодан торып балык тоту өчен конус сыман итеп эшләнган зур ятьмә* **2.** *мина аулау өчен җайланма* **3.** *диңгез төбен тикшерү, андагы хайваннарны һәм үсемлекләрне эләктереп кутәрү приборы*)

трале́ние *с см.* **тра́лить**

тра́лить *несов. что* **1.** траллау, трал белән балык тоту **2.** трал белән мина тоту **3.** (*диңгез төбен*) трал белән тикшерү; **~ проли́в** трал белән бугазны тикшерү

тра́лов||ый, -ая, -ое **1.** трал белән ...; **~ый лов ры́бы** трал белән балык тоту **2.** траллы, трал белән җиһазланган; **~ая флоти́лия** трал белән җиһазланган флотилия

тра́льщик *м* траллаучы, тральщик (**1.** *трал белән җиһазланган судно* **2.** *диңгезче, траллау эше белгече*)

трамбова́ть *несов. что* төйгечләп (төеп) тыгызлау; төйгечләп тигезләү; **~ зе́млю** җирне төеп тыгызлау

трамбо́вка *ж* **1.** *см.* **трамбова́ть**; **2.** (*орудие*) трамбовка, төйгечләп тигезләү коралы

трамбо́вочн||ый, -ая, -ое төйгечләп тыгызлау ...ы, төйгечләп тигезләү ...ы; **~ая маши́на** төйгечләп тыгызлау машинасы

трамва́||й *м* трамвай; **сесть в ~й (на ~й)** трамвайга утыру; **е́хать ~ем (на ~е)** трамвайда бару ♦ **речно́й ~й** су трамвае

ТРА-ТРА

трамплúн *м* **1.** *спорт.* сикерү басмасы, трамплин; **лы́жный ~** чаңгычыларның сикерү басмасы **2.** *перен.* трамплин (*берәр эшнең башлангыч пункты, таяныч*)

транжúр *м*, **транжúра** *ж*, *разг.* мал туздыручы, акча туздыручы, акча әрәм-шәрәм итүче

транжúрить *несов. что, разг.* (*акча һ.б.ш.*) туздыру, әрәм-шәрәм итү, җилгә җибәрү

транжúрка *ж разг.* акча туздыручы хатын (кыз)

транжúрств||о *с см.* **транжúрить**; **привы́чка к ~у** акча туздыру гадәте

транзúстор *м* транзистор

транзúсторный, -ая, -ое транзистор[лар] ...ы; транзисторлы; **~ приёмник** транзисторлы радиоалгыч; **~ вычисли́тель** транзисторлы хисаплап чыгару приборы

транзúт *м* **1.** транзит (*бер илдән икенче илгә арадагы өченче ил аркылы товар яки пассажирлар алып бару*); **посла́ть гру́зы ~ом** йөкләрне транзит белән җибәрү

транзúтник *м разг.* транзит пассажир, транзитчы

транзúтн||ый, -ая, -ое транзит ..., транзит белән җибәрелә торган; **~ый по́езд** транзит поезд; **~ые пассажи́ры** транзит пассажирлар

транквилиза́тор *м мед.* транквилизатор

транс *м мед.* транс; **впасть в ~** акыл томалану (*нервларның ярсуы нәтиҗәсендә*)

транс² *кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «аша» сүзе белән тәрҗемә ителә, күпчелек очракта тәрҗемә ителми, мәс.* **трансполя́рный** полюс аша

трансатлантúческий, -ая, -ое Атлантик океан аша йөри торган, трансатлантик; **~ ла́йнер** трансатлантик лайнер

трансконтинента́льн||ый, -ая, -ое континентлар аша, трансконтиненталь; **~ая раке́та** континентлар аша очучы ракета

транскрибúровать *сов., несов. что, лингв.* транскрипцияләү

транскрипцио́нн||ый, -ая, -ое *лингв.* транскрипцион, транскрипция ...ы; **~ая систе́ма** транскрипция системасы; **~ые зна́ки** транскрипция билгеләре

транскрúпция *ж лингв.* транскрипция; **междунаро́дная фонети́ческая ~** халыкара фонетик транскрипция

трансли́ровать *сов., несов. что* трансляцияләү, (*радио яки телевидение аша*) тапшыру; **~ конце́рт** концертны трансляцияләү

трансляцио́нный, -ая, -ое трансляция ...ы; **~ у́зел** трансляция үзәге

трансля́ци||я *ж* трансляция; **слу́шать ~ю из Москвы́** Мәскәүдән трансляцияне тыңлау

трансмиссио́нный, -ая, -ое хәрәкәт тапшыргыч, хәрәкәт күчергеч, трансмиссион

трансми́ссия *ж* трансмиссия (*хәрәкәтне двигательдән эш машинасына күчерә торган барлык механизмнар*)

транспара́нт *м* транспарант (**1.** *сызыксыз кәгазь астына куела торган калын кара сызыклы кәгазь бите* **2.** *рамга киереп беркетелгән рәсемле яки язулы тукыма*)

трансплантáция *ж* күчереп кую, трансплантацияләү; трансплантация (*организмның берәр тукымасын яки органын икенче урынга яисә организмга күчерү*); **~ по́чки** бөерне күчереп кую

трансплантúровать *сов., несов. что* күчереп кую, трансплантацияләү, трансплантация ясау

тра́нспорт *м в разн. знач.* транспорт; **городско́й ~** шәһәр транспорты; **пассажи́рский ~** пассажирлар ташу транспорты; **гужево́й ~** атлы транспорт; **санита́рный ~** санитария транспорты

транспо́рт *м бухг.* транспорт (*бухгалтерия эшендә сумманы икенче биткә күчерү*)

транспорта́бельность *ж* күчереп йөртү булу, транспортабельлелек

транспорта́бельный, -ая, -ое күчереп йөртеп була торган, транспортабель

транспортёр *м* **1.** транспортёр, конвейер (*йөкләрне бер урыннан икенче урынга туктаусыз күчереп тора торган җайланма*); **ле́нточный ~** тасмалы транспортёр; **ро́ликовый ~** роликлы транспортёр **2.** транспортёр (*җәяүле гаскәр һәм йөкләр ташый торган хәрби машина*)

транспорти́р *м* транспортир

транспорти́рование *с см.* **транспорти́ровать**; **~ зерна́** ашлык ташу

транспорти́ровать *сов., несов. кого-что* ташу, йөртү, күчерү, илтү; транспортлау; **~ гру́зы** йөк ташу

транспортиро́вка *ж см.* **транспорти́ровать**; **~ га́за и не́фти** газ һәм нефтьне транспортлау

тра́нспортник *м* транспортчы, транспортта эшләүче

тра́нспортн||ый, -ая, -ое транспорт ...ы; **~ые сре́дства** транспорт чаралары; **~ый самолёт** транспорт самолёты; **~ое хозя́йство** транспорт хуҗалыгы; **сниже́ние ~ых изде́ржек** транспорт чыгымнарын киметү

трансформа́тор *м* **1.** *тех.* трансформатор; **повыша́ющий ~** күтәрүче трансформатор; **понижа́ющий ~** төшерүче трансформатор **2.** *театр.* трансформатор (*бер нәрсәне башка нәрсә итеп күрсәтүче фокусчы*)

трансформа́торн||ый, -ая, -ое трансформатор ...ы; **~ая бу́дка** трансформатор будкасы

трансформа́ция *ж* трансформация, әверелү, әверелдерү, үзгәрү, үзгәртү

трансформи́зм *м биол.* трансформизм (*дарвинизмга кадәр булган тәгълимат*)

трансформи́ровать *сов., несов. что* үзгәртү, әверелдерү, трансформацияләү, әйләндерү

трансформи́роваться 1. *сов., несов.* үзгәрү, әверелү, трансформацияләнү, әйләнү **2.** *несов. страд. от* **трансформи́ровать**

транше́йн||ый, -ая, -ое траншея ...ы; траншея ярдәмендә ...; **~ые ору́дия** траншея орудиеләре

транше́я *ж* траншея (*озын чокыр*)

трап *м* баскыч, трап

тра́пеза *ж* ашъяулык, аш өстәле, аш табыны (*монастырьда күмәк кеше өчен*); (*гомумән*) ашау-эчү, трапеза

трапециеви́дный, -ая, -ое трапеция-сыман, трапециягә охшаган

трапе́ция *ж* трапеция (**1.** *мат.* *икеягы бер-берсенә параллель, калган икеягы бер-берсенә параллель булмаган дурт-почмак* **2.** *спорт.* *икебауга асылган аркылы агачтан яки тимердән гыйбарәт гимнастик снаряд*)

тра́сса *ж* **1.** (*направление*) юл, юл сызыгы, трасса; **~ но́вого кана́ла** яңа канал юлы **2.** (*дорога*) юл; **автомоби́льная ~** автомобиль юлы

трасси́рование *с см.* **трасси́ровать**

трасси́ровать *сов., несов.* **1.** *что* юнәлешен билгеләү, трасса билгеләү **2.** эз калдырып очу, яктыртып очу (*снаряд, пуля турында*)

трассиро́вка *ж см.* **трасси́ровать**

трасси́рующ||ий -ая, -ее **1.** *прич. от* **трасси́ровать**; **2.** яктыртып очучы; **~ая пу́ля** яктыртып очучы пуля

тра́т||а *ж* **1.** *см.* **тра́тить**; **пуста́я ~а вре́мени** вакытны бушка үткәрү **2.** (*расход*) чыгым; **больши́е ~ы** зур чыгымнар

тра́тить *несов. что* тоту, түгү, кую, салу, сарыф итү; **~ де́ньги** акча тоту; **~ си́лы** көч салу (түгү)

тра́титься *несов.* **1.** *на кого-что, разг.* акча тоту, тоту, чыгымлану **2.** *страд. от* **тра́тить**

тра́улер *м см.* **тра́льщик**

тра́ур *м* **1.** (*состояние скорби*) матәм, траур **2.** (*одежда*) матәм киеме, кара-[кием]; **носи́ть ~** карадан киенү

тра́урн||ый -ая, -ое **1.** матәм ...ы, траур ...ы; **~ый ми́тинг** траур митингы; **~ый марш** матәм маршы; **~ая оде́жда** матәм киеме **2.** *перен.* кайгылы, траурлы; **~ое настрое́ние** кайгылы рух

трафаре́т *м* **1.** трафарет (*бизәк төшерә торган өлге, калып*) **2.** трафарет (*кисеп эшләнгән хәрефләр, цифрлар белән язылган язу*) **3.** *перен.* искергән үрнәк, таушалган өлге

трафаре́тный, -ая, -ое трафарет ..., трафарет ...ы, трафарет буенча эшләнгән; **~ рису́нок** трафарет рәсеме

трах 1. *межд.* гөрс; шап, шалт, шарт **2.** *в знач. сказ. прост.* шап, шалт итеп сукты, шап итеп сукты; **~ кулако́м по́ столу** йодрыгы белән шап итеп өстәлгә сукты

трахеи́т *м мед.* трахеит

трахе́я *ж анат.* трахея

тра́хнуть *сов. однокр. прост.* **1.** (*о звуке*) шарт итү, гөрс итү **2.** *кого-что и без доп.* шап итеп бәрү, шап итеп сугу; **~ по спине́** аркага шап итеп сугу

тра́хнуться *сов. прост.* шап итеп бәрелү (төшү, егылу); гөрс итеп егылу; ~ **об зе́млю** җиргә гөрс итеп егылу

трахо́ма *ж мед.* трахома (*йогышлы күз авыруы*)

трахомато́зный, -ая, -ое 1. *мед.* трахома ...ы; ~ **ви́рус** трахома вирусы 2. трахомалы; ~ **больно́й** трахомалы авыру

трахо́мный, -ая, -ое *см.* **трахомато́зный** 2

тре́бник *м* догалык, дога китабы

тре́бовани||е *с* 1. *в разн. знач.* таләп, сорау; **челове́к с высо́кими ~ями** югары таләпле кеше; **выдвига́ть ~я** таләпләр кую; **удовлетворя́ть** *чьи-л.* ~**я** *кемнең дә булса* таләпләрен үтәү; **по ~ю суда́** суд таләбе буенча; **дать све́дения по пе́рвому ~ю** беренче сораудан ук мәгълүматлар бирү 2. (*официальный документ*) требование, сорау язуы; **вы́писать ~е на то́пливо** ягулык алырга требование язу

тре́бовательность *ж* таләпчәнлек, таләп итүчәнлек

тре́бовательный, -ая, -ое 1. (*строгий*) таләпчән, таләп итүчән; ~ **командо́р** таләпчән командир 2. (*разборчивый*) талымлаучан, таләпчән; ~ **чита́тель** таләпчән укучы

тре́бовать *несов.* 1. *что, чего и с неопр.* таләп итү, сорау; ~ **объясне́ний** *у кого-л. кемнән дә булса* аңлатып бирүне таләп итү 2. *кого-чего* таләп итү, кирәк булу, мохтаж булу; **дом тре́бует ремо́нта** өйгә ремонт ясарга кирәк; **э́та боле́знь тре́бует лече́ния** бу авыру дәвалауны таләп итә 3. *кого-чего* (*вызывать*) чакыру, чакырту; ~ *кого-л.* **к нача́льнику** *кемне дә булса* начальникка чакырту

тре́б||оваться *несов.* 1. таләп ителү, кирәк булу; **заво́ду ~уются рабо́чие** заводка эшчеләр таләп ителә; **что и ~овалось доказа́ть** *безл.* шуны исбат итәргә кирәк иде дә 2. *страд. от* **тре́бовать** 1, 3

требуха́ *ж* эчәк-бавыр

трево́га *ж* 1. (*волнение*) курку, шом, шомлану, хафа, хафалану; тәшвиш, хәвеф 2. (*сигнал*) тревога; **возду́шная ~** һава тревогасы

трево́ж||ить *несов.* 1. *кого-что* (*волновать*) борчу, тынычсызлау, хәвефләндерү, хафалау, хафаландыру, тәшвишләндерү; **меня́ ~ит его́ опозда́ние** мине аның соңгаруы хафалый; **отца́ ~ило отсу́тствие пи́сем от сы́на** улыннан хат-хәбәр килмәү әтисен бик борчыды 2. *кого-что* (*нарушать покой*) комачаулау, борчу; **не ~ь его́** борчыма аны 3. *что* (*причинять боль*) аздыру, ярсыту; ~**ить ра́ну** яраны ярсыту

трево́ж||иться *несов.* 1. (*волноваться*) борчылу, тынычсызлану, хәвефләну, хафалану, шомлану, тәшвишләну 2. (*затруднять себя*) мәшәкатьләну, борчылу; **не ~ьтесь, я сам сде́лаю** мәшәкатьләнмәгез, мин үзем эшләрмен

трево́жн||ый, -ая, -ое 1. (*полный тревоги, волнения*) борчулы, хәвефле, шомлы, хафалы, хәвеф-хәтәрле, тәшвишле; ~**ый го́лос** шомлы тавыш 2. (*вызывающий тревогу*) борчулы; ~**ые све́дения** борчулы хәбәрләр 3. (*объявляющий тревогу*) тревога ...ы; ~**ый сигна́л** тревога сигналы

треволне́ние *с книжн.* борчылу, маза, тынычсызлык

трегла́в||ый, -ая, -ое 1. өч гөмбәзле; ~**ая це́рковь** өч гөмбәзле чиркәү 2. өч башлы (*әкиятләрдә*); ~**ый змей** өч башлы елан

тре́звенник *м разг.* (*аракы*) эчми торган кеше, аек кеше

трезве́ть *несов. прям., перен.* айну, айный төшү, айный бару

трезво́н *м* 1. (*звон во все колокола*) даң-доң, барлык кыңгыраулар(ны) (чаңнарны) кагу 2. *перен. разг.* (*пересуды, толки*) гайбәт, имеш-мимеш 3. *перен. разг.* (*шум, скандал*) гауга, җәнҗал, ыгы-зыгы

трезво́нить *несов.* 1. (*звонить во все колокола*) барлык кыңгыраулар(ны) (чаңнарны) кагу 2. *перен. что и без доп., разг.* (*распускать слухи*) гайбәт тарату, шалтырау, хәбәр тарату 3. *разг.* (*сильно звонить*) даң-доң итү, [бик нык] шалтырау

тре́звость *ж прям., перен.* аеклык, аек булу, аек акыл; ~ **рассужде́ний** фикер йөртүнең аеклыгы

тре́звый, -ая, -ое 1. (*не пьяный*) аек, айнык 2. (*не пьющий*) аракы эчми торган 3. *перен.* аек, аек акыллы; ~**ум** аек акыл; ~ **взгляд на собы́тия** вакыйгаларга аек караш

трезу́бец *м* өч япле, өч тешле (*сәнәк, якорь һ.б.ш.*)

трек *м спорт.* узышу юлы, трек

трель *ж* чут-чут итү, чутылдау; чыңчың итү, чыңлау; шылтырау; **соловьи́ная ~** сандугачның чут-чут итеп сайравы

трельяж *м* 1. (*зеркало*) өч бүлемтекле көзге, трельяж 2. (*решётка*) трельяж, рәшәткә (*үрмә гөл өчен*)

трена́ж *м* тренаж (*кунектергеч шөгыльләр системасы*)

тренажёр *м* тренажёр (*тренировка ясау җайланмасы*); **трениро́вка космона́втов на ~ах** космонавтларның тренажёрларда күнегүләре

тре́нер *м* тренер

тре́нерск||ий, -ая, -ое тренер[лар] ...ы, тренерлык ...ы; ~**ая рабо́та** тренерлык эше

тре́нзель *м* авызлык, авызлык чылбыры

тре́ни||е *с* 1. ышку, ышкылу; ~**е дета́лей** детальләрнең ышкылуы; **добыва́ть ого́нь ~ем** ышкып ут табу; **коэффицие́нт ~я** ышкылу коэффициенты; **си́ла ~я** ышкылу көче 2. *мн.* ~**я** *перен.* тынышмау, талаш, ызгыш, низаг

трениро́ванность *ж* өйрәтелгәнлек, өйрәнгәнлек, күнеккәнлек

трениро́ванный, -ая, -ое 1. *прич. от* **трениро́вать**; 2. күнеккән, өйрәнгән, өйрәтелгән; ~ **футболи́ст** күнеккән футболчы

трениро́вать *несов.* 1. *кого-что* өйрәтү; ~ **ю́ных фигури́стов** яшь фигурачыларны өйрәтү 2. *что* күнектерү, өйрәтү; ~ **па́мять** хәтерне күнектерү

трениро́ваться *несов.* 1. күнегү; өйрәнү, тренировка ясау; ~ **в бе́ге** йөгерергә өйрәнү 2. *страд. от* **трениро́вать**

трениро́вка *ж* күнекмә, күнегү, өйрәнү; ~ **по пла́ванию** йөзәргә өйрәнү

трениро́вочн||ый, -ая, -ое өйрәнү ...ы; күнегү ...ы, тренировка ...ы; өйрәнә (күнегә) торган; ~**ый костю́м** тренировка костюмы; ~**ая площа́дка** өйрәнү мәйданчыгы

трено́га *ж* 1. *см.* **трено́жник**; 2. (*путы*) тышау, кешән

трено́жить *несов. кого* кешәнләү, тышаулау

трено́жник *м* өчаяк, өчаяклы өстәл (*мәс. фотоаппаратны ныгытып куя өчен*)

тре́ньканье *с см.* **тре́ньканье**

тре́ньк||ать *несов. разг. на чём* деңгелдәтү, чиртү; ~ **на балала́йке** балалайканы чиртү

трепа́к *м* трепак (*русларда халык биюе*)

трепа́лка *ж*, **трепа́ло** *с* талкы

трепа́льн||ый, -ая, -ое талку ...ы, талкый торган; ~**ая маши́на** талку машинасы

трепа́льщик *м* талкучы

трепа́льщица *ж* талкучы хатын (кыз)

трепа́н *м* трепан (*хирургиядә сөяк тишү коралы*)

трепана́ция *ж мед.* трепанация, трепанациялә (*операция ясау өчен сөяк куышлыгын ачу*); ~ **че́репа** баш сөяген трепанациялә

трепа́нг *м зоол.* трепанг (*диңгез хайваны*)

трепа́ние *с см.* **трепа́ть** 6

трепани́ровать *сов., несов. кого-что, мед.* трепанация ясау, трепанациялә; ~ **больно́го** авыруга трепанация ясау

трёпан||ый, -ая, -ое 1. *спец.* талкыган, талкылган; ~**ый лён** талкыган җитен 2. *разг.* таушалган, тузган, ертылып беткән; ~**ая кни́га** тузган китап 3. *разг.* тузгыган, таралмаган; ~**ые во́лосы** тузгыган чәч

трепа́ть *несов.* 1. *что* туздыру, тузгыту; **ве́тер трепле́т во́лосы** җил чәчләрне тузгыта 2. *кого* (*дёргать, тормошить*) тарту, бору, йолку; ~ **за́ уши** колагын бору; ~ **за́ волосы** чәчтән тарту 3. *кого-что, разг.* (*похлопывать*) кагу, шапылдату, шапылдатып сөю; ~ **по плечу́** җилкәсеннән шапылдатып сөю 4. *что* туздыру, таушалдыру; теткәләп бетерү, эштән чыгару; ~ **кни́ги** китапларны таушалдыру 5. *кого, разг.* калтырату, дерелдәтү; **его́ тре́плет лихора́дка** аны бизгәк дерелдәтә 6. *спец.* (*очищать, раздёргивая волокно*) тетү, талку; ~ **конопли́** киндер талку ♦ ~ **не́рвы** *кому* кан бозу, теңкәгә тию; ~ **языко́м** чүбек чәйнәү

трепа́ться *несов.* 1. (*развеваться*) җилфердәү, җилбердәү, тузгу 2. *разг.* (*изнашиваться*) таушалу, тетелү, тузу, эштән чыгу 3. *прост.* чүбек чәйнәү, юк-барны сөйләү

ТРЕ-ТРЁ

трепа́ч *м прост.* лыгырдавык, лыгырдык, чүбек чәйнәүче

тре́пет *м* **1.** селкенү, тирбәлү; **~ ли́стьев** яфракларның селкенүе **2.** *перен.* (*куркудан яки дулкынланудан*) дерелдәү, тетрәү, тетрәну, калтырау, калтырап тору, калтырану, кот очып тору

трепета́ние *с см.* **тре́пет**

трепета́ть *несов.* **1.** (*колебаться, дрожать*) селкенү, җилфердәү, җилбердәү, тирбәлү; **ли́стья трепе́щут от сла́бого дунове́ния ве́тра** әкрен генә искән җилдән яфраклар селкенә **2.** (*испытывать сильное волнение*) дулкынлану, тетрәп тору, дерелдәү, тетрәү, калтырау, калтырану; **~ всем те́лом** бөтен тәне белән калтырау; **~ от у́жаса** куркудан дерелдәп тору; **се́рдце трепе́щет** йөрәк дулкынлана **3.** *за кого-что и без доп.* (*тревожиться*) калтырау, калтырап тору, борчылу, тынычсызлану; **~ за свои́х дете́й** үз балаларын өчен калтырап тору **4.** *перед кем-чем, при ком-чём* (*испытывать страх, ужас*) курку, калтырап тору, кот очып тору

тре́петн||ый, -ая, -ое **1.** (*дрожащий, колеблющийся*) лепелдәп торган, җилфердәп торган, тирбәлеп торган, тетрәүле; **~ый огоне́к свечи́** шәмнең тирбәлеп торган уты **2.** (*взволнованный*) дулкынланган, дулкынланып ...; **~ое ожида́ние** дулкынланып көтү

трёпк||а *ж* **1.** *см.* **трепа́ть** 1-4, 6; **2.** *прост.* (*наказание, побои*) тукмау, арт сабагын укыту; **зада́ть ~у** *кому-л. бергә кешегә* арт сабагын укыту ♦ **~а не́рвов** һәрвакыт нервыга тиеп тору

трепыха́ние *с см.* **трепыха́ть, трепыха́ться**; **~ ра́неной пти́цы** җәрәхәтләнгән кошның тыпырчынуы

трепыха́ть *несов. см.* **трепыха́ться**; **отча́янно ~ кры́льями** өзгәләнеп канатларын сугып тыпырчыну

трепыха́||ться *несов. разг.* **1.** (*судорожно дёргаться*) тыпырчыну, тыпырчынып яту, бәргәләнү; **ры́ба ~ется на берегу́** балык яр буенда тыпырчынып ята **2.** (*дрожать, трепетать в воздухе*) җилфердәү, лыпылдау, селкенү; **парусá ~ются** җилкәннәр лыпылдый; **занаве́ски ~лись от ве́тра** җилдән тәрәзә пәрдәләре селкенә иде

треск *м* **1.** чатнау [тавышы], шартлау, шарт-шорт итү, шатыр-шотыр килү, чатырдау, шатырдау; **~ су́чьев** ботакларның шарт-шорт итүе **2.** *перен. разг.* (*шумиха*) шау-шу, шапырыну ♦ **с ~ом прова́литься** хур булу, адәм көлкесенә калу

треска́ *ж* тәрәч, тәрәч балыгы

тре́скание *с см.* **тре́скаться I**; **~ льда** боз ярылу

тре́ска||ться I *несов.* чатнау, ярылу, шартлау; **потоло́к ~ется** түшәм чатный

тре́скаться II *несов.см.* **тре́снуться**

трескó||вый, -ая, -ое тәрәч ...ы; **~ая пе́чень** тәрәч бавыры; **~ое филе́** тәрәч филесе

трескотня́ *ж разг.* **1.** (*непрерывный треск*) шатырдау, шатыр-шотыр итү, шарт-шорт килү; **~ пулемётов** пулемётлар шатырдавы **2.** *перен.* (*болтовня*) такылдау, туктаусыз сөйләү, лыгырдау, юк-бар сүзләр сөйләү

тресну́||вший, -ая, -ее яңгыравыклы, шапырынулы; **~ие фра́зы** шапырынулы сүзләр ♦ **~ий моро́з** чатлама суык

тре́снут||ый, -ая, -ое чатнаган, шартлаган, ярылган; **~ая ча́шка** чатнаган чынаяк

тре́сн||уть *сов.* **1.** *однокр.* шарт итү; **вдруг ~ла ве́тка** кинәт ботак шарт итте **2.** ярылу, чатнау, шартлау; **стака́н ~ул** стакан чатнады **3.** (*потрескаться*) ярылу; **ко́жа на рука́х ~ула** кулның тиресе ярылды **4.** *кого, чем по чему, прост.* сугу, кундыру, тондыру; **~уть кулако́м по́ столу** өстәлгә йодрык белән сугу ♦ **хоть ~и** *прост.* шартласаң да (*булмый*); **хоть ~и, не дам** шартласаң да бирмим

тре́снуться *сов. прост.* бәрелү; сугылу; **~ лбом о де́рево** маңгай белән агачка бәрелү

трест *м* трест (**1.** *бер типтагы предприятиеләр берләшмәсе* **2.** *берничә предприятиенең монополистик берләшмәсе*)

трста́ *ж с.-х.* талкынмаган җитен, талкынмаган киндер

тре́стовский, -ая, -ое *эк.* трест ...ы; **~ капита́л** трест капиталы

третье́йский: ~ суд третейский суд (*бәхәсле, конфликт эшне өченче, битараф якның хәл итүе*)

тре́т||ий, -ья, -ье **1.** *числ.* өченче; **~ье число́ ме́сяца** айның өченче көне **2.** (*беспристрастный*) битараф, бер яклы да булмаган; **он в э́том де́ле ~ья сторона́** бу эштә ул битараф кеше **3.** (*одна треть чего-л.*) өчтән ...; **~ья часть** өчтән берсе **4.** *в знач. сущ.* **~ье** *с* (*сладкое блюдо*) өченче, өченче ризык; **на ~ье — компо́т** өченчегә — компот ♦ **из ~ьих рук** (*получить*) башка берәүләрдән (*алу*), кеше аркылы; **~ий звоно́к** өченче звонок; **~ьего дня** өченче көн; **~ье лицо́** *грам.* өченче зат; **~ья ско́рость** өченче тизлек

третирова́ть *несов. кого-что* кимсетү, түбәнсетү, кимсетеп карау

третья́||ший, -ая, -ее өченче, өченчел; **~ый пери́од боле́зни** авыруның өченче периоды; **~ая эпо́ха** *геол.* өченчел дәвер

треть *ж* өчтән бер, өчтән бер өлеш; **~ рабо́ты** эшнең өчтән бер өлеше

третье- *кайбер кушма сүзләрнең береченче кисәге, татар теленә «өченче» сузе белән тәрҗемә ителә, мәс.* **третьесо́ртный** өченче сортлы; **третьеразря́дный** өченче разрядлы

третьекла́ссник *м* өченче сыйныф укучысы

третьекла́ссница *ж* өченче сыйныфта укучы кыз

третьеку́рсник *м* өченче курста укучы

третьеку́рсница *ж* өченче курста укучы кыз

третьестепе́нный, -ая, -ое өченче дәрәҗәдәге, артык мөһим булмаган; уртача, урта кул; **~ актёр** уртача кул актёр

треуго́льник *м* **1.** *мат.* өчпочмак; **прямоуго́льный ~** турыпочмаклы өчпочмак; **равносторо́нний ~** тигезьяклы өчпочмак **2.** *разг.* (*предприятиедә, учреждениедә*) өчпочмак (*директор, парторг, профорг*)

треуго́льн||ый, -ая, -ое өчпочмаклы, өчпочмак формасындагы; **~ая площа́дка** өчпочмак формасындагы мәйданчык

треу́х *м* колакчын бүрек, колаклы бүрек, колакчынлы бүрек

тре́фовый, -ая, -ое *карт.* треф ...ы; **~ коро́ль** треф короле

тре́фы *мн. карт.* треф

трёх- *кайбер кушма сүзләрнең береченче кисәге, татар теленә «өчле», «өч» диган сүзләр белән тәрҗемә ителә, мәс.* **трёхдне́вный** өч көнлек

трёха́ктн||ый, -ая, -ое өч пәрдәлек..., өч пәрдәле; **~ая коме́дия** өч пәрдәлек комедия

трёхба́лльн||ый, -ая, -ое **1.** өч баллы; **~ый ве́тер** өч баллы җил **2.** өч баллга нигезләнгән; **~ая систе́ма** өч баллга нигезләнгән система

трёхгоди́чн||ый, -ая, -ое өч ел ...; өч еллык ...; **~ый срок** өч еллык срок; **~ое пребыва́ние** өч ел тору

трёхгодова́лый, -ая, -ое *см.* **трёхле́тний** 2

трёхголо́сн||ый, -ая, -ое *муз.* өч тавышлы, өч тавыш өчен язылган; **~ая фу́га** өч тавыш өчен язылган фуга

трёхгра́нный, -ая, -ое өч кырлы; **~ у́гол** өч кырлы почмак

трёдне́вный, -ая, -ое өч көнлек ..., өч көн ...; **в ~ срок** өч көн эчендә

трёхдюймо́вка *ж* **1.** *уст.* (*полевое орудие*) өч дюймлы орудие **2.** (*доска*) өч дюймлы такта

трёхдюймо́вый, -ая, -ое **1.** өч дюйм калибрлы **2.** өч дюйм калынлыктагы (киңлектәге, биеклектәге)

трёхзна́чн||ый, -ая, -ое өч урынлы; **~ое число́** өч урынлы сан

трёхкилометро́вый, -ая, -ое өч километрлы, өч километр озынлыгындагы

трёхколёсный, -ая, -ое өч тәгәрмәчле, (көпчәкле); **~ велосипе́д** өч тәгәрмәчле велосипед

трёхкопе́ечн||ый, -ая, -ое өч тиенлек ..., өч тиенле; **~ая моне́та** өч тиенлек акча

трёхкра́тн||ый, -ая, -ое өч тапкыр ...; **~ый чемпио́н ми́ра** өч тапкыр дөнья чемпионы; **плати́ть в ~ом разме́ре** өч тапкыр арттырып түләү

трёхле́тие *с* **1.** (*срок*) өч ел **2.** (*годовщина*) өч еллык, өч ел тулу

трёхле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) өч еллык ...; **~ план** өч еллык план **2.** (*о возрасте*) өч яшьлек ...; **~ ребёнок** өч яшьлек бала

трёхле́ток *м разг.* өч яшьлек (*тай, тана h.б.ш.*)

трёхлине́йн||ый, -ая, -ое өч линияле, калибры өч линияле; **~ая винто́вка** өч линияле винтовка

трёхма́чтовый, -ая, -ое өч мачталы; **~ кора́бль** өч мачталы корабль

трёхме́рный, -ая, -ое **1.** өч үлчәүле, өч үлчәнешле (*озынлыгы, киңлеге, биек-*

леге булган) 2. *муз.* өчкә бүленә торган; ~ **такт** өчкә бүленә торган такт

трёхме́стн||ый, -ая, -ое өч урынлы, өч кешелек ...; ~**ая каю́та** өч урынлы каюта

трёхме́сячный, -ая, -ое өч айлык ..., өч айга сузылган; ~ **о́тпуск** өч айлык ял; ~ **ребёнок** өч айлык бала

трёхнеде́льный, -ая, -ое өч атналык..., өч атнага сузылган; ~ **о́тпуск** өч атналык ял

трёхно́гий, -ая, -ое *разг. см.* **трено́гий**

трёхпа́лый, -ая, -ое өч бармаклы

трёхпо́ле *с с.-х.* өч басу, өч басулы чәчү әйләнеше

трёхпо́льный, -ая, -ое *с.-х.* өч басулы; ~ **севообора́т** өч басулы чәчү әйләнеше

трёхпроце́нтный, -ая, -ое *в разн. знач.* өч процентлы; ~ **заём** өч процентлы заем; ~ **раство́р** өч процентлы эремә

трёхра́зов||ый, -ая, -ое өч мәртәбә[ле]; ~**ое пита́ние** өч мәртәбә ашату

трёхрублёвка *ж разг.* өчлек, өч тәңкәлек

трёхря́дка *ж прост.* өч рәтле гармун

трёхсло́жн||ый, -ая, -ое өч иҗекле; ~**ое сло́во** өч иҗекле сүз

трёхсме́нн||ый, -ая, -ое өч сменалы; ~**ая рабо́та** өч сменалы эш

трёхсотле́тие *с* 1. (*срок*) өч йөз ел 2. (*годовщина*) өч йөз еллык, өч йөз ел тулу; ~ **го́рода** шәһәрнең өч йөз еллыгы

трёхсотле́тний, -яя, -ее 1. (*о сроке*) өч йөз ел ... 2. (*о годовщине*) өч йөз еллык ...; ~ **юбиле́й** өч йөз еллык юбилей

трёхсо́тый, -ая, -ое *числ.* өч йөзенче

трёхство́лка *ж* өч көпшәле мылтык

трёхство́рчатый, -ая, -ое өч бүлемтекле, өч капкачлы, өч ишекле; ~ **шкаф** өч ишекле шкаф

трёхсто́пный, -ая, -ое *лит.* өч буынлы, өч стопалы; ~ **стих** өч буынлы шигырь

трёхсторо́нний, -яя, -ее 1. (*с тремя сторонами*) өч яклы 2. (*с участием трёх сторон*) өч яклы, өч як катнашкан; ~ **договор** өч як катнашкан килешү

трёхстру́нн||ый, -ая, -ое өч кыллы; ~**ая балала́йка** өч кыллы балалайка

трёхступе́нчат||ый, -ая, -ое өч баскычлы, өч киртләчле; өч буынлы; ~**ая раке́та** өч буынлы ракета

трёхсу́точный, -ая, -ое өч тәүлекле

трёхта́ктный, -ая, -ое *муз., тех.* өч тактлы

трёхто́мник *м* өч томлык (*басма*)

трёхто́мный, -ая, -ое өч томлы

трёхто́нка *ж разг.* өч тонналы йөк автомашинасы

трёхто́нный, -ая, -ое өч тонналы; ~ **груз** өч тонналы йөк

трёхты́сячный, -ая, -ое 1. *числ.* өч меңенче; ~ **но́мер** өч меңенче номер 2. (*стоимостью в три тысячи*) өч мең сумлык ..., өч меңлек ... 3. (*состоящий из трёх тысяч единиц*) өч меңлек ...; өч меңнән бер...; ~ **отря́д** өч меңлек отряд

трёхфа́зный, -ая, -ое *эл.* өч фазалы; ~ **трансформа́тор** өч фазалы трансформатор; ~ **ток** өч фазалы ток

трёхцве́тн||ый, -ая, -ое өч төстәге, өч төрле төстәге; ~**ое зна́мя** өч төрле төстәге байрак

трёхчасово́й, -а́я, -о́е 1. өч сәгатьлек ...; ~ **докла́д** өч сәгатьлек доклад 2. өч сәгатьтә китә (килә) торган; ~ **по́езд** сәгать өчтә килә торган поезд

трёхчлен *м мат.* өчбуын; **квадра́тный** ~ квадратлы өчбуын

трёхчле́нн||ый, -ая, -ое *мат.* өчбуынлы, өч буыннан торган; ~**ое управле́ние** өчбуынлы тигезләмә

трёхязы́чн||ый, -ая, -ое 1. өч телле, өч телдә төзелгән; ~**ый слова́рь** өч телдә төзелгән сүзлек 2. өч телле, өч телдә сөйләшә торган; ~**ое населе́ние** өч телдә сөйләшә торган халык

трёхэта́жный, -ая, -ое өч катлы, өч этажлы; ~ **дом** өч катлы өй

трещ||а́ть *несов.* 1. шатырдау, шытырдау, шарт-шорт килү, чытырдау; лёд ~**и́т** боз шатырдый 2. черелдәү; ~**а́т кузне́чики** чикерткәләр черелди 3. *перен. разг.* (*болтать*) лыкылдау, лыгырдау, такылдау, күп сөйләү ♦ **де́ло** ~**и́т по всем швам** эш жимерелеп бара

тре́щина *ж* 1. ярык, ярылган (чатнаган) урын; ~ **в стене́** стенадагы ярык 2. *перен.* ара бозылу; **в их отноше́ниях образова́лась** ~ аларның аралары бозылды

трещо́тка *ж* 1. (*сторожа*) шакылдавык; (*детская игрушка*) шалтыравык 2. *перен.* (*болтун, болтунья*) лыкылдык, лыгырдык, шалтыравык, ярык барабан

три *числ.* өч, өч саны

триа́да *ж книжн.* триада (*өч кисәктән (өлештән) гыйбарәт булган бердәмлек*)

трибу́н *м* трибун; **наро́дный** ~ халык трибуны

трибу́н||а *ж прям., перен.* трибуна; ~**ы стадио́на** стадионның трибуналары; **подня́ться на** ~**у** трибунага менү; **газе́та — по́длинная** ~ **общества́ мне́ния** газета — чын-чынлап иҗтимагый фикер трибунасы

трибунал *м* трибунал (*гадәттән тыш суд органы*); **вое́нный** ~ хәрби трибунал

тривиа́льность *ж книжн.* күп чәйнәлгәнлек, күп тапталганлык

тривиа́льн||ый, -ая, -ое *книжн.* күп чәйнәлгән, күп тапталган; ~**ая мысль** күп чәйнәлгән фикер

тригонометри́ческ||ий, -ая, -ое тригонометрия ...ы, тригонометрик; ~**ие фу́нкции** тригонометрик функцияләр

тригономе́трия *ж* тригонометрия

тридева́т||ый, -ая, -ое: **в** ~**ом ца́рстве** *фольк.* бик ерактагы бер патшалыкта

три́девять: за ~ **земе́ль** *фольк.* бик еракта, җир читендә (*әкиятләрдә*)

тридцатиле́тие *с* 1. (*срок*) утыз ел 2. (*годовщина*)утыз еллык, утыз ел тулу

тридцатиле́тний, -яя, -ее 1. (*о сроке*) утыз еллык 2. (*о возрасте*) утыз яшьлек, утыз яшьтәге

три́дцать *числ.* утыз; **ему́ за** ~ ул утыздан узган

триеди́н||ый, -ая, -ое өч өлештән торган, өч яклы, өч нәрсәдән гыйбарәт; ~**ая зада́ча** өч нәрсәдән гыйбарәт бурыч

три́ер *м с.-х.* триер

триерова́ть *несов. что, с.-х.* триерлау, триердан үткәрү, триерда чистарту

три́жды *нареч.* өч тапкыр (мәртәбә, кат), өч җирдә; ~ **три — де́вять** өч җирдә өч — тугыз була

трико́ *с нескл.* трико (1. *элмәклән бәйләнгән тукыма* 2. *бәйләнгән тукымадан тәнгә сыланып тора торган итеп тегелган костюм* 3. *хатын-кызларның эчке трикотаж ыштаны*)

трикота́ж *м* трикотаж (*тукыма һәм шуннан эшләнгән әйберләр*)

трикота́жн||ый, -ая, -ое 1. трикотаж ...ы; ~**ая фа́брика** трикотаж фабрикасы 2. трикотаж ..., трикотаждан эшләнгән; ~**ое бельё** трикотаж эчке кием; **ве́рхние** ~**ые изде́лия** өске трикотаж әйберләр

трили́стник *м бот.* тукранбаш

триллио́н *м* триллион

трило́гия *ж* трилогия (*бер үк авторның сюжет һәм төп фикер ягыннан берберсе белән бәйләнешле булган өч әсәре*)

трина́дцатый, -ая, -ое *числ.* унөченче

трина́дцать *числ.* унөч

три́о *с нескл.* трио; **вока́льное** ~ вокаль трио; ~ **баяни́стов** баянчылар триосы

три́ппер *м мед.* триппер (*венерик авыруның бер төре*)

три́птих *м* триптих (1. *иск. идеясе ягыннан берләштерелгән өч картина, сурәт һ.б.ш.* 2. *лит. төп фикер ягыннан бәйләнешле өч шигырьдән торган поэтик әсәр*)

три́ста *числ.* өч йөз

трито́н *м* тритон (*җир-су хайваны*)

триу́мф *м* триумф, тантана; казаныш

триумфа́льный, -ая, -ое триумф ...ы; тантаналы, триумфаль

тро́гательность *ж* тәэсирлелек, кызганучанлык, күңелне дулкынландыра торган булу

тро́гательн||ый, -ая, -ое күңелне дулкынландыра торган, дулкынландыргыч, күңелне йомшарта (эретә) торган; ~**ый расска́з** күңелне йомшарта торган хикәя; **прояви́ть** ~**ую забо́тливость** дулкынландыргыч кайгыртучанлык күрсәтү

тро́га||ть *несов.* 1. *кого-что* (*прикасаться*) тию, кул тидерү, кагылу, орыну, тоту, тотыну; җиңелчә генә бәрелү; **рука́ми не** ~**ть!** кул белән тотмаска! 2. *что, разг.* (*брать, пользоваться*) кагылу, орыну, тию; рөхсәтсез тотыну; **нельзя́** ~**ть чужи́е ве́щи** кеше әйберенә кагылырга ярамый 3. *кого-что* (*обижать, приставать*) тию, кагылу, орыну; **не** ~**й его́, он расстро́ен** тимә син аңа, аның кәефе юк; **никто́ его́ не** ~**л** аңа беркем дә тигәне юк 4. *что* (*едва обнаруживаться*) ...п алу, ...п кую; аз гына белену, күренә башлау; **сла́бая улы́бка** ~**ет её гу́бы** аның иреннәре җиңелчә генә елмаеп куя; **седина́ уже́** ~**ет виски́**

аның чигәләрендә ак чәчләр күренә башлаган **5.** *перен. кого-что* (*вызывать сочувствие*) күңел эретү (йомшарту), тәэсир итү, дулкынландыру, кызгандыру; **~ть расска́зом** сөйләп дулкынландыру **6.** (*начинать движение*) кузгалу, кузгалып китү; **ло́шади ~ют** атлар кузгала; **ну, ~й!** кузгал! әйдә киттек!

тро́га||ться *несов.* **1.** (*умиляться*) күңел эрү (йомшару), тәэсирләнү, дулкынлану; кызгану, жәлләү; **~ться до слёз** күздән яшьләр килгәнче тәэсирләнү **2.** (*начинать движение*) кузгалу, чыгу, кузгалып (чыгып) китү; **~ться в путь** юлга чыгып китү; **по́езд ~ется** поезд кузгала **3.** *страд. от* **тро́гать** 1-3

троглоди́т *м* троглодит (**1.** *борынгы мәгарәләрдә яшәгән кеше* **2.** *перен. тупас, культурасыз кеше*)

тро́е *числ. собир.* өч, өчәү; **не спать ~ су́ток** өч тәүлек йокламау

троебо́рье *с спорт.* өч төр ярыш, өч төрле ярыш

троежёнец *м* өч хатынлы кеше

троежёнство *с* өч хатынлы булу, өч хатын белән тору

троекра́тн||ый, -ая, -ое өч тапкыр; **~ое напомина́ние** өч тапкыр кабатлап әйтү

тро́ечник *м разг.* өчкә укучы

тро́ечница *ж разг.* өчкә укучы кыз

трои́т||ься *несов.* өчкә аерылу, өч булып күренү; **у него́ ~ся в глаза́х** аның күзенә өч булып күренә

тро́йка *ж* **1.** (*цифра, количество*) өч **2.** (*группа из трёх единиц*) өч, өчәү **3.** өченче (*троллейбус, трамвай һ.б.ш.*) **4.** (*оценка*) өчле **5.** *карт.* өчле

тройни́к *м* өчле, өчәрләнгән (*өч япьле көпшә, өч япьле кармак, өч тармаклы, өч катлы, өчәрләп эшләнгән нәрсә*)

тройни́чный, -ая, -ое: **~ нерв** *анат.* өч тармаклы нерв

тройн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*втрое больше*) өч тапкыр артык, өч мәртәбә күп, өчләтә ...; **в ~о́м разме́ре** өчләтә [зурлыкта] **2.** (*состоящий из трёх частей*) өч катлы, өч бүлекле, өч бүлектән гыйбарәт булган; **~ы́е ра́мы** өч катлы рам ♦ **~о́е пра́вило** *мат.* өчле кагыйдә; **~о́й одеколо́н** тройной одеколон

тро́йн||я *ж* өч игез бала; **роди́ть ~ю** өч игез бала табу

тройня́шка *ж прост.* (*близнец*) өч игез баланың берсе

тро́йственность *ж* өчлелек, өч элементтан гыйбарәт булганлык

тро́йственн||ый, -ая, -ое **1.** *см.* **тро́йкий; 2.** (*заключённый тремя сторонами*) өчле, өчлекле, өч дәүләт ...ы; **~ое соглаше́ние** өчлекле килешү; **~ый сою́з** өч дәүләт союзы

тролле́йбус *м* троллейбус

тролле́йбусный, -ая, -ое троллейбус[лар] ...ы; **~ парк** троллейбус[лар] паркы

тромб *м мед.* тромб (*кан тамырында оешкан кан*)

тромбо́з *м мед.* тромбоз (*кан тамырларында кан оешу авыруы*)

тромбо́н *м* тромбон (*музыка коралы*)

тромбони́ст *м* тромбончы, тромбонда уйнаучы

тромбофлеби́т *м мед.* тромбофлебит

трон *м* тәхет; **вступи́ть на ~** тәхеткә утыру, патшалык итә башлау

тро́нн||ый, -ая, -ое тәхет ...ы; **~ый зал** тәхет залы ♦ **~ая речь** тәхет нотыгы (*монархның тантаналы очракларда сөйләгән нотыгы*)

тро́ну||ть *сов.* **1.** *см.* **тро́гать; 2.** *что* (*попортить*) тию, алу, зарар китерү; **моро́з ~л дере́вья** агачларны салкын алган; **за́суха не ~ла урожа́я** корылык уңышка зарар китермәде

тро́нуться *сов.* **1.** *см.* **тро́гаться** 1, 2; **2.** *перен. разг.* (*помешаться*) акыл зәгыйфьләнү, акылдан язу

троп *м лит.* троп, киная

тропа́ *ж* сукмак; **го́рная ~** тау сукмагы

тро́пик *м* **1.** тропик (*экваторга параллель һәм аннан төньякка яки көньякка 23°27′ ераклыкта булган уйланма тугәрәк*) **2.** *мн.* **~и** тропиклар (*экватор белән шул тугәрәк арасындагы иң эссе җир*)

тропи́нка *ж* сукмак, тар сукмак; **лесна́я ~** урман сукмагы

тропи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** тропик ...,тропиктагы; **~ие стра́ны** тропиктагы илләр **2.** (*свойственный тропикам*) тропик..., тропикларга хас; **~ий кли́мат** тропик климат

тропосфе́ра *ж астр.* тропосфера (*Җир атмосферасының стратосферага кадәр булган түбәнге катлавы*)

трос *м* трос; аркан; **букси́рный ~** буксирлау тросы

тростни́нка *ж* камыш, камыш сабагы

тростни́к *м* камыш ♦ **са́харный ~** шикәр камышы

тростнико́в||ый, -ая, -ое **1.** камыш ...ы; **~ые за́росли** камыш куаклыгы **2.** (*сделанный из тростника*) камыш ..., камыштан ясалган; **~ая кры́ша** камыш түбә

тро́сточка, трость *ж* кул таягы, таяк

троти́л *м* тротил (*шартлаучан матдә*)

тротуа́р *м* тротуар (*җәяүлеләр юлы*); **широ́кий ~** киң тротуар

трофе́й *м* трофей, ганимәт

трофе́йн||ый, -ая, -ое трофей ...ы; ганимәт ...; **~ое ору́жие** трофей кораллары

троюро́дный, -ая, -ое өч туган (*өченче буын буенча кардәш булган*); **~ брат** өч туган абый [эне]

троя́кий, -ая, -ое өч төрле, өч яклы; **~ смысл** өч төрле мәгънә

труба́ *ж* **1.** торба, көпшә; моржа; **водопрово́дная ~** водопровод торбасы; **водосто́чная ~** су агызу торбасы; **печна́я ~** мич моржасы **2.** *муз.* быргы, труба **3.** *анат.* көпшә; **евста́хиева ~** евстахий көпшәсе (*колак белән борын-йоткылык куышлыгын тоташтыручы көпшә*) **4.** *в знач. сказ. прост.* начар, харап; **де́ло — ~** эшләр харап

трубаду́р *м* җырчы, җырчы-шагыйрь (*урта гасырда көньяк Франциядә*)

труба́ч *м* трубачы, трубада уйнаучы, быргычы

труб||и́ть *несов.* **1.** *во что* уйнау; кычкырту; **~и́ть в трубу́** труба кычкырту; **~и́ть в рог** бырга кычкырту **2.** кычкырту; **тру́бы ~я́т** трубалар кычкырта **3.** *что, воен.* трубада уйнап сигнал бирү; **~и́ть сбор** трубада уйнап җыелырга сигнал бирү **4.** *перен., о ком-чём, прост.* (*разглашать*) шаулау, шаулап йөрү, кычкырып йөрү

тру́бк||а *ж* **1.** *уменьш. от* **труба́** 1; **рези́новая ~а** резин көпшә **2.** торба; **свернýть чертёж в ~у** сызымны торба ясап төреп кую **3.** (*курительная*) трубка **4.** (*телефонная*) трубка, телефон трубкасы

тру́бный, -ая, -ое **1.** торба ...ы, көпшә ...ы; моржа ...ы; **~ дым** моржа төтене **2.** труба ...ы, бырга ...ы; **~ звук** труба тавышы

трубопрово́д *м* трубопровод; үткәргеч труба; **прокла́дка ~а** трубопровод үткәрү

трубопрово́дн||ый, -ая, -ое трубопровод ...ы; **~ые рабо́ты** трубопровод эшләре

трубопрово́дчик *м* трубопроводчы, трубопровод эшчесе

трубопрока́тный, -ая, -ое трубалар прокатлау ...ы, трубалар ясый торган

трубоукла́дчик *м* трубалар салучы кран

трубочи́ст *м* моржа (торба) тазартучы (чистартучы)

тру́бчатый, -ая, -ое **1.** (*в форме трубки*) трубкасыман, көпшәсыман **2.** (*сделанный из трубок*) трубалы

труд *м* **1.** хезмәт; **у́мственный ~** акыл хезмәте; **физи́ческий ~** физик хезмәт; **производи́тельность ~а́** хезмәт җитештерүчәнлеге **2.** (*работа, занятие*) эш; **тяжёлый ~** авыр эш **3.** (*усилие*) эшләү, көч түгү, көч; **напра́сный ~** файдасызга көч түгү; **положи́ть мно́го ~а́** бик күп көч кую; **с ~о́м** (*сделать что-л.*) көчкә-көчкә, чак-чак кына **4.** (*произведение*) әсәр, хезмәт; **нау́чные ~ы́** гыйльми хезмәтләр ♦ **сизи́фов ~** сизиф эше (*бетмәс-төкәнмәс файдасыз эш турында*)

труди́ться *несов.* **1.** эшләү, хезмәт итү; **~ с утра́ до ве́чера** иртәдән кичкә кадәр эшләү **2.** *над чем* эшләү, көч кую (түгү); **~ над перево́дом** тәрҗемә өстендә эшләү **3.** (*затруднять себя*) мәшәкатьләнү; **он напра́сно тру́дится** ул юкка мәшәкатьләнә

тру́дно *нареч. и в знач. сказ. безл.* авыр, кыен, читен; **в э́то ~ пове́рить** моңа ышануы кыен; **его́ ~ поня́ть** аны аңлавы авыр

трудновоспиту́ем||ый, -ая, -ое тәрбияләргә авыр..., тәрбияләргә авыр булган; **~ые де́ти** тәрбияләргә авыр булган балалар

труднодосту́пн||ый, -ая, -ое юлы (барырга, менәргә, керергә) кыен булган; **~ые го́рные райо́ны** барырга кыен булган таулы районнар

труднопроходи́м||ый, -ая, -ое үтәргә кыен булган; **~ая ме́стность** үтәргә кыен булган урын

тру́дност||ь *ж* **1.** авырлык, кыенлык, читенлек; мәшәкать; **~ь пути́** юлның

авырлыгы; **~ь вопро́са** мәсьәләнең читенлеге 2. *обычно мн.* **~и** авырлыклар, кыенлыклар; **не боя́ться ~ей** кыенлыклардан курыкмау

тру́дн||ый, -ая, -ое 1. авыр, кыен, читен; **~ая рабо́та** авыр эш; **~ый вопро́с** авыр мәсьәлә 2. авыр; **~ое положе́ние** авыр хәл; **~ый день** авыр көн 3. мәшәкатьле; **~ый ребёнок** мәшәкатьле бала 4. (*о болезни, больном*) куркыныч, авыр

трудов||о́й, -а́я, -о́е 1. эш ...ы, хезмәт ...ы; **~о́й проце́сс** эш процессы; **~о́й стаж** хезмәт стажы; **~о́й семе́стр** хезмәт семестры; **~о́й по́двиг** хезмәт батырлыгы; **~о́е воспита́ние** хезмәт тәрбиясе 2. хезмәт ...ы, хезмәтчел, эшләп көн күрә торган; **~о́й наро́д** хезмәтчел халык, хезмәт халкы 3. эшләп (хезмәт итеп) тапкан; **~ы́е де́ньги** эшләп тапкан акча ♦ **~а́я кни́жка** хезмәт кенәгәсе

трудоде́нь *м* (*1966 елга кадәр*) хезмәт көне

трудоёмк||ий, -ая, -ое авыр, күп көч куюны таләп итә торган; **механиза́ция ~их рабо́т** авыр эшләрне механизацияләү

трудоёмкость *ж* бик күп көч куюны таләп итү

трудолюби́в||ый, -ая, -ое хезмәтчел, хезмәт сөючән; эш сөючән, эш ярата торган, эшчән; **~ая де́вушка** эш сөючән кыз

трудолю́бие *с* хезмәт сөючәнлек, эш ярату, эш сөю

трудоспосо́бност||ь *ж* хезмәткә (эшкә) сәләтлелек, эшкә яраклылык; **утра́та ~и** эшкә яраклылыкны югалту

трудоспосо́бн||ый, -ая, -ое хезмәткә (эшкә) сәләтле, эшкә яраклы; **~ое населе́ние** эшкә яраклы халык

трудоустро́йство *с* эшкә урнашу (керү); **~ молодёжи** яшьләрнең эшкә урнашуы

трудя́щ||ийся, -аяся, -еюся 1. *прич. от* **труди́ться**; 2. хезмәт ...ы, хезмәт итүче, хезмәтчел, эшләүче; **~иеся ма́ссы** хезмәт ияләре 3. *в знач.сущ.* **~ийся** *м* хезмәтчән, хезмәт иясе; **~иеся го́рода и дере́вни** шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәре

тру́женик *м* эшчән, хезмәтчән

тру́женица *ж* эшчән хатын (кыз)

труп *м* үлек, мәет (*кеше турында*); үләксә (*хайван турында*) ♦ **переступи́ть (перешагну́ть) че́рез** *чей* **~** мәет аша атлау (*уз максатына ирешү өчен кеше гомерен кызганмау*)

тру́пный, -ая, -ое үлек ...ы, мәет ...ы; үләксә ...ы; **~ за́пах** үләксә исе

тру́ппа *ж* труппа; **гастро́льная ~** гастроль труппасы

трус *м* куркак, куян йөрәк, куркак жан ♦ **~а пра́здновать** шүрләү, курку

тру́сики *мн. см.* **трусы́**

тру́сить *несов.* 1. (*быть трусом*) куркак булу 2. *перед кем-чем, кого-чего* (*бояться*) курку, шүрләү; өркү

трусить I *несов. что, прост.* селкү, кагу, селкеп кагу; **~ муку́ из мешка́** капчыкның онын кагу

трусить II *несов. разг.* (*бежать, ехать мелкой рысью*) лурт-лурт юрту

труси́ха *ж разг.* куркак хатын(кыз), куркак жан

трусли́вость *ж* куркучанлык, өркәклек, кыюсызлык, йөрәксезлек

трусли́вый, -ая, -ое куркак, өркәк, кыюсыз, йөрәксез

тру́сость *ж* куркаклык, өркәклек, йөрәксезлек

трусц||а́ *ж разг.* (*неторопливый бег*) лерт-лерт ...; тыр-тыр ...; лурт-лурт юырту; **бежа́ть ~о́й** лерт-лерт йөгерү

трусы́ *мн.* трусик

трут *м* чакма мамыгы; ку

тру́тень *м* 1. *пчел.* сорыкорт, әрә корт 2. *перен.* сорыкорт, әрәмтамак

тру́тник, трутови́к *м* (*губчатый гриб*) ку, ку гөмбәсе

трутовка *ж пчел.* эшче корт, бал җыючы корт

трухá *ж* 1. черек оны, черек 2. *перен. разг.* чүп-чар, чүп, вак-төяк

трухля́в||ть *несов.* черү; **ста́рый пень ~ет** иске агач төбе чери

трухля́в||ый, -ая, -ое черек, черегән; **~ая соло́ма** черегән салам

трущо́ба *ж* 1. (*труднопроходимое место*) чытырманлык; **лесна́я ~** урман чытырманлыгы 2. (*глушь, захолустье*) караңгы почмак 3. (*грязная, тесная часть города*) җимерек өй[ләр]; ярлы квартал[лар]

трын-трава́ *в знач. сказ. прост.* барыбер, чүп кенә, берни түгел; **всё э́то ему́ ~** аның өчен болар берни түгел

трюи́зм *м книжн.* (*избитая истина*) трюизм, һәркемгә мәгълүм нәрсә

трюк *м* трюк (1. *оста кыланыш* 2. *перен. оста эшләнгән хәйләле эш*)

трюка́ч *м разг.* трюклар ясаучы

трюка́ческ||ий, -ая, -ое трюклар ясау ...; **~ие приёмы** трюклар ясау алымнары

трюка́чество *с* трюкачлык, трюклар ясарга ярату

трюм *м* трюм

трю́мн||ый, -ая, -ое трюм ...ы; **~ое отделе́ние** трюм бүлеге

трюмо́ *с нескл.* трюмо (*бастырып куелган зур көзге*)

трю́фель *м* трюфель (1. *бот. ашарга яраклы гөмбә* 2. *шоколад конфеты*)

тряпи́ца *ж разг.* чүпрәк кисәге

тряпи́чник *м* 1. *разг.* (*любящий наряды*) чүпрәк колы 2. *уст.* (*скупщик тряпья*) чүпрәкче, чүпрәк җыючы, иске-москы җыючы

тряпи́чница *ж* 1. *разг.* (*любящая наряды*) чүпрәк колы хатын (кыз) 2. *уст.* (*скупщица тряпья*) чүпрәкче хатын (кыз)

тряпи́чный, -ая, -ое чүпрәк ..., чүпрәк ...ы, чүпрәктән эшләнгән; **~ мяч** чүпрәк туп

тря́пк||а *ж* 1. чүпрәк; **полова́я ~а** идән чүпрәге 2. *мн.* **~и** *разг.* (*женские наряды*) чүпрәк-чапрак; кием-салым 3. *перен. разг.* (*о безвольном человеке*) җебегән, йомшак кеше, мәми авыз

тря́почк||а *ж уменьш. от* **тря́пка** 1 ♦ **молча́ть (пома́лкивать) в ~у** *прост.* авыз да ачмау, эндәшмәү, бөтенләй сөйләшмәү

тря́почн||ый, -ая, -ое чүпрәктән ясалган, чүпрәк ...; **~ая ку́кла** чүпрәк курчак

тряпьё *с собир.* чүпрәк-чапрак; **собира́ть ~** чүпрәк-чапрак җыю

тряси́на *ж* 1. сазламык, баткаклык, тетрәвек, сазлык 2. *перен.* баткаклык; **~ обыва́тельщины** обывательлек баткаклыгы

тряси́нн||ый, -ая, -ое баткаклыклы, сазламыклы, тетрәвекле, сазлыклы; **~ое боло́то** тетрәвекле сазлык

тря́ска *ж см.* **трясти́** 1-3, **трясти́сь** 1, 2

тря́ск||ий, -ая, -ое 1. (*к-рый трясётся*) селкенә торган; дыңгырдык; **~ая теле́га** дыңгырдык арба 2. (*к-рый трясёт*) сикәлтәле, селкетә торган; **~ая доро́га** сикәлтәле юл

трясогу́зка *ж зоол.* чәперчек, сиртмәкойрык

тряс||ти́ *несов. кого-что* селкү, селкетү; **~ти́ де́рево** агачны селкетү 2. *перен. кого* калтырату, дерелдәтү; тоту; **меня́ всего́ ~ёт** *безл.* мине бик нык калтырата; **его́ ~ёт лихора́дка** аны бизгәк тота 3. *что* селкү, кагу; **~ти́ мешо́к** капчыкны кагу; **~ти́ ковры́** келәмнәрне кагу 4. *чем* селкү, селкетү, чайкау; **ло́шадь ~ёт гри́вой** ат ялын селкетә; **~ти́ голово́й** башны чайкау 5. селкетү; **в авто́бусе ~ёт** *безл.* автобуста селкетә

тряст||и́сь *несов.* 1. селкенү, калтырану, дерелдәү, дерелдәп тору, дер-дер килү; **~ от стра́ха** куркудан калтырану 2. (*ехать на чём-л. трясясь*) селкенеп бару 3. *перен. над кем-чем* куркып тору, калтырап тору, дерелдәп тору; **~ над ребёнком** баласы өчен куркып тору; **~ над деньга́ми** бер тиен өчен калтырап тору 4. *перед кем-чем и без доп., разг.* калтырау; **~ пе́ред нача́льством** начальниклар алдында калтырау

тряхну́ть *сов. однокр. кого-что, чем* селкү, селкетү, кагу, селкеп (селкетеп, кагып) алу ♦ **~ стари́ной** үткән заманны искә төшерү, яшьлекне искә төшерү; **~ мошно́й** кесәне бушату

тсс *межд. разг.* тшш, чү (*тын булыгыз*)

туале́т *м* 1. туалет, кием-салым (*кубесенчә хатын-кызлар киеме турында*) 2. (*одевание*) киенү-ясану; **у́тренний ~** иртәнге киенү-ясану 3. (*столик с зеркалом*) бизәнү өстәле, көзгеле өстәл 4. (*уборная*) бәдрәф, хәжәтханә, туалет

туале́тн||ый, -ая, -ое туалет ...ы; **~ые принадле́жности** туалет кирәк-яраклары; **~ое мы́ло** исле сабын; **~ая бума́га** туалет кәгазе

туберкулёз *м* туберкулёз; **~ лёгких** үпкә туберкулёзы; **ко́стный ~** сөяк туберкулёзы

туберкулёзник *м разг.* 1. (*врач*) туберкулёз табибы, туберкулёздан дәвалый торган табиб 2. (*больной*) туберкулёз белән авыручы

туберкулёзн||ый, -ая, -ое 1. туберкулёз ...ы; **~ая па́лочка** туберкулёз таякчыгы 2. туберкулёзлы, туберкулёз

белән авыручы; **~ ый больно́й** туберкулёз белән авыручы

тубероза *ж* тәбәр (*гөл*)

тувинец *м* тувалы, тува кешесе

тувинка *ж* тува хатыны (кызы)

тувинский, -ая, -ое тува[лар] ...ы; Тува ...ы; **~ язы́к** тува теле

тувинцы *мн.* тувалылар, тувалар, тува халкы

ту́го *нареч.* **1.** нык, нык итеп, каты, тыгыз итеп, тыгызлап; тартып; **~ завяза́ть** тартып бәйләү; **~ наби́ть чемода́н** чемоданны тыгызлап тутыру **2.** *в знач. сказ. безл.* (*трудно*) авыр, кыен, мөшкел; **у нас с деньга́ми ~** бездә акча хәле бик мөшкел

тугоду́м *м разг.* озак уйлаучы кеше

туг||о́й, -а́я, -о́е **1.** нык тарттырылган; кысан; **~а́я струна́** нык тарттырылган кыл; **~о́й воротничо́к** кысан яка **2.** (*плотно набитый*) тыгыз, тыгызлап тутырылган ♦ **~о́й на́ ухо** колакка каты

тугопла́вкий, -ая, -ое авыр эрүчән; **~ мета́лл** авыр эрүчән металл

тугопла́вкость *ж* авыр эрүчәнлек

тугоу́хий, -ая, -ое начар ишетүче, колакка каты кеше

тугоу́хость *ж* (*частичная потеря слуха*) колакка каты булу

ту́грик *м* тугрик (*Монголиядә акча берәмлеге*)

туда́ *нареч.* ары, шунда, шул урынга, шул [теге] якка, тегеләй; **ты ~ пойдёшь** син шунда барырсың; **иди́те ~** ары барыгыз ♦ **~ же** *в знач. частицы* тыгылган була тагы; **ни ~ ни сюда́** ни ары, ни бире; **~ и доро́га** (*так и надо*) аңа шул кирәк тә; **~-сюда́** *в знач. прост.* (*ничего, годится*) анда-монда, ярарлык, бер хәл

ту́ев||ый, -ая, -ое савыр ...ы; **~ые ши́шки** савыр күркәләре

тужи́ть *несов. по ком-чём, о ком-чём, по кому-чему и без доп., прост.* пошыну, кайгыру, хәсрәтләнү, борчылу

ту́житься *несов. прост.* көчәнү, тырышу

тужу́рка *ж* тужурка

туз *м* **1.** *карт.* туз **2.** *перен. чего, какой* зур кеше, дәрәҗәле кеше, туз

тузе́мец *м* җирле кеше, туземец

тузе́мка *ж* җирле хатын (кыз)

тузе́мн||ый, -ая, -ое җирле; **~ое населе́ние** җирле халык

тузе́мцы *мн.* җирле кешеләр, туземецлар

тузи́ть *несов. кого, прост.* тукмау, йодрыклау, дөмбәсләү

тузлу́к *м спец.* тозлык, тоз эремәсе (*балык, уылдык һ.б.ш. тозлау өчен*)

ту́кать *несов. кого-что, во что и без доп., прост.* шакылдату, дөбердәтү, тукылдату

ту́кнуться *сов. однокр. разг.* бәрелү, сугылу

тук-ту́к *звукоподр.* тук-тук, шак-шок

ту́ловище *с* гәүдә

тулу́п *м* толып

туль||я́ *ж* түбә (*эшләпә, фуражка, бүрек түбәсе*); **фура́жка с высо́кой ~ёй** биек түбәле фуражка

тума́к *м прост.* йодрыклау, йодрык белән сугу

тума́н *м* томан; **оку́таться ~ом** томанга өртелү; **спусти́лся ~** томан төште ♦ **~ в голове́** баш томалану, баш тубал булу; **напусти́ть ~у** бутау, төтен жибәрү

тума́н||ить *несов. что* **1.** (*делать невидимым*) томанландыру, караңгыландыру **2.** *перен.* каплау, томалау, томанландыру; **слёзы ~ят глаза́** күзләрне яшь каплый; **вино́ ~ит го́лову** аракы башны томаландыра

тума́нит||ься *несов.* **1.** (*застилаться туманом*) томанлану, томан белән капланы **2.** *перен. разг.* караңгылану; **взор ~ся** күз аллары караңгылана **3.** *страд. от* **тума́нить**

тума́нность *ж* **1.** (*скопление тумана*) томанлык, томанлылык **2.** *астр.* (*скопление звёзд*) томанлык, йолдызлар тупланышы **3.** *перен.* томанлылык, аңлаешсызлык, буталчыклык; **~ ре́чи** сөйләүнең аңлаешсызлыгы

тума́нн||ый, -ая, -ое **1.** томан ...ы; **~ая полоса́** томан катлавы **2.** томанлы, томан каплаган, томан баскан; **~ый день** томанлы көн **3.** *перен.* тонык, караңгы; **~ый взгляд** тонык караш **4.** *перен.* томанлы, буталчык, аңлаешсыз; **~ый отве́т** томанлы җавап

ту́мба *ж* **1.** тумба (*юл читендә тәбәнәк багана*); **2.** (*подставка*) тумба (*кечкенә тәбәнәк шкаф*) **3.** *перен. прост.* (*о неповоротливом человеке*) ит бүкәне

ту́мблер *м тех.* тумблер

ту́мбочка *ж* тумбочка

тунгу́с *м уст.* тунгус, тунгус кешесе

тунгу́ска *ж уст.* тунгус хатыны (кызы)

тунгу́сский, -ая, -ое *уст.* тунгус [лар] ...ы; **~ язы́к** тунгус теле

тунгу́сы *мн. уст.* тунгуслар

ту́ндра *ж* тундра

ту́ндров||ый, -ая, -ое тундра ...ы; **~ая зо́на** тундра зонасы

туне́ц *м* тунец (*балык*)

туней́дец *м* әрәмтамак, кеше җилкәсен кимерүче

туней́дка *ж* әрәмтамак хатын (кыз)

туней́дство *с* әрәмтамаклык, әрәмтамак булу, кеше җилкәсен кимерү

туней́дствовать *несов.* әрәмтамак булып яшәү, кеше җилкәсен кимерү

туннéль *м* туннель; **железнодоро́жный ~** тимер юл туннеле; **копа́ть ~** туннель казу [салу]

туннéльный, -ая, -ое туннельле; туннель ...ы

тупе́ть *несов.* **1.** үтмәсләнү, йөзе кайту **2.** *перен.* аңгыралану, миңгерәүләнү; тупаслану

тупи́к *м* **1.** тупик, тыкрык **2.** *ж.-д.* тупик **3.** *перен.* аптыраш, аптырау, ни эшләргә белмәү; **поста́вить в ~** *кого* аптыраштa калдыру; **быть в ~é** аптырап калу

тупи́ть *несов. что* үтмәсләндерү, йөзен кайтару, кыршылдыру; **~ нож** пычакны үтмәсләндерү

тупи́ться *несов.* үтмәсләнү, кыршылу, йөзе кайту

тупи́ца *м, ж разг.* аңгыра, томана

тупоголо́вый, -ая, -ое *разг.* чүбек баш, аңсыз, томана, зиһенсез

туп||о́й, -а́я, -о́е **1.** үтмәс, кыршылган; **~о́й нож** үтмәс пычак **2.** (*не суживающийся к концу*) җәенке, тупыйк; **~о́й нос ло́дки** көймәнең җәенке башы **3.** *перен.* (*невыразительный*) мәгънәсез, тонык, тәэсирсез; **~о́й взгляд** мәгънәсез караш **4.** *перен.* (*несообразительный*) миңгерәү, миңгерәүле, аңгыра, сантый **5.** (*не резкий*) сызлаулы, сызлый торган; каты булмаган; **~а́я боль** каты булмаган авыртып тору **6.** *перен.* (*безропотный*) юаш, карусыз, сүз кайтармый торган; **~а́я поко́рность** бер сүз кайтармый буйсыну ♦ **~о́й у́гол** *мат.* җәенке почмак

туполо́бый, -ая, -ое *разг.* аңгыра, аңсыз

тупоно́с||ый, -ая, -ое тупыйк борынлы; тупа башлы; **~ые сапоги́** тупа башлы итекләр

ту́пость *ж* **1.** үтмәслек; **~ ножа́** пычакның үтмәслеге **2.** *перен.* мәгънәсезлек; **~ взгля́да** күз карашының мәгънәсезлеге **3.** *перен.* миңгерәүлек, аңгыралык; **~ ума́** аңгыралык

тупоуго́льный, -ая, -ое *мат.* җәенке почмаклы

тупоу́мие *с* миңгерәүлек, аңгыралык, сантыйлык

тупоу́мный, -ая, -ое аңгыра [баш], сантый

тур I *м в разн. знач.* тур; **~ ва́льса** бер тур вальс; **пе́рвый ~ соревнова́ний** ярышларның беренче туры; **пе́рвый ~ вы́боров** сайлауларның беренче туры; **опа́сный ~ го́нки вооруже́ний** кораллануның тагын да куркынычрак туры

тур II *м* тур (**1.** *хәзерге көндә юкка чыккан кыргый үгез* **2.** *Кавказдагы кыр кәҗәсе төкәсе*)

тура́ *ж шахм.* тура (*ладья*)

турба́за *ж* турбаза, туристик база

турби́на *ж* турбина; **водяна́я ~** су турбинасы

турби́нн||ый, -ая, -ое **1.** турбина ...ы; **~ая установка** турбина установкасы **2.** турбиналы; **~ый наcóс** турбиналы насос

турби́нщик *м* турбиначы (*турбина производствосы белгече*); турбинада эшләүче

турбобу́р *м горн.* турбобур (*бораулау машинасы*)

турбовинтово́й, -а́я, -о́е турбовинтлы; **~ самолёт** турбовинтлы самолёт

турбово́з *м* турбовоз (*пар яки газ турбинасы ярдәмендә эшләүче локомотив*)

турбогенера́тор *м* турбогенератор

турбореакти́вный, -ая, -ое турбореактив; **~ самолёт** турбореактив самолёт

турбостроéние *с* турбиналар төзү (эшләп чыгару)

турбострои́тельный, -ая, -ое турбиналар төзү ...ы, турбиналар эшләп чыгара торган

турбуле́нтность *ж спец.* турбулентлык

турбуле́нтн||ый, -ая, -ое *спец.* турбулент ...; **~ое движе́ние** турбулент хәрәкәт; **~ое тече́ние** турбулент агым

туре́цкий, -ая, -ое төрек ...ы; Төркия ...ы; **~ язы́к** төрек теле

тури́зм *м* **1.** *спорт.* туризм, туристлык; **го́рный ~** тау туризмы; **во́дный ~** су туризмы **2.** (*вид путешествий*) туризм, туристлык; **междунаро́дный ~** халыкара туризм; **Сове́т по ~у и экску́рсиям** Туризм һәм экскурсияләр буенча совет

тури́ст *м* турист

туристи́ческ||ий, -ая, -ое турист [лар] ...ы, турист; **~ая путёвка** туристик юллама; **~ий похо́д** туристик поход

тури́стка *ж* турист хатын (кыз)

тури́стск||ий, -ая, -ое турист[лар] ...ы; **~ая ба́за** туристлар базасы; **~ие тро́пы** туристлар сукмагы

ту́рки *мн.* төрекләр, төрек халкы

туркме́н *м* төркмән, төркмән кешесе

туркме́нка *ж* төркмән хатыны (кызы)

туркме́нский, -ая, -ое төркмән[нәр] ...ы; Төркмәнстан ...ы; **~ язы́к** төркмән теле

туркме́ны *мн.* төркмәннәр, төркмән халкы

турмали́н *м мин.* турмалин

турмали́новый, -ая, -ое турмалин ...ы; турмалин..., турмалиннан ясалган; **~ пе́рстень** турмалин йөзек

турма́н *м* (*голубь*) турман, әйләнчек күгәрчен

турне́ *с* турне (**1.** *сәяхәт итеп урап кайту* **2.** *артистларның гастрольгә чыгулары, шулай ук спортчыларның чыгыш ясап йөрүләре*)

турне́пс *с бот.* турнепс, азык шалканы

турни́к *м* турник

турнике́т *м* турникет (*кешеләрне берәмләп керту һәм чыгару өчен әйләнмәле җайланма*)

турни́р *м* турнир, ярыш; **ша́хматный ~** шахмат буенча ярыш

турну́ть *сов. однокр. кого-что, прост.* куып чыгару; төртеп чыгару

ту́рок *м* төрек, төрек кешесе

туру́сы *мн. прост.*: **разводи́ть ~** ләүтит сату

турухта́н *м зоол.* корыхтан, яр кулиры

турча́нка *ж* төрек хатыны (кызы)

ту́склость *ж* **1.** (*мутность*) тоныклык, төссезлек **2.** (*неяркость*) тоныклык **3.** *перен.* (*безжизненность*) җансызлык, рухсызлык, тоныклык **4.** *перен.* (*бессодержательность*) күңелсезлек, кызыксызлык

ту́скл||ый, -ая, -ое **1.** тонык; төссез; **~ое стекло́** тонык пыяла **2.** тонык; **~ый свет** тонык яктылык **3.** *перен.* җансыз, рухсыз, тонык, сүрән; **~ый взгляд** тонык караш **4.** *перен.* күңелсез, кызыксыз; **~ая жизнь** кызыксыз тормыш

тускне́||ть *несов.* **1.** тоныклану, төссезләну; **серебро́ ~ет** көмеш тоныклана **2.** *перен.* кимү, кими бару, сүрелү; **его́ сла́ва ~ет** аның даны кими бара

ту́скнуть *несов. разг. см.* **тускне́ть**

тут *нареч.* **1.** (*здесь*) биредә, монда; **~ всегда́ мно́го люде́й** монда һәрвакыт кеше күп **2.** шунда, шул чакта, шул вакытта; **~ он и яви́лся домо́й** шул вакытта ул өйгә кайтып керде **3.** *в знач. частицы усил.* кая ул; **кака́я ~ любо́вь!** кая ул мәхәббәт дигән нәрсә! ♦ **а он ~ как ~** *в знач. сказ.* ул ялт итеп килде дә чыкты; **и всё ~** вәссәлам, эш бетте; **не ~ -то бы́ло** (*вышло по-другому*) эш барып чыкмады

ту́товник, тутовник *м* **1.** (*дерево*) тут агачы **2.** (*участок*) тут агачлыгы

тутово́дство *с* тут агачы үстерү, тут агачы үстерүчелек

тутово́дческий, -ая, -ое тут агачы үстерү ...ы, тут агачы үстерә торган

ту́тов||ый, -ая, -ое тут ...ы, тут агачы ...ы; **~ое де́рево** тут агачы; **~ые я́годы** тут агачы җиләкләре; **~ый шелкопря́д** тут агачы корты, ефәк корты

туф *м мин.* туф

ту́фельн||ый, -ая, -ое туфли ...ы; **~ая коло́дка** туфли калыбы

ту́фли *мн.* туфли; **мужски́е ~** ирләр туфлие

туфобето́н *м* туфлы бетон

ту́фов||ый, -ая, -ое **1.** *мин.* туф ...ы; **~ая ла́ва** туф лавасы **2.** туфтан эшләнгән; **~ый дом** туфтан салынган йорт

тухли́нк||а *ж разг.* сасы ис, сасыган ис; исләнә башлау; **мя́со с ~ой** исләнә башлаган ит

ту́хл||ый, -ая, -ое сасы, сасыган, сөрсегән, исләнгән; бозык, чәберчек, черек; **~ое яйцо́** чәберчек йомырка; **~ое мя́со** исләнгән ит

тухля́тина *ж разг.* исләнгән ашамлык, сасыган ашамлык

ту́хн||уть I *несов.* (*гаснуть*) сүнү, сүнә бару; **ого́нь ~ет** ут сүнә

ту́хнуть II *несов.* (*загнивать*) сасу, сөрсү, исләнү; бозылу; чәберчекләнү, черү

ту́ч||а *ж* **1.** болыт **2.** *перен.* (*о грозящей беде*) болыт; **над ним нависли́ ~и** аның өстендә болытлар куера башлады **3.** *перен. чего* (*множество*) болыт, өер, көтү; **~и мух** чебен болыты ♦ **~а ~ей** (*о мрачном человеке*) кара болыт кебек, кара янып, карасы йөзенә чыккан

тучев||о́й, -а́я, -о́е болыт ...ы; **~а́я ма́сса** болыт массасы

тучне́||ть *несов.* көрәю, симерү; юанаю; **скот ~ет** мал көрәя

ту́чность *ж* **1.** (*полнота*) симезлек, көрлек; юанлык **2.** (*плодородность почвы*) уңдырышлылык **3.** (*сочность травы*) куелык

ту́чн||ый, -ая, -ое **1.** симез, көр; юан; **~ый скот** көр терлек **2.** (*плодородный*) уңдырышлы; **~ый чернозём** уңдырышлы кара туфрак **3.** (*сочный*) куе үләнле; **~ые луга́** куе үләнле болыннар

туш *м муз.* туш (*сәламләү музыкасы*)

ту́ша *ж* **1.** тушка **2.** *перен. прост.* (*о тучном человеке*) ит бүкәне (чүмәләсе)

туше́ *с нескл.* туше (**1.** *муз. пианинода уйнаганда клавишларга басу ысулы* **2.** *спорт. көрәштә җиңү билгесе буларак, көрәшченең калак сөяген җиргә тидерү*)

тушева́льный, -ая, -ое тушь ...ы, рәсемгә күләгә сала торган; **~ каранда́ш** тушь каләме

тушева́льщик *м* рәсем күләгәләүче, рәсемгә күләгә салучы

тушева́ние *с см.* **тушева́ть**

тушева́ть *несов. что* сурәткә күләгә төшерү (салу), күләгәләү, тушь салу

тушева́ться *несов.* **1.** (*смущаться*) каушау, каушап тору; шүрләү, курку **2.** *страд. от* **тушева́ть**

тушёвка *ж* **1.** *см.* **тушева́ть**; **2.** (*тени, штрихи*) штрихлар, күләгәләр (*рәсемдә*); **густа́я ~** калын штрихлар

ту́шев||ый, -ая, -ое тушь ...ы; тушь белән ясалган; **~ые черни́ла** тушь карасы

туше́ние I *см.* **туши́ть** I; **~ пожа́ра** янгынны сүндерү

туше́ние II *см.* **туши́ть** II; **~ мя́са** томалап ит пешерү

тушёнка *ж разг.* тушёнка (*консервланган ит*)

тушён||ый, -ая, -ое томалап пешерелгән; **~ое мя́со** томалап пешерелгән ит

туши́лка *ж* күмер савыты (чүлмәге), күмер сүндергеч

туши́ть I *несов.* **1.** *что* (*гасить*) сүндерү **2.** *перен.* (*подавлять*) басу, туктату, сүндерү; **~ гнев** ачуны басу; **~ очаги́ вое́нных конфли́ктов** сугыш конфликты учакларын сүндерү

туши́ть II *несов. что* томалап пешерү; **~ мя́со** итне томалап пешерү

тушка́нчик *м* кушаяк, җир куяны

тушь *ж* тушь; **чёрная ~** кара тушь; **цветна́я ~** төсле тушь

ту́я *ж* савыр

тща́тельность *ж* җентеклелек

тща́тельн||ый, -ая, -ое җентекле, тырышып эшләнгән, пөхтә эшләнгән, җентекләп; **~ое изуче́ние** җентекләп өйрәнү

тщеду́шие *с*, **тщеду́шность** *ж* хәлсезлек, көчсезлек

тщеду́шный, -ая, -ое хәлсез, көчсез, чирләшкә, арык; **~ челове́к** арык кеше

тщесла́вие *с* шөһрәт ярату, дан ярату; масаючанлык

тщесла́вность *ж* шөһрәт ярату, дан яратучанлык; масаючанлык

тщесла́вный, -ая, -ое шөһрәт яратучан, дан сөючән; масаючан

тщета́ *ж уст.* буш булу, файдасызлык, нәтиҗәсезлек

тщётность *ж* файдасыз (нәтиҗәсез) булу

тщётн||ый, -ая, -ое буш, файдасыз, нәтиҗәсез; **~ые наде́жды** буш өметләр

ты (тебя́, тебе́, тебя́, тобо́й, о тебе́) *мест.* син; **ты ли э́то?** синме бу?; **как тебя́ зову́т?** синең исемең ничек?; **тебе́ ну́жно ещё учи́ться** сиңа тагын укырга кирәк әле; **они́ тобо́й о́чень дово́льны** алар синнән бик канәгатьләр ♦ **вот тебе́ и на́** менә сиңа кирәк булса; **на ты** *с кем* (*быть, говорить и т.п.*) синләү, «син» дип әйтү (*якын, иптәшләрчә яхшы мөнәсәбәтле кешеләр арасында кулланыла*)

ТЫК-ТЯГ

ты́кать I *несов.* **1.** *что, чем, разг.* (*ударять*) төртү, төртеп тору; **~ па́лкой в зе́млю** таяк белән җиргә төртү **2.** *что, прост.* (*вонзать*) кадау, чәнчү, кадап (чәнчеп) кую; **~ ко́лья в зе́млю** җиргә казык кадау **3.** *что, прост.* (*совать*) тыгу, кыстыру **4.** *перен. кого-что, кем-чем, прост.* (*постоянно напоминать*) искәртү, искә төшерү ♦ **~ в глаза́ (в нос)** *кому, кого-что, кем-чем* әрләп теңкәгә тию, шелтәләү; **~ [свой] нос** борын тыгу, кысылу, тыгылу; **~ па́льцем (па́льцами)** *на кого-что берәр кешегә* бармак белән төртеп күрсәтү

ты́кать II *несов. кого, прост.* «син» дип эндәшү (*«сез» урынына*)

ты́каться *несов.* **1.** *прост.* төртелү, бәрелү; **~ в сте́ну** стенага бәрелү **2.** *перен.* (*беспорядочно двигаться*) бәргәләнеп йөрү; кысылу, тыгылу; **~ всю́ду** бөтен җиргә тыгылу; **~ туда́-сюда́** әрле-бирле йөрү ♦ **~ но́сом** йоклап утыру, утырган килеш йоклау

ты́ква *ж* кабак

ты́квенник *м кул.* кабак боткасы

ты́квенн||ый, -ая, -ое кабак ...ы; **~ые семена́** кабак орлыклары

тыл *м* **1.** (*задняя сторона*) арт, арт як; **напа́сть с ~а** арттан һөҗүм итү **2.** *воен.* (*территория позади фронта*) тыл **3.** *обычно мн.* **~ы́** тыл (*фронттан тыш торып фронтны тәэмин итә торган өешмалар һәм хәрби частьлар*)

тыловы́к *м* тыловик, тылда хезмәт итүче

тылово́й, -а́я, -о́е тыл ...ы, тылдагы; **~ го́спиталь** тылдагы госпиталь

ты́льн||ый, -ая, -ое арт ..., арткы, арт (арка) як тагы; **~ая сторона́** арткы ягы

тын *м* казык читән; текмә, текмә читән

ты́сяч||а **1.** *числ.* мең; **~а рубле́й** мең сум **2.** *мн.* **~и** (*огромное количество*) меңнәрчә, меңләп-меңләп; мең-мең; бик күп, чиксез күп; **издава́ть ~и книг** меңнәрчә китап бастырып чыгару; **прое́хать ~и киломе́тров** меңнәрчә километр җир үтү ♦ **~у раз говори́ть** мең тапкыр әйтү

тысячеголо́с||ый, -ая, -ое мең тавышлы, меңнәрчә тавыш белән әйтелгән; **~ое ура́** мең тавышлы ура

тысячекра́тный, -ая, -ое мең кат, мең тапкыр

тысячеле́тие *с* **1.** (*срок*) мең ел **2.** (*годовщина*) меңъеллык, мең ел тулу

тысячеле́тн||ий, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) мең еллык; **~яя исто́рия го́рода** шәһәрнең мең еллык тарихы **2.** (*о возрасте*) мең яшьлек (яшьтәге)

тысячели́стник *м бот.* меңъяфрак, ярмабаш, ак мәтрүшкә, акбаш (*чүп үлән*)

ты́сячн||ый, -ая, -ое **1.** *числ.* меңенче **2.** (*получаемый делением на тысячу*) меңнән бер, меңенче; **~ая до́ля секу́нды** секундның меңнән бер өлеше **3.** (*состоящий из тысячи, тысяч*) меңлек, меңле; мең ...дан гыйбарәт; мең кешелек; меңнәрчә кешеләрдән гыйбарәт; **~ый отря́д** мең кешелек отряд **4.** *разг.* (*ценою в тысячу рублей*) мең сумлык, мең сум торырлык

тычи́нка *ж бот.* серкәч

тычи́нков||ый, -ая, -ое, **тычи́ночн||ый**, -ая, -ое *бот.* серкәч ...ы; **~ая нить** серкәч җебе

тьма I *ж* **1.** караңгылык, дөм караңгы; **ночна́я ~** төн караңгылыгы; **~ кроме́шная** дөм караңгы **2.** *перен.* (*невежество*) наданлык, томаналык, караңгылык, культурасызлык

тьма II *ж* **1.** *уст.* ун мең **2.** *чего* (*множество*) бик күп, хисапсыз, әйтеп бетергесез күп, дөнья кадәр; **~ наро́ду** әйтеп бетергесез күп халык ♦ **~ тьму́щая** *прост.* исәбе-хисабы юк, әллә никадәр

тьфу *межд.* **1.** (*подр. звуку плевка*) тфү **2.** *в знач. сказ.* (*наплевать*) төкерәм; **да я на тебя́ — ~!** төкерәм мин сиңа!

тюбете́йка *ж* түбәтәй

тю́бик *м* тюбик; **~ па́сты** паста тюбигы; **~ кра́ски** буяу тюбигы

тюк *м* зур бәйләм, зур төргәк, тюк; **~и́ хло́пка** мамык тюклары

тюкова́ть *несов. что, спец.* бәйләмләү, тюкка бәйләү, тюклау

тюко́вка *ж см.* **тюкова́ть**

тю́лев||ый, -ая, -ое **1.** тюль ...ы; челтәр ...ы; **~ое произво́дство** тюль производствосы **2.** тюль ..., челтәр ..., тюльдән тегелгән (эшләнгән); **~ые занаве́ски** тюль пәрдә

тюле́нев||ый, -ая, -ое **1.** тюлень ...ы; **~ый про́мысел** тюлень аулау промыселы **2.** тюлень ..., тюлень тиресеннән тегелгән; **~ые сапоги́** тюлень тиресеннән тегелгән итек[ләр]

тюле́н||ий, -ья, -ье тюлень ...ы, тюлень ...; **~ий жир** тюлень мае; **~ье ста́до** тюлень көтүе

тюле́нина *ж* тюлень ите

тюле́нь *м* **1.** тюлень, су эте **2.** *перен. разг.* (*о неуклюжем человеке*) су сыеры, салмак кеше

тюль *м* челтәр, тюль

тю́лька *ж* тюлька (*вак балык*)

тюльпа́н *м* лалә, кызалак

тюрба́н *м* чалма

тюре́мн||ый, -ая, -ое төрмә ...ы; **~ые поря́дки** төрмә тәртипләре

тюре́мщик *м* **1.** *уст.* (*надзиратель*) төрмәче, төрмә сакчысы (надзирателе) **2.** *перен.* (*угнетатель*) төрмәче, җәберләүче, изүче

тю́ркски *мн.* төркиләр (*төрки телләрдә сөйләшүче халыклар*)

тюрколо́г *м* тюрколог

тюрколо́гия *ж* тюркология (*төрки халыкларның телләрен һәм культурасын өйрәнә торган фән*)

тю́ркск||ий, -ая, -ое төрки; **~ие языки́** төрки телләр

тюрьма́ *ж* төрмә, зиндан

тю́ря *ж* тюря (*суга яки куаска суган белән ипи турап ясалган ашамлык*)

тю́тельк||а *ж:* **~а в ~у** *прост.* (*точь-в-точь*) нәкъ; **он пришёл ~а в ~у** ул нәкъ вакытына килде

тю-тю́ *в знач. сказ. разг.* түгү, юк, бетте

тютю́н *м прост.* тәмәке (*түбән сортлы тәмәке*)

тюфя́к *м* **1.** түшәк, тюфяк; **соло́менный ~** салам түшәк **2.** *перен. прост.* (*о безвольном человеке*) булдыксыз кеше, булмаган, пешмәгән кеше

тя́вканье *с см.* **тя́вкать; ~ соба́к** этләр өрүе

тя́вка||ть *несов.* өрү, ләңгелдәү, ләңгелдәп өрү; **соба́ки ~ют** этләр ләңгелдәп өрә

тя́вкнуть *сов. однокр.* өреп (ләңгелдәп) кую

тяг: дать ~у *прост.* таю, шылу, табан ялтырату

тя́га *ж* **1.** (*тянущая сила*) тарту, тарту көче, көрәкәткә китерү; **парова́я ~** пар машинасы белән хәрәкәткә китерү; **ко́нная ~** ат көче белән тарту **2.** (*в печи и т.п.*) тарту, суыру **3.** *перен.* к *кому-чему* тартылу, омтылу, омтылыш; **~ к зна́ниям** белемгә омтылыш; **~ к иску́сству** сәнгатькә омтылыш

тяга́ться *несов. с кем* (*соперничать*) ярышу, узышу; көрәшү

тяга́ч *м тех.* тягач, йөк тракторы

тя́гло *с собир.* (*рабочий скот*) җигү хайваны, җигә торган хайван

тя́глов||ый, -ая, -ое тарту ...ы, җигү ...ы, җигә торган; **~ая си́ла** тарту көче; **~ый скот** җигә торган хайван

тя́гостн||ый, -ая, -ое авыр, кыен, читен, интектергеч, күңелсез, газаплы; **~ый труд** авыр эш; **~ое впечатле́ние** күңелсез тәэсир

тя́гость *ж* **1.** (*то, что обременяет*) авырлык, мәшәкать, кыенлык, авыр йөк; **быть в ~ кому-л.** *беркемгә* авыр йөк булу **2.** *прост.* (*усталость*) арыганлык, хәлсезлек; **чу́вствовать ~ в те́ле** тәндә арыганлык сизү

тяготе́ние *с* **1.** *физ.* тартылу, тартылыш; тарту көче; **земно́е ~** җирнең тарту көче **2.** *перен. к кому-чему* (*влечение*) тартылу, омтылыш, омтылу; **~ к нау́ке** фәнгә омтылыш

тяготе́||ть *несов.* **1.** *к кому-чему* омтылу, күңел яту, күңел тарту, мавыгу; **~ть к иску́сству** сәнгатькә күңел яту **2.** *перен. над кем-чем* (*постоянно угрожать*) басу, изү, өстә авырлык булып тору; **несча́стья ~ют над ним** аны бәхетсезлекләр изә

тяготи́||ть *несов. кого-что* мәшәкатьләү, уңайсызлау, мазасызлау, авырсындыру; **меня́ ~т его́ дру́жба** аның дуслыгы мине авырсындыра

тяготи́ться *несов. кем-чем* авырсыну, уңайсызлану, борчылу; **~ свои́м одино́чеством** үзеңнең ялгызлыгыңнан уңайсызлану

тя́готы *обычно мн. см.* **тя́гость** 1; **~ вое́нного вре́мени** сугыш елларының авырлыклары

тягу́честь *ж* **1.** сузылучанлык; **~ смолы́** сумаланың сузылучанлыгы **2.** (*густота, вязкость*) ябышкаклык, ябышучанлык; куелык **3.** *перен.* (*томительность*) акрынлык, озакка сузыла торганлык

тягу́ч||ий, -ая, -ее 1. (*способный растягиваться*) сузылучан, сузылмалы, сузыла торган, 2. (*густой*) ябышкак, ябышучан; куе 3. *перен.* (*медленный*) акрын, салмак; **~ая речь** салмак сөйләү

тяж *м* 1. *спец.* (*ремень, трос*) каеш, аркан 2. (*в упряжке*) тәҗе, тәртә бавы

тя́жба *ж* дау, дәгъва, даулашу, дәгъвалашу, судлашу; **~ о насле́дстве** мирас өчен дәгъвалашу

тяжеле́||ть *несов.* 1. (*становиться тяжелее*) авыраю, авырлыгы арту 2. *перен.* (*становиться тяжеловесным*) авырлашу 3. (*испытывать утомление*) авыраю; **ве́ки ~ют** күз кабаклары авырая

тяжело́ *нареч.* 1. авыр; **~ нагру́женный автомоби́ль** авыр йөк төягән автомобиль; **~ ступа́ть** авыр атлау, салмак кына атлап бару 2. (*серьёзно*) авыр, каты, житди; **он ~ бо́лен** ул бик каты авырый; **~ ра́неный бое́ц** авыр яраланган сугышчы 3. *в знач. сказ. безл.* кәефсез, әрнүле, тынычсыз; **у меня́ ~ на душе́** йөрәгем әрни, эчем поша

тяжелоатле́т *м спорт.* авыр атлет

тяжелоатлети́ческ||ий, -ая, -ое *спорт.* авыр атлет[лар] ...ы; **~ие состяза́ния** авыр атлетлар ярышы

тяжелове́с *м* авыр үлчәүле спортчы (*көрәшче, боксёр, штангачы*)

тяжелове́сность *ж* авырлык; **~ сти́ля** стильнең авырлыгы

тяжелове́сн||ый, -ая, -ое 1. авыр йөкле; **~ый железнодоро́жный соста́в** авыр йөкле тимер юл составы 2. *перен.* авыр; авыр (кыен, читен) аңлашыла торган; **~ые остроты́** читен аңлашыла торган тапкыр сүзләр

тяжелово́з *м* авыр йөк аты, авыр йөкләр ташый торган ат

тяжёл||ый, -ая, -ое 1. авыр; **~ый чемода́н** авыр чемодан 2. авыр, кыен, читен, мәшәкатле; **~ая рабо́та** авыр эш; **~ая обя́занность** мәшәкатле вазифа 3. авыр, салмак; **~ые шаги́** авыр адымнар 4. (*напряжённый; доставляющий беспокойство*) авыр, кайгылы, хәсрәтле, газаплы, күңелсез; **~ое дыха́ние** авыр сулыш; **~ый сон** газаплы йокы 5. (*суровый, серьёзный*) авыр, зур, каты; **~ое наказа́ние** каты җәза; **~ая вина́** зур гаеп 6. (*очень серьёзный*) авыр, каты, куркынычлы; **~ая ра́на** авыр яра 7. (*горестный*) авыр, кайгылы, күңелсез; **~ое чу́вство** авыр тойгы; **~ое зре́лище** авыр күренеш; **~ые дни** күңелсез көннәр; **~ые мы́сли** авыр уйлар 8. (*неприятный — о запахе*) авыр, начар, тынчу 9. (*о машинах и средствах вооружения*) авыр; **~ое машинострое́ние** авыр машиналар төзу; **~ая артилле́рия** авыр артиллерия; **~ый танк** авыр танк ♦ **~ая пи́ща** авыр азык; **~ая промы́шленность** авыр промышленность; **~ая рука́** *у кого* каты куллы (нык суга торган) кеше; **~ый водоро́д** *хим.* авыр водород; **~ый день** авыр көн; **~ый на подъём** авыр сөякле, акрын кыймылдаучан, тиз кузгалмый торган

тя́жест||ь *ж* 1. *физ.* авырлык; **центр ~и** авырлык үзәге 2. *обычно мн.* **~и** авырлык, авыр нәрсә, йөк; **подня́тие ~ей** авыр әйберләр күтәрү 3. авырлык, кыенлык, читенлек; **говори́ть о ~и пути́** юлның авырлыгы турында сөйләү; **~ь разлу́ки** аерылышуның читенлеге

тя́жк||ий, -ая, -ое *см.* **тяжёлый** 2, 4, 5, 7; **~ая до́ля** авыр язмыш; **~ое преступле́ние** авыр җинаять ♦ **во все ~ие пусти́ться** бозыклыкка бирелү, типтерә башлау

тяну́ть *несов.* 1. *кого-что* (*натягивая, тащить*) тарту; **~ верёвку к себе́** бауны үзенә таба тарту 2. *что, тех.* (*изготовлять из металла*) тартып (сузып) ясау; **~ про́волоку** тартып тимерчыбык ясау 3. *что* (*натягивать*) сузу, тарту, үткәрү; **~ верёвку че́рез двор** йорт аша бау сузу; **~ телефо́нную ли́нию** телефон линиясе үткәрү 4. *кого-что* (*тащить*) сөйрәү, өстерәү, тарту, тартып бару; **парохо́д тя́нет ба́ржу** пароход баржа тартып бара 5. *кого* (*влечь, привлекать*) ...сы килү, күңел тарту; **меня́ тя́нет ко сну** *безл.* минем йокым килә 6. *кого-что, разг.* (*убеждать пойти куда-л.*) өстерәү, сөйрәү, тарту; **~ в кино́** кинога өстерәү 7. (*обладать тягой*) тарту; **пе́чка хорошо́ тя́нет** мич яхшы тарта 8. *безл. чем* (*о струе воздуха, о запахе*) аңку, исү, бәрү, килү; **тя́нет хо́лодом от окна́** тәрәзәдән салкын бәрә 9. *что* (*всасывать, поглощать*) тарту, суыру; суырып эчү, чөмерү; **насо́с тя́нет во́ду** насос суны суыра; **~ чай с блю́дечка** чәйне тәлинкәдән чөмерү 10. *что* (*исполнять*) сузу; сузып җырлау; **~ пе́сню** җырны сузып җырлау 11. *что, с чем* (*медленно делать*) озакка сузу (җибәрү); **~ де́ло** эшне озакка сузу 12. (*весить*) тарту, килү; **тюк тя́нет 50 кило́** тюк илле кило тарта ♦ **~ жи́лы** *из кого кемнең дә булса* жилеген суыру; **~ за язы́к** *кого* көчләп сөйләтү

тяну́ться *несов.* 1. (*увеличиваться в длину, ширину*) сузылу; **рези́на тя́нется** резина сузыла 2. (*расправлять руки, ноги*) киерелү 3. үрелү, сузылу, алырга тырышу; **~ за мячо́м** тупка үрелү 4. (*простираться*) сузылу, сузылып китү; җәелү, җәйрәү, җәйрәп яту; **за дере́вней тя́нутся поля́** авыл аръягында кырлар сузылып китә 5. (*длиться*) сузылу, дәвам итү, үту; **вре́мя тя́нется до́лго** вакыт әкрен үтә 6. *к кому-чему* (*поворачиваться, направляться*) тартылу, сузылу; **цвето́к тя́нется к со́лнцу** чәчәк кояшка таба тартыла 7. (*двигаться один за другим*) бер-бер артлы бару, сузылу; **тя́нутся обо́зы** обозлар сузыла 8. *перен. за кем-чем, разг.* (*стремиться сравняться*) тиңләшергә тырышу; **~ за това́рищами** иптәшләре белән тиңләшергә тырышу 9. *страд. от* **тяну́ть** 1-4, 6, 9-12

тяп *межд.* **тя́п да ля́п** *или* **тя́п-ля́п** әштер-өштер (эшләү)

тя́пка *ж* 1. тәпке, чапкы 2. (*мотыга*) китмән, мотыга

У

у I *межд.* 1. (*выражает укоризну, угрозу, негодование*) һай, әй, ух; **у, бесстыдник!** һай, оятсыз! 2. (*выражает испуг, страх*) ah, абау; **у, как стра́шно!** абау, нинди куркыныч! 3. (*выражает одобрение, восторг, восхищение*) ай-яй, ай-һай; **у, как хорошо́!** ай-яй, нинди әйбәт!

у II *предлог с род.п.* 1. (*около, возле*) янында, буенда, алдында, катында, төбендә; **дом у са́мого бе́рега** яр буендагы өй; **стоя́ть у воро́т** капка төбендә басып тору; **у две́ри** ишек катында 2. (*при, вместе*) ...да, белән бергә; **жить у роди́телей** әти-әни белән бергә тору; **у нас сего́дня гость** бүген бездә кунак бар 3. (*при указ. обладателя, владельца*) ...ның; **у певца́ си́льный го́лос** җырчының тавышы көчле 4. (*при указ. на источник получения чего-л.*) ...дан; **спроси́ть у учи́теля** укытучыдан сорау; **купи́ть кни́гу у букини́ста** букинисттан китап сатып алу 5. (*при указ. лиц, с участием к-рых что-л. происходит*) ... ны; **вы́играть па́ртию в ша́хматы у това́рища** бер партия шахмат уйнап ептәшеңне оту ♦ **быть не у дел** эшсез йөрү, хезмәттә булмау

у[2] *алкушымча, фигыль ясауда кулланылып, татар теленә түбәндәге чаралар ярдәмендә тәрҗемә ителә*; 1. *«китү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **увезти́** алып китү; **улете́ть** очып китү; **ускака́ть** чабып китү 2. *«кыскарту» дигән фигыль ярдәмендә. мәс.* **уре́зать** киселән кыскарту; **уши́ть** бөгеп кыскарту 3. *«чыгу» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **убели́ть** агартып чыгу; **устла́ть** җәеп чыгу 4. *«бетерү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **умести́ть** сыйдырып бетерү 5. *«җитү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **упе́чься** пешеп җитү; **уки́снуть** әчеп җитү 6. *«калу» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **убере́чь** саклап калу; **удержа́ть** тотып калу 7. *«кую» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **уго́товить** хәзерләп кую; **упря́тать** яшереп кую 8. *«төшү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **улу́чшить** яхшырта төшү 9. *«алу» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **унасле́довать** мирас итеп алу; **усынови́ть** уллыкка алу 10. *«бирү» дигән дәрәҗә фигыле ярдәмендә, мәс.* **увеща́ть** үгет-нәсихәт бирү; **удостове́рить** таныклык бирү 11. *«тутыру» дигән фигыль ярдәмендә, мәс.* **усе́ять** чәчеп тутыру; **усы́пать** сибеп тутыру 12. *«киму» дигән фигыль ярдәмендә, мәс.* **усо́хнуть** кибә-кибә кимү; **угоре́ть** янып кимү 13. *кайбер приставкалы фигыльләрнең бары тик төп фигыле генә тәрҗемә ителә, мәс.* **ужа́лить** чагу; **укра́сть** урлау

уба́ви||ть *сов.* 1. *что* киметү, азайту, әкренәйтү; **~ть це́ну** бәяне киметү; **~ть ско́рость** тизлекне киметү 2. *что и без доп.* кыскарту, кечерәйтү, тарайту; **~ть рукава́** җиңнәрне кыскарту 3. *в чём, разг.* авырлык кимү, ябыгу; **больно́й ~л в ве́се** авыруның авырлыгы кимегән

уба́ви||ться *сов.* кимү, азаю, кыскару; **воды́ в о́зере ~лось** күлдә су кимегән; **дни ~лись** көннәр кыскарды

убавле́ние *с см.* **уба́вить, уба́виться**

убавля́ть *несов. см.* **уба́вить**

убавля́ться *несов.* 1. *см.* **уба́виться**; 2. *страд. от* **убавля́ть**

убаю́кать *сов.* 1. *кого* тирбәтеп йоклату; әлли-бәлли итеп йоклату; **~ ребёнка** баланы тирбәтеп йоклату 2. *кого* (*нагнать дремоту*) оету, йокымсырату, йокыны китерү 3. *перен. кого-что* (*успокоить*) юату, тынычландыру

убаю́кивание *с см.* **убаю́кать**

убаю́кивать *несов. см.* **убаю́кать**

убега́||ть *несов.* 1. *см.* **убежа́ть**; 2. (*быстро удаляться, перемещаться*) агылу 3. сузылу; **тропи́нка ~ла далеко́ в лес** сукмак бик ераккa урманга хәтле үк сузылган

убе́гаться *сов. разг.* (*устать*) йөгерә-йөгерә арып бетү, йөгереп йөреп хәлдән таю

убеди́тельность *ж* ышандырырлык булу, нигезле булу, нигезлелек; **~ до́водов** дәлилләрнең нигезлелеге

убеди́тельн||ый, -ая, -ое 1. ышандырырлык, ышандыра торган, инандырырлык; **~ый отве́т** ышандырырлык җавап 2. үтенүле, ялварулы, үтенеп, ялварып, гозерләп; **~ая про́сьба** үтенеп сорау

убеди́ть *сов. кого-что* 1. *в чём* ышандыру, инандыру; **~ слу́шателей в свое́й правоте́** тыңлаучыларны үзеңнең хаклы икәнлегеңә ышандыру 2. *с неопр.* күндерү; **~** *кого-л.* **лечи́ться** *берәрсен* дәваланырга күндерү

убеди́ться *сов. в чём* ышану, инану; **~ в и́скренности** *кого-л. кемнең дә булса* ихласлыгына ышану

убежа́||ть *сов.* 1. йөгереп китү, йөгерү; **де́ти ~ли в лес** балалар урманга йөгерделәр 2. качу, качып китү (чыгу), чыгып качу; **кро́лик ~л из кле́тки** кролик читлектән чыгып качкан 3. *разг.* ташу, ташып түгелү; **молоко́ ~ло** сөт ташып түгелгән

убежда́ть *несов. см.* **убеди́ть**

убежда́ться *несов.* 1. *см.* **убеди́ться**; 2. *страд. от* **убежда́ть**

убежде́ни||е *с* 1. *см.* **убеди́ть** 1, **убеди́ться**; 2. караш, ныклы фикер, мәсләк; **отста́ивать свои́ ~я** үз карашларыңны яклау

убеждённость *ж* ышанганлык, ышанган булу, инанганлык; **~ в своей правоте́** үзеңнең хаклы икәнлегеңә инанганлык

убеждённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **убеди́ть**; 2. ышанган, инанган; **говори́ть ~ым го́лосом** ныклы ышанган тавыш белән сөйләү 3. тайпылмас, какшамас, ныклы торучан; **~ый революционе́р** тайпылмас революционер

убе́жищ||е *с* 1. сыенырурын, яшеренер урын, ышыклурын; **иска́ть ~е от зно́я** эсселектән сыенырурын эзләү 2. *юр.* сыену; **пра́во ~а** сыену хокукы (*бер ил тарафыннан эзәрлекләнүче кешеләрнең икенче ил химаясендә яшәү хокукы*) 3. убежище (*һава хәҗүменнән саклану өчен махсус эшләнгән ныгытма*)

убел||и́ть *сов. кого-что, книжн.* агартып чыгу, агарту, агартып бетерү, чал кертү; **вре́мя ~и́ло его́ го́лову** вакыт аның чәчләренә чал керткән; **~ённый седино́й** чәчләренә чал кергән

убеля́ть *несов. см.* **убели́ть**

уберега́ть *несов. см.* **убере́чь**

уберега́ться *несов.* 1. *см.* **убере́чься**; 2. *страд. от* **уберега́ть**

убере́чь *сов. кого-что* саклап [алып] калу, саклау; **~ ребёнка от просту́ды** баланы салкын тиюдән саклап калу; **~ ве́щи от мо́ли** әйберләрне көядән саклап калу

убере́чься *сов.* саклану, сакланып калу; **~ от просту́ды** салкын тиюдән саклану

убива́ть *несов. см.* **уби́ть**

убива́ться *несов.* 1. *см.* **уби́ться**; 2. *страд. от* **убива́ть**; 3. *о ком-чём, по кому-чему и без доп., прост.* (*сильно горевать*) ачыну, бик нык кайгыру, [чиктән тыш] хәсрәтләнү, үтә борчылу, өзгәләнү, ачыргалану 4. бар көченә бирептырышу, хәлдән тайганчы көчәнү; **сто́ит ли ~ ра́ди де́нег?** акча дигән булып хәлдән тайганчы көчәнү кирәкме икән?

уби́йственн||ый, -ая, -ое 1. (*непереносимый*) түзеп булмаслык, чыдый алмаслык; **~ая жара́** түзеп булмаслык эсселек 2. *перен. разг.* (*поразительный*) чамадан тыш, искиткеч, гаҗәеп, коточкыч, котчыккыч; **~ое хладнокро́вие** искиткеч салкын канлылык

уби́йство *с* үтереш, үтерү; **предумы́шленное ~** усал ният белән (алдан уйлап) эшләнгән үтерү; **полити́ческое ~** политик үтереш

уби́йца *м, ж* кеше үтерүче, катыйль

убира́ть *несов. см.* **убра́ть**

убира́||ться *несов.* 1. *см.* **убра́ться**; 2. *страд. от* **убира́ть** ♦ **~йся [вон]!** күземә күренәсе булма!, югал күз алдымнан!

уби́тый, -ая, -ое 1. *прич. от* **уби́ть** 1; 2. *в знач. сущ. м* үтерелгән кеше, үлгән кеше, үлек 3. *перен.* хәсрәтле, кайгылы, каты кайгыга төшкән, кайгы баскан; **~ вид** кайгы баскан кыяфәт ♦ **спать как ~** үлгән кешедәй йоклау

уби́ть *сов.* 1. *кого* үтерү, башын бетерү, башына җитү, һәлак итү, җанын кыю 2. *перен. кого-что* каты кайгыга салу, хәсрәткә төшерү; өметсезлеккә төшерү; **печа́льное изве́стие мо́жет его́ ~** кайгылы хәбәр аны өметсезлеккә төшерергә (батырырга) мөмкин 3. *перен. что* юк итү, юкка чыгару, бетерү; **~ все наде́жды** өметләрне юкка чыгару 4. *перен. что, разг.* әрәм (исраф) итү; **~ вре́мя** вакыт әрәм итү

уби́ться *сов. прост.* (*ушибиться*) имгәнү; **~, упа́в с ло́шади** аттан егылып имгәнү

ублаготвори́ть *сов. кого-что, ирон.* канәгатьләндерү, [күңелен] хушландыру, күңелен күрү

ублаготворя́ть *несов. см.* **ублаготвори́ть**

ублажа́ть *несов. см.* **ублажи́ть**

ублажи́ть *сов. кого-что, разг.* күңелен күрү, юмалап күңелен табу

ублю́док *м прост.* 1. *уст.* (*помесь — о животных*) азман, кушылгак 2. *перен. бран.* адәм актыгы

убо́р||ий, -ая, -ое 1. фәкыйрь, ярлы; **~ое жили́ще** фәкыйрь торак 2. *перен.* сай, сыек, бик ярлы; **~ое воображе́ние** бик ярлы хыял 3. *разг.* гарип, зәгыйфь, мескен; **~ая стару́ха** гарип карчык

убо́гость *ж*, **убо́жество** *с* 1. (*бедность*) фәкыйрьлек, ярлылык 2. *перен.* сайлык, ярлылык, мескенлек; **~ мы́слей** фикер сайлыгы

убо́й *с спец.* сую, чалу, сугым ♦ **корми́ть (пои́ть) на ~** сугымга симертү; **посыла́ть на ~** үлемгә җибәрү

убо́йн||ый, -ая, -ое 1. сугым ...ы; **~ый скот** сугым малы; **~ый вес** сугым авырлыгы 2. үтерү ...ы, кыру ...ы; **~ая мо́щность артиллери́йского огня́** артиллерия утының үтерү көче

убо́р *м уст.* кием; **сва́дебный ~** туй киемнәре

убо́ристый, -ая, -ое тыгыз, еш; **~ почерк** тыгыз почерк

убо́рка *ж* 1. *см.* **убра́ть** 1, 2, 4; **~ помеще́ния** бүлмәне җыештыру; **~ урожа́я** игеннәрне үрып-җыю; **~ карто́феля** бәрәңге алу; **разде́льная ~** аеры урып-җыю 2. *см.* **убо́рочная**; **наступи́ла ~** урак өсте җитте

убо́рная *ж* 1. *театр.* киенү бүлмәсе 2. бәдрәф, әбрәкәй

убо́роч||ная *ж* урып-җыю, урып-җыю вакыты, урак өсте; **все за́няты на ~ной** барысы да урып-җыюда эшлиләр

убо́рочн||ый, -ая, -ое урып-җыю ...ы; **~ые маши́ны** урып-җыю машиналары; **~ая кампа́ния** урып-җыю кампаниясе

убо́рщик *м* җыештыручы

убо́рщица *ж* җыештыручы хатын (кыз)

убра́нство *с* 1. (*меблировка, сервировка и т.п.*) җиһаз, йорт җиһазлары; зиннәтләү (бизәү) әйберләре 2. *перен.* (*наряд, украшение*) бизәнү, киенү, кием

убра́ть *сов.* 1. *кого-что* җыеп алу, җыештырып (җыеп) кую, алып кую; **~ посу́ду со стола́** өстәлдән савыт-сабаны җыеп алу; **~ кни́гу в шкаф** китапларны шкафка алып кую 2. *что* урып-җыю, җыеп алу; **~ зерновы́е** бөртекле ашлыкларны урып-җыю 3. *кого-что* кыскарту, төшереп калдыру; **~ из по́вести длинноты́** повестьтагы күп сүзле урынларны кыскарту 4. *что* җыештыру; **~ помеще́ние** бүлмәне җыештыру 5. *кого-что* бизәү, матурлау, җиһазлау; киендерү; **~ ко́мнату цвета́ми** бүлмәне чәчәкләр белән бизәү; **~ неве́сту** *уст.* кәләшне киендерү

убра́ться *сов.* 1. *разг.* җыештырыну; **~ к пра́зднику** бәйрәмгә каршы җыештырыну 2. *прост.* китү, чыгып китү, ычкыну; **~ подобру́-поздорову́** яхшы чакта чыгып ычкыну 3. *уст.* (*наряди́ться*) киенү, киенү-ясану, бизәнү

убыва́ние *с см.* **убы́ть**

убыва́ть *несов. см.* **убы́ть**

у́быль *ж* 1. кимү, азаю, кайту; **вода́ пошла́ на ~** су кими башлаган 2. кимегән өлеш, зарар, зыян; **возмести́ть ~** күрелгән зыянны каплау

убыстри́ть *сов. что, разг.* тизләтү, кызулату, җәһәтләтү, ашыктыра төшү; **~ произво́дственные проце́ссы** җитештерү процессларын тизләтү; **~ шаг** адымны кызулату

убыстри́ться *сов. разг.* тизләнү, тизләнә төшү, тизлеге арту, җәһәтләнә төшү

убыстря́ть *несов. см.* **убыстри́ть**

убыстря́ться *несов.* 1. *см.* **убыстри́ться**; 2. *страд. от* **убыстря́ть**

убы́т||ок *м* зыян, зарар; **терпе́ть ~ки** зыян күрү; **возмести́ть ~ки** зыянны каплау

убы́точность *ж* зыянлылык, зыянлы булу, зарар күреп эшләү

убы́точн||ый, -ая, -ое зыянлы, зарарлы, зарар китерә торган

убы́||ть *сов.* 1. кимү, азаю, кайту; **вода́ ~ла́** су кайткан; **си́лы у́были** көчләр азайды 2. *офиц.* (*выбыть из состава*) китү, чыгу; **~ть из полка́** полктан китү

уважа́емый, -ая, -ое хөрмәтле, мөхтәрәм, могтәбәр

уважа́ть *несов. кого-что* 1. ихтирам итү, хөрмәтләү, олылау; **~ ста́рших** өлкәннәрне ихтирам итү 2. (*считаться с кем-чем-л.*) тәкъдир итү, санлау, исәпләшү; **~ поря́док** тәртипне тәкъдир итү

уваже́ни||е *с* хөрмәт, кадер-хөрмәт, ихтирам, олылау, ихтирам итү; **~е прав челове́ка** кеше хокукларын ихтирам итү; **досто́йный ~я** хөрмәткә лаеклы

уважи́тельн||ый, -ая, -ое 1. игътибарга алырлык, гафу итәрлек, кичерерлек, нигезле; **~ая причи́на** нигезле сәбәп 2. ихтирамлы, хөрмәт итә торган; **~ое отноше́ние** ихтирамлы мөнәсәбәт

ува́жить *сов.* 1. *что, разг.* игътибарга алу, үтәү, кире какмау, канәгатьләндерү; **~ чью-л. про́сьбу** *кемнең дә булса* үтенечен канәгатьләндерү 2. *кого-что, прост.* олылау, күңелен күрү, хөрмәтләү; **~ старика́** карт кешене хөрмәтләү

у́валень *м разг.* авыр сөякле кеше, нәкәс кеше, сүлпән кеше

ува́ривать *несов. см.* **уварі́ть**

ува́риваться *несов.* 1. *см.* **уварі́ться**; 2. *страд. от* **ува́ривать**

уварі́ть *сов. что* 1. *разг.* пешереп житкерү; **~ ку́рицу** тавыкны пешереп житкерү 2. (*кипячением уменьшить объём чего-л.*) кайнатып кимету, кайната-кайната азайту

уварі́||ться *сов. разг.* 1. пешеп житу, пешеп чыгу; **мя́со ещё не ~лось** ит пешеп житмәгән әле 2. (*уменьшиться от варки*) кайнап [күләме] кимү, кайный-кайный күләме азаю

уведоми́тель *м офиц.* белдерүче, хәбәр итүче

уведоми́тельн||ый, -ая, -ое *офиц.* хәбәр итү ...ы, хәбәр итә торган, белдерү ...ы, белдерә торган; **~ое письмо́** хәбәр итү хаты

уве́домить *сов. кого-что, офиц.* хәбәр итү, белдерү; **~ о дне заседа́ния** утырышның көне турында хәбәр итү

уведомле́ние *с офиц.* 1. *см.* **уве́домить**; 2. (*документ*) белдерү кагәзе (хаты); **получи́ть ~** белдерү кәгазе алу

уведомля́ть *несов. см.* **уве́домить**

увезти́ *сов. кого-что* 1. алып китү (*атка, машинага һ.б.ш. утыртып яки төяп*); **~ детей в дере́вню** балаларны авылга алып китү 2. (*похитить*) урлап алып китү, үрлап китү

увекове́чение *с см.* **увекове́чить**

увекове́чивать *несов. см.* **увекове́чить**

увекове́чиваться *несов.* 1. *см.* **увековечи́ться**; 2. *страд. от* **увекове́чивать**

увекове́чить *сов. кого-что* мәңгеләштерү, гомерлеккә (мәңгегә) калдыру; **~ па́мять ста́вших геро́ев** һәлак булган батырларның истәлеген мәңгеләштерү

увекове́читься *сов.* мәңгеләшү, гомерлеккә (мәңгелеккә) калу, мәңгегә истәлек булып калу

увеличе́ние *с см.* **увели́чить, увели́читься**

увели́чивать *несов. см.* **увели́чить**

увели́чиваться *несов.* 1. *см.* **увели́читься**; 2. *страд. от* **увели́чивать**

увеличи́тель *м фото* зурайткыч

увеличи́тельн||ый, -ая, -ое 1. зурайтып күрсәтә торган, зурайта торган, зурайткыч; **~ое стекло́** зурайтып күрсәтә торган пыяла 2. *лингв.* артыклык ...ы; **~ые су́ффиксы** артыклык суффикслары

увели́чить *сов. что* 1. арттыру, күбәйтү, ишәйтү; **~ число́ рабо́чих** эшчеләр санын арттыру 2. зурайту, олайту, киңәйту; **~ портре́т** портретны зурайту; **~ пло́щадь посе́вов** чәчүлек мәйданын киңәйту 3. (*усилить*) көчәйту, арттыру

увели́чи||ться *сов.* 1. (*по количеству*) арту, күбәю, ишәю; (*по величине, объёму*) зураю, олаю, киңәю; **число́ уча́щихся ~лось** укучылар саны артты; **террито́рия па́рка ~лось вдво́е** парк территориясе ике тапкырга зурайган 2. (*усилиться*) көчәю, арту; **опа́сность ~лась** куркыныч артты

увенча́||ть *сов.* 1. *кого-что* венок кидерү; **~ть чемпио́на ла́вровым венко́м** чемпионга лавр веногы кидерү 2. *что чем* (*закончить собой верхнюю часть чего-л.*) очлап кую, очлау; **зда́ние ~ли ба́шней** бинаны манара белән очлаганнар 3. *перен. что* (*успешно завершить*) уңышлы төгәлләү, уңышлы тәмамлау

увенча́ться *сов. чем* (*успешно завершиться*) уңышлы төгәлләнү, уңышлы тәмамлану

уве́нчивать *несов. см.* **увенча́ть**

уве́нчиваться *несов.* 1. *см.* **увенча́ться**; 2. *страд. от* **уве́нчивать**

увере́ние *с* ышандыру, инандыру

уве́ренность *ж* ышанганлык, инанганлык, ныклы ышаныч, ышану; **~ в побе́де** җиңүгә ныклы ышаныч

уве́рен||ный, -ая, -ое 1. ышанган, ышанычлы, ышанулы; **~ным шагом** ышанычлы адым 2. нык ышанган, инанган; **~ным отве́т** инанган җавап ♦ **бу́дьте ~ы** ышаныгыз, борчылмагыз, шикләнмәгез

уве́рить *сов. см.* **убеди́ть** I; **~ в свое́й правоте́** үзеңнең хаклыгыңа ышандыру

уве́риться *сов. см.* **убеди́ться**; **~ *в чьей-л.* пре́данности** *кемнең дә булса* чын күңелдән бирелгәнлегенә инану

уверну́ться *сов. от кого-чего и без доп.* 1. тайпылу, читкә тайпылып калу; **~ от уда́ра** сугудан читкә тайпылып калу 2. *см.* **увильну́ть** 2; **~ от прямо́го отве́та** туры җаваптан качу

уве́ровать *сов. в кого-что, книжн.* ышану, инану; **~ *в чью-л.* и́скренность** *кемнең дә булса* ихласлыгына ышану

увёрт||ка *ж разг.* хәйлә, ялган сәбәп, әмәл, алдау-йолдау; **говори́ без ~ок** алдау-йолдаусыз гына сөйлә

увёртливость *ж разг.* 1. (*ловкость*) елгырлык, елдамлык, җитезлек 2. *перен.* (*хитрость*) хәйләгә осталык, алдау-йолдауга оста булу

увёртливый, -ая, -ое *разг.* 1. (*ловкий*) елгыр, елдам, җитез 2. *перен.* (*хитрый*) хәйләкәр, хәйләгә оста, алдау-йолдауга оста

увёртываться *несов. см.* **увернýться**

увертю́ра *ж муз.* увертюра (1. *операга, балетка, кинофильмга һ.б.ш. музыкаль кереш* 2. *оекстр өчен соната формасында язылган музыкаль әсәр*)

уверя́ть *несов. см.* **уве́рить**

уверя́ться *несов.* 1. *см.* **уве́риться**; 2. *страд. от* **уверя́ть**

увеселе́ни||е *с* 1. *см.* **увеселя́ть**; 2. тамаша, күңел ачу; **ма́ссовые ~я** күмәкләп күңел ачулар

увеселя́тельн||ый, -ая, -ое күңел ача торган, уен-көлкеле, хозурландыра торган, күңел ачу ...ы; **~ая прогу́лка** күнел ачу прогулкасы

увеселя́ть *несов. кого-что* күңелен ачу, кәефен күтәрү, хозурландыру; юату, көлдерү

уве́систый, -ая, -ое *разг.* 1. салмак, авыр; **~ ка́мень** авыр таш 2. *перен.* көчле, каты, нык; **~ уда́р** каты сугу

увести́ *сов. кого-что* 1. алып китү (*җитәкләп, куып, иреке зләп һ.б.ш.*); **~ детей домо́й** балаларны өйгә алып китү 2. (*украсть*) урлап алып китү (чыгу); **~ ло́шадь** атны урлап алып китү

уве́чить *несов. кого-что* имгәтү, гарипләндерү

уве́читься *несов.* 1. (*калечиться*) имгәнү, гарипләнү 2. *страд. от* **уве́чить**

уве́чный, -ая, -ое *уст.* гарип, имгәнгән

уве́чье *с* гариплек, имгәнү; имгәтү

уве́шать *сов. кого-чего* элеп (асып) бетерү, элеп (асып, тагып) тутыру; **~ сте́ны карти́нами** стеналарны картиналар элеп тутыру

УВЕ-УГЛ

уве́шаться *сов.*, чем [үзеңә төрле әйберләр] тагын бетерү, асып бетерү

уве́шивать *несов. см.* **уве́шать**

уве́шиваться *несов.* **1.** *см.* **уве́шаться; 2.** *страд. от* **уве́шивать**

увеща́ние *с* **1.** *см.* **увеща́ть; 2.** (*наставление*) үгет-нәсихәт, дим

увеща́ть *несов. уст. см.* **увещева́ть**

увещева́ние *с см.* **увещева́ть**

увещева́ть *несов. кого-что* үгетләү, үгет-нәсихәт бирү; димләү

увива́ть *несов. см.* **уви́ть**

увива́ться *несов.* **1.** *см.* **уви́ться; 2.** *за кем и без доп., разг.* (*вертеться возле кого-чего-л.*) чуалу, сырышу, куштанланып йөрү, бөтерелеп йөрү **3.** *страд. от* **увива́ть**

увида́ть *несов. разг. см.* **уви́деть**

увида́ться *несов. разг. см.* **уви́деться**

уви́де||ть *сов. кого-что* **1.** күрү, күреп алу; **я его́ ~л и́здали** мин аны ерактан ук күреп алдым; **~ть ста́рого дру́га** иске дусны күрү **2.** (*осознать, понять*) күрү, аңлау, аңлап алу; **он ~л, что опозда́л** ул кичеккәнлеген аңлады ◆ **поживём — уви́дим** исән булсак күрербез; **~ть свет** дөнья күрү, басылып чыгу (*мәс. китап турында*)

уви́деться *сов. с кем и без доп.* күрешү, очрашу

уви́ливать *несов. см.* **увильну́ть**

увильну́ть *сов. разг.* **1.** *от кого-чего* тайпылу, тайпылып калу; **~ от уда́ра** сугудан тайпылып калу **2.** *перен. от чего* хәйләләп котылу; сызу, таю, качу; **~ от ответственности** җаваплылыктан качу

уви́||ть *сов. кого-что, разг.* урау, үрү, чорнау, урап (үреп, чорнап) алу; **цветы́ ~ли терра́су** чәчәкләр террасаны үреп алган

уви́ться *сов. разг.* (*о растительности*) урап (үреп, чорнап) алу, үрелеп үсү

увлажне́ние *с см.* **увлажни́ть, увлажни́ться**

увлажни́тель *м* дымландыргач, дымлаткыч

увлажни́тельн||ый, -ая, -ое дымландыру ...ы; **~ая маши́на** дымландыру машинасы

увлажни́ть *сов. что* дымландыру, дымландырып җибәрү, юешләндерү, юешли төшү, чыландыру

увлажни́ться *сов.* дымлану, дымланып китү, юешләну, юешләнә төшү, чылану

увлажня́ть *несов. см.* **увлажни́ть**

увлажня́ться *несов.* **1.** *см.* **увлажни́ться; 2.** *страд. от* **увлажня́ть**

увлека́тельность *ж* мавыктыргыч булу, кызыклылык

увлека́тельный, -ая, -ое мавыктыргыч, кызыклы, сокландыра торган; **~ расска́з** мавыктыргыч хикәя

увлека́ть *несов. см.* **увле́чь**

увлека́ться *несов.* **1.** *см.* **увле́чься; 2.** *страд. от* **увлека́ть**

увлека́ющийся, -аяся, -еяся **1.** *прич. от* **увлека́ться**; **2.** мавыгучан, кызыксынучан, кызыксынучан табигатле; **~ю́ноша** кызыксынучан табигатле егет **3.** (*легко влюбляющийся*) бик тиз гашыйк булучан, чуар йөрәкле

увлече́ние *с* **1.** (*пыл, воодушевление*) күтәренке рух, дәрт **2.** *кем-чем* мавыгу, бирелү; **~ футбо́лом** футбол белән мавыгу **3.** (*влюблённость*) күңеле төшү, күзе төшү, гашыйклык

увлечённость *ж* мавыкканлык; **~ матема́тикой** математика белән мавыкканлык

увле́чь *сов.* **1.** *кого-что* ияртеп (кызыктырып, ирексезләп, сөйрәп *һ.б.ш.*) алып китү; **пото́к воды́ увлёк ло́дку** су ташкыны көймәне агызып алып киткән **2.** *перен. кого-что* күңелен биләү, мавыктыру; **рабо́та увлекла́ его́** эш аның бөтен күңелен биләгән **3.** *перен. кого-что* сокландыру, таңга калдыру; **игра́ актёра увлекла́ зри́телей** актёрның уйнавы тамашачыларны таңга калдырды **4.** *кого-что* (*влюбить в себя*) яраттыру, сөйдерү, күңелен җәлеп итү

увле́чься *сов.* **1.** *кем-чем* мавыгу, бирелү, мавыгып (бирелеп) китү; әвәрә булу; **~ кни́гой** китап белән мавыгу; **~ футбо́лом** футбол белән әвәрә булу **2.** *кем* (*влюбиться*) күңеле төшү, күзе төшү, гашыйк булу, сөю

уво́д *м* **1.** *см.* **увести́**; **2.** *тех.* (*смещение*) күчү; **~ автомоби́льного колеса́** автомобиль тәгәрмәченең күчүе

уводи́ть *несов. см.* **увести́**

увози́ть *несов. см.* **увезти́**

увола́кивать *несов. см.* **уволо́чь**

уво́л||ить *сов. кого-что* **1.** чыгару, эштән чыгару, азат итү; **~ить с рабо́ты** эштән чыгару **2.** коткару, арындыру; **~ьте меня́ от ли́шних хлопо́т** артык мәшәкатьләрдән коткарыгыз мине

уво́литься *сов.* чыгу, эштән чыгу, хезмәттән китү; **~ с рабо́ты** эштән чыгу

уволо́чь *сов. кого-что, прост.* сөйрәп (өстерәп) алып китү; **~ мешо́к в подва́л** капчыкны өстерәп подвалга алып китү

увольне́ние *с см.* **уво́лить** I

увольни́тельн||ый, -ая, -ое **1.** чыгару ...ы, отпускка чыгару ...ы, азат ителгәнлекне раслый торган; **~ая запи́ска** азат ителгәнлекне раслый торган язу **2.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж воен.* увольнительный (*документ*)

увольня́ть *несов. см.* **уво́лить** I

увольня́ться *несов.* **1.** *см.* **уво́литься; 2.** *страд. от* **увольня́ть**

увуля́рн||ый, -ая, -ое *лингв.* увуляр (*кече тел ярдәме белән әйтелә торган*); **~ые согла́сные** увуляр тартыклар

увы́ *межд.* (*выражает сожаление*) и-их, э-эх, ah

увяда́ние *с см.* **увя́нуть**

увяда́ть *несов. см.* **увя́нуть**

увя́дш||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **увя́нуть**; **2.** *прям. перен.* сулган, шиңгән, пәжгән; **~ие ли́стья** пәжгән яфраклар; **~ая красота́** сулган матурлык

увяза́ть I *несов. что* **1.** бәйләү, урап (төреп) бәйләү; **~ ве́щи** әйберләрне төреп бәйләү **2.** *перен.* бәйләү, яраштыру; **~ тео́рию с пра́ктикой** теорияне практика белән бәйләү

увяза́ть II *несов. см.* **увя́знуть**

увяза́||ться *сов.* **1.** *прост.* (*связать, упаковать вещи*) әйберләрне җыеп төенләү (бәйләү-төенләү) **2.** *перен. за кем-чем, разг.* тагылу, иярү, ияреп китү, арттан калмый ияреп бару; **за на́ми ~лся щено́к** бер көчек артыбыздан калмый ияреп барды

увя́зка *ж см.* **увяза́ть** I

увя́знуть *сов. в чём* **1.** батып калу, бату; **~ в снегу́** карга бату **2.** *перен.* (*запутаться*) буталып калу, буталу, бату

увя́зывать *несов. см.* **увяза́ть**

увя́зываться *несов.* **1.** *см.* **увяза́ться; 2.** *страд. от* **увя́зывать**

увя́||нуть *сов. прям., перен.* сулу, шиңү; пәжү; **цветы́ ~ли** чәчәкләр сулган; **красота́ её́ ~ла** аның чибәрлеге сулган

угада́ть *сов.* **1.** *что* белү, сизү, белеп алу; **~ чью-л. мысль** *кемнең дә булса* фикерен белеп алу **2.** (*случайно оказаться правым*) туры китерү, өстенә басу **3.** (*предугадать*) алдан белү; **~ пого́ду** һава хәлен алдан белү

уга́дывать *несов. см.* **угада́ть**

уга́р I *м* **1.** (*газ*) ис, сөрем **2.** *перен.* исереклек, сөрем; **любо́вный ~** мәхәббәт исереклеге; **в пья́ном ~е** исереклек сөремендә

угар II *м спец.* **1.** янып (эреп) киму **2.** *обычно мн.* **~ы** калдык-постык, чүбек (*мәс. текстиль промышленности*)

уга́рн||ый I, -ая, -ое ис ...ы, сөрем ...ы, исле; **~ый газ** *хим.* ис газы; **~ый за́пах** сөрем исе; **~ая ба́ня** исле мунча

уга́рн||ый II, -ая, -ое *спец.* чүбек ...ы, калдык-постыктан эрләнгән; **~ая пря́жа** калдык-постыктан эрләнгән җеп

угаса́ние *с см.* **уга́снуть**

уга́с||нуть *сов.* **1.** сүнү; **костёр уга́с** учак сүнде **2.** *перен.* суыну, сүрелү, сүну, бетү, басылу; **любо́вь ~ла** мәхәббәт сүрелде **3.** *перен.* (*умереть*) үлү, җан бирү

углеводоро́ды *мн.* (*ед.* **углеводоро́д** *м*) *хим.* углеводородлар (*углерод белән водородтан торган органик кушылмалар*)

углево́ды *мн.* (*ед.* **углево́д** *м*) *биол., хим.* углеводлар (*углерод, водород һәм кислородтан торган матдәләр*)

угледобыва́ющ||ий, -ая, -ее күмер чыгару ...ы, ташкүмер чыгару ...ы; **~ая промы́шленность** күмер чыгару промышленносте

угледобы́ча *ж* күмер чыгару, ташкүмер чыгару

угледроби́льн||ый, -ая, -ое күмер ваклагыч, ташкүмер ваклый торган; **~ая маши́на** күмер ваклагыч машина

углежже́ние *с спец.* күмер яндыру, күмер алу өчен агач яндыру

углежо́г *м* күмер яндыручы, күмер алу өчен агач яндыручы

углекислота́ *ж хим.* углекислота

углеки́сл||ый, -ая, -ое *хим.* углекислоталы, углекислый; **~ое соедине́ние** углекислоталы кушылма; **~ый газ** углекислый газ

углеко́п *м уст.* ташкүмер казучы

углено́сн||ый, -ая, -ое таш күмере булган, таш күмерле; **~ые пласты́** ташкүмерле катламнар

углепромы́шленность *ж* ташкүмер промышленносте, күмер промышленносте

углепромы́шленный, -ая, -ое ташкүмер чыгару ...ы, күмер чыгару ...ы; **~ райо́н** ташкүмер чыгару районы

углеро́д *м хим.* углерод

углеро́дист||ый, -ая, -ое *хим.* углеродлы; **~ая сталь** углеродлы корыч

углеро́дн||ый, -ая, -ое *хим.* углерод ...ы; **~ые а́томы** углерод атомнары

углова́тость *ж* **1.** (*неровность*) почмаклы-почмаклы булу, керентеле-чыгынтылы булу **2.** *перен.* (*неуклюжесть*) авыр гәүдәлелек, тупас хәрәкәтлелек, килбәтсезлек

углова́т||ый, -ая, -ое **1.** почмаклы-почмаклы, керентеле-чыгынтылы, чыгып тора торган; **~ые ску́лы** чыгып тора торган яңак сөяге **2.** авыр гәүдәле, тупас хәрәкәтле, килбәтсез; **~ые движе́ния** килбәтсез хәрәкәтләр

углов||о́й, -а́я, -о́е **1.** почмак ..., почмак ясап тора торган; **~о́й вы́ступ** почмак ясап тора торган чыгынты **2.** почмактагы, почмак ...; **~а́я ко́мната** почмак бүлмә; **~о́й дом** почмактагы йорт **3.** *спец.* почмакча ...; **~а́я ско́рость** почмакча тизлек ♦ **~о́й уда́р** *спорт.* почмактан торып тибү (*мәс. футбол уенында*)

угломе́р *м тех.* почмак улчәгеч (*прибор*)

углуби́ть *сов. что* **1.** тирәнәйтү, тирәнәйтә төшү; **~ я́му** чокырны тирәнәйтү **2.** *перен.* тирәнәйтү, тулыландыру, арттыру; **~ свои́ зна́ния** белемнене тирәнәйтү **3.** (*вбить глубже*) тирәнрәк кагу, батыра төшү; **~ сва́ю** субайны батыра төшү

углуби́||ться *сов.* **1.** тирәнәю, тирәнәя төшү; **я́ма ~лась** чокыр тирәнәйгән **2.** *перен.* тирәнәю, тулылану; кискенләшү; **его́ зна́ния ~лись** аның белемнәре тирәнәйгән **3.** *во что* эчкәрәк керү; **~ться в лес** урманның эченәрәк керү **4.** *перен. во что* кереп китү, бирелү; чуму, бату; **~ться в изуче́ние литерату́ры** әдәбият өйрәнүгә бирелү ♦ **~ться в себя́** уйга чумып онытылу

углубле́ние *с* **1.** *см.* **углуби́ть, углуби́ться; ~ проце́сса разря́дки** киренкелекне йомшарту процессының тирәнәюе **2.** (*выемка, впадина*) уем, иңкүлек, чокыр, батынкылык

углублённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **углуби́ть**; **2.** тирәнтен, нигезле, төпле; **~ое изуче́ние литерату́ры** әдәбиятны тирәнтен өйрәнү **3.** бирелгән, чумган, баткан; **~ый в размышле́ния** уйга чумган

углубля́ть *несов. см.* **углуби́ть**

углубля́ться *несов.* **1.** *см.* **углуби́ться**; **2.** *страд. от* **углубля́ть**

угляд||е́ть *сов. прост.* **1.** *кого-что* (*увидеть*) күрү, [карый торгач] күреп алу **2.** *за кем-чем* күзәтеп (карап торып) саклап калу, күз-колак булу, күреп бетерү; **за всем не ~и́шь** барысын да күреп бетерә алмассың

угна́ть *сов. кого-что* **1.** куып алып китү, куа китү; **~ табу́н в степь** ат көтүен далага куып алып китү **2.** (*похитить*) урлап китү; **~ маши́ну** машинаны урлап китү

угна́ться *сов. за кем-чем* **1.** куып җитү, йөгереп артынан җитү, куып җитә алу; **за хоро́шим бегуно́м не ~** яхшы йөгерүче артыннан куып җитеп булмый **2.** *перен. разг.* артыннан җитә алу, ярыша алу, тиңләшү; **в учёбе за ним не ~** укуда аның артыннан җитеп булмый

угнезди́||ться *сов. разг.* оялау; **ча́йки ~лись в рассе́лине скалы́** акчарлаклар кыядагы ярыкка кереп оялаганнар

угнета́тель *м* изүче, җәберләүче, залим

угнета́||ть *несов. кого-что* **1.** (*притеснять, эксплуатировать*) кысу, изү, җәберләү, золым итү, эксплуатацияләү **2.** [күңелне] җәфалау, [күңелне] җәберләү; **его́ ~ют мра́чные мы́сли** аның күңелен күнелсез уйлар җәфалый

угнете́ние *с* **1.** *см.* **угнета́ть**; **2.** (*подавленное состояние*) боеклык, күңел боеклыгы, төшенкелек, күңел (рух) төшенкелеге

угнетённость *ж* **1.** изелгәнлек, изелгән булу, җәберләнгән булу **2.** *см.* **угнете́ние** 2

угнетённ||ый, -ая, -ое **1.** (*притесняемый, эксплуатируемый*) җәберләнгән, изелгән **2.** *перен.* боек, төшенке; **~ое настрое́ние** төшенке күңел

угова́ривать *несов. см.* **уговори́ть**

угова́риваться *несов.* **1.** *см.* **уговори́ться**; **2.** *страд. от* **угова́ривать**

уговор *м* **1.** *см.* **уговори́ть**; **2.** (*взаимное соглашение*) күешкан сүз, сүз беркетү, килешү, шарт, вәгъдә; **де́йствовать по ~у** килешеп эш итү; **~ доро́же де́нег** *посл.* ≈ вәгъдә — иман

уговори́||ть *сов. кого-что* **1.** *с неопр.* күндерү, димләп күндерү, ризалаштыру; **он ~л друзе́й пойти́ с ним вме́сте** ул дусларын үзе белән бергә барырга күндерде **2.** *разг.* (*успокоить*) көйләү, юату, тынычландыру

уговори́||ться *сов. с кем-чем и с неопр., разг.* вәгъдәләшү, сүз куешу, сүз беркетү, сүз берләшү; килешү; **мы ~лись пойти́ в театр** театрга барырга вәгъдәләштек

уго́д||а *ж*: **в ~у** *кому-чему кемнең дә булса* теләген үтәп, *кемгә дә булса* ярарга тырышып, ярамсакланып

уноди́||ть *сов.* **1.** *кому-чему, на кого-что* канәгатьләндерү, күңелен табу, ярау; **всем (на всех) не ~шь** бар кешегә дә ярый алмассың **2.** *во что, разг.* [өстенә] туры килү, барып чыгу, басу, төшү, эләгү; **лиса́ ~ла в капка́н** төлке капкынга эләккән; **~ть в я́му** чокырга барып төшү **3.** *в кого-что, кому во что, разг.* [атып] тидерү, [атып] туры китерү, [сугып] тидерү, тию; **~ть ка́мнем в окно́** таш атып тәрәзәгә тидерү; **пу́ля ~ла ему́ в плечо́** пуля аның иңбашына тигән

уго́дливость *ж* ярарга тырышучанлык, ялагайлык, тәлинкә тотучанлык, ярамсаклык

уго́длив||ый, -ая, -ое ярарга тырышучан, ялагай, тәлинкә тотучан, ярамсак; **~ая улы́бка** ялагай көмлемсерәү; **~ый челове́к** ярамсак кеше

уго́дник *м* **1.** *разг.* ярарга тырышучан кеше, ялагай кеше, тәлинкә тотучан кеше, ярамсак кеше **2.** (*святой*) әулия

уго́дничать *несов. разг.* ярарга тырышу, ярамсаклану, ялагайлану, ошарга тырышу, тәлинкә тоту; **~ пе́ред си́льным** көчле алдында ярарга тырышу

уго́дничество *с см.* **уго́дничать**

уго́дно **1.** *в знач. сказ. кому* кирәк, телисез; **что вам ~?** сез нәрсә телисез? **2.** *частица* булса да; теләсә; **како́й ~** теләсә нинди; **где ~** кайда булса да; **кто ~** кем булса да; **ско́лько ~** күпме булса да

уго́дный, -ая, -ое *кому* яраклы, кирәкле, теләгән, күнелгә хуш килә торган

уго́дь||е *с* жир-сулар; урманнар; файдаланыла торган җирләр; **ры́бные ~я** балыклы сулар; **охо́тничьи ~я** аучылык урманнары; **земе́льные ~я колхо́за** колхозның файдаланыла торган җирләре; **лесны́е ~я** урманнар

угожда́ть *несов. см.* **угоди́ть**

у́гол *м* **1.** *мат.* почмак; **о́стрый ~** кысынкы почмак; **тупо́й ~** җәенке почмак; **~ паде́ния** төшү почмагы; **~ отраже́ния** чагылу почмагы **2.** почмак, чат; **~ стола́** өстәл почмагы; **на углу́ у́лицы** урам чатында **3.** почмак [урын], сыенып урын, бүлмәнең бер өлеше; **име́ть свой ~** сыенып урынын булу ♦ **загна́ть в ~** китереп кысу; **из-за угла́** почмактан [торып], яшерен рәвештә, астыртын рәвештә; **ста́вить в ~** почмакка бастырып кую; **ходи́ть из угла́ в ~** әрле-бирле йөренү, ишекле-түрле йөренү; **пере́дний ~** түр, түр башы

уголо́вник *м* уголовник, уголовный җинаятьче, җинаятьче

уголо́вн||ый, -ая, -ое **1.** җинаять ...ы, җинаятьләр турындагы; **~ый ко́декс** җинаять кодексы **2.** уголовный, баш китәрлек; **~ое преступле́ние** уголовный җинаять ♦ **~ый ро́зыск** уголовный розыск (*милициядә җинаятьчеләрне эзләү булеге*)

уголо́вщина *ж разг.* **1.** (*уголовное дело*) уголовный эш, җинаять **2.** *собир.* (*уголовники*) [уголовный] җинаятьчеләр

уголо́к *м* **1.** *уменьш. от* **у́гол** 2, 3; **2.** почмак; **кра́сный ~** кызыл почмак

у́голь *м* күмер; **ка́менный ~** ташкүмер; **древе́сный ~** агач күмере ♦ **бе́лый ~** ак күмер (*суның көче*); **голубо́й ~** зәңгәр күмер (*җилнең көче*)

уго́льник *м* почмаклык (*линейканың бер төре*)

у́гольн||ый, -ая, -ое күмер ...ы, күмер чыгару ...ы, күмер чыгарыла торган; **~ые пласты́** күмер катламнары; **~ая ша́хта** күмер шахтасы; **~ая промы́шленность** күмер промышленносте

уго́льный, -ая, -ое *см.* **углово́й** 1, 2

у́гольщик *м* **1.** (*работник угольной промышленности*) күмер чыгаручы **2.** (*изготовитель древесного угля*) күмер яндыручы, күмерче

УГО-УДА

угомо́н *м*: **~ у нет** *на кого, разг.* тынгы юк, тынычлык бирмиләр

угомони́ть *сов. кого-что, разг.* тынычландыру, тыю; **~ дете́й** балаларны тынычландыру

угомони́||ться *сов. разг.* тынычлану, тыну; **де́ти ~лись** балалар тынычландылар

уго́н *м* **1.** *см.* **угна́ть; ~ самолёта** самолётны урлап китү

угоня́ть *несов. см.* **угна́ть**

угора́зди||ть *сов. кого-чего с неопр., разг.* мәҗбүр итү, кушу, котырту (*берәр кирәкмәгән эш эшләргә*); **~ло же его́ уе́хать** *кем* кушкан инде аңа китеп барырга

угора́ть I *несов. см.* **угоре́ть** I

угора́ть II *несов. см.* **угоре́ть** II

угоре́лый, -ая, -ое *уст.* ис тигән, ис тиеп чирләгән ♦ **как ~** ут капкандай; **бе́гать как ~** ут капкандай йөгерү

угоре́ть I *сов.* (*отравиться угаром*) ис тию, башка ис кабу

угореть II *сов. тех.* (*уменьшиться при плавке, горении*) янып киму; эреткәндә киму

у́горь I *м* (*рыба*) еланбалык

у́горь II (*прыщик*) бетчә, сыткы

угости́ть *сов. кого-что чем* сыйлау, кунак итү; **~ ча́ем** чәй белән кунак итү

угото́вливать *несов. см.* **угото́вить**

угото́ванный, -ая, -ое *высок.* хәзерләнгән, әзерләнгән

угото́вить *сов. что, уст.* хәзерләп кую, әзерләп кую

угоща́ть *несов. см.* **угости́ть**

угоща́ться *несов.* **1.** сыйлану, кунак булу **2.** *страд. от* **угоща́ть**

угоще́ние *с* **1.** *см.* **угости́ть; 2.** (*еда, питьё*) сый, сый-хөрмәт

угрева́тый, -ая, -ое бетчәле, сыткылы, сыткы баскан; **~ нос** бетчәле борын

угро́бить *сов. прост.* **1.** *кого* (*убить*) үтерү, башын ашау, башына җитү **2.** *что* (*испортить*) һәлак итү, харап итеп ташлау, бозу; **~ де́ло** эшне харап итеп ташлау

угрожа́емый, -ая, -ое *см.* **угрожа́ющий** 3

угрожа́||ть *несов. кому-чему* куркыту, өркетү, янау; куркыныч булу, куркыныч алдында тору; **~ть наказа́нием** җәза бирү белән куркыту; **ему́ ~ла смерть** ул үлем куркынычы алдында тора иде

угрожа́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **угрожа́ть; 2.** куркыта (өркетә) торган, янаулы, яный торган; **~ий жест** янаулы ишарә **3.** куркынычлы, куркыныч, хәвеф-хәтәрле, хәтәр; **~ее положе́ние** куркыныч хәл

угро́з||а *ж* **1.** янау, куркыту, өркетү; **де́йствовать ~ами** янаулар белән эш итү; **быть под ~ой** куркыныч астында булу **2.** куркыныч, хәвеф-хәтәр; **~а войны́** сугыш куркынычы

угро́зыск *м* угрозыск

у́гро-фи́нск||ий, -ая, -ое угро-фин ...ы; **~ие языки́** угро-фин телләре (*мәс. венгр, фин, карел, эстон, мордва телләре*)

угро́ха||ть *сов. прост. что* тоту, исраф итү; **он все де́ньги ~л на да́чу** бар акчасын ул дача салуга исраф итте

угрызе́ни||е *с*: **~я со́вести** вөҗдан газабы

угрю́мость *ж* караңгы чырайлылык, төнтекләк, төкселек

угрю́мый, -ая, -ое **1.** караңгы чырайлы; кырыс, сүрән, төнтек, төксе; **~ стари́к** караңгы чырайлы карт **2.** *перен.* караңгы, күңелсез; **~ лес** караңгы урман

уда́бривать *несов. см.* **удо́брить**

уда́в *м* буар елан

удава́ться *несов. см.* **уда́ться**

удави́ть *сов. кого* буып үтерү, буу

удави́ться *сов. разг.* буылып үлү, буылу

уда́вленник *м прост.* буылып үлгән кеше, асылынып үлгән кеше; буып үтерелгән кеше

уда́вливать *несов. см.* **удави́ть**

уда́вливаться *несов.* **1.** *см.* **удави́ться; 2.** *страд. от* **уда́вливать**

удале́ние *с см.* **удали́ть, удали́ться; ~ пя́тен** тапларны бетерү

удалённость *ж* ераклык, ераклы булу, ерак булу

удалённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **удали́ть; 2.** ераклагы, ерак урындагы; **~ые места́** ерак урыннар

удале́ц *м* кыю (батыр) кеше, егет кеше, булдыклы кеше

удали́ть *сов.* **1.** *кого-что* ерагайту, ераклаштыру; **~ мишéнь на дéсять мéтров** мишеньне ун метрга ерагайту **2.** *кого-что* чыгарып җибәрү, куып чыгару; **~ посторо́нних** чит кешеләрне чыгарып җибәрү **3.** *что* алу, алып ташлау; суыру, суырып алу; **~ зуб** теш суыру **4.** *что* бетерү, китәрү; **~ пя́тна** тапларны бетерү

удали́ться *сов.* **1.** ерагаю, ераклашу, читкә китү, читләшү; **~ от до́ма** йорттан ераклашу; **~ от люде́й** кешеләрдән читләшү **2.** (*уединиться*) чыгып китү, кереп китү, китү; **~ к себе́ в ко́мнату** үз бүлмәнә кереп китү ♦ **~ на поко́й** картлыкта хезмәттән чыгу, эшләми башлау

удало́й, -а́я, -о́е, **уда́лый**, -ая, -ое кыю, булдыклы, җитез

у́даль *ж* кыюлык, чаялык, булдыклылык, җитезлек, егетлек; **~ молоде́цкая** егетләр чаялыгы

удальств||о́ *с разг. см.* **у́даль; сде́лать** *что-л.* **из ~а́** чаяланып *ни дә булса* эшләү

удаля́ть *несов. см.* **удали́ть**

удаля́ться *несов.* **1.** *см.* **удали́ться; 2.** *страд. от* **удаля́ть**

уда́р *м* **1.** сугу, бәрү, ору, чабу, кундыру; **~ прикла́дом** приклад белән сугу; **са́бельный ~** кылыч белән чабу; **свали́ть** *кого-л.* **одни́м ~ом** *кемне дә булса* бер сугуда егу; **нанести́ ~** сугып җибәрү **2.** (*звук*) каккан (суккан, бәргән) тавыш, тавыш; **~ ко́локола** чан каккан тавыш; **~ы гро́ма** күк күкрәгән тавышлар **3.** *перен.* (*стремительное нападение*) һөҗүм, бәреп керү; **~ с фла́нга** флангтан бәреп керү; **~ с во́здуха** һавадан һөҗүм **4.** бәла, зур кайгы, каза, бәхетсезлек; **для него́ э́то си́льный ~** аның өчен бу зур кайгы **5.** (*кровоизлияние в мозг*) мигә кан бәрү, мигә кан саву **6.** (*толчкообразное колебание сердца, пульса*) тибү, тибеш ♦ **[быть, находи́ться] в ~е** күңеле үтә күтәренке булу, түбәсе күккә тию; **со́лнечный ~** кояш сугу; **[ста́вить, поста́вить] под ~** *кого-что* куркыныч хәлгә кую; **теплово́й ~** эссе сугу

ударе́ние *с лингв.* басым; (*знак*) басым билгесе; **~ па́дает на пе́рвый слог** басым беренче иҗеккә төшә; **поста́вить ~** басым билгесе кую

уда́ри||ть *сов.* **1.** *кого-что по чему или во что* сугу, сугып җибәрү, ору, чабу, кундыру, тондыру; **~ть па́лкой** таяк белән сугу; **~ть в лицо́ (по лицу́)** биткә сугу **2.** *что, во что* кагу, сугу; **~ть в бараба́н** барабан кагу; **часы́ ~ли по́лночь** сәгать ярты төнгә сукты **3.** *на кого-что, по кому-чему* һөҗүм итү, бәреп керү; **~ть по врагу́** дошманга һөҗүм итү **4.** *перен. по кому-чему* чик кую; башына сугу, көрәш ачу; **~ть по бюрократи́зму** бюрократизмга каршы көрәш ачу **5.** *разг.* башлану; **~ли моро́зы** салкыннар башланды ♦ **вино́ ~ло в го́лову** кызыл аракы башка китте; **не ~ть лицо́м в грязь** йөзгә кызыллык китермәү; **~ть по карма́ну** кесәгә сугу, зарар китерү; **~ть по рука́м** кул сугышу, килешү

уда́ри||ться *сов.* **1.** *о кого-что, чем* бәрелү, орылу, сугылу; **~ться о ка́мень** ташка бәрелү; **~ться голово́й** баш белән бәрелү **2.** *во что* [барып] тию, бәрелү; **пу́ля ~лась в сте́ну** пуля стенага [барып] тиде **3.** *во что или с неопр., разг.* башлау, керешү, тотыну; **~ться в бе́гство** йөгерә башлау, йөгерергә тотыну; **~ться в слёзы** яшь коярга тотыну; **~ться в амби́цию** амбициягә бирелү **4.** *перен. во что, разг.* (*увлечься чем-л.*) бирелү

уда́рник I *м* ударник, алдынгы

уда́рник II *м* **1.** *воен.* ударник (*мылтык затворында*) **2.** *тех.* бәргеч, ударник (*механизмнарда*) **3.** *муз.* ударник (*бәрмә уен коралларында уйнаучы музыкант*)

уда́рница *ж* ударник хатын (кыз)

уда́рничество *с* ударниклык, ударниклар хәрәкәте

уда́рн||ый I, -ая, -ое **1.** алдынгы, ударниклар ...ы; **~ая брига́да** ударниклар бригадасы; **~ый труд** ударный эш; **~ая стро́йка** ударный төзелеш **2.** ашыгыч, кичектергесез, ашыгыч эш ...ы; **~ое зада́ние** ашыгыч задание; **~ый ме́сяц** ашыгыч эш ае

уда́рн||ый II, -ая, -ое **1.** кагып (сугып, бәреп) уйнала торган, бәрмә; **~ый музыка́льный инструме́нт** кагып уйнала торган музыка коралы; **~ая волна́** бәрмә дулкын **2.** хәлиткеч һөҗүм ясый торган; **~ая а́рмия** хәлиткеч һөҗүм ясый торган армия **3.** *лингв.* басымлы, басым төшә торган; **~ый гла́сный** басым төшә торган сузык аваз

ударя́емый, -ая, -ое *лингв. см.* **уда́рный** II 3

ударя́ть *несов. см.* **уда́рить**

уда́||ться *сов.* 1. уңышлы барып чыгу, уңышлы булу (чыгу), уңу, эш пешү; **опера́ция ~ла́сь** операция уңышлы чыкты 2. *безл. с неопр.* туры килү, барып чыгу; **пое́хать не ~лось** китәргә туры килмәде

уда́ч||а *ж* уңыш, бәхет, җай килү, эш пешү; юл уңу; **больша́я ~а** зур уңыш; **пожела́ть ~и** уңыш теләү

уда́чливый, -ая, -ое эше уңа торган, эше уңучан, эше пешә торган, уңышка очраучан; **~ челове́к** эше уңа торган кеше

уда́чн||ый, -ая, -ое уңышлы, уңышлы чыккан, уңышлы башкарылган; **~ая охо́та** уңышлы ау; **~ое произведе́ние** уңышлы әсәр

удва́ивать *неов. см.* **удво́ить**

удва́иваться *несов.* 1. *см.* **удво́иться**; 2. *страд. от* **удва́ивать**

удвое́ние *с см.* **удво́ить, удво́иться**

удвое́нн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **удво́ить**; 2. икеләтә, икеләтә артык; **рабо́тать с ~ой эне́ргией** икеләтә энергия белән эшләү 3. *лингв.* икеләштерелгән, куш

удво́ить *сов. что* икеләтү, ике өлеш арттыру, икеләтә арттыру, бермә-бер арттыру; **~ опла́ту** туләүне икеләтә арттыру; **~ внима́ние** игътибарны бермә-бер артыру

удво́и||ться *сов.* икеләтә арту, ике тапкыр арту, бермә-бер арту; **си́лы ~лись** көчләр бермә-бер артты

удо́л *м* 1. *ист.* удел (*борынгы Русьта: князь кул астындагы өлкә*) 2. *ист.* удел (*революцигә кадәрге Россияда: патша семьясының җир-сулары*) 3. *уст.* (*участь, судьба*) язмыш, тәкъдир, өлеш, тигән өлеш

удели́ть *сов. что кому-чему* 1. бүлеп бирү, өлеш чыгару; **~ часть де́нег** акчаның бер өлешен бүлеп бирү 2. бирү; **~ внима́ние** игътибар бирү

уде́льн||ый I, -ая, -ое *физ.* чагыштырма; **~ое сопротивле́ние** чагыштырма каршылык; **~ый вес** 1) чагыштырма авырлык; 2) *перен.* (*роль, место, значение кого-чего-л.*) тоткан урын

уде́льн||ый II, -ая, -ое *ист.* 1. удел белән идарә итүче ...ы; **~ый князь** удел белән идарә итүче князь 2. удел ...; **~ые зе́мли** удел җирләр

уделя́ть *несов. см.* **удели́ть**

у́держ *м*: **без ~у** *разг.* бертуктаусыз, тыелгысыз, тыела алмыйча; **пла́кать без ~у** тыела алмыйча елау; **~у нет** *кому, на кого, разг.* тыеп булмый, туктатып булмый; **расшаля́тся де́ти, ~у на них нет** балалар бер шаяра башласалар, ниҗ тыеп булмый; **~у не знать** *в чём, разг.* чиген белмәү, тыела белмәү

удержа́ние *с* 1. *см.* **удержа́ть** 3; 2. (*сумма*) тотып калынган акча, тотып калынган сумма

удержа́ть *сов.* 1. *кого-что* тотып калу, җибәрмәү, ычкындырмау, төшермәү; **~ в рука́х** кулдан җибәрмәү 2. *что* саклап калу, саклау, бирмәү, ычкындырмау; **~ пе́рвое ме́сто в соревнова́ниях** ярышларда беренче урынны саклап калу 3. *что* тотып калу; басып калу, чигереп алып калу; **~ пять рубле́й из зарпла́ты** эш хакыннан биш сум тотып калу 4. *кого-чего* тыеп калу, тыю; **~ лошаде́й** атларны тыю 5. *кого-что от чего* тыеп калу, юл куймау, туктатып калу; **~ от необду́манного посту́пка** алдынартын уйламаган эштән тыеп калу 6. *что* тыю; **~ слёзы** яшьне тыю

удержа́ться *сов.* 1. тотынып (торып, егылмый) калу, басып тора алу; **~ на нога́х** аякка басып тора алу 2. торып калу, урынында калу, тора алу; **~ на ста́рых пози́циях** иске позицияләрда торып калу 3. *от чего* тыелу, тыелып калу (тору), түзеп калу; **~ от сме́ха** көлүдән тыелып калу

уде́рживать *несов. см.* **удержа́ть**

уде́рживаться *несов.* 1. *см.* **удержа́ться**; 2. *страд. от* **уде́рживать**

удесятери́ть *сов. что* 1. (*увеличить в десять раз*) унлата арттыру, ун тапкыр арттыру 2. *перен.* (*усилить во много раз*) бик нык арттыру, күп тапкыр көчәйту; **~ уси́лия** тырышлыкны күп тапкыр көчәйту

удесятери́||ться *сов.* 1. (*увеличиться в десять раз*) унлата арту, ун тапкыр арту 2. (*усилиться во много раз*) бик нык арту, күп тапкыр көчәю; **си́лы ~лись** көч бик нык артты

удесятеря́ть *несов. см.* **удесятери́ть**

удесятеря́ться *несов.* 1. *см.* **удесятери́ться**; 2. *страд. от* **удесятеря́ть**

удешеви́ть *сов. что* арзанайту, арзанлату, очсызландыру, очсызлату, бәясен төшерү; **~ това́ры** товарларны арзанайту

удешеви́ться *сов.* арзанаю, арзанлану, очсызлану, бәясе төшү

удешевля́ть *несов. см.* **удешеви́ть**

удешевля́ться *несов.* 1. *см.* **удешеви́ться**; 2. *страд. от* **удешевля́ть**

удиви́тельно *нареч.* 1. искиткеч, гаҗәп, галәмәт, хәйран калырлык; **он ~ измени́лся** ул искиткеч үзгәргән 2. *в знач. сказ. безл.* гаҗәп, сәер, таң калырлык; **не ~, что так случи́лось** болай килеп чыгуы бер дә гаҗәп түгел

удиви́тельн||ый, -ая, -ое 1. сәер, гаҗәп-хәйран, гаҗәеп, искиткеч, искитәрлек; **~ый слу́чай** гаҗәеп хәл 2. бик яхшы, менә дигән, искиткеч шәп, таң калырлык, галәмәт; **у него́ ~ое здоро́вье** аның сәламәтлеге менә дигән ♦ **ничего́ ~ого** искитәрлек бернәрсә дә юк

удиви́||ть *сов. кого-что* гаҗәпләндерү, шаккатыру, гаҗәпкә (таңга, хәйранга) калдыру, ис китерү; **~ть неожи́данным отве́том** көтелмәгән җавабы белән гаҗәпкә калдыру; **его́ ниче́м не ~ишь** аны берни белән дә шаккатыра алмыйсың

удиви́ться *сов.* гаҗәпләнү, шаккату, гаҗәпкә (таңга, хәйранга) калу, ис китү

удивле́ние *с* гаҗәпләнү, таң (хәйран) калу, шаккату ♦ **на ~ *кому*** менә дигән, бик яхшы, гаҗәеп шәп, искитәрлек

удивлённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **удиви́ть**; 2. гаҗәпләнгән, гаҗәпсенгән, таң калган, хәйранга калган; **смотре́ть ~ыми глаза́ми** гаҗәпсенгән күз белән карау

удивля́ть *несов. см.* **удиви́ть**

удивля́ться *несов. см.* **удиви́ться**

удила́ *только мн.* авызлык

уди́лище *с* кармак сабы (таягы)

уди́льщик *м* кармакчы, кармак салып балык тотучы, балык каптыручы

удира́ть *несов. см* **удра́ть**

уди́ть *несов. кого* кармак салу, балык каптыру

уди́ться *несов.* кабу, эләгү; **здесь ры́ба хорошо́ у́дится** биредә балык әйбәт эләгә

удлине́ние *с*: *см.* **удлини́ть, удлини́ться**

удлинённ||ый, -ая, -ее 1. *прич. от* **удлини́ть**; 2. озынча, сузынкы; **~ое лицо́** озынча бит

удлини́ть *сов. что* 1. озынайту, сузу; **~ ю́бку** юбканы озынайту 2. (*сделать более продолжительным*) озайту

удлини́ться *сов.* 1. (*стать длиннее*) озынаю, сузылу 2. (*сделаться более продолжительным*) озаю

удлиня́ть *несов. см.* **удлини́ть**

удлиня́ться *несов.* 1. *см.* **удлини́ться**; 2. *страд. от* **удлиня́ть**

удму́рт *м* удмурт, удмурт кешесе

удму́ртка *ж* удмурт хатыны (кызы)

удму́ртский, -ая, -ое удмурт[лар] ...ы; **~ язы́к** удмурт теле

удму́рты *мн.* удмуртлар, удмурт халкы

удо́бно *нареч.* 1. җайлап, уңайлап, җайлы (уңайлы) итеп; **~ усе́сться** җайлап утырышу 2. *в знач. сказ. безл.* уңайлы, җайлы, кулай; **мне и здесь ~** миңа монда да җайлы

удо́бн||ый, -ая, -ое 1. уңайлы, җайлы, көйле, ипле; **~ое кре́сло** уңайлы кәнәфи 2. уңайлы, уңай, кулай; **вы́брать ~ое вре́мя** уңайлы вакыт табу 3. (*уместный*) уңайлы, урынлы; **вполне́ ~ый вопро́с** бик тә урынлы сорау

удобно- *кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «уңайлы», «җайлы», «кулай», «җиңел» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.* **удобопереноси́мый** җиңел күчерелә торган

удобовари́м||ый, -ая, -ое 1. җиңел үзләштерелүчән, җиңел үзләштерелә торган, тиз сеңүчән, җиңел; **~ая пи́ща** җиңел үзләштерелә торган азык 2. *перен. разг.* җиңел үзләштерелә торган, җиңел аңлашыла торган; **~ая шу́тка** җинел аңлашыла торган мәзәк

удобопоня́тный, -ая, -ое җиңел аңлаешлы, бик ансат аңлашыла торган; **~ текст** бик ансат аңлашыла торган текст

удобопроизноси́м||ый, -ая, -ое әйтүе җиңел булган, ансат әйтелә торган, җиңел әйтелешле; **~ое сочета́ние зву́ков** җиңел әйтелешле авазлар тезмәсе

удобочита́емый, -ая, -ое җиңел укыла торган, ансат укылышлы; **~ по́черк** җиңел укыла торган почерк

удобре́ние *с* 1. *см.* **удо́брить**; 2. ашлама; **минера́льное ~** минераль ашлама

УДО-УЖА

удо́брить *сов. что* ашлау, ашлама кертү; ~ **землю навóзом** җирне тирес белән ашлау, җирне тиреслә

удобря́ть *несов. см.* **удо́брить**

удо́бств||о *с* **1.** уңайлылык, җайлылык, кулайлылык; **отлича́ться ~ом** уңайлылык белән аерылып тору **2.** уңайлы шартлар, уңайлыклар; **кварти́ра со все́ми ~ами** барлык уңайлыклары булган квартир

удовлетворе́ние *с* **1.** *см.* **удовлетвори́ть; ~ зако́нных прав** законлы хокукларны канәгатьләндерү **2.** канәгатьлек, канәгатьлек хисе, канәгатьлек тойгысы, күңел булу; **с больши́м ~м** зур канәгатьләнү белән

удовлетворённость *ж* **1.** канәгатьләнгәнлек, канәгать булу, күңел булу **2.** *см.* **удовлетворе́ние** 2

удовлетворённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **удовлетвори́ть; 2.** канәгатьләнгән, канәгатле, күңеле хушланган, күңеле булган; **~ый взгляд** канәгатьләнгән күз карашы; **~ое самолю́бие** канәгатьләнгән мин-минлек

удовлетвори́тельно 1. *нареч.* канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек итеп, канәгатьләнерлек рәвештә **2.** *нескл. в знач. сущ. с* уртача, канәгатьләнерлек; **сдать экза́мен на ~** имтиханны уртачага тапшару

удовлетвори́тельный, -ая, -ое канәгатьләндерерлек, канәгатьләндерә торган, канәгатьләнерлек, ярыйсы, уртача; **~ отве́т** канәгатьләндерерлек җавап

удовлетвори́ть *сов.* **1.** *кого-что* канәгатьләндерү, кандыру, үтәү; **~ потре́бности населе́ния** халык ихтыяҗларын үтәү **2.** *чему* канәгатьләндерү, туры килү, җавап бирү, яраү; **~ всем тре́бованиям** барлык таләпләргә җавап бирү **3.** *кого-что, офиц.* тәэмин итү; **~ провиа́нтом** язык-төлек белән тәэмин итү

удовлетвори́ться *сов.* канәгатьләнү, канәгать булу

удовлетворя́ть *несов. см.* **удовлетвори́ть**

удовлетворя́ться *несов.* **1.** *см.* **удовлетвори́ться; 2.** *страд. от* **удовлетворя́ть**

удово́льствие *с* **1.** рәхәт[лек], хозур, ләззәт, кәеф; **доста́вить ~** рәхәтлек китерү **2.** (*забава, развлечение*) уен-көлке, мәзәк, куаныч

удово́льствоваться *сов. чем* канәгатьләнү; тәэмин ителү

удо́д *м* һөдһөд (*кош*)

удо́||й *м* **1.** (*количество молока*) савым, бер савым сөт, бер сауган сөт; **су́точный ~й** тәүлеклек савым **2.** (*доение*) саву; **молоко́ у́треннего ~я** иртән сауган сөт

удо́йливость *ж разг.* **удо́йность** 1

удо́йливый, -ая, -ое *разг. см.* **удо́йный** 2

удо́йнос||ть *ж* **1.** сөтлелек, сөт бирү[чәнлек], сөт бирү дәрәҗәсе; **повыше́ние ~ти коро́в** сыерларның сөт бирүчәнлеген күтәрү **2.** *см.* **удо́й** 1

удо́йный, -ая, -ое **1.** (*полученный с одного удоя*) бер савым ...ы, бер савуда алынган **2.** (*дающий много молока*) сөтле, күп сөт бирә торган

удорожа́ние *с см.* **удорожи́ть, удорожи́ться**

удорожа́ть *несов. см.* **удорожи́ть**

удорожа́ться *несов.* **1.** *см.* **удорожи́ться; 2.** *страд. от* **удорожа́ть**

удорожи́ть *сов. что* кыйбатландыру, кыйммәтләндерү, кыйбатландыра (кыйммәтләндерә) төшү

удорожи́ться *сов.* кыйбатлану, кыйммәтләнү

удоста́ивать *несов. см.* **удосто́ить**

удоста́иваться *несов.* **1.** *см.* **удосто́иться; 2.** *страд. от* **удоста́ивать**

удостовере́ние *с* **1.** *см.* **удостове́рить; 2.** (*документ*) таныклык, таныклык язуы; **~ ли́чности** шәхес таныклыгы

удостове́рить *сов. что, офиц.* раслау, дөреслеген раслау, таныклык бирү; **~ по́дпись** имзаның дөреслеген раслау

удостове́риться *сов. в чём* [дөреслеген] тикшереп белү; **~ в пра́вильности сообще́ния** хәбәрнең дөреслеген тикшереп белү

удостоверя́ть *несов. см.* **удостове́рить**

удостоверя́ться *несов.* **2.** *см.* **удостове́риться; 2.** *страд от* **удостоверя́ть**

удосто́ить *сов.* **1.** *кого-что чего, книжн.* бирү, бүләкләү; **~ прави́тельственной награ́ды** хөкүмәт бүләге бирү **2.** *кого-что чем* илтифат итү, илтифат күрсәтү; **~ ла́сковым сло́вом** илтифат күрсәтеп җылы сүз әйтү

удосто́иться *сов.* **1.** *чего, книжн.* лаек булу; бирелү, бүләкләнү; **~ прави́тельственной награ́ды** хөкүмәт бүләгенә лаек булу **2.** *чего и с неопр.* бәхетенә ирешү; **~ похвалы́** мактау бәхетенә ирешү

удосу́живаться *несов. см.* **удосу́житься**

удосу́жи||ться *сов. разг.* вакыт табу, ара табу; **не ~лся рассказа́ть** сөйләп бирергә вакыт таба алмады

удочери́ть *сов. кого* кызлыкка алу, [кыз баланы] асрамага алу

удочеря́ть *несов. см.* **удочери́ть**

у́дочка *ж* кармак

удра́ть *сов. разг.* качып китү, таю, сызу, шылу, табан ялтырату; **~ из до́му** өйдән качып чыгып китү

удружи́ть *сов. кому, разг.* **1.** (*оказать услугу*) яхшылык эшләү, ярдәм күрсәтү, булышлык итү, хезмәт күрсәтү **2.** *перен. ирон.* (*причинить неприятность*) аю хезмәте күрсәтү, зыян китерү

удруча́ть *несов. см.* **удручи́ть**

удручённый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **удручи́ть; 2.** төшенке, боек, күңелсез, борчулы; **~ вид** борчулы кыяфәт

удручи́ть *сов. кого-что* кайгыга салу, кайгыга төшерү (калдыру), кәефен китерү, хафага төшерү; **~ печа́льной ве́стью** кайгылы хәбәр әйтеп кәефен китерү

удуша́ть *несов. см.* **удуши́ть**

удуше́ние *с см.* **удуши́ть**

удуши́ть *сов. кого, разг.* буу, буып үтерү, тончыктыру

уду́шливость *ж* тончыктыргыч булу, бөркүлек, тынчулык, тынны бетерә торган булу

уду́шливый, -ая, -ое **1.** сулышны кыса торган, тынны бетерә торган, тынчу, бөркү; **~ за́пах** тынчу ис **2.** тончыктыргыч, тончыктыра торган, буылдыргыч; **~ газ** буылдыргыч газ

уду́шь||е *с* тын бетү, сулыш кысылу, тын кысылып буылу; **при́ступ ~я** тын бетү өянәге

удэге́йский, -ая, -ое удэге[лар] ...ы; **~ язы́к** удэге теле

удэге́йцы *мн.* удэгелар, удэге халкы

уедине́ни||е *с* **1.** *см.* **уедини́ться; 2.** (*одиночество*) ялгызлык, ялгыз тору; **жить в ~и** ялгызлыкта яшәү; **он лю́бит ~е** ул ялгыз торырга ярата

уединённость *ж* ялгызлык; **~ жи́зни** тормышның ялгызлыгы

уединённ||ый, -ая, -ое **1.** ялгыз, кешеләрдән аерылган; **~ая жизнь** ялгыз тормыш **2.** аулак [урындагы], ялгыз; **~ый дом** аулак урындагы йорт; **~ое ме́сто** аулак урын

уедини́ться *сов.* кешеләрдән читләшү, аралашмый башлау; [башкалардан] аерылып ...га кереп китү; **~ в ко́мнату для разгово́ра** гәпләшү өчен башкалардан аерылып бүлмәгә кереп китү

уедини́ться *несов. см.* **уедини́ться**

уе́зд *м* өяз (*революциягә кадәр Россиядә һәм районнар төзелгәнгә кадәр СССРда: административ-территориаль берәмлек*)

уе́здный, -ая, -ое өяз ...ы; **~ го́род** өяз шәһәре

уезжа́ть *несов. см.* **уе́хать**

уе́хать *сов.* китү, китеп бару (*атка, машинага һ.б.ш. утырып*)

уж I *м зоол.* тузбаш, тузбаш елан

уж II 1. *нареч.* инде; **он ~ давно́ пришёл** ул күптән килде инде **2.** *частица усил.* чыннан да, ...а икән; **~ е́сли де́лать, то на́до де́лать хорошо́** әгәр дә инде ясарга икән, яхшылап ясарга кирәк **3.** *частица усил.* ... шул, ... ук; **о́чень ~ мно́го дел** эш бик күп шул; **не так ~ пло́хо** ул хәтле үк начар түгел

ужа́лить *сов. кого* чагу (*мәс. елан турында*)

ужа́ривать *несов. см.* **ужа́рить**

ужа́ривание *несов.* **1.** *см.* **ужа́риться; 2.** *страд. от* **ужа́ривать**

ужа́рить *сов. что, разг.* кыздырып (куырып) җиткерү

ужа́риться *сов. разг.* **1.** (*изжариться до готовности*) кыздырылып җитү, куырылып җитү **2.** (*жарясь, уменьшиться*) кыздырганда (куырганда) кимү (кечерәю)

у́жас *м* **1.** кот алыну, кот очу; **его́ охвати́л ~** анын коты очты; **наводи́ть ~** *на кого-л. кемнең дә булса* котын алу **2.** *обычно мн.* **~ы** дәһшәт, коточкыч хәл; **~ы войны́** сугыш дәһшәтләре **3.** куркыныч, куркынычлык, котылгысызлык; **почу́вствовать весь ~ своего́ положе́ния** үз хәленнән бөтен куркынычлыгын тою **4.** *в знач. сказ. разг.* искиткеч, гажәеп; **~ как жа́рко!** гажәеп эссе! **5.** *в знач. нареч. разг.* бик, чиктән

тыш, әллә нихәтле, дөнья кадәр; **~, ско́лько вре́мени прошло́** әллә нихәтле вакыт үтте ♦ **до ~а** бик, чиктән тыш; **к ~у** *чьему* кызганычка каршы, бәхетсезлеккә каршы

ужаса́ть *несов. см.* **ужасну́ть**

ужаса́ться *несов. см.* **ужасну́ться**

ужа́сно *нареч.* **1.** (*скверно*) бик яман, коточкыч; **э́то ещё не так ~** бу әле бик үк коточкыч түгел **2.** *прост.* (*очень, чрезмерно*) бик, бик тә, гаять дәрәҗәдә, чиксез; **я ~ рад** мин чиксез шатмын **3.** *в знач. сказ.* коточкыч хәл, бик яман; **э́то ~!** коточкыч хәл бу!

ужасну́ть *сов. кого-что* котын алу, котын очыру, куркыту, имәндерү, хәвефләндерү

ужасну́ться *сов.* кот алыну, кот очу, курку, имәну, хәвефләну

упере́ться *сов.* 1. *чем во что* таяну, сөялү, терәлү, терәү; **~ весло́м в дно** ишкәк белән су төбенә таяну; **~ нога́ми в зе́млю** аякларны җиргә терәү 2. *в кого-что, разг.* килеп бәрелү (төртелү); **шёл, шёл и упёрся в забо́р** бара торгач коймага килеп бәрелгәнмен 3. *перен. на чём и без доп., прост.* киреләнү, үҗәтләнү, кәҗәләнү, аяк терәп каршы тору, үзсүзлеләнү, үз дигәнен итү; **он упёрся и не пое́хал никуда́** үз дигәнен итте, бер кая да бармады

упе||чь *сов.* 1. *что, разг.* пешереп җиткерү; **хлеб не ~чён** ипи пешеп җитмәгән 2. *кого-что, прост.* олактыру, сөрү, җибәрү; **~кли его почти́ на край све́та** аны дөньяның читенә үк диярлек олактырдылар

упе́чься *сов. разг.* пешеп җитү, пешүе җитү, йөзе килү; **пирог ещё не упёкся** бәлеш пешеп җитмәгән әле

упива́ться *несов. см.* **упи́ться**

упира́ть *несов. см.* **упере́ть**

упира́||ться *несов.* 1. *см.* **упере́ться**; 2. *разг.* килеп терәлү (төртелү); бәйләнешле булу, бәйләнгән булу; **разреше́ние э́того вопро́са ~ется в отсу́тствие де́нег** бу мәсьәләнең хәл ителеше акча юклыкка бәйләнгән 3. *страд. от* **упира́ть**

описа́ть *сов. что* 1. *разг.* сыйдыру, (*язганда*) сыйдырып бетерү; **~ всё заявле́ние на одно́й страни́це** бөтен гаризаны бер биткә сыйдырып бетерү 2. *прост.* ашап (бүсеп, тыгып) бетерү, сыпыру, сыпырып салу; **~ весь пиро́г** бөтен бәлешне сыпырып салу

описа́||ться *сов. разг.* сыю, сыеп бетү; **ве́сь доклад ~лся на не́скольких страни́цах** бөтен доклад берничә биткә сыеп бетте

опи́сывать *несов. см.* **описа́ть**

опи́сываться *несов.* 1. *см.* **описа́ться**; 2. *страд. от* **опи́сывать**

опи́танност||ь *ж* көрлек, көрлек дәрәҗәсе, симезлек; **мя́со сре́дней ~и** уртача симезлектәге ит

опи́танный, -ая, -ое көр, симез, таза; **~ скот** симез терлек; **~ ребёнок** таза бала

опи́ться *сов.* 1. *прост.* (*напиться допьяна*) исергәнче эчү, ләх булганчы эчү, эчеп исерү 2. *перен. чем, книжн.* (*испытать упоение, восхищение*) ләззәтләнү, хозурлану; **~ гармо́нией зву́ков** авазлар гармониясеннән хозурлану

упла́та *ж см.* **уплати́ть**

уплати́ть *сов. что и без доп.* түләү, түләп бетерү; **~ за обе́д** көндезге аш өчен түләү

упла́чивать *несов. см.* **уплати́ть**

уплести́ *сов.* 1. *что чем, разг.* (*увить*) үрү, үреп кую 2. *что, разг.* (*сделать тугим*) чирак итеп үрү, чирак итеп ишү

~ **кана́т** арканны чирак итеп ишү 3. *что, прост.* (*съесть быстро*) сыпыру, сыпырып салу, ялмап кую, сосу, сосып бетерү

уплета́ть *несов. см.* **уплести́**; ~ **за о́бе щёки** тәмләп ашау, ияк биетү

уплотне́ние *с* 1. *см.* **уплотни́ть, уплотни́ться**; 2. (*место*) каты урын, каты төер, оры, биз 3. *тех.* тыгызлагыч (*газ, пар кебекләрнең деталь араларыннан чыгуын киметү өчен эшләнгән җайланма*)

уплотнённость *ж* тыгызлык, тыгызланганлык; ~ **рабо́чего вре́мени** эш вакытының тыгызлыгы

уплотнённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **уплотни́ть**; 2. тыгызланган, тыгызландырылган, тыгыз; ~**ая по́чва** тыгызланган туфрак; ~**ый гра́фик рабо́ты** тыгызландырылган эш графигы

уплотни́ть *сов.* 1. *что* куеландыру, тыгызландыру; ~ **слой гли́ны** кызыл балчык катламын тыгызландыру 2. *кого-что* (*заселить плотнее*) тыгызлап кеше[ләр] кертү, өстәп кеше[ләр] урнаштыру 3. *перен. что* тыгызландыру, тыгызайту, тулы файдалану; ~ **рабо́чий день** эш көнен тыгызайту

уплотни́ться *сов.* 1. (*стать плотнее*) куелану, тыгызлану 2. (*поместиться более тесно*) өстәмә рәвештә кеше[ләр] керү, кеше[ләр] урнашу (*мәс. квартирга*) 3. *перен.* (*стать целиком заполненным, напр. о рабочем времени*) тыгызаю

уплотня́ть *несов. см.* **уплотни́ть**

уплотня́ться *несов.* 1. *см.* **уплотни́ться**; 2. *страд. от* **уплотня́ть**

упл|ы́||ть *сов.* 1. [йөзеп] китү, агып китү; ~**ть далеко́ от бе́рега** ярдан бик еракка йөзеп китү; **бревно́** ~**ло** бүрәнә агып китте 2. *перен.* үтеп китү, узып китү, үтү; **го́ды** ~**ли** еллар үтте дә китте 3. *перен. разг.* бетү, юкка чыгу, юк булу; **де́ньги** ~**ли** акча бетте

упова́ние *с уст.* өмет, ышаныч

упова́ть *несов. на кого-что, уст.* өметләнү, өмет итү, өмет (ышаныч) баглау; ~ **на успе́х** уңышка өмет баглау

уподо́бить *сов. кого-что кому-чему* охшату, тиңләштерү; ~ **мо́лодость весне́** яшьлекне язга охшату

уподо́биться *сов. кому-чему* охшау, охшап калу

уподобле́ние *с* 1. *см.* **уподо́бить, уподо́биться**; 2. *лит., лингв.* охшашлык; охшашлану, охшашландыру

уподобля́ть *несов. см.* **уподо́бить**

уподобля́ться *несов.* 1. *см.* **уподо́биться**; 2. *страд. от* **уподобля́ть**

упое́ние *с* ләззәт, рәхәт[лек], хозур[лык], куаныч; **рабо́тать с** ~**м** ләззәт белән эшләү

упоённый, -ая, -ое *книжн.* ләззәтләнгән, хозурланган, исергән; ~ **взор** ләззәтләнгән караш

упои́тельный, -ая, -ое ләззәтләндергеч, исерткеч, гаҗәеп, искиткеч, сокландыргыч; ~ **во́здух** исерткеч һава

упои́ть *сов. кого-что, прост.* эчереп исертү, исерткәнче эчерү, ләх булганчы эчерү, лаякыл булганчы эчерү

упоко́ить *сов. кого-что, уст.* тулы тынычлык бирү, тулы тынычлык булдыру

упоко́иться *сов. уст.* мәңгелек йокыга талу, үлү

упоко́й *м*: **за** ~ *уст.* әрвахлар рухына

уползá́ть *несов. см.* **уползти́**

уполз||ти́ *сов.* 1. шуышып китү (китеп бару), үрмәләп китү (китеп бару); **змея́** ~**ла́** елан шуышып китеп барды 2. акрын гына китеп бару, әкрен генә китү; **ту́ча** ~**ла́ за лес** болыт әкрен генә урман артына таба китеп барды

уполномо́ченный, -ая, -ое 1. *прич. от* **уполномо́чить**; 2. *в знач. сущ. м* вәкил

уполномо́чивать *несов. см.* **уполномо́чить**

уполномо́чи||е *с*: **по** ~**ю** *чьему, кого, офиц. берәүнең* вәкаләте буенча, ышанып тапшыруы буенча

уполномо́чить *сов. кого-что на что* вәкаләт бирү, ышанып эш тапшыру, вәкил итеп жибәрү; ~ **на веде́ние де́ла** эшне алып бару өчен вәкаләт бирү

упомина́ние *с* 1. *см.* **упомяну́ть**; 2. (*замечание*) искәртү, искәртмә; телгә (искә) алыну, исеме аталу; **бе́глое** ~ *о ком-л. берәр кеше турында* өстән-өстән генә искәртеп китү

упомина́ть *несов. см.* **упомяну́ть**

упо́мн||ить *сов. кого-что* хәтердә саклау, истә (хәтердә) калдыру, истә тоту, онытмау; **всего́ не** ~**ишь** барысын до истә тотып бетерә алмассың

упомяну́ть *сов. кого-что, о ком-чём или с союзом «что»* телгә (искә) алу, исемен атау, кагылып (әйтеп, искә төшереп) китү; ~ **и́мя дру́га** дустының исемен телгә алу

упо́р *м* 1. *см.* **упере́ть, упере́ться**; **то́чка** ~**а** таяну ноктасы; **завинти́ть до** ~**а** терәлгәнгә кадәр борып кую 2. (*подпорка*) терәк, таяныч; ~ **для но́г** аяклар өчен терәк ♦ **в** ~ **сказа́ть** туп-туры әйту; **в** ~ **смотре́ть** текәлеп карау; **вы́стрелить в** ~ терәп ату; ~ **де́лать** *на кого-что, на ком-чём* басым ясау, төп игътибарны юнәлтү

упо́рный I, -ая, -ое терәк ...ы, таяныч ...ы; ~ **болт** терәк болты; ~ **шест** таяныч колгасы

упо́рн||ый II, -ая, -ое 1. (*настойчивый*) үз сүзендә нык торучан, үз дигәнендә нык торучан, үз дигәнен итүчән, үз сүзле; ~**ый челове́к** үз сүзендә нык торучан кеше 2. (*требующий выдержки*) каты, кискен, чыдамлы; ~**ая борьба́** кискен көрәш; **ока́зывать** ~**ое сопротивле́ние** каты каршылык күрсәтү 3. *перен.* (*не прекращающийся*) өзлексез, бетмәс, тынмас, тукталмас; ~**ый ка́шель** тынмас ютәл

упо́рство *с* 1. (*настойчивость*) ныклык, нык тору, катылык, киренкелек 2. (*упрямство*) үзсүзлелек, кирелек, киребеткәнлек, тешләклек, үҗәтлек

упо́рств||овать *несов.* 1. нык тору, ныклык күрсәтү; ~**овать в свои́х тре́бованиях** үз таләпләреңдә нык тору 2. үз сүзлеләнү, киреләнү, тешләкләнү, үҗәтләнү; **не** ~**уй, соглаша́йся** үҗәтләнмә, килеш

упорхну́||ть *сов.* 1. (*улететь*) күтәрелеп (пырхылдап) очып китү; **пти́ца** ~**ла** кош пырхылдап очып китте 2. *перен.* (*быстро удалиться*) ялт китеп бару, йөгереп китеп бару, капыл гына чыгып китү

упоря́дочение *с см.* **упоря́дочить**

упоря́дочивать *несов. см.* **упоря́дочить**

упоря́дочиваться *несов.* 1. *см.* **упоря́дочиться**; 2. *страд. от* **упоря́дочивать**

упоря́дочить *сов. что* тәртипкә китерү (кертү), рәткә (җайга, юлга, көйгә) салу; ~ **взаимоотноше́ния** үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу

упоря́дочи||ться *сов.* тәртипкә килү, рәткә (җайга, көйгә) салыну; **отноше́ния** ~**лись** мөнәсәбәтләр җайга салынды

употреби́тельность *ж* кулланылу дәрәҗәсе, кулланылыш

употреби́тельн||ый, -ая, -ое киң кулланылыштагы, кулланышта булган, киң кулланыла торган; ~**ое сло́во** киң кулланылыштагы сүз

употреби́ть *сов. кого-что* куллану, файдалану, тоту, сарыф итү; ~ **де́ньги на поку́пку книг** акчаны китаплар сатып алуга тоту; ~ *кого-л.* **в ка́честве посре́дника** *берәр кешене* арадашчы итеп файдалану

употреби́ться *сов.* кулланылу, тотылу, файдаланылу

употребле́ние *с см.* **употреби́ть, употреби́ться**

употребля́ть *несов. см.* **употреби́ть**

употребля́ться *несов.* 1. *см.* **употреби́ться**; 2. *страд. от* **употребля́ть**

упра́в||а *ж* 1. *разг.* җиңү мөмкинлеге, буйсындыру чарасы, йөгәнләү әмәле; **найти́** ~**у** *на кого-л. кемне де булса* буйсындыру чарасы табу 2. управа (*революциягә кадәрге Россиядә: кайбер җирле учреждениеләрнең исеме*)

управделá́ми *м нескл.* эш башкаручы (*учреждениедә эчке эшләр белән идарә итүче хезмәткәр*)

управдо́м *м* управдом (*йортлар белән идарә итүче*)

управи́тель *м уст.* управляющий, идарә итүче (*мәс. алпавыт имениесендә*)

упра́виться *сов.* 1. *с кем-чем* башкарып чыгу, башкару, ерып чыгу, булдыра алу, алып бара алу; ~ **со сти́ркой** кер юу эшен башкарып чыгу; ~ **с хозя́йством** хуҗалык эшләрен алып бара алу 2. *с кем* (*одолеть*) жинеп чыгу, җиңү, көч җитү, өстен чыгу; **с ним ника́к не** ~ аңа ничтә көч житәрлек түгел

управле́нец *м разг.* идарә эшчесе, идарә хезмәткәре

управле́ни||е *с* 1. *см.* **управля́ть** 1, 2; **нау́ка** ~**я** идарә итү фәне 2. идарә; **ме́стное** ~**е** жирле идарә 3. *спец.* (*совокупность приборов*) идарә; **рычаги́** ~**я** идарә рычаглары 4. *грам.* башкару, башкарылыш, башкарылу; **предло́жное** ~**е** предлоглар ярдәмендә башкарылу

управле́нческий, -ая, -ое идарә [итү] ...ы; ~ **аппара́т** идарә аппараты

управля́емость *ж* идарә ителеш, идарә ителү үзлеге; **сохрани́ть ~ самолёта** самолётның идарә ителү үзлеген саклау

управля́ем||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **управля́ть**; **2.** идарә ителә торган, идарә ителмәле; **~ая раке́та** идарә ителә торган ракета

управля́ть *насов.* **1.** *кем-чем* идарә итү, йөртү; тотып бару; **~ автомоби́лем** автомобиль йөртү; **~ конём** дилбегә (ат) тотып бару **2.** *кем-чем* (*руководить*) идарә итү, җитәкчелек итү, алып бару **3.** *чем, грам.* башкару

управля́ться *несов.* **1.** *см.* **упра́виться**; **2.** *страд. от* **управля́ть**

управля́ющий *м* **1.** *прич. от* **управля́ть**; **2.** управляющий (*берәр хуҗалык, учреждение һ.б.ш белән идарә итүче*)

упражне́ни||е *с* **1.** *см.* **упражня́ть, упражня́ться**; **2.** күнегү, күнекмә; **сбо́рник ~й по правописа́нию** дөрес язу буенча күнегүләр җыентыгы

упражня́ть *несов. что* күнектерү, өйрәтү, күнегүләр үткәрү, күнекмәләр бирү; **~ па́мять** хәтерне күнектерү; **~ му́скулы** мускулларны күнектерү

упражня́ться *несов. в чём, на чём, с чем и без доп.* үз-үзеңне күнертерү, күнегүләр үткәрү (ясау); **~ на роя́ле** рояльдә күнегүләр үткәрү

упразднé́ние *с см.* **упразднúть**

упразднúть *сов. что* юкка чыгару, бетерү, юк итү

упразднúться *сов.* юкка чыгу, бетү, юк булу

упраздня́ть *несов. см.* **упразднúть**

упраздня́ться *несов.* **1.** *см.* **упразднúться**; **2.** *страд. от* **упраздня́ть**

упра́шивать *несов. см.* **упроси́ть**

упрева́ть *несов. см.* **упре́ть**

упрёк *м* шелтә[ләү], үпкә, әр; **дру́жеский ~** дусларча шелтәләү; **бро́сить ~** *кому-л. кемгә дә булса* үпкә белдерү

упрека́ть *несов. кого-что* шелтәләү, әрләү, битәрләү, үпкә белдерү, тел тидерү

упрекну́ть *сов. однокр. см.* **упрека́ть**

упре́||ть *сов.* **1.** *разг.* (*свариться*) пешү, пешеп җитү, парланып (изелеп) пешү; **ка́ша ~ла** ботка пешеп җиткән **2.** *прост.* (*вспотеть*) тирләү, тиргә бату, пышлыгу

упроси́ть *сов. кого-что с неопр.* ялынып (инәлеп) күндерү, ялварып (үтенеп) ризалату

упрости́ть *сов. что* **1.** гадиләштерү, җиңеләштерү; **~ констру́кцию самолёта** самолётның конструкциясен гадиләштерү; **~ правописа́ние** дөрес язу кагыйдәләрен җиңеләштерү **2.** (*сделать примитивным*) артык гадиләштерү, тупасландыру

упрости́ться *сов.* гадиләшү, җиңеләшү, ансатлану

упроче́ние *с см.* **упро́чить, упро́читься**; **~ ми́ра** тынычлыкны ныгыту

упро́чивать *несов. см.* **упро́чить**

упро́чиваться *несов.* **1.** *см.* **упро́читься**; **2.** *страд. от* **упро́чивать**

упро́чи||ть *сов. что* **1.** ныгыту; **~ть мир** тынычлыкны ныгыту **2.** *перен. за кем-чем* раслау, ныгыту; **эта карти́на ~ла за ним сла́ву большо́го худо́жника** бу картина аның зур художник икәнлеген раслады

упро́чи||ться *сов.* **1.** (*занять прочное положение*) ныклап урнашу; **~ться на но́вых пози́циях** яңа позицияләрдә ныклап урнашу **2.** (*стать прочным*) ныгу; **международное положе́ние страны́ ~лось** илнең халыкара хәле ныгыды **3.** *перен.* за *кем-чем* [исем, дан] алу, урнашу; **за ним ~лась сла́ва хоро́шего организа́тора** ул яхшы оештыручы дигән дан алды

упрочни́ть *сов. что, спец.* ныгайту, ныгыту, чыдамлырак итү; **~ изде́лия из ко́жи** күннән эшләнә торган әйберләрне чыдамлырак итү

упрочня́ть *несов. см.* **упрочни́ть**

упроща́ть *несов. см.* **упрости́ть**

упроща́ться *несов.* **1.** *см.* **упрости́ться**; **2.** *страд. от* **упроща́ть**

упроще́ние *с* **1.** *см.* **упрости́ть, упрости́ться**; **~е пи́сьменности** язуны гадиләштерү **2.** гадилек, гадиләштерү; **внести́ ~я в констру́кцию самолёта** самолётның конструкциясенә гадиләштерүләр кертү

упрощённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **упрости́ть**; **2.** (*несложный*) гадиләштерелгән, җиңеләйтелгән; **~ая орфогра́фия** гадиләштерелгән орфография **3.** (*примитивный*) артык гади, примитив; **~ые рассужде́ния** артык гади фикер йөртүләр

упрощённый, -ая, -ое артык гади, артык гадиләштерә торган, артык гадиләштереп ..., артык гадиләштерелгән; **~ подход к реше́нию вопро́са** мәсьәләне хәл итүгә артык гадиләштереп карау

упрощéнчество *с* артык гадиләштерү, җиңелчә карау

упру́г||ий, -ая, -ое **1.** сыгылмалы, бөгелүчән, пеше, сыек, сузылучан; **~ая пружи́на** сыгылмалы пружина **2.** (*плотный*) тыгыз; **~ие мы́шцы** тыгыз мускуллар **3.** (*плавный*) салмак; **~ие движе́ния** салмак хәрәкәтләр

упру́гост||ь *ж* **1.** сыгылмалылык, пешелек, сузылучанлык; **~ь пружи́ны** пружинаның сыгылмалылыгы **2.** тыгызлык; **~ь мы́шц** мускулларның тыгызлыгы **3.** салмаклык; **~ь ша́га** адымның салмаклыгы ◆ **теория ~и** *физ.* сыгылмалылык теориясе

упря́ж||ь *ж* **1.** җигем (*бергә җигелгән берничә ат, болан яисә эт*) **2.** *см.* **у́пряжь** ◆ **в одно́й ~е** бергә җигелеп, иңгә-иң торып

упряжн||о́й, -а́я, -о́е **1.** ат җигү ...ы, **~ы́е принадле́жности** ат җигү кирәк-яраклары **2.** җигелә торган, җигүле, җигелгән; **~о́й конь** җигелә торган ат

у́пряжь *ж* дирбия, сбруй, җигү кирәк-яраклары

упря́мец *м разг.* кире (тискәре, үзсүзле) кеше, киребеткән, тешләк, үҗәт

упря́миться *несов. разг.* киреләнү, тискәреләнү, кәҗәләнү, тешләкләнү, үзсүзләләнү, үҗәтләнү

упря́мица *ж* тискәре хатын (кыз), үзсүзле хатын (кыз)

упря́мство *с* кирелек, тискәрелек, киребеткәнлек, тешләклек, үзсүзлелек, үҗәтлек

упря́мствовать *несов.* үз киресен итү, тискәреләнү, кәҗәләнү, үзсүзләләнү, тешләкләнү, үҗәтләнү

упря́мый, -ая, -ое **1.** (*неуступчивый*) кире, киребеткән, тискәре, тешләк, үзсүзле, үҗәт **2.** (*настойчивый*) үз сүзендә (дигәнендә) нык торучан, үз дигәнен итүчән

упря́тать *сов. разг.* **1.** *кого-что* (*спрятать*) яшереп кую, җыеп кую; **~ ве́щи в сунду́к** әйберләрне сандыкка яшереп кую **2.** *перен. кого-что, прост.* (*услать*) озату, сөрү, олактыру, илтеп тыгу; ябу

упря́таться *сов. разг.* нык яшеренү, качу

упря́тывать *несов. см.* **упря́тать**

упря́тываться *несов.* **1.** *см.* **упря́таться**; **2.** *страд. от* **упря́тывать**

упуска́ть *несов. см.* **упусти́ть**

упусти́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*случайно не удержать*) кулдан ычкындыру, ычкындырып жибәрү; **~ трос** тросны кулдан ычкындыру **2.** *кого-что* (*дать возможность уйти*) тота (эләктерә) алмый калу; **~ зве́ря** җәнлекне тота алмый калу **3.** *перен. что* ычкындыру, файдалана алмый калу; **~ возмо́жность** мөмкинлектән файдалана алмый калу **4.** *перен. кого-что, разг.* (*оставить без внимания*) карап җиткермәү, күздән (игътибардан) ычкындыру, игътибар биреп җиткермәү

упуще́ние *с* **1.** (*пропуск чего-л.*) кимчелек, җитешсезлек **2.** (*недосмотр, ошибка*) күреп җиткермәү, ялгышлык, хата, игътибарсызлык

упы́рь *м прост.* (*в сказках*) убыр, өрәк

ура́ *межд.* **1.** (*боевой клич*) ура **2.** (*восхищение*) ура кычкыру, ура тавышы ◆ **на ~** 1) *воен.* ура кычкырып; 2) *перен.* дәртләнеп, кайнарланып; **предложе́ние приня́ли на ~** тәкъдимне дәртләнеп кабул иттеләр; 3) *перен.* (*не подготовившись*) хәзерләнмичә, очраклы уңышка ышанып

уравне́ние *с* **1.** *см.* **уравня́ть, уравня́ться**; **2.** *мат.* тигезләмә; **~ с двумя́ неизве́стными** ике билгесезле тигезләмә

ура́внивать I *несов. см.* **уравня́ть**

ура́внивать II *несов. см.* **уровня́ть**

ура́вниваться I *несов.* **1.** *см.* **уравня́ться**; **2.** *страд. от* **ура́внивать** I

ура́вниваться II *несов.* **1.** *см.* **уровня́ться**; **2.** *страд. от* **ура́внивать** II

уравни́ловка *ж разг.* уравниловка, тигезләүчелек

уравни́тельн||ый, -ая, -ое *книжн.* **1.** *спец.* тигезли торган, тигезләүче, тигезләү ...ы; **~ые прибо́ры** тигезләү приборлары **2.** тигезләүчелек ...ы; **~ый подхо́д** *к чему-л. нәрсәгә дә булса* тигезләүчелек ноктасыннан якын килү

уравнове́сить *сов. что* **1.** тигезләү; **~ ча́шки весо́в** үлчәү тәлинкәләрен тигезләү **2.** *перен.* тигезләштерү, бертигез итү, тиңләштерү; **~ си́лы** көчләрне тиңләштерү

уравнове́ситься *сов.* **1.** тигезләнү **2.** *перен.* тигезләшү, тиңләшү

уравнове́шение *с см.* **уравнове́сить**

уравнове́шенность *ж* сабыр холыклылык, басынкылык

уравнове́шенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **уравнове́сить**; **~ые ча́шки весо́в** тигезләнгән үлчәү тәлинкәләре **2.** тыныч, сабыр, бысынкы; **~ый хара́ктер** тыныч характер; **~ый челове́к** сабыр кеше

уравнове́шивать *несов. см.* **уравнове́сить**

уравнове́шиваться *несов.* **1.** *см.* **уравнове́ситься**; **2.** *страд. от* **уравнове́шивать**

уравня́ть *сов. кого-что* тигезләү, бертигез итү, тигезләштерү, тиңләштерү; **~ в права́х** хокукларны тигезләү

уравня́ться *сов.* тигезләнү, бертигез булу, тигезләшү, тиңләшү

ура́ган *м* ураган, гарасат, көчле давыл ♦ **промча́ться ~ом** җил-давылдай [бик тиз] үтеп китү

ура́ганный, -ая, -ое (*очень сильный*) бик көчле, жимергеч; **~ ве́тер** бик көчле җил

уразумева́ть *несов. см.* **уразуме́ть**

уразуме́ние *с см.* **уразуме́ть**

уразуме́ть *сов. что, книжн.* аңлау, аңлап алу, төшенү; **~ значе́ние** *чего-либо* берәр нәрсәнең әһәмиятен аңлап алу

ура́н *м хим.* уран

ура́нов||ый, -ая, -ое уран ...ы; **~ая руда́** уран рудасы; **~ые месторожде́ния** уран ятмалары

урбаниза́ция *ж книжн.* урбанизация (*хәзерге жәмгыятьтә икътисадый һәм культура тормышының эре шәһәр үзәкләрендә генә туплана баруы*)

урбани́зм *м книжн.* урбанизм (**1.** *материаль һәм рухи культураны эре шәһәрләргә генә туплауны яклаучы агым* **2.** *сәнгатьтә эре шәһәр тормышын мактап җырлаучы юнәлеш*)

урбани́ст *м книжн.* урбанист, урбанизм тарафдары

урбанисти́ческ||ий, -ая, -ое *книжн.* урбанистик, урбанизм ...ы, урбанизмга хас булган; **~ая му́зыка** урбанистик музыка

урва́ть *сов. что, чего, прост.* **1.** (*оторвать, вырвать для себя*) йолкып алу, умырып алу **2.** *перен.* (*добыть*) кулга төшерү, кулга эләктерү; **~ деньжа́т** бераз акча кулга төшерү **3.** *перен.* (*выделить время*) табу, җай табу, ара табу

урду́ *м нескл.* урду (*Пакистанда дәүләт теле*)

урегули́рование *с см.* **урегули́ровать**; **ми́рное ~ спо́ров** бәхәсләрне тыныч юл белән җайга салу

урегули́ровать *сов. что* хәл итү; тәртипкә (җайга) салу, җайлау, көйләп җибәрү; **~ спо́рные вопро́сы** бәхәсле мәсьәләләрне җайлау

урегули́роваться *сов.* хәл ителү; тәртипкә (җайга) салыну, җайлану, көйләнү, көйләп җибәрелү

уре́зать *сов. что* **1.** *разг.* (*отрезать, укоротить*) кисеп кыскарту, кисеп кечерәйтү (киметү) **2.** *перен.* азайту, киметү, кыскарту, кечерәйтү; кису; **~ расхо́ды** чыгымнарны киметү

уреза́ть *несов. см.* **уре́зать**

урезо́нивать *несов. см.* **урезо́нить**

урезо́нить *сов. кого-что, разг.* күндерү, ышандыру, ризалату (*төшендереп, аңлатып, дәлилләп*)

уре́зывать *несов. см.* **уре́зать**

уреми́ческ||ий, -ая, -ое *мед.* уремия ...ы; **~ое заболева́ние** уремия авыруы

уреми́я *ж мед.* уремия (*сидек канлану авыруы*)

у́рна *ж* урна (**1.** *яндырылган мәет көлен саклау өчен махсус савыт* **2.** *сайлау бюллетеньнәрен салу өчен махсус тартма* **3.** *урамнарга куела торган чүп савыты*)

у́ров||ень *м* **1.** (*высота подъёма воды*) биеклек, тигезлек **2.** (*степень*) дәрәҗә; **культу́рный ~ень** культура дәрәҗәсе; **~ень разви́тия** үсеш дәрәҗәсе **3.** *см.* **ватерпа́с ♦ в ~ень** *с чем* 1) (*на одной высоте*) бер биеклектә, бер тигезлектә; 2) *в знач. предлога* бергә, бер адымнан, сулышын тоеп; **жить в ~ень с ве́ком** заман сулышын тоеп яшәү; **на ~не** *в знач. сказ.* тиешле югарылыкта, тулысынча канәгатьләнерлек; **докла́д был на ~не** доклад тиешле югарылыкта булды

уровня́ть *сов. что* тигезләү, такырайту; **~ доро́гу** юлны такырайту

уровня́ться *сов.* тигезләнү, такыраю

уро́д *м* **1.** (*человек с физическим недостатком*) гарип, гарип кеше **2.** (*некрасивый человек*) ямьсез, килбәтсез, шөкәтсез, иләмсез, шыксыз (кеше) **3.** (*человек с дурными свойствами характера*) бозык, азгын, әхлаксыз (кеше)

уро́дина *м, ж бран. см.* **урод** 1, 2

уроди́||ть *сов.* **1.** *что* уңыш бирү, уңдыру, җимеш бирү; **земля́ хорошо́ ~ла** җир мул уңыш бирде **2.** *кого-что, разг.* (*родить*) тудыру, табу

уроди́ться *сов.* **1.** (*созреть, вырасти*) уңыш бирү, уну, өлгерү **2.** *в кого, разг.* охшап туу; **~ в отца́** әтиенә охшап туу

уро́дливость *ж* **1.** (*физический недостаток*) гариплек **2.** (*внешнее безобразие*) ямьсезлек, иләмсезлек, шыксызлык, шөкәтсезлек **3.** *перен.* (*ненормальность, нелепость*) бозыклык, әшәкелек

уро́длив||ый, -ая, -ое **1.** (*с физическим недостатком*) гарип; **~ый но́готь** гарип тырнак **2.** (*безобразный*) иләмсез, кыяфәтсез, ямьсез, шыксыз, шөкәтсез; **~ая вне́шность** ямьсез кыяфәт **3.** *перен.* (*нелепый*) бозык, ялгыш, нормаль булмаган; **~ое воспита́ние** бозык тәрбия

уро́д||овать *несов.* **1.** *кого-что* ямьсезләү, бозу; **о́спа ~ует лицо́** чәчәк авыруы йөзне ямьсезли **2.** *кого-что* (*калечить*) гарипләндерү, гарипләтү, гарип итү, имгәтү; **рана́ения ~уют люде́й** яраланулар кешеләрне гарип калдыра **3.** *кого-что* (*портить*) ямьсезләү, шыксызлау; **~овать себя́ плохо́й причёской** начар причёска белән үзеңне ямьсезләү **4.** *прен., что* (*искажать*) бозу; **~овать** *чью-л.* **мысль** *кемнең дә булса* фикерен бозу

уро́доваться *несов. разг.* **1.** (*причинять себе увечье*) гарипләнү, гарип булып калу **2.** (*безобразить себя*) ямьсезләнү, үз-үзеңне ямьсезләү, кыяфәтеңне бозу **3.** *страд. от* **уро́довать**

уро́дск||ий, -ая, -ое *разг. см.* **уро́дливый** 2, 3; **~ий костю́м** килбәтсез костюм

уро́дство *с* **1.** (*физический недостаток*) гариплек **2.** (*безобразная внешность*) ямьсезлек, кыяфәтсезлек, килбәтсезлек, шөкәтсезлек **3.** *перен.* бозыклык, ялгышлык; **уро́дства бы́та** көнкүрешнең бозыклыклары; **нра́вственное ~** әхлакый бозыклык

урожа́й *м* **1.** уңыш; **оби́льный ~** мул уңыш **2.** *прям., перен.* (*изобилие, множество чего-л.*) мул уңыш, муллык, күп булу

урожа́йность *ж* уңдырышлылык, уңдырыш; **подня́ть ~ поле́й** кырларның уңдырышлылыгын күтәрү

урожа́йн||ый, -ая, -ое **1.** уңыш ...ы; **~ая ве́домость** уңыш ведомосте **2.** уңдырышлы, мул уңыш алган, уңыш мул булган; **~ый год** мул уңыш алган ел **3.** уңа торган, мул уңыш бирә торган; **~ый сорт** мул уңыш бирә торган сорт

урожда́ть *несов. см.* **уроди́ть**

урождённая кыз [вакытындагы] фамилиясе ... (*кияүгә чыккач фамилиясе үзгәргән хатынның кыз чактыгы фамилиясе алдыннан әйтелә*)

урожене́ц *м* ...да туган, туган җире ...; **~ Каза́ни** Казанда туган

урожене́нка *ж см.* **урожене́ц**

уро́к *м* **1.** дәрес; **~ матема́тики** математика дәресе; **~ му́зыки** музыка дәресе; **вы́учить ~** дәрес хәзерләү **2.** *перен.* сабак, гыйбрәт; **~ и исто́рии** тарих сабаклары; **э́то ему́ ~ на бу́дущее** бу аңа киләчәк өчен гыйбрәт булыр ♦ **брать ~ и** *чего у кого* дәресләр алу (*мәктәпкә йөрмичә хосусый тәртиптә уку*); **дава́ть ~ и** дәресләр бирү, укыту

уро́лог *м* уролог, урология белгече

урологи́ческий, -ая, -ое урология ...ы; **~ кабине́т** урология кабинеты

уроло́гия *ж* урология (*сидек-җенес ограннарындагы авыруларны тикшерә торган фән*)

урон *м* зыян, зарар, югалту; **нанести́** *~ кому-л. кәмгә дә булса* зыян китерү

урони́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*выпустить из рук*) [күлдан] төшерү, [күлдан] төшереп җибәрү **2.** *что* (*потерять*) төшереп калдыру, югалту; **~ кошеле́к** кошелекны төшереп калдыру **3.** *что* (*бессильно опустить вниз*) түбән ию, салындыру; **~ го́лову** башны салындыру **4.** *перен. что* (*унизить*) төшерү, дәрәҗәсен (абруен) төшерү; **~ своё досто́инство** үзеңнең дәрәҗәңне төшерү **5.** *перен. что* (*произнести*) сүз әйтү, сүз дәшү, эндәшү

уро́чище *с* **1.** (*природная межа*) табигый ызан, табигый чик (*мәс. чокыр, тау һ.б.ш.*) **2.** (*участок*) аймак, табигый урын (*мәс. басу уртасында калган урман яисә күл*)

уро́чн||ый, -ая, -ое билгеләнгән, тиешле, килешенгән, гадәттәге; **~ое вре́мя** билгеләнгән вакыт

урча́ние *с см.* **урча́ть**

урча́ть *несов.* **1.** (*о собаке*) ырылдау; (*о кошке*) мырылдау, мыраулау **2.** *безл.* (*в желудке*) быгырдау, чурлау, гөбердәү

уры́вками *нареч.* **1.** (*отрываясь от другого дела*) эштән туктаган араларда **2.** (*по временам*) ара-тирә, вакыт-вакыт, өзә-төтә, урык-сурык; **ви́деться ~** аратирә күрешкәләү

уро́к *м собир.* өрек (*киптерелгән абрикос җимеше*)

ура́дник *м* урядник (**1.** *патша армисенең казачий гаскәрләрендә: унтер-офицер* **2.** *революциягә кадәрге Россиядә: өяз полициясендә түбанге чиннарның берсе*)

уса́дебн||ый, -ая, -ое утар ...ы, усадьба ...ы; **~ые постро́йки** утар каралтылары

усади́ть *сов.* **1.** *кого-что* утырту, утырырга булышу; **~ дете́й** балаларны утырту **2.** *кого-что за что и с неопр.* утырту, ...п утырырга кушу; **~ чита́ть** укып утырырга кушу **3.** *что чем* утыртып бетерү, утыртып чыгу; **~ клу́мбы цвета́ми** клумбаларга чәчәкләр утыртып чыгу

уса́дка *ж спец.* утыру, керешү, кимү; **~ тка́ней** тукымаларның утыруы

уса́дочн||ый, -ая, -ое *спец.* утырудан хасил булган, кимүдән барлыкка килгән; **~ые пусто́ты** утырудан хасил булган куышлыклар

уса́дьба *ж* **1.** йорт (*каралты-кураларыбелән*); утар; **крестья́нская ~** крестьян йорты; **поме́щичья ~** алпавыт утары **2.** (*хозяйственный и жилой центр*) усадьба; **центра́льная ~ колхо́за** колхозның үзәк усадьбасы

уса́живать *несов. см.* **усади́ть**

уса́живаться *несов.* **1.** *см.* **усе́сться**; **2.** *страд. от* **уса́живать**

уса́тый, -ая, -ое мыеклы, мыеклач, озын мыеклы

уса́ч *м разг.* мыекбай, зур мыеклы кеше, озын мыеклы кеше

усва́ивать *несов. см.* **усво́ить**

усвое́ние *с см.* **усво́ить**

усво́ить *сов. что* **1.** үзләштерү, гадәтенә кертү; **~ но́вый обы́чай** яңа йоланы үзләштерү **2.** (*запомнить*) үзләштерү, отып алу, анлап җиткерү; **~ уро́к** дәресне анлап җиткерү **3.** (*об организме*) үзләштерү, сеңдерү; **~ пи́щу** азыкны үзләштерү

усвоя́емость *ж книжн.* үзләштерелүчәнлек, сеңдерелүчәнлек, сеңдерелеш; **хоро́шая ~ пи́щи** азыкның яхшы үзләштерелүчәнлеге

усе́ивать *несов. см.* **усе́ять**

усе́иваться *несов.* **1.** *см.* **усе́яться**; **2.** *страд. от* **усе́ивать**

усека́ть *несов. см.* **усе́чь**

усе́рдие *с* тырышлык, дәрт; **рабо́тать с ~м** дәрт белән (дәртләнеп) эшләү

усе́рдность *ж* тырышлык, дәртлелек, ихласлык; **изли́шняя ~** кирәгеннән артык тырышлык

усе́рдный, -ая, -ое тырыш, дәртле, ихласлы; **~ труд** тырыш хезмәт; **~ рабо́тник** тырыш эшче

усе́рдствовать *несов.* тырышлык (дәрт) белән эшләү, тырышып эшләү, тырышлык кую, казгану

усе́сться *сов.* **1.** утырышу, утыру, җайлап утыру; **~ на дива́н** диванга җайлап утыру **2.** *за что и с неопр.* (*начать заниматься*) ...га утыру, утырып ...а башлау; **~ за рабо́ту** эшкә утыру; **~ чита́ть** укырга утыру

усечённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **усе́чь**; **2.** *мат.* кисек, киселгән; **~ая пира́мида** кисек пирамида **3.** *грам., лит.* кыскартылган; **~ые прилага́тельные** кыскартылган сыйфатлар; **~ый стих** кыскартылган шигырь

усе́чь *сов. что* кисеп кыскарту, кисеп алу; **~ ко́нус** конусны кисеп кыскарту

усе́я||ть *сов. что* **1.** (*засеять*) чәчү, чәчеп тутыру; **~ть уча́сток пшени́цей** участокны бодай чәчеп тутыру **2.** каплап алу, сибелү, тутыру; **звёзды ~ли не́бо** йолдызлар күк йөзен каплап алган

усе́я||ться *сов.* каплану, чәчелеп каплап алу, сибелеп каплап алу; өртелү; **не́бо ~лось звёздами** күк йөзе йолдызлар белән капланган

усид||е́ть *сов.* **1.** (*остаться сидеть*) түзеп (чыдап) утыру; **ребя́та мину́тки на ме́сте не ~я́т** балалар урыннарында бер генә минут та түзеп утыра аймыйлар **2.** *что, прост.* ашап бетерү; эчеп бетерү; **весь пиро́г ~е́ли** бөтен бәлешне ашап бетерделәр **3.** *перен. разг.* (*удержаться на какой-л. работе*) урынында калу

уси́дчивость *ж* тырышлык, түземлек

уси́дчивый, -ая, -ое басылып эшләүчән, баш күтәрми эшләүчән, тырыш, түземле; **~ учени́к** тырыш укучы

уси́живать *несов. см.* **усиде́ть**

у́сики *мн.* **1.** *уменьш.-ласк. от* **усы́**; **2.** *бот.* мыекча (*усемлекләрдә*) **3.** *зоол.* мыек (*бөҗәкләрдә*)

усиле́ние *с см.* **уси́лить, уси́литься**; **~ контро́ля** контрольне көчәйтү

уси́ленн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **уси́лить**; **2.** (*улучшенный*) яхшыртылган, көчәйтелгән; **~ое пита́ние** яхшыртылган туклану **3.** *книжн.* (*крайне настойчивый*) бик үтенеп ..., ялварып ..., инәлеп ...; **~ые про́сьбы** бик үтенеп ялварулар

уси́ливать *несов. см.* **уси́лить**

уси́ливаться *несов.* **1.** *см.* **уси́литься**; **2.** *страд. от* **уси́ливать**

уси́ли||е *с* тырышлык, көч кую, куелган көч, көчәнеш; **приложи́ть ~я** *к чему-л. нәрсәгә дә булса* көч кую

усили́тель *ж* **1.** (*прибор*) көчәйткеч; **магни́тный ~** магнитик көчәйткеч; **~ мо́щности** егәрлек көчәйткеч (арттыргыч) **2.** (*вещество*) ныгыткыч, беркеткеч, көйчәйткеч; **~ рези́ны при вулканиза́ции** жылытып эшкәртүдә резинаны ныгыткыч

усили́тельн||ый, -ая, -ое *спец.* көчәйтү ...ы, көчәйткеч ...; **~ая аппарату́ра** көчәйткеч аппаратура

уси́лить *сов. что* көчәйтү, куәтләндерү, шәбәйтү, көчен арттыру, куәтен арттыру; **~ борьбу́ с престу́пностью** җинаятьчелеккә каршы көрәшнс көчәйтү

уси́ли||ться *сов.* көчәю, көче арту, куәтләнү, шәбәю; **ве́тер ~лся** җил көчәйде

ускака́||ть *сов.* **1.** чаба-чаба китеп бару, чаптырып китеп бару, сикерә-сикерә китеп бару; **ко́ни ~ли** атлар чаптырып китеп бардылар **2.** *разг.* (*быстро удалиться*) бик тиз китеп бару, бик тиз китү, чабып китү, йөгерү; **~л с прия́телями на футбо́л** иптәшләре белән футболга йөгерде

ускользá́ть *несов. см.* **ускользну́ть**

ускользну́||ть *сов.* **1.** шуып төшеп китү, шуып кулдан ычкыну; **нали́м ~л из рук** шамбы кулдан шуып төшеп китте **2.** *перен. разг.* (*уйти незамеченным*) таю, шылу, сызу, ычкыну, качып китү; **незаме́тно ~ть из дома́** сиздермичә генә өйдән чыгып сызу **3.** *перен. от кого-чего* күренмичә калу, сизелмичә калу, читтә калу, төшеп калу; **это не ~ло от моего́ внима́ния** бу минем игътибардан читтә калмады **4.** *перен. от чего, разг.* (*уклониться*) тайпылу, качу; **он ~л от прямо́го отве́та** ул туры җавап бирүдән тайпылды

ускоре́ние *с* **1.** *см.* **ускори́ть, ускори́ться**; **2.** *физ.* тизләнеш

ускоре́нн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **ускори́ть**; **2.** (*более быстрый, чем обычно*) тиз, кызу, еш; **~ое движе́ние по́езда** поездның тиз хәрәкәт итүе

ускори́тель *м тех.* тизләткеч; **~ заря́женных части́ц** корылмалы кисәкчекләр тизләткече

ускори́тельный, -ая, -ое *тех.* тизләткеч ..., тизләту ...ы; **~ прибо́р** тизләткеч прибор

ускори́ть *сов. что* **1.** тизләту, кызулату, җәһәтләү, шәбәйтү; **~ шаги́** адымнарны тизләту **2.** (*приблизить наступление чего-л.*) ашыктыру, тизләту; **~ отъе́зд** китүне тизләту

ускори́||ться *сов.* **1.** (*стать более быстрым*) тизләнә төшү, кызулана төшү, шәбәю, җәһәтләну **2.** (*приблизиться во времени*) алданрак булу, ашыктырылу, иртәрәк булу; **отъе́зд ~лся** китү алданрак булды

ускоря́ть *несов. см.* **ускори́ть**

ускоря́ться *несов.* **1.** *см.* **ускори́ться**; **2.** *страд. от* **ускоря́ть**

усла́вливаться *несов. см.* **усло́виться**

усла́да *ж уст.* ләззәт, рәхәт, хозур [-лык]

услади́тельн||ый, -ая, -ое *уст.* ләззәтләндергеч, хозурландыргыч, рәхәтләндергеч; **~ое пе́ние соловья́** сандугачның хозурландыргыч итеп сайравы

услади́ть *сов. кого-что, уст.* ләззәтләндерү, рәхәтләндерү, хозурландыру, ләззәт бирү; **~** *кого-л.* **пе́нием** жырлавы белән *кемне дә булса* ләззәтләндерү

услади́ться *сов. кем-чем, уст.* ләззәтләнү, рәхәтләнү, хозурлану, ләззәт табу

услажда́ть *несов. см.* **услади́ть**

услажда́ться *несов.* **1.** *см.* **услади́ться**; **2.** *страд. от* **услажда́ть**

усла́||ть *сов. кого-что* җибәрү, чыгарып җибәрү; сөрү, олактыру

уследи́||ть *сов. за кем-чем* **1.** күзәтеп саклап калу, күз-колак булып саклап калу, күздән ычкындырмау, күзәтеп җиткерү; **не ~ла за молоко́м: убежа́ло** сөтне күзәтеп җиткерә алмаган: ташыган **2.** (*не упустить из виду*) тикшереп бару, күзәтеп бару, аңлап бару; **~ть за хо́дом мы́сли** фикер сөрешен күзәтеп бару

усло́ви||е *с* **1.** (*обстоятельство*) шарт; **постоя́нный труд — ~е успе́ха в учёбе** даими хезмәт — укулар уңышлы баруның шарты **2.** (*требование*) таләп, шарт; **назови́те ва́ши ~я** үзегезнең таләпләрегезне әйтегез **3.** (*уговор*) килешү, сүз куешу; **нару́шить ~е** килешүне бозу **4.** *мн.* **~я** (*обстановка*) шартлар; **хоро́шие ~я для рабо́ты** эш өчен унай шартлар; **жили́щные ~я** торак шартлары **5.** *обычно мн.* **~я** (*правила*) кагыйдәләр, шартлар; **~я по́льзования электри́чеством** электрдан файдалану кагыйдәләре

усло́виться *сов. с кем о чём* килешү, сүз куешу, вәгъдәләшү; **~ *с кем-л.* о встре́че** *кем белән дә булса* очрашу турында сүз куешу

усло́вленн||ый, -ая, -ое килешенгән, сүз куешкан, вәгъдәләшкән, сөйләшенгән; **~ая встре́ча** килешенгән очрашу

усло́вливаться *несов. см.* **усло́виться**

усло́вност||ь *ж* **1.** шартлылык; **~ь а́дреса** адресның шартлылыгы; **~ь декора́ции** декорациянең шартлылыгы **2.** шартлы гадәтләр, шартлы кагыйдәләр; **он враг вся́ких ~ей** ул һәртөрле шартлы кагыйдәләрнең дошманы

усло́вн||ый, -ая, -ое **1.** шартлы, килешенгән; **~ый знак** шартлы билге; **~ый язы́к** шартлы тел **2.** шартлы, чикләнгән; **~ый приго́вор** шартлы хөкем; **~ое согла́сие** шартлы ризалык **3.** шартлы, уйланма; **~ая ли́ния** уйланма сызык; **~ая декора́ция** шартлы декорация **4.** *грам.* шарт ...; **~ое предложе́ние** шарт җөмлә

усложне́ние *с* **1.** *см.* **усложни́ть, усложни́ться**; **2.** (*усложнённое положение*) катлаулы хәл, четерекле хәл, кыен хәл

усложнённость *ж* катлаулылык, четереклелек, кыенлык

усложнённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **усложни́ть**; **2.** катлауландырылган, кыенлаштырылган, катлаулы; **~ая те́хника** катлаулы техника

усложни́ть *сов. что* катлауландыру, четереклеләндерү, кыенлаштыру, читенләштерү, авырлаштыру; **~ рабо́ту** эшне кыенлаштыру; **~ прое́кт** проектны катлауландыру

усложни́||ться *сов.* катлаулану, четереклеләнү, кыенлашу, читенләшү, авырлашу; **зада́ча ~лась** мәсьәлә кыенлашты

усложня́ть *несов. см.* **усложни́ть**

усложня́ться *несов.* **1.** *см.* **усложни́ться**; **2.** *страд. от* **усложня́ть**

услу́г||а *ж* **1.** ярдәм, булышлык, хезмәт; **дру́жеская ~а** дусларча ярдәм **2.** *мн.* **~и** уңайлыклар; **комму́нальные ~и** коммуналь уңайлыклар (*водопровод, канализация һ.б.ш.*)

услуже́ни||е *с*: **быть в ~и** *уст.* ялчы булып тору; хезмәтче булып тору; асрау булып тору

услу́живать *несов. уст. см.* **услужи́ть**

услужи́ть *сов. кому* ярдәм итү (күрсәтү), булышлык күрсәтү, булышу; **всегда́ рад вам ~** сезгә ярдәм күрсәтергә һәрвакыт әзермен

услу́жливость *ж* ярдәмчеллек, хезмәт күрсәтергә әзер тору, булышлык күрсәтергә әзер булу

услу́жливый, -ая, -ое ярдәмчел, булышучан, ярдәм кулы сузарга әзер торучан

услыха́ть *сов. разг. см.* **услы́шать** 1, 2

услы́ша||ть *сов.* **1.** *что и с союзом «что»* (*воспринять слухом*) ишетү; **~ть пе́ние соловья́** сандугач сайраганны ишетү **2.** *что, про кого-что о ком-чём и с союзом «что»* (*узнать*) ишетү, белү; **я ~л об э́том вчера́** мин бу турыда кичә ишеттем **3.** *что* (*ощутить*) сизү, тою **~ть за́пах я́блок** алма исе сизү

усма́тривать *несов. см.* **усмотре́ть**

усмеха́ться *несов. см.* **усмехну́ться**

усмехну́ться *сов.* көлемсерәү, елмаеп кую, авыз еру

усме́шка *ж* елмаю, көлемсерәү; **лука́вая ~** хәйләле елмаю

усмире́ние *с см.* **усмири́ть**

усмири́тель *м* тынычландыручы, басынкыландыручы, юашландыручы; бастыручы

усмири́ть *сов. кого-что* **1.** юашландыру, буйсындыру, кулга өйрәтү, тынычландыру, басынкыландыру; **~ льва** арсланны юашландыру **2.** *уст.* бастыру, туктату; **~ мяте́ж** фетнәне бастыру

усмири́ться *сов.* басынкылану, юашлану, тынычлану, басылу, тыну

усмиря́ть *несов. см.* **усмири́ть**

усмиря́ться *несов.* **1.** *см.* **усмири́ться**; **2.** *страд. от* **усмиря́ть**

усмотре́ни||е *с книжн.* карау, хөкем, ихтыяр, карамак; **я передаю́ э́то на ва́ше ~е** мин моны сезнең карамакка тапшырам; **де́йствовать по своему́ ~ю** үз ихтыярың буенча эш итү

усмотре́ть *сов.* **1.** *за кем-чем, разг.* күзәтү, күз-колак булу, күз җитү, күздән ычкындырмау; **за все́ми сра́зу не усмо́тришь** барысын да берьюлы күзәтеп бетерә алмассың **2.** *что в чём* ... дип тану, ... дип санау, ... дип исәпләү, ... дип табу; **~ в реше́нии серьёзную оши́бку** карарда җитди хата бар дип табу

уснасти́ть *сов. что чем* **1.** (*снабдить*) җиһазлау, тәэмин итү **2.** *перен.* (*украсить*) бизәү, чуарлау, тутыру; **~ речь цита́тами** сөйләмне цитаталар белән чуарлау

уснаща́ть *несов. см.* **уснасти́ть**

усну́||ть *сов.* **1.** йокыга китү, йокыга талу, йоклап китү; **ребёнок ~л** сабый йокыга китте **2.** *перен.* (*затихнуть*) тынтын калу, тыну, сүнү, басылу; **река́ ~ла** елга тып-тын булып калды; **~вшие наде́жды** сүнгән өметләр **3.** (*о рыбе*) үлү, тыну ♦ **~ть наве́ки (ве́чным сно́м)** мәңгелек йокыга талу

усо́бица *ж уст.* үзара дошманлык, үзара тартыш, үзара низаг, үзара көрәш

усовершéнствовани||е *с* **1.** *см.* **усовершéнствовать, усовершéнствоваться**; **2.** камиллек; **но́вые ~я в маши́не** машинага кертелгән яңа камиллекләр

усовершéнствованный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **усовершéнствовать**; **2.** камилләштерелгән, камилләшкән; **~ дви́гатель** камилләштерелгән двигатель

усовершéнствовать *сов. что* камилләштерү

усовершéнствоваться *сов.* камилләшү

усо́вестить *сов. кого-что, разг.* оялту, инсафка китерү

усо́веститься *сов. разг.* оялу, инсафка килү

усомни́ться *сов. в ком-чём* шикләнү, шик туу, шиккә төшү, шөбһәләнү; **~ в ве́рности сообще́ния** хәбәрнең дәрәслегеннән шикләнү

усо́пший, -ая, -ое *высок.* мәрхүм, вафат булган, үлгән

усо́хнуть *сов.* кибеп кимү, кибә-кибә кечерәю, кибә-кибә бәләкәйләнү

успева́емость *ж* өлгереш; **высо́кая ~ студе́нтов** студентларның югары өлгереше

успева́||ть *несов.* **1.** *см.* **успе́ть**; **2.** (*успешно учиться*) өлгерү

успева́ющ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **успева́ть**; **2.** өлгерүче; **~ие ученики́** өлгерүче укучылар

успе́ется *сов. безл.* ашыгуның кирәге юк, өлгерәбез әле; **посиди́м, ещё ~** бераз утырыйк, өлгерәбез әле

успе́||ть *сов.* **1.** (*сделать в срок*) өлгерү, җитешү **2.** (*прибыть к сроку*) килеп җитү, барып җитү, өлгерү; **~ть на заседа́ние** утырыш башлануга килеп җитү; **~ть на по́езд** поездга өлгерү **3.** *в чём, уст.* (*достигнуть успеха*) уңышка ирешү, уңыш казану; **~ть в нау́ках** фән өлкәсендә уңыш казану ♦ **не ~ешь огляну́ться, как ...** күз ачып йомганчы ...; **не ~ть и гла́зом моргну́ть** күз ачып йомарга да өлгермәү

успе́х *м* **1.** (*достижение*) уңыш, уңышлык; **доби́ться ~а** уңышка ирешү **2.** (*общественное признание*) уңыш, казаныш, уңыш казану; **по́льзоваться больши́м ~ом** зур уңыш казану **3.** *мн.* **~и** (*хорошие результаты*) өлгерү, өлгереш ♦ **с ~ом** ансат кына, жинел генә, уңышлы рәвештә; **с таки́м же (с тем же) ~ом** шундый ук уңыш белән, шуның шикелле үк

успе́шность *ж* уңышлык, уңышлы булу, уңышлы бару; **~ рабо́ты** эшнең уңышлы баруы

успе́шный, -ая, -ое уңышлы, отышлы; **~ ход рабо́ты** эшнең уңышлы барышы

успока́ивать *несов. см.* **успоко́ить**

успока́иваться *несов.* **1.** *см.* **успоко́иться**; **2.** *страд. от* **успока́ивать**

успокое́ние *с см.* **успоко́ить, успоко́иться**

успоко́енность *ж* **1.** (*умиротворённость*) тынычлану, тынычлыкка бирелү **2.** (*беспечное спокойствие*) урынсызга тынычлану, гамьсезлек

успокои́тельн||ый, -ая, -ое **1.** тынычландыра торган, тынычландыргыч, юата торган; **~ое изве́стие** тынычландыргыч хәбәр **2.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* тынычландыра торган дару

успоко́ить *сов.* **1.** *кого-что* тынычландыру, юату; **~ ребёнка** баланы юату **2.** *что* киметү, басу, басылдыру, җиңеләйтү; **~ боль** авыртуны басу

успоко́и||ться *сов.* **1.** тынычлану, тыну; **ребёнок ~лся** бала тынычланды; **мо́ре ~лось** диңгез тынды **2.** кимү, басылу, тыну; **боль ~лась** авырту басылды

уста́ *только мн. уст.* авыз, ирен ♦ **из пе́рвых уст узна́ть** үзеннән белү; **из уст в ~** телдән телгә; **э́то у всех на ~х** барысының да авызында (телендә) шул, барысы да шул турыда сөйли; **ва́шими бы ~ми [да] мёд пить** авызыгызга бал да май

уста́в *м* устав; **во́инский ~** хәрби устав

устава́ть *несов. см.* **уста́ть**

уста́вить *сов.* **1.** *кого-что* (*разместить*) тезү, урнаштыру, сыйдыру; **~ все кни́ги на по́лку** барлык китапларны киштәгә урнаштыру **2.** *что* (*занять всю поверхность*) куеп тутыру, тезеп тутыру; **~ по́лку кни́гами** китаплар тезеп киштәне тутыру **3.** *перен. что в кого-что, на кого-что, разг.* төбәү, текәү, текәлеп карау; **~ взгляд** *на кого-л. кемгә дә булса* текәлеп карау

уста́ви||ться *сов.* **1.** урнашып бетү, сыеп бетү; **кни́ги ~лись на по́лке** китаплар киштәгә сыеп бетте **2.** тулу, тулып бетү; **поле ~лось скирда́ми** басу эскертләр белән тулды **3.** *на кого-что, в кого-что, разг.* күз төбәү, текәлеп карау, карап кату; **что ты на меня́ ~лся?** нәрсә син миңа карап каттың?

уставля́ть *несов. см.* **уста́вить**

уставля́ться *несов.* **1.** *см.* **уста́виться**; **2.** *страд. от* **уставля́ть**

уста́вн||ый, -ая, -ое устав ...ы, уставта кабул ителгән; **~ые но́рмы** устав нормалары

уста́лость *ж* арыганлык, талчыкканлык, алҗыганлык, тылчыгу, ару, алҗу, йөгенү; **почу́вствовать ~** арыганлык тою ♦ **~ мета́ллов** *спец.* металлның талуы (*нагрузканың әледән-әле үзгәреп торуы тәэсирендә металлның ныклыгы кими*)

уста́л||ый, -ая, -ое арыган, талчыккан, алҗыган, хәлсез; **~ый пу́тник** арыган юлчы; **~ые глаза́** талчыккан күзләр

у́стал||ь *ж*: **без ~и** армый-талмый, ару-талуны белмичә

устана́вливать *несов. см.* **установи́ть**

устана́вливаться *несов.* **1.** *см.* **установи́ться**; **2.** *страд. от* **устана́вливать**

установи́ть *сов. что* **1.** урнаштыру, көйләү, кую; **~ прице́л** прицел кую **2.** билгеләү, раслау, гамәлгә кертү; **~ дни о́тдыха** ял көннәрен билгеләү; **~ но́вое расписа́ние** яңа расписаниене гамәлгә кертү **3.** урнаштыру, булдыру; **~ связь** *с кем-л. кем белән дә булса* элемтә урнаштыру; **~ мир** тынычлык урнаштыру **4.** табу, ачу, аныклау, ачыклау, исбатлау; **~ факт** фактны ачыклау; **~ и́стину** хакыйкатьне табу

установи́||ться *сов.* **1.** (*наладиться*) урнашу, булдырылу, рәтләнү, жайга салыну; **~лась тишина́** тынлык урнашты; **пого́да ~лась** көннәр рәтләнде **2.** (*сформироваться*) җитлегү, ныгып житү, формалашып җитү; **го́лос у него́ ещё не ~лся** аның тавышы формалашып житмәгән әле

устано́вк||а *ж* **1.** *см.* **установи́ть** 1; **2.** (*механизм, приспособление*) җайланма, механизм, установка; **заводски́е ~и** завод җайланмалары **3.** (*целевая направленность*) күздә тоту, максат итеп кую, юнәлеш, куелыш; **~а на высо́кое ка́чество проду́кции** югары сыйфатлы продукция бируне максат итеп кую **4.** (*указание*) күрсәтмә, директива; **~а центра́льных о́рганов** үзәк органнарның күрсәтмәсе

установле́ни||е *с* **1.** *см.* **установи́ть** 2, 3, 4; **2.** *уст.* закон, устав; **свод ~й** законнар җыелмасы

устано́вленн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **установи́ть**; **2.** уставта каралган, закон белән билгеләнгән, законда каралган; **в ~ом поря́дке** закон белән билгеләнгән тәртиптә

устано́вочн||ый, -ая, -ое **1.** урнаштыру ...ы, көйләү ...ы; **~ый винт** көйләү винты **2.** юнәлеш бирә торган, күрсәтмә бирә торган, юл күрсәтүче; **~ые те́зисы** юнәлеш бирә торган тезислар

устано́вщик *м* куючы, көйләп куючы, коручы, җыючы; **~ маши́н** машиналарны җыючы

устарева́ть *несов. см.* **устаре́ть**

устаре́лый, -ая, -ое искергән, гамәлдән чыккан; **~ фасо́н** гамәлдән чыккан фасон; **~ взгляд** *на что-л.* искергән караш

устаре́||ть *сов.* искерү, гаймәлдән чыгу, кулланылмау; **э́тот учёбник ~л** бу дәреслек искергән

уста́||ть *сов.* ару, арып бетү, талу, талчыгу, хәлдән таю, өшәнү, ялыгу, йөгенү; **~ть от ходьбы́** күп йөреп ару; **я ~л ждать** көтә-көтә арып беттем

устели́ть *сов. прост. см.* **устла́ть**

устели́ться *сов. прост. см.* **устла́ться**

устере́чь *сов. кого-что, разг.* саклау, саклап калу, саклап алып калу; **~ ребёнка от просту́ды** баланы салкын тиюдән саклап калу

устер||е́чься *сов. разг.* саклану, сакланып калу; **я не ~ёгся от просту́ды** салкын тиюдән сакланып кала алмадым

устила́ть *несов. см.* **устла́ть, устели́ть**

устила́ться *несов.* **1.** *см.* **устла́ться, устели́ться**; **2.** *страд. от* **устила́ть**

устла́ть *сов. что чем* җаю, түшәү, җәеп (түшәп) чыгу, каплау, каплап алу; **~ пол ковра́ми** идәнгә келәмнәр җәеп чыгу

устла́ться *сов. разг.* җәелү, түшәлү, капланы

у́стн||ый, -ая, -ое сөйләм ...ы, телдән; **~ая речь** сөйләм теле; **~ый отве́т** телдән җавап бирү

усто́||й *м* **1.** (*опора*) терәк, таяныч, багана; **быки́ и береговы́е ~и мосто́в** күпернең баганалары һәм ярдагы таянычлары **2.** *мн. ~и перен.* нигез; **мора́льные ~и челове́ческого о́бщества** кешелек җәмгыятенең әхлак нигезләре **3.** куерык (*сыекчаның өстенә җыелган куесы, мәсәлән, сөт өстенә җыелган каймак*)

усто́йчивость *ж* **1.** тотрыклылык; **~ самолёта** самолётның тортрыклылыгы **2.** *перен.* (*стабильность, постоянство*) тотрыклылык, үзгәрмәүчәнлек; **~ репертуа́ра** репертуарның тотрыклыгы

усто́йчив||ый, -ая, -ое **1.** тотрыклы, чайкалмый торган; **~ая ло́дка** чайкалмый торган көймә **2.** *перен.* тотрыклы, ныклы, үзгәрми торган, һәртөрле тәэсирләргә бирелми торган; **~ые урожа́и** тотрыклы иген уңышы; **~ая валю́та** тотрыклы валюта

***усто́йчивый**, -ая, -ое *кушма сүзләрнең икенче кисәге, татар теленә «бирешмәүчән», «чыдамлы», «түземле» сүзләре белән тәрҗемә ителә, мәс.* **морозоусто́йчивый** салкынга чыдамлы

усто́я||ть *сов.* **1.** (*не упасть*) аумау, егылмау, баскан жирдә түзеп тору; **~ на нога́х** аяктан егылмау **2.** *перен.* нык тору, бирешмәү, бирелмәү; **~ в спо́ре** бәхәстә бирешмәү

усто́я||ться *сов.* **1.** (*отстояться*) өстә утыру, өсте җыелу (*мәс.,сөтнең*) **2.** тону, тоныклану; **му́тная вода́ ~лась** болганчык су тонган **3.** *перен.* утыру, басынкылану, тотрыклы хәлгә килү; **хара́ктер ещё не ~лся** характеры әле тотрыклы хәлгә килеп җитмәгән

устра́ивать *несов. см.* **устро́ить**

устра́иваться *несов.* **1.** *см.* **устро́иться**; **2.** *страд. от* **устра́ивать**

устране́ние *с см.* **устрани́ть**

устрани́ть *сов.* **1.** *кого-что* читкә (кырыйга, янга) алып ташлау; **~ все прегра́ды** барлык тоткарлыкларны читкә алып ташлау **2.** *что* бетерү, юк итү, арыну; **~ недочёты** кимчелекләрне бетерү **3.** *кого-что, офиц.* [эштән] чыгару, урыннан төшерү, эштән алу; **~ от рабо́ты** эштән чыгару

устрани́ться *сов.* читләшү, [баш тартып] китү; **~ от дел** эштән читләшү

устраня́ть *несов. см.* **устрани́ть**

устраня́ться *несов.* **1.** *см.* **устрани́ться**; **2.** *страд. от* **устраня́ть**

устраша́ть *несов. см.* **устраши́ть**

устраша́ться *несов.* **1.** *см.* **устраши́ться**; **2.** *страд. от* **устраша́ть**

устраша́ющий, -ая, -ое куркыныч, имәнеч; **~ вид** куркыныч кыяфәт

устраше́ние *с см.* **устраши́ть, устраши́ться**

устраши́тельный, -ая, -ое *уст.* куркыта торган, куркытkыч, күңелгә шом сала торган

УСТ-УТВ

устраши́||ть *сов. кого-что, книжн.* куркыту, өркетү, курку салу, куркуга төшерү, котын алу; **тру́дности его́ не ~ли** кыенлыклар аны куркытмады

устраши́ться *сов. кого-что, книжн.* курку, өрку, шүрләү, коты чыгу; **не ~ угро́з** янаулардан курыкмау

устреми́ть *сов. что* **1.** ябырылдыру, ташландыру, жибәрү; **~ та́нки на врага́** дошман өстенә танклар ябырылдыру **2.** *перен.* төбәү, ташлау, юнәлтү, юнәлдерү; **~ взгля́д** күз төбәү

устреми́||ться *сов.* **1.** ябырылу, ыргылу, ташлану; **бойцы́ ~лись в ата́ку** сугышчылар атакага ташландылар **2.** *перен.* төбәлү, ташлану, текәлү, юнәлү; **взо́ры всех ~лись на вошёдшего** барысының да күзләре кергән кешегә төбәлде

устремле́ние *с* **1.** *см.* **устреми́ть, устреми́ться**; **2.** *книжн.* (*намерение*) теләк, максат, ният, омтылыш

устремлённость *ж* омтылышлы булу, юнәлешле булу, [максатка] юнәлтелгәнлек

устремля́ть *несов. см.* **устреми́ть**

устремля́ться *несов.* **1.** *см.* **устреми́ться**; **2.** *страд. от* **устремля́ть**

у́стрица *ж* устрица (*диңгез моллюскы*)

у́стричн||ый, -ая, -ое устрица ...ы, устрица эшкәртү ...ы; **~ая ра́ковина** устрица кабырчыгы; **~ый про́мысел** устрица промыселы

устрое́ние *с см.* **устро́ить** 1, 2, 4, 6

устро́енн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **устро́ить**; **2.** жайланган, тәртипкә салынган, тәртипкә китерелгән, көйләнгән, жайлы, төзек; **~ая жи́знь** тәртипкә салынган тормыш

устро́итель *м* оештыручы; **~ конце́рта** концерт оештыручы

устро́ительница оештыручы хатын (кыз)

устро́ить *сов.* **1.** *что* кору, салу, булдыру; **~ плоти́ну на реке́** елгада буа кору **2.** *что* (*организовать*) оештыру; **~ конце́рт** концерт оештыру **3.** *что* (*учинить*) күтәрү, куптару, чыгару; **~ сканда́л** җәнҗал куптару **4.** *что* (*наладить*) рәтләү, жайга салу, көйгә салу; **~ свои́ дела́** эшләреңне жайга салу **5.** *что кому, разг.* (*посодействовать*) булышу, ярдәм итү; **~ биле́т в теа́тр** театрга билет алырга булышу **6.** *кого-что* (*определить*) урнаштыру, кертү; **~ на рабо́ту** эшкә урнаштыру **7.** *кого-что* (*оказаться удобным*) канәгатьләндерү, кулай булу, яраклы булу, ярау; **тако́е реше́ние меня́ не устро́ит** мондый карар мине канәгатьләндерми

устро́иться *сов.* **1.** (*наладиться*) рәтләнү, рәткә салыну, жайлану, жайга салыну **2.** (*поступить*) урнашу, керү; **~ на заво́д** заводка эшкә урнашу **3.** (*расположиться*) урнашу, жайлап урнашу; **~ спа́ть на дива́не** диванда йокларга урнашу

устро́йство *с* **1.** *см.* **устро́ить** 1, 2, 4, 5, 6; **2.** (*конструкция*) төзелеш, корылыш, ясалыш; **~ радиоприёмника** радиоалгычның төзелеше **3.** (*строй*) төзелеш, строй; **госуда́рственное ~** дәүләт төзелеше **4.** (*механизм*) корылма, жайланма, төзелмә; **тормозно́е ~** тормоз жайланмасы

усту́п *м* киртләч, чыгынты; **на ~ах гор** тау киртләчләрендә

уступа́ть *несов. см.* **уступи́ть**

уступи́тельн||ый, -ая, -ое: **~ое прида́точное предложе́ние** *грам.* иярчен кире жөмлә

уступи́||ть *сов.* **1.** *кого-что кому* бирү, сабу; **~ть место** урын бирү; **~ть доро́гу** *кому-л. кемгә дә булса* юл сабу **2.** *кому в чём* (*покориться*) юл кую, каршы килмәү; **~ть в спо́ре** бәхәстә юл кую **3.** *кому-чему в чём* (*оказаться ниже*) калышу, бирешү; **он никому́ не ~т в хра́брости** батырлык ягыннан ул беркемгә дә бирешмәс **4.** *что кому, разг.* (*продавая, отдать дешевле*) киметү, төшү, ташлама ясау; **~ть два рубля́** ике сумга киметү

усту́пк||а *ж* **1.** *см.* **уступи́ть** 2, 4; **2.** (*компромисс*) ташлама; **пойти́ на ~и** ташлама ясау **3.** (*скидка с назначенной цены*) киметү; **прода́ть с ~ой** бәясен киметеп сату

усту́пчат||ый, -ая, -ое киртләчле-киртләчле, баскычлы-баскычлы, керентеле-чыгынтылы; **~ая возвы́шенность** киртләчле-киртләчле калкулык

усту́пчивость *ж* юл куючанлык, килешүчәнлек; күндәмлек

усту́пчивый, -ая, -ое килешүчән, юл куючан, сүзгә күнүчән; күндәм; **~ челове́к** юл куючан кеше

устыди́ть *сов. кого-что* оялту, кызарту

устыди́ться *сов. чего* оялу, кызару, хурлану

у́стье *с* **1.** тамак, елга тамагы; **~ Ка́мы** Кама тамагы **2.** (*выход*) авыз; **~ ша́хты** шахта авызы

усугуби́ть, усугу́бить *сов. что, книжн.* көчәйтү, арттыру, кискенләштерү, авырлаштыру; **~ вину́** гаепне көчәйтү

усугуби́ться, усугу́биться *сов. книжн.* көчәю, арту, кискенләшү, авырлашу

усугубле́ние *с см.* **усугуби́ть, усугу́бить**

усугубля́ть *несов. см.* **усугуби́ть, усугу́бить**

усугубля́ться *несов.* **1.** *см.* **усугуби́ться, усугу́биться**; **2.** *страд. от* **усугубля́ть**

усу́шка *ж* кибә-кибә кимү, кибә-кибә кимегән авырлык

усы́ *мн.* **1.** мыек; **отрасти́ть ~** мыек жибәрү **2.** *бот.* мыекча (*усемлекләрдә*) ◆ **и в ус [себе] не ду́ть** исе дә китмәү; **са́ми с уса́ми** үзебез дә беләбез, үзебезнең дә башка тай типмәгән

усыла́ть *несов. см.* **усла́ть**

усынови́тель *м офиц.* уллыкка алучы, кызлыкка алучы

усынови́ть *сов. кого* уллыкка алу; кызлыкка алу (*үз улы яки кызы итеп яздырып тәрбиягә алу*)

усыновле́ние *с* уллыкка алу; кызлыкка алу

усыновля́ть *несов. см.* **усынови́ть**

усыпа́льница *ж книжн.* төрбә (*бер ыру яисә бер гаилә членнарын кому өчен махсус бина*)

усы́пать *сов. что* сибеп (чәчеп) чыгу, сибеп (чәчеп) тутыру; **~ доро́жки песко́м** юлларга ком сибеп чыгу

усыпа́ть *несов. см.* **усы́пать**

усыпи́тельн||ый, -ая, -ое *разг.* йоклата торган, йокы китерә торган, йоклаткыч, йокы китергеч; **~ го́лос** йокы китергеч тавыш

усыпи́ть *сов.* **1.** *кого-что* (*заставить уснуть*) йоклату, йокыга талдыру **2.** *кого-что* (*умертвить*) агулап үтерү; **~ больну́ю соба́ку** авыру этне агулап үтерү **3.** *перен. кого-что* йокы китерү, йокымсырату, оету; **~ моното́нным чте́нием** бертөрле укып йокыны китерү **4.** *перен. что* киметү, йомшарту, зәгыйфьләтү; **~ бди́тельность** уяулыкны киметү

усыпле́ние *с см.* **усыпи́ть**

усыпля́ть *несов. см.* **усыпи́ть**

усыха́ть *несов. см.* **усо́хнуть**

ута́ивать *несов. см.* **утаи́ть**

утаи́ть *сов. что* **1.** (*сохранить в тайне*) сер итеп тоту (саклау), яшерү, әйтми калдыру; **~ пра́вду** дөреслекне яшерү **2.** (*тайно присвоить*) үзләштерү, үзләштереп алып калу, сиздермичә үзләштерү; яшереп алып калу; **~ чужи́е ве́щи** кеше әйберләрен сиздермичә үзләштерү

ута́йка *ж см.* **утаи́ть**

ута́птывать *несов. см.* **утопта́ть**

утащи́ть *сов. кого-что* **1.** өстерәп (сөйрәп) алып китү; **~ мешо́к в подва́л** капчыкны өстерәп подвалга алып китү **2.** *перен. шутл.* (*повести с собой*) иректезләп алып китү, көчләп алып китү; **~ *кого-л.* в го́сти** *кемне дә булса* иректезләп кунакка алып китү **3.** (*украсть*) урлау, чәлдерү, сорамыйча алып китү

у́тварь *ж собир.* кирәк-яраклар, жиһазлар; **дома́шняя ~** йорт кирәк-яраклары

утверди́тельн||ый, -ая, -ое **1.** канәгатьләндерерлек, уңай; **~ый отве́т** канәгатьләндерерлек жавап **2.** *грам.* раслау ...ы; **~ая ча́стица** раслау кисәкчәсе

утверди́ть *сов.* **1.** *кого-что* раслау, кабул итү; **~ план рабо́ты** эш планын раслау; **~ но́вый зако́н** яңа закон кабул итү **2.** *что, книжн.* ныгыту, беркетү; **~ опо́ры в земле́** терәкләрне җиргә беркету **3.** *кого-что* ышандыру, инандыру; **~ в *каком-л.* мне́нии** *нинди дә булса* фикергә ышандыру

утверди́||ться *сов.* **1.** урнашу, тамыр жәю, ныгу; **~лся порядок** тәртип урнашты **2.** ышану, инану; **~ться в своём мне́нии** үз фикереңнең дөреслегенә инану

утверажда́||ть *несов.* **1.** *см.* **утверди́ть**; **2.** *что* әйтү, сөйләү, раслау; **все ~ют, что он прав** барысы да аны хаклы дип әйтәләр

утверажда́ться *несов.* **1.** *см.* **утверди́ться**; **2.** *страд. от* **утверажда́ть**

утвержде́ни||е *с* **1.** *см.* **утверди́ть, утверди́ться**; **2.** раслау, караш, фикер, положение; **пра́вильные ~я** дөрес фикерләр

утека́ть *несов. см.* **уте́чь**

утёнок *м* үрдәк бәбкәсе

утепле́ние *с см.* **утепли́ть**

утеплённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **утепли́ть**; 2. җылытылган, җылы; **~ый грунт** җылытылган грунт; **~ая о́бувь** җылы аяк киеме

утепли́тель *м* җылыткыч, җылыткыч материал; **~ аккумуля́тора** аккумулятор җылыткычы

утепли́ть *сов. что* җылыту, җылыландыру; **~ коро́вник** сыер абзарын җылыту

утепля́ть *несов. см.* **утепли́ть**

утере́ть *сов. кого-что, разг.* сөртү, сөртеп алу, корыту, корытып сөртү; **~ лицо́** битне сөртү

утере́ться *сов. разг.* сөртенү, битне сөртү; **~ полоте́нцем** сөлге белән сөртенү

утерпе́||ть *сов.* түзеп (чыдап) калу, түзеп (чыдап) тора алу; **не ~л, что́бы не возрази́ть** каршы әйтмичә түзеп тора алмады

уте́ря *ж офиц.* югалту, югалу; **~ докуме́нтов** документларны югалту

утеря́ть *сов. что* югалту, жую, төшереп калдыру; **~ де́ньги** акча югалту

утёс *м* кыя, кыяташ

утеса́ть *сов. что, спец.* юнып алу, юнып юкарта төшү

утёсистый, -ая, -ое кыялы, кыяташлы; **~ бе́рег** кыялы яр

утёсывать *несов. см.* **утеса́ть**

уте́ха *ж* 1. (*забава*) кызык, уенкөлке, мәзәк, рәхәт, уен; **де́тская ~** балалар уены 2. (*утешение*) юаныч, куаныч; **вну́ки — его́ ~** оныклары — аның юанычы

уте́чка *ж* (*читкә агудан*) кимү, (*читкә таралудан*) азаю, түгелеп-чәчелеп кимү, саркып югалу; **~ га́за** газның саркып югалуы

уте́чь *сов.* 1. агу, агып бетү; **вода́ утекла́** су агып беткән 2. *перен.* үтү, үтеп китү, узу; **утекли́ го́ды** бик күп еллар үтте

утеша́ть *несов. см.* **уте́шить**

утеша́ться *несов.* 1. *см.* **уте́шиться**; 2. *страд. от* **утеша́ть**

утеше́ние *с* 1. *см.* **уте́шить, уте́шиться**; 2. юаныч, куаныч; **найти́ себе́ ~** *в чём-л. нәрсәдән дә булса* үзенә юаныч табу

утеши́тель *м* юатучы, юаныч бирүче, тынычландыручы

утеши́тельница *ж* юатучы хатын (кыз)

утеши́тельный, -ая, -ое юаткыч, юата торган, юаныч бирә торган, юанычлы, тынычландыра торган; **~ отве́т** юата торган җавап

уте́шить *сов. кого-что* юату, тынычландыру, күңелен ачу, күңелен күтәрү, юаныч бирү; **~ ребёнка** баланы юату

уте́шиться *сов.* юану, тынычлану, күңел ачылу

утилизи́ровать *сов., несов. что* утильләштерү, файдалану, файдалы эшкә тоту; **~ отхо́ды произво́дства** производство калдыкларын файдалы эшкә тоту

утилитари́зм *м книжн.* утилитаризм (*һәр нәрсәдән бары тик материаль файда күрүне генә алга сөрүче тар практицизм*)

утилитари́ст *м книжн.* утилитарист (*утилитаризм рухы белән сугарылган кеше*)

утилитари́стск||ий, -ая, -ое утилитаризм ...ы, утилитаристларча; **~ие взгля́ды** утилитаризм карашлары

утилита́рн||ый, -ая, -ое 1. (*проникнутый утилитаризмом*) утилитар, файда артыннан куу ...ы, файда күрү ...ы; **из ~ых соображе́ний** файда күрүне күздә тотып 2. (*прикладной*) утилитар, практик; **~ые зна́ния** практик белемнәр

ути́ль *м собир.* утиль (*производство калдыклары, тимер-томыр, иске-москы, чүпрәк-чапрак һ.б.ш.*)

ути́льный, -ая, -ое утиль ...ы; **~ цех** утиль цехы

утильсырьё *с собир. см.* **ути́ль**

ути́н||ый, -ая, -ое үрдәк ...ы; **~ое я́йцо́** үрдәк күкәе

утира́ть *несов. см.* **утере́ть**

утира́ться *несов.* 1. *см.* **утере́ться**; 2. *страд. от* **утира́ть**

утиха́ть *несов. см.* **ути́хнуть**

ути́хнуть *сов.* 1. (*умолкнуть*) тыну, тынып калу; **шум ути́х** тавыш тынды 2. (*прекратиться*) басылу, туктау; **бу́ря ути́хла** давыл басылды; **боль ути́хла** авырту басылды 3. (*успокоиться*) тынычлану, тыну; **она́ до́лго пла́кала, наконе́ц, ути́хла** бик озак елаганнан соң инһаять тынычланды

утихоми́ривать *несов. см.* **утихоми́рить**

утихоми́риваться *несов.* 1. *см.* **утихоми́риться**; 2. *страд. от* **утихоми́ривать**

утихоми́рить *сов. кого-что* тынычландыру, юашландыру, басынкландыру; **~ драчуно́в** сугыш чукмарларын тынычландыру

утихоми́риться *сов. разг.* тынычлану, юашлану, басынкылану

у́тк||а *ж* 1. үрдәк; **ди́кая ~а** кыр үрдәге 2. (*сосуд*) сидек савыты, утка 3. *разг.* ялган хәбәр, ялган, куык; **пусти́ть ~у** ялган хәбәр тарату

уткну́ть *сов. что* во *что* 1. яшерү, тыгу; **~ лицо́ в воротни́к** битне яка эченә яшерү 2. *перен.* (*глаза́, взгляд*) күз текәү, текәп карау ♦ **~ нос в кни́гу** баш күтәрми китап уку

уткну́ться *сов. во что* 1. чуму, каплану, яшеренү, баш төртү; **~ голово́й в поду́шку** башны мендәргә төртү 2. *перен.* чуму; ныкбирелү, текәлеп утыру; **~ в кни́гу** китапка чуму

утконо́с *м* үрдәкборын (*Австралиядә яши торган имезүче хайван*)

у́тлый, -ая, -ое ышанычсыз, иске, тузган; **~ чёлн** тузган каек; әҗәл тагарагы

уто́к *м текст.* аркау җебе, аркау (*туку эшендә*)

утоле́ние *с см.* **утоли́ть**

утоли́ть *сов. что* 1. кандыру, басу; **~ жа́жду** сусын кандыру, сусаганны басу 2. *уст.* (*ослабить, умерить*) басу, басылдыру, кимету; **~ боль** авыртуны басу

утолсти́ть *сов. что* юанайту, калынайту, юанайта (калынайта) төшү; **~ верёвку** бауны юанайта төшү

утолсти́ться *сов.* юанаю, калынаю, юаная (калыная) төшү

утолща́ть *несов. см.* **утолсти́ть**

утолща́ться *несов.* 1. *см.* утолсти́ться; 2. *страд. от* **утолща́ть**

утолще́ние *с* 1. *см.* **утолсти́ть**; 2. (*место*) калынайган урыны, юанайган җире; **~ ствола́** стволның юанайган урыны

утоля́ть *несов. см.* **утоли́ть**

утоми́тельность *ж* ялыктыргыч булу, алҗыткыч булу, йончыткыч булу, интектергеч булу, эчпошыргыч булу

утоми́тельн||ый, -ая, -ое ялыктыргыч, алҗыткыч, йончыткыч, зарыктыргыч, интектергеч, эчпошыргыч; **~ое путеше́ствие** ялыктыргыч сәяхәт; **~ый разгово́р** эчпошыргыч сөйләшү

утоми́ть *сов. кого-что* ялыктыру, алҗыту, йончыту, талдыру, талчыктыру; **~ глаза́** күзләрне талдыру

утоми́ться *сов.* ялыгу, ару, алҗу, йончу, талчыгу, зирегү, өшәнү, мәлҗерәү, йөгенү

утомле́ние *с* арыганлык, талчыкканлык, алҗыганлык, хәлсезлек, зирегү

утомлённ||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **утоми́ть**; 2. арыган, талчыккан, алҗыган, йончыган, зиреккән; **~ый вид** йончыган кыяфәт; **~ые глаза́** алҗыган күзләр

утомля́емость *ж* аручанлык, талучанлык, тиз талчыгучанлык; **быстра́я ~ организ́ма** организмның бик тиз талчыгучанлыгы

утомля́ть *несов. см.* **утоми́ть**

утомля́ться *несов.* 1. *см.* **утоми́ться**; 2. *страд. от* **утомля́ть**

утону́||ть *сов.* 1. бату, суга бату; **ведро́ ~ло** чиләк батты 2. (*погибнуть*) батып үлү, суга батып үлү 3. *в чём* (*погрузиться во что-л. вязкое*) бату, чуму 4. *перен. в чём* күмелү, чуму; **всё ~ло в зе́лени** бөтен нәрсә яшеллеккә күмелгән

утончи́ть *несов. см.* **утончи́ть**

утончи́ться *несов.* 1. *см.* **утончи́ться**; 2. *страд. от* **утончи́ть**

утончённость, утóнченность *ж* нечкәлек; нәзакәтлелек

утончённ||ый, утóнченн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **утончи́ть**; 2. (*изощрённый*) нечкә, сизгер, үткен, нәзакәтле; **~ый вкус** нечкә зәвык; **~ые мане́ры** нәзакәтле манерлар

утончи́ть *сов. что* 1. нечкәртү, нәзегәйтү, юкарта төшү; **~ ни́тку** җепне нәзегәйтә төшү; **~ ко́жу** күнне юкарта төшү 2. *перен.* нечкәртү, нәзакәтләндерү; **~ вкус** зәвыкны нечкәртү

утончи́ться *сов.* 1. (*стать более тонким*) нечкәрү, нәзегәю, юкару, юкара төшү 2. *перен.* нечкәрү, нәзакәтләнү

утопа||ть *сов. прост.* 1. *см.* **утопта́ть**; **~ть сне́г у крыльца́** болдыр төбендәге карны таптап тигезләү 2. китү, тәпитәпи китеп бару; **~ли домо́й** тәпи-тәпи өйләренә кайтып киттеләр

УТО-УХА

утопа́||ть *несов. см.* **утону́ть**; **дом ~ет в зе́лени** йорт яшеллеккә күмелгән

утопа́ющий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **утопа́ть**; **2.** *в знач. сущ. м* батучы, батып баручы; **~ хвата́ется за соло́минку** *посл.* батып баручы саламга тотына

утопи́зм *м книжн. см.* **утопи́чность**

утопи́ст *м* утопист (*утопик социализм тарафдары*)

утопи́ть *сов. кого-что* **1.** батыру; **~ су́дно неприя́теля** дошманның судносын батыру **2.** *перен.* (*погубить*) батыру, һәлак итү, харап итү, башып ашау

утопи́ться *сов.* батып үлү, суга бату

утопи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** *филос.* утопик, утопиягә нигезләнгән, фәнни булмаган; **~ий социали́зм** утопик социализм **2.** (*нереальный*) тормышка ашмастай, реаль булмаган, хыялый; **~ие взгля́ды** тормышка ашмастай карашлар **3.** *лит.* утопик, утопиядән гыйбарәт булган; **~ий рома́н** утопик роман

утопи́чность *ж* утопиялек, тормышка ашмаслык булу, хыялыйлык

утопи́чный, -ая, -ое *см.* **утопи́ческий** 2; **~ за́мысел** тормышка ашмастай ният

уто́пия *ж* **1.** *филос.* утопия (*социаль үзгәртеп кору, идеаль иҗтимагый җәмгыять турында җәмгыять усешендәге объектив закончалыкларны фәнни аңлауга нигезләнмәгән тәгълимат*) **2.** (*неосуществимая мечта*) буш хыял, тормышка ашмаслык хыял, фантазия, утопия **3.** *лит.* утопия (*идеаль иҗтимагый төзелешле киләчәкне сурәтли торган әдәби әсәр*)

уто́пленник *м* суга баткан кеше, суга батып үлгән кеше

уто́пленница сүга баткан хатын (кыз), суга батып үлгән хатын (кыз)

утопта́ть *сов. что* таптап тыгызландыру (тигезләү), төйгечләп тыгызландыру; **~ зе́млю** җирне таптап тигезләү

утопта́ться *сов.* тапталып тигезләнү (тыгызлану), тапталу

уточне́ние *с* **1.** *см.* **уточни́ть**; **2.** төгәллек, аныклык, төзәтмә; **внести́ ~ в прое́кт** проектка аныклык кертү

уточни́ть *сов. что* аныклау, ачыклау, аныклык (ачыклык) кертү, төгәллек кертү; **~ све́дения** мәгълүматларга аныклык кертү

уточни́||ться *сов.* аныклану, ачыклану; **формулиро́вки ~лись** формулировкалар аныкланды

уточня́ть *несов. см.* **уточни́ть**

уточня́ться *несов.* **1.** *см.* **уточни́ться**; **2.** *страд. от* **уточня́ть**

утра́ивать *несов. см.* **утро́ить**

утра́иваться *несов.* **1.** *см.* **утро́иться**; **2.** *страд. от* **утра́ивать**

утрамбова́ть *сов. что* төйгечләп тыгызлау (тигезләү), таптап тыгызлау, таптый-таптый такырайту

утрамбова́ться *сов.* төйгечләнеп тыгызлану, төйгечли-төйгечли тигезләнү, таптый-таптый такыраю

утрамбо́вка *ж см.* **утрамбова́ть**

утрамбо́вывать *несов. см.* **утрамбова́ть**

утрамбо́вываться *несов.* **1.** *см.* **утрамбова́ться**; **2.** *страд. от* **утрамбо́вывать**

утра́т||а *ж* **1.** *см.* **утра́тить, утра́титься**; **2.** (*потеря, урон*) югалту, зарар, зыян; **понести́ тяжёлую ~у** зур югалтуга юлыгу

утра́тить *сов. кого-что* югалту, жую; **~ трудоспосо́бность** хезмәткә сәләтлелекне югалту

утра́ти||ться *сов.* югалу, юкка чыгу, бетү; **~лись ста́рые тради́ции** иске традицияләр юкка чыкты

утра́чивать *несов. см.* **утра́тить**

утра́чиваться *несов.* **1.** *см.* **утра́титься**; **2.** *страд. от* **утра́чивать**

у́тренн||ий, -ая, -ое иртәнге; **~ая заря́дка** иртәнге зарядка; **~ий уда́й** иртәнге савым

у́тренник *м* **1.** утренник; **де́тский ~** балалар утреннигы (*бәрәр бәйрәм уңае белән балалар өчен оештырыла торган уен-тамаша*) **2.** (*утренний мороз*) иртәнге салкын

утри́рование *с см.* **утри́ровать**

утри́ровать *сов., несов. что* арттыру, арттырып җибәрү, күпертү, күпертеп күрсәтү, кабарту; **~** *чьи-л.* **слова́** *кемнең дә булса* сөйләгәннәрен арттырып җибәрү

у́тр||о *с* иртә, таң; **ра́нним ~ом** иртә таңнан; **под ~о** таң алдыннан; **в шесть часо́в ~а́** иртәнге алты сәгатьтә; **с до́брым ~ом!** хәерле иртә! ♦ **~о ве́чера мудрене́е** *посл.* иртә кичтән хәерлерәк (*бу эшне иртәнгә калдыру хәерлерәк*)

утро́б||а *ж прост.* карын, корсак, эч; **в ~е ма́тери** әнисе карынында; **ненасы́тная ~а** туймас корсак, бирән корсак

утро́бный, -ая, -ое **1.** карындагы, ана карынындагы; **~ пери́од разви́тия** ана карынындагы үсеш чоры **2.** (*о звуке, голосе*) күкрәк ...ы, күкрәктән чыккан; калын, юан; **~ го́лос** күкрәктән чыккан тавыш

утрое́ние *с см.* **утро́ить**

утро́енный, -ая, -ое **1.** *прич. от* **утро́ить**; **2.** өчләтелгән, өч тапкыр арттырылган

утро́ить *сов. что* өч тапкыр (мәртәбә) арттыру, өчләтә арттыру; **~ уси́лия** тырышлыкны өчләтә арттыру

утро́и||ться *сов.* өч тапкыр (мәртәбә) арту, өчләтә арту; **си́лы ~лись** көч өч тапкыр артты

у́тром *нареч.* иртән, иртәнчәк, иртә белән; **встать ра́но ~** иртән иртүк тору

утружда́ть *несов. кого-что* мәшәкатьләү, бимазалау, тынычсызлау, борчу

утру́ска *ж спец.* **1.** (*уменьшение веса*) чәчелеп кимү, түгелеп кимү, чәчелеп-түгелеп кимү **2.** (*недостающее количество*) чәчелгәне-түгелгәне, чәчелгән-түгелгән өлеше, коелган өлеше

утряса́ть *несов. см.* **утрясти́**

утряса́ться *несов.* **1.** *см.* **утрясти́сь**; **2.** *страд. от* **утряса́ть**

утряс||ти́ *сов.* **1.** *что* селки-селки басылдыру, селкеп (селеккәләп) тыгызландыру; **~ти са́хар в мешке́** капчыктагы шикәрне селеккәләп тыгызландыру **2.** *обычно безл. кого-что, разг.* (*измучить*) селкетеп алҗыту, дыңгырдата-дыңгырдата йончыту; **~ло в доро́ге** юлда килгәндә селкетеп алҗытып бетерде **3.** *перен. что, разг.* рәтләү, җайлау, көйләү; **~ти вопро́с** мәсьәләне җайлау

утряс||ти́сь *сов.* **1.** *разг.* селкенә-селкенә басылу, селкенә-селкенә тыгызлану; **крупа́ ~лась** ярма селкенә-селкенә тыгызланган **2.** *прост.* селкенеп [барып] алҗып бетү, силкенеп [барып] интегеп бетү, селкенеп барып җәфаланып бетү; **~тись в теле́ге** арбада селкенеп җәфаланып бетү **3.** *перен.* (*уладиться*) рәтләнү, җайлану; көйләнү; **недоразуме́ния ~лись** аңлашылмаучылыклар рәтләнде

уты́кать *сов. что чем* **1.** *разг.* кадап бетерү (тутыру), чәнчеп (кадап) чыгу; **~ поду́шечку була́вками** күпчеккә булавкалар кадап тутыру **2.** *прост.* тыгып (кыстырып) чыгу, тыгу, кыстыру; **~ ще́ли па́клей** ярыкларга чүбек кыстырып чыгу

утыка́ть I *несов. см.* **уткну́ть**

утыка́ть II *несов. см.* **уты́кать**

утыка́ться *несов.* **1.** *см.* **уткну́ться**; **2.** *страд. от* **утыка́ть** I

уты́кивать *несов. см.* **уты́кать**

утю́г *м* үтүк, өте; **электри́ческий ~** электр үтүге

утю́жение *с см.* **утю́жить**

утю́ж||ить *несов.* **1.** *что* үтүкләү, өтеләү; **~ить брю́ки** чалбар үтүкләү **2.** *перен. кого, прост.* (*колотить*) тукмау, дөмбәсләү **3.** *перен. что* тигезләү, таптау, таптап үтү; **та́нки ~ат око́пы** танклар окопларны таптап үтәләр

утю́жка *ж см.* **утю́жить**

утяжеле́ние *с см.* **утяжели́ть, утяжели́ться**

утяжели́тель *м спец.* авырайткыч; **~ глини́стого раство́ра** балчык измәсен авырайткыч

утяжели́ть *сов. что* авырайту, авырлыгын арттыру; салмаклату; **~ маши́ну** машинаны авырайту

утяжели́ться *сов.* авыраю; салмаклану

утяжеля́ть *несов. см.* **утяжели́ть**

утяжеля́ться *несов.* **1.** *см.* **утяжели́ться**; **2.** *страд. от* **утяжеля́ть**

утяну́ть *сов. прост.* **1.** *кого-что* (*уволочь за собой*) сөйрәп (өстерәп) алып китү **2.** *что* тартып буу, кысып буу; **~ живо́т** эчне кысып буу **3.** *перен. кого-что* (*украсть*) урлап китү, чәлдереп китү

уть́тина *ж разг.* үрдәк ите

уть́тица *ж* **1.** үрдәк караучы (*үрдәк фермасында эшләүче*) **2.** (*посуда*) үрдәк кыздыра торган савыт

уф *межд.* уф, уһ; **~, уста́л!** уф, арыдым!

ух *межд.* аһ, ах, абау, ай-яй; **~, како́й большо́й!** ай-яй, нинди зур!

уха́ *ж* балык шулпасы, уха; **стерля́жья ~** чөгә балыгы шулпасы

уха́б *м* сикәлтә, казылма, чокыр (*юлда*); салу (*кышкы юлда*)

уха́бина *ж разг. см.* **уха́б**

уха́бист||ый, -ая, -ое сикәлтәле, казылмалы, чокырлы-чакырлы; **~ая доро́га** чокырлы-чакырлы юл

ухажёр *м прост.* ухажёр (*хатын-кыз артыннан йөрүче*)

ухажёрск||ий, -ая, -ое *прост.* ухажёр ...ы

уха́живание *с см.* **уха́живать**

уха́живать *несов.* **1.** *за кем-чем* карау, карап-тәрбияләп тору, карап үстерү; **~ за больны́м** авыруны карау; **~ за цветы́** чәчәкләрне карап үстерү **2.** *за кем* ухаживать итү, хатын-кыз артыннан йөрү, хатын-кызга илтифат күрсәтү

у́харский, -ая, -ое *разг.* егетләрчә, егетләргә хас, бик җилле; **~ вид** егетләрчә кыяфәт

у́харство *с разг.* егетлек, егетләнү, кыюлык, чаялык

у́харствовать *несов. разг.* егетләнү, егетлек (чаялык) күрсәтү

у́харь *м разг.* чая кеше, елгыр кеше, егет кеше

у́хать *несов. см.* **у́хнуть**

у́хаться *несов. см.* **у́хнуться**

ухва́т *м* ухват (*мичтән чуен чүлмәк кебекләрне алу өчен*)

ухва́тист||ый, -ая, -ое *разг.* **1.** нык тотучан, нык эләктерүчән; **~ые ру́ки** нык тотучан куллар **2.** үткен, булдыклы, елгыр, җитез; **~ый па́рень** үткен егет

ухвати́ть *сов.* **1.** *кого-что* эләктерү, каптыру, тотып алу; эләктереп калу; **~ за́ ногу** аягыннан эләктерү **2.** *перен. что. разг.* тотып алу, эләктереп алу, аңлау, төшенү; **~ мысль собесе́дника** гәп-төшеннән фикерен эләктереп алу

ухвати́ться *сов.* **1.** за *кого-что* тотыну, ябышу; **~ за пери́ла** култыксага тотыну **2.** *перен.* за *что* (*приняться, взяться*) бик зур тырышлык белән тотыну, бик зур тырышлык куеп керешү; **~ за но́вую рабо́ту** яңа эшкә бик зур тырышлык куеп керешү **3.** *перен.* за *кого-что, разг.* (*воспользоваться в своих интересах*) эләктереп алу, файдалану; **~ за интере́сную мысль** кызыклы фикерне эләктереп алу

ухва́тк||а *ж разг.* **1.** (*манера поведения*) кыланыш; **молоде́цкая ~а** егетләрчә кыланыш **2.** (*ловкость*) елгырлык, булдыклылык, җитезлек, осталык; **он берёт не си́лой, а ~ой** ул көч белән түгел, осталык белән алдыра

ухва́тывать *несов. см.* **ухвати́ть**

ухва́тываться *несов.* **1.** *см.* **ухвати́ться**; **2.** *страд. от* **ухва́тывать**

ухитри́||ться *сов. с неопр., разг.* җаен табу; хәйләсен (әмәлен) табу, акыл (баш) җитү; **как вы ~лись сде́лать э́то?** ничек итеп сез моны эшләү җаен таба алдыгыз?

ухитря́ться *несов. см.* **ухитри́ться**

ухищре́ни||е *с* хәйлә, әмәл, осталык, хәйләкәрлек; этләшү, этлек; **прибега́ть к ра́зным ~ям** һәртөрле хәйләләр куллану

ухищрённость *ж* хәйләлелек, чослык, хәйләкәрлек

ухищрённый, -ая, -ое хәйләле, хәйләкәр, чос, оста; **~ приём** хәйләле алым

ухищря́ться *несов.* хәйлә кору, хәйләләү, хәйләсен (әмәлен) табу; җаен табу; этләшү

ухлёстывать *несов. прост. см.* **уха́живать** 2

ухло́пать *сов. прост.* **1.** *кого-что* (*убить*) үтерү, башын бетерү, дөмектерү **2.** *что* (*истратить*) тоту, туздыру, сарыф (исраф, әрәм) итү, түгү; **~ мно́го де́нег** бик күп акча исраф итү

ухло́пывать *несов. см.* **ухло́пать**

ухмы́лка *ж разг.* авыз еру, мыек астыннан елмаеп кую, көлемсерәү

ухмыльну́ться *сов. разг.* авыз еру, (*канәгатьлек белән*) елмаеп кую, мыек астыннан көлемсерәү

ухмыля́ться *несов. см.* **ухмыльну́ться**

у́хну||ть *сов. однокр.* **1.** гөрселдәү, гөрелдәү, күкрәү, дөбердәп китү; **~ла бо́мба** бомба гөрселдәде **2.** «ух» дип кычкыру, «ух» дип кую, ухылдап кую; **в ро́ще ~л фи́лин** куаклык эчендә мәче башлы ябалак ухылдап куйды **3.** *что, прост.* томыру, тондыру, кинәт атып җибәрү, кинәт түгеп җибәрү, төшереп җибәрү; **~ть ка́мень в овра́г** ташны чокырга томыру **4.** *прост.* (*упасть*) лач итеп барып төшү, лап итеп егылу; **~л в лу́жу** лач итеп күлдәвеккә барып төште **5.** *что прост.* (*израсходовать*) тотып бетерү, туздыру, исраф итү, очыру; **~ть у́йму де́нег** бик күп акча туздыру **6.** *прост.* (*исчезнуть*) бетү, юкка чыгу; **~ли де́нежки** акча бетте **7.** *кого-что, по чему, прост.* (*ударить*) шап итеп сугу, кундыру; **~ть кулако́м по столу́** йодрык белән шап итеп өстәлгә сугу

у́хнуться *сов. прост.* лап итеп егылу; лап итеп барып төшү; **~ в кана́ву** лап итеп канауга барып төшү

у́хо *с* **1.** колак; **дли́нные у́ши** озын колак; **сре́днее ~** урта колак; **взя́ть за́ ухо** колагыннан эләктереп алу; **отморо́зить у́ши** колакны өшетү **2.** *перен.* колак, ишетү сәләте; **чу́ткое ~** сизгер колак **3.** (*у нек-рых предметов*) колак; **у́ши у ведра́** чиләк колагы **4.** *мн.* **у́ши** колакчын; **ша́пка с уша́ми** колакчынлы (колакчын) бүрек **5.** (*в иголке*) күз, энә күзе ♦ **в одно́ ~ вошло́, в друго́е вышло** *у кого* бер колактан керде, икенчесеннән чыкты; **во все у́ши слу́шать** колакларны торгызып тыңлау, бик бирелеп тыңлау, күңел биреп тыңлау; **за́ уши тащи́ть** *кого* колагыннан сөйрәү (*берәр эшне башкаруда ярдәм итү*); **и ~м не ведёт** колагына да элми; **на́ ухо говори́ть** колагына гына әйтү, сер итеп кенә әйтү; **по́ уши влюби́ться** бик нык гашыйк булу; **~ ре́жет** колакны яра; **у́ши вя́нут** тыңларга оят

уховёртка *ж зоол.* эскәккойрык (*бөҗәк*)

ухо́д I *м см.* **уйти́** 1, 2; **~ с рабо́ты** эштән китү ♦ **вы́йти [за́муж] ~ом** *уст.* ябышып чыгу (*ата-ана ризалыгыннан башка кияүгә чыгу*)

ухо́д II *м см.* **уха́живать** 1; **~ за посе́вами** чәчүлекләрне карау; **~ за ра́неными** яралыларны карау

уходи́ть I *несов.* **1.** *см.* **уйти́**; **2.** китү, сузылу, юнәлү, юл алу; **доро́га уха́дит в лес** юл урманга таба китә

уходи́ть II *сов. кого-что. прост.* **1.** (*измучить*) интектереп (йәдәтеп) бетерү, җәфалау, хәлдән тайдыру **2.** (*погубить*) һәлак (харап) итү, үтерү, бетерү, башын бетерү

уходи́||ться *сов. прост.* **1.** (*измучиться*) алҗып (арып) бетү, йөри-йөри хәлдән таю **2.** (*перестать бродить*) әүүдән туктау; **квас ~лся** квас әүүдән туктаган

ухо́женный, -ая, -ое *разг.* каралган, тәрбияләнгән, тәрбия күргән; **~ ребёнок** тәрбия күргән бала

ухудша́ть *несов. см.* **уху́дшить**

ухудша́ться *несов.* **1.** *см.* **уху́дшиться**; **2.** *страд. от* **ухудша́ть**

ухудше́ние *с см.* **уху́дшить, уху́дшиться**

уху́дшенн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **уху́дшить**; **2.** начарайган, начарланган; **~ая поро́да** начарланган токым

уху́дшить *сов. что* начарлату, начарландыру, начарайту, начарайта төшү

уху́дшиться *сов.* начарлану, начарая төшү, койтылану, хәртиләнү, мөшкелләнү

уцеле́||ть *сов.* исән калу, зарарланмый калу, сакланып калу; **все ве́щи ~ли** әйберләрнең барысы да исән калган

уценённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **уцени́ть**; **2.** хакы төшерелгән, бәясе төшерелгән; **~ые това́ры** бәясе төшерелгән товарлар

уце́нивать *несов. см.* **уцени́ть**

уцени́ть *сов. что* бәясен төшерү, хакын киметү, арзанайту; **~ това́р** товарның бәясен төшерү

уце́нк||а *ж* **1.** *см.* **уцени́ть; произвести́ ~у о́буви** аяк киемнәренең бәясен төшерү **2.** (*скидка в цене*) киметелгән өлеш (*баштагы хак белән яңа хак арасындагы аерма*)

уцепи́ть *сов. кого-что, разг.* эләктереп алу, эләктерү, тотып алу; **~ коне́ц верёвки** бауның очыннан эләктереп алу

уцепи́ться *сов. разг.* **1.** за *кого-что* тотыну, ябышу, чат ябышу; **~ за рука́в** җиңенә тотыну **2.** *перен. за что* эләктереп алу; файдалану; **~ за чью-л. мысль** *кемнең дә булса* фикерен эләктереп алу

учáствовать *несов. в чём* **1.** катнашу; **~ в рабо́те** эштә катнашу; **~ в бою́** сугышта катнашу **2.** (*иметь долю*) уртагына керү, бүлешү, уртак күтәрү, бергәләп күтәрү; **~ в расхо́дах** чыгымнарны бергәләп күтәрү

учáствующ||ий, -ая, -ое **1.** *прич. от* **учáствовать**; **2.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* катнашучылар

учáстие *с* **1.** катнашу, катнашлык; **приня́ть ~ в вы́борах** сайлауларда катнашу **2.** (*сочувствие*) теләктәшлек, уртаклашу (*мәс. берәүнең кайгысын*); **прояви́ть ~** теләктәшлек белдерү

участи́ть *сов. что* ешайту, ешайта төшү; **~ посеще́ния** килеп йөрүләрне ешайту

участи́||ться *сов.* ешаю, ешая төшү; **уда́ры гро́ма ~лись** күк күкрәгән тавышлар ешайды

участко́в||ый, -ая, -ое **1.** участок ...ы; **~ая избира́тельная коми́ссия** участок сайлау комиссиясе **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м разг.* участковый (*милиционер*)

уча́стливый, -ая, -ое теләктәшлек белдергән; кайгыны уртаклашучан, хәленә керүчән; **~ взгляд** теләктәшлек белдергән караш

уча́стник *м* катнашучы, катнашкан кеше; **~ совеща́ния** киңәшмәдә катнашучы

уча́стница *ж* катнашучы хатын (кыз)

уча́сток *м* **1.** участок, өлеш; **поражённый ~ ко́жи** тиренең авыру җәелгән өлеше **2.** участок, бүлемтек, кишәрлек; **земе́льный ~** жир участогы **3.** участок; **избира́тельный ~** сайлау участогы **4.** участок, өлеш; **~ оборо́ны полка́** полкның оборона тоткан участогы **5.** тармак, өлкә; **ва́жный ~ рабо́ты** эшнең мөһим тармагы **6.** *уст.* участок (*полиция бүлеге*)

у́часть *ж* язмыш, тәкъдир, өлеш; **го́рькая ~** ачы язмыш; **их пости́гнет та́ же ~** аларны шундый ук язмыш көтә

учаща́ть *несов. см.* **участи́ть**

учаща́ться *несов.* **1.** *см.* **участи́ться**; **2.** *страд. от* **учаща́ть**

учаще́ние *с см.* **участи́ть, участи́ться**

учащённ||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **участи́ть**; **2.** еш, еш-еш; **~ое дыха́ние** еш-еш сулау; **~ый пу́льс** пульсның еш-еш тибүе

уча́щ||ийся, -аяся, -еяся **1.** *прич. от* **учи́ться**; **2.** *в знач. сущ.* **~ийся** *м*, **~аяся** *ж* укучы; **конце́рт для ~ихся** укучылар өчен концерт

учёба *ж* уку, белем алу, өйрәнү

уче́бник *м* дәреслек; **стаби́льный ~** стабиль дереслек; **~ геогра́фии** география дәреслеге

уче́бн||ый, -ая, -ое **1.** уку ...ы; **~ый год** уку елы; **вы́сшее ~ое заведе́ние** югары уку йорты **2.** уку ...ы, уку-укыту ...ы; **~ый план** уку планы; **~ая часть** уку-укыту эшләре бүлеге **3.** өйрәнү ...ы, өйрәтү ...ы, күнегү ...ы; **~ое су́дно** өйрәнү судносы

учёни||е *с* **1.** *см.* **учи́ть, учи́ться**; **2.** тәгълимат, өйрәтмә; **филосо́фско- религио́зное ~е** философик-дини тәгълимат **3.** *обычно мн.* **~я** *воен.* өйрәнүләр; күнегүләр

учени́к *м* **1.** укучы, мәктәп укучысы **2.** өйрәнчек; **~ сле́саря** слесарь өйрәнчеге **3.** (*последователь*) шәкерт; **досто́йный ~ своего́ учи́теля** үз остазының лаеклы шәкерте

учени́ца *ж* **1.** укучы кыз **2.** өйрәнчек кыз

учени́ческий, -ая, -ое **1.** укучы ...ы, укучылар ...ы; **~ дневни́к** укучы көндәлеге **2.** *перен.* (*несамостоятельный*) мәстәкыйль булмаган, укучыларча ..., укучыларга хас ..., өйрәнчек ...

учени́честв||о *с* **1.** укучылык, уку; **го́ды ~а** укучылык еллары **2.** (*обучение квалифицированному труду*) өйрәнчекләр, өйрәнчеклек; **шко́ла фабри́чно-заводско́го ~а** фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбе (*1959 елга кадәр*)

учёность *ж* галимлек, белемле булу, белемлелек, укымышлылык, гыйлемлек; **выделя́ться свое́й ~ю** үзеңнең гыйлемлелегең белән аерылып тору

учён||ый, -ая, -ое **1.** өйрәтелгән; **~ые медве́ди** өйрәтелгән аюлар **2.** укымышлы, белемле, укыган, галим; **~ые лю́ди** укымышлы кешеләр **3.** гыйльми, фәнни; **~ая сте́пень** гыйльми дәрәҗә; **~ый сове́т** гыйльми совет; **~ый спор** фәнни бәхәс **4.** *в знач. сущ.* **~ый** *м* галим; **знамени́тый ~ый** атаклы галим

учёсть *сов.* **1.** *кого-что* (*подсчитать*) исәпкә (хисапка) алу, хисаплау, барлау; **~ расхо́ды** чыгымнарны хисаплау **2.** *что* (*принять во внимание*) күздә тоту, исәпкә алу, игътибарга алу, искә алу; **~ пре́жний о́пыт** үткәндәге тәҗрибәне исәпкә алу

учёт *м* **1.** *см.* **учёсть**; **~ това́ров** товарларны барлау **2.** учёт, исәпкә алу, барлау, теркәү; **взя́ть на ~** учётка алу

учётн||ый, -ая, -ое учёт ...ы, учётка алу ...ы, хисап ..., барлау ...ы; **~ая ка́рточка** учётка алу карточкасы

учётчик *м* хисапчы, учётчик

учётчица *ж* хисапчы хатын (кыз), учётчица

учи́лище *с* училище; **педагоги́ческое ~** педагогия училищесы

учини́ть *сов. что, разг.* эшләү, ясау, үткәрү, чыгару, куптару; **~ сканда́л** җәнҗал куптару

учиня́ть *несов. см.* **учини́ть**

учи́тел||ь I *м* (*мн.* **~я́**) укытучы, мөгаллим, өйрәтүче; **~ь матема́тики** математика укытучысы

учи́тел||ь II *м* (*мн.* **~и**) (*глава, автор учения*) остаз

учи́тельница *ж* укытучы хатын (кыз)

учи́тельская *ж* укытучылар бүлмәсе (*мәктәптә*)

учи́тельство *с* **1.** (*деятельность учителя*) укытучылык, укытучылык эше (хезмәте); **занима́ться ~м** укытучылык белән шөгыльләнү **2.** *собир.* (*учителя*) укытучылар; **наро́дное ~** халык укытучылары

учи́тельствовать *несов.* укыту, укытучылык итү, укытучы булып эшләү

учи́тывать *несов. см.* **уче́сть**

учи́ть 1. *кого-что чему и с неопр.* укыту, өйрәтү; **~ ру́сскому языку́** рус телен укыту; **~ игра́ть в ша́хматы** шахмат уйнарга өйрәтү **2.** *перен. кого-что чему и с неопр.* (*наставлять*) өйрәтү, үгет-нәсихәт бирү **3.** *с союзом «что»* (*обосновывать*) өйрәтү **4.** *что* (*усваивать, высказывать какую-л. мысль, какое-л. положение*) хәзерләү, өйрәнү, ятлау; **~ уро́к** дәрес хәзерләү; **~ стихи́** шигырь ятлау ♦ **~ уму́-ра́зуму** акылга өйрәтү, акыл бирү

учи́ться *несов.* **1.** *чему и с неопр.* өйрәнү; **~ му́зыке** музыкага өйрәнү; **~ пла́вать** йөзәргә өйрәнү **2.** уку; **~ в шко́ле** мәктәптә уку

учреди́тель *м* оештыручы, башлап җибәрүче, корып җибәрүче, нигез салучы

учреди́тельница *ж* оештыручы хатын (кыз), башлап җибәрүче хатын (кыз), корып җибәрүче хатын (кыз)

учреди́тельный, -ая, -ое оештыру ...ы; **~ съезд** оештыру съезды ♦ **Учреди́тельное собра́ние** *ист.* Учредительный собрание (*кайбер дәүләтләрдә: төп закон нигезләрен эшләү очен чакырыла торган вәкиллекле орган*)

учреди́тельск||ий, -ая, -ое оештыручылар ...ы; **~ое совеща́ние** оештыручылар киңәшмәсе

учреди́ть *сов. что* **1.** (*основать*) оештыру, оештырып җибәрү, нигезен салу, төзү; **~ нау́чное о́бщество** гыйльми җәмгыять оештырып җибәрү **2.** (*ввести*) булдыру, кертү, урнаштыру; **~ но́вые поря́дки** яңа тәртипләр урнаштыру

учреди́ться *сов.* (*основаться*) оешу, төзелү

учрежда́ть *несов. см.* **учреди́ть**

учрежда́ться *несов.* **1.** *см.* **учреди́ться**; **2.** *страд. от* **учрежда́ть**

учрежде́ние *с* **1.** *см.* **учреди́ть**; **2.** (*заведение*) учреждение; **госуда́рственное ~** дәүләт учреждениесе; **нау́чное ~** гыйльми учреждение

учрежде́нческий, -ая, -ое учреждение ...ы; **~ аппара́т** учреждение аппараты

учти́вость *ж* ихтирамлылык, илтифатлылык, игътибарлылык, әдәплелек, нәзакәтлелек, ягымлылык

учти́вый, -ая, -ое ихтирамлы, илтифатлы, игътибарлы, әдәпле, нәзакәтле, ягымлы; **~ челове́к** илтифатлы кеше

учу́я||ть *сов. кого-что, разг.* сизеп алу, тоеп алу, сизү, тою; **соба́ка ~ла дичь** эт киек кошлар барлыгын сизеп алды

уша́н *м зоол.* озын колаклы ярканат

уша́нка *ж* колакчын бүрек, колакчынлы бүрек

уша́стый, -ая, -ое *разг.* зур (олы, озын) колаклы

уша́т *м* ушат, колаклы кисмәк, лакан

ушиб *м* **1.** *см.* **ушиби́ть, ушиби́ться**; **2.** (*место*) бәрелгән урын, имгәнгән урын, күгәргән урын

ушиба́ть *несов. см.* **ушиби́ть**

ушиба́ться *несов.* **1.** *см.* **ушиби́ться**; **2.** *страд. от* **ушиба́ть**

ушиби́ть *сов. кого-что* бәреп имгәтү (авыртыру, күгәртү); **~ ру́ку** кулны бәреп имгәтү

ушиби́ться *сов.* бәрелеп имгәнү, (*берәр җиреңне*) бәреп имгәтү

ушива́ть *несов. см.* **уши́ть**

уши́ть *сов. что* **1.** кыскарту, тегеп тарайту; **~ ю́бку** юбканы кыскарту **2.** (*нашить*) чигеп чыгу, тезеп чыгу, тотып чыгу; **~ по́яс би́сером** путага сәйләп тезеп чыгу **3.** (*зашить кругом*) тирәли тегеп чыгу, һәр ягыннан тегеп чыгу; **~ тюк** тюкны тирәли тегеп чыгу

у́шко, ушко́ *с* **1.** *уменьш. от* **у́хо** 1; **2. (ушко́)** элмәк, колак; **~ сапога́** күн итек элмәге **3. (ушко́)** (*в иголке*) күз, энә күзе **4.** *обычно мн.* **ушки́** (*род пельменей и макарон*) салма, колак яфрагы итеп эшләнгән макарон ♦ **у́шки на маку́шке** *у кого* колакларын торгызган, уяу, сизгер

ушку́й *м* ушкуй (*борынгы зур көймә*)

ушку́йник *м ист.* ушкуйник, елга юлбасары (*борынгы Русьта елгаларда көймә белән йөреп кеше талаучы*)

ушку́йничать *несов. ист.* елгаларда юлбасарлык итеп йөрү, ушкуй белән йөреп кеше талау

у́шлый, -ая, -ое *прост.* житез, елгыр, чая, үткен; **~ па́рень** үткен егет

ушни́к *м разг.* колак врачы

ушн||о́й, -а́я, -о́е колак ...ы; **~ а́я ра́ковина** *анат.* колак яфрагы; **~ о́й врач** колак врачы

уще́лист||ый, -ая, -ое тарлавыклы; **~ые го́ры** тарлавыклы таулар

ущелье *с* тарлавык (*ике тау арасындагы тар аралык*)

ущеми́ть *сов.* **1.** *что* кысу, кыстыру; **~ ру́ку две́рью** кулны ишеккә кыстыру **2.** *перен. кого-что* (*стеснить*) кысу, чикләү; **~** *чьи-л.* **права́** *кемнең дә булса* хокукларын чикләү **3.** *перен. кого-что* (*оскорбить*) рәнҗетү, мыскыл итү, кимсетү, хурлау, тию; **~ досто́инство** кешелек дәрәҗәсенә тию

ущемле́ние *с см.* **ущеми́ть**

ущемля́ть *несов. см.* **ущеми́ть**

ущёрб *м* зыян, зарар, каза, югалту; **в ~ здоро́вью** сәламәтлеккә зыян китереп ♦ **на ~е** 1) (*в упадке*) бетеп бара; сүнеп бара; **си́лы его́ на ~е** аның көче бетеп бара; 2) (*о луне, месяце*) кими башлаган (*ай турында*)

ущерблённый, -ая, -ое **1.** *см.* **ущёрбный** 1; **2.** (*оскорблённый*) рәнҗетелгән, кимсетелгән, мыскыл ителгән

ущёрбный, -ая, -ое **1.** (*о луне, месяце*) кими башланган (*ай турында*) **2.** (*ненормальный*) кимчелекле, нормаль булмаган, тулы булмаган

ущипну́ть *сов. кого* чеметеп алу, чеметү; **~ за́ руку** кулын чеметү

ущу́пать *сов. что, прост.* капшап табу, кармалап табу

ую́т *м* ямь, ямьлелек, уңайлык; жайлылык; **созда́ть ~ в до́ме** йортка ямь кундыру

ую́тн||ый, -ая, -ое уңайлы, җайлы, жыйнак, ямьле; **~ая ко́мната** җыйнак бүлмә

уязви́мость *ж* йомшаклык, зәгыйфълек

уязви́м||ый, -ая, -ое **1.** (*такой, к-рого легко оскорбить*) [бик тиз] кимсенә торган, рәнҗи торган, хәтере кала торган, күңеле кителә торган **2.** (*слабо защищённый*) йомшак; зәгыйфь; **~ые места́** йомшак яклары

уязви́ть *сов. кого-что* кимсетү, рәнҗетү, җәберләү, хәтерен калдыру, кагылу, тию

уязвле́ние *с см.* **уязви́ть**

уязвля́ть *несов. см.* **уязви́ть**

уясне́ние *с см.* **уясни́ть**

уясни́ть *сов. что* ачыклау, аныклау; **~ себе́ суть де́ла** мәсьәләнең асылын ачыклау

уясни́ть *сов.* ачыклау, аныклау

уясни́ться *сов.* ачыклану, аныклану

уясня́ть *несов. см.* **уясни́ть**

уясня́ться *несов.* **1.** *см.* **уясни́ться**; **2.** *страд. от* **уясня́ть**

Ф

фа *с нескл.* фа (*музыка гаммасында дуртенче нота*)

фабко́м *м* фабком (*фабриканың профсоюз комитеты; 1982 елга кадәр*)

фа́брика *ж* фабрика; **бума́жная ~** кәгазь фабрикасы; **конди́терская ~** кондитер фабрикасы; **тексти́льная ~** туку фабрикасы

фа́брика-ку́хня *ж* фабрика-кухня (*механикалаштырылган бик зур ашханә*)

фабрика́нт *м* **1.** фабрикант, фабрика хуҗасы **2.** уйлап чыгаручы, тарату; ясаучы; **~ы лжи** ялган хәбәр уйлап чыгаручылар

фабрика́т *м* фабрикат (*фабрикада эшләп чыгарылган әзер продукт*)

фабрика́ция *ж см.* **фабрикова́ть**

фабрикова́ть *несов. что* **1.** күп итеп этмәләү; күп итеп язу; **~ статьи́** күп итеп мәкаләләр язу **2.** *перен.* тарату, уйлап чыгару; **~ слу́хи** ялган хәбәрләр тарату

фабри́чно-заводск||о́й, -а́я, -о́е фабрика-завод ...ы; **~о́е произво́дство** фабрика-завод производствосы

фабри́чн||ый, -ая, -ое **1.** фабрика ...ы; **~ое клеймо́** фабрика келәймәсе; **~ые корпуса́** фабрика биналары; **~ый рабо́чий** фабрика эшчесе; **~ый цех** фабрика цехы **2.** фабрикада эшләнгән (ясалган); **ковёр ~ого произво́дства** фабрикада эшләнгән хәтфә келәм **3.** фабрикалы, промышленностьлы; **~ый го́род** фабрикалы шәһәр

фа́була *ж лит.* фабула (*әдәби әсәрнең төп эчтәлеге, сюжет сызыгы*); **интере́сная ~** кызыклы фабула

фа́бульный, -ая, -ое *лит.* фабула ...ы; **~ материа́л** фабула материалы

фавн *м* фавн (*Рим мифологиясендә урман, тау, кырлар алласы*)

фавори́т *м* **1.** фаворит (*бераз югары дәрәҗәле кешенең яраткан һәм һәрвакыт яклый торган кешесе*) **2.** *шутл.* сөеклесе, яратканы **3.** *спорт.* фаворит (*бәйгедә, ат чабышында алдын чыгуы күпчелек тарафыннан өмет ителгән ат*)

фавори́тка *ж* сөяркә, мәгъшука, фаворитка

фаго́т *м* фагот (*музыка коралы*)

фаготи́ст *м* фаготта уйнаучы, фаготчы

фагоци́т *м биол.* фагоцит (күзәнәк)

фагоцито́з *м биол.* фагоцитоз

фа́з||а *ж* **1.** дәвер, чор, фаза; стадия (*бераз куренешнең, процессның үсешендәге бер баскыч*); **пе́рвая ~ туберкулёза лёгких** үпкә туберкулёзының беренче дәвере; **~а ро́ста расте́ния** үсемлек үсешенең бер чоры **2.** *спец.* (*положение, момент в изменении чего-л.*) фаза; **~а колеба́ния ма́ятника** маятник тирбәнешенең бер фазасы; **~а враще́ния плане́ты** планетаның әйләнү фазасы; **~ы Луны́** Ай фазалары **3.** *хим.* (*однородная часть*) фаза; **жи́дкая ~** сыек фаза; **твёрдая ~** каты фаза **4.** *эл.* фаза (*күп фазалы генератор обмоткаларының аерым төркеме*); **~а то́ка** ток фазасы

фаза́н *м* фазан, кыргавыл, фазан тавыгы

фаза́н||ий, -ья, -ье, **фаза́нов||ый,** -ая, -ое фазан[нар] ...ы; **~ьи кры́лья** фазан канатлары

фа́зис *м книжн. см.* **фаза** 1

фа́зный, -ая, -ое *эл.* фаза ...ы, фазалы

фа́зов||ый, -ая, -ое *спец.* фазалы, фазаара; **~ое напряже́ние** фазаара көчәнеш

фазо́метр *м эл.* фазометр (*үзгәрешнең фазаларын үлчи торган прибор*)

фазотро́н *м физ.* фазотрон (*зарядлы элементар кисәкчәләрнең хәрәкәтен тизләтү өчен корылма*)

фазоуказа́тель *м физ.* фаза күрсәткеч

фай *м* фай (*ефәк тукыма*)

фа́кел *м* факел; **заже́чь ~** факел яндыру

фа́кельн||ый, -ая, -ое факел ...ы; факел...; **~ый свет** факел яктысы; **~ое ше́ствие** факеллар тотып урамнан бару

фа́кельщик *м* **1.** (*несущий факел*) факелчы, факел тотып баручы **2.** (*поджигающий что-л. факелом*) ут төртүче, яндыручы

факи́р *м* **1.** дәрвиш **2.** фокусчы, фокус күрсәтүче

факси́миле **1.** *с нескл.* факсимиле (*кулъязманың, имзаның, документның фотография яки басма ярдәмендә төшереп алынган күчермәсе*); **~ по́дписи** имзаның күчермәсе **2.** *в знач. неизм. прил., нареч.* төшереп алып басылган, төшереп алынган; **ру́копись и́здана ~** кулъязма төшереп алып басылган

факт *м* **1.** факт, булган эш (хәл), чын вакыйга; **достове́рный ~** чыннан да булган хәл; **прове́рить ~ы** фактларны тикшерү; **изложи́ть ~ы** булган хәлне сөйләп бирү; **осно́вываться на ~ах** фактларга нигезләнү **2.** (*наличие*) мисал, очрак, факт; **~ наруше́ния дисципли́ны** тәртипне бозу очраклары **3.** *в знач. частицы и сказ.* факт, хакыйкать ♦ **~, что ...** дөрестән дә, чыннан да; **~ тот, что ...** эш шунда ...

факти́чески *нареч.* фактта, асылда, чынында; **~ де́ло бы́ло так ...** фактта эш болай булды...

факти́ческ||ий, -ая, -ое фактик, фактка нигезләнгән; чын, хакыйкый; **~ий материа́л** фактик материал; **~ие да́нные** фактик мәгълүматлар ♦ **~ий брак** *юр.* язылмыйча өйләнешү

ФАК-ФАН

фактогра́фия *ж* фактларны тасвирлау (*фактларга бернинди дә анализ ясамый һәм гомумиләштерми генә тасвирлау*)

фа́ктор *м* фактор (*берәр процессны, вакыйганы тудыручы шарт, сәбәп*); **климати́ческие ~ы** климат факторлары; **жи́зненно ва́жный ~** иң мөһим фактор; **постоя́нно де́йствующие ~ы** даими рәвештә тәэсир итә торган факторлар; **~ вре́мени** вакыт факторы; **~ы ро́ста** үсү шартлары

факто́рия *ж* фактория (*ерактагы промысел районнарында аучылар өчен оештырылган сәүдә-тәэминат пунктлары*)

факту́ра *ж* фактура (**1.** *иск. сәнгатьтә художество техникасының үзенчәлеге* **2.** *эшкәртелә торган агач, тукыма, мәрмәр һ.б.ш.ның үзенчәлекле сыйфаты* **3.** *торг. җибәрелгән товарның хакын, микъдарын курсәтеп, товар алучыга озатыла торган документ*)

факту́рн||ый, -ая, -ое *торг.* фактура-[лар] ...ы; **~ая кни́га** фактура кенәгәсе

факультати́в *м разг.* факультатив (*ихтыяри өйрәнелә торган фән яки курс*); **вести́ шко́льный ~** мәктәптә факультатив алып бару

факультати́вный, -ая, -ое факультатив, ихтыяри, мәҗбүри булмаган; **~ спецку́рс** ихтыяри спецкурс **~ курс ле́кций** мәҗбүри булмаган лекцияләр курсы

факульте́т *м* факультет; **юриди́ческий ~** юридик факультет; **дека́н ~а** факультет деканы

факульте́тск||ий, -ая, -ое факультет ...ы; **~ое бюро́** факультет бюросы

фал *м спец.* бау, аркан, фал

фала́нга *ж* **1.** *ист.* фаланга (*борынгы грекларда коралланган җәяүле гаскәрнең тыгыз сафка тезелгән строе*) **2.** *перен.* фаланга (*тигез итеп тезелгән саф*) **3.** *анат.* бармак сөяге **4.** *зоол.* бөе, фаланга

фа́лда *ж* фалда, [ирләр киемендәге] арткы чабу (*фрак, сюртук, мундир чабуы*)

фальсифика́тор *м* ялганлап күрсәтүче, бозып күрсәтүче, фальсификатор; **~ы исто́рии** тарихи фактларны бозып күрсәтүчеләр

фальсифика́ция *ж* **1.** фальсификацияләү; ялганлап күрсәтү; бозып күрсәтү; **~ исто́рии второ́й мирово́й войны́** икенче бөтендөнья сугышы тарихын бозып күрсәтү **2.** (*подделывание*) фальсификация[ләү]; ялган ... ясау, алдап ясау; **~ докуме́нтов** документларны алдап ясау **3.** (*подделанная вещь*) ялган әйбер, ясалма әйбер

фальсифици́ровать *сов., несов. что* фальсификацияләү; ялганлап күрсәтү, бозып күрсәтү; **~ истори́ческие фа́кты** тарихи вакыйгаларны фальсификацияләү

фальста́рт *м спорт.* фальстарт (*вакытыннан элек башланган старт*)

фальц *м спец.* **1.** (*басма кәгазь табагының*) бөкләнү урыны **2.** (*загиб, шов*) җөй, бөгелеш (*ике калайның бөгеп ялганган урынындагы*) **3.** (*паз*) ырмау

фальцева́льный, -ая, -ое *спец.* фальцовкалау ...ы; **~ цех** фальцовкалау цехы

фальцева́ние *с спец. см.* **фальцева́ть**

фальцева́ть *несов. что, спец.* **1.** фальцовкалау, бөгү; фальцевать итү; **~ газе́ты** газеталарны бөкләү; **~ кни́гу** китап битләрен фальцовкалау **2.** фальц ясау, бөгү; **~ кро́вельное желе́зо** түбә калаеның читләрен бөгү **3.** ырмау алу (*бүрәнәдә, тактада, борыста һ.б.ш.*)

фальце́т *м муз.* фальцет

фальцо́вка *ж см.* **фальцева́ть**

фальцо́вочн||ый, -ая, -ое *спец.* фальцевать итә торган, бөгә торган; **~ая маши́на** фальцевать итә торган машина

фальцо́вщик *м* фальцовкалаучы, фальцевать итүче

фальцо́вщица *ж* фальцовкалаучы хатын (кыз)

фальши́ви||ть *несов.* **1.** *муз.* көйне бозып җырлау, бозып уйнау; **певе́ц ~т** җырчы көйне бозып җырлый **2.** *разг.* хәйләләү, ялганлау

фальши́вка *ж разг.* ялган документ

фальшивомоне́тчик *м* ялган акча ясаучы (сугучы)

фальши́вость *ж* **1.** ялгышлык (җырда, уенда); **~ то́на** тавышның ялгышлыгы **2.** (*двуличие*) икейөзлелек **3.** (*двусмысленность*) ике мәгънәлелек

фальши́в||ый, -ая, -ое **1.** (*ненастоящий*) ялган, ясалма; **~ый докуме́нт** ялган документ; **~ые во́лосы** ясалма чәч **2.** (*неверный*) фальш ..., ялгыш; хата ...; **~ая но́та** ялгыш нота **3.** (*неискренний*) эчкерле, монафикъ, риялы, икейөзле; ясалма; **~ый челове́к** риялы кеше; **~ая улы́бка** ясалма елмаю **4.** (*двусмысленный*) икеле, уңайсыз; **оказа́ться в ~ом положе́нии** уңайсыз хәлдә калу

фальшь *ж* **1.** хата, ялгышлык (*музыкада*) **2.** (*искусственность, надуманность*) фальшь, ясалмалык **3.** (*неискренность*) эчкерлелек, икейөзлелек **4.** (*обман*) алдау, алдашу, хәрәмләшү

фами́лия *ж* **1.** фамилия; **де́вичья ~** кыз фамилиясе **2.** нәсел, ыруг; **стари́нная дворя́нская ~** борынгы дворян нәселе **3.** *уст.* гаилә, семья

фами́льн||ый, -ая, -ое **1.** нәсел ...ы, гаилә ...ы; **~ый архи́в Пу́шкиных** Пушкиннарның гаилә архивы **2.** (*наследственный*) ата-бабадан калган, мирас булып калган; **~ое серебро́** ата-бабадан калган көмеш әйберләр; **~ые драгоце́нности** мирас булып калган кыйммәтле әйберләр

фамилья́рничать *несов. с кем, разг.* үзен артык иркен тоту, әрсезләнү, үзен әрсез тоту, тартынмау

фамилья́рность *ж* үзеңне артык иркен тоту, тартынмау, тәкәллефсезлек, әрсезлек

фамилья́рный, -ая, -ое артык иркен, тартынусыз, тәкәллефсез, әрсез; **~ тон** тәкәллефсез тон

фанабе́рия *ж разг.* урынсыз тәкәбберлек, әрелек, һавалылык, минминлек

фана́тизм *м* фанатиклык (*үз идеясенә чиктән тыш бирелү*)

фана́тик *м* фанатик (**1.** *диндар, дингә бик нык бирелгән кеше* **2.** *берәр идеягә, эшкә бик нык бирелгән кеше*)

фанати́ческ||ий, -ая, -ое фанатикларча ...; фанатик; **~ая ве́ра** фанатикларча ышану

фанати́чка *ж* фанатик хатын (кыз)

фанати́чность *ж* фанатиклык

фанати́чный, -ая, -ое **1.** (*исступлённо религиозный*) динле, фанатик **2.** *см.* **фанати́ческий**

фане́ра *ж* фанер, фанер такта; **трёхсло́йная ~** өч катламлы фанер

фане́рн||ый, -ая, -ое фанер ...ы, фанердан ясалган; **~ая перегоро́дка** фанердан ясалган бүлмә стенасы

фанерова́ть *несов. что* фанерлау, фанер белән каплау

фанеро́вка *ж см.* **фанерова́ть**; **~ ко́мнаты** бүлмәне фанерлау

фа́нза *ж* фанза (*Кытайда, Кореяда крестьян өе*)

фантазёр *м* хыялланучы, хыялый кеше, фантазёр

фантазёрка *ж* хыялый хатын (кыз)

фантазёрство *с* фантазёрлык; булмас хыял

фантази́ровать *несов.* **1.** (*мечтать*) хыяллану, хыялга бирелү, хыяллар белән мавыгу **2.** (*выдумать неправдоподобное*) (*юк нәрсәләр*) импровизация ясау, яңа көй чыгару (алдан хәзерлексез)

фрега́т *м* фрегат (**1.** *өч мачталы паруслы эллекке сугыш корабле* **2.** *зоол. диңгез кошы*)

фреза́ *ж тех.* **1.** фреза (*кискеч инструмент*) **2.** (*машина*) кискеч, фреза; **боло́тная ~** сазлык фрезы; саз кискеч; **по́чвенная ~** туфрак фрезы, туфрак кискеч

фре́зер *м* фрезер (*туфрак эшкәрту машинасы*)

фре́зерн||ый, -ая, -ое **1.** фрезер ...ы; фрезерлы; **~ый стано́к** фрезерлы станок; **~ые ножи́** фрезер пычаклары **2.** фрезер белән чыгарылган; **~ый торф** фрезер белән чыгарылган торф

фрезерова́ние *с см.* **фрезерова́ть**; **~ по́чвы** туфракны фрезерлау

фрезерова́ть *несов. что* **1.** *тех.* фрезерлау, (*фрезер станогында*) кырып

эшкәртү (*металлны, агачны һ.б.ш.*) **2.** фреза белән кистерү

фрезеро́вка *ж см.* **фрезерова́ть**

фрезеро́вщик *м* фрезерчы (*фрезер станогында эшләүче кеше*)

фрезеро́вщица *ж* фрезерчы хатын (кыз)

фре́йлина *ж* фрейлина (*патша хатынына хезмәт итүче кыз*)

френо́лог *м* френолог, френология белгече

френологи́ческий, -ая, -ое френология ...ы, френологик

френоло́гия *ж* френология (*кешенең психик һәм әхлак сыйфатларын аның баш сөяге формасына карап белеп була дигән фәнни булмаган тәгълимат*)

френч *м* френч (*кием*)

фре́ска *ж иск.* фреска (*дымлы штукатурка өстенә суда изелгән буяу белән төшерелгән бизәк*)

фриво́льность *ж* **1.** (*лёгкая непристойность*) әдәпсезлек, килешсезлек **2.** (*фривольное выражение*) әдәпсез (килешсез) сүз

фриво́льн||ый, -ая, -ое әдәпсез, килешсез; **~ый та́нец** әдәпсез бию; **~ое выраже́ние** килешсез сүз

фрикаде́лька *ж* фрикаделька (*тарттырылган иттән, балыктан ясалган чумар*)

фрикати́вн||ый, -ая, -ое *лингв.* фрикатив, өрелмәле; **~ые зву́ки** фрикатив авазлар

фро́нда *ж* фронда (**1.** *17 гасырда Франциядә абсолютизмга каршы көрәшкән дворян-буржуаз хәрәкәт* **2.** *перен. книжн. шәхси сәбәпләргә бәйле оппозиция, ризасызлык, килешмәү*)

фрондёр *м книжн.* фрондёр (**1.** *фрондада катнашучы* **2.** *перен. ризасызлык курсәтүче кеше*)

фронди́ровать *несов. книжн.* килешмәгән булып кылану, ризасызлык күрсәтү

фронт *м в разн. знач.* фронт; **отпра́виться на ~** фронтка китү; **быть на ~е** фронтта булу; **~ борцо́в за мир** тынычлык өчен көрәшчеләр фронты; **борьба́ на идеологи́ческом ~е** идеологик фронтта барган көрәш; **культу́рный ~** мәдәният фронты; **широ́ким ~ом** кин фронт белән ♦ **ни́ два ~а де́йствовать** ике юнәлештә хәрәкәт итү

фронта́льн||ый, -ая, -ое **1.** фронталь, фронтка туры юнәлдерелгән; **~ая ата́ка** фронталь атака **2.** *перен.* гомуми, фронталь; **~ый опро́с** бар укучыдан берьюлы дәрес сорау

фронтиспи́с *м полигр.* фронтиспис (*китапның беренче бите алдыннын яки бер биттә текст өстенә урнаштырылган рәсем*)

фронтиспи́сный, -ая, -ое *полигр.* фронтиспислы, фронтисписы булган; **~ лист** фронтиспислы бит

фронтови́к *м* фронтовик

фронтов||о́й, -а́я, -о́е фронт ...ы, фронттагы ...; фронт өчен эшләнгән; **~ой го́спиталь** фронт госпитале; **~ая доро́га** фронт юлы

фронто́н *м архит.* фронтон (*өй түбәсенең алгы яктагы өчпочмак формасындагы өлеше*)

фронто́нн||ый, -ая, -ое *архит.* фронтондагы..., фронтон ...ы; **~ые украше́ния** фронтон бизәкләре

фрукт *м* **1.** җимеш, җиләк-җимеш; **ра́нние ~ы** иртә өлгерә торган җимешләр **2.** *прост.* (*субъект*) наян кеше, әрсез кеше; **ну и ~!** наян кеше дә соң инде үзе!

фрукто́в||ый, -ая, -ое **1.** җимеш ...ы; җиләк-җимеш ...ы; **~ый сад** җимеш бакчасы; **~ое де́рево** җимеш агачы **2.** җимеш ...ы; җиләк-җимеш ...ы, җимеш салып ясалган, җимештән ясалган; **~ые консе́рвы** җимеш консервлары; **~ый сок** җимеш суы; **~ый квас** җимештән ясалган куас

фрукто́за *ж хим.* җимеш шикәре, фруктоза

фтизиа́тр *м* фтизиатр, фтизиатрия белгече

фтизиатри́ческий, -ая, -ое фтизиатрия ...ы; **~ кабине́т** фтизиатрия кабинеты

фтизиатри́я *ж* фтизиатрия (*медицинаның туберкулёз авыруын һәм аны дәвалау методларын өйрәнә торган бүлеге*)

фтор *м хим.* фтор

фто́ристый, -ая, -ое *хим.* фторлы; **~ водоро́д** фторлы водород

фу *межд.* фу; фи; **~, воня́ет!** фу, сасы ис килә!

фу́га *ж муз.* фуга

фуга́нок *м* озын ышкы, фуганок

фуга́с *м воен.* фугас (*шартлаткыч матдә заряды*)

фуга́ска *ж разг.* фугаслы авиабомба; фугаслы снаряд

фуга́сн||ый, -ая, -ое фугас ...ы, фугаслы; **~ая бо́мба** фугаслы бомба

фугова́льный, -ая, -ое *спец.* фуговкалый (струклый) торган; **~ стано́к** струклый торган станок

фугова́ние *с см.* **фугова́ть**

фугова́ть *несов. что, спец.* **1.** (*выстрагивать фуганком*) фуговкалау, фуганок белән струклау, ышкылау **2.** (*плотно пригонять*) (*кырларын тигезләп, бер-берсенә якын китереп*) беркетү (*мәс. такталарны*)

фугО́вка *ж см.* **фугова́ть**

фугО́вочный, -ая, -ое *см.* **фугова́льный**

фу́говый, -ая, -ое *муз.* фуга ...ы; фугага хас булган; **~ стиль** фуга стиле

фуже́р *м* фужер (*озын аяклы зур бокал*)

фу́кать *несов. см.* **фу́кнуть**

фу́кнуть *сов. разг.* **1.** *что, на что* (*дунуть, задуть*) өф итү, өрү, өреп төшерү (сүндерү) **2.** *что* фукка алу (*шашка уенында*)

фукси́н *м хим.* фуксин (*кызыл төстәге анилин буяу*)

фу́ксия *ж бот.* тамчы гөл, алка гөл

фуля́р *м* фуляр (*ефәк тукыма*)

фуля́ровый, -ая, -ое фулярдан тегелгән, фуляр ...; **~ плато́к** фуляр яулык

фунда́мент *м* **1.** нигез, фундамент; **кирпи́чный ~** кирпеч фундамент; **заложи́ть ~** нигез салу **2.** *перен.* нигез, таяныч; **~ эконо́мики** икътисадның нигезе; **нау́чный ~** гыйльми нигез

фундамента́льность *ж* **1.** (*прочность*) фундаменталь, зурлык **2.** *перен.* (*основательность*) төплелек, тирәнлек, фундаменталь

фундамента́льн||ый, -ая, -ое **1.** (*прочный*) фундаменталь, зур; **~ое зда́ние** зур бина **2.** *перен.* (*основательный*) төпле, тирән нигезле, фундаменталь; **~ые зна́ния** тирән белемнәр; **~ое иссле́дование** төпле тикшеренү **3.** (*основной*) фундаменталь, төп; **~ая библиоте́ка** фундаменталь китапханә

фунда́ментн||ый, -ая, -ое фундамент ...ы; нигез ...ы; **~ая плита́** фундамент плитәсе; **~ая вы́емка** нигез чокыры

фунду́к *м* фундук (*чикләвек төре*)

фуникулёр *м* фуникулёр (*текә таулы җирләрдә корыч аркан буйлап йөрү өчен ясалган махсус тимер юл*)

функциона́льн||ый, -ая, -ое функция ...ы, функциональ, функциягә бәйләнешле; **~ый ана́лиз** функциональ анализ; **~ая зави́симость** функциональ бәйлелек; **~ое уравне́ние** *мат.* функциональ тигезләмә; **~ое расстро́йство** *мед.* функциональ какшау

функциони́рование *с см.* **функциони́ровать**

функциони́ровать *несов.* эшләү, эшләп тору; хәрәкәт итү

фу́нкци||я *ж* **1.** *спец.* (*зависимость явлений*) функция (*берәр куренешкә бәйле булган һәм ул үзгәргәндә үзгәрә торган күренеш*) **2.** *мат.* функция; **тригонометри́ческие ~и** тригонометрик функцияләр **3.** *биол.* функция; **~я щитови́дной железы́** калкансыман биз функциясе; **наруше́ние ~и по́чек** бөерләр функциясе бозылу **4.** *перен.* (*обязанность*) йөкләнгән бурыч, эш, вазифа; **служе́бные ~и** хезмәт вазифалары; **э́то не вхо́дит в его́ ~и** бу аның вазифаларына керми

фунт I *м* **1.** *уст.* (*мера веса*) кадак, гөрәнкә (*409,5 граммга тигез булган борынгы рус үлчәү берәмлеге*) **2.** фунт (*Англиядә һәм башка кайбер илләрдә иске үлчәү берәмлеге — 453,6 граммга тигез*) ♦ **не ~ изю́му** *шутл.* бу бәрәнге ашау түгел, бу кечкенә эш түгел

фунт II *м* фунт (*кайбер илләрдә төп акча берәмлеге*); **австрали́йский ~** Австралия фунты

фу́нтик *м разг.* (*бумажный кулёк*) фунтик (*бурәнкәгә охшатып ясалган кәгазь пакет*)

фу́ра *ж уст.* (*телега*) фура (*өсте ябык озын йөк арбасы*)

фура́ж *м* фураж, терлек азыгы, мал азыгы

фуража́р *м* фуражир (*терлек азыгын саклаучы һәм бирепторучы кеше*)

фуражиро́вка *ж* гаскәрләр өчен фураж җыю

фура́жка *ж* фуражка; **фо́рменная ~** форма фуражкасы

фура́жный, -ая, -ое фураж ...ы; ~ **овёс** фураж солысы; ~ **фонд колхо́за** колхозның фураж фонды

фурго́н *м* фургон (*арба яки автомашина*)

фу́рия *ж разг.* усал хатын, усал телле хатын (*борынгы Рим мифологиясендә алла исеменнән уч алучы хатын*)

фурниту́ра *ж спец.* фурнитура (*бер эр төрле производствода кулланыла торган ярдәмче материал*); **часова́я** ~ сәгать фурнитурасы

фурниту́рный, -ая, -ое фурнитура ...ы; ~ **магази́н** фурнитура кибете; ~ **това́р** фурнитура товарлары

фуро́ *м* шау-шулы уңыш, шаккатыру; **произвести́** ~ кешеләрне шаккатыру

фуру́нкул *м* чуан, сызлавык (*тиредә шеш авыруы*)

фурункулёз *м* чуан (сызлавык) басу, фурункулёз

фурункулёзный, -ая, -ое чуан (сызлавык) баскан, фурункулёзлы

фут *м* (*мера длины*) фут (*30,48 см га тигез озынлык үлчәве берәмлеге*)

футбо́л *м* футбол

футболи́ст *м* футболчы, футбол уйнаучы

футбо́лка *ж* футболка (*кием*)

футбо́льн||ый, -ая, -ое футбол ...ы; ~**ый мяч** футбол тубы; ~**ая кома́нда** футбол командасы; ~**ое по́ле** футбол кыры

футля́р *м* футляр, савыт, тартма, кыны (*кыйммәтле яки ватылучан әйберне саклау тартмасы*); ~ **для очко́в** күзлек савыты

футури́зм *м иск.* футуризм (*20 гасыр башында сәнгатьтә һәм әдәбияттагы формалистик агым*)

футури́ст *м* футурист, футуризм тарафдары

футуристи́ческ||ий, -ая, -ое *иск.* футуризм ...ы, футуристик; ~**ие стихи́** футуристик шигырьләр

футури́стский, -ая, -ое футуризм ...ы, футурист[лар] ...ы; ~ **журна́л** футуристлар журналы

футурологи́ческ||ий, -ая, -ое футурологик, футурология ...ы; ~**ие учрежде́ния** футурологик учреждениеләр

футуроло́гия *ж* футурология (*киләчәкне алдан күрү законнары һәм методлары турындагы фән*)

фуфа́йка *ж* **1.** фуфайка, бәйләгән җылы күлмәк **2.** (*стёганка*) фуфайка, сырма

фы́ркать *несов. разг.* **1.** (*о лошади*) пошкыру, пошкырыну **2.** *перен. разг.* (*смеяться*) пырх итеп көлү, пырхылдау **3.** *перен. разг.* (*брюзжать*) мыгырдау, сукрану, ачулану

фы́ркнуть *сов. однокр.* **1.** (*о лошади*) пошкырып җибәрү, пошкырып кую **2.** *перен. разг.* (*засмеяться*) пырх итеп көлеп җибәрү, пырхылдап кую **3.** *перен. разг.* (*выразить недовольство*) мыгырдап кую, сукранып алу; ~ **вме́сто отве́та** җавап урынына мыгырдап кую

фюзеля́ж *м ав.* фюзеляж

фюзеля́жн||ый, -ая, -ое *ав.* фюзеляж ...ы; ~**ая моде́ль планёра** планёрның фюзеляж моделе

фьють, фюйть *межд. разг.* (*исчез, пропал*) фү, тайды, шылды

Х

хаджи́ *м нескл.* хаҗи

ха́живать *несов. разг. многокр.* йөргәләү, йөргәләштерү, баргалаштыру, килгәләү

хака́с *м* хакас кешесе

хака́ска *ж* хакас хатыны (кызы)

хака́сский, -ая, -ое хакас ...ы; Хакасия ...ы; ~ **язы́к** хакас теле

хака́сы *мн.* хакаслар, хакас халкы

ха́ки **1.** *прил. неизм.* (*о цвете*) яшькелт төс **2.** *с нескл.* (*ткань*) хаки, яшькелт материя; **челове́к в** ~ яшькелт төстәге киемле кеше

ха́ла *ж* хала (*булканың бер төре*)

хала́т *м* **1.** халат; **тёплый** ~ җылы халат; **дома́шний** ~ өйдә кия торган халат; **больни́чный** ~ хастаханә халаты; **маскирово́чный** ~ *воен.* маскировка халаты **2.** (*восточный*) чапан; **узбе́кский** ~ үзбәк чапаны; **буха́рский** ~ Бохара чапаны

хала́тность *ж* салкын карау, гамьсезлек, васемсызлык

хала́тн||ый, -ая, -ое **1.** халат ...ы, халатлык; халат тегә торган; ~**ый материа́л** халатлык материал **2.** *разг.* (*небрежный*) салкын карашлы; васемсыз, сүлпән; ~**ое отноше́ние к рабо́те** эшкә салкын карау

халва́ *ж* хәлвә; **оре́ховая** ~ чикләвек хәлвәсе

халиф *м ист.* хәлифә (*гарәп илләрендә мөселманнарның югары башлыгы*) ◆ ~ **на час** бер сәгатьлек хәлифә (*кыска вакытка гына хакимияткә ирешкән кеше турында әйтелә*)

халифа́т *м ист.* хәлифәлек (*башында хәлифә торган дәүләт*)

халту́ра *ж разг.* **1.** өстән-өстән генә эшләү; әштер-өштер эшләү; алай-болай итеп эшләнгән эш, халтура **2.** (*лёгкий заработок*) җиңел табылган акча; җинел кәсеп

халту́рить *несов. разг.* (*плохо работать*) өстән-өстән генә эшләү, әштер-өштер генә эшләү

халту́рн||ый, -ая, -ое *разг.* начар эшләнгән (язылган *һ.б.ш.*); ~**ая рабо́та** өстән-өстән генә эшләнгән эш

халту́рщик *м разг.* әштер-өштер эшләүче, өстән-өстән генә эшләүче, халтурачы

халту́рщица *ж разг.* халтурачы хатын (кыз)

халу́па *ж* (*убогое жилище*) алачык

халцедо́н *м мин.* халцедон

халцедо́новый, -ая, -ое *мин.* халцедон ...ы, халцедон ..., халцедоннан ясалган

хам *м бран.* (*оятсыз һәм тупас кеше*)

хамелео́н *м* **1.** *зоол.* хамелеон **2.** *перен.* монафикъ, икейөзле кеше, хамелеон (*карашларын тиз алмаштыра торган принципсыз кеше турында*)

хами́ть *несов. прост.* тупас кылану, хамлану, хамнарча кылану

ха́мка *ж бран.* оятсыз, тупас хатын (кыз)

хамса́ *ж* хамса (*балык*)

ха́мск||ий, -ая, -ое *разг.* оятсыз, тупас, хамнарча...; ~**ое отноше́ние** хамнарча мөнәсәбәт

ха́мство *с разг.* оятсызлык, тупаслык, хамлык

хан *м* хан

хандра́ *ж* күңел төшенкелек, эч пошу, кәефсезлек

хандри́ть *несов.* күңел төшенкелегенә бирелү, эч пошу, кәефсезләнү

ханжа́ *м, ж разг.* икейөзле (эчкерле) кеше, монафикъ, ханжа

ха́нжеск||ий, -ая, -ое монафикъларча..., икейөзле, ханжа ...ы; ~**ие слова́** монафикъ сүзләр

ха́нжество *с* монафикълык, икейөзлелек, эчкерлелек, ханжалык

ха́нск||ий, -ая, -ое хан ...ы; ~**ие зе́мли** хан җирләре; ~**ое во́йско** хан гаскәре

ха́нство *с* ханлык; **Каза́нское** ~ *ист.* Казан ханлыгы

ха́нты *мн.* (*ед.* **ха́нты** *м, ж нескл.*) хантлар, хант халкы

ханты́йский, -ая, -ое хант ...ы; ~ **язы́к** хант теле

ха́ша *ж* хан хатыны

ха́ос I *м миф.* хаос (*борынгы грек мифологиясендә оешмаган материя, стихия*)

ха́ос II *м*, **хао́с** *м* (*беспорядок*) хаос, тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык

хаоти́ческий, -ая, -ое тәртипсез, чуалчык, буталчык

хаоти́чность *ж* тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык

хаоти́чный, -ая, -ое *см.* **хаоти́ческий**

ха́пать *несов. см.* **ха́пнуть**

ха́пнуть *сов. однокр. что и без доп., прост.* (*украсть*) урлау, чәлдерү, эләктерү

хапу́га *м, ж прост.* ришвәт алучы; урлаучы, чәлдерүче

харакири́ *с нескл.* харакири (*Япониядә самурайларның үз эчләрен ярып үз-үзләрен үтерү йоласы*)

хара́ктер *м* **1.** характер, холык, табигать; **мя́гкий** ~ йомшак характер; **тяжёлый** ~ авыр характер **2.** төс, сыйфат, үзенчәлек, характер; ~ **по́чвы** туфракның сыйфаты; ~ **ме́стности** урынның үзенчәлеге; **приня́ть ма́ссовый** ~ массовый төс алу **3.** *лит., иск.* (*образ*) характер ◆ **в** ~**е** *чьём берәр кешенең* гадәтенә туры килү, *берәр кешегә* хас булу

характериз||ова́ть *сов., несов. кого-что* **1.** (*давать характеристику*) сыйфатлау, характерлау, характеристика

бирү 2. (*составлять отличительную черту*) күрсәтү, чагылдыру; **э́то хорошо́ ~ у́ет его́** бу аны бик яхшы күрсәтә

характеризова́ться *несов.* 1. характерлану, аерылып тору (*берәр сыйфаты белән*), билгеләнү 2. *страд. от* **характеризова́ть** I

характери́стик||а *ж* 1. характеристика, характерлау; **~а гла́вного геро́я расска́за** хикәянең баш героен характерлау 2. характеристика; **брать ~у с ме́ста рабо́ты** эшләгән җирдән характеристика алу 3. *тех.* характеристика, тасвирлама, сыйфатлама; **~а дви́гателя** двигательнең характеристикасы; **силова́я ~а** көч характеристикасы

характе́рность *ж* характерлылык, үзенә генә хаслык, үзенчәлеклелек

характе́рн||ый, -ая, -ое 1. үзенчәлекле, үзенә бертөрле; **~ые черты́ лица́** үзенә бертөрле кыяфәтле йөз 2. характерлы, [үзенә] хас; **~ый для се́вера кли́мат** төньякка хас климат; **~ая мане́ра говори́ть** үзенә хас сөйләү рәвеше 3. (*свойственный определённому народу, эпохе*) характерлы, характер ...ы; **~ые та́нцы** үзенчәлекле биюләр

ха́риус *м* бәрдә, хариус (*балык*)

ха́ркать *несов. разг.* какыру; төкерү; **~ кро́вью** кан төкерү

ха́ркнуть *сов. однокр. разг.* какырып ташлау

ха́ртия *ж* хартия (1. *борынгы кулъязма* 2. *кайбер әһәмиятле иҗтимагый-сәяси эчтәлекле документларның исеме*)

харче́вня *ж уст.* ашханә, хәрчәүнә

харчи́ *мн. прост.* ашамлык, азык, азык-төлек

харчо́ *с нескл. кул.* харчо

ха́та *ж* өй, хата ♦ **моя́ ~ с кра́ю, я ничего́ не зна́ю** минем эшем юк, бу эшкә минем бөтенләй катнашым юк

ха-ха́, ха-ха-ха́ *межд.* ха-ха-ха

ха́ять *несов. кого-что, прост.* хурлау, яманлау, сүгү, тиргәү

хвала́ *ж* мактау, дан; **честь и ~ геро́ю!** каһарманга дан һәм хөрмәт!

хвале́бн||ый, -ая, -ое мактау ...ы; **~ая песнь** мактау җыры; **~ая речь** мактау сүзе, мәдхия

хвалёный, -ая, -ое *ирон.*; макталган, мактаулы (*гадәттә кире мәгънәдә кулланыла*)

хвали́ть *несов. кого-что* мактау; **~ ученика́ за прилежа́ние** тырышлыгы өчен укучыны мактау

хвали́ться *несов.* 1. *разг. см.* **хва́статься**; 2. *страд. от* **хвали́ть**

хва́стать *несов. разг.*, **хва́статься** *несов. кем-чем* мактану, шапырыну, масаю, лаф ору; **~ успе́хами** уңышлар белән шапырыну

хвастли́вость *ж* мактанчыклык, шапырынучанлык, масаючанлык

хвастли́в||ый, -ая, -ое 1. (*склонный к хвастовству*) мактанчык, шапырынучан, масаючан 2. мактанып (шапырынып) әйтелгән, мактанулы, шапырынулы; **~ое заявле́ние** шапырынып әйтелгән сүзләр; **говори́ть ~ым то́ном** мактанчык тон белән сөйләү

хвастовство́ *с* мактанчыклык, шапырынучанлык, масаючанлык

хвасту́н *м разг.* мактанчык, шапырынырга (масаерга) яратучы

хвастуни́шка *м, ж разг.* мактанчык, мактанырга яратучы

хвасту́нья *ж разг.* мактанчык хатын (кыз)

хват *м разг.* җилле егет, үткер (булдыклы, гайрәтле) кеше

хвата́тельн||ый, -ая, -ое тотып ала торган, эләктергеч, эләктереп ала торган; **~ые о́рганы насеко́мых** бөҗәкләрнең эләктереп ала торган органнары

хвата́ть *несов.* 1. *кого-что* тотып алу, эләктереп алу, ябышу; **~ за́ руку** кулдан тоту; **~ кость** сөякне эләктереп алу; **~ когтя́ми** тырнаклары белән эләктереп алу 2. *кого, разг.* (*задерживать, ловить*) кулга алу, тоту 3. *что, разг.* (*приобретать без разбора*) алу, эләктереп алу; **~ что попа́ло** ни туры килсә шуны эләктерү 4. *см.* **хвати́ть** 7, 8 ♦ **~ за́ душу** йөрәккә үтү; **~ на лету́** бик тиз аңлау, авыздан чыгуга эләктереп алу

хвата́||ться *несов.* 1. за *кого-что* тотыну, ябышу; **утопа́ющий за соло́минку ~ется** *посл.* суга батучы саламга тотына; **~ться за са́блю** кылычка тотыну 2. *перен. за что, разг.* (*поспешно делать что-л.*) тотыну, керешү, ташлану; **~ться то за одно́, то за друго́е де́ло** әле бер, әле икенче эшкә тотыну; **нельзя́ ~ться за всё сра́зу** берьюлы бөтен нәрсәгә ташланырга ярамый 3. *страд. от* **хвата́ть** 1, 2, 3 ♦ **~ться за ум** акыл керү; **~ться за го́лову** башны тоту

хвати́||ть *сов.* 1. *см.* **хвата́ть** 1; 2. *чего, прост.* (*выпить поспешно*) эчеп җибәрү 3. *перен. чего, разг.* кичерү, баштан кичерү; **~ть го́ря** баштан кайгы кичерү 4. *кого-что, чем, прост.* сугу, бәрү, тондыру; **~ть кулако́м по́ столу** йодрык белән өстәлгә сугу 5. *кого-что, разг.* алу, сугу; **его́ ~л парали́ч** аны паралич суккан; **моро́зом ~ло посе́вы** ашлыкларны суык алган 6. (*допустить преувеличение*) арттырып җибәрү, уздырып җибәрү; **ну э́то уж ты ~л!** син инде моны арттырып җибәрдең! 7. *безл. чего* (*быть достаточным*) җитү; **у него́ хва́тит си́лы подня́ть ги́рю** гер күтәрергә аның көче җитәр; **де́нег ~ло то́лько на неде́лю** акча бер атнага гына житте 8. *безл. разг.* (*оказаться в силах*) булдыру, кулыннан килү; **его́ не хва́тит на э́то де́ло** ул аны булдыра алмас 9. *безл.* **хва́тит** *с неопр., без доп.* (*довольно*) булды, житте, җитәр; **хва́тит шали́ть!** җитәр, шаярмагыз! ♦ **с меня́ хва́тит!** мина житте!; **~ть че́рез край** артыкка китү, арттырып җибәрү

хвати́||ться *сов.* 1. *кого-чего и без доп., разг.* (*вспомнив, обнаружить отсутствие*) эзләргә тотыну, (*юклыгын белеп алып*) эзли башлау; **~ться ключе́й** ачкычларны эзли башлау 2. (*спохватиться*) абайлап өлгерү, сизеп алу, кинәт исенә төшү; **~лся, что дверь откры́та** ишекнең ачык икәне кинәт исенә төште

хва́тк||а *ж* 1. тоту алымы, тоту ысулы; тоту, алу, тешләп алу; **це́пкая ~а** нык тоту; **мёртвая ~а** авызын каерып ачмаслык итеп тешләү 2. *перен. разг.* булдыклылык, юньлелек; **прояви́ть делову́ю ~у** эштә булдыклылык күрсәтү

хва́тк||ий, -ая, -ое *разг.* 1. нык тотучан, каты тотучан, нык тота торган; **у него́ ~ие ру́ки** аның куллары нык тота торган 2. *перен.* зирәк, тиз аңлый (төшенә) торган, тиз тотып ала торган; **~ий ум** тиз төшенә торган акыл

хво́йн||ый, -ая, -ое 1. ылыс ...ы; **~ый за́пах** ылыс исе 2. ылыслы; **~ый лес** ылыслы урман; **~ое де́рево** ылыслы агач 3. *в знач. сущ.* **~ые** *мн. бот.* ылысылар, ылыслы агачлар

хвора́ть *несов. разг.* чирләү, авыру, сырхаулау

хво́рост *м собир.* 1. чыбык-чабык, коры-сары 2. (*печенье*) кош теле

хворости́на *ж* озын чыбык, озын коры-сары ботак

хво́рость *ж см.* **хворь**

хво́рый, -ая, -ое *прост.* чирле, авыру, сырхау ...

хворь *ж прост.* авыру, чир, сырхау

хвост *м* 1. койрык; **ко́нский ~** ат койрыгы; **змей**ный ~ елан койрыгы; **~ ры́бы** балык койрыгы 2. арт, койрык, арткы өлеше; **~ самолёта** самолётның койрыгы; **в ~е́ по́езда** поезднын койрыгында 3. *разг.* койрык, арткы өлеше; чират; **~ за биле́тами** билетка чират; **встать в ~ [о́череди]** [чиратның] койрыгына килеп басу 4. *перен. прост.* (*остаток, задолженность*) койрык (*уз вакытында тапшырылмаган зачётлар, имтиханнар һ.б.ш.*); **ликвиди́ровать ~ы́** койрыкларны бетерү ♦ **[и] в ~ и в гри́ву** *прост.* бөтен көчкә

хвостат||ый, -ая, -ое койрыклы, озын койрыклы, зур койрыклы; **~ые земново́дные** *зоол.* койрыклы җир-су хайваннары

хво́стик *м уменьш.-ласк. от* **хвост** ♦ **с ~ом** артыграк, артыгы белән; **ему́ пятьдеся́т [лет] с ~ом** аңа артыгы белән илле яшь; **до го́рода де́сять киломе́тров с ~ом** шәһәргәчә ун километрдан артыграк юл бар

хвостов||о́й, -а́я, -о́е 1. койрык ...ы; койрыктагы; **~о́й плавни́к** койрык йөзгече; **~о́й позвоно́к** *анат.* койрык сөяге; **~ые пе́рья у птиц** кошларның койрыктагы каурыйлары; **~о́е опере́ние** койрык яссылыклары 2. арткы, арттагы; **~ые ваго́ны** арттагы вагоннар

хвощ *м бот.* наратбаш, нарат (чыршы) үләне; **полево́й ~** кыр наратбашы

хво́я *ж собир.* энә, ылыс; **сосно́вая ~** нарат ылысы

хе́дер *м с.-х.* хедер (*комбайнның ура торган өлеше*)

хек *м* хек, хек балыгы

хе́рес *м* херес

херуви́м *м* фәрештә, баш фәрештә (*христиан мифологиясендә*)

хиба́ра, хиба́рка *ж разг.* алачык, кетәк

хи́жина *ж* кечкенә өй, алачык, куыш; **го́рная ~** тау алачыгы

хи́лость *ж* хәлсезлек, чирләшкә булу

хи́л||ый, -ая, -ое хәлсез, чирләшкә, зәгыйфь; **~ый ребёнок** чирләшкә бала; **~ые расте́ния** зәгыйфь үсемлекләр

хим= *кайбер кушма сүзләрнең «химия ...ы», «химик» мәгънәләрен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **химкомбина́т** химия комбинаты

химе́ра *ж книжн.* (*несбыточная мечта, фантазия*) буш хыял, буш өмет

химери́ческ||ий, -ая, -ое, **химери́чный,** -ая, -ое *книжн.* буш, хыялда гына булган, тормышка ашмас ...; **~ие наде́жды** буш өметләр

химиза́ция *ж см.* **химизи́ровать**; **~ се́льского хозя́йства** авыл хуҗалыгын химияләштерү

химизи́ровать *сов., несов. что* химияләштерү, химизация үткәрү

хи́мик *м* химик

химика́ли||и *мн.* химикалийлар; **обраба́тывать по́чву ~ями** туфракны химикалийлар белән эшкәртү

химика́ты *мн.* химикатлар, химик препаратлар

химиотерапи́я *ж мед.* химиотерапия (*авыруларны организмга химик матдәләр керту юлы белән дәвалау*)

хими́ческ||ий, -ая, -ое *в разн. знач.* химик, химия ...ы; **~ий элеме́нт** химик элемент; **~ая реа́кция** химик реакция; **~ая эне́ргия** химик энергия; **~ие удобре́ния** химик ашламалар; **~ое ору́жие** химик корал; **~ий заво́д** химия заводы; **~ая промы́шленность** химия промышленносте ♦ **~ий каранда́ш** химик карандаш

хи́мия *ж* **1.** химия; **аналити́ческая ~** аналитик химия; **органи́ческая ~** органик химия; **неоргани́ческая ~** органик булмаган химия; **физи́ческая ~** физик химия **2.** *чего* (*качественный состав*) химик сыйфаты; **~ не́фти** нефтьнең химик сыйфаты

химчи́стка *ж разг.* химчистка, химик юл белән чистарту

хи́на *ж разг. см.* **хини́н**

хини́н *м фарм.* хинин

хи́нн||ый, -ая, -ое хин ...ы, хинлы; **~ый порошо́к** хин порошогы; **~ое мы́ло** хинлы сабын ♦ **~ое де́рево** *бот.* хин агачы

хире́ть *несов. разг.* **1.** (*о человеке*) хәлсезләнү, ябыгу, арыклану **2.** (*о растениях*) кору, шиңү **3.** *перен.* (*приходить в упадок*) сүнү, сүнә бару; юкка чыгу; бетү, бетә бару

хирома́нт *м* кул багучысы, хиромант, күрәзә, күрәзәлек итүче

хирома́нтия *ж* хиромантия, күрәзәлек (*кешенең язмышы турында учтагы җыерчыкларга карап күрәзәлек итү*)

хиру́рг *м* хирург

хирурги́ческ||ий, -ая, -ое хирургия ...ы, хирургик; **~ое отделе́ние** хирургия бүлеге; **~ая опера́ция** хирургик операция; **~ое вмеша́тельство** операция ясау, операция юлы белән дәвалау

хирурги́я *ж* хирургия; **экспериментáльная ~** эксперименталь хирургия

хити́н *м биол.* хитин (*урмәкучләрнең, бөҗәкләрнең һ.б.ш. тышкы ягын каплаган каты органик матдә*)

хито́н *м* хитон (*борынгы грекларда озын күлмәксыман кием*)

хитре́ц *м* хәйләкәр кеше

хитре́ц *ж*, **хитри́нка** *ж разг.* хәйлә, кечкенә хәйлә; **сказа́ть с хитрецо́й** хәйлә белән әйтү; **он не без хитрецы́** аның хәйләсе юк түгел; **взгляд с хитри́нкой** хәйләле караш

хитри́||ть *несов.* **1.** (*лукавить*) хәйләләү, хәйлә кору, әмәл-чәмәл китерү **2.** *разг.* (*проявлять изворотливость*) уйлап карау, баш вату; **как ни хитри́ ...** күпме генә баш ватсаң да ...

хитросплете́ние *с книжн.* **1.** (*коварный замысел*) мәкерле уй, мәкерле ният **2.** (*вычурное изложение*) [фикерне] катлаулы итеп әйтү, уратып әйтү

хи́трость *ж* **1.** хәйлә, хәйләкәрлек; **вое́нная ~** хәрби хәйлә; **взять ~ю** хәйлә белән алдыру; **пусти́ться на ~** хәйлә кору **2.** (*уловка*) мутлык, наянлык **3.** *разг.* (*сложность*) хикмәт; **~ механи́зма** механизмның хикмәте

хитроу́мн||ый, -ая, -ое **1.** хәйләле, хәйләкәр, тапкыр; **~ый за́мысел** бик хәйләле ният **2.** (*замысловатый*) хикмәтле, катлаулы, хәйлә белән ..., башваткыч, серле; **~ое устро́йство** катлаулы җайланма

хи́тр||ый, -ая, -ое **1.** хәйләкәр; **~ый челове́к** хәйләкәр кеше; **~ая поли́тика** хәйләле сәясәт **2.** хәйләле, мут, шаян, үенчак; **~ый взгляд** үенчак караш **3.** башваткыч, катлаулы, хикмәтле, кыен аңлаешлы; **~ый вопро́с** башваткыч сорау; **~ый механи́зм** катлаулы механизм

хи-хи́, хи-хи-хи́ *межд.* кет-кет, кет-кет-кет

хихи́канье *с см.* **хихи́кать**

хихи́кать *несов. разг.* кет-кет көлү, кеткелдәү, хихылдау

хихи́кнуть *сов. однокр.* кеткелдәп көлеп җибәрү, хихылдап кую

хище́ние *с книжн.* урлау, урлаучылык, үзләштерү

хи́щник *м* **1.** ерткыч **2.** *перен.* ерткыч, талаучы

хи́щница *ж* ерткыч хатын

хи́щничать *несов.* **1.** (*о животных, птицах*) ерткычлык итү **2.** *перен.* ерткычларча эш итү

хи́щническ||ий, -ая, -ое **1.** ерткыч [лар] ...ы, ерткыч хайван ...ы; **~ие пова́дки** ерткыч хайваннар гадәте **2.** *перен.* ерткычларча ..., юлбасарларча ..., **~ая эксплуата́ция** ерткычларча изү **3.** *перен.* ерткычларча ..., вәхшиләрчә ...; **~ая вы́рубка ле́са** урманнарны вәхшиләрчә кисү

хи́щничество *с* **1.** ерткычлык **2.** *перен.* вәхшилек

хи́щн||ый, -ая, -ое **1.** ерткыч; **~ые пти́цы** ерткыч кошлар; **~ые живо́тные** ерткыч хайваннар **2.** *перен.* ерткычларча ..., явыз, комсыз; **~ый взгляд** комсыз караш

хладнокро́ви||е *с* салкын канлылык, тыныч табигатьлелек, басынкылык; **не теря́ть ~я** салкын канлылыкны югалтмау

хладнокро́вный, -ая, -ое **1.** салкын канлы, тыныч табигатьле, басынкы; **~ челове́к** салкын канлы кеше **2.** салкын; **~ отве́т** салкын җавап

хлам *м собир.* чүп-чар, иске-москы, алам-салам

хлами́да *м разг. шутл.* хламида (*озын ямьсез кием турында*)

хлеб *м* **1.** икмәк, ипи; **бе́лый ~** ак икмәк; **чёрный ~** кара икмәк; **чёрствый ~** каткан ипи **2.** (*зерно, злаки*) иген, ашлык; **ози́мые ~á** үҗым ашлыклары; **яровы́е ~á** сабан ашлыгы; **се́ять ~** ашлык чәчү **3.** *перен. разг.* (*заработок, пропитание*) ризык, икмәк-тоз; **добыва́ть ~** ризык табу; **зараба́тывать на ~** икмәклек-тозлык эшләү ♦ **~ да соль!** аш тәмле булсын!; **~ насу́щный** көндәлек ризык; **~ом не корми́** *кого нәрсәгә дә булса* бик ныклы бирелү, дөньясын онытып тотыну; **~-соль** (*угощение*) сый-хөрмәт

хлеба́ть *несов. что и без доп., прост.* **1.** (*есть жидкое*) ашау; **~ ухý** балык шулпасы ашау **2.** (*пить большими глотками*) эчү, чөмерү

хле́б||ец *с* күмәч, кечкенә икмәк; **хрусту́щие ~цы** кетердәп торган икмәк

хле́бница *м* икмәк тәлинкәсе, икмәк табагы

хлебну́ть *сов.* **1.** *однокр. что и без доп.* ашап алу **2.** *что, чего, разг.* (*выпить*) эчеп җибәрү, эчү, төшереп алу **3.** *перен. чего* (*испытать*) баштан үткәрү, кичерү, күрү; **~ го́ря** кайгы-хәсрәт баштан кичерү

хле́бн||ый, -ая, -ое **1.** икмәк ...ы; икмәктән ясалган; **~ый мя́киш** икмәк йомшагы; **~ый за́пах** икмәк исе; **~ый квас** икмәктән ясалган куас **2.** ашлык ...ы; ашлык белән ...; иген ...ы; **~ый запа́с** ашлык запасы; **~ые поля́** ашлык басулары; **~ая торго́вля** ашлык белән сату итү **3.** (*урожайный*) иген уңган, иген уңа торган, ашлыклы; **~ый год** иген уңган ел; **~ый край** иген уңа торган төбәк **4.** *перен. разг.* (*прибыльный*) файдалы, төшемле, табышлы; **~ое местé́чко** төшемле урын

хлебо= *кушма сүзләрнең «икмәк», «иген», «ашлык» мәгънәләрен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **хлеботорго́вля** ашлык сәүдәсе, ашлык белән сәүдә итү; **хлебозаку́пки** *мн.* ашлык сатып алу

хлебобу́лочный, -ая, -ое икмәк-күмәч...

хлебозаво́д *м* икмәк заводы

хлебозаготови́тель *м* икмәк хәзерләүче

хлебозаготови́тельн||ый, -ая, -ое икмәк хәзерләү ...ы; **~ый пункт** икмәк хәзерләү пункты; **~ая кампа́ния** икмәк хәзерләү кампаниясе

хлебозагото́вки *мн.* ашлык хәзерләү; икмәк хәзерләү

ХЛЕ-ХЛЮ

хлебопа́шество *с* иген игү, игенчелек, иген игүчелек; **занима́ться ~м** игенчелек белән шөгыльләнү

хлебопа́шец *м* игенче, иген игүче, игенчелек белән көн итүче

хлебопёк *м* икмәк пешерүче

хлебопека́рн||ый, -ая, -ое икмәк пешерү ...ы; **~ая промы́шленность** икмәк пешерү промышленносте

хлебопека́рня *ж* икмәк пешерү йорты, пекарня

хлебопече́ние *с* икмәк пешерү

хлебопроду́кты *мн.* ашлык продуктлары (*он, ярма һ.б.ш.*)

хлеборе́зка *ж* **1.** икмәк кискеч (*җайланма*) **2.** *разг.* (*работница*) икмәк кисүче хатын (кыз)

хлеборе́зный, -ая, -ое икмәк кисү ...ы, икмәк кисә торган; **~ нож** икмәк кисә торган пычак

хлеборо́б *м* игенче, иген игүче

хлебоно́дный, -ая, -ое уңдырышлы; ашлык (иген) уңган; ашлык (иген) уңа торган; **~ год** иген уңган ел; **~ край** ашлык уңа торган як

хлебосда́ча *ж* ашлык тапшыру (*дәүләткә*)

хлебосо́л *м* кунакчыл кеше

хлебосо́льный, -ая, -ое кунакчыл, кунак сыйларга ярата торган; **~ хозя́ин** кунакчыл хуҗа

хлебосо́льство *с* кунакчыллык; юмартлык

хлебоубо́рк||а *ж* иген урып жыю, ашлык урып жыю, **пери́од ~и** иген урып жыю вакыты

хлебоубо́рочн||ый, -ая, -ое (ашлык) урып жыю ...ы; **~ая кампа́ния** иген урып жыю кампаниясе; **~ый комба́йн** иген урып жыю комбайны

хлев *м* абзар; **коро́вий ~** сыер абзары

хлестако́вщина *ж* хлестаковчылык, үтә шапырынучанлык

хлестану́ть *сов. однокр. кого-что, прост.* сугып алу, сыптырып алу

хлеста́||ть *несов.* **1.** *кого-что, кем-чем, по кому-чему* сыдыру, чыбыклау; камчылау, чыбыркылау, кыйнау; **~ть ло́шадь кнуто́м** атка чыбыркы белән сыдыру **2.** *во что* бәрү; **ве́тер ~л в лицо́** җил биткә бәрә иде; **во́лны хле́щут о бе́рег** дулкыннар ярга китереп бәрәләр **3.** ургылып агу; чаптырып агу; кою; **из ра́ны хле́щет кровь** ярадан кан чаптырып ага; **из кра́на хле́щет вода́** кранннан су ургылып ага; **дождь так и хле́щет** яңгыр коепмы коя

хле́стк||ий, -ая, -ое **1.** авырттыра торган, авырттырып сыдыра торган; кискен; **~ий ве́тер** кискен җил **2.** *перен.* ачы, үткен; **~ие слова́** үткен сүзләр

хлестну́ть *сов. однокр. кого-что, по чему* сугу, сугып алу, сыдыру, сыдырып җибәрү, сыптырып алу, чыбыклап алу; **~ плёткою** камчы белән сыдырып җибәрү

хли́пк||ий, -ая, -ое хәлсез, начар; **~ий челове́к** хәлсез кеше; **~ое здоро́вье** начар сәламәтлек

хлоп *межд. в знач. сказ. разг.* **1.** (*хлопнул*) шап итеп сугу, чалт итеп сугу; **~ его́ по спине́** чалт аның аркасына **2.** (*упал, хлопнулся*) шап итеп егылу; **идёт челове́к и вдруг ~** бер кеше барганда кинәт шап итеп егылды

хло́панье *с см.* **хло́пать; ~ дверьми́** ишекне шапылдатып ябу; **послы́шалось ~ в ладо́ши** кул чабу тавышы ишетелде

хло́па||ть *несов.* **1.** *кого-что, по чему* сугу, кагу, суккалау; **~ть по плечу́** кулбашыннан кагу **2.** *чем* шапылдату, шап иттерү, шапылдатып ябу; **~ть дверьми́** ишекне шапылдатып ябу **3.** *кому* (*рукоплескать*) кул чабу, алкышлау; чәбәкләү **4.** шартлау, шартлату; ... тавышлар чыгу; **~ть кнуто́м** чыбыркы шартлату; **~ют вы́стрелы** аткан тавышлар ишетелә ♦ **~ть глаза́ми** аптырап карап тору, авыз ачып (карап) тору; **~ть уша́ми** колак йомып утыру, колак салып тыңламау

хло́паться *несов. разг.* егылу, барып төшү, мәтәлү

хло́пец *м прост.* егет, малай

хлопко- *кушма сүзләрнең «мамык» мәгънәсен аңлатканберенче кисәге, мәс.* **хлопкоубо́рка** мамык җыю; **хлопкокомба́йн** мамык җыю комбайны; **хлопкосе́ющий** мамык игүче

хлопково́д *м* мамыкчы, мамык игүче, мамыкчылык остасы; **~ы Узбекиста́на** Үзбәкстан мамыкчылары

хлопково́дство *с* мамыкчылык, мамык игү, мамык игүчелек

хлопково́дческий, -ая, -ое мамык ...ы; мамык игү ...ы; мамыкчылык ...ы; **~ совхо́з** мамыкчылык совхозы

хло́пков||ый, -ая, -ое мамык ...ы; **~ое ма́сло** мамык мае; **~ые поля́** мамык кырлары

хлопкоочисти́тельн||ый, -ая, -ое мамык чистарткыч ..., мамык тазарта торган; **~ый заво́д** мамык тазарта торган завод; **~ая маши́на** мамык чистарткыч машина

хлопкопряде́ние *с* мамык эрләү

хлопкопряди́льн||ый, -ая, -ое мамык эрләү ...ы; мамык эрли торган; **~ая маши́на** мамык эрли торган машина

хлопкоро́б *м* мамык игүче

хлопкоубо́рка *ж* мамык җыю

хлопкоубо́рочн||ый, -ая, -ое мамык җыю ...ы; **~ая маши́на** мамык җыю машинасы

хло́пнуть *сов. однокр. см.* **хло́пать**

хло́пнуться *сов. однокр.* шап итеп егылу, лап итеп барып төшү

хло́п||ок *м* мамык; **длинноволокни́стый ~ок** озын сүсле мамык; **~ок-сыре́ц** эшкәртелмәгән мамык; **сбор ~ка** мамык җыю

хлоп||о́к *м* **1.** (*звук*) шартлау (шартлату) тавышы, шарт иткән тавыш **2.** *мн.* **~ки́** (*аплодисменты*) кул чабу, чәбәкәйләү, алкыш

хлопота́ть *несов.* **1.** кайгырту, мәшәкатьләнү; өтәләнү; **~ по хозя́йству** хуҗалык белән мәшәкатьләнү **2.** *за кого* кайгырту, артыннан йөрү, юллау; **~ за дру́га** дус өчен юллау

хлопотли́вость *ж* мәшәкатьлелек; тынгысызлык, кайгыртучанлык

хлопотли́в||ый, -ая, -ое **1.** мәшәкатьле, ыгы-зыгылы; **~ое де́ло** мәшәкатьле эш **2.** тынгысыз, кайгыртучан; **~ый челове́к** тынгысыз кеше

хло́потно *нареч. в знач. сказ.* мәшәкатьле; **э́то о́чень ~** бу бик мәшәкатьле

хло́потный, -ая, -ое *см.* **хлопотли́вый** 1

хло́поты *только мн.* мәшәкать, кайгырту, арттыннан йөрү; **жите́йские ~** дөнья мәшәкатьләре; **дома́шние ~** өй мәшәкатьләре; **создава́ть ~** мәшәкать чыгару ♦ **хлопо́т по́лон рот** эш муеннан

хлопу́шка *ж* **1.** (*для мух*) чебен үтергеч, чапалак **2.** (*игрушка*) шапылдаткыч, шапылдавык **3.** *бот.* шартлавык (*чуп үлән*)

хлопча́тник *м* мамык куагы, пахта

хлопчатобума́жн||ый, -ая, -ое **1.** киже-мамык ...ы; мамык җеп ...ы; **~ая промы́шленность** киже-мамык промышленносте **2.** киже-мамыктан тукылган, мамык җеп ...; **~ые тка́ни** мамык җеп тукымалар

хло́пья *только мн.* лачаулар, укмашкан йон (мамык); **снег идёт ~ми** ябалак-ябалак кар ява ♦ **кукуру́зные ~** кукуруз кисәкләре

хлор *м хим.* хлор

хлоре́лл||а *ж спец.* хлорелла; **культива́ция ~ы в косми́ческих усло́виях** космик шартларда хлорелла үстерү

хлори́рование *с см.* **хлори́ровать**

хлори́рованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **хлори́ровать**; **2.** хлорланган; **~ая вода́** хлорланган су

хлори́ровать *сов., несов. что* хлорлау (**1.** *хлор белән дезинфекция ясау* **2.** *хлор белән эшкәрту*)

хло́ристый, -ая, -ое *хим.* хлорлы, хлор катыштырылган; **~ на́трий** хлорлы натрий (*аш тозы*)

хло́рн||ый, -ая, -ое хлор ...ы; хлорлы; **~ый за́пах** хлор исе; **~ая кислота́** хлор кислотасы; **~ая и́звесть** хлорлы известь

хлорофи́лл *м* хлорофилл (*усемлекларнең яшеллек пигменты*)

хлорофи́ллов||ый, -ая, -ое хлорофилл ...ы; **~ые зёрна** хлорофилл бөртекләре

хлорофо́рм *м* хлороформ (*наркоз өчен кулланыла*)

хлы́ну||ть *сов.* **1.** ташып чыгу; чаптырып ага башлау; бәреп керү; **~л дождь** коеп яңгыр ява башлады; **из ра́ны ~ла кровь** ярадан кан ургылып ага башлады; **во́лны ~ли на бе́рег** дулкыннар ярга ташып чыкты; **в ко́мнату ~л све́жий во́здух** бүлмәгә саф һава бәреп керде **2.** *перен. разг.* ябырылу; **толпа́ ~ла на пло́щадь** мәйданга халык төркеме ябырылды

хлыст *м* **1.** (*прут*) сыек чыбык, пеше чыбык **2.** (*плётка*) камчы; **уда́р ~о́м** камчы белән сугу

хлыщ *м разг.* фырт егет, кием калыбы

хлю́пать *несов.* **1.** *разг.* (*о воде, грязи*) чапылдау, лычкылдау, чаптыр-чоптыр (чапыр-чопыр, лач-лоч) итү **2.** *прост.* (*идти*) пычрак ерып бару, лычкылдатып бару, чаптыр-чоптыр (лач-лоч) килү;

~ **по гря́зи** пычрак ерып бару ♦ ~ **но́сом** мышкылдау, мыш-мыш итеп борын тарту; мыш-мыш елау

хлю́пик *м прост.* ихтыярсыз, мескен кеше, җебегән кеше

хлю́пкий, -ая, -ое *прост.* **1.** (*жидкий, вязкий*) изрәгән, изрәп беткән; чапырдап торган, чапыр-чопыр килә торган; ~ **снег** чапыр-чопыр килә торган кар **2.** *перен.* җебегән, булмаган, ихтыярсыз; ~ **челове́к** җебегән кеше

хлю́пнуть *сов. однокр. см.* **хлю́пать**

хлю́пнуться *сов. прост.* лач (шап) итеп егылу; ~ **в грязь** лач итеп пычракка егылу

хлюст *м прост.* мут кеше, ертлач кеше

хляб||ь *ж уст.* (*бездна, глубина*) упкын, чоңгыл ♦ **разве́рзлись ~и небе́сные** *шутл.* күкнең төбе тишелде *(көчле яңгыр яуганда әйтелә)*

хля́стик *м* хлястик (*кием биллеге*)

хм *межд.* hе, hм

хмелево́д *м* колмак үстерү белгече

хмелево́дство *с* колмак үстерү, колмак үстерүчелек

хмелево́дческий, -ая, -ое колмак үстерү ...ы; ~ **совхо́з** колмак үстерү совхозы

хмелев||о́й, -а́я, -о́е колмак ...ы; ~**ы́е дро́жжи** колмак чүпрәсе

хмел||ёк *м разг.*: **быть под ~ько́м** кызмача булу, бераз эчкән булу

хмеле́ть *несов. разг.* исерү, исереп китү

хмель I *м* (*растение*) колмак

хмел||ь II (*опьянение*) исереклек, исереклек хәле; **быть во ~ю́** исерек булу; **с него́ ~ь как руко́й сня́ло** исереклектән ул бик тиз айныды

хмельн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*нетрезвый*) исерек **2.** (*пьяница*) исерткеч, исертә торган **3.** *в знач. сущ.* ~**о́е** *с* исерткеч эчемлек; **он в рот ~о́го не берёт** ул бөтенләй эчми торган кеше

хму́рить *несов. что* (*брови*) җыеру; (*лицо*) сыту

хму́риться *несов.* **1.** (*о бровях*) җыеру; (*о лице*) бозу, сыту **2.** *перен.* (*о погоде, небе*) болытлау, караңгылану, болытлап (караңгыланып) тору

хму́р||ый, -ая, -ое **1.** караңгы [чырайлы], төмсә ...; ~**ое лицо́** караңгы чырайлы кеше; ~**ый вид** караңгы чырай **2.** *перен.* болытлы, салынкы, сүрән; ~**ое у́тро** болытлы иртә; ~**ый день** салынкы көн

хмы́кать *несов. разг.* hм-hм итеп тору *(хәйран калып яки аптырап)*

хмы́кнуть *сов., однокр. разг.* hм-hм итеп кую

хна *ж* кына (*үсемлек һәм саргылт кызыл буяу*); **покра́сить во́лосы хной** чәчне кына белән буяу

хны: хоть бы ~ *в знач. сказ. прост.* колак та салмау

хны́канье *с см.* **хны́кать**

хны́||кать *несов. разг.* **1.** шыңшу, шыңшып елау; **ребёнок ~чет** бала шыңшып елый **2.** *перен.* (*слезливо жаловаться*) шыңшу, зарлану

хо́бби *с нескл.* хобби (*мавыккан нәрсә, кызыккан әйбер*)

хо́бот *м* **1.** хортум; ~ **слона́** фил хортумы **2.** *зоол.* борын (*сукыр тычкан, җөфәр һ.б.ш. хайваннарда*) **3.** хобот (*пулемёт яки туп лафетының арткы өлеше*)

хоботн||о́й, -а́я, -о́е *зоол.* **1.** хортумлы **2.** *в знач. сущ.* ~**ы́е** *мн.* хортумлылар (*мәс. фил*)

хобото́к *м зоол.* хортумчык, борынчык (*бөҗәкләрдә*)

ход *м* **1.** (*движение*) йөреш, бару; ~ **ло́шади** ат йөреше; ~ **по́езда** поезд барышы; **по́лный ~** бик тиз бару; **на по́лном ~у́** барган шәпкә, бик шәп барганда; **ти́хий ~** әкрен бару; **за́дний ~** артка йөреш, артка чигенү; **пе́шим ~ом** җәяү бару; **приба́вить ~у** тизлекне арттыру, адымны шәбәйтү; **заме́длить ~** йөрешне әкренәйтү; **туда́ два часа́ ~у** анда ике сәгатьлек юл; **2.** (*течение, развитие*) барыш; ~ **собы́тий** вакыйгалар барышы; ~ **сраже́ния** сугышның барышы **3.** *тех.* (*функционирование*) эшләү, йөреш, йөрү, адым; ~ **винта́** винт йөреше; ~ **по́ршня** поршень адымы; **холосто́й ~** буш[ка] йөреш **4.** (*в игре*) йөрү, йөреш; чыгу; ~ **бе́лых** аклар йөри; **сде́лать ~ ферзём** ферзь белән йөрү **5.** (*приём, манёвр*) алым, ысул; **дипломати́ческий ~** дипломатик алым; **ло́вкий ~** оста алым **6.** (*вход; проход*) кереп йөрү юлы; ишек; **пара́дный ~** урам ягындагы ишек; **чёрный ~** арткы ишек; **подзе́мный ~** җир астындагы юл; **потайно́й ~** яшерен юл; ~**ы́ сообще́ния** *воен.* йөрү юллары (*окопларда*); **знать все ~ы́ и вы́ходы** *перен.* бөтен юлларын белү **7.** *тех.* (*рабочая часть*) тәгәрмәч, йөрешә; **на гу́сеничном ~у́** гусеницалы йөрештә; **коля́ска на рези́новом ~у́** резина шинлы коляска ♦ **в ~е** *предлог с род.п.* барышында, вакытында; **в [большо́м] ~у́** 1) (*во время движения*) барган вакытта; 2) сөйләп торган вакытта, шул ук вакытта; **перекуси́ть на ~у́** аяк өстендә генә тамак ялгап алу; **с ~у** 1) (*не останавливаясь*) барган килеш, барышлый; 2) (*сразу, без подготовки*) шунда ук; ~**у!** *прост.* тизрәк бар[ыйк]!

хода́**тай** *м* **1.** *разг.* (*защитник*) юлаучы (*берәр кешенең эшен* хәл итәргә тырышып йөрүче) **2.** *юр. уст.* (*поверенный*) адвокат, яклаучы

хода́**тайство** *с* үтенеч; юллама; үтенеч язуы, гариза; **пода́ть ~** үтенеч язуы бирү; **удовлетвори́ть ~** үтенечне канәгатьләндерү

хода́**тайствовать** *несов. о ком-чём, за кого-что* сорау, үтенү, юллау

хо́дики *только мн. разг.* герле гади сәгать

ходи́ть *несов.* **1.** йөрү, йөреп тору; ~ **по́ лесу** урманда йөрү; ~ **на цы́почках** аяк очында гына басып йөрү; ~ **взад-вперёд** әрле-бирле йөрү; ~**на лы́жах** чаңгыда йөрү **2.** йөрү, бару, барып йөрү; ~ **в теа́тр** театрга йөрү; ~ **по магази́нам** кибетләрдә йөрү; ~ **в го́сти** кунакка йөрү; ~ **на охо́ту**ауга йөрү; ~ **в ата́ку** атакага бару; ~ **в похо́д** походка йөрү **3.** (*о средствах транспорта*) йөрү **4.** йөрү; таралу; ~ **по рука́м** кулдан-кулга йөрү; **хо́дят слу́хи** хәбәрләр таралган **5.** *разг.* (*шататься, дрожать*) селкенү, селкенеп тору; **пол хо́дит под нога́ми** йөргәндә идән селкенеп тора **6.** (*о часах*) йөрү **7.** *за кем-чем* (*заботиться, ухаживать*) карау, күзәтү; ~ **за больны́м** авыруны карау; ~ **за цвета́ми** чәчәкләрне карап үстерү **8.** киеп йөрү; ~ **в вое́нной фо́рме** хәрби форма киеп йөрү; ~ **в сапога́х** итек киеп йөрү; ~ **босико́м** яланаяк йөрү **9.** (*в игре*) йөрү, чыгу; ~ **с ко́зыря** козырь белән йөрү; **вам ~** сез йөрергә тиеш **10.** (*пребывать в каком-л. состоянии*) йөрү; ~ **голо́дным** ач йөрү **11.** (*быть кем-л.*) ... булып эшләү; ~ **в председа́телях** рәис булып эшләү **12.** *разг.* (*испражняться*) тышка чыгу, тәрәт итү ♦ ~ **вокру́г да о́коло** мәсьәләне аңлап җиткермәү, мәсьәләнең асылына төшенеп җитмәү; ~ **на за́дних ла́пках** *перед кем* тәлинкә тоту, ялагайлану, юмакайлану; ~ **по́ миру** хәер сорашу; ~ **по стру́нке** *у кого, перед кем* песи кебек йөрү, биеп кенә тору

хо́дкий, -ая, -ое *разг.* **1.** тиз йөрешле, тиз йөри торган; ~ **конь** тиз йөрешле ат **2.** үтемле

ходов||о́й, -а́я, -о́е *тех.* **1.** йөреш ...ы, очыш ...ы; ~**ы́е ка́чества су́дна** судноның йөреш сыйфатлары **2.** *спец.* йөрү ...ы, йөртү ...ы; эш ...ы; ~**о́й винт** эш винты; ~**о́е колесо́** йөртү тәгәрмәче **3.** (*часто употребляемый*) еш кулланыла торган; ~**о́е выраже́ние** һәрвакыт кулланыла торган әйтем **4.** (*о товаре*) үтемле

ходо́к *м* **1.** (*пешеход*) җәяүле, җәяүле кеше; җәяү йөрүче **2.** *уст.* (*выборное лицо*) юллап йөрүче, йөрген (*крестьяннар арасыннан сайланган кеше*)

ходу́ли *мн.* челән аяк, колга аяк

ходу́льн||ый, -ая, -ое *разг.* ясалма, табигый булмаган; күперенке; күп чәйнәлгән; ~**ое выраже́ние** күп чәйнәлгән сүз

ходуно́м: ~ **ходи́ть** *разг.* нык селкенү, тетрәп (дерелдәп) тору; **пол ~ хо́дит** идәннәр нык селкенә

ходьб||а́ *ж* йөрү, йөреш; юл; **бы́страя ~а́** тиз йөрү; **полчаса́ ~ы́** ярты сәгатьлек юл; **он живёт в двух часа́х ~ы́ отсю́да** ул моннан ике сәгатьлек юлда тора

ходя́ч||ий, -ая, -ее **1.** йөри алган, йөри ала торган; ~**ий больно́й** йөри ала торган авыру **2.** (*обычный*) киң таралган, күп кулланыла торган; йөремтек; ~**ее выраже́ние** киң таралган әйтем **3.** *перен. ирон.* аяклы ...; ~**ая добродете́ль** аяклы гаделлек, изге җан; ~**ая энциклопе́дия** *шутл.* белем капчыгы, аяклы энциклопедия

хожде́ние *с см.* **ходи́ть** 1, 2, 4; ~ **взад и вперёд** алга-артка йөреп тору; ~ **во вре́мя ле́кции** лекция вакытында йөрү **2.** *лит.* сәяхәтнамә ♦ **име́ть ~** йөрү, кулланылу; ~ **по му́кам** газап (җәфа) чигеп йөрү

ХОЗ-ХОЛ

хоз- *кушма сүзләрнең «хуҗалык» мәгънәсен аңлаткан беренче кисәге, мәс.* **хозаппара́т** хуҗалык аппараты; **хозоговóр** хуҗалык шартнамәсе

хоза́рский, -ая, -ое *ист.* хазар ...ы; **хоза́рское ца́рство** хазар патшалыгы

хоза́ры *мн. ист.* хазарлар (*борынгы төрки халык*)

хозрасчёт *м* хозрасчёт, хуҗалык исәбе (*үз чыгымын үзе каплау нигезенә корылган планлы хуҗалык итү*); **быть на ~е** хозрасчётта булу

хозрасчётн||ый, -ая, -ое хозрасчётлы, хозрасчёттагы, хуҗалык исәбе ...; **~ое предприя́тие** хозрасчёттагы предприятие

хозя́ин *м* **1.** *в разн. знач.* хуҗа, ия; **~ до́ма** йорт хуҗасы; **~ иму́щества** милек иясе; **~ и го́сти** хуҗа белән кунаклар; **~ свое́й судьбы́** үз язмышының хуҗасы; **быть самому́ себе́ ~ом** үзеңә үзең хуҗа булу **2.** *прост.* (*муж*) ир ◆ **быть ~ом своего́ сло́ва** үз сүзендә тору

хозя́йка *ж* **1.** хуҗа хатын (ханым) **2.** *прост.* (*жена*) хатын, хуҗа хатыны

хозя́йничать *несов.* **1.** (*вести хозяйство*) хуҗалык алып бару, хуҗалык итү **2.** (*бесцеремонно распоряжаться*) хуҗа булу, үзе теләгәнчә эшләү; **~ в чужо́й ко́мнате** кеше бүлмәсендә хуҗа булу

хозя́йск||ий, -ая, -ое **1.** хуҗа ...ы; **~ая до́чка** хуҗа кызы **2.** хуҗаларча ..., хуҗалыклы; **~ое отноше́ние к де́лу** эшкә хуҗаларча караш

хозя́йственник *м* хуҗалыкчы (*хуҗалык эшләре белән шөгыльләнүче*)

хозя́йственно-полити́ческ||ий, -ая, -ое: **~ая зада́ча** хуҗалык-сәяси бурыч

хозя́йственность *ж* хуҗалыклылык, хуҗалыкны дөрес алып бара белү; **прояви́ть большу́ю ~** зур хуҗалыклылык күрсәтү

хозя́йственно-экономи́ческий, -ая, -ое хуҗалык-икътисади...

хозя́йственн||ый, -ая, -ое **1.** хуҗалык ...ы; **~ая жизнь страны́** илнең хуҗалык тормышы; **~ые организа́ции** хуҗалык оешмалары **2.** хуҗалык ...ы; **~ый магази́н** хуҗалык товарлары кибете; **~ый инвента́рь** хуҗалык кирәк-яраклары; **~ые това́ры** хуҗалык товарлары **3.** хуҗалыкчыл, хуҗалыкчан; **~ый челове́к** хуҗалыкчыл кеше; **~ое по́льзование землёй** җирдән хуҗалыкчан файдалану ◆ **~ое мы́ло** кер сабыны

хозя́йств||о *с* **1.** *в разн. знач.* хуҗалык; **натура́льное ~о** натураль хуҗалык; **пла́новое ~о** планлы хуҗалык; **ли́чное подсо́бное ~о** ярдәмче шәхси хуҗалык; **се́льское ~о** авыл хуҗалыгы; **лесно́е ~о** урман хуҗалыгы; **ры́бное ~о** балыкчылык хуҗалыгы; **единоли́чное ~о** аерым хуҗалык; **заводско́е ~о** завод хуҗалыгы; **~о фе́рмы** ферма хуҗалыгы; **дома́шнее ~о** йорт хуҗалыгы; **хло́поты по ~у** хуҗалык мәшәкатьләре; **вести́ ~о** хуҗалык итү, хуҗалык алып бару **2.** *разг.* (*предметы быта*) өй әйберләре, хуҗалык кирәк-яраклары; **обзавести́сь ~ом** хуҗалык кирәк-яраклары булдыру; **э́то всё на́ше ~о** болар бар да безнең өй әйберләре

хозя́йствование *с см.* **хозя́йствовать**

хозя́йствовать *несов.* хуҗалыкны алып бару, хуҗалык итү

хоккейст *м* хоккейчы, хоккей уйнаучы

хокке́й *м* хоккей; **~ на льду** боз хоккейы; **травяно́й ~** үлән хоккейы; **~ с ша́йбой** алкалы хоккей; **игра́ть в ~** хоккей уйнау

хокке́йн||ый, -ая, -ое хоккей ...ы; **~ая кома́нда** хоккей командасы; **~ый матч** хоккей ярышы; **~ая клю́шка** хоккей кәшәкәсе

хо́лен||ый, -ая, -ое иркә, назлы; пөхтә; **~ый ребёнок** назлы бала; **~ые ру́ки** пөхтә куллар

холе́р||а *ж* ваба, холера; **больно́й ~ой** ваба белән авыручы

холе́рик *м* холерик, кызу табигатьле кеше

холери́ческий, -ая, -ое холерик, холерикка хас, холерик ...ы; кызу; **~ темпера́мент** холерик темперамент

холе́рный, -ая, -ое **1.** ваба ...ы, вабалы, холера ...ы, холералы; **~ вибрио́н** ваба вибрионы; **~ год** холера елы **2.** ваба (холера) белән авыручы; **~ больно́й** ваба белән авыручы

холецисти́т *м мед.* холецистит

хо́лить *несов. кого-что* иркәләп (кадерләп) тоту, назлау, чиста (пөхтә) тоту; **~ ко́жу** тәнне чиста тоту

хо́лка *ж* ял; җилкә, җилкә калкымы (*хайваннарда*)

холл *м* холл (*театрда, кинода, кунакханәдә һ.б.ш. көтеп тору залы*)

холм *м* калкулык, үр

хо́лмик *м уменьш. от* **холм**; таучык

холми́ст||ый, -ая, -ое үрләре булган, калкулыклы; **~ая ме́стность** калкулыклы урын

хо́лод *м* **1.** суык, салкын, суыклык, салкынлык; **дрожа́ть от ~а** суыктан калтырану; **из щеле́й несло́ ~ом** ярыклардан салкын өрә иде; **соба́чий ~** *прост.* бик суык, катып үләрлек суык **2.** *мн.* **~а́** суыклар, салкыннар, салкын (суык) вакыт; **зи́мние ~а́** кышкы суыклар; **наступи́ли ~а́** салкыннар башланды **3.** *перен.* (*безразличие, равнодушие*) салкынлык, игътибарсызлык, салкын карау ◆ **~ и го́лод терпе́ть** кыенлыклар кичерү, ач-ялангач булу

холода́ть *несов. безл.* салкынайту, суыту; **на́чало ~** суыта башлады

холоде́||ть *несов.* **1.** туңу, өшү; суыну, салкынаю; **ру́ки ~ют** куллар туңа **2.** кот очу, салкын йөгерү, эсселе-суыклы булып китү; **~ть от у́жаса** куркудан тәнгә салкын йөгерү

холоде́ц *м* койка

холоди́льник *м* суыткыч

холоди́льн||ый, -ая, -ое суыткыч ...; суыткыч ...ы; суыту ...ы (*суыту өчен хезмәт итә торган*); **~ая ка́мера** суыткыч камера; **~ая устано́вка** суыткыч җайланма

холоди́льщик *м* суыту техникасы белгече

холоди́||ть *несов.* **1.** *что, разг.* (*охлаждать*) суыту **2.** (*освежать*) салкынайту; **мя́та ~т во рту** бөтнек авызны салкынайта

хо́лодно *нареч.* **1.** суык, салкын; **~ встре́тить** *кого-л. кемне дә булса* салкын каршы алу; **~ отве́тить на приве́тствие** исәнләшүгә салкын җавап бирү **2.** *в знач. сказ. безл.* суык, салкын; **на у́лице о́чень ~** урамда бик суык **3.** *в знач. сказ. кому-чему* суык, салкын; **мне ~** миңа суык; **вам не ~ без пальто́?** пальтосыз сезгә суык түгелме? ◆ **ему́ ни ~ ни жа́рко** ул өшеми дә, пешми дә

холоднокро́вные *мн. зоол.* салкын канлылар (*балыклар, амфибияләр һ.б.ш. турында*)

хо́лодность *ж* суыклык, игътибарсызлык; **~ отноше́ний** мөгамәләдәге салкынлык

холо́дн||ый, -ая, -ое **1.** салкын, суык; **~ый ве́тер** салкын жил; **~ая пого́да** салкын һава; **~ое осе́ннее со́лнце** көзге салкын кояш; **~ый день** суык көн; **~ая вода́** суык су; **~ая ко́мната** суык бүлмә; **~ая печь** салкын мич **2.** салкын; юка (*җылысы булмаган*); **~ое оде́яло** салкын юрган; **~ое пальто́** юка пальто **3.** салкын; **~ый чай** салкын чәй; **~ые блю́да** салкын ашлар (блюдолар) **4.** *перен.* тонык; **~ые кра́ски** тонык буяулар **5.** *перен.* салкын, илтифатсыз; **~ый взгляд** салкын караш; **~ый приём** салкын каршы алу; **быть в ~ых отноше́ниях** *с кем-л. берәр кеше белән* салкын мөнәсәбәттә булу **6.** *тех.* кыздырмыйча ..., салкын килеш [хәлдә]; **~ая обрабо́тка мета́ллов** металларны салкын килеш эшкәртү ◆ **~ая война́** салкын сугыш; **~ое ору́жие** салкын корал (*кылыч, хәнҗәр һ.б.ш.*)

холод||о́к *м* **1.** салкынчалык; күләгә, күләгәле урын; жиләслек; **у́тренний ~о́к** иртәнге салкынчанлык; **отдыха́ть в ~ке́** күләгәле урында ял итү **2.** салтырану; **~о́к пробежа́л по те́лу** тәне салтыранып куйды **3.** *перен.* (*сдержанность, равнодушие*) салкынлык, читләшү

холодосто́йкий, -ая, -ое салкынга чыдамлы, суыкка бирешмәүчән

холодосто́йкость *ж* салкынга чыдамлылык, суыкка бирешмәүчәнлек

холо́п *м* **1.** *ист.* холоп (*борынгы Русьта: кол*) **2.** *уст.* холоп (*крепостной крестьянин, крепостной хезмәтче*) **3.** *перен.* ялагай, куштан кеше

холо́пск||ий, -ая, -ое колларча ..., кол ...ы; **~ие привы́чки** коллар гадәте

холо́пство *с* **1.** *ист.* (*рабство*) коллык, холоплык **2.** *перен.* колларча кылану, тәлинкә тоту, ялагайлык, юмакайлык

холо́пствовать *несов.* (*раболепствовать*) колларча кылану, тәлинкә тоту, ялагайлану

холости́ть *несов. кого* печү

холост||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*неженатый*) буйдак, өйләнмәгән, дуадак **2.** буйдак[лар] ...ы; **~а́я жизнь** буйдак тормышы; **~а́я компа́ния** буйдаклар компаниясе **3.** *тех.* буш, файдасыз; **~о́й ход** буш йөреш **4.** *воен.* ядрәсез, пулясыз; **~о́й патро́н** пулясыз патрон

холостя́к *м* буйдак, буйдак кеше
холостя́цк||ий, -ая, -ое буйдак[лар] ...ы; **~ая жизнь** буйдаклар тормышы
холоще́ние *с см.* **холости́ть**
холощёный, -ая, -ое печелгән
холст *м* **1.** (*ткань*) киндер, киндер тукыма **2.** *жив.* картина (*киндергә ясалган рәсем*); **~ы Ре́пина** Репин картиналары
холсти́на *ж* **1.** *см.* **холст** 1; **2.** (*кусок ткани*) бер иң киндер
холу́й *м прост.* **1.** *уст.* (*слуга*) холуй **2.** *перен. презр.* ялагай, тәлинкә тотучы
холу́йствовать *несов. презр.* ялагайлану, тәлинкә тоту, холуйларча кылану, лакейларча кылану
холщо́в||ый, -ая, -ое киндер ...; **~ый мешо́к** киндер капчык; **~ая руба́шка** киндер күлмәк; **~ое полоте́нце** киндер сөлге
хо́л||я *ж*: **жить в ~е** тәрбиядә тору
хому́т *м* **1.** камыт; **снять с ло́шади ~** атның камытын салдыру **2.** *перен. разг.* камыт, авырлык, мәшәкать; **наде́ть на себя́ ~** *или* **ве́шать себе́ ~ на ше́ю** камыт кию, авырлыкны үз җилкәңә алу
хомути́на *ж* бөят, камыт бөяте
хомя́к *м* әрлән
хомя́ч||ий, -ья, -ье әрлән ...ы; **~ья но́рка** әрлән өне
хор *м* **1.** хор; **молодёжный ~** яшьләр хоры; **де́тский ~** балалар хоры **2.** *в знач. нареч.* **~ом** барысы бергә, күмәкләшеп; **петь ~ом** күмәкләшеп җырлау; **говори́ть ~ом** *перен.* (*все сразу, дружно*) барысы берьюлы сөйләү
хора́л *м муз.* хорал (*куп тавышлы дини җыр*)
хорва́тск||ий, -ая, -ое хорват ...ы; **~ая литерату́ра** хорват әдәбияты
хорва́ты *мн.* хорватлар
хо́рда *ж* **1.** *мат.* хорда; **2.** *зоол.* хорда, арка сөяге (*мәс. балыкларда*)
хоре́й *м лит.* хорей
хорёк *м* көзән, сасы көзән (*җәнлеге һәм тиресе*)
хореогра́ф *м* хореограф, бию сәнгате белгече
хореографи́ческ||ий, -ая, -ое хореографик, хореография ...ы; **~ое иску́сство** хореографик сәнгать; **~ая сту́дия** хореография мәктәбе
хореогра́фия *ж* хореография, бию сәнгате
хори́ст *м* хорчы, хорда җырлаучы
хори́стка *ж* хорчы хатын (кыз)
хормейстер *м* хормейстер (*хор җитәкчесе, хор дирижёры*)
хорово́д *м* хоровод, әйләп-бәйләп; **води́ть ~ы** әйләп-бәйләп уйнау
хорово́дн||ый, -ая, -ое әйләп-бәйләп ...ы, әйләп-бәйләп уены ...ы; **~ые пе́сни** әйләп-бәйләп җырлары
хоров||о́й, -а́я, -о́е хор ...ы; хор белән ...; **~о́й кружо́к** хор түгәрәге; **~о́е пе́ние** хор белән җырлау
хоро́мы *только мн.* зур өй, күп бүлмәле өй
хорони́ть *несов.* **1.** *кого-что* (*погребать*) күмү, җирләү **2.** *перен. что* (*предавать забвению*) оныту
хорони́ться *несов. прост.* (*прятаться*) яшеренү, качу
хорохо́риться *несов. разг.* әтәчләнү, кыдрачлану, гайрәт чәчү
хоро́шеньк||ий, -ая, -ое **1.** сөйкемле генә, чибәр генә, сылу гына; **~ая де́вочка** сөйкемле генә кыз **2.** *ирон.* начар, шәп түгел; **~ое де́ло!** эшләр шәп түгел! ♦ **~ого понемно́жку** *ирон.* яхшы нәрсә күп булмый
хорошо́нько *нареч. разг.* яхшылап, әйбәтләп, яхшы гына; **я ещё ~ и сам не зна́ю** мин үзем дә яхшылап белмим әле; **ну́жно его́ ~ проучи́ть** аны яхшы гына акылга утыртырга кирәк
хороше́||ть *несов.* **1.** (*становиться красивее*) матурлана бару, чибәрләнә бару, күркәмләнү **2.** *перен.* яхшылану, яхшыру, яхшыра бару; **наш го́род ~ет с ка́ждым днём** безнең шәһәр көннәнкөн яхшыра бара
хоро́ш||ий, -ая, -ее **1.** яхшы, әйбәт; **~ий пиани́ст** яхшы пианист; **~ие лю́ди** яхшы кешеләр; **~ая пого́да** әйбәт көн; **~ее настрое́ние** яхшы көеф; **подава́ть ~ий приме́р** әйбәт үрнәк күрсәтү **2.** якын, яхшы, ихлас күңелле; **он мой ~ий знако́мый** ул минем яхшы танышым **3.** *разг.* шактый зур, яхшы гына, күп кенә; **съесть ~ую по́рцию моро́женого** шактый зур порция туңдырма ашап бетерү **4.** матур, чибәр, гүзәл, күркәм; **она́ ~а́ собо́ю** ул төскә-буйга матур; **как ~и́ э́ти цветы́!** бу чәчәкләр нинди гүзәл! **5.** *разг. ирон.* (*при неодобрении*) яхшы инде, шәп инде; **хоро́ш, не́чего сказа́ть!** яхшы, әйтеп торасы да юк! **6.** *разг.* сөекле, кадерле; **мой ~ий** жаныем, сөеклем! **7.** *в знач. сущ.* **~ее** *с* яхшылык, яхшы нәрсә; **ничего́ ~его в э́том нет** монда бернинди яхшы нәрсә дә юк; **всего́ [вам] ~его** (*при прощании*) [сезгә] уңышлар телим ♦ **~их кровей** яхшы нәселле
хорошо́ *нареч.* **1.** яхшы, әйбәт; **~ рабо́тать** яхшы эшләү; **~ себя́ чу́вствовать** үзеңне яхшы сизү **2.** *в знач. сказ. безл. кому* яхшы; **мне здесь ~** миңа монда яхшы **3.** *в знач. сказ. безл.* ярый, яхшы; **~, е́сли он придёт** ярый ла ул килсә **4.** *в знач. вводн. сл.* яхшы, ярый; **~, пусть бу́дет по-тво́ему** ярый, синеңчә булсын әйдә **5.** *в знач. утв. частицы* ярый; **я приду́ че́рез час, ~?** мин бер сәгатьтән килермен, ярыймы? **6.** *в знач. частицы разг.* (*означает угрозу*) яхшы, ярый; **~, я э́того не забу́ду!** ярый, мин моны онытмам!
хору́вь *ж* хоругвь (**1.** *уст. гаскәр байрагы* **2.** *церк. изгеләр рәсеме төшерелгән байрак*)
хору́нжий *м* хорунжий (*революциягә кадәр казачий гаскәрдә: подпоручикка тиң офицер чины һәм шул чиндагы кеше*)
хо́ры *только мн. архит.* хоры (*ачык галерея*)
хорь *м см.* **хорёк**
хорько́в||ый, -ая, -ое **1.** көзән ...ы; көзән ... **2.** көзән тиресеннән тегелгән; **~ая шку́рка** көзән тиресе; **~ая шу́ба** көзән тиресеннән тегелгән тун
хоте́ние *с разг.* теләү, теләк
хот||е́ть *несов.* **1.** *чего и с неопр.* (*иметь желание, намерение*) теләү, ...сы килү; **~е́ть учи́ться** укырга теләү; **~е́ть пить** эчәсе килү **2.** *кого-чего, чего от кого и с союзом «чтобы»* (*добиваться чего-л., стремиться к чему-л.*) теләү, көтү, кыҗырау; **мы ~и́м ми́ра** без тынычлык телибез; **я хочу́, что́бы вы пришли́** мин сезнең килүегезне телим ♦ **где хо́чешь** кайда теләсәң; **е́сли ~и́те (хо́чешь)** *вводн. сл.* (*пожалуй*) бәләсегез килсә; **как ~и́те (хо́чешь)** 1) теләсәгез нишләгез (теләсәң нишлә); **как ~и́те, но э́то неве́рно** теләсәгез нишләгез, ләкин бу дөрес түгел; 2) никадәр генә әйтсәң дә; **как ~и́те, я не могу́ без книг** никадәр генә әйтсәң дә, мин китапсыз тора алмыйм; **ско́лько хо́чешь** күпме теләсәң; **хо́чешь не хо́чешь** теләсәң-теләмәсәң дә, ихтыярлы-ихтыярсыз; **что хо́чешь (~и́те)** нәрсә теләсәң (теләсәгез); **бери́те, что ~и́те** нәрсә теләсәгез шуны алыгыз
хоте́ться *несов. чего и с неопр. безл.* ...сы килү; **мне хо́чется домо́й** минем өйгә кайтасым килә; **что́-то мне не хо́чется е́хать** нигәдер минем барасым килми
хоть 1. *союз уступ.* (*несмотря на то, что*) булса да, булуга карамастан, ...да; **он ~ и мо́лод, но де́ло своё зна́ет** ул яшь булса да, үз эшен яхшы белә **2.** *союз. уступ.* (*можно, впору*) ...да, гәрчә; **~ уби́й, не скажу́** үтерсәң дә әйтмим; **темно́, ~ глаз вы́коли** күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгы **3.** *союз уступ.* (*или*) ...мы; **~ сего́дня, ~ за́втра, а де́лать на́до** бүгенме, иртәгәме, барыбер эшләргә кирәк **4.** *частица усил.* (*по крайней мере, только*) ичмасам, һич булмаса; **скажи́те ~ одно́ сло́во** ичмасам бер генә сүз әйтегез **5.** *частица разг.* (*например*) мәсәлән, әйтик, мисал өчен; **взять ~ э́ту кни́гу** мисал өчен бу китапны алсак **6.** *частица усил. разг.* (*любой*) ... булса да; **~ кто** кем булса да; **~ како́й** нинди булса да, теләсә нинди; **~ когда́** кайчан булса да; **~ где** кайда гына булса да ♦ **~ бы** 1) *см.* **хоть** 4; 2) ...са иде; **~ бы он поскоре́й пришёл** тизрәк килсә ярар иде; **~ бы и так** шулай да булсын, булса ни; **~ бы что** *кому* теләсәң нишләт, колагына да элми; **~ куда́** *в знач. сказ.* бик яхшы, бик шәп; **па́рень ~ куда́** бик шәп егет
хотя́ *союз* **1.** *см.* **хоть** 1; **~ и согласи́лся, но оста́лся недово́лен** риза булса да, канәгатьсез калды **2.** *против.* (*но*) ...са да; **он учи́лся хорошо́, ~ ча́сто боле́л** еш авырса да, яхшы укый иде ♦ **~ бы** (*даже, например*) мәсәлән; **взять ~ бы тако́й факт ...** мәсәлән, менә шушы фактны алыйк ...; **~ бы и так** *см.* **хоть (хоть бы и так)**
хохла́тка *ж разг.* бүрекле кош
хохла́т||ый, -ая, -ое бүрекле; **~ая ку́рица** бүрекле тавык
хо́хлиться *несов.* **1.** кабарыну, йоннарын (канатларын) тырпайту **2.** *перен.*

разг. (*быть мрачным — о человеке*) чырай сыту, карангы чырайлы булу

хо́хма *м прост.* (*насмешка, весёлая шутка*) шаянлык, көлке

хохо́л *м* (*у человека*) тырпаеп торган чәч; (*у птиц*) бүрек

хо́хот *м* шаркылдау, хахылдау, шаркылдап көлү [тавышы], ихахай; **гро́мкий ~** кычкырып көлү; **гомери́ческий ~** тыела алмый шаркылдап көлү; **разрази́ться ~ом** кычкырып көлә башлау

хохота́ть *несов.* шаркылдау, шаркылдап (хахылдап) көлү, ихахайлау; **~ до упа́ду** егылып көлү

хохоту́н *м разг.* шаркылдык, шаркылдап көлүчән

хохоту́нья, хохоту́шка *ж разг.* шаркылдык хатын (кыз)

храбре́ть *несов.* батырлана (кыюлана, гайрәтләнә) төшү

храбре́ц *м* батыр, кыю [кеше]

храбри́ться *несов. разг.* батырлану, кыюлану, йөрәкләну

хра́брость *ж* батырлык, кыюлык, гаярьлек; **беззаве́тная ~** фидакарь батырлык; **прояви́ть ~** кыюлык күрсәтү

хра́бр||ый, -ая, -ое батыр, кыю, йөрәкле, гаярь; **~ый во́ин** батыр сугышчы ♦ **не ~ого деся́тка** батырлардан түгел

храм *м* **1.** гыйбадәтханә, чиркәү **2.** *перен. высок.* сарай, йорт; **~ нау́ки** фән сарае; **~ иску́сства** сәнгать йорты

хране́ни||е *с см.* хранить; **ка́мера ~я багажа́** багаж саклау камерасы; **сдать ве́щи на ~е** әйберләрне сакларга тапшыру

храни́лище *с* саклау урыны

храни́тель *м* **1.** саклаучы, саклап торучы; **~ преда́ний** риваятьләр саклаучы; **~ тради́ций** гореф-гадәтләрне саклаучы **2.** (*должность*) саклаучы хезмәткәр, хранитель; **~ музе́я** музейда саклаучы хезмәткәр; **~ ру́кописей** кулъязмалар саклаучы

храни́ть *несов. в разн. знач. кого-что* саклау, тоту, саклап тоту; **~ де́ньги в сбербе́нке** акчаны саклык банкысында тоту; **~ проду́кты в холо́дном ме́сте** ашамлык әйберләрен салкын урында саклау; **~ ста́рые пи́сьма** иске хатларны саклап тоту; **~ в па́мяти** истә тоту; **~ в се́рдце** йөрәктә саклау; **~ та́йну** сер саклау; **~ в та́йне** сер итеп саклау ♦ **~ молча́ние** эндәшмәү, бер сүз дә әйтмәү; **~ го́рдый вид** горур кыяфәтле булу; **~ споко́йствие** тынычлык саклау

хран||и́ться *несов.* **1.** саклану, тотылу; **проду́кты ~я́тся в холоди́льнике** азык суыткычта саклана **2.** *страд. от* **храни́ть**

храп *м* **1.** (*звуки*) гырылдау тавышы, гырлау **2.** (*часть переносья у животных*) храп, танау чиге (*хайваннарда борын тишекләре арасының урта һәм түбән өлеше*)

храпе́ние *с см.* **храпе́ть**

храпе́ть *несов.* **1.** (*во сне*) гырылдау, гырлау, гырылдап йоклау **2.** (*о животных*) пошкыру

хреб||е́т *м* **1.** (*позвоночник животного*) умырткалык **2.** *перен. прост.* арка, сырт, җилкә; **всё вы́нести на своём ~те́** барысын да үз җилкәсендә тату **3.** (*горная цепь*) тау сырты, тау тезмәсе

хребто́в||ый, -ая, -ое **1.** умыртка ...ы; **~ые позво́нки** умыртка сөякләре **2.** сырт ...ы; **~ая ше́рсть** сырт йоны **3.** (*горный*) тау сырты ...ы, тау тезмәсе ...ы; **~ые перева́лы** тау сыртлары аша кичү урыннары

хрен *м* (*растение*) керән; (*корень*) керән тамыры

хрестомати́йн||ый, -ая, -ое: **~ая и́стина** һәркемгә билгеле хакыйкать

хрестома́тия *ж* хрестоматия

хризанте́ма *ж* хризантема, алтын чәчәк (гөл)

хризоли́т *м мин.* хризолит (*асылташ*)

хрип *м* гыжлау, хырылдау, хырылдау тавышы, гыжлаган тавыш; **у него́ ~ы в лёгких** аның үпкәсендә хырылдау тавышы бар

хрипе́ние *с см.* **хрипе́ть**

хрипе́ть *несов.* **1.** гыжлау, гырылдау, хырылдау **2.** *что и без доп.* (*хрипло говорить, петь*) карлыккан тавыш белән сәйләшү (*әйту, җырлау*)

хри́плый, -ая, -ое карлыккан; **~ го́лос** карлыккан тавыш

хри́пнуть *несов.* (*о голосе, человеке*) карлыгу

хрипот||а́ *ж* карлыгу; **крича́ть до ~и́** тамак карлыкканчы кычкыру

христиани́н *м* христиан, христиан динендәге кеше, христиан динен тотучы

христиа́нка *ж* христиан хатын (кыз)

христиа́нск||ий, -ая, -ое христиан [нар] ...ы; **~ая рели́гия** христиан дине; **~ая це́рковь** христиан чиркәве

христиа́нство *с* христианлык, христиан дине; **обрати́ть в ~** христианлаштыру; **приня́ть ~** христианлашу

христо́сик *м разг. шутл.* фәрештә, христосик

хром *м* хром (**1.** *химик элемент, аксыл сары катты металл* **2.** *сары буяуның бер төре* **3.** *йомшак юка күн*)

хромати́зм *м* хроматизм (**1.** *физ. ак нурларның төрле төстәге нурларга таркалу сыйфаты* **2.** *муз. авазның, тавышның ярты тон белән күтәрелүе һәм төшүе*)

хромати́ческ||ий, -ая, -ое *физ., муз.* хроматик; хроматизмга нигезләнгән; **~ое разложе́ние луче́й** нурларның хроматизмга нигезләнгән таркалышы; **~ая га́мма** хроматик гамма

хрома́||ть *несов.* **1.** аксау, аксап йөрү, чатанлау; **ло́шадь ~ет** ат аксый **2.** *перен. разг.* аксау; **у него́ фи́зика ~ет** ул физикадан аксый ♦ **~ть на о́бе но́ги** ике аякка да аксау, җитешсезлекләр күп булу

хроми́рование *с см.* **хроми́ровать**

хроми́рованн||ый, -ая, -ое хромланган, хром белән капланган; **~ая сталь** хром белән капланган корыч

хроми́ровать *сов., несов. что* хромлау, хром белән каплау

хро́мист||ый, -ая, -ое *хим.* хромлы, хром катыш; **~ая сталь** хромлы корыч; **~ый железня́к** хромлы тимер рудасы

хро́мка *ж разг.* хромка (*ике рәт хроматик гармунның бер төре*)

хро́мов||ый, -ая, -ое **1.** *хим.* хромлы, хром катнашкан; **~ая руда́** хромлы руда **2.** хром ...; хромнан тегелгән; **~ая ко́жа** хром күн; **~ые сапоги́** хром итек

хромо́й, -а́я, -о́е **1.** аксак, чатан **2.** *разг.* (*о мебели*) ватык, кыска аяклы, аягы сынган; аксак; **~ стул** аксак урындык

хромолитогра́фия *ж полигр.* хромолитография (**1.** *литографиядә күп төстә бастыру ысулы* **2.** *шул ысул белән бастырылган басма*)

хромоно́гий, -ая, -ое *разг. см.* **хромо́й**

хромоно́жка *ж разг.* аксак хатын (кыз)

хромосо́ма *ж биол.* хромосома (*усемлек һәм хайван организмының күзәнәк төшендәге буялучан элемент*)

хромосфе́ра *ж астр.* хромосфера (*Кояш атмосферасының кояш тотылганда куренә торган кызыл алкасыман тышкы катлавы*)

хромота́ *ж* аксаклык, чатанлык, аксак булу, зәгыйфь аяк

хромоти́пия *ж полигр.* хромотипия (*күп тостә басып чыгару һәм шундый ысул белән типографиядә басылган басма*)

хро́ник *м разг.* хроник (*озак авыручы*)

хро́ника *м* хроника (**1.** *ист. вакыйгаларны хронологик тәртип белән язып бару* **2.** *лит. тарихи, сәяси, иҗтимагый һ.б.ш. вакыйгаларның тарихын үз эченә алган әдәби әсәр* **3.** *газетта көндәлек вакыйгалар турында язылган кыска хәбәрләр бүлеге* **4.** *документаль фильм*)

хроника́льный, -ая, -ое хроникаль, хроника ...ы; **~ фильм** хроникаль фильм

хроникёр *м* хроникачы, хроника язучы (*газетның хроника бүлегенә хәбәрләр язып торучы хезмәткәр*)

хрони́ческ||ий, -ая, -ое **1.** хроник, озакка сузыла торган, озак дәвам итә торган; **~ое заболева́ние** озакка сузыла торган авыру **2.** хроник, озак авыручы; **~ий больно́й** хроник авыру **3.** *перен.* озак, дәвамлы, озакка сузылган; **~ое безде́нежье** озакка сузылган акчасызлык

хроно́граф I *м* хронограф (*берәр илнең тарихи вакыйгасын үзенә алган борынгы китап, язма*)

хроно́граф II *м* хронограф (*кыска вакытлы куренешләрнең тизлеген улчәп, үзе яза торган прибор*)

хронологи́ческ||ий, -ая, -ое хронологик, хронология ...ы; **в ~ом поря́дке** хронологик тәртиптә; **~ая табли́ца** хронологик таблица

хроноло́гия *ж* хронология (**1.** *ел исәбе тарихын өйрәнә торган фән* **2.** *вакытлары күрсәтелеп бер-бер артлы тезелеп язылган вакыйгалар исемлеге* **3.** *вакыйгаларның бер-бер артлы кайчан булу вакытын билгеләү*)

хроно́метр *м* хронометр (*аеруча төгәл сәгать*)

хронометра́ж *м* хронометраж (*берәр эш яки процесның дәвамлылыгын зур дөреслек белән улчәп билгеләү*); **~ рабо́чего дня** эш көненең хронометражы

хронометра́жист *м* хронометражчы (*хронометраж белән шөгыльләнүче белгеч*)

хронометри́ровать *сов., несов. что* хронометраж ясау (үткәрү)

хронометри́ст *м* хронометрист (*берәр эшкә хронометраж алып баручы кеше*)

хронометри́ческ||ий, -ая, -ое хронометрик; хронометр ярдәмендә ...; **~ое определе́ние вре́мени** вакытны хронометр ярдәмендә билгеләү

хроноско́п *м* хроноскоп (*бик кыска вакыт арасын улчи торган корал*)

хру́пать *несов. что, разг.* шатырдату; шатырдатып ашау; шатырдау; **~ морко́вку** кишерне шатырдатып ашау

хру́пк||ий, -ая, -ое **1.** уалучан, тиз ватылучан; **~ий лёд** уалучан боз; **~ий мета́лл** уалучан металл; **~ая посу́да** тиз ватылучан савыт-саба **2.** *перен.* (*слабый, болезненный*) зәгыйфь, чирләшкә **3.** *перен.* (*нежный, тонкий*) нәфис, нечкә; **~ая де́вушка** нәфис кыз

хру́пкость *ж* **1.** (*ломкость*) уалучанлык, тиз ватылучанлык **2.** (*слабость, болезненность*) зәгыйфьлек, чирләшкәлек **3.** *перен.* (*нежность, тонкость*) нәфислек

хруст *м* шытырдау, чытырдау, шыгырдау; шартлау; кыштыр[т]-кыштыр[т] итү; **~ сне́га под нога́ми** аяк астында карның шыгырдавы; **~ па́льцев** бармак шартлату; **с ~ом есть сухари́** шытырдатып кәтермәч ашау

хруста́лик *м анат.* хрусталик, күз ясмыгы

хруста́ль *м* хрусталь (**1.** *бик яхшы сыйфатлы пыяла* **2.** *собир. шундый пыяладан ясалган савыт-саба*)

хруста́льн||ый, -ая, -ое **1.** хрусталь ...ы; хрусталь ...; **~ый заво́д** хрусталь заводы; **~ая ва́за** хрусталь ваза **2.** *перен.* бик тоник, саф, чиста, үтә күренеп тора торган; **~ая вода́** бик тоник су; **~ый во́здух** бик чиста һава

хруте́ть *несов.* кетердәү, керт-керт итү; (*при еде*) кытырдау; (*о сене, соломе*) кыштырдау; (*о снеге*) шыгырдау; (*о песке*) шытырдау

хру́стнуть *сов. однокр.* кетердәп кую, керт-керт итеп кую; (*при еде*) кытырдап кую; (*о сене, соломе*) кыштырдап кую; (*о снеге*) шыгырдап кую; (*о песке*) шытырдап кую

хрущ *м зоол.* май коңгызы

хрыч *м бран.*: **ста́рый ~** картлач, карт тәре

хрычо́вка *ж бран.*: **ста́рая ~** карт пәри, карт убыр

хрю́канье *с см.* **хрю́кать**

хрю́кать *несов.* мыркылдау, мыркмырк итү

хрю́кнуть *сов. однокр.* мыркылдап кую

хрю́шка *ж разг.* мыркылдык, дуңгыз, чучка

хряк *м* ата дуңгыз

хрящ I *м анат.* кимерчәк; **носово́й ~** борын кимерчәге

хрящ II *м геол.* эре ком

хрящева́т||ый I, -ая, -ое кимерчәкле; **~ое мя́со** кимерчәкле ит

хрящева́тый II, -ая, -ое *геол.* эре комлы, эре комнан торган

хрящев||о́й I, -а́я, -о́е **1.** *анат.* кимерчәк ...; **~а́я ткань** кимерчәк тукыма **2.** кимерчәк скелетлы; **~ы́е ры́бы** кимерчәк скелетлы балыклар

хрящево́й II, -а́я, -о́е *геол.* эре комлы; **~ грунт** эре комлы грунт

худе́ть *несов.* ябыгу, арыклану, арыгаю, суырылу, чандырлану, кагаю

худи́ть *несов. кого-что, разг.* ябык күрсәтү (итеп күрсәтү); **э́тот костю́м его́ худи́т** бу костюм аны ябык күрсәтә

ху́д||о I *с разг.* яманлык, начарлык, күңелсезлек; **он никому́ не де́лает ~а** ул бер кемгә дә яманлык эшләми; **нет ~а без добра́** *посл.* бер яманлыкның бер яхшы ягы

ху́до II *нареч.* **1.** яман, начар, әшәке; яманлык белән; **э́то мо́жет ко́нчиться ~** моның начар бетүе мөмкин **2.** *в знач. сказ. безл.* авыр, начар; **больно́му ~** авыруның хәле начар; **здесь совсе́м не ~** монда бер дә начар түгел; **мне ~** минем хәл яман; **ему́ пришло́сь ~** аңа бик авыр туры килде

худоба́ *ж* ябыклык, чандырлык, арыклык

худо́жественность *ж* художестволылык

худо́жественн||ый, -ая, -ое **1.** матур, нәфис, матур әдәбият ...ы, художество-[лы] ...ы; **~ая литерату́ра** матур әдәбият; **~ый фильм** нәфис фильм, уен фильмы **2.** сәнгать ...ы, художество ...; **~ая шко́ла** сәнгать мәктәбе; **~ый руководи́тель теа́тра** театрның художество җитәкчесе **3.** нәфис; бизәкләп эшләнгән; сәнгать [әсәрләре] ...ы; художестволы; **~ая вы́ставка** сәнгать [әсәрләре] күргәзмәсе; **~ый музе́й** художество музее **4.** нәфис; художество ...ы; **~ая вы́шивка** нәфис чигү; **~ое сло́во** нәфис сүз; **~ая гимна́стика** художество гимнастикасы; **~ый свист** сызгырып көй чыгару (башкару) **5.** нәфис, художество ...ы, сәнгать ...ы, сәнгатьчә ...; **~ое мастерство́** сәнгать осталыгы; **~ая вырази́тельность** сәнгатьчә матурлык; **~ый приём** художество алымы **6.** художниклык ...ы; художество ...ы; **~ое дарова́ние** художниклык сәләте ♦ **~ая самодея́тельность** үзешчән сәнгать; **~ая часть** художество өлеше (*мәҗлестән, утырыштан соң үткарелә*); **~ый беспоря́док** күркәм тәртипсезлек

худо́жеств||о *с* **1.** *уст.* (*искусство*) сынлы сәнгать, художество; **Акаде́мия ~в** Художество академиясе **2.** *перен. разг.* (*проделка*) начар кыланыш, начар эш, әшәкелек; **брось свои́ ~а** ташла үзеңнең начар кыланышларыңны

худо́жник *м* **1.** (*живописец*) художник, рәссам **2.** художник (*мәс. язучы, артист һ.б.ш.*); **~ по костю́мам** костюмнар буенча художник **3.** *перен.* оста; **он ~ своего́ де́ла** ул үз эшенең остасы

худо́жница *ж* художник хатын (кыз), рәссам хатын (кыз)

худо́й I, -а́я, -о́е ябык, арык, чандыр, какча, арык-торык; **~ как спи́чка (ще́пка)** шырпы кебек

худ||о́й II, -а́я, -о́е *разг.* **1.** (*плохой*) алама, начар, әшәке, яман; бозык; **~а́я сла́ва** начар дан; **~ы́е ве́сти** начар хәбәрләр **2.** тузган, сәләмә, ертык, тишек, ертык-портык; **~о́й карма́н** тишек кесә; **~о́е ведро́** тишек чиләк ♦ **на ~о́й коне́ц** һич югында, һич тә булмаса; **не говоря́ ~о́го сло́ва** эндәшмичә генә, бернәрсә дә әйтмичә, эндәшми-нитми

худосо́чие *с разг.* артык ябыклык, чирләшкәлек, ябыгып хәлсезләнгән булу (*авырудан, азык җитешмәүдән һ.б.ш.*)

худосо́чный, -ая, -ое артык ябык, чирләшкә, бетерешкән

худоща́вость *ж* ябык булу, какчалык, чандырлык

худоща́вый, -ая, -ое ябык, какча, чандыр

ху́дш||ий, -ая, -ее *превосх. ст. от* **худо́й** II 1 *и* **плохо́й** 1 ♦ **в ~ем слу́чае** актык чиктә

худы́шка *ж разг.* (*обычно о девочке*) бик ябык кыз бала

ху́же *сравн. ст. от* **худо́й** II 1, **плохо́й** 1, **ху́до** II, **пло́хо** начаррак, аламарак; **пого́да сего́дня да́же ~, чем вчера́** бүген һава кичәгегә караганда да начаррак; **оди́н ~ друго́го** берсе икенчесеннән начаррак

хула́ *ж уст.* яманлау, хурлау, тиргәү

хулига́н *м* хулиган

хулига́нить *несов.* хулиганлык итү, хулиганлану

хулига́нка *ж* хулиган кыз (хатын)

хулига́нский, -ая, -ое хулиганнарча ..., хулиган[нар] ...ы; **~ посту́пок** хулиганнарча кыланыш

хулига́нство *с* хулиганлык; **борьба́ с ~м** хулиганлыкка каршы көрәшү

хулиганьё *с собир. разг.* хулиганнар

хули́ть *несов. кого-что* яманлау, хурлау; тиргәү, шелтәләү

ху́нта *ж* хунта (**1.** *кайбер Латин Америкасы илләрендә*: а) *төрле берләшмәләр, группировкалар, союзлар;* б) *хөкүмәт органы хакимияте* **2.** *хакимиятне үз кулына законсыз рәвештә тартып алучы һәм диктатор методлары белән идарә итүче заговорчылар төркеме*)

хура́л *м* хурал (*Монголия Халык Республикасында сайланып куела торган югары һәм җирле хакимият органнарының исеме*)

хурма́ *ж* хөрмә (*агачы һәм җимеше*)

ху́тор *м* хутор, кечкенә авыл; утар

хуторск||о́й, -а́я, -о́е хутор ...ы; **~о́е хозя́йство** хутор хуҗалыгы

хуторя́нин *м* **1.** (*житель хутора*) хуторда яшәүче **2.** (*владелец хутора*) хутор биләүче, хутор хуҗасы

хуторя́нка *ж* хуторда яшәүче хатын (кыз)

Ц

цап *в знач. сказ. прост.* һоп, элэктерде, элэктереп алды; ~ **егó зá руку** кулыннан элэктереп алды

цáпать *несов. кого-что, прост.* элэктереп (тотып) алу; тартып алу

цáпаться *несов. прост.* **1.** (*царапаться*) тырнашу; тырнау, тешлэү **2.** *перен.* (*ссориться*) элэгешү, тиргэшү, әрлэшү

цáпка *ж* тэпке, китмэн

цáпля *ж* челэн

цáпнуть *сов. однокр. см.* **цáпать**

цáпфа *ж тех.* цапфа (*валның яки күчәрнең подшипникка таянган өлеше*)

цап-царáп *в знач. сказ. шутл.* һап-һоп; элэктерде, каптырды, элэктереп алды; **кóшка мышóнка** ~ мәче тычканны элэктерде

царáпать *несов.* **1.** *кого-что* тырнау, тырнап яралау **2.** *что* сызгалау, тырнап язу; ~ **бýквы на стенé** диварга хәрефләр тырнап язу; ~ **в тетрáдке** *перен.* дәфтәргә сызгалау

царáпа||ться *несов.* **1.** *см.* **царáпать** 1; **2.** тырнашу; **кóшка** ~**ется** мәче тырнаша

царáпина *ж* тырнак эзе, тырналган урын, тырналган эз; **глубóкая** ~ тирән тырналган эз

царéвич *м* патша улы

царéвна *ж* патша кызы

царедвóрец *м уст.* патша яраны, сарай түрәсе, сарай әһеле

цареубúйство *с* патша[ны] үтерү

цареубúйца *м, ж* патша[ны] үтерүче

царúзм *м* царизм, патшалык; **сверженúе** ~**а** царизмны бәреп төшерү

царú||ть *несов.* **1.** *уст.* патшалык итү, патша булып тору **2.** *перен.* хөкем сөрү; **в лесý** ~**т тишинá** урманда тынлык хөкем сөрә; ~**ть над всéми** барысы өстеннән хөкем сөрү

царúца *ж* **1.** хатын патша, әби патша **2.** (*жена царя*) патша хатыны **3.** *перен.* күрек; патша; **рóза** — ~ **цветóв** роза — гөлләр күрке

цáрск||ий, -ая, -ое патша ...ы; ~**ий двор** патша сарае; ~**ое правúтельство** патша хөкүмәте; ~**ий режúм** патша режимы; ~**ое самодержáвие** патша самодержавиесе

цáрственный, -ая, -ое мәһабәт, мәгърур; горур; ~ **вид** мәһабәт кыяфәт

цáрство *с* **1.** (*государство*) патшалык **2.** патшалык итү; **избрáть на** ~ патшалык итүгә сайлау **3.** *перен.* дөнья; **живóтное** ~ хайваннар дөньясы; ~ **грёз** хыял дөньясы

цáрствование *с см.* **цáрствовать** 1

цáрств||овать *несов.* **1.** патшалык итү, патша булып тору **2.** *перен.* хөкем сөрү; ~**ует тишинá** тынлык хөкем сөрә

цар||ь *м прям., перен.* патша, падишаһ; ~**ь зверéй** җәнлекләр патшасы; ~**ь природы** табигать патшасы ◆ **без** ~**я в головé** башында шары юктыр, акылга тамандыр; **Царь-кóлокол** патша чан; **Царь-пýшка** падишаһ туп, патша пушка

цве||стú *несов.* **1.** чәчәк ату, чәчәкләнү; серкә очыру; **яблоня** ~**тёт** алмагач чәчәк ата; **рожь** ~**тёт** арыш серкә очыра **2.** *перен.* (*о человеке*) чәчәк кебек булу, шаулап чәчәк ату **3.** *перен.* (*процветать*) чәчәк ату, алга китү, алга бару, үсү **4.** (*о стоячей воде*) яшәлләнү, бака ефәге белән каплану; **пруд** ~**тёт** буа яшәлләнә

цвет I *м* төс; **крáсный** ~ кызыл төс; **тёмный** ~ кара төс; **я́ркие** ~**á** ачык төсләр ◆ **в** ~**е** *фото, кино* төсле

цвет II *м* **1.** *обычно мн.* ~**ы́** чәчәк, гөл, чәчкә; **живы́е** ~**ы́** тере чәчәкләр; **иску́сственные** ~**ы́** ясалма чәчәкләр; **ли́повый** ~ юкә чәчәге **2.** (*период цветения*) чәчәк; чәчәкләнү, чәчәк ату (*чоры*); **я́блоня в** ~**ý** алмагач чәчәктә **3.** *перен.* чәчәк, иң яхшы өлеше; ~ **нау́ки** фән чәчәге ◆ **во** ~**е лет** гомере (көче) шаулап чәчәк аткан чагында (*иң яхшы вакытында*)

цвета́ст||ый, -ая, -ое *разг. см.* **цвети́стый** 2; ~**ый сарафáн** чәчәкле сарафан; ~**ая шаль** чәчәкле шәл

цвете́ние *с см.* **цвести́**; ~**е ржи** арышның серкә очыруы; ~**е воды́** суның яшәлләнүе

цвети́ст||ый, -ая, -ое **1.** чәчәкле, [шау] чәчәккә күмелгән, чәчәк белән капланган; ~**ые луга́** чәчәкле болыннар **2.** чәчәкле, аллы-гөлле, чәчәкле-чачаклы; ~**ый ковёр** чәчәкле келәм **3.** *перен.* (*о слоге, речи и т.п.*) күперенке, чуар

цветко́в||ый, -ая, -ое *бот.* чәчәкле; ~**ые расте́ния** чәчәкле үсемлекләр

цветни́к *м* чәчәклек, чәчәк түтәле; чәчәк бакчасы, гөлбакча

цветн||о́й, -а́я, -о́е **1.** төсле; ~**а́я фотогра́фия** төсле фотография; ~**о́й фильм** төсле фильм; ~**ы́е каранда́ши** төсле карандашлар **2.** (*о людях*) төсле тәнле ◆ ~**а́я капу́ста** чәчәк кәбестә; ~**ы́е мета́ллы** төсле металлар

цветово́д *м* чәчәкче, чәчәк (гөл) үстерүче

цветово́дство *с* **1.** (*разведение цветов*) чәчәкчелек, чәчәк (гөл) үстерүчелек **2.** (*хозяйство*) чәчәк (гөл) үстерү хуҗалыгы

цветово́дческ||ий, -ая, -ое чәчәкчелек ...ы; гөл үстерү ...ы; ~**ая брига́да** чәчәкчелек бригадасы

цветов||о́й, -а́я, -о́е төс[ләр] ...ы; ~**ые отте́нки** төс төсмерләре ◆ ~**а́я слепота́** төсне аера алмау

цвет||о́к *м* чәчәк, чәчкә; гөл; **буке́т** ~**о́в** чәчәкләр бәйләме; **сажа́ть** ~**ы́** чәчәкләр утырту

цветоло́же *с бот.* чәчәк (гөл) төбе, чәчәк (гөл) түшәге

цветоно́жка *ж бот.* чәчәк (гөл) сабагы

цвето́ч||ек *м уменьш. от* **цветóк** ◆ **э́то то́лько (ещё)** ~**ки, а я́годки впереди́** бу әле баласы, мичтә калгандыр анасы

цвето́чница *ж* **1.** чәчәк сатучы хатын (кыз) **2.** (*напр. ящик для цветов*) чәчәк (гөл) савыты; гөл тартмасы

цвето́чн||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* чәчәк ...ы, гөл ...ы; ~**ая пы́льца** *бот.* чәчәк серкәсе; ~**ый горшóк** гөл чүлмәге; ~**ая клу́мба** чәчәк түтәле; ~**ый магази́н** чәчәк кибете

цвету́щ||ий, -ая, -ое **1.** *прич. от* **цвести́**; **2.** шау чәчәкле, шау чәчәктә утыра торган; ~**ый сад** шау чәчәкле бакча **3.** *перен.* чәчәк кебек, чәчәктәй; ~**ий ю́ноша** чәчәк кебек егет; ~**ее здоро́вье** чәчәктәй сәламәтлек **4.** *перен.* чәчәк аткан, алга киткән; ~**ая страна́** чәчәк аткан ил

це́вка *ж* **1.** *тех.* шүре, кәтүк **2.** (*у веретена*) баш **3.** *анат.* (*кость*) шүре (орчык, бөкәл) сөяге

цевни́ца *ж уст.* цевница (*тынлы халык музыка коралы*)

цевьё *с* **1.** *воен.* көбәк (*мылтыкта*) **2.** (*стержень*) кендек, күчәр; таяк; ~ **я́коря** якорь күчәре

цеди́лка *ж разг.* сөзгеч; ~ **для молока́** сөт сөзгеч

цеди́льн||ый, -ая, -ое сөзгеч ..., сөзә торган, сөзү ...ы; ~**ая маши́на** сөзгеч машина

цеди́ть *несов. что* **1.** сөзү; ~ **молоко́** сөт сөзү **2.** (*медленно наливать*) саркыту, акрын агызу **3.** (*медленно пить*) чөмерү, акрын эчү **4.** *перен. разг.* сөйләү, әкрен генә (иренеп кенә) сөйләү, әйтү; ~ **сквозь зу́бы** теш арасыннан сөйләү; ~ **слова́** сүзләрен иренеп кенә әйтү

це́дра *ж* цедра (*вакланган лимон, әфлисун кабыгы*)

це́зий *м хим.* цезий

цезу́ра *ж лит.* цезура, тыныш (*шигырь төзелешендә: шигырьне аерым өлешкә булә торган сүзләр арасындагы тыныш*)

цейтно́т *м* **1.** *шахм.* цейтнот **2.** *перен.* вакыт җитмәү

целе́бность *ж* шифалылык, дәвалылык; ~ **трав** үләннең шифалылыгы

целе́бн||ый, -ая, -ое шифалы, дәвалый торган, савыктыргыч; ~**ая вода́** шифалы су; ~**ый исто́чник** шифалы чишмә; ~**ый кли́мат** шифалы климат; ~**ые тра́вы** дәвалый торган үләннәр

целев||о́й, -а́я, -о́е **1.** максатлы, билгеле бер максатны күздә тоткан, аерым бер максатка билгеләнгән; ~**о́й ава́нс** аерым бер максатка билгеләнгән аванс **2.** максат ...ы, максатка ярашлы, максатка муафыйк; ~**а́я установ́ка рабо́ты** эшнең максатка ярашлыгы

целенапра́вленность *ж* максатчанлык, билгеле бер максатка юнәл[тел]гәнлек; ~ **де́йствий** хәрәкәтләрнең максатчанлыгы

целенапра́вленн||ый, -ая, -ое максатчан, билгеле бер максатка юнәл[тел]гән; ~**ая де́ятельность** билгеле бер максатка юнәлтелгән эшчәнлек

целесообра́зность *ж* максатка юнәл[тел]гәнлек (ярашлылык, муафыйк) булу, максатчанлык; ~ **реше́ния** карарның максатчанлыгы

целесообра́зн||ый, -ая, -ое максатчан, максатка ярашлы (муафыйк), максатка туры килә торган; **~ое мероприя́тие** максатчан чара; **~ое испо́льзование де́нежных средств** акчаны максатка ярашлы файдалану

целеустремлённость *ж* максатка омтылышлылык, максатка юнәл[тел]гәнлек, максатлылык; **~ в рабо́те** эштә максатка омтылышлылык

целеустремлённ||ый, -ая, -ое максатка омтылышлы, максатка юнәл[тел]гән, максатлы; **~ый челове́к** максатка омтылышлы кеше

це́лик *м воен.* целик (*туп һәм пулемётларда прицельның шудырма өлеше*)

целико́м *нареч.* **1.** тулаем, бөтенләй, тулы килеш, бөтен килеш, тоташлый; **проглоти́ть ~** тулы килеш йотып җибәрү **2.** *перен.* тулысынча, бөтенләй, һәрьяклап, баштанаяк; **он ~ прав** ул тулысынча хаклы; **он ~ отда́лся нау́ке** ул баштанаяк фәнгә бирелде ♦ **~ и по́лностью** тулысынча һәм бөтенләе белән

целин||а́ *ж* чирәм, чирәм җир; **осва́ивать ~у́** чирәмне үзләштерү; **пое́хать на ~у́** чирәм җиргә китү ♦ **сне́жная ~а́** кар сахрасы

цели́нник *м* чирәм җирче

цели́нн||ый, -ая, -ое чирәм ...; чирәм җир ...ы; **~ые зе́мли** чирәм җирләр; **~ый совхо́з** чирәм җир совхозы

цели́тельный, -ая, -ое *см.* **целе́бный**

цели́тель *м* дәвалаучы, савыктыручы, терелтүче; **~ неду́гов** авырулардан дәвалаучы

цели́тельница *ж* дәвалаучы, савыктыручы, терелтүче хатын (кыз)

це́лить *несов.* **1.** *см.* **це́литься; 2.** *перен. прост.* (*метить*) исәп тоту, ...га омтылу; **~ в нача́льники** башлык булырга исәп тоту, түрәлеккә омтылу

це́литься *несов.* төзәү, төбәү; **~ в мише́нь** мишеньгә төбәү

целлофа́н *м* целлофан

целлофа́нов||ый, -ая, -ое целлофан ..., целлофан ...ы; **~ый паке́т** целлофан капчык

целлуло́ид *м* целлулоид (*сыгылмалы каты матдә*)

целлуло́идн||ый, -ая, -ое, **целлуло́идов||ый,** -ая, -ое целлулоид ..., целлулоид ...ы; **~ые игру́шки** целлулоид уенчыклар; **~ая ма́сса** целлулоид массасы

целлюло́за *ж* целлюлоза (*узагчатан алынган матдә*)

целлюло́зно-бума́жн||ый, -ая, -ое: **~ый комбина́т** целлюлоза-кәгазь комбинаты; **~ая промы́шленность** целлюлоза-кәгазь промышленносте

целлюло́з||ный, -ая, -ое целлюлоза ..., целлюлоза ...ы; **~ая фа́брика** целлюлоза фабрикасы

целова́ние *с ист.* (*клятва, присяга*) тәре үбеп ант итү, ант бирү

целова́ть *несов. кого-что* үбү; **~ *кого-л.* в щёку** *кемнең дә булса* яңагыннан үбү; **~ ребёнка** баланы үбү; **~ ру́ку** кулын үбү

целова́ться *несов.* үбешү

целому́дренность *ж см.* **целому́дрие**

целому́дренный, -ая, -ое **1.** (*девственный*) гыйффәтле **2.** *перен.* (*нравственный*) әхлаклы, әхлакый саф, пакъ; **~ ю́ноша** әхлаклы егет

целому́дрие *с* **1.** (*девственность*) гыйффәтлек **2.** *перен.* (*нравственность*) әхлаклылык, әхлакый сафлык, пакълык; **~ мы́слей и чувств** фикер һәм хисләр пакълыгы

це́лостность *ж* бөтенлек, бер бөтенлек, тулылык; **~ госуда́рства** дәүләт бөтенлеге

це́лост||ый, -ая, -ое бөтен, бер бөтен, тулы; **~ое впечатле́ние** тулы тәэсир

це́лост||ь *ж* **1.** (*неповреждённость*) бөтенлек; сау-сәламәт булу, исән-имин булу (*берәр нәрсәнең*) **2.** (*внутреннее единство*) бөтенлек; тәмамлаганлык ♦ **в ~и и невреди́мости** сау-сәламәт [көе], исән-сау, зыян тидермичә, жиңгыр тидермичә; **в ~и и сохра́нности** барысы да сау-сәламәт; барысы да исән-имин

це́л||ый, -ая, -ое **1.** (*полный, непочатый*) бөтен, бер бөтен, тулы бер; төгәл бер; **~ый хлеб** бер бөтен икмәк; **~ое ведро́ молока́** тулы бер чиләк сөт **2.** бөтен, тулы бер, төгәл бер, буй; **~ый час** тулы бер сәгать; **~ыми часа́ми** сәгатьләр буе; **~ая истори́ческая эпо́ха** тулы бер тарихи дәвер; **~ый век** гомер буе; бөтен гомере; **~ый день** көн буе; көн озын **3.** (*значительный, большой*) бик күп, бик зур, зур бер, бөтен бер; **~ый ряд вопро́сов** бик күп мәсьәләләр; **~ая исто́рия** зур бер тарих **4.** (*неповреждённый*) бөтен, исән, имин, зыян-зарарсыз, бозылмаган, ватылмаган; **цел и невреди́м** исән-сау, сау-сәламәт, саутаза; **оста́ться ~ым** исән-сау калу **5.** (*не пропавший*) исән-сау, исән, югалмаган; **все ве́щи ~ы** барлык әйберләр дә исән **6.** *в знач. сущ.* **~ое** *с* (*нечто единое*) бер бөтен, тулы бер **7.** *мат.* бөтен; **~ое число́** бөтен сан **8.** *в знач. сущ.* **~ое** *с*, **~ая** *ж мат.* бөтен; **одна́ ~ая пять деся́тых** бер бөтен уннан биш ♦ **в ~ом** гомумән, тулаем алганда; **в о́бщем и ~ом** гомумән һәм тулаем, гомумән

цел||ь *ж* **1.** *воен.* цель; **дви́жущаяся ~ь** хәрәкәт итә торган цель; **попа́сть в ~ь** цельгә тидерү **2.** максат, морат, мәсләк, теләк, исәп; **доби́ться свое́й ~и** үз максатына ирешү; **пресле́довать** *какую-л.* **~ь** *берәр максатны* күздә тоту; **задава́ться ~ью** *сделать что-л. берәр нәрсә* эшләүне максат итеп кую ♦ **с ~ью** *или* **в ~ях** *чего и с неопр. предлог берәр нәрсәгә* дип ..., исәп тотып, берәр максат белән; **прийти́ с ~ью поговори́ть** сөйләшергә дип килү; **уда́рить в ~ях самозащи́ты** үз-үзеңне саклау максаты белән сугу

цельнометалли́ческий, -ая, -ое тоташ металл..., тоташ металлдан эшләнгән; **~ ваго́н** тоташ металл вагон

це́льность *ж* **1.** бөтенлек, тоташлык **2.** *перен.* ныклык, бердәмлек, тулылык

це́льн||ый, -ая, -ое **1.** (*единый*) бөтен, тоташ **2.** (*о молоке*) өсте алынмаган, аертылмаган; (*о винах*) су кушылмаган **3.** *перен.* бер бөтен, тулы, ныклы; бердәм; **~ый хара́ктер** ныклы характер; **~ое впечатле́ние** тулы тәэсир

цеме́нт *м* цемент

цемента́ция *ж* **1.** *тех.* цементлау, цементлаштыру, цементлап ныгыту; **~ сква́жины** скважинаны цементлап ныгыту **2.** *тех.* цементацияләү, чыныктыру; **~ ста́ли** корычны цементацияләү **3.** *геол.* цементлану, цементлашу

цементи́рование *с см.* **цементи́ровать**

цементи́ровать *сов., несов.* **1.** *что, тех.* цементлау, цементлаштыру, цементлап ныгыту **2.** *что, тех.* (*сталь*) цементацияләү, чыныктыру **3.** *перен. кого-что* (*укреплять*) ныгыту, бердәмләштерү

цементи́роваться 1. *сов., несов.* цементлашу **2.** *несов. страд. от* **цементи́ровать**

цеме́нтный, -ая, -ое цемент ..., цемент ...ы; **~ заво́д** цемент заводы; **~ пол** цемент идән

цен||а́ **1.** (*стоимость*) бәя, хак, бәһа; **госуда́рственные це́ны** дәүләт бәяләре; **опто́вая ~а́** күпләп сату бәясе; **ро́зничные це́ны** ваклап сату бәяләре; **сни́зить це́ны** бәясен төшерү **2.** (*плата*) бәя, хак; **~а́ биле́та** билет бәясе **3.** *перен.* (*ценность, достоинство*) кадер, кыйммәт, бәя, бәһа; **~а́ дру́жбы** дуслыкның кадере **4.** *тв.п.* **~о́ю** корбан итеп; **~о́ю свое́й жи́зни** үз тормышын корбан итеп ♦ **быть в ~е́** кыйммәт бәядә булу; **любо́й ~о́й** берни белән исәпләшмичә; **доби́ться любо́й ~о́й** ничек кенә булса да ирешү; **~ы́ нет** 1) *чему* бәһа булмау (*бик кыйммәтле әйбер турында*); 2) *кому* хакы юк, бәялап бетергесез, бик кадерле

ценз *м* ценз (*теге яки бу хокукларны тормышка ашырганда кешенең катнашын чикли торган шарт*); **возрастно́й ~** яшь цензы; **иму́щественный ~** милек цензы; **образова́тельный ~** белем цензы

це́нзор *м* цензор

це́нзорск||ий, -ая, -ое цензорлык ...ы, цензор ...ы; **~ие обя́занности** цензор вазифалары

це́нзорство *с* цензорлык

цензу́р||а *ж* цензура; **вое́нная ~а** хәрби цензура

цензу́рн||ый, -ая, -ое **1.** цензура ...ы; **~ые поме́тки** цензура билгеләре **2.** әдәпле, әхлаклы; **вполне́ ~ое выраже́ние** тулысынча әдәпле әйтем

цени́тель *м* бәяли алучы, бәяли белүче, кадерен белүче; **~ поэ́зии** шигъриятне бәяли белүче

цени́ть *несов.* **1.** *кого-что* (*назначать цену*) бәяләү, бәя кую, бәһалау, бәһа кую, хак кую, бәя бирү, хакын билгеләү; **до́рого ~ вещь** әйберне кыйммәт бәяләү **2.** *перен. что* (*дорожить чем-л.*) бәяләү, кадерен белү; **~ дру́жбу** дуслыкның кадерен белү **3.** *кого* ихтирам итү, тәкъдир итү; **его́ це́нят как врача́** аны табиб буларак ихтирам итәләр

цени́ться *несов.* **1.** (*иметь цену, обладать ценностью*) бәяләнү, бәһалану, бәһа бирелү, бәя бирелү; **дёшево ~** арзан бәяләнү **2.** (*быть ценимым*) бәяләнү;

наро́дные тала́нты высоко́ це́нятся в на́шей стране́ безнең илебездә халык таланлары югары бәяләнә **3.** *стард. от* **цени́ть**

це́нник *м* бәяләр (бәһалар) күрсәткече, бәяләр белешмәлеге

це́нност||ь *ж* **1.** бәя, бәһа, хак, кыйммәт; **бага́ж с объя́вленной ~ью** бәясе билгеләнгән багаж **2.** әһәмият, кыйммәт; **э́то произведе́ние и ны́не сохраня́ет свою́ ~ь** бу әсәр бүген дә кыйммәтен саклый **3.** *обычно мн.* **~и** кыйммәтле (затлы) әйбер; **хране́ние ~ей** кыйммәтле әйберләрне саклау **4.** *перен. обычно мн.* **~и** байлык, хәзинә; **культу́рные ~и** культура хәзинәләре; **материа́льные ~** матди байлыклар

це́нн||ый, -ая, -ое **1.** (*имеющий цену*) бәяле, бәһалы, хаклы, бәясе (бәһасы, хакы) куелган; бәясе күрсәтелгән; **~ая посы́лка** бәясе күрсәтелгән посылка **2.** кыйммәтле; **~ый пода́рок** кыйммәтле бүләк **3.** *перен.* әһәмиятле, кыйммәтле; **~ый докуме́нт** әһәмиятле документ; **~ое предложе́ние** кыйммәтле тәкъдим; **~ое откры́тие** кыйммәтле ачыш

цент *м* цент (*АКШта һәм кайбер башка илләрдә акча берәмлегенең йөздән бер өлешенә тигез вак акча*)

це́нтнер *м* центнер

центр *м в разн. знач.* үзәк, мәркәз; **~ окру́жности** *мат.* әйләнмә үзәге; **~ тя́жести** *физ.* авырлык үзәге; **жить в ~е го́рода** шәһәр үзәгендә яшәү; **~ наро́дного движе́ния** халык хәрәкәте үзәге; **промы́шленный ~** сәнәгать үзәге; **торго́вый ~** сәүдә үзәге; **директи́вы ~а** үзәктән килгән күрсәтмәләр; **в ~е внима́ния** игътибар үзәгендә

центра́л *м* централ (*патша Россиясендә: үзәк төрмә*)

централиза́ци||я *ж см.* **централизова́ть, централизова́ться; ~я госуда́рственной вла́сти** дәүләт властен үзәкләштерү; **проце́сс ~и капита́лла** капиталның бер үзәккә туплану процессы

централи́зм *м полит.* централизм, бер үзәктән идарә итү, үзәкләштерү системасы; **демократи́ческий ~** демократик централизм

централизо́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **централизова́ть; 2.** үзәкләштерелгән, мәркәзләштерелгән, бер үзәктән идарә ителә торган, үзәктән ...; **~ое госуда́рство** үзәкләштерелгән дәүләт **3.** бер үзәктән ..., бер мәркәздән ...; **~ое плани́рование** бер үзәктән планлаштыру; **~ое управле́ние** бер үзәктән идарә итү

централизова́ть *сов., несов. что* үзәкләштерү, мәркәзләштерү, бер үзәккә туплау (җыю); **~ рабо́ту** эшне үзәкләштерү

централизова́ться 1. *сов., несов.* үзәкләшү, мәркәзләшү, бер кулга туплану (җыелу) **2.** *несов. страд. от* **централизова́ть**

централисти́ческ||ий, -ая, -ое централизм ...ы; **~ие взгля́ды** централизм карашлары

центра́лка *ж разг.* централка (*мылтыкның бер төре*)

центра́ль *ж* централь, үзәк магистраль

центра́льн||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* үзәк, үзәктәге, мәркәз, төп, урталыктагы; **~ая газе́та** үзәк газета; **~ая у́лица** мәркәз урам; **~ый райо́н** үзәк район; **~ый вопро́с** үзәк мәсьәлә; **~ая мысль кни́ги** китапның төп фикере ♦ **~ое отопле́ние** үзәктән ягып җылыту системасы

центри́рование *с см.* **центри́ровать**

центри́ровать *сов., несов. что, тех.* бер үзәккә туры китерү (кую, беркетү); үзәкләрен туры китерү

центрифу́га *ж* центрифуга

центробе́жн||ый, -ая, -ое *спец.* үзәктән куа торган (куучы); үзәктән куу ...ы; **~ая си́ла** үзәктән куу көче; **~ый наcóc** үзәктән куа торган насос; **~ый вентиля́тор** үзәктән куу вентиляторы

центрова́льный, -ая, -ое *тех.* үзәк тишү ...ы; **~ стано́к** үзәк тишү станогы

центрова́ние *с см.* **центрова́ть**

центрова́ть *сов., несов. что, тех.* үзәк тишү

центростреми́тельн||ый, -ая, -ое *спец.* үзәккә омтылу ...ы, үзәккә омтылучы ...; **~ое движе́ние** үзәккә омтылучы хәрәкәт; **~ая си́ла** үзәккә омтылу көче

цеп *м с.-х.* чабагач; **колоти́ть ~о́м** чабагач белән сугу

цепене́ть *несов.* кату, күшегү, катып калу; **ру́ки на́чали ~ от хо́лода** суыктан куллар ката башлады

це́пк||ий, -ая, -ое **1.** каты кыса торган, эләктерә торган, эләктерүчән; **~ие ко́гти** эләктерүчән тырнаклар; **~ие ру́ки** каты кыса торган куллар **2.** *перен.* үткен, үзенекен итүче (итә торган), үз дигәнен булдыручы; **~ий челове́к** үзенекен итүче кеше; **~ий ум** үткен акыл

це́пкость *ж* **1.** каты кыса торган булу, эләктерүчән булу, эләктерүчәнлек; **~ рук** кулларның каты кыса торган булуы **2.** *перен.* (*взгляда, ума, памяти и т.п.*) кискенлек, үткенлек

цепля́ться *несов.* **1.** *за кого-что* (*задевать*) ябышу, эләгү, сарылу **2.** *за кого-что* (*держаться*) тотыну, асылыну **3.** *перен. за что* ябышу, ябышып яту, эләктереп алу; **~ за жизнь** тормышка ябышу

цепн||о́й, -а́я, -о́е **1.** чылбыр ...ы, зынҗыр ...ы; **~о́е звено́** чылбыр буыны **2.** *тех.* чылбырлы; **~а́я переда́ча** чылбырлы күчергеч **3.** чылбырдагы, бәйдәге; **~а́я соба́ка** чылбырдагы эт **4.** (*следующий один за другим*) чылбырлы; **~ы́е рефле́ксы** *физиол.* чылбырлы рефлекслар ♦ **~а́я реакция** *физ., хим.* чылбырлы реакция

цепо́чк||а *ж* **1.** (*для часов*) нечкә чылбыр, сәгать чылбырлы **2.** бер саф, тезмә; **~а фонаре́й** бер сафтагы фонарьлар; **~а автомашин** автомашиналар тезмәсе **3.** *в знач. нареч.* **~ой** бер саф белән, бер рәт белән; **грузовики́ дви́гались ~ой** йөк машиналары бер саф белән хәрәкәт иттеләр

цеп||ь *ж* **1.** чылбыр, зынҗыр; **я́корная ~ь** якорь чылбыры; **привяза́ть соба́ку на ~ь** этне чылбырга бәйләп кую **2.** *мн. ~и прям., перен.* богау, зынҗыр; **заkова́ть в ~и** богау кидерү; **~и ра́бства** коллык богаулары **3.** (*ряд, вереница*) тезмә; **~ь озёр** күлләр тезмәсе **4.** *воен.* чылбыр, цепь; **наступа́ть ~ью** цепь белән һөҗүм итү ♦ **он как с цепи́ сорва́лся** ул бәйдән ычкынган шикелле

церемониа́л *м* церемониал, тантана тәртибе; **~ встре́чи** каршы алу тәртибе

церемониа́льный, -ая, -ое церемониал ..., тантаналы; **~ марш** тантаналы марш

церемо́ниться *несов.* **1.** (*быть церемонным*) тәкәллефләнү, тәкәллефләнеп тору, тартынып тору; **прошу́ не ~** тәкәллефләнеп тормавыгызны үтенәм **2.** *с кем-чем* назланып тору, тартынып тору

церемо́ни||я *ж* **1.** церемония, йола; **сва́дебная ~я** туй йоласы **2.** *обычно мн. ~и перен.* тәкәллеф, кылану, тартыну; **к чему́ э́ти ~и?** нигә бу кыланулар?

церемо́нность *ж* **1.** (*утончённая вежливость*) тәкәллефлелек, нәзакәтлелек, әдәплелек; **~ ре́чи** сөйләмнең тәкәллефлелеге **2.** (*жеманность*) назлылык

церемо́нный, -ая, -ое **1.** (*утончённо вежливый*) тәкәллефле, нәзакәтле **2.** (*жеманный*) кыланчык, назлы; **~ гость** назлы кунак

церко́вник *м* **1.** (*служитель культа*) чиркәү кешесе, чиркәү әһеле **2.** (*сторонник религии*) диндар, динле кеше

церковноприхо́дск||ий, -ая, -ое: **~ая шко́ла** чиркәү-мәхәллә мәктәбе (*патша Россиясендә: чиркәү-мәхәллә карамагындагы уку йорты*)

церковнославя́нский, -ая, -ое: **~ язы́к** чиркәү-славян теле

церко́вность *ж* диндарлык; динилек

церко́вн||ый, -ая, -ое **1.** чиркәү ...ы; **~ые зе́мли** чиркәү жирләре; **~ый суд** чиркәү суды **2.** дин ...ы, дини; **~ая литерату́ра** дини әдәбият

це́рковь *ж* **1.** чиркәү, дин; **католи́ческая ~** католик чиркәве; **правосла́вная ~** православие дине **2.** (*здание*) чиркәү, кәлисә

цесаре́вич *м* тәхет варисы (*патшаның үзеннән соң тәхеткә утырасы улы*)

цесаре́вна *ж* **1.** тәхет варисы хатыны **2.** патша кызы

цеса́рка *ж зоол.* мисыр тавыгы

цех *м* цех; **лите́йный ~** кою цехы; **кузне́чный ~** тимерчелек цехы

цехов||о́й, -а́я, -о́е **1.** цех ...ы; **~о́й ма́стер** цех мастеры **2.** цех[чы]лык ...ы; тар төркем ...ы; чикләнгән; **~ы́е интере́сы** тар төркем мәнфәгатьләре

цеховщи́на *ж разг.* цехчылык, тар төркемчелек, чикләнгәнлек

циа́н *м хим.* циан (*газ*)

циа́нистый, -ая, -ое *хим.* цианлы; **~ ка́лий** цианлы калий

циа́нов||ый, -ая, -ое *хим.* циан ...ы; **~ая кислота́** циан кислотасы

циано́з *м мед.* цианоз (*кайбер авырулар вакытында тән тиресе күгәрү*)

цивилиза́ция *ж* мәдәният, цивилизация; **анти́чная ~** антик мәдәният

цивилизо́ванность *ж* мәдәниятлелек, цивилизациялелек

цивилизо́ванн||ый, -ая, -ое мәдәниятле, цивилизацияле

цивилизова́ть *сов., несов. кого-что* мәдәниятләштерү, цивилизацияләштерү, мәдәниятле итү

цивилизова́ться *сов., несов.* мәдәниләшү, цивилизацияләшү

цига́рка *ж разг.* сигарка, төрелгән тәмәке

циге́йк||а *ж* цигейка, сарык мехы; **воротни́к из ~и** цигейка яка

циге́йков||ый, -ая, -ое цигейка ..., цигейкадан тегелгән, сарык мехыннан тегелгән; **~ая шу́ба** цигейка тун

цика́да *ж зоол.* цикада, кыр чикерткәсе

цикл *м в разн. знач.* цикл; **произво́дственный ~** җитештерү циклы; **годово́й ~ враще́ния Земли́** Җир әйләнешенең еллык циклы; **истори́ческий ~** тарих фәннәре циклы; **~ стихотворе́ний** шигырьләр циклы; **~ ле́кций** лекцияләр циклы

цикламе́н *м бот.* цикламен, Альп миләүшәсе

циклева́ние *с см.* **циклева́ть**

циклева́ть *несов. что* циклёвкалау, кырып шомарту

циклёвка *ж см.* **циклева́ть**

цикли́ческ||ий, -ая, -ое **1.** цикллы, цикллап [башкарыла торган]; цикл белән [кабатлана торган]; **~ое разви́тие** цикллы үсеш **2.** (*составляющий цикл*) бер цикл тәшкил иткән, бер цикллы **3.** *хим.* циклик; **~ие аминокисло́ты** циклик аминокислоталар

цикли́чность *ж* **1.** цикллылык, кабатланмалы булу **2.** (*в производстве*) цикллап эшләү

цикли́чн||ый, -ая, -ое **1.** *см.* **цикли́ческий** 1; **2.** цикллап, цикл белән кабатлана (башкарыла) торган; **~ая рабо́та** цикл белән башкарыла торган эш

цикло́ида *ж мат.* циклоида (*кәкре сызыкның бер төре*)

циклоида́льн||ый, -ая, -ое, **цикло́идн||ый,** -ая, -ое *мат.* циклоида ...ы, циклоидаль; **~ая ли́ния** циклоидаль сызык

цикло́н *м* **1.** *метео* циклон **2.** (*ураган*) давыл, көчле җил, өермә

циклони́ческ||ий, -ая, -ое *метео* циклон ...ы, циклоник; **~ие явле́ния** циклон күренешләре; **~ие ви́хри** циклон өермәләре

циклотро́н *м физ.* циклотрон (*корылган авыр микрокисәкчәләрне тизләтү өчен җайланма*)

цико́рий *м* һиндыба, цикорий

цику́та *ж бот.* түндербаш, су балтырганы

цили́ндр *м* **1.** *мат., тех.* цилиндр **2.** (*шляпа*) цилиндр эшләпә

цилиндри́ческ||ий, -ая, -ое **1.** *мат.* цилиндр ..., цилиндр ...ы; **~ий ко́рпус** цилиндр корпусы **2.** цилиндрик, цилиндрсыман; **~ая пила́** цилиндрик пычкы ♦ **~ая пове́рхность** *мат.* цилиндрик өсләзлек

цили́ндров||ый, -ая, -ое *тех.* **1.** цилиндр ...ы; **~ая кры́шка** цилиндр капкачы **2.** цилиндрлы; **~ая маши́на** цилиндрлы машина

цимбали́ст *м* цимбалчы, цимбалда уйнаучы

цимба́лы *только мн.* цимбал (*кыллы музыка коралы*)

цинга́ *ж* зәңгелә, зәңгелә авыруы

цинго́тн||ый, -ая, -ое зәңгелә ...ы, зәңгелә авырулы, зәңгеләле; **~ые при́знаки** зәңгелә билгеләре; **~ый больно́й** зәңгелә белән авыручы; **~ые дёсны** зәңгеләле теш казнасы

цини́зм *м* оятсызлык, әдәпсезлек

ци́ник *м* оятсыз, әдәпсез

цини́чность *ж* оятсызлык, әхлаксызлык

цини́чный, -ая, -ое оятсыз, әхлаксыз; **~ отве́т** оятсыз җавап; **~ челове́к** оятсыз кеше

цинк *м* цинк, тутыя

цинкова́ть *несов., что, тех.* цинклау, тутыялау, цинк каплау (йөгертү), тутыя каплау

ци́нков||ый, -ая, -ое **1.** цинк ...ы, тутыя ...ы; **~ый порошо́к** цинк порошогы **2.** цинклы, тутыялы, цинк ...ы; **~ая мазь** цинклы май; **~ый сплав** цинк эретмәсе **3.** (*оцинкованный*) цинк ...; цинклы, тутыялы, цинк капланган (йөгертелгән); **~ое ведро́** цинк чиләк

цинко́граф *м полигр.* цинкограф

цинкографи́ческ||ий, -ая, -ое *полигр.* цинкография ...ы, цинкографик; **~ое клише́** цинкографик клише

цинкогра́фия *м полигр.* цинкография (**1.** *клишелар әзерләү ысулы* **2.** *предприятие, цех*)

ци́нния *ж бот.* цинния (*декоратив үсемлек*)

цино́вка *ж* чыпта

цино́вочн||ый, -ая, -ое чыпта ...ы, чыпта ...; **~ая подсти́лка** чыпта аслык

цирк *м* цирк, кәмит

цирка́ч *м разг.* циркач, цирк артисты, кәмитче

цирков||о́й, -а́я, -о́е цирк ...ы, кәмит ...ы; **~о́й арти́ст** цирк артисты

циркули́р||овать *несов.* йөрү, әйләнеп йөрү, әйләнеп тору; **кровь ~ует по сосу́дам** кан тамырлар буенча әйләнеп йөри

ци́ркуль *м* җәзбә, циркуль

ци́ркульн||ый, -ая, -ое **1.** җәзбә ...ы, циркуль ...ы; **~ая игла́** җәзбә энәсе **2.** (*в форме круга*) түгәрәк; **~ый зал** түгәрәк зал; **~ая пила́** түгәрәк пычкы

циркуля́р *м* циркуляр, күрсәтмә

циркуля́рн||ый I, -ая, -ое циркуляр ..., күрсәтмә ...; **~ое письмо́** циркуляр хат; **~ое распоряже́ние** циркуляр боерык

циркуля́рн||ый II, -ая, -ое түгәрәк ...; **~ая пила́** түгәрәк пычкы

циркуляцио́нн||ый, -ая, -ое әйләнеп йөрү ...ы, әйләнмә, циркуляция ...ы, циркуляцион; **~ое движе́ние** әйләнмә хәрәкәт; **~ые тру́бы** циркуляция торбалары

циркуля́ция *ж см.* **циркули́ровать; ~ кро́ви** канның әйләнеп йөрүе

цирро́з *м мед.* цирроз; **~ пе́чени** бавыр циррозы

цисте́рна *ж* цистерна; **нефтяна́я ~** нефть цистернасы

цисти́т *м мед.* цистит (*сидек куыгының ялкынсынуы*)

цитаде́ль *ж* **1.** цитадель (*ныгытылган корылма*) **2.** *перен.* терәк, нигез, таяныч; **~ ми́ра** тынычлык терәге

цита́т||а *ж* өземтә; **привести́ ~у** өземтә китерү

цита́тный, -ая, -ое өземтә ...ы, өземтә итеп алынган; **~ матери́ал** өземтә материалы

цитва́рн||ый, -ая, -ое: **~ое ма́сло** дәрмана мае; **~ая поли́нь** дәрмана, дәрмана үләне; **~ое се́мя** дәрмана орлыгы

цити́рование *с см.* **цити́ровать**

цити́ровать *несов. кого-что* өземтә китерү; **~ кла́ссиков** классиклардан өземтә китерү

цитологи́ческ||ий, -ая, -ое *биол.* цитологик, цитология ...ы: **~ие иссле́дования** цитологик тикшеренүләр

цитоло́гия *ж* цитология *(биологиянең күзәнәк төзелеше турындагы тармагы)*

ци́трa *ж* цитра (*кыллы музыка коралы*)

ци́трус *м* цитрус (*лимон, әфлисун кебек үсемлекләр*)

ци́трусов||ый, -ая, -ое **1.** цитрус ...ы, цитрус ...; **~ые плоды́** цитрус җимешләр **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* цитруслар, цитрус үсемлекләр

цифербла́т *м* циферблат, сәгать битлеге

цифербла́тн||ый, -ая, -ое **1.** циферблат ...ы; **~ый круг** циферблат түгәрәге **2.** циферблатлы; **~ые весы́** циферблатлы үлчәү

ци́фр||а *ж* **1.** цифр, сан билгесе; **ара́бские ~ы** гарәп цифрлары **2.** (*сумма, число*) сан, сумма; **контро́льные ~ы** контроль саннар

цифрова́ть *несов. что, спец.* (*нумеровать*) цифрлау, нумерлау, сан куеп чыгу, сан белән билгеләү

цифров||о́й, -а́я, -о́е **1.** цифр ...ы; **~а́я систе́ма** цифр системасы **2.** цифрлы, саннлы, сан ...ы; **~ые да́нные** саннлы мәгълүматлар

ци́церо *с нескл. полигр.* цицеро (*уникe пунктлы хәреф*)

цо́ка||ть I *несов.* чак-чок килү, чакылдау; **подко́вы ~ют по мостово́й** таш урамда дагалар чак-чок килә

цо́кать II *несов.* цылаштыру (*«ч» урынына «ц» белән сөйләү*)

цо́коль *м* **1.** *архит.* цоколь (*стенаның тышка чыгып торган аскы өлеше*) **2.** *тех.* цоколь, лампочка төплеге

цо́кольный, -ая, -ое *архит.* цоколь ...ы; **~ ка́мень** цоколь ташы; **~ эта́ж** цоколь биеклегендәге кат

цо́кот *м* чык-чык (чак-чок) килү, чакылдау; **~ копы́т** тояк тавышы, тояк чакылдавы

цокота́ть *несов.* (*производить цокот*) чыкылдату, чакылдату

цуг *м* очлап җигү, мичәүләп җигү

цугов||о́й, -а́я, -о́е очка җигелгән, мичәү ...ы; **~а́я ло́шадь** мичәү аты

цу́гом *нареч.* мичәүләп, очлап җигеп (*атны*); **е́хать ~** мичәүләп җигелгән атларда бару

ЦУК-ЧАС

цука́т *м* цукат, шикәрле җимеш

цука́тный, -ая, -ое цукат ...ы, шикәрле җимеш ...ы; ~ **торт** шикәрле җимеш торты

цуна́ми *с нескл.* цунами (*океанда су асты җир тетрәвеннән яки су асты һәм утрау вулканнары атудан хасил булган галәмәт зур дулкын*); **во́лны ~** цунами дулкыннары; **~-слу́жба** цунами хәзмәте

цыга́н *м* чегән

цыга́не *мн.* чегәннәр, чегән халкы

цыга́нка *ж* чегән хатыны (кызы)

цыга́нск||ий, -ая, -ое чегән[нәр] ...ы; **~ий язы́к** чегән теле; **~ая му́зыка** чегән музыкасы; **~ая пля́ска** чегәннәр биюе

цыга́нщина *ж разг.* **1.** (*стиль исполнения романсов*) чегәнчелек **2.** (*романсы цыганского характера*) чегән җырлары

цы́пк||и *мн. разг.* чеби (*аяк-кулда*); **но́ги у него́ бы́ли в ~ах** аяклары чебиләгән иде

цыплёнок *м* чеби, чебеш

цыпля́чий, -ье, -ье чеби[ләр] ...ы, чебеш[ләр] ...ы; ~ **пух** чебиләр йоны

цы́почк||и *только мн.* : **на ~ах** аяк очы белән генә; **встать на ~и** аяк очында гына басып тору

цыц *межд.* тс, чү, дәшмә

Ч

чаба́н *м* чабан, сарыклар көтүче; **о́пытные ~ы́** тәжрибәле чабаннар

чаба́н||ий, -ья, -ье чабан ...ы; **~ья стоя́нка** туплавык

чаба́нить *несов.* чабанлык итү, көтү көтү

чаба́нск||ий, -ая, -ое чабан ...ы; **~ая собака́** чабан эте

чабёр *м бот* чабыр

чабре́ц *м бот.* чамбыр

ча́вканье *с см.* **ча́вкать**

ча́вкать *несов.* **1.** чапылдату, авыз чапылдату; ~ **во вре́мя еды́** ашаганда авыз чапылдату **2.** *перен.* лач-лоч итү, лачкылдату; ~ **по гря́зи** пычрактан лач-лоч итеп бару

чад *м* **1.** ис, сөрем, төтен; **угоре́ть от ~а** сөремнән исерү, башка ис тию **2.** *перен.* (*дурман*) сөрем, исереклек; **в ~у́ стра́сти** дәрт исереклегендә

чади́||ть *несов.* төтәү, төтенләү, ис чыгару; **печь ~т** мич төтенли; **из ку́хни ~т** кухнядан төтенли

ча́дно *нареч. в знач. сказ. безл.* төтен (сөрем, ис) тулган; **в ку́хне ~** кухняга төтен тулган

ча́дн||ый, -ая, -ое төтенле, сөремле, төтенли (сөремли) торган; **~ый во́здух** төтенле һава; **~ая ку́хня** төтенли торган кухня

ча́д||о *с шутл.* бала; ул; кыз; **со все́ми ~ами и домоча́дцами** барлык балачагасы һәм өй ишләре белән

чадолюби́вый, -ая, -ое *шутл.* балаларын яратучы; ~ **папа́ша** балаларын яратучы эти

чадра́ *ж* чадра, бөркәнчек

чаёвник *м разг.* чәйхур, чәй яратучы

чаёвница *ж разг.* чәйхур, чәй яратучы хатын (кыз)

чаёвничать *несов. разг.* чәй эчеп утыру, чәйләп утыру, чәйләү

чаево́д *м* чәй игү белгече, чәй игүче

чаево́дство *с* чәй игү

чаево́дческ||ий, -ая, -ое чәй игү ...ы; **~ое хозя́йство** чәй игү хуҗалыгы

чаевы́е *только мн.* чәйлек

чаепи́тие *с* чәй эчү, чәйләү; **вече́рнее ~е** кичке чәй эчү

чаеразве́сочн||ый, -ая, -ое чәй төрү ...ы; **~ая фа́брика** чәй төрү фабрикасы

чаеторго́вля *ж* чәй сәүдәсе, чәй белән сәүдә итү

чаеторго́вл||ый, -ая, -ое чәй сәүдәсе ...ы, чәй белән сәүдә итү ...ы; **~ые организа́ции** чәй белән сәүдә итү оешмалары

чайнка *ж* чәй бөртеге (чүбе)

чай *м* чәй; **зелёный ~** яшел чәй; **кре́пкий ~** каты чәй; **мали́новый ~** кура җиләге чәе; **кирпи́чный ~** такта чәй; **завари́ть ~** чәй пешерү; **пить ~** чәй эчү ♦ **за ча́ем** *или* **за ча́шкой ча́я** чәй янында, бер чынаяк чәй эчкәндә; **на ~** (*давать*) чәйлек бирү; **пригласи́ть на ча́шку ча́я** бер чынаяк чәйгә чакыру

ча́йка *ж* акчарлак

ча́йная *ж* чайханә

ча́йник *м* чәйнек

ча́йница *ж* чәй савыты

ча́йн||ый, -ая, -ое чәй ...ы; **~ый лист** чәй яфрагы; **~ая планта́ция** чәй плантациясе; **~ая фа́брика** чәй фабрикасы; **~ая ча́шка** чәй чынаягы; **~ая ло́жка** бал кашыгы ♦ **~ая ро́за** *бот.* сары роза, чәй розасы

чайхана́ *ж* чәйханә

чал *м* аркан, чылбыр (*пристаньнарда коймәларне һ.б.ш. бәйләп кую өчен*)

ча́лить *несов. что* (*коймәне һ.б.ш.*) бәйләп кую (*аркан белән*)

чалма́ *ж* чалма

ча́лый, -ая, -ое (*о масти лошади*) бурлы

чан *м* чан, зур мичкә; **краси́льный ~** буяу чаны

чарда́ш, ча́рдаш *м* чардаш (*венгр биюе һәм шул көйгә язылган музыка*)

ча́рка *ж* чәркә

чарльсто́н *м* чарльстон (*кызу танец һәм музыка*)

чарова́ть *несов. прям., перен. кого-что* сихерләү, тылсымлау, әсир итү, хәйран калдыру, сокландыру; ~ **свои́м го́лосом** тавышы белән сихерләү

чароде́й *м прям., перен.* сихерче, тылсымчы, күрәзә, әфсенче

чароде́йка *ж прям., перен.* сихерче, тылсымчы, күрәзә (әфсенче) хатын (кыз)

чароде́йск||ий, -ая, -ое (*колдовской*) сихри, тылсымлы; **~ая си́ла** сихри көч

чароде́йство *с уст.* (*колдовство*) сихер, сихерчелек, әфсенчелек

ча́ры *только мн.* **1.** (*колдовство*) сихер, тылсым, әфсен **2.** *перен.* тылсым, сокландыру; ~ **любви́** мәхәббәт тылсымы

час *м* **1.** сәгать; **кото́рый ~?** сәгать ничә?; **в кото́ром ~ý?** ничә сәгәттә?; **до кото́рого ~а?** сәгать ничәнчегә кадәр? **сейча́с два ~á** хәзер сәгать ике; **в пе́рвом ~ý** сәгать беренчедә; **за ~ до полу́ночи** төн уртасына бер сәгать кала; **в тече́ние ~а** бер сәгать эчендә; **опозда́ть на ~** бер сәгәткә соңга калу **2.** вакыт, мизгел, сәгать; **вече́рние ~ы́** кичке вакыт; **~ы́ рабо́ты** эш сәгатьләре ♦ **в до́брый ~!** хәерле сәгәтлә!; **до э́того (до сего́) ~а** бу вакытка кадәр; **неровён ~** *вводн. сл.* әйтеп булмый, әллә нәрсә булмагае, белмәссең, нәрсә булыр; **неровён ~, опозда́ем** белмәссең, нәрсә булыр, соңга калабыз; **по ~а́м** сәгатьләп; **стоя́ть на ~а́х** каравылда тору; **с ~у на ~** менә-менә, тиз арада; **~ о́т ~у** сәгатьтән сәгәткә, сәгать саен; **~ о́т ~у не ле́гче** көннән көн авырая бара

часа́ми *нареч.* сәгатьләр буе, озак; **~ сиде́ть на берегу́** сәгатьләр буе ярда утыру

часо́вня *ж* кәшәнә, часовня

часов||о́й I, -а́я, -о́е **1.** бер сәгатьлек; **~а́я бесе́да** бер сәгатьлек әңгәмә **2.** *разг.* сәгать бердәге; **уе́хать ~ы́м по́ездом** сәгать бердәге поезд белән китү

часов||о́й II, -а́я, -о́е сәгать ...ы; **~а́я стре́лка** сәгать теле; **~о́й механи́зм** сәгать механизмы; **~о́й заво́д** сәгать заводы; **~о́й магази́н** сәгать кибете; **~а́я мастерска́я** сәгать остаханәсе; **~о́й ма́стер** *или* **~ы́х дел ма́стер** *см.* **часовщи́к**

часово́||й III *м* часовой, сакчы; **поста́вить ~го** часовой кую; **смени́ть ~ого** сакчыны алыштыру

часовщи́к *м* сәгатьче, сәгать остасы

ча́сом *нареч. разг.* **1.** (*иногда*) кайчак, кайвакыт, вакыт-вакыт, ара-тирә **2.** (*кстати*) ...дыр [бит], алай-болай; **ты, ~, не меня́ и́щешь?** син мине эзләмисеңдер бит?

часте́нько *нареч. разг.* еш кына, бик еш, әлдән-әле; **он ~ к нам захо́дит** ул безгә еш кына кергәли

части́ *м спец.* (*частый невод*) күзәнәкле җылым, ятьмә

части́ть *несов. разг.* ешлату, ашыгу, тизләтү

части́||ца *ж* **1.** кисәкчек, кисәкчә; бөртек; **мельча́йшая ~а** бик вак кисәкчә; **~ы пы́ли** тузан кисәкчекләре **2.** *перен.* бөртек, кисәк; өлеш; **в э́том нет и ~ы пра́вды** монда бөртек тә дөреслек юк **3.** *грам.* кисәкчә

части́чн||ый, -ая, -ое өлешчә, бераз, берникадәр; **~ая обрабо́тка сырья́** чималны өлешчә эшкәртү; **~ое улучше́ние** өлешчә яхшырту; **~ое возмеще́ние ущёрба** зыянны өлешчә кайтару

ча́стник *м* хосусыйчы (*хосусый эшмәкәр*)

частновладе́льческ||ий, -ая, -ое хосусый биләмәдәге, хосусый милекче ...ы; **~ие зе́мли** хосусый биләмәдәге җирләр; **~ое иму́щество** хосусый милекче мөлкәте

ча́стное *с мат.* бүленмә, өлеш

частнопрактику́ющий, -ая, -ее хосусый практика белән шөгыльләнүче; **~ врач** хосусый практика белән шөгыльләнүче табиб

частносо́бственническ||ий, -ая, -ое хосусый; хосусый милек ...ы; **~ие интере́сы** хосусый милек мәнфәгатьләре

ча́стност||ь *ж* **1.** (*единичность*) аерымлылык, хосусыйлык **2.** (*подробность, деталь*) вак-төяк, деталь; **обраща́ть внима́ние на ~и** вак-төякләргә игътибар итү ♦ **в ~и** *вводн. сл.* аерым алганда, атап әйткәндә, хосусан

ча́стн||ый, -ая, -ое **1.** (*единичный*) аерым, хосусый; **~ый слу́чай** аерым очрак **2.** (*личный*) шәхси; **~ая перепи́ска** шәхси язышу; **~ая жизнь** шәхси тормыш; **э́то его́ ~ое де́ло** бу аның шәхси эше; **~ое лицо́** шәхси кеше **3.** хосусый; **~ая собственность** хосусый милек; **~ая торго́вля** хосусый сәүдә ♦ **~ое определе́ние** *юр.* аерым билгеләмә

частоко́л *м* казык читән, утыртма читән (койма)

частота́ *ж спец.* ешлык; **сравни́тельная табли́ца часто́т** ешлыкларның чагыштырма таблицасы; **~ колеба́ний ма́ятника** маятникның тибрәнүләр ешлыгы

часто́тн||ый, -ая, -ое *спец.* ешлык ...ы; **~ые измене́ния** ешлык үзгәрешләре

часту́шка *ж* такмак

ча́ст||ый, -ая, -ое **1.** еш, куе; **~ый гре́бень** еш тешле тарак; **~ая и́згородь** еш читән; **~ое си́то** еш күзле иләк; **~ые зу́бы** еш тешләр; **~ый лес** куе урман **2.** тоташ; **~ый дождь** тоташ яңгыр **3.** еш, еш-еш; **~ый пульс** еш пульс; **~ый шаг** еш адым; **~ый пулемётный ого́нь** пулемёттан еш-еш ату **4.** әлдән-әле, гел, еш; **~ые встре́чи** әлдән-әле очрашулар; **~ый гость** еш килүче кунак **5.** янәшә; **~ые звёзды** янәшә йолдызлар

част||ь *ж* **1.** өлеш, бер өлеш, кисәк; **~ь це́лого** бөтеннең бер өлеше; **~ь зда́ния** бинаның бер өлеше; **одна́ пя́тая ~ь** биштән бер өлеш; **рвать на ~и** *прям., перен.* кисәкләргә өзү **2.** часть, әгъза; **~и маши́ны** машина частьләре; **запасны́е ~и** запас частьлар; **~и те́ла** тән әгъзалары **3.** бүлек, кисәк; **рома́н в трёх ~я́х** өч кисәктән торган роман **4.** бүлек; **санита́рная ~ь** санитария бүлеге; **учёбная ~ь** укыту бүлеге **5.** вазифа, эш, өлкә; **он рабо́тает по фина́нсовой ~и** ул финанс өлкәсендә эшли; **э́то не по мое́й ~и** бу минем вазифама кагылмый **6.** *воен.* часть; **пехо́тные ~и** пехота частьләре ♦ **по ~и** *предлог с род.*п. ...дан, өлкәсендә; **он знато́к по э́той ~и** ул бу өлкәдә белгеч; **~и ре́чи** *грам.* сүз төркемнәре; **~и све́та** дөнья кисәкләре

частью *нареч.* өлешчә; **~ он сам де́лал, ~ помога́ли** өлешчә ул үзе эшләде, өлешчә ярдәм иттеләр

час||ы́ *только мн.* сәгать; **ручны́е ~ы́** кул сәгате; **стенны́е ~ы́** стена сәгате; **песо́чные ~ы́** ком сәгате; **со́лнечные ~ы́** кояш сәгате; **бой ~о́в** сәгать сугу; **~ы́ спеша́т** сәгать алга китә; **~ы́ отстаю́т** сәгать артка кала

ча́хлость *ж* **1.** (*о растительности*) сулганлык, шиңгәнлек, корыганлык, кипкәнлек **2.** (*хилость*) ябыклык, зәгыйфьлек, чирләшкәлек

ча́хл||ый, -ая, -ое **1.** сулган, шиңгән, корыган, кипкән; **~ое расте́ние** сулган үсемлек **2.** ябык, зәгыйфь, чирләшкә; **~ый ребёнок** чирләшкә бала

ча́хн||уть *несов.* **1.** сулу, кору, кибү; **цветы́ ~ут** чәчәкләр сула **2.** ябыгу, зәгыйфьләнү, чиргә сабышу, кибү; **~уть от тоски́** сагыштан кибү

чахо́тка *ж уст.* чахотка, үпкә авыруы

чахо́точный, -ая, -ое *уст.* чахотка ...ы; **~ ка́шель** чахотка ютәле

ча́ша *ж* **1.** касә, тустаган; **~ вина́** бер касә шәраб **2.** тәлинкә; **~ весо́в** үлчәү тәлинкәсе ♦ **дом — по́лная ~** өй — ашсулы; **~ терпе́ния перепо́лнилась** сабыры төкәнде, сабыр касәсе тулып ашты; **пить горькую ~у** ачы кайгы кичерү

чашели́стик *м бот.* касә яфракчыгы

ча́шечка *ж* **1.** *уменьш. от* **ча́шка; 2.** *бот.* касә

ча́шечн||ый, -ая, -ое: **~ые весы́** тәлинкәле үлчәү

ча́шка *ж* **1.** чынаяк, йомыры; **кофе́йная ~** кофе чынаягы **2.** *прост.* (*миска*) касә **3.** *см.* **ча́ша** 2

ча́ща *ж* куе урман, чытырман, куелык

чащо́ба *ж разг. см.* **ча́ща**

ча́яни||е *с* өмет, ният, ышаныч; **~я наро́да** халык өметләре ♦ **па́че ~я** көтмәгәндә, өмет итмәгәндә

ча́ять *несов. уст.*: **душо́й не ~** *в ком-л. кемне дә булса* өзелеп ярату

чва́ниться *несов.* һавалану, мактану, масаю, тәкәбберләнү, кәперәю

чванли́вость *ж* һавалылык, мактанучанлык, масаючанлык, тәкәбберлек, кәперәючәнлек

чванли́вый, -ая, -ое һавалы, һаваланучан, мактанучан, мактанчык, масаючан, тәкәббер

чва́нный, -ая, -ое һавалы, мактанчык, тәкәббер

чва́нство *с* һавалану, мактану, мактанчыклык, масаю, мин-минлек, тәкәбберлек

чей, чья, чьё *мест.* **1.** *вопр.* кем; **~ э́то конь?** бу кем аты?; **э́то ~ парни́шка?** бу кем малае? **2.** *относ.* ...ган; **сча́стлив человек, чья жизнь посвящена́ Ро́дине** гомерен Ватанга багышлаган кеше бәхетле ♦ **~ бы то ни́ был** кемнеке булса булсын; **чья взяла́?** кем алдырды?, кем жинде?

че́й-либо, че́й-нибудь *мест.* кем булса да, кем дә булса, кемдер булса да

че́й-то *мест.* кемдер

чек *м* чек; **вы́писать ~** чек язу

чека́ *ж тех.* чикә (*у колеса*) чигә чөй, чәкүшкә

Чека́ *ж нескл.* Чека (*1918-1922 елларда контрреволюция һәм саботаж белән көрәшү өчен булган гадәттән тыш комиссия*)

чека́н *м* **1.** (*штамп*) штемпель **2.** (*оттиск*) нәкышь, бизәк **3.** (*инструмент*) чүкү коралы, чекан

чека́нить *несов. что* **1.** сугу, бизәк төшерү; **~ моне́ту** акча сугу **2.** *перен.* ачык әйтү, ярып салу; нык басып атлау; **~ слова́** сүзләрне ярып салу; **~ шаг** нык басып атлау

чека́нк||а *ж* **1.** *см.* **чека́нить; 2.** (*рисунок, изображение*) бизәк, нәкыш ыр; **ружьё с ~ой** бизәкле мылтык

чека́нность *ж* чарланганлык, ачыклык, төгәллелек; **~ сти́ля** стильнең чарланганлыгы

чека́нн||ый, -ая, -ое **1.** бизәк (нәкышь) төшерү ...ы, сугу ...ы; **~ый стано́к** бизәк төшерү станогы **2.** чүкеп бизәлгән, чүкеп бизәк төшерелгән; **~ые пистоле́ты** чүкеп бизәлгән пистолетлар **3.** *перен.* чарланган, ачык; төгәл; **~ый стих** чарланган шигырь; **~ый шаг** нык басып атлау

чека́ночный, -ая, -ое бизәк (нәкышь) төшерү ...ы, сугу ...ы; **~ пресс** бизәк төшерү прессы

чека́нщик *м* акча сугучы; бизәк төшерүче, нәкышь ясаучы

чеки́ст *м* чекист (*Чека хәзмәткәре*)

чекме́нь *м* чикмән

че́ков||ый, -ая, -ое чек ...ы; **~ая кни́жка** чек кенәгәсе; **~ые опера́ции** чек операцияләре

чёлка *ж* **1.** (*у лошади*) маңгай ялы **2.** (*у человека*) маңгай чәче

чёлн *м* каек, көймә

челно́к *м* **1.** *см.* **чёлн; 2.** (*в ткацком станке, швейной машине*) соса

челно́чн||ый, -ая, -ое **1.** каек ...ы, көймә ...ы; **~ые приспособле́ния** каек җайланмалары **2.** соса ...ы; **~ая коро́бка** соса тартмасы; **~ая шпу́лька** соса шүресе

чело́ *с высок.* маңгай ♦ **бить ~м** 1) *уст.* баш ору, баш иеп сәламләү; 2) *перен.* үтенү, сорау

челове́к *м* **1.** кеше, адәм, инсан; **до́брый ~** игелекле кеше; **че́стный ~** намуслы кеше **2.** (*личность*) шәхес, кеше; **помо́чь стать ~ом** кеше булырга ярдәм итү **3.** (*кто-то, некто*) берәү, бер кеше, бер адәм; **вас ~ спра́шивает** сезне бер кеше сорый **4.** *уст.* (*слуга, крепостной*) хезмәтче, ялчы ♦ **молодо́й ~** (*при обращении*) энекәш, туганкай

челове́ко-день *м эк.* кеше-көн (*бер кешенең эш көне*)

человеколюби́вый, -ая, -ое кеше сөючән (яратучан), кешелекле

человеколю́бие *с* кеше сөючәнлек (яратучанлык), кешелеклелек; **прояви́ть ~** кешелеклелек күрсәтү

человеконенави́стник *м* кеше сөймәүче (күрә алмаучы)

человеконенави́стническ||ий, -ая, -ое кешеләрне сөймәү ...ы, кешеләрне күрә алмау ...ы; кешелекне сөймәү ...ы, кешелекне күрә алмау ...ы; **~ая поли́тика** кешеләрне күрә алмау сәясәте

человеконенави́стничество *с* кешеләрне сөймәү (күрә алмау), кешелекне сөймәү (күрә алмау)

человекообра́зн||ый, -ая, -ое кешегә охшаш, кешесыман; **~ая обезья́на** кешесыман маймыл

человекоподо́бн||ый, -ая, -ое кешегә охшаган; **~ое су́щество** кешегә охшаган зат

челове́ческ||ий, -ая, -ое **1.** кеше ...ы, адәм ...ы; кешелек ...ы; **~ий труд** кеше хәзмәте; **~ое о́бщество** кешелек җәмгыяте **2.** *см.* **челове́чный**; **~ое отноше́ние** кешелекле мөнәсәбәт

челове́чество *с* кешелек, инсаният; **исто́рия ~а** кешелек тарихы

челове́ч||ный, -ья, -ье *разг.* кеше ...ы, инсан ...ы; **~ьи голоса́** кеше тавышлары

челове́чность *ж* кешелеклелек

челове́чн||ый, -ая, -ое кешелекле, кешечә ...; **~ое отноше́ние** кешелекле мөнәсәбәт

челюстн||о́й, -а́я, -о́е казналык ...ы, теш казнасы ...ы; **~а́я кость** казналык сөяге; **~а́я опера́ция** теш казнасы операциясе

че́люсть *ж* **1.** казналык, теш казнасы; **ни́жняя ~** аскы теш казнасы; **ве́рхняя ~** өске теш казнасы **2.** (*зубной протез*) ясалма тешләр; теш протезы; **вста́вить ~** теш протезы кую

чем *союз* **1.** *сравн.* ...га караганда; **э́та ко́мната лу́чше, ~ ва́ша** бу бүлмә сезнекенә караганда яхшырак; **в э́том году́ добы́то не́фти бо́льше, ~ в про́шлом** быел нефть былтыргыга караганда күбрәк чыгарылды **2.** *сравн. с нареч. «лучше», «скорее»* ...ганчы, ...га караганда; **~ торопи́ться, лу́чше вы́йдем пора́ньше** ашыкканчы иртәрәк чыгыйбыз яхшырак **3.** *сравн.* (*чем ..., тем ...*) никадәр ..., күпме, ...ган саен; **~ вы́ше подними́лись в го́ры, тем станови́лось холодне́е** тауга күтәрелгән саен, салкыная барды **4.** (*вместо того, чтобы*) ...га караганда, ...ганчы; **~ осужда́ть друго́го, лу́чше на себя́ посмотри́** башкаларны тикшергәнче үзеңә кара

чемери́ца *ж бот.* аксыргак

чемода́н *м* чемодан; **сложи́ть ве́щи в ~** әйберләрне чемоданга салу

чемода́нн||ый, -ая, -ое чемодан ...ы ◆ **~ое настрое́ние** күңелле юлда

чемпио́н *м* чемпион; **~ ми́ра** дөнья чемпионы; **~ по ша́хматам** шахмат буенча чемпион

чемпиона́т *м* чемпионат, ярыш; **ша́хматный ~** шахмат чемпионаты

чемпио́нка *ж* чемпионка

чемпио́нск||ий, -ая, -ое чемпион ...ы; **~ое зва́ние** чемпион исеме

чемпио́нство *с* чемпионлык; **завоева́ть ~** чемпионлык яулап алу

чепух||а́ *ж* **1.** (*вздор, чушь*) буш сүз, юк-бар сүз, сафсата, ләчтит; **нести́ ~у́** юк-бар сүз сөйләү **2.** (*пустяк*) юк нәрсә; **бо́льно бы́ло? — Чепуха́!** авыртмадымы? — Юк нәрсә!

чепухо́в||ый, -ая, -ое **1.** буш, юк-бар; мәгънәсез; **~ый расска́з** буш хикәя **2.** вак-төяк, вак кына, юк кына, кечкенә генә, бәләкәй генә; **~ая цара́пина** юк кына тырналу

че́рва *ж собир. пчел.* чага, ак корт

червеобра́зн||ый, -ая, -ое **1.** суалчансыман; **~ый отро́сток** суалчансыман үсенте **2.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн. зоол.* суалчансыманнар

че́рви *мн. карт.* черви

черви́веть *несов.* кортлау

черви́в||ый, -ая, -ое кортлы, кортлаган; **~ое я́блоко** кортлы алма

черво́вый, -ая, -ое *карт.* черви ...ы; **~ туз** черви тузы

черво́нец *м* червонец, унлык, ун сумлык

черво́нн||ый, -ая, -ое: **~ое зо́лото** кызылсу алтын

червото́чин||а 1. корт тишеге, корт юлы; **~а в я́блоке** алмадагы корт тишеге **2.** (*повреждение, напр. червями*) кортлы, кортлаган **3.** *перен.* кортлы, бозык; **челове́к с ~ой** бозык кеше

че́рвы *см.* **че́рви**

червь *м* суалчан, корт; **дождево́й ~** яңгыр суалчаны; **шелкови́чный ~** ефәк корты ◆ **~ сомне́ния** шикләнү корты, шикләнү төене

черва́к *м* **1.** *см.* **червь; 2.** *тех.* винтлы тапшыргыч

черва́чн||ый, -ая, -ое *тех.* винтлы тапшыргыч ...ы; **~ое колесо́** винтлы тапшыргыч көпчәге

червяч||о́к *м уменьш.-ласк от* **черва́к ◆ замори́ть ~ка́** тамак ялгап алу

черда́к *м* чарлак, чорма

черда́чн||ый, -ая, -ое чарлак ...ы, чорма ...ы; **~ое окно́** чорма тәрәзәсе

черёд *м разг.* чират, тәртип, нәүбәт ◆ **идти́ (пойти́) свои́м чередо́м** үз тәртибендә бару, гадәттәгечә бару, үз нәүбәтендә бару

чередá I *ж* **1.** *уст. см.* **черёд; 2.** чиратлашу; **~ дней** көннәрнең чиратлашуы ◆ **всему́ прихо́дит свои́ ~** һәр нәрсәнең үз вакыты җитә

чередá II *ж бот.* эт тигәнәге

чередова́ние *с см.* **чередова́ть, чередова́ться; ~ зву́ков** *лингв.* авазларның чиратлашуы

чередова́ть *несов. кого-что с кем-чем* чиратлаштыру, нәүбәтләштерү, аралаштыру; **~ труд с развле́чениями** хезмәтне күңел ачулар белән чиратлаштыру

чередова́ться *несов.* **1.** аралашу, чиратлашу, нәүбәтләшү, аралашып (чиратлашып) тору **2.** *страд. от* **чередова́ть**

чере́з *предлог с вин.п.* **1.** (*поперёк чего-л.*) аша, аркылы; **мост ~ ре́ку** елга аша күпер; **перепры́гнуть ~ ручёй** инеш аша сикерү; **реме́нь ~ плечо́** иң аркылы каеш **2.** (*сквозь что-л.*) аша; **exа́ть ~ го́род** шәһәр аша бару; **влезть ~ окно́** тәрәзә аша керү **3.** (*поверх. чего-л.*) аркылы, аша; **прыгнуть ~ забо́р** койма аркылы сикерү **4.** (*при помощи кого-чего-л.*) аша, ярдәмендә; **оповести́ть ~ газе́ту** газета аша белдерү; **писа́ть сло́во ~ чёрточку** сүзне сызыкча аша язу; **бесе́да шла ~ перево́дчика** әңгәмә тәрҗемәче ярдәмендә барды **5.** (*спустя какое-л. время, минуя пространство*) ...дан, ...дан соң; **приду́ ~ час** бер сәгатьтән килермен; **~ две страни́цы** ике биттән соң **6.** (*повторяя какие-л. промежутки времени, пространства*) саен, аралаш; **~ час по столо́вой ло́жке** сәгать саен бер аш кашыгы (*дару эчү*); **печа́тать ~ два интерва́ла** ике интервал аралаш басу

черми́сы *мн. уст.* чирмешләр (*мариларның элекке исеме*)

черёмуха *ж* шомырт

черёмуховый, -ая, -ое шомырт ...ы, шомырт ...; **~ за́пах** шомырт исе

черемша́ *ж бот.* кыр сарымсагы

черенкова́ть *несов. что, сад.* чыбыкча ялгау

черенко́в||ый, -ая, -ое **1.** сап ...ы; **~ая часть ножа́** пычакның сап өлеше **2.** *сад.* чыбыкча ялгап үстерелгән

черено́к *м* **1.** сап; **~ ножа́** пәке сабы **2.** *разг. см.* **черешо́к; 3.** чыбыкча, ботак

че́реп *м* баш сөяге

черепа́х||а *ж* **1.** ташбака; **идти́ как ~а** ташбака кебек бару **2.** *собир.* ташбака кабыгы; **изде́лия из ~и** ташбака кабыгы әйберләре

черепа́ховый, -ая, -ое **1.** ташбака ...ы; **~ суп** ташбака шулпасы **2.** ташбака кабыгыннан эшләнгән; **~ гре́бень** ташбака кабыгыннан эшләнгән тарак

черепа́ший, -ья, -ье *прям., перен.* ташбака ...ы; **~ па́нцырь** ташбака кабыгы; **~ шаг** ташбака адымы

черепи́ца *ж собир.* чирәп

черепи́чн||ый, -ая, -ое чирәп ...ы; чирәп ...; **~ый заво́д** чирәп заводы; **~ая кры́ша** чирәп түбә

черепн||о́й, -а́я, -о́е баш [сөяге] ...ы; **~ые ко́сти** баш сөякләре; **~а́я коро́бка** *анат.* баш сөяге тартмасы

черепо́к *м* ватык, чүлмәк ватыгы (*чүлмәкнең, савыт-сабаның*)

чересполо́сица *ж* басу ашалык, җир ашалык

чересседе́льник *м* аркалык

чересчу́р *нареч.* артык, гаять, ифрат, чамадан (чиктән) тыш; **~ горя́чий суп** гаять кайнар аш; **он ~ много говори́л** ул чамадан тыш күп сөйләде; **э́то уж ~!** бу инде чиктән тыш!

чере́шнев||ый, -ая, -ое төче чия ...ы; **~ое варе́нье** төче чия вареньесы

чере́шня *ж* **1.** (*плод*) төче чия **2.** (*дерево*) төче чия агачы

черешо́к *м* (*листа*) сабак

черка́ть, чёркать *несов. что и без доп.* **1.** *см.* **черкну́ть** 1; **2.** *разг.* (*зачёркивать*) сызып ташлау, бозу

черке́с *м* черкас, черкас кешесе

черке́ска *ж* якасыз җилән, черкас җөббәсе

черке́сский, -ая, -ое черкас[лар] ...ы; **~ язы́к** черкас теле

черке́сы *мн.* черкаслар, черкас халкы

черке́шенка *ж* черкас хатыны (кызы)

черкну́ть *сов. что, разг.* **1.** сызу, сызып алу **2.** язып алу, язып ташлау; **~ письмо́** хат язып ташлау

черне́ть *несов.* **1.** (*становиться чёрным*) каралу, караю **2.** (*виднеться — о чём-л. чёрном*) каралып (караеп) күренү, каралып тору

черне́ться *несов. см.* **черне́ть** 2

черни́ка *ж* каражиләк

черни́ла *только мн.* кара, язу карасы; **чёрные ~** кара кара; **кра́сные ~** кызыл кара

черни́льница *ж* кара савыты

черни́льн||ый, -ая, -ое кара ...ы; **~ое пятно́** кара табы

черни́ть *несов.* **1.** *что* каралту, карага буялу; **~ бро́ви** кашны каралту **2.** *перен. кого-что* каралау, пычрату, кара ягу; **~ свои́х пре́жних друзе́й** элекке дусларыңа кара ягу

черни́чник *м* карагжиләклек, карагжиләк куаклыгы

черни́чн||ый, -ая, -ое карагжиләк ...ы; **~ый куст** карагжиләк куагы; **~ое варе́нье** карагжиләк вареньесе

чернобо́родый, -ая, -ое кара сакаллы

чернобро́вый, -ая, -ое кара кашлы

чернобу́рк||а *ж разг.* кара көрән төлке мехы; **пальто́ с ~ой** кара көрән төлке якалы пальто

черно-бу́р||ый, -ая, -ое кара көрән; **~ая лиси́ца** кара көрән төлке

чернобы́льник *м бот.* кара әрем

черновы́к *м* каралама

чернов||о́й, -а́я, -о́е **1.** каралама ...; **~а́я тетра́дь** каралама дәфтәр **2.** *разг.* (*вспомогательный*) кара, ярдәмче, **де́лать ~у́ю рабо́ту** кара эш эшләү

черноволо́сый, -ая, -ое кара чәчле

черногла́зый, -ая, -ое кара күзле

чернозём *м* кара туфрак

чернозёмн||ый, -ая, -ое кара туфраклы; **~ая о́бласть** кара туфраклы өлкә; **~ая по́чва** кара туфрак

чернока́жий, -ая, -ее кара тәнле

черноле́сье *с* карурман, яфраклы урман

чернома́зый, -ая, -ое *прост.* **1.** (*смуглый*) кара, кара тутлы **2.** (*грязный*) кара, пычрак

черномо́рец *м* Кара диңгезче, Кара диңгез флоты диңгезчесе

черномо́рск||ий, -ая, -ое Кара диңгез ...ы; **~ое побере́жье** Кара диңгез буе

чернораба́чая *ж* кара эшче хатын (кыз)

чернораба́чий *м* кара эшче

черносли́в *м собир.* каражимеш

черносли́вовый, -ая, -ое каражимеш ...ы; **~ сок** каражимеш суы

черносо́тенец *м ист.* карагруһ, карагруһчы

черносо́тенн||ый, -ая, -ое *ист.* карагруһ ...ы карагруһчы[лар] ...ы; **~ые организа́ции** карагруһ оешмалары

чернота́ *ж* **1.** каралык, кара; **~ воло́с** чәч каралыгы **2.** (*тьма*) караңгылык

чернота́л *м бот.* кара тирәк, кара тал

черну́шка *ж* **1.** (*гриб*) кара гөмбә **2.** (*растение*) күкчәчәк **3.** (*птица*) кара уткойрык

чёрн||ый, -ая, -ое **1.** кара; **~ая кра́ска** кара буяу; **~ое пла́тье** кара күлмәк; **~ый дым** кара төтен **2.** *разг.* (*грязный*) пычрак, керле **3.** *перен.* авыр, кайгылы, кара, караңгы; **~ые дни** авыр көннәр; **~ые мы́сли** кара уйлар; **ви́деть всё в ~ом све́те** барысын да кара төстә күрү **4.** (*неквалифицированный и физически тяжёлый*) кара; **~ая рабо́та** кара эш **5.** *перен.* (*злостный, коварный*) кара, мәкерле, усал; **~ые си́лы реа́кции** реакциянең кара көчләре **6.** арт, арткы; ярдәмче; **~ый ход** арткы ишек; **~ая ле́стница** ярдәмче баскыч **7.** *в знач. сущ.* **~ые** *мн.* каралар (*шашка, шахмат фигуралары турында*); **ходи́ть ~ыми** каралар белән йөрү ♦ **на ~ый день** кара көнгә; **~ая ба́ня** кара мунча; **~ая би́ржа** кара биржа, яшерен сәүдә; **~ая ко́шка пробежа́ла** *между кем* араларыннан кара мәче узган (*ара бозылды*); **~ые спи́ски** кара исемлекләр; **~ый ры́нок** кара базар, яшерен базар; **~ыми слова́ми руга́ть (брани́ть)** «шайтан» дип тиргәү; сүгенү

чернь *ж* **1.** (*гравировка на металле*) каралтылган көмеш; **табаке́рка с ~ю** каралтылган көмешле тәмәке савыты **2.** (*краска*) кара буяу **3.** *уст.* (*простонародье*) кара халык

черпа́к *м* чүмеч, соскыч

черпа́лка *ж* чүмеч, соскыч

черпа́льн||ый, -ая, -ое соскыч ..., чумырып алучы, сосып (чумырып) ала торган; **~ая маши́на** соскыч машина

черпа́ть *несов. что* **1.** чумыру, чумырып алу; **~ во́ду** су чумырып алу **2.** *перен.* алу; **~ зна́ния** белем алу

черстве́||ть *несов.* **1.** кату, искерү, кибү; **хлеб ~ет** ипи ката **2.** *перен.* каты күңеллеләнү, рәхимсезләнү, кансызлану

чёрствость *ж* **1.** катылык, искергәнлек, кипкәнлек **2.** *перен.* катылык, каты күңеллелек, рәхимсезлек, кансызлык, туңлык

чёрств||ый, -ая, -ое **1.** каткан, искергән, кипкән; **~ый хлеб** искергән ипи **2.** *перен.* каты, каты күңелле, рәхимсез, кансыз, туң; **~ая душа́** туң йөрәк; **~ый челове́к** каты күңелле кеше

чёрт *м* шайтан, җен ♦ **до ~а** 1) (*очень много*) чиксез күп, ифрат күп; 2) бик нык; ≈ эт кебек; **я уста́л до ~а** мин эт кебек арыдым; **к ~у на рога́ (на кули́чики)** җәһәннәмгә, җәһәннәм тишегенә; **на кой ~** ни пычагыма, ни шайтаныма; **ни к ~у не годи́ться** шайтаныма да ярамый; **ни черта́ нет** шайтаным да юк, берни да юк; **посла́ть к ~у** *или* **ко всем чертя́м** чәнчелеп китсен; **~ возьми́!** шайтан алгыры!; **~ подери́ (поберй́)!** шайтан алгыры!; **чем ~ не шу́тит** белмәссең, белеп булмый; **что за ~!** бу нинди шайтан бу!; **~а с два** ... гына тор әле; **~а с два сдви́нешь э́тот ка́мень!** кузгатмый гына тор әле бу ташны!; **~ его́ зна́ет** шайтан белсен аны; **~ зна́ет что!** *или* **~ -те что!** нәрсә икәнен шайтан белсен!; **~ -те где (куда́, отку́да, когда́)** шайтан белсен кайда (кая, кайдан, кайчан); **~ но́гу сло́мит** шайтан аягын сындырыр, башың белән кереп батырсын

черт||а́ *ж* **1.** сызык; **волни́стая ~а́** дулкынлы сызык; **провести́ ~у́** сызык сызу **2.** (*граница, предел*) сызык, чик, эч; **в ~е́ го́рода** шәһәр эчендә **3.** *перен.* сыйфат, үзенчәлек; холык; **~ы́ хара́ктера** характер үзенчәлекләре; **~ы́ но́вого челове́ка** яңа кеше сыйфатлары; **отличи́тельная ~а́** аерым үзенчәлек **4.** *обычно мн.* **~ы́** *перен.* кыяфәт; **краси́вые ~ы́ лица́** матур кыяфәтле йөз ♦ **в о́бщих ~а́х** гомумән, вак-төгенә тукталмыйча; **подвести́ ~у́** *под чем* берәр нәрсәгә йомгак ясау

чертёж *м* сызым; **~ зда́ния** бина сызымы

чертёжник *м* сызым сызучы, чертёжник

чертёжница *ж* сызым сызучы хатын (кыз), чертёжница

чертёжн||ый, -ая, -ое **1.** сызым ...ы; **~ая доска́** сызым тактасы **2.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж* сызым бүлмәсе

чертёнок *м* **1.** (*дьяволёнок*) шайтан баласы, җен баласы; пәри баласы **2.** (*о шалуне, озорнике*) шайтан, җен, пәри

черти́ть *несов. что и без доп.* сызу; **~ план** план сызу

чёртов: ~а дю́жина шайтан дүжинасы (*13зле сан турында*); **к ~ой ба́бушке** чәнчелеп киткере

черто́вски *нареч. разг.* гаять, гаять дәрәҗәдә, бик, бик нык; **~ далеко́** бик ерак; **я ~ уста́л** мин гаять арыдым

черто́вск||ий, -ая, -ое **1.** иблис ...ы, шайтан ...ы, җен ...ы; **~ие наважде́ния** иблис вәсвәсәләре **2.** *разг.* яман, бик әшәке, ләгънәт төшкән; **~ий хо́лод** бик әшәке салкын

чертовщи́на *ж разг.* буталчыклык, аңлашылмау; *что* **за ~ здесь твори́тся?** монда нинди буталчылык хөкем сөрә?

чертополо́х *м бот.* шайтан таягы (*үсемлек*)

чёрточка *ж* **1.** *уменьш. от* **черта́** 1, 3, 4; **2.** (*дефис*) сызыкча

чертыха́ться *несов.* «тфү, шайтан» дип сүгенү, каһәрләп сүгенү

черче́ни||е *с* **1.** *см.* **черти́ть**; **2.** сызым; **уро́ки ~я** сызым дәресләре

чеса́лка *ж* тарагыч, тәрәшле тарак

чеса́льн||ый, -ая, -ое тарагыч ..., тарау ...ы; **~ая маши́на** тарау машинасы

чеса́льщик *м* тараучы; тәрәшләүче

чеса́ние *с см.* **чеса́ть**; **~ льна** житен тәрәшләү

чёсанный, -ая, -ое таралган, тәрәшләнгән; **~ лён** тәрәшләнгән җитен

чеса́ть *несов.* **1.** *что* кашу; **~ру́ку** кулны кашу **2.** *кого-что, разг.* тарау; **~ во́лосы** чәчне тарау **3.** *что* тәрәшләү; **~ лён** җитен тәрәшләү ♦ **~ заты́лок (в заты́лке)** баш кашу (*авыр эш алдында аптырап калу*); **~ язы́к (языко́м)** ләчтит сату, юк-барны сөйләү

чеса́ться *несов.* **1.** кашыну **2.** (*об ощущении зуда*) кычыту, кымыршу; **спина́ че́шется** арка кычыта

чесно́к *м* сарымсак

чесно́чн||ый, -ая, -ое **1.** сарымсак ...ы; **~ый за́пах** сарымсак исе **2.** сарымсаклы; **~ая колбаса́** сарымсаклы колбаса

че́стн||ый, -ая, -ое **1.** намуслы, гадел, хәләл, тугры; **~ый челове́к** намуслы кеше; **~ое наме́рение** гадел ният; **~ый за́работок** хәләл эш хакы **2.** намуслы, гыйффәтле, саф; **~ое и́мя** саф исем ♦ **~ое сло́во** билләһи, валлаһи, ихластыр; **дать ~ое сло́во** валлаһи дип сүз бирү; **на ~ом сло́ве [держа́ться]** чакчак эләгеп тору, көчкә эләгеп тору

честолю́бец *м* шөһрәт яратучы, дәрәҗә яратучы, дан яратучы

честолюби́вый, -ая, -ое шөһрәт яратучы ..., дан яратучы ..., дәрәҗә яратучы ...; ~ **челове́к** шөһрәт яратучы кеше

честолю́бие *с* шөһрәт (дан) яратучанлык, дәрәҗә яратучанлык

чест||ь *ж* **1.** намус; **де́ло ~и** намус эше; **заде́ть** *чью-л.* **~ь** *кемнеңдер* намусына кагылу **2.** (*целомудрие, девственность*) гыйффәтлелек, сафлык **3.** (*почёт, уважение*) хөрмәт, шәрәф, кадер; **~ь и сла́ва геро́ям!** каһарманнарга хөрмәт һәм дан ♦ **в ~ь** *кого-чего кемнең, нәрсәнең дә булса* хөрмәтенә; **вы́йти с ~ью** *из чего бераз нәрсәдән* намус белән чыгу; **де́лать ~ь** *кому-чему кемнеңдер, нәрсәнеңдер* бәясен күтәрү, дәрәҗәсен тагын да күтәрү, ихтирам тудыру; **к ~и** *кого, чьей* аның яхшы ягы шунда; **отдава́ть ~ь** 1) *воен.* честь бирү; 2) *шутл.* игътибар итү, хөрмәт күрсәтү (*бераз нәрсәгә*); **пора́ (надо́) и ~ь знать** житкән, чамасын белергә кирәк; **по ~и сказа́ть** турыдан-туры әйткәндә, ачыктан-ачык әйткәндә; **с ~ью** (*сделать что-л.*) *бераз нәрсәне* намус белән үтәү; **~ью проси́ть** яхшылык белән сорау, яхшылык белән үтенү; **~ь ~ью** *или* **~ь по ~и** яхшылап

чесуча́ *ж* чесуча (*тукыма*)

чесуча́вый, -ая, -ое чесуча ..., чесучадан тегелгән; ~ **костю́м** чесучадан тегелгән костюм

чёт *м* җәп, җәп сан

чета́ *ж* иш, тиң, пар; **супру́жеская ~** ирле-хатынлы; **счастли́вая ~** бәхетле пар ♦ **не ~** *кому-чему кемгә, нәрсәгә* тиң түгел

четве́рг *м* пәнҗешәмбе, атнакич ♦ **по́сле до́ждичка в ~** кызыл кар яугач

четвере́ньк||и *только мн.*: **стать на ~и** дүрт аяклану; **ходи́ть на ~ах** мүкәләп йөрү, дүрт аякланып йөрү; **стоя́ть на ~ах** дүрт аякта тору

четвёрка *ж* **1.** (*цифра*; *группа*) дүрт **2.** (*отметка*) дүртле, дүртле билгесе **3.** (*напр. трамвай, автобус*) дүртенче **4.** (*лошадей*) дүрт ат **5.** (*лодка*) дүрт ишкәкле көймә

четвертн||о́й, -а́я, -о́е дүртләтелгән, дүртләтә артык, дүрт тапкыр артык; **в ~о́м разме́ре** дүртләтә артык күләмдә

че́тверо *числ. собир.* дүртәү, дүрт; **~ о бра́тьев** дүрт туган; **~ о су́ток** дүрт тәүлек; **нас ~ о** без дүртәү; **дели́ть на ~ы́х** дүрткә бүлү

четвероклáссник *м* дүртенче сыйныф (класс) укучысы

четвероклáссница *ж* дүртенче сыйныфта (класста) укучы кыз

четвероку́рсник *м* дүртенче курста укучы

четвероку́рсница *ж* дүртенче курста укучы кыз

четверонóг||ий, -ая, -ое дүрт аяклы; **~ое живо́тное** дүрт аяклы хайван

четверости́шье *с лит.* дүрт юллык шигырь

четверти́нка *ж прост.* чәкүшкә, бер чәкүшкә аракы

четверти́чный, -ая, -ое *геол.* дүртенчел; ~ **пери́од** дүртенчел чор

четвертн||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*являющийся четвертью чего-л.*) дүрттән бер ..., чирек ... **2.** чирек ...ы; **~ы́е оце́нки** чирек билгеләре

четвертова́ние *с см.* **четвертова́ть**

четвертова́ть *сов., несов. кого-что* ботарлап үтерү, дүрткә ботарлау (*борынгы җәза исулы*)

четвёрт||ый, -ая, -ое **1.** *числ.* дүртенче; **~ый эта́ж** дүртенче кат; **в ~ый раз** дүртенче тапкыр **2.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж* дүрттән бер, чирек

че́тверт||ь *ж* **1.** чирек, дүрттән бер; **~ь ча́са** чирек сәгать; **~ь го́да** чирек ел; **~ь я́блока** алманың дүртән бере; **без ~и двена́дцать** уникә туларга чирек сәгать **2.** (*часть учебного года*) чирек; **втора́я ~ь** икенче чирек; **отме́тки за ~ь** чирек билгеләре

четвертьфина́л *м спорт.* чирек финал

четвертьфина́льн||ый, -ая, -ое чирек финал ...ы; **~ые соревнова́ния** чирек финал ярышлары

чётки *только мн.* тәсбих, дисбе

чётк||ий, -ая, -ое **1.** ачык, аныкк, төгәл; **~ие движе́ния** төгәл хәрәкәтләр; **~ий по́черк** ачык язу; **~ий рису́нок** ачык рәсем **2.** *перен.* ачык, ачык аңлаешлы; **~ая формулиро́вка** аныкк тәгъбир **3.** *перен.* пөхтә, төгәл, жиренә житкерелгән; **~ая рабо́та** төгәл эш; **~ое исполне́ние** пөхтә башкару

чёткость *ж* **1.** ачыклык, аныкклык, төгәллек; ~ **по́черка** язуның ачыклыгы **2.** *перен.* (*ясность, точность*) ачыклык, ачык аңлаешлылык **3.** *перен.* (*точность, организованность*) пөхтәлек, төгәллек, жиренә житкерелгәнлек

чётность *ж* җәплелек

чётн||ый, -ая, -ое җәп; **~ые чи́сла** җәп саннар

четы́ре *числ.* дүрт

четы́режды *нареч.* дүрт тапкыр, дүрт жирдә, дүрт мәртәбә; ~ **пять — два́дцать** дүрт жирдә биш — егерме; ~ **орденоно́сный заво́д** дүрт орденлы завод

четы́реста *числ.* дүрт йөз

четырёхвесе́льн||ый, -ая, -ое дүрт ишкәкле; **~ая ло́дка** дүрт ишкәкле көймә

четырёхгоди́чн||ый, -ая, -ое дүрт еллык ...; **~ые ку́рсы** дүрт еллык курслар

четырёхгодова́лый, -ая, -ое *см.* **четырёхле́тний**

четырёхголо́сый, -ая, -ое дүрт тавышлы; ~ **хор** дүрт тавышлы хор

четырёхгра́нник *м мат.* дүрткырлык

четырёхгра́нный, -ая, -ое дүрт кырлы; ~ **брус** дүрт кырлы борыс

четырёхдне́вный, -ая, -ое дүрт көнлек ...

четырёхкла́сс||ный, -ая, -ое **1.** дүрт класслы, дүрт сыйныфлы; **~ая шко́ла** дүрт сыйныфлы мәктәп **2.** дүрт класслык ..., дүрт сыйныфлык ...; **~ое образова́ние** дүрт сыйныфлык белем

четырёхкопе́ечный, -ая, -ое дүрт тиенлек ...

четырёхкра́тный, -ая, -ое дүрт тапкыр ..., дүртләтә; ~ **чемпио́н** дүрт тапкыр чемпион

четырёхле́тие *с* **1.** (*срок*) дүрт ел **2.** (*годовщина*) дүрт еллык, дүрт яшьлек

четырёхле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) дүрт еллык ... **2.** (*о возрасте*) дүрт яшьлек ..., дүрт еллык ...

четырёхме́стн||ый, -ая, -ое дүрт урынлы; дүрт кешелек ...; **~ое купе́** дүрт урынлы купе

четырёхме́сячный, -ая, -ое дүрт айлык ...; ~ **ребёнок** дүрт айлык бала

четырёхпа́лый, -ая, -ое дүрт бармаклы; ~ **след** дүрт бармаклы эз

четырёхпо́лье *с с.-х.* дүрт басулык, дүрт кырлык

четырёхрублёвый, -ая, -ое дүрт сумлык ...

четырёхсло́жн||ый, -ая, -ое дүрт ижекле; **~ое сло́во** дүрт ижекле сүз

четырёхсотле́тие *с* **1.** (*срок*) дүрт йөз ел **2.** (*годовщина*) дүрт йөз еллык, дүрт йөз яшьлек

четырёхсотле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) дүрт йөз еллык ... **2.** (*просуществовавший четыреста лет*) дүрт йөз яшьлек ..., дүрт йөз еллык ...

четырёхсо́тый, -ая, -ое *числ.* дүрт йөзенче

четырёхсторо́нн||ий, -яя, -ее дүрт яклы, дүрт тарафлы; **~ее соглаше́ние** дүрт яклы килешү

четырёхта́ктн||ый, -ая, -ое дүрт тактлы; **~ая па́уза** *муз.* дүрт тактлы пауза; **~ый дви́гатель** дүрт тактлы двигатель

четырёхты́сячный, -ая, -ое **1.** *числ.* дүрт меңенче, дүрт меңле **2.** дүрт меңлек ...; ~ **отря́д** дүрт меңлек отряд

четырёхуго́льник *м мат.* дүртпочмак

четырёхуго́льный, -ая, -ое дүрт почмаклы

четырёхчасов||о́й, -а́я, -о́е **1.** дүрт сәгатьлек ...; **~а́я бесе́да** дүрт сәгатьлек әңгәмә **2.** сәгать дүрттә китә (килә) торган; **~о́й по́езд** сәгать дүрттә китә торган поезд

четырёхэта́жный, -ая, -ое дүрт катлы

четырнадцатиле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) ундүрт еллык ... **2.** (*о возрасте*) ундүрт яшьлек ..., ундүрт еллык ...

четы́рнадцатый, -ая, -ое *числ.* ундүртенче

четы́рнадцать *числ.* ундүрт

чех *м* чех, чех кешесе

чехарда́ *ж* **1.** (*игра*) шыгырдый, сикерешле уены **2.** *перен. разг.* буталчыклык, болагай; **министе́рская ~** министрлык болагае

че́хи *мн.* чехлар, чех халкы

чехли́ть *несов. что* чехол (тышлык) кидерү, япкыч каплау; ~ **ору́дия** туплларга тышлык кидерү

чехо́л *м* тышлык, япкыч, чехол

чехо́льн||ый, -ая, -ое тышлык ...ы; япкыч ...ы, тышлыклык, япкычлык; **~ая ткань** тышлык тукыма

чечеви́ца *ж бот.* ясмык (*үсемлек һәм орлыгы*)

чечеви́чн||ый, -ая, -ое ясмык ...ы; **~ые посе́вы** ясмык чәчүлекләре; **~ый суп** ясмык ашы ♦ **прода́ть за ~ую похлёбку** ≈ сукыр бер тиенгә сатып жиберү

чече́нец *м* чечен, чечен кешесе
чече́нка *ж* чечен хатыны (кызы)
чече́нский, -ая, -ое чечен ...ы; ~ **язы́к** чечен теле
чече́нцы *мн.* чеченнәр, чечен халкы
чечётка *ж* (*танец*) тыпырдап бию
че́шка *ж* чех хатыны (кызы)
че́шский, -ая, -ое чех ...ы; ~ **язы́к** чех теле
чешу́йк||а *ж* тәңкәчек, кабырчык; **ры́бьи ~и** балык тәңкәләре
чешу́йчат||ый, -ая, -ое **1.** тәңкәле; кабырчыклы; ~ **ая ры́ба** тәңкәле балык **2.** *в знач. сущ.* ~ **ые** *мн. зоол.* тәңкәлеләр
чешу́я *ж* (*напр. рыбья*) тәңкә; (*у пресмыкающихся*) кабык; (*на коже нек-рых животных*) кабырчык
чи́бис *м зоол.* бибек, тәкәрлек
чиж *м зоол.* сары чыпчык
чили́йск||ий, -ая, -ое чилиле[ләр] ...ы; Чили ...ы; ~ **ие патрио́ты** Чили патриотлары
чили́йцы *мн.* чилилеләр, Чили халкы
чин *м* **1.** чин, дәрәҗә; **офице́рский ~** офицерлык дәрәҗәсе; **получи́ть ~ полко́вника** полковник чины алу **2.** хезмәткәр, вәкил; ~ **ы́ дипломати́ческого ко́рпуса** дипломатия корпусы вәкилләре ♦ ~ ~**ом** *или* ~ **по** ~**у** тәртипкә туры китереп
чина́ра *ж бот.* чинар, чинар агачы
чини́ть I *несов. что* **1.** төзәтү; ямау; сипләү; ~ **замо́к** йозак төзәтү; ~ **о́бувь** аяк киеме ямау **2.** очлау; ~ **каранда́ш** карандаш очлау
чини́ть II *несов. что* ... итү, кору, ясау; эшләү; ~ **препя́тствия** киртәләр кору; ~ **распра́ву** җәзалау
чини́ться *несов. уст.* (*излишне скромничать*) артык кылану (тәкәллефләнү), чамадан тыш назлану, боргалану-сыргалану
чи́нный, -ая, -ое әдәпле, тәртипле
чино́вник *м* **1.** чиновник; түрә **2.** *перен.* (*бюрократ*) чиновник
чино́вничество *с собир.* чиновниклар; түрәләр
чино́вничь||ий, -ья, -ье **1.** чиновник ...ы, чиновниклык ...ы **2.** *перен.* чиновникларча ...; ~ **ье отноше́ние к де́лу** эшкә чиновникларча караш
чи́рей *м* чуан, сызлавык
чири́канье *с см.* **чири́кать**
чири́кать *несов.* чыркылдау, черкелдәү, чырлау, черелдәү
чири́кнуть *сов. однокр.* чыркылдап (черкелдәп, чырлап, черелдәп) кую
чирóк *м зоол.* чүрәкәй
чи́сленность *ж* сан, исәп; ~ **населе́ния** халык саны; ~ **во́йска** гаскәр саны
чи́сленн||ый, -ая, -ое **1.** сан ...ы; исәп ...ы; ~ **ое реше́ние уравне́ния** тигезләмәнең сан чишелеше **2.** сан ягыннан, исәп ягыннан; ~ **ый соста́в войск** гаскәрнең сан ягыннан составы; ~ **ое превосхо́дство** сан ягыннан өстенлек
числи́тель *м мат.* санаучы
числи́тельн||ое *с грам.* сан; **коли́чественные** ~ **ые** микъдар саннары; **поря́дковые** ~ **ые** тәртип саннары; **и́мя** ~ **ое** сан исеме, сан
чи́слить *несов. кого-что* санау, исәпләү; ~ **в командиро́вке** командировкада дип санау; ~ **вы́бывшим** киткән дип исәпләү
чи́сли||ться *несов.* саналу, исәпләнү; ~ **ться в командиро́вке** командировкада саналу; **он** ~ **тся руководи́телем** ул җитәкче дип исәпләнә; **в спи́ске его́ фами́лия не** ~ **тся** исемлектә аның фамилиясе исәпләнми
чи́сл||ó *с* **1.** *мат.* сан; **це́лое** ~ **ó** бөтен сан; **дро́бное** ~ **ó** вакланма сан; **положи́тельное** ~ **ó** уңай сан; **тео́рия чи́сел** сан теориясе **2.** көн, число; **в пе́рвых** ~ **ах ма́я** майның беренче көннәрендә; **сего́дня пя́тое** ~ **ó** бүген бишенче число **3.** (*количество*) исәп, сан **4.** (*состав, ряд*) исәп, ара; **э́тот специали́ст — из** ~ **á лу́чших** бу белгеч — иң яхшылар исәбендә **5.** *грам.* сан; **еди́нственное** ~ **ó** берлек саны; **мно́жественное** ~ **ó** күплек саны ♦ **без** ~ **á** исәп-хисапсыз, сансыз, бихисап; **в том** ~ **é** шул исәптән, шул җөмләдән
числов||о́й, -а́я, -о́е **1.** сан ...ы; ~ **а́я величина́** сан зурлыгы **2.** (*выраженный числом*) сан ...ы; сан ягыннан, исәп ягыннан; ~ **ы́е да́нные** сан мәгълүматлары
чисти́лище *с рел.* араф (*оҗмахка керер алдыннан гөнаһлардан чистарыну урыны*)
чи́стильщик *м* чистартучы, тазартучы; ~ **сапо́г** итек чистартучы
чи́стить *несов.* **1.** *кого-что* чистарту, тазарту; ~ **зу́бы** теш чистарту; ~ **о́бувь** аяк киеме чистарту; ~ **коня́** ат чистарту **2.** *что* арчу, чистарту; ~ **ви́шни** чия чистарту; ~ **апельси́н** эфлисун арчу; ~ **грибы́** гөмбә чистарту **3.** *что* чистарту, арындыру, тазарту; ~ **дно реки́** елга төбен чистарту
чи́ститься *несов.* чистарыну, тазарыну
чи́стка *ж см.* **чистить**; ~ **о́буви** аяк киемен чистарту
чи́сто *нареч.* **1.** чиста, чиста итеп; ~ **вы́мытый** чиста юылган; ~ **одева́ться** чиста киену **2.** (*подлинно*) саф; ~ **отцо́вское чу́вство** атаның саф хисе **3.** *в знач. сказ. безл.* чиста, таза; **в помеще́нии** ~ бинада чиста ♦ ~ **-на́чисто** чип-чиста
чистови́к *м разг.* чисталама; **переписа́ть на** ~ чисталамага күчереп язу
чистово́й, -а́я, -о́е чисталама ...; ~ **экземпля́р** чисталама нөсхә
чистокро́вность *ж* саф токымлылык (нәселлелек, канлылык); ~ **жеребца́** айгырның саф нәселлелеге
чистокро́вный, -ая, -ое **1.** (*о животных*) саф токымлы (нәселле, канлы) **2.** (*о людях*) саф, чын
чистописа́н||ие *с* матур язу; **уро́к** ~**я** матур язу дәресе
чистопло́тность *ж* **1.** пакьлек (чисталык) ярату, пөхтәлек **2.** (*порядочность, честность*) намуслылык, сафлык
чистопло́тный, -ая, -ое **1.** пакьлек (чисталык) яратучы, пөхтә **2.** (*порядочный, честный*) намуслы, саф, әхлаклы
чистопоро́дность *ж с.-х.* саф токымлылык (нәселлелек, канлылык)
чистопоро́дный, -ая, -ое *с.-х.* саф токымлы (нәселле, канлы); ~ **скот** саф токымлы терлек
чистопро́бный, -ая, -ое (*о золоте, серебре*) саф, чиста
чистосерде́чность *ж* саф күңеллелек (йөрәклелек), самимилек, эчкерсезлек, ихласлык
чистосерде́чн||ый, -ая, -ое саф күңелле (йөрәкле), самими, эчкерсез, ихлас; ~ **ый челове́к** саф күңелле кеше; ~ **ое призна́ние** эчкерсез тану
чистот||á *ж* **1.** чисталык, пакьлек; ~**á ко́мнаты** бүлмәнең чисталыгы **2.** *перен.* сафлык, намуслылык, пакьлек; **нра́вственная** ~ **á** әхлакый саф **3.** (*тщательность, аккуратность*) пөхтәлек, мөкамәллек; ~ **á рабо́ты** эшнең пөхтәлеге; ~ **á обрабо́тки дета́ли** детальне эшкәртү пөхтәлеге **4.** ачыклык, аязлык, чисталык, тазалык; ~ **á о́кон** тәрәзәләр тазалыгы **5.** (*отсутствие примеси*) сафлык, чисталык, ачыклык; ~ **á воды́** суның сафлыгы **6.** ачыклык, аерымачыклык, сафлык; ~ **á произноше́ния** әйтелеш сафлыгы **7.** *перен.* эчкерсезлек, сафлык; ~ **á по́мыслов** уй-теләкләр сафлыгы
чистоте́л *м бот.* канлы үлән
чистошерстяно́й, -а́я, -о́е саф йон ...; ~ **плато́к** саф йон яулык
чи́ст||ый, -ая, -ое **1.** чиста, таза, пакь; ~ **ый воротничо́к** чиста яка; ~ **ая посу́да** чиста савыт-саба; ~ **ая ко́мната** чиста бүлмә **2.** *перен.* саф, намуслы, пакь, керсез, эчкерсез; **с** ~ **ой со́вестью** саф вөждан белән; ~ **ая душа́** эчкерсез күңел **3.** (*свободный, открытый — о поверхности*) ачык, аяз, чиста, буш; ~ **ое по́ле** буш кыр; ~ **ое не́бо** аяз күк йөзе; ~ **ая тетра́дь** чиста дәфтәр **4.** *разг.* (*не тяжёлый, не грязный — о работе*) пөхтә, чиста **5.** саф, чип-чиста, кушылмасыз; ~ **ое зо́лото** саф алтын; ~ **ый спирт** чип-чиста спирт; ~ **ый во́здух** саф һава; ~ **ая поро́да** саф токым; ~ **ая при́быль** *эк.* саф табыш; ~ **ый вес** саф үлчәү **6.** ачык, чиста, аерымачык саф; ~ **ая ру́сская речь** саф русча сөйләм; ~ **ое произноше́ние** ачык әйтелеш **7.** *разг.* чеп-чи, шыр, төгәл, чын; ~ **ый вздор** шыр сафсата; ~ **ое мучи́ние** чын газап **8.** (*тщательный, аккуратный*) пөхтә, мөкаммәл; ~ **ая рабо́та** пөхтә эш ♦ ~ **ая пра́вда** дөп-дөрес, дөреслекнең нәкъ үзе; ~ **ое иску́сство** саф сәнгать
чистю́ля *м, ж разг.* чамадан тыш чисталык яратучы
чита́льный, -ая, -ое уку ...ы; ~ **зал** уку залы
чита́льня *ж* уку бүлмәсе (бинасы); **райо́нная** ~ районның уку бинасы
чита́тел||ь *м* укучы; **конфере́нция** ~**ей** укучылар конференциясе
чита́тельница *ж* укучы хатын (кыз)
чита́тельск||ий, -ая, -ое укучы[лар] ...ы; ~ **ая конфере́нция** укучылар конференциясе
чита́ть *несов.* **1.** *кого-что* уку; ~ **кни́гу** китап уку; ~ **Пу́шкина** Пушкинны уку; ~ **по слога́м** иҗекләп уку **2.** *что* (*понимать*) уку, аңлау; ~ **но́ты** ноталар

уку; ~ **чертёж** сызымны уку **3.** *перен. что* күрү, тою, сизү, күреп тору, сизеп тору; ~ **печа́ль на** *чьём* **лице́** *кемнеңдер* кайгысын чыраеннан күрү **4.** *кого-что* (*произносить*) уку, сөйләү; ~ **стихи́** шигырьләр уку **5.** *что* уку, бирү; ~ **нравоуче́ния** үгет-нәсихәт бирү; ~ **мора́ль** мораль уку **6.** *что* укыту, уку; ~ **ле́кцию** лекция уку ♦ ~ **в се́рдце (в душе́)** йөрәгендәген (күңелендәген) сизү; ~ **ме́жду строк** юл арасын уку, киная-сен аңлау; ~ **по глаза́м** күзенә карап белү, күзенә карап чамалау

чита́||ться *несов.* **1.** укылу, укып булу; **на́дпись ~ется с трудо́м** язма авырлык белән укыла **2.** *безл. кому* укыйсы килү; **ему́ не ~лось** аның укыйсы килми **3.** *перен.* күренү, сизелү, тоелу; **в глаза́х его́ ~лась ску́ка** күзләрендә аның сагыш сизелә иде **4.** *страд. от* **чита́ть**

чи́тка *ж* **1.** *см.* **чита́ть** 1, 4; ~ **корректу́ры** корректура уку; **2.** (*вид репетиции*) өйрәнү, укып танышу

чиха́тельный, -ая, -ое төчкертү ...ы, төчкертә торган; ~ **газ** төчкертә торган газ

чиха́ть *несов.* **1.** төчкерү **2.** *перен. на кого-что* санга сукмау, төкерү, төкереп карау; ~ **мне на него́** мин аңа төкереп карыйм

чихну́ть *сов. однокр.* төчкереп жибәрү

член *м* **1.** әгъза; ~ **профсою́за** профсоюз әгъзасы; ~ **правле́ния** идарә әгъзасы; ~ **семьи́** гаилә әгъзасы **2.** (*часть тела*) әгъза, орган **3.** *мат.* буын **4.** *грам.* кисәк; ~**ы предложе́ния** җөмлә кисәкләре

члене́ние *с см.* **члени́ть**

членистоно́гие *мн. зоол.* буынтыкаяклылар

члени́ть *несов. что* кисәкләргә аеру (бүлү), ваклау

члени́т||ься *несов.* **1.** (*кисәкләргә*) аерылу (бүленү, ваклану); **сло́во ~ся на сло́ги** сүз иҗекләргә аерыла **2.** *страд. от* **члени́ть**

членовреди́тельство *с* әгъза имгәтү, әгъза бозу

членораздели́||ый, -ая, -ое ачык, анлаешлы, аныкъ; ~**ая речь** ачык сөйләм

чле́нск||ий, -ая, -ое әгъзалык ...ы; ~**ие взно́сы** әгъзалык взносы; ~**ий биле́т** әгъзалык билеты

чле́нство *с* әгъзалык; **профсою́зное** ~ профсоюз әгъзалыгы

чмо́ка||ть *несов.* **1.** (*губами*) чапылдату, чупалдату **2.** лачкылдау, чапылдау; **грязь ~ет под нога́ми** аяк астында пычрак лачкылдый **3.** *кого, шутл.* (*звучно целовать*) чупылдатып үбү, чуп итеп үбү **4.** чөнгерү (*атка*)

чмо́кнуть *сов. однокр.* **1.** (*губами*) чупылдатып (чапылдатып) алу **2.** *кого, шутл.* (*поцеловать*) үбеп алу, чуп итеп үбеп алу

чо́каться *несов.* чәкешү, чәкештерү

чо́порность *ж* кыланчыклык, һавалылык, назлылык, тәкәллефлелек

чо́порный, -ая, -ое кыланчык, һавалы, назлы, тәкәллефле; ~ **челове́к** кыланчык кеше; ~ **вид** тәкәллефле кыяфәт

чо́хом *нареч. прост.* тулаем, күмәртә; **прода́ть все ве́щи ~** бөтен әйберләрне тулаем сату

чрева́т||ый, -ая, -ое китереп чыгарырлык, барлыкка китерерлек, тудырырлык; **собы́тия, ~ые тяжёлыми после́дствиями** авыр нәтиҗәләр китереп чыгарырлык вакыйгалар

чре́||во *с уст.* карын, корсак, эч; **во ~е ма́тери** анадан туганчы, ана карынындагы

чревовеща́ние *с* эчтән сөйләү

чревовеща́тель *м* эчтән сөйли алучы кеше

чревоуго́дие *с уст.* бирәнлек

чревоуго́дник *м уст.* бирән

чревоуго́дничать *несов. уст.* бирәнләнү, бирән булу

чреда́ *ж см.* **чередá** I 2

чрезвыча́йност||ь *ж* гадәттән тышлык, чиктән тышлык; **до ~и про́сто** бик гади

чрезвыча́йн||ый, -ая, -ое **1.** гадәттән тыш, чиктән тыш; **~ый успе́х** чиктән тыш уңыш **2.** махсус, гадәттән тыш; **~ые расходы** махсус чыгымнар; **~ая коми́ссия** гадәттән тыш комиссия; **~ое положе́ние** гадәттән тыш хәл

чрезме́рн||ый, -ая, -ое чиктән тыш күп, кирәгеннән артык, чамасыз күп, чамасыз; **~ое внима́ние** чиктән тыш күп игътибар; **~ые тре́бования** чамасыз күп таләпләр

чте́ни||е *с* **1.** *см.* **чита́ть; бе́глое ~е** йөгерек уку; **~е книг** китап уку; **~е ле́кции** лекция уку **2.** (*читаемый текст*) китап, әсәр; **интере́сное ~е** кызыклы китап **3.** *мн.* **~я** укулар; **Ломоно́совские ~я** Ломоносовка багышланган укулар

чтец *м* **1.** укучы, кычкырып укучы; **он хоро́ший ~** ул яхшы кычкырып укучы **2.** (*артист*) сәнгатьчә укучы; **ко́нкурс ~о́в** сәнгатьчә укучылар конкурсы

чтить *несов. кого-что* хөрмәтләү, олылау, искә алу; ~ **па́мять поги́бших** һәлак булганнарны искә алу

что I *мест.* **1.** *вопр.* нәрсә, ни; ~ **случи́лось?** ни булды?; ~ **с ва́ми?** ни булды сезгә? ~ **вы купи́ли?** нәрсә сатып алдыгыз?; ~ **э́то тако́е?** бу ни бу?; **чего́ ты хо́чешь?** син нәрсә телисең?; **чем вы недово́льны?** сез нәрсәдән канәгать түгел?; **о чём вы говори́те?** нәрсә турында сөйлисез? **2.** *вопр. в знач. сказ.* (*в каком положении*) нихәл, ничек, ни хәлдә; ~ **больно́й?** авыру ни хәлдә?; ~ **ва́ша рабо́та?** эшегез ничек? **3.** *вопр. в знач. нареч.* (*почему*) ник, нигә, нәрсәгә; ~ **ты заду́мался?** нигә син уйга калдың?; **я не пое́ду. - Что так?** мин бармыйм. - Ник алай? **4.** *вопр.* (*сколько*) күпме, ни хак, ни; ~ **стои́т кни́га?** китап күпме тора?; ~ **возьмёшь за рабо́ту?** эшләгән өчен күпме алырсың? **5.** (*при выражении сомнения*) ни; ~ **то́лку в э́том?** моннан ни мәгънә?; ~ **по́льзы?** ни файда **6.** *неопр.* (*что-нибудь*) берәр нәрсә булса, нәрсә дә булса; **в слу́чае чего́** берәр нәрсә булган очракта; **чуть что́ — сра́зу сообщи́** берәр нәрсә булды исә — шунда ук хәбәр ит **7.** (*всё без исключения*) бөтен, ниләр; **тут есть всё,** ~ **уго́дно** анда ниләр кирәк — бөтенесе бар **8.** *относ.* (*который*) кайсы ки; ...ган; **дом,** ~ **стои́т на углу́** почмакта торган йорт ♦ **а** ~**?** ник?; нигә?; **ни к чему́** кирәге юк, кирәкмәс; **ни за что́** һичбер вакытта; **ни за что́, ни про что́** юкка, тиктомалга, бушка; **ни с че́м** бер нәрсәсез; **при чём?** ни катнашы бар?; **с чего́?** нигә?, нилектән?, кайдан алып?; ~ **до меня́** *или* ~ **каса́ется меня́** мина килгәндә; ~ **ж, ты прав** ярый, синеке дөрес; ~ **и говори́ть** әйтәсе дә юк; ~ **ли** *в знач. вводн. сл.* ...мы әллә?; ~ **ты!** син нәрсә!; ~ **бы́ло сил** бөтен көченә; **бежа́ть ~ есть ду́ху** бөтен җанфәрманга йөгерү

что II *союз* **1.** *изъясн.* дип, ...ки; ...га, ...ганын, ...ган, икәнен; **доса́дно, ~ ты опозда́л** синең соңга калуың үкенечле; **тако́й тяжёлый, ~ не подня́ть** шул кадәр авыр ки, күтәрерлек тә түгел; **я наде́юсь, ~ вы не отка́жете** сез баш тартмассыз дип ышанам; **он сча́стлив, ~ ви́дит тебя́** сине күрүгә ул шат **2.** (*с частицей «ни» и без неё*) һәр ... саен, саен; ~ **ни день, растёт движе́ние за мир** тынычлык өчен көрәш көн саен көчәя бара; ~ **ни взмах, то гото́ва копна́** җилпенгән саен чүмәлә әзер **3.** *разд.* ...мы, әллә ...мы; ни ...ни; ~ **ты пойдёшь, я ~ всё равно́** син барасыңмы, минме — барыбер

что́бы 1. *союз цели* өчен, ...дип; **я тороплю́сь, ~ успе́ть на по́езд** поездга өлгерү өчен ашыгам; **я пришёл, ~ взять кни́гу** мин китап алырга дип килдем **2.** *союз изъясн.* ...сен, ...ны; **я сомнева́юсь, ~ он оста́лся дово́лен** аның канәгать калуына шикләнәм **3.** *частица разг.* ...ыры, ...сын; ~ **э́того бо́льше не́ было!** бу башка кабатланмасын! ♦ **не то** ~ *или* **не так** ~ ул чаклы ... түгел; **не то** ~ **хо́лодно, а прохла́дно** ул чаклы салкын түгел, ә салкынча

что́-либо, что́-нибудь *мест.* берәр нәрсә, нәрсә дә булса; **не могу́ сообщи́ть чего́-либо утеши́тельного** тыныч-ландырырлык нәрсә дә булса әйтә алмыйм; **нет ли чего́-нибудь почита́ть?** укырга берәр нәрсә юкмы?

что́-то I *мест.* нәрсәдер, нидер; **ему́ чего́-то не хвата́ет** аңа нәрсәдер җитми

что́-то II *нареч. разг.* **1.** (*в нек-рой степени*) бераз, азрак; **мне ~ нездоро́вится** минем бераз хәлем китеп тора **2.** никтер, нигәдер; ~ **хо́лодно** нигәдер салкын; ~ **не по́мню** никтер хәтерли алмыйм **3.** чамасы, якын, ахрысы, ... лап; ~ **о́коло ста рубле́й** йөз сумга якын

чу *межд.* чү, тукта, тик тор; тыңла; **чу, трещи́т!** чү, шытырдый!

чуб *м* маңгай чәче

чуба́рый, -ая, -ое (*о масти лошади*) чуар, алмачуар

чуба́тый, -ая, -ое *разг.* маңгай чәчле; тузгыган чәчле; ~ **па́рень** маңгай чәчле егет

чубу́к *м* **1.** чубук, төребкә сабы **2.** *сад.* чыбык (*утырту өчен кулланыла*)

чува́ш *м* чуаш, чуаш кешесе

чува́ши *мн.* чуашлар, чуаш халкы

чува́шка *ж* чуаш хатыны (кызы)

чува́шский, -ая, -ое чуаш[лар] ...ы; ~ **язы́к** чуаш тел

чу́вственность *ж* **1.** сизеп (тоеп) белү, сизем белән белү **2.** (*склонность к чувственным влечениям*) шәһвәт, җенси теләк

чу́вственн||ый, -ая, -ое **1.** сизү (тою) белән ..., сизем белән ..., сизеп (тоеп) беленә торган; ~**ое восприя́тие** тоеп белү **2.** җенси; җенси теләкле, шәһвәтле; ~**ая любо́вь** җенси мәхәббәт

чувстви́тельность *ж* **1.** сизгерлек, хислелек; ~ **прибо́ра** приборның сизгерлеге **2.** (*ощутимость, значительность*) сизәрлек, сизелерлек **3.** (*сентиментальность*) әсәрләнүчәнлек, нечкә хискә бирелүчәнлек

чувстви́тельн||ый, -ая, -ое **1.** сизгер, сизүчән; ~**ый прибо́р** сизгер прибор; ~**ый нерв** сизгер нерв **2.** хисле; нечкә күңелле, нечкә тойгылы; ~**ое се́рдце** хисле йөрәк; ~**ая девица** нечкә күңелле кыз **3.** сизелерлек; шактый зур; ~**ый ущерб** сизелерлек зыян; ~**ые переме́ны** сизелерлек үзгәрешләр

чу́вств||о *с* **1.** тойгы, сизү; **о́рганы чувств** сизү органнары **2.** хис, тойгы; ~ **о за́висти (ре́вности)** көнләшү хисе; ~ **о жа́лости** кызгану хисе; ~ **о бо́ли** авырту тойгысы; ~ **о вку́са** зәвык тойгысы; ~ **о но́вого** яңалык хисе; **у него́ нет ~ а ме́ры** аның чаманы белү тойгысы юк **3.** һуш; **лиши́ться чувств** һуштан язу; **прийти́ в ~ о** һушка килү; **привести́** *кого-л.* **в ~ о** *берәүне* һушка китерү, аңына китерү **4.** (*любовь*) хис; **большо́е ~ о** олы хис ♦ ~ **о ло́ктя** иптәшлек (дуслык) хисе (тойгысы)

чу́вствова||ть *несов. что* **1.** хис итү, тою, сизү; ~**ть тепло́** җылы тою; ~**ть волне́ние** дулкынлану тою; ~**ть на себе́ чей-то взгляд** үзеңдә кемнеңдер карашын тою; ~**ть ответственность** җаваплылык сизү; ~**ть свою́ вину́** үз гаебеңне сизү; ~**ть прису́тствие** *кого-л. берәүнең* барлыгын сизү **2.** аңлау; ~**ть му́зыку** музыканы аңлау ♦ **как вы себя́ чу́вствуете?** сез үзегезне ничек хис итәсез?, кәефегез ничек?; ~**ть себя́** *кем-чем* үзеңне *кем итеп* хис итү; **я ~ую себя́ хорошо́** мин үземне яхшы хис итәм

чу́вств||оваться *несов.* тоелу, сизелү; **во всём ~уется забо́тливая рука́ хозя́ина** бөтен нәрсәдә хуҗаның хәстәрле кулы сизелә; **в его́ движе́ниях ~уется уве́ренность** аның хәрәкәтләрендә ышаныч сизелә

чугу́н *м* **1.** чуен; **вы́плавка ~а́** чуен кою **2.** (*сосуд*) чуен савыт, чуен чүлмәк

чугу́нн||ый, -ая, -ое **1.** чуен ...ы; ~**ая доска́** чуен тактасы **2.** чуен ...; ~**ый горшо́к** чуен чүлмәк

чугунолите́йный, -ая, -ое чуен кою ...ы; ~ **заво́д** чуен кою заводы

чуда́к *м* сәер, әкәмәт (*кеше*)

чудакова́тый, -ая, -ое сәеррәк, әкәмәтрәк; ~ **стари́к** сәеррәк карт

чуда́чество *с* сәерлек, әкәмәтлек, мәзәклек, кызыклык

чуда́чка *ж* сәер (әкәмәт) хатын (кыз)

чуде́сн||ый, -ая, -ое **1.** (*необычайный*) искиткеч, гаҗәп; ~**ое спасе́ние** гаҗәп котылу **2.** искиткеч, гаҗәп, гаҗәеп матур (искиткеч); ~**ый день** гаҗәеп матур көн; ~**ый челове́к** гаҗәп кеше

чуди́||ть *несов.* сәер (әкәмәт, гаҗәп) кылану, әкәмәтләр кору

чу́ди||ться *несов. безл.* ...ган кебек тоелу (сизелү), хис итү; **ему́ ~тся стук** аңа кемдер шакыган кебек тоела

чудно́ *нареч. разг.* **1.** сәер, әкәмәт, гаҗәп, кызык; **он ~ одева́ется** ул сәер киенә **2.** *в знач. сказ. безл.* (*удивительно, поразительно*) бик шәп, бик яхшы

чудно́й, -а́я, -о́е сәер, әкәмәт, гаҗәп; ~ **челове́к** сәер кеше

чу́дн||ый, -ая, -ое *см.* **чуде́сный** 2; ~**ое о́зеро** гаҗәеп матур күл

чу́до *с* **1.** могҗиза; **соверши́ть ~** могҗиза эшләү **2.** могҗиза, таң калырлык нәрсә; ~ **иску́сства** сәнгать могҗизасы; **чудеса́ геро́изма** каһарманлык могҗизалары **3.** *в знач. сказ.* гаҗәп, гәҗәеп, гаҗәп матур; **пого́да сего́дня — ~!** бүген һава — гаҗәп матур!; **~, как хоро́ш!** гаҗәп яхшы! ♦ ~**-богаты́рь** гаҗәп баһадир; ~**-ю́до** албасты

чудо́вище *с* **1.** (*сказочное существо*) албасты **2.** *перен.* (*о жестоком человеке*) албасты, аждаһа

чудо́вищность *ж* куркынычлык, коточкычлык; ~ **преступле́ния** жинаятьнең коточкычлыгы

чудо́вищн||ый, -ая, -ое **1.** (*страшный*) куркыныч, коточкыч; ~**ый зверь** коточкыч жанвар **2.** *перен.* коточкыч зур, искиткеч зур, әкәмәт зур; ~**ое преступле́ние** коточкыч зур жинаять; ~**ые разме́ры** әкәмәт зур күләм; ~**ый аппети́т** искиткеч зур аппетит

чудоде́йственн||ый, -ая, -ое искиткеч яхшы, гаҗәеп яхшы, могҗизалы; ~**ое лека́рство** искиткеч яхшы дару

чу́дом *нареч.* могҗиза белән, гаҗәеп рәвештә; **я ~ спа́сся** мин могҗиза белән котылдым

чужа́к *м разг.* ят, чит (*кеше, хайван хакында*)

чужби́на *ж* ят җир, чит җир, ят ил, чит ил

чужда́ться *несов.* **1.** *кого-чего* читләшү, ятсыну, читсенү; ~ **друзе́й** дуслардан читләшү **2.** *перен. чего, книжн.* белмәү, чит күрү, ят күрү; ~ **за́висти** көнчелекне белмәү

чу́жд||ый, -ая, -ое **1.** ят, чит, башка; ~**ые элеме́нты** чит элементлар; ~**ая идеоло́гия** чит идеология; **он мне соверше́нно чужд** ул минә бөтенләй ят **2.** *книжн.* (*не обладающий чем-л.*) белмәүче, чит күрүче, ят күрүче; **челове́к, ~ый ре́вности** көнләшүне белмәүче кеше

чуж||о́й, -а́я, -о́е **1.** (*не собственный*) кеше ...ы, башка кеше ...ы; ~**и́е ве́щи** кеше әйберләре; ~**а́я кни́га** кеше китабы; **под ~и́м и́менем** башка кеше исемендә; **на ~о́й счёт** башка кеше исәбенә **2.** *в знач. сущ.* ~**о́е** с башка; **взять ~о́е** башканыкын алу **3.** (*не родной; посторонний*) чит, ят; **стесня́ться ~и́х** чит кешеләрдән оялу **4.** башка, чит, ят; ~**о́й язы́к** чит тел; ~**и́е края́** ят җирләр ♦ **в ~о́м пиру́ похме́лье** ≈ ак эт бәласе кара эткә; **де́лать** *что* ~**и́ми рука́ми** *берәр нәрсәне* башкалар кулы белән эшләү; **с ~и́х слов (знать, говори́ть)** *берәр нәрсәне* чит кешедән (*белү*); **расска́зывать с ~и́х слов** кешедән ишеткәнне сөйләү; **с ~о́го го́лоса [говори́ть** *и т.п.*] кеше сүзе буенча, кеше фикерен кабатлап; ~**и́ми рука́ми жар загреба́ть** кеше кулы белән ут көрәү

чуко́тский, -ая, -ое чукча[лар] ...ы; Чукотка ...ы; ~ **язы́к** чукча теле

чу́кча *м, ж* чукча, чукча кешесе

чукча́нка *ж* чукча хатыны (кызы)

чу́кчи *мн.* чукчалар, чукча халкы

чула́н *м* чолан

чулки́ *мн.* оек[лар]; **шёлковые ~** ефәк оеклар

чуло́чник *м* оек бәйләүче

чуло́чница *ж* оек бәйләүче хатын (кыз)

чуло́чн||ый, -ая, -ое **1.** оек ...ы; ~**ая фа́брика** оек фабрикасы **2.** оеклык ...; ~**ая шерсть** оеклык йон

чум *м* чум (*төньяк халыкларында торак*)

чума́ *ж* чума (*йогышлы авыру*)

чума́з||ый, -ая, -ое *разг.* пычрак, шапшак; ~**ый мальчуга́н** шапшак малай

чумно́й, -а́я, -о́е **1.** чума ...ы; ~ **микро́б** чума микробы **2.** (*заражённый чумой*) чумалы

чумово́й, -а́я, -о́е *прост.* (*шальной, очумелый*) тиле, котырган

чура́ться *несов. кого-чего, разг.* качу, читләшү; ~ **люде́й** кешеләрдән качу

чурба́н *м* **1.** бүкән, түмәр, тумран; **берёзовый ~** каен түмәр **2.** *перен. бран.* (*о человеке*) күзле бүкән, аңгыра, ахмак

чуре́к *м* чүрәк, көлчә

чу́тк||ий, -ая, -ое **1.** сизгер, сак, үткен; ~**ий зверь** сизгер җәнлек; ~**ое у́хо** үткен колак; ~**ий сон** сак йокы **2.** *перен.* (*отзывчивый*) сизгер, игътибарлы, диккатле; ~**ое отноше́ние к лю́дям** кешеләргә игътибарлы караш; ~**ий челове́к** игътибарлы кеше

чу́ткость *ж* **1.** сизгерлек, саклык, үткенлек; ~ **прибо́ра** приборның сизгерлеге **2.** сизгерлек, игътибарлылык, диккатьлелек; **прояви́ть ~** игътибарлылык күрсәтү

чу́точк||а *ж разг.*: **ни ~и** *нареч.* аз гына да, чак кына да; **ни ~и я не уста́л** аз гына да арымадым; ~**у** *нареч.* бераз, бераз гына; ~**у лу́чше** бераз яхшырак

чуть 1. *нареч.* (*едва, немного*) бераз, аз гына, чак кына, чак-чак, көчкә генә; ~ **живо́й** чак-чак тере; ~ **бо́льше** бераз зуррак **2.** *союз* үк, белән үк ...са, шунда үк; ~ **кто войдёт, услы́шу** берәрсе керә калса, шунда үк ишетермен; ~ **ве́тер ду́нул, он уж простуди́лся** җил исү белән үк аңа салкын тия ♦ ~ **бы́ло не ...** чак кына, аз-аз гына ... диярлек; **он ~ бы́ло не упа́л** чак кына егылмады; ~ **[ли] не ...** бугай, ахры; **э́то произошло́ ~ ли не в про́шлом году́** бу хәл былтыр булды бугай; ~ **свет** таң беленгәч үк, таң ата башлагач үк; ~ **что** (*при малейшем поводе*) берәр нәрсә була калса; ~**-~** аз гына, чак кына

ЧУТ-ШАР

чутьё *с* **1.** (*у животных*) сизу, тою, сизгерлек **2.** *перен.* сизгерлек, уяулык, аңлау; **полити́ческое ~** сәяси сизгерлек; **худо́жественное ~** сәнгатьне аңлау; **~ языка́** телне аңлау

чу́чело *с* **1.** (*фигура животного*) сөкәт; **~ медве́дя** аю сөкәте **2.** (*пугало для птиц*) карачкы **3.** *перен. прост.* (*о грязном человеке*) карачкы, килбәтсез кеше ◆ **~ горо́ховое** шамакай, адәм көлкесе

чу́шка *ж* **1.** (*поросёнок*) чучка, дуңгыз баласы **2.** *спец.* (*слиток металла*) коелма кисәге

чушь *ж разг.* сафсата, буш нәрсә, юкбар; **говори́ть ~** юк-бар сөйләү

чу́ять *несов.* **1.** *кого-что* сизү, тою; **~ дичь** киек кошны сизү **2.** *что* сизү, белү; **чу́ет моё се́рдце, что он придёт** аның киләсен күңелем сизә ◆ **не ~ под собо́й ног (земли́)** аягы җиргә дә тимәү

чу́я||ться *несов. безл. разг.* сизелү, тоелу, беленү; **~лось приближе́ние весны́** яз якынлашуы сизелә иде

Ш

шаба́ш *неизм. в знач. сказ. прост.* житте, бетте, вәссәләм; **бо́льше я не курю́, ~!** бүтән тәмәке тартмыйм, житте!

шаба́шник *м прост.* шабашчы; **наня́ть ~ов** шабашчылар яллау

шаба́шничать *несов. прост.* (*наниматься частным образом за высокую плату на строительство, ремонт чего-л.*) шабашлык итү

шабло́н *м* **1.** (*образец*) шаблон, калып, өлге, үрнәк **2.** *перен.* тапталган, чәйнәлгән [фикер]; әзер калып, шаблон; **он пи́шет по ~у** ул шаблон буенча яза

шабло́нность *ж* шаблонлык, әзер калыплылык, тапталганлык; **~ письма́** язманың шаблонлыгы

шабло́нн||ый, -ая, -ое **1.** шаблон ..., әзер калып белән эшләнгән; **~ая дета́ль** шаблон деталь **2.** *перен.* тапталган, чәйнәлгән, шаблон; **~ая фра́за** тапталган гыйбарә; **~ый отве́т** шаблон җавап

ша́вка *ж* (*маленькая собачка*) маэмай

шаг *м* **1.** адым; **сде́лать не́сколько ~о́в** берничә адым атлау; **отме́рить ~а́ми** адымлап үлчәү; **услы́шать** *чьи-либо* **~и́** *кемнең дә булса* адымын ишетү; **чека́нить (печа́тать, отбива́ть) ~** шап иттереп басып атлау **2.** (*темп движения*) адым, атлау, йөреш; **приба́вить ~у** адымны тизләтү; **уско́рить ~** тизрәк атлау; **заме́длить ~** адымны акрынайту; **идти́ обы́чным ~ом** гадәти адым белән бару **3.** *перен.* адым, хәрәкәт, чара; **э́то ответственный ~** бу җаваплы адым; **сде́лать необду́манный ~** уйланмый ясалган адым **4.** *тех.* адым ◆ **в двух (трёх) ~а́х** *от чего берәр нәрсәдән* ике (өч) адымда; **в ~у́ узки́** (*о брюках*), **в ~у́ узка́** (*о юбке*) атларга читен (кысан); атлаганда тарта; **ни на ~** бер адым да; **ни на ~ не отходи́ть** бер адым да читкә китмәү; **ни на ~ не продви́нуться** бер адым да алга китмәү; **ни ~у наза́д!** бер адым да чигенмәскә!; **он без тебя́ ни на ~** синсез ул бер адым да атламас; **что ни ~** адым саен; **~ за ~ом** 1) (*медленно*) әкренләп, әкрен-әкрен генә; 2) (*постепенно, неуклонно*) тайпылышсыз, эзлекле рәвештә

шага́||ть *несов.* **1.** атлау, атлап бару; **~ть по доро́ге** юлдан атлау; **~ть в но́гу** бер сафта атлау; бер аяктан атлау **2.** *перен. разг.* (*развиваться*) [алга] бару, [алга] атлау, үсү; **3.** (*переступать*) атлау; **~ть че́рез поро́г** бусага аша атлау **4.** *разг.* (*идти*) атлау, бару; **куда́ ~ешь?** кая барасың?

шагну́ть *сов. однокр.* **1.** бер адым атлау, атлап кую; **~ в кана́ву** канауга атлау **2.** *перен.* [алга] атлап кую, үсү

ша́гом *нареч.* **1.** (*не бего́м*) атлап, атлап кына **2.** (*не рысью*) атлатып, атлап; **ко́ни шли ~** атлар атлап бардылар

шагоме́р *м* адымүлчәгеч

шагре́нев||ый, -ая, -ое шигрин ..., шигрин ...ы; **~ая ко́жа** шигрин күн; **~ый портфе́ль** шигрин портфель

шагре́нь *ж* шигрин (*йомшак күн*)

ша́йба *ж* **1.** *тех.* шайба **2.** *спорт.* алка, шайба

шайка I шайка, өер, төркем; **~ воро́в** караклар төркеме

ша́йка II *ж* лакан; **ба́нная ~** мунча лаканы

шайта́н *м* шайтан, җен

шака́л *м* чүл бүресе, шакал

шака́л||ий, -ья, -ье чүл бүресе ...ы, шакал ...ы; **~ьи пова́дки** шакал гадәтләре

шала́нда *ж* **1.** (*баржа*) шаланда **2.** (*рыболовная лодка*) шаланда

шала́ш *м* куыш, шалаш; **рыба́чий ~** балыкчы куышы

ша́лев||ый, -ая, -ое шәл ...ы; **~ые узо́ры** шәл бизәкләре ◆ **~ый воротни́к** шәл яка

шале́ть *несов. прост.* шашу, котыру; **~ от ра́дости** шатлыктан котыру

шал||и́ть *несов.* **1.** шаяру, шуклану, уйнау; **не ~и́!** шаярма! **2.** *разг.* шаярту, дөрес йөрмәү; **часы́ ~я́т** сәгать дөрес йөрми; **здоро́вье что-то ~и́т** сәламәтлек нигәдер шаярта ◆ **~и́шь!** алай булмый торсын әле!

шаловли́вость *ж* шаянлык, наянлык, шуклык

шаловли́вый, -ая, -ое шаян, наян, шук; **~ ребёнок** шаян бала; **~ взгляд** шаян караш

шалопа́й *м разг.* эшлексез, җилкуар, шалапай

шалопа́йничать *несов. разг.* җилкуарлану, шалапайлану

ша́лост||ь *ж* (*проказа*) шаянлык, юләрлек; (*озорство*) дуамаллык, шуклык; **де́тские ~и** балалык шуклыклары

шалу́н *м* шаян, наян, шук [кеше]

шалу́нья *ж* шаян хатын (кыз)

шалфе́й *м бот.* шалфей; **~ лугово́й** болын шалфее

шаль *ж* шәл; **цвета́стая ~** чәчәкле шәл ◆ **воротни́к ~ю** шәлсыман яка

шальн||о́й, -а́я, -о́е **1.** акылын югалткан, шашкан; **смотре́ть ~ы́ми глаза́ми** шашкан күз белән карау **2.** дуамал, тиле, азгын; **~а́я мысль** тиле фикер; **~о́й па́рень** дуамал егет **3.** (*случайный — о пуле, снаряде*) адашкан, саташкан ◆ **~ы́е де́ньги** ансат килгән акча, җиңел кәсептән килгән акча

шама́н *м* шаман

шаманизм *м см.* **шама́нство**

шама́нск||ий, -ая, -ое шаман ...ы, шаманлык ...ы; **~ий бу́бен** шаман шөлдере; **~ая оде́жда** шаман киеме

шама́нство *с* **1.** (*форма религии*) шаман дине, шаманизм **2.** (*колдовство*) шаманлык

ша́мканье *с см.* **ша́мкать**

ша́мкать *несов. разг.* пышылдап сөйләү, пышылдау; **~ беззу́бым ртом** тешсез авызы белән пышылдап сөйләү

шампа́нское *с* шампанский

шампиньо́н *м* шампиньон (*ашамлык гөмбә*)

шампу́нь *м* шампунь

шанс *м* өмет, ышаныч, мөмкинлек; **ни одного́ ~а на успе́х** уңышка бернинди өмет юк; **после́дний ~** соңгы өмет

шансоне́тка *ж* **1.** (*песня*) шансонетка, әдәпсез җыр **2.** (*певица*) шансонетка, әдәпсез җыр башкаручы

шанта́ж *ж* шантаж; **занима́ться ~о́м** шантаж белән шөгыльләнү

шантажи́ровать *несов. кого-что* шантаж ясау, шантаж юлы белән эш итү

шантажи́ст *м* шантажчы

шантрапа́ *м, ж прост.* **1.** (*ничтожный человек*) юньсез кеше; (*проходимец*) әрсез кеше **2.** *собир.* юк-бар кешеләр

ша́нцев||ый, -ая, -ое *воен.* шанец ...ы; **~ый инструме́нт** шанец коралы; **~ая лопа́та** шанец көрәге

ша́пк||а *ж* **1.** бүрек; **мехо́вая ~а** мех бүрек; **без ~и** бүрексез **2.** (*заголовок в газете*) гомуми баш ◆ **дать по ~е** *прост.* 1) (*ударить*) башына сугу, тондыру; 2) (*уволить*) сөрү, куу; **на во́ре ~а гори́т** каракның бүреге яна; **получи́ть по ~е** 1) (*получить удар*) тукмак алу; 2) (*быть уволенным*) куылу, сөрелү; **по Се́ньке и ~а** чиләгенә күрә капкачы; **~ами закида́ть** бүрек белән бәреп егу (*дошманны җиңүгә җиңел карау*); **~а-невиди́мка** *фольк.* тылсымлы бүрек

ша́почка *ж* **1.** *уменьш. от* **ша́пка** 1; **2.** балалар башлыгы

ша́почник *м* бүрекче, бүрек тегүче

ша́почн||ый, -ая, -ое бүрек ...ы, бүрек тегү ...ы; **~ая мастерска́я** бүрек тегү остаханәсе ◆ **~ое знако́мство** бүрек танышлыгы, очраклы танышлык; **прийти́ к ~ому разбо́ру** ≈ туйдан соң дөмбергә

шар *м в разн. знач.* шар; **ра́диус ~а** шарның радиусы; **бильярдный ~** бильярд шары; **возду́шный ~** һава шары; **земно́й ~** җир шары ◆ **хоть ~о́м покати́** тап-такыр, шар тәгәрәтерлек, буп-буш

шара́да *ж* шарада, башваткыч

шара́хаться *несов.* **1.** *см.* **шара́хнуться; ~ из стороны́ в сто́рону** бер яктан

икенче якка ташлану 2. *перен. разг.* (*сторониться кого-л.*) читләшү, читкә тайпылу

шара́хнуть *сов. однокр. прост.* 1. *кого-что и без доп.* бәрү, сугу, тондыру, кундыру 2. гөрселдәтү, ату, гөмбердәтү ~ **из пу́шки** туптан ату 3. *см.* **шара́хнуться**

шара́хну||ться *сов. однокр.* 1. (*отпрянуть*) читкә ташлану, [читкә] тайпылу; **ло́шадь ~лась в сто́рону** ат читкә тайпылды 2. *прост.* (*сильно удариться*) шап итеп бәрелү, шап итеп төшү; ~ **ться голово́й о сте́нку** баш белән диварга шап итеп бәрелү

шарж *м* шарж, көлү; **дру́жеский** ~ дусларча көлү

шаржи́ровать *несов. кого-что и без доп.* шаржлаштыру, шаржга бирелү

шариа́т *м* шәригать

ша́рик *м* 1. *уменьш. от* **шар**; шарчык 2. *физиол.* тәнчек; **кра́сные кровяны́е** ~**и** (*эритроциты*) кызыл кан тәнчекләре; **бе́лые кровяны́е** ~**и** (*лейкоциты*) ак кан тәнчекләре

ша́риков||ый, -ая, -ое шарлы; ~**ая автору́чка** шарлы авторучка; ~**ый подши́пник** шарлы подшипник

шарикоподши́пник *м тех.* шарлы подшипник; ~**и велосипе́да** велосипедның шарлы подшипниклары

шарикоподши́пниковый, -ая, -ое шарлы подшипник ...ы; ~ **заво́д** шарлы подшипник заводы

ша́рить *несов.* капшау, актару, актарып эзләү, капшап эзләү; ~ **рука́ми в темноте́** карангыда куллары белән капшап эзләү; ~ **в карма́нах** кесәләрен капшау

ша́ркать *несов.* 1. *чем* кыштырдату, шапылдату; ~ **ту́флями** туфлиләр белән шапылдату 2. (*при поклоне, приветствии*) аякны аякка бәрү

шарлата́н *м* шарлатан, алдакчы; **знахо́рь-** ~ имче шарлатан

шарлата́нить *несов.* шарлатанлану, шарлатанлык итү (кылу)

шарлата́нск||ий, -ая, -ое шарлатанча ..., шарлатанлык ...ы, шарлатан ...ы; ~**ие зама́шки** шарлатан кыланмышлары

шарлатанство́ *с* шарлатанлык, алдакчылык; **разоблачи́ть** ~ шарлатанлыкны фаш итү

шарма́нк||а *ж* шарманка ♦ **[опя́ть] завёл свою́** ~**у** *прост.* бер балык башын чәйнәү

шарма́нщик *м* шарманчы, шарманкада уйнаучы

шарни́р *м* күгән, тупса; **шарово́й** ~ шарлы тупса; **универса́льный** ~ универсаль күгән; **дверь на** ~**ах** тупсада утырган ишек

шарни́рный, -ая, -ое күгәнле, тупсалы; ~ **механи́зм** күгәнле механизм

шарова́ры *только мн.* чалбар; **широ́кие** ~ киң чалбар

шарови́дный, -ая, -ое шарсыман, шарга охшаган; ~ **гриб** шарсыман гөмбә

шаров||о́й, -а́я, -о́е 1. шар ...ы, шарлы, йомры; ~**а́я пове́рхность** шар өсйөзлеге; ~**о́й сегме́нт** шар сегменты 2. (*имеющий форму шара*) шарсыман; ~**а́я мо́лния** шарсыман яшен

шарф *м* шарф; **пёстрый** ~ чуар шарф

шасси́ *с нескл. тех* шасси; **убира́ющееся** ~ җыелулы шасси; **неубира́ющееся** ~ җыелмый торган шасси; **самохо́дное** ~ үзйөрешле шасси

шата́ни||е *с* 1. *см.* **шата́ть** I, **шата́ться**; 2. *перен.* (*неустойчивость во взглядах, убеждениях*) аумакайлык

шата́||ть *несов.* 1. *что* селкетү, чайкалту; **ве́тер** ~**ет дере́вья** җил агачларны селкетә; ~**ть зуб** тешне селкетү 2. *кого* чайкалу, алпан-тилпән килү; **его́** ~**ет от уста́лости** арганлыктан ул алпан-тилпән килә

шата́||ться *несов.* 1. селкенү, какшау; **зуб** ~**ется** теш селкенә; **стол** ~**ется** өстәл селкенә 2. (*при ходьбе*) чайкалу, алпан-тилпән килү 3. *перен. прост.* тик йөрү, селкенеп йөрү; ~**ться по го́роду** шәһәр буйлап тик йөрү

шате́н *м* коңгырт чәчле кеше

шате́нка *ж* коңгырт чәчле хатын (кыз)

шатёр *м* чатыр; **цыга́нский** ~ чегән чатыры; **раски́нуть** ~ чатыр кору

ша́тк||ий, -ая, -ое 1. селкенә торган, какшый торган, какшау; ~**ий стул** селкенә торган урындык; ~**ая похо́дка** селкенеп йөрү 2. *перен.* тотрыксыз, ышанычсыз; ~**ое положе́ние** тотрыксыз хәл ♦ **ни** ~**о, ни ва́лко** *погов.* ≈ бер көе, бер төрле

ша́ткость *ж* 1. селкенгәнлек, какшаганлык 2. *перен.* тотрыксызлык, ышанычсызлык; ~ **мне́ний** фикерләрнең тотрыксызлыгы

шату́н *м тех.* шатун

шафра́н *м бот.* зәгъфран

шафра́нн||ый, -ая, -ое 1. *бот.* зәгъфран ...ы; ~**ые ры́льца** зәгъфран авызчыклары 2. зәгъфранлы; ~**ое те́сто** зәгъфранлы камыр 3. (*о цвете*) зәгъфран төсендәге, кызгылт сары

шафра́новый -ая, -ое *см.* **шафра́нный** 3

шах I *м* (*титул*) шаһ

шах II *м шахм.* шах; **объяви́ть** ~ шах белдерү; ~ **королю́** корольгә шах

шахиншах *м* (*титул*) шаһиншаһ

шахи́ня *ж* шаһ хатыны

шахмати́ст *м* шахматчы, шахмат уйнаучы

шахмати́стка *ж* шахматчы хатын (кыз)

ша́хматн||ый, -ая, -ое шахмат ...ы; ~**ая доска́** шахмат тактасы ♦ **в** ~**ом поря́дке** шахмат тәртибендә

ша́хматы *только мн.* 1. (*игра*) шахмат; **игра́ть в** ~ шахмат уйнау 2. (*набор*) шахмат

ша́хский, -ая, -ое шаһ ...ы; ~ **престо́л** шаһ тәхете

ша́хт||а *ж* шахта; **рабо́тать в** ~**е** шахтада эшләү; **каменноуго́льная** ~**а** ташкүмер шахтасы

шахтёр *м* шахтёр, шахтачы, шахтада эшләүче

шахтёрка *ж* 1. шахтёр хатын (кыз) 2. (*жена шахтёра*) шахтёр хатыны 3. (*рабочий костюм*) шахтёрка

шахтёрск||ий, -ая, -ое шахтёр ...ы; шахтёрлар ...ы; ~**ая ла́мпа** шахтёр лампасы

ша́хтн||ый, -ая, -ое шахта ...ы; ~**ая печь** шахта миче ♦ ~**ый ствол** *горн.* шахта стволы

ша́шечный, -ая, -ое шашка ...ы; ~ **турни́р** шашка турниры

ша́ши́ст *м* шашкачы, шашка уйнаучы

ша́шк||а I *ж* 1. *только мн.* ~**и** шашка; **игра́ть в** ~**и** шашка уйнау 2. (*кружок для игры*) шашка, шакмак (*шундый уенда кулланыла торган шакмак*) 3. шашка; **дымова́я** ~**а** төтен шашкасы; **подрывна́я** ~**а** шартлаткыч шашка ♦ **в** ~**у** *или* ~**ами** *в знач. нареч.* шакмаклы; **ткань в** ~**у** шакмаклы тукыма; **си́тец** ~**ами** шакмаклы ситса

ша́шк||а II *ж* (*оружие*) кылыч, шашка

шашлы́к *м* кәбап, шашлык

шашлы́чная *ж* кәбапханә, шашлыкханә

ша́шни *только мн. разг.* 1. (*интриги*) хәйләләр 2. (*любовные*) гыйшык-мыйшык, гыйшык бәйләнешләре

шва́бр||а *ж* швабра, мунчала пумала, киндер пумала; **мыть полы́** ~**ой** идәнне швабра белән юу

шваль *ж прост.* 1. (*негодная вещь*) яраксыз әйбер, чүп-чар 2. (*негодный человек*) чүп кеше, нәҗес кеше, юк-бар кеше

швартов *м мор.* швартов, бәйләү арканы; **отда́ть** ~**ы** швартовны ычкындыру

швартова́ть *несов. что, мор.* арканлап кую, швартов белән бәйләп кую; ~ **су́дно** судноны арканлап кую

швартова́ться *несов. мор.* 1. арканлап куелу, бәйләп куелу 2. *страд. от* **швартова́ть**

швартов||ый, -ая, -ое *мор.* швартов ...ы; ~**ые концы́** швартов очлары

швах *в знач. сказ разг.* мөшкел, начар, яман, хөрти; **дела́ у него́** ~ эшләре яман аның

швед *м* швед, швед кешесе

шве́дка *ж* швед хатыны (кызы)

шве́дск||ий, -ая, -ое швед ...ы; шведлар ...ы; Шве́ция ...ы; ~**ий язы́к** швед теле ♦ ~**ая сте́нка** *спорт.* швед стенкасы

шве́ды *мн.* шведләр, Швеция халкы

шве́йник *м* тегүче, тегүче эшче

шве́йн||ый, -ая, -ое тегү ...ы; тегүчелек ...ы; ~**ая маши́на** тегү машинасы; ~**ая игла́** тегү энәсе; ~**ая фа́брика** тегү фабрикасы

швейца́р *м* швейцар, ишек каравылчысы

швейца́рск||ий I, -ая, -ое Швейцария ...ы; швейцарияле[ләр] ...ы; ~**ая приро́да** Швейцария табигате; ~**сыр** Швейцария сыры

швейца́рск||ий II, -ая, -ое швейцар ...ы; ~**ая ливре́я** швейцар ливреясе

швейца́рцы *мн.* швейцариялеләр; швейцарлар, Швейцария халкы

шве́ллер *м тех.* швеллер (*«п» сыман борыс*)

шве́ллерн||ый, -ая, -ое *тех.* швеллер ...ы, швеллер ...; ~**ая ба́лка** швеллер өрлек; ~**ое желе́зо** швеллер тимере

швея́ *ж* тегүче хатын (кыз)

швырну́ть *сов. однокр. см.* **швыря́ть**

швыря́||ть *несов. кого-что, чем, разг.* ыргыту; ату; **~ть ка́мни (камня́ми)** *в кого-л. кемгәдер* ташлар ату; **куда́ его́ то́лько не ~ла судьба́!** язмыш аны кая гына ыргытмады ♦ **~ де́ньги (деньга́ми)** акча туздыру

швыря́ться *несов.* **1.** *чем* ыргыту, ату, ыргытышу, атышу; **~ камня́ми** таш атышу **2.** *перен. кем-чем* санга сукмау, хисаплашмау, читкә кагу; **нельзя́ ~ людьми́** кешеләрне читкә кагарга ярамый; **~ дорогими́ пода́рками** кыйммәтле бүләкләрне санга сукмау

шевели́ть *несов.* **1.** *что* кыймылдату, кузгату, селкетү; **~ дрова́ в пе́чке** мичтә утынны кузгату **2.** *чем* кыймылдату, селкетү; **~ губа́ми** иреннәрне кыймылдату; **~ вёслами** ишкәкләрне селкетү **3.** *что, с.-х.* күпертү, кабарту; **~ се́но** печән кабарту ♦ **~ мозга́ми** *шутл.* башны эшләтү, уйлап карау

шевел||и́ться *несов.* **1.** кыймылдау, селкенү; **ли́стья ~я́тся** яфраклар селкенә; **не ~и́сь!** кыймылдама! **2.** *перен.* уяну, кузгалу, борчу; **~и́тся наде́жда** өмет уяна; **~я́тся сомне́ния** шикләнүләр борчый; **в голове́ у меня́ ~и́лся оди́н вопро́с** башымда бер мәсьәлә уянды ♦ **~и́сь!** кыймылдагыз!

шевельну́ть *сов. однокр. см.* **шевели́ть** ♦ **[и] бро́вью не ~** керфек тә селкетмәү

шевельну́ться *сов. однокр. см.* **шевели́ться**

шевелю́ра *ж* куе чәч

шевио́т *м* шевиот (*йон тукыма*)

шевио́товый, -ая, -ое шевиот ...ы; шевиот ...; **~ костю́м** шевиот костюм

шедёвр *м* шедевр, гүзәл әсәр; **~ иску́сства** сәнгать шедевры

шезло́нг *м* шезлонг (*сөзәк аркалы утыргыч*)

ше́йка *ж* **1.** *уменьш. от* **ше́я;** муенчык **2.** (*узкая часть чего-л.*) муен, муентык; **~ ре́льса** рельс муентыгы; **~ зу́ба** теш муентыгы

ше́йн||ый, -ая, -ое муен ...ы, муендагы; **~ые позвонки́** *анат.* муен умырткалары; **~ый плато́к** муендагы яулык

шейх *м* шәех (**1.** *Гарәбстанда: кайбер күчмә кабиләләрнең башлыгы.* **2.** *гарәп илләрендә: авыл старостасы* **3.** *мөселманнарда: гомумән дини башлык*)

ше́лест *м* кыштырдау, шабырдау; шыштырдау; **~ ли́стьев** яфраклар кыштырдавы; **~ пла́тья** күлмәк шыштырдавы

шелест||е́ть *несов.* кыштырдау, кыштыр-кыштыр килү, шыштырдау; **ли́стья ~я́т** яфраклар кыштырдыйлар

шёлк *м* ефәк; **~-сыре́ц** чимал ефәк; **иску́сственный ~** ясалма ефәк; **пла́тье из ~а** ефәк күлмәк

шелкови́нка *ж* ефәк жебе

шелкови́ст||ый, -ая, -ое ефәксыман, ефәктәй, ефәк төсле; **~ая ткань** ефәксыман тукыма

шелкови́ца *ж бот.* тут агачы

шелкови́ч||ый, -ая, -ое тут агачы ...ы; **~ые планта́ции** тут агачы плантацияләре ♦ **~ый червь** ефәк корты

шелково́д *м* ефәкче, ефәкчелек белгече

шелково́дство *с* ефәкчелек, ефәк корты үрчетү

шелково́дческ||ий, -ая, -ое ефәкчелек ...ы; ефәк корты үрчетү ...ы; **~ие райо́ны** ефәкчелек районнары

шёлков||ый, -ая, -ое **1.** ефәк ...ы; ефәк ...; **~ое волокно́** ефәк сүсе; **~ая нить** ефәк җеп; **~ая ле́нта** ефәк тасма; **~ая фа́брика** ефәк фабрикасы **2.** ефәк ..., ефәктәй; **~ые во́лосы** ефәктәй чәчләр **3.** *перен. разг.* тыңлаучан, басынкы, юаш, инсафлы; **ма́льчик стал ~ым** малай инсафланды

шёлкокомбина́т *м* ефәк комбинаты

шёлкообраба́тывающий, -ая, -ее ефәк эшкәртү ...ы; ефәк эшкәртүче ...

шёлкомота́льня *ж* ефәкханә, ефәк урау эшханәсе

шёлкомота́льщик *м* ефәк ураучы

шёлкомота́ние *с* ефәк урау

шелкопря́д *м зоол.* ефәк күбәләге

шёлкопряде́ние *с* ефәк туку

шёлкопряди́льный, -ая, -ое ефәк туку ...ы; **~ стано́к** ефәк туку станогы

шелла́к *м* шеллак (*табигый сумала*)

шелохну́||ть *сов. что, чем* селкетү, селкетеп кую, кузгату, кузгатып кую, кыймылдату; **ветеро́к ~л листву́** җил яфракны селкетеп куйды

шелохн||у́ться *сов.* селкенү, кузгалу, кыймылдау, селкенеп (кузгалып, кыймылдап) кую; **ни оди́н листо́к не ~ётся** бер яфрак та селкенми

шелуди́вый, -ая, -ое *прост.* кутырлы, кырчын, корчангы, таз

шелуха́ *ж* **1.** кабык; **карто́фельная ~** бәрәңге кабыгы **2.** *перен.* чүп-чар, кибәк

шелуше́ние *с см.* **шелуши́ть, шелуши́ться**

шелуши́ть *несов. что* кабыгыннан арчу, кабыгыннан арындыру; **~ зёрна** ашлык бөртекләрен кабыгыннан арындыру

шелуши́||ться *несов.* (*о коже*) кубалаклану, кубу; **ко́жа на лице́ ~тся** битнең тиресе кубалаклана

ше́льма *м, ж прост.* **1.** (*хитрец*) мут, ертлач, алдакчы **2.** *бран.* явыз кеше

шельмова́ть *несов. кого-что, разг.* яманлау, яман атын сату; пычрак ату; **~ че́стного челове́ка** намуслы кешегә пычрак ату

шемая́ *ж зоол.* майбалык, шемая

шепеля́вить *несов.* шышылдап сөйләү, шышылдау

шепеля́вость *ж* шышылдап сөйләү, шышылдаучанлык

шепеля́вый, -ая, -ое шышылдап сөйләүче, шышылдаучы

шепну́ть *сов. однокр. см.* **шепта́ть** 1, 3

шёпот *м* **1.** пышылдау, пышылдап сөйләү **2.** *перен.* (*листьев*) кыштырдау; (*воды́*) чылтырау

шёпотом *нареч.* пышылдап, шыпырт; **говори́ть ~** пышылдап сөйләү

шепта́ть *несов.* **1.** *что и без доп.* пышылдау; **~ на́ ухо** колагына пышылдау **2.** *перен.* (*о листве*) кыштырдау; (*о воде, ручье*) чылтырау **3.** *что разг.* (*передавать по секрету*) чыш-пыш тарату, гайбәт тарату

шепта́ться *несов.* **1.** пышылдашу, пышылдап сөләшү **2.** *см.* **шепта́ть** 2

шепту́н *м разг.* пышылдап сөйләшүче, гайбәтче, сүз йөртүче

шербе́т *м* ширбәт

шере́нг||а *ж* рәт, саф, **вы́строиться в две ~и** ике рәткә тезелү; **~а автомаши́н** автомашиналар сафы ♦ **быть (стоя́ть) в одно́й ~е** *с кем кем беләндер* бер сафта булу (тору)

шери́ф I *м* (*судья*) шәриф

шери́ф II *м* (*у мусульман*) шәриф (*Мөхәммәт пәйгамбәр нәселеннән килгән мөселман*)

шероховáтост||ь *ж* **1.** кытыршылык, кытырлык; **~ь ко́жи** күннең кытыршылыгы; **~ь доски́** тактаның кытыршылыгы **2.** кытыршы, кытыр; **~и на доске́** тактадыгы кытыршылыклар **3.** *перен.* кытыршы, тупас; **в рабо́те появи́лись ~и** эштә кытыршылар туды

шерохова́т||ый, -ая, -ое **1.** кытыршы, кытырлы; **~ая доска́** кытыршы такта **2.** *перен.* кытыршы, тупас, килешсез; **~ый стиль** кытыршы стиль

шерсти́нка *ж* **1.** (*волосок шерсти*) төк **2.** (*шерстяная нить*) йон жебе

шерсти́ст||ый, -ая, -ое **1.** йонлач, озын куе йонлы; **~ые о́вцы** озын куе йонлы сарыклар

шерст||и́ть *несов. что и без доп.* кычыттыру, кыру, чәнчү (*тәнне*); **пла́тье ~и́т** күлмәк тәнне чәнчә

шерстопряде́ние *с* йон эрләү

шерстопряди́льн||ый, -ая, -ое йон эрләү ...ы; **~ая фа́брика** йон эрләү фабрикасы

шерстотка́цк||ий, -ая, -ое йон туку ...ы; **~ая фа́брика** йон туку фабрикасы

шерстотка́чество *с* йон туку

шерст||ь *ж* **1.** йон, төк; **густа́я ~** куе йон; **обрабо́тка ~и** йон эшкәртү; **ове́чья ~** сарык йоны; **бить ~** *спец.* йон тетү **2.** (*пряжа, нитки*) йон, йон җеп **3.** (*ткань*) йон, йон тукыма ♦ **гради́ть про́тив ~и** йонын киргә сыпыру

шерстян||о́й, -а́я, -о́е **1.** йон ..., йон ...ы; **~а́я ткань** йон тукыма; **~а́я пря́жа** йон эрләнмәсе; **~ы́е перча́тки** йон перчатка; **~о́е пла́тье** йон күлмәк **2.** йон ...ы; йон эшкәртү ...ы; **~а́я фа́брика** йон эшкәртү фабрикасы

шерша́в||ый, -ая, -ое кытыршы, ярганланган, бирчәйгән; **~ые ру́ки** кытыршы куллар

ше́ршень *м* божан

шест *м* колга; **прыжки́ с ~о́м** *спорт.* колга белән сикерү

ше́ствие *с* **1.** йөреш, атлау; **торже́ственное ~** тантаналы йөреш **2.** *перен.* атлау, адым

ше́ствовать *несов.* [тантаналы] йөрү, бару, атлап бару; **~ по пло́щади** мәйданнан атлап бару

шестерёнка *ж см.* **шестерня́**

шестёрка *ж* **1.** (*цифра или группа из шести единиц*) алты **2.** *разг.* (*напр. трамвай, автобус*) алтынчы **3.** (*упряжка*) җигүле алты ат **4.** *спорт.* (*лодка*) алты ишкәкле көймә **5.** (*в картах*) алтылык

шестерня́ *ж тех.* шестерня, тешле тәгәрмәч; (*в мельнице*) алтагач

ше́стеро *числ. собир.* алтау, алты; **их бы́ло ~** алар алтау иде; **~ из нас** безнең алтыбыз; **~ су́ток** алты тәүлек

шести- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге; татар теленә «алты» сүзе белән тәрҗемә ителә, мәс.* **шестигра́нный** алты кырлы; **шестипудо́вый** алты потлы

шестигра́нник *м мат.* алтыкырлык

шестигра́нн||ый, -ая, -ое *мат,* алты кырлы; **~ая фигу́ра** алты кырлы фигура

шестидесятиле́тие *с* **1.** (*срок*) алтмыш ел **2.** (*годовщина*) алтмыш еллык, алтмыш яшьлек

шестидесятиле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) алтмыш еллык ... **2.** *(о возрасте)* алтмыш яшьлек ...

шестидеся́т||ый, -ая, -ое *числ.* алтмышынчы; **~ые го́ды** алтмышынчы еллар; **~ый киломе́тр** алтмышынчы километр

шестидне́вный, -ая, -ое алты көн ..., алты көнлек ...; **~ путь** алты көнлек юл; **в ~ срок** алты көн эчендә

шестикла́ссник *м* алтынчы сыйныф (класс) укучысы

шестикла́ссница *ж* алтынчы сыйныфта (класста) укучы кыз

шестикра́тн||ый, -ая, -ое алты тапкыр, алты мәртәбә, алтылатылган; **в ~ом разме́ре** алтылатылган күләмдә

шестиле́тн||ий, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) алты еллык ..., алты ел ... **2.** (*о возрасте*) алты яшьлек ...

шестиме́сячный, -ая, -ое алты айлык; **~ ребёнок** алты айлык бала

шестинеде́льный, -ая, -ое алты атналык ...; **~ о́тпуск** алты атналык ял

шестипа́лый, -ая, -ое алты бармаклы; **~ след** алты бармаклы эз

шестисотле́тие *с* **1.** (*срок*) алты йөз ел, алты гасыр **2.** (*годовщина*) алты йөз еллык; **~ го́рода** шәһәрнең алты йөз еллыгы

шестисотле́тний, -яя, -ее алты йөз еллык ..., алты гасырлык ...; **~ юбиле́й** алты йөз еллык юбилей

шестисо́т||ый, -ая, -ое *числ.* алты йөзенче; **~ый но́мер** алты йөзенче номер

шестиуго́льник *м мат.* алтыпочмаклык

шестиуго́льн||ый, -ая, -ое алтыпочмаклы; **~ая ко́мната** алтыпочмаклы бүлмә

шестичасово́й, -а́я, -о́е **1.** алты сәгатьлек ..., алты сәгатьле; **~ рабо́чий день** алты сәгатьлек эш көне **2.** сәгать алтыда китә (килә) торган; **~ по́езд** сәгать алтыда китә торган поезд

шестиэта́жный, -ая, -ое алты катлы; **~ дом** алты катлы йорт

шестнадцатиле́тний, -яя, -ее **1.** (*о сроке*) уналты еллык ... **2.** (*о возрасте*) уналты яшьлек ...

шестна́дцат||ый, -ая, -ое *числ.* уналтынчы; **~ая страни́ца** уналтынчы бит

шестна́дцать *числ.* уналты

шест||о́й, -а́я, -о́е *числ.* алтынчы; **~о́й но́мер** алтынчы номер; **~а́я часть** алтынчы өлеше; **~о́е апре́ля** алтынчы апрель; **ему́ ~о́й год** аңа алтынчы яшь

шесто́к *м* мич алды

шесть *числ.* алты

шестьдеся́т *числ.* алтмыш

шестьсо́т *числ.* алты йөз

шестью́ *нареч.* алты мәртәбә, алты тапкыр, алты җирдә; **~ шесть — три́дцать шесть** алты җирдә алты-утыз алты

шеф *м* **1.** (*начальник*) шеф, башлык **2.** шеф, шефлык итүче; **заво́д — ~ шко́лы** завод — мәктәп шефы ♦ **~-по́вар** шеф-повар, өлкән пешекче

ше́фск||ий, -ая, -ое шеф ...ы; шефлык ...ы; **~ая по́мощь** шефлык ярдәме

ше́фство *с* шефлык, шефлык итү; **взять ~** *над кем-чем-л. кемне-нәрсәне булса да* шефлыкка алу

ше́фствова́ть *несов.* шеф булу, шефлык итү; **~ над де́тским до́мом** балалар йортына шефлык итү

ше́я *ж* муен ♦ **ве́шаться (броса́ться) на ше́ю** *кому* муенына асылыну, ник итеп кочаклашу; **гнать (вы́гнать) в ше́ю** *кого* куып чыгару, төрткәләп чыгару

ши́ворот *м*: **схвати́ть** *кого-л.* **за ~** *кемнең дә булса* якасыннан эләктерү; **взять** *кого-л.* **за ~** *кемне дә булса* якасыннан алу; **~-навы́ворот** алдын-артка; **он наде́л руба́шку ~-навы́ворот** күлмәген алдын-артка кигән; **дела́ пошли́ ~-навы́ворот** эшләрнең алды-арты китте

шизофре́ник *м* шизофреник, шизофрения белән авыручы

шизофрени́я *ж мед.* шизофрения (*психик авыру*)

шик *м* купшылык, фыртлык; **пройти́сь с ~ом** фырт итеп үтеп китү; **зада́ть ~у** *прост.* купшылык күрсәтү

ши́канье *с см.* **ши́кать**

шика́рно *нареч.* **1.** шәп [итеп], купшы [итеп]; матур; фырт; **~ обста́вленная ко́мната** купшы итеп җиһазланган бүлмә **2.** *в знач. сказ. безл.* менә дигән, бик шәп; **здесь ~!** биредә менә дигән!

шика́рн||ый, -ая, -ое *разг.* бик шәп, купшы, матур; фырт; **~ая кварти́ра** бик шәп квартира; **~ое пла́тье** купшы күлмәк

ши́кать *несов.* **1.** *на кого* (*отгонять птиц*) «көш» дип әйтү, «көш» дип куу **2.** *на кого* (*призывать к тишине*) тшылдау, «тш» дип әйтү, «төш» дип әйтү **3.** (*выражать неодобрение*) мәсхәрәләп кычкыру, мәсхәрәләп сызгыру

ши́кнуть *сов. однокр. см.* **ши́кать**

ши́ллинг *м* шиллинг (*акча берәмлеге*)

ши́л||о *с* без ♦ **~а в мешке́ не утайшь** *посл.* без капчыкта ятмый

шимпанзе́ *м нескл.* шимпанзе

ши́на *ж* **1.** шин; **автомоби́льная ~** автомобиль шины **2.** *мед.* тугым, шин

шине́л||ь шинель

шине́льн||ый, -ая, -ое шинель ...ы; шинельлек ...; **~ое сукно́** шинельлек постау

шинка́рь *м уст.* мәйханәче

шинкова́ть *несов. что* турау, телемләп турау; **~ капу́сту** кәбестә турау

ши́нный, -ая, -ое шин ...ы; **~ заво́д** шин заводы

шино́к *м уст.* мәйханә

шиньо́н *м* шиньон; ясалма чәч

шип *м* **1.** (*у растения*) чәнечке, кылчык, энә **2.** чыгынты, тырнак, шип; теш (*дагада*); **боти́нки с ~а́ми** шиплы ботинкалар **3.** (*выступ на деревянной детали*) чыгынты

шипе́ние *с см.* **шипе́ть**

шип||е́ть *несов.* **1.** чыжылдау; (*о гусе*) ысылдау, ыслау; (*о паре, воздухе*) шыш итү; **мя́со ~и́т на сковороде́** табада ит чыжылдый; **спи́чка ~и́т и га́снет** шырпы чыжылдый да сүнә **2.** (*ворчать*) ысылдау, мыгырдану

шипо́вник *м* **1.** (*растение*) гөлҗимеш, гөләп **2.** (*плод*) гөлҗимеш

шипу́ч||ий, -ая, -ее (*о напитках*) чыжылдый торган, чемерди торган

шипя́щ||ий, -ая, -ее: **~ие согла́сные** *лингв.* чыжылдаучы тартыклар

ширин||а́ *ж* киңлек, иң, калынлык; **~а́ реки́** елга киңлеге; **~а́ тка́ни** тукыма иңе; **~о́й в пять ме́тров** биш метр киңлегендә; **~о́й в па́лец** бармак калынлыгында

шири́нка *ж* чалбар изүе, ыштан изүе

ши́рить *несов. что* киңәйтү, җәелдерү; **~ движе́ние за ми́р** тынычлык өчен хәрәкәтне киңәйтү

ши́ри||ться *несов.* киңәю, җәелү

ши́рм||а *ж прям., перен.* ширма, пәрдә; **крова́ть за ~ами** ширма артындагы карават; **служи́ть ~ой** *кому-чему-л. кемгәдәр* пәрдә булып тору; ширма булып хезмәт итү; **за ~ой гро́мких слов** яңгыравыклы сүзләр пәрдәсе артында

широ́к||ий, -ая, -ое **1.** киң, инле; **~ие пле́чи** киң җилкәләр; **~ая у́лица** киң урам; **~ая пло́щадь** киң мәйдан; **~ая ле́нта** киң тасма **2.** иркен, киң; **~ий пиджа́к** иркен пиджак **3.** иксез-чиксез, киң; **~ие просто́ры** иксез-чиксез киңлекләр; **наступле́ние на ~ом фро́нте** киң фронт буйлап һөҗүм итү **4.** *перен.* киң, зур; **~ий спрос** киң сорау; **~ий сбыт** киң сату; **в ~их масшта́бах** киң масштабларда; **в ~ом смы́сле сло́ва** сүзнең киң мәгънәсендә **5.** *перен.* киң катлау, киң; **~ая обще́ственность** киң катлау җәмәгатьчелек; **~ие слои́ населе́ния** халыкның киң катлаулары; **това́ры ~ого потребле́ния** киң куллану товарлары; **~ие возмо́жности** киң мөмкинлекләр; **~ое распростране́ние техни́ческих зна́ний** техник белемнәрне киң тарату **6.** *перен.* киң; **у него́ ~ая нату́ра** ул киң холыклы ♦ **~ая улы́бка** киң елмаю; **[сде́лать] ~ий жест** зур юмартлык [күрсәтү]; **~ий о́браз жи́зни** мул тормыш алып бару

ШИР-ШЛЯ

широко- *рус телендәге кушма сүзләрнең беренче кисәге, татар теленә «киң» сүзе белән тәрҗемә ителә, мәс.* **ширококры́лый** киң канатлы

широковеща́тельный, -ая, -ое *ирон.* шау-шулы, күпне вәгъдә итүче; **~ые заявле́ния** күпне вәгъдә итүче белдерүләр

широкогру́дый, -ая, -ое киң күкрәкле; **~ челове́к** киң күкрәкле кеше

ширококоле́йный, -ая, -ое *ж.-д.* киң колеялы; **~ая доро́га** киң колеялы юл

ширококо́стный, -ая, -ое эре сөякле; **~ челове́к** эре сөякле кеше

широколи́ственный, -ая, -ое яфраклы; куе яфраклы; **~ лес** яфраклы урман

широколи́цый, -ая, -ое киң битле, киң йөзле; тулы йөзле

широкопле́чий, -ая, -ое киң җилкәле, киң кулбашлы; **~ па́рень** киң җилкәле егет

широкопо́лый, -ая, -ое (*о шляпе*) киң кырыйлы; (*об одежде*) киң чабулы

широкоэкра́нный, -ая, -ое киң экранлы; **~ фильм** киң экранлы фильм

широ́т||а *ж* **1.** киңлек, иркенлек; **~а́ взгля́дов** карашлар киңлеге; **~а́ познáний** танып-белү киңлеге **2.** *геогр.* киңлек; **на пятидеся́том гра́дусе се́верной ~ы́** төньяк киңлегенең илленче градусында

ширпотре́б *м* киң куллану товарлары

ширь *м* киңлек; **степна́я ~** дала киңлеге; **необозри́мая ~, поле́й** кырларның иксез-чиксез киңлеге ♦ **во всю́ ~** бөтен киңлегенә

ши́т||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **шить**; **2.** чигүле, чигелгән; **~ое полоте́нце** чигүле сөлге; **~ый во́рот руба́шки** күлмәкнең чигүле якасы **3.** (*сшитый*) теккән; тегелгән; **~ые ремни́** теккән каеш

шит||ь *несов.* **1.** *что и без доп.* тегү, тектерү; **~ь пальто́** пальто тегү; **~ь сапоги́** күн итек тектерү; **~ь на маши́нке** машина белән тегү; **учи́ться ~ь** тегүгә өйрәнү **2.** *чем, по чему* (*вышивать*) чигү; **~ь шёлком** ефәк белән чигү ♦ **~ о-кры́то** беленмәде, эзе дә калмады, сизелмәде

шить||ё *с* **1.** *см.* **шить**; **~ё оде́жды** кием тегү; **ку́рсы кро́йки и ~я́** кием кисү һәм тегү курслары; **ручно́е ~ё** кулдан тегелгән әйбер **2.** (*вышивка*) чигү, чигелгән бизәк; **золото́е ~ё** алтын белән чигелгән бизәк

ши́фер *м* шифер; **дом крыт ~ом** йорт шифер белән ябылган

шифо́н *м* шифон (*юка тукыма*)

шифо́нов||ый, -ая, -ое шифон ...ы, шифон ...; **~ая блу́зка** шифон блузка

шифонье́р *м* шифоньер

шифр *м* **1.** (*условная азбука*) шифр; **ключ к ~у** шифр ачкычы **2.** (*библиотечный*) билге, шифр

шифрова́льный, -ая, -ое шифровкалау ...ы, шифр ...ы; **~ отде́л** шифровкалау бүлеге

шифрова́льщик *м* шифровкалаучы, шифрлаучы

шифро́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **шифрова́ть**; **2.** шифрлы; **~ая телегра́мма** шифрлы телеграмма

шифрова́ть *несов. что* шифрлау, шифр белән язу

шифро́вка *ж* **1.** *см.* **шифрова́ть**; **2.** (*текст*) шифрлы язу

ши́хта *ж тех.* шихта (*катнашма*)

шиш *м* көжә тоягы ♦ **ни ~á** *прост.* бернәрсә дә, берни дә

ши́шк||а *ж* **1.** күркә; **сосно́вая ~а** нарат күркәсе **2.** шеш, оры, кабырчык; **у него́ на лбу вскочи́ла ~а** маңгаена шеш чыкты **3.** *прост.* (*важная персона*) түрә ♦ **~а на ро́вном ме́сте** *ирон.* тигез җирдә түмгәк

шишкова́тый, -ая, -ое орылы, төерле, шешле; **~ лоб** орылы маңгай

шишкови́дн||ый, -ая, -ое шешсыман, орысыман; **~ая железа́** *анат.* шешсыман биз

шкала́ *ж* шкала; **~ радиоприёмника** радиолгыч шкаласы; **~ термо́метра** термометр шкаласы; **~ зарпла́ты** эш хакы шкаласы

шкату́лка *ж* тартмачык, шкатулка ♦ **музыка́льная ~** музыкаль тартма

шкаф *м* шкаф; **книжный ~** китап шкафы; **несгора́емый ~** янмый торган шкаф; **суши́льный ~** киптерү шкафы

шквал *м* **1.** өермә, өермәле җил, давыл; **налете́л ~** өермәле җил күтәрелде **2.** *перен.* көчле атыш, өермә; **~ огня́** үт өермәсе; **артиллери́йский ~** артиллериянең көчле атышы

шква́льн||ый, -ая, -ое **1.** өермәле, давыллы; **~ый ве́тер** өермәле җил **2.** *перен.* бик көчле, дәһшәтле; **~ый ого́нь пулемётов** пулемётларның бик көчле уты; **подве́ргнуть ~ому обстре́лу** бик көчле атышка тоту

шкив *м тех.* шкив; **веду́щий ~** әйдәүче шкив; **ремённый ~** каешлы шкиф

шки́пер *м мор.* шкипер

шко́л||а *ж* **1.** мәктәп; **нача́льная ~а** башлангыч мәктәп; **сре́дняя ~а** урта мәктәп; **вы́сшая ~а** югары мәктәп; **вече́рняя ~а** кичке мәктәп; **спорти́вная ~а** спорт мәктәбе; **~а-интерна́т** интернат мәктәп **2.** *перен.* мәктәп, тәҗрибә; **пройти́ хоро́шую ~у в а́рмии** армиядә яхшы мәктәп үтү; **~а жи́зни** тормыш мәктәбе **3.** мәктәп, юнәлеш; **ре́пинская ~а в жи́вописи** сынлы сәгатьтә Репин мәктәбе; **созда́ть свою́ ~у в нау́ке** фәндә үз мәктәбеңне тудыру

шко́льник *м* укучы, мәктәп баласы

шко́льница *ж* укучы кыз, мәктәптә укучы кыз бала

шко́льническ||ий, -ая, -ое укучыга хас, мәктәп баласына хас, укучыларча ..., мәктәп балаларыча ...; **~ое поведе́ние** мәктәп баласына хас кыланыш; **~ий отве́т** укучыга хас җавап

шко́льничество *с* [үз-үзеңе] укучы кебек тоту, мәктәп баласы кебек тоту; мәктәпчелек

шко́льн||ый, -ая, -ое мәктәп ...ы; **~ая фо́рма** мәктәп формасы; **~ый во́зраст** мәктәп яше; **~ые кани́кулы** мәктәп каникуллары; **~ые принадле́жности** мәктәп әсбаплары; **~ый това́рищ** мәктәптәш, сабакташ

шкот *м мор.* шкот (*җилкәнне киеру һәм идарә итү баулары*)

шку́р||а *ж* **1.** тире; **~а медве́дя** аю тиресе; **ове́чья ~а** сарык тиресе **2.** *разг.* (*кожура*) кабык, яры **3.** *прост.* баш, җан; **страх за со́бственную ~у** үз җаны өчен курку; **спаса́ть свою́ ~у** үз башын коткару ♦ **быть** *в чьей* **~е** *кемнең дә булса* хәленә төшү; **содра́ть ~у** *с кого* тиресен тунау, тереләй тунау

шку́рк||а *ж* **1.** *уменьш. от* **шку́ра** 1; **2.** *см.* **шку́ра** 2; **3.** *спец.* шомарткыч шомарткыч кәгазь; **наждачная ~а** наждаклы шомарткыч

шку́рник *м разг.* үз файдасын гына күзәтүче, үзен генә кайгыртучы, шкурник

шку́рничество *с разг.* үз файдасын гына күзәтү, үзен генә кайгырту

шлагба́ум *м* шлагбаум, күтәрмә киртә

шлак *м* шлак

шланг *м* шланг, резин эчәк

шлем *м* **1.** *ист.* шлем **2.** шлем, башлык; **про́бковый ~** бөкедән эшләнгән башлык; **водола́зный ~** водолаз шлеме

шлемофо́н *м спец.* шлемофон

шлёпанцы *мн. разг.* артсыз туфли

шлёпать *несов.* **1.** *кого-что, по чему* чабакълау, чәбәкләү, шапылдату **2.** чапылдату, лачкылдату; **~ ту́флями** туфлиләрне чапылдату **3.** *прост.* чапыр-чопыр бару, лачкылдатып бару; **~ по гря́зи** пычрактан чапыр-чопыр бару

шлёпаться *несов. разг.* гөпелдәү, гөрселдәү, шап итеп егылу (килеп төшү)

шлёпнуть *сов.* **1.** *однокр. кого-что, по чему* шап итеп сугу, шапылдатып сугу **2.** *кого, прост.* (*убить*) чәкү, атып үтерү

шлёпнуться *сов. однокр. см.* **шлёпаться**

шлепо́к *м* чалт (шап) итеп сугу, чалтыратып жибәрү, шап итеп сугып жибәрү; **дать шлепка́** *кому-л.* шап итеп сугу

шлея́ *ж* эшлея

шлифова́льный, -ая, -ое шомарту ...ы; **~ стано́к** шомарту станогы

шлифова́льщик *м* шомартучы

шлифова́льщица *ж* шомартучы хатын (кыз)

шлифова́ть *несов. что* **1.** шомарту; **~ дета́ль** детальне шомарту **2.** (*полировать*) ялтырату **3.** *перен.* яхшырту, шомарту, камилләштерү; **~ свой стиль** үз стиленңне шомарту

шлифо́вка *ж см.* **шлифова́ть**

шлюз *м в разн. знач.* **шлюз**

шлю́зн||ый, -ая, -ое шлюз ...ы; **~ые воро́та** шлюз капкалары

шлюзова́ть *сов., несов. что* **1.** (*реку*) шлюз кору, шлюз төзү, шлюз ясау **2.** (*суда*) шлюз аша уздыру

шлюзов||о́й, -а́я, -о́е *см.* **шлю́зный**; **~о́е устро́йство** шлюз җайланмасы

шлю́пка *ж* шлюпка; **спаса́тельная ~** коткару шлюпкасы

шля́п||а *ж* **1.** эшләпә; **соло́менная ~а** салам эшләпә; **без ~ы** эшләпәсез; **он был в ~е** ул эшләпәдән иде **2.** *разг.* (*о растяпе*) булдыксыз, пешмәгән, эшләпә ♦ **дело́ в ~е** эш пеште

шля́пка *ж* **1.** кеченә эшләпә **2.** (*гвоздя, шурупа*) баш; (*гриба*) эшләпә

шля́пник *м* эшләпәче, эшләпә ясаучы

шля́пница *ж* эшләпәче хатын (кыз)

шля́ться *несов. прост.* тик йөрү, буш йөрү, селкенеп йөрү, каңгырап йөрү

шлях *м* (*дорога*) шлях, олы юл

шля́хта *ж ист.* шляхта (*элекке Польшада: вак дворяннарның гомуми исеме*)

шля́хтич *м ист.* шляхтич (*элекке Польшада: вак дворян*)

шмели́ный, -ая, -ое төклетура ...ы; **~рой** төклетура күче

шмель *м* төклетура, кормыш

шмы́гать *несов. разг.* (*быстро двигаться*) тыз-быз йөрү, арлы-бирле йөрү, кереп-чыгып йөрү ♦ **~ но́сом** борын тарту

шмыгну́ть *сов. однокр. разг.* чыгып (кереп, үтеп) китү; **~ в дверь** ишектән кереп китү; **~ меж куст о́в** куаклар арасыннан үтеп китү

шни́цель *м* шницель

шнур *м* **1.** шнур, бау; **шёлковый ~** ефәк бау; **запа́льный ~** яндыру шнуры; **ме́рный ~** *топ.* үлчәү шнуры **2.** *эл.* шнур, үткәргеч

шнурова́ть *несов. что* **1.** шнурлау, бәйләү; **~ боти́нки** ботинканы шнурлау **2.** шнур белән тегү, шнурлау; **~ инвента́рную кни́гу** инвентарь кенәгәсен шнурлау

шнуро́вк||а *ж* **1.** *см.* **шнурова́ть; 2.** шнур; **распусти́ть ~у** шнурны чишү

шнур||о́к *м* бау, шнур; **~ки́ для боти́нок** ботинка бавы

шныря́ть *несов. разг.* әрле-бирле йөрү, йөренеп тору; **~ в толпе́** төркем эчендә әрле-бирле йөрү; ♦ **~ глаза́ми** күзләре белән капшау

шов *м* **1.** җөй; **маши́нный ~** машина җөе; **распоро́ть по шву** җөеннән сүтү **2.** җөй, ябыштырылган урын; (*хирургический*) тегү; **сварно́й ~** *тех.* эретеп ябыштырылган җөй; **заклёпочный ~** *тех.* заклёпка җөе; **черепны́е швы** *анат.* баш сөяге җөйләре; **наложи́ть швы** *мед.* яраны тегү; **снять швы** *мед.* җепләрен алу (*тегелгән яра төзәлгәннән соң*) ♦ **ру́ки по швам** кулларны гәүдә буенча төшереп [тору]: **по всем швам трещи́т** *что берәр нәрсә* бөтенләй җимерелергә тора

шовини́зм *м* шовинизм, шовинистлык

шовини́ст *м* шовинист, шовинизм тарафдары

шовинисти́ческ||ий, -ая, -ое шовинистик, шовинизм ...ы; **~ая пропага́нда** шовинистик пропаганда

шок *м мед.* шок; **не́рвный ~** нерв шогы; **в состоя́нии ~а** шок хәлендә

шоки́ровать *несов. кого-что* уңайсызландыру, оялту, оялдыру; **~ окружа́ющих свои́м поведе́нием** үзенең тәртибе белән тирә-юньдәгеләрне уңайсызландыру

шокола́д *м* шоколад; **пли́тка ~а** шоколад плиткасы

шокола́дка *ж* шоколадка (*кечкенә шоколад плиткасы*)

шокола́дн||ый, -ая, -ое **1.** шоколад ...ы; **~ые конфе́ты** шоколад конфетлары; **~ый торт** шоколад торты; **~ый набо́р** шоколадлар җыелмасы **2.** (*о цвете*) шоколад төсендәге, куе көрән; **~ый зага́р** шоколад төсендә каралу

шо́мпол *м* шомпол

шо́мпольн||ый, -ая, -ое **1.** шомпол ...ы; **~ый наконе́чник** шомпол очлыгы **2.** көпшәдән корыла торган; **~ые ру́жья** көпшәдән корыла торган мылтыклар

шо́рник *м* сбруйчы; каешчы

шо́рн||ый, -ая, -ое каеш сбруй ...ы; **~ые изде́лия** каеш сбруй әйберләре; **~ая мастерска́я** каеш сбруй остаханәсе

шо́рох *м* кыштырдау, шыштырдау; **~ сухи́х ли́стьев** коры яфраклар кыштырдавы; **послы́шался ~** кыштырдау тавышы ишетелде

шо́рты *только мн.* шорт

шо́р||ы *только мн.* **1.** (*наглазники*) күзлегерек **2.** (*упряжь*) мичәү ♦ **взять** *кого* **в ~ы** *кемнең дә булса* хәрәкәтен чикләү; **держа́ть** *кого* **в ~ах** *кемне дә булса* тышауда тоту; **~ы на глаза́х у** *кого кемнең дә булса* күзләрен томалау

шоссе́ *с нескл.* шоссе, таш юл; **асфальти́рованное ~** асфальт юл

шоссе́йн||ый, -ая, -ое шоссе ..., шоссе ...ы; **~ая доро́га** шоссе юл; **~ые рабо́ты** шоссе эшләре

шотла́ндец *м* шотланд, шотландияле, Шотландия кешесе

шотла́ндка I *ж* шотландияле хатын (кыз)

шотла́ндка II *ж* (*клетчатая ткань*) шотландка, шакмаклы тукыма

шотла́ндский, -ая, -ое Шотландия ...ы; шотланд[лар] ...ы; **~ язы́к** шотланд теле

шотла́ндцы *мн.* шотландлар; шотландияләр, Шотландия халкы

шофёр *м* шофёр

шофёрск||ий, -ая, -ое шофёр ...ы; шофёрлык ...ы; **~ие права́** шофёрлык хокуклары

шпа́га *ж* шпага

шпага́т *м* шпагат, ник бау

шпажи́ст *м спорт.* шпагачы; **соревнова́ние ~ов** шпагачылар ярышы

шпаклева́ть *несов. что* шпаклёвкалау, тигезләп сылау; **~ пол** идәнне тигезләп сылау

шпаклёвка *ж* **1.** *см.* **шпаклева́ть; 2.** (*замазка*) шпаклёвка

шпаклёвочн||ый, -ая, -ое шпаклёвка ...ы; шпаклёвкалау ...ы; сылау ...ы; **~ые рабо́ты** сылау эшләре

шпа́ла *ж ж.-д.* шпал

шпале́р||ы *мн.* ике рәт, ике саф, шпалер; **солдаты стоя́т ~ами** солдатлар ике саф булып торалар

шпана́ *ж собир. груб.* шпана, жуликлар

шпангу́т *м мор., ав.* **1.** (*поперечный брус*) аркылы борыс **2.** *собир.* кабырга

шпа́нск||ий; ~ая му́шка *зоол.* шпан чебене, яшькелт коңгыз

шпарга́лк||а *ж разг.* шпаргалка; **говори́ть по ~е** шпаргалкадан карап сөйләү

шпа́рит||ь *несов.* **1.** *что* (*кипятком*) пешекләү; **~ь у́тку** үрдәк пешекләү **2.** *прост.* әлдертү; (*о речи*) сиптерү; **~ь по у́лице** урам буйлап әлдертү; **шпарь отсю́да!** әлдерт моннан!; **он так и ~ по англи́йски** ул инглизчә сиптерә генә

шпат *м мин.* шпат; **полево́й ~** кыр шпаты

шпа́тель *м* **1.** (*для шпаклёвки*) калак **2.** (*инструмент художника*) пычак **3.** *мед* шпатель

шпигова́ть *несов. кого-что* шпиклау, дуңгыз мае тутыру; **~ за́йца свины́м са́лом** куян итен дуңгыз мае белән шпиклау

шпик I *м* (*сало*) дуңгыз мае

шпик II *м разг.* (*сыщик*) шымчы, шпик

шпиль *м* **1.** оч; **~ ба́шни** манара очы **2.** (*длинный гвоздь*) зур кадак

шпи́льк||а *ж* **1.** (*для волос*) шпилька, чәч кыстыргыч **2.** *сапожн.* шпилька **3.** *перен.* чәнечкеле сүз, энә; **подпуска́ть ~и** *кому-л. кемгәдер* чәнечкеле сүзләр әйтү

шпина́т *м* шпинат (*яшелчә*)

шпингале́т *м* **1.** эшермә, бик **2.** *прост.* (*о маленьком бойком мальчишке*) шаян малай

шпи́ндель *м тех.* шпиндель, күчәр

шпио́н *м* шпион

шпиона́ж *м* шпионлык

шпио́нить *несов.* **1.** (*заниматься шпионажем*) шпионлык итү **2.** *за кем-чем* (*выслеживать*) шымчылык итү, күзәтү

шпио́нск||ий, -ая, -ое шпион [нар] ...ы; шпионлык ...ы; **~ая организа́ция** шпионнар оешмасы; **~ий центр** шпионлык үзәге

шпиц *м* шпиц (*эт*)

шплинт *м тех.* шплинт, беркеткеч

шпон м, **шпо́на** *ж полигр.* шпон (*юка металл пластинка*)

шпо́р||а 1. шпор; **дать ~ы коню́** атка шпор бирү **2.** типке; **~ы у петуха́** әтәчнең тыпкеләре

шпо́рить *несов. кого* шпорлау; **~ ло́шадь** атны шпорлау

шприц *м* шприц

шпро́ты *мн.* шпрот (**1.** *диңгез балыгы* **2.** *вак балык консервасы*)

шпу́лька *ж* шүре, кәтүк

шпу́нт *м тех.* шпунт (*тактада яки борыстагы буйдан-буй чыгынты яки ырмау*)

шрам *м* яра эзе, җөй

шрапне́ль *ж* шрапнель (*шартлап ярыла торган, күп пулялы снаряд*)

шрапне́льный, -ая, -ое шрапнель ...ы; шрапнельле; **~ ого́нь** шрапнельле ут; **~ снаря́д** шрапнельле туп

шрифт *м* шрифт, хәреф; **кру́пный ~** эре шрифт; **ме́лкий ~** вак хәреф; **типогра́фский ~** типография шрифты; **курси́вный ~** курсив хәрефләр

штаб *м* **1.** штаб; **~ полка́** полк штабы **2.** *перен.* (*руководящий о́рган*) штаб

шта́бел||ь *м* әрдәнә; **~ь дров** утын әрдәнәсе; **укла́дывать** *что-л.* **в ~ь** *берәр нәрсәне* әрдәнәгә өю

штаб-квартира *ж* штаб-квартира (*штаб урнашкан урын*)

штабн||о́й, -а́я, -о́е **1.** штаб ...ы; **~а́я ро́та** штаб ротасы **2.** *в знач. сущ.* **~о́й** *м* штабчы, штабта хезмәт итүче

штаке́тник *м* **1.** (*планки*) штакетник **2.** (*забор*) штакетник, рәшәткә

ШТА-ШУЛ

штамп *м* 1. (*печать*) мөһер; **поста́вить ~** мөһер сугу 2. *тех.* (*инструмент*) пресс калыбы; (*для чеканки*) чакма 3. *перен.* шаблон, штамп; **речево́й ~** сөйләмдәге штамп

штампова́льный, -ая, -ое *тех.* калыплау ...ы; штамповкалау ...ы; **~ стано́к** штамповкалау станогы

штампо́ванн||ый, -ая, -ое 1. *прич. от* **штампова́ть**; 2. *тех.* штамповкалаган; **~ая дета́ль** штамповкаланган деталь 3. *перен.* штамп ...; **~ые фра́зы** штамп гыйбарәләр

штампова́ть *несов. что* 1. (*ставить штемпель*) мөһерләү, мөһер сугу 2. *тех.* штамповкалау 3. *перен.* әзер өлге (калып) белән эшләү

штампо́вка *ж* 1. *см.* **штампова́ть** 1, 2; **~ дета́лей** детальләрне штамповкалау; **холо́дная ~** салкын штамповка 2. (*изделие*) штамповка

штампо́вщик *м* штамповкачы

штампо́вщица *ж* штамповкачы хатын (кыз)

шта́нг||а *ж* штанга; **подня́ть ~у** штанга күтәрү

штангенци́ркуль *м* штангенциркуль (*әйберләр калынлыгын үлчәү коралы*)

штанги́ст *м* штангачы

штани́на *ж* балак

штаны́ *только мн. разг.* ыштан, чалбар

шта́пель *м* штапель (*тукыма*)

штат I штат; **Соединённые Шта́ты Аме́рики** Америка Кушма Штатлары

штат II *м* штат; **~ преподава́телей** укытучылар штаты; **зачи́слить в ~** штатка алу; **сокраще́ние ~ов** штатларны кыскарту; **утвержде́ние ~ов** штатларны раслау

штати́в *м* төплек, өчаяк, штатив; **~ фотоаппара́та** фотоаппарат өчаягы; **~ микроско́па** микроскоп штативы

шта́тн||ый, -ая, -ое штаттагы, штатта торучы; **~ая до́лжность** штаттагы вазифа; **~ый преподава́тель** штатта торучы укытучы

шта́тск||ий, -ая, -ое 1. штатский; **~ая оде́жда** штатский кием 2. *в знач. сущ.* **~ий** *м* штатский; **тро́е ~их** өч штатский 3. *в знач. сущ.* **~ое** *с* штатский кием; **он был в ~ом** ул штатский киемнән иде

штемпелева́ть *несов. что* штемпельләү, штемпель сугу, штемпель басу

што́мпель *м* штемпель; **почто́вый ~** почта штемпеле

што́мпельн||ый, -ая, -ое штемпель ...ы; **~ая кра́ска** штемпель буявы

што́псель *м эл.* штепсель

што́псельн||ый, -ая, -ое штепсель ...ы; **~ая розе́тка** штепсель розеткасы; **~ая ви́лка** штепсель вилкасы; **~ое соедине́ние** штепсель тоташтыруы

штибле́ты *мн.* штиблет (*ирләр ботинкасы*)

штилев||о́й, -ая, -о́е тып-тын, җилсез; **~а́я пого́да** тып-тын һава

штиль *м* штиль, җилсезлек

што́льня *ж горн.* штольня

што́пальн||ый, -ая, -ое тупчу ...ы; **~ая игла́** тупчу энәсе

што́пальщица *ж* тупчучы хатын (кыз)

што́пан||ый, -ая, -ое тупчылган, тупчып ямалган; **~ые чулки́** тупчылган оеклар

што́пать *несов. что* тупчу, тупчып ямау; **~ чулки́** оек тупчу

што́пка *ж* 1. *см.* **што́пать**; 2. (*нитки*) тупчу җебе

што́пор *м* 1. (*для бутылок*) бөке суыргыч 2. *ав.* штопор; **войти́ в ~** штопорга керү; **вы́йти из ~а** штопордан чыгу

што́порить *несов. ав.* штопор ясау, штопор ясап төшү

што́р||а *ж* пәрдә, штор; **подня́ть ~ы** пәрдәләрне күтәрү

шторм *м* шторм, давыл; **поднялся́ ~** шторм кузгалды

шторми́||ть *несов.* штормлау, штормлап тору, давыллап тору; *с* **утра́ ~ло** иртәдән бирле давыллап тора

штормов||о́й, -а́я, -о́е 1. шторм ...ы; давыл ...ы; **~о́й я́корь** шторм якоре 2. штормлы, давыллы; **~а́я пого́да** давыллы һава; **~о́й ве́тер** давыллы җил

што́фн||ый, -ая, -ое штофтан тегелгән; штоф белән тышланган; **~ые порть́е́ры** штофтан тегелгән ишек чаршаулары; **~ая ме́бель** штоф белән тышланган мебель

штраф *м* штраф; **плати́ть ~** штраф түләү; **взима́ть ~** штраф алу; **наложи́ть ~** штраф салу

штрафни́к *м разг.* штрафник (1. *гаскәри* 2. *спортчы*)

штрафн||о́й, -а́я, -о́е штраф ...ы; **~ые де́ньги** штраф акчасы; **~о́й уда́р** *спорт.* штраф тибүе

штрафова́ть *несов. кого-что* штраф салу, штраф түләтү

штрейкбре́хер *м* штрейкбрехер; хыянәтче

штрейкбре́херство *с* штрейкбрехерлык; хыянәтлек

штрек *м горн.* штрек, жир асты юлы

штри́пка *ж* балак тасмасы; **брю́ки со ~ми** балагы тасмалы чалбар

штрих *м прям., перен.* штрих, нечкә сызык; **~и́ на бума́ге** кәгазьдәге нечкә сызыклар; **любопы́тный ~ в расска́зе** хикәядәге кызыклы штрих

штрихова́ть *несов. что* штрихлау, нечкә сызыклар сызу; **~ чертёж** сызымны штрихлау

штрихо́вк||а *ж* 1. *см.* **штрихова́ть**; 2. штрихлар, нечкә сызыклар; **нанести́ густу́ю ~у** еш итеп нечкә сызыклар сызу

штрихово́й, -а́я, -о́е штрихлы, нечкә сызыклы; **~ рису́нок** штрихлы рәсем

штуди́ровать *несов. кого-что* өйрәнү, җентекләп өйрәнү; **~ кла́ссиков филосо́фии** фәлсәфә классикларын җентекләп өйрәнү

шту́к||а *ж* 1. данә, бер данә; **пять штук я́блок** биш данә алма; **по рублю́ ~а** бер данәсе бер сум 2. (*предмет, явление*) әйбер, нәрсә; **что за ~у ты купи́л?** син нинди әйбер сатып алдың?; **тру́дная ~а матема́тика** авыр нәрсә математика 3. *разг.* (*хитрость, проделка*) хәл, эш; хәйлә, уйдырма, әкәмәт; **его́ на э́ту ~у не поймáешь** аны бу хәйләгә тота алмыйсың 4. (*рулон ткани*) оч; **~а сукна́** бер оч постау ♦ **вот так ~а!** менә сиңа мә!

штукату́р *м* штуктур, штукатурчы

штукату́рить *несов. что* штукатурлау, сылау; **~ дом** йортны штукатурлау

штукату́рка *ж* 1. *см.* **штукату́рить**; 2. штукатурка; **суха́я ~** коры штукатурка; **сыра́я ~** юеш штукатурка; **~ отвали́лась** штукатуркасы күбып төшкән

штукату́рн||ый, -ая, -ое штукатурка ...ы; **~ые рабо́ты** штукатурка эшләре

штукова́ть *несов. что* (*җәве беленмәслек итеп*) тегү, ямау; тупчу; **~ ды́рку на брю́ках** чалбар ертыгын җәе беленмәслек итеп ямау

штукóвка *ж* 1. *см.* **штукова́ть**; 2. (*место*) тупчылган урын

штурва́л *м* штурвал; **~ комба́йна** комбайн штурвалы; **~ самолёта** самолёт штурвалы

штурва́льн||ый, -ая, -ое 1. штурвал ...ы; **~ое колесо́** штурвал тәгәрмәче 2. *в знач. сущ.* **~ый** *м* штурвалчы, штурвалда торучы

штурм *м* штурм, штурмлау; **~ кре́пости** кальганы штурмлау; **~ ко́смоса** космосны штурмлау; **взять ~ом** штурм белән алу; **идти́ на ~** *прям., перен.* штурмга бару

шту́рман *м* штурман; **~ да́льнего пла́вания** ераккa йөзү штурманы

шту́рманск||ий, -ая, -ое штурман [-нар] ...ы; **~ое учи́лище** штурманнар училищесы

штурмова́ть *несов. кого-что* штурмлау, штурм ясау; **~ кре́пость** кальганы штурмлау

штурмови́к *м ав.* штурмовик (*хәрби самолёт һәм аның очучысы*)

штурмов||о́й, -а́я, -о́е штурм ...ы; штурм ясау ...ы; **~а́я гру́ппа** штурм төркеме; **~ые ле́стницы** штурм баскычлары; **~а́я авиа́ция** штурм авиациясе

штурмовщи́н||а *ж неодобр.* штурмчылык; **рабо́тать без ~ы** штурмчылыксыз эшләү

шту́чн||ый, -ая, -ое данәләп, берәмләп сатыла торган; **~ый това́р** данәләп сатыла торган товар; **~ая прода́жа** данәләп сату

штык *м* штык; **коло́ть ~о́м** штык белән чәнчү; **пойти́ (идти́) в ~и́** штыкка бару; **отря́д в ты́сячу ~о́в** мең штыклы отряд ♦ **в ~и́ [встре́тить, приня́ть** *и т.д.*] штыкка алу, дошманлашып каршылау; **держа́ться на ~а́х** штык ярдәмендә тору, гаскәр көче белән тору; **как ~ тёп-тёгәл, һичшиксез; придёшь ве́чером? — Как ~!** кичен киләсеңме? — Һичшиксез!

штыков||о́й, -а́я, -о́е штык ...ы; **~а́я ра́на** штык ярасы; **~а́я ата́ка** штык һөҗүме

шу́ба *ж* тун; **ли́сья ~** төлке тун

шуга́ *ж* зим, сил

шу́лер *м* шулер, хәйләләп уйнаучы; алдакчы

шу́лерск||ий, -ая, -ое шулер[лар] ...ы; **~ая игра́** шулер уены; **~ий приём** шулер алымы

шу́лерство *с* 1. (*нечестная игра в карты*) шулерлык, хәйләләп уйнау 2. *разг.* (*мошенничество*) алдакчылык

шум *м* 1. тавыш, шау, шау-шу, шаулау; ~ **по́езда** поезд шаулавы; ~ **ле́са** урман шавы; **в за́ле** ~ залдагы шау-шу; **подня́ть** ~ тавыш куптару 2. *разг.* (*ссора*) тавыш, шау-шу, кычкырыш 3. *перен.* шау-шу, тавыш; **кни́га вы́звала** ~ китап шау-шу кузгатты ♦ ~ **в голове́** баштагы шау; ~ **в уша́х** колак шавы

шум||е́ть *несов.* 1. шаулау; **лес** ~**и́т** урман шаулый; **самова́р** ~**и́т** самовар шаулый; **мо́ре** ~**и́т** диңгез шаулый 2. *разг.* (*ссориться*) тавышлану, шаулау, шау-шу күтәрү, кычкырышу 3. *разг.* шаулау, шау-шу кузгату; **на́до поме́ньше** ~**е́ть о свои́х успе́хах** уңышларың турында азрак шаулау кирәк ♦ ~**и́т в голове́** баш шаулый; ~**и́т в уша́х** колак шаулый

шуми́х||а *ж разг.* шау-шу, тавыш; **подня́ть** ~**у вокру́г** *чего-л. берәр нәрсә тирәсендә* шау-шу күтәрү

шумли́в||ый, -ая, -ое тавышлы; шаулы, шау-шулы

шу́мно *нареч.* 1. тавышланып, шаулашып, шаулап, шау-шу белән; **собра́ние прошло́** ~ җыелыш шау-шу белән узды; ~ **обсужда́ть** *что-л. берәр нәрсәне* шаулашып тикшерү 2. *в знач. сказ. безл.* тавышлы, шаулы, шау-шулы; **на у́лице** ~ урам шау-шулы

шу́мн||ый, -ая, -ое *в разн. знач.* тавышлы; шау-шулы, шаулы; ~**ая у́лица** тавышлы урам; ~**ый день** шау-шулы көн; ~**ое собра́ние** шау-шулы җыелыш; ~**ый успе́х** шау-шулы уңыш

шумо́вка *ж* сөзгеч, тишекле чүмеч

шумо́к *м* әкрен тавыш, ишетелер-ишетелмәс тавыш ♦ **под** ~ шыпырт кына, астыртын, кеше күрмәгәндә

шу́рин *м* (*старший брат жены*) каенага; (*младший брат жены*) каенэне

шурова́ть *несов.* 1. *что, тех.* болгату (*яна торган мичне*) 2. *прост.* (*энергично действовать*) шатырдатып эшләү, тырыштыру

шурф *м горн.* шурф

шурша́ние *с см.* **шурша́ть**

шурш||а́ть *несов.* кыштырдау, шыштырдау; ~**а́т камыши́** камышлар кыштырдый; **под нога́ми** ~**и́т песо́к** аяк астында ком шыштырдый

шу́стрый, -ая, -ое җитез, тере, өлгер; ~ **ма́льчик** җитез малай

шут *м* 1. (*при барском или царском дворе*) шамакай 2. *перен. пренебр.* мәзәкче, көлдерүче, сәвәләй; **не строй из себя́** ~**а́** үзеңне мәзәкче итеп куйма ♦ **на кой** ~**?** ни шайтаныма?; ~ **горо́ховый** шамакай (*буш кеше турында*); ~ **его́ зна́ет!** шайтан белсенме аны!

шут||и́ть *несов.* 1. шаяру, җорлану, шаярышу; ~**и́ть с детьми́** балалар белән шаяру; **остроу́мно** ~**и́ть** тапкыр сүзләр әйтеп җорлану 2. шаярту; **не ве́рьте ему́, он шу́тит** ышанмагыз аңа, ул шаярта 3. *над кем* (*смеяться*) көлү, мыскыллап көлү, мыскыл итү 4. *чем* шаяру; **нельзя́** ~**и́ть свои́м здоро́вьем** сәламәтлеген белән шаярырга ярамый ♦ ~**и́ть с огнём** ут белән шаяру

шу́тк||а *ж* шаярту, мәзәк, кызык; **глу́пая** ~**а** акылсыз шаярту; **дура́цкая** ~**а** тиле шаярту; **первоапре́льская** ~**а** беренче апрель шаяртуы; **сказа́ть** *что-л.* **в** ~**у** мәзәк өчен *берәр нәрсә* әйтү; **не обижа́ться на** ~**и** шаяртуларга үпкәләмәскә ♦ **кро́ме шу́ток** шаяртып әйтмим, шаяртмыйча; **не в** ~**у** *в знач. сказ.* уен түгел, уен эш түгел; **не на** ~**у** чынчынлап, чынлап; ~**а ли [сказа́ть]** *в знач. вводн. сл.* уен эшмени; ~**и в сто́рону** шаяруларны бер якка, шаяруларны калдырып тор; **шу́тки пло́хи** *с кем-чем кем яки нәрсә белән* шаярып булмый

шутли́в||ый, -ая, -ое 1. шаяртучан, шаяртырга яратучан, мәзәкчел, җор; ~**ый челове́к** җор кеше 2. шаян, көлкеле; ~**ый разгово́р** шаян сөйләшү; ~**ая пе́сенка** шаян җыр

шутни́к *м* җор, мәзәкче, шаяртучан, шаяртырга яратучы; шаян

шутни́ца *ж* җор, мәзәкче, шаяртырга яратучы хатын (кыз)

шутовск||о́й, -а́я, -о́е 1. шамакай [-лар] ...ы; сәвәләй[ләр] ...ы; ~**о́й наря́д** шамакайлар киеме 2. шамакайларча ..., сәвәләйләрчә ...; ~**и́е вы́ходки** шамакайларча кыланышлар

шутовство́ *с* шамакайлык, сәвәләйлек

шу́точн||ый, -ая, -ое күңелле, көлкеле, кызыклы, шаян; ~**ый расска́з** күңелле хикәя; ~**ый разгово́р** кызыклы сөйләшү; ~**ое про́звище** көлкеле кушамат; ~**ое стихотворе́ние** шаян шигырь; ~**ое ли де́ло!** уен эш түгел!, уен эшмени!

шутя́ *нареч.* 1. бик җиңел, җиңел генә, шаярып кына, шаярып; **он** ~ **по́днял тяжёлый чемода́н** ул авыр чемоданны бик җиңел күтәрде 2. шаяртып; **не серди́сь, я э́то сказа́л** ~ ачуланма, мин моны шаяртып әйттем ♦ **не** ~ чынчынлап

шу́шер||а *ж обычно собир. прост.* юкбар кешеләр, әтрәк-әләм; **он со вся́кой** ~**ой зна́ется** ул юк-бар кешеләр белән таныш

шушу́канье *с см.* **шушу́каться**

шушу́каться *несов. с кем и без. доп.* 1. (*шептаться, секретничать*) пышылдашу, чыш-пыш (пыш-пыш) сөйләшү; шыпырт сөйләшү 2. (*сплетничать о ком-л.*) гайбәт сату; ~ **по угла́м** почмакларда пышылдашу

шхе́ры *только мн.* шхерлар

шху́на *ж* шхуна (*җилкәнле судно*)

ш-ш *межд.* тш, тавышланма[гыз], шаулама[гыз]

Щ

щаве́лев||ый, -ая, -ое кузгалак ...ы; ~**ые щи** кузгалак ашы ♦ ~**ая кислота́** *хим.* кузгалак кислотасы

щаве́ль *м* кузгалак; ~ **ко́нский** *бот.* ат кузгалагы; ~ **ма́лый** *бот.* чыпчык кузгалагы

ща́д||ить *несов. кого-что* 1. (*давать пощаду*) аяу 2. (*относиться бережно*) саклау, кызгану, аяу; ~ **своё здоро́вье** үз сәламәтлегеңне саклау; **не** ~ **свои́х сил** үз көчеңне кызганмау

щебёнка *ж разг. см.* **ще́бень**

щебёночн||ый, -ая, -ое вак таш ...ы; вак таш җәелгән; ~**ый заво́д** вак таш заводы; ~**ое основа́ние мостово́й** юлның вак таш җәелгән нигезе

ще́бень *м* вак таш, кирпеч ватыгы

ще́бет *м*, **щебета́ние** *с прям., перен.* чәрелдәү, чәрелдәшү, черелдәү, сайрау; **пти́чий** ~ кошлар чәрелдәве; **де́тский** ~ балалар чәрелдәве

щебета́ть *несов. прям., перен.* чәрелдәү, черелдәү, сайрау; **пти́цы щебе́чут** кошлар черелдәшә; **де́ти щебе́чут** балалар чәрелди

щегол́ *м* купшыл, купшы чыпчык

щеголева́тый, -ая, -ое 1. (*нарядный, модный*) купшы; ~ **костю́м** купшы костюм 2. (*со щегольством одеватый*) купшы (көяз) киенгән; ~ **молодо́й челове́к** купшы киенгән егет

щёголь *м* купшы [киенгән] кеше, фырт [киенгән] кеше, көяз кеше; **он большо́й** ~ ул гаять купшы кеше

щегольско́й, -ая, -ое купшы, фырт, бик көяз; ~ **костю́м** купшы костюм; ~ **вид** купшы кыяфәт

щегольств||о́ *с* купшылык, фыртлык, көязлек, купшыланырга ярату; **отлича́ться** ~**о́м** купшылыгы белән аерылып тору

щеголя́ть *несов.* 1. (*нарядно одеваться*) купшылану, көязләну, купшы (фырт) киену 2. *разг. в чём* купшыланып (көязләнеп) йөрү; ~ **в но́вом пла́тье** яңа күлмәк киеп көязләнеп йөрү 3. *перен. чем* мактану, һавалану, борын чөю; ~ **свои́ми зна́ниями** үзеңең белеме белән мактану

ще́дрость *ж* юмартлык

щедро́ты *мн.*: **от [свои́х] щедро́т** үз кесәңнән, үзеңнән, үз байлыгыңнан

ще́др||ый, -ая, -ое 1. *прям., перен.* юмарт; ~**ый челове́к** юмарт кеше; ~**ый на обеща́ния** вәгъдәләргә юмарт 2. кыйммәтле; мул; ~**ые пода́рки** мул бүләкләр; ~**ая по́мощь** мул ярдәм; ~**ые дожди́** мул яңгырлар

щек||а́ яңак; **поцелова́ть в щёку** яңагыннан үбеп алу ♦ **упи́сывать (уплета́ть) за о́бе** ~**и́** комсызланып ашау

щека́стый, -ая, -ое *прост.* тулы яңаклы

щеко́лд||а бик, келә, бикләвеч; **закры́ть дверь на** ~**у** ишекне келә белән бикләү

щекота́ть *несов.* 1. *кого-что* кытыклау 2. *безл.* кычыту, кымыржу, кымыржып тору; **в го́рле щеко́чет** тамак төбе кымыржып тора; **в носу́ щеко́чет от пы́ли** борын тузаннан кычыта 3. *перен. безл. кому-чему* кытыклау, кагылу; ~ **не́рвы** нервларны кытыклау; ~ *чьё-л.* **самолю́бие** *кемнең дә булса* горурлыгына кагылу

щеко́тк||а *ж* кытык, кытыклану; **боя́ться ~и** кытыктан курку

щекотли́в||ый, -ая, -ое четерекле; **~ое поруче́ние** четерекле йомыш; **~ое положе́ние** четерекле хәл; **~ый вопро́с** четерекле сорау

щеко́тно *в знач. сказ. безл. кому-чему* кытык килә; **мне ~** минем кытыгым килә; **босико́м ~ идти́ по мху** мүктән яланаяк барганда кытык килә

щелев||о́й, -а́я, -о́е **1.** *тех.* ярыклы; **~а́я анте́нна** ярыклы антенна **2.** *лингв.* ярык ...ы; **~ы́е согла́сные** ярык тартыклары

щели́стый, -ая, -ое *разг.* күп ярыклы; **~ пол** күп ярыклы идән

щёлканье *с см.* **щёлкать**

щёлка||ть *несов.* **1.** *кого-что* (*давать щелчки*) чиртү; **~ть по́ лбу** маңгайга чиртү **2.** *чем и без доп.* шартлату; **~ть кнуто́м** чыбыркы шартлату; **~ть языко́м** тел шартлату; **~ть па́льцами** бармак шартлату; **3.** (*петь — о некоторых птицах*) чутылдау, сайрау; **в саду́ ~л солове́й** бакчада сандугач чутылдады **4.** *что* яру; **~ се́мечки** көнбагыш яру

щёлкнуть *сов. однокр. см.* **щёлкать** 1-3

щёлок *м* селте, көл селтесе

щелочн||о́й, -а́я, -о́е селтеле; селте ...ы; **~а́я вода́** селтеле су; **~а́я реа́кция** *хим.* селте реакциясе; **~ы́е мета́ллы** селтеле металлар

щёлочь *ж хим.* селте

щелч||о́к *м* **1.** чиртү, чиртеш; **~о́к по́ лбу** маңгай чиртү; **дать ~ка́** *кому-л. кемгә дә булса* чиртү **2.** *перен.* (*оскорбление, обида*) мәсхәрә, мыскыл

щель *ж* **1.** ярык, жек, тишек; **~ в полу́** идәндәге ярык; **голосова́я ~** *анат.* тавыш ярыгы; **смотрова́я ~** күзәтү тишеге; **жа́берная ~** саңак тишеге **2.** (*укрытие*) яшеренү урыны, саклану урыны

щеми́ть *несов.* **1.** *безл.* кысу, әрнү, чәнчү, сызлау; **щеми́т грудь** күкрәкне кыса; **щеми́т в боку́** билне чәнчи **2.** *перен. что* кысу, чәнчешү, сызлау, әрнү; **уны́лый напе́в щеми́т ду́шу** моңлы көй күңелне әрнетә

щемя́щ||ий, -ая, -ее **1.** *прич. от* **щеми́ть**; **2.** кыса (чәнчи, сызлый, әрни) торган; **~ая боль** сызлый торган авыру

щени́ться *несов.* балалау (*эт, буре, төлке турында*)

щено́к *м* көчек, әнчек ♦ **ах ты, ~!** әй, син, маңка малай!

щеп||а́ *ж* йомычка; йомычкалар; **дом крыт ~о́й** йорт йомычка белән ябылган

щепа́ть *несов. что* яру, телү; **~ лучи́ну** чыра телү

щепети́льность *ж* **1.** (*принципиальность*) җентекләүчәнлек, чокчынучанлык **2.** (*деликатность*) нәзакәтлелек

щепети́льный, -ая, -ое **1.** (*строго принципиальный*) вакчыл, чокчынучан; **~ челове́к** вакчыл кеше **2.** (*деликатный*) четерекле, нәзәкатле; **~ вопро́с** нәзәкатле мәсьәлә

щепк||а́ *ж* йомычка, чыра; **сосно́вые ~и** нарат йомычкалары; **худо́й как ~а** чыра кебек ябык; **лес ру́бят — ~и лета́т** *посл.* ≈ ат аунаган жирдә төк кала

щепо́тка, щепо́ть *ж* чеметем, бер чеметем; **~ со́ли** бер чеметем тоз; **~ табаку́** бер чеметем тәмәке

щерба́т||ый, -ая, -ое кытыршы, шадра; **~ый пол** кытыршы идән; **~ое лицо́** шадра бит; **~ый ребёнок** шадра бала

щерби́на *ж* **1.** (*зазубрина*) сыр, киртек **2.** (*на лице*) шадра бөртеге, шадра **3.** (*пустота между зубами*) тешсезлек

щети́на *ж* **1.** кыл; **свина́я ~** дуңгыз кылы **2.** *разг.* кыл сакал; **~ отросла́** кыл сакал басты

щети́нист||ый, -ая, -ое **1.** (*о животном*) кыллы **2.** каты, тырпаеп тора торган; **~ые во́лосы** тырпаеп тора торган чәч **3.** *разг.* кыл сакаллы; **~ый подборо́док** кыл сакаллы ияк

щети́ни||ть *несов. что, разг.* (*йонын*) кабарту, (*йонын*) тырпайту; **ко́шка ~т шерсть** мәче йонын кабарта

щети́ниться *несов.* **1.** (*о шерсти, щетине*) кабару, тырпаю, үрә тору **2.** (*о животном*) йонын кабарту (тырпайту)

щети́нн||ый, -ая, -ое кыл ...ы; кыл ...; **~ая щётка** кыл щётка

щётка *ж* щётка; **сапо́жная ~** аяк киеме щёткасы; **зубна́я ~** теш щёткасы

щи *только мн.* кәбестә ашы, щи

щи́колотк||а *ж* ашык, ашык сөяге; **по ~у** ашык сөягенә кадәр

щипа́ть *несов.* **1.** *кого-что* чемету; **~ за́ руку** кулны чемету **2.** *что* чеметтерү, әчеттерү, көйдерү; **пе́рец щи́плет язы́к** борыч телне әчеттерә **3.** *что* чемчү, чемчеңү; **ло́шадь щи́плет траву́** ат үлән чемчи **4.** *кого-что* йолку; **~ ку́рицу** тавык йолку **5.** *что* тарту, чиртү; **~ стру́ны гитары́** гитара кылларын тарту

щипа́ться *несов.* **1.** *см.* **щипа́ть** 1; **2.** (*щипать друг друга*) чеметешү, бер-берен талау

щипко́в||ый, -ая, -ое чиртеп уйный торган; **~ые стру́нные инструме́нты** чиртеп уйный торган кыллы кораллар

щипну́ть *сов. однокр. кого-что* чеметеп алу

щипо́к *м* чеметү

щипцы́ *только мн.* кыскыч; эскәк; ваткыч; **~ для оре́хов** чикләвек ваткыч; **хирурги́ческие ~** хирург кыскычы

щи́пчики *только мн.* кечкенә кыскыч; кечкенә эскәк; кечкенә ваткыч

щит *м* **1.** *ист.* калкан **2.** *перен.* калкан, киртә; **быть ~о́м** *кому-л. бераүгә* калкан булу **3.** киртә, калкан, щит, **оруди́йный ~** туп калканы; **снеговы́е ~ы** кар киртәләре **4.** (*у плотины*) капка **5.** (*стенд*) щит, күргәзмәдәге щит **6.** *спорт.* щит (*баскетбол уенында*) ♦ **на ~е́ (верну́ться)** жинелеп кайту; **со ~о́м (верну́ться)** жиңүче булып кайту; **подня́ть** *кого-л.* **на ~** *кемне дә булса* күккә күтәрү, мактау

щитови́д||ный, -ая, -ое: **~ая железа́** *анат.* калкансыман биз

щито́к *м* **1.** калканчык; битлек, такта; **прибо́рный ~** прибор тактасы **2.** *бот., зоол.* калкан

щу́ка *ж* чуртан

щуп *м* **1.** (*ручной бур*) борау; **ма́сляный ~** май боравы **2.** щуп; **зерново́й ~** ашлык щупы **3.** капшавыч, кармавыч; **разве́дка мин ~ом** миналарны капшавыч белән эзләү

щу́пальца *мн.* капшавычлар; **~ осьмино́га** сигезаяк капшавычлары

щу́пать *несов. кого-что* капшау, капшап карау; **~ пульс** пульсны капшау ♦ **~ глаза́ми** *кого-что кемгә-нәрсәгә дә булса* сөзеп карау

щу́пл||ый, -ая, -ое **1.** арык, ябык, зәгыйфь; **~ый челове́чек** ябык кеше **2.** *с.-х.* ач; **~ое зерно́** ач бөртек

щур *м зоол.* бүздәк, корташар (*кош*)

щурёнок *м* чуртан баласы

щу́рить *несов. что* кысу; **~ глаза́** күз кысу

щу́риться *несов.* **1.** (*щурить глаза*) күз кысу **2.** (*прикрываться — о глазах*) күз кысылу

щу́ч||ий, -ья, -ье чуртан ...ы; **~ья икра́** чуртан уылдыгы

Э

э *межд.* э, э-э-э; **э, да э́то ты!** э, син мени әле бу!; **э, нет, я не согла́сен** э, юк, мин килешмим!

эбе́нов||ый, -ая, -ое; **~ое де́рево** эбен агачы

эбони́т *м* эбонит (*каты резин*)

эбони́тов||ый, -ая, -ое эбонит ...ы, эбонит ...; **~ая па́лочка** эбонит таякчык; **~ая тру́бка** эбонит көпшә

эвакогоспита́ль *м* эвакуация госпитале, эвакогоспиталь

эвакопу́нкт *м* эвакуация пункты, эвакопункт

эвакуацио́нный, -ая, -ое эвакуация ...ы, эвакуацион; **~ пункт** эвакуация пункты

эвакуа́ция *ж* эвакуация, эвакуацияләү; **~ завода** заводны эвакуацияләү

эвакуи́рованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **эвакуи́ровать**; **2.** *в знач. сущ.* **~ый** *м*, **~ая** *ж* эвакуацияләнгән кеше

эвакуи́ровать *сов., несов. кого-что* эвакуацияләү, эвакуация ясау, күчерү; **~ заво́д** заводны эвакуацияләү

эвакуи́роваться *сов., несов.* эвакуацияләну, эвакуация ясалу, күчерелү

эве́н *м* эвен, эвен кешесе

эве́нка *ж* эвенк, эвенк кешесе

эве́нка *ж* эвен хатыны (кызы)

эве́нки *мн.* эвенклар, эвенк халкы

эвенки́йка *ж* эвенк хатыны (кызы)

эвенки́йский, -ая, -ое эвенк[лар] ...ы; **~ язы́к** эвенк теле

эве́нский, -ая, -ое эвен ...ы; **~ язы́к** эвен теле

эве́ны *мн.* эвеннар, эвен халкы

эвкали́пт *м* эвкалипт (*маңге яшел агач*)

эвкали́птов||ый, -ая, -ое эвкалипт ...ы; **~ое ма́сло** эвкалипт мае; **~ый лист** эвкалипт яфрагы

эволюционизи́ровать *сов., несов. книжн.* үсеш кичерү, үзгәреш кичерү

эволюциони́зм *м книжн.* эволюционизм (*эволюцион үсеш турындагы тәгълимат*)

эволюциони́ст *м книжн.* эволюционист, эволюция тарафдары

эволюциони́стск||ий, -ая, -ое *книжн.* эволюционист[лар] ...ы, эволюционистик; **~ие взгля́ды** эволюционистлар карашы

эволюцио́нн||ый, -ая, -ое эволюция ...ы, эволюцион; **~ый проце́сс** эволюцион процесс; **~ое учéние** эволюцион тәгълимат

эволю́ция *ж* эволюция; **~ живо́тного ми́ра** хайваннар дөньясы эволюциясе; **~ иску́сства** сәнгать эволюциясе

эвфеми́зм *м лингв.* эвфемизм (*тупас, дорфа тоелган сүзләр урынына башка нәфис сүзләр куллану*)

эвфемисти́ческ||ий, -ая, -ое *лингв.* эвфемизм ...ы, эвфемистик; **~ое выраже́ние** эвфемистик әйтелмә

эвфони́ческий, -ая, -ое *лит.* эвфоник, матур яңгырашлы, аһәңле; **~ подбо́р зву́ков** авазларның аһәңле сайланышы

эвфони́я *ж лит.* эвфония (*поэтиканың шигырь яңгырашын өйрәнә торган булеге*)

эге́ *межд.* эһе, әһә, оһо; **эге́! Ты уже́ пришёл!** эһе! Син инде килдеңмени!

эги́д||а *ж:* **под ~ой** *чего-л. берәүнең* химаясендә булу, яклавында булу, канаты астында булу; **под ~ой зако́на** закон яклавында булу

эгои́зм *м* эгоизм, үз-үзеңне ярату

эгои́ст *м* эгоист, үз-үзен яратучы

эгоисти́ческ||ий, -ая, -ое эгоистлык ...ы, үз-үзен ярату ...ы; эгоисларча ...; **~ое чу́вство** эгоистлык хисе; **~ий посту́пок** эгоисларча кыланыш

эгоисти́чность *ж* эгоистлык, үз-үзен ярату

эгоисти́чный, -ая, -ое *см.* **эгоисти́ческий**

эгои́стка *ж* эгоист хатын (кыз)

эготи́зм *м книжн.* эготизм (*үзең турында югары фикердә булу*)

эгоцентри́зм *м книжн.* эгоцентризм, иң чик дәрәҗәдәге эгоизм

эди́кт *м ист.* эдикт, фәрман; **королéвский ~** король фәрманы

эжéктор *м* эжектор (*пар көче белән эшли торган насос*); **~ для очи́стки су́дна** судноны чистарту эжекторы

эзо́пов: ~ язы́к эзоп теле (*кинаягә бай тел*), тәгъриз

эй *межд.* әй; кара аны; **эй, кто там?** әй, кем анда?

эква́тор *м* экватор

экваториа́л *м* экваториал (*астрономик корал*)

экваториа́льн||ый, -ая, -ое экваториаль, экватор ...ы; экватордагы ...; **~ый круг** экватор әйләнәсе; **~ые стра́ны** экватордагы илләр; **~ый кли́мат** экваториаль климат

эквивале́нт *м* эквивалент (*берәр нәрсәгә тиңдәш булырлык икенче бер нәрсә*)

эквивале́нтность *ж* эквивалентлык, тиңдәшлек, тиң булучылык; **~ обме́на** алмашу эквивалентлыгы

эквивале́нтн||ый, -ая, -ое эквивалент ..., эквивалентлы, тиңдәш, тиң булган; **~ый обме́н** тиңдәш алышу; **~ые уравне́ния** эквивалент тигезләмәләр

эквилибри́ровать *несов.* эквилибристика ясау, эквилибристика белән шөгыльләнү

эквилибри́ст *м* эквилибрист (*эквилибристика белән шөгыльләнүче цирк артисты*)

эквилибри́стика *ж* **1.** эквилибристика (*иң кыен торышларда, мәс. корыч аркан өстендә тигезлек саклау осталыгы*) **2.** *перен.* зирәклек, үткенлек, тапкырлык; **у́мственная ~** акыл тапкырлыгы

эквилибристи́ческий, -ая, -ое эквилибристик; **~ трюк** эквилибристик трюк

экзальта́ци||я *ж* чиксез шатлыклы хәл, күтәренке халәт; **впасть в ~ю** чиксез күтәренке халәткә бирелү

экзальтиро́ванность *ж* **1.** чиксез шат булу, чиксез күтәренке халәттә булу **2.** (*экзальтированный поступок*) чиксез шатлык белән сугарылу

экзальтиро́ванн||ый, -ая, -ое чиксез шатлыклы хәлдәге ..., чиксез күтәренке халәттәге ...; **~ый челове́к** чиксез шатлыклы хәлдәге кеше; **~ое поведе́ние** чиксез күтәренке халәттә үзүзеңне тотыш

экза́мен *м прям., перен.* имтихан, сынау; **госуда́рственный ~** дәүләт имтиханы; **~ по фи́зике** физикадан сынау; **выпускны́е ~ы** чыгарылыш имтиханнары; **сдать ~** имтихан тапшыру; **вы́держать ~ы** сынауларны үтү; **~ на му́жество** кыюлыкка сынау

экзамена́тор *м* имтихан алучы, сынау алучы

экзамена́торск||ий, -ая, -ое имтихан алучы ...ы, сынау алучы ...ы; **~ие обя́занности** имтихан алучы вазифалары

экзаменацио́нн||ый, -ая, -ое имтихан ...ы, сынау ...ы; **~ая коми́ссия** имтихан комиссиясе; **~ая се́ссия** имтихан сессиясе; **~ый биле́т** сынау билете

экзаменова́ть *несов. кого-что* имтихан (сынау) алу; **~ студе́нта** студентан имтихан алу; **~ по исто́рии** тарихтан сынау алу

экзаменова́ться *несов.* имтихан (сынау) тапшыру (бирү, тоту, үтү); **~ по фи́зике** физикадан имтихан тапшыру

экзеку́ция *ж* экзекуция, тән җәзасы

экзе́ма *ж* экзема, тимрәү

экземпля́р *м* **1.** нөсхә, данә; **два ~а кни́ги** ике данә китап; **напеча́тать в трёх ~ах** өч нөсхәдә бастырып алу **2.** төр, үрнәк, вәкил; **ре́дкий ~ цветка́** чәчәкнең сирәк төре

экзога́мия *ж этн.* экзогамия (*үз кабиләсеннән хатын алуны тыю*)

экзоге́нн||ый, -ая, -ое *геол.* экзоген, тышкы көчләрдән үзгәрә торган; **~ые проце́ссы** экзоген процесслар

экзотерми́ческ||ий, -ая, -ое *хим.* экзотермик, җылылык чыгара торган; **~ие реа́кции** экзотермик реакцияләр

экзо́тика *ж* экзотика; **восто́чная ~** шәрык экзотикасы

экзоти́ческ||ий, -ая, -ое **1.** экзотик, чит, ят, чит җир ...ы; **~ие стра́ны** экзотик илләр; **~ие расте́ния** ят үсемлекләр **2.** *перен.* гаҗәп, кызык, сәер, әкәмәт; **~ий костю́м** сәер костюм; **~ий та́нец** әкәмәт бию

экзоти́чность *ж* **1.** экзотиклык, ятлык; **~ де́рева** агачның экзотиклыгы **2.** *перен.* гаҗәплек, кызыклык, сәерлек, әкәмәтлек; **~ та́нца** биюнең сәерлеге

экзоти́чный, -ая, -ое *см.* **экзоти́ческий** 2

экиво́к||и *мн.* ике мәгънәле сөйләү, мәгънәне боргаулар, кинаяләр; **отвеча́ть без [вся́ких] ~ов** кинаяләрсез җавап бирү

э́кий, -ая, -ое *разг.* кара нинди, нинди, менә нинди; **~ шалу́н** кара нинди шаян!; **э́кая говору́нья!** кара нинди тел бистәсе!

экипа́ж I *м* (*лёгкая повозка*) экипаж, җиңел арба

экипа́ж II *м* экипаж; **~ космического корабля́** космик корабль экипажы; **~ земснаря́да** земснаряд экипажы; **~ та́нка** танк экипажы

экипирова́ть *сов., несов. кого-что* **1.** (*снабдить всем необходимым*) кирәк-ярак белән тәэмин итү, кирәк-яракны булдыру; **~ экспеди́цию** экспедицияне кирәк-ярак белән тәэмин итү **2.** (*одеждой и обувью*) киендерү, кием-салым белән тәэмин итү

экипирова́ться *сов., несов.* **1.** (*снабдиться всем необходимым*) кирәк-ярак белән тәэмин ителү, кирәк-ярак булдырылу **2.** *разг.* (*одеждой и обувью*) киендерелү, кием-салым белән тәэмин ителү

экипиро́вка *ж* **1.** *см.* **экипирова́ть, экипирова́ться; 2.** (*снаряжение*) кирәк-ярак **3.** *разг.* (*одежда, обувь*) кием-салым

эклекти́зм *м книжн.* эклектизм (*төрле идея юнәлешләрен, карашларны, теорияләрне принципсыз, ирекле рәвештә берләштерү күренеше*); **~ в филосо́фии** фәлсәфәдә эклектизм

экле́тик *м книжн.* эклектик, эклектизм тарафдары

экле́ктика *ж книжн.* эклектика (*эзлексезлек белән сугарылган барлык нәрсә*)

эклекти́ческ||ий, -ая, -ое *книжн.* эклектизм ...ы, эклектик; **~ая филосо́фия** эклектик фәлсәфә

эклекти́чность *ж книжн.* эклектиклык, эзлексезлек; **~ сужде́ний** фикерләр эзлексезлеге

эклекти́чный, -ая, -ое *см.* **эклекти́ческий**

экле́р *м* эклер (*бөккәннең бер төре*)

экли́птика *ж астр.* эклиптика

эклипти́ческий, -ая, -ое *астр.* эклиптика ...ы; эклиптик; **~ круг** эклиптик әйләнмә

экологи́ческ||ий, -ая, -ое экологик, экология ...ы; **~ая экспеди́ция** экологик экспедиция

ЭКО-ЭКС

эколо́гия *ж* экология (*тирә-як мохит белән организмның үзара мөнәсәбәтен өйрәнүче фән*)

экономи́зм *м* экономизм (*19 гасыр ахырында 20 гасыр башында рус социал-демократик хәрәкәтендә оппортунистик агым*)

эконо́мика *ж* икътисад; **~ капитали́зма** капитализм икътисады; **~ страны́** ил икътисады; **~ се́льского хозя́йства** авыл хуҗалыгы икътисады

экономи́ст *м* **1.** икътисадчы, экономист; **рабо́тать ~ом** икътисадчы булып эшләү **2.** (*сторонник экономизма*) экономист, экономизм тарафдары

эконо́мить *несов.* **1.** *что* сак тоту, бәрәкәтле тоту, кысып тоту, экономияләү, экономия ясау; **~ де́ньги** акчаны сак тоту; **~ си́лы** көчне экономияләү; **~ вре́мя** вакытка экономия ясау **2.** *на чём* (*выгадывать*) янга калдыру, файда күрү, файда итү; **~ на материа́лах** материаллардан файда күрү

экономи́ческ||ий, -ая, -ое *в разн. знач.* икътисад ...ы, икътисадый, экономика ...ы, экономик; **~ий кри́зис** икътисадый кризис; **~ое сотру́дничество** икътисадый хезмәттәшлек; **~ая геогра́фия** экономик география; **~ий журна́л** экономик журнал

экономи́чность *ж* файдалылык, отышлылык, бәрәкәтлелек, икътисадлылык, экономиялелек; **~ произво́дства бума́ги** кәгазь җитештерүнең экономиялелеге

экономи́чный, -ая, -ое файдалы, табышлы, отышлы, бәрәкәтле, икътисадлы, экономияле; **~ спо́соб окра́ски** буяу буяуның отышлы ысулы; **~ расхо́д мета́лла** металлны бәрәкәтле тоту

эконо́ми||я *ж* **1.** (*бережливость*) экономия, икътисад, саклык, хәстәрлек; **навести́ ~ю** *в чём-л. берәр нәрсәдә* экономия ясау **2.** (*выгода*) экономия, файда; **~я в то́пливе** ягулыкка экономия; **~я на спи́чках** *шутл.* шырпыга экономия ясау

эконо́мка *ж уст.* экономка, хуҗабикә

эконо́мничать *несов. разг.* үтә саклап тоту, саранлану, карунлану

экономи́чность *ж* исәпләп тотучанлык, бәрәкәтлелек, сакчыллык, экономиялелек, икътисадлык

эконо́мный, -ая, -ое **1.** исәпләп тотучан, сакчыл; **~ хозя́ин** сакчыл хуҗа **2.** *перен.* (*скупой*) саран, карун **3.** (*способствующий экономии*) экономияле, икътисадлы, бәрәкәтле; **~ о́браз жи́зни** бәрәкәтле яшәү рәвеше

экра́н *м* **1.** *тех.* экран, каплавыч; **~ плоти́ны** плотина экраны **2.** экран; **~ телеви́зора** телевизор экраны **3.** экран, пәрдә; **кинематографи́ческий ~** кинематография экраны **4.** *перен.* экран, кино сәнгате, кино күрсәтү; **звезда ~а** кино сәнгате йолдызы; **фильм идёт пе́рвым ~ом** фильм беренче тапкыр күрсәтелә

экраниза́ция *ж* экранлаштыру; **~ рома́на** романны экранлаштыру

экранизи́ровать *сов., несов. что* экранлаштыру; **~ о́перу** операны экранлаштыру; **~ по́весть** повестьны экранлаштыру

экрани́рование *с тех.* экран кору, каплавыч кору, каплап кую; **~ прибо́ра** приборны каплап кую

экрани́ровать *сов., несов. что, тех.* экран кору, каплавыч кору, каплап кую; **~ прибор** приборны каплап кую

экра́нн||ый, -ая, -ое экран ...ы; **~ое полото́** экран тукымасы; **~ое вре́мя** экран вакыты (*киноның экранда бару вакыты*)

экскава́тор *м* экскаватор; **шага́ющий ~** атлап йөрүче экскаватор

экскава́торный, -ая, -ое экскаватор ...ы; **~ ковш** экскаватор чүмече

экскава́торщик *м* экскаваторчы, экскаватор машинисты

экскреме́нты *только мн.* тизәк, тәрәт

э́кскурс *м* экскурс, күз ташлау; **~ в про́шлое** үткәнгә күз ташлау

экскурса́нт *м* экскурсант, экскурсиядә катнашучы

экскурса́нтка *ж* экскурсант хатын (кыз)

экскурсио́нн||ый, -ая, -ое экскурсия ...ы, экскурсион; **~ый сезо́н** экскурсия сезоны; **~ая ба́за** экскурсия базасы; **~ый авто́бус** экскурсия автобусы

экску́рсия *ж* **1.** экскурсия; **~ по го́роду** шәһәр буйлап экскурсия **2.** (*группа*) экскурсия, экскурсантлар

экскурсово́д *м* экскурсовод, экскурсия җитәкчесе

экслибрис *м* экслибрис (*китап тышлыгының эчке ягына ябыштырыла торган, китап хуҗасының исеме язылган кәгазь*)

экспанси́вность *ж* экспансивлык, шашкынлык, үзен тыя алмаучылык; **~ хара́ктера** холкының шашкынлыгы

экспанси́вный, -ая, -ое экспансив, шашкын, үзен тыя алмый торган; **~ челове́к** шашкын кеше

экспа́нсия *ж* экспансия; **экономи́ческая ~** икътисадый экспансия

экспатриа́ция *ж* экспатриация, Ватаныннан сөрелү

экспатрии́ровать *сов., несов. кого-что* экспатриацияләү, Ватаныннан сөрү

экспатрии́роваться *сов., несов.* **1.** экспатриацияләнү, Ватаныннан сөрелү **2.** *страд. от* **экспатрии́ровать**

экспеди́ровать *сов., несов. что, спец.* озату, җибәрү, тарату; **~ груз** йөкне озату

экспеди́тор *м* экспедитор (*әйберне кабул итеп, җибәреп, таратып торучы кеше*)

экспеди́торск||ий, -ая, -ое экспедитор ...ы; **~ая рабо́та** экспедитор эше

экспедицио́нн||ый, -ая, -ое **1.** *спец.* озату ...ы, җибәрү ...ы; **~ый груз** озату йөге **2.** экспедиция ...ы; **~ое снаряже́ние** экспедиция кирәк-ярагы

экспеди́ци||я *ж* **1.** *спец.* (*отправка и приём грузов*) озату, җибәрү; **~я посы́лок** посылкаларны җибәрү **2.** (*отдел отправки*) экспедиция; **газе́тная ~я почта́мта** почтамтның газеталар экспедициясе **3.** экспедиция; **нау́чная ~я** фәнни экспедиция; **спаса́тельная ~** коткару экспедициясе **4.** (*группа лиц*) экспедиция, экспедиция төркеме

эксперимéнт *м* **1.** (*научный опыт*) эксперимент, тәҗрибә **2.** (*опыт, попытка*) тәҗрибә, сынау; **сме́лый ~** кыю тәҗрибә; **риско́ванные ~ы** тәвәккәлле сынаулар

эксперимента́льн||ый, -ая, -ое эксперименталь, эксперимент ...ы, тәҗрибә ...ы; **~ые рабо́ты** эксперименталь эшләр; **~ые да́нные** эксперимент мәгълүматлары; **~ый стано́к** эксперименталь станок; **~ая фи́зика** эксперименталь физика

эксперимента́тор *м* экспериментчы, тәҗрибәче; **учёный- ~** экспериментчы галим

эксперимента́торский, -ая, -ое экспериментчы ...ы, тәҗрибәче ...ы; **~ тала́нт** экспериментчы сәләте

эксперименти́рование *с см.* **эксперименти́ровать**

эксперименти́ровать *несов. над кем-чем, с кем-чем и без. доп.* эксперимент ясау, тәҗрибә ясау (үткәрү), сынап карау; **~ с морски́ми сви́нками** диңгез күселәре белән эксперимент ясау

экспе́рт *м* эксперт; **заключе́ние ~ов** экспертлар нәтиҗәсе

экспе́ртиза *ж* экспертиза, тикшерү, карау; **медици́нская ~** медицина экспертизасы; **суде́бная ~** суд экспертизасы; **производи́ть ~у** экспертиза ясау

экспе́ртн||ый, -ая, -ое эксперт ...ы, экспертлар ...ы; **~ая коми́ссия** экспертлар комиссиясе

эксплантáция *ж биол.* эксплантация, күчереп утырту

эксплуата́тор *м* эксплуататор, эксплуатацияләүче, изүче

эксплуата́торск||ий, -ая, -ое эксплуататор[лар] ...ы, изүче[ләр] ...ы; **~ие кла́ссы** эксплуататор сыйныфлар

эксплуатацио́нн||ый, -ая, -ое эксплуатация ...ы; эксплуатацион, файдалану ...ы; **~ые рабо́ты** эксплуатация эшләре; **~ый срок** файдалану срогы, эксплуатация срогы

эксплуата́ци||я *ж* **1.** (*присвоение чужого труда*) эксплуатация, эксплуатацияләү, изү **2.** файдалану, эксплуатация; **~я недр земли́** җир байлыкларын файдалану; **~я маши́н** машинаны файдалану; **сдать до́мну в ~ю** домнаны эксплуатациягә тапшыру

эксплуати́ровать *несов.* **1.** *кого-что* эксплуатацияләү, изү; **~ чужо́й труд** кеше хезмәтен эксплуатацияләү **2.** *что* файдалану, эксплуатацияләү; **~ маши́ны** машинаны файдалану

экспози́ци||я, *ж* **1.** *лит., муз.* экспозиция, мәкатдимә **2.** (*показ*) экспозиция, куелу; (*выставленные вещи*) куелган әйберләр; **музе́йная ~я** музей экспозициясе **3.** *фото* экспозиция, яктыртып алу; **снима́ть с дли́тельной ~ей** озак яктыртып фотога төшерү

экспона́т *м* экспонат; **вы́ставочный ~** күргәзмә экспонаты; **музе́йный ~** музей экспонаты

экспона́тный, -ая, -ое экспонат ...ы, экспонатка куела торган; ~ **экземпля́р** экспонат нөсхәсе

экспоне́нт *м* экспонент, экспонат куючы

экспони́рование *с см.* **экспони́ровать**

экспони́ровать *сов., несов.* **1.** *кого-что* күргәзмәгә кую, күрсәтергә кую; ~ **карти́ну** картинаны күргәзмәгә кую **2.** *что, фото* яктылык бирү, яктырту

э́кспорт *м* экспорт, чит илгә чыгару; ~ **хле́ба** чит илгә икмәк чыгару

экспортёр *м* экспортёр, чит илгә чыгаручы; ~ **не́фти** нефтьне чит илгә чыгаручы, нефть экспортёры

экспорти́рование *с см.* **экспорти́ровать**

экспорти́ровать *сов., несов. что* чит илгә чыгару; ~ **това́р** товарны чит илгә чыгару; ~ **капита́л** капиталны чит илгә чыгару

э́кспортн||ый, -ая, -ое экспорт ...ы, чит илгә чыгару ...ы; ~**ые опера́ции** экспорт операцияләре; ~**ые това́ры** чит илгә чыгару товарлары; ~**ый лес** экспорт агачлары

экспре́сс *м* экспресс (*тиз йөрешле автобус, поезд һ.б.ш.*)

экспресси́вность *ж* экспрессивлык, җанлылык, тәэсирлелек; ~ **ре́чи** сөйләмнең тәэсирлелеге

экспресси́вн||ый, -ая, -ое экспрессив, җанлы, тәэсирле; ~**ая речь** тәэсирле сөйләм; ~**ый жест** җанлы ишарә

экспрессиони́зм *м* экспрессионизм (*20 гасырның беренче яртысында сәнгатьтә һәм әдәбияттагы агым*)

экспрессиони́ст *м* экспрессионист, экспрессионизм тарафдары

экспрессиони́стский, -ая, -ое экспрессионист ...ы, экспрессионистлар ...ы; экспрессионизм ...ы; ~ **стиль** экспрессионалистлар стиле

экспре́ссия *ж* экспрессия, җанлылык, тәэсирлелек

экспре́ссный, -ая, -ое экспресс ..., экспресс ...ы; ~ **по́езд** экспресс поезд; ~ **соста́в** экспресс составы

экспро́мт *м* экспромт (*хәзерлексез сөйләнгән нотык, кинәт язылган әсәр*); **уда́чный** ~ уңышлы экспромт

экспро́мтом *нареч.* алдан әзерләнмичә, кинәттән, көтмәгәндә, капыл гына; **произнести́ речь** ~ алдан әзерләнмичә нотык сөйләү

экспроприа́тор *м* экспроприатор, көч белән тартып алучы

экспроприа́ция *ж* экспроприация, көч белән тартып алу

экспропри́ировать *сов., несов. кого-что* экспроприацияләү, тартып алу; ~ **капита́л** капиталны экспроприацияләү

экста́з *м* экстаз, чиктән тыш шатлану, шашып шатлану; **впасть в** ~ экстазга бирелү

экстенси́вн||ый, -ая, -ое *книжн.* экстенсив, киңәюгә генә нигезләнген; ~**ое земледе́лие** экстенсив игенчелек

экстёрн *м* экстерн (*уку йортында укымыйча гына үзлегеннән укып сынау бирүче*); **око́нчить университе́т** ~**ом** университетны экстерн булып тәмамлау; **сдать экза́мены** ~**ом** имтиханнарны институтта укымыйча тапшыру

экстерна́т *м* экстернат, үзлегеннән укып сынау бирү; **записа́ться в гру́ппу** ~**а** экстернат төркеменә язылу

экстерриториа́льност||ь *ж юр.* экстерриториальлек, үз иле хокукына гына буйсыну; **пра́во** ~**и** экстерриториальлек хокукы

экстерриториа́льный, -ая, -ое *юр.* экстерриториаль, үз иле хокукына гына буйсынган

экстерье́р *м* экстерьер, буй-сын, тышкы күренеш; ~ **рыси́стых лошаде́й** юртак атларның тышкы күренеше

э́кстра *неизм. прил.* экстра; **това́р** ~ экстра товар; **чай** ~ экстра чәй

экстравага́нтный, -ая, -ое экстравагант, сәер, әкәмәт, әфәләм төрле; ~ **костю́м** сәер костюм

экстра́кт *м* сыгынты; **я́годный** ~ җиләк сыгынтысы

экстракти́вн||ый, -ая, -ое экстрактив, аерып (сыгып) алына торган; ~**ые вещества́** аерып алына торган матдәләр

экстра́ктовый, -ая, -ое сыгынты ...ы; ~ **заво́д** сыгынты заводы

экстраордина́рность *ж* гадәттән тышлык, гадәттән тыш булу, сирәк очрый торганлык; ~ **посту́пка** кыланышның гадәттән тыш булуы

экстраордина́рн||ый, -ая, -ое гадәттән тыш, сирәк очрый торган; ~**ое происше́ствие** гадәттән тыш вакыйга

экстреми́зм *м* экстремизм (*чиктән тыш карашлар яклы булу*)

экстреми́ст *м* экстремист (*чиктән тыш карашлар яклы кеше*)

экстреми́стск||ий, -ая, -ое экстремизм ...ы, экстремист[лар] ...ы; ~**ая та́ктика** экстремистлар тактикасы

э́кстренность *ж* ашыгычлык, кичектергесезлек; ~ **сообще́ния** хәбәрнең ашыгычлыгы

э́кстренн||ый, -ая, -ое **1.** (*срочный, спешный*) ашыгыч, кичектергесез; ~**ый отъе́зд** ашыгыч китеп бару; ~**ый вы́зов** ашыгыч чакыру **2.** (*чрезвычайный, непредвиденный*) гадәттән тыш, көтелмәгән; ~**ые расхо́ды** көтелмәгән чыгымнар

эксце́нтрик *м* (*артист*) эксцентрик (*әкәмәт кыланышлар ясап көлдерүче*)

эксце́нтриковый, -ая, -ое *тех.* эксцентрик ...; ~ **пресс** эксцентрик пресс

эксцентри́ческий I, -ая, -ое **1.** *театр.* эксцентрик ..., көлдерүче ...ы; ~ **но́мер** эксцентрик номер **2.** гажәп, сәер, мәзәкчән; ~ **посту́пок** сәер кыланыш

эксцентри́ческ||ий II, -ая, -ое *мат.* уртак үзәккә карамаган, уртак үзәге булмаган; ~**ие фигу́ры** уртак үзәге булмаган фигуралар

эксцентри́чность *ж* эксценриклык, гажәплек, сәерлек

эксцентри́чный *см.* **эксцентри́ческий** I 2

эксце́сс *м* **1.** (*крайнее проявление чего-л.*) тотнаксызлык, чыгырыннан чыгу, тыйнаксызлык; **чу́вственные** ~**ы** хис тотнаксызлыклары **2.** (*нарушение общественного порядка*) тәртип бозулар, бәрелешүләр; **предотврати́ть** ~**ы** тәртип бозуларны булдырмау

эласти́чность *ж* **1.** эластиклык, сыгылмалылык, сыгылучанлык; сузылучанлык; ~ **рези́ны** резинаның эластиклыгы **2.** *перен.* салмаклык, талгынлык; ~ **движе́ния** хәрәкәтнең салмаклыгы

эласти́чн||ый, -ая, -ое **1.** эластик, сыгылмалы, сыгылучан; сузылмалы; ~**ая рези́на** эластик резина; ~**ые чулки́** эластик оек **2.** *перен.* салмак, талгын; ~**ые движе́ния** салмак хәрәкәтләр

элева́тор *м* **1.** (*зернохранилище*) элеватор **2.** (*подъёмник*) күтәрткеч, элеватор

элега́нтность *м* элегантлык, купшылык, көязлек, нәфислек; ~ **костю́ма** костюмның купшылыгы; **отлича́ться** ~**ю** купшылыгы белән аерылып тору

элега́нтный, -ая, -ое элегант, купшы, көяз, нәфис; ~ **костю́м** купшы костюм

элеги́ческ||ий, -ая, -ое **1.** элегик, элегия ...ы; ~**ая поэ́зия** элегик шигырият **2.** (*мечтательный*) кайгылы, сагышлы, моңсу, уйчан; ~**ое настрое́ние** сагышлы күңел

элеги́чность *ж* кайгылылык, сагышлылык, моңсулык, уйчанлык; ~ **стиха́** шигырьнең сагышлылыгы

элеги́чн||ый, -ая, -ое *см.* **элеги́ческий** 2; ~**ое настрое́ние** сагышлы күңел

эле́гия *ж лит., муз.* элегия

электриза́ция *ж* **1.** *физ.* электрлау, электрлану **2.** *мед.* электр белән дәвалау

электризова́ть *сов., несов. что, физ.* электрлау, электрландыру

электризова́ться **1.** *сов., несов. физ.* электрлану, электр белән корылу **2.** *несов. страд. от* **электризова́ть**

эле́ктрик *м разг.* электрчы

электри́к *прил. неизм.* күгелҗем, зәңгәрсу-соры; **цвет** ~ күгелҗем төс

электрифика́ция *ж* электрлаштыру; ~ **желе́зных доро́г** тимер юлларны электрлаштыру

электрифици́ровать *сов., несов. что* электрлаштыру; ~ **промы́шленность** промышленностьне электрлаштыру

электри́ческ||ий, -ая, -ое *в разн. знач.* электр ...ы; ~**ий ток** электр тогы; ~**ая ста́нция** электр станциясе; ~**ая и́скра** электр очкыны; ~**ая батаре́я** электр батареясы; ~**ий мото́р** электр моторы; ~**ое освеще́ние** электр белән яктыру ♦ ~**ий скат** электрлы скат; ~**ий стул** электр урындыгы

электри́чество *с* электр; **провести́** ~ электр үткәрү

электри́чк||а *ж разг.* электричка; **е́хать на** ~**е** электричкада бару

электро- *кушма сүзләрнең «электр» мәгънәсендәге беренче өлеше, мәс.* **электролече́ние** электр белән дәвалау; **электробри́тва** электр бритвасы

электроаппарату́ра *ж* электр аппаратлары

электробри́тва *ж* электр бритвасы

электробу́р *м* электробур, электр көче белән эшли торган борау

электрово́з *м* электровоз

электро́д *м* электрод; **положи́тельный ~** уңай электрод; **отрица́тельный ~** тискәре электрод

электродви́гатель *м* электродвигатель, электр двигателе

электродви́жущ||ий, -ая, -ее электр йөртү ...ы; **~ая си́ла** электр йөртү көче

электродина́мика *ж* электродинамика

электродинами́ческ||ий, -ая, -ое электродинамик ...; **~ое реле́** электродинамик реле

электро́дный, -ая, -ое электрод ...ы; **~ заря́д** электрод корылмасы

электродое́ние *с* электр белән саву

электродои́лка *ж* электр белән саву аппараты, электр саугыч

электродои́льн||ый, -ая, -ое электр белән саву ...ы, электр саугыч ...ы; **~ая устано́вка** электр белән саву җайланмасы

электродре́ль *ж* электродрель, электр тишкеч

электроёмкость *ж физ.* электрсыешлык

электроизмери́тельный -ая, -ое электр үлчәгеч ...; **~ прибо́р** электр үлчәгеч прибор

электроинструме́нт *м* электр коралы

электрока́р *м* электрокар, электр арбасы

электрокардиогра́мма *ж* электрокардиограмма

электрокардио́граф *м* электрокардиограф (*прибор*)

электрокардиогра́фия *ж* электрокардиография

электрола́мповый, -ая, -ое электр лампалары ...ы; **~ заво́д** электр лампалары заводы

электролече́бн||ый, -ая, -ое электр белән дәвалау ...ы; **~ый кабине́т** электр белән дәвалау бүлмәсе; **~ые процеду́ры** электр белән дәвалау процедуралары

электролече́ние *с* электр белән дәвалау

электро́лиз *м* электролиз (*эремә хәлендәге матдә аша электр тогы үткәреп, аны төрле состав өлешләргә аеру*)

электро́лизн||ый, -ая, -ое электролиз ...ы; **~ая ва́нна** электролиз ваннасы

электроли́ни||я *ж* электр линиясе; **столбы́ ~и** электр линиясе баганалары

электроли́т *м* электролит (*матдәнең төрле состав өлешләргә аерылырлык эремәсе*)

элетролити́ческ||ий, -ая, -ое электролитик, электролит ...ы; **~ая ва́нна** электролит ваннасы

электроли́тный, -ая, -ое электролит ...ы; **~ заво́д** электролит заводы

электромагнети́зм *м физ.* электромагнетизм

электромагни́т *м* электромагнит (*электр тогы ярдәмендә магнит кыры алу җайланмасы*)

электромагни́тн||ый, -ая, -ое электромагнит ...ы; **~ые во́лны** *физ.* электромагнит дулкыннары; **~ый сигна́л** электромагнит сигналы

электромаши́на *ж* электр машинасы

электромашинострое́ние *с* электр машиналары төзү

электро́метр *м физ.* электрометр

электрометри́ческий, -ая, -ое *физ.* электрометрик, электрометр ...ы; **~ показа́тель** электрометрик күрсәткеч

электроме́трия *ж физ.* электрометрия

электромеха́ник *м* электромеханик

электромеха́ника *м* электромеханика

электромехани́ческ||ий, -ая, -ое электромеханика ...ы, электромеханик; **~ая обрабо́тка мета́ллов** металларны электромеханик юл белән эшкәртү

электромоби́ль *м* электромобиль

электромонта́ж *м* электромонтаж

электромонта́жник *м* электромонтажчы

электромонта́жн||ый, -ая, -ое электромонтаж ...ы; **~ые рабо́ты** элетромонтаж эшләре

электромонтёр *м* электромонтёр

электромото́р *м* электр моторы, электромотор

электро́н *м* электрон

электро́ника *ж* электроника

электро́нно-вычисли́тельн||ый, -ая, -ое электрон-хисаплау ...ы; **~ый центр** электрон-хисаплау үзәге; **~ая маши́на** электрон-хисаплау машинасы

электро́нн||ый, -ая, -ое электрон ...; **~ый телеско́п** электрон телескоп; **~ая счётная маши́на** электрон хисаплау машинасы

электрообору́дование *с* электр җиһазы; **~ заво́да** заводның электр җиһазы

электропередач||а *ж* **1.** электр тапшыру **2.** (*совокупность сооружений*) электр тапшыру корылмалары; **ли́ния ~и** электр тапшыру линиясе

электропе́чь *ж* электр миче

электропла́вка *ж* электр белән кою, электр белән эретү

электроплита́ *ж* электр плитәсе

электропли́тка *ж* электр плитәсе

электропое́зд *м* электр поезды, электропоезд

электроприбо́р *м* электр приборы

электропро́вод *м* электр үткәргеч

электропрово́дность *ж физ.* электр үткәрүчәнлек

электропрово́дн||ый, -ая, -ое *физ.* электр үткәрүче, электр үткәрүчән; **~ые мета́ллы** электр үткәрүчән металлар

электропрои́грыватель *м* электр уйнаткыч

электропромы́шленность *ж* электр промышленносте

электросва́рка *ж* электр белән эретеп ябыштыру

электросва́рочн||ый, -ая, -ое **1.** электр белән эретеп ябыштыру ...ы; **~ый агрега́т** электр белән эретеп ябыштыру агрегаты **2.** *в знач. сущ.* **~ая** *ж разг.* электр белән эретеп ябыштыру бүлмәсе

электросва́рщик *м* электр белән эретеп ябыштыручы

электросе́ть *ж* электр челтәре

электроско́п *м* электроскоп (*прибор*)

электроснабже́ние *с* электр белән тәэмин итү

электроста́ль *ж* электр корычы

электроста́нция *ж* электр станциясе

электроста́тика *ж* электростатика

электростати́ческ||ий, -ая, -ое электростатик; **~ие си́лы** *физ.* электростатик көчләр; **~ие маши́ны** электростатик машиналар

электротерапи́я *ж* электротерапия, электр белән дәвалау

электротерми́ческ||ий, -ая, -ое электротермик; **~ая печь** электротермик мич

электротерми́я *ж* электротермия

электроте́хник *м* электротехник

электроте́хника *ж* электротехника

электротехни́ческ||ий, -ая, -ое электротехника ...ы, электротехник; **~ое обору́дование** электротехника җиһазы; **~ая промы́шленность** электротехника промышленносте

электрохими́ческ||ий, -ая, -ое электрохимия ...ы, электрохимик; **~ие иссле́дования** электрохимия тикшеренүләре

электрохи́мия *ж* электрохимия (*физик химиянең бер бүлеге*)

электроход *м* электроход (*электр двигателе белән йөри торган судно*)

электроэне́ргия *ж* электр энергиясе

элеме́нт *м* **1.** (*составная часть*) элемент, өлеш, кисәк; **важне́йшие ~ы произведе́ния** әсәрнең мөһим элементлары **2.** (*характерная деталь*) элемент; **~ драмати́зма в расска́зе** хикәядә драматизм элементы **3.** *разг.* (*о человеке*) кеше, адәм, шәхес; **ненадёжный ~** ышанычсыз адәм; **подозри́тетельный ~** шикле кеше **4.** *хим.* элемент: **гальвани́ческий ~** гальваник элемент

элемента́рность *ж* **1.** (*отсутствие сложности*) элементарлык, гадилек; **~ вопро́са** мәсьәләнең гадилеге **2.** (*упрощённость*) җиңелчәлек, тарлык, чиклелек, чикләнгәнлек; **~ утвержде́ния** фикренең чикләнгәнлеге

элемента́рн||ый, -ая, -ое **1.** (*начальный*) элементар, башлангыч, төп; **~ая матема́тика** башлангыч математика **2.** *перен.* (*простейший*) гади, ачык, аңлаешлы; **~ый приме́р** гади мисал **3.** *хим., физ.* элементар; **~ый ана́лиз** элементар анализ

эликси́р *м* эликсир; **зубно́й ~** теш эликсиры ◆ **~ жи́зни** *уст.* тереклек эликсиры, тереклек суы

эли́та *ж собир.* элита (**1.** *сайлап алынган иң яхшы токым* **2.** *аерым үсемлекләрнең иң яхшы төрләре* **3.** *җәмгыятьнең иң яхшы, сайланган өлеше*)

эли́тн||ый, -ая, -ое элита ...ы; **~ые живо́тные** элита хайваннары

эллини́зм *м* эллинизм (**1.** *борынгы Грециядә мәдәният чәчәк аткан чор* **2.** *борынгы грек теленнән алынган сүз яки гыйбарә*)

эллини́ст *м уст.* эллинист (*борынгы грек мәдәниятын яратучы*)

э́ллины *мн.* эллиннар (*борынгы греклар*)

э́ллипс *м мат.* эллипс

э́ллипсис *м лингв.* эллипсис

эллипсо́ид *м мат.* эллипсоид

эллипти́ческ||ий, -ая, -ое *мат.* эллиптик; **~ая фо́рма те́ла** җисемнең эллиптик формасы

эма́лев||ый, -ая, -ое эмаль ...; эмальле; **~ая кра́ска** эмаль буяу; **~ый соста́в** эмальле состав

эмалиро́ванн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **эмалирова́ть; 2.** эмальле; эмальләнгән; **~ая посу́да** эмальле савыт-саба; **~ый таз** эмальләнгән таз

эмалирова́ть *несов. что* эмальләү, эмаль белән каплау; **~ ведро́** чиләкне эмальләү; **~ дета́ль маши́ны** машина детален эмальләү

эмалиро́вка *ж* **1.** *см.* **эмалирова́ть; 2.** (*слой эмали*) эмаль, эмаль өслек; **~ потре́скалась** эмаль өслек чатнаган

эмалиро́вочн||ый, -ая, -ое эмальләү ...ы, эмаль белән каплау ...ы; **~ые рабо́ты** эмаль белән каплау эшләре

эма́л||ь *ж* **1.** эмаль **2.** *обычно мн.* **~и** эмальләр; **колле́кция ~ей** эмальләр коллекциясе **3.** (*зуба*) эмаль

эмансипа́ция *ж книжн.* эмансипация, азат итү, иреккә чыгару, коткару; **~ же́нщин** хатын-кызларны азат итү

эмансипи́рованн||ый, -ая, -ое **1.** *прич. от* **эмансипи́ровать; 2.** азат, иреккә чыгарылган, коткарылган; хәр фикерле; **~ые же́нщины** азат хатын-кызлар

эмансипи́ровать *сов., несов. кого-что* азат итү, иреккә чыгару, коткару

эмба́рго *с нескл. юр.* эмбарго; **наложи́ть ~** эмбарго салу

эмбле́ма *ж* эмблема, билге; **серп и мо́лот — ~ труда́** урак белән чүкеч — хезмәт эмблемасы

эмболи́я *ж мед.* эмболия, кан тамыры томалану

эмбрио́лог *м* эмбриолог, яралгы үсешен өйрәнүче белгеч

эмбриоло́гия *ж* эмбриология (*яралгы үсешен өйрәнә торган фән*)

эмбрио́н *м биол.* эмбрион, яралгы

эмбриона́льн||ый, -ая, -ое *биол.* эмбрион ...ы, яралгы ...ы; эмбриональ, яралгы хәлендәге; **~ый пери́од** яралгы чоры; **~ое разви́тие** яралгы үсеше; **~ая кле́тка** яралгы күзәнәге

эмигра́нт *м* эмигрант, мөһаҗир; гөрбатчы (*чит илгә кучкан кеше*)

эмигра́нтка *ж* эмигрант хатын (кыз)

эмигра́нтск||ий, -ая, -ое эмигрант(лар) ...ы, эмигрантлык ...ы; **~ая печа́ть** эмигрантлар матбугаты

эмиграцио́нн||ый, -ая, -ое эмиграция ...ы

эмигра́ци||я *ж* **1.** эмиграция, һиҗрәт; гөрбат; чит илгә күчеп китү; **жить в ~и** эмиграциядә яшәү **2.** *собир.* эмигрантлар

эмигри́ровать *сов., несов.* [чит илгә] күчеп китү; **~ за грани́цу** чит илгә күчеп китү

эми́р *м* әмир

эмисса́р *м* эмиссар (*яшерен сәяси йомыш белән чит илгә җибәрелә торган кеше*)

эмиссио́нн||ый, -ая, -ое *фин.* эмиссион, эмиссия ...ы; **~ое пра́во** эмиссия хокукы; **~ый банк** эмиссия банкы

эми́ссия *ж фин.* эмиссия (*кәгазь акчалар чыгару*)

эмити́ровать *сов., несов. что, фин.* эмиссия ясау, чыгару (*кәгазь акча, кыйммәтле кәгазь*); **~ заём** заём чыгару

эмоциона́льность *ж* эмоциональлек, хислелек, тойгыга бирелүчәнлек

эмоциона́льн||ый, -ая, -ое эмоциале, хисле, тойгылы; **~ая речь** хисле сөйләм; **~ый челове́к** хисле кеше

эмо́ция *ж* эмоция, хис, тойгы, кичереш; **~ гне́ва** ачу хисе; **~ ра́дости** шатлык тойгысы

эмпире́||й *м*: **в ~ях вита́ть (быть, находи́ться)** *книжн.* күкләрдә йөзү, хыял диңгезендә йөзү

эмпири́зм *м филос.* эмпиризм

эмпи́рик *м* эмпирик, эмпиризм тарафдары

эмпириокри́тик *м* эмпириокритик

эмпириокритици́зм эмпириокритицизм (*19 гасыр ахырындагы фәлсәфәдә субъектив-идеалистик агым*)

эмпири́ческ||ий, -ая, -ое *филос.* эмпиризм ...ы, эмпирик; **~ая филосо́фия** эмпиризм фәлсәфәсе

эмпири́я *ж* эмпирия (**1.** *кеше тәҗрибәсе, тою-сизү органнары аша алган тәэсирләр* **2.** *табигый шартлардагы күзәтүләр*)

эму́льсия *ж* эмульсия (**1.** *нинди дә булса берәр матдәнең эреми торган тамчылары белән туендырылган сыекчасы* **2.** *фотокәгазьләрдә, фотопластинкаларда яктылыкка үтә сизгер катлам*)

эмфа́за *ж* эмфаза (**1.** *лит. сөйләмнең тәэсирлелеген көчәйтү* **2.** *лингв. кайбер авазларны әйтүдә киренкелек*)

эмфизе́ма *ж мед.* эмфизема (*органнарда һава тупланып калудан туган авыру*)

эндога́мия *ж этн.* эндогамия (*бер кабилә эченнән өйләнү*)

эндокри́нн||ый, -ая, -ое *физиол.* эндокрин, эндокрин ...ы; **~ые же́лезы** *анат.* эндокрин бизләр; **~ая систе́ма** эндокрин системасы, эчке бизләр системасы

эндокрино́лог *м* эндокринолог, эндокринология белгече

эндокриноло́гия *ж* эндокринология (*эчке секреция бизләре турындагы фән*)

эндоско́п *м* эндоскоп (*прибор*)

э́ндшпиль *м* эндшпиль (*шахмат уены ахыры*)

энерге́тик *м* энергетик, энергетика белгече

энерге́тика *ж* энергетика, энергия фәне

энергети́ческ||ий, -ая, -ое энергетик, энергетика ...ы; **~ое хозя́йство** энергетика хуҗалыгы; **~ое обору́дование** энергетика җиһазы; **~ие ресу́рсы** энергетик ресурслар

энерги́чность *ж* энергиялелек, дәртлелек, гайрәтлелек; кискенлек

энерги́чн||ый, -ая, -ое энергияле, дәртле, гайрәтле; кискен; **~ый челове́к** энергияле кеше; **~ый проте́ст** кискен протест; **~ые ме́ры** кискен чаралар

эне́рги||я *ж* **1.** *физ.* энергия; **тепловая ~я** җылылык энергиясе; **затра́та ~и** энергия сарыф итү **2.** (*решительность, настойчивость*) дәрт, гайрәт, куәт; **взя́ться за де́ло с ~ей** эшкә дәрт белән алыну

энергосисте́ма *ж* энергия системасы

э́нн||ый, -ая, -ое ...нче, ниндидер бер; **~ое число́** ...нче сан; **~ая су́мма** ниндидер бер сумма

энтомо́лог *м* энтомолог, энтомология белгече

энтомологи́ческ||ий, -ая, -ое энтомологик, энтомология ...ы; **~ое иссле́дование** энтомологик тикшеренү

энтомоло́гия *ж* энтомология (*бөҗәкләр өйрәнү фәне*)

энтузиа́зм *м* энтузиазм, дәрт, күтәренкелек; **рабо́тать с ~ом** дәртләнеп эшләү; **боево́й ~** сугышчан дәрт

энтузиа́ст *м* энтузиаст (*эшкә бирелгән кеше*)

энтузиа́стка *ж* энтузиаст хатын (кыз)

энцефали́т *м мед.* энцефалит (*баш мие ялкынсынуы*)

энциклопеди́зм *м* энциклопедизм (*һәр яктан белемле булу*)

энциклопеди́ст *м* энциклопедист, киң белемле кеше

энциклопеди́ческ||ий, -ая, -ое энциклопедик, энциклопедия ...ы; **~ий слова́рь** энциклопедик сүзлек; **~ие зна́ния** энциклопедик белемнәр

энциклопеди́чность *ж* энциклопедиялелек; **~ зна́ний** белемнәр энциклопедиялелеге

энциклопе́дия *ж* энциклопедия ♦ **ходя́чая ~** аяклы энциклопедия, белем капчыгы

эпиго́н *м* эпигон, иярчен, тәкълитче

эпигра́мма *ж* эпиграмма

эпи́граф *м* эпиграф; **~ к расска́зу** хикәягә эпиграф

эпигра́фика *ж* эпиграфика, ташъязмалар фәне

эпиграфи́ческий, -ая, -ое эпиграфика ...ы, эпиграфик; **~ текст** эпиграфик текст

эпидемио́лог *м* эпидемиолог, эпидемиология белгече

эпидемиологи́ческ||ий, -ая, -ое эпидемиология ...ы, эпидемиологик; **~ие иссле́дования** эпидемиология тикшеренүләре

эпидемиоло́гия *ж* эпидемиология (*йогышлы авырулар турындагы фән*)

эпиде́мическ||ий, -ая, -ое эпидемия ...ы, эпидемик, кизү ...ы; **~ая боле́знь** кизү чире

эпиде́мия *ж* эпидемия, кизү, мур; **~ гри́ппа** грипп эпидемиясе

эпиде́рмис *м биол., бот.* эпидермис

эпизо́д *м* **1.** (*случай, происшествие*) хәл, вакыйга, хадисә **2.** эпизод; **вставно́й ~ в пье́се** пьесада өстәлгән эпизод

эпизоди́ческ||ий, -ая, -ое, **эпизоди́чный,** -ая, -ое **1.** очраклы, көтелмәгән, әллә нидә бер; **~ий факт** очраклы факт; **~ая прове́рка** әллә нидә бер тикшерү **2.** эпизодик; **~ая роль** эпизодик роль

э́пика *ж лит.* эпика, эпик әсәрләр

эпикуре́ец *м* эпикурейчы

эпикуре́йзм *м* **1.** эпикуреизм (*борынгы грек фәлсәфәчесе Эпикур тәгълимате*) **2.** *перен.* эпикурейчылык, ләззәткә бирелү

ЭПИ-ЭТИ

эпикуре́йск||ий, -ая, -ое эпикуреизм ...ы; эпикурейчыларча ...; **~ая филосо́фия** эпикуреизм фәлсәфәсе; **~ая жизнера́достность** эпикурейчыларча шат күңеллелек

эпиле́псия *ж* эпилепсия, өянәк, зыяндаш

эпиле́птик *м разг.* эпилептик, өянәкле кеше, зыяндаш авырулы кеше

эпилепти́ческий, -ая, -ое эпилепсия ...ы, өянәк ...ы, зыяндаш ...ы; **~ припа́док** эпилепсия өянәге

эпило́г *м* **1.** эпилог, хатимә; **~ рома́на** роман эпилогы **2.** йомгак; **~ всей жи́зни** бөтен тормыш йомгагы

эпистоля́рн||ый, -ая, -ое *лит.* эпистоляр, хат ...ы, хатлар төрендәге; **рома́н в ~ой фо́рме** хатлар төрендәге роман

эпита́фия *ж* эпитафия, кабер ташъязмасы

эпите́лий *м анат.* эпителий, тәннең өске тукымасы

эпи́тет *м лит.* эпитет; **постоя́нный ~** даими эпитет; **неле́стный ~** *ирон.* яман эпитет

эпице́нтр *м прям., перен.* эпицентр, [жир тетрәү] үзәге; **~ землетрясе́ния** җир тетрәүнең эпицентры; **в ~е собы́тий** вакыйгалар үзәгендә

эпи́ческ||ий, -ая, -ое **1.** эпик, эпос ...ы; **~ая поэ́ма** эпик поэма; **~ий стиль** эпос стиле **2.** күтәренке, тантаналы, тыныч; **~ое споко́йствие** тантаналы тынлык

эполе́ты *мн.* эполетлар; **генера́льские ~** генерал эполетлары

эпопе́я *ж прям., перен.* эпопея; **~ Льва Толсто́го «Война́ и мир»** Лев Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» эпопеясы; **~ граждан́ской войны́** гражданнар сугышы эпопеясы

э́пос *м* эпос, дастан

эпо́х||а *ж* эпоха, дәвер, чор; **геологи́ческие ~и** геологик чорлар; **геро́йческие ~и в жи́зни наро́да** халык тормышының каһарман дәверләре

эпоха́льн||ый, -ая, -ое эпохаль, бөтен бер эпоха (дәвер, чор) тәшкил итә торган; **~ое собы́тие** эпохаль вакыйга

э́ра *ж* **1.** эра; **но́вая ~ в исто́рии челове́чества** кешелек тарихында яңа эра **2.** *геол.* эра; **палеозо́йская ~** палеозой эрасы

эрг *м физ.* эрг (*эш берәмлеге*)

эрза́ц *м* эрзац, алыштыргыч; **~ ко́жи** күнне алыштыргыч

э́рзя *мн. нескл.* (*ед.* **э́рзя** *м, ж*) эрзя

эрзя́нский, -ая, -ое эрзя ...ы; **~ язы́к** эрзя теле

эритроци́ты *мн. физиол.* кызыл кан тәнчекләре, эритроцитлар

эро́зия *ж геол., тех. мед.* эрозия; **~ по́чвы** туфрак эрозиясе; **~ мета́ллов** металлар эрозиясе

эроти́зм *м* эротизм (*гадәттән тыш җенси хискә бирелүчәнлек*)

эро́тика *ж* эротика; җенси хис

эроти́ческ||ий, -ая, -ое **1.** эротик, җенси хискә бирелгән; **~ие наклоннности** эротик гадәтләр **2.** гыйшык-мәхәббәт ...ы; **~ая поэ́зия** гыйшык-мәхәббәт шигырияте

эруди́рованный, -ая, -ое эрудицияле, киң белемле, укымышлы; **~ челове́к** эрудицияле кеше

эруди́т *м* эрудит (*киң белемле кеше*)

эруди́ция *м* эрудиция, киң белемлелек

эсе́р *м* эсер

эска́дра *ж* эскадра; **~ миноно́сцев** миноносецлар эскадрасы

эска́дренный, -ая, -ое эскадра ...ы; **~ миноно́сец** эскадра миноносецы

эскадри́лья *ж* эскадрилья; **~ бомбардиро́вщиков** бомбардировщиклар эскадрильясы

эскадро́н *м* эскадрон; **кавалери́йский ~** кавалерия эскадроны

эскадро́нный, -ая, -ое эскадрон ...ы; **~ командир́** эскадрон командиры

эскала́тор *м* эскалатор; **подня́ться на ~е (по ~у)** эскалаторда менү

эскала́ция *ж* эскалация, үсү, киңәю; **~ вое́нных де́йствий** хәрби хәрәкәтләрнең киңәюе

эски́з *м* эскиз; **~ к карти́не** картинага эскиз; **~ы декора́ций** декорацияләрнең эскизлары

эски́зный, -ая, -ое эскиздагы ..., эскиз рәвешендәге ...; **~ набро́сок** эскиз рәвешендәге каралама

эскимо́ *с нескл.* эскимо

эскимо́с *м* эскимос

эскимо́ска *ж* эскимос хатыны (кызы)

эскимо́сский, -ая, -ое эскимос ...ы; **~ язы́к** эскимос теле

эскимо́сы *мн.* эскимослар, эскимос халкы

эско́рт *м воен.* эскорт (*хәрби конвой*); **почётный ~** шәрәфле эскорт, мактаулы эскорт

эскорти́ровать *сов., несов. кого-что* эскорт белән алып бару (озату); **~ карава́н суде́в** суднолар кәрванын эскорт белән озату

эско́ртный, -ая, -ое *воен.* эскорт ...ы; **~ отря́д** эскорт отряды

эсми́нец *м* эсминец

эспадро́н *м* эспадрон (*тупыйк очлы кылыч*)

эспера́нто *с нескл.* эсперанто (*халыкара ясалма тел*)

эссе́нция *ж* эссенция; **у́ксусная ~** серкә эссенциясе

эстака́да *ж* эстакада (*корылма*)

эстака́дн||ый, -ая, -ое эстакада ...ы; **~ая желе́зная доро́га** эстакада тимер юлы

эста́мп *м* эстамп (*гравюрадан төшереп алынган сурәт*)

эстафе́т||а *ж* эстафета; **~а на 400 ме́тров** 400 метрга эстафета ◆ **приня́ть ~у** *у кого берәүдән* эстафетаны кабул итү, берәү башлаган эшне дәвам иттерү

эстафе́тн||ый, -ая, -ое эстафета ...ы; **~ый бег** эстафета йөгерүе; **~ая па́лочка** эстафета таякчыгы

эсте́т *м* **1.** эстет, эстетизм тарафдары **2.** (*поклонник прекрасного*) гүзәлеккә табынучы

эстети́зм *м книжн.* эстетизм (*сәнгатьтә идея эчтәлеген читкә кагып, тышкы матур формалар белән мавыгу*)

эсте́тика *ж* **1.** эстетика **2.** гүзәллек, эстетика; **~ бы́та** көнкүреш эстетикасы; **~ произво́дства** производство эстетикасы

эстети́ческ||ий, -ая, -ое **1.** эстетика ...ы, эстетик; **~ое воспита́ние** эстетик тәрбияләү **2.** эстетик, гүзәллек ...ы; **~ие вку́сы** эстетик зәвыклар; **~ое удово́льствие** эстетик канәгатьләнү

эстети́чн||ый, -ая, -ое матур, гүзәл, нәфис; **~ое оформле́ние** матур бизәү

эсто́нец *м* эстон, эстон кешесе

эсто́нка *ж* эстон хатыны (кызы)

эсто́нский, -ая, -ое эстон[нар] ...ы; **~ язы́к** эстон теле

эсто́нцы *мн.* эстоннар, Эстония халкы

эстра́д||а *ж* **1.** эстрада, сәхнә; **выступа́ть на ~е** эстрадада чыгыш ясау **2.** (*искусство малых форм*) эстрада; **арти́ст ~ы** эстрада артисты; **теа́тр ~ы** эстрада театры

эстра́дн||ый, -ая, -ое эстрада ...ы; **~ое иску́сство** эстрада сәнгате; **~ый арти́ст** эстрада артисты; **~ый конце́рт** эстрада концерты

э́та *ж см.* **э́тот**

эта́ж *м* кат, этаж; **пе́рвый ~** беренче кат; **дом в де́сять ~е́й** ун катлы йорт

этаже́рка *ж* этажерка; **~ с кни́гами** китаплар куелган этажерка

э́так *нареч. разг.* **1.** алай, болай, шулай; **так и ~** алай да болай; **ни так, ни ~** ни алай, ни болай; **~ ничего́ не полу́чится** алай берни дә барып чыкмас **2.** *в знач. частицы* (*примерно*) якынча, чама белән; **киломе́тров ~ два́дцать и́ли три́дцать** чама белән егерме яки утыз километр булыр

э́такий, -ая, -ое *мест. разг.* шундый бер, мондый; **~ плут!** шундый бер алдакчы

этало́н *м* **1.** эталон, үрнәк; **ме́тра** метр үрнәге **2.** *перен.* әзер калып, яхшы үрнәк

этало́нн||ый, -ая, -ое эталон ...ы; **~ые весы́** эталон үлчәве

эта́н *м хим.* этан (*газ*)

эта́п *м* **1.** этап; **но́вый ~ рабо́ты** эшнең яңа этабы **2.** *воен.* этап, туктау урыны **3.** *спорт.* этап; **после́дний ~ эстафе́ты** эстафетаның соңгы этабы ◆ **по ~у** *или* **~ом** *уст.* этап белән, тоткынарны конвой белән озату

э́ти *мн. см.* **э́тот**

э́тика *ж* **1.** этика; **материалисти́ческая ~** материалистик этика **2.** әхлак, этика; **нау́чная ~** фән этикасы; **врачебная ~** табиб этикасы; **парти́йная ~** партия этикасы

этике́т *м* этикет; **придво́рный ~** сарай этикеты; **соблюда́ть ~** этикет саклау

этике́тка *ж* этикетка, ярлык

эти́л *м хим.* этил

этиле́н *м хим.* этилен (*газ*)

эти́ловый, -ая, -ое *хим.* этил ...ы; **~ спирт** этил спирты

этимо́лог *м* этимолог, этимология белгече, этимология галиме

этимологи́ческий, -ая, -ое этимология ...ы, этимологик; **~ слова́рь** этимологик сүзлек

этимоло́ги||я *ж* 1. (*отдел языкознания*) этимология 2. (*происхождение слова*) этимология, килеп чыгыш; **установи́ть ~ю сло́ва** сүзнең килеп чыгышын билгеләү ♦ **наро́дная ~я** халык этимологиясе

этиоло́гия *ж мед.* этиология (*авыруның килеп чыгу сәбәпләре турындагы өйрәтмә һәм берәр авыруның килеп чыгу сәбәбе*)

эти́ческ||ий, -ая, -ое этик, этика ...ы, әхлакый, әхлак ...ы; **~ие взгля́ды** әхлакый карашлар; **~ие но́рмы** әхлак нормалары

эти́чность *ж* этикалыклык, әхлаклылык, әдәпләлек; **~ поведе́ния** үз-үзеңне тотуның әдәпләлеге

эти́чный, -ая, -ое этикалы, әхлаклы, әдәпле; **~ посту́пок** әдәпле кыланыш

этни́ческ||ий, -ая, -ое этник; **~ие элеме́нты** этник элементлар

этно́граф *м* этнограф, этнография белгече

этнографи́ческ||ий, -ая, -ое этнография ...ы, этнографик; **~ая экспеди́ция** этнографик экспедиция; **~ий музе́й** этнография музее

этногра́фи||я *ж* этнография; **~я кра́я** туган як этнографиясе; **рабо́тать в о́бласти ~и** этнография өлкәсендә эшләү

э́то I *частица* 1. *указ.* ул, бу; **кто ~ пришёл?** кем ул килде? 2. *усил.* ул, бу, болай; **как ~ так?** ничек инде ул алай?; **что ~ ты так ве́сел?** ничек син болай бик кәефле? 3. (*связка при сказ.*) ул, бу; **жизнь — ~ борьба́** тормыш — ул көрәш; **руководи́ть — ~ быть всегда́ впереди́** җитәкчелек итү — ул һәрвакыт алда бару

э́то II *с см.* **э́тот**

э́тот *мест.* 1. бу, шушы; **~ и́ли тот дом?** бу яки теге өйме?; **на э́той стороне́ пло́щади** мәйданның шушы ягында; **э́то его́ сестра́** бу аның сеңлесе; **в э́том году́** бу ел; **в э́ти дни** *или* **на э́тих днях** бу көннәрдә; **в э́то вре́мя** бу вакытта 2. *в знач. сущ.* **~ м, э́та ж, это** *с* бу, шушы, шул, ул; **что э́то?** бу нәрсә? **что в э́том смешно́го?** монда көлкеле нәрсә бар? **никто́ э́тому не пове́рит** моңа берәү дә ышанмас; **как э́то случи́лось?** бу ничек булды соң?; **э́то хорошо́** бу шәп; **э́то бы́ло так неожи́данно** бу шулкадәр кинәт булды ♦ **на э́том све́те** бу дөньяда; **при э́том** шуның белән бергә; өстәвенә, шуның өстенә

этю́д *м в разн. знач.* этюд; **~ к карти́не** картинага этюд; **~ы Рахма́нинова** Рахманинов этюдлары; **ша́хматный ~** шахмат этюды

этю́дник *м* этюдник (*рәсем ясау әйберләре һәм этюдны урнаштыру урыны булган махсус яссы әрҗә*)

этю́дн||ый, -ая, -ое этюд ...ы; **произведе́ние ~ого хара́ктера** этюд төсендәге әсәр

эфеме́рный, -ая, -ое *книжн.* 1. тиз үтүчән; **~ успе́х** тиз үтүчән уңыш 2. уйланма, буш; **~ая мечта́** буш хыял

эфе́нди *м нескл.* әфәнде

эфе́с *м* эфес, сап, тотка (*хәнҗәр, кылычныкы*)

эфио́п *м* хәбәш, эфиоп

эфио́пка *ж* хәбәш (эфиоп) хатыны (кызы)

эфио́пск||ий, -ая, -ое хәбәш[ләр] ...ы; эфиоп[лар] ...ы; **~ая культу́ра** хәбәш мәдәнияте

эфио́пы *мн.* хәбәшләр, хәбәш халкы, эфиоплар, эфиоп халкы

эфи́р *м* 1. (*высь*) эфир, һава 2. эфир; **передава́ть** *что-л.* **в ~** эфирга *берәр нәрсә* тапшыру; **вы́йти в ~** эфирга чыгу 3. *хим.* эфир

эфи́рн||ый, -ая, -ое 1. эфир ...ы, эфирлы; **~ый за́пах** эфир исе; **~ые масла́** эфир майлары 2. *перен.* җиңел, юка, сәмави; **~ое созда́ние** җиңел зат

эфирноо́сн||ый, -ая, -ое эфирлы, эфирга бай, эфир алына торган; **~ые расте́ния** эфирлы үсемлекләр

эффе́кт *м* 1. эффект, көчле тәэсир, йогынты; **производи́ть ~** көчле тәэсир итү 2. *обычно мн.* **~ы** эффектлар; **световы́е ~ы** яктылык эффектлары; **шумовы́е ~ы** тавыш эффектлары 3. (*результат*) нәтиҗә, файда; **экономи́ческий ~** икътисадый нәтиҗә; **лека́рство не дало́ жела́емого ~а** дару көтелгән нәтиҗәне бирмәде

эффекти́вность *ж* нәтиҗәлелек, файдалылык; **~ уро́ка** дәреснең нәтиҗәлелеге

эффекти́вн||ый, -ая, -ое 1. нәтиҗәле; **~ые ме́ры** нәтиҗәле чаралар 2. нәтиҗәле, нәтиҗә бирүче, файдалы; **~ые прибо́ры** нәтиҗә бирә торган приборлар; **~ый спо́соб** нәтиҗәле ысул

эффе́ктн||ый, -ая, -ое эффектлы, эффект ясый торган, көчле тәэсир ясый торган, тәэсир итүчән; **~ая по́за** эффектлы кыяфәт; **~ый костю́м** эффектлы костюм

эх *межд.* их, әй, эх; **~, ты, рази́ня!** их, син, ачык авыз!

эхинокО́кк *м зоол., мед.* эхинококк (*тасма суалчанның бер төре һәм анын корты*)

э́хо *с* кайтаваз, яңгыравык; **лесно́е ~** урман кайтавазы

эхоло́т *м* эхолот (*диңгез тирәнлеген үлчәгеч*)

эшафо́т *м* эшафот (*улем җәзасын башкару өчен ясалган махсус куперчек*)

эшело́н *м* эшелон (1. *воен.* сугыш тәртипләрендә эчкә табан бер-бер артлы урнаштырылган төркемнәр, берләшмәләр 2. *масса-куләм төстә йөк күчеру өчен поезд*)

эшелони́ровать *сов., несов. что, воен.* эшелонлаштыру, эшелон-эшелон итеп урнаштыру; **~ войска́** гаскәрне эшелонлаштыру

Ю

ю́ань *м* юань (*Кытайда акча берәмлеге*)

юбиле́й *м* юбилей; **пра́здновать ~** юбилеен бәйрәм итү

юбиле́йн||ый, -ая, -ое юбилей ...ы; **~ые торжества́** юбилей тантаналары; **~ая меда́ль** юбилей медале; **~ое изда́ние** юбилей басмасы

юбиля́р *м* юбиляр

ю́бка *ж* юбка, итәк ♦ **держа́ться за ~у** *чью* кемнәндер итәгенә ябышып йөрү, итәгенә тагылып йөрү

ювели́р *м* ювелир, зәркән

ювели́рн||ый, -ая, -ое 1. ювелир ..., зәркән ...; **~ые изде́лия** ювелир әйберләр; **~ый магази́н** зәркән кибете 2. *перен.* нечкә, нәфис; **~ое исполне́ние** нәфис башкару

юг *м* көньяк

ю́го-восто́к *м* көньяк-көнчыгыш

ю́го-восто́чный, -ая, -ое көньяк-көнчыгыш ...ы; **~ ве́тер** көньяк-көнчыгыш җиле

ю́го-за́пад *м* көньяк-көнбатыш

ю́го-за́падный, -ая, -ое көньяк-көнбатыш ...ы; **~ ве́тер** көньяк-көнбатыш җиле

югосла́в *м* югослав, югославияле

югосла́вка *ж* югослав хатыны (кызы), югославияле хатын (кыз)

югосла́вск||ий, -ая, -ое югослав ...ы, югославияле ...ы; Югославия ...ы; **~ая промы́шленность** Югославия промышленносте

югосла́вы *мн.* югославлар, югославияләр, Югославия халкы

южа́нин *м* көньяк кешесе, көньякта яшәүче кеше

ю́жный, -ая, -ое 1. көньяк ..., көньяк ...ы; **Ю́жный по́люс** Көньяк котып; **~ ве́тер** көньяк җиле 2. кайнар, көньяк кешеләренә хас; **~ темпера́мент** кайнар темперамент

ю́зом *нареч.* 1. өстерәп, сөйрәп; **передвига́ть груз ~** йөкне сөйрәп күчерү 2. шуып, тәгәрәмичә шуып; **за́дние колёса шли ~** арткы тәгәрмәчләр шуып бардылар

юка́гир, юкаги́р *м* юкагир

юка́гирка, юкаги́рка *ж* юкагир хатыны (кызы)

юка́гирский, -ая, -ое **юкаги́рский,** -ая, -ое юкагир[лар] ...ы; **~ язы́к** юкагир теле

юка́гиры, юкаги́ры *мн.* юкагирлар, юкагир халкы

ю́кка *ж бот.* юкка (*мәңге яшел куак*)

юла́ 1. *ж* (*игрушка*) бөтерчек, зырылдавык 2. *м, ж разг.* (*непоседа*) тиктормас, кыбырсык (*бала турында*)

юлиа́нск||ий, -ая, -ое: **~ий календа́рь** юлиан календаре; **~ое летоисчисле́ние** юлиан ел исәбе

юли́ть *несов. разг.* 1. (*вертеться, суетиться*) әйләнү, бөтерелү, тулгану 2.

перен. перед кем и без доп. (*лебезить*) ялагайлану, тәлинкә тоту, куштанлану **3.** *перен.* (*хитрить*) койрык болгау; **не юли́, говори́ пра́вду** койрык болгама, дөресен сөйлә

ю́мор *м* **1.** юмор, көлке; **чу́вство ~а** юмор хисе; **говори́ть с ~ом** юмор белән сөйләү **2.** *лит., иск.* юмор; **~ и сати́ра** юмор һәм сатира; **отде́л ~а в газе́те** газетада юмор бүлеге

юморе́ска *ж лит., иск.* юмореска (*кечкенә көлкеле әсәр*)

юмори́ст *м* **1.** (*автор юмористических произведений*) юморист **2.** (*человек, склонный к юмору*) җор кеше, мәзәк кеше

юмори́стика *ж* **1.** *лит.* юмористика, көлкеле әсәрләр **2.** *разг.* (*что-л. смешное*) көлке нәрсә, мәзәк нәрсә

юмористи́ческий, -ая, -ое юмористик, шаян, көлкеле; **~ расска́з** шаян хикәя; **~ журна́л** көлкеле журнал

ю́нга *м мор.* юнга

юне́ц *м* яшүсмер, малай

юнио́р *м* яшүсмер; **соревнова́ния ~ов** яшүсмерләр ярышы

ю́нкер *м ист.* юнкер (**1.** *хәрби училищедә укучы* **2.** *Германиядә эре алпавыт*)

юннат *м* юннат (*яшь натуралист*)

юннáтовский, -ая, -ое, **юннáтский,** -ая, -ое юннат[лар] ...ы, яшь натуралист[лар] ...ы; **~ кружо́к** юннатлар түгәрәге

ю́ность *ж* **1.** (*возраст*) яшьлек, яшь чак, яшүсмер чак **2.** *перен. собир.* (*о юном поколении*) яшьләр, яшүсмерләр; **~ ми́ра про́тив войны́** дөнья яшьләре сугышка каршы

ю́ноша *м* яшүсмер, яшь егет

ю́ношеск||ий, -ая, -ое яшьлек ...ы, яшьләр ...ы; **~ие мечты́** яшьлек хыяллары; **~ий задо́р** яшьлек дәрте; **~ое движе́ние** яшьләр хәрәкәте

ю́ношество *с* **1.** *собир.* яшьләр, яшүсмерләр **2.** *см.* **ю́ность** 1

ю́ный, -ая, -ое **1.** яшь, яшьлек ...ы; **~ геро́й** яшь каһарман; **ю́ные го́ды** яшьлек еллары **2.** (*свойственный юности*) яшь, яшьлек ...ы; яшьлеккә хас; **~ задо́р** яшьлек дәрте

юпи́тер *м* юпитер (*бик көчле яктырткыч прибор*)

юр *м*: **на [са́мом] юру́** 1) (*на открытом месте*) ачык урында; **дом стои́т на юру́** йорт ачык урында тора; 2) (*на людном месте*) кеше күп йөри торган урында

юриди́ческ||ий, -ая, -ое юридик, хокук ...ы; **~ие нау́ки** хокук фәннәре; **~ий факульте́т** юридик факультет; **~ое лицо́** юридик шәхес

юрисди́кц||ия *ж юр.* юрисдикция (*судка кую хокукы, хокук мәсьәләләрен хәл итү хокукы*); **облада́ть ~ей** юрисдикциягә ия булу; **подлежа́ть** *чьей-л.* **~и** *кемнең дә булса* юрисдикциясендә булу

юриско́нсульт *м* юрисконсульт, хокук киңәшчесе

юриспруде́нция *ж* юриспруденция, хокук фәннәре

юри́ст *м* юрист; хокук белгече

ю́рк||ий, -ая, -ое җитез, елгыр, елдам; **~ая мышь** елгыр тычкан

ю́ркну||ть *сов.* елт итеп кереп югалу; сызу; **мышь ~ла в щель** тычкан тишеккә елт итеп кереп югалды

ю́ркость *ж* җитезлек, елгырлык, елдамлык

юро́дивый, -ая, -ое **1.** дивана, акылсыз, юләрсымак **2.** *в знач. сущ. м.* күрәзәче дивана

юро́дство *с* **1.** дивана булып кылану, диваналану, юләргә сабышу, акылсызлану **2.** (*нелепый поступок*) диваналык, юләрлек, акылсызлык

юро́дствовать *несов.* диваналыклар (юләрлекләр, акылсызлыклар) эшләү

ю́рский, -ая, -ое: **~ пери́од** *геол.* юр дәвере

ю́рта *ж* тирмә, киез өй

Ю́рьев: вот тебе́, ба́бушка, [и] ~ день! менә сиңа мә!

юсти́ци||я *ж* юстиция; **министе́рство ~и** юстиция министрлыгы

ют *м мор.* ют (*югары палубаның арткы өлеше*)

юти́ться *несов.* **1.** (*помещаться на небольшом пространстве*) урнашу, сыену **2.** (*иметь пристанище*) тору, сыену, сыенып тору

ю́фтев||ый, -ая, -ое йомшак күннән тегелгән, юфть ...; **~ые сапоги́** йомшак күннән тегелгән итек

юфт||ь *ж* йомшак күн, юфть; **сапоги́ из ~и** юфть итек

юфтяно́й, -а́я, -о́е *см.* **ю́фтевый**

Я

я *мест.* (меня́, мне, меня́, мно́ю, обо мне́) **1.** мин; **я сейча́с приду́** мин хәзер килермен **2.** *в знач. сущ. с нескл.* шәхес, мин; **он моё второ́е «я»** ул минем икенче «мин» ♦ **я не я** мин хәбәрдар түгел; **я́ тебя́!** мин сиңа!; **я́ тебе́!** мин сине!; **я тебе́ дам!** кирәгенне бирермен!; мин сиңа күрсәтермен!; **[я] не я бу́ду, е́сли не добью́сь своего́** әгәр үземнекен итмәсәм, исемем ... булмасын!

я́беда *м, ж* әләкче, чагучы, яла ягучы

я́бедник *м* әләкче, чагучы, яла ягучы

я́бедничать *несов. на кого и без доп., разг.* әләкләү, чагу, яла ягу, сүз йөртү

я́блок||о *с* алма; **~о от я́блони недалеко́ па́дает** *посл.* алма агачыннан ерак төшми ♦ **ада́мово ~о** *анат.* бугаз төене; **глазно́е ~о** *анат.* күз алмасы; **ло́шадь в ~ах** алмачуар ат; **~о раздо́ра** ызгыш алмасы, җәнҗал (ызгыш) сәбәбе; **~у не́где упа́сть** алма төшәр урын юк, энә төртер урын юк, аяк басар урын юк

я́блонев||ый, -ая, -ое **я́блонн||ый,** -ая, -ое **1.** алма ...ы; алмалы; **~ый сад** алма бакчасы **2.** алмагач ...ы; **~ая ве́тка** алмагач ботагы

я́блоня *ж* алмагач; **ди́кая ~** кыргый алмагач

яви́ть *сов. кого-что, книжн.* күрсәтү, белдерү; **~ собо́й приме́р му́жества** үз белән батырлык үрнәге күрсәтү

яви́ться *сов.* **1.** (*прийти, прибыть*) килү, килеп җитү; кайту, кайтып җитү **2.** (*возникнуть*) килеп чыгу, барлыкка килү, туу; **~лась мысль** фикер туды **3.** (*оказаться*) булу, булып чыгу; **э́то ~лось для нас по́лной неожи́данностью** бу безнең өчен һич көтелмәгән хәл булып чыкты

я́вка *ж* **1.** килү; **~ в суд** судка килү; **~ на собра́ние** җыелышка килү **2.** (*место конспиративных встреч*) яшерен очрашу урыны

явле́ни||е *с* **1.** күренеш; **~я приро́ды** табигать күренешләре; **ре́дкое ~е** сирәк күренеш **2.** вакыйга, хәл; **отра́дное ~е** сөенечле хәл **3.** *театр.* күренеш, манзара

явля́||ться *несов.* **1.** *см.* **яви́ться; 2.** (*быть кем-чем-л.*) булу, булып тору; **его посту́пок ~ется новым доказа́тельством дру́жбы** аның кылган эше дуслыкның яңа дәлиле булып тора

я́вн||ый, -ая, -ое ачыктан-ачык, көн кебек ачык, ярылып ята торган; **~ая ложь** ярылып ята торган ялган; **~ое противоре́чие** ачыктан-ачык капма-каршылык

я́вор *м* ак чаган

я́вочн||ый, -ая, -ое яшерен очрашу ...ы; **~ая кварти́ра** яшерен очрашу фатиры ♦ **~ым поря́дком** алдан рөхсәт алмыйча, алдан килешүсез

я́вственный, -ая, -ое ачык, ап-ачык, аермачык, аныкланган, аңлаешлы; **~ звук** ачык аваз

я́вств||овать *несов. книжн.* күренү, килеп чыгу; ачыклану, аныклану; **из э́того ~ует сле́дующее ...** моңардан түбәндәгеләр килеп чыга ...

явь *ж* өн, чын, чынбарлык; **сон и ~** төш һәм өн; **мечта́ ста́ла ~ю** хыял чынга ашты

яга́ *ж* убыр; **ба́ба-~** убырлы карчык

ягдта́ш *м охот.* аучы сумкасы

я́гель *м* болан мүге, ягель

ягнёнок *м* бәрән, бәти, кузы

ягни́ться *несов.* бәрәнләү, бәтиләү, бәрән китерү

я́года *ж* җиләк ♦ **на́шего по́ля ~** безнең кеше, безнең ише кеше, үз кеше; **одного́ по́ля ~** бер чыбыктан сөрелгән

ягоди́ц||а *ж* **1.** *мн.* **~ы** (*седалище*) утракса, арт сан **2.** арт санның бер ягы

ягоди́чн||ый, -ая, -ое арт сан ...ы; **~ые мы́шцы** арт сан мускуллары

я́годник *м* **1.** (*место*) җиләклек, җиләкле урын **2.** (*ягодный куст*) җиләк куагы, җиләк үләне

я́годн||ый, -ая, -ое җиләк ...ы, җиләкле; **~ый куст** җиләк куагы; **~ое вино́** җиләк шәрабы

ягуа́р *м* ягуар (*ерткыч хайван*)

яд *м* **1.** агу; **змеи́ный яд** елан агуы **2.** *перен.* зәһәр, агу; **яд шовини́зма** шовинистлык агуы **3.** (*злость, ехидство*) зәһәр, агу; **слова́, по́лные я́да** зәһәрле сүзләр ♦ **яд сомне́ний** шикләнүләр газабы, шикләнүләр җәфасы

я́дерн||ый, -ая, -ое төш ...ы, атом-төш; **~ая реа́кция** төш реакциясе;

~ая эне́ргия төш энергиясе; **~ое ору́жие** атом-төш коралы; **~ый реа́ктор** төш реакторы

ядови́т||ый, -ая, -ое **1.** агулы, зәһәрле; **~ое вещество́** агулы матдә; **~ый газ** агулы газ; **~ая змея** агулы елан; **~ый гриб** агулы гөмбә **2.** *перен.* (*злобный, язвительный*) зәһәрле, мәкерле, агулы

ядоно́сн||ый, -ая, -ое агулы, зәһәрле; **~ое насеко́мое** агулы бөҗәк

ядохимика́ты *мн.* агулы химикатлар

ядрёный, -ая, -ое *разг.* **1.** (*о плодах*) эре, тук **2.** таза, нык, тыгыз; **~ па́рень** таза егет **3.** *перен.* саф, чиста, шифалы; **~ во́здух** саф һава

я́дрица *ж* эре ярма (*кубрәк карабодай ярмасы турында*)

ядро́ *с* **1.** төш; **~ оре́ха** чикләвек төше; **2.** төш; үзәк; **~ а́тома** атом төше; **~ древеси́ны** үзагач үзәге; **~ Земли́** Җир үзәге **3.** *перен.* (*наиболее важная часть чего-л.*) төп өлеш, үзәк, нигез, асыл **4.** *воен., спорт.* ядрә

я́зва *ж* **1.** җәрәхәт, [эренле] яра **2.** *перен.* (*зло, вред*) зарар, афәт, бәла **3.** *перен. разг.* (*о человеке*) зәһәр телле, ачы телле ♦ **сиби́рская ~** түләмә; **~ желу́дка** ашказаны җәрәхәте

я́звенн||ый, -ая, -ое [эренле] яра ...ы, җәрәхәт ...ы; **~ая боле́знь** ашказаны җәрәхәте

язви́тельность *ж* зәһәрлелек, чәнечкелелек, чәнчү

язви́тельн||ый, -ая, -ое зәһәрле, зәһәр, чәнечкеле; **~ое замеча́ние** зәһәрле искәрмә; **~ый отве́т** чәнечкеле җаваб; **~ый челове́к** зәһәр кеше

язви́ть *несов.* чәнчеп сөйләү, әче (зәһәр) тел белән сөйләү, төрттереп сөйләү; *~ на чьей-л.* **счёт** *берәүгә* төрттереп сөйләү

язы́к *м в разн. знач.* тел; **коро́вий ~** сыер теле; **лиза́ть ~о́м** тел белән ялау; **показа́ть ~** телне күрсәтү; **у него́ отня́лся ~** телдән калды; **копчёный ~** *кул.* ысланган тел; **родно́й ~** туган тел, ана теле; **ру́сский ~** рус теле; **~ ко́локола** чаң теле; **~и́ пла́мени** ялкын телләре; **захвати́ть ~а́** *воен.* тел эләктерү; **у него́ ядови́тый ~** аның теле зәһәрдер; **о́стрый на ~** телгә үткен; **дать во́лю ~ю́** телгә салыну, теле тегермән тарту ♦ **у него́ дли́нный ~** теле озын; **~ без косте́й** *у кого* телнең сөяге юк; **держа́ть ~ за зуба́ми** телне тыю, күп сөйләмәү; **злы́е ~и́** усал телләр; **~ хорошо́ подве́шен** *у кого* телгә оста; **трепа́ть (болта́ть) ~о́м** чүбек чәйнәү, ләчтит сату; **придержа́ть ~** телне тыеп тору; **развяза́ть ~** телен чишеп җибәрү; **тяну́ть (дёргать) за ~** теленнән тартып сөйләтү; **проглоти́ть ~** телне йоту; **~ проглоти́шь** телеңне йотарсың (*бик тәмле*); **~ че́шется** *у кого кемнең дә булса* теле кычытып тора; **~ не повернётся сказа́ть** әйтергә тел бармый; **найти́ о́бщий ~** уртак тел табу; **говори́ть на ра́зных ~а́х** төрле телдә сөйләшү (*аңлашмау*) ≈ һәркемнең үз туксаны туксан

языка́стый, -ая, -ое **языка́тый,** -ая, -ое *разг.* үткен телле; усал телле; **~ па́рень** үткен телле егет

языково́д *м* тел белгече, тел галиме, телче

языково́дение *с см.* **языкозна́ние**

языково́дческ||ий, -ая, -ое тел белеме ...ы, тел гыйлеме ...ы; **~ая те́ма** тел белеме темасы

языков||о́й, -а́я, -о́е тел ...ы; **~а́я систе́ма** тел системасы

языко́в||ый, -ая, -ое **1.** тел ...ы; **~ые мы́шцы** тел мускуллары **2.** телдән әзерләнгән; **~ая колбаса́** телдән әзерләнгән колбаса

языкозна́ние *с* тел белеме (гыйлеме)

язы́ческ||ий, -ая, -ое мәҗүсиләр ...ы, мәҗүсилек ...ы; **~ая рели́гия** мәҗүсиләр дине

язы́чество *с* мәҗүсилек, потка табыну

язы́чник *м* мәҗүси, потка табынучы

язы́чница *ж* мәҗүси (потка табынучы) кыз (хатын)

язычо́к *м* **1.** *уменьш.-ласк. от* **язы́к; 2.** *анат.* кече тел **3.** тел; **~ замка́** йозак теле; **~ колоко́льчика** кыңгырау теле **4.** *бот.* кыякча, кыякчык

язь *м зоол.* бәртәс, опты

яи́чко *с* **1.** *уменьш.-ласк. от* **яйцо́** 2; **2.** *анат.* күкәй

яи́чники *мн. анат.* аналык бизләре, күкәйлекләр

яи́чница *ж* йомырка тәбәсе, куырган йомырка

яи́чн||ый, -ая, -ое йомырка ...ы; **~ая скорлупа́** йомырка кабыгы; **~ый порошо́к** йомырка порошогы

яйла́ *ж* җәйләү

яйцеви́дный, -ая, -ое йомыркасыман, йомыркага охшаган

яйцево́д *м анат.* күкәй юлы

яйцее́д *м зоол.* күкәйашар

яйцекла́д *м зоол.* йомырка (күкәй) салгыч

яйцекладу́щ||ий, -ая, -ее *зоол.* **1.** йомырка (күкәй) сала торган **2.** *в знач. сущ.* **~ие** *мн.* йомырка салучылар, күкәй салучылар

яйцекле́тка *ж биол.* күкәй күзәнәге

яйцено́ск||ий, -ая, -ое *с.-х.* күп йомырка (күкәй) сала торган; **~ие ку́ры** күп йомырка сала торган тавыклар

яйцено́скость *ж с.-х.* йомырка (күкәй) салучанлык

яйцеобра́зный, -ая, -ое *см.* **яйцеви́дный**

яйцеро́дный, -ая, -ое *см.* **яйцекладу́щий**

яйц||о́ *с* **1.** *биол.* күкәй, күкәй күзәнәк **2.** йомырка, күкәй; **~о́ всмя́тку** пешәр-пешмәс итеп әзерләнгән йомырка ашамлыгы; **крутое́ ~о́** каты пешкән йомырка ♦ **вы́еденного ~а́ не сто́ит** сукыр бер тиен дә тормый

як *м зоол.* як (*күшәүче зур хайван*)

я́кобы 1. *союз изъясн.* ... дип, ... имеш дип; **говори́ли, ~ вы уе́хали** сезне киткән имеш дип сөйләгәннәр иде **2.** *частица* имеш, имештер, гүяки, янәсе; **он ~ всё по́нял** ул имештер бөтенесен аңлаган

я́корн||ый, -ая, -ое **1.** якорь ...ы; **~ая цепь** якорь чылбыры **2.** якорьда тору ...ы; **~ая стоя́нка** якорьда тору урыны

я́кор||ь *м мор., эл.* якорь; **бро́сить ~** якорь ташлау; **стоя́ть на ~е** якорьда тору; **отда́ть ~ь** якорьны ычкындыру; **выбира́ть ~ь** якорьны алу, якорьны күтәрү; **сня́ть с ~я** якорьдан алыну; **~ь электромото́ра** электромотор якоре ♦ **~ь спасе́ния** котылуның соңгы өмете, котылуның соңгы чарасы

яку́т *м* якут, якут кешесе

яку́тка *ж* якут хатыны (кызы)

яку́тский, -ая, -ое якут[лар] ...ы; **~ язы́к** якут теле

яку́ты *мн.* якутлар, Якутия халкы

якша́ться *несов. с кем, прост.* аралашу, дуслашу

ял *м мор.* ял (*каек*)

я́лик *м* каек (*кечкенә көймә*)

я́ловеть *несов.* кысыр калу (булу) (*сыерга карата*)

я́ловичн||ый, -ая, -ое сыер күненнән тегелгән (эшләнгән); **~ые голени́ща** сыер күненнән тегелгән итек кунычлары

я́ловость *ж* кысырлык, кысыр калу (булу)

я́лов||ый, -ая, -ое **1.** кысыр; **~ая коро́ва** кысыр сыер **2.** *см.* **я́ловичный**

я́ма *ж* **1.** чокыр; баз; **вы́рыть я́му** чокыр казу; **карто́фельная ~** бәрәңге базы; **помо́йная ~** юынтык су базы; **выгребна́я ~** чүп-чар чокыры **2.** (*низина, впадина*) иңкүлек, иңкү урын; уйсулык, уйсу урын

ямб *м лит.* ямб

я́мк||а *ж* **1.** *уменьш. от* **я́ма** 1; **2.** (*небольшое углубление*) чокыр, чокырчык; **~и на щека́х** яңактагы чокырчыклар

я́мочк||а *ж уменьш.-ласк. от* **я́мка** чокырчык; **~и на щека́х** яңактагы чокырчыклар

ямщи́к *м* ямчы, ямщик

янва́рск||ий, -ая, -ое гыйнвар ...ы; **~ие холода́** гыйнвар суыклары

янва́рь *м* гыйнвар ае

я́нки *м нескл. собир.* янки, янкилар (*АКШтагы америкалыларның кушаматы*)

янта́рный, -ая, -ое **1.** гәрәбә ...ы, гәрәбә ...; **~ мундшту́к** гәрәбә мундштук **2.** (*о цвете*) гәрәбә төсле, ачык сары

янта́р||ь *м* **1.** гәрәбә; **мундшту́к из ~я́** гәрәбәдән эшләнгән мундштук **2.** *собир.* (*изделие*) гәрәбә, гәрәбә әйбер[ләр]

яныча́ры *мн.* янычарлар (*элеккеге Төркиядә өстен хокуклар белән файдаланып килгән җәяүле гаскәр*)

япо́нец *м* япон, япон кешесе

япо́нка *ж* япон хатыны (кызы)

япо́нский, -ая, -ое япон[нар] ...ы; **~ язы́к** япон теле

япо́нцы *мн.* японнар, Япония халкы

яр *м* **1.** (*обрыв*) яр, текә яр **2.** (*овраг, лощина*) куе үләнле тирән чокыр

ярáнга *ж* яранга (*кучмә тирмә*)

ярд *м* ярд (*Англиядә: 91,4 сантиметрга тигез үлчәү берәмлеге*)

ярём *м уст. см.* **ярмо́**

я́рка *ж с.-х.* саулык бәрән, шешәк сарык

ЯРК-ЯЩУ

я́рк||ий, -ая, -ое **1.** яп-якты, якты, көчле; **~ий свет** көчле яктылык; **~ое со́лнце** якты кояш; **~ая ла́мпа** якты лампа **2.** (*о цвете*) ачык; **~ие кра́ски** ачык буяулар **3.** *перен.* күренекле, якты; **~ий тала́нт** якты талант **4.** *перен.* (*убедительный*) ачык, көчле; **~ий приме́р** ачык мисал

я́ркость *ж* **1.** яктылык; **~ огня́** утның яктылыгы **2.** ачыклык; **~ кра́сок** буяуларның ачыклыгы **3.** *перен.* күренеклелек, яктылык; **~ тала́нта** талантның яктылыгы **4.** (*убедительность*) ачыклык, көчлелек

ярлы́к *м* ярлык; **бага́жный ~** багаж ярлыгы; **люби́тели накле́ивания ~ов** *перен.* ярлыклар ябыштырырга яратучылар

я́рмарка *ж* ярминкә; **промы́шленная ~** промышленность ярминкәсе; **междунаро́дная ~** халыкара ярминкә

я́рмарочн||ый, -ая, -ое ярминкә ...ы; **~ая пло́щадь** ярминкә мәйданы

ярмо́ *с* **1.** (*деревянный хомут*) агач камыт, үгез камыты **2.** *перен.* золым, изү, богау; **~ самодержа́вия** самодержавие богауы

яровиза́ция *с.-х.* яровойлаштыру

яровизи́ровать *сов., несов. с.-х.* яровойлаштыру; **~ семена́** орлыкларны яровойлаштыру

яров||о́й, -а́я, -о́е *с.-х.* **1.** язгы, сабан ...ы; **~а́я пшени́ца** сабан бодае **2.** *в знач. сущ.* **~ы́е** *мн.* сабан ашлыгы

я́ростн||ый, -ая, -ое **1.** (*гневный*) ачулы, ярсулы **2.** (*неукротимый*) гайрәтле, ярсулы, котырынган; **~ая ата́ка** ярсулы һөҗүм; **~ый ве́тер** котырынган җил

я́рость *ж* **1.** (*гнев*) ачу, ярсу; **прийти́ в ~** ачу килү, ярсулану **2.** (*неукротимость*) гайрәтләнү, ярсу, котырыну

я́рус *м* **1.** (*ряд горизонтально расположенных предметов*) кат, ярус **2.** *театр.* ярус; **ло́жа второ́го ~а** икенче ярус ложасы **3.** *геол.* кат, катлам

я́рый, -ая, -ое **1.** *см.* **я́ростный**; **2.** ялкынлы, чын күңелдән бирелгән; **~ покло́нник му́зыки** музыканың ялкынлы тарафдары ♦ **~ воск** *уст.* саф балавыз

яса́к *м ист.* ясак (*Идел буенда, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта яшәүче кайбер халыклар түләп килгән натуралата салым*); **плати́ть ~** ясак түләү

я́сельный, -ая, -ое ясле ...ы; **~ ребёнок** ясле баласы; **~ режи́м** ясле режимы

я́сеневый, -ая, -ое корычагач ...ы, дардар агачы ...ы; **~ лист** корычагач яфрагы

я́сень *м* корычагач, дардар агачы

я́сли *только мн.* **1.** (*кормушка для скота*) утлык **2.** (*детское учреждение*) ясле

ясне́||ть *несов.* ачылу, ачыклану, яктыру, аязу, ачыла (ачыклана, яктыра, аяза) бару; **на восто́ке ~ет** көнчыгышта яктыра бара

